ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г.ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

## I том
## А–В

Казан • 2015

УДК 811.512.145'374.3
ББК 81.2Тат-4
Т 23

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

«2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

*Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы законнары белән саклана (РФ ГК, 4 өлеш). Китапны тулысы белән яки өлешчә, төрле, шул исәптән, электрон мәгълүмат чыганакларына күчереп яки яздырып алу, сурәтен төшерү авторлык хокукына ия юридик затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела*

**Проект җитәкчесе –** А.Ә. Тимерханов

**Төзүче авторлар:**

Р.Р. Абдуллина, А.М. Сәгыйтова, Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, О.Н. Галимова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Д. Фәтхетдинова, Ф.И. Таһирова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.М. Газизова

**Фәнни редакторлар:**

Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова

**Бәяләүчеләр:**
*Д.Б. Рамазанова*, филология фәннәре докторы, профессор (ТӘҺСИ);
*Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар тел белеме кафедрасы* (мөдире – Г.Р. Галиуллина, филология фәннәре докторы, доцент)

**Т 23** **Татар теленең аңлатмалы сүзлеге:** I том: А–В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.
ISBN 978-5-93091-189-3

Татар теленең күп томлык фундаменталь аңлатмалы сүзлеге – күләме һәм эчтәлеге белән мондый төр сүзлекләрдән иң зурысы һәм тулырагы. Ул татар тел белеме, тюркология һәм гомуми лексикографиянең ирешкән уңышларын, уңай тәҗрибәсен исәпкә алып төзелде.

I томда барлыгы 11 меңгә якын сүз һәм 2 меңнән артык фразеологик берәмлек теркәлде. Төп фигыль оясында мәгънә төсмерләренә ия булган тезмә фигыльләр дә исәпкә алынды. Сүзлек хәзерге татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасы һәм фразеологиясеннән, төрле фән һәм хуҗалык тармакларына караган термин, атамалардан гыйбарәт. Анда соңгы вакытта татар теленең үз мөмкинлекләре исәбенә ясалып, кулланышка кереп киткән неологизмнар, кабат торгызылган сүзләр, телне баетырдай диалектизмнар, алынмалар да чагылыш тапты.

Сүзлек киң катлау укучыларга гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә. Ул, беренче чиратта, филолог галимнәр, тюркология белгечләренә юнәлдерелгән. Югары уку йортлары укытучылары һәм укучылары, матбугат, радио, телевидение хезмәткәрләре, тәрҗемәчеләр өчен дә файдалы белешмә булып хезмәт итәчәк. Ул татар телен өйрәнүчеләр, туган телне һәрьяклап үзләштерергә теләүчеләргә ярдәмлек-кулланма да була алыр.

**ISBN 978-5-93091-189-3**
© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ, 2015

# СҮЗ БАШЫ

Күп гасырлар дәвамында кулланышта, үсеш-хәрәкәттә булу нәтиҗәсендә, татар теле төзек бер система булып формалашкан, тормыш, көнкүрешнең барлык өлкәләрендә дә аралашу, фикер алышу ихтыяҗын тулысы белән һәм нәтиҗәле итеп канәгатьләндерә алырлык дәрәҗәдә һәр яктан эшкәртелгән. Телебезнең сүзлек составы гаҗәеп дәрәҗәдә бай булып оешкан, аның лексик системасы бүген дә хәрәкәттә, туктаусыз үсештә. Соңгы елларда татар теле үзен фән теле, махсус белгечлек теле буларак та мөкәммәл, төгәл формалашкан камил тел булуын күрсәтте. Ул күп кенә хуҗалык, фән тармакларына караган терминологик сүзлекләрдә чагылыш тапты. Шушы үсешүзгәрешләрне барлау, теркәү, аларга фәнни нигездә тәфсилле аңлатма бирү бурычын күптөрле максатлар белән төзелә торган сүзлекләр үтәп килә. Сүзлекләр арасында исә тел берәмлекләре аша объектив чынбарлыкны мөмкин кадәр тулырак һәм киңрәк планда тасвирлап чагылдыру ягыннан үзәк урынны аңлатмалы сүзлек алып тора.

Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге XIX гасыр ахырында дөнья күрә. Ике кисәктән торган сүзлекне, 1895 һәм 1896 елларда «Ләһҗәи татари» (Татарское наречие) исеме белән, күренекле галим, татар халкының мәгърифәтчесе Каюм Насыйри бастырып чыгара. Сүзлек 20 меңгә якын сүзне туплап бирә. Ул гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрнең татарча мәгънәсен аңлату, татар сүзләренең гарәпчә һәм фарсыча вариантларын китерү, аларның нинди сүзтезмәләрдә кулланылуын күрсәтү тәртибендә эшләнгән. Бу сүзлек татар теле өчен генә түгел, гомумән барлык төрки телләр өчен дә беренче аңлатмалы сүзлек функциясен үти.

Бу юнәлештә башланып киткән эшнең дәвамы буларак, 1927, 1929 елларда Җамал Вәлиди тарафыннан аңлатмалы сүзлек шәкелендә әзерләнгән «Татар теленең тулы сүзлеге» бастырып чыгарыла. Галим, халыкның үз җанлы сөйләм теленә якын торган әдәби тел булдыру зарурияtennән чыгып, һәр шивәдә кулланылган барлык сүзләрнең дә сүзлектә теркәлүе гаять мөһим булуын аңлап эш итә. Бу сүзлек гарәп графикасына нигезләнгән татар алфавитының өч хәрефен – *әлиф, би, ти* хәрефләрен эченә ала. Кириллицага күчерсәк, сүзлек *әлиф* белән башланган А, Э, Ы, У, Ү, О, Ө, Ә, И хәрефләренә, *би* белән Б, П, *ти* белән Т хәрефләренә төзелә. Авторның әйтүенчә, сүзлек, 1925 елда төзелеп беткән булса да, тулысынча нәшер ителми кала. Мәгълүм булганча, галим хаксызга репрессияләнә, сүзлекнең калган материалы кулга алына һәм юкка чыгарыла. Шулай да сүзлек, дөнья күрә алган күләмендә дә, тел материалларына гаять бай булуы, аларның эзлекле бер системага китереп, эшкәртеп бирелүе белән аерылып тора. Аны татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү өлкәсендә мөһим бер этап итеп караргa мөмкин.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү эше, 1950 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына караган Тел, әдәбият һәм тарих институтында Г.С. Әмиров җитәкчелегендә лексикография бүлеге ачылгач кына, кабаттан торгызыла. Бүлектә эш иң башта классик һәм күренекле язучыларның әсәрләреннән, башка төр әдәбияттан иллюстратив лексик материал туплау белән башланып китә, картотека базасы булдырыла. 1962 елда төзелә башлаган күләмле хезмәт – өч томнан гыйбарәт «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» – 1977–1981 елларда дөнья күрә. Үз вакыты өчен саллы, эчтәлеге һәм эшләнеше белән мөкәммәл дип саналырга хаклы бу аңлатмалы сүзлекне төзеп бастырып чыгаруны, гомумән, татар лексикографиясенең яңа уңышы, яңа казанышы дип күрсәтергә кирәк. Ул – лексикография секторы хезмәткәрләренең зур тырышлыгы, фидакярлеге нәтиҗәсе. Аны эшләүдә танылган тел галимнәре И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Г.Х. Ахунҗанов, Ш.Р. Ханбикова, Р.Г. Әхмәтьянов, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизовалар катнаша. 47 мең сүз һәм фразеологик берәмлекне туплаган әлеге хезмәтнең басылып чыгуы гомумтюркология күләмендә татар тел белеменең, аеруча татар

лексикографиясенең, үткән гасыр ахырында янә бер югары баскычка күтәрелүенең ачык дәлиле булып тора.

Өч томлык аңлатмалы сүзлек фәнни әйләнешкә кертелгәннән соң, тагын шактый вакыт үтте. Табигый ки, шул вакыт эчендә телдә, аның лексик системасында барлыкка килгән һәртөрле үзгәрешләрне кабат күз алдыннан үткәреп, яңа сүзлекләрдә чагылдыру бурычы туды. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының (ТӘһСИ) лексикография бүлегендә хезмәт куйган ике буын галимнәренең уртак тырышлыгы белән төзелеп, 2005 елда нәшер ителгән бер томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» нәкъ менә шушы бурычны үти. Ул тупланган сүзләрнең күләме белән элегрәк дөнья күргән өчтомлыктан шактыйга артыграк. Чагыштырмача җыйнак булуына карамастан, сүзлеккә барлыгы 58 мең мөстәкыйль сүз һәм фразеологик берәмлек теркәлгән. Беренче чиратта, сүзлек бай эчтәлекле, файдалы һәм уңайлы гамәли кулланма булуы белән аерылып тора. Сүзлектә тел күренешләрен дөрес теркәп тасвирлауга бәйле берничә мөһим мәсьәләне хәл итү юнәлешендә җитди эш башкарылган. Шуларның берсе һәм аеруча әһәмиятлесе – тезмә фигыльләрне теркәү. Мөстәкыйль лексик мәгънәгә ия булган андый берәмлекләр телебездә һәрдаим кулланылса да, моңа кадәр алар сүзлекләрдән читтә калып килгән иде. Димәк ки, телебезнең байлыгы да тулысы белән чагылып бетмәгән. Биредә аларның иң киң кулланылганнары, аңлатмасыз гына, үзләре ясалган фигыльләр оясында китерелде. Конверсия күренеше дә, ягъни бер сүз төркемендәге сүзнең икенче бер сүз төркеменә күчеп, шул сүз төркеменә хас функция үти алу үзлеге дә, әлеге хезмәттә шулай ук эзлекле рәвештә чагылыш тапты.

2010 елда ТӘһСИнең лексикография бүлегендә тагын бер зур хезмәт – «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» эшләнеп бетеп, 2013 елда басылып чыкты. Бу сүзлек күләм ягыннан кыскарак, куллану өчен уңайлы итеп, мәктәпләр өчен махсус төзелде. Ул мәктәп программасы күләмендә укучыларга туган телне үзләштерү, белемнәрен тирәнәйтү өчен ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Аннан татар телендә мәгълүмат алу чыганагы буларак та файдаланырга мөмкин.

Соңгы вакытта басылып чыккан сүзлекләрдән профессор Ф.Ә. Ганиев авторлыгындагы ике кисәктән торган «Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге»нә (2009, 2012) татар телендә еш очрый торган тезмә фигыльләр тупланып бирелгән. Тезмә фигыльләр, сүзлек берәмлеге буларак, татар теленең тәрҗемә сүзлекләрендә, бигрәк тә 1966 елгы «Татарча-русча сүзлек»тә шактый чагылыш тапкан булса да, алда әйтелгәнчә, аларны күрсәтү бер томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән (2005) башланып китте. Тезмә фигыльләр төрле фәнни яссылыкта каралсалар да, тюркология, шул исәптән татар тел белеме өлкәсендә эшләүче галимнәрнең күптәннән килгән тикшеренү объекты булып тора. Г. Алпаров ярдәмче фигыльләр төп фигыльгә өстәмә мәгънә бирү өчен кулланыла дип белдерсә, В. Хангилдин, ярдәмче фигыльләр төп фигыльнең семантикасына йогынты ясый дип, шул ук фикерне куәтли. Р. Газизов аларны сүзлекләрдә урын алырга хаклы лексик берәмлек буларак карый. Югарыда әйтелгән «Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге»ндә тезмә фигыльләр лексик берәмлек буларак каралган. Аларны сүзлекләрдә чагылдыру татар теленең байлыгын тулырак ачарга мөмкинлек бирә.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы халыкара мәйданда да, ил күләмендә дә кискен сәяси-икътисади, иҗтимагый, мәдәни һ.б. күптөрле вакыйгаларга бай булуы, фән-техниканың сизелерлек алга китүе, халыкара элемтәләр, бәйләнешләр, үзара аралашуның шактый нык артуы белән аерылып тора. Мондый вазгыять телләргә дә зур йогынты ясый. Тормышта булган үзгәрешләр иң элек телнең сүзлек составында, аның лексик системасында чагылыш таба. Нәтиҗәдә, соңгы вакытта татар телендә күп кенә яңа сүзләр кулланышка кереп китте. Тел үз мөмкинлекләре исәбенә дә, искергән сүзләрне торгызу һәм диалектизмнар исәбенә дә нык баеды. Алынмалардан файдалану да телебезнең сүзлек составын киңәйтүдә мөһим бер ысул булып кала. Шул рәвешле соңгы чирек гасыр эчендә татар әдәби телендә тагын шактый гына яңа лексик берәмлекләр барлыкка килде, телебезнең лексик системасында башка күпсанлы үзгәрешләр теркәлде. Аларның барысын бергә туплап тасвирлау ихтыяҗы туды. Бу бурычны үтәү максатында, татар теленең яңа зур фундаменталь аңлатмалы сүзлеген төзү кирәклеге көн үзәгенә басты. Әлеге хезмәт – гаять күп көч һәм вакыт сарыф итүне сорый торган зур фәнни проект. Аның төп бурычы – татар әдәби теленең лексик-фразеологик байлыгын мөмкин кадәр туплап чагылдыру; гомуми кулланышта булган сүзләргә, тотрыклы берәмлекләргә, аларның мәгънәләренә, мәгънә төсмерләренә мөмкин кадәр тулы һәм төгәл аңлатма бирү; сүзләрнең грамматик табигатен, стилистик төсмерләрен дөрес билгеләү, кулланылыш үзенчәлекләрен барлау, матур әдәбият, публицистика һ.б. күптөрле чыганаклардан китерелгән мисаллар белән дәлилләү.

Сүзлек Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре тарафын-

нан профессор Ф.Ә. Ганиев әзерләгән Инструкция нигезендә төзелде.

Әлеге гаять күләмле һәм үтә җаваплы эш 2002 елда башланып китте. 4 томнан торачак әлеге сүзлекнең күләме якынча 400 табак булыр дип фаразланган иде. Эш барышында чыганакларның даирәсен киңәйтеп, яңадан-яңа тел материалларын анализлау һәм эшкәртү нәтиҗәсендә, сүзлекнең күләме артканлыгы ачыкланды. Шуның белән бергә теоретик планда аңлатмалы сүзлек төзүгә бәйле кайбер мәсьәләләрне, аерым алганда, конверсия күренешен әтрафлы чагылдыру, тезмә фигыльләрне теркәү рәвеше, аларның мәгънәләрен аңлату ысуллары, татар тел белеме һәм гомуми тюркологиядә ирешелгән башка фәнни уңышларны исәпкә алып эш итү нәтиҗәсендә, инструкциягә шактый үзгәрешләр, өстәмәләр кертелде, аның аерым принциплары үстерелде, камилләштерелде. Шул рәвешле, бүген барлык тупланган тел материаллары 6–7 том тәшкил итәр дип исәпләнә.

Сүзлектә сүзләрнең орфографиясе гамәлдә булган традицион кагыйдәләргә нигезләнеп бирелде. Басымны күрсәтү дә шул ук принципларны истә тотып башкарылды.

Проектның гомуми координаторы һәм җитәкчесе – А.Ә. Тимерханов.

Сүзлекнең I томын төзүдә түбәндәге хезмәткәрләр катнашты: **А хәрефе**: Г.Г. Саберова, А.М. Сәгыйтова, А.Ф. Гайнетдинова; **Ә хәрефе**: Г.Д. Фәтхетдинова, А.М. Сәгыйтова; **Б хәрефе**: Р.Р. Абдуллина, О.Н. Галимова; **В хәрефе** (коллектив): Р.Р. Абдуллина, О.Н. Галимова, Г.Г. Саберова, А.Ф. Гайнетдинова, Ф.Ф. Гаффарова, Ф.М. Газизова, А.М. Сәгыйтова, Ф.И. Таһирова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина.

Ф.Ф. Гаффарова А–В хәрефләренә тезмә фигыльләр өстәп төзеде.

Төзүче авторларның исемнәрен күрсәтү тәртибе аларның сүзлек төзүгә керткән өлешләрен исәпкә алып билгеләнде.

Сүзлекнең I томын түбәндәге хезмәткәрләр редакцияләде: Ф.Ф. Гаффарова һәм Г.Г. Саберова – тулысынча; Ф.И. Таһирова – А хәрефен.

Алфавитка салу эшен Ф.Ф. Гаффарова, Ф.И. Таһирова башкарды.

Сүзлекне техник редакцияләү һәм нәшриятка әзерләүдә Я.М. Абдулкадыйрова катнашты.

«Сүз башы» өлешен А.Ә. Тимерханов, Ф.Ф. Гаффарова, «Файдаланылган махсус әдәбият», «Лексикографик чыганаклар», «Сүзлекнең төзелеше», «Кыскартылмалар» өлешләрен Ф.Ф. Гаффарова эшләде һәм бу томны нәшриятка әзерләде.

Сүзлеккә кагылышлы фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
йорт, 48 бүлмә, Г. Ибраһимов исем. Тел,
әдәбият һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН МАХСУС ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

*Сабиров К.С.* Татар телендә тыныш билгеләре. – Казан: Таткнигоиздат, 1956.

Татар грамматикасы. Т. I–III. – М.-Казан: «Инсан», «Фикер», 1998, 2002, 1999.

*Сәлимов Х. Х.* Татар теленең орфографиясе. – Алабуга, 2001.

*Абдуллина Р. С.* Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

*Хисамова Ф. М.* Татар теле морфологиясе. – Казан: Мәгариф, 2006.

## ЛЕКСИКОГРАФИК ЧЫГАНАКЛАР

### Аңлатмалы сүзлекләр

*Насыйри К.* Ләһҗәи татари: 2 томда. – Казан: Ун-т типолитогр., 1895, 1896.

*Вәлиди Җ.* Татар теленең тулы сүзлеге. 2 кисәктә. – Казан, 1927, 1929.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т. I–III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981.

Ислам дине турында белешмә сүзлек / Төз. Я. Г. Абдуллин, Ш. Ш. Абилов, Р. Г. Балтанов һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Ф. Ә. Ганиев ред. – Казан: Матбугат йорты, 2005.

Миллият сүзлеге / Төз.-автор А. Тимергалин. – Казан: Мәгариф, 2007.

Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта / Төз. К. Р. Галиуллин, Р. Н. Кәримуллина. – Казан: Мәгариф, 2009.

*Ганиев Ф. Ә.* Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге: Ике кисәктә. Беренче кисәк (А–К). – Казан: Мәгариф, 2009; икенче кисәк (Л–Я). – Казан: Паравитта, 2012.

### Энциклопедик сүзлекләр

Татар энциклопедия сүзлеге / Баш мөхәррир М. Х. Хәсәнов. – Казан: ТР ФА Татар энциклопедия институты, 2002.

Татарская энциклопедия. Т. I–IV. – Казань: Ин-т Татар. энцикл. АН РТ, 2002, 2005, 2006, 2008.

*Урманче Ф. И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Т. I–III. – Казан: Мәгариф, 2008, 2009, 2011.

### Алынма сүзләр сүзлекләре

*Җантурин С.* Лөгать. – Уфа: «Шәрык» матбагасы, 1911.

*Беляев Г.* Керәшеннәргә татар-гарәп сүзләрен аңлату өчен сүзлек. – Казан: Яңалиф, 1929.

*Ишмухаметов Г.* Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлекчә. – Казан, 1954.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / Төз. К. З. Хәмзин, М. И. Мәхмүтов, Г. Ш. Сәйфуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

*Мәхмүтов М. И.* Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан: Иман, 1993.

*Зәйнуллин Җ. Г.* Шәрык алынмалары сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 1994.

### Фразеологик сүзлекләр

*Җәләй Л., Борһанова Н. Б., Мәхмүтова Л. Т.* Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1957.

*Борһанова Н. Б., Мәхмүтова Л. Т.* Русча-татарча фразеологик сүзлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Т. I–III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959, 1963, 1967.

*Әхәтов Г. Х.* Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989, 1990.

*Байрамова Л. К.* Учебный тематический русско-татарский фразеологический словарь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991.

*Сафиуллина Ф. С.* Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001.

*Гаффарова Ф. Ф., Саберова Г. Г.* Татарча-русча идиомалар сүзлеге / Ф. И. Таһирова ред. – Казан: Алма-Лит, 2006.

Кыскача үзбәкчә-татарча мәкаль һәм әйтемнәр сүзлеге / М. М. Абдурахимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

Русско-англо-немецко-турецко-татарский фразеологический словарь. – Казань: Изд-во КГУ, 2008.

### Этимологик һәм диалектологик сүзлекләр

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 4 томда. I т. – Бөре: БДПИ, 2005.

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А–Л). – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015. – 543 б.

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II том (М–Я). – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015. – 567 б.

Диалектологик сүзлек. Беренче чыгарылыш / Төз. Л. Җәләй, Х. Шабанов, А. Камский, С. Әмиров. – Казан: Таттосиздат, 1948.

Диалектологик сүзлек. Икенче чыгарылыш / Төз. Н. Б. Борһанова, Г. К. Якупова / Л. Җәләй ред. – Казан: Татгосиздат, 1953.

Диалектологик сүзлек. Өченче чыгарылыш / Төз. Н. Б. Борһанова, Л. Т. Мәхмүтова / Л. Җәләй ред. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

Татар теленең диалектологик сүзлеге / Л. Т. Мәхмүтова ред. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.

*Тумашева Д. Г.* Словарь диалектов сибирских татар. – Казань: Изд-во КГУ, 1992.

Татар теленең диалектологик сүзлеге / Д. Б. Рамазанова ред. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка. – Т. I. Ч. I–II / Авт.-сост. А. Г. Шайхулов, Л. У. Бикмаева, З. Р. Садыкова. – Уфа: РИО БашГУ, 2005.

Татар халык сөйләшләре. Ике китапта / Төз.: Ф. С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, Т. Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / Төз.: Ф. С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, З. Р. Садыйкова, Т. Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.

### Синонимнар сүзлекләре

*Ханбикова Ш. С.* Синонимнар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962.

*Ханбикова Ш. С., Сафиуллина Ф. С.* Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.

### Орфографик сүзлекләр

Татар теленең орфографик сүзлеге / Төз. А. Х. Нуриева һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

*Нуриева А. Х.* Татар теленең орфографик сүзлеге. Башлангыч мәктәп укучылары өчен. – 4 басма. – Казан: Мәгариф, 1996.

*Ганиев Ф. Ә., Сабитова И. И.* Татар теленең орфографик сүзлеге. – Казан: Раннур, 2002.

*Газизова Ф. М.* Татар теленең латинда һәм кириллда орфография сүзлеге. – Казан, 2003.

### Төрки телләрнең сүзлекләре

Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1969.

Türkçe sözlük. T. I–II = Төрек теленең аңлатмалы сүзлеге. – Ankara, 1988.

Татарча-төрекчә сүзлек / Төз. Ф. Ганиев, Р. Әхмәтьянов, Х. Ачыкгөз; Фәнни мөх. Х. Ачыкгөз, А. Рәхимова. – Казан–Мәскәү: Инсан, 1997.

Төрекчә-татарча сүзлек / Төз. Р. Әхмәтьянов, Р. Мөхәммәтдинов, Ф. Нуриева, Ф. Ганиев. – М.: Инсан, 1998.

Къарачай-малкъар тилни ангылатма сёзлюгю: Ючтомлукъ. – Нальчик: «Эль-Фа» Китап басма, 1996, 2002.

Диалектологический словарь башкирского языка. – Уфа: Китап, 2002.

Хәҙерге башҡорт әҙәби теленең аңлатмалы һүҙлеге / Яуаплы мөхәррире З. Ғ. Ураксин. – Өфө, 2004.

Қазақ тілінің синонимдер сөздігі / Құраст. С. Бизаков, Ә. Болғанбаев, Ш. Дәулетқұлов. – Алматы: «Арыс» баспасы, 2005.

Қазақ тілінің аймақтық сөздігі / Құраст. Ғ. Қалиев, О. Нақысбеков, Ш. Сарыбаев, А. Үдербаев және т.б. – Алматы: «Арыс» баспасы, 2005.

Қазақ әдеби тілінің сөздігі. Он бес томдық. I–II том / Құраст Т. Жанұзаков, С. Омарбеков, Ә. Жүнісбек және т.б. – Алматы: «Арыс» баспасы, 2006.

*Әхтәмов М. Х.* Башҡорт халыҡ мәҡәлдәре һәм әйтемдәре һүҙлеге. – Өфө: Китап, 2008.

### Рус теле сүзлекләре

Толковый словарь русского языка: В 4-х т. / Под ред. Д. Н. Ушакова. – М.: ОГИЗ, 1935, 1938, 1939, 1940.

Словарь современного русского литературного языка. Т. I–XVII. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948 –1965.

*Даль В. И.* Толковый словарь живого великорусского языка. – 6-е изд. – Т. I–IV. – М., 1955.

Большая Советская Энциклопедия. – М.: Сов. энцикл., 1969–1978.

Новые слова и значения. Словарь-справочник по материалам прессы и литературы 60-х годов / Под. ред. Н. З. Котеловой, Ю. С. Сорокина. – М.: Сов. энцикл., 1971.

Советский энциклопедический словарь. – М.: Сов. энцикл., 1981.

Словарь русского языка: В 4-х т. / Под ред. А. П. Евгеньевой. – 2-е изд., испр. и доп. – М.: Рус. яз., 1981, 1986, 1987, 1988.

Новейший энциклопедический словарь. – М.: РИПОЛ классик, 2010.

Новые слова и значения. Словарь-справочник по материалам прессы и литературы 70-х годов / Под ред. Н. З. Котеловой. – М.: Рус. яз.,1984.

*Ожегов С. И.* Словарь русского языка / Под ред. Н. Ю. Шведовой. – 22-е изд., испр. – М.: Рус. яз., 1990.

Современный словарь иностранных слов. – М.: Рус. яз., 1993.

Современный словарь иностранных слов. – 4-е изд., стереотип. – М.: Рус. яз., 2001.

Большой словарь иностранных слов. – М.: ЮНВЕС, 2001.

Толковый словарь русского языка: С включением сведений о происхождении слов. / Отв. ред. Н. Ю. Шведова. – М. Издательский центр «Азбуковник», 2007.

*Крысин Л. П.* Иллюстрированный толковый словарь иностранных слов / Л. П. Крысин. – М.: Эксмо, 2008.

**Татарча-русча сүзлекләр**

*Гиганов И.* Слова, коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку. – СПб.: Императорская Академия наук, 1801.

*Троянский А.* Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нём речений арабских и персидских: В 2-х т. – Казань: Тип. ун-та, 1833, 1835.

*Остроумов Н. П.* Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещённых татар Казанской губернии. – Казань: Тип. ун-та, 1876.

*Насыйри К.* Татарча-русча лөгать китабы. – Казань: Тип. ун-та, 1878.

*Катанов Н. Ф.* Краткий татарско-русский словарь. – Казань: Типолитогр. ун-та, 1912.

*Рахманколый С.* Татарча-русча лөгать. – Казан: И. Н. Харитонов лито тип., 1913.

Татарско-русский словарь / Сост. М. Корбангалиев, Р. Газизов, М. Кулиев. – Казань: Татгосиздат, 1931.

Татарско-русский словарь / Сост. Р. Газизов, Н. Исанбет, Г. Ишмухаметов. – Казань: Татгосиздат, 1950.

Татарско-русский словарь. – М.: Сов. энциклопедия, 1966.

Татарско-русский учебный словарь / Под ред. Ф. А. Ганиева. – М.: Рус. яз. 1993.

*Сафиуллина Ф. С., Ризванова Л. М.* Татарча-русча антонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1997.

*Сафиуллина Ф. С., Газизова Ф. М.* Татарча-русча тезмә сүзләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.

Татарско-русский словарь / Сост. И. А. Абдуллин, Ф. А. Ганиев, М. Г. Мухамадиев, Р. А. Юналеева / Под ред. Ф. А. Ганиева. 4-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002.

Татарско-русский словарь: В 2-х т. – Казань: Магариф, 2007.

**Русча-татарча сүзлекләр**

*Насыри К.* Полный русско-татарский словарь. – Казань: Типолитогр. ун-та, 1892.

*Воскресенский А.* Русско-татарский словарь. – Казань: Типолитогр. ун-та, 1894.

*Рахманколый С., Кәрам Г.* Русча-татарча мөкәммәл лөгать. – Казан: Гасыр, 1920.

Русча-татарча яңа лөгать. – Казан: Яңа китап, 1929.

*Нугайбек Г.* и др. Русско-татарский словарь. – 2-е изд. – Казань: Татгосиздат, 1940.

Русско-татарский словарь: В 4-х т. – Казань: Таткнигоиздат, 1955, 1956, 1958, 1959.

*Махмутов М. И.* Школьный русско-татарский словарь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1967.

Русско-татарский словарь / Отв. ред. Р. С. Газизов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1971.

*Сафиуллина Ф. С., Галиуллин К. Р.* Тематический русско-татарский словарь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989.

*Ганиев Ф.* А., *Гаффарова Ф. Ф.* Русско-татарский словарь / Под ред. Ф. А. Ганиева. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

*Юналеева Р. А., Абдуллина Р. Р.* Русско-татарский словарь / Под ред. Ф. А. Ганиева. – Казань: Магариф, 1996.

Русско-татарский словарь / Сост. Э. М. Ахунзянов, Р. С. Газизов, Ф. А. Ганиев и др.; Под ред. Ф. А. Ганиева. – 4-е изд., испр. – М.: Инсан, 1997.

*Агишев Х. Г.* Русско-татарский словарь словосочетаний: В 2-х т. / Под ред. М. З. Закиева, С. М. Ибрагимова. – Казань: Матбугат йорты, 1998.

**Терминологик сүзлекләр**

*Насыйри К.* Гөлзар вә чәмәнзар китабына сүзлек. – Казан, 1894.

*Габидов Г.* Русча-татарча сәяси лөгать. – Оренбург: Өлфәт, 1918.

*Камал Г.* Кесә өчен русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгать. – Казан: Васита, 1918.

Сәяси лөгать / Төз. Г. Нигъмәти, М. Мөхәммәдиев, С. Шәрәфетдинов. – М.: СССР халыкларының үзәк нәшрияты, 1925.

Краткий татарско-русский словарь военных терминов (толмач). – М.: Искра революции, 1926.

Физика атамалары. – Казан, 1927.

Газета укучылар өчен кесә сүзлеге / Төз. М. Гали. – Казан: Татиздат, 1928.

Медицинадан татарча атамалар. I кис. Нормаль анатомия атамалары. – Казан, 1929.

Атамалар сүзлеге. XI серия. Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары. – Казан: Татиздат, 1931.

Химия атамалары: Анорганик җыелмаларның яңа номенклатурасы. I бүлек / Төз. Г. Вәлитов. – Казан: Татиздат, 1931.

Урысча, латинча һәм татарча атамалар сүзлеге. Кеше морфологиясе (анатомия, гистология). III серия. – Казан: Татиздат, 1931.

Урысча-татарча атамалар сүзлеге. Физика, математика, астрономия. – Казан: Татиздат, 1931.

Математика атамалары: Русча-татарча сүзлек. – Казан: Татгосиздат, 1934.

Химия терминнары: Русча-татарча сүзлек / Төз. Г. Дистанов, Г. Вәлитов. – Казан: Татгосиздат, 1934.

Табигыять һәм биология терминнары. – Казан: Татгосиздат, 1935.

Элементар математика терминнары җыентыгы / Төз. Х. Халиков, И. Алексеев, З. Исаев. – Казан: Татгосиздат, 1935.

Физика һәм метеорология терминнары / Төз. М. Галиев, Х. Мөштәри, Х. Хөснуллин. – Казан: Татгосиздат, 1939.

Политик-экономик терминнар (русча-татарча һәм татарча-русча сүзлек) / Төз. Ф. Махианов, Г. Шәфиев, Г. Нугайбәк. – Казан: Татгосиздат, 1941.

Русча-татарча математик терминнар сүзлеге. – Казань: Таттосиздат, 1949.

Русча-татарча физика һәм геофизика терминнары сүзлеге / Төз. М. С. Галеев. – Казан: Татгосиздат, 1949.

Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге / Төз. Г. Г. Әхмәтов, М. Гыймадиев. – Казан: Татгосиздат, 1950.

Русча-татарча психология һәм педагогика терминнары сүзлеге / Төз. В. Горохов, А. Касимов, В. Хангильдин. – Казан: Татгосиздат, 1950.

Тел белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге / Р. Шакирова ред. – Казан: Татгосиздат, 1953.

Русча-татарча география сүзлеге / Төз. З. С. Дусаев. – Казань: Татгосиздат, 1953.

Политик сүзлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

Әдәбият белеме сүзлеге / Төз. Н. Гыйззәтуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

Русча-татарча техника терминнары сүзлеге / Төз. А. К. Тимергалин, М. С. Галеев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.

Русча-татарча математик терминнар сүзлеге / Төз. В. З. Закиров, З. Г. Мортазин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970.

Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге / Төз. А. К. Тимергалин, Г. Г. Әхмәтов, Ш. Г. Садыйков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.

Русча-татарча биология терминнары сүзлеге / Төз. О. Ж. Курмаев җитәкчелегендәге коллектив. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.

Русча-татарча физика терминнары сүзлеге / Төз. М. С. Галеев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.

Русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге / Төз. М. С. Галеев, А. К. Тимергалин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

Русча-татарча химия терминнары сүзлеге / Төз. Г. Дистанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

Русча-татарча физика терминнары сүзлеге / Төз. М. С. Галиев, А. К. Тимергалин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред. А. Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

*Гарипова Ф. Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

Русско-татарский словарь биологических терминов / Сост. Ф. Г. Ситдиков, Н. А. Бакиева, А. Х. Гарифуллина и др. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985.

Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеге / Төз. Я. И. Ханбиков, Ш. С. Ханбикова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.

Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге / Төз. Р. А. Шакирҗанов / Р. Г. Әхмәтьянов ред. – Яр Чаллы, 1992.

*Гарипова Ф. Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге / Фәнни ред. М. З. Зәкиев. – 1–2 кит. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992, 1993.

Краткий русско-татарский словарь исторических терминов / Сост. Г. И. Мустафина / Ред. Ж. С. Минуллин. – Казань: КГПИ, 1993.

Краткий русско-татарский толковый словарь медицинских терминов / Сост. М. М. Миннебаев. – Казань: Медицина, 1994.

Краткий русско-татарский словарь для работников ЗАГСа / Сост. Ф. С. Баязитова / Науч. ред. З. Р. Садыкова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1994.

Краткий русско-татарский общественно-политический словарь / Сост. И. М. Низамов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

Краткий русско-татарский словарь для работников культуры / Сост. Д. Б. Рамазанова / Под ред. Ф. С. Сафиуллиной. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

Краткий русско-татарский словарь для работников общественного питания / Сост. Т. Х. Хайрутдинова / Науч. ред. Д. Б. Рамазанова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

Краткий русско-татарский словарь для работников сельского хозяйства / Сост. Ф. Ф. Гаффарова, З. Р. Садыкова / Науч. ред. Г. Р. Муртазин, С. Г. Муртазина, Д. Б. Рамазанова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

Краткий русско-татарский словарь для работников торговли / Сост. М. Г. Мухаммадиев / Науч. ред. А. М. Хазрятов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

Русско-татарский словарь-минимум для работников предприятий бытового обслуживания / Сост. Р. Р. Абдуллина / Науч. ред. Ф. И. Тагирова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

Русско-татарский словарь-минимум для работников леса / Сост. А. Г. Гаянов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлекчә / Төз. Р. Р. Шәмсетдинова / Фәнни ред. Н. Г. Халфеев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Сайфуллин Р. С., Хисамеев Г. Г.* Толковый словарь-справочник по физике, химии и химической технологии на русском, татарском и английском языках. – Казань: Фән, 1996.

Азбука природы: Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов: В 6 кн. / Сост. А. Б. Халидов, А. С. Казанцева, В. И. Гаранин и др. – Казань: Магариф, 1996–2001.

*Амиров К. Ф.* Русско-татарский юридический словарь / Под ред. Ф. А. Ганиева. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Англо-русско-татарский словарь физических терминов / Сост. З. М. Вагизова, Г. Ю. Даутов, О. Аслан. – Казань: Таң = Заря, 1996.

*Кафиатуллина В. И.* Англо-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики / Науч. ред.

В. Ш. Фатхуллин, Р. А. Шакирзянов, Р. Н. Куряева. – Казань: КГАСА, 1996.

*Кафиатуллина В. И.* Немецко-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики / Науч. ред. В. Ш. Фатхуллин, Р. А. Шакирзянов. – Казань: КГАСА, 1996.

Русско-татарский словарь-минимум для работников связи / Сост. Р. Г. Гатауллина / Науч. ред. И. М. Низамов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Краткий русско-татарский словарь для работников транспорта / Сост. Д. Б. Рамазанова, Ф. И. Тагирова / Науч. ред. Р. Г. Ахметьянов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Русско-татарский словарь-минимум для работников химической промышленности / Сост. Р. И. Халиуллин, Н. Ш. Мифтахова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Русско-татарский словарь-минимум для работников нефтяной промышленности / Сост. М. Б. Газизов, Р. З. Фахрутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Русско-татарский словарь-минимум для строителей / Сост. Р. Г. Ахметьянов, Р. А. Шакирзянов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Русча-татарча, татарча-русча физика терминнары сүзлеге / Төз. Г. Ю. Даутов, З. М. Вәгыйзова / Ред. Г. Ю. Даутов. – Казан: Таң = Заря, 1996.

Финансово-экономические и юридические термины. Толковый словарь / Сост. К. М. Гарифуллин, К. Г. Хайруллин, Ф. Н. Фаткуллин и др. – Казань: изд-во Каз. фин.-экон. ин-та, 1996.

Краткий русско-татарский словарь для работников народного образования / Сост. К. Р. Галиуллин, Ф. С. Сафиуллина. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997.

Краткий русско-татарский словарь для работников охраны природы / Сост. М. М. Гимадиев, А. И. Щеповских. – Казань: Фән, 1997.

Математикадан русча-татарча белешмә сүзлек / Төз. И. Г. Галәветдинов, Г. Г. Гафуров, В. З. Закиров, М. З. Хөснетдинов. – Казан: Мәгариф, 1997.

Русско-татарский общественно-политический словарь / Сост. Ф. А. Ганиев, И. М. Низамов и др. / Под рук. Р. М. Харисова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997.

Русско-татарский словарь для работников музыкальных учреждений / Сост. И. Г. Алмазов, Д. Б. Рамазанова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997.

Русско-татарский словарь-минимум для работников лесной промышленности / Сост. Г. Г. Саберова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997.

Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек / Төзүчеләре: Ф. Г. Ситдиков, Р. К. Зәкиев, А. Б. Халидов һ.б. / Ред. Ф. Г. Ситдиков, Р. К. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 1998.

Русско-татарский словарь для работников библиотек, издательств и информационных служб. – Казань: Магариф, Милли китап, 1998.

*Газизова Ф. М.* Русча-татарча икътисади атамалар сүзлеге. – Казан: Раннур, 1999.

Русско-татарский словарь терминов журналистики / Сост. Ф. А. Агзамов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1998.

Краткий русско-татарский словарь для бизнесменов и предпринимателей / Сост. С. Ф. Гарифуллин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1999.

Международная анатомическая номенклатура: Латинско-русско-татарский словарь / Авт.-сост. Р. М. Гатин. – Казань: Магариф, 1999.

*Мугинов Р. А.* Русско-татарский словарь военных терминов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2000.

Русча-татарча техник терминнар сүзлеге / Төз. А. К. Юлдашев, А. З. Әфләтунов, А. Х. Зимагулов, Р. Г. Нуруллин. – Казан: Мәгариф, 2000.

*Мифтахова Н. Ш.* Русча-татарча химик терминнар сүзлеге / Ред. Н. С. Әхмәтова. – Казань: Мәгариф, 2002.

Татарча-русча-латинча үсемлек атамалары сүзлеге / Төз. Г. Г. Саберова / Ф. А. Ганиев ред. – Казан: Фикер, 2002.

Медицинадан русча-татарча аңлатмалы сүзлек / Төз. М. М. Гыймадеев, Н. Х. Әмиров, К. Ш. Зыятдинов. – Казан: Мәгариф, 2003.

Агрохимия һәм туфрак белеме терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге / Төз. М. Ю. Гыйләҗев, С. Г. Мортазина, Ф. Ф. Гаффарова. – Казан: Мәгариф, 2003.

Русча-татарча нефть сәнәгате сүзлеге / Төз. Ф. С. Хәкимҗанов, Р. А. Шакирҗанов, З. Г. Хәбипова. – Казан: Мәгариф, 2004.

Медицина терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге / Төз. Р. Р. Шәмсетдинова. – Казан: Мәгариф, 2004.

Ветеринария медицинасы терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге / Авт.-төз. Ф. Г. Нәбиев, Р. Г. Госманов, Р. И. Ситдиков, М. Ш. Шакуров һ.б. – Казан: Мәгариф, 2004.

Химиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек / Авт.-төз. Г. Г. Хисамеев, А. И. Нарбеков, Н. Х. Әмиров һ.б. – Казан: Мәгариф, 2004.

Информатика һәм мәгълүмат технологияләре терминнары: Инглизчә-татарча-русча аңлатмалы сүзлек / Авт.-төз. Җ. Ш. Сөләйманов, А. Ф. Галимьянов, М. Х. Вәлеев. – Казан: Мәгариф, 2006.

Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлеге / Авт.-төз. Р. Ф. Галләмов. – Казан: Мәгариф, 2006.

*Сафиуллина Р. Р.* Мөселман терминологиясе сүзлеге. – Казан: «Алма-Лит» нәшр., 2006.

Русско-татарский музыкальный словарь / Сост. И. Г. Алмазов, Д. Б. Рамазанова. – Казань: Изд-во КГУ, 2007.

Агроэкология терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге / Төз.: М. Ю. Гыйләҗев, С. Г. Мортазина, Ф. Ф. Гаффарова, М. Г. Муртазин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.

Тасвири сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате атамалары: аңлатмалы сүзлек / Төз. Ф. Г. Вагапова / Р. Т. Сафаров ред. – Казан: Магариф–Вакыт, 2011.

# СҮЗЛЕКТӘ ФАЙДАЛАНЫЛГАН БАШКА ЧЫГАНАКЛАР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ

1. Сүзлек бирәмлеге итеп алынган сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең мәгънә төрлелекләрен, стилистик үзенчәлекләрен аерып биргән аңлатмалар матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицистик һәм фәнни-популяр әсәрләрдән, дәреслекләрдән һ.б. чыганаклардан алынган мисаллар ярдәмендә дәлилләнде. Матур әдәбияттан һәм татар телендә язылган яки тәрҗемә ителгән әдәбияттан алынган мисаллар янында, кагыйдә буларак, әсәрнең исеме түгел, ә, иң беренче чиратта, автор исеме күрсәтелде. Мәсәлән, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г.Ибраһимов, И.Гази, Г.Бәширов, Ә.Еники, Г.Ахунов, Ф.Хөсни, Э.Касыймов, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Г.Гыйльманов, М.Маликова, Г.Нигъмәти, И.Таһиров, Р.Әмирхан, С.Алишев, М.Пришвин, В.Сабунаев, Н.Сладков һ.б.

2. Авторларның фамилияләре, инициаллары (яки псевдонимнары) бер үк төрле булган очракта, алар түбәндәге тәртиптә бирелде: Гали Рәхим (Гали Рәхим) һәм Г.Рәхим (Гәрәй Рәхим); Мәрди Рафиков (Мәрди Рафиков) һәм М.Рафиков (Мәҗит Рафиков); Мансур Хәсәнов (Мансур Хәсәнов) һәм М.Хәсәнов (Мәхмүт Хәсәнов); Римзил Вәлиев (Римзил Вәлиев) һәм Р. Вәлиев (Разил Вәлиев) һ.б.

3. Нигездә башка телләрдән тәрҗемә ителгән дәреслекләрдән, методик ярдәмлекләрдән, иҗтимагый-сәяси, фәнни-популяр әсәрләрдән алынган мисаллар янында китапның исеме күрсәтелде: ... Арифметика; ... Ботаника; ... Геометрия; ... Урта гасырлар тарихы; ... Физикадан мәсьәләләр җыентыгы; ... Кызыклы география; ... Могҗизалар энциклопедиясе; ... Кызыклар дөньясында; ... Йорт эшләре һ.б.

4. Вакытлы матбугаттан алынган мисаллар янында шул газета-журналларның исемнәре күрсәтелде: ... Татарстан; ... Казан утлары; ... Мирас; ... Идел; ... Хокук һәм хәят; ... Ватаным Татарстан; ... Шәһри Казан; ... Мәдәни җомга; ... Татарстан яшьләре, ... Татар иле һ.б.

5. Алда әйтеп кителгәнчә, башка телләрдән тәрҗемә ителгән әсәрләрдән алынган мисаллар янында югарыда күрсәтелгән тәртиптә я авторның үзе, я китапның исеме бирелде. Хезмәтнең тәрҗемәчеләре күрсәтелмәде. Шуның өчен, иллюстратив материал буларак мисаллар алынган әсәрләрнең исемлеген, тәрҗемәчеләрен күрсәтеп, аерым китерәбез.


*Алексеев И. А.* Югары математика нигезләре / Г. Г. Тумашев тәрҗ. – Казан: Татгосиздат, 1953.

*Андерсен Һ. К.* Унике сәяхәтче: Әкиятләр / Л. Гыйззәтуллина тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2008.

*Бахаров А. Н., Яковлев П. Н.* Иван Владимирович Мичурин / Г. Әхмәтов тәрҗ. – Казан: Татгосиздат, 1941.

*Верзилин Н.* Робинзон эзләреннән / Р. Вәлиева тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

*Веселов Е. А.* Дарвинизм нигезләре. Урта мәктәпнең IX классы өчен дәреслек / Г. З. Бакирова, З. С. Рахматуллина тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.

*Григорьев Н. В.* Татарстанда терлекчелек. Тәҗрибә, проблемалар, перспективалар / Коллектив тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

*Гунтәкин Р.-Н.* Чалы кошы / Т. Нурмөхәммәтов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

*Девятков А. К., Макаревич А. И.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре / Коллектив тәрҗ. – Казан, 1993.

Дөньяда ниләр бар. Табигать турында хикәяләр / Коллектив тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

Йорт эшләре / Коллектив тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Казневский В. П.* Космик ракеталар / М. Исхаков тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.

*Конан Дойл А.* Баскервильләр эте; *Киплинг Р.* Маугли; *А. де Сент-Экзюпери.* Нәни принц / Р. Вәлиев тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2004.

*Макиавелли Н.* Падишаһ / М. А. Аверьянов тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2006.

*Марк Твен.* Том Сойер маҗаралары / С. Ибраһимова тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2003.

*Мульги А. Я.* Мәктәптә кул эше / Ф. Зыятдинова тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

*Перельман Я. И.* Кызыклы физика. Беренче китап / Н. К. Раимов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Плавильщиков Н.* Диңгез тирәнлегендә / З. Мәҗит тәрҗ. – Казан: Татгосиздат, 1940.

*Платонов Г. В.* Дарвинизм һәм дин / Ф. М. Байчурина тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962.

*Платонов К. К.* Кызыклы психология / Р. Х. Камалова тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

*Покровский А. А.* Ашаганың аш булсын / Н. С. Вәлиева, Ф. Ә. Ганиев тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.

*Пришвин М.* Аучы хикәяләре / Б. Шәрәфетдинов тәрҗ. – Казан: Татгосиздат, 1951.

*Рейнберг М. Г.* Уйлаучы машиналар / Д. С. Зарипов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Родкина Р. А.* Йөкле хатын гигиенасы / С. Вилданова тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.

*Сабунаев В. Б.* Кызыклы ихтиология / Р. А. Шахмуратова тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970.

*Сафонов. В.* Җир чәчәктә / С. Каратай тәрҗ. – Казан: Таткнигоиздат, 1954.

*Сергеев Б. Ф.* Кызыклы физиология / Р. А. Шахмуратова, Р. К. Камалова тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

*Сладков Н. И.* Баллы яңгыр. Әкиятләр, хикәяләр / Л. Нәҗмиева тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

*Солодухин Е. Д.* Урман аптекасы / М. Ә. Мостаев тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

*Тургенев И. С.* Аучы язмалары / Ф. Зыятдинов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

*Ходаков Ю. В.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр / А. К. Тимергалин тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.

*Шекспир У.* Сайланма әсәрләр: 2 томда / Коллектив тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

*Щербина П.С.* Умартачылык / Г. Ш. Кадыйров тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

## СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ

### I. Сүзлеккә сүзләр алу тәртибе

§ 1. Сүзлекнең нигезен хәзерге әдәби тел сүзләре һәм фразеологик берәмлекләре тәшкил итә.

§ 2. Сүзлеккә түбәндәге төркем сүзләр дә кертелде:

а) урта мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә очраган төп төшенчәләрне белдергән сүзләр (**БА́ЗИС, БАКТЕ́РИЯ, ТИГЕЗЛӘМӘ, ФО́РМУЛА** һ.б.);

ә) газета-журналларда урын алган күпчелек иҗтимагый-сәяси терминнар (**ДОТА́ЦИЯ, ВӘКАЛӘТ, РЕФЕРЕ́НДУМ, РЕЙД** һ.б.);

б) моңа кадәр басылып чыккан лексик минимумнарда һәм терминологик сүзлекләрдә тәкъдим ителгән аерым терминнар яки аларның тәрҗемәләренең шактый күләме (**АСТӨШЕРМӘ, БАШЛАМ, БИЗӘМ, ӨЛГЕ, ТАМГАХАНӘ, ТЕРКӘҮ** һ.б.);

в) бүгенге көн өчен яңа булган, вазгыятьнең үзгәрүе белән килеп кергән, язма әдәбиятның барлык төрләрендә дә очраган Европа телләреннән алынган сүзләр (**БАЙКЕР, БАЙТ, БОНУС, ДИВИДЕНД, ДИ́ЛЕР, ИПОТЕКА** һ.б.);

г) дингә, халык ышануларына, мифологиягә, йолаларга, төрле ырымнарга бәйләнешле сүзләр (**БАКЫЙ, БАПТИЗМ, БӘДӘЛ, БӘРМӘНЧЕК, НАРДУГАН, ФАНИ** һ.б.);

д) яңадан кулланышка актив кереп бара торган, телдә кабат торгызылган искергән сүзләр (**БАГАВЫЛ, БАЕК, БАЙСА, БАЛГА** һ.б.);

е) хәзерге чорда активлашкан һәм урта мәктәп, югары уку йортларында өйрәнелә торган борынгы әдәбиятта очраган гарәп һәм фарсы телләреннән кергән шактый алынма сүзләр (**БАБ, БАГБАН, БАЗАРКӘН, ҖӘНҮБ, ИГАНӘ, ИГЪДАДИ, ИГЪТИБАРӘН** һ.б.);

ж) тарихи фактларны һәм электәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган искергән сүзләр (**ӘДЕРНӘ, БАРЫМТА, БАТМАН, БАТРАК, БИЗМӘН, КАБИЛӘ, КАГАН, КАГАНЛЫК, НӨГӘР** һ.б.);

ж) әдәбиятта еш очраган һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган диалекталь сүзләр (**ӘНӘЧӘ, БАДЪЯН, БАШБАТА, КАБЫГУ, КАЗЫМА, ШАМА** һ.б.);

з) матур әдәбият әсәрләрендә очраган яки хәзерге әдәби телдә еш кулланыла торган гади сөйләм сүзләре (**БӘЛШӘЮ, БӘРГӘЛӘШ, БЕЛӘМӘН** һ.б.);

и) киң кулланышка кергән яңа реалияләрне белдерү өчен, телнең үз җирлегендә ясалган яки мәгънәләре киңәйгән яңа сүзләр (**БАКЫЙЛЫК, БАРЛАМА, БАСМАК, ИГАНӘЧЕ, КОЛАКСА, КЕРТЕМ, ЭШМӘКӘР** һ.б.).

§ 3. Сүзлек берәмлеге итеп барлык грамматик сүз төркемнәренә дә караган сүзләр алынды. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләр һәм аларның мәгънәләре төп сүз мәкаләсендә күрсәтелде.

**ӘВӘРӘ** *и. фар.* **1.** Бик буталчык хәлләр, вакыйгалар. *Аның ул әвәрәгә ничек катнашып китүен һич аңлап та булмый, юкса, ireккә чыгарына да нибары өч ай гына калган булган.* Казан утлары

**2.** *хәб. сүз мәгъ.* Бер нәрсәгә бирелеп китү, мавыгу. *Нинди эшкә башың әвәрә?* Н.Исәнбәт

§ 4. Мөстәкыйль сүзлек берәмлеге буларак, тамыр сүзләр белән беррәттән, барлык сүз төркемнәренә дә караган төрле типтагы ясалма сүзләр дә кертелде. Шул исәптән: а) кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр (**ӘЙЛӘНЕШ, ВӘКАРЬЛЕК, ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК** һ.б.); ә) саф кушма сүзләр (**АМПЕРМЕТР, АРПАБАШ**, **АЯГҮРӘ, БАШКИСӘР** һ.б.); б) кыскартылган кушма сүзләр (**БАТРАЧКОМ, БЕНЗОВОЗ, РАБФАК** һ.б.); в) парлы сүзләр (**АНДАМОНДА, БАШ-АЯК**, **КҮРШЕ-КҮЛӘН, САВЫТ-САБА** һ.б.); г) компонентлары аерым язылса да, кушма һәм тезмә сүзләр (**БАКА ЕФӘГЕ**, **БАКА ЯФРАГЫ**, **БАЛАН БАРМАК, БАСЫМЧА́К ИТҮ**, **ВАҖИБ ИТҮ**, **ВАСЫЯТЬ КЫЛУ** һ.б.).

§ 5. Киң кулланылышлы һәм продуктив булган алкушымчалар, шулай ук кушма сүзләрнең беренче яки икенче кисәкләре сүзлектә аерым мәкалә итеп бирелде (**АВИА-, АВТО-, АГРО-, -АРА, БИ-, БИО-, НЕО-, -СЫМАННАР** һ.б.).

§ 6. Сүзлектә түбәндәге сүзләр бирелмәде: а) үтә профессиональ сүзләр, ягъни фәннең һәм техниканың тик аерым тармакларында гына белгечләр тарафыннан кулланыла торган сүзләр; ә) әдәби телне баетмый һәм әдәбиятта гомумән очрамый торган җирле сөйләм сүзләре (диалекталь сүзләр); б) тупас сөйләм сүзләре, жаргон сүзләр; в) хәрефләрдән һәм авазлардан торган кыскартылма сүзләр; г) ялгызлык исемнәре.

## II. Сүзлекнең төзелеше

§ 7. Сүзлектә баш сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылды, һәм алар үзләренә караган материал (аңлатмалар, мисаллар, фразеологик берәмлекләр) белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итә.

§ 8. Баш сүздән соң аның сүз төркемен, чыганак телен, стилистик үзенчәлекләрен сыйфатлый торган билгеләре куелды. Шуннан соң мәгънәгә аңлатма бирелде, иллюстратив материал китерелде. Сүзнең барлык мәгънәләрен дә ачып бетергәннән соң, кызыл юлдан шул сүз белән башланган фразеологик берәмлекләр теркәлде.

§ 9. Башка сүз төркеменә күчеп ясалган сүзләр нокталы калын, ә аларның мәгънәләре җәяле якты гарәп цифрлары белән аерылды.

**ИКМӘК** *и.* **1.** 1) Ачытылган камырдан мичтә пешерелгән ризык; ипи. *Һади, ап-ак тешләрен икмәккә батырып: – Тәмле! – диде. Икмәк телеме күз ачып йомганчы юкка чыкты.* А.Гыйләҗев ...

2) Ашлык. *Гектарыннан утыз, кырык центнер алган хуҗалык күп булды. Колхоз ындырларында икмәк таулары ясалды.* М.Мәһдиев ...

3) Кырда үсеп утырган иген. *Болгарларның җирләрендә бодай, арпа, тары һәм башка төрле икмәк тә үскән.* Г.Гобәйдуллин ...

**2.** *ы. мәгъ. сөйл. к.* **икмәктер**. *Конкурста мин беренче урынны алам, Гөлүсә. Чын, икмәк!* Н.Гыйматдинова ...

§ 10. Һәр мәгънә кызыл юлдан башланып китте. Сүзнең якынрак мәгънә төсмерләре параллель сызыклар (//), ә тагы да якын мәгънәләре нокталы өтер (;) ярдәмендә аерып күрсәтелде.

**ӘДӘП** *и. гар.* 1) Җәмгыятьтә гомум кабул ителгән әхлак кагыйдәләре; яхшы гадәтләр ... // Кеше арасында үз-үзеңне әхлак кагыйдәләренә туры китереп тота белү сыйфаты ...

2) Яхшы гадәт, йола ...

**АРКАДАШ** *и.* **1.** Иптәш, дус; таяныч. *Иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде.* Г.Исхакый ...

§ 11. Тигез хокуклы грамматик һәм фонетик вариантлар мөстәкыйль сүзлек берәмлекләре итеп алындылар, һәм һәркайсы алфавит тәртибендә үз урынында бирелде.

**АСТРОЛЯБ** *и. гр. сөйл. к.* **астролябия**. *Бер якта астролябка таянган Әбелхарис күренә. --- Әбелхарис астролябын тоткан килеш катып кала*. Н.Исәнбәт

**АСТРОЛЯ́БИЯ** *и. гр.* Астрономиядә: озынлык һәм киңлекне, шулай ук җир үлчәү эшләрендә горизонталь почмакларны билгели торган почмак үлчәү әсбабы

§ 12. Компонентлары аерым язылган, лексик берәмлек тәшкил иткән кушма һәм тезмә сүзләр дә аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде, сүзлектә алфавит тәртибендә урнаштырылды һәм аңлатылды.

**ӘҖЕ́-ГӨҖЕ КИЛҮ** *ф.* Озак итеп, дусларча сөйләшү ...

**ИГЕН ГӨМБӘСЕ** *и. а. х.* Ашлык бөртекләрен, зарарлап, кара тузанга яки кибәккә әйләндерә торган гөмбә авыруы; корымбаш; *русчасы*: **головня**

§ 13. Омонимнар шулай ук һәрберсе аерым мөстәкыйль сүзлек берәмлеге итеп алынды һәм якты рим цифрлары белән күрсәтелде.

**БИК** I *и.* 1) *иск. кит. к.* **бәк**

2) Морзалар нәселендәге фамилияләрдә һәм кайбер кушма исемнәрдә сакланган компонент: *Биктимер, Бикбулат, Ханбиков*

**БИК** II *и.* 1) Бикләп кую җайланмасы; йозак, келә, бастырык, бикләвеч. *Сыерның тыныч кына күшәп ятуын ишеткәч, җиңел сулап җибәрә, чолан ишегенең биген тикшерә, өй ишеген «бисмилла» әйтеп яба, аннары түшәген җәеп, ятарга әзерләнә башлый.* И.Гази ...

**БИК** III *рәв.* **1**. 1) Гаять, көчле дәрәҗәдә, гадәттән тыш, чиктән ашкан, югары дәрәҗәдә, искиткеч, искитмәле. *Шулай бик озак барганнан соң, алда, бик еракта, кыр өстендә аз гына калкып, соры карамчык кына булып, бер авыл күренә башлады.* Г.Бәширов ...

## III. Сүзләрнең мәгънәләрен билгеләү һәм аларны аңлату

Мәгънәләрне алу һәм урнаштыру тәртибе

§ 14. Сүзлектә китерелгән һәр тел берәмлегенең хәзерге әдәби телдә кулланылган барлык мәгънәләре дә аерып күрсәтелде.

§ 15. Алынма сүзләрнең бары тик татар телендә кулланылган мәгънәләре генә китерелде.

§ 16. Күп мәгънәле сүзләрне шәрехләгәндә, аның бөтен семантик кыры исәпкә алынып, аерым мәгънәләре билгеле бер тәртиптә урнаштырылды:

а) мәгънәләрнең бирелеш тәртибе, беренче чиратта, аларның хәзерге әдәби телдәге кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнде; мәгънәләр логик эзлеклелекне һәм генетик бәйләнешне мөмкин кадәр сакларга тырышып урнаштырылды;

ә) мәгънәләрнең үсеш-үзгәрешендәге тарихи эзлеклелекне хәзерге тел материаллары ачык күрсәтеп торганда, сүзнең мәгънә төзелешен аңлауны җиңеләйтерлек очракларда, беренчел мәгънәләр, искергән булса да, алдан бирелде. Калган барлык очракларда искергән мәгънә, кагыйдә буларак, хәзерге мәгънәләрдән соң гына теркәлде;

б) конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алдарак урнаштырылды;

в) киң кулланыштагы мәгънәләр аның таррак кулланыштагы (гади сөйләм, диалекталь, терминологик һ.б. өчен хас булган) мәгънәләреннән алдарак китерелде;

г) диалекталь мәгънәләр гомуми һәм махсус кулланыштагы мәгънәләрдән соң теркәлде;

д) күчерелмә мәгънәләр туры мәгънәләрдән соң бирелде;

е) бер үк стилистик төсмергә ия булган мәгънәләрнең куллану ешлыгы югарырак булганы алданрак китерелде;

ж) сүзнең аерым синтаксик позициядә ачылган мәгънәләре төп мәгънәләрдән соң урнаштырылды.

**БА́ЙТАК** *рәв.* **1.** Шактый, шактый зур, шактый күп. *Кичкә таба өй тәмам туздырылып, аннары тау башындагы күрше авылга ташылып беткәч тә, капка һәм койма баганалары белән байтак изаландык әле без.* М.Вәли-Барҗылы ...

**2.** *с. мәгъ.* Шактый санда булган, күп. *Инде байтак гомер яшәлгән, байтак һава суланган, су эчелгән, дөнья күрелгән, дигән сүз.* Ф.Латыйфи ...

**3. байтагы, байтагысы** *и. мәгъ. тартымлы форм.* Зур өлеш, зур кисәк, зур төркем; бөтеннең зуррак өлеше. *Үрдәкләрнең байтагысы күл өстендә пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр.* Я.Зәнкиев ...

ж) мөстәкыйль сүзнең ярдәмлек функциясендә кулланылган мәгънәсе (яки мәгънәләре) аның мөстәкыйль мәгънәләреннән соң бирелде.

**БӘРАБӘР** *с. фар.* **1.** Бердәй дәрәҗәдәге, тиң булган, лаек. *Үзенә бәрабәр ана арыслан белән юлдаш булып, сахрада кунды.* Дастан ...

**2.** *рәв. мәгъ.* Бердәй, тиң. *Ә бит чыдамлык белән сабырлык фатихага бәрабәр, дигән китап.* М.Хәсәнов

**3. бәрабәренә** *бәйл. функ.* Хакына, исәбенә. *Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан, дөньядагы афәтләрнең берсен – фашизмны җиңеп чыктык.* А.Гыйләҗев ...

§ 17. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләрдә ачылган мәгънәләр шул ук мәкалә эчендә төп мәгънәдән соң теркәлде.

**ЕЛДЫРЫМ** *и.* **1.** 1) Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен, төннәрен офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен чаткысы; аҗаган. *Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында күк күкрәүсез, ул яшен елдырымны никтер «рәшә уйнау» дип атыйлар.* А.Хәмидуллин ...

2) *диал.* Яшен. --- *бөтен тирә-якны сызылып яктырткан елдырым балкышындагы төсле [күзаллады]*. Т.Әйди ...

3) Нинди дә булса утлар уйнау чагылышы. *Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә.* Х.Камалов ...

4) *күч.* Берәр өлкәдә аз вакыт эчендә эз калдырган күренекле кеше. *Үзе дә әдәбият тарихында якты эз сызып, мәдәниятебез күгендә беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган олы әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында мондый сүзләр язып калдырган ---*. Л.Хәмидуллин ...

5) *күч.* Көтмәгәндә һәм тиз арада булып алган нинди дә булса физик яки рухи халәт, психик күренеш. *Уттай кайнар елдырым аркасын пешереп узды.* Х.Камалов ...

**2.** *с. мәгъ. күч.* Елгыр, җитез, өлгер; хәрәкәтчән. *Мин Зөһрә туташ белән сөйләштем. [Гарифҗан:] Сөйләштең? Елдырым егет икән син.* Н.Исәнбәт ...

§ 18. Сүзнең берәр кыек грамматик формасы өчен генә хас булган мәгънә (яки мәгънә төсмере) шул ук мәкалә эчендә әйтелгән грамматик формада гомуми кагыйдәләр нигезендә бирелде.

**БАШ** *и.* **1.** 1) ...

21) **башында** *күч. тарт. һәм кыек килеш форм.* Төп җитәкче, оештыручы урынында, башлык дәрәҗәсендә. *Иптәшләр, хәзер җирле граждан эшләре башында торучы Ногматов иптәшкә яшьләрнең регистрацияләре турында хәбәр итү өчен сүз бирелә.* Ф.Бурнаш.

**БАГУ** I *ф.* **1**. 1) *диал.* Карау, күз карашын юнәлтү, күз салу. ...

**3**. **бак, ба́ксана** *ы. мәгъ.* Кара син аны, кара әле, мәгънәсендә, игътибар итәргә кирәклекне, гаҗәпкә калуны белдерә. *Баксана! Бөтен күлем айкала!* Н.Исәнбәт. *Гөлҗамал абыстай, ишеткәнең бармы әле, менә бу кем малаеннан, баксана, аты коргыры, үләме әллә югыйсә...* М.Гали

**4. баксаң, бактың исә** *кер. сүз мәгъ.* 1) Чын-чынлап уйласаң, игътибар итсәң. *Баксаң, шунда бер матур кыз тынып калган.* Н.Исәнбәт. *Бактым исә, бер дә катлауландырасы юк, барысы да мөмкин икән.* Ф.Хөсни

2) Соңыннан билгеле булганча, чынлыкта, чынбарлыкта. *Баксаң, әле генә китерелгән сан да «соңгы сүз» булмаган икән.* М.Госманов...

§ 19. Алынма сүзләрнең мәгънәләрен бирү тәртибе татар телендә кулланылган мәгънәләренең үзара бәйләнешеннән чыгып билгеләнде.

**РАДИА́ТОР** *и. лат.* 1) Эчке янулы двигательләрне сыеклык ярдәмендә суыту җайланмасы. *Йөк машинасында йөрүче безнең бер шофёрның радиаторына ябалак бәрелгән булган.* Г.Әпсәләмов

2) Үзәктән ягып җылыту системасында пар яки кайнар су йөри торган торбаларга тоташтырылган җайланма

Мәгънәләргә аңлатма бирү тәртибе

§ 20. Сүзлек берәмлеге итеп алынган барлык гади, кушма һәм тезмә сүзләрнең һәм фразеологик гыйбарәләрнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә тиешле аңлатма бирелде.

§ 21. Аңлатмалар стилистик яктан нейтраль, туры мәгънәдәге һәм гомуми кулланыштагы сүзләр ярдәмендә генә төзелде. Тар кулланылышлы (гади сөйләмгә караган, поэтик, диалекталь, махсус һ.б.), сирәк очрый торган, искергән сүзләр яки сүзләрнең күчерелмә мәгънәләре, шулай ук бу сүзлеккә кермәгән сүзләр аңлатмаларда файдаланылмады.

§ 22. Сүзлектә, сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аңлатмаларның өч төрле ысулы кулланылды:

1. Тасвирлаулы аңлатма. Сүзләрнең мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләре күпчелек очракта кыскача аңлатма бирү юлы белән ачыкланды.

**ҖАМАЯК** *и.* Төрле зурлыкта һәм тирәнлектә булган тоткасыз савыт. *Карчыкның кулыннан агач җамаягы төшеп китеп, ат аягы астына тәгәрәде.* М.Галәү ...

2. Синонимик аңлатма, ягъни сүзнең мәгънәсен ачу өчен, аның синонимын (синонимнарын) файдалану. Мондый аңлатмалар бигрәк тә нинди дә булса берәр стилистик төсмере булган (искергән, диалекталь, гади сөйләмгә караган һ.б.) сүзнең яки алынма сүзләрнең мәгънәсен ачу өчен кулланылды.

**ӘШТЕ́Р-ӨШТЕР** *рәв. сөйл.* Ашыгып, аннан-моннан, өстән-өстән генә ...

3. Башка сүзгә яки аның аерым мәгънәсенә (мәгънәләренә) җибәрү. Бу ысул мәгънәләре охшаш яки бик нык якын булган сүзләрдә (синонимнарда) кулланылды. Төп аңлатма тиңдәшләренә караганда күбрәк кулланыла торган сүз янында бирелде, ә калганнарының мәгънәсе шул сүзгә җибәрү юлы белән аңлатылды.

**БАЛАШАР** *и. к.* **балимәр**

**БАЛИМӘР** *и.* Сайрар чыпчыклар семьялыгыннан, тонык көрән яки яшел төстә, тел очында чәчәкләрнең баллы суын суырырга махсус щёткасыман әгъзасы булган кечкенә көньяк кошы; *русчасы:* **медосос**

Күпмәгънәле сүзләргә яки омонимнарга җибәргән очракларда, сүзнең кайсы мәгънәсенә яки кайсы омонимга җибәрелүе күрсәтелде. Искәрмә буларак, сүзлекнең зур күләмле булуын исәпкә алып, икенче сүзнең мәгънәсенә җибәргәндә, ул сүз кергән томның басылып чыккан булу шарты куелды. Бу шартка туры килмәгән очракларда, сүзләр алда күрсәтелгән тәртиптә (нигездә синонимын күрсәтү юлы белән) ачыкланды.

**КАЕРЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **каеру**. *Урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган.* Ә.Еники ...

5) *к.* **каеру** (*5 мәгъ.*). *[Бригадир] Шофёрга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н.Фәттах

§ 23. Сүзнең мәгънәсен тулырак ачыклау өчен, кайбер аңлатмаларда кулланылган өстәмә чаралар:

1. Әгәр сүзнең мәгънәсе тасвирлау юлы белән генә ачылып бетмәсә, аңлатмага өстәп, шул сүзнең синонимнары да китерелде.

**КАЗЫЙ** *и. гар. тар.* Шәригать законнарына нигезләнеп хөкем итүче рухани; хәким, судья. *[Хуҗа:] Өч сум өчен, минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы*? Н.Исәнбәт ...

2. Аерым очракларда бирелгән сүзнең аңлатмасы аның капма-каршы мәгънәдәге сүзләре (антонимнары) белән дә тулыландырылды.

**ҖИҢЕЛЛЕК** *и.* 1) Авырлыгы аз булу; *киресе:* **авырлык**. *Җисми кагылу түгел, Мамык җиңеллеге белән Ачылып китте күгем*. Б.Рәхимова ...

2) Уңайлы, җиңел булу: *киресе:* **авырлык, кыенлык**. *Һәр авырлыкның бер җиңеллеге бар.* Мәкаль ...

3. Сирәк очракларда, бигрәк тә вариантлары күп булган, төрле сүзлекләрдә төрлечә бирелгән атамаларның русчага тәрҗемәләре дә китерелде.

**БАКА́ ТӘҢКӘСЕ** *и. бот.* Нәрсенчәләр семьялыгыннан, вак яфраклы йөзмә су үсемлеге; нәрсен; *русчасы:* **ряска**

4. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (антонимнар) һәм тәрҗемәләр аңлатма ахырында нокталы өтер белән аерып бирелделәр.

**БАЙЛЫК** *и.* ...

2) Җитешлек, муллык, иркенчелек; *киресе*: **ярлылык, мохтаҗлык**

§ 24. Сүзнең телдә сирәгрәк кулланылган мәгънәләренә сылтамалар биргәндә, ул мәгънә җәя эчендә күрсәтелде.

**ВАФАСЫЗ** *с.* **1.** *иск. кит.* Тугрылыксыз, хыянәтчел, былагай (*1 мәгъ.*) ...

§ 25. Сүзләрнең индивидуаль, метафорик, шигъри мәгънәләренә, шулай ук чагыштыруларда очрый торган мәгънәләренә аңлатмалар бирелмәде. Сүзләрдәге мондый мәгънәләр, аерым очракларда, мисалларда гына күрсәтелеп китте.

## IV. Иллюстратив материалны бирү тәртибе

§ 26. Сүзләрнең мәгънәләренә аңлатмалар биргәннән соң, аерым очракларны исәпкә алмаганда, иллюстратив материал белән ныгытып барылды.

§ 27. Иллюстрация өчен китерелгән мисаллар, күбесенчә, татар телендә басылган матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицистик, фәнни-популяр, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән һәм вакытлы матбугаттан алынды.

§ 28. Мисалга китерелгән җөмләләр артык озын булган очракта, мәгънәгә зыян китермичә, кыскартулар ясалды. Сүзләр төшеп калган урыннар өч сызыкча (---) белән күрсәтелде:

**ӘБИ́-БАБА(Й)** *җый. и.* 1) ... 2) ...

3) Борынгылар, өлкән буын кешеләре. *Бу китапны укып, мәктәп балалары --- хәтта ике-өч буын әби-бабалары да белмәгән, ишетмәгән вакыйгалар --- дәрьясына чумачаклар.* Р.Әмирхан

§ 29. Китерелгән мисаллардагы алмашлык алыштырган сүз, эш-хәрәкәтнең кем тарафыннан башкарылуы, репликаның кемгә төбәлгән булуы яки кем тарафыннан әйтелүе яисә алдагы җөмләләрдән аңлашылган әйтелми калган сүз квадрат җәяләр эчендә искәрмәләр рәвешендә биреп барылды:

**БӘЙЛӘВЕЧ** *и.* 1) Бербөтеннең очларын, ян-якларын (мәс., изүне, балак очларын һ.б.) тоташтыру, бәйләү өчен кара-каршы тагылган бауларның берсе. *Ул [лейтенант], сөйләшү тәмам, дигән шикелле, папкаларын ябып, бәйләвечләрен бәйли башлады.* Х.Камалов ...

**БИКЛЕ** *с.* 1) Йозак белән бикләнгән; нәрсә белән дә булса кирә алмаслык итеп ябылган, йозакланган. *Капка бикле иде, [Камали] авыр гәүдәсе белән ятып, күпме этәрсә дә ачылмады.* К.Нәҗми ...

**ӘЙТЕШҮ** *ф.* 1) ...

2) Гаепләшү, тиргәшү, ачуланышу. *Ачуланышмыйлар, әйтешмиләр дә, шул ук вакытта ачылып сөйләшмиләр дә иде [каенана белән килен].* М.Маликова ...

§ 30. Һәр җөмлә янында чыганакның авторы күрсәтелде.

§ 31. Аерым очракларда, мисал итеп, сүз тезмәләре яки кыска җөмләләр дә китерелде:

**АБАЙСЫЗ** *рәв. сөйл.* Саксызлык, гамьсезлек күрсәтеп, хафасыз; таркау. *Абайсыз бәреп төшерү*

**БУР** I *и. сөйл.* Ак төстәге йомшак известь. *Балалар бур белән асфальтка рәсем ясый*

### V. Алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү тәртибе

§ 32. Тел хәзинәсендә чит (рус, гарәп, фарсы, фин-угор һ.б.) телләрдән турыдан-туры күчкән алынма сүзләр бар. Алар татар халкының күп гасырлар буена бу халыклар белән якыннан аралашып яшәве нәтиҗәсе булып тора. Борынгы алынмалар, фонетик һәм морфологик үзләшеп, татар теле грамматикасына тулысынча буйсынганнар, аның үз сүзләренә якынайганнар. Хәзерге тел хәлендә бу алынма сүзләрне аерып алу гади кулланучыга мөмкин дә булмас иде.

§ 33. Татар телендә шулай ук европа телләреннән алынган сүзләр дә бар. Алар, нигездә, хәзерге чорда рус теле аша күчкән сүзләр. Сүзлектә мондый сүзләрнең беренчел чыганагы – европа телләре күрсәтелде.

Сүзлек массакүләм белешмәлек булганлыктан, сүз турында мәгълүмат алу өчен, барлык алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү кирәк дип табылды.

### VI. Сүз төркемнәренең бирелеше

§ 34. Сүзлек берәмлеге буларак барлык төр сүз төркемнәре дә алынды. Баш сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы грамматик билгеләр белән күрсәтелде: *и.* (исем), *ф.* (фигыль), *с.* (сыйфат), *а.* (алмашлык), *сан* (сан), *рәв.* (рәвеш), *бәйл.* (бәйлек), *терк.* (теркәгеч), *кис.* (кисәкчә), *ы.* (ымлык), *иярт.* (ияртем), *хәб. сүз* (хәбәрлек сүз), *мод. сүз* (модаль сүз).

§ 35. Исемнәр сүзлектә берлек санда, баш килештә китерелде һәм *и.* грамматик билгесе белән аерымланды.

§ 36. Җыйма мәгънәдәге парлы исемнәр сүзлек берәмлеге буларак китерелде һәм *җый. и.* грамматик билгесе белән аерымланды:

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ** *җый. и.* 1) Аласы һәм бирәсе әйбер(ләр); алачак һәм бирәчәк нәрсә(ләр) ...

2) Сәүдә, сату-алу эше, кәсебе ...

**ӘЙБЕ́Р-КАРА** *җый. и.* Төрле кирәк-яраклар ...

§ 37. Ялгызлык исемнәренең, күмәклек мәгънәсе алып, киң кулланышка кереп киткәннәре сүзлектә китерелде (**А́МПЕР, ӘБҮҖӘҺЕЛ, ГАЗРАИЛ, ГАЙДАМАК, ГАЙДУК, ДӘҖҖАЛ, ИБЛИС, МА́УЗЕР, ОМ** һ.б.)

§ 38. Урта мәктәп дәреслекләрендә һәм матбугатта еш очрый торган төрле ил халыкларының һәм милләтләренең исемнәре чикләнгән күләмдә китерелде (**АБХАЗ, АВАР, АВСТРАЛИЯЛЕ, АВСТРИЯЛЕ, АЗӘРБАЙҖАН, АЛБАН, ӘРМӘН, ӘФГАН, БАЛКАР, БАШКОРТ, БОЛГАР** һ.б.).

§ 39. Исемләшкән исем һәм сыйфат фигыльләр (**АВЫРУ, АСРАУ, БЕЛДЕРҮ, ЧӘЧҮ, САТУ, ӘЙДӘҮЧЕ, БИЮЧЕ, ОЕШТЫРУЧЫ, УКУЧЫ** һ.б.), сыйфатлашкан сыйфат фигыль (**ЕЛЛАГАН, ЯРАТКАН** һ.б.), рәвешләшкән хәл фигыльләр (**БАГАНАЛАП, БАЛЛАП, БАТМАНЛАП, ЕЛЛАП, ИПЛӘП** һ.б.) аерым сүзлек мәкаләсе итеп алынды.

§ 40. Алмашлыклар *а.* грамматик билгесе белән аерымланды. Сүзлек мәкаләсендә зат алмашлыкларының һәм *ул, бу, шул* алмашлыкларының кыек килеш формалары да бирелде. Ул баш сүз артыннан гади җәя эчендә күрсәтелде. Сүзнең нигезе үзгәргән очраклар аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде:

**МИН** (**минем, миңа, мине, миннән, миндә**) *а.* Сөйләүченең үзен атап күрсәтү өчен кулланыла торган беренче зат алмашлыгы

**УЛ** II (**аның, аңа, аны, аннан, анда**) *а.* 1) Өченче затны яисә гомумән предметны белдерә …

2) Исемнәрне ачыклаган сүзне алмаштырып килә торган күрсәтү алмашлыгы; андый, мондый, шундый …

**АҢА** *а. Ул* алмашлыгының юнәлеш килеш формасы

§ 41. Фигыльне сүзлектә бирү формасы итеп, төп юнәлештәге (*-у/-ү*) исем фигыль формасы алынды һәм *ф.* грамматик билгесе белән аерымланды: **АЛУ, ӘЙТҮ, ДИМЛӘҮ, ЗЫҢЛАУ, КҮЗӘТҮ, КАЙТУ, КӨЛҮ** һ.б.

§ 42. Грамматик мәгънә белдерә торган фигыльләрнең саф юнәлеш формалары телнең грамматик төзелешенә карый, шунлыктан алар сүзлектә теркәлмәде.

§ 43. Лексик мәгънәгә ия булган фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә бирелде. Аларның беренче грамматик мәгънәсе төп формага җибәрү юлы белән күрсәтелде, ә лексик мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатмалар китерелде:

**АШАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ашау** (*1 мәгъ.*). *Хәзрәтләр – шактый күп алган туй сәдакасыннан, авыл кешеләре – тәмле иттереп ашалган ашлардан, кода-кодагыйлар – яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлеснең муллаларча затлы үтүеннән разый калдылар.* Г.Исхакый

2) Кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү (йөз-кыяфәт, кием-салым һ.б.ш. турында). *Җил-яңгыр белән калай түбәләренең буяулары ашалган, үзе*

*җиргә сеңәргә әзерләнгән күн заводының корпуслары янын-нан, култыкланып, Миләүшә елгасы ага.* А.Алиш

3) Кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. *Ботинканың ашал-ган үкчәләрен дә төзәткән иде ул.* А.Шамов

§ 44. Дәрәҗә белдерә торган тезмә фигыльләрнең телдә киң кулланылганнары, төп сүзгә аңлатма бирелгәч, фразео-логизмнарны күрсәтеп бетергәннән соң, беренче сүз прин-цибы белән шул фигыль янында ояда алфавит тәртибендә теркәлде:

**БӘЙЛӘ́Ү** I *ф.* 1) ...

2) ...

◊ **Бәйләп тоту** Ирексезләү, көчләү

**Бәйләп алу** Тиз генә бәйләү; бәйләгән булу

**Бәйләп ату** Аннан-моннан, ничек кирәк шулай бәйләү

**Бәйләп бару** Эзлекле рәвештә бәйләү; бер-бер артлы бәйләү

**Бәйләп бетерү** Тулысынча бәйләү; бәйләү эшен төгәлләү

**Бәйләп кую** 1) Алдан бәйләп әзер итү

2) Бәйләнгән хәлдә калдыру, бәйләнгән хәлдә тоту

**Бәйләп ташлау** Тиз-тиз генә бәйләү

**Бәйләп тору** 1) Булган берсен, һәрберсен бәйләү

2) Сөйләү моментында, әле бәйләү белән мәшгуль булу

3) Һәрвакыт, гел бәйле итү

**Бәйләп чыгу** Һәммәсен бер-бер артлы бәйләү; һәрберсен бәйләү

**Бәйли бару** Һәммәсен тоташтан яки эзлекле рәвештә бер-бер артлы бәйләү

**Бәйли башлау** Бәйләргә тотыну

**Бәйли төшү** Тагын да кысыбрак, тыгызрак бәйләү

§ 45. Сүзлектә тезмә фигыльләр ясый торган түбәндәге модификацияләүче фигыльләр (дәрәҗә фигыльләре) куллан-ылды: **алу, ату, бару, башлау, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, җиткерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, ташлау, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту**

§ 46. Сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары, грам-матик категория буларак, сүзлектә аерым китерелми. Әмма кайбер вакытта алар төп фигыльдән үзгә сыйфат һәм рәвеш мәгънәләрен дә белдерергә мөмкин. Бу очракта төп сүзнең барлык мәгънәләренә дә аңлатма биргәч, нокталы ярымка-лын гарәп цифрыннан соң, алар аерым күрсәтелеп теркәлде һәм лексик мәгънәләре аңлатылды:

**ВАКЛА́У** *ф.* **1.** 1) Вак-вак, кечкенә кисәкләргә, өлешләргә бүлгәләү, вату, тураклау, аеру; вак итү. *Койма буендагы так-таларны, кисеп, утынга вакларга кирәк.* М.Мәһдиев

2) Эре акчаны шул ук суммадагы вак акчага алмашты-ру. *[Тәзкирә:] Соңгы егерме бишлекне вакларгамы?* А.Гый-ләҗев...

**2**. **ваклап** *рәв. мәгъ.* 1) Аз-азлап, өлешләп, бүлгәләп. *Фәния кисәк-кисәк ваклап сөйләшә торган теле белән зар-ланып та алырга өлгерде.* Ф.Яхин

2) Данәләп, берәмләп, берәрләп; килолап, граммлап. *Кү-гендә-түшәгендә чалкан яткан, ваклап сатучыларның кы-ланышына өйрәнгән айның да исе китми.* Т.Галиуллин

3) Нечкәлекләренә төшенеп, җентекләп, төпченеп. *Кыз-дырып барган кояш нуры астында, ваклап, тармаклап, җинаятьнең урынын сыйфатлап язды.* Г.Ибраһимов

§ 47. Татар телендә кайбер мөстәкыйль фигыльләр яр-дәмче фигыль функциясендә йөри. Сүзлектә бу күренеш күрсәтелде:

**КИТҮ** *ф.* **1.** 1) ... ; 2) ... .

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Юнәлеш килешендәге кайбер исем, сыйфат, рәвешләр белән килеп, шулардан аңлашылган то-рыш, билге һәм рәвешкә күчүне белдерә. *Эшләр уңайга китте. Талашуга киткәч булмый инде ул*

2) Эш-хәлнең кинәт булуын белдерә. *Балкып китте*

3) Эшнең башка бер эш уңаенда кыска гына аралыкта булуын белдерә. *Таныштырып китү. Искә төшереп китү*

4) Эшнең башлануын һәм дәвам итүен белдерә. *Сөйләп китте. Санап китү*

## VII. Сүзнең басымын күрсәтү тәртибе

§ 48. Татар телендә басым, күбесенчә, сүзнең ахыргы иҗегенә төшә. Баш сүз булып килгән мондый очракларга (шул исәптән алынма сүзләргә дә) басым куелмады. Басым башка иҗекләргә төшкән очракларда гына сүзнең басымы күрсәтелде.

**БАТЫРЛА́РЧА** *рәв.* ...

**Ю́ГЫЙСӘ** *тер.*

**ГИГИЕ́НА** *и.* ...

Бу кагыйдә омографларга да карый, әмма басымның кай-да булуына карамастан, чагыштыру һәм дөрес уку өчен, ба-сым икесенә дә куелды.

**А́РКА** *и. лат.* 1) *махс.* Ишек, тәрәзә, мич кебек нәрсә-ләрнең көймәләп эшләнгән түбәсе (түшәме)

**АРКА́** *и.* **1.** 1) Кеше гәүдәсендә муеннан алып оча сөягенә кадәрге арткы як ...

§ 49. Татар телендә *-а / -ә* сузыкларыннан соң килгән *-у / -ү* авазлары сөйләмдә, кыскарып, ирен-ирен *в [w]* сонанты булып әйтелә, ә төзелмә үзе *[aw] / [әw]* тибындагы ялган дифтонг булып ишетелә, шул сәбәптән, басым *-а / -ә* сузык-ларына төшә. Бу очрак сүзлектә күрсәтелде.

**АБА́У** *ы.* ...

**АҢКА́У** II *и. анат.* ...

**БИКЛӘ́Ү** I *ф.* ...

**ВАКЛА́У** *ф.* ...

**ДӘ́Ү** *с. фар.* ...

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*а.* – алмашлык
*авиа.* – авиация
*агроэкол.* – агроэкология
*анат.* – анатомия
*артык.* – артыклык (дәрәҗәсе)
*археол.* – археология
*архит.* – архитектура
*астр.* – астрономия
*а. х.* – авыл хуҗалыгы
*әд.* – әдәбият термины
*әрл.* – әрләү
*баш. кил.* – баш килеш
*бәйл.* – бәйлек
*бәйл. сүз* – бәйлек сүз
*берл.* – берлек сан
*биол.* – биология
*биохим.* – биохимия
*б-сез.* – билгесезлек
*бор.* – борынгы (сүз)
*бот.* – ботаника
*бүл. саны* – бүлем саны
*вет.* – ветеринария
*гади с.* – гади сөйләм
*геогр.* – география
*геол.* – геология
*геом* – геометрия
*грам.* – грамматика
*дәр.* – дәрәҗә
*диал.* – диалекталь сүз
*дини* – дини сүз
*диңгез.* – диңгезчелек термины
*жарг.* – жаргон
*җый. и.* – җыйма исем
*җыр* – халык җыры
*җыю саны* – җыю саны
*зоол.* – зоология
*з.-сыз* – затланышсыз (фигыль)
*и.* – исем
*икът.* – икътисад
*информ.* – информатика
*ирк.* – иркәләү сүзе
*ирон.* – ироник мәгънәдә
*иск.* – искергән сүз
*иял. кил.* – иялек килеше
*иярт.* – ияртем
*иҗт.* – иҗтимагый
*йөкл. юн.* – йөкләтү юнәлеше
*к.* – кара
*кбт. форм.* – кабатлаулы формада
*кайт. юн.* – кайтым юнәлеше
*карг.* – каргау (каргыш) сүзе
*кер. сүз* – кереш сүз
*кеч.* – кечерәйтү
*килеш* – килеш (формасында)
*ким.* – кимлек дәрәҗәсе
*кимс.* – кимсетеп әйтү
*кино* – кинематография
*кис.* – кисәкчә
*кит.* – китап теле
*комп.* – компьютер
*көч.* – көчәйтү
*кулин.* – кулинария термины
*күпл.* – күплек санда
*күрс.* – күрсәтү
*күч.* – күчерелмә мәгънәдә
*лингв.* – лингвистика
*лог.* – логика
*мат.* – математика
*махс.* – махсус термин
*мәгъ.* – мәгънәдә, мәгънәсендә
*мед.* – медицина
*метеор.* – метеорология
*микробиол.* – микробиология
*минер.* – минералогия
*миф.* – мифология
*мод. сүз* – модаль сүз
*мод.ф.* – модаль фигыль
*мөн.* – мөнәсәбәтлек (сүз)
*муз.* – музыка
*мыск.* – мыскыллау сүзе
*неол.* – неологизм
*нәфр.* – нәфрәтләнү
*пед.* – педагогика
*психол.* – психология
*радио* – радиотехника
*рәв.* – рәвеш
*рәсм.* – рәсми
*ритор.* – риторик
*с.* – сыйфат
*сан* – сан

*сәнг.* – сәнгать
*сәяси* – сәяси термин
*сир.* – сирәк кулланышта
*сөйл.* – сөйләм телендә
*спорт* – физкультура һәм спорт
*сын.* – сынлы (сәнгать)
*тар.* – тарихи
*тарт. форм.* – тартымлы формада
*тасв.* – тасвири сәнгать
*тәрт. саны* – тәртип саны
*театр* – театр сәнгатенә караган сүз
*терк.* – теркәгеч
*тех.* – техника термины
*типогр.* – типография термины
*тирг.* – тиргәү сүзе
*төзел.* – төзелеш термины
*төш. кил.* – төшем килеше
*төш. юн.* – төшем (юнәлеше)
*туп.* – тупас сүз
*урт. юн.* – уртаклык (юнәлеше)
*у.-вак. кил.* – урын-вакыт килеше
*ф.* – фигыль
*фарм.* – фармацевтика
*физ.* – физика
*физиол.* – физиология
*филос.* – философия
*финанс.* – финанслар
*фольк.* – фольклор
*форм.* – формасында
*фото.* – фотография
*функ.* – функция
*хим.* – химия
*хуплм.* – хупламау
*хупл.* – хуплау
*хурл.* – хурлау
*хәб. функ.* – хәбәр функциясендә
*хәб. сүз* – хәбәрлек сүз
*хәрби* – хәрби сүз
*чаг.* – чагыштыру
*чыг. кил.* – чыгыш килеше
*шаярт.* – шаярту сүзе
*шелт.* – шелтәләү сүзе
*шигъ.* – шигъри сөйләмдә
*шөб.* – шөбһәләнү
*ы.* – ымлык
*эвф.* – эвфемизм
*энд.* – эндәш сүз
*электро.* – электротехника
*эпис.* – эпистоляр стиль
*этн.* – этнография
*юг.* – югары стиль
*юкл.* – юклык
*юн.* – юнәлеш
*юн. кил.* – юнәлеш килеше
*юр.* – юридик термин
*ярд.* – ярдәмче (фигыль яки сүз)

**Чыганак телләрнең кыскартылмалары**

*алб.* – албан теле
*амхар* – амхар теле
*әрм.* – әрмән теле
*баконго* – баконго теле
*бурят* – бурят теле
*венг.* – венгр теле
*гар.* – гарәп теле
*голл.* – голланд теле
*гр.* – грек теле
*груз.* – грузин теле
*ингл.* – инглиз теле
*исланд* – исланд теле
*исп.* – испан теле
*ит.* – итальян теле
*кельт* – кельт теле
*кечуа* – кечуа индеецлары теле
*коми* – коми теле
*кыт.* – кытай теле
*лат.* – латин теле
*литв.* – литва теле
*малая* – малая теле
*мар.* – мари теле
*монг.* – монгол теле
*мордв.* – мордва теле
*нем.* – немец теле
*пол.* – поляк теле
*португ.* – португал теле
*румын* – румын теле
*рус* – рус теле
*саам* – саам теле
*санскр.* – санскрит теле
*сканд.*– скандинав телләре
*слав.* – славян телләре
*тамил* – тамил теле
*тат.* – татар теле
*төрек* – төрек теле
*төрки* – борынгы төрки сүз
*тунг.* – тунгус теле
*тупи* – тупи теле
*удм.* – удмурт теле
*уйг.* – уйгур теле
*укр.* – украин теле
*үзб.* – үзбәк теле
*фар.* – фарсы теле
*фин* – фин теле
*фин-угор* – фин-угор телләре
*фр.* – француз теле
*һинд.* – һинди теле
*чех.* – чех теле
*эст.* – эстон теле
*як.*– якут теле
*яп.* – япон теле
*яһүд* – яһүд теле

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Аа** | **Дд** | **Зз** | **Мм** | **Пп** | **Үү** | **Чч** | **ь** |
| **Әә** | **Ее** | **Ии** | **Нн** | **Рр** | **Фф** | **Шш** | **Ээ** |
| **Бб** | **Ёё** | **Йй** | **ң** | **Сс** | **Хх** | **Щщ** | **Юю** |
| **Вв** | **Жж** | **Кк** | **Оо** | **Тт** | **Һһ** | **ъ** | **Яя** |
| **Гг** | **Җҗ** | **Лл** | **Өө** | **Уу** | **Цц** | **Ыы** | |

# А

**А** I Алфавиттагы беренче хәрефнең – «А» хәрефенең исеме. *А хәрефе рәвешендә мәйданга керү капкасы да ясасагыз, иллә шәп буласы ---.* Мәдәни җомга

**А** II, **А-А-А** *ы.* 1) Кем белән дә булса очрашкач, таныганлыкны, нәрсәне дә булса искә төшерүне белдерә. *А! Габдулла агай! Әйдә, түргә уз.* Һ.Такташ

2) Кем яки нәрсәне дә булса күргәч туган шатлануны, канәгатьлекне белдерә. *А, ишетсәгез лә, китерегез, китерегез миңа чәчәкләр!..* Ф.Әмирхан. *– А, нинди яхшы биредә! – диде Шәмси, эскәмиягә утырып.* Г.Шәрипова

3) Кинәт килеп туган хәлгә гаҗәпләнүне белдерә. *Җәлал тәрәзәгә карады да, сискәнеп киткән адәм сыман: – А..., яктырып беткән икән... Соңга калмасак ярар иде. Тизрәк булырга кирәк, – дип урыныннан торды.* Г.Ибраһимов. *А! Сез ничек болай тиз килеп җиттегез!* Казан утлары

4) Ризасызлык, канәгатьсезлек, килешмәгәнлекне яки нәфрәтләнүне белдерә. *– Син нәрсә, үз-үзеңне яклый алмыйсыңмыни? А, юкны сөйләмә! – Искәндәр йөзен чытты.* Г.Шәрипова. *– А-а! Агулы елан! Дөньядан юк итмәкчеме мине? Бозарга уйладыңмы? – дип, бөтен йортка акырды Ишми һәм, табылдыкны селки-селки, эчке күлмәкыштаннан гына кухняга йөгереп керде.* Г.Шәрипова

**А** III, **А-А-А** *иярт.* Физик яки мораль газаптан ыңгырашканда, елаганда чыккан тавышны белдерә. *– А-а-а! – дип кычкыра-кычкыра арып беттем.* Н.Дәүли. *Тешем сызлый – һич түзәр чама юк. А-а-а, зинһар ярдәм ит, Гафур.* Г.Шәрипов

**АБА** *ы. к.* **абау**

**АБАГА** *и. бот.* 1) Аспленийчәләр семьялыгыннан, юан, кыска тамырчалы, яфраклары каурыйсыман телгәләнгән, төньяк ярымшарның уртача зонасы урманнарында үсә, чәчәк атмыйча, споралар ярдәмендә үрчи торган югары төзелешле үсемлек, *русчасы:* **папоротник**. *Абаганың чәчәген тел астына алсаң, имеш, күренмәс кешегә әйләнәсең, ди.* Әкият. *Ахырдан, берничә еллар узгач, мин «уфалла» арбасы белән бу урманнан утын ташыдым. Абагалар беткән, мәче башлы ябалаклар да күренми иде.* М.Мәһдиев. *Безнең урманнардагы абагалар – күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Алар дымлы, күләгә урында, еш кына урман ялмасы астында һәм дымлы ерымнарда үсәләр.* Биология

2) *күч.* Кышын бозланган тәрәзәләрдә була торган, шул үсемлек яфрагына охшаш бизәк. *Тышта, салкын тәрәзәләрдә – беренче абагаларның сихерле яфраклары.* А.Гыйләҗев

◊ **Абага чәчәк аткач** Бервакытта да, беркайчан да булмаячак эш турында

**АБАГАЛЫ** *с.* Абагалар күп үскән, абагалар булган. *Абагалы урманнарның Бормалы сукмаклары, Каерылып карап калган Каеннар, усаклары...* Ф.Чанышева. *Мәгърур Чатыр тау, абагалы каен урманнары, гүзәл Ык, сез кайчандыр Екатерина II нең безнең төбәкләрдән үтүен күреп калгансыз.* М.Галиев

**АБАГАЛЫК** *и.* Абагалар күп үскән урын. *Озак бара торгач, малайлар куе абагалыкка очрадылар.* Казан утлары

**АБАГА́СЫМАН** *с.* Абагага охшаган, абага төсле. *Абагасыман үсемлекләр, ягъни абага, плаун һәм нарат-башлар, мүкләр кебек үк, псилофитлардан – борынгы үлеп беткән җир өсте үсемлекләреннән килеп чыкканнар.* Ботаника

**АБАГА́СЫМАННАР** *и. бот.* Күбесенчә җир өстендә үсә торган, югары төзелешле споралы үлән һәм агач үсемлек төренең атамасы; *русчасы:* **папоротниковидные**, **папоротникообра́зные**. *Борынгы абагасыманнар сулыкларның ярлары буенда гына үсү белән чикләнмәгәннәр, бәлки агачсыман гигант үсемлекләрдән торган искиткеч зур урманнар тәшкил иткәннәр. Моннан 300 млн. ел элек коры җирдә абагасыманнар хакимлек иткән.* Биология

**АБАЖУР** *и. фр.* Яктылык күзне чагылдырмасын һәм тиешле урынга гына тупланып төшсен өчен, лампага куела торган җайланма. *Түшәмнең кыл уртасында --- абажуры тутыккан егермеле керосин лампасы асылынып тора иде.* Ф.Хөсни. *Лампаның яшел абажуры, бүлмәне моңлы караңгылык эчендә калдырып, өстәлнең бер почмагына гына якты чәчә.* Гали Рәхим

**АБАЖУРЛЫ** *с.* Абажуры булган, абажур куелган. *– Без, кышкы салкын кичләрдә, – дип сөйләгән иде ул, – бөтен гаиләбез белән җылы залдагы зур түгәрәк өстәл тирәсенә җыелып, яшел абажурлы асылмалы лампа яктысында һәркайсыбыз нәрсә дә булса укып утыра идек.* Ә.Еники. *Өстәлдә зәңгәр абажурлы лампа яна.* Р.Ишморат. *--- уртада – язу өстәле, аның өстендә – абажурлы лампа.* Җ.Фәйзи

**АБАЙ** *с.* **1.** Сак, сизгер, уяу. *Абай кеше*

**2.** *ы. мәгъ. сөйл.* Нинди дә булса эшне тыйганда, сак, сизгер, уяу булырга өндәп, истә тотуны таләп итеп әйтелә; акрын. *Абай, артыңда машина кузгалырга тора*

**АБАЙ БУЛУ** *ф.* 1) Сак, сизгер, уяу булу. *Язмыш аргамагы хәтәр – Бәхетеңне оттырма. «Абай бул да, уяу бул» ---.* А.Юнысова

2) Истә тоту. *Бадамшин малаена ни әйтте Шәмсетдин абый! Абай бул, ул якка каерыла күрмә, диде.* А.Гыйләҗев

**АБАЙЛА́МАГАНДА** *рәв.* Сизмәгәндә, көтмәгәндә, уйламастан. *Шәриф, азык-төлек алып китеп баручы немец*

*солдаты абайламаганда, арттан килеп, ат арбасына утыра һәм, бер капчыкны ярып, алдан әзерләнгән оекка ярма тутыра башлый.* Кызыл таң

**АБАЙЛА́МАСТАН** *рәв. к.* **абайламыйча**. *Үзе дә абайламастан, егеткә каршы талпынырга да өлгергән иде булса кирәк... [Альбиноза].* Р.Мөхәммәдиев. *[Зифаның] Тәне яна, йөрәге кага, ләкин аңа ничек булса да үзен якларга, бер абайламастан килеп юлыккан пәри өермәсеннән котылырга кирәк иде.* Д.Булатова

**АБАЙЛА́МЫЙЧА** *рәв.* Сизмәстән, искәрмичә. *Ә ул кызларның берсе, ап-ак йөзле, зәп-зәңгәр күзле, картлар әйтмешли, тал чыбыгыдай зифа буйлы Мәскәү кызы Наилә, Фәләхне шундый итеп, бөтереп, үз орбитасына алып кереп китте, Фәләх ни булганын үзе дә абайламыйча калды.* В.Нуруллин. *Берсендә Әлимхан этне җиргә яткырганда, абайламыйча, икмәкле кулы белән Дүрткүз муенына үрелгән генә иде, маэмай кымәч кисәгеннән «һап» эләктерде дә йотып та җибәрде.* Р.Батулла

**АБАЙЛА́У** *ф.* **1.** 1) Эш-хәлне сизеп алу, сизенү, чамалау, алдан күреп тору. *Үзенчә нидер чамалый, нидер абайлый, үзенчә нидер төшенгәндәй була.* Г.Бәширов. *Ул чакта Җәгъфәр эченнән шактый шүрләгән иде, тик Гәүһәр генә моны абайламады.* Г.Әпсәләмов. *[Бакый Урманче] Һәммә ниятен гамәлгә ашырып бетерә алмасын абайлады бугай инде...* К.Миңлебаев

2) Чамалау, искәрү, белү. --- *машина йөртүчегә ашыгу һич ярамый, абайламый йөрсәң, кеше дә таптатырсың...* Г.Әпсәләмов. *Тегендә дә, монда да күзләренә ак-кара күренмәслек хәлгә җиткән дөяләр, атлар, сыерлар чабыша – абайлап өлгермәсәң, таптап, яньчеп китәрләр ---.* Б.Рафиков. *Хәзер ул [Идел] үзе киң диңгез булып җәелгән! Шуны абайламый торам икән...* С.Сабиров

3) Күрә алу, аера алу, шәйләү. *Күп тә үтмәс, башка капкалар өстендә дә күзәтчеләрнең үткен күзе яңа кәрваннарны күрер, Идел өстеннән Казан суына борылучы көймәләрне абайлар.* Ф.Латыйфи. *Баскычтан менүчене абайлагач, Рәсимә чатыр-чотыр сөйләгән җиреннән шып туктады.* С.Сөләйманова. *Вагоннан чыгу белән, тирәюньне тиз генә абайлап та булмады.* Ә.Еники

**2. абайлап** *рәв. мәгъ.* 1) Сак кына, уйлап, килеп чыгарга мөмкин нәтиҗәләрне истән чыгармыйча. *Абайламый сөйләгән – авырмый үлгән.* Мәкаль

2) Җайлап, ашыкмыйча, сакланып кына. *Аяк асты бик тайгак, абайлап атламасаң, егыласыңны күр дә тор*

**Абайлап алу** 1) Бик тиз, шунда ук абайлау. *Әмма ерак китәргә өлгермәде, агачлыктан кара киемле алман солдаты пәйда булуын абайлап алды да яшен тизлегендә җиргә тәгәрәде.* Т.Әйди. *Казан түрәләре, бигрәк тә Казан халкы, Шаһгалинең чын йөзен бик тиз абайлап алалар.* Ф.Урманче. *Ләкин тәҗрибәле остазның очлы күзләре бу чын алмазның әле байтак кыркабыргаларын шомартырга кирәклеген дә абайлап алды.* Р.Вәли

2) Нәрсәне дә булса якынча сизенү, искәрү. *Күл буена килеп туктадык. «Чишмә» колхозының мәшһүр балыкчылык хуҗалыгына килеп җиткәнлегебезне Мөхәммәт абый тиз абайлап алды.* Х.Низамов. *Аннары бу өйдә буйга җиткән кызның яшәвен дә абайлап алды ул.* Ә.Еники

**Абайлап бетерү** Барысын да, тулысынча абайлау. *Тавыш бирүче – юл буе бер сүз дә эндәшми барган тоткын иде булса кирәк, караңгыда абайлап бетереп булмады.* И.Сираҗи

**Абайлап йөрү** Һәрвакыт, гел, бар урында да абай булырга тырышу. *«Елан мөгезен күргән – бәхетле булыр» дигәнне ишетеп калдым яңарак, шуннан бирле, кая барсам да, аяк астымны абайлап йөрергә тырышам: мөгезен салып китмәгәнме берәр елан?* Г.Якупова

**Абайлап калу** Абайларга өлгерү, тоемлап калу. *Ул хатын-кыз нәрсә турындадыр бик нык уйлый иде булса кирәк, минем бүлмәгә керүемне абайламыйча калды.* Ф.Хөсни. *Морза малае арка белән килеп төшкәнен абайламый да калды.* Р.Мөхәммәдиев. *Тик абайламый калганбыз; йөз, йөз илле метрлар чамасы артта, шул машинаны саклап, тагын бер тимер машина килә икән.* Казан утлары

**Абайлый бару** Бер-бер артлы һәрберсен абайлау

**Абайлый башлау** Абайларга керешү, нидер сизенү, беленә башлау. --- *Рәйха Илдарга сәерлекләр хаслыгын абайлый башлады.* Рифә Рахман

**Абайлый төшү** Бераз абайлау

**АБАЙЛЫ** *рәв. сөйл.* Сак, сизгер, алдын-артын карап. *Һәр эштә абайлы булу кирәк*

**АБАЙЛЫЛЫК** *и. сөйл.* Саклык, сизгерлек, алдан күрүчәнлек. *Абайлылык күрсәтү*

**АБАЙСЫЗ** *рәв. сөйл.* Саксызлык, гамьсезлек күрсәтеп, хафасыз; таркау. *Абайсыз бәреп төшерү*

**АБАЙСЫЗЛЫК** *и. сөйл.* Саксызлык, гамьсезлек; таркаулык, игътибарсызлык. *Абайсызлык күрсәтү*

**АБА́КА** *и. лат. бот.* Банан ыругыннан булган, ныклы җепселләреннән текстиль җепләре җитештерү өчен тропикларда игелә торган күпьеллык үләнчел үсемлек; җепселле банан. *Абаканың туган җире булып Филиппин утраулары санала*

**АБАЛАНУ** *ф. диал. сир.* 1) Ашыгу, кабалану. *Ул, юлның күп өлешен абаланып кайтканга, арыган, мышкылдаган һәм нәрсәдәндер каушаган иде.* А.Шамов

2) Үрмәләп менү. *Печәнлеккә абаланып менеп китү*

3) Сөртенү. *Бераздан соң алар игеннәр арасыннан абаланып бара башладылар.* А.Шамов

**Абалана башлау** Абаланырга керешү

**Абалана төшү** Бераз абалану

**Абаланып алу** Кинәт, кыска вакыт абалану

**Абаланып кую** Бер тапкыр, азга гына абалану

**АБАЛА́У** *ф. диал.* **1.** Бер артка, бер алга төшеп, юл бирмичә өрү. *Курыкканны эт абалый.* Мәкаль

**2. абалап** *рәв. мәгъ.* Ярсып, өскә ташланырдай булып. *Басу капкасын чыкканда, Этләр калды абалап.* Җыр. *Василь чайкалды, әмма егылмады...*

*Этләр, абалап, аның өстенә ташланды.* И.Салахов

**Абалап алу** Кинәт абалау; һәр яклап абалау

**Абалап тору** Һәрвакыт, гел абалау

**Абалый башлау** Абаларга керешү

**АБА́У** *ы.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса күргәч туган шатлык, куану, соклану, гаҗәпләнү хисләрен белдерә. *Абау, җаныем, керфегең, Бирче миңа бөртеген.* Җыр. *Зөбәйдәнең сеңле уйнап йөри, Абау матур! Күзем тимәсен...* Һ.Такташ

2) Куркып калу, кот очу, шомлану, шөбһәләнү, аптырау, көтелмәгән хәлгә шаккату хисләрен белдерә. *Абау, атасы, сиңа бирәр нәрсә булдымы әллә?* Д.Аппакова. *«Абау!» – дип чырыйлап кычкырды алдан йөзүче, аягын тартып алды.* Г.Ахунов. *Рабиганың төсе ап-ак булган иде. – Абау, Ходаем! Мин инде, безне сукты, дип торам... – диде.* Гали Рәхим. *Миләүшә сәгатенә карап алды. – Абау, кинога кичегә язганбыз ич.* Г.Әпсәләмов. *– Абау!.. Без таңны аттыра язганбыз икән, – диде дә Гайния урыныннан кузгалды.* Г.Ибраһимов

3) Ачулану, тиргәү, шелтәләү, нәфрәтләнүне белдерә. *– Абау, норсыз, – дип мыгырданды карчык, – Син нәрсә, әллә кешегә җүнләп сүз ката белмисеңме?* М.Мәһдиев

◊ **«Абау» гына да димәс идем** Офтанып та тормас идем, үкенмәс идем. *Шулай гарип кенә булып калган булса, «абау» гына да димәс идем, балаларга ата булыр иде, дип офтанды.* Г.Гафурова

**АБАУЛА́У** *ф. сөйл.* Сөйләмендә «абау» сүзен еш кабатлап тору. *– Абау, тагын тотынды... – Син, кем, абауларга гына торма, башың булса, тегене, аңларга да тырыш, мин хөсетлектән түгел.* Мирас

**Абаулап кую** Бер тапкыр «абау» дип әйтү

**Абаулап тору** Бертуктаусыз абаулау

**Абаулый бирү** Абаулавын дәвам итү

**АББАТ** *и. лат. дини сир.* 1) Католикларда: ирләр монастыре башлыгы

2) Франциядә: югары дәрәҗәле католиклар рухание

**АББАТЛЫК** *и.* 1) Аббат вазифасы

2) Аббат биләмәсе

**АББРЕВИАТУ́РА** *и. ит.<лат. кит.* Ике яки берничә сүздән кыскартып ясалган сүз яки аларның баш хәрефләреннән торган кыскартылмасы. *БМО (Берләшкән Милләтләр Оешмасы); КФУ (Казан федераль университеты)*

**АБЕ(Л)ХӘЯТ** *и. гар.-фар.* 1) Терек суы, тереклек суы, мәңгелек суы. *Кем караңгылык эчендә табалыр абехәят?* С.Сараи. *Ник ләгыйн абелхәятне урлаган?* Ш.Бабич. *Таҗеддин Ялчыгол Искәндәр Руминың (Александр Македонскийның) Сократ хәким белән Болгарга килүе, аннан, «абехәят» (тереклек суы) эзләп, Төньякка походка китүе турында яза.* Х.Миңнегулов

2) *күч. сөйл.* Аракы. *Йә сихерле шешәдән абелхәят эчмәктәме?* Г.Тукай

**АБЗА** *и. диал. к.* **абзый**. *Әһли абзаң киштәсенә түтәрәм каз элделәр.* Бәет. *Шуннан аны зур базарлы авылда тире-яры белән кәсеп итеп торучы Шәяхмәт дигән абзасы (әнисенең агасы) «тәрбиягә» алган. Абзасының каты кулыннан ничек ычкынырга белмичә тыпырчынып яшәгән чагында, ул милиционер Идияткә тап булган.* Ә.Еники

**АБЗАР** *и.* 1) Каралтыда терлекләр ябар өчен бүрәнәдән мүкләп эшләнгән яисә таштан салынган җылы урын; хуҗалык корылмасы. *Хәзер кул астындагы барлык атларны карау, абзарларны чистарту --- кебек эшләр – барысы да Сабир бабай белән Газинур өстенә төшә.* Г.Әпсәләмов. *Ераккарак, аулаграк җиргә – абзарларга таба уздым да шундагы арт капкадан болынга, Түреш буена чыгып киттем.* Ә.Еники. *Ат абзарлары тирәсеннән барабыз. Яктырып килә. Ат абзарлары янында зур тирес өеме бар.* М.Мәһдиев

2) Кыш өчен саманнан эшләнгән җылы урын

3) *күч.* Җыештырылмаган, пычрак урын. *Сиңа монда кунаклар килә, ә синең өстәлеңдә – дуңгыз абзары.* М.Мәһдиев

◊ **Абзар керү** *диал.* Көзен терлекне көтүгә кумый башлау, терлекне йортта асрый башлау

**АБЗА́Р ИЯСЕ** *и. миф.* Гадәттә, кеше яисә хайван кыяфәтендә булырга мөмкин, ишегалдында яки абзарда яши, дип уйланылган зат. *Абзар иясе булгач, ул йорт хайваннарын, бигрәк тә атларны төрле афәттән яклаучы һәм саклаучы дип күзаллана.* Ф.Урманче

**АБЗА́Р-КУРА** *җый. и.* Йорт алдындагы ярдәмче корылмалар (өй һәм мунчадан башка). *Ихатаң җимерелсә дә, абзар-кураң тузса да, бармак юанлыгы тал коткарды.* Ф.Яруллин. *Җиргә тын гына караңгылык иңә, терлек-туар озын, ризыклы рәхәт төнгә әзерләнә, абзар-курада кәефсез җан иясе – тик ана каз гына.* М.Мәһдиев. *[Нурулла] Яшьтән үк абзар-кура, мал-туар арасында чуалырга яратты.* А.Гыйләҗев. *Аннары авыл кешеләренең абзар-куралары, мунча-келәтләре төтен булып күккә оча башлады.* Г.Гыйльманов

**АБЗАЦ** *и. нем.* 1) Текст башындагы яки аның аерым фикер белдергән өлешендәге беренче сүзне берничә хәрефкә уңгарак эчкә кертеп башланган урын; кызыл юл, яңа юл. *Иероглифларны кара төстәге кара белән язганнар, ә һәр яңа абзацны кызыл кара белән башлый торган булганнар (шуннан барлык халыкларга «кызыл юлдан язу» дигән термин кереп калган).* К.Гыйззәтов

2) Текстның бер яңа юлдан икенчесенә кадәрге өлеше. *Әсәрнең беренче абзацында автор табигать кануннары турында уйлана.* Н.Гафиятуллина. *Аларның биографияләрен бер-ике җөмләгә яки абзацка кыскарту хисабына, Фараби, Әбүгалисина кебек йөзләгән гомумтөрки бөекләрнең тормышын, иҗатын --- киңрәк яктыртырга мөмкин булыр иде.* Казан утлары

**АБЗЫЙ** *и.* 1) Үзеннән олырак яшьтәге ир туган; абый. *Габдулла аны бик аз гына, Мирхәйдәр абзыйның күңеле булсын дип кенә, авыз итте.* Ә.Фәйзи

2) Әти яки әнинең бертуган ир туганнары. *Икенче якын кардәшебез Ибраһим абзыйлар бездән ерак та тормыйлар иде.* Ә.Еники

3) Яше ягыннан сөйләүче кешедән олырак булуны белдереп, ир кеше исеменә кушып әйтелә торган сүз. *Аның үзен татарлар – Хәсәнша абзый,*

*руслар, Хасан Яруллович, дигән хәлдә, артында булса, татарлар «Сары Хәсәнша» дип кенә йөртәләр иде.* Ш.Камал. *Сәгъди абзый, башына төшкән бу хәлгә тәмам буйсынып, бер сүз дә әйтә алмады.* Ә.Фәйзи. *Бу абзыйның тәбәнәк, тулы гына хатыны (исеме онытылган) һәм Мәһинур исемле бик чибәр җиткән кызы да бар иде.* Ә.Еники. *Төнлә кайтканда исә авылдан, иң беренче булып, Сафый абзыйлар уты күренә.* М.Мәһдиев

**АБЗЫКАЙ** *и.* 1) *к.* **абзый** (*1, 2 мәгъ.*). *Нигъмәтулла абзыкайларның яшел чирәмле иркен ихатасына килеп керсәм, ишек төбенә тарттырып куйган җигүле ат тора.* Ә.Еники

2) Ир кешегә, әйдә, үзеңнең осталыгыңны күрсәтеп кара әле, мәгънәсендә кинаяләп әйтелә торган сүз. *Кемдер, бәлки, сынап карарга уйлагандыр, йомшак машинада күп тибрәлдең, хәзер, поди, укытучы булып йөреп күрсәт әле, абзыкай, дип тә фараз кылгандыр.* Т.Галиуллин

**АБИССАЛЬ** *и. гр.* **1.** Диңгез һәм океаннарның зур тирәнлекләр зонасы, 3000 – 6000 м тирәнлегендәге катламнары. *Абиссальнең хайваннар дөньясы бай түгел, алар суның өске катламнарыннан төшкән органик матдәләр исәбенә яшиләр.* География

**2.** *с. мәгъ.* Тирән сулы, иң зур тирәнлектәге. *Абиссаль тирәнлектәге катламнар. Океанның абиссаль запасы*

**АБИССИ́НИЯЛЕ** *и. тар.* Көнчыгыш Африкада яшәүче Эфиопия халкының элеккеге атамасы. *Абиссинияләр итальян гаскәрләрен Адуа шәһәрчеге янындагы сугышта туздырып ташлыйлар.* Яңа тарих

**АБИТУРИЕНТ** *и. лат.* Югары уку йортына керер өчен имтиханнар тапшыручы. *Иң элек аның өчен көн кебек ачык бер хакыйкать шуннан гыйбарәт ки: сугыштан соң ук укырга килгән яшьләр белән хәзерге абитуриентлар арасында искиткеч зур аерма бар.* Ә.Еники

**АБЛАТИВ** *и. лат. лингв.* Чыгыш килеше

**АБОНЕМЕНТ** *и. фр.* 1) Билгеле бер вакыт эчендә берәр нәрсәдән (мәс., телефоннан, китапханәдән, спорт залыннан) хак түләп файдалану хокукы; абунә. *Хәзер Татарстанның сәнгать коллективлары чыгышлары Мәскәү филармониясенең абонемент концертлары программасына да кертелә.* Б.Рәхимова

2) Шул хокукны раслый торган документ. *Китапханә абонементыннан файдалану. Бассейнга йөрү абонементы. Абонемент билеты*

3) Вакытлыча файдалану өчен китапны, яздырып, үзең белән алу урыны; китапханә. *Күрәсең, [Рәшит] үзенә кирәкле мөһим нәрсәне тапмады, торып, абонемент ягына чыгып китте.* Ф.Латыйпов

**АБОНЕНТ** *и. фр.* Абонемент иясе, абунәче. *Телефоннар челтәре абоненты. Лекцияләр циклына абонент алу. Абонентлар бүлеге*

**АБОРДАЖ** *и. фр. тар.* Ишкәкле яки җилкәнле флот чорында корабльләрнең бер-берсенә якын ук килеп һөҗүм итүләре. *Ят көч тәэсирен сизеп, «Җилкән» капыл янтайды һәм берәр чиләк су чумырып алды. – Абордаж! Абордаж! – дип кычкырдылар яланаяклы пиратлар.* А.Тимергалин

**АБОРИГЕН** *и. лат.* 1) Теге яки бу илнең төп халкы вәкиле, төбәкнең җирле кешесе. *Шул арада йорт тирәсенә яшьрәк ир-ат, бала-чага җыела. Робинзон Крузоны беренче күргән абориgennар кебек, якын килмиләр. Көтәләр.* Т.Галиуллин. *Безгә нәрсә, без – җирле абориgennар, без – чыныккан халык. Өстебездә дә калын.* А.Хәсәнов

2) *кит.* Аерым бер төбәкнең, илнең шул җирдә туып үскән организмнары: хайваннары, үсемлекләре

**АБОРТ** *и. лат. мед.* 1) Йөклелекнең үзеннән-үзе яки берәр сәбәп белән туктaлуы, бала төшү; хайваннарда: бала ташлау. *Алкоголизм булган гаиләләрдә 19 – 34 яшьтәге хатын-кызларда аборт – 1,5 мәртәбә, үле бала туу очрагы 2 мәртәбә ешрак күзәтелә.* Р.Гыйльметдинова

2) Ясалма юл белән йөклелекне туктату, бала төшерү. *Гинекология бүлегендә, күрмисеңмени, яшь кенә кызлар абортка чират көтә.* Ш.Янбаев

**АБОРТИВ** *с. мед.* 1) Җитлекмәгән, тулы үсеш алмаган. *Үсемлекләрнең абортив органнары*

2) Берәр процессның үсешен тиз туктата алырдай. *Абортив чаралар*

**АБРАЗИВ** *и. фр.* **1.** Каты матдәләрнең өстен (мәс., пыяланы, ташны, агачны, пластикларны һ.б.) шомарту, ялтырату өчен кулланыла торган авыр эрүчән каты материал. *Табигый абразив алмаз тузаныннан, кремнезёмнан, корундтан, кыр шпатларыннан, күбекташтан тора.* Төзү материаллары

**2.** *с. мәгъ.* Абразивтан ясалган, составында абразив булган; кыра, өслектә механик эз калдыра торган. *Корундтан утка чыдам һәм абразив материаллар җитештерелә.* Төзү материаллары

**АБРИКОС** *и.* 1) Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, озынча яки йөрәк формасындагы яфраклы, ак яки ал чәчәк ата торган, эчендә каты төше булган сусыл җимешле агач; өрек агачы. *Абрикос, башлыча, Азиянең урта поясында таулыкларда үсә.* Биология

2) Шул агачның эре, каты төшле, кызгылт сары төстәге сусыл җимеше. *Абрикос компоты. Абрикос желесы*

**АБРИКОТИН** *и. фр.* Өрек җимешеннән ясалган ликёр

**АБРУЙ** *и. фар.* 1) Җәмгыятьтә, халык алдында ышаныч, хөрмәт, зур ихтирам казанганлык; авторитет. *Соңыннан бу мәшһүр ханым [Нурсолтан] Казан вә Кырым ханнары нәсел җебен башлап җибәрүчеләрдән саналып, абруе үсә, исеме төрле дастаннарда җырланып, риваять-легендаларга кереп китә.* Ф.Урманче. *Мәхдүмнәрнең берсенә никахланып алсаң, --- дәүләт байлыгы да, шөһрәт абруе да табыла.* Т.Гыйззәт. *Бәяләрне куйганда, сыйфаттан бигрәк, теге яки бу малны эшләп чыгарган фирманың, илнең, хуҗаның абруе өстенлек ала.* Т.Галиуллин // Рейтинг. *Гәзитнең абруен һәм популярлыгын, еш кына очракларда, аңа язышкан мәшһүр шәхесләр, аларның заманга муафыйк язмалары билгели.* Р.Әмирхан. *Фирка исеменнән сыланган җәзаның абруе нинди югары иде ул заманда. Кол муенына сугылган тамга төсле, еракган күренеп, хәбәр салып тора.* Т.Галиуллин

2) Исем, дәрәҗә, кайсы ягы белән булса да танылганлык, атаклылык; намус, дан. *Хәтта ул үз баласының абруе өчен генә дә көенми, сугыштагы ирләрен онытып, азып-тузып йөрүче хатыннарның барысын да кұралмый, алар Хәдичә түтинең иң авыр дошманнары иде.* Г.Бәширов. *Нәфыйк Чумара шундый абруйга ия. Аңардан куркалар – ул усаллансамы! Ул тузынсамы!..* Ш.Галиев

3) Намус; гыйффәтлелек, сафлык. *Кыз баланың абруе кыл өстендә, кылдан төшсә – юл өстендә.* Мәкаль. *Егет, кызаруын яшерер өчен, йөзен читкә борды. Бу инде егетлек абруена сугу иде.* Г.Бәширов

4) Берәр төркем, коллектив эчендә дәрәҗәле, ихтирам казанган кеше. *Ньк абынгач ялган абруйларга, Таныйм хәзер алар битлеген.* А.Хәсәнов. *Көнчыгыштагы дини агымнар белән җәдитчелек арасындагы зур аерма менә шуннан гыйбарәт тә инде – абруй артыннан барумы, әллә инде, тәнкыйтьчел фикер йөртеп, аң-белемеңне күтәрүме?* Казан утлары

◊ **Абруен җую** *к.* **абруе югалу**. **Абруе югалу** Исемен, дәрәҗәсен җую, үзенә, сүзенә илтифат бетү. *Ниһаять, урам сүзләре белән ваксынса, килене каршында абруен югалтачагын тоеп, сүзне Нәфисәнең йөрәгенә якын урыннан башлап җибәрде.* Г.Бәширов. *Япон сугышыннан соң абруйларын югалттылар.* К.Нәҗми. **Абруй казану** Яхшы исем алу, халык арасында хөрмәткә ия булу. *«Син теге җыелышта критика сөйләп кенә абруй казанмакчы идеңмени?» – дип, теңкәмә тия башлады председатель.* А.Расих

**АБРУЙЛЫ** *с.* 1) Дәрәҗәле, авторитетлы, ышаныч казанган. *Бу көнне аның абруйлы исеме телдән-телгә, өйдән-өйгә күчеп, авылны, бер генә түгел, әллә ничә кат әйләнеп чыккандыр.* Ф.Мансуров. *Ул чактагы абруйлы әдәбият түгәрәгендә, студентлар, укытучылар гына түгел, күренекле әдипләр дә күренгәләп китә.* А.Гыйләҗев. *Әмма бит надан булгач, ул [мөселман] Коръәннең мәгънәсенә төшенә алмый һәм нинди дә булса башка бер абруйлы кешенең аңлатып бирүенә мохтаҗ була.* Р.Хәким

2) Ышанычлы, тулы ышаныч тудыра торган, нык ышандырырлык. *Абруйлы мәгълүмат чыганакларына таянсак, Россиядә бүген нефть – 35 елга, табигый газ – 81 елга, ташкүмер 60–180 елга, алтын 12–37 елга гына җитәрлек калган.* Ә.Борһанов

3) Саф, намуслы (хатын-кыз турында)

**АБРУЙЛЫЛЫК** *и.* Абруйлы булу, дәрәҗәгә, абруйга ирешкән булу. --- *доктор Туран Язган кереш сүзендә Сөембикәне кызларыбызга каһарманлык, фазиләтлелек вә абруйлылык, камиллек вә идарәчелек үрнәге буларак тәкъдим итте.* С.Ибраһимова

**АБСЕНТ** *и. фр.* Әрем төнәтмәсеннән гыйбарәт исерткеч эчемлек

**АБСОЛЮТ** *и. лат.* **1.** Идеалистик философиядә: дөньяда булган бар нәрсәнең мәңгелек, үзгәрмәс, беренчел нигезе – рух, идея; диндә: Алла, Тәңре. *Сәнгатьнең максатын Абсолютны хисси чагылдыруда күргән Гегель, әсәрләр ярдәмендә шәхес үз-үзен танып белү юлына чыга, дип карый.* Д.Заһидуллина

**2.** *с. мәгъ.* 1) Дөньяда булган бар нәрсәнең мәңгелек, үзгәрмәс, беренчел нигезеннән гыйбарәт булган. --- *һичнинди билгесез, сыйфатсыз «ас-сәбәп», «ас-әввәл» рәвешендәге Абсолют идеянең үсеш процессындагы чагылышы дип кенә бәяләргә.* К.Гыйззәтов

2) Үзгәрешсез, бертөрле. *Без әдәбияттагы форманы туңган абсолют бер төстә алмыйбыз.* Һ.Такташ

3) Бернәрсә белән дә чикләнмәгән, тулы хакимияткә ия булган. *Шул чордагы [1905] инкыйлаб гөрелтесе абсолют хакимият диварларын нык кына какшата, чикләүләр буасы берничә «нечкә җир»дән ерылып, Русияне моңарчы күрелмәгән хөрриятләр ташкыны күмеп китә.* Р.Әмирхан

4) Тулы, тулысынча, бөтенләе белән; иң зур күрсәткечкә ия булган. *Инсаният тарихында иң күренекле абсолют реаль шәхес [Мөхәммәд пәйгамбәр] булган гали зат турында язганда аеруча игътибарлы булу зарур.* Казан утлары. *Космонавтлар арасында [Сергей Авдеев] галәмдә иң озак булучы кеше булып танылa, һәм шуның белән ул, абсолют рекорд куеп, Гинесснның рекордлар китабына кертелә.* Мәгърифәт. *Абсолют җиңү. Абсолют ышаныч*

5) Мөмкин булган барлык, бөтен. *Абсолют тизлек. Абсолют шартлар*

**3.** *кис. мәгъ.* Асыл сыйфат алдында килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый: үтә, бик, иң, нык. *Әгәр алар сүзе белән әйтсәк: «Сиңа абсолют тынычлык кирәк», – диделәр.* А.Шамов. *Галимнәр шундый ук диаметрлы абсолют чиста су баганасын өзү өчен 95 тонна чамасы көч кирәк булачагын исәпләп чыгарганнар.* Кызыклы физика

**АБСОЛЮТИЗМ** *и. фр. сәяси* Илнең бер генә кеше тарафыннан идарә ителү формасы; чикләнмәгән монархия. *Россиядәге абсолютизм мәсьәләләрен өйрәнүче галимә Н.Демидова урыс бюрократиясенең туу тарихын XVI–XVIII гасырларга бәйләп карый.* Казан утлары

**АБСОЛЮТЛАШТЫРУ** *ф.* Абсолют итү, абсолютка әйләндерү. *Бәйсезлекне болай абсолютлаштыру мәгънәсезлек булыр иде.* С.Максуди. *Шуңа да Тукайның тәнкыйтен абсолютлаштырырга, аны бердәнбер хакыйкать дип танырга ярамый.* Р.Фәтхрахманов

**АБСОЛЮТЛАШУ** *ф.* Абсолютка әйләнү

**АБСОЛЮТЛЫК** *и.* Чикләнмәгәнлек, шарт куелмаганлык. *Шулай итеп, без хәрәкәтнең тагын ике капма-каршы сыйфатын күрсәтә алабыз. Бу – аларның абсолютлыгы һәм нисбилеге. Хәрәкәтнең өзлексез була алуы – бер сыйфат. Аның әзлекле (дискрет) рәвештә чагылуы – икенче (капма-каршы) сыйфат.* К.Гыйззәтов

**АБСОРБЕНТ** *и. лат.* Сеңдергеч, йоткыч матдә. *Күмер – яхшы абсорбент*

**АБСТРАКТ** *с. лат.* 1) Конкрет булмаган, гомуми. *Символист язучы, мондый сурәтне бирү белән, нинди булса бер реаль тормышның конкрет күренешләрен бирүдән качкан, абстракт фикерләр бирүгә киткән була.* Г.Нигъмәти. *Юк, ул андый кеше түгел,*

*салкын рационалист кеше ул, намус – аның өчен абстракт төшенчә генә.* Ә.Еники. *Предметның абстракт билгеләре. Тормышка бәйләнмәгән абстракт образлар*

2) Абстракциягә нигезләнгән. *Абстракт метод. Абстракт хезмәт*

**АБСТРАКТЛАШТЫРУ** *ф. кит.* Абстракция ясау. *Ә инде тенденция төсе ала барган космик күләмдә абстрактлаштыру кеше образының конкрет-реалистик асылын һәм, димәк, сәнгатьчә фикерләүнең нигезен какшата.* Н.Хисамов. *Танып белү тоюдан башлана, интеллект танып белүне абстрактлаштырып, әйберләрнең асылына ирешүне тәэмин итә.* К.Гыйззәтов

**Абстрактлаштырып карау** Абстракция буларак күзаллау, гомумиләштерергә омтылу

**АБСТРАКТЛАШУ** *ф. кит.* Абстрактка әйләнү, гомумиләшү, конкретлыгын югалту

**Абстрактлаша бару** Абстрактлашуы акрынлап көчәю, абстрактлыгы акрынлап арту

**Абстрактлаша башлау** Абстрактлашу билгеләре күренү, абстрактлашырга керешү

**АБСТРАКТЛЫК** *и.* Конкрет булмау, гомумилек, абстракт булу. *Абстрактлыкны белдерә торган терминнар бездә артык күп үрчеде, аннан да битәр, шулардан ясалган сыйфатлар, рәвешләр чын мәгънәсендә «кермешәк» саналырга тиеш: пленар утырыш, наив кеше, приоритетлы юнәлеш... Боларны һәр очракта татар чаралары белән белдереп була.* И.Низамов

**АБСТРАКЦИОНИЗМ** *и. фр.* XX йөз рәсем сәнгатендә: чынбарлыкны абстракт формалар яки төсле таплар тезмәсе итеп сурәтли торган иң чик формаль агым. *Кемдер – реализм, кемдер экспрессионизм йә булмаса сюрреализм, абстракционизм стилендә иҗат итә.* Шәһри Казан

**АБСТРА́КЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Фикерләгәндә предметның мөһим гомуми үзенчәлекләрен аерып күрсәтү өчен, аның конкрет сыйфатларын, үзлекләрен, бәйләнешләрен читләтеп уйлау ысулы. --- *Мәрҗани исә конкретлыкның асылына югары дәрәҗәгә ирешкән абстракция юлы белән якынаю сәләтенә ия философ һәм кырыс тарихчы иде.* М.Госманов

2) Абстракт төшенчә, теоретик гомумиләштерү. *Абстракция шигырьне матурламый да, тирән мәгънәле дә итми.* Һ.Такташ

**АБСУРД** *и. лат.* **1.** Акылга сыймаслык нәрсә; искиткеч мәгънәсезлек. *Хикәяләүче үзе – өч юлның да мәгънәсезлеген, файдасызлыгын аңлаган кеше, абсурд, мәгънәсез дөньяда яшәүче ялгызак, матурлыкны сарайларга ябып саклау мөмкин түгеллеккә төшенгән экзистенциалист.* Д.Заһидуллина. *Яраткан кешеңә ышанмыйча мөмкин түгел, абсурд бу!..* Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* Акылга сыймый торган, мәгънәсез. *Әсәр текстына абсурд элементның кертелүе бүгенге чынбарлыкның тотрыклы булмавын күрсәтү бурычына хезмәт итә.* А.Шәмсутова. *Ашыгып, абсурд нәтиҗәләр ясап ташлау*

**АБСУРДЛЫК** *и.* 1) Акылга сыймаслык мәгънәсезлек. *Ул дәүләткә һәм халыкка каршы сәяси җимерү эше алып баруда һәм террорда катнашуда гаепләнә. Бүгенге көндә бу гаепнең абсурдлыгы һәм мәгънәсезлеге директив органнар һәм компетентлы оешмалар тарафыннан расланды.* М.Сәхапов

2) Драматургиядә: әйләнә-тирә дөньяны «мәгънәсез», «буш» дип аңлата торган юнәлеш, агым

**АБСУРДЧЫ** *и.* Драматургиядә абсурдлык тарафдары. *Танылган абсурдчы*

**АБСЦЕСС** *и. нем.<лат.* Тәндәге эренле ялкынсыну; эренле чуан. *Абсцесс булганда, күзәнәкләр үлеп, тукымаларда эренле куышлык барлыкка килә.* Биология. *Җиһан апаның аяк сынган җирендә абсцесс (үлек җыелу) булган да, канына таралып, каны агуланып үлде ул.* Безнең гәҗит

**АБСЦИ́ССА** *и. лат. мат.* Тирәнлектә ноктаның торышын билгели торган өч координатның берсе. *Почмаклар уңнан сулга таба, абсциссалар күчәренең уңай юнәлешеннән башлап саналалар.* Югары математика нигезләре

**АБСЫН** *и. диал.* Килендәшләр, ике туганның хатыннары. *Абсыннарыгыз тату торамы, дип сорыйлар иде элек...*

**АБУ ИТҮ** *ф.* Кечкенә балалар телендә: тәне бәрелү, егылудан, тырналудан авырту. *Абу итте бармагым, би-би итте тырнагым.* Табышмак (*ипи изү*)

**АБУНӘ** *и. к.* **абонемент**

**АБУНӘЧЕ** *и. к.* **абонент.** *«Тәрҗеман»ның иганәче һәм абунәчеләре исемлегендә Рәмиев фамилиясе беренче булып теркәлә.* Л.Хәмидуллин

**АБХАЗ** *и.* Абхазиянең төп халкы (үзатамалары – *апсуа*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Абхазлар арасында сөнни мөселман динен дә, православие динен дә тотучылар бар*

**АБХАЗИЯЛЕ** *и.* Абхазиядә яшәүче, Абхазия кешесе

**АБХА́ЗЧА** *рәв.* **1.** Абхаз телендә. *Абхазча сөйләшү*

**2.** *с. мәгъ.* Абхаз телендәге. *Абхазча газета*

**АБЫЗ** *и. иск.* 1) Белем, тәҗрибә иясе, хәбәрдар, укымышлы кеше. *Абыз – атасыннан олырак.* Мәкаль. *Аксакаллардан башка, авыл башында иң хөрмәтле кешеләрдән берсе – абыз торган, тормыш-көнкүрештә килеп чыккан барлык бәхәс-низагларны хәл итү өчен, абыз янына килгәннәр.* А.Тимергалин. *Мондагы авылларның һәркайсында мулла яки абызлар булып, Казан өязеннән күчеп утырган татарлар тора. Аларның һәркайсы – укымышлы, зирәк.* Р.Зәйдулла

2) Җитәкче ага. *Абыз сөйләгәндә, авыз йом.* Әйтем

3) Гаиләдә балаларның әтисе яки әнисенең апасы һәм сеңлесе. *Абыз әти – әтисе белән бертуган абыйсы.* Г.Камал. *Безнең абыз анай дөньядамы икән әле, аның балалары безне хәтерлиләрме икән?* К.Нәҗми

4) Өлкән хатын-кызга хөрмәтләп эндәшү сүзе

**АБЫЗ ТУТАЙ** *и. иск. к.* **абыстай**

**АБЫ́ЗТҮТИ** *и. диал.* 1) *к.* **абыз** (*3 мәгъ.*)

2) Кемнең дә булса әтисенең яки әнисенең апасына эндәшү сүзе. *Абызтүти, ашарга кил!*

**АБЫЙ** *и.* 1) Үзеннән олырак яшьтәге ир туган. *Менә хәзер дә ул аны күргәндәй булды, һәм абыйсы, имеш, ишекне ачып керер дә: «Солтан монда торамы?» – дип, энекәше белән килеп күрешер төсле.* Г.Кутуй. *Шул арада бертуган абыйсы Гомәрнең, туганнан туган абыйсы Ибраһимның «халыклар атасы» җәһәннәмендә һәлак булулары турындагы хәбәр килеп ирешә әтиебезгә.* Р.Әмирхан. *Күпме генә яшереп маташсаң да, үзеңнең – мулла малае, абыеңның әүвәлге Колчак әфисәре икәнен дә беләләр анда.* Р.Әмирхан

2) Яшь ягыннан сөйләүчедән олырак ир кеше исеменә кушып әйтелә. *Карт сугышчы Давыт абый сөйләвеннән туктады.* Г.Кутуй. *Әкрен генә [баян] уйный башладым. Гадәттәгечә, салмак көйләрдән башлап, кыскарак көйләргә, аннары бию көйләренә, соңрак мажор ладка, тантаналы моңнарга тоташканымны Сафуан абый сикереп торгач аңладым.* Ә.Баян

3) *сөйл.* Яше ягыннан олырак, исеме билгеле булмаган ир-атның профессиясенә кушып әйтелә. *Матрос абыйлар чуен бүкәнгә эләктерелгән тимерчыбык арканнарны пароход эченә тартып алдылар.* Г.Мөхәммәтшин. *Бала-чагалар да, борыннарын тартып, башларын бәпкә төсле кыңгырайтып, ят абыйга шикләнеп карыйлар иде.* А.Гыйләҗев

**АБЫЙЛЫ́-СЕҢЕЛЛЕ** *с.* **1.** Абый белән сеңел, ага белән сеңел

**2.** *рәв. мәгъ.* Абый белән сеңел кебек, ага белән сеңел сыман. *Тәфсилләп сөйләп торырга вакыт юк иде. Абыйлы-сеңелле, кулга-кул тотышып, түгәрәккә ашыктылар – уен башланды.* Г.Шәрипова

**АБЫЙЛЫ́-ЭНЕЛЕ** *с.* **1.** Абый белән эне, ага белән эне. *Абыйлы-энеле Райтлар төзегән очкыч 1903 елда уңышлы очышын башкара.* Р.Нуруллин. *Ни кызганыч, абыйлы-энеле ике туганга бер җирдә хезмәт итәргә насыйп булмый.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Абый белән эне кебек, ага белән эне сыман. *Игезәк малайларның абыйлы-энеле булып үсүе Миргалимнең әнә шул үҗәтлегеннән башланды.* Н.Акмал

**АБЫ́Л-КОБЫЛ** *рәв.* Ашык-пошык, кабаланып, эштер-өштер. *Иртәнге чәйне дә ул көндәгечә абыл-кобыл эчеп, өстәл яныннан торып китәргә ашыкмады.* Г.Минский

**АБЫНА́-ЕГЫЛА** *рәв.* 1) Абына-сөртенә (*1 мәгъ.*). *Әледән-әле артына карый, як-ягына карана, абына-егыла, каядыр ашыга.* Н.Фәттах

2) *күч.* Тырыша-тырмаша, зур тырышлык, көч куеп, күп төрле хаталар ясап, ялгышып. *Кыйтгам эзлим шулай, абына-егыла, Фани өметемә ябышып торам. Юклык кичеп йөргән илгизәр мин, Билгесезлек – минем туктар урын.* С.Әхмәтҗанова

**АБЫНА́-СӨРТЕНӘ** *рәв.* 1) Ашыгып, кабаланып, аяк астындагы нәрсәләргә бәрелеп. *Казак, ат өстеннән сикереп төшеп, кылычына абына-сөртенә ишегалдына ташланды.* И.Гази. *Әмма ул әле ят шәһәрнең тротуарлары буйлап абына-сөртенә озак барды.* Ә.Мушинский. *Ул абына-сөртенә капчыкка таба атлый.* А.Расих. *Кара мөһер суккан ачы хәсрәтле өчпочмакны тотып, абына-сөртенә юлга кузгалды.* Сөембикә

2) *күч.* Күп хаталар ясап, ялгышып. *Нәзирә тәмам арыган, ул инде соңгы көченә бара --- язмышына буйсынып, абына-сөртенә бара да бара.* Г.Гыйльманов. *Ул, абына-сөртенә, адаша-ялгыша булса да, үз сызыгы белән китәчәк.* Г.Бәширов. *Гармонияле мохиттә абынмый-сөртенми көн итүе заруp икән шул.* Л.Шагыйрьҗан

**АБЫНКЫ** *с. сөйл.* 1) Боек, сүлпән, омтылышсыз; дәртсез, рухсыз (кешегә карата)

2) Абынучан, сөрлегүчән, абына-сөрлегә торган; үшән. *Үзе салынкының – аты абынкы.* Мәкаль

**АБЫНМАЛЫ** *с.* 1) Тигезсез, тигез булмаган, чокыр-чакырлы

2) *күч.* Катлаулы, четерекле, мәшәкатьле, авыр. *Иске интеллигентның [Фатих Кәрими] бик катлаулы чорларда абынмалы юллардан гражданлык хисенә тап төшермичә уза алуы да ихтирамга лаек.* М.Госманов

**АБЫНУ** *ф.* 1) Атлап барганда нәрсәгә дә булса эләгеп сөртенү, сөрлегеп китү, тигезлекне югалту. *Сәхибҗамал өйгә кереп барганда абынып егыла, кулындагы ящигы җиргә төшә.* А.Әхмәт. *Аяк астындагы юлга карамый, шуңадыр күрәсең, әле түмгәккә абына, әле трактор эзенә төшеп китә.* Ф.Яруллин. *Ләкин кинәт ул «дерт» итеп китте һәм, нәрсәгәдер абынган шикелле, боз өстенә чәчрәп барып төште.* И.Гази. *Күз ияләшеп өлгермәгән караңгыда берәр нәрсәгә абынмас өчен, аяк астына карап, сакланып кына барабыз.* Ә.Еники

2) *күч.* Эштә, тормышта ялгышлык җибәрү, хаталану. *Ни бит, килен, менә болай бит. Дүрт аяклы ат та абына. Әллә, минәйтәм, балалар хакына килешәсезме?* М.Мәһдиев. --- *һәр түмгәккә абына торган яшьтә түгел инде хәзер. Ныклап уйладым мин.* Ф.Зариф. *Юк, юк, кеше беркайчан да бер үк вакытта өч заман турында уйлый алмый. Шуңа ялгыша, абына адәм баласы.* Казан утлары

3) *күч. сөйл.* Өметне, ышанычны акламау; сынату. *[Мирсәет:] Сәләхи абзый белән ярышасың икән, кара аны, аягыңны ныклабрак киен. Абынуың бар.* Р.Ишморат. *Ярый, дидем, риза булса, алып кайтырмын, дидем. Мал иясендә абынмасын! Ләкин минем мал абынды.* Х.Сарьян

**Абына башлау** Абынырга тотыну, абынулар җибәрү. *Мин тагын да еш-рак абына башлыйм.* И.Гази

**Абына төшү** Бераз абыну

**Абына язу** Чак кына абынмый калу, абынудан сакланырга өлгерү. *Тигез җирдә абына яздым. И беркатлы да инде мин, кеше иренә сөенә-сөенә, урам әйләнәм.* Н.Гыйматдинова. *Каберлекләр арасыннан узганда, Габделвәли аяк астында аунап яткан корыган ботакка абына язды.* Рифә Рахман

**Абынып алу** Кинәт, бер тапкыр абыну

**Абынып китү** Тигез генә барган җирдән кинәт абыну. *Рифгат алда күренгән тыкрыкка борылырга тиеш иде. Шуның өчен ул шпалларга басып, рельсларны аркылы чыгарга уйлады. Һәм кинәт абынып китте.* А.Алиш. *Көтмәгәндә ул нәрсәгәдер абынып китте.* Н.Фәттах

**Абынып куюю** 1) Көтмәгәндә кинәт абыну. *Бар да җайланыр. Тормыш шундый бит ул. Анда абынып куйган чаклар да була.* А.Гыйләҗев

2) Бер тапкыр абыну. *Ат чабып барган җиреннән абынып куя*. Р.Батулла

**Абынып тору** Әледән-әле абыну; еш, һаман абыну

**АБЫСТАЙ** *и.* 1) Коръәнне яттан белүченең хатыны; абыз тутай

2) Коръәнне укый белгән, ислам йолаларын үтәгән, ислам сабагын бирүче хатын-кыз. *Алты-җиде яшьлек бер малайны абыстайга сабакка биргәннәр.* Г.Бәширов. *Зур кызыл яулык өстеннән иске камчат бүрек киеп, астына мендәр салып, сәке йөзлеге кырыена аяк бөкләп утырган, битләре җыерчыкланып беткән карт абыстай колак артына җеп белән тарттырып бәйләгән бер пыяласы ватык күзлеген маңгаена күтәрде.* М.Гали

3) Дин әһеленең хатыны. *Абыстай да боларга чәй эчереп, аш ашатып, киткән арада ярты кадак чәй, берәр кадак шикәр яисә яулык вә күлмәклек биреп, фатихаларын алып озатадыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Мулла --- үз аягы белән керә алмады, аны абыстай күтәреп диярлек кертте.* Г.Ибраһимов

4) *сөйл.* Гомумән сөйләүчедән өлкәнрәк яшьтәге хатын-кызның исеменә кушып яисә таныш булмаган хатын-кызга мөрәҗәгать иткәндә әйтелә. *Зөләйха абыстай аның кайтуы һәм теге куркыныч хәлнең ни рәвешле булуы турысында тәфсил бирергә тотынды.* Г.Ибраһимов. *Бүген исә Мәрьям абыстайның кәефе шәптән түгел иде.* Ә.Еники

◊ **Абыстай, ничә әйтсәң дә бер сүз, ике кешегә – дүрт күз** Берәр гаеп эш өчен, «нигә күрмәдең?» дип, икенче кешене гаепләгәндә, җавап буларак әйтелә

**АБЫШКА** *и.* 1) Карт, карый. *Мәкаль жанрының XI гасырда тагын «абышка сүзе» исеме белән йөртелүе дә мәгълүм.* Х.Мәхмүтов

2) Беренче хатынын югалткан яки хатын аерган ир кеше; гомумән карт ир кеше

**АВА́-ЕГЫЛА** *рәв.* Бер авып, бер егылып; кабаланып, кызуланып. *Әйберләрне шул зур имән төбендә – күләгәдә калдырдылар да текә ярдан, ава-егыла, зур кыенлык белән түбәнгә, Яманкул төбенә, Фәхринең гәүдәсе табылган җиргә төштеләр.* Г.Ибраһимов

**АВАЗ** *и.* 1) Сулыш ярдәмендә тамак ярыларының тирбәлүеннән барлыкка килә һәм һава дулкыны белән тарала торган яңгыраш, тавыш. *Халык бер аваздан, барысы бергә, бердәм рәвештә күнеп, яңа патша белән таныштырга телəделәр.* Әкият. *Мин оныттым нәфис авазыңны, Фәрештәдәй якты сыныңны.* А.Пушкин. *Бу – кош тавышы да, хайван тавышы да, кеше сөйләшкән тавыш та түгел, бу – җырлаган аваз иде --- . Аваз – хатын-кыз тавышы иде.* Гали Рәхим. *Гөнаһсыз бала күкрәгеннән атылып чыккан иң беренче яшәү авазыннан да кыйммәтлерәк аваз дөньяда юк, кызым.* Г.Кутуй

2) Һава тирбәлүләре нәтиҗәсендә кире кайтып ишетелгән яңгыраш; кайтаваз. *Килә шунда бер аваз әллә кайдан: «Ышанма, дөньяда һәркемдә ялган!»* Г.Тукай. *Үз тавышыңны танымыйча торасың: кое җавап бирәдер, җир авазыдыр сыман.* Ш.Галиев. *Боларны [сүзләрне] мин аваз яңгырашы буенча французга якын икәнен чамалап алдым һәм бу яңгырашны гомер буе хәтердә сакладым.* М.Мәһдиев

3) Нинди дә булса эш-хәрәкәттән, физик күренештән барлыкка килгән тавыш, өн. *Ерактан, әллә кайдан, ишетелә күк күкрәгән аваз.* Г.Тукай. *Көлтә допылдаган, салам чытырдаган авазлар --- авылның ерак урамнарына кадәр китеп яңгырыйлар.* М.Гали. *Һәм мин бер нәтиҗәгә килдем: кошларда очраклы бер генә хәрәкәт, кирәксезгә бер генә аваз да булмый.* М.Мәһдиев. *Юк, бөтенләй үк тынлык түгел, су тавышы, төнге елга авазы бар. Табигать авазы...* Р.Фәйзуллин

4) Төрле уен коралларында уйнаганда чыга торган тавыш, шул тавышның яңгырашы. *Кемдер, колакка ягымлы булган авазлар чыгарып, скрипкада көйгә сала...* Г.Кутуй

5) *лингв.* Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге. *Яңалифкә күчәргә өндәүчеләрнең фикере буенча, латин алфавиты телебезнең авазлар системасына туры килә.* Г.Ибраһимов. *К.Насыйриның «Кыскача татар грамматикасы»нда аваз чиратлары, авазларның үзара тәэсир итешүләре, сүз басымы кебек мәсьәләләр карала.* Татар грамматикасы

6) *күч.* Җавап буларак барлыкккка килгән, кабатланган күренеш, вакыйга турында. *Әсәрдә [«Алтын кашбау»] ерак тарихлар авазы да, бүгенге аянычлы хәлләр дә бербөтен булып яши.* Н.Ханзафаров. *Гасырлар авазын тыңлап, мәхәббәт хакындагы моңсу да, ләззәтле дә риваятьне ишетергә дип, Кыз тавына елның-елында әллә кайлардан сәяхәтчеләр, сәфәрчеләр килә.* Сөембикә

7) *күч.* Эчке сиземләү, тоем. *Күңеленең кайсыдыр почмагында ят бер аваз: «Янына бар, якынрак бар», – дип пышылдады.* Казан утлары

8) *күч.* Рух, җан. *Әллә сандугачлар яу кырыннан кайтмыйча калганнарның җаннарымы, өн-авазларымы?.. Архив бакчасында сандугачлар сайрый. Яу кырыннан кайтмый калганнарның җан авазлары булып тоела миңа кошлар сайравы.* Ш.Мостафин

◊ **Аваз бирү** 1) Эндәшү, кайда икәнлеген белгертү. *Бу – шагыйрәнә як... Мәйданга киләчәк яңа әдәбияттан узган йөздә үк аваз биреп куйган Г.Кандалый --- шушыннан чыккан.* Н.Хисамов; 2) Җавап бирү. *Минә бит, әтиең киткән кайгыга каршы, син нарасыем, үзеңнең барлыгыңны белдереп, аваз бирдең, мине шатландырдың.* Сөембикә. **Аваз салу** 1) Кычкыру, тавыш бирү. *Авыл малае булгангамы, әллә үсмер чагымда ук авылда бригадир булып эшләгәнгәме — таң әтәчләре аваз салуга уяндым.* Г.Ахунов. *Күршеләр капка шыгырдатып казларын урамга чыгарды, каршындагы күршеләрнең эте аваз салды.* М.Мәһдиев; 2) Хәбәр итү, барлыгын, яшәвен белдерү. *Хәзерге үлчәм белән килсәк, «Нур»ның татар көндәлек матбугаты буларак дөньяга аваз салуын (милләт масштабында, әлбәттә) бүгенге цивилизациянең Марска кеше утыртуына тиң бер вакыйга дияргә мөмкин.* Р.Әмирхан

**АВАЗДАШ** *с.* 1) *лингв.* Авазлар яңгырашы ягыннан охшаш, бер-берсенә охшаган, бердәй яңгырашлы, тәңгәл. *Мәкальдә исә ул [«Халикъ» сүзе] үзенә тулысынча диярлек авааздаш булган «халык» сүзе белән алмашынган.* Х.Мәхмүтов

2) Үзара ярашлы, бер-берсенә тәңгәл; аһәңдәш. *...Күзаллый күңелем шушындый бер чакны: Аваздаш булыр җыр өр-яңа чор белән!* З.Нури. *Мәкалә басылып чыкты, без аңа аваздаш хатлар көттек.* Идел. *Ким Ир Сен үз халкыныкына аваздаш моң белән җырлаган.* Мәдәни җомга

3) Нәрсә белән дә булса охшаш, бертөрле, уртак. *Бу җәһәттән, Умай Борынгы Греция мифларындагы иң күренекле алиһә Афина Паллада белән бик тә аваздаш.* Г.Дәүләтшин. *Эчке поэтик интонация, революцион пафос һәм «көннең кадагына суга» белү ягыннан да [Такташ шигырьләре] Маяковский шигырьләре белән аваздаш.* Х.Хәйри. *Үзләрендә изге җир-су, мәңгелек ил, халык язмышы кебек җитди проблемаларны күтәрүләре белән дә Орхон язмалары төрки эпос әсәрләренә бик аваздашлар.* Х.Мәхмүтов

**АВАЗДАШЛАНУ** *ф. лингв.* Аваздашка әйләнү, яңгырашлары тәңгәлләшү; омонимлашу. *Сөйләмдә бер сүз икенче бер сүзнең формасы белән аваздашланырга мөмкин*

**АВАЗДАШЛЫК** *и. әд.* 1) Шигырьдә сузык авазларның кабатланып килүе; рифма. *Басымлы иҗеккә тәмамлана торган юлларның аваздашлыгы*

2) *лингв.* Мәгънәсе белән төрле булган сүзләрдә авазлар яңгырашының тәңгәллеге; омонимия. *Омонимия телнең үз сүзләре һәм алынма сүзләр аваздашлыгы аркасында барлыкка килә.* Лексикология

**АВА́З ИЯРТЕМЕ** *и. лингв.* Табигатьтәге берәр төрле тавышка, җанлы затларның тавышына, нииндидер яңгырашка охшатып ясалган сүз (мәс., *вау-вау, голт-голт, чут-чут, жый-жый* һ.б.). *Аваз ияртемнәре телебезнең сүзлек составында бай һәм гаять үзенчәлекле лексик бер катламны тәшкил итәләр.* Татар грамматикасы

**АВАНГАРД** *и. фр.* **1.** 1) Гаскәрнең яки флотның төп көчләрдән алда бара торган, алдынгы отряды; алдан бара торган гаскәр, иравыл. *Атлы гаскәр авангарды*

2) *күч.* Нинди дә булса иҗтимагый хәрәкәтнең, сыйныфның алдынгы, әйдәп баручы төркеме. *Кемнедер яклатмадылар, аларга аяк чалдырып, аларның бер төрлесе шәһәрен алыштырды, икенче төрлесе инфаркт, инсульт алды. Әмма тырышлар, бәреп, авангардка чыкты.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Төп көчләрдән алда бара торган, әйдәп баручы, алдынгы, үрнәк. *Авангард ролендәге иҗтимагый көчләр*

**АВАНГАРДИЗМ** *и. фр. к.* **авангардчылык**. *Шулай ук бу урында мөгътәбәр әдәбият белгечләренең кайбер хезмәтләрендә авангардизм әсәрләрен әдәбиятның гел гүзәл казанышлары рәвешендә тәкъдим итү күңелдә, ким дигәндә, гаҗәпләнү һәм сәерсенү уята.* Р.Сверигин

**АВАНГАРДИСТ***и. фр.* **1.** *к.* **авангардчы**

**2.** *с. мәгъ.* Шул юнәлештә иҗат итүче. *Юк, аның йөзе урынында бушлык түгел анысы, хәзерге авангардист рәссамнар төшергәнчә, нииндидер минут саен алышынып торучы эре сызыклар, чалымнар гына.* Р.Мирхәйдәров

**АВАНГАРДЛЫК** *и.* Авангард булу, алдынгылык, әйдәп баручылык. *Рәсем сәнгатендә гел эзләнү мәслихәт. Әмма яңалыкка омтылам, дип, авантюрага барырга, авангардлык пәрдәсе артына яшеренеп, зәвыксызлыкка бирелергә ярамый.* Мәдәни җомга

**АВАНГАРДЧЫ** *и.* Сәнгатьтә авангардчылык юнәлешендә иҗат итүче, шул иҗат юнәлешен өстен күрүче; авангардчылык тарафдары. *Авангардчы рәссам*

**АВАНГАРДЧЫЛЫК** *и.* XX йөздән башлап сәнгатьтә реализмнан гайре яңа сүрәтләү чаралары һәм формалар эзли торган юнәлешләрнең гомуми исеме. *Авангардчылык стилендә язылган натюрмортлар һәм пейзажлар*

**АВАНПОСТ** *и. фр.* 1) Кайбер армияләрдә, дошманның кинәт һөҗүмен хәбәр итү өчен, төп көчләрдән алда чыгарып куелган сакчы отряд

2) Алгы пост һәм шундый пост урнашкан урын. *Европа белән Азия чигендә күп еллар буенча Россия капитализмының аванпосты булып торган бу шәһәр чиновниклар, сәүдәгәрләр, спекулянтлар, колонизаторлар белән тулган иде.* Ш.Усманов

**АВАНС** *и. фр.* **1.** 1) Җибәреләчәк товарлар, башкарылачак эш һәм күрсәтеләчәк хезмәт өчен алдан бирелгән өлешчә түләү (акча яки продукт). *Бүген колхозчыларга аванс бирергә кирәк. Бер хәл алсыннар.* М.Мәһдиев. *Икенче көнне үк Тимерхан, әвеннән чыккан арышны тарттырып, халыкка аванс бирде.* М.Мәһдиев. *Авансның киң кулланыла торган формасы – эшче-хезмәткәрләргә тиешле хезмәт хакының бер өлешен алдан бирү.* Безнең гәҗит

2) Берәр чыгым өчен исәп-хисап ясаганга кадәр, түләнәсе акчаның алдан бирелә торган өлеше. *Гаиләдә иң олы бала булган Әркәшә авансны биология дәфтәренең соңгы битенә үзе язып бара.* М.Мәһдиев. *Командировкага бару өчен аванс алу*

**2.** *с. мәгъ.* Аванс рәвешендәге, алдан түләп куелган. *Кичә ферма көтүчеләре шешенгәннәр. Бүген аларга аванс он бирмичә ярамый.* М.Мәһдиев

**АВА́НСЛАТА** *рәв. сөйл.* Аванс итеп, аванс рәвешендә, алдан түләп

**АВА́НСЛАУ** *ф.* 1) *икът.* Аванс бирү, өлешчә алдан түләү. *Минем заем, доходыма нисбәтән, аз түгел: 50 сум! Яртысын, көн исәбеннән, авансλап, колхоз кертте.* Х.Туфан

2) *күч.* Алдан башкару, алдан эшләп кую. *Чөнки «Сагынгач нихәл итәрбез» булгач, димәк, бу җырны җырлаучы кеше әле сагынмаган, киләчәк өчен авансλап кына җырлый булып чыга.* Т.Гыйззәт

**Авансλап бару** Һәрберсен, булган берсен авансλау

**Авансλап килү** Электән, даими рәвештә авансλау

**Авансλап тору** Әледән-әле авансλау; даими рәвештә авансλау

**Авансλый башлау** Авансларга керешү, аванс бирүне башлау

**АВАНСЦЕ́НА** *и. фр.* Сәхнәнең тамашачылар залы ягында кала торган ачык өлеше, сәхнә алды. *Сәхнә караңгылана. Пәрдә төшә. Әсфан авансценага чыга.* А.Гыйләҗев

**АВАНТЮ́РА** *и. фр.* 1) Уңышлы булачагын алдан уйлап җиткермичә, реаль шартларны, мөмкинлекләрне исәпкә алмыйча эшләнгән эш. *Бу авантюрага каршы Петроград эшчеләре протест белдереп урамга чыккач, Вакытлы хөкүмәт аларны мылтык һәм пулемёт уты белән таратты.* К.Нәҗми

2) Алдауга корылган, очраклы уңышка исәпләнгән, хәвефле тәвәккәллек белән башкарылган эш, гамәл. *Бер үк вакытта буржуазия, властьны үз кулында саклап калу өчен, яңа авантюралар оештыра.* К.Нәҗми. *Финанс авантюрасы*

3) *әд.* Маҗара. *Әсәрдә авантюра элементлары бар. Ә болар яшеренкелекне, башта әйтелмәүне, билгесезлекне телиләр.* Г.Нигъмәти

**АВАНТЮ́РАЛЫ** *с.* 1) Авантюрага корылган, хәвефле, хәтәр. *Менә шунда фашистлар Германиясе авантюралы инсценировка ясауга бара.* К.Гыйззәтов

2) Маҗаралы, төрле маҗаралар сурәтләнгән. *Барыннан да элек роман мәхәббәткә, авантюралы сюжетка корылган.* Ф.Габидуллина

**АВАНТЮ́РАЧЫ** *и.* Авантюрага һәвәс, авантюрага нигезләнеп эш итүче кеше

**АВАНТЮ́РАЧЫЛ** *с.* Авантюрага корылган. *Авантюрачыл сюжет*

**АВАНТЮ́РАЧЫЛЫК** *и.* Авантюраларга бирелгәнлек; иҗтимагый һәм сәяси эшләрдә нык принциплар, карашлар булмау; принципсызлык. *Сәяси авантюрачылык*

**АВАНТЮРИЗМ** *и. рус кит. к.* **авантюрачылык**

**АВАНТЮРИСТ** *и. рус к.* **авантюрачы**. *Урамнар купецлар, банкирлар, вояжёрлар, караклар, авантюристлар белән тулган.* К.Тинчурин

**АВАНТЮРИ́СТИК** *с. к.* **авантюралы**. *Норадынның һәлакәтен сурәтләгәндә, дастан берникадәр авантюристик күренешләргә дә урын калдыра.* Ф.Урманче

**АВАНТЮРИСТЛЫК** *и. к.* **авантюрачылык**

**АВАР** *и.* 1) Дагстанда яшәүче төп халыкларның берсе һәм шул халыкның бер кешесе (үзатамалары – *маарулал*). *Аварлар – сөнни мөселман динендәге халык. Авар телендә сөйләшү. Авар халык биюе*

2) *тар.* VI гасырда Дунай тирәсендәге өлкәләрне басып алып, шунда каганат оештырып, X гасыргача яшәгән төрки кабиләләр

**АВА́Р-АУМАС** *рәв.* Бер якка авышып, аварлык хәлгә җитеп, кыйшаеп. *Галимә апа бер сүз дә дәшми --- башын түбән иеп, атлар-атламас кына кайта, авар-аумас килгән кебек күренә ---.* М.Гафури

**АВА́РИЯ** *и. ит.<гар.* 1) Берәр төрле эш яки хәрәкәт вакытында машинаның, приборның нинди дә булса механизмы ватылуы, яраксыз хәлгә килүе. *Авария-фәлән булмаса, берәр айдан нефть яткан катлауга барып җитәчәкбез.* А.Әхмәт. *Кечкенә авария белән котылдык.* Р.Ишморат. *Әгәр шәһәр электр челтәрендә ниндидер авария булса, дәвалау-профилактика учреждениеләренең нинди хәлдә калачагын күз алдына китерү авыр түгел.* Мәдәни җомга

2) Зур бәхетсезлек, фаҗига, һәлакәт. *Авария булып узган урынга бару. Авариягә юл куймау*

3) *күч. сөйл.* Уңышсызлык; берәр эшнең, планның көтмәгәндә таркалуы, барып чыкмавы

**АВА́РЧА** *рәв.* **1.** Авар телендә, аварлар сөйләшкәнчә; аварлар кебек. *Гамзатов әйтә, юл кырында үләргә ятканымда, янымнан узып баручыларның аварча сөйләшкәнен ишеттем һәм мин терелдем, ди...* Р.Вәлиев

**2.** *с. мәгъ.* Авар телендә булган, аварларга караган. *Аварча җыр*

**АВА́-СӨРТЕНӘ** *рәв.* Егыла-тора, бик ашыгып, кабаланып

**АВА́-ТҮНӘ** *рәв.* Як-якка авып, алпан-тилпән килеп. *Исерек картачылар компаниясе бер минут гаҗәпсенеп карадылар да, ава-түнә Булатовны сырып алдылар.* Г.Ибраһимов. *Тузан кунган яшел «Волганы» бала-чага сырып алган иде. Аягына чак тәпи басканы да ава-түнә килеп җиткән.* Ә.Еники

**А́ВГУСТ** *и. лат.* Календарь елының сигезенче ае. *Августның егерме бишенче көне – Мәкәрҗә ярминкәсенең ахыргы, кыямәтнең беренче көнедер.* Ш.Мөхәммәдев. *Беренче имтиханга керүебезнең тәгаен числасын күптән оныткanмын, һәрхәлдә, августның егермеләре тирәсендә булды шикелле...* Ә.Еники. *Август ахырында басулар саргайды, зәп-зәңгәр күк гөмбәзе астында кырлар, ындырлар алтын сары көлтә, салам чүмәләсе, эскертләр, кибәннәр белән тулды.* М.Мәһдиев

**АВЕНИ́ДА** *и. фр.* Латин Америкасы илләрендәге шәһәрләрдә агачлар утыртылган киң урам; проспект. *Иске шәһәрнең җанга якын киң авенидалары*

**АВЕНЮ́** *и. фр.* Як-ягына агачлар утыртылган киң урам

**А́ВИА-** *лат.* 1) Кушма сүзләрдә авиациягә караганлыкны белдерә торган беренче кисәк (мәс., *авиабаза, авиаконструктор, авиазавод, авиасәнәгать, авиатехник һ.б.*)

2) Кушма сүзләрдә «һава» мәгънәсенә бәйләнешле, аңа караган беренче кисәк (мәс., *авиалиния, авиапочта, авиамодель һ.б.*).

**АВИАБА́ЗА** *и. лат.-гр.* Авиация, һава флоты эшләренә хезмәт күрсәтү өчен ремонт мастерскойлары, складлары булган аэродром. *М.Гаркави туган якларына – Казанга кайтып китә. Нәкъ шул чорда Татреспублика каршында авиабаза оештырыла.* Р.Ибраһимов

**АВИАДЕСАНТ** *и. лат.* Дошман территориясенә самолёт яки вертолёттан төшерелгән гаскәр; һава десанты. *Авиадесант операцияләрендә катнашу*

**АВИАДЕСАНТЧЫ** *и.* Һава десанты гаскәре сугышчысы. *Шәһәргә ун мең авиадесантчы кертелгән иде*

**АВИАКОНСТРУ́КТОР** *и. лат.* Самолётлар яки һава флоты двигательләре конструкторы. *Академик А.И.Микоян исемендәге авиаконструктор бюросында ясалган МиГ–31 истребитель-бомбардировщигы искиткеч самолёт була.* Р.Ибраһимов

**АВИАЛА́ЙНЕР** *и. лат.-ингл.* Күп урынлы пассажир самолёты, һава лай-

неры. *Хәзер инде авиакомпаниянең карамагында 17 авиалайнер исәпләнә.* Р.Ибраһимов. *Реактив авиалайнер*

**АВИАМОДЕЛИСТ** *и. рус к.* **авиамодельче**

**АВИАМОДЕЛЬ** *и. лат.* Оча торган аппарат моделе. *Безнең республикада спортның 20 дән артык хәрби-техник төре буенча эш алып барылды: авиамодель, самолёт, дельтаплан, парашют, планер, мотокросс, автокросс, авторалли, картинг, радио, биатлон ---.* Г.Шакиров. *Бензин двигательле авиамодель*

**АВИАМОДЕЛЬЧЕ** *и.* Оча торган аппаратларның модельләрен ясаучы һәм, очыртып карау нигезендә, авиация эшенә өйрәтүче. *Зыятдин картны авиамодельчеләр түгәрәге оештырырга кодалаган, имеш.* Р.Вәлиев. *Авиамодельчеләр ярышы*

**АВИАНО́СЕЦ** *и. рус* Диңгез авиациясе өчен хәрәкәттәге база булып хезмәт итә торган диңгез корабы. *«Кирсадж» авианосецы, суда тугыз көн йөзгәннән соң, аларны Сан-Франциско шәһәренә китерә.* Ш.Мостафин

**АВИАПО́ЧТА** *и. лат.-ит.* Һава почтасы. *Ә легендар Михаил Водопьянов – Мәскәүдән Казанга көне-төне авиапочта ташып, шушы һава трассасында канат ярган мәшһүр очучы.* Р.Ибраһимов

**АВИА́ТОР** *и. фр.* Очучы, пилот. *Ул очу аппаратлары янында кайнашкан авиаторлар белән кул биреп күрешә.* Р.Ибраһимов. *Чкалов – илнең данлыклы авиаторы*

**АВИА́ТОРЛЫК** *и.* Очучылык, авиатор булу. *Авиаторлык хезмәте. Авиаторлык профессиясе*

**АВИАҺӘЛАКӘТ** *и.* Һава флоты катастрофасы, самолёт, вертолёт һ.б.ш. очкычларның һәлакәткә юлыгу очрагы. *2003 ел – авиаһәлакәтләрнең иң күп елы булыр, дип фаразлана.* Мәдәни җомга

**АВИА́ЦИЯ** *и. фр.* Һава флоты. *Авиация, туплар, танклар ул хәрби ныгытмаларны, япон гаскәрләрен ут астында тоталар.* Г.Ахунов. *Немец авиациясе очып кергәч тә, --- бернинди хәтәр сизмичә һәм беркемнән явызлык көтмичә, тыныч кына яшәгән шәһәрне ярты сәгать эчендә җир белән тигезләде дә куйды.* Ә.Еники. *Мин бит армиядән качмыйм, киресенчә, гомеремне хәрби авиациягә багышларга әзер.* Р.Мөхәммәдиев

**АВИАШО́У** *ингл. спорт* Очу спортының бәйрәм тамашасы. *Авиашоуда катнашу*

**АВИТАМИНОЗ** *и. лат. мед.* Организмда витаминнар җитешмәү сәбәпле була торган авыру. *Авитаминоз организм витаминнарны үзләштерә алмаган очракта да күзәтелә.* Биология

**АВОКА́ДО** *и. порт.* Дәфнәчәләр семьялыгыннан, ашарга яраклы эре җимешле мәңге яшел тропик агач һәм аның җимеше

**АВО́МЕТР** *и. ингл. тех.* Амперметр, вольтметр һәм омметрның – өчесенең дә эшен башкара торган прибор

**АВРАЛ** *и. ингл.* 1) Хәрби корабльдә барлык команданың катнашы белән үткәрелә торган ашыгыч эш. *Кичке прогулкаларда, аврал вакытларында, строй белән культпоходларга барганда, безгә «Варяг», «Плещут холодные волны» --- кебек җырларны җырлаталар иде.* М.Мәһдиев

2) *куч.* Бөтен коллектив катнашында күмәк башкарыла торган ашыгыч эш. *Аврал режимында эшләү*

**АВРАН** *и. нем. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан, уртача һәм тропик поясларның тау битләрендә үсә торган үләнчел үсемлек; бизгәк үләне. *Авран үләненең уртача һәм тропик поясларның тау битләрендә егермеләп төре үсә.* Биология

**АВСТРА́ЛИЯЛЕ** *и.* Австралиядә яшәүче җирле халык һәм шул халыкның бер кешесе. *XX гасыр алдыннан Фрэнк Мельбури исемле австралияле Америкага килгән һәм үзен «яңгырлар яудыручы» дип игълан иткән.* Ватаным Татарстан. *Ә инде финалда рейтинги буенча дөньяда икенче урында баручы австралияле Лейтон Хьюит та Маратка каршы тора алмады.* Татарстан яшьләре

**А́ВСТРИЯЛЕ** *и.* Телләре герман телләре төркеменә караган, Австриядә яшәүче җирле халык (үзатамалары – эстеррайхер) һәм шул халыкның бер кешесе. *Альп тауларын уңышлы үтеп, австриялеләр белән кушылгач, батырлык күрсәткән офицер һәм солдатларны бүләкләү башлана.* З.Зәйнуллин. – *Аем сорри! – диде австрияле.* Р.Батулла

**АВТО** *и. сир.* Автомобиль. *Такыр юлдан совхоз автолары Ашлык ташый хәзер калага.* М.Җәлил

**А́ВТО-** I *гр.* Кушма сүзләрдә «автомобиль» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *автокар, автокатастрофа, автоколонна, автомашина, автопарк, автотрасса, автотуризм, автотурист, автофургон* һ.б.)

**А́ВТО-** II *гр.* Кушма сүзләрдә «автомат» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *автотормоз, автоклав, авторучка, автодиспетчер* һ.б.)

**А́ВТО-** III *гр.* Кушма сүзләрдә «үзйөрешле», «үз двигателе белән хәрәкәт итә торган» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *автодрезина, автогрейдер, автофургон*)

**А́ВТО-** IV *гр.* Кушма сүзләрдә турыдан-туры, «үзе, үз кулы белән язылган» мәгънәсен аңлата торган беренче кисәк (мәс., *автобиография, автограф, автореферат* һ.б.)

**АВТОБА́ЗА** *и. гр.* Автомобиль базасы; автомобильләрне туплау һәм ремонтлау урыны. *Кайдарак соң ул автобаза дигәнең?* Ә.Дусайлы

**АВТОБИОГРА́ФИК** *с.* Авторның тормыш юлын, тәрҗемәи хәлен чагылдырган. *Тагын менә нәрсә: автобиографик повестьларны еш укыйбыз. Ул әсәрләрдә еш кына вузда укыган студентлык еллары турында сүз бара.* М.Мәһдиев. *Моннан егерме еллар элек «Урталыкта» исемле, күбесенчә автобиографик әсәремдә, «остазның куркак шәкерте булу»ның аянычлыгы хакында бер искәртеп киткән идем инде мин.* А.Гыйләҗев

**АВТОБИОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Тәрҗемәи хәл; берәр кешенең үз тормыш юлы турындагы язмасы. *Автобиографиямне язарга утырсам, аптырап калам. Кем соң минем әтием? Кайда ул? Нинди кеше булган соң ул?* И.Салахов. *Иң элек ул теге саран хуҗаның «автобиографиясен» сөйләп чыга. Аннары*

*туган-тумачаларын сүгәргә керешә.* В.Нуруллин. *Инде бетмәс-төкәнмәс анкеталарда, автобиографияләрдә үзенең социаль чыгышын яшерүгә --- артык ихтыяҗ калмый.* Р.Әмирхан

**АВТО́БУС** *и. ингл.* Билгеле бер маршрут буенча пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган күп урынлы ябык автомобиль. *Ә өзлексез йөреп торган автомобильләр, автобуслар, трамвайлар шырпы тартмалары шикелле кечкенә генә булып күренәләр.* А.Шамов. *Автобус асфальт юлдан выжылдап кына оча.* Г.Әпсәләмов

**АВТО́ГРАФ** *и. гр.* 1) Авторның үз кулы белән язылган истәлекле язмасы яки имзасы. *Мин аңа [Хәсән Туфанга] китапларымны автограф белән бүләк иткәләдем.* М.Мәһдиев. *Бишебез төшкән ике йөздән артык фотокарточка эшләтеп алган идек. Автографларыбыз куелган ул карточкалар бик тиз арада сатылып беттеләр.* М.Фәйзи. *Елгыр күзле, нурлы йөзле бу яшь кызга ак бәхетләр теләп, автографымны язып бирдем.* Казан утлары

2) Авторның үз кулы белән язылган текст, үз кулъязмасы

**АВТОГРА́ФИК** *с.* Автор үзе язган, авторның үз кулы белән язылган

**АВТОЗАВОД** *и. рус* Автомобильләр һәм аларга запас детальләр эшләп чыгара торган завод

**АВТОКАР** *и. ингл.* Йөк ташу өчен хезмәт итә торган, эчке янулы двигательле яки аккумуляторлы арба

**АВТОКРАН** *и. рус тех.* Авыр йөкләрне күтәреп күчерү өчен, автомобиль шассиенә утыртылган йөк күтәрү краны. *Күпме азаплансак та, аны [ташны] урыныннан кузгата алмадык. Ахырда төзелештән автокран китерергә булдык.* М.Сәлим

**АВТОКРАТ** *и. гр.* Чикләнмәгән югары властька ия кеше; патша, монарх

**АВТОКҮПЕР** *и.* Елга, чокыр, тимер юл һ.б. аша автомобиль транспорты үтү өчен салынган күпер. *Казансу аша эшләнгән автокүпернең исеме «Миллениум» дип атала.* Татар иле

**АВТО́Л** *и. лат. тех.* Автомобиль, трактор двигательләрен майлау өчен кулланыла торган, нефтьне кудыртып табылган май. *Автолга буялып бетү*

**АВТОЛА́ВКА** *и. рус* Көнкүреш әйберләре белән күчеп йөреп сәүдә итү өчен көйләнгән, өсте ябулы автомашина. *Автолавка кырыендагы зур карагай күләгәсендә җыелма өстәл тора.* И.Салахов. *Сәет кичә, автолавкага барып, Зөбәрҗәткә – күлмәклек, ефәк шарф, Газизәгә бәләкәй генә, бик килештереп тегелгән моряк костюмы алды.* И.Салахов

**АВТОМАГИСТРАЛЬ** *и. лат.* Машиналар йөрү өчен махсус төзелгән юл. *[Кубадагы] Бу автомагистраль совет белгечләре ярдәмендә төзелгән.* Р.Ибраһимов

**АВТОМАТ** I *и. нем.* **1.** 1) Тиешле эшләрне кеше катнашыннан тыш башкара ала торган аппарат (машина, прибор, җайланма һ.б.). *Егетнең: «Армиядән коткарып калырга әти-әниләр йөз мең акча түләделәр», – дию, Фатыйманың күңелен йомшартып акча алу һәм шуның белән уен автоматларында оттырган бурычын түләү иде.* Ф.Яруллин. *Алар «Меха» дип язылган кибет, отыш автоматлары янына килеп, сул кулдарак үскән каеннар астында күкрәгенә ниндидер язу аскан картны күреп алдылар.* А.Хәлим

2) Үзлегеннән тиз ата торган сугыш коралы. *Стенага эленеп куелган автомат та, парторгның каскасы белән шинеле дә сугыш заманыннан бик ерактагы әйберләр кебек, истәлекләр кебек кенә күренәләр.* Г.Әпсәләмов. *Василийның башында бер исәп тә туып өлгерде: менә шулай, өркетмичә генә, немецларга якынлашып, кинәт кенә автоматларын тартып алып булмасмы?* Ә.Еники. *Автомат, гранатомёт кебек яңа корал алган яшь сугышчылар аеруча тырышалар.* Казан утлары

3) Автомат рәвешендәге балалар уенчыгы, уенчык автомат. *«Әти, миңа автомат алып кайт», – дип, сабыйларча мөлаемлык белән язып торуы исенә төшкәч, күңеле тулып, тамак төпләре кытыкланып китте.* И.Гази

**2.** *с. мәгъ.* Автоматлаштырылган юл белән, үзлегеннән эшли торган. *Кабина тәрәзәсе алдындагы автомат щёткаһың туктаусыз уңга-сулга авышып, пыяланы сөртеп-тазартып торуына да карамастан, юл бөтенләй күренми башлады.* И.Салахов. *Бәшир балачактан ук төрле электр автомат җайланмалар уйлап табу белән мавыга.* Татарстан

◊ **Автоматтан атылгандай** Бик тиз, зур тизлек белән. *Мәктәптә озын тәнәфес булуга, бөтен бала-чага, автоматтан атылгандай, өенә йөгерә.* М.Мәһдиев

**АВТОМАТ** II *и. нем.* Телефон-автомат урнаштырылган кабина. *Автоматтан шалтырату*

**АВТОМА́ТИК** *с.* 1) Үзеннән-үзе (үзлегеннән) эшли торган, автоматикага бәйләнешле, автоматлаштырылган. *Автоматик стабилизатор. Машиналарның автоматик системасы. Транспорт хезмәтенең автоматик счётлары*

2) *күч.* Ирексездән, уйламыйча башкарылган. *Автоматик хәрәкәтләр ясау*

**АВТОМА́ТИКА** *и. нем.* 1) Эш процессларын автоматлаштыру юлларын һәм чараларын эзләп табу, өйрәнү белән шөгыльләнә торган фән һәм техника өлкәсе

2) Автомат рәвештә, үзлегеннән эшли торган механизмнар, җайланмалар җыелмасы. *Барысы да электроника, автоматика галәмәтләре икән, шулай да ниндидер мещанлык исе аңкып тора үзләреннән.* Г.Госман. *Мәскәү аэропортлары инде күптән автоматикага җайлаштырылган.* Р.Ибраһимов

**АВТОМАТЛАШТЫРУ** *ф.* Хуҗалыкта, гомумән җитештерү, эшләп чыгаруга караган өлкәләрдә автоматикадан файдалану. *Сыерларның җиленнәрен юу, корыту һәм саву белән идарә итү тулысынча автоматлаштырылган.* М.Хәсәнов. *--- игътибарга лаек тагын бер әһәмияте шунда: полимер материалларны куллану, технологик яктан эш процессын автоматлаштырып, конвейерга көйләргә мөмкинлек бирә.* Р.Ибраһимов

**Автоматлаштыра бару** Акрынлап, аз-азлап автоматлаштыруны арттыру

**Автоматлаштыра башлау** Автоматлаштырырга керешү, автоматлаштыруны башлап җибәрү

**Автоматлаштыра төшү** Бераз автоматлаштыру

**Автоматлаштырып бетерү** Бөтенесен автоматлаштыру

**Автоматлаштырып җиткерү** Ахырына кадәр автоматлаштыру

**Автоматлаштырып килү** Күптәннән, электән үк, акрынлап, аз-азлап автоматлаштыруга ирешү

**Автоматлаштырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да автоматлаштыру

**АВТОМАТЛАШУ** *ф.* 1) Җитештерү, эшләп чыгаруга караган өлкәләргә төрле автомат приборлар, җайланмалар кертелгән булу. *Заман урманы машиналаша, автоматлаша!* И.Юзеев

2) *күч. сөйл.* Автоматка әйләнү, автоматик рәвештә эшләү

**Автоматлаша бару** Акрынлап, азазлап автоматлашу. *Хезмәт процессларының һаман да автоматлаша баруы, кибернетиканың көннән-көн тормышка, аңга ныграк үтүе һәм башка бик күп казанышлар Җир һәм Кеше, Кеше һәм Галәм арасындагы мөнәсәбәтләргә җентекләбрәк карарга боералар.* Р.Харис

**Автоматлаша башлау** Автоматлаштыру процессы башланып китү

**Автоматлаша төшү** Тагын да автоматлашу

**Автоматлашып бетү** Тәмам автоматлашкан булу, тулысынча автоматлашкан хәлгә килү

**Автоматлашып җиту** Тиешенчә дәрәҗәдә автоматлашу

**Автоматлашып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә автоматлашу

**АВТОМАТЛЫ** *с.* 1) Автоматы булган, автомат белән коралланган. *Тере коридор булып баскан автоматлы сакчыларның этләре, команда биргәндәй, шашып, чабучыны өзгәләрдәй үрсәләнеп өрә башлады.* И.Сиражи. *Танклар өстенә автоматлы унар сугышчы утыртып һөҗүм итәләр.* З.Зәйнуллин

2) Автомат эшләүгә көйләнгән. *Автоматлы станокны эшләтеп җибәрү*

**АВТОМАТЧЫ** *и.* 1) Автомат белән коралланган сугышчы, гаскәри. *Свастикалы машина саен берничә автоматчы урнашкан.* К.Нәҗми. – *Качарга уйламагыз, сез автоматчылар белән уратып алынган! – дип кычкыра-кычкыра, Сәйфелмөлеков бандитларга атаба йөгерде.* Ф.Яруллин

2) Автомат аппаратта эшләүче

**АВТОМАШИ́НА** *и. гр.-лат. к.* **автомобиль**. *Тагын станциягә килә. Вокзалда йоклый. Икенче көнне автомашина белән юлга чыга.* И.Салахов. *Җил автомашина моторы өстенә ябылган сырма капотны юл буенча тартып-йолкып килде-килде дә, бер борылышта кинәт күтәреп алып китеп, күздән югалтты.* И.Салахов

**АВТОМОБИЛЬ** *и. гр.-лат.* Рельссыз юлларда йөк яки кеше ташый торган эчке янулы машина. *Аңа [рәссамга] махсус автомобиль бирелде.* Г.Кутуй. *Мөниргә автомобиль бик әкрен бара шикелле тоелды.* Г.Әпсәләмов. *Җиңел автомобильләр әле сирәк очрый торган замана иде, бәхетеңә орлык ташучы йөк машинасы килеп чыкса гына.* Т.Галиуллин

**АВТОНОМ** *с. гр.* **1.** Үзидарәле, мөстәкыйль идарә итү хокукы алган. *Республикаларның хәзерге шартларындагы яшәешен хәтта «автоном» дип әйтү дә кыен.* Татарстан. *Хәер, хәзер аптекалар челтәре юк инде, һәр аптека – үзе бер автоном оешма.* Мәдәни җомга

**2.** *рәв. мәгъ.* Бәйсез, мөстәкыйль рәвештә. *Мәшһүр тәре яулары, бу хәрәкәтнең автономрак эш йөрткән көнчыгыш һәм көнбатыш бүлекләрен берләштереп, ул чордагы сәяси картаның дөньякүләм мәгълүм бердәмлеген мәйданга китерә.* М.Гайнетдинов. – *Автоном эшли торган электр станциясе дә сафка бастырылачак, – дип ачыклык кертә директор.* Борынгы Калатау итәгендә

**АВТОНО́МИЯ** *и. гр.* Үзидарә, мохтарият, мөстәкыйль идарә итү хокукы. *1917 елгы инкыйлабтан соң, кыска гына булып узган Ленин заманында, совет хөкүмәте буйсындырылган милләтләргә автономия бирә.* М.Шакирҗанов. *Мәскәү милли-мәдәни автономиясенең эшчәнлеге һәрвакыт игътибар үзәгендә.* Мәдәни җомга. *Свердловск өлкәсенең күпчелек шәһәрләрендә һәм Екатеринбургның үзендә региональ автономия җитәкчелегендәге бүлекчәләр эшләп килә.* Мәдәни җомга

**АВТОНО́МИЯЛЕ** *с.* Автономиягә, үзидарә хокукына ия булган, автономия алган. *Әгәр дә, автономияле республикалар вәкилләре, шул исәптән мин дә, күп көч куймасак, уяулык күрсәтмәсәк, закон проектларының байтагында безнең хокуклар шактыйга чикләнгән булыр иде.* Т.Миңнуллин

**АВТОПАНСИОНАТ** *и. гр.-лат.* Автотуристлар өчен кунакханә. *Автопансионат бинасы*

**АВТОПАРК** *и. гр.-лат.* Автомобильләр куела һәм ремонтлана торган махсус урын. *Автопаркта чәчелеп, тузып яткан иске бульдозерын көчхәл белән сафка бастыра алгач, ул, ниһаять, кырга көзге сукага чыкты.* Х.Ибраһимов

**АВТОПИЛОТ** *и. гр.* Очкыч аппаратлар (мәс., самолёт, ракета һ.б.), автомобиль белән автоматик рәвештә идарә итә торган җайланма. *Очкыч кинәт калтырап алды. Автопилот көйлиләр, дип уйладым.* М.Юныс

**АВТОПИЛОТАЖ** *и. гр.* Автоматлаштырылган очкыч аппаратлар (планер, ракета һ.б.) белән һавада төрле манёврлар ясау. *Үсмерләр кеше ышанмаслык автопилотаж фигуралары ясап күрсәттеләр.* Мәдәни җомга

**АВТОПОРТРЕТ** *и. гр.-фр.* Кемнең дә булса үз кулы белән эшләгән үз портреты. *Бакый Урманченың автопортреты*

**А́ВТОР** *и. лат.* Фән, матур әдәбият, сәнгать, проектлаштыру һ.б.ш. өлкәләрдә иҗат итүче яки нәрсә дә булса уйлап табучы. *Син – заводыбызның мактанычы бит. Син – шундый гүзәл проектның авторы.* Г.Иделле. *Лирик шигырьдә автор өчен иҗат объекты булып кешенең хисе, эчке кичереше тора.* М.Җәлил. *Арча педагогика көллияте укытучылары Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова – татар балалары өчен «Әлифба» дәреслеге авторлары.* Татарстан // Берәр эш-шөгыльнең башкаручысы. *1990 елның язгы көннәрендә өйдә телефон шалтырады.*

*Авторы Мөхәммәт Мәһдиев булып чыкты.* Т.Галиуллин. *Әсәрнең сыйфатын әдәбиятның төп кануннарына таянып бәяләү юкка чыккач, авторның түшендәге калайларга, алган бүләкләренә, хакимияткә якын булуына таянып эш итү киң колач җәйде.* М.Юныс

**А́ВТОРДАШ** *и.* Берәр өлкәдә кем белән булса да уртак иҗатташлык, бергәләшеп иҗат итү эшчәнлеге. *Рәссам язучының чын мәгънәсендә автордашы булса гына, чын балалар китабы дөнья күрә ала, дип уйлыйм мин.* Р.Миңнуллин

**А́ВТОРДАШЛЫК** *и.* Икенче кеше яки кешеләр белән бергә нәрсәнең дә булса (әсәр, фәнни хезмәт, проект һ.б.ш.) авторы булу

**АВТОРЕФЕРАТ** *и. гр.-лат.* Берәр фәнни хезмәтнең автор тарафыннан язылган кыскача эчтәлеге. *Авторефератны укырга торганда гына, бернichә шагыйрь ияртеп, Илдус Гаделшин килеп керде.* Ф.Яруллин. *Ул минем авторефератны актарып чыкты, --- аннан кайсыдыр битенә тукталды.* М.Мәһдиев

**АВТОРИТАР** *с. фр. кит.* 1) Хакимияткә сукырларча буйсынуга нигезләнгән. --- *тарихта өч идарә итү ысулы билгеле: демократик, тоталитар һәм авторитар ысуллар.* К.Гыйззәтов. *Кызганыч, олуг галимнәребез туып килә торган яңа мәгариф системасын бүгенге унитар һәм авторитар дәүләт принципларыннан чыгып бәяли.* И.Әмирханов

2) Үзенең хакимиятен, авторитетын ныгытуга омтылган. --- *авторитар тәнкыйть пропагандалаган сәяси юнәлешне генә сыйдыра алган тар реализм.* Ә.Баян

**АВТОРИТАРЛЫК** *и.* Үзенең хакимлеген, авторитетын ныгытуга, үзенә буйсындырырга омтылган диктаторлык режимы системасы, идарә системасы. *Авторитарлык һәрвакыт безнең халыкка каршы эшләде, аны исән калукалмау чигенә җиткерде.* Р.Хәкимов. *Тоталитарлык та, авторитарлык та – шәхес белән халык массаларының мөнәсәбәтен гәүдәләндерүче күренешләр.* К.Гыйззәтов

**АВТОРИТЕТ** *и. нем.* 1) Җәмгыятьтә, халык арасында ышаныч, ихтирам казанганлык; абруй, дәрәҗә. *Бөтенесе аңа, түбәнчелек белән, «Хәбиб Гатауллович» дип кенә торалар. Шушы үзе генә дә кешенең эштәге авторитетын гына түгел, аның кайбер башка якларын да аңлатса кирәк.* Ә.Еники. *Лобачевскийда үз дәрәҗәсен тою хисе бик көчле була, ул үз йогынтысын һәм авторитетын да яхшы белеп тора…* Җ.Тәрҗеманов. *Ә «авторитет» дигән нәрсә аңа кирәк, бик кирәк. Ни өчен дигәндә, соңгы бер-ике елда бу мәсьәләдә эшләре бик шәптән түгел аның: абруе күзгә күренеп кими бара.* Мирас

2) Башкаларга йогынты ясарлык, ышаныч казанган, абруйлы кеше; авторитетлы кеше. *Аннары сүз авиациягә, тавыштан тиз очучы самолётларга, ракеталарга сикерә. Бу өлкәдә безнең үз авторитетыбыз бар.* Г.Әпсәләмов. --- *ул сәяси яктан миңа караганда көчлерәк булганга, аннары партиядә дә әгъза булып торганга, бу мәсьәләләрдә Муса минем өчен зур авторитет иде.* Р.Мостафин

3) *куч.* Башкаларны үзенә ияртә алырлык кеше, лидер. --- *караклык гамәле белән астан гына эш йөртте, авыл яшьләре арасында чыккан вактөяк каршылыкны җайлаучы «авторитет» булды.* Мәдәни җомга

4) *куч.* Җинаятьчел даирәләрдә йогынтылы кеше. *Розаның ир туганнары --- җинаятьчел дөньяда зур абруй казанган «авторитет» егетләр булып чыкты*. Казан утлары

**АВТОРИТЕТЛЫ** *с.* Абруйлы; ышаныч, авторитет казанган. *Фанатик Казан татарларының тискәрелеген җиңеп, ачылган Русско-татарская школада авторитетлы татар укымышлыларыннан беренче булып эшләүче кем иде? – Мәрҗани.* М.Госманов. *Үзбәкстанга «частное лицо» булып түгел, берәр авторитетлы, сүзе үтә торган оешма вәкиле булып барырга тиешмен, дип санадым.* Казан утлары

**А́ВТОРЛАП** *рәв.* Һәр авторны аерып, берәмтекләп. *Мин Октябрь борылышына кадәр чыккан бөтен татар вакытлы матбугатын картотекага алып, битләп, авторлап укып чыктым.* М.Мәһдиев

**А́ВТОРЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Үз әсәренең күчермәсен, тәрҗемәсен, репродукциясен һ.б.ш.ны бастырып чыгару өчен, рәсми рәвештә раслату, рәсмиләштерү

2) *сөйл.* Үз исеменнән сөйләү. *Монда – барысына да күптән таныш булган хәлләргә бермә-бер яңалык өстәп, «авторлаштырып» сөйләүчеләр аерым почётта.* Ә.Хәсәнов

**Авторлаштыра бару** Һәрберсен, булган берсен авторлаштыру

**Авторлаштырып бетерү** Барысын да, тулысынча авторлаштыру

**А́ВТОРЛЫК** *и.* 1) Билгеле бер авторга караган булу. *Без вакытлы матбугат битләрендә Зөфәр Рәмиевнең имзасыз текстларның авторлыгын ачканын күрәбез.* Рифә Рахман. *Нәкъ менә быел аның [Мәсгут Имашевның] авторлык концерты минем ул ниятемне яңадан кабызып җибәрде.* Г.Ахунов. *Имашев җырларын җырлый халык… Февраль аеның башларында ике көн рәттән куелган авторлык концерты шуны раслады.* Г.Ахунов

2) Әсәрнең, проектның иҗатчысы булу. *Мин бер сүз дә әйтми аптырап торганда, яныма [Мәҗитов Илдар] килеп басты. Гадәтенчә, авызын ачмый тамак төбе белән көлеп: «Авторлык газабы кичерәбезме?» – диде.* Җ.Фәйзи

3) Иҗат иткән әсәрләрне бастыру һәм сату эшендә авторның махсус хокукы

**АВТОРУ́ЧКА** *и. рус* Эченә кара яки паста (гель) тутырылган язу әсбабы. *Гөлфия тынычланды, янә авторучкасын кулына алды.* Казан утлары

**АВТОСАУГЫЧ** *и.* Сыер саву өчен махсус автомат җайланма. *Шәми кызганнан-кыза барды. Фермада катлаулы аппаратлар: электроҗиһазлар, радиоидарә, автоэчергеч, автосаугыч. Авто да авто.* Р.Батулла

**АВТОСЕ́РВИС** *и. гр.-лат.* 1) Машиналарга барлык төр техник хезмәт күрсәтү эшләре

2) Шундый хезмәт күрсәтә торган урын. *Юл кырыенда, уңга борылып өч йөз метр үткәч автосервис барлыгын*

*күрсәтүче билге күреп, Айсылу машинасын шунда бора.* Ф.Яруллин

**АВТОСТРА́ДА** *и. ит.* Автомашиналар йөрү өчен махсус төзелгән киң юл, шоссе. *Әлеге өр-яңа автострада, Азатлык утравын буйдан-буйга кисеп чыгып, Кубаның башкаласы Гаванаңы Сантьяго-де-Куба шәһәре белән тоташтыра.* Р.Ибраһимов. *Автобус кузгалды. Автострада Тибр елгасы буйлап салынган.* М.Юныс

**АВТОТО́МИЯ** *и. гр. биол.* Кайбер хайваннарның үз тәненең кайбер әгъзаларын өзеп калдыра алу сәләте (мәс., *гидрасыман полиплар, кәлтәләр*). *Автотомия организмның югалган органнарын яңадан үстерү сәләте белән аңлатыла.* Биология

**АВТОТӨЯГЕЧ** *и.* Йөкне үзе төяп, ерак булмаган арага күчерә, бушата торган машина; үзтөягеч

**АВТОТРА́НСПОРТ** *и. гр.-лат.* Кешеләр һәм йөк ташу өчен автомобиль транспорты. *Биргали Баймактагы автотранспорт предприятиесенә эшкә керә.* Ф.Фәтхи

**АВТОТРАНСФОРМА́ТОР** *и. гр.-лат.* Көчәнешләрне төрлечә үзгәртеп була торган, беренчел һәм икенчел кәтүкләре бергә тоташкан трансформатор. *Тактаның уртасында --- кубны җылытуны көйләү автотрансформаторы куелган.* Химия технологиясенең процесслары һәм аппаратлары

**АВТОТРА́ССА** *и. гр.-нем.* Автомобиль юлы, тиз хәрәкәт итү өчен шартлары булган олы юл. – *Без бара торган автотрасса «җен юлы» дип аталган, – дип сөйли тәрҗемәчебез Алла Мельничук. – Шушыннан әсирләрне котырган тизлек белән, этләр өстерәп, таяклар белән кыйный-кыйный куганнар.* Т.Нәҗмиев

**АВТОЭЧЕРГЕЧ** *и.* Терлекләргә эчерү өчен автоматлаштырылган су бирү җайланмасы. – *Автоэчергеч җайларга, электр кертергә, электр белән савуны оештырырга... – Ул, башын артка ташлап, яңгыратып көлеп җибәрде.* А.Расих

**АВУ** *ф.* 1) Үсеп утырган яки төз утыртып куелган нәрсә егылу, горизонталь торыш алу. *1956 елның җилле, коры бер җәйге көнендә таш ауган.* М.Мәһдиев. *Ә бер кичне безнең горур наратыбыз гөрселдәп җиргә ауды. Ыңгыраша-ыңгыраша ауды нарат, гүя тормыш белән саубуллашу аңа авыр иде.* А.Хәсәнов. *Менә боз ява, агачлар ава, әллә кемнәр каһкаһәләп көләләр, кычкырышалар...* Ш.Камал

2) Егылып китү, тигезлекне югалтып, җиргә барып төшү. *Берәү саташа, урыныннан сикереп торып, ике бармагын авызына тыгып ачы итеп бер сызгыра да гөрселдәп урынына ава.* М.Мәһдиев. *Батырхан, хәлсезләнеп, урындыкка килеп ава.* Г.Ибраһимов. *Бу хатын иренең каберен табу белән кабер өстенә ауды, аны тырный-тырный акырып еларга тотынды.* Г.Ахунов

3) Каты авырып китү, урынга яту. *[Карт] Карчыгын җирләп кайткач, кайгысыннан үзе дә түшәккә ауды.* Ф.Яруллин. *Ә теге бичараның күзен инде кан баскан, ул инде сәкегә ауган.* М.Мәһдиев. --- *чая хатыны килеп, чираттагы җәнҗалларның берсен чыгарып киткәч, мин дә түзмәдем – икеме, өчме көннән соң, кан басымым күтәрелеп, урынга аудым.* Җ.Дәрзаман

4) Үсеп утырган үлән, куак һ.б. турында: бер якка яту, сөрлегү. *Корыган үсемлекләр су баскан туфракка ауганнар.* Ботаника. *Иксез-чиксез бодай диңгезе инде ава, ята башлаган.* Казан утлары

5) Бер якка кыйшаю, читкә янтаю, тайпылу. *Тәртә сынды, арба ауды, сыер үзе, чиләнне аударып, арт якка чыгып чапты.* Г.Бәширов. *Ташландык кое, --- бераз артка таба ауган рәшәткәсе, бакча коймасы --- ишегалдына ташландыклык төсе биреп тора.* Ф.Әмирхан

6) Оешкан, корып куелган нәрсә таркалып җимерелү, ишелеп төшү. --- *Искәндәрев, җилдәй очып, күпер өстеннән үтеп тә китә, һәм --- күпер тоташы белән гөрселдәп ава.* Ә.Еники. *Әбинең өе төртсәң аварга тора, яңартырга уйлаган идек.* Мирас

7) *күч.* Авышу, узу, үтү (вакытка карата). – *Өй күтәрәм, өмәгә! – дигән чакыру ишетелү белән, Әхмәдиләр, Шәяхмәтләр, Шәңгәрәйләр, Ситдыйклар, Җиһанша бабайлар җыелып килделәр дә, иртәнчәк кояш белән бергә тотынып, төш авуга өйне аякка бастырдылар.* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Авышу, фикере, карашы үзгәрү; кемнеңдер ягына басу. *Сания, ятимнең күңелсезләнгәнен күреп, аны иңнәреннән кочып алды һәм, әллә инде әнисен Илдар ягына авар дип шикләнде, шыңшып куйды.* Г.Гобәй. ---, *ахырдан, Давыт яңа фикергә ава, дамелла белән талаша, шәкертләрне котырта, дип, аны кадим мәдрәсәдән кудылар.* Г.Ибраһимов. *Тирә-якның түрәсе, мулласы – бар да аның җиле искән якка авалар.* Г.Ибраһимов

9) *күч.* Кинәт килеп чыгу, пәйда булу. *Ләкин Петя, дурак, өстенә ауган бу бәхетнең әһәмиятен дә аңламый, кадерен дә белми иде булса кирәк.* Ә.Еники

10) *күч.* Кемгә дә булса кагылу, бәйле булу (шик, гаеп һ.б.ш. турында). *Эш бик зурга китсә, казыйга хөкемгә барырга туры килә. Гаеп сиңа ауса, җәзаңны күрәсең...* М.Гафури

◊ **Аварга тору** 1) Җимерек, бик иске булу. --- *меңгә якын акча калган иде, чыгарып салдым шуны өсталгә: «Мә, минһәйтәм, иске мәчетегезнең манарасы кеше өстенә аварга тора. Турайтыгыз, рәтләгез шуны!»* Р.Вәлиев; 2) Көчсез, хәлсез булу. *Серёжаның җиленнән аварга торадыр әле.* Казан утлары. *Хәзер хатын-кыз карарлык егетләр бармыни? Кайсына карама, синең җилеңнән аварга тора. Җыены-сы малай-шалай.* Казан утлары; 3) Бик якында булу, терәлеп кенә тору. *Урман өскә аварга тора.* **Авар якка таба терәү салу** Булышлык күрсәткән булып, эшне бозу, артка җибәрү

**Ава башлау** Аварга керешү, янтая башлау. *Әмма көннәрнең берендә аның йөк төягән чанасы салулап китә дә бик текә яр астына таба ава башлый...* М.Хәсәнов

**Ава бару** 1) Торган саен ныграк аву, янтаю. --- *калак сөягe турында арттан бик каты сукканны, аркасын пешереп узганны һәм хәле бетүен, немецның кызыл кан буялган битенә таба ава баруын тойды.* Х.Камалов

2) Рәттән бер-бер артлы аву

**Ава тору** Берсе артыннан икенчесе аву. *Тик шуны алдан белеп торыгыз, татар гаскәрләре --- ава торалар, килә торалар ...* М.Әмирханов. *Мескен качкыннарның әле берсе, әле икенчесе ава торды.* Р.Сәгъди

**Ава төшү** Бераз аву. *Ул су буеннан әтигә таба, тар басмадан чыккандагы шикелле, әле бер ягына кыйшаеп, әле икенче ягына ава төшеп, чалыш-чолыш атлый башлаган иде.* Г.Бәширов

**Ава язу** 1) Чак кына аумый калу

2) *күч.* Көтелмәгән вакыйгага, эшкә, ишеткән сүзгә бик нык гаҗәпләнү, шаккату. *Авыл белән элеккеге Яков утары арасында йөгереп йөргән чакта, Гөлтуташ күрше хатыннар авызыннан гаҗәп сәер хәбәрләр ишетеп артына ава язды.* В.Имамов

**Авып бару** 1) Аз-азлап, акрынлап аву. *Габдулла абзыйны мин үзем аңга керттем, дип уйлый идем – хәзер ул да бит Гәрәйләр койрыгына тагылып авып бара.* Г.Ибраһимов. *Авып барган имәнне яшен уты урталай ярып уздымыни!* Н.Хәсәнов.*– Ә син үз эшеңне кара! Кибәнең бер якка авып бара! – дип, сикерә-сикерә булса да, ташыган печәнен кыска сәнәк белән аткаруын белде.* Ф.Абдуллин

2) Бер-бер артлы аву. *Чалгы артыннан ачылып, авып барган җиләк тәлгәшләре күз явын алып, авыз суларын китерә.* З.Фәйзи

**Авып бетү** Бөтенләй, тулысынча аву; барысы да аву. *Берничә минуттан бөтен тирә-як тынган, бөтен полк иң актык солдатына кадәр юл читенә авып беткән...* Г.Бәширов. *Мәҗлес төнге икеләргә кадәр дәвам итеп, кайсы кая авып беткәч кенә тукталды.* Р.Сәгъди

**Авып калу** Билгеле бер вакыттан, вакыйгадан соң, нинди дә булса сәбәп белән ауган хәлгә килү. *Иңенә, күңеленә йөк тавы авып калды.* Ф.Җамалетдинова

**Авып китү** Көтмәгәндә, уйламаганда кинәт аву. *Әни сискәнеп күтәрелеп карады, пышылдап кына тагын: «Ә...ә», – диде дә, ике кулы белән күкрәген кысып авып китте.* И.Салахов. *– Кая, Гази абый, өегезгә үк кертеп куйыймчы үзегезне... – Рәхмәт, Өлфәт, борчылма, – диде Гази, авып китүдән курыккандай, һаман да әле машинаның ачык ишегеннән кулын алмыйча.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Көтелмәгән вакыйгадан, эштән шаккатып калу, бик нык гаҗәпләнү. *Авыл советы рәисе агарынды, баскан җирендә авып китәрдәй булды.* Я.Шәфыйков

**Авып тору** 1) Әле, хәзер, күз алдында ауган торыш алу, ауган торышта булу. *Кайбер ерганак-ерымнар шактый тирән казылган, ярларының югары өлеше ерымнар өстенә авып тора иде.* Т.Нәбиуллин

2) Бертуктаусыз, әледән-әле аву; бер-бер артлы аву

3) *күч.* Бик якын, янәшәдә генә булу. *Урман өскә авып торгач, ипи пешерергә дип, утынны җәй буе күтәреп ташыйбыз.* З.Дәүләтов

4) *күч.* Бертуктаусыз туу, берсе артыннан берсе барлыкка килү, килеп чыгып тору. *Мохтарның хыялында төрле уйлар, ермакланып җәелгән ташкын шикелле, әрле-бирле авып тордылар.* Ш.Камал

**Авып төшү** Егылу, түбәнгә мәтәлү. *Хәзер мәтәлчекне генә булдыра алмады, башын җиргә кадап, аякларын күтәрә башлауга, яны белән лап итеп авып төште.* Г.Гобәй. *Шунда ук аның [егетнең] күз аллары караңгыланып китте, башы, хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште.* Ә.Еники. *Сакчының авыр гәүдәсе, янтаеп, бераз ат өстендә селкенеп барды да кинәт җир өстенә авып төште.* И.Гази

**Авып утыру** Бераз ауган торышта булу. --- *ярым авып утырган багана башларында ят кошлар күренгәли.* Г.Госман

**АВЫЗ** *и.* 1) Өске һәм аскы казналыклар арасыннан йоткылыкка кадәр куышланып киткән сөйләү (кешедә) һәм ашау функциясен башкара торган әгъза. *Авызына теле сыймый, теленә сүзе сыймый.* Әйтем. *Исерекнең теленә бик мәгънәле бер сүз килгән. Авызы шуны әйтәм дисә, бык-бык, дигән.* Н.Исәнбәт. *Салкын җилле көн булуга карамастан, атлар бик нык тирләгән, авызлары күбекләнгән, өсләреннән пар күтәрелә.* А.Шамов. *Авыз куышлыгында азыкның тәме беленә, азык ваклана һәм сәләгәй белән чылатыла.* Анатомия

2) Мич, шалаш, алачык һ.б.ш. кебек, эче куыш нәрсәләрнең алгы өлешендәге ачыклык. *Акшары коелып беткән, бер якка кыйшайган мичнең корымлы авызы шомлы гына ыржаеп тора.* А.Шамов. *Аны мич авызы каршында керләр уып торган хатыны каршылады.* А.Расих

3) Кар базы, кое, шахта һ.б.ш. кебек, эче җирне казып ясалган корылмаларның өске өлешендәге ачык торган урын, башлангыч өлеше. *[Сөләйман] Бер кулы белән баз авызының бурасына ябышты.* К.Тинчурин. *«Җиде күлдән» әйләнеп килгәнче, Каратаев заводында тәгәлләнмичә калган коеның авызы ишелеп бүрәнкәләнгән иде...* К.Кәримов. *Фәнис, башы белән ымлап, ис-акылларын югалта язып утыручы Нәзирә белән Айгөлгә аю өененең авызына таба барырга кушты.* Г.Гыйльманов

4) Янартау түбәсендә лава агып яки атылып чыга торган тирән тар тишек. *Без, янартау авызыннан атылган утлы туфрак һәм көл булып, һавага ыргытылдык.* Ә.Еники. *Кайдадыр җир тетри, кайдадыр янартаулар авызыннан ут чәчелә.* Казан утлары

5) Ваза, кувшин, шешә, банка кебек савытларның тараеп килгән ачык башы. *Бу банканың авызы бик тар*

6) Утлы кораллар көпшәсенең снаряд, пуля атылып чыга торган тишеге. *Дары белән атыла торган ау мылтыгы авызы белән күккә карап тора --- .* М.Галәү

7) Капчык, пакет кебек нәрсәләрнең бәйләнә торган өске ягы. *Капчык авызын бәйләү*

8) Елга яки инешнең башка зуррак елгага, күлгә койган урыны; тамак

9) Урман, әрәмәлек, агачлык кебек җирләргә кереп китә торган урын, юл ачыклыгы башланган урын. *Сәлим шунда ук нечкә генә кыңгырау тавышы ишетте, һәм урман авызында җигүле ат күренде.* Г.Гобәй. *Үзе яшь, үзе нарат урманы да булганга, үзе урман*

*авызы да булганга, [бередә] бер дигән майлы гөмбәләр дә бар иде.* Г.Хәсәнов

10) Кеше, җан иясе. *Әткәңнең арышы уңмаган. Иманалар, бурычлар түлисе бар, бер тиен акчасы юк, ә авызлар әллә ничәү – ашатырга кирәк.* Г.Тукай

11) Сөйләү өчен хезмәт итә торган орган, тел. *Иләк сорарга да авыз кирәк.* Әйтем. *Авыз саклаган – җан саклар.* Мәкаль

◊ **Авыз ачтыру** Рамазан аенда, кояш баегач, ураза тотучы мөселманнарны ашка чакырып мәҗлес үткәрү. **Авыз ачу** 1) Берәүгә эндәшеп сүз башлау, сүз кушу, әйтү; ни дә булса әйтергә җыену. *Мәчет картлары Мифтахка авыз ачарга да ирек бирмиләр --- .* К.Нәҗми. *Әгъзам Билал Шәңгәрәевнең бөтен мәхәббәт тарихын белә, бу мәхәббәт бар чакта, ул үз хисе турында авыз ачарга да курыкты...* Г.Әпсәләмов. *Киткән чакта Нуруллага таба каерылып-каерылып караса да, авыз ачып сүз әйтә алмады.* Р.Мөхәммәдиев; 2) *дини* Ураза тоткан көнне кояш баеганнан соң ифтар кылу; ризык кабул итү, ашау; 3) *шаярт.* Кием сүтелү, ертылу. **Авыз ачып** 1) Бернәрсәсез, буш. *Иң җайсызы – авыз ачып, акчасыз калудыр әле.* Т.Галиуллин; 2) Булган мөмкинлекләрдән файдаланмыйча, чара күрмичә. *Көзгә хәтле дөньяны корытасың, болай булгач. Авыз ачып күккә карап утыргач.* Ә. Баян. **Авыз ачып йөрү** Сизгер булмау, уяулык сакламау, гамьсез булу. *– Ярый алайса, бар, эшлә, тик моннан соң авызыңны ачып йөрмә, – дип озатты [Нургали].* Ә.Еники. **Авыз ачып калу** Ваемсызлык, игътибарсызлык күрсәтү аркасында берәр нәрсәдән мәхрүм булу, җитешмәү, өлгермәү. *Миңа мат ич!.. Авыз ачып калганмын, их...* Җ.Тәрҗеманов. **Авыз ачып, ләм-мим ник бер сүз дәшсен** Бер сүз дә дәшмәү, бернәрсә әйтмәү. *Малай шулхәтле шүрләде, авызын ачып, ләм-мим ник бер сүз дәшсен.* **Авыз ачып тору** 1) *к.* **авыз ачып йөрү.** *--- мин авыз ачып торган арада, ике кармак сабы, дулкыннарның үзләрен уздырып, еракта каралып күренгән таш күпер ягына агалар иде инде.* Ф.Сафин. *Һич кеше китереп бирмәс, алыгыз, дип, Үзебез авыз ачып торсак.* М.Гафури; 2) Нәрсәгә дә булса гаҗәпләнеп, сокланып карап тору. *Дөресрәге, тау хәтле печән олавын иңе белән җиңелчә генә кагылып аударганы, үзенең авыз ачып карап торганы хәтеренә төшүгә, Майкап тораташтай катып калды.* Т.Миңнуллин. **Авыз бер булу** Бердәм булу; алдан сүз куешканча эшләү. *Бүре күргән этнең авызы бер булыр.* Мәкаль. **Авыз бөрештерү, авыз бөршәйтү** Ризасызлык белдереп, иреннәрне бөрү. *Җиңгәсе, авызын бөрештереп, көйли-көйли әйтеп куйды.* Г.Бәширов. **Авызга авыз** Икәү генә бик якын торып, беркемгә дә ишеттермичә. **Авызга алгысыз** 1) Авызга кабарлык түгел, ачы яки чи, тәмсез һ.б.ш. сыйфатсыз ризык турында. *Бер көннәрне мин Чурпи Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лачкылдап тора.* Г.Камал; 2) Әйтергә тел әйләнмәстәй, начар, затсыз сүз турында. *Аның әйткәне – авызга алгысыз*; 3) Пычрак, җирәнгеч, түбән җанлы кешегә карата әйтелә. **Авызга карап тору** Кушканны берсүзсез тыңлау, ни кушсалар, шуны үтәргә әзер булу. **Авызга керү** Бик бирелеп, йотылып, колак салып тыңлау. *Карале, энем, Фәтхи абзыең әкиятне матур сөйли дигәч тә, авызына кереп бетәсең бит инде.* Н.Исәнбәт. **Авызга май (сары май) кабу** Берни дәшми, эндәшми тору. *Кызлар, нәрсә авызыгызга май каптыгыз? Җырлагыз!* Н.Исәнбәт. **Авызга су кабу (су кабып тору)** Сораганга җавап бирмәү, дәшми тору. *«Кантурга керәм, яңадан чутлатам!» – дигән әти. Әйтүен әйткән дә бит... Калган иптәшләре, авызларына су кабып, тик торганнар.* Ш.Маннур. *Егетләрнең күңеленә шом керде... Авызларына су капкандай, катып калды алар.* Р.Мөхәммәдиев. **Авызга сүз төшмәү** Әйтергә кирәкле сүз табылмыйча тору. *– Ник әйтмисең? – Авызыма сүз төшми әле.* Н.Исәнбәт. **Авызга хуҗа булу** Артын уйлап сөйләү; эндәшми кала белү. **Авызга чәйнәп салу** Җентекләп, бәйнә-бәйнә аңлатып бирү. **Авызда ботка пешерү** *к.* **авыз эченнән ботка пешерү**. **Авызда сүз тормау** Сер саклый белмәү. *Өстеңдәге күлмәгеңнең Җиң очлары каралы, Авызыңда сүз тормыйдыр, Тешең бигрәк аралы.* Җыр. **Авыздан авызга (сүз) китү** Хәбәр таралу, телдән-телгә сөйләнү. **Авыздан акты, тамакка кермәде** Була-була, дип өмет иткән нәрсә, кулга кермичә, башка кешегә булып, алданып калу. **Авыздан алып әйтү** Кем дә булса әйтергә теләгән сүзне икенче берәү әйтергә өлгерү. **Авыздан кош очыру** 1) Мактану; 2) Алдашу. **Авыздан сулар агызу** 1) Җиләк-җимеш, яшелчә я башка ризык күреп, ашыйсы килеп кызыгу, ымсыну. *Казанда гөбер-гөбер ит кайный. Ул кайчан пешеп чыгар икән, дип, без, авыздан сулар агызып, казан тирәсендә бөтереләбез.* Ф.Яруллин; 2) Ир-атка яки хатын-кызга нәфсе төшү, кызыгу. **Авыздан сулар килү** *к.* **авыздан сулар агызу**. **Авыздан төшермәү** Гел бер сүзне кабатлау, бер исемне әйтү. *Сезнең исемегезне мин дәрвишнең зикре кебек әйтәм, авызымнан төшермим.* Я.Вәли. **Авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп алу** Кеше сүзен әйтеп бетергәнче үк, ни әйтәсен аңлап алу, бик тиз төшенү, бик зирәк булу. **Авыздан энҗе-гәүһәр чәчү** Матур, килешле итеп сөйли белү. **Авыз еру** Көлү, елмаю. *Җырлагыз, кызлар, җырлагыз, Муеныгызда – сыргагыз; Яшь чагында җырлап калыйк, Үскәч авыз ермабыз.* Җыр. **Авыз ерып карау** Кинаяле мөнәсәбәт; мәсьәләнең җитдилеген аңламау. *Сезнең фидакярлеккә авыз ерыбрак карарга өйрәндекме?* Т.Миңнуллин. **Авыз исемле капчыктан учлап борчак ату** Чамасыз мактану, шапырыну. *Авыз исемле капчыктан борчакны учлап кына ата.* Г.Тукай. **Авыз итү** Аш-суның тәмен татып карау, бераз ашау-эчү. *Майдан авыз итегез.* Г.Камал. *Аннары --- остазбикә әзерләткән сыйдан, чәйдән авыз итә икән болар.* Р.Әмирхан. *Тирес коңгызының да, чәчәккә менеп, балдан авыз итәсе килә.* Н.Исәнбәт. *[Энә карагы] Пыр-пыр оча, ул да, мескенчәгем, чәчәк балын авыз иткән була.* А.Алиш. **Авыз йому (йомып калу)** Эндәшмәү, сүз

әйтмәү яки, җавап таба алмыйча, дәшми калу. *Ә мин, авызымны йомып, аның шул ачык ялганына ышанган күренеш белән калдым.* Ф.Әмирхан. *Ничек булса да, мин авызымны йомып торам әле хәзергә. Белмим, бернәрсә дә белмим…* Гали Рәхим. **Авыз каплау** Сөйләргә ирек бирмәү, эндәшмәскә мәҗбүр итү. *Боерыклы тавышы белән, ул әйтерсең лә байны урындыкка кадаклап куйды һәм аның авызын каплады.* Г.Шәрипова. **Авыз колакка җиту** *сөйл.* Бик шатланган булу, нык куану. *Бер чирек әче бал белән бер бөтен кызылбашны күргәч, картларның авызлары колакларына җитте.* Г.Ибраһимов. *Әтием, елмаеп: «Ничек соң, ошыймы?» – дип сорады. Нәрсә әйтим, авыз колакка җиткән. Җыя алмыйм гына бит, сүзсез калдым.* Җ.Фәйзи. **Авыз колакка кадәр ерылу** *к.* **авыз колакка җиту**. *Бары да [немец солдатлары] сугым малыдай көрләр, баштанаяк өр-яңадан киенгәннәр --- авызлары колакларына кадәр ерылган…* Ә.Еники. **Авыз күгәрмәсен өчен генә** Сүз юктан сүз ясап кына, авыз тик тормасынга гына. **Авыз күгәртеп сөйләү** Файдасызга, корыга буш сүз сөйләү. *Болай булгач, тел талдырып, авыз күгәртеп сөйләп торасы да юк*. К.Тинчурин. **Авыз күтәреп** Ачыктан-ачык, яшермичә, бөтен кеше алдында. *Әстәгыфирулла, әстәгыфирулла! Көфер сүз сөйлисең бит. Карт башым белән авыз күтәреп җырлап йөрергә мин юләрмени?* Ф.Яруллин. *Син, авызыңны күтәреп, клуб ишеге янында тәмәке тартып торганда, бугазын әллә ниткән шарфлар белән урап (май ае) сәхнәгә таба җырчы кереп китә.* М.Мәһдиев. *Сан-Мартин бульварында йөргәндә, мин чит илдән килгән туристларның авыз күтәреп, шаккатып карап торган товарларына игътибар иттем: бу товар – кызылга каккан кайры тун иде.* М.Мәһдиев. **Авыз күтәреп калу** 1) Бер эш яки әйбердән, артыннан өметләнеп йөреп тә, мәхрүм булып калу. *Без анда да авызыбызны күтәреп калдык*. Г.Камал; 2) Күрә торып, кирәк эшне кулдан ычкындыру, мөмкинлектән файдаланмый калу. *Ул арада аңарга аны сатып та куя, мин авыз күтәреп калам*. Г.Камал. **Авыз күтәреп көлү** Юкка-барга кычкырып көлү. **Авыз күтәреп яту** Эшләмичә, әзерне генә көтеп яту. *Алма пеш, авызга төш, дип, авыз күтәреп яту бер дә килешми.* Ялт-йолт. **Авызны чөйгә элеп йөрү** 1) Ашамау, ач тору; 2) Дәшми тору, сүзгә катнашмау; 3) Ваемсыз, гамьсез булу. *«Их, корт иле очрасын иде дә, умарталы кеше булып, баеп китсәң иде», – дип, авызны чөйгә элеп йөргән чакларым аз булмады.* Ф.Хөсни. **Авыз пешү** Ашыгып яки сынамыйча керешкән эштә уңышсызлыкка очрау. **Авыз пычрату** Телгә алырлык булмаган сүзләр яки яман кеше турында сөйләү. *Мин аның сүзләрен авызымны пычратып сөйләп тә тормыйм. Күрәсең, юлбашчыдан шундый әмер булган: 1941 елдан бирле ач яшәгән, педагогика, психологиядән башка нәрсәне белмәгән бу йонлы муен белән авыз пычратып маташмаска.* М.Мәһдиев. **Авыз сулары килү** *к.* **авыздан сулар килү** (*1 мәгъ.*). *Рәмзинең авыз сулары килде, күзләре елтырап китте. Шулай да ул, баллы ипи сузган кулны эткән булып, читкә борылды*. Г.Бәширов. **Авыз суы кипмәгән** Тәҗрибәсез, малайлыгы чыгып бетмәгән. **Авыз суын агызу** Тәмгысын сузу, үтә кызыгу, ымсыну, нәфесен сузу. **Авыз суын корыту** Берәр кеше яки берәр нәрсә белән мавыгып, һаман аны телгә алып сөйләү яки даулау. **Авыз талдырып** Корыга, бушка, файдасызга, көч, акыл әрәм итеп. **Авыз тәме** Аппетит, ашау теләге. **Авыз тәме бетү** Ашау-эчү, ризык ләззәтен тоймау. **Авыз тәме китү** *к.* **авыз тәме бетү**. **Авыз тәмен җибәрү** Кычкырышу, талашу, бер-береңә каты-каты сүзләр әйтешү. **Авыз томалау** Сый-хөрмәт, блат яки ришвәт белән, сүз әйтә, каршы килә алмаслык итү. *Кунакка чакырып тыгындырсаң, шуның белән авызы томалана ич аның*. И.Гази. **Авыз турсайту** Үпкәләү, үпкәләүдән авызны бөрештерү. *Бер авызын турсайтса, тиз генә иман көтмә инде син аңардан. Кара коелып йөри*. Р.Төхфәтуллин. **Авыз тутырып ашау** Туйганчы ашау. *Ипи ашыйсы килгән вакытның иң үзәк өзгече – язын үлән типкәндә. Һай, шул вакытта авыз тутырып бер ипи кабарга да күздән яшь килгәнче рәхәтләнеп сытып чәйнәргә иде!* М.Мәһдиев. **Авыз тутырып әйтерлек түгел** Бик мактарлык түгел. **Авыз тутырып әйтү** 1) Зурдан кубып, зур сүз итеп сөйләү. *Казан ханлыгында авыз тутырып әйтерлек бер генә шәһәр – Казан гына була.* Г.Дәүләтшин. *Үлем ачысын татыдым, дип, авыз тутырып әйтә алам. Караватта тәгәрәп ятам; аяклар шешкән.* Т.Галиуллин; 2) Уйлаганын ачыктан-ачык әйтү, турысын әйтү. **Авыз үлчәшү** Үбешү. *Син тагын минем хатын белән ничек авыз үлчәшкәнеңне дә сөйләргә уйламыйсыңмы?* З.Бәширов. **Авыз хәбәре** Телдән таралган сүз, имеш-мимеш. **Авыз чайкау** 1) Берәүнең гайбәтен сөйләү. *Җыен җилбәзәк хатын минем кызым белән авыз чайкамый торсын әле!* М.Маликова; 2) Кат-кат, кайта-кайта сөйләү. *Артык авыз чайкап торуны кирәк тапмадым, күзенә терәп әйттем дә салдым сүземне.* Ф.Хөсни. **Авыз чатнау** Бик эчәсе килү, авыз кибү. *Я, күп лыкылдамый гына сал әле, авызларым чатнап бара.* М.Фәйзи. **Авыз чылатып алу** Бераз исерткеч, хәмер эчү. **Авызы арандай ачык** Авызын артык зур ачып, киереп иснәү, әдәпсезлек күрсәтү. **Авызына алу** Бер сүзне каткат әйтү, кабат-кабат әйтеп битәрләү, сукрану, мыгырдану. **Авызына бармагын кабу** Ялгышын сизү, тотылу, җавапсыз калу, сүз дәшмәс булу. **Авызына бармак тыксаң да тешләми** Бик юаш, мәхлук кеше хакында. **Авызына [берне] тамызу** *к.* **авызына менеп төшү**. **Авызына [берне] тондыру** Кемне дә булса ачуланып, авызына сугу. **Авызына җен төкергән** Җавапка өлгер, тапкыр, җор телле. *Бар да рәхәтләнеп бер көлделәр… – Хи-хи, хи… Бу Бикмулланың авызына җен төкергәндер, каян таба, гыйбрәт!* Ә.Еники. **Авызына шайтан төкергән** *к.* **авызына җен төкергән**. **Авызына йөзек яшергән** Берни дә дәшмичә, сүзгә җавап бирмичә утырган кеше турында. **Авызына карату (каратып тоту)** Оста теле, тәмле сүзе белән кешене үзенә, сүзенә карату; үзенә ияртү, ба-

гындырып тоту. **Авызына каратып катыра** Кешене үзенең оста теленә хәйран калдырып, каратып утырта. **Авызына керердәй булып** Бик бирелеп, йотылып. **Авызына кош канаты төшәрлек** Үзен бик зур гыйлем я акыл иясе санап, я талант иясе булуына дәгъва кылып, борынын бик югары чөю, үзенә үзе исе китеп һавалану. *Өстенә – җөббә, башка – зәңгәр фәс, күзгә – күзлек, аякка ботинка кигән, авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкерт*. Г.Тукай. **Авызына көмеш кашык кабып туган** Эше гел уңа, алга бара торган, бәхетле кеше турында. *Тыштан караганда, Исмәгыйль агай улы – авызына көмеш кашык кабып туган, тоталитар җәмгыять өчен көнләшерлек язмышлы кеше*. Т.Галиуллин. **Авызына менеп төшү** Берәүнең авызына йодрык белән нык кына сугу, сугып җибәрү. **Авызына саескан төкергән** Күп сөйләүче, такылдык. **Авызына салган салманы йота белмәү** Кулына төшкән бәхетне, ризыкны ычкындыру, мөмкинлектән файдалана белмәү. **Авызына су капкандай** Эндәшмичә, бер сүз әйтмичә. *Әмма мин көткән исәнлекне белешү, лекция сәгатьләрен ачыклау да --- хәтта Татарстан депутатларын, шулхәтле акча алып та, авызларына су капкандай, залда тып-тын утырулары өчен әрләү дә булмады*. Т.Галиуллин. *Тик, карыйм, бер дә минем сүзләремне күтәреп алучы юк. Авызларына су капкандай, тик мыек астыннан гына елмаеп утыралар иптәшләр*. А.Расих. **Авызына су салыр кеше булмау** Ялгыз, ташландык хәлдә үлү. **Авызына сугу** Бик узынган, һәркайда тел озайткан яки шапырынган кешене җаваптан гаҗиз итү, кеше алдында хур итү, оятка калдыру. **Авызына сугып сөйләтмәдем (ич)** Көчләп я куркытып сөйләргә мәҗбүр итмәдем, үз ихтыяры белән, үз авызыннан әйткән сүз, дигән мәгънәдә. **Авызына сумала капкан** Авызын ачып сүз дә әйтә алмыйча, үзен-үзе яклый алмыйча, дәшми торучы турында. **Авызына сүзе сыймый** Сүзен уйламыйча, кабалаланып, бутап сөйләүче турында. **Авызына теле сыймаган** 1) Сүзне уйламый, урынсыз сөйләүче, әдәп сакламыйча, теләсә ничек җавап бирүче; 2) Сер саклый алмый торган. **Авызына Хозыр төкергән** Теленнән гыйлем-хикмәт коючы, теле татлы, оста, галим кешегә карата әйтелә. **Авызын ачса, үпкәсе күренә** Ач-ялангач, бик фәкыйрь яки үтә ябык, арык кеше. *Кызык адәм син! Авызын ачса, үпкәсе күренеп торган мәңге хәерче татар язучысын жәлләп, шундый бай республика хуҗалары ачлы-туклы утырмас бит инде*. Т.Галиуллин. *Авылдан килгән, авызын ачса үпкәсе күренергә торган аспирантның диссертация язу процессында эшләргә өйрәнгән башы тиз генә «масса» мәсьәләләр чишә*. М.Мәһдиев. **Авызын ачып сүз әйтә алмау** Рәтләп сөйләшерлек хәлдә булмау; тел көрмәкләнү. *Аның кыяфәтендә ниндидер куркыныч төс булгандыр ахры, Газизә абыстай, аны күргәч, авызын ачып сүз әйтә алмады*. С.Шәрипова. **Авызын бәлшәйтү** Авызын бәлеш кебек җәеп, үпкәләп елау. **Авызында – анасы** «Ана» сүзен кушып сүгенүче пычрак телле кеше турында. **Авызындагын каерып алыр** Кеше кулындагы нәрсәгә канызгучы, ничек тә булса үзенә алучы әрсез кешегә карата. **Авызында кош уйната** Бик оста телле, килешле, матур итеп сөйләүче кеше турында. **Авызында сүз тормый** *к.* **авызына теле сыймаган** (*2 мәгъ.*). **Авызында төкереге кору** Күп сөйләү, теле кибешкәнче сөйләү, һаман бер нәрсәне кабатлау. **Авызында эт балалаган** 1) Бер генә сүз белән әйтсә нәрсәне әйтә алмыйча, әллә нихәтле итеп, сүз куертеп сөйләүче турында; 2) Мәгънәсез, кирәкмәгән сүз генә сөйли торган кеше турында. **Авызын каплау (томалау, ябу)** Сүз әйтә, каршы җавап бирә алмаслык хәлгә кую. *Син миңа сораганны бирдем дә, Җиһанның авызын капладым дип уйлыйсың*. Ә.Фәйзи. *Кешеләр шыпырт кына сөйләшеп алдылар: – Дөрес әйтте Сираҗи, егет икән... – Авызын каплады*. Ә.Фәйзи. **Авызын корт чаккыры!** Ачу килгәндә кемнедер тиргәп әйтелә торган фраза. *«Ау»ның уңышсыз чыгуына эче пошып, ул җиргә төкерде һәм нәкъ Сәгъди абзыйча сүгенеп куйды: «Авызын корт чаккыры, ә!»* Ә.Фәйзи. **Авызын майлау** Кешене, сыйлап, каршы сүз әйтмәс хәлгә китерү. **Авызын мүкләгәннәр** Кемне дә булса куркытып, янап я башкача каршы сүз әйтмәслек хәлгә китерү. **Авызыннан ана сөте (дә) кипмәгән** Яшь, тәҗрибәсез, малайлыгы чыгып бетмәгән, акыл утырмаган, дөнья күрмәгән. **Авызыннан бер өзми** 1) Кем белән, ни белән булса да мавыгып, һаман шуны телгә алып сөйли; 2) Өзлексез тәмәке тартучы турында. **Авызыннан җаны чыгарга тора** Бик бетәшкән, бетеренгән (авырудан яки картлыктан). **Авызыннан өзелеп төшкән** Ике әйбернең яки ике кешенең берберенә бик нык охшаган булуы. **Авызыннан өзеп** Үз өлешеннән бүлеп, берәр кеше белән бүлешергә әзер булып. *Аңа [бәби тапкан хатынга] күрше-тирә, үз авызыннан өзеп, бәби ашы кертә, бәбие белән котлый*. Ф.Яруллин. **Авызыннан селәгәен агызып** Кеше кулындагы нәрсәгә тәмгысын сузып яки һәр очраган хатын-кызга мәхәббәт белдереп йөрүче бозык кеше хакында. **Авызын томалау** 1) Кешегә өстән кушып, боерып, янап, каршы бер сүз дә әйтмәслек хәлгә китерү; сүз әйтергә бирмәү; 2) Кешенең шәхси гражданлык хокукын чикләү, демократияне бозу; 3) Кеше белән бәхәстә аны, дәлилле, төпле яки тапкыр сүз әйтеп, җаваптан гаҗиз калдыру; 4) Төрлечә сыйлап я ришвәт биреп, каршы сүз әйтмәс хәлгә китерү. **Авызының тоткасы юк** Күп сөйләүче, авызында сүз тормаучы. **Авызын яба белми** Берөзлексез сөйләп тора. **Авызың белән әйт, борының белән тарт** Кемнең дә булса каргышына каршы җавап рәвешендәге әйтем (ягъни, каргышың үзенә кайтсын). **Авызыңа – бал да май** Сөенечле, файдалы хәбәр китерүчегә әйтелә. **Авызыңа бал да май булып керә** Төче телле, ялагай, юмакай кеше турында. **Авызыңа – каз мае** Егетләр арасында сөенечле хәбәр китерүчегә «сиңа – шәп сый» дигән мәгънәдә әйтелә. **Авызыңа каз мае капкан идеңме әллә** Берәү бер

кирәкле эшне сизмичә яки кирәкле сүзне әйтмичә калганда әйтелә. **Авызыңа таш тыгылсын** *карг.* Яман телле кешегә әйтелә. **Авызыңа чәйнәп сала** Сүзне, белемне яки дәресне һәркем аңларлык бик ачык, җиңел һәм гади телдә әйтеп, сөйләп бирүче турында. **Авызыңнан җил алсын** Берәү берәр яман сүз я күңелсез хәбәр әйтсә, я яманга юрап сөйләсә, аңа каршы башкача мондый сүз сөйли күрмә, мәгънәсендә әйтелә. *Авызыңнан җил алсын! Кем турында сөйләгәнеңне беләсеңме? Әтиең турында сөйлисең бит син!* М.Шалаков. *Ни сөйлисең син, мелла Бәдретдин, тузга язмаганны. Ирекле көннән кыз бала качкынга ияреп китәме, авызыңнан җил алсын!* М.Хәбибуллин. **Авызыңнан кереп эчеңнән үтә чыгар** Һәр ябык ишекне ачтыра, һәркая үтә, сүзен үткәрә, үз дигәненә ирешә ала торган, чая, үткен, әрсез кеше турында. **Авызыңнан чыгып, җылы куеныңа керсен** Каргаган кешегә каргышын үзенә кайтарып әйтү. **Авызыңнан чыкканчы эләктереп ала** Сүзне бик тиз аңлый, әйтеп бетергәнче тотып алучы, елгыр зиһенле кеше турында. **Авызыңны да ачма (ачасы булма)** Берәр кешедән берәр нәрсә сорап я даулап, сүз кузгатмаска кисәтеп әйтелә. *[Фәтхия карчык:] Авызыңны да ачасы булма – диде, – туйга барам, дип, синең ул кыланчыгың белән бер табында янәшә утырыр хәлем юк, --- диде.* Г.Ибраһимов. **Авызыңны җыя төш** Бик иркенәеп, теләсә кем алдында теләсә ни сөйләүгә, чама белмәүгә каршы әйтелә. **Авызыңны чамалап ач** Артык сүз сөйләшмә, сак бул, мәгънәсендә. **Авызы пешмәгән** Дөнья күрмәгән, тәҗрибәсез. **Авызы тишек** Авызында сүз тормый, сер саклый белми. **Авыз эчендә (эченнән) ботка пешерү** *кимс.* 1) Үз фикереңне аңлаешлы итеп әйтә алмау; 2) Мыгырдану, үзалдына гына сөйләнү. *Тавышны җәлләп, авыз эчеңнән ботка пешермә, изелеп аккан балан бәлеше төсле мәлҗерәеп торма.* Г.Ахунов. **Авыз эченнән** Үзалдына, үз-үзенә генә, кешегә ишеттермичә. *[Мостафа] Хатынын, бала-чагасын сагынып, авыз эченнән гел бер көйне көйли иде.* М.Мәһдиев. *Абзый, авыз эченнән генә сөеп, сары атның ялын тараштыргалады, тирләгән муенын сыпыргалады, тәртәсен селкетеп, аркалыгын тартып карады.* Ә.Еники. **Авыз эченнән көлү** Тавышсыз көлү, елмаю. *Солдат авыз эченнән генә көлеп куйды.* Г.Бәширов

**АВЫ́З-БОРЫН** *җый. и.* Авыз һәм борын. *Рәиснең авыз-борыныннан кан китте, бераз вакыттан соң, күзебите адәм танымаслык булып шешеп чыкты.* Н.Измайлова. *Садри – аеруча усалы. Чана белән таудан төшешли, сине каршы алып, чанаңны борып ега да авыз-борыныңны бозга каткан киндер тышлы бияләе белән уа. Садрига туры килгәндә, безнең авыз-борын чепчи кан була иде.* М.Мәһдиев

◊ **Авыз-борын төйнәп утыру** Кемгә дә булса ачулану, үпкәләү, нәрсәдән дә булса канәгать булмау. **Авыз-борыныгыз май булсын** Яхшы теләкләр теләгәндә әйтелә. *Килен төшүгә, аңа каршы чыгып, аяк астына юрган җәеп җибәрә... Җамаякка салган маен аңа суза: – Кап, кызым, кап (аркасыннан сөя), авыз-борыныгыз май булсын... Тигез, рәхәт гомер итәргә язсын.* А.Шамов. **Авызын-борынын кан итү** Битен-башын, кыйнап, канга батыру, кыйнау

**АВЫЗГА́-АВЫЗ** *рәв.* 1) Икәүдән-икәү генә, башкаларны катыштырмыйча. *– Авызга-авыз куеп, нәрсә серләшәсез? – дип ачулы гына энесенә карады [Булат].* З.Кадыйрова. *Моңа кадәр авызга-авыз, колакка-колак диярлек сөйләшеп утырган ике милләтпәрвәр идек, инде күзләребез маңгайларны узды, тыннарыбыз кысылды.* Ф.Яхин

2) *күч.* Кеше ишетмәслек итеп якын ук килеп, серләшеп. *[Наять] Хәзер алай итми: Бикә белән авызга-авыз килеп сөйләшеп торганнарын яратмый.* Н.Акмал

**АВЫЗГА́ЧА** *рәв.* Авызына кадәр, авызына җиткәнче. *Ботларындагы бераз тышка бәреп торган калын, каты итләр белән киң күкрәк, маңгайдан авызгача боргаланып төшкән кара кашка айгырның нечкә сылу гәүдәсенә аерым бер --- төс бирә.* Г.Ибраһимов

**АВЫ́З-ИРЕН** *җый. и.* Авыз һәм ирен. *Авыз-иреннәр эштән чыгып бозылган, тел, бер чирек булыр, каралып, салынып тора.* Г.Ибраһимов. *Соңыннан гына ачыкланды: идәндә аунап яткан хатын белән кыз баланың авыз-иреннәренә дә ниндидер тасмалар ябыштырылган икән.* Мәдәни җомга

**АВЫЗЛАНДЫРУ** *ф. диал.* 1) Яңа туган имчәк баласына беренче мәртәбә ризык (гадәттә бал яки май) каптыру. *Ул, чәен эчәр-эчмәс, хаҗ шәрифтән килгән, балалар авызландырырга тотыла торган хөрмәне алып, --- хәл белергә китте.* Г.Исхакый. *Оланны юындыралар, юындыргач, ак май каптыралар, ул – авызландыру була.* Д.Рамазанова

2) *күч.* Кыюландыру, батырайтып җибәрү

**Авызландыра төшү** 1) Беркадәр авызландыру

2) *күч.* Кыюландырып, гайрәтләндереп җибәрү. *Гөлгыйзарның минем берлән бертуктамаенча сөйләве мине тагын да авызландыра төште.* Г.Исхакый

**Авызландырып җибәрү** Авызландырырга ярдәм итү

**АВЫЗЛАНУ** *ф. диал.* 1) Тәнгә чыккан чуанның яки сызлавыкның тишелер алдыннан башы агара башлау, эренләү. *Авызланган инде чуаның, тишелер*

2) *сөйл.* Телгә килү, сөйләшә башлау; сөйләнергә тотыну. *Хуҗа Насретдинне җибәрик, дип авызланалар!* Н.Исәнбәт

**Авызлана бару** Вакыт үткән саен ныграк авызлану

**Авызлана башлау** Авызланганы күренү, авызланырга керешү

**Авызланып җитү** Тишелерлек булып авызлану

**Авызланып килү** Акрынлап авызлана башлау, авызланганы күренү

**Авызланып китү** Бераз авызлану, авызланырга керешү

**АВЫЗЛЫК** *и.* 1) Ат авызына кидерү өчен, йөгән каешына беркетелгән тимер җайланма. *Лапас эчендә арбага бәйләгән безнең сары ат ашыкмый гына үлән кетердәтә ---, салдырылган авызлыгын әледән-әле чылтыратып ала.*

Ә.Еники. *Аты чишмәгә суга төшкән бер кызның чиләгенә үрелеп, авызлыклары белән зыңгылдап, төкле кара ирennәре белән чиләк бавын кыймылдатып ята икән.* М.Мәһдиев. *Җитмәсә, үзе [айгыр] алгы аяклары белән үрә ыргыды, арт санын чөеп тибенде, тимер авызлыгын туктаусыз чәйнәде.* Мирас

2) *күч.* Билгеле бер чикләрдә буйсындырып тоткан көч, куәт. *Ул үзенең минминлеген авызлыкта тота белә торган олы сәнгатькяр иде.* Р.Харис. *Туктады уйлар агышы, Авызлык кидерделәр.* Р.Гаташ. *Көнчелектән туа явызлык, Вөҗдан исә – аңа авызлык.* Х.Халиков

◊ **Авызлыгын тешләп, җан-фәрманга чабу** Үз иркенә йөрергә, беркемгә дә баш бирмичә, үзе кая тели, шунда таба бар көченә чабучы чыгымчы атка тиңләү. **Авызлык кидерү** *к.* **авызлыклау** (*3 мәгъ.*). **Авызлык тешләү** *к.* **авызлыгын тешләп, җанфәрманга чабу** *Артист бер авызлыкны тешләп алса, сөйләүдән тиз генә туктар, димәгез.* Г.Әпсәләмов

**АВЫЗЛЫКЛА́У** *ф.* 1) Авызлык кидерү (атка). *Атларны авызлыклап, аркалык белән бавыргалыкларын яңадан ныгыттылар.* М.Гафури

2) *күч.* Нәрсәне дә булса үз иркеңә буйсындыру. *[Ләйлә:] Техниканы авызлыкладым! Ә хәзер үземнең көзгегә карарлыгым да калмаган.* И.Салахов. *[Мөхәммәт карт] Дөньяны авызлыклап алган сыман иде кана, кая ул, карчыгы вафатыннан соң биреште карт, корган йорт-курасы таралып ята хәзер.* Ф.Сафин

3) *күч.* Кемгә дә булса берәр нәрсә эшләргә рөхсәт итмәү, тыю, үз иркенә куймау, бәйле хәлдә тоту. *Ваемсыз булырга ярамый, Аерым булырга ярамый. Явызлыкны авызлыклар өчен Бердәм булу кирәк.* Т.Миңнуллин. *Без килен чакта, каенатай мәрхүм --- синең анаңны авызлыклый, таяклый торды.* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Үз-үзен яки башкаларны берәр төрле хис һ.б.ш. белдерүдән туктатып калу, тыю. *Хисләремне авызлыклап йөгәнләдем. Әй Гарифҗан, әллә үзең сиздең инде Гомер көймәң комга килеп терәлгәнен.* Г.Мөхәммәтшин

5) *күч.* Кешеләр өчен мәҗбүри булган кагыйдәләргә буйсындыру, тәртипкә салу. – *Борчылма, Рөстәм, тиздән авызлыклыйбыз аларны, – диде Марат.* З.Фәйзуллин. *Кайтыгыз, иптәш Вәлетдинов, эшләгез… Ләкин нервларны авызлыклый белергә дә өйрәнегез…* М.Мәһдиев. *Язмыштан узмыш юк, дип әйтсәләр дә, күпләр бу башбирмәс үҗәт нәрсәне үзләре авызлыкларга тырышалар.* Казан утлары

6) Балаларның бер-берсен бау белән ат итеп тотып йөгерүдән гыйбарәт уеннарына ишарә. *Без исә, ат югында, бер-беребезне авызлыклап, ат-ат уйнап үскән иләс-миләсләрбез.* Р.Әхмәтҗанов

◊ **Авызлыкламакчы булу** Баш булмакчы, кулда тотмакчы булу. *Сизәсезме, егетләр, безне авызлыкламакчы булалар. Юк, юк, күрә торып, ирекле баштан моңа юл куярга ярамый.* Ш.Усманов. *Сизенүемчә, кайбер райком работниклары мине авызлыкламакчы булалар.* А.Расих

**Авызлыклап алу** Тиз арада авызлыклау, авызлыклауга ирешү. *Авызлыклап алдым, менеп атландым.* Г.Бәширов. *Иллә мәгәр, хатынны өйләнешкән көннән үк авызлыклап алырга кирәк.* Р.Батулла

**Авызлыклап карау** Авызлыкларга омтылу, авызлыкларга тырышу. *Ул өйдәгеләр турында уйламаска никадәр генә тырышса да, никадәр генә үзенең тойгыларын авызлыклап караса да, барыбер булдыра алмады.* И.Гази

**Авызлыклап кую** Кыска вакыт эчендә бөтенләй авызлыклау; авызлыкланган хәлдә тоту. *Ни генә димә, вакыт-вакыт, ярсучан характерга йөгән кигезергә, авызлыклап ук куярга кирәк.* Р.Сибат. *--- арыш башакларына үрелүенә үртәлеп булса кирәк, әткәй, төшеп, атны авызлыклап куйды.* Н.Гамбәров

**Авызлыклап тору** Әле, хәзерге вакытта авызлыклау; һәрвакыт авызлыклау. *Алар, буш эчтәлекле язымтыкларын югарыга күтәреп, чын-чыннан тирән фикерле, олы җанлы шагыйрьләрне исә авызлыклап торырга исәп тоталар.* Р.Мостафин. *Җиһанны авызлыклап торган тәкъдир.* М.Җәләлиева

**Авызлыклап чыгу** Һәрберсен берәм-берәм авызлыклау. *Картлар өчдүрт көн эчендә Җидегән басуындагы иң хәтәр ерганакларның һәммәсен дә диярлек авызлыклап чыктылар.* Г.Бәширов

**Авызлыклый бару** Аз-азлап, акрынлап, һәрберсен бер-бер артлы авызлыклау. *Партия һаман үсә, галәмәт олы Рәсәйнең һәр почмагын үз кулына ала, авызлыклый бара.* В.Имамов

**Авызлыклый башлау** Авызлыкларга тотыну

**Авызлыклый төшү** Бераз авызлыклау

**АВЫЗЛЫКЛЫ** *с.* 1) Авызлыгы булган, авызлык кидерелгән, авызлыкланган, авызлык беркетелгән. *[Габдулла] Учына төкергәләп, йөгәннең авызлыклы башы белән Зәйтүнәгә селтәнде.* Ф.Хөсни

2) *күч.* Рәхимсез, шәфкатьсез, каты куллы. --- *даһи юлбашчының «нәфис» кулыннан төшкән тимер авызлыклы хакимият тезгенен кем алыр, кем бушап калган иң югары урынга менеп утырыр?* Ә.Еники

**АВЫЗЛЫКСЫЗ** *с.* 1) Авызлык кидерелмәгән, авызлыгы салдырылган. *Акылсыз егет – авызлыксыз ат, Юньсез егет – йөгәнсез ат.* Мәкаль

2) *күч.* Тотнаксыз, әдәпсез, инсафсыз. *Шулай да бер мәсьәләдә, әйтик, хур кызлары белән очрашуны тасвирлаган чакта, шагыйрь [Г.Кандалый] үзен, могтәбәр җәннәт әһеленнән бигрәк, әдәптә авызлыксыз җир бәндәсе шикелле тота башлый…* Г.Госманов

3) *күч.* Ярсулы, котырынкы, тыелгысыз (*теләк, көч, хыял, хис* һ.б.ш.). *Авызлыксыз яшьлек тилергәндә: «Саклан!» – диеп аңа кем дәшсен?* М.Шабаев

◊ **Авызлыксыз калу** Тотнаксыз, инсафсызга әйләнү. *Әле хәзердән үк болай җенләнгән анасы, Шибай карт үлеп, йөгәнсез, авызлыксыз калса, --- бәйләүдән ычкынган эткә әйләнер.* Г.Ибраһимов

**АВЫЗСЫН** *и. диал. к.* **зәңгелә**

**АВЫ́З-ТЕЛ** *җый. и.* 1) Авыз һәм тел. --- *беркөнне кинәт кенә Кәшфине паралич сукты. Аяк-кул, авыз-тел, күз исән, әмма колаклар дөм томаланган*

*иде*. М.Мәһдиев. *Татар фольклорында да, жанрлар белән үрелеп, халкыбызның тарихы, тормыш-көнкүреше, йола-гадәтләре, мифологиясе һәм дини ышанулары, авыз-тел һәм музыка иҗаты, бию-хореографиясе һәм драма-театр башлангычы, шулай ук сурәтле-образлы фикерләве --- культурасы белән тыгыз бәйләнештә карала*. М.Бакиров

2) Сөйли алу, сөйләү сәләте

◊ **Авыз-тел бәйләнү** Артык сокланудан яки көтелмәгән хәбәрдән сүз әйтә алмас хәлгә килү, ни дияргә дә белми аптырап калу. *Менә аның шундый ягымлылыклары мине бөтенләй эретеп бетерде. Авызым-телем бәйләнеп, әйтә торган сүземне әйтә алмадым*. М.Гали

**АВЫЗЧЫК** *и. бот.* 1) Үсемлек яфрагы тиречегенең яшел төстәге парлы күзәнәкләре арасында урнашкан ярык. *Авызчык күзәнәкләре яфрак тиречегенең башка күзәнәкләреннән нәрсә белән аерылалар?* Биология

2) Чәчәкнең җимеш ясауда катнашучы төп өлеше, җимешлек, чәчәк аналыгы; *русчасы:* **пестик**. *Җил серкәләрне эләктереп алып китә һәм күрше үсемлекләрнең чәчәкләреннән чыгып торган йомшак йонлы авызчыкларга илтә*. Биология. *Җилсез көндә серкәләр, еш кына, авызчыкларга эләкмичә, җиргә коела, һәм күп кенә җимшәнле чәчәкләр серкәләнмәгән килеш чәчәк коялар*. Биология. *Авызчыклары нәкъ җимшән өстендә утыра, шуңа күрә аларны «утырма авызчыклар» диләр*. Ботаника

**АВЫК** I *и. бор.* Киек, ауланган хайван

**АВЫК** II *и. гар*. Вакытның бик кыска бер кисәге, бер сулыш озынлыгы вакыт, мизгел, вакыт аралыгы. *Маяк күзен йомган арада узып өлгергән әнә шул кыска бер авык, әнә шул бер сулыш озынлыгы гына вакыт кисәге, --- мәңгегә юк була*. Г.Бәширов. *Ул авык аякларыбызга карап торды да пырхылдап көлеп җибәрде*. М.Ибраһимов

**АВЫЛ** *и.* 1) Игенчелек, терлекчелек һәм яшелчәчелек эшләре белән шөгыльләнүче халык даими яши торган җир, урын. *И авыл, син мең шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш*... Дәрдемәнд. *Аяусыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң, мин Казанга килеп чыктым*. Г.Кутуй. *Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә космонавт та, бер генә академик та чыкмаган. Гап-гади, иң гадәти бер авыл*. М.Мәһдиев

2) Шул торак пунктта яшәүче төп халык. *Һәм... сугыш. Егерме икенче июнь көнне төш вакытында моны безнең авыл белде. Авыл тынсыз калды*. М.Мәһдиев

◊ **Авылга йөз белән** Авылга булышлык, ярдәм күрсәтеп. **Авыл гыйбады** *кимс.* Авылдан килгән, шәһәр тәртипләрен белмәгән кеше

**АВЫЛДАГЫ́ЧА** *рәв. к.* **авылча**. *Яшьләр дә, урта яшьтәгеләр дә, олыраклар да атылып чыгып биергә тотынды. Берсе икенчесен чакырып, авылдагыча бер-берсенең кулларыннан тотып әйләнгәләп ду-у килделәр*. Ә.Салах

**АВЫЛДАШ** *и.* Кем белән дә булса бер авылда туган, туып-үскән яки яшәгән кеше. *Авылдашлар көлгә утлы күмер күмеп, шул күмер белән учак тергезә*. Ф.Яруллин. *Ул бит, шушы тәрәзәдән карап торгач, авылдашларыннан берничә кешенең фронттан кайтуларын беренче булып күргән иде*. Ә.Еники. *Акылы җитмәде шул Сәләхетдиннең авылдашлары булып уйлап карарга... Кулак булып калды, аннары индукка әйләнде, аерым хуҗалыкка чыкты*... К.Миңлебаев

**АВЫ́Л-КАЛА** *җый. и.* Авыллар һәм калалар, гомумән торак пунктлар. *Авыл-калаларда адәм заты калмый, бар да урманнарга, тугандаш удмурд-башкорт җирләренә качып бетә*. Мирас

**АВЫЛЛАШУ** *ф. сир.* Авыл кешесе гадәтләрен алу, авылча яшәргә күнегү, авыл тормышын үз итү. *Ул бөтен табигате белән каланы ярата, шул дәрәҗәдә ки, Гәрәй мирзага иргә килеп, утыз еллап торса да, авыллаша, авыл тормышын үз итә алмады*. Г.Ибраһимов

**Авыллаша бару** Аз-азлап, акрынлап авыллашу

**Авыллаша башлау** Авыллашу билгеләре сизелү

**Авыллаша төшү** Берникадәр, бераз авыллашу

**Авыллашып бетү** *к.* **авыллашып җитү**

**Авыллашып җитү** Бөтенләй авыллашу

**Авыллашып китү** Билгеле бер вакыттан, вакыйгадан соң кинәт авыллашу

**АВЫЛЛЫК** *и.* 1) Авыл кешесенә хас сыйфатларга, авыл гадәтләренә ия булу. *Аның [егетнең] бик тә, бик тә европача буласы килә иде, шул максаттан чыгып, ул үзенең авыллыгыннан баш тартты! Мин елмаеп күзәттем: авыллыктан баш тартам дип, киндер капчык асып, ул авылдагы ата-бабаларга кире кайтты*. М.Мәһдиев. *Шунда мин бер егетлек күрсәтеп алдым: авыллыкның шәһәр тормышында файдасы тия торган бик аз очраклардан берсе булды инде ул. Осетин абзыйдан --- саллы чалгысын сорап алдым да очын җиргә төртеп, чыңгылдатып янап җибәрдем*. М.Мәһдиев

2) Авыл булу дәрәҗәсе, авыл буларак бөтенлеге. – *Шодада көннәр бик-бик күңелле уза, – дип яза драматург 1916 елгы килүендә. – Авыл минем күңелемнең кәгъбәсе булганга, Шоданың авыллыгы мөкәммәл булып, күптән көткән бәхетемә юлыкканга бик шат идем*. Идел

**АВЫ́ЛЧА** *рәв.* Авылдагы кебек, авыл гадәтенчә. *[Кызларның] Авылчарак киенгәннәре дә бик көяз-ыспайлар, шуның өстенә шактый кыю-шаяннар да иде*. Ә.Еники

**АВЫЛЧЫ** *с. сөйл.* Өйдән-өйгә эшсез-йомышсыз йөрергә яратучы; *к. шулай ук* **биләмче**. *Авылчы хатынның колагы озын, теле аннан да озын*. Г.Нәбиуллина

**АВЫНКЫ** *с. сөйл*. Бер якка янтая төшкән, авышып торган. *Диңгез ягасында, суга кермәскә тырышып аякларын алга терәгән шикелле, тышка таба авынкы бер казык күренә иде*. Ш.Камал

**АВЫНКЫЛЫК** *и.* Бер якка авышкан, янтайган булу; янтайганлык

**АВЫНКЫРА́У** *ф. сөйл.* Бераз авышу, янтаебрак, авыбрак тору

**Авынкырап калу** Ниндидер этәргечтән, сәбәптән соң авынкы хәлгә килү

**Авынкырап китү** Кинәт авынкырау

**Авынкырап тору** Берникадәр авынкы хәлдә булу

**Авынкырый бару** Акрынлап, авышлыгы арту, торган саен ныграк авынкырау

**Авынкырый башлау** Авышырга керешү, авышлык барлыкка килә башлау

**Авынкырый төшү** Бераз авынкырау

**АВЫ́П-ТҮНЕП** *рәв. к.* **ава-түнә**. *--- ана ике кулы белән битен каплады да бермәл як-якка авып-түнеп торды.* М.Хәбибуллин

**АВЫР** I *с.* **1.** 1) Авырлыгы зур булган, зур үлчәүле; *кирессе:* **җиңел**. *Дүрт ел буе авыр итек кидек. Дүрт ел буе авыр йөк тарттык.* Ә.Ерикәй. *Асып куелган рельс кисәге көнгә дүрт тапкыр авыр чүкеч астында ыңгырашып чыңлады.* Г.Шәрипова. *Юеш кер авыр булырга кирәк, кызның нәзек кенә буе көянтә астында сыгыла төшкән, үзе, бу авыр йөкне җилкәсеннән тизрәк төшерер өчен, барасы җиренә җәһәтҗәһәт атлый.* Ә.Фәйзи

2) Кыен, читен, мәшәкатьле, тынычсыз. *– Егеткә сүзем юк, хәлле чагым булса, туйлап бирер идем. Гайния минем авыр елымны хәтергә алмады, – дип, аларны куып чыгарды.* Г.Ибраһимов. *Авыр, кырыс еллар үтелгән. Ничек үтә алганбыз, аңа көч каян килгән?* М.Мәһдиев. *Авыр мизгелләрдә кешеләр ахыргача, йозаксыз сандык төсле ачыла да куя.* Т.Галиуллин

3) Җанны, күңелне борчый, тәшвишли торган, борчулы. *Син минем хәлемне, авыр кичерешләремне аңлап, чын дусларча җылы мөгамәлә күрсәтерсең, дип өмет иткән идем.* Ш.Камал. *Шул авыр, тирән моң мине басты, ---.* Г.Ибраһимов. *Геройларның авыр кичерешләре турында укыганда, аның [Катяның] күзләре мөлдерәмә яшь белән тулы була.* Г.Әпсәләмов

4) Кайгылы, хәсрәтле. *Бу көннәр, башка һәркемнән бигрәк, аналарга авыр хәсрәтләр, каты кайгылар алып килделәр.* Г.Ибраһимов. *Тагы имешләр, хәбәрләр --- тагы йокысыз төннәр, өмет-газап эчендә үткәрелә торган авыр минутлар.* Г.Ибраһимов

5) Кешенең кәефен җибәрә торган, начар, тупас, кимсетүле. *Авыр сүзләр ишетсәгез, үткәреп җибәрегез.* Җыр. *Әйтергә генә ансат бит ул вәгъдәне кире алу!.. Күпме авыр сүз ишетергә туры киләчәк.* Ә.Еники. *Сабира каенана өчен дөньяда иң начар, иң авыр сүз шул Кәҗә иде.* Г.Ибраһимов

6) Тормыш алып бару өчен кыен, кырыс. *Авыр шартларда, авыр елларда туганлыктан ахрысы, әни мине башка балаларына караганда күбрәк ярата, күбрәк якын итә иде.* М.Мәһдиев. *Яңа бистәдә быелгы шикелле авыр көзне картлар да бик аз хәтерлиләр.* Ә.Фәйзи

7) Читен, зур физик яки акыл көче таләп итә торган. *Бу килен сүзсез, талашсыз булып чыкты, авыр эшкә гаҗәп батыр.* Г.Ибраһимов. *Авыр эш, авыр хезмәт, шунда кулы-аягы тайган, бармагы, кулбашы каймыккан кешеләр һәр атна саен булып тора иде.* М.Мәһдиев

8) Матди яктан кыен булган, начар; бәхетсез. *Мәҗит Гафури хуҗаларга кул көчен сатып, ярлы авыр тормышта яшәгәнгә, хезмәт ияләренең ул вакыттагы тормыш шартлары аның башыннан да кичтеләр.* М.Җәлил

9) Зур, эре. *Борынгырак заманнарда, авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләре авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә йомырка да чәчә торган булган.* Г.Бәширов. *Авыр эре тамчылар, кан тамчыларыдай, тамамтамам дип асылынып торалар.* И.Гази

10) *күч.* Сулыш юлларына начар тәэсир итә торган, тынчу. *Ишектән керүгә, борынга авыр ис бәрелде. Өй эчендәге авыр ис һәм Газизәнең, күңелсез тавыш белән, «һаман бер килеш ята» дию Төхфәтнең терелү ягына бармаганлыгын ачык аңлата иделәр.* Ш.Камал

11) *күч.* Каты, кырыс, аяусыз. *Авыр табигатьле кеше. Авыр җәза*

12) *күч.* Салынкы, төшеп, салынысбрак торган. *Күк йөзе дә күңелле-күркәм түгел: саллы авыр болытлар гүя каек өстенә ишелеп төшәргә торалар…* К.Нәфыйков. *Авыл өстенә килеп салынып торган авыр болытлар каядыр китеп барганнар; күк йөзе офык сызыгына хәтле тәмам ачылган иде.* Ә.Еники

13) *күч.* Куе, тыгыз, яктылык үткәрми торган. *Иртәгәсен, куе авыр томан таралгач, аны [сыерны] карарга халык җыелды.* М.Мәһдиев

14) *күч.* Куркыныч, хәтәр, каты. *Тол хатынның әйткәннәре күңел түрендә авыр җәрәхәт калдырды.* А.Расих. *Гөлбануның йөрәгеннән авыр төш алынды.* Г.Ибраһимов

15) *күч.* Аңлаешсыз, буталчык, катлаулы. *[Әсәрдә] Балалар теле эшләнмәгән. Озын авыр җөмләләр күп очрый.* М.Җәлил. *Китапта Аллаяр суфый мөнәҗәтләре, гарәп, фарсы сүзләре катнаштырып, бик авыр тел белән язылган.* Ә.Фәйзи

16) *күч.* Маемлата торган, начар эшкәртелә торган. *Авыр ризык*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Күп күтәртеп, тарта алмаслык итеп. *Атка йөкне авыр төяү*

2) Ашыкмыйча, кабаланмыйча, салмак. *Кояшны тузанмы, болытмы каплады, манара төшкән урынга халык бармады, авыр гына таралышты.* М.Мәһдиев

3) Каты, җитди. *Авыр яраланган батыр егет сыкранганда, түзми киләсең, Башын салып йомшак кулларыңа, Син егетнең хәлен беләсең.* Ф.Кәрим

4) Тирән итеп, уфтану белдереп. *Зәкәрҗан инде олыгая төшкән, авыр сулап куйды.* М.Мәһдиев. *--- үзенең юлдан язган улын уйлап, авыр көрсенде.* Идел

5) Начар, яман. *Бу сөйләшү әллә кайсы ягы белән авыр тәэсир итте миңа.* Җ.Фәйзи

**3.** *и. мәгъ.* 1) Авыр эш. *Чабышкыны авырга җикмиләр*

2) Күңелсезлек, сагыш, хәсрәт. *Күңеллене искә төшерү генә рәхәт бит. Авыры һаман йөрәкне яра, теләү.* Ф.Бәйрәмова

**4.** *хәб. функ.* Үзеңне физик яки мораль яктан начар сизү турында. *Ә теге елга – игенле-печәнле тук елга килсәк – ул елның да көзе авыр булды.*

М.Мәһдиев. *Җиһангир өчен беренче сүз авыр иде*. Г.Ибраһимов. *Курыктык, улым, курыктык, йөрәгеңә авыр булыр, дидек*. Казан утлары

◊ **Авыр аяк (авыр аяклы)** 1) Иренчәк, ялкау, эшкә ихлассыз, акрын кыймылдаучан кеше; 2) *иск*. Йөкле, көмәнле (хатын). *Авыр аяклы хатыным белән көн саен кайгырышабыз.* Г.Чыгтай; 3) Берәр кайгылы хәбәр китерүче; бәхетсезлек китерүче (кеше). **Авыр башы төшү** Эшнең авыррак, мәшәкатьлерәк ягы туры килү. *Әмма яңгырлы көннең иң авыр башы бораулаучыларга төшә.* Г.Ахунов. **Авырга алу** Кешенең берәр сүзе күңелгә тию, хәтер калу; кеше сүзен үпкә белән кабул итү. *Туктале, минәйтәм, абзый кеше. Нигә алай авырга аласың?* М.Әмир. – *Син аның ярсулык белән әйткән сүзләрен авырга алма. Ул җитәкче кеше бит, нәрсәдер әйтергә тиеш, – дип тынычландырырга тырышты әни.* Г.Тавлин. **Авырга килү** 1) Артык көч төшү, дәрман китү, хәл бетү, көч килү. *Сез бик бирелеп сөйлисез, Николай Максимович, авырга килмәсен.* Г.Әпсәләмов; 2) Берәр эшне йөкләргә яки үтәргә авырсыну. *Ул эш миңа авырга килә шул. Иртәдән кичкә кадәр ул хәзер бушамаячак, ашау-эчү, яту-торуның да рәте-юне булмаячак, кыскасы, авырга киләчәк аңа.* Ә.Еники. **Авыр гәүдәле** 1) Бик симез, таза кеше турында. *[Әпипәнең] Чәчләре битенә төшкән, ул авыр гәүдәсе белән әүмәкләнеп шуыша иде.* Г.Бәширов; 2) Кузгалырга яратмаучы, урыныннан тиз кузгала алмаучы. **Авыр кеше** *к.* **авыр холыклы.** *Ай-һай, сүз белән генә игә китереп булыр микән? Бик авыр кеше.* Н.Исәнбәт. **Авыр куллы** 1) Көчле, нык куллы; 2) Кешене кыйнаудан тайчанмаучы кеше. *Ул – хатынына авыр куллы ир*; 3) Эш уңмаган очракта, шул эшне башлап җибәрүче кешегә карата әйтелә. **Авыр күтәрү** Үпкә-сапка сүзне кичерә алмыйча, күңелдә озак саклау, сүз күтәрмәү; кисәтүне авыр кабул итү. **Авыр санлы** Урыныннан кузгалырга, күтәрелергә авыр кеше, ялкау. **Авыр сүз** Хәтерне калдыра, рәнҗетә торган сүз; урынсыз гаепләү, тәнкыйть. *Гомер буе иренә бер авыр сүз әйтмәгән юаш, басынкы хатын.* А.Гыйләҗев. *Күпме авыр сүз ишетергә туры киләчәк.* Ә.Еники. *Бөдрә чәч, зәңгәр күз, әйтмә лә, бәгърем, авыр сүз.* Җыр. *Бу авыр сүзне ишетү барган саен артты, күбәйде.* М.Гафури **Авыр тию** Кемнең дә булса әйткән берәр сүзенә күңел рәнҗү, җанга авыр тоелу. **Авыр туфрагы җиңел булсын** Мәетне күмгәндә, өстенә туфрак салганда яки мәрхүмне искә алганда әйтелә торган сүз. *Картлар беләләр, --- ул – авылда беренче усал карчык иде. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмәнең!* А.Шамов. **Авыр хәл** Чишелүе авыр, уңайсыз хәл яки зур кайгы, үкенечле хәл. *Нужа килсә, тартып ала, Илтеп дәрьяга сала. Бик авыр хәл.* Җыр. **Авыр хәсрәт, каты кайгы** Башка килгән төрле кайгы-хәсрәт; бәла-каза. *Ачы буран, суык җил Чиметә ике битемне; Авыр хәсрәт, каты кайгы Ашый йөрәк итемне.* Җыр. **Авыр холыклы** Киңәшкә күнми торган я һәр сүзгә каршы әйтә торган; үзсүзле. *[Ул] – Бик авыр холыклы кеше, берүк, баламны үз канат астыңа алсана, миннән хәер-дога, дөнья-ахирәттә бәхетле булыгыз, – диде.* Г.Бәширов. **Авыр язмыш(лы)** Тормышы төрле бәхетсезлекләргә дучар булып үткән кеше гомере

**АВЫР** II *и.* Йөк, корсак, көмән. *[Әти-әниләре] Кызларының авырын күреп алгач, --- аны Казандагы ерак бер туганнарына озатканнар.* Ф.Яруллин

◊ **Авырга калу** *к.* **авырга узу**. *Тик аның өчен үкенечле бер генә ягы бар: йөгәнсез атка йөгән кидерәм, барыбер минеке булырсың, дип шаярып тотынган мәхәббәт уенының тирәнгә кереп китүе Мәрьямне борчый башлаган, чөнки ул үзенең авырга калуын сизгән иде.* Г.Ахунов. **Авырга узу** Балага узу, көмәнле булу

**АВЫРАЙТКЫЧ** *и.* Авырлык өсти торган нәрсә, өстәмә авырлык. *Кургаш авырайткыч. Авырайткыч элеп кую*

**АВЫРАЙТУ** *ф.* 1) Авыр итү, авырлыгын, үлчәмен арттыру. *Үзле балчык аякларны тагын да авырайта, көне буе яуган яңгырдан баткакка әверелгән юл, үзәгенә суырып алырдай булып, үзенә тарта.* Рифә Рахман. *Алдан беренче булып юл салып бару йөгеңне икеләтә авырайта.* А.Хәсәнов

2) Авырлык китерү, начар якка үзгәртү. *Зәйтүнә апаның үксеп елавы үлем кайгысын тагы да авырайта.* А.Кутуй. *--- ә хәзер март чуагы урамны каралткан, ат тизәге, чәчелеп калган салампечән яз җылысына йомшарып ята, чана табанын авырайта.* Ш.Янбаев

3) *күч.* Катлауландыру, кыенлаштыру, читенләштерү. --- *этисе Троицкида мулла булырга ризалык бирә. Бу адым аларның гаилә тормышына кискен үзгәрешләр кертә, авырайта, катлауландыра.* Р.Зарипова. *Күплек кушымчаларының урынсыз кулланылуы, тезелеп килүе сөйләмне авырайта.* Р.Юсупов. *Ә бу [фрагментарлык] истә калдыруны кыенайта, редакторга да, укучыга да үзләштерү процессын авырайта.* М.Вәли-Барҗылы

4) *күч.* Саулыкны алу, кәефне бозу, күңелне басып тору. --- *этәге ашлар авырайтып басып торса да, юлның бер бүлеген җәяү үттеләр.* Г.Исхакый. *Яшең олыгаеп килгәндә, тәнне авырайта, күңелне сүрелдерә торган сәбәпләр аз буламыни!* М.Маликова

**Авырайта бару** Торган саен ныграк авырайту; тагын да авырайту. *Барыр юлларыңа буран чыкса, Авырайта барыр юлыңны.* В.Галиев. *[Чулпани] Үзенең шигырьләрен гарәп һәм фарсы сүзләре белән авырайта барды.* Ә.Фәйзи

**Авырайта башлау** Авырайганны сизенү, авырайган кебек булу. *Тракторчының күз кабакларын авырайта башлаган йокысы таралып киткәндәй тоелды*. Р.Фәизов

**Авырайта килү** *к.* **авырайтып килү**. *Менә бугазларның шулкадәр зур әһәмиятле булуы, Истанбулның дөнья бизмәненең уртасында торуы бугазларны, Истанбулны алу мәсьәләсен авырайта килде.* Г.Исхакый

**Авырайта төшү** Тагын да авырайту, авырлыгын бераз арттыру. *Юл кыенлыклары һәм бүтән төр җайсызлыклар аның хәлен авырайта төште булса кирәк.* З.Әмирханов

**Авырайтып җибәрү** Бераз, берникадәр авырайту

**Авырайтып килү** Торган саен, көннән-көн ныграк авырайту

**Авырайтып кую** Кинәт авырайту

**Авырайтып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле авырайту. *Кичәге макмыр аның башын кургаш тутырган кебек томалап, авырайтып торды.* Ә.Фәйзи

**АВЫРАЮ** *ф.* 1) Авырлыгы арту, авыр булып китү, авыр булып тоелу. *Әлегәчә көннәр әйбәт торды, бал төшкәндер, шәт. Бу умартаң шактый авырайды бит.* Ф.Яруллин. --- *юеш кием, авыраеп, тәнгә ябыша.* Р.Вәлиев

2) Начарлану, кыенлашу, читенләшү, тагын да катлаулану. *Без үсеп буйларга җиткәч, Авырайды замана.* Җыр. *Йөрәге --- пешереп-пешереп авыртырга тотынды. Тын алуы авырайды.* Ф.Яруллин. *Юнысның йөреше дә үзгәрде, авырайды, картларча кыштырдап атлый башлады ул.* Г.Шәрипова. *Ике ай чамасы элек базарда күргән иде, бик бетәшкән, мескен. Күрәсең, Нургата бабай үлгәннән соң, яшәве күпкә авырайган.* Казан утлары

3) Хәлсезләнү, көчсезләнү, хәл, егәр бетү. *Тамырларыма кан урынына эрегән кургаш тутырылгандай, тәнем авырайды.* Ф.Яруллин. *Күз кабакларың авырайдылар, алар йомылалар.* Җ.Фәйзи. *Аны [даруны] эчкәч, көне буе тинтәк сыман йөрдем. Башым авырайды, үзе йокы килә, үзе йоклап булмый.* Казан утлары

4) Чирләү, хәл начарлану, үлем хәленә җитү. *Ул, мине күргәч тә, әтинең бик авырайганын, үзенең мине алырга килгәнен сөйләде.* М.Гафури. *Бер кичне, атай бик авырайгач, өйдәгеләре ясин укытырга уйлаша...* Э.Касыймов. *Сөннәтче бабай килеп, егълаган тавыш белән: «Хәзрәт, [Гөлһөзем әби] бик авырайды, телдән калды», – диде.* Г.Исхакый

5) Йөкле хатынның бала табар вакыты якынлашу. *Балага авыраю*

6) *күч.* Начарлану, бозылу, тынчулану. *Бүлмәнең һавасы авырайган, бераз җилләтеп алырга кирәк*

7) *күч.* Авыр бер тойгы, хис тәэсире чолгап алу. *Ә чынлыкта авырайдым, Уй-исәп барыбер басты.* Р.Фәйзуллин

**Авыраеп алу** Кыска гына вакыт эчендә авыраю

**Авыраеп бару** Аз-азлап, акрынлап арта барып авыраю. *Мин, гәүдәм авыраеп барганын да онытып, киртә аша сикереп чыктым да, нәкъ каршысына – ул төшеп килгән сукмакта туктап, аның берничә адым атлаганын көттем.* Рифә Рахман

**Авыраеп калу** Ниндидер сәбәптән, тышкы тәэсирдән соң авыраю. --- *яшьләнгән күз төпләреннән зәңгәрсу капчыклар асылынып төшкән, гәүдәсе дә хәлсезләнеп, авыраеп калган.* Р.Вәлиев. *Бөтен тән ватылып, авыраеп калган иде.* Э.Шәрифуллина

**Авыраеп килү** *к.* **авыраеп бару**

**Авыраеп китү** Көтмәгәндә, кинәт авыраю. *Туктап, атларны ашарга кушу белән, берьюлы авыраеп киткән аякларын көч-хәл белән сөйрәп, кайсы-кая барып түнделәр.* Г.Бәширов. *Шулай да, сөйләшә торгач, башым артык авыраеп киткәнне сизеп, аны куеп торырга урын караштыргалый башладым.* Ф.Хөсни. *Ләкин әби Нәфисә белән булган сүзен болай дип бетерде: «Дөньяларыбыз авыраеп китмәгән булса, бер дә генә үземнән җибәрмәс идем дә бит, нишләмәк кирәк?..»* Ә.Фәйзи

**Авыраеп тору** Әле, хәзер авыраю, бераз авырайган хәлдә булу. *– Якын бабай, авылыйсыңмы әллә? – Юк, олан. Хәлем генә авыраеп тора.* Г.Гыйльманов. *Уф, әллә яңгыр яварга җыена – авыраеп торам!* З.Гиниятова

**Авыраеп утыру** Авырайган халәт кичерү

**Авырая бару** Торган саен ныграк авыраю. *Таймыйча атлау торган саен авырая барды.* И.Гази. *Авыру апабызның хәле күзгә күренеп авырая барды.* Г.Галиев

**Авырая башлау** Авыраерга тотыну. *«Бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына» дигән мәкальдәге кебек, бер татар хатыны, тормышы авырая башлагач, сандык төбеннән өр-яңа ап-ак ефәк шәлен сатарга алып чыккан – алар шуны күреп алдылар.* Ә.Салах

**Авырая төшү** 1) Бераз авыраю. *Габдуллага җавап кайтару авырая төште һәм, ниһаять, ул Чулпанның бер шигыренә җавап бирә алмый тукталып калды.* Ә.Фәйзи

2) Тагы да авыраю. *Егерменче елларда, билгеле объектив сәбәпләр аркасында, хокуклары чикләнеп, үз эчләренә йомылып өлгергән руханиларның, авыл картларының китап хезмәтләренә юл табуы авырая төшә.* М.Госманов. *Аның хәле бер дә җиңеләймәгән, киресенчә, тагы да авырая төшкән кебек.* Ф.Бәйрәмова

**АВЫРЛАНУ** *ф. сир. к.* **авыраю**

**АВЫРЛАШТЫРУ** *ф. к.* **авырайту**. *Күз күргән барлык нәрсәнең «бу» булуы сөйләшүне шактый авырлаштырган.* А.Яхин. *Эшне авырлаштыру. Көтмәгәндә килеп чыккан хәлне тагы да авырлаштыру. Сулышны авырлаштырган һава. Калын кием хәрәкәтне авырлаштыра*

**Авырлаштыра төшү** Алдагы белән чагыштырганда тагы да авырлаштыру

**Авырлаштырып җибәрү** Сизелерлек авырлаштыру

**Авырлаштырып тору** Бертуктаусыз авырлаштыру

**АВЫРЛАШУ** *ф.* 1) Кыенлашу, авыррак була бару. *Дөрес, университетка керү, сугыштан соңгы елларга караганда, шактый авырлашты.* Ә.Еники. --- *үзең беләсең, өй карау авырлашты. Мин өйне квартирга алышырга сөйләштем.* Мәдәни җомга

2) Начарлану, начар якка үзгәрү, читен хәлдә калу. *Минем уку ягы яхшы, ләкин азык мәсьәләсе барган саен авырлашты.* М.Гафури

**Авырлаша бару** Торган саен ныграк авырлашу. *Бөтен өмет Сөмбелдә менә. Врач булам, ди. Тик хәзер институтка керүләр елдан-ел авырлаша бара бит.* Ф.Яруллин

**Авырлаша башлау** Соңгы вакытта, хәзер авырлыклар сизелү, авырлашырга тотыну. *Тынлык авырлаша башлагач, Искәндәр, күптәнге сөйләшүне дәвам иткәндәй: «Ә шигырьләр сиңа ошадымы?» – дип сорады.* М.Кәбиров

**Авырлаша төшү** Бераз авырлашу; тагы да авырлашу. *Мостафа җизни эчәк авыруыннан үлеп киткәч, тормышлары тагын да авырлаша төште.* Р.Мостафин

**Авырлашып бару** *к.* **авырлаша бару**. *Заманалар бигрәк авырлашып бара, чиновниклар котыра.* Т.Галиуллин

**Авырлашып бетү** Бөтенләй авырлашу; тәмам авырлашкан хәлгә килү

**Авырлашып калу**Ниндидер вакыйгадан, сәбәптән соң авырлашу

**Авырлашып китү** Кинәт кенә авырлашу. *Юллар тагы авырлашып китте, Хасил булды кинәт зур бер тау.* Г.Зәйнашева

**Авырлашып кую** Кинәт кенә, кыска вакыт арасында авырлашу

**Авырлашып тору** Әлегә, хәзерге вакытта авырлашу

**АВЫРЛЫ** *с.* Балага узган, йөкле, авыры булган. *Авырлы чагында ул, бөтен дөньясын онытып, үзенең күңелен тик шул туачак балага баглап бетергән --- иде.* Г.Ибраһимов. *Саматы хаклы икән: «Авырлы хатыннардан да гүзәл җан иясе була аламы?» – дия иде.* Г.Галиева. *Лена үзе дә әле бала гына. Үзенең авырлы икәнен әти-әниләреннән яшереп йөргән.* Ф.Яруллин. *Сәлимов хатыны Солтания, Шәүкәтне кызы өчен бигүк тиң күрмәсә дә, кызы авырлы икәнен әйткәч, килешми булдыра алмады.* Г.Ахунов

**АВЫРЛЫК** *и.* 1) *физ.* Әйбернең үлчәүгә салып билгеләнә торган күләме, микъдары. *Озак килүгә дә, йөкнең авырлыгына да карамастан, тән – ниндидер бер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән тыныч бер рәхәтлек тоя.* Ә.Еники. *Хәлим, чиләк авырлыгына янтаеп, йөгерә-йөгерә барды да узгынчының нәкъ ак котомкасы өстенә сибеп җибәрде.* И.Гази. *Кеше гәүдәсенең авырлыгы даими рәвештә үзгәреп тора.* Кызыклы физиология. *--- колхоз да ярыйсы керем алды: әзерләүләр пункты һәр баш терлекнең нормадан тыш авырлыгына да өстәмә хак түләде.* Мирас

2) *физ.* Җирнең тарту көче йогынтысында җисемнең үзе таянган ноктага яки үзе эленгән җепкә ясаган тәэсир көче белән үлчәнә торган зурлык

3) Күтәрүгә, тартуга авыр булу. *Аның кулы бодай көлтәсенең авырлыгын сизеп тора.* Г.Бәширов. *Килене Миңсылу белән оныгы Фәридә коры кура авырлыгы гына калган мәрхүмәне, җиләнгә төреп, өйгә кайтарганнар.* Ә.Еники // Нәрсәнең дә булса көче, куәте, ныклыгы. *Йодрыкның авырлыгын, ныклыгын Рәмзинең авызы бик тиз сизде.* Казан утлары

4) Читенлек, кыенлык, мәшәкать. – *Көне-төне тырышып эшләгәч, --- ял итим әле, димәгәч, бар авырлыкларны да җиңеп була икән, – дигән.* А.Алиш. *Сүзләр күбрәк Төхфәтнең вакытсыз әрәм булуы, сугышның бөтен авырлыгы, бөтен фаҗигаләре ярлы халык өстенә төшү тирәләрендә әйләнде.* Ш.Камал. *Ә авырлыклар булган да булган инде. Кимендә ун баланы ашатып-киендереп, кеше итеп тәрбияләп, олы тормыш юлына кертеп җибәрергә кирәк булган ич.* М.Әхмәтҗанов. *Әнинең кисәтүе дөрескә чыкты: бөтен авырлык, бөтен газап аның өстенә төште.* Ә.Еники

5) Катлаулы, мәшәкатьле хәл; каршылык. *[Кеше] Никадәрле авырлыклар күрсә дә сабыр итә, авырлыкларга каршы сугыша.* М.Гафури. *Тик бу авырлыкны мин кешегә сиздермичә генә күтәрергә тырыштым.* М.Әмир. *Бу авырлыктан сине кемнәр йолар, кем коткарыр?* М.Гали. *Мәдинә хәзер авырлыкларны уздырган һәм тынычланган икән!* А.Расих

6) Арыганлык, хәлсезлек. *Ишү – рәхәт авырлыкны тойдырта торган ирләр эше.* Р.Фәйзуллин

7) *куч.* Газап, кайгы-хәсрәт, зур күңелсезлек. *Скрипкаң элек сез күргән авырлыкларның барысын да сөйләде дә бирде.* А.Әхмәт. *Ул кергәч, безнең өй эчен тагын да моң, авырлык басты...* М.Гафури. *Ләкин бөтен авырлыклардан иң авыры, минем өчен, билгесезлек иде.* Ә.Еники. *«Тукран тәүбәсе» тәгъбире, берәр начар гадәт, ярамас гамәл китереп чыгарган газапларны кичергәндә, башка алай эшләмәскә кат-кат ант итеп тә, авырлыклар үтеп китүгә, янә шул хатаны кабатлауны белдерә.* Х.Мәхмүтов

8) Җирне хәрәкәткә китерә торган көч чыганагы, җирнең тарту көче үзлеге. *Авырлыксыз шартларда сулыш алу мәсьәләсен хәл итү кыенрак.* Планетаара очышлар

9) *спорт* Авыр атлетиканың кайсы да булса бер төрен белдереп әйтелә. *Авырлык күтәрү буенча ярышларда җиңеп чыгу*

10) *спорт* Бокс, дзюдо, көрәш һ.б.ш. спорт төрләрендә кулланыла торган үлчәм. *60 кг кадәрле авырлыкта чыгыш ясау*

◊ **Авырлыгым шунда калсын** *ырым* Берәр җирдә хәл җыярга утырган җирдән торып киткәндә, шуны әйтеп, җиргә төкереп китү. **Авырлык белән** 1) Интегеп, җәфаланып, газап белән. *Башка малайлар белән сөйләшеп аңлашкач ачыкланды: һәрберсен ([кендекче әби] үзе таптырган баланы) очраткач, башыннан сыйпый да елап җибәрә икән: – Тәүфыйклы булып үс, балам, анаң сине бик авырлык белән тапты, – ди икән.* М.Мәһдиев; 2) Кыенлык белән, мәшәкатьләнеп. *Ул үзе – бөтенләй укымаган кеше, дип сөйлиләр иде, --- бик авырлык белән үзенә юл салган.* Ә.Еники. *Язгы чәчү бик авырлык белән бара.* М.Мәһдиев; 3) Көчкә, чак кына, көч-хәл белән. *Авырлык белән таныдым Борис дусны. Башына соры, җиңел эшләпә кигән, тәнендә – иркен, гади тукымадан тегелгән пижама тибындагы кием, кулында – шланг.* Т.Галиуллин

**АВЫРСЫ** *с. диал.* Авыр, күңелгә тия торган (*ашамлык яки ис турында*). *Кәҗә сөте куерак, баллырак һәм авырсы була.* Г.Галиев

**АВЫРСЫНДЫРУ** *ф. з.-сыз* Мәшәкать, уңайсызлык, читенлек тудыру. *Эш Габдулланы артык авырсындырмады.* Ә.Фәйзи

**АВЫРСЫНУ** *ф.* 1) Авыр, кыен, мәшәкатьле эшкә санау. *Боларның бөтенесен Габдулла авырсынмыйча --- ялгыз калган әнисенә ярдәм итә алуына кинәнеп эшләде.* Ә.Фәйзи. *Баруын-кайтуын бергә кушканда да, нибары уналты чакрым гына була ич. Бер дә авырсынмам, тик синең [укырга җибәрергә] ризалыгың гына булсын.* В.Нуруллин. *Аларга шул ук укытучылар дәрес бирделәр. Берсе дә авырсынмады.* Ф.Яруллин

2) Базмау, уңайсызлану, кыенсыну, читенсенү. *Аның шулчаклы оялуы, хәтта безнең өйгә дә иң куркыныч, булмаса, иң ышанычсыз бер урынга кергән кебек авырсынып керүе --- безнең һәммәбезгә дә бик кызганыч булып күренде.* М.Гафури. *Бурычка акча сорарга авырсыну*

3) Берәр нәрсәне эшләргә теләмәү яки теләр-теләмәс кенә үтәү. *Ул забой астыннан күмер тартуны да авырсынып эшли иде.* Ш.Камал. *--- бөтен авылларда да чөгендерне шулай бүлеп бирәләр. Халык авырсына, билгеле, үзара зарланыша, әмма аяк терәп баш тартучы сирәк.* М.Маликова

4) Кыенлык кичерү, аңлатып бетерә алмау, белеп бетермәү. *--- бу пунктның зарурлыгын мин күңелем белән тоям, аңлыйм, әмма, җәелеп китеп, үзем белгән тел белән сөйләргә авырсынам.* Т.Миңнуллин

5) Теләмәү, кирәксенмәү. *Кыз авырсынып кына торып басты*

6) *диал.* Бераз авырып, кәефсезләнеп тору

7) **авырсынмау** *юкл. формасында* Читенгә, кыенга санамау, ярдәм итүдән баш тартмау. *Кыз аның янына ук барып, үтенгән тавыш белән: «Минем өчен, бәлки, авырсынмассыз», – диде.* К.Тинчурин

**Авырсына башлау** Авырсынырга тотыну. *Җомга һәм гаед намазлары укуларга мөмкинлек булмагач, халык инде аларны үтәүне авырсына башлый.* М.Әхмәтҗанов

**Авырсына тору** Һәрвакыт, гел авырсыну. *– Щи исе күңелемә тия, – дип, кичләрен аш пешерергә авырсына торган булды.* М.Маликова

**Авырсына төшү** Берникадәр, бераз авырсыну

**Авырсынып йөрү** Әле, хәзер авырсыну халәте кичерү

**Авырсынып кую** Кинәт кенә авырсыну хисе барлыкка килеп алу

**Авырсынып тору** Әле, хәзерге вакытта бераз авырсыну

**АВЫРСЫНУСЫЗ** *рәв.* Теләп, бер дә авырсынмыйча. *Юлга чыгарга авырсынусыз ризалык бирде*

**АВЫРТТЫРУ** *ф.* 1) Организмга зарар китерерлек дәрәҗәдә сугу, имгәтү һ.б. сәбәпләр аркасында авырту барлыкка китерү. *Идрис атның авызын авырттырып читкә таба тартты, санламагач, янтавына каеш дилбегә белән сыпырды.* Г.Бәширов. *Айсылу, ачудан, машинага берничә тапкыр тибә, ләкин аякларын гына авырттыра.* Ф.Яруллин

2) Берәр нәрсә тәэсирендә авырту барлыкка килү. *Судан чыгып, калтырана-калтырана өстемә киенгәндә, яр кырыендагы ташлар аягымны авырттыралар.* Г.Рәхим. *Аның чәчәген тотарга ярамый, ул бармакны авырттыра!* Т.Мөбарәков. *Ашамыйм кәбестә ашы, эчне авырттыра.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Сызлану, кайгыру, рухи газаплану. *Кайгылы хәбәр җанны телеп авырттыра*

**Авырттыра башлау** Авырттырырга тотыну, кинәт авырту сизү. *Бервакыт аңа нидер төртә, кыса, бөтен җирен авырттыра башлый.* Ф.Садриев

**Авырттыра төшү** Берникадәр авырттыру

**Авырттырып алу** Кыска гына вакыт эчендә кинәт авырту тою. *Тик торганда гына күңелнең бер үзәк тамыры тартылып куя, йөрәкне авырттырып ала ---.* Г.Гыйльманов

**Авырттырып кую** Кинәт бераз авырттырып алу. *Ихтыяр аларга кушылып елмайса да, аның күңелен бик эчтән нәрсәдер тырнап, авырттырып куйды.* Р.Вәлиев

**Авырттырып тору** Бертуктаусыз, гел авырттыру. *Танклар килгәнче өлгерә алмаслар инде, дигән борчу эчен әрнетеп, авырттырып торды.* Х.Камалов

**Авырттырып үтү** Кинәт кенә авырту тою. *Җан өшеткеч уй аның сабый күңелен авырттырып үтте: ул аягына баса алмый!* Г.Гыйльманов

**АВЫРТУ** *ф.* **1.** Нинди дә булса авыру аркасында физик газап барлыкка килү, организмның кайсы да булса берәр урынында авырту, сызлау сизү. *Монда трамвай юк. Извозчикта эч кенә авырта, эч авырттырмый торганына утырсаң, кесә авырта иде.* Г.Тукай. *Профессор аның эченә кагылуга, Чибәркәева илереп җибәрде. [Профессор:] «Нигә кычкырасыз, авыртмый ич».* Г.Әпсәләмов. *Бавыры бик нык авырта. Түзә алмый, стенага менә.* Т.Галиуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) *диал.* Авыру, чир, хасталык. *Доктор [Төхфәтнең] авыртуы «куркынычлы» дип тә, «куркынычсыз» дип тә ачык әйтмәгән.* Ш.Камал

2) Бер әгъзадагы сызлау, әрнү, ачыту кебек билгеләр. *– Тирләсәң ару булыр, башың авыртуы бетәр, – дип, сандыктан как ала башлады.* М.Гафури. *Альфа [эт], авыртуга түзә алмыйча, бөтен көченә чинап җибәрде.* А.Хәсәнов. *Кайсы – үзенең начар йоклавыннан, кайберсе ярасы авыртуыннан зарлана башлады.* Ә.Айдар. *Алдагысыннан да көчлерәк авырту аның күзләрен томалады, чак сөйрәлеп, урын өстенә барып ята алды, авырту басылмады.* Идел

◊ **Авырткан башка тимер тарак (таяк)** Үз бәласе өстенә яңасы да өстәлеп килү. **Авырткан җир** Баштан үткән нинди дә булса газаплы, фаҗигале хәлнең искә төшкәндә күңелдә авыр хисләр уята торган, йөрәктә калган ярасы, эзе. **Авырткан җиргә кагылу** Кемнең дә булса күңел җәрәхәтенә, үкенечле хисенә кагылу; күңелсез хәлне искә төшерү. *Әллә нидә бер сүз кушып, анда да кызның авырткан җиренә кагылуы өчен, Равил күңеленнән тагын да үзен нык кына битәрләп алды.* В.Нуруллин. **Авырткан җиргә тию** *к.* **авырткан җиргә кагылу**. *Мөхәммәт бабаның китап турындагы сүзе Кадыйрның иң авырткан җиренә тиде.* Ф.Яруллин. **Авырткан сөялгә басу** *к.* **авырткан җиргә кагылу**. *Менә шул, инде тынычландым, басылдым, дигәндә генә, китерәләр дә авырткан сөялгә басалар.* Г.Насрый. **Авыртмаган башка тимер таяк** Гаепсез кешегә тик кенә торганда гаеп ташлану

**Авырта башлау** Авыртырга тотыну, авыруы башлану. *Йодрыкларымны кысып йомарладым, кысылудан тешләрем авырта башлады.* М.Юныс

**Авырта бирү** Авыртуын дәвам итү

**Авырта төшү** Авырту берникадәр көчәю

**Авыртып алу** Кыска гына вакыт эчендә авырту. *Әтием исемә төшеп,*

*күкрәгемдә нәрсәдер авыртып алды: бәгырь микән, әллә ул өзелде микән?* Г.Якупова

**Авыртып бетү** Тәмам, бик нык авырту. *«Алтынчәч» операсы белән туктаусыз кычкырып мактана-мактана, тавышларыбыз карлыкты, горурланып суга-суга, күкрәкләребез авыртып бетте.* И.Юзеев. *Алар, күзләре авыртып беткәнче, дошман ягын бинокль белән күзәттеләр.* Г.Әпсәләмов

**Авыртып йөрү** Әле, хәзерге вакытта авырту. *--- яз җитте исә, тез башлары авыртып йөри иде.* А.Гыйләҗев

**Авыртып китү** Көтмәгәндә, кинәт авырта башлау. *– Кайда, Гали абзый, чыгар әле, баш авыртып китте, – диде.* М.Гафури. *Әбиеңнең аяклары авыртып китте әле, кызым.* Ф.Яруллин

**Авыртып кую** Кинәт кенә авырту тою. *Рәфитнең кинәт эче авыртып куйды.* Р.Бәшәр. *Аларны [балаларны] кызганудан йөрәге кысылып, авыртып куйды.* Р.Хәбибуллина

**Авыртып тору** 1) Әле, хәзерге вакытта, бераз авырту. *Аның башы авыртып тора икән, пирамидон белән кара кофе эчеп, бераз ятып торса, бәлки, рәтләнеп тә китәр.* Ш.Маннур

2) Бертуктаусыз, әледән-әле авырту

**Авыртып чыгу** Нинди дә булса вакыт дәвамында авырту. *--- кендектән түбән ягы төне буе авыртып чыкты.* Р.Сибат

**Авыртып яту** Озак вакытлардан бирле урын өстендә ятып, туктаусыз авырту. *Бу үткән кышта Кырлайдагы анам да кура җиләге кагы җибәргән иде. Атам бер елдан бирле авыртып ята икән.* Г.Тукай

**АВЫРТУЛЫ** *с.* 1) Әрнеп авырта торган. *Авыртулы җәрәхәт. Авыртулы яра*

2) *күч.* Авырту хисе сиздерә (тудыра) торган, әрнеткеч, газаплы. *Иптәшләрнең мине болай җылы каршылаулары йөрәгемдә артык авыртулы хисләр уята.* Мәдәни җомга

**АВЫРУ** I *ф.* 1) Хаста булу, чирләү, сырхаулау, нинди дә булса берәр авыруга дучар булу. *Авырсаң, имче күбәер.* Мәкаль. *Авырганда, үлем кочагына үзен атып, Сине яклаган ул кем?* Һ.Такташ

2) *күч.* Хафалану, кемдер яки нәрсәдер өчен борчылу, пошыну. *Эшнең болайга борылуы йөрәктә авыру тудырды*

**Авырый башлау** Авырырга тотыну, авыру билгеләре күренү. *Озак та үтмәде, әби саташып авырый башлады.* Җ.Фәйзи

**Авырып алу** Кыска гына вакыт эчендә авыру. *Күршеләре, җәлләп, сөт биргәч, сөтле аш ашыйлар да, чирләп, үтләп, өй эчләре белән авырып алалар.* М.Мәһдиев. *Галимҗан Ибраһимов соңгы вакытларда бик җитди рәвештә авырып алды.* Ш.Камал

**Авырып йөрү** Әле, хәзерге вакытта авыру, авыру хәлендә булу. *Һаман аяк өстеннән авырып йөри, кеше була алмый.* М.Гафури. *Рафиканың әнисе кыш кергәннән үк авырып йөри, көнекөне белән бөтенләй хәлдән таеп, урын өстендә ята.* Г.Галиев

**Авырып китү** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт авырый башлау. *[Галиулла] Хәзер авырып киткән икән, авыру бит ул казык башыннан йөрми, кеше башыннан йөри: үзеңнең дә бүген булмаса иртәгә егылып ятуың бар.* И.Гази. *--- бер елны, Пицундадан кайтуга, Шәйхи абый авырып киткән.* М.Мәһдиев

**Авырып тору** Әле, хәзер бераз авыру. *Җәмәгатем авырып тора иде шул, сезгә сәлам, рәхмәт әйтергә кушты.* Н.Исәнбәт

**Авырып яту** Дәвамлы рәвештә авыру, озак вакытлардан бирле урыныннан тормыйча авыру. *Гаҗәп хәл: айлар буе авырып ятса да, бите-йөзе бер дә үзгәрмәгән. Әнә шул үзгәрмәве белән ул [Хәсән Туфан] җаннарны айкап алды.* Г.Ахунов. *[Апам] Кайту белән түшәккә егылып, күпмедер авырып ятканнан соң, күкрәк хасталыгы белән вафат булды.* М.Гафури

**АВЫРУ** II *и.* **1.** 1) Чир, хаста, сырхау, хасталык. *Авыру батманы белән керер, мыскаллап чыгар.* Мәкаль. *Аңарда авыру тапканнармы, белгән юк, тик шул көннән Таһирны «генерал» дип йөртә башладылар.* Н.Измайлова

2) *күч.* Кешедәге нинди дә булса кире сыйфат, гаеп итәрлек эш, начар гадәт. *Кешенең үзенә, нинди хисләр, нинди идеаллар белән яшәвенә, ничек уйлавына игътибар итүдән элек, аның тышкы күренешенә, кием-салымына карап, шуның нигезендә аның турында хөкем чыгару авыруы бик көчле иде әле ул заманда.* А.Шамов

**2.** *с. мәгъ.* Чирле, сәламәт булмаган. *Бу соңгы сугыш аның карт, авыру тәнендә --- талчыккан, гаҗизләнгән күңелендә шулкадәр көчле яшәү дәрте уяткан иде.* Г.Гыйльманов. *– Курыкма, курыкма, җаным, авырттырмыйм, – диде Газинур һәм атның авыру аягын, бөгеп, тезенә куйды.* Г.Әпсәләмов. *Икенче тәүлектә таң алдыннан авыру әтисе, хәерчелек, хәсрәт мирас итеп, бу дөньялыктан китте.* Мирас

◊ **Авыруга сабышу** 1) Берәр сәбәп (борчу-мәшәкать, кайгы-хәсрәт) аркасында авырый башлау, сау баштан авыру кебек хәлгә әйләнү. *Мин аларны ташлап киткәч, әни кайгысыннан авыруга сабышкан.* Г.Рәхим. *– И, сагынмаган кая ул!.. Мин дә бик сагындым, сине сагынудан авыруга сабыштым, – дип, Айсылуның битләрен, кайнар иреннәрен тыным беткәнче үптем.* С.Сабиров; 2) *к.* **авыруга салыну**. **Авыруга салыну** Сау башы белән үзен авыру күрсәтү, башын авыруга салу

**АВЫРУ** III *и.* Авырган кеше, сәламәтлеген югалткан сырхау кеше, хаста. *Авыруга елан ите дә хәләл.* Мәкаль. *[Врач:] Авыруларны дәвалау – безнең эш. Һәм авыруга нинди медикаментлар бирүне уйлау да.* Ш.Хөсәенов. *Госпитальгә керүенең дүртенче көнендә авыруым аңын югалтты.* Г.Кутуй. *Бу исемне әйткәч, яңгыр ява, ташны суга салып авыруга эчергәч, авыру терелә.* Г.Дәүләтшин

◊ **Авыру көен көйләү** Авырган кешене карау, тәрбияләп асрау, хаста багу

**АВЫРУЛЫ** *с.* Авыруы булган, авырып йөргән. *ВИЧ йогышлы авырулы кешеләрне күпләр җәмгыятьтән аерып, андыйларга сагаеп карый.* Шәһри Казан

**АВЫРУЧАН** *с.* Авыруга бирешүчән; еш авырый торган. *Табигатьләре*

*буенча бу балалар – оялчан, үз эчләренә бикләнүчән, кәефләре китүчән, еш авыручан, кайберләре мөстәкыйль рәвештә йөри алмый.* Маяк

**АВЫРЫКСЫНДЫРУ** *ф. з.-сыз к.* **авырсындыру**

**АВЫРЫКСЫНУ** *ф. диал.* 1) *к.* **авырсыну**. *Бибинурәттәйнең бу мәшәкатьтән зарланганын, авырыксынганын авыл халкы хәтерләми.* М.Мәһдиев. *Вәлиулла телгә килде: --- «көтүче хатыны булырга хурланмасаң, өч баламны авырыксынмасаң, чык үземә».* Ф.Бәйрәмова. *Ул төнге сменада эшләүне сөйми. Юк, эшен дә авырыксынмый, менә шушы төнге урам куркыта иде.* Казан утлары

2) Бераз авырып, хәл бетеп тору. *[Хәбир] Җитмәсә, әни авырыксына әле, диген була.* Ш.Хөсәенов

**Авырыксына башлау** Бераз авырып тору. *Тик менә абыең авырыксына башлады.*

**Авырыксына бирү** Авырыксынуын дәвам итү

**Авырыксына төшү** 1) Бераз авырыксыну

2) Авырга килү; бераз авырту кичерү. *[Каюм:] Чәчүгә мин барыр идем, ләкин аяк авырыксыныр дип куркам.* Ш.Камал

**Авырыксынып алу** Кыска вакыт эчендә, аз гына авырыксыну

**Авырыксынып йөрү** Әле, хәзерге вакытта дәвамлы рәвештә авырыксыну

**Авырыксынып калу** 1) Кинәт авырыксыну кичерү

2) *күч.* Ни эшләргә белмәү, югалып калу. --- *киресенчә, язып күнеккән кешегә берәр җыенда яисә радио, телевидениедә чыгыш ясарга туры килсә, ул авырыксынып кала.* И.Низамов

**Авырыксынып тору** 1) Күпмедер вакыт авырыксыну кичерү

2) Күпмедер вакыт бераз авыру. *Волостьтан кайткannan соң, Рәүфә берничә көн авырыксынып торды.* А.Шамов

**Авырыксынып утыру** Авырыксынган хәлдә булу. *Проекттагы терминнарны, формулаларны тиешенчә аңлап җиткермәгәнгә күрә, Солтан башта авырыксынып утырды.* Г.Кутуй

**АВЫШ** *с.* **1.** 1) Бер якка янтайган, кыйшайган, кыек. *Ә без, иске чүлмәктер, тимер кыршаудыр эленгән ярым авыш киртә казыкларына карап, тәгәри-тәгәри көләбез.* М.Галиев. *Сикерүче балык агачның авыш кәүсәләреннән үрмәли, хәтта ботактан ботакка сикерә ала.* Кызыклы ихтиология. *Әнә Нәүширван абзыйның аркылы такталы авыш капкасын өстерәтеп ачтылар.* Казан утлары. *Италиянең Пиза шәһәрендәге авыш манара бөтен дөньяга билгеле.* Мирас

2) Сөзәк, сөзәкләнеп торган. *[Балалар] Авыш такта өстенә салган борчак кебек, тәгәрәргә генә торалар.* Ф.Яруллин. *Авыш тау сыртлары. Авыш түбә*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бер якка кыйшаеп, янтаеп. *Авыш үскән агачлар*

2) Сөзәк итеп, бераз кыйшайтып. *Әти урындыкны ясап куйды. Аркасы, утырырга җайлы булсын дип, бөгелмәле итеп, артка таба авышрак итеп эшләнгән.* Г.Бәширов. *Театрның залы авыш итеп күтәртелде.* Мәдәни җомга

◊ **Авыш якка салам кыстыру** Кемне дә булса мактаган булып үсендерү

**АВЫШАЙТУ** *ф.* Авыш хәлгә китерү; кыйшайту, бер якка янтайту

**Авышайта бару** Авышлыгын торган саен аз-азлап арттыру

**АВЫШАЮ** *ф.* 1) Авыш хәлгә (торышка) килү, кыйшаю, янтаю. *Мачта авышаю*

2) *к.* **авышу** (*1 мәгъ.*)

**Авышаеп китү** Көтмәгәндә, кинәт авышаю

**Авышаеп кую** Авышкан хәлгә килү

**Авышаеп тору** Әле, хәзер авыш булу

**Авышая төшү** Бераз авышаю

**АВЫ́Ш-КЫЕШ** *рәв. к.* **авыш-түеш**. *Шөкер әле, бер көе генә авыш-кыеш китергәләп гомер итеп килгән булам шунда.* Ә.Камал

**АВЫШЛЫК** *и.* 1) Авыш булу, авышу үлчәме (дәрәҗәсе). *Ул гына да түгел, эклиптиканың, ягъни күзгә күренгән кояшның күк гөмбәзе буенча еллык хәрәкәт сызыгының экваторга авышлыгын да белә алганнар.* Р.Шәймәрданов

2) Авыш урын; битләү, сөзәк өслек, сөзәклек. *Шиңмәс үлән үсемлеге урманлы зонада, барыннан да ешрак лишайниклы урманнарда һәм тау авышлыкларында очрый.* Е.Солодухин

**АВЫШМА** *и.* **1.** *геом.* Бирелгән ноктадан икенче туры белән кисешү ноктасына кадәрге кисемтә

**2.** *с. мәгъ.* Бераз авыш. *Авышма өслек. Авышма яссылык*

**АВЫШ ПРИЗМА** *и. геом.* Кабыргалары нигезләренә авыш булган призма

**АВЫ́Ш-ТӘВЕШ** *рәв. к.* **авыш-түеш**

**АВЫШ-ТӘВЕШ КИЛҮ** *ф. к.* **авыш-түеш килү.** *Камыт аяклары белән авыш-тәвеш килеп, урамнан бер юантык карчык барса, ул – Газзәтти.* М.Мәһдиев

◊ **Авыш-тәвеш китергәләп** Тормышта бер җитешсезлекне икенче җитешсезлек белән каплап, аннан-моннан тартып-сузып, ничек тә булса яшәү

**АВЫ́Ш-ТҮЕШ** *рәв. сөйл.* **1.** Авыптүнеп, алпан-тилпән, бер яктан икенче якка кыйшаеп. *Кечкенә мие алып ташланган хайваннарда хәрәкәтләр чуалчык була. Йөрүе ышанычсыз, авыш-түеш килеп чыга.* Анатомия

**2.** *с. мәгъ.* Тигезсез, керентеле-чыгынтылы. *Агыйделкәй яры авыш-түеш, Колагыма килә бер тавыш.* Җыр

◊ **Авыш-түеш килү** 1) Алпан-тилпән йөрү, як-якка чайкалу; 2) Урыннары алмашыну, буталып, чуалып бетү. **Авыш-түеш китерү** 1) Әштер-өштер генә, җиренә җиткермичә, нәрсәдер эшләү; 2) Урыннарын алыштыру, чуалту. *Кара әле, әти, пароход китәргә бары ярты сәгать вакыт калган, син монда чәй-шикәрне авыш-түеш китереп азапланасың.* Ф.Әмирхан; 3) Сатуалу, сәүдә белән шөгыльләнү

**АВЫШТЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса бер якка кыйшайту, янтайту. *Гафифә, бераз вакыт хәрәкәтсез яткач, башын азрак Мусага авыштырды.* Ш.Камал. *Имән, башын җиргә таба авыштырып, дөнья белән хушлаша, әтисенә бәйләнешле чор истәлекләрен үзе белән алып, ул киткән якка ава.* Н.Хәсәнов

2) Кыегайту, кыек хәлгә китерү. *Әркәшә вак яза, пөхтә яза. Хәрефләрне*

*авыштыруны бер дә яратмый, һәр хәрефен туры гына итеп утыртып куя.* М.Мәһдиев

3) Читкә елыштыру, этәреп кую. *Сабит агач ботакларын читкәрәк авыштырды.* Казан утлары

4) Сыеклыкны берсеннән икенчесенә бушату, бер урыннан икенче урынга күчерү. *Суны чиләктән кисмәккә авыштыру*

5) Үткәреп җибәрү, уздыру. *Унбишуналты яшьләренә җиткәч, бу егет кырларга чыгып, урманнарга барып, кош-кортлар алып кайта икән дә, ди, болар шуның белән, алай-болай итеп, көннәрен авыштыралар икән, ди.* Әкият

6) Тәрҗемә итү. *Ирем кайбер сүзләрне миңа үзебезчәгә авыштырып әйтә тора.* Г.Ибраһимов

7) *күч.* Берәүнең фикерен, карашларын, мөнәсәбәтен үзгәртеп, икенче як файдасына күчерү, аудару. *Маловның исә төп максаты мөселман татарларны мөмкин кадәр күбрәк христиан диненә күчерү була. --- ул берничә татарны үз диненә авыштыруга ирешә.* Идел

8) *күч.* Игътибарны читкә юнәлтү өчен, сүз яки фикернең темасын үзгәртү, алмаштыру, икенчегә күчерү. *Мөнирә шундый кызып китте, әгәр яшь кеше Бәдретдинов, моның барысын да җиңел шуклыкка авыштырырга теләп, стакан белән су китермәсә, ихтимал, нәрсә булса да булган булыр иде.* Ф.Хөсни

**Авыштыра бару** 1) Рәттән, һәрберсен бер-бер артлы авыштыру

2) Аз-азлап, акрынлап, авышлыгын арттыру

3) *күч.* Һаман да күчерү, кичектерү. *Син, карлыгачым, ак канатым, сүзне ашау, тамак күңелен күрү кебек ярдәмчел төшенчәләргә күчереп, төп сорауга җавапны арткы рәткә авыштыра барасың түгелме?* Т.Галиуллин

**Авыштыра башлау** Авыштырырга тотыну

**Авыштыра төшү** Бераз авыштыру. *--- гармун телләренә баскан бармакларын, чак кына бер якка авыштыра төшкән башын, йөрәк хисләрен кушып уйнаган моңсу йөзләрен бүгенгедәй күрә.* Н.Хәсәнов

**Авыштырып алу** Бераз яисә тиз арада авыштыру

**Авыштырып бетерү** Бөтенесен дә, барысын да авыштыру. --- *бушлай ашау-эчүгә хирыс булган милиция хезмәткәрләрен дә үз якларына авыштырып бетерделәр.* Х.Ибраһимов

**Авыштырып йөрү** Хәзерге вакытта нәрсәне дә булса авыштыру белән мәшгуль булу. *Корыны бушка авыштырып йөрергә сезгә дә киңәш итмим!* А.Гыйләҗев

**Авыштырып калдыру** 1) Тулысынча авыштыру, авыштырган хәлдә тоту

2) *күч.* Нинди дә булса эш башкаруны, бурыч үтәүне кемгәдер йөкләү. *Без күп еллар инде тәрбия эшен мәктәп һәм милициягә авыштырып калдырдык та, үзебез рәхәтләнеп кәеф-сафа кылып, дөньябызны онытып йөрдек.* Ә.Гадел

**Авыштырып кую** Авыштырган хәлдә калдыру. --- *тактаны, 30–45°лы почмак ясап, авыштырып куй.* Э.Нигъмәтуллина

**Авыштырып тору** 1) Бертуктаусыз авыштыру

2) Әле, хәзерге вакытта авыштыру. *Ә сүзләрен бер тылмач теге якка да, бу якка да авыштырып тора.* Ф.Баттал

**Авыштырып чыгу** Һәрберсен бербер артлы авыштыру; башыннан ахырына кадәр авыштыру

**АВЫШУ** *ф.* **1.** 1) Бер якка янтаю, кыегаю, аву. *Солтан, талчыккан кыяфәттә, колясканың сәхтиян артына авышты.* Г.Шәрипова. *Тишек чиләгенең суы агып беткәч, җиңеләйгән кое сиртмәсе, авыр шыгырдап, икенче якка авыша, коры агач тавышы, салкын төн тынлыгын кистереп-кистереп, еракка яңгырый...* М.Мәһдиев. *[Сафа белән солдат] Бер алга, бер артка авышып, көчле дулкында чайкалган көймәдә басып торган шикелле, егылмаска тырыша иделәр.* Ш.Камал

2) Елышу, якынаю. *Ара-тирә, чана чалулап киткәндә, Наилә миңа таба авыша, мамык шәле астыннан чыгып бәсләнгән чәч бөртекләре минем битемә тиеп ала.* Ә.Еники. *Кадыйр икенче ягына авышты, кулларын ялварган кыяфәттә күкрәгенә куйды.* Г.Шәрипова

3) Урыны күчү, икенче якка тайпылу. *Сәгать теле уникедән авышкач, әбәткә утырдык.* И.Гази

4) Тайпылу, юнәлешен үзгәртү. *Малай --- бары тик читкәрәк кенә авышты.* Г.Гобәй. *[Кемдер:] – Йөгерешчеләр килә! – дип кычкырды. Кешеләр аланлыкның читенә авыштылар.* Ә.Фәйзи

5) Вакыт, берәр хәл турында: килү, якынаю; билгеле бер вакытка җитү. *Көн кичкә авышты, тиз-тиз караңгыланды.* А.Гыйләҗев. *Декабрь төне тиз кичкә авышты.* М.Мәһдиев. *Васфикамал зур самавырны өченче мәртәбә күтәреп чыкканда, инде төн уртасы авышкан, мәҗлес кызган иде.* М.Мәһдиев // Вакытның бер өлеше яки фасылы үтеп, икенчесенә (өлешенә, фасылына) керүне аңлата. *Баксаң, аның [лампаның] инде күптән кирәге дә юк, июньнең кыска төне әллә кайчан таңга авышкан икән.* М.Мәһдиев. *Җәйге озын көн күптән инде төшлектән авышса да, кояш баерга ерак иде әле.* Ә.Еники. *Печән өстенең киң күңелле юмарт кояшы, Идел буе халкының киң тугайлардагы бетмәс-төкәнмәс печәнен киптереп арыганнан соң, баер якка авышкан иде.* Г.Бәширов

6) Билгеле бер яшькә якынаю, җитү. *Дүрт буыннан торган бу гаиләне әтиебез, ничектер, бик үз итә, аның иске патриархаль нигезгә корылуын, ягъни яше туксанга авышкан аксакал картның гаилә дилбегәсен үз кулында тотуын бик хуплый.* Р.Әмирхан

7) *күч.* Фикере, карашы үзгәрү, аву. *Ләкин дәмолла, урыс уку йортында уку аркасында, кызының иманы «авышуыннан» шикләнә, төрле чаралар белән аны бу теләгеннән ваз кичтерергә омтыла.* Р.Әмирхан

8) *күч.* Бер якны ташлап, икенче якка кушылу, чыгу. *Дин-исламны, кешелеклелекне, иманны кыйбла иткән хәзрәт уңга да, сулга да авышмый, үзенең тугры сүзле, тугры гамәлле шәхес булуына күләгә төшерми.* Р.Әмирхан

9) Тану, кушылу, нинди дә булса фикерне кабул итү, хуплау. *Галимнәр, татар чабата үрүне маридан өйрәнгән, дигән фикергә авышалар.* А.Тимергалин

10) *диал.* Авыру булу, авыруга әйләнү. *Биредә җан асраган ялгыз хатынның күзе коточкыч каты, дип сөйлиләр иде. Ул сокланып караса, кешеме, хайванмы, шунда ук сырхауга авыша, кайсысы, урынга авып, җан тәслим кыла икән.* Р.Зәйдулла

11) *диал.* Үтү, булып узу (авыру турында). *Куркыткач, бизгәк кача дип --- торам; бетмәде бизгәк чире, дару алып кайткач кына авышты шунда.* Мирас

12) *күч.* Акылга җиңеләю, акылы зәгыйфьләнү, белештерми башлау. *Минем берни аңламаганны күреп, яңадан: – Укый-укый авышкан бер нәрсә инде, кем булсын, – диде.* Ф.Яруллин

**2. авышкан** *и. мәгъ.* 1) Акылга таман, акылга зәгыйфь кеше. *– Алай шыр юләр булса, больницага салырлар иде, – дидем, һаман ышанып җитмичә. – Юләрләр өчен больница каян җиткерсеннәр? Бигрәк тә укып авышканнар күбәйде хәзер.* Казан утлары

2) Фикере, карашы үзгәреп торучы кеше. *Байлыкка өметләнеп, руслар ягына авышканнарның башында Мәмәд була. Шуның бүтәннәрне өстерүе нәтиҗәсендә, Сөембикә дә, Мөхәммәдъяр да зинданга ябыла.* К.Нәфыйков

**Авыша бару** Аз-азлап, акрынлап авышуы арту, торган саен ныграк авышу. --- *чит кеше күзенә чалынмый торган ваклыклары аша исенә, хәтеренә төшергәч, шуларга сәер тавышлы кешенең телефоннан ирештергән дошман тәкъдимнәрен өстәгәч, ул, әкренләп, карт ягына авыша барды.* Т.Галиуллин

**Авыша башлау** Авышуы сизелү; авышырга тотыну. *Канзәфәр сугышчыларын урнаштырып бетергәндә, көн инде кичкелеккә авыша башлаган иде.* З.Зәйнуллин. --- *хәзрәтләренең бәддогаларына, янау-куркытуларына керфекләрен дә селкетмәгән кыяфәт белән, һич икеләнмичә, Мифтах хәлфә ягына авыша башладылар.* Ф.Сафин. *Син нәрсә, Миңсылу апа, әллә син дә авыша башладыңмы? Ничек инде шыр юләр кешегә баласын бирсеннәр?* Ф.Яруллин

**Авыша бирү** Авышуын дәвам итү. *Офыкка сылап куелган күгелҗем кара урман әкрен генә бер якка авыша бирә.* И.Гази

**Авыша төшү** Берникадәр, бераз авышу. *Ул, дөбер-шатыр кубарылып килеп, юп-юка булып ябыгып калган карчыгын иппәп кенә арбасыннан күтәреп алды да, артка авыша төшеп, вак-вак атлап, өстәл башында махсус ясалган ярым бөҗра сыман терәүле йомшак утыргычка алып китте.* А.Вергазов

**Авышып бару** Акрынлап авышу, авышуы аз-азлап арту. *Ә үзе япа-ялгыз, җитмәсә тагын көн кичкә авышып бара, нык кына буранлап та тора иде.* Ф.Хөсни

**Авышып бетү** Тәмам, тулысынча авышу

**Авышып калу** 1) Ниндидер сәбәп белән авыш торыш алу, авышкан хәлгә килү

2) Авышырга өлгерү

3) *күч.* Берәр сәбәп белән акылга җиңеләю

**Авышып килү** Акрынлап, аз-азлап авыша башлау. *Инде таңга таба авышып килә, инде беренче әтәч кычкырды, инде су буеннан яшьләр таралыштылар.* М.Мәһдиев

**Авышып киту** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт авышу. *Бервакыт этләр тутырган читлекле арбаның кузгалуына, бу этләр, чайкалып, бер якка авышып киттеләр.* М.Гафури

**Авышып тору** Әле, хәзер авышкан торыш алу, авышкан хәлдә булу

**АГ** *и. иск.* Ау, тозак, җәтмә. *Бүре агы*

**АГА** *и.* 1) Яшь ягыннан сөйләүченең үзеннән олы булган ир туган, абый. *Ага булыр егетнең итәк-җиңе киң килер.* Мәкаль. *Агаларың безнең бөтен гомеребезне агуладылар – хәзер сине котырталар, синнән агулатмакчы булалар.* Ф.Әмирхан. *Ун яшьтә чагында агам мине Себер ягына алып китте, шунда сатуга өйрәндем.* Г.Ибраһимов

2) Өлкән яшьтәге ир кеше. *Зурларның, агаларның каһарманлыклары [Шәяхмәтнең] күз алдыннан үттеләр.* Г.Ибраһимов

3) Сөйләүченең үзеннән олырак булган ир кешегә мөрәҗәгать итү сүзе. *Моңа мисал итеп, --- Сибгат ага Хәкимнең туган тел язмышын кайгыртып, --- тыштан бик тыныч агышлы кебек тоелган, уйга сала торган чыгышларын китерергә мөмкин.* Мәдәни җомга

4) Өлкән, хөрмәтле кеше; аксакал. --- *бер сүз белән әйткәндә, гасырны иңләп-буйлап кичкән ил агасы Әмирхан Еники сүзе бүгенге шартларда да безгә аксакалның зирәк киңәше булып ишетелә.* Мәдәни җомга

◊ **Агага – эне, энегә – ага** Олыгакечегә ихтирамлы, игътибарлы; кардәш-туган хакын белүче

**АГА́ВА** *и. гр. бот.* Агавачалар семьялыгыннан, үләнчел үсемлекләр ыругына караган, үсү дәверендә бер генә мәртәбә чәчәк ата торган эре яфраклы, чәнечкеле үсемлек. *Җирдән ук калын, озын кыякларын чыгарып үскән бу сыек яшел төстәге үсемлек «агава» дип атала икән. --- Зөһрә ханым әйтә, ул, ягъни агава, үз гомерендә бер генә тапкыр чәчәк ата, ди; чәчәген койгач, үзе дә һәлак була, ди.* Ә.Еники. *Агаваның Мескикада һәм аңа якын районнарда 300 ләп төре үсә.* Биология

**АГА́-ҖИҢГӘ** *җый. и.* Ага белән җиңгә; туган-тумача. *[Гөлбану] Кеше алдында хур булмаска, ага-җиңгәнең яман теленә калмаска теләде.* Г.Ибраһимов

◊ **Ага-җиңгә кулына калу** Ага белән җиңгә, туган-тумача тәрбиясендә яшәү кыенлыгы турында. *Ага-җиңгә кулына калырга язмасын, әти-әнигә гомер бирсен.* Җ.Вәлиди

**АГАЙ** *и.* 1) *к.* **ага** (*1 мәгъ.*). *– Агай, балык капмадымы? – ди энем. – Хәзер, хәзер каба, – дип ышандырам.* М.Кәрим

2) Исемнәргә ялганып, сөйләүченең үзеннән олырак кеше, абый, мәгънәсен белдерә. *Ә авылның үзендә Әсәдулла агай – мөхтәрәм, өстәвенә, бик диндар бер кеше, биш вакыт намазын калдырмый, мәчеткә дә чалмадан гына йөри.* Ә.Еники. *Күрәсең, Солтан агай, бу фани дөньядан аерылганда, барлык малын «очлап» бетерергә өлгергән инде. Аны, бик эчкән, диләр.* Ә.Еники

3) Өлкән ир кеше; ир-ат. *Өстәл тирәсе кунаклар белән тулган. Барысы да диярлек – әтием яшендәге пөхтә киенгән агайлар.* Җ.Фәйзи

4) Авыл кешесе, игенче. *Инәй ягыннан кардәш тиешле мин белгән Янгуразларның күбесе җир эшен яратып, җигелеп эшләүче таза тормышлы агайлар иде.* Ә.Еники. *Буразнада туган, буразнада үскән, җирне хөрмәтләгән, җирдән хөрмәтләнгән агайлар икмәк тәмен беләләр.* М.Рафиков

◊ **Агай олы, мин зур** 1) Яше белән зур булмаса да, берәр төрле исеме, дәрәҗәсе белән үзен зурга куючы; 2) Агайдан элек өйләнү очрагына карата да әйтелә

**АГА́ЙНЕ** *и. к.* **агай-эне** (*6 мәгъ.*). *Берәр кешенең юньсезлеген күрәм дә уйлап куям: юк, агайне, син шундый бер иртәне күрми калгансың.* М.Мәһдиев

**АГА́Й-ЭНЕ** *и. җый.* 1) Ага белән эне, бертуган ике ир кардәш

2) Нәсел-нәсәп, кардәш-ыру. *Базарда, кибетләрдә, мәҗлесләрдә агай-эне аның зур гыйлем иясе булуына, зирәклегенә, чибәрлегенә исләре китеп, тел шартлатып сөйли торган булдылар.* Ә.Еники. *Ире сугышларда йөргәндә, илдән урын сорап алды да, агай-эненең, күрше-күләннең булышлыгы белән, менә шул хәзерге өйне бетереп керә алды.* Г.Ибраһимов. *Шул кыска гына вакыт эчендә ул бу авылга тәмам ияләшә, бу авыл үзенең туган иле кебек, кешеләре үзенең агай-энесе, кардәшләре кебек ягымлы, сөйкемле күренә башлыйлар.* Ш.Камал

3) Әшнә, кода-кодагый. *Кияү алырга бару вакыты җиткәч кенә, кайдандыр шунда агай-энеләр табылдылар.* Ф.Хөсни

4) Гавам; халык, халык массасы. *«Сабантуй» дигән зур хезмәт бәйрәменең вакытына, эчтәлегенә акыллы агай-эне соң заманда ике төрле зарар салды.* М.Мәһдиев. *Әмма Алабуга якларында, җае чыккан саен, гыйбрәтле бер вакыйганы бәян итәргә бик тә ярата иде агай-эне.* Т.Галиуллин. *Агай-эне бераз аптырап кала: – Бу ни гаҗәп?! Бик яман сөйлиләр. Бары да – безнең кебек кешеләр!* Г.Ибраһимов

5) Җәмәгать; мөрәҗәгать сүзе (гадәттә, якын күргән, теләктәш-фикердәш булган кешеләргә юнәлтелә). *Саумысыз, агай-энеләр? Ерак юллардан исән-сау кайтуыгыз белән тәбрик итәм сезне!* М.Мәһдиев

6) Исеме билгесез, таныш булмаган кешегә яки берәр нәрсәгә карата мөрәҗәгать итү сүзе. *Алай дип әйтмә, агай-эне, дим тегеңә, нишләп сәдака булсын. Син бит эшләдең. Миңа никадәр хезмәт күрсәттең. Мә ал, берәр эшеңә ярар.* М.Әмир

◊ **Агай-эне, авыл-күрше** Үзара аралашып, туганлык-кардәшлек белән, бер халык, бер ил булып яшәү. **Агай-эне ак мыек** 1) Агай-энечелек, әшнәлек, кода-кодачалык, үз туган-тумачаңны гына кайгырту. *Хуҗага ошый белгән агай-эне ак мыек рәхәттә, халык әйтмешли, балда-майда йөзеп калды.* Т.Галиуллин; 2) Үз кеше, бер-берен яклаучы бер даирә кешеләре; танышбелешлек. *Агай-эне ак мыек, Бер-берpermalink*

**АГА́Й-ЭНЕЛӘРЧӘ** *рәв.* 1) Агай белән эне кебек

2) *куч.* Артык исәпләшеп тормыйча, тартынмыйча, үз кешеләрчә

**АГА́Й-ЭНЕЛЕ** *с.* 1) *к.* **абыйлы-энеле**. *Ул яши торган йортта агай-энеле ике сәрхуш бар.* С.Зыялы

2) Туган-тумачасы, кардәшләре күп булган

3) *куч.* Күп, ишле, үзе генә түгел. *Бәла җиде агай-энеле, диләр. Дөрес икән.* Шәһри Казан

**АГА́Й-ЭНЕЛЕК** *җый. и.* 1) Туган-тумачалык, якын кардәшлек, туганлык

2) *куч.* Әшнәчелек, кода-кодагыйлык. *Тирә-юньдә агай-энелек хөкем сөрә*

**АГАЛА́У** *ф. сир.* Олылау, тирән ихтирам күрсәтү. *Үз агасын агаламаган кеше агасын сагалар.* Мәкаль

**АГАЛТЫН** *и. к.* **ак алтын**

**АГАЛЫ́-СЕҢЕЛЛЕ** *с.* Ага белән сеңел, абый белән сеңел. *Агалы-сеңелле бертуганнар кебек, без гел бергә уйнап, бергә укып үстек.* С.Сабирова. *Безгә агалы-сеңелле дуслар кеби карыйлар.* Г.Ибраһимов

**АГАЛЫ́-ЭНЕЛЕ** *с.* Ага белән эне, абый белән эне. --- *агалы-энеле, кызып, шушы хәйләне тикшерә башладылар.* С.Шәрипова. *Агалы-энеле, --- күп вакытта аралары бозылып, үпкәләшеп йөри иделәр.* Ш.Камал

**АГАМАСЫМАННАР** *и. биол. күпл.* Кәлтәләр семьялыгына кергән, койрыгы озынча, башы вак кына мөгезтәңкәләр белән капланган кәлтәләр; *русчасы*: **агамовые**

**АГАР** *с.* Агып яткан. *Агар су – татлы, саф. Салкын, гаҗәиб чишмәләр, күлләр.* Г.Тукай. *Кояш йөзен чытты. Аглады. Инде көлми агар сулар.* Г.Тукай

**АГАР-АГАР** *и. малая* Койка ясау өчен кулланыла торган, диңгез суүсемнәреннән киптереп әзерләнгән ике әче полисахарид кушылмасы

**АГАРТКЫЧ** *и.* **1.** 1) *махс.* Агарту матдәсе (сыекча яки порошок хәлендә була). *Суга иң кыйммәтле порошок, агарткыч сала.* Татарстан яшьләре. *Беренче тапкыр кигән киемдәге тапны бетерү өчен ниләр генә эшләп карамыйсың, сабын белән дә, порошок белән дә юасың, агарткычларга да саласың.* Ватаным Татарстан. *Тапка агарткычны пипетка белән тамызу*

2) *сөйл.* Аш яки чәй тәмләү өчен салына торган каймак яки сөт. *Чәйгә агарткыч салсаң, тәмлерәк була*

**2.** *с. мәгъ.* Агарта, ак төс бирә торган. *Селтеле һәм агарткыч эреткечләрне бары тик ак керләрне агарту өчен генә кулланырга ярый.* Ватаным Татарстан

**АГАРТУ** *ф.* 1) Ак яки аксыл төскә кертү, ак итү. *Җир ачылып, үлән кипкәч, боларны үзе кебек кызлар белән елга буенда, яшел чирәмдә, кояшта киптереп агартты, аннан җәйге кичләрдә иптәшләре белән җыелып тукмадылар.* Г.Ибраһимов. *Иртә белән, өй түбәләрен, каралты башларын, урманнарны агартып, ап-ак кырау төшә ---.* Г.Бәширов. *Рәшә шушы дүрт-биш көн эчендә арышларны агартты ---.* Г.Галиев

2) Акшарлау, акшар белән буяу, аклау, акка буяу. *Имтиханга кем мич агарта, кем идәнен юа, --- кем урманнан ылыс алып кайта – шуларны бүлешеп куйдылар.* Г.Гобәй. *Илсөя үзенең ике иптәш кызы белән яңа квартираны җыештырырга килде ---. Кырдылар. Юдылар. Агарттылар.* Ф.Яруллин. *Менә җыен атнасы да килеп җитте. Хатын-кыз өйләрне җыештырып,*

*стена, идән, сәкеләрне юа, мичләрне агарта.* М.Галәү

3) Нәрсәнең дә булса өслегеннән тузанын, пычрагын, тутыгын һ.б.ш.ны сөртеп алып, аны ялтыраган хәлгә китерү. *Хатыным ул өйне курчак итте – идәнне кырып агартты, стеналарын сабынлап юды.* Г.Шәрипова. *Кайткан араларда [кыз] өй эшләренә йөгерә: суын китерә, идәнен сап-сары итеп юып ала, самавырын агарта.* Ф.Хөсни. *Гайния, килгән саен, безнең әллә ничаклы эшләрне башкара: өйне җыештыра, самавырны агарта, карчыкның --- яшелчәләренә сулар сибә иде.* Г.Ибраһимов

4) Юып, пычрактан, кердән арындыру. *[Азали] --- өстебездән йолкып алып диярлек, бер-ике генә көн кигән күлмәкләребезне юып, сөттәй агартып бирә.* Х.Сарьян

5) *күч.* Аң-белемле, гыйлемле итү, аң-белем бирү. *[Габдрахман абзыйның] Бөтен хыялы һәм максаты татар, башкорт халкын агарту иде.* Ә.Еники. *Халыкны агартуда Булат иптәш арабызда күпләрдән алда тора.* М.Җәлил. *Халыкны агартуны, дәүләтле милләтләр дәрәҗәсенә җиткерүне зыялы байлар, химаячеләр үз өстенә алган.* Ф.Яруллин

6) Чал төскә кертү, чаларту. *[Алар] Үзләре дә бәхетсез булды, минем дә чәчләремне вакытсыз агарттылар.* Г.Ибраһимов. *Курыктык, улым, курыктык, йөрәгеңә авыр булыр, дидек. Мондый авыр хәбәр олыларның да башын агарта, буйларын сындырып сала.* Казан утлары

7) Начарлыклардан яки бозык уйлардан, начар теләкләрдән арындыру, пакьләү; рухи сафландыру. *Вахит, «кяфер» коллыгында йөреп карайган күңелен агартуын, укулар яңартып, бер авылга мулла булып, --- матур гына кызга өйләнүен уйлап, күңелен баса иде.* З.Һади. *Безнең өчен иман шулдыр: бу дөньяның Карасына мана-мана җаның агарт.* Х.Әюпов

**Агарта бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы агарту

**Агарта башлау** Агартырга тотыну. *Кызлар гөрләшә-көлешә чәй эчте, ә мин, җилкәмә атланган өр-яңа мәшәкать турында уйлап, чәч агарта башладым.* Н.Гыйматдинова

**Агарта төшү** Берникадәр, бераз агарту; тагын да агарту

**Агартып алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә агарту; берара агарту эше белән мәшгуль булу. *Өйне дә чистартып, агартып аласы бар, кайда ишелгән, кайда купкан.* З.Дәүләтов. – *Рашат, морҗа башын агартып аласы бар иде бит, – ди бу.* Р.Низами

**Агартып бетерү** Бөтенесен, тулысынча агарту. *Бу сакалымны шулар гына агартып бетерделәр инде.* Г.Камал. *Эчкән дарулар каныңны агартып бетерде синең, шул дарулар сине үтерәчәк тә!* А.Гыйләҗев

**Агартып җибәрү** Берара, бераз агарту, агартырга да өлгерү. *Безнең якта шулай ул: яз-җәй җиттеме, бөтен өйләрнең дә тышларын агартып җибәрәләр.* Д.Бүләков. *Дөрес, бөтен бүлмәләрнең дә түшәм-стеналары бик керләнгән инде, ләкин буясын буяп, агартасын агартып җибәрсәң, өй эче яңадан көлеп торачак!* Ә.Еники

**Агартып йөрү** Хәзерге вакытта агарту белән мәшгуль булу. *Кызы, килеп, самавырларына чаклы агартып йөри бит!* М.Фәйзи. --- *әнием һич эштән бушамый – әле, чөгендердән арынып торганда, колхоз келәтләрен агартып йөри.* Г.Якупова

**Агартып карау** Агартырга омтылу, төрлечә сынап агарту. *Факия апа шул азауларын чистарта-чистарта иза чигә. Күмер белән дә агартып карады, киндер белән дә ышкыды.* Р.Батулла

**Агартып кую** Алдан ук агарган хәлгә китереп калдыру. *Өстәл өсләрендә, мич яннарында – һәйбәт агартып куйган шәмдәлләр, җиз тазлар.* К.Насыйри. *Безнең бакчадагы алмагачларны да агартып куйганнар.* Т.Миңнуллин

**Агартып тору** 1) Һәрвакыт, гел агарту. *Шәһит киткәннәрнең исемнәре Килер буыннарга күчкән дә Хакыйкатьне гел агартып тора, Хәтерләрне гел яңартып тора Гасырларны узган көннәрдә.* Ф.Тарханова

2) Әле, хәзерге вакытта агарту белән шөгыльләнү. *Бәхеткә, өй эчендә беркем дә юк, әнкәйнең ишегалдында самавыр агартып торган чагы иде.* Г.Галиев

**АГАРТУЧЫ** *и. махс.* 1) Нәрсәне дә булса кырып, буяп, ак (ялтырап торган) төскә кертүче кеше; *русчасы*: **отбельщик**. *Күн агартучы*

2) *күч. кит.* Аң-белем таратучы; мәгърифәтче. *Китап – кеше җанын агартучы, илһам бирүче, нур сибүче һәм матурлык-изгелеккә өндәүче.* Ә.Закирҗанов. *Исхакый фикеренчә, муллалар авылда әхлак, иман саклаучы, халыкка аң-белем бирүче, агартучы укытучы булырга тиеш.* М.Сәхапов

**АГАРУ** *ф.* 1) Ак яки аксыл төскә керү. *Киң яланнар, биек таулар, урманнар, болыннар – һәммәсе карның үзенә бер яңа матурлыгы белән түшәлеп агардылар.* Г.Ибраһимов

2) Аксыл булып күренү. *Сулда, карлы дала кебек агарып, мамык басуы күренә.* Д.Аппакова

3) Пычрактан, кердән арыну, чистару

4) Юганнан соң, кердән, пычрактан арыну. *Минем каралган кульяулыгым агарыр әле юсаң.* Бәет. *Кайнатып югач, керләр бик агарган*

5) Яктыру, караңгылыктан арыну. *Сафа белән Саҗидә аулак урыннарыннан кузгалганда, инде кояш чыгышы ягы агарган, өченче әтәчләр кычкырган иде.* М.Галәү. *Чынлап та, Фәнис күптән чамалап килә инде, төнгә каршы табигать кискен үзгәрә икән: кар карая, ә төн агара, яктыра.* Мәдәни җомга

6) Дулкынлану, курку, суыктан туңу һ.б.ш. сәбәп аркасында йөзнең, битнең төсе үзгәрү; чырай китү. *Менә берзаман мич артыннан озак вакыт ояда утырып чырае агарган кара тавык, яман кабарынып, Машаның аяк тирәсендә әйләнә-әйләнә, «кор, кор» дия-дия килеп чыкты.* Ә.Еники. *Әнә борыннарың, битләрең агарган, мөгаен, өшегәндер.* М.Гали. *Менә бердән аның кып-кызыл бите агарды. Калтырана башлады.* Г.Исхакый. *Аның йөзе марля кебек агарган, авызыннан чыккан сүзләрен аңлап булмый.* Казан утлары

7) Озак киюдән, юудан яки кояш ашаудан әйбернең төсе китү, буявы уңу, төссезләнү

8) Чалару, бәсәрү, өлешчә яки тулысынча ак төскә керү, чалга әйләнү. *29 яшьлек ирнең чәче, сакал-мыегы агара, күзләре эчкә бата, битен җыерчык баса.* Г.Гобәй. *Ә күңелдә яшәү омтылышы чәч агарган саен яңара.* Ф.Кәрим. *Бу угыллар үсеп җитәр вакытларда, Мөхәммәтгали бабай зур-зур эшләргә ирешкән вә башы кар төсле агарган [иде].* Г.Тукай

9) *куч.* Аң-белем алу, гыйлем белән кораллану; рухи сафлану. *Китап укысаң – күңел агара*

10) Югалып, каушап калудан, дулкынланудан һ.б.ш. йөздән кан качу, агарыну. *Аны күргәч, Тимербулат каушап калды, агарды.* М.Җәлил. *Бикә куркудан калтырана башлады, ә инде аның кулындагы тамырны күргәч, кар кебек агарды.* Г.Шәрипова. *Шәрхемулла шул вакытта кинәт кенә агара, катып кала һәм --- баскан җиреннән күккә карап үкерә башлый иде.* М.Мәһдиев

**Агара бару** Акрынлап, аз-азлап агаруы арту. *Офык читеннән кызгылт бакыр ай тәгәрәп чыкты. Күтәрелгән саен ул агара барды.* М.Кәрим. --- *ябалак-ябалак кар ява башлады. Һәр тараф тын һәм торган саен ныграк агара, яктыра барды.* Ф.Садриев

**Агара башлау** Агарырга керешү, аклыгы сизелерлек булу. *Ялкын агара башлау белән, топкаңны ач та эреп укмашкан күмер катламын лом белән каерып сындыр.* М.Юныс. *Җәйге төн инде агара да башлаган*... Гали Рәхим

**Агара төшү** Бераз агару, аксыллану; тагы да күбрәк агару. *Бер айдан бирле түр сәкедә авырып яткан Һаҗәрнең йөзе, бу сүзләрдән соң, тагы да ныграк агара төште.* К.Нәҗми. *Әтием сизелерлек агара төште.* Ә.Еники

**Агарып бетү** Тәмам, бөтенләй агару. *Мәгъсүм үзенең сукно чалбарын юа-юа агарып беткән --- юка яшел галифегә алмашты.* Г.Гобәй. --- *отрядыбыз башлыгы Пепин агайның, билдән үлән ерып, юлсыз җирдә юл салып барган армас-талмас тынгысыз җанның, кояшта, җилдә агарып беткән плащ аркасын күрәм.* Л.Ихсанова

**Агарып калу** Нindидер сәбәптән соң яки вакыт узгач агарган хәлгә килү. *Ай агарып калды.* И.Гази. *Әтисенең ике ягыннан да милиционер атлый. Ник? Әтисенең йөзе каны качкан кешенекедәй көлсуланып агарып калган.* Н.Хәсәнов

**Агарып килү** Кинәт агару; акрынлап, аз-азлап агару. *Көнчыгыш ягындагы күк итәге инде агарып килә, йолдызлар да нурларын югалта, тоныклана баралар.* А.Шамов. *Далада таң агарып килә бугай.* Г.Ибраһимов. *Учебный корпус янында постта торганда, таң агарып килгәндә, мин ул спутникны күрдем.* М.Мәһдиев

**Агарып китү** Кинәт кенә агару. *[Рәүфәнең] Күз төпләре күгәргән, яңаклары, ничектер, бер төн эчендә агарып китеп, суырылып кергән.* А.Шамов. *Хәбибуллин җавапсыз кала, күзләре аның зур булып ачылалар, һәм йөзе сизелерлек дәрәҗәдә агарып китә.* Ә.Еники. *Фаягөлнең бу сөйләшүдән ризасызлыгы чыраена бәреп чыкты: бите, әлерәк кенә алсуга кабынган бит алмалары сулды, агарып китте.* Г.Ахунов

**Агарып тору** 1) Һәрвакыт, гел аклыгын саклау. *Туган илнең ап-ак нигез ташы Гел агарып тора күңелдә.* Р.Ягъфәров

2) Әле, хәзер ак булып күренү. *Агарып тора Кремль, Борынгы манарасы. Үткән аның башларыннан Тарихлар маҗарасы.* Н.Исәнбәт. *Чәчәк аткан суган түтәле төнлә агарып тора.* Ш.Галиев. --- *шул канәфер арасында ике ак мәрмәр кабер ташы агарып тора.* Ә.Гаффар

**Агарып чыгу** Бөтенләй, бөтен җире агару, ак төскә керү. *Без үр битен казып кереп ясалган зур мичтә акбур ташын яндырганнарын, эче кар кебек агарып чыкканын карап тордык.* Г.Гобәй. *Фәйзулласының каратут йөзе көлсуланып агарып чыкты, ирен читләрендә күбекләр пәйда булды.* Н.Хәсәнов

**АГАРЫНУ** *ф.* 1) Артык куркудан, дулкынланудан яки ачудан төс китү, чырайга ак төс иңү. *Хат иясе Сәйфуллин, агарынып, ни эшләргә белми катып торды да, кинәт кәгазьне авызына кабып чәйни башлады.* Г.Ибраһимов. *Гамбәр, дулкынлануыннан агарынып, почмактан-почмакка йөренде.* Г.Шәрипова. *Тукта, нинди күләгә төште соң әле аның йөзенә? Күзләре нигә болай куркынып ачылды, йөзе нигә болай агарынды?* М.Маликова

2) Озак авырудан, ачыгудан яки каты салкыннан үзенең табигый төсен югалту

**Агарына бару** Торган саен ныграк агарыну. *Ел патшабикәсенең чырае торган саен уйчанлана, моңсулана һәм агарына барды.* Һ.Андерсен

**Агарына башлау** Агарынырга тотыну. *Комиссиядәгеләрнең бер өлеше куркып агарына башлый, бер өлеше куркып кызара, бер өлеше моны шаяртуга ала.* Р.Батулла. *Чибәр ханым күзгә күренеп агарына башлады, гәүдәсе кечерәеп калгандай булды.* Т.Галиуллин

**Агарына төшү** Бераз агарыну, аклыгы тагын да арту. *Өй эче дә ничектер агарына төшкән кебек булды.* Ә.Еники

**Агарынып калу** Нindидер сәбәптән яки вакыттан соң агарынган хәлгә килү. *Бәдретдин агарынып калды, чарасыздан йөзеген салып, шәехкә сузды.* М.Хәбибуллин. --- *хастаханә һавасын сулап ятканга элеккеге алсулыгын югалтып, агарынып калган йөзен ничектер үзенә бер ямь белән яктыртып, матурайтып җибәргәндәй булды.* Ә.Сафиуллин

**Агарынып китү** Көтмәгәндә, кинәт агарыну. *«Сезгә бу исем берәр нәрсә сөйлиме? Минем белүемчә, сез аның әнисе булырга тиеш». Хатын агарынып китте.* Ф.Яруллин

**Агарынып тору** Әле, хәзерге вакытта агарынган хәлдә булу

**АГАЧ** *и.* **1.** 1) *биол.* Төп сабагы каты кәүсә, ботаклары ябалдаш хасил иткән каты үзагачлы үсемлекләрнең гомуми атамасы. *Аннары, берзаман, юлыбыз калын урман эченә кереп китә, ике яклап сузылган куе, таза агачлар арасыннан берни күрмичә озак кына барабыз.* Ә.Еники. *Агачлар кәүсәсе, ябалдашы, үсү юнәлеше, тамырларының үзенчәлекләре буенча бик күп төрле.* Биология. *Ылыслы һәм ике өлешле агачларда ботаклар типик ябалдаш хасил итә.* Биология

2) Әйберләр ясауга һәм төзелеш эшләренә китә торган материал; үзагач. *Манара үзәгенә ботаксыз кара чыршы, я булмаса төз нарат булсын, ди. Дүрт буйлык агачны каян табасың тиз генә.* М.Мәһдиев. *Флейта кара агачтан гына түгел, соңгы вакытларда металлдан һәм пыяладан да эшләнә башлады.* Ә.Бакиров. *Зинһар, кем, Мортаза туган, агачның адәм рәтлерәкләрен бирә күр инде.* М.Хәсәнов. *Шулай өчдүрт көн үтте, буралык агачларны аударып, иңнәренә бау уздырып, бауны бүрәнә башына бәйләп, һай-һайлап, кирәк кадәр агачларны аланга ташып та куйдылар.* Я.Зәнкиев

3) Элгеч хезмәтен үти торган, шул материалны юнып эшләгән чөй, таякчык. *Стенаның сул ягына берничә агач кадалган, боларда камытлар, йөгәннәр, ияраләр элүле тора.* Г.Ибраһимов

4) *күч. гади с. хур.* Аңгыра, миңгерәү, надан

5) *тар.* Электә ераклык үлчәү берәмлеге; ачык җирдә агач күренерлек ара

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул материалдан эшләнгән (салынган), шуннан торган. *Ике чат ара узгач, шактый зур, агач түбәле, алты почмаклы искергән өйгә керде.* А.Расих. *Гыйльмениса апа мичтән чыккан бәрәңгене агач табакка сала, өстенә су бөркә һәм, киндер ашъяулык каплап, парланырга куя.* М.Мәһдиев. *Әйбәт, әдәпле егетләр – Гыйльмулла, Нуриәхмәт, Шәһидулла, Галиәхмәт – агач бүкәндә утырып үстеләр дә Ватан азатлыгы өчен көрәшкә чыгып киттеләр...* М.Мәһдиев. *Ул заманда хәзерге кебек җыйнак тимер сабаннарның исеме дә юк, һәркем, зур һәм авыр булганга, агач сабанга дүрт ат җигеп, җирне шуның белән сөрәләр иде.* М.Гафури

2) *күч.* Катып калган, җансыз. *Директорның йөзе чырагач кебек кипкән, каткан. Ләкин ул агач елмаю белән елмайды...* М.Мәһдиев. *Моннан соң мин куркак булмыйм, беркем алдында да җебеп тормыйм, төкерәм мин сезнең таш, тимер, агач чырайларыгызга...* М.Мәһдиев

◊ **Агач авыз** *гади сөйл., тирг. с.* Уен-фикерен үз теле, үз сүзләре белән оешмырып әйтә, фикерен юньләп аңлата алмый торган рәтсез кеше; тупас телле, итагатьле итеп сөйләшә белми торган кеше. **Агач акча** Бәясе бик нык төшкән яки ялган акча. **Агач акчага алу** Көтәргә бурычка алу яки йөрми торган, ялган акчага сатып алу. **Агач арасыннан урман күрмәгән** Аңсыз, аңгыра кешегә карата әйтелә. **Агач ат** Ясалма, алдавыч нәрсә. *Сөю шигыре агач аттыр «Вакыт»ча, Зарар юк, ул сөйләр анчак вакытча.* Г.Тукай. **Агач атка атландыру** Кешене алдау, ялганга ышандыру, алдандырып калдыру. *Кайвакыт мәҗнүн кеби көлмәс вә шатланмас идем, Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң.* Г.Тукай. **Агач атка атлану** Алдану, өметләнеп көткәнеңә ирешә алмау. *Шул вакытта иптәшлеккә алдылар да, Акыртынлап, агач атка атландылар.* З.Бәшири. **Агач башы тәсбих әйтә** Агач башының акрын искән җилгә һаман бертөсле чайкалып, яфракларының лепердәп торуы. *Агач башкайлары тәсбих әйтә Акрын гына искән җил белән; Еламачы, сылуым, ник елыйсың, Бер без генә түгел – ил белән.* Җыр. **Агач башындагы карга авызыннан калҗа тартып ала** Кеше өлешен, еракттан торып, кулларыннан тартып алырлык дәрәҗәдә үткен кеше. **Агач игәү** *к.* **агач пәке**. **Агач пәке** Сүзен җиткереп әйтә белмәүче, сүзен үткәрә алмаучы; сүзе үтмәс кеше. **Агачтан төймә генә төйми** Кулыннан килмәгән эш юк, үтә оста куллы, һөнәрле кеше

**АГА́Ч АЯК** *и.* 1) Югары очыннан кул белән тотынып атлап йөртелә торган, аркылы басмалы ике озын таяк; *русчасы*: **ходули**

2) Ясалма аяк, протез. *Нәкъ шушы минутта ишекне киң ачып, Мәрьям абыстайның агасының улы, былтыр фронттан агач аяк белән кайткан Шәрифулла килеп керә.* Ә.Еники. *Тизрәк! Тизрәк! Ашыккан саен, агач аяк төртелә, сөртенә.* И.Салахов

**АГА́Ч БОГАУ** *и. тар.* Борынгы дәвердә кешенең муенына һәм кулларына кидерелә торган богау; *русчасы*: **колодка**

**АГА́Ч-БОГАЧ** *җый. и. сөйл.* 1) Һәртөрле агач үсентеләре

2) Вак-төяк агач кисентеләре; кирәксез ботак-сатак. *Әухәди сугышка кадәр үк китереп ташлаган бүрәнәләрен каезлап, черемәсеннәр өчен астына агач-богач кыстырып, әйбәтләп өйде.* Ф.Яруллин

**АГА́Ч ГӨЛ** *и. бот.* Тутчалар семьялыгыннан, сөтчел сыекчалы, кайбер төрләре каучуклы, кыйммәтле үзагачлы, мәңге яшел, төренә карап агач, куак, сирәк кенә лиана; *русчасы:* **фикус.** *Агач гөлне тропик урманнарда күпләп очратырга мөмкин.* Биология

**АГА́Ч КОРТЫ** *и. зоол.* 1) Төн күбәләкләре семьялыгыннан, канатлары челтәрсыман бизәкле, агачның үзагачын ермачлап ашап юллар ясый торган корт; *русчасы*: **короед**

2) Коңгызның агачларга зыян сала торган төре, кисмән; *русчасы*: **дровосек**

3) *күч.* Тынгысыз, тиктормас кеше. *И, бу малай агач корты икән бит, бигрәк тиктормас инде*

**АГАЧЛАНУ** *ф.* 1) Агач кебек катылану, каты хәлгә килү. *Күп кенә агаччыл үсемлекләрнең агачлану дәрәҗәләре төрлечә була.* Биология. *Яшь ылыслар үсә башлаган вакытта, карагайда күп санда күркәләр барлыкка килә. Көзгә алар агачлана һәм ачык көрән төскә керә.* Ботаника

2) *күч.* Тупаслану, миңгерәүләнү, наданга әйләнү

**Агачлана бару** Акрынлап агачлану; агачлыгы торган саен арту. *[Илшат] --- үзенең, ничектер, тупаслана, агачлана баруын әйтте.* Г.Әпсәләмов

**Агачлана башлау** Агачлану үзлекләре күренү. *Сабакларының түбәнге өлешләре агачлана башлаган үсемлекләрнең гадәттә очларын гына файдаланалар.* Е.Солодухин

**Агачлана төшү** Бераз агачлану; тагы да агачлану

**Агачланып бетү** Тәмам, тулысынча агачлану, каты хәлгә килү

**Агачланып җиту** Тәмам агачланган хәлгә килү

**Агачланып китү** Кинәт агачлану, бераз агач сыман булу. --- *тынгысыз бармаклар орынуга, Зәйтүнәнең тәне агачланып киткәндәй була. Эчтә – ут, тышта – агач кабык...* М.Маликова

**Агачланып тору** Агач сыман булып күренү

**АГАЧЛЫК** *и.* 1) Төрле агачлар күп үскән урын. *Шуннан соң атларның тезгененнән тотып, тыя-тыя гына, бөтен ягын куе агачлык каплаган тирән чокырга төштеләр.* Ә.Еники. *Череп ята торган кәүсәләр, кеше аягы тимәгән куе агачлык арасында аюлар күп, диләр.* Н.Хисамов

2) Вак агачлар, куаклар утыртылган урын. *Агачлыкка күмелгән яшел калай түбәле мәктәп тирәсендә ниндидер карамчыклар мәш киләләр.* А.Гыйләҗев. *Бөтен бакчалар, бөтен агачлыклар сандугач белән тулган төсле.* Гали Рәхим

3) Утыртылган буй урман, кыр ышыклау полосасы. --- *ул [бүре] кинәт кыр ышыкларга утыртылган яшь агачлык арасына кереп ятты*. Р.Батулла

4) *диал.* Зират. *Берәр елдан Шакир абый дөнья куйды, бөтен авыл ирләре аны агачлыкка озатты*. М.Мәһдиев

**АГА́Ч МАЕ** *и.* Түбән сыйфатлы зәйтүн мае. *Кара мулладан өшкертеп алган агач маен ул эссе мунчада һәм мунчадан соң да кабат-кабат сөртте.* Ш.Камал

**АГА́ЧСЫМАН** *с.* Агачка охшаган, агач шикелле ябалдашлы, ябалдашланып торган. *Бу чорда [Ташкүмер чоры] абагасыманнар яр буендагы үсемлекләр дөньясын гына түгел, бәлки бик көчле үскән агачсыман гигант нарат, плаун һәм абага урманнарын да тәшкил иткән.* Ботаника

**АГАЧЧЫЛ** *с.* Тукымасы агачныкына охшаган, үзагачлы. *Агаччыл үсемлекләрнең дару чималын төп һәм арадаш урман кисү вакытында аударылган агачлардан --- әзерләргә кирәк.* Е.Солодухин. *Җимешнең агаччыл кабыгы*

**АГА́-ЭНЕ** *җый. и. к.* **агай-эне**. *Агаэненең, якын кардәшләрнең балалары бар.* Г.Ибраһимов

**АГГЛЮТИНАТИВ** *с. лингв.* Ялганмалы, сүзләргә кушымчалар ялганып ясала һәм төрләнә торган. *Агглютинатив телләр системасы*

**АГГЛЮТИНАТИВЛЫК** *и. лингв.* Ялганмалылык, ялганмалы булу сыйфаты. *Татар теленең агглютинативлык табигате*

**АГГЛЮТИНА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *лингв.* Тамыр үзгәрмәгән хәлдә, сүзнең тамырына кушымчаларның бер-бер артлы ялгану күренеше

2) *биол.* Бактерияләр, эритроцит, лейкоцитлар һ.б. күзәнәкләрнең укмашуы. *Агглютинация кан группаларын, бактерияләрнең төрләрен, йогышлы авыруларны ачыклау өчен кулланыла.* Биология

**АГГЛЮТИНИННАР** *и. биол. күпл.* Кан плазмасы составындагы антитәнчекләр. *Агглютининнар күзәнәк мембранасындагы антигеннар белән үзара бәйләнешкә кереп, аларны ябыштыралар*. Биология

**АГЕНТ** *и. лат.* 1) Берәр кешенең, учреждениенең яки предприятиенең тапшыруы буенча эш йөртүче кеше, вәкил. *[Майпәрвәз:] Әнә дәүләткә тире, йон, йомырка җыючы агент булып кер. Күрәсеңме, агентлар балда-майда йөзәләр.* Ә.Еники. *Шул көннәрдә генә авылга райфо агенты килеп төшә; --- агент бер көн ята авылда, ике көн ята*. М.Мәһдиев. *Азмы-күпме ашамлык табарга җае булыр, дип, әтием «Киргосторг» дигән әртилгә агент булып эшкә керде.* Җ.Фәйзи

2) Кемнеңдер мәнфәгатен яклап, астыртын эш йөртүче. *Вәли бай, җир эшләре идарәсендәге агентлары аркылы бармак йөртеп, [совхозның] бөтен байлыгын --- суырып яткан*. Г.Ибраһимов

3) Яшерен хезмәткәр. *Шпион МГБ да йоклап ятмаган, агент арты агент җибәреп, уй сукмакларына җәтмә салган.* А.Гыйләҗев. *Үз сәяси максатларын күздә тотып, рус хөкүмәте дә Казан төркиләре арасына агентларын кертә.* Ә.Мәңгәр. *Аларның икесенең [жандарм управлениесендә] яшерен агент булулары фаш ителгән*. К.Нәҗми

**АГЕНТЛЫК** *и.* 1) Агент вазифасы, агент булу. *Закир – әүвәл учитель булган, соңыннан аны ташлап, страховой агентлык итә башлаган ---*. Ф.Әмирхан

2) Нинди дә булса учреждениенең урындагы бүлеге; шулай ук кайбер арадаш учреждениеләренең атамасы. *Татарстан президенты Рөстәм Миңнеханов Женевада узган инвестиция-ләр агентлыкларының халыкара берләшмәләр конференциясендә (WAIPA) чыгыш ясады*. Татар заманы. *Бу очракта агентлык тиешле документлар тутыру белән генә шөгыльләнде*. Ватаным Татарстан. *Шунлыктан Русиянең эре туристлык агентлыклары Мисырга очучы чартер рейслары санын киметә башлаган*. Татарстан яшьләре

3) *махс. к.* **агентура** (*1 мәгъ.*). *Юк шул, коры бүләк түгел, агентлык өчен «эш» хакы.* Ш.Камал

**АГЕНТУ́РА** *и. лат.* 1) Берәр илдә икенче дәүләт агентлары тарафыннан алып барыла торган һәртөрле җимерү, корткычлык һәм шпионлык эшләре

2) *җый. и.* Агентлар. *Аның [жандарм] эчке агентурасы да, тышкы күзәтчелеге дә яхшы куелган иде.* Г.Ибраһимов

**АГИТ-** *лат.* Кушма сүзләрдә «агитация» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *агитмәйданчык, агитпоезд, агитпункт*)

**АГИТА́ТОР** *и. лат.* Агитация эшләре алып баручы, агитацияләүче, өндәүче. *Почмакта отряд агитаторы Гайфи, ике туташ арасына утырып, аларга әллә нәрсә сөйләп, эчләрен катырганчы көлдерә*. Ш.Усманов. *[Солтан:] – Нинди шәп агитатор, сизми торганбыз, – диде ул эченнән, – бу эшне бит аңа берәү дә йөкләмәде.* Г.Кутуй. «*Үзара ярыш» дигәнен дә көйләп җибәрәсе булыр, агиторга әйтермен.* Г.Бәшиpов

**АГИТАТО́РЛЫК** *и.* Агитатор булу. *Мин, --- завод эшчеләре арасында агитаторлык хезмәтен дә үти башладым.* Х.Садри. *Кәгазь эше, прививка, медосмотр, флюорография үткәртү, районга хисап тотарга барулар гына түгел, колхоз эшенә йөрү, агитаторлык ише мәшәкатьләре дә бетәсе түгел бит әле аның.* Сөембикә. *1950–1960 елларда авыл укытучылары, балалар укытудан тыш, агитаторлык вазифасын да үтиләр иде.* Татарстан яшьләре

**АГИТАЦИОН** *с. кит.* Агитация рухында, агитация рухы белән сугарылган. *Сатирик юнәлешле бу комедияләр*

*көннең актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыгулары, агитацион рухта язылулары белән аерылып торалар*. Казан утлары

**АГИТА́ЦИЯ** *и. лат.* Берәр сәяси кампания уңае белән телдән һәм язма рәвештә өндәү, максатчан идеяләр тарату эшчәнлеге; нәрсәгә дә булса өндәү, чакыру эше алып бару. *Агитация, пропаганда – шул приказны тизрәк тормышка ашыруда ярдәмче.* И.Салахов

**АГИТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Агитация эше белән шөгыльләнү, агитация алып бару // Нәрсәгә дә булса өндәү, димләү. *Сәламәт тормыш алып баруны агитацияләү*

2) *сөйл.* Кемне дә булса үгетләп, аның фикерен үзгәртеп, үз ягына аударырга тырышу

**Агитацияләп йөрү** Анда-монда барып, һәрберсен агитацияләү

**Агитацияләп карау** Агитацияләргә тырышу, агитацияләргә омтылыш ясау

**Агитацияләп килү** Күптәннән, элек-электән агитацияләү; озак вакытлар дәвамында агитацияләү

**Агитацияләп тору** Бертуктаусыз, әледән-әле агитацияләү

**АГИТБРИГА́ДА** *и. рус* Халык арасында агитация эшләрен алып бара торган коллектив, кешеләр төркеме. *Агитбригада килсә – Ташлытаудан. Әле күз башында гына килеп, мәктәптә сәхнә ясап, пыр туздырып тәнкыйтьләп киттеләр.* М.Мәһдиев. *Хәзер менә агитбригадалар төзеп, концертлар куеп йөриләр.* Ф.Яруллин

**АГИТЛА́У** *ф. к.* **агитацияләү**

**АГИТПУ́НКТ** *и. рус* Халык массалары арасында агитация эшләрен үткәрү буенча җирле иҗтимагый-сәяси учреждение

**АГЛА́У** *ф. иск.* Елау. *[Карчык] Өч көн, өч төн үзен тота алмый каты аглады.* Г.Ибраһимов

**АГЛОМЕРАТ** *и. лат.* 1) *геол.* Тау токымнары ватыкларының көпшәкләнгән тупланмасы

2) *тех.* Югары температура тәэсирендә йомшак вак рудаларны, тузансыман материалларны кушып ясалган зур кисәкле концентрат. *Ныклыгы белән аерылып торган агломерат җитештерү*

**АГНОСТИЦИЗМ** *и. гр. филос.* Объектив дөньяны һәм аның закончалыкларын танып белү мөмкин түгел, дип раслый торган философик тәгълимат. *Ул [Фейербах] Кантның субъектив идеализм һәм агностицизм белән сугарылган карашларын тәнкыйтьләп чыга.* К.Гыйззәтов

**АГО́НИЯ** *и. гр.* Клиник үлем алдыннан организмда саклагыч реакцияләрнең соңгы мәртәбә көчәюе; үлем газабы. *Яралының хәле авыр иде. Агония. Дарулар ярдәм итми.* Х.Камалов

**АГРАР** *с.* 1) Җиргә, җирдән файдалануга бәйле. --- *йола-бәйрәмнәр крестьяннарның ел да бер тәртиптә кабатлана торган хезмәтенә, тege яки бу аграр эшнең кайчан, ничек каршылануына һәм башкарылуына нигезләнеп формалашкан*. М.Бакиров

2) Авыл хуҗалыгына бәйләнешле. *Аграр кризисларның иң зур авырлыгы крестьяннарның төп массалары өстенә төшә*. Политэкономия

**АГРА́РИЙ** *и. лат.* 1) Авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче

2) Эре җир биләүче

3) Аграр фирка вәкиле

**АГРАРЧЫ** *и. сөйл.* Аграр (җир) мәсьәләләре белгече

**АГРЕГАТ** I *и. лат.* 1) Күмәк эшләү өчен төрле типтагы машиналар җыелмасыннан торган җайланма. *[Арсланов] Егетләр! Көн отличный. Бүген барлык педальләргә басыгыз! Мин инде агрегатларны тикшереп чыктым*. И.Салахов

2) Катлаулы машиналарда нинди дә булса эшне башкару өчен көйләнгән детальләр җыелмасы. *Тиздән колхозга «Ёлочка» тибындагы сыер саву агрегаты куелып бетәчәк икән.* М.Хәсәнов. *Ясалма көтүлекләрне сугару агрегаты*

**АГРЕГАТ** II *и. лат.* Туфрак кисәкчекләренең төзелеше, составы

**АГРЕГАТЛАШУ** *ф. кит.* Вак кисәкчекләрнең бергә укмашуыннан зуррак кисәкләр, йомарламнар хасил булу. *Туфрак агрегатлашу*

**АГРЕССИВ** *с.* 1) Агрессиягә, басып алуга бәйләнешле. *Аның [сугыш сәясәте] белән көрәшү өчен барлык илләрнең бердәм булуы сорала. Юкса бу сәясәтне алып баручы агрессив көчләр каршы чыгучыларны берәм-берәм юк итеп баралар*. К.Гыйззәтов

2) Дошманлык белән сугарылган, һөҗүмчән. --- *минем әйткәнемне бар бала да карышусыз тыңларга тиеш, дигән нәрсә бүтәннәр белән сөйләшкәндә дә сизелә – алар агрессив наданнар*. Т.Миңнуллин

**АГРЕССИВЛЫК** *и.* Корал көче белән басып алучылык, һөҗүм итүчелек. *Дөрес, бу «сәер» тенденцияне аларның табигый агрессивлыгы, ягъни гел яулап алуга омтылулары белән дә аңлатырга тырышучылар булмады түгел*. М.Госманов

**АГРЕССИННАР** *и. мед. күпл.* Авыру таратучы бактерияләрнең тереклек эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм аларның үрчүенә ярдәм итә торган матдәләр. *Агрессиннар организмның йогышлы авыруларга каршы тору сәләтен – иммунитетын киметәләр*

**АГРЕ́ССИЯ** *и. лат.* Көчлелегеннән файдаланып, нинди дә булса дәүләтнең яшәвенә куркыныч тудыру максаты белән, аңа көтмәгәндә һөҗүм итү, территориясенә басып керү. *Кенәз Александр (булачак Невский), көнбатыш агрессиясенә каршы, монголлар дәүләте белән хәрби-сәяси союзга керә.* Г.Дәүләтшин. *Әмма безнең агрессия корбаны булуыбыз Сталинга шунда ук бик мөһим мораль өстенлек китерде.* Ә.Еники

**АГРЕ́ССОР** *и. лат.* Башка илне корал көче белән басып алучы, һөҗүм итүче як. *«Сөембикә» кыйссасы татар дәүләтчелегенең ничек җимерелүен, агрессор кулы астында калуын җанлы мисалларда күрсәтә*. Ф.Хатипов

**АГРО-** *лат.* Кушма сүзләрдә «агрономик» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс.: *агротехника, агрочара, агропункт, агроуку*)

**АГРОБИОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Үсемлекчелек һәм терлекчелек буенча гомуми биологик закончалыкларны өйрәнә торган фән тармагы. *Агробиология станциясе*

**АГРОНОМ** *и. лат.-гр.* Агрономия белгече. *Телефоннан күпме генә шал-*

*тыратса да, абыйсын ул тота алмады. «Сугарулы көтүлектә», – диде аңа орлыкчылык буенча агроном.* Ф.Садриев. *Тимербулат – хат ташучы, агроном кыз – Фәйрүзә. Тимербулатның үзәген шушы Фәйрүзә өзә.* М.Җәлил

**АГРОНО́МИК** *с.* Агрономиягә караган, агрономиягә бәйләнешле. *Халыкның педагогик гыйлеме һәм идеяләре аның яшәү фәлсәфәсе, тормыш әхлагы, агрономик, метеорологик, астрономик һ.б. төр белемнәре белән тыгыз элемтәдә булган.* Ш.Җәләлиев

**АГРОНО́МИЯ** *и. лат.-гр.* Игенчелек һәм авыл хуҗалыгы эшләре турындагы фән. – *Мин – хуҗалык һәм агрономия мәсьәләсендә мәгълүматсыз кеше, – диде ул.* Р.Зарипова. *Башта аларның хуҗалыкларын машиналаштырырга, агрономия белеме белән коралландырырга, культураларын үстерергә кирәк.* Т.Гыйззәт

**АГРОТЕ́ХНИК** I *и. рус* Агротехника белгече. *Башта Кыргызстан ССРның Җәләл-Абад районындагы Беговат кышлагында – агротехник, аннары биредәге машина-трактор станциясендә хисапчы-бухгалтер булып эшли...* Ш.Мостафин

**АГРОТЕ́ХНИК** II *с.* Агротехникага бәйләнешле, агротехникага караган. *Механикалаштырылган авыл хуҗалыгы производствосында барлык урып җыю эшләрен оптималь агротехник срокларда гына үткәрү таләп ителә.* Урып җыю машиналары

**АГРОТЕ́ХНИКА** *и. рус* Игенчелектәге фәнни-техник алымнар, чаралар системасы. *Маннур җитәкчелек иткән агротехника курсларында занятиеләр аеруча җанлы барды.* М.Хәсәнов

**АГРОФИ́РМА** *и. рус* Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән бергә, аны эшкәртү, сату эшчәнлеге белән шөгыльләнүче предприятие. *Ә авыл хуҗалыгы идарәсен агрофирма дип карарга ярамый. Бу идарәгә буйсынган күмәк хуҗалыклар, фермерлар һәрберсе юридик көчкә ия, кулында мөһере бар.* З.Дәүләтов

**АГРОФИТЛАР** *и. биол. күпл.* Игүле үсемлекләр. *Борчак, бодай һәм арыш агрофитлардан саналалар*

**АГУ** I *и.* 1) Тереклек (җан) иясен зарарлый, үтерә торган матдә. *Мәкнең бер сабагы – дару, бер сабагы – агу.* Әйтем. *Япон солдатының гимнастёрка якасына агу тегелгән. Үлем куркынычы яки әсир төшү куркынычы янау белән, ул якасын чишеп җибәрә дә агуны тешләп, үлеп тә китә.* Г.Ахунов

2) *күч.* Зыян, зарар китерә торган нәрсә. *Спиртлы эчемлекләрне күп куллану – организм өчен агу*

3) *күч.* Явызлык, астыртын усаллык, мәкер. *Татлы тел – агу. Ачы тел – дару.* Мәкаль

◊ **Агу йоткан** Эчендәге зәһәрен, усаллыгын теле белән белдереп торган, зәһәр, кара эчле. *Син дә шул диңгез ярында, и агу йоткан көчек, Телләрең сузган буласың, җитми, җитми, кит күчеп!* Г.Тукай. **Агу тел** Кешенең хәтере белән санашмыйча, йөрәккә кадап сөйләүче, ачы, зәһәр телле кеше

**АГУ** II *ф.* 1) Сыеклыкның берәр төрле юнәлеш алып хәрәкәт итүе. *Ага сулар, ага сулар, Ага сулар ник болай? Аккан сулар кире кайтмый, яшь гомерләр дә шулай.* Җыр. *Аккан суга кан койма, эчәр суың тапмассың, Каудан җиргә ут куйма, керер куыш тапмассың.* Мәкаль. *Туктале, бу – безнең чишмәләрдән, безнең басу-кырлардан, кар суларыннан аккан гөрләвекләр, бәлки, безгә дә хезмәт итәрләр?* М.Мәһдиев. --- *Болак Казансуга коя торган булган, язгы ташу вакытында гына, су кирегә агып, Кабан күленә кергән.* Казан утлары

2) Сыеклык өстендә яки эчендә булган хәлдә агымга ияреп бару. *Су өстендә, балдак кебек түгәрәкләнеп, тимгел-тимгел булып, нефть ага иде.* А.Әхмәт. --- *корыч төсле ялтырый торган Идел өстендә, берсе артыннан берсе, эч пошыргыч акрынлык белән, бөтен Иделне тутырып, озын саллар агалар.* Г.Рәхим. *Чулымның каршы ярында яңгыр томаны эчендә утырган наратлар белән көмешләнеп аккан бу мизгеле тылсымлы әкиятне хәтерләтә иде.* А.Хәсәнов

3) Савыттан, тишек яки ярыктан күпләп коелу, чәчелү. *Сезнең менә күргәнегез бармы Бункерлардан икмәк акканын?* М.Әгъләмов. *Их! Алдан килгән булсагыз, мин сезгә быелгы әпәйнең бункердан ничек акканын күрсәтер идем.* К.Тимбикова. *Көн-төн ашлык тарттым, ару-талуны белмәдем ---. Мөшкәм бушап тормады – улагымнан ап-ак он акты.* Мирас

4) Төзек булмау аркасында сыеклыкны үткәрү. *Бу чиләк тишелгән, аннан су ага*

5) Сыеклыкның нинди дә булса әйбер аша үтеп чыгуы, саркып, тамып торуы. *Түшәмнән су ага. Кибән эченә су ага*

6) Кайбер физиологик хәлләр яки психологик кичерешләр вакытында организмнан күпләп сыеклык бүленеп чыгу (күз яше, тир, селәгәй). *Яшьләре аның, ана йөрәгендә изге бер чишмә ачылган шикелле, туктаусыз агалар.* Ә.Еники. *Бичараның ак сакалы буенча мөлдер-мөлдер күз яше акты.* Г.Ибраһимов. *Ул чагында аның колагы ага иде, югарыдагылар янына тагын әнә шул колак мәсьәләсе дә килеп кушылгач, бөтенләй ярап куйды.* Ф.Хөсни

7) Бер юнәлештә тоташ масса булып өзлексез хәрәкәт итеп тору. *Ә ком үз юлында.... Кая ага, кая күчә бу җитез бөртекләр?* М.Кәрим. *Мәйданга халык ташкыны ага*

8) Салмак кына бер урыннан икенче урынга күчү, хәрәкәт итеп тору. *Морҗалардан чыккан төтеннәр һаваның бу хәлен ганимәт белеп, саннарын күтәрә алмый, җиргә таба агарга бер дә мәҗбүрият күрмиләр…* Г.Ибраһимов. *Тик куе кара болытлар, җил белән кузгалып, --- тыныч йокыдагы җәйләүләр өстеннән, ашыгыпашыгып, каядыр агалар.* Г.Ибраһимов. --- *дирижабль зур балык булып күк йөзеннән бара, акрын, салмак. Ага, ага, болыт кебек агып бара…* М.Мәһдиев

9) *сөйл.* Суга бату. *Авыл уртасындагы инештән шарлап аккан ташу тавышына кемнеңдер ачы авазы кушылды: – Ярдәм итегез! Агабыыз…* М.Мәһдиев

10) *күч.* Узу, үтү (вакыт, гомер турында). *Шау да гөр килеп аккан бу гүзәл тормыш көннәрнең берендә аз гына янып көлгә әйләнмичә калды.*

Г.Минский. *Бу ике ятимнең тормышы шулай әкрен генә акты*. Г.Ахунов

11) *куч*. Өзлексез дәвам итү (сүз, уй, әңгәмә, җыр һ.б.ш. турында). *Кайгы, шатлык тагын бергә кушылып акты*. Г.Ибраһимов. *Гүя, анда музыка уенчының йөрәгеннән күтәрелеп, моның йөрәгенә туры ага*. Г.Ибраһимов. *Минем хикәям чишмә күк туктаусыз ага да ага иде. Ник акмасын: ике пар күз миңа каһарманга караган төсле карамыйлар идемени соң?* Г.Рәхим

12) *куч*. Чыгып таралу, бөркелү, сибелү (нур, ис һ.б.ш.). *Күзләреңнән нурлар ага, Кыймыйм туры карарга*. Җыр. *Алмагач ботаклары арасыннан бүлмәгә җылы кояш нурлары ага*

13) *куч*. Күп, мул булып керү (байлык, мал, ашамлык һ.б.ш турында). *Байларның акмаса да тама бит ул*. М.Гафури

14) *куч*. Юкка чыгу, тотылу, әрәмшәрәм ителү. *Акча су урынына ага*

15) *куч. сир*. Авышу, берәр кешегә яки кешеләр төркеменә кушылу. *Ул, Гәрәйнең күз карашы усал, дип зарлана торган булды, ничектер, сизелмәстән, Давытлар ягына таба акты*. Г.Ибраһимов

**Ага башлау** Агарга тотыну. *Икенче көнне Галимҗан абзыйның йортында гадәттәге тормыш, үз ярлары эченә кайткан елга кебек, акрын гына ага башлады*. Ә.Еники. *Су агып, тәлинкәдән ташып чыгып, подноска ага башлагач кына: – Рәбига туташ, чәй ташыды, – дидем*. Гали Рәхим. *Комны учка салсаң, әкрен-әкрен, бармак араларыннан ага башлый, ә инде агуын туктатыйм дип, бармакларыңны кыса төшсәң, тагы да тизрәк ага башлый*. Ф.Яруллин

**Ага бирү** Бернәрсәгә (бернигә) карамастан агуын дәвам итү. *Килә язлар, ага бозлар, замана ташкыннары гасыр үзәннәрен чистартып ага бирә*. Ш.Галиев. *Боз юрганын ябынган елга --- чылтыр-чылтыр ага бирә иде*. А.Алиш

**Ага тору** Бертуктаусыз агу. *Ел артыннан еллар ага торды. Һәр елны Сәхия чираттагы ялында авылга кайтырга җыенды*. Ф.Яруллин

**Агып бару** Өзлексез агуын дәвам итү. *Көмеш төсле ак болытлар һавада бер-берсе артыннан агып баралар*. Ш.Камал. *Ул гасырлар буенча шул гадәтләр, шул кануннар эзеннән агып бара*. Г.Ибраһимов. *Игътибар иткәнегез бардыр, Иделгә Кама дәрьясы кушылганнан соң, ике агым – берсе яктырак, икенчесе караңгырак агым – чакрымнар буе янәшә ике төстә агып баралар*. Г.Ахунов

**Агып бетү** Бөтенләй, тулысынча агып юкка чыгу. --- *самавырдагы су агып бетү генә түгел, бөтен коймаклары, баллары белән бергә ашъяулыгың, подносың агып китсә дә гамендә юк аның*. М.Әмир

**Агып китү** Кайдан да булса читкә агу, агымга ияреп бару. *Без коенган сулар олпат өянкеләр күләгәсеннән еракеракларга агып киткән, кабатлану булмый*. М.Галиев. *Күп сулы елгалар ташыганда, хәтсез күп ауган агачлар агып киткән һәм ком белән күмелеп калган*. Ботаника

**Агып тору** Бертуктаусыз агу. *Шулай ел артыннан ел, Иделдәге су кебек, агып кына торды*. И.Гази. *Аның сүзләре, хәвефсез-нисез, көмеш улактан аккан саф су кебек агып тора*. Ш.Камал. *«Гомер» дигән агымсу Гомәр исемле кешеләрне дә кызганмый, көн дими, төн дими, агып тора икән*. Т.Галиуллин

**Агып яту** Дәвамлы рәвештә, бертуктаусыз агу. *– Анда шифалы чишмәләр агып ята, – ди Зәкия*. Г.Ахунов. *Кар астыннан сиздерми генә су агып ята икән*. М.Маликова. *Сулыйм дисә – һавасы нинди, эчим дисә – челтерәп, чишмәләре агып ята*. Р.Мөхәммәдиев

**АГУЛАГЫЧ** *и.* **1.** Агулый торган әйбер, агуы булган матдә. *Формалин – дезинфекция ясау өчен кулланыла торган көчле агулагыч*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Агулый торган. *Агулагыч матдәләр*

2) Агулау эшен башкара торган, агулый торган. *Агулагыч машина бик әкрен йөри*

**АГУЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **агулау**

2) Үз-үзен үтерү максаты белән агу эчү. *Цианлы калий эчеп агулану*

3) Агулы матдәләр тәэсиреннән зарарлану. *– Үләмме, дип торам әле, нәрсәдер ашап агуланганмын, Ифрат абый, – диде юаш кына*. А.Расих. *[Барсик] --- урамда йөргәндә ярамаган берәр нәрсә ашый да агулана, аннары хуҗасы көч-хәл белән аякка бастыра*. А.Мельников. *Гөмбәләр белән агуланмас өчен, гөмбә җыйганда бик игътибарлы булырга кирәк*. Биология

4) Агулы матдәләр һ.б. төрле шартлар йогынтысында зарарлану, зарарлыга әйләнү. *Чишмәгә нәҗес әйберләр салсаң, аның суы агулана*. Ф.Садриев. *Узган ел кар иртә төште, җир туңмаган килеш калды. Мондый елларда кар астында калган ашлык агулана*. М.Кәбиров

5) Агу катнаштыру, агу белән эшкәртү. *Чәчү орлыклары агуланган*

6) *куч*. Начар (кире) йогынты тәэсирендә булу, начар гадәтләр алу; зарарлы фикер белән сугарылу. --- *тартмасаң да зыян юк. --- Ташлый алсам, кабат авызыма якын да китермәс идем үзен. Бер агулангач, аерылып булмый, – диде Ром*. З.Фәйзуллин. *Син гыйлемле вә мәдәниятле тормышның зәһәре белән бер мәртәбә агулангансың*. Г.Ибраһимов. *Кызганыч, Рәсәй империясендә әле бүген дә миллионлаган балалар мәктәпләрдә ялган тарих укып агулана*. В.Имамов

**Агулана бару** Торган саен ныграк агулану. *Ил-җирнең элекке гүзәллеген искә төшерә алмый, суы саега, көннәнкөн агулана бара*. Ф.Зариф

**Агулана башлау** Агулану билгеләре сизелү. *Шулай да тар идеология белән агулана башлаган кешеләрнең фантазиясе бер тирәдә әйләнә*. А.Әхмәдуллин. *Үзе чыгарган төтенгә тончыга, үзе пычраткан судан агулана башлаган шәһәр кешесе тәртәне авыл ягына каерыр*. Т.Миңнуллин

**Агулана язу** Чак кына агуланмыйча калу

**Агулана төшү** Бераз агулану

**Агуланып бетү** Тәмам агуланган хәлгә килү, бөтенләй агулану

**Агуланып кую** Агуланган хәлгә килү

**АГУЛА́У** *ф.* 1) Агу эчерү, агу салу. *Ханны агуладылар, шиксез, агуладылар*. Р.Батулла

2) Тискәре тәэсир ясау, агулы матдәләр белән зарарлау, зәгыйфьләтү. *Сивашның тозлы суы үләннең тамырын корыта, җан иясенең канын агулый.* Г.Бәширов. *Кеше агу ата һаваларга, Агулый ул елга-суларны.* М.Шиһапов. *Дуңгыз фермасыннан пычрак ага. Шул агулый елганы.* Р.Бәшәр

3) Агу катнаштыру, махсус рәвештә агу белән эшкәртү. --- *өйне кырмыска басты. Атна саен агуладык.* К.Кәримов. *Чәчүлек орлыкларын агулау*

4) *күч.* Начар йогынты ясау, зарарлы фикерләр белән сугару. --- *басып алучы ил үз мәдәниятенең төссез, ямьсез тауарын басып алынган илгә кертеп тутыра һәм шуның белән «кол» халыкның миен агулый, күңелен тупасландыра, пычрата.* З.Хөснияр. --- *айлар, еллар буе эфирда сатлык дикторлар котырына, котырта, яла яга, ялганлый. Эфир зарлана, шыңшый, кешеләрнең яшәвен агулый.* М.Юныс

5) *күч.* Тормышның кызыгын, ямен җибәрү. *Бәхетсез мәхәббәт әнә нишләтә, дәвалап булмый торган авыру кебек, кешене саргайтып киптерә, бөтен тормышын агулый.* С.Сабиров. *Иң әшәке нәрсә – политика. Менә шул бетерә, тормышны агулый.* Х.Камалов. *Гөлйөзем янында, балалары арасында узган кадерле сәгатьләрнең тәмен агулый иде.* Ф.Латыйпов

**Агулап алу** Кыска гына вакыт эчендә агулау; берникадәр агулау

**Агулап бетерү** Бөтенесен дә агулау; агулау дәрәҗәсенә җитү

**Агулап килү** Билгеле бер вакыттан алып агулауны дәвам итү

**Агулап кую** Алдан агулау

**Агулап тору** Бертуктаусыз агулау

**Агулап чыгу** Бөтенесен дә башыннан ахырына кадәр агулау, һәрберсен агулау

**Агулый бару** Һәрберсен, булган берсен агулау

**Агулый төшү** Беркадәр агулау

**АГУЛАУЧЫ** *с.* 1) *махс.* Агулый торган. *Әлеге язмада сүзебез – өйләребезне токсиннар белән агулаучы иң куркыныч ун химик матдә турында.* Ватаным Татарстан. *Предприятие никадәр зуррак булса, табигатьне агулаучы калдыклар өчен түләү дә шулкадәр зуррак булырга тиеш.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Тынгылык бирми, борчый торган. *Халыкларның тормышын агулаучы иң зур бозык эшләрнең берсе итеп, ул мөселманнарга карата алып барылган рухи һөҗүмне атый.* Фән һәм тел

**АГУЛЫ** *с.* 1) Агулый торган, агу бүлеп чыгара торган, составында (үзендә) агу булган. *Ул [арыш анасы] таза бөртекләрне агулы кара мөгезчекләргә әверелдерә.* Биология. *Агулы үрмәкүчләр тешләве һәм еланнар чагуы нерв системасы эшчәнлеген зарарлый.* Анатомия. *Кызы кар астында кышлаган башак җыеп кайткан. Икәүләшеп ашаганнар. Ул агулы була икән.* Казан утлары

2) Агулый торган матдә кушылган, агу сеңдерелгән. *Ләкин, һич көтмәгәндә, Актырнак дигәне нииндидер агулы нәрсә ашаган булып чыкты.* А.Хәсәнов. *Егеткә агулы ук чәнечкәндәй булды.* Г.Ибраһимов

3) Организмның, тереклекнең яшәешенә туры килми торган, сәламәтлек өчен зарарлы. *Җир астында күп эшләп, таш казармаларда торгач, аларның [элекке шахта эшчеләренең] тән тамырларындагы кызыл каннары агулы сары суларга әйләнгән.* М.Гафури

4) *күч.* Явыз, мәкерле, зәһәрле. *Колагымда --- мәсхәрәләп әйткән агулы сүзләр.* Ф.Кәрим. --- *көлке сүз әйтеп башкаларны мыскыл итәргә туры килсә, --- ул инде безнең үз йөрәкләребезгә дә ешеш агулы укларын кадый.* Г.Ибраһимов

◊ **Агулы елан** Эчкерле, явыз уйлы, мәкерле кеше турында. – *А-а! Агулы елан! Дөньядан юк итмәкчеме мине? Бозарга уйладыңмы? – дип, бөтен йортка акырды Ишми.* Г.Шәрипова. *Аппаратта агулы еланнар үрчетеп ятабыз икән ич, менә бәла нәрсәдә.* Казан утлары

**АГУЛЫ́ КӨПШӘ** *и. диал. к.* **агу уты**

**АГУЛЫЛЫК** *и.* Агулы булу дәрәҗәсе, агу концентрациясе. *Эшкәртүнең төгәл вакыты, нинди исемдәге препарат кулланыласы, агулылык дәрәҗәсе, --- турында мәгълүматны газета аша да җиткерергә була.* Мәдәни җомга. *Пенополистиролның агулылык төркемен ачыклау. Гөмбәнең агулылыгы. Еланның агулылыгы*

**АГУСЫЗ** *с.* 1) Агуы булмаган, чакмый торган. *Агусыз еланнар*

2) Составында агуы булмаган, агуламый торган. *Усак гөмбәсе – агусыз гөмбәләрдән санала*

**АГУ́ УТЫ** *и. бот.* Чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан, күбесенчә сулык читләрендә, сазлыклы урыннарда үсә торган, эфир майларына бай булган, тырпайган ботаклы, куыш сабаклы үсемлек; агулы көпшә; *русчасы*: **омежник водный**. --- *чатыр чәчәклеләрдән республикада тимгелле түндербаш, су балтырганы (агулы сәрәтә), агу уты, киң яфраклы су буе чатыр уты үсә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**АГУЧАНЛЫК** *и.* 1) Агучан булу (сыекчалар, газлар турында). *Югары температура корычның эластиклык модулен, өзелүгә вакытлыча каршылыгын, агучанлык чиген киметә.* Төзү материаллары. *Алар, беренче кабат йөкләүдәге көчәнешләргә өстәлеп, цикллар саны үскән саен, бетондагы, аркылы һәм буй арматурлардагы агучанлык көчәнешләрен һәм аларның асимметрия коэффициентларын даими үзгәртеп торалар.* Фән һәм тел

2) Сибелүчәнлек, коелучанлык, чәчелүчәнлек (чәчелә, сибелә торган матдәләр турында). *Елга комының агучанлыгы*

**АГЫЗУ** *ф.* 1) Сыеклыкны үз агымы белән кирәкле юнәлешкә җибәрү, агып китәрлек итү. *«Зәңгәр күзләр» көен көйли-көйли, Сулар агызам тирән күлләрдән.* Һ.Такташ

2) Нәрсәне дә булса сыеклык өстеннән яки эченнән агым юнәлеше белән хәрәкәт иттерү. *[Алар] Икенче көнне йон түкләрен Иделгә ташлап агызганнар.* К.Тинчурин. *Татар ташкүмер чыгарган, ләмке киеп йөк бушаткан, сал агызган.* Г.Ахунов. *Урал таудан агып төшкән гөрләвекләр буенда, кәгазь көймә агызып, малайлар йөгерешә.* Р.Мөхәммәдиев

3) Сыек, бөртекле нәрсәләрне савыттан кою, чәчү, түгү. *Улактагы суны агызу. Бункердагы бодайны агызу*

4) Сыек яки бөртекле әйберләрне бер савыттан икенчесенә бушату, күпләп салу. *Ул, сөтен бидонга агызгач, кыю һәм очкынлы күзләрен Солтанга текәде.* А.Расих. *Шәкүр абзый чынаякларга чәй агызганнан соң, картларча онытылып, бераз вакыт сүзенең очын таба алмыйча утырды...* Ф.Хөсни. *Марат, газлы су агызып, башта Гамирга тоттырды, аннары үзенә агызды.* З.Фәйзуллин

5) *махс.* Нәрсәне дә булса бер савытка туплау, җыю. *Сагыз агызу. Каен суы агызу*

6) Нәрсә дә булса агым көченә буйсынып агып китү. *И яуды, и яуды [яңгыр], күперләрне агызды, буаларны ерды.* А.Гыйләҗев. *Азаплана-азаплана йөзеп киттем. Йөзүе авыр, Идел бик каты агыза иде.* Гали Рәхим. *Коргаксып, кибеп барган инеш су белән тулып, ярлар ишелеп төште, буаларны ерып алып китте, --- кош-кортны агызды.* Ә.Фәйзи

7) *күч.* Кою, түгү (кан, яшь, тир һ.б.). *Балалары, аптырап: «Әни, җаный, син акылыңдамы, нигә күз яше агызасың?» – дип әйтеп карадылар.* Г.Әпсәләмов. *[Яралылардан] Берәүсе солдатларга карап: --- «Сез кемнәргә каршы мылтык күтәреп килеп, кемнәрнең йөрәк каннарын агызуыгызны беләсезме?» [диде].* М.Гафури

8) *күч.* Нәрсәне дә булса тыелган юллар белән күпләп алу; үзләштерү. *Әнә шул рестораннарның, кабакларның бер-бер сәгатьләре Берлин аристократиясе кесәсеннән йөз мең маркаларны үзләренә агызалар.* Г.Гали

9) *күч.* Җәелдерү, тарату. *Безнең янга утыра һәм, күзләреннән гадәттән тыш сагыш, моң агызып, бас белән җырлый башлый.* М.Мәһдиев

◊ **Агызмаган бал** Саф, гыйффәтле кыз. *Алсае җаный, алсае, Агызмаган баллар булсае, Хәләл малларыңны биреп алгач, Кул тимәгән ярлар булсае.* Җыр

**Агыза бару** Һәрберсен, булган берсен агызу

**Агыза башлау** Агызырга тотыну. *--- таш йөрәкләрне эретерлек итеп сайрый торган сандугачның тавышын ишеткәч, карт күңеленең йомшавына чыдамады, күзеннән яшьләрен агыза башлады.* А.Таһиров

**Агыза бирү** Агызуын дәвам итү

**Агыза тору** Һәрвакыт, гел агызу. – *Сез аны [Кабан күлен] шакшы сулар агыза торган ташландык күлгә әверелдердегез! – диләр.* Г.Бәширов

**Агыза төшү** Бераз агызу, тагы да агызу

**Агыза язу** Чак кына агызмый калдыру. – *Каһәр суккан нәрсә, [борыны куелмаган самавырга] су агыза яздым бит! – дип сукрана-сукрана, Миңлеҗиһан карчык як-ягына каранды.* Н.Әхмәдиев

**Агызып алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә агызу

**Агызып бару** Рәттән агызу

**Агызып бетерү** 1) Тулысынча, ахырына кадәр агызу; савыты бушаганчы, бөтенесен дә агызу. *Татар кешесе суелган малның канын тамчысына кадәр агызып бетерә. Суелган мал канын агызып бетерү гадәтен хәзер мөселманлык белән аңлатырга яраталар.* Н.Фәттах

2) Савытны тутырганчы агызу. *Чынаяк тулар-тулмас хәлдә тагын бер кашык сөт өсте өстәде һәм, калганын самавырдан агызып бетерер, дип көткән идем, юк, самавырдан әз генә тамызды да калганын кабат чәйнектән тутырды.* Н.Әхмәдиев

**Агызып җибәрү** Агып китәрлек итү, агарга этәргеч бирү. *--- машинадан коштай атылып кына чыгасы да елгага йөгереп керәсе, чумасы, йөзәсе, арыганны алкын суга агызып җибәрәсе, якты дөньяга яңа килгән сабый сыман таралып ятасы килә.* Ф.Сафин

**Агызып йөрү** 1) Әле, хәзерге вакытта нәрсә дә булса агызу белән мәшгуль булу. *Күпер башында малайлар, көрәкләр күтәреп, гөрләвек агызып йөриләр.* И.Гази

2) Даими рәвештә, һәрвакыт агызу. *Әхмәтсафа ике җәй ал-ялсыз сал агызып йөрүенә карамастан, эш өчен тияр әҗерен бирмичә, һаман алдагы елга калдырып килә.* Ф.Сафин

**Агызып кую** Алдан ук агызу. *Мозаффар, канәтем, бәрәңгенең эше бетсә, порошок салып, керләргә кайнар су агызып куй әле, яме.* Ф.Баттал. *Хлоры очып бетсен өчен, үткәргечтән суны алдан ук агызып куялар.* Мәдәни җомга

**Агызып тору** 1) Бертуктаусыз агызу. *Иплән кенә суганны йолкыдык, сары кыякларыннан чистарттык, күзгә ачысы кереп, гел яшьне агызып торды.* Х.Камалов

2) Билгеле бер вакыт эчендә, әледәнәле агызу

3) Әле, хәзерге вакытта агызу. *--- вахтадашым Җәмилә штурвал көпчәге янында сүзсез генә күз яшьләрен агызып тора.* С.Сабиров

**Агызып утыру** Әле, хәзерге вакытта агызу. *Хәбибә хатын-кызлар мәҗлесендә өч сәгать буе, бер сүз сөйләмичә, ике күзеннән яшь агызып утырды.* Казан утлары

**Агызып чыгу** Һәрберсенә агызу; бөтенесенә дә берәм-берәм агызу. *Бераздан соң, күптән көткән урыс миче хәтле апабыз пәйда була да өстәлдәге теге уналты кырлы стаканнарга чәй агызып чыга.* Т.Нәҗмиев

**АГЫЛУ** *ф.* **1.** 1) Күпләп агып тору. *Бодайның машина артына шаулап агылуы ишетелгән сыман тоела.* Г.Бәширов

2) *күч.* Билгеле бер юнәлештә тоташтан күп булып хәрәкәт итү, туктаусыз үтеп тору. *Бөтен тирә-якның ялланырга теләгән ярлы егетләре, урак, печән эзләгән фәкыйрьләре җомга саен безгә агылалар.* Г.Ибраһимов. *Караңгы төште, кызлар-егетләр уенга агылдылар.* М.Мәһдиев. *Шатлыклы Беренче Май. Яз киемнәренә киенгән урамнар буйлап халык диңгезе агыла.* Г.Кутуй. *Киноларга, ресторан-кафеларга халык агыла, бөтен җирдә күңелле музыка яңгырый.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Масса тоташ агым булып хәрәкәт итү. *Агыла да болыт агыла Туган үскән җирләр ягына; Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр Нәрсә әйтер туганнарыма?! Агыла да болыт агыла.* Х.Туфан

4) *күч.* Салмак кына өзлексез дәвам итү, таралу, җәелү. *Зал тынды, музыка башланды, сәхнәдән моңнар агылды.* Җ.Фәйзи. *Әйдә, кызый, җырла, хатын-кыз тавышы ишетмәгәнгә ике ай ярым безнең ---. Көмеш тавыш залга агыла.*

М.Мәһдиев. *Уйлар бер-бер артлы кәгазьгә агыла. Давыллы еллар күз алдына килә.* Ф.Яруллин

**2. агылып** *рәв. мәгъ.* Күп булып, тоташ, киң масса белән. *Тамашаларына халык агылып йөри, эшчеләр клубы гөрләп тора.* А.Әхмәтгалиева. *Күпме яшьләр шәһри Казанга укыр өчен агылып килмәде!* Ә.Еники. *Әхмәт әфәндедең автомобиле урман янына килеп җиткәндә, кешеләр төягән башка автомобильләр төрле яктан агылып киләләр иде.* Ф.Әмирхан

**Агыла бару** Торган саен ныграк агылу

**Агыла башлау** Бердәм, дәррәү агылырга тотыну. *Шулчак стеналар музыкаль шкатулка сыман зеңгелдәп куя да, бу бүлмәгә бөтен җирдән – тәрәзәләрдән, ишекләрдән --- музыка агыла башлый.* Р.Вәлиев. *Менә бервакыт халык агыла башлады, әйтерсең инде бөтен дөнья монда җыелды.* Г.Ибраһимов

**Агыла бирү** Агылуын дәвам итү. *Көй һаман агыла бирә...* Р.Харис

**Агыла тору** Бертуктаусыз агылу. *Хәлсезләнә барган ил-дәүләтнең чималы да, табигый байлыклары да, валютасы да, тыелгысыз ташкын булып, Көнбатыш илләренә агыла тора.* Р.Мирхәйдәров. *Мәргәннәр кыюларны чүпли барсалар да, дошман дулкын-дулкын агыла торды.* М.Хәбибуллин

**Агыла төшү** Тагы да агылу; бераз агылу

**Агылып бару** Рәттән бертуктаусыз агылу. *Тырма үрле-кырлы сикерә, тырма артыннан очсыз-кырыйсыз вак балчык тасмасы, тип-тигез тырма эзләре агылып бара иде.* Г.Бәширов. *Ягымлы моң аның салмак адымнары белән бергә агылып бара әйтерсең!* З.Фәйзи

**Агылып бетү** Тулысынча агылу, беткәнче агылу. *Болытлар агылып беткән.* А.Гыйләҗев

**Агылып тору** Өзлексез, бертуктаусыз агылу, дәвамлы рәвештә агым булып хәрәкәт итү. *Аның янында гел төрек моңнары гына агылып тора.* М.Мәһдиев. *Машиналар агылып торган олы урам.* Ш.Галиев

**Агылып үтү** Сиздермичә, кинәт агылу. *Хәтер күгеннән «балачак» дигән чор соры болыт булып агылып үтте.* Ф.Яруллин

**АГЫЛЫЙ** *и.* «Тагылый» сүзе белән килеп, һәрвакыт бер-береннән аерылмыйча йөри торган кешеләрне белдерә. *Агылый белән тагылый кебек күзгә ташланып йөрмәскә тырыша.* Ф.Хөсни

**АГЫЛЫШ** *и.* 1) Агым юнәлеше, агым рәвеше. *Очерк --- заманыбызның алдынгы идеяләре белән сугарылырга, тормыш агылышына турыдан-туры --- йогынты ясарга --- тиеш.* Г.Иделле. *Яңгыр уттай эш өстендәге авыл тормышының бөтен ритмын, тигез агылышын бозды.* С.Рафиков. *Бу очракта шигырь, үзенең интонациясе белән тыгыз ритмик агылыш алып, бер сулыштан әйтелә торган монологка әверелә.* Әдипләребез

2) *күч.* Агып тору, агылу; күпләп, агым булып килү яисә китү. *Безгә бүген иң яхшы сыйфатлы продукциянең ике өлеш булып өзлексез агылышы кирәк.* Р.Ишморат

**АГЫМ** *и.* **1.** 1) Елга юлы буйлап аккан су хәрәкәте. *Без тизрәк каты агымны үтеп, агым акрынрак булган аргы якка чыктык.* Р.Рәхим. *Ә елга коточкыч агым белән ага.* Ф.Яруллин. *Бикмуш бабай, чалбарының бер генә балагын салган килеш, су читенә үк килеп кычкырды: – Кызы-ым, бик эчкә кермә, агым алып китмәсен.* Г.Гобәй. *Менә пароход --- берничә тапкыр өзеп-өзеп кычкыртты да, каты су агымын ерып, авыр, салмак кына кузгалып та китте.* Ә.Еники

2) Диңгезләрдә, океаннарда үзенең аерым сыйфатлары белән аерылып торган су массасы, ташкын хәрәкәте. *Гольфстрим җылы агымы белән лабрадор салкын агымы бергә кушылган урында температура 10–12$^{o}$ аерма күрсәтә.* Кызыклы география

3) Физик мохиттәге тирбәнешле хәрәкәт; һава дулкыны. *Көчле һава агымы тәэсире нәтиҗәсендә җисемнәрнең хәрәкәткә килүе.* Физика

4) *күч.* Бер-бер артлы бер юнәлештә хәрәкәт итүче ишле төркем, әйберләр теземе. *Күпме яшьләр шәһри Казанга укыр өчен агылып килмәде! Менә шул агымга ияреп, мин дә киттем.* Ә.Еники. *Озак та үтмәде, Болак ягыннан ташкын кебек килгән халык агымы күренде.* Җ.Фәйзи

5) *күч.* Тормышка караш, уй, фикер һ.б.ш. кебек хис-тойгыларның эзлекле юнәлеше, барышы. *Аларда язмышның бу агымына каршы барырлык куәт юк.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Иҗтимагый эшчәнлек яки әдәбият-сәнгать өлкәсендәге юнәлеш. *Шулар буенча аның [шәкертнең] сәяси, иҗтимагый агымнарга да карашы үзгәрде.* Г.Ибраһимов. *Уйлыйм ки, әгәр Каргалыда үскән булсам, мин дә шул агымга ияреп киткән булыр идем, бу «язучылык» дигән шактый азаплы кәсеп, бәлки, төшемә дә кермәс иде.* Ә.Еники. *Бу әлегә без белмәгән, аңламаган «торгынлык» дип аталачак чор башланды. Яңа диссертацияләр агымы башланды.* М.Мәһдиев. *Әдәбиятта романтизм агымы*

7) *күч.* Хисләр ташкыны, эчке кичерешләр агышы. *Әминә көймәдән сикергәндә егыла язды да, мин аны тотып калдым. Аның тәненең җылылыгыннан минем тәнемә кайнар бер агым – бер электрик агымы йөгерде.* Гали Рәхим

**2.** *с. мәгъ.* Ага торган, агып торган, хәрәкәттә булган. *Ә агым су ага, миңа «әйдә» дигән сыман бөтерелеп, уйнакланып ага да ага.* Ә.Еники. *Биек тауга менимме, агым суга керимме?* С.Сөләйманова. *Агым суга ташламыйлар Ак каен каерысын…* Җыр

◊ **Агымга иярү** Күпчелеккә иярү, башкалар ни эшләсә, шуны эшләү. **Агымга каршы бару** Җәмгыятьтә урнашкан, гадәти булган берәр шаблон карашларга, юнәлешкә, тәртипкә каршы чыгу, алар белән килешмәү. **Агымга каршы йөзү** *к.* **агымга каршы бару**. **Агым уңаена йөзү** 1) Тормыш барышына буйсынып яшәү; нинди дә булса юнәлеш уңаена хәрәкәт итү; пассив яшәү; 2) Үз фикерең булмау; кем өстен чыкса, шуның фикеренә кушылу

**АГЫМДАГЫ** *с.* 1) Хәзерге, шушы вакытка караган, бүгенге көнгә (елга)

караган. *Дәүләт Советы алдагы сайлауларны агымдагы елның декабрендә билгеләде.* Мәдәни җомга. *Агымдагы елның 25 апреленнән 25 маена кадәр барлык гомуми белем бирү мәктәпләрендә янгын, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча дәресләр һәм күнегүләр үткәрелде.* Мәдәни җомга

2) Көндәлек, көн саен була яки башкарыла торган. *Минем килүемнең сәбәбе агымдагы хәлләр белән --- түгел. Әнә шул синең китабыңның язмышы борчыганга килдем мин.* Г.Ахунов. *Иртә-кич кабинетыннан чыкмыйча, ул [Мостафин] райкомның агымдагы эшләре белән шөгыльләнде...* Ә.Еники

**АГЫМЛЫ** *с.* Ага торган, агышы булган, хәрәкәттәге. *Үзләреннән инешләр, кечкенә һәм зур елгалар агып чыга торган күлләрне «агымлы күлләр» дип атыйлар.* Физик география

**АГЫМСУ** *и.* Агып торган, агып яткан, агар су. *Бәпкәләрем әле үзләрен агымсуга куалап төшерәсемне белмиләр, яр өстендәге яшел үләнне чемченеп йөриләр.* Ф.Яруллин. *Моңга серләр, сагышка җыр ялгап, карый кеше агымсуларга.* Казан утлары

**АГЫМСЫЗ** *с.* Торгын, агымы булмаган. *Агымсыз күл сазлана.* Әйтем. *Агымсыз күлләрдән су агып чыкмый.* Физик география

**АГЫНТЫ** *и.* 1) Сыеклык яки газсыман әйбернең нинди дә булса юнәлештән яки сыешлыктан бәреп чыккан агымы. *Борынга саф һава агынтысы килеп бәрелде.* А.Хәсәнов. *Лафет көпшәсеннән атылып чыккан кайнар агынты, ут булып, [Арсланның] битен, күзләрен пешерә.* Г.Ахунов

2) Агып, саркып чыккан яки тамып җыелган сыеклык, агып чыккан сыек калдыклар. *Хәзер агынтыларның бер өлеше – гадәти юлдан, икенче өлеше Кабанга ага.* Р.Мостафин. *Бу күлнең Оренбург газ эшкәртү заводы агынтыларыннан хасил булганлыгын белгәч, исем китте.* Р.Мостафин

3) *диал.* Агым су

**АГЫШ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса агуы, агып тору хәрәкәте. *Күзле күрә су агышын гына, Сукыр күрә вакыт агышын.* Р.Харис. *Яшел чирәм өстендә чалкан ятып, болытлар агышын күзәтү кызык.* Казан утлары

2) *к.* **агым** (*1 мәгъ.*). *Елганың югары агышына таба агачлар арасыннан киткән сукмак бик аз тапталган.* Ш.Камал. *Шул тирәгә җиткәч, Агыйдел үзенең агышын борып, бераз кояш батышына табарак китә.* М.Гафури

3) *күч.* Нинди дә булса эш-хәлнең, вакыйганың барышы. «*Психиатр» дигәнебез, башлап, Кәримне урынына яткыра, аннан чирнең гомуми агышы турында тәфсилле итеп сораштырырга керешә.* Т.Галиуллин. *Вакыт агышы әллә ниләргә сәләтле. Елга ярын да ул әнә күпкә эчкә күчергән.* Сөембикә. *Их-х, аңгыра баш мин, тормыш агышын белеп тордым лабаса! Шул тормыш агышы турында күңелемнән хикәяләр язып йөрим дә шуңа канәгать булам янәсе!* Казан утлары

4) *күч.* Җыр, музыканың билгеле бер эзлеклелектә барышы, таралышы. *Нәфисә, кулларын алъяпкыч күкрәгенә яшереп, урман куелыгына караган килеш, җырының агышы уңаена салмак кына башын чайкый...* Г.Бәширов. *[Көйнең] Яңгырашы, агышы – бөтенләй яңача, колак ишетмәгәнчә!..* Ә.Еники

5) *күч.* Гомумән эзлеклелек, эзлекле булу (фикердә, сүздә һ.б.да). *Сабый чакларда, егет вакытларда мин аның фикер агышы эчендә булырга, бергә агарга өйрәнгәнмен.* Г.Ибраһимов. *Тирән агымлы дәрья сыман, фикер агышы, сүз сөреше сабыр, ипле генә барса да, бу – көрәш авазы, кыю фикер кылычы иде.* Мәдәни җомга

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса составы үзгәреп, алмашынып тору. *[Дирекция] Җилкуар, очраклы кешеләрне студиягә күп тартты. Ләкин алар составта озак калмыйча, килеп-китеп, студиядә агыш тудырдылар.* М.Җәлил

7) Хәрәкәт итүче ишле төркем, халык дулкыны. *Карасалар, киң урамнарны, тротуарларны каплап, ниндидер бер агыш килә.* Г.Ибраһимов

**АГЫШЛЫ** *с.* 1) *к.* **агымлы**

2) *күч.* Үзеннән алда килгән сүз белән ачыкланган хәрәкәткә ия булган. *Композиторның якты сагышлы, җиңел агышлы музыкасы тамашачыны битараф калдырмады, алар спектакльне дә яратып карадылар.* Идел

**АГЯҺ** *хәб. сүз фар.* Белеп тору, хәбәрдар булу

**АГЯҺ БУЛУ** *ф.* Алдан белеп тору, мәгълүмат алу, хәбәрдар булу. *Әгәр хезмәт идәрсәң гайреләргә, үзең хезмәт күрерсең, улгыл агяһ.* Г.Утыз-Имәни

**АДАПТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *биол.* Организмның, сизү органнарының тирәяк шартларга җайлашуы. *Соңрак аңладым, өзлексез өшүем салкыннан түгел, ә шушы климатка, вакытка күнегү (анда көн булганда, бездә – төн), адаптация галәмәте булып чыкты.* Сөембикә. *Бу уңайдан шуны да әйтеп үтү урынлы булыр – космонавтлар Космос шартларына тизрәк ияләшә (берничә тәүлектә); ә кире кайткач, Җирдәге шартларга кабат көйләнү (адаптация) атналар-айлар таләп итә икән.* Идел. *Авыл хуҗалыгы культуралары сортларының адаптация потенциалын арттыру*

2) *пед.* Чит телне өйрәнә башлаучылар өчен текстны җиңелләштерү, җайлаштыру

3) Мохиткә ияләшү, җайлашу; теләсә нинди шартларга яки кешеләргә яраклашу, җайлашу. *Балалар яңа чынбарлыкка тизрәк ияләшә, тизрәк адаптация үтә.* Сөембикә. *Моннан тыш, курска килүчеләр үзләренә һөнәр үзләштерә һәм адаптация курслары уза.* Шәһри Казан. *Теләсә кайсы тармакка, дөнья базарына чыкканчы, адаптация узу мөмкинлеге биреләчәк.* Татарстан яшьләре // Гомумән яраклашу, җайлашу. *Яңа терминнарның адаптация узганын көтеп торырга безнең вакытыбыз юк.* Р.Миңнуллин

**АДАПТА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **адаптацияләү**

2) *биол.* Яңа яки үзгәрә торган шартларга яраклашу

**АДАПТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.*1) Адаптациягә дучар итү

2) *пед.* Тел, бигрәк тә чит тел өйрәнә башлаучылар өчен текстны җиңелләштерү, гадиләштерү. *Ул тагын ике мәсьәләгә басым ясады: татар телен өйрәнүчеләр өчен әдәби әсәрләрнең текстын*

*адаптацияләү, җиңелләштерү һәм татар әдипләренең әсәрләрен рус теленә тәрҗемәдә бастырып чыгару.* Фән һәм тел

**АДАРЫНУ** *ф.* 1) Берәр эшне башкару алдыннан, ул эш уңышлы чыксын өчен, алдан багышлап кую, нәзер әйтү. *Берсе, кызым баладан исән-сау котылса, дип, икенчесе, сыерым тана бозау китерсә, дип адарынган икән.* Г.Бәширов

2) Көчле дәрт, теләк белән ашкынып, нәрсәгәдер омтылу; алгысу. *Шундый гаҗәеп бер логика белән Нургали эшкә тотынмакчы була, аңарда дәрт, энергия һәм адарыну – барысы бергә кайный.* Ә.Еники. *Китапларда нәрсә язылa икән? Укып карыйсы иде тизрәк. Күңелем адарына.* Н.Дәүли

3) Багыну, бик нык мавыгу. *Аның тормышында адарынган, киләчәктә буйсынырга уйлаган әмәле дә [сөйгәне] иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *– Хәниф абый исән, исән! – дип адарына-адарына, солдат абыйның кулларына ябыштым.* Н.Дәүли. *Тыныч иртәгә, ил-төякнең кабатланмас бизәкле манарасына адарынып, шактый торды ул.* Ф.Сафин

**Адарынып алу** Бераз, берара адарыну

**Адарынып йөрү** Күптәннән бирле адарыну. *Күпме адарынып йөреп, иеме, сәвиттәгеләрне пыр туздыртам, шулар аркасында гына коры калдым.* Ф.Сафин

**Адарынып китү** Кинәт адарына башлау. *Адарынып китмә, шөһрәт алсаң. Сөенербез, вөҗданыңны саклап, Рухи биеклектә кала алсаң...* Р.Ягъфәров

**Адарынып кую** Алдан ук әзерләнеп адарыну, нәзер әйтү. *Анысын, күпер төзелеп беткәч, Сабан туена сөлге җыеп йөрүче «никрут» егетләргә бирергә дип адарынып куйды инде.* М.Шаһимәрдәнов

**Адарынып тору** Бертуктаусыз адарыну. *Ул шулай, җае чыккан саен, Олуг Мөхәммәдтән теге ярлык ачуын алырга адарынып тора.* Р.Вәлиев

**АДАШ** *и.* Бер үк исем белән аталучыларның берсе; исемдәш. *Иптәшләрем алдында, фикердәшләрем алдында, Йосыф, Ярулла адаш алдында мин бернигә яраксыз кеше булып калдым бит.* Ә.Фәйзи. *Берсенең дә хатын җавапсыз калдырмадым. Рәхмәтләрне әйттем. «Кызганыч, мин эзли торган Юлдаш Азимов ул Сез түгел», – дип яздым дустымның барлык адашларына.* Казан утлары. *Кеше холкының йөздән күбрәк сыйфаты генетик нигезгә салынганга, бер исемдәге кешеләрнең – адашларның күпчелеге бер үк сыйфатка ия.* Мәдәни җомга // Исемдәш кешеләрнең бер-берсенә мөрәҗәгать итү сүзе

**АДАШЛЫК** *и.* Икенче бер кешегә адаш булу, исемдәш (фамилиядәш) булу. *Киләсе гәзитегездә, сабын заводының эшчесе Фәтхулла Насыйров белән буржуй Фәтхулла Насыйров арасында адашлык та, кардәшлек тә, туганлык та, чорт та юк, дип бастырыгыз!* К.Тинчурин

**АДАШТЫРГЫЧ** *с.* 1) Адаштыра торган, юлдан яздыра торган. *Нинди елак кыш булды бу? Кайда суыкзәмһәрир, Адаштыргыч бураннары?..* И.Иксанова

2) Алдагыч, алдый торган, алдандыра торган. *Ләкин бу җылыту – адаштыргыч җылы гына булып чыкты: беркөн иртән кинәт суытып, утыз градусны бирде.* М.Мәһдиев

**АДАШТЫРУ** *ф.* 1) Барган юлыннан читкә җибәрү, юлын буташтыру. *Хәер сорашып кайтканда, авылыбызның Гөлҗамал исемле кызы туңып үлгән бу кара урманда. Әнә шул Гөлҗамал өргә адаштыра кешеләрне.* Н.Кәримова. *Әче елгасы – Олы Мәңгәрдән Иске Кишеткә барганда адаштыра торган елга.* Ф.Гарипова

2) Берәр кешене яки хайванны таныш булмаган юлдан җибәрү, каядыр илтеп, кире кайта алмаслык итеп ташлап калдыру. *Җиде көн, җиде төн буена, һичтуктаусыз, Зирәк карт дошман гаскәрен чүлгә алып керә, адаштыра, борма-урау юллар белән йөртеп әлсерәтеп бетерә.* Р.Батулла

3) Кая да булса еракка җибәрү, берберennән ераклаштыру. *Бу каһәр суккан Мостафа башыбызны әллә кайларга илтеп адаштыра бит!* Ш.Камал

4) *күч.* Начар, бозык юлга кертү, юлдан яздыру. *Игътибар белән тирәюнегезгә карагыз әле – бу тормышта кешене адаштыру, һәлак итү өчен атлаган саен җәтмәләр корылган.* Ф.Бәйрәмова

5) *күч.* Уй-фикер, зиһен, хисап кебек хис-тойгыларның бәйләнешен югалту, чуалту, саташтыру. *Тау өстендә ике җил тегермәне бик еpактан күренә иделәр. Алар минем зиһенемне адаштыралар. Миңа алар җанлы кебек тоела иделәр.* Ш.Камал. --- *чыпчык үтмәс куе, кара урманнарны үтәм, печтекәй генә дә адашмыйм, ә менә тел урманы адаштыра, капландыра, сазга батыра...* С.Поварисов

**Адаштыра бару** Торган саен ныграк адаштыру

**Адаштыра төшү** Тагын да ныграк адаштыру. *Юеш карлы карга бураннары адаштыра төшә*

**Адаштырып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле адаштыру

**АДАШУ** *ф.* **1**. 1) Таныш булмаган урында юлны югалту, ялгышып, юлдан читкә китү. *Авыл зур юллар чатында түгел, адашып та килеп чыгучы булмас монда.* Р.Мөхәммәдиев. *Инде бу адашкандыр, кайтырга юл табалмыйдыр, дип хафаланып торганда, «күккү» дип, әллә каян куак астыннан атылып чыгар иде.* Ф.Яруллин. *– Бәлки, сез адашкансыздыр, – дидем. Ул, көлеп: – Юк, адашмадым. Мин урманда йөрергә өйрәнгән, һичбер вакытта адашмыйм, – диде.* Гали Рәхим

2) Үзенә тиешле урында булмау, тиәлегенә туры килмәү, сыешмау. *Басу кырыенда адашып чыккан өчдүрт бөртек арыш башагын кулларымда удым да авызыма каптым.* Д.Салихов

3) *күч. сөйл.* Берәр сәбәп аркасында туганнарыннан аерылып, читтә каңгырып йөрү. *[Мотый]: Бу сеңелкәш тә безнең кебек илләреннән адашып йөргән егетләрнең күңелен табарга тырышыр.* М.Фәйзи

4) *күч.* Уй, фикер буталу, саташу, ялгышу. *Бер, ике, дүрт... адаштым, Ун..., егерме, ах тагын! Мин югалттым шомлы көннәрнең, Гасырларның санын.* Һ.Такташ. *Тукта, мин юлдан адашканмын икән бит, күр әле; Әллә*

*ник истән дә чыккан, сүз башым бит: «Шүрәле».* Г.Тукай

5) *күч.* Ялгышу, хаталану. *Үкенечләр – урман, өметләрем – буран, --- Көлә-көлә кереп адаштым. Ялгышларым – урман, язмышларым – буран. --- Йөгерә-йөгерә кереп адаштым.* Н.Измайлова. *Давылларда бер буразна ярып Тапкан дуслык мәңге адашмас.* А.Хәлим. *Булды минем адашканым Кереп авыр уйларга.* Р.Мингалим // Берәр кеше турында ялгыш фикердә булу. *«Усал» патша урынына «яхшы» патша эзләүнең бик кыйбатка төшкән наив адашу икәнлеге бүген көн кебек ачык.* М.Госманов

6) *күч.* Зиһен чуалу, күңел утыра алмау. *Юк, бу адашып сөйли торгандыр; бездә бит әле халык, Аллага шөкер, көненә икешәр-өчәр выпускадан китә торган газеталар асрарлык дәрәҗәдә юләр түгел.* Ш.Камал

7) *күч.* Бозыклыкка бирелү, әхлаксызлану, начар гадәтләр алу. *Бар җирдә тигезсезлек чиктән ашкан. --- Күп кешеләр туры юлыннан адашкан...* Г.Камал

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ялгышлык; хата; хаталык. *Без ул чакта күңелләребез белән сизә идек, болар – вакытлы адашулар, болар – акыл җитмәүдән.* М.Мәһдиев

2) **адашкан** Юлын ялгыштырган, юл таба алмаучы, юлыннан читкә киткән кеше. *Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан, Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.* Г.Тукай. *Вакытында юл күрсәтүче табылса, адашканнар да үз сукмагын табарга мөмкин.* Сөембикә

**Адашып алу** Кыска гына вакыт эчендә бераз адашу

**Адашып бетү** Тәмам адашу. *Шундый зур йортта ул абыйның әнисе белән икәү генә яшәвенә гаҗәпләнде. Бүлмә эчләрендә бүлмә иде, кергәндә, малай адашып бетте хәтта.* Л.Гыймадиева. *Кирәкле чүлмәгеңне сайлап алыйм дисәң, монда көне буе йөрергә кирәк, адашып бетәрсең.* Н.Фәттах

**Адашып йөрү** Әле, хәзер, күптәннән бирле адашкан булу. *Балалык елларым, үсмер чагым, туры юлымны таба алмыйча, төрле сукмакларда адашып йөрүләрем --- күз алдымнан уздылар.* Җ.Фәйзи. *Тормыш карурман гына булса, Илсөя анда адашмый йөрергә өйрәнгән иде инде.* Ф.Яруллин. *Мин – туксан мәртәбә ялгышып, алданып, тәүбә итеп, аннан тагын тәүбәмнән баш тартып, яшәеш карурманнарында адашып йөргән бер ятим, бер хыялый адәм баласы гына.* Ә.Рәшит

**Адашып калу** Ниндидер моменттан, вакыттан соң адашу, югалу. *Ярый, бәхетегезгә, урманда адашып калмагансыз әле.* С.Җәләл. *Кайларда адашып калдың?* Р.Мулланурова. *Аналарыннан адашып калган кайбер сарык, кәҗә бәрәннәре, --- нечкә әче тавыш белән өзлексез кычкырып, аналарын эзлиләр.* М.Гали

**Адашып китү** Көтмәгәндә, уйламаганда кинәт адашу. *Чөнки дөньяга яңа килгән бала – әле ул мөселман. Аннары ул адашып китә.* Фольклор практикасы

**Адашып кую** Көтмәгәндә, кинәт адашу. *Әнә шулай йөри торгач, бервакыт ул адашып куйды.* Ф.Яруллин

**Адашып тору** 1) Еш, әледән-әле адашу

2) Әле, хәзер адашкан булу. *Юлны тапмыйча адашып тору*

**АДӘМ** *и. гыйбрани* 1) *дини* Коръән Кәримдә сөйләнгәнчә, Җир йөзендә Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылган беренче кеше. *Мәгълүм булганча, атабыз Адәм фани дөньяда 930 ел яшәгән*

2) Кеше, шәхес. *Эт, кинәт, хуҗасына һөҗүм иткән адәмгә ыргылды, тешләре белән аның чалбарын каптырып алды.* А.Хәсәнов. *Ихлас куеп дәресләрдә калмак кирәк, Күңелебезне гыйлем белән нурлау кирәк, Укыган адәмнәрне зурлау кирәк.* Г.Камал. *Бик кырыс адәм иде ул өлкә комитетында эшләгәндә. Ольгая төшкәч исә кешелек сыйфатлары көчлерәк бәреп чыга башлады.* Т.Галиуллин

3) Таныш булмаган ир кеше. *Арбаның астына тире чиләкләр, турсыклар асылган. Картлар, ир уртасы адәмнәр – атта.* И.Салахов. *Кызыл йөзле адәмнәрнең берсе карлыккан тавыш белән җыр башлады.* М.Мәһдиев. *Бу шагыйрь – җырчы адәм иде.* Г.Ибраһимов

4) *кимс.* Бәндә; начар, явыз ниятле яки булдыксыз кеше. *Бер гаилә кебек яшибез. Ләкин безнең артельдә бер тотнаксыз адәм бар – Аникин.* А.Хәсәнов. *Ә теге, кичә төнлә безнең купеда барган адәм – кеше түгел. Ул үзенең тормышын барыбер чәнечкеле чыбык эчендә чикләячәк.* М.Мәһдиев. *Шаһгали исә – Мәскәү сәясәтенең төп максатларыннан берсен – Казан ханлыгын һәм Түбән Идел буйларын, Нугай вә Хаҗи Тархан урдаларын яулап алу һәм тулысынча Мәскәүгә буйсындыру ягын кайгыртып йөргән адәм.* Ф.Урманче

◊ **Адәм актыгы** *кимс.* Үз-үзен тотышы, әхлагы белән түбән дәрәҗәдәге кеше. *Карт тиз генә сынмый: «Бу адәм актыгы белән коньяк әрәм итәсе түгел иде дә бит, нишлисең, әйдә китер, килен».* М.Мәһдиев. *«Жигули»га гына утырып йөрмәс бу адәм актыгы. Димәк, иномарка.* Мәдәни җомга. **Адәм акыллы** 1) Кешеләрчә уй-фикер йөртә торган, кешеләрне аңлый, тиз төшенә торган (хайван); 2) Акылга сыя торган, мәгънәле, юньле, рәтле (сүз, фикер). **Адәм аламасы** Начар, йолкыш, сатлык кеше. **Адәм ахыры** *к.* **адәм актыгы**. *Һи, адәм ахыры! Син дә сөйләшкән буласың тагы!* Г.Камал. **Адәм аягы басмаган** Моңарчы кеше эзе булмаган җир. **Адәм аякланмаслык** Йөрергә кыен булган, кеше йөри алмаслык. *Урамда адәм аякланмаслык пычрак.* М.Мәһдиев. **Адәм әйтеп бетерә алмас** Тел белән генә әйтеп, сөйләп җиткерә алмаслык шәп, үтә яхшы. *Патша хәзрәтләренең хатынын да күргән --- адәм әйтеп бетерә алмастай уңган икән, ди.* Г.Ибраһимов. **Адәм әйтеп, адәм ышанмас** Әйтсәң, кеше ышанмаслык дәрәҗәдә гаҗәп, ләкин үзе реаль эш, булган хәл. *Абзар тутырып мал-туар асрыйлар, ишегаллары тулы кош-корт. Өстәвенә, адәм әйтеп, адәм ышанмас, илле баш умарта тоталар.* Г.Ахунов. *Ә андый ташны – адәм әйтеп, адәм ышанмас – көненә өч кубометр чокырга кирәк.* Г.Ахунов. **Адәм баккысыз** 1) Карар җире калмаган, пычранып беткән. *Өйгә, адәм баккысыз булып балчыкка буялган хәлдә, сыңар итектән кайтып керде.* Г.Ахунов; 2) Бик иләмсез, ямьсез. **Адәм баласы** Гомумән кеше. *Җан тынычлыгы*

*булмаса, адәм баласына берни дә кирәк түгел икән.* Т.Галиуллин. *Адәм баласы туа, үсә, табигать аңа күпме гомер биргән, шул хәтле яши дә мәңгелек йортына китеп бара*. Г.Ахунов. – *Адәм баласы үзенә генә түгел, әнә шул кулына карап торган хайваннар өчен дә җаен табарга тиеш! – диде Нургали.* Ә.Еники. **Адәм баш тыккысыз** Кеше бик күп булган, тыгыз җир. *Ул судка кереп булмый, анда адәм баш тыккысыз*. **Адәм башы** Гомумән кеше. *Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри*. Мәкаль. *Тузга язмаган гайбәт тарату дисеңме, --- яисә тәнкыйть китапларыма тискәре мәкаләләр оештыру дисеңме – барсын да күрде адәм башлары*. Т.Галиуллин. **Адәм белмәгән, адәм ишетмәгән** Кеше колагы, аңы өчен ят авазлар, сүзләр, сәер хәлләр турында. *Очсыз-төпсез сәхрә шикелле, үзенең тирә-ягы адәм белмәгән, адәм ишетмәгән куркыныч тавышлар илән тулган.* Г.Колахмәтов. **Адәм булды, дигәндә әрәм булу** Үсеп, белем алып, кеше булып җитте, дигәндә вакытсыз үлеп китү яки берәр төрле бәлагә тару. **Адәм булу** 1) Кешелек сыйфатларын үзеңдә булдыру, әхлак нормаларыннан читкә чыкмау, үзеңне лаеклы тоту, кешелекле булу, шуңа ирешү. *Сез, адәм булсагыз, атагыздан гыйбрәт алыр идегез*. Г.Ибраһимов; 2) Авырудан савыгу, аякка басу. *Кызым инде авыруыннан терелә башлады, адәм булып килә*; 3) Укып, белем алып, гыйлем-һөнәр иясе булып җитешү. *Ни күрсәм дә күрдем, балаларым, укып, бар да адәм булдылар.* **Адәм галәйһессәлам киемендә** Ялангач, киемсез, шәрә хәлдә. **Адәм гарибе** Эшкә яраксыз, булдыксыз, тормышын алып бара алмый торган. *Айдан якты нәрсә юк, Кара болыт басмаса; Адәм гарибе шул булыр, Кайтып илен тапмаса*. Дастан. **Адәм җәфасы** *кимс. к.* **адәм имгәге. Адәм заты** Кеше, кеше токымы. **Адәм имгәге** 1) Үзен-үзе карый алмыйча, кешеләр өстенә салынып, үзенә дә, кешеләргә дә йөк булып яшәүче; урын өстендә ятып авыручы яки гарип кеше; 2) Акылга тулы булмаган, аңгыра. *Әнә шул, бар ич әле, бер адәм имгәге Биби.* Г.Камал. **Адәм итен чәйнәү** Кеше гайбәтен сату. *Ә адәм итен чәйнәү, көн буе гайбәт сатып утыру – ансы хәрәм түгел[ме]?* Г.Камал. **Адәм ишетеп, адәм ышанмас** *к.* **адәм әйтеп, адәм ышанмас**. *Кызны кодаларга үзе барган ардаклы-хөрмәтле кешенең малае адәм ишетеп, адәм ышанмас явызлык кылды. Әхмәйгә ярәшелгән Миңлегөлне урлап, үзләренең чапкын айгыры белән кайдадыр китеп олакты*. Ф.Мансуров. **Адәм йөргесез** Юлның бик пычрак булуы яки кар-буран басып китү, кеше йөрерлек булмау. *Бүген бөтен дөньяны кар баскан, адәм йөргесез буран*. **Адәм калдыгы** Үзен начар яктан күрсәткән, уңай сыйфатлары аз булган кеше. *Аның эше киләчәккә идеалын югалткан, күрше хатыннары белән чуалудан башка эше булмаган адәм калдыгыннан нәрсә көтәсез?* Казан утлары. **Адәм карагысыз** *к.* **адәм баккысыз**. *Адәм карагысыз юан*. М.Әмир. **Адәм карасы** Адәм сыны, адәм силуэты. *Бер сәгатьтән соң кар баскан яланда көчкә бер адәм карасы күренде.* Н.Исәнбәт. **Адәм көеге** Кешеләргә җәфа, хәсрәт булып яшәүче. *Их син, адәм көеге!* К.Нәҗми. *Адәм көеге булганчы, урман киеге бул*. Мәкаль. **Адәм көлкесе** Кеше арасында хурлык, түбәнлек хәле; шундый хәлгә калган кеше. *Җил баш син! Күк күкрәгән өчен болытларга бармак янап маташасың, адәм көлкесе!* Ә.Еники. **Адәм көлкесе булу** Кеше арасында оятка калу. *Берсе өстенә берсе сөйләп, бутап бетереп, адәм көлкесе булып беттеләр*. Г.Камал. **Адәм көлкесе итү** Кешене хур итү, мәсхәрәгә калдыру. **Адәм көлкесенә калдыру** Хур итү, оятка калдыру. *Аның Солтанны болай адәм көлкесенә дә калдырасы килми иде, әлбәттә.* А.Расих. **Адәм көлкесенә калу** *к.* **адәм көлкесе булу**. – *Солтан абый, әйдә, без, бөтенләй адәм көлкесенә калганчы, авылга кайтып китик, – диде ул, тәмәке төтененнән йөзен чытып.* А.Расих. *Люция дә шундый кадерсез булыр микәнни, ул да шулай адәм көлкесенә калыр микәнни?* М.Маликова. **Адәм күзенә күренерлеген калдырмау** Кешене тәмам хурлыкка төшерү, оятка калдыру. *Бу эчкече ир минем адәм күзенә күренерлегемне калдырмады.* Н.Исәнбәт. – *Ир булып йөрүең корсын, мескенкәем! – дип, егетнең адәм күзенә күренерлеген калдырмадылар*. Г.Ибраһимов. **Адәм күтәргесез** 1) Кеше күтәрә алмаслык авыр яки бик зур әйбер турында; 2) Олы бәла-каза, михнәт, җәза һәм газап чигүләр хакында. **Адәм күтәрмәслек** *к.* **адәм күтәргесез.** *Балдакларына күз салдыңмы? Адәм күтәрмәслек иде бит.* Ф.Яруллин. **Адәм кыяфәте калмау** 1) Йөзе-чырае, буе-сыны, өсбаш киемнәре бозылган булу; 2) Нинди дә булса авырудан сулып, ябыгып калу. *Көчкә танnetwork ныдым, бөтенләй кыяфәтең калмаган*. Н.Исәнбәт. **Адәм мәсхәрәсе (булу)** Нинди дә булса берәр гамәле яки гадәте белән башкалар алдында оятлы булу. *Лаләдән яңаклатып, елап кайтып килмәсен тагын, адәм мәсхәрәсе булып!* М.Фәйзи. *Ул инде авылга кире кайтмаска булып киткән икән. Шулчаклы зур гөнаһ эшләп, адәм мәсхәрәсе булгач, ничек кайтсын соң?..* М.Гафури. *Әле күптән түгел безнең кибетләрдә тулып яткан атаклы Ленинград буяуларының хәзер әсәре дә юк. Аларны хәтта рәссамнар да махсус заказлар биреп тә алдыра алмыйлар. Адәм мәсхәрәсе*. Мәдәни җомга. **Адәм мәсхәрәсе итү** Кеше алдында хур итү, кеше көлкесенә калдыру. *Барчабызны адәм мәсхәрәсе итәргә кайткан лабаса ул, бөтен авылыбызның көлен күккә очырырга кайткан!* К.Миңлебаев. **Адәм мәсхәрәсенә калдыру** Хур итү, мәсхәрәләү, мыскыллау. *Бер хохол кешесе, --- шәһәр советы рәисе булып күп еллар буена утырып, --- шәһәребезне адәм мәсхәрәсенә калдырды.* Т.Галиуллин. **Адәм рәвешле** Кешечә, кешеләрчә кыяфәтле, кешегә хас сыйфатларга ия булган. *Яле, адәм рәвешле генә утырыйк әле бер*. **Адәм рәтенә кермәгән** Юньсез, игелексез, рәтсез, мәнфәгатьсез кеше, мәгънәсез кеше турында. *Аларның адәм рәтенә кермәгән исерек малайларына ефәк кебек кызымны бирәмме соң!* Н.Исәнбәт. **Адәм рәтенә керү** Кеше арасына керү, эше, белеме, үз-үзен тотышы белән уңай бәяләнү. **Адәм рәтенә сукмау**

Уңай кешегә исәпләмәү, башка кешеләр белән тиң санамау. *Син аны ничә еллар буе адәм рәтенә сукмыйча, балаң итмичә йөр дә, ул синнән килеп киңәш сорамагае.* Г.Ахунов. **Адәм рәтле** 1) Әйбәт, яхшы, юньле (кеше турында). *Аннары тирән сулап: – Шартым шул, – диде. – Миңа оныклар булдырып, адәм рәтле итеп үстерә алырлык булсагыз гына фатихамны бирәм.* М.Маликова. *Ичмасам, адәм рәтле кешегә дә чыкмаган.* Ф.Бурнаш; 2) Затлы, яхшы (әйбер, кием яки мал турында). *Хәзер халык бик сайлана башлады, кеше арасына чыкканда, адәм рәтлеләрген дә киясе килә.* М.Шабай; 3) Эшкә ярарлык, файдалы. *Фермабыз алама, адәм рәтле доход китергәне юк, колхозчыларга бер кружка сөт, сыңар бияләйлек йон бирә алганыбыз юк.* Ә.Еники. *Шәпеш [хәлфә] дөньяда бер кешене дә белемле ясамады, аңарда укыган шәкертләр үзе шикелле томана, дорфа булып чыктылар, адәм рәтле эшкә ярамадылар.* Ә.Фәйзи; 4) Яхшы, рәхәт, җитеш. *Синең адәм рәтле тормыш күрәсең килә.* М.Әмир; 5) Итагатьле, әйбәт итеп. *Кешеләр белән адәм рәтле сөйләшә белмәвенә аның үз-үзенә чынлап ачуы килде.* Ә.Еники. **Адәм рисвае итү** *к.* **адәм мәсхәрәсе итү.** *Нафиганың олы кызы Хания кайтып киткән булды бит әле. Менә шул адәм рисвае итеп китте бит, имансыз нәрсә.* Г.Мөхәммәтшин. **Адәм санына керү** Башкаларның игътибарын казану, олылауга, хөрмәткә ирешү. *Инде бер адәм санына кергәч, мондый өс-баш белән дә йөреп булмый бит.* М.Гафури. **Адәм сизмәс, эт өрмәс** Беркемгә дә сиздермичә, астыртын рәвештә, яшерен генә эшләнгән эш. *Аларныкын белмәссең, ни кыралар, ни эшлиләр – адәм сизмәс, эт өрмәс.* Н.Исәнбәт. **Адәм сөяге** Күтәрәмгә калган кешене яки зурайганчы үзен кешедән күтәртеп йөрергә яратучы баланы күтәрүнең җиңел түгеллеге хакында әйтелгән сүз. *Авыр булмыйча, өченче катка хәтле күтәреп менгезәм. Адәм сөяге бит ул!* Н.Исәнбәт. **Адәм страмы** *сөйл. к.* **адәм хуры.** «*Оят» дигән нәрсә кайда, ә? Бөтен кеше эштә, --- ә син, әзер чәйгә тормыйча, түр башында аунап ятасың. Адәм страмы!* Ә.Еники. **Адәм сынлы** 1) Кешенең буй-сыны, киеме башкалардан ким булмау, тиешенчә булуы. *Адәм сынлы йөри дә белми*; 2) Адәмгә лаеклы. *Адәм сынлы гына сөйләш, исердеңме әллә?* Н.Исәнбәт. **Адәм тилчәсе** *хурл.* Үзе генә түгел, теле белән дә ни үзенә, ни кешегә көн күрсәтми торган җәфа кеше. **Адәм төсе керү** Йөзенә сәламәтлек төсе инү, чырай керү. *Артык тазара алмады, шулай да адәм төсе керде.* Г.Ибраһимов. **Адәм төсле** Кеше арасында күренерлек өс-баш, кием-салым, кыяфәт яки югары рухи сыйфатка ия булу турында. *Адәм төсле бүреге дә юк.* Н.Исәнбәт. *Адәм төсле бер роль уйнаганы да юк, йөри ул да.* Н.Исәнбәт. **Адәм үләксәсе** *хурл.* 1) Үзенә дә, кешегә дә игелек күрсәтмәгән, кара фикерле, караңгы чырайлы, сөмсез, начар кеше. *Әйтәм ич, бер адәм үләксәсенә барып сөртенәселәре килсә, алсыннар (хатын алу турында).* Г.Камал. 2) Бик ябык, коры сөяккә калган, тәмам бетеренгән кеше **Адәм хурлыгына калу** *к.* **адәм мәсхәрәсе булу.** *Ул вакытта да Фатыйма Баһавидан котылырга теләп бер талпынган иде. Тик үзе чак кына адәм хурлыгына калмады.* А.Расих. **Адәм хуры** *хурл.* Үз кадерен белмәгән, түбәнлеккә төшеп, кеше алдында хурлыкка калып йөргән кеше турында. *Әбәү мәхәббәтсез, адәм хуры, кешедән көлгән була, үзенең бите читек балтыры төсле җыерчыкланып беткән.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Син үл генә, сиңа дөнья хәрәм. Адәм хуры, йөрмә, диделәр.* М.Җәлил. **Адәм чыдамаслык** Авыр, кыен, түзеп булмаслык, көч җитмәслек. *Инде өч сәгать этәбез, кояш та авышты, ләкин адәм чыдамаслык эссе, бөркү.* М.Мәһдиев. **Адәм ышанмаслык** 1) *к.* **адәм әйтеп, адәм ышанмас**; 2) Ялган, уйдырма (сүзгә карата)

**АДӘМИ** *с. гар. кит.* Адәмгә, кешеләргә хас булган. *Әй, нәҗес, адәми халык!* Әкият. *Әнә шул серле Кояш-Тәңрене ерак бабаларыбыз «Күк-Тәңре» дип атасалар, фарсылар «Ходай» дип дәшәләр, гарәпләр исә «Аллаһ», руслар җирдә туган адәми баланы «Христос-Бог» дип табыналар.* М.Хәбибуллин

**АДӘМИ́ ЗАТ** *и. кит.* Кеше, кеше заты. *Күккә карап, бала елаган тавышлар чыгарып, үксеп-үксеп уладылар алар [этләр]. Әйтерсең лә алар күк йөзендә адәми зат күрмәгәннәрне күрә иде.* Ф.Бәйрәмова. *Һәрбер адәми затка атап, шунда берәр шешә сыра, су, сок куелган.* Т.Галиуллин. *Һәркемнең үз юлы, үз язмышы. Аны адәми зат кына билгели алмый.* Г.Гыйльманов. *Аллаһе Тәгалә тарафыннан балчыктан бар ителгән һәм җан өрелгән адәми зат.* Мөселман календаре

**АДӘ́МЧӘ** *рәв.* Билгеле бер тәртип белән, кагыйдәләрне бозмыйча, кешеләргә хас булганча. *Аллаһе Тәгалә кешелек дөньясын, хайваннар дөньясыннан аерылып торсын өчен, адәмчә яшәү өчен биргән.* Мөселман календаре

**АДӘМЧЕК** *и.* Кешегә карата кимсетү, кешене санга санамау сүзе, адәм кисәге

**АДВОКАТ** *и. лат. юр.* 1) Хокук мәсьәләләре буенча киңәшләр бирүче югары белемле хокук белгече, адвокатлар коллегиясе әгъзасы. *Эльмира кызым, син тагын адвокатка бар әле! Врачларның баланы бирмәскә хаклары юк!* Г.Зәйнашева. *Адвокатлар коллегиясе утырышында катнашу*

2) Судта гаепләнүчене яклаучы хокук белгече, юрист. *Арада иң озын, иң оста сөйләгән яклаучы карт адвокат Ардатов булды.* Г.Ибраһимов. *Ул арада Фәргать, укуын тәмамлап, судта адвокат булып эшли башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Адвокат сезнең дәгъвагыз асылын кыскача гына шәрехләп китте.* Ә.Сафиуллин

3) *куч. сөйл.* Кемнең дә булса карашын, сүзен, фикерен хуплап, аның ягында булып, кирәген-кирәкмәгәнен сөйләнеп утыручы кеше, ярарга тырышучы кеше

4) *куч. сөйл.* Арага керүче, тыкшынучы кеше

**АДВОКАТЛЫК** *и.* 1) Адвокат хезмәте, адвокат вазифасы. *Адвокатлыкка укыган кеше мал карауга күчсә, ул адвокат булудан туктый.* Р.Батулла

2) *куч. сөйл.* Кешеләргә киңәш биргән булып, бер-берсенә каршы котыртып, талаштырып, ара бозып йөрү гадәте

**АДВОКАТУ́РА** *и. лат.* 1) Адвокатлар коллегиясе, оешмасы. *Республика суверенлыгын ныгыту буенча законнар, Конституция кабул итү, --- халыкара мөнәсәбәтләр урнаштыру, суд, прокуратура, адвокатура, башка күп кенә мәсьәләләрне Татарстанның мөстәкыйль хәл итәчәге белдерелде.* Мәдәни җомга. *Район халык суды, район прокуратурасы, адвокатура, --- хокук саклау, тәртип мәсьәләре белән шөгыльләнә.* Шәһри Казан. *«Адвокат эшчәнлеге һәм Россия Федерациясендә адвокатура турында»гы федераль закон*

2) *җый. мәгъ.* Адвокатлар, адвокатлар катлавы

**АДВОКАТЧЫЛЫК** *и. к.* **адвокатлык** (*2 мәгъ.*). *Чистай татарлары --- Юнысовны Чистай мәдрәсәсе каршындагы «учитель» вазифасыннан азат итүне сорый. Сәбәп итеп түбәндәгеләр күрсәтелә: балаларны бөтенләй укытмый, адвокатчылык, әләк белән шөгыльләнә, ришвәт ала.* Р.Әмирхан

**АДЕКВАТ** *с. лат.* 1) Тиңдәш, тәңгәл, бер үк төрле, туры килгән. «*Дөрес тәрҗемә» дигәндә – төгәл, адекват яки тулы кыйммәтле тәрҗемәләрне, «дөрес булмаган тәрҗемә» дигәндә, хәрефкә-хәреф һәм формаль тәрҗемәләрне аңларга кирәк.* Ф.Юсупов. *Телнең орфографиясен мөмкин кадәр аның табигатенә иң тәңгәл, иң адекват ысуллар белән өйрәтү иң дөрес юл булыр.* Фән һәм тел. *Россия ислам уку йортлары дини дисциплиналар буенча заманча һәм тәңгәл (адекват) уку әсбаплары белән, хәтта, 20 процентка да тәэмин ителмәгән ---.* Мәдәни җомга

2) *сөйл.* Дөрес. *Мин сезне аңларга тырышам, әлбәттә, әмма соңгы вакытта дәресләргә соңга калуыгыз, минем сорауларга адекват җавап бирә алмавыгыз, онытылып йөрүегез үзегезгә начар булып куймагае.* Кәеф ничек?

3) Үз акылында, нормаль. *Минем фикеремчә, төптән уйлап гаилә корган, адекват кешеләрнең гаиләләре таркалмый.* Шәһри Казан. *Разил Вәлиев фикеренчә, Жириновскийның сүзләре беренче карашка адекват кешенеке кебек кабул ителмәсә дә, аның тел төбендә дәүләт сәясәте ята.* Ватаным Татарстан. *Грузия президентының психик халәтен табиблар адекват булмаган дип бәялиләр.* Кәеф ничек?

**АДЕКВАТЛЫК** *и.* Адекват булу. *Адекватлык ягыннан караганда да алар акыллыга һәм хак шопоголикларга аерыла.* Кәеф ничек? *Тәрҗемәнең оригиналга адекватлыгы. Фикерләүнең чынбарлыкка адекватлыгы*

**АДМИНИСТРАТИВ** *с.* **1**. Администрациягә караган, администрациягә мөнәсәбәтле, аңа бәйләнешле. *Ак колонналы фән йортында берни белән дә аерылып тормаган фәннәр кандидатлары, идеология, фән һәм уку йортлары административ бүлек мөдирләре булып расланып, йомшак креслоларга --- күчеп утырдылар.* Т.Галиуллин. *Казан ханлыгы заманыннан сакланып килгән административ бүленеш булган Җөри юлында ---.* М.Әхмәтҗанов. *Административ җаваплылык мәгариф оешмаларында гражданнарның бушлай белем алу хокукын бозучыларга карата кулланылачак.* Мәгърифәт

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Рәсми кабул ителгән рәвештә, рәсми хакимият органнары таләп иткәнчә яки кушуы буенча. *Гадәти административ басым ясау юлы белән нәрсәләргә ирештек?* Р.Хәкимов

2) Бюрократларча, формаль, эшнең асылына төшенмичә. *Кулакны административ тәртиптә кысуны, аның милкен конфисковать итүне туктатып, аңа каршы көрәшне авылда совет эшләрен җанландыру юлы белән алып бару тәртибенә күчкәч, кайбер ярлылар нишләде, диген?* М.Әмир

**АДМИНИСТРА́ТОР** *и. лат.* Идарә итү кешесе, идарә итүгә җаваплы кеше. *Татарстан хөкүмәте Мәскәүнең Чайковский исемендәге консерваториясе каршында татар опера студиясе оештырырга булган ---, администраторы тегеатаклы мандолиначы Исмәгыйль Һилялов икән.* Җ.Фәйзи. *Нык куллы, җайлы, ипле администратор буларак, вазифасын тигез генә тартып алып бара.* Г.Ахунов

**АДМИНИСТРА́ТОРЛЫК** *и.* 1) Администратор вазифасы (хезмәте). *Ул [Мөхит Кичүбаев] үзе артист та, режиссёр да, музыкант һәм композитор да була, шул ук вакытта администраторлык вазифаларын да башкара.* Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры

2) *күч.* Җитәкчелектә мәсьәләнең асылына төшенмичә эш итү ысулы; формаль бюрократлык. – *Беләсеңме, бүген правление утырышында Нәби абый белән Гөлҗиһан апаны кавыштырабыз бит. Киләсеңме? – Бу нинди чеп-чи администраторлык тагын?* Р.Төхфәтуллин

**АДМИНИСТРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Башкарма хакимият органнары; учреждение, предприятие һәм оешманың җитәкче органы. *Төрле дәрәҗәдәге мәэмүрләр алдында тез чүгү турында уйлап та карамаган ишан өстеннән администрация адресына яңадан-яңа әләкләр ява.* Р.Әмирхан. *Әле биш-алты ел элек кенә югары уку йортларында бер шөгыль дә өлкә комитеты рөхсәтеннән башка эшләнми иде. Ә хәзер – бөтенләй үзгә дөнья, администрациягә совет иле тарихында беркайчан да шундый мөстәкыйльлек, хокук ирегe бирелгәне юк иде әле.* Т.Галиуллин. *Җирле администрация*

2) Идарәдә җитәкчелек итүче кешеләр. *Без ул шахтаның тиздән җимереләчәген атна буена әйтә килдек. Ләкин администрация безнең сүзне колагына да элмәде.* М.Гафури. *Гомере буе кешеләргә, балаларына игелек күрсәтеп яшәгән әнинең үлеме дә символик булды: без – дүрт бала – әни үлде, дип, үзебез эшли торган урыннарда гариза язып, «отгул»лар алып администрацияне мәшәкатьләмәдек.* М.Мәһдиев

**АДМИРА́Л** *и. ингл.<гар.* 1) Хәрби диңгез флотының командирлар составындагы югары дәрәҗә һәм шул дәрәҗәне йөрткән кеше. *Пантелей карт шагыйрь дә, маршал да түгел, --- алтын галунлы фуражкасы һәм лампаслы чалбарлары белән, ул бераз гына маршалны хәтерләтә. Дөресрәге – адмиралны.* М.Мәһдиев. *Флот адмиралы. Адмирал дәрәҗәсе. Адмирал флагы*

2) *зоол.* Нимфалидлар семьялыгыннан, канатлары кара, арткы канатлары читендә кызыл сызыгы булган, сирәк очрый торган көндезге күбәләк. *«Адми-*

*рал» дип аталган күбәләкнең көньякта бер ел эчендә ике-өч буыны үсеп җитә ала.* Биология

**АДМИРАЛЛЫК** *и.* Адмирал дәрәҗәсе; адмирал вазифасы, хезмәте. *Адмираллык дәрәҗәсенә ирешү*

**АДМИРАЛТЕ́ЙСТВО** *и. рус* 1) *иск.* Хәрби суднолар ясау һәм аларны җиһазлау, ремонтлау урыны

2) Патша Россиясендә һәм Англиядә: диңгез көчләренең иң югары идарә органы; диңгез ведомствосы

3) Санкт-Петербургта элеккеге хәрби флот баш идарәсенең бинасы

**АДО́НИС** *и. гр. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, алтынсу сары чәчәк ата торган бер яки күпьеллык үсемлек; кыйммәтле дару үләне. *Адонисның Европада һәм Азиянең уртача климатлы районнарында 20 ләп төре үсә.* Биология

**АДРЕНАЛИН** *и. лат. биол.* Бөер өсте бизе эшләп чыгара торган гормон. *Адреналин йөрәк кыскаруларын көчәйтә һәм ешайта.* Биология. *Адреналин корсак куышлыгы органнарындагы һәм скелет мускулларындагы кан тамырларының тараюына китерә, кан басымын күтәрә.* Биология

**А́ДРЕС** *и. фр.* 1) Кемнең дә булса яшәү-тору урынын күрсәткән язу. *Хәят матур кашларын җиңел генә күтәренкеләде дә: – Ах, гафу итегез, Николай Иванович, әүвәл «мена язам, менә язам» дип йөрдем дә, --- аннан соң, сезнең адресыгыз алышынган дип ишеттем* Ф.Әмирхан. *Казанга килеп төшүгә, Качалов театрына ике билет алам да, --- теге адрес буенча, оча-куна, бер йортның ишегенә барып җитәм.* М.Мәһдиев

2) Хат, телеграмма, бандероль һ.б.ш. әйберләрнең тышында кая һәм кемгә тапшырылырга тиешлеген күрсәткән язу. *Миләүшә хатны сузды да, озак юанма, дип, китеп тә барды. Кире адресы юк, кулы да таныш түгел.* Г.Әпсәләмов

3) Тәбрик хаты, котлау нотыгы; котлаунамә. *Аңа [Хәсән Туфанга] әйтәсе сүзләрен һәммә кеше дә сөйләп бетерерлек түгел иде. Ринат Мөхәммәдиев аңа 12 адрес-папканы җыеп тапшырды.* Г.Ахунов

4) **адресына, адреска** Нинди дә булса сүзнең, фикернең кемгә дә булса төбәп, кемнең дә булса исеменә карата әйтелгән, язылган булуы. *Әсәрләрен укымыйча, сәяси карашлары, ачы язмышы белән танышмыйча, --- берничә тапкыр әдип адресына яман сүзләр әйтте.* Т.Галиуллин. *Бу төче сүзләрнең иң зур өлеше соңгы вакытта Нәсимә адресына төшә.* К.Нәҗми. *Х.Ярми һәм минем адреска никадәр сатира! Ай-һай хитри син, Әмирхан ага!* М.Мәһдиев

**АДРЕСАНТ** *и. нем.* Хат, посылка, бандероль җибәрүче

**АДРЕСАТ** *и. нем.* Җибәрелгән хатны, посылканы, бандерольне алырга тиеш булган кеше яки учреждение. *Бу хатлар биш-алты көндә адресатлар кулында булачак.* И.Салахов. *Марат хатны Зәлифәгә – Бәләбәй медицина училищесына җибәргән иде. Адресат, укуын тәмамлап, районга китте, дигән җавап белән кире кайтты.* З.Фәйзуллин. *Бу шигъри юллар адресатына барып ирешә алгандырмы, ирешә алгандырмы аларны Миңниса апа?* Сөембикә

**А́ДРЕСЛАНУ** *ф.* Кемнеңдер исеменә яки нәрсәнеңдер тәгаенләнгән урынына язылу, аталу. *Редакциягә килгән хатлардан тыш, авторның үзенә адресланганнары да бар.* М.Госманов. *Фоторәсем шул ук көнне, Яңа Актауга – әти-әнигә адресланып, почта ящигына салынды.* Р.Мөхәммәдиев. *Хат кызның нәкъ үзенә адресланган.* Ф.Хөсни. *Атна саен Фәниярдән Фәүриягә адресланган хатлар килеп торуын яхшы белгән почтальон кыз Гөлсәйдәгә килгән телеграмманың моңа да кагылышы барын сизә иде шул.* Ф.Яруллин

**А́ДРЕС(ЛАР) ӨСТӘЛЕ** *и.* Адреслар бюросы; шәһәрдә яшәүчеләрнең адресларын барлап, аларның тору урыннары турында белешмәләр бирә торган учреждение. *Адрес өстәле аша эзләтер өчен, эзли торган кешеңнең исем-фамилиясен, әтисенең исемен, кайчан һәм кайда туган икәнен язарга кирәк.* Казан утлары

**А́ДРЕСЛАУ** *ф.* **1.** 1) Хат, посылка, бандероль кебек нәрсәләрне адрес белән җибәрү. *Бераздан егет хатларын турыдан-туры кызның үзенә адреслап та җибәрә башлый.* С.Сабиров

2) Кемгә дә булса юнәлтү, багышлау, тәгаенләү. *Муса Җәлил, коточкыч фаҗигаләргә юл куйган өчен, үзенең рәнҗүле мөрәҗәгатен бөтен дөньяга адреслаган.* Н.Хисамов. *Тәнкыйтьне яшь прозаикларга адреслау*

**2. адреслап** *рәв. мәгъ.* Атап, исемләп, исемен әйтеп. *Әйе, беркөнне үземә дә тимер юл станциясенә бер «Волга» илтеп куярга туры килде. Дивизия командиры генерал Серебряков аны Мәскәүгә улына адреслап җибәргән, диделәр.* Ф.Яруллин. *Менә мин [Алексей Маресьев] моны сиңа адреслап яздым.* М.Мәһдиев. *Ниһаять, Татобкомол Ферганә ЛКСМ обкомы секретарена адреслап, миңа ярдәм күрсәтүләрен сорап, рәсми үтенеч язып бирде.* Казан утлары

**А́ДРЕСЛЫ** *с.* 1) Адрес язылган, кемгәдер адресланган. *Бер көн каталажкада тоттылар да, частеннән уңай хәбәр алгач, чыгарып җибәрделәр. Тик, барыбер, адреслы кәгазьне бирмәделәр.* Г.Гыйльманов

2) Конкрет катламнарга яки конкрет кешеләргә дип билгеләнгән, төгәл билгеле максатларга юнәлтелгән. *Татарстан базар шартларына чагыштырмача югалтуларсыз килеп керде, --- шул сәбәпле, республикада аз керемле халыкны адреслы яклау мөмкин булды.* Татарстан

**А́ДРЕССЫЗ** *с.* 1) Адресы язылмаган. *Адрессыз конверт*

2) Беркемгә дә төбәлмәгән, гомумән әйтелгән. *Үзебезгә сүз килмәсен дисәк, адрессыз тәнкыйтьләүләргә күчик, ягъни исем-фамилияләрне атаудан читтә торыйк.* Ф.Давлетбаев. *Шушы акция кысаларында почта бүлекчәләрендә картлык көннәрендә ялгыз калганнар язмышына битараф булмаган кешеләрдән ай дәвамында адрессыз котлаулар, хатлар, шулай ук посылкалар да кабул итәчәкләр.* Саба таңнары

**АДСОРБЕНТ** *и. лат.* Үзенең өслеге белән башка матдәне йотарга сәләтле җисем. *Агач күмере актив адсорбентларның берсе булып санала.* Химия

**АДЪЮ́НКТ** *и. лат.* 1) Югары хәрби уку йортларында фәнни-педагогик эшкә әзерләнүче; аспирант

2) *тар.* Инкыйлабка кадәрге Россиядә һәм Көнбатыш Европада: кайбер фәнни учреждениеләрдәге кече гыйльми дәрәҗә һәм шул дәрәҗәдәге кеше

3) Көнбатыш Европада һәм иске Россиядә профессор яки академик ярдәмчесе

**АДЪЮТАНТ** *и. лат.* Югары хәрби начальник карамагында хезмәт йомышларын яки штаб эшләрен башкаручы офицер. *Дары исен иснәгән солдат дип, ахры, аны рота командиры үзенең адъютанты итеп билгеләде.* Т.Әйди. *Юан хатынның бу сүзләре Сөләйманга адъютант ягыннан китәргә юл күрсәтте.* К.Тинчурин

**АДЪЮТАНТЛЫК** *и.* Адъютант хезмәте, вазифасы. *Адъютантлыкка поручик Марковны билгеләрсез.* Т.Гыйззәт

**АДЫГ** *и.* Адыгеяда яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Аучы ничә ал белсә, адыг анча юл белер.* Мәкаль. *Бу тирәләрдә элек убыг, адыг халыклары яшәгән.* Татарстан яшьләре

**АДЫГЧА** *рәв.* Адыг телендә; адыглар кебек. *Мәктәпләрдә адыгча укыту*

**АДЫМ** *и.* 1) Аякның төрле якка: алга, артка яки янга таба бер тапкыр атлау хәрәкәте. *Ул, авылга кергәч, адымын кызулатты.* Ш.Камал. *Яшел капкага җитәрәк, адымнарын акрынайтты.* Л.Гыймадиева. *Юныс абзый адымнарын һич кенә дә кызулатмады ---.* С.Шәрипова

2) Атлап бару, йөреш, хәрәкәт итү рәвеше. *Һәм --- шул талгын адымнар белән аны узып та китте.* Л.Гыймадиева. *Тырмачы малайлар, --- тыныч адым белән җир үлчәп йөрүче картлар, язгы җилдә көрәнләнә башлаган алсу битле таза кызлар ---.* Г.Бәширов. *Рафаэль, бишмәт изүләрен ача төшеп, олы адымнар белән алдан атлады.* Р.Мөхәммәдиев

3) Аяк атлау тавышы, йөреш, хәрәкәт вакытында чыга торган тавыш. *Хәлим [сестраның] адымнарын, аның, ничектер, аз гына каушый төшеп сулавын ишетә.* А.Шамов

4) Халык метрологиясендә ике аяк табаны арасы белән билгеләнгән озынлык һәм мәйдан үлчәү берәмлеге; атлам (озынлык үлчәме буларак 0,75 см га тигез)

5) Озынлык үлчәве, атлаганда, адымнар санындагы ара; бик кыска ара, якын ара. *Кадыйр бай ике адым да атлый алмады, Җиһангир янындагы урындыкка сикереп менде.* Г.Ибраһимов. *Хәзер «Пыяный шап» Болак елгасыннан ике генә адым еракта булганга, --- Болакка җимерелеп төшеп, алдыбыздагы кышта шунда ятачак.* Г.Тукай. *Аяклар тиздән бөгелгән, шуннан бер адым читтә төймәле кепка ята…* М.Мәһдиев

6) *күч.* Берәр эшне башлап җибәрүгә юнәлтелгән хәрәкәт, кылган гамәл, чара. *Озак кына карап торгач, чыгып китәргә дә ниятләде ул. Шулай да, ни өчендер, бу адымга җөрьәт итмәде.* С.Поварисов. *Ләкин ул ике турыдагы ялгыш адымнарның авыр нәтиҗәләре быел ачыла төште.* Г.Ибраһимов. *Элеккеге дипломатның «чатак» сәяси адымы аның бөтен киләчәк карьерасын харап итә.* Р.Әмирхан

7) *күч.* Үсештә яңа баскыч, этап, чор. *Ниһаять, югары уңышка таба тагы бер зур һәм кыю адым атланды.* Г.Гобәй

8) *күч.* Урын, җир, очрак. *Алабугада миңа мөнәсәбәтнең киеренке һәм «үзенчә» икәнлеге һәр адымда сизелеп тора.* Т.Галиуллин

◊ **Адым атларга да бирмәү** Кая да булса барырга, нинди дә булса бер нәрсә хакында сүз әйтергә яки берәр эш эшләргә ирек, мөмкинлек бирмәү, юл калдырмау, аркылы төшү. **Адым да атламау** Кайсы да булса якка яки нинди дә булса кешеләргә бармас булу, барудан бизү. *Мин анда адым да атламыйм.* Н.Исәнбәт. **Адым да атлатмау** Кемне дә булса берәр җиргә җибәрмәү, тыю. **Адым да басмау** *к.* **адым да атламау**. **Адым саен** 1) Бертуктаусыз, һәр атлаган адымында. *--- үтә озын чикмән кигән юлаучы, нишләргә белмичә, шулар белән кайнаша һәм, адым саен, чикмәненең теткәләнеп беткән итәгенә абына.* Г.Шәрипов; 2) Еш-еш очрый торган. 2) Эзлекле рәвештә, һәрвакыт, гел, әледән-әле, еш. *--- колхоз җитәкчесенең иреген буу, адым саен шелтә белдерү, партиядән чыгарып ташлау белән куркытулар хакында бик тәфсилләп, җан ачысы белән язылган китап бу.* Г.Ахунов. **Адымын санап атлау** Акрын гына, салмак кына атлау, ашыкмау

**АДЫМЛА́У** *ф.* **1.** 1) Атлау, аяклар белән адымнар ясау, атлап бару. *Ләкин, читтән караганда, аның хәрәкәте, адымлавы әүвәлгедән әллә ни аерылмый иде.* Э.Касыймов

2) Нәрсәнең дә булса күләмен, зурлыгын адым белән үлчәү, билгеләү, адымга салу. *Миннән егерме адымлап арттарак Минневәлинең аты шәйләнә...* Р.Бәшәр. *Ул тубалын куйды да, сукрана-сукрана, адымлап, җир башын үлчәргә тотынды.* Г.Бәширов

**2. адымлап** *рәв. мәгъ.* 1) Салмак кына атлап, ашыкмыйча. *Агыйделнең аръягыннан атлар килә адымлап.* Җыр

2) Җәяү, җәяүләп. *Ул ботинка белән мин Германияне адымлап таптап чыктым.* А.Шамов

3) *күч.* Аз-азлап, акрынлап. *Зур дәрәҗәгә адымлап ирешү*

**АДЫМЛЫ** *с.* 1) Кеше яки хайванның йөреш рәвешен белдергән. *Артистка --- аю адымлы, комсыз Тутакайны күз алдыбызга бастырды.* М.Җәлил

2) Адымы зур булган, киң алымлы, зур алдыра торган. *Адымлы ат – алымлы ат.* Мәкаль

**АДЫМЛЫК** *с.* Ничәдер адым ераклыкта яки озынлыкта булган. *Аның [кибеткә баруның] ни мәшәкате бар? Ике адымлык җир ул.* Г.Ибраһимов

**АЕК** *с.* **1.** 1) Исерткеч эчемлек эчмәгән, исерек түгел, айнык. *Менә инде, хәзер өч ел булды, шул өч ел эчендә мин аның һичбер аек көнен күргәнем юк, дисәм дә хата булмас.* Г.Камал. *Хәмитнең аек вакытын, инде бөтенләй үк булмаса, ярым аек вакытын туры китерер дә әйтеп булачагын әйтеп шатландырыр.* Г.Шәрипова. *Моны миңа берничә көннән соң Әминә көләкөлә сөйләде. Әлбәттә, аек хәлдә бу сүз миңа бик көлке тоелды.* Гали Рәхим

2) *күч.* Акыллы, төпле, дөрес (фикер. акыл, караш һ.б.). --- *Г.Ибраһимовның*

*фаҗигасенең ач күзенә карап язылган «Адәмнәр» әсәре, Ф.Әмирханның күрәзәлеге, сәяси-икътисади хәлгә аек бәясе белән Короленко, Бунинннар дәрәҗәсендә торган кыю публицистикасы --- яктылыгында бик күп әдәби әсәрләребезне яңабаштан карап, тәфсилләп чыгарга тиешбез.* Т.Галиуллин. *Тормышны аек бәяләү рухы, тәнкыйди караш, яңа бер дулкын булып, Ә.Еники, Р.Төхфәтуллин, Н.Фәттах, М.Мәһдиев иҗатларына өстәмә көч бирә.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Уйлап эш йөртә торган, аңлы. *Гөлсем апаның асрамага бала алуын аек фикерле күршеләре мактап сөйләделәр.* Г.Гобәй. *Ә инквизиция вакытында --- аек фикер йөртүчеләрне утта яндырганнар.* М.Әхмәтҗанов

**2.** *рәв. мәгъ. күч.* Акыл белән, уйлап. *Мин эш турында уйларга, киләчәккә аек карап яшәргә вакыт җиткәнен аңладым.* А.Гыйләҗев. *Саша, син үпкәләмә, үз хәлеңә аек карарга тиешсең.* Х.Камалов

◊ **Аек акыл** Төпле, дөрес караш, ачык фикер. *Киерелеп үз караватыңда аунамыйча, читтә – кеше өендә, ярым кадерсез бер хәлдә күпме яшәргә мөмкин? Ярамый бит болай, ярамый! Аек акыл шулай ди.* М.Мәһдиев. *Ләкин Әхмәтнең тынгысыз йөрәге аек акылына каршы төште.* Мирас. *Минем кайвакыт үз-үземә сорау биреп уйланганым бар: аек акылга алдан ук аңлаешлы тоелган кирәкмәс бәхәсләргә без нилектән әле шулкадәр күп көчебезне сарыф итәбез икән?* Мәдәни җомга. **Аек акыллы** Аңлы, уйлап эш йөртә торган. *Мөфти Галимҗан Баруди Коръән аяте укый башлауга, Мирсәетнең күзләренә яшь килде, дингә мөнәсәбәттә шактый аек акыллы булуына да карамастан, бу күренеш, әлеге моң балачактан ук якын һәм сихерле торган иде аны.* Р.Мөхәммәдиев. **Аек баш белән** *к.* **аек баштан**. **Аек баштан** Ачык зиһен белән, хисләргә өстенлек бирмичә, акыл белән. *Ә бәлки, мине бераз суынсын, язганы турында аек баш беләнрәк уйлансын, дигәннәрдер....* М.Вәли-Барҗылы. **Аек караш** Эшнең торышын тикшереп, акылга салып, үлчәп, гадел, уяу карау; объектив караш. *Хәзер Тукай иҗатына һәм, гомумән, аның бөтен тормышына да яңача, аек караш белән бәя бирә алабыз.* Мирас. **Аек күз** *к.* **аек караш**. *Шуннан үзеннән-үзе башың җәһәтрәк эшли, миеңнең фикерләү куәте арткандай була, дөньяга аек күз белән карый башлыйсың.* Р.Кәрами. **Аек фикер иясе** Эшнең торышын өйрәнеп, гадел фикер йөртүче, акыл иясе

**АЕКЛЫК** *и.* 1) Аек булу хәле, исерек түгеллек. *Бу кеше миңа эчеп исергән адәмнәр арасындагы бердәнбер аек кеше шикелле күренә һәм үзенең шул аеклыгы белән минем исереклегемне оялта иде.* Ф.Әмирхан

2) Төпле фикерлелек, уйлап эш йөртүчәнлек. *Ата-анага мәрхәмәт, олыларга карата ихтирам, аеклык, сабырлык һәм башка шушындый әхлакый сыйфатлар шул ук вакытта нәфасәтлелеккә дә ия.* К.Гыйззәтов

**АЕЛ** *и.* 1) Ыңгырчакның һәм иярнең ат корсагы астыннан алып эләктерә торган каеш бавы, киндер тасмасы. *Ләкин дуламады егет, ял асларын карап, аелны бераз йомшартты.* Г.Ибраһимов. *Аелны каты тартып бәйләгәндә, ала айгыр бөтенләй шашты.* Г.Ибраһимов

2) Аяк киемендә: каешны беркетеп куя торган җайланма; прәшкә. *Туфлиемнең каешын эләктерә торган аелы бозылган.* Г.Галиев

**АЕМ** *с. бор.* Матур, күркәле. *Аем кыздан ай бизәр, яман кыздан яу бизәр.* Мәкаль

**АЕНДА** *рәв.* Бер ай вакыт эчендә, бер ай вакыт аралыгында. *Ай – аенда, ир елында танылыр.* Мәкаль

**АЕРА́ТА** *рәв.* Аеруча, бигрәк тә, бик. *Харрасның миңа карата булган олы җанлылыгын, минем исән калуыма сәбәпче булуын ишеткәч, ул миңа аерата якын булды.* Ә.Айдар. *Шулай да аерылышу миңа аерата читен булды.* М.Җәлил. *Бүген аерата кәефле көне булгандырмы, ул күп көлә, шаяра иде.* Гали Рәхим

**АЕРГЫСЫЗ** *с.* **1.** 1) Бер-берсеннән аерып алгысыз, нык береккән (мәс., *чылбыр буыны, бау, төрле җеп кисәкләре һ.б.*)

2) Аерып булмый торган, бердәй, бер үк төсле. *Рекламадагы гүзәлләрдән аергысыз бу Гүзәл.* Ш.Галиев. *Өнме, төшме – аергысыз...* Ә.Исхаков

3) *күч.* Бүленми, таркалмый торган; бербөтен тәшкил итә торган. *Хезмәт һәм бәхет – аергысыз нәрсәләр*

4) *күч.* Нык, ышанычлы, какшамас. *Аергысыз дуслык хисләрен йөрәгеңдә саклау. Аергысыз хезмәттәшлек*

**2.** *рәв. мәгъ. күч.* Аерып алмаслык итеп, нык берегеп. *Икътисади яктан аергысыз бәйләнгән булу*

**АЕРГЫСЫЗЛЫК** *и.* 1) Бер-беренә нык береккәнлек (мәс., *чылбыр буыны*)

2) *күч.* Берлек, бергәлек, бербөтенлек. *Шәхси бәхетнең иҗтимагый бәхеттән аергысызлыгы*

3) *күч.* Охшашлык, бердәйлек. *Апа белән сеңелнең бер-берсеннән аергысызлыгы*

**АЕРГЫЧ** I *и.* **1.** 1) *махс.* Каталогларда тупланган карточкалар арасына куела торган бүлгеч

2) *а. х.* Бөртекле ашлыкны сортларга аера торган машина. *Орлык аергыч сатып алу*

3) *махс.* Пычкы тешләрен аера торган корал. *Аергыч ярдәмендә пычкы тешәү*

4) *махс.* Югары вольтлы электр чыбыгында ток агымын өзә һәм ялгый торган аппарат. *Автомат аергычтан файдалану*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Аерып, бүлеп тору өчен билгеләнгән. *Аергыч карточкалардан файдалану*

2) *махс.* Өзеп-ялгап торган. *Аергыч клапан*

3) *күч.* Башкалардан аерып торган, үзгә. *Төрки кабиләләрнең, байракәләмнәрдән тыш, тагын дүрт төрле аергыч билгеләре булган: алар кош, агач, тамга һәм оран.* Р.Әхмәтьянов

**АЕРГЫЧ** II *и. лингв.* Предмет төшенчәсен атаучы сүзгә ияреп, шул предметның билгесен, үзлеген, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын белдергән җөмлә кисәге, атрибут. *Тезмә җөмләләрдә аергыч үзенең аерылмышыннан соң килергә һәм аерымланырга мөмкин.* К.Сабиров. *Билгеле әйберләрне, кешеләрне атаучы сүзләр*

*белән бирелсәләр, аергычлар, күбесенчә, иялек килешендә булалар.* Татар синтаксисы

**АЕРМА** *и.* 1) Аермалык, башкалык, үзгәлек. *Әйтик, «Тәфтиләү» бар, «Алмагачлар» бар, икесе дә пентатоникага нигезләнгән, ә аермалары нинди!* Ә.Еники. *Укучыларның буй-сынында гына түгел, хәтта үз-үзләрен тотышы белән хәрәкәт-йөрешләрендә дә аерма күзгә бәрелерлек.* З.Фәйзуллин. *Күзәнәкләр арасындагы аерма микроскоп аша караганда яхшы күренә.* Ботаника

2) Капма-каршылык: контраст. *Бигрәк тә дин һәм милләт аермасы, күп кенә очракта, гашыйкларны әнә шундый фаҗигагә китерә дә.* Ә.Еники. *Гали белән Вәли арасында зур аерма – тормышка төрлечә карауларында.* М.Гафури. *Авыл хуҗалыгы предприятиеләре сатып ала торган техника, ашлама бәясе алар үзләре сата торган бәяләрдән 1,5–2 тапкыр югары. Инде хәзер бу аерма 7–8 тапкырга җитте.* Ф.Зыятдинов

3) Туры килмәүчелек, аермалык (үлчәүдә, санда, исәптә, яшьтә һ.б.да). *Яшь аермабыз шактый булуга карамастан, без аның берлән бертуганнар шикелле якыннар идек.* К.Латыйп. *Тик бер нәрсә генә Мостафинның эчен кыра, ул да булса – яшь аермасы.* Ә.Еники. *Абый, бәләкәй чагыннан ук, юаш, күндәм булгач, яшь аермасы, ничектер, сизелми иде.* М.Кәрим. *Яшь ягыннан аермабыз зур түгел. Аерма тик шунда гына: Шәфикъ үсә муллыкта, «индук» малае – фәкыйрьлектә.* К.Миңлебаев

4) Нәрсәнең дә булса тармакланып, аерылып киткән урыны (мәс., юлда, сукмакта). *Тот та аермадан сулга каер, авылның аргы башында мин үзем каршы алырмын.* Ф.Хөсни. *Аннары, бездән ерак түгел, юл аермасында туктап, кая барырга белми торган берәр атлы юлаучы --- кая да булса берәр авылга китәргә юл сорый.* М.Гали. *Тик Сафа бабай гына: – Башта бик каулама, аерманың бу ягына чыккач, кызганма, нык сук! – дип, кат-кат әйтеп калды.* Г.Ибраһимов

5) Чәчне ике якка тараганда яки толымлап үргәндә, маңгайдан – түбәгә, түбәдән муенга кадәр калган ачык юл; чәч юлы

6) *мат.* Ике санның зуррагыннан кечерәген алу гамәле башкарганда барлыкка килә торган сан. *Уннан җидене алсаң, аерма өч кала*

7) Зурлыкларны, массаны чагыштыру нәтиҗәсе. *Квадратлар аермасы. Прогрессив аерма*

◊ **Аермасы** – **берсе кара, берсе кашка** Икесе дә бер җенес, затлары бер, аермасы тыштан әһәмиятсез нәрсәдә генә, димәктән. **Аермасы – җир белән күк арасы** Ике кеше, ике эш, ике әсәр, ике нәрсәнең бер-берсеннән сыйфатча аермасы бик зур, бик ерак

**АЕРМАЛЫ** *с.* 1) Аермасы булган, башкаларга охшамаган, үзгә, башка. *Каенанам, әнисеннән күп аермалы буларак, «туфрагы» бик уңдырышлы хатын булып чыга.* Г.Галиева. *Минә бу кәгазьдә, моңа чаклыларыннан аермалы буларак, сезнең намусыгызга энә очы зурлыгы да кара тап төшермәгән нәрсәләр язылган.* С.Поварисов. *Татарстан авылларыннан аермалы буларак, йорт артларында бәрәңге бакчалары юк, алар каядыр читтә, басуда икән.* Сөембикә

2) Тармакланып киткән, аерылып киткән (мәс., *юл, сукмак*)

3) *мат.* Алу гамәле нәтиҗәсендә барлыкка килгән (сан турында). *Аермалы саннар*

**АЕРМАЛЫК** *и.* Үзгәлек, башкалык, аерма. *Минә сиңа тагын бер аермалык, аермалыкның да ниндие, --- дигән уйлар белән, Зәйтүнә Аниясен үз янына алып сөйләштерә башлады.* Г.Галиева. *Казакъ даласы аның тел-стиль чаралларына, сурәтләгән мохитенә дә казакъ ягы сулышын өсти, башка әдипләрдән аермалык китереп кертә.* Г.Ахунов. *И.Таһиров --- аның [Солтангалиевнең] үз милләттәшләре арасындагы сыйнфый аермалыкларны гына түгел, ә сыйнфый капма-каршылыкларны да исбатлавы турында яза.* Казан утлары

2) Туры килмәү, аерымлык (үлчәүдә, санда һ.б.ш.да). *Базарга кергәч үк, товар бәяләрендә аермалыклар күзгә ташлана.* Мәдәни җомга

**АЕ́РМАЧЫК** *рәв.* 1) Бик ачык, ачыктан-ачык, төгәл. *Басу ягыннан, аермачык булып, көтүченең чыбыркы шартлатканы ишетелә.* Г.Бәширов. *Ай шундый якты, Зөһрә кызның көянтәчиләкләре аермачык күренә.* Г.Гобәй. *Ул чуар күбәләкләрнең иртәнге биюләрен һәм куаклыктагы пәрәвезләрдә, энҗе бөртекләре кебек, чык тамчыларының ялтыравын аермачык күрә.* К.Нәҗми

2) Анык, аңлаешлы итеп. *Сөйлә әйдә, аермачык кына.* Ш.Камал. *Аның аермачык булып ишетелгән беренче җөмләсе ук Мирсәетнең колагын үрә торгызды.* Р.Мөхәммәдиев

**АЕ́РМЫЙЧА** *рәв.* 1) Җибәрмичә, ычкындырмыйча. *Кыз исә, имчәкне авызыннан аермыйча гына, икенче сыер ягына ишарәләде. «Бар, им», янәсе...* Г.Гыйльманов

2) Бүленмичә, тукталмыйча. *Алтынбай гаҗәп бер кызулык белән эшкә тотынды, бер көн кичектерми, --- көнентөнен аермыйча, бил бәйләп, җиң сызганып эшләде.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Барысын да берьюлы, тикшереп тормыйча, бер уңайдан. *Аермыйча ачуланып ташлау*

**АЕРТКЫЧ** I *и. махс.* Электр чылбырына зыян килгәндә, аны тиз генә автомат рәвештә өзә торган югары вольтлы аппарат

**АЕРТКЫЧ** II *и. махс.* Балны кәрәздән суырту җайланмасы. *Күрше бабай аерткыч белән бал суырта*

**АЕРУ** *ф.* **1**. 1) Нинди дә булса бер бөтенне яки тоташ нәрсәләрне өлешләргә, кисәкләргә бүлү. *Калган бу токым катнашмаларын аеру өчен, рудага флослар --- кушалар.* Химия

2) Бер-берсеннән аралау, кубару. *Шул мәче баласы, гадәттәгечә, аягыма килеп ябышты. Шундый нык ябышты, аерып алыр хәл юк. Көч-хәл белән аердым үзен.* Г.Шәрипова

3) Янәшә торган берничә кешене яки әйберне бер-берсеннән ераграк арага күчерү. *Бераздан мине бу төркемнәрдән аердылар.* М.Мәһдиев. *Гаҗәп сагышлы, моңлы ишетелә шул чакта кичке азан! Гүя фани дөньядан аера ул сине.* Ә.Еники

4) Бербөтеннең аерым кисәген бүлеп алу, төркемнән берничәсен бүлеп

күрсәтү. *Минем суверен Татарстаннан икәнне, шигырьләремне татар телендә язуымны аерып әйткәннәр икән*. Р.Миңнуллин. *Көтүдән ун елкыны аеру*

5) Як-якка этәреп ара ясау, ачыклык барлыкка китерү, юл яру. *Йөгереп барып терәлүгә, Зөлфия, ике дә уйлап тормыйча, читән ботакларын аерып башын тыкты.* М.Мәһдиев. *Кешеләр төркемен аерып, алгарак чыгу*

6) Читләштерү, ераклаштыру, якын мөнәсәбәтләрне бетерү, аралаштырмый башлау. *Динне дәүләттән аеру, теләгән һәм, иң мөһиме, аңлаган, кабул иткән кешеләргә дәһрилек, ягъни атеизм юлын сайлау хокукы бирелү – ул да чорның --- котылгысыз таләбе иде.* М.Госманов. *[Мөхәммәт] Урманчы кызы Гөлчәчәкне, урманыннан аерып, шәһәргә алып китү турында хыялланам.* З.Хөснияр. *Бигрәк тә әтием моны кичермәячәк һәм хөкеме каты булачак аның!.. Иң әүвәл ул мине Салихтан аерачак.* Ә.Еники. *Юк, ул дөнья Әмирханны – үзенең кымызлы Дәүләкәненнән, мине фәкыйрь, тыйнак Казан артыннан, бәрәңге бакчаларыннан, чикерткәләр моңыннан аерган.* М.Мәһдиев

7) Нәрсәне дә булса сыйфаты, кыйммәте буенча төрләргә, сортларга бүлү. *Мин аларны [депутатка бирелгән йомышларны], сортларга аерып: монысы – мөһим, монысы чүп кенә, дип карамыйм.* Т.Миңнуллин. *Тамга салучы агачларның сортларын аера белергә, аларны бутамаска тиеш.* Ботаника. *Йомыркаларны эрелегенә карап аеру. Ашлыкны сортларга аеру*

8) Нәрсәнең дә булса асылын яки кирәкле бер эчке сыйфатын таный белү. *Тик байлыкны аера белергә кирәк. Менә синең йомшак, ягымлы тавышың, шушы сизгер бармакларың – минем өчен зур байлык.* Ә.Еники. *Матур ак кәүсәле каенны кыш көне дә башка агачлардан җиңел аерып була.* Ботаника. *Әни… Бишектән алып бүгенге көнемә кадәр җил-яңгырдан саклап, яхшыны – яманнан, савапны гонаһтан аера белергә өйрәтүче якын кешем.* Сөембикә

9) Нәрсәнең дә булса бөтенлеген бозу, бер кисәген ертып алу, умыру, өзү (кәгазь, тукыма һ.б.ш. әйберләр турында). *Күлмәкнең итәген урталай аеру*

10) Орлык, җимеш һ.б.ш. кебек бөртекле ризыкларны чүбеннән арындыру, чистарту. *Маһи әби, каравылчыны каргый-каргый, күлмәк итәгенә җиләген салып, чүпләрен аера.* М.Гали. *Ашлыкны кибәгеннән аеру*

11) Бал кортларының күбәюе, ишәюе сәбәпле, аларны аерым оя итеп бүлеп чыгару. *Гаяз умартачыга кортлар аерырга булышты.* И.Гази. *Кортлар, үз өйләренә генә сыеша алмыйча, аерырга тотындылар.* Ф.Яруллин

12) Химик матдәләрне аерым состав өлешләренә таркату. *Нефтьне термик ысул белән аеру.* Химия

13) Аерым билгеләр буенча кешенең кем булуын яки предметның кемнеке яисә нинди төрдән булуын тану, белеп алу. *Карчык бусаганы атлады да кулларын алга сузып туктады: – Килен… Берәрегез өйдәме? Күзләрем аермый!* Г.Ибраһимов. *Әмма, исемнәрен ятласам да, үзләрен аеруы авыр. Үзләрен бутыйм, исемнәрен бутыйм*. Ф.Яруллин

14) Нәрсәне дә булса гаделлек белән үзара бүлешү, уртаклашу. *Кот килмәгән көндә бар тотканны өйгә алып кайтабыз. Монда тамак аермыйбыз.* М.Кәрим

15) Ир турында: хатын белән никахны бозу. *Шәйхразый Мирвәлине чакыртты: «Синга ике генә юл – я үйнашчы өтеңеңне бүген үк талаклап аерасың, я аның белән өйдән чыгып китәсең».* А.Гыйләҗев. *Сез ни теләсәгез шул булыр, китап кушса, үз хәләл хатынымны, аерып, сезгә бирергә риза, калганын үзең кара инде, хәзрәт.* К.Тинчурин

16) Чәч юлы ясау, толымнарга бүлү. *Чәчен ике толымга аерып үргән*

17) Нәрсәне дә булса тоташтырылган, элэктерелгән урыныннан ычкындырып җибәрү. *Вагоннарны паровоздан аеру*

18) Баланы, шулай ук яшь бозауны, колынны, бәрәннәрне һ.б.ны имүдән туктату. *Яшь баланы имчәктән аеру*

19) Нинди дә булса хәлдән йолып калу, яклау

20) Сугышып яки бәхәсләшеп торучыларның арасына кереп, сугышудан яки бәхәсләшүдән туктату, аралау. *Ул арада зурлар катнашып, безне аердылар, кем кыйнады моны, дип тикшерә башладылар.* Г.Ибраһимов

21) Җәю, киң итеп як-якка җибәрү (кул, канат, аяк турында). *Аякларны аерып басу*

22) Тиз аңлап, төшенеп алу. *Караңгыда кем килгәнен тиз генә аермау*

23) Кемне дә булса төрле шөгыленнән туктатып өзеп тору, бүлдерү, игътибарын башкага тарту. *Сөләйман абый, мин сезне шулкадәр яхшы сөйләшеп утырган җирегездән аердым бугай.* Ф.Әмирхан

24) Тигез күрмәү, кыерсыту, читкә кагу. *Кеше аеру*

**2. аерып** *рәв. мәгъ.* 1) Нинди дә булса аерым бер максат белән атап, хаслап, басым ясап. *Алдынгыларны аерып бүләкләү*

2) Эштән азат итеп, бушатып. *Укучыларны, дәрестән аерып, шәһәргә җибәрергә рөхсәтем юк.* З.Фәйзуллин

3) Тиешен бүлеп алып. *Рәүфәне полный йорт-җир белән аерып чыгарырга ясаганнар бит.* А.Шамов

4) Кушмыйча, ике сүз итеп (язу)

5) *күч.* Аңлаешлы, ачык итеп, бәйнәбәйнә. *Кайтыр булсаң, аерып яз, каршы алырбыз*

**3. аерып алганда** *кер. сүз функ.* Аеруча, бигрәк тә, атап әйткәндә

**Аера башлау** Аерырга тотыну. *Җәйгә чыгуга, кортлар аера башлар. Яңа умартага менә шул күчләрне ябарбыз.* Ф.Яруллин

**Аера төшү** 1) Бераз аеру

2) Икегә аеру; бераз бер-берсеннән ерагайтып, аерылган хәлгә китерү. *Янәшә үскән куакларны аера төшү*

**Аерып ату** 1) Искәрмәстән, кинәт аеру

2) Кискен хәрәкәт ясап, нәрсәне дә булса тартып, кисеп өзү

**Аерып бару** Даими, системалы рәвештә аеру эшен башкару

**Аерып бетерү** Тулысынча аеру. *Колак ишетә алмаган ультрадулкыннар,*

*күз аерып бетермәгән төсләр, төсмерләр бар*. Ш.Галиев. *Ашлыкны чүптән аерып бетерү*

**Аерып җибәрү** 1) Аз гына, бераз гына аеру

2) Бөтенләйгә аеру, мөнәсәбәтләрне тулысынча өзү. *Карале, минем таныш бер иргә сөйләгәннәр иде: авырып киткән хатынын ике баласы белән аерып җибәргән дә, үзе яшь, тазаны алып кайткан.* М.Мәһдиев

**Аерып йөрү** Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында аеру. *Гап-гади эчкече бит бу, әллә нинди әкиятләр сөйләп, кешене эштән аерып йөри*. Р.Сәгъди

**Аерып кую** Алдан ук аерылган хәлгә китерү. --- *ул чырай – парафин чырай, беренче секундта ук үзеннән сине, залны, аудиторияне аерып куя*. М.Мәһдиев. --- *урып җыюга әзерләү чаралары мондый төп операцияләрне үз эченә ала: машиналарның өзлексез эшләвен читенләштерә алырдай комачаулыкларны ачыклау һәм аерып кую; басуларны билгеләү һәм аерым кишәрлекләргә бүлеп чыгу* ---. Урып җыю машиналары. *Ата-бабаларыбыз беркайчан да үзләрен табигатьтән аерып куймаганнар.* Казан утлары

**Аерып ташлау** *к.* **аерып ату**

**Аерып тору** 1) Даими, һәрвакыт аеру. *Кортлар үрчеп, аерып торалар.* Ф.Яруллин

2) Әле, хәзерге вакытта аерган булу. *Биек яр итәге белән кояш нурлары качышлы уйнагандай елык-елык балкып аккан елганы комлы үзәнлек аерып тора*. Ф.Сафин

**Аерып чыгару** 1) Бер-бер артлы аеру, һәрберсен берәм-берәм аеру. --- *фәлсәфи-эстетик концепцияләрне, дөньяның сәнгатьчә чагылышын, образлар системасындагы үзенчәлекләрне аерып чыгару омтылышы ясала*. А.Шәмсутова

2) *мат.* Нинди дә булса санның тамырын табу

**Аерып чыгу** Бөтенесен дә бер-бер артлы аеру, һәрберсен берәм-берәм аеру

**АЕРУ́ЧА** *рәв.* **1.** 1) Бик, бигрәк тә; күбесенчә, барыннан да бигрәк. *Менә шул дүрт мәсьәлә турында Туфан аеруча ялкын, дәрт белән яза*. Г.Нигъмәти. *Аеруча салкын төннәрдә агачлар шарт-шорт итә, әйтерсең мылтык аталар.* Г.Әпсәләмов. *Болгар һөнәрчеләренең осталыгы аеруча соңгы елларда булган археологик ачышларда күренә*. Г.Дәүләтшин

2) Махсус; кемгә яки нәрсәгә хас булганча. *Газинур Павел Ивановичны аеруча хөрмәт итә иде.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин гомумән түрәлектән түгел, ә түрәлекнең аерым бер, аеруча ләззәтле бер мизгелендә яшәреп, сафланып китәләр алар*. М.Мәһдиев

3) Башкалардан аерып, махсус, атап. *Аныңча, Нәфисәнең яулыгы өстеннән башын бәйләгән киң зәңгәр тасмасы йөзенә аеруча бер нәзакәт өсти кебек.* Г.Бәширов. *Илдар, әллә инде сөйләгәнен онытып, әллә аеруча яратып, бу җирен кат-кат сөйли*. Г.Гобәй. *Нәүбәт өченче папкага җитте. Закуан анысын аеруча кадерләп, аеруча саклык белән күкрәгенә кысты*. Ф.Яруллин

4) Нык, каты, көчле итеп. *Ул заманда ике төрле чир – чахотка белән тиф – яшьләрне аеруча кырды*. Ә.Еники

**2.** *кер. сүз функ.* «Бигрәк тә», «барыннан да элек» кебек сүзләрне алыштырып, бүлеп алынган өлешкә атап басым ясарга кирәк булганда әйтелә. *Шуның өстенә тагы Зарифулла үз хуҗалары каршында, аеруча яшь хуҗа Хисами каршында, колларча бирелгәнлеге белән дә аерыла иде*. М.Гали. *Табигать яз көне, аеруча май аенда, матур булучан*

**3.** *с. мәгъ.* Аерата, үзенә бер, аерылып торган. *Аеруча сизгерлек күрсәтү. Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен бүләкләнү*

**АЕРЧА** *и.* Аерылып торган, аерым-аерым торган өлеш, ябь. *Таҗ аерчасын югары төзелешле үсемлекләрдә очратырга мөмкин.* Биология

**АЕРЧАЛЫ** *с.* Аерчасы булган, ябьле, аерылып торган. *Учак урыннарында аерчалы казык таяклар кагылган.* Р.Фәйзуллин. *Биш аерчалы өрәңге яфрагы*

**АЕРЧАЛЫ́ ТӘПИЧӘ** *и. бот.* Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, сары чәчәк ата торган күпьеллык дару үсемлеге; *русчасы*: **лапчатка вильчатая**

**АЕРЫ** *с.* **1.** 1) Ике якка аерылып торган, аерым-аерым торган. *Зур гәүдәле, аеры сакаллы солдатның кулына сарылган урта яшьләрдәге хатын таkмаклап еларга тотынды.* Н.Исәнбәт. *Аеры таҗ яфракчыклы чәчәк*

2) Аерып торган, чатлы, ябе булган. *Учакта – аеры башлы ике казык башындагы аркылы агачка асып куелган зур казанның астында – коры чыбык-чабык яна.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Аерым-аерым; берәм-берәм; үзе генә. *Ана сөтен аеры имә Бала, игез булмаса.* Дәрдемәнд. *Бу авыл – зур юлдан читтә, тискәре якта. Шулай да ул олы дөньядан аеры яшәмәде.* Мирас

◊ **Аеры сүнгән** Даны-шөһрәте беткән, дәвере үткән

**АЕРЫ-АЕРЫ** *рәв. к.* **аерым-аерым**

**АЕРЫЛГЫСЫЗ** *с.* 1) Аерылмас, какшамас, нык. *Нинди генә бизмәннәр белән үлчәсәк тә, халкыбыз мәнфәгатьләрен яклап, беренче буларак оран салган бу басманы рухи мирасыбызның асыл һәм аерылгысыз бер өлеше дип танырга тиеш булабыз*. Р.Әмирхан. *Илечко көлемсерәп башын чайкый: «Әгәр үз халкыңның тарихи юлын ачарга теләсәң, иң беренче нәүбәттә, гарәп телен өйрәнергә, халкыңның аерылгысыз өлеше булган Коръәнне гизеп чыгарга кирәк», – дип кабатлый.* А.Гыйләҗев

2) Аерылмый, бүленми торган. *Изге таулар, биеклекләр, биек ялгыз агачлар да «җир-су» культының аерылгысыз бер өлеше булган.* Г.Дәүләтшин. *20 нче – 30 нчы елларда татар әдәбият белеме фәне дөнья әдәби фикер хәрәкәтенә актив кушылып, аның аерылгысыз бер өлеше буларак үсте.* Э.Галиева

**АЕРЫЛГЫСЫЗЛЫК** *и.* 1) Өзелмәү, аерылмау, бүленмәү. *Чылбырның буыннары аерылсызлыгы*

2) Бер-берсеннән аерылмас булу; бер-берсенә бик якын булу. *Дусларның аерылгызлыгы*

**АЕРЫЛМАС** *с.* 1) Какшамас, нык, җимерелмәс. *Олпат язучыбыз Шәйхи ага Маннурның үзләренә атап язган*

*васыятьнамәсен җиренә җиткереп үтәү буенча да әлеге аерылмас дуслар-сердәшләр бик күпләргә якты үрнәк күрсәтте.* Ш.Мостафин

2) Аерылгысыз, бик якын. *Аларны тагын бер нәрсә кызыктырды – матрос егетнең аерылмас юлдашы, сөяктәй саргылт шома трубка.* А.Хәсәнов

**АЕРЫЛМАСЛЫК** *с. к.* **аерылмас.** *Аерылмаслык дуслар булу өстенә, ул миңа туган тиешле кеше дә.* М.Мәһдиев

**АЕРЫЛМЫШ** *и. лингв.* Аергыч белән ачыкланып килә торган сүз; аергычны ияртеп килгән сүз. *Аергыч белән аерылмыш арасында ияртүле бәйләнеш була. Татар телендә аергыч һәрвакыт аерылмышыннан алда килә.* Татар теле

**АЕРЫЛУ** *ф.* 1) Бөтен яки тоташ нәрсә берничә кисәккә таркалу, бүленү. *Бүлмә, җыйнак кына җыелып, ширма белән икегә аерылган.* Һ.Такташ. *Иң элек кем бирелер, кем сыгылып төшәр, дип көткәндә, авыр сыкрау авазы чыгарып, имән тумраны үзе икегә аерылды.* Р.Мөхәммәдиев // Җимерелү, ишелү. *Сакмар суы аша чыга торган тимер юл күпере җимерелгән. Ул икегә аерылган, --- аны сугыш вакытында шартлатканнар икән.* Җ.Фәйзи

2) Береккән җиреннән кубу, каерылу, ычкынып китү. *Ишек тупсасыннан аерылды. Көчле давылдан соң алмагач ботагы аерылды*

3) Китеп бару. *Әмма, соңгы дистә адымын ясаганчы, якындагы йортның стенасыннан нәзек кенә бер фигура аерылды.* Г.Шәрипова. *Башка ирләр дә кузгалдылар, бары кимперләр генә, каберләрдән аерыла алмыйча, битләрен тырнап, озак газапландылар.* И.Салахов. *Рәсемнән аерыла алмыйча озак карап торуыма Әсма түти дә игътибар итте.* С.Сабиров

4) Бер-береннән ераклашу, киң булып ачылу, җәелү. *Шәрәфи әгъзалык билетын күрсәткәч, ишек ике якка аерылды.* Г.Ибраһимов

5) Башкаларга охшамау; сыйфат үзгәлеге булу; үзлекләре гадәти булмау. *Сез беләсезме сентябрь кояшының язгы, җәйге кояшлардан ни белән аерылганын?* М.Мәһдиев. *Агач кимергәндә, алар (кәҗәләр) барысы да бер дәрәҗәдә, әмма мамык биргәндә аерылалар.* М.Мәһдиев. *Дим буе башкортларының теле хәзерге башкорт әдәби теленнән шактый ук аерыла.* Ә.Еники. *Бу сүзләр әдәби телдәге эквивалентларыннан фонетик яңгырашлары белән беркадәр аерылалар.* Татар грамматикасы

6) Ир белән хатын арасында гаилә мөнәсәбәтләре өзелү. *Ал бидерә, гөл бидерә суларны болгандыра; Бергә чакта берни түгел, аерылгач уйландыра.* Җыр. *Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре, Гомерләрне кыскарта ул аерылу сәгатьләре.* Җыр. *Аның йорты бөтән урамда, --- ире белән аерылган ялгызак хатын.* Казан утлары

7) Аерым яши башлау, башка чыгу, үз көнеңне үзең күрү. --- *Закир кисеп әйтте: – Мин башкасын белмим… Аерылып чыктың, өлешең бетте.* Г.Ибраһимов. *Төп нигездән аерылу*

8) Торган, яшәгән, эшләгән урыннан китү, ераклашу, читләшү. *Гомерем булса, ата-баба җиреннән аерылмам, әҗәлем җитсә – туфрагым читтә булмас.* К.Нәҗми. *Аңа да туган-үскән җирләреннән аерылып, байтак чит җирләрдә кагаеп йөрергә туры килде.* С.Җәләл. *Әминә ханымның сәхнә тормышы 1926 елга кадәр генә бара, аннан ул сәхнәдән аерыла.* Татарстан

9) Ишәю сәбәпле, аерым оя булып чыгу. *Ел саен, җиткән кортлар, аерылып, Һәр якка таратыла билгеле айда.* Ш.Бабич. *Апаның иң нык эчен пошырган нәрсә шул: умарталар һаман аера, ә аерылган умартадан бал көтмә инде.* Ф.Яруллин

10) Нәрсәнедер ташламау, үз янында йөртү. *Егет, диплом алганчы, киндер капчыктан бер дә аерылмады. Аның бик тә, бик тә европача буласы килә иде…* М.Мәһдиев

11) Җирдән күтәрелү, очып китү. *Самолёт җирдән аерылды*

12) Орлык, җимеш һ.б.ш. бөртекле ризыклар башагыннан, кабыгыннан, чүп-чардан арыну, чистару. *Бу уралмалар ярдәмендә ротор әйләнгәндә, сугылучы салам массасында тартылу көчләре барлыкка килә. Шуның аркасында сугылган бөртекләр күбрәк аерыла, һәм югалтулар күпкә кими.* Урып җыю машиналары. *Өлгергәч, тары чүбе яхшы аерыла*

13) Бүленеп, тармакланып китү. *«Кыр капкасы» дип йөртелгән җирдә – авыл башында – юл икегә аерыла, уңдагысы, боргаланып-боргаланып, Акташ тауга таба менә, сулга каерылсаң, Күҗемгә – ар авылларына барып чыгасың.* Р.Мулланурова. *Елга юлы икегә аерылган*

14) Организмда матдәләр алмашы барлыкка килү, бүлеп чыгару. *Үсемлекнең сулавы вакытында тереклек эшчәнлеге өчен кирәкле энергия аерыла*

15) Тере организмда матдәләр алмашу процессы тукталу, үлемгә дучар булу. *Кешенең тәненнән җаны аерылуны «үлү» диләр.* Татар мөселман календаре

16) Методикасы, фикер юнәлешләре төрле булу, эчтәлектә, карашларда бердәйлек булмау, үзгә булу. --- *әлифба әлегә чаклы басылып чыккан, бөтен сүзләрне күзәтү методы белән язылган әлифбалардан байтак кына яклары белән аерыла.* Ф.Вәлиева. *Яңа иҗтимагый шартларда исә җыр йола һәм аңа бәйле уен хәрәкәтләреннән аерыла, аның эстетик роле киңәя, эчтәлеге дә мөстәкыйльләшә, гомумиләшә бара.* К.Миңнуллин

17) *куч.* Эшләгән эшеннән, шөгыленнән туктап, игътибарын читкә юнәлтү. *Укый-укый башы катып киткән араларда, ул, китаптан аерылып, Барыйга карап торды.* М.Хәбибуллин. *Төп эштән аерылмыйча, аспирантурада уку*

**Аерыла төшү** Бераз аерылу. *Чананың үрәчәсе аерыла төшкән*

**Аерылып калу** Нindидер сәбәп белән яки күпмедер вакыттан, моменттан соң аерылу. *Дәү тәкә бүген дә кәҗә көтүеннән аерылып калган.* Р.Мөхәммәдиев. *Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды.* Ә.Еники

**Аерылып китү** 1) Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт аерылу. *Аерылып*

*китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин, и Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.* Г.Тукай. *Ярдан аерылып китәргә дә өлгермәдек, Салих тарантасындагы өч егет «Сәфәр» көен уйнап җибәрмәсеннәрме?!* Ә.Еники

2) Билгеле бер вакыттан яки нинди дә булса сәбәптән соң аерылу. *Ыруглар, кабиләләр һәм кабилә союзларының интеграция һәм дифференциация процесслары нәтиҗәсендә, алтай телләре башта иң төп өч тармакка аерылып китәләр: төрки-монгол, тунгус-маньчжур һәм япон-корея.* Ф.Сафиуллина

**Аерылып тору** 1) Әледән-әле, еш аерылу

2) Башкалардан үзгәлеге ачык булып күренү. *Ни хикмәттер, бу да кечкенә буйлы иде, әмма башкалардан бөтен килеш-килбәте белән бик нык аерылып тора.* Ә.Еники. *Бу өй авылдагы башка өйләрдән үзенең зурлыгы белән аерылып тора иде.* Ә.Айдар. *Үз классташлары арасында ул, чыпчыклар янындагы күгәрчендәй, әллә каян аерылып тора.* Ф.Яруллин

**АЕРЫЛЫ** *с.* Аерысы булган, ябьләнеп торган. *Ике аерылы каен агачы. Өч аерылы сәнәк*

**АЕРЫЛЫШ** *и.* 1) Юл чаты, юлның аерылып киткән урыны

2) Бер-береңнән аерылу, аерым яшәү хәле. *Элек аны бер генә ай күрмичә яшәргә дә сабыры җитмәс кебек тоелган йөрәк ничә еллык аерылыш газабын, кайгы һәм борчу тулы ялгызлык елларын кичерде.* К.Нәҗми

**АЕРЫЛЫШУ** *ф.* **1.** 1) Бер-береңнән аерылу, бергә булудан туктау, икесе ике якка китү. *Без, бер-беребездән ераклаштык – сукмакларыбыз аерылышты.* Ә.Еники. *Аһ, яңадан кайтарасы иде Аерылышу дигән мизгелне.* Ш.Маннапов. --- *Гафур Хөсәенгә кул болгады, тегесе башын иде, шуның белән аерылыштылар да.* Г.Шәрипова. *1931 елда без аерылыштык. Тәннәребез түгел, җаннарыбыз аерылып, атаем Аксалны [айгырны] колхоз көтүенә илтеп кушты.* М.Кәрим. *Бу җырдан сугыш, аерылышу, кавыша алмау фаҗигасе ургылып чыга иде.* М.Мәһдиев

2) Кем беләндер аралашудан, очрашудан туктау; ара бозылу, дуслык бетү. *Аерылышу шушы була икән инде, Тик соңыннан гына аңладым.* Җыр

3) Рәсми рәвештә никахны туктату, гаилә мөнәсәбәтләре өзелү. *Сине бик каты яратканын белмәсәм, хәзер үк аерылышыгыз, дип әйтер идем дә, гөнаһтан куркам.* М.Мәһдиев. *Алар бергә укыганнар. Башта әти өйләнгән, аннары ул [әни] кияүгә чыккан. Ләкин озак тора алмаган, аерылышканнар.* М.Хәбибуллин. *Кытайда, Һиндстанда да «аерылышу» дигән нәрсә бик аз яки бөтенләй юк.* М.Әхмәтҗанов

4) Каршы килгәндә, бер-береңә юл биреп тайпылу. *Юл биреп аерылышу*

5) *күч.* Нәрсәдән булса да ераклашу, китеп бару. *Менә туган җирем белән аерылышу сәгатьләре дә якынлаша.* А.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ. к.* **аерылыш** (*2 мәгъ.*). *Чит-ят җирләрдә, бөтенләй диярлек таныш булмаган кешеләр янында, аерылышулар икеләтә моңсу һәм йөрәк өзгеч тоела.* Казан утлары

**Аерылышып алу** Кыска гына вакытка аерылышу

**Аерылышып бетү** Тәмам, бөтенләй аерылышу. *Безнең хәзер төп максатыбыз берләшү булырга тиеш. Болай да таралып, сибелеп беткән халкыбызны бөтенләй таралышып, аерылышып бетүдән саклау.* Р.Миңнуллин

**Аерылышып йөрү** Әле, хәзерге вакытта аерылышу белән мәшгуль булу. *Шушы яшьтә судларда аерылышып йөрүләре оят ич инде.* К.Кәримов

**Аерылышып китү** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт аерылышу. *Авылдашлар Барый, Әкмал окопларында калды; Аерылышып киткән чакта кайнар яшьләрем тамды.* Бәет

**Аерылышып кую** Алдан ук аерылышу; кинәт аерылышу. *Юк, юк, нишләп мыскыл итим. Яшь вакытта була торган ул. Аерылышып та куясың.* Ш.Камал

**Аерылышып тору** 1) Бертуктаусыз, еш аерылышу

2) Әлегә, вакытлыча аерылышкан булу. *Бер-беребезнең кадерен белү, ныграк ярату өчен, аерылышып тору, бәлки, кирәктер дә.* З.Хәким

3) Аерылышкан хәлдә яшәү. *Аерылышып торган дүрт ай ярым вакыт эчендә, тәмуг утыннан кайткан Мифтахны танырлык та түгел иде.* Ә.Салах. *Ни әйтсәң дә бер атна аерылышып тордык ич!* Ә.Еники

**АЕРЫМ** *с.* **1.** Башкалардан аерылып торган, үзенә бер. *Тузганакның сары башчасы аерым чәчәк түгел, ә тулы бер чәчәкләр төркеме ул.* Л.Ихсанова. *Үсемлекчелекнең төп продукциясе, һичшиксез, аерым культуралар (бодай, арпа, солы, карабодай) буенча исәпкә алына.* Социалистик Татарстан. *Акрынлап, аерым төр үсемлекләрнең үзлекләре һәм авыруларны дәвалау ысуллары турындагы белемнәр буыннан-буынга күчә барган.* Е.Солодухин

2) Махсус билгеләнгән, үзенә башка. *Ничектер, бала тәрбияләргә аерым вакыт юк иде.* М.Мәһдиев. *Аерым цензордан матбугат эшләренең Казан инспекторы дәрәҗәсенә күтәрелгән Пинегин Баш идарәгә яңадан мөрәҗәгать итә.* Р.Әмирхан. *Шагыйрьнең [Г.Кандалый] «Мәгъшукнамә» дип исемләнгән әсәре, авторы күрсәтелмәгән хәлдә, аерым китап рәвешендә ике мәртәбә басылып чыга.* М.Усманов

3) Башкалар белән бергә түгел. *Башта аерым җырлар җырланды, шуннан соң сәхнәгә ефәк күлмәктән зифа буйлы бер кыз килеп чыкты.* М.Фәйзи

4) Үзенә бер төрле, үзенә генә хас, үзенчәлекле, аңа гына характерлы. *Анда ирләр – озын буйлы, эре тешле, кап-кара кашлары килеп кушылган үзенә бер аерым кешеләр.* М.Мәһдиев. *Бу кошларның һәрберсе кеше күңеленә үзенчә тәэсир иткән, кеше күңеленең аерым халәтенә аерым кош булган.* М.Мәһдиев. *Һәркемнең үзенә аерым ләззәт тапкан шөгыле буладыр*

5) Берүзенә генә, уртак булмаган. *Кызлары шикелле каршы алырлар сине. Үзеңә генә аерым урын әзерләрләр ---.* Ә.Еники. *Билгеле, безгә – балаларга – аерым спектакль куеп маташмыйлар, керә алган кеше кич белән зурларга ияреп керә.* Ф.Яруллин

6) Кайбер, арадан берсе. *Аерым кешенең хокукы, дәрәҗәсе хакында фикер тугач, аның шәхси бәхете мәсьәләсе дә шул ук эзләрдән бара.* М.Усманов. *Аерым кешеләр генә түгел, бөтен иҗтимагый тормыш бер идеалсыз бара алмый.* Казан утлары

7) Хосусый, коллектив эшчәнлектән читтә булган. *Аерым хуҗалыктан китереп берләштергән бөтен атлар дип әйтерлек язгы ташу вакытында ачлыктан кырылып беттеләр.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Һәркайсы үзе генә, аерым-аерым. *Иртән апаң белән аерым утырып ашадык. Сөйләшү юк. Калган аш, каткан ипи, салкын чәй.* М.Мәһдиев

2) Нинди дә булса бер максат белән, махсус. *Һәр эшләгән эшенә аерым түләмәсәң, табарсың аның белән уртак тел.* Ф.Яруллин. *Ул минем белән аерым саубуллашты*

**3. аерым алганда** *кер. сүз функ.* Бигрәк тә, аеруча, хосусан, аерып алып әйткәндә, атап әйткәндә

◊ **Аерым оя кору** Үз йортын, үз хуҗалыгын булдыру

**АЕРЫ́М-АЕРЫМ** *рәв.* 1) Һәрберсен аерып, берәмләп, берәм-берәм. *Маратның һәркемгә аерым-аерым игътибар бирүе төркемне дә сагаерга мәҗбүр итте булса кирәк.* З.Фәйзуллин. *Мәсьәләләрне аерым-аерым тавышка кую*

2) Берәрләп, ялгыз. *Әмма китап бер дә мактамый шул Аерым-аерым дөнья куганны.* Н.Әхмәдиев. *Кышлаганда, ата һәм ана кошлар аерым-аерым яши.* Кызыклы физиология. *Аерым-аерым үткән җәяүлеләр күзгә ташланды.* Казан утлары

3) Берәр-берәр итеп, берәмләп. *Малайлар капчыкларның һәрберсен аерым-аерым күтәреп ташыдылар.* И.Гази

4) Махсус, аерып алып. *Сумманы нинди дә булса санга бүлү өчен, һәр кушылучыны аерым-аерым бу санга бүлү һәм чыккан өлешләрне кушу җитә.* Арифметика. *Бригадир һәр кучне аерым-аерым үлчәп чыкты*

**АЕРЫМЛАНУ** *ф.* **1.** Берәр үзенчәлекле сыйфат белән башкалардан аерылып тору, башкаларда булмаган нинди дә булса сыйфатка ия булу. *Ул чагында Татарстан белән Русия тарихы объектив рәвештә каршы куела түгелме соң? – Бу билгеле бер шартларда изоляциягә һәм аерымлануга этәрмәсме?* Мәдәни җомга

**2. аерымланган** *с. мәгъ. грам.* Үзенә караган җөмлә кисәгеннән ераклашып, логик басым һәм интонация белән әйтелгән. *Җөмләнең аерымланган кисәге. Аерымланган хәл*

**Аерымлана башлау** Аерымлануы сизелү, күренерлек булу. *Константин I нең шушы шәһәрне салырга карешүе белән Византия Рим империясеннән аерымлана башлый.* К.Гыйззәтов

**Аерымлана бару** Торган саен ныграк аерымлану. --- *бүленеп чыгудан соң бик күп вакытлар үтү сәбәпле, әлеге төркемнәрнең телләре дә бер-берсеннән аерымлана барган.* Н.Фәттах

**Аерымлана төшү** Тагы да күбрәк аерымлану; бераз аерымлану. --- *«үсү – үсеш», «яшәү – яшәеш» кебек сүзләрнең даими кулланылышы нәтиҗәсендә, аларның мәгънәләре тагын да конкретлаша, аерымлана төшә.* Ф.Сафиуллина

**Аерымланып бетү** Бөтенләй (тулысынча) яки барысы да аерымлану

**Аерымланып җитү** Тәмам, ахырга кадәр аерымланган хәлгә килү. *Аларның [әкият белән табышмакның] уртак исеме «йомак» фольклорның бик борынгы чордагы синкретик хәлен, ягъни жанрларның аерымланып җитмәгән чорын чагылдыра.* Л.Җамалетдин

**Аерымланып китү** Кинәт, билгеле бер моменттан соң, нинди дә булса сәбәп белән аерымлану. *Төрки телләрендә «з ~ р» авазларының бер уртак аваздан аерымланып китүе шундый борынгы заманнарга карый ки, нилектән алай булганлыгын ачыклап бетерү дә кыен.* Ф.Сафиуллина

**Аерымланып тору** 1) Әледән-әле, еш аерымлану

2) Билгеле бер үзенчәлек белән аерымлану яки аерымланганы ачык булып күренү. *Ләкин аның икенче яртысы мануфактура җитештерүнең үсешендә аерымланып тора.* С.Алишев. *Шулай да иҗади эзләнүләрендә берничә юнәлеш аерымланып тора.* Ә.Закирҗанов

**Аерымланып чыгу** Билгеле бер үзенчәлекләре белән аерымланып аерылу. *Татар телендә, мәсәлән, гомумтөрки (хәтта гомумалтай) чорында ук башка телләрдән алынган сүзләр дә, борынгы төрки телләр чорында алынганнар да, татар теле үзе аерымланып чыккач, башка телләрдән кергән сүзләр дә бар.* Р.Әхмәтьянов

**АЕРЫМЛАШУ** *ф. сөйл.* Аерылып китү, аерылып чыгу. *Аларның телендә исә аерымлашу, мохтарият.* Ф.Сафин

**Аерымлаша бару** Торган саен ныграк аерымлашу

**Аерымлаша башлау** Аерымлашырга тотыну

**Аерымлаша төшү** Тагы да бераз аерымлашу

**Аерымлашып бетү** Тулысынча, тәмам аерымлашу

**АЕРЫМЛЫ** *с.* Аерылып киткән, тармакланып киткән. *Ай киттеләр, ел киттеләр, карыш буе җир киттеләр, барып җиттеләр өч аерымлы бер юлга.* Әкият

**АЕРЫМЛЫК** *и.* 1) Аерма, аермалык. *Аерымлыкларның бер төрлесе күрше рус сөйләшләренең о-лаштыра торган булуы белән аңлатыла.* Лексикология һәм лексикография мәсьәләләре

2) Башкалык, үзгәлек. *Галим ике төркем телләр арасындагы кайбер лексик аерымлыкларны күрсәтә.* Х.Мәхмүтов. *Рәссамнарның тормыш, иҗатларында аерымлыклар да юк түгел.* Шәһри Казан

3) Әйбернең яки затның башкаларга охшамаган булуы, үзенә хас сыйфаты, асылы. *Читтән карагандa, татарларның һәм башка мөселманнарның үз-үзен тотышындагы аерымлыклар һәрвакыт күренеп тормый, ә инде бу мохитне якыннанрак белсәк, аерымлыклары искиткеч зур булып чыга.* С.Хәким. *Әйе, бер елдан охшашлыклар яки аерымлыклар аныграк күренер.* Г.Галиева

**АЕРЫ́-ЧӨЕРЕ** *рәв.* Төрлесе төрле урында, һәркайсы үзе генә, аерым.

*Юлда аеры-чөере аунап яткан бүрәнәләр күренә*

◊ **Аеры-чөере килү** Таркалып һәм чуалып бетү, һәркайсы үзенә аерым эшләү. **Аеры-чөере китерү** Таркатып һәм чуалтып бетерү, аерым-аерым эшләү. *Алар бу эшне, аеры-чөере китереп йөртмичә, берьюлы тәмамларга карар биргәннәр иде.* Ш.Маннур

**АЖГЫР** *с. сөйл.* 1) Усал, шәфкатьсез, мәрхәмәтсез. *Ажгыр кайнана*

2) Үтә көчле. *Ажгыр суык. Ажгыр җил*

**АЖГЫРТЫП** *рәв. сөйл.* 1) Зур дәрт белән, бөтен көчне салып, гайрәтләнеп; бик тиз (эшләү). *Кара, тракторны ничек «йөгәнли», кара, комбайннарны ничек ажгыртып йөртә.* Э.Шәрифуллина

2) Мул тормышта, рәхәтләнеп, үзең теләгәнчә (яшәү)

**АЖГЫРУ** *ф.* **1.** 1) Ярсып, котырынып исү. *Апрельләрдә буран гел котыра. Пәри туе булып ажгыра.* К.Булатова. *Өй түрендә ачы җил ажгыра*

2) Нык давыллау, зур көч белән дулкын өермәсе кубару, көчле ташкын булып, котырып килү. *Көчле дулкыннар, ажгырып, ярга ташланалар. [Илсөя] Ажгырып килгән дулкыннарга куркусыз ташлана, пошкырына, чәбәләнә.* Ф.Яруллин. *Артмакташ ягыннан агып килгән кече Эйек елгасы гына, үзенең җәйге ярына сыймыйча, тирәклекләрне басып, язгы ташкында өерелеп-өерелеп ажгыра, дулый.* Ш.Янбаев

3) Ыжгыру, сызгыруга охшашлы ыжылдау тавышлары чыгару; бик зәһәрләнеп, усалланып ыжылдау, ысылдау. *Егермешәр метрлы газ аеру колонкаларының тып-тын көнне дә колакларны ярырдай булып ажгыруына җил-давыллы буран котыруы өстәлә.* Р.Хисмәтуллин

4) *күч. сөйл.* Ачу белән нәфрәтләнеп кычкыру, зәһәрлеген күрсәтү, җикерену. *Әллә син Ниса апагыз гына миңа ажгыра дип уйлыйсыңмы?* М.Маликова. *Бары теге Вазих дигән малай гына көлми, Габдулланы ашардай булып, ажгырып торды-торды да: – Әһә, синең шундый гадәтең дә бармыни әле? – дип кычкырды.* Ә.Фәйзи

**2. ажгырып** *рәв. мәгъ.* 1) Ярсып, көчле дәрт, теләк белән (кеше турында); гайрәтен баса алмыйча, атылырга әзер булып (ат турында). *Янып, ажгырып тора егетең.* Р.Ишморат. *Малайлар ажгырып торган атларны тынычландырырга тырышалар.* И.Гази

2) Түземсезләнеп, ашкынып. *Атлар, бәйге якынлашканны тоеп, ажгырып тыпырдашалар*

3) Ут чәчеп, ут бөркеп. *Ажгырып торган амбразурадан берничә адымда Газинур кинәт тукталып калды.* Г.Әпсәләмов

4) Зур тизлек белән, өермә кубарып. *Мәнә бераз вакыттан, ажгырып, аждаһа килеп тә җиткән.* Әкият

5) Куркыныч итеп кычкыртып, көчле сызгыртып. *Поезд, ажгырып, көнчыгышка таба чаба.* М.Әмирханов

**Ажгыра башлау** Ажгырырга тотыну. --- *әле, ажгырынып, бүре улаган тавышлар чыгара, әле җен алмаштырган бала шикелле елый да тагын үкерә, тагы сызгыра, тагы ажгыра башлый иде.* Г.Исхакый

**Ажгырып алу** Бераз ажгыру

**Ажгырып тору** Бертуктаусыз, әле, сөйләү моментында ажгыру. *Бөтен авыл «җир» дип ажгырып тора ич.* И.Гази

**АЖДАҺА** *и. фар.* 1) *миф.* Әкиятләрдә: йөз ел яшәгәннән соң канатланып оча торган, берничә башлы, зур, куркыныч елан. *Һәр елны бер вакытта аждаһа килеп, сәмруг кошның балаларын ашап китә икән.* Әкият. *Аждаһа хан кызын чолгап алган, йоту [максаты] илә авызына таба суырмакта иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Халыкта, елан, йөз ел яшәгәч, аждаһага әйләнә, дигән ышану бар.* Татар мифлары

2) *күч.* Бик явыз, зәһәр кешегә (гадәттә хатын-кызга) карата әйтелә. *Йа Аллам! Каршыларында, тешләрен җемелдәтеп, аждаһа ыржая иде. Гыймран! Сөнчәледә генә түгел, күрше авылларда да аткан-аскан, кискән-тураган җәллад Гыймран!* Н.Гыйматдинова. *Гөлбану бит шул йортка төшәр, шул аждаһаның [кайнананың] кул астында гомер итәр. Мин мәнә шуннан куркам.* Г.Ибраһимов. *Артында: «Аждаһа» дип, «Гыйфрит» дип, «Котырган эт» дип тиргиләр иде.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Куркыныч, иләмсез, ниндидер билгесез җан иясе, әкият образы. *Вәләкин синең хыялларыңны «сугыш» дигән аждаһа каба да йота.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Авыр шартлар, кыенлыклар, кысулар. *Көн, үзенең бөтен иләмсезлеге, ачлыгы, талаш-сугышлары белән, Габдулланы ашыкмый гына үтерә торган зур аждаһага әверелде.* Ә.Фәйзи

◊ **Аждаһа кебек (күк) ыжгыра** Бик яман итеп сызгыра, усал тавыш чыгара. *Халит морза мәйданында аждаһа күк ыжгыра.* Ш.Мөдәррис

**АЖДАҺА́ ЕЛЫ** *и.* Көнчыгыш (Кытай) йолдызнамәсе буенча изгеләштерелгән хайваннарның 12 еллык циклында куян белән елан еллары арасындагы бишенче ел атамасы (...1988, 2000, 2012 һ.б. еллар) һәм шул елларда туган кеше. *Куян елына алмашка аждаһа елы килә.* Х.Бәдигый

**АЖУР** *и. фр.* 1) Челтәрләп эшләнгән нәфис юка тукыма. *Эшләпәгә ажур тегеп кую*

2) Бик нәфис, үтә күренмәле бәйләм, чигеш

**АЖУРЛЫ** *с.* Бик нәфис, үтә күренмәле һәм челтәрле. *Ажурлы кофта бәйләтү. Ажурлы оек*

**АҖАГАН** *и.* 1) Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен, төннәрен бик еракта, офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен чаткысы; елдырым. *Аҗаган – күкрәвеннән тол калган кысыр яшен.* М.Галиев. *Офык читендә аҗаган уйнауны халык ышануларында, Тәңре игеннәргә куркыныч янаган угрыларны, явыз затларны утлы сөңгесен атып, утлы камчысы белән көйдерә, дип уйлаганнар*

2) Ялт-йолт килеп елдырым уйнауны хәтерләтә торган нәрсә. *Кайтышлый өченче цех турыннан узганда, сварка участогы стеналарында ялт та йолт «аҗаган» уйный иде.* Н.Хәсәнов

3) *тар.* Элекке СССРда, хәрби укуларны, сугышчан хәрәкәтләрне хәтерләткән, пионерларның хәрби-спорт команда уены; *русчасы:* **зарница.** *«Аҗа-*

*ган» уены аркылы малайлар һәм кызлар армия фәненең нигезләренә төшенәләр, спортка тартылалар, ныклы, сәламәт булып үсәләр.* Ялкын

**АҖАР** *и.* Грузиннарның аерым этник төркеме атамасы һәм шул халыкның бер кешесе (күпчелеге мөселман динен тота). *Берьюлы алтмыш кешегә хезмәт күрсәтүче кафеда татар, төрек, үзбәк, аҗар халык ашлары әзерләнә.* Татарстан яшьләре

**АҖА́У** *и. диал. зоол.* Карплар семьялыгыннан, төче суда яши торган киң башлы балык; кушбаш; *русчасы:* **голавль**. *Камыш төпләренә качкан чуртаннар су өстенә чыгачак чабакларның, аҗауларның ялтыравын көтәләр.* М.Әмир. *Аҗауның иң яраткан азыгы чикерткә икәнен дә без ышанган идек.* Ак юл

**АЗ** *рәв.* **1.** 1) Саны ким, күләме, микъдары зур булмаган, җитәрлек түгел. *– Анасы, чәең аз калган икән инде. – Ник аз булсын: әле яртысы да бетмәгән.* М.Фәйзи. *Тулпан урманнарын кисеп, тимер юл сызыгы үткәч, аз җирле Тулпан авылы егетләре чит җирләргә, ерак шәһәрләргә таралып беткәннәр.* Һ.Такташ

2) Күп түгел, сирәк кенә, берән-сәрән; ара-тирә. *Хәким әйтте: «Әгәр сүзендә күбрәк сүзе дөрес булса вә хатасы аз булса, гакыллы дип беләмен», – диде.* К.Насыйри. --- *һәртөрле гыйльми атамаларны аз куллануыма укучыларым, шаять, гаҗәпсенмәсләр.* Н.Исәнбәт

3) Озак түгел, кыска арада, бераз вакыт. *Ә тегесе [кыз] аз гына юанды да тизрәк кереп китте.* Ә.Еники. *Менә аз гына сабыр итегез.* Р.Вәли. *– Бригадир әйтмәсә дә эшлибез, – диде ат караучы Исхак абый. – Аз гына утырып тор, – дип өстәде.* Т.Миңнуллин

4) Бераз, беркадәр. *Яңгырдан соңгы аз гына дымсу һава, салкынча ефәксыман, [Гөлшаһидәнең] йөзенә, муенына сарылды.* Г.Әпсәләмов. *Туташ урыныннан бик аз күтәрелде, күкрәге белән партага ята төште.* Г.Ибраһимов. *Ясәви аганың аз гына булса да горурланасы, мактанасы килә инде, сизеп торам.* Р.Миңнуллин. *Зөбәрҗәтнең аларга [балаларга] аз гына да исе китми.* З.Фәйзи

5) Чама белеп, чамалап. *Аз сөйләшсәң – күп белерсең, күп сөйләшсәң – өзлегерсең.* Мәкаль

**2.** *и. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса кечкенә өлеше; кечкенә нәрсә. *Күп тә – бетә, аз да – җитә.* Мәкаль. *Һәм ни могҗиза: оҗмахка керергә чират торалар. Кәримә дә шунда. Тик хатынкызлардан бик азлары гына оҗмахка эләгәләр.* М.Хәбибуллин. *Бары тик бик азлар, сыналган дуслары гына белә Хөсәеннең бу икенче тормышы турында.* С.Шәрипова

**3.** *с. мәгъ.* Саны, күләме кечкенә; санаулы. *Аз малың, күп куанычың булсын.* Мәкаль. *– Әсәрдә, – ди [Җиһангир], – аз сүз белән безем хатыннарның авыр язмышы ачык күрсәтелгән.* Г.Ибраһимов. *– Карале, кино башланырга аз гына вакыт калган, ә бу ашап утыра, – диде ул, керә-керешкә үк.* М.Кәбиров

**4.** *хәб. функ.* Микъдары, көче җитәрлек түгел, тиешле дәрәҗәсеннән ким булу. *Безнең ишегалдында минем белән яшьтәш малайлар аз түгел иде.* Ә.Фәйзи. *Ә Мирзаһитның бу җитәкче эштә тәҗрибәсе аз.* Г.Әпсәләмов

◊ **Аз азыклы, күп языклы** Изгелек запасы аз, гаебе-гөнаһы күп. **Аз булса да, күп итеп ал** Теләк; бүләк яки күчтәнәч тапшырганда әйтелә. **Аз дигәндә** Ким дигәндә, кимендә; аз куйганда; минимум. *Аз дигәндә, 30 центнерлап чыгар.* Казан утлары. **Азрак баш-күз алу** Берәр мәшәкатьле эштән арынып, бераз тынычлану, иркенәю. **Азын күп санап, күбен юк санап** Юкны бар итеп, барын күрмәмешкә салынып сөйләү турында. **Аз эшли дә күп тешли** Эшенә караганда үзенә күбрәк алырга, күбрәк эләктерергә тырышучы кешегә карата

**АЗА** *и. иск.* Шау-шу, тавыш-гаугa

◊ **Аза кубу** 1) Шаяру, уйнау, азу; 2) Шау-шу күтәрелү, ызгыш-талаш чыгу. **Аза куптару** Шау-шу күтәрү, ызгышу-талашу, гауга чыгару

**АЗАГЫНА́ЧА** *рәв.* Ахырынача, ахырына кадәр, беткәнче. *Аның нинди генә әсәрен кулыңа алма – азагынача укымыйча куя алмыйсың.* Ф.Чанышева

**А́З-АЗ** *рәв.* Бик аз, азлап, аз гына күләмдә. *Өч-дүрт авылда аз-аз гына укытучы булып эшләп алган Сәхип Зәкиев Акъюл авылына килә дә шушында төпләнә.* А.Гыйләҗев. *Йомырка агы салынган кайнар суны тышта тиз-тиз суытты да, [әнисе] авыру сабыйның хәлсез иреннәрен ачып, аз-аз йоттырды.* Г.Ибраһимов

**А́З-АЗДАН** *рәв. сөйл.* Азлап, бераз. *Тартынып тормагыз, җәмәгать, аз-аздан капкаларга ярый, зарар юк.* Ш.Камал

**А́З-АЗЛАП** *рәв.* 1) Аз гына күләмдә, күпләп түгел, чак кына. *Безгә комганнан суны да түгәрәк йөзлесе аз-азлап салып торды.* Ә.Еники

2) Акрынлап, торган саен, вакыт узу белән. *Аз-азлап тәҗрибә туплау*

**АЗАЙТУ** *ф.* Күләм, зурлык, сан ягыннан киметү, кечерәйтү; азга калдыру. *Тазарту гаскәрне сан ягыннан азайтса да, дисциплина ныгыды, күтәрелде.* Ш.Усманов. *Терлекнең баш санын азайтырга булдылар.* Мәдәни җомга

**Азайта бару** Акрынлап, аз-азлап азайту. *Бурычны азайта бару*

**Азайта төшү** Бераз азайту; тагын да азайту

**Азайтып алу** Тиз арада азайту

**Азайтып бетерү** Бөтенләй азайту, акрынлап азайту, бик аз калдыру

**Азайтып кую** Аз хәлгә, азайган хәлгә китерү; алдан ук азайту

**Азайтып тору** Әледән-әле, еш азайту. *Бәяләрне күтәреп, реаль эш хакын азайтып торалар*

**Азайтып чыгу** Башыннан ахырына кадәр азайту

**АЗАК** I. *и.* **1.** 1) Бербөтеннең (предмет яки күренешнең) актыккы өлеше, иң соңгы кисәге, бетеме, ахыры. *Кемнәр – яшәү, кемнәр үлем даулый, Хак хөкемен ала азакта.* Ә.Баянов. *Хикәянең азагына җиткәч, аның күзләренә яшьләр килде.* А.Алиш. *– Көчеңне, патроннарыңны кызганма, Хафиз абый, яме! – диде Хәлим хатының азагында.* Г.Гобәй

2) Нинди дә булса вакыт арасының соңгы моменты, беткән чагы, ахыры. *Нигә соң чәчәктәй яшь гомернең Кавышу булмаган азагы?* Җыр.

*Әйтергә кирәк, Закир ишанга лаеклы алмаш буларак, Нәҗип хәзрәт бу шигарьгә (девизга) гомеренең азагына чаклы тугрылык саклый.* Р.Әмирхан. *Гаҗәеп зур ябалдашлы, колач җитмәслек юан нарат кына, җил-давылларның берсенә дә бирешмичә, горур басып тора, хәер, горурлыгы картлар-чарак инде, аның да гомер азагы җитә бугай.* Казан утлары

3) Нинди дә булса эшнең, күренешнең яки вакыйганың йомгагы, нәтиҗәсе, соңы. *«Сак-Сок» әсәре фаҗигале азагы белән куәтле дә, шуның аркасында ул мең елларны узып та искермәгән.* Р.Батулла. *Эшнең азагы без көткәнчә булып чыкмады, начар тәмамланды*

**2.** *рәв. мәгъ.* Соңында, ахырда. *Әмма ул, азак председатель кисәтүен онытмаса да, алачыкта үйламаганны ычкындырды.* Ф.Мансуров. *Азак карт түзмәде, күңеле йомшарып, аны [этне] кара-соры сырт буйларын сыйпап иркәләде.* Мирас

◊ **Азагы хәерле булсын** Эшнең яхшы төгәлләнүен теләп әйтелә торган сүз. **Азагына чыгу** 1) Тәмамлау, төгәлләү; 2) Тикшереп, мәсьәләне хәл итү. *Ләкин хәзер тукталып калу мөмкин түгел. Сүзнең азагына чыгасы, кемнең кемлеген тәмам ачыклыйсы бар.* Казан утлары

**АЗАК** II *и. иск.* Аяк. *Нә гәүдәсе, нә азакы, нә әле, Бер кисек башдыр, һаман сүзләр теле.* Г.Тукай

**АЗАККА́ЧА** *рәв.* 1) Ахырга кадәр, беткәнче, бетергәнче. *Азаккача дәвам иткән тема – Батырҗан белән Гөлйөземнең бер-берсен сөешү темасы.* М.Җәлил. *Әсхәт Лотфиевич монда да, остаханәдәге кебек, дилбегәне азаккача үз кулында тотарга исәп итә иде бугай.* М.Шаһимәрдәнов. *Әсәр азаккача шул гаҗәпләндергеч тәэсирчәнлек дулкынына корылган.* М.Гайнетдинов

2) Тиешенчә, җиренә җиткереп, тиешле шартына китереп. *Азаккача киерелгән җәя*

3) Барлык көче белән, иң соңгы хәлгә кадәр. *Сабан туенда азаккача көрәшү. Азаккача түземлелек күрсәтү*

4) *куч.* Тулысынча, бөтенләе белән, бар күләмендә. *Тик Гөлнара сер капчыгын азаккача чыгарып селкергә ашыкмады.* А.Гыйләҗев

**АЗАККЫ** *с.* **1.** Актыккы; ахыргы, соңгы. *Күңеленнән ул барлык гаепләүләр белән килеште, тик азаккы нәтиҗәне көтте.* Ә.Еники. *Азаккы пароходлар тәртипсез йөргәнлектән, кайберләре Шиловка пристанена туктамыйча ук үтеп киттеләр.* К.Тинчурин. *Завхоз азаккы капчыкны күтәреп алып чыга.* А.Алиш

**2. азаккысы** *и. мәгъ.* Калганы, соңы. *Азаккысын тартып алу*

◊ **Азаккысы булсын**. Бүтән кабатланмасын

**АЗАККЫ́ ИСӘПТӘ** *кер. сүз* Актык чиктә

**АЗАКТА** *рәв.* Соңыннан, ахырда. *Азакта пар килеп чыгармы-юкмы, дип күзәтү генә түгел, алып баручыларның үзенә тиң кешене ничек сайларга, нинди сыйфатларга игътибар итәргә кирәклеге турында киңәшләрен тыңлау да кызык.* Ирек майданы. *Азакта асфальтта рәсем ясау бәйгесе оештырылды.* Маяк

**АЗАКТАН** *рәв.* Соңыннан, ахырдан; нәрсә булса да тәмамлангач, билгеле бер вакыт үткәч. *Оныткан мын, азактан гына исемә килде.* Г.Ибраһимов

**АЗА́ЛИЯ** *и. гр. бот.* Арчанчалар семьялыгыннан, көньякта үсә торган куакчыл үсемлек. *Азалиянең агаччыл, сары, ябышкак, шуышма төрләрен оранжереяларда үстерәләр.* Биология. *Азалия – мәңге яшел куак. Ул кышның икенче яртысында һәм иртә язда чәчәк ата.* Ботаника

**АЗАМАН** *и. диал. к.* **атаман**

**АЗАМАТ** *и. гар.* **1**. 1) *иск.* Сугыш була калса, иң беренче чиратта гаскәргә алынасы 20 – 30 яшьләр арасындагы таза ир-егет

2) Батырлыгы, кыюлыгы белән танылган, мөхтәрәм ир-ат. *Кешегә шәфкать итеп юл бир, азаматка хөрмәт итеп кул бир.* Мәкаль

**2**. *с. мәгъ.* Батыр, кыю, курку белмәгән. *Азамат ирнең билгесе – аз сөйләр дә күп тыңлар.* Мәкаль. *Ә бит ул – азамат ир-ат, утызга якынлашып килгәндә, шулай гыйшык диванасына әверелсен инде.* М.Хәбибуллин. *Гайшәнең сеңлесе исә, зәм-зәм суында коенган фәрештәдәй, азамат ир-атларга тартылды.* М.Хәбибуллин

**АЗАМАТЛЫ** *с.* Абруйлы, зур ихтирамга лаеклы (ир кеше турында)

**АЗАМАТЛЫК** *и.* Батырлык, кыюлык, курыкмаучылык. *Мондый энтузиастларның эшчәнлеген чын мәгънәсендә «рухи азаматлык», «тарихи каһарманлык» дип атарга мөмкин.* Р.Әмирхан

**АЗАН** *и. гар. дини* Намазга чакырып, мәчет манарасыннан кычкырып укыла торган дога. *Аккүл авылы безне көндезге азан тавышы белән каршы алды.* Ф.Бәйрәмова. *Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан; И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!* Г.Тукай. *Шәһәрдә, авылларда, дөньяга ямь биреп, азан авазлары яңгырый, мәчет манараларында айлар калка.* Шәһри Казан

◊ **Азан әйтми, камәт төшермиләр** Мәзин азан әйтмичә, алдан намаз укырга керешмиләр, ягъни һәр эш үз рәте, үз тәртибе белән эшләнә

**АЗАНЧЫ** *и.* 1) *дини* Мәчеттә азан әйтүче дин әһеле; мәзин. *Таң атты. Мәчет манараларыннан --- азанчылар азаннарын кычкырдылар.* К.Тинчурин

2) *куч.* Хәбәр китерүче, хәбәр бирүче, яңалык китерүче. *Ала карга – азанчы, кара карга – казанчы.* Мәкаль

**АЗАП** *и. фар.* 1) Авырлык, кыенлык, михнәт. *Синең кебек җир казып, күрмимен һичбер азап.* М.Гали. – *Шушы азаплардан бер котылып, өемә исән-сау гына кайтып керсәм, бер ай буе хатыннан мунча яктырып, ләүкәдән төшми чабынып ятар идем, – диде.* М.Гали. *Күпме азап күрдек шуның өчен, күпме тал чыбыгы ашадык.* Һ.Такташ

2) Рухи интегү, авыр эчке кичерешләр

**АЗАПЛАНУ** *ф.* 1) Берәр эш башкарганда кыенлыклар, мәшәкатьләр кичерү, интегү. *Эш чиксез авыр, унике сәгать буена җир астында тиргә батып, эштән чыгып азапланасың, ә тамак туярлык акча бирмиләр.* Ш.Камал. *Кызганыч, гарәпчәне генә өйрәнә алмый азаплана әлегә. Үч иткәндәй,*

*өйдәге китапларның яртысы диярлек – гарәп телендә.* Р.Мөхәммәдиев. *Әтинең шушы сүзе җитә калды. Җәй буе, әтидән качып, турникта азапландым.* Ф.Яруллин

2) Рухи яки физик газап кичерү, газаплану. *Аның бер аягында сөяк туберкулёзы иде, шуның белән ул берничә ел азапланды.* Ә.Еники

3) Үзеннән алда килгән фигыль белән белдерелгән максатка, теләккә ирешү өчен көч кую, тырышу; маташу. *Уенга борырга азапланма, Гаяз, син аларны чынлап әйттең һәм дөрес әйттең, дөрес характеристика бирдең син миңа.* М.Әмир. *Ә кеше торырга азаплана, тырмаша, юл эзли.* А.Шамов. *Ул үзе, исерек булуын сиздерүдән һаман әле куркып, сорашырга яки ни дә булса әйтергә кыймыйча азаплана иде.* Ә.Еники. *Шуннан бер инструктор хатын микрофон аша безгә белдерү ясады. Татарча сөйләмәкче, әмма булдыра алмый азаплана.* М.Мәһдиев

4) Кемдер яки ниндидер булып күренергә тырышу, кылану. *Әллә, кулларына эләккән тоткынның психологиясен җимерү өчен, тыштан гына шулай бәйрәм шатлыгы чыгарып азапланалармы?* Г.Ибраһимов. *[Әнвәр:] Син юкка гына, Гөлсинә, прокурор булып азапланасың.* Р.Ишморат

**Азаплана башлау** Азапланырга тотыну. *--- пеләш башка ничек бантик куймак кирәк! Ул, ал тасманы аяк астына ташлап, зәңгәре белән азаплана башлады.* Ф.Сафин

**Азаплана бирү** Азаплануын дәвам итү

**Азаплана төшү** Бераз азаплану; тагын да азаплану

**Азапланып алу** Бераз, кыска вакыт эчендә азаплану

**Азапланып бетү** Тәмам азаплану. *Бер кат җәймә генә ябынып ятсаң да, йоклап китә алмыйча азапланып бетәсең.---.* Ә.Еники. *Алар операның исемен, эчтәлеген үзгәртә-үзгәртә азапланып беттеләр.* У.Альмеев

**Азапланып йөрү** Берәр нәрсә булдыруда күп азаплар кичереп эш йөртү. *Шунда миңа бик тә күңелсез булып китте. --- кая барам соң мин?! Нигә азапланып йөрим?!* Г.Бәширов. *Минем дә, каладан яңа килеп, колхозның чиләнеп беткән төеннәрен, тырнак белән генә түгел, теш белән дә чишә алмыйча азапланып йөргән чагым...* Ә.Еники

**Азапланып карау** Нәрсә дә булса эшләргә омтылу. *Каушавыннан тотлыга башлаган Ногман үзенең кем булуын аңлатырга азапланып карады.* И.Хәйруллин. *Шулай фикер йөртеп, ул үз каршында үзен акларга бик күп азапланып карады.* М.Әмир

**Азапланып тору** Озак, еш яки хәзерге вакытта азаплану. *Мин шулай уйлап, бик нык ачуланып, әмма ачуымны сиздермәскә азапланып торган арада, директор өстәл тартмасыннан бер папка чыгарып, аның эчендәге кәгазьләр арасыннан берсен тартып алды.* В.Нуруллин

**Азапланып чыгу** Әйтелгән вакыт аралыгында, шул вакытның башыннан ахырына кадәр азаплану. *--- әгәр кичен эштән кайткан вакытта, Зиннәт, болар янына килмичә, бүтәннәр белән кайтса, Нәфисә төне буе азапланып чыга торган булды.* Г.Бәширов

**Азапланып яту** Озак вакытлардан бирле азаплану. *--- гармунында ниндидер көй чыгарырга азапланып яткан Илгиз уйнавыннан туктады.* Н.Фәттах

**АЗАПЛА́У** *ф.* 1) Интектерү, тинтерәтү, аптырату, җәфалау. *Зифаны шулай азаплаганда, берсе идәнгә яткан җиреннән кычкырып җибәрде.* Г.Ибраһимов

2) Җәзалау, физик газаплау. *Анда безнең шәһәрләребезне, авылларыбызны җимертәләр, кешеләрне асалар, кыралар, азаплыйлар.* Г.Ибраһимов

3) Тынычсызлау, тынычлыгын бозу, тынгы бирмәү, борчу. *Күрмәс идем, ул чүмәләләр кыш буе минем йөрәгемне талап чыктылар, күз алдымнан китмәделәр, төшемә кереп азапладылар.* Г.Бәширов

**Азаплап алу** Кыска вакыт дәвамында азаплау. *Песиләрне азаплап алырга да күп сорамый*

**Азаплап бетерү** Тәмам, бөтенесен азаплау. *Сабира да мине тәмам азаплап бетерде.* Ә.Еники. *Шәфигулла агай көне буе демонстрантларга ияреп йөри, балаларын да азаплап бетерә, кече улына салкын тиюгә һәм аның үлеменә төп сәбәпче була.* А.Әхмәдуллин

**Азаплап йөрү** Әле, хәзерге вакытта азаплау. *– Пычагыма кирәкмени буранда халык изалап, ат азаплап йөрергә! – дип кычкырды.* А.Расих. *Моңарчы эндәшми торган, ак челтәр кулмәк кигән ир кулын селтәп куйды: – Хайван азаплап йөрисе юк иде инде. Ятсын иде абзарында колынын имезеп!* К.Тимбикова

**Азаплап калу** Азапларга өлгерү

**Азаплап килү** Электән, күптәннән, бертуктаусыз азаплау

**Азаплап тору** Даими рәвештә, гел азаплау

**Азаплап чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында, шул вакытның башыннан ахырына кадәр азаплау

**Азаплап яту** Һәрвакыт, гел азаплау. *Юк-барга ышанып, үзеңне-үзең азаплап ятасың икән, яныңа да килеп карамыйм!* Г.Бәширов

**Азаплый башлау** Азапларга керешү. *Ислах азаплый башлаганчы, чыгып качтым.* М.Хуҗин

**Азаплый бирү** Азаплавын дәвам итү

**Азаплый төшү** Бераз азаплау

**АЗАПЛЫ** *с.* 1) Азап, җәфа, михнәт белән башкарыла торган, ниндидә булса физик һәм рухи борчулар таләп итә торган. *Бу азаплы эш, ким дигәндә, ун минут дәвам итте.* А.Расих

2) Борчулы, хафалы, тынычсыз. *Пышылдауга якын бер кысык, азаплы тавыш белән сорап куйды.* Г.Бәширов

**АЗАПЛЫК** *и.* Авыр мәшәкать, кыенлык, михнәт, авырлык. *Ул җирдә кар бик тирән булганлыктан, кулларына мылтык тотып, җәяү баручы солдатларга да билдән кар ерып, бик зур азаплык белән барырга туры килде.* М.Гали

**АЗАПЛЫЛЫК** *и.* Азаплы булу. *Укенүнең азаплылыгы*

**АЗА́П-МИХНӘТ** *җый. и.* Авырлык, һәртөрле газап, михнәт, кыенлыклар. *Әйе, кеше нәрсәгә генә ияләшми! Азап-михнәткә ияләшү кыен булса да, рәхәткә ияләшүе, һичшиксез, ансатрак ич...* Ә.Еники

**АЗАПСЫЗ** *рәв.* Ансат, җиңел, кыенлыксыз. *Азапсыз килгән мал затсыз була.* Мәкаль

**АЗА́П ЧИГҮ** *ф.* 1) Рухи җәфалану, авыр кичерешләргә дучар булу (мәс., юлда, тормышта). *Хәерниса карчык, бәетләр, әкиятләр, такмаклар белүе белән тирә-як авылларда дан алган булса да, бу чакыруны тиз генә төшенә алмыйча, байтак азап чикте.* Ф.Хөсни

2) Кыенлыклар кичерү; михнәт күрү. *Гүя Мәрьям үзе аңа: «Азап чикмә, дустым, тап үзеңә яхшы бер хатын», – дип әйтеп тора иде.* Ә.Еники. *Фәйзулла Сембер циркында нәкъ өч ел эшләде, дөресрәге, нәкъ өч ел азап чикте*. Ф.Хөсни

**АЗА́Р-АЗАР** *рәв. сөйл.* Аз-аз, азлап, аз-азлап. *Икмәкне азар-азар кабып ашау*

**АЗА́Р-БИЗӘР** *җый. и.* Азгынлык, бозыклык. *Мәхәббәт уеныннан, азар-бизәрдән башланган тикшерү җитди нәтиҗәләргә алып килә.* Т.Галиуллин

**АЗА́Р-БИЗӘР ИТҮ** *ф.* 1) Тарату, таркату, таркаулык кертү. *Юк, хатын кардәше, өйне басып алып, алай азар-бизәр итми.* Г.Ахунов

2) Әрәм итү, юкка чыгару. *Җитмәсә, шул бәндә азмы-күпме малны азар-бизәр итте, атасыныкын да, колхозныкын да*. Мирас

3) Иләсләндерү, күңелне җилкендерү

**АЗА́Р-БИЗӘР КИЛҮ** *ф.* 1) Иләсләндерү, күңелне җилкендерү. *Күңелне азар-бизәр китерә башлый.* Г.Ахунов

2) Азып-тузып, ахырын уйламыйча эш йөртү. *Юк, аның улы дөнья болгатучылар белән түгел! Аның улы азар-бизәр килеп йөрми! Менә шул җитә Нәриман абзыйга, шуннан артыгы кирәкми.* Г.Ахунов

**АЗА́Р-БИЗӘР КИТЕРҮ** *ф. к.* **азар-бизәр итү**

**АЗАРЛА́У** *ф. диал.* Кайта-кайта ачулану, кабат-кабат шелтәләү

**Азарлап бетерү** Бик нык азарлау

**Азарлап тору** Бертуктаусыз азарлау

**АЗАРТ** *и. фр.* 1) Нәрсә белән булса да мавыгучанлык, һәвәслек; комар. *Тормыш – кәртле уен. Кирәк ничек гомер итмәк?Азартка кереп, еш кына, Кителә талашып. Кеше икәнне оныты, Якадан алышып*. И.Әширов

2) Мавыгып, һәвәсләнеп, дәртләнеп китүчәнлек, үзен-үзе оныту. *Алда булачак азартны тоюдан агентның яшькелт тиресе дулкынланып алды*. А.Гыймадиев. *Спорт ярышларында була торган азарт биләп алды егетне*. Р.Кәрами

**АЗАРТЛАНУ** *ф.* Азартка, комарга бирелү, комарлану

**Азартланып китү** Кинәт азартка бирелү. --- *шәхси мәнфәгать яклары да зур роль уйнады, ләкин күбесе бу кычкырышу, бу итәк асты тарткалашуына картага азартланып киткән кеше кебек кенә керде. Менә шуның аркасында, Казан үзенең әүвәлге урынын югалтты*. Г.Исхакый

**АЗАРТЛЫ** *с.* 1) Бик мавыгучан, дәртле, хирыслы, комарлы. *Ә үз театрында, бигрәк тә үзе куйган спектакльләр турында фикер алышканда, Марсель Хәкимович азартлы бәхәсчегә әверелә*. Р.Харис

2) Акчалы, отышлы. *Азартлы уеннар*

**АЗАРТЛЫЛЫК** *и.* Азартка бирелүчәнлек; мавыгучанлык, комарлык (*уенда, спортта*)

**АЗАРЫНУ** *ф. диал.* Кайнашу, маташу. *Елгага да ут капкан бит! Дулкыннар берчә бурлат кызыл, берчә чи сары телен чыгарып азарына ләса*. Г.Якупова

**АЗАТ** *с. фар*. **1**. 1) Ирекле, беркемгә дә буйсынмаган, хөр. *Бу азат, бәхетле тормышны, кан биреп, сугышып алдык без.* Ә.Исхак. *Теләгән тартып алырга Ул каләмемне минем, Ишетмәсен, дип, азат җыр Сөекле туган илем.* Ә.Исхак. *Латышлар, фетнә бетү белән үк, бөтенесеннән бәйсез, мөстәкыйль дәүләт булып, үзләре теләгәнчә яши башлыйлар. Читендер ... әмма инде алар – азат халык, азат ил*. Ә.Еники

2) Үз ихтыярлы, мөстәкыйль, бәйсез. *Яңгырасын мәңге яшьлек җыры, күкрәп торсын азат, шат хезмәт.* Ш.Маннур. *Күргәнем бар читлектәге кошның Омтылуын чыгып очарга. Күргәнем бар аның котылуын, Кушылуын азат кошларга.* З.Мәҗитов

**2.** *рәв. мәгъ.* Бәйсез, мөстәкыйль, ирекле рәвештә; буйсынмыйча. *Барлык халыкларның ирекле һәм азат яшәргә, үзләренә тормыш үрнәге һәм җәмгыять строе сайлап алырга мөмкинлеге булырга тиеш.* Татарстан яшьләре

**3.** *хәб. функ.* Нинди дә булса сыйфатка, йогынтыга, эшкә бәйле булмавын белдерә. *Күңеле саф, мәкерләрдән азат*

**АЗА́Т БУЛУ** *ф.*1) Тоткынлыктан яки коллыктан котылып, ireккә чыгу. --- *халык авыз иҗаты әсәрләре – барысы да болгар-татар халкының монгол-татар коллыгыннан азат булу өчен көрәш сюжетында төзелгәннәр*. С.Алишев

2) Нәрсәдәндер котылу, арыну. *Зур язучы әсәрләренең йогынтысын тоя башлый икән, ул бөтен көчен аңа охшамаска тырышуга бирә, аның йогынтысыннан азат булу турында уйлый башлый*... К.Гыйззәтов

**АЗА́Т ИТҮ** *ф.* 1) Тоткынлыктан ирекккә чыгару, җибәрү. *[Милиционер] Паспортны ачкач, андагы фото белән минем битне кат-кат озак өйрәнде, шулай да бик шикләнеп, азат итте.* М.Мәһдиев

2) Басып алынган җирдән дошманны куып чыгару. *Рим папасы Урбан II, Гайсә пәйгамбәр табутын һәм Иерусалим шәһәрен дини дошманнардан – мөселманнардан азат итү өчен, Якын Көнчыгышка яу чабарга чакыра*. М.Гайнетдинов

3) Эшеннән чыгару, урыныннан алу, эштән бушату. *Шул елны Разилне эшеннән азат итү (күпме тикшерү-казынулардан соң, ниһаять) идарә утырышында каралды*. М.Галиев

4) Нинди дә булса эшкә мәҗбүр итмәү. --- *3 елга салым түләүдән, рекрутлыктан, җинаять кылганнарны – җаваплылыктан, бурычлыларны әҗәттән азат итү турында махсус указлар чыгарыла*. Ф.Ислаев

**АЗАТКЫ** *и. диал.* Ашлык җилгәргәндә аерылып чыга торган ач бөртекләрдән, башак калдыкларыннан, чүп үләннәре орлыкларыннан һ.б.ш.дан гыйбарәт катнашма. *Бодайның азаткыларын бер урыннан икенче урынга күчерү*

**АЗАТЛЫК** *и.* Ирек, хөрлек, бәйсезлек. *Бу каһарманнарның олуг хезмәтләре безнең милли азатлыгыбыз тари-*

*хында алтын хәрефләр белән язылачак.* Г.Ибраһимов. *Авторның симпатиясе, әлбәттә, зинданда биш-алты ел яткан һәм, ни бәрабәренә булса да, азатлык яуларга алынган тоткын Батырша ягында.* К.Нәфыйков. *Аларның [латышларның] инде азатлык өчен үз туфракларында каннары да коелды.* Ә.Еники. *Милли азатлык өчен көрәшкә бөтен гомерен биргән бу атаклы шәхеснең мирасы үткәнне танып белү һәм бүгенгене аңлау өчен дә кыйммәтле.* Мирас

**АЗА́У** *и. диал.* 1) *к.* **азау тешләр**. *Факия апа шул азауларын чистарта-чистарта иза чигә. Күмер белән дә агартып карады, киндер белән дә ышкыды.* Р.Батулла

2) Чәчелмичә, көздән коелып калган орлыктан үскән иген

3) Кыргый хайван, киек. *Угалап барып ни аттың, атай, азаулар алып килдеңме, атай?* Дастан

**АЗА́У АЙГЫР** *и. диал.* Елкы көтүен әйдәп йөртә торган көчле нәсел айгыры, *к. шулай ук* **асау айгыр**. *Без азау айгыр асрый алмадык, бия асрадык.* Казан утлары

**АЗАУЛАНУ** *ф. сөйл. сир.* Шомару, үткенләнү; усаллану. *Егетләр армиядән азауланып кайта*

**Азаулана бару** Торган саен ныграк азаулану

**Азаулана төшү** Бераз азаулану

**Азауланып бетү** Тәмам, бөтенләй азаулану

**АЗАУЛЫ** *с. сөйл.* Булдыклы, үткен, елгыр. *Азаулы егет*

**АЗА́У ТЕШЛӘР** *и.* 1) Аслы-өсле урнашкан, яссы өслекле арттагы тешләр; урт тешләр. *Почмактагы сандык өстендә аклы-каралы мәче ята: вакыт-вакыт, киерелеп, авызын ачып иснәгәндә, саргылт азау тешләре күренеп кала.* А.Хәсәнов. *Хәлимнең йөзе ачудан күгәрде. Аның азау тешләрен кыскан-лыгы чандыр иякләрендә ачык булып күренделәр.* К.Тинчурин. *Нотыкчы, бер бал кашыгы абхаз аджикасын капкан кешедәй, чыраен бозды, азау тешен суырып алды.* Казан утлары

◊ **Азау (теше) ярган** 1) Акыл теше чыккан яшьтән узган, балигъ булган; 2) Берәр төрле эштә зур тәҗрибә туплаган, булдыклы; дөнья күргән, акылга утырган. – *Дустың Буранбай нигә өйрәтми? – Әйе, ул белә, ул бөркетче булып азау ярган.* Г.Якупова; 3) Яше җитеп узган, сазаган (кыз турында). *Инде аларның Гөлҗамалларының азау теше ярганына да ун еллап бардыр.* Г.Камал; 4) Усал, гайрәтле, баш бирми торган. *Шундый халык авылда биш-алтыга җыелды, иң азау теше ярган икесен утырттылар.* Г.Ахунов. **Азау тешен ашаган** Күп яшәгән, азау тешләре ашалып беткән. **Азау тешен күрсәтү** Усаллыгын белдерү, ризасызлыгын сиздерү. *Әмма Сибгатуллин аларга уңга да, сулга да берни әйтмәде, ә икенче катта тагын шулай үстереп тапшыргач, рәхмәтләр әйтеп, кул кысасы урында, азау тешен күрсәтте.* Мирас. **Азау тешләрен җимерү** Бик нык кыйнау; усаллык, комсызлыкларына чик кую

**АЗАЮ** *ф.* 1) Күләм, зурлык, сан ягыннан кимү, кечерәю, аз калу. *[Шәйхезаман:] Мин бүген мәчет астына төшкән идем, ни өчендер, утын азайган.* Т.Гыйззәт. *Күңелем, һәр нәрсәдән элек, хәзерге тормыштагы ямь вә матурлык азаюына кайгыра.* Г.Ибраһимов. *Тракторлар сабан сөрә, эш азайды атларга.* М.Җәлил. *Тик атлар шактый азайган иде инде. Менә шул елларда күп кенә колхозларда үгез җигүгә күчтеләр.* Казан утлары

2) Киеренкелек кимү, эшнең иң кызу вакыты үтү, җиңеләю. *Чәчү эше бераз азайгач, шәһәргә барып кайтырга уйлады*

3) Ярлылану, кимүгә, бетүгә бару. *Елгаларда балык азайды дип, экологлар чаң суга.* Мәдәни җомга. *Җир шарында казылма байлыклар азаю*

4) Сирәгәю, булуы кимү. *Соңгы вакытларда --- кинәт куркып, сискәнеп китүләре азайган кебек булса да, хәзер даими рәвештә килделе-киттеле бер кеше булып әйләнде.* М.Гафури. *Шулай сүзләр азаеп, Марат китәргә урыныннан кузгалгач, Тәнзилә дә торып басты.* З.Фәйзуллин. *Туксаннар тирәсенә җиткәч, моңарчы гәпләшергә яраткан әбекәйнең сүзе азайды.* Сөембикә

5) Кибү, саегу; тиешле юешлеге, дымлылыгы бетү, парга әйләнү. *Агыйдел, сулга борылып китеп, бездән шактый еракта, куркыныч яр булып күтәрелгән, --- бу җирдә сөзәкләнеп азайган иде инде.* М.Әмир

**Азаеп бару** Торган саен азаю, саны көннән-көн кимү. *Без бит болай да азаеп барабыз. Катнаш гаиләләр һаман арта, ә аларның берсендә дә балалар татар телен өйрәнеп үсмиләр...* Д.Нигъмәтҗанова. *Безне Габдрахман абыең Таһиров дәшә. Сине күрәсе килә. Татарстанда сезнең кебек шәрә батырлар азаеп бара, юк хәлендә дияргә була.* Казан утлары

**Азаеп бетү** Тәмам азга калу

**Азаеп калу** Аз хәлгә килү; бөтенләй азаю. *[Фазыйлга] Быел кыш Казанда имтиханнар алдыннан бик каты укырга туры килде, ахрысы, шуннандыр, кан азаеп калган, ди.* Г.Ибраһимов

**Азаеп китү** Көтмәгәндә, кинәт азаю; бераз азаю. *Степановның башы авыртуы азаеп китте, ә Якубовка азрак гайрәт кереп киткән кебек булды.* Рәмзи Вәлиев

**Азая бару** Торган саен азга калу, кимү. --- *теге зур күлнең суы һаман кибә, азая барып, берәр дистә әрсез вә җәнҗаллы бакаларга шаулашып, кычкырышып торырлык кечкенә бер сазлык булып калган иде.* Ш.Камал. *Авылда салам түбәле өйләр азая бара.* М.Гали

**Азая башлау** Азрак булуы күренү. *Инде урамда кеше дә азая башлаган иде бугай.* М.Вәли-Барҗылы

**Азая төшү** Бераз, өлешчә азаю, тагын да кимү. *Председательләр үзара җыелып шешәләр бушатканда зарланышканнарын райкомга әләкләшүчеләр азая төште.* Т.Миңнуллин. *Өйдә эшләр азая төшкәч, Илдар буш вакытларын урамда үзе кебек малай-шалай белән уздыра башлый.* Р.Могыйнов

**АЗӘРБАЙҖАН** *и.* Телләре төрки телләр семьялыгының угыз тармагына караган, шигый мөселман динендәге, Азәрбайҗанда яшәүче төп халык атамасы (үзатамасы – *азәри*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Азәрбайҗан теле. Азәрбайҗан әдәбияты*

**АЗӘРБАЙҖАНЛЫ** *и.* 1) Азәрбайҗанда яшәүче кеше. *Чынлыкта, Сәлимәнең башын әйләндерүче – үзбәк кешесе түгел, азәрбайҗанлы Нури иде.* З.Хөснияр

2) Чыгышы белән Азәрбайҗаннан булган, шуннан күчеп килгән кеше. *Сәетне азәрбайҗанлылар чорнап алды.* Т.Галиуллин

**АЗӘРБАЙҖА́НЧА** *рәв.* **1.** Азәрбайҗан телендә. *Азәрбайҗанча сөйләшү*

**2.** *с. мәгъ.* Азәрбайҗан телендә булган, азәрбайҗаннарга караган. *Кавказның идарәсе аерымча булганга, Кавказ наместнигы азәрбайҗанча гәзитә чыгарырга рөхсәт иткәләгән.* Г.Исхакый

**АЗБАР** *и. диал.* 1) *к.* **абзар.** *Төнлә азбар иясе йөри, ди.* Әкият. *Бакчадан, андагы түтәл вә агачлардан башлап бөтен йортны: сарай, келәт, азбар һәм ындырларны аерым кереп карап, һәммәсе белән исәнләшеп чыктым.* Г.Ибраһимов

2) Йорт алды корылмалары, каралты-куралар; гомумән хуҗалык

**АЗГЫН** I *с.* **1.** 1) Әхлаксыз, мораль тотнаксыз, тәүфыйксыз. *Ләкин мәдрәсә ябылмый калса, бу азгын, бозык унике шәкертне куарга кирәк.* Г.Ибраһимов. *Үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып, халык исеменә кара тамга төшерүче мескен, азгын, сатлык бәндәләр һәр кавемдә бар.* Т.Галиуллин

2) Кабул ителгән кагыйдәләрне бозучы, тәртипсез, тәрбиясез. *Азгын малайлар, сез нигә кызлар янына килдегез, ә?* М.Фәйзи. *Хәзер бит Зыя – азгын шәкерт, юләр малай түгел.* Г.Ибраһимов

3) Җиңел табигатьле, җилбәзәк; җилкенчәк. *Инде тәүбә иттем бу эшләрдән, Азгын күңел күпкә басылды.* Һ.Такташ. – *Болай киенү хатын-кызны чит ирләрнең азгын карашларыннан да саклый бит, Тимербулат, – диде ул, соңгы саламга ябышкандай.* Ф.Бәйрәмова

4) Хуҗасын тыңламый торган, читтә йөрергә әвәс; йөремчәк. *Сезнең азгын сыерларыгызны мин нишләтим аны?* М.Фәйзи. *Әмма азгын хайван, көтүдән качып, иркенләп, басуда сыйланырга гадәтләнде.* Н.Гыйматдинова

5) *сөйл.* Кайбер тире авыруларына тиз бирешүчән, каршы торырга сәләтсез (тән турында)

6) *диал.* Талымсыз, ашау-эчүдә әрсез. *Ашауга азгын кеше ул. Азгын тамак*

**2.** *и. мәгъ.* Әхлаксыз, мораль яктан тотнаксыз кеше. *Ул азгыннарга нинди җәза бирик?* М.Җәлил. *Йомарлана куллар, кысыла тешләр, Юк! Котылмас фашист азгыны.* Ш.Маннур. *Уйламаганда-көтмәгәндә генә мастерның шундый буйсындыру көче күрсәтүе, теге азгыннарны гына түгел, бөтен группаны таңга калдырды.* З.Фәйзуллин // Җенси яктан тотнаксыз кеше. *[Дуңгыз] Начтә – азгын ул, апай. Урмандагы кабан дуңгызлары белән гүләй-мүләй итә дә бәби таба унарны.* Н.Гыйматдинова

◊ **Азгын тамак** Төрле тәм-том, ачытөчегә туймас, гел ни дә булса кабарга эзләнеп торган ашамсак кеше. **Азгын тән** Туктаусыз бозылып, кабырчыклар чыгып торган тән тиресе, аллергияле тән

**АЗГЫН** II *с. диал.* Чәчелмичә, алдагы елда коелып калган орлыктан үскән. *Эре дә булмый, азгын мәк түгелеп кенә чыккан*

**АЗГЫНЛАНУ** *ф.* 1) Әхлаксызлану, инсафтан чыгу, бозыклыкка бирелү, тәүфыйксызлану

2) Азу, начарлану, көчәеп китү (авыру, яра турында)

**Азгынлана төшү** Тагы да азгынлану. *Яктырды, чебеннәр, тагын да азгынлана төшеп, көтүе белән килеп сарылалар.* Г.Бәширов

**Азгынланып йөрү** Әле, соңгы вакытта әхлаксыз, бозык эшләргә бирелү

**АЗГЫНЛЫК** *и.* 1) Әхлакый бозыклык, күңел бозыклыгы, мораль тотнаксызлык. *Аллаһы Тәгалә кешене бу дөньяның падишаһы итеп яраткан булган. Кеше, үз теләге белән, күктән чүпкә төшкән, алтын таҗын аракыга, азгынлыкка алыштырган икән.* Ф.Бәйрәмова. *Икенчедән, иске авыл тормышыбызда байгураларның, хәлле муллаларның ике-өч хатын асраулары тик җенси азгынлык нәтиҗәсе генә түгел, бәлки күп очракта хуҗалык интересыннан чыгып эшләгәнлекләре апачык күренеп тора.* М.Госманов

2) Тәрбиясезлек, тәртипсезлек. *Шулай да, бу малайларның азгынлыгы берничә тапкыр кабатлангач, түзмәде, кыска кулларын еш-еш селтәп, туптуры атлап, председательнең үзенә үк китте.* Н.Измайлова

**АЗДАН** *рәв.* Аз дигәндә, иң кимендә, ким дигәндә, минимум; бик азга. *Аздан да күңеле була торган әнинең йөзе елмаюлы.* Н.Гариф

**АЗДЫРУ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **азу**

2) Начар, бозык юлга кертү, юлдан яздыру. – *Булатны аздырыр, аңа кияүгә чыгар, дип коты очадыр, – ди.* Г.Ибраһимов. *Хатын-кызлар, гомумән, Мәдинәне яратмыйлар: «Шадра шайтан, ирдәүкә, кыланчык, ир-ат күңелен аздырып кайнаша ---», – дип, аның гайбәтен сата иделәр.* Ш.Камал. *Андый-мондый җирләргә йөртергә, күңелен иләсләндерергә, аздырырга кара.* М.Фәйзи. *Әнә шул нәгъләт, шул каһәр суккан карчык аздырган.* Г.Камал

3) Тәрбиясезлеккә, тәртипсезлеккә юл кую. *Һәм адәмнәргә таратырбыз аны, аздырырбыз, туздырырбыз дөньяны.* Ш.Бабич. *Аздырырга Тәңредән рөхсәт тә бар: Кем, туганнар, мондый зур форсат та бар?* Ш.Бабич

4) Күңелен җилкетү, җилкендерү, иләсләндерү. *Минем күңелем ник аздырдың, Ихлас берлән сөймәгәч?* Г.Тукай. *Читкә җибәреп, аның күңелен аздырмакчы булгансыз.* М.Фәйзи

5) Организмга авыру йоктыручы бактерияләр кертеп, авыруны, җәрәхәтне көчәйтү

6) Иркәләп бозу. *[Баланы] Үзегез безгә каршы котыртып торгач ятсыныр шул. Мин ишеттем инде: аны сез аздырасыз.* Ф.Яруллин

**Аздыра бару** Көннән-көн азгынлыгын арттыру. *Иркәләп, әнисе кызын аздыра бара*

**Аздыра башлау** Аздырырга керешү. *Кызларны аздыра башлагач, куып җибәрделәр. Җыелыш җыеп кудылар.* Т.Миннуллин. *Иремне читтә генә аздыруыгыз җитмәгән икән, тагы монда, өйгә килеп тә аздыра башладыгызмыни инде?* Г.Камал

**Аздыра бирү** Аздыруын дәвам итү

**Аздыра төшү** Тагын да аздыру

**Аздырып бетерү** Барысын да яки бөтенләй аздыру. *Теге сугыш чукмары Публий гына сезне аздырып бетерде. Рим аллалары да түзмәде аңа, әнә дөмектергәннәр үзен.* Р.Сәгъди

**Аздырып җибәрү** Азарга этәргеч бирү, кинәт аздыру. *Болай кадерләп, аздырып җибәрмәгез тагын. Мин бит андыйга күнекмәгән...* Г.Бәширов. *Рас операция икенче авыруны кузгатып, аздырып җибәргәч, нигә аны эшләгәннәр?* Х.Камалов

**Аздырып йөрү** 1) Төрле урыннарда, төрле кешеләрне аздыру. *Шул аздырып йөри бөтен авыл малаен.* И.Гази

2) Әле, хәзерге вакытта аздыру. *Менә нәрсә, энекәш... Син күңелеңне аздырып йөрмә.* Т.Миннуллин

**Аздырып ташлау** Кинәт аздыру. *Шәфкатьбикә әби, Коръән укы, сабак укы, ди, пәри кызлары ияләшмәсен, алар синең ише ялгыз ирне чамалап кына йөриләр, аздырып ташлаулары бар, дип көлдерә.* С.Поварисов

**Аздырып тору** 1) Бертуктаусыз, гел, һәрвакыт аздыру

2) Әле, хәзер аздыру. --- *ярым ачык күкрәкләрен күрсәтеп – күзне котыртып, җанны аздырып тора, җитмәсә, ерык итәк чабуын гелән юри ачып җибәрә.* М.Хәбибуллин

**Аздырып яту** Озак вакытлар дәвамында аздыру. *«Астыртын дин дошманы булып, җырлары белән яшьләрне аздырып яткан» дип коткы таратты.* Г.Бәширов

**АЗИАТ** *и. рус* **1.** Азиядә яшәүче халык яки аның бер вәкиле; азияле. *Рина, астыртын гына күз салгалап, ят егеттә теге гайрәтле Атилланың – Көнбатыш Аурупага килеп җиткән азиат каганның яугирлек чалымнарын ачарга тырышты.* Т.Әйди

**2.** *кимс.* Кыргый, культурасыз кеше. *Фрау Берна, өйдәшлеккә нииндидер бер азиатны кертермен, дип һич уйламаган иде.* Т.Әйди

**А́ЗИМУТ** *и. ингл.<гар.* 1) *астр.* Меридиан яссылыгы белән берәр планета аша үтә торган вертикаль яссылыклар арасындагы почмак

2) *хәрби* Бирелгән юнәлеш белән төньякка таба булган юнәлеш арасындагы почмак. *Азимутны компаска карап билгеләү*

3) Җир өсте яссылыгы буенча карта һәм компас ярдәмендә билгеләнгән хәрәкәт юнәлеше. *Укучы А пунктыннан Б пунктына 360° азимут буенча 100 м юл узган*

4) *күч.* Иҗтимагый хәрәкәттә аерым бер тенденция, үсеш юнәлеше. *М.Худяков, Л.Гумилёв кебек берничә намуслы тарихчы гына дәүләт машинасының гомуми юнәлешен, азимутын үзгәртә алмадылар.* Т.Галиуллин

**А́ЗИЯ** *и. бор. гр.* Җир шарындагы алты кыйтганың (континентның) берсе. *Җир шарында алты кыйтга, Аның берсе – Азия.* Ш.Галиев. *Журнал сәхифәләрендә мөселман дөньясы, аның күренекле шәхесләре, дини бәйрәмнәр һәм чаралар да даими игътибар үзәгендә. Кытайдагы хәлләр, көньяк-көнчыгыш Азиядәге мөһим вакыйгалар да мәҗмугадан читтә калмый.* Казан утлары

**А́ЗИЯЛЕ** *и. к.* **азиат.** *Тарихта тагын Сиипион Азияле билгеле.* Н.Макиавелли

**А́ЗКАНЛЫЛЫК** *и.* Төрле сәбәпләр белән кан югалту, эритроцитларның күпләп үлүе, гемоглобин кимү, туклану бозылу һ.б. аркасында, кызыл кан тәнчекләре азаю белән характерлана торган авыру; анемия. --- *җитәрлек ашамау, кайбер йогышлы авырулар, күп кан югалту, сөяктәге кызыл җелекнең функцияләре бозылу да азканлылык килеп чыгуга сәбәп булырга мөмкин.* Биология

**АЗЛАП** *рәв.* 1) Аз-аз гына итеп, бүлеп-бүлеп, аз өлешләр белән. *Калай кружкага азлап кына салып, бүтәннәргә дә бирдек.* А.Таһиров

2) Акрынлап, вакытлар үтү белән. *Шигырьләрем азлап кына булса да язылa, җыела торды, басыла барды.* Р.Ягъфәров

**АЗЛА́П-АЗЛАП** *рәв. к.* **азлап**. *Тик күп тә үтми, кияү кешенең әлеге мут, кырыс, усал яклары үзенең барлыгын башта акрын-акрын, азлап-азлап, аннан күпләп-күпләп, тиз-тиз сиздерә башлады.* С.Поварисов

**АЗЛЫК** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса аз булуы, җитмәве; җитмәүчелек. *Үзебезнең завод конторындагы курьер жалованьесы азлыктан ташлап чыгып китте.* Ш.Камал. *Кемне сүгәргә?.. Ул җир азлыктан авылны ташлап китте, заводка эшкә керде.* Ш.Камал

2) Аз санлылык; нәрсәнең дә булса саны, микъдары аз булу, җитәрлек булмау. *Ничек куандыра бәгъзеләрне Татарларның саны азлыгы.* Н.Әхмәдиев

**А́З-МАЗ** *рәв.* 1) Азлап кына, бик аз, бераз. *Гәрчә анда тумасам да, Мин бераз торган идем. Җирне аз-маз тырмалап, Чәчкән идем, урган идем.* Г.Тукай. *Узган-барганда һаман миңа төшеп, аз-маз булса да --- биреп китәләр.* Г.Камал. *Ничек болай бик ансат сөйли бу чибәр егет? Аз-маз булса да белепме әллә?..* Г.Бәширов

2) Билгеле бер дәрәҗәдә, өлешчә, беркадәр. *Колын үсеп, җиңел-җилпе ат эшенә ярый башлагач та, Ишмай аның әнкәсен, аз-маз симертеп, сугымлыкка сатты.* Ш.Камал. *Ул авылда үзенең булачак диплом эшен аз-маз караштыргаларга гына исәпләгән.* Г.Әпсәләмов

**А́З-МАЗЛАП** *рәв. к.* **аз-азлап.** *Нәкъ менә 90 нчы еллар башында үзәк телевидение, аз-мазлап, Көнбатышта барган спорт чараларын күрсәтә башлады.* Ялкын. *Кемнеңдер аз-мазлап күрсәткән ярдәме дә күлгә өстәлгән тамчы гына.* Шәһри Казан

**АЗМАН** I *и. зоол.* Чын шөпшәләр семьялыгыннан, үзләренең шарсыман ояларын агач куышларында ясый торган зур зәңгәрсу корт; төклетураның зурысы; божан. *Азманнарның умартачылыкка зарар китерү очраклары бар.* Биология. *Азман бик авырттырып чага*

**АЗМАН** II *и.* **1.** 1) *биол.* Ике төрле хайван кушылудан барлыкка килгән токымсыз хайван, гибрид (мәс., *ат белән ишәк, бүре белән эт кушылудан*)

2) *күч. сөйл.* Азгын, бозык кеше. *Әби сүзе... Җилдән туган, азман калдыгы, диде.* С.Сабиров

**2.** *с. мәгъ.* Катнаш нәселдән туган; токымсыз. *Азман мал. Азман ат*

**А́ЗМЫ-КҮПМЕ** *рәв.* 1) Бераз, беркадәр, аз гына булса да, зур булмаган

күләмдә. *Мәйпәрвәз байлыкның да читен генә булса да күреп калган, азмы-күпме, рәхәт тормышны да татыган.* Ә.Еники. *Аның [Җәмилнең] әнисе үги, келәтләрендә азмы-күпме он запасы бар, алар ара-тирә ипи салалар ---.* М.Мәһдиев. *Ул, улыннан килгән азмы-күпме акча белән, авылда шактый авыр гомер кичерә.* Ә.Фәйзи

2) Билгеле бер дәрәҗәдә, өлешчә. *Аның белән азмы-күпме килешергә дә мөмкин.* Ш.Камал. «*Инкыйраз*» *авторының эшчәнлеге белән азмы-күпме таныш булган һәр кешегә бу төр гаепләүләрнең чынбарлыкка туры килмәвен аңлау һич кыенлык тудырмый.* Х.Миңнегулов. *Әгәр дөнья халкыбыз турында азмы-күпме хәбәрдар икән, безне күбрәк Җәлил (Муса Җәлил) буенча беләләр.* Мәдәни җомга

**АЗНА́У** *ф. диал.* Көчле тавыш белән кешнәү. *Азнаган айгырның өерен күр.* Мәкаль

**АЗО́Й ЭРАСЫ** *и.* Җирнең геологик тарихында органик тормыш булмаган иң борынгы дәвер

**АЗО́Т** *и. гр. хим.* Атмосфераның зур өлешен тәшкил иткән һәм үсемлекләр туклану өчен төп чыганак булып торган иссез, төссез газ. *Бактерияләр үлгәннән соң, органик матдәләрдәге азот, минеральләшеп, үсемлекләр файдалана алырлык формага килә, һәм туфрак азотка баетыла.* Биология. *Һава (күләме буенча) 78% азоттан тора*

**АЗОТЛА́У** *ф.* Азот, азотлы матдәләр белән туендыру, азот кертү (мәс., туфракка)

**Азотлап бетерү** Тулысынча, бөтенләй азотлау

**Азотлап тору** 1) Даими рәвештә, һәрвакыт азотлау

2) Әле, хәзерге вакытта азотлау. *Борчак чәчелгән басуны икенче елда азотлап торуның кирәге юк.* Татар иле

**Азотлап чыгу** Барысын да башыннан ахырына кадәр азотлау

**АЗОТЛЫ** *с.* Составында азот булган, азот катнашкан. *Азотлы ашламалар күбесенчә гидротукландыргыч аша кертелә.* Борынгы Калатау итәгендә. *Азотлы һәм калийлы ашламалар суда башкаларга карганда тизрәк эри*

**АЗСЫНУ** *ф.* Аз күрү, җитәрлек дип санамау, канәгать булмау. – *Мә, сиңа бүләгем булсын, азсынмыйча кабул ит, – диде ул, кулындагы әчмуха чәйне карчык алдына куйды.* Г.Минский. *[Егет:] Мин, Гомәр абзый, бу турыда әти белән киңәш-табыш итеп карыйм әле. Жалованьены азсынырлар азсынуын да инде, эш өметле, дигәч, тагы ни әйтерләр.* Ф.Әмирхан. *[Кыз] Форточкадан кергән һаваны азсынып, тәрәзәсен киереп ачып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**Азсынып тору** Аз дип санап туктап калу; аз дип уйлап, икеләнеп калу. *Биргән бәягә риза булмыйча, азсынып тору*

**АЗУ** *ф.* 1) Азгынлыкка бирелү, бозык (яман) юлга керү, әхлаксызлану. *Егетнең анасы бу саф дуслыкны кайдандыр ишетә дә, углым азган икән, Казанда әллә ниткән мөселман марҗалары белән сихерләнеп йөри икән, ди.* Г.Ибраһимов. *Мин, имеш, азам, Мин, имеш, тузам; Гөнаһым – тузан, Тау кебек – җәзам…* Ш.Бабич

2) Үз-үзен тотышы начарлану, тәртипсезләнү. *Бала азар булса да, ана бизәр түгел.* Әйтем

3) Нинди дә булса процесс көчәеп китү, үсү. --- *аның [Батырша] турында роман иҗат иткән Җәмит Рәхимов сүзләре белән әйтсәк, мөселманнарны чукындыру иң нык азган бер вакытка туры килә.* К.Нәфыйков // Начарлану, көчәеп китү (авыру, яра турында). – *«Җаны азгынның тәне дә азгын» дигәннәре дөрес. Бәләкәй генә җәрәхәте, азып, башына җитте, – дип уфтана-уфтана, әкият сыман сөйли иде.* Ш.Янбаев

4) Нинди дә булса бер эшкә омтылу, нәрсә дә булса эшләргә ашкынып, ярсып тору. *Арслан йөрәк, никтер, Азган йөрәк, никтер, Тын тибә.* М.Җәлил

5) *сөйл.* Артык үсеп китү (үсемлекләргә карата). *Суган кыякка азган. Бәрәңге сабакка азган*

6) *диал.* Үрчү, сан һәм күләм ягыннан таралып, артып китү. *Ул вакыттан бирле күпме халык азгандыр…* Мирас

7) Хайваннарда, нәсел үзгәрүдән, яңа токым барлыкка килү

**Аза бару** *к.* **азып бару**. *Ярдәмчеләрнең сөйләвенә караганда, Шамбы аза бара иде: әллә нинди курсларга йөреп, суыткычлар буенча мастер булган, уңайлы эшкә урнашкан.* М.Насыйбуллин

**Аза төшү** Тагын да азу

**Азып бару** Акрынлап, азгынлыгы көчәю. *Күз алдында сәүдә азып бара, Бозыклыкка ничек карышасы?!* И.Гыйләҗев

**Азып бетү** Тәмам азган булу. *[Мулла:] Үткән елгы хәлфәмез дә яхшы кеше иде. Кыш буе ник кенә бер баланы чиертсен! Балалар, ягъни мәсәлән, тәмам азып беттеләр.* Ш.Камал

**Азып йөрү** Даими рәвештә, хәзерге вакытта азган булу

**Азып китү** Уйламаганда, көтмәгәндә, кинәт азу. *Ярчык утыра минем күкрәктә, Гаптелмән абзый, мина ярчыгы. [Гаптелмән]: Докторларга барырга кирәк иде, энем, азып китүе бардыр бит.* Р.Ишморат. *Әминә панарицийның җан өзгеч газаплы шеш булуын белсә дә, моның ише азып киткән рәвешен күргәне юк иде әле.* Г.Минский

**Азып яту** Әле, хәзер азган булу. *Үзгәрәбез яхшы, яманга да... --- Үзгәртәме заман базары? Намуслылар илнең йөгән сөйри, Азып ята әле азары.* М.Шиһапов

**АЗУЛЫ** *с.* Үткен, усал телле

**АЗУ́-ТУЗУ** *ф.* **1.** Азгынлыкка бирелеп, эштән чыгу; бозык юлга керү, әхлаксызлану. *Болай үзе [егет] азып-тузып йөргәнгә охшамаган.* Г.Галиева

**2.** *җый. и.* Һәртөрле азгынлык, әхлаксызлык. *Әдип юл буе Гайнанның яшь егетләрчә зифа буй-сынына, азу-тузуны белмәгән, бозылмаган саф яшьлегенә кызыгып барды.* Г.Бәширов

**АЗЧЫЛЫК** *и.* 1) Нинди дә булса бербөтеннең, берәр төрле төркемнең азрак, кимрәк өлеше, кисәге. *Укучыларның күбесен таратып, азчылык белән монда тик ятарга уйламыйсыздыр бит?* З.Фәйзуллин. *Мондый вазгыятьтә милләтнең күндәм күпчелеге булган кебек, көрәшче азчылыгы да булырга тиеш.* Мәдәни җомга

2) Нәрсәнеңдер саны, күләме ким булу. *Бердән, алар үзләренең азчылык*

*булуларын сизделәр, икенчедән, Габдулланың теленнән курыктылар.* Ә.Фәйзи

**АЗЫК** *и.* 1) Ашау-эчү өчен кулланыла торган продукт, ашамлык, ризык. *Чык беткәнче дип, умарта кортлары шул аланлыкны бизәгән матур чәчәкләрдән бал алырга, үзләренә кышлык азык әзерләргә төшкәннәр.* М.Гали. *Әткәйләр киткәндә катык оеп житмәгән, шуңа күрә азык алмый киткәннәр икән, аларга ашарга илтергә кирәк булды.* Г.Ибраһимов. *Ашны тәмле итәсегез килсә, аңа азыкларны чама белән генә салыгыз.* Татар халык ашлары

2) Ашау-эчү, туклану, тамак туйдыру. *Азык ягы начар тора.* М.Гали. *Азык мәсьәләсендә көймә тагын комга терәлде.* М.Гали. *Юк, теш белән тартып чишә алмаслык бер чи төен булды бу азык мәсьәләсе.* Ә.Еники

3) *күч.* Берәр төрле эшчәнлек өчен материал, иҗат чыганагы. *Алар [агачлар] тирә-якка үзенә бертөрле төс бирә. Художник өчен монда «азык» күп.* Г.Әпсәләмов. *Шагыйрь, язучы, драматург – гомумән, иҗат кешесе, уйлану өчен азык бирә, башкаларны рухландыра.* Мәдәни җомга // Рухи канәгатьләнү хисе, күңелне канәгатьләндергән нәрсә. *Уеннар да уйналып бетә – әйтелмәгән такмак, табылмаган табышмак калмый. Балаларның кызыкка сусаган йөрәкләре яңа азык сорый.* Ә.Фәйзи. *[Мортазин] Миллионнар белән идарә итүдән тәм һәм рухи азык таба, үзен көчле итеп сизә.* Г.Әпсәләмов

**АЗЫ́К БЕРӘМЛЕГЕ** *и.* Азыкның туклыклылыгын билгеләү һәм үлчәү берәмлеге (бер кг коры солының туклыклылык дәрәҗәсенә тигезләштереп алына). *Хәзер азыкларның туклыклылыгын азык берәмлеге белән үлчиләр.* А.Расих

**АЗЫКЛАНДЫРУ** *ф. сир.* Азык белән тәэмин итү, тукландыру, ашату. *Башка ирләр – атларны туарып, азыкландыру, хатын-кызлар өй әйберләрен рәтләп урнаштыру белән шөгыльләнәләр.* Ш.Камал

**АЗЫКЛАНУ** *ф.* 1) Берәр төрле азык кабул итү, ашау-эчү

2) *күч.* Рухи, иҗади канәгатьлек алу. *Октябрьгә кадәр, көрәш ялкыны белән азыкланып, бернichә әсәр язып ташланылган иде.* Г.Камал. *Төркиядә белем алу, гарәп-фарсы телләрен өйрәнү, төрек теле һәм әдәбияты белеме нигезләре белән танышу, төрек әдәбияты һәм әдәби фикер үрнәкләреннән азыклану булачак галимнең филологик карашлары формалашуга зур йогынты ясаган.* Мәдәни җомга

**Азыкланып алу** Тиз арада азыклану. *Юлга чыгар алдыннан, бераз азыкланып алдылар.* Мәдәни җомга

**АЗЫКЛАТА** *рәв.* Азык (азык-төлек) әйберләре белән, натуралата. *Хезмәт хакының бер өлешен азыклата түләү*

**АЗЫКЛА́У** *ф. сир.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса азык бирү, ашату. – *Терлекләр азыкламаганмы әле? – Хәзер чыгам, азыклыйм.* Мирас

**АЗЫКЛЫ** *с.* Азыгы җитәрлек булган, азык мул булган. *Азыклы ат арымас.* Мәкаль

**АЗЫКЛЫК** *и.* **1.** 1) Азык булу. *Чөгендернең азыклыгы*

2) Ашый торган ризык; ашау әйбере. *Мәченең аяк бармакларында тиречел йомшак мендәрчекләр була, шуның аркасында, ул азыклыгына тавыш-тынсыз гына килә ала.* Зоология

**2.** *с. мәгъ.* Азык өчен билгеләнгән, азык итеп әзерләнгән. *Азыклык хайваннар күп булмаса да бар. Печән һәм урак өсләрендә бер тана, ике-өч сарык суярга чамалап торалар.* Р.Гайфуллина. *Кышка азыклык яшелчә әзерләү*

**АЗЫ́КТАМЫРЛАР** *и. күпл.* Тамырларының юанайган өлеше азык буларак кулланыла торган яшелчәләр. *Азыктамырлар төркеменә өч ботаник семьялыкка караган үсемлекләр (зонт чәчәклеләр, алабутачалар һәм әвернә чәчәклеләр) керә.* Яшелчәчелек. *Азыктамырлар чи килеш яхшы сакланалар һәм ел буе халыкның азык рационының аерылгысыз өлеше булалар.* Яшелчәчелек. *Азыктамырларны траншеяларга катлаулап салмаганда, корзинкалардан яки капчыклардан бушатып тутыралар.* Яшелчәчелек

**АЗЫ́К-ТӨЛЕК** *и.* 1) Ашарга яраклы әйберләр, азык продуктлары. *Марат әйткән матур шәл артыннан бик күп нәрсә азык-төлеккә алыштырылган, сандык төбе тәмам коргаксыган.* Г.Гобәй. *Әле аңа нихәтле азык-төлек, кием-салым кирәк.* К.Нәҗми. *Үзәктән бүленеп калган авыл-кышлакларга азык-төлек илтергә кирәк иде.* З.Фәйзи. *Ашыгып, Гомәрнең юл капчыгына оекбашлар, сөлге, яулыклар һәм азык-төлекләр салып йөргән Камилә дә үкси башлый.* Ә.Еники

2) Терлек (мал) азыгы. *Мал-туарны, хуҗалыкта азык-төлек булмаган хәлдә, үлемнән коткарып калу – ул безнең өчен зур сынау, бу – безнең намус эшебез.* А.Расих

**АЗЫМТЫК** *и. диал.* Ялкау, ата ялкау, эшләмичә тик ятучы. *Ул кеше эшкә чыгар микән? Ул азымтык кый*

**АЗЫНДА** *рәв. к.* **аз дигәндә**. *[Бай крестьяннар] --- ярлылардан җыйганнарын бергә кушып, азында бөтен бер шобага белән, кайбер вакыт унар, унбишәр өлеш белән җирдән файдаланалар.* Г.Ибраһимов

**АЗЫНДЫРУ** *ф. к.* **аздыру**. *Балаларны артык азындыру*

**Азындырып бетерү** Тәмам, бик нык азындыру. *Милиционер: «Сез бер дә жалоба бирмичә азындырып бетергәнсез аны», – ди.* Ф.Яруллин

**Азындырып йөрү** Һәрвакыт, бөтен җирдә азындыру. *Хушбуй сибенеп, хатын чит ирләрне азындырып йөрмәсен әле, шулай итсәм, үземә дә өлеш чыгачак.* Ф.Дәүләтбаев

**АЗЫНТЫК** *и диал. к.* **азымтык**. *Хайваннарның да ата заты азынтык була*

**АЗЫНУ** *ф.* 1) Азгынлыкка, бозыклыкка бирелү; бозык кешегә әйләнү. *Ул азынып, тугарылып йөри, Азып тузу аңа – мәртәбә!* Зөлфәт

2) Артык тәртипсезләнү, тыйнаксызлану; шуклыкка бирелү. *Үзе һөнәр училищесын тәмамлаган Моратка әлеге кыланышлар ят булмаса да, бу дәрәҗәдә үк азынуны күргәне юк иде әле.* З.Фәйзуллин // Рәте китү, рәтсезләнү, бозылу, көе китү, тәртибе чуалу. *Кичке якка сыерлар азындылар, төрлесетөрле якка таралыша башладылар.* А.Хәсәнов

3) Оятсызлану, оятсыз рәвештә эш итү; юньсезләнү. *Бәяләр дә шашынды,*

*бәяләрдән битәр түрәләр азынды, майларына чыдаша алмый үтләделәр.* Н.Хәсәнов. *Хәзер бит ирләр азынды. Хатыннары туйдыра, ә аларның эше рәхәт, дандарага җон тетеп йөриләр шунда.* М.Мәһдиев

4) Артык күп булып үрчү. *Кемнәрнеңдер чүп агач – Америка өрәңгесе утыртып, хәзер шул агачның, азынып, урманнарга үтеп керә башлавын каһәрли.* А.Гыйләҗев

**Азына бару** Торган саен, көннәнкөн ныграк азыну. *Ул шулай кыланган саен, Кәрәм азына барды.* Ф.Садриев

**Азына башлау** Азынырга тотыну. *Соңгы вакытта Мансур артыгын азына башлаган иде.* Т.Галиуллин

**Азына төшү** Бераз, берникадәр азыну

**Азынып алу** Кыска гына вакыт эчендә азыну. *Азынып алсаң да, хатаң тану кирәк.* Ш.Җиһангирова. *Инде килеп, син дә исәпләп кара: олыгайгач, ир кеше бер тапкыр азынып ала. Табигать законы ул.* М.Мәһдиев

**Азынып бетү** Бөтенләй, тәмам азыну; барысы да азыну. *Аннары: – Акчаны күп каера болар, братан, акчаны күп «төшереп» азынып беткәннәр, синең тиеннәрең белән хисаплашып та тормыйлар, – дип өстәде.* М.Шаһимәрдәнов

**Азынып җитү** Тәмам азыну; азынуның чигенә җитү

**Азынып йөрү** Озак вакыт дәвамында азынган булу. *Оятсыз, таңга чаклы азынып йөрүеңнең азагы шул булдымы?* Г.Галиев. *Эчеп, азынып йөргән икән, җәзасын алган, штраф түләгән. Унбиш тәүлек утырган, хөкем ителгән.* М.Насыйбуллин

**Азынып калу** Азынырга өлгерү. *Һай, җүнсезләр, көш, дим, көш, азынып калыгыз, киләсе елга берегезне дә калдырмыйм, чисти үзәкләремә үттегез, гомерләрем әрәм узды...* М.Мәһдиев

**Азынып китү** 1) Соңгы вакытта азыну. *[Сафа кебек] Кабахәт җаннарга шулай кирәк, ярлы кызларны мыскыл итмәсеннәр. Бик азынып киткәннәр иде.* А.Шамов

2) Билгеле бер вакыттан алып азыну

**Азынып кую** Көтмәгәндә, кинәт азыну

**АЙ** I *и.* 1) Кояш нурлары яктылыгын чагылдыра торган һәм Җирнең иң якын табигый иярчене булган күк җисеме. *Ай янында якты йолдыз, Минем йолдызым гына.* Җыр. *Бер кырыйда туган ай, урман эчләренә моңсу ак нурын сибеп, әкрен генә йөзә.* Г.Әпсәләмов. *Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов әгәр булса Кояш, Ай кеби, Нурны алардан икътибас иткән бу баш.* Г.Тукай

2) Астрономик елның һәрберсе аерым исем белән йөртелә торган уникедән бер өлеше. *Остабикә үзен, озын, озак бураннар, каты суыклардан соң, кинәт кенә май аеның иркәле кояшы алдына барып чыккан әдәм кебек хис итте.* Г.Ибраһимов. *Май айлары. Бөтен дөнья яшел киемнәргә киенгән.* Һ.Такташ. *Ул китте, дөньяны февраль аеның тәртипсез, мәгънәсез бураннары басты, аннан март аеның иләмсез, холыксыз җилләре исте.* М.Мәһдиев

3) Календарь елның бер ае чамасындагы вакыт арасы. *Шул йомшаруның башлануына бер ай дигәндә, картның, чыбыркы тотып, сыер артыннан йөрерлек чамасы бөтенләй бетте.* И.Гази

4) Мәчет манарасының очына куелган ураксыман әйбер. *Кичә җомга намазы да булмый калган. Ае кыйблага карамагач, дөрес булмый, ди.* Г.Гыйльманов. *Бабаларыбыздан мирас булып калган изге намаз йортларының айлары сындырылган, манаралары киселгән, михраблары кубарылган, алар йә клуб, йә мәктәп биналарына --- әйләндерелгән иде.* Р.Әмирхан

5) Төрки халыклар яши торган кайбер илләрнең (мәс., Төркиянең) флагына төшерелгән рәсем

6) Кызыл ай җәмгыяте эмблемасындагы бер деталь

◊ **Ай белән көндәй, һәркемгә бердәй** Һәркемгә яхшы һәм һәркемгә кирәкле, гадел кеше турында. **Ай бирде, кояш алды** Күзгә бик азга гына күренеп, тиз югалган яки яшьли үлеп киткән якын кеше турында. **Айга көлмәк киертмиләр** Табигый матур, сау кешене артык киендерәсе-ясандырасы юк, мәгънәсендә. *Зарар юк, матур булгач, киенмәсәң дә ярый ул, айга күлмәк киертмиләр. Бар, тизрәк чыгып ач!* Г.Камал. **Айга сикерү** Азу-тузу, чамадан ашу, ашкыну, гайрәте ташыганнан нишләгәнен белмәү. **Айга утыз көн ирон.** Бушка, түләве булмаган хезмәт көне язылуга, я тамак ялына эшләп йөрү хакында. *Син ничегрәк соң? Айга утыз көн эш хакы алып эшләп йөрисеңме әле?* **Айда бер, кайда бер, дигәндәй** Ара-тирә, сирәк кенә булгалап үтүче, сирәк күренүче тансык әйбергә карата. *Айда бер, кайда бер, дигәндәй, театр килә.* Социалистик Татарстан. **Айдан ару бул, судан сылу бул** Айдан пакь, гөнаһсыз, чиста бул, борылып аккан су-елга кебек ямьле, матур бул, дигән мәгънәдә. **Айдан кыеп алгандай** Түгәрәк тулган айның бер кырыен пычак белән кыеп, кисеп алгандай. *Матур-матур көннәрдә кулына, айдан кыеп алгандай, тәмле кыерчык ипи тотып, безнең тәрәзәгә карый-карый, көлә-көлә, рәхәтләнеп чәйни-чәйни урам уза.* Ә.Баянов. **Айдан төшкән кеше кебек** Үз ишләре арасында үзен чит-ят кеше кебек тою, тартынып утыру. **Айдан төштеңме әллә?** Дөньядан, тормыштан хәбәрсез, ят сүзләр сөйләп, сәер сораулар биреп утырган кешегә карата әйтелә. *Әбәү, айдан төшкән кеше кебек сөйләшеп утырмачы.* Р.Төхфәтуллин. **Ай дисәң – авызы, көн дисәң – күзе** Шул дәрәҗәдә матур, шул дәрәҗәдә нурлы. **Айдыр әгәр** Үз сүзенә, вәгъдәдә тугрылыгына Айны таныкитеп ант итү. **Ай йөз** Айның нурлылыгын йөзгә күчереп, берсе урынына икенчесен алыштырып әйтү. *Әгәр җәннәттә күрсәм бән йөзеңне, күрмен ай йөзендә үз йөземне.* Г.Тукай. *Аның кем ай йөзендә миң яратты. Аягына сачыны тиң яратты.* Мәхәббәтнамә. **Ай йөр, аман йөр** Юлга озатканда әйтелә торган теләк. **Ай киткән, ел киткән, энә бue җир киткән** Торган җиреннән беркая да китмәүгә, һаман бер урында таптануга карата әйтелә. **Ай күрде, кояш алды** Тиз арада күренеп китү, бик тиз юкка чыгу. *Мине исә ай күрде, кояш алды.* М.Мәһдиев. *Бу тикле булган, өлгер егетләрне күргәнем юк иде. Ай күрде, кояш алды, дигәндәй, кай арада җыелып та бетгегез.* Р.Мөхәммәдиев. *Тукай бик яшь-*

*ли әрәм булды, безнең әдәби күгебездә бик тиз балкып күренеп кенә үтеп китте, ай күрде, кояш алды.* Тәрҗеман. *Күзләремә күренеп кенә калды. Әйтерсең ай күрде, кояш алды.* Мәдәни җомга. **Айны итәге белән каплар иде** Комсыз, барын да басып алырга, үзенеке генә итәргә омтылучы; эгоист. **Айныкын айга җиткерү** Айлык хезмәт хакын ай ахырынача тотарга җиткерү. **Айның ундүртенче кичәсе кебек** Яше җиткән матур кызның яки егетнең нурлы йөзен айның яңа гына тулып торган чагына тиңләп әйтелә. **Ай үсәсен көн үсә** Әкияттәгечә тиз үсә, зурая, мәгънәсендә. *Ул, әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн асыллана бара.* **Ай юктан чыраг** Төп урын тоткан әйбер үзе юклыктан, икенче бер затсыз әйбергә канәгать булып торырга мәҗбүр булу

**АЙ** II *ы.* 1) Авырту, сызлану, әрнү, газаплану һ.б.ш. хисләрне белдерә. *[Зифа:] Учларым кабара язды бугай. Ай, --- кара әле, Сылу, чынлап та кабарып чыккан.* М.Фәйзи

2) Соклану, шатлану, гаҗәпләнү, якын күрү, үз итү хисләрен белдерә. *[Ана:] – Ай балам! Бу җирләрдә ризыкларың бетмәгән икән әле, – диде дә кочаклап катты.* Г.Ибраһимов. *– Ай Аллам! – ди карчык, җанланып китеп. – Карасана, танымый да торам ласа, Әхмәтвәли бәпкәм, син икәнсең.* Ә.Еники

3) Эч пошу, кайгыру, борчылу, ачыну, үкенү хисләрен белдерә. *Ай, түрәм, ай! Безне кемгә калдырдың, ай!* Г.Ибраһимов

4) Нәрсә дә булса теләү, зарыгу хисләрен белдерә. *Ай, тагын бер күрергә иде үзен, айдай матур йөзен!* Н.Исәнбәт. *Ял итәргә вакыт юк. Иртәгә тагын эшкә барасы бар. Ай, урыннан тормыйча, атна буе ял итәр идем дә соң...* Г.Шәрипова

5) Канәгатьсезлек, риза булмауны, икеләнүне һ.б.ш. хисләрне белдерә. *[Биктимер:] Ай бу Нургалине, вакытсыз өйләнеп бөлдерде бит атасын.* Т.Гыйззәт. *Ай, тәмам сагыз булдыгыз ла соң, яшьләр, сөйлә дә сөйлә, дисез, тын алырга да бирмисез.* А.Шамов. *«Ай, кыйммәт сорый әткәй! – дип куырылып калды Хәмит һәм калтыранган тавыш белән сорады: – Кемгә?»* Г.Шәрипова. *Ай-й, җил керә башлады; һава бозыла дип әйтимме?* Р.Ишморат

6) Озын җырларда ялгау өчен музыкаль фраза буларак кулланыла. *Ай бормалы, бормалы ла, Бормалы су буйлары.* Җыр. *Ай йолдызым, йолдызым, Йолдызым – Рушаным, Син йөргән гөл бакчасына керергә тырышамын.* Җыр. *Үз бәхеткәйләрең, ай, булмаса, Байга хезмәт итеп кем ярый.* Җыр

7) Шигырьләрдә иҗек санын тутыру өчен килә. *Ай нужа, вай нужа, Кемнәр башыннан уза!* Н.Исәнбәт. *Ай Дилбәр, вай Дилбәр! Йөзең гөлгә тиң, диләр*

◊ **Ай, рәхмәт төшкере, кулыңа гөлләр үскере** Бер-бер ярдәм күрсәткән кешегә рәхмәт теләге

**А́ЙАРА КӨН** Иске ай бетеп, яңа ай туганчы булган вакыт; ике ай арасы

**АЙБАГАР** *и. диал.* Көнбагыш. *Ягу ягына һич тә аптырамадык, әниебез чарасын күргән: бәп-бәләкәй мичебезгә айбагар сабагы, камыл ташып, өйне җылы тотарга иялашеп киттек.* К.Миңлебаев

**АЙБАЛТА** *и. тар.* Ярым айга охшашлы, үткен йөзле, озын саплы борынгы сугыш коралы. *Капкадан үткәндә, каравыл алыплар айбалталарын читкә алдылар.* М.Хәбибуллин

**АЙБАЛЫК** *и.* Энәкорсаксыманнар отрядыннан, гәүдәсе як-яктан кысынкы, тешләре тоташ пластинкадан торган, койрык йөзгечe булмаган балык; *русчасы*: **луна-рыба**. *Айбалыкларның ите ашарга яраксыз.* Биология

**АЙБАЛЫКЛАР** *и. күпл.* Энәкорсаксыманнар отрядыннан, озынлыклары 3 метрга кадәр җитә торган, гәүдәләре як-яктан кысынкы, кысласыманнар, кальмарлар белән туклана торган, аз хәрәкәтләнүчән океан балыклары семьялыгы; *русчасы*: **луны-рыбы**. *Айбалыклар бик үрчемлеләр.* Биология

**АЙВА** *и. төрки бот.* Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, көньякта үсә һәм җимеш бирә торган агач һәм аның эре ачы җимеше. *Айва, җиләк-җимеш культурасы буларак, Урта диңгез буйларында, Көньяк Америкада, Австралиядә үстерелә*

**А́Й-ВАЙ** *ы.* **1.** Ризасызлыкны, шелтәләүне, нәрсәдән дә булса канәгать булмауны, авыртуны, сызлануны, куркуны һ.б.ш. тойгыларны белдергәндә кулланыла. --- *кичкән хәлләрне сөйләп биргәч, ике кулы белән эре сөякле яңакларын кысып тоткан директор Фенстер теше сызлаган кешедәй ыңгырашып куйды: – Ай-вай-вай-й-й!..* Р.Вәли. *Күзләрем йомылмый, Авызым ачылмый. Ай-вай тешем, вай, тешем! Сызлавы басылмый...* Ш.Галиев

**2.** *и. мәгъ.* Ризасызлык, канәгатьсезлек, зар; шелтә. *Ай-вайлары күп булды. Ай-вайлары бөтен ишегалдына ишетелеп тора*

◊ **Ай-ваена куймау** Киреләнеп торырга ирек бирмәү. *Алай итеп булмаган, Ай-ваена куймаган.* Бәет. *Әнисе аны, ай-ваена куймый, кыстап чишендерде дә ләгәнгә утыртты.* Ә.Фәйзи. **Ай-вайга карамыйча (карамастан)** 1) Бернәрсәгә карамыйча, беркем яки бернәрсә белән дә хисаплашмыйча, беркемнең дә сүзен игътибарга алмыйча. *Банкетлары да шул бүлмәдә узды, шунда ук, ай-ваема карамыйча, кунарга да калдырдылар.* К.Миңлебаев. *Бераз икеләнеп торганнан соң, әти, әнинең ай-ваена карамыйча, безнең сыерны, кышлый асрап чыгу өчен, җизниләргә биреп җибәрергә булды.* Ф.Хөсни; 2) Кемнең дә булса каршы килүенә карамыйча, нәрсәдер эшләргә мәҗбүр итү. *Ул чат ябышты дәрвишкә, ай-вайга да карамады, аны кунакка алып китте.* Мирас. *Ләкин, ярсынып, Фәүрия килеп керде һәм, һичберсенең ай-ваена карамыйча, Гөлсәйдә белән үзенең барачагын белдерде.* Ф.Яруллин. *Бикә белән Морза, ананың ай-ваена карамыйча, теге миңле кызны үзләре белән алып киттеләр.* Г.Галиев. **Ай-вай итү** Берәр кайгы, бәла-каза, үлем-җитем килгәндә елау-сыктау яки куанычтан үзара шаугөр килү. *Иртәгәсен сыерым җитәкләп мин, Алып киттем күрше базарга; «Ай-вай» итеп, үкереп-үкереп елап, Хатын егылып калды абзарда.* Ш.Маннур. **Ай-вай килү** *к.* **ай-вай итү**. **Ай-вай салу** *к.* **ай-вай итү**

**АЙ-ВАЙЛА́У** *ф.* Нәрсәгә дә булса каршы килү, нәрсәдәндер риза

булмыйча, еламсырап кычкыру. *Бу көнне итле аш пешкәнен шулай артистланып күрсәтсә дә, ай-вайлап чакырсак та, табынга калмады: – Нәкыя апагызның токмачы казанда сикереп калды, булмый, парин.* Б.Рәхимова

**АЙВАН** *и. фар.* Беседка, күшәк. *Кичләрен Рушан белән үги әтисе уллары үзбәкчәләтеп ясап куйган айванда – урысча әйтсәк, беседкада утыргалыйлар...* Р.Мирхәйдәров

**АЙГАК** *и. диал.* Ялган шаһит; ялачы, әләкче

**АЙГЫЛДА́У** *ф.* **1.** Атның көчле, көр тавыш белән кешнәп аваз салуын белдерә. *Айгылдап кешни айгырлар, Ярларын ташлый сулар. Без киткәч тә дөнья шулай Бик азга ямансулар.* М.Галиев

**2. айгылдап** *рәв. мәгъ. сөйл.* Ихахайлап, ямьсез тавыш белән кычкырып. *Тирә-якта утыручы кешеләр айгылдап көлә башладылар.* Р.Батулла

**Айгылдап алу** Кыска гына вакыт эчендә айгылдау

**Айгылдап тору** Әле, хәзер айгылдау; бертуктаусыз айгылдау

**АЙГЫР** *и.* Ата җенестәге печтерелмәгән ат. *Айгырга аз төя дә каты йөр, алашага күп төя дә җай йөр.* Мәкаль. *Әйтик, хуҗаның үз улы Таһир урамнан кирәсе килмәгәндә, Муллагаян, еш кына, кола айгырга атланып, бияләрне, тайларны Комачка сугарырга төшә.* Ә.Еники. *Бигрәк тә нәсел айгыры күзен яндыра аның. [Сәхиянең] Шул айгырга атланып, авылны урыйсы, болыннарны иңлисе килә.* Ф.Яруллин. *Өлкән өйнең артында көмешләнгән иярле сылу айгыр, көннең кызулыгыннан, йөрүдән тирләп, башып чайкап тора.* Г.Ибраһимов

◊ **Айгыр ашак** Тик тора алмаучы, анда-монда атланырга торучы кыбырсык кеше. **Айгыр кешнәгәндәй** Шаркылдап, ихахайлап. *Хәлфә айгыр кешнәгәндәй көлеп җибәрә.* Ә.Еники. **Айгыр кытыгын качыру** Җигелмәгән, кулга өйрәнмәгән айгырны, башлап җигеп, хәлен-дәрманын алып, авызлыкка күчәргә мәҗбүр итү. *[Әти] Бүген айгырның кытыгын качырып карарга кирәк булыр, диде.* Ф.Хөсни

**АЙДАЛА** *и. иск.* Ачык җир, киң дала. *Туксан башлы урданың Туксан углы, бер булып, Айдалага килгәндә, Алар белән ант тотты.* Дастан

**АЙДА́Н-АЙГА** *рәв.* Һәр ай саен, даими рәвештә. *Хәрби комиссариат таныклыгы нигезендә Юлдаш өчен билгеләнгән кырык бер сум пенсиясе генә айдан-айга килеп тора.* Казан утлары. *Айдан-айга посылка салып тору*

**АЙДА́Р-АЙДАР** *с. сир.* Тап-тап, ала-кола (мәс., *бит, тән*)

**АЙДАРЛАНУ** *ф. сир.* Бөдрәләнү, көдрәләнү; бөтеркәләнү; бөтеркәчләнеп тору. *Айдарсылу, маңгай чәчең айдарланган, Күзләреңдә гыйшык буы кайнарланган.* Ш.Бабич

**АЙДАШ** *и.* Бер үк айда туган кешеләр. *Без аның белән айдашлар: икебез дә май аенда туганбыз.* Мирас

**АЙКАЛДЫРУ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **айкалу**. *Ерганак ачыклыгыннан шашып искән җилләр тәүдә чокыр төпкелендәге карт өянкегә килеп бәйләнәләр. Аны айкалдырып, чайкалдырып үтәләр дә юллары уртасында җайсызлап утырган безнең өйгә ташланалар һәм бертуктаусыз сызгырырга, чыелдарга тотыналар.* С.Кудаш

2) *күч.* Берәр фаҗига, хәвефле хәбәр нәтиҗәсендә ыгы-зыгы тудыру, бик нык дулкынландыру, ярсыту

**Айкалдырып җибәрү** Айкалырга этәргеч бирү

**АЙКАЛУ** *ф.* **1.** 1) Су, җил, өермә һ.б. тәэсирендә бер яктан икенче якка чайкалу, дулкынлану, тибрәнү. *Айкала суларыбыз, чайкала суларыбыз. Кайсы йолдызлар астында йөрегән юлларыгыз.* Җыр. *Илсөяр ыңгырашырга теләп тыпырчынды, ә күзләре асты өстенә килеп айкалган Агыйделдән әле һаман да әтисен эзли иде.* Г.Гобәй. *Җил дә үти үзенең эшен: Кырда дулкын айкала.* Ә.Ерикәй

2) Ыгы-зыгы килү, кайнашу, мәш килү. *Әпипәнең күләгәсе һаман клуб янында айкала иде.* Г.Бәширов. *Бу вокзал тирәсендә заграницага китүчеләр һәм аннан кайтучылар айкалалар.* Г.Гали. *Һавада, чәрелдәп кычкыра-кычкыра, акчарлаклар айкала.* А.Шамов. *Халык һаман айкала, яшьләр бер-берсенә сыенып үтә.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Туу, уяну, барлыкка килү (хис, уй һ.б.ш. турында). *Аның башында бик әшәке уйлар айкалуын берәү дә белми...* Г.Әпсәләмов. *Давылдагы диңгез дулкыныдай Айкалалар уйлар башымда.* Ф.Кәрим. *«Дустының әтисенә, нигезенә хөрмәт, ихтирам күрсәткән бу бөек затны нинди гамәлләр белән олылап була икән?» дигән сорау аның баш миендә айкалды.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Ашкыну, йөрәксенеп, нәрсәгәдер омтылу, иләсләнеп китү. *Вадим белән Зуфирә ашкынулы өермә эчендә айкалдылар.* М.Маликова. *Күңел айкалу*

**2. айкалып** *рәв. мәгъ.* Дулкынланып, борчылып, ашкынып. *Йөрәге айкалып типкән хәлдә, [Гомәр] агитаторлар исемлегендә үз исемен көтте.* Р.Шәйхетдинов

**Айкала башлау** Айкалырга тотыну. *Тын гына яткан караңгы урамда күренеп, тагын югалып, кечкенә утчыклар айкала башлады.* Г.Бәширов

**Айкала төшү** Тагы да ныграк айкалу; бераз айкалу

**Айкалып алу** Кыска вакыт эчендә тиз генә айкалу. *Чүкеч һавада айкалып алды.* Ә.Гаффар

**Айкалып бетү** Тәмам, бик нык айкалу. *Актарылсын, куптарылсын, дөнья бетсен айкалып!* Р.Гайфуллина

**Айкалып йөрү** Анда-монда килеп, бик озак айкалу. *Ишекләре каерылып ташланган буш амбарлар эчендә көзге җил айкалып йөри.* И.Гази. *Түр тәрәзә ачык иде, Бер чыпчык очып керде. Керде керүен, чыгалмый Өйдә айкалып йөрде.* С.Шакир

**Айкалып китү** Билгеле бер моменттан, нинди дә булса сәбәп белән кинәт айкалу. *Салихов белән Байдамшинның көчәнмичә, кыланмыйча җырлаулары да әсирләрнең күңелләренә бик хуш килде, йөрәкләре айкалып китте.* Г.Әпсәләмов. *Габделбәрнең җаны айкалып китте, бу турыда берни дә белмичә яшәгән Фатыймасын кызганып, үзәге өзелеп куйды.* Казан утлары

**Айкалып кую** Кинәттән, кыска гына вакыт эчендә айкалу

**Айкалып тору** 1) Туктаусыз, әледән-әле айкалу

2) Әле, күз алдында айкалу. *Ялкау килен Пәрихәне каенанасы беркөнне җитен йолкырга җибәргән. Җитен җилдә су кебек йөгереп уйнап, айкалып тора икән.* Н.Исәнбәт

**АЙКАЛУ́-ЧАЙКАЛУ** *ф.* 1) Айкалу һәм чайкалу, буталу. *Дистә ярымлап тимер тырма, урам киңлегедәй урынны иңләп, дулкын өстендә баргандай айкала-чайкала, җир өстенә кереп китте.* Г.Бәширов. *Имәнлегә автобус көтүчеләр, бер урында айкалып-чайкалып торганнан соң, койма күләгәләренә, вокзал баскычларына җыелышып утырдылар.* Г.Мөхәммәтшин

2) Як-якка аву, тигез бармау, алпан-тилпән килү. *Тиз-тиз генә җыендылар да тагын кузгалдылар. Исерек кеше кебек айкалып-чайкалып барган Майяга Гөләшне бирергә курыкты Хәлим.* Г.Гыйльманов

3) Иләсләнү, ашкыну, каядыр омтылу. *Габделбәр шактый вакытка сүзсез калды. Күңеле айкалган-чайкалган иде.* Казан утлары

**АЙКАЛЫШ** *и.* 1) Көчле чайкалыш, актарылыш. *Кергән шәпкә су салкыны, дулкыннар айкалышы, баштарак, тәнеңне куырып алгандай итә.* Р.Низами

2) *күч.* Ыгы-зыгы, шау-шу килеп, ары-бире чабышу

**АЙКАЛЫШУ** *ф.* Төрлесе-төрле юнәлештә тәртипсез хәрәкәт итү. *Базар тулы халык айкалыша*

**Айкалышып алу** Кыска гына вакыт эчендә, берара айкалышу

**Айкалышып йөрү** Төрлесе төрле юнәлештә айкалышу. *Җилдә егылып төшкән балаларын Коткаручы кошлар шикелле, Айкалышып йөри югарыда Көмеш самолётлар төркеме...* Ф.Кәрим

**Айкалышып кую** Кинәттән, көтмәгәндә, кыска гына вакыт эчендә айкалышу

**Айкалышып тору** Туктаусыз, һаман айкалышу

**АЙКАНУ** *ф.* Селтәнү, кизәнү (кул яки корал белән). *Гәрәй абзый, тәбене айканып ташка бәргән саен: – Менә шулай, менә шулай! – дип, тешен кыса-кыса кычкыра иде.* А.Вергазов

**Айканып алу** Тиз генә берничә мәртәбә айкану хәрәкәте ясау. *Рәшәткә башындагы чыбыркыны алдым да, бер-ике мәртәбә кул язу өчен генә айканып алганнан соң, --- шартлатып җибәрдем.* Казан утлары

**Айканып җибәрү** Кинәт айкана башлау. *Карап-карап торды да минем сумка белән Резедага айканып җибәрде: – Тай моннан, шаркүз! – дип кычкырды.* Л.Гыймадиева

**Айканып тору** Туктаусыз, әледән-әле айкану

**АЙКА́У** I *ф.* Киң итеп төрле якка болгау, ян-якка селтәү. *Госман, чыгу белән, дип әйтерлек, камчысын айкый башлады.* Ф.Хөсни. *Ак бандитлар, кылычларын, сәнәкләрен айкый-айкый, улап, акырып, Җәүдәтләрнең артына төшеләр.* Г.Бәширов. *Гражданнар сугышы чорында аңа атка атланып, кылыч айкап, ярты илне гизеп чыгарга туры килә.* Казан утлары

**Айкый башлау** Айкарга тотыну

**Айкап алу** Кинәт айкау; бер тапкыр селтәп айкау

**Айкап йөрү** Төрле якка, бертуктаусыз айкау. *Империя оныклары әнә Чукмар айкап йөри мәйданда.* Г.Моратов

**Айкап карау** Сынау өчен төрлечә айкау. *Сыек чыбыкны, сызгыртып, һавада айкап карады да егет тирә-якта өзлексез гөҗелдәп утырган шайтан таякларының чукмар башларына, ярсып, кызып, чаж-чож суга башлады.* А.Гыйләҗев

**Айкап тору** Бертуктаусыз айкау

**АЙКА́У** II *ф.* Болгату, астын-өскә китерү, бутау, су, җил, өермә тәэсирендә дулкыннар хасил итеп айкалдыру, хәрәкәткә китерү. *Бакты Аллага [иблис] Шушы ялыныч белән: «Дөнья беткәнче җиһанны айкарым, Бар иман, вөҗданнарны чайкарым».* Ш.Бабич. *Айка, давыл, диңгез өстен, Сал кырларга тавышың.* М.Җәлил. *Әйе, матрос ялы бетеп, эшкә урнашканчы, Иделне бер айкап керергә исәп бар.* Г.Ахунов

**Айкап алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә айкау; бер тапкыр айкаган хәрәкәт ясау

**Айкап йөрү** Астын-өскә китереп, әле анда, әле монда булып айкау. *Дошманның сакчы корабльләре дә тәүлек буенча диярлек диңгезне айкап йөрүдән туктамыйлар.* Г.Әпсәләмов

**Айкап тору** Бертуктаусыз айкау

**АЙКА́У** III *ф.* 1) Астын-өскә китереп эзләү, болгату. *Төнне – көнгә, көнне төнгә катып, бөтен тирә-якны айкадылар.* Г.Ибраһимов. *Эзләмәгән җирем калмады, бөтен йортны айкадым.* Мирас

2) Чагыштырмача зур араны, урынны йөреп чыгу, гизү, төрле урыннарда булу. *Исмәгыйль баба – утыз өч ел буе илләр гизеп, дөнья айкап кайткан илгизәр җан – үзе генә дә ни тора.* Ф.Сафин. *Фронтын айкадым, ачлыгын кичердем, сәнәклеләрнең фетнәсен бастыруда катнаштым.* А.Расих. *Ә ул, минем газизем, инеш буйларын ураган, бергә-бергә йөргән җирләрне ялгыз башы айкаган, бәгырьләрен актарып чыгарган шәфкатьсезлектән иза чиккән.* К.Миңлебаев

3) Күз белән бөтен тирә-якны күзләү, күрү. *Туган авылына ничәмә еллардан соң аяк баскан егетнең хәле аңлашыла: урамда берни күренми, ә аның бөтенесен үз күзләре белән айкыйсы килә.* Мирас

4) Үткәннәрне искә төшерү; нинди дә булса көчле хисләр кузгату. *Кешеләрнең җаннарын айкап, эшләп бетермәгән эшләре барлыгын искә төшереп, үкендереп һәм тетрәндереп агыла матәм моңы.* Г.Ахунов. *Ләкин күңелне айкаган җырны хәтерләмим. Күрәсең, аларның әле миңа тәгаенләнгәне булмаган.* М.Кәрим. *Кыз инде Гафур йөрәген айкамый иде, бүлмәне тутырган башка кешеләрне күрмәгән кебек үк, аны да күрми башлады.* Г.Шәрипова. *[Самат:] – Бу җырың белән җаннарны айкадың, Саимә. Рәхмәт! – диде.* Г.Галиева

5) Әйләндерә-әйләндерә актару. *Кинәт әтием, бик каты ютәлләп, өстәл яныннан сикереп торды. Юынгыч янына килеп, бармагы белән тамагын айкый, үзе гырылдый башлады.* Җ.Фәйзи

6) Араны бозу, аерырга тырышу. *Кара ки, җаным, кара ки, Без кигән караларны; Язгы кар сулары кебек, Айкыйлар араларны.* Җыр

**Айкап алу** 1) Бер тапкыр, кыска гына айкау. *Ул арада урам коймаларын ут яктысы айкап ала.* М.Галиев

2) Кинәттән айкау; бөтен барлыкны биләп айкау. *Тимерхан истәлекләр дөньясына кереп китсә, әйләнеп чыгар дип уйлама – җаннарны айкап алырлык итеп сөйли белә ул.* Г.Ахунов. *Гәүдәсенең һәр хәрәкәте, күкрәк түреннән чыккан калын йомшак тавышы белән йөрәкләрне айкап ала иде ул.* М.Маликова

**Айкап бетерү** Бөтен җирне дә айкау, барысын да айкау. --- *йөри алган яше дә, карты да эзләде Айнурны. Мәктәптә укулар булмады. Укытучылар, укучылар елга буйларын, бакча артларын айкап бетерделәр.* М.Әхмәтшина

**Айкап җибәрү** Кинәт айкый башлау. --- *бер тында бөтен дөньяны яктыртып, айкап җибәргән яшен яктысы күк, күңелгә уелып калыр идемени?!* М.Вәли-Барҗылы

**Айкап йөрү** Төрле урыннарда булырга өлгерү, күп урыннарны айкау. --- *җиде төн уртасында чыгып кит тә җәһәннәмеңне айкап йөр!* Т.Мөбарәков

**Айкап кайту** Бар урынында да булып, бөтенесен дә күреп йөрү. *Әллә шул Арча ягына барып чыгып, бер айкап кайтыйммы, дип тә уйланам.* А.Хәсәнов

**Айкап ташлау** Көтмәгәндә, кинәт, астын-өскә китереп айкау. *Шпионлык карьерасы уңышлы гына алга тәгәрәгәндә, Октябрь иске Россиянең астын өскә айкап ташлады.* И.Гази

**Айкап тору** Даими рәвештә, бертуктаусыз айкау

**Айкап узу** Тоташтан айкау. *Атнаун көн эчендә бөтен Оренбург өлкәсен айкап узып, җил очырган җенле күбәләктәй пыр тузынып, Башкортстан җирләренә барып чыктык.* М.Госманов

**Айкап үтү** *к.* **айкап узу**. *Ярдан күтәрелә торган җирдән кисәк туктап, кире Сакмарга күз ташладым, карашым каршы яктагы шактый калын күренгән урманны айкап үтте.* Ф.Сафин

**Айкап чыгу** 1) Үтәли, башыннан ахырына кадәр, буйдан-буйга айкау. *Мин аның белән Колчак фронтын буйдан-буйга айкап чыктым.* Г.Бәширов

2) Барысын да бер-бер артлы айкау. *[Әпипә] Сикереп торды да, үз тирәсендәгеләрне усалланган күзләре белән бер айкап чыккач, үз-үзенә исе киткәндәй: «Канатым...» – дип сузды.* Г.Бәширов. *Мин кичә генә анда бөтен җирне айкап чыктым.* Г.Әпсәләмов. *Нинди ике-өч кибет[тә] генә булу? Әллә ничә урамны айкап чыктым.* С.Рафиков

**А́Й-КОЯШ** *и.* 1) Ай белән кояш, ай һәм кояш. *Әй Тукай, ил һәм гасырда ялкының янган Тукай, Ай-кояштан, хөррияттән яктылык алган Тукай!* Ш.Мөдәррис

2) *күч.* Бик балкып, якынлык күрсәтеп йөргән мөгамәлә. – *Кычкырышканнармыни? Әле генә бер-берсенә бик ай-кояш булып йөриләр иде бит.* Н.Исәнбәт

3) *күч.* Бөтен бер дөньяга, галәмгә тиң кадерле зат, әйбер. *Ай-кояштан, Зөһрә йолдызлардан да сылурак җанкисәгем, Айсылу! Сине якынлашып килүче Яңа ел бәйрәме белән котлыйм!* Р.Вәлиев

**А́Й-КӨН** *и.* Билгеләнгән вакыт

◊ **Ае-көне белән** Төгәл үз вакытында, нәкъ срогында. **Ае-көне җитү** 1) Билгеләнгән вакыт җитү; 2) Йөкле хатынның бала тудыру мөддәте җитү

**АЙЛАП** *рәв.* 1) Айга якын, ай дәвамында, ай буена. *1907 елда ул «Йолдыз» газетасыннан Мәкәрҗә ярминкәсенә корреспондент булып бара, анда айлап тора.* М.Гали

2) Ай исәбеннән, айлыклап. *Хезмәт хакын айлап түләү*

3) Айлар буенча, күп айлар дәвамында. *Мәрьям абыстай картының бу сүзләрен ишетүгә кабынып китте: «Гомәр бит айлап торырга кайтмаган, ата кеше син, файдалы киңәшләреңне бирер идең».* Ә.Еники

**АЙЛА́П-КӨНЛӘП** *рәв.* Ай (көн) исәбе белән; ай (көн) саен, ай (көн) үткән саен, күзгә күренерлек булып, тиз. *Еллап түгел, айлап-көнләп алга бара бит хәзер тормышыбыз.* Р.Төхфәтуллин

**АЙЛА́У** *ф. сөйл.* Кайда да булса ай буена тору (яшәү), озак булу. *Айлаган кунак – кунак саналмый.* Әйтем

**А́Й-ЛИ** *ы.* Кайбер җырларның кушымтасында музыкаль фраза буларак кулланыла. *Ай-ли замана, Замана үтеп бара.* Җыр

**АЙЛЫ** I *с.* Ай нуры яктыртып торган, ай нуры сибелгән. *Иделгә сузылган айлы юлдан Тын гына, моң гына җыр ага.* Җыр. *Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер егет Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.* Г.Тукай. *Аның [кызның] кичәдә ерак айлы күктән килгәнгә охшаш гаҗәеп моңын яңадан ишетәм.* Г.Ибраһимов. *Кышкы шактый салкын айлы төн иде...* Ә.Еники

**АЙЛЫ** II *и. диал.* Айлык хезмәт хакы. *Күпме айлы аласың?*

**АЙЛЫК** I *с.* 1) Тулы бер айга караган, бер айга исәпләнгән. *«Әхмәт кода миңа математикадан бер айлык дәрес планнары төзеп калдырган, рәхмәт яугыры», – дип, сөенеп искә ала иде шул апа.* М.Ибраһимов. *Көндәлек эшеңне дә алып бар, шул ук вакытта айлык исәпне дә йомгакла.* И.Салахов

2) Саннар янында шул сан күрсәткән айга исәпләнгән, шулкадәр ай эчендә башкарыла торган. *Бу салкынлык әниләре карточкага алып кайткан ярты айлык конфетны бер утыруда өчесенә ашатып бетергәч тә бетмәде.* Г.Гобәй

3) Күпмедер айга сузыла торган, күпмедер ай дәвам итә торган. *Мәскәүдән алты айлык курсларга чакыру килеп, «кемне җибәрергә?» дигәндә, җитәкчеләр Нургалиевне атадылар.* А.Гыйләҗев. *Өч айлык компьютер курслары оештыру*

4) Бер ай эчендә җыелган, тупланган яки җыела, туплана торган. *Айлык явым-төшем. Айлык савым*

5) Аена бер тапкыр чыга торган, айга бер була торган. *«Яңа япун мөхбире» – урта форматлы айлык журнал.* Х.Миңнегулов

6) Туганнан соң ничәдер ае тулган. *Алты айлык бала, елый-елый, Капшый аның сулган күкрәген.* М.Җәлил. *Ахыр чыдамады, кулындагы алты айлык кызы Факиһәне Гайнигә тоттырды ---.* Г.Ибраһимов

7) Бер ай өчен түләнә (бирелә) торган. *Шул көннәрдә генә солдатларга, фронттагы күтәренке ставка буенча, 75 әр тиеннән айлык жалованье бирделәр.* К.Нәҗми. *Рудольф Хәмитович, бухгалтериягә кереп, айлык хезмәт*

*хакыгызны алыгыз да тыныч күңел белән яңа фатирыгызга күченегез!* Р.Вәли

**АЙЛЫК** II *и.* 1) Берәр эшне үтәп чыгу өчен билгеләнгән бер ай вакыт арасы. *Вагонга җыелышкач, удар айлыкта җиңеп чыкканнары өчен, бригадага күчмә вымпел тапшырылды.* Р.Вәлиев. *Газет-журналларга язылу айлыгы башланды*

2) *сөйл.* Бер айга түләнә торган хезмәт хакы. *Парижда яшәр өчен, аз жалованье алып эшләүче кыз-хатыннарның айлыклары җитми.* Г.Гали

**АЙЛЫКЛАП** *рәв.* Ай исәбе белән, ай исәбеннән; ай саен, ай үткән саен. *Бервакыт әллә кем промыслосында, шуның кебек тачка эшләрен, аларга – берничә иптәшкә – вагон башыннан бирмәкче булганнар. Болар, разый булмыйча, айлыклап керешкәннәр. Менә шушы елны балыкның булуы, илаһым!* Ш.Камал

**АЙЛЫКЛЫ** *с.* 1) Бер ай өчен эшләнгән. *Айлыклы график*

2) Ай исәбеннән килешенгән. *Айлыклы хезмәт хакы*

**АЙЛЫКЧЫ** *и.* Айлыклап эшләүче. *Алар болай [гади] айлыкчы булып түгел, «сдельно» керешкәннәр иде бит.* Ш.Камал

**АЙМАК** *и. монг.* 1) *диал.* Җир, урын, төбәк. *Гата абзый, сызгырасызгыра, урам буйлап түбән аймакка таба узды.* Н.Булат. *Алар башлыгы Буян би Күчем ханны олылап каршы алган һәм төрле аймакларга атчабарлар җибәргән.* Риваятьләр һәм легендалар

2) Нәсел-нәсәп, ыру; кавем-кабилә. *– Менә шулай, – дип хикәясен тәмамлый Михаил Тихонович, – монголларда бала туу – зур бәйрәм, бөтен аймак бәйрәме.* М.Мәһдиев. *Аларның бабалары бер аймактан булган*

3) *иск.* Төркем, даирә. *Синең урының – үлекләр аймагында.* Дәрдеменд. *Җитмәсә, бу кичне тышта, җир-күкне томалап, өермә буран кузгалды, әйтерсең үлекләр аймагындагы җен-пәриләр өй артында улады.* Ф.Мансуров

4) *диал.* Ишле гаилә. *Аймак булгач, эш тиз бетә.* Әйтем

**АЙМАКЛАП** *рәв. к.* **аймаклашып**. *«Мине аймаклап ашарга җыеналар икән болар!» – дип шомланды ул.* И.Хуҗин

**АЙМАКЛАШЫП** *рәв. диал.* Бергәләшеп, бергә-бергә, күмәкләшеп. *Аймаклашып килеп керделәр дә идәнемне таптап чыгып киттеләр.* Мәдәни җомга

**АЙМУТ** *и. рус диал.* Печән яки салам эскерте. *Бездә саламны, печәнне аймутка куялар*

**АЙМЫЛ** *рәв.* Очрашмыйча, юллары кисешмичә. *«Кырык капка» урманында күке кычкыра. Ул безнең аймыл үткән елларны саный, Рифкать абый, җанкисәгем...* К.Кәримов

**АЙМЫ́Л БУЛУ** *ф. к.* **аймылыш булу**. *Аерым торып еллар, Аймыл булып юллар Нигә синнән читтә узган соң?* Ш.Галиев

**АЙМЫ́Л ИТҮ** *ф.* Очраштырмау, туры китермәү. *Ләкин тәкъдир, ни кызганыч, яшьләрнең сукмакларын аймыл итә.* Р.Әмирхан

**АЙМЫЛЫШ** *рәв.* **1.** 1) Аркылы-торкылы, берсе өстенә икенчесен атландырып. *Күкрәкчәнең баулары аймылыш тегелә*

2) *диал.* Хәрефләре ачык язылмаган, таный алмаслык итеп. *Аймылыш язган хатны укып та булмый*

3) *диал.* Ялгыш, хаталык белән. *Мин монда аймылыш килеп кердем*

**2.** *хәб. функ.* Туры килмәгән, очрашмаган хәлдә. *Кайдан белеп бетермәк кирәк. Мин – төнге сменада, ул – иртәнгесендә. Без һаман аймылыш.* К.Нәҗми

◊ **Аймылышка яңгылыш** Юлда бер-берең белән очрашмау аркасында, ялгышып, икенче җиргә килеп чыгу. *Мин монда – аймылышка яңгылыш кына килеп эләккән кеше*

**АЙМЫЛЫ́Ш БУЛУ** *ф.* Очрашмау, бер юлда булып та бер-берен күрмәү. *Без бүгенге очрашуга гаҗәпләнмәдек тә шикелле. Ә менә Шәриптә аймылыш булуыбызга торып-торып исебез китте.* М.Кәрим. *Яшь аркылы сынык тавыш белән иренә сораулар бирде: – Кайда очраштыгыз? Ничек кенә булды соң бу? Ничек аймылыш булмадыгыз?* Ә.Фәйзи. *Юлларыбыз аймылыш булды шул безнең. Минем техникум тәмамлаганны, армиядән йөреп кайтканны көтеп ала алмады Газизәм.* Мәдәни җомга

**АЙМЫЛЫШУ** *ф.* 1) Аймылыш булу, очрашмау. *Мин байтак еллар үткәч кенә аңладым: Шәриптә аймылышмасак, --- Өфедә очрашуның мәгънәсе бөтенләй икенче булыр иде.* М.Кәрим

2) Юлдан чыгу, читкә китү

3) *күч. сөйл.* Саташу, зиһене чуалу

**АЙНУ** *ф.* 1) Исерек хәлдән чыгу, исерткеч эчемлек тәэсире бетү. *Ул хәзер исереклегеннән шактый айныды, Гафифә кайтып кермәгәнгә борчыла башлады.* Ш.Камал. *Эчертеп, исертеп сыйлаганда, һәммәсе дә сиңа дус булып, әллә ниләр эшләргә вәгъдәләр кылалар, айныгач, макмыр башларыннан бар вәгъдәләре дә очып беткән була.* Г.Камал. *– Бераз айнысын, – диде ачу белән Ифрат, – аннан тикшерербез.* А.Расих

2) Чирләүдән, авырту-сызлаудан туктау, савыгу. *Тик теге таза егетнең авыру иптәше генә, әле дә булса, үзенең авыруыннан айный алмаган.* М.Гафури

3) Аңын җуйганнан яки каты йокыдан соң аңга килү, уяну; аңлы фикер йөртә алырлык булу. *Ул, елавыннан айнып, вакыт белән кызыксынырлык хәлгә җиткәндә, сәгать уникенче иде инде.* А.Расих. *Авыр уйлардан айнырга тырышып, шул ритмны тыңлап кайтам.* М.Мәһдиев. *Мин, йокыдан айныр өчен башымны селким дә, Челтер чишмәгә йөгерәм.* М.Галиев

4) Исерткеч, дару, чәй һ.б.ш. нәрсәләрнең озак вакыт ачык килеш тору аркасында көче, тәэсире кимү, искерү. *Әче бал айныган, бөтенләй тәме калмаган*

5) Аңлап алып, карашны, фикерне үзгәртү, элеккеге фикердән, нияттән кире кайту. *Укытучы абыйсы да айныган: «Ничек соң, әллә алып кына калыйкмы кызны?» – ди.* М.Мәһдиев. *Шуннан җиде балалы безнең гаиләне аларның кечкенә йортына, ә аларны безнең зур йортка күчерәләр. Авыл халкы берәр атнадан соң айный: ни өчен? Нигә болай?* М.Мәһдиев. *Зифа айныган. Шунлыктан, һәммәбез дә битебезгә олтан каплаган хәлдә, сезне өйгә кабул итми торырга туры килә.* М.Фәйзи

6) Тирән кичерешләрдән арыну, көчле тәэсирләнүдән нормаль хәлгә кайту. *[Һади Такташ] Куе чәчен сыпырып, ашыкмый гына сөйли башлаган иде, ниндидер хисләрдән айныган залдагылар кул чаба башладылар.* Ж.Фәйзи. *Мин әле Салих белән очрашудан айныганым юк, мин әле аның сүзләрен күңелемдә йөртәм.* Ә.Еники. *Тынып калдылар, күккә ашканнар иде сыман, кемдер дәшеп, капылт икесен дә җиргә төшерде – айнадылар.* М.Хәбибуллин. *Менә шундый төш, Олег. Билгеле, син төшләргә ышанмыйсың, ләкин мин төштән һич айный алмыйм.* Ф.Яруллин

**Айный бару** Акрынлап айну, аз-азлап аңына килү

**Айный төшү** Беркадәр, бераз айну. *Апасы, күрешү ыгы-зыгысыннан айный төшкәч, яулык почмагына күзләрен сөртеп, мышкылдарга тотынды.* Казан утлары. *Бераз айный төшкәч, минем кемгә дә булса зарымны сөйлисем килә башлады.* Казан утлары

**Айнып бетү** Тулысынча аек хәлгә килү, бөтенләй айну. *Йөзе йокыдан айнып бетмәгән.* Т.Галиуллин. *Икенче көнне язучылар, поездга утырып, Казанга юл алалар. Фатих Хөсни һаман әле айнып бетмәгән була.* Р.Батулла

**Айнып җитү** Бөтенләй айну. *Йокысыннан һаман әле айнып җитмәгәнме ул, кем килгәнен, ни өчен килгәнен аңлап җиткермәгәнме, – ләкин аның бу кадәр ваемсыз тынып утыруын аңлавы читен иде.* Ә.Еники. --- *Тинчурин, Болгарская, Синяеваларның сокландыргыч уеннары... Әле дә менә шулардан айнып җиткәнем юк...* Ә.Еники. *Юк, айнып та җитмәде, ә арткы урыннарның берсендә утырып барган хуҗасының нидер әйткәнен генә ишетте бугай.* Казан утлары

**Айнып калу** Кинәт айныган хәлгә килү. *Уйлардан бүленеп, кинәт айнып калдым.* Р.Вәлиев

**Айнып килү** Акрынлап, аз-азлап айный башлау. *Туган апамның операциясеннән айнып кына килгән чагы булган.* Р.Батулла

**Айнып китү** 1) Көтмәгәндә, кинәт айну. *Зәйтүнә чиләк-көянтәләрен иңенә күтәрә башлагач кына, [Сәфәргали] кинәт айнып китте.* Ф.Хөсни. *Солтан айнып киткәндәй булды, тирә-ягына каранды.* Г.Шәрипова. *Баскычтан ничек төшкәнемне хәтерләмим. Урамда бер су колонкасы янында гына айнып киттем.* Ф.Яруллин

**АЙНЫК** *с. сөйл. к.* **аек**. *Ләкин, олуг татлы хиссияткә бирелеп ятудан бигрәк, ул, айнык акыл белән, булып үткән хәлне ничек тә аңларга тырыша иде.* Ә.Еники. *Хәзер, айнык акыл белән уйлап карасаң, бу кыланышларда әллә ни зур җинаять булмаган кебек, --- шул ук вакытта мәҗбүрияттән туган садә тәвәккәллек иканлеген дә аңлавы читен түгел.* М.Госманов. *Бу мәсьәләне антропонимнар, ягъни кеше исемнәре яссылыгына күчереп карасак, милли үзаңны тарихи традициягә айнык һәм әдәпле мөнәсәбәттә күзәтергә мөмкин.* М.Госманов

**АЙНЫКЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **айну** (*5 мәгъ.*). *Еллар узган саен айныкланам, Акны күктән аера башладым.* Ә.Ерикәй

**АЙНЫКЛЫК** *и. сөйл. к.* **аеклык**. *Атна буе эчү... Ун-унбиш көн айныклык... Шушы газаплар белән тарткалашып, айлар түгел, еллар үтте.* Ә.Моталлапов

**АЙНЫҢ-АЕНДА** *рәв.* Һәр айны, айдан-айга, ай саен кабатланып. *Дәүләт планы айның-аенда үтәлеп килә.* Кызыл таң

**АЙНЫТКЫЧ** *и.* **1.** Айныту йорты. *Атна буе ач-ялангач, пычрак, сасы, кандалалы агач сәке өстендә – айныткычта әвәләнәсең.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* 1) Айныта торган. *Айныткыч дару*

2) *күч.* Аңга китерә, акыл бирә торган, нык уйланырлык. *Мин инде күптән саташкан булыр идем – ярый ла мәхәббәтеңдә янәшә яши исерткеч наз һәм айныткыч нәфрәт.* Р.Харис

**АЙНЫТУ** *ф.* 1) Аек хәлгә китерү. *Исерекне айнытып чыгару пунктына озаттылар, ә шиклене, ачыклау өчен, милициягә тапшырдылар.* Г.Минский

2) *күч.* Агарту, аңлы итү, аң-белем бирү. *[Нурулла] Авылны иске тормыш томаннарыннан айнытуда бөтен көчен куеп, төпкә җигелгән ат шикелле, эшкә чумды.* С.Рафиков

3) *күч.* Хыял дөньясыннан чыгару, акыл белән уйлап эш итәргә мәҗбүр итү. *Кияү егетен «сигез яки ун ел» дигән сүз айныткан, ул тиз генә үзенең нәсел-нәсәбен — егетләр, яшь ирләрне җыйган да кызны урлап алып калмакчы була.* М.Мәһдиев. *Безнең сабый күңелләр ялгышмады: безне кырык беренче елның июне айнытты.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Фикереннән, уеннан, ниятеннән кире кайтару. *Бераздан хатынны машина белән алып киттеләр. Шушы хәл чираттагы халыкны айнытырга тиеш кебек иде, тик чират котырганнан котырды.* Ф.Яруллин. *Әгәр Галиябануны Хәлилдән айнытып, иртәгүк миңа никах укытып бирә алсаң, туйлык мәһәрләрдән башка, үзеңә – мең сум.* М.Фәйзи. *[Зифа:] Юк, юк! Мине андый сүзләр белән генә айныта алмыйсың инде.* М.Фәйзи

**Айныта алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз арада айныту

**Айныта төшү** Беркадәр, бераз айныту. *Киленнең зур ачылган, очкынланган күзләре, гарьләнеп калтыраган газаплы тавышы карчыкны айныта төште.* Г.Бәширов

**Айнытып бетерү** Бөтенесен айныту; бөтенләй, тулысынча айныту

**Айнытып җибәрү** Бераз, кинәт айныту. *Мәктәп бинасы эчендәге тынлык Нургалине уйларыннан айнытып җибәргәндәй итте.* Ә.Еники. *Тамараның сүзе мине айнытып җибәрде.* Ф.Яруллин. *Миңниса апа артыннан ук Мирхәйдәр абзый кайтып керде, һәм аның борчулы кыяфәте Габдулланы мәхәббәт исереклегеннән берьюлы айнытып җибәрде.* Ә.Фәйзи

**Айнытып тору** Бераз, берникадәр вакытка айныту. *Ул якынрак килә башласа, идәнгә бер лампочканы ыргытам. Аның шартлау тавышы Айтуганны күпмедер вакытка айнытып торгандай итә.* Ф.Яруллин

**АЙРАВЫК** *и. бот.* Бөртеклеләр семьялыгына караган, себерке башлы кыяк үсемлек; *русчасы*: **вейник наземный**. *Кындырак, айравык, солыча, төлке койрык, болын саруты... зама-*

*нында авыл табынының хуш исле чәен алыштырган*. М.Рәфыйков

**АЙРЫКОЙРЫК** *и. диал.* Карлыгач. *Явым булыр ахры, айрыкойрыклар түбән генә очалар*

**А́ЙСБЕРГ** *и. ингл.* Диңгездә, океанда йөзеп йөри торган боз тавы. *Поляр диңгездәге сыман айсберглар йөзгән тау күле һәркайсының хәтеренә сеңеп кала.* А.Муранов

**АЙТ** *ы.* 1) Балалар белән качышлы уйнаганда күрүне, табуны белдереп әйтелә

2) Балаларны егылудан кисәтү өчен әйтелә

3) Хайваннарны куркыту, куып җибәрү өчен әйтелә

◊ **Айт дигәнгә тайт дип тору** Кушкан йомышны шунда ук йөгерә-йөгерә үтәргә әзер тору. **Айт дигәндә** Шунда ук, шул ук минутта, бик тиз

**АЙТАШ** *и.* Зәңгәрсу төстәге минерал; *русчасы*: **лунный камень**

**АЙ-ҺА́Й** *ы.* 1) Күңел күтәренкелеге, шатлану, куану, соклану, гаҗәпләнү, канәгатьлек һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Кайгысы юк ул песинең, тик һаман уйнау уе; Бик шаян! Ай-һай наян! Уйнарга хәзер көн буе.* Г.Тукай. *Ай-һай, бу елга! Аш та ул бирә, су да эчерә. Тәнгә саулык та, Җанга шатлык та – барын җиткерә.* М.Кәрим. *Ай-һай ла, партия-совет эшендә тәҗрибәсе ташып торган кеше белән, Моназыйр абыең белән ягъни, алышуы җиңел булмастыр.* М.Хуҗин

2) Икеләнү, шикләнү, уйлану, чамалау, раслау, хуплау, ышану һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Ай-һай, булдыра алырсыз микән?* Т.Гыйззәт. *Гыймай энем! Ай-һай, дөрес булырмы икән бу?* Г.Бәширов. *Ай-һай, килешер микән безгә алай кылану?* Д.Аппакова

3) Ачулану, тиргәү, шелтәләү, зарлану, сукрану һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Ай-һай начар бу малай!* М.Гали

4) Ис китмәү, санга сукмау, кимсетү, мыскыл итү, сарказм, ирония һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Йомыш төшкәч үзәнмени? Ай-һай!.. Остарып киттегез, егетләр.* К.Тинчурин

◊ **Ай-һаенда да юк** Исендә дә юк, уйлап та карамый. **Ай-һай салу (салып йөрү)** Аптырау хәлдә ярдәм сорап яки үзенең берәр кайгы-сагышы эченә сыймаудан ай-һай килеп йөрү, айһайлау

**АЙҺАЙЛА́У** *ф.* 1) «Ай-һай» дип, икеләнү, шикләнү, ышанмау яки гаҗәпләнү, соклану хисләрен белдерү

2) Көтүне, эш хайваннарын, ауда җәнлекләрне куганда шундый ымлыклар белән кычкыру

3) Төрле яктан кычкырышу, шаулашу. *Алар, айһайлап, кырык тамактан кычкырып, кранны утыртып та куйдылар.* А.Гыйләҗев

**Айһайлап алу** Бераз вакыт айһайлау, төрле авазлар чыгарып кычкыру. *Урмандагы җиләкчеләр, адашмас өчен, айһайлап алдылар*

**Айһайлап җибәрү** Кинәт барысы да айһайлый башлау. *Бу хәбәрне ишеткәч, барысы да айһайлап җибәрделәр*

**Айһайлап тору** 1) Әле, хәзерге вакытта айһайлау

2) Бераз, берникадәр айһайлау

**АЙЧӘЧӘК** *и.* Әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан, миләүшә төсендәге эре чәчәкле, җимеше кузакта урнашкан үсемлек. *Татарстанда берьеллык айчәчәкне декоратив үсемлек итеп үстерәләр.* Биология

**АЙ-Я́Й** *ы.* 1) Куркыну, аптырау, тирән борчылу, кайгыру хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Шунда бер малай, минем аркага бармагы белән төртеп: «Ай-яй! Нинди яман шеш!» – дип әйтеп салмасмы!* Җ.Фәйзи

2) Үпкәләү, шелтәләү, ризасызлык хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Ай-яй, кыланып та карадың инде?*

3) Соклану, гаҗәпләнү, зур куаныч, шатлык хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Мин боларны малайларга сөйлим. Алар, «ай-яй, күпне белә бу» дигәндәй, авызларын ачып тыңлыйлар.* Җ.Фәйзи. *Без алар белән Сөембикә манарасын карарга бардык. Ай-яй, биек икән!* Җ.Фәйзи. *Бүлмәдә иң элек ул зур-зур тәрәзәләрне күрде. Ай-яй олы! Ишегалды ап-ачык күренеп тора!* А.Гыйләҗев

4) Шикләнү, икеләнү, ышанып бетмәү хисләрен белдерә. *Ай-яй, булдыра алырсыңмы икән?*

**АК** I *с.* **1.** 1) Кар, сөт төсендәге; *киресе:* **кара**. *Тышта мамык кебек ак, йомшак беренче кар ява башлаган иде.* А.Шамов. *Малайга үзеннән дә зур баян китереп тоттырдылар. Ак төймәле, бака ягында да шундый ук ак төймәләр.* Ф.Хөсни. *Андагы хисапсыз вак күлләр өстендә төтен төсле куе ак томан җәелгән.* Гали Рәхим. *Бервакыт агач яфраклары арасында Мәдинәнең алсу чәчәк төсендәге күлмәге һәм ак кар төсле баш яулыгы Фәтхинең күзенә чалынды.* Ш.Камал

2) Үз төсен югалткан, чал, чаларган, көмеш төсле. *Катлаулы иҗат юлында аларның уңайлары да, тискәреләре дә, көлкеләре дә, яшь егетләр дә, ак сакаллы картлар да бар.* И.Илялова. *Каюм бабай урта буйлы, киң маңгайлы, ак сакаллы, түземлелек сыйфаты йөзеннән беленеп торган алтмыш сигез яшендә фәкыйрь бер карт иде.* А.Таһиров. *Маңгае өстендә генә өч бөртек ак чәч күреп, Халисәнең тарак тоткан кулы кинәт туктап калды.* Р.Юсупова

3) Ялтырап торган көмешсыман төстәге, өстеннән никель йөгерткән. *Хатыны гөрләп торган ак самавырны яшел чәчәк төшерелгән кечкенә поднос өстенә кертеп куйды.* А.Шамов

4) Борчылудан, каушаудан, авырудан йөзе үзгәргән, төсе, чырае киткән, агарынган. *Ак йөзенә түземсезлек билгесе чыккан Ләлә Халидова Хафиз Гайнуллин каршына килеп басты.* Г.Әпсәләмов

5) *махс.* Ике яки өч сүздән торган зоологик һәм биологик терминнарның (атамаларның) беренче кисәге. *Ак чыршыны, икенче төрле әйткәндә, «себер чыршысы» дип тә йөртәләр.* Биология. *Ак аю. Ак гөмбә. Ак күрән. Ак төлке*

6) *күч.* Чиста, керсез, пычранмаган, юылган (*кием-салым турында*)

7) *күч. тар.* Революциягә һәм Совет хөкүмәтенә каршы булган. *[Вәли: (Фәттахка)] Менә сезнең атыгызны кем алып киткән иде. Нindидер ак әфисәр, опять-таки байгура малае.* Т.Гыйззәт

8) *күч.* Алдынгы; укымышлы, прогрессив. *Алла хакына, гафу итегез! Бик югартын күз салырга башладык*

*әхлакка без, Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.* Г.Тукай. *Сездәй ак фикерле мулланы моңарчы очратканым булмады.* Мирас

9) *күч.* Язмыйча, буш калдырып, фикернең тәмамланмавына, яшерен эчке мәгънә булуына ишарә иткән. *Ак баганалар, күп нокталар, тәмамланмаган фикерләр, имзасыз басылган мәкаләләр – полиция һәм цензура эзәрлекләүләренең ачык мисаллары.* Р.Әмирхан. *Ак юл*

**2.** *и. мәгъ.* 1) **аклар** *күпл.* Шашка, шахмат кебек спорт уеннарының ак яки ачык төстәге фигуралары

2) **аклар** *күпл. тар.* Революция һәм Совет хөкүмәтенең дошманнары, акгвардиячеләр. *Чынлап та, язга чыгу белән, дөньялар тагын буталып китте. Аклар-кызыллар сугыша башлады.* Ә.Еники. *Хәлим баржада тоз бушатучы егеттән күп нәрсәләргә өйрәнде, һәрхәлдә ул акларның кем икәнлекләренә ачык төшенде.* И.Гази. *Байлар очы бөтенләй котырынган. Совет яклы кешеләрне акларга чагып кына торалар.* К.Тинчурин

3) **аклар** *күпл. сөйл.* Затлы, җиңел, кешлеккә кия торган кием тегүчеләр. *Безнең авылда алты тегүче булып, болар ак һәм кара тегүчеләргә бүленәләр иде. «Аклар» – пальто, бүрек, костюм, мундир, тужурка, «каралар» толып, тун, тире чалбар, бишмәт тегәләр иде.* М.Мәһдиев

4) Ак яки ачык төс. *Алтынчәч – гаҗәеп чибәр, саф күңелле, шигъри җанлы кыз. Аны актан киендерү мәгъкуль булырдыр, декорация дә аның сафлыгына тәңгәл килергә тиештер.* Мирас

5) Чиста кәгазь, төзәтелгәннән соң шул кәгазьгә күчереп язылган кулъязма, каралама түгел. *Женни Маркс әсәрләрен акка күчергән.* Г.Кутуй. *Ниһаять, «Яктылык» дигән поэма язып бетердем. Акка күчереп, әтиемә бирдем.* Җ.Фәйзи. *Башымда туганны кәгазьгә төшерергә, караламага теркәлгәнен акка күчерергә дә --- вакытым булмады минем.* Мәдәни җомга

6) *гади. сөйл.* Аракы мәгънәсендә. *Син, сыраны керткәнче, кара сыраның эченә бераз акны тамызып керт.* Г.Камал. *Ул арада Шәңгәрәй этажерка артыннан бер бөтен акны тартып чыгарды. Үзе: – Аракысыз пилмән харам ул! – дип шаярта-шаярта, учына сугып ачты.* Г.Ибраһимов. – *Миңа бер генә рюмка акны бирсәгез иде, – дидем мин, хуҗаларның тәкәбберлеген сытып. Шуннан китте ыгы-зыгы... Баксаң, тегеләрнең агы бөтенләй юк икән.* М.Мәһдиев

◊ **Ак бәхет** Борчусыз, тыныч, уңайлы һәм уңышлы язмышлы яшәеш. *Ак бәхетләр тели-тели озатканда, Карап калам күз керфегем талганчы.* М.Фәйзи. *Шанлы тарих – үткәннәрең, Ак бәхетләр – көткәнең.* Р.Вәлиева. **Ак билет** Солдат хезмәтенә яраксыз дип табылып, шуны раслап кулга бирелгән таныклык. *Наборга кергән көнне, туксан мыскал күкерт яндырып, аның төтенен иснәде, аның да файдасы булды. Менә шул юк кына нәрсәләр аркасында, кулына ак билетны эләктерде.* К.Тинчурин. *Комиссия, Фәйзуллага ак билет бирергә һәм аны солдат хезмәтеннән бөтенләйгә коткарырга, дигән карарны чыгарды.* Ф.Хөсни. **Ак дими, кара дими** 1) Аерып, талымлап тормыйча, барына риза булу, талымламый ашау; 2) Кемнең йогынтысы зуррак булса шуңа, кем икәнен аермый, ияреп йөрү, тикшереп тормау; 3) Бер сүз дә эндәшмәү. **Ак җәймәле көн туу** Ниһаять, кайгылар, борчулар арта калып, шатлыклы, бәхетле заман килү. **Ак җеп белән генә типчегән** Нәрсәнең дә булса аннан-моннан гына эшләнгәнен күздән яшерергә маташу, әмма яшерүгә беленеп, күренеп тору. **Ак җир** Кайбер сөйләшләрдә: сөрелмәгән ялан җир, дала җир; яткын җир; чирәм җир. **Акка кара белән язган (язылган)** Беркая да яшереп булмый торган эш, хәл; инкяр итеп булмый торган дәлил. *Әмма шулай да, яратуыңны аңлатыр өчен, барыбер, хат язу кирәк икән. Акка кара белән язмыйча торып, кызларны ышандыруы читен икән.* Ә.Еники. **Акка кара ямау** Эшне төзәтәм дип бозып кую; оста хәйләли белмәү, хәйләсе ачык күренеп тору. *Хәйләң – акка кара ямау шул, сикрит-микритләреңне мич башында сөйләшерсең.* Б.Каюмов. **Ак кул** 1) Эшләми, хезмәт итми, кеше көченнән файдаланып яшәүче; эш сойми торган кеше; 2) Аристократ. **Ак күбеккә бату (батыру)** Озак чабып, бик ашыгып килү. **Ак күбеккә төшү** *к.* **ак күбеккә бату**. *Ак күбеккә төшкән атның урман юлыннан чабып килгәне күренгән.* Ф.Хөсни. **Ак күке – ят күке** Башкаларга катышмый; ияләшми торган, үзенә бер ят кеше. *Ак күке – ят күке булып калмаммы?* Ш.Маннур. **Ак күңел (күңелле)** 1) Намуслы, саф, керсез, гөнаһсыз, пакь уйлы, гадел, ихлас күңелле; 2) Йомшак, ягымлы, җылы. *Кунакларны ак күңел, ачык йөз белән каршы алу.* **Акны карадан аермау** Яхшы белән яманны аера алырлык тәҗрибә булмау. **Ак өстенә кара төшерү** Гаепсез кешеләр өстенә ялган яла, әләк, донослар язып, берәр кешене һәлак итү. **Ак өстендә кара кебек** Аермачык аерылып, күзгә бәрелеп торган. **Ак өстендә кара таныган (аерган)** 1) Хәреф таныган, укыган, укый-яза белгән, грамоталы; 2) Яхшыны яманны аера белгән. **Ак сакаллы карт булган булыр идем** Кемнең дә булса, тәҗрибә җитмәүдән, хата эш эшләвенә үкенеч белдереп әйтүе. **Ак тап** Билгесез булып калган, ачыкланмаган, ачылмаган. *Бу китап әлеге ак тапны бетерү йөзеннән, бай мәдәни мирасыбызның моңа кадәр ачылмаган тармагын халыкка кайтару максатыннан чыгып язылды.* М.Арсланов. **Ак төшү** Чәч яки сакал агару, чал төс алу. *Бер экспедициядә күңелсез хәл булды. Ул хәлдән соң минем чәчләремә ак төште.* М.Мәһдиев. **Ак эчле** Эчкерсез, саф күңелле, кешегә яхшылык теләүче һәм кеше бәхетен сөенеп кабул итүче. **Ак эш** Физик көч таләп итми торган, акыл, зиһен ярдәмендә башкарыла торган эш яки, тегү-чигү кебек, буялмый, керләнми торган кул эше. – *Ике кулың белән рәхәтләнеп ит ашыйсың, бал-май эчендә йөзәсең килсә, әнә шундый ак эшкә өйрәнергә кирәк, – диде Габделбарый агай Кәшфигә. – Кара эшне аны мәнди анасы да булдыра...* М.Мәһдиев. **Ак юл** 1) Юлга чыгучыга уңышлы юл теләге. *Палубадан берәү кул изәде – Берәү китә ерак сәфәргә.*

*Яшем тыеп, аңа ак юл телим, Мин каламын монда яшәргә...* Р.Идиятуллин; 2) Өйләнешүчеләргә якты, бәхетле яңа тормыш юлы теләп котлау. *Ак юллар, бәхетле тормышлар телим.* М.Фәйзи. **Ак ябалак сөте** Аракы. *Стаканнарда «ак ябалак сөте» һәм вәссәлам!* Ш.Маннур. **Ак як** 1) Казаннан төньяктагы тараф, Казан арты ягы. *Алат юлы – ак як*; 2) Өйнең түр ягы, зал. *Ак яктагы лампыга ут кабызып җибәрегез әле.* И.Гази. **Ак яка(лар)** *тар.* 1) Элек, модага ияреп, европалыларча ак катыргы яка киюче яшь татар зыялылары. *Ул зыялыдыр, беләмсез, мәгърифәт-хикмәт сата; Манжет алган ун тиенгә, биш тиенгә – ак яка.* Г.Тукай; 2) Кадимчеләрнең җәдитчеләрне мыскыллап атап йөртү сүзе. *Әнә тагын бер ак якасы муенын катырып монда килә, тиргәп җибәр кафирне!* Н.Исәнбәт; 3) Һөнәре буенча физик хезмәт белән шөгыльләнмәүче, интеллектуаль хезмәт өлкәсендә, гадәттә җитәкче урында эшләүчеләр катламы

**АК** II *и.* 1) *мед.* Нәрсә белән дә булса зарарланудан яки авырудан соң, күзнең мөгез катлавында була торган аксыл тап. *Абдулның, кызамык авыруыннан, бер күзенә ак төшеп калган.* Ф.Хөсни. *«Тукайның кайсы күзенә ак төшкән булган?» дигән сорауга галимнәребезнең әлегә төгәл җавабы юк.* Р.Батулла. *Үзе туган өязендә ул [Тукай] солдатка каралырга тиеш була, һәм аны, күзенә ак төшкән сәбәпле, патша хезмәтенә яраксыз, дип табалар.* Идел

2) Күзнең бәбәк тирәсендәге ак өлеше. *Әти миңа күзенең агы белән карады.* Ә.Еники

3) Йомырканың, сарысыннан тыш, пешкәч ак төскә керә торган үтә күренмәле сыек өлеше

**АК** III *и. сөйл.* Сөт азыклары (сөткатык, әйрән һ.б.). *Акка тук, печмәгә киндере юк.* Мәкаль. *Агы барның тугы бар.* Мәкаль

**АК** IV *и. гар. диал.* «*хак*» *сүзеннән* Хаклык, хакыйкать, дөреслек. *Акны яклаган алкыш алыр, караны яклаган каргыш алыр.* Мәкаль. *Акка кара йокмый.* Мәкаль. *Бар шундыйлар: күрәләтә, Акны – ак түгел, диләр, я ишектән йөрмичә, Тәрәзәдән йөриләр.* Ә.Фәйзи

**АК** V *с.* 1) Саф, риясыз, садә. *Бердәнбер көнне Рәхмәт, Зәлиләсен озатып, татлы хыялларга чумып кайтып килгәндә, авыл читендә урнашкан умартачы йортында торган Ак бабайның хәлен белеп чыкмакчы була.* Г.Гыйльманов. *Ак әбиләрнең, дүртенче көн ураза тотып, эсседә, тау сыртында һаман да догада булулары сәбәпле, алар өчен күңелләребез сызлый иде.* Ф.Яхин

2) Өлкән яшьтәге туган яки кардәш кешене, исеме белән әйтмичә, кадерләп һәм олылап атап йөртү сүзе. *Ак әби. Ак туган. Ак тутай (тәтәй)*

**АКАДЕМИЗМ** *и. рус* 1) Сынлы сәнгать өлкәсендә аерым классик (антик) үрнәкләргә иярүнең яшәп килгән традицияләрен саклый һәм сәнгатьтәге реалистик агымнарга каршы көрәшә торган юнәлеш

2) Саф теориягә бирелеп, тормыштан, гамәлдәге таләпләрдән читләшү; теориянең практика белән бәйләнмәве

**АКАДЕ́МИК** I *и. рус* 1) Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы. *Академик Камил Вәлиев – Россия микроэлектроникасына нигез салучыларның берсе*

2) *махс.* Нинди дә булса академиягә сайланган галим, сәнгать әһеле, рәссам һ.б. кешеләрнең гыйльми исеме

**АКАДЕ́МИК** II *с.* 1) Текстлар һәм аның вариантлары чагыштырып фәнни тикшерелгән, аларга искәрмәләр, комментарийлар, белешмәләр бирелгән, чыганаклары күрсәтелгән, иң тулы (басма хезмәт турында). *Әмин, белгәнегезчә, фәнни хезмәт язмадым, шулай ук классикларыбызның академик басмаларын әзерләү, ягъни әсәрләрнең беренчел чыганакларын эзләү, чагыштыру белән дә шөгыльләнмим.* Г.Галиева. *Тукай әсәрләренең академик басмасын әзерләү.* Мәдәни җомга

2) Академизм принципларына ияргә торган. *Академик сынлы сәнгать*

3) Теориягә генә корылган, гамәли ягына игътибар итмәгән. *Академик бәхәс*

4) Югары уку йортларында уку чорында авыру яки башка төрле сәбәп белән алынган. *Данис, белешмә җибәреп, академик ял бируләрен сорады.* Ә.Моталлапов //Югары уку йортларының эшчәнлеге белән бәйләнгән. *Академик ел*

5) Хөр фикерле; иректә, бәйсез. *Дөрес, университетта яшәп килгән мондый академик атмосферага югарыдагы бюрократия аяк чала.* М.Мәһдиев

**АКАДЕ́МИЯ** *и. гр.* 1) Фән һәм сәнгать эшчәнлегендә җитәкчелек итә торган, югары квалификацияле дәүләт учреждениесе. *Академия театры сәхнәсендә традицияләр яңаруга багышлап, сәнгать белгечләре аерым бер хезмәт язарлар әле, дигән уйдан минем әле кире кайтканым юк.* Г.Ахунов. *[Илсөянең әнисе] Академия театрында барган яңа спектакльләрнең берсен дә калдырмый.* Ф.Яруллин. *Татарстан Фәннәр академиясе*

2) Кайбер югары уку йортларының исеме. *Хәрби академиягә керер өчен, ике тапкыр Мәскәүгә бардым.* Ф.Яруллин. *[Командующийның] Кайсы академияне тәмамлавын хәтерләмим, әмма чыраеннан ук күренеп тора: зур тәрбия алган укымышлы кеше.* Г.Бәширов. *Хәрби медицина академиясе*

**АКАЙ** *с. гади сөйл.* Зур булып ачылып алга чыгып торган, акайган. *Атның зур акай күзләре усал, тәкәббер ялтырыйлар...* Т.Мөбарәков

◊ **Акай бизәкле** Башка төсләр арасыннан күзгә ташланып торган зур-зур бизәкләре булган. **Акай күз** *гади сөйл.* 1) Игътибарсызлыктан, гамьсезлектән яки ашкынып йөргәннән аны-моны күрмәгән кешене ачуланганда әйтелә; 2) Агы акаеп торган күз; 3) Һәрнәрсәне күреп, күзәтеп, анда-монда эзләнеп йөри торган кеше

**АКАЙТУ** *ф.* Күзләрне зур итеп ачып карау. *Яраббем, бервакыт әлеге мәхдүмә шул гөнаһсыз хатынга, күзләрен акайтып, котырган эт кебек ябышмасынмы?* Ш.Камал. *Кан баскан күзләрен усал акайтып, ул шәкертләр өстенә карлыгып кычкырды.* Ә.Фәйзи. *Хәлдән таеп, шунда күз акайтып, карап тора кайсыберләре.* М.Гали

**Акайта бару** Торган саен ныграк акайту

**Акайта төшү** Тагы да акайту

**Акайтып алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә акайту, кинәт акайту. *Җәмилә исә артына борылды да Галимәгә күзен акайтып алды.* Н.Фәттах. *Таешова исә, Комзинаны күрү белән, усалланып, көндәшенә күз алмаларын акайтып алды.* М.Насыйбуллин

**Акайтып җибәрү** Кинәт акайту. *Бәбәген бер акайтып җибәрсә...* А.Гыйләҗев

**Акайтып йөрү** Һәрвакыт, гел акайган хәлдә булу, күзләренә ни дә күренмәү. *Бу нәкъ Гайдарлар ише җыен әтрәк-әләмнәрнең, капитализм төзибез, яңача яши башлыйбыз, дип, бәбәкләрен акайтып йөргән чаклары иде.* И.Хәйруллин

**Акайтып кую** Акайган хәлгә китерү

**Акайтып тору** Әле, хәзерге вакытта акайту. *Нәрсә күзеңне акайтып торасың тагы?* Д.Аппакова. *Эләктереп алдым да мин моны, коридорга сөйрәп алып чыгып, үзеннән дә уздырып сүгендем. Күзләрен акайтып тора.* Т.Миңнуллин

**АКАЙ-ШАКАЙ** *с.* Күзенә ни дә күренми торган, акайган

◊ **Акай-шакай килү** Тәртипсезләнеп, тәүфыйксызланып йөрү

**А́К АЛТЫН** *и.* 1) Химик ныклыгы һәм авыр эрүчәнлеге белән аерылып торган, көмеш төсендәге иң авыр затлы металл; *русчасы*: **платина**

2) *күч.* Мамык

3) *күч.* Су энергиясе чыганагы

**АКА́ЦИЯ** *и. лат. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, күбесенчә мәңге яшел агач яки куак; сәрби. *Анда [бакчада] син сап-сары кыңгырауларга төренгән карт акацияләрне, томалап-томалап чәчәк аткан канәфер агачларын күреп, рухыңа рәхәт алырсың.* М.Мәһдиев. *Акациянең 750–800 төре ике ярымшарның да тропик һәм субтропик поясларында таралган.* Биология

**АКА́ШКА** *и. диал.* Язгы чәчү алдыннан кырга чыгып үткәрелә торган бәйрәм

**А́К АЮ** *и. зоол.* Аюлар семьялыгыннан, куе озын ак төстәге йонлы, сузаеп торган муенлы, озынча танаулы, тырнаклары эчкә бөгелеп торган юан аяклы, кыска койрыклы имезүче эре ерткыч хайван. *«Көтмә инде син кызыңны, аны Ак аю алып китте», – диләр тегеләр.* Әкият. *Зал идәненә ак аю тиресе җәелгән, киң табаннары яккякка тырпаеп тора, озын муенын сузган.* Г.Госман

**АКАЮ** *ф.* 1) Авыртудан яки берәр төрле физик газап кичерүдән, күзләрнең агы әйләнеп, хәрәкәтсез хәлдә калу

2) Түгәрәкләнеп, зур булып ачылу. *Көчәнеп кычкырудан һәм ярсудан булса кирәк, аның зәңгәр күзләре акайган, муен тамырлары бүртеп чыккан иде.* И.Гази. *Андый авыруларның калкансыман бизләре зурая, күзләре акая.* Биология

3) Ярсудан күзләр күрмәс хәлгә килү яки төссезләнү. *Мондый җаваптан соң, Маликның күзләре акайды, борын яфраклары уйный башлады.* И.Гази

**Акаеп йөрү** 1) Һаман күзгә бәрелеп, як-ягына карангалап йөрү. --- *керәч белән бизәлгән дәү мичләрне, дивар тулы шәрык нәкыше, рәсем, кәкре кылыч, алтатарларны күргәч, тилебәрән орлыгы ашагандай, гел акаеп йөрде.* В.Имамов

2) Абына-сөртенә йөрү

**Акаеп калу** Акайган хәл, торыш алу. *Жихрайның күзләре генә акаеп калган, рәтләп сүзен дә әйтә алмый, янәсе.* Ш.Камал. *Өлкән камның тары бөртегедәй елтыр күзләре чәчрәп чыгардай булып акаеп калды.* Н.Фәттах

**Акаеп китү** Көтмәгәндә, кинәт акаю. *Мәһдинең күзләре акаеп китте, ачылып калган авызыннан сүзе аңламаслык булып гыжылдап чыкты.* Гөлшәһидә

**Акаеп тору** 1) Әле, хәзер акайган торышта булу. *Акылы юк башка акаеп торган күз үсәр, Тавышы юк авызга шыбырдаган сүз үсәр.* Мәкаль. *Сыңар күзе акаеп тора...* З.Хәким

2) *күч.* Күзгә артык бәрелеп тору, ачык күренеп тору (төс, бизәк, формага карата әйтелә). *Ансар урнашкан фатир – ике катлы агач йорт, Дегетле урамының теге башында, алгы тәрәзәләре белән шәһәр күленә акаеп тора.* К.Кәримов

**Акаеп чыгу** Акайган хәлгә килү. *Болай ук булыр дип уйламаган иде Афзал: аның күзләре акаеп чыкты, үзе, лач итеп, идәнгә төкерде.* Г.Шәрипова. *Тилебәрән орлыгы ашаган сыман, һәммәсенең күзе акаеп чыккан, авызларын бүрек йотардай ачып үкерәләр: – Безнең батыр җиңде! Алёша, Алёша!* В.Имамов

**Акая бару** Торган саен ныграк акаю

**Акая төшү** Бераз, беркадәр акаю

**А́К ӘРЕМ** *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, сабагы һәм яфраклары аксыл төстәге, көчле әчкелтем исле, дару үләне буларак та кулланыла торган әрем төре; *русчасы*: **полынь горькая**. *Меңьяфрак, гөлбадран, ак әрем сабаклары, аны яшереп, биегәеп киткәндәй булдылар.* М.Маликова

**АКБАЙ** *и.* 1) Ак төстәге этләргә бирелә торган кушамат. – *Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор.* Г.Тукай. *Акбай кәефләнде: – Ну каймагы әйбәт икән, – Диеп мактады.* Һ.Такташ. *Бер этебез Акбай, бер этебез Сарбай.* Г.Бәширов

2) *сөйл.* Гомумән, нәселсез эт, урам эте

**А́К БАЛЧЫК** *и.* Чынаяк һәм башка савыт-саба ясау өчен файдаланыла торган яхшы сыйфатлы балчык; каолин. *Ак балчыкка дип, көянтә-чиләк асып, шушы чокырга килгәниек.* А.Вергазов

**АКБАШ** I *и. сөйл.* 1) Ак аракы. *Табынга әсәтер шулпасы килгәч, ул шкафтан бер шешә акбаш алып стаканнарга салды.* С.Сабиров

2) Ак чәчле кеше. *[Официантка:] Үләм-бетәм, ял көне дә килгән бит теге «акбаш» дигәне ---.* М.Мәһдиев

**АКБАШ** II *и. бот.* Чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан, аш тәмләткеч буларак кулланыла торган, әчкелтем хуш исле үлән үсемлек; тмин

**АКБУР** *и.* 1) Сәнәгатьнең химия, резина һ.б.ш. әйберләр җитештерү өлкәләрендә кулланыла торган, нигездә кальций карбонатыннан гыйбарәт, ак төстәге йомшак известьташ. *Акбур составында микроорганизмнарның казылма калдыклары да очрый.* Химия

2) Шул известьташның язу-сызу, акшарлау, чистарту өчен кулланыла торган йомшаграк төре. *Яз, газиз углым, кара тактаны сыз акбур белән!*

Г.Тукай. *Аршины белән кайчысын, бер шакмак акбурын, инәсен-җебен киндер алъяпкычына төреп чана башына бәйли дә авылларга чыгып китә.* Г.Гобәй. *– Әни! – дип, ул бераздан йөгереп кайтып керде. – Капкаларга акбур белән цифр сугып йөриләр!* И.Гази

3) *кимс.* Кершән, пудра. *Күңелемә хуш килмәде ак йөзең акбур иткәнең*! Дәрдемәнд

**АКБУРЛА́У** *ф.* 1) Акбур белән агарту, акшарлау. *Мич акбурлау*

2) *кимс.* Кершән, пудра ягыну. *Ә инде битне акбурлап, иренне кызарта башласаң, сәгать сигез җиткәнен сизми дә каласың.* М.Юныс

**Акбурлап алу** Кыска гына вакыт эчендә акбурлау; тиз генә акбур белән агарту

**Акбурлап бетерү** Бөтенләй яки барысын да акбурлау

**Акбурлап җибәрү** Аз гына, бераз акбурлау

**Акбурлап җиткерү** Тиешенчә акбурлау

**Акбурлап кую** Нәрсәне дә булса ахырына кадәр акбурлау; алдан акбурланган хәлгә китерү

**Акбурлап тору** Әледән-әле акбурлау

**Акбурлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, тулысынча яки барысын да акбурлау

**АКБУРЛЫ** *с.* 1) Составында акбур булган. --- *иң биек тау дигәнең акбурлы токымнардан гыйбарәт булып, башка заманда ямьсез чокырга әверелеп, хәзер без төзергә азапланган исемлекнең яраксызга чыгуы ихтимал.* Ә.Баян

2) Акшарланган, акбур йоктырылган.

3) Акбурга буялган. *Күзлеген акбурлы борынына төшереп, метрын минем драпның өстенә сузды.* И.Гази

**АКБҮЗ** *с.* **1.** 1) Аксыл күк төсмере булган, күксел төс катышкан ак. *Чишмә тын; ул көлми, Тибрәнми, селкенми; Акбүз таш өстендә Тамчылар сикерми.* М.Җәлил. *Акбүз юргаларга менеп, илләрне гизәр идем.* М.Фәйзи

2) Ак төстәге юка киҗе-мамык тукымадан тегелгән яки эшләнгән. --- *акбүз халат киеп, шул чагында, Син арчырсың яра канымнан* ---. Ш.Мәннур. *Җиләнен салып, камзулдан утырган, озын акбүз күлмәге тезләренә хәтле җиткән.* Ф.Әмирхан

**2.** *и. мәгъ.* 1) Аксыл төстәге юка киҗе-мамык тукыма

2) *к.* **акбүзат**. *– Төкле аягың белән килеп иң, малкай, – диде атаем, акбүзнең яңагыннан сөеп.* М.Кәрим. *Әйе, әйе, озын борынлы, киң күкрәкле акбүзенә менгән Батырай, булат кылычын ялтыратып, урамны бер итеп йөрер, ярлы-ябагайны җыеп, аларның һәммәсенә җир-су өләшер.* Мирас

**АКБҮЗАТ** *и.* 1) Акбүз төсендәге ат. *Бер акбүзат сузылып килә, Ял-койрыгы тузылып килә.* Н.Исәнбәт

2) Татар һәм башкорт фольклорында батырның аксыл көлсыман төстәге могҗизалы аты-ярдәмчесе

**АКВАЛАНГ** *и. лат.* Су астында йөзгәндә файдаланыла торган махсус сулау аппараты. *Акваланглар кигән спортчылар су төбен бик җентекләп күзәтә, тикшерә башлыйлар.* А.Муранов. *Кемдер акваланг белән чума, кайсыдыр берсе, гарпун белән, су астында балык чәнчеп үтереп йөри.* М.Мәһдиев

**АКВАЛАНГИСТ** *и. рус к.* **аквалангчы**. *Аквалангистлар күлгә егылып төшкән шул самолётның су төбендәге калдыкларын эзләргә керешәләр.* А.Муранов

**АКВАЛАНГЧЫ** *и.* 1) Акваланг киеп, су астын тикшерүче

2) *спорт* Су астында йөзү төре белән шөгыльләнүче спортчы

**АКВАМАРИН** *и. лат.* Зәңгәрсу яшькелт төстәге асылташ. *Аквамарин каш*

**АКВАРЕЛЬ** *и. фр.<ит.* 1) Су белән изелә, җебетелә торган җилемле буяу. *Иске гәзит һәм журналлар арасыннан мин берничә тузанланып беткән акварельләр таптым.* Гали Рәхим. *Рамнарның берсенә, акварель белән, түгәрәк йөзле хатын портреты ясалган иде.* М.Маликова

2) Тасвири сәнгатьнең шул буяу белән эшләнә торган төре. *Иртән Зуфирә редакцияләргә ашыга, заказлар ала, үзе өчен акварельләр яза иде.* М.Маликова

**АКВА́РИУМ** *и. лат.* Балыкларны, су хайваннарын һәм су үсемлекләрен саклау, үрчетү һәм аларны күзәтү өчен эшләнгән пыяла савыт; ясалма сулык

**АКВА́РИУМЧЫ** *и.* Аквариумда балыклар, су хайваннары һәм су үсемлекләре үрчетү белән шөгыльләнүче кеше

**АКВАТО́РИЯ** *и. лат.* Билгеле бер максат өчен чикләре билгеләнгән һәм махсус җиһазландырылган су участогы, сулык мәйданы. *Яңа портның акваториясе, әнә теге баклар тирәсеннән башланып, калкулыктагы аерым совхоз йортларына кадәр сузылачак.* Г.Әпсәләмов. --- *составына инженер Маркин да кергән үлчәүчеләр партиясе дә ел дәвамында утрауның акваториясен өйрәнде.* Мирас. *Коткаручылар Идел һәм Казансу елгалары акваториясендә күзәтчелек итәләр, пляжларда һәм су буйларында кизү торалар.* Мәдәни җомга

**АКГВА́РДИЯ** *и. тар.* 1917 елгы инкыйлаб чорында Кызыл армиягә каршы сугышучы көчләр; ак армия. --- *большевик, саташып, подпольщикларның адресларын санап чыга, моны кемдер ишетеп, акгвардия контрразведкасына җиткерә дә, һәммә кешене кулга алалар.* М.Җәлил

**АКГВА́РДИЯЧЕ** *и. тар.* Совет хакимиятенә каршы булган хәрби контрреволюцион оешма әгъзасы, контрреволюционер һәм акгвардия сафларында советларга каршы көрәшкән кеше. *Керестенево авылы тирәсендә генерал Юденичның акгвардиячеләренә каршы барган көрәштә комсомолец Пелевин күкрәге белән дошманның ут ноктасына ята.* Ш.Мостафин

**А́К ГӨМБӘ** *и. бот.* 1) Юан ныклы аяклы, куе көрән яки ачык көрән төстәге эшләпәле, ашарга яраклы кыйммәтле гөмбә; *русчасы:* **белый гриб.** *Мәсәлән, ак гөмбә. Ул ит шикелле үк.* Г.Мөхәммәтшин

2) *диал.* Гөреҗдә

**А́К ДЕЛЬФИН** *и. зоол.* Дельфиннар семьялыгыннан, озынлыгы 6 м га кадәр, авырлыгы 2 тоннага җиткән ак төстәге диңгез хайваны; эре поляр дельфин; *русчасы*: **белуха**

**АККАНАТ** *и. бот.* Ароидчалар семьялыгыннан, сулыкларның баткак ярларында үсә торган, юан тамырчалы, шуышма яфраклы агулы үсемлек; *рус-часы*: **белокрыльник, калла**. *Бу исемлектә – ароидчалар семьялыгыннан саз акканаты, шулай ук һәркемгә билгеле булган декоратив үсемлек – калла.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**АККАНЛЫЛЫК** *и. мед.* Кан составы үзгәрү, ак кан шарчыкларының (лейкоцитларның) күбәюе белән характерлана торган авыру; лейкемия

**АК КАН ТӘНЧЕКЛӘРЕ** *и. биол.* Кеше һәм хайван каны составында антитәнчекләр эшләп чыгара, организмда барлыкка килгән бактерияләрне йота торган төссез күзәнәкләр; лейкоцитлар

**А́К-КАРА** *с.* **1.** Ак һәм кара төсләрдән торган. *Менә шул чакта инде Заһидулла абзый мине рояль алдына утыртып, --- рояльнең ак-кара телләренә басарга да өйрәтә башлады.* Ә.Еники

**2.** *и. мәгъ.* 1) Теләсә нинди әйбер, теләсә нәрсә. *Ак-карага игътибар итмәү*

2) *күч.* Яхшы һәм яман. *Болай да беркая чыгып йөргәнең юк, әзрәк дөнья белән танышырсың, ак-караны аерырга өйрәнерсең.* А.Әхмәтгалиева

◊ **Акка-карага карамыйча** Яхшысына да, яманына да карамыйча, тәвәккәл хәрәкәт итү. *Зачётлар бетү белән, акка-карага карамый, өйгә ашыктым.* Ш.Камал. **Ак-карадан бер сүз әйтмәү** *к.* **актан-карадан сүз әйтмәү**. **Ак-кара димәү** *к.* **актан-карадан сүз әйтмәү**. *Күнегелгән кагыйдәләр буенча, ул картка ак-кара димәде, кайтарып җавап бирмәде.* А.Гыйләҗев. **Ак-караны белмичә** Бик ашыгып, аны-моны аермыйча, бернигә карамыйча. **Акны-караны күрмичә** Ашыгу, кабаланудан берни күрмичә, бернәрсәне абайламыйча, игътибар итмичә. *Без, акны-караны күрмәстән, кая басканны белмәстән, Зәңгәр Чишмәгә чаптык.* Г.Ибраһимов. *Мин, тотылган карактай, гаять уңайсызланып, кызарып киттем һәм, тиз генә борылып, ак-караны күрмичә, китеп тә бардым.* Ә.Еники. **Ак-кара танымый** Хәреф танымый, бөтенләй надан, грамотасыз. **Актан-карадан сүз әйтмәү** Берәр нәрсә турында яклап та, яманлап та сөйләмәү, үз мөнәсәбәтеңне белдермәү. *Равил, бөтенләй ишетмәгәнгә салышып, аңа актан да, карадан да җавап бирмәде.* В.Нуруллин. *Чаллыга вакытыннан алда кайтуның сәбәбен сораштыра башлагач, егет ул вакытта актан-карадан сүз әйтмәде.* К.Тимбикова

**А́К КЕЛӘТ** *и. тар.* Җәен йоклау өчен җайланган, гадәттә буй җиткән кыз ята торган тәрәзәле келәт. *Әни ак келәткә бик әйбәтләп урын җәеп куйган.* Ф.Хөсни. *--- ак келәт, ап-ак җәймә җәелгән йомшак урын.* М.Мәһдиев

**АККЛИМАТИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Яңа климат, яңа тормыш шартларына җайлашу, күнегү чоры (хайваннар, үсемлекләр турында). *Үсемлекнең җайлашу чоры «акклиматизация» дип атала.* Биология

2) Яңа климат һәм географик шартларга күнегү, адаптацияләнү процессы; яңа мохиткә, яңа урынга күнегү, җайлашу, үзләшү вакыты (кеше турында). *Алар инде Универсиада авылына 29 июньдә үк килеп урнашты; сәбәбе – акклиматизация үтәргә кирәк.* Ватаным Татарстан. *--- спортчылар тиз генә акклиматизация үтте һәм шуннан соң иң яхшы нәтиҗәләр күрсәтергә әзер иде.* Мәдәни җомга

**АККЛИМАТИЗА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Акклиматизация кичерү; акклиматизация үтү

**АККОМПАНЕМЕНТ** *и. фр. муз.* Җырлаучыга яки көйне икенче музыка коралында төп башкаручыга кушылып уйнау. *Гармун тавышы да, башкаларның җыры да [егет белән кыз җыры янында] үзенә бер матур аккомпанемент булып яңгырый.* С.Сабиров. *Бу көйгә аккомпанемент язарга мин хөрмәтле композиторыбыз Нәҗип ага Җиһановтан сорадым.* И.Шакиров. *Тукай шигырьләренең барысы да саз аккомпанементына көйләнгән.* Н.Хисамов

**АККОМПАНИА́ТОР** *и. фр. муз.* Аккомпанемент башкаручы. *Композиторның үзе аккомпаниатор булуы кичәгә ямь өстәде.* М.Шиһапов

**АККО́РД** *и. ит. муз.* Музыкада төрле югарылыктагы авазларның бергә кушылып яңгыравы. *Миңа бөек Сәйдәшевнең бер аккорды җитә! Бер!* А.Гыйләҗев. *Ә пианинода көйне тибрәтә торган аккордлар да бар.* Җ.Фәйзи. *Баянчы солдат та йокысыннан солдатча айныды һәм аккорд та алды.* М.Мәһдиев

**АККОРДЕОН** *и. фр.* Клавиатурасы фортепьяно тибында эшләнгән гармун. *Гармунчы, гадәттәгечә, аккордеонын чыгарды ---.* А.Әхмәт. *Гармуным минем җырларда җырлана торган кыңгыраулы саратовский түгел түгелен, шулай да шәп – ярым аккордеон.* Ф.Яруллин

**АККОРДЕОНЧЫ** *и.* Аккордеонда уйнаучы. *Мин Башкорт дәүләт драма театрына эшкә килгәндә, ул анда аккордеончы иде.* Ватаным Татарстан. *Ә инде музыка ягын мәшһүр аккордеончы Бәхти Гайсин алып бара.* Кызыл таң

**АККОРДЛЫ** *с.* 1) Төрле музыкаль авазлар, тоннар кушылган. *Композиторның «Синең өчен», «Кил, чибәрем» (Ә. Ерикәй сүзләре), «Килен төшә» (Р.Миңнуллин) һ.б. аккордлы фактуралы романслары нәкъ менә романтик рухта булулары белән үтә дә тәэсирле.* Мәдәни җомга

2) Килешү нигезендә эшләнә, түләнә торган. *Аккордлы түләү. Аккордлы эш*

**АККОШ** *и.* 1) Үрдәк кошлар семьялыгыннан, нәфис озын муенлы, парлы булып яшәүче, бик матур күчмә су кошы. *Аккош очар, күл күреп; Былбыл очар, гөл күреп.* Мәкаль. *Ят кошны пар итмәс аккош, Ялгыз канат какса да.* Җыр. *Салмак кына канат кагып, җылы яктан, аккошларның килүләре якын миңа.* З.Мансур

2) **аккошым** *күч. тарт. форм.* Иркәләп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Җиңгәсе аны бөтенләй башкача аңлады. – Әйтә күрмә, аккошым! – диде ул, кулын селтәп.* Ә.Еники

◊ **Аккош кебек** Ап-ак төстә булган, бик нәфис. *Иделнең түбән ягыннан аккош кебек бер пароход күренде.* Ш.Мөхәммәдев. **Аккош очырып баеган** 1) Акча уйнап отып баеган (көмеш акчаны тырнак очында чөеп төшереп

уйнау хакында әйтелә); 2) Ялган көмеш акча суккан. **Аккош сөте** Исерткеч, аракы. **Аккоштан ычкындыру** Көмеш акча белән сәдака-хәер бирү

**АККРЕДИТИВ** *и. фр.<лат. фин.* Клиент соравы буенча һәм аның исәбенә, юридик яки физик затларга күрсәтелгән сумма күләмендә акча түләү турында бер банк тарафыннан икенче банкка бирелгән йөкләмә документы (ышаныч кәгазе). *Товар аккредитивы. Аккредитив белән исәп-хисап ясау*

**АККУМУЛЯ́ТОР** *и. нем. тех.* Химик энергияне соңыннан файдалану максаты белән туплый һәм аны электр энергиясе рәвешендә бүлеп чыгара ала торган прибор, туплаучы җиһаз. *Мотоциклның аккумуляторы утырган.* Р.Батулла. *Аккумуляторы яңадырмы, суынып, майлары куерса да, двигатель тиз кабынды.* К.Кәримов

**АККУРАТ** *с. рус сөйл.* **1.** 1) Һәрнәрсәсе – киеме, җиһазлары пөхтә, урынлы, җыйнак

2) Эшне пөхтә башкара торган, төгәл, җентекләп үтәүчән. *Ул шундый аккурат – нәкъ вакытында кайтып китә*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Урынлы, кирәк җирдә, тиешенчә. *Аккурат саклап тотканда, бу байлык шактый озакка җитәчәк, дип уйлыйм мин.* А.Расих

2) Төгәл итеп, җиренә җиткереп. *Мин аккурат эшләргә яратам...* Х.Ибраһимов

3) Вакытлы, нәкъ моментына, кирәк чакта, соңга калмыйча. *Аккурат нәкъ сәгатенә килеп җиттек*

**3.** *хәб. функ.* Зурлыгы, күләме яки башка үлчәме буенча кирәгенчә, таман. *Итекләр икенче берәүнең аягына аккурат булып чыкты.* Ә.Исхак

**АККУРАТЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Җыйнаклану, җыйнакка әйләнү, пөхтәләнү

2) Зурлыгы, күләме яки башка үлчәме буенча килешеп тору, туры килү

3) Тәненең тулылыгы кимү, җыйнаклана төшү. *Шәһәрдә торып, ул бераз ябыккан, фигурасы аккуратланган*

**АККУРАТЛЫК** *и.* Аккурат булу. *Немец кешесенең аккуратлыгы, педантлыгы мәкальләргә кергән.* И.Гази

**АККУРГАШ** *и.* Йомшак, җиңел чүкелүчән көмешсыман металл; химик элемент. *Аларны металлар, мәсәлән: тимер, алюминий, бакыр, цинк, кургаш, аккургаш һ.б., шулай ук пластмассалар, минераль ашламалар, медикаментлар һ. б. табу өчен кулланалар.* Химия

**АККҮЗ** *и. зоол.* Карп балыклар семьялыгыннан, эре тәңкәле, көмеш коңгырт төстәге промысел балыгы; *русчасы:* **белоглазка**

**АКЛАМА** *и.* Кулъязманың акка күчерелгән нөсхәсе; *киресе*: **каралама**. *Тукайның дуслары, бөек шагыйрьнең биографлары, кызыклы гына һәм Тукайга нисбәтле бик уникаль шундый бер факт китерәләр: ул Байронның Сүнчәләй җибәргән «Шильон мәхбүсе» тәрҗемәсен хуплап кына калмый, үзе аны редакцияләп, басарга әзерли, үз кулы белән акламага күчерә, кереш сүз-фатиха язып, аерым китап итеп чыгара.* Р.Мостафин

**АКЛАН** *и. диал.* Урман эчендәге яки куаклык арасындагы ачык урын, алан. *Буага якын гына урында аклан чирәмендә яшьләр уенга җыелганнар.* А.Гыйләҗев. *Хәзер әрәмәләрдә акланнар кардан ачыла башлагандыр.* Ф.Яруллин

**АКЛАНУ** I *ф.* Аксыл яки ак төскә керү, агару. *Яңа кием кигән, пакьләнгән, акланган.* Г.Тукай

**Аклана төшү** Бераз аклану, аз гына ак төскә керү

**АКЛАНУ** II *ф.* 1) Үзеңнең хаклыгыңны, гаепсез булуыңны расларга тырышу. *Егет үзен гаепле сизгәндәй һәм, шул ук вакытта, акланырга теләгәндәй тавыш белән җавап бирде.* А.Шамов. *Кояшта да тап була, дип, Тырышма акланырга; Бик ерак әле, туганкай, Сиңа кояш булырга!* Ә.Исхак. *Юклык әгәр аклану икән – ул чагында бөтен каракларны, кеше талаучыларны акларга мөмкин. Үзге саф кеше нинди хәлдә дә бүтәннәр өлешенә кул сузмый.* Ф.Яруллин

2) Алдан уйланган нәрсә тормышка ашу. *Ләкин атаның сәгатьләр буена сабак биреп торуы бушка китте, көткәне акланмады.* Ф.Хөсни. *Кыз Фәниярне курорттан терелеп кайтыр дип көткән иде, өмете акланмады.* Ф.Яруллин. *Ике әбием хәбәрсез югалган улларын соңгы көннәренә кадәр көтте, ни аяныч, өметләре акланмады, алар газиз балаларын кабат күрә алмады.* Мәдәни җомга

3) Нәрсәнең дә булса дөрес булып чыгуы фактлар белән исбатлану, раслану. *[Либреттода Гөлгенәнең кайтуы] --- берни белән дә акланмый һәм, шуның өстенә, беренче актта ук барлык вакыйганы тәмамлый иде.* М.Җәлил. *Балаларның иҗат эше дә, шулай ук иҗтимагый кыйммәте булганда гына, педагогик яктан аклана ала.* Ә.Хуҗиәхмәтов

4) Гаепсез дип табылу, хөкемнән котылу. *Нәгыймнең суд тарафыннан акланып чыкканлыгын алар моннан ике атналар чамасы элек ишеткән иделәр.* Ш.Камал. *Соңгы ун ел эчендә бер Татарстанда гына да бер гаепсезгә хөкем ителгән ике йөз меңнән артык элекке сәяси тоткыннарның исемнәре акланды.* Казан утлары. *1960 елның 23 маенда гына, хаксыз җәберләнгән шәхес культы корбаны буларак, Мөхлис бабай аклана.* Сөембикә

5) Каплану, тотылган расходлар кире кайту. *Тотылган чыгымнар аклану*

**Аклана бару** Барысы да рәттән аклану; вакыт узган саен ныграк аклану. *Әлмәндәрнең күркәм холык сыйфатлары сәхнәдә кылган эшләре белән аклана бара.* А.Әхмәдуллин

**Аклана башлау** Акланырга тотыну. *Нәкый Исәнбәт үзенә сузылган кулны алмый: – Син шул кулың белән донос яздың! – ди. – Нәкый абзый, миңа обком кушты! – дип аклана башлый Ишморат.* Р.Батулла

**Аклана бирү** Аклануын дәвам итү. *Чөнки ул [мәкаль] анда конкрет иҗтимагый кулланышында яки сүзгә мисал булып килә һәм шуның белән аклана бирә.* Н.Исәнбәт

**Аклана килү** Даими рәвештә, электән үк системалы аклану. *Ләкин Фәләх, нинди дә булса сәбәп табып, Роза алдында гел аклана килде.* В.Нуруллин. *Җиңү бәйрәменнән соң, --- ышаныч күпмедер дәрәҗәдә аклана килсә дә, тормыш, барыбер, тиз генә җиңеләя алмады.* Ә.Баян

**Акланып алу** Аз гына, нинди дә булса сүз әйтеп аклану. *Абзый, гаебен сизеп, акланып алды: – Гафу ит, энекәш. Янә сугыш төшкә керде*. Р.Мирхәйдәров

**Акланып бетү** Тулысынча аклану. *Кешеләрнең мәхәббәт хисләрендә һәр очракта фәкать нәфасәти ихтыяҗны гына күрү дә акланып бетми, биредә, югарыда әйтелгәнчә, физиологик ихтыяҗларны да танырга кирәк*. К.Гыйззәтов. *Сарыф ителгән көч һәм чыгымнар акланып бетми*. М.Вәлиев

**Акланып җитү** Ахырынача аклану. *Түләкнең, җирдән баш тартып, Сусылуга ияреп китүе әзерлексезрәк чыккан, акланып җитми*. М.Җәлил

**Акланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта үзен аклау белән мәшгуль булу. *--- егетнең йөрәге бу шикләнүләрне сизмәде, дисезме?! Хәер, әйтүчеләре дә булды бугай. Тик Тимерхан акланып йөрмәде*. В.Нуриев

**Акланып карау** Акланырга омтылу. *Алай түгел, эш болай бит, дип акланып кара инде соңыннан*. Б.Рафиков

**Акланып килү** Һәр очракта, һаман да аклану. *– Гел исемдә, – дип акланып килде Миңлекәен, Маһруй апаны күргән саен. – Ләкин арттырып кына булмый бит*. Г.Әпсәләмов

**Акланып кую** Үзен аклап, кыска гына нинди дә булса сүз әйтү. *Бу сүз белән урынсыз мавыккан язучылар, Мөхәммәт Мәһдиев тә язган ул сүзне, дип акланып куяр*. И.Низамов

**Акланып тору** Әле, хәзерге вакытта аклану. *Җитте! Мин сезнең алда акланып торырга җыенмыйм*. Х.Ибраһимов

**Акланып утыру** *к.* **акланып тору**. *Ул боларны, Сәрия алдында акланып утырудан бигрәк, үзен юату өчен сөйли иде бугай*. Л.Гыймадиева

**АКЛА́У** I *ф.* 1) Ак итү, ак төскә кертү, агарту. *Ябалактай яуган карлар Аклый микән кырларны?* Җыр

2) Акшарлау, акбурлау, акка буяу. *Мич аклау*

**Аклап алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә аклау

**Аклап бетерү** Бөтенләй яки барысын да аклау. *[Гөлшаһидә] Аклап бетергәч, крахмалдан җилем кайнатып, обойларны ябыштырды*. Г.Әпсәләмов

**Аклап җибәрү** Бераз аклау

**Аклап җиткерү** Тиешенчә аклау

**Аклап калу** Ниндидер моментка кадәр аклап өлгерү. *Яңгыр яуганчы, диварларны аклап калдык*

**Аклап кую** Нәрсәне дә булса аклаган хәлгә китерү; алдан аклау. *Тәүге тапкыр Кар яуды бит, ябалаклап. Уңган да соң: көн эчендә Бөтен җирне куйды аклап*. Г.Юнысова

**Аклап тору** Бертуктаусыз, әледән-әле аклау; әле, хәзер акка буяу. *Мин гүя тылсым иясе – Дөньяны аклап торам. Очмасын дип, шул аклыкны Көн буе саклап торам!* Г.Гыйльманов

**Аклап чыгу** Бөтенесен дә аклау; башыннан ахырына кадәр аклау

**Аклый бару** Барысын да рәттән аклау

**Аклый төшү** Бераз аклау; тагын да аклау. *Иңемдәге ак шәлемә сарган энҗе кар бөртекләре күңелемне тагын да аклый төшә*. Н.Хәсәнов

**АКЛА́У** II *ф.* 1) Хаклы дип күрсәтү, кемнең дә булса гаепсез булуын тану. *Фәрит үзен акларга сүз таба алмады*. Г.Бәширов. *– Теләсәң каян тап, түлә, – дип кычкырына башлагач, асрау, үзен аклар өчен, Шаһбаз өстенә нахак сөйләгән*. Г.Ибраһимов. *Бер уйлаганда, аларны да аклап була. Ни алам дисәң – шул юк*. Ф.Яруллин

2) Нәрсәгә дә булса лаек булуны, шундый сыйфатка ия булуны раслау, исбатлау. *Безне олылап, безнең профессия ияләренә ышанып, хәтта табынып караучыларның өметен акламау яки турыдан-туры алдашу – зур гөнаһ*. Т.Миңнуллин. *[Зөләйха:] Монда сиңа ике генә юл: я, башыңны иеп, тик каласың, я, көрәшеп, исемеңне аклыйсың*. М.Фәйзи. *Үләр идем аклап йөрәгемне Керсез актык сугыш кырында*. М.Җәлил. *Тәрҗемә әдәбиятның вакыты-вакыты белән милли әдәбиятны кысрыклавы сизелсә дә, бу хәл үз чоры өчен – әле татар балаларын рус телендә укыту тиешле юлга салынмаган утызынчы еллар өчен – үзен аклый торгандыр*. Ф.Ибраһимова

3) Гаепсезгә санап, хөкемнән коткару, кичерү. *Үзенең качуын аклар өчен, әллә нинди уйдырма хәбәрләр сөйләтә*. Ш.Усманов. *Әкайберләре, Газизовны акларлык күп кенә дәлилләр табып, барлык гаепне кыз өстенә ташлыйлар иде*. А.Шамов. *Моның йөзендә, бөтен торышында, хөкем алдында үзен акларга теләгән гаепләнүчедән бигрәк, бөтен дөньяга каршы көрәшкә әзерләнгән кеше төсе бар иде*. Г.Ибраһимов. *– Ничек дим, төрлечә булуы мөмкиндер, әмма хыянәтне бер сәбәп тә аклый алмый бит, Анна Сергеевна, – диде Туфайлов*. Х.Камалов

4) Көрәштә, бәхәстә бер якта булу, ул якның хокукы, интересы өчен көрәшү. *Ул тиз генә эчтән үзен-үзе акларга кереште: шулаен шулай, туганкай, ләкин бит әһәмиятле эшләрнең һәммәсен дә берьюлы эшләп булмый*. Ш.Камал

5) Тотылган чыгымнарны кайтару, каплау. *Туйга тотылган чыгымнар үзләрен акладылар*

**Аклап бетерү** Бөтенләй, тулысынча яки барысын да аклау. *Ләкин социаль философиянең функцияләрен артык «киңәйтелгән» (дөресрәге, артык конкретлаштырылган) вариантта күрергә тырышу үзен аклап бетерми*. К.Гыйззәтов

**Аклап җиткерү** Тулысынча аклау; тиешле дәрәҗәдә аклау. *«Җидегән чишмә» минем ышанычымны аклап җиткермәде. Ягъни мин уйлаган дәрәҗәдәге яхшы әсәр булып җитмәде*. Г.Бәширов

**Аклап калу** Аклый алу, аклауга ирешү. *--- карап уйга чумдың әле нигә, Сөембикә манарасы? Син торасың... авышсаң да бераз, Шул ук Җыр – дастаннар баганасы. Тарих үзе саклап, аклап калган; Хәзер Ник ят күрсен заманасы?* Р.Гаташ

**Аклап калдыру** Үзен аклый алу, аклануга ирешү. *Теләсә нинди очракта да үзен мир күзендә аклап калдыра*. Х.Камалов

**Аклап карау** Акларга омтылыш ясау. *--- нинди фашистлар булсын, ди, ә менә безнең служба синең белән миннән дошман табуны таләп итә. Син минә боларны аклап кара, агай-эне, ты-*

*рышып кара. Акны – кара, диеп, синең үзеңне дә шушы протоколга кертеп, Себер җибәрәчәкләр бит.* Рәмзи Вәлиев

**Аклап килү** Күптәннән, элек-электән үк, системалы аклау; һаман да аклау. --- *ата-бабаларыннан килгән Соседкин фамилиясенә төкереп, үзенең шома балык иканлеген шеф алдында да, әшнәләре алдында да аклап килде.* М.Насыйбуллин. *Яшь чагында ялгышкандыр... дип, сине аклап килдем...* Р.Батулла

**Аклап кую** Бер-бер сәбәбен табып аклау, тиз генә аклау. *Мәскәүнең читендәрәк бер кафеда тамак туйдыру сәеррәк тоелган иде дә, азактан моны да үзенчә аклап куйды: «Миңа каланы күрсәтергә теләгәндер...» – дип уйлады.* Ш.Янбаев

**Аклап тору** Һәрвакыт, гел аклау

**Аклап чыгу** Һәр очракта да аклау; ахырга хәтле аклау. *Бу яшь егет барлык спектакльләргә дә дип әйтерлек тартыла, һәм ул барысында да үзен аклап чыга.* И.Илялова

**Аклый төшү** Бераз аклау; тагын да аклау. *Шуның белән Фәсхигә карата булган нәфрәтне һәм тәнкыйтьне дә аклый төшкән: киръксез эпизодларны кыскарткан (Фәсхинең такмакларын), аерым күренешләрне бер урыннан икенче урынга күчергән.* М.Җәлил

**АКЛАШУ** *ф.* 1) Үзара бер-берсен аклау

2) *этн. диал.* Ярәшү, кызны яучылаган егеткә бирергә риза булу. --- *патша шул кызын кешегә күрсәтми үстерә икән, син, ди, патша сараена барып, шул кызны миңа аклашып кайт әле, ди.* Ф.Урманче. *Башта яучы йөри, әтиәнисе риза булса, аклашалар аннан. Аклашканда инде бүләкләр алышалар.* Ф.Баязитова

**АКЛЫ** I *с.* **1.** 1) Агы булган, ак төс катнаш. *Һәм ул ут чиксез матур: Күкле, кызыллы, аклы, ди.* Г.Тукай

2) Ак төстәге яки ак бизәкләре күп булган. *Аклы күлмәк якаларын кимичә каралтмагыз.* Җыр. *Аклы ситсы күлмәгемне Кисәм, каралыр микән, Искән җилгә сәлам әйтсәм, Алып баралыр микән.* Җыр. *Аклы күлмәк матур була якаларын каегач.* Җыр

**2.** *и. мәгъ.* Ак яки ак тукымадан тегелгән кием-салым. *Аклылары акка калсын, Каралыны киегез.* Җыр. *Иртәләр җитте исә, Аклысын кия ярың…* Х.Туфан

**АКЛЫ** II *с.* Ак төшкән, ак яры белән капланган. *Кайчагында Фәйзулла агай миңа, аклы күзен генә әйләндереп, калын тавыш белән: – Нихәл, чәүкә? Йокы ачыламы?* – ди. Ш.Камал. *Ләкин керфек араларыннан күзләре күренә, икесе дә аклы кебек, хәрәкәтләнәләр.* Ш.Камал

**АКЛЫК** *и.* 1) Ак булу. *Кар аклыгы кырдан киткәнче, без ак халат киеп йөрдек.* Ф.Кәрим. *Карлар ява, ап-ак карлар ява, Аклыклары – күңелләргә дәва.* Җ.Дәрзаман

2) Нинди дә булса чыганактан килгән яктылык. *Караңгы, шомлы булып күренгән биек таулар артындагы --- офык буйлап сызылган таң аклыгы күзгә сизелерлек тизлек белән киңәя бара иде.* М.Әмир. *Еракта-еракта – сыек кына, моң гына пәрдәгә төрелгән зур бер аклык.* Г.Исхакый

3) *күч.* Эчкерсезлек, риясызлык, пакьлек, сафлык. *Телим мин ак күңелне, ак йөрәкне, нурлы аклыкны.* Н.Исәнбәт. *Беренче китап... Һәр сүз, һәр шигырь юлы, күңел чишмәсеннән саркып чыгып, тел очында күпме тибрәлгән. Шагыйрь аларга җанының никадәр аклыгын салган…* Ф.Яруллин. *Аклык кайда, пакьлек, сафлык кайда? Кыйбла кайда? Бар да буталганмы?* Җ.Дәрзаман

4) Матурлык, яхшылык, изгелек. *«Кыямәт газапларын татыма, оҗмахлы бул! Чөнки син кешеләргә бары тик матурлык, аклык кына теләдең!»* – *дип кат-кат инәлде ул.* А.Гыйләҗев

5) Абруй, дәрәҗә, яхшы исем. *Шәбрәк җиһаз белән барса, Галиябануның үзенә дә кайниш арасында йөз аклыгы булыр.* М.Фәйзи

6) *диал.* Кыз ягыннан егет ягына вәгъдә бүләге итеп бирелә торган әйбер. *Сөлге сугам, сөлге сугам, Сөлге сугам аклыкка, Кызыл башлы сөлгеләрем язсын бәхет-шатлыкка.* Җыр

**АКЛЫ́-КАРАЛЫ** *с.* 1) Ак белән кара катнашкан; ак белән кара аралаш. *Авыр һәм аяусыз заманда болын-тугайларны тутырып кайткан, хуҗаларына чиләге белән сөт алып кайткан аклы-каралы сыерларны күрү күңелле.* Г.Ахунов. *Сәет җәһәт кенә чыгып китте дә, яңгырга чыланып, күшеккән аклы-каралы эт баласын күтәреп керде.* Г.Бәширов. *Почмактагы сандык өстендә аклы-каралы мәче ята.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Яхшысы да, яманы да булган; шатлыгы да, кайгысы да булган. *Әмма бу тормыш гел актан гына тормый шул, ул аклы-каралы, ак янында – кара, каралык янәшәсендә аклык бигрәк тә калку булып күренә.* Ф.Бәйрәмова

**АКЛЫ́-КЫЗЫЛЛЫ** *с.* Ак белән кызыл катнашкан; ак белән кызыл аралаш. *Карлыгачка атланып, ферма артына килеп чыгуга, яшел уйсулыкның инеш белән коры елга килеп кушылган турында аклы-кызыллы шәүләләр күземә чалынып китте.* Ф.Шәфигуллин

**АКМА** *с.* **1.** Ага торган (авырулы), агып торган

**2.** *и. мәгъ.* Ага торган шеш. *Аннан соң чишеп караганда, күр дә тор менә, Алла теләсә, шул дару салган җир бөтенләй акмага әйләнә.* Г.Гали

◊ **Акма колак** 1) Колагы ага торган кеше; 2) Кеше сүзен тыңламый, аңлап, отып кала алмый торган хәтерсез кеше. *Акма колакка әйтсәң – агып китәр, койма колакка әйтсәң – коеп алыр.* Мәкаль

**АКМАЙ** *и.* Сыер сөтеннән аерткан каймакны яки сөт өстен атлап алынган май, гөбе мае. *Чоландагы акмайга ияләшкән күселәр…* М.Җәлил. *Карчык уртага пыяла савыт белән акмай китереп утыртты.* А.Гыйләҗев. *Газизә, өстәмә итеп, чәй янына сумсалар һәм акмай куйды, шкафтан тагын ике чынаяк алды.* Ш.Камал. *Акмай белән дөге ярмасы азрак булды. Муса агай, иртәгә базага барып алып киләм, ди.* И.Салахов

**АКМЕИЗМ** *и. гр. әд.* Эчтәлеккә илтифат итмичә, бары нәфислекне генә алга сөргән, «сәнгать – сәнгать өчен» дигән карашны күтәреп чыккан әдәби агым. --- *Такташ, Җәлил, Гафури, Исәнбәт иҗатларына зур йогынты ясаган дини-мифологик катламның,*

*символизм, футуризм, акмеизм кебек «йомры» агымнарның, шәкли тәҗрибәләрнең татар поэзиясе үсешенә ясаган тәэсирен фәнни бәяләү ихтыяҗы ачык сизелә.* Т.Галиуллин

**АКМЕИСТ** *и. рус* Акмеизмны яклаучы, шул агым тарафдары

**А́К ӨЙ** *и. этн.* Кара-каршы ике өйнең кунак кертелә торган түр ягы. *Беркөнне, кичке чәйдән соң, ул үз янына, ак өйгә, Сафаны чакыртып алды.* А.Шамов. *Бу – тирмә йортның ак өе санала, байбичәнең даими торуы шунда була.* Г.Ибраһимов. *Тирмәнең уң ягында утырган тукал, Юныска карап: – Мин ак өйгә ит бирмәдем, шуннан өлеш чыгарырсыз, – диде.* Г.Ибраһимов

**АКР** *и. ингл.< лат.* Англиядә һәм Америкада 4047 кв. метр мәйданга тиң үлчәү берәмлеге

**АКРОБАТ** *и. фр.< гр.* Цирк гимнасты. *Егет --- идәндәге чемоданнар, төеннәр арасыннан акробат шикелле кыеклап кына үтеп киткәч, карт соклангандай әйтеп куйды: – Ух, шайтан!* Ә.Еники

**АКРОБА́ТИК** *с.* Акробатикага караган. *Ярминкә көннәрендәге бәйрәмгә уен карарга килүчеләр аны гадирәк акробатик номер башкаручы сыйфатында --- күрергә күнегәләр.* Казан утлары

**АКРОБА́ТИКА** *и. фр.< гр.* Гимнастика һәм цирк сәнгатенең бер төре. *Әниснең курсташы Марс, аның ишектән карап торганын күргәч: – Әнис, әллә син дә безнең акробатика түгәрәгенә керәсеңме? Уз, әйдә, – диде.* Ә.Хәсәнов

**АКРЫН** *рәв.* **1**. 1) Хәрәкәт тизлеген зур итмичә, гадәти тизлектән түбәнрәк итеп; салмак. *Ул, кулын артка куеп, урман буеннан акрын гына югарыга таба атлый башлады.* Г.Бәширов. *Миңа поезд бик акрын барадыр кебек тоелды.* Казан утлары

2) Талгын, җиңелчә. *Тирәдәге агач яфраклары, акрын искән җил белән, ни-нәрсә хакындадыр җилфер-җилфер сөйләшәләр.* Г.Ибраһимов

3) Гадәттә *генә/гына, кенә/кына* кисәкчәләре белән килеп: басынкы тавыш белән, ашыкмыйча. *Ястүне соң гына укыгач, әти, караңгы почмакка каршы утыра да, акрын гына көйли башлый.* Г.Ибраһимов

4) Саклык белән, җай белән. *Ул икенче кулы белән акрын гына минем кулыма сукты һәм үз кулын минем учымнан ычкындырды да җитез генә сикереп торды.* Ф.Әмирхан

5) Озак, көттереп (вакыт, гомер узу турында). *Караңгы төн акрын уза иде.* Г.Бәширов

6) Ипләп, җайлап, сиздермичә. *Акрын кирәк, иплә кирәк Ишетергә сандугач сайрауларын.* Җыр. *Һәммә нәрсә үтә. Идел дә бертуктамый акрын гына агып тора, гомернең дә акрын гына, тавышсыз гына узып торган көне.* Гали Рәхим

7) Шыпырт, ишетелер-ишетелмәс итеп. *Нургали янында янәшә үк басып торган Кәримәгә акрын гына әйтеп куйды.* Ә.Еники. *Анасы исә әллә акрын гына елый, дога кыла, әллә бик акрын тавыш белән Коръән укый иде – ул бу икене аера алмады, ләкин күңеле әүвәлгесенә китте.* Г.Ибраһимов

8) Билгеле бер дәрәҗәдә генә, беркадәр, аз гына. *Ишектән килеп керүгә, инде казанда акрын гына гөбер-гөбер кайнаган итнең өйгә таралган буы, мичтән чыккан бәлеш исе борынны кытыклап җибәрә.* Ә.Еники

9) Билгеле бер эзлеклелек саклап. *Ул, авыл өстенә йомшак канатын җәйгән таң һавасының акрын гына агылып торуын бөтен тәне белән тоеп, балалардай сулкылдап куя.* Г.Бәширов. *Кыр өстенә, шәһәр өстенә караңгылык пәрдәсе акрын гына җәелә.* А.Шамов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Салмак, авыр хәрәкәтле. *Акрын, салмак адымнар белән, мин дүрт мәртәбә бу урамны буйдан-буйга таптап чыктым.* Ф.Әмирхан

2) Ашыкмаучан, авыр хәрәкәтле. *Акрын кеше*

**3.** *ы. функ.* Нинди дә булса эшне тыйганда, сак, сизгер, уяу булырга өндәп, истә тотуны таләп итеп әйтелә; абай. *Акрын! Акрын! Аягыңа әйбер кадалмасын, – ди ул.* И.Гази. *Акрын! Килен бала йоклата.* Т.Гыйззәт

**АКРЫНАЙТУ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса хәрәкәт тизлеген, темпын киметү, акрынрак итү. *Бара торгач, алар, үзләре дә сизмәстән, аяк адымнарын акрынайттылар.* Ш.Камал

2) Нәрсәнең дә булса көчен, тавышын һ.б.ны киметү, югарылык дәрәҗәсен кечерәйтү. *– Анда гайбәтче карчык утыра, әйдә монда, – дип, келәткә таба тартып, тавышын акрынайтып әйтте.* Г.Ибраһимов

**Акрынайта бару** Торган саен ныграк акрынайту, аз-азлап акрынайту

**Акрынайта башлау** Акрынайтырга тотыну

**Акрынайта бирү** Акрынайтуын дәвам итү. *Машина, тизлеген азрак акрынайта биреп, сулга, икенче капка ягына борыла башлый.* З.Зәйнуллин

**Акрынайта төшү** Беркадәр, бераз акрынайту. *Сабир абзый улының хәлен аңлады, ахрысы, адымын акрынайта төште.* Р.Батулла. *Тикшерүче, яшерен сер әйткәндәй, тавышын акрынайта төште.* С.Сабиров

**Акрынайтып җибәрү** Кинәт акрынайту

**Акрынайтып җиткерү** Билгеле бер дәрәҗәгә туры китереп акрынайту

**Акрынайтып кую** Акрын хәлгә китереп калдыру

**Акрынайтып тору** Әледән-әле яки вакыт-вакыт акрынайту

**АКРЫ́Н-АКРЫН** *рәв.* 1) Акрын гына, салмак кына, ашыкмыйча гына. *Аннан поезд кузгала башлады. Башта акрын-акрын гына.* А.Алиш

2) Акрынлап, аз-азлап, тора-бара. *Әйтерсең, авылны кан туфаны басып яки авыл аркылы ут бураны үтеп китте. --- Ләкин бу куркынычлары акрын-акрын гына туктадылар.* Г.Тукай. *Тормышның кояшы акрын-акрын гына баешына якынлаша башлауга, ирексездән артка, үткәннәреңә борылып карыйсың икән: нәрсәгә ирештең... ә нәрсәгә ирешмәдең?* Р.Мирхәйдәров. *Америка, акрын-акрын гына, Франция, Германия, Испания, Австрия кебек дәүләтләрне дә ваклап-бүлгәләп, күпмедер вакыт бөтен Җир шарына хуҗа булып торды...* З.Мәхмүди. *Минә аның аркасы черки тешләгән кебек аз гына авырту сизде, минә бөтен тәнемә акрын-акрын гына җылы йөгерде ---.* Р.Вәлиев

**АКРЫНАЮ** *ф.* 1) Берәр эш яки хәрәкәтнең тизлеге, темпы, ритмы кимү, әкренәю. *Автобус, акрынаеп, бер йорт тирәсендә туктады.* М.Мәһдиев. *Шыкы-шыкы килеп, вагоннар юлдан-юлга күчтеләр, акрынайдылар.* М.Мәһдиев

2) Салмаклану. *Адымнары акрынаю. Хәрәкәтләре акрынаю*

3) Нәрсәнең дә булса көче, тавышы, кискенлеге кимү. *Аның тавышы бер акрыная, бер дулкынланып яңгырап китә, ара-тирә ул, йодрыгын селти-селти, кемгәдер янап та куя иде.* Г.Бәширов

**Акрынаеп алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә акрынаю

**Акрынаеп җитү** Чигенә килеп акрынаю

**Акрынаеп калу** Билгеле бер моменттан яки сәбәптән соң кинәт акрынаю

**Акрынаеп килү** Аз-азлап, җай гына акрынаю. *Фронтта эшләр ярыйсы иде, хәзер акрынаеп килә.* Г.Бәширов

**Акрынаеп киту** Көтмәгәндә, кинәт акрынаю

**Акрынаеп тору** Әле, хәзерге вакытта акрынаю

**Акрыная бару** Торган саен ныграк акрынаю, аз-азлап акрынаю. *Тора-бара, тавыш акрыная барып, инде басылды, дигәндә, икенче малайның көр тавышы елауны эләктереп алды.* Казан утлары

**Акрыная төшү** Беркадәр, бераз акрынаю. *Берсенең янындан узып барышлый, Шәмси, аның бөкрәеп торуына гаҗәпләнеп, акрыная төште.* Г.Бәширов

**АКРЫНЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **акрынаю**. *Колагымда һич дөньяда булмаган ләззәтле, акрын гына күңелне тырный торган уен тавышы ишетелә. Уен тавышы акрынлана, уен тавышы эри.* Г.Рәхим

**АКРЫНЛАТУ** *ф. к.* **акрынайту**. *Атларыбызны бераз акрынлатып, аларның артына юлга төштек.* Ф.Әмирхан

**АКРЫНЛА́У** *ф.* **1.** *к.* **акрынаю**. *Бу гөрелдәү бер акрынлый, тагы күтәрелеп китә, вакыт-вакыт, гөрелдәү аркылы [кешеләрнең] ялгыз-ялгыз тавышлар ишетелеп китәләр.* Р.Гали

**2. акрынлап** *рәв. мәгъ.* 1) Ашыкмыйча, акрын гына, артык кабаланмыйча. *Аның белән акрынлап сөйләшә-сөйләшә кайттык.* Ш.Камал. *Ферманың азмы-күпме уңышларын телгә алып сүзен башлаган яшь председатель, акрынлап, ләкин эзлекле һәм рәхимсез рәвештә, ферма мөдирен кысрыкларга тотынды.* Ә.Еники

2) Эзлекле рәвештә, тора-бара, вакыт үтү белән. *Тик Мәләкәстән кайткан бу асыл сөяк сыерның нәселе, ни хикмәттер, безнең Яушырмәдә мантый алмый, икенче, өченче буыннан ук акрынлап ваклана башлый, тора-бара, бөтенләй югала иде.* Ә.Еники. *Ул [хис], акрынлап булса да, һаман дөрләп тора, акрынлап булса да, һаман көчәя бара.* Ш.Камал

3) Көттереп, зарыктырып. *Язлар җитә, әнә тамчы тама, Җылы чаклар килә якынлап, Синең кебек матур, моңлы кошлар Килә башлар инде акрынлап.* Ш.Бабич

**Акрынлый төшү** *к.* **акрыная төшү**. *Сукмакның кырыена ук килеп үскән биек усакка җитәрәк, егет акрынлый төште.* Г.Бәширов. *Пәрдә ахырына таба, кул чабуларның нормасы бераз үзгәрде: партер белән ложалар бераз җанландылар. Галерка аз гына акрынлый төште.* Ш.Камал

**АКРЫНЛЫК** *и.* Акрын булу, сүлпәнлек. *Байрашта газетага язылу темплары бик акрынлык белән бара.* Тәтеш таңнары

**АКСАК** *с.* **1.** 1) Аксап йөри торган, аягы зәгыйфь, чатан. *Ә Васябыз ай ярымнан соң терелеп чыкты. Аллага шөкер, аксак түгел. Тыпырдап йөгереп тора.* Ф.Яруллин. *Мәчеттән, иң соңгы булып, аксак мөәзин – сикеребрәк атлаганы өчен «бия» дигән кушамат тагылган Галимҗан чыкты.* Г.Шәрипова. *Чаялыгы белән даны таралган Ситдыйк Мөнәвәрәсе: «Нигә минем хезмәт көннәремне урлап калдың, аксак ристан», – дип, хисапчы Сабирның якасына ябышты.* А.Расих

2) *күч.* Ватык, сынык аяклы, селкенә торган. *Аксак урындык. Аксак кәнәфи*

**2.** *и. мәгъ.* Аягы гарип, аксап йөри торган; титак кеше. *Аксак күп йөрер, сукыр күп күрер.* Мәкаль

**АКСАКАЛ** *и.* 1) *тар.* Борынгы җәмгыятьтә: уртак баба, ыруг башлыгы. *Ыруг общинасын --- аксакаллар --- идарә иткән.* Урта гасырлар тарихы

2) Өлкән яшьтәге ихтирамга лаек кеше. *Аксакаллар бу начар җирне бирергә уйласалар да, Мете моңа каршы төшә.* Г.Дәүләтшин. *Аксакал сүзен аяк астына салмау турысында баш редактор Харрас Әюпкә сүз катарга туры килде.* Мәдәни җомга. – *Әллә ни хөрмәтем юк, аксакал, гафу итәрсез, – диде ул башта, – сезне сыйларга кымыз да казылык кына бар.* Мирас

3) Өлкән, хөрмәтле кеше, ил агасы. *[Фатыйма] Үзе авылның мулла-мәзине белән берничә могтәбәр аксакалыннан башка адәмнән качмый.* Г.Ибраһимов. *Әле үзенең 80 яшьлек юбилеен да аксакал шагыйребез илһамлы иҗат белән каршылады.* Мәдәни җомга. *Бер сүз белән әйткәндә, гасырны иңләп-буйлап кичкән ил агасы Ә.Еники сүзе бүгенге шартларда да безгә аксакалның зирәк киңәше булып ишетелә.* Мәдәни җомга.

**АКСАКЛА́У** *ф. к.* **аксау**. *Аягы кысылудanмы, ул бераз аксаклый иде ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Сыңар култык таягы белән титак-титак аксаклап йөри иде әле Мөнир ул вакытта.* Р.Төхфәтуллин

**Аксаклап калу** Ниндидер сәбәптән яки вакыттан соң аксак хәлгә килү. *Ат типкәннән соң, ул аксаклап калды*

**Аксаклый төшү** Бераз аксаклау, сизелер-сизелмәс аксаклау

**АКСАКЛЫК** *и.* 1) Аксак булу, аксап йөрү, аксакка әйләнү. – *Миңа аның [Равилнең] аксаклыгы бөтенләй сизелми, – диде бу.* Н.Фәттах

2) *күч.* Кимчелек, җитешсезлек. *Әлбәттә, басмада Ф.Яхинның шагыйрьлеге тулысынча җиңә алмаган юллар да юк түгел. Андыйлардагы рифмасызлык, ритмик аксаклык нидән килә?* А.Әхмәдуллин

**АКСА́К-ТУКСАК** *с. сөйл.* **1.** Аксак, гарип. *Авылда аксак-туксак карт-коры гына.* Н.Гыйматдинова

**2.** *җый. и. мәгъ.* Аяклары аксак гарип кешеләр. *Аксак-туксак – бер тәлинкә бавырсак.* Такмак. *Әйе, сугыш елларында колхозларга җитәкче булып,*

*йә ярым гарипләр, йә аксак-туксак, бөкре-кәкреләр килде.* А.Гыйләҗев

**АКСАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **аксау.** *Шакир Зифа әбине янына утыртты да зур күк атны, аксата-аксата, басу капкасына чаптырды.* Г.Ибраһимов

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса аягын имгәтү, гарипләндерү. --- *кайтканда, колхоз атының аягын сындырган. Бу хәлне утырышка куйганнар. Авыл советы секретаре Җәмил абый беркетмәгә «Иванов аксатып кайткан атны суярга» дип язасы урынга, ялгышып, әлбәттә, «Ивановны суярга» дип язган.* Т.Нәҗмиев

3) *күч.* Нинди дә булса эштә комачаулау, тоткарлык ясау, нәрсәгә дә булса аркылы төшү

**АКСА́У** *ф.* 1) Аякның авыртуы яки гарип булуы аркасында титаклау, чатанлау. *Нервысына түзә алмыйча, хуҗа килеп чыга калса, тиз генә сыпыру ягын карый. Андый чакта аягы да аксамый.* В.Нуруллин. *[Отделком абый] Чынлап та, сул аягына аксый, кәкре башлы таякка таянып йөри икән.* Т.Мөбарәков

2) *күч.* Берәр эш яки хәлнең торышы канәгатьләнерлек булмау, кимчелекле булу, эш акрын, сүлпән бару. *Аннары, бергәләп, хата төзәтәләр. – Рус телегез аксый сезнең, егетләр, – дип башын селки Григорий Феофанович.* Г.Шәрипова. *Тәртип ягы аксый синең, туган, сүзне тыңламыйсың.* Казан утлары

3) *күч.* Башкалардан калышу, артта калу

◊ **Аксаган белән аксау** Башлыгың яки юлдашыңның күңеле булсын өчен, үзеңне дә шундый кимчелек иясе итеп күрсәтү; ялагайлану. **Аксаган як** Кимчелекле, җитешмәгән урын

**Аксап алу** Бераз, кыска вакытлы аксау. *Ничек инде гомер бакый төгәл йөр дә аксап ал?!* З.Мансуров

**Аксап бару** Акрынлап, аз-азлап көчәя барып аксау. *Күрәсез, безнең цехта эш аксап бара.* А.Алиш. *Сыйфат мәсьәләсе аксап барса да, сан ягыннан борчылырга урын юк сыман.* Р.Харис

**Аксап бетү** Тәмам аксау, аксаган булу, аксаган хәлгә килү

**Аксап йөрү** Әле, хәзерге вакытта аксау. *Аксап йөргән кәҗәңне дәваласа да, бозаулый алмый яткан сыерыңны бозаулатса да, Пермяковның исеме гел «ат врачы» булып калды.* М.Мәһдиев

**Аксап калу** Нинди дә булса сәбәптән, вакыттан соң аксау. *Хәер, «антилопа»сына ачу да килми бугай, тик менә әллә кайчангы бер өмәдә аягына имән бүрәнә төшеп аксап калган этине «чатан» дип мәсхәрәләттерәмме соң!* М.Шаһимәрдәнов

**Аксап китү** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт аксый башлау. *Бергә таянабыз таякларга, Аксап киткән чакта – нилектән?* В.Галиев

**Аксый башлау** Аксарга тотыну. --- *соңгы елларда бездә эстетик як белән тәрбияви әһәмият еш онытыла. Шушы ике мәсьәләдә безнең әсәрләр соңгы елларда нык кына аксый башлады.* М.Вәли-Барҗылы

**Аксый төшү** Бераз аксау, чак кына аксаклау. --- *[Шәмсетдин] уң аягына бераз аксый төшеп, урамның кыл уртасыннан атлый иде.* Г.Бәширов

**АКСА́У-ТУКСАУ** *ф. сөйл. к.* **аксау** (*1 мәгъ.*). *Мәһабәт колонналы ак бинаның озын коридорында сары кайры тун, төпле пималар кигән Эткол егете, аксый-туксый, укып йөри башлый.* Ә.Еники. *Үз аяклары белән, ике кулын селтәп кайтып килүен күреп, гаҗәпкә калалар. Чөнки әле моңа кадәр бу юлдан, аксап-туксап, яралы фронтовиклар гына кайта торган булганнар. Ә Юлдаш аксамый да, туксамый да...* Казан утлары

**АКСЕЛЬБАНТ** *и. нем.* Кайбер армияләрдә бәйрәм мундирларының уң җилкәсенә беркетелә торган, алтын, көмеш яки төсле җепләрдән үрелгән, кайвакытта ялтыравык очлыклар белән бизәлгән шнур. *Башта бу кибеттә нинди-нинди китаплар барлыгын тезеп киткәннәр, аннары шушы ук кибеттә, аз гына тотылган алтын аксельбант та сатыла, дип язганнар.* Г.Әпсәләмов

**АКСЕЛЕРАТ** *и. лат.* 1) Акселерация билгеләре сизелә торган тере организм (мәс., хайваннар). *Әбүзәр абыйның акселерат куяннары 4 ай эчендә 4–5 килограммга җитә икән.* Безнең гәҗит

2) Физик, физиологик һәм психологик яктан башкалардан алдарак үсә, өлгерә торган бала, яшүсмер. *Ике метрлы акселерат укучы, тупны тотып ала да: «Иии-яяя!» – дип үкереп, аңа тибеп җибәрә!* Сәхнә

**АКСИО́МА** *и. гр.* Дөреслеген исбатлау таләп ителмәгән хакыйкать. *Табигать турындагы фәндә аксиомалар юк.* Д.Менделеев. *Һәр әдәбиятның нигезендә фольклор ята, дип саный Горький. Бу – дөрес фикер, аксиома кебек хакыйкать.* Р.Фәйзуллин. *Кичә генә аксиома булып кабул ителә торган рухи кыйммәтләр бүген инде кискен бәхәсләр кузгата.* Ф.Галимуллин

**АКСИО́МАЛАШУ** *ф.* Аксиомага әйләнү

**АКСӨЯК** *и.* 1) Затлы, югары нәселдән булган кеше; аристократ, дворян. *Шул стиль Ибраһимовта да бар. Җамал Вәлидидә ул юк. Ул – тумыштан аксөяк. «Сөяк» бу очракта «нәсел» дигән сүз. Аксөяк – ул затлы нәсел, «аристократия» дигән сүз.* Р.Батулла. *Мәмләкәт – өлкәләргә, әлкәләр волостьларга бүленгән, һәм бөтен халык аксөяк (дворян) белән карасөяк (гавам) исемендә икегә аерылган иде.* Мирас

2) *күч.* Эш сөйми торган, тәмле ашап, матур киенүне ярата торган кеше. *Юк, мин аксөяк түгел. Аксөяк булып, көчсезләрне елатып йөрүчеләрдән мин җирәнәм. Мин – сукачы баласы.* М.Фәйзуллин

**АКСӨЯКЛЕК** *и.* Аксөяк булу. *Штабс-капитан озын буйлы, таза гәүдәле, һәрнәрсәне үзенең аксөяклек вкусына карап эшләргә ярата торган, чын аристократ табигатьле бер офицер иде.* М.Гали

**АКСЫЛ** *с.* 1) Ак төскә тартым, ачык төстәге. --- *Сакмар урманы да, аксыл томанга уралып беткән ераклыклар да дәшми иде.* Ф.Сафин. *Шушы биеклек өстеннән, кайсы якка карасаң да, җәелеп яткан аксыл иген кырлары, яшел үзәннәр, күгелҗем урманнар --- күренә иде.* Ә.Еники. *Ул кешенең өстендә – сүсәргән саргылт төстәге казаки, башында – аксыл бүрек, үзе – бөтен генә карт.* Ш.Камал. *Аның аксыл сирәк чәчләре, --- майлап таралган, ак-*

*сыл мыегы нәкъ борын астында гына урталай бүленеп, борын турысында ирене ялтырап тора.* М.Мәһдиев

2) Төсне атаган сүзләр янында шул төснең сыеграк, уртача дәрәҗәдән кимрәк булуын белдереп, кимлек дәрәҗәсендәге тезмә сыйфатлар барлыкка китерә (мәс., *аксыл зәңгәр, аксыл сары, аксыл кызыл, аксыл яшел* һ.б.). *Ләкин фаралар яктысына, әледән-әле, аксыл соры төн күбәләкләре килеп чыга.* Г.Бәширов. *Ә күк йөзе шундый чиста, исең китәрлек сихри төскә – аксыл зәңгәр төскә кергән.* Р.Мөхәммәдиев

3) Төссез; нурсыз, төсе киткән. *Ниндидер көрәк сакаллы бер кеше аксыл гына чырайлы, шәһәрчә, ләкин бик тәкәллефсез генә киенгән бер кызны шәһәргә алып бара.* Ф.Әмирхан. *Шул сигез ай эчендә ул бик ябыккан. Электә дә аксыл йөзе хәзер, ничектер, үлем аклыгы белән капланып, эчкә суырылган.* Г.Ибраһимов

**АКСЫЛЛАНУ** *ф.* 1) Аксыл төскә керү, аксыл булып күренү

2) Караңгы төсен югалтып, яктыра бару, агарып күренү. *Күк чите аксыллану*

**Аксыллана бару** Торган саен ныграк аксыллану. *Инде күк йөзе аксылланганнан аксыллана бара.* А.Шамов

**Аксыллана башлау** Аксыллыгы сизелерлек булу. *Яфраклар, җәйге карасу яшеллекләрен югалтып, аз гына аксыллана башлыйлар.* Г.Гамов

**Аксыллана төшү** Бераз, беркадәр аксыллану. *Вәдүт абый, кара бөдрә чәчләрегез аксыллана төшкән.* И.Юзеев

**Аксылланып бетү** Тәмам аксыл төскә керү, бөтенләй аксыллану

**Аксылланып җитү** Тулысынча аксыллану

**Аксылланып калу** Ниндидер сәбәп яки вакыттан соң аксыл төс алу. --- *стенадагы икесе бергә төшкән портрет урыны аксылланып калган.* Р.Вәлиев. *Кыш буе тынчу мәдрәсәдә ятудан аксылланып калган йөзләренә шаянлык, мутлык төсмерләре җәелде.* Ф.Сафин

**Аксылланып килү** Акрынлап, азазлап аксыллык иңү. *Шаулый җилдә бодай басулары, Аксылланып килә арышы.* Г.Сәгыйров

**Аксылланып китү** Көтмәгәндә, кинәт аксыллану. *Тын гына утырса да, җыерыла төшкән киң маңгае, ике уртада түбәнгә бөгелгән куе кашлары һәм ничектер аксылланып киткән чырае җанындагы киеренкелекне яшерә алмады.* А.Вергазов

**Аксылланып тору** Аксылланган хәлдә булу; әле, хәзерге вакытта аксылланып күренү. *Зәңгәр күк йөзе, бүз тарткан кебек, аксылланып тора.* Ә.Салах

**АКСЫМ** *и.* Хайван һәм үсемлек организмының әһәмиятле өлешен тәшкил иткән органик матдә. *Аксымнар үсемлек һәм хайваннардан алына торган азыкларда булалар.* Биология. *Күп тереклек функцияләре – мәсәлән, кислородны күчерү, иммун процесслар, мускуллар кыскару аксымнарга бәйле.* Анатомия. *Бер тонна ит җитештерү өчен, аксымга ярлы азыкны, аксымы мул булган азыкка караганда, бик күпкә артыграк ашатырга кирәк.* Кызыклы физиология

**АКСЫМЛЫ** *с.* Составында аксым булган; аксымга бай. *Әгәр организмда аксым җитмәсә, сәламәтлек какшый. Димәк, һәркөн аксымлы азыклар ашау шарт.* Биология

**АКСЫРГАК** *и. бот.* 1) Лаләчәләр семьялыгыннан, юантык кыска тамырчалы, эре яфраклы, себеркесыман чәчәкле, дымлы җирдә үсә торган агулы үсемлек; *русчасы*: **чемерица**. *Анда бака яфрагын да, кычытканны да танырга була, аксыргак, абага белән андыз тамыры да бар.* Ш.Бикчурин

2) *күч.* Агу. *Ул карт күсегә [Габсатарга] әллә кайчан аксыргак бирергә кирәк иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**АКТ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса юридик факт турында язылган документ. *– Барысы да кырылып бетмәсә шөкер инде, боларына акт төзербез, – диде ул. – Акт кына умарта кортларын үлүдән коткара аламыни? – диде апа, үртәлеп.* Ф.Яруллин. --- *Сибгатуллин акт төзеде дә, берничә шаһиттан имза салдырып, район милиция бүлегенә җибәрде.* Мирас

2) Дәүләт күләмендә зур әһәмияте булган указ, карар. *Совет хөкүмәте 1921 елны «Ясная поляна»ны дәүләт заповедныгы итеп игълан итә һәм, бу акты белән, ул үзен бөек язучының туган-үскән, иҗат иткән җирен дөнья культурасы өчен мәңге саклаучы бердәнбер чын хуҗа итеп күрсәтә.* Ә.Еники

3) Драма әсәре яки спектакльнең тәмамланган бер өлеше. *Икенче актта аңа ариозо бирелсә, картина көчәя төшәр иде, һәм бу вакыйга гадәттән тыш бер нәрсәгә әйләнер иде.* М.Җәлил

4) Сынлы сәнгатьтә кешенең сурәтен шәрә көенчә тасвирлау алымы

5) Очраклы бер хәл, аерым бер вакыйга, очрак. *Мәктәптән дәфтәр урлаганда, мин моны онытып торырга тырыштым. Чөнки бу актны «караклык» дип түгел, ә бер зарури хәл, табигый эш дип кабул иттем.* М.Мәһдиев

6) *сир.* Уку йортларында уку елы тәмамланганнан соң үткәрелә торган тантаналы җыелыш

**АКТАМЫР** *и. бот. диал.* Сарут; *русчасы:* **пырей**

**АКТАРУ** *ф.* 1) Бергә торган әйберләрнең билгеле тәртибен бозу, бутау, чуалту

2) Әйберләр арасыннан нәрсә дә булса эзләү. *Өйгә кайтып, кәрҗинемне төбенә кадәр актардым. Кәрҗинемне актарган чакта, әллә нихәтле кирәкмәс әйбернең төялеп килгәнлеге мәгълүм булды.* Гали Рәхим. *Ялгызы гына калгач, сандыкларын актарырга тотынды, инде күптән кимәгән ефәк күлмәкләрен тартып чыгарды.* Г.Шәрипова

3) Җир астында яткан нәрсәләрне казып чыгару, береккән, ябышкан нәрсәләрне бер-береннән аеру, куптару, ермачлау. *Кышын түгелгән чүп өемнәрен актарабыз. Шаккатырлык матур бизәкле ташаяклар килеп чыга алардан.* Ш.Маннур. *Үрдәкләр, борын очлары белән күл төбен актарып, бүтәкәләренә ком тутыралар.* К.Нәҗми. *Гаярь егетләр тау-ташларны актарып юл салганнар.* Мәдәни җомга

4) Зур күләмле итеп каеру, куптару, ермачлау. *Чи калган җирдә сабан төрәне мул итеп актарган кәсләр тезелеп ята.* Мәдәни җомга

5) Нәрсәне дә булса тузгыту, туздыру; пыран-заран китерү. *Янган өйләр көлен актара җил, Зур кайгы бар төсле аңарда.* З.Мансур. *Кулына кисәү агачы тотып мич актара торган Гөлбаһар абыстай, үзенең корымга буялган кулларын аларга күрсәтәсе килмичә, оялып, алъяпкыч аша гына сузды.* М.Гали

6) Китап, дәфтәр кебек нәрсәләрнең кирәкле урыннарын эзләп, ачып карау. *Шул вакытта мин кулыма китап алам, аның изге сәхифәләрен актарам.* Г.Тукай. *Бикмулла куен кесәсенән чуар тышлы озынча бер дәфтәр чыгарды да, бармакларын төкерекләп, актарырга тотынды.* Г.Бәширов. *Күгелҗем төстәге кыштырдап торган битләрне актарам. Бу – XVIII гасырның башында гына Россиядә эшләнгән мәгълүм күксел кәгазь.* М.Госманов

7) *күч.* Карап чыгу, күздән кичерү, күз белән айкап чыгу. *Күзләрем бөтен пароходны актардылар, --- пристаньга төштеләр һәм анда Хөршитне таптылар.* Ф.Әмирхан

8) *күч.* Баштан үткән хәлләрне, вакыйгаларны искә төшерү, хәтердә барлау. *Ләкин инде аның күңеле бер дә ала торган нәрсәдә түгел, моннан биш сәнә мокатдәм булган вә үткән хатирәләрне актаруда иде.* М.Гафури. *Фикер әллә кайларда сәяхәт кыла ---. Күңел сандыгымның төбендә сакланып калган алтын бөртекләрен, акрын-акрын актарып, берсе артыннан берсен казып чыгарам.* Гали Рәхим. *– Акланмады минем ул өметләрем, – дип авыр көрсенде Әпсәләм. – Газаплама үзеңне, актарма иске җәрәхәтләреңне.* Г.Шәрипова

9) *күч.* Нинди дә булса көчле хисләр кузгату, берәр хис, рухи халәт хасил итү. *Бу күз карашлары нидер эзли аңардан, алар аны һәрьяктан капшый, аның күңелен актара, йөрәгенә сузыла.* А.Сафин

10) *күч.* Тикшерү, җентекләп карап, ачыклап чыгу. *– Мондый закон бармы? Шәригать бармы? Мин һәммәсен актарырмын!..* Г.Ибраһимов

11) *күч.* Бик зур эшләр башкару, булдыру. *Их, аның урысчасы, укымышы тагын да көчлерәк булса, ул таулар актарыр иде, ди.* Г.Ибраһимов

12) *күч.* Зур булдыклылык күрсәтү, мал-байлык табу артыннан чабу. *– Безнең Сөендекне дә үз бригадаңа чакырмадың, энекәш, дип йөргән буласың үзең. – Аңа болай да җиткән, трактор белән дә, ферма үгезләрен үстереп тә дөньяны актара.* Мирас

**Актара башлау** Актарырга тотыну. *– Әй, туктагыз әле, – ди Нәзирә һәм тиз генә сумкасын актара башлый.* Ф.Яруллин

**Актара төшү** Беркадәр, бераз актару; тагын да актару. *Тимергалиевнең болай да тынгысыз күңелен тагын да актара төшә.* Г.Исхакый

**Актарып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада актару. *Моннан өч-дүрт ел элек, комсомолда эшләгәндә, дус кызына язган хаты иде бу. Кайлардан актарып алган бу хәйләкәр төлке!* Г.Бәширов

**Актарып ату** 1) Тиз генә, аннан-моннан актару

2) Кинәт актару. *Ул да булмады, кемнеңдер карлыкканрак тавышлы моңы бәгырьләремне актарып атты.* Р.Бәшәр

**Актарып бетерү** Бөтенләй яки барысын да актару, тәмам тәртибен бозганчы актару. *Газинур --- автомашиналарның тәгәрмәчләре һәм чылбырлы тракторлар актарып бетергән киң урамның аргы башына таба йөгереп китте.* Г.Әпсәләмов. *Кызлар бар булган байлыкларын актарып бетерделәр һәм бер тукыма кисәге таптылар.* Г.Шәрипова

**Актарып җибәрү** Актарырга тотыну, актара башлау. *Башмак йорт уртасына өеп куйган кар йомгагын туздыра, мөгезе белән актарып җибәрә – тәүфыйксыз малайлар кебек шаяра.* М.Әмир

**Актарып ташлау** 1) Рәттән бөтенесен дә актару, тәртипсез тарату. *Хәят, гадәтенчә, комод тартмаларын актарып ташлады да йөз кат күргән нәрсәләрен йөз дә беренче кат күздән үткәреп чыкмакчы булды.* Ф.Әмирхан

2) Актарып, ишеп төшерү. *Ул, күз ачып йомганчы, өстендәге саламнарын актарып ташлады.* Г.Ибраһимов

**Актарып тору** Бертуктаусыз, гел, һәрвакыт актару. *Әгәр дә бар икән иреңнең акчасы, нигә аны актарып торырга. Кирәк икән – үзе бирер.* Т.Миңнуллин

**Актарып чыгару** 1) Кайдан да булса нәрсәне дә булса актарып алу. *Әйтерсең лә күктән яшен ташы төшеп, аны шулай чәрдәкләп, чәчеп ташлаган, җир астыннан бәргән ялкын барысын өскә актарып чыгарган.* Ф.Бәйрәмова

2) Югалган яки онытылган нәрсәне эзләп табу. *[Нәгыйм] Мич башыннан күгәреп беткән ышкы актарып чыгарды.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Электә, үткәндә булган хәлне, эшне торгызу, казып чыгару, аның асылын ачыклау. *Моннан биш ел элек булган бер эшне актарып чыгарып, хөкемгә биргәннәр*

**Актарып чыгу** Барлык нәрсәләрне, барысын да берәм-берәм яки башыннан ахырына кадәр актару. *Ләкин, кемнәндер хат көткән кебек, килгән хатларны һәрвакыт игътибар белән актарып чыга.* И.Гази. *Ул китапны актарып чыкты да янәшәсенә куйды һәм күзләремә карады.* Казан утлары

**АКТАРЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **актару** (*1–5, 8, 9 мәгъ.*). *Тояк асларында җир актарылды, зәңгәр күктә нурлар чайкалып торды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Җимерелеп, авып төшү. *Тупка эләккән мәчет манарасы Актарылып төшкән бөтенләй.* Ф.Кәрим. *Аюларның өне актарылды, Бүреләрнең юлы бозылды.* Ә.Ерикәй

3) Айкалу, көчле чайкалу, бер-берсенә бәрелә-бәрелә ургылып агу. *Киң Иделдә, актарылып, бозлар актылар.* Г.Хуҗин. *Ипле һәм тыныч кына аквариумда йөзеп йөргән балыкны, кинәт, беркөн, шаулап, актарылып аккан киң дәрьяга җибәргәнне күз алдына китерә аласызмы? Бу нәкъ минә шундый очрак иде инде.* Р.Мөхәммәдиев. *Горизонттан тау-тау болыт чыгып, Актарылып килде, ыжгырып.* Е.Уткин

4) Күп булып, өем-өем булып агу, бер юнәлештә ташкын булып килү. *Күк йөзен томалап өлгергән каракучкыл болытлар, тау-тау булып, берсе өстенә берсе актарылды, болганып*

*кайнашырга тотынды*. Г.Бәширов. – *Ничек болай бу?.. – диебрәк әйләнеп карасалар, --- теге болытлар, ишерелеп-ишерелеп, боларга таба актарылып киләләр*. Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ*. Ташып, мул булып. *Бөтен тәненә һәм мөгезләренә актарылып гайрәт тулганны тойды ул шунда*. Р.Мөхәммәдиев

**Актарыла башлау** Актарылырга тотыну. *[Тырмалаганда] Дымлы кара туфрак, күңелне рәхәтләндереп, тәмле ис аңкытып актарыла башлады.* И.Гази

**Актарыла төшү** Тагын да актарылу; бераз актарылу

**Актарылып бетү** Бөтенләй, тулысынча актарылу. *Машина туктап җитәр-җитмәс кабинадан чыкты, трактор табаннары белән ермачланып, актарылып беткән такыр басу өстеннән факел утларына таба китте*. Г.Ахунов

**Актарылып калу** Нindидер сәбәптән актарылган хәлгә килү. *[Акчарлаклар] Үзләре туктаусыз бөтереләләр, теплоход артында актарылып калган суга кадалып, нидер эләктермәкче булалар*. М.Рәфыйков

**Актарылып ташлану** Асты-өскә китерелеп, тәртипсез яту. *Тирә-якта тездән кайнар ком, актарылып ташланган кызыл балчык, көйгән дала җәйрәп ята иде*. Ф.Бәйрәмова

**Актарылып яту** Әле, күз алдында актарылган хәлдә булу. *Җан өшеткеч булып актарылып ята йорт урыныбыз!* Г.Бәширов

**АКТАРЫНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **актару**

2) Әйберләрне актарып, алар арасыннан нәрсәдер эзләү. *Нiләр актарынасың анда, Шәмси туган?* Г.Бәширов

3) Тикшерену, кызыксыну күрсәтү, эзләнү. *Кирәкле мәгълүматларны табу өчен, аңа архивларда шактый эзләнергә, актарынырга туры килде*. Мәдәни җомга. *Хәтер янчыкларында актарынып, булып узган хәлләр, аларның әһәмияте турында уйлана торгач, хикәямнең киңрәк буласын аңладым*. Мирас

**Актарына башлау** Актарынырга тотыну. *Миңсылу биксез сандыкны киң ачып, капкачын диварга терәде һәм аның эчендә актарына башлады*. А.Хәлим

**Актарына бирү** Актарынуын дәвам итү. *Ул, кесәсендә актарына биреп, егеткә кырыс кына бер күз ташлады*. Г.Бәширов

**Актарына тору** Бертуктаусыз актарыну. *Нигәдер, кабаланып, кесәләренә тыгылды, озак актарына торгач, аннан кечкенә челемен тартып чыгарды*. Г.Бәширов

**Актарына төшү** Бераз актарыну, тагын да актарыну

**Актарынып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә актарыну. *Хәтердә актарынып алдым. Төрле вакыйгалар искә төште*. Т.Миңнуллин

**Актарынып йөрү** Әле, хәзерге вакытта анда-монда барып актарыну. *Төнлә ачыксаң, складларда актарынып йөрмә, әнә плитәдә калган аш, калҗалар, чәй дә бар*. К.Кәримов

**Актарынып тору** Әледән-әле актарыну

**АКТАШ** *и. диал.* 1) Известьташ

2) Сөяктән ясалган ялтыравыксыз ак төймә

3) Таблеткалы дару

**АКТЁР** *и. фр.* Төрле тамашаларда – спектакльдә, кинода, телефильмнарда рольләр башкаручы артист. *Әйе, искиткеч зур талантка ия булган Шукшин – артист – егермедән артык фильмда уйнаган актёр*. Ә.Сафиуллин

**АКТЁРЛЫК** *и.* Актёр һөнәре, актёр хезмәте. *Т.Миңнуллинның «Җанкисәккәем» дигән лирик комедиясен Ф.Бикчәнтәев мәдәният һәм сәнгать институтының актёрлык, режиссёрлык курсларын тәмамлаучылар көче белән сәхнәләштерә*. Татар театры

**АКТИВ** I *и. лат. финанс.* 1) Бухгалтерлык балансының мәгълүм предприятиенең барлык матди кыйммәтләрен һәм акча средстволарын, бурыч таләпләрен чагылдыра торган бүлеге. *Актив һәр елның азагында һәм башында акча бирәмлеге белән бәяләнә һәм пассив белән балanslана*

2) Физик яки юридик затның барлык милке

3) Бер дәүләтнең чит илләрдән кергән акчалата кеременең чит илләрдәге чыгымнарыннан артыграк булуы

**АКТИВ** II *и. лат.* **1**. Оешманың, коллективның иң эшчән, эшлекле өлеше. *Ләкин тиешле кешеләр активның нәрсә өчен җыелганын беләләр, һәм моңа инде ун-унбиш көн буе әзерлек тә алып барылган икән*. М.Мәһдиев. *Тагын берәү әйтте, --- бүген үк силос әзерләргә чыгасы, район активы шуның өчен җыелган, диде.* М.Мәһдиев. *Ниһаять, кичә кич алар, --- «Кызыл ышна» колхозына килеп, колхоз активы белән беседа уздырдылар. Актив утырышы төнге сәгать бергә кадәр сузылды.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ*. Эшлекле, эшчән, булдыклы; *киресе*: **пассив**. *Актив иҗат формасын саклау – автордан көндәлек газаплы зур хезмәт, чиге күренмәгән рухи батырлык, көрәш таләп итә.* Р.Рахман. *Имашев, син – бик актив, бик җитез, бик булдыклы комсомолец, без сине күтәрергә булдык*. Г.Ахунов. *Ә минә оешманың үзешчәннәре арасында аннан да остасы, аннан да активы юк.* Казан утлары

**3.** *рәв. мәгъ*. Бар көчен, энергиясен биреп; турыдан-туры даими катнашып. --- *милли хәрәкәттә актив катнашкан тагын бер фамилиягә игътибар иттем.* Мәдәни җомга

**АКТИВИСТ** *и. рус* 1) Төрле оешма (предприятие) һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашучы кеше. *Мәдәният үзәкләреннән ерак, караңгы бер мишәр авылында күп балалы гаиләдә туып-үскән егет, университетта юридик факультетта укыганда ук, өлгер активист булып китә*. Т.Галиуллин. *Аннан янындагы активистларга карап әйтте: – Победаны машинадан алам әле мин, бик азынды, – диде.* М.Мәһдиев

2) *ирон*. Кирәкмәс урында, кирәкмәс эштә артык активлык күрсәтүче, үзен булдыклы санаучы кеше. *Ике класс белемле «активист», хәерчедән чыккан Ибрай Сәлиме дигән кеше, анда чыгыш ясаган иде*. М.Мәһдиев

**АКТИВЛАНУ** *ф. к.* **активлашу.** *Аннары фронттан шактый үзгәреп, сәяси яктан активланып, терелә́неп кайткан иде...* В.Нуруллин

**Активлана бару** Торган саен ныграк активлану, көннән-көн активлыгы арту

**Активлана төшү** *к.* **активлаша төшү**

**Активланып бетү** *к.* **активлашып бетү**

**Активланып китү** *к.* **активлашып китү**. *...Бәрәңге алганчы ниндидер бер ара вакыт бар. Шул көннәрдә әни активланып китә: аеруча бер дәрт белән авылдаш «киленнәргә» йөри башлый.* М.Мәһдиев

**АКТИВЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса актив эшчәнлеккә этәрү, тарту; эшчәнлеген көчәйтергә этәргеч бирү, җанландыру. *Хәзер аерым һөнәри, фәнни терминологияләр буенча республикада махсус секцияләр оеша башлады. Аларның эшен ашыгыч рәвештә, төпле итеп активлаштырасы бар.* И.Низамов. *Габделбарый Баттал Төркиядә әдәби-гыйльми эшчәнлеген тагын да активлаштыра, Абдулла Баттал-Таймас исеме белән күп хезмәтләр бастыра*. Мирас

2) *физ.* Химик яки физик үзгәрешләрне үткәрү, тизләтү өчен, матдәне җылылык, радиация яки активландыргыч агент белән эшкәртү

**Активлаштыра бару** Торган саен ныграк активлаштыру. *Министрлык татар мәктәпләрен башкортлаштыру эшен торган саен активлаштыра бара*. Р.Сибагатов

**Активлаштыра башлау** Активлаштырырга тотыну

**Активлаштыра төшү** Тагын да активлаштыру

**Активлаштырып җибәрү** Активлашуга этәргеч бирү. *Соңыннан, секретарь буларак Шаһинур Мостафин өстәлеп, ул эшебезне тагын да активлаштырып җибәрде*. И.Юзеев

**Активлаштырып килү** Акрынлап, аз-азлап активлаштыру

**Активлаштырып тору** Һәрвакыт, гел активлаштыру

**АКТИВЛАШУ** *ф.* 1) Актив булып китү; актив катнашу, активлык күрсәтә башлау

2) Көчәеп китү, куәтләнү. *Бу җырларның бер чорда – берсе, икенче чорда икенчесе активлаша, берсе көчәйгәндә, икенчесе ял итеп тора*. М.Мәһдиев. *1907 ел дәвамында илдә, татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдә үзешчәнлек хәрәкәте активлаша*. Мирас. *Калкансыман бизнең эшчәнлеге нык активлашканда, алмашу процесслары да тиешле дәрәҗәсен узып китә*. Биология

3) *күч.* Бер-бер эш булдырган кыяфәттә йөрү. *Иртәгә юлга чыгасы көнне Вәлит Хлестаков бик активлашты, колхоз складыннан күмәч, шикәр, чәй дисеңме – нәрсә бар шуны ташыды.* М.Мәһдиев

**Активлаша бару** Торган саен ныграк активлашу. --- *хәзерге вакытта татар телендә активлаша барган бу төзелмәләр телебезнең үз мөмкинлекләре, үз табигый чаралары нигезендә формалашкан*. Г.Нәбиуллина

**Активлаша башлау** Активлашырга тотыну

**Активлаша төшү** Беркадәр активлашу; бераз актив булып китү, тагын да активлашу. *Мондый эш әрсез егеткә, әлбәттә, ошый – ул тагын да активлаша төшә*. Т.Миңнуллин. *Шулай ук Разил Вәлиев, Әмир Мәхмүдев иптәшләр дә соңгы вакытта активлаша төштеләр*. Р.Фәйзуллин

**Активлашып алу** Аз гына, кыска вакытка активлашу. --- *һәрхәлдә, XIX йөзнең икенче яртысында хрестоматияләрне М.Ивановтагы ысуллар белән төзү активлашып ала*. Ф.Ибраһимова

**Активлашып бару** *к.* **активлаша бару**. *Дәүләкәннең үз яшьләре дә күп, бик активлашып барган чаклары*. Ә.Еники

**Активлашып бетү** Тәмам активлашкан хәлгә килү, бөтенләй активлашу. *Коллективта егетебез активлашып бетте*

**Активлашып җитү** Бөтенләй, тулысынча активлашу

**Активлашып китү** Тиз арада яки кинәттән активлашу. *1920 елның 25 июнендә ТАССР төзелгәннән соң, татар музыка сәнгатен үстерү юнәлешендәге эшләр тагын да активлашып китә*. К.Миңнуллин. *Әйтик, хәзерге поэзиядә «гамь» сүзе гаять активлашып китте*. Ф.Сафиуллина

**Активлашып тору** Әле, хәзерге вакытта активлашу

**АКТИВЛЫК** *и.* 1) Актив булу, нинди дә булса өлкәдәге яки тармактагы актив эшчәнлек, шөгыль. *Кояшның активлыгы гадәттәгедән шактый кимеп торган периодлар да була.* А.Муранов. *Хәрәкәттә – бәрәкәт, дигәндәй, ике юнәлешле менә бу активлык чорында фәнни мирасны барлау-өйрәнү җанланды...* И.Низамов

2) Нинди дә булса органнарның (әгъзаларның) эшчәнлеге, хәрәкәте турында. *Калкансыман бизнең активлыгы кимү балаларның физик һәм акыл ягыннан үсешләрен акрынайта*. Биология

**АКТИ́НИЯ** *и. гр.* Коралл полиплар классыннан, капшавычлары булган эчәккуышлы диңгез хайваны. *Скелетсыз мәрҗән полиплары да очрый, мәсәлән, актиния – эре ялгыз полип, гидраны бик хәтерләтә һәм мускул табаны ярдәмендә бер урыннан икенче урынга күчә.* Биология

**АКТИНИ́ДИЯ** *и. гр. бот.* Дилленийлылар семьялыгыннан, чиратлашып үскән тулы яфраклы, C витаминына бай, озынча түгәрәк яшькелт сары җимешле агачсыман лиана. *«Ямь һәм тәм, яки безнең бакча» китабында үзебездә үсә торган алма, груша, карлыган, слива, чия, кура һәм бакча җиләкләре, шулай ук сирәк очрый торган япон айвасы, актинидия, ирга, кытай лимоннигы кебек үсемлекләргә зур игътибар бирелгән.* Р.Миңнуллина. *Җимеш бирә торган куаклар һәм агачлардан аеруча карлыган, кура җиләге, крыжовник, кара бөрлегән, актинидия, лимонник, виноград, груша, слива, алмагач һ.б. күп үсә.* Биология

**АКТЛА́У** *ф. сир.* Нәрсәнең дә булса барлыгын яки юклыгын ачыклап акт төзү

**Актлап бетерү** Актлау эшен тәгәлләү, барысын да актлау

**Актлап чыгу** Барлык нәрсәләрне дә берәм-берәм, бер-бер артлы актлау, барысын да ахырына кадәр актлау

**АКТОЯК** *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, зур елгалар уйсу-

лыкларындагы комлыкларда үсә торган тамырчалы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **белокопытник**

**А́К ТӨЛКЕ** *и. зоол.* 1) Этләр семьялыгыннан, кышын ак төстәге кыйммәтле тиреле имезүче ерткыч җәнлек; котып төлкесе; *русчасы*: **песец**

2) Шул җәнлекнең тиресе

**АКТРИ́СА** *и. фр.* Хатын-кыз актёр, артистка. *Актрисаның бу хәлләрне кичерүе дә, ариясен җырлавы да гаять табигый чыга.* Мирас

**АКТУАЛЬ** *с. лат.* Хәзерге чор, бүгенге көн өчен әһәмиятле, көн үзәгендә торган, көн тәртибендәге. *Ислам дине, мөселман әдәбияты тәэсирендә халкыбызның көндәлек фәлсәфәсе – холкы, әхлагы, әдәбияты формалашуын җентекләп өйрәнү – киләчәктәге бурыч, актуаль бурыч.* М.Усманов. *Укымышлы, тәҗрибәле, бай тормыш мәктәбе үткән Гатаулла хәзрәт бу гәзит битләрендә заманының бихисап актуаль мәсьәләләрен күтәргән.* Р.Әмирхан

**АКТУАЛЬЛӘШҮ** *ф.* Актуальлегә, хәзерге вакытта әһәмияте арту, мөһимләшү. *Милли язмышның иң киеренке чагы. Мондый вакытта әдәбиятның милли эчтәлеге актуальләшә.* Р.Рахман

**Актуальләшә бару** Көннән-көн актуальләшү, вакыт үткән саен ныграк актуальләшү. *Шуңа да карамастан, тәрҗемә мәсьәләләре һаман актуальләшә генә бара.* Р.Фәйзуллин

**Актуальләшә башлау** Актуальләшергә керешү

**Актуальләшә төшү** Бераз, беркадәр актуальләшү; тагын да актуальләшү. *Шул уңайдан әле куелган сораулар тагын да актуальләшә төшә.* М.Вәли-Барҗылы

**Актуальләшеп алу** Күпмедер вакыт эчендә, кыска вакыт арасында актуальләшү

**Актуальләшеп бару** Аз-азлап, акрынлап актуальләшү

**Актуальләшеп бетү** Тәмам актуальләшкән булу

**Актуальләшеп килү** Әле, хәзерге вакытта акрынлап актуальләшү

**Актуальләшеп китү** Ниндидер сәбәптән, этәргечтән соң актуальләшү. *Сүз бүгенге көндә актуальләшеп киткән мөһим бер проблема – яшүсмерләр арасында еш очрый торган тәртип бозу күренеше турында бара.* М.Сәхапов

**АКТУАЛЬЛЕК** *и.* Актуаль булу, хәзерге вакыт өчен әһәмиятле булу, мөһим булу. *Шуңа күрә дә заман темаларына куелган спектакльләрнең төп үзенчәлекләре актуальлек, тормыш материалының танылып калку торуы булды.* М.Арсланов

**АКТЫГЫНДА** *рәв. сөйл.* Ахыр чиктә, соңгы чиктә. *Актыгында ике кулын күкрәгенә басты да, ашыгып-ашыгып, елгага таба төшеп китте.* Ш.Камал

**АКТЫК** *с.* **1.** Ахыргы, азаккы, соңгы. *Син бит минем актык улым, төпчек улым.* А.Әхмәт. *Әткәй, коткарам дип йөри торгач, актык атыннан, сыерыннан яза.* Г.Ибраһимов. *Конкурс башланган булып чыкты. Бүген икенче турның актык көне икән.* Мирас

**2.** *и. мәгъ.* 1) Нәрсәнең дә булса ахыры, соңы. *Актыгы: мин бар вөҗүдемне сиңа иттем фида; Белмәдең лә белмәдең кадрем! гөнаһ! и бивафа!* Г.Тукай

2) Ахыргысы, соңгысы. *[Михайлов:] Куй! Күрәсең бит, актыгы. Әнә күрмисеңмени, винтовка алырга йөгереп киләләр.* А.Шамов. *Кайттыңмы, улым, алтыным! Куанычым минем, актыгым.* М.Җәлил

◊ **Актыгы булсын (булыр)** Яңадан кабатланмасын, соңгысы булсын. *Актыгы булсын, моннан соң аңа бурычка бирү бетте.* **Актык бирнә** *этн.* Иргә чыкканда, кыз ягыннан кияү ягына килә торган сандык малы, кода-кодагыйларына бирелә торган кием-салым бүләкләрне соңгы кат багу, кабул итү йоласы. *Актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт калын ука тирәкле асыл бирмәкче булалар.* Г.Камал. **Актык гомерендә** Гомеренең соңгы елларында, үләр көннәрендә. **Актык могикан** Нәрсәнең дә булса (халыкның, буынның, иҗтимагый төркемнең) соңгы вәкиле. **Актык сулыш (сулу)** Гомернең соңгы мизгелләре. *Бадьян чәчәк ата микән Уфа су буйларында; Син җаныйны онытасым юк Актык сулуларымда.* Җыр. **Актык сулышка җитү** Икътисади яктан я башка яктан эшләр тәмам соңгы чиккә җитү. **Актык тамчы яшь** Җан биргәндә тамган соңгы тамчы яшь. **Актык чиктә** Иң актыгында, иң ахырында. *Иң актык чиктә Нуруллинның кылычы бу кыз баш очында икеләнүсез ялтыраячагын белә иде командир.* А.Шамов

**АКТЫККЫ** *с.* Ахыргы, соңгы. *Рәүфә куначадагы әтәчнең актыккы кычкыруы белән тора.* А.Шамов. *Актыккы очрашуыбызда ул бик моңсу иде.* Идел

**АКТЫКТА** *рәв.* Ахырда, азакта. *Иң актыкта Солдат, торып, болай да якты янмаган лампаны азрак бастырды.* Ш.Камал

**АКТЫКТАН** *рәв.* Ахырдан, соңыннан, эш узгач. *Чөнки актыктан күңеленә зур үкенечләр килер.* А.Гыйләҗев

**АКУ́ЛА** *и. бор. исл. зоол.* 1) Кимерчәкле балыклар отрядыннан, зур авызлы, бик зур гәүдәле, диңгездә яшәүче ерткыч балык; күпек балык. *Акулаларны ите, мае һәм тиресе өчен аулыйлар.* Биология. *Акула казналыгының барлык эчке өслеген тешләр каплап алган*

2) *күч.* Комсыз, ертлач кеше; эксплуататор. *Шул ук вакытта, кыргый базар шартларының табигый чагылышы буларак, кечкенә нәшриятларның «акула»лар тарафыннан йотылуы һәм китапны ихтыяҗдан артык җитештерү кебек тенденцияләр барлыкка килә башлый.* М.Вәлиев

**АКУ́СТИК** I *и. рус* 1) Акустика белгече

2) *сөйл.* Авазтоткыч аппаратларга хезмәт күрсәтүче кеше. *Шаховский, бик кыенлык белән генә күтәрелеп, акустик урынына барып утырды.* Г.Әпсәләмов

**АКУ́СТИК** II *с.* 1) Акустикага мөнәсәбәтле, акустикага караган. *Ә бу юлы, бәхетсезлеккә, бүтән төр мина – мотор гөрелдәүдән шартлый торган акустик мина булып чыкты...* С.Сабиров. --- *дәвамлы эволюция нәтиҗәсендә формалашкан, һәм ул бал кортларының төрле рецепторлар белән кабул итә торган химик, оптик, механик, акустик, электрик һәм башка хәбәрләрне тапшыруына нигезләнә.* Татар балы. *Акустик резонанс. Акустик шартлар*

2) Әйтелеш, яңгыраш; ишетелеш. *«Фонетика – ул тел фәненең кеше сөйләмендәге авазларның төзелү (барлыкка килү) алымнарын һәм акустик үзенчәлекләрен өйрәнә торган бүлеге» диелә лингвистика терминнары сүзлегендә.* И.Низамов. *Акустик яктан сузык авазлар ясалышында нәрсә катнаша?* Р.Шәмсетдинова. *Мәсәлән, Сафиэддин Урмави (XIII гасыр) үзенең музыка турындагы трактатында аның акустик үзенчәлекләрен ача.* К.Гыйззәтов

**АКУ́СТИКА** *и. гр.* 1) Физиканың тавышны һәм аның таралуын өйрәнә торган бүлеге (өлеше). *Физиканың акустика бүлеге авазларны ишетелеше ягыннан өйрәнгәндә турыдан-туры катнаша.* Ф.Сафиуллина

2) Музыка, гөрелте һәм гомумән тавышның төрле шартларда таралу үзлеге. *Чүмәлә-төрмәнең акустикасы шундый шәп: тыңлаучыга сигез метр түбәндә сөйләшкән кешеләрнең сүзләре колакка пышылдаган шикелле ишетелә икән.* Р.Фәйзуллин

3) Биналарда музыканың, тавышның матур яңгыравы, ишетелүе өчен уңай шартлар. *Филармониясе бар, артистлары бар, концертлары булып тора, әмма концерт залының акустикасы юк.* М.Юныс

**АКУШЕР** *и. фр.* Акушерлык белгече, акушерлык буенча табиб ярдәмчесе. *Ә монда, үзең беләсең, бала табу йорты, гинеколог кына түгел, гап-гади акушер да юк.* М.Әхмәтҗанов

**АКУШЕ́РКА** *и. рус* Хатын-кыз акушер. *Әнигә күпмедер игелек күрсәттем, әмма дөньядагы иң якын кешеләремнән булган Газзәтигә дә, Чүриле акушеркасына да --- файда күрсәтә алмадым, рәхмәт әйтә алмадым.* М.Мәһдиев. *Йөзләренә, төсләренә аруы чыккан --- акушерка килеп чыкты.* Г.Исхакый

**АКУШЕРЛЫК** *и.* 1) Медицинада: йөклелек, бала тудыру вакытларында табиб ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен карый торган бүлек. *Татар акушерлык курслары 1925 елның декабрендә ачылa.* З.Кириллова

2) Бала тудырганда ярдәм күрсәтү. *Авылда акушерлык хезмәтен башкаручы ике әби бар иде: Газзәтти һәм Гайшәтти.* М.Мәһдиев. *Әнисә авылның акушерлык пунктына медицина училищесын тәмамлап, юллама белән килеп урнашкан иде.* Мәдәни җомга

**АКЦЕНТ** I *и. лат.* 1) *лингв.* Сүздәге басым

2) Бер тел авазларын һәм сүзләрен, икенче бер тел яки сөйләш үзенчәлекләре тәэсирендә, бозып, үзгәртеп әйтү. *– Рәхим итегез! – диде ул саф татарчалап, ләкин берникадәр мишәр акценты белән.* А.Шамов. *Ягымлы хатын-кыз тавышы русча латыш акценты белән сөйләшә иде.* З.Зәйнуллин. *--- Г. Девишев моңа кадәр дә үзен актёр буларак сынап караган була. Тик телне җитәрлек белмәү үзенекен итә, актёрда, сөйләгәндә, акцент, ышаныч җитмәү сизелә.* М.Арсланов

3) *күч.* Берәр нәрсәгә аерым игътибар, ассызыклау, әһәмият бирү. *--- әсәрдә ачыктан-ачык сөйләшү бара, бигрәк тә Фуад абый тарафыннан акцент дөрес, образ тулы канлы.* И.Илялова. *Дөрес, күбрәк тышкы билгеләргә акцент ясаучы авторлар да аз булмады.* Д.Нигъмәтҗанова. *Сюжетта акцент шул дәһшәтләр аша, курыкмыйча, кыенлыкларны җиңеп чыккан каһарманның батырлыгына ясала.* М.Сәхапов

**АКЦЕНТ** II *и. финанс.* 1) Банк һәм кредит оешмасы аша, кулга акча бирмичә исәп-хисап ясау ысулы

2) Бер якның икенче як тәкъдим иткән шартлар нигезендә шартнамә төзергә ризалыгы

3) Ике якның да килешенгән товар өчен акча түләргә гарантия бирүе

**АКЦИЗ** *и. фр.* Илдә эшләп чыгарылган исерткеч эчемлекләр, тәмәке, автомобильләр, алтыннан ясалган һ.б.ш. кайбер куллану товарларын сату, көнкүреш хезмәте күрсәтү бәяләренә өстәлә торган, турыдан-туры булмаган салым төре; кыек салым. *Акцизның күләме бюджетның керемнәр өлешен арттыру ихтыяҗларыннан яки салым салуның башка максатларыннан чыгып бәяләнә.* Мәдәни җомга

**АКЦИОНЕР** *и. фр.* Акцияләр сатып алу юлы белән акционерлар җәмгыяте әгъзасы булган зат; акцияләр хуҗасы, пайчы. *«Өмет» дип исемләнгән акционерлар оешмасының эшчәнлегенә җинаятьчелек эше кузгатылды.* Х.Ибраһимов

**АКЦИОНЕРЛА́У** *ф.* Дәүләт предприятиясен акцияләр чыгару һәм аларны сату юлы белән акционерлар җәмгыятенә әйләндерү

**А́КЦИЯ** I *и. лат.* Берәр максатка ирешү өчен башкарылган эш, чыгыш, хәрәкәт. *Төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең татарча китапларга зур мохтаҗлыгы барлыгын истә тотып, алар өчен китап җыю акциясен игълан иттек.* Мәдәни җомга. *Дипломатик акция. Протест акциясе*

**А́КЦИЯ** II *и. фр. фин.* Берәр предприятиегә билгеле бер күләмдә пай взносы кертүне раслый торган кыйммәтле кәгазь. *Шәхеснең абруе принципиаль мөнәсәбәтләргә бәйле. Акцияләр курсы кебек үзгәреп тора.* Ш.Галиев. *Акцияләрнең исемле яки күрсәткән затныкы, иркле йөрештә яки чикләнгән әйләнештә булуы мөмкин.* Татарстан

**АКЧА** *и.* 1) Сату-алуда әйберләрнең кыйммәтен билгели торган һәм, түләү чарасы буларак, дәүләт тарафыннан чыгарылган кәгазь һәм металл билгеләр. *Акча бетсә кесәдә, ефәк була мунчала.* Мәкаль. *Бабай шап итеп пижама кесәсенә сукты: «Акча бар! Я, әйтегез, ни теләр идегез?»* Ф.Яруллин. *Башта болгарларда Көнчыгыш акчалары йөрсә, инде X гасырдан үз акчаларын да суга башлыйлар.* Г.Дәүләтшин

2) Әйберләрне алмашканда гомуми эквивалент вазифасын башкара торган махсус товар

3) Капитал, байлык, тупланган мал. *Вәли бай, атасыннан калгач, зур акчалар белән эш итте.* К.Нәҗми. *– Бераз акча ясыйм да авылга кайтып китәм, – ди.* Казан утлары

4) *күч.* Кадерле нәрсә. *Вакыт – акча, гафил булма – кача.* Мәкаль

◊ **Акча исе чыгу** Кулда акча барлыкның билгесе сизелү. *Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!* Г.Тукай. **Акча колы** Акча өчен, акча җыю өчен яшәүче, акча өчен җанын сатучы. **Акча кою** Акчаны күп эшләү, күп табу. *Якында гына урман, үз-*

*ләрендә алтын куллы осталар бар, тугым тәгәрмәчне әйләнә-тирәдәге колхозлардан өзлексез сорап торалар – кой да утыр акчаны.* Ф.Хөсни. **Акча сугу** Акчаны күп табу, күп эшләү. *Хәбиргә дә әйтергә уйлаган идем кичә, стансага барып, акча сугып кайтыйк, дип.* Ф.Шәфигуллин. **Акча тоту** Акча чыгару, чыгым ясау, расходлану. *Рәхмәт, анасы, рәхмәт! Мине дә күп акча тотудан коткардың.* Г.Камал. **Акча төшерү** Беркадәр акча эшләп алу. *Әти, эш әйбәт туры килеп, акча төшерә алсак, миңа Вәлиәхмәтнеке төсле кәләпүш алырбызмы?* Ф.Хөсни. **Акча чыгу (чыгару)** Кулдан акча чыгу, расходлану. *Бу арада, Мәскәүгә барып, акча күп чыкты. Итен, маен, чәен, солы ярмасын дигәндәй, барын да төяп кайтырга туры килде.* Ә.Камал. **Акча эшләү** Эшләп, акча алу. *Шәһәргә зур өметләр белән, язгы ярминкәдә атлык акча эшләргә дәртләнеп килүче мишәргә дә ул үзен мосафир карчык итеп кенә танытты.* К.Нәҗми. *Бөтен матбугат шаулап-гөрләп торды ул чакта. Бу – үзенә күрә пиар идеме, әллә акча эшләүнең бер юлымы?* Шәһри Казан

**АКЧАЛАТА** *рәв.* **1.** Акча белән, акча килеш. *Ә хезмәт хакын колхозчыларга, хәзерге шикелле акчалата түгел, натуралата, ягъни ашлык белән түлиләр.* В.Нуруллин. *Шуның өстенә акчалата һәм әйберләтә иганә җыю да булачак икән.* Ә.Еники. *Хезмәт көненә хәзер икмәкләтә дә, акчалата да мул гына түли башлаганнар.* Э.Касыймов

**2.** *с. мәгъ.* Акчага әйләндерелгән, акча исәбе белән күрсәтелгән, акча исәбенә салынган. *Акчалата налогның, заемның очы-кырые юк.* М.Мәһдиев

**АКЧАЛЫ** *с.* **1.** 1) Акчага бай, дәүләтле. *Булганым бар анда [Парижда], матур шәһәр, бигрәк тә акчалы кешеләргә. Ләкин Ленинградны мин аңа гомердә алмаштырмас идем.* Г.Әпсәләмов. *Акчалы кешеләрнең малайлары, ак атларга утырып, карусельдә әйләнә башладылар.* Ә.Фәйзи. *Сезнең кебек акчалы, икмәкле кешеләр сатмый шул җирне.* Ә.Фәйзи

2) Түләүле; акча түли торган. *Яңа елдан ук акчалы хезмәткә күчерелгән сыер савучыларга түләү ни сәбәптәндер тоткарланды.* М.Шабаев

3) Акча күп түләнә торган. *Әти минем алдыма кечкенә генә брошюра куеп, укып чыгарга һәм тәрҗемә итәргә кушты. Ник тәрҗемә итмәскә, итәм, әлбәттә, акчалы эш тә булгач.* Җ.Фәйзи. *Күптәннән бирле бер киңәш бирәсем килә үзеңә: ташла син кибетне, күч башка эшкә, акчалы урын төс түгел сиңа!* К.Кәримов

4) Күп керемле, бай. *Иген уңган тыныч елларда иң күп акчалы, иң шау-шулы көзге базарлар була.* М.Галәү

**2.** *и. мәгъ.* Акчасы булган кеше. *Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный.* Мәкаль

◊ **Акчалы уйнау** Отышлы, комарлы уеннарда катнашу. *Акчалы уйнаганчы, укырга-язарга өйрәнсәгез, белемегезне арттырсагыз, үзегезгә зыян булыр дисезмени?* Г.Тавлин

**АКЧАРЛАК** *и. зоол.* Йөзүче кошлар семьялыгыннан, озын канатлы һәм озын томшыклы, ак яки соры төстәге куе йомшак мамыклы, балыклар белән туклана торган кош; су тавыгы; *русчасы*: **чайка**. *Пароход өстендә, зур ак чәчәк яфракчыклары сыман, акчарлаклар өере бөтерелә.* М.Галәү. *Балыкчылар Арал диңгезенең климатик холкын бик әйбәт өйрәнгәннәр. Акчарлаклар ярдан еракта оча икән – димәк, көннең бу яртысында көчле җил булмаячак. Акчарлаклар яр тирәсендәрәк оча икән – шторм буласын көт тә тор.* А.Муранов. *Шәрәфи агайның тәҗрибәсе буенча, суның җылылыгына, акчарлакларның хәзердән үк чит буйларда очып йөрүләренә карaганда, быел да балык күп булырга чамасы юк түгел.* Ш.Камал

**АКЧАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Акчасы юк, сәрмаясыз, ярлы. *Мин үзем мәнә – акчасыз кеше. Хәерчелекнең нинди яман нәрсә икәнен бик яхшы беләм.* З.Хәким. *Исәнме, акчасыз үзидарәнең юк рәисе!* Т.Миңнуллин

2) Бушлай, буш, түләүсез. *Оренбургтагы кеби, укырга теләгән кешеләргә акчасыз фатир табып бирүче булса, кереп тыңлаучылардан акча алмаса, ул вакыт укучылар күп табылыр.* Г.Камал

3) *фин.* Акча үзе катнашмаган. *Сәүдә хәтәр корылган иде монда. Акчалы кеше – акчага, акчасызы йомыркага, майга алмаштыра ала.* Р.Батулла. *Акчасыз расчёт*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Акчасы булмыйча, акча бирелмичә. *Болай да оят, тегеләй дә уңайсыз. Иң җайсызы – авыз ачып, акчасыз калудыр әле.* Т.Галиуллин

2) Акча алмыйча, бушка, бушлай. *Акчасыз җырлый кош та. Алтыны да, көмеше дә, Җимеше дә... гел бушка.* И.Юзеев. *Акчасыз эшләү*

◊ **Акчасыз кәмит** Адәм көлдерерлек берәр хәл эшләүче; шул хәлне тамаша кылу. **Акчасыз фатир** Төрмә. *Эләгерләр әле. Акчасыз фатирга кергәннәрен сизми дә калырлар.* Г.Камал

**АКЧАСЫЗЛЫК** *и.* Акчага мохтаҗлык, акча юклык; гомумән мохтаҗлык. *Тик, нишләмәк кирәк, бу – игътибарсызлыгымнан түгел, һаман да шул җитмәгән тормыштан – акчасызлыктан иде.* З.Фәйзи

**А́К ЧЫРШЫ** *и. бот.* Наратчалар семьялыгыннан, биеклеге 50–100 метрга кадәр җитә торган, конуссыман куе ябалдашлы мәңге яшел ылыслы агач; *русчасы:* **пихта**. *Мичтә ак чыршы утыны шартлап яна, ике туган, берсен-берсе бүлдермичә генә, сугышка кадәрге тормышны, мул ризыкны, рәхәт көнне, тыныч төнне искә алалар.* М.Мәһдиев. *Ак чыршы агачын целлюлоза алу өчен, музыка кораллары ясау өчен кулланалар.* Ботаника

**АКШАР** *и.* 1) Акшарлау, агарту өчен кулланыла торган матдә, акбур. *Бусагадан атлауга уң якта – зур мич, аның акшарлары кубып беткән.* Г.Ибраһимов

2) *күч. ирон.* Пудра, кершән. *Шул бизәнү генә аз кебек күренгән булырга кирәк, кодагый, ап-ак иттереп, акшар белән, битенә кершән яккан.* Г.Исхакый

**АКШАРЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) *кайт. юн. к.* **акшарлау**. *Таш диварлар тора ап-ак булып, Акшарланган алар, буялган.* Җ.Дәрзаман. *Айсылу ап-ак итеп акшарланган мичкә аркасы белән терәлгән.* Ф.Бәйрәмова

2) Пудра сөртү, кершән ягу. *Бай йорты тәрәзәләренең берсендә ашыгыч*

*кына күтәрелгән кисея пәрдәнең күбектәй кабаруын һәм, тәрәзә янында акшарланган, иннек сөрткән, үтә дә гаҗәпкә калган бер йөзне күреп, шундук кире төшүен ул искәрмәде.* Г.Шәрипова

**АКШАРЛА́У** *ф.* 1) Акшар белән буяу, агарту, акка буяу. *Мич акшарлау*

2) *күч.* Пудра ягу, кершән ягу. *Ә мәнә битен тигез итеп акшарларга, иннек сөртергә, күзләренә сөрмә тартырга һич кенә дә иренмәде.* Г.Шәрипова. *Кавины карчык итеп киендерергә, битен бик тырышып акшарларга, буярга тотындык.* Казан утлары

**Акшарлап алу** Тиз генә акшарлау; тиз генә акшарга буяу

**Акшарлап бетерү** 1) Нәрсәне дә булса тулысынча акшарлау, ахырга кадәр акшарга буяу

2) Акшарны тулысынча тоту

**Акшарлап җибәрү** Бераз акшарлау; акшарларга да өлгерү

**Акшарлап йөрү** Хәзерге вакытта акшарлау белән шөгыльләнү. *Өйләренә кайтса, бабасы бакчада алмагач төпләрен акшарлап йөри.* Н.Каштанов

**Акшарлап килү** Электән үк, күптәннән, һәрвакыт акшарлау

**Акшарлап китү** Билгеле бер урыннан яки вакыттан башлап акшарлауны дәвам итү

**Акшарлап кую** Алдан акшарланган хәлгә китерү. *Морҗа-мичләрне акшарлап куйгач, сокланып туялмыйсың.* Р.Мулланурова. *Тәүге кар соры мохитне акшарлап куйгач, Балантауның исеме җисеменә тач туры килде.* К.Кәримов

**Акшарлап тору** 1) Һәрвакыт акшарлау, әледән-әле акшарлау

2) Әле, хәзер акшарлау эшен башкару

**Акшарлап чыгу** Барысын да акшарлау, бер җирне дә калдырмыйча акшарлау; башыннан ахырына кадәр акшарлау. *Буяучы кызлар Руфия белән Маһирә баш механик Рифат Зөбәеров кабинетын яңартып, буяп, акшарлап чыгарга булдылар.* Н.Хәсәнов

**Акшарлый башлау** Акшарларга тотыну

**Акшарлый бару** Һәрберсен, булган берсен акшарлау

**Акшарлый бирү** Акшарлавын дәвам итү

**Акшарлый төшү** Бераз акшарлау

**АКШАРЛЫ** *с.* 1) Акшарланган, агартылган. *Гыйльметдиннең халатына, битләренә, чүпрәк кәпәченә акшарлы су тамчылары чәчри.* Шәһри Казан

2) *күч. кимс.* Пудраланган. *Фәкать бер бүлмәдә, һич кемсә күрмәс, Китерттек берничә акшарлы кыз да!* Г.Тукай

**А́К ШИГЫРЬ** *и. әд.* Силлабик һәм силлабо-тоник шигырь системаларында кулланыла торган, төрле үлчәмдәге рифмасыз тезмәләрдән гыйбарәт шигырь формасы; рифмасыз шигырь

**АКЫЛ** *и. гар.* 1) Кешенең тумыштан бирелгән уйлый белү, фикерләү сәләте, аңлылык дәрәҗәсе. *Теге яки бу һөҗүмнең уңышлы булуы --- разведчикларның зиһен белән, акыл белән хәрәкәт итүләренә бәйләнгән.* Г.Галиев. *Әмма аның акылы гаҗәп ачык, үткен иде, бик кыю, бик кызу эшли иде.* Ә.Еники. *Күрә, аңлый иде ич ул – малай эзләнә, акылын, зиһенен кая юнәлтергә белми боргалана әнә.* Р.Мөхәммәдиев

2) Иҗтимагый аң; дөньяга, чынбарлыкка, тормышка караш. *[Хәйретдиннең] Яше үсү, буе үсү белән бергә, аның фикере дә, акылы да үсә.* М.Гали

3) Уйлану, фикерләү нәтиҗәсендә туган, барлыкка килгән уй, фикер; идея. *Чишмәне буралап, өстен каплап зерә дә яхшы эшләгәннәр, кайсы изге бәндәнең башына килде бу акыл?* Ф.Хөсни. *Нишләргә дә белмим инде. Хөсәенгә рәхмәт әле, ул акыл бирде.* Г.Шәрипова

4) Акыллылык; аңлылык, зиһенлелек. *Үзең яшь-яшь малай гына, Сүзең шундый акыллы... Сезнең, походка катнашмый, читтә калу – акылмы?!* М.Җәлил. *Бәргәләшеп алган чаклар да була. Мәнә мондый заманнарда Фазыйл әллә кайдан акыл таба, кызык сүз әйтә...* Г.Ибраһимов. *Альфаның [бүре] бар тормыш тәҗрибәсе аңа тупланган, анда калган. Ул әле бүре акылын, бүре усаллыгын да аклады.* А.Хәсәнов

5) Киңәш, нәсыйхәт; сабак, үрнәк, гыйбрәт. *Аннан соң Гайшә үз кайгысына сүзне тартты: атлаган саен калага килеп булмый. Миңа акыл әйтегез: пионерым Саматны кая бирим? – диде.* Г.Ибраһимов. *Әле без башлангыч классларда акыл, гыйбрәт җыябыз.* Ә.Еники. *Өлкәннәр һәрвакыт үзләрен акыллыга саныйлар. Безгә акыл өйрәтәләр.* Ф.Яруллин

◊ **Акыл белән** Төптән уйлап, җентекле тикшереп. **Акыл бирү** 1) Акыллы киңәш бирү, чара өйрәтү. *Нишлим икән? Миңа бер акыл бирсәнә*; 2) Орышу, бик каты шелтәләү, ачуланып я кыйнап өйрәтү. *Малайга бик нык акыл биргәннәр, яңаклары күгәреп чыккан. Бик узынып киткән иде шул.* **Акылга беткән** Бик акыллы, зирәк. **Акылга җиңеләю** Акылдан язу, юләрләнү. *Әллә, абыстай, син дә акылга җиңеләя башладыңмы?* Г.Камал. **Акылга килү** 1) Истән-һуштан язганнан соң, яңадан исенә килү, шундый чирдән савыгу, уйлый алу сәләте кайту; 2) Хискә бирелүдән айну. *Әмма Хатыйп хәзрәт кулын тартып алды һәм: – Акылыңа кил, Садыйк! – дип кычкырды.* Г.Шәрипова; 3) Сабак алу, нәтиҗә ясау. *Инде Хисамый Әсмасы да акылга килер. Гөлбануны көнләп үлеп барадыр иде.* Г.Ибраһимов. **Акылга сыймаган (сыймаслык)** Кеше акылы кабул итә алмаслык ят, сәер эш, кеше ышанмаслык эш. *Ә кар шулкадәр күп яуды, акылга сыймаслык инде мәнә.* Г.Шәрипова. **Акылга туймый калган** Акыл ягыннан җитлекмәгән. *Мөбарәкнең дә эшләре шәптән түгел: тумыштан ук акылга туймый калган.* Ш.Маннур. **Акылга утырту** 1) Кешегә дөрес эшләү юлын күрсәтү, тормыш тәҗрибәсенә өйрәтү. *[Хәйри:] Их карт, карт! Егерме ел сине өйрәттем, һаман акылга утырта алмадым.* Г.Ибраһимов. *Җәзаның әллә ниндиләрен башымнан кичердем. Ләкин апаны акылга утыртырлык нәрсә уйлап таба алмадым.* Ф.Яруллин; 2) Бик каты шелтәләү, кыйнау, тиешле җәзасын бирү. *Бабасы да дәшми, әмма аның сәбәбе бөтенләй башка: йокымсырый башлаган ваемсызлыкны бер селтәнүдә челпәрәмә китерәсе, үзенең бөтен ачуын тышка чыгарасы һәм киявен, яраткан кызыкаен кыерсытмаслык итеп, акылга утыртасы килә.* Г.Шәрипова. **Акылга утыру** *к.* **акыл**

**керү**. *Кинәт Гөлшаһидә өзеп алган шикелле кырт борылды да больница юлына төшеп китте. Җитте инде, акылга утырырга вакыт.* Г.Әпсәләмов. *Аның [апаның] бит бервакытта да болай җилкенгәне юк иде. Әллә әнә шулай итеп акылга утыралар микән?* Ф.Яруллин. **Акылдан сапкан** Акылдан тайпылган, җиңеләйгән, акылдан шашкан. *Акылдан сапкан кешечә җикеренеп килә.* Г.Камал. **Акылдан шашу** 1) Акылын югалту, җиңеләю, тилерү, юләрләнү. *Әле былтыр гына бер хатын, төнлә ындырдан кайтышлый, каберлек өстендә ак нәрсә күреп акылдан шашкан иде.* К.Нәҗми. *Акылдан шашкан, дип әйтмәсәләр дә, аның кебекләр турында «хыялый» гына диләр шул.* Р.Мөхәммәдиев. **Акылдан язу** *к.* **акылдан шашу**. *Әнием берничә тапкыр мине туктатырга омтылды: «Акылдан язасыңмы әллә?!»* Ә.Еники. **Акыл җитмәслек** *к.* **акыл ирешмәслек**. **Акыл җую** Нәрсә дә булса эшләгәндә аптырап калу. *Баштан салкын су сипкән төсле калтыранып алдым, йөрәгем жу итте, акылымны җуйгандай булдым.* Г.Минский. **Акыл җыю** 1) Рухи киеренкелектән соң нормаль уйлый, фикер йөртә алу хәленә кайту; 2) Булган хәлне аңлап алып, уйлау сәләтен эшкә җигү. *Бер кискән икмәк кире ябышмый, акылыңны җый, илдә сылу бетмәгән, тәмле ашыңның тәмен калдырып, хәйран башыңны вәйран итеп йөрмә, Нәфисә шикелле матурлар тагын да табылмас дисеңме?* Г.Бәширов; 3) Бар булган белемне, сәләтне, фикерне һ.б. туплау, билгеле бер максатка юнәлтү. *Бүген Ринат Тимершин беренче тапкыр университетка дәрес тыңларга бара. Ул укыр, белем туплар, акыл җыяр.* М.Маликова. **Акыл ирешмәслек** Аңлый, төшенә алмаслык ят нәрсә, ят эш. *Каршыбызда, акыл ирешә алмаслык сер булып, бөтенләй диярлек ялангач кыз басып тора иде.* М.Әмир. **Акыл иясе** Зирәк акыллы, күп гыйлем җыйган, белемле, тәҗрибәле кеше. **Акыл йөртү (йөртеп карау)** Төрлечә уйлап, төрлечә фикер йөртеп эшләү; акылны эшләтү. **Акыл казаны бушау** Акыл кимү, акыл саегу. *Картның акыл казаны бераз бушаган әле аның.* М.Гали. **Акыл капчыгы** 1) *к.* **акыл иясе**; 2) *ирон.* Кешегә акыл сатарга яратучы. **Акыл кергән** Белем-тәҗрибә туплаган, сабак алган. *Узган елдан бирле байтак кына вакыт узган, аз-маз гына акыл да кергән.* Ф.Хөсни. **Акыл керү** Тормышны аңлый, яхшыны начардан аера башлау, акыллылану. – *Укуын ярты юлда ташламаса рәхмәт әйт инде, – диде әни. – Әллә кайда буталып йөргәнче, укый торсын әле. Бәлки, акыл кереп куяр.* Ф.Яруллин. **Акыл китү** 1) Картаю яки авыру сәбәпле, уй, фикер йөртү сәләте кимү. *Кайберәүләр, моның картлыгы җиткән, акылы китеп калган, диделәр.* Г.Ибраһимов; 2) Хис-тойгыга бирелеп, үз-үзенә һәм гамәлләренә контрольлек кимү, нишләгәнен белмәү. **Акыл күзе белән күрү** Әйберне, дөньяны үз акылың белән танып белү, үз тәнкыйть күзең белән карау. *Бер дә шуларны акыл күзе белән күрүче булмады микәнни соң?* Ш.Маннур. **Акыл күзе җиту** Төптән җентекләп уйлау, аның асылына төшенү, алда ни буласын тою. *Акыл күзе җитмәслек.* Һ.Такташ. **Акыл кыскалык** Ерактан, төптән уйларга сәләтсезлек, белем-тәҗрибә булмау, логик фикерләү җитмәү, баш эшләмәү. **Акыл өйдә булу (булмау)** Акылы-башы уй уйларлык хәлдә, үз урынында булу, башында акыл булу. *Мәхәббәт уңышсызлыгына очраган кыз, уйлап та тормастан, андый чакта акыл өйдә булмый бит, юк, дип кырт кисте.* Г.Әпсәләмов. **Акыл өйрәтү** Белдекләләнеп, башкаларга киңәш бирү, үз карашын үткәрергә тырышу. *Сезгә әйтсәң, акыл өйрәтергә тотынасыз, анда кермә, монда кер, имеш.* Ф.Яруллин. – *Әллә мин аңгырамы? Һаман миңа акыл өйрәтәсез! – Ана башлаган сүзен кинәт өзде дә еларга тотынды.* Ф.Яруллин. – *Ә үзе дә-әәү! – дип суза ул, мыскыллавын яшермичә, һәм, акыл өйрәтеп, өстәп куя: – Укырга кирәк!* Г.Шәрипова. **Акыл өләшкәндә, өйдә булмаган** *мыск.* Акылсыз, корыга буй үстерүче. **Акыл сату** Кешеләргә акыл өйрәтеп, үзен башкалардан акыллырак итеп күрсәтергә ярату. *Арбага, бигрәк тә мондый иске арбага, бу кадәр авыр йөк төяргә ярамавы хакында озын итеп акыл сатарга гына җыенган иде, икенче тапкыр аркасына шундый итеп төрттеләр, кучер чак телен тешләмәде.* Г.Шәрипова. *Хәзер акыл сатучылар бик күбәеп китте.* **Акыл тарлык** Фикерләү сәләте чикле булу, белем җитмәү. --- *бу дөньядан туйдым инде. Моңарчы да торганмын мин гакыл тарга.* Г.Тукай. **Акыл туплау** *к.* **акыл җыю**. **Акыл чыгу** *к.* **акыл китү**. *Әллә, «хис» дигән нәрсәгә артык бирелеп китеп, акыл чыгып торган чакларда була торган бер кабынып китү генәме бу?* Г.Гобәй. **Акылы арттан йөрү** Уйлап җиткермичә, ашыгып эш итү. *Минем ишеләрнең шул инде ул: дуамаллык – алдан, акыл арттанрак йөри.* В.Нуруллин. **Акылы камил** Акылы һәр яктан төгәл, тулы, җитеш. *Парлап кына парлап ат җиктергән, Кайсы илләрдән килгән бу түрә? Бу түрәлек сиңа бирелгәндер Акылларың камилгә күрә.* Җыр. **Акылың алтын икән** *ирон.* Үзен бик акыллыга, белгәнгә санап йөрүчегә карата әйтелә. **Акылы үзе белән** Холыксыз, тотрыксыз кеше, әйткәненең киресен эшләүче. *Холкына ничек туры килсә – шулай. Аның акылы үзе белән.* Н.Исәнбәт. **Акыл югалту** *к.* **акыл җую**

**АКЫЛЛАШУ** *ф. сөйл. сир.* Киңәшләшү, киңәш-табыш итешү; фикер алышу, мәслихәтләшү

**Акыллашып алу** Тиз генә акыллашу, уртак бер фикергә килү

**Акыллашып тору** Әледән-әле, еш акыллашу

**АКЫЛЛЫ** *с.* **1.** 1) Аңлы, зиһенле, зирәк, уйлап эш итә торган, төпле. *Акыллы башың белән юләр сүз сөйләп торма, улым.* Р.Ишморат. *Шуларны исәпләп карасаң, бер семья корт кына да никадәр эш башкара. Ә акыллы кешеләр моны исәпләп чыгарганнар да инде. Кортлар алар кеше шикелле акыллы, һәр эшне үзара бүлешеп эшли.* Ф.Яруллин

2) Күркәм холыклы, тәрбияле, һәркайда үзен тота белә торган. *Акыллы кеше дошманнан дус ясый белер.*

Мәкаль. *Өч ел буена аларга [флотта хезмәт итүчеләргә] бер генә тапкыр да концерт күрсәтмәгәннәр. Юк, безнең заманда безне тәрбияләүче өлкән офицерлар акыллырак иде…* М.Мәһдиев. – *Беләсеңме, апа, акыллы егет ул. – Акыллыдыр инде, – дип көлемсерәде Гамбәр. – Нинди акыл бирде соң ул сиңа?* Г.Шәрипова

3) Акылга, күңелгә ятышлы; тирән эчтәлекле. *Һа, кара син аны, акыллы сүз бит бу, Газинур*! Г.Әпсәләмов. *[Миңнурның] Картларга йомшак тавышы, акыллы сүзләре гаҗәп нык тәэсир итә иде*. А.Шамов. *Чарасыздан туган акыллы гадәт бу*. Г.Хөсәенов

4) *күч.* Акыллылык сизелеп, чагылып торган. *Алар эттән акыллы, бүредән усалраклар*. Т.Миңнуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Зиһенле, тәрбияле кеше. *Акыллы – юл бирдем, дияр, җүләр – җиңдем, дияр*. Мәкаль. *Акыллы хаталанса – үзен гаепләр, акылсыз хаталанса – юлдашын гаепләр*. Мәкаль

2) **акыллым** *тарт.* Яратып, үз итеп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. – *Биология укытучысы Җәүһәрия апа белән сөйләшеп карарга кирәк. – Сөйләш әле, Фәйрүз акыллым. – Үзенә кирәк чакта апа да хәйләкәр, «акыллым» дип җибәрә*. Ф.Яруллин

**3.** *рәв. мәгъ.* Акыл белән, төптән уйлап, рәтен белеп. *Корбангали алардан бик акыллы файдалана белде*. М.Әмир

◊ **Акыллы баш булып** Кемнеңдер үзен эре кыяфәттә тотып фикер йөртүе. *--- үзеңә бик үк тыныч карый алмаган шундый чибәр яшь хатын утырганда, акыллы баш булып, берни дә күрмәгәнгә сабышу җиңел түгел*. Г.Бәширов

**АКЫЛЛЫБАШ** *и.* 1) Эшне акыл белән йөртә белгән, тәҗрибәле, төпле акылга ия кеше. *Юк, малай, тинтәк түгел, акыллыбаш син*. Г.Мөхәммәтшин

2) *ирон.* Үзендә юк акылны кешегә «сатарга» яратучы, белдекле булып кыланучы. *Ул утырган бик матурлап һәм акыллыбашланып, Уйга чумган, җиргә күз теккән, җиһаннан баш алып*. Г.Тукай. *Ә кайбер акыллыбашлар фикеренчә, татарча белем алу – бөтенләй дә «зыянлы» икән бит*. Мәдәни җомга

**АКЫЛЛЫЛАНУ** *ф.* 1) Акыл, аңбелем дәрәҗәсе үсү; акыллыга әйләнү, акыл керү. *Ул акыллыланган, олыгайган һәм үзенә хөрмәт уяттыра ала иде*. Г.Әпсәләмов

2) *ирон.* Артык белдеклеләнеп, башкаларга киңәш бирү. *Ә Рәисә бит үзе дә ул чакта болай акыллыланып мораль укымый иде*. Ш.Бикчурин

**Акыллылана бару** Торган саен ныграк акыллылану

**Акыллылана төшү** Беркадәр акыллылану

**Акыллыланып бетү** Бик нык акыллылану. *Киресенчә, минәйтәм, аның белән бергә йөргән бүреләр эт кебек акыллыланып беттеләр*. Ф.Шәфигуллин

**Акыллыланып җитү** Бөтенләй акыллылану, акыллыга әйләнү

**Акыллыланып китү** Кинәт акыллылану. *Бик тиз акыллыланып киткәнсең әле син, Әхнәф Хәсәнович*. Ф.Садриев

**Акыллыланып тору** Әле, хәзерге вакытта акыллылык күрсәтү

**Акыллыланып утыру** *к.* **акыллыланып тору**. *Акыллыланып утырмасана. Сезгә бит хәзер минем улым кирәкми. Әнә Дамираңның Чәчкәсен үстер*. Ф.Яруллин

**АКЫЛЛЫЛЫК** *и.* Акыллы булу, мөкәммәл акылга ия булу. *Үзенең акыллылыгы, НКВДда сорауларга җавап бирә белүе, аналитик булуы аркасында гына Антонов исән кала алгандыр*. З.Зәйнуллин. *Балаларының акыллылыгына исем китеп карап тордым*. Мәдәни җомга

**АКЫЛСЫЗ** *с.* **1.** 1) Аңгыра, юләр, уйламыйча эш итүчән. *Белмим, кемгә охшап бу кадәр мисез, акылсыз булгандыр*. Г.Камал

2) Акылга ятышсыз, мәгънәсез. *Чөнки кеше акыллы эшкә караганда акылсыз эшләрне ансатрак эшли шикелле*. Х.Камалов

3) Акылсызлык күрсәткән, дөрес эшләмәгән. *Акылсыз эт көндез өрә*. Мәкаль

**2.** *рәв. мәгъ.* Ахмакларча, уйламыйча. *Акылсыз гомер итте, дип, Дошманнар сөйләгәнче*. К.Булатова

**АКЫЛСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Ахмаклану, акылсызга әйләнү, акылсыз булып китү

2) Акылдан язу, юләрләнү, җиңеләю

3) Тәрбиясезләнү, холыксызлану, дуамаллык күрсәтү. *[Әткәй:] – Солтан, син нигә алай акылсызланасың?.. Кемнәр икәнен танымыйсыңмыни? – дип кычкырды*. Г.Ибраһимов

**Акылсызлана бару** Акылсызлыгы арта бару. *Өйдәге муллыктан файдаланып, хатынның ясалып җитмәгән тормыш иптәше көннән-көн аза, акылсызлана барды*. Р.Сәгъди

**Акылсызлана башлау** Акылсызланырга тотыну

**Акылсызлана төшү** Бераз, беркадәр акылсызлану, тагы да акылсызлану

**Акылсызланып алу** Кыска гына вакыт арасында акылсызлану. *Чәчләре инде маңгайдан коелып керә. Гәүдә дә көпшәкләнгән, бушаган. Бу вакытта кеше бер акылсызланып ала*. М.Мәһдиев

**Акылсызланып бетү** Бөтенләй акылсызлану

**Акылсызланып китү** Көтмәгәндә, кинәт акылсызлану, акылсызлык халәтенә килү

**Акылсызланып тору** Әле, хәзер акылсызлык күрсәтү

**АКЫЛСЫЗЛЫК** *и.* Акылсыз булу; дуамаллык, башсызлык. *Әмма шул вакыт Сәхип: – Нигъмәтҗан, акылсызлык эшләмә! Миңа берни дә булмас, барырмын да кайтырмын, – дип әйтте, ди*. Ә.Фәйзи. *[Разия:] Юк, болай ярамый. Бу – акылсызлык. Боларга яңадан кайтырга ярамый*. Г.Ибраһимов

**АКЫ́Л ТЕШЕ** *и.* Кешедә егермеләрдән соң чыга торган иң арткы азау теш

◊ **Акыл теше чыккан** Тәҗрибә туплаган, акылга утырган, тормыштан җитәрлек сабак алган. *Юк, абзый, безне бик җиңел генә алдый алмассың. Безнең инде акыл теше чыккан*. Ф.Хөсни

**АКЫ́Л-ФИГЫЛЬ** *җый. и.* Кешенең акылы, үз-үзен тотышы, уйлап эш итү дәрәҗәсе. *Ольганың зәңгәр күзләре белән аксыл алтын чәчләре генә дә ни тора! Ә буй-сыны, акыл-фигыле!* Р.Сибат. *Әллә үзе картайды инде, әллә килененең акыл-фигылен бигүк өнәп җиткермәде, һаман уйда, һаман бор-*

*чуда яшәде әни кеше*. Г.Ахунов. *Мөәзин кызы Мәүдүдә дә – укымышлы иренә таяныч булырдай акыл-фигыль, белем туплаган хатын*. Татарстан

**АКЫН** *и. каз.* Казакъ, кыргыз, уйгур кебек төрки халыкларда шагыйрь-импровизатор һәм җырчы. *Илбашы учын учка бәреп шапылдатуга, алгы яктан Төп акын – Баянҗар килеп чыкты*. М.Галиев

**АКЫРТУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **акыру**. *Бу халәтемнән мине матай коткарды. Сүндерергә вакыт булса да, алай эшләмим, матайны һаман акыртам да акыртам.* Казан утлары

2) Тавышын нык ачып кую; көчле итеп уйнату, кычкырту. *Авылның ямен бозып йөри бит. Магнитофон акырта*. Т.Миңнуллин. *Уйнаңыз, әйдә, гармун, Акырт, кызганма телен*. Г.Камал

**2. акыртып** *рәв. мәгъ.* Мәҗбүр итеп, көчләп, бернәрсәгә карамыйча, кычкыртып. *Крестьянны акыртып талау, җирсез калдыру бу*. В.Имамов

**Акырта бару** Торган саен ныграк акырту

**Акырта башлау** Акыртырга тотыну

**Акырта бирү** Акыртуын дәвам итү. *--- миңа нидер ымлый, әйтә бугай, аны ишетмим, матайны һаман акырта бирәм*. З.Хөснияр

**Акырта тору** Һәрвакыт, гел акырту. *Талон, штраф турында искәртеп, колак төбендә микрофон акырта торган иде*. М.Галиев

**Акырта төшү** Беркадәр, бераз акырту, тагын да акырту

**Акыртып алу** Берара, беравык акырту. *Мотоциклда утырган егет, газга басып, бер мәртәбә мотоциклын акыртып алды да стартер ачкычын борды*. Х.Ибраһимов

**Акыртып җибәрү** Кинәттән акырта башлау

**Акыртып кую** 1) Бер тапкыр акырту

2) Акырган хәлдә калдыру, нәрсәнең дә булса тавышын көчәйтеп калдыру

**Акыртып тору** Бертуктаусыз акырту

**АКЫРТЫН** *рәв. сөйл. к.* **акрын** (*1–4 мәгъ.*). *Бу манара, акыртын кына төшкән кояш нуры белән ялтырап, гаҗәп бер күренештә иде*. Г.Исхакый. *Мәхдүм акыртын гына әтисе янына килде*. Г.Исхакый

**АКЫРУ** *ф.* **1.** 1) Яман тавыш белән кычкыру, тавышлану, елау. – *Син, шуннан соң, койрыгы кысылган кәҗә бәкәе кебек бәәлдәп акырырга тотындың, – дип үртәп алды Заһид абыйлары*. Ф.Яруллин. *Күк фәсле кеше тагын акырды, тагын кычкырды*. К.Тинчурин. *Матур музыка әсәрләре уйналганнан соң йәки тирән хисле бер-бер пьесада пәрдә төшкәч, публиканың кул чабарга, акырырга тотынуы һәрвакыт минем нервларымны боза, фикеремне чуалта…* Гали Рәхим

2) *ирон.* Бик каты тавышланып җырлау яки музыка коралларында уйнау. *Ай-яй шәп акыра икән. Мөхәммәдия көйләрен дә чиерттерә беләсеңме әллә, җанкаем?* Ш.Камал. *Бу егетнең сәхнәдә үзен гади, табигый тотуы куандырды. Залны шаккатырыйм дип, кыргый тавыш белән дә акырмый, ясалма мелизмнар өстәргә азапланып, җырның мәгънәсен дә югалтмый*. Мәдәни җомга

3) *сөйл.* Җикеренү, сүгенү, кычкырышу. *Акырганмын, имеш, җикергәнмен, ямен бозып бөтен урамның*. З.Мансур. *Сорау алучы, өстәлгә сугып, акырырга тотынды*. Г.Гобәй. – *Кабахәт! – Тәбрик шулай дип кенә акыра алды*. Ә.Баян

**2. акырып** *рәв. мәгъ.* Бик каты тавыш-гауга күтәреп, тавышланып, шаулашып. *Ак бандитлар, кылычларын, сәнәкләрен айкый-айкый, улап, акырып, Җәүдәтләрнең артына төштеләр*. Г.Бәширов

**Акыра башлау** Акырырга тотыну. *Гали, сикереп торып, акыра башлады: – Бу – хулиганлык! Мин хәзер урәтникне, земскине чакыртам! – ди*. Г.Ибраһимов

**Акыра бирү** Акыруын дәвам итү. *Бөтен тавышка акыра бирәләр*. Т.Гыйззәт. – *Юк, хакыбыз юк! – дидем мин, акыра биреп*. Г.Галиев

**Акыра төшү** Тагын да көчлерәк акыру

**Акырып алу** Берара акыру

**Акырып җибәрү** Кинәттән акыра башлау. *Иртән иң элек, үз тавышым үземә хуш дип, шул юньсез акырып җибәрә*. Г.Мөхәммәтшин

**Акырып йөрү** Төрле урыннарда, төрле кешегә ризасызлык белдерү; артык тавышлану. *«Урладылар, суктылар минем темамны!» – дип акырып йөрсә дә, файдасы тимәде*. Х.Ибраһимов. *--- баш түбәләрен горурлык белән күтәреп, урамнар буйлап акырып йөрделәр*. Р.Батулла

**Акырып кую** Кинәт акыру; бер тапкыр акыру. *Ул, капылт килеп, кушучына пычрак суны алды да Никитичның чыраена чәпәде. – Нишлисең син, сволочь! – дип акырып куйдым мин*. Х.Камалов

**Акырып тору** 1) Бертуктаусыз, һаман акыру. *Сәлимхан ат өстеннән: – Турарга, тапарга, чәнчергә! – дип акырып торды*. М.Хәбибуллин

2) Әле, хәзер, күз алдында акыру

**Акырып утыру** Әле, хәзер, күз алдында акыру. *Белер-белмәс акырып утырсаң, машинасына утыртып алып та китәр*. Д.Салихов

**Акырып яту** *к.* **акырып утыру**. *Бер ай элек кенә туып, бишектә акырып яткан малаемның исеме Эрнест дип, [халык дошманы булудан] котыла алмыйсың...* Р.Зәйдулла. *--- теленә нинди җыр килсә, шуны акырып ята...* И.Гыйләҗев

**АКЫРЎ-БАКЫРУ** *ф. гади с.* Каты итеп, бөтен көчкә кычкыру. *Кыйныйлармы, качканнарны куып тоталармы? Акырып-бакырып йөгерәләр*. Г.Ибраһимов. *Тамаклары ачыкса, ярты авылны күтәреп, акыра-бакыра башлыйлар*. Казан утлары. *Исерек ир акыра-бакыра җырлады*. Мирас

**АКЫРЫНУ** *ф.* Күп һәм озак итеп акыру. *Гайнетдиннең башка чакта да чиртсәң каны чыгардай кызыл булган йөзе бу акырынудан тагын яман бүртенеп каралды, күзләрен кан басты*. Г.Ибраһимов. *Кинәт акырыну бетеп калды. Әмма тынлык биредә җыелган кешеләргә тагын да куркынычрак булып тоелды*. Г.Шәрипова

**Акырына башлау** Акырынырга тотыну. *Шаһиәхмәтов безне генә күргән иде, китәсе җиреннән борылып, тагы акырына башлады: – Ә-ә! Сезмени әле*

*бу? Безне куып чыгарып, хәзер бәйрәм итәсезме?* Ә.Баян

**Акырына бирү** Акырынуын дәвам итү

**Акырына төшү** Тагын да бераз акырыну

**Акырынып алу** Бераз вакыт акырыну

**Акырынып йөрү** Барысына да акырыну. *Нәрсә акырынып йөри ул монда?* Ш.Камал

**Акырынып кую** Кинәт акырыну; бер тапкыр акырыну

**Акырынып тору** Әле, хәзер акырыну

**АКЫРЫШ** *и.* Күпләгән кешенең каты тавыш белән кычкырышуы. *Акырыш, кисеш, атларның шашып кешнәве, тояк тавышлары тоташ бер гөрелтегә әвереледе.* Р.Батулла. *Китте кычкырыш, акырыш.* З.Зәйнуллин. *Бездә ил-көн тыныч торса да, поезд көткән төркем дистә кешедән артса, бер кеше өстенә икенчесе менә, таптый, кием сәдәфләрен өзә, акырыш һәм талаш башлана.* Ватаным Татарстан

**АКЫРЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **акыру**. *Менә бервакыт авылга көтү керә, урам тагын артык шатланып китә: ул куйлар йөгерә, ул яшь сыерлар акырышып, уйнашып сикерәләр.* Ш.Камал

2) Бер-берсенә тупас итеп җикеренү, үзара акыру

**Акырыша башлау** Акырышырга тотыну. *Фрицлар да, каушап, акырыша башладылар.* Х.Камалов

**Акырыша бирү** Акырышуын дәвам итү

**Акырышып алу** Бераз, берара акырышу

**Акырышып йөрү** Барысы да акырышу. *--- күзләреннән нур кача, аннан кыргыйларча чабып, акырышып йөриләр яр читендә.* Ф.Сафин

**Акырышып кую** Кинәт, бердән акырышу

**Акырышып тору** Бертуктаусыз акырышу

**АКЫ́Ш-МАКЫШ** *рәв. диал.* **1.** 1) Рәтле-рәтсез, белер-белмәс, ялгыш. – *Йә, акыш-макыш елама, сугышка озатмыйсың бит, – диде ул.* Л.Ихсанова

2) Алдап-йолдап, ялганлап. *Вәзыйх хәйләләп, акыш-макыш китереп, берике участок бодайны, үзе теләгәнчә, солычаны «провокацияләп» чәчә алды.* Х.Камалов

**2.** *с. мәгъ.* Аңгы-миңге, аңгыра, юләр сыман. *Йокыдан соң акыш-макыш кыяфәттә басып тору*

**А́К ЯК** *и. к.* **ак өй**. *Ак яктан куса, кара яктан керә.* Әйтем

**АЛ** I *и.* **1.** 1) Гадәттә кыек килеш формаларында килеп, пространствода: күз караган як, йөз белән торган тараф; алгы як; *киресе:* **арт**. *Ике бик таныш күз, ике яшел күз һаман минем алдымда торалар.* Гали Рәхим. *Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам.* Г.Тукай

2) Кеше гәүдәсендә һәм киемендә: йөз, күкрәк ягы; *киресе:* **арт**. *Үзләре, бичаралар, кия дә белмиләр икән: ал ягын – артка, арт ягын алга киеп куйганнар!* Ф.Әмирхан. *Алга ябу өчен, кызыл ситсы юрган да куелган иде.* М.Гали

3) Нәрсәнең дә булса тышкы, алгы ягы. *Агач бакчалары юк диярлек, тик кайбер йортларның гына тәрәзә алларында сирень куагы --- яки миләш агачы үсеп утыра.* Ә.Еники. *[Шәйхи карт] Әвенне бер кат әйләнеп чыга, мич алларын тикшерә.* М.Мәһдиев. *Буран читән буйларына, өй алларына шактый кар өеп өлгергән иде инде.* А.Расих

4) Эшкәртү (утау, уру һ.б.) өчен бүлеп бирелгән тар, озын җир мәйданчыгы; кишәрлек. *Мин апа белән әни уртасында [урак урырга] ал алдым.* М.Гафури. *Арыдым, димә әле, алың зур. Җир башына әле ераксың!* М.Кәрим

5) Берәр нәрсә куярлык яки утырырлык итеп җайланган тез өсте. *Бала, ашыкмыйча гына, әнисе алдына менеп утырды.* Казан утлары

6) Берәр нәрсә тотар, җыяр яки салыр өчен бөреп, күтәрә төшеп тотылган күлмәк итәге, алъяпкыч. *Кызарып пешкән җиләкне алларыма җыямын.* Җыр

7) Утырып яки басып торган кешенең каршысы, карап торган ягы. *Син теләсәң, таң чыклары булып, Алларыңа тамар идем мин.* Җыр

8) Өстәл янына килеп утырганда, һәр кешенең турысына килгән урын. *Кунак шикелле, без кыстатып торырга белмибез, алга нәрсә килсә, табак төбе күренгәнче, шуны ялтырата гына бирәбез.* М.Гали. *Безнекеләр, рәхмәт әйтеп тормыйча, алларына төшкәнне, бик эшлекле кыяфәт белән, иплән кенә сыпыра бирделәр.* Г.Кутуй. *Алдымдагы ясалган чәемне онытып, бернәрсә уйламыйча утырам икән.* Гали Рәхим

9) Бер-бер артлы тәртип белән тезелгән сафның яки нинди дә булса нәрсәләрнең беренче рәте. *Теге эшләпәле абый алга чыгып, кушылыгыз, ди, җырлагыз, ди.* Җ.Фәйзи. *Кызларның әниләреннән алга чыгарга кыюлыгы җитмәде.* Г.Шәрипова. *Беренче класслар, шаулашып, алга килеп бастылар.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* 1) Алгы, алдагы, алда урнашкан. *Ал тәгәрмәч кайдан йөрсә, арт тәгәрмәч шуннан йөрер.* Мәкаль. *Күчәре сынган ал арбаның иске тәртәләре арасындагы бахбай, арт арбадан ике адымнар читтә, башын иеп басып тора.* Г.Шәрипова

2) Хайван гәүдәсенең баш ягында, алгы санында урнашкан. *Альфа [эт], башын ал тәпиләренә куеп, гүя йокыга гына талды.* А.Хәсәнов

**3. алдында** *рәв. мәгъ. сөйл.* Яшермичә, ачыктан-ачык, шәхсән үзенә белдереп. *Ленарның, артында түгел, алдында сүккәнгә дә исе китми әле.* М.Мәһдиев

**4.** *бәйл. сүз* 1) **алды** Берәр эш-хәлнең башлануына кадәрге вакыт аралыгын белдерә. *Икенде алды, көн караңгыланып килә.* М.Гали. *Сабантуй алды әзерлекләренең иң кызган чагы.* Казан утлары

2) **алдына** Эш-хәлнең урыны предметка, аның алгы, йөз ягына юнәлгәнен белдерә; каршына, каршысына. *Кунаклар алдына, ике-өч кулдан, тәлинкә-кашыклар тарата башладылар.* Ә.Еники. *Атлылар кое алдына килеп туктадылар.* Казан утлары

3) Эш-хәлнең кемгә дә булса караганын тәгъбир итә. *Ил тарихындагы борылыш сәнгать әһелләре алдына заманча яңгырашлы, чор проблемала-*

*рына аваздаш әсәрләр тудыру бурычы куя.* М.Арсланов

4) **алдында** Эш-хәлнең предметның алгы, йөз ягында эшләнүен белдерә; каршында, каршысында. *Имтихан бара торган аудитория ишеге алдында азакка калган берничә кеше генә үз чираты җиткәнен көтеп тора.* Н.Фәттах

5) Эш-хәлнең кемнең дә булса каршында эшләнүен, кемдер күреп, карап торганда булуын белдерә; каршында, каршысында. *Сәкинәнең шулай Фәрхәнә апа янында, кызлар, малайлар алдында шелтә белдерүе аның өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булды.* Н.Фәттах. – *Кеше алдында оятка калдырма, балам! – диде ана.* Казан утлары

6) Кемгә яки нәрсәгә булса да мөнәсәбәтле эш-хәлне белдерә. *Тимери уйга калды. Аланбашлар алдында колхозның болай оятка калуы аны аеруча гарьләндерде.* Г.Бәширов. *Тагын да гафу, улым! Нәрсә өчен мине шулай чит-ят күрер булдың, үз алдымда да, синең алдыңда да нинди хаерсез эш кылдым?* Мирас

7) Берәр эш-хәл башланганчы булган вакыт аралыгын белдерә. *Җәмгыять гаять зур куркыныч алдында тора...* Р.Мирхәйдәров. *Византия империясе һәлакәт алдында.* М.Гайнетдинов

8) **алдыннан** Хәрәкәтнең берәр нәрсә яныннан, аның алгы ягыннан башланып китүен белдерә. *Олы юл нәкъ безнең йорт алдыннан башланып китә.* Мирас

9) Нәрсәнең дә булса алгы ягында башкарылган эш-хәлне белдерә. *Мич алдыннан ут төсле бер күз, чекерәеп, миңа карап тора!* Г.Бәширов

10) Эш-хәлнең, вакыйганың икенче бер эш-хәлдән элек булуын белдерә. *Кич кояш иңәр алдыннан, Газизә, әнкәсе карчык белән, казарманың ишегалды баскычына чыгып утырды.* Ш.Камал. *Малай сугыш башланыр алдыннан ун көн элек туды.* М.Мәһдиев. *Тәнәфес бетәр алдыннан гына, лекция сөйләячәк профессорның университетка килмәгәнлеген әйттеләр.* М.Юныс

◊ **Алга алган** 1) Тотып күрсәтерлек, мактарлык, мактанырлык. *Аның теле генә сөйли бит, алга алган бер эше дә юк*; 2) Бар нәрсәдән дә артыграк, әһәмиятлерәк. *Ике бите кызыл нур булыр; Егет сүзен алга алмаган – Ахыр бер көн үзе хур булыр.* Җыр. **Алга (килеп) басу** 1) Күз алдына килү, кабат гәүдәләнү. *Баса үткән гомер алга.* Н.Исәнбәт; 2) Көн тәртибенә куелырга тиешле эш-хәл, мәсьәлә булып җитлегү, өлгерү. *Мәсьәлә алга килеп басты.* А.Расих; 3) Реаль чынбарлыкка әйләнү, тормышка ашу. *Уйга килгән – алга килә.* Мәкаль. **Алга бастыру** Күз алдына китерү, җанландыру. *Монда «Безнең көннәр» һәм «Кызыл чәчәкләр»дә күренмәгән яңа типлар да алга бастырылган.* Г.Нигъмәти. **Алга кую** Бар нәрсәдән артыграк күрү, әһәмиятлерәк санау. *Ярый, ачуны – артка, акылны алга куйдым, ди. Сөйлә, аксакал, ни дип үзеңне аклый аласың.* Мирас. **Алда бару** 1) Беренчеләр, алдынгылар рәтендә булу (эштә, ярышта һ.б.да); 2) Узып китү, алга чыгу. **Алда йөрү** 1) Башлап йөрү, узаман булу; 2) Кадерле булу, өстен исәпләнү. **Алда күрү** *к.* **алда тоту**. *Андый чакта тизрәк качуны алда күрә.* Н.Исәнбәт. **Алдан калганчы** Тәмам туйганчы, туйгач та артык калырлык итеп (мәс., ашау-эчү турында). **Алда тору** 1) Башкалардан өстен булу, яхшы якка аерылып тору; 2) Беренче чиратта эшләнергә, хәл ителергә тиешле эш-мәсьәлә булып саналу. **Алда тоту** 1) Истә тоту, актуаль, кирәкле дип санау; игътибарда, күз уңында тоту; 2) Башкаларга караганда яхшырак, артыграк күрү, югарырак, өстенрәк санау. *Ул Гафуридан Тукайны алда тота иде.* Н.Исәнбәт. **Алдында баш ию (ору)** 1) Кемнең дә булса талантлы, батырлыгы, дәрәҗәсе алдында ихтирам күрсәтеп иелү; 2) Кемгәдер буйсыну, аның йогынтысына бирелү. **Алдында бүрек салу** *к.* **алдында баш ию**. **Алдында җир үбү** Чинга, дәрәҗәгә табыну, ясалма хөрмәт, риялык күрсәтү. **Алдында сәҗдә кылу** Кемгәдер колларча буйсыну, аннан культ ясау. **Алдыннан арты яхшы** Күңелгә якын булмаган, ошамаган кешегә карата әйтелә. **Алдыңа ак көн тусын!** Кемгәдер якты киләчәк теләү. **Алдыңа кара да атыңны куала** Як-ягыңа күп илтифат итмә, кеше сүзенә карама, үз юлыңны бел дә эшеңне эшлә, дигән мәгънәдә әйтелә. **Алдыңда – ашыңны, артыңда башыңны ашый** Эчтән – дошман, тыштан дус булып йөрүче яман кеше турында. **Алдыңнан артың** Күңеленә хуш килмәгән кешене озатканда үзенә үк яки артыннан әйтеп калу сүзе

**АЛ** II *с.* **1.** 1) Янып торган кызыл, ачык кызыл; кан төсе. *Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата.* Г.Тукай. *Әнә сандугач та сайрамый хәзер, аның мәгъшукасы – гүзәл ал гөләп чәчәге дә, атып бетереп, коелган инде.* Гали Рәхим

2) *бор.* Асыл, асыл затлы, кыйммәтле, бик яхшы, югары сыйфатлы. – *Яурыннары каймалы, Төймә бавы тартмалы Ал кара кеш тун бирим. Бу тунымны ки, – диде.* Дастан

3) *иск.* Солтанатлы, патшаныкы. *Ал фәрман – ул «патша фәрманы» дигән сүз.* Р.Әхмәтьянов. *Ал морза*

4) *күч.* Матур, гүзәл, күркәм. *Ал чәчәкләрдән илһам эзләшик, Былбыллар кебек Гөр-гөр гөрләшик...* Җыр. *Тиздән шаулап яфрак ярыр Озын ак каен, Ал чәчәкләр алып килер Безгә май ае.* Ф.Кәрим. *Ал чәчәкләр кочып, рәхәтләнеп Йоклап ята идем багларда.* М.Җәлил. *Кирәк түгел миңа мәрмәр һәйкәл, Ал чәчәкләр сибә Ана-җир.* Г.Кутуй

**2.** *и. мәгъ. шигъ. фольк.* 1) Халык җырларында «гөл» сүзе белән янәшә килеп, матурлык, шатлык, гүзәллек, әсәрләнү, соклану һ.б.ш. хисләр тудыра алырлык әйберләр, күренешләрне белдерә. *Ал да булырбыз әле, Гөл дә булырбыз әле.* Җыр. *Алым түгел, гөлем түгел, җаным җәл түгел сиңа.* Җыр

2) *тарт. форм.* Матурым, гүзәлем. *Алым-гөлем түгелсең, Төшләремә кермә инде, Минем ярым түгелсең.* Җыр

◊ **Ал да гөл (кебек)** Бик матур, һәр ягы килгән, төгәл, бик шәп. – *Сиңа хәзергә һәммәсе дә ал да гөл булып күренә, – диде әти, – ләкин, эшкә тотынгач, китапча гына барып чыкмый ул.* Ф.Яруллин. *[Бәдига:] Әлхәмделилла, яучы булып бирдергән кызларым бары да ал да гөл булып гомер итәләр.* М.Фәйзи. **Ал төстә күрү**

Тормышны, чынбарлыкны идеаллаштырып күрү. *[Кияүгә барганчы] Нәгыймә дөньяны матур ал төстә итеп күрә килде.* Г.Ибраһимов

**АЛ** III *и. бор.* Хәйлә, алдау, алдак; алым, әмәл. *Аучы ничә ал белсә, аю шуныңча юлын белер.* Әйтем

**АЛ** IV *и.* Алдынгылык, беренчелек. *Бу ат әйбәт чаба торган иде, һәрвакыт ал аныкы булды*

◊ **Ал бирү** Ярышта, көрәштә җиңелү, башкаларны үзеңнән уздыру. *Ал биргәнче, җан бир.* Мәкаль. *Киң күкрәкле, нык аяклы, озын мул яллы кызыл айгыр юртаклыкта үз ишләренә һич ал бирми торган иде.* А.Гыйләҗев. **Алга чыгу** 1) Белем-һөнәрдә, мәдәнияттә, хезмәт ярышында җиңүгә ирешү, беренчелекне яулау; 2) Өстенлеккә ирешү, узып китү

**АЛА** *с.* **1.** 1) Ак белән башка төс аралашкан. *Бераздан карт атларны барлап караса, көтүдә ала бияне күрмәгән, ди.* Мәзәкләр. *Ала сыер торып китте, кара сыер ятып калды.* Табышмак (*яз җитеп, кар эреп бетү*). *Ала каз үзе дә, акрынлап, безнең солдатларга ияләште.* Ә.Еники

2) Төрле төсләрне аралаштырып ялганып ясалган, тегелгән; чуар. *Ала ашьяулык. Ала эскәтер*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Нindидер төскә ак аралашкан төс. *Аттан ала да туа, кола да туа.* Мәкаль

2) *бор.* Хәйлә, мәкер; яшерен, явыз уй. *Кеше аласы эчтә, елкы аласы тышта.* Мәкаль. *Карганың яшен кем белер, кешенең аласын кем табар (белер).* Әйтем

◊ **Ала да түгел, кола да түгел** Бер генә ягы белән дә аерылып тормаган, төсмерен атап булмаган әйбер. **Ала да ярамый, кола да ярамый** Көйсез, вакчыл кешегә карата әйтелә. **Ала кар** Язын җир өстендә, эреп бетмичә, урын-урын калган карлар. **Ала каргадай алдан кычкыру** Булмаган эшне «була» дип яки «булды» дип, алдан мактанырга ярату. *Син дә, Бикмулла абзый, ала каргадай, алдан алай кычкырмаска кирәк иде.* Г.Бәширов. **Ала каргадан хәбәр көтеп яту** Китәсе булса да, юк сылтауны бар итеп, барасы җиренә китмичә йөрү. **Ала кош** 1) Ала карга яки саескан кебек, сайрый белми торган ала кошлар; 2) Затсыз кеше. *Ала кошларга бакмачы, газизем, булма такмакчы, матур гөлләргә бул былбыл, нәзакәт багына сакчы.* Дәрдемәнд. **Ала күз** Кемгә яки нәрсәгә дә булса күзен ямьсез алартып карап торучы, яман күзле. *Карамасана ул кош баласына ала күз белән, күзең сукыраер.* Г.Әпсәләмов. **Ала күңел** 1) Тыштан ягымлы күренеп, эчтән явыз кара ниятле, үч саклаучы кеше. *Аларның ала күңел билатил айтып илгар кылганы.* Туктамыш хан ярлыгы. 2) Үз фикере булмаган, еш үзгәреп торучан кешегә карата әйтелә

**АЛАБАЙ** I *и.* 1) Урта Азиядә барлыкка килгән, эре гәүдәле, төрле табигый шартларга чыдам, көчле саклау инстинктына ия булган бик борынгы эт токымы; Урта Азия овчаркасы. *Ә җиңүче алабай авызын көндәшенең муеныннан арындырып аягүрә торып басты.* Р.Мөхәммәдиев. – *Нәрсә, «алабай» дип аталган нәсел бармы?.. Әллә сездә һәммә этләрне дә шулай атап йөртәләрме? – дип сорамый булдыра алмадым.* Р.Мөхәммәдиев

2) Токымсыз ала авыл эте. *Килен кеше ким кеше – алабайга тиң кеше.* Әйтем. *Капкаларын кагыйм дисәм – алабай этләре өрә, тиз-тиз качарга туры килде.* Казан утлары

3) Ала этләргә бирелә торган кушамат. *Имчәкләренең җиргә тияр-тимәс чайкалып баруыннан абайладым – һичшиксез, яшь көчекләре янына ашыга иде бу алабай (соңыннан белдем: исеме дә Алабай икән).* Ф.Шәфигуллин

**АЛАБАЙ** II *и. бот.* 1) Кырда үсә торган саргылт чәчәкле чүп үләне

2) *диал.* Оешма чәчәкләр семьялыгыннан, уртасы сары, кырыйдагы телсыман аерчалары ак төстәге чәчәкле үләнчел үсемлек; ак чәчәк, ромашка. *Әгәр июль башында узсаң – барыбер безнең бакчага кер: чәчәк диңгезен күрерсең, анда алабай чәчәге, алма үләне, сандугач тәпие, баллы куәт гөрләп утыра.* Сабантуй

**АЛА́ БАЛЫК** *и. зоол.* Сөләйман балыклары семьялыгыннан, чиста сулы тау елгаларында үрчи торган, кызыл һәм кара тимгелле балык; *русчасы*: **форель**. --- *юан кәүсәле зирекләрнең тамырлары арасыннан көмештәй чиста сулы елга ага. Шул елгада ала балык – форель күп иде.* М.Юныс

**АЛАБУГА** *и. зоол.* Алабугасыманнар семьялыгыннан, кызгылт йөзгечле, буй-буй таплары булган, күбесенчә төче сулыкларда яши торган, чәнечкеле ерткыч балык; *русчасы:* **окунь**. *Әллә-лә-лә! Чабакларны шактый тарттыргансың икән. Кызыл канат та, алабуга да бар, имеш.* Ә.Еники. *Алабугалар, судаклар көтә безне. Ачка интегеп беткәннәрдер, бичаралар.* Җ.Тәрҗеманов

**АЛАБУТА** *и. бот.* 1) Алабутачалар семьялыгыннан, чиратлашып урнашкан яфраклары ончыл куник белән капланган үләнчел үсемлек, чүп үлән; *русчасы:* **лебеда.** *Бөтен әйләнә-тирәдә – котырып үскән алабута, кычыткан, әрекмән, шайтан таяклары...* Ә.Еники. *Тигез урыннарда кычыткан, әрем, алабута кебек кыргый үләннәрне күрмәссең.* Т.Галиуллин

2) Шул үләннең орлыгы, бөртеге. *Ярый инде, барына да түзеп, кычыткан ашап, алабута, куак бөресе ашап --- түзик, дидек.* А.Расих. *Кырда эшләгән берничә карчык ураза тотып маташалар. Сәхәргә алабута кушылган арыш онынnan талкан болгаталар да көне буе кырда ачка кибегәләр.* М.Мәһдиев. *Ябыгып, тиресе сөягенә ябышып беткән Тимеркүкне пот ярым алабута онына алыштырдылар.* Г.Ибраһимов

◊ **Алабута елы** Ачлык ел, иген булмаудан, халык икмәккә алабута орлыгы кушып ашаган ел, алабута ашаган ел. *Алабута елны халык кырылып, безнең авыл яртыга гына калды.* Мирас. *1921 ел тарихка алабута елы булып кереп калган*

**АЛАБУТАЧАЛАР** *и. күпл.* Канәферчәләр рәтендәге, себеркәч яки башак чәчәк төркеменә тупланган, вак чәчәкле бер һәм күпьеллык үләнчел һәм куакчыл үсемлекләр семьялыгы; *русчасы*: **маревые.** *Алабутачалар семьялыгыннан булган яшелчәләргә чөгендер һәм шпинат керә.* Яшелчәчелек

**АЛАГАЕМ** *рәв.* 1) Бик, артык, гаять, чамадан тыш. *Һәм алагаем дәү, калын кыптыр туны белән, кысыла-кысыла, ул аралыкка кереп китте.* А.Гыйләҗев. *[Газизов] Алагаем озын буйлы, чыгынкы яңаклы.* А.Тимергалин. *Аларның һәммәсе алагаем зур биштәрләрен, бүселгән төргәк-чемоданнарын, ыгы-зыгы килеп, автобусның багаж бүлегенә тутырды.* Т.Әйди

2) Бар көчкә, бик нык. *Следователь, алагаем кизәнеп, яңак төбенә китереп сукты.* М.Галиев. *Көтү куар вакыт җиткәч, абзарның ишеген ачып җибәрүе була, алагаем ыргылып, әсәрләнгән кара нәрсә Мулланурның баш өстеннән очып чыгып китүе була.* Казан утлары

**АЛАГАЕМГА** *рәв. сөйл. к.* **алагаем**. *Малай кызарынып-бүртенеп карап торды да көлеп торган Хөсәеннең яңагына алагаемга китереп сукты.* А.Гыйләҗев

◊ **Алагаемга алганда (әйткәндә)** Гомумән алып әйткәндә, барысын бергә җыеп тоташ алганда. *Алагаемга алганда, быел авыл советларына сайлау яхшы үтте.* С.Айнагулов

**АЛАГА́Й-БОЛАГАЙ БУЛУ** *ф.* Бар да бер-беренә тискәреләнеп, бозылышкан булу

**АЛАГА́Й-БОЛАГАЙ КИЛҮ** *ф. к.* **алайгай-болагай булу**

**АЛАЙ** I *а.* **1.** 1) Эш-хәлнең рәвешенә, сыйфатына ишарәли торган күрсәтү алмашлыгы; шулай, шушылай. *Ул, өстәл өстенә ятыбрак, астан минем күзләремә карады да: – Алай күңелсезләнеп утырсагыз, апа ачуланыр бит, – диде.* Гали Рәхим. *Ләкин Гөлсәйдә, киңәш-табыш кылгандай сабыр гына: – Алай килешеп бетмәс бит, балалар, – диде.* Ф.Яруллин. *Ләкин Фатыйманың алай уйлап ялгышканлыгы тиз арада беленде.* А.Расих

2) Берәр эш-хәл, күренешкә ишарәләп чагыштыру өчен кулланыла. *Юк, алай түгел, анасы... Бу «Кәрван» чәе торып торсын әле...* Ф.Әмирхан. *Бибинурның: «Синең улыңның алай булуына минем кызым гаеплемени?» – диясе килгән иде дә, күп хәсрәтләр эчкән ананы җәберсетәсе килмәде.* Ф.Яруллин. *Җирле-сулы, иген-тарулы бер төбәктә атларның ачтан үлүе – бары тик урындагы җитәкчеләрнең тавык миле булуыннан гына иде, ләкин ул вакытта алай уйларга ярамый иде.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Ул кадәр, шул дәрәҗәдә. *Минем багалмасы төсле кызым алай егетләр белән йөрмәс.* Г.Камал. *Алай бик күп талкыйсың икән, хәзер без синнән башка җирдән дә урак табарбыз.* М.Гафури. *Киленнең якты чыраен, үзе өчен чын күңелдән борчылуын күргәч, алай каты бәрелергә теле бармады.* Г.Бәширов. *Дөрес, Шәриф үзе ул яктан моңарчы бик алай бирешмәде, тезгенне каты тотып килде.* Мирас

2) Мөмкин булган ике хәлнең, халәтнең һ.б.ның берсен гәүдәләндереп; тигеләй. *Алай уйлады, болай уйлады ---. Ләкин барып сыенырлык ышанычлы бер урынны, бер кешене очрата да, таба да алмады.* К.Тинчурин

**3.** *ы. функ.* Кем беләндер сөйләшкәннән соң нәрсәнедер хәтерләүне, кинәт булган бер хәлгә гаҗәпләнүне белдерә. *[Хәйбүш бабай] Алай икән... Ятимә кыз буласың икән. Авыр шул берүзеңә дөнья көтүләре.* Г.Әпсәләмов. *– Беләсең килсә, мин эшләргә килдем. Менә өтергем, менә чүкечем. – Алай, алай... Эшләргә, диген.* Ф.Яруллин. *Алай... Син дә аңа тәлинкә тота башладыңмыни?* Т.Гыйззәт

◊ **Алаен алай да** Берәүнең китергән дәлиле белән килешмичә, аны кире кагуны аңлата. *Алаен алай да, бу ягы да бар бит әле аның.* Н.Исәнбәт. **Алайга калгач (калса)** Нәрсәдер эшләргә кирәк булгач, шарты булгач, булмый инде ул, мәгънәсендә. *Алайга калгач булмый инде ул, дип, бер якка карап, уң кулын селтәде.* М.Гали. **Алайга китсә (калса)** Киресенчә булса, югыйсә, юкса. **Алайга китү (борылу)** Эш-хәлнең көтелмәгән юнәлеш алуы турында. **Алай гына** 1) Бернинди бәла-казасыз, зарарсыз; 2) Бер дә көч куймыйча; 3) Бернинди максатсыз, гадәттәгечә, уйламыйча гына. **Алай гына да түгел** Шуның өстенә, тагын да, булганына өстәп. *Алай гына да түгел, суның җылылыгын көйләп-үзгәртеп торырга була.* А.Вергазов. *Татар әдипләре әлеге процессларда эчендә яши, алай гына да түгел, аерым мәсьәләләрдә әйдәп баручы ролен үти.* Ә.Закирҗанов. **Алай да** 1) Алда әйтелгән фикер белән килешеп бетмәүне белдереп, каршы фикер, дәлил китергәндә кулланыла; 2) Әмма, шуңа карамастан. *Алай да мин борчылып-дулкынланып йөрдем.* М.Маликова. *Алай да акылга утырмасаң, җир йөзеннән юкка чыкканыңны көт тә тор!* Т.Нәбиуллин. **Алай дисәң (дияр идең)** Алай дип уйлар булсаң; хәлбуки, ләкин. *Алай дисәң, бу малайны, авызына да алмый, дип әйтәләр.* М.Мәһдиев. *– Алай дияр идең, нигә алайса Татьяна Николаевнаның үз улын, үз канын якламый...* С.Баттал

**АЛАЙ** II *и.* 1) *тар.* Гаскәр; команда, гаскәри төркем, полк. *Милләт мәҗлесе исеменнән татар алаена байрак бирелде.* Г.Исхакый. *Рус гаскәрләре берлә, Багдад астында сугыша торган инглиз гаскәре берлә кушылу хәрәкәтендә, аның алаена зур йөк йөкләнелəчәк булды. Шуның өчен Русиянең төрле халыкларыннан тупланган аның алае айлар буе әзерләнде.* Г.Исхакый. *Дала тармы аңа? Хан кызына өйләнде, кул астында бер бөтен алай, диләр.* М.Хәбибуллин

2) Уртак максатлар, карашлар, уртак эшчәнлек нигезендә берләшкән кешеләр төркеме; коллектив. *Сезнең буында композиторларның көчле бер алае бар иде: Җ.Фәйзи, М.Мозаффаров, Заһид Хәбибуллиннар замандаш татарларның күңеленә алтын ачкыч ярата алдылар лабаса!* А.Гыйләҗев

**АЛА́Й-БОЛАЙ** *рәв.* **1.** 1) Бер анда, бер монда; төрле җиргә. *Күл читендә бер малай Карана алай-болай.* Р.Бәшәр

2) Аннан-моннан, тиз-тиз; өстән-өстән генә, бөтен шартын китермичә, нечкәләп тормыйча гына. *Күлмәкне алай-болай киеп, кыска җиңле казакины кия-кия, түргә чыктым.* Г.Исхакый. *Әле без бит бирeдә ике ел эшләргә тиеш һәм, алай-болай гына да түгел, ә бөтен җегәрне, осталыкны салып.* Р.Фәизов

3) Әгәр, әгәр дә мәгәр. *Алай-болай Төлке килсә, тәрәзәдән карый күрмә.* Әкият. *Соң, бабакай, алай-болай нефть*

*фонтаны була калса, газета хәбәрчесе редакциядә утырып калырга тиешмени?* А.Әхмәт. *Шул уңайда, алай-болай мотор туктап калса...* Р.Ибраһимов. *Алай-болай табалмасак җаен, Үзебезгә – актык гранат.* М.Җәлил

4) Бер урынга да, бер җиргә дә, һичбер кая. *Алай-болай керергә уйлама, өйгә туры кайт. Кич, соңга калып, алай-болай чыгып йөрмә*

5) Уйламаганда, көтмәгәндә, кинәт. *Саубуллашып, сәхнә алдына баш иярго килгәндә, алып баручы яшь егетне култыклап өлгерде, мактаныр өченгә түгел, алай-болай сөрлегеп китмәгәем, диде...* К.Кәримов

6) Нәрсә эшләргә, ни дә булса уйларга белмичә. *Алай-болай уйлап өлгергәнче, әйтеп тә бирде*

7) Берәр төрле эшнең башкарылу ихтималын белергә теләгәндә әйтелә. *Арада, аларныкын белмәссең, алай-болай көнен чигермәсеннәр тагы, дип шикләнүчеләр дә юк түгел иде.* Э.Касыймов. *Алай-болай шәһәргә барасыгыз юкмы?*

**2.** *а. мәгъ.* Эш-хәлнең сәбәбенә күрсәтеп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; нидер, нәрсәдер, нәрсәгәдер. *Алай-болай булса, дип, кесәмә биш кадаклы гер тыккан идем.* Ф.Хөсни. *--- чехол кидертелгән ялтыравыклы үткен пычагын алып, итек кунычына шудырды, алай-болай кирәк булса, диптер.* М.Рәфыйков

◊ **Алай-болай булмасын (була күрмәсен)** Бер-бер начар хәл була күрмәсен. **Алай-болай булса (була калса, була калганда)** Бер-бер көтелмәгән аянычлы хәл булган очракта. *Ә алай-болай була калса, туачак бу нарасый кемгә «әти» дип дәшәр соң, кем аны «үчти-үчти» итәр?* Сөембикә. **Алай-болай гына** Аннан да моннан, бик тиз, ашыгып. **Алай-болай иткәләгәнче** Вак-төяк эшләр белән юанганчы, тиз арада. *Әткәй туры барды да [биянең] муенына нуктаны ташлады, алай-болай иткәнче, бурлы биянең башы калын нукта эченә кереп тә өлгерде.* Г.Ибраһимов. *Алар алай-болай иткәнче, кояш чыгып, шактый гына күтәрелгән, инде кыздыра да башлаган иде.* Ә.Салах. **Алай-болай итеп** Ничек кирәк алай, ничек булса да җаен табып. *Алай-болай итеп, көчкә-иллалла үзебезнең авыл урманына чыгып котылдык.* М.Гали. *Көчкә, алай-болай итеп, ялганлап котылдым бит. Югыйсә эш харап иде.* Гали Рәхим

**АЛА́Й БУЛГА́Ч** *рәв. к.* **алайса**. *Алай булгач, болай итәбез: тотабыз да үзләренә барабыз.* Н.Исәнбәт

**АЛАЙСА** *рәв.* **1.** Әгәр алай булса, алай булган очракта; ул чагында (вакытта). *Димәк, сез яралыны озатырга кеше таба алмыйсыз, алайса санитарный поездны көтәргә кала.* Ш.Усманов. *Әлегә чаклы бер көлтә дә җыелмаган, алайса мин бирегә башка бригаданы китерәм.* Ф.Хөсни. *Алайса куркуым бушка чыкты: минем сукбай төсле кыяфәтем аңар артык начар тәэсир итмәгән икән.* Гали Рәхим. *Алайса мин сезгә башка вакытта кереп чыгармын.* Идел

**2.** *кер. сүз* Димәк, шулай итеп. *Алайса, син Фәрит абзый кызы икән!* Н.Гыйматдинова. *Алайса, син бәхетле кеше икән!* В.Нуруллин

**АЛАКАЙ** *и. диал.* 1) Акай күзле кеше. *Я, бу тикле ялагай булыр икән, җенем сөйми шул алакайны.* Ә.Камал

2) *туп.* Сүзендә һәм хәрәкәтендә чама белмәгән, тыйнаксыз, әрсез кеше. *Кая кеше өстенә килеп менәсең, алакай, юньләбрәк кара!*

◊ **Алакай бизәк** Актан кала, нинди дә булса башка төсле җирлеккә төшкән эре-эре ак бизәк. **Алакай күз** Игътибарсызлыктан яки ашыгып йөргәннән аны-моны күрмәгән кешене ачуланганда әйтелә

**АЛАКАЙЛАНУ** *ф. диал.* 1) Башкалар белән санлашмыйча үзенекен эшләү, әрсезләнү, тыйнаксызлану. *Алакайланып, монда нигә килеп кердең әле син?*

2) Әсәрү, нәрсә эшләгәнен дә белештермәү. *Хәмзә (тәмам алакайланып). Ә, ни дисең? Вәли кияү дә китте, дисеңме?* Г.Камал

**АЛАКАНАТ** *и. гади с. иск.* 1) Авылдан шәһәргә килеп эшләүче сезонлы эшче. *[Әхмәт бай фабрикасында] Квалификация соралмаган эштә эшләүчеләрнең күпчелеге – алаканатлар.* К.Тинчурин

2) Күчмә башкорт

**АЛА КАРГА** *и. зоол.* 1) Карга кошлар семьялыгыннан, аралаш кара һәм соры каурыйлы, урта зурлыктагы кош; *русчасы:* **ворона**. *Абзар артына сояк чыкмый башлады. Ала каргалар, саесканнар да андый авылның бакча киртәсенә, абзар түбәсенә кунмый башладылар.* М.Мәһдиев. *Торак пунктларны кара каргадан, ала каргадан, чәүкә, шәһәр карлыгачы һәм сыерчыктан башка күз алдына да китереп булмый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) *күч.* Үзенең кайсы булса да ягы, гадәтләре, тотышы белән башкалардан кискен аерылып торган кеше. *Вильсур гомуми фәлсәфи-әхлакый кагыйдәдән чыгарма, төркемдә ала карга булырга теләмәде. Моннан башка җәмәгать эшендә югары дәрәҗәгә күтәрелеп булмасын ул инде аңлаган иде.* Т.Галиуллин

**АЛАКАЮ** *ф. диал.* Игътибарсызлыктан яки ашыгып йөргәннән анымоны күрмәү; әсәренгән булу. *Аларның да шул сезнеке шикелле күзе-башы алакайган бер асраулары бар.* Г.Камал. *Каравылчы Габбас атның ак күбеккә батып, әсәренеп, алакаеп кайтып керүенә гаҗәпләнә, югыйсә Вениамин абзый малны каулый, куа торган кеше түгел.* В.Нуриев

**Алакаеп кую** Кинәт алакаю

**Алакаеп тору** Әле, хәзер, күз алдында алакайган булу

**Алакая төшү** Бераз алакаю. *Күзләре алакая төшкән*

**АЛА́К-ЙОЛАК** *рәв.* Әле тегендә таба, әле монда таба; бер урында туктамыйча, бер нәрсәдән икенчесенә йөгереп. *Казан каласының иске тимер юл вокзалыннан, алак-йолак каранып, корак-корак йөткереп, кулына иске чемодан тоткан бөкре бер карт килеп чыкты.* З.Мәхмүди

**АЛА́-КОЛА** *с.* 1) Ала; ак һәм бүтән нindидер төсләрдән торган. *Кар катыш ала-кола җир җәйрәп ята.* М.Мәһдиев

2) Төрле төстә булган, чуар. *[Сәйфи] Төсе уңган ала-кола күлмәгенең итәген тарткалап, сөйләнә-сөйләнә, тәмәке төрергә тотынды.* Г.Бәширов. *Бу кеше*

*минем бабай шикеллерәк иде. Бүреге генә башка төрле, ә бишмәте ала-кола ямаулы.* Казан утлары

**АЛА́-КОЛАЛАНУ** *ф.* Ала-кола төскә керү, ала-кола төс алу

**Ала-колалана бару** *к.* **ала-колаланып бару**

**Ала-колалана башлау** Ала-кола төс алганы сизелерлек булу

**Ала-колалана төшү** Тагын да ала-колалану

**Ала-колаланып бару** Аз-азлап, акрынлап, ала-кола төс алу

**Ала-колаланып бетү** Тәмам ала-кола төскә керү, тулысынча ала-колалану. *Яз көне җир өсте ала-колаланып беткән.* Казан утлары

**Ала-колаланып җитү** Тулысынча, бөтенләй ала-колалану

**Ала-колаланып калу** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң ала-колалану. *Ул арада, корбаннарын йоткан аждаһа сыман, буяулары кубудан ала-колаланып калган тимер капка да дөбердәп ябылды.* М.Хәсәнов

**Ала-колаланып тору** Ала-кола төстә булу

**АЛА́-КОЛАЛЫ** *с.* Ала-кола булган. *Ала-колалы кырлар*

**АЛА́-КОЛАЛЫК** *и.* Ала-кола булу. *Бик байлык, --- пөхтәлек белән эшләнгәнлегә күренеп торган бу йортның хәзерге кыяфәте, ала-колалыгы, купкалап, җимерелгәнлеге --- күңелемне каралта, моңландыра, әллә нишләтә иде.* Ф.Әмирхан

**АЛА́К-ШАЛАК** *с.* **1.** 1) Шапшак, җыйнаксыз. *Беркайда да алак-шалак яткан мендәрләр юк, кием-салымнар да таркау ятмый, аларны да вагонка башларына элеп куйганнар.* А.Гыйләҗев. *Шулай да, ул юкта да, Җәүдәт ишегалдына алак-шалак киемнәрдән чыгарга базмый иде.* А.Гыйләҗев

2) Җиренә җиткермичә генә эшләнгән, буталчык, уйлап бетерелмәгән. *Әллә әтисе белән бер-бер хәл чыгып, күршеләре, аны кинәттән хәсрәт дәрьясына салырга теләмичә, шундый алак-шалак телеграмма сукканнармы...* Р.Зәйдулла

3) Үзендә тискәре сыйфатларны күп туплаган. *Әгәр без – шушындый ваемсыз, алак-шалак, хуҗалыксыз, исрафчыл халыклар – нәни утрауларда, әйтик, япон утраулары төсле утрауларда яшәсәк, биш-алты елдан бер-беребезне ашарга тотыныр идек.* А.Гыйләҗев. *Имай – шактый алак-шалак кеше, тракторны игътибар белән карап йөретми.* Х.Камалов

4) *куч.* Җилбәзәк, иләс-миләс, җиңел акыллы. *Дания хатны сирәк язды, күңеле һаман алак-шалак булды.* М.Мәһдиев. *Аның алак-шалак, юлдан язган, бозык хатын икәнлеге йөзенә чыккан!* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Шапшак, җыйнаксыз кеше

2) Булдыксыз, кулыннан эш килми торган, аннан-моннан эшләүче кеше. *Бу бәрәкәтле «гарасатта» инде белемсезләр, теләксезләр, хөрәсән ялкаулары, алак-шалаклар читкә тибәрелеп кала.* М.Галиев. *Әтигә, ямап бир, дигән идем, кул гына селтәде. Җыен алак-шалакка биреп йөрткәч, тишелә инде ул камера, ди.* Р.Бәшәр

3) *куч.* Җилбәзәк, җиңел акыллы кеше. *Бер кешегә таянып булмый, дус дигәнең алак-шалак булып чыга?..* Х.Камалов. *Ә хатының берүзе ике кеше кадәр эшли, дисәм, һич тә ялган катнашмас. Шуның өстенә бик акыллы, карусыз, итагатьле. Алак-шалакны мин бер күз төшерүдән таныйм.* М.Хәсәнов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Җавапсызлык, гамьсезлек күрсәтеп, ваемсыз булып. *Шулай булмый ни: әтиләрең, абыйларың фронтта – ут эчендә булсын да, ничек инде алак-шалак йөрергә мөмкин?* Р.Низами

2) Теләсә ничек, тәртипсез рәвештә. *Ачкычын оясында калдырып, эчкә керде, диванга тотына-тотына мыштырдап чишенде, киемнәрен кул астындагы урындыкка алак-шалак өя барды.* А.Гыйләҗев

**АЛА́К-ШАЛАКЛЫК** *и.* Җилбәзәклек, җиңел акыллылык, иләс-миләслек; гамьсезлек, ваемсызлык. *Иң мөһиме, иң куанычлысы, Хәниянең концертында алак-шалаклык юк, аның репертуарына моңсулык хас.* Р.Батулла

**АЛА́К-ЯЛАК КАРАНУ** *ф.* Як-ягына тиз-тиз карану, тирә-ягына бертуктаусыз шикләнеп карау. *Бәрәкәт, акча түгелме соң бу? Унлык икән. (Алак-ялак каранып, кесәсенә сала).* А.Әхмәт. *Сәхнәдә – эскрипкәче Әбүбәкер. Ул моңлы бер көй уйный, халык тын да алмыйча тыңлый. Шулчак бер тамашачы, алак-ялак карангалап, әле бер кешене, әле икенчесен: – Бу эскрипкәче кем икән ул? Аның социаль чыгышы кем икән? --- дип йөдәтеп бетерә.* Р.Батулла

**АЛАЛАНУ** *ф.* 1) Кар урыны-урыны белән эреп, ала-кола төскә керү. *Кырда кар алаланса, ташу ага башлый*

2) *куч.* Ярсудан, куркудан яки берәр төрле кайгыдан төсе китү. *Ярсудан, Һаҗәр апаның какча чырае алаланды.* Г.Тавлин

**Алалана бару** Торган саен ныграк алалану

**Алалана башлау** Алаланырга тотыну

**Алалана төшү** Беркадәр, бераз алалану

**Алаланып бетү** Бөтенләй, тулысынча алалану

**Алаланып калу** Нинди дә булса хәлдән, сәбәптән ала төскә керү, шундый төс алу

**Алаланып тору** Әле, хәзер ала булып күренү. *Тау битләре алаланып тора*

**АЛАЛЫ́-КОЛАЛЫ** *с. к.* **ала-колалы**. *Ул, капканы ачып җибәрүгә, каршында язгы күбәләкләр шикелле алалы-колалы киемнәргә төренгән хатын-кызны күреп, оялып киткәндәй булып, капканы япмакчы булганда: – Кая качасың, кая качасың? Әссәламегаләйкем! – дигән таныш тавышны ишетеп: – Вәгаләйкемәссәлам!.. Хуш килдегез, Нигъмәтҗан абзый, әйдә, үтегез, Мәфтуха абыстай, әйдәгез, хуш килдегез, әйдә, туры бакчага, бакчага үтегез, – диде.* К.Тинчурин

**АЛАЛЫ́-ТИЛӘЛЕ** *с. сөйл. к.* **ала-колалы**. *Калкулык һәм ызаннар күбесенчә алалы-тиләле булып яталар.* С.Рафиков

**АЛАМА** *с.* **1.** 1) Сәләмә, иске, тузган. *Тәрәзәдән карама, бүрек читең алама.* Җыр. *Ишектә алама киемле берәү күренде.* Казан утлары //

Таушалган, картайган, сәламәтлеге югалган; начар, таркау. *Газын мин үзем керттермәдем. Хәтерем алама, шартлармын, дип курыктым.* Д.Салихов

2) Начар гадәтле, кире сыйфатлары булган, яман, рәтсез. *Сөнгатьләр шикелле алама егет түгел бит син, егетнең асылы.* М.Фәйзи. *– Былтыр да шул [инспектор] килгән иде. Бик алама кеше. Сөйләшми-нитми яза да яза. Гаеп табарга гына тора! – дип, безне дә куркытты.* Җ.Фәйзи. *Алама кешеләргә катнашып, тирә-яктагыларга күпме зыян салдык.* Идел

3) Начар, әшәке; ямьсез, күңелсез. *Соң белә идеме Тамара Сергеевна үзе хакында йөргән шул алама гайбәтне?* Ә.Еники. *Әти, ачуланган вакытларында, әнигә ачуланып, аны тиргәп ташласа да, әнигә кул сузганын күргәнем булмады. Күп гаиләләрдә була торган андый алама гадәт безнең өйгә кермәде.* М.Гафури. *Ноябрьнең бересе – яңгырлы, бозлы алама бер төн иде.* М.Мәһдиев

4) Түбән сыйфатлы, куелган таләпләргә туры килми торган, начар. *Һәрхәлдә ул, алама шигырь язуга караганда, матур итеп кубыз уйнауны артыграк күрә.* Ә.Еники

5) Бетәшкән, арык. *Моның каршына алама гына бер биягә атланган кеше килеп чыкты, ди.* Г.Гыйльманов

6) Җыйнаксыз, оешмаган, таркау. *– Синең кислотаң чуртыма киракмени, кем алсын аны, үзең алама син, әйберне кая куйганыңны белмисең, – дип, әтисе аны сүккән иде.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Начар, яман гадәтле кеше. *Биктимер бабайның угыллары арасында бик аламалары булганга, ул үз исеменең җир йөзеннән бөтенләйгә югалуыннан курка башлады.* К.Тинчурин. *Менә теге егет аламасы, артына борылып, ялына-ялына, утырырга кыстар, синең кебек кызны утыртып йөрү – үзе зур бәхет,дияр кебек тоелды.* Казан утлары

2) Иске-москы, сәләмә чүпрәк-чапрак, алам-салам кием

3) *күч. кимс.* Предмет яки зат исеменнән соң килеп, аның начар булуын белдерә; нәрсәнеңдер шәп булмаган төре, кәмәше. *Ул кое янындагы зур тагарактан кепка аламасы белән су чумырып алып килгән арада, малай тракторын төзәтеп маташты.* Г.Гобәй. *Аннан-моннан ерткалап, әйтерсең исерек кул белән чәчелгән, шундый тигезсез чыккан дүрт дисәтинә арыш аламасы ята.* Г.Ибраһимов

**3.** *рәв. мәгъ.* Теләсә ничек, тәртипсез рәвештә, аннан-моннан. *Бала чакта, кеше башы белән песи башын --- алама гына сызгалап маташуны исәпләмәгәндә, мин рәсем ясау белән шөгыльләнмәдем дә һәм чынлап мавыкмадым да.* Ә.Еники

**АЛАМАЛАНУ** *ф.* 1) Алама хәлгә килү, тузып-ертылып, сәләмәгә әйләнү. *Күрсәң, син аны танымыйсың. Ябыкты. Өс-башы аламаланды.* М.Юныс

2) *диал.* Начарлану, начар якка үзгәрү. *[Мәрхәбә әби:] Хәтер аламаланды. Атагызның исемен оныттым. Гафу итегез. [Нурфатих:] Зыян юк. Исемне беләсез бит. Исем белән генә сөйләшегез, апа.* Д.Салихов. *Теге чакта мөнәсәбәтләр тәмсезләнеп, аламаланып очланды, күңелдә борчый торган юшкын калдырган иде.* Х.Камалов

3) *диал.* Җыйнаксызга әйләнү, таркаулану

**Аламалана бару** Көннән-көн ныграк аламалану

**Аламалана башлау** Аламаланырга керешү. *Шуңа күрә дә Гөлзиләнең әтисе ерак командировкалардан баш тартып килде дә, хатынының хәле аламалана башлагач, бөтенләй эшен ташлады.* М.Кәбиров

**Аламалана төшү** Беркадәр, бераз аламалану

**Аламаланып алу** Берара, кыска вакыт эчендә аламалану

**Аламаланып бетү** Тәмам алама хәлгә килү, бөтенләй аламалану

**Аламаланып житү** Бөтенләй, тулысынча аламалану

**Аламаланып калу** Берәр хәлдән (күренештән) алама хәлгә килү

**Аламаланып китү** Берәр хәлдән, сәбәптән соң, соңгы вакытта аламалану

**Аламаланып тору** Аламаланган хәлдә булу; соңгы вакытта аламалану. *Аларның тормышы аламаланып тора*

**АЛАМАЛЫК** *и.* 1) Алама булу; сәләмәлек, тузганлык. *Урын-җиренең аламалыгы күзгә ташлана*

2) Әшәкелек, бозыклык (кешенең холкы-гадәте турында). *Тормыштан алынган кире сыйфатлар канны кайната, ярсыта, ургыта. Боларның барысы да Галимҗанның кырыс йөзенә аламалыкка каршы нәфрәт ташкыны булып чыкты.* С.Поварисов

3) *күч.* Начар, алама эш, начарлык. *Дәрдемәнд, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Ф.Кәрими, Г.Исхакыйлар тудырган нәфис әдәбият урынына тупаслык, гайбәт, сүгенү, аламалык, шапшаклык кереп тула.* Рәмзи Вәлиев. *Яхшылыкка җавап бирми калу – аламалык.* Ә.Баян

**АЛАМА́-САЛАМА** *с.* 1) Иске, тузган, сәләмәләнеп беткән

2) Таркау, таралган, аерылган хәлдәге; корама. *Кышкы алама-салама болытлар калмагач, күк йөзе биегәйде.* Ф.Яруллин

**АЛАМАЧЫ** *и.* Чүпрәк-чапрак җыючы, иске-москычы, чүпрәкче. *Аламачы чүпрәк теләнүдән исәпләми иде туктарга.* З.Мансуров. *Асламчы-аламачы килгән. Арбасында – хуш исле, аллыгөлле әйберләр. Әй, аламачы! Оялады учка сандугачы, һәр малайда – таш сыбызгы.* М.Галиев

**АЛАМА́-ШАЛАМА** *с. к.* **алама-салама**. *Тәмләп ашарга керешәбез дигәндә генә, алама-шалама киемле бишалты кеше аларны урап алды: «Солдат, солдат, сатлык шпигың юкмы?»* А.Гыйләҗев

**АЛА́ МИЛӘҮШӘ** *и. бот.* Миләүшәчәләр семьялыгыннан, һәрбер чәчәге өч төстә булган, болыннарда, урман буйларында үсә торган берьеллык үсемлек; өч төсле миләүшә; елан күз; *русчасы*: **анютины глазки**. *Ала миләүшә июльдән августка кадәр чәчәк ата.* Ботаника

**АЛА́М-САЛАМ** *җый. и.* **1.** Иске-москы, сәләмә нәрсәләр. *Тик авылда бар кеше алам-саламнар белән йөргәндә, мондый кәчтүм бик ошап бетмәс, улым.* Ф.Яруллин. *Ул күз алдына килеп басу белән, Сәхия гүзәл бер кызга әйләнә: өстендәге барлык алам-*

*саламнар шуып төшә, тел үзе белгән иң матур сүзләрне кабатлый*... Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* 1) Алама, иске, сәләмә. *Күрендем үз-үземә бик зур кеби; Алам-салам ак якалар куелмаса, Була инде гүяки бер кимчелек кеби.* М.Гафури

2) Юк-бар, мәгънәсез, сафсата. *Андый алам-салам сүзне сөйләмәскә иде*

**АЛАН** *и.* 1) Урманда ачык җир, агачсыз урын, ачыклык, аклан. *Ул өй тау итәгеннән бәреп чыккан чишмә буенда, Ык ярында, матур аланда, юкә, нарат урманы эчендә урнашкан булырга мөмкин.* Т.Галиуллин. *Вак кына аланнарда икешәр, өчәр булып моңаеп утырган печән кибәннәре.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Нинди дә булса бер өлкәгә караган урын, мәйдан. *Миңа инде сәнгать аланы бушап та калган сыман тоела башлаган иде.* Ф.Урманче. *Кеше җанының һәркөн яңа катламнарын ача бару, анда башкалар күрмәгән көяшлы аланнар күрү, шул аланнарга керергә нәкъ менә үзенә хокук бирелү белән бәхетле иде Сәхия.* Ф.Яруллин

**АЛА́Н-БОЛАН КИЛҮ** *ф. к.* **алан-йолан карану**

**АЛА́Н-ЙОЛАН** *рәв. к.* **алак-йолак.** *[Таһир] Бераздан башы кабат күтәрелде, алан-йолан карангалап алды, аннан соң, кыяр-кыймас кына, кыз утырган өстәлгә килеп таянды.* М.Кәбиров

**АЛА́Н-ЙОЛАН КАРАНУ** *ф.* Хәвеф-хәтердән сакланып, як-ягына ялт-йолт каранып бару (йөрү). *Ерак Көнчыгышка баргач, өй түбәсенә менеп, Саламторхан кебек, алан-йолан каранып утыра алмыйсың.* Ф.Шәфигуллин

**АЛАНЛЫК** *и.* Урман эчендәге ачыклык, алан. *Менә җиләк җыярга килгәч, карурман эченә кереп китәр алдыннан туктап ял итә --- торган кечкенә аланлык.* Г.Бәширов. *Шәһәрдә түгел, конспирация максатларында, Агыйдел аръягындагы әрәмәлектә урнашкан нәни генә аланлыкта очраштылар.* Р.Мөхәммәдиев. *Менә шактый иркен аланлык янынн ан үтәбез. Аланлыкның түрендә карт имәнлек башлана.* Ә.Еники

**АЛАП** I *и.* **1.** 1) Ашлык, кибәк ташу яки бөртек, он саклау өчен, кабыктан эшләнгән савыт, зур әрҗә. *[Шәйхелләрнең] Ишкәк, иштергән арканнары, ясаткан --- алап, чуман чиләкләре --- зур базарларга таба юл алды.* Г.Ибраһимов

2) Тарантасның чыбыктан үрелгән әрҗәсе

**2.** *с. мәгъ. күч.* Артык зур, бик киң. *Корсагың – киң алап, көн күрдең син алдалап. Ашау-эчү, кәеф кору, кәеф кору – Байбикәнең уйлары, уйлары.* Г.Камал

◊ **Алап (кадәр) авыз** *кимс.* 1) Бик зур авыз. *Ат дагалаганда бака ботын кыстырган кебек, алап кадәр авызын тутырып сөйләнгән була, тәмле сүзнең ямен җибәрә.* А.Гыйләҗев; 2) Сер саклый белми торган, күп сөйләүчән кеше. *Яклаучысы да табылган, бикә. Алап авыз, әлеге Батырҗан.* Т.Гыйззәт. **Алап аяк** *ким.* Әйберләргә бәрелеп-сугылып йөри торган, ипсез, зур аяклы кеше. **Алап сугып, ат өркетү** Юктан гына кинәт зур тавыш кубарып, юк хәтәрне бар итеп күрсәтеп, кешене куркыту; ипле барган эшнең тәртибен югалту

**АЛАП** II *и. к.* **алып**. *Китмәсәм, мине яргыччы кылый Җәгүргә кияүгә бирәләр иде. Исерек алапка. Бер хатынын чабата калыбы белән бәреп үтерде инде ул.* А.Гыйләҗев

**АЛАПА** *и. гар.* 1) *тар.* Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен яугиргә бирелә торган мал, ганимәт. *Алапасы – олы, кабыргасы – коры.* Мәкаль

2) *диал.* Сабантуй батырына бирелә торган бүләк. *«Алапа» дип, татар теленең кайбер шивәләрендә Сабантуй батырына тигән бүләкне атыйлар.* С.Зыялы

3) *күч.* Зур, таза гәүдәле, озын буйлы кеше

◊ **Алапа күтәрү** Мал-ганимәт бүлү; бүлешү гаугасы; шау-шу, гауга күтәрү

**АЛАПАЙ** 1) *с.* Килешсез, төпкә таба җәенке, килбәтсез олы. *Әле менә өченче ел гына, алапай олы мичне сүтеп, заманча җыйнаклап чыгарттык.* С.Рафиков

2) Игътибарсыз. *Алапай кеше*

◊ **Алапай белән шалапай** *кимс.* Әзерне алырга, алдап-йолдап көн итәргә өйрәнгән, бер-беренә тагылган ике юньсез. *Шулай да алапай белән шалапай кебек карашып торуның сукыр бер тиенлек тә фәтвасы юк.* С.Поварисов

**АЛАПА́Й-ШАЛАПАЙ** *с.* **1.** *сөйл.* Җыйнаксыз, шапшак, пычрак. *Алапай-шалапай йөрүчеләрне җенем сөйми, дип ачуланып калды әбисе.* Мәдәни җомга

**2.** *и. мәгъ.* Эшсез интегеп йөрүче, җилкуар, тәртипсез, җиңел акыллы кешеләргә карата әйтелә. *Бетмәс монда җыен алапай-шалапай.* М.Мәһдиев

**АЛА́ПТАЙ** *с. сөйл.* Бик зур (*төрле предметлар яисә кеше әгъзалары – аяк, куллар һ.б. турында*). *Егет алаптай аягы белән бер генә типте, агач шунда ук җиргә ауды.* Әкият

**АЛАР** *а.* 1) Сөйләмдә катнашмый торган берничә затны белдергән күплек сандагы III зат алмашлыгы. *Китә башлады бездән инде кошлар; Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.* Г.Тукай. *Рәсемнәрдә күбрәк Идел манзаралары, таулар, агачлар иде. Аларны күрү минем күңелемдә әллә ниләр уятты.* Гали Рәхим. *Өч тәүлек буенча ул хикәясендәге каһарманнар белән сөйләшеп, аларның тормышлары белән яшәп, алар төсле үк шатланды, газапланды. Аларның йөрәк кайгыларын үз йөрәгендә кайнатып, кәгазь өстенә төшерде.* К.Тинчурин

2) Күз алдындагы зат һәм предметларга яки сөйләмдә алдан билгеле төшенчәләргә төбәп күрсәтү функциясендә кулланыла торган күрсәтү алмашлыгы. *Әнә алар – түбән оч малайлары. Үз халкының ямьнәренә, гадәтйолаларына хөрмәт һәм мәхәббәт нык аларда [авыл халкында].* М.Фәйзи

**АЛАРНЫКЫ** *а.* 1) Алар милкендә, аларга караган булуны белдергән тартым алмашлыгы. *Аларның магазиннары аерым, мәктәпләре, клублары аерым, хәтта икмәк заводы да, электр станциясе дә – барысы да аерым, барысы да аларныкы.* Н.Фәттах

2) Алар әйткән. *Аларныкы закун... Ходай хәерле кылсын...* Р.Батулла

◊ **Аларныкын белмәссең** Аларны аңлавы кыен

**АЛАРТУ** I *ф.* Ала төскә кертү

**АЛАРТУ** II *ф. сөйл.* Күзнең агы белән усал итеп карау, акаеп карау. *Кичә әнә бозау куып барганда, тыкрыктан, күзләрен алартып, ике эт ыргып килеп чыкты*. Г.Якупова. *Тик карт анда чыга алмый, ишекнең теге ягында, күзләрен алартып-акайтып, ата шайтан-иблис сакта тора*. Мирас. *Сөендек тә катып калды, күзләрен алартып, тик карап торды.* Мирас

**Аларта төшү** Бераз аларту

**Алартып бетерү** Бөтенләй аларту

**Алартып җибәрү** Кинәт аларту

**Алартып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле аларту. *Шунда Якуп агай, тегеңә борылып, бераз күзен алартып торды да кисәк бәрде: «Дөнья наданы бит син! Бар, күземнән югал!»* М.Мәһдиев

**Алартып яту** Әле, хәзерге вакытта аларткан булу. *Күзен алартып яткан анасы янына килеп, аның баш астына мендәр салды.* М.Мәһдиев

**АЛАРУ** I *ф.* Ала төскә керү, алага әйләнү, алалану. *Болытлар сәер итә, анда алара, Алар артында зур таулар агара*. Г.Тукай

**Алара бару** Торган саен ныграк алару

**Алара башлау** Аларырга тотыну. *Март урталары җиткәч, карлар алара башлады*

**Алара төшү** Тагын да алару; бераз алару

**Аларып китү** Бераз, берникадәр алару

**Аларып тору** Әле, хәзер аларган булу

**Аларып чыгу** Кинәт аларган хәлгә килү

**АЛАРУ** II *ф.* Куркыныч кыяфәткә керү, ямьсез итеп акаеп карау. *Чынлап та, хәзер бу кешенең күзләре аларган, йөзе агарган, үзе соң дәрәҗәдә куркыныч бер кыяфәткә кергән иде*. М.Гафури. *Акчаны күрүгә, хатынның күзләре алардлы, төшемме-өнемме, дип, кире чигенде, шулай да тиз генә электерде дә, нинди гөнаһысы өчендер, миннән гафу үтенә башлады*. Г.Ибраһимов

**Алара бару** Торган саен ныграк алару

**Алара башлау** Аларырга тотыну

**Алара төшү** Тагын да алару; бераз алару

**Аларып китү** Бераз, берникадәр алару. *Әнисенең төсе үзгәрде, аның күзләре аларып киткәндәй булды*. А.Хәлим. *– Ә мин? – дип авызын ачты ак башлы Капитан, йөзе агарып, күзләре аларып китте*. Р.Камал

**Аларып тору** Әле, хәзер аларган хәлдә булу

**Аларып чыгу** Кинәт аларган хәлгә килү. *Бу сүзләрдән атаманның күзләре аларып чыкты, мыегы кабарды, кулы кылычына үрелде*. Ф.Бәйрәмова

**АЛА́РЧА** *рәв.* Алар гадәтенчә, аларга хас булганча, алар әйткәнчә. *Ни өчен барысы да гел аларча гына, берсе дә безнеңчә түгел?* Г.Шәрипова

**АЛА́-ТИЛӘ** *с.* Ала-кола, ак һәм башка төсләрдән торган; чуар, таплы. *Бер көн эчендә басу ала-тилә булып калды.* М.Мәһдиев. *Бер кар явып, бер эретеп торганга, җир өстенә ала-тилә ямаулыклар салынды.* С.Рафиков

**АЛА́-ТИЛӘЛӘНҮ** *ф. сөйл. к.* **ала-колалану**

**АЛА́-ТИЛӘЛЕ** *с. сөйл. к.* **ала-тилә**

**АЛАЧА** I *и. этн.* **1.** Гадәттә ак яки кызыл төсләрдән буй-буй сугылган киндер. *Ашъяулыклар, тастымаллар, чаршаулар гадәттә алачадан була.* Ф.Вәлиев

**2.** *с. мәгъ.* Шундый киндерләрдән тегелгән. *Сөләйман, һәркөн кичке аштан соң, Зәйтүнәләрнең алача чаршау белән корылган почмакларында Зәйтүнәне --- һәм бер эшченең ике малаен укытуында дәвам итә.* К.Тинчурин. *Алача ыштанны бабайлар кия.* Ш.Галиев. *Алача күлмәк, өр-яңа ак чабата кигән Ипис түти – Сатыйның әнисе --- малайны сәерсенеп күзәтте.* А.Гыйләҗев

**АЛАЧА** II *и. к.* **әлүчә**. *Тәүге кабат бирегә аяк баскан көнне, иң беренче кабат, мин шул алачага килеп кагылган идем. --- ул үзенең очлы энәләре белән кулларымны чәнчеде.* Казан утлары

**АЛАЧАК** *и.* Биреп торучыга кире кайтару шарты белән, вакытлыча алынган әйбер яки акча; бурыч. *Ала каргада алачагың булсын.* Мәкаль. *Алачак кичексә, бурычка бирүче аякланыр.* Мәкаль. *Алачак алынгач яки бирәчәк түләнгәч, бу кенәгәдә язылган җирне Әхмәтсафа агай яисә приказчик Тимергали зәңгәр карандаш илә аркылыторкылы сызгалап, бозып куялар.* Ш.Мөхәммәдев

**АЛА́-ЧОЛА** *с.* **1.** *сир. к.* **ала-кола**

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Чак кына, тонык, томанлы. *Ала-чола күренү*

2) *күч.* Өстән-өстән генә, аз-маз, үтеп барышлый гына, ашык-пошык. *Ала-чола караштыру*

3) *күч.* Өзек-төтек, чак кына. *Ала-чола гына ишетелү*

**АЛАЧЫК** *и.* 1) Төрле хуҗалык эшләре өчен кабык, такта, калай һ.б. материаллардан оештырылган корылма. *Әмир, алачыгын да бикләп тормыйча, урман аша күрше авылга йөгерде.* А.Хәсәнов. *Хөснимәрдән белән Мәхмүдбәк егетне ипләп кенә күтәреп, алачыгына алып кереп, җәйлап кына урынга салдылар.* Р.Сибай

2) *иск.* Җәй айларында вакытлыча яшәп тору өчен көйләнгән куыш, шалаш. *Алачыкта бурсык ите ашап тик ятабыз.* Ә.Айдар. *Исхак үзенең ишле гаиләсе белән сәүдәгәр Дәүләтшинның тол хатынының йортына кыйгач яктагы җимерелә язган алачыкта тора иде.* Г.Шәрипова. *Ишегалдында балчык белән сылаган читән алачыгы һәм салам япкан читән абзары бар.* Ә.Еники

3) Ишегалдындагы махсус аерым каралты, җәйге кухня

4) *диал.* Мунча алды, мунча алды корылмасы

**АЛАША** *и.* 1) Печтерелгән айгыр. *Алаша юлны үзе белә.* Әйтем. *Җизнинең күк айгырын төпкә, Госманнарның кара туры алашаларын прәшкәгә җигеп, пар ат булып киттек тә бардык.* Ф.Хөсни. *Җиңелчә шәп йөрүе белән даны чыккан кара туры алаша --- бер дә алай тыртыр юыртмый, җәй белән, әкрен генә атлый бирә.* Ф.Хөсни. *Кара алашаны ак күбеккә батырып, печәнчеләр янына килеп туктаганда, төшке аш вакыты җиткән иде инде.* Мирас

2) Эш аты

3) *күч. гади сөйл.* Карусыз һәм күп эшли торган, күндәм кеше

◊ **Алаша ирен** Салпы ирен. **Алашасы колынлау** Бәхете алга китү, көтмә-

гәндә, сәбәпсез, малы ишәю, уйламаганда баеп китү. *Шуннан соң алашасы колынлады Галиәкбәрнең.* Ш.Мөхәммәдев

**«А»ЛАШТЫРУ** *ф. лингв.* Басымсыз иҗекләрдә «о» авазы урынына «а» әйтү

**«А»лаштыра төшү** Бераз «а»лаштыру

**АЛӘТ** *и. гар. иск.* 1) Корал. *Сугышканда, хәзер ике төрле аләт белән сугышалар.* Г.Газиз. *--- әмире Бохараның өч чакрымнан күрсәтә торган аләте бар, диләр иде.* Г.Исхакый

2) Чара, әмәл. *Ләкин бер мәҗлестә әйткән идең ки, шәех булган кемсәнәгә дүрт аләт кирәк. Әүвәл – халь кирәк. Икенче – каль кирәк. Өченче – саль кирәк. Дүртенче – мал кирәк. Әмма боларның һичберсе миндә юк.* К.Насыйри

**АЛБАКЧА** *и.* Өйнең алгы, урам ягында киртәләп алынган кечкенә бакча. *Албакча артына поскан Хәсәнша Айдаш карт янына йөгереп килде.* Р.Батулла. *– Кара инде бу зиһенне! – дип үзалдына мыгырдана-мыгырдана, коймалар, албакчалар буйлап Түбәночка очты гына Нурҗи.* Җ.Юныс. *Ниһаять, рәшәткәле албакчасы, челтәр түбәле капкасы, --- булган алты почмаклы йорт каршына килеп туктадылар.* Р.Низами

**АЛБАН** *и.* Сөнни мөселман динендәге, Албаниядә яшәүче төп халык (үзатамалары – *шкиптар*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Ул албан (тарихи Кавказ албаннарының хәзерге албаннар белән берниНди бәйләнеше юк) епископ Исраэл сүзләренә таяна.* Г.Дәүләтшин. *Аны кем, кайсы композитор чыгарган? Үзе татарча, үзе бераз гына албан халкы көйләрен дә хәтерләтә кебек.* Р.Вәли

**АЛБА́НИЯЛЕ** *и.* 1) Албаниядә яшәүче төп халык һәм аның бер кешесе

2) Чыгышы белән Албаниядән булган, шуннан күчеп килгән. *Мәчетләрнең иң данлыклысы – Мөхәммәт Гали мәчете. Мөхәммәт Гали – албанияле мәмлүк, бу мәчетне төзегән бөтен осталарны мәчет ачылган көнне кунак иткән...* М.Мәһдиев

**АЛБА́НЧА** *рәв.* Албан телендә; албаннар кебек. *Албанча сөйләшергә өйрәнү*

**АЛБАСТЫ** *и.* 1) *миф.* Халык ышануларында: йоклаганда, кешенең күкрәгенә басып яисә буып газаплый торган явыз рухларның берсе. *Албасты көчсезләрне баса.* Мәкаль. *[Урманында] Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр.* Г.Тукай. *Әллә нинди кабахәт төшләр күрде, албасты, Ширин бабайлар, юха еланнар, шайтаннар белән булашты, шабыр тиргә батып, куркып уяна торган булып китте.* Т.Галиуллин. *Кеше яшәми торган йортларда, ташландык җирләрдә, кырларда, чокыр буйларында яшәүче кара көчләргә, явыз рухларга Албасты дип исем биргәннәр.* Татар мифлары

2) *күч.* Буй-гәүдәсенә килешми торган яки гадәттән тыш зур кием-салым киеп йөрүче, таркау, килбәтсез гәүдәле кеше. *Фатыйманың эчендә нәфрәт утлары дөрли иде: «Ничек кенә итеп шул албастыны дөмектерим икән?»* А.Расих

3) *күч.* Артык зур, килбәтсез нәрсә. *– Соң ничек итеп ышанырга була инде, Солтан абый? – диде Шмит, әрнеп. – Мондый албастыны [эскертне] ничек тарттырмак кирәк!* А.Расих

◊ **Албасты басу** Йоклаганда, авыр төш күреп саташу, бастырылу. **Албасты пәрие** Төсе-буе, кыяфәте, кием-салымы кеше куркытырлык дәрәҗәдә ямьсез зат

**АЛГА** *рәв.* **1.** Ал якка таба, хәрәкәт итү юнәлешендә, үзең караган юнәлештә. *--- алар бер-бер артлы алга элдерттеләр.* Р.Кәрами. *Ул, ни эшләргә белмичә, арткамы, алгамы атларга аптыраган минутта, әллә кайдан шунда бер күләгә ясалды.* Г.Ибраһимов. *Урманов алга ыргылды һәм, яңа эленгән стена газетасын күреп, кинәт туктап калды.* Г.Әпсәләмов

**2.** *ы. мәгъ.* Эшкә, көрәшкә өндәү, чакыру авазы буларак әйтелә. *Безнең бүтән юлыбыз юк. Безгә кичегергә ярамый. Һәр минут кадерле. Алга, иптәшләр!* Г.Әпсәләмов. *– Шофёр, тагын алга! --- Без – Сикертән тау башында.* М.Мәһдиев

◊ **Алга бару** 1) Шәхес, милләт яки ил, халыкның белем-сәнгать, техникада, байлык, культурада алдынгылыкка ирешүе; тәрәккыят, прогресс. *Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!* Г.Тукай; 2) Яхшы итеп, булсынга эшләү; 3) Сәламәтләнә башлау, яхшыра бару (авыру кешенең хәле турында). **Алга җибәрү** Үстерү, яхшырту (мәс., *тормышны, эшне* һ.б.). **Алга карау** Киләчәк белән яшәү, киләчәкне күздә тотып эш итү. **Алга китеп** 1) Алдан, эзлеклелек сакламыйча; 2) Билгеләнгән вакыттан алда. **Алга киткән** Югары үсешкә ирешкән, прогрессив. **Алга китү** 1) Ашыгу, кызурак йөрү; 2) *к.* **алга бару**. **Алга сөрү** 1) Бер эшне мәгъкуль күрү, куәтләү, алга уздыру. *Ул, татар балалар театрын булдырырга күптән вакыт, дигән фикерне алга сөрде.* А.Әхмәт; 2) Алга җибәрергә, үстерергә тырышу. **Алга таба** Моннан соң, киләчәктә. *Алга таба ничек яшәргә ---?* Ф.Бәйрәмова

**АЛГА́Й-САЛГАЙ** *рәв. диал.* Эленке-салынкы, ничек җитте шулай, тәртипсез

**АЛГАРУ** *ф. сир.* 1) Нинди дә булса бер өлкәдә (эштә, мәдәниятгә һ.б.да) алга китү

2) Эшне, тормышны, халыкны алга үстерү, алга җибәрү. *Ләкин һөҗүм дәвам итте һаман, яшь батырның данын алгарып.* Ш.Маннур

**АЛГАРЫШ** *и.* Алга барыш, алга китеш; тәрәккыят; прогресс, үсеш. *Алгарыш – тәрәккыят үткәннәрне себереп ташлау юлы белән генә бармаска тиеш.* Казан утлары. *Татар теленең дәүләт теле буларак алгарышы, аның функциональ мөмкинлекләре фәнни стильнең үсеш-үзгәрешендә аеруча нык чагыла.* Мәдәни җомга. *Ул [Сергей Лесков] китабында тормышны алгарышка илткән бөек ачышлар һәм аларның авторлары турында тәфсилләп яза.* Мәдәни җомга

**АЛГАСАК** *с. к.* **алгысак**

**А́ЛГЕБРА** *и. лат.< гар.* Математикада: сан берәмлекләренең нинди булуына карамастан, хәрефләр белән билгеләнгән зурлыкларның үзлекләрен өйрәнү бүлеге. *Тик менә алгебраны ничек «очлап» чыгарга? Шушы фәннең исемен ишетеп бер калтыраса, укытучысы Сәлим Хәйдәревичтан ике шүрли иде ул.* Р.Галиуллин

**АЛГЕБРА́ИК** *с.* Алгебра ысуллары белән чишелә торган. *Бирелгән системаны гадәттәгечә, алгебраик кушу юлын кулланып чишик.* Югары математика нигезләре. *Чылбырның төенендә очрашучы агымнарның алгебраик суммасы нульгә тигез.* Физика

**АЛГОРИТМ** *и. лат. мат.* 1) Мәсьәлә чишү, исәпләү барышында кулланыла торган гамәлләр, операцияләр эзлеклелеге. *Алгоритм, алгебра – Әлхәрәзми атамасыннан.* Ватаным Татарстан

2) *информ.* Электрон исәпләү машиналарында: кирәкле мәгълүматны табарга, ачыкларга ярдәм итү өчен махсус уйлап табылган программа. *Юлы табылыр сыман тоелса, «Бэйсик» (яки «Паскаль») дип атала торган махсус алгоритм телендә чытырмандай катлаулы бер әсәр язарга утырасың...* З.Мифтахов. *Борынгы телне заман теленә яраштыру, тәңгәлләштерү өчен махсус алгоритм таләп ителә.* Кызыл таң

3) *куч.* Ниндидер бер эшчәнлекнең гомуми схемасы. «*Алгоритм» дигәндә, ничек яшәргә икәне алдан билгеле түгел, ләкин яңалыклар ачу юлы бирелгән.* Татар әдипләре. *Алдан әзерләнгән алгоритм юк.* Ялкын

**АЛГЫ** *с.* **1**. 1) Ал яктагы, түр; алдагы, алда торган; *киресе:* **арткы.** *Алгы сафлар хәзрәт белән бергә елыйлар, --- инде куркыныч ерагайды дигәндә, бер хәлдә өйләренә кайталар.* Г.Ибраһимов. *--- Мәһүб карчык, алгы рәттә утыруына карамастан, җырның сүзләрен аңламаган.* М.Мәһдиев. *Түшәмдәге унлы лампа яктысында өйнең алгы ягы тагын да бәләкәйләнеп күренде.* Мирас

2) Алгы өлештә урнашкан, ал өлешне билгеләгән. *Алгы аяклары белән җир тырнап, муен өстендәге йоннарын кабартып, очлы мөгезләрен аңарга төбәп куйган бу иләмсез һәм шыксыз тәкәнең кан сауган күзләреннән генә дә куркып качарлык...* Р.Мөхәммәдиев. *Юк, малай, булмас аннан да, алгы саны биек аның, алгы аяклары озын булган атның узганын син һичкайда күрмәссең.* М.Гали

3) Алда яшәячәк, моннан соң яши торган (кеше, буын һ.б. турында). *Әкият түгел, болар – чынбарлык бит: Безнең буын – кеше язмышы. Алгы буыннарга берүк килмәсә иде Тарихларның андый ялгышы.* В.Галиев

4) Хәзергедән соң буласы, алда булачак, алдагы киләчәк һ.б. *Алгы көндәге яшәеш белән кызыксынучы әлеге шәхесләрне даими борчыган сораулар бар: – Кешелек кая бара?* Р.Сафин

**2.** *рәв. мәгъ. диал.* Элек, элегрәк, әүвәл. *Алгы суны инештән эчә идек*

◊ **Алгы итәгеңне бала бассын, арт итәгеңне мал бассын** Балаларың күп булсын, терлек-туарың нык үрчесен, дигән теләкне белдерә

**АЛГЫР** *с.* 1) Зирәк, үткен. *Үзе сүзгә дә бик алгыр, бик чапак.* Г.Ибраһимов

2) Җитез, өлгер. *Чабышта аллыартлы килгән алгыр өч атны чалдылар. Янып, җиргә сузылып ятканнары өчендер инде.* Ә.Гаффар

3) Үткен, булдыклы, үз дигәнен булдыручы. *Тиз арада бу үсмер, үзенең табигый сәләте, хезмәт сөючәнлеге белән, сәүдәгәрнең алгыр ярдәмчесенә әверелә.* Х.Бәдыгый

**АЛГЫРЛЫК** *и.* 1) Зирәклек, үткенлек; җитезлек, өлгерлек

2) Булдыклылык, үз дигәнен булдыра алучанлык

**АЛГЫСАК** *с.* 1) Тиктормас, тынгысыз. *Боларының күңеле алгысак, чөнки тормышлары тум-түгәрәк ук түгел.* М.Маликова

2) Ашкынулы, кайнар дәртле. *Июль кичендә шундый алгысак күңелле ике егет остаханәдә дуслары белән очрашып, сөйләшеп утырдылар.* Казан утлары

**АЛГЫ́-САЛГЫ** *рәв. к.* **алкы-салкы**. *Ударниклар шул! Синең шикелле алгы-салгы гомер уздырып, чабата туздырып йөрмибез.* Т.Гыйззәт

**АЛГЫСА́У** *ф. к.* **алгысу**. *Үзен бик иркен, тыныч тота, олы юл алдыннан алгысауның әсәре дә анда сизелми.* М.Маликова

**АЛГЫСУ** *ф.* 1) Ашкыну, җилкенү, туктаусыз омтылу. *Ә юк, алгысый, барыбер нидер җитмәгән шикелле. Кинәт кенә аңлап алдык – арыш ипие.* Р.Кәрами. *Зуфирәнең күңеле нечкәргән чак, билгесез юлга кузгалганда, гомумән, күңел алгысый.* М.Маликова. *Без килгәндә, Разия апаның бик тә борчылган, алгысыган чагы иде.* Ватаным Татарстан

2) Нәрсәдер эшләргә теләк уяну; кызыгу. *Башында төрле планнар чуала, шуннан соң инде, күңеле алгысып, балта-пычкыга тотына.* Г.Ахунов. *Бу адымга ул байтактан әзерләнеп йөрде. Күңелендә ниндидер бер алгысу, бушлык, пошаманлык үзен гел-гел талкып торды.* Мәдәни җомга

**Алгысый бару** Торган саен ныграк алгысу

**Алгысый башлау** Алгысырга тотыну. *Әнлия хәзер, күңеле алгысый башлады исә, утыра да авылга кайтып килә.* К.Тимбикова

**Алгысый бирү** Алгысуын дәвам итү

**Алгысый төшү** Тагын да алгысу; бераз алгысу

**Алгысып китү** Кинәт алгысый башлау. *Фәләх, үзе дә сизмәстән, кодрәтләнеп, алгысып китте.* В.Нуруллин

**Алгысып кую** Кинәт, кыска вакытка алгысу. *Бермәл ул, юктыр, берәрсенең йөз чалымы гына аны хәтерләтәдер, дип, тынычланган кебек тә булды, аннары янә күңеле алгысып куйды, башына кереп оялаган уй аңа тынгы бирмәде.* Р.Кәрами

**Алгысып тору** Һаман, бертуктаусыз алгысу. *Кормашбаш җегетләре сугышырга алгысып тора, Рәуфне арба башыннан бәреп төшерделәр.* Р.Батулла

**АЛГЫСЫ** *с. сөйл.* Алда булачак. *Алгысы көндә нишләрбез, ике тамак бит әле без.* Ш.Маннур

**АЛГЫСЫНУ** *ф.* **1.** *к.* **алгысу.** *Төштә күрәм каргышымның Сиңа чынлап төшкәнен. Алгысынмый һәм ярсынмый Яшәр көннәр җиткәнен.* Н.Измайлова. *Күкеле сәгать теләп, урмандагы күкегә дә әллә ничә кат алгысынуы инде Нәгыйматтәйнең.* К.Кәримов. *Койма аша карап торып тәмам арыган Нәзифә, йөрәге алгысынуына түзә алмыйча, капка келәсенә тотына.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* Җилкенү, эчке дәрт. *Баштан ук белгән булсам, дигән нәүмиз алгысыну белән, аның бер күрүдә*

*хәтердә кала торган кыяфәтен күздән кичерәм.* М. Галиев

**Алгысына бару** Торган саен ныграк алгысыну

**Алгысына башлау** Алгысынырга тотыну

**Алгысына бирү** Алгысынуын дәвам итү

**Алгысына төшү** Тагын да алгысыну

**Алгысынып алу** Кинәт кенә, кыска вакыт эчендә алгысыну

**Алгысынып бетү** Бик нык, тәмам алгысыну

**Алгысынып китү** Нинди дә булса сәбәп аркасында яки вакыт үтү белән алгысынуга этәргеч булу. *Биктимернең йортын күргәч, күңеле тагын алгысынып китте.* Р.Зәйдулла

**Алгысынып кую** Кинәт алгысыну. *Үгетли торгач, күңелем алгысынып куйды бит.* Н.Хәсәнов

**Алгысынып тору** Һаман, гел, бертуктаусыз алгысыну. *Күңеле гел шуңа ымсынып, алгысынып тора иде.* В.Нуруллин. *Әнә кылычын кынынннан суырып чыгарган көе, Ибраһим урынында алгысынып тора.* В.Имамов

**АЛГЫСЫТУ** *ф.* Күңелне җилкендерү, нәрсәгә дә булса омтылу хисе тудыру, ашкындыру. *Күңелен алгысыткан сәхнә бар бит әле: завод каршындагы клубта җырчы, биюче, һәвәскәр музыкант булып йөри, көйләр яза башлый.* Г.Ахунов. *Фәнияр, туктаусыз диңгез турында сөйләнеп, Илсөянең күңелен алгысытуы өчен үзен битәрләде.* Ф.Яруллин. *Елга уртасыннан, кызның болай да җилкенгән, ашкынган күңелен алгысытып, су өстенә тияртимәс йөзеп, «Метеор» узып бара.* Р.Мөхәммәдиев

**Алгысыта башлау** Алгысытырга тотыну

**Алгысыта бирү** Алгысытуын дәвам итү

**Алгысыта төшү** Беркадәр, бераз алгысыту; тагы да алгысыту

**Алгысытып алу** Кыска гына вакыт эчендә алгысыту

**Алгысытып бетерү** Тәмам, бик нык алгысыту

**Алгысытып җибәрү** Кинәттән, көтмәгәндә алгысыта башлау, шул халәткә этәргеч бирү. *Казан ягына агучы Иделне, әнисен, үзенең балачагын искә төшерүләр Габделнур күңелен янә бер алгысытып җибәрде.* Р.Кәрами. *Кичке тынлыкта яңгыраган гармун тавышы йөрәкне алгысытып җибәрде.* Казан утлары

**Алгысытып йөрү** Килеп йөреп, күз алдында булып, үзенә игътибарны тартып алгысыту. *– Борчылмагыз, Маратның хәле әйбәтләнә, үсә, күңелен алгысытып йөрмәгез, – дип җавап язды.* Ф.Садриев

**Алгысытып китү** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт алгысыту

**Алгысытып кую** Кинәт кенә, кыска вакытка алгысыту. *Көн кояшлы иде, шәһәрнең киң һәм якты манзарасы Мансуровны бермәл гаҗәпләндереп һәм алгысытып куйды.* Ф.Хөсни

**Алгысытып тору** Бертуктаусыз, әледән-әле алгысыту. --- *туган туфракны сагыну хисе, туган авылымны, сине күрәсем килү тойгысы алгысытып торды.* М.Хәсәнов. *Күзләрен җылы да, ягымлы да булган яшел чиксезлек берөзлексез алгысытып торды.* Р.Мөхәммәдиев

**АЛГЫЧ** *и.* **1.** *тех.* Радио тапшыруларны кабул итә торган җайланма. *Алгычтан соңгы яңалыклар тыңлау*

**2.** *с. мәгъ. махс.* Кабул итә торган, үзенә туплый торган

**АЛДА** *рәв.* **1.** 1) Ал якта, каршыда, йөз, күз караган якта. *Алдыңда – очсызкырыйсыз озын юл. Атла да атла, бар да бар!* Г.Мөхәммәтшин. *Алда Казанка күренде.* Г.Әпсәләмов

2) Югарыда яки түбәндә (сөйләүченең үз фикерен кай урында әйткәнен яки әйтәчәген белдергәндә кулланыла). *Теге елны – бу турыда алдарак яздым – РСФСР Язучылар Союзының проза буенча кучмә семинарына барганда, соңгы бер көнне бер сарайда тантаналы кичә булган иде.* М.Мәһдиев. --- *алар турында алда сүз булыр.* А.Әхмәдуллин

3) Киләчәктә, булачак тормышта. *Минем алда эшләргә торган бер эшем бар.* М.Фәйзи. *Алда мине, янар учак булып, өмет көтә.* Ш.Таһирова. *Алда шактый кыенлыклар, зур югалтулар, җан сыкраулары һәм йөрәк әрнүләре көткәнен Дисә бик яхшы белә иде.* М.Хәсәнов

4) Башкалардан элек, беренче булып. *Без, яшь шәкертләр, ястү намазыннан алдарак чыгып, мәдрәсәгә кайттык.* М.Гафури. *Ләкин егет укуны бездән алда тәмамлады да, һич көтмәгәндә мединститут бетергән бер кызга өйләнеп, башка шәһәргә китеп барды.* М.Маликова. *Аның исеме дә үзенә ярашып тора – Чапкыртай. Нишләп шулай атаганнарын ул белми. Бәйгеләрдә чапкыр аты белән алда килгәне өченме, әллә орышларда дошманына кылыч белән хәтәр чапканы өченме – билгесез.* Р.Батулла

**2.** *бәйл. функ.* Каршыда. --- *минем алда хуҗасының байлыгын барлый.* Р.Зәйдулла

**3.** *хәб. функ.* Алга киткән. *Сәгать – 15 минут алда, ашыкмасак та була*

**АЛДАВЫЧ** *и.* **1.** 1) Балык, кош һәм кайбер җәнлекләрне алдап тотарга ярдәм итә торган нәрсәләр; җим. *Авылга бүре килеп бик җәфалагач, бер аучы үзенең бакча артындагы иске коесы өстенә төнгә ит куйган. Кое өстендәге алдавычка бүренең килеп керүе булган, черек такта сынып, бүре коега егылып төшкән.* М.Мәһдиев

2) Туклыксыз, туйдырмый торган, калориясе аз булган ашамлык. *Чәй дә бәрәңге, бәрәңге дә чәй, туйганчы итенмаен ашасаң иде. Болары бит аның – тамак алдавычы гына.* Г.Ахунов

3) *диал.* Яз көне – карны казып, өстенә кар яки салам салып, җәй көне өстенә балчык сибеп капланган ау чокыры

**2.** *с. мәгъ.* 1) Алдый торган, алдандыра торган. *Кайсы урамнан кайтсалар да, теге алдавыч яшелле-сарылы вывеска күренә.* Г.Тукай. *Иртәнчәк алдавыч һава тын тора, караганник яфракларында чык җемелди.* А.Гыйләҗев. *Түбәндә «текә ярлар» да, «төпсез упкыннар» да бар. Ләкин алар – чын түгел, болытлардан гына укмашкан алдавыч күренешләр.* Казан утлары

2) Ясалма, табигый булмаган, ялган. *Алдавыч фикерләр исә әүвәл җәмгыятьнең табигый үсешенә зыян*

*салды, шуның белән беррәттән, хатын-кызны бәхетсез итте!* З.Хөснияр. *Моның азагы бар: алдавыч хисләр дулкынында кабынган учак үзеннән-үзе сүнә дә китә.* Казан утлары

**АЛДАГЫ** *с.* **1.** 1) Алгы яктагы, алгы, алда урнашкан, алгы рәттәге. *Сугышчыларның күпчелеге йоклый. Бары тик часовойлар, алдагы дозорлар, секретлар гына төннәрне йокысыз үткәрәләр.* Г.Иделле. *Күзе алдагы утыргыч кесәсен «капшап» алды.* Т.Галиуллин

2) Баштагы, беренче. *Дүрт атымны бер-бер артлы тездем дә алдагы арба башына сикереп мендем.* Г.Ибраһимов. *Бу язманың алдагы өлешләрендә, өзек-өзек булса да, шактый нәрсә язылды инде.* Ә.Еники. *Китапның алдагы бите ертылган*

3) Киләчәктәге, алда торган. *Бу сорауның җаваплары алдагы тарих битләренең эченә яшеренгәннәр.* Г.Ибраһимов. *Эшләп үскәннең алдагы тормышы бәрәкәтле булыр. Кызның барлык туганнары шушы хакыйкатьне раслап яши.* Мәдәни җомга

4) Киләсе, иртәгәсе. *Кичә эшләгән эшләргә хисап та бирерсез, алдагы көн турында да фикер алышырбыз...* Р.Вәлиев. *«Милләт сафлыгы» программасын алардан башка тикшерү булмаслыгы көн кебек ачык иде, бу эшне алдагы кичкә калдырып торырга булдылар.* Ф.Сафин

**2.** *и. мәгъ. тарт. форм.* Киләчәк; алда булачак көн. *Алдагысын ишәк кайгыртсын.* Әйтем. *Биек тауда бер авыл, Ничек күтәрми давыл; Алдагысын Алла белә, Хәзергесе бик авыр.* Җыр. *Алдагысын беребез дә белми: син югында тегеләй-болай булып куйсам, белеп тор, мин сиңа рәнҗемим.* Ф.Яруллин

◊ **Алдагы көн** Киләчәк, алдагы тормыш; перспектива. *Колхоз җитәкчеләре арасында төрлесе бар. Бер төрлесе алдагы көнгә карап эшли. Перспектива белән эшли.* С.Рафиков

**АЛДАГЫЧ** *с.* Алдый торган, алдандыра торган, ышанычсыз. *[Нуруллин] Егылмас өчен, сул кулы белән тотынырга теләде; гаҗәп алдагыч, тиз онытылмый торган хәрәкәт, һәм бу хәрәкәт аны харап итте.* А.Шамов

**АЛДАК** *и. сөйл.* Ялган, алдаш. *Кайвакытта җитәкчеләрнең сүзе я алдак була, яисә халыкка каршы юнәлдерелгән була.* Идел. *Төрле алдак белән кеше малын үзләштерү*

**АЛДАКЧЫ** *и.* **1.** Алдый торган, ялганчы кеше. *Алдакчының бүреге яна.* Мәкаль. *– Эне-ем, – диде ул, сузып кына, – алдакчы да түгелсеңдер, бәлки, әйбәт малай син. Шулай да дөресен сөйләмисең.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Алдаша торган, ялганлый торган. *Мин үземне синең каршыңда алдакчы кеше итеп калдырасым килми.* Т.Гыйззәт

◊ **Алдакчы капчыгы** Үтә ялганчы, кеше алдап яшәүче; шарлатан

**АЛДАКЧЫЛЫК** *и.* Алдакчы булу, ялганчылык. *Дөресрәге, ул үз акылыаңы аша мондый алдакчылыкны берничек тә кабул итеп бетерә алмый кебек иде.* З.Зәйнуллин

**АЛДАЛА́У** *ф. к.* **алдау**. *Алдалый, валлаһи алдалый, ышанмагыз, сандыкта һич киелмәгән биш-алты асыл күлмәге череп ята.* Г.Камал. *Идарәгә чакырып килүче Шәмгунны күргәч, өйдә юк, дип алдалап җибәрергә омтылу очраклары да булмаган түгел.* Т.Нәҗмиев

**Алдалап алу** Бераз алдалау. *Мин алдалап алдым, өйгә кайтты инде, дидем.* Г.Әпсәләмов. *Элек без әти белән йоклап алдык, ә аннан соң әни дә бераз күзен алдалап алды.* Г.Бәширов

**Алдалап бетерү** Барысын да алдалау; әллә ниләр алдалау

**Алдалап йөрү** Төрле җирдә һәр кешене алдау. *Разияны, «сөям» дигән сүзне шулкадәр чынлык белән күзгә карап әйтә торган Разияны, ничек итеп, моңар чаклы алдалап йөргән, дип уйларга мөмкин булсын?* Р.Гали

**Алдалап килү** Күптәннән, электән үк, һаман алдаган булу

**Алдалап китү** Бераз алдалау, сүз уңаенда алдалау. *Мин генә сезгә шулай язып үттем, сезне дә әз генә алдалап киттем.* А.Алиш

**Алдалап кую** Бер тапкыр алдалау

**Алдалап тору** 1) Күз алдында, сөйләү моментында алдалау. *Таз һаман: «Кычытуы бетмәде әле, кычыта», – дип алдалап тора икән.* Мәзәк

2) Гел, һаман алдалау. *Без, аның мондый гадәтен белгәнгә күрә, еш кына алдалап торабыз.* Ф.Яруллин

**Алдалап утыру** Әле, хәзерге вакытта алдалау. *Ап-ак сакалың белән алдалап утырма инде, ичмасам, кешене ышандырырсың.* Т.Миңнуллин

**Алдалый башлау** Алдаларга тотыну

**Алдалый бирү** Алдалавын дәвам итү

**АЛДАН** *рәв.* 1) Ал (алгы) яктан, йөз яктан. *Йорт алдан биек койма белән тотылган*

2) Баштан, башыннан ук. *Кешенең иң зур, көчле хисләреннән берсе – алдан сизү.* М.Мәһдиев. *Киләчәкнең күзе юк, алдан ни буласын төгәл әйтә алмыйм.* Н.Гариф

3) Хәзерге вакыттан элек, моннан элек, күптән. *Бүләге дә алдан ук әзерләп куелган.* Ш.Галиев. *Бистә халкы гаилә башлыгы Юныс һәм аның уллары Газиз, Гафур, Каюм, Муса белән күп көннәр алдан таныш*ты. Г.Шәрипова

4) Беренче булып, барысыннан да элек. *Зур хәбәр, сөенеч бирергә халкына, Китте алдан илче Каф-тау артына.* Ш.Бабич. *Шакир Җиһаншин --- нәтиҗәсе, ни белән бетәре билгеле булмаган мәсьәләләрне тикшергән җыелышларда алдан чәчрәп чыкмый, башкалар тарткалашканны тыңлап кына утыра.* В.Нуруллин. *Җиңел түгел ул алдан һава ярып барулар.* Г.Бәширов. *Гармунчы алдан бара, әледән-әле, култыклашкан егетләргә борылып, арты белән атлый.* Ә.Баян

5) Вакытыннан алда, иртәрәк. *Алдан килгән – урын өчен, арттан килгән – тамак өчен.* Мәкаль. *Алдан кычкырган күкенең башы авырта.* Мәкаль. *---театрга-мазарга барам дисәң, берәр сәгать чамасы алдан чыкмыйча ярамый.* М.Вәли-Барҗылы

◊ **Алдан алу** *к.* **алдан аяк киенү**. *Авыруны алдан ал (ягъни тудыра торган сәбәбен булдырмаска тырыш).* Мәкаль. **Алдан аяк киенү** Алдан белеп, әзерлек чарасын күрү, алдан ук әзерләнеп тору. *Без быел язын, колхоз правлениесенең алдан аяк киенмәве аркасында, тавыкларыбызны, бер че-*

*метем фуражсыз, яшел кычыткан ашатып асрадык.* Ф.Хөсни. **Алдан әйткәнем булсын** Әйтмәдең, димәгез, менә әйтеп куюым, дип кисәтү. **Алдан кул юу** Соңыннан гаеп ителәчәк эшкә катышмау, үзен алдан ук аклап кую. **Алдан күрү** Киләчәктә булачак эшне алдан ук белеп, сизеп тору, чарасын күрү. **Алдан сүз куешкандай** Алдан килешеп куйган кебек, бер үк ниятне, эшне бер үк вакытта, берьюлы башкару. *Без, алдан сүз куешкандай, тагын шул тауга килдек.* Ә.Еники. **Алдан шапырыну** Булмаган эшне булган, булдырган кебек, алдан сөйләп мактану. *Алдан шапырынып, быел да оятка каласым килми, вәт!* Г.Бәширов

**АЛДА́Н-АЛА** *рәв.* Эш булмастан элек, эшен эшләп бетерми торып, алдан ук. *Мәүлиха түти әле сугылмаган, бер өлеше ындырга кереп җитмәгән игенне алай алдан-ала бүлгәләп ташлауны ошатмый иде булса кирәк.* Г.Бәширов

**АЛДАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **алдау**

2) Алдауга ышанып ялгышу. *Ул үзенең, Садыйк байга алданып, бик авыр хәлгә калганлыгын, --- быел бөтенләй укый да алмячагын сөйләп бирде.* К.Тинчурин. *Кайтучыларның бәгъзеләре әрсез таксистларның татлы сүзенә алданды.* Казан утлары

3) Кызыгу, нәрсәгә дә булса ия булырга теләү. *Мондагы юк-барга алданып, күңелеңне аздырма!* Г.Коләхмәтов. *Малайлар көне буе Ыкта су керәләрдер, ә син, ярты кашык балга алданып, шушында ят инде.* Ф.Яруллин. *Автор анда --- байларның алтынга алданып, саташып йөрүләреннән көлә һәм аларның никадәр ач күзле, комсыз икәнлекләрен күрсәтә.* М.Гали

4) Отылу, уңышсызлыкка дучар булу. *[Пристаньда] Саталар, алалар, алдыйлар, алданалар, мактыйлар, мактаналар, шау киләләр.* К.Тинчурин. *Нигә без шушы тоташ хәерчелекне туктаусыз мактыйбыз? Нигә без балачактан гүргәчә бер-беребезне алдарга һәм алданырга өйрәтәбез?* А.Гыйләҗев. *Солтан кинәт үзенең алдануын, ниндидер бер сыер савучы хатын тарафыннан адәм көлкесенә калдырылуын аңлады.* А.Расих

5) Мавыгу; хирыслану; нәрсә белән булса да артык бирелеп шөгыльләнү. *Уенга алданып, туемнан калма.* Мәкаль. *Җыр бит ул морфий шикелле,: без шул җырга алданган ---.* М.Мәһдиев. *Алданып, күп вакытта бушка калдык – Инде бер тырышаек алданмаска!* Р.Гайфуллина

6) Көчләнү, мәсхәрәләнү (кыз балаларга карата). – *Сорашмадыңмы, нишләп алай алданган? [Тимай:] – Иләсмиләс чагы бит. Хатынлыкка алам, дигән тасма теленә ышанган.* Т.Гыйззәт. *[Китапта] --- онытылган яки аңлы рәвештә төшереп калдырылган йолалар да юк түгел. Мәсәлән, кызның кавышырга килгән кияүне чишендерүе, кыз алданып килгән булса, никах төненнән соң, кияүнең кияү коймагын тишеп чыгаруы, килен булып төшкән кызның таянычык малга таянуы ---.* М.Бакиров

**Алдана бару** Торган саен күбрәк алдану

**Алдана төшү** Тагын да алдану

**Алдана язу** Чак кына алданмый калу

**Алданып бетү** Бөтенләй, нык алдану

**Алданып йөрү** Озак вакытлар дәвамында алданган булу. *Мин бу көнгә кадәр [Гайнинең] алдалап сөйләгән сүзләренә, үзен гыйффәтле итеп күрсәткән кыланышларына алданып йөргән икәнмен.* Г.Камал. *Әнә, синең сыман, хәзер орденга алданып йөри.* Т.Миңнуллин

**Алданып калу** Алданып, нәрсәдән дә булса тоткарлану, катнашмау; нәрсә дә булса эшләнмичә калу. *Бәс, надан, ахмак мөрид алданып калды.* К.Насыйри

**Алданып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан, һаман алдану

**Алданып кую** Кинәт, көтмәгәндә алдану. *Аннан бигрәк, өйнең күпмерәк торуын беләсе иде. Алданып куюың бар.* Ф.Яруллин

**Алданып тору** Һәрвакыт алдану

**Алданып яту** Әле, хәзерге вакытта алдану. *Аю шул вак-төяк белән алданып ята, нишләсен!* Әкият

**АЛДАР** *с.* **1.** Алдаша торган, алдашырга, ялганларга оста булган. *Вакытлы хөкүмәт «Алдар таз»дан да болайрак булып чыкты түгелме?* Т.Гыйззәт

**2.** *и. мәгъ. к.* **алдакчы 1.**

◊ **Алдар борчагын чәчү** Алдап шапырыну. *Хөсәен абзый шаярып, кеше көлдереп, алдар борчагын уңлы-суллы чәчеп яши иде.* Г.Мөхәммәтшин

**АЛДАТУ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **алдау**. *--- быргы белән иркәк боланнарны алдатып чакыру – болар барысы да соңрак уйлап чыгарылганнар.* Р.Әхмәтьянов

2) *к.* **алдану** (*2–5 мәгъ.*). *Тик Зөфәр бу юлы алдатмады, күгәрченнәре янына иң элек үзе менеп басты.* Ф.Хөсни. *Әгәр инде теш кысып түзсә, атай үлгәч, үзара мал бүлгәндә, Алтынбай алай алдатмас.* Г.Ибраһимов

**АЛДА́У** *ф.* **1.** 1) Хәйләләү, ялган белән ялгыш фикергә китерү. *Барча кызлар алдый дип, һичберсе юк алдамас; Кайсы кызлар алдамас соң, син фәрештәм алдагач!* Г.Тукай. *Әмма большевиклар империясе аларны [латышларны] тырнагыннан ычкындырырга теләми, алдап, көчләп булса да тота, аерылып чыгарга һич берничек тә юл куймый иде.* Ә.Еники. *Ай Аллам, харап икән. Аларны алдыйм, имеш. Әйдә, алдана торсыннар, тормыш әле аларны моның кебек кенә алдамас.* Казан утлары

2) Дөрес булмаганны чын итеп сөйләү; ялганлау. *Сөяксез тел алдаса да, Күз карашы, җаным, алдамас.* М.Җәлил. *Мин һаман шул җен-пәри, өрәк-бичура турында уйланам. Юк бит алар, юк! Егетләр бит чын ышану белән сөйлиләр. Кайберләре үзләре күргән. Алдыйлармы? Юк, алдамыйлар.* Җ.Фәйзи

3) Биргән сүзне, вәгъдәне бозу. – *Килерме, дип көткән идем дә, килмәде. – Алдадымыни? – Нишләп алдасын, ди? Андыйлар алдамый ул. Сәбәбе булгандыр.* Г.Шәрипова

4) Кызыктыру, ымсындыру. *Алдама мине, Ярың күрсәтеп, Аулама мине, Кызың күрсәтеп.* Ш.Бабич. *Мөршидә җаным, мин уйнап яисә сине мыскыл итәр өчен, алдар өчен бу сүзләрне сөйләмәдем.* К.Тинчурин

5) Ялгыштыру, хаталандыру. *Календарь алдамады, әлбәттә, кояш җәйгә*

*авышты, әмма көннең озынаюы артык сизелми әле.* Г.Шәрипова. *Матурлык ул, дөрес, әйбәт нәрсә, Тик алдый шул, каһәр суккыры.* М.Хөсәен. *Тышкы кыяфәт еш кына алдый, бутый.* А.Гыйләҗев

6) *күч.* Көчләү, мәсхәрәләү; көч кулланып, җенси мөнәсәбәткә керергә мәҗбүр итү. *Ул моннан биш ел элек Зәйнәпне алдап киткән бай баласы Гали әфәнде иде.* М.Гафури. *Синең төсле, авыз сулары агызып, мискинә ул кыз бик кызганыч, бер егет алдап ташлаган, фәлән егет бик аяныч булган, фәкыйрь дип, сөйгәнен бирмәгәннәр, дип торыймммы?* Г.Исхакый

**2.** *и. мәгъ. к.* **алдаш**. *Әле алдау, власть өчен көрәш, Гасыр буе килде кырын эш.* Х.Хабаров. *Мондый халык бернинди алдауларга, провокацияләргә бирешми, бирелми, ә бу – зур үсеш.* Б.Рәхимова. *Шаулый базар, гөрли базар, Елмая алыпсатар. Алдау кәсебе үзләштерә Монда «яңа татар».* М.Шиһапов

**Алдап бетерү** Бөтенесен алдау; әлләниләр әйтеп алдау

**Алдап йөрү** Даими рәвештә алдау; һаман да алдау. *Халыкны алдап йөргән өчен төрмәгә тыгып куя күрмәсеннәр инде, Ходаем!* Аманулла

**Алдап карау** Алдарга омтылу. *Чибәр кызлар, хәмер-шәраб белән Әлләничә алдап карады.* Р.Ягъфәров

**Алдап килү** Күптәннән, элек-электән, системалы алдау. *Аны гасырлар буе, син бөек, дип алдап килделәр.* Т.Миңнуллин

**Алдап кую** Көтмәгәндә яки кинәт алдау

**Алдап тору** 1) Һәрвакыт, гел алдау. *Чөнки тормыштагы ялтыравык, тышкы яктан матур тоелган күренешәйберләр кешене һәрчак ымсындырып, алдап торалар.* А.Шәмсутова

2) Әле, хәзерге вакытта алдау. *Ялганыңны сизеп торам, аңлап торам. Бер мизгелгә ышанып та куя язам: Хак сөйли, дип, үз-үземне алдап торам.* С.Әхмәтҗанова

3) Бераз, вакытлыча алдау. *Әле ярый аяк астында үлән бар, Маһинур абыстай аны кайда күрсә, шунда өзеп каба. Әмма үлән ачлыкны басмый шул, бераз алдап торырга гына ярый.* Ф.Бәйрәмова

**Алдап утыру** Әле, хәзерге вакытта алдау. *Нәрсә дип языйм? Алдап утырырга иренәм, ә дөресе Кәримгә нәрсәгә?* А.Гыйләҗев

**Алдап яту** *к.* **алдап утыру.** *Син әле, авыл мәчесе булган килеш, безне – городской мәчеләрне алдап ятасыңмы?* Т.Миңнуллин

**Алдый башлау** Алдарга керешү, алдарга тотыну. *Күз дә йоммый, һәр кешене алдый башлыйм инде мин!* Г.Тукай

**Алдый бирү** Алдавын дәвам итү

**АЛДА́У-ЙОЛДАУ** *ф. сөйл.* **1.** Төрлечә алдау, хәйләләрнең күп төрлесен куллану

**2.** *җый. и. мәгъ.* Һәртөрле алдаулар, хәйләләр, ялганнар. *Куй, зинһар, андый алдау-йолдаулар булырлык булганда, мин соң, олы башымны кече итеп, андый юк-бар эшләргә катышып йөримме?* Г.Камал. *Безнең әни, алдау-йолдау белән хәйләнең нәрсә икәнен белмичә, һәммәсен турыдан-туры ярып салучы, чамасыз да беркатлы кеше иде.* Г.Бәширов

**3. алдап-йолдап** *рәв. мәгъ.* Һәртөрле хәйлә-алдаулар белән, төрле рәвешчә кызыктырып. *Асаф тиз генә әти-әнисе янына барып килде, алдап-йолдап ачкыч биреп, аларны Казандагы фатирларына кайтарып җибәрде.* Р.Батулла

**Алдап-йолдап йөрү** Даими рәвештә, һәрвакыт алдау

**Алдап-йолдап тору** Әле, хәзер алдау

**АЛДАУСЫЗ** *с.* **1.** Алдауга корылмаган, алдашмый торган. *Шушындый ачык вә һич алдаусыз мөнәсәбәтләр Рәхилә белән Кәбир арасын тагын да ныгытты; Рәхиләнең – Кәбиргә, Кәбирнең Рәхиләгә ышанычы, хөрмәте артты.* Р.Батулла. *Тәү көрешү алдаусыз була.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Алдамыйча, хәрәмсез. *Дөресен әйткәндә, ялгансыз бер көн дә яшәлми, алдаусыз барып булмый.* Х.Камалов. *Дөрестән дә, сәүдә эшен алдаусыз гына күз алдына китерүе кыен.* Шәһри Казан

**АЛДАУЧАН** *с.* 1) Алдарга һәвәс, алдашырга ярата торган (кеше турында). *Алдый торган кеше, гадәттә, гел алдаучан була.* Шәһри Казан

2) Ялгыштыручан, саташтыручан. *Көндез алдаучан җылы булып торды да, төш авышуга, мә сиңа, зират тавыннан өзлексез җил исә башлады.* Рифә Рахман. *Тышкы кыяфәт алдаучан, дип юкка гына әйтмиләр икән.* Ватаным Татарстан. --- *нәкъ менә яз кояшы бераз гына елмая башлауга, хатын-кызларыбыз капрон оекларга, җиңел аяк киемнәренә күчә дә бетә, гәрчә язның алдаучан булуын барыбыз да белә.* Шәһри Казан

2) Кызыктыргыч, вәсвәсәләндерүчән. *Урманның алдаучан тынлыгы, җылы кояшлы иртә аның уйларын туган авылына, өенә, гаиләсе янына алып китә.* Әдәбият. *Ләкин әле бу – бәхет кояшының офыктан күренгән алдаучан кызгылт нурлары гына була шул.* Ватаным Татарстан

**АЛДАШ** *и.* 1) Ялган, хәрәм гамәл; дөрес булмаган эш. *Малай алдан ук кисәтеп куйды: – Уенда алдаш булмасын!* Мирас

2) Хәйлә, мәкер. *Алдашның аягы кыска.* Мәкаль. *Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны, Капчыктан ул алып килә шул ук башны.* Г.Тукай

**АЛДА́Ш-ЙОЛДАШ** *и. сөйл. к.* **алдау-йолдау**

**АЛДАШЛЫ** *с.* **1.** Алдауга корылган, кагыйдә буенча түгел. *Алдашлы уен*

**2.** *рәв. мәгъ.* Алдарга тырышып, алдап

**АЛДАШУ** *ф.* 1) Алдау, ялганлау. *Минем алдашканым юк, Якуб абый, чын... Ә сез... ни, сөйләгән сүземә ышанмастай иттегез.* Э.Касыймов. *Кыз, башын иеп, шактый дәшми торды. Ләкин ул хәзер алдаша алмый иде инде.* Ә.Еники

2) Хәйләләү, хәрәмләшү, башкаларны алдау. *Яшь, шома, телгә оста егетнең сихерләүләрен, матур итеп алдашуларын күзәтә торгач, --- бер шаян хикәя дә язып ташладым.* Т.Галиуллин

**Алдаша башлау** Алдашырга тотыну. *Каяндыр тавык исе килә. Әкият! Каян килсен монда тавык ите? Борын алдаша башлады соңгы вакытта, картаю галәмәте инде.* З.Мәхмүди

**Алдаша бирү** Алдашуны дәвам итү

**Алдаша төшү** Бераз алдашу

**Алдашып алу** Аз гына, бераз алдашу

**Алдашып йөрү** Әле, хәзерге вакытта төрле урыннарда, төрле кешегә алдашу. *Алдашып йөрергә, мине кем дип белдегез?* И.Сәйфуллин

**Алдашып карау** Алдашырга омтылу. *Карыймын алдашып та, Карыймын аңлатып та. Аңламагач Аңламый! Тыңламагач Тыңламый!* Р.Миңнуллин

**Алдашып килү** Элек-электән үк, системалы алдашу. *Әлегә кадәр алдашып килсә дә, Бакировның «абруйлы» көннәре санаулы гына кала, чөнки чын каһарманнарны эзләү өчен көрәш сафына басучылар табыла.* Р.Зарипова

**Алдашып кую** Бер мәртәбә алдашу

**Алдашып тору** Әледән-әле, еш алдашу; һәрвакыт алдашу. *Ничек оялмыйсыз сез шушылай алдашып торырга?* В.Нуруллин

**Алдашып утыру** Әле, күз алдында алдашу. *Син нәрсә, шахтёр башың белән, көпә-көндез алдашып утырасың?* Г.Бәширов. – *Карт башым белән мине алдашып утыра дип уйлыйсызмы? – дигән Кара елан.* Ф.Яруллин

**АЛДЫ́-АРТЫ** *җый. и.* 1) Ал һәм арт, тирә-як. – *Алдың-артыңны карап йөри күр, балам, – диде карчык, көрсенеп.* Казан утлары

2) Ахыры, соңы, нәтиҗәсе. *Мирсәет тә алдын-артын уйламастан әйтеп салмасынмы шунда: – Минем кадәр өч булгач, ул, Зәки әфәнде, синең тикле биш кеше дигән сүздер инде, ә?!* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Алды-арты хәерле булсын** *теләк* Хәвеф-хәтәр, үлем-китем, югалтулар булганда, кабат зыян килмәсен, дигән мәгънәдә әйтелә. *Ярар, алды-арты хәерле булсын, сандыгыңны әтиең кичкә китерер.* М.Мәһдиев. **Алды-артына карамыйча** 1) Шикләнмичә, курыкмыйча, сакланмыйча; 2) Бернигә карамый, бик кызу (*йөгерү*), тәвәккәллек күрсәтеп (*хәрәкәт итү*). *Ул, сукыр чебен кебек, алдын-артын карап тормыйча, теләсә кая бара да керә.* Казан утлары. **Алдын-артын уйлап тормыйча (тормастан)** Эш-хәлнең ничек булуына төшенмичә, ни белән бетәсен уйламыйча (*эш итү*). *Рөстәм, моңа чаклы аңарда һич күрелмәгән уенчаклык белән, алдын-артын уйлап тормастан тезеп китте.* Ф.Хөсни

**АЛДЫ́М-БӘРДЕМ** *рәв. сөйл.* Ашык-пошык, тиз генә; җиренә җиткермичә (нәрсәнедер эшләү турында). *Әйтик, ихлас табигатьле кеше эшне алдым-бәрдем генә эшләми, аны бар күңелен, булдыра алганча осталыгын салып, юаныч, тәм, илһам табып башкара.* Әдипләребез. *Мин алдым-бәрдем генә сылаштырып куелган, ясалма кыяфәт кенә кертелгән урыннарга игътибар итәм, ә аларны өйдән чыгуга күрәм.* Безнең гәҗит

**АЛДЫ́М-БИРДЕМ** *ф.* 1) Сату-алу, товар алмашу

2) *этн.* Кыз ярәшү. *Кирәк булса, хәзер үк берәребезгә «алдым-бирдем» ясап, яучылык кылып, туй ясап алырга була.* Ф.Бурнаш

**АЛДЫН** *с.* 1) *к.* **алдынгы** (*1 мәгъ.*). *Алдын ударниклардан бөтен Татарстаннан без ун кеше сайландык.* Ф.Бурнаш

2) Өстен, олы, бөек. *Хаклык алдын барчадан, Өстен барча нәрсәдән.* М.Җәлил

**АЛДЫНГЫ** *с.* **1.** 1) Тормышта хезмәте, эше белән башкалардан алда булган, үрнәк. *Сәхибгәрәй хан чыннан да бик мәдәниятле, тирән фикерле, укымышлы кеше була. Аның кылган эшләре дә --- аның үз вакытының алдынгы кешесе булуын күрсәтәләр.* С.Алишев

2) Аңлы, зыялы, прогрессив карашлы, югары фикер йөртә торган. *Алтын Урда чорында һәм шуннан соңгы ханлыкларда үз заманының алдынгы белгечләре дәрәҗәсендә чор белемнәрен үзләштергән, җәмәгатьчелектә олы ышаныч казанган зур галимнәр булган.* М.Гайнетдинов

3) Үсеш кимәле ягыннан югары булган. *Нәҗип җирне ярата, туфракның уңдырышлылыгын арттыру буенча алдынгы технологияләрне куллана, күп укый, өйрәнә, фән казанышларын исәпкә алып эшли.* Л.Шәех. *Киләчәктә дә казанлыларның алдынгы тәҗрибәсен өйрәнәчәкбез.* Я.Шәфыйков

4) Иң алдагы, беренче. *Җамалилар ротасы да, җир асты юлларын үтеп, алдынгы линия окопларына кереп урнашты.* М.Гали

5) Әйдәп баручы, өстенлекле. *Бу исә уку-тәрбия эшен җитештерүчән хезмәт белән бергә бәйләп алып бару, хезмәтнең алдынгы формаларын һәм заманча индустрия яңалыкларын дөрес файдалану исәбенә хәл итәлергә мөмкин.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**2.** *и. мәгъ.* Эштә, укуда һ.б.ш. тармакларда алда баручы, югары күрсәткечләргә ирешкән кешеләр. – *Батыр булыгыз! – диде Вәли агай. – Сез бит алдынгылар!* Ш.Мостафин

**АЛДЫНГЫЛЫК** *и.* 1) Алдынгы булу, беренчелек. *Моңа тиклем алдынгылыкны беркемгә дә бирмәгән сыер савучы Мөсфирә кара көнләшү белән янды.* Х.Ибраһимов. *Алдынгылыкны чит-ятларга биргән юк.* Д.Бүләков

2) Яңалык, прогрессивлык. *Нәкъ менә яңалык, алдынгылык китерәсе мәгариф челтәре – иң консерватив өлкә булып чыкты.* Ш.Галиев

3) Әйдәп баручылык, өстенлек. *[Әдһәм:] Булган шул заманалар, ат белән иргә пачут булган. Хәзер сыер белән хатын-кыз алдынгылыкка чыкты.* А.Гыйләҗев

**АЛДЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **алу**. *Математика укытучысы, кибетчене эшеннән алдыртып, аның урынына калды.* К.Кәримов

2) *к.* **алдыру** (*2–5, 10 мәгъ.*). *Кайсылары, дилбегәне бер кагып, чөңгереп җибәрүеңә, озын сыйракларын еш-еш алдыртып, биегәндәй тигез юыртып бара.* К.Миңлебаев

**АЛДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **алу**.

2) Берәр сәбәп белән читтән чакырып китерү. *Берәр ел эшләгәннән соң, ул үз янына бөтен семьяларын алдырды.* Һ.Такташ. *Калада берәүнең кулымы, аягымы чыккан икән, ди, шуны докторлар төзәтә алмагач, Карамалы остасын алдырганнар, ди, инде менә хәзер, көненә ничә белешеп, шуларның кайтканнарын көтәләр, ди.* Г.Ибраһимов

3) Китертү, алып кайттыру. *[Карчык:] – Юк, рәхмәт. Кирәк булса, мин асраудан алдырырмын, – дип, кырт*

*кисте*. Г.Ибраһимов. --- *сәгать бавы өзелгән иде, көмешче киявеннән аны эшләтте, каладан яңа Казан кәләпүше алдырды.* Г.Ибраһимов

4) Эштә, тормышта ниндидер уңышка ирешүдә эшлеклелек, сәләтлелек, җитезлек, осталык, зирәклек күрсәтү. *Егет кеше яуда көче белән алдырса, яланда эше белән алдыра*. Мәкаль. *Мансур Вәлиев – эмоциональ тәнкыйть тарафдары. Дәлилләп бирүдән, анализдан бигрәк, ул еш кына хис белән, кайнарлык белән алдыра*. Мәдәни җомга

5) Ярышта алдан килү, алга чыгу. *Яхшы ат соңыннан алдыра*. Мәкаль. *– Атлар килә! – дип кычкырды кемдер, – Фәсхетдиннең кола биясе түгелме? – Алдыра бит кашка, алдыра бит*. Ә.Фәйзи

6) Эш йөртү, башкару сәләте, куәте, көче зуррак, өстенрәк булу. *Әтәй киң алдырып алга бара, кояшта янган ялангач аркасындагы мускуллар нәни бурсыклар сыман бер-берсенә таба йөгерә иде*. Р.Зәйдулла. *Чалгысын җиңел селти, пакус арасын да киң алдыра*. Җ.Дәрзаман. --- *бу дөньяда акыл алдан йөрми, акча алдыра, ул башлап сүз әйтә...* Ф.Сафин

7) Нәрсәне дә булса исеменә яздырып алу. *Ул китапларны хәзер сораучы юк, шуңа күрә алдырмыйбыз*. Г.Ибраһимов. *Карчыгы – элеккеге укытучы – мәхәббәт гәзите алдыра, «Таһир-Зөһрә» дигән*. З.Хөснияр

8) Ихтыярсыз кулдан ычкындыру, югалту яки урлату. *Алдырыр көн – яздырыр*. Әйтем

9) Кырктыру; кистерү. *Мин чәчемне озын йөртсәм ни зарар да, кыска йөртсәм, аннан сезгә ни файда! Закир шул чәчен алдырып йөрткәнгә шулай бик тәүфыйклы булдымыни?* Г.Камал. *Атаклы урыс композиторы Рахманинов, замандашлары озын чәч үстергәндә, чәчен алдырып, такырбаш булып йөргән, диләр*. Р.Батулла

10) Суырту, тартып алу. *Теш алдыру*

11) Организмдагы кан, сүл һ.б.ш. сыекчаны суырту, агызу. *Сөннәтче бабай да элгәреге Кәбир хәзрәт, Сафа хәзрәтләрнең кан алдырулары хакында, бер мәртәбә Кәбир хәзрәтнең кан алдыргач һушы китү кыйссасыны сөйли иде*. Г.Исхакый

**Алдыра башлау** Алдырырга тотыну. *Азакка калган чаптар, кинәт ярсып, ирдәге җайдагын чөеп төшерә дә, чалыклап, урманга таба алдыра башлый*. М.Галиев

**Алдыра төшү** Ныграк, күбрәк алдыру. --- *хезмәт вазифасыннан бушатылган Әхәткә ярдәм кулы сузарга курыккан сыек буынлы Идристән аермалы буларак, аларга караганда чагыштырмача яшь буын вәкиле Мөзәкир үзенең ихласлыгы һәм көрәшче сыйфатына ия булган көчле рухы белән алдыра төшә*. М.Сәхапов

**Алдырып бару** Һәрвакыт, системалы алдыру. *Газетабызны ел саен алдырып баручы абый-апаларны, әбибабайларны да очратканым бар минем*. Р.Миңнуллин

**Алдырып китү** Билгеле бер урыннан, вакыттан соң кинәт алдыру. *Кинәт кызу алдырып китүдән, чанадагы кешеләр артка сөрлегеп куйды*. А.Вергазов. *Соңыннан алдырып киттем, минсиңайтим! Эшен дә актарып салам, акчасын да каерып алам*. З.Фәйзи

**Алдырып ташлау** Тиз арада, тиз үк алдыру. *Түлке син, ыстудин иптәш, чәчеңне алдырып ташла, иелгәч күзеңә керә*. Н.Фәттах

**Алдырып тору** Һәрвакыт, даими алдыру. --- *тау өстенә аэродром кордырып, Тымытык кымызын атна саен Франциягә алдырып торырга теләде*. М.Галиев

**АЛДЫРЫКЛЫ** *с.* **1.** Киң алдыра торган; алымлы, эре адымлы, йөгерек. *Әгъләм юыртырга керешкән олы торыклы, зур алдырыклы туры атның дилбегәсен бушатыбрак җибәрде*. С.Рафиков

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Кызу, бик тиз, җәһәт. *Алдырыклы атлап бару*

**АЛЕБАСТР** *и. гр.* **1.** 1) *физ.* (Мисырдагы шәһәр исеменнән) Өлешчә сусызландырылган гипс

2) Төзү эшләрендә төелгән рәвештә кулланыла торган гипслы таш. *Төзелештә еш кулланыла торган үзле акбалчыкка – гипска – алебастр диләр*. Н.Фәттах. *Инде килеп, алебастр, акбур, цемент, буяу, кләй, паркет такталары һәм ремонт өчен кирәкле бүтән әйберләрне эзләп табуы – үзе мең бәла*. Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ.* Шул материалдан ясалган, шуннан эшләнгән. *Алебастр бюст*

**АЛЕУТ** *и.* Алеут утрауларының төп халкы (күпчелеге Аляскада һәм Камчатка краенда яши) һәм шуларның бер вәкиле. *Әнием – алеут кызы*. И.Хуҗин. *Кичә, өченче көн генә (сүз – еллар, гасырлар турында, әлбәттә) үз әбибабасының татар, чуваш, калмык, хакас, шор, алеут, якут иңенен белеп яки тоеп торган яңа «урыс» шул яңа халәтенә искесен дә алып килми калмый, билгеле*. Татарстан яшьләре

**АЛЕУ́ТЧА** *рәв.* **1**. Алеут телендә. *Алеутча уку*

**2**. *с. мәгъ.* Алеут телендә язылган. *Алеутча китап*

**АЛЖИРЛЫ** *с.* 1) Алжирда яшәүче яисә шунда туып-үскән кеше. *Илнең төп халкы – гарәпләр һәм бәрбәрләрдән торган алжирлылар*. Материклар һәм океаннар географиясе. *Француз телендә белем алалар, француз телендә төзелгән документлар белән эш алып баралар, ә барыбер алжирлы гарәп булып калалар*. Фән һәм тел. *Алжирлы һәм немка гаиләсендә дөньяга килгән актриса очрашуда, кайберәүләр кебек, тәкәбберләнеп маташмады һәр сорауга чын күңеленнән җавап бирергә тырышты*. Ватаным Татарстан

**АЛҖУ** *ф.* 1) Ару, талчыгу; хәл китү, хәлсезләнү. *Безләр болай арып, алҗып барган чакта, Австриләр тоталар туп ташына*. Бәет. *Операция ничек узды соң? Алҗыган кебек күренәсез...* Э.Касыймов. *[Озерцов] Алҗыган булса да, хакыйкатьнең ачыкланганнан-ачыклана барганына күңеленнән шатланды*. Р.Мөхәммәтҗан. *Арыса арыды, алҗыса алҗыды, хәл җыйды да янә талчыкканчы шөгыльләнде*. Б.Камалов

2) Аптырау, тилмерү; җәфалану. *Ялгызлыктан алҗу. Көтеп алҗу*

**Алҗый бару** Торган саен ныграк алҗу

**Алҗый башлау** Алҗу билгеләре күренү, алҗу сизелү. *Фәрештә кебек булсаң да, халык гел бер җитәкчегә*

*табынып диярлек яшәүдән алҗый башлый.* Ә.Исхаков

**Алҗып бетү** Тәмам, бик нык алҗу. *Калмыкларның старосталары үз «шәкертләрен» кат-кат санап алҗып беткән.* Т.Нәҗмиев. *Муса, аңа сораулар бирә-бирә, алҗып бетте.* Ш.Маннур. *[Юрий Петрович Козарь] Тегендәмонда шалтыратып, әйткәләшеп алҗып беткәндер.* Н.Хәсәнов

**Алҗып йөрү** Әле, хәзерге вакытта күп йөреп алҗу. *Шунда арып, алҗып йөргән фидакярләр демонстрациягә йөрергә яратмаган, әмма кунак чакырырга маһир булган дусларына аш мәҗлесенә җыелалар иде.* Х.Сарьян

**Алҗып китү** Кинәт, бераз алҗу

**Алҗып тору** Әле, хәзер бераз алҗыган булу

**Алҗып чыгу** *к.* **алҗып бетү**. *Икесе дә тирләп, алҗып чыктылар.* З.Зәйнуллин

**АЛҖЫТКЫЧ** *с.* Алҗыта торган, ялыктыра торган; күңелсез. *Ул үзенең поручик белән булган туен хәтерләде: нинди шау-шулы, күп сүзле, алҗыткыч туй булган иде ул!* Р.Сибат

**АЛҖЫТУ** *ф.* 1) Арыту, талдыру, хәлсезләндерү. *Олаучылар атларны куаламаска тырышалар, бахбайларны алҗытасылары килми.* Ф.Сафин

2) Аптырату, тилмертү, йөдәтеп бетерү. *Алай гына да түгел, Чабаксарда яшәгәндә, көн саен, мине «Әйдә загска» дип алҗыта иде.* А.Вергазов

**Алҗыта бару** Торган саен ныграк алҗыту

**Алҗыта башлау** Алҗытканы сизелү

**Алҗыта төшү** Бераз алҗыту

**Алҗытып бетерү** Бик нык алҗыту. *Күселәр [песи баласын] куа-куа алҗытып бетерганнәр.* А.Алиш. *– Гимназия! Ул нинди булыр икән? – дип, малай әнисен алҗытып бетерде.* Ж.Тәрҗеманов

**Алҗытып җибәрү** Бераз, берникадәр алҗыту. *Аның өстенә тыгыз һәм эссе трамвай да ялыктырып, алҗытып җибәргән иде бугай.* Р.Гарипов

**Алҗытып кую** Кинәт алҗыту

**Алҗытып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз алҗыту. *Гөлфинур сеңелкәшне тыңлыйк та аннары аны алҗытып тормабыз, кайтарып җибәрербез.* А.Вергазов

**АЛҖЫГАНЛЫК** *и.* Алҗыган булу, арыганлык, йончыганлык. *Көнчелек яки алҗыганлык аркасында, гаиләдә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр суына.* Тигез гомер итегез!

**А́ЛИБИ** *и. лат. юр.* Җинаять ясалган вакытта, гаепсезлегенә төп дәлил буларак, гаепләнүченең башка урында булуы. *Ксенофонтов, үзенә алиби өчен, әти өстеннән донос яздырта.* Х.Камалов

**АЛИМЕНТ** *и. лат.* Аерым яшәүче, хезмәткә яраксыз гаилә әгъзаларына (балаларга, ата-анага) туганлык мөнәсәбәтендә булган кешеләр тарафыннан закон нигезендә түләнә торган акча. *Алай булгач, Яуми җаным, мин дә сиңа бер сорау бирим әле. Ничә алимент түлисең?* Ж.Фәйзи. *Эш урынын, торган җирен ничәмә-ничә тапкыр алмаштырып караса да, алимент кәгазе, шомлы күләгә кебек, гел аңа ияреп йөри, һәм ул эш хакыннан билгеле сумманы җибәреп тора, аннары аны оныталармы, күздән югалталармы шунда, һәрхәлдә, алимент белән борчымый башладылар.* С.Сабиров. *Беренчесе исерекбаш булса, икенчесе – алименттан качып йөрүче.* Т.Галиуллин

**АЛИМЕНТЧЫ** *и.* Алимент түләүче

**АЛИҺӘ** *и. гар.* 1) Хатын-кыз илаһ; илаһә. *Борынгы грек пантеонында Гефест – тимерче, тимерчеләрне яклаучы; Афродита мәхәббәт алиһәсе саналган.* Татар мифологиясе

2) *куч.* Үз эшен гаять зур осталык, сәнгатьчә камиллек белән башкаручы хатын-кыз. *Комбинезонлы яшь илаһлар, алиһәләр, Жирдән күккә йөртеп грацияле кулларын, Ак оҗмах сала пыяладан, кирпечтән.* Ә.Давыдов

**АЛЙОТ** *и. сөйл.* Ахмак, тилемсә. *Син белсәң, бер алйот бит алар – кара кавказлар, үзе – әйбәт егет, мине алай башкалардан кыерсыттырмай.* З.Кадыйрова. *Баксаң, әлеге утрауда туган илебездәге бандитлардан, алардан да бигрәк алйот чиновниклардан качкан Айрат исемле татар егете үзе бер нәни Татарстан булып яшәп ята икән.* Казан утлары

**АЛКА** *и. гар.* 1) Гадәттә металлдан эшләнгән кыршау формасындагы боҗра, бөгәлҗә. *Карама дуга, җиз алка, байлар җигә дан өчен; Күп егетләр башын җуя Алалмаган яр өчен.* Җыр. *Дугадагы алканың деңгердәве аермачык булып ишетелә, атның башы якын гына селкенә башлады.* И.Гази. *Тимерченең бәхетенәдер инде, күрек сабын тоташтыра торган алканы алыштырыйм дип алып аткан иде, өрдерә алмадылар.* Б.Камалов

2) Колак йомшагына тага торган бизәнү әйбере; сырга. *Алтын алкаларым сынса, Алырсың микән алка?* Җыр. *[Дикә] Нәфис муенына – диңгез буендагы асылташлардан тезелгән муенса, нәни генә колакларына ялт итеп торган бакыр алкалар таккан, ди.* Н.Фәттах. *Минә шулай: кара чәч арасыннан бары тик алка гына күренепкүренеп китәргә тиеш, алка Мәрьямнең йөзенә серләрәк, уйчанрак төс бирер.* М.Маликова

3) Чәч, йон уралмасы, бөтеркә. *Менә ул көзгә каршына утырды, көлсу чәч алкаларын ике яктан шома яңаклары тирәсенә җәйләп куйды...* М.Маликова. *Башындагы ак шапкасы астыннан кызның вак бөдрә чәчләре чыгып, күпсанлы кара алкаларны хәтерләтәләр.* Р.Кәрами

4) *бот.* Кайбер үсемлекләрдә булган, колак алкасына охшаш орлыкча. *Кояшбикәгә матуррак күренер өчен, купшы юкәләр яфрак колакларына чәчәк алкалар тага. Ул алкаларны җил малайлары, агач саен менеп, селкетеп йөри.* Ф.Яруллин. *Вакыт-вакыт, умарта корты, тик бер аягы белән генә ябышкан хәлдә, чәчәк алкасында асылынып тора.* И.Халифман. *Зирек алкасы*

5) Нәрсәне дә булса тирәләп уратып алган әйбер; кайма. *Салкыннар башлангач, боз, иң элек, күлнең яр буйларында, саерак урыннарда ката. Шулай итеп, күлнең читләре боз алкасы белән уратып алына. Ул алка акрынлап калыная һәм киңәя бара.* А.Муранов

6) *спорт* Түшәмнән сузылып төшкән (ике) бауның түбәнге очына беркетелгән (ике) боҗра. *[Кыз] Алкаларда*

*шундый җиңел атынырга тотына, минем исем китә.* Г.Әпсәләмов

7) *спорт* Хоккей уенында кулланыла торган түгәрәк резина; *русчасы*: **шайба**

8) Тәмәке тартканда, авыздан өзек-өзек чыгарылган төтен бөҗралары. *[Егет] Ашыкмыйча гына, папиросыннан «алкалар» җибәрә һәм, чабак сагалаган чуртан шикелле, кызлар күзәтә.* Ә.Еники

9) Су өстендә җил тәэсиреннән яки авыр әйбер ыргытканда барлыкка килә торган, бер-бер артлы түгәрәкләнеп җәелеп киткән дулкыннар. *Каракучкыл чоңгыл өстендә балыклар уйный, түгәрәк-түгәрәк җитез алкалар йөгерешә.* Э.Касыймов

10) Диаграммада төрле зурлыкларның үзара чагыштырмасын сурәтли торган сызым, схема. *Почта бүлеге коймасында – бик зур почёт тактасы. Анда – план үтәлешенең Диаграмма алкасы.* М.Җәлил

11) Нәрсәнең дә булса аны әйләндереп алган чите, кырые, әйләнәсе. *Кояш яңа чыгып, тирә-ягы зур алка белән әйләндерелеп алынган иде. Кояшның буйлә киртәләнеп, зур алка эчендә калуы бик салкын вакытларда гына булганга күрә, кояшка караганда, кояш үзе бер салкын боз табы кебек күренә иде.* М.Гафури

12) *күч.* Кемне дә булса чолгап, камап торучылар төркеме, бөҗра, камалыш. *[Туташ һәм ханымнар] Мәдинәләрне бер читтә калдырып, Хәбирне алка эченә кысты.* Ш.Хөсәенов

**АЛКАЛАНУ** *ф.* **1.** 1) Алка формасына керү; бөҗралану, бөдрәләнү

2) Алкалар җибәрү, алкалар чыгару. *Безнең якларда, беренче булып, зирек, чикләвек агачы алкалана.* Ботаника

**2. алкаланып** *рәв. мәгъ.* Бөтеркәләнеп, бөдрәләнеп. *Чәчләре бөдрә – алкаланып, маңгаена ук төшеп тора.* Ф.Бәйрәмова. *Калын кара кашлар, бер ачылып, бер йомыла төшеп, тынгысыз карый торган көрәнсу күзләр, маңгае өстенә алкаланып төшкән, аз гына чал йөгергән чем-кара чәч ---.* Ә.Еники. *Әминә аның башындагы косынкасы кырыеннан алкаланып чыккан чәч бөдрәсен күрде.* Г.Минский

**Алкалана төшү** Бераз алкалану

**Алкаланып бетү** Бик күп алкалар барлыкка килү

**Алкаланып тору** Әле, хәзер, күз алдында алкаланган хәлдә булу

**АЛКАЛА́У** *ф.* Әйләндереп алу, чолгап алу, уратып алу. *Мәйдан тирәли алкалап чаба торгач, ханның ак күбеккә төшкән аты арыды һәм тизлеген сизелерлек киметте.* Т.Нәбиуллин

**Алкалап алу** Кыска гына вакыт эчендә алкалау; бар яктан да алкалау. *Иртә белән күк битенә нечкә генә аксыл болытлар кунып, кояшны алкалап алганнар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**АЛКАЛО́ИД** *и. фр.<нем. хим.* Гадәттә үсемлекләрдән алына торган, селтегә хас үзлеге булган азотлы органик кушылма (мәс., *атропин, морфин, никотин, кофеин*). *Зур дозаларда алкалоидлар бик тә агулы, кечкенә дозаларда исә кыйммәтле дәвалау чарасы була алалар.* Е.Солодухин

**АЛКАЛО́ИДЛЫ** *с.* Составында алкалоид булган, алкалоид алына торган. *Алкалоидлы үсемлекләр. Алкалоидлы химик кушылмалар*

**АЛКАЛЫ** *с.* 1) Колагына алка таккан, алкасы булган. *Чәчләрен ипле генә итеп уртадан аерып үргән дә, кара төрткеле ак яулыгын, җыерчыклатып, алкалы колакларын тышта калдырып бәйләгән.* А.Хәлим

2) Алкалар (*4 мәгъ.*) белән капланган, алкалар чыгарган. *Алтын алкалы солылар, чыршы күркәсе кебек эре башаклы бодайлар, берсен-берсе чиратлап, әле уңга, әле сулга җәелгәннәр.* А.Гыйләҗев

3) *спорт* Алка белән уйнала торган. *Татарстанның Зур концерт залында 1997–1998 еллар сезонында алкалы хоккей буенча Россия чемпионы исемен яулап алган «Ак Барс» командасын хөрмәтләү булды.* Татарстан – реформалар чорында

**АЛКАШ** *и. рус сөйл. к.* **алкоголик**. *Кабан күле спирт булган алкашка. Галимнәргә надан килә алмашка.* Р.Фәйзуллин

**АЛКИСӘКЧӘ** *и. лингв. к.* **алкушымча**

**АЛКОГОЛИЗМ** *и. рус* Эчкечелек, эчкечелек авыруы. *Бүгенге заман яшьләре өчен иң зур бәхетсезлекләрнең беренчесе һәм соңгысы – алкоголизм, наркомания колына әверелү.* Мәдәни җомга

**АЛКОГО́ЛИК** *и. рус* **1.** Эчкечелеккә сабышкан кеше, эчкече, исерекбаш. *Яшь тол хатын, ире алкоголик булып киткән...* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Эчәргә ярата торган, сәрхуш. *Алкоголик кияү белән берәр ай яшәгәч, бичара хатын моны, җитәкләп, әнисенә илтеп тапшыра.* М.Мәһдиев

**АЛКОГОЛЬ** *и. нем.<гар.* Спиртлы исерткеч эчемлек. *Феликс ямьсез итеп елмайды: «Алкоголь парлары гына йөрәгемне җылыта ала».* М.Юныс

**АЛКОГОЛЬЛЕ** *с.* Составында алкоголь булган, спиртлы, исерткеч. *Моңа кадәр татарны, ислам белән бергә тән, шундый аз алкогольле эчемлекләр алкоголизмнан коткарып калгандыр да.* Г.Дәүләтшин

**АЛКУШЫМЧА** *и. лингв.* Сүзнең тамыр алдындагы кисәге; *русчасы*: **приставка**. --- *«би-» алкушымчасы ярдәмендә берничә дистә яңа сүз барлыкка килде.* Р.Мөхиярова

**АЛКУШЫМЧАЛЫ** *с.* Алкушымчасы булган. *Фарсы телендә юклыкны белдереп, татар телендәге «-сыз/-сез» кушымчасы мәгънәсен бирүче «би-» алкушымчалы алынма сүзләр татар телендә шактый.* Р.Мөхиярова

**АЛКЫМ** *и. гар. диал.* Үңәчнең өске өлеше, тамак, бугаз. *Алкымы тыгылу*

◊ **Алкымыннан килгәнче** Гарык булганчы, туйганчы (*ашау*)

**АЛКЫН** I *с.* Мул сулы, көчле агымлы. *Агыйделкәй алкын, суы салкын, Дулкыннары килеп какмасын.* Җыр. *Алкын Идел үзе тели төсле Минем белән сердәш булырга.* Җыр. *Идел алкын, суы салкын, ишеп булмый салларны; Беребез анда, беребез монда, белеп булмый хәлләрне.* М.Фәйзи

**АЛКЫН** II *и. диал.* Аяк һәм аяк киеменең йөзеннән югары өлеше, тамагы; *русчасы*: **подъём**. *Аягының алкыны биек. Алкыны тар туфли*

**АЛКЫ́-САЛКЫ** *рәв.* **1.** Ялкау гына, теләр-теләмәс кенә. *Акылга утыр, менә синә да Җир йөзендә тын почмак табылды, шаяруларыңнан, илебезнең бер читеннән икенче читенә алкы-салкы*

*йөрүләрдән туктарга вакыттыр.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* 1) Акрын кыймылдаучан, иренчәк. *Алкы-салкы кеше*

2) *күч. сир.* Алмашынучан, тотрыксыз, үзгәреп торган. *Алкы-салкы һава*

**АЛКЫ-САЛКЫЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Акрынаю, сүлпәнләнү. *Йөреше алкы-салкылану*

2) Ялкаулану, иренчәкләнү. *Эштә алкы-салкылану*

3) *күч. сир.* Алмашыну, тотрыксызлану, еш үзгәреп тору (һава, кеше һәм аның характеры турында)

**АЛКЫШ** I *и.* 1) Татар халык авыз иҗатының афористик жанры. *Алкыш алган – аман, каргыш алган – тәмам.* Мәкаль. *Алкышларны «изге теләкләр» дип тә атыйлар. Бу төр афоризмнарның мәгънәсе һәм төп вазифасы сүзнең бик борынгыдан килгән магик-мифологик көченә ышану белән бәйләнгән.* Татар мифологиясе

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса хөрмәт күрсәтү яки котлау билгесе итеп кул чабу. *Зал озак гөжләп торды, әледән-әле алкышлар яңгырады.* Г.Шәрипова. *Суд карарын аклый кайнар алкыш, Ак сакаллы картлар, балалар.* Ф.Кәрим. *Бәйрәм кичәсендә «Ялкын» бию ансамбле егет-кызлары чыгышын да халык яратып тамаша кылды, моның шулай икәнен алкышлар раслады.* Мәдәни җомга

3) Хөрмәт, ихтирам. *Акны яклаган – алкыш алыр, караны яклаган – каргыш алыр.* Мәкаль. *Герасимов монда шул моментны, әрнеп, йөрәгенә алды: ораторның сүзе ничаклы кискен чыкса, халыкның алкышы да шулкадәрле көчле була.* Г.Ибраһимов

**АЛКЫШ** II *и. бор.* Дога, ялвару, динне данлыклау җыры

**АЛКЫШЛА́У** *ф.* Тәбрик итеп, хуплап яки котлап кул чабу. *Халыкның әле бер катлавы, әле икенчесе ораторларның әле берсенә, әле икенчесенә алкышлап кул чаптылар.* Г.Ибраһимов. *Халык, --- шыгрым тулы зал аны, аяк өсте басып, бик озак алкышлады.* Г.Ахунов. *Концерт беткәннән соң, гомеремдә бер генә мәртәбә булса да, зал мине аягүрә басып алкышласа, «бис, браво, афәрин» дип кычкырса, мин үземне гомергә бәхетле санар идем.* Р.Вәлиев

**Алкышлап алу** Бар яктан, бердәм алкышлау. *Аңа ияреп, бүтәннәр дә алкышлап алдылар.* Г.Бәширов

**Алкышлап калу** Алкышларга өлгерү; алкышлап озату. *Күп кенә озатучылар безне алкышлап калалар, ярдан дулкыннарга чәчәкләр сибелә. «Хәерле юл сезгә, кыю егетләр!» дигән сүзләрне җил уңаенда гына ишетеп калабыз.* Р.Ибраһимов

**Алкышлап тору** 1) Бертуктаусыз, һаман алкышлау

2) Әле, хәзер, озак вакыт дәвамында алкышлау. --- *өр-яңа идарә итү ысулы барлыкка килү ихтималын шулкадәр мавыктыргыч итеп сөйләде ки, рәхмәтле аудитория лекторны, аягүрә басып, озак алкышлап торды.* Т.Мөбарәков. *Парижның югары зәвыклы тамашачылары, аягүрә басып, Рудольф Нуриевны ярты сәгать буе алкышлап торалар.* М.Галиев

**АЛКЫШЛЫ** *с.* Алкышлар белән барган, алкышлап кабул ителгән. *Тик шулай да хәзерге пропаганда машинасы коммунистик мафиозиларның дәррәү алкышлы чыгышлары замалыннан берникадәр аерыла.* Сөембикә. *Киңәшмә алкышлы минутлар --- Рәис Миңнехановка ТР автомобиль һәм мотоспорт Федерациясенең истәлек медален тапшыру белән башланып китте.* Ватаным Татарстан

**АЛЛА** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Ислам динендә, бөтен дөньяны яраткан, «бар вә бер» итеп танылган иң югары илаһи зат, аның 99 исеменең иң әүвәлгесе; Тәңре, Ходай. *Тукмә күз яшь: ярдәмендә һәр заманда Алла бар; Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!* Г.Тукай. *Шуны белегез, кадерле балалар, Аллага ихлас күңелдән ышанган, дингә тугрылык саклаган кешедән җинаятьче һичкайчан чыкмаячак.* Р.Әмирхан. *Мәгълүм ки, Җир кешесе өчен табыну затларыннан: иң әүвәл – Алла, икенче – Аның пәйгамбәре, өченче – ана.* Сөембикә

2) *миф.* Мәҗүсилек чорында төрле өлкәләргә караган илаһи көч. *Политеистик дини системаларга – күп санлы аллага, монотеизмга бер генә аллага ышану хас.* Татар мифологиясе

3) *күч.* Табынырлык дәрәҗәдә олылау предметы, табыну объекты; күпчелек тарафыннан ихтирам ителә торган абруйлы, авторитетлы кеше. *Мин ял көннәрендә, махсус Казанга килеп, рус театрының спектакльләрен карый башладым. Островский, Гоголь, Горький, Чехов… Болар Галяның дүрт алласы иде.* М.Мәһдиев. *Алар күптән таныш булганнар, баш врач Шәйхи Маннур дигән язучыны алла урынына күреп табынып яшәгән.* М.Мәһдиев. *Картлык көнендә ул дингә ышана башлады. Авыл советында эшләгәндә, мөһер үз кулында вакытта, ул үзе алла иде.* Ф.Бәйрәмова

**2.** *ы. мәгъ.* 1) Соклану, гаҗәпләнү хисләрен белдерә. *Алла ходаем, зур бүрәнә кылә!* К.Нәҗми. *Ах алла, күрми дә торам, яңа күлмәгең ич…* Ф.Хөсни. *– Алла! Үтерде! Бигрәк югары күтәреп ыргытты.* Ә.Фәйзи

2) Канәгатьсезлек, ризасызлык, килешмәүчелек һ.б.ш. хисләрне белдерә. *Алла, инде бигрәк, әйтмәгән була.* М.Фәйзи. *– Уф алла! Билем, аркам, – дип сыкранганы ишетелә торган булды.* Г.Ибраһимов

3) Хупламау, лаек санамау, җиңелчә көлү һ.б.ш. хисләрне белдерә. *Алла, кем булган!*

4) Әрнү, авырту, курку яки нәфрәт кебек хисләрне белдерә. *Көрәкнең туфракка шомарып кайралган йөзе Габдулланың аяк тирәсендә ялтырады. – Алла! – дип, кинәт кычкырып җибәрде Габдулла…* Ә.Фәйзи. --- *утыра торгач онытылып китә, аш өе ягыннан көйгән ис килә башлагач кына: «Ай аллам!» дип сикереп тора һәм җан-фәрманга казан янына чаба.* А.Гыйләҗев

◊ **Алла әҗерен бирсен** Бәясе Алладан кайтсын, яхшылыкның савабын Ходай үзе бирсен, дигән мәгънәне белдерә. *Бик рәхмәт, бик күп ярдәм иттең инде аңа, Алла әҗерен бирсен.* М.Фәйзи. **Алла бәндәсе** Саф күңелле, беркатлы, карусыз, юаш кеше. *Ишетәсеңме, Алла бәндәсе! Булмый, дип әйтәләр бит инде сиңа!* Г.Ахунов.

*Без кешеләр ләбаса, Алла бәндәләре. Бер-береңә булышу – изге эштер.* Казан утлары. **Алла белә** *к.* **Алла белсен**. *Дим Агыйделгә коя, Агыйдел кая барадыр – анысын бер Алла белә.* Г.Ибраһимов. **Алла белсен** Мәгълүм түгел, билгесез. *Алла белсен, бу китаптан иске дуслар үчләшер! Һич белер хәл юк җиһанны, әллә бар да дуслашыр.* Ш.Бабич. *Акылың, фигылең Алла белә, Зифа буең яратам.* Җыр. **Алла бирсә** *сөйл. к.* **Алла боерса**. **Алла боерса** Берәр эшкә ниятләгәндә, өмет белдергәндә, аның уңышлы үтәлүен теләп әйтелә; насыйп булса, тәкъдирдә язган булса. *Әле Әсмабикәләрдән килешем; аларда бик озаклап чәй эчтем, инде, Алла боерса, алар эшне башларга торалар.* Г.Камал. *Ходаның рәхмәте белән эшне җайласак, сездән бер генә бөртек җылы сүз, миһербанлы вәгъдә алсам, хаҗи аның ишедән генә туктальп тормас, Алла боерса.* Ш.Камал. *– Апаң эшнең җаена төшенеп килә. Алла боерса, өч-дүрт елдан менә дигән умартачы булыр, – ди.* Ф.Яруллин. **Алла бозавы** Бик юаш, карусыз кеше. **Аллага тапшыру** Берәр эшне башлаганда, юлга чыкканда, уңыш теләп тәвәккәлләү. *Соңгарак таба мин күләгәләрнең төшүенә карап юл табарга өйрәндем. Шул вакытта инде торасың да, Аллага тапшырып, бер якка китәсең.* Гали Рәхим. *Шулай байтак икеләнеп утырганнан соң, шактый ук күтәрелеп җылыта башлаган кояшка күз салды. Күрше-тирәдәге чәчүләргә карап алды да аягүрә басып: «Аллага тапшырдык!» – диде.* Г.Бәширов. **Аллага шөкер** 1) Тормыштан риза, канәгать булганны белдерә. *Аллага шөкер, мин дә бөтенләй һөнәрсез малай түгел инде, дип уйладым.* Ф.Әмирхан. *Ерак юлдан килгән кунакны --- миңа алып килергә кирәк иде. Аллага шөкер, ишекнең кай якка ачылганын беләсең.* А.Шамов. *Аллага шөкер, абзар тутырып, сарык асрадык.* Г.Мөхәммәтшин; 2) Артыгы белән күп, зур, бик мул. *Күкрәк тә киң, корсак та Аллага шөкер.* А.Расих. **Алла йорты** 1) Кәгъбәтуллаһ, бәйтуллаһ; 2) *тар.* Борынгы Багдад каласы. *Борынгы Багдад, ягъни Алла йорты каласында һәр мәчеттә әңгәмә корып, бәхәсләшеп утырырга мөмкин булган.* М.Хәбибуллин; 3) Мәчет. **Алла каберен якын итмәсен** Кабере якын булса, гүрдә дә тынычлык бирмәс, шулкадәр явыз, дигән мәгънәдә. **Алла куәт бирсен** Эш өстендәге кешене күргәндә яки авыруның хәлен белгәндә әйтелә торган изге теләк. *Сәлим карт такта яручыларга сәлам ишарәсе күрсәтеп кулын күтәрде дә, пычкы чыжылдавын басып китәрдәй каты тавыш белән: – Алла куәт бирсен! – дип кычкырды.* М.Галәү. **Алла кунагы** Чакырылмыйча, юл төшереп, ләкин бик вакытлы килгән кунак. **Алла кушса** *к.* **Алла боерса**. *Бүген сине, чибәркәй, хәләл җефетеңә илтеп ташларбыз, Алла кушса…* К.Нәҗми. **Алланың биргәненә шөкер** *к.* **Аллага шөкер**. **Алланың биргән көнендә** *к.* **Алланың бирмеш көне.** *Алланың биргән көнендә аның күлмәген-ыштанын алыштырды.* Г.Исхакый. **Алланың бирмеш көне** Һәр көнне, көн саен кабатланып торган бер эш яки хәлгә карата әйтелә. **Алланың каһәре төшсен** *карг.* Кешегә җәфа салучы кемне яки нәрсәне дә булса каты каргаганда әйтелә. *Кадалып кына китсен! Муены астына килсен. Алланың каһәре төшсен! Бары да шуңардан. Бары да шул явыз килененнән!* Г.Ибраһимов. **Алланың кашка тәкәсе** Чин-дәрәҗә я ялган шөһрәт аркасында башкалардан аерылып торган, үзгә булган кеше. *Алар – «югары каста», Алланың кашка тәкәләре, төрмә – «аларның төп йортлары», ирекә чыгып, алар әз-мәз һава үзгәртеп кенә яшиләр дә тиз үк төп йортларына әйләнеп кайталар.* А.Гыйләҗев. *Карагызсана бу чәүчәләк байбичәгә, Алланың кашка тәкәсе диярсең, гел үз мәнфәгатьләрен генә кайгырта, янәсе.* Мирас. **Алланың рәхмәте төшсен** Яхшылык теләгәндә әйтелә. **Алла сакласын** 1) Кемнең дә булса исән, сау-имин яшәвен теләгәндә әйтелә; 2) Хәвеф-хәтәрдән саклану теләге буларак әйтелә. *Ишек төбендә: – Абау, бәреп үтерер, Алла сакласын! – дип чырылдаган хатын-кыз тавышы ишетелде.* Ф.Хөсни. *– Я, атасы, шулай язгандыр инде. Бирик. Алла сакласын, әлләниләр күрербез, – диде ул һәм елап та җибәрде.* Ә.Фәйзи. *Давыл чыкса да, күк күкрәп, яшенле яңгыр башланса да, безнең әби: «Хәвеф-хәтәрдән Алла үзе сакласын», – дип кабатларга ярата иде.* Мәдәни җомга. **Алла теләсә** *сөйл. к.* **Алла боерса**. *Исән-сау кайтсын гына, Алла теләсә, барысын да сөйләп бирермен.* Н.Думави. *Без, Алла теләсә, иртәгә кичкә сәфәргә чыгабыз инде.* Ф.Әмирхан. **Алла язган булса** *к.* **Алла боерса. Алла ярдәм бирсен** *к.* **Алла куәт бирсен**. *Алла ярдәм бирсен мескеннәргә.* Г.Мөхәммәтшин

**АЛЛАЛАШТЫРУ** *ф.* **1.** 1) Аллага тиңләү, илаһи көчкә, кодрәткә ия дип тану; табыну. *Сынга табынучылар дине табигатьне аллалаштыра, ата-бабалар культын тудыра.* Табигатьне буйсындыру юлында

2) Алла итеп күрү, Алла дәрәҗәсенә күтәреп ярату

**2.** *и. мәгъ.* Аллага тиңләү, илаһлаштыру. *Башка халыкларның әкиятләреннән билгеле булганча, бу төр әкиятләргә хайваннарны олылау, аларны изгеләштерү, хәтта аллалаштыру да хас булырга тиеш.* Ф.Урманче

**Аллалаштыра башлау** Аллалаштырырга тотыну

**Аллалаштыра төшү** Бераз, берникадәр аллалаштыру

**Аллалаштырып бетерү** Тәмам, бик нык Аллага тиңләү

**Аллалаштырып килү** Элек-электән үк, күп заманнардан бирле аллалаштыру. *[Кешеләр] Күп гасырлар буена Айны, Кояшны, планеталарны аллалаштырып килгәннәр.* Астрономия

**Аллалаштырып тору** Һәрвакыт, гел аллалаштыру

**АЛЛА́МДЫР** *ы. гади с.* Нәрсәнең дә булса чынлыгына, дөреслегенә ышандырып әйтелә торган ант сүзе: валлаһи, билләһи; икмәктер, чыннан да

**АЛЛАНУ** *ф.* 1) Ал төскә керү, янып торган кызыл, ачык кызыл төс алу, кызыллану (офык һ.б.). *Такыя тау аръягыннан Кояш чыга алланып.* Р.Маннапов. *Таңнар хәзер матур алланалар, Көннәр якты нурга чумалар,*

*Кичләр хәзер яз сафлыгы белән, Яз шатлыгы белән тулалар*. Р.Рахман

2) Пешеп җитү, өлгерә башлау алдыннан ал төс алу, кызару. *Табын әзер, авызга су китереп, ахак күмерләр өстендә шашлык кәчәннәре аллана.* А.Гыйләҗев

3) Оялудан, ачу килүдән яисә салкыннан һ.б.ш.дан йөзгә (тәнгә) ал төс йөгерү, ал төскә керү, кызару. *Резеда Фәритовна болыт пәрдәсе астына кергән кояш кебек алланды.* М.Маликова. *Шушы үзе дә аңлап җиткермәгән эчке төгәллектән, илаһилыктан аның йөзләре алланды, күзләре нурланды.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Аллана бару** Әкрен генә, эзлекле рәвештә арта, көчәя барып ал төс алу, аз-азлап аллану

**Аллана башлау** Алсулык күзгә күренерлек булу

**Аллана төшү** Тагын да аллану; бераз аллану

**Алланып бетү** Тәмам, тулысынча аллану

**Алланып килү** *к.* **аллана бару**. *Күзләрен ача төшеп тәрәзәгә караса, офык инде алланып килә.* Г.Дәүләтказин

**Алланып китү** Кинәт, тиз арада аллану. *Гөлйөземнең бите алланып китте, таң белән килеп кергән хәбәрдән каушап калган хатын сүз дәшмичә генә күз сирпеде.* Ф.Латыйфи

**Алланып кую** Бик азга гына, кыска вакытка аллану. *Факелда җилләр шаяра, Алланып куя һава*. Х.Туфан

**Алланып тору** Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында алланган хәлдә булу. *Тик бер дә төс кунмады, [баланың] бите тимгел-тимгел алланып торды.* А.Гыйләҗев. *Ул элеккедән дә яшәргән, чибәрләнгән, бит очлары алланып тора*. Ф.Садриев

**Алланып чыгу** Кинәт, көтмәгәндә, ниндидер сәбәп белән (психик яки физиологик халәттән) аллану. *Кызларның күзләре шар ачылды, бит очлары китереп суккандай алланып чыкты.* М.Маликова

**АЛЛАСЫЗ** *с.* **1.** Алланың барлыгын танымаган, дингә ышанмаган; дәһри. *Исемем Ибраһим, яшь чагында «Алласыз Ибраһим» дип кушамат биргәннәр иде*. Социалистик Татарстан // Яраксыз, файдасыз, дин таләпләренә туры килми торган. *Мәчеттән клуб ясатып, Алласыз эш кылдым, Иманыма пычрак сулы Ерганакны ердым*. Р.Шиһапов

**2.** *и. мәгъ.* Дингә каршы пропаганда алып баручы, дәһри кеше, атеист. *– Кайттыңмы, алласыз?! – дип ыжылдады ул [бабасы], Василийның аркасына сыдырып*. З.Мәхмүди

**3.** *рәв. мәгъ.* Алланың барлыгын танымыйча, Аллага, дингә ышанмыйча. *Инде менә җитмеш ел без Алласыз һәм динсез яшибез*. Ә.Еники. *Алла юк, ләкин аны ясарга кирәк иде, чөнки кешеләр Алласыз яши алмый*! Р.Мөхәммәдиев

**АЛЛАСЫЗЛЫК** *и.* Алланың барлыгын танымаганлык; динсезлек, дингә ышанмаучанлык, имансызлык; дәһрилек. *Беренчедән, бик чиста, икенчедән, Шәмсия карчык өйдәшенең алласызлыгына бәйләнми.* Ф.Хөсни

**АЛЛА́У** *ф.* 1) Ал итү, алландыру, ачык кызыл төс бирү, кызарту

2) Ал төскә буяу, алга ману, ал төскә кертү. *Чәчрәп аккан каным Идел дулкыннарын аллады*. Р.Харис

3) Биткә ал, ачык кызыл төстәге иннек ягу, иннек сөртеп аллandыру. *Ал битләрең аллама, телең белән баллама*. М.Фәйзи

**Аллап алу** Кыска вакыт аралыгында, тиз генә аллау

**Аллап бетерү** Тулаем яки барысын да аллау

**Аллап кую** Аллаган хәлгә китереп калдыру

**Аллап тору** 1) Һәрвакыт, даими, гел аллау

2) Әле, хәзерге вакытта аллау

**АЛЛАҺ(Ы)** *и. гар. кит. к.* **Алла**. *Йөзеңне кыйблага юнәлдереп, Аллаһның кодрәте алдында тез чүгеп, кылганнарың өчен кичерүен сорап, намазга бас.* Л.Ибраһим-Вәлиди

◊ **Алла(һы, һе, һу) әкбәр** *гар.* 1) Тәкбир («Аллаһ – иң бөек зат») сүзләрен әйтеп, Алланы олылау һәм мактау (азан әйткәндә, мәчеткә барганда, намаз укыганда, тәсбих тартканда кулланыла). *Автомобиль җил тизлеге белән бара, хәзрәт тә, бөтен көче белән кычкырып тәкбир әйтә иде: – Аллаһы әкбәр! Аллаһы әкбәр!..* Ф.Әмирхан. *«Шайтан» дигән сүздән уттай куркып, Чынга алып әнкәм әйткәнне, Бер урынына дистә, йөз мәртәбә Әйтә идем «Аллаһу әкбәр»не.* Ш.Җиһангирова; 2) Ашап туйганнан соң, кул күтәреп дога укыганда әйтелә торган сүз. *Малай, катыкны ашап бетереп, дога укый башлаган иде. «Аллаһу әкбәр» дип догасын тәмамлауга, хәерче салмак кына сәлам бирде.* Р.Батулла; 3) *куч.* Нинди дә булса эшне ахырына кадәр башкарып чыга алу уңаеннан канәгатьлек хисе белән, «тәмам» мәгънәсендә әйтелә. *[Имам хатип Күбәк:] Ходай Тәгаләгә шөкрана кылып, Турайбәкнең тәкъдиме белән килешәм. Аллаһы әкбәр!* Т.Нәбиуллин; 4) *куч.* Көтмәгәндә берәр нәрсәдән колак кагу, кулдан байлык, табыш һ.б. ычкынуга карата яки бетүен белдереп әйтелә. *Җир читеннән алтын бәясенә төшереп ташыган комбикорма кичә бетте. Аллаһы әкбәр!* Р.Зарипов. **Аллаһи-билләһи** *сөйл.* Ант итеп, берәр нәрсәнең чынлыгын раслаганда кулланыла: чынлап әйтәм, дөресе шул, алдамыйм. *Менә шунда йоклаганда, Өлфәт абзый, төннең иң караңгы вакытында тын гына күккә карап ятсаң, аннан көй ишетелә башлый. Әйе, әйе, чынлап менә, аллаһи-билләһи, Өлфәт абзый.* Мәдәни җомга. **Аллаһ рәхмәте** *к.* **Алланың рәхмәте төшсен**. *Ә телефон трубкасын, Аллаһ рәхмәте, Мәгъсүм ага үзе алды*. Ф.Яхин. **Аллаһ сакласын** *к.* **Алла сакласын**. *Билләһи, моннан түбән, тәүбә-тәүбә, Аллаһ сакласын, көянтәмне сындырмам*! Ф.Яхин. **Аллаһы боерса** *к.* **Алла боерса**. *Менә баланы күргәч, җаны түзмәс, килер, Аллаһы боерса, дип юата*. М.Маликова. **Аллаһыга шөкер** *к.* **Аллага шөкер**. *Әмма, Аллаһыга шөкер, күршемдәге иркен холыклы юлдашым, бабайның сүзләрен үзенә кабул итеп: – Әйтеп карагыз, тыңлыйк! – диде.* Ф.Яхин

**АЛЛАҺЫ́ ТӘГАЛӘ** *и. гар. к.* **Алла** (*1 мәгъ.*). *Иншаллаһ, Аллаһы Тәгалә моның өчен беркайчан да рәнҗетмәс үзеңне!* С.Поварисов. *Шулай инде, шулай, туган, барысы да бер Аллаһы Тәгалә кулында.* Ф.Хәбибуллин

**АЛЛАЧЫЛ** *с.* Динле, диндар. *Авторның лирик каһарманы – аллачыл, диндар кеше.* Х.Миңнегулов

**АЛЛЕГО́РИК** *с.* 1) Аллегория эчтәлегендә булган, аллегория алымы кулланылган, аллегориягә нигезләнгән (*сәнгать яки әдәби әсәр, образ, сөйләм һ.б.*) *Әҗәл – биредә аллегорик персонаж.* И.Нуруллин. *Эдик түшәмгә ясаган аллегорик рәсемнәргә күрсәтте.* М.Юныс. *Аларның бер өлеше дини китапларда урын алса, икенчеләре, аллегорик формада, мәсәл жанрына якынайтылып, һиндларның «Панчатантра», гарәпләрнең «Кәлилә вә Димнә»ләрендә күп очрый.* Казан утлары

2) *күч.* Читләтеп әйтелгән, ишарәләп күрсәткән, кинаяле; иронияле. *Мәсәлән, түбәндәге мәкальләр туры мәгънәсендә дә, күчерелмә, аллегорик мәгънәсендә дә кулланылырга мөмкин: «Кояш барда йолдыз күренми»...* Ф.Урманче

**АЛЛЕГО́РИЯ** *и. гр.* 1) Сәнгатьтә (мәс., Урта гасыр сәнгатендә, Яңарыш, барокко, классицизм чорларында) һәм әдәбиятта абстракт төшенчәләрнең нинди дә булса конкрет художество образлары яки формалары ярдәмендә бирелеше (гадәттә читләтеп әйтү өчен кулланыла). *Болар, янәсе, тормышны үзгәртеп, сәерләндереп сурәтлиләр, гипербола, аллегория, символ, гротеск алымнарын мул кулланалар.* И.Нуруллин. *Символлардан аллегория, башлыча, конкрет әйберләргә бөтән мәгънә бирүе белән аерыла.* Әдәбият

2) *ирон.* Яшерен эчтәлектәге мәгънә, кемгә (нәрсәгә) дә булса ишарә, киная. *Бу егет аллегория белән исәпләшеп вакланмый.* М.Юныс

**АЛЛЕГО́РИЯЛЕ** *с. к.* **аллегорик**

**АЛЛЕГРЕ́ТТО** *рәв. ит. муз.* **1.** Музыкаль әсәрне башкару темпы: уртача дәрәҗәдәге тизлектә, җиңел

**2.** *и. мәгъ.* Шушы темпта башкарылган музыкаль әсәр яки аның бер өлеше

**АЛЛЕ́ГРО** *рәв. ит. муз.* **1.** Музыкаль әсәрне башкару темпы: тиз, йөгерек, кызу, җәһәт. *Уйнаганда, миңа, бу җирендә – анданте (салмаграк), бу төшендә – аллегро (кызурак), дип әйтеп тә тора.* Ә.Еники

**2.** *и. мәгъ.* Шушы темпта башкарылган музыкаль әсәр яки аның бер өлеше. *Симфония түбәндәге бүлекләрдән тора: беренче бүлек – аллегро, ягъни тиз башкарыла торган музыка; икенче бүлек – анданте, ягъни салмак башкарыла торган, өстәвенә лирика белән сугарылган музыка; өченче бүлек – менуэт (аристократлар даирәсендә башкарыла торган нәзакәтле бию) яисә скерцо, ягъни шаян өлеш; дүртенче бүлек – финал, кагыйдә буларак, кабатлану нигезендә башкарыла.* К.Гыйззәтов

**АЛЛЕРГЕН** *и. гр. мед.* 1) Аллергия барлыкка китерә, аллергия бирә торган матдә. *Аллергеннар 4 төргә бүленәләр: серкәләр, ашамлыклар, көнкүреш һәм эпидермаль аллергеннар.* Мәйдан

2) Аллергия авыруларына диагноз кую һәм аларны дәвалауда кулланыла торган препаратлар

**АЛЛЕ́РГИК** I *с.* Аллергия китереп чыгара торган, аллергия бирә торган. *Аллергик сәбәпләрне әйтеп үтик – мәсәлән, өй тузаны, йорт хайваннарының йоны, үсемлекләрнең серкәләре, ашамлыклар һ.б.* Мәйдан

**АЛЛЕ́РГИК** II *и. рус* Аллергия белән авыручы кеше

**АЛЛЕРГИ́Я** *и. гр.* Организмның кайбер ярсыткыч матдәләр тәэсиренә нормаль булмаган реакциясе (гадәттә тәнгә, биткә кызыл таплар чыга һәм кеше авыру халәте кичерә: температурасы күтәрелә, тәне кычыта, күңеле болгана һ.б.). *Инде рәтләнеп кенә килә дигәндә, Маратның бөтен йөзе, тәне, шешеп, ямьсез таплар белән капланды, ул көне-төне акырды. Врачлар, аллергия, диделәр.* Ф.Садриев. «*Аллергия*» *дигән нәрсәне беләсеңме син, инженер?* А.Гыйләҗев. *Шул бала һич авырудан мантый алмады. Аллергия.* Н.Хәсәнов

**АЛЛЕРГО́ЛОГ** *и. мед.* Аллергология белгече, аллергология табибы. *Авыруга вакытында аллергологка килү кирәк.* Мәйдан

**АЛЛЕРГОЛО́ГИЯ** *и. гр. мед.* Аллергия барлыкка килү сәбәпләрен, чирнең билгеләрен, барышын, авыруга диагноз кую һәм аны дәвалау ысулларын, чараларын өйрәнә торган медицина фәне тармагы. *Хәзерге көндә аллергология үсә бара.* Мәйдан

**АЛЛЕ́Я** *и. фр.* Як-ягына агачлар, куаклар яки чәчәкләр утыртылган юл; парклардагы, шәһәр бакчаларындагы юл. *Иртән ул, бакча аллеясындагы агач эскәмиягә чыгып утырып, ярты сәгать чамасы кытай гимнастикасы белән шөгыльләнә.* М.Мәһдиев. *Мин үземне хәзер лаләләр аллеясында итеп хис кылам.* Г.Кутуй. *Анда каршы яктагы тын аллеяда бала арбасы тәгәрәтүче бер яшь хатыннан бүтән кеше күренмәде.* Г.Тавлин // Як-ягына сугышта һәлак булганнарның, берәр өлкәдә танылган затларның һәйкәлләре, исемнәре куелган юл. *Шул паркның нәкъ урта бер җирендә «Батырлар аллеясы»на нигез салынып, --- каһарманнарыбызга һәйкәлләр куелды.* Ш.Мостафин

**АЛЛЕ́ЯЛЫ** *с.* Аллеясы булган (*юл, парк*). *Ә син --- Шундый бер уңайсыз хәлдә калып, Аллеялы юлдан киткәнсең.* Н.Баян

**АЛЛИГА́ТОР** *и. ингл.<исп.* 1) Америкада һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядә яши торган крокодилларның бер төре. *--- безнең песнәккә охшаганрак ике кошчык нидер чүпләнеп йөри. Әгәр крокодил авызын шап итеп япса, шунда калалар бит инде. Әмма аллигатор ник бер селкенеп карасын.* Р.Ибраһимов

2) **аллигаторлар** *күпл.* Тешләре, авызын япканда, тулысынча казналыгы белән томаланусы, авызының очы тупыйграк булуы, бары тик төче суларда гына яши алуы белән аерылып торган крокодилларның аерым бер семьялыгы (бу семьялыкка аллигаторлар һәм кайманнар керә). *Крокодиллар, аллигаторлардан аермалы буларак, тел очларындагы һәм яшь бизләре аша, тәнәрендәге артык тозны бүлеп чыгару сәләтенә ия, шуңа күрә алар тозлы суларда да яши ала*

**АЛЛИТЕРА́ЦИЯ** *и. лат. әд.* Шигырь төзелешендә: әсәр яңгырашының аһәңлелеген көчәйтү өчен, бер төрле тартык авазларны еш кабатлау юлы белән ясалган алым. *Рифмасыз шигырь бер-ике табышмакта гына күренеп китә. Бу очракта аһәңдәшлек аллитерация һәм ассонанс хисабына хасил*

*була.* Х.Мәхмүтов. *Аллитерация – сөйләмне яки әсәр телен авазлар ягыннан оештыруның бер төре.* Әдәбият

**АЛЛИТЕРА́ЦИЯЛЕ** *с. әд.* Аллитерациягә нигезләнгән, аллитерация ысулында язылган. *«Димче диңгез кичерер» дигәндәге сүзләр әйтерсең лә аллитерацияле рифмалардан гына төзелгәннәр!* Х.Туфан. *Яңгырау характерына карап, төгәл һәм төгәл булмаган, бай, ярлы, кушма, рәдифле, аллитерацияле, ассонанслы һ.б. төрле рифмаларны аерып күрсәтергә була.* Г.Нуриев

**АЛЛО** *ы. ингл.* Шалтыраган телефонның трубкасын алгач, «тыңлыйм» яки «тыңлагыз» мәгънәсендә, эндәшү сүзе буларак кулланыла. – *Алло! – Әюпов телевизорның тавышын акрынайтты. Майя шалтырата иде.* Ә.Мушинский

**АЛЛОМОРФ** *и. гр. лингв.* Тиңдәш мәгънәгә ия булган, әмма бер-берсеннән кулланышының морфонологик шартлары белән аерылган морфлар (мәс., *халык – халк-ым, озын – оз-аю* һ.б.). *Флектив телләрдә, шул исәптән рус телендә, алломорфлар һәм морфның фонетик төрләре аерылалар, алломорфлар – морфонологиядә, морфның фонетик вариантлары фонетикада җентекләп өйрәнелә.* Татар грамматикасы

**АЛЛОПАТ** *и. рус* Эш тәҗрибәсендә аллопатия методлары белән дәвалаучы табиб

**АЛЛОПА́ТИЯ** *и. гр.* Гадәти дарулар кулланып, дарулар ярдәмендә дәвалау системасы (гомеопатиягә каршы мәгънәдә)

**АЛЛЫ** *с.* Ал төстәге, ал төсмерле; ал бизәкле. *Аллы күлмәккәеңне ки, Бит очларың аллансын.* Җыр. *Җепләре бигрәк матур, Кызыллы, аллы икән. Болында бит кибет юк, Кайлардан алды икән?* Йолдыз

**АЛЛЫ́-АРТЛЫ** *рәв.* 1) Бер-бер артлы, берсе артыннан икенчесе, рәт белән. *Хәзер урман шулкадәр куе иде, безнең юлчыларга аллы-артлы барырга туры килде.* Г.Гобәй. *Сәгать ярым узмады, идарә каршына аллы-артлы ике «УАЗ» килеп туктады.* Г.Кашапов. *Шуңа күрә Сәрвия белән Галияр өске яктагы сукмактан аллы-артлы бардылар.* М.Хуҗин

2) Бер кешенең яки нәрсәнең алдыннан һәм артыннан. *[Милиционерлар] Тагын аллы-артлы саклап, Мотаһирны урамга алып чыктылар.* Р.Кәрами

3) Нәрсәне дә булса җилкәнең ике ягына: берсен алга, икенчесен артка каратып. *Шулвакыт, аларның әңгәмәләрен бүлеп, сөттән бушаган --- әрҗәләрен аллы-артлы асып, Зәмзәмбикә килеп керде.* М.Хәсәнов. *Мотаһир аллы-артлы аскан йөген, янтаеп, иңеннән төшергәндә, арттагы бәндә аның муен тамырына китереп сукты.* Р.Кәрами

4) Кыска вакыт аралыгында, бер-бер артлы, берсен икенчесе артыннан бастырып. *Алар шулай аллы-артлы авылга кайтып керәләр.* Хәйдәр

5) Бер-бер артлы, берсе икенчесеннән соң (мәс., *искә төшү, вакыйгалар булу*)

6) Әле алга, әле артка (*бару, йөрену*). *«Соңгы вакытларда мондый мәҗлесләр арыта башлады», – дип, аллы-артлы йөренеп алды.* М.Сәлимҗанов

**АЛЛЫ́-ГӨЛЛЕ** *с.* **1.** 1) Төрле ачык төсләрдәге. *Алан тиз арада ямь-яшел булды, аллы-гөлле чәчәкләргә күмелде.* Р.Фәизов

2) Ал, аксыл кызыл, сыек кызыл, кызгылт ак һ.б.ш. төсле бизәк(ләр) төшерелгән, рәсемнәр ясалган, чигелгән, тегелгән, шундый төсләр белән буялган. *[Диләрам] Урындыкка утыргач, вак толымнарының берничәсе яңагына төште, башын түбән игәнгә, түбәтәе өстендәге аллы-гөлле чигешнең бөтен бизәкләре күренде.* М.Маликова. *[Чиләкләрнең] Тышлары аллы-гөлле бизәкле, эчләре ялтырап тора иде.* Р.Хафизова

3) Җемелдәп торган, җемелдәвекле. *Хәзер алай йөри алмыйм, утыз-кырык адым атлауга башым әйләнә, күз алдымда аллы-гөлле, күкле-яшелле, сарылы-кызыллы очкыннар бии башлый.* Г.Тавлин. *Ул керфекләрен йома, күз алдында аллы-гөлле тәңкәләр биешә.* Н.Хәсәнов

4) *күч.* Якты, гаҗәеп матур, искиткеч гүзәл (киләчәк, өмет һ.б. турында). *Тыңлаган кешеләрнең күз алдына ул сөйләгән вакыйгалар аллы-гөлле чынбарлык булып килеп баса.* В.Юныс. *Әлегә барысы да бәхетле, дөнья аллы-гөлле төсләргә буялган иде.* Т.Галиуллин

5) *күч.* Берәр кемгә яки нәрсәгә яраргa тырышып эшләнгән, мактап күрсәтелгән; арттырып әйтелгән. *Нәчәлство якты йөз күрсәткән иде, икенче көнне үк, гәҗит тутырып, аллы-гөлле мәкалә язып чыкты.* Т.Миңнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Төрле ачык төсләр булып; ачык, якты төсле итеп. *Зиһеннәре чуалмаган кешеләргә Минем халәт – бер юләрлек, чын менә. Ак һәм кара бу дөнья, дип кабатласам, Синең сурәт аллы-гөлле күренә.* Ф.Мөслимова. *--- бер акланның бер башында аллы-гөлле киенгән авыл кызлары тупланган.* А.Таһиров

**3.** *хәб. функ.* Әйбәт, кулай, яхшы; теләгәнчә булу, шома бару турында. *[Самат:] Айлар буе барысы да көйле иде, Эшләребез җайлы, аллы-гөлле иде.* Т.Миңнуллин

**АЛЛЫ́-ЗӘҢГӘРЛЕ** *с.* Ал һәм зәңгәр төсләре булган. *Аллы-зәңгәрле ленталар тагып, шомырт кара күзләреңне сирпеп, сикергәли-сикергәли, әллә кайдан гына килеп чыктың.* Ф.Хөсни. *Аллы-зәңгәрле электр лампалары белән яктыртылган международный вагонның урта купесында киң өлгеле тәрәзәдән Юныс Вәлишин йөзе чагылып үтте.* К.Нәҗми

**АЛЛЫК** *и.* Ал төс, ал төстәге күренеш. *Аның бит алмаларыннан шәфәкъ аллыгы йөгереп үтте.* Х.Сарьян

**АЛЛЫ́-КАРАЛЫ** *с.* Ал һәм кара төсләре булган

**АЛЛЫ́-КҮКЛЕ** *с.* Ал һәм күк төсләре булган

**АЛЛЫ́-КЫЗЫЛЛЫ** *с.* Ал һәм кызыл төсләре булган. *Әүвәле башта, күз тимәсен өченгә, колынның маңгай чәченә артыш ботагыннан нәни генә тияк ясап тактым, ялына аллы-кызыллы чуклар бәйләдем.* Г.Бәширов

**АЛЛЫ́-САЛЛЫ** *рәв.* Эленке-салынкы, алпы-салпы, аннан-моннан, тырышмыйча гына. *Җанын-тәнен җәлләмичә эшләгән колхоз белән аллы-саллы*

*йөргән колхозлар хезмәт көннәренә бер дәрәҗәдә уңыш бүләргә тиеш түгелләр*. Т.Гыйззәт

**АЛЛЫ́-САРЫЛЫ** *с.* Ал һәм сары төсләре булган

**АЛЛЫ-ШӘМӘХӘЛЕ** *с.* Ал һәм шәмәхә төсләре булган. *Буа артындагы аллы-шәмәхәле сулы тобага җил мендәр-мендәр җирән күбек куып кертте дә туктаусыз әйләндерергә кереште.* Ә.Гаффар

**АЛЛЫ́-ЯШЕЛЛЕ** *с.* Ал һәм яшел төсләре булган. *Аңлаган кеше кебек, алдындагы аллы-яшелле саннарга, рәсемнәргә баккан була, шуннан соң гына ачкычны бора*. Т.Галиуллин

**АЛЛЮВИЙ** *и. лат. геол.* Су ташыган вакытта, су агымы нәтиҗәсендә, комнан, чуерташлардан, вак ташлардан барлыкка килә торган катламнар, утырмалар

**АЛЛЮР** *и. фр.* **1.** Атның чабып бару яки йөрү рәвеше (мәс., юырту, атлап бару, чабып бару)

**2.** *ы. мәгъ.* Тиз арада кит, китеп бар, мәгънәсендә. *Киттек! Турагентствога барып путёвка алабыз да, и аллюр!* Х.Ибраһимов

**АЛМА** *и.* 1) Алмагачның җимеше. *Алмалар пешкән чак*. М.Юныс. – *Алма сатарбыз, – диде Хәлим. – Алма... Алма ул әле кайчан өлгерә.* И.Гази

2) **алмасы** *тарт. форм.* Күзнең түгәрәк рәвешендәге урта өлеше, үзәге. *Кысыла төшкән күзләре эчендә йөргән кара алмаларыннан да, вакыт-вакыт мимылдап куйган юка күгелҗем иреннәреннән дә авыр уйларыннан котыласы килгәнлеге әллә кайдан аңлашылса да, сүзне Нурисә башлады*. Р.Харрасова

3) Хайваннарның тиресендәге төп төс өслегендә ак яки кара, күгелҗем һ.б.ш. түгәрәк тап барлыкка китергән йон төкләре

4) *сөйл.* Алмагач. *Һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке – миләшчә, алманыкы – алмача!* Г.Исхакый

5) **алмам** *куч. тарт. форм.* Гашыйкларның берсе, сөйгән яр. *Ярты алмам, ярты алмам кайда? Үземнекен ничек табарга? Сайлап алган ярым хата булса, Ялгышырлар башка ярлар да.* Ф.Мөслимова

◊ **Алма бит(ле)** Бите, йөзе матур, чибәр булган; алсу түгәрәк битле. *Әй алма бит, алма бит, дип, Алма битләр кала бит, дип, Җырлый-җырлый моңаям да Елап кына юанам.* Ф.Мөслимова. *Кызлары да кызлары – Алсу алма йөзләре, Ялкауларга яр булгач, Акаядыр күзләре.* Такмак. **Алма йөз(ле)** *к.* **алма бит(ле)**. **Алма кебек** Бик матур, искиткеч гүзәл, сылу. *Башыма әллә нинди уйлар, күз алдыма алма кебек улым белән кызым һәм җәмәгатем килде.* Т.Нәҗмиев. **Алма кисәгем** Иң якын, яраткан, сөйгән кешегә яисә сөйләмгә ягымлылык өстәү өчен әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *[Автобусны] Үткәреп җибәрүне сорап, кызга ялынып-ялварып карадылар, «җаным, бәгырем, алма кисәгем»не әйтеп карадылар, ләкин ул берничек тә игә килмәде.* Ш.Бикчурин. **Алма төсле** *к.* **алма кебек.** *[Онык] Үсеп килә сылу булып кына, Алсу алма төсле тулып кына! Алмаз төсле затлы булып кына!..* Р.Миңнуллин. **Алма төшәрлек урын булмау (калмау)** Бик тыгыз, кеше бик күп булу, басып (утырып) тору өчен урын бетү. *Кичә тархан Әхмәт, иртәгә барысы да хәл ителәчәк, дип тынычландырып җибәргән иде, таң белән янә килеп тулганнар – мәйданда алма төшәрлек урын да калмаган.* М.Хәбибуллин. **Алма шикелле** *к.* **алма кебек.** *Күзләреңнән күреп торам, би-и-ик чибәр, би-и-ик сылу, алсу алма шикелле би-и-ик татлы шаһиңгә өйләнәчәксең тиздән.* Л.Лерон

**АЛМА́ АПА** *и. диал.* Балаларның әниләренең бертуган кече сеңлесенә мөрәҗәгать итү сүзе. *Рәсимә – башкомандующий урынында, кияүләр аңа барысы да «апа» дип, сеңелләре исә төрлечә, исем белән дә, «апа» дип тә, «дәү апа», «алма апа» дип тә дәшәләр.* М.Мәһдиев. – *Гөлсем апа! Алма апакаем! – дип чәр кычкырып, ярсып елыйелый, эне-сеңелләре төрле яктан килеп ябырылдылар.* В.Имамов

**АЛМАГАЧ** *и.* Розачалар семьялыгыннан, хуш исле алма бирә торган җимеш агачы. *Чөнки ул бер алмагачка төрле токым алмагачларның тармакларын тоташтырган.* Г.Кутуй. *Урманда кыргый алмагач ялгыз үсте.* Р.Гаташ. *Мәктәп артындагы «Аю күле» дигән үзән кырда колхоз берничә меңтөп алмагач утырткан булган.* Р.Сибат

**АЛМАГАЧЛЫК** *и.* Алмагачлар үскән урын; алма бакчасы. *Инде картая башлаган алмагачлыкны үзенеке итеп тою кыз белән егетнең соңгы сөйләшүеннән соң туды.* Р.Сибат

**АЛМА́-ҖИЛӘК** *җый. и.* Алма, җиләк һәм башка шундый төрле-төрле җимешләр. *Бәләкәй чакта мин ул бакчага барганымны, алма-җиләк ашаганымны хәтерлим.* С.Сөләйманова

**АЛМАЗ** *и.* **1.** 1) Үзенең ялтыравы һәм катылыгы белән башкалардан өстен булган минерал. *Ни генә юк анда – алтыны да, бакыры да, тимере дә, мәрмәре дә, нефтегазы да, гәүһәр ташлар, алмазлар – барысы да бар...* Ф.Бәйрәмова. *Ләкин тәҗрибәле остазның очлы күзләре бу чын алмазның әле байтак кыр-кабыргаларын шомартырга кирәклеген дә абайлап алды.* Р.Вәли

2) Үтә күренмәле, кырланган һәм шомартып ялтыратылган кыйммәтле асылташ. *Ашлыкның һәр бөртеге – алмаздан, алтыннан кыйммәтрәк.* Б.Камалов

3) Пыяла кисү өчен, кечкенә сапка шул ташны беркетеп ясалган корал. *Менә ул --- пыяланы кысты, чак кына уңга янтайды һәм --- кулындагы алмаз белән «чыж-ж» иттереп йөртеп алды.* А.Гыйләҗев. *Алмазны күкрәк кесәсеннән чыгарып, бик кадерләп төргән ак яулыгымнан алдым да пыяланы кирәк урыныннан чыжылдатып кына сыздым.* Г.Бәширов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул материалдан эшләнгән, шундый таш уеп утыртылган. *Әбинең сандыгында алтын беләзекләре белән алмаз кашлы йөзекләре һәм ике билеты бар.* Ш.Мөхәммәдев. *Анда – алтын-көмеш акчалар, муенса, беләзек, алмаз ташлар, тагын бик күп төрле бизәнү әйберләре...* Р.Сәгъди

2) *куч.* Елтырап торган. *Сөмбеләнең алмаз яшьләре шунда эзсез сеңеп бара...* А.Гыйләҗев

3) *куч.* Каты һәм нык; үткен. *Алып кайтты алмаз кылычында Ил саулы-*

*гын, җиңү шатлыгын.* М.Җәлил. *Җил анага улларының сугыш кырында алмаз кылычлары кулларыннан төшмәве, соңгы тамчы каннары тамганчы көрәшүләре турындагы изге хәбәрне алып килә.* С.Поварисов

4) *күч.* Бик кыйммәтле, кадерле нәрсә. *Балкып торган, үзенә тартып торган «Татарстан» дигән бу алмаз – Хәтәр елларда да югалмады, Президентлы чакта югалмас, Югалмас!* Р.Низами. *Сабырлыклар – алтын, сүзләр – көмеш, Күзләр, дөрес, алмаз бәясе. Яши-яши аңлый икән кеше Һәр нәрсәнең үлчәм мәгънәсен.* С.Якупова

5) *күч.* Берәр нәрсәнең нигезен, үзәген чагылдырган; үзенә иң әһәмиятлесен алган. *Телнең үсеш хасияте дә шулай: дәверләр буена берничә сүз берләшеп чарлана-чарлана килә дә, ниһаять, тыгыз кысылып, алмаз ядрә булып йомарлана, төп сүзне хасил итә.* М.Галиев

**3.** *хәб. функ.* Бик яхшы, бик әйбәт; үткен, очлы. *Белекченең күзләре алмаз иде, ул алай да күзлек киде.* Н.Гыйматдинова

**АЛМАЗЛАНУ** *ф.* Алмаз кебек булу, алмаз шикелле ялт-йолт итү. *Яланнар, урманнар, болыннар иртәнге чык белән алмазландылар.* Г.Ибраһимов

**Алмазланып тору** Әле, хәзер, күз алдында алмазланган хәлдә булу

**АЛМАЗЧЫ** *и.* 1) Алмаз чыгаруда яки эшкәртүдә эшләүче

2) Алмаз ташларын кыру, уеп утырту буенча белгеч; ювелир

**АЛМА́ КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол.* Вак күбәләкләр төркеменнән корткыч күбәләк; *русчасы:* **плодожорка яблонная**

**АЛМАЛАНУ** *ф.* 1) Алмагач алмага җимешләнү, алмагачның, чәчәкләре коелып, җимешләре барлыкка килү. *Алма алмаланган чак та кебек.* Т.Нәҗмиев

2) *күч.* Алсулану, алсу төс йөгерү, алмага охшап тору. *Тик очынып бию-дән алмаланган йөзе генә елт-елт күренгәләп ала.* Н.Нотфуллина

**Алмалана бару** *к.* **алмаланып бару**

**Алмалана башлау** Алмаланырга тотыну

**Алмалана төшү** Бераз алмалану

**Алмаланып бару** Акрынлап, алмалар барлыкка килә башлау

**Алмаланып җитү** Алмаланган хәлгә килү, тулысынча алмалану

**Алмаланып килү** Акрынлап алмалану

**Алмаланып тору** Әле, хәзер күз алдында алма сыман булып күренү. *Яңа туган сабый димәссең – яңа тулган ай диярсең: бит очларың туа-туышка алмаланып тора.* Ә.Галиев

**АЛМАЛЫ** *с.* 1) Алма бирә торган, алма күп булган. *Алмалы ел иде ул!* Р.Фәйзуллин. *Яшь күңелләренә тәүге кайнар сөю хисе килеп тулган ул ел әнә шул кояшлы, җылы, матур, алмалы сентябрь көнендә башланды.* Ә.Хәсәнов

2) Алмасы булган. *Мин утырам агачта, Алмалы алмагачта.* Л.Шәех. *Бүген ул --- үзен өйрәнде. Тар маңгай, эчкә баткан сары алмалы күзләр, җилкәгә үк сыланып утырган имән муен.* Т.Галиуллин

3) Алма кушып әзерләнгән, алма катнаштырылган. *Моннан тыш әле уылдыклы бутерброд, яшел борчаклы бутерброд, эремчекле бутерброд, алмалы бутербродлар бар...* Матур буласың килсә

4) Алма кебек бизәк (рәсем) төшерелгән; эре-эре бизәкләре булган. *Безнең кызлар суга бара, Чиләкләре алмалы. Алмалы чиләкләренә Кунмаган кош калмады.* Җыр. *Аның нәфис гәүдәсен нәкъ менә шушы алмалы күлмәктә, ап-ак зур чиләкләр тагын да матурлаталар.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Якты, матур, искиткеч гүзәл (киләчәккә өмет һ.б. турында). *Азмы – алмалы хыял алдады!* Ф.Яруллин

**АЛМАЛЫК** *и. к.* **алмагачлык**. *Тау буйлары – алмалык. Үкенечкә шунсы калды: --- Бергә була алмадык.* Р.Вәлиуллин. *Алмаларсыз калган алмалык.* Х.Хөснуллин

**АЛМАН** *и. гар.* 1) Телләре һинд-европа семьялыгының герман төркеменә караган, Германиядә яшәүче төп халык атамасы (үзатамалары – *дойче*). *Без аларны «җәлилчеләр төркеме» дип йөртсәк, алманнар исә аларны «Курмашев группасы» дип атый.* Р.Мостафин. *Тимергалиев урыс, француз, алман телләрен яхшы белә.* Х.Миңнегулов. *Менә шулай алман җире Йотып калды гүзәлне.* Ә.Хәсәнов. *Үзем дә юлга чыгар алдыннан Казанда алмаштырып алган барлы-юклы алман маркаларын саклар өчен хатынга биреп куюыма куанып бетә алмадым.* Н.Әхмәдиев

2) Шул халыкның бер кешесе. *Безгә бик кызык эчтәлекле бер хат килде: Алманиядә эшләүче төрек егете алман кызына өйләнгән.* Инсан һәм дин

**АЛМА́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Алман телендә. *Француз белән – французча, инглиз белән – инглизчә, алман белән алманча теттереп сөйләшәләр.* Х.Сарьян

2) Алманнарча, алман халкындагыча. *Ә ул урысча, ләкин сизелерлек (алманча дип әйтимме) акцент белән әйтә куйды.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Алман теленә караган, алман телендә булган. *Әдипнең [Г.Исхакыйның], татар теленнән тыш, төрекчә, гарәпчә, урысча, полякча, французча, инглизчә, әрмәнчә, алманча һәм кайбер башка телләрдә язылган яисә басылган материаллары да бар.* Х.Миңнегулов

**АЛМАС** *и. к.* **алмаз**. *Шулвакыт егет, алмас кылычын чыгарып, диюнең тугыз башын тугыз җиргә кисеп ташлады да үзе сарайга керде.* Әкият. *Аның кесәсендә кулъяулыкка төргән алмазы була иде, Шәйхи аны «алмас» дип йөртә иде.* М.Мәһдиев

**АЛМАСАР** *с. диал.* 1) Билгесезлек һәм кыюсызлык халәтендә булган, кыюсыз һәм икеләнгән. *Аягыңа калуш алсаң, алмасар булма, начары туры килмәсен.* Д.Рамазанова

2) Йөдәгән, газаплы, боек. *Ярый ла күңеле Булмаса алмасар.* С.Хәким. *Алмасар булма, җанашым, Насыйп түгел яр өчен.* Җыр

**АЛМАСАРЛАНУ** *ф. диал.* Алмасар булу; алмасар булып йөрү

**Алмасарлана калу** Алмасарланган халәттә булу; шундый халәт кичерү. *Көн инде кичкә авышкан, Балҗанның хәрби госпитальдәге эш вакыты тәмамланып килә иде. Шуңа күрә ул чыннан алмасарлана калды.* Т.Әйди

**АЛМАСАРЛА́У** *ф. диал.* Юмалау, алдап ышандыру, өметләндерү

**Алмасарлап йөртү** Озак вакыт алмасарлау. *Мине алмасарлап йөртмичә, шул чагында ук дөресен әйтеп ташлавы әйбәт булган әле.* Ә.Фазылҗанов

**АЛМА́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кирказончалар семьялыгыннан, шуышма сабаклы күпьеллык шифалы үлән (медицинада кулланыла); *русчасы:* **кирказон.** *Кирказон яки алма үләне ыругы – күпьеллык үләнчел үсемлекләр, я үрмә куаклар* (*лианалар*). Л.Мәүлүдова

**АЛМА́ЧА** *рәв.* Алмагачның алмасына хас булганча, алмагачның алмасы шикелле. *Хәлил Гөлсемнең күзенә бик мәгънәле иттереп карады, балаларны күздән кичерде: «Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке – миләшчә, алманыкы – алмача!» – диде.* Г.Исхакый

**АЛМА́ЧУАР** *с.* **1.** 1) Аксыл, каралҗым түгәрәк (алмасыман) таплары булган җирән яки күк төстәге (ат турында). *Яшел эшләпәңне киеп, алмачуар атка менеп аласың да, иртә таңнан кояш баеганчы, син шунда – яшеллек кочагында.* Р.Төхфәтуллин. *Хыяллана бит инде Хәмит, бәләкәй алмачуар бияне шуңа җигәм, дип.* З.Зәйнуллин

2) Төрле төстәге таплары, бөрчекләре булган; ала-кола, чуар. *Әнисе шулай дип җавап кайтарды, үзе башындагы алмачуар яулыгыннан да битәр кызарды.* Х.Хәйруллин

**2.** *и. мәгъ.* Аксыл, каралҗым түгәрәк таплары булган җирән яки күк ат; ат кушаматы. – *Чү Алмачуар, таптатма!* Н.Гыйматдинова. *Бәхәссез, ат шәп, Алмачуар кебек ат Болгарда бер иде.* М.Хәбибуллин. – *Алмачуар алдан киләчәк! – диде Әмир.* Р.Зәйдулла

**АЛМА́ЧЫ** *и.* 1) Алма үстерүче. *Әнә утыра безнең алмачылар, начармыни, әйтеп карагыз!* М.Җәлил

2) Алма сатучы

**АЛМАШ** *и.* **1.** 1) Алмаштыручы, алмашка килүче. *Беренче класста шуларны хәтерләткән йә шук, йә тыңлаусыз балалар була икән, күңелдән: «Фәлән малайга алмаш килде инде!» – дип уйлап куймыйсыңмыни?* Я.Зәнкиев // Алмаштыра торган, шуның урынына кулланыла торган әйбер. *Йөзәрләгән эшче, куәтле техника бер-ике елда кырган агач урынына алмаш утырту өчен, дистәләгән ел кирәк.* Г.Якупова. *Горкида урнашкан аптекага кереп, бер сәгать эчендә Сакманов барлык кирәкле даруларны күтәреп чыкты. Тик берсенә генә алмаш биргәннәр.* Т.Галиуллин

2) Хезмәт урынында, постта һ.б.ш.да бер-берсен алыштыручы, эш сәгате бетүгә, икенчесе, килеп, аның эшен дәвам итүче; сменадаш. *Дежурда корымга буялып беткән соры бушлат кигән әрмән егете Папаян белән рус Менькаев төнгә кадәр, алмаш килгәнче булачаклар.* С.Шәрипов. *Бер тәүлектән алмаш җибәрәм, дип Калган иде кече лейтенант.* Г.Сәгыйров // Эштән азат ителүче урынына аның вазифаларын үтәү өчен билгеләнгән икенче кеше. *Һәр председатель бу эшне үзеннән соңгы алмашына калдыра килде.* Н.Хәсәнов

3) Өлкән буын кешеләрен алмаштыручылар, аларның эшен дәвам итүчеләр (гадәттә яшь буын турында). *Хәзер алар вахтага басты, бабайларына, аталарына алмаш үсте.* Ә.Хәбибуллин. *Юк, арттан ияреп килүче яшь көчләр күренми. Алмаш күрмим.* Ф.Сафин. *Мондый күңелсезлекнең бер сәбәбен тәҗрибәле белгечләрнең үзләренә алмаш әзерләмәүләреннән, бәлки, әзерли алмауларыннан эзләргә кирәктер.* М.Госманов

4) *грам. иск.* Алмашлык. *Сорауны аңлата торган алмашлар сөаль алмашы булалар.* Ж.Вәлиди. *Декламация тибындагы шигырьләргә күз салсак, аларда күбесенчә «без», «сез» кебек алмашларны күрәбез.* Г.Нигъмәти

**2.** *с. мәгъ.* 1) Берсе урынына юылганы, чистасы яки яңасы булган; берсен салып, икенчесен кия торган, алмаштыра торган. *Сөлге, алмаш күлмәк алып, Габдрахман мунчага китте.* М.Юныс // Бер-берсен алмаштырып торган, берсе икенчесен алмаштыру өчен тотылган. *Аннан, ике көнгә бер, пайтәхеткә алмаш җайдаклар чаба.* Ф.Латыйфи. *Кибәкне алмаш арбаларга җыялар, ә саламны, бөтен килеш, тезем ясагыч ярдәмендә, теземләп салып чыгалар.* Урып җыю машиналары // Берсе урынына икенчесе кулланыла торган. *Кеше, алмаш исемнәр кулланып, сүзнең тылсым көченнән файдаланырга, үзе өчен хәвефле затны сүз ярдәмендә зарарсызландырырга, буйсындырырга, яхшы якка үзгәртергә омтылган.* Х.Мәхмүтов

2) Хезмәт урынында, постта һ.б.ш.да бер-берсен алыштырган, эш сәгате бетүгә, икенчесе аның эшен дәвам иткән. *Август ахырларына кадәр Рәхилә әнисе белән бергә җәйләүгә йөрде, алмаш савымчы булып эшләде.* Ф.Сафин // Алмашлап, чиратлап эшли торган; алыштырылган. *Барлык комбайннарның да басуда була алмавының икенче сәбәбе – алмаш сменага кеше җитмәү.* И.Низамов

3) Өлкән буын кешеләрен алыштырган, аларның эшен дәвам иткән. *Мөмкин булган бар чаралар белән бу хәзинәне ишәйтергә, аны алмаш токымга да тапшырырга тырыша.* Ф.Дунай

**3.** *рәв. мәгъ. сөйл. к.* **алмашлап**. *Алмаш эшләү*

**АЛМАША** *с. сөйл.* Акылга тулы түгел, исәр

**АЛМАШАЛАНУ** *ф. сөйл.* Акылга җиңеләю, исәрләнү

**Алмашалана төшү** Бераз алмашалану

**Алмашаланып бетү** Тәмам, бөтенләй алмашалану

**Алмашаланып калу** Нинди дә булса сәбәптән алмашалану

**АЛМА́Ш-АЛМАШ** *рәв. к.* **алмаштилмәш**. *Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш, Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш, Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса Хәзер генә сыглыпсыглып еглаган яшь.* Г.Тукай

**АЛМАШКА** *рәв.* **1.** Кемнеңдер урынына, аны алмаштыру өчен. *Чалабай агасы елына ике-өч мәртәбә кышлакка – гаиләсе янына кайтып киткән көннәрдә, иптәшенә алмашка кеше килсә дә, Амантай һәрвакыт ялгызлык хисе кичерә иде.* Т.Әйди. *[Кәбир:] Сәми бабасына алмашка ат караучы булып барачак.* А.Хәлим. *Аларга алмашка башка кабиләләр һәм халыклар килә дә үз дәүләтләрен төзи.* Г.Фәйзрахманов // Берәр нәрсә урынына (киелү, тотылу, саклану, файдаланылу). *Һәм өйдәгеләреңә алмашка дип җибәргән күл-*

*мәк-ыштанынны, юып, шикәр суында кайнатып алып киләләр дә, ашказаның ачка киселгән саен, имчәк бала кебек, шуларны суырып ятасың.* Р.Сибат. *Гафу итегез, хәрби комиссарныкы дип исәпләнгән маузерны вакытлыча үземнекенә алмашка биреп тора алмассызмы икән?* Т.Әйди // Берәр нәрсә урынына, аны алмаштырып. *Иренә яшьлеген, мәхәббәтен бирде. Өч ул бүләк итте. --- Алмашка ни алды? Хыянәтме*? Ф.Җамалетдинова. *Яшьлек талпынуына алмашка үкенү, ачыну килә.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ. к.* **алмаш 2.** (*1 мәгъ.*). *Алмашка күлмәк тә эләкмәде хәтта, яну-пешүдән көчкә котылып, бер кат киемнән, сәләмә йорт бусагасына кайтып аудылар.* Н.Гыйматдинова

**АЛМАШЛАНУ** *ф. сөйл.* Акылга җиңеләю, белештерми башлау, саташу

**Алмашланып бетү** Тәмам, бөтенләй алмашлану

**Алмашланып тору** Әле, хәзерге вакытта алмашланган хәлдә булу

**АЛМАШЛА́У** *ф.* **1.** *сөйл.* Алмаш-тилмәш эшләү, чиратлашу яки чиратлаштыру, берсе икенчесен алыштыру

**2. алмашлап** *рәв. мәгъ.* 1) Бер-берсен алмаштырып яки чиратлаштырып, бер-берсе белән чиратлашып. *Сөргән җирдән атларны алмашлап менәм дә, әйдә куарга.* З.Зәйнуллин. *Болай булса, чанада үзләренә урын да калмас, Минзәләгә кадәр, алмашлап, җәяү кайтырга туры килмәгәе, дип курка да башлаган иде.* Ф.Сафин. *Уллары Айдар белән кызлары Лилияне алмашлап карау өчен, Фирая ханымга эшкә кичке мәктәпкә күчәргә туры килә.* Э.Шәрифуллина. --- *бергә укыган дус егетем белән хәтта әти-әниләр дә буташтыра иде, ә башкалар хакында сүз дә юк, без хәтта кызлар озатырга да алмашлап йөри идек.* М.Кәбиров

2) Кулалмашка, әле берсенә, әле икенчесенә. *Вилдан абзыйларың да безнең белән бергә чирәм алганнар икән, шулар белән алмашлап сөрергә булганнар.* Г.Ибраһимов

3) Чиратлап, алмаш-тилмәш; әле берсе, әле икенчесе алышынып. *Мәшти әйткән: «Алмашлап торырбыз: элек мин йоклармын, син каравылларсың, аннан син каравылларсың, мин йоклармын».* Әкият. *Без --- алмашлап, тары төябез.* Ч.Айтматов. *[Егетләр] Нечкәрәк бүрәнәләрне алмашлап кисеп, сал бәйли башладылар.* Р.Батулла. *Ике уку йортыннан да студентлар ашханәгә, алмашлап, дежурга йөри торган иде.* Д.Бүләков

**АЛМАШЛАШЫП** *рәв. к.* **алмашлап**. *Габделхәй белән Гобәй, баскыч култыгындагы чиләктән кружка белән су алып, алмашлашып, битләрен юалар.* Ш.Камал. *Илленче елларда Рауза бу рольләрдә Мәрзия Миңлебаева белән алмашлашып уйный.* Р.Юсупова

**АЛМАШЛЫ** *с.* Алмашып, чиратлашып башкарыла торган. *Мәшһүр гарәп сәяхәтчеләре әл-Гарнатый белән Ибне Баттута, болгарларда үзләре булып һәм аларның төньяк кабиләләре белән мөнәсәбәтләре турында күп тапкырлар ишетеп, XII һәм XIV йөзләрдә дә шул ук алмашлы сәүдә ысулы яшәве хакында язып калдырганнар.* Р.Фәхретдинов

**АЛМАШЛЫК** *и. грам.* Зат яки предмет, күренеш исемен турыдан-туры атамыйча, бары тик аларга ишарә ясап, сөйләмдә, контекстта гына ачыкланган һәм исемгә, сыйфатка, рәвешкә, фигыльгә караганда гомумирәк, абстрактрак төшенчәләрне белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме. *Алмашлыклар, галимнәр әйтүенчә, иң борынгы сүзләр дип саналалар.* Ф.Сафиуллина. *Бередә «анын» алмашлыгы, күп гасырлар җәберләнгән туган халык, мәгънәсендә алынган була.* Казан утлары

**АЛМАШСЫЗ** *с.* **1.** Алмаштырылмый торган, алмашы булмаган. *Ләкин аларның алмашсыз җитәкчесе, әлбәттә, һәрвакыт Хәмит Ярми булды.* Х.Мәхмүтов

**2.** *рәв. мәгъ.* Берәү белән дә алышмыйча, үзе генә; бер нәрсәне дә алыштырмыйча. *Бернечә көн радиоактив тузаннар очып торган күл төбендә алмашсыз эшләгәч, әзмәвердәй Фәргатькә дә әллә нәрсә булды.* Ф.Бәйрәмова

**АЛМА́Ш-ТИЛМӘШ** *рәв.* 1) *к.* **алмашлап** (*1 мәгъ.*). *Ун-унбиш көн ачык далада, учак ягып, иптәшләре белән алмаш-тилмәш черем итеп төн үткәрүләр --- аны тәмам йончыткан иде.* Ф.Садриев. *[Вәкилләрне] Агай янына меңгерү өчен, унлап ир-егет алмаш-тилмәш, сәгатьләр буена баскыч казыды.* Г.Үзиле

2) Әле берсен, әле икенчесен. *Тимгелкүк, соңгы көчләрен җыеп, алгы аякларын алмаш-тилмәш күчерә-күчерә, авылга таба борыла башлады.* М.Хуҗин // Әле берсенә, әле икенчесенә. *Шактый чаларган чәчле бер майор, алмаш-тилмәш, сәгатенә һәм кабинет ишегенә карый-карый, ишекле-түрле йөренә.* Г.Бәширов

**АЛМАШТЫРГЫСЫЗ** *с. к.* **алыштыргысыз**. *Нәкъ вакытына туры килде, кукурузны якларга кирәк, безнең шартларда әйбәт үсә ул, маллар өчен алмаштыргысыз азык булачак.* Х.Сарьян. *Буфетның ул чакта тулы һәм алмаштыргысыз хуҗасы булып, югарыда әйтелгән Зифа эшли иде.* Я.Шәфыйков. *Бүрежан, гомумән, шушы җимерек дөньяда кирәкле нәрсәләрне эзләп табу буенча алмаштыргысыз ярдәмчегә әверелде.* Б.Рафиков

**АЛМАШТЫРГЫЧ** *и.* Нәрсәне дә булса алмаштыра торган әйбер, алмашка кулланыла торган әйбер. *Беренче нитрогруппа, икенче төр алмаштыргыч буларак, икенче нитрогруппаны боҗраның м-торышына юнәлтә.* Ф.Ямбушев

**АЛМАШТЫРМА** *и. мат.* Математикада элементларның билгеле бер тәртиптә урнашкан рәвеше. *1, 2, 4 саннарыннан алмаштырмалар төзик.* Л.Галиева

**АЛМАШТЫРУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне биреп (сатып, үзара килешеп һ.б.), аның урынына икенче әйбер алу; бер әйберне башка нәрсәгә алмашу. *Шуннан мин шикәргә алмаштырам аны, майга-фәләнгә алмаштырам инде.* Р.Миңнуллин. *Әмма ул, озак уйлап тормыйча, аерым фатирын тагын, өстәмә акча алып, бер бүлмәгә алмаштырды.* Я.Шәфыйков

2) Искергән, картайган, тузган һ.б.ш. әйбер урынына яңаны (сатып) алу, әйбер яңарту. *Харис ага белән Кифая ханым, шәһәрдәге оныклары*

*кайтыр алдыннан, сыерларын алмаштырган булалар.* Т.Нәҗмиев // Вакыты чыккан, файдаланылган, кирәк булудан туктаган берәр нәрсә урынына икенчене (эчтәлеге, сыйфаты, билгеләнеше һ.б. буенча башкача булган әйбер) алу, алмашу. *Китапханәгә китаплар алмаштырырга барса, аның үтенеп сораганы бер генә булды: батырлар турындагы, табигать турындагы китап.* Г.Кутуй. *Багдад сәүдәгәрләре, гадәттә, үз гомерләрендә күп кенә кибетләр алмаштыралар, бер ширкә ябып, бөтенләй башка эш белән алыш-биреш итә торган яңа ширкә ачып җибәрәләр.* М.Юныс

3) Исем-фамилияне яисә берәр нәрсәнең исемен үзгәртү, башкача итү. *Бер елны Мәскәү газеталарында: «Мин, Хәйретдин Минһаҗев, исем-фамилиямне Харитон Михайловка алмаштырам», – дип язылган була.* Г.Бәширов. *[Хатта поэмагызның] «Исемен алмаштырырга туры килер», – дип язылган иде.* Ә.Галиев

4) Нәрсәләрнең дә булса урыннарын үзгәртү; берсе урынына икенчесен кую (әйтү һ.б.). *Чөнки, шул беренче хәрефне алмаштырып әйтү аркасында, бөтенләй ямьсез мәгънәле икенче сүз килеп чыга.* Ш.Маннур. *Ул бер-берсенә чалыштырып утырган аякларын әле тегеләй, әле болай алмаштырды.* Р.Харрасова

5) Эштән азат ителгән зат урынына аның вазифаларын башкару өчен икенче кешене билгеләү. *Җәмил Баймуллин Партиянең югары уку йортына китү сәбәпле, аны Фадбир Сафин алмаштырды.* Г.Шакиров // Өлкән буын кешеләренә алмашка килү, аларның алмашчысы, дәвамчысы булу. *Инде менә без, моңарчы мәче тиресе белән куян тиресен дә аера белмәгән яшь егетләр, яшь кызлар, шул мишәр дәдәйләрдән мех сортлауның нечкә серен өйрәнергә һәм, тора-бара, аларны акрынлап алмаштырырга тиеш идек.* Ә.Еники // Эш урынына, постка һ.б.га яңа смена килү. *Алар артыннан ике кыз, чыгып, каравылны алмаштырды.* Р.Батулла. *Хөрмәт --- осталарның сүлпәнрәк эшләгәнен алмаштырды.* Б.Рафиков

6) Өс киемен яки аяк киемен салып, икенчесен кию. *Үземә дә өс-башны алмаштырып чыкмый булмас.* Ә.Фазылҗанов. *Алар эш киеме булган кожаннарын, кайры туннарын, мамык сырмаларын каракүл якалы пальтоларга, кубанка яки йөнтәс мех бүрекләргә алмаштырганнар.* Г.Ахунов // Моңарчы кулланылган әйбер урынына башканы кую. *Әни миңа, аягымдагы бәйләүне алмаштырырга медпунктка керергә кушып, язу калдырган.* Г.Тавлин. *Ничә кат инде чыбыркысын, иярен тикшерде, киеп чыгасы галошларының эченә салган кәгазьләрен, ошатмыйча, кат-кат алмаштырды.* Н.Әхмәдиев

7) Юкка чыгып, кулланыштан чыгып бара торган нәрсә урынына алмашка икенче төрлесе барлыкка килү. *Элекке гарәп алынмаларын рус сүзләре һәм рус теле аша кергән халыкара терминнар белән алмаштыру*

8) Чиратлашу, берсе урынына икенчесе килү. *Мәсәлән, төн уртасында күк меридианы тирәсеннән, берсен-берсе алмаштырып, төрле даталарда төрле йолдызлыклар үтеп китә.* Левитан. *Әле менә шулардан айнып, улына күзен күтәреп карагач, бер хатирәне икенчесе алмаштырды.* Х.Сарьян

9) Саф һава кертү, җилләтү. *Тәрәзәләрне ачтырып, һаваны алмаштырдым.* Г.Кутуй

10) Берсе икенчесен алыштыру, алмашлау, алмаш-тилмәш башкару. *Аннары Гайнулланы – Мостафа, Мостафаны Галимҗан алмаштырды.* Т.Нәбиуллин

11) Акчаны ваклау яки эреләү. *Әле монда килгәндә генә, тәмәке алганда, бишлек алмаштырды.* Г.Камал

12) *куч.* Дөньяга карашыңны, иленне, урыныңны, динеңне һ.б.ш.ны ташлап, башкага күчү, хыянәт итү. *Фазыйлның иман алмаштыруыннан --- миллион мәртәбә алдарак торган бер хәбәрне --- атлар җигелә башлагач кына сөйләде.* Г.Ибраһимов // Эш, шөгыльне үзгәртү; икенче эшкә күчү

13) *күч.* Кешенең психик, рухи халәтендә үзгәреш булу. *Бичәнең чыраенда иртәнге матур алсулык сүнгән, күзләрендәге яшел яктылык уңган, яшел һәм ал төсләрне каракучкыллык алмаштырган иде.* Ә.Баянов. *Күлүне тагын сагыш алмаштырды.* Р.Батулла. *[Ир] Мөлаемлыгын, төчелеген бик тиз астыртын усаллыкка алмаштырды.* Г.Әпсәләмов

14) *күч.* Кыяфәтне, өс-башны яки берәр нәрсәнең төсен үзгәртү

15) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса тиң булу, аңа тәңгәл килү. *Кояш нурын тәмле аш та, кыйммәтле җиһаз да, акчага алган бәхет тә алмаштыра алмый.* М.Юныс. *Димәк, бары ул гына Зәнфирәне алмаштыра ала, бары ул гына аның йөрәк ярасын төзәтә ала.* Ф.Садриев

**Алмаштыра башлау** Алмаштырырга тотыну. *Алар урыннарыннан кузгалыштылар, ашыга-ашыга, киемнәрен алмаштыра башладылар.* Г.Әпсәләмов

**Алмаштыра бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы алмаштыру. *Шунысы да мәгълүм, идарә итүче катлам яки төркем, иртәме-соңмы, үзенең җитәкчелек итү ысулларын үзгәртә, алмаштыра барырга мәҗбүр.* Ә.Баян

**Алмаштырып бетерү** Тулысынча, барысын да алмаштыру

**Алмаштырып килү** Һәрвакыт, даими алмаштыру. *Ул исемне алмаштырып килә.* Татар грамматикасы

**Алмаштырып кую** Алдан алмаштыру; алмаштырган хәлгә китерү. *Кичә генә хәреф танымый иде, бер төн эчендә әйтерсең [Хәбибә түтине] алмаштырып куйганнар.* Г.Тавлин. *Иртән табигатьне икенче ягы белән алмаштырып куйганнар диярсең: яңгыр туктаган, күк йөзе шома зәңгәр булып ачылган, аяк асларын туңдырган.* Р.Низамиев

**Алмаштырып тору** Еш, әледән-әле алмаштыру. *Моңа рәхәтләнеп эшләргә дә, ашарга да, яшәргә дә, иске машиналарны яңага алмаштырып торырга да була.* М.Юныс

**Алмаштырып чыгу** Һәрберсен, рәттән бер-бер артлы алмаштыру

**АЛМАШУ** *ф.* **1.** 1) *к.* **алмаштыру** (*1 мәгъ.*). *[Танышы] – Биш төрерлек тәмәкегә алмаштым, – диде ул, шатланып.* Р.Зарипова. *Сату-алу белән, мал алмашып кына яшисе иде дә бит.*

Ф.Латыйфи. *Йә инде, дөя хәтлек гәүдәле атны бер башмакка башма-баш алмаш инде, ә?* З.Зәйнуллин

2) Башкага үзгәртү (исем, фамилия турында)

3) Эзлекле рәвештә берсенә алмашка икенчесе килү. *Алмаша төн, әкрен-әкрен көн туа, Көн туып, ямьсез болытларны куа.* Н.Исәнбәт. *Казан читендәге төрле зурлыктагы яшел ямаулыкларга охшаган урман кишәрлекләрен соргылт кырлар, кечкенә генә болынлыклар алмашты.* Г.Тавлин // Үзгәрү. *Камиләнең тормышы яңа вакыйгаларга баеды; яшен тизлеге белән, күңелендә уйлар, фикерләр алмашты, яңа тәэсирләр, яңа хисләр пәйда булды...* Матур буласың килсә

4) Хезмәт урынына яңа кеше, постка сменачы килү. *Гадәттә, ул, смена алмашу алдыннан, диспетчер дебаркадеры янына килеп туктаган була иде.* С.Сабиров // Өлкән буын кешеләренә алмашка килү, аларның алмашчысы, дәвамчысы булу. *Ул вакыйгалардан соң алты дистә ел вакыт узды, бернисә буын язучылар алмашты.* Ә.Мостафин

5) Бер як, ил кешесе урынына икенче як, ил кешесен алу. *Хәтта без «варвар» дип атаган чорларда да сугыш соңында әсирләрне алмашу булган.* М.Галиев. *Ләкин хәзергә кадәр Бохара иң якын күршесе Әфганстан белән дә илче алмашырга ашыкмый.* Т.Әйди

6) Киемнең чистасын, юылганын яисә эш (хезмәт) киеме урынына башкасын кию. *Юынып, чиста күлмәк-ыштаннар алмашып, аннары бер тәлинкә тары боткасы ашап, кайнар чәй дә эчеп алганнан соң, Каюм үзен бу дөньяга яңадан тугандай хис итә башлый.* Р.Төхфәтуллин. *Мулланур шуннан алдагы төнне генә минем өемнән, киемен алмашып, ашап-эчеп, үз аягы белән чыгып китте.* Ә.Гаффар

7) *юк. форм.* Берәр нәрсәне бүтән әйбергә караганда кыйммәтрәк, кадерлерәк санау, аны бернәрсәгә дә үзгәртмәү. --- *кыйбламны мин – туган туфрагымны – бүтән кыйблаларга алмашмам.* Х.Әюпов

8) Бер-берсенә такмак әйтү, чиратлап, җырлар җырлау; әйтешү. *Алар, төн буе шулай сөйләшеп, җырлар алмашып, бер-берсенә булган саф мәхәббәт һәм дуслыкларын уртаклашып, бөтен кайгы һәм борчуларын оныттылар.* К.Насыйри

9) Туган илне, динне һ.б.ш.ны башкага алмаштыру. *Токымың иман алмашты.* Ш.Галиев

**2. алмашып** *рәв. мәгъ.*1) *к.* **алмашлап**. *[Зөбәйдә] Фермада сыерларны алмашып сава.* Б.Камалов. *Дания белән Сания Яшьтән үк бик дус иделәр: Алмашып, кием киделәр, Алмашып, егет сөйделәр.* Г.Афзал. *– Барыбыз да [гармунны] алмашып тарткалый идек, – дип көлде Илдар.* Р.Хәбибуллина

2) Аралашып, уртаклашып. *Тамырына төшеп караганда, Г.Толымбайскийның фикерендәге төп нәрсә – безнең башка әдәбиятлар белән рухи алмашып яшәргә тиешлегебез, һичсүзсез, дөрес иде.* Ф.Галимуллин

**3.** *и. мәгъ.* Бер нәрсәне икенче бер нәрсәгә алмаштыру. *Әмма, утызынчы еллардан башлап, бу мөмкинлекләр тәмам бетерелә, төрки халыкларга мәдәни, рухи кыйммәтләр белән алмашу юллары ябыла.* Ф.Галимуллин. *Шул рәвешле, үсеп бара торган җәмгыятьтә сәүдә мөнәсәбәтләрен тудыру һәм яшәтү өчен алмашу кыйммәте кирәк була башлый, аның нәтиҗәсе буларак, акча барлыкка килә.* Философия

**Алмашып бетү** Һәрберсе, барчасы, булган бар нәрсә тулысы белән алмашу

**Алмашып җибәрү** Бераз, тиз арада алмашу. *Әби кайнатып куйган җылы су белән юынып, өс-башны да алмашып җибәргәч, үзен җиңеләеп һәм яшәреп киткәндәй сизә башлады.* Г.Бәширов

**Алмашып кую** Кинәт алмашу. *Кайберсенең яшь кызны шәп мылтыкка алмашып куюы да бар.* Г.Якупова

**Алмашып тору** Еш, әледән-әле алмашу; бертуктаусыз алмашу. *Бертуктаусыз алмашып торган ышану, шатлану һәм көенүләрнең ни мәртәбәгә җиткәнен, бер Ходай, үзең генә белерсең.* Г.Ибраһимов. *Чираттагылар биш минут саен алмашып торды.* Һ.Такташ

**АЛМАШЧЫ** *и.* **1.** 1) *к.* **алмаш 1.** (*2 мәгъ.*). *Әле, җитмәсә, алмашчысы авылга кайтып киткән икән.* Р.Кәрами. *Шуңа күрә Сәрвия белән алмашчысы көндезләрен трактор янында кизү торалар.* М.Хуҗин

2) Гомумән алыштыручы, алмашучы. *«Вакыт» дигән нәрсә аңа алмашчы китерә.* Ә.Баян

3) Алмаштыра торган, алмашка килә торган берәр нәрсә. *Маркс --- капитализмның яңа формация белән алмашыначагын күрәзәлек итә, һәм шушы «алмашчы»ны ул «коммунистик формация» дип атый.* К.Гыйззәтов

3) *к.* **алмаш 1.** (*3 мәгъ.*). *Шул дөрес башлангычлы сәнгатьтән калган карашы, фикер йөртүе белән, бала чын кеше, хөрмәткә лаек яшь бер гражданин, алмашчы булсын.* М.Шиһапов. *Без хәзердән үк хезмәт сөеп, сезгә лаеклы алмашчылар булып үсәбез.* М.Хәсәнов. *Остаз үзеннән соң алмашчылар калдырмаса, аның китәргә хакы юк!* Р.Фәйзуллин

**2.** *с. мәгъ.* **алмаш 2.** *Алмашчы солдатлар да --- бер урында катып калды.* Р.Батулла. *Ә моның өчен синнән дә, Миннән дә җавап сорар Килер көн, улың, оныгың, Алмашчы укучылар.* К.Булатова

**АЛМАШЫНУ** *ф.* **1.** 1) Берәр нәрсә, эш-хәл урынына икенчесе килү. *[Риан:] Ситуация алмашынды, картлач, ситуация.* Г.Тавлин

2) Дежур булу яки эшләү сәгате тулгач, урынына кеше килеп, эштән бушату. *Барып җитәр өчен егерме өч сәгать очарга кирәк, самолёт экипажы өч тапкыр алмашына.* М.Юныс. *Хәзер сине китергән городовойлар ярты төннән соң алмашына.* Казан утлары

3) Үзгәрү, бер хәлдән икенче хәлгә күчү. *Фидаяров күрде: бу юлы инде Тинчуринның күзләрендә баягы очрашудан туган шатлык чаткылары әллә нинди бер томанлы караш белән алмашынган иде.* Г.Үзиле. *Тора-бара, Самат күңелендәге бу сагыш үкенү тойгысы белән алмашынды.* Г.Гыйльман. *Ләкин башта аның чыдамлылыгына, кайгыдан сыгылып төшмәвенә, иренә турылыклы булып калуына соклану, соңга таба, аның үзенә соклану һәм, ниһаять, ярату белән алмашынды.* Р.Кәрами // Кешенең рухи халәте, үз-үзен

тотышы кинәт үзгәрү, башкачалану. *[Габбас абый] Бер карасаң – бер төрле, икенче карасаң – бөтенләй башка, күзге көйсез көн кебек, һич уйламаганда алмашына.* Г.Тавлин. «*Чибәркәй» дигәнебез шундук кара коелып төште, күзләрендәге матурлык, күз ачып йомганчы, ямьсез нәфрәт белән алмашынды.* Р.Низамиев

4) Билгеле бер тәртип белән берсе артыннан берсе килеп тору, берсе урынын икенчесе алу, чиратлашу. *Көй алмашынганда, [Равил] --- Рухия янына барыр иде дә аны танцыга чакырыр иде.* В.Нуруллин

5) Акылы, зиһене үзгәрү; сәерләнү, җиңеләю

**2.** *и. мәгъ.* Үзгәреш, бүтәнчәлек. *Шул нисбәттә инде әүвәлге пәрдәдә күрелгән кешеләрдә дә алмашыну сизелә.* Ф.Әмирхан. *Тик Наҗия генә әтисендәге бу алмашынуларны төшенә алмыйча азаплана.* Ф.Хөсни. *Әгәр күзен ачыбрак, зиһенен туплап караса, [Нәҗип] үзе яшәгән бәләкәй дөньяда да әллә ниләр туып алмашынуын, үзе катнашкан вак-вак эшләрнең дә баш китәрлек олы вакыйгаларга барып тоташуын аңлар иде.* А.Гыйләҗев

**3. алмашынып** *рәв. мәгъ. к.* **алмашлап**. *Моторлы көймәдә хуҗа үзе генә, ә моторсыз көймәдә гадәттә ике-өч кеше була: ишкәкләр белән ишү җиңел эш түгел, шуңа күрә көймә хуҗасы үзе һәм бер-ике улы алмашынып эшлиләр.* М.Юныс

**Алмашына бару** Эзлекле рәвештә, бер-бер артлы берсе икенчесенә алмашу. *Ләкин, яши торгач, бу сөенечләр яшь ир-атның күңелендә көенечләр белән алмашына барды.* З.Хөснияр. *Бер-бер артлы алмашына барган буыннар – кешеләр язмышы матурлый җирне, озак дәвер яшәгән Өянке моңа инде күптән төшенгән иде.* М.Галиев

**Алмашына башлау** Алмашыну билгеләре барлыкка килү. *Тик соңгы вакытта гына төннәрен саташа, алмашына башлады.* М.Әмирханов

**Алмашына төшү** Бераз, берникадәр алмашыну

**Алмашынып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада алмашыну

**Алмашынып бару** Акрынлап, бер-бер артлы алмашыну

**Алмашынып бетү** Тулысынча, һәрберсе алмашыну. *Ун ел түгел, дүрт ел эчендә кеше тәнендәге бөтен күзәнәкләр дә тузып, алмашынып бетәләр.* Р.Батулла

**Алмашынып китү** Кинәт, көтмәгәндә алмашыну. *[Повар] Газета өстенә иелгән генә иде, кинәт алмашынып китте.* Г.Гобәй

**Алмашынып тору** Һәрдаим, бертуктаусыз, рәттән алмашыну. *Койкалар үзгәрешсез кала бирә, ә авырулар алмашынып тора.* Р.Кәрами. *[Профессорның] Сырхаулыгы да бар, халәте рухиясе дә тиз һәм еш алмашынып тора.* И.Нуруллин. *Берсен-берсе кабатламый торган ямьле күренешләр әнә шулай алмашынып торалар.* Г.Гобәй

**АЛМАШЫНУЧАН** *с. к.* **алышынучан**. *Көзге вә кышкы көннәрдә Истанбулның һавасы никадәр тиз алмашынучан булса, Төркиянең сәясәт галәме дә шулкадәр үк тиз алмашынучандыр.* Г.Камал. *Бу дәһшәт тирәсендә, алмашынучан яктылыкта ут сүндерергә килүчеләр бик көчсез булып күренә иде.* М.Маликова

**АЛМАШЫНУЧАНЛЫК** *и. к.* **алышынучанлык**

**АЛОГИЗМ** *и. гр. кит.* 1) Мантыйк кагыйдәләренә сыешмый торган фикер сөреше; фикер йөртүдә логикасызлык, каршылык. *Юк, бу – алогизм, башка сыймастай хәл, алай булуы һич мөмкин түгел.* М.Сәхапов. *Сез уйлап карагыз, алогизм: кешене – җирнең продуктын – сатарга ярамый, җирне сатарга ярый.* Т.Миңнуллин

2) *әд.* Текстта көлдерү, ирония эффекты бирү өчен кулланыла торган стилистик ысул. *Сатирада деформация – фантастик образлар, гипербола, гротеск, алогизм – шулай ук мул кулланыла.* И.Нуруллин

**АЛО́ГИК** *с.* Алогизмга нигезләнгән; алогизмга мөнәсәбәтле

**АЛО́Э** *и. гр. бот.* 1) Лаләчәләр семьялыгыннан, калын, озынча итләч яфраклы, тропикларда үсә торган агач яки үлән, күпьеллык үсемлек (медицинада кулланыла). *Күпчелек очракта бу – пальмаларда, алоэ, драцена, агава һ.б.да күзәтелә.* Л.Мәүлүдова

2) Оранжереяларда һәм бүлмә шартларында үстерелә торган шундый үсемлекнең бер төре; йөзьяшәр. *Бал булмаса, алоэ яфрагын кайнатып эчәргә була.* Н.Фәттах

**АЛПА** *и. диал. к.* **алпар.** *Тау ягы авылларында халык Сабан туенда көрәшчеләрне әле дә: «Алпа! Алпа!» – дип дәртләндерә икән.* С.Зыялы

**АЛПАВЫТ** *и.* 1) Россиядә 1917 елга кадәр эре җир биләүче; дворян. *Алпавытлар заманында табак-савыт җыештыру ялчылар өстендә булган.* М.Юныс. *Авылда мине элеккеге алпавыт йортына – икенче катка урнаштырдылар.* Ә.Гаффар // Феодаллык мөнәсәбәтләре булган илләрдә: эре җир биләүче. *Алиш немец алпавыты хуҗалыгында да хезмәт иткән, заводта шомартучы булып та эшләгән, урман да кискән.* Р.Мостафин

2) *иск.* VI–XIII йөзләрдәге төрки дәүләтләрдә гаскәр берәмлеге башлыгының хәрби титулы. *Курганнарда табылган затлы металлдан ясалган сәнгать әсәрләре исә сугышчы алпавытлар һәм грек колонияләре арасындагы алыш-бирешнең зуррак күләмле булуы турында сөйлиләр.* Ә.Мөхәммәдиев

**АЛПАВЫТЛЫК** *и.* Алпавыт булу. *Әлеге партиянең әгъзасы буласың килә икән, ун нәрсәгә иман китерергә тиешсең: байлык, җирлелек, алпавытлык, кода-кодачалык һ.б.* Казан утлары

**АЛПАК** *и. тар.* Хәрби кием

**АЛПАМША** *и.* **1.** 1) *фольк.* Әкиятләрдә: батыр егет. *Күп кенә галимнәр соңгы дәвер татар фольклорындагы Алып батыр, Алпамша, Сак-Сок сюжетларының --- болгар-хәзәр чорларыннан ук килүен искәртәләр.* Х.Миңнегулов

2) *күч.* Баһадирдай зур гәүдәле, көчле кеше. *Алпамша сыңары үзе, ә хәрәкәтләре искиткеч төгәл.* М.Әмирханов. *Ә мин аны фил гәүдәле бер алпамша дип уйлаган идем.* Р.Зәйдулла

**2.** *с. мәгъ.* Баһадир, зур гәүдәле, көчле. *Алпамша ир Гайнияне сәкегә аударды.* Н.Әхмәдиев. *Кысык күзле, бөтен битен сипкел баскан бу чуваш егете,*

*алпамша гәүдәле булса да, бик тә юаш, сүзен дә күбрәк пышылдап кына сөйләшә торган егет иде.* Х.Хәйруллин

**АЛПАМЫШ** *и. к.* **алпамша**. *Бу сурәт бүрегә генә түгел, ә дастани Алып – Алпамша – Алпамышларга да туры килә.* Ф.Урманче. *Алпамыш белән Алпамша батырларның икесе дә шул нәселдән, ягъни Алып нәселеннән чыккан булуы да бик ихтимал.* Р.Батулла

◊ **Алпамыш (батыр) йокысы** Уятып булмаслык каты, тирән йокы

**АЛПА́Н-ТИЛПӘН** *рәв.* **1.** Йөргәндә, гәүдәне адым ясаган якка авыштырып, ян-якка авып; ава-түнә, айкала-чайкала (*атлау, бару, йөрү*). *Әнә аларның берсе, алпан-тилпән килгән арада, европача киенгән әфәндегә килеп бәрелә.* Ә.Исхак. *Йөзә башлаган елларны Андрей, карт диңгезчеләргә охшарга тырышып, алпан-тилпән басып йөри иде.* М.Юныс. *Залга кереп, пыялаланган күзләре белән карап торгач, алпан-тилпән атлап, иң алдагы урынга барып утырды.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Әле бер, әле икенче якка авышып барган. *Алпан-тилпән адымнар*

**АЛПА́Н-ЧАЛПАН** *рәв. сир. к.* **алпан-тилпән**. *Садри белән Гайнулла мине «әбижәйт» иткән малайны, боз өстендә алпан-чалпан килеп шугалап, каядыр алып киттеләр.* М.Мәһдиев

**АЛПАР** *и. иск.* **1.** Көчле, батыр сугышчы; яугир; рыцарь. *Алпарына күрә – тулпары.* Мәкаль. *Шома диңгез ташлары түшәлгән бу урамнардан узган гасырларда алпарлар йөргән.* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Көчле, нык, кыю. *Шул урамның бер йортында туган Авылыбызның алпар егете.* Р.Могыйнов

**АЛПЫ́-САЛПЫ** *рәв.* **1.** 1) Акрын кыймылдап, теләмичә, өстерәлеп; ава-түнә (*бару, хәрәкәт итү*)

2) Иренеп, сузылып-тартылып, ялкауланып; тырышмыйча гына, аннан-моннан гына. *Алпы-салпы йөрүләр беткәч, хезмәттә дә тырышлык күрсәтә башлаганмын икән!* Ш.Маннур

**2.** *с. мәгъ.* 1) Акрын кыймылдаган, теләр-теләмәс барган. *Үз җае белән алпы-салпы тәгәрәгән тормышта мондый көтелмәгән хәл шактый киренкелек тудырды.* Д.Гыйсметдин

2) Ялкау, тырышмый торган, җиренә җиткереп эшләми торган; ваемсыз, эшкә салкын карашлы

3) Ышанычсыз

4) Үзгәрүчән, тотрыксыз

**АЛПЫТ** *и. сөйл. к.* **алпавыт** (*1 мәгъ.*). *– Кем бу, мондый әйбәт егет була, – дисезме? Бу бит безнең теге алпыт улы «Кулакэтдин» була шикелле...* Һ.Такташ

**АЛСУ** *с.* **1.** 1) Ал төснең уртача дәрәҗәсеннән кимрәк булган төсне белдерә: аксыл кызыл, сыек кызгылт, кызгылт ак. *Агачлар өстенә кунган алсу шәүләләр яшел яфракларны шәмәхә төсләргә манган.* Н.Хәсәнов. *Бу вакытта таңның алсу нурлары инде күк читен яктыртып килә.* Ф.Садриев // Шундый төстә булган. *Ул хатынының сызылып киткән кара кашларына, чак кына киңәя төшкән килешле матур борынына, алсу битләренә һәм күзгә ташланып торган кабарынкы иреннәренә иркәләп карады.* Р.Кәрами. *Озынчарак алсу йөзенә, им өчен генә дигәндәй, бераз гына сипкел сипкәннәр шикелле.* Ф.Садриев

2) Төсне атаган сүзләр янында, шул төскә сыеграк ал төс катышуын белдереп, тезмә сыйфатлар барлыкка китерә (мәс., *алсу кызыл, алсу сары, алсу яшел, алсу зәңгәр, алсу шәмәхә* һ.б.) *Фагыйлә --- алсу яшел бизәкле яулыгын артка бәйләгән.* М.Хуҗин. *Алсу шәмәхә офык, җемелдек тәрәзәле карасу өйләр, моңсу гына башларын игән карасу тупыллар – барысы да аста калды бугай.* Р.Төхфәтуллин. *Әйе, ни генә булмасын, бүгенге матур иртәгә, алсу зәңгәр күк йөзенең ерак читендә пәйда булган бер томам кара болыт кисәге кебек, әлеге төш килеп кысылды.* Р.Кәрами

3) *куч.* Якты, бәхетле, шатлыклы. *Ир-егетнең гомерендә тылсымлы бер алсу көн була.* М.Юныс

4) *куч.* Ясалма оптимизм белән сугарылган, артык романтик. *Разилнең бу әсәре татар әдәбиятындагы төче, алсу әсәрләр мәктәбенә каршы гыйсъян куптару иде.* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ.* Алсулык. *Иртүк торып, чишмәгездән Алып кайт син таң суы, Сөттәй битләреңә төшсен Җитмеш таңның алсуы.* Ш.Галиев. *Моны бераүләр таң ату билгесе дип, икенчеләре кичке шәфәкъ алсуы итеп аңлады.* М.Вәли-Барҗылы

**3.** *хәб. функ.* Алсулык, ал төстә булу. *Йөгереп чыктым урамнарга, – Таңнар аткан чак иде: Дөнья әле алсу иде, Үзәннәргә зәңгәр ефәк Томан яткан чак иде.* Ф.Зыятдинова

◊ **Алсу буяу** Киләчәкне якты, гаҗәеп матур, өметле, ышанычлы итеп күрсәтә торган әйбер. *Кайсылары, кемгәдер ярарга тырышып сөйләгәндәй, чыгышында алсу буяуларны кызганмады.* Р.Кәрами. *Уңай геройны алсу буяуларга гына манып, киресен начар итеп кенә күрсәтү алымы, гомумән, А.Расих өчен ят нәрсә.* Р.Зарипова. **Алсу җимеш** Берәр нәрсәнең иң якты, уңай нәтиҗәсе. *Сәер һәм кайнап, дулкынланып торган соңгы мәхәббәтемнең алсу җимеше Зәминәм хәзер инде җиденче сыйныфта укый.* Ә.Гадел. **Алсу иллюзия** *к.* **алсу күзлек**. *Димәк, кайчандыр булган алсу иллюзияләр төтен булып күккә очкан.* Г.Әпсәләмов. **Алсу күзлек** Һәрнәрсәне кимчелексез һәм җитешсез итеп кабул итү, артык оптимистик караш. *«Алсу күзлекләрең» бу вакытка инде йә ватылган, йә бөтенләй югалган була.* Р.Мирхәйдәров. *Адәм баласы, үзе бәхетле, көр күңелле булганда, әйләнәтирәдәге мохиткә алсу күзлектән карый, тормышны якты, матур итеп күрә.* С.Сабиров. **Алсу (пыялалы) күзлек аша карау (күрү)** Кемнең яки нәрсәнең дә булса җитешсез, кимчелекле якларын күрмәү; идеаллаштыру. *Чөнки сезнең халык тормышка алсу күзлек аша карап өйрәнгән.* Д.Бүләков. *Сез бөтен тормышны алсу пыялалы күзлек аша күрергә өйрәнгәнсез.* И.Хуҗин. **Алсу күзлек киеп фикер йөртү** *к.* **алсу (пыялалы) күзлек аша карау**. **Алсу хыял** Якты, матур, күңел түрендәге хыял; чынбарлыктан ерак торган, буш уй-теләк. *Алсу хыялларга батып, кем белән бергәләп антпланнар кордык*? Р.Хисмәтуллин

**АЛСУЛАНДЫРУ** *ф.* Алсу төскә кертү, алсу төс бирү. *Елга аръягындагы урман өстен алсуландырып, таң беленә.* М.Хәсәнов. *Йөзәр грамм коньяк*

*икесенең дә йөзләрен алсуландырды.* Х.Хәйруллин // Алсу төскә буяу. *Аның [яраланган кошның] каерылган канатыннан энә очы кадәр генә кан тамчылары саркып чыга да җиләк чәчәкләрен буйый, алсуландыра.* Ф.Шәфигуллин

**Алсуландыра бару** Торган саен ныграк алсуландыру

**Алсуландыра төшү** Бераз алсуландыру

**Алсуландырып бетерү** Тәмам, бик нык алсуландыру

**Алсуландырып җибәрү** Бераз алсуланган төс бирү. *Шулай уйлап, Галимҗанга сиздермичә генә, битенә иннек-кершән сөртте, иренен алсуландырып җибәрде.* С.Поварисов

**Алсуландырып кую** Алдан ук алсуландырган хәлгә кертү

**АЛСУЛАНУ** *ф.* 1) Алсу төскә керү, алсу төс алу; аллану. *Тышта ниләр бар икән: Юллар зәңгәр кар микән? Боз тәрәзә алсулана, Пожар микән, таң микән?* Х.Туфан. *Сәгатьләр үтә, ниһаять таң беленә, офыклар алсулана.* Р.Фәйзуллин. *Ул үз йортларыннан ерак булмаган Мәрҗани мәчете манарасының кичке шәфәкътә алсулануын күзәтә.* Казан утлары

2) Алсу төс йөгерү, кызгылт төс барлыкка килү. *Шул караштан икесенең дә бит алмалары алсулана.* М.Хәбибуллин. *Бу вакытта аның күзләре очкынлана, эчкә баткан яңаклары алсулана.* С.Поварисов. *Кыз әле генә биеп туктаган иде, йөзе алсуланып яна.* М.Әмирханов. *Алсуланып, кояш чыгып килә.* Т.Миңнуллин

**Алсулана бару** *к.* **алсуланып бару**

**Алсулана башлау** Аз гына алсулык йөгерү, алсуланырга totыну

**Алсулана төшү** Бераз, берникадәр алсулану. *Йөзе азрак алсулана төшә.* З.Зәйнуллин

**Алсуланып бару** Аз-азлап, акрынакрын алсулану. *Аннан соң яңа революцион күтәрелеш чоры башлана: шагыйрьнең «кояшы» да янә актыра, алсулана бара.* Р.Нуруллина

**Алсуланып бетү** Тулысынча, тәмам алсулану

**Алсуланып җитү** Тиешенчә, соңгы чиккә җитеп алсулану

**Алсуланып килү** Акрынлап алсулану. *Шәфәкъ алсуланып килә*

**Алсуланып китү** Кинәт алсулану. *Аның бит очларына хәтле алсуланып китте.* Р.Хафизова. *Лизаның йөзе бер генә секундка алсуланып китте.* Ф.Әмирхан

**Алсуланып кую** Кинәт алсулану

**Алсуланып тору** Әле, хәзер алсуланган хәлдә булу. *Күзләрендә кабынган елмаю бит алмаларында бераз алсуланып торды да иреннәренә барып җитә алмыйча сүнде.* Р.Вәлиев

**Алсуланып чыгу** Алсу төскә керү. *Фәриданең сулган йөзе алсуланып чыкты.* М.Маликова. *Кояшка караган ягы гына кызлар бите шикелле алсуланып чыга.* Ф.Латыйпов

**АЛСУЛА́У** *ф. к.* **алсуландыру**. *Кичке кояш алсулый сахра-кырны.* Р.Гаташ

**АЛСУЛЫ** *с.* 1) *к.* **алсу** (*2 мәгъ.*). *Җимешләре грушасыман, саклаганда, кояш тигән ягында матур гына алсулы сары төскә керә.* А.Девятков

2) *күч. к.* **алсу** (*3 мәгъ.*). *Мин тормыштан күпне өмет итмим, Җиңел язмыш гөлле, алсулы.* Е.Уткин

**АЛСУЛЫК** *и.* Алсу төс. *Таң алсулыгында җил кузгалыр алдыннан була торган тоныклык сизелә иде.* М.Юныс. *Кояш яңарак баеган, күрәсең, бүлмәгә, матур да, моңсу да булып, шәфәкъ алсулыгы җәелде.* К.Нәҗми. *Аның битенә сыек алсулык йөгерде.* Ф.Сафин

**АЛСЫ́З-ЯЛСЫЗ** *рәв.* Ял да итмичә, эшне туктатмыйча, өзлексез. *Алсыз-ялсыз эшләү авырга туры килсә дә, ахыргы нәтиҗә сөенечле булды.* Ф.Сафин

**АЛСЫН** *и. а. х.* Чабылган җирдә шул ук елны үскән үлән; курпы

**АЛТАИСТ** *и. рус* Алтаистика белән шөгыльләнүче

**АЛТАЙ́СТИКА** *и. рус* Чагыштырма тарихи тел гыйлеменең алтай телләрен өйрәнә һәм, лексик, грамматик элементларының охшашлыгы нигезендә, аларның гомумилегенә караган мәсьәләләрне тикшерә торган бүлеге

**АЛТАЙЛЫ** *и.* 1) Телләре төрки телләр семьялыгына караган, күпчелеге православие динендәге, Алтай краеның Таулы Алтай автономияле өлкәсендә яшәүче төп халык (үзатамалары – *алтай-кижи*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Алтайлыларга гына хас гадәтенчә, [Токмашев] хатын-кызга күтәрелеп, озаклап карап тора белми.* Ә.Галиев. *Шул ук алтайлы халыклар фольклорында «Тулгаулар» жанры бар.* Т.Миңнуллин. *Ротабызда ойрот егете бар – алтайлы, казахка якын халык.* Ш.Мостафин

**АЛТАЙ ТЕЛЛӘРЕ** *и. күпл.* Сүзлек составы һәм грамматик төзелеше ягыннан охшаш үзенчәлекләргә ия булган, төрки, монгол һәм тунгус-маньчжур, кайбер галимнәр тарафыннан шулай ук япон һәм корея телләрен дә үз эченә берләштергән баба тел макросемьялыгының уртак исеме. *Шунлыктан, әлеге телләрнең барысын бергә «алтай телләре» дип аталган тел семьялыгына кертеп карыйлар.* Н.Фәттах

**АЛТА́ЙЧА** *рәв.* **1.** 1) Алтай телендә

2) Алтайларга хас булганча, алтайларга охшатып

**2.** *с. мәгъ.* Алтай теленә караган, алтай телендә булган. *Ап-ак, көмеш канатлар Җилгә тиеп сызгыра. Телләремә алтайча Иң кадерле сүз куна.* Р.Вәлиев. *В.Радловның замандашы А.Калачев исә теленгитларда (телеутларда) сүз осталарының «кожонче» (алтайча «кожоң» – җыр) дип йөртелгәнлеге турында әйтә ---.* Татар халык иҗаты

**АЛТАКТА** *и. махс.* Киемдә гәүдәнең алгы ягын каплый торган өлеш. *Мәсәлән, тегүчеләр сөйләмендәге – күкләү, алтакта, уелма --- кебек сүзләр.* Х.Сәлимов

**АЛТАРЬ** *и. лат.* Чиркәүнең көнчыгыш өлешендә иконостас белән бүлеп алынган һәм тәхет торган түр як. *Әхмәровны тизрәк алтарь каршына бастырырга, христиан диненә күчүен тизрәк рәсмиләштерергә кирәк.* Т.Миңнуллин. *Христианнарда әнә кайсарларны, кенәзләрне, аксөякне алтарь янынарак, башкалардан аерып, өскә бастыралар.* В.Имамов

**АЛТАТАР** *и.* Алты патрон белән корыла торган ату коралы; револьвер. *Поручик --- алтатарын күтәрергә омтылган иде, өске палубада тезелеп торучы матросларны күреп, каушап калды.* К.Нәҗми. *Махно уч төбе белән*

*алтатарлы кобурасына сугып куйды.* З.Фәтхетдинов

**АЛТА́У** *сан* **1.** Барысы, бөтенесе бергә алты булуны белдергән җыю саны. *Аларны күргән саен аптырый идем: мин әниемә бирәү генә, әле үзем дә эшлим, акча алам, алай да җитми, Мәсүфә апаның ялгызына – алтау!!!* М.Хәбибуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Алты зат бергәләп, алтысы берьюлы. *Ике бүлмәле кечкенә фатирда алтау яшәделәр алар.* И.Гыйләҗев. *Алтау киткәннәр иде, бишәү кайттылар.* Н.Әхмәдиев

**АЛТАУЛАП** *сан* **1.** Чама белән алты, якынча алты булуны белдергән чама саны; алтылап. *Кияү егете ягыннан алтаулап кунак килергә тиеш*

**2.** *рәв. мәгъ.* Алты зат бергәләп, алтысы берьюлы. *Биш бала белән алтаулап акырып елап калдык.* А.Хәмзин

**АЛТАУЛАШЫП** *рәв. к.* **алтаулап** (*2 мәгъ.*). *Без, алтаулашып, аны котларга бала табу йортына бардык*! Г.Афзал

**АЛТАЯК** *и.* Тегермән ташын әйләндерә торган орчыкның кырык чөйгә тоташкан югары башы. *Алтаякның белә һәм зыңлавын, Шул зыңына куша җырларын.* Н.Исәнбәт

**АЛТМЫШ** *сан* **1.** 60 санын, микъдарын һәм цифрын белдергән сан атамасы. *Алты яшьлек кунак кайтса, алтмыш яшьлек күрешә бара, диләр.* М.Хуҗин

**2.** *и. мәгъ.* 60 саны. *Йә Хода, ул әле утыз җиде яшьтә генә икән бит. Әмма үзен алтмыштагы карт кебек хис итә.* Р.Кәрами

**АЛТМЫШАР** *сан* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) алтмыш, бертигез күләмдәге алтмыш булуны белдергән бүлү саны. *Безнекеләр чигенә дә чигенә, дошман аларны көненә алтмышар чакрым куа.* Р.Сибат

**АЛТМЫШЛАП** *сан* Чама белән алтмыш; якынча алтмыш булуны белдергән чама саны. – *Бездә алтмышлап татар гаиләсе яши, – диде ул.* Идел

**АЛТМЫШЛЫ** *с.* Күләме, номеры яки үлчәме алтмыш булган. *Аптырап беткәч, башындагы алтмышлы бүреген, салып, бер як күкрәгенә куйган да: – Менә минем хатынга шушы бик таман була, – дигән.* Р.Гарипов

**АЛТМЫШЫНЧЫ** *сан* Рәт, тәртип белән санаганда алтмыш урынында килә торган тәртип санын белдерә. *Фоатның --- килеп чыгышы, туган-торган урыннары алтмышынчы еллар ахырына кадәр һаман ачыкланмаган, туган-тумачалары табылмаган иде.* Р.Мостафин

**АЛТӨРӘН** *и. а. х.* Сабанның кәс кисеп бара торган алгы өлеше. *Бу вакытта рус телендәге кушма сүз үрнәгендә ике тамыр (нигез) кушыла: аккойрык (кош), аккүз (кош), --- алтөрән...* Р.Нурмөхәммәтова

**АЛТЫ** *сан* **1.** 6 санын, микъдарын һәм цифрын белдергән сан атамасы. *Безнең байлык хатын теккән алты ак сәрпинкә капчыкка сыйган иде.* Т.Галиуллин. *Әскар автовокзалга иртән сәгать алты тулганчы ук килде.* М.Хуҗин

**2.** *и. мәгъ.* 1) 6 саны. *Алтыны өчкә тапкырласак, унсигез була. Тик... нәрсә бу – аңа [жетонга] да шул ук «алтылар» чүкелгән түгелме – «66666»?* Г.Гыйльманов

2) **алтыбыз, алтыгыз, алтысы** *тарт. форм.* Алты кеше, алты зат. *Алтыбыз кошлар очып җитмәс җиргә китеп гаип булды.* А.Гыйләҗев. *--- авылга нигез салучы алты иптәше, алтысы да бер сүздә булып, «теге» тормышның серен беркемгә ачмадылар.* Т.Нәбиуллин

◊ **Алтыдагы – алтмышка (бара)** Алты яшьтә холык-фигыле, гадәтләре нинди булса, алтмыш яшендә дә шундый; кеше картайгач та үзгәрми, кешене үзгәртеп булмый, мәгънәсендә кулланыла. *[Заһидә:] Алтыдагы – алтмышка. Башта ук шулай икән, яңадан холкы үзгәрер дисеңме аларның?* Ф.Сафин

**Алтың алты якка китү** Төрлесе төрле якка таралышу

**АЛТЫ́-БИШ** *и. сөйл.* Юләр, акылсыз, тиле. *Җаектан мине алырга килүче алты-биш Сапый дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән икән.* Г.Тукай. *Ә күрше хатын әйтте, йөзгә бәреп әйтте: «Дурак, юләр, алты-биш!» – диде.* Р.Вәлиев

**АЛТЫЛАП** *сан* **1.** Якынча алты, чама белән алты булуны белдергән чама саны

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Алты зат бергәләп, алтысы берьюлы

2) Алты итеп, алтыдан

**АЛТЫЛАТА** *рәв.* **1.** Алты тапкыр, алты мәртәбә, алты өлеш (*артык алу, түләтү, арттыру, кимету һ.б.*). *Коллыгыбыздан котылмасак, тора-бара, бишләтә, алтылата... [кимербез].* Ф.Латыйфи

**2.** *с. мәгъ.* Алты тапкыр, алты мәртәбә, алты өлеш артык яисә ким булган

**АЛТЫЛЫ** *с.* **1**. 1) Алты санын белдергән. *Алты саны – алтылы, Эчендә бар алтыны.* Г.Беляева. *Баягы «алтылы» номер аркасында күңелдә туган шик-шөбһәләрне таратырга теләп, руль артындагы егеткә күтәрелеп карадым.* Г.Гыйльманов

2) Алты кисәкле, алты компонентлы. *Шул ук унберлене, киресенчә, алтылы һәм бишле буыннар тәртибендә төзегәндә, тагы да салмаграк, җитди һәм мәһабәтрәк ритмик алымда мәкальләр килеп чыга.* Н.Исәнбәт

3) Күләме, номеры яки үлчәме алты булган

**2**. *и. мәгъ.* 1) Күләме, номеры яки үлчәме алты булган әйбер. *Шуның өстенә соңгы ике айда иң зурларын – алтылыларын бирә башладылар.* Я.Шәфыйков

2) Халык метрологиясе буенча, пычагының үлчәме алты уч озынлыгына тигез булган чалгы. *Хәле бераз сыекланган картлар да шул алтылы белән чаба.* М.Мәһдиев

3) «Жигули» автомобиленең алтынчы моделе. *Бутәннәрдән бик үк калышасы, кем әйтмешли, йөз белән туфракка капланасы килмичә, кредитка «алтылы» алган идем.* Р.Зарипов. *– Бар, тегеләргә әйтеп кил, «бишле»не яисә «алтылы»ны [машинаны] карасыннар! – диде ул.* Ә.Сафиуллин

4) Карта уенында: колоданың алты саны төшерелгән алты очколы картасы. *[Беренчесе] Мин – пас! Алтылы тәмле булыр әле ул.* Г.Камал

5) *ирон.* Мәктәптә: «бик яхшы»дан да яхшы билгесе (биш баллы системада

кулланылмый, арттырып әйтү). *«Алтылы»га җавап бирим, Укытучы абый?!* Ә.Шәрәфиев

6) *күч.* Йомыш үтәүче, хезмәт күрсәтүче. «*Шестерка*», *ягъни «алтылы» – халык телендә хуҗаның артын ялаучы хезмәтче ул, Гөлфия.* Н.Гыйматдинова

**АЛТЫЛЫ́-БИШЛЕ** *с.* Холыксыз, кызу, кире. *Чөнки холкым алтылыбишле.* Т.Миңнуллин

**АЛТЫЛЫК** *и.* **1.** 1) Алтылы цифры

2) Алты очколы кәрт яки алты күзле домино. *Уйный белеп уйнаучылар кулында кайчакларда гап-гади генә алтылык та этлек эшли аладыр.* Т.Миңнуллин

3) Алты кешедән торган төркем

**2.** *рәв. мәгъ.* Алтыга тутырып, алтыга торырлык иттереп; «бишле» генә түгел «алтылы» билгесе дә (биш баллы системада кулланылмый, арттырып әйтү) куярлык. *Кирәк булса, алтылык укып күрсәтермен, дидем.* Э.Яһүдин

**АЛТЫН** *и.* **1.** 1) *хим.* Сары яки кызгылт сары төстә, авыр, йомшак, чүкүгә бирелүчән затлы металл, химик элемент (сәнәгатьтә, медицинада, ювелир әйберләр ясау эшендә һ.б.да киң кулланыла). *Минем беркайчан да алтын күргәнем юк.* Р.Хафизова

2) *тар.* Шундый металлдан коелган акча. *Алтын булгач, докторын да, алласын да, мулласын да, патшасын да сатып алып була икән шул.* Г.Ибраһимов. *Кадер-хөрмәтенең соңында бу мөритнең каршына йөз илле алтын китереп бирделәр.* Идел // Гомумән акча мәгънәсендә. *Саф көмештин җырларымны Җырламыйм алтын өчен.* Ш.Бабич

3) Шундый металлдан эшләнгән затлы ювелир әйберләр. *[Дамир:] Шәһәргә килгәндә, ул кызның бете дә юк иде. Ә хәзер танымыйсың. Колагы, һәр бармагы саен – алтын.* Д.Салихов. *Соңра хуҗа, алтыннарын акчага әйләндереп, атасыннан калган өйне җимереп, яңа өйләр салдырып, бөтенләй башка тормыш белән тора башлады.* Мирас

4) Гомумән байлык. *Минем атам, мирас итеп, Алтыннар калдырмаган.* Ә.Ерикәй

5) Шуңа манылган ефәк җеп

6) Алтынлы яки алтын төсендәге буяу. *Утә күренмәле юка чынаяк китегенең нәфис бизәкләре өстенә --- алтын белән нәрсәдер язган булган, ләкин, заман үтү белән, сүзләре ашалып беткән иде.* Г.Гобәй

7) *күч.* Яхшы, күркәм сыйфатларга ия булган; игелекле, изге күңелле яисә коллектив өчен бик кадерле булуы белән башкалардан аерылып торган кеше. *Бер түгел, ун матай алып бирәм, дисәләр дә, барыбер, Хаҗи малае булмас идем мин. Минем үз әтием алтын!* З.Хөсният. *Кеше түгел, алтын син, Мәрьям!* Х.Хәйруллин

8) *күч.* Кадерле, бик кирәкле, әһәмиятле әйбергә карата кулланыла. *И туганым, алтыннарның алтын түгеллеген, ә дөньяның – кояш, урманкыр, су-дәрьяларның – чиксез кадерле алтын икәнлеген без бик соңлап, кабер якасында гына аңлыйбыз икән шул!* Р.Хисмәтуллин

9) *күч.* **алтыным, алтынкай** Кадерләп, иркәләп һәм яратып әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Сибай абый: «Я, булды, алтыным, булды», – дип кабатлый.* Р.Хафизова. *Өйләнешкәч, көннәрдән бер көнне Гөлмәрьям Габдрахманын иркәли-иркәли генә болай диде: – Алтыным! Үзең беләсең, хатын-кыз йорт җанлыклы була.* Р.Хисмәтуллин. *«Улым, алтыным минем, ничек яшисең, ничек гомер итәсең?» – дип сорый шикелле.* Н.Дәүли. *[Матэ:] Барыгыз, бар, чибәркәйләр, барыгыз, алтынкайлар.* З.Зәйнуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Алтыннан ясалган, алтыннан коелган. *[Җангали хан:] – Алтын чүмеч кая, нигә көмештән саласың, – дип, бавырчыны орышып ташлады.* М.Хәбибуллин. *Сания туган көненә Рәшат Галиевич алып биргән йөзек кашы хәтле генә алтын сәгатенә карады.* Х.Хәйруллин. *[Замир] «Туйга чаклы төзәлер», – дип өстәмәкче иде дә, кире уйлады, алтын тешләрен ялтыратып алу белән чикләнде.* Т.Галиуллин

2) Алтынга манылган; алтын йөгертелгән; алтын белән язылган. *Аның өстендә – инәдән-җептән генә чыккан бик килешле хәрби кием, җилкәләрендә алтын укалы өлкән лейтенант погоны иде.* Ш.Маннур

3) *Сары* сүзе янында килеп, ялтырап торган сары төсне белдерүче тезмә сыйфатлар барлыкка китерә (мәс., *алтын сары*, *алтынсыман сары, алтынга тартым сары*)

4) Ботаника, зоология һәм минералогия атамалары составында килеп, тезмә терминнар ясый (мәс., *алтын балык, алтын кондыз, алтын корсак, алтын камчы* һ.б.)

5) *күч.* Алтын төсле, ялтырап торган ачык сары төстәге; алтынсыман. *Күе болыт арасыннан ай чыгып, бодайларны алтынга манды.* Г.Гобәй. *[Кояшның] Алтын нурлары көмеш бөркеттәй һава лайнеры канатларында уйный иде.* Х.Хәйруллин. *Ләкин озын, сылу керфекләр артына яшеренгән шаян күзләргә нәкъ шул алтын чәчләр мең матурлык, бетмәс тылсым өсти.* В.Имамов

6) *күч.* Бик яхшы яклары, уңай сыйфатлары белән аерылып торган; уңган, булдыклы. *Нәсимә, аның сүзен җөпләп: – Алтын егет... – диюгә, ул тагын --- хатны Нәсимәгә бирде.* К.Нәҗми. *Дөньяга күзеңне ачып бер карасаң, менә нинди икән бит ул хатын-кызның тезләнеп табынырдай алтын заты!* В.Имамов

7) *күч.* Табышлы, файдалы, төшемле. *Без инде үзебезнең байлыкларның, нефть һәм газларның нинди алтын мал икәнен бик яхшы аңладык.* Р.Хисмәтуллин. *– Диңгезчелек, Норочка, алтын һөнәр, – диде Феликс, кызның фикерен инкяр итеп.* М.Юныс

8) *күч.* Сагынып искә ала торган, рәхәт, күңелле, кадерле. *Ничек итеп онытыйм туган ягымны, анда узган алтын балачагымны?!* И.Юзеев

9) *күч.* Бик акыллы, мәгънәле, әһәмиятле, игътибарга лаек. *– Сүзләрең – алтын! – диде егет, аның белән килешеп.* Р.Сибат. *– Алтын сүзләр сөйлисең бит, Хәкимҗан абзый, – диде ул.* В.Нуруллин. *Ул чагында, шул минутларда, күрәсең, Илшадия бөек педагогның алтын сүзләрен онытып җибәргән булгандыр.* Б.Камалов

**3.** *хәб. функ.* Бик әйбәт, бик яхшы; мөһим. *Шуңа күрә --- дәшмәвең – алтын.* Р.Кәрами

◊ **Алтын алмам** Балаларга карата иркәләп, кадерләп, яратып әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *[Бәдәр малайларга:] «Әйдәгезче, былбылларым... Мин сезне бер җиргә алып барыймчы, алтын алмаларыма керпе күрсәтимче...»* А.Гыйләҗев. **Алтын багана** 1) Кадерле, кыйммәтле, бик кирәкле кеше. *Күпме вакыт Гомәр абзыйсын – инде яше алтмышны узып барган, халык арасында абруй-дәрәҗәсе булган гыйлем иясен, нәселләренең алтын баганасы саналган мөхтәрәм затны тыңлап утыра.* Ф.Сафин; 2) Ныклы терәк, тотып (туплап) торган зат яки нәрсә. *[Дубасов:] Монархия – Россия өчен алтын багана.* Р.Ишморат. *Авылның алтын баганасы булган ун миллионнан артык крестьянны, «кулаклар» дип, бер гөнаһсыз килеш төрмәләргә утырталар, Себергә сөрәләр.* Ватаным Татарстан. **Алтын балык** Кемнең дә булса теләкләрен тормышка ашырырлык мөмкинлек. *Тәвәккәллә, алтын балык бер генә тапкыр эләгә, ычкындырмаска тырыш!* Ф.Сафин. **Алтын балык тоткандай булу** Бик нык шатлану, куану, сөенү. *Алтын балык тоткандай булды Ибраһим Гашигуллович.* А.Вергазов. **Алтын башлы** Сәләтле, талантлы; якты һәм матур уйлы. **Алтын бәһасе тору** *к.* **алтын бәясе тору**. *Менә-менә бу тирене кара син, кара-кара, җем-җем итә, көмеш тә көмеш, бу да – көмеш, алтын бәһасе тора.* М.Хәбибуллин. **Алтын бәясе** Алтынга тиң, бик кыйммәтле, кадерле, әһәмиятле. *– Күрик әле, нинди була икән ул андый алтын бәясе кеше, – дип шаяртып кычкырды арткы рәттән кайсыдыр.* М.Хуҗин. **Алтын бәясенә йөрү** *к.* **алтын бәясе тору**. **Алтын бәясе тору** Алтын кебек югары бәяләнү, үз бәясеннән кыйммәтрәк тору, кыйммәткә төшү. **Алтын бәясенә төшү** Бик нык кыйммәткә төшү, күп акча сарыф ителү. *Ничәмә-ничә мең чакрым юллар, диңгез-елгалар кичеп монда килгән һәм алтын бәясенә төшкән бу җиһаз ни хәлдә икән?* Р.Кәрами. **Алтын белән күмү** *к.* **алтынга күмү**. *Асылгәрәй улым, җанымны кыйма, гомереңә җитәрлек алтын белән күмәрмен үзеңне!* Х.Хәйруллин. **Алтын белән язу** *к.* **алтын хәрефләр белән язу. Алтын бөҗра** Яшәеш, тормыш итү өчен тудырылган барлык уңайлыклар, шартлар. *Әлеге кызлар үзләренең алар өчен әти-әниләре махсус уйлап тапкан алтын бөҗра эчендә икәнлекләрен беләләр.* З.Хөснияр. **Алтын бөртегем** Балаларга карата кадерләп, иркәләп, яратып әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. – *Үземнең улым, үземнең алтын бөртегем! – диде ул, горурлык белән.* Ф.Сафин. **Алтынга күмү** Алтынны күп итеп, мул итеп бирү; зиннәттә, байлыкта, муллыкта яшәтү. *Аннары аның йонлач кулларын үбә-үбә ялвара башладым: – Мәрхәмәтле бул, харап итмә; алтынга күмәрмен үзеңне, и кодрәтле вә гыйззәтле Иблис әфәнде!* З.Мәхмүди. **Алтын гасыр** Дәүләт, фән, әдәбият, сәнгать һ.б.ш. тарихында чәчәк аткан чор. *Гораций һәм Вергилий поэзия өлкәсендә «алтын гасыр» вәкилләре дип танылалар.* К.Гыйззәтов. **Алтынга (да) табып булмый** 1) Акча түләп тә эзләп табылмый торган; 2) Кыйммәтле, бик кирәкле (кеше, зат, һөнәр иясе турында). **Алтынга яллану** Нинди дә булса эшне күп акча алу шарты белән башкарырга алыну. **Алтын запас** *к.* **алтын фонд** (*1 мәгъ*). **Алтын кагыйдә** Җәмәгатьчелек тарафыннан аксиома дәрәҗәсендә кабул ителгән һәм кешеләрнең үз-үзен тоту тәртипләрен билгели торган әхлак кагыйдәләре җыелмасы. *Монысы – яңа кешелекнең һәр әгъзасы өчен алтын кагыйдә!* Р.Фәизов. **Алтын көз** Көз айларында (сентябрь, октябрь) агач яфраклары ачык сары, кызгылт сары, янып торган кызыл һ.б.ш. төсләргә кереп чуарланган җылы, аяз вакыт. *Чын мәгънәсендә алтын көз булды.* Т.Нәҗмиев. **Алтын кул(лы)** Оста, сәләтле, булдыклы. *Әтисе, минем бабай була инде, алтын куллы кеше.* Т.Нәҗмиев. *Моңардан Ингель Наузинның алтын куллы булуын күрделәр.* Х.Камалов. *Ул, ничектер, бу кешене телгә алып: «Бөек кеше, алтын куллы кеше!» – диган иде.* Р.Мирхәйдәров. **Алтын мая** Хәзинә, берәр нәрсәнең нигезен тәшкил иткән кыйммәтләр. *Кайчандыр Мәрҗани тарафыннан башланган кульязма мирасыбызны җыю һәм өйрәнү юнәлеше С.Вахиди эшчәнлегендә элегрәк чорларда күрелмәгән нәтиҗәләргә иреште һәм гомуммәдәни фондыбызның алтын маясына керде.* М.Госманов. **Алтын таулар вәгъдә итү** Тормышка ашмастай вәгъдәләр бирү. *Халидә, телдән алтын таулары вәгъдә итмәсә дә, йорт һәм хуҗалык кирәкләрен күңеленнән бик нык кайгыртып, алар турында уйланып йөри иде.* Ф.Хөсни. *Аларга бүген нинди дә булса вазифа башкарырга кеше кирәк икән, бернәрсә алдында да туктап калмаячаклар, алтын таулар вәгъдә итеп булса да, кешесен табып, шул урынга китереп куячаклар.* Ф.Сафин. **Алтын төп(ле) (булу)** Керемнең бетмәс-төкәнмәс, иксез-чиксез күп табыш бирә торган чыганагы булу турында. **Алтын туй** Ир белән хатынның, гаилә корып, бергә тормыш итә башлауларына илле ел тулган дата. **Алтын фонд** 1) Дәүләтнең кыйммәтле металл коелмалары яки тәңкәләр фонды; 2) Әһәмияте зур булган, халык күңелендә сакланган һәм югары бәяләнгән сәнгать әсәрләре, әдәби әсәрләр тупланмасы. *Югыйсә, ул мәхәббәт булмаса, гасыр дәвамында сәхнәләребез түрендә, күңелләребез түрендә яшәүче, сәнгать хәзинәсенең алтын фондын тәшкил итүче --- җырлар туар иде микән?!* Мин сине ничек яраттым. *«Шүрәле» балеты --- күпмилләтле совет музыкасының алтын фондында урын алды.* Н.Юзиев. **Алтын хәзинә** *к.* **алтын фонд** (*2 мәгъ.*). *Булган гомерендә халкына хезмәт күрсәтүдән башканы белмәгән, әдәбиятыбызның алтын хәзинәсен тәшкил итәрлек әсәрләр калдырган шәхеснең якты рухы каршында баш ияр өчен туган мөмкинлек иде бу!* Э.Шәрифуллина. **Алтын хәрефләр белән язу (басу)** Кемнең дә булса исемен тарихка кертү, мәңгеләштерү. **Алтын эчендә йөзү** Бик бай, мул тормышта яшәү. **Алтын юбилей** Илле яшь тулу белән бәйле дата. *2003 елның гыйнварында Рәхимҗан*

*Хөсәенов алтын юбилеен билгеләп үтте.* Т.Нәҗмиев

**АЛТЫ́Н КАМЧЫ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, шуышма тамырчалы, туры сабаклы, ланцетсыман кыяк яфраклы, алтынсу сары вак чәчәкле күпьеллык баллы үсемлек (халык медицинасында кулланыла); *русчасы*: **золотая розга, золотарник**

**АЛТЫ́Н-КӨМЕШ** *җый. и.* **1.** Алтын һәм көмеш; гомумән кыйммәтле минераллар, асылташлар. *Алтын-көмеш чыңнарыннан Башларың әйләнмәсен. Алтын-көмеш чылбырларга Хыяллар бәйләнмәсен.* М.Миншин. *Һичшиксез, алтын-көмеш, энҗе-мәрҗәннәрне эзләгәннәр.* Р.Сибат

**2**. *с. мәгъ.* Шундый кыйммәтле асылташлардан эшләнгән яки ясалган. *Алтын-көмеш әйберләр*

**АЛТЫНКҮЗ** *и. зоол.* 1) Бөҗәкләр классының челтәр канатлылар отрядыннан, зәңгәр яшел төстә, күзләре алтынсыман һәм чыгынкы, челтәр канатлы бөҗәк; *русчасы:* **золотоглазка, флёрница**

2) Сукыр кигәвеннәр семьялыгына кергән кигәвеннең бер төре; *русчасы:* **златоглазик**

**АЛТЫНЛАНУ** *ф.* **1**. 1) *төш. юн. к.* **алтынлау** (*1 мәгъ.*)

2) Алтын сары төскә керү, алтынсыман сарыга әйләнү. *Ә Иделнең аръягында өлгергән арышлар алтынлана!* Ә.Гаффар

3) Алтынсыман ялтырау, алтынсыман күренү, алтынга охшап калу. *Ә ул яктан, нәкъ үзләренә каршы, әле зәңгәрләнеп, әле алтынланып, әле яшелләнеп, утлы бер таш тәгәрәп, юк, очып килә иде.* Ә.Гаффар

**2**. **алтынланган** *с. мәгъ.* Алтын йөгертелгән, алтын белән капланган, алтынга манылган. *Ул да булса – алтынланган яхшы рамдагы хатын-кыз рәсеме.* М.Хәсәнов

**Алтынлана бару** Аз-азлап, акрынакрын алтынлану

**Алтынлана башлау** Алтынлык йөгерү, алтынланырга тотыну. *Каеннар ямь-яшел,чаганнар матур гына алтынлана башлаган.* Ш.Галиев

**Алтынлана төшү** Бераз алтынлану

**Алтынланып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада алтынлану

**Алтынланып бетү** Тәмам, тулысынча алтынлану

**Алтынланып җитү** *к.* **алтынланып бетү**

**Алтынланып килү** Акрынлап, алтынланган төс алу. *Ул имән төбенә, аның алтынланып килгән яфракларына карап сузылып ятты да җырлады.* Г.Гобәй

**Алтынланып китү** Кинәт алтынлану, алтын төсмер керү

**Алтынланып тору** Алтынланган хәлдә булу; әле, хәзер алтынланып күренү. *Клиндернең өске ягы суган кабыгыдай алтынланып тора*

**АЛТЫНЛАТА** *рәв.* Алтын белән. *Моннан ун еллар элек, ул Африка илләренең берсендә, дәүләтара килешү буенча, алтынлата түләүле, шактый кыйммәткә төшкән ауда катнашкан иде.* М.Галиев

**АЛТЫНЛА́У** *ф.* 1) Алтын белән каплау (бизәү, эшкәртү), алтын йөгертү. *Һәммә дивары көзге кебек ялтыраган, гөмбәзләре кызыл алтын белән алтынлаган.* К.Насыйри

2) Алтынсыман сары төскә кертү, алтынсыман төс бирү. *Көз буташтырмый буявын, алтынлый бар дөньясын.* Казан утлары

**Алтынлап алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә алтынлау

**Алтынлап бетерү** Тулысынча, барысын да алтынлау

**Алтынлап тору** Еш, әледән-әле алтынлау

**Алтынлап чыгу** Һәрберсен, барчасын берәм-берәм алтынлау яки башыннан ахырына кадәр алтынлау

**Алтынлый бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы алтынлану

**Алтынлый башлау** Алтынларга тотыну

**Алтынлый төшү** Бераз алтынлау

**АЛТЫНЛАУЧЫ** *и.* Алтын йөгертү, алтынга буяу белән шөгыльләнүче кеше; оста, белгеч. *Кашыклар алтынлаучы*

**АЛТЫНЛЫ** *с.* 1) Составында алтын булган; алтын кушылган; алтын катнаштырылган. *Касыйм абый алар казып чыгарган алтынлы комны юдыргычка ташыды.* Гасырлар авазы

2) Алтын йөгертелгән, алтын белән эшкәртелгән; алтынга манылган яки алтын җеп белән чигелгән. *Алтынлы парчадан тегелгән хатын-кыз камзулы*

3) Алтынсыман, алтын төсендәге. *Бервакыт шулай, байларга барганда, ишегалдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны күреп, бигрәк тә сокландым.* И.Нуруллин

**АЛТЫНСУ** *с.* 1) Алтынсыман сыек сары, саргылт төстәге. *Тузгыган алтынсу чәчләре юеш битләренә ябышып калды.* Н.Хәсәнов. *Мин карап-карап тордым да, «Удостоверение татарина» дип, алтынсу хәрефләр белән язылганын алдым.* Т.Нәҗмиев. *Көз көне агачлар алтынсу, кызгылт һәм сары төскә керә.* Ватаным Татарстан

2) Төсне атаган сүзләр янында килеп, шул төп төскә сыеграк алтынсу төс катышуын белдереп, тезмә сыйфатлар барлыкка китерә (мәс., *алтынсу кызыл, алтынсу сары, алтынсу яшел, алтынсу зәңгәр* һ.б.). *Баш очында агач ябалдашларына эләгеп калган тулган ай аланны алтынсу яшькелт төскә манган.* Ф.Сафин. *Мәгъфүрә Сабировна өстәл тартмасыннан алтынсу көрән төстәге зур гына балык алып кәгазьгә төрде дә Тәнзиләгә сузды.* Р.Төхфәтуллин. *Тирә-якка туп-туры сызылып киткән алтынсу көмеш җепләр.* Р.Низамиев

**АЛТЫНСУЛАНУ** *ф. к.* **алтынлану** (*2 мәгъ.*). *Баярак тоташ күгелҗем булып кына күренгән болыт чаршавы хәзер күз алдында гаҗәеп тиз үзгәрә иде: әнә ул агара, әнә алтынсулана.* Г.Әпсәләмов

**Алтынсулана бару** Акрынлап, азазлап алтынсулануы арту

**Алтынсулана башлау** Алтынсуланырга тотыну. *Каен чәчләре очыннан алтынсулана башлый.* С.Поварисов

**Алтынсулана төшү** Бераз алтынсулану

**Алтынсуланып бетү** Тәмам, тулысынча алтынсулану

**Алтынсуланып бару** *к.* **алтынсулана бару**

**Алтынсуланып калу** Нинди дә булса сәбәп белән алтынсу төс алу

**Алтынсуланып китү** Кинәт алтынсулану

**Алтынсуланып тору** Әле, хәзерге вакытта алтынсу төстә булу

**АЛТЫНСУЛА́У** *ф. к.* **алтынлау**

**АЛТЫНСУЛЫ** *с.* Алтынсыман сыек сары, саргылт төстә булган. *Яфраклар көзгә манчылган: Кызыл, көрән, алтынсулы.* Иделбикә

**АЛТЫ́НСЫМАН** *с.* Алтын төсендә булган. *Кеше-кара читкә киткән арада, өстәлдәге вазадан алтынсыман чәчәк эләктердем.* Г.Мөхәммәтшин

**АЛТЫНЧЫ** I *сан* **1**. Бер-бер артлы санаганда, урыны биш белән җиде арасында булуны белдергән тәртип саны. *Әйе, паспорттагы алтынчы графа күпләргә читәнне сикереп чыгарга бирмәде.* Ә.Хәбибуллин. – *Син өченче, син дүртенче, син алтынчы... – дип саный-саный, ул Рәхимҗанга җитте.* Н.Гыйматдинова

**2**. *и. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса шуңа туры килгән үлчәмен, номерын яисә кемнең дә булса мәктәптә укыган сыйныфын белдерә. *Алтынчыда гына укыса да, мәктәптә китапханәче булып эшли Галиябану.* М.Хуҗин. *Илфат татар классында алтынчыда укыды.* Б.Камалов. *Ә бит, иптәшләр, алтынчылар дер селкенеп торалар хәзер тарих дәресе керер алдыннан.* М.Мәһдиев

◊ **Алтынчы континент** Антарктида. **Алтынчы тоемлау** *к.* **алтынчы тойгы**. *Менә шул алтынчы тоемлау аны иң авыр хәлләрдә дә һәрвакыт коткарып килде.* Р.Сибат. **Алтынчы тойгы** Интуиция, алдан сизү; алдан сиземләү сәләте. *Ә Муса үзенең шундый көзгеләр арасыннан йөрисен, ниндидер алтынчы тойгысы белән дигәндәй, үзе үк сизеп алды.* Ш.Маннур

**АЛТЫНЧЫ** II *и.* 1) Алтын остасы; алтын-көмештән, коеп, төрле затлы нәрсәләр эшләүче; зәркән

2) Алтын җитештерүдә эшләүче, алтын юучы

**АЛТЫШАР** *сан* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) алты, бертигез күләмдә алты булуны белдергән бүлем саны. *Станокларның һәркайсы алтышар сыерга көйләнгән.* М.Хәсәнов

**АЛТЫШАРЛАП** *рәв.* Алтышарга бүлеп, һәрберсенә алтышар-алтышар итеп. *Һәр арбада – дүрт-биш бала, кечкенәләрне хәтта алтышарлап та утырткаsuccessnнар.* Б.Камалов

**АЛТЫШАРЛЫ** *с.* Алтыдан торган, һәрберсендә алтышар булган; алтышарга бүленгән

**АЛУ** I *ф.* **1**. 1) Нәрсәне дә булса кулга тоту. *Рамай идарә болдырына чыкты да кесәсендә йөреп таушалып беткән «Беломорканал» пачкасыннан соңгы папиросын алды.* Х.Хәйруллин

2) Нәрсәне дә булса авызга кабу, иреннәр арасына кыстыру. *Көймәче, сүзеннән туктап, авызына трубкасын алган иде.* Ш.Камал

3) Нәрсәне дә булса эләктерү, эләктереп, кысып тору. *Мин шулай басып торам, кем дә кем, биеп, кулымдагын алса, шәл шуңа булыр.* К.Тинчурин

4) Көрәштә яки сугышкан вакытта: берәр җиреннән эләктереп, ябышып тоту. *Ике ир каһарман ярты сәгать буенча, бер-берсенең билләреннән алган хәлдә, мәйданны урап йөриләр.* Г.Ибраһимов

5) Кабул итү, төяү; сыйдыру. *Пароход үзенең трюмнарына --- ун мең тоннадан артык марганец концентраты алды.* Р. Мостафин

6) Үзенә ияртү, үзеннән калдырмау; үзе белән йөртү, үзендә йөртү. --- *кайтырмын, дидем, авылга, Агыйдел буена. Үзем белән хатынны, бәләкәй кызчыкны алырмын, дидем.* Э.Касыймов. *Чабылган печәнне киптереп, чүмәләгә салырга дип, әти үзе белән мине дә алды.* З.Хөснияр. – *Андрей, – дидем мин аңа, ялынып, – ал мине үзең белән!* А.Шамов. *Ир балалар балта-көрәк алдылар.* М.Мәһдиев

7) Тартып чыгару, йолку, казып чыгару, казып җыю. *Балалар, атнадан артык, колхозга бәрәңге алуда эшләделәр.* Ф.Садриев

8) Әйберне өстен каплап торган нәрсәдән кыркып, йолкып, кисеп, кубарып һ.б.ш. юллар белән арындыру. *Егет, диюнең сүзенә ышанмыйча, сакалыннан тоткан килеш, берәм-берәм, сакалының йонын йолкый башлый, һәр бөртек йон алган саен күк күкри, тагын әллә нинди куркыныч тавышлар чыга.* Әкият. *Вәзиренең сүзен сынап карау өчен, палас астына бер алтын тәңкә куйган, үзе шул урынга якын утырып, чәч алучысын чакырткан да чәчен алырга кушкан.* Н.Исәнбәт

9) Кисеп ташлау, операция юлы белән юк итү. *Бер көзен клиникада шул ук көнне алганнар, ә икенчесе күрмәс булган, томаланган...* Э.Касыймов

10) *махс.* Агач эшләнмәләргә чокып, кисеп һ.б. юл белән уем, ырмау ясау. *[Эш] Озакка сузылды, баганалары черегән икән, яңа баганаларга ырмау алу кулны тотты, ә югыйсә баганаларны алыштырырга исәпләмәгәннәр иде.* М.Хуҗин

11) Борын яки авыз аша эчкә суыру, сулау. *Тузан, бөркү, һава җитми, сулыш алу читен.* С.Зыялы. *Әйе, бу минутта миңа, Гаяз белән бергә ишегалдына чыгып, саф һава алу кирәк иде.* М.Әмир

12) Башкару, үтәү максаты белән, үз өстеңә эш, йомыш, йөкләмә кабул итү. *Шушы җыелышта без һәрберебез, уку елы башланганчы колхозда иллешәр хезмәт көне эшләрбез, дип йөкләмә алдык.* Р.Хафизова. *Төнге бердә участокта нәрәт алалар, сәгать икедә забойда смена алышына.* Ә.Галиев. *Мәскәү Сабан туен быел Чаллы шәһәре шефлыкка алган иде.* Мәдәни җомга

13) Теләгәнне, кирәгрәкне, әйбәтрәкне аерып сайлау, сайлап булдыру. *Батима карчык утынчы белән сатулашып тормады. Иң элек иң кирәген алырга кирәк иде.* --- *ниһаять, базарның он-ярма, орлык-ашлык сата торган төшенә якынлаштылар.* Н.Фәттах. --- *чынлыкта, тәрҗемә бервакытта да оригиналның билгеле бер сүзенә тәңгәллек буларак сүзлекләрдә --- теркәлгән берәмлекләр арасыннан сайлап алу белән генә чикләнми.* Р.Юсупов. *Әмма, үз кирәген алу белән, шундук башка авылга чыгып чапса, ул әле Ярми үк булып җитмәс иде.* Х.Мәхмүтов

14) Берәр нәрсәне эшләргә мөмкинлек булдыру, шуңа ирешү. *Моңарчы да, аларның ризалыкларын алабыз,*

*дип, кара җәяүгә калып беттек инде.* Г.Камал. --- *ауга чыгарга рөхсәт алу белән, төрле тарафка таралып, сунарны башлап җибәрделәр.* Т.Нәбиуллин

15) Бирелгән, җибәрелгән нәрсә килеп ирешү, кулга керү. *Телеграмманы алу белән, Каюм җизнәсе юлга җыена башлады.* Р.Хафизова. *Күптән түгел мин туган шәһәрем Киренскидан хат алдым.* Ф.Углов. *[Зөләйха] Казанда тулай торакта яшәп ятучы авылдаш кызының адресын алды.* З.Хөснияр. *Мәүлиха апа, җаным, тагын ни булды? Кайгылы хәбәр алмагансың бит?* Г.Бәширов

16) Кабул итү. *Синнән хат алу – үзе бер бәйрәм.* Н.Нәҗми. *Редакциядән тема, киңәш алу – начар эш түгел, ләкин безнең үз инициативабыз да кирәк бит.* Х.Туфан // Телдән яки язма рәвештә билгеле булу. *[Борһан] Улы үлгән, дигән хәбәрне алгач: «Һич югында, каберен күреп кайтырмын...» – дип, улы һәлак булган якларны әйләнергә уйлаган.* М.Хәсәнов

17) Нәрсә белән дә булса бүләкләнү; нинди дә булса дәрәҗәгә ирешү, ия булу. *Ә 1950 елның 18 маенда Находка шәһәр статусы алды.* Ә.Хәбибуллин. *Р.Харисның «Ат иярләү» поэмасы көндәлек матбугатта үзенә лаек бәяне алды инде.* Казан утлары // Нинди дә булса дәрәҗәгә, хәлгә ирешү, ия булу. *Бер эштә дә сынатмый ул, Һәрбер эштә дан ала.* Ә.Ерикәй. *[Вахит Хөҗҗәт улы Хаков] --- татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсешенә багышланган, филология фәннәре докторы исемен алу өчен язылган докторлык диссертациясен, 10 ел үткәч, 1971 елда яклый.* Р.Фәйзуллин

18) Аң-белемгә, мәгълүматка, берәр төрле белгечлеккә ия булу; белемле, мәгълүматлы, тәрбияле булу. *Әлбәттә, укып, белем алу, белгеч яки галим булу – бик күркәм эш.* Ә.Еники. *Көнбатыш Казахстанның финанс бүлеге оештырган салым бухгалтерлары курсында белгечлек алу өчен, Уральскига китеп бара.* Т.Кәримов. *[Гөлүсә] --- бер файдалы һөнәр алу теләге белән, профессиональ-техник училищега укырга керде.* Г.Сабитов

19) Эшләп, тир түгеп, вакыт сарыф итеп яисә башка юллар белән, хезмәт хакына, әҗеренә ия булу. *Тегесе нәрәтләрдә эшче сыйфатында үтә, аена өч йөз сум хезмәт хакы ала.* Р.Кәрами. *Кирәк чагында, сметада каралганнан тыш акча алу да берни тормый иде аңа.* В.Нуруллин

20) Файдалану өчен үз карамагында булдыру. *Машина алу факты бәхет түгел, машина алам, дип хыялланып йөргән көннәр – бәхет.* Т.Галиуллин. *Моторлы көймә алам, дип җенләнеп йөри бит.* Ф.Шәфигуллин. --- *бер йорт алып, шуны яхшылап төзәттерде һәм җәмгыять өчен кирәк булган җиһазлар алды.* З.Мөхәммәтшин

21) Басып керү, яулау, хуҗа булу. *Бастилияне алганмы әллә минем башкисәрләр?* Т.Галиуллин. *Шәһәрне алырга дошман соңгы көчен куеп көчәнә.* Р.Хафизова

22) Эш башкару өчен яллау, нинди дә булса эш башкаруны сорау. *Гөлбикә карышмады, извозчик алдылар да туры егетнең номерына киттеләр.* Г.Ибраһимов

23) Кагыйдәләрне, таләпләрне бозган яки җаваплылыкны үтәмәгән өчен акча түләтү яисә дәүләт тарафыннан мәҗбүри җыем буларак билгеләнгән акчаны түләттерү. *Авыл советы председателе Нуркаев, хайваннарны суярга ярамау, суйган кешеләрдән штраф алу турындагы игъланны совет йортынаябыштырып куйды.* Һ.Такташ

24) Файдалы казылмалар чыгару, җир асты байлыкларыннан һәм башка әйберләрдән икенче продукт җитештерү, җәнлек яки кош-корт аулау яки тоту, чәчеп (утыртып) үстергән нәрсәләрне өлгергәч җыю. *Нардуган – үзенең асылы белән аграр йола, ягъни ул игеннәрдән мул уңыш алу хакына, шундый өмет белән уздырылган.* Н.Максимов. *Нефтьтән төрле сыек ягулык алу*

25) Су, төтен, ут һ.б.ш. берәр нәрсәнең өслегенә таралу, басып китү, каплап китү, уратып алу; үзенә буйсындыру. *Тик шулай да бик сак булырга кирәк – эчтәрәк агым ифрат көчле, эләксәң, йомычка урынына ала.* Ә.Еники. *Бар җирне су алу. Йортны ут алу*

26) Эш кораллары, утлы кораллар һ.б.ш.ның эш башкару мөмкинлеген белдерә. *Сабан төрәне чирәмне киң алу. Туплар ерактан алу*

27) Кемнең дә булса вакытын икенче эшкә, кешегә сарыф иттерү, игътибарын чит әйбергә җәлеп иттерү. *Сез, зинһар, гафу итегез, Сезне урынсыз борчыдык, ахры. Вакытыгызны гына алдык.* Г.Минский

28) Оешмага, уку йортына яки берәр бүлеккә кабул итү, вазифа бирү. *Шуңа тегене эшкә, шикләнебрәк, мәҗбүр булганга гына алган иде.* В.Нуруллин. *Каравылчы итеп алу. Бүлеккә яшь белгечләр алу*

29) Эштән азат итү, эш урыныннан чыгару. *[Сулимов] Назыйм абыйны председательлектән алу мәсьәләсен куйдырды.* М.Вәли-Барҗылы // Нинди дә булса эшчәнлегеннән мәхрүм итү. *Мандатын алу*

30) Берәр оешмага, коллективка, нәрсәнең дә булса составына кертү, кабул итү. *[Булат:] Демьяныч, шулай булгач, армиядә булмый торып, югары белем бирә торган хәрби училищеларга алу, анда биш ел укыту дөресме?* Ә.Хәбибуллин. *Ә Платонның эшләре уңайга китте, аны аспирантурага алдылар.* Х.Камалов

31) Өйләнү, җәмгатьле булу, тормыш кору. *Ләкин көзен өйләнергә Өлгерми калды Аман: «Көз – күңелле вакыт түгел, Кызны мин язын алам!» [диде].* З.Мансур

32) Берәр авыруга дучар булу, авырудан нәрсә белән дә булса дәвалану. --- *бинаның беренче һәм икенче катларында – төрледән-төрле процедура алу бүлмәләре.* Ә.Салах

33) Юнәлеш килешендәге исемнәр белән килгәндә, берәр сүз яки эш турында күңелдә туган уйны белдерә. *Газ турында әйтүемне чынга алды, шаярып әйткәнне аңламады.* Г.Кутуй. *Әнипә, моны уенга алып, тамак төбе белән көлеп җибәрде.* Г.Бәширов

34) *сөйл.* Кисү, кыскарту, тарайту; киемне гәүдә калыбына яраклаштыру. *Күлмәкнең ике яклап бил турыннан алу*

35) Урлау, үзләштерү. *Акча шкатулкасын алганнар!* К.Камал. *[Фәния:] Ни-*

*чек бирелмәгән?! Син бит аның өлешен алып калдың.* Д.Салихов

36) Бетерү, юкка чыгару. *Күңел тынычлыгын алу. Гаепне алу. Шелтәне алу*

37) Һәлак итү, бозу. *Матур чәчәкне кырау тиз ала.* Х.Мәхмүтов

38) Үз эченә, үзенә сеңдерү, суыру. *Каян аш та, каян дым ала икән бу мәһабәт наратлар?* М.Хәбибуллин

39) Конфискацияләү; көчләп, ирексезләп, кая да булса тапшырырга, бирергә мәҗбүр итү. *Хосусый заводларны дәүләткә алу*

40) Тоткын итү, азатлыгын чикләү. *Дошманның дүртесе үтерелгән, берсе, күзе яралысы, пленга алынган.* Г.Минский

41) Балык тоту, эләктерү, каптыру. *Малайлар, килү бушка китмәде, диештеләр, унар-унбишәр балык алганнар.* Г.Ибраһимов. --- *беренче балыкны үзем алыр төсле тоям, һәр минутта, менә эләгә, менә эләгә... дип тора идем.* Г.Ибраһимов

42) Кертү, теркәү. *Теләсә нинди башка тел кебек, татар теле дә, яңа төшенчәләрне белдерү һәм булган төшенчәләрне тагын да дифференциацияли төшү өчен, башка телләрдән сүзләр алган һәм ала.* Татар грамматикасы. *Сүзлеккә җирле сөйләм сүзләрен дә алу*

43) Куллану өчен үзләштерү, кулланышка кертү, берәр максат белән файдалану. *Сәнгатьне тәрбия коралы итеп алу*

44) Бер ноктадан (урыннан) кайсы якка булса да читкә(рәк) күчерү, бору, юнәлдерү, тайпылу. *– Замир, пока турыга бар. Уңга ал. Хәзер үз ягыңа бор, – дип, Зөлфия юлны күрсәтеп барды.* Т.Галиуллин

45) Телефон, рация һ.б.ш. аша тоташу, бәйләнешкә керү. *Вәдүт телефонга тотынды. «Үрнәк»не алып сөйләште.* Х.Хәйруллин

46) Укучыларның белеме һәм тәртибе билге белән бәяләнү, билгегә ия булу. *Рафаэль ык-мык итте, аклан-макчы булып: – Быел беренче тапкыр «дүртле» алуым ла әле, гел «бишле» иде, – диде.* М.Хуҗин

47) Игътибар итү, тукталып үтү. *Менә минем хатынны гына алыйк, мин анда-монда китсәм, бөтенләй зарыгып көтеп тора, ашамый-эчми.* А.Шамов. *Алып карасаң, барлык табигатьне дә тере дип фараз итәргә була бит.* Р.Фәизов

48) *мат.* Кушу гамәленең киресен эшләү, бер санны икенче санга киметү гамәле башкару. *Унбиштән җидене алу*

49) *күч.* Берәр яңа сыйфатка күчү, үзгәрү, яңа сыйфатка ия булу. *Нәтиҗәдә, образ әйтеп бетергесез зур символик яңгыраш ала.* М.Хәсәнов. *Сугышчан чыныгу алу. Хезмәт күнекмәсе алу. Мөстәкыйльлек алу*

50) *күч.* Нинди дә булса тәэсир ясау, элекке сыйфатын үзгәртү, юкка чыгару. *Врачлар авыртуны ала торган инъекция ясадылар. Тәнен кояш алган. Бу тапны кислота алмый*

51) *күч.* Кешедән нидер таләп итү (көч, вакыт, энергия). *Аннан учакта ашарга әзерләү, утны, сүндермичә, тәүлек буе саклап тоту да – күңелле мәшәкать, тик күп вакытны ала иде.* Р.Фәизов. *Көндәлек эш күп көч, энергия ала*

52) *күч.* Күзәтү, тикшерү, өйрәнү максатын куюу. *Шунда ук Балык базары тирәсен дә күзәтү астына алдылар.* З.Фәтхетдинов

53) *күч.* Психик яки физиологик кичерешләр чолгау, биләү. *Әллә никадәр кешене үзенең авызына каратып торудан ул бары тик ләззәт кенә алды.* Ф.Садриев. *Хәдичә түтинең бөтен тәнен ут алды, күз алды караңгыланды.* Г.Бәширов. *Арба янына килеп ятып, йоклау хәстәрен күрә башлагач, мине бизгәк кебек калтырау алды.* Г.Ибраһимов

54) *күч.* Очлы әйбергә кадау, кадап күтәрү. *Штыкка алу. Сәнәккә алу*

**2. аласы** *и. мәгъ. к.* **алачак**. *Аласым да юк, бирәсем дә бетте*

**3. алып** *бәйл. функ.* 1) Эш-хәлнең башлану вакытын белдерү өчен кулланыла. *Ел кебек озын җәйге көндә таңнан алып кичкә кадәр көнозын көтүдә йөргәннән соң, капканы сыңар мөгезе белән генә төртеп ачып, әлсерәп, ишегалдына кайтып кергән сыер хайванын күргәнегез бардыр инде.* З.Хөснияр. *Шул көннән алып, татарлар --- текә генә тау итәгендә алты урыннан бәреп чыгып яткан чишмә янына утар салып утыралар.* З.Зәйнуллин

2) Билгеле бер предметтан (әйбердән) санала башланганын белдерә. *Һәм шулай ук анда нинди генә кошлар булмый!.. Баш бармак хәтледән алып бозау чаклысына кадәр!* Ә.Еники

**4.** *ярд. ф. функ.* 1) Төп фигыльләргә тизлек, кыска вакыт эчендә башкарылу төсмере өсти. *Нурисламның кинәт йөрәге чәнчеп алды.* Р.Хафизова. *Махно бармак буыннарын шартлатып алды.* З.Фәтхетдинов

2) Эш-хәлнең тәмамлануын, нәтиҗәсен белдерә: *Мин аларны тикшерүче язганнардан күчереп алдым.* Р.Мостафин. *Азактан траншея буйлап ярдәмгә килгән иптәшләре снаряд күмгән туфрактан казып алган Раянны.* Ш.Янбаев

3) Эш-хәлнең бер генә тапкыр булуын белдерә. --- *тигез хәрәкәтләнә торган бармаклары ялгышып алгандай булды.* Н.Фәттах. *Минһаҗ, чын күңелдән куанып, кулын кулга сугып алды.* Г.Бәширов

4) Эш-хәлнең аз дәвамлылыгын, озак бармавын белдерә. *Егерме еллар элгәре безнең тәнкыйтьтә, акыл поэзиясеме, хис поэзиясеме, дип бәхәсләшеп алалар иде.* Р.Зәйдулла. *Тик аның гомере кояшлы яңгыр кебек кыска булды, ул атылган йолдыз кебек ялтырап алды да сүнде.* Г.Тавлин

5) Эш-хәлнең тизлеген, көтмәгәндә, кинәт башкарылуын белдерә. *Оча торгач, күзәтә торгач, биек тау башында туп сыман түгәрәк әйбер күреп алган.* Ф.Яруллин. *Каян өйрәнеп алган бу Васих мондый төчелекне?..* Р.Батулла

◊ **Алмаган бия, тумаган колын (тай)** *ирон.* Буласы мәгълүм түгел, булуы бик шикле өмет-хыялдан көлеп әйтелә. **Алып биреп** Тиктомалдан бик каты тиргәп, орышып. **Алып биреп китү** Чыгымчылап чабып китү. **Алып мактарлык түгел, салып таптарлык түгел** Уртача. **Алып та ега, чалып та ега** Теләсә ничек хәрәмли, өстен чыгу өчен бер чарадан да тайчынмый. **Алып узу** Артык узыну. **Алырсың шайтаннан иман** 1) Акчага, малга табынган комсыз кеше хакында әйтелә;

2) Йомыш үтәргә, нәрсә дә булса бирергә бик саран кешегә карата әйтелә

**Ала бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы алу

**Ала тору** *к.* **алып тору** (*1 мәгъ.*). *Аннан язып кайткан эшләре яхшы бәяләмә ала тора.* Ф.Әхмәтова-Урманче

**Алып ату** 1) Кинәт, көтмәгәндә, искәрмәстән алу, башкача эшләтмәү. *Аннары минем эш кузгатучылар кирәкле кәгазьләрне җыеп бетергәнче, --- корольнең үзен алып аттылар.* Р.Мостафин. *Димәк, аны беренче секретарьлыктан алып ату җаен эзли.* Ф.Садриев. *Шуның өстенә, конаралаш диярлек, котүгә бөтенләй чыкмый калуларын да Фәйрүзә апасына әйтсә – берсүзсез эшеннән алып атачаклар аны.* В.Нуруллин

2) Дуамалланып ыргыту. *Өстәлдә өелеп торган кәгазьләрне алып ату*

**Алып бару** 1) Нинди дә булса эшне даими рәвештә үтәү, һәрвакыт башкару. *Көндәлек эшләре муеннан булса да, Гашигуллин санаторий-профилакторийдагы дәвалау методикасы буенча эзләнүләр дә алып бара.* А.Вергазов. *Мәмләкәтнең барлык эшләре шушы вәзир җилкәсендә икән, ул аларны бик уңышлы алып барган.* Г.Исхакый

2) Әле, хәзерге вакытта нинди дә булса эш башкару. *Тапшыруны тәҗрибәле журналист алып бара.* Татар иле

3) Эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе кая да булса яки берәр хәлгә китерү, китереп җиткерү, дучар итү. *Демокрит кешенең хакыйкатькә ирешү сәләтен таный, бу мәсьәләдә ул шул заманда вәсвәсәгә алып барган софистларга, скептикларга каршы чыга.* К.Гыйззәтов. *Һәлакәткә алып барган бу гөнаһны Сез үзара ризалашып кылдыгызмы?* У.Шекспир

4) Берәр эшне башкаруга, оештыруга җитәкчелек итү. *Ул аны яхшы белә: бу кеше – үз урынында, Бөек Ватан сугышында катнашкан, эшен гөрләтеп алып бара, колхоз үргә менә, үсеш бар.* М.Хәбибуллин. *Ул көне-төне колхоз-совхозларга чапты, ә газетаны шәхси ял вакытлары хисабына алып барды.* Ф.Садриев. *Җыелышны колхозның партоешма секретаре Хафиз алып бара.* М.Хәсәнов

5) Дәресләр үткәрү, укыту. *Шуннан соң директор, моңарчы үзе алып барган математика, физика фәннәрен аңа [Ибраһим Нуруллинга] биреп, югары сыйныфларны укытырга күчерә.* Р.Нуруллина

6) Юл күрсәтеп, юнәлеш биреп, артыннан ияртү, әйдәү. *Куудан бигрәк, атларны Кара Кашка алып бара.* З.Зәйнуллин

7) Илтү, кая булса да китереп чыгару. *Ул, бу җирләргә карау белән, кайда, нинди юл үткәнен, нинди сукмакларның кая алып баруын --- бик ачык хәтеренә төшерде.* Ә.Еники

8) *сөйл.* Җиңел машина, самолёт, судно һ.б.ш. транспорт кебек нәрсәләр белән идарә итү, аларны йөртү

**Алып бетерү** Ахырына кадәр алу, булганның барысын да алу. *Бирелә, исемлек төзи башласаң, аларны искә алып бетерү дә мөмкин түгел.* М.Вәли-Барҗылы. *--- сез ник ул үзеңезнең эш бәһаңезне алып бетерергә тырышмыйсыз, менә бу газитә әйткәнчә, тартышмыйсыз?* Г.Исхакый

**Алып йөрү** Нәрсәне дә булса һәрберсен, рәттән алу; әле, хәзерге вакытта нәрсә дә булса алу белән мәшгуль булу. *--- җинаять кылынган, кеше каны аккан урынга, ягъни кунак-кунак уйнаган җиргә барып, таныклыгын күрсәтеп, үзе тикшерү – сорау алып йөрү юлыннан ул баш тартты.* Т.Галиуллин

**Алып калу** 1) Алырга өлгерү. *Малай, тегеләрдән папирос алып калырга ниятләп, машина янына килә.* Р.Мөхәммәтҗан

2) Яшереп, әйтмичә калдыру; яклашу, йомып калу. *--- берәребезгә югары оч малайлары бәйләнә башласа, хәзер калган икебез килеп җитә дә, бер-беребезне яклап алып кала торган идек.* В.Нуруллин

**Алып килү** Гел, һәрвакыт, даими алу. *Май-июнь айлары аның тормышында нинди дә булса борылыш ясарлык вакыйгалар алып килә иде.* Ф.Сафин. *Ел буена «өчле» алып киләләр. Дүртенче чиреккә дә «өчле» чыгарга тора.* Э.Яһүдин

**Алып китү** Билгеле бер вакыттан, урыннан эш-хәрәкәт яхшырып китү. *Салкында тора-тора туңып беткән ат шактый гына кызу алып китте.* И.Гази. *Аннары, лава ташкыныдай шаулап торган көр тавыш белән, әти шул көйне алып китте.* Ә.Галиев

**Алып кую** 1) Алдан алу, алып хәстәрен күрү

2) Каядыр икенче урынга алып урнаштыру. *Рәсемгә озак кына карап торгач, саклык белән генә, аның янына чәчәкләр бәйләмен алып куйды.* Г.Тавлин. *Мәгъфүрә Сабировна посылканы алып куярга кузгалгач, Тәнзиләнең дә бик матур челтәр кысалы шул көзгегә күз саласы килеп китте.* Р.Төхфәтуллин

**Алып ташлау** Көтмәгәндә, искәрмәстән, тиз хәрәкәтләр белән читкә алу. *Иптәш егете кечкенә баланы рельстан алып ташлаган, ә үзе өлгерә алмаган.* Р.Кәрами. *Әхмәт, үзенә юнәлгән утлы карашларны алып ташлау нияте белән, сүзен дәвам иттерде.* Ш.Маннур

**Алып тору** 1) Һәрвакыт, гел, даими алу. *Чит илләр белән элемтә оештырдык, аннан әдәбият алып тордык.* Казан утлары

2) Әле, хәзер алу. *Болар арасында жанр таләпләренә бәйле сораулар аерым урын алып тора.* М.Вәлиев

3) Вакытлыча файдалану өчен алу. *Нигъмәт казыйдан алып торган сәгатьне өстәлгә алып куйды.* Г.Ибраһимов

4) Биләү, үз эченә алу. *Болар арасында кыпчаклар һәм болгарлар күпчелекне алып торганнар.* Х.Миңнегулов. *Җирнең 70%тан артыграк өлешен океаннар алып тора*

**Алып чыгу** Һәрберсеннән берәмберәм алу

**АЛУ** II *мод. ф.* 1) Нәрсә дә булса эшләргә булдыру, кулдан килү. *Әмма Җир шары, аның табигате үзенә килгән бу тетрәнүләрдән, гарасатлар калдырган яралардан чагыштырмача тиз арада арына да алды.* Р.Фәизов. *Татар җырының җаны булган әнә шул олы хәзинәне нечкә чагылдыра алды.* Казан утлары

2) Нәрсә дә булса эшләргә базу, кыю, кыюлык җитү. *Кызлар күзенә карый алмау. Үзе өчен сорый алмау*

3) Нәрсә дә булса эшләргә мөмкинлек булу. *Рух нык булганда гына кеше күңелендә өмет туа һәм яши ала.* Г.Гыйльманов. *Ә милләт динсез дә, телсез дә була аламы?* Ә.Еники

**АЛУ́-БИРҮ** *җый. и. к.* **алыш-биреш**. *Аның бәхетсезлегенә, өлкәдә соңгы өч елда ришвәт алу-бирү маддәсе буенча бер эш тә каралмаган икән.* Т.Галиуллин

**АЛУ́-КУШУ** *җый. и. мат.* Саннарның суммасын яки калдыгын табу билгеләре; арифметика гамәлләре. *Туфаилне исә әти-әнисе дә, абый-апалары да, мәктәпкә кергәнче үк хәреф танытып һәм алу-кушу гамәлләренә өйрәтеп, зур укымышлы кеше итәргә җыеналар.* М.Хуҗин

**АЛУ́-САТУ** *җый. и.* Сәүдә, сату эше. *Беренчедән, ул коллык, кешене алу-сату шөгыленең гайре табигый хәл булуын күрсәтә.* Х.Миңнегулов

**АЛУЧЫ** *и.* 1) Нәрсәне дә булса үз карамагында булдыручы, нәрсәгә дә булса ия булучы, кабул итүче кеше. *Ләкин аның уйлап тапкан әйберен алучы булмады.* Ф.Яруллин

2) Яулаучы, яулап буйсындыручы. *Көннәрдән бер көнне Әхмәди карт, Парижны алучы кыяфәтендә, элеккеге Лаеш өязенең Сиңгеле авылына кайтып төшә.* Н.Гамбәров

**АЛФАВИТ** *и. лат.* Аерым бер телнең авазлары системасын чагылдырган язуда кабул ителгән хәрефләренең билгеле бер тәртиптә бирелгән исемлеге; әлифба. *Ләкин анда бу алфавитның абруе юк.* И.Надиров. *Алфавит башындагы өч иң мөһим хәрефләр болар.* М.Юныс

**АЛФАВИТЛЫ** *с.* 1) Алфавиты булган. *Уйгурларның яңа алфавитлы язмаларының теле Орхон язмалары теленнән дә, Енисей кыргызлары язмалары теленнән дә аерылмый.* Л.Фәйзрахманов

2) Алфавит тәртибендә төзелгән. *Авыр аңлаешлы сүзләргә аңлатмалар һәм алфавитлы исемнәр күрсәткече төзеп бирелде.* М.Әхмәтҗанов

**АЛХӘБӘР** *и.* Нәрсәнең дә булса булачагын алдан белгертә торган билге, сиздереп торган хәбәр. *Нинди дер көчкыч алхәбәрме бу?* Р.Сибат. *«Известия» гәҗитендәге кумәк тәнкыйть мәкаләсе дә тиздән кубачак дәһшәтле давылның алхәбәре түгелме?* Р.Вәли

**АЛХИ́МИК** *и. рус тар.* Алхимия белән шөгыльләнүче кеше. *Муса, могҗизалар күрсәтә белә торган алхимик булмаса да, кайсы ягы беләндер шул ук Фаустка охшый кебек хәзер.* Ш.Маннур

**АЛХИ́МИКЛЫК** *и.* Алхимик булу

**АЛХИ́МИЯ** *и. гар.* Урта гасырларда химия, фармакология һ.б.ш. фән тармаклары үсеш алганга кадәр, гади металларны алтынга әйләндерү юлларын эзләгән, барлык авыруларны дәвалый торган могҗизалы «фәлсәфи таш» уйлап табуга юнәлдерелгән мистик тәгълимат; симия. *Лобачевскийның хәтеренә, кылт итеп, Иван Иванович Дунаевның химиядән кереш лекцияне башлап җибәргәндә әйтергә ярата торган сүзләре килде: «Алхимия, әфәнделәр, химиянең анасы ул».* Җ.Тәрҗеманов

**АЛЧАК** *с. диал.* 1) Явыз, оятсыз; кешелексез. *[Әсфәндияровның] Шулкадәр алчак, кансызлыгын күреп, чәчләр үрә торды.* К.Тинчурин

2) Кече күңелле, түбәнчелекле, ихтирамлы. *Бөтенесе синең үзеңнән: Илгә илткән ямьле сүзеңнән, Алчак күңел, якты йөзеңнән, Миңа баккан нурлы күзеңнән – Бөтенесе синең үзеңнән.* Чиләбе моңнары

3) Якты йөзле, йомшак күңелле; ачык. *Түгәрәк кенә алчак абыстай аларны ишек ачып ук каршы алды.* Р.Зәйдулла. *Кияү белән кыз янына куелган хатын инде бу, үзе бик алчак, җор булса кирәк, теле-телгә йокмый, гел нидер әйтеп, көлдереп кенә тора.* Ә.Еники

**АЛЧАКЛАНУ** *ф. диал.* 1) Явызлану, оятсызлану; шәфкатьсез, миһербансыз булу

2) Якты йөз күрсәтү; ачык булу, кече күңелләнү. *– Әйдәгез, түрдән узыгыз, Габдулла таң белән үк киткән иде, хәзер кайтып җитәр, – дип алчакланып кыстый башлады апа.* М.Ибраһимов

**Алчаклана төшү** Тагы да алчаклану

**Алчакланып алу** Кыска вакыт эчендә, азга гына алчаклану

**Алчакланып бетү** Тәмам, бөтенләй алчаклану

**Алчакланып китү** Кинәт алчаклану

**Алчакланып тору** Әле, хәзерге вакытта алчаклану

**АЛЧАКЛЫК** *и.* Алчак булу; ачыклык. *Риза әфәнде! Мин сездән мондый алчаклык көтмәгән идем.* Ш.Усманов. *Алчаклыгы бар инде Хәтимәнең.* Д.Рамазанова

**АЛШАРТ** *и.* Берәр нәрсәне башкару өчен кирәкле уңайлыклар, мөмкинлекләр; алдан таләп ителгән шартлар. *Бу аңа Җир шарының башка өлешләрен колонизацияләүнең алшарты булып торды.* Ә.Борһанов. *Иллә бер алшартны ачык белә иде ул: үз халкы белән үз халкыннан чыккан хан гына идарә итәргә тиеш.* М.Хәбибуллин. *Аның алшарты бер генә – еллык йөкләмәләрне үтәү.* Ф.Сафин

**АЛЪЙОТ** *с. иск.* Ахмак, башсыз, акылсыз; юньсез, тупас. *Алъйот булсаң, акыл кирәкми.* Мәкаль

**А́ЛЪЯК** *и. сөйл.* Йортның алгы ягы; алгы бүлмә; *киресе:* **түр як**. *Алъякка, гөрләшеп, кунаклар килеп кергәне ишетелде*

**АЛЪЯПКЫЧ** *и.* Киемнең алгы өлешен йорт эшләрен үтәгәндә пычранудан, тапланудан яисә тиз тузудан саклау өчен, артка бау белән бәйләп куела торган япма. *Ул арада кухнядан кызыллы-зәңгәрле алъяпкыч бәйләгән --- Кәүсәрия килеп чыкты.* М.Маликова. *Хәмдениса апай алъяпкыч итәге белән күз яшьләрен дә сөртеп ала.* М.Мәһдиев. *[Хатын-кызлар] Өсләренә зәңгәр, сары, яшел күлмәкләр өстеннән чиккән алъяпкычлар кигәннәр.* Р.Хафизова. *Өстәл янына зәңгәрсу алъяпкычлы урта яшьләрдәге ханым --- килде.* Т.Галиуллин

**АЛЪЯПКЫЧЛЫК** *с.* **1.** Алъяпкычка яраклы, алъяпкыч тегү өчен җитәрлек. *Әни белән бертуган апага дигән алъяпкычлык шотландка, җизнигә дигән ефәк майка, Шәрифулла карчыгына дигән яулык, миңа хат язучы Оркыя күршегә исле сабын белән гәрәбә алдан әзерләнеп куелган иде.* М.Юныс

**2.** *и. мәгъ.* Алъяпкыч тегәргә җитәрлек материя. *«Кычкырырга беләсез, ә өскә-башка ясарга белмисез, минә алъяпкычларым тузып беткән, кычкырганчы, бер алъяпкычлык алып бир», – ди.* Г.Камал. *Ярыш алдынгыларына 5 кап шырпы һәм 2 метр алъяпкычлык биргәннәр.* Ф.Гарипова

**АЛЪЯПМА** *и. к.* **алъяпкыч**. *Алъяпма бәйләгән, 35 яшьләр чамасындагы бер җуан гына, тигез генә маңгайлы хатын казан тирәсендә кайнаша иде.* Г.Исхакый

**АЛЫМ** *и.* 1) *әд. сәнг.* Билгеле бер чорда иҗат итүче әһелләрнең дөньяга карашларын һәм сәнгатьчә фикерләвен чагылдырган, тарихи яктан формалашкан төп принциплар җыелмасы. *Безнең поэзиядә төрле шигъри алымнар, юнәлешләр булды.* Г.Ахунов. *Пикассо кубизм алымы белән иҗат итә бит.* З.Хөснияр. *Либретто авторы Георгий Ковтун А.Хачатурянның танылган балетына яңа алым тәкъдим итте.* Ватаным Татарстан

2) Эшне башкару ысулы, үзенчәлеге; метод. *Ул укыту процессын кайбер яңа алымнар белән баетырга омтыла.* Казан утлары. *Матди яктан уңышка ирешә алмаучыларга түбәнсетеп карау аларны баю юлында төрле (хәтта кешелексез) алымнар кулланырга мәҗбүр итә.* Мәдәни җомга

3) *а. х.* Эшкәртелә торган мәйданны иңләп үтү киңлеге (мәс., урганда, печән чапканда, сөргәндә). *Тезмә ургычларның типажы аларны агрегатлау ысулын, алым киңлекләрен һәм башка техник күрсәткечләрне исәпкә алып эшләнгән.* Урып җыю машиналары

4) Адым, атлау арасы. *Бу атның алымы зур*

5) Аралашу, фикер йөртү үзенчәлеге, рәвеше. *Андый хатларда --- кешенең сөйләшү алымы, хәтта аның холкыфигыле дә чагылыш таба.* М.Зәкиев, С.Ибраһимов

**АЛЫМЛЫ** *с.* **1.** 1) Нинди дә булса берәр иҗат алымына караган. --- *авторның тирән хисле, күтәренке рухлы әсәрләре, стиль ягыннан, романтик агымга якын торган уен алымлы «Ширкәт», «Нур» артистларына күбрәк туры килә.* М.Арсланов

2) Алымы (*3 мәгъ.*) зур булган. --- *киң алымлы ЖШН-6 һәм ЖВР-10А ургычлары --- бөртекле культураларны, урып, теземнәргә салу өчен билгеләнгән.* Урып җыю машиналары

3) Алдырыклы; кызу йөри торган, зур атлый торган. *Алымлы ат*

4) *күч.* Рухи дәрәҗәсе, иҗат итү мөмкинлеге, фикер йөртү рәвеше киңрәк, югарырак булган. --- *«иң зур культура көчләре» тигезлегенә күтәрелеп җитә язганмын, күрәсең: тагын да югарырак баскычка күтәрелү өчен, зуррак алымлы җиргә баруым кирәклек сизелгән.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Киң алым белән. *Кузаклы-бөртекле ашлыкларны алымлы уру*

**АЛЫМСАК** *с. сир.* **1**. Алырга ярата торган, алырга гадәтләнгән. *Асыл түрә сүзеңә карар, алымсак түрә күзеңә карар.* Мәкаль

**2**. *и. мәгъ.* Алырга ярата торган, алырга гадәтләнгән кеше; ришвәтче. *Алымсак белән уртак эш йөртмә*

**АЛЫ́М-САЛЫМ** *җый. и.* Һәртөрле җыемнар, салымнар. *Алым-салым җыю*

**АЛЫМЧАК** *с. сир. к.* **алымсак**

**АЛЫН** *и.* Кыр эшләрендә: бер буйның башыннан алып ахырына кадәр бер яки берничә кеше бергәләп эшкәртә торган кишәрлек. *Без дә, кызып тотынып, бер-ике минутта алынны юк итеп ташладык.* Г.Ибраһимов

**АЛЫНКЫ́-САЛЫНКЫ** *рәв. сөйл.* Алпы-салпы, эленке-салынкы, аннанмоннан, тырышмыйча гына

**АЛЫНМА** *с.* **1.** 1) Башка телдән алынган, чит телдән кергән. *Чит телләрнең, шул исәптән гарәп теленең йогынтысында, алынма сүзләр, сингармонизмы булмаган хәлдә, татар әдәби телендә нормалашып киткән.* Р.Абдуллина // Башка халыклардан, чит илдән алынган. *Әмма Казан әдибе алынма материалларны тегеяки бу дәрәҗәдә үзгәртә, аларны үзенең иҗади максатларына яраклаштырып эшкәртә.* Х.Миңнегулов

2) *к.* **алынмалы**. *[Әләметдин карт] Онытылып, ютәлли-ютәлли көлгәндә, алынма теш казнасын авызыннан чүт кенә төшереп җибәрмәде.* Р.Зарипов

**2.** *и. мәгъ. грам.* Алынма сүз. *Кайчак алынмалар телнең үз сүзләре белән параллель йөри.* Ф.Сафиуллина. *Алынмаларның байтагы татар теле тарафыннан фонетик һәм морфологик яктан үзләштерелгән, ягъни телебезнең структур үзенчәлегенә яраклаштырылган.* Татар грамматикасы

**АЛЫНМАЛЫ** *с.* Алына торган, алынып куела торган; салына торган; эләктереп куелган урыныннан салдырыла торган. *Әгәр алынмалы теш протезлары йөртсәгез, ашаган саен, аларны яхшылап юыгыз.* Хокук һәм хәят

**АЛЫНУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **алу.** *Һәр гектары кимендә утыз центнер уңыш бирер дип торган уҗым бодаеннан нибары егерме җиде центнер бөртек алына.* Б.Камалов. *Бу исемнәр дә – гади генә, табигатьтән, чәчәкләр, йолдызлар исемнәреннән алынганнар.* Р.Фәизов

2) Эшкә тотыну, эшне башлап җибәрү, шул эш белән шөгыльләнә башлау. *Арада бары тик бер кеше – Манька атлы кыз гына эшкә алынырга ашыкмады.* М.Хәсәнов

3) Әйтелгән, кушылган эшне башкарырга ризалашу; кем белән дә булса шул эшне үтәргә килешү, өстенә алу. *Взводның иң асыл егетләре бу эшкә алындылар (бөркетләр!): Ишмаев, Гыйззәтуллин һәм украинлы Остапчук.* Н.Гарифуллин

4) *бот.* Тамыр җибәреп, буйга үсеп китү

**2.** *и. мәгъ.* Алынган булу. *Барысы да минем бу эшкә җитди алынуымны күрделәр.* Г.Шәйхиева. *Ачканчы, һәрберсенә алыну көнен, вакытын, кирәк була калса дип, исәп санын да язды.* Р.Мирхәйдәров

**Алынып бетү** Тәмам, барысы да, тулысы белән алыну. *Хәзер инде алынасы белем алынып беткән.* Н.Фәттах

**Алынып җитү** Тулысынча, тиешле дәрәҗәдә алыну. *Ләкин монда ике нәрсә исәпкә алынып җитми. Беренчедән, --- бу очракта, сүз барыннан да бигрәк, оригинал җөмләсен тәрҗемә телендә дә җөмлә итеп саклау турында бара.* Р.Юсупов

**Алынып ташлау** Тиз арада, кыска вакыт эчендә, алынып, юкка чыгарылу. *Мин урынымнан кузгалмадым, чөнки күреп торам ич – моторларның пропеллерлары алынып ташланган.* С.Баттал

2) Уйлап бетермичә, нинди дә булса эшкә алынырга өлгерү, ашыгып, ризалык бирергә өлгерү

**АЛЫНЧА** *и. этн.* Гадәттә күлмәк өстеннән киелә торган һәм вак тәңкәләр белән бизәлеп тегелгән күкрәкчә. *Элек тәңкәләр тезеп яки ука тотып ясалган изүне – алынчаны – хатын-кызлар күлмәк өстеннән түшкә кигәннәр*

**АЛЫП** *и.* **1.** 1) *фольк.* Гадәттән тыш зур гәүдәле, көчле, батыр йөрәкле егет образындагы әкият герое. *Мин кайсыдыр ил музеендагы аллалар белән алыплар сугышы тасвирланган ватык мәрмәр барельефны яңадан күргәндәй булдым.* Ә.Гаффар

2) Таза, зур гәүдәле кеше. *Гайшә кызлары азат алыпларның күңелләрен күрергә тиешләр, моның өчен һәр кыз, көрәп үк булмаса да, шактый мул акча ала иде.* М.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ.* Озын буйлы, таза, көчле. *Минвәли – Бәдәрнең кече энесе, алып гәүдәле кеше, райпотребсоюзның сәүдә берләшмәсендә товаровед булып эшли.* Р.Сибат. *Алып буйлы скандинавияленең үлеме яшь инженерны бик нык тетрәткән иде.* Д.Лондон

**АЛЫ́П БАРУЧЫ** *и.* Телерадиотапшырулар, концертлар, мәҗлесләрдә һ.б.ш.ларда халыкка мәгълүматны җиткерүче, сөйләүче, таныштыручы; аларга җитәкчелек итүче. *Конкурсның 14 ел гамәлдә булуы вакытында «Россия», «Культура», «Спорт», «Вести-24», «Бибигон»ны үз эченә алган ВГТРК конкурска үз программаларын, фильмнарын һәм алып баручыларын тәкъдим итмәгән.* Шәһри Казан

**АЛЫ́П БАТЫР** *и. фольк. к.* **алып.** *Әйтерсең Алып батыр таш ыргытыш уйнаган да аларны җыймыйча калдырган.* Р.Кәрами. *Бу – аның үзен Алып батыр кебек гайрәтле итеп күрсәтергә маташу галәмәте.* С.Поварисов. *Чыпчык кача. Алып батыр кошлар гына кыю оча.* Н.Фәттах

**АЛЫПСАТАР** *и.* Алып сату белән шөгыльләнүче; базарчы, бизнесмен. *[Флорид:] Акча хәзер өч кешедә. Алыпсатарларда, бизнесменнарда һәм, әзме-күпме, минә боларда.* Д.Салихов. *Аңардан [наркоманиядән] тиз генә арынырмын да димә, аны төрмәләр дә өркетми, алыпсатарлары судка да эләкми.* Н.Хәсәнов

**АЛЫПСАТАРЛЫК** *и.* Алып сату эше; сәүдәгәрлек. *Аннан соң Польша җиренә качкан урыс крестьяннарына каршы көрәшеп йөргән Пугачёв алыпсатарлык кәсебе ярдәмендә бик тиз генә баеп китәргә хыялланa.* В.Имамов. *Алыпсатарлыкка китәр иде – хәйләсе юк, аннан соң ул инде олы яшьтә – бер елдан пенсиягә.* Р.Батулла

**АЛЫПТАЙ** *с.* Бик зур, эре (гәүдә төзелеше турында)

**АЛЫС** *с.* **1.** Ерак, ерактагы. *Тарих төпләренә төшим әле, Гасырлардан алыс гасырга.* Ф.Тугызбаева. *Күрдем мин дә алыс киңлекләрне, Дәрьяларны һәм иркенлекләрне.* Р.Миңнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Еракта. *Алыс булса – кешнәмә, якын булса – тешләмә.* Мәкаль

2) Ерак. *Безгә бик алыс кайтасы.* Н.Фәттах

**3.** *и. мәгъ.* Зур ара, ераклык. *Мәңгелеккә атлап, Юл алысы ята.* Г.Афзал

**АЛЫЧА** *и. бот.* 1) *к.* **әлүчә**. *Аһ, шәп иде дачасы – өч-дүрт төрле йөзем иде, груша, алычасы, алма, өрек һәм абрикос, чия, төче чиясе... һәрхәлдә, бик канәгатьтер аның яңа иясе.* Р.Харисов

2) Шул агачның җимеше. *Әнә чияләрне, алычаларны җыяр идегез, ичмасам...* А.Хәлим. *Бары тик шуннан соң гына Мирзанур, сәкегә куеп торган төенчеген чишеп, бер яулык һәм кәгазьгә төрелгән күрәгә, киптерелгән алыча, алма, тагын бераз йөзем сузды.* Н.Әхмәдиев

**АЛЫШ** *и.* 1) Көрәш, сугыш. *Алышларга чыгар алдыннан һәрвакыт шулай итә.* Р.Фәизов. *Турайларның өчесен бил алышка чакырырлык гәүдәсе белән, Низам күн итек буе малайлардан өркеп яши.* К.Кәримов. *Алай гына түгел, фехтование аны театрга тагын да якынайта – спектакльләрдә ул фехтование алышларын куя башлый.* Казан утлары. *Спартак исән кала, ике туган арасында көрәш кыза, ә иң соңгы алышта алар бер-берсен үтерә.* Ватаным Татарстан

2) Берәрсе белән (кем яки нәрсә өчен) бәргәләшү, кыйнашу. *Шулай итеп, япуннарны тар-мар итүдә катнашкан фронтовик Хираҗ Камалиев өчен Күперледәге алыш уңышсыз тәмамланды.* Ф.Сафин

3) *күч.* Сүз көрәштерү, бәхәсләшү. *Әмма ул – үзенең көченә һәм һәр алышта да җиңеп чыгачагына нык ышана торган хатын.* З.Хөснияр

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ** *җый. и.* 1) Аласы һәм бирәсе әйбер(ләр); алачак һәм бирәчәк нәрсә(ләр). *Хәмдүнә Дамира белән булган алыш-бирешен, ягъни берничә көнгә генә дип алып торган әйберләрен – алтын йөзекләрен, йөз меңнән артык акчасын, өр-яңа күлмәген, еллар үтеп тә кире кайтарылмагач, аннан сорап йөрмәскә, ә уздырып җибәрергә, онытырга булды.* Казан утлары

2) Сәүдә, сату-алу эше (кәсебе). *Алыш-бирешүсеш алган өлкәләрдә ниндидер бер товар үзенең үтемле булуы белән аерылып торган.* Ә.Мөхәммәдиев

3) Бергәләп башкарасы эшләр, үзара тыгыз, якын мөнәсәбәтләр. *Чөнки син исән, синең әле алар белән алыш-бирешең бетмәгән, синең алар белән яшисең, бергә эшлисең бар.* Р.Кәрами. *Йортка Васфикамал килгәннән бирле, күрше-күлән белән алыш-бирешбетте.* М.Мәһдиев

4) Исәп-хисап; аласын – алу, бирәсен – бирү; күрсәтмәләр бирү. *Алыш-бирешләрне төгәлләп, колхоз печате салынган кара бәрхет янчыкны кесәсенә тыгып куйгач, өенә кайтып китте.* Х.Хәйруллин

5) Кыз алу һәм бирү турында. *Ә нигә дип сезгә кунакка йөри соң ул [карт буйдак егет]? Әллә алыш-биреш мәсьәләсе генәме?* Р.Вәлиев. *[Габдерәхим:] Өч дистә ел үз-үземне ашадым, Рабига. Төкерергә иде миңа «алыш-бирешләр»гә, сине култыкларга да әтинең Гөләндәм апаларына күчәргә иде.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Алда эшләнгән гамәлгә җавап бирерлек лаеклы эш, кайтарылырга тиешле үч. *Ул тәти егет белән минем алыш-биреш тә бар бит әле.* В.Нуруллин

7) *күч. сөйл.* Берәр нәрсәгә мөнәсәбәт, бәйләнеш, кагылыш. *Бу нәрсә дигән сүз тагын? Хәдичәнең партия белән нинди алыш-бирешe булсын, ди!* М.Хәсәнов. *Бөек шагыйрьләрнең күбесе, 30–40 яшьләрендә, матди дөнья белән алыш-бирешен өзеп киткәннәр инде.* Р.Фәйзуллин. *Гөманлап тору артык, картның ошбу дөнья белән алыш-бирешe бетеп бара инде.* В.Имамов

◊ **Алыш-бирешне өзү** 1) Ике арада аласын – алып, бирәсен биреп бетерү. *Инде Рөстәм Исмәгыйлевичны бу илдә берни дә тотып тормый, бөтен алыш-бирешe өзелде.* И.Сиражи; 2) Аралашуны туктату, һәртөрле бәйләнешләрне бетерү. *Шуннан соң, узган өч елда болгарларның үз өйләрендә үзара талашуларын күреп, алар белән алыш-бирешне бөтенләй өзәләр.* Н.Фәттах; 3) Үч алу. *Исмәгыйль, ун ел үткәннән соң, элеккеге алыш-бирешен өзәргә, Гамир белән күзгә-күз очрашып сөйләшергә һәм ике арага нокта куярга дип, туган авылына кайтты.* Казан утлары

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ ИТҮ** *ф.* 1) Сәүдә итү, алу-сату белән шөгыльләнү. *Идрис үзе дә Хизбулланы, атасының алыш-биреш иткән кешесе булганлыктан, бик яхшы таный.* К.Нәҗми

2) *күч.* Эш итү, мөнәсәбәттә булу, бәйләнештә тору. *Уңмаган, булдыксыз кешеләрне җене сөйми, андыйлар белән алыш-биреш итәргә дә теләми, исәпләшми дә иде.* Г.Бәширов

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ ИТҮЧЕ** *и. к.* **алыпсатар**. *Дөрес, Каргалы – үзе сәүдә җире, --- ләкин, һәрбер зур авылдагы шикелле, монда да базардан базарга йөреп алыш-биреш итүчеләр аз булмаган.* Ә.Еники

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ ЙӨРТҮ** *ф. к.* **алыш-биреш итү**. *Аның шактый күп пароходлары, шул юл берлән, чыгып-кереп, Төркиянең Яфадагы шәһәрләре арасында алыш-биреш йөртә иде.* Г.Исхакый

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ КЫЛУ** *ф. к.* **алыш-биреш итү**. *Шуның өчен дә Болгар сәүдәгәрләре кояш чыгыш, кояш батыш, төшлек һәм төньягындагы чит илләр, чит патшалар белән алыш-биреш кылалар.* Ш.Әхмәдиев

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ ЯСАУ** *ф. к.* **алыш-биреш итү**. *Фәрит Садыйков, кычкырып: «Туктагыз, хәзер алар минем белән алыш-биреш ясаячаклар, туктагыз! Хәзер үзем сөйләшеп бетерәм», – дип, тегеләрне янә туктатты.* Р.Сәгъди

**АЛЫ́Ш-САЛЫШ** *и. к.* **алыш**. *Сабан туйлары икән. Кызыгы инде үткән. Яңгырап тынган мәйдан, алыш-салышлар беткән.* К.Сибгатуллин

**АЛЫШТЫРГЫСЫЗ** *с.* Алыштырып булмый торган; алыштырырга мөмкин булмаган. *Ә уен ул чорда аның үзе өчен, берниндi тәҗрибәсез, методик көчсез яшь укытучы өчен, берни белән алыштыргысыз тәрбия чарасы булган икән.* Г.Ахунов. *Хан үзе дә, мин дә Болгар-йорт өчен, тәхет өчен аның алыштыргысыз кеше булуын бары ул юкка чыккач кына аңлый алдык.* Н.Фәттах. *Хезмәт – кеше тормышында матди һәм рухи-мәдәни чыганак, укучыны физик, акыл һәм әхлак ягыннан тәрбияләүдә башка бернәрсә белән дә алыштыргысыз чара.* Мирас

**АЛЫШТЫРГЫСЫЗЛЫК** *и.* Алыштыргысыз булу

**АЛЫШТЫРГЫЧ** *и.* **1.** 1) *к.* **алмаштыргыч**

2) Исемгә ияреп, терминологик сүзтезмәләр ясый: беренче компонент белдергән әйберне икенчесенә тапшыра (күчерә) торган җайланма (мәс., *җылылык алыштыргыч*)

**2.** *с. мәгъ.* Берәр нәрсә урынына алмашка кулланыла торган, алыштыра торган. *Ә австриякләр төгәл халык икән, алыштыргыч материалны кабул итмиләр.* Х.Камалов

**АЛЫШТЫРУ** *ф. к.* **алмаштыру.** *[Карт:] Гел куркып-өркеп, урын күчеп, фамилия алыштырып яшәдем.* Р.Кәрами. *[Нәфига:] Төне буе сызгырып йоклавың гына җитмәгән, гырылдавыңнан, дүрт як күрше дә фатирларын алыштырып качтылар бит.* Д.Салихов. *Дөньяда һәркемнең үз урыны бар, кеше кешене алыштыра алмый.* М.Маликова. *Ул аны [шинне], поездда кайтканда, вагон эчендәге бер капкорсактан шинеленә алыштырып алган иде.* Р.Сибат

**Алыштырып алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә алыштыру

**Алыштырып бару** Әзлекле рәвештә, аз-азлап, акрынлап алыштыру. *Бодай куе, көр булып буй тарткан, яшелне саргылт төс алыштырып бара.* Б.Камалов

**Алыштырып бетерү** Тәмам, ахырынача, тулысынча алыштыру. *Гәҗиттә язып чыкканнар: кулдагы зур акчаны яңасына алыштырып бетерергә кушканнар, кассага салсаң да ярый, ди.* К.Кәримов

**Алыштырып йөрү** 1) Әле, хәзерге вакытта алыштыру эше белән мәшгуль булу

2) Һәрвакыт, бертуктаусыз алыштыру. *Гомумән, дин алыштырып йөрүчеләр, мулла яки поп ошамый, дип кенә диненнән ваз кичкәннәр – куркыныч кешеләр.* Т.Миңнуллин

**Алыштырып кую** 1) Тиз арада, бик кыска вакыт эчендә алыштыру. *Урындыкны алыштырып куярга туры килде.* Р.Кәрами. – *Керосинканың фитильләрен күптән караган юк. Кул җитми, искергәннәр. Шуңа төтенле булырлар. Хәзер алыштырып куям мин аны, – диде.* А.Хәсәнов

2) Алыштырган булу, икенче төрлегә әйләнү. *Әле кичәгенәк кенә мыскыл итәргә теләгәндәй ихахайлап көлеп, эткәләп-төрткәләп уза торган малайларны алыштырып куйганнармыни!* М.Хәсәнов. *Гөлйөземне гүя алыштырып куйдылар, йөзе, күзләре, бөтен тәне нур булып балкыды.* М.Әмирханов. *Гомумән, бөтен халәте белән дә ул алай балкып-елмаеп торучылардан түгел. Ә бу көнне аны алыштырып куйганнар диярсең...* Р.Сибат

**Алыштырып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә, гел алыштыру. *Ләкин комсомол секретаренең мораль яктан тотнаксызлыгы, егет башы белән хатыннар янына йөрүе, көнаралаш диярлек, аларны «пирчәткә кебек» алыштырып торуы әйтелгән иде.* Р.Кәрами

**Алыштырып чыгу** Һәрберсен бербер артлы алыштыру

**АЛЫШТЫРУЧЫ** *и.* **1.** *к.* **алмашчы**. *Әйе, кыз һаман әбисе белән иде, ул дөньяда Гөлгенәнең иң якын, әтиәнисен дә алыштыручы иң изге кешесе булды.* Ә.Сафиуллин. *Әнәс уенчыларны алыштыручылар эскәмиясенә килеп утырды.* Ә.Мушинский. *Андый мисаллар бар бит: тәмле ашау, кызыктыргыч дан хакына телен дә, денен дә, хәтта, ата-ана рухына хыянәт итеп, милләтен алыштыручылар да булды.* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ. к.* **алмаш**. *Киләчәк буын тарихыбызны һәм бүгенге тантананы хәтерендә калдырыр, үзен алыштыручы буыннарга язып һәм сөйләп калдырыр, дип өметләнәбез.* Т.Миңнуллин

**АЛЫШУ** *ф.* **1.** 1) *урт. юн. к.* **алу**. *Казан ханлыгын шушы хәлгә китергән Шаһгали моннан соң да Казанны алышып бирергә тырышыр.* А.Таһиров. *Хәтерлим әле, бервакыт ул, мине бер складка алып кереп, миңа күлмәк алышты.* Р.Хәйретдинова

2) Хәбәрләшү, уртаклашу, белдереп тору. *Моназыйр хезмәт срогын тутырып кайтып киткәч, алар хат алыштылар.* М.Хуҗин. *Кем белә, бәлки, менә шушы агачлар да, нинди дә булса юл белән, үзара мәгълүмат алыша торгандыр.* Р.Фәизов

3) *к.* **алмаштыру** (*1 мәгъ.*). *Ары таба ике яшь түрә туганлашалар, атларын, коралларын алышалар.* М.Хәбибуллин. *Бер тартырлык тәмәкене биш кешегә бүлеп бирелгән икмәккә талап диярлек алышалар.* С.Йосыпов

4) *к.* **алмашу** (*4 мәгъ.*). *Ул терлекчелек буенча төнге дежур торачак ветврачка: «Бүген мин торыйм әле, мин торасы төнне син торырсың», – дип, дежурлыгын алышты.* Ф.Садриев

5) Берсе урынына икенчесе килү. *Авылда, колхозда ничәмә-ничә начальство алышты.* Т.Миңнуллин. *Карцерда инде берничә тапкыр тоткыннар алышты.* Л.Гыйззәтуллина // Берәр нәрсә икенчегә үзгәрү, алмашыну. *Үттеләр, шәп чылтырап аккан Судай, шат көннәрем; Бер караңгы һәм төтенле Көнгә алышты төннәрем.* Г.Тукай

6) *к.* **алмаштыру** (*6 мәгъ.*). *Алинә өс-башын алышты.* Х.Ширмән

7) Яшәү урынын үзгәртү, авылга яисә шәһәргә күчү. *Туып-үскән авылымны ташлап, Шәһәр тормышына алыштым.* Х.Хабаров

8) Көч кулланып, егарга һәм җиңәргә тырышу; ярышта көч сынау, көрәшү. *[Дию:] И егет, инде без никадәр алыштык, бер-беребезне җиңә алмадык.* Әкият

9) Сугышта каршы як белән сугышу, кораллы бәрелештә кыйнашу. *Бәкләр бәге Идегәй Туктамыш хан белән моңарчы унбиш орышта алышты.* Р.Вәлиев

10) *күч.* Кемгә дә булса каршы тору һәм аңа бирешмәү. *Яшәмәдем куркып яки көнләшеп, Яшәдем мин тормышка туры эндәшеп. Сугыштым, алыштым, кирәк икән дуладым, Бар йөрәктән сөйдем, көйдем, көлдем, еладым!* Р.Фәйзуллин

**2.** *и. мәгъ.* Алыш, көрәш, ярыш. *Айһай ла, партия-совет эшендә тәҗрибәсе ташып торган кеше белән, Моназыйр абыең белән ягъни, алышуы җиңел булмастыр.* М.Хуҗин

**Алыша башлау** Алышырга тотыну. *Соңра дию белән егет, сахрага чыгып, тагын алыша башладылар.* Әкият

**Алыша бирү** Алышуны дәвам итү

**Алыша төшү** Тагын да бераз алышу

**Алышып бетү** Тулысынча, барысын да алышу. *Чебеннәрне алышып беткәннән соң, яллыйм бер ун-унбиш көтүче, бу сыерларны куып төшерергә усак буенча.* Әкият

**Алышып карау** Көчеңне сынау өчен алышу. *Бүре белән бер тапкыр да алышып караганым юк.* Т.Миңнуллин

**Алышып килү** Күптәннән, элек-электән даими рәвештә алышу. *Урыс-болгар элек-электән кәләшләр алышып килгән.* М.Хәбибуллин

**Алышып кую** Алдан алышу. *Дамир өс киемен алышып куйды*

**Алышып тору** 1) Даими, регуляр рәвештә алышу. *Миңнеруй Сылу Бариевна белән хат алышып тора.* Р.Хафизова. *Чөнки мәктәпләрдә еш булам, укытучылар белән даими очрашып, фикер алышып торам.* Т.Миңнуллин

2) Әле, хәзер алышу. *Күптәнге кан дошманы белән аңа бөтенләй алышып торырга да туры килмәде.* Р.Вәлиев

**Алышып яту** *к.* **алышып тору**. *Контр Зәки Вәлидов белән хат алышып ятасың, дигән уйдырмага, кыйнап, ачыктырып кул куйдырмакчы булалар.* С.Шәрипов

**АЛЫШЫНУ** *ф. к.* **алмашыну**. *Ләкин бу шундук ирен җәлләү, кызгану, элеккечә якын итү белән алышынды.* Р.Кәрами. *Планетада ел алышына.* М.Юныс

**Алышына бару** Эзлекле рәвештә берсе артыннан берсе алышыну. *Бирелә электән мирас булып калган салкынлык иҗади ялкын, кайнарлык белән алышына бара.* М.Вәлиев

**Алышына башлау** Алышынырга тотыну. *Шартлар алышына башлаганчы ук яңача эш йөртергә күчмәсәң – харап.* З.Фәтхетдинов. *[Руслан:] Әллә алышына башладым инде?* З.Зәйнуллин

**Алышына тору** *к.* **алышынып тору.** *Хәтерем – нәкъ кинофильм тасмасы кебек. Кадрлар берсе артыннан берсе, чиратлашып, алышына тора.* З.Хөснияр

**Алышына төшү** Бераз, өлешчә, аз гына алышыну

**Алышынып бару** Акрынлап, азазлап алышыну. *Тышта кояшлы, матур язгы көн кичке эңгер-меңгер белән алышынып бара иде.* М.Насыйбуллин

**Алышынып бетү** Тәмам, тулысынча, бөтенләе белән алышыну. *Ярты гасыр эчендә Дәүләкән халкы алышынып бетте диярлек.* Ә.Еники. *Алар кайчан даими тешләр белән алышынып бетәләр?* З.Хисамов. *Баштанаяк алышынып беткәч, мин инде мин түгел, бөтенләй яңа кеше булам ич!* Ф.Хатипов

**Алышынып җитү** Ахырына кадәр, тулысынча алышыну

**Алышынып китү** Кинәт, уйламаганда алышыну. *Бер караганда [Артур Николаевич] ару гына, икенче карасаң... алышынып китә шикелле.* С.Зыялы. *Ханша шундук агарынып китте. Ханша Аппакның йөзе алышынып китүен күзәтеп торган Феофанның эченә җылы йөгерде.* М.Хәбибуллин

**Алышынып кую** Вакыты-вакыты белән, көтмәгәндә алышыну. --- *«Социалистик йөкләмә» алып ярышмасалар*

*да, күңелләреннән үзара ярышып, берберсен узарга тырышып эшлиләр иде, шуңа күрә беренчелек, икенчелек еш кына алышынып та куйгалый иде: иң алга йә Ислам, йә Андронов чыга ---.* Н.Фәттах

**Алышынып тору** 1) Һәрвакыт, даими алышыну. *Минем тәрбияче марҗаларым әле берсе, әле берсе алышынып торганга, мин, күбәләк кебек, әле бер ут янында, әле бер ут янында оча идем.* Г.Исхакый. *Рәсәйдәге шикелле һәр уңдырышлы елның кытлык алып килә торган корылык, икмәк уңмый торган еллар белән алышынып торуы монда булмаган.* М.Юныс

2) Бер-бер артлы алышыну; әле, хәзер алышыну. *Аннары аның тавышында йомшару илә көчәю алышынып торды.* М.Хуҗин

**АЛЫШЫНУЧАН** *с.* Алышына торган, еш үзгәрүчән. *Чөнки капитанның холкы бик тиз алышынучан, белеп булмый – юктан гына гауга чыгара күрмәсен тагы!* М.Вәли-Барҗылы

**АЛЫШЫНУЧАНЛЫК** *и.* Алышынучан булу

**АЛЬБАТРОС** *и. фр. зоол.* Давыл кошларысыманнар отрядыннан, очы кәкрәеп килгән озын томшыклы, тар һәм нәзек озын канатлы, кыска гәүдәле диңгез кошы. *Шулчак безнең баш очында кап-кара болыт җәелде. Ныклабрак карасам, «болыт» дигәнем альбатрос булып чыкты.* Э.Шәрифуллина. *Альбатрослар миңа, канат болгап, Хәерле юл теле тумыштан.* Ф.Шәех

**АЛЬБИНИЗМ** *и. лат. биол.* Үсемлекләрдә һәм җан ияләрендә тукымада буягыч матдәнең (пигмент) җитәрлек булмавы. *Кешедәге альбинизм (тәннең, күзнең, чәчнең пигментсыз булуы) аутосомада урнашкан рецессив ген белән билгеләнә.* Р.Зәкиев

**АЛЬБИНОС** *и. лат.* **1**. Альбинизм билгеләре булган, пигмент җитешмәгәнлектән ак төстәге үсемлек яки җан иясе. *Альбинос бит бу! Үз кардәшенә охшамаган моның ише затлар ничә гасырга бер генә килеп чыга.* Р.Гаффар

**2**. *с. мәгъ.* Шундый билгеләре булган, ак төстәге. *Акбүре, кешеләр теле белән әйтсәк, альбинос бүрене күргән аучылар бар.* Р.Батулла

**АЛЬБОМ** *и. фр.* 1) Фотосурәтләр, открыткалар, маркалар һ.б.ш. урнаштыру яисә төсле карандашлар, майлы буяулар белән рәсем ясау өчен, калын кәгазьле, зур форматлы китап рәвешендәге дәфтәр. *Аның эш өстәлендә бер альбом саклана.* А.Вергазов. *Әсгать тиз генә алгы яктан рәсемнәр альбомын күтәреп керде.* Р.Хафизова

2) Тасвири сәнгать әсәрләре, шигырь, репродукция, сызым һ.б.ның коллекциясен билгеле бер темага берләштереп урнаштырган китап яки папка. *Фотолабораториядә архитектура ансамбльләреннән, күренекле һәм билгесез рус архитекторларының әсәрләреннән төзелгән альбомнар саклана иде.* Ф.Углов

3) Музыкаль композицияләрнең, җырларның магнитлы тасмада яки информацион дисктагы тупламы. *Җырчының концерт альбомы*

**АЛЬБОМЛА́У** *ф.* Альбомга туплау, альбом рәвешендә эшләү

**Альбомлап кую** Альбом хәленә китереп тоту

**АЛЬБУМИННАР** *и. лат. күпл. биохим.* Йомырка агында, сөттә һәм үсемлек орлыкларында була, медицинада, кондитер әйберләр җитештерүдә һ.б.да кулланыла торган гади табигый аксымнарның суда эрүчән төркеме

**АЛЬБУЦИД** *и. лат. мед.* Офтальмологиядә кулланыла торган антибактериаль чара; күз даруы

**АЛЬВЕО́ЛАЛАР** *и. лат. күпл. мед.* 1) Үпкәдә бронхларның тармакланган очларындагы сулыш алуда катнашкан вак-вак куыклар. *Бронхлар агач ботаклары шикелле тарала, ә соңыннан аларның аралыгы, тарая барып, альвеолаларга әйләнә.* Мәйдан

2) Авыз куышлыгында теш тамырлары урнаша торган уемнар

**АЛЬДЕГИДЛАР** *и. күпл. лат. хим.* Беренчел спиртларны бүлеп чыгару продукциясе, органик кушылмасы (полимерлар җитештерүдә яки органик синтезда һ.б.да кулланыла). *Машиналардан чыккан газда, кеше өчен зарарлы булган кургаш кушылмаларын, бензопирен, альдегидлар һ.б. кертеп, 200 гә якын компонент барлыгы билгеле.* Сәламәт яшәү нигезе

**А́ЛЬМА-МА́ТЕР** *и. лат.* Югары уку йортлары студентлары һәм аларны тәмамлаучылар telендә үзләре белем алган югары уку йортын якын итеп атау исеме. *Монда кадәр килгәч, «Альма матер»га кереп, сәлам биреп чыкмый килешмәс.* А.Хәсәнов

**АЛЬМАНАХ** *и. нем.<гар.* Бер чорда яшәгән төрле авторларның билгеле бер темага, жанр һ.б.ш. буенча берләштереп бирелгән әдәби, тарихи һәм публицистик характердагы әсәрләре җыентыгы. *Хәбәрдар булмаган иптәшләргә белешмә биреп китик: әлеге альманахта басылыр өчен, «тамак төбе белән сөйләшеп, бармак очлары белән генә көрешүче» агайлар да еллар буе чират тора.* Т.Миңнуллин

**АЛЬПЕНШТОК** *и. нем.* Альпинистлар биек тауларга, бозлыкларга менгәндә куллана торган, бер башында очлы тимере булган озын таяк

**АЛЬПИНА́РИЙ** *и. фр.* Бакчаның яки паркның биек таулы җирлекләрдә үсә торган үсемлекләр утыртылган ясалма ташлы таучык урыны

**АЛЬПИНИА́ДА** *и. нем.* Альпинистларның массакүләм сәяхәте

**АЛЬПИНИЗМ** *и. фр.* Үтә текә кыяларга, биек түбәләргә махсус күтәрелүдән гыйбарәт спорт төре. *Китапка кергән «Прогулка за эдельвейсами» повестен язу өчен, Ә.Мушинский, альпинизм буенча республика җыелма командасы составында, Тянь-Шань тауларына экспедициягә бара.* Әдипләребез

**АЛЬПИНИСТ** *и. рус* Альпинизм белән шөгыльләнүче кеше. *Моңа кадәр кеше менә алмаган биек тауга күтәрелгән альпинист кичерешләре булырга тиеш иде миндә.* М.Юныс. *Альпинистлар, егылмас өчен, түбән караудан сакланган шикелле, син дә --- үткәннәреңне үлем янаган төпсез чоңгыл итеп күрәсең.* Ә.Гаффар. *Кытай Эверестка альпинистларны кертүне чикли.* Мәдәни җомга

**АЛЬПИНИ́СТКА** *и. рус* Альпинист хатын-кыз

**АЛЬТ** *и. ит. муз.* 1) Хорда яки вокаль ансамбльдә балалар яки хатын-кызлар калын тавыш белән башкара торган партия. *Мин бит альт тавышлы, шуңа да карамастан, «до, ре, ми»ны алдым.* Р.Батулла

2) Күләме белән скрипкадан зуррак, тавышы аннан калынрак булган кыллы уен коралы. *Мәсәлән, ике скрипка, альт һәм виолончельдән торган кыллы квартет өчен татар халык җырлары темаларына ун пьесадан цикл төзи.* Н.Гамбәров

**АЛЬТЕРА́ЦИЯ** *и. лат. муз.* Тавышның ярты тонга яки бер тонга күтәрелү яки төшү күренеше. *Еш кына, гадәти музыкаль мәктәп дәрәҗәсендәге традицияләрдән чыгып, --- нота ачкычы янындагы альтерация билгеләренең саны белән генә тәгаенләнергә тиеш түгел.* Милли моңнар

**АЛЬТЕРНАТИВ** *с.* Икенең берсе мөмкин яки тиеш булган; шуның берсен генә сайлап алу мөмкин булган. *Аерым чорларда ниндидер альтернатив мөмкинлекләр, әлбәттә, тугандыр, булгандыр.* М.Гайнетдинов. *Афәтнең башында «демократия» дигән бик матур сүз калыкты да, «альтернатив кандидат» дигән нәрсәне керттеләр.* Ф.Садриев

**АЛЬТЕРНАТИ́ВА** *и. фр.* 1) Бер-беренә каршы килгән ике яки берничә арасыннан берсен генә сайлап алу мөмкинлеге. *Алар – альтернативага тартылучы, дөньяга башка күзлектән караучы яшьләр.* Шәһри Казан

2) Бер-беренә каршы килгән аерым-аерым һәрбер мөмкинлек

**АЛЬТЕРНАТИ́ВАЛЫ** *и. к.* **альтернатив**

**АЛЬТЕРНА́ЦИЯ** *и. лат. лингв.* Билгеле бер закончалык нигезендә, тел берәмлекләренең үзара парадигматик мөнәсәбәтләргә керү күренеше (сүз составында авазларның бер-берсе белән чиратлашуы: *к ~ г, п ~ б, д ~ т* һ.б.). *Фактлар күрсәткәнчә, авазлар альтернациясе татар теленең тарихи сүз ясалышында билгеле бер урын алып тора.* Татар грамматикасы

**АЛЬТРУИЗМ** *и. фр.* Чын күңелдән, үз-үзен аямыйча, кемгә дә булса ярдәм итү, булышу; кеше турында кайгыртучанлык; *киресе*: **эгоизм**. *Альтруизм, ягъни кешеләргә ихлас күңелдән яхшылык эшләргә тырышу, гаиләдә искиткеч зур әһәмияткә ия.* Ф.Углов

**АЛЬТРУИСТ** *и. рус* Кешеләргә яхшылык кылучы, файда китерергә тырышучы кеше. *Альтруист – кылган яхшылыгы җавапсыз каласын белсә дә, кешеләргә игелек кыла торган шәхес.* Р.Батулла

**АЛЬТРУИ́СТИК** *с.* Альтруизмга нигезләнгән, альтруизмга мөнәсәбәтле; *киресе*: **эгоистик**. *Чын мәхәббәт – асылда альтруистик хис.* Ф.Углов

**АЛЬТЧЫ** *и. муз.* Альтта уйнаучы

**А́ЛЬФА** *и. гр.* Грек алфавитында беренче хәреф исеме. *Габдрахман Аккош йолдызлыгының альфасы Денеб белән горизонт арасындагы почмакны үлчәде.* М.Юныс

**А́ЛЬФА-НУРЛАР** *и. физ.* Матдәнең радиоактив таркалышы вакытында барлыкка килгән уңай корылмалы кисәкчәләр ташкыны

**А́ЛЬФА-СПЕКТРО́МЕТР** *и. рус физ.* Альфа-кисәкчекләрнең энергиясен үлчәү әсбабы

**АЛЬЯНС** *и. фр.* 1) *кит.* Нинди дә булса уртак максатларга ирешә торган сәяси партияләр, икътисади төркемнәр берлеге, берләшмәсе

2) *сөйл.* Аерым кешеләрнең бер-берсе белән тыгыз элемтәсе. *Мондыйлар уртак ятакта да ир белән хатын арасындагы татулыкны – «альянс», ризасызлыкны – «конфликт», бәхәсне – «дискуссия», хыялны – «иллюзия», максатны «принцип» дип сөйләшәләрдер.* Ф.Баттал

**АЛЮМИН** *и. сөйл.* **1.** *к.* **алюминий**. *Күрәсең, тәкъдиремдә ун ай алюмин кайнатучы завод эшчесе – электролизник булырга язгандыр.* Т.Галиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Алюминийдан ясалган, эшләнгән. *Алтын комлы яр буенда йөзтүбән каплап куелган алюмин көймәләр дулкын кагып чыгарган эре балыклардай ялтырап ята.* Н.Хәсәнов. *Хисмәт аның үзе ясаган алюмин кашыгын баш очыннан алды да --- Абдуллага сузды.* Ш.Маннур

**АЛЮМИ́НИЙ** *и. лат. хим.* **1.** Көмешсыман төстәге йомшак һәм җиңел металл (химик элемент). *10,8 г алюминий массасындагы алюминийның микъдарын билгеләргә.* Г.Хисамиев

**2.** *с. мәгъ.* Алюминийдан ясалган, эшләнгән. *Карт, кыска чалбарының кесәсеннән ике алюминий акча чыгарып, идәндәге беретка ташлады.* М.Юныс

**АЛЮМИ́НИЙЛЫ** *с. к.* **алюминий 2.** *Бу режимны --- тутыкмый торган, кызуга чыдамлы эретмәләрне (легирланган корычларны, алюминийлы һәм бакырлы эретмәләрне) ябыштыру өчен кулланалар.* Электр контактлы эретеп ябыштыру

**АЛЮМИНЛА́У** *ф. махс.* Алюмин белән каплау

**Алюминлап бетерү** Барысын да ахырына кадәр алюминлау

**Алюминлап кую** Алдан алюминланган хәлгә китерү

**АЛЮМОСИЛИКАТ** *и. нем. хим.* Анионнары составында алюминий һәм кремний булган тоз. *Колонка сферик формадагы алюмосиликат катализатор кисәкчәләре белән тутырылган.* Химик технологиянең гидромеханик процесслары

**А́Л-ЯЛ** *җый. и.* Эштә, юлда һ.б.ш.да кыска вакытлы ял. *Әхмәтсафага ике җәй ал-ялсыз сал агызып йөрүенә карамастан, эш өчен тияр әҗерен бирмичә, һаман алдагы елга калдырып килә.* Ф.Сафин

◊ **Ал(ны)-ял(ны) белмәү (күрмәү)** Ял итмичә эшләү, туктаусыз хәрәкәтләнеп тору. *Хәер, кеше дә шулай бит, нәкъ корыч шикелле, алын-ялын белми эшли-эшли дә көтмәгәндә генә кылт итеп сынып та куя.* Л.Хәмидуллин. **Ал(ны)-ял(ны) күрмәү** *к.* **ал(ны)-ял(ны) белмәү**. **Ал(ны)-ял(ны) оныту** *к.* **ал(ны)-ял(ны) белмәү**

**АМ** *ы.* Авыз белән берәр нәрсәне кабып, тешләп алуны белдерә

**АМАЛЬГА́МА** *и. фр. хим.* 1) Нинди дә булса металлның терекөмеш белән эретмәсе яисә терекөмештә металл эремәсе

2) Көзгенең арткы өслеген каплау өчен файдаланыла торган терекөмеш һәм көмеш эретмәсенең юка катламы. *Ялтыравык амальгамасы купкан кызыллы-яшелле көзге...* А.Тимергалин

**АМАЛЬГА́МАЛАУ** *ф.* Амальгама белән каплау

**АМАН** *рәв. гар. сир. иск.* Имин, исән-сау. *Угълым, сабыр бул, түз, аман бул, чыдам бул, дип юата анам, кинәт шунда уянамын.* Р.Батулла. *Бу тәгъбир, һәр нәрсә аман, әйбәт булсын, дигәнгә туры килә.* Сөембикә. *Без кыскача гына бәян иткәннәр Урта гасырларның олы дәүләте булган Алтын Урданың аман яшәве һәм үсүе өчен кирәкле бөтен нәрсәнең дә булганлыгын исбатлый.* Фән һәм тел

**«АМ» ИТҮ** *ф.* Тешләп алу. *Ә ул шунда кинәт кенә ыргылды да минем иреннең яртысын «ам» итте дә ташлады.* В.Нуруллин

**АМБАР** *и. фар.* Иген, он һ.б.ш. кирәк-яраклар саклый торган салкын (ягылмый торган) зур корылма. *Көзнең уңышы амбарларга күчеп бетте.* К.Кәримов. *Әнигә бүген амбарлар юарга әйткәннәр иде.* М.Хуҗин

◊ **Амбар кебек (кадәрле)** Бик зур, артык иркен; буш, җылы тотмый торган, шыксыз (өй яки бүлмә турында әйтелә). *Әмирнең ярый әле аның, миннән яшьрәк булса да, амбар кадәрле ике катлы йортлары бар.* Ф.Яхин

**АМБА́Р-АМБАР** *с.* Гадәттән тыш зур, олы-олы. *Поезддагы теге матросның сүзен әйтүгә, Габдрахман каланчаның ачык җиреннән чыкты да, башы белән, Ярмәкәй тавы астындагы амбар-амбар ташларга таба очты.* Р.Сибат

**АМБА́Р КЕНӘГӘСЕ** *и.* Калын тышлы зур дәфтәр. – *Юк ул, – диде табельчы кыз, амбар кенәгәсенә бүген объектка килгән материалларны язып утырган җиреннән.* Р.Кәрами. *Шахтком председателе Николай Тараканов кулында амбар кенәгәсе калынлыгы кәгазьләр күренә.* Ә.Галиев

**АМБАРЧЫ** *и.* 1) Амбар мөдире. *Ул колхозда амбарчы булып эшли.* Х.Камалов

2) Амбар каравылчысы. *Амбарчы сменага соңга калып килде*

**АМБИЦИОЗ** *с. к.* **амбицияле**. *Анда күңел ачарга яратучы, амбициоз һәм сәләтсез халык җыелган.* Шәһри Казан

**АМБИ́ЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Бик көчле үз-үзен ярату; мин-минлек, тәкәбберлек тойгысы. *Сезнең мәзәкчел кеше икәнлеген аңламаган берәү булса, әлбәттә, бик нык амбициягә бирелер иде.* Ә.Фәйзи

2) Нәрсәгә дә булса дәгъва итү, үз таләпләрен тиешсез һәм артык кую. *Үзеңнең сәяси амбицияләреңне оныт әле*

**АМБИ́ЦИЯЛЕ** *с.* Амбициягә нигезләнгән; мин-минлекле, тәкәббер, һавалы. *Сәламәт амбицияле һәр кешедә дә идеяләр, инициативалар булырга тиеш.* Ватаным Татарстан

**АМБРАЗУ́РА** *и. фр.* 1) Хәрби ныгытмаларның диварларында яки хәрби корабларда ышыкланып ату өчен ясалган махсус уем. *Дошманны чигенделәр өчен бүтән бер чара да калмагач, Матросов туктаусыз ут чәчеп торган амбразурага таба шуыша башлый.* В.Нуруллин. *Амбразуралардан муенналарын сузып, култыкка керүче корабларга карап торган туп көпшәләре кайда?* М.Юныс. *Саня рулевой амбразурада тора иде.* Ә.Хәбибуллин

2) *махс.* Диварда тар гына ишек яки тәрәзә уемы

**АМБУЛАТОР** *с.* Амбулаториядә яки поликлиникада үткәрелә торган. *Бу – амбулатор кабул итү үткәрә торган урын.* Р.Кәрами

**АМБУЛАТО́РИЯ** *и. лат.* Поликлиникага йөреп яки өендә ятып дәваланучыларга гадәти медицина ярдәме күрсәтә торган дәвалау учреждениесе. *Алар амбулаториягә – буазлыклары соңгы көнгә җиткән сыерлар торагына керделәр.* Х.Хәйруллин. *[Фәрхия:] – Сезгә, һичшиксез, амбулаториядә булса да дәваланып алырга кирәк, – дип, кулыма юллама тапшырдылар.* Татар иле

**АМЕ́РИКАЛАШТЫРУ** *ф.* Иҗтимагый мөнәсәбәтләрне һәм мәдәниятне Америка Кушма Штатларында кабул ителгәнчә үзгәртү, Америкача яшәү рәвешен урнаштыру, шуны пропагандалау

**АМЕ́РИКАЛАШУ** *ф.* Америка Кушма Штатларыннан кабул ителгән гадәтләргә, аларның мәдәниятенә, модасына иярү, Америкача яшәү рәвешенә иярү, шуны кабул итү

**Америкалашып бетү** Тулысынча америкалашу

**АМЕ́РИКАЛЫ** *и.* **1.** 1) Америка Кушма Штатларында яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Тик бер генә өмет: бомбежкага эләгеп үлмичә, инглизләргәме, америкалыларгамы барып сыенасы иде!* Ш.Маннур. *Якты чырайлы, кунакчыл, безгә карата теләктәш америкалылар белән аралашудан туган күренекле хисләр дә сүрелә төштеләр.* М.Госманов

**2**. *с. мәгъ.* Америка Кушма Штатында туып-үскән, яшәгән, шунда торган халыктан чыккан. *Америкалы социолог Н.Тимашевның 1948 елда ук игълан ителгән белдерүеннән күренгәнчә, СССР әлеге сугыш вакытында утыз җиде миллион ярым кешесен югалткан булып чыга.* Ш.Мостафин

**АМЕРИКАН** *и. к.* **америкалы.** *Бу ысулны әлегә американнар гына куллана.* М.Юныс. *Әмма теге американның бурычлары күп булган, ди.* Р.Хафизова

**АМЕРИКА́НЕЦ** *и. рус к.* **америкалы.** *[Руслан:] Без кермәсәк, анда американецлар керә иде.* З.Зәйнуллин

**АМЕРИКА́НЧА** *рәв. к.* **америкача.** *Андыйлар янына ул американнарча ап-ак тешләрен балкытып килә, бик ягымлы гына итеп, туп-туры сөйләшә.* Р.Мирхәйдәров

**АМЕ́РИКАЧА** *рәв.* Америка Кушма Штатларында яшәүче халыклар кебек; аларга охшатып. *Америка – нәкъ америкача яши торган ил.* Р.Батулла

**АМЕТИСТ** *и. гр.* Шәмәхә яки зәңгәрсу шәмәхә төстәге кыйммәтле асылташ (минерал, кварцның бер төре; төрле бизәнү әйберләрен ясаганда кулланыла). *Бөрек кыйммәтле асылташлар: энҗе, сапфир, аметист, зөбәрҗәт белән бизәлгән.* Р.Әхмәтҗанов

**АМЁБА** *и. гр. зоол.* 1) Хәрәкәт иткәндә гәүдә формасы үзгәрә торган, бер күзәнәкле иң гади тереклек иясе

2) *күч.* Кеше фикере белән яши торган, төгәл үз фикере булмаган, характерсыз кеше

**АМИН** *мод. с. гар. дини* Намаз, дога укыганда, вәгазь сөйләгәндә яки теләк теләгәндә, нәкъ шулай булсын, кабул булсын, мәгънәсендә соңгы сүз итеп әйтелә

**АМИНОКИСЛОТА** *и. рус* Бер үк вакытта кислоталар үзлегенә дә ия булган һәм нигезне дә тәшкил иткән органик матдә (үсемлек һәм тереклек организмнары аксымнарының төзелешендә төп элемент булып тора). *Ул төрле аминокислоталарга бай.* А.Девятков, А.Макаревич. *Азыкны төрләндерү «алыштыргысыз аминокислоталар» дип аталган бик кирәкле матдәләрдән кеше мәхрүм булмасын өчен кирәк.* Ф.Углов

**АМИН ТОТУ** *ф.* Ашаганнан яки намаз, дога укыганнан соң, ике кулны уч төпләре белән йөзгә таба күтәреп, теләкләр теләп, битне сыпырып алу. *Карчык авыз эченнән генә нәрсәдер мыгырданды, әти өстенә төкерә-төкерә амин тотты.* Н.Дәүли. *Корсагы гөп итеп калган малай, ниһаять, амин тотып, сәке читенә шуышты.* А.Хәлим. – *И Ходаем, балаларга, барлык бәндәләргә бәхет бир, бозыклыклардан сакла, илдә тынычлык булсын, – дип амин тотты*. С.Поварисов

**АММИАК** *и. фр. хим.* Азот белән водород кушылмасыннан торган һәм аны суда эреткәндә нашатырь спирты барлыкка килгән бик ачы исле, төссез газ (ашлама җитештерүдә, суыткыч җайланмаларында һ.б. кулланыла). *Сагаеп калдым: аммиак исе!* И.Низамов

**АММИАКЛЫ** *с.* Составында аммиак булган, аммиак катнаштырылган. *Көл һәм аммиаклы ашламаларны бер үк вакытта кулланганда, азот очмасын өчен, аларны коры килеш тә, сыек хәлдә дә бергә катнаштырырга ярамый*. А.Девятков

**АММОНАЛ** *и. рус тех.* Тау, юл эшләрендә һәм хәрби максатларда кулланыла торган, аммоний селитралы шартлаткыч катнашма. *Махсус чакырылган белгечләр әлеге тишекләргә тутырылган аммоналны бикфорд шнурлары сузып шартлаталар.* Р.Кәрами

**АММО́НИЙ** *и. гр. хим.* 1) Табигатьтә иреклe хәлдә очрамый торган азот һәм водород атомнарының кушылмасы (авыл хуҗалыгы һәм техникада киң кулланыла торган тозлар составына керә). *Безнең бригадага 25 тонна аммоний сульфаты һәм 80 тонна фосфорит оны кайтарылды.* Борынгы Калатау итәгендә

2) Чүпрә урынына файдаланыла торган порошок

**АММО́НИЙЛЫ** *с.* Составында аммоний булган. *Органик кислоталарның аммонийлы тозларын җылытканда, амидлар барлыкка килә.* Органик химия

**АММОФОС** *и. гр. хим.* Составында азот һәм фосфор булган ашлама. *«Аммофос» дигән ашлама масса буенча 85% аммоний дигидрофосфатыннан, 8% аммоний гидрофосфатыннан һәм азотсыз катышмадан тора.* Г.Хисамиев

**АМНИ́СТИЯ** *и. гр. махс.* Суд хөкеменә дучар ителгән затларны, хөкүмәт башлыгы указы белән, гаепләреннән өлешчә яки бөтенләйгә азат итү. *Әле, бәлкем, сугыш бетеп, амнистия булмасмы?* Р.Кәрами. *Бәхетемә, дип әйтимме, амнистиягә эләктем.* Р.Низамиев. *Ам-нис-тия! Әлеге хәбәр Сәләхи җанын коштай талпындырды.* Н.Хәсәнов // Гаептән азат итү турындагы указ. *Утыртуын утырттылар, ә Вакытлы хөкүмәт, үткән елның февралендә амнистия ясап, шул Балабановны иреккә чыгарды.* З.Фәтхетдинов

**АМНИ́СТИЯЛӘҮ** *ф.* Амнистия нигездә азат итү, амнистиягә кертү

**АМОРА́ЛКА** *и. рус сөйл.* Үз-үзен әдәпсез тоту; нинди дә булса әшәке гамәл кылу; начар яктан танылу һ.б.ш. туплаган сыйфатлар. *Ә бу жалу тегеләреннән бик нык аерыла. Зәһәр жалу бу. Аморалка!* М.Әмирханов

**АМОРАЛЬ** *с. кит.* Әдәп нормаларына һәм принципларына каршы килә торган, әхлаксыз, бозык. *Сиңа «амораль» дигән ярлык такмаслар.* Х.Хәйруллин

**АМОРАЛЬЛЕК** *и.* Әхлаксызлык, бозыклык, моральсезлек. *Гомумән, мин бу күренешне аморальлек дип саныйм*

**АМОРТИЗА́ТОР** *и. рус тех.* Бәрелү-сугылуны йомшарта торган җайланма. *Умырткалар арасындагы кимерчәк дисклар амортизатор ролен үйныйлар, умырткалык баганасына хәрәкәтчәнлек, сыгылмалылык бирәләр.* Сәламәт яшәү нигезләре

**АМОРТИЗА́ЦИЯ** I *и. лат. икът.* Төп фондның (мәс., корылмалар, машиналар, җиһазлар һ.б.ш.) тузуы, искерүе нәтиҗәсендә кыйммәте (бәясе) кимү. *Амортизация балансы төзү бик уңайлы.* Х.Камалов

**АМОРТИЗА́ЦИЯ** II *и. фр.* Амортизатор ярдәмендә төрле механизмнарның бәрелүен-сугылуын йомшарту. *Шунлыктан, су катламы кысылып, амортизация ясый алмый.* М.Юныс

**АМОРТИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Амортизация ясау

**АМОРФ** *с. гр.* 1) *хим. минер.* Кристалл төзелешле булмаган, кристаллашмаган. *Утә күренмәле аморф матдәләрдә һәм кубик системага кергән кристалларда икеләтә нур сыну күренеше тышкы көчләр тәэсире астында барлыкка килергә мөмкин.* Физика

2) *лингв.* Грамматик формалары, морфологик категорияләре булмаган (телләр турында). *Аерым телләрдә, бигрәк тә аморф (тамыр) телләрдә (борынгы кытай, вьетнам телләрендә), сүз белән морфеманың каршы куелышы юк.* Ф.Сафиуллина

3) *күч.* Билгеле бер төгәллеге булмаган, тонык, ачык түгел, таркау хәлендәге. *Монда, күрәсең, аларга объектив фактор – авторның үзенең шәхес буларак аморф хәлдә булуы, ныгымаган, үз-үзен тапмаганлыгы да килеп кушыладыр.* М.Вәли-Барҗылы

**АМО́РФЛАНУ** *ф.* Аморфка күчү, аморфка әйләнү

**АМО́РФЛАШУ** *ф. к.* **аморфлану**

**АМОРФЛЫ** *с.* 1) *к.* **аморф** (*1 мәгъ.*)

2) *күч.* Формасыз, таркау. *Әгәр дә индивид үзенең һичнинди мәнфәгатьләрен күздә тотмый икән, коллектив каршында ул «аморфлы» җан иясенә, конформизмга бирелүчән субъектка гына әверелеп калачак*. К.Гыйззәтов

**АМОРФЛЫК** *и. хим.* Аморф булу, кристаллик төзелешкә ия булмау

**АМПЕР** *и. фр. физ.* Халыкара системада электр агымы көчен үлчәү берәмлеге (француз галиме А.Ампер исеменнән). *Анда вольт белән амперны гына белү җитми икән.* А.Гыймадиев

**АМПЕРМЕТР** *и. фр.-гр. физ.* Электр тогы көчен үлчәү әсбабы. *Мансур тумбочкасында амперметр, реестр --- ята.* Р.Кәрами

**АМПИР** *и. фр.* XIX йөз архитектурасында һәм гамәли сәнгатьтә Борынгы Мисыр һәм антик дәвергә хас монументаль формалар, бай бизәкләр үрнәгендә үсеш алган һәм дәүләт бөеклеге, хәрби данлылык идеясен сурәтләгән стиль; классицизмның соңгы чоры. *Соңрак чорда (XIX гасырда) архитектура күп илләрдә ампир стиле белән катнаш үсеш кичерә башлый.* К.Гыйззәтов

**АМПЛИТУ́ДА** *и. лат.* 1) *физ.* Тирбәлеп торган җисемнең тик торыш хәленнән иң зур тайпылыш хәленә кадәр булган киңлек; тирбәлү колачы. *Соңгы елларда һава үзгәрешләре амплитудасы артык нык шаяра башлады.* Р.Хисмәтуллин

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса алмашынуы, үзгәрүе. *Ринат 90 саны өстендә дерелдәгән спидометр угына күз салды – кәеф амплитудасы да төрле тирбәлешкә күчеп үзгәрә иде.* Н.Хәсәнов

**АМПЛУА** *и. фр. театр* 1) Актёр башкара торган рольләрнең тибы. *Элек «инженю-комик», «инженю-драматик» дигән амплуа бар иде театрда.* Р.Батулла

2) *сөйл.* Билгеле бер шөгыльләр, мәнфәгатьләр, гадәтләр, башкарган бурычлар, коллективта тоткан социаль роль. *Минем ике яхшы дустым бар. Уртаклыклар күп үзләрендә: амплуа бер үк, талантлар, карашлар, рухи мәнфәгатьләр тәңгәл.* Ф.Углов

**А́МПУЛА** *и. лат.* Аз дозаларда дару һ.б.ш. сыек матдәләр саклау өчен, герметик ябыштырылган, тар муенлы озынча пыяла савыт. *Иң элек бусага аша нечкә озын бармаклы сап-сары кул күренде, һәм ул теге себерелмәгән тәмәке төпчекләре, канлы мамык кисәкләре, ампула ватыклары --- аунап яткан идәнгә таянды.* Ф.Садриев. *Ася приборларны кайнатырга куйды, зур шкафны ачып, аннан кирәкле ампулалар, дарулар алырга кереште.* Х.Камалов

**АМПУТА́ЦИЯ** *и. лат. мед.* Хирургик юл белән авыру тән әгъзасын (гадәттә, кулны, аякны) өлешчә яки тулысынча кисеп алу. *Аларның йөзенә, бит хәрәкәтләренә карап, Альбин Васильевичның ампутация мәсьәләсендә сабыр итеп тору ягында икәнен чамалап була иде.* Х.Камалов. *Дөрес дәваламаганнар, берничек тә ярдәм итеп булмый, ампутация кирәк, дип кайтардылар.* Р.Кәрами

**АМПУТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. мед.* Ампутация ясау

**АМУНИ́ЦИЯ** *и. лат.* Хәрби хезмәткәрнең кием һәм коралларыннан башка кирәк-яраклары яки ат дирбиясе. *Сезнең егерме легиончыгыз, кырык немец солдаты белән бергә, Украина фронтына амуниция эшелоны озатырга җибәрелгән иде.* Ш.Маннур

**АМУР** *и. лат. кит.* Мәхәббәт, гыйшык тоту. *Әнвәр абый егет чагын искә төшерде. Бер утыз ел элек булган «амур» якларын, ягъни мәхәббәт тарихларын.* Ә.Хәбибуллин

**АМФИ́БИЯ** *и. гр.* 1) *зоол.* Җирдә дә, суда да яши ала торган умырткалы җир-су хайваны. *«Амфибия» сүзе грек теленнән кергән һәм «ике төрле тормыш белән яшәү» дигән мәгънәне аңлата. Амфибияләр җирдә дә, суда да яши ала.* Т.Шакирова

2) *биол.* Җир-су үсемлеге

3) Җирдә дә, суда да хәрәкәтләнү өчен җайлаштырылган җиңел машина, танк һ.б.; җиргә дә, суга да утыра торган самолёт. --- *яшел ботаклар капланган танклар агыла. Виллислар, амфибияләр выжылдап үтеп китәләр, ә юлның ике ягыннан пехотачылар атлый.* Г.Әпсәләмов

**АМФИБРА́ХИЙ** *и. гр. әд.* Силлабо-тоник шигырь төзелешендә басымлы иҗеге уртада килгән өч иҗекле стопа. *Шулай ук мондый өчәр иҗекле юлларның басымнары икенче иҗеккә төшкәннәре дә («амфибрахий» дигәне) була.* Н.Исәнбәт

**АМФИБРА́ХИК** *с.* Амфибрахийга нигезләнгән, амфибрахий нигезендә язылган. *Амфибрахик үлчәм*

**АМФИТЕАТР** *и. гр.* 1) Борынгы Греция һәм Римда: тамашачылар өчен, урындыклары, баскыч-баскыч итеп, арена тирәли ярым түгәрәк яки түгәрәк ясап урнаштырылган ачык түбәле корылма. *Амфитеатрга җитәрәк, мәйдан уртасында грек осталары бер бинаны торгызып яталар иде.* М.Галиев

2) Хәзерге театрда: тамаша залының партеры артында яки ложалар өстендә урнашкан урыннар. *Уртада – партер, ике якта, ике канат кебек, амфитеатрлар өскә таба күтәрелә.* Г.Әпсәләмов

**А́МФОРА** *и. гр.* Шәраб, май һ.б. саклау өчен кулланыла торган тар авызлы, ике тоткалы зур савыт. *Анда шулай ук Византиядә эшләнгән әйберләр: пыяла бизәнү әйберләре һәм савыт-саба, керамика, амфора табылган.* И.Гафаров

**АНА** *и.* **1.** 1) Бала тапкан, бала тәрбияләп үстергән хатын; әни. *Рәшит белән Кяфия шикләнә-шикләнә генә анага сүз кушалар.* К.Тимбикова. *Киләмле баскычтан менә башлауга, һич көтмәгәндә, бөтенләй истә-оста югында, Нурҗиһанның күз алдына, төштә күргән шикелле сәер генә булып, анасы Агафия килеп басмасынмы!* Г.Бәширов

2) Баланың үз әнисен атау, аңа мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе. *Шәфкатьле анам! Бер генә йөземә кара.* Ш.Камал

3) **анасы** *тарт. форм.* Гадәттә, ирнең хатынына мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе. *[Галләм:] Анасы, дөньялар бозыларга тора бит әле, балалар турында уйламый булмый.* Р.Харрасова

4) Ибраһими диннәрдә: Аллаһ тарафыннан ире Адәмнең кабыргасыннан яратылган иң беренче хатын-кыз; барлык кешеләрнең нәсел башы, башлангыч әнисе. *Анабыз Хәүва. Адәмдер бәнем атам, Хәүвадыр бәнем анам...* Мөнәҗәт

5) Ислам динендә изге дип танылган кайбер хатыннарны хөрмәтләү сүзе. *Мәрьям ана (Гайса пәйгамбәрнең әнисе, Коръәндә исеме телгә алынган бердәнбер хатын-кыз), Хәдичә анабыз, Гаишә анабыз*

6) Ана җенестән булган, үрчем китергән хайван, җәнлек, кош-корт яки үсемлек (күбрәк тарт. форм. кулланыла). *Әхнәф ясап куйган ояда сыерчык балалары чыр-чу килешә, аналары җим ташып өлгерә алмый.* Ф.Сафин. *Актүш – атасы ягыннан овчарка катнаш токымнан, анасы ягыннан – гади йорт эте.* Т.Нәби

7) *күч.* Аергыч урынында яки өстәмә сүз булып килгәндә, якын, иң ка-

дерле, мөкатдәс нәрсә, мәгънәсендә. *[Дөнья] Аерып мине Анам-Ватанымнан, Кай җирләргә китереп ташладың?!* М.Җәлил

8) *күч.* Нәрсәне дә булса барлыкка китерүче, тудыручы. *Табигать-анабыз бу дөньяга теләсә кайсы җан иясен кирәк булганга, бүтәннәре белән тыгыз бәйләнештә торып яшәргә яраткан.* Р.Фәизов

9) **анаңны..., анаңның..., анасын...** *гади сөйл.* Тиргәү, шелтәләү, сүгенү сүзе. *Эх, анасын... Сул як шлюпка кырык градуска янтайган.* М.Юныс. *Әгәр дә ялкын торпеда камерасына барып җитсә? Ул чагында... Анаңны...* Ф.Шәфигуллин. *Бәйрәмхан, шул хәбәрне ишеткәч, Бикмураевны яман сүзләр белән сүгеп ташлады. – Анаңның... Аяклары башыңа уралгыры!* М.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ.* Хайван, җәнлек, кош-корт яки үсемлекләрдә ана женесеннән булган; әнкә, теше. *Аннары, икенче тур балалыйсы ана дуңгызларның да вакытлары җитеп килә бит.* Х.Хәйруллин. *Җәй башында, көрән төстәге бәпкәләрен ияртеп, су өстендә ана үрдәкләр күренә башлый.* Хәйдәр. *Ана торна, үзәк өзгеч тавышлар чыгарып, кагына-сугына, күккә томырыла.* Р.Хисмәтуллин. *Ана бүре, уңайлы моменттан файдаланып, һөҗүмгә әзерләнде.* Ф.Шакирова

◊ **Анадан тума** 1) Тумыштан, дөньяга килгән көннән. *Анадан тума телсез*; 2) Берни дә кимәгән, шәрә, ялангач. *Ул арада Кәбир тиз генә чишенде һәм анадан тума калган килеш --- суга кереп китте.* Р.Сибат. *Тәрәзәләрен кырулары бер хәл, үзен анадан тума чишендереп, йомшак җирләрен кычыткан белән чапканнар, ди.* Ф.Сафин; 3) Булган бар әйберне (мәс., йортны, мал-туарны, акчаны һ.б.) югалтып, урлатып, бернәрсәсез калу. *[Карак:] Анадан тума калдыра идем, җәлләдем мескенне.* А.Несин. **Анадан яңа туган** Шәрә, яланөс, бернәрсәсез. *Менә шул чакта, анадан яңа гына туган кебек, шыр ялангач көе каршыма киләчәк Илюха, күз яшьләрен сыга-сыга гафу сораячак.* З.Фәтхетдинов. **Ана йөрәге** Үз баласына карата олы кайгыртучанлык күрсәткән, аны газиз иткән әни күңеле турында. *Бер ана йөрәге бит ул.* С.Поварисов. *Ана йөрәгендә Аллаһы Тәгалә күзәнәге бар, диләр иде, дөрес икән...* Г.Гыйльманов. **Ана куеныннан чыкмаган (чыгып җитмәгән)** *ирон.* Әнисеннән аерылып бетмәгән; олыларча эш итә алмаган. **Анаңны эт ялагыры** *гади с. к.* **анасын эт еккыры**. – *Азман... анаңны эт ялагыры! Яп инде шул ипи шүрлегеңне! – дип кычкырып җибәрде Мунча Миче.* З.Фәтхетдинов. **Ана сөте белән керү (иңү, сеңү)** Нинди дә булса сыйфатларның кешегә кечкенәдән, әнисе тәрбиясе аша күчүе, бирелүе. *Бу изге хисләр аның күңеленә ана сөте белән иңгән.* Р.Хафизова. *Хәзерге заман хатыннары гадәти санаган күп нәрсәне кабул итә алмый иде Мәрьям. Ана сөте белән кергәндер инде.* М.Юныс. **Анасы кызы (улы)** 1) Төсе, кыяфәте, холкы белән әнисенә охшаган кыз (ул); 2) Артык иркә, назлы кыз (ул). **Анасын корт чаккыры** *гади с.* Тиргәү, шелтәләү, сүгенү сүзе. *Кая соң, кая соң, анасын корт чаккыры...* М.Мәһдиев. **Анасын сатты** *гади с.* Тиргәү, шелтәләү, сүгенү сүзе. *Шуннан соң залда утыручыларның берсе: «Анасын сатты!» – дигән җөмлә ыргытты.* Т.Нәҗмиев. **Анасын таныту** *гади с.* Җәзалау, кыйнау; кирәген бирү. **Анасын эт еккыры** *гади с.* Тиргәү, шелтәләү, сүгенү сүзе. – *Анасын эт еккыры... – дип, Саша кузгалды да Ася белән саубуллашып чыгып китте.* Х.Камалов. **Анасы яламаган** *тирг.* 1) Пөхтә булмаган, юылмаган; пычрак, шапшак; 2) Әшәке, бозык, әхлаксыз, тәртипсез (кеше турында)

**АНА ӘРЕМ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, көпшәсез тәбәнәк әрем, ак әрем; *русчасы*: **полынь горькая**

**АНАБИОЗ** *и. гр.* 1) *биол.* Кайбер тереклек ияләренең, начар шартларга реакциясе буларак, уңай шартлар туганга кадәр яшәешен саклау өчен, тереклек функцияләрен сүлпәнәйтү күренеше. *Һәлакәт башлану очрагында, академикка шушы капсулага кереп яту, анабиоз йокысына талу, ә аннары инде, Җир йөзендәге гарасатлар үтеп, аз гына яшәү шартлары туу белән, приборларның аны йокысыннан уятуы каралган иде.* Р.Фәизов

2) *күч. кит.* Нинди дә булса эшчәнлекнең барышы, темпы вакытлыча акрынаю яисә вакытлыча туктау күренеше

**АНАГРА́ММА** *и. фр.* Башка сүзнең хәрефләрен алмаштырып ясалган сүз (мәс., *табак – кабат, идән – Динә һ.б.*). *Бер-берсеннән хәрефләренең урыны белән генә аерыла торган сүзләр «анаграммалар» дип атала.* Г.Нуриев

**АНАЙ** *и. сөйл. к.* **анакай.** *Анай, иртәгә көлтә бирергә чыга алмассың микән?* Ф.Абдуллин

**АНАКАЙ** *и. сөйл.* **1.** Өлкән яшьтәге, ана булган хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе. *[Икенчесе:] Рәхмәт яусын, анакай! Һич онытмам!* Ә.Гаффар

**2**. **анакаем, анакайларым** *ы. мәгъ.* Гаҗәпләнүне, шатлануны, куркуны һ.б.ш. хис-тойгыларны белдерә. *Кайтып җитәргә бары тик санаулы минутлар гына кала, дип, җиңел сулап куйган идем, артыма борылып карасам, анакаем!* Р.Ибраһимов

**АНАКО́НДА** *и. исп.* Буар еланнар семьялыгыннан, Көньяк Америкада елга, күл ярларында яши, балаларын тереләй тудыра торган иң эре елан. *Ә бик зур буар елан анаконда һәм су тузбашы бик озаклап йөзәләр.* Т.Шакирова

**АНА́ КОРТ** *и. зоол.* Умарта илендә иң зур, озынча корсаклы, йомырка сала торган бердәнбер корт. *Ана корт булмаса, умарта туза.* Мәкаль

**АНАКРЕО́НТИК** *с. әд.* Картлык яисә якынлашып килгән үлем авырлыклары фонында яшәү шатлыгын, рәхәтне мактап язылган (*әсәр*)

**АНАЛА́РЧА** *рәв.* Ана булган хатын-кыз кебек, анага хас сыйфатлар күрсәтеп. *Әмма тормышның ачысынтөчесен күргән Гайнисә түти, аларны үзенчә юатып, аналарча акыл бирде.* М.Хәсәнов. *Ул аналарча тавышсыз елый белә иде.* М.Юныс

**АНА́ЛИЗ** *и. гр.* 1) Бөтенне өлешләргә (кисәкләргә) таркатып өйрәнүгә нигезләнгән фәнни тикшеренү ысулы;

*киресе*: **синтез.** *Хәлбуки тарихилык категориясе – җентекле анализны сорый торган шактый катлаулы күренеш.* Казан утлары

2) Нинди дә булса күренешне, фактик материалларны һәрьяклап өлешләп тикшерү, кисәкләргә бүлеп өйрәнү. *Сара апа иҗаты турында бездә, аның дуслары һәм якыннарында, бик күп әйберләр (фотолар, магнит тасмалары һ.б.) бар, алар җыелып, фәнни анализ ясалып халыкка җиткерелсә иде.* Р.Исмәгыйлов. *Тексттагы сүзтезмәләрне аерып алып язгыз һәм аларга анализ ясагыз.* М.Зәкиев. *Анализ өчен нигез итеп, функциональ-семантик кыр эчендәге төп грамматик категориянең мәгънәсе алына, һәм бу мәгънәнең башка фигыль формалары белән реальләшүе карала.* Татар грамматикасы

3) Нинди дә булса матдәнең составын, үзенчәлекләрен билгеләү, аларны тикшерү; шул тикшерү барышында билгеле булган нәтиҗә. *Алтынчәч бүген сүзгә катнашмады, түземсезләнеп, анализ нәтиҗәсен көтте.* М.Маликова. *Соңыннан мине тешләгән этнең канын алдырып, анализ нәтиҗәсен дә китерттеләр.* Ф.Хөсни

**АНАЛИЗА́ТОР** *и. гр.* 1) Нинди дә булса матдә табарга, аның составын билгеләргә, күренешләрнең физик һәм башка якларын ачыкларга ярдәм итә торган әсбап

2) *физиол.* Баш миенең бер өлешенә урнашкан, әйләнә-тирә мохитнең тәэсиреннән барлыкка килгән тышкы, шулай ук эчке ярсыткычларны кабул итеп һәм анализлап торган нерв җепселләре системасы

**АНА́ЛИЗЛАУ** *ф.* Анализ ясау; анализ бирү, җентекләп тикшерү, өйрәнү. *Шуннан Әхмәтов бер-бер артлы сораулар бирә башлый, җавапларын анализлый.* Р.Кәрами. *Аңа бары тик уйлау, ягъни логик бер эзлеклелектәге мәгълүматларны математик ысуллар белән анализлау мөмкинлеге генә бирелгән.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Югарыда санап үтелгән авторларның тамырдан ялгыш тарихи «концепцияләрен» һәрьяклы, этрафлы анализлап тормастан, аларның карашларына каршы үз аргументларыбызны бәян итәбез.* М.Әхмәтҗанов

**Анализлап алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә анализлау

**Анализлап бару** Берсе артыннан иекенчесен рәттән, даими рәвештә анализлау. *«Албастылар»дагы кебек үк, монда да автор вакыйгаларны һәрдаим анализлап бара.* А.Шәмсутова

**Анализлап бетерү** Тулысынча анализлау. *Галимнәр матдә-төшенең үзгегә үтеп өйрәнә алсалар да, хис һәм фикер төенен таркатып, анализлап бетерү җаен тапканнары юк әле.* Р.Аймәтов

**Анализлап йөрү** Озак вакытлардан бирле анализлау белән мәшгуль булу. *Назаны әйт син, Назаны! Менә нәрсәләр уйлап, һәммәсен күңеленә җыеп, анализлап йөри икән бит!* А.Гыйләҗев

**Анализлап килү** Эзлекле рәвештә, системалы бер-бер артлы анализлау. *Анда Г. Ибраһимов татар мәгыйшәтенең шагыйрьгә бирерлек яктылыгы һәм мәдәни тәрәккыяте булмавын хәсрәтләнеп анализлап килә дә, «талант трагедиясе»нә сәбәп итеп, Тукай шәхесенә тискәре кагылган хаксыз фикерләрен яудыра.* М.Җәләлиева

**Анализлап кую** Алдан анализлау

**Анализлап тору** Һәрвакыт, гел, даими анализлау

**Анализлап үтү** Сүз барышында, сүз уңаенда анализлау. *Ул пьесаларның һәрберсенә тукталып, анализлап үтү мөмкин түгел.* Н.Юзиев. *Гариф Ахунов күзәтүчәнлегенең кайбер үзенчәлекле якларын анализлап үтик.* Р.Фәтхрахманов

**Анализлап чыгу** Һәрберсен, берсен дә калдырмыйча яки башыннан алып ахырына кадәр анализлау. *Галим, беренчедән, бөек шагыйрьнең халык иҗатына, аның табигатенә, асылына караган теоретик фикерләрен бер системага салып анализлап чыкты.* Х.Мәхмүтов. *М.Җәлилгә бәйле пунктка килсәк, ТАССР КГБ рәисенең урынбасары Кузнецов махсус бүлектә бу мәсьәләнең тарихын гаять җентекләп анализлап чыга.* Р.Мостафин

**АНА́ЛИЗЛЫ** *с.* Анализга нигезләнгән, яхшы анализ ясалган. *Сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Фоат кызы Вәлиева-Сөләйманиованың рәссамнарыбыз турында язылган язмалары да тирән анализлы булулары белән хәтердә кала.* Ватаным Татарстан. *Белгечләрнең анализлы чыгышлары. Җентекле анализлы мәгълүмат бирү*

**АНАЛИ́ТИК** I *и. рус* Анализ методлары белән оста эш итүче, яхшы анализлаучы кеше; аналитик геометрия, химия һ.б.ш. тармак белгече; табигате белән анализ ясарга яраткан, анализлый торган кеше. *Безнең аналитиклар хаклы булып чыга: Татлян бик җитди рәвештә бандитлар белән кызыксына.* Р.Мирхәйдәров

**АНАЛИ́ТИК** II *с.* Анализга (*1 мәгъ.*) нигезләнгән. *Аналитик геометриядә «нокта бирелгән» дигәнне «ноктаның координаталары бирелгән» дип, «ноктаны табарга» дигәнне «ноктаның координаталарын табарга» дип аңларга кирәк.* Югары математика нигезләре

**АНАЛИ́ТИКА** *и. рус* Күренеш, фактларга җентекле анализ ясау

**АНАЛИ́ТИКЛЫК** *и.* Аналитикага нигезләнгән булу. *Хәзер бу телдә аналитиклык сыйфатлары көчәя бара.* Ф.Сафиуллина

**АНА́ЛОГ** *и. гр. кит.* Нинди дә булса предмет яки күренешкә тәңгәллек, охшашлык; шуңа охшаш булган башка предмет яки күренеш. *Бүген Россиянең барлык телеүзәкләре телесигналны аналог форматында тапшыра.* Ватаным Татарстан

**АНАЛО́ГИК** *с.* Аналогиягә нигезләнгән. *Әйтик, типик татар халык җыры строфасындагы дүртьюллыкның ике өлешенә, туры мәгънәви бәйләныш түгел, бәлки кучерелмә, аналогик яисә параллель настроение уртаклыгы хас.* М.Госманов

**АНАЛО́ГИЯ** *и. гр.* Предметлар, күренешләр, төшенчәләр арасында нинди дә булса мөнәсәбәтләрдәге охшашлык, тәңгәллек, тиңдәшлек. *Сүз составының аналогия буенча үзгәреше нидән гыйбарәт?* Ф.Сафиуллина

**АНАЛО́ГИЯЛЕ** *с. к.* **аналогик**

**АНАЛЫ́-АТАЛЫ** *рәв.* **1**. Анасы һәм атасы белән бергә

**2**. *и. мәгъ.* Анасы да, атасы да исән булган, тигез яшәгән кеше. *Аналы-аталы – алтын канатлы.* Мәкаль

**АНАЛЫ́-БАЛАЛЫ** *рәв.* Анасы һәм баласы бергә. *Ашыкмыйча, салмак кына чабып барган аналы-балалы пошиларны күреп алгач, --- машинаны читкә бордым.* В.Нуруллин

**АНАЛЫК** *и.* 1) Ана булу. *Әнә Көмешбикә кебекләр дә, ана булып та, аналык хокукыннан мәхрүм ителгәннәр дә, балаларын туу белән ишек төпләренә ташлап качкан түбән җаннар да бар.* Р.Хисмәтуллин. *Кеше акылыннан мәхрүм булган ат, тере җан, аксыл рәшәләр аша, кешеләргә хас акыл һәм сизенү, аналык тойгысы белән, туган ягына ашкына иде.* А.Хәлим

2) *анат.* Хатын-кызның һәм бала тудыра торган хайваннарның яралгы үсә торган эчке җенси әгъзасы

**АНАЛЫ́-КЫЗЛЫ** *рәв.* Ана белән кыз бергә, ана белән кыз бергәләп. *Аналы-кызлы өйгә керделәр.* А.Гыйләҗев. *Аларның аналы-кызлы кебек бер-берсенә сарылулары бөтен мәйданны тетрәндерде.* Б.Камалов. *Диләфрүз апа белән Сәрия, аналы-кызлы, берберсенә карашып алдылар.* Р.Хафизова

**АНАЛЫ́-УЛЛЫ** *рәв.* Анасы белән улы бергә, ана белән ир бала бергәләп. *Тегеләр аналы-уллы бер мәлгә, ни әйтергә белмичә, бер-берсенә карашып тордылар.* Г.Галиев. *Курай-малай боларның аналы-уллы Сукыр тычканнар икәнен төшенеп алды.* Р.Хафизова

**АНАЛЬГИН** *и. гр. фарм.* Авыртуны баса торган, температураны төшерә торган дару. *Баш авыртканда, аспирин йә анальгин бирергә кирәк.* М.Маликова

**АНА́МНЕЗ** *и. гр. мед.* Авыручының яшәү, тормыш итү шартлары, нинди авырулар белән авыруы һ.б. турында мәгълүмат (гадәттә, авыруның үзеннән яки туганнарыннан алына). *[Алтынчәч] Утыз биш яшендә беренче тапкыр буйга узган, йөклелеге егерме тугыз атна, анамнезы начар.* М.Маликова

**АНАМОРФИЗМ** *и. гр. геол.* Югары басым һәм югары температура шартларында тау токымнары үзгәрү күренеше

**АНАМОРФОЗ** *и. гр. биол.* Үсемлекләр үсешендә нормадан тайпылу күренеше

**АНАНАС** *и. исп. бот.* 1) Бромелийчалар семьялыгыннан, калын кыяк яфраклы, эре татлы җимешләре калын кабыклы, озынча түгәрәк формада булган тропик үсемлек

2) Шул үсемлекнең җимеше. *Тау-тау итеп өелгән бәрхет кабыклы бананнар, алтын тышлы әфлисуннар, кәрәз кабыклы ананаслар, хуш ис таратып, ымсындырып торалар.* М.Юныс. *Җырчы аңа бер сумка тутырып ананасын, бананын, әфлисунын илтте.* Мирас

**АНА́ПЕСТ** *и. гр. әд.* Силлабо-тоник шигырь төзелешендә ике басымсыз иҗектән соң бер басымлы иҗек килгән өч иҗекле стопа. *Басымнарга күз салып узгәндә күрдек ки, татар телендә басымнар эчтәлеккә буйсынырга тырышалар, хорей, анапест һ.б.лар киртәсенә керергә теләмиләр.* Х.Туфан

**АНАПЕ́СТИК** *с.* Анапестка нигезләнгән

**АНАР** *и. фар. бот.* 1) Анарчалар семьялыгыннан, чәчәкләре кып-кызыл төстә, җимеше түгәрәк формалы, эче карасу кызыл әчкелтем баллы төшләрдән гыйбарәт көньяк агачы яки куагы; гранат. *Синең бакчаңда – дүрт анар агачы.* Р.Харис

2) Шул агачның җимеше. *Инде болар өстенә тагын анар төшләре сибәбез дә эре кәбестә яфраклары белән томалыйбыз.* М.Галиев. *Иң татлы, иң файдалы ширбәт эчерәм мин сиңа. Анар ширбәте.* М.Әмирханов

**АНАРХИЗМ** *и. гр.* 1) Һәртөрле дәүләт хакимлеген, оештырылган сәяси көрәшне инкяр иткән һәм шәхеснең бәйсезлеген яклаган иҗтимагый-сәяси агым

2) Җәмгыятьтә кабул ителгән әхлак кагыйдәләрен саклаудан, нинди дә булса йөкләмәне үтәүдән баш тарту. *Гыйсъянчылыкны вак буржуа бунтарьлыгы, хәтта «анархизм» дип атаулар да булды.* Ф.Галимуллин

**АНА́РХИК** *с.* Анархиягә мөнәсәбәтле, анархиягә бәйләнешле. *Бу агымнарның тагын бер тармагы М.Штирнерның (1806—1856) анархик тәгълиматларында чагыла.* К.Гыйззәтов

**АНАРХИСТ** *и. рус* 1) Анархизм (*1 мәгъ.*) тарафдары. *Анархистлар белән һөҗүмне оештыру өчен, Мәскәүгә махсус эмиссар чыгып китте.* З.Фәтхетдинов

2) Башбаштаклык күрсәткән, хөкүмәткә, әхлак кагыйдәләренә буйсынмаган кеше. *Аларга әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән «анархист», «бунтовщик» дигән исемнәр тагып бетерделәр.* Х.Хәйруллин. *Алар: «Без аклар да түгел, кызыллар да түгел, без үзебезгә-үзебез хуҗа! Без – анархистлар!» – дип, авылларны, бистәләрне кырыштырып йөргәннәр.* Н.Дәүли

**АНАРХИ́СТИК** *с.* Анархиягә караган, анархизмга нигезләнгән, анархиягә бәйләнеше булган. *Бөтен бер илнең бар булган дәүләтен таратып ташлауда анархистик шаукымны чамалау кыен түгел.* Х.Госман

**АНАРХИ́СТКА** *и. рус* Анархист хатын-кыз. *[Сәрвәр:] Син просто кеше алдында мине үзе теләгәнчә йөри торган бер анархистка итеп күрсәтмәкче буласың.* Ф.Хөсни

**АНАРХИСТЛЫК** *и.* 1) *к.* **анархизм**

2) Анархист булу. *Синең андый анархистлыгың гадәтеңә кереп бара.* Т.Миңнуллин

**АНА́РХИЯ** *и. гр.* 1) Җәмгыятьтә дәүләт хакимиятенең, идарә итү оешмаларының, законнар үтәлешенең һ.б.ш.ның артык йомшак булуы; шәхескә чикләнмәгән ирек бирү; хакимиятсезлек. *Анархия хәрәкәтенә искиткеч зур зыян киләчәк.* З.Фәтхетдинов

2) Тәртипсезлек, хаос; башбаштаклык. *[Боцман матросларга:] Анархияне, бардак ясап йөрүегезне тиз бетерермен!* М.Юныс. *[Яббаров:] – Әйтик, без, бригадирлар, аның сүзен санга сукмасак, ә сез – бригадирныкын, Альберт, бу нәрсә була? [Альберт:] – Анархия.* Р.Кәрами

**АНА́РХИЯЧЕЛ** *с.* Анархиягә хас

**АНАСЫ́-АТАСЫ** *и.* Анасы һәм атасы. *– Ничек керергә катауга, ничек анасы-атасы янына барып җитәргә? – аның күңелен менә шундый сорау тынычсызлый иде.* Н.Фәттах

◊ **Анасы-атасы белән сүгү** Бик тупас, әшәке сүзләр белән тиргәү. **Анасы-атасы юк** Рәте-чираты, тәртибе, мәгънәсе юк

**АНА́ ТЕЛЕ** *и.* Туган тел, үз милләтең теле. *Асия апа Таҗиева ана теле һәм әдәбияты укытучысы булмаган булса,*

*мәктәп елларын искә алмаска да булыр иде.* Ә.Хәбибуллин. *Кылычтан кыелмаган ул, упкынга убылмаган, ялкыннан ялманмаган ул, алтынга алданмаган – менә шундый үлемсез тел бит ул, Ходай кодрәте белән иңдерелгән Газиз Ана теле!* М.Галиев

**АНА́ТОМ** *и. рус* Анатомия белгече. *Анатом минем фикеремне тулысынча раслады.* Г.Әпсәләмов

**АНАТО́МИК** *с.* Анатомиягә бәйләнешле. *Ул, врач һәм культуралы кеше буларак, анатомик вариацияләр, имгәнү, бәхетсезлек очраклары һәм башка факторларның кайчак организмның табигый төзелешенә зарар китерүен --- белергә тиеш иде.* Ф.Углов. *Аны саклауны төрле урыннарда оештырдык, мәсәлән, университетта аны иптәш Державин анатомик театрда саклады.* Казан утлары

**АНАТО́МИЯ** *и. гр.* 1) Тере организмның һәм аерым әгъзаларның төзелеше һәм формасы турындагы фән. *Анатомия дәресендә безгә укытучы дөрес туклану турында сөйләгән иде.* М.Юныс. *Анатомия фәне сөйләм авазларын биологик аспектта өйрәнгәндә кулланыла.* Ф.Сафиуллина

2) Организм яки аерым әгъза төзелеше. *Розидлар асклассына керүче үсемлекләр тышкы күренеше, чәчәк төзелеше һәм вегетатив органнарының анатомиясе буенча гаять күп төрле.* Л.Мәүлүдова

3) *күч.* Теләсә нинди объектның, әйбернең эчке төзелеше, кисәкләрнең, өлешләрнең үзара мөнәсәбәте. *Бозыклык «анатомия»сен шушының кадәр җентекләп тасвирларга кирәк бит!* Р.Шәрәфиев

**АНА́ФЕМА** *и. гр.* 1) *дини* Ниндидер нәзер әйтеп, Аллаларга атап аерып куелган, изгеләштереп багышланган корбан

2) *дини* Чиркәү тарафыннан салынган каргыш, ләгънәт; общинадан куылган, читләштерелгән булу

3) *күч.* Кискен гаепләү, ачулану, тиргәү сүзе; мәлгунь, ләгънәт төшкән нәрсә, каһәр суккыры. *Нишләвегез бу, иблис токымнары! Мәлгуньнәр! Анафемнар!* И.Гази

**АНА́ФОРА** *и. гр. әд.* Бер-беренә янәшә яки якын торган шигъри юл, строфа яки фразаларда бер үк сүзләрнең, җөмләләр яки авазларның кабатлануыннан гыйбарәт булган стилистик алым. *«Диване хикмәт»тә һәм «Бакырган китабы»нда юлбаш анафоралар да очрый.* Х.Миңнегулов. *Кайбер шигъри әсәрләрдә анафора стилистик фигура булып кына калмый, ә бөтен әсәрне төзүгә хезмәт итә.* Әдәбият

**АНАХРОНИЗМ** *и. гр.* Бер чор күренешләрен яки вакыйгаларын, ялгышып, башка (икенче бер) чорныкы дип карау, хронологияне бозу. *Сатирик жанрлар --- искергән, картайган һәм анахронизм хәленә килгән күренешләр белән эш итәләр.* И.Нуруллин. *«Юлий Цезарь» трагедиясен язганда, Шекспирның антик чордагы Рим өчен характерлы булмаган детальләр – пушкалар һәм башнядагы сәгатьләр кертеп җибәрүе дә анахронизмга мисал була ала.* Әдәбият

**АНАХРО́НИК** *с.* Анахрониягә нигезләнгән, анахрониягә мөнәсәбәтле

**АНА ЧӘКИ** *и. гади с.* 250 граммлы шешәдәге ак аракы. *Әти-әнисе кушуы буенча, шофёр абыйсына «ана чәки» биргән бу.* Т.Нәҗмиев

**АНАША** *и. төрки* 1) Киндерчәләр семьялыгыннан берьеллык үсемлек; яфракларында, чәчәкләрендә һәм серкәләрендә көчле әфьюн булган кыргый киндер төре

2) Шул киндердән киптереп ясалган наркотик матдә. *Алты яшүсмерне анаша белән сыйлап, шартлап баеган бер кооператорның квартирасын талап чыгарга котырттык.* З.Мәхмүди

**АНАЭРОБ** *и. гр. биол.* Ирекле кислород булмаганда да яши һәм үрчи алган организмнар, микроблар; *киресе:* **аэроб**

**АНГАЖЕМЕНТ** *и. фр.* Артистны яки труппаны билгеле бер срокка спектакльләрдә һәм концертларда катнашу өчен чакыру, катнашу турындагы килешү, шартнамә

**АНГАР** *и. фр.* Самолёт, вертолёт, дирижабль һ.б.ш.ны ремонтлау, саклау һәм аларның төзеклеген тикшерү өчен ясалган махсус корылма яки бина. *Таңнан торган очучылар, эшләрен тәмамлап, самолётларын ангар янына китереп туктатканнар иде.* С.Баттал

**АНГИДРИД** *и. гр. хим.* Су белән гипс катнашканнан соң барлыкка килә торган минерал; зәңгәрсу яки сары төсле таш (цемент җитештергәндә кулланыла)

**АНГИ́НА** *и. лат.* Йоткылыктагы лайлалы катлауның, тамак бизләренең ялкынсынуыннан барлыкка килгән йогышлы авыру; тамак шеше авыруы. *Минем өч бала ангинадан үлгән.* Ф.Садриев. *Медик Җәүдәтнең ангина белән авыруын, кимендә ике-өч көн ятактан тормаска кирәклеген әйтә.* Казан утлары

**АНГЛИЧАН** *и. сөйл.* Англиядә яшәүче җирле халык; шул халыкның бер вәкиле; инглиз. *Әнә бит англичаннар нинди хәйләкәр.* Ш.Маннур

**А́НГЛИЯЛЕ** *с.* Англиядә туып үскән яки шунда яшәүче кеше. *Йөздән артык яшь англияле, турист рәвешендә Советлар Союзына барып, иврит телендә әдәбият, видеокассеталар һәм башка пропаганда материаллары тарата.* З.Хөснияр

**АНГЛОМАН** *и. ингл.-гр.* Англомания тарафдары

**АНГЛОМА́НИЯ** *и. ингл.-гр.* Инглизләр тормышына, яшәешенә, гореф-гадәтләренә, гомумән аларның мәдәниятенә мөкиббән китү, иярү, аларны башка барлык халыклардан өстен кую

**АНГЛОМАНЛЫК** *и. к.* **англомания**

**АНГЛОСАКС** *и. ингл. тар.* Тарихчылар Эльба һәм Рейн елгалары арасында яшәгән дип фаразлаган англо һәм сакслар, соңыннан ютлар кушылган борынгы алман кабиләләренең уртак атамасы (безнең эраның V гасырында алар икегә бүленеп, бер өлеше көньякка – Германиягә, икенче өлеше көнбатышка күчә һәм инглиз этносына нигез сала). *Инглиз теле – элеккеге англосакс теле – флектив тел булган.* Ф.Сафиуллина

**АНГЛОФИЛ** *и. ингл.-гр. к.* **англоман**

**АНГЛОФОБ** *и. ингл.-гр.* Инглиз халкыныкы булган барлык нәрсәләрне кире кагучы, аңа каршы баручы

**АНГОР** *и. сөйл. к.* **ангора**. *Кыска йонлы ана мәче белән ангор йонлы ата мәчене кушылдырудан кыска йонлы – 6, ангор йонлы 2 мәче баласы туган.* Р.Зәкиев

**АНГО́РА** *и. төрек* 1) *сөйл.* Озын йомшак йон. *Ангорадан бәйләнгән свитер*

2) *зоол.* Тезмә исемнәрдә: икенче компонент урынында килгән хайван, җәнлекнең озын йомшак йонлы тукымнан булуын белдерә (Төркиянең башкаласы Анкараның элеккеге (Ангора) исеменнән алынган). *Ангора кәҗә. Ангора куян. Ангора мәче*

**АНДА** *а.* **1**. 1) «Ул» алмашлыгының урын-вакыт килеше формасы; алда әйтеп үтелгән яки җөмләдән аңлашылган нәрсәнең (предметның) үзенә, урынына ишарәләп әйтелә торган күрсәтү алмашлыгы; ул урында, шунда. *Җем-җем генә тамчылый кар, анда йолдыз җылысы бар.* Р.Рахман. *Мин гөҗ иттем: син хезмәт иткән часть-ка барып керсәм, анда син юк, улым.* Н.Хәсәнов. *Тиздән үзенең Казанга барасын, анда Миңнеруйны очратасын уйлап юана булыр.* Р.Хафизова. *Анда, чыннан да, ниндидер йортлар, манаралар төшерелгән, шәһәр планына охшаган сызыклар бар иде.* З.Фәтхетдинов

2) Нинди дә булса әйбергә (предметка), мәсьәләгә (эшкә) яки кешегә ишарә итеп күрсәтү өчен кулланыла. *Авыл халкы баштарак чәйнәде-чәйнәде дә, хәзер ияләнде, ризалашты бугай – исләре китми, аерым торалармы, бергәме – авылның анда эше юк.* З.Хөсният. *Ләкин эш анда түгел.* К.Кәримов

3) Сөйләүчегә һәм тыңлаучыга таныш эш-хәл, вакыйгага ишарәләп күрсәтү өчен кулланыла; шунда, шул очракта, шул вакытта. *Менә сиңа кирәк булса, гомеремдә бер ялганлаган идем, анда да эләктем.* Р.Ишморат

**2.** *мөн. сүз функ.* Иярченле урын җөмләдә *кайда, кая* сүзләре белән мөнәсәбәттә булып, иярченле кушма җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Иртә белән кайнамакта бу базар, Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.* Г.Тукай

**3.** *кис. мәгъ.* Боерык җөмләнең ахырында килеп, боеру төсмерен көчәйтә һәм сөйләмгә тупас тон бирә. – *Бар әле, чык әле, әтиең нишли анда? – ди әни.* Т.Миңнуллин

**АНДАГЫ** *а.* Анда булган, ул җирдәге. *Дөрес, андагыларны бик үк мактап бетермәде.* Ф.Яхин. *Белемем андагыларныкыннан артык булса да, китапханәләрдән чыкмыйча, яхшы әзерләндем.* Р.Батулла. *Кемнәр андагыны укый соң?* Ф.Дәүләтгәрәева

**АНДАЛЫК** *и. сөйл.* Анда, ул урында булу. *Ачык ишек аша Ринатның күзенә Хәниянең дә андалыгы чалынды.* Н.Хәсәнов

**АНДА́-МОНДА** *рәв.* 1) Берсе монда, икенчесе тегендә; сирәк кенә, анда-санда, берән-сәрән, кайбер урыннарда гына. *Иртәдән үк шәһәр өстендә анда-монда төтен күтәрелде.* Р.Кәрами. *Анда-монда ташланган – кечкенә генә өйләрдә беркем дә яшәми диярсең.* Н.Дәүли

2) Әле тегендә, әле монда; төрле җирдә (булу). *Анда-монда җиңел эш эзләп йөреп гомерен әрәм-шәрәм итмичә, юл карауга багышлаган – намуслы кеше.* Л.Хәмидуллин. *Малмыжга алар иртүк чыгып киткәннәр иде, анда-монда туктала торгач, төнлә генә килеп җиттеләр.* Р.Сибат

3) Кая да булса, берәр яры, берәр төрле урынга. *[Хәнифә:] Әгәр анда-монда чыксаң, менә йозак, өйне бикләп чыгарсың.* Р.Ишморат

4) Ниндидер нәрсәдә, һичбер нәрсәдә, һичбер кешедә. *Әмма Гөлнурның анда-монда эше булмады.* М.Хәсәнов

**АНДА́НТЕ** *и. ит. муз.* 1) Музыкаль әсәрнең әкрен, салмак башкарылу темпы. *Неаполь театрында башкарыла торган увертюраларга аллегро белән анданте элементларын, каршылыклы тональлекләрне кертү хас булган.* К.Гыйззәтов

2) Шул темпта уйналган музыкаль әсәр яки аның бер кисәге

**АНДА́-САНДА** *рәв.* 1) Сирәк кенә, берән-сәрән; кайбер урыннарда гына, урыны-урыны белән. *Мәдинәнең читендә анда-санда хөрмә бакчалары күренә.* А.Расих. *Анда-санда эт өргәне колакка чалына.* Р.Кәрами. *Ул анда-санда утырып калган көнбагыш сабакларын кыймылдаткалады.* А.Хәсәнов

2) Кайвакыт, вакыты-вакыты белән, әллә нидә бер. *Тын гына, анда-санда тибрәнгәләп, ябалак кар төшеп тора.* Х.Хәйруллин. *Анда-санда гына, тәрәзә каршындагы куе тополь яфракларын кыштырдатып, йомшак җил исеп куйгалый.* Ә.Галиев

**АНДА́У** *ф. диал.* Сагалау, саклап, күзәтеп тору. *Юлдагы таш аксакның аягын андый, имеш.* Мәкаль

**АНДЫЗ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, дымсу җирдә үсә торган, озын сабаклы, эре, киң яфраклы, сары чәчәкле үсемлек; *русчасы:* **девясил.** *Танавын җыера-җыера, даруны андыз яфрагына сылады.* А.Хәлим

**АНДЫЗЛЫК** *и.* Андыз күп үскән, андыз күп булган урын

**А́НДЫЙ** *а.* **1.** Вакыйга, күренеш, предмет яки затка яисә аларның берәр төрле сыйфатына, үзенчәлегенә ишарәли торган күрсәтү алмашлыгы; шундый. *Юк, мең кабат юк, аның әтисе андый кеше түгел иде.* Р.Кәрами. *Аннары бит аның кызлары да андый төшеп калганнардан түгел.* Ф.Хөсни. *Казанда көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый ич андый конфетларны.* Хәйдәр. *Ә андый йорт әле хәзер дә – Таукашта берәү генә, син генә салдыра алдың андый йортны.* М.Хуҗин

**2.** *и. мәгъ.* Килеш кушымчаларын алганда, аерылмыш урынында килгән күренеш, предмет яки кеше исемен атамыйча гына, аларның сыйфатына, үзенчәлегенә ишарәли. *Синең андыйга осталык җитә.* Хәйдәр. *Андыйны театр сәхнәсендә күрмәссең. Акча түләп керсәң дә.* Л.Ихсанова. *Симезрәк «кош» эләккәндә, Махно үзе дә андыйларны чакырып сөйләштерми калмый.* З.Фәтхетдинов

**3.** *кис. мәгъ.* Тиңдәш кисәкләр янында кабатланып килеп, аларны бәйләү белән бергә, экспрессияне арттыру, мәгънәне көчәйтү өчен кулланыла. *[Мостай абзый кебек] Андый да итагатьле, андый да зыялы, тәрбияле кеше, гомумән, шагыйрьләр арасында сирәк була.* Р.Миңнуллин

**А́НДЫЙЛЫК** *с.* Аңа җитәрлек, аны сатып алырлык. *Юк, андыйлык кына акча бар иде барын.* Ш.Маннур

**А́НДЫЙ-МОНДЫЙ** *с.* 1) Берәр төрле, нинди дә булса. *Андый-мондый яңалык күренми, бар да искечә.* М.Хәсәнов. *«Ничек тә өйгә кайтып егылырга, юлда андый-мондый булып, адәм көлкесенә генә калмаска иде», – дип, эченнән генә Ходайга ялвара ул.* Ф.Сафин

2) Юк-бар, имеш-мимеш; әһәмиятсез. *Андый-мондый җайсызрак сүз ишетсә, борылып чыгып китәргә дә ул әзер иде.* Хәйдәр

3) Теләсә нинди, юк-бар, игътибарга лаек булмаган, килделе-киттеле. *Аның уйламый әйтелгән сүзе кәефемне шактый бозса да, мин аңа үземнең «андый-мондый кеше» түгеллегемне исбат итеп тормадым.* А.Шамов. *Стена буендагы эскәмиягә чәйнекне юри каты куя. Аңа каршы улы тамагын кыра. Бу андый-мондый гына авазлар түгел, бу – мәгънәле сөйләшү.* Р.Зәйдулла

4) Начар, бозык, шикле; юлдан язган. *Андый-мондый хәлләреңне ишетсәм, кайтмам да, бел аны!* М.Хәбибуллин

5) Көтелмәгән, кинәт булган, уйламаган; капыл килеп чыккан. *[Гөлсем:] Зәйтүнә апа, әгәр минем белән андый-мондый хәл килеп чыкса, зинһар, кызымны ташламассың инде.* Д.Салихов. *Сабадыревның шактый тәвәккәл һәм кызу холыклы булуын белгәнгә күрә, андый-мондый хәл килеп чыкса, дип, сиздермичә генә, пистолет чакмасын тартып куйды Илья.* З.Фәтхетдинов

**АНЕКДОТ** *и. гр.* 1) Тормышның тискәре якларыннан, кешенең үзендәге кимчелекләрдән көлеп, кешедән-кешегә сөйләнеп күчеп йөри торган шаян мәзәк. *Колхозга барып җиткәнче җырладылар, уен-көлке, шигырь, анекдот сөйләделәр.* Р.Кәрами. *Әмма үзе моның бүтәннәргә сизелүеннән бик курка, шуңа күрә Эдик сөйләгән тозсыз анекдотлардан, ошаса-ошамаса да, ихластан көләргә тырыша иде.* З.Хөснияр

2) *күч.* Тормышта булган кеше ышанмаслык вакыйга, гадәттән тыш мәзәк хәл. *Нигә килмәде икән? Нәрсә дип акланыр икән? Мөгаен, тагын берәр анекдотка охшаган вакыйга уйлап табар әле.* М.Әмир

3) *күч.* Уйдырма, ялган. – *Анекдот бу*, – *диде Пламадьяло.* М.Юныс

**АНЕКДОТЧЫ** *и.* Анекдот сөйләүче, анекдот уйлап чыгаручы. *Ләкин, ди, врач әйтә, бу анекдотчыга андый җәза да аз.* Г.Әпсәләмов

**АНЕМИ́Я** *и. гр. мед.* Азканлылык. *Хастаханәдә гастрит, тукланугa бәйле гиповитаминоз, анемия авыруы белән авыручылар ята.* Г.Галиев

**АНЕМО́ГРАФ** *и. гр.* Һава тизлеген өзлексез үлчәү әсбабы

**АНЕМО́МЕТР** *и. гр.* Җил тизлеген һәм юнәлешен үлчәү приборы

**АНЕМОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Җил үзгәрешен өйрәнә торган фән

**АНЕСТЕЗИО́ЛОГ** *и.* Анестезиология белгече (табиб). *Хәер, аның һөнәре шул – операция вакытында сызлануларны җиңеләйтүче, кешенең җан сагында торучы – анестезиолог Наил Хәйдәрович.* М.Маликова

**АНЕСТЕЗИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Анестезия мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган фән тармагы

**АНЕСТЕЗИ́Я** *и. гр. мед.* 1) Авыртуларны, тышкы ярсыткычларны сиземләү тойгысын өлешчә яки тулысынча югалту

2) Тәнгә сыеклык җибәреп, кешенең сиземләвен вакытлыча бетерү

**АНЕСТЕЗИ́ЯЛӘҮ** *ф.* Анестезия ясау; авырту сизүне бетерү

**АНИЛИН** *и. порт.* Майлы, төссез агулы сыеклык – органик кушылма (буяулар, шартлаткычлар, төрле дарулар һ.б.ны ясаганда кулланыла). *Анилин пары, әчеттереп-әчеттереп, күзне кисә.* К.Кәримов

**АНИМАЛИЗМ** *и. лат. сәнг.* Хайваннар сурәтен ясауга нигезләнгән сынлы сәнгать жанры

**АНИМАЛИСТ** *и. ит. сәнг.* Хайван рәсемнәрен сурәтләгән рәссам, сынчы

**АНИМА́ТОР** *и. лат.* 1) Мультипликатор, мультфильм төшерүче художник

2) Ял итү, күңел ачу урыннарында халык белән уеннар оештыручы

**АНИМА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Мультипликация. *Постановканың тагын бер үзәнчәлеге – анда анимация, акробатика, каскадёр трюклары куллану.* Ватаным Татарстан

2) Ял йортларында һ.б.ш. җирләрдә халык өчен һәм халык катнашында алып барылган, җыр-бию, уеннардан торган күңел ачу программасы

**АНИМИЗМ** *и. лат.* Табигать көчләрен һәм күренешләрен җанландыру; гомумән җансыз әйберләрнең дә җаны барлыгын тану белән бәйле дини-фәлсәфи тәгълимат. *Төрле халыклар мифологиясендә өч төрле караш күзәтелә: анимизм* (*табигать күренешләренең аллалары бар дип санау*), *тотемизм* (*илаһилыкны хайваннарда тану*) *һәм фетишизм* (*табигатьнең төрле предметларын илаһи көч дип санау һәм аларга табыну*). К.Гыйззәтов

**АНИМИСТ** *и. рус* Анимизм тарафдары

**АНИМИ́СТИК** *с.* Анимизмга бәйле. *Бик борынгы чорларда барлыкка килгән әкиятләрдә кешеләрнең тотемистик һәм анимистик (хайваннарны кешеләр белән тиңләштерү) карашлары киң чагыла.* Ф.Урманче

**АНИОН** *и. гр. хим.* Тискәре корылган ион. *Гидроксидның эквивалент массасы металлның һәм гидроксид төркемнәренең эквивалент массалары суммасына, ә тозның эквивалент массасы металлның һәм анионның (кислота калдыгының) эквивалент массалары суммасына тигез.* Г.Хисамиев

**А́НКЕР** *и. нем. тех.* 1) Корылма, машина һ.б.ш.ларның кисәкләрен тоташтыру өчен деталь; тимер ныгыткыч. *Анкерларны җыю һәм трассага китерү белән --- Г.Бесчастнов җитәкчелек итте.* Казан утлары

2) Сәгать теленең хәрәкәтен көйләгән өлеш

**А́НКЕРЛЫ** *с.* Анкеры булган, анкер белән тоташтырылган, беркетелгән, ныгытылган

**АНКЕ́ТА** *и.* Тутыручы турында нинди дә булса мәгълүмат алу яки берәр нәрсәгә карата җәмәгатьчелек фикерен белү өчен төзелгән сораулык кәгазе. *Сәләхов анкетага «тугызны бетердем» дип язды.* М.Юныс. *Бервакыт Азиз Несин Иранда чыга торган газетаның анкетасын ала.* Р.Мостафин. *Шуннан да түбән анкета мәгълүматлары булган кешенең мондый урын дәгъвалавы – көлке.* В.Имамов

**АНКЕ́ТАЛАУ** *ф. к.* **анкеталаштыру**

**АНКЕ́ТАЛАШТЫРУ** *ф.* Анкета ярдәмендә мәгълүматлар яки фикерләр җыю. *Эзләнүләр нәтиҗәсе буенча, тирәбездәгеләр өчен файдалы дип тәкъдим ителгән эшләр конкурсы оештыру; анкеталаштыру үткәрү --- – аерым бер эш төре өчен җаваплы кешеләрнең тәкъдимнәре.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**АНЛАР** *а. иск. к.* **алар**. *Тик ул авыр хәбәр ирешкән көннән ике ел үтеп, дөньялар басыла башлагач кына, анлар Сабирның «...» шәһәрендә икәнен белеп, бераз тәэсирләрен үзгәрттеләр.* Г.Ибраһимов

**АНЛЫК** *с.* Аңа җитәрлек, аңа кирәк кадәр. *Райбашкарманың да, безнең дә анлык рәт югын сез үзегез дә әйбәт беләсез.* Х.Хәйруллин. *Бик теләгәндә, анлык кына акчаны барыбер табып була.* Ватаным Татарстан

**АННАЛЛАР** *и. лат. күпл.* Борынгы Римда истәлекле һәм әһәмиятле булган тарихи вакыйгаларны еллап теркәп барган язма; елъязма. *Византиянең хәтәр уен алып баруын тарих анналлары яшереп кала алмаган.* М.Галиев

**АННАН** *а.* **1.** 1) «Ул» зат алмашлыгының чыгыш килеше формасы; ул әйбердән, ул нәрсәдән (күбрәк җансыз предметларга яисә хайваннарга ишарәли). *Аннан [төенчектән] байтак кына көмешләр, бакырлар һәм берничә кәгазь акча килеп чыкты.* К.Нәҗми. *Гадәттәгечә пөхтә итеп җыештырылган авыл өйләрендә генә була торган яктылык, күңелгә тынычлык иңдерә торган тыйнак пөхтәлек бөркелеп тора иде аннан.* Ф.Сафин. *Балан авылында гына түгел, якын-тирәдә дә аннан зур ат юктыр.* Хәйдәр

2) Аңардан, сөйләүчегә билгеле кешедән, ул заттан. *Хәсән аннан дәлил сорады.* Ф.Әмирхан. *Аннан җавап килмичә, яу кузгалу мөмкин түгел иде.* М.Хәбибуллин

3) Эш-хәлнең башкарылу эзлеклелегенә ишарәләп әйтелә торган күрсәтү алмашлыгы буларак кулланыла; шуннан. *Карт --- нидер иснәнгәндәй итте, як-ягына, аннан күккә карады.* Г.Бәширов. *Өйнең ишеге ачылып, иң алдан түбән оч мулласы, аннан хәлфәләр, соңра мөәзин өйгә керделәр.* М.Гафури

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бер-бер артлы, берәр эш-хәлдән соң, аның артыннан. *Әйдүк көтүне бер җиргәрәк җыярга, аннан бәрәнге пешерергә уйлады.* Һ.Такташ

2) Соңыннан, күпмедер вакыттан соң; ахырдан. *Аннан яланаяклы, йокыдан шешенгән бригадир Силантьич күренде.* А.Чурбанов

3) Ул урыннан, ул җирдән. *Сыер абзарлары ватык-җимерек, тирәү өстенә тирәү, диварлары аннан да, моннан да ямалган, тишекләрдән җил өрә.* Н.Хәсәнов

**3.** *мод. сүз мәгъ.* Сөйләмдә хәбәр ителгән фактның реальлегенә ышану төсмерен белдереп килә; тәгаен, дөресен әйткәндә. *Аннан бит, кем, Мирсәет, безнең колхозда сәп-сәламәт кешеләр дә эшкә чыкмыйча яталар.* Р.Ишморат

◊ **Аннан ары** *к.* **аннан соң**. *Аннан ары инде, иркен тын алып, үзе сөт сорап эчте.* Г.Ибраһимов. – *Галимҗан улым, бик озак йөрергә тырышма, иртәгә сәфәр чыгасы бит, аннан ары сөйләшеп тә утырырбыз, – диде.* С.Поварисов. **Аннан (да) бигрәк** Анысыннан да әһәмиятлерәк, тагы да мөһимрәк (алда әйтелгәннәрдән өстен булган берәр нәрсәгә басым ясап әйтелә). **Аннан кала** Алда әйтелгәннән тыш, болардан башка, тагы. *Аннан кала алпавытның атка атланган көйгә озын каешлар белән эт тотып, өстертеп, котыртып торучы кызыл казаки кигән сары чәчле малайлары да күп иде.* Ә.Гаффар. **Аннан килеп** *мод. сүз мәгъ.* Шуңа өстәп, җитмәсә, җитмәсә тагы. *Аннан килеп, ничек кенә әйтмә – яңа эш.* Ф.Хөсни. *Аннан килеп, үз-үзләрен хөрмәт итә белгән бу җанварлар акыллы да, табигатьнең патшасы саналган кешегә гадәттә һөҗүм итмиләр иде.* Р.Фәизов. **Аннан соң** 1) Берникадәр вакыт үткәч, нәрсәдер булып үткәч, аның соңында. *Аннан соң спектакль башлана.* М.Әмир. *Аннан соң, кинәт җендәй кыланып, --- Галимҗанны кулыннан тотып җилтерәтеп торгызды.* С.Поварисов; 2) Берәр эш-гамәлнең нәтиҗәсе буларак – аны эшләгәч, монысы килеп чыгар тагын. *Йөрерсең аннан соң муеныңа салкын тәре асып.* З.Хөснияр; 3) *сөйл.* Берәр кеше артыннан, аңардан соң; 4) Җитмәсә, өстәвенә

**АННА́Н-МОННАН** *рәв.* 1) Төрле урыннан, төрле җирдән. *Солдат, иярне рәтләп, аннан-моннан тарткалады.* Н.Дәүли

2) Ашык-пошык, җиренә җиткермичә, теләр-теләмәс; өстән-өстән генә. *Андагы врачмы, фельдшермы кисәге аның күкрәк һәм аркасын аннан-моннан гына тыңлаган булды да бер сүз әйтмәде.* Ш.Маннур. *Суфия ялгыз калырга теләмәде, пальто төймәләрен аннан-моннан эләктереп, Бикләмишев артыннан иярде.* К.Нәҗми

3) Аяк өсте, ашыгып, кабаланып; нәрсә бар шуны. *Батый хан --- аннан-моннан капкалады да урынына ятты.* М.Хәбибуллин. *Эштән кайтып, аннан-моннан гына капкалап алу өчен генә дә сәгатьтән артык вакыт кирәк.* М.Юныс. *Өйләренә кереп, аннан-моннан капкаладык та, иске-москы туннар кыстырып, каралты башына мендек.* Ш.Маннур

4) *күч.* Көч-хәл белән, ничек кирәк алай. *Аннан-моннан җыештырып түләдек*

5) *күч.* Берәр начар ният белән, әллә нинди шикле сәбәп белән. *Аннан-моннан әйтүем түгел*

**АННА́РЫ** *рәв.* **1.** Аның артыннан, берәр эш-хәлдән соң, шуннан соң. *Аннары, сабырлыгын җыеп, чана табаннарыннан ике якка сибелеп калган сусыл карга карап бара башлады.* А.Вергазов. *Аннары син дөньяга килдең.* Р.Низамиев

**2.** *мод. сүз мәгъ. к.* **аннан 3.** *Аннары үзегез беләсез: Мәскәү халкы, гомумән, бушлай сыйланырга бик тә ярата бит ул!* М.Вәли-Барҗылы

**3.** *кис. мәгъ. сөйл.* Җөмлә ахырында килеп, мәгънәгә көчәйтү төсмере өсти. *Кызып китеп әйтеп ташларсың берәр сүз, нигә әйткәнеңә үкенеп туймассың аннары.* Т.Миңнуллин

◊ **Аннары бит** *к.* **аннары** (*2 мәгъ.*). *Бер котыласың, ике котыласың – әмма аннары бит тотыласың!* Р.Мостафин

**АННЕ́КСИЯ** *и. лат.* Берәр дәүләтнең җирен (территориясен) яулап алу һәм башка дәүләтнекенә көчләп кушу

яисә берәр халыкны чит дәүләт чигендә, ирексезләп, чыгармыйча тору

**АННЕ́КСИЯЛӘҮ** *ф.* Аннексия ясау

**АННЕ́КСИЯЧЕЛ** *с.* Аннексиягә нигезләнгән, аннексиягә мөнәсәбәтле

**АННОТА́ЦИЯ** *и. лат.* Берәр китап, кулъязма яки мәкаләнең төп эчтәлеге, фәнни яңалыгы һәм кыйммәте турында кыскача язма. *Аннотацияләр әдәби белешмә материалларында, китап каталогларында һ.б. да басылалар.* Әдәбият

**АННОТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Аннотация бирү, аннотация язу. *Эш кәгазьләрен автомат рәвештә индекслау һәм аннотацияләү.* И.Бәширова

**АНОД** *и. гр. физ.* Уңай корылган электрод. *Гальваник элементлар – анод һәм катод арасындагы ионнар хәрәкәте турында Рушад татарча ярды да салды.* М.Мәһдиев

**АНОДЛА́У** *ф.* Коррозиядән саклау, электр изоляциясе катламын ясау өчен яки декоратив максатларда, металл өслегендә оксид катлавы булдыру

**АНОДЛЫ** *с.* Аноды булган. *Металларның потенциаллары анодлы өлкәгә авышканда, металл өслеге пассивлана.* Г.Хисамиев

**АНОМА́ЛИЯ** *и. гр. кит.* Гомуми кагыйдәдән, нормадан, закончалыктан тайпылыш. *Чөнки аномалия аяк астында нииндидер байлык ятуны искәртә бит.* Р.Хәкимов

**АНОМАЛЬ** *с. кит.* Гомуми кагыйдәгә, нормага, закончалыкка туры килмәгән, нормадан авышкан. *Аномаль күренешләрне тикшерүчеләр Коста-Рикада табылган шарлар белән уртаклык эзлиләр.* Мәдәни җомга

**АНОНИМ** *и. гр.* **1.** 1) Кемгә яки кая да булса, үз исемен әйтмичә, хат (әләк һ.б.) язучы, билгесез автор. *Шакшы яла яга аноним, тик Үз исемен килми әйтәсе.* Ә.Фәйзи // Әсәренә исемен яки псевдонимын куймыйча бастырган автор

2) Авторы күрсәтелмәгән хат (әләк һ.б.). *Икенче хат – аноним.* Ф.Сафин // Авторы билгесез әсәр

**2.** *с. мәгъ.* Авторы күрсәтелмәгән, авторы билгесез. *Димәк, әлеге аноним хатны язган кешенең эше инде бу.* В.Нуруллин. *Алар арасыннан кайчандыр, кемнәрдер өстеннән язган имзасыз, ягъни аноним шикаятьләре дә килеп чыкты.* Н.Хәсәнов. *Утызынчы елларның икенче яртысында Вахиди тирәсендә электән килә торган вактөяк ыгы-зыгылар, урынсыз гаепләүләр, бигрәк тә аноним әэзәрлекләүләрнең куерып китүен, ахыр чиктә башына җитүен менә шулай аңларга кирәк.* М.Госманов

**3.** *рәв. мәгъ.* Авторы, исеме күрсәтелмичә. *Гали тамгалы тәңкәләр аноним чыгарылган һәм аларда акчаны суктыручы хөкемдарның исеме дә, сугылган елы да куелмаган.* Ә.Мөхәммәдиев

**АНОНИ́МКА** *и. рус сөйл.* Аноним хат, авторы билгесез язма. *[Прокурор:] Сашаны ни өчен кире чакырткан идегез? Шул анонимка өчен генәме?* Р.Мөхәммәтҗан

**АНОНИМЧЫ** *и.* Аноним хатлар язучы. *Ләкин анонимчы тиз генә чигенә торганнардан булмаган.* Ф.Углов. *Анонимчының ачыклануына Липатникова да шатланыр, дип, кәгазьләрне күтәреп, партбюрога кердем.* Т.Галиуллин

**АНОНИ́МЩИК** *и. рус сөйл. к.* **анонимчы**. *Ә анонимщиклар белән минем сөйләшү каты булачак!* М.Мәһдиев

**АНОНС** *и. фр. кит.* Булачак тамаша турында алдан ясалган белдерү. *Газетада анонс басылгач: «Венера кияүгә чыгамы әллә?» – дип кызыксынучылар да күп булды.* Г.Шәйхиева

**АНО́ФЕЛЕС** *и. гр.* Малярия озынборыны. *Бизгәк плазмодиен теләсә нинди озынборын таратмый, ә бәлки җылы илләрдә генә очрый торган анофелес ыругына керүче озынборыннар тарата.* И.Рәхимов, К.Ибраһимова

**АНСАМБЛЬ** *и. фр.* 1) Музыка, драма һ.б.ш. әсәрләрне берничә артист башкарганда барлыкка килгән үзара ярашканлык, аһәңлелек, төзеклек. *Фаил Ибраһимов сәләтенең тагын бер гүзәл ягы бар: ул спектакльдә ярашканлык (ансамбль) хасил итә ала.* Р.Батулла

2) Составында ике яки берничә артист булган иҗади төркем. *Бервакыт Роман аңа бергәләп шөгыльләнсәләр, үзенең бәхетле булачагын, бик шәп пианист белән скрипкачы ансамбле төзи алачагын әйткән.* Ф.Углов. *Вагоннарның берсеннән «Червоны гитары» ансамбле җырлары яңгырый.* А.Сафин

3) Бербөтеннең кисәкләре, төзек, килешле булып, үзара бәйләнешкә кергәннән соң, гармония хасил итү күренеше. *Биналар, корылмалар, бер-берсе белән ярашып, тирә-юнь белән гармония хасил иткәндә, ансамбль төзегәндә бик матур күренәләр.* Ф.Хатипов. *Алар барысы бергә [гарәп нәкыше, каллиграфия ысулы] искиткеч нәфасәти ансамбль тәшкил итәләр.* К.Гыйззәтов

4) Берничә кеше бергә башкару өчен язылган музыкаль әсәр

**АНСА́МБЛЬЛЕ** *с.* Ансамбльгә нигезләнгән, ансамбльгә хас булган, ансамбльгә караган

**АНСА́МБЛЬЛЕК** *и.* Ансамбль булу. *Кайбер номерларның вакытлыча яки бөтенләйгә икенче коллективка күчерелүе коллективның ансамбльлегенә, программаның бөтенлегенә кире тәэсир ясый.* Казан утлары

**АНСАТ** *с.* **1**. Зур көч таләп итмәгән, авырлык тудырмый торган, кыен булмаган. *Кара көчнең илһамы, үзенең кырык еллык тәҗрибәсе белән, ул татар кызын җанлы курчак ясарга иң кыска һәм иң ансат юлны тапты.* Ф.Әмирхан

**2.** *рәв. мәгъ.* Җиңел, җайлы, уңай (юл белән); тиз. *Кешенең тормышын бозу да, аны дөньядан туяр хәлгә китереп җиткерү дә бик ансат икән.* В.Нуруллин. *Ә хәзерге шартларда аны үтәү ансат түгел.* А.Шамов. *Андагы хәлләр белән Муса резервта чакта ук таныш иде, шуңа күрә бу «ут капчыгы»на барып керү аңа бер дә ансат булмады.* Ш.Маннур

◊ **Ансатка килү** Җайлы, уңай булу; мәшәкатьсез, борчусыз булу. *Минемчә, Майпәрвәз дөрес әйтә: үз өең булса – яхшы инде ул, тормыш ансаткарак килә.* Л.Гыйззәтуллина

**АНСАТЛАНДЫРУ** *ф.* Ансат итү, җиңеләйтү; ансатлаштыру

**Ансатландыра төшү** Бераз ансатландыру

**Ансатландырып бетерү** Тулысы белән, бөтенләй ансатландыру

**Ансатландырып кую** Алдан ансатландырган хәлгә китерү

**АНСАТЛАНУ** *ф.* Җайлашу, җиңеләю, ансатка әйләнү

**АНСАТЛАШТЫРУ** *ф.* Ансат итү, җиңеләйтү. *Әйе, көлкеле конфликт ярдәмендә җиңелчәлек һәм шаянлык рухы тудырып, автор әсәренең нигезендә яткан, бик җитди булган үлем темасын, Ю. Әминев әсәрендәге кебек үк, кабул итүне ансатлаштыра.* А.Әхмәдуллин

**Ансатлаштыра төшү** Бераз, берникадәр ансатлаштыру

**Ансатлаштырып бетерү** Тулаем, бөтенләй ансатлаштыру

**Ансатлаштырып кую** Алдан ансатлаштырган хәлгә китерү

**АНСАТЛАШУ** *ф. к.* **ансатлану**. *Язу да ансатлаша, сүзләр, җөмләләр, строфалар да каләм очыннан язып өлгермәслек тизлектә сибеләләр.* А.Расих

**Ансатлашып бару** Торган саен ныграк ансатлашу

**Ансатлашып бетү** Тулысынча, тәмам ансатлашу

**Ансатлашып килү** Соңгы вакытта, бераз ансатлашу

**АНСАТЛЫК** *и.* Ансат булу. *Әйе, җизни, син бик ансатлык белән алгансың...* Т.Гыйззәт

**АНСЫЗ** *а.* **1.** «Ул» зат алмашлыгының юклык формасы; аннан (аңардан) башка, ул булмаса да, ул булмаганда. *Әгәр Бикә түти булмаса, Яңа Салага нидер җитенкерәмәс, ансыз күңелсезрәк булып калыр иде.* Г.Бәширов. *Бу үзсүзле җанкисәкне мин башымны җуеп яратам. Ансыз бер минут та яши алмам төсле.* А.Хәсәнов

**2.** *мод. сүз мәгъ.* Сөйләмдә хәбәр ителгән фактның реальлегенә ышану, аны тагын да көчәйтү төсмере белдереп килә; тәгаен, дөресен әйткәндә. *Күлмәгенең, килешеп, ансыз да ак, ансыз да алсуланып янып торган йөзен ачып җибәрүен генә күр әле син.* М.Хәсәнов. *Ансыз да моңлы тавышын җитмәсә әле тибрәндереп сузуы белән дә әллә нишләтеп җибәрә.* К.Миңлебаев

**АНТ** *и.* 1) Ватанга яки кемгәдер тугрылыклы калу, законнарны бозмыйча үтәү турында биргән вәгъдә; бәйгать. *Күзлек кигән бер лейтенант кызыл тышлы китаптан хәрби ант текстын укый башлады.* Х.Камалов. *Ант кабул итү көненә Ленинградтан адмирал киләсе, дип сөйләнәләр иде.* Р.Кәрами. *Сүз уңаеннан әйтим, армиядә һәм флотта антның көче изге дип исәпләнә.* Ф.Углов

2) Кемгә дә булса бирәр нәрсә ышандырып, иң газиз, кадерле кеше (мәс., ана, ата, бала), бик тә кирәкле, әһәмиятле әйбер (мәс., тел, теш, икмәк һ.б.) яки мәҗүси табыну объектлары (мәс., кояш, якты дөнья) исеме белән биргән вәгъдә сүзе. *Бу юлы алып барам үзегезне. Ант әгәр, исемем Нәби булмасын!* А.Гыйләҗев. *--- өеңә башка аяк та басмаячакмын. Ант итеп әйтәм, ипи тотып ант итәм!* Х.Ибраһим. *Болар барысы да – күңелемдәге изге уй-теләкләрне сүндерә барганым өчен, яшьлек антларыбызга хыянәт иткәнем өчен җәзадыр, дип уйлый-уйлый, газапларда яна-көя идем.* Р.Хисмәтуллин. *Инде антын җиренә җиткереп башкармаса, нәзере тотар.* М.Хәбибуллин

◊ **Ант бозу** Сүздә тормау, хыянәт итү. *Ант итеп, антын бозган – җаны корсын.* С.Поварисов. *Ант бозучыдан --- бөтен табигать дөньясы --- йөз чөерә дип ышанганнар.* Н.Исәнбәт. **Ант китерү** *к.* **ант бирү.** *Габдулланың, әманәт илтергә, каганга ант китерергә дип, пайтәхеткә кат-кат барганы бар.* В.Имамов. *[Күчем:] Башкорт мәмләкәтенең җитмеш биш старшинасы сиңа тугры хезмәт кылырга ант китерә.* В.Имамов. *Парта арасыннан партиясез Толлар ант китерә дөньяга: – Хәрабәдә яткан Ватан, сине Тагын да гүзәл итеп корырбыз.* Б.Хәлимов. **Ант ору** Вәгъдә бирү. **Антны таптау** *к.* **ант бозу.** *Руанет – государь император галиҗәнапләренә биргән антын таптаган --- полковник.* Ә.Гаффар. **Ант тоту** Вәгъдәсезлектән зыян күрү. **Ант чүмерү** *сөйл. к.* **ант эчү.** *Мөхәммәтҗан, сабырлыгын югалтып: – Сөйлә инде, Шәкүр агай? Билләһи, беркемгә дә әйтмәм! – дип үтенүендә һәм ант чүмерүендә булды.* Ф.Яхин. **Ант (суы, касәсе) эчү** Вәгъдә бирү; катгый ышандырып әйтү. *Сәфәрдән кайткач, куйган малын саррафтан кайтарып сорады, сарраф инкяр кыйлды, миңа тапшырганың юк, дип ант эчте.* К.Насыйри. *[Гали:] Уразбәк! Кыпчаклар! Болгарлар! Моннан соң кыпчаклар белән болгарлар үзара дуслату булырбыз, дип, теләсә нинди дошманга каршы бергәләп сугышырбыз, дип ант эчик!* Н.Фәттах. *Сөембикә елый, бәрелмим, киемнәремне пычратмыйм, дип, ант сулары эчә.* Ф.Садриев. *Леназа белән аралар чиста, вәгъдәләр бирелмәгән, ант касәләре эчелмәгән әле.* М.Маликова

**АНТАГОНИЗМ** *и. гр.* 1) Капма-каршы көчләр арасында килешә алмаслык каршылык. *Әмма хезмәт ияләре белән феодаллар, аларның да иң дәве булган патша арасындагы мөнәсәбәт һәм мөгамәләләр сыйнфый антагонизм, дошманлык, нәфрәт белән сугарылган.* Х.Госман. *Марксизм-ленинизмны нигезләүчеләр К. Маркс, Ф. Энгельс һәм В. И. Ленин «антагонизм» дигән сүзне сыйнфый җәмгыять каршылыкларының характерын ачыграк күрсәтү өчен кулланалар.* М.Абдрахманов // Карашларын үзара килештереп булмаслык дошманлык

2) *биол.* Яшәеш өчен көрәш

**АНТАГОНИСТ** *и. гр.* 1) Кем яки нәрсә белән дә булса капма-каршы (дошман) мөнәсәбәттә булган кеше. *Автор --- геройларын антагонист сыйныф вәкилләре итеп күрсәтә.* Ф.Габидуллина

2) *биол.* Үзара бәйләнеше, функцияләре белән бер-берсенә капма-каршы торган матдәләр яки әгъзалар

**АНТАГОНИ́СТИК** *с.* 1) Үзара килешә алмаслык, дошманлык хисе саклаган

2) Антагонизмга нигезләнгән. *Алар – антагонистик сыйныфларга бүленгән җәмгыять, социаль мохит, иҗтимагый тәрбия бозган бәндәләр.* Казан утлары

**АНТА́НТА** *и. фр. тар.* Хәрби берләшмә (1904 – 1907 елларда Англия, Франция һәм Россия дәүләтләреннән оешкан берләшмә атамасы; 1914–1919 еллардагы Беренче Бөтендөнья сугышында бу берләшмә Германиягә, аның союздаш илләренә каршы көрәшә; Октябрь революциясеннән соң, Советлар иленә каршы көрәш алып бара).

*Алар бергә-бергә изге союз – Антанта төзеделәр.* Р.Ишморат

**АНТА́РКТИК** *с.* Антарктикага мөнәсәбәтле

**АНТА́РКТИКА** *и. гр.* Җир шарының Көньяк поляр өлеше. *Антарктикада – шундый кырыс табигатьтә кышлаган кешеләрнең язганнарын укымау аларның авыр хезмәтен, тормышын санламау һәм аңламау булыр иде.* Ә.Хәбибуллин

**АНТ БИРҮ** *ф. к.* **ант итү**. *12 апрельдә С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш пленар утырышында М.Ш.Шәймиев Татарстан халкына тугрылыклы хезмәт итәргә ант бирде.* Хокук һәм хәят. *Көн-төн үз-үземә антлар биреп, аны онытырга тырышам, уйламаска телим – берсе дә барып чыкмый!* Ш.Маннур

**АНТЕ́ННА** *и. лат.* Радиодулкыннарны тоту һәм тарату өчен хезмәт итә торган җайланма. *Ике мачта арасына элгән антеннага карлыгачлар тезелеп утырган.* М.Юныс. *Ягулык төкәнде... Моторлар сүрелде... Антенна җимерелде... Элемтә өзелде...* Х.Туфан

**А́НТИ-** *гр.* Алынма кушма сүзләрнең беренче кисәге: 1) Берәр нәрсә белән көрәшүне, берәр нәрсәгә каршы булуны белдерә: *антимилитаризм, антикоммунизм* һ.б.

2) Берәр нәрсәгә капма-каршы булуны белдерә: *антидошман, антироман, антикисәкчә* һ.б.

3) *физ.* Нинди дә булса билгесе, сыйфаты белән киресе булганын белдерә: *антикисәкчекләр* һ.б.

**АНТИБАКТЕРИАЛЬ** *с.* Авыру тудыручы бактерияләрне бетерүгә яки аларның көчен киметүгә юнәлдерелгән. *Каратамыр, антибактериаль үзлекле булганлыктан, бик аз дозада дару үсемлеге буларак та кулланылырга мөмкин.* И.Рәхимов, К.Ибраһимова

**АНТИБИО́ТИК** *и. гр.* **1.** *мед.* Төрле авырулар тудыра торган бактерияләрне, микробларны үтерергә сәләтле матдә. *Клиникада кызга антибиотик һәм витаминнар белән гомуми дәвалау курсы билгеләделәр.* Ф.Зариф

**2.** *с. мәгъ.* Шундый бактерияләрне, микробларны үтерә торган. *Ул [бал], башка катнашмалар кебек үк, антибиотик үзлеккә ия һәм консервланып саклануны тәэмин итә.* Татар балы

**АНТИВИ́РУС** *и. гр.-лат. информ.* Компьютер вирусына каршы программа. *Минем супер антивирус программасын җиңәргә маташасыңмы?* Т.Миңнуллин

**АНТИГУМАНИ́СТИК** *с.* Гуманизм принципларына каршы килгән. *Бер караганда, бик эгоистик, антигуманистик уй.* Р.Төхфәтуллин

**АНТИДЕМОКРАТ** *с. к.* **антидемократик**

**АНТИДЕМОКРА́ТИК** *с.* Демократия принципларына каршы торган; халык мәнфәгатьләренә каршы юнәлдерелгән. *Ләкин Конституцион суд, халыкара кануннар белән санлашмыйча, Думаның антидемократик законын яклап чыкты.* Т.Миңнуллин

**АНТИДИАЛЕ́КТИК** *с.* Диалектика принципларына каршы килгән (мәс., ысул, алым). *«Механицизм» – әнә шушы антидиалектик фикер йөртүнең чагылышы ул.* К.Гыйззәтов

**АНТИИМПЕРИАЛИЗМ** *и. гр.-лат.* Империализмны кире каккан, империализмга каршы килгән сәяси агым

**АНТИИМПЕРИАЛИСТ** *и. рус* Антиимпериализм тарафдары

**АНТИИМПЕРИАЛИ́СТИК** *с.* Антиимпериализмга нигезләнгән

**А́НТИК** *с. фр.* 1) Борынгы грек һәм рим мәдәниятенә караган. *Бирелә атлаган саен антик табылдыклар очрый.* Ф.Бәйрәмова

2) *күч.* Борынгы. *Татарның антик даһиен Күрегез, дигән сыман, Кол Гали калка ерактан, Гасырлар түбәсеннән.* Ә.Рәшитов

**АНТИКВАР** *и. лат.* **1**. 1) Борынгы сәнгать әсәрләре, иске, кыйммәтле әйберләр һәвәскәре, шуларны җыючы. *Яки берәр үҗәт антиквар – иске нәрсәләр җыючы кеше – озакламый Ленин һәйкәлләрен, мавзолейны барыбер ватачаклар, җимерәчәкләр дип, мумияне урлаган.* Р.Батулла

2) Шундый әйберләр белән сату итүче

**2.** *с. мәгъ.* 1) Борынгы һәм кыйммәтле. *Ниһаять, режиссёрның һәм татар театрының казанышы сыйфатында, гаҗәеп матур антиквар өстәл пыяласына сөяп куелган «Алтын битлек» карап тора.* М.Сәлимҗанов

2) Шул әйберләрне сата торган. *Инде ничә тапкыр шул сәгатьне антиквар кибетенә илтергә җыенды.* Р.Вәлиев. *Гыйнвар аенда Фешин Мәскәү елгасы аръягындагы бер кечкенә антиквар кибетенә кереп чыккан иде.* Р.Мирхәйдәров

**АНТИКОЛОНИАЛЬ** *с.* Колониализмга каршы булган; колониализм системасын йомшартуга яки тулысынча тар-мар итүгә юнәлдерелгән

**АНТИКОММУНИЗМ** *и. гр.-лат.* Маркс-Ленин тәгълиматына һәм коммунизм идеологиясенә каршы юнәлдерелгән идеология һәм сәясәт. *Бу Балтыйк буе дәүләтләре коммунизм-антикоммунизм тартышларында үзләренең битарафлыкларын игълан итте.* Х.Миңнегулов

**АНТИКОММУНИСТ** *и. рус* Антикоммунизм тарафдары, коммунизмга каршы көрәшүче. *Әнкәй – бик диндар кеше, гомере буе намазлык өстендә булды. Ә бабай исә – антикоммунист.* М.Галиев

**АНТИКОММУНИ́СТИК** *с.* Антикоммунизмга нигезләнгән, коммунизмга каршы булган. *Аларның антикоммунистик сәясәт алып барасы килеп тормый.* Р.Хәкимов

**АНТИЛО́ПА** *и. фр. зоол.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан, пар тояклы, күшәүче, көтү-көтү булып яши торган кыргый хайван. *Кайчандыр граф урманы булган иксез-чиксез паркның тын сукмакларыннан, әледән-әле, кыр кәҗәләре, алмачуар, затлы боланнар, антилопалар йөгереп узалар.* А.Хәсәнов

**АНТИМАРКСИ́СТИК** *с.* Марксизмны инкяр иткән, кабул итмәгән

**АНТИМАТЕРИАЛИ́СТИК** *с.* Материализмны инкяр иткән, аның принципларына каршы килгән

**АНТИМИЛИТАРИЗМ** *и. гр.-лат.* Милитаризм сәясәтенә һәм сугышларга каршы массакүләм хәрәкәт

**АНТИМИЛИТАРИСТ** *и. рус* Антимилитаризм тарафдары

**АНТИМИЛИТАРИ́СТИК** *с.* Милитаризмга каршы килгән, антимилитаризмны яклаган

**АНТИМО́НИЯ** *и. сөйл.* Буш сүз, юкбарны сөйләү, такылдау, сафсата сату («антиномия» сүзеннән бозып алынган). *Тәртип бозсаң, начар эшләсәң, антимония куертсаң – «Чолман»нан китәргә туры килер.* М.Юныс

**АНТИМОНОПОЛИ́СТИК** *с.* Антимонополиягә нигезләнгән, монополиягә каршы булган

**АНТИНО́МИЯ** *и. гр. филос.* Логика законнары нигезендә раслап була торган ике нигезләмәнең бер-берсенә каршылыгы. *Ул антиномияләргә корылган хәяти күренешләрнең берсен дә кире какмый.* А.Шәмсутова

**АНТИПА́РТИЯЧЕЛ** *с.* Партиягә, аның эшчәнлегенә каршы юнәлдерелгән

**АНТИПА́ТИЯ** *и. гр. кит.* Яратмау, нәфрәт тойгысы, күралмау хисе; *киресе:* **симпатия**. *Монысы инде гаҗәп кенә түгел: сиңа ачыктан-ачык антипатия белән караучы кайберәүләр иҗатыңны тикшерергә, бәя бирергә алыналар!* Р.Әхмәтҗанов

**АНТИПА́ТИЯЛЕ** *с. кит.* Нәфрәт тудыра торган, сөйкемсез; *киресе:* **симпатияле**

**АНТИПЕДАГО́ГИК** *с.* Педагогика принципларына каршы килгән, аларны инкяр иткән. *Бу караштан Рушад: – Йә, тагын нинди антипедагогик адым ясыйсың син, малай актыгы? – дигән сүзләрне аңлагандай булды.* М.Мәһдиев

**АНТИПОД** *и. гр.* **1.** 1) *геогр.* Җир шары диагоналенең капма-каршы ягында яшәүче кешеләр

2) *күч.* Үзенең холык-фигыле, зәвыгы һәм карашлары белән кемгә яки нәрсәгә дә булса капма-каршы булган кеше яки күренеш. *Хәтта алар бу жанрга хас, кайчандыр мәҗбүри саналган физик контрастлыкны файдаланудан да, тышкы антиподны үзмаксат итеп алудан да баш тарталар.* Казан утлары

3) *күч.* Берәр нәрсәнең капма-каршы ягы. *Әйтелгәнчә, ямьсезлек ул – гүзәллекнең антиподы.* К.Гыйззәтов

**2.** *с. мәгъ.* Берәр нәрсәнең капма-каршысы булган. *Шунысы кызык: бериш мәкальләрдә хәтта бер объект үзе генә дә тиңдәш яки антипод компонентларга бүленә, һәм мондый пар, гадәттә, субъектның сыйфатлары исәбенә хасил була.* М.Бакиров

**АНТИСАНИТАР** *с.* Санитария нормаларына туры килмәгән

**АНТИСАНИТАРИ́Я** *и. рус* Санитария нормаларына туры килмәү. *Столыпин вагоны ул – тимер читлекле вагон. Хайван вагоннары. Анда – антисанитария.* Р.Батулла

**АНТИСЕМИТ** *и. фр. кит.* Антисемитизм тарафдары

**АНТИСЕМИТИЗМ** *и. фр. кит.* Яһүдләргә карата дошманлык мөнәсәбәтен белдергән милли һәм дини түземсезлекнең бер төре

**АНТИСЕМИ́ТИК** *с. кит.* Антисемитизмга нигезләнгән

**АНТИСЕ́ПТИК** *и. гр.* **1**. Микробларны юкка чыгара торган матдә (медицинада, азык-төлек сәнәгатендә, шулай ук үзагач, текстиль материаллар һ.б.ны бозылудан саклау өчен кулланыла)

**2**. *с. мәгъ.* Микробларны юкка чыгара, бетерә яисә киметә торган. *Ул авыз куышлыгында ялкынсыну процессларын кисәтә, антисептик йогынты ясый.* Хокук һәм хәят

**АНТИСЕ́ПТИКА** *җый. и. гр. мед.* Химик һәм биологик юл белән, ярадагы, предметлардагы инфекция белән көрәшү алымы. – *Аны башкарып чыгарлык кына инструментларың һәм антисептика даруларың бардыр бит синең? – диде Мөнирә.* Г.Тавлин

**АНТИСКЛЕРО́ТИК** *с.* Склерозны дәвалау өчен билгеләнгән, склерозның үсүен туктата торган

**АНТИСОВЕТИЗМ** *и. рус* Советлар Союзына һәм аның төзелеш структурасына каршы көрәшүгә юнәлдерелгән идеология һәм сәясәт. *Журналда антибольшевизм (антикоммунизм), антисоветизм ярылып ята.* Х.Миңнегулов

**АНТИСОВЕ́ТЧИНА** *и. рус тар.* Советлар Союзы идеологиясенә һәм сәясәтенә каршы алып барылган эшчәнлек. *Әҗәлен сизенә бу, дип уйлады Заһит, мондый баш бетәрлек антисоветчина сөйләмәс иде.* М.Әмирханов

**АНТИСОВЕТЧЫ** *и. тар.* **1**. Антисоветизм тарафдары, шул юнәлештә көрәшүче. *Әмма ниндидер күләмдә мин үземне-үзем коткарып калдым шикелле, янәсе, мин антисоветчы түгел, имеш.* Р.Батулла

**2**. *с. мәгъ.* Советлар Союзы идеологиясенә һәм сәясәтенә, төзелешенә каршы көрәшүгә юнәлдерелгән. *Татар язучыларын нәрсәдә генә гаепләмиләр: «Икейөзлеләр, контрреволюционерлар, антисоветчы элементлар, кыскасы, халык дошманнары!»* З.Зәйнуллин

**АНТИСОВЕТЧЫЛ** *с. тар.* Советлар Союзына һәм аның төзелеш системасына каршы көрәшүгә юнәлдерелгән. *Аларны антисоветчыл милләтчелек берләштерде.* Ф.Сафин. *Әлбәттә инде, мине югары кабинетка алып менделәр, каян синдә мондый антисоветчыл фикерләр, кем котырта сине, ди-ди, җанга төштеләр.* Х.Камалов

**АНТИСОЦИАЛИ́СТИК** *с.* Социализмга, аның принципларына каршы юнәлдерелгән

**АНТИСТИЛЯ́ГА** *и. рус* Көнбатыш илләренең модасына ияреп киенмәгән, аны кабул итмәгән кеше. *Безнең Өметгали стилягалыкның капма-каршы ягы – антистиляга иде.* М.Юныс

**АНТИТӘНЧЕКЛӘР** *и. күпл.* Кешенең һәм җылы канлы хайваннарның канында булган, андагы микроорганизмнар белән бәйләнешкә кереп, аларны зарарсызландыра торган аксымнар. *Авыруларга каршы хайван организмында исә махсус саклагыч матдәләр – антитәнчекләр эшләнә.* Ф.Бәйрәмова. *Күпчелек авырулар вакытында зарарланган урынга, күпләп, антитәнчекләр юнәлә.* Сәламәт яшәү нигезләре

**АНТИТЕ́ЗА** *и. гр. әд.* Капма-каршы яки кискен аерылып торган образларны һәм төшенчәләрне чагыштырып карауга нигезләнгән әдәби стилистик алым. *Гыйлемнең өстенлеген күрсәтү өчен, автор антитеза алымын куллана.* Ә.Шәрипов. *Антоним сүзләр кулланып сурәт ясау әдәбият белемендә «антитеза» дип атала.* Ф.Сафиуллина. *Икенче бер урында шагыйрь яз-кыш антитезасы аша яшьлек-картлык төшенчәләрен ачып сала.* Х.Миңнегулов

**АНТИТЕ́ЗАЛЫ** *с.* Капма-каршы куелган, капма-каршы чагыштырып

каралган. *Антитезалы фикерләү – шагыйрь кулланган төп әдәби алымнарның берсе.* Х.Миңнегулов

**АНТИТЕ́ЗИС** *и. гр. филос.* Тезиска капма-каршы куелган фикер. *Фихтенең карашынча, «мин» – тезис, «мин түгел» – антитезис, «абсолют мин» – синтез ролендә чагылалар.* К.Гыйззәтов

**АНТИТО́КСИК** *с.* Организмдагы токсиннар, агулы матдәләр һәм агулы сүлләрнең көчләрен юкка чыгара торган, йогышсызландыра торган

**АНТИТОКСИН** *и. гр. биол. хим. мед.* Организмда барлыкка килгән токсиннарның йогынтысы нәтиҗәсендә бүленеп чыга торган һәм агуланудан саклый торган тәнчек

**АНТИТОКСИНЛЫ** *с.* Антитоксины булган

**А́НТ ИТҮ** *ф.* 1) Рәсми вәгъдә бирү. *Солдатлар командирлары, тантанага җыелган халык һәм ата-аналары алдында ант итте*

2) Сүз бирү, ышандыру; вәгъдәләшү, килешү. *Баштарак ул, андый затлы нәрсәләр складта юк, дип ант итте.* М.Юныс. *[Ирек:] Яңадан йөз ел буе ачуланышмаска ант итәбезме, Зәнфирә?* Ф.Садриев. *[Шәмсетдин:] Коръән белән, атам-анам белән, барлык изгеләр белән ант итәм – ялган түгел!* Н.Фәттах

**АНТИФАШИЗМ** *и. гр.-ит.* Фашизмга каршы хәрәкәт

**АНТИФАШИСТ** *и. рус* Фашизмга каршы булган кеше; фашизмга каршы көрәшүче. *Ә без алып кайткан «тел» Митавадагы немец антифашистларына барып эләккән.* Х.Камалов. *– Антифашист? – дип пышылдады ул. – Мин дә бит, мин дә... О, без бер фронт кешеләре икәнбез!* Ш.Маннур

**АНТИФАШИ́СТИК** *с.* Фашизмга каршы килә торган, аңа каршы юнәлдерелгән. *Монда журналист, Берлиндагы антифашистик яшерен оешма члены Әхмәт Садретдин улы Симаев укыды.* Р.Мостафин

**АНТИФАШИСТЛЫК** *и.* Антифашист булу

**АНТИФОН** *и. гр.* Тавышның организмга тискәре йогынты ясавыннан саклану өчен, колак тишекләрен каплап киелә яки колак тишегенә тыгыла торган җайланма

**АНТИФРИЗ** *и. ингл.* Ноль градустан түбән температурада да туңмый торган матдәләрнең судагы эремәсе. *[Мәүлитҗан:] Зыян юк. Самолётымның суы катмый, антифриз.* Д.Салихов

**АНТИ́ХРИСТ** *и. гр.* 1) Христиан динендә: Гайсә пәйгамбәрнең тәгълиматын кире кагучы. *Өстәл башындагы Игнат карт: «Федька, ты что, антихрист, чукынмыйсың? Чукынмыйча, кашыкка тотынмаска!» – дип җикерде.* Т.Мөбарәков

2) *сөйл.* Үз-үзен тотышы, өс-кыяфәте, кылган гамәлләре нәфрәт уята торган кешегә карата кулланылган тиргәү сүзе. *Күз алдыңа китер инде, йә: кичтән ачы бал чөмереп килгән бер антихрист --- җырлап җибәрсә?* З.Фәтхетдинов

**АНТИЦИКЛОН** *и. гр. метеор.* Атмосфераның циклоннар арасындагы һава басымы тотрыклы югары торган, һава торышы коры һәм аз болытлы булган өлкәсе. *Җир өстендә циклон, антициклоннар сугышы була тора – салкын агым белән җылы агым көрәшә.* Ш.Галиев

**АНТЛЫ** *с.* Ант биргән, анты булган. *Мөхәммәдәмин антлы ярлык язгач кына, 1509 елның гыйнвар аенда, җиде ел Аккүл тоткынлыгында булганнан соң, Габделлатыйф хан да ирекккә чыкты.* М.Әмирханов

**АНТОЛО́ГИК** *с. кит.* Антология формасындагы. *Антологик характердагы бу беренче җыентыкка мең ике йөзгә якын җыр кертелгән.* К.Миңнуллин

**АНТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Билгеле бер гасыр язучыларының яки бер әдәби юнәлештә иҗат ителгән сайланма әсәрләр җыелмасы. *«Татар балалар поэзиясе антологиясе»н, мәсәлән, Габделмәннан Рахманколый иҗаты турындагы язма ачып җибәрә.* Казан утлары. *«Наёмщик», «Зәңгәр шәл» спектакльләрендәге җырлар, опералардан арияләр, шулай ук халык җырларының аның башкаруындагы язмалары, бик хаклы рәвештә, татар музыкаль культурасы антологиясенә кертелде.* Казан утлары

**АНТОНИ́МИК** *с. к.* **антоним** (*2 мәгъ.*). *Антонимик мәгънәләр бер-берсенә каршы куелганлыгы белән аерылып торалар.* Ф.Сафиуллина

**АНТОНИ́МИКА** *с. рус лингв.* Тел гыйлеменең антонимнарны өйрәнә торган тармагы

**АНТОНИМИ́Я** *и. рус лингв.* Капма-каршы мәгънәгә ия булган лексик берәмлекләрнең (антонимнарның) семантик мөнәсәбәтләре

**АНТО́НИМЛАШУ** *ф. лингв.* Антонимга әйләнү, антоним булу

**АНТО́НИМНАР** *и. гр. лингв.* **1.** Капма-каршы мәгънә белдерә торган сүзләр (мәс., *бай – ярлы, дус – дошман, күләргә – еларга* һ.б.). *Антонимнарның үсеше кешенең чынбарлыктагы капма-каршы күренешләрне танып белүенә бәйле.* Ф. Сафиуллина

**2. антоним** *с. мәгъ.* Капма-каршы мәгънә белдергән. *Сөйләмдә, кайчак, антоним сүзләр үзара бәйләнешкә керәләр һәм бер сүзтезмә булып йөри башлыйлар.* Ф. Сафиуллина

**АНТО́НОВКА** *и. рус* 1) Алмагачның яшел сары төстәге әчкелтем тәмле җимеш бирә торган кышкы сорты. *Антоновка утыртканнан соң 7–8 елдан алма бирә.* А.Девятков, А.Макаревич

2) Шул агачның көз көне өлгерә торган хуш исле, яшел сары төстәге, әчкелтем тәмле алмасы. *Арырак тартмаларда – пычкы чүбе белән аралаштырып тутырылган антоновка алмалары.* Ф.Садриев

**АНТОЦИАН** *и. гр. биол.* Үсемлекләрнең яфракларындагы, чәчәк бөреләрендәге күзәнәк согында була, аларга төрле төс бирә торган матдә. *Моның сәбәбе: күзәнәк согындагы «антоциан» дигән пигмент, әкренләп, төсен үзгәртә.* И.Рәхимов, К.Ибраһимова

**АНТРАКТ** *и. фр. театр* 1) Спектакль актлары (күренешләре) яки концерт бүлекләре арасындагы тәнәфес. *Антракт вакытында сөйләргә дип ничә мәртәбә авызымны ачсам да, кайтканда иркенләп аңлатырмын, дип, ниятемне озату вакытына калдыра килдем.* М.Юныс

2) Спектакль күренешләре, циркта чыгышлар арасында уйнала торган

кечкенә музыкаль әсәр. *Музыкаль антрактта томан һәм дулкыннар белән капланган диңгез өстен күрсәтергә һәм музыкада өермә (шторм) башлануын чагылдырырга була.* М.Җәлил

**АНТРАЦЕН** *и. гр. хим.* Ташкүмер сумаласыннан алына һәм буяу матдәләре әзерләүдә кулланыла торган углеводород

**АНТРАЦИТ** *и. гр. геол.* Ташкүмернең кап-кара, ялтырап торган, җылылыкны күп бирә алган иң яхшы төре. *Антрацит валчыклары, олтанга ябышып, коридорга, каюталарга керә.* М.Юныс

**АНТРАША** *и. фр.* Классик балет биюендә: аякларны бер-беренә тидереп һәм тиз арада чалыштырып алудан гыйбарәт сикерү алымы. *Нәкъ балет биючесенең пируэтлар, антраша һәм арабескалар ясаган вакытындагы кебек!* Р.Вәли

**АНТРЕКОТ** *и. фр. махс.* 1) Сыерның сырт белән кабырга арасыннан алынган ит

2) Шул иттән тапап әзерләнгән котлет. *Ресторанда пешекче булып эшләүче бу хатын сумкасына бифштекслар, антрекот-эскалоплар, пирәшкиләр салмыйча кайтмый.* Ф.Баттал

**АНТРЕПРЕНЁР** *и. фр.* Шәхси театр, цирк һ.б.ш.ны тотучы

**АНТРЕПРЕНЁРЛЫК** *и.* Шәхси театр, цирк һ.б.ш.ны тоту эшчәнлеге

**АНТРЕСОЛЬ** *и. фр.* Кием-салым һ.б.ш. әйберләрне саклау өчен, түшәмгә терәп эшләнелгән киштә яки шкаф, сервант һ.б. өстенә куела торган ябык киштә. *Ә бишенче стена, «германский» дип телгә кергән, көзгеле-көзгесез, ябылулы-ишексез, шифоньер, сервант, антресоль һәм сандыклардан өелгән чит ил җиһазы.* К.Кәримов

**АНТРОПОГЕНЕЗ** *и. гр.* 1) Кешенең тарихи-эволюцион формалашу һәм үсү процессы. *Антропогенез процессында биологик факторның роле – һичшиксез беренчел.* К.Гыйззәтов

2) Кешенең барлыкка килүе һәм үсүе турындагы тәгълимат

**АНТРОПО́ИД** *и. гр.* Иң борынгы казылма зат: кешесыман маймыл

**АНТРОПО́ЛОГ** *и.* Антропология белгече. *Антропологлар кешеләрнең баш, йөз төзелешләрен, алай гына да түгел әле, халыкның кан составын тикшереп, эксперимент ясаганнар.* Р.Ягъфәров

**АНТРОПОЛО́ГИК** *с.* Антропологиягә караган, антропологиягә мөнәсәбәтле. *Сократ, антропологик фәлсәфәгә нигез салучы буларак, төп игътибарын кеше проблемасын эшкәртүгә бирә.* К.Гыйззәтов. *Татарларның кыска буйлы, киң күкрәкле булуын, тамырдан нык чыгуларын галимнәрнең антропологик тән төзелеше яки борынгы ата-бабаларыбызның ат өстендә йөрүләре белән генә аңлаткан фәнни фәлсәфәләре – дөрес түгел ул.* Н.Гариф

**АНТРОПОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Кешенең килеп чыгышын, үсешен, расалар барлыкка килүен, кешенең тән төзелеше үзгәрешләрен өйрәнә торган фән. *Тел гыйлеменең антропология фәне белән бәйләнеше дә әһәмиятле.* Ф.Сафиуллина. *Теләсә кайсы халыкның реаль этносы төрле сыйфат-хасиятләр белән билгеләнә (мәсәлән, тел, гореф-гадәтләр, йолалар, дини ышанулар, яшәү рәвеше, культура, антропология һ.б.).* Ә.Кәримуллин

**АНТРОПОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Кеше гәүдәсен һәм аның аерым әгъзаларын үлчәү белән шөгыльләнә торган антропологик тикшеренү алымнары җыелмасы

**АНТРОПОМОРФИЗМ** *и. гр.* 1) Кешегә хас психик үзенчәлекләрне табигать күренешләренә, хайваннарга, үсемлекләргә, предметларга һ.б.га күчерү. *Сынландыру антропоморфизмнан үсеп чыккан сурәтләү чарасы булып тора.* Әдәбият

2) Алланы кеше рәвешендә күзаллау күренеше (күп диннәргә хас)

**АНТРОПО́НИМ** *и. рус лингв.* Кеше исеме. *Этноним хәзер топоним, гидроним һәм антропоним формасында ныгып калган.* Ф.Гарипова. *XIV–XV гасыр төрки-татар чыганакларында без түбәндәге кушма антропоним үрнәкләре барлыгына игътибар итәрбез.* М.Әхмәтҗанов

**АНТРОПОНИ́МИК** *с. лингв.* Антропонимикага караган, антропонимикага мөнәсәбәтле. *Телләрнең антропонимик системалары*

**АНТРОПОНИ́МИКА** *и. гр. лингв.* Тел гыйлемендә кеше исемнәрен, фамилияләрен, кушаматларын өйрәнә торган лексикология тармагы. *Ономастика үз чиратында антропонимика һәм топонимика тармакларына бүленә.* Ф.Сафиуллина

**АНТРОПОФАГ** *и. гр. кит.* Кеше ашаучы

**АНТРОПОФА́ГИЯ** *и. гр.* Кеше ашаучылык. *Фәндә әлеге куркыныч йоланың үз исеме дә бар: антропофагия. Килеп чыгышы ягыннан иң борынгылардан булган бу йола кешене, аеруча үз балаларын үтереп, аларның ите белән «туклануdan» килә булса кирәк.* Ф.Урманче

**АНФАС** *рәв. фр.* Кешенең яки предметның алгы ягы белән, йөзе белән. *Инде, утырып, иреккә чыкканнарына аерым игътибар ителгән, аларның профиль һәм анфас алынган фоторәсемнәре теркәлгән.* Р.Мирхәйдәров

**АНФИЛА́ДА** *и. фр. архит.* Бер үзәк буенча урнашкан, бер-берсе артыннан тезелеп киткән ишекләр уемы, бүлмәләр рәте

**АНЧАК** *терк. төрк. иск.* 1) Фәкать, тик, бары. *Бирмә сер һичкемгә: сөйләшсәң сөйләш өстән генә; Көл – караңгы йөз бирү анчак килешмәстән генә.* Г.Тукай. *Сөю шигыре – агач аттыр «Вакыт»ча, Зарар юк, ул сөйләр анчак вакытча.* Г.Тукай. *Ләкин бу кеби хушлашулар анчак саф мәхәббәт әһелләрендә генә ула белер.* Р.Фәхретдинов

2) Әмма, ләкин

**АНЧАР** *и. малая биол.* Тутчалар семьялыгыннан, агулы сөтсыман сыекчасы булган тропик агач. *Юлымда – анчар куагы, Агуы тора тамып. Күзенә туры карадым – Кемлеген алдым танып.* С.Мулла Гали. *Җирле халык, ауга чыкканда, ук очларын анчар сыекчасына манганнар*

**АНШЛАГ** *и. нем. театр* 1) Театр, цирк, кинотеатр һ.б. кассаларында «барлык билетлар сатылып бетте» дип язып эленгән игълан; тамашаның тулы зал белән баруы. *Иптәшләр, аншлаг! Зал шыгрым тулы.* Г.Әпсәләмов

2) *махс.* Газеталарда зур-зур хәрефләр белән язылган мәкалә яки тема исеме

**АНЫ** *а.* **1.** «Ул» зат алмашлыгының төшем килеш формасы: ул кешене, ул әйберне. *Озак еллар буена аны, сугышта катнашкан, дип искә дә алмадылар.* Б.Камалов. *Бернинди ачу, бунтарьлык калмый, ә бары кызгану кала. Аны һәм үземне кызгану.* М.Галиев. *Бу егетне таныйсызмы? Ул яшь чагында сезнең авылда көтү көтте. Сез аны кыерсытмадыгызмы?* М.Мәһдиев

**2.** *кис. мәгъ. сөйл.* 1) Хикәя фигыль белдергән эш-хәрәкәтнең тиешенчә башкарылып җитмәвенә ишарә итеп, шулай эшләргә яки шулай эшләмәскә кирәк иде, мәгънәсендә килә. – *Сиздерергә кирәк аны, – диде Разия.* А.Алиш. *Шул кирәк сиңа, чапмыйлар аны.* А.Галиева

2) Хикәя фигыльнең беренче зат күплек формасыннан соң килеп, нинди дә булса эш-хәлнең сөйләүче тарафыннан һич икеләнүсез һәм каршылыксыз башкарылуына ишарә итә. *Менә бу каенның суы шундый тәмле! Хәзер агызып алабыз аны...* Таңчулпан. *Кирәк икән, эшлибез аны*

3) «Иде» ярдәмче фигыленнән соң килеп, нәрсәгә дә булса карата шикшөбһәле уйларның раслануына ишарә итә. *Ана мәче асрамагыз, дип әйткәннәр иде аны.* Ә.Сафиуллин. – *Кире борылып кайтырга туры килгәч, юлым уңмас инде, дип уйлап куйган идем аны, – диде [каенанасы].* А.Фәләх

◊ **Аны әйткән дә юк** Контекстта аңлашылган нәрсә (кем) турында әйтеп торасы да юк, анысы болай да билгеле; нинди булса, шундый; ничек булса, шулай

**АНЫК** *рәв.* **1.** Ачык итеп, төгәл генә, аңлаешлы итеп; аермачык итеп, дөрес итеп. *Ләкин барыбер Рухиясен кайда һәм ничек каршылау мәсьәләсен анык кына хәл итә алмаган иде әле.* В.Нуруллин. *[Мәҗит:] Анысын анык кына беребез дә белмибез.* Д.Салихов. *Кояшы үтә җете бүген, күләгә бик анык төшә.* М.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ.* Аңлаешлы, төгәл булган, дөрес булган. *Кыскасы, кече яшьтән үк анык максатым булды.* Р.Вәлиев. *Бу процесста электән килгән Шәрык традицияләренең анык урынын билгеләү әдәбият белеменең чираттагы бурычларыннан берсе булып тора.* А.Әхмәдуллин

**АНЫКЛАГЫЧ** *и. грам.* **1.** Җөмләдә ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык керткән, өстәмә төгәллек биргән кисәк (*мәс., Мин озаттым аны сугышка, Йөрәгемнең сүнмәс кояшын.* М.Җәлил). *Димәк, аныкланмышка бәйләнү ягыннан караганда, аныклагыч ике төрле: аныкланмышка ярашкан аныклагыч һәм аныкланмышка ярашмаган аныклагыч була.* Татар грамматикасы

**2.** *с. мәгъ.* Җөмләдә иярткүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык керткән, өстәмә төгәллек биргән. *Көчәйткеч, аныклагыч кисәкчәләр, мәгънәви басымның юлына киртә булып, күп очракта аны үзләренә күчерәләр.* Г.Нуриев

**АНЫКЛАМА** *и.* Ачыклык, төгәллек; өстәмә аңлатма. *Дөрес, әлегә ул күбрәк җәя эче аныкламасы белән яисә аныклаулы атамалар составында кулланыла.* Р.Мөхиярова

**АНЫКЛАНМЫШ** *и. грам.* **1.** Җөмләдә аныклагыч тарафыннан аныкланган, ачыкланган иярткүче кисәк (*мәс., Мин озаттым аны сугышка, Йөрәгемнең сүнмәс кояшын.* М.Җәлил). *Икенче төр аныклагычлар аныкланмыш белән ярашкан булалар һәм һәрвакыт аерымланалар.* Татар грамматикасы

**2.** *с. мәгъ.* Җөмләдә аныклагыч тарафыннан аныкланган, ачыкланган

**АНЫКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **аныклау**

2) Ачыклану. *«Без, студентлар, тырышып укыйбыз» дигән җөмләдә «без» сүзе «студентлар» тарафыннан өстәмә рәвештә аныклана.* Ф.Сафиуллина

**Аныклана бару** Эзлекле рәвештә аныклану. *Әдәбияттагы талантлар юлы турындагы фикер дә бу хезмәттә сәхифәдән сәхифәгә үсә, аныклана бара.* Н.Нәҗми. *Тик тулай да әдәбият белеме әлегә социализм тәгълиматының торган саен аныклана барган кимчелекләреннән арынып җитә алганы юк.* А.Әхмәдуллин

**Аныклана башлау** Аз-азлап, акрынлап аныкланырга керешү. *Шуннан сызыклары ачыклана төшә, сурәте, конструкциясе аныклана башлый.* Ш.Галиев

**Аныклана төшү** Бераз аныклану

**Аныкланып бетү** Тулысынча, ахырына кадәр аныклану. *Дөрес, әлегә тел белемендә телнең эчке (үз) һәм тышкы ресурслары төгәл генә аныкланып бетмәгән.* Р.Мөхиярова

**Аныкланып җитү** Тулысынча аныкланган хәлгә килү. *Восстание темасы либреттода ахыргача аныкланып җитми.* М.Җәлил. *Соңгы ике мәкаләдә бәхәсле һәм ахыргача аныкланып җитмәгән урыннар булса да, авторларның --- татар әдәбиятын Бөтенсоюз масштабында тикшерергә омтылулары игътибарга лаеклы.* Т.Галиуллин

**Аныкланып тору** Һәрвакыт, әледән-әле аныклану

**АНЫКЛА́У** *ф.* Билгеләү, ачыклау, дөрес итеп белү, аңлаешлы итү; ачыклык кертү. *Кичәге бюро утырышы Сабир Салиховичка күп нәрсәне яңабаштан аныкларга ярдәм итте.* Г.Кашапов. *Күңеле ак бу агайның, дип аныклады бәясен һәм картка турылап борылды.* М.Хуҗин. *Төп ударны, әлбәттә, былтыргыга караганда һәр сыердан сөт савып алуның ни өчен киму сәбәпләрен аныклауга бирде.* Х.Хәйруллин

**Аныклап бетерү** Бөтенесен, һәрберсен аныклау; ахыргача аныклау. *[Әнвәр:] Әйдә, аныклап бетермик әле. Син – минем өчен туган ай да, татлы җиләк тә.* М.Маликова. *Рәхим абзый мәсьәләнең асылын дөрес аңласа да, Галимгә ярдәм итү юлын аныклап бетермәгән иде әле.* Г.Әпсәләмов

**Аныклап бирү** Аныкларга ярдәм итү. *Аптырап, югалып калган карчыкка мәсьәләнең асылын аныклап бирә: – Бу урында уналты катлы өй салыначак.* Т.Галиуллин

**Аныклап җиткерү** Тәмам, тиешенчә ачыклык кертеп аныклау

**Аныклап китү** Сүз уңаенда аныклау. *Иң элек җисемнең исемен аныклап китик.* Р.Батулла

**Аныклап кую** Кыскача аныклау; алдан аныклау. *Билалов аныклап куй-*

*ды: – Әйе, шушында.* С.Шәрипов. *Француз язучысы Альбер Камюның эпиграф рәвешендә бирелгән сүзләре дә әсәрнең идея юнәлешен алдан ук аныклап куя шикелле*. Г.Морат

**Аныклап тору** 1) Һәрвакыт, системалы аныклау

2) Әле, сөйләү моментында аныклау. *Хәрби часть командиры белән мин, яңа алынган приказны ничек үтәү турында киңәшеп, Сталинград районында туктыйсы урынны карта буенча аныклап тора идек*. С.Сабиров

**Аныклап чыгу** Башыннан ахырына кадәр аныклау; барысын да берәмберәм аныклау

**Аныклый төшү** Бераз, берникадәр аныклау. *Бу юлы да, шикләнергә урын калмасын дип, аныклый төште*. Ф.Сафин. *Харрас Шәмгунович, аның хәлен аңлап, сүзне аныклый төшәргә булды: – Уйладык-киңәштек тә бу урынга сезне тәкъдим итәргә булдык, – дип, аңа сынаулы караш ташлады*. Р.Вәлиев

**АНЫКЛАУЛЫ** *с. грам*. Аныклый, ачыклый торган. *Аныклаулы мөнәсәбәт булганда, иярүче сүз, ияртүче сүздән соң килеп, аңа өстәмә төгәллек, аныклык бирә.* Татар грамматикасы

**АНЫКЛАУЧЫ** *и. грам.* **1.** Аныклаулы мөнәсәбәттә, башка кисәкне аныклап килгән кисәк

**2.** *с. мәгъ. к.* **аныклаулы.** *Аныклаучы исем баш килештә килсә, предметлар арасында урынга, вакытка, материалга, өлешкә, милләткә, ни өчен кирәклеккә һ.б. төшенчәләргә карата булган мөнәсәбәтләр белдерелә.* Татар грамматикасы

**АНЫКЛЫК** *и.* Ачыклык, аңлаешлылык, төгәллек. *Ир-ат биюе хатын-кызларныкыннан зур динамикалылык, көч-куәт һәм аныклык белән аерылып тора.* Ф.Хатипов

**АНЫКСЫЗ** *с.* 1) Ачык булмаган, төгәл түгел, аңлашылмый торган

2) *мат.* Билгесез. *Кульязманың икенче бүлеге төрле типтагы сызыкча һәм квадрат тигезләмәләрне чишү алымнарын, шулай ук ике билгесезле бер тигезләмәне яки өч билгесезле ике тигезләмәне эченә алган аныксыз тигезләмәләр җыелмасын чишү ысулларын аңлатуга багышланган*. Татар милли педагогикасы

**АНЫКСЫЗЛА́У** *ф.* Билгесезлек, төгәлсезлек кертү

**Аныксызлап кую** Аныксызланган хәлгә китерү

**АНЫКСЫЗЛЫК** *и.* Билгесезлек, төгәлсезлек, аныксыз булу. «*Утын яру*» *дигән төшенчәдә шулай ук «утын» аныксызлык төсмере белән кулланыла.* Р.Юсупов

**АНЫКЫ** *а.* **1**. Берәр кешегә яки предметка караган, аңа мөнәсәбәтле булуны белдергән тартым алмашлыгы. *Үз хәлен, аныкы белән чагыштыргандa, ул кадәр үк куркыныч түгел, дип саный.* Р.Кәрами. *Аныкы булып калсам, биш ел көтәргә дә риза.* М.Фәйзи. *Үзе дә казакъныкыннан да кысыграк күзле, аныкыннан да киңрәк битле Солтанморат башкорт камчысы белән офык ягына селти*. З.Зәйнуллин

**2**. **аныкылар** *и. мәгъ. күпл. сөйл.* Аңа туган тиешле яки аның белән якыннан аралашкан, шул төркемнән булган кешеләр. *Бистәдә бизәкле читек-итекләрне, затлы туннарны да аныкылар гына кия.* Р.Юсупова. *Менә бу бәрелештә аныкылар чын батырлык күрсәттеләр*. Х.Камалов

◊ **Аныкын кем белсен** Аңларлык түгел, билгесез. *Аныкын кем белсен инде. Барысын да үзе хәл итсен.* И.Гази

**АНЫ́-МОНЫ** *и.* **1.** 1) *җый.* Төрле нәрсәләр, төрле вак-төякләр. *Кичләрен яшьләр килгәли, кычкырып укулар оештырабыз, аны-моны сөйләшкәлибез.* Ш.Маннур. *Кибеттән аны-моны алу*

2) Нинди дә булса әйбер, вакыйга, фикер; теләсә кем, теләсә нинди кеше яки теләсә нәрсә. *Аны-моны җыеп утырма. Аны-моны уйлама*

**2.** *а. функ.* 1) Эш-хәл белән бәйле сәбәпнең бөтенләй булмавына, табылмавына ишарәләп, юклык алмашлыгы буларак кулланыла; һични, бернәрсә, һичнәрсә, нәрсә дә. *Долгоруков Илсөяргә, аны-моны белмәгән кебек, чирәмдә утырып торырга кушты*. Г.Гобәй. *Шуңа күрә, Зәйтүнә хәл-әхвәл сорашканда да, Динә аны-моны әйтмәде.* М.Маликова. *Бераз кәефе кырыла төшкән булса да, аны-моны сиздермәде, төшен үзенчә фаразлады.* Н.Хәсәнов

2) Эш-хәлнең вакытына, тизлегенә ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; нидер, нәрсәдер. *Тирә-юньдәгеләр аны-моны абайлап өлгергәнче, бабай, тимер култыкса аркылы очып, дыңк итеп, чирәмлеккә барып төште.* М.Маликова

**АНЫҢ** *а.* **1.** «Ул» зат алмашлыгының иялек килеше формасы: ул кешенең, ул нәрсәнең. *Ул бер сүз дә залга әйтмәсә дә, Зал йөрәген аның аңлады.* Һ.Такташ. *Кешенең үзенең кәефе, үз-үзен тотышы, сүзләре – һәммәсе дә аның авыр кичерешләрен җиңеләйтүгә булыша ала.* Ф.Углов. *Аның белән бергә без дә көттек Сафуан абыйны*. М.Галиев

**2.** *кис. мәгъ.* Җөмлә ахырында *инде* сүзеннән һәм *-мыни/-мени* кисәкчәләреннән соң мәгънәгә басым ясау, ассызыклау өчен кулланыла. *Йөреп укуның рәте буламыни аның.* Р.Миңнуллин

◊ **Аның ише** Ул кеше яки нәрсә кебек. *Юк, андый коткыларга бирелергә һич тә ярамый, аныңише ерык авызлар күп булыр дөньяда.* Н.Фәттах. **Аның каравы** Әмма, шулай да, шулай булса да. *Аның каравы, яшел калай түбәле йортлары зур да, бик таза да иде.* Ә.Еники. **Аның өстәвенә** Шуңа өстәп, өстәвенә, җитмәсә. *Аның өстәвенә, бу елларда югалту бушлыгын тиз арада яңа көчләр тулыландыра башлый.* Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. **Аның саен** Шулай булган саен, шуның аша (берәр нәрсәнең көчәюе яки кабатланып килүе турында). *Ул, хәтерен тәртипкә китерергә теләп, башын селкеп карады, учлары белән чигәләрен уды, ләкин авылны бөтенләй диярлек каплап киткән томан аның саен куера гына барды*. Р.Вәлиев

**АНЫ́ҢЧА** *рәв.* **1**. Аның кебек, аның рәвешле. *Шәмси, нәкъ аныңча итеп: – Каян беләсең бит, Әхмәди абый, – дигән булды*. Г.Бәширов. *Бәлки әле, Тукайның Аллага мөнәсәбәтен дә нәкъ аныңча аңлый торганнардыр.* Ә.Еники

**2**. *кер. сүз мәгъ*. Аның фикеренчә. *Аныңча, бу бик кирәкле нәрсә иде.*

Ш.Маннур. *Аныңча, Россиядәге барлык мөселманның күзе Татарстанда булырга тиеш.* И.Гази. *Аныңча, калганы, тормыш көткәндә, майлы табада шуган коймак шикелле, үзеннән-үзе җайга салына.* С.Поварисов

**АНЫСЫ** *а.* **1.** 1) «Ул» зат алмашлыгының төшем килешендәге тартымлы формасы. *Анысы, качканда, безгә таба йөгермәде.* А.Расих

2) Бераз читтәрәк торган кешегә, җан иясенә яки предметка ишарәли, ымлый торган күрсәтү алмашлыгы буларак кулланыла; *киресе*: **монысы**. *Анысына да кредит бирдек.* И.Гази

3) Күпмедер вакыт алдан булган, элек сөйләнгән эш-хәлгә, затка яки әйбергә ишарәли торган күрсәтү алмашлыгы буларак кулланыла. *Мин анысын йөгерә башлагач кына тоям.* Ф.Бәйрәмова. *Сөйләгәндә шома сиптерәсез, кызларның күңелендә нәрсәләр бар – анысын уйлап та карамыйсыз.* Ф.Сафин. *Ул күпме шулай яткандыр, анысын һичкем белми.* Ш.Маннур

**2.** *кис. мәгъ.* Фигыльдән соң килеп, эш-хәлнең һичшиксез үтәлүен белдерә. *Балан авылында малайлар кызларны рәнҗетми анысы.* Хәйдәр. *[Шәфика:] – Сәламәтләнегез инде, Салих абый, аннары уйнарсыз да, язарсыз да. [Салих:] – Бирешмим анысы, бәгырь.* Мирас

◊ **Анысы – анда, монысы – монда** Теләсә кайда, кайсы-кайда; берсе – бер, икенчесе башка урында. **Анысы әле – анысы** Монысы әле ярый, моннан тыш әле башкасы да бар. *Нигә соң ике матурның бер-берсенә өйләнешүләре сирәк була? Анысы әле – анысы. Шуннан соң син тагын ике ямьсезне әйт.* Н.Исәнбәт. **Анысы – бер (хәер) хәл** Ул гына түгел, әле тагын монысы да бар; аннан да хәтәррәге бар. *Хәер, анысы – бер хәл, аның әле сугыш күргән егетләре дә күбәеп киттеләр.* Ф.Яхин. *Янәсе, Кырымда чирләп яткан зур бер язучы (хәзер «халык дошманы») Казанга килеп чыккач, Шиһапов шул язучы белән бик тәмләп сөйләшеп утырган, анысы гына әле – бер хәер, анысын гафу да итеп булыр иде.* И.Гази. **Анысы гына җитмәгән** Өстәвенә, җитмәсә; шуңа өстәп. *Анысы гына җитмәгән, үзлегеннән ул туктаусыз китап укыды.* Н.Фәттах. **Анысы да анысы** Аннан тыш, шулардан башка; аннан да мөһимрәк. *Анысы да анысы, минә үзебезнекеләр кайткач, безне нишләтерләр.* Х.Камалов. **Анысы да монысы** Ул арада, тегеләй-болай иткән арада. *Анысы да монысы: Ярулла абзыйның матаен ремонтларга да без Барый белән икәүләшеп йөри башладык.* З.Хөснияр. **Анысыннан да бигрәк** *к.* **аннан (да) бигрәк**. *Анысыннан да бигрәк, Мансурның ни йомыш табып монда уралуын, Фәйрүзәгә мөнәсәбәтен ачыклыйсы килә аның.* Р.Мулланурова

**АНЫСЫ́-АНЫСЫ** *мод. с.* Аннан тыш, моннан (шулардан) башка; шулай да, чынлыкта. *Әле анысы-анысы, Гай Юлий Цезарь татар икән бит.* Р.Батулла

**АНЫСЫ́-МОНЫСЫ** *җый. и.* 1) Әле бер нәрсә, әле икенче нәрсә; төрле нәрсәләр, төрле вак-төякләр. *Номерга кереп йөрүче половойдан чәй соратып ала, я кергән-килгән аша анысын-монысын алдырта, ләкин, бер каба да, һич теләмәгәнлеген тоеп, кашыкны өстәлгә куя иде.* А.Расих. *Менә хәзер ул матайны гараждан чыгарды, анысын-монысын карады.* Г.Кашапов. *Үзе, атналар буе яныннан китмичә, иске тракторны сүтте, хасиятләп җыйды, анысын-монысын яңартты.* Р.Фәизов. *Ник дисәң, сәбәбе бар: ындыр табагында эшләүче кызлар бу кала егетенең эшкә ябышып торган кулын, анысы-монысы белән исәпләшмәвен бик ошаттылар.* Ф.Хөсни

**АҢ** I *и.* 1) Кешенең чынбарлыкны фикерләп кабул итү, уйлый белү сәләте. *Мәхәббәткә аң катнаша аламыни ул?* Р.Сибат. *Бая Гыйльметдин әйткән хәбәр хатынның аңына яңа барып җитте, ахрысы.* Ф.Сафин

2) Дөньяга караш, иҗтимагый тормыш барышын кабул итү, төшенү. *Ул феодал руханиларның һәм диннең, иске мәдрәсә схоластикасы һәм дини уйдырмаларның халык массасы аңын агулавын күрә, ачыграк төшенә килде.* Г.Нигъмәти

3) *филос.* Кешенең акылында чынбарлыкның, барлык психик эшчәнлегенең чагылышы. *Тормыш ничек – аң шундый, дигән фәлсәфи законга буйсынып, без кечкенә караклар булып үстек.* К.Йосыпов // Нинди дә булса бер иҗтимагый сыйныф вәкиле буларак, кешеләрнең психологиясе, аларның сәяси, фәлсәфи һ.б. карашлары. *[«Тормыш баскычлары»] Әсәр[ен]дә сыйнфый аңы ачыла барган, ахыр килеп, революциягә һәм гражданнар сугышына кызыл командир булып катнашкан Вахит образы матур, җанлы бирелгән.* М.Җәлил

4) Аек акыл; белем, аң-белем. *Мохтарның сынавына караганда, Гыйльмулланың аң, тапкырлык дәрәҗәсе Сәхипнекенә караганда күпкә түбән.* Ш.Камал. *Дөньяның уңын-сулын белдереп, аң бирә торган җирдә укырга кирәк икән, мин, солдатта йөреп, шул тәҗрибәне алдым.* М.Гафури

◊ **Аң ачылу** *к.* **аң керү. Аңга кертү** 1) Акыл бирү, аң бирү, тормыш серләренә төшендерү. *Габдулла абзыйны мин үзем, аңга керттем, дип уйлый идем – хәзер ул да бит Гәрәйләр койрыгына тагылып авып бара.* Г.Ибраһимов; 2) Тәнкыйть белән яки бераз тәпәләп тәртипкә китерү, акылга утырту. **Аңга килү** 1) Һуштан язып аңсыз ятканнан соң, сиземли, тирә-юньне тоя, фикер йөртә башлау. *Кичә гипска салганнан бирле юньләп аңына да килгәне юк.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Больницада ул бер тәүлектән соң гына аңына килде.* Ф.Садриев; 2) Мәсьәләне аңлап алу, аның серенә төшенү, хәлне аңлау. *Тик авылларына кайтып, велосипедны тапшырырга баргач һәм Йосыф абыйсы, иртән сөйләшенгәнчә, велосипед хакына чикләвек сорагач кына аңына килде.* В.Нуруллин; 3) *к.* **акылга утыру. Аңга китерү** 1) Һуштан язган кешегә һушына килергә ярдәм итү; 2) Уйларга мәҗбүр итү, айнытып җибәрү. *Васфиянең кинәт як-ягына карануы гына аларны аңнарына китерде.* М.Хуҗин; 3) *к.* **аңга кертү** (*2 мәгъ.*). **Аңда булу** Акылында, зиһенендә булу, фикерле, тоемлый алу. *Аңында булса, мине сораса, хафаланмагыз, диегез, бирedә, Казанда, диегез.* Х.Хәйруллин. *[Пәнәри:] Зөбәйдулла аңында булса*

*да, авылга кайтасы килмәгәндер инде.* З.Зәйнуллин. **Аң җую** 1) Кинәт сиземләүне югалту, тирә-юньне тоймый башлау, аңсызланып егылу. *Чыктым һәм, кинәт хәлем китеп, аңымны җуйдым.* В.Нуруллин; 2) Нәрсәгә дә булса бик нык аптырау, шаккату, ис китеп тору, таң калу. **Аң керү** Тормышның җаена, бөтен нечкәлекләренә, барлык серенә төшенү. **Аң китү** Бик нык гаҗәпләнү, шаккату, аптырап калу. **Аңына кайту** *к.* **аңга килү.** *Рәхилә, куркынып, күзләрен ачты, башын селкеп куйды, һәм аңына кайту белән башына килгән беренче уй – «ни өчен бу гаделсезлек?» дигән уй булды.* Ә.Еники. **Аңын ачу** Фикерен ачу, аң-белемен үстерү; нәрсәне дә булса аңлатып бирү. *Чын күңелдән укып синең язганнарыңны, Карт көнемдә ачтым тагын да аңым. Ачык күрдем дошманнарымны һәм танып дусларымны.* Ә.Исхак. **Аңын җыю** *к.* **аңга килү.** *Әле дә аңымны җыя алмыйм: синең өскә бомба яуды бит, су һәм саз таулары күтәрелеп капланды.* Ш.Маннур. **Аңын югалту** *к.* **аң җую**

**АҢ** II *с.* Бик сизгер, уяу, бик сак

◊ **Аң бул** Абай бул, исеңдә тот, сизгер, уяу бул (нәрсәне дә булса кисәтеп әйткәндә кулланыла). *Ярый, бар, юлыңда бул! Ләкин, кара аны, аң бул! Бер юлга кичерәм.* Г.Камал. *Дөньяда торырга исәбең булса, аң бул, бала: ничек өйрәнсәң – шуңа китә...* Г.Гобәй. *Аң булыгыз, шундый кешеләргә тап булмагыз, провокацияләргә бирелмәгез, имза куймаска чакырам.* Ф.Сафин

**АҢА** *а.* «Ул» зат алмашлыгының юнәлеш килеш формасы. *Заһит та почмакка посмакчы иде дә, күреп алып, аңа түрдән – гармунчы яныннан урын бирделәр.* М.Әмирханов. *Инәсенең күз яшеннән дә газаплырак нәрсә юк иде аңа бу тормышта.* А.Хәлим. *Ләкин Мишель аңа сөйләп бетерергә бирмәде.* З.Фәтхетдинов

**АҢА́-МОҢА** *җый. и.* Һәрбер нәрсә, теләсә кем, теләсә нәрсә; вак-төяк. *Поездда ул аңа-моңа игътибар итмәде, юл буе бәйрәм итеп кайттылар, башкасына вакыт калмады.* М.Әмирханов

◊ **Аңа-моңа карамастан** Бернәрсәгә дә карамыйча, бөтен кыенлыкларны да җиңеп. **Аңа-моңа карамыйча** *к.* **аңа-моңа карамастан**

**АҢАР** *а. к.* **аңа.** *Хәер, Борһан белән Мәдинә дә аңар әллә ни әһәмият бирмәделәр.* М.Хәсәнов. *Менә ул тагы өйләнә, тагы аңар шул вакыттагы кеби кызык, күңелле була...* Г.Исхакый. *Газизә кайда? Әнә ул теге якта, кухняда аш пешерүче хатын янында, аңар булыша, сөенеченнән дөньясын оныткан, әнкәсе янына да килми: ашлар әйбәтрәк булсын, ди торгандыр.* Ш.Камал

◊ **Аңар Себер ни**, **Сембер ни** Бернәрсә турында да уйламый (башбаштакланып, закон бозучылар турында әйтелә)

**АҢАРГА** *а. к.* **аңа**. *Сыер дигәнең бик ахмак нәрсә бит ул, яхшылыкны белми, аңарга ашарга гына булсын; корсак өчен кырык мәртәбә үләргә әзер.* Һ.Такташ

**АҢАРДА** *а.* «Ул» зат алмашлыгының урын-вакыт килеше формасы; кемдә дә булса, ул кешедә. *Кабул итсә табигате кешенең, Калачак тәрбия эзе аңарда.* Ә.Исхак. *Өлкәннәр кушканны үти алса, бала үзе дә куана һәм киләчәктә дә шулай булырга тиешлегенә төшенә, аңарда кушканны үтәү теләге тәрбияләнә.* Өегез ямьле булсын

**АҢАРДАН** *а.* «Ул» зат алмашлыгының чыгыш килеш формасы; ул кешедән, ул әйбердән. *Аннары Илфатның хезмәттәшләре, эшкә аңардан өйрәнгән яшь механизаторлар котлау сүзе әйтте.* Б.Камалов. *Алдан сөйләшеп билгеләнгән көнне Муса юлга чыкты, Берлиндагы иптәшләре аңардан ике көн соңрак кузгалырга тиеш иде.* Ш.Маннур. *Җитмәсә тагын халык та, аңардан нәрсәдер көткән, ни булса да өмет иткән кебек, тынып калды.* М.Хәсәнов

◊ **Аңардан кышын кар сорап ала алмассың** Үтә дә саран кеше

**АҢА́РЧЫ** *рәв.* Аңа кадәр, билгеле бер вакытка яки вакыйгага чаклы. *Мәҗит аңарчы бер өйләнгән булган инде.* Р.Төхфәтуллин. *Аңарчы мин командующийга эшелоннар турында сведение тапшырып өлгерәм.* К.Нәҗми. *Аңарчы бераз ял итеп алабыз.* Р.Сибат

**А́Ң-БЕЛЕМ** *җый. и.* Тулаем, гомумән белем, гыйлем. *Бала-чагага аң-белем бирүчене кем ялганласын инде, йә?* Хәйдәр. *Алай гына да түгел, авыл яшьләренә үзләренең эчке дөньясын, аң-белем дәрәҗәләрен үстерү шартларын булдыру кирәк иде.* Г.Кашапов. *Гомумән, бала чактан авыр хезмәт белән үсеп, яшьтән аң-белемгә тартыла ул.* Т.Нәҗмиев

**А́Ң-БЕЛЕМЛЕ** *с.* Укымышлы, аң-белемгә ия булган

**АҢГА́РМАСТАН** *рәв. диал.* 1) Искәрмәстән, искәрмичә; абайламаганда, сизмәгәндә

2) Аңлап, белеп, төшенеп җиткермичә, ныклап, яхшылап уйламыйча

**АҢГА́РМЫЙЧА** *рәв. диал.* 1) Искәрмичә, сизмичә

2) Аңлап, белеп җиткермичә, яхшылап уйламыйча. --- *баздан каймаклап катык салып алып менгән дә караңгыда Мокытка сузган. Сузган да шаяртып: – Мә, тык! – дип, кулына кашыгын тоттырган. Мокыт, аңгармыйча: – Ә, мәтыкмыни? – дип, бу нindiдер бер ят аш бирделәр дип уйлап, кашык белән, алдына алып ашарга тотынган.* Н.Исәнбәт

**АҢГАРТУ** *ф. диал.* 1) Төрле ишарә, киная белән нәрсә булса да, ничек булса да сиздерү, кисәтү

2) Аңлату. --- *бик күбесенең йөзләре, төсләре тирән мәсьәлә чишүгә юнәлделгән уйлаучылык, җитдилек аңгарта иде.* Ш.Камал

**Аңгарта бару** Акрынлап, берсе артыннан икенчесен аңгарту

**Аңгарта төшү** Бераз аңгарту

**Аңгартып бирү** Аңларга ярдәм итү. *Ул хәлфәсенең рәсемле китапларын иптәшләренә күрсәтә, белгән җырларен аларга аңгартып бирә.* Ак юл

**Аңгартып йөрү** Һәрберсенә, булган берсенә аңгарту

**Аңгартып тору** Һәрвакыт, гел аңгарту

**Аңгартып үтү** Тиз генә аңгарту; сүз арасында аңгарту

**АҢГАРУ** *ф. диал.* 1) Абайлау. *Без аңгарып та өлгермәдек.* Ә.Айдар

2) Аңлау. *Ашаган саен тәмле тоелган, алай да нәрсә ашаганын*

*аңгармаган, бу – «мәтык» дигән аш икән, дип, күңеленә салып куйган.* Н.Исәнбәт. – *Әби, --- мин бит син укыганнарны аңгарам, – дидем.* Ак юл

**Аңгара бару** Торган саен ныграк аңгару; һәрберсен аңгару

**Аңгара төшү** Берникадәр, бераз аңгару

**Аңгарып алу** Тиз арада, шунда ук аңгару

**Аңгарып бетерү** Барысын да тулысынча аңгару. *Шунысын гына аңгарып бетерә алмыйм, Ганыс, син – кала кешесе, өс-башың да авыл егетләренекеннән аерылып тора, чәч дисеңме, сакал дисеңме, кыланыш дисеңме... Машинаң дисеңме, «Чемердес»ме әле?* Р.Батулла

**Аңгарып җитү** Ахырына кадәр, тиешенчә аңгару. *Бу вакытка кадәр язылганнар йөз мәртәбә, мең мәртәбә язылса да, һәмишә аз, һәмишә җитми, һәмишә халык аңгарып җитә алмый.* Г.Камал

**Аңгарып калу** Кинәт аңгару, аңгарырга өлгерү

**Аңгарып тору** Әле, хәзерге вакытта барысын да аңгару

**АҢГЫ́-МИҢГЕ** *с.* **1**. 1) Аңгыра, юләр сымак, тинтәк, сантый, миңгерәү. *Аңгы-миңге башына Габдуллалар белән сөйләшүе искә төште.* Р.Сибат

2) Ярым уяу, йокылы-уяулы яисә һушсыз, аңсыз

**2**. *рәв. мәгъ.* 1) Аңгыра, тинтәк кебек, шундый рәвешле. *Берсендә шулай, аңгы-миңге килеш, лапаска килеп кергән иде.* Р.Сибат

2) Йокылы-уяулы хәлдә, берни дә уйлый, аңлый алмыйча

◊ **Аңгы-миңге булу** *к.* **аңгы-миңге килү**. *Аңгы-миңге булмасам, трактор чанасыннан да егылмас идем мин.* А.Вергазов. **Аңгы-миңге йөрү** *к.* **аңгы-миңге килү**. **Аңгы-миңге килү** Аңгыра сымак, һични уйлый алмаслык бер хәлдә булу. *Төне буена клубта утыралар да, аннан ары көн буена аңгы-миңге килеп йөриләр.* Г.Камал. **Аңгы-миңге яту** *к.* **аңгы-миңге килү**. *Шулай аңгы-миңге ята торгач, чынчынлап йокыга киткәнлегемне сизми дә калганмын.* Н.Фәттах

**АҢГЫРА** *с.* **1.** 1) Аңсыз, надан, ахмак. *Җинаятьчене бервакытта да аңгырага санарга ярамый.* Р.Мөхәммәтҗан

2) Акылга тулы булмаган, акылга зәгыйфь. *Биби – Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.* Г.Камал. *Хөсниҗамал Мохтарны, бөтенләй тиле, аңгыра кешеме әллә, дип тә исәпләп алды.* Ш.Камал

**2.** *и. мәгъ. тирг.* Тинтәк, ахмак, сантый, юләрбаш

◊ **Аңгыра байгыш** *к.* **аңгыра баш**. *Ник мин шулхәтле аңгыра байгыш, шундый да беркатлы тинтәк булдым икән?* Ш.Маннур. **Аңгыра баш** Томана, аңгыра кешегә карата хурлап, кимсетеп әйтелә. **Аңгыра бәрән** *к.* **аңгыра баш**. *Менә бит, аңгыра бәрән, шуны да күрми!* Г.Бәширов. **Аңгыра катык** *сөйл.* Булдыксыз кеше. **Аңгыра күке** *к.* **аңгыра баш. Аңгыра сарык** *к.* **аңгыра баш. Аңгыра тавык** *к.* **аңгыра баш. Аңгыра ябалак** *к.* **аңгыра баш.** *Әй аңгыра ябалак, матур булмагач, мин сиңа китерәмме соң аны!* Г.Камал

**АҢГЫРАЙТКЫЧ** *с.* Аңгырайта, миңгерәүләтә торган. *Кайбер үсемлекләрнең составында аңгырайткыч матдә була*

**АҢГЫРАЙТУ** *ф. сөйл.* 1) Миңгерәүләндерү, аңны-исне югалттыру, аңгы-миңге хәлгә китерү

2) Аптырату, туйдырып бетерү, нәрсә дә булса сорап йөдәтү. *Аннары урамны, андагы коены, аның капкачын кем килеп рәтләргә тиешлеген сорап аңгырайтты*. Т.Нәҗмиев

**Аңгырайта төшү** Бераз аңгырайту

**Аңгырайтып бетерү** Бик нык, тәмам аңгырайту. *Бу көннәрдәге уйлар өермәсе Мансурның баш миен тәмам аңгырайтып бетерде*. Г.Галиев

**Аңгырайтып җибәрү** Азга гына, кинәт аңгырайту

**Аңгырайтып тору** Вакыт-вакыт яисә гел аңгырайту

**АҢГЫРАЛАНДЫРУ** *ф. сөйл. к.* **аңгырайту**

**АҢГЫРАЛАНУ** *ф. сөйл.* Аңсызлану, аңгыра хәлгә килү, миңгерәүләнү

**Аңгыраланып бетү** Бик нык аңгыралану; тәмам аңгыралану. *Тәмам аңгыраланып беткәнмен икән!* Х.Камалов

**Аңгыраланып җитү** Бик нык, тәмам аңгыралану

**Аңгыраланып йөрү** Кешеләр алдында аңгыралык күрсәтү, нәрсә эшләгәнен белмәү. *Кара аны, аңгыраланып йөрмә*. Д.Бүләков

**Аңгыраланып калу** Кинәт аңгыралану; берникадәр вакытка аңгыралану. *Хәзер дөнья буталып, җирнең асты-өскә килгәч, язмыш арбасы тагын, дөбердәп, егетне таптап үткәч, ул исәнгерәп, аңгыраланып калды*. А.Гыйләҗев

**Аңгыраланып китү** Берәр төрле сәбәп белән кинәт аңгыралану; азга гына аңгыралану. *Ишеткән хәбәрдән аңгыраланып китү*

**Аңгыраланып тору** Бераз вакыт аңгыралану халәте кичерү. *Беркавым аңгыраланып торганнан соң, көч-хәл белән кайтарып сорый алдым: – Ки-яүгә чыкты?* Н.Әхмәдиев

**АҢГЫРАЛАТУ** *ф.* Аңсыз итү, аңгыра хәлгә китерү, миңгерәүләтү. *Өч мәхәлләдә икешәр хатынлы өч мулла халыкның башын тәмам аңгыралаткан.* Казан утлары

**Аңгыралатып бетерү** Бик нык, тәмам аңгыралату

**АҢГЫРАЛЫК** *и.* Аңгыра булу. *Дәрдемәнд сүзләре аша безне аңгыралыкта гаепләп ташлады.* Ф.Сафин. *Турыдан-туры «ахмак» дип әйтергә кирәк иде миңа. Һәм, ахмаклыгын, аңгыралыгын исбатлап, тиз генә чыгып китәргә иде.* Т.Миңнуллин

**АҢГЫРАЮ** *ф.* Миңгерәүләнү, билгеле бер вакытка аңлау сәләтен югалту. *Нәрсә булганын белми, аңгыраеп, шактый яттым.* Т.Миңнуллин. *Ирексездән, В.Гюго сүзләре исемә төште: «Мохтаҗлыкның мәгълүм бер баскычында, – ди Гюго, – фәкыйрь кеше шул дәрәҗәдә аңгырая ки, ул инде үзенең газаплы тормышыннан зарланмый һәм яхшылык эшләүчегә рәхмәт тә әйтми».* М.Мәһдиев

**Аңгыраеп бетү** Тәмам аңгыраю

**Аңгыраеп йөрү** Озак вакытлар дәвамында аңгырайган халәттә булу. *Ә безнекеләр, телеграмманы тотып,*

*аңгыраеп йөргәннәр.* Т.Нәҗмиев. *Болай аңгыраеп йөрсәң, гомергә дә кибетче дәрәҗәсенә үсеп җитә алмассың.* Г.Каюмов

**Аңгыраеп калу** Кинәт, берәр көтелмәгән хәлдән аңгыраю. *Моңа каршы ни дияргә дә белмәде Гафур, җавап сүз таба алмыйча аңгыраеп калды.* Ж.Рәхимов

**Аңгыраеп китү** Кинәт, азга гына аңгыраю

**Аңгыраеп тору** Билгеле бер вакытка гына аңгыраю. *Ялгыз озынборын --- машина кабинасына яисә кызавына килеп куна, әмма аннан мазут белән бензин исе генә аңкыгач, аңгыраеп тора да --- тагы каядыр китеп югала.* Р.Сибат

**Аңгыраеп утыру** Әле, хәзер аңгырайган хәлдә булу. *Игорь, беравык, исенә килә алмый аңгыраеп утырды.* С.Шәмси. *Юк, башыма күсәк төшеп, ангыраеп утырам.* Ф.Бурнаш

**Аңгырая язу** Чак кына аңгыраймый калу. *Килен булып килгәч, Моназыйрның шундый начар гадәтен белеп, бер тапкыр аңгырая язган идем инде.* М.Хуҗин

**АҢДА́У** *ф. диал. к.* **андау**. *Аңдып кына йөргән каргалар бернечә чебешне тибеп тә өлгергәннәр.* М.Гафури

**АҢДАШ** *и.* Бер үк төрле фикердәге, уртак уйдагы кеше; фикердәш. *Бу – синдәме, шигърият, сүз пәйгамбәре тарафыннан сайланган кандаш, аңдаш, моңдаш сүзләрнең илаһи бердәмлегә: думбра, кубыз, саз, гөслә кыллары чиртеп, тормыш-хәят хакында тәүлекләр буена, кабатланмыйча, җыру әйткән чәчәннәрнең тиңдәшсез тапкырлыгы?* М.Галиев

**АҢДУ** *ф. диал. к.* **андау**

**АҢДЫРУ** *ф. иск.* 1) *диал.* Күзәтү, сагалау

2) Искә төшерү, теге яки бу сыйфаты белән нәрсәне дә булса хәтерләтү, хәтергә төшерү. *[Лиза:] – Хаечка, закройся, вон мусульманин идёт, – дип аңдырудан кире тормый вә үзенең бу эшен дустының дин тойгысын хөрмәт итүдән килә дип уйлый иде.* Ф.Әмирхан. *Аның үзе дә, сүзе дә, йөзе дә, күзе дә миңа әллә нинди авыр суыкны аңдыралар.* Г.Ибраһимов. *Күксел урманнар еракта әллә ниләр аңдыра.* Н.Исәнбәт

**АҢДЫШУ** *ф. иск.* Берсе-берсен күзәтеп тору. *Аңдышкан – авылдаш булмый, исәпләшкән – дус булмый.* Мәкаль

**А́Ң-ЗИҺЕН** *җый. и.* Аң һәм зиһен, акыл, фәһем, фикерләү сәләте. *Чөнки бу сүзләр минем туган телемнән яралмаган, тән күзәнәкләремне, аң-зиһенемне балачагымнан сугарып килмәгән.* М.Галиев

**АҢКА́У** I *ф. диал.* Искә төшерү, аерым бер сыйфаты белән нәрсәне дә булса хәтерләтү, хәтергә төшерү

**АҢКА́У** II *и. анат.* Авыз куышлыгының өске ягы, өске өлеше, стенасы. *Ирекнең теле аңкавына ябышты, түзә алмаслык булып, тамагы кипте.* Ф.Садриев. *Аның теле, тибрәнә дә алмыйча, аңкавына ябышты.* Г.Гобәй

**АҢКА́У** III *и. иск.* Миңгерәү, зиһенсез, аңгыра. *Аңкау аңламас, үзсүзле тыңламас.* Мәкаль

**АҢКАУЛЫК** *и. иск.* Аңгыралык, зиһенсезлек, миңгерәүлек. *Үзеңдә – ялкаулык, Хатыныңда – аңкаулык, Кайда кышка азык, Ачлыктан сакларлык?* Г.Тукай

**АҢКУ** *ф.* 1) Бик көчле рәвештә бөркелеп тору, чыгу, таралу (ис турында). *Абзар эче ярым караңгы, җылы тирес һәм сөт исе аңкый.* Ә.Еники. *Яшереп торасы юк, җанга тансык ис аңкый төтеннән.* Ф.Сафин. *Киемнән әле һаман да морфий, хлор, палата исе аңкый иде.* Р.Хисмәтуллин. *Чаттагы «Икмәк» кибете ишегеннән аңкып чыккан яңа ипи исе, Садрыйның ашыйсын китереп, киңәйгән борын тишекләрен кытыклады.* Л.Лерон

2) *күч.* Бик көчле сизелү, әллә каян ук беленеп, аңлашылып тору (хисләр, кичерешләр турында). *[Лилия:] Яшьлек аңкый аннан, яшьлек.* Д.Салихов

3) *күч.* Нәрсәгә дә булса хас билгеләр чагылу. *Музей эчендә рыцарьлар рухы аңкый.* Г.Гали. *Әмма һавада инде яз исе аңкый, урам-тыкрык чатларында беренче су тибеп чыга, кар көртләре күз алдында чүгеп-кечерәеп баралар.* Р.Мирхәйдәров

**Аңкый башлау** Аңкырга тотыну, сизелү, тоелу. *Мичкә куелган чуеннан, тәмле булып, ит исе, аңа кушылып, төрле ярмалар салып пешерелгән өйрә яки борчак исе, яисә кәбестә исе аңкый башлый.* Р.Таҗетдинов

**Аңкый төшү** Бераз аңку

**Аңкып калу** Һаман да аңку, берникадәр аңкып тору. *Ә кабинетта ул калдырган, бары аңа гына хас татлы, исерткеч ис аңкып калды.* Х.Хәйруллин. *Аркасындагы торыпшадан балык исе аңкып калды.* Ш.Галиев

**Аңкып китү** Кинәт аңку, әледән-әле аңкып тору. *Төтен диңгез ягына авышкан арада, ташландык кабырчыклардан тарала торган авыр ис аңкып китә иде.* М.Юныс

**Аңкып кую** Кинәт кенә, кыска вакытка, аз гына аңку. *Аңкып куйса яңа тоткан балык исе, Чыкта юешләнгән дары исе, Аллабыздан бик үтенеп сораганын Онытa да куя минем ише. Шунда әз-мәз аңкып куйса карлыган да, Бер яшь кыз да күзен кысса... тагын, Рәхәтлеккә чыдый алмый, җаным чыртлап, Үләм инде синдә, туган ягым.* Ш.Гаделша

**Аңкып тору** Бертуктаусыз аңку. *Бу шәһәрдә, гомумән, диңгез һавасы белән кушылып, һәр тарафтан сирень, юкә һәм кәстәнә агачларының хуш исе аңкып тора.* Р.Кәрами. *Әмма авызымнан кичәге Сабантуй «исе» аңкып тора кебек.* Т.Нәҗмиев. *Гади генә киенгән, чәчләрен урталай ачып, иңбашына ак шәл салган урта яшьләрдәге хатынның күзләрендә исә рәсем аша да сагыну, ирен юксыну моңнары аңкып тора.* А.Шамов

**Аңкып утыру** Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында аңку. *Мондый олы бәладән соң бик күп вакыт үтмәгән иде, күрәсең, бүрәнә калдыкларыннан әле дә булса күмер, төтен исе аңкып утыра.* В.Имамов

**АҢКЫ́-МИҢКЕ** *с. сөйл. к.* **аңгы-миңге.** *Сабан туеннан соң да нәкъ бер атна тирәсе аңкы-миңке йөрдем әле.* З.Хөснияр

**АҢКЫ-ТИҢКЕ** *с. диал. к.* **аңгы-миңге**

**АҢКЫТУ** *ф.* 1) Чыгару, тарату, бөркетү (ис турында). *Нindидер сукмакка килеп чыгуга, хуш исләр аңкытып,*

*нарат урманы башланды.* Р.Сибат. *Аларның симез хатыннар шикелле буынтыклы-буынтыклы кисәкләрен кысып бәйләгән сүс баулары гына да әллә нинди исләр аңкыта иде.* Ә.Гаффар. --- *читкә утыртылган резедалар көчле исләре белән юл өстендәге һаваны аңкыталар.* М.Әмир

2) *күч.* Бик нык сиздерү, белдерү (хисләр, тойгылар турында)

**Аңкыта башлау** Аңкытырга тотыну. --- *карасана бу чәчкәләргә, без килгәч, тагын да хушлырак исләрен чәчә, аңкыта башладылар.* А.Таһиров

**Аңкыта төшү** Бераз аңкыту

**Аңкытып алу** Берникадәр вакыт кына аңкыту, аз гына аңкыту. *Гомәр Хәйям генә түгел, үзен шагыйрь санаган һәр акыл иясе шәрабка мәдхия язган. Җәләлетдин Руми да бу кояшлы эчемлекне ят итми, робагыйларында хуш исен аңкытып ала.* М.Галиев

**Аңкытып җибәрү** Кинәт аңкыта башлау

**Аңкытып йөрү** Төрле тарафка аңкыту. *Шактый шулай йөгергәч, Хуш ис аңкытып йөргәч, Кайтыйм, дисәм, төшке ашка, Бәла булды бит башка. Адаштырып та булмый, Алмаштырып та булмый. Бетми генә ислемай.* Ш.Галиев

**Аңкытып кую** Кыска вакытка аңкыту, аз гына аңкытып алу

**Аңкытып тору** Бертуктаусыз аңкыту. *Ул яхшылык аңкытып торган мөлаем күзләре белән залдагы халыкны сөзеп карап чыкты.* А.Шамов. --- *аның тәрәзәләренә элгән зәңгәрлеяшелле шарлары ук кызыктырып чакырып тора, ишегалды чирәмнәренә кадәр алма исе аңкытып тора иде.* Г.Бәширов

**Аңкытып утыру** Әле, хәзер, сөйләү моментында аңкыту. *Кайчакларда ат кояш нуры тулган, чәчәкләргә күмелеп, бал исе, кызган үлән исе аңкытып утырган түгәрәк болыннарга килеп чыкты.* Н.Фәттах

**Аңкытып яту** *к.* **аңкытып утыру.** *Үзенә бертөрле салкынча хуш ис аңкытып яткан йоп-йомшак шул дымсу җир өстендә, әле генә борын төртеп чыга башлаган яшь чирәмдә бер-береңбелән әүмәкләшеп аунау үзе бер рәхәт иде.* Г.Бәширов

**АҢКЫШ** *с. диал.* Аңгыра, миңгерәү, юүләр

**АҢКЫ́Ш-МИҢКЕШ** *с. диал. к.* **аңкыш.** *Шуннан нәселенә бәрде җүләрлек чире бу кавемнең, туган бер бала – аңкыш-миңкеш.* Н.Гыйматдинова

**АҢЛАЕШЛЫ** *с.* **1.** Җиңел аңлашыла торган, буталчык булмаган, гади, ачык, анык. *Бәлки, ул – олыларга гына аңлаешлы, безнең өчен кызыксыз булган четерекле нәрсәкәйдер?* Р.Низамиев. *Газетаның теле кыска, аңлаешлы һәм коры булырга тиеш.* Т.Миңнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Җиңел аңларлык итеп, гади итеп. *Без бик аңлаешлы итеп язарбыз.* Р.Төхфәтуллин. *Без яхшырак төшенсен өчен, остазлар да җөмләләренә татарга гына хас сүзләр кыстырырга, аларны үзгәртебрәк, аңлаешлырак әйтергә тырышалар.* Рифә Рахман

**АҢЛАЕШЛЫЛЫК** *и.* Аңлаешлы булу. *Ике вариантның берсен сайлап алганда, исемнең аңлаешлылык, халык телендә кулланылу дәрәҗәсе, икетеллелек тәэсире исәпкә алынырга тиеш.* Р.Юсупов

**АҢЛАЕШСЫЗ** *с.* **1.** Аңлашылмый торган, буталчык, гади, ачык аңлаешлы булмаган. *Ялкау колагыма аңлаешсыз шигырьләреңне мине ярату хакында түгеллекне аңлар дәрәҗәдә генә.* Р.Рахман

**2.** *рәв. мәгъ.* Буталчык итеп, аңлап булмаслык итеп

**АҢЛАМАМЫШ** *и.* Аңламаган булып кыланганлык. *Мин аңламамышка салынып тордым, Разия да, йокым килде, дигән булып, чыкмаячагын сөйләде.* Ф.Әмирхан. *Бу юлысы хихылдауга юл куярга һичберебез дә батырчылык итмәде. Әмма Әмир генә: – Чеби чыгарганмы? – диде, аңламамышка сабышып.* Ф.Яхин. *Ирек сизә, Мидхәт юри аңламамышка салыша, хәвефле хәбәрне йомшаграк итеп әйтер өчен урау юл эзли.* Р.Мулланурова

**АҢЛА́МАСТАН** *рәв. сөйл.* 1) Белмичә, төшенмичә, аңламыйча. *Сабантуйларында булсам, ул юксыну татлы бер газапка әйләнә, үзем дә аңламастан, гомеремдә бер күргән, дәртле көйләрен тыңлаган скрипкачы мари картын эзлим.* Ф.Латыйпов

2) Көтмәгәндә, искәрмәстән. *Сискәнеп, безнең егет катып кала аягүрә, Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.* Г.Тукай

**АҢЛАТМА** *и.* 1) Нинди дә булса хәл-вакыйганы, билгеле бер мәсьәләне аңлатып, тәфтишләп сөйләп яки язып биргән нәрсә. *Берсен дә яшермичә, тәфсилләп, аңлатма язарга туры килде.* Х.Хәйруллин. *Лия Никифоровнаның бу аңлатмасыннан соң, Ася уйланып калды.* Х.Камалов. *Китик, юкса безгә милициядә, шаһит буларак, аңлатма язып утырырга кирәк булачак.* З.Мәхмүди

2) Билгеле бер мәсьәләгә яки аерым хезмәткә карата бирелгән ачыклау, комментарий. *Җырны җыйнап алучы тарафыннан аңлатма бирелгән, җырларның язылып алу вакытлары, районнары күрсәтелгән.* М.Җәлил // Сүзнең теге я бу мәгънәсен ачыклый торган текст. *Ул теге яки бу сүзне һәм исемне ала да аңа үзенчә аңлатма бирә.* Казан утлары

3) *мат.* Билгеле бер математик мөнәсәбәтне белдерә торган формула

**АҢЛАТМАЛЫ** *с. лингв.* Аңлатма бирелгән, мәгънәсе аңлатылган, мәгънәсе ачылган. *Коръәннең башка басмаларына тел-теш тидерүдән ерак торган хәлдә, без бирегә аның Валерия Порохова тарафыннан эшләнгән урысчага аңлатмалы тәрҗемәсен һәм язучы Рабит Батулланың татарчага шулай ук шәрехле басмасын аерым күрсәтеп үтәр идек.* Ф.Урманче. *Татар теленең аңлатмалы сүзлеге*

**АҢЛАТУ** *ф.* **1.** 1) Аңлатма бирү, төшендерү, нәрсәнең дә булса мәгънәсен, асылын ачып бирү, аңлаешлы итү. *Булган белемне аңлату берни түгел аны.* В.Нуруллин. *Табылды бит җае – күрче, ничек җиңел икән мәхәббәтне аңлатуы!* М.Хуҗин. *Иртән укуга баргач, сугыш бетүен аңлатып, митинг үткәрделәр.* К.Йосыпов

2) Нәрсәнең дә булса сәбәбен, законлыгын ачып бирү, билгеләү. *Бу вакыттагы татар тәнкыйтендә Галим-*

*җан Ибраһимов авазы үзенчә аерылып торды. Ул зур мәсьәләләрне аңлатуда тарихилыкка омтылды.* Х.Госман

3) Теләкне, фикер-ниятне ишарә итү, белдерү. *Нәкъ кирәк мизгелендә генә телдә ярала һәм бары тик үзе генә төшенгән бу сәер ымлыклар өермәсе: «Кузгал. Сәгатең сукты», – дигәнне аңлата иде.* А.Хәлим

4) Сүз, тамга, билге, галәмәт һ.б.ш. турында: чагылдыру, мәгънә белдерү. *Бу караш, ай яктысында булгангамы, нәрсә беләндер хушлашу, аерылышу һәм үкенү төсмерен аңлата иде.* Ф.Садриев. *Кешенең киләсе көннәргә өмете киселү, һәрнәрсәгә, һәркемгә ышанычы бетү, дигәнне аңлата иде мондый чарасыз битарафлык.* Ф.Сафин. *Әгәр дә «песи» сүзенең мәгънәсен япон теленнән тәрҗемә итеп аңлатсак, ул «уч төбеннән ашаучы юлбарыс» булып чыга.* Казан утлары

**2. аңлатып** *рәв. мәгъ.* Ачык аңлаешлы итеп, аңларлык итеп

**Аңлата бару** Һәрберсен, булган берсен аңлату. *Булат --- һәр рәсемне берничә сүз белән генә аңлата барды.* Б.Камалов

**Аңлата башлау** Аңлатырга тотыну. *Чая Васил*ә*, урыс сүзләрен юри бозабоза, кияү мунчасының ни икәнен аңлата башлады*. Р.Батулла

**Аңлата төшү** Тагын да аңлату, бераз аңлату

**Аңлатып алу** Тиз генә аңлату, артык тәфтишләп тормыйча гына аңлату. *– Яшьләрне саклап ял иттергәннәр, – дип аңлатып алды Әбүзәр абзый.* З.Фәйзи

**Аңлатып бару** *к.* **аңлата бару.** *Кызганыч, үз уй-фигылебезне аңлатып барырга, безнең татарлар чыгара торган русча газетабыз юк.* М.Галиев

**Аңлатып бетерү** Тулысынча, ахырына кадәр аңлату, аңлатуны тәмамлау. *Аңлатып бетерү белән, яңабаштан сорашырга тотындылар*. З.Фәтхетдинов. *Ирек! Нинди бәхет икән ул адәм баласы өчен! Аны тулысынча аңлатып бетерү дә кыендыр, мөгаен.* Н.Хәсәнов. *Туапседан башлап, тимер юл да, автомобильләр магистрале дә диңгезнең ярына терәлеп үтә. Шулай итеп, пассажирлар алдында аңлатып бетерә алмаслык искиткеч манзара ачыла*. Т.Нәҗмиев

**Аңлатып бирү** Аңларга ярдәм итү. *Абзый үз тирәсендә утырганнарга Мотаһирның кайсы авылдан, кем икәнен бер-ике сүз белән генә аңлатып бирде.* Р.Кәрами. *Хәзер аңлатып бирәм үзеңә.* Б.Сөләйман. *Әйт әле син аңа, Ибраһим, аңлатып бир әле үзенә.* А.Шамов. *Казанның үзенә багышланган халык җырлары юк дәрәҗәсендә аз. Бу – аңлатып бирә алмаслык башваткыч.* К.Йосыпов

**Аңлатып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә аңлату. --- *татар белгечләре, галимнәр белән сөйләшә алам, үз фикеремне аларга аңлатып җиткерә алам.* Р.Вәлиев

**Аңлатып йөрү** Һәрберсенә, һәр урында аңлату. *Шуңа күрә, без браконьерны, немецның иң явыз шпионы, дип аңлатып йөрдек.* М.Юныс

**Аңлатып килү** Электән үк, системалы рәвештә аңлату. *Улыма да шулай аңлатып килдем.* Ш.Маннур

**Аңлатып китү** Сөйләм, эш-хәл барышында аңлату; нииндидер урыннан, сүздән соң аңлата башлау. --- *әдәби тел белән диалектизмнар нисбәтен кыскача гына аңлатып китик.* Р.Юсупов. *Кешеләрнең «армия» дигәннәрен аңлатып китәм: армия кешеләргә үз илләрен дошманнардан саклау яисә чит илләргә һөҗүм итү өчен кирәк.* Р.Сибат

**Аңлатып кую** Алдан аңлату, яки тиз генә аңлату. *Гази да бу әмергә буйсынгандай булды. Шулай да кисәтеп, хәлне аңлатып куюны үзенең бурычы итеп санады*. М.Хәсәнов

**Аңлатып тору** 1) Һәрвакыт аңлату, әледән-әле аңлату. *[Мәлс:] Мин ни өчен соңарганымны, кайларда булганымны, нишләп, кем белән аракы эчкәнемне гел аңлатып торам.* Ф.Садриев

2) Әле, хәзерге вакытта аңлату. *Хәер, аның ни дәрәҗәдә кыйммәт икәнен сезгә аңлатып торасы юк.* Р.Ишморат

3) *күч.* Ачык тоелып, күренеп тору, ишарәләү. *Һәрхәлдә, «киләчәк» дигәнең түбәнгә якта түгел, моны «түбән» сүзенең мәгънәсе ачык аңлатып тора*. М.Хуҗин

**Аңлатып үтү** Сүз уңаенда аңлатып алу, артык тәфтишләп тормыйча гына аңлату. *Баш врач нинди температурада дәвалануның шифасы зуррак булуын аңлатып үтә.* А.Вергазов. *Сезгә, кыскача гына итеп, уразаның килеп чыгуы --- турында аңлатып үтәргә булдык.* Ф.Хөсни

**Аңлатып чыгу** Башыннан ахырына кадәр аңлату; бар кешегә дә, һәммәсенә дә берәм-берәм аңлату. *Әнәс, берничә көн буе, әлеге яңа ысулны һәр звенога аңлатып чыкты.* Р.Хисмәтуллин

**АҢЛА́У** *ф.* **1**. 1) Нәрсәнең дә булса мәгънәсенә, асылына төшенү, эчтәлеген ачыклау. *Васиякәем, сез мине берүк аңлый күрегез дә гафу гына итегез.* М.Хуҗин. *Салих, авылга кайту белән, сөйгән кызының өй турына килгән икән – монысын инде һәркем үзенчә аңласын.* К.Кәримов

2) Кемнең дә булса уй-фикерен, ниятен сизү, чамалау, төшенү. *Алар хәзер бер-берсенең хәлен ярты сүздән үк, күз карашыннан ук аңларга өйрәнделәр.* К.Нәҗми

3) Нәрсәне дә булса тану, белү, аның асылына төшенү. *Шулай икән, димәк, бирелә авторның үзенең бүгенге социаль чынбарлыкны аңлау тирәнлеге, аңлау перспективасы үтә мөһим роль уйный.* Казан утлары

4) Чит телдә, икенче бер телдә сөйләгәнне төшенү

5) Бәяләү, тану (кешене, хезмәтне һ.б.ш.). *Галәү мунча салуның, ашлык сугуның мәгънәсе нәрсә икәнене аңлаган кеби булды.* Г.Исхакый. *Миңа ияреп кереп, кают-компаниянең ишеген бикләргә керешкәч кенә, Анастасия Аристарховнаның комсоставка аш биреп торучы буфетчы икәнлеген аңладым.* М.Юныс. *Әгәр дә элекке Үзәк һәм бүгенге Россия парламенты безнең Декларацияне вакытында танысалар, республикабызның, Россия бөтенлеген бозмый-нитми, үз дәүләтчелеген ныгытуга юнәлдерелгән конструктив, демократик алымнарын аңлаган булсалар, референдумның да кирәге калмас иде.* Мирас

6) Уйлау, күз алдына китерү, күзаллау. *Шунсыз [мораль сафлыктан*

*башка] мин аңлаган семьяның бәхетле булуы мөмкин дә түгел.* Г.Кутуй

**2**. **аңлап** *рәв. мәгъ.* Аңлы рәвештә, белгән хәлдә, юри. *Биредә [«Таулар» пьесасында] сурәтләр гомумиләштерә төшеп бирелгәннәр, кешеләр авторның теге яки бу идеясен ачуда чара буларак аны кызыктыралар. Автор моны аңлап шулай ала.* Г.Нигъмәти

**3**. **аңлавымча** *кер. сүз функ.* Минем белүемчә, минем фикерләвемчә. *Гражданин капитан, аңлавымча, ул офицерны Николаевский урамында, чәйханә тирәсендә бәреп екканнар.* З.Фәтхетдинов

**Аңлап алу** Тиз арада аңлау, шунда ук төшенү. *Кемдер, аны аңлап алып, тиз генә балкон ишеген ачты.* Р.Хисмәтуллин. *Аның нәрсә әйтергә теләвен мин шундук аңлап алдым.* Р.Хафизова. *Ара-тирә кырыс йөзе аша ягымлы елмаюын сирпүгә, балалар аны шунда ук аңлап алалар.* К.Йосыпов

**Аңлап бару** Һәрберсен, һәр әйтелгәнне, укыганны аңлау. *Бу китапны шәкерт тә, мөгаллимә үзе дә ярым-йорты гына аңлап барсалар да, аңланган кадәресеннән кирәкле нәтиҗәне чыгару Хәятка артык читен булмады.* Ф.Әмирхан

**Аңлап бетерү** Тулысынча, барысын да аңлау. *Профессор әйткән сүз әллә каз турында, әллә Рәмзинең үзе турында иде, ихлас күңелле егет аңлап бетермәде.* Р.Фәизов. *Бәләкәй чакта барын да ничек аңлап бетерәсең?!* Р.Хафизова. *Сөйләп кенә аңлап бетермәссең, Иң яхшысы – җыру җырлыйм бер.* Л.Шагыйрьҗан

**Аңлап җиткерү** Нәрсәнең дә булса бөтен нечкәлеген аңлау, тулысынча, тиешле дәрәҗәдә төшенү. *Әхмәтсафа әлеге сәяси агартуның үзе өчен үткәрелүен яхшы аңласа да, Рәҗәповның тел төбен аңлап җиткерми иде әле.* Ф.Сафин. *Тарих китапларын мин дә укып-укып карыйм да тик аңлап җиткермим.* М.Хуҗин. *[Миләүшә:] Иптәш авылдан яңа килгән, күп нәрсәләрне аңлап җиткермәве бар.* Д.Салихов

**Аңлап җитү** Тулысынча аңлау, барысын да төшенү. *Мин бу сүзләрнең мәгънәсен әле аңлап җитмәдем ул чакта.* Н.Дәүли. *Сине аңлап җитү өчен дә бит Синең биеклеккә менү кирәк.* М.Мәһдиев

**Аңлап калу** Аңларга өлгерү, аңлауга ирешү. *Шайтанның ничек котыртканын аңлап калу.* М.Миншин. *Өлкәннәрдән Хәлим шуны аңлап калды: Фаяз өйләнгән икән, хатыны – Камышлыныкы.* Хәйдәр. *Аның военком сөйләгәннәрдән ничек тә күбрәкне белеп, аңлап каласы килә иде булса кирәк.* Ф.Хөсни

**Аңлап карау** Аңларга тырышу, аңларга омтылу. --- *күргәннәрен кат-кат хәтереннән кичереп, тегеләй дә, болай да аңлап карарга тырышты.* Ә.Еники

**Аңлап килү** Алдагыларыннан башлап, барын да аңлау

**Аңлап тору** Чынбарлыкта әйтелгәннән башкачарак булуны эчтән аңлау, бик яхшы төшенү, бөтен нечкәлекләре белән аңлау. *Нишлисең бит, якасыннан борып алмый торып, аның инде үз хуҗасының исемен әйтмәячәген болай да аңлап торам.* З.Зәйнуллин

**Аңлый бару** Торган саен нырак аңлау. *Миңзаһит үзе корган ояда төскыяфәте белән ике тамчы су кебек аңа охшаган, әмма эчке омтылышлары, кыланмышлары белән ят җан иясе – «күке баласы» үстерүен һаман тирәнрәк аңлый барды.* Ф.Садриев

**Аңлый төшү** Бераз аңлау, элеккегә караганда яхшырак аңлау. *Инде менә мөдирлектән мәтәлдергәч, ул дөньяны яхшырак аңлый төште.* М.Миншин. *Бүген шундый җитәкчеләр кирәклеген тулырак аңлый төшәм.* М.Вәлиев. *Мин моны соңрак тагын да аңлый төштем.* Н.Хәсәнов

**АҢЛА́ШМАУЧЫЛЫК** *и. к.* **аңлашылмаучылык**

**АҢЛАШУ** *ф.* **1**. 1) Бер-береңне аңлау, төшенү. *Икесе ике телдә сөйләшсәләр дә, уртак сүзләр хисабының уңае белән, алар бер-берсен яхшы ук аңлашалар.* Р.Сибат. *Музыка – аңлашу өчен төп аралашу коралы.* Ватаным Татарстан

2) Уртак фикергә килү, үзара килешү. *Икесенең дә күңелләрен биләп алган куанычтан соң сүзсез генә аңлашу кирәк иде.* Р.Кәрами. *Аңлаша алам, Җайлаша алам, Алдаша алам бик уңай; Инде синсез яшәүгә дә Өйрәнеп киләм бугай…* Р.Рахмани. *Ничекләр сөйләшеп аңлашканнардыр, үткән атнадан бирле Шәмсия Фәтхулла белән кире кушылганнар.* Ф.Сафин

3) Билгеле бер мәсьәләне ачыклау, мәсьәләгә ачыклык кертү

4) Фикер алышу, сөйләшү. *Очрашу, аңлашу бөтенләй көтелмәгәнчә булды.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Иң мөһиме – ике арада әйбәт кенә аңлашу килеп чыкты.* Р.Низамиев. *Аларның гөр килеп, куллары бутап сөйләшкәннәрен, аңлашканнарын авызымны ачып тыңлап торам.* А.Хәсәнов

**2. аңлашып** *рәв. мәгъ.* Килешеп, берләшеп, бер сүздә, бер фикердә булып. *Корткычлык эшендә [Лутов], үзе кебек корткычлар белән аңлашып, дирекциягә, партия эшчеләренә каршы көрәш алып бара.* Г.Нигъмәти. *Без синең белән аңлашып эш итәбез.* Ш.Камал

**Аңлаша бару** Торган саен әйбәтрәк аңлашу

**Аңлаша башлау** Бераз аңлашуга ирешү

**Аңлаша төшү** Бераз аңлашу

**Аңлаша язу** Шактый ук аңлашу, аңлашырга аз гына калу

**Аңлашып алу** Тиз генә аңлашу. *Майя белән сөйләшеп, аңлашып алгач, беренче җай чыгу белән качып китәчәк. Майясы, баласы белән бергә китәчәк.* Г.Гыйльманов. *Элемтәче күз күргән кеше икән, бик тиз аңлашып алдылар.* Х.Камалов

**Аңлашып бетерү** Барын да, ахыргача аңлашу. *Бая син, аңлашып бетердек, дип әйткән идең. Күрәсең, иң кирәге калган ич әле...* А.Гыйләҗев

**Аңлашып бетү** Тулысынча аңлашып килешү. *Инде аңлашып беттек дигәндә генә, кулындагы ишек тоткасын әйләндереп-әйләндереп торган эшем кешеләренең берсе дежур колагына пышылдап өлгерде.* Р.Гаффар

**Аңлашып җитү** Бөтен нечкәлекләре белән, тиешле дәрәҗәдә аңлашу. *Гомумән, сугыш үзе – ул гади хәл түгел, бәлки фәүкылгадә хәл. Ул – дөньяда яшәүче кешеләрнең үзара аңлашып җитмәүләреннән килә торган кыргый бер хәл.* Г.Бәширов

**Аңлашып йөрү** Үзара аңлашкан булу. *Без хәзер бер-беребезне сүзсез генә аңлашып йөрибез.* Н.Дәүли

**Аңлашып калу** Аңлашырга өлгерү. *Берничә көннән армиягә китәсе Сәүбән, сөйгәне Маһитап белән очрашып, аңлашып калырга тели.* Ф.Галимуллин

**Аңлашып карау** Аңлашырга омтылу. *Шул ук вакытта Янтыкка барып, сөйләшеп, аңлашып карарга да көчем җитми, үҗәтлегем ирек бирми.* В.Нуруллин

**Аңлашып китү** Ниндидер моменттан, берәр нәрсәдән, вакыйгадан соң аңлаша башлау. *Сөйләшеп, аңлашып китәргә нәрсәдер җитми.* Г.Гыйльманов

**Аңлашып кую** Алдан аңлашу; тиз арада аңлашу. *Алар инде әллә кайчан аңлашып куйдылар*

**Аңлашып тору** 1) Һәрвакыт, даими аңлашу. *Югыйсә без һаман да бер-беремезнең максудларымызны «тәрҗеман» аркылы гына аңлашып торсак – «милләт» бетте.* Г.Тукай

2) Әле, сөйләү моментында аңлашу. *Әмма минем белән күп сөйләшеп, аңлашып торырга теләүче күренмәде.* Ф.Яхин

**АҢЛАШЫ́ЛМАУЧАНЛЫК** *и. к.* **аңлашылмаучылык.** *Күрүебезчә, бу – җитди каршылык түгел, аңлашылмаучанлык кына.* М.Җәлил

**АҢЛАШЫ́ЛМАУЧЫЛЫК** *и.* Килешеп, берләшеп, бер сүздә, бер фикердә булып эшләмәү аркасында килеп чыккан каршылык; аңлашылмау. *– Минем бит синең янда калуым яшьлектәге ул аңлашылмаучылыкны ачыклау өчен түгел, ә әтием язмышын белергә теләүдән иде, – диде Минзифа.* Р.Сибат. *Ниндидер аңлашылмаучылык туган икән, секретарь председательгә ярдәм итәргә тиеш булачак.* М.Хәбибуллин. *Хуҗа кеше белән дә аңлашылмаучылык килеп чыкса, хәлләр түзеп тормаслыкка әйләнәчәк.* А.Вергазов. *Яңалык борын төртте исә, аңлашылмаучылык башлана.* Казан утлары

**АҢЛАШЫЛУ** *ф.* **1**. Ачыклану, аңга барып җитү, билгеле булу. *Берничә минут сөйләшкәннән соң аңлашылды: Когунский тәрбия буенча командир ярдәмчесе, элекке замполит икән.* Н.Хәсәнов. *– Аңлашылды, – дип, Григорьев аны шунда ук туктатты.* М.Әмирханов. *Укучы, --- Дәүләт Думасы һәм Дәүләт Советы сессияләрендә халык депутатлары чыгышларын ишетеп, еш кына ярдәмчесез кала. Мәсәлән, «эксклюзивный» (исключительный) --- «консенсус» (согласие) дигән терминнар бары тик шушы өлкәдән хәбәрдар булган кешеләргә генә аңлашыла.* Мирас

**2.** *кер. сүз функ.* 1) **аңлашылганча** Билгеле булганча, һәркем белгәнчә. *Әсәрдән аңлашылганча, самими авыл егете Шәфкать тормыш авырлыкларын, яшәү өчен көрәшне ничек алып барырга кирәклеген, армиянең нинди җитди фаҗигаләргә китерергә мөмкин икәнен әле аңлап та җиткерми.* Н.Гамбәр. *Аңлашылганча, аяусыз көрәш өчен барлык шартлар да бар иде.* Ватаным Татарстан

2) **аңлашылса кирәк** Нинди дә булса билгеле, анык, ачык әйбернең дөреслеген, шулай булырга тиешлеген дәлилләп әйтелә; димәк. *Аңлашылса кирәк, йөрәк парәсенә бары изгелек теләгән ата-ана әлеге киңәшләр белән килешә.* Т.Галиуллин

**3. аңлашылмау** *и. мәгъ. юкл. форм. к.* **аңлашылмаучылык**. *Пароходлар төшкәч тә җибәрелгән иген баржалары белән ниндидер аңлашылмау чыккан икән.* Г.Ибраһимов

**Аңлашыла бару** Арынлап, аз-азлап аңлашыла башлау; торган саен ныграк аңлашылу

**Аңлашыла башлау** 1) Бераз, берникадәр аңлашылырга тотыну

2) Башка эчтәлек алу, башкача аңлашылырга керешү. *Соңгы чорда аларның тотемистик мәгънәләре онытылгач, ул образлар кергән санамышлар яшерен эчтәлектәге әсәрләр булып аңлашыла башлаган.* Р.Ягъфәров

**Аңлашыла төшү** Әйбәтрәк аңлашылу. *Алиянең академик ял алуын әйтсәм, безнең хәлләрнең ничек икәнлеге аңлашыла төшәр.* Р.Вәлиев. *--- бая әйтелгән әхлакый бәянең хикмәте тагын да аңлашыла төшсә кирәк.* Ә.Баян

**Аңлашылып бетү** Тулысынча, тәмам аңлашылу. *Бабасы белән әтисенең әңгәмәсе бигүк аңлашылып бетмәсә дә, Айбулатка куркыныч була башлады.* Хәйдәр. *--- башлангыч чор әсәрләренә шактый урын бирелеп тә, атаклы «Кырыгынчы бүлмә» турында бер сүз дә диярлек әйтелмәве аңлашылып бетми.* Р.Фәйзуллин

**Аңлашылып җитү** Бөтенләе белән, тулаем аңлашылу. *Дамирның, Чаллыга китәм, дию аңлашылып җитми бит әле.* Х.Хәйруллин. *Тик миңа бер нәрсә аңлашылып җитми, Габдрахман ага.* Р.Вәли

**Аңлашылып калу** Кинәт кенә аңлашылу, кайсыдыр вакыттан соң аңлашылу, аңлашылырга өлгерү. *Аның ни өчен шулай эшләргә чакыруы соңгы җөмләсеннән ачык аңлашылып кала.* Ф.Галимуллин

**Аңлашылып килү** Бераз аңлашыла башлау

**Аңлашылып китү** Кинәт, көтмәгәндә аңлашылу

**Аңлашылып тору** Ап-ачык булып аңлашылу. *Бригадирның нилектән шулай кәефсез булуы болай да бик яхшы аңлашылып торса да, кинәт кенә аның Тәзкирәне пыр туздырып ташлавы шулай да гаҗәбрәк тоелды.* Н.Фәттах

**АҢЛЫ** *с.* **1.** 1) Фикерләү, уйлау сәләте булган, зиһенле. *Мәнә син, аңлы икәнсең, безнең сүзне тыңла, ата-ана догасын ал.* Ф.Әмирхан. *Күрсәгез иде сез [улымны]: гаҗәп шаян һәм аңлы малай.* А.Шамов

2) Тирәнтен уйлап эш итә торган, төпле фикерле. *Югары аңлы кеше, намуслы, вөҗданлы кеше начар эшли алмый.* Б.Камалов

3) Аңлы рәвештә, акыл белән уйлап эшләнгән. *Үләр алдыннан күрше авылдан кәҗә бәтие алып кайткан Муллаҗан абзый исеменә ятышлы булсын дигәндерме, әллә ирләрне олылыкларга күнеккән, нәсел умырткасы санаган мөселман карчыгының аңлы эше идеме, бу турыда сорарга хәтта Рәшитнең дә уена килмәде.* Рифә Рахман

4) Сәяси аңы үскән, алдынгы, прогрессив карашлы. *Артамонов – күрше рус авылының аңлы кешесе, Мирвәлинең якын дусты.* Т.Гыйззәт. *Әсәрдә Әхмәди шактый аңлы һәм революцион*

*настроениеле эшче итеп бирелә.* М.Гали. *Пролетариатның иң аңлы өлеше үз партиясе сафларында [дошманнарга каршы] көрәште.* Г.Нигъмәти

**2. аңлы рәвештә** *рәв. мәгъ.* Аңлап, белгән хәлдә, күрәләтә, юри. *Бу бит – аңлы рәвештә корткычлыкка бару.* Х.Хәйруллин. *Соңгы вакытларда бу чорны ул аңлы рәвештә борчылу белән көтә башлады.* Ф.Садриев. *Бу мактаулы күренешләр – колхозчыларның, аңлы рәвештә, илгә азык-төлекне күбрәк җитештерергә тырышуларына дәлил.* Казан утлары

**АҢЛЫЛЫК** *и.* Аңлы булу

**АҢСЫЗ** *с.* **1.** 1) Һушыннан язган, аңын югалткан

2) Аңлау, уйлау, фикер йөртү дәрәҗәсе түбән булган

3) Надан, иске, кара фикерле; киләчәкне аңлап, уйлап эш итә белми торган. *Мин, сиңа беренче очраганда, аңсыз идем.* М.Гафури. *Аңсыз кеше булып калмас өчен укыйм.* Ф.Әмирхан. *Бу эштә --- картлар – урталык урынын тотып, ярлы, ләкин аңсыз, эчкече Әхмиләр корал хезмәтен үтиләр.* Г.Нигъмәти

4) Акылы булмаган, акылсыз, аңгыра, юләр, тиле. *Габдулла аңсыз малай түгел иде.* Р.Сибат. *Алар – бик тупаслар, аңсызлар.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Һушсыз рәвештә, аңсыз калып, аңын югалтып

2) Уйлап бетермичә, гамьсез рәвештә; уйламыйча, үзеннән-үзе. *Ул башта – аңсыз рәвештә, бара-тора, аңлап, физкультура белән шөгыльләнә.* Г.Гобәй

**АҢСЫЗДАН** *рәв.* 1) Абайламаганда, көтмәгәндә-уйламаганда, искәрмәстән. *Аңсыздан, атның берсе пошкырып җибәрде.* Ш.Мөхәммәдев. *Аңсыздан, бер көн каты җилләр исте, Үрмәкүчнең пәрәвезен төтен кисте.* Г.Камал

2) Ныклап уйламыйча, механик рәвештә. *Аңсыздан гына кылынган җинаять*

**АҢСЫЗЛЫК** *и.* 1) Аңсыз булу, аңында булмау

2) Томаналык, наданлык, фикерләү дәрәҗәсе түбән булу, аңлап эш итә белмәүчәнлек. *[Энҗебикә:] Кирәк чагында үзеңне аңлый алмаган өчен, син мине аңсызлыкта гаепләргә җыенмыйсыңдыр ич, әтием?* Н.Фәттах

3) *к.* **аңгыралык**

**А́Ң-ТАҢ БУЛУ** *ф.* Гаҗәпләнеп, аптырап калу

**А́Ң-ТАҢ КАЛУ** *ф. к.* **аң-таң булу**

**АҢЫНЧЫ** *рәв. сөйл.* Ул вакытка кадәр, шул вакыт җиткәнче. *Аңынчы инде син тәгаен үзең дә гарипләнерсең.* Ф.Садриев

◊ **Аңынчы булмады** Шул арада

**АҢЫ́ШМАСТАН** *рәв. сөйл. к.* **аңышмыйча**

**АҢЫ́ШМЫЙЧА** *рәв. сөйл.* Аңышып җитмичә, аңлап-төшенеп бетермичә. *Иртәгәсен кара махмырдан уяныт китеп, байтак вакыт үземнең кайдалыгымны аңышмыйча яттым.* З.Хөснияр

**АҢЫШУ** *ф.* 1) Аңлап алу; абайлап алу. *Тракторчы, беразга тукталып, үз хәлен аңышты.* Р.Фәизов. *Әхмәтсафа ул санап киткән нәрсәләрдән, дөресен әйткәндә, бернәрсә дә аңышмады.* Ф.Сафин. *Нидер сизенеп чыккан әнисе, үзе күренмичә генә, ни булганын да аңышмыйча, ишекләрне ачып торды.* М.Галиев

2) Аңлашу, уртак тел табу, уртак фикергә килү. *– Йә, аңыштык ич инде, бетте инде, йә, бетте, – дип, Гүзәлне юата иде.* Г.Гобәй

**Аңыша бару** Торган саен ныграк аңышу; акрынлап, аз-азлап аңышу. *Өлфәтнең күзләре башта түгәрәкләнде, аннан ярык шикелле генә булып кысылды. Аңыша барган саен, авызы ерылды.* А.Тимергалин

**Аңыша башлау** Берникадәр күләмдә, акрынлап аңышу, аңышырга керешү. *Габдулла аңыша башлады: «тавыш» дигәне – Габдрахман бит. Бернинди җен дә, гөрзи дә юк.* Р.Сибат

**Аңыша төшү** Бераз аңышу. *Бераздан, аңыша төшкәч, прокурор өстәл кырыендагы кыңгырау төймәсенә басты.* М.Галиев

**Аңышып алу** Тиз арада, шунда ук аңышу

**Аңышып бетү** Тулысынча, ахырына кадәр аңышу. *Аптыраушта калдырдың, Таифә түтекәем, әйдә, утыр әле, аңышып бетеп кенә булмый бит...* Ф.Сафин

**Аңышып җитү** Тулысынча, тәмам аңышу. *Галияр энекәш, син генә шуны аңышып җитмәсәң инде.* М.Хуҗин. *--- әмма шундый газаплар хакында ул кемгә дә сөйләми, мин генә беләм, хәтта балалар да аңышып җитмиләр иде.* Р.Нуруллина

**Аңышып калу** Аңышырга өлгерү. *Мин аның: «И кодрәтлеләрнең кодрәтлесе – бөек Аллаһ...» – дигән мөрәҗәгатен генә аңышып калдым.* М.Әмирханов

**Аңышып китү** Кинәт аңышу. *– Киткәч? Син кабат китәсең дәмени? --- Кем белән яшәргә миңа, Костя? Әйт, кем белән? – дип сорады аңышып киткәндәй, әмма берни күрмәгән, күзләре томаланган карчык.* Рифә Рахман

**Аңышып тору** Бөтен нечкәлекләре белән, барысын да аңышу. *Их-х, аңгыра баш мин, тормыш агышын аңышып тордым лабаса!* М.Хуҗин

**АО́РИСТ** *и. гр. лингв.* Грек, иске славян һәм кайбер башка телләрдә: фигыльнең тулысынча үткәнгә караган хәрәкәтне яки хәл-торышны белдерә торган үткән заман формасы

**АО́РТА** *и. гр. анат.* Тәннең, үпкәдән кала, барлык әгъзаларын кан белән тукландырып торган, йөрәкнең сул ягыннан башланган иң юан кан тамыры. *Баш миен кан белән тәэмин итүче тамырларга эләксен өчен, аортага контраст матдә кертергә --- кирәк иде.* Ф.Углов

**АП-** *кис.* «А» авазына башланган кайбер сыйфат һәм рәвешләргә ялганып һәм һәрвакыт басымны үзенә алып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган алкисәкчә (*мәс., ап-ак, ап-авыш, ап-арык, ап-ачык һ.б.*). *Карчык укалап тегелгән озын күлмәктән, ап-ак шәл ябынган.* Р.Фәизов. *Ләкин, ни гаҗәп, әлеге «мине дә» сүзен ишек артындагы, ишекнең теге ягындагы Заһидулла ап-ачык ишетә иде.* Р.Сибат. *Бөрлегән суыдай ап-алсу иреннәрең, кызым, кара җиләк, шомырт, карлыган ашап каралып беткән.* Ә.Галиев. *Ишекне тырнавы ап-аермачык ишетелә колагыма.* М.Хуҗин

**АПА** *и.* 1) Үзеңнән олырак яшьтәге кыз туган. *Апаларда, болай, күңелсез*

*түгел иде ул.* Ә.Гаффар. *«Зилә» дип исем белән эндәшү юк, «апам» да «апам» гына.* Р.Хафизова

2) Яше ягыннан сөйләүче кешедән олырак булуны белдереп, хатын-кыз исеменә кушып әйтелә торган сүз. – *Хәлимә апа, ничек соң яшәүләр? – дип сүз башлады Мәрфуга.* Р.Хисмәтуллин. *Кәлбикамал апа тавышы, әкрен генә җылап: – И Туктабай?! И Туктабай?!* Г.Мөхәммәтшин

3) Үзеңнән олырак хатын-кызның һөнәре атамасына кушып әйтелә торган сүз. *Гаскәрләребезнең шәһәрләрне калдырып чигенүләре турындагы хәбәрләрне карт бабайлар, колхозчы апалар --- тешләрен кысып, йодрыкларын йомарлап тыңлыйлар.* Р.Хафизова

4) Гомумән олы яшьтәге хатын-кызга мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе. *Малай, атылып, ишек янына бара. – Апа-у! – Нәрсә бар? – дип сорый кырыс тавыш.* А.Гыйләҗев

**АПАЙ** *и. диал.* 1) *к.* **апа**. *Апайларга да актив көрәштә бил алышу җиңел булмагандыр.* М.Хуҗин

2) Үзеңнән кечерәк яшьтәге ир яки кыз туган. *[Әбием] Мунча тирәсендә кайнашкан җиреннән кисәктән генә туктап өйгә кереп китте, апайны уятты.* А.Хәсәнов

3) **апаем** *тарт. форм.* Үзеңнән кечерәк яшьтәгеләргә мөрәҗәгать итү сүзе. *Әйе, башкорт мин, апаем, паспортым да башкорт.* В.Имамов. *Солтангәрәй апаем, тагын ни турында сөйләшик соң без?* А.Гыйләҗев

**АПАКАЙ** *и.* **1**. Яратып, иркәләп эндәшү сүзе. – *Чәйләрегез тәмле булсын, апакайлар! – дип, күңелле эндәште бер егет.* Д.Бүләков. *Әткәй миңа Мәкәрҗәдән, апакай, бүләк итеп башмак алган, җизнәкәй!* Т.Гыйззәт. *[Гөлнур:] – Их, Мәдинә апакаем! – ди ул, кинәт канатланып.* М.Хәсәнов

**2**. **апакаем** *ы. мәгъ.* Гаҗәпләнүне, шаккатуны, ышандыруны, үтенүне, сискәнүне һ.б.ш.ны белдереп әйтелә. – *Әй, баскан җирдән ут чыгарабыз инде анысы, апакаем! – дип, сүзгә дерт кабынды Халисә.* М.Хуҗин. *Апакаем, күзләремә ышанмыйм. Нинди җилләр белән син бу якларда?!*

◊ **Апакай гынам** *к.* **апакаем.** *Берсен дә калдырмыйлар, апакай гынам.* У.Шекспир

**АПАЛЫ́-СЕҢЕЛЛЕ** *рәв.* Апа белән сеңел, апа белән сеңел бергә; апа белән сеңел кебек. *Юк, Рабига белән Җамал һич кенә дә апалы-сеңелле бертуганнар була алмый.* Ф.Сафин. *Алар белән дә, Аллага шөкер, апалы-сеңелле кебек яшибез.* Мин сине ничек яраттым

**АПАЛЫ́-ЭНЕЛЕ** *рәв.* Апа белән эне, апа белән эне бергә; апа белән эне кебек. *Апалы-энеле, икәүләшеп, бакчага керделәр.* А.Гыйләҗев. *Алар, апалы-энеле, һәр эшне бергәләп башкарырга тырышалар иде.* Х.Камалов

**АПАРА** *и.* 1) Суга он, чүпрә кушып изелгән камыр; камыр башы. *Аны [аулыкны] артка каерып бәйләп, коштабакта апара бутый.* А.Хәсәнов

2) Малларга эчерү өчен, суга он кушып әзерләнгән сыек боламык. *Апара ясаучы абзый да төшеп калганнардан түгел.* Т.Нәҗмиев. *Минем сыерларым шунда ук дәррәү күтәрелеп, тәмле апараны чөмерә башладылар.* Г.Мөхәммәтшин

3) *күч.* Тәмсез, сыек яки куерып изелгән (озак кайнаудан) аш. *Аш пешерсә – апара, бите-кулы кап-кара.* Мәкаль

◊ **Апара корсак** *мыск.* Зур корсаклы, күп һәм талымсыз ашый торган кеше турында. *Хафиз киткән ил буена, илдән хәер сорарга, Хафиз бүкән, апара корсак, илдән хәер сорарга.* Г.Камал. **Апара мичкәсе** *мыск. к.* **апара корсак**. *Җае чыккан саен «апара мичкәсе» дип ычкындыргаласа да, үз иренең бәясен бик яхшы белә иде ул.* Г.Кашапов. **Апара чумары** *мыск.* Булдыксыз, оешмаган

**АПАРТАМЕНТ** *и. фр.* 1) Берничә бүлмәдән торган иркен һәм зиннәтле бина. *Кайберләре үзләренә апартамент төзергә кызыга.* Ф.Садриев

2) *күч. шаярт.* Теләсә нинди торак, тору урыны, өй, квартира. *Алар шунда, кунакханәнең берәр номерында яки Дантесның үз апартаментларында тәүлекләр буе кәрт сугалар.* Р.Мирхәйдәров

**АПАРТЕИД** *и. ингл. махс.* Расадан чыгып, халыкның көнкүрешен, сәясәтен һәм икътисадын чикләү сәясәте; кара тәнлеләрне ак тәнлеләрдән аеру сәясәте. *Германиядәге фашизмны, Африкадагы апартеид режимын һәм кайбер илләрдә таралган сионизмны бу күренешкә мисал итеп күрсәтергә мөмкин.* А.Низамов

**АПАРТЕИДЧЫ** *и.* Апартеид тарафдары

**АПАТИТ** *и. гр. махс.* Кальций фосфаты; фосфорлы ашламалар әзерләүдә кулланыла торган минерал

**АПАТИТЛЫ** *с.* Составында апатит булган, апатит белән катнаш

**АПА́ТИЯ** *и. гр.* Битарафлык, ваемсызлык, дәртсезлек; күңел төшенкелеге. *Салкын битарафлык, исәп-хисап, апатия каян килә хәзерге активлык һәм тизлек заманында?* Казан утлары

**АПАШ** *и. фр.* **1**. 1) Франциядә: карак, угры, жулик

2) Киң, ятма, төймәсез яка; шундый якалы күлмәк. *Яңа апашиемның сынып-сынып торган бөкләм эзләре бетсен дип, кроватька ятып аунадым.* М.Әмир

**2**. *с. мәгъ.* Киң, ятма, төймәсез (яка яки шундый якалы күлмәк турында). *Ак апаш күлмәк*

**АПЕЛЛЯЦИОН** *с.* Апелляциягә караган, апелляциягә мөнәсәбәтле

**АПЕЛЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *юр.* Суд карарыннан риза булмыйча, югары суд органына язылган шикаять. *Утыз тугызда партиядән төшерелгәч, йомшап калды ул. --- Апелляция белән дә йөрмәде.* Х.Камалов

2) *кит.* Ярдәм, киңәш сорап, кемгә дә яки кая да булса язылган мөрәҗәгать. *Шуннан соң КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Партия контроле комиссиясенә апелляция бирдем.* Р.Вәлиев

**АПЕЛЬСИН** *и. голл.* 1) Цитруслар семьялыгыннан, мәңге яшел җимеш агачы, әфлисун. *Минзөфәр апельсин агачының чәчәк бөреләренә карап сокланды.* Н.Хәсәнов

2) Шул агачның кызыл сары төстәге, түгәрәк яки озынча формадагы, калын кабыклы, эче сусыл өлешләрдән торган баллы җимеше. *[Ирек] Кызына алып кайткан курчагын сузды, өстәлгә торт, алма, апельсин куйды.* Ф.Садриев

**АПОГЕЙ** *и. гр.* 1) *астр.* Ай орбитасының яки Җирнең ясалма иярченнәре орбитасының Җир үзәгеннән иң ерак ноктасы; *киресе:* **перигей**

2) *кит.* Иң югары нокта, иң югары баскыч. *Менә шунда ул үзенең апогеена күтәрелде.* Ф.Садриев

**АПО́КОПА** *и. лингв.* Сүзнең соңгы бер яки берничә авазы төшеп калу күренеше (мәс., *кайта алмады – кайталмады*). *Язма истәлекләр телендә позицион үзгәрешләр: апокопа, протеза, синкопа күренешләре.* Ф.Нуриева

**АПО́КРИФ** *и. гр.* Библия сюжетларына нигезләнеп язылган, әмма, бик үк төгәл һәм ышандырырлык булмаганга күрә, рәсми чиркәү тарафыннан инкяр ителә торган әсәр

**АПОЛИТИЗМ** *и. фр.* Сәяси мәсьәләләргә карата битарафлык, гамьсезлек

**АПОЛИ́ТИК** *с.* Сәяси мәсьәләләрдә битараф, гамьсез; иҗтимагый-сәяси тормышта катнашмаган

**АПОЛОГЕТ** *и. гр. кит.* Кемне яки нәрсәне дә булса яклап чыгучы, мактаучы кеше. *Анда иске җәмгыятьне тәнкыйтьләү --- аның «гомумиләштерелгән» вәкилләрен һәм апологетларын утлы табага бастыру линиясе буенча да бара.* Казан утлары

**АПОПЛЕ́КСИК** *с.* Апоплексиягә нигезләнгән, апоплексиягә мөнәсәбәтле

**АПОПЛЕКСИ́Я** *и. гр. мед. иск.* Нинди дә булса әгъзага тиз вакыт аралыгында кан саву күренеше. *Полиция табибы, --- мәетне өстән-өстән генә карап, хезмәтченең, аракыны гадәттән тыш дәрәҗәдә күп эчеп, апоплексия сугудан үлүен язып, мәетен җирләргә рөхсәт бирде.* К.Насыйри

**АПОРТ** I *и. гр.* 1) Алмалары соң өлгерә торган алмагач сорты

2) Шул агачның эре, әчкелтем баллы сусыл алмасы. *Тирә-якка шулкадәр тәмле алма – апорт алмасы исе таралган иде.* Р.Мирхәйдәров

**АПОРТ** II *и. фр.* Өйрәтелгән, күнектерелгән этләр өчен «алып кил» дигән команданы аңлата торган сүз. *Башта сөяк кисәген атып бәреп, «Апорт, Бүләк, апорт!» дип кычкырырга тотынган идек, Бүләк колак очын да селкетмәде.* Г.Мөхәммәтшин

**АПОСТРОФ** *и. гр. лингв.* Хәрефләр арасында аеру билгесе (ь һәм ъ) барлыгын белдерә торган яки төшеп калган сузык хәреф урынына куела торган (мәс., гарәп телендә) өтерсыман тамга

**АПОФЕОЗ** *и. гр. махс.* 1) Спектакльнең яки бәйрәм концерты программасының күп халык катнашында йомгаклау тантанасы

2) Берәр күренешнең иң нык үсеш алган, иң нык чагылган чоры, иң югары ноктасы. *Казан ханлыгының канлы апофеозы.* М.Галиев. *Сугыш апофеозы*

**АППАГЫМ** *и. тарт. форм. сөйл.* Бик яратып, иркәләп эндәшү сүзе. *Менә шулай, аппагым: егетнең кияү булып йөриселәре бар әле.* Р.Сибат. *Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, аппагым?* Р.Төхфәтуллин. *[Ире хатынына:] Аннары үзеңне кызганам, каты-коты белән интегеп, эчеңә язва-фәлән булып куймасын, аппагым.* Р.Хисмәтуллин

**АППАРАТ** *и. лат.* 1) *тех.* Билгеле бер эш башкару өчен махсус механик җайланма, әсбап. *Сыерларның улакка туралган чөгендерне шытырдатып чәйнәве, савымчыларның, резин итекләрен юеш сайгак буйлап лыштырдатып, саву аппаратларын әзерләп йөрүләре күзгә чалынып калды.* А.Вергазов. *Йөри торгач, --- фотосурәткә төшәргә булдык. Аппаратыбыз үзебез белән иде.* Т.Нәҗмиев. *Комсомол секретаре ике-өч тапкыр аппаратын чыртлатып алды.* Р.Кәрами

2) Организмда берәр аерым функцияне үти торган әгъзалар җыелмасы. *Акустик яктан бары тавыштан гына торучы, әйткәндә, һава агымының сөйләм аппараты аша тоткарлыксыз үтеп китүе нәтиҗәсендә ясалучы, иҗек төзүче авазлар.* Х.Сәлимов

3) Нинди дә булса өлкәнең идарә итү органнарына яки хуҗалык тармагына хезмәт күрсәтә торган оешмалар җыелмасы; шундагы хезмәткәрләр. *Республика профсоюз аппаратында эшләүчеләр дә андый үтенечләр белән еш мөрәҗәгать иттеләр.* Ф.Садриев. *Дәүләт хакимиятенең башкаручы аппараты турыдан-туры хакимлек итүче дворяннар сыйныфы вәкилләреннән --- тора.* Ә.Борһанов. *Якты, биек заллар, дисталәгән тренер аппараты, аерым предметниклар.* В.Имамов. *Мәктәп аппаратында ярты хезмәт хакына слесарь-төзәтүче штаты тоту каралган, югыйсә.* В.Имамов

**АППАРАТУ́РА** *җый. и. лат.* Билгеле бер эшне башкару өчен хезмәт иткән аппаратлар җыелмасы, җайланмалар. *Оет авылы клубына музыкаль аппаратура алынды.* Т.Нәҗмиев. *Чөнки андый аппаратуралар яшерен акча сугу урыннарында файдаланылырга бик мөмкиннәр.* Р.Мирхәйдәров

**АППАРАТУ́РАЛЫ** *с.* Аппаратурасы булган, аппаратура белән җиһазландырылган. *Зур аппаратуралы цехларның исә үз өстенлеге бар.* М.Зарипов

**АППАРАТЧЫ** *и.* 1) Аппаратлар белән эш итүче кеше; аларны җайлаучы, көйләүче, төзәтә торган эшче. *Гади аппаратчыдан алып химкомбинат директорына кадәр --- шушы сорау борчый иде.* Р.Кәрами. *Бу эретмә ярдәмендә аппаратчылар чималны төрле компонентларга таркаталар.* М.Зарипов

2) Аппаратта (*3 мәгъ.*) эшләүче. *Үзегез уйлап карагыз: кичәге үрнәк һәм кристалл кебек чиста ҮК аппаратчысы, провинциягә килеп төштеме, кинәт үзгәрә дә куя.* Т.Кәримов

**АППЕ́НДИКС** *и. лат.* 1) *анат.* Сукыр эчәктәге суалчансыман кечкенә үсенте. *Аппендикс алуда азмы-күпме тәҗрибәсе бар иде Рәисәнең.* Ш.Бикчурин

2) *тех.* Аэростатта, дирижабльдә һәм һава шары тышчасының аскы өлешендә газ кертү һәм чыгару өчен хезмәт итә торган кыска шланг

**АППЕНДИЦИТ** *и. лат. мед.* Сукыр эчәк үсентесенең ялкынсынуы, шешүе. *Авыруның, касыгын тотып, уң якка бөгәрләнеп ятуыннан Рәисә диагноз куеп алды: Хафизовта – кискен формадагы аппендицит өянәге.* Ш.Бикчурин

**АППЕТИТ** *и. лат.* 1) Ашыйсы килү теләге, җиңелчә ачыгу халәте. *Вәт аппетит дисәң дә аппетит!* Р.Сибат

2) *күч.* Ихтыяҗ, теләкләр, таләпләр. *Чыңгыз туруны (оныгы) Бату ханның яулап алу ниятләрен һәм «аппетитын» чамалап өлгергән болгарлар, әлбәттә, үз дәүләтләренең чиген ныгыталар.* М.Мәхмүтов

**АППЕТИТЛАП** *рәв.* 1) Аппетит белән, бик тәмләп, бик яратып

2) *күч.* Теләп, ошатып, рәхәтләнеп, шөгыльдән тәм табып

**АППЕТИТЛЫ** *с.* 1) Аппетиты яхшы булган

2) Ашыйсыны китерә торган, тәмле

3) *күч.* Күңелне җәлеп иткән, үзенә тарткан. *Син шундый аппетитлы күренәсең, Фалия.* Х.Камалов

**АППЕТИТЛЫЛЫК** *и.* Аппетитлы булу

**АППЛИКА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Төрле төстәге, төрле формадагы кәгазь, тукыма, күн кисәкләрен берәр нәрсәгә ябыштырып яисә тегеп сурәт ясау ысулы. *Төрле төстәге яфракларны сайлап, аппликация итеп файдалан, алардан картиналар төзе.* Ф.Ибраһимова. *Нәтиҗәдә, рәссамның аппликация, тамбур чигүе, беркетү, зәркән белән эшләү кебек техникалардан торган үз иҗат өслүбе барлыкка килә.* Мәдәни җомга

2) Шул ысул белән ясалган сурәт, рәсем, бизәк. *Балаларның язучылар әсәрләренә нигезләнеп ясалган эшләнмәләреннән – аппликация, рәсем һ.б. – күргәзмәләр оештырыла.* Мин бәйрәмнәр яратам

3) *мед.* Тәннең аерым бер урынына ләм, парафин һ.б.ш. куеп дәвалану төре

**АППЛИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Аппликация төшерү, аппликация беркетү

**АПРЕЛЬ** *и. лат.* Календарь елының – дүртенче, язның икенче ае. *Яңадан начальник булып эшли башлавы тагын апрель аена туры килә.* Т.Нәҗмиев. *Көлтәаякның мышнавыннан аяк астындагы апрель суы дулкын-дулкын булып дерелдәде.* М.Мәһдиев. *Апрель аенда Шәфиканы Казанга чакырып калдылар.* Мирас

**АПРИОР** *с. лат.* 1) *филос.* Фактларга, мантыйкка нигезләнмәгән, коры фикергә таянган. *Кайчандыр ул җәмгыять кешеләренең аңында тумыштан ук (априор рәвештә) яши торган булган, тик менә җәмгыятьнең бозылып китүе бу сыйфатка зарар китергән.* К.Гыйззәтов

2) Тикшерелмәгән, алдан билгеләнмәгән

**АПРИО́РИ** *рәв. лат.* 1) *филос.* Фактларга нигезләнмичә, тәҗрибәсез килеш, коры фикер йөртеп

2) Тикшермичә, алдан ачыкламыйча

**АПРИОРЛЫК** *и. филос.* Тәҗрибәгә таянмаганлык, фактка нигезләнмәгәнлек. *И.Кант* (*XVIII гасырлар*) *исә кешеләрнең иҗади эшләрен үзенең трансценденталь теориясе* (*тегe яки бу категорияләрнең априорлыгы*) *белән аңлатырга тырыша.* К.Гыйззәтов

**АПРОБА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Тикшерү, сынау нигезендә, берәр оешманың эшчәнлеген яки берәр хезмәтнең сыйфатын рәсми хуплау. *Алар төрле типтагы белем бирү учреждениеләрендә тикшерелделәр, апробация үттеләр.* Ф.Харисов

2) *а. х.* Тәҗрибә участокларында, сынау юлы белән, чәчү орлыкларының сортын, чисталыгын, корылыгын билгеләү

**АПРОБА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Апробация үткәрү, рәсми хуплау бирү

2) *а. х.* Тәҗрибә участогында сынау, апробация ясау

**Апробацияләп чыгу** Һәрберсен башыннан ахырына кадәр апробацияләү

**Апробацияләп тору** Һәрвакыт, әледән-әле апробацияләү

**АПТЕ́КА** *и. гр.* Дарулар (ясап) сата торган оешма; даруханә. *Аның өчен кура җиләге кайнатабыз, куе итеп чәй ясап бирәбез, температурасын үлчибез, аптекага барып, тиз генә дару алып кайтабыз.* Р.Мостафин

**АПТЕ́КАЧЫ** *и.* Даруханә хезмәткәре, фармацевт. – *Нәни балаларга сөт эчерә торган шешә һәм имезлек бирегез әле, – диде ул мөлаем гына елмаеп торучы сатучы кызга. – Нигә ул сиңа? – диде аптекачы, көлемсерәп.* Л.Закирова

**АПТЕ́ЧКА** *и. рус* Төрле оешма, транспортларда һәм өй шартларында даруларны саклау өчен махсус тартмачык яки стенага беркетелеп куелган кечкенә шкаф. *Өйдәге аптечкамда һәммә нәрсә бар – бәйлисен бәйләп, әйтәсен әйтеп, дигәндәй, андыйларга кулымнан килгән ярдәмне кызганмадым.* Р.Низамиев

**АПТЫРАТКЫЧ** *с.* **1**. Аптырата торган, йөдәтә торган; аптыраштa калдырган. *Мәсьәләнең аптыраткыч ягы шунда: мин – өлкән яшьләрдәге укытучы, класс җиткәчесе, хәлне ачыкларга, малайны дөрес юлга күндерергә дип килгән кеше.* Ф.Хөсни

**2**. *җый. и. мәгъ.* Табышмак, ребус, шарада, кроссворд һ.б.ш. кебек баш ваткычлар. *Шулар арасында: 7 сүз уйнату, 7 табышмак, 8 кечкенә әкият һәм 1 аптыраткыч.* Ф.Урманче

**АПТЫРАТУ** *ф.* Йөдәтү, бик нык борчу; тынгылык бирмәү; җәфалау, интектерү. *Шулай күп аптырата торгач, егет бер бай кызына өйләнергә риза була.* Әкият. *Шулай да иң аптыратканы – кызларның сәер кыланышы иде.* Ф.Сафин

**Аптырата башлау** Аптыратырга тотыну. *Һәркөнне Хәләфнең эш урынына килеп, аны аптырата башлады.* Х.Ибраһимов

**Аптырата бирү** Аптыратуын дәвам итү

**Аптырата төшү** Тагын да ныграк аптырату. *Әнвәрнең: – Менә, әнием, күрдеңме? – дигән соравы Хәдичәне тагын да аптырата төште.* К.Тимбикова

**Аптыратып алу** Кыска вакыт эчендә аптырату. *Әнә шул бәхетле баскычка күтәрелгәнче, күп кенә яшьләрне бер чир аптыратып ала.* М.Вәли-Барҗылы

**Аптыратып бетерү** Тәмам, соңгы чиккә җиткереп аптырату. *Югары оч малайларын [Зәбир] аптыратып бетерә.* М.Галиев. *Әнә Зиннәт аптыратып бетерә торганые.* Р.Кәрами

**Аптыратып җибәрү** Кинәт аптырату. *Кинәт кенә башына килгән бу шөбһәле фикер Вәлине әллә ничек куркытып һәм аптыратып җибәрде.* Р.Гали

**Аптыратып йөрү** Озак вакытлардан бирле бертуктаусыз аптырату. *Өйрәнгән тәки, әнисен юкка аптыратып йөрмәгән икән.* Г.Якупова. *Оялмыйча, бу яшьтә ничек, квартира сорап, хөкүмәтне аптыратып йөрим?* Г.Зәйнашева

**Аптыратып карау** Бик нык аптырату

**Аптыратып кую** Кинәт аптырату. *Аптыратып та куйды ул Наилне!* Р.Габделхакова

**Аптыратып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз аптырату. *Мине күптәннән аптыратып торган соравым тел очымнан үзеннән-үзе ычкынып китте.* Г.Мөхәммәтшин

**АПТЫРА́У** *ф.* **1.** 1) Гаҗәпләнү, аңламау, нәрсә дип уйларга белмәү. *Фәрит үзе дә аптырады, әллә авылга соңгы мәртәбә кайтуым микән, дип, хәвефле уйларга да төште*. Ф.Садриев

2) Гаҗәпсенү, гаҗәпкә калу, шаккату, хәйран булу. *– Менә инде! – дип аптырады Заһидуллла тагын. – Мин әле, сиңа кырык та юктыр, дип йөри идем*. Р.Сибат. *Нигә болай кинәт кенә минем белән кызыксына башладың әле син, дип аптырама, Равил абый*. В.Нуруллин

3) Авыр хәлгә юлыгу, югалып калу, каушау, нишләргә белмәү. *Аптырау һәм курку шул секундта ук аларның агарган йөзләренә бәреп тә чыкты.* Ә.Еники

4) Яшәү авырлыклары кичерү, төрле кыенлыклар күрү

5) Нәрсәгә дә булса ихтыяҗ булу, мохтаҗ булу. *Монда балыкка аптырау юк.* Каһарман каләме

6) Йөдәү, ару, талчыгу; җәфаланып бетү

**2.** *и. мәгъ.* 1) Вакытлыча туган таркаулык хәле, югалып калу халәте, паника. *[Хатынның] Бөтен кыяфәтендә – югалып калу, аптырау билгесе.* Г.Тавлин. *Кыз, сөрмәле күзләрен аңа төбәп, йөзенә аптырау галәмәте җәеп: – Вәгъдә биргәнемне хәтерләмим [диде].* Т.Галиуллин. *Боларны күреп торган Ф.Әмирхан Октябрьдән соң аптырау хәлендә кала.* Ф.Ибраһимова

2) Нәрсәгә дә булса ихтыяҗ булу, мохтаҗ булу. *Хәзерге эшче көченә аптырау заманында куркырга ярамый.* А.Алиш

**3. аптыраганга, аптыраганнан** *рәв. мәгъ.* Мохтаҗлыктан, җитешмәүдән. *Мәктәпләргә, укытучылык эшенә аптыраганнан гына алынган, мәктәптә тарта-суза «өч»кә укыган кызыйлар килә башлады.* Т.Миңнуллин

**Аптырап алу** Кыска вакыт эчендә, беразга аптырау. *Тынлыкны бозган бу сорауга Абу баба аптырап алды.* Б.Сөләйманов

**Аптырап бетү** 1) Тәмам, бөтенләй аптырау. *Шулай да, «пүрәтке»ләре белән бик мактансалар да, иртәгәсен, сәгать уникегә хәтле, мәйданны башлап җибәрә алмыйча аптырап беттеләр.* Ф.Хөсни. *Ике аягына, биленә кат-кат операцияләр ясап, аптырап беткәннән соң, Габбаниның, оча сөяге яныннан ярып, эчен ачтылар.* Ә.Галиев

2) Соң чиккә җитеп алҗу. *[Мәүлитҗан:] Аптырап беттем, бер – уң кулымны, бер сул кулымны күтәреп честь бирә-бирә.* Д.Салихов.

**Аптырап йөрү** Озак вакыт аптыраган халәттә булу; рәтенә, тәртибенә төшенә алмау. *Шәһәр кунаклары аптырап йөрмәсен өчен, тышкы ишек турысына кызыл фонарь элеп куйганнар.* З.Фәтхетдинов

**Аптырап калу** Кинәт аптырау, югалып калу. *Мин аптырап калу берлә кызганудан җыелган бер хис астында калдым.* Г.Исхакый. *Кешеләр, өр-яңа киемле, алтын погонлы, күкрәгендә унлаган орден-медальләр чылтырап торган ыспай хәрбине күргәч, аптырап калдылар*. М.Әмирханов. *Иреккә нидер булды, ул ничек башларга белмичә аптырап калды*. Ф.Садриев

**Аптырап китү** Кинәт, уйламаганда аптырау. *Тәкыя бу кадәресен ишеткәч тә аптырап китте.* Н.Хәсәнов

**Аптырап кую** Кинәт, бераз вакыт, азга гына аптырау. *Мондый тасвирына үзе үк аптырап куя*. М.Хуҗин. *Әүвәл, нигә бу кыз шулчаклы күп сөйләшә әле, дип, аптырап та куйган идем.* З.Хөснияр

**Аптырап тору** Әле, хәзер аптыраган хәлдә булу, нишләргә белмәү. *Мин шулай аптырап торганда, кармагым төпкә чумды.* Г.Ибраһимов. *Асия апа беркавым аптырап торды.* В.Нуруллин

**Аптырый калу** *к.* **аптырап калу.** *Аптырый калдым: бер уч черегән саламга шөкер итеп яшәгән ферма савымчысының бүгенге терлекчеләргә нинди дәгъвасы булырга мөмкин?* К.Тимбикова

**Аптырый төшү** Бераз, берникадәр аптырау. *Әнә шул нәни генә сөенечнең йорты яну көенечен Ярмәкәй тавы кадәр таш белән каплый алуына ул, бер яктан, аптырый төшсә, икенчеләй карaганда, үзендә шундый ипле-игелекле тынычлык тууына гаҗәпләнеп тә куя иде*. Р.Сибат

**АПТЫРАУЛЫ** *с.* 1) Гаҗәпләнгән. *Сафта басып торгандай, гәүдәсен катырып тоткан, зиһене томаланган Мотаһир әле һаман аптыраулы хәленнән чыга алмый иде.* Р.Кәрами. *Атай, кулындагы кәгазьгә күз йөртеп чыкты да, аптыраулы кыяфәт белән: – Ун кешегә җиңел эш ничек табыйм, ди, мин? – диде.* С.Йосыпов

2) Борчулы, каушаулы, уңайсызланган. *– Мин бара алмыйм, Зөфәр Шәрипович, – диде ул, аптыраулы карашын аңа төбәп.* Ф.Садриев. *Ишек артында Заһид Шәркыйның аптыраулы, гасабилы йөзе күренеп калды.* Ф.Сафин

**АПТЫРАШ** *и.* **1**. Аптырау, каушап калу. *Бу аптыраш минем хәбәрдарсызлыгым, наданлыгым аркасында гына булган икән*. Т.Галиуллин. *Табиблар үзләре дә аптырашта иделәр*. З.Хөснияр

**2**. *ы. мәгъ.* Сүз, җөмлә башында килеп, сөйләүченең гаҗәпләнүен, чарасызлыктан исе китүен, җавап таба алмавын белдерә. *Аптыраш, мин аннан көләсе урынга, ул миннән көлә.* Р.Сибат. *Аптыраш, нинди җәмгыять төзибез, кая бармакчы булабыз*? Ф.Сафин

◊ **Аптырашка калу** Аптыраган хәлдә булу. *Василий аптырашка калды. Ни эшләргә?* Р.Зарипова. **Аптырашка салу** *к.* **аптырашта калдыру**. *Ул, --- Гөлзадәне аптырашка салып, бер сүз әйтми китеп тә барды.* Ф.Сафин. **Аптырашка төшү** Бик нык аптыраган хәлдә калу; гаҗәпсенү. *Фәүриянең кыланмышыннан балалары аптырашка төшеләр.* М.Хуҗин. **Аптырашта калдыру** Гаҗиз итү, кыен хәлгә дучар итү. *Бу хат бөтенләй аптырашта калдырды Әхмәтсафаны*. Ф.Сафин. **Аптырашта калу** *к.* **аптырашка калу.** *Ул, күтәрелеп, ят кунакка карады, аптырашта калды.* Р.Кәрами. **Аптырашта тору** Берникадәр вакыт, аптырап, нишләргә белмәү. *Нишләргә, дип аптырашта торганда*, *шул ук Хәйдәр абый хәйләсен тапты*. С.Йосыпов

**АПТЫРАШЛЫ** *с.* 1) *к.* **аптыраулы.** *Күчәрбай, аларга ни дип җавап бирергә белмичә, аптырашлы елмаю белән кызарып тик тора.* М.Әмир. – *Зинһар өчен, аңлатыгыз: сез ни турында сөйлисез? – диде ул, аптырашлы күз карашын аңа төбәп.* Ф.Садриев

2) Аптырата, йөдәтә торган. *Суфия, аларның аптырашлы сорауларына җавап урынына, --- моңсу тавыш белән, үзенең юл планын сөйләп китте.* К.Нәҗми

**АПУЙКА** *и. рус сөйл.* **1.** Яшь бозау тиресеннән эшләнгән күн; опоек, опойка

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тиредән тегелгән

**АР** I *и. иск.* Удмурт. --- *аның янына бер ар карты килеп басты. Бөрешеп беткән.* М.Әмирханов. *Әнә шул кышта аның кырына, бер болгар наиб-тарханнары гына түгел, тирә-юньдә тереклек иткән мукшы, эрҗә, чуваш, ар, чирмеш ил-тарханнары да килеп сыгындылар.* М.Хәбибуллин. *Ар, чирмеш, мукшы, башкорт якларыннан Ханбалыкка кораллы көчләр килә.* Н.Фәттах

**АР** II *и. лат.* Йөз квадрат метрга тигез җир үлчәү берәмлеге

**АР** III *с. к.* **аргы**. *Агыйделнең ар ягында бер инәгә – бер сыер.* Әйтем

**А́РА** *и. тупи зоол.* Попугайлар отрядыннан, озын койрыклы һәм ачык зәңгәр, кызыл һ.б. төстәге каурыйлы кош, попугайларның эре төре (Көньяк Америка илләрендә очрый)

**АРА** I *и.* **1.** 1) Ике әйберне аерып торган буш урын, ачыклык. *Һәнүз башын артка чөеп җибәрде, блокнотын бармак араларына кыстырып, урыныннан кузгалды.* Х.Хәйруллин. *Укытучы Сөләйман Габдулыч та үз эше белән мәшгуль: акрын гына атлап, укучыларның мәсьәләне ничек чишүләрен күзәтеп, парта араларында йөри.* В.Нуруллин // Ике предмет яки ике кеше арасындагы урталык. – *Ике арага минем чаршауны корып куй әле, – диде Җәмилә.* М.Гафури

2) Ераклык, дистанция, интервал. *Ун чакрым ара лабаса.* Ә.Галиев. *Ара ерагая башласа, кызуланып, дустын куып җитә.* М.Хуҗин. *Ара ерак булмаса да, манма чыланып барып керде ул шәкерт абыйларының өенә.* М.Әмирханов. *Юл арасы да ерак түгел, югыйсә. Өч кенә чакрым.* Х.Ибраһим

3) Вакыт, мизгел. *Заһит, бер ноктага текәлеп, шактый ара гаҗизләнеп утырды.* М.Әмирханов. *Өстен алыштырырга да ара булмады.* Т.Нәҗмиев. *Ул арада тышта көн дә матурланды.* Р.Фәизов

4) Кешеләрнең бер-беренә якын һәм тыгыз мөнәсәбәте, үзара бәйләнеше. *Ә инде ире Динәгә мөнәсәбәтен үзгәртсә, аралар яхшырса, бала кирәксенсәләр, тагын булыр әле – яшь чаклары!* М.Маликова. *Язучы Әсрар абый Галиевтән хат алгач, аралар тагын да якынайды.* Ә.Хәбибуллин. *Шуннан соң, билгеле, аралар бөтенләй бозылды.* З.Фәтхетдинов. *Сезнең Мәрзизә белән араларыгыз ничек?* Р.Төхфәтуллин // Берәр нәрсә белән бәйләнеш. *Ресторан белән араны өзәргә!* Р.Вәлиев

5) **арадан, арада** *чыг., у.-вак. килеш форм.* Затлар яки әйберләр арасыннан берсе яки берничәсе (аерып күрсәткәндә кулланыла). *Арада рус телен бөтенләй вата-сүтә генә сукалаучылар да бар.* Р.Хафизова. *Арада ике-өч кенә бөртек кыз-кыркын да күренә.* Ф.Хөсни. *Марат күз алдына сарык көтүен китерде һәм, арадан сайлап, ак сарыкларны саный башлады.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Арадан берсе скрипка сызып маташа.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Ике категория, төр һ.б.ш. уртасындагы, арадаш. *Иске төр яңа төрне берниндн кучешсез һәм ара формаларсыз гына китереп чыгара.* Биология

**3.** *бәйл. функ.* 1) **арасына** *юн. килеш форм.* Пространство мөнәсәбәтен белдереп, эш-хәлнең берничә яки күп зат эченә, теге яки бу мохиткә юнәлгәнлеген күрсәтү өчен кулланыла. *Нәрсә киеп барасың инде менә хәзер җыелышка, кеше арасына?* Р.Хисмәтуллин. *Малайлар, ул әйткәнчә, кайсы кая – әрекмән арасына постылар.* Р.Хафизова. *Басу капкасын чыккач, куе арыш арасына кереп яттым.* Г.Сабитов

2) Кемнәр яки нәрсәләр рәтендә, дәрәҗәсендә булу-булмауны белдерү өчен кулланыла. *Бер генә көнгә, бер генә сәгатькә үзләрен шушы мескеннәр арасына кертәсе, бер генә чакрым юл үткәртәсе иде.* Р.Кәрами

3) Затларның үзара мөнәсәбәтен белдерү өчен кулланыла

4) **арасында** *у.-вак. килеш форм.* Эш-хәлнең башкарылу урынына бәйле рәвештә кулланыла. *Шушылай сөйләшү, килешү алар арасында инде моңарчы да булган кардәшлек, якын туганлык хисләре ялкынын тагы да үстереп, үсендереп җибәрде.* Р.Сибат

5) Эш-хәлнең ике яки берничә предметка, затка мөнәсәбәтле булуын, арадашлык мәгънәсен белдерү өчен кулланыла. *Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?* Ә.Еники. *Ә бит Вакыйф, ике гаилә арасында чын дуслык башланыр, дип уйлаган иде теге чакта.* С.Шәмси. *Р.И.Нафигов яшь Ульяновларның иптәшләре арасында пензалы А.А.Тенишевны атый.* И.Абдуллин

6) Теге яки бу затларның үзара нинди дә булса мөнәсәбәтләре характерын белдерү өчен кулланыла. *Араларына, кара мәче булып, мәкер кермәде микән*? И.Нуруллин. *Алар арасында дуслык юк*

7) Коллективтагы шәхесне аерып күрсәтү өчен кулланыла; кемнең дә булса алдында, каршында. *Тырыштым, укыттым баланы, кеше арасында абруйлы булыр, дидем.* Ә.Айдар

8) Эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерү өчен кулланыла. *Бриан ролен башкаручы Сабир, речь арасында туктап, маңгай тирен сөртә.* А.Алиш. *Сүз арасында гына булса да, бу мәсьәләгә дә кагылып үтәсем килә.* Идел

9) **арасыннан** *чыг. килеш форм.* Эш-хәлнең предметлар яки нинди дә булса затлар аралыгындагы пространство аша үтеп башкарылганлыгын күрсәтү өчен кулланыла. *Карасалар, карт тупыллар арасыннан, шома таягын күтәреп, Аяз мулла болар өстенә килә.* Р.Сибат. *Үзе биеклек арыш арасыннан, машина тавышлары ишетелеп торган таш юлга барып җитә.* М.Галиев

**4. арада** *мөн. сүз функ. у.-вак. килеш форм.* Вакыт мөнәсәбәтен белдереп, иярчен вакыт җөмләне баш җөмләгә

бәйләү өчен кулланыла. *Әтисенә су сибешкән арада, көтү дә кайтты.* Хәйдәр. *Габбани ирләргә авыл, юл, отпуска хәлләрен сөйләп утырган арада, без, хатын-кызлар, табын әзерләдек.* Ә.Галиев. *Өлкәннәр печән чапкан арада, Барый белән рәхәтләнеп җиләк ашадык.* З.Хөснияр. *Бил каешын рәтләгән арада, янтыгындагы наган кобурасына да кул тидереп алды.* Р.Кәрами

◊ **Ара айкау** *к.* **ара бозу**. **Ара бетү** *к.* **ара бозылу** (*1 мәгъ.*). *Безнең ара беткән инде, миңа хат язып мәшәкатьләнмәгез.* Н.Исәнбәт. **Ара бозу (бозыштыру)** Кемнәрнеңдер үзара мөнәсәбәтен начар якка үзгәртү; талаштыру, дошманлаштыру; бер-берсенә каршы котырту. *Түгел, Хәсән, аның өчен түгел. Синең хатларыңны ул алып барган, араны махсус бозу өчен.* Ф.Тарханова. **Ара бозылу** 1) Кызыксыну бетү, хисләр сүрелү. *Башта алар, яшьтәш булгангамы яисә хатын ир назын тансыклагангамы, әйбәт кенә яшәсәләр дә, соңрак аралары бозылды.* Р.Сибат; 2) Дуслык бетү; үпкәләшү. *Ләкин --- еш кына берәр туры сүз әйтеп куям да, шуның аркасында, «дус» дип йөргән иптәш кешеләрем белән үпкәләшүгә, дус булмаганнары белән бөтенләй ара бозылуга кадәр барып җитә.* В.Нуруллин. *Ара бозылуны мин Апушның яңа эшләпәсенә сылтаган идем.* М.Юныс. **Ара болгату** *к.* **ара бозу. Ара бутау** *к.* **ара бозу.** *Аксу өлкәсендәге барлык милли көчләрне таркату, халыклар арасын бутау – монысы инде яшь каладагы хезмәт кенә түгел иде.* Ф.Сафин. **Арага алу** Тиң күреп, якын итеп, үз кешеләре рәтенә кертү. **Арага җил (дә) кермәү (үтмәү)** Бик көчле дуслык, әшнәлек турында. **Арага кара елан керү** *к.* **арадан кара мәче үтү**. **Арага кара мәче (песи) керү** *к.* **арадан кара мәче үтү**. **Арага кертү** *к.* **арага алу**. *Чуртан тыңлап та бетермәде: – Ят кешене арага кертү тыела [диде].* М.Насыйбуллин. **Арага керү** 1) Нинди дә булса коллективның үз кешесе булып китәргә тырышу, шуларга катнашу; 2) Берәр эш эшләп яки берәр нәрсә сөйләп торучы ике кеше янына өченче кешенең килеп катнашуы; 3) Талашып яки сугышып торган ике кешене аерып, килештерергә тырышу, аралау. *Кияү буласы авылдаш егет түзмәгән, картны яклап, араларына кергән.* Б.Камалов; 4) Дус булып йөргән ике кешенең яки яратышып йөргән егет белән кызның мөнәсәбәтен бозу. *[Фәхри:] Яшьләр арасына керү килешми.* Д.Салихов. **Арага күләгә төшү (яту)** *к.* **арага салкын йөгерү. Арага кыл да сыймау** *к.* **арадан җил дә үтмәү. Арага кысылу** *к.* **арага керү** (*2, 4 мәгъ.*). **Арага салкын (суык) йөгерү (төшү)** Кызыксыну кимү, читләшү. **Арага салып** Мәсьәләне ачыктан-ачык, һәр ягын аңлатып һәм үзара килешеп. *Әйе, бу уйлар аны шактый бимазалый, ә менә җай чыгып, шуны Миләүшә белән ураклашканы, арага салып сөйләшкәне юк.* Р.Кәрами. **Арага таяк тыгу (кыстыру)** *к.* **арага чөй кагу**. **Арага төшү** *к.* **арага керү** (*3–4 мәгъ.*). *Хатыннар шунда гына аларның араларына төштеләр.* М.Хәсәнов. **Арага тыгылу** *к.* **арага керү** (*2, 4 мәгъ.*). **Арага чөй кагу (кыстыру, сугу)** Якын дус, яратышкан кешеләрнең мөнәсәбәтләрен бозу, аларны бер-берсеннән ераклаштыру өчен хәйлә-мәкер эшләү. **Арада гына калсын** Ике арада калсын, башка берәү дә белмәсен. *Бу сер безнең арада гына калсын иде.* Х.Ибраһим. **Арадан җил дә үтмәү** *к.* **арага җил кермәү.** *Менә шундый ике аерылмас җан дус, гәүдә, кыяфәт ягыннан капма-каршы булсалар да, арадан җил дә үтми.* А.Гыйләҗев. **Арадан кара мәче (песи) үтү (узу)** Мөнәсәбәтләр бозылу. *Әйбәт кенә барганда, арадан ниндидер кара мәче үтте шикелле.* Х.Камалов. **Арадан китү** Вафат булу, үлү. *Ул безнең арабыздан китте.* Г.Ахунов. **Ара ерагаю** Читләшү, аралашу кимү, дуслык бетү. *Кызарып таң аткан саен Ерагайды арабыз да.* Ф.Мөслимова. **Араны ныгыту** Үзара дуслык, якынлык мөнәсәбәтләрен яхшырту, дуслыкны тагын да арттыру. *Мәскәү белән дустанә яшәү – бик тә мөһим сәясәт, хан; әмма ут күршеләремез нугайлар илә араны ныгыту – иң олы фәгалиятләрнең берсе...* Р.Батулла. **Араны өзү** 1) Мөнәсәбәтне, үзара бәйләнешне бетерү; бозылышу, дуслык китү. *Ни өчен соң Тукай нәкъ менә шушы «чиле-пешле» кешеләр арасына эләккән һәм, үзләрен танып алгач, ник алар белән арасын өзмәгән?* И.Нуруллин; 2) Алыш-биреш ясау; ике арада аласы яки бирәсе нәрсәләр калмау. **Ара өзек (өзелгән)** Алыш-биреш беткән; биреләсе бирелгән, алынасы алынган, исәп-хисап ясалган. *Ара өзек булса, дуслык якын була.* Мәкаль. **Ара өзелү** Якынлык яки туганлык мөнәсәбәтләре бозылып, дуслык бетү. *Шуңа күрә алар өчен ара өзелү – барыбер көтелмәгән хәл.* Ә.Баян. **Ара салкынаю** *к.* **ара суыну.** *Иренең әбәтне өйгә кайтып ашамавын Рәисә үзенчә юрады: аларның арасы салкынаю галәмәте түгелме икән ул, янәсе.* Р.Батулла. **Ара суыну** Ике дус кешенең яисә йөргән егет белән кызның үзара мөнәсәбәтләре өзелү, бер-береннән ераклашу, читләшү. *Ә Гөлүс өчен бу туй Миләүшә белән ара суынуның артуына һәм өметсезлек тойгысының һаман көчәюенә сәбәп булды.* Р.Кәрами

**-АРА** II Кушма сүзләрдә уртак мөнәсәбәтләрне, үзара бәйләнешне белдергән икенче кисәк (мәс., *ведомствоара, вузара, илара, халыкара, милләтара, шәһәрара, колхозара*)

**АРАБЕ́СКА** *и. фр.* 1) *архит.* Геометрик фигуралар һәм стильләштерелгән яфраклар, чәчәкләр һ.б. белән ясалган катлаулы бизәк, нәкыш (башлыча, гарәп сәнгате үрнәкләрендә кулланыла). *Владимир-Суздаль өлкәсендәге биналарның, храмнарның тышкы як диварларын каплаган кабарынкы сурәт мотивлары һәм арабескалар да болгарларның йогынтысы турында сөйли.* И.Гафаров

2) *махс.* Классик биюдә: бер аякны артка таба югары күтәреп, икенчесе белән тигезлек саклап тору рәвеше. *Арабеска! Гарәпләр төсмере, мөселманнар сулышы бөркелеп торган бу алым классик биюдәге иң төп хәрәкәтләрдән санала иде.* Р.Вәли

**АРАБИЗМ** *и. рус лингв.* Гарәп теленнән алынган яки гарәп теле калыбы буенча төзелгән сүз, тәгъбир; гарәп алынмасы. --- *килеп чыгышы ягын-*

*нан интернациональ сүзләрне татар телендә дүрт төркемгә бүлеп карыйлар: 1) европеизмнар, 2) русизмнар, 3) арабизм-фарсизмнар, 4) кытай һәм япон сүзләре.* Ф.Сафиуллина

**АРАБИСТ** *и. рус* Гарәп телен, мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүче белгеч. *«Кәлилә вә Димнә»нең гарәп версиясе Европада атаклы француз арабисты Сильвестр де Саси тарафыннан беренче тапкыр 1816 елда басылып чыга.* Кәлилә вә Димнә

**АРАБИ́СТИКА** *и. рус* Гарәп телен, мәдәниятен һәм тарихын өйрәнә торган гыйльми тармаклар җыелмасы

**АРАДАГЫ** *с.* 1) *к.* **арадаш** (*1 мәгъ.*)

2) Кемнәрнеңдер, нәрсәләрнеңдер арасында булган (урнашкан), кемнәрнеңдер арасындагы; кемнәрне яки нәрсәләрне дә булса аерып торган, бүлеп торган. *Дуслыкның тәүге шарты – ике арадагы серне чишмәү.* А.Гыйләҗев. *Күршеләр белән ике арадагы таш коймa ягында тагын баягыча шакылдаган тавыш ишетелеп китте.* Н.Фәттах

**АРАДАШ** *с.* 1) Составында ике төргә караган элементлар, компонентлар һ.б. булган, ике төр арасында торган; катнаш. *Күчмә типтагы торфлы саз туфраклары уйсулык торфлы һәм мүкле торфлы туфраклар белән арадаш булып тора.* А.Девятков, А.Макаревич

2) Бер төрле, охшаш, үзара бәйле (җитештергән әйберләре буенча). *Алар газүткәргеч салуда катнашучы барлык арадаш оешмаларны «Эшче эстафетасы» дигән комплекслы ярышка кушылырга чакырдылар.* Казан утлары

**АРАДАШЛЫК** *и.* Ике якны үзара килештерү, сәүдә эшендә алыш-бирешне җайга салырга ярдәм итү эше. *Курамшин карт менә шулар арасында, әйбер танучы буларак, арадашлык итеп, берәүләренә – сатышып, икенчеләренә алышып йөри...* Ә.Еники

◊ **Арадашлыкны өзү** *к.* **араны өзү** (*1 мәгъ.*). *Әйткәнебезчә, Нәҗип Сабит абыйсы белән хат алышмады, бүтән туганнары белән дә арадашлыкны өзгән иде.* А.Гыйләҗев. *Ерак туганнарым бар-барын... Тик алар әни белән арадашлыкны күптән өзеп бетергәннәр.* А.Гыйләҗев

**АРАДАШЛЫК ИТҮ** *ф.* Арадашчы булу. *Ул, Ишмөхәммәт абый белән бергә, маклерлык эше, ягъни мал-туар сатучы белән алучы арасында арадашлык итү белән көн күргән.* Т.Нәҗмиев

**АРАДАШЧЫ** *и.* 1) Ике якны килештерүче, арадашлык итүче; маклер. *Шәхси игъланнарның күбесен фатир сату-алу, фатирга кеше кертү, яшәргә бүлмә эзләү кебек ихтыяҗларга бәйле реклама текстлары тәшкил итә. Мондый игъланнар артында, күп очракта, арадашчылар тора икән.* Ватаным Татарстан. *Декан һәм абитуриент арасында кафедра аспиранты да арадашчы булуы ачыкланган һәм, тикшерү барышында, аннан ришвәт акчасының бер өлеше алынган.* Татар иле

2) Җитештерүче белән кулланучы арасындагы бер өстәмә буын булган зат. *Бу шактый тәкәббер кыяфәтле агач йортның күршесендә, нәкъ Ольковицкий өйрәтеп җибәргәнчә, арадашчы мебель конторасы булып чыкты.* З.Фәтхетдинов

3) Ир-ат белән хатын-кызны таныштыручы, очраштыручы, кавыштыручы; яучы. *Шуннан соң ике арада, тыз-быз, арадашчылар йөри башлады.* Н.Фәттах

**АРАДАШЧЫЛЫК** *и.* 1) Арадашчы эшчәнлеге. *Арадашчылык ролен Галимҗан Шәрәф үз өстенә ала.* Р.Вәлиев

2) Арадашчы (*2 мәгъ.*) хәле, статусы

3) Ир-ат белән хатын-кызны мәхәббәт бәйләнешләренә кертү кәсебе

**АРАКЧЕ́ЕВЧЫЛЫК** *и. тар.* 1) XIX йөз башында Россиядә урнашкан, чикләнмәгән полиция деспотизмы режимы, Аракчеев режимы (Александр I патшалыгында вакытлыча хәрби министр вазифасын башкаручы граф А.А.Аракчеев исеменнән)

2) *күч.* Иҗтимагый яки сәяси тормышның берәр өлкәсендә барлыкка килгән башбаштаклык, деспотлык күренеше

**АРАКЫ** *и.* Этил спирты һәм су катнашмасыннан торган исерткеч эчемлек. *Очына чыга алмастай уйларны Заһит, гадәттә, аракы белән томалап куя.* М.Әмирханов. *Бер кулына – шешә, икенчесенә аракылы стакан тоткан килеш, иреннәрен кысып уйланып торды.* М.Хуҗин

◊ **Аракы мичкәсе** *гади с.* Эчкече, һәрвакыт исерек йөрүче кеше. *Ә элек! У-у! Элек аракы мичкәсе идем.* Г.Мөхәммәтшин

**АРАКЫЛЫК** *с.* **1**. Аракыга җитәрлек, аракы өчен. *Бәлки, ул бер йотым аракылык акча тапкандыр?* Г.Гыйльманов. *Атлар сатылгач, һәрберегезгә берәр шешә аракылык өлеш чыгарам.* З.Зәйнуллин

**2**. *и. мәгъ.* Аракыга җитәрлек акча. *Әтисен эчерткәләп, аракылык биргәләп торалар.* Р.Зарипов

**АРАКЫЧЫ** *и.* 1) Аракы эчүче, аракы эчү белән мавыгучы; исерек кеше. *Кем белә, бәлки, ул аракычы ире кулында мәҗбүрилектән генә яши торгандыр.* А.Шамов

2) Аракы яки аракы кебек исерткеч эчемлекләр җитештерүче

3) Аракы яки шуныңише белән сату итүче. *Кибет бикле булса да, аракычы Зина карчык җиңел кулдан гына аларга аракы сатып, шуны күтәреп ята иделәр.* Ф.Яхин

**АРАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **аралау**

2) *сөйл.* Төркемнән аерылу, төркемнән аерылып калу яки башка юнәлештә аерылып китү. *Араланган куйны бүре алыр.* Мәкаль. *Сарык көтүдән аралану*

3) *күч. сир.* Үзеңне-үзең яклау, каршы тору, каршылык күрсәтү. *Аны кулыннан тотып алмакчы булдылар, ләкин ул, алардан араланып, икенче тәрәзәгә сикерде.* А.Вергазов

4) *диал.* Таралу, таралып бетү (*болытлар*)

**Араланып бетү** Тулысынча, тәмам аралану

**Араланып калу** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң араланган хәлгә килү. *Араланып калды ботаклары, сирәгәйде яфраклары.* М.Галиев

**Араланып тору** Әле, хәзер араланган хәлдә булу

**АРАЛА́У** *ф.* 1) Кеше төркемен яки куе, тыгыз булып (үсеп) утырган нәрсәләрне як-якка этәреп юл ачу; үтә алырлык ачыклык, ара (*1 мәгъ.*) булдыру. *Ул төнне Рәсим ашыга иде шул, аны-моны карап тормады – хуш ис*

*аңкытып утырган үләннәрне аралап, юан киртәгә, киртәдән – багана башына, багана башыннан ат сарае түбәсенә менеп китте.* Ф.Шәфигуллин. *Верхильо сикереп торды да, кино караучы рус диңгезчеләрен һәм порт эшчеләрен аралый-аралый, читкә чыга башлады.* М.Юныс

2) Орлык, җимеш һ.б.ш. нәрсәләрне чүбеннән чистарту яки нәрсәдән дә булса арындыру. *Мин мөлдерәп пешкән җиләкне әчкелтем таҗыннан аралап кабам да тел өстендә суырып тотам.* М.Галиев // Орлык, яшелчә, җиләк-җимешләрне сортларга һәм төрләргә аеру

3) Бармакларны чәч, йон, сакал, чук кебек нәрсәләр арасыннан йөртү, уздыру. *Әтисе, җитез генә торып, нәрсәдер эзләгәндәй, мич яныннан урап килде дә кулын Ирекнең башына куйды, кытыклагандай, чәчләрен аралады.* Ф.Садриев. *Хәмит тырпаеп торган тыңлаусыз кара чәчләрен бармаклары белән аралаган да идән ярыгына карап уйга чумган.* Р.Вәлиев. *Гөлфия, куркуын җиңеп, шәл чугын аралады.* Н.Гыйматдинова

4) Яклау, кимсетергә бирмәү, кимсеттермәү; үз итү. *Кыш Әби таягы белән балаларга да кизәнмәкче булган икән, тик әниләре борылып кергән дә, канатларын җәеп, аларны явыз карчыктан аралаган.* Ф.Тарханова. *Китап сүзе адәм баласын түбәнлектән, рәхимсезлектән, ваклыктан аралаган.* М.Вәлиев

5) Сугышып яки бәхәсләшеп торучыларны аеру, сугышудан яки бәхәсләшүдән туктату яисә араларыннан берсен аерып алу. *Юл тузанында ауный-ауный чәкәләшкән ике «әтәчне» классташлары Барый килеп аралады.* З.Хөснияр. *Шунда ишектән килеп кергән бер терлекче белән ферма мөдире безне аралады.* Ф.Садриев

6) Авыр хәлдән йолу, коткару; саклап калу. *Бәхетемә, мине аннан [төрмәдән] Кәбир исемле олы җанлы бер абый аралады.* Г.Тавлин. *Шулчак Вәлиднең, вәхшиләрдән араларга чакырып: «Әслаах!...» – дип, йөрәк өзгеч тавыш белән кычкыруы шомлы тынлыкны ярып үтте.* М.Хәсәнов

7) Психик халәттән чыгару, үз халәтенә кайтару. *Кызчыкның яңгыравык шат тавышы ирне авыр уйларыннан аралады.* Р.Габделхакова

8) *сөйл.* Куе чәчелгән, куе утыртылган нәрсәләрне сирәкләү

9) *сөйл.* Кем яки нәрсәне буталыпчуалып эләккән яки бәйләнгән җиреннән аерып алу, ычкындыру. *Таза гәүдәле, җылы киемле бу чибәр немецны парашют бауларыннан Гата малайлары аралап алышты.* М.Мәһдиев

10) *куч.* Хезмәткәрләрне, туганнарны һ.б. аерып карау. *Дусларны аралап булмый.* В.Фатыйхов

11) *куч.* Берәр нәрсәне башкалардан аеру, аерып алу. *[Хатларның] Эшлекле язылганнарын, аралап, бүлекләргә аерып куйганнан соң, бер озын хатны гына укыйсы калды.* Г.Бәширов

**Аралап алу** 1) Тиз арада аралау. *«Тышкы матурлык эчке матурлык белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин...» – дигән уй гына сукыр нәфрәтеннән аралап алды аны.* Р.Низамиев. *Касыйм аны әллә нинди мыскыллаулардан да аралап алыр иде.* Хәйдәр. *Камил абыйны лагерьдан сугыш кына аралап алды.* Мирас

2) Бөтен булып торган нәрсәне өлешкә аеру, берничә өлешкә бүлү. *Гөлүс зур бәйләм чыбыктан берникадәрен үзе күтәрерлек күләмдә аралап алды да кискеч белән өзде.* Р.Кәрами

**Аралап бару** Берсе артыннан икенчесен аралау. *Әскәр аны ишетте һәм, кешеләрне аралап барып, аның бугазыннан кысып алырга каны кызышты.* М.Хуҗин

**Аралап бетерү** Тулысынча аралау

**Аралап калу** Араларга өлгерү, нәрсәдән булса да коткара алу. *Беләсеңме, сине үз улы кебек итеп яратачак, безне ятимлек җилләреннән аралап калачак, синең өчен гомерлеккә әтиеңне алыштырачак кеше иде ул.* Р.Низамиев

**Аралап тору** Гел, һәрвакыт аралау. *Әмма аларны печән чапканда аралап тормыйлар.* М.Хуҗин

**Аралый башлау** Араларга тотыну. *Зәйнәп, челәеп, кибеттәгеләрне берәмберәм аралый башлауга, шым булдылар.* А.Гыйләҗев

**Аралый килү** Күптәннән, дәвамлы рәвештә, һәрвакыт, даими аралау. *Афәтләрдән һәрчак аралый килде.* Д.Бүләков

**Аралый төшү** Бераз, тагы да, берникадәр дәрәҗәдә аралау

**АРАЛАУЧЫ** *и.* 1) *махс.* Берәр нәрсәне төрләргә (мәс., сортларга) аеручы кеше

2) Коткаручы, ярдәм итүче кеше. *Тәмуглардан гөнаһлыны йолыр ул, Кыяматтә аралаучы булыр ул.* Котб

**АРАЛАШ** *рәв.* **1.** 1) Аралаштырып, катнаштырып, чиратлап. *Ә ул исә үзе кичке бер кафеда --- аракыны әфлисун суы аралаш уртлап утырган чагында аңа берәү: – Исәнмесез! – дип эндәште.* Ә.Гаффар. *Суганны кишер белән аралаш утырту*

2) Кем беләндер яки нәрсә беләндер бергә, рәттән, берсе арты берсе, бергәләп. *Кырыйдагы ян сәкене минут эчендә уртагарак тарттылар да егете-кызы аралаш килеп тезелешеп утырдылар.* Г.Бәширов

3) Бергә кушып, бутап. *Тәлинкәгә дөге, тары һәм карабодай ярмасы аралаш салынган*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Аралаштырылган, чиратлаштырылган, кушылган, бутап бирелгән. *Кара белән кызыл аралаш кием кигән иде ул.* Р.Батулла. *Юан-юан өянкеләр артта калды, шомырт, зирек агачлары, вак таллык аралаш куаклык башланды.* Н.Әхмәдиев

2) Берәр нәрсә белән катнаш булган. *[Түбәләре] Күбрәк чирәм, камыш аралаш җир белән капланган.* Т.Нәбиуллин. *Кирпеч ватыклары, кызыл балчык аралаш көл катламнары бирелә тимер кыздыра торган учак булганлыгына ишарәли.* Ф.Хуҗин

3) *мат.* Санаучысы ваклаучысына тигез яки аннан зуррак булган. *Аралаш ваклама*

**3.** *бәйл. функ.* 1) Билгеле бер вакыт арасы үткән саен кабатлана торган эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Апрель урталарына кадәр, Дамир ерактагы Урманлы мәктәбендә калган Надирәсенә көнаралаш хат язып торды.* Г.Кашапов

2) Икенче бер эш-хәл белән аралаштырылып яки бүлдерелеп башкарыла

торган эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Йокы аралаш сизәм: чыннан да, чаршау артындагы пышылдаулар, өзек-өзек ишетелгән сүзләр һәм өй эченә кереп тулган төнге караңгылык артында нindидер билгесезлек, яшертенлек посып ята.* Р.Низамиев. *Хәер, Шамил үзе дә аларга игътибар итми, ничектер йокы аралаш бер халәттә атларны куа иде.* З.Фәтхетдинов. *Әти яшь аралаш елмайды да, мине көчле кулларына алып, түшәмгә кадәр күтәрде.* Ш.Маннапов

3) Берсен үтеп, икенчесендә башкарыла торган эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Авыл аралаш туктап ял итү*

4) Нинди дә булса эш-хәлнең, күренешләрнең башка күренешләргә яки эш-хәлгә вакыт-вакыт аралашып, катнашып китүен яисә бер үк вакытта булуын белдерү өчен кулланыла. *Әкрен искән җилдә әле чәчкә генә атып килгән мәтрүшкә, бөтнек исе белән аралаш кичәге учак, бәрәңге ысы аның борынын кытыклады.* А.Хәлим. *Йокы качырып, күңелгә сагыш аралаш моң агылып керә.* Н.Хәсәнов. *Гыйльметдин үзенең сырлы будкасыннан һәрбер узгынчыны, курку аралаш шикләнеп, дәшми-тынмый, күзе белән генә озата иде.* К.Нәҗми

**АРАЛАШТЫРУ** *ф.* **1**. 1) *йөк. юн. к.* **аралашу**. *Зур илебездә генә түгел, дөньяда вакыт чикләре бетте – хәзерге техника тиз аралаштыра*. Ш.Галиев

2) Төрле нәрсәләрне (әйберләрне) катнаштыру, бергә кушу, үзара бутау. *Буа нык. Аны --- тауда үскән куак агачларын кызыл балчыклар белән аралаштырып, саламнар белән ныгытып, катлам-катлам итеп, таптап салганнар.* Н.Хәсәнов. *Атларның ялларына, койрыкларына, маңгай чәчләренә очлы тимер, җиз кисәкләре, бөркет каурыйлары, бүре тешләре белән аралаштырып, төрле төстәге тасмалар тагылган иде.* Н.Фәттах. *Мәкчимнең ысланган балыгын да аралаштырып, бик тәмләп, мич бәрәңгесе ашадылар.* Р.Сибат

3) Ике яки берничә әйберне үзара чиратлаштыру. *[Цехлар, корпуслар] Берсеннән-берсе биек, тәрәзәләр биш-алты метрлы, кызыл я ак кирпечне аралаштырып бизәкләп, я тимер-бетон һәм пыяладан салынганнар.* Р.Кәрами

4) Нинди дә булса эш-хәлне башка эш-хәл барышына катнаштыру, ике төрле эш-хәлне бер үк вакытта башкару. *Кемдер, хатын-кыз чырылдавына аралаштырып, яшь тай кешнәгән төсле итеп, озак хихылдады.* К.Нәҗми

5) Нинди дә булса эш-хәлне берсе артыннан берсен башкару; әле – берсен, әле икенчесен эшләү. *Күп кеше, башка ял бирү өчен, акыл хезмәтен физик эш белән аралаштыра.* Ф.Галимуллин

6) Нәрсәне дә булса берсе арасына икенчесен кыстыру, үзара катнаштырып кую. *Батталов басты да, ике кулының бармакларын аралаштырып, кендек турына куйды.* Ф.Садриев. *Бер үк нәрсәләрне рәткә тезеп тә, аларны сүтеп, төрлечә аралаштырып та каткат уйланды ул.* Ф.Хуҗин. *Сәүдәгәрләр дә көя ашаган --- тиреләрен, керосин белән майлап, яхшы тирегә аралаштырып сатарга тырышалар.* Ш.Мөхәммәдев

7) Бармакларны чәч, йон, сакал, чук кебек нәрсәләр арасыннан йөртү; аралау. *Санька, яңа гына күргәндәй, әтисенә, аның шомланып калган җете зәңгәр күзләренә, сакалын аралаштырып кыймылдаган юан бармакларына карап катты да калды.* Ф.Латыйпов // Берәр нәрсә өстеннән кулны йөртеп, шуның кисәкләрен яки өлешләрен бербер артлы кузгату, күчергәләү, хәрәкәтләндерү. *Ул пианино өстендә бармакларын аралаштырып, нindидер тавыш табарга азаплана.* Ф.Әмирхан

8) Карта уенында: бутау, буташтыру

**Аралаштыра башлау** Аралаштырырга тотыну. *Гыйльманов --- җир идәнгә [шинелен] җәеп килеп утырды да картасын чыгарып аралаштыра башлады.* М.Гали

**Аралаштыра бирү** Аралаштыруны дәвам итү

**Аралаштыра төшү** Бераз аралаштыру, тагы да аралаштыру. *Бармакларын аралаштыра төшеп, Әхмәди бабай сүзен дәвам итте.* Казан утлары

**Аралаштырып алу** Тиз арада, бераз аралаштыру. *Барыйга кайсы төшне ныграк таптарга, ничек таптарга кирәклеген әйтте, сыек ләпеккә әледән-әле тирес ташлады һәм кулындагы көрәге белән балчыкны бутап, аралаштырып алды.* Н.Фәттах

**Аралаштырып бару** Берсе артыннан икенчесен, бер-бер артлы аралаштыру. *Аннан соң бит әле тагын шунысы да бар: моңа хәтле уку белән эшне гел аралаштырып барды ул.* М.Вәли-Барҗылы

**Аралаштырып бетерү** Тәмам, тулысынча аралаштыру. *Сыек ләпекне тирес һәм балчык белән аралаштырып бетерү*

**Аралаштырып кую** Алдан аралаштыру. *Измә өчен ком белән балчыкны аралаштырып кую*

**Аралаштырып ташлау** Искәрмәстән, көтмәгәндә, тиз-тиз аралаштыру. *Измәсен изеп, тирес белән аралаштырып ташлыйм әле шул уйнашчыны.* М.Хәсәнов

**Аралаштырып тору** Һәрвакыт, гел, бертуктаусыз аралаштыру. *---халыкларның бердәнбер матбугат органы булып кына калмый, бәлки төрки кардәшлек идеясен ныгытучы һәм төрки халыкларны үзара бәйләп, аралаштырып торучы үзенчәлекле гыйльми һәм мәдәни халыкара оешма вазифасын да үти.* М.Сәхапов. *Алар яшьләрне үзара якынайтып, аралаштырып тора, алар йогынтысында, мәктәпләр арасында дуслык күпере салына.* Р.Мирхәйдәров

**Аралаштырып чыгу** Һәрберсен, башыннан ахырына кадәр аралаштыру. *Үсентеләрне аралаштырып чыгу*

**АРАЛАШУ** *ф.* **1**. 1) Кем белән дә булса дустанә мөнәсәбәттә бәйләнеш тоту, еш очрашу, сөйләшү, фикер алышу, күрешү. *Әти-әниләре аралашмагач, алар да читләште.* М.Әмирханов. *Заһит алар белән турыдан-туры мөнәсәбәттә тормый, аның әле хәтта колхоз җитәкчеләре белән дә якыннан аралашканы юк.* М.Әмирханов. *[Муса] Рабфакта белем эсти, газета-журналлар белән элемтә тота, язучылар, зыялылар белән аралаша.* Ф.Сафин // Туган-тумачалар һ.б. белән бик якын булу, аларның хәл-әхвәлен белешеп, ярдәмләшү. *Кода-кодагый булып, үз*

*ишләрең белән аралашып, ярдәмләшеп яшәүгә ни җитә?!* Ф.Латыйфи // Ир-ат яки хатын-кыз белән очрашу, үзара якын мөнәсәбәттә булу. *Әмма Ләйлә барысын да кире какты, ир-ат заты белән аралашмады, кияүгә чыкмады.* Ф.Латыйфи

2) Нәрсә дә булса бергә кушылу, буталу. *Кыскасы, Гайниянең онга тиенү шатлыгы, бер үк вакытта, «җиремне ничек сөдерим?», «кемгә барып егылыйм?» сорауларыннан килеп туган кара кайгы белән аралашты.* Ф.Хөсни. *Теге яктан тынчулык, биредәге сидек исе белән аралашып, күңелне болгатып җибәрде.* Ф.Садриев. *Союзниклар, Италиягә төшкәч, немец гаскәрләре белән бергә аралашып сугышканнар.* Ш.Маннур. *Ишек төбенә килеп җитәрәк, әче сыра белән аралашкан тынчу һава борынын ярып керде.* Н.Хәсәнов. *Кыздан кояш нурлары белән аралашкан чәчәкләр исе, урман исе, дала исе килә иде.* С.Поварисов

3) Аңлашу, сөйләшү. *Ерткыч җанвар белән ничек аралашырга?* Р.Фәизов

**2.** *и. мәгь.* Сөйләшү, фикер алышу, аңлашу. *Әгәр кеше зыялыларның аралашу кагыйдәләрен бозса, ул үзенең кешелек дәрәҗәсен шик астына куя.* Ф.Углов. --- *икенчедән, зонаның сахра түгеллеген онытмыйк – анда аралашу да чикләнгән...* С.Йосыпов. *Аның сүзләренә караганда, «Беренче канал» тамашачылар белән аралашу моделен алыштырырга җыена.* Шәһри Казан

**Аралаша бару** Торган саен күбрәк аралашу. *Чөнки ул, берәр сүзләп-берәр сүзләп ана телендә аралаша барып, сизелми генә алмаша ала.* Г.Алпаров. --- *төрле башлангыч һәм юнәлешләрнең үзара кушыла, аралаша баруы «Рәссам»да ачык чагылышын тапкан.* Т.Галиуллин

**Аралаша башлау** Танышлык урнаштыру, аралашырга керешү. *Аның Габдулла Тукай белән якыннан аралаша башлавы һәм дуслашып китүе дә шушы вакытларга туры килә.* Р.Даутов

**Аралаша бирү** Аралашуны дәвам итү. --- *аргыяк – биргеякка, биргеяк аргыякка карата күпмедер дәрәҗәдә «оппозиция» саклап яши, уйнаша, сугыша, җырлаша, аралаша бирә иде.* М.Мәһдиев

**Аралаша тору** *к.* **аралашып тору**. – *Беренчедән, кешеләребездә нечкә зәвык тәрбияләсә, икенчедән, шулай язучылар белән аралаша торып, кем белә, безнең проблемалар турында да әдәби әсәрләр туар, – диде ул.* Р.Хисмәтуллин

**Аралаша төшү** Тагы да аралашу; бераз аралашу

**Аралашып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада аралашу. *Аның белән аралашып алу кирәк булыр сиңа.* Т.Галиуллин

**Аралашып бару** Берсе артыннан икенчесе эзлекле рәвештә аралашкан булу. *Соңрак гарәп һәм латин хәрефләре аралашып барган.* И.Надиров. *Ике тавыш аралашып бара – кыңгырау һәм тояк тавышлары.* М.Хуҗин. *Анда мәгънәсез җырлар мәгънәсез сүзләр белән аралашып бара.* Мәйдан

**Аралашып бетү** Тулысынча үзара буташып аралашу. *Юллар, сукмаклар аралашып бетkәннәр.* А.Шамов

**Аралашып китү**Ниндидер моменттан, вакыттан соң аралашу, аралаша башлау. *Теге көнне танышкан Гайнан исемле сөйкемле егет белән якыннан аралашып киттек.* С.Йосыпов. *Ләкин язучы халкы бик тиз аралашып китә бит ул.* Р.Сибат. *Мин бит сине, кешеләр белән тиз аралашып китүдән горурлыгы тыя, дип уйлый идем.* М.Хуҗин

**Аралашып тору** Һәрвакыт, даими, гел аралашу. *Кыюсызлык «һәрдаим үз-үзеңә ышанмау» дигән хәерсез хисгамәл белән аралашып тора.* З.Хөснияр

**АРАЛАШУЧАН** *с.* Тиз аралаша торган, аралашырга ярата торган; әңгәмәдәше белән сүз таба белгән. *Аның кеше белән аралашучан икәнлеге дә хәтерендә яхшы сакланган.* Р.Кәрами. *Холкы ягыннан кешеләр белән тиз аралашучан, бигрәк тә хатын-кыз белән.* З.Фәтхетдинов

**АРАЛАШУЧАНЛЫК** *и.* Аралашучан булу. *Имеш, миндә җитдилек, аралашучанлык җитми.* Р.Сәгъди

**АРА́ЛИЯ** *и. лат. бот.* Чормавыкчалар семьялыгыннан, эре яфраклы һәм себеркесыман чәчәк төркемле куак үсемлек (Көньяк һәм Көнчыгыш Азиядә, Төньяк Америкада үсә)

**АРАЛЫК** *и.* 1) Ике нәрсәне аерып торган ачык урын, буш ара. *Күңелендә малайлык шаяруы уянып, Тайфә карчыкларга урам як капкасыннан түгел, ә читән белән лапас арасындагы аралыктан, мәче кебек, шылт иткән тавыш чыгармый үтте.* Ф.Сафин. *Чүп баскан аралыкны үткәч, ул Нәбиләр тыкрыгына кадәр аягүрә торып чапты.* Н.Хәсәнов. *Каршы як тәрәзәләрдән кырларны карамакчы булды, ләкин берни күренми иде – аралык тулы кеше, тагын үз тәрәзәсенә елышты.* М.Хуҗин

2) *сөйл.* Авыл өйләрендә мич белән стена арасында калдырылган ара, ачыклык. *Мәдинә, утлы кисәү тоткандай кабаланып, утын агачын аралыкка ташлады.* М.Хәсәнов. *Кичке чәйдән соң, мич артындагы аралыкка, инде күптән кирәге беткән балалар караватына чүмәшеп, изрәп киткән иде китүен.* Җ.Рәхимов

3) Ике әйбер арасы, аларның интервалы. *Вагоннар тоташкан аралык бик каты чайкала.* Р.Вәлиев

4) Ара озынлыгы, ераклык. *Урманның бик киң түгел генә юлы тирәсендә, әледән-әле, яшь агачларның нәзек һәм сыгылмалы ботаклары кул белән тотып алырлык кына якын аралыкта калалар.* Ф.Әмирхан

5) *диал.* Ике каралты арасына салынган сарай. *Әнвәр тиз генә тәрәзәдән чыгып, аралыкка кача.* Г.Камал

**АРАН** *и.* 1) Нечкә бүрәнәдән, калын тактадан, саман кирпеченнән корылган җылы ат абзары. *Абу баба аран ишеген көч-хәл белән генә ачып керде.* Б.Сөләйман. *[Әтиең] Лапас артындагы аран буенда таптана икән.* Р.Низамиев

2) Абзарда бер ат яки сыер өчен киртә яисә такта белән бүлеп куелган урын. *Карпат, араннан башын күтәреп, аларга карый: ни кирәк, янәсе, ни йомышыгыз төште?* Хәйдәр. *Аны, күбрәк, аранда гына тоталар.* Ә.Еники

3) Маллар өчен махсус киртәләп алынган ачык урын. *Терлекләр урман буендагы аранга ябылды*

4) *тех.* Трамвай, троллейбус, локомотив ремонтлау өчен билгеләнгән махсус урын, секция. *Уртада – ак бетон түшәлгән юл, ике якта ак бетон плитәләрдән төзелгән бүлмәләр – араннар иде*. Х.Камалов

**АРАНЖИРО́ВКА** *и. фр. муз.* Берәр музыка коралында уйнау өчен язылган музыкаль әсәрне икенче бер уен коралында яки берьюлы берничә уен коралында башкару, берничә тавышка җырлау өчен эшкәртү. *Ул, режиссёр буларак, әле бер дә җыр язып карамаган, бары тик аранжировкалар белән генә шөгыльләнгән Рәискә «Газинур җыры»н иҗат итәргә киңәш бирә.* М.Макаров

**АРАНЖИРО́ВКАЛАУ** *ф. муз.* Аранжировка ясау

**АРАНЛЫК** *и.* 1) *к.* **аран** (*2 мәгъ.*). *Абзарга керсәм, аранлык буш иде*

2) Ат араны, мал сарае. *Ул бит, тегенең шикелле, аранлыкта солы да печән генә ашап ятмый, көне-төне җигелә, эшли*. Ә.Галиев

**АРАТ** *и. монг.* Монгол һәм туваларда: иген игүче, көтүче, терлек асраучы

**АРАТА** *и.* 1) Багана, казык һ.б.ш.ның ике ягына рәт-рәт аркылы беркетелгән берничә озын агач. *Текә баскычның тимер араталарыннан кул-аяклар таеп-таеп китә.* Р.Кәрами

2) Аркылы борыс, киртә, планка (арбада, көймәдә, коймада). *Кыз, күпер аратасына тотынган килеш, аңа карап үксеп елый*. Р.Хафизова

3) *спорт* Тигез аралы терәкләргә горизонталь беркетелгән ике янәшә борыстан гыйбарәт гимнастик җиһаз

4) *диал.* Өрлек

**АРАТАЛА́У** *ф.* 1) Арата белән уратып алу, тирә-ягына арата тоту

2) Арата куеп, бер-берсенә беркетү, арата белән үзара тоташтыру. *Минә каяндыр җигүле атлар килеп чыкты, арбалардан бүрәнәләрне араталап беркеткән кечкенә салларга охшаш җайланмалар төшерде*. Ф.Латыйпов

3) *сөйл.* Берәр нәрсәне икенче әйбергә аркылы кую. *Бер таза егет беләге белән ишекне араталады.* М.Хуҗин

**Араталап алу** Бөтен тирә-ягын араталау. *Бакчаны араталап алу*

**Араталап бетерү** Тулысынча, тоташ араталау. *Игенлекне араталап бетерү*

**Араталап кую** Араталанган хәлгә китереп калдыру. *Бакчаны араталап кую*

**Араталап тору** Һәрвакыт, гел араталау. *Игенлекләрне араталап тору*

**Араталап чыгу** Һәрберсен, башыннан ахырына кадәр араталау. *Бакчаны араталап чыгу*

**АРАТАЛЫК** *с.* **1**. Арата итеп файдалана алырлык, аратага ярарлык. *Күрше авылдан араталык такта алып килергә куштым*

**2**. *и. мәгъ.* 1) Арата өчен материал. *Әти базардан араталык алып кайтты*

2) *к.* **арата** (*1 мәгъ.*). *[Ак айгыр] Араталык аша сузылып, [хуҗасы] кочагына башын тыкты.* Ф.Яхин

**АРА́-ТИРӘ** *рәв.* 1) Кайчак, кайвакыт, сирәк-сирәк. *Ара-тирә, Фәтхетдин хатларына да җавап бирә.* Р.Хафизова. --- *яңа кешеләр белән ара-тирә сөйләшкәләп алу гына Абдулланың тынгысыз йөрәген баса алмый иде.* Э.Касыймов

2) Сирәк, әллә нидә бер, онытылып беткәндә. *Без аның шәкерт чагында ук «ачы суны» ара-тирә авыз иткәнлеген күргән идек*. И.Нуруллин

3) Вакыты-вакыты белән, әледәнәле. *Алар арасында бердәнбер ир кеше Зәки абый да, түзми, ара-тирә кычкырып куя*. Р.Хафизова. *Ара-тирә кабыштырса да, [Вафа] аракы белән артык мавыкмады*. З.Моталлапов // Урыны-урыны белән, аз-азлап. *Мин ни диярга белмәдем. Тик Әхминең рәхимсезлеге хакында ара-тирә бер-ике сүз кыстыргаладым*. Г.Ибраһимов

4) Өзек-өзек; әле – бер, әле икенче урыннан. *Гөлдания китапның битләрен, ара-тирә укып, ахырына кадәр карап чыкты*

5) Әле монда, әле тегендә; анда-санда, берән-сәрән. *Ара-тирә көлешкән тавышлар да тынды.* Р.Кәрами

**АРА́-ТУРА** *рәв. диал. к.* **ара-тирә**

**АРА́У** *ф. иск.* Берәр нәрсә эзләү, көтү, сорау, өметләнү. *Аһ, чәчәкләр, былтыр, сезне өзеп, Кемнең күкрәгенә кададым, Кемгә кадап, кемгә моңлы карап, Күзләреннән җавап арадым?* Ш.Бабич

**АРАУКА́РИЯ** *и.* Араукариячәләр семьялыгыннан, Көньяк Америкада һәм Австралиядә таралган, биек булып үсә торган, чатырсыман ябалдашлы мәңге яшел ылыслы агачлар ыругы (Чилидагы Араука провинциясе исеменнән). *Хәзерге вакытта араукарияләр Көньяк ярымшарның тропик һәм субтропик зоналарында киң таралган.* Л.Мәүлүдова

**АРА́ХИС** *и. гр. бот.* 1) Кузаклылар семьялыгыннан, кызыл тышчалы озынча тар җимешләре кузаклары эчендә тезелеп үсә торган майлы үсемлек. *Дөньякүләм зур мәйданнарда эшкәртелүче төп культуралы үсемлекләр исәбенә соя, фасоль, борчак, арахис, ногыт керә.* Л.Мәүлүдова

2) Шул үсемлекнең җимеше; кытай яки җир чикләвеге. *Бу сый инжир белән җир җиләгенә арахис чикләвеге кушып ясалган ризыкны хәтерләтә иде.* Р.Сәгъди

**АРБА** *и. гар.* 1) Хуҗалыкта, йөк ташу өчен, атка җигелә торган дүрт тәгәрмәчле транспорт чарасы. *Урамда арба шыгырдаган тавыш ишетелде, карасам: көлтә төялгән аллы-артлы ике арба югары таба менеп баралар.* Г.Ибраһимов. *Кинәт арба, дырт-дырт итеп, нәрсәгәдер бәрелә-сугыла узды.* Н.Дәүли. *Ә бүген!.. Без йоклаган арба төбендәге, кичә генә чабып кайтарылган печән исе дә мине исертә.* М.Әмир

2) Йөк ташу өчен җайланган, кул белән этеп, тартып яки җиңел машинага һ.б.га тагып йөртелә торган ике яки дүрт тәгәрмәчле хуҗалык әйбере. *Рөстәм Әхмәткә велосипед арбасыннан сүтеп алган частьларны яшерергә ымлады.* Р.Хафизова. *Шул көнне үк Галимә, бәләкәй арба тартып, элеваторга чыгып китә.* Хәйдәр. *Шулвакыт Бәдринең арба белән чыгып барган тавышы ишетелә.* М.Фәйзи

3) Йөк транспортында йөк ташу яки кеше утыртып йөртү өчен махсус җайланган, өсте ачык яки ябулы кузов. *Дүрт тәгәрмәч өстенә ящик куелган, «трамвай» дип аталган арба атлар белән хәрәкәткә китерелгән.* А.Алиш. *Бер куәтле «Кировец» тракторы озын арбага салынган юан колонна сөйрәп бара.* Р.Кәрами

4) Сугышта: туп, снаряд ташу җайланмасы. *Хәзер инде барысына да тәбәнәк атларга җигелгән нечкә көпшәле ике пушка белән снаряд арбасы ачык [күренә]*. К.Нәҗми

5) *спорт* Ат ярышында ике тәгәрмәчле, өсте ачык җиңел транспорт чарасы. *Чаптар бия, биш ел чамасы, ике эрзинкә көпчәкле җиңел арба өстерәп, ипподром юлларында беренчелекне алып, зур дан тоткан асыл хайван булган икән шул.* З.Зәйнуллин

6) *сөйл.* Сабыйларны утыртып яки яткырып йөртү өчен ясалган дүрт тәгәрмәчле махсус җайланма; коляска. *Ирек ишегалдында Алмазны арбада тартып йөри.* Ф.Садриев

7) *сөйл.* Инвалидлар коляскасы. *Аның аяклары тездән түбән генә юк. --- Утырып йөри торган арбасы белән баскычтан төшү уңайсыз иде аңа*. Т.Миңнуллин

8) *куч.* Бергә эшләгән, бергә тормышка ашырган уртак эшчәнлек, тормыштагы уртак авырлыклар. *Бер арбада, без «Нур» арбасында Киләчәккә үтик әле тагын...* Р.Әхмәтҗан

◊ **Арба белән куян тоту** Кирәкмәгән, мәгънәсез эш эшләү. **Арбага җигелү** Коллектив белән җитәкчелек эшенә алыну. *Дөрес, ул үзенең кая килүен, нинди арбага җигелүен белә иде.* Р.Кәрами. **Арбадан төшеп калмау** Үз дәрәҗәсен, абруен саклау; булдыклы булу. *Егетнең үзенә дә әйттем, дөньялар ничек кенә болганса да, барыбер, безнең нәсел арбадан төшеп калмады.* Ф.Сафин. **Арбадан төшеп калу** Билгеле бер кешеләр төркеменнән читкә этәрелү, дәрәҗәсен яки эш урынын югалту, булдыксыз булып калу. *Ә инде «дан, шөһрәт» дигән алдавыч нәрсәләрдән авыз итеп өлгергән кемсә өчен арбадан төшеп калу – чын-чынлап фаҗига*. Т.Миңнуллин. **Арбадан төшереп калдыру** Читләштерү, эштән яки вазифадан бушату; аяк чалу. *– Арбадан төшереп калдырырга иртә әле безне. Дөнья дилбегәсе кулдан ычкынмаган, җаным, – дип, башта серле-сәер генә сөйләште ул.* В.Имамов

**АРБА́ АЛДЫ** *и.* Арбаның кендек белән тоташтырыла торган алгы өлеше

**АРБАГА́Й-ТЫРБАГАЙ** *с.* Төрле якка тырпаеп, чыгып торган

**АРБА́ КАРАМАЛАРЫ** *и.* Арбаның төбен тоташтырып торган, дугаланып эшләнгән агачлар

**АРБАКАШ** *и.* Олаучы, йөк ташучы, арбачы; кучер. *Инде кабул күрмәсәң, Кайлардан кая китием? Арбакаш булып, су ташып, Әүкатемне итием.* Дастан

**АРБА́ КЕНДЕГЕ** *и.* Арба алдын төп арбага тоташтырып торган озынча юан тимер. *Баганага, хәвеф-хәтәр чыкса дип, чаң кагар өчен, тимер юл шпалы һәм арба кендеге асылган.* Д.Салихов

**АРБА́ КҮКРӘГЕ** *и.* Арбаның алгы күчәренә кендек ярдәмендә тоташа торган өлеше

**АРБАЛАП** *рәв.* Арба белән. *[Прокурор:] Бер кесә ашлык өчен без кешеләрне унар елга утыртабыз, ә син арбалап таратасың.* М.Әмирханов

**АРБАЛЕТ** *и. фр. тар.* Урта гасырларда укны, ядрәне, корыч яки агач җәягә тарттырып, механик көч ярдәмендә атып җибәрү җайланмасы; үзаткыч. *Сәрпи ук – арбалет белән ата торган зур ук*. М.Хәбибуллин

**АРБАЛЕТЧЫ** *и. тар.* Арбалеттан атучы

**АРБАЛЫ** *с.* 1) Арба җигелгән, арбасы булган. *Ә бүген --- монда – шыгрым тулы халык, --- арбалы атлар, чалгы, тырма, капчык тоткан кешеләр*. А.Чурбанов

2) Җигүле арбага утырган. *Безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады.* Г.Тукай. *Ярты чакрым юл үткәнмендер, артымнан ат җиккән арбалы кеше килеп чыкты.* Х.Ибраһимов

3) *куч. сөйл.* Нәрсә генә эшләсә дә, дөбер-шатыр килеп, бәрелеп-сугылып, орынып йөри торган. *Арбалы кеше ишеккә сыймас.* Мәкаль

**АРБАЛЫК** *с.* **1**. 1) Арба ясарга яраклы, арба ясарга җитәрлек

2) Бер арбага сыярлык. *Авыл карты кагып куйды дилбегәсен һәм Чайкалды хәтерендә бер арбалык гаиләсе: Олы улы, уртанчысы, кече малай, төпчек кызы.* Р.Мингалим. *Тонна, иптәшләр, бәләкәй әйбер түгел! Кимендә ул – ике арбалык*. Х.Туфан

**2**. *и. мәгъ.* 1) Арба ясарга әзерләнгән материал. *Арбалык хәстәрләү*

2) Бер арбага сыярлык итеп куелган көлтә өеме, кечкенә зурат. *[Карчыклар], кыштырдый торгач, шактый гына эш эшләп ташлаганнар: кысыпкысып бәйләнгән көлтәләре пөхтә итеп куелган арбалыклар --- тезелешеп-тезелешеп торалар иде.* Ф.Хөсни

**АРБА́У** *ф.* **1**. 1) *иск.* Әфсенләү, сихерләү

2) Кемнең дә булса игътибарын үзенә җәлеп иттерү, карату, сихри сүз белән үз ихтыярына буйсындыру, яраттыру. *Китапның үзенә тарту, күңелне арбау, сихерләү һәм шаукымландыру сәләте азыктан, акчадан һәм магниттан көчлерәк.* А.Хәлим

3) *диал.* Тәэсир итү, үз юлына төшерү, күндерү. --- *йола җыры «Яңа өйне арбау»да түбәндәге сүзләр бар: «Чулпан бабай мал бирсен, Зәнки бабай юл бирсен»*. Ф.Урманче

**2**. *и. мәгъ.* Әфсен сүзе, тылсым; сихерләү чарасы, серле ысул. *Арбавын белсәң, кара елан да карышмый.* Мәкаль. *Нинди ирен арбау пышылдады?* Р.Харис

**АРБАУЧЫ** *и.* Тылсым иясе; сихерче. *Болары – имче-сихерчеләр, арбаучы-ырымчылар тарафыннан әйтелә торган гадәти сүзләр.* Ф.Урманче

**АРБАЧЫ** *и.* 1) Арба ясаучы

2) Арба сатучы. *Арбачылар башлыча кала кешеләре булса, утынчыларның барысы диярлек төньяктан – таулар арасыннан килгән авыл кешеләре*. Н.Фәттах

3) Кешеләр яки йөк ташый торган арбалы атлар йөртүче. *Субай --- арбачыга кул болгады.* М.Хәбибуллин

**АРБИТР** *и. лат.* 1) Ике арадагы бәхәсләрне хәл итәргә алынган кеше, арадашчы

2) Кайбер төр спорт ярышларында судья. *Әмма соңгы минутларда арбитрлар аның күп кенә уңышлы алымнарын нигъдер «күрмәделәр» һәм очко исәпләмәделәр.* Н.Максимов

**АРБИТРАЖ** *и. фр.* 1) Юридик затлар (предприятиеләр һәм оешмалар) арасында барлыкка килгән мөлкәт бәхәсләрен хәл итә торган махсус орган.

*Бу өлкәдә Дәүләт арбитражы башкаларга матур үрнәк күрсәтте.* Р.Миңнуллин

2) Суд хөкеменә карамаган бәхәсле мәсьәләләрне арбитрлар (*1 мәгъ.*) хәл итү

**АРБИТРЛЫК** *и.* 1) Арбитр эшчәнлеге (шөгыле, эше)

2) Арбитр бурычы (вазифасы)

**АРБОЛИТ** *и. гр.* **1.** Бетонга агач калдыклары, йомычка ише әйберләр кушып ясалган, аз катлы йортлар төзегәндә кулланыла торган җиңел төзелеш материалы төре

**2.** *с. мәгъ.* Шундый төзелеш материалыннан ясалган, салынган. *Менә бу арболит плитәдән салынган ике йорт әлегә буш.* А.Вергазов

**АРГАМАК** *и.* **1.** Чабышкы ат; яхшы токымлы йөгерек ат. *Тәңре аргамакны, яратып, җир өстенә җибәргәч, аның матурлыгына сокланмаган зат калмаган.* Т.Миңнуллин. *Дөньяда иң шәп нәселле атлар гарәп аргамаклары санала.* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Йөгерек, чабышта катнаша торган. *«Исме Әгъзам» догасы ярдәмендә ---, хәтта, кул астына аргамак атын, елгыр лачынын --- китертә алган.* М.Госманов

**АРГЕНТИ́НАЛЫ** *и.* Аргентинада туып үскән һәм шунда яшәүче, нигездә католик динендәге, испан теленең аргентина диалектында сөйләшүче халык; шул халыкның бер кешесе. *Башка матчларда балкыган «йолдыз»лар – аргентиналы Домингес та, бразияле Калисто да – бу юлы яшь кенә егетләр алдында берни майтара алмадылар.* Ватаным Татарстан

**АРГО** *и. фр. лингв.* Билгеле бер төркем (мәс., караклар) сөйләмендә генә кулланыла торган сүзләр; жаргон. *Гади сөйләм, жаргон һәм арго сүзләрнең, бигрәк тә тупас сүзләрнең, аерым кешеләр сөйләмендә мул кулланылуы аларның культура дәрәҗәләре югары булмавын күрсәтә.* Р.Юсупов

**АРГОН** *и. гр.* Химик элемент (Ar), һава составына кергән иссез, төссез инерцияле газ (металлургиядә, химиядә һ.б.да кулланыла, электр лампаларына тутырыла). *Мин хәзер, вакуум булмәсенә кереп, моның эченә аргон газы һәм, яхшырак яктыртсын өчен, терекөмеш салырга тиеш.* А.Вергазов

**АРГОНАВТЛАР** *и. гр. кит.* 1) Борынгы грек мифологиясе буенча: «Арго» кораблендә Колхида ярларына тылсымлы тәкәнең алтын тиресен эзләп барган геройлар. *Аргонавтлар шушыннан Эгей патшасының алтын тәкә тиресен һәм аның чибәр кызы Медеяны урлап киткәннәр.* М.Юныс. *Ниһаять, миңа борынгы аргонавтлар йөзгән Урта диңгез дулкыннарына колач салу 1981 елның май аенда насыйп булды.* М.Галиев

2) *күч.* Батыр диңгезче-сәяхәтчеләр; маҗара эзләүчеләр

3) *күч.* Фәнни экспедицияләрдә, сәяхәтләрдә катнашучы(лар)

**АРГОТИЗМ** *и. фр. лингв.* Әдәби телгә берәр аргодан, жаргоннан үтеп кергән сүз; арго сүз

**АРГУМЕНТ** *и. лат.* 1) Берәр нәрсәне раслау яки аның киресен исбатлау өчен китерелә торган дәлил, нигез. *[Хөсәен:] Ләкин син моны бер генә аргумент белән дә исбат итә алмыйсың бит.* А.Расих. *Ә матур фразаларга төрелгән аргументны шәрәләндерсәң, асылын ачсаң, аның нигезендә, барыбер, шул салам яндыру-яндырмау факты калачак.* Х.Хәйруллин

2) *мат.* Ирекле рәвештә үзгәрә торган алмаш зурлык

**АРГУМЕНТА́ЦИЯ** *и.* 1) Аргументлар китерү ярдәмендә нәрсәне дә булса раслау ысулы, дәлилләү алымы

2) Аргументлар (*1 мәгъ.*) җыелмасы

**АРГУМЕНТЛА́У** *ф.* Аргумент китерү; аргументлар белән дәлилләү, аргументка нигезләү. *Фән теле белән, һәр сүзен аргументлап, сабыр гына сөйләде ул анда.* Т.Миңнуллин

**Аргументлап бирү** Дәлилләргә нигезләнеп, аңлаешлы итеп аргументлау

**АРГУМЕНТЛЫ** *с.* Аргументы булган, аргумент китерелгән, аргументка нигезләнгән. *Менә бу аргументлы синдромны күрәсеңме?* Р.Гаффар

**АРГЫ** *с.* 1) Кара-каршысы, икенче ягында булган; теге (ике яклы яки ике очлы нәрсәләргә карата кулланыла). *Өстәлнең аргы почмагында, каешын бер якка кыйшайтып, моңаеп кына, гармун тора.* Р.Хафизова. *[Телефон] Чыбыкның аргы башы бер мәлгә тынды.* Н.Хәсәнов. *Айрат Бәдретдинович --- ярның аргы ягындагы хатын-кызларны берәм-берәм барлый башлады.* А.Вергазов. *Гайния апаның сыерлары озын абзарның аргы башында ук иде.* М.Хәсәнов // Берәр нәрсәнең ерактагы баш өлеше. *Ә-әнә чүнникнең аргы башындагы шәрәрәк наратны күрәсеңме?* М.Хуҗин. *Паркка түгел, урамыбызның аргы башына да барып җитмәдем, бәлагә тап булдым.* А.Шамов. *Станциянең аргы ягында – кар басып киткән кыр.* Ф.Хөсни

2) *сөйл.* Санны белдергән сүз белән килеп, шуннан соң, шул санны узганнан соң, мәгънәләрен белдерә. *[Шәйхулла карт:] Яшең сиксәннең аргы ягына чыккач, бик пөхтә булып булмый икән ул.* Д.Салихов

**АРГЫ́ ОЧ** *и.* Гадәттә шәһәрнең, авылның, урамның үзәктән ераклашкан ягы, икенче башы. *Мәктәптә дә хәзер мине аргы очның атаманы Гатуф белән утырттылар.* Р.Хафизова

**АРГЫШ** *и. этн.* 1) Туй олаулары (поезды)

2) Туй олаулары башлыгы (хатын-кыз булуы мәҗбүри)

3) Туй башлыгы, мәҗлес хуҗасы. *Туй мәҗлесенең үзенә килгәндә, анда персонажларның иң үзәктәгесе аргыш – туй башлыгы.* Татар халык иҗаты

4) *күч.* Шәрәфле кунак

**АРГЫЯК** *и. к.* **аргы оч.** *Безнең авыл ике урамнан булып, шул урамнар икешәр «оч»тан тора. «Аргыяк», «Биргеяк». Теге як өчен без – «аргыяк», безнең өчен теге як – «аргыяк».* М.Мәһдиев

**АРГЫ́ ЯК** *и. к.* **аргы оч**. *Аргы якның кыр казларын бирге яктан саныйбыз...* Җыр

**АРДАК** *и. диал.* 1) Кадер-хөрмәт, игътибар. *Асрадың, әнкәй, син ардакта, ятыр урыным – югары чардакта.* Җыр

2) Наз, иркә, иркәлек. *Утта янып харап булган илдә кызның ардагы.* Бәет

**АРДАКЛА́У** *ф. диал.* 1) Кадер-хөрмәт күрсәтү, кадерләү; хөрмәтләү. *[Бакый:]Менә ул синең колың! Аны*

*ардаклап куандыра торган яр мин.* М.Фәйзи. *Менә шуның өчен дә халык аны үз эшенә карап кына ардакламый (олыламый), бәлки бабаларының изгеләрдән, өлкәннәрдән булуларына карап та ардаклый иде.* Әдипләребез

2) Сөю, иркәләү

**АРДАКЛЫ** *с. диал.* 1) Хөрмәтле, хөрмәткә ия, мактаулы. *Кызны кодаларга үзе барган ардаклы, хөрмәтле кешенең малае адәм ышанмас явызлык кылды. Әхмәйгә ярәшелгән Миңлегөлне урлап, үзләренең чапкын айгыры белән каядыр китеп олакты.* Ф.Мансуров.

2) Кадерле, якын; иркә. *Ардаклыйдем, хөрмәтлейдем Әткәй-әнкәй түрендә.* Жыр

**АРДАКСЫЗ** *с. диал.* Кадерсез, хөрмәтсез. *Аталы бала ардаклы, Атасыз бала ардаксыз.* Мәкаль. *Анасыз балалар ардаксыз.* Жыр

**АРДЫРТУ** *ф. к.* **ардыру**

**Ардырта башлау** Ардыртырга тотыну. *Яшь бабай дәшми утыра да: – Бераз ардырта башлады, – ди.* Т.Миңнуллин

**АРДЫРУ** *ф.* Арыту, талчыктыру, йончыту. *Гомумән, ул күп сөйләшкәнне яратмый, эш түгел, күп сүз ардыра иде аны.* Р.Сибат. *Көне буе, җәяүләп, кырык чакрым араны узу да нык ардыра.* Т.Нәбиуллин

**Ардыра төшү** Бераз, берникадәр ардыру. *Як-ягымдагы бөтен күз күреме җирдә мыжгып, кайнап торган халык диңгезе дә, озак карый торгач, ардыра төште.* Г.Бәширов

**Ардырып бетерү** Тәмам, соң чиккә җитеп ардыру. *Әгәр дә аның җырчы икәнен белсәләр, истәлек имзалары сорап, кунакка чакырып, җырлатып ардырып бетерәчәкләр.* Р.Батулла

**Ардырып җибәрү** Кинәт ардыру; бераз, җиңелчә ардыру. *Бар дөньяга шаулап, ыгы-зыгы килеп, кайчак, энем, бик ардырып җибәрәсең.* Р.Шәрипов

**Ардырып тору** Әле, хәзер бераз ардырган булу. *Мин, синең белән бәхәсләшеп, телемне дә ардырып тормыйм.* К.Тимбикова

**АРЕАЛ** *и. лат.* 1) *зоол. биол.* Тегe яки бу хайванның яисә үсемлекнең җирдә, суда таралу өлкәсе. *Республиканың территориясендә яки ареал чигендә булган төрләрнең популяцияләрен дә даими контрольдә һәм күзәтүдә тотарга кирәк.* И.Рәхимов, К.Ибраһимова

2) *кит.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса (күренешнең, әйбернең) таралып урнашу өлкәсе. *Чыннан да, җирдә, адәм баласының яшәү ареалында, төгәл, бәхетле тормыш кору өчен күпме эшлисе, күпме көч түгәсе бар!* М.Юныс

**АРЕ́НА** *и. лат.* 1) Циркта: залның үзәгендә төрле тамашалар күрсәтү өчен көйләнгән түгәрәк мәйдан; манеж. *Беренче карашка, алар цирк аренасындагы гладиаторларны хәтерләтәләр.* М.Хәсәнов. *Аларның язмышы аяныч: тамашачының кәефен күрер өчен, цирк аренасында бер-берсен үтерергә тиеш булалар.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Берәр төрле эшчәнлек өлкәсе. *Инде андыйларның җитәкчелек аренасыннан киткәненә илле-алтмыш ел гына түгелдер.* Ф.Садриев. *Шагыйрь поэзиясендә күтәрелгән --- темалар һәм мотивларның күбесе тарих аренасына Утыз Имәнидән соң аяк баскан татар мәгърифәтчеләренең карашлары белән авазлаш яңгырыйлар.* Ә.Шәрипов

**АРЕ́НДА** *и. пол.* 1) Шартнамә нигезендә, билгеле бер хак түләп, кучемсез милектән вакытлыча файдалану. *Ә кулакка хөкүмәт юлны ачты: кулак арендага җир ала, батрак тота, аңа шундый хокук бирелде.* И.Гази

2) *сөйл.* Шундый файдалану өчен түләү. *«Сәйяр»ның эшләре бик шәптән түгел, театр арендасы бик кыйммәт.* Г.Камал

**АРЕ́НДАЛАУ** *ф.* Арендага алу. *Тимер юл билетлары, кунакханәләр кыйммәт, театр бинасын арендалау зур акча сорый.* М.Сәлимҗанов

**Арендалап тору** Әле, хәзерге вакытта арендалау, арендаланган хәлдә файдалану

**АРЕНДА́ТОР** *и. рус к.* **арендачы**. *Минем абыем Рәүфнең улы – безнең «Яңарыш» арендаторлар берлеге рәисе...* Р.Сибат

**АРЕ́НДАЧЫ** *и.* Арендага алучы, арендалаучы. *Ул – Кукмара районындагы «Яңа тормыш» арендачылар берләшмәсе җитәкчесе Рәфыйк Габдерәүф улы Рәүпов.* Ф.Галимуллин

**АРЕО́ЛА** *и. лат. мед.* 1) Имчәк башы яны түгәрәге. *Еш кына бәбиләр, ими башы белән генә канәгатьләнеп, ареолны капмыйча гына имәләр.* Ватаным Татарстан

2) Тәндә зур булмаган пигментлы урын

**АРЕО́МЕТР** *и. гр. физ.* Сыеклыкларның һәм таралучан каты матдәләрнең тыгызлыгын, куелыгын үлчи торган әсбап

**АРЕСТ** *и. нем.* 1) Кулга алу, сак астына алу, иректән мәхрүм итү. *«Арест!» Бер дә ишетәсе килми бу сүзне.* Н.Хәсәнов

2) Хөкем карары нигезендә мөлкәт һәм акча маясыннан файдалануны тыю. *– Каян алыйм мин ул акчаны, болай да арестта утырабыз, бирәчәк – муеннан, – ди бит бу.* Х.Хәйруллин. *[Прокурор:] – Ашлык ведомостена арест салам, – диде ул аңа.* М.Әмирханов

**АРЕСТАНТ** *и. рус* Ирегеннән мәхрүм ителгән, кулга алынган кеше. *[Сабиров:] Нәрсә сөйлим? Менә, арестант хәлендә, сезнең каршыга китереп бастырдылар.* Ф.Сафин

**АРЕФЛЕКСИ́Я** *и. гр.-лат. мед.* Бер яки берничә рефлекс булмау

**АРЗАН** *с.* **1.** 1) Түбән хактагы (бәяле), очсыз, юнь; *киресе:* **кыйммәт.** *Хәлсез хуҗалыклар исә икмәкләрен көз көне үк хөкүмәткә арзан бәягә сатып бетерде.* Ф.Сафин

2) *күч. сөйл. к.* **арзанлы** (*3 мәгъ.*). *Качтым арзан ләззәтләрдән, Баш идем Мәхәббәткә!* Р.Рахмани. *Сөйләүчеләребез эстрада сәхнәсен гел кәмиткә, гел арзан шаяруга гына әверелдереп калдырмагайлары, дигән шөбһә бар.* Р.Батулла

**2. арзанга** *рәв. мәгъ.* Түбән бәягә, түбән бәя белән, очсызга. *Әзер йорт сатып алу арзанга төшә!* К.Кәримов. *[Иптәшләре] Атларның азрак арзанга булса да сатылуы белән килештеләр.* З.Зәйнуллин

◊ **Арзанга бирмәү** Берәр нәрсә өчен бик нык көрәшү, күп көч кую. *[Туйкә:] Минем үчем олы, Имән батыр, арзанга гына гомеремне бирмәм!* В.Имамов.

*Ә инде һәлак булырга туры килсә, мин тормышымны арзанга бирмәячәкмен!* Р.Батулла. **Арзанга килмәү** Берәр нәрсәне башкарып чыгу өчен бик күп көч һәм вакыт сарыф ителү, авырга туры килү. *Бүрегә мондый гимнастика арзанга туры килмәгәндер, билгеле.* Ә.Баян. **Арзанга кую** Берәр нәрсәнең, хезмәтнең бәясен төшерү, тиешле хакын киметү. **Арзанга төшмәү** *к.* **арзанга килмәү.** *Күрше-тирә мине мактап сөйли башлады: тик бу хәл минем өчен бик арзанга төшмәде.* Г.Садри

**АРЗАНАЙТУ** *ф.* 1) Бәясен төшерү, очсызландыру, түбәнәйтү. *Хәзер --- крәстиянгә кирәк булган завод-фабрика малларын арзанайту юлы тотыла.* Һ.Такташ. *Товарларның бәясен арзанайту.* Х.Туфан

2) *күч.* Түбәнсетү, дәрәҗәсен төшерү. *Инде «суверенитет» сүзен арзанайта, таушалта башладык.* Т.Миңнуллин. *Гөлфинурга Шәмсүннең җитәкчеләргә хас кырыслыгы, хатын-кыз чибәрлеге каршында баш иеп, үзен арзанайтып маташмавы ошады.* А.Вергазов

**Арзанайта төшү** Бераз, берникадәр арзанайту

**Арзанайтып бетерү** Тәмам, бик нык арзанайту

**Арзанайтып кую** Кинәт арзанайту; алдан ук арзанайту

**Арзанайтып тору** Даими, әледән-әле арзанайту

**АРЗАНАЮ** *ф.* 1) Бәясе төшү, очсызлану, бәясе кимү. *Сатучы күбәйгәч, сыерларның бәһасе бик арзанайды.* В.Нуруллин

2) Дәрәҗәсе төшү, әһәмияте кимү. *Ә монда кайтып, якташлары белән аралашкач, кызыйның үзенә куйган бәясе арзанайды.* Г.Бәширов. *Яшәвегезнең мәгънәсе арзанайды, гыйшкыгыз саекты.* Т.Миңнуллин. *Бар иде кыйммәтле фикерем – ул да арзанайды.* Ш.Галиев

**Арзанаеп бетү** Бик нык арзанаю

**Арзанаеп калу** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң арзанаю. *Әллә югыйсә әдәбият, элекке тылсымлы тәэсир көчен югалтып, дәрәҗәсен төшердеме? Арзанаеп калдымы?* Г.Бәширов

**Арзанаеп китү** Бераз, берникадәр, соңгы вакытта кинәт арзанаю

**Арзанаеп кую** Кинәт арзанаю

**Арзанаеп тору** Һәрвакыт, әледән-әле арзанаю

**Арзаная бару** Торган саен ныграк арзанаю. *Әмма, ни кызганыч, җәмгыятьтә көннән-көн мал кыйбатлана, җан арзаная бара.* Т.Миңнуллин

**Арзаная төшү** Бераз арзанаю

**АРЗАНЛАНУ** *ф. к.* **арзанаю**

**Арзанлана төшү** *к.* **арзаная төшү**. *Базар ябылыр алдыннан, сатылып бетмичә калган җимешләр тагын да арзанлана төште.* М.Юныс

**АРЗАНЛАШУ** *ф. сөйл. к.* **арзанаю**

**АРЗАНЛЫ** *с.* 1) Кыйммәт түгел, юньсез, очсыз; сатылган әйберләре түбән бәяле булган. *Мин укыган рабфакта арзанлы ашханә барлыгы искә төште.* Ә.Гаффар

2) Күп көч, тырышлык сорамый торган, җиңел табыла яки башкарыла торган. *Туздырылган, таланган Болгар урысларга иң арзанлы җим булып калачак.* М.Гайнетдинов. *Шул шул, бердәнбер арзанлы рәхәт безнең өчен – кәләш алу.* М.Әмир

3) *күч.* Нигезсез, әһәмиятсез, игътибарга лаексыз. *Шушындый әйбәт хәзергелек мизгелен ташлап киләчәккә ашыгу – арзанлы дуамаллык кына бит ул.* М.Юныс

4) *күч.* Буш, юк-бар, кирәк-кирәкмәс (сүзләр, хәрәкәтләр һ.б. турында). *Аш китерүче мондый арзанлы тел шомартуларны күп күргәнгә охшый.* Т.Галиуллин

**АРЗАНЛЫК** *и.* Арзан булу. *Шуның өстенә һәртөрле азыкның муллыгы һәм арзанлыгы үпкәсенә сихәт эзләүчеләрне бу тирәләргә күпләп тарта башлый.* Ә.Еники

**АРЗАНЧЫЛЫК** *и.* Әйберләр арзан булу, юньсез бәяле булу; очсызлык; *киресе*: **кыйммәтчелек**. *Ул заманда хезмәт хаклары зур түгел иде, ләкин арзанчылык аркасында бәрәкәтле иде.* Ә.Еники

**АРЗУ** *и. фар. иск. кит.* 1) Кызыксыну, дәрт, азарт. *«Гаип казна» дигән сүз Тудыра һәркемдә бер арзу.* М.Гафури

2) Теләк, омтылыш. *Янә мәхәббәте артып, хәзрәти Рәсүлне күрмәгә арзу кыйлды.* К.Насыйри

**АРЗУ́ ИТҮ** *ф. иск.* Теләү. *Шул сәбәптән, бу мәдрәсәдә дәрес итәчәк гали мөдәррисләрнең кемнәр идекене белергә һәркем арзу итәр.* Г.Камал

**АРЗУ́ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **арзу итү.** *Сезнең белән юлыкмакны күптән арзу кыладыр идем.* М.Акъегетзадә. --- *имамнар җитештерерлек мәдрәсәи галияләрнең булуы – милләтнең иң арзу кыйлган нәрсәләремнән бередер.* Г.Камал

**А́РИЙЛАР** *и. санскр. тар.* Көнбатыш Азиядә һәм Европада яшәгән һәм, берничә гасырлар элек, кайберләре Америкага, Австралиягә, Африкага һәм Полинезиягә күчеп киткән, һинд-европа телләре гаиләсенә кергән халыкларның гомуми атамасы. *Чиләбе өлкәсендәге Аркаим шәһәрендә, галимнәр исбат итүенчә, 4000 еллар элек арий халыклары яшәгән.* Чиләбе моңнары

**АРИО́ЗО** *и. ит. муз.* Сүз белән катнаш башкарыла торган лирик ария. --- *соңгы пәрдәдә сәхнәгә чыккач, ул белорус авылының якын торганын күрә, шунда үзенең ариозосын башкара. Гади генә итеп башкарылган шушы ариозо матур яңгырый, ышандыру көченә ия була.* Мирас

**АРИСТОКРАТ** *и. гр.* **1.** 1) Аристократия вәкиле, аксөяк. *Пароход комендантлы де Сегюр да, күрәсең, француз аристократларыннандыр...* Ә.Гаффар. *Аристократлар шәһәр читендә сарайлар төзетә башлый.* А.Әминов

2) *күч.* Нинди дә булса кешеләр төркеменнән өстен булуы белән аерылып торган кеше

3) *күч.* Үзен артык һавалы тотучы, үзен башкалардан өстен куючы кеше. *Тик бер генә тапкыр күтәрелеп карасын иде халыкка, аристократ!* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Аристократия (*1 мәгъ.*) вәкиле булган. *Монда элек аристократ кызлар институты булган.* М.Юныс. *Юкка гына аңа теге аристократ поручик күз атмады ич.* Р.Сибат

**АРИСТОКРА́ТИК** *с.* 1) Аристократиягә мөнәсәбәтле, аристократлар мәнфәгатен яклый торган. *Дидро, аристократик сәнгатьне тәнкыйтьләп, гади халык тормышын чагылдыручы сәнгатьне яклап чыга.* К.Гыйззәтов

2) *күч.* Аристократларга хас булган. *Аристократик кыланышлар*

**АРИСТОКРА́ТИЯ** *и. гр.* 1) Җәмгыятьтә хакимлек итүче югары даирә катламы, аксөякләр. *Казанның милли аристократиясе дә, яңа карашлы байлары да --- бар.* И.Нуруллин. *Ул чорда феодаль аристократия дә зур сәяси йогынтыга ия була һәм дәүләт эшләрендә актив катнаша.* Ә.Мөхәммәдиев

2) Берәр иҗтимагый төркемнең өстен хокуклы катламы. *Финанс аристократиясе*

3) *тар.* Дәүләт белән азсанлы югары даирә катламы – аксөякләр генә идарә итү формасы. *Югары катлау греклар үз идарәләрен «аристократия» дип атаганнар, ул «иң яхшылар власте» дигәнне аңлаткан.* Борынгы заман тарихы

**АРИСТОКРАТЛАНУ** *ф. сөйл.* Үзүзен аристократлар кебек тоту; эреләнү, масаю, кылану

**Аристократланып китү** Ниндидер вакыйгадан, вакыттан соң аристократлану

**АРИСТОКРАТЛА́РЧА** *рәв.* Аристократлар кебек, аристократларга хас булганча. *Норман шәп мыеклы, аристократларча тәкәллефле бу әфәндене шундук күз алдына китерде.* Р.Мирхәйдәров

**АРИСТОКРАТЛАШУ** *ф.* Аристократка әйләнү, аристократ булып китү

**АРИСТОКРАТЛЫК** *и.* Аристократ булу, аристократларга хас сыйфатлар. *Ләкин аның чын мирза икәнлеген йөзенә бер мәртәбә карагач та белергә мөмкин: сакал-мыегын кырган йөзендә --- аристократлык беленеп тора.* Р.Гали

**АРИТМИ́Я** *и. гр. мед.* Йөрәк тибешенең ритмы бозылу. *Аның йөрәк тибешендәге аритмия дә әлеге шул дулкынлану яки борчылудан, соклану яки нәфрәтләнүдән иде.* М.Вәли-Барҗылы

**АРИФМЕ́ТИК** *с.* Арифметикага мөнәсәбәтле. *1880 елда басылган «Кырык бакча» китабында, шулай ук «Хисаплык» дәреслегендә К.Насыйри да «Бүре, кәҗә, кәбестә», «Йөз каш» шикелле арифметик табышмаклар урнаштыра.* Х.Мәхмүтов

**АРИФМЕ́ТИКА** *и. гр.* Математиканың иң гади саннар белән эш итәргә – кушарга, алырга, тапкырларга, бүләргә һәм гамәлләр (мисаллар, мәсьәләләр) чишәргә өйрәтә торган бүлеге. *Гата күрсенеп куйды: арифметика белән дуслыгы бик шәптән түгел шул аның.* Р.Хафизова. *Шундыйларның берсендә беренче сыйныфларга арифметика --- предметын керткәннәр.* Ватаным Татарстан

**АРИФМО́ГРАФ** *и. гр. иск.* Арифметик гамәлләрне механик юл белән башкарып, нәтиҗәсен автоматик рәвештә чыгара торган хисаплау машинасы

**АРИФМО́МЕТР** *и. гр. иск.* Арифметик гамәлләрне башкара торган кечкенә өстәл машинкасы. *Лагуткинның өстәлендә – акча саклый торган тимер сандык, аңа янәшә арифмометр алдында – экипаж исемлеге.* М.Юныс. *Нәкыя, арифмометрын зырылдатудан туктап, --- егеткә, пышылдап диярлек: – Бигрәк усал, астыртын карыйсың син, әзрәк елмай ичмаса, – диде.* Р.Кәрами

**А́РИЯ** *и. ит. муз.* 1) Бер генә тавышка җырлана торган яки бер генә уен коралында башкарыла торган партия. *Монда катнашучылар арияләр, композиторларның классик әсәрләрен һәм, шул ук вакытта, татар халык җырларын да башкарырга тиеш.* Ватаным Татарстан

2) Җырлау яки уен коралларында уйнау өчен язылган музыкаль пьеса. *Салих Сәйдәшевның «Гөлйөзем» ариясен дә җырлар идем.* Мирас

**А́РКА** *и. лат.* 1) *махс.* Ишек, тәрәзә, мич кебек нәрсәләрнең көймәләп эшләнгән түбәсе (түшәме)

2) *архит.* Көймәләп, дугасыман итеп ясалган декоратив корылма. *Дачаның капкасы шактый зур арка рәвешендә эшләнгән.* Ш.Камал. *Триумфаль арка*

3) Берничә катлы һәм озын итеп салынган йорт аша үтү өчен, бер яисә ике этаж биеклегендә калдырылган буш аралык яки күпернең ныгытма аралырында калган уем

**АРКА́** *и.* **1.** 1) Кеше гәүдәсендә муеннан билгә кадәр булган арткы өлеш, ә хайваннарда, кош-кортларда муеннан коерыкка кадәрге сырт як өлеше. *Бәрәннәрнең мамыкланып, көдрәләнеп торган аркаларын сыйпамакчы булды.* Г.Исхакый. *Безнең татар карчыклары да элек-электән арка сылатырга яратканнар.* Г.Әпсәләмов. *Бибисараттәй күзен тагын алъяпкыч чите белән сөртеп алды да, озак итеп, минем аркамнан сөйде.* М.Юныс

2) Өс киемендә арка өлеше, арттакта. *Фәйзулла агайның керле аркасы, кара җилкәсе миңа тагын да сөйкемлерәк күренә.* Ш.Камал

3) Кулның учка кире ягы, арты. *Икенче кул аркасына да, җиң эченнән нәзек кенә юл ясап, кан агып төшкән иде.* Ш.Маннур. *Карт исә тамак кыргалап алды, кул аркаларын ышкыштыргалады.* Б.Камалов

4) Бияләй һәм перчатканың кулның учка кире ягын каплый торган өлеше. *Ул бияләй аркасы белән Николайның беләгенә [сукты].* Ш.Камал

5) Пычак, балта, чалгы һ.б.ш. кискеч коралларның йөзенә каршы ягы, сырты

6) Кашыкның чокырлы ягына каршы ягы. *Кашык аркасы белән өскә төшсә, теләгең үтәлми, чокырлы ягы белән өскә төшсә, теләгең үтәлә.* Ф.Зарипова

7) Урындык, диван кебек җиһазларның арка терәп утыра торган тактасы, арты. *Җәмилә Закировна сикереп тора да урындык аркасында эленеп торган күлмәген ала.* М.Маликова. *Кайсылары Улинә әби утырган урындык аркаларына, кайсылары иңбашына ук кунаклады.* Р.Фәизов

8) *сир.* Арт I (*1 мәгъ.*), арт як. *Агач башкайлары шаулыйдыр, Аркалардан җилләр искәндә.* Г.Тукай

9) *диал.* Биеклек, калкулык. *Елгадан үтеп, арыш басуы аша аркага менгәч, кояш та чыкты.* М.Гафури

**2. аркада, аркамда, аркабызда, аркаңда, аркагызда, аркасында** *бәйл. функ.* Эш-хәлнең башкарылуына сәбәпче, ярдәмче булган затны, предметны, күренешне белдерү өчен кулланыла. *Бер «рәхмәт» сүзе аркасында янә ахирәттә дә дәрәҗәләргә ирештерсә, гаҗәп булмас иде.* Гыйбрәтле хикәятләр. *Минем аркада шундый авыр газаплар чигәсезмени сез?..* Ш.Маннур.

*Күрәсең, җил аркасында, кайдадыр авария булган.* С.Йосыпов. *Барысы да бер гаепсез телефон аркасында килеп чыкты.* Р.Низамиев. *Барысы да – синең аркаңда.* Р.Төхфәтуллин

◊ **Арка бирү** 1) Нинди дә булса бәйгедә (мәс., көрәштә) җиңелү; 2) Артка чигенү, качу (мәс., сугышта). *Чыннан да, халык «Сугышта арка биргәннән күкрәк биргән артыграк» дигән принципны үзенең кыйбласы, идеалы итеп таныды.* Ш.Җәләлиев; 3) *иск.* Оныту, ташлау. *Зирәк булган вакытыгызда – зирәклеккә ышанып яки һөнәрле булган вакытыгызда – һөнәргә арка биреп, эшсез вә хәрәкәтсез тик ятмагыз.* Р.Фәхреддин. **Аркага алу** Үз-үзенә йөкләү, үз өстенә алу. **Аркага арка куеп яшәү** Янәшә һәм үзара тату яшәү. **Аркага арка терәп** Бер-берсе белән килешеп; бер-берсенә булышып, ярдәмләшеп. *Солтанбәк нәселе, ике гасыр урыс авыллары белән аркага арка терәшеп яшәсә дә, кан катыштырмаган.* Н.Гыйматдинова. **Аркага атландыру** 1) Узындыру, теләгәнен эшләргә ирек кую; 2) Ирексездән асрау, карау. **Аркага (менеп) атлану** Баш булып алу, кеше җилкәсенә салыну. **Аркадан килеп (аркага) пычак кадау** Көтмәгәндә һөҗүм итү, уңай моменттан файдаланып һөҗүмгә ташлану (ачыктан-ачык көрәшүгә каршы мәгънәдә); астыртын эш итү. – *Хыянәт бу, иптәшләр, коточкыч хыянәт! Почмактан чыгып, аркага пычак кадау,* – *диде военком, әрнүле көр тавыш белән.* Х.Камалов. **Аркадан сыйпамаслар** Гафу итмәсләр, хупламаслар, мәгънәсендә. **Аркадан сыйпау** *к.* **баштан сыйпау**. *Минем үземнең дә купләрне әрләгәнем бар, мине дә гел аркадан сыйпап кына тормыйлар, әмма беркайчан да болай җәбегәнем юк иде.* М.Хуҗин. **Аркадан тараканнар йөгерә** Тән чемердәү турында. **Арка йонын кабарту (торгызу)** Усаллану, ачулану, зәһәрләнү. **Арка кашу** *к.* **аркасын кашу. Арка кочтыру** Баланы аркага атландырып күтәрү. **Арка кочтырып алу** *этн.* Ата-ана ризалыгыннан башка хатынлыкка алу, үзенә ябыштырып алу. **Арка кую** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса арт белән борылу, аңа карамау; 2) Нәрсәгә дә булса каршы килү, ризалашмау; яратмау, өнәмәү. **Арка кыздыру (киптерү)** Эшсез булу, тик яту, тик тору, эшсез яту, эшсез йөрү. --- *измә аркасында, икенче көн арка кыздырып ят инде.* Ә.Баянов. **Арка кымырҗу (чымырдау)** Берәр нәрсәнең йогынтысы белән тәннең чирканган кебек яки эсселе-суыклы булу хәле. *Хәл кискен иде, Мостафинның аркасы чымырдап куйды.* Х.Камалов. **Аркада тату** Үз башыннан үткәрү, йөрәге аша кичерү. **Арка сөяге йомшак** *к.* **арка сөяксез**. **Арка сөяксез (үзәксез)** Принципсыз, үзенең төпле фикере булмаган. *Алик – бөтенләй намуссыз, арка сөяксез егет икән!* А.Гыйләҗев. **Аркасы белән тору** *к.* **аркан тору**. *Тукай хәмергә аркасы белән торган суфи булып яшәмәгән, әлбәттә.* И.Нуруллин. **Аркасына ышыклану** Аркалану, елышу, кемнең дә булса ярдәменә таяну. **Аркасын кашу** 1) Кыйнау, җәзалау; 2) Бераз тәнкыйтьләү, кимчелекләрен күрсәтү. **Аркасын күрсәтү** *к.* **арка бирү** (*3 мәгъ.*). **Арка таянычы** Беренче ярдәмче, ярдәм кулын сузучы. *Бу тынгысыз, михнәтле заманда, революциягә кадәрге төсле үк, Ибраһимның иң якын киңәшчесе һәм рухи яктан арка таянычы абыйсы Фатих була.* Р.Әмирханов. **Арка терәге** *к.* **арка таянычы**. *Бу әле – арка терәге булган кешеңнең, гарипләнеп калса да, яныңда булуы, сиңа эндәшүе дигән сүз.* Ш.Маннур. **Арка тире агызу** Тир түгеп, зур көч куеп эшләү. **Арка тиресен каезлау (тунау, тукмау)** 1) Бик нык кыйнау, суктыру. *Мастерларның зурраклары ---, заводка кермичә, төркемләшеп торган эшчеләргә: «Арка тирегезне каезлатасыгыз килә торгандыр шул», – дип көлеп, заводка керәләр иде.* А.Таһиров; 2) Бик нык изү, эксплуатацияләү. **Арка чиләнү** Бик мәшәкатьле, күп физик көч сораган эштә озак эшләп җәфалану

**АРКАГА́-АРКА** *рәв.* Арканы аркага терәп, бер-береңә арка белән. *Аркага-арка терәп, тын гына оеп баралар да баралар алар.* Р.Мулланурова

**АРКА́ДА** *и. ингл. архит.* Размер, форма һәм шәүләләре бердәй булган а́ркалар рәте

**АРКАДАШ** *и.* **1**. Иптәш, дус; таяныч. *Иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде.* Г.Исхакый. *Гадәт буенча, апам белән мине, тугач ук, әти үзенең ямчы дусаркадашларының улларына ярәшеп куйган.* Ф.Сафин. *Сакалы биленә җиткән Аппакай морза кенәз Мороз белән аркадаш, хәтта үзара кунакка йөрешәләр иде.* М.Хәбибуллин

**2**. *рәв. мәгъ.* 1) Дус булып, аралашып, иптәшләр кебек. *Без гел бергә булырга, аркадаш яшәргә тырыштык.* Мирас. *Фетнә була, урысларны кыралар, күбесе кача, әлбәттә, яшеренүчеләре дә булгандыр, чөнки татар халкы күп кенә урыслар белән туганлашкан, аркадаш яшиләр иде инде.* М.Хәбибуллин

2) Арканы аркага терәп, бер-берсенә арка белән. *Көдрә Матә белән улы Арабей, хәнҗәрләрен чыгарып, аркадаш басалар.* З.Зәйнуллин

**АРКА́ ҖЕЛЕГЕ** *и.* Умыртка сөяге эчендәге җелек, арка мие

**АРКА́-ҖИЛКӘ** *җый. и.* Арка һәм җилкә бергә. *Рушан, кызарынып, күпмедер вакытка арка-җилкәләрен турайтып ала.* Р.Мирхәйдәров

**АРКА́-КҮКРӘК** *җый. и.* Арка һәм күкрәк бергә. *Арка-күкрәк тирәсе авырту*

**АРКАЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Кем яки нәрсәне дә булса үз канаты, яклавы астына алу

2) Яклап иркәләү, назландыру

**Аркаландыра төшү** Бераз аркаландыру

**Аркаландырып бетерү** Тәмам, бик нык аркаландыру

**Аркаландырып җибәрү** Артыграк аркаландыру

**АРКАЛАНУ** *ф.* 1) Кем яки нәрсәнең дә булса ярдәменә таяну яки ышану; иркәләнү. *Кешегә аркаланып укыдың, кешегә аркаланып эшкә урнаштың да бит, эшли башлагач ни кылырсың икән соң син?* В.Нуруллин. *Чөнки Кадриянең, бер түгел, күп тапкырлар: «Берәрсе тия-нитә калса, җәберләттермә үзеңне, миңа гына әйт», – дип кисәтеп куйгалаганы бар. Шуңа аркалана Вәлидә.* М.Хәсәнов. – *Иван Васильевич, Македонов сезгә*

*аркалана, шуңа узына, – диде Туфайлов.* Х.Камалов. *Атасына аркаланып кала алмасын белсен.* Р.Кәрами

2) *күч.* Берәр сәбәпкә кайтарып калдыру, берәр нәрсәнең юклыгы дип күрсәтү, шуны сылтау итү. *Ләкин без бүгенге көнгә генә ябышып ятмыйк әле, хәзерге экономиканың хәлсезлегенә, китап басу техникасының артталыгына, ташландык хәлдә булуына аркаланмыйк – зуррак, колачлырак масштабта фикер йөртик.* Ә.Кәримуллин

**Аркалана башлау** Аркаланырга керешү. *Хәйләкәр кызый шуннан бирле абыйсына аркалана башлады ---.* Г.Якупова

**Аркалана төшү** Бераз аркалану

**Аркаланып бетү** Гел, тәмам, тулаем аркалану

**Аркаланып йөрү** Күп вакытлар, һәркайда яклау тоеп яшәү. *Ул, башкаларга ышанып, аркаланып йөрмәгән, һәрнәрсәне үзе башкарырга, үз тормышын үзе көйләргә омтылган.* Х.Миңнегулов

**Аркаланып тору** Әле, хәзерге вакытта аркалану

**АРКАЛА́У** *ф. диал.* 1) Аркага салу, аркага күтәрү (мәс., капчыкны, сумканы һ.б.)

2) *сөйл.* Кыйнау

3) Тупас рәвештә куып, төрткәләп чыгару. *«Кармен»ның аяк тырнаклары, канга манчылгандай, кып-кызыл итеп буялган иде... Эльвир аны хатыныннан аркалап чыгарып җибәрде.* М.Маликова

4) *иск.* Артыннан куып бару, эзәрлекләү. *Аркалап барып ни аттың, атай? Мараллар атып килдеңме, атай?* Дастан

**АРКАЛАШ** *рәв. диал.* Арканы аркага куеп, аркага-арка

**АРКАЛЫ** *с. сөйл.* Артлы, арка терәп утыра торган. *Вокзал бинасы эчендә аркалы скамейкалар тезелеп киткән.* Д.Салихов

**АРКАЛЫК** *и.* Ат җигү дирбиясендә, ыңгырчак өстеннән үткәрелеп, ике тәртәне күтәртеп бәйли торган каеш яисә башка төрле бау. *Шамил, шулай сөйләнеп, тәртә янына килде, аркалыкны төшереп бәйләде.* М.Рафиков. *Аннары артка беркетелгән чалгысын алып җиргә кадады, атының аркалыгын төшереп, үлән ашарга куйды.* Ф.Садриев. *Аркалыкны ыңгырчактан бушатып, камыт бауларын чишкән арада, карт, Кәбир сизмәсен дигәндәй, саклык белән генә атның сылу гәүдәсен ниндидер төсмерләүләр аша тикшерә, чагыштыра [башлады].* А.Хәлим

**АРКА́ МИЕ** *и. к.* **арка җелеге**. *Арадан берәү: «Баш миең түгел, арка миең кибәр».* Д.Салихов. *Врачлар Җиһангирның арка миеннән сары су алдылар.* Н.Хәсәнов

**АРКАН** I *и.* Юкә, сүс яки нечкә тимерчыбыклардан юан итеп ишелгән озын бау, трос. *Бозауны тау читендәге иң үләнле җиргә арканлады, аркан озынлыгын чишмә суына җитәрлек итте.* Н.Хәсәнов. *Атларның икесе дә, муеннарына салган арканнар белән, тал куакларына бәйләп куелган иде.* З.Зәйнуллин. *Гөлчәчәк булмагач, күрәсең, атның күп гомере арканда уза.* З.Хөснияр. *Үгез бозау арканда торырга яратмый*

◊ **Аркан белән дә тарттыра алмассың** Кузгатып та булмый, чакырып-чакырып та килергә теләми. **Аркан буе** 1) Чама белән озынлыкны билгеләү берәмлеге; 2) Бик озын, гадәтидән күпкә озын. *Сүзләре озын боярларның, аркан буе.* М.Әмирханов. **Аркан ишәрлек** Кирәгеннән артык күп. *«А-ах-ух»тан соң – пуф-пуф тәмәке, Өйдә төтен – аркан ишәрлек, Агыла тәрәздән.* Р.Идиятуллин

**АРКАН** II *рәв.* **1**. 1) *сөйл.* Арка белән, сырт белән, аркасын куеп. *Ул, кыпкызыл кызарып, миңа аркан әйләнде дә, куллары белән чәчен каплап, кире бүлмә эченә сикерде.* Р.Гали. *Почмак өстәлгә утырырга исәпләп, аларга аркан борылган гына идем, «Миллипипед»: – О-о, мәскәүләр! – дип куйды.* Ә.Гаффар

2) Аркага яткан хәлдә, чалкан. *Шундый киң елганың теге ярына аркан йөзеп чыкты Фәһим.* Заман

3) *сөйл.* Арты (арт ягы) белән. *Нәрсә икән ул, дип кызыксынып, шул саргылт өемнең янына барып җитүе булды, чак кына аркан авып китмичә калды.* В.Нуруллин

4) *диал.* Аркылы. *Күпергә аркан тарттырылган тимерчыбык*

**2**. *с. мәгъ.* Аркага, юл уңаена исә торган (*җил*)

◊ **Аркан әйләнү (борылу)** 1) Үпкәләү, ачулану, мөнәсәбәтен кирегә үзгәртү; 2) Тыңламау, ризалашмау, киреләнү; мөнәсәбәтләрне өзү. *Нәтиҗә буларак, әдип әсәрләре яңадан басылмый, татар театры репертуарыннан пьесалары чыгарып ташлана, матбугат идарәләре аңа аркан борыла.* Р.Әмирханов

**АРКАНЛА́У** *ф.* **1**. 1) Арканга тагу, аркан белән бәйләп кую. *Мәгъфүрә җигеп кайткан атны, шунда ук тугарып, тау астына илтеп арканлыйлар.* Р.Төхфәтуллин. *Юлдан эчкәрәк кертеп, бер елга буена атын тугарды да үләнгә арканлады.* Ш.Маннур. *Пароходтан юан баулар ыргытылып, аны тимер бүкәннәргә арканлап әвәрә килгәндә, --- Кутуй, Такташ, Усманов палубага ыргылдылар.* Ф.Сафин. *Причалга килеп терәлү белән, тимер пароходны, арканлап, ярга беркетә башлыйлар.* М.Юныс

2) Аркан белән уратып алып тоту, аулау. *Арканлап егу*

3) *иск.* Аркан белән үлчәү

4) *күч.* Кемгә дә булса тапшыру, аның карамагына бирү. *[«Нива» машинасын] Озак тотмады, Иске Җөри авыл советы рәисенә күчереп арканлады ул аны.* Т.Нәҗмиев

**2**. **арканлап** *рәв. мәгъ. күч.* Көчләп, мәҗбүр итеп. *Бүген тынычлап йокла, таң белән мин сине, арканлап, олы юл тукталышына илтәм.* Н.Гыйматдинова

◊ **Арканлап китерү** Көчләп китерү, ай-вайга карамыйча китерү (алып бару)

**Арканлап алу** Тиз арада, җәһәт кенә арканлау

**Арканлап кую** Арканлаган хәлдә тоту. *Атны дилбегә белән арканлап куйдым.* Н.Мадьяров. *Картаерга ашыкмыйк әле, өйләндем, дип, үзеңне карават аягына арканлап кую – юләрләр эше ул!* Ш.Маннур

**Арканлап тору** Һәрвакыт, гел арканлау

**АРКАНЛЫК** *с.* **1**. Арканга яраклы, арканга җитәрлек

**2**. *и. мәгъ.* Арканга яраклы материал

**АРКА́Н ТАРТУ** *ф. тар.* Арканга җигелеп, баржа, пароход өстерәү (бурлаклар турында). *Меңәр чакрымнарга сузылган ул ярлар буенча элек бурлаклар аркан тарткан булса, хәзер мәһабәт ак теплоходлар елына илле миллионлап пассажирга хезмәт күрсәтә.* Р.Фәйзуллин

**АРКА́Н ТАРТЫШУ** *ф. спорт* Ике төркемгә бүленеп, арканны ике башыннан капма-каршы якка тартып көч сынашу. *Йөгерешәләр, чүлмәк ваталар, аркан тартышып уйныйлар.* Г.Бәширов

**АРКАНЧЫ** *и.* 1) *сир.* Аркан ишү һәм сату белән шөгыльләнүче

2) *тар.* Элмәкле аркан белән коралланган сугышчы. *Борындагы арканчы таза күкрәкле, таза беләкле ялан аяклы эшчегә элмәкле аркан ыргытты.* Н.Фәттах

**АРКА́ СУГЫШ** *и.* Яшьләр уенының бер төре: берәү аркасын куеп иелергә һәм кем сукканын белергә тиеш; белсә – тотылган кеше аркасын куя, белмәсә – үз аркасына суктыруны дәвам итә

**АРКА́ СУГЫШЛЫ** *и. к.* **арка сугыш.** *Китте җыр, китте уен. Йөзек салышлы да, түгәрәкле дә, почталы да, арка сугышлы да – берсе дә калмады.* Ш.Маннур. *Эчкә салкын үтә башлагач, халык чарасын тапты: арка сугышлы уйнарга керештек.* А.Тимергалин

**АРКА́У** *и.* Тукымадагы аркылы җеп. *Аркау җебе куелган сосаны шул арадан йөртәсең...* Х.Камалов

**АРКАУЛЫК** *с.* **1**. Аркау өчен билгеләнгән, аркауга яраклы

**2**. *и. мәгъ.* Аркау өчен әзерләнгән җеп

**А́РКТИК** *с.* Арктикага мөнәсәбәтле. *Чын чиста сулар арктик бозлар куенында гына калды бугай инде.* Р.Фәйзуллин. *Кайберләре Ерак Төньякта таралган һәм алар – арктик өлкәләргә хас үсемлекләр.* Л.Мәүлүдова

**А́РКТИКА** *и. гр.* Җир шарының төньяк поляр өлкәсе. *Тарихта беренче буларак, зур экспедиция, диңгезнең көчле дулкыннарын ера-ера, еракка – Арктикага юл алды.* А.Алиш

**АРКЫЛА́У** *ф.* Берәр нәрсәне аркылы үтү, аркылы чыгу. *Көтүне аркылап, униформа кигән кызлар мәктәпкә сабакка баралар.* М.Мәһдиев. *[Талия, әнисен үртәп:] Керәм, Иделне аркылап чыгам, Идел буйлап, диңгезгә йөзеп төшәм.* Т.Миңнуллин

**АРКЫЛДЫРУ** *ф. диал.* **1.** 1) Селкетеп, бәрдереп, чайпалдырып, савыт эчендәге сыеклыкны азрак түгеп җибәрү

2) Савытның читеннән чыкканчы, тулып артып киткәнче салу

**2. аркылдырып** *рәв. мәгъ.* Ашырып, күтәреп, биеклеккә җиткереп. *Ялгыз улыгызны тау аркылдырып укыткан булдыгыз, әнә ата нигезен ташлап чыгып китте читкә.* Ш.Янбаев

**Аркылдырып җибәрү** Артык аркылдыру

**АРКЫЛУ** *ф. диал.* 1) Бер ягыннан икенче ягына үтеп чыгу

2) Тулып ташып чыгу, берәр нәрсә өстеннән (читеннән) ташып агу

3) Бөртекле яки сыек нәрсәләрнең, тулып, савыт кырыеннан түгелүе, сибелүе. *Ходайга шөкер, буралар быел аркылып тулды: бодай, арыш, тары...* С.Поварисов

4) *күч.* Берьюлы күп булып агылу, күп булып үтеп керү (мәс., кояш нурлары, яктылык һ.б.). *Кояш чыкты, нур балкыды, тәрәзәдән өйгә аркылды.* Ф.Урманче

**Аркылып чыгу** 1) Бер ягыннан икенче ягына үтәли аркылу. *Зәй – зур елга түгел. Агымы тиз булса да, аны өч сулышта аркылып чыгарга була*. Т.Нәбиуллин

2) Эченнән читенә аркылу

**АРКЫЛЫ** I *рәв.* **1.** 1) Буйга перпендикуляр рәвештә. *Инде үрсәләнеп аунаган хатынкай ишеккә аркылы яткан җиреннән буйга сузылып төште.* А.Хәлим. *Авырайган гәүдәне ияренә аркылы салды.* З.Зәйнуллин. *Якын-тирәдәге урамнарга зур-зур йөк машиналарын аркылы куйганнар.* Мирас

2) Иңгә, иңе буенча. *Шулай ук теземнәрдәге сабакларның аркылыга һәм буйга тигез урнашуын табу зарури.* Урып җыю машиналары

**2**. **аркылысы** *и. мәгъ.* Иңе. *Син гастрольләрдә күп йөрдең, буе – унбер мең чакрым, аркылысы алты мең чакрымны кат-кат әйләнгән кеше син.* Р.Батулла

**3**. *с. мәгъ*. Буйны иңгә кисеп үтә торган, шул юнәлештә беркетелгән, куелган, эшләнгән. *Алар, бер дә диярлек, урамга чыкмыйлар һәм үзләренә дә беркемне кертмиләр бугай – капкаларының аркылы агачы һәрвакытта шылдырып куелган була.* Ә.Еники

◊ **Аркылыга җәелү** Юанаю, тазару. *Оксана ишеккә сыймаслык булып аркылыга җәелде.* Р.Мулланурова. **Аркылыга үсү** *к.* **аркылыга җәелү**. *Корсагы аркылыга үскән, карбыз кебек чырайдагы күзләре чучканыкы сыман.* Ф.Баттал. **Аркылы килү** *к.* **аркылы төшү.** *Яңгыр гына аркылы килде миңа.* Ә.Гаффар. **Аркылыны (аркылы ятканны) буйга салмау** Ялкау булу, бер эш тә эшләмәү, булышмау. *Туганнан бирле аркылыны буйга алып салмаган, үзе икърар иткәнчә, «егерме өч яшенә кадәр салам да селкетмәгән бер әрәмтамак».* Ф.Галимуллин. **Аркылы төшү** 1) Кеше сөйләгәннең киресен сөйләү, каршы сөйләү; 2) Нинди дә булса эшкә комачаулау, аяк чалу. *Ниятенә аркылы төшеп, тәмам кәефен кырдылар.* Б.Камалов

**АРКЫЛЫ** II *бәйл.* 1) Бер яктан икенче якка үтү (чыгу) белән бәйләнешле эш-хәрәкәтнең урынын белдерү өчен кулланыла. *Бакча аркылы узганда, туктап, Җидегән йолдызга карап тордык.* И.Гази. *Урам аркылы чыкканда, Әзһәм хатыны белән каяндыр кайтып килүче яшь бала күтәргән бер танышын очратты.* Р.Кәрами. *Көтүче малай әйтүенчә, «Нива» килгәндә, көтү юл аркылы чыга торган була.* Р.Мөхәммәтҗан

2) Эш-хәлнең урыны нәрсәнең дә булса бөтен киңлегенә юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Безнең басу аркылы кайчандыр Гондыр елгасы аккан.* М.Хуҗин

3) Эш-хәрәкәтнең башкарылган урыны берәр предмет өстеннән, аның аша булуын белдерү өчен кулланыла. *Егет, --- сак-сак атлап, киртә аркылы абзарга керде.* Г.Ибраһимов

4) Эш-хәрәкәт башкарылган урын ике нокта арасында булуны белдерү өчен кулланыла. *Ничек кенә карасак*

*та, безнең әти передовойга Мәскәү аркылы үткән булырга тиеш.* Р.Хафизова. *Саба-Арташ автобусы Олы Нырты аркылы йөри башлады.* Т.Нәҗмиев

5) Нәрсә дә булса үтәли башкарыла торган (мәс., үтәли күренә, ишетелә торган, тишеп, ерып, саркып торган һ.б.ш.) пространствоны, урынны, предметны белдерү өчен кулланыла. *Кузов рәшәткәләре аркылы тирә-ягына хәйран күз белән карый-карый барган Муса уйга батты.* Ш.Маннур. *Рәхимсез кылаалар [кырмыскалар], берничәсе күлмәк-ыштан аркылы мине дә тешләргә маташты.* Р.Низамиев

6) Кем яки нәрсәнең дә булса башка зат яки предметны узып, шул заттан, предметтан соң урнашкан урынын белдерү өчен кулланыла. *Тәмәке тарту бүлмәсенә бару өчен, картка көлләү цехы аркылы узарга кирәк.* А.Алиш. *Ике йорт аркылы*

7) Эш-хәлнең тигез урын аралыкларында үтәлүен белдерү өчен кулланыла. *Шунлыктан ул үзеннән бер кеше аркылы яткан кызылармеецка, ачуланып: – Атлы... – дип кычкырырга өлгермәде.* Ш.Усманов

8) Эш-хәлнең нигезен күрсәтү өчен кулланыла. *Элек шигырьне укый да белмәгән Рушатов, Муса аркылы, шигырьнең чын тәмен, образлар тирәнлеген аңлый башлады.* Ш.Маннур

9) Эш-хәлне башкаруга арадашлык иткән, ярдәме, булышлыгы тигән предметны, чараны, җайланманы һ.б.ш.ны белдерү өчен кулланыла. *Җил аркылы сәлам әйтәм, Җилләр сезгә исәме?* Җыр. *Ләкин [Хәсән], һәр икесендә дә ерак лазаретларга эләгеп, хат аркылы гына хәбәр бирде дә, тагын фронтка, бу юлы Балтик ягына китеп барды.* К.Нәҗми. *Ә башка халыкларның әдәбият җәүһәрләре белән танышу мөмкинлегенә һәр халык тәрҗемә аркылы ирешә.* К.Миңлебаев

10) Эш-хәлнең башкарылуына сәбәпче булган предметны яки затны белдерү өчен кулланыла; аркасында. *Шул залимнәр аркылы халыкка туды ярлы көн.* М.Җәлил

11) Берәр нинди эш-гамәлне башка зат аша, аның арадашлыгы белән башкаруны белдерү өчен кулланыла. *Кантон шәһәрендә ачылган «Союзкож» тире җыю бүлегенә агентлар кирәк, дигәч, Һашимов дус-иш аркылы анда да үрмәләп алды.* А.Алиш. *Ул үзенең тәнкыйть фикерләрен, әйбәт теләкләрен я Такташ, я Гомәр Гали аркылы җиткереп торды.* Г.Минский. *Хуҗасы ул бияне кала ипподромыннан, шунда ат караучы булып эшләгән, сугышта ятып калган әтисенең бертуган энесе Гарәфетдин абзасы аркылы сатып алды.* З.Зәйнуллин

**АРКЫЛЫ́ БАЛТА** *и.* Балта эшендә ырмау ясау өчен кулланыла торган корал. *Археология мәгълүматларына караганда, болгар осталары аркылы балта ярдәмендә эшкәртелгән тактаны киң файдаланганнар.* И.Гафаров

**АРКЫЛЫГА** *рәв. к.* **аркылы** I (**1.**). *Егет, яңабаштан сызып, өстәл кырыенда сындырмакчы иде, пыяла, буйга гына түгел, аркылыга да ярылды.* Р.Кәрами

**АРКЫЛЫГА́-БУЙГА** *рәв.* 1) Төрле юнәлешләрдә, һәм аркылыга, һәм буйга. *Аркылыга-буйга сөреп чыгу*

2) *куч.* Бер җирен дә калдырмыйча, җентекләп, һәрьяклап. *Аркылыга-буйга тикшереп чыгу*

◊ **Аркылыга-буйга айкау** Бик күп җирләрдә, төрле урыннарда булу, сәяхәт кылу. *Кунакчыл хуҗалар үз башкалаларын җентекле экскурсия белән, аркылысын-буен айкап дигәндәй, күне буе күрсәтеп йөрделәр.* З.Нури. *Гражданнар сугышында илне кылыч белән аркылыга-буйга айкап чыккан кеше бит мин!* Ф.Сафин. **Аркылыга-буйга гизү** *к.* **аркылыга-буйга айкау.** *[Заһит:] Әмма дә Европаны аркылыга-буйга гизеп, үзебезнең авылдагы Гөлйөзем исемле кыздан да чибәррәк кызны күргәнем булмады, монысы хак.* М.Әмирханов. **Аркылыга-буйга йөрү (йөреп чыгу)** *к.* **аркылыга-буйга айкау.** *Шунлыктан без Венецияне «унберенче номер» белән аркылыга-буйга йөрдек.* М.Юныс. *Юк, наныем, башта син, безнең Гриша кебек, биш-алты ел буе Себер юлларын тапта, аркылыгабуйга йөреп чык, аннары, улларыгызны күрер өчен мең чакрымнар үтәсе бар, дип шыттырсаң да ышаныр идек.* И.Зарипов. **Аркылыга-буйга кичү** *к.* **аркылыга-буйга айкау**. *Дөньяны аркылыга-буйга кичкән, хезмәт юлын гади эшчедән башлап, тормыш сандалында чүкелгән егетнең күңеленә гүя Җир шарының бөтен тулай тораклары сыйган иде.* Р.Хисмәтуллин. **Аркылыга-буйга үлчәү** Җәяүләп, бер башыннан икенче башына кадәр үтү

**АРКЫЛЫ́ ПЫЧКЫ** *и.* Очларыннан ике кеше алмаш-тилмәш тартып кисә торган пычкы. *[Фәттах:] Бар, аркылы пычкыны, иске кул пычкысын алып чык.* Д.Салихов

**АРКЫЛЫСЫ́-БУЕ** *и.* Барлык үлчәмнәре. *Аркылысы-буе бер үлчәмдә булса да, искиткеч җиңел сөякле кеше иде бәк.* М.Әмирханов

◊ **Аркылысы-буе бер** Бик симез, юан; буе аркылыга киткән. *Бездә Маша исемле складчы бар иде. Аркылысы-буе бер.* Э.Яһүдин. **Аркылысын-буен үлчәү** *к.* **аркылыга-буйга үлчәү**. *Без, дүртәүләп чыгып, тагын бер кат урамның аркылысын-буен үлчәдек.* Р.Хафизова. **Аркылысын-буен үткән** 1) Күпне күргән, күп гизгән; 2) Тәҗрибәсе зур булган, берәр мәсьәләдә күпне белгән

**АРКЫЛЫ́-ТОРКЫЛЫ** *рәв.* **1.** 1) Бер-беренә кара-каршы авышлатып; берсе – буйга, икенчесе – иңгә; берсе өстенә икенчесен аркылы китереп // Бер аркылыга, бер буйга. *Эзли-эзли, бөтен урманны аркылы-торкылы карап чыкканнар – бала табылмаган.* З.Хөснияр

2) Тәртипсез рәвештә; ничек эләкте шулай; төрле юнәлештә. *Ул, ачынган тавыш белән, тагын бер-ике кәлимә сүз өстәде дә Әхмәтсафаны сал өстенә аркылы-торкылы ташланган агач өеменә этеп җибәрде.* Ф.Сафин. *Зөфәр Шәриповичның эшләрне контрольдә тота торган калын кенәгәсе бу көннәрдә фамилияләр, башкарасы эшләр, үтәлү вакытын күрсәткән язулар белән аркылы-торкылы чуарланып беткән.* Ф.Садриев

**2**. *с. мәгъ.* Берсе икенчесенә авыш итеп атландырылган, бер-беренә аркылы торган. *Өйнең ишекләре бикләнгән,*

*тәрәзә капкачлары ябылган. Өсләреннән аркылы-торкылы такталар кадакланган.* Н.Дәүли. *Башына кара күн шлем кигән, зур кара күзлекле очучыны да, җилкәсен аркылы-торкылы каешлар белән эләктереп, аның артында утырган Нурислам абыйларын да малайлар ап-ачык күрделәр.* Р.Хафизова

**АРКЫЛЫЧА** *и.* 1) *тех.* Аркылы агач, арата

2) *спорт* Ике багана башына кул сузымы биеклегендә аркылы беркетелгән таяктан гыйбарәт гимнастик әсбап, җайланма; турник

**АРЛЫ́-БИРЛЕ** *рәв.* 1) Әле – теге, әле бу якка; әрле-бирле. *Ул атын, йөгәненнән тотып, арлы-бирле йөртеп тора, үзе дулкынланып сөйли иде.* Р.Хафизова. *[Нажия Гобәевна] Аннары урыныннан купты да, такта янында арлы-бирле йөреп, яңа материалны аңлата башлады.* В.Нуруллин

2) Төрле юнәлештә. *Аның яшькелт күзләре, кая барып сугылырга белмәгәндәй, арлы-бирле йөгерә иде.* А.Вергазов

◊ **Арлы-бирле бәргәләнү** Нәрсә эшләргә белмичә аптырау, борчылып йөрү. **Арлы-бирле сугылу** *к.* **арлы-бирле бәргәләнү**. *Рәис сикереп торды да, кыскарган аягы белән титаклап, арлы-бирле сугылды.* Г.Бәширов

**АРМАЙ** *и. тар.* 1) Күзәтеп, тикшереп торучы; староста (авылда)

2) Салымнар җыючы

3) Туйда тәртипне күзәтүче

**АРМАТУ́РА** *и. лат. тех.* 1) Төрле аппарат, машина һәм электр җиһазларының эшен тәэмин итә торган ярдәмче детальләр һәм җайланмалар комплекты

2) Тимер-бетон корылмаларның корыч каркасы; төзелеш корылмаларының ныклыгын арттыру өчен катнаштырыла торган металл чыбыклар җыелмасы. *Якында гына берничә экскаватор, бульдозерлар тык-тык эшләп утыра, такта һәм арматура өемнәре калкып тора.* Р.Кәрами. *Арматура чыбыкларыннан ябыштырып ясалган тимер капка ике якка ачып куелган.* З.Фәтхетдинов

3) *махс.* Корал һәм сугыш киемнәрен сурәтли торган декоратив сын

**АРМАТУ́РАЛАУ** *ф.* Арматуралап эшләү, арматура белән ныгыту, арматура өстәү

**Арматуралап кую** Арматураланган хәлгә китереп калдыру

**АРМАТУРЧЫ** *и.* Арматура әзерләүче, коручы яки арматура белән эш итүче. *Гомерендә бер генә сәгать тик утыруны да белмәгән бишенче разрядлы арматурчы, эшсезлектән җанын кая куярга белмичә, җитәкчеләр янына керә.* Л.Ихсанова

**АРМЕ́ЕЦ** *и. рус* 1) *иск.* Армиядә хезмәт итүче солдат. *Малаеның армеецларга эшкә яравы хуҗа хатынның да кәефенә килде.* Х.Камалов

2) ЦСКА клубы әгъзасы булган спортчы

**А́РМИЯ** *и. фр.* 1) Дәүләтнең барлык (коры җир, диңгез, һава) кораллы көчләре. *Вафа самолётка беренче мәртәбә армиядән кайтканда утырды.* З.Моталлапов. *Армиядә хезмәт итү миңа бик күп нәрсә бирде.* В.Нуруллин. *[Сәрия:] Син армиядә чагында, ул минем белән гел бергә булды.* Д.Салихов

2) Диңгез һәм һава кораллы көчләреннән аермалы буларак, коры җир хәрби көчләре

3) Төрле гаскәрләрдән торган берничә корпус яки дивизияләр берләшмәсе. *Обер-лейтенант бик мөһим «кош» булып чыга, шул ук көндә аны армия штабына озаталар.* В.Казыйханов

4) *күч.* Бертөрле гомуми эш, һөнәрбелгечлек буенча берләшкән күп кешеләр төркеме

**АРМУТ** *и. фар. бот.* 1) Роза чәчәкләләр семьялыгыннан, көньякта үсә торган, матур сурәтле үзагачлы, күп тармаклы җимеш агачы; *русчасы:* **груша**

2) Шул агачның татлы сусыл җимеше. *[Матэ:] Молдова, Болгария якларында да юк шундый хуш исле алмалар, андый армутлар.* З.Зәйнуллин. *Биек-биек хрусталь вазаларга матур итеп тезелгән алма, йөзем, армут, шәфталу, әфлисун, слива шикелле җимешләр --- табынны мул итеп күрсәтәләр.* Ш.Маннур

**А́РМЫЙ-ТАЛМЫЙ** *рәв.* Аруны белмичә, ял да итмичә, бертуктаусыз. *Киләчәктә белем һәм иҗат диңгезендә армый-талмый алга баруын тәэмин иткәндер.* Э.Шәрифуллина

**АРНАЛУ** *ф. диал.* Багышлану, аталу. --- *ирешелгән бөтен данлы эшләремнең таҗы ул – Синдер, Күк-Тәңрем. Бу олылау сүзләре минем йөрәгем аша Сиңа арнала ---.* М.Галиев

**АРПА** I *и.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан, орлыгы ярма, сыра һәм фураж әзерләүгә китә торган, озын кылчыклы башаклы үсемлек. *Тагын мең ярым гектар арыш, көзге бодай, арпа һәм солы ята.* Г.Кашапов

2) Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. *Узган сезонда «Яңа юл» колхозы дәүләткә ике мең центнер арпа тапшырды.* М.Мәһдиев

◊ **Арпа камыры** Булдыксыз, оешмаган, таркау кеше. *Боларны җанландыра торган мәсләк тә, «берлек» дигән зур бер көч тә булмаганга, болар арпа камыры кебек [«иттифакчы»лар] таралды да китте.* Г.Исхакый. **Арпа суы** Сыра. **Арпа эчендә бер бодай** Бертөркем кешеләр арасында нинди дә булса өстенлеге (уңганлыгы, матурлыгы һ.б.) белән аерылып торган кеше

**АРПА** II *и. мед.* Күз кабагы читенә чыга торган эренле шеш. *Хәйрүш абыйның күзенә арпа чыккан.* Ф.Зарипова

**АРПАБАШ** *и. бот.* Йончалылар семьялыгыннан, яссы яфраклы, башы арпага охшаган күпьеллык чүп үләне; *русчасы:* **костёр безостый**

**АРПАГАН** *и. бот.* Кыргый арпа; *русчасы:* **овсюг** *Урыны-урыны белән, арпаган үскән*

**АРСЕНАЛ** *и. фр. хәрби* 1) Сугыш кораллары һәм хәрби кирәк-яраклар саклый торган склад. *Брандт шәһәр арсеналында булган барча коралларны тикшерттерә.* В.Имамов

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса зур микъдары, саклык чыганагы

3) *күч.* Кемнең дә булса эш итү ысуллары, чаралары җыелмасы. *Ялындырганда, кыланганда, --- хатынкызны бөгәргә, сындырырга Сабит арсеналында йөзләгән ысул бар иде.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Запас. *Оригиналда ул әдәби эшләнеше ягыннан кайтышрак булса*

*да, театр белгечләре аны арсеналга алырга булдылар*. Г.Ахунов

**АРСЕНИДЛАР** *и. лат. күпл. хим.* Мышьякның металлар белән химик кушылмасы

**АРТ** I *и.* **1.** 1) Гадәттә кыек килеш формаларында килеп, пространствода: күз караган якка капма-каршы як, арка белән торган тараф; арткы як; *киресе*: **ал**. *Ул артына борылып карамый, ләкин буразнаның туры булуында шикләнми*. Г.Әпсәләмов. *Рим бусагасында гаскәр диңгезе тора: уң якта – ак атлылар чиреүе, сул якта – күк атлылар, маңгай якта – җирән атлылар, артта – өстәмә көч – чем-кара атлылар чирүе*. М.Галиев

2) Нәрсәнеңдер аргы ягы, алдан күренми торган каршы як. *Урман артына түгәрәк кызыл кояш тәгәрәп төшеп бара.* Хәйдәр. *Әхмәтсафа пәрдә артына кереп китәм дигәндә, шигырьдән үзе дә тәэсирләнгән Һади Такташ сәхнәгә кабат сикереп менде.* Ф.Сафин. *[Гали:] Каяле, ишек артында берәрсе юк микән.* Н.Фәттах. *Ил чиген чыгуга, туган җир офык артында гынадыр шикелле иде.* М.Галиев

3) Нәрсәнеңдер яны. *Ишектән кергәч тә, кечкенә тәрәзәле пыяла бүлемнәр эчендә – пульт артында утыручы кизү офицерга баш кагып, кемнәрдер честь биреп узалар.* Н.Хәсәнов. *[Лилия:] Сигез сәгать станок артында басып торып та, 3000 сумны бик тиз генә бирмиләр әле аны*. Д.Салихов. *Галәф агай буш вакытларында пианино артына утыра, думбра чиртә.* Казан утлары

4) Кеше гәүдәсендә һәм кием-салым әйберләрендә арка ягы; *киресе:* **ал.** *Аннары үзе дә, стенаның чыгып торган тәбәнәк киртләченә арт терәп, тәмәкегә керешә*. Ш.Маннур. *Сәет диварга арты белән утырды.* Т.Галиуллин. *Яңа, икенче күлмәк кигән дип белсеннәр өчен, алдын артка кигән була*. Н.Исәнбәт. *Аның кара йон юбкасының арты ап-ак иде.* В.Нуруллин

5) Хайван гәүдәсендә артсан. *Аптыраган үрдәк арты белән күлгә чумган.* Әйтем. *Атның шаянлыгына, арт сикертеп чапкынлавына, кыланмышларына түзәр әмәл калмагач, тоттык та җылы абзарга чыгардык үзен.* Шәһри Казан

6) Урындык, диван, чана кебек һ.б.ш. нәрсәләрнең арка терәп утыра торган өлеше, аркасы. *Хәдичәне сүс аркан белән, ныклап, урындык артына бәйләделәр*. З.Зәйнуллин

7) **арты** *тарт. форм.* Торак пункт исемнәре белән килеп, шул урыннан ары булган төбәк мәгънәсен белдерә. *Ул Урта Азиядә белем алып, аннан Казан артындагы авылларда мөдәррис булып эшли*. Х.Миңнегулов

8) *гади с.* Кеше гәүдәсендә билдән түбән (йомшак) итләч урын, утыра торган әгъза. *Аны сөйрәп торгыздылар да арт ягына тибә-тибә алып киттеләр.* Ш.Маннур

**2.** *с. мәгъ.* 1) Нәрсәнең дә булса артында урнашкан, артта булган, арткы, арттагы. *Арт бакчамда унике сутый бәрәңге җирем булганда, баш очымда йодрык уйнатып кына мине кем ач калдыра алсын?* А.Хәсәнов. *Арт капкадан гына кермәкче иде дә, әтисенең артта – мунча тирәсендә – нидер кыштырдап йөрүен күргәч, тыкрыктан әйләнеп, урам капкадан керергә булды*. Ф.Хөсни. *Ул килеп җиткәндә, поезд яңа гына кузгалган иде, йөгерә торгач, көч-хәл белән генә соңгы вагонның арт баскычына эләгеп калды*. Ш.Маннур

2) Хайван гәүдәсендә һәм арба кебек нәрсәләрнең арткы өлешендә булган; арткы, арттагы. *Ал тәгәрмәч кайдан йөрсә, арт тәгәрмәч шуннан йөрер.* Мәкаль. *Артларын сикертеп, ике арт аякны берьюлы селтәп, алар сугышкан кебек иттереп кыйланалар гына*. З.Зәйнуллин

**3. арты(нда)** *рәв. мәгъ.* Үзе булмаган вакытта, яшертен. *Чын дус булсаң, алдында мактама, артында макта.* Мәкаль. *Ленарның, артында түгел, алдында сүккәндә дә исе китми әле.* М.Мәһдиев

**4.** *бәйл. функ.* 1) **арты** Берәр эш-хәлнең, күренешнең һ.б.ның эзлекле рәвештә икенче эш-хәл, күренеш һ.б. белән алмашынуын белдерү өчен кулланыла. *Аннары сорау арты сорау китәчәк: кем ул Сиринә дигәнең, нигә ул синң машинасын бушка бирсен?* З.Хөснияр. *Намаз арты саен, олы бәхет теләп дога кылырмын үзеңә.* С.Поварисов

2) **артына** Эш-хәлнең предметның арткы ягына юнәлгәнен белдерү өчен кулланыла. *Соңыннан ачыкланды: мәнсез остабикәсе абзар артына күмерле көл түккән булган.* С.Поварисов

3) **артында** Эш-хәлнең предметның арткы ягында эшләнүен белдерү өчен кулланыла. *Елады ул олыларча үксеп, Үзе өйгән бура артында*. С.Хәким

4) **артыннан** Эш-хәлнең нәрсәнең дә булса арткы ягыннан юнәлгәнен белдерү өчен кулланыла. *Шулвакыт ындыр артыннан – Камышлы ягыннан – ниндидер хатын-кызның килгәне күренде.* Хәйдәр

5) Эш-хәлнең ераклашып барган зат яки предмет ягына таба юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Сәгыйдулла бабай поезд артыннан йөзүче айга карап алды.* Р.Вәлиев

6) Берәү башкара торган эш-хәлгә икенче берәүнең кушылып китүен, шундый ук эш-хәл башкарырга керешүен белдерү өчен кулланыла. *Менә беренче сарык таякны сикереп чыга, аның артыннан икенче... өченчесе...* М.Галиев

7) Берәр максатка юнәлтелгән эшхәлне белдерү өчен кулланыла. *Мин дә халык эше артыннан йөрим*. Ш.Камал

8) Аркылы, аша. *Дуслары артыннан әнисенә кучтәнәч җибәрде*

◊ **Арт аяклары белән тәпәнләп тору** Яхшатланып ярарга тырышу, үзеннән өстен торган кешеләр алдында ялагайлану. **Арт белән утыру** Мөнәсәбәт үзгәрү, читләшү, йөз бору. **Арт бирү** 1) Битарафлык күрсәтү, нәрсәгә дә булса салкын мөнәсәбәттә калу, кызыксынмау; 2) Читләшү, теләк бетү, кызыксыну югалу; 3) *гади с.* Качу, качып китү. **Арт борырга урын булмау** Тар, кысан булу. *Тәбәнәк кечкенә сарайның эчендә арт борырга да урын юк – кысан иде.* Р.Кәрами. **Арт ишектән** 1) Танышлык буенча яшертен рәвештә берәр нәрсә (бәясен арттырып) алу яки сату. *[Ипине] Кайтарсалар да, безнең ише карт-корыга тәтеми,*

*хәзер арт ишектән бүлешеп бетерәләр.* А.Гыйләҗев. *Ярты товарны арт ишектән дус-иш спекулянтларына озатты.* Г.Мөхәммәтшин; 2) Танышлык аша берәр эшкә урнашу яки укырга керү. *Малаегызны институтка арт ишектән кертүне сорап, миңа мөрәҗәгать итүегезне [онытмагансыздыр].* Казан утлары. **Артны җыеп йөрү** Уяу булу, сак йөрү; үз артыңнан әйбер калдырмау. **Арт сабагын укыту (өйрәтү, тыңлату)** 1) Бик каты шелтәләү, тәнкыйтьләү; җавапка тарту. *[Илшат:] Кара аны, колагыңа киртеп куй: әгәр театр киемнәрен урлап качсаң, арт сабагыңны укытам.* Д.Салихов. *Кире илтсәң, кирәкне бирәчәкләр. Арт сабакны укытачаклар.* Б.Камалов; 2) Бик нык кыйнау, физик көч кулланып кирәген бирү, күрмәгәнен күрсәтү. *Дутовны кызыл гаскәр сугышчылары, яңадан мәңге Оренбург далаларына аяк басмаслык итеп, арт сабагын укытып җибәрделәр.* Ф.Сафин. *Безнең гаскәрләр немецларның арт сабагын укыталар.* Р.Хафизова. *Их, дидем эчтән генә, Мохтар абыйга әйтәсе иде. Ул бу бәндәнең арт сабакларын укытыр иде. Ничек кенә әле!* Н.Дәүли. **Арт санын күтәрә алмау** *к.* **арты авыр. Арты авыр** Эшкә-йомышка авыр кузгалучан, сузылып-тартылып йөрүчән, ялындыручан. **Арты ачылу** Гаебе фаш булу, яшерен эше билгеле булу. **Арты белән киртә җимерү** Эшне бозу, киреләнү; булмас эшкә гайрәт ору. *Үҗәт кеше ул, арты белән киртә җимерергә маһир.* Ф.Сафин. **Арты белән тору** 1) Тискәреләнү, киреләнү, җайга килмәү; 2) Каршылыклар гел чыгып тору, авырлыклар килеп чыгу (тормышка, эшкә карата). **Артына төшү** Эзәрлекләү; кайдалыгын белеп алу. *Кошчак углан белән өч йөз егет, хатыннарын, балаларын калдырып, төн уртасында Казаннан чыгып качарга мәҗбүр булалар. Ниятләре – Нугай, Кырымга барып, Иван гаскәренең артына төшү була.* Ф.Хатипов. **Артына ут капкан кебек** Ашыгып, кабаланып. **Артында сөйләү (чәйнәү)** Үзе югында сөйләү, гайбәтен сату. **Артын кысу** Үз-үзен белеп дәшмәү. **Артыннан бару (иярү)** 1) Кемнең дә булса юлдашы, фикердәше, тарафдары булу; 2) Кемнән яки нәрсәдән дә булса үрнәк алып эш итү. **Артыннан йөрү (чабу)** 1) Юллау, хәстәрен күрү; 2) Нинди дә булса эш башкару; 3) Кемне дә булса яратып, үзенә каратырга йөрү; хатынкызга илтифат күрсәтү. **Артыннан куу** Нәрсәгә дә булса артык игътибар итеп, башкаларын читтә калдыру. *Ә бит чынлыкта, җитештерү темплары артыннан кумыйча да, зур уңышларга ирешергә мөмкин иде.* Идел. **Артыннан тере саескан очыру** Алдау, ялган сөйләү, сөйләгәндә үзеннән өстәү, арттыру. **Артыннан чыгару** Ялган сөйләү, шыттыру; булмаганны чынбарлык итеп күрсәтү

**АРТ-** II *фр.* Кушма сүзләрдә «артиллерия» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *артбаза, артдивизион, артполк һ.б*). *Боларга бирәсе боерыкларын бетергәннән соң, озак итеп полкларга һәм артдивизионга, миномётчыларга шылтыратып, транспорт таләп итте.* Ш.Маннур

**АРТАК** *с.* Кыргыйлашкан, өйрәтелмәгән яисә холкы бозылган, тыңлаусыз. *Тауга каршы менгән чакта Атың артак булмасын.* Җыр

**АРТЕЗИАН** *с. фр.* 1) Тау токымнарының тирән катламнарыннан табигый басым астында чыга торган, зур тирәнлектәге (мәс., су һ.б.)

2) Шундый суларны алу өчен махсус җайлаштырылган (мәс., кое һ.б.). *Элекке артезиан скважиналары ихатасында исән калган берән-сәрән агачлар өстеннән кояш күтәрелеп килә.* Р.Кәрами

**АРТЕЛЬ** *и. рус* 1) Уртак җаваплылык нигезендә эш башкарып, табышфайданы бертигез итеп бүлә торган берләшмә. *Мине эзләп, урман эчләрендә адашып йөргән, «Фәйзулла Хәкимовны белмисезме?» – дип, әле – бер, әле икенче артельгә барып чыккан.* Н.Хәсәнов. --- *ул Кычыткалыда үз эшен, хәзерге атама белән кыйландырганда, коммерциягә нигезләнгән артель ачып җибәрде.* Т.Галиуллин

2) *күч.* Төркем. *Ирекле рәссамнар артеле*

**АРТЕЛЬДӘШ** *и.* Бер артельдә эшләүче, бер артель кешесе

**АРТЕЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф.* Артельгә берләштерү, кумәкләштерү

**АРТЕЛЬЛӘШҮ** *ф.* Артельгә берләшү, артель булып оешу

**Артельләшеп алу** Кыска вакыт эчендә артельләшү; артельләшүгә ирешү

**Артельләшеп бетү** Тулаем, бөтенесе дә артельләшү

**Артельләшеп килү** Эзлекле рәвештә, акрынлап артельләшү

**АРТЕЛЬЧЕ** *и.* Артель әгъзасы. *Тәүфыйк, еш кына, артельче карчыкларның эшләгәнен карап торырга килә.* Т.Мөбарәков

**АРТЕРИАЛЬ** *с.* Артериягә мөнәсәбәтле. *Ләкин шул көнне үк, нилектәндер, Фатихның күз эчендәге кан басымы да, артериаль кан басымы да күтәрелде.* С.Ибраһимова

**АРТЕРИОСКЛЕРОЗ** *и. гр. мед.* Артерия стеналарының калынаюы һәм катылануы нәтиҗәсендә барлыкка килгән хроник авыру

**АРТЕРИОСКЛЕРО́ТИК** *с.* Артериосклерозга мөнәсәбәтле. *Әгәр дә инде ачыклыкны каплап торучы артериосклеротик тәңкәчек кенә булса, ул чагында, аны алып, кан тамырының үткәрүчәнлеген кире кайтарырга өмет бар.* Ф.Углов

**АРТЕ́РИЯ** *и. гр.* 1) *анат.* Канны йөрәктән бөтен тәнгә – әгъзаларга һәм тукымаларга тарата торган кан тамыры. *Шул чагында артерия – кан тамыры зарарланган булырга тиеш.* Э.Шәрифуллина

2) *күч.* Әһәмияте зур булган, мөһим роль уйнаган бәйләнеш, элемтә чарасы (мәс., *тимер юл һ.б.*). *Әйе, ул – чыннан да киң тормыш белән сугарылган артерия, Чаллының хезмәт кайнап торган организмына көч бирүче артерия.* М.Сафин

**АРТЕФАКТ** *и. лат.* Табигый хәлдә очрамый торган, ясалма барлыкка китерелгән әйбер яки күренеш; эксперимент үткәргәндә методикадан тайпылу аркасында барлыкка килгән нәтиҗә

**АРТИКЛЬ** *и. лат. лингв.* Кайбер телләрдә исемнең билгелелек-билгесезлек,

род һәм сан категорияләрен белдерә торган грамматик кисәкчә. *Артикль, мөстәкыйль сүзләр белән килеп, аларның грамматик үзенчәлекләрен күрсәтә.* Ф.Сафиуллина

**АРТИ́КУЛ** *и. лат.* Җитештерелгән товарның төре, тибы; шуларны белдергән санлы яки хәрефле билгеләр

**АРТИКУЛЯЦИОН** *с. лингв.* Артикуляциягә мөнәсәбәтле. *Артикуляцион базаның тотрыклылыгы чит телләрне өйрәнгәндә шактый нык сизелә.* Ф.Сафиуллина

**АРТИКУЛЯ́ЦИЯ** *и. лат. лингв.* 1) Сөйләү әгъзаларының авазларны әйткән вакыттагы хәрәкәте һәм торышы. *Авазның акустик билгеләре сөйләм аппаратының эшчәнлегенә – авазның артикуляциясенә бәйле була.* Ф.Сафиуллина

2) Сөйләмдә сүзләрне, авазларны дөрес һәм ачык итеп әйтү дәрәҗәсе. *Әлбәттә, диктор сөйләменең иң мөһим сыйфатларыннан тагын берсе – яхшы дикция һәм төгәл артикуляция.* Р.Заһидуллина

**АРТИКУЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Артикуляция ясау

**АРТИЛЛЕРИСТ** *и. рус* Артиллериядә хезмәт итүче солдат; тупчы. – *Сез нинди частьтан? – дип сорады ул Зөфәрдән. – Мин артиллерист, ә сез?* Ә.Галиев. *Әти фронтта артиллерист булган.* Ш.Маннапов

**АРТИЛЛЕРИСТЛЫК** *и.* Артиллерист булу. *Ул үзенең лагерьда артиллеристлыкка өйрәнгән көннәрен хәтерләп алды.* Ш.Маннур

**АРТИЛЛЕ́РИЯ** *и. фр.* 1) *җый*. Төрле конструкциядәге һәм калибрдагы туплар. – *Ә пулемётлар, артиллерия?!* Г.Бәширов. *Бохара өлкәсенең Каган шәһәрендәге янгын артиллерия складларын юкка чыгарган.* Шәһри Казан

2) Шундый туплар белән коралланган гаскәр төре. *Алар белән артиллерия һәм атларны чыгарырга исәп тотылды.* В.Казыйханов. *Түбән Новгородка, чит ил инженерлары белән бергә, артиллерия җибәрелә.* Идел

3) Төрле утлы ату коралларының төзелеше һәм алардан файдалану ысуллары турындагы фән

**АРТИСТ** *и. лат.* 1) Сәнгать әсәрләрен тамашачылар алдында башкаручы (җырчы, актёр, музыкант һ.б.). *[Күршем:] «Бу мөгаллимә ролендәге артист бик яхшы уйный», – диде.* Г.Исхакый. *Артист халкы кайда да артист булып кала.* Ф.Сафин

2) *күч. сөйл.* Берәр эштә зур талант иясе, нинди дә булса эшне бик оста башкаручы (тискәре мөнәсәбәттә дә). *Һәммәсеннән димәсәк тә, сатучыларның күбесеннән менә дигән артист чыгар иде.* К.Кәримов

3) *күч. гади с. шаярт.* Кыланчык, уйнап сөйләшкән, үзен ясалма тоткан кеше. *Кави карт, Исбахны күреп, шаркылдап көлә: «Монысы тагын нинди клоун?! Артист!»* Д.Салихов. *«Ә-ә, шулаймыни...» – дигән булды Хәдичәтти артистка.* М.Мәһдиев

**АРТИ́СТКА** *и. рус* Артист хатынкыз, *к.* **артист**. *Анда чибәр артисткалар, генерал кызлары белән вальс-бостон биергә яратадыр?* М.Юныс. *Безгә бер артистка җитмәде.* А.Расих. *Бу атаклы артистка концертларын мин һәрьюлы яратып, бирелеп тыңлый идем.* А.Шамов. *Күршебез Хәлимә апа да чын артистка – көйләрне үзе чыгара.* А.Хәсәнов

**АРТИСТЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Образ барлыкка китерү, образ тудыру. *Бу көнне итле аш пешкәнен шулай артистланып күрсәтсә дә, ай-вайлап чакырсак та, табынга калмады: – Нәкыя апагызның токмачы казанда сикереп калды, булмый, парин.* Б.Рәхимова

2) Кылану, көлдерү, үз-үзен ясалма тоту. *[Полковник:] Комедия ясап, артистланмагыз, зинһар, сез театрда түгел!* Ә.Гаффар. *Карачкы --- артистланырга ярата.* З.Фәтхетдинов. *[Кыз Ринатка:] – Алдашасыз. Артистлану сезгә килешми.* В.Нуруллин

**Артистланып алу** Бераз, аз гына, тиз арада артистлану. *Салих янә кәнфитләнеп, артистланып алырга булды.* Т.Галиуллин

**Артистланып бетү** Артистлану дәрәҗәсенә җитү

**Артистланып тору** Әле, хәзер артистлану

**АРТИСТЛА́РЧА** *рәв. сөйл.* 1) Артист кебек, артистларга хас булганча. *[Сәгыйть] Китап-дәфтәр кыштырдатып дәрес әзерләргә җыенган җиреннән, кинәт башын күтәреп, артистларча килештереп, шигырь укый башлады.* Ф.Сафин. *Бераз вакыт үткәч, Сәгыйть Рәмиев, артистларча баскан килеш, көчле тавыш белән, бер озын көйгә, аннары кыска көйгә җырлады.* Казан утлары

2) Оста, шома, бик яхшы белеп. *Тик ул шундый матур итеп, нәфис итеп артистларча сөйли ки, – тыңлаган кешеләрнең күз алдына ул сөйләгән вакыйгалар аллы-гөлле чынбарлык булып килеп баса.* В.Юнысов

3) *күч. гади с.* Ясалма, сәхнәдә уйнаганча. *Ул шушындый матур хәрәкәтләр белән артистларча гына чыгып китәргә уйлаган иде, ләкин аны Муса бүлде.* Ш.Маннур. *Харис Рәмзия апасы алдыннан ишекне каерып ачты, аннары, рәхим итегез, дигәнне аңлатып, артистларча кулын алга сузды.* Б.Камалов

**АРТИСТЛЫК** *и.* Артист булу; артист һөнәре, профессиясе. *Ирек бу эштән дә җиранмәде, үзенең артистлык сәләтен эшкә җигәргә тырышты.* Ф.Садриев. *Ләкин һич кенә дә артистлык һөнәре юк икән егетнең, хәтта кубыз да уйный белми, сәхнә уены юк та юк инде!* Ш.Маннур. *Мәгәр кызый авылдан китү турында сүз кузгатмый, артистлык хыялы турында кат-кат искәртеп, өйдәгеләрнең теңкәсенә тими.* К.Кәримов

**АРТИШОК** *и. нем. биол.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, эре чәчәк төркемле, аскы калын итләч өлеше ашарга яраклы күпьеллык үлән үсемлек

**АРТКА** *рәв.* Арт якка, юнәлешнең кире ягына. *Вакыйф сумкасын идәнгә куюга, дуслар ирләрчә кочаклаштылар да, берәр адым артка чигенеп, бер-берсен тагын күздән кичерделәр.* С.Шәмси. *Ул тыңлаусыз сирәк чәчләрен артка сыпырды.* Р.Сибат. *Сиңа тик бер адым алга, ә миңа бер адым артка атларга иде! – без аңлашыр идек!* Р.Гаташ

◊ **Артка китү** Начарлану. **Артка чигерү** Кичектерү, күчерү, соңарту.

*Җәза бирү чаралары да бар: фатир чиратын артка чигерү, җәй көне ял бирмәү һ.б.* Р.Кәрами

**АРТКУРА** *җый. и.* 1) Абзар, келәт һ.б. каралтылар барысы бергә

2) *куч. иск.* Бай йортында хезмәтчеләр яшәү өчен эшләнгән, алачыклардан торган урын. *Кайчандыр үзенең беркатлы, күңелле табигате белән бөтен арткурага ямь биреп торучы --- акыллы кызны, Нәсимәне, ул беренче күрүдән үк ошаткан иде.* К.Нәҗми

**АРТКЫ** *с.* Артта булган, артка урнашкан, арт ягындагы, *киресе:* **алгы.** *Арбаның арткы бер тәгәрмәче --- кыек-мыек бара.* Р.Сибат. *[Рухия] Мотоциклның арткы утыргычына барып тотынды.* В.Нуруллин. *[«Нива» машинасының] Арткы ишеге булмагач, ошатмаган.* Т.Нәҗмиев

◊ **Арткы акыл** Эш үткәч кенә башка килә торган, ачы тәҗрибә белән килгән акыл, сабак. --- *мәкаль, күбесенчә, һәммәбез өчен гыйбрәтле бер өлге сүз, уртак әһәмияте булган бер арткы акыл, бер тәҗрибә яки иҗади хыял кыставы астында килеп чыккан бер мисал булып туа.* Н.Исәнбәт. **Арткы планга калу** Онытылу, сүрелү, игътибар үзәгеннән төшү. *Печән өстендә чуртан балыгыннан пешкән шулпа авыз иткәнгәме, Вятка буенда уха пешерү арткы планга кала башлаган иде.* Р.Сибат. **Арткы уй** Яшерен явыз ният. **Арткы число белән** Соңыннан, күпмедер вакыт үткәннән соң. *[Шәмгун] Димәк, мин аларга арткы число белән кул куярга тиеш?!* Ә.Фәйзи

**АРТКЫ́ САН** *и. гади с. к.* **артсан** (*1 мәгъ.*), **арт** (*4, 8 мәгъ.*). *[Савымчылар] Рәфис үзләренә дәшмәсен дигән күк, бер дә кирәкмәгәнгә, сыерларына: «Пуга, пуга!» – дип кычкырып, арткы саннарын учлары белән чапылдата-чапылдата, каядыр кугандай итәләр иде.* А.Вергазов

**АРТКЫ́ ЯК** *и. диал.* Авыл өенең йорт ягына чыккан өлеше; кара як (ашарга пешерү, терлеккә, кош-кортка ризык әзерләү һ.б. хуҗалык эшләре башкарыла торган бүлмә). *Ул арада Мәрьям нииндидер эш тапкан булды да ачык ишектән арткы як бүлмәгә чыгып китте.* Н.Фәттах

**АРТЛАП** *бәйл. сөйл.* Берәр нәрсәнең арткы ягы буйлап башкарылган эш-хәрәкәтне белдерә. *Кеше күзе күрмәгәндә генә, ындыр артлап, тагын чыгып таям.* Р.Вәлиев. *Бакча артлап кына басуга чыгып йөгергәнеңне сизми дә каласың.* Р.Төхфәтуллин

**АРТЛАТЫП** *бәйл. сөйл. к.* **артлап.** *Без, бакча артлатып кына, Рөстәмнәргә йөгердек.* Р.Хафизова. *Оялчан елгасына тагын турыдан – ындыр артлатып та төшәргә була.* Хәйдәр

**АРТЛЫ** *с.* Арты булган, арка терәп утыра торган, арка терәргә җайлап ясалган. *Җир асты келәтенең уртасында юан аяклы язу өстәле һәм бөгеп эшләнгән артлы урындык тора.* А.Тимергалин. *Авылга яңа клуб салдыргач, анда артлы урындыклар кайтарып тезделәр.* Татар иле

**АРТРИТ** *и. гр. мед.* Буыннарның ялкынсынуы. *Хәсән абыйның тауга күтәрелгәндә аягы авырта, аңарда – артрит.* Ш.Галиев

**АРТСАН** *и.* 1) Түшкәнең билдәмә һәм арт ботларыннан торган өлеше. *Алар үлән чемченәләр, артсаннарын көлкеле сикертеп, бер урыннан икенче урынга күчәләр иде.* Р.Фәизов

2) *сөйл. к.* **арт** (*8 мәгъ.*). *Табигать, ничектер, артсан белән күкрәкне турыга тоташтырган.* М.Юныс

**АРТСЫЗ** *с.* 1) Арты юк, арка терәве булмаган. *Шуңа күрә [Мотаһир] тәрәзә каршындагы өстәл янынннан артсыз ике урындыкны, уртадагы тишекләренә бармак тыгып, ишек катынарак кузгатып куйды.* Р.Кәрами. *Аның кинәт көлеп җибәргән тавышына, газ плитәсе янындагы артсыз урындыкта йокымсырап яткан йонлач песие дә башын күтәреп карады.* З.Хөснияр

2) Үкчәсе ачык (аяк киеме турында). *Бер кат трико-футболка, джинсы күлмәк, артсыз башмаклардан гына урам буйлап атлаучыга кешеләр сәерсенеп карыйлар.* И.Сираҗи

**АРТСЫ́З УРЫНДЫК** *и.* Табуретка, бүкән. --- *кулдан ясалган гади өстәл, артсыз урындык та шулкадәр якын, үз тоелды.* Р.Вәлиев

**АРТТА** *рәв.* Арткы якта. *Артта Аскәрнең хатын-кызларны, кычкырып, куып йөргәне ишетелә.* Т.Гыйззәт

◊ **Артта булу** Калышу. **Артта калу** 1) Эш барышы начарлану, әкренәю. *Ә уңай герой җиңәргә тиешле тормыш каршылыклары булып, җитмешенче еллар прозасында артта калган колхозлар һәм төрле оешмалар, маңгай тире, арка тире түгүне көтеп яткан зур-зур эшләр сурәтләнде.* Казан утлары; 2) Надан калу, белеме сай булу, тормыш таләпләренә җавап бирерлек хәлдә булмау. *Артта калдым бу мәсьәләдә.* Ф.Хөсни; 3) Вакыйга, хәл-кичерешләр үткәнгә күчү, үткәндә калу, онытылу, бетү. *Димәк, бөтен мәшәкатьләр артта калды.* Ф.Садриев. **Артта тору** 1) Исемлек буенча яки тезелеп торган рәттә иң артта булу; 2) Икенче планда булу, әһәмиятле булмау

**АРТТАКТА** *и. махс.* Киемнең арканы каплый торган өлеше

**АРТТАЛЫК** *и.* 1) Артта булу, артта калу. *Безнең техник һәм технологик арттальікның нигезендә социаль яктан артта калу ята.* Ә.Борһанов. *Әмма бу юлы --- артталыкның сәбәпләрен берәм-берәм күрсәттеләр.* Г.Кашапов. *Ул да, иң беренче, туңга сөрүнең барышын сорады, артталыкның сәбәпләрен ачыклады.* Х.Хәйруллин

2) Наданлык, мәгърифәтсезлек. *Әлеге китапта ---, икенчедән, феодаль Көнчыгыш, гарәп илләрендәге артталыкны, үзе әйткәнчә, төрле «юньсезлекләр»не тәнкыйть итү --- ачык төсмерләнә.* Ш.Садретдинов

**АРТТАН** *рәв.* **1.** 1) Арткы яктан, арка ягыннан, бару юнәлешендә. *Авылдан чыгып шактый баргач, арттан аларны җигүле ат куып җитте.* Р.Кәрами. *Менә болар шулай барганда, арттан: «Һайт, бер якка!» – дигән тавыш ишеттеләр.* Г.Исхакый

2) Ахырдан, соңыннан, соңгысы булып. *Иң алдан Зөфәр, аннан – атасы, арттан Абу баба бара.* Б.Сөләйман

**2.** *бәйл. функ.* Берәр нинди эш-гамәлне башка зат аша, аның арадашлыгы белән башкаруны белдерә; аркылы, аша. *Күршем улына дигән күчтәнәчләрне минем арттан җибәрде*

◊ **Арттан куучы бармы (юк)** Ашыктырып торучы, куалап торучы булмагач ашыкмаска да мөмкин, дигән мәгънәдә. *Көнозын авыр чүкеч белән селтәнү җиңел түгел, әмма түзәргә була, арттан куучы юк.* З.Моталлапов. **Арттан этүче** Ярдәм итүче, булышлык күрсәтүче. *[Әсләф:] Тормышымда арттан этүчеләр булмаса да, юашларны таптап, усалларны җайлап күтәрелдем мин.* Д.Салихов

**АРТТЫРУ** *ф.* **1**. 1) Сан, күләм, үлчәм ягыннан күбәйтү, үстерү, ишәйтү. *Ә бит сөтне, киметү түгел, ике атна эчендә сыер башына йөз иллешәр грамм арттыру бурычы куелды.* Ф.Садриев. *Мин ханның, Болгарның җирен-суын арттыру өчен, чит халыклар белән сугыштым.* Н.Фәттах

2) Эш-хәрәкәтнең тизлеген, интенсивлыгын көчәйтү, зуррак итү. *Аяклар таш шикелле булса да, кызулыкны арттырдым.* Ә.Хәбибуллин. *Янчурин, уйларыннан арынып, Байталының янтыгына шпорларын кыскалады, тизлекне арттырырга тырышты.* Ш.Шәйдуллин. *– Тизлекне дә арттырып, күмергә дә экономия ясарга йөкләмә алгач, кочегарларга нык тырышырга туры киләчәк, – диде өченче механик Горбенко.* М.Юныс

3) Дәрәҗәсен, куәтен яки нинди дә булса сыйфат билгеләрен күтәрү, үстерү. *Аннан, белемен арттыру өчен, Мәскәү тимер юл техникумына җибәрәләр.* Т.Нәҗмиев. *Мондый хәл исә җаваплылыкны тагын да арттырырга тиеш.* Т.Галиуллин. *Шушы уй аның күңелен җылытып җибәрә, укуга дәртен тагын да арттыра иде.* Ф.Сафин. *Монысы аның матурлыгын бары тик арттыра гына.* М.Хәсәнов

4) Бәя, хезмәт хакын күтәрү. *Тагын азрак кына [бәясен] арттырырга була.* Хәйдәр

5) Кемгә дә булса үзеңә дигәннән бүлеп бирү, өлеш чыгару. *Дөресен генә әйткәндә, Халидә үзе дә Рифгатьне әнисеннән ким яратмый, кайткан чакта, стипендия акчасын ничек кирәк алай арттырып, аңарга Алабугадан нинди дә булса берәр бүләк алып кайтырга тырыша иде.* Ф.Хөсни. *Мәскәүләр кайтып төшсә, үзебезнең кышлык ит-бәрәңгедән аларга да бераз арттырырга туры килер, дип, әти күңелгә шом салып куйды.* Заман

6) *куч. сөйл.* Берәр хәл, күренеш турында, үзеннән ялган кушып, күпертеп сөйләү; чынбарлыкта да нәкъ шулай булган кебек күрсәтү; шапырту, шапырыну. *Малайлар миңа «арттырасың түгелме?» дигән кебек карап куйдылар.* Р.Хафизова. *Арттырып сөйләгәч, вакыйгага үзең дә катнашкан кебек буласың.* М.Галиев

**2**. **арттырып** *рәв. мәгъ.* Билгеләнгән нормадан, тиеш күләмнән артыграк итеп. *Иптәшләр, быел без сезгә планны икеләтә арттырып бирәбез.* Б.Сөләйман. *Планны да, өстәмә планны да арттырып үтәдек, бусын азрак киметеп булмыймы, Рәшат Галиевич?* Х.Хәйруллин. *Ул бу срокны арттырып тутырган иде инде.* М.Хуҗин

**Арттыра бару** Торган саен күбрәк арттыру, арттырганнан арттыру. --- *һәр гектарыннан уңыш алуны да арттырганнан-арттыра барганнар.* М.Хәсәнов. *Матурлыгын дөнья Гел арттыра бара.* Г.Афзал

**Арттыра башлау** Арттырырга тотыну. *[Мәүлитҗан:] Әгәр арттыра башласам, аякка басарсың.* Д.Салихов

**Арттыра тору** Эзлекле рәвештә, азазлап арттыру. *Ә тормыш шартлары, дуслар ярдәмендә, ихтыяҗны көннән-көн арттыра гына тора.* М.Юныс. *Җае чыккан саен, ул исәпне арттыра торды, һәм «Партизан Расад» сүзләре немецлар арасында телгә дә керә башлады инде.* Г.Кутуй

**Арттыра төшү** Бераз арттыру. *Идарә башлыгы, аяк өсте торып сөйләшүнең рәсмилекне арттыра төшүен шәйләп, урынына утыргач, халык бераз тын торды.* Р.Кәрами. *Кырга чыккач, тизлекне тагын да арттыра төшеп, ул инде Чүкәйгә бара торган юл өстендәге таныш урман буена килеп тә җиткән иде.* В.Нуруллин

**Арттырып алу** Тиз арада, кыска вакытка арттыру

**Арттырып бетерү** Артык, чамадан тыш арттыру. *Мәгънә, рифма бөтенлеген сакламыйча, әллә нинди сүзләр, җөмләләр арттырып бетергәннәр.* М.Җәлил

**Арттырып җибәрү** 1) Мөмкинлектән файдаланып кинәт арттыру. *Үз йортларына кайткач, сарыклар санын арттырып җибәрделәр.* З.Зәйнуллин

2) *куч.* Сөйләгәндә, язганда билгеле бер чиктән, чамадан чыгып арттыру; булмаганны да, булды, дип әйтү, сөйләү, артыграк арттыру. *Арттырып җибәрдем бугай, министр көлеп куйды.* Х.Хәйруллин. *[Сәлмән:] Арттырып җибәрдем бугай.* Д.Салихов. *Автор арттырып җибәрмәде микән, дип тә куясың.* С.Шәмси

**Арттырып кую** Арткан хәлгә китерү. *– Син малыңны миңа калдырып кит, мин аны арттырып куярмын, – ди.* Х.Гатина

**Арттырып ташлау** *к.* **арттырып җибәрү** (*2 мәгъ.*). *Арттырып ташлый торган гадәтем бар шул.* Ә.Гаффар

**Арттырып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз арттыру. *Шуңа күрә ул, үз-үзен саклар, яшәтер өчен, бертуктаусыз салым күләмен һәм түрә-чиновниклар санын арттырып торырга мәҗбүр.* Т.Миңнуллин. *Кара чәчләреңә бәс кунган; бу ак чәчләрең затлы тоз кебек матур ялтырый. Алары да килешеп, ышандыру көчен арттырып тора.* Т.Галиуллин

**АРТТЫРУСЫЗ** *рәв.* Арттырмыйча, чамадан читкә чыкмыйча, чаманы белеп; чын дөресен. *Бу чаклысын мин һич арттырусыз әйтәм, ник дисәң, шул койрыкта сөйрәлүчеләрнең берсе мин идем.* Ф.Хөсни. *Һич арттырусыз, авыз-борын кискән кебек булды да куйды.* Шәһри Казан

**АРТУ** *ф.* 1) Сан, күләм, авырлык ягыннан күбәю, зураю, үсү, ишәю. *Сөтнең тулай җыеме быел кимендә егерме-егерме биш процентка артачак.* Х.Хәйруллин. *Яңгырдан соң, елгада су артты.* А.Чурбанов. *Маңгаенда җыерчыклар арткан бугай.* К.Кәримов. *– Безнең халыкның каны коелганнан, илдә ятимнәр артканнан аларга ни соң? – дип куйды Мукум абзый.* А.Хәсәнов. *Заһит китергән әйберләрне арзан бәягә алып, кыйммәткә сатып җибәрә башлагач, Сәгыйтьнең кереме күзгә күренеп артты.* Ф.Яруллин

2) Моңарчы булганга яңадан берәр нәрсә (мәс., эш) өстәлү. *Язга чыгу белән, алар өчен эш тагы да артты, төзелештәге көнлек эшләреннән соң, кешеләрне далага чирәм җир казырга куа башладылар.* Ф.Бәйрәмова. --- *котельныйдан чыккан төтеннең, гараж-мастерскойларда аккан бензин-майларның, фермадан чыккан тиреснең күләмен билгеләп, табигатькә ни дәрәҗәдә зыян салынуын ачыклый һәм чистарту юлларын күрсәтә. Әгәр шундый документ булмаса, хуҗалык җитәкчесенә штраф артыннан штраф салалар. Шул рәвешле, авыл кешеләренең тагын бер мәшәкате артты.* М.Маликова

3) Күрсәтелгән эш-хәлдән соң узып китү, үтеп китү (мәс., ел, яшь, гомер). *Анда карт шаһиншаһ гүр иясе булып, тәхеткә аның улы Бахрам менеп утыруы хакында хәбәр таралуга бер елдан артты инде.* Б.Рафиков. *[Җамал әби:] Инде миңа сиксән тулып артты.* К.Сибгатуллин. *Гафу итегез, Касыйм Сабирханович, безнең килгәнгә ике сәгатьтән артты инде.* Д.Салихов

4) Берәр нәрсәнең бәясе яки сату кыйммәте күтәрелү. *Яңа елдан коммуналь хезмәтләр өчен түләү шактый артты.* Ф.Зариф. *Исәпләсәң, искитәрлек, бәяләр бит ничек артты.* Р.Хисмәт // Хезмәт өчен түләү хакы, пенсия акчасы күтәрелү. *«Сугышта катнашучы» таныклыгын да бирделәр, пенсиясе дә артты.* М.Ибраһимов. *Ул арада гонорарлар да артты.* М.Маликова

5) Артык булу, кирәкмәскә әйләнү; ташлану. *Кем аңлатыр: нәрсә булды илгә, Ничек ипи артты табыннан?* В.Галиев

6) Нинди дә булса үзлекнең, сыйфатның һ.б. билгеләрнең чагылыш дәрәҗәсе көчәю, күрсәткече күтәрелү. *Ырынбур тирәләрендә эсселек тагын да арта.* М.Юныс. *Бу исә культурабыз үсү, кешеләрнең рухи таләпләре арту, тормышның көннән-көн катлауланa баруы --- белән бәйләнгән.* Г.Ахунов. *Икесендә дә ихласлык, бер-берсенә ышаныч арта иде кебек.* Х.Камалов

7) *күч.* Берәр кемнең яки нәрсәнең абруе, дәрәҗәсе, даны күтәрелү. *Колхозлашу чоры башлангач, ул козырьның [Сабирның] кыйммәте тагын да артты.* М.Әмир. *О бәрәңге, елдан-елга даның артты, Туган җирең – тирес түккән абзар арты, Өстәлләрдә кышын да син, җәен дә син, Тема булдың Тукайга, Хөсәенгә син.* Г.Афзал. *Мондый хәл районда күрелмәгән нәрсә иде, минем дан артты бугай, югарырак постлар тәкъдим итә башладылар.* Н.Гыйматдинова. *Хан моңа ышанып, күңеле шат булып, сәламәтлеге артты, аны үзенә угыл кылып, Нурмөхәммәд дип исем куйды.* Ә.Баһадир

**Арта бару** Һаман саен, эзлекле рәвештә, акрын гына арту. *Җәннәт эзләп, авылдан китүче яшьләр саны арта бара.* Ф.Садриев. *Уйлаган саен, сагышларым арта бара.* Н.Дәүли. *Көн үткән саен, үтәлмәгән хезмәт көннәре арта бара.* Ф.Сафин. *Погром куркынычы арта барды.* Казан утлары

**Арта башлау** Артырга тотыну. *Бу вакытта инде көннәр озыная, яктылык арта башлаган иде.* Г.Әпсәләмов

**Арта бирү** Артуын дәвам итү

**Арта килү** Эзлекле рәвештә, системалы арту, өсте-өстенә өстәлеп арту. *Завод-фабрикалар, автомашиналар чыгарган газ һәм төтен күләме елдан-ел арта килә*

**Арта тору** *к.* **арта бару**. *Без беләбелгәннән бирле штат кыскарту бара, ләкин, кыскарткан саен чиновниклар саны арта тора.* Р.Миңнуллин. *Мөхәммәд пәйгамбәрнең иманга чакыруларына колак салып мөселман булган кешеләр Мәккә шәһәрендә арта торды.* Ф.Яхин. *Демонстрантлар саны һаман арта торды.* Казан утлары

**Арта төшү** Бераз арту; тагын да арту. *Әгәр егеттә кызга карата тирән хис борын төрткән икән, гадәттә, аның тыйнаклыгы арта гына төшә.* Ф.Углов. *Җәмгыять аяусызлана һәм саңгыраулана барган саен, кешеләрдә эгоизм һәм хөсетлек арта төшә.* Н.Хәсәнов. *Бездә соңгы елларда комплиментарлык кимеде, аның каравы, барлык әсәрләрне бергә тезеп яманлау арта төште.* Г.Ахунов

**Артып бару** Якын вакытта, шушы тирәләрдә артачак яки арткан булу; акрынлап арту. *Яшем инде сиксәннән артып бара.* Н.Фәттах

**Артып калу** Билгеле күләмгә сыймау. *Миндә ике пропуск артып калды.* Мирас. *Ләкин Хупҗамал абыстайның күңеле булган, тавык буяу планы тулысынча үтәлгән, өстәвенә, әле ярты бактан артыграк буявы да артып калган.* Ф.Хөсни. *Эш урыны гел артып кала монда, кешеләр гел җитми.* Ә.Галиев

**Артып китү** Билгеле бер чиктән, нормадан, тиешле күләмнән арту. *Температурасы кырыктан артып киткән иде.* Х.Камалов. *Терлекче Рәшит Мортазинның фермадагы хезмәт стажы 36 елдан артып китә.* К.Тимбикова. *Көннең эсселеге кырык биш градустан узып, һавадагы дым туксан проценттан артып китсә, хәлем шәптән булыр, дип өметләнмә.* М.Юныс. *Андый мәкаләләр өчен каләмхак – гонорар да кайвакытларда газеттан алган айлык хезмәт хакыннан артып китә иде.* Р.Мирхәйдәров

**Артып тору** Эзлекле рәвештә, азазлап арту. *Фронтларда сугышлар кыза барган саен, безнең чабаталарга да сораулар артып кына тора.* А.Хәсәнов

**АРТЧА** *и. этн.* Тукыма кисәгенә берничә рәт тәңкә тезеп ясалган, хатыннарның чәченә тагыла торган бизәнү әйбере, тезмә. *Бизәнү һәм кием-салым өлкәсенә караган сүзләр: артча – хатын-кызларның бизәнү әйбере, 3–4 рәт тәңкәләр тезелгән һәм чәч толымнары өстенә куела торган 2 тар тукыма кисәге.* Татар халык сөйләшләре

**А́РТ ЧҮМЕЧ** *и.* Башның арткы өлеше. *Шамил аның соңгы сүзләрен ишетмәде, кинәт башының арт чүмеченә кемдер җылы чүпрәк куйган кебек булды да, күз аллары караңгыланып, машина басмасына утырды.* З.Фәтхетдинов

**АРТЪЯПМА** *и. этн.* Хатын-кызларның баш киеменә ялгап эшләнгән һәм чәч толымын каплап торган япма

**АРТЫГЫ́НЧА** *рәв.* Артыгыннан тыш, артыгы белән

**АРТЫК** *с.* **1.** 1) Кирәгеннән артып киткән, артып калган; кирәгеннән тыш. *[Сыер] Бер елдан соң сөтне ике мәртәбә артык бирә башлаган.* Р.Сибат.

*Артык бүлмәләрендә, хәтта мунчасында да фатирчылар тота һәм хакын да каерып ала иде*. Ш.Маннур. *Артык кием-салым хатын-кызның гүзәллеген, сылулыгын яшерә генә.* М.Хәсәнов

2) Кирәксез, хаҗәте булмаган; тиешсез, урынсыз булган. *Артык сүз ычкындырмагаем, дип, үзе дә шүрләгән булса кирәк, башы күккә тиярдәй шатланып кайтып киткән шул сүзләрдән соң.* Ф.Хөсни. *Ул үзенең бу мәҗлестә инде артык кеше булуын сизә.* А.Вергазов

3) *күч.* Әллә ни; күзгә күренерлек, сизелерлек. *Галәмне айкап төшкән космонавтларга да артык исе китми башлаган безнең заман халкын фән кандидаты булу белән генә шаккатырып булмый да булмый инде.* В.Нуруллин. *Аларга үрнәк булган Көнбатыш Европа илләреннән Алмания, Италия, шулай ук Австралиядә гөрләп чәчәк аткан классик музыка әсәрләренең дә нindирәк даирәләрдә туганлыгы, үстерелгәнлеге артык сер булмаса кирәк.* М.Госманов. *Аның киләчәге фаҗига булып бетәчәге дә артык шик тудырмый.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик нык, чиктән тыш, чамасыз. *Нәкъ шуны искәрткәндәй, Әхмәтсафа артык коелып төшмичә генә сүз башлап азаплана әнә.* Ф.Сафин. *Халыкның артык дәрәҗәдә күндәмлеге, юашлыгы, үҗәтлеге шаккатыра иде аны.* М.Әмирханов. *Ни өчен безне туган җирдән аердылар? Әллә әтинең артык та намуслы, артык та эшсөяр булуы сәбәп булдымы?* Идел

2) Күп, күбрәк. *Наратлык буенда уздырган сәгатьтән артык вакыт эчендә, ул тагын икенче кешегә әверелде.* Ф.Садриев. *Әхмәдулла – сабыр кеше, гадәтенчә, артык сөйләшми.* Р.Сибат. *Районда меңнән артык трактор бар.* Казан утлары. *Москонцерт уздырган гаять таләпчән конкурста Шәфика, ике йөздән артык җырчыны артта калдырып, җиңеп чыкты*. Мирас

3) Кирәгеннән тыш, тиешеннән күп; чаманы белмичә; арттырып. *Син дусты бит, әйт әле шуңа, артык көчәнмәсен, яраткан энекәшемнән колак кагасым килми, ди.* З.Хөснияр. *Чөнки, артык тел озайта башласа, бер баруында, үзенең дә ике катлы йортта «куна калуы» ихтимал.* Р.Кәрами. *Я моңаеп, уйланып утыра, я кирәгеннән артык шаяра.* Р.Кәрами

4) Шуннан ары, аннан тыш; алга таба. *Мин ул чакта боларның һәммәсен, шулай тиеш, дип кабул иттем һәм бу турыда артык баш ватмадым.* Д.Лондон. *– Бу хәтле җаһил да булырсың икән! – Нәгыймәттәй, ярсуына буылып, шуннан да артыгын әйтә алмады.* К.Кәримов. *Юк, хатны артык укый алмадым.* Н.Дәүли

5) Шулардан башка, тагы, өстәмә. *Аларда бер кечкенә гаилә өчен кирәк булган әйберләрдән артык берни юк.* А.Шамов. *Бәлки, ул кульъязманы сүтеп ташларга теләмәгәндер, ә, бәлки, әйтеп торудан файда юк, бу карттан шуннан артыгын көтеп булмый, дип уйлагандыр.* Ә.Еники

6) Кирәксез, урынсыз, вакытсыз. *Әухәтнең сүзләренә җавап кайтаруны артык санап, Гөлҗиһан эндәшмәде.* Ф.Сафин

7) Кабаттан, яңадан, янәдән; башкача, тагын да. *Чәй эчкән вакытта, шинель белән итекләр мәсьәләсе артык телгә алынмады.* Ш.Камал

8) Күбрәк, ныграк. *Мин аны, ата булганга күрә генә түгел, акыллы булуы, ягымлылыгы, сөйкемлелеге өчен, дөньяда һәммә нәрсәдән дә, барлык кешеләрдән дә артык яратам.* Г.Бәширов

**3.** *хәб. функ.* 1) Яхшы, яхшырак. *Ул юлда йөргәнче, пристаньда бер атна пароход көтеп утыруың артыграк.* Т.Галиуллин. *Атасы, онытма инде, болай итеп мал асраганчы, асрамавың артык.* Х.Хәйруллин. *– Минем өчен аның эшкә урнашуыннан укырга керүе артык, – диде Татьяна апа.* М.Юныс

2) Кирәге калмау, ихтыяҗ бетү, артыксыну, мәгънәсендә. *Үз хатыны да артыктыр әле...* З.Фәтхетдинов

**4.** *и. мәгъ.* Кирәгеннән артып киткән берәр нәрсә. *Бу минутларда аның артыгын, кирәкмәсне сорашуы, барлык уй-гамәлне бутап ташлавы мөмкин иде.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Әмма, җәяүлегә янчык та авыр, дигәндәй, малай моннан да артыгын күтәрә алмам, кадерле азыкны ярты юлда ташлап калдырырга туры килмәгәе, дип борчылды.* А.Хәлим. *Ярый, дускайларым, артыгын да текелдәп ташладым бугай инде.* Ш.Маннур

◊ **Артыгы белән җиткән** Булган кадәресе дә бик иркен, таман, артып калырга мөмкин дәрәҗәдә җиткән, башкача кирәкми. *Хәер, монысы да артыгы белән җиткән иде кызны бәхетле итәргә.* М.Кәримов. **Артыгы-киме юк** Чын дөресе, һич арттырусыз. **Артыгын ычкындыру** Кирәкмәгәнне, ярамаганны сөйләп (әйтеп) ташлау. *Язган хатлар барысы да ачып укылды, артыгын ычкындырган кешеләр шунда ук хөкем ителде.* Ф.Бәйрәмова. **Артык итенү** Чамасыз масаеп китү, узыну, чаманы белмәү. **Артык йөк** Мәшәкать тудыручы, кирәксез кеше яки эш. *Үз өстемә артык йөк алырга, кемнәр өчендер җаваплы булырга теләмәгәнмендер.* М.Кәримов. **Артыкка җибәрү** Чамадан уздыру (мәс., сүздә, кыланышта). **Артыкка китү** Чама югалу, чама бозылу. *[Тикшерүче:] Молчать! Саботажник! Мин сиңа күрмәгәнеңне күрсәтермен. Монысы инде артыкка китте!* Р.Кәрами. **Артык кашык** Эшләмичә ашап ятучы, кирәксез кеше. *Бригада – менә-менә сүрүе ертылырга торган мендәр кебек, ә яшь-җилбәзәк, юашрак егетләр беркайчан да артык кашык булмый.* Р.Кәрами. **Артык күз** Берәр нинди эш-хәрәкәтне күрергә, белергә тиеш булмаган кеше. **Артык кылану** *к.* **артык итенү.** *Бик явыз, кирәгеннән артык явыз кыланды шул, дип уйлап куйды Җәмилә.* М.Хәсәнов. **Артык тамак** *к.* **артык кашык**

**АРТЫКЛЫК** *и.* 1) Билгеле бер сан, күләм, үлчәмнән артык булу. --- *һәркем үз алдындагы шакмакларны кабат санаган булды: артыклык юк, ә, барыбер, тугыз шакмак җитми иде.* К.Тимбикова

2) Кемнән яки нәрсәдән өстенлек, яхшырак сыйфат. *Сөйгәненеңнең артыклыгы була, кимчелеге булмый.* Мәкаль. *[«Байлык – бер айлык», «Байлык – морад түгел, фәкыйрьлек – оят түгел» һ.б. мәкальләрдә] --- кешенең төп артыклыгы, төп кешелек сыйфаты байлык яки ярлылыкта түгел икәнлеге бик ачык әйтелә.* Н.Исәнбәт. *Әнә шул ар-*

*тыклыгы ятимгә азмы-күпме юаныч бирми калмаган.* И.Нуруллин

3) *лингв.* Артык сүзләр кулланылу; *русчасы:* **плеоназм**. *Телләрдә аналитик һәм синтетик чараларның кушылуы кайчак артыклыкка китерә, чөнки бер үк грамматик мәгънә берничә төрле грамматик чара белән белдерелә.* Ф.Сафиуллина

4) *грам.* Сыйфат һәм рәвештә белдерелгән үзлекләрнең иң югары дәрәҗәсен күрсәткән грамматик категория. *Артыклык дәрәҗәсе сыйфаттан алда урнаша торган универсаль «иң» кисәкчәсе һәм индивидуаль, бары тик бер сыйфатка гына яки фонетик яктан үзара охшаш берничә сыйфатка гына ялгана торган препозитив кисәкчәләр ярдәмендә ясала.* Татар грамматикасы

**АРТЫ́К-ПОРТЫК** *с.* **1.** *сөйл.* 1) Кирәксез, яраксыз, иске-москы; үзеннән арткан. *Артык-портык язуларын, хатларын юкка чыгарды.* Ш.Маннур

2) *күч.* Тегенди-мондый. *[Гайния] «Бу Бичураны, әкренләп, җимгә иялә-штерергә, илдә шаукым кузгалып торган арада, аңарда артык-портык әйберне саклап калырга булмасмы?» – дип, эченнән план корып азаплана иде.* Ф.Хөсни

**2.** *и. мәгъ.* 1) Вак-төяк, юк-бар нәрсә. *Кәеф корып яшәүчеләр, Көне буе кырын ятып, Көн итәләр толчокларда Артык-портыкны сатып.* Г.Камал

2) Гади, дәрәҗәсез, хөрмәткә лаек булмаган кеше. *[Кәнтәйләр] ирләрнең асылларына асылыналар үзләре, бер дә койма янында аунаган артык-портыкка карамыйлар!* М.Маликова

**АРТЫКСЫНУ** *ф.* Артык дип уйлау, кирәк түгел дип исәпләү. *Мортазин таләпчән кул хуҗасын өзгәләргә җитешеп шашынса да, хакыйкать даулап йөрүне, билгеле, артыксынды.* В.Имамов

**АРТЫМ** *и.* 1) Симертүдәге терлекнең арткан авырлыгы. *Шундый шартларда асралган терлекләрдән нинди артым, нинди үрчем көтәргә кирәк?* М.Хәсәнов

2) Табыш, керем, үсеш һ.б.ның алдагы яки билгеләнгән нормадан артып киткән өлеше. *[Айхенвальд:] Еллык артым – биш процент.* Ф.Сафин

**АРТЫМЛЫ** *с.* 1) Артым бирә торган; табышлы. *Артымлы терлек*

2) *күч.* Арта торган, күбәя, ишәя торган. *Нихәл итәсең, арттагы сүз артымлы була шул.* Х.Сарьян

**АРТЫН-АРТЫН** *рәв.* Акрын-акрын, арты белән. *Ул ике чигәсен тотты, артын-артын өстәлгә таба китте һәм биек артлы креслога лып итеп утырды.* Х.Хәйруллин

**АРТЫШ** *и.* **1.** Кипариссыманнар семьялыгыннан мәңге яшел ылыслы куак яки агач (җимеше медицинада кулланыла); *русчасы:* **можжевельник**. *Ярга сырышып үскән артыш куакларына тотынып, аска, вак ташлыкка төштек.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* Артыштан ясалган, артыштан киселгән. *90 яшен тутырган Мәлик картка күршесе үзе урманнан алып кайтып ясаган артыш таяк бүләк итте.* Татар иле

**АРТЫШЛЫК** *и.* Артыш күп үсә торган урын. *Урта Саба авылы янындагы артышлыкта бер-беребезне мактыйбыз.* Т.Нәҗмиев

**АРУ** I *ф.* 1) Физик көч, егәр бетү; хәлсезләнү. *Күрмәве дә бик ихтимал: Галия, фермада эшләгәч, көндезләрен бик арый, кичкә аның җеп өзәрлек тә хәле калмый.* Хәйдәр. *Шуңа күрә йөкле чагында һәм бала имезгән чорда хатын-кыз киеренке акыл хезмәте белән шөгыльләнергә тиеш түгел, чөнки бу – аның нерв һәм ми тукымаларының аруына китерүе мөмкин.* Ф.Углов. *Көне буе чалгы белән селтәнеп каткан куллар язылa, арулар онытыла.* Р.Хафизова

2) *күч.* Ялыгу, туеп бетү. *[Барын да көйләп] Йөри торгач, Фатыйма да: – Арыдым... – диде.* А.Алиш

**Арый башлау** Ару билгеләре сизелү, арганы тоелу. *Тиз арый башлаган әле энекәш. Безнең яшькә җиткәч нишләр?* Т.Миңнуллин

**Арый төшү** Бераз, берникадәр ару. *Мин дә инде аңардан арый төшкән идем, шуңа күрә артыгын кыстамадым.* М.Вәли-Барҗылы

**Арып бетү** Тәмам, бик нык ару. *Мин дә әле – берсе берлә, әле берсе берлә бии-бии арып беттем.* Г.Исхакый. *Мин дә йөгерә-йөгерә арып беттем.* Н.Дәүли. *«А-а-а!» – дип кычкыра-кычкыра арып беттем.* Н.Дәүли

**Арып китү** Берара, бераз арыганлык тою. *Көннәрдән бер көнне Хәлимә ханым шушы рәвешле азык җыеп йөргәнендә бик арып китә һәм йокыга тала.* Ф.Яхин

**АРУ** II *с.* **1.** 1) *сөйл.* Яхшы, әйбәт. *Кыскасы, ару нәстә.* Т.Нәҗмиев. *Галимнең әти-әнисе ару гына урында эшлиләр, имеш.* Ә.Хәбибуллин

2) Авырлыгы сизелерлек булган, зур, күләмле, авыр. *Җилкәмә ару гына киртәлек яткырып, кулларымны шуңарга бәйләп куйганнар!* Р.Низамиев. *Ул чакта Батталовка котылмак юк, Арслановның да түбәсенә ару гына күсәк төшәчәк иде.* Ф.Садриев

3) *диал.* Чиста, пөхтә, пакь. *Һәм ул, тиз-тиз генә юынып, арурак күлмәкчалбарын киде дә --- Чүкәйгә китте.* В.Нуруллин. *– Арурак күлмәк-ыштанынңны ки дә киттек, энекәш, – диде ул.* М.Әмирханов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шәп, әйбәт, ярыйсы. *Аңа да ару гына эләкте.* Ф.Садриев. *Ул барып кергәндә, Кендекәй белән Мәдинә ару гына сөйләшеп утыралар иде.* С.Поварисов

2) Шактый әйбәт, яхшы. *[Ул] Үзе дә урыс телен ару гына сукалый иде.* М.Хәбибуллин. *Ару яшәү*

3) **аруга** Яхшыга, кешлеккә. *Йортка яңа гына төшкән алсу битле, кирәк булса да, кирәк булмаса да һәрвакыт беләкләрен сызганып йөри торган яшь килен нәзек кенә итеп эрләгән бәрән йонынннан аруга ябыныр өчен шәл бәйләгән иде.* А.Алиш

**3.** *хәб. функ.* Ярыйсы, канәгатьләнерлек; уртача. *Тормышым ару, яшем җиткән, киләсе яздан да калмыйм, өйләнәм.* Ф.Хөсни. *– Исәнме, Хәсән абый! – Ару, кем, Харис туган,ниләр җимерәсең?* Х.Хәйруллин

**АРУЛАНУ** *ф.* **1.** 1) Матди як яхшыру, әйбәтләнү. *Шагыйрь аруланган, өсте-башы шомарган – костюм, галстук, эшләпәдән.* Г.Әпсәләмов. *Тормыш арулану* // Берәр нәрсәнең сыйфаты яхшыру, әйбәтләнү, уңайрак булу. *Зәйгә җитәрәк, юл аруланды.* А.Гыйләҗев

2) Берәр авырудан соң терһәкләнү, рәтләнү. *Ул инде аруланган, аягына басып йөри ала.* Г.Гыйльманов. – *Арулан, балакай, арулан. Синсез бик кыен... Йортыбызның яме югалды, нуры сүнде ---.* Г.Гыйльманов

3) Чистару, сафлану; чит нәрсәләрдән арыну. *Нәкъ әнисе кушканча аруланды, кырынды, пөхтә иттереп киенде.* К.Тимбикова. *Анда [Болгарга] барган кешеләрнең арулана күңелләре.* Г.Макаров

**2.** *и. мәгъ.* Терһәкләнү, тазару. *Юлдашының хәле аруланууга Зөннүн чын күңелдән сөенә иде.* М.Юныс. – *Ничек соң хәлләрең, кызым? – Арулануга таба, диделәр, шуңа ышанам инде.* Г.Гыйльманов

**Арулана бару** Аз-азлап, акрынлап арулану. *Күбрәк кыймылдаган саен, хәлем арулана бара.* Б.Камалов

**Арулана төшү** Бераз, берникадәр арулану. *Ә нишләп ут юк? Мөгаен, әтинең хәле арулана төшкәндер, йокласын, дип сүндергәннәрдер.* Н.Әхмәдиев

**Аруланып алу** Бер арада, кыска вакытка арулану. --- *мәчет эченә кердеңме, дин белән исәп-хисабы булмаган кешенең дә күңеле берничә минутка гына булса да сафланып, пакьләнеп, аруланып ала.* Т.Миңнуллин

**Аруланып бетү** Тәмам, тулаем арулану

**Аруланып җитү** Ахырына кадәр, тиешенчә арулану

**Аруланып калу** Ниндидер сәбәп белән аруланган халәт алу. *Тәне җиңеләеп, аруланып калса да, бу юлы бар кере дә чыгып бетмәде шикелле.* З.Хөсникяр

**Аруланып килү** Әзлекле рәвештә акрынлап арулану. – *Әйбәт, кызым, инде аруланып килә, – диде ана.* Ф.Зариф. *Бу арада мөнәсәбәтләре чак кына җылынып, аруланып килгәндә, тагын ызгыш-талаш килеп чыкмасмы?* А.Гыйләҗев

**Аруланып китү** Соңгы вакытта бераз арулану. *Мәрьям әбинең дә хәле аруланып китте бугай, хәзер үзе дә йөри алачак ул.* Хәйдәр. *Замполит, килү белән, ниндидер дару эчте һәм бераз аруланып киткән кебек булды.* Х.Камалов

**АРУЛА́У** *ф.* 1) Чистарту, сафлау, пакьләү. *[Бабай егеткә:] Әй, улым, --- мин ашлык чәчәм, игенем бик уңа, аны аруларга чарасын таба алмыйм.* Әкият

2) *диал.* Йола буенча, мәетне җирләүгә әзерләү (юу, кәфен кидерү һ.б.). *Җеназаңны чыгарып, Баялычтан ут ягып, Таза арулап күмәем.* Дастан

**Арулап алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә арулау. *Егет шул вакыт, яшереп куйган җиреннән көрәкне алып, көрәк белән ашлыкны, бик яхшы җил килгәндә, бер минутта тау кадәр арулап алды.* Әкият

**Арулап кую** Аруланган хәлгә китереп калдыру; алдан арулау. --- *карткоры күзгә чалынды, малае-шалае шунда урала, капка төпләрен көриләр, урамны – без узасы юлларны – ялт итеп арулап куйганнар.* А.Гыйләҗев

**АРУЛЫК** *и.* Чисталык, пакьлек. *Олысын-кечесен хөрмәтләү, арулык, пакьлек, тыйнаклык, көнкүреш культурасы бүген дә татар халкы арасында югары бәяләнә.* М.Мәхмүтов

**АРУСЫЗ** I *с.* **1.** Ару-талуны белми торган. *Арусыз яшьләр*

**2.** *рәв. мәгъ.* Армый-талмый, ял итмичә, туктаусыз. *Гомер буе хезмәт иттем арусыз.* Г.Мөхәммәтшин

**АРУСЫЗ** II *с. диал.* Ару булмаган, арулыгы җитмәгән, пычрак. – *Бал кортлары тир исен бер дә яратмый, – диде ул Зөһрәгә, юынып чыккач. – Арусыз килеш тотынсаң, чакмаган җиреңне калдырмыйлар.* Ф.Яруллин

**АРУСЫНМА́У** *ф. сир. юкл. форм.* Яхшы дип тапмау, читенсенеп тору. *Тик Хәниягә эш кушуны арусынмады.* Н.Хәсәнов

**Арусынмый тору** Әле, хәзер арусынмау, арусынмыйча, беразга тоткарлану. *Сүз әйтергә арусынмый тору*

**АРУСЫ́НМЫЙЧА** *рәв.* Читенсенеп, кыенсынып, уңайсызланып. *Тик яр буенда утырган Хөснижамал, Гөлбаһар, Мәүлиха апалардан арусынмыйча һәм Хафиз карт кисәтеп куйганга гына тыелып тора идем.* В.Нуруллин

**АРУ́-ТАЛУ** *ф.* Бик нык ару, көчхәл бетү. *Кәефсезләнү, кайгы-хәсрәт, көнләшү, ару-талу организмга бик нык тәэсир итә.* М.Маликова. *Көннәр буе арып-талып эшләп кайткан җир кешесенә «хезмәт көне» язалар.* Ә.Сәлах

◊ **Ару-талуны белмичә** Бертуктаусыз, өзлексез. *Кырык яшькә чаклы «ару-талу» дигән нәрсәнең ни икәнен дә белми иде.* Х.Хәйруллин

**А́РФА** *и. нем.* Зур өчпочмак рәвешендәге рама эченә кыллар тезелгән, шуларга чиертеп көйләр уйнала торган уен коралы. *Сөйләшүләренең берсендә Сәйдәш --- театрга арфа кайтарту кирәклеген үзенчә бәйнә-бәйнә аңлатып караган иде.* Р.Низами

**А́РФАЧЫ** *и.* Арфада уйнаучы. *Фалия арфачыга җырланачак җырның көен әйтү белән, көмеш кыллар җиңелчә чыңлап алды.* Н.Фәттах

**АРХАИЗМ** *и. гр.* 1) Искелек калдыгы, борынгылык калдыгы (көндәлек тормыш әйберләре, күренешләр, төшенчәләр һ.б. турында). *Сәгать биредә – бары шайтан тәгәрмәче, архаизм!* Р.Әхмәтҗан. – *Сафлык?.. – Архаизм!* М.Мирза

2) *лингв.* Искергән сүз яки тәгъбир, искергән грамматик форма. *Төрки телләрдәге архаизмнарның бер өлешен гарәп-фарсы сүзләре тәшкил итә.* Ф.Сафиуллина

**АРХА́ИК** *с.* 1) Борынгы, үткәндәге. *Архаик чорның беренче яртысына караган тәңкәләр бер яклы гына итеп сугылган.* Ә.Мөхәммәдиев

2) *лингв.* Кулланыштан төшеп калган, искергән. *Иске сүзләрнең, архаик формаларның чагыштырмача яңарак чор әсәрләренә килеп керүләре – ул традицион әдәби телнең, китаби фикерләүнең генә тәэсире булырга мөмкин.* М.Госманов

**АРХА́ИКА** *и. гр. кит.* Борынгылык, искелек. *Чынбарлыкны архаика аша ачу яки борынгылык белән үреп бирү [хас].* А.Шәмсутова

**АРХА́ИКЛАШУ** *ф.* Архаизмга әйләнү. *Табигый, сүзләрнең архаиклашу процессы төрле төрки телләрдә төрлечә.* Г.Мөгътәсимова

**АРХА́ИКЛЫК** *и.* Борынгы, иске булу. *Кол Гали поэмасы, үзенең чагыштырмача архаиклыгына карамастан, татарлар арасында иң популяр --- әсәр булып кала бирә.* М.Госманов

**АРХАИСТ** *и. рус* Борынгы эпоха осталарының иҗат итү алымына ияргән язучы яки рәссам

**АРХАЙСТИК** *с.* Архаистикага нигезләнгән

**АРХАЙСТИКА** *и. рус* Сәнгатьтә борынгы эпоха осталарының алымнарына, өслүбенә һәм формаларына ияреп иҗат итү юнәлеше

**АРХАР** *и. төрки* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан, спиральсыман бөтерелеп үскән мөгезле кыргый тау сарыгы

**АРХЕО́ГРАФ** *и. гр.* Археография белгече. *Шулай итеп, безне, Әбрар Кәримуллин белән икебезне, археограф язмышы Касим шәһәренә китереп ташлаган иде.* М.Госманов

**АРХЕОГРА́ФИК** *с.* Археографиягә мөнәсәбәтле. *Бүгенге көнгәчә татарлар яши торган регионнарга ясалган археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә, халык арасыннан «Кыйссаи Йосыф»ның 160 тан артык кульъязма нөсхәсе табылган.* М.Хәсәнов

**АРХЕОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Борынгы язма истәлекләрне җыю, туплау, тасвирлама язу һәм бастырып чыгару белән шөгыльләнә торган фән. *Археографиянең бурычы бары бик борынгы, бары бик сирәк язмаларны гына барлау, саклау һәм өйрәнүгә кайтып калмый, әлбәттә.* М.Госманов. *Бу эш белән лингвистика һәм тарих өлкәләренә караган археография һәм эпиграфика фәннәре шөгыльләнә.* М.З.Зәкиев, С.М.Ибраһимов

**АРХЕО́ЛОГ** *и. рус* Археология белгече. *Археологлар аның эчендәге хәзинәләрен алганнар.* Ә.Гаффар. – *Әллә археологмы сез? – диде Габдрахман.* М.Юныс

**АРХЕОЛО́ГИК** *с.* Археологиягә мөнәсәбәтле. *Түбән Кама сусаклагычы тирәсендәге 200 ләп археологик истәлекне саклап калу өчен дә эш алып барабыз.* Ватаным Татарстан

**АРХЕОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Сакланып калган тарихи истәлекләр, казылып табылган әйберләр буенча кешелек җәмгыятенең үткәнен өйрәнә торган фән. *Син укыдыңмы, бер газетта язганнар, ди, Кипрдамы, Грециядәме бер хатын – археология буенча галим хатын – җир казу эшләре алып бара икән.* Г.Зәйнашева

**А́РХИ-** *гр.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса икенче кисәктә күрсәтелгән сыйфаты, үзенчәлеге иң югары дәрәҗәдә булуны белдергән алкушымча. *Ә чынын әйткәндә, революциянең язмышы өчен архикуркыныч вакытлар безнең бер-беребезгә соң дәрәҗәдә турылыклы икәнебезне раслады.* Ә.Гаффар

2) Кушма сүзләрдә: чиркәү хезмәткәрләренең иң югары дәрәҗәсен белдерә торган беренче кисәк: *архидиакон, архиерей һ.б.*

**АРХИВ** *и. лат.* 1) Иске язма истәлекләрне, тарихи документларны тәртипкә китерә һәм саклый торган махсус учреждение. *Аның архивка килеп керү тарихы болайрак.* М.Госманов // Берәр оешмада иске документлар саклана торган бүлек (бүлмә). *Вакытлы хөкүмәтнең контрразведка архивлары исәндер әле...* З.Фәтхетдинов. *Землемер актын Ахияр үзе эзләп тапты, архивтан копиясен алдырды.* М.Мәһдиев

2) Аерым оешма яки берәр кешенең эшчәнлегенә бәйле документлар, кульъязмалар, фоторәсемнәр һ.б. *Бу әсәрнең дә кульъязмасы архивта саклана.* Н.Юзиев. *Ул фото хәзер дә саклана әле архивымда.* Т.Нәҗмиев. *Безнең гаиләархивында әтине мактап язган уңай характеристикалар әле дә исән.* Идел

◊ **Архив вирусы** Үзлегеннән, архив материалларында эзләнергә, казынырга ярату хирыслыгы. *Зур хәрефле әлеге Эзтабарлар безнең кебек сугыштан соң туган буын вәкилләренә дә «архив вирусы»н гомерлеккә йоктырдылар.* Ш.Мостафин

**АРХИВА́РИУС** *и. лат.* Архивта эшләүче, архив документларын саклаучы; архивчы. *Шувалов аны архивариус --- итеп билгели.* Ф.Ислаев

**АРХИВЛЫК** *и.* Архив була алырлык, архивка җитәрлек. *Алар – үзе бер архивлык!* Р.Миңнуллин

**АРХИВЧЫ** *и.* Архив эшләре белгече

**АРХИЕПИ́СКОП** *и. гр. дини* Епископ белән митрополит арасындагы рухани дәрәҗәсе; шундый дәрәҗәдәге кеше; өлкән епископ. *Казан епархиясе архиепископы Лука Канашевич җитәкләгән елларда аеруча аяусыз, шәфкатьсез эш итә ул.* Мирас

**АРХИЕПИ́СКОПЛЫК** *и.* Христиан динендә: архиепископлар җитәкчелегендәге дини-административ берәмлек

**АРХИЕРЕЙ** *и. гр. дини* Христиан динендә: югары дәрәҗәдәге руханиларның (епископ, архиепископ, митрополит, патриархларның) гомуми атамасы; шул дәрәҗәдәге кеше. *Бүген дә ул, архиерей сүзләреннән кәефсезләнеп, шул турыда озаклап сөйләргә җыенган иде.* К.Нәҗми

**АРХИМАНДРИТ** *и. гр. дини* Монастырь руханиларының югары титулы; ирләр монастыренда шушы титулга ия башлык; руханилар семинариясенең ректоры. *Поплар, архиерейлар, архимандритлар һәм башкалар – төрле христиан «изге аталары» – кораллы командалар белән авылларга чыгып, кешеләрне мәҗбүри рәвештә православие диненә кертеп йөриләр.* Җ.Рәхимов

**АРХИПА́СТЫРЬ** *и. гр.-лат. дини* Христиан динендә: югары дәрәҗәле руханиларга (патриарх, митрополит һәм епископларга) хөрмәт белән әйтелә торган атама; өлкән пастырь

**АРХИПЕЛАГ** *и. гр. геогр.* Бер-берсенә якын урнашкан, гадәттә төзелеше, килеп чыгышлары бертөрле һәм охшаш булган диңгез утраулары төркеме. *Көньяк Спорада архипелагының бер атавы яныннан узып бара идек.* М.Юныс

**АРХИТЕКТО́НИК** *с.* Архитектоникага нисбәтле. *Текстка бәйле архитектоник сөйләм формалары – монолог, диалог, полилог.* Ф.Сафиуллина

**АРХИТЕКТО́НИКА** *и. гр.* 1) *махс.* Кисәкләрнең, өлешләрнең үзара гармоник ярашып, матур, төзек бербөтен тәшкил итүе. *Архитектоника – әсәрне төзүче кисәкләрне бербөтен итеп оештыручы формаль-техник чара.* Әдәбият

2) *геол.* Теге яки бу урындагы тау катламнары яту, урнашу үзенчәлекләренең, аларның геологик төзелешенең гомуми картинасы

**АРХИТЕ́КТОР** *и. рус* Архитектура белгече, архитектура белән

шөгыльләнүче. *Башкала урамнарындагы биналарга карап, йорт салдыручының зәвыгын, архитекторның талантын, заманның таләбен һәм мөмкинлеген аңлап була иде*. М.Юныс. *Архитектор Самат Гәрәевич Кадыйргулов, мөгаен, бик күп яктан, сезнең белән минем кебек үк гадәти бер кеше булгандыр*. М.Вәли-Барҗылы

**АРХИТЕ́КТОРЛЫК** *и.* Архитектор һөнәре (эшчәнлеге, вазифасы, исеме). *Мине дә бик кызыксындыра анысы... архитекторлыкка уку!* Ә.Еники

**АРХИТЕКТУР** *с.* Архитектурага нисбәтле, архитектурага бәйләнешле. *Шулай туры килгәнме, Совет урамында таза, нык хуҗалыклы халык яши, йортларны да «немец манерында» – төрле архитектур бизәкләр белән җиткезәләр иде.* Р.Мирхәйдәров

**АРХИТЕКТУ́РА** *и. лат.* 1) Бина, йортлар проектлаштыру, аларны төзү һәм бизәү сәнгате. *Аннан мин архитектураны бик яратам*. Р.Кәрами. *Мәктәптә укыганда, мин бит архитектура институтына керергә хыялланып йөргән идем*. М.Юныс

2) Төзелешнең юнәлеше, корылма бизәлешенең стиле, характеры. *Нәкышнең геометрик рәсеме интерьерның турыпочмаклы архитектура формалары белән, аларның ритмы белән ярашып килә*. Г.Вәлиева. *Бохара – шәһәр генә түгел ич, шәһәр-музей ул. Мондагы архитектура истәлекләрен, ай буе карап йөрсәң дә, карап бетерерлек түгел*. Р.Сибат

3) *күч.* Берәр нәрсәнең төзелеш үзенчәлеге, композициясе. *Бакча-парк архитектурасы. Ландшафт архитектурасы*

**АРХИТЕКТУ́РАЛЫ** *с.* Архитектура элементлары булган, бизәк, нәкыш кулланылган. *Үзәгендә ике-өч катлы, аратирә архитектуралы таш йортлар булса да, тулаем алганда, бер катлы агач йортлардан торган ул.* И.Нуруллин

**АРХИТЕКТУ́РАСЫЗ** *с.* Архитектура элементлары булмаган, бизәк, нәкыш кулланылмаган. *Өч-дүрт катлы, бәләкәй тәрәзәле, архитектурасыз, соры таш йортлар, тар һәм кәкре урамнар башланды*. Ш.Маннур

**АРХОЗА́ВРЛАР** *и. гр. зоол.* Сөйрәлүчеләр классының гомуми атамасы (крокодиллар, динозаврлар, текодонтлар һәм оча торган кәлтәләр)

**АРХОНТ** *и. гр.* Борынгы Грециядә: югары дәүләт хезмәтендәге кеше

**А́РЧА** *рәв. сөйл.* Удмуртча

**АРЧА** *и. бот.* Артышның бер төре

**АРЧАН** *и. бот.* Арчанчалар семьялыгыннан, өч кырлы вак яфраклы, алсу шәмәхә чәчәкле, нык тармакланып үсә торган мәңге яшел тәбәнәк куак; *русчасы:* **вереск.** *Августның урталарында һәм ахырында, карабодайга алмашка, арчан һәм башка соңгы үлән чәчәкләре өлгереп җитә.* Яшелчә бакчалары

**АРЧАНЛЫК** *и.* Арчан күп үскән урын

**АРЧА́НЧАЛАР** *и. бот.* Ике өлешле үсемлекләр семьялыгы, арчанчәчәкләр

**АРЧИ** *и.* 1) *тар.* Патша, хан карамагындагы иң әйбәт гаскәр һәм шул гаскәрдә хезмәт итүче

2) *этн.* Кызны кияү йортына озата баручы(лар). --- *тарантасның арткы уң як тәгәрмәче, күчәреннән чыгып, бер якка тәгәрәп китте: --- кияү белән кәләш, кияү егете һәм башкалар чак кына егылып төшми калдылар. Арчи кайтканын карап торган авыл халкы «аһ» итте: – Әстәгъфирулла! – И-и Ходаем, ахыры гына хәерле булсын!* Ә.Салах

**АРЧИ́ АТНАСЫ** *и. этн.* Килен төшерү атнасы (гадәттә, урып җыю эшләре башланганчы булган)

**АРЧИЛА́У** *ф. этн.* Кызны кияү йортына озата бару

**АРЧИЛЫК** *и.* Арчи булу. *Китәсе киленгә арчилык итмә*. Әйтем

**АРЧУ** *ф.* 1) Чистарту; чүп, пычрак һ.б.ш. нәрсәләрдән арындыру; аркылы-торкылы яткан нәрсәләрне алып ташлау. *Соңрак килеп утырган халык урманнарны, арчып, чәчүлек җиргә әйләндерә*. Г.Саттаров. *Ул арада Баһадир [үгез] да ял иткән: юлны арчуга, дәшкәнне дә көтмичә, үзе кузгалып китте.* В.Нуруллин. *Серле нәрсәгә сокланган-дай, чак кына хәрәкәтсез калдым, анары, чүгәләп утырып, аны [китапны] туфрактан, кәгазь черемәләреннән арчыдым*. М.Госманов

2) Куллар яки пычак кебек үткен кораллар белән, берәр нәрсәнең ашарга яраксыз өлешен – кабыгын, тышчасын салдыру; әрчү. *Ул бүген, бичара, шуның аркасында, камбузда төне буе бәрәңге арчый.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Дошман басып алган урынны азат итү, дошманнарны куып чыгару. *Сез кичә немец явыннан Арчыган җирдә Гөрләвек гөрли.* М.Җәлил

4) *күч.* Нинди дә булса оешманың яки коллективның кадрлар мәсьәләсе буенча үзгәртү эшләре алып баруы (мәс., башка вазифа үтәргә күчерү; эштән чыгару һ.б.)

5) *күч. сир.* Чит, искергән яки бозык нәрсәләрдән арындыру. *Ул аларны, әсирлектән коткарып, тамакларын туйдырачак, өс-башларына, менә бу лагерь сәләмәләреннән арчып, һәйбәт яшькелт постаудан тегелгән «Идел – Урал» формасы кидерәчәк.* Ш.Маннур. *Ул Җир йөзендәге начарлыкларны арчырга да тели*. Г.Ибраһимов

6) *күч. сөйл. жарг.* Урлау, талау, басу. *Беренче Кадимченең кесәсен арчый.* Г.Камал

**Арчып алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә арчу. *Каз канаты белән сул колагын арчып ал, шуннан соң менә шушы даруны колагына сал да менә монысын аның өстенә сал...* К.Тинчурин

**Арчып бетерү** Барысын да, тулысынча арчу

**Арчып җиткерү** Тиешенчә, тиешле дәрәҗәдә арчу. --- *юлны арчып җиткерү өчен, мондый кечкенә калибрлы пушкалардан ату гына җитмәвен алдан ук сизеп тора, шуңа борчыла иде*. Г.Бәширов

**Арчып йөрү** Һәрвакыт, гел, бөтен урыннарда арчу. *Бик «яхшы» кеше иде, өйләрне немецлар белән бергә арчып йөрде*. Казан утлары

**Арчып кую** Арчылган хәлгә китерү; алдан арчу. *Кайдадыр чишмә булырга тиеш, үлән япкан авызын арчып куйсаң, үзе бер ямь булачак бу җирдә...* Г.Гыйльманов. --- *чакмасын сугып җибәргән иде, кошның нәкъ күкрәгенә барып тиде дә, әйләнеп төште. Соңра егет аты янына алып кайтып арчып куйды*. Әкият

**Арчып тору** 1) Һәрвакыт, гел, даими арчу

2) Хәзерге вакытта, әле арчу. *Генерал киеме кигәне Бәрәңге арчып тора.* Х.Туфан

**АРЧЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **арчу** (*1–3 мәгъ.*). *Алар тиз арада кардан арчылды.* Р.Фәизов

2) *күч.* Котылу, бушау; азат ителү, азат булу. *Ул, күздән тамган яшьләрнең ачылыгыннан арчыла алмыйча, елау аралаш, юл буенча клиндер кимереп барды.* К.Нәҗми

**АРШЫН** *и. фар.* **1**. 1) Метр системасы кертелгәнгә кадәр кулланылган, кулбашыннан алып бармак очларына кадәр сузылган кулның бар озынлыгын алып торган үлчәү берәмлеге (0,71 метрга тигез). *Күтәрелеп җитәргә берничә аршын калганда, Гыйммран сулыш алып җибәрде.* М.Юныс. *– Бер ун-егерме аршын булса да читкәрәк кит, сулга кит! – ди аңа аң.* Ә.Гадел. *Шулай итеп, буйга аршын ярымлы --- уналты яшьлек Канатны --- башлангыч классларына укытучы итеп билгеләделәр.* Ф.Хөсни

2) Чирек һәм карышларга бүленгән үлчәү таягы. *Әмма бу эштә дә күп кыенлыклар килеп чыга торган, чөнки кешеләр алма санап, алтын-көмеш үлчәп, аршынга тукыма тарттырып иза чиккәннәр.* Г.Исхакый

**2**. *с. мәгъ. к.* **аршынлы** (*2 мәгъ.*). *Байназар --- аршын буйлы, киртә юанлыгы агачны кәкре елтыр пәкесе белән юнуында булды.* М.Хуҗин. *Ишектә тәбәнәгрәк буйлы, аршын җилкәле, цирк көрәшчесен хәтерләткән бер кеше күренде.* Г.Кашапов

**АРШЫНЛА́У** *ф.* Аршын белән үлчәү. *«Иңе тар булса да, буе озын». Аршынлап ситсы сатканда, алучы, иңе тар, дип әйткәнгә каршы, узелчы мишәрләр шулай әйткәннәр.* Н.Исәнбәт

**Аршынлап кую** Алдан аршынланган булу

**АРШЫНЛЫ** *с.* 1) Аршын белән үлчәнә торган, гомумән, метрлап сатыла, алына торган. *Аршынлы товар*

2) Аршын озынлыгындагы (биеклегендәге, киңлегендәге). *Бер елны Нократта ике метрлы су сыерын тоттык. Бер-бер мыегы гына яртышар аршынлы иде.* Р.Сибат. *Зәкәрия аларны ярты аршынлы, озын саплы ачкыч белән ныгытып борып бара иде.* Л.Хәмидуллин

3) *күч.* Бик зур, шактый эре. *Аның текә битләвенә, аршынлы латин хәрефләре белән, «Дөньяны мәхәббәт коткарыр» дип язылган.* А.Тимергалин

**А́РЪЯК** *и.* **1.** 1) Урам, елга, чокыр һ.б.ш.ның теге, икенче ягындагы урын; аргы як; *киресе*: **бирге як**. *Чокыр аръягында кыр – беренче трактор тәүге бураздны сызасы җир җәелгән иде.* Г.Тавлин. *Алда, юлны бүлеп яткан елга аръягында, биек тау өстендә агач стеналар белән әйләндереп алынган Зәй крепосте күренде.* В.Имамов. *Юлда берничә төн кунып килә торгач, ниһаять, алар Кама аръягындагы зур гына татар авылларыннан берсендә – «Т» авылында тукталырга булдылар.* Ф.Хөсни

2) Эш-хәлнең алга табаны яки үткәне, калганы. *Бар да артка йөгерә – хәтер аръягына.* М.Галиев. *Чөнки һәрнәрсәне муллалар хөкем кыла: «Яшел тышлы китап»ны ала да фәтва бирә, хөкем кыла, аръягын тикшерергә хокук юк!* Ф.Ибраһимова

**2.** *с. мәгъ.* Аргы якта булган, теге якта урнашкан. *Аръяк урамда каршысына очраган һәр кешегә кычкырып сәлам биреп, сәлам алып йөрде Айдаш баба.* Р.Батулла. *Клуб урамыннан икәү янәшә кайтып барган кызларның ---, икенчесе --- аръяк күпергә таба китте.* Н.Хәсәнов. *Аръяк болынны иңләп бер йөгерергә иде хәзер!* М.Галиев

**3. аръягында** *рәв. мәгъ.* Артык, бик. *Сагынуның аръягында булу*

◊ **Аръягына чыгу** 1) Моннан да артык мөмкин булмау, чиктән ашу; 2) Кирәгеннән, чамадан артып китү; 3) Билгеле бер яшьне узып китү. *[Шәйхулла карт:] Сиксәннең аръягына чыгып 90 ны кусам да, күргәнем юк.* Д.Салихов

**А́РЪЯКТАГЫ** *с.* Аргы яктагы, теге ягындагы. *Аръяктагы тугайда, нәкъ Көрмәнкәй каршысында, Япраклы дигән зур гына күл бар.* Ә.Еники. *Аръяктагы болынлыкта бытбылдык үз телендә нәрсәдер сөйли.* И.Гази

**АРЫ** *рәв.* **1.** 1) Билгеле бер урыннан алга таба, еракка. *Малайга кул селтәп, Хәлим ары китте.* Хәйдәр. *Шакшы тәэсирләрдән, авыр уйларымнан качарга теләп, ары китәм.* Н.Хәсәнов. *Көн уртасында кояш безне үртәгән мәлдә Джеффны куып җитәбез --- һәм ары китәбез.* Д.Лондон // Әлеге юнәлештән бераз алга китеп, әлеге урыннан күпмедер ара калдырып. *Хәзер өч квартал ары торалар бугай.* И.Низамов

2) Артык, күбрәк. *Дөрес, аны бер биттән ары бирмиләр, шулай да, көн саен алып кергәч, ярап куя ул.* Ш.Маннур. *Чокырның тирәнлеге егерме метрлар чамасы, иңе сигез-ун метрдан ары юк иде.* Г.Тавлин. *Әзһәмгә, болай, карап торуга, егерме өч-егерме дүрттән ары биреп булмый.* Р.Кәрами

3) **ары..., бире...** формасында килгәндә, нинди дә булса эш яки гамәлнең әле – бу якка, әле теге якка юнәлтелүен белдерә. *Ары янтаеп, бире иңкәеп барган вагон җир тетрәгәндәгечә тартылып сикерде дә шып туктады.* К.Нәҗми. *Шахта бабай ары карады, бире борылды, нишләргә белмәде.* Ә.Галиев

**2.** *с. мәгъ. к.* **аргы** (*1 мәгъ.*). *Балыкчылардан бер көймә алдык та, ярдан ярга тулышып аккан Агыйделнең көчле дулкыннары белән көрәшә-көрәшә, ары ярга чыктык.* Г.Ибраһимов

**3.** *бәйл. функ.* Кайбер күрсәтү алмашлыклары белән килеп, эш-хәлнең билгеле бер вакыт үтү белән башланып киткән чыгыш ноктасын белдерә; соң. *Әгәр дә аждаһа тирә-якка зыян тидермәсә, меңгәчә яши икән дә, ди, аннан ары «юха» еланга әйләнә икән, ди.* Әкият. *Шуннан ары байтак вакыт Самат абый безгә килмәде.* В.Нуруллин. *Шәкүрне бу йортта моннан ары аркан белән дә бәйләп калдырырлык түгел иде инде.* Р.Гаффар

◊ **Ары бәрелү (кагылу), бире сугылу** Нәрсә эшләргә белмичә, каңгырып, аптырап йөрү. *Җәмилә дә, ары бәрелеп, бире сугылып йөри торгач, күршеләргә кереп китте.* Л.Ихсанова. **Ары китә алмау** Артыгын эшли алмау, булдыра алганы шушыннан артмый, мәгънәсендә. *Ләкин бу очракта ул да, кулын җәеп, уфтанудан ары китә алмый.*

Р.Кәрами. **Ары китмәгән** Нииндидер сыйфаты, гамәле белән кемнән яки нәрсәдән дә булса яхшырак түгел. *Кызулыгы белән әтисеннән әллә ни ары китмәгән.* **Ары таба(н)** Алга таба. *Ары табан, тәнкыйтьче бу стильгә дә каршы түгеллеген белдерә.* И.Нуруллин. *Ары таба, егет белән кыз, иңне-иңгә терәп, кулларындагы сәнәкләрен алга сузып, үзләрен төрле көтелмәгән хәлләргә, куркынычларга әзер тотып атладылар.* Р.Фәизов. **Ары торсын** Кирәк түгел. *Хәмит кенә, авыр сулап, әйтеп салды: – Риза кебек «дуслар» ары торсын икән.* Р.Вәлиева

**АРЫ-БИРЕ** *рәв.* 1) Башта бер якка, аннан кирегә; әле – бер, әле икенче юнәлештә; әрле-бирле. *Линар диванда, корсагын бүлтәйтеп, хоккейчыларның ары-бире чапканын караштырып ята.* М.Маликова // Як-якка, төрле якка. *Тукта, аты кая соң моның? Ары-бире карандым.* Н.Дәүли. *Гөлфинур, Рәфиснең күкрәгеннән аерылмаган килеш, үрсәләнеп, башын ары-бире боргалады.* А.Вергазов

2) Төрлечә; тегеләй дип тә, болай дип тә (*сөйләү, уйлау*)

3) Кая да булса, берәр кайда (кая), анда-монда. *Ирен дә ары-бире күрештереп торам.* М.Кәримов

◊ **Ары-бире килү** 1) Аптыраудан, туктаусыз йөренү; 2) Урынында булмау, таралып юк булу (әйберләр). **Ары-бире китерү** 1) Кая эләкте шунда, тәртипсез рәвештә калдыру; 2) Тиз генә, ашыгыч рәвештә, кайсын кая алып кую (яшерү, урнаштыру, сату); 3) Теләсә кая, теләсә нәрсәгә бәрәкәтсез тоту, файдалану (акча, азык-төлек һ.б.)

**АРЫГАЮ** *ф.* Ябыгу, тәннең тулылыгы кимү. *Ул бик тиз ябыгып китте, өшәнде, арыгайды.* Г.Исхакый

**АРЫК** I *с.* 1) Ябык; таза, нык булмаган. *Аннары Энҗе, рәсемне урынына куеп, өстәл янына барып утырды да, арык йодрыкларын ияк астына терәп, терсәкләре белән өстәлгә таянган килеш, уйга калды.* Г.Тавлин. *[Михайлов] Зур кулын, сак кына, егетнең арык иңбашына салды.* Р.Кәрами

2) Нечкә озын буйлы, ябык (кешеләр турында). *Арык ирландияле этә-төртә моны, ә тегесе сабый бала күк үкереп елый.* Д.Лондон. *Шул килеш, үзенең шыксыз озын, нечкә һәм арык гәүдәсе белән кибән өстендә тору аңа һич тә килешми генә түгел, эчеңне тотып көләрлек.* Р.Сибат

3) Көр, симез булмаган; хәлсез (хайваннар турында). *Мескен арык вә кечкенә ат, сыртына чыбыркы төшкән саен, арт санын азрак сикертә вә койрыгын ике якка чайкап ала.* Ш.Камал. *Тик, бераз үтүгә, Гатаның арык аты тәмам хәлдән тая.* Ә.Салах

**АРЫК** II *и.* 1) Буадан артык суны агызу яки тегермән чарыгын әйләндерергә су җибәрү өчен махсус эшләнгән ачылмалы-ябылмалы улаксыман корылма. *Буадан арыкка шаулап, суырылып су агып ятуы, шул суның яшел мүк белән капланган кырык чөй куласасын әйләндерүе аңа бик хикмәтле тоела.* Хәйдәр. *Кайдадыр, шырлап, кечкенә елгамы, яисә арыкмы ага.* Р.Сибат. *Зирекләр күләгәсеннән аккан арык суы да кипкән.* М.Галиев

2) Сугару каналы (Урта Азиядә, Кавказ артында). *Елгалар әби-баба заманыннан сакланган арыкларга су койган.* Г.Исхакый

**АРЫКЛАНУ** *ф.* Арыкка әйләнү, ябык-какча хәлгә килү, нык ябыгу. *Каз, ничек арыкланса да, барыбер карга булмас.* М.Хәсәнов

**Арыклана төшү** Бераз арыклану

**Арыкланып бетү** Тәмам, бик нык арыклану. *Йорт анасы сөйми торган атлар арыкланып бетәләр, бик өшәнәләр.* Риваять

**Арыкланып калу** Нииндидер сәбәптән арыкланган хәлгә килү. *Юкарып, арыкланып калган Йосыф караваткa сеңгән, аяк-куллары хәрәкәтсез таралган иде.* А.Гыйләҗев

**Арыкланып китү** Кинәт кенә, бераз арыклану. *[Хаҗирәнең] Күзләре эчкә баткан, үзе арыкланып киткән.* Р.Гайфуллина

**АРЫКЛА́У** *ф. сир.* Берәр нәрсәдән арындыру, азат итү, бушату. *Пәрдә ачылганда, Иңәл кам бәкнең өен арыклый, ягъни явыз рухларны куалый: барабан кага, кычкырып-кычкырып җибәрә.* Н.Фәттах

**Арыклап алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә арыклау

**Арыклап бетерү** Бөтенесеннән дә тулысынча арыклау

**Арыклап калу** Арыклаган хәлгә килү. *Шулай итеп, Әрлик ханның әшәке ялчыларын ике тапкыр турап, атып, чәнчеп чыккач, үләксәләрен яндырып, төтен белән бергә күккә очыргач, изге нарат яны тулысынча арыклап калды.* Н.Фәттах

**Арыклап кую** Алдан арыклау

**Арыклап тору** Һәрвакыт, гел арыклау

**АРЫКЛЫК** *и.* Арык булу. *Гафил, үзенең нечкәлегеннән оялып, зуррак үлчәмле костюм астыннан җәй көне дә ике кат күлмәк яисә свитер кия, әмма бу гына аның арыклыгын яшерә алмый иде.* Р.Сибат

**АРЫ́К-ТОРЫК** *с. сөйл.* Үтә ябык; хәлсез, кабыргалары күренеп торган. *Арык-торык ат бирделәр.* Х.Хәйруллин

**АРЫЛУ** *ф. з.-сыз* Ару, хәл бетү, көч китү. *[Судья:] Бик арылды.* М.Миншин. *Бик арылган иде, әллә ни йоклап булмады.* Р.Зарипов

**Арыла төшү** Бераз арылу

**АРЫМСАК** *с.* Тиз арый торган, озак эшләүгә, йөрүгә чыдам булмаган. *Әле ярый артыбыздан атлы куып җитте, арымсак балаларны аңа утырттык.* Мәгърифәт

**АРЫМСАЛ** *с. к.* **арымсак**

**АРЫМТАЛ** *с. к.* **арымсак**

**АРЫНДЫРУ** *ф.* 1) Чистарту, тазарту, чүпләрен алу. *Өй тирәсен янган бүрәнә, кисәүләрдән арындырып, кара күмерләрне кар белән күмделәр.* Р.Сибат. *Ирекләр, район үзәге учреждениеоешма кешеләрен, мәктәп укучыларын алып барып, ферма торакларын тирестән арындырдылар, юдырдылар, агарттырдылар.* Ф.Садриев

2) Дошман басып алган җирне азат итү, дошманны куып чыгару // Каршылык күрсәтүче, аяк чалучы кешеләрне юлдан алу. *[Мәмле-Гомәр:] Мәгәр пайтәхетне, аңа тиклем, безнең гамәлләргә аяк чалырдай бәгъзе хакимнәрдән арындыру фарыз.* В.Имамов

3) Нәрсәдән дә булса азат итү, ирекккә чыгару. «*Кыйсса*»*ның эчтәле-*

*генә дөнья әдәбиятындагы мәгълүм сюжетны алуы белән, Кол Гали сүз сәнгатенең яшәешен тар этник чикләреннән арындыра һәм дөнья әдәбиятының гомуми чылбырына тоташтыра.* Н.Юзиев. *Аның уйлавынча, әлеге изге эшкә болай гына тотынып булмый, аңа, пакьләнеп, үзеңне, тормыш вактөякләреннән арындырып, тулаем багышларга кирәк.* Ф.Садриев. *Шуңа күрә без яшьләрне хәтәр юлга бастыра торган сәбәпләрдән арындыруны төп максатыбыз итеп куярга тиешбез.* М.Хәсәнов

4) *күч.* Уй-кичерешләрне һ.б.ны бүлдерү, туктату; хыял дөньясыннан чыгару. *Озерцовны уйларыннан машина кычкырткан тавыш арындырды.* Р.Мөхәммәтҗан

**Арындыра башлау** Арындырырга керешү. *Б.э.ның тәүге гасырларында христиан (бер аллалык) диненең римлылар рухи тормышына үтеп керүе аларны күп аллалыкка ышанулардан арындыра башлый.* К.Гыйззәтов. *Бүлмәгә узып, әнисен ике-өч катлы шәл һәм яулыклардан арындыра башлагач, үзе дә сизми-тоймыйча, калай мич шикелле янды, кызарды ул.* В.Имамов

**Арындыра төшү** Бераз арындыру

**Арындырып бетерү** Бөтенләе белән, тулаем арындыру. *Икенче көнне, пароходны тутыктан арындырып бетергәч, шәрә металлга сурик салырга керештек.* М.Юныс. *Җаек буйларын колчакчылардан һәм калдык-постык казак отрядларыннан тулысынча арындырып бетерергә мөмкин булачак.* Ф.Сафин

**Арындырып җибәрү** Бераз арындыру, арынырга этәргеч бирү. *Сабыйның бәхетле чыркылдавы әти кешене газаплы уйларыннан арындырып җибәрде.* Т.Мөбарәков

**Арындырып җиткерү** Тиешенчә, тиешле дәрәҗәдә арындыру

**Арындырып кую** Арындырган хәлгә китерү; алдан арындыру. *Җиңүче матадор халык алкышын кабул иткән арада, арена хезмәткәрләре мәйданны канлы комнардан арындырып --- куялар.* Р.Фәйзуллин

**Арындырып тору** 1) Һәрвакыт, гел, даими рәвештә арындыру. *Наилә терриконда эшли. Җир астыннан чыгарылган ташкүмерне, чистартып, ят токымнардан арындырып тора алар.* Ә.Галиев

2) Әле, хәзерге вакытта арындыру. *Мин Халидә апага рәхмәтле идем. Күпмедер мизгелгә, үз хәлләрен сөйләп, мине тилмерүле уйлардан арындырып торганы өчен.* М.Кәбиров

**АРЫНУ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса чистарып калу, арчылу. *Шунда гына күк йөзе болытлардан арынды.* Р.Фәизов // Чистарыну, үзен үзе чистарту. *Кеше, нәфес колы булудан туктап, үз күңелен пакьләргә, игелекле гамәлләр кылырга, булган гөнаһларыннан арынырга бурычлы.* Х.Миңнегулов

2) Дошман яулап алган җирләр азат булу; дошманнан котылу // Ireккә чыгу, һәртөрле изүдән азат булу. *Шул ук вакытта, кимсетелүдән арыну, билгесез киләчәгемнең рәхим-шәфкатьле көннәренә ышану хисе – бөтенесе берьюлы кушылып, җанымда рәшә күк уйный.* Р.Низамиев // Ычкыну, бушау, чишелү. *Аркан егетнең муенына килеп төште, [ул] арканнан арынырга итте, әмма өлгерә алмады.* М.Хәбибуллин

3) Шөгыль, мәшәкатьтән бушау, берәр эш белән мәшгуль булудан туктау. *Ибраһим Гашигуллович, кәгазьләрдән арынып, тәрәзә аша яшәреп күренгән бакчага карады.* А.Вергазов. *Ул әле мәдрәсәдә уку-укытуны яңарту, аңламаган гарәп сүзләрен ятлатудан арыну --- өчен көрәшә.* С.Поварисов

4) *күч.* Искелекне, комачаулап торган нәрсәләрне бетерү, җимерү; котылу. *Театрның гомумән эш методына карата төп әйтә торган сүз: «җанлы газетчылык», «курчак уены» методыннан арынып, психологик образлар бирүгә күчәргә --- кирәк.* М.Җәлил. *Болар артыннан, үтмәс товарларыннан арынуны өмет итеп, уртакул сәүдәгәрләр агыла башлыйлар.* И.Нуруллин

5) *күч.* Уй, хис, тойгылардан котылу, кире үз халәтенә кайту. *Заһидулла иртәнге авыр сорауларыннан, җелегенә үткән үкенүләрдән, бигрәк тә юләрләндерә язган икеләнүләрдән тәмам арынды.* Р.Сибат. *Юлында тап булган кайгы-хәсрәттән арынмаса, --- аның өчен яшәүнең бер кызыгы да калмас иде.* Р.Хафизова. *Муса, уйларыннан арынып, шул якка күз йөгертте.* Ш.Маннур // Каты йокыдан соң кире аңга килү; аптырап, югалып калудан аңлы фикер йөртү хәленә кайту. *Эзәрлекләүчеләр, йокыдан арынып, өйгә килеп керсәләр, Мөхәммәд урынына Әбуталипны күреп хәйран калалар.* С.Поварисов

**Арына бару** Аз-азлап, акрынлап, торган саен ныграк арыну. *Биегрәк очу өчен, ком балластларыннан арына барырга кирәк.* Ш.Галиев. *Ничә көннәр инде вак яңгыр койган болытлар, Мәрҗән тавы ягыннан килеп, шомыртлык борынына таба агылалар, алар артыннан күк йөзе чистара, яңгыр болытларыннан арына бара иде.* Г.Кашапов. *Йорт --- Гыйбадулла картны югалту кайгысының кара корымыннан ипләп кенә арына бара.* Р.Сибат

**Арына төшү** Бераз арыну. *Улы, ниһаять, авыр тойгылардан арына төшкән.* Ф.Сафин

**Арынып бетү** Ахырынача, тулысынча арыну. *Мәҗлестән алган авыр тәэсирләрдән арынып бетә алмый, эш бүлмәсендә, уйланып, кул астындагы кәгазьләр белән әвәрә килеп утыра иде.* Ф.Сафин

**Арынып җитү** Тулысынча арыну, арынган халәт алу. *Дамир йокыдан тәмам арынып җитте.* Г.Кашапов. *Автобус көткәндә дә хат тәэсиреннән арынып җитмәде әле ул.* М.Вәли-Барҗылы. *Әмма ул – чагыштырмача гына ят, безнең рухыбыз ярлы булганлыктан, шартлы субъектлылык әсирлегеннән арынып җитә алмаганлыктан гына шулай чит булып тоела.* Казан утлары

**Арынып килү** Акрынлап арына башлау. *Гөлҗиһан баштагы югалып калудан арынып килә иде инде.* Ф.Сафин

**Арынып калу** Билгеле бер моменттан, нининдер сәбәп белән арыну. *--- эшләгән машина гөрелтесеннән, үзара кычкырып-кычкырып сөйләшкән тавышлардан арынып калган.* Н.Хәсәнов

**Арынып китү** Кинәт арыну. *Заһидулла уйларыннан арынып китә.* Р.Сибат

**Арынып тору** Вакытлыча, хәзергә арыну. *[Заһит] Марусядан котылуына*

*да, аракыдан арынып торуына да шат иде.* М.Әмирханов. --- *әнием һич эштән бушамый – әле, чөгендердән арынып торганда, колхоз келәтләрен агартып йөри.* Г.Якупова

**АРЫ́П-ТАЛЫП** *рәв.* Бик нык арып, хәлдән таеп. *Ихтимал, шуңа күрәдер, арып-талып кына 1961 елгы җәйгә чыккан чакта, доцент Диләрә ханым Тумашева мине Себергә, андагы Бараба татарларына оештырыла торган диалектологик экспедициягә чакырды.* М.Госманов

**АРЫСЛАН** *и.* **1**. 1) Мәчесыманнар семьялыгыннан, кыска йонлы, саргылт төстәге эре ерткыч хайван (ата арысланнар күпереп торган йомшак яллы була). *Төлке ишәкне туп-туры арыслан янына алып барган.* Әкият

2) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган йолдызлык атамасы һәм шул йолдызлыкның тамгасы; әсәд

3) Кояш календаре буенча унике айдан торган йолдызлыкның бишенче ае исеме (23 июльдән 23 августка кадәр) һәм шул айда туган кеше. *Минем улым арыслан аенда туды*

4) *күч.* Батыр, кыю, гайрәтле кешегә карата әйтелә. *Яшәсен гайрәтле милләт арысланнары!* Г.Тукай

5) *күч.* Берәр нәрсәгә хуҗа булган, көчле, куәтле, йогынтылы кешегә карата әйтелә. *Бу арыслан исән чакта, аның «колхоз» дип аталган бакчасына бер генә чит җанвар да үтеп керә алмаячак.* Ф.Садриев

**2**. *с. мәгъ.* Батыр һәм кыю булган, гайрәтле. *Арыслан егеткә кызның да чәчрәп торганы кирәк.* Г.Әпсәләмов

◊ **Арыслан йокысы** Сизү тойгылары яхшы булу, йокы халәтендә дә сизгер, уяу булу турында. *Йокысы да үтә сизгер, арыслан йокысына тиң бу илне [Кытайны] ат ияреннән торып, баш түбәсен генә күреп аңлап булмаган шул.* М.Галиев. **Арыслан йөрәкле** Курку белмәс, көчле, кыю. *[Күчем батыр:] Мөхтәрәм яугирләр! Арыслан йөрәкле ошбу егетне танийсыздыр, шаять.* В.Имамов. **Арыслан сөте** Аракы

**АРЫТУ** *ф.* 1) Хәлсезләндерү, ардыру, хәлдән тайдыру. *Чөнки бүген шактый арытты, ватты, душта коенып алырмын да ял итәрмен, дигән иде.* З.Хөснияр

2) Ялыктыру, туйдыру. *Кешеләр белән аралашу арыта, ялыктыра, ялгыз калып уйланасы иде, дисең.* Ш.Галиев

**Арыта төшү** Бераз арыту. *Качышлы уены да арыта төште аларны.* Н.Максимов

**Арытып бетерү** Тәмам, хәлдән тайганчы арыту. *Әле – бер, әле икенче нәрсәне күрсәтеп, үз гомерендә Бөгелмәдән ары чыгып йөрмәгән Гөлҗиһанга юл буе нәрсәдер сөйләп арытып бетергән иде.* Ф.Латыйпов

**Арытып җибәрү** Бераз, берникадәр арыту. *Кайвакыт Кәмәрия Зиннуровна: «Фәнис абый, берәр шигырь укыгыз әле, арытып җибәрде, күңелгә ял булсын», – дип, махсус шылтырата.* Ф.Яруллин

**АРЫШ** *и.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан, орлыгын онга әйләндереп, кара икмәк пешерүгә китә торган, игүле башаклы үсемлек. *Аеруча Дүчән басуында арыш башаклары авырлыктан җиргә кадәр сыгылып төшкән була.* Г.Гыйльман. *Арыш саламы ябылган «алтын түбәле» өй, балачакның бөек әкияте булып, хәтер утравына күчкән.* М.Галиев. *Арыш кыры азрак дулкынлана да башлады.* Г.Исхакый. *Арыш урагын бетереп, сабанга төшәргә торганда, авылда хәбәр таралды.* Г.Ибраһимов

2) Шул үсемлекнең орлыгы. *Колхоз кырында башта арыш өлгерә, аннары – борчак.* Ә.Салах. *Табынга, хуш исләрен бөркеп, табагы белән аш килде. Куе арыш чумары. Тәмле, туклыклы.* Р.Хафизова. *Карт белән карчык кына булган гаиләләргә яисә ялгыз кешеләргә, буханкалап, бөтен арыш ипие, күмәч сатып алу артык та килеп чыга, чөнки алар бик тиз кибә, күгәрә башлый.* Ватаным Татарстан

◊ **Арыш боламыгы** Бик җебегән, булдыксыз кешегә карата әйтелә. *[Миләүшә:] Кызлардан да оялгач, егет булмый инде ул! Арыш боламыгы була.* Д.Салихов. *Әмма Шәмсуар да җебеп төшмәде, изрәгән арыш боламыгы түгел икән егетебез.* М.Хуҗин. **Арыш мае** Аракы. *Соң сез, [Әхмәтне] ни эшләп, бераз арыш майлары белән җебетмисез?* Г.Камал

**АРЫ́Ш АНАСЫ** *и.* 1) *миф.* Игенлекләрне, арыш басуын карап, тәрбияләп торучы, дип күзалланган, шул иген эчендә яши торган мифик зат

2) *бот.* Шул мифик затның эзләре дип кабул ителгән, арыш башагына ябышып үсә һәм арыш белән бергә өлгерә торган кара төстәге, агулы озынча паразит гөмбә; *русчасы:* **спорынья.** *Арыш анасы арыштан алда өлгерә.* Мәкаль. *Татарларда, мәсәлән, арышның да үзенең анасы булган, «арыш анасы» – зыянлы гөмбә – арыш алласының үзе өчен калдырган өлеше, дип исәпләнгән.* Р.Әхмәтьянов

**АРЫШБАШ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, арышка охшаган башаксыман себеркәчле, чук тамырлы печән үләне; сүсән; *русчасы:* **житняк**, **тимофеевка**. *Болын арышбашы да тышкы күренеше белән үзенчәлекле: сабак очында тар цилиндрсыман чәчәк төркеме – солтан урнашкан.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**АРЫ́Ш КАМЧЫЛАУ** *ф.* Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен; нәҗәгай уйнау; *к. шулай ук* **аҗаган**. *Күктә, ялтырап, аҗаганнар уйнап ала. Аҗаган арышны камчылый, дип сөйли халык бу вакытны.* Х.Ибраһимов

**АРЫШЛАТА** *рәв.* Арыш белән. *Салымны арышлата түләү*

**АРЫ́Ш УТЫ** *и. бот. к.* **арышбаш**

**АРЬЕРГАРД** *и. фр.* Гаскәр яки флотның артка чигенү вакытында, төп көчләрне саклау, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, гомуми хәрби кушылмалардан җибәрелә торган төркем. *Болар – утрауга керүчеләрне каплый торган арьергард булырга --- тиешләр иде.* Ш.Маннур

**АС** I *и.* **1**. 1) Гадәттә кыек килеш формаларында килеп, пространствода: билгеле бер өслектән, җирдән түбән урын, түбәнге тараф; *киресе:* **өс.** --- *бетон баскычтан аска таба атлады.* М.Маликова. *Син тизрәк аска, үзәнлеккә, кешеләр янына төш тә Кызыл Чәчәк алып кил.* Р.Киплинг.

*Үлчәү тәлинкәләре, тагандагы кызчык кебек, әле – өскә, әле аска атына.* Н.Гыйматдинова. *Тәскирә, ниһаять, исенә-аңына килде. Артка тайпылып, аска караган килеш: «Ходаем, барлык гөнаһларым өчен кичер мине», – диде.* Г.Гыйльман

2) Берәр нәрсәнең түбәнге ягындагы өслек, түбәнге җирлек; *киресе:* **өс.** *Кояш күтәрелеп кыздыра башлагач, туң эреде, аяк асты җепшеде, кар ярмаланды.* Ш.Янбаев. *Ә йортлар каршыдагы тауга һәм шул тау асты буйлап сузылган әрәмәлеккә карый.* М.Хуҗин. *Авызым бәйләүле килеш, ул мине аска алып төште, монда бөтен шартлары китереп эшләнгән җир асты куышы иде.* Р.Батулла

3) Берәр нәрсәнең тирәсе, тирә-ягы, яны. *Кызлар, егетләр каравыл өе янындагы чирәмлектә таган астына җыелдылар.* М.Гали. *Мәскәү астындагы зур авыл өчен атакага барганда, флангта посып калган бер фашист пулемётчысы аларның ротасын бөтенләе белән диярлек кырып салды.* Р.Фәизов

4) Берәр нәрсәнең түбәнге өлеше, нигезе, төбе. *Төп бабам Хәсәннең асты – таш, өсте агач йорты бу.* А.Хәсәнов. *Ул үз уйлары белән мавыккан арада, аста җыештыручы хатын тагын нәрсәләрдер кычкырды, нидер боерды.* К.Кәримов. *Астан күтәрелгән су ике елганың да бозларын туктаусыз алга куалый.* К.Йосыпов. --- *хәзер исә суы куерды, тәнгә сылана, Баязитны аска сөйри.* М Хуҗин

5) Яткан яки утырган урын. *Малларны эчереп, асларын җыештырасым, азык саласым бар.* Ш.Маннапов. *Әтиле кешенең малае, укудан кайткач, сыер асты җыештыра, башакка салам турый...* К.Кәримов. *Нәкъ минем аска гына чыршы ботагының бастырык юанлыгын салгансыз бит, хәчтерүшләр.* А.Хәсәнов

6) Аяк киеменең җиргә басып йөри торган өлеше; табан, олтан, аслык. *Егет, су төбен итегенең табан асты белән капшый-капшый, акрын гына шуа башлады.* В.Нуриев. *Аягында – астына салынган киез итек, өстендә – иске сары тун.* Ф.Хөсни. *Ул, калын гына ас-лар салган зур киез итекләренә сырышкан карларны каккалап алгач, зур бүреген маңгаена баса төшеп, алга атлады.* Ш.Камал // Нәрсәнең дә булса төбе, асты. *[Мичебезгә] Нихәтле күп яксаң да, икмәкнең асты килми.* М.Гали. *Юллары бәлеш табасы асты кебек тигез, такыр.* Т.Галиуллин // Аскы өлеш. *Муен асты салынып төшкән, калын гәүдәле, түм-түгәрәк сыер иде ул.* Ә.Галиев. *Ерактан бу кошлар [көмеш акчарлаклар] ап-ак булып күренәләр, ә, якыннан караганда, корсак һәм канат асты гына ак төстә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

7) Нәрсәнең дә булса эчке ягы, эче. *Гимнастёрка төсле яшькелт пинжәк астыннан аның мускуллары уйнап тора.* Р.Хафизова. *Карчык бер вакытны яшел булган чапан ябынган һәм дә чапан астыннан бик иске түгел генә бишмәт кигән --- иде.* Г.Исхакый. *Инде сугыш алды, сугыш елларында ук киез итекләрдә, пальтоларда булып та, татарча ак ефәк шәл астыннан калфакларны төшермәгән бу асыл затлар, үзләре ач килеш, салкын сәхнәләрдән елмая-елмая, борынгы җырларыбызны ата-бабалардан кабул итеп алып, безгә җиткерә алдылар.* К.Йосыпов

8) Ут яга торган урын, учак. *Камилә торып, су китереп, сыер савып кергәнче, аның казан асты ягылып, бәрәңгесе пешеп, самавыры куелып өлгергән була.* Ә.Еники. *Юкны төпченеп утырганчы, бар, учак астына коры утын тура.* Ш.Янбаев

9) **астагылар** *күч.* Түбән дәрәҗәдәге кешеләр. *Өстәгеләргә астагыларны саталар, астагыларга өстәгеләрнең нәрсә сөйләгәннәрен җиткезеп торалар.* Ә.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ.* Аскы, астагы, аскы яктагы. *[Еланның] --- ас казналыгы баш сөяге белән хәрәкәтчел тоташкан.* Т.Шакирова. *Икмәкнең ас ягы кайракланган*

**3**. *бәйл. функ.* 1) **астына** Берәр эшхәлнең, хәрәкәтнең нәрсәнең дә булса аскы, түбәнге ягына юнәлүен белдерә. --- *беләсең килсә, аның өстендә сабаклары бишәр метр су астына киткән төнбоек чәчәкләре, --- саз үләннәре үсәләр.* И.Гази. *Ул табышын өйалдында каплап куелган чиләк астына яшереп маташканда, әтисе килеп чыкты.* Р.Кәрами. *Көлеп туйгач, фельетон астына минем яңа исемне язды да басарга җибәрде.* Р.Мостафин

2) Эш-хәрәкәтнең нәрсәнең дә булса йогынтысына дучар итү максатыннан эшләнүен белдерә. --- *ишегалды чирәменә сибәләгән вак яңгыр астына кыз-кыркын чүлмәк-чүлмәк гөл чыгарып тезәләр – шифалы яңгырга алар да коенсын!* Т.Мөбарәков

3) Нәрсәнең дә булса хәрәкәт сферасын, берәр төрле хәлгә дучар булуны, юлыккан шартларны белдерә. *Шулай итеп, төзүчеләрнең бөтен тырышлыгын шик астына куюы, юкка чыгаруы мөмкин.* Р.Кәрами. *Якынлашып килүче яңгырны уздырып җибәрмичә торып игенне җиргә егу – ярты ашлыкны су астына салып черетү, дигән сүз.* Г.Гыйльман. *[Газинурның кызлары] Коеп яуган яңгыр астына эләгеп туңганнары, өшегәннәре дә бар.* А.Хәсәнов. --- *тугандашлыкны куркыныч астына куя.* Ә.Хуҗиәхмәтов

4) **астында** Эш-хәлнең берәр предметның аскы ягында эшләнүен белдерә. *Тау астында изге чишмә ага.* Т.Миңнуллин. *Тимерхан өстәл астында мияулап торган песигә калҗа бирде.* Р.Вәлиев. *Кирпеч келәт астында тирән баз казыткан Фәрдүс Зәбихов.* М.Хуҗин

5) Кемне яки нәрсәне дә булса үз тәэсиренә, үз йогынтысына дучар итә торган әйбер яки күренешне белдерә. --- *бары тик үзенең җан газабы белән генә яшәсә дә, аңарга ышаныч кими бара, һәм ул һәрчак күзәтү астында яши.* З.Зәйнуллин. --- *безнең халкыбызның киләчәге куркыныч астында, без барыбыз да моны белергә тиешбез.* Т.Миңнуллин

6) Кемдер берәү нәрсә дә булса баскарган вакыттагы хәл-торышны, вакытны белдерә. *Таң беленеп килгәндә, тынычсыз полк, конвой сагы астында товар вагоннарына төялеп, билгесез якка җибәрелгән иде инде.* К.Нәҗми

7) Берәр эш-хәлнең, хәрәкәтнең башка эш-хәл, хәрәкәт белән беррәттән

башкарылуын белдерә. *Байрак, йөзләрчә тавышлар күтәреп алган җыр астында чайкалып, Вәлишиннәр фабрикасына таба үрләп килүче ялкын төсле, алга йөзеп китте.* К.Нәҗми. *Алар шулай, эчтән генә куанышып, төнге яңгыр шавы астында бер-берсенә сыенып, шактый озак бардылар.* А.Гыйләҗев

8) Эш-хәлнең сәбәбен белдерә; аркасында, нәтиҗәсендә. *Ут-күз чыгуга, күбесенчә, көл астында посып калган күмер яисә сиздерми генә пыскып яткан кисәү сәбәпче була.* М.Насыйбуллин *--- ул үрмәкүчкә охшаган алты аяклы машина иде һәм аның «аяклары» кушылыкларында һава басымы үзгәрүе астында эшли ---.* Р.Мөхәммәдиев

9) Затны, предметны, төшенчәне икенче затлар, предметлар, төшенчәләр рәтеннән аерып туплаган характерлы билгене күрсәтә. *Журнал тарихи материалларны нигездә «Мәшһүр адәмнәр вә бөек хәдисләр» дигән даими рубрика астында биреп бара.* М.Әмирхан

10) Мәгънәсе ачыла торган яки ачыларга тиешле сүзне, атаманы һ.б.ш. белдерә. *Бу сүзләр астында нинди мәгънә ята соң?* Казан утлары

11) **астыннан** Эш-хәрәкәтнең берәр нәрсәнең аскы ягыннан читкә юнәлүен белдерә. *Зәңгәр төтен, җил белән, капка астыннан урамга суырылып чыгып бетте.* З.Хөснияр. *Алан уртасында гомердә уйламаган уйларыма чумып утырганда, аяк астындагы җәлпәк таш астыннан бер кәлтә еланы атылып чыкты да, үчләшкән кебек, койрыкларын болгый-болгый, үлән өстендә бормалы эз калдырып, йөгереп китте.* Г.Гыйльман. *Төне буе укып чыктык шулай Һәм йокладык соңлап барсыннан. Иртән, мине уятмаска теләп, Песи чыга юрган астыннан...* М.Галиев

12) Кемнең яки нәрсәнең дә булса карамагыннан, йогынтысыннан, тәэсиреннән азат ителгән, коткарылган берәр хәл-торышны белдерә. *Көймәдән чыккач, шул матур манзарадан аерыла алмаенча, шул нурга коенган күлнең тәэсире астыннан чыга алмаенча, берсенә берсе тотынышып, бик озак карап тордылар.* Г.Исхакый. *Ул --- шик астыннан чыгу, кимсетелү-хурлаулардан котылу дип кабул итә.* Г.Кутуй. *--- басып алучыларның изүе астыннан котылу өчен, күп гасырлар буена көрәш алып баралар.* Ф.Галимуллин

◊ **Аска су йөгерү** *к.* **аска су керү**. *[Актай:] Астыңа су йөгерсә, әллә ниләр әйтерсең, кызым!* Н.Фәттах. **Аска су керү** 1) Эшне вакытында эшләмәү сәбәпле ашыгычка әйләнү; 2) Авыр хәлдә калу, ни эшләргә белмәү. *Дөрес, астына су кергәч, сезнеңише галиҗәнапларның дә зиһене ачылучан була.* З.Фәтхетдинов. **Аска су үтү** *к.* **аска су керү.** *Директорның җавабы да бик кырыс яңгырады: – Астыгызга су үткәнче кыймылдарга кирәк иде аны, – диде ул.* М.Хәсәнов. **Аста калдыру** 1) Кемнең дә булса сүзен, үтенечен тыңламау, үтәмәү; 2) Башка вакыйга, күренеш һәм эш-хәлләрнең әһәмиятен, урынын киметеп күрсәтү. **Астан карау** Яшертен генә, астыртын карау. **Астан кисеп, өстән ямау** Хәйләкәр һәм усал булу. **Астан тешләү** Берәр кешегә карата астыртын әшәкелек эшләү. **Астан ут (үрт) йөртү** Сиздерми генә астыртын эш йөртү, комачау итү. *[Сәгыйтов:] Мин, ал-ял белми, таралып беткән колхозларны кире җыеп, укмаштырып йөрим, син --- астан ут йөртәсең икән.* Ф.Сафин. **Астын өскә китерү** 1) Зур чуалчыклык, буталчыклык барлыкка китерү, бөтен нәрсәнең тәртибен бетерү; бар нәрсәне урыныннан кузгалту. *Бу хәл бөтен идарәнең астын өскә китерде.* Р.Хисмәтуллин. *Тик нишләмәк кирәк, сугыш кайчандыр изге саналган гыйбарә-гамәлләрне бер селтәнүдә юкка чыгарды, дөньяның астын өскә китерде.* М.Әмирханов; 2) Нәрсәне дә булса бик тырышып эзләү, бер җирне дә калдырмый актару. *Шул рәвештә, бер атна-ун көн чамасы, Галиәкбәр агай, шәһәрнең астын өстенә китереп, беренче класс ресторанынннан башлап түбән дәрәҗәдәге кабакка кадәр һичбер зыярәт итмәгән җирне калдырмады.* Ш.Мөхәммәдев. **Асты өскә килү** Зур чуалчыклык, буталчыклык барлыкка килү, әйберләрнең тәртибе югалу. *Дөньяларың ник асты өскә килми шунда.* Ф.Сафин

**АС** II *и. зоол.* **1.** Сусарлар семьялыгыннан, җәен саргылт көрән, кышын ак, койрык очы һәрвакыт кара булган кыйммәтле мехлы җәнлек; *русчасы:* **горностай.** *Юл аркылы ас йөгереп үтте, арырак хәйләкәр төлкенең күләгәсе чагылып алды.* М.Рәфыйков. *Киштәләрне сыгып төшергән төлке, кеш, ас, кондыз тиреләрен, тәпән-тәпән балларны, таудай өелгән ул күннәрне, савыт-сабаны, агач-ташны нишләтергә?* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Шул җәнлек мехыннан тегелгән

**АС** III *и. фр.* 1) Очу һәм сугышчан осталыгы белән танылган очучы

2) *күч.* Гомумән нинди дә булса өлкәдә танылган, нинди дә булса эшне бик оста итеп башкара торган кеше; үз эшенең остасы

**АС** IV *и.* Төрки халыкларда ыруг һәм кабилә атамасы (әлеге атама, бик борынгы чорда ук, төркиләрне атау өчен кулланыла торган этноним булган). *Бу һөҗүмнән соң, аланнарның «аслар» дигән төркеме Төньяк һәм Көньяк Донец елгаларының югары агымына күчеп утыралар.* Ф.Вәлиев

**АСА** I *и.* 1) Киндер сугу эшендә, рәтләр кыекланып китмәсен, туры барсын өчен кыстырыла торган җеп

2) Тукыма сукканда, җеп кыстырып эшләнә торган бизәк. *«Аса», «чүпләм» дип йөртелә торган тукыма бизәкләр, туку техникасына буйсындырылганлыктан, киртләч-киртләч геометрик фигура рәвешен алганнар.* Казан утлары

**АСА** II *и.* 1) *тар.* Нинди дә булса югары чин, дәрәҗә символы буларак кулланыла торган махсус шәкелле таяк; *русчасы*: **жезл**

2) Урамда транспорт хәрәкәтен күзәтүченең махсус таягы

**АСАБА** *и. гар. тар.* **1.** 1) Җирле халык, төп халык; *русчасы*: **абориген**

2) Нәселдән күчкән, ата-анадан калган җир, биләмә; *русчасы:* **вотчина**

3) Вотчина биләүче, вотчина хуҗасы. *--- типтәрләрнең исә бер өлеше --- асаба хокуклары алгач һәм, бигрәк тә, --- типтәрләрне «башкорт гаскәрләре»нә кушу сәбәпле, аларны*

*«яңа башкортлар» дип йөртү көчәйгәч, бу этносослов үзаң хәтта «башкортлык» билгеләрен дә ала.* Д.Исхаков

4) Ата ягыннан булган барлык ир туганнар

5) *диал.* Нигез хуҗасы, төп йортта калырга тиеш кеше, варис

6) Ата-анасын тәрбияләүче ир бала

**2**. *с. мәгъ.* Асабага (*2 мәгъ.*) нигезләнгән. *Аларның исә ахыры – ул өмет иткән асаба хакимлек күренми дә күренми.* Җ.Рәхимов. --- *соңгы дистә елларда төп халык, асаба милләт дип исәпләргә өйрәнгән башкортлар да, татар халкының үзләреннән күбрәк булуын инкяр итмәде.* Ф.Фаткуллин

**АСАБАЛЫК** *и.* Асаба (*2 мәгъ.*) хокукы. *Ясак бирмәгәч, җир-суга хакыбыз да бетә, асабалыгыбыз югала булып чыга.* Җ.Рәхимов

**АСАБАЧЫ** *и. тар.* Асаба (*2 мәгъ.*) хуҗасы, варис; *русчасы*: **вотчинник**

**АСАЛА́У** *ф.* Аса I кыстырып сугу, бизәк төшерү. *Тукыманың җирлеге, гадәттә, кызыл төстә булган. Күп төсле чүпләмле бизәкләр, асалап сугу кебек үк, ачык җете төсләре, төсләрнең байлыгы белән аерылып тора.* Н.Закирова

**АСАЛЫ** *с.* Аса I кыстырылган, бизәкләп тукылган

**АСАТ** *с. сөйл.* **1.** Ансат, җиңел. *Мондый җирдән коткаруы да бик асат эш түгел.* Ш.Мөхәммәдев

**2.** *хәб. функ.* Берни дә түгел. *Аның чарасы бик асат, бер дә аптырасы юк.* Ш.Мөхәммәдев

**АСАТЛАНДЫРУ** *ф. сөйл. к.* **ансатландыру**

**АСАТЛАНУ** *ф. сөйл.* Ансатка әйләнү, җиңеләю

**АСАТЛЫК** *и. сөйл.* Ансатлык, җиңеллек, асат булу, җиңел булу

**АСА́У** *с.* Елкы көтүен әйдәп йөртә торган, кулга иялләштерелмәгән, кыргый өер айгыры. *Шулар белән беррәттән торган, әле бүген генә, тотып, җылкы көтүеннән кайтарылган бер асау айгыр, бу кара болытның үз өстенә таба агылып килүеннән куркып, арлыбирле дулый башлады.* Г.Ибраһимов. *Заманында баш бирмәгән асау айгыр, бәйгеләрдә ал бирмәгән ярсу чаптар, ятлар кулына калгач, кыйнаулардан гарипләнә һәм соңгы узышта яныпу үлә, «телен аркылыга тешләп» җиргә ава.* Р.Батулла

**АСБЕСТ** *и. гр.* **1.** *махс.* Силикатлар классына керә торган, утка, селте-кислотага чыдам, сәнәгатьтә изоляция материалы буларак файдаланылган минералларның гомуми атамасы; тау сүсе

**2.** *с. мәгъ.* Асбесттан эшләнгән, асбесттан ясалган. *Өсләренә асбест плащлар кигән, гаять зур асбест җәймәне як-ягыннан тоткан унөч кеше --- дөрләп янган ут эченә кереп киттеләр.* Г.Ахунов. *Вагонда болай да салкын түгел, юан асбест торбага спираль тимер чыбык урап ясалган электр миче очкыннар чәчеп кызып тора.* В.Нуруллин

**АСИММЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Симметриянең бозылуы яки бөтенләй булмавы

**АСИММЕ́ТРИЯЛЕ** *с.* Симметриясе бозылган, симметриясез

**АСКАРИ́ДА** *и. гр. зоол.* Паразит суалчаннар семьялыгыннан, кеше һәм умырткалы хайваннарның эчәкләрендә тереклек итә торган озын йомры корт

**АСКЕТ** *и. гр.* **1.** 1) Дөнья рәхәтеннән ваз кичкән, үз-үзен чикләп, авыр тормыш алып бара торган кеше. *Кешеләр [Арсланны] аскет дип, чамадан тыш коры, күңелсез кеше дип уйлыйлар иде.* Г.Ахунов

2) Борынгы заманда: үзен ач торып җәфалаган христиан динендәге кеше

**2.** *с. мәгъ.* Аскетка хас сыйфатларга ия булган. *Бу ячейка секретаре үзенең шәхси тормышына вак мәсьәлә дип караучы, --- кызлар белән йөрүне иске тормыш калдыгы дип исәпләүче, --- аскет табигатьле бер егет икән.* Ф.Хөсни

**АСКЕТИЗМ** *и. гр.* 1) Кайсыбер фәлсәфә мәктәпләренә һәм шулай ук төрле диннәргә хас булган, рухи камиллеккә ирешү өчен хис-тойгыларны, теләк һәм омтылышларны буйсындыру, үзең теләп, физик авыртуларга, ялгызлыкка һ.б.ш. чикләүләргә өндәүдән гыйбарәт дини-әхлакый тәгълимат. *Шул чор поэзиясенә хас бу күренешне әдәбият белгечләре «аскетизм», ягъни кирәгеннән артык бирелгәнлек, дип атадылар.* Т.Галиуллин. *Аның аскетизмы кешелек сафлыгыннан килә.* Казан утлары

2) *к.* **аскетлык**

**АСКЕТЛЫК** *и.* Дөнья рәхәтеннән ваз кичү, баш тарту, аскет булу; дәрвишлек, суфилык. *Сез капитан Газизовны аскетлыкта гаеплисез, хәтта кайвакытларда, көлеп, аңа монахлыкка язылырга тәкъдим итәсез.* А.Шамов

**АСКУЙМА** *и.* Берәр әйбер астына кую өчен махсус ясалган җайланма. *Алар кергән җыйнак бүлмә кыйммәтле обойлар белән бизәлгән, озын аяклы аскуймаларга утыртылган гөл савытларыннан стеналарга үрмә гөлләр сузылып киткән.* А.Вергазов. *Шуның төтененнән талпаннар вазелинлы аскуймага мәтәләләр дә ябышып калалар.* Б.Камалов

**АСКЫ** *с.* Аста булган, ас яктагы, ас өлештәге, астагы; *киресе*: **өске**, **югарыгы.** *Карт --- кәзәкиенең аскы каптырмасын эләктерде.* М.Хуҗин. *Сезгә нинди номер кирәк, кадерлем: аскы каттамы, әллә өстәгесендәме?* З.Фәтхетдинов. *Ул сүзләрне әйтмәсә дә, Гөлфинур, үпкәләп, аскы иренен бүлтәйтте.* А.Вергазов

**АСКЫЛЫК** *и. диал.* Ачык яланда, кырда аш-су пешерү вакытында, чәй кайнату өчен, казанны, чиләкне, чәйнекне ут өстенә элеп (асып) куя торган таяк, колга; таган, өчаяк

**АСЛА** *кис. гар. иск.* Юклык мәгънәсен көчәйтүне, куәтләүне белдерә; бер дә, һич, һич тә, һичбер. *Моның асла колагына да керми, тыңламый да.* Г.Камал

**АСЛАМ** *и.* Закладка салына торган кыйммәт бәяле әйбер

◊ **Асламга салу** Түлисе бурыч урынына, вакытлыча, кыйммәтле әйберне бирү; закладка салу

**АСЛАМЧЫ** *и.* 1) Процент алу, арттырып түләтү исәбенә акча биреп торучы кеше; *русчасы*: **ростовщик**

2) Төрле вак товарлар белән йөреп сату итүче, кырыктартмачы, вак сәүдәгәр. *Ләкин, һәрвакытта ложаны алып, безнең янымызга йә күрше Мәрфугасын, йә исә асламчы Фәхриясен тагып җибәрә иде.* Г.Исхакый. --- *Җәмил асламчы картныкы шикелле әллә ниләр белән тулган хәтер сандыгын актарып утыра.* Н.Әхмәдиев

**АСЛАМЧЫ-АЛАМАЧЫ** *и. к.* **асламчы** (*2 мәгъ.*). *Салам түбәле авылның*

*кадерле хатирәсе: урам гөр килә. Асламчы-аламачы килгән. Арбасында – хуш исле, аллы-гөлле әйберләр.* М.Галиев

**АСЛАМЧЫЛЫК** *и.* Асламчы булу, асламчы хезмәте. *Андый чакта Сәфәргали үзенең асламчылыкта булганлыгын оныта – теленә ни килсә шуны такылдый бирә.* Ф.Хөсни

**АСЛАН** *кис. гар. иск. к.* **асла**. *Шулай да Азольгә дәрес калдырырга аслан ярамаганлыкны малайның үзенә дә, әлбәттә, әтисенә дә төшендерерлек итеп әйттем.* Ф.Хөсни

**АСЛАП** *бәйл.* Эш-хәрәкәтнең нәрсәнең дә булса аскы ягына, аскы торышына юнәлгәнлеген белдерә. *Бәрәңгенең итенә тияр-тимәс, Кабык аслап, пычак йөридер.* Х.Хөснуллин

**АСЛАТЫП** *бәйл. к.* **аслап.** *Бу апайдан котылганнан соң, тау аслатып кына, күрше урыс авылына сыпырттым.* Л.Гыйззәтуллина. *Юан кара бүрәнәгә охшашлы куркыныч бер җанварның, су аслатып, дусты үрдәккә якынаюын шәйләп ала мәче.* Р.Хафизова

**АСЛЫК** *и.* 1) Нинди дә булса әйбер астына куела торган җәйланма. *Арткы палубада тәбәнәк кенә аслыкка утыртылган кечкенә каен бар иде.* С.Сабиров

2) Аяк киеменең астына, табанына тегелә, кагыла торган нәрсә, олтан, табан. *Көя кискән киез итеккә аслык салган кебек, һәр тишеккә үз теориягезне китереп кыстыра беләсез инде.* З.Фәтхетдинов. *Син Котди, --- педаленә дә оекбаш белән генә бас, аның өчен мин аслыкка калын күн тектем.* Р.Фәизов

3) *сөйл.* Астар. *Яка аслыгын да яка җебе юнәлешендә кисәләр, ләкин, утырткannан соң, яканың почмаклары өскә таба тырпаеп тормасын өчен, яка аслыгының кырыен һәм очын якадан 2–3 мм га кимрәк итеп кисәләр.* Өегез ямьле булсын

4) *этн.* Элекке заманда, өйне чыра белән яктыртканда, чыра астына куела торган әйбер

5) Түшәк, матрац сыман йомшак әйбер. *Машина әрҗәсенә каяндыр табып китерелгән калын аслык җәйделәр, башы ак марляга бәйләнгән Әхнәфне шунда сузып салдылар.* Ф.Сафин. *Идәнгә йомшак калын аслык түшәлгән.* М.Хәсәнов

6) Мал астына салына, түшәлә торган нәрсә (салам, пычкы чүбе һ.б.)

**АСЛЫ́-ӨСЛЕ** *с.* **1**. 1) Ике катлы, берсе икенчесе өстенә урнашкан. *Шәмсүн күз карашын аслы-өсле киштәләргә тезелеп куелган китапларга юнәлдерде, аннары бүлмәне күздән кичерде.* А.Вергазов

2) Астагы һәм өстәге. *Аслы-өсле нарларда эшчеләр кайсы – утырып, кайберләре ятып торалар.* Ш.Камал

**2**. *рәв. мәгъ.* Кат-кат итеп, катлы итеп, берсе өстенә икенчесен куеп. *Аннары кәкре башлы таягы өстенә ике кулын аслы-өсле куйды да сүзгә керешеп китте.* Ш.Маннур

◊ **Аслы-өсле сүгенү** Ямьсез сүгенү сүзләре әйтү. *Авызга алмаслык әшәке сүзләр белән аслы-өсле сүгенү, тоткыннарга карата рәхимсезлек төрмәгә якынлашкан саен бермә-бер артты.* Р.Кәрами

**АСМА** I *и. махс.* 1) Вертикаль юнәлешне билгеләү өчен кулланыла торган, йөк тагылган озын бау

2) Күтәрү краны, сиртмәле кое һ.б. сиртмәсенә тигезлекне саклау, баланс ясау өчен тагылган йөк

3) *этн.* Асылмалы бизәк. *Сакланып калган әйберләр арасында көмештән эшләнгән чигә алкасы һәм шалтыравык асма бизәк чылбыры бар иде.* Ф.Хуҗин

**АСМА** II *с.* 1) *к.* **асылмалы.** *Газизәнең матур борыны белән килешле алсу иреннәре якты гына яна торган асма лампа яктысында гадәттән тыш матур күренә иде.* Ш.Камал. *Манараның нәкъ өстендә ике сакчы йөренә, Мөхәммәдъяр аттан төште дә капкачыга ярлыгын күрсәтте, капкалар ачылды, асма күпер төшерелде.* М.Хәбибуллин. *Яшь пожарник шоп-шома асма бау буйлап бик җитез менеп китте.* М.Фәйзуллина

2) *физ. иск.* Югарыдан түбәнгә таба төшерелгән, вертикаль. *Асма сызык*

**АСМАЛЫ** *с. сөйл. к.* **асылмалы**. *Асмалы лампа да кабызылды.* М.Әмир

**АСМАН** *и. фар. кит.* Күк, күк йөзе. *Асманга карап йөрсәң абынырсың.* Мәкаль

**АСПЕКТ** *и. лат. кит.* Нинди дә булса күренеш, төшенчә һәм перспективаларга бәя бирүдә бер караш, юнәлеш. *Поэманың сигезенче гасыр дәвамында халык хәтереннән төшми яшәп килүен һәм киләчәккә үтүен тәэмин иткән идея-эстетик җегәрнең әһәмиятле бер аспекты шунда икәнлеге бәхәссез булса кирәк.* М.Хәсәнов

**АСПИРАНТ** *и. лат.* Фәнни-тикшеренү институты, шулай ук югары уку йорты карамагында гыйльми яки педагогик хезмәткә әзерләнүче кеше. *И рәхмәт укый Аксубайдагы теге тылмач абыйга яшь аспирант.* Т.Нәҗмиев

**АСПИРА́НТКА** *и. рус* Хатын-кыз аспирант. *Аның креслосында, аның күзлеген борын очларына элеп, башына аның эшләпәсен киеп, әлеге яшь укытучы утыра. Куллары --- кочагына ук сеңеп беткән аспирантканың изүен чишеп азаплана...* Рифә Рахман

**АСПИРАНТЛЫК** *и.* 1) Аспирант булу

2) Аспирантура. *Деканат [аны] аспирантлыкка калдырырга карар бирде.* М.Гали

**АСПИРАНТУ́РА** *и. лат.* Фәнни-тикшеренү институтлары, югары уку йортлары каршында гыйльми һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү системасы. *Ә Мәскәүдә аспирантурада укый башлагач, аның хыялларының чынга әверелү мөмкинлеге тагын да ераклашты.* В.Нуруллин. *Укуны тәмамлагач, диплом яклаганда ук, аспирантурада калырга үгетлиләр.* Н.Гамбәр. *Кече уллары Свердловскида аспирантура бетереп ята икән.* А.Гыйләҗев

**АСПИРА́ЦИЯ** *и. лат. мед.* 1) Махсус аппарат яки шприц ярдәмендә, берәр орган куышлыгыннан җыелган су, һава яки эренне суырту

2) Дөрес йотмау нәтиҗәсендә, ашамлык, кан (кан китү вакытында) һ.б.ш. чит нәрсәләрнең сулыш юлына эләгүе. *Консилиум аның ике үпкәсендә дә, аспирация аркасында пневмония башланган, дигән карарга килде.* Совет әдәбияты

**АСПИРИН** *и. нем. махс.* Тәннең температурасын төшерү һәм авыртуны киметү өчен кулланыла торган дару. *Медпункт врачы, авыруның күңеле бул-*

*сын, дигән төсле итеп кенә, бер таблетка аспирин бирде.* М.Әмир

**АСРАМА** *с. сир.* **1.** Асрауга алынган. *Хәлимә ханым үзенә асрамага бала эзли башлады.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Асрауга алынган бала. *[Әсләф:] Мин сине асрамага алмадым, хезмәт итәргә, безнең арттан җыештырып йөрер өчен алдым.* Д.Салихов. *Апамны асрамага алырга кичә килеп белешкәннәр иде.* М.Хуҗин

**АСРА́У** I *ф.* **1**. 1) Хуҗалыкта һәртөрле мал-туар, кош-кортны карап, тәрбияләп, үстереп, үрчетеп тоту. *Йортҗирем яңа, мал-туарын, кош-кортын ишле асрыйм.* М.Хуҗин. *Кичтән «күршеләрдән йөри башлармын» дип ныклы маршрут төзеп куйса да, иртән, урамга чыккач, бу карарын кинәт үзгәртеп, өч-дүрт йортны үтеп китте һәм эт асрамаган Мекетә дигән кешеләргә кереп китте.* А.Гыйләҗев. *Тирә-якны айкап йөрүче бандитлар да, җир чәчеп, мал асрап көн күрүче җирле халык та – бар да --- пограничник Василийны беләләр.* Ә.Айдар

2) Нинди дә булса кешене, ашатыпэчертеп, үз янында тоту, яшәтү. *Син өеңдә студентлар асрыйсың икән.* Г.Ибраһимов // Карап, тәрбияләп үстерү. *– Миңа бирегез, миңа, – диде тагын бер агай. – Үз улым итеп асрармын.* Н.Дәүли. *Кечкенә бала көннәремдә, һичбер эшкә ярамасам да, атам-анам мине киендереп асрап үстерделәр.* Дәрдемәнд

3) *сөйл. иск.* Матди яктан тәэмин итеп тору. *Ул, янәсе, үз милкендәге җирләрне, урманнарны, болыннарны, Казанда яңа мәчет белән мәдрәсә асрау өчен вәкыф итеп бирәчәк, имеш, дигән ялган хәбәр тараттыра.* К.Нәҗми. *Байлар эчәләр, тарталар, карта уйныйлар, бишәр җирдә матур кызлар асрыйлар.* Г.Ибраһимов

4) *сөйл. иск.* Хезмәттә тоту, эшләтү. *Берничә ялчы асрау*

5) *күч.* Саклау, саклап тоту. *Бездә әле халык, Аллага шөкер, өчәр выпускадан торган газеталар асрарлык дәрәҗәдә үк юләр түгел.* Ш.Камал

6) *күч.* Үзе белән йөртү, үзендә йөртү. *Казачий пулясын йөрәк астында асрар хәлем юк!* Г.Ибраһимов

7) *күч.* Нинди дә булса хис, уйларны саклау, хәтерендә тоту. *Ул үзе дә, кайчандыр, күңелендә Булатка каршы бер дулкын асрый иде.* Г.Ибраһимов. *Шушындый гашыйклар йөрәгендә нинди хисләр асралганын телләреңнән гөл итеп тамдыр.* М.Фәйзи

**2.** *и. мәгъ. к.* **асраучылык.** *Баштa тирә-күрше районнардагы нигездә терлек асрау белән генә шөгыльләнә торган хуҗалыкларны ачыклады.* З.Фәтхетдинов. *Урыс кешесенең бар тапканы гаскәр асрауга китеп барган.* Т.Миңнуллин

**Асрап яту** Озак вакытлар үзеңдә тоту, саклау; озак вакыт асрау. *– Беренче, ул – контрреволюционер, кулак, --- авыл кулакларын развёрсткадан саклый, дезертирлар асрап ята, аларда сыйланып йөри.* Һ.Такташ. *[Мәүлитҗан:] Нәрсә дип боларны [китапларны] саклап, асрап яталар икән?* Д.Салихов

**АСРАУ** II *и.* Кемнең дә булса өендә йорт эшләрен башкаручы хезмәтче хатын-кыз. *Шуннан соң, асрауга күрсәтә-күрсәтә, әллә ни сөйләргә тотындылар, көлешергә тотындылар.* Г.Исхакый. *Бердәнбер түрәнең исә янып торган асраулары бар.* Ж.Рәхимов

**АСРАУЛЫК** *и.* Асрау булу. *Кайсы: «Миңа асраулыкка кеше кирәк иде-е», кайсы «Хатын авырый, бала карарга кеше юк иде-е», кайбер шаянраклары: «Өйләнергә исәп бар иде-е», – дип, төрле яктан сырып алдылар.* Т.Гыйззәт

**АСРАУЧЫ** *и.* Хайван атамалары белән янәшә килеп, тезмә сүз ясый һәм терлекчелекнең шул тармагы белән кәсеп итүче кешене белдерә. *Кош-корт асраучы хуҗалык*

**АСРАУЧЫЛЫК** *и.* Хайван атамалары белән килеп, тезмә сүз ясый һәм терлекчелек хуҗалыгының шул төр тармагын белдерә. *Вахитов совхозы – сарык асраучылык белән дан казанган хуҗалык.* М.Хәсәнов

**АССАМБЛЕ́Я** *и. фр.* 1) Халыкара оешма әгъзаларының гомуми җыелышы. *Бәлки, анда безнең ассамблея кебек ассамблеялар да меңләгән һәм миллионлагандыр, моны белеп бетерү генә түгел, хәтта күз алдына да китереп булмый.* Р.Мөхәммәдиев

2) *тар.* Петр I заманында бөтен җәмәгатьчелек катнашы белән үткәрелә торган җыелыш, бал

**АССЕНИЗА́ТОР** *и. рус* Ассенизация эшен башкаручы

**АССЕНИЗА́ЦИЯ** *и. фр.* Халык яши торган урыннарны сыек шакшылардан чистарту эше һәм шул эшне башкару өчен билгеләнгән чаралар системасы (аларны җыю, вакытлыча саклау, читкә чыгару, зарарсызландыру һәм юк итүне үз эченә ала)

**АССИГНА́ЦИЯ** *и. пол.* 1) Россиядә 1769 елдан 1843 елга кадәр чыгарылган акча

2) *сөйл. иск.* Гомумән кәгазь акча

3) *фин.* Нинди дә булса сәбәп белән, бер як икенче якка билгеле суммада акча, кыйммәтле кәгазь бирүгә нигезләнгән контракт

**АССИГНОВА́НИЕ** *и. рус кит.* Билгеләнгән, сметага кертелгән акча

**АССИМИЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Яраклашу, охшашу, кушылу, йотылу

2) Бер халыкның, икенче халык (яисә аның бер өлеше) белән кушылып, үз телен, мәдәниятен, үзаңын югалту күренеше. *Халкымны ассимиляция көтә, --- дип куркыталар.* М.Юныс

3) *лингв.* Сөйләмдә авазның үзеннән алда килгән (прогрессив ассимиляция) яисә үзеннән соң килгән (регрессив ассимиляция) аваз белән охшашлануы, берсе икенчесенә охшавы. *Нәтиҗәсе буенча, ассимиляция тулы һәм өлешчә төрләргә аерыла. Бер аваз икенче авазны үзенә тулысынча охшашландырса, тулы ассимиляция була.* Ф.Сафиуллина

4) *биол.* Тереклек иясе яки үсемлек организмының үзенә кергән матдәләрне эшкәртеп үзләштерүе, сеңдерүе // Күзәнәкләргә кергән гади матдәләрнең катлаулы органик кушылмаларга әверелү процесслары (фотосинтез, тамыр абсорбциясе һ.б.ш.)

**АССИМИЛЯ́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Ассимиляциягә дучар булу, ассимиляциягә дучар ителү. *XI йөздә немец телле франклар, галло-роман җирләренә кереп, «франк-француз» дигән дәүләт төзиләр, үзләре тиздән җирле*

*галло-роман телен кабул итәләр, ягъни ассимиляцияләнәләр*. М.Зәкиев

**АССИРИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Борынгы Ассириянең һәм Вавилонның культурасын һәм чөйсыман язмаларын өйрәнә торган фән

**АССИ́РИЯЛЕ** *и.* 1) Алгы Азиядә безнең эрага кадәр III меңенче елдан VII йөз ахырынача яшәгән иң борынгы дәүләтләрнең берсе – Ассирия дәүләтенең халкы һәм аның бер вәкиле

2) Якын Көнчыгышта, Европада, АКШта һ.б. яшәүче, семит телендә сөйләшә торган халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Ассириялеләр күпчелек очракта христиан динен тоталар*

**АССИСТЕНТ** *и. лат.* 1) Фәнни эшчәнлектә яисә операция ясау вакытында профессорның, табибның ярдәмчесе. *[Суфия:] Мин үзем, үз теләгем белән, патолого-анатомик тикшерүдә катнаштым. Мин ассистент булдым.* А.Расих. *Доцент Зәйтүнәне операцияләрдә ассистент булып торган чакларында элек тә мактый иде.* М.Маликова // Кинода, театрда нинди дә булса өлкән вазифадагы кешенең ярдәмчесе. *Болардан тыш, театрның художество составыннан – балетмейстер ассистенты иптәш Карыйны, художник-бутафор Хәбибуллинны --- алырга кирәк.* М.Җәлил. *Спектакльне куюю өчен, Казанга Л.Якобсон ассистенты хореограф Юрий Дружинин чакырыла.* Казан утлары

2) Югары уку йортларында билгеле бер факультет, кафедрага караган кече дәрәҗәдәге укытучы вазифасы һәм шул вазифаны башкаручы кеше. *Ә өч елдан соң, кандидатлык диссертациясе яклагач, аны кафедрада ассистент итеп калдырганнар.* Ф.Углов

**АССИСТЕНТЛЫК** *и.* Ассистент вазифасы, хезмәте

**АССОНАНС** *и. фр. әд.* Шигырь төзелешендә: охшаш сузык авазлар кабатлану күренеше. *Рифмасыз шигырь берике табышмакта гына күренеп китә. Бу очракта аһәңдәшлек аллитерация һәм ассонанс хисабына хасил була.* Х.Мәхмүтов. *[Табышмакларда] Мәсәлән, һәркайсында диярлек авазлар чиратлашуы (аллитерация һәм ассонанс) яки эчке рифмалар бар.* Х.Мәхмүтов

**АССОРТИ** *и. фр.* Билгеле бер әйбернең охшаш төрләреннән әзерләнгән җыелма, кушылма, катнашма. *Миңзаһит полиэтилен капчыкка беркадәр алма, туңдырылган чия, крыжовник салды, ике литрлы банкадагы ассортины култык астына кыстырды да, подвалның утын сүндереп, кухняга керде.* Ф.Садриев. *Минем дипломатта ассорти бар иде, алып килим әле.* Хәйдәр

**АССОРТИМЕНТ** *и. фр. махс.* 1) Сәүдә яки эшләп чыгару сәнәгатьләрендә сатыла яисә җитештерелә торган төрле сортлы әйберләр, товарлар җыелмасы. *Концерт программаларын һәм музыкантларны Хавтан меню белән эчемлекләр ассортиментына караганда да ешрак алыштырып тора иде.* Р.Мирхәйдәров

2) *күч.* Бер үк төрдәге әйбернең, күренешнең төрчәләре. *Хыял ассортименты бермә-бер кимеде.* М.Юныс

**АССОЦИА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Катнашучылары уртак максат белән берләшкән, бер үк характердагы эш алып бара торган оешма, берлек. *1929 елда экспериментальь фонетика буенча [Г.Шәрәф] Халыкара ассоциациягә гамәли әгъза буларак кабул ителә.* Р.Вәлиев. *«Алга» крәстияннәр хуҗалыклары ассоциациясе рәисе Риф Йосыпов оештыру эшләрендә маһирлык күрсәтте.* К.Йосыпов

2) Нинди дә булса төркем, билгеле бер нәрсәләрнең төркеме

3) *психол.* Нерв-ми эшчәнлегенә нигезләнгән аерым төшенчәләр, төрле психик хәлләр (күзаллау, фикерләү, хисләр) арасындагы бәйләнеш; бер төшенчәгә охшатып, шуның белән бәйле икенчесен искә төшерү. *Димәк, теге сүзләр белән чиртү арасында нининдер ассоциация туып өлгергән.* Ш.Камал

**АССЫЗЫК** *и. кит.* Нинди дә булса фикерне аерып басым ясап күрсәтү өчен җөмлә, сүз һ.б.ш. астына сызыла торган сызык

**АССЫЗЫКЛА́У** *ф.* Нәрсәгә дә булса басым ясау. *Нәтиҗәдә, үзен аңлаган, яраткан якын дуссыз, җан кардәшсез кешегә бу дөньяда яшәүнең гаять авыр булуын, хәтта мәгънәсе юклыгын ассызыклый.* А.Шәмсутова. *--- башлам нинди генә булса да, ул әкияттәге вакыйгаларның борынгылыгын, безнең заманга түгел, күптән узган чорларга каравын ассызыклап әйтергә тиеш.* Ф.Урманче. *Безнекеләр дә, оештыру конференциясендә үк, һичшиксез, әтиләр көне булдыру кирәклеген ассызыкладылар.* Ватаным Татарстан

**Ассызыклап алу** Берникадәр ассызыклау

**Ассызыклап бару** Эзлекле рәвештә, берсе артыннан берсен ассызыклау. *Кәбирне чагыштыру аша, татар халкының чор күзлегеннән фаҗигасен, бу аяныч язмышның киләчәк буыннарга тәэсирен фәлсәфи-публицистик рухта ассызыклап бара.* А.Шәмсутова

**Ассызыклап бирү** Махсус рәвештә ассызыклау. *Кагыйдә буларак, градация вазифасын үтәгән сүз-гыйбарәләрне Г.Тукай мәгънәви-интонацион яктан калкуландырып, ассызыклап бирә: Кычкырадыр: «Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!».* Х.Миңнегулов

**Ассызыклап китү** Сүз уңаенда, җае туры килгәндә ассызыклау. *Аның тагын бер зур хезмәтен ассызыклап китү урынлы булыр, ул да булса – китапханәнең яңа бинасын төзү, аны проектлаштыру.* Ф.Чанышева. *Мөдәррис Вәлиевнең аналитик мәкаләэсселарындагы шигъриятне, алардагы сурәт-тасвир осталыгын, сүз тылсымын ассызыклап китү укучы белән уртаклашуга юнәлтелгән булыр.* Р.Әхмәтҗанов

**Ассызыклап кую** Аеруча басым ясап ассызыклау, алдан ук ассызыклау. *Военкоматтагы абыйсы, син – әниеңнең бердәнбер баласы икәнне билгеләп, ассызыклап куйсын.* З.Хәким

**Ассызыклап тору** Гел, һәрвакыт ассызыклау. *Китапның өчтән бер өлешен алып торган «Ачык хатлар» әлеге омтылышны тагын да ассызыклап тора.* М.Вәлиев. *--- көч-куәтле сәламәт егет икәнен ассызыклап торган, таза, киң гәүдәле, озын буйлы Таһирның әлеге сәер кылыгы Гөлзиләнең күләсен китереп, күңелен күтәреп җибәрде.* М.Кәбиров

**Ассызыклап үтү** Сүз уңаенда, җае туры килгәндә ассызыклау. *Монда та-*

*тар милли хәрәкәтенең роле гаять зур булуын тагы бер тапкыр ассызыклап үтәргә кирәк.* Ф.Бәйрәмова

**АСТАР** *и. гар.* 1) Киемнең тышлыгы белән эчлеге арасына салынган тукыма (марля, киндер һ.б.ш.)

2) *диал.* Эчлек. *Астары ертылган пинжәкнең инде кызыгы калмаган.* З.Фәтхетдинов

3) Нәрсәне дә булса беркетү, ныгыту өчен, аның аскы ягына куела торган әйбер; аскуйма

4) Аска җәелә торган берәр нәрсә, аслык. *Сәгыйть астарсыз, җәймәсез буш караватны күрсәтте.* Ф.Сафин

5) *күч.* Асыл нигезе, мәгънәсе. *Ләкин бу сүзләрнең әнә шундый астары барлыгын да сизми калмады.* Х.Камалов

**АСТАРЛА́У** *ф.* 1) Астар кую, астар салу, астарлы итү. --- *хан затлы алтын парчага кеш тиресеннән астарлап тегелгән тун кигән иде.* М.Галиев

2) Нинди дә булса өслекне агартыр, буяр алдыннан шомарту, тигезләү яисә беренче кат буяу, агарту

**Астарлап бетерү** Тәмам астарлау, барысын да астарлау

**Астарлап җибәрү** Бераз, берникадәр астарлау

**Астарлап кую** Алдан астарлап әзер итү

**Астарлап тору** Даими, әледән-әле астарлау

**АСТАРЛЫ** *с.* 1) Астары булган, астар куеп тегелгән. *Сәлимгәрәй байның туганы Хаҗимөхәммәт бай да астарлы намазлыгыннан күтәрелмәде.* Х.Хәйруллин

2) *күч.* Эчке мәгънәгә ия булган, яшерен мәгънә белдергән. *Тамашачыга, тыңлаучыга шагыйрьнең фикерен, астарлы сүзен, кинаясен җиткезер өчен, актёр шагыйрь язган шигырьне үз сүзе итәрлек дәрәҗәдә яттан бикләгән.* Р.Батулла

**АСТАРЛЫК** *и.* **1**. 1) Астар өчен билгеләнгән махсус тукыма // Астар була алырлык әйбер

2) *диал. к.* **астар** (*2 мәгъ.*). *Күлмәк астарлыгы*

3) *күч.* Яшерен нигез, чыганак

**2**. *с. мәгъ.* Астар өчен билгеләнгән, астар буларак кулланылган. *Дүрт елда ике тапкыр яңа толь япсалар да, уңмадылар, әллә тольнең начары туры килде, әллә япканда тишкәләнде шунда, астарлык тактага яңгыр саркый торган урыннар кала бирде.* М.Хуҗин

**АСТЕРО́ИД** *и. гр. астр.* Кояш системасында диаметры 1 дән 1000 км га кадәр булган күк җисемнәренең берсе; кояш тирәсендә әйләнеп йөри торган вак планета. *Күп кенә астероидларның орбиталары Марс һәм Юпитер орбиталары арасына урнашкан. Барлык астероидларның суммар массасы Җир массасыннан бик күп мәртәбәгә аз*

**А́СТМА** *и. гр. мед.* Йөрәк (йөрәк астмасы) һәм бронхларның (бронхиаль астма) сәламәт булмавы нәтиҗәсендә, шулай ук тын юлларына ят әйберләр эләгү сәбәпле кабатланып торган тын бетү, буылу өянәгеннән гыйбарәт авыру. *Астма белән авыручылар чебен шикелле кырыла, ди.* М.Юныс. *Шулай яши-яши, ул башта – йөрәк, аннары астма чиренә сабышты.* Ф.Садриев

**АСТМА́ТИК** *и. рус мед.* Астма белән авыручы кеше

**АСТӨШЕРМӘ** *и.* Текстта кулланылган әдәбиятка, чыганакларга текст беткәч бирелә торган исемлек. *Тексттан соңгы астөшермәдә Алдар исеме нәкъ менә башкортларның әйдәп баручысы сыйфатында китерелә.* Гасырлар авазы

**А́СТРА** *и. рус бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, төрле төстәге иссез чәчәк ата торган декоратив, күпчелек очракта күпьеллык үсемлек, бакча гөле; кашкарый, *диал.* йолдыз. *Без аның «астра» дигән сүзен генә аңладык.* Р.Хафизова. *Көньяк һәм Төньяк Америка, Африка, Евразиядә астраларның 250ләп төре билгеле.* Биология

**АСТРОБИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Төрле космик җисемнәрдә, башка планеталарда, галәмдә тереклек булу мөмкинлегенең биологик аспектларын өйрәнә торган фән

**АСТРО́ГРАФ** *и. гр. астр.* Күктәге йолдызларның рәсемен төшерү өчен хезмәт итә торган астрономик торба

**АСТРО́ЛОГ** *и. рус* Астрология белән шөгыльләнүче белгеч, фалчы

**АСТРОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Күктәге йолдызларның, торышына карап, җиргә һәм кешеләргә (аларның темпераментына, характерына, эшләренә һәм киләчәгенә) тәэсир итә алуын өйрәнә торган фән. *Астрология – чыннан да, йолдыз һәм планеталарның торышы нинди булуга карап, кеше язмышын әйтеп бирү белән шөгыльләнүче фән.* З.Фәйзи

**АСТРОЛЮК** *и. гр.-голл.* Очкыч аппаратларда герметик ябыла торган итеп эшләнгән капкачлы тишек, очкычка керү урыны; люк. *Читкәрәк шуышып утырдым да астролюкны каерып ача башладым.* М.Юныс

**АСТРОЛЯБ** *и. гр. сөйл. к.* **астролябия.** *Бер якта астролябка таянган Әбелхарис күренә. --- Әбелхарис астролябын тоткан килеш катып кала.* Н.Исәнбәт

**АСТРОЛЯ́БИЯ** *и. гр.* Астрономиядә: озынлык һәм киңлекне, шулай ук җир үлчәү эшләрендә горизонталь почмакларны билгели торган почмак үлчәү әсбабы

**АСТРОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Астрономиянең күк йөзендәге җисемнәр торышын билгели һәм вакыт үлчи торган бүлеге

**АСТРОНАВТ** *и. гр.* 1) Астронавтика белгече

2) Космонавт

**АСТРОНА́ВТИКА** *и. гр.* Галәмне һ.б. чит объектларны космик аппаратлар кулланып өйрәнә, үзләштерә торган төрле фәнни һәм техник тармаклар берлеге; космик аппаратларның галәмгә очышын өйрәнә торган фән; космонавтика. *[Пилот] Астронавтика кагыйдәләрен бозып, авыр киемне салып ташлады.* А.Тимергалин

**АСТРОНОМ** *и. рус.* Астрономия белгече, астрономия галиме. – *Икенче кнопкага басып кына туктаттым үзен, – диде астроном Дамиров.* М.Юныс. *Астрономнар Галлей исемле комета ачканнар.* И.Юзеев. *Астрономнар да йолдызлар юлын гына беләләр.* М.Мәһдиев

**АСТРОНО́МИК** *с.* 1) Астрономиягә караган, астрономиягә мөнәсәбәтле. – *Корабльне җыештыру белән, астрономик күзәтүгә керешермен, – диде Дамиров.* М.Юныс

2) *күч.* Бик зур, исәпсез, исәбенә чыга алмаслык. *Ә бәлки, Неделин – Россиядәге бихисап алдашу-афералардан соң җыелган астрономик суммаларны Көнбатышка --- озатып торучы бер «шүре» генәдер?* Р.Мирхәйдәров

**АСТРОНО́МИЯ** *и. гр.* Йолдызларның, планеталарның һәм күк йөзендәге башка җисемнәрнең төзелешен, килеп чыгышын, үсешен, табигатен һәм хәрәкәт итү законнарын өйрәнә торган фән. *Ни яраткан фәне астрономиядән дә җавабы галәм серләре кебек буталчык булды.* М.Хуҗин. *– Аның өчен астрономия фәнен укырга кирәк, – ди Нурислам абый.* Р.Хафизова

**АСТРОФИ́ЗИК** *и. рус* Астрофизика белгече. *– Астроном дип әйтү дөрес булмас иде, мин – астрофизик.* Х.Ширмән. *Астрофизик сүзләренә караганда, бу эзләнүдә күпсанлы галимнәр катнаша.* Казан утлары. *Астрофизиклар, хәзерге вакытта Кояшның температурасы күтәрелә бара, дип саныйлар.* Фән һәм тел

**АСТРОФИ́ЗИКА** *и. гр.* Күк йөзендәге җисемнәрнең, аларның системаларының, шулай ук йолдызара һәм галактикаара мохитләрнең физик хәлен һәм химик составын, аларда барган процессларны өйрәнә торган фәннең бер бүлеге

**АСТЫРТЫН** *с.* **1.** 1) Мыштым, хәйләкәр; астан яшерен эш алып барган, яшертен эш йөртә торган. *Уразаев легион солдатлары арасында астыртын агымның һаман көчәя баруын --- әйтте.* Ш.Маннур. *Астыртын Гүйәк хан Батый ханның абруен төшермәкче була.* М.Хәбибуллин

2) Яшертен булган. *Токсикоз – бик астыртын нәрсә, ди профессор.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Яшерен рәвештә, яшертен генә, сиздермичә, сиздермәскә тырышып. *Вакыт, астыртын гына, кешеләрнең язмышы белән уйный, шаяра иде.* М.Юныс. *Мыштым гына утырса да, астыртын гына үзен күзәткәнен Мәрьям сизенгән иде.* З.Моталлапов. *Күрегезче бу күршеләрне, астыртын эш йөртмәкчеләр!* М.Хуҗин

**АСТЫРТЫНЛЫК** *и.* Астыртын булу. *[Фәттах:] Үзенең күзләрендә – мәкер, астыртынлык.* Д.Салихов. *Әхнәфтә астыртынлык, икейөзлелек көчле.* Ф.Садриев

**АСУ** *ф.* 1) Берәр әйберне нәрсәгә дә булса эләктереп беркетү яисә түбән таба салындырып бәйләп, тагып, элеп кую. *Урман кырыенда гына таган асып чәй кайнатканнар.* Х.Хәйруллин. *Багана --- янында – зур табаклары асылган үлчәү.* А.Әхмәт

2) Нәрсәне дә булса түбән салындырып, аркага, җилкәгә, кулга күтәрү. *[Мәгъфия:] «Кәҗә белән сарык» әкиятендәгечә, капчыкны аркага асыйм да юлга чыгыйм.* Д.Салихов. *Аркаларына мылтык асканнар.* Н.Дәүли. *Син дә кайттыңмы таныш ызаннарга? Биштәр аскан бөкре шәүләң алабуталар хәтерен кытыклап бара.* М.Галиев

3) Үлем җәзасының бер төре: кешене, муенына элмәкле бау кидереп, түбән таба салындырып кую. *[Фашистлар аны] Туйганчы җәзалап, соңыннан ялгыз ак каенга астылар.* М.Җәлил

**Аса башлау** Асарга керешү. *Бабай казанны аса башлый, балалар аңа ярдәм итеп йөриләр.* Р.Вәлиева

**Аса килү** Электән, күптәннән асу, эзлекле рәвештә асу. *Вәхшиләрнең хәлен төшенеп карыйк. Сезне аса килгән кемнәр алар, кайда?* Ә.Баян

**Аса төшү** Тагы да салындырыбрак асу

**Асып бетерү** Барысын да асу, асуны тәмамлау

**Асып кую** Асылынып торган хәлгә китереп калдыру. *Сарык бәрәннәренә ике бәйләм юкә себеркесе асып куйды.* Х.Хәйруллин. *Уң аягына кабат операция ясап, аны герләр белән тарттырып, аякны карават башына асып куйдылар.* Ә.Галиев

**Асып тору** Әле, хәзер күз алдында асу

**АСУ́-КИСҮ** *ф.* Үлем җәзасына күпләп дучар итү, күпләп үтерү, кыру. *Явыз дошман үләт кебек үткән, Асыпкисеп, утта яндырган.* Ә.Ерикәй. *Эшчәннәрне чәнчеп, асып-кисеп йөргән --- атлы казаклар.* М.Гафури. *Йә халыкны аса-кисә торган канечкеч залим була, йә – моның ише бер тинтәк.* Г.Бәширов

**Асып-кисеп бару** Беркемне кызганмый, бернәрсәне калдырмый рәттән асу-кисү

**Асып-кисеп бетерү** Барысын да асу-кисү. --- *иң акыллы, иң булдыклы кешеләрне асып-кисеп бетерделәр.* Г.Бәширов

**Асып-кисеп йөрү** Рәттән, бөтен җирдә барысын да асу-кисү. --- *император Ираклий яһүдиләрне асып-кисеп йөри.* М.Хәбибуллин

**Асып-кисеп тору** Даими рәвештә, әледән-әле асу-кисү

**Асып-кисеп чыгу** Барысын да рәттән, бер-бер артлы, башыннан-ахырына кадәр асу-кисү

**АСУЛЫ** *с.* **1**. Асып куелган, элеп куелган

**2.** *хәб. функ.* Асып, элеп куелган хәлдәге, шундый торыштагы. *[Гали:] Яхшы кешеләргә учагым ягулы, казаным асулы.* Н.Фәттах. *Түшәмгә лампа асулы.* М.Фәйзи

**АСУЧЫ** *и.* Асу белән шөгыльләнүче, асуны башкаручы, үтәүче. *Асучылар киткәч сорый каен: – Авыртмыймы муенын, авылдаш? – Авыртуга түзәр идем, каен, Тын алуы бигрәк авыр ла.* Х.Туфан

**АСФАЛЬТ** *и. гр.* **1.** 1) Җиргә түшәп юл һәм тротуарлар ясый торган, сумала сыман кара соры төстәге табигый һәм ясалма масса. *Аэропорттан райкомга кадәр юлның асфальты вак ташлары чыгар дәрәҗәдә юылган, су сиптерелгән иде.* Ф.Садриев

2) Әлеге масса җәелгән, түшәлгән тротуар, юл. *Шушы тынлык аша шәһәрнең уянуын, төн буе ял иткән асфальт өстендә урам җыештыручы картның себеркесе кыштырдавын --- ишетәсеңме?* Р.Низамиев

**2.** *с. мәгъ.* Шундый масса җәелгән, түшәлгән. *Чиста асфальт юллардан деталь-узеллар ташыган электрокарлар --- тыз да быз чабышалар.* Н.Хәсәнов. *Чәченә чал керә башлаган прораб шат иде: аның коллективы планны срогында үтәде, асфальт юл күрше өлкә чигенә кадәр китереп җиткерелде.* М.Хәбибуллин

**АСФАЛЬТЛАНУ** *ф.* Асфальт җәелү, асфальт белән каплану. *Юллар,*

*мәйданнар, үзәк урамнар асфальтланды.* Казан утлары

**АСФАЛЬТЛА́У** *ф.* Асфальт түшәү, асфальт җәю, асфальт белән каплау. *Асфальтламый калган уч төбе кадәр җирдә дә төрле чәчәкләр үсеп утыра.* Казан утлары

**Асфальтлап бару** Рәттән, тоташ, бер җирен дә калдырмый асфальтлау; торган саен күбрәк урыннарны асфальтлау

**Асфальтлап бетерү** Бөтен җирне дә асфальтлау; асфальтлау эшен тәмамлау

**Асфальтлап килү** Өлешләп асфальтлау; акрынлап, рәттән асфальтлау

**Асфальтлап тору** Кабат асфальтлау; гел, әледән-әле асфальтын яңарту

**Асфальтлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр асфальтлау

**Асфальтлый бару** Рәттән асфальтлау

**Асфальтлый төшү** Бераз асфальтлау

**АСФАЛЬТЛЫ** *с.* Асфальт түшәлгән, асфальт җәелгән, асфальтланган. *Асфальтлы зур урамнан пыяла ишекне ачып кергән җирдә хатын швейцар каршы алды.* Г.Ибраһимов

**АСФАЛЬТЧЫ** *и.* Асфальт җитештерү, асфальт әзерләү яки юлларга асфальт җәю эшендә эшләүче кеше

**АСЦИТ** *и. гр.* Бавыр циррозы вакытында, бөер төшкән очракта, бавырда һәм ашказаны-эчәк трактында шеш булганда, корсак куышлыгына су җыелу күренеше. *Һәр ике очракта да асцит барлыкка килә.* Ф.Углов

**АСЪЮЛ** *и.* Текст ахырында нәрсәгә дә булса бирелгән аңлатма. --- *асъюл белән янәшә астөшермә дә урын алса иде.* Ф.Сафиуллина

**АСЫЛ** I *и. гар.* **1.** Затлы ефәк тукыма төре. *Бервакытны иптәш кызым Нәгыймә белән, аршины дүрт таңкәгә, икебезгә пар тирәкле асыл алган идек, шуны тектерер өчен, бер көн эчендә биш җөйчегә җиттек, эшебез күп, дип, һичберсе дә алмадылар.* Г.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Рәсемнәрнең берсендә укалы-чуклы асыл күлмәк вә аның өстеннән чатма камзул кигән дүрт татар хатыны төшерелгән иде.* Ф.Әмирхан

◊ **Асылга төрү** Үтә дә затлы, кыйммәтле киемнәрдән генә йөртү

**АСЫЛ** II *с. гар.* 1) Бик кыйммәтле, затлы. *Сөенеп-сөенеп яна утлы йөрәк – Бер сүз катса миңа – сөенечтән, Тавышлары аның асылрак Чылтырап аккан көмеш инештән.* Ш.Бабич

2) Яхшы нәселле, яхшы токымлы (хайван турында). *Моннан ун еллар элек, хаҗи исән чагында, менә шул менгәнегез сынлы асыл юргасын каракларның авызыннан тартып алып биргән идем...* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Гел яхшы сыйфатларга гына ия булган, акыл, белем, абруе белән аерылап торган; изге күңелле. – *Әмма асыл егет иде Алиш, – дип дәвам итте кунак.* Ш.Маннур. *Байтак дошманнар гөрселдәп җиргә ауды, үзләреннән дә кадерле дуслар, асыл егетләр шәһит китте.* Р.Фәизов. *Шанлы дәүләтле Хантимер мирзаның --- гайрәтле улы Шаһтимер белән --- асыл токым Сәлим мирзаның --- гүзәл кызы Хәмдия бер-берсенә яр булырга вәгъдә бирделәр.* М.Фәйзи. – *Сезме безнең туганнарыбызның асыл сөякләреннән үзегезгә сарайлар салдыручы? – дип барып ябыштылар, ди, алар Капкорсак патшаның һәм министрларның бугазына.* А.Алиш

4) *күч.* Яхшы; изге, чын күңелдән әйтелгән. *Асыл сүзләр. Асыл теләк*

◊ **Асыл зат** 1) Бик дәрәҗәле һәм хөрмәтле кеше. *Татар җырларының чит җирләрдә иҗат ителгәннәре арасында «Шәмшәриф» – хаклы рәвештә җәүһәр саналырлык. Кайсы асыл зат иҗат иткән бу көйне?* К.Йосыпов; 2) Югары сыйныф кешесе, аристократия вәкиле, аксөяк; 3) *диал.* Алтын-көмеш әйберләр, затлы, кыйммәтле товарлар. *Калымлык өчен --- биш йөз сум акча, ике сандык асыл зат алып куйганнар.* Г.Ибраһимов; 4) Нәселле, токымлы (мал); 5) Хатын-кыз. *2004 елның 8 Марты – асыл затлар бәйрәменә районыбызның төрле елларда Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган хезмәткәре исеменә лаек булган илле сигез хатын-кыз чакырылды.* Т.Нәҗмиев. **Асыл кош** 1) Искиткеч матур итеп сайрый торган әкият кошы. *Асыл кошлар канат кактылар да Ботакларга чыгып бастылар.* М.Җәлил; 2) *ирон.* Чибәр кыз (яки егет). – *Юк, сиңа бер дә канатыңны салпайтып йөрисе түгел, – диде күрше хатыны. – Кукрәгеңне киереп йөр, асыл кошым!* Ш.Маннур; 3) *ирон.* Югары дәрәҗәле, бик булдыклы, мактаулы, дип күрсәтелгән билгесез кеше. *Әсирләр, игъланны укыйлар да, үзара фикерләшәләр, «яңа президент» дигәннәре нинди «асыл кош» икән тагын, диләр.* К.Йосыпов. **Асыл мал** 1) Алтын-көмеш әйберләр, затлы, кыйммәтле товарлар. *Ул үз гомерендә --- югалган асыл малларны караклардан ничек табып алганын көлке һәм куркыныч итеп сөйләде.* Г.Ибраһимов; 2) Бик матур, сылу хатын-кыз. **Асыл сөяк** 1) Тумыштан гүзәл, сөекле, кадерле кеше; 2) *иск.* Аксөяк, морза нәселеннән чыккан кеше, аристократ; 3) Нәселле, токымлы, яхшы нәселдән булган (хайван турында)

**АСЫЛ** III *и. гар.* **1.** 1) Берәр нәрсәнең нигезе, төп җирлеге, чын дөресе. *Хәер, хикмәт анда гына да түгелдер, мәсьәләнең асылы түбәндәрәк ята.* М.Әмирханов. *Габделмоталлип аның белән күрешеп, эшнең асылын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.* Ф.Яхин. *Минем характерымның асылы – үземне мәҗбүр итә белү.* Т.Миңнуллин. *Байтурәнең җеназасына чакырып, атчабар чыккан, диделәр, бу хәбәрнең асылы бармы?* Г.Ибраһимов

2) *филос.* Әйберне (күренешне) шул әйбер итеп таныткан аның төп үзенчәлеге, сыйфаты, эчтәлеге, җисеме. *Күңелдән кәгазьгә күчкән чакта асылы җуелып, хәрабәле кайтавазы гына калган сүзләр...* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Төп, оригинал. *Ул әкиятләрнең әдип кулы белән язылган асыл нөсхәләрен алып килгән иде.* Мирас

◊ **Асылына кайту** Элек булган хәленә килү, башлангыч халәтенә кайту. *Ләкин озак сагышлана, төшенкелеккә бирелә белми торган шат күңелле Газинур, бара торгач, яңадан үзенең асылына кайтты.* Г.Әпсәләмов

**АСЫЛДА** *кер. сүз* Нигездә, чынбарлыкта, дөресендә, төбендә. *Асылда,*

*Батый хан Гүйәк хан белән килешә дә алыр иде, ләкин, барыбер, күңеле бу кешене якын итә алмады.* М.Хәбибуллин. *Асылда, барлык әзерлек мәшәкатьләре Шәвәлиев җилкәсенә төшә.* Ф.Садриев. *Хезмәт сараенда чит ил туристларын әзерләү бүлегендә эшли, ләкин ул, асылда, министр Асаф Зәкиевнең хатыны иде.* А.Гыйләҗев

**АСЫЛЗАДӘ** *и. гар.-фар.* Иң югары катлам кешесе; аксөяк. *Гелән-гелән асылзадәләр арасында буталып, бәкләр, морзалар итагатенең йола-гадәтләрен үзләштереп бетергән чая егет бөтен шартын китереп сәлам бирде.* Ф.Латыйпов

**АСЫЛЗАТЛЫЛЫК** *и.* Асыл зат булу. *Сәбәпләр, бәлкем, аның җырлау культурасындагы рухи асылзатлылыктан, образлырак итеп әйткәндә, «аксөяклелектән» киләдер?* М.Госманов

**АСЫЛЛЫК** *и.* Асыл булу. *Егетнең асыллыгы – кулыннан килгән эш белән.* Мәкаль. *Нәсел, ген, асыллык, затлылык турында күпме сөйләсәк тә, кешене калыплауда тирәлек, мохит кебек әкәм-төкәмне чуттан ташлап булмый икән.* Т.Галиуллин

**АСЫЛМА** I *с.* **1.** *к.* **асылмалы.** *Шушмадагы асылма басма турына төшә торган тыкрыкка борылгач, Петрух кыска бер хикәятен сөйләде.* М.Хуҗин. *Урам яктан беренче рәткә кыска сабаклы һәм асылма гөлләр --- утыртырга мөмкин.* Өегез ямьле булсын

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чук, чачак. *Шуның өчен дә без Бүген төндә Аны матур итеп тегәбез, Читләренә асылмалар асып, Ука белән читен бөгәбез!* Һ.Такташ

2) Өчаяк, таган. *Ул арада егетләр, асылмалар ясап, учак өстенә чиләк элделәр, чәйнек астылар.* Р.Хафизова

**АСЫЛМА** II *и.* Бизәү, бизәнү өчен эләктереп, элеп куя торган әйберләр, бизәкләр. *Аның бәллүр асылмалары кояш яктысында әкрен генә тирбәлеп, стеналарга һәм түшәмгә салават күпере төсләрен чәчеп уйный иде.* З.Фәтхетдинов

**АСЫЛМАЛЫ** *с.* Асып куела торган, асып куелган, асма. *Палата уртасында асылмалы лампа янып тора.* Р.Хафизова. *Вагон стенасына беркетелгән асылмалы өстәлгә төрле тартмалар, юл сервизлары, ислемай шешәләре тезелделәр.* К.Нәҗми

**АСЫЛСЫЗ** *с.* 1) Тәрбиясез, юньсез, начар. *Асылсыз атка менсә, атасын танымас.* Мәкаль. *Асылсыз вә нәселсез кешегә һичбер чара юк: ничек булса да, ул үз юлын тотар.* К.Насыйри

2) Нигезсез. *Аякларын кисү хәбәре фәкать авылда гына чыгарылган асылсыз ялган булган.* Ш.Камал

**АСЫЛТАШ** *и.* 1) Кыйммәтле, затлы минерал (бизәнү өчен кулланыла). *Рәсәй империясенең казнасына тиң торырлык алтын һәм асылташлар запасын күп булса бер-ике ай эчендә туплаларга мөмкин.* З.Фәтхетдинов. *Кайсылары, иптәшләре, кардәшләре килгәнне көткән кебек, шул күлнең эчендәге асылташлар, хикмәтле серләрне карап торган кебек, тик бер җирдә катып тордылар.* Г.Исхакый

2) *күч.* Асылташка тиң әйбер. *Әмма эчендәге асылташ, күңелендәге гәүһәр, йөрәгендәге кешелеклелек энҗеләре хәзергә ару гына сакланган.* С.Поварисов

**АСЫЛТАШЛЫ** *с.* Асылташ куеп эшләнгән, шуның белән бизәлгән. *[Заһидулла] --- кесәсенә Тамара бүләк иткән асылташлы алтын чылбыр муенсаны --- салды.* Р.Сибат. *Депутат хатын төенчекне, ниһаять, чиште, аннан кәгазь төргәктән пар көмеш беләзек, пар алка, пар йөзек һәм асылташлы балдак китереп чыгарды.* А.Хәлим

**АСЫЛТАШТАЙ** *рәв.* Асылташ кебек. *Сүзләр мириадасы... Хәтер ятьмәсенә эләккән кайбер асылташтай сүзләрне үзалдыма кабат-кабат әйтеп карыйм: борынгы заманнар кайтавазы яңгырап ишетелә.* М.Галиев

**АСЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **асу.** *Тагы, тиз-тиз кадаклар кагып, җеп үткәрделәр, чыбылдык кияү белән кызның ятагы өстенә менеп асылды.* Г.Ибраһимов. *Уйлар һәр очраган ак каенның Ботагына асылып калалар.* Һ.Такташ. *«Елан бар», – дигән булып, Кучәрбайга якынаялар, Кучәрбайның көчле кулларына асылып, җиңел генә күтәрелмәкче иделәр.* М.Әмир

2) *диал. к.* **асылыну** (*6, 7, 8 мәгъ.*). *Мәһибикә минем беләкләремә асылды.* М.Әмир. *Ә бер көнне, безгә ачу итеп, Тоталар да асылып үләләр.* Һ.Такташ

**Асылып йөрү** Бөтен җирдә артыннан калмыйча ияреп йөрү. *Әле Зәки Вәлиди дә, үзенең ак башкортлары белән, Дутов койрыгына асылып йөри, диләр.* Ф.Бурнаш

**Асылып тору** Әле, хәзер асылган хәлдә булу. *Мин туганда, илем эргәсендә Кургаш болыт торган асылып.* Р.Шиһапов. *Кесәләрем тышкы якка асылып тора.* З.Фәйзи

**Асылып төшү** Салыну, аска таба сузылу. --- *ике як ярларында үскән куаклардан асылып төшкән күләгә эчендә бөтенләй агуын онытып тора.* М.Әмир

**АСЫЛЫНДЫРУ** *ф.* 1) Басып, өстерәп, тартып, салынкы хәлгә китерү, шундый торыш бирү. *Күз алдында гарасат капылт кына дуамаллана да мине гәрдап кырыена китереп асылындыра, шул упкынга очмас өчен, бармак очларым уелып-ертылып беткәнче тырышам.* М.Хуҗин

2) Югарыдан аска таба төшерү, салындыру (мәс., кулны, аякларны һ.б.ш.). --- *тәрәзә каршына, аякларын асылындырып, тезелеп утырдылар.* Р.Вәлиев. *Афзал Сәет белән кәләшине арбаның артына утыртты. Үзе, үрәчәдән аякларын асылындырып, алга урнашты.* Ф.Яруллин. *Сары толымнарын асылындырып уйга талган ялгыз каенны рәсемгә төшерә башлыйм.* Гөлшәһидә

3) Киемнең (кесә, итек кунычы һ.б.ш.) читеннән чыгарып калдыру, салындыру. *Бәй, җегет булсаң, башта җолаларын китер: бер балагын читегеннән асылындырып, икенче балагын читек кунычына кыстырып, бик шәптән бер яучы җибәр.* Г.Бәширов

**АСЫЛЫНУ** *ф.* 1) Аска таба, түбән таба салыну. *Чөнки, печән кыштырдаган тавышка чыдаша алмыйча, кәҗә, бауга асылынган килеш, печәнгә сузылып маташа иде.* Ш.Камал. *Куллар ванна читенә асылынып төшкән.* М.Юныс. *Әһә! Әнә өянкенең су өстенә асылынып төшкән чуклары дулкын*

*өсләренә тиеп китәләр дә бер серле көй чыгаралар... Чың-чың... чың-чың-чың...* Г.Гыйльман. *Әнисе ияр өстенә аркылы яткан, чәчләре асылынып төшкән, ике кулы, ат тилпенгән уңайга, җансыз нәрсәдәй атына иде.* Г.Бәширов

2) Эленү, эленгән булу. *Менә өрлеккә асылынган үлчәү көянтәсе әле бер, әле икенче якка атынгалап торды да тынып калды.* Г.Бәширов

3) Үзеңнән югарырак урнашкан нәрсәгә дә булса тотынып, гәүдәне түбән таба салындырып тору. *Данилов, тешен кысып, бер – пулемётка, бер бандага карап икеләнеп калганда, Шәмси, ничектер, шулай кирәген күңеле белән сизеп булса кирәк, атларның башына барып асылынды...* Г.Бәширов

4) Бара торган нәрсәләргә тотынып, тагылып, эләгеп бару. *Дулкын эчкә кайткан арада, Гариф, сикереп торып, көймәгә ташланды һәм көймәнең читенә барып асылынды.* Ш.Камал. *Бер-ике атлагач ук, мин аның, баягы кебек, муеныма асылынып бара алмаячагын сиздем.* А.Шамов

5) Нәрсәне дә булса (тотынып, тешләп) түбән таба тарту. *Икенче бакчаның читәненә үрмәләп менгәндә, кемнеңдер эте чалбарымның исән калган балагына асылынды.* М.Юныс

6) Үлү максатыннан, тартылганда тын юлларын буарлык итеп, муенга бау салу. *Минем урында башка берәү булса, әллә кайчан асылынып үлгән --- булыр иде.* А.Шамов. *Бу хурлыкка түзә алмыйча, асылынып үлде чибәркәй.* Р.Батулла

7) *күч.* Кемгә дә булса барып сарылу, кочаклау. *Ул, арыган гәүдәсе белән, аңа килеп асылынды.* Р.Сибат. *Мин, йөгереп килеп, аның муенына асылындым.* Р.Хафизова. *– Әни! Без сине туган көнең белән котлыйбыз! – дип, ананың муенына асылынды кызы.* М.Хуҗин

8) *күч.* Ялынып тагылу, артыннан йөрү. *[Лилия:] Хәзерге кызлар егетләрнең муеннарына асылына.* Д.Салихов. *Авыл кешеләре шундый бит алар: үз дәрәҗәсендәге бәндәләрне генә кешегә санийлар, кем дә булса алга чыгарга, узарга җыенса, аның чабуына асылыналар. Алга чыгучы чабуына асылындырмаса, үпкәлиләр, аны дошман күрәләр.* Т.Миңнуллин

**Асылынып калу** Әле, хәзер, сөйләү моментында асылынган хәлдә булу, шул рәвешне саклау. *Изаил Харисовичның ишек тоткасына сузылган кулы һавада асылынып калды.* М.Маликова. *Ак халатлы хатынның пенснесе, борыннан ычкынып, кара тасмасында асылынып калды.* Г.Гобәй

**Асылынып тору** *к.* **асылынып калу.** *Җиз калайчыкка беркетелгән ачкыч исә, көндәгечә, урынында асылынып тора иде.* Ф.Латыйфи. *Хәстә ягында бер читкә тартып куйган күк чаршау вә берничә күлмәк асылынып торалар.* Ш.Камал

**АТ** I *и.* 1) Атсыманнар семьялыгыннан, борынгы бабасы тарпаннар булган, кешеләр йөртү һәм йөк ташу өчен файдаланыла торган, имезүче, так тояклы йорт хайваны, эре терлек. *Кәбир, гомер буе күрмәгәндәй бер сагыну белән, атның муенына килеп сарылды.* А.Хәлим. *Ә шул вакытта үзебезнең халык яшелчәгә тилмерә: хатыннарыбыз корсак күтәргәндә тозлы кәбестә талымласалар, ат җигеп, күрше авылларга чабабыз ---.* М.Әмир

2) *спорт* Ат башлы, дүрт шакмакта «г» хәрефе рәвешле «хәрәкәт итә» торган шахмат фигурасы

3) *спорт* Күн белән тышланган юан бүкәнне дүрт аякка беркетеп ясалган гимнастик җайланма

◊ **Ат бәясе** Кирәгеннән артык кыйммәтле, сатып алырлык булмаган бәя; зур бәя. *[Шайтан:] Алар бит концертларны стадионнарда оештыралар. Билетлары да – ат бәясе.* М.Миншин. **Ат белән чыпчык куу** Бик күп көч сарыф итеп, юк әйбер артыннан йөрү. **Ат җене кагылу** Атны карап-тәрбияләп, атта йөреп, бик күп вакытын ат тирәсендә уздыра торган, ат яратучы кешегә карата әйтелә. *Яшьтән үк ат җене кагылган иде шул кызга.* З.Хөсният. **Ат кебек** Бик таза, зур гәүдәле кешегә карата әйтелә. *Хәзер дә әле ат кебек таза, көчле, дисезме?* А.Шамов. **Ат кебек эшләү** *к.* **ат урынына эшләү**. **Ат койрыгын кисү** Элеккеге йола буенча: туй вакытында кияү яки кодалар җигеп килгән атның койрыгын кисү юлы белән кәләшнең кыз түгеллеген белдереп, кияүне мыскыл итү. **Ат күз** Күзе акайган, акай күзле кешегә карата әйтелә. **Ат менү** Атка атлану. *Ат менгән ике кеше бирегә таба чабып килә.* И.Гази. **Ат суыту** Юлдан алҗып, тирләп кайткан атны, ашатмый-эчертми, бераз бәйләп тоту. **Атта да бар, тәртәдә дә бар** Ике як та гаепле. **Ат тотучы** Җигүле атның дилбегәсеннән тотып, командалар биреп алып баручы кеше. **Ат урынына эшләү** Авыр эшләрдә һәм армый-талмый эшләү. *Җәй буена ат урынына эшләткәнсең дә аерып җибәргәнсең.* А.Шамов

**АТ** II *и.* 1) Кешегә кушылган исем. *«Мин – менеджер...» – ди Эдуард, «Бизнесмен!» – ди Фердинанд... Майкл әйтә: «Кем булса да, Кеше алсын изге ат!».* Р.Рахмани. *[Әхмәт:] Әйтсәм әйтим. Минем чын атым – Былтыр.* Д.Аппакова. *[Абдулла] Башы-аягы белән мәгърифәт вә голүм дөньясына чумды, мәхәллә эшләре белән мавыкты – гаилә коручы яшьләргә никах укыды, яңа туган сабыйларга ат куйды, бу фани дөньядан киткәннәргә ясин укып, аларны дәфен кылды.* Җ.Рәхимов

2) Кушамат, атама, атак. *Атның аты өлкән, дөянең табаны өлкән.* Мәкаль. *Авыл хатыннарына: «Канатым, абыстаем!» – дип сүзләргә башлаган кебек, кош-кортларга, мал-туарга да сөюле атлар кушты.* Г.Исхакый. *Авыл балалары «Челем бабай» дип ат та куштылар.* Г.Ибраһимов

◊ **Ат алу** *к.* **ат казану.** *Янды Фәрһат, янды Ширин, Бер якын ат алдылар.* Дәрдемәнд. **Ат казану** Даншөһрәт казану, танылу. **Атка калу** Оятлы булу, оятка калу, яманаты чыгу. **Ат калдыру** Исемеңне нинди дә булса эш белән мәңгеләштерү. *Ат калдырдык бергә туган илгә Сагынып яд итәргә гомергә.* Ф.Бурнаш. **Ат сату** Кемнең дә булса исемен пычрату, гайбәтен сөйләү. **Аты да, заты да юк** Бөтенләй юк, гомумән юк. **Аты коргыры** Сукрану сүзе: кешенең яки әйбернең исемен искә төшерә алмаганда әйтелә. *Менә*

*инде, аты коргыры, тел очымда гына тора бит.* Т.Гыйззәт. **Аты чыгу** Начар яктан танылу, яманлыгы фаш булу, нәрсә белән булса да телгә керү. *Нинди дә булса җәнлек тотып яки атып кайтканын күргән-белгән кеше юк икән юклыкка да, әмма «сунарчы» дигән аты чыккан.* Ф.Хөсни

**АТА** *и.* **1**. 1) Балалары булган, бала тәрбияләп үстергән ир кеше; эти. *Карачы, ата белән баланың бер-берен тирән ярату, сөю көче нинди кодрәткә ия икән!* Ш.Маннур. *Ә минем бердәнберем кем? Ташлап китсәм, атам йортына кире кайту юк, дигән сүз.* Рифә Рахман. *Мин, ирек теләп, атам йортын тарсынып чыгып киткән кыз.* М.Фәйзи

2) Баланың үз этисен атау, аңа мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе. – *Мин синнән олы булырга тырышмыйм, атам! – диде Тотыш углан, тезләнеп.* Н.Фәттах

3) **атасы** *тарт. форм.* Хатынның иренә мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе. *Быел үзең дә бик зур эшкә алындың, атасы, киленгә җиңел булмас инде.* Г.Бәширов

4) Ибраһими диннәрдә: Аллаһ тарафыннан балчыктан яратылган иң беренче ир кеше, барлык кешеләрнең нәсел башы, башлангыч этисе; Адәм. *Адәмдер бәнем атам, Хәүвадыр бәнем анам...* Мөнәҗәт

5) *күч.* Берәр нәрсәгә башлап нигез салучы; үз ишләре арасында иң алдынгысы, иң булдыклысы, иң бирелгәне. *Ата коммунистларның берсенә дә җил-яңгыр тимәде, һәммәсе дә үзләренең җылы урыннарында әйбәт кенә утырып калдылар.* Казан утлары. *Лозунглары матур тоелса да, ата коммунистларның эш-гамәлләре бүтәнчәрәк булып чыкты.* А.Гыйләҗев. *Студентлар аны [Профессор И.Е.Жуковскийны], рус авианиясенең атасы, дип атыйлар.* Р.Ибраһимов. *С.Сәйдәшев – татар профессиональ музыка сәнгатенең атасы*

6) Өлкән буын, өлкәннәр. *Әйтик, мондый характердагы каршылык «Алдым-бирдем» драмасында, бер гаилә мисалында, --- аталар белән балалар тартышы кебек классик конфликт формуласына килеп чыкса, «Тартышу» драмасында (1908) --- шактый җитди сәяси фон тудыра.* Мирас

7) *күч. сөйл.* Кемгә дә булса ярдәм итүче, тәрбия күрсәтүче кеше. *Ул миңа һәрвакыт ата булды*

8) Иркәк җенестән булган хайван, җәнлек, кош-корт яки үсемлек (күбрәк тарт. форм. кулланыла). *Актүш атасы ягыннан овчарка катнаш токымнан, анасы ягыннан – гади йорт эте.* Т.Нәби

**2**. *с. мәгъ.* 1) Хайваннар, җәнлек, кош-корт һәм үсемлекләр дөньясында: иркәк җенестән булган. *Коймa буйлатып, нидер сагалый-сагалый, ата мәче узды.* Р.Хафизова. *Ата каз талагач, акырып-бакырып елаганмын.* Н.Дәүли. *Мидхәт ата күркәдәй кабарына һәм, үз дигәнен таш ярылса да эшләргә дип, учларына төкергәләп куя иде.* Ф.Хөсни

2) *сөйл.* Берәр сыйфаты белән билгеле, бик тә, үтә дә атаклы. *Ушан Бузмах – ата ялкау, әмма хәйләкәр.* Р.Батулла. *Дачама керүче ул гына! Ата ялганчы! Әнә эзләрен күрегез!* М.Насыйбуллин. *Бармагыз, йөрмәгез, хараплар гына булырсыз, ул бит – ата карак!* Т.Мөбарәков

◊ **Ата баласы** 1) Кеше, адәм баласы. *Сез дә ата баласы, Без дә ата баласы, Сөймәгәнгә сөйкәнмибез, Сөйсәң, ярлар табыласы.* Җыр; 2) Ата кулында тәрбияләнгән, инсафлы. **Ата дошман** Төп дошман, иң явыз дошман. **Ата казга сәлам бирү** Салкын тию яисә башка сәбәпләр аркасында, муен бер якка янтаеп, кәкрәеп тору, муен нервларының авыртуыннан гыйбарәт авыру. **Ата казның күкәй саламы?** Сүз югында сүз булсын, дигәнне аңлатып әйтелә торган тәгъбир. – *Исән торасыңмы, Газинур, ата казның күкәй саламы? – Ачуы килмәгәндә, – диде Газинур һәм кроватька сузылып ятты.* Г.Әпсәләмов. **Ата канаты астында яту** Ата тәрбиясендә, авырлык күрмичә генә гомер итү, ата йортында яшәү. *Мыек тибә башлаган егет кеше гомер буе ата канаты астында ятмас.* С.Рафиков. **Ата күркә** Бик эре кыяфәтле, тәкәббер, һавалы кеше. **Ата малы** Атадан калган байлык, атадан килгән мирас; үз көчең кереп табылмаган әзер байлык. *Үзең тырышып тапмасаң, ата малы – бер айлык.* Мәкаль. **Атаң башы** *гади с.* 1) Тиргәү сүзе. *Галошларың салмый, ни дип инде килеп кердең атаң башына!* Һ.Такташ; 2) Кемнең дә булса сүзенә, фикеренә каршы ирония белән әйтелә. – *Нигә менә монда да таш кала – таш кала булмый? – Нигә булмасын, бик була! – Була, атаң башы!* Г.Ибраһимов. **Атаң башы гына юк** Ни генә юк, бар да бар, дигәнне аңлата. **Ата төлке** Бик үткен, бик астыртын, хәйләкәр кеше. **Ата шайтан** Яшүсмерләрне һәртөрле шуклыкларга, уен-көлкегә әйдәп йөрүче кеше

**АТА́-АНА** *җый. и.* Ата һәм ана. *Яшәү законы ата-анадан алган тәрбияне үз балаңа кайтарып бирүне таләп итә.* М.Юныс. *Хәзер зур шәһәрләрдә ата-ана киңәшен, янәсе, психология кабинетлары алыштыра икән.* Р.Хисмәтуллин

◊ **Ата-анасы белән сүгенү** Әшәке, яман сүзләр әйтеп тиргәшү. **Ата(сы)-анасы юк** Тәртибе, рәте, җае юк. *Безнең якта Балтун Шәрәфие бар иде, мәрхүм. Сүзенең бер дә атасы-анасы булмас иде.* М.Хәсәнов. **Атаң-анаң гына (монда) юк** *к.* **атаң башы гына юк**

**АТА́-АНАЛАРЧА** *рәв.* 1) Ата-ана буларак

2) Ата-ана кебек кайгыртып, үз итеп

**АТА́-АНАЛЫ** *с. к.* **аталы-аналы.** *Менә ата-аналы булдым!* Р.Батулла. *Ата-аналы балаларга мондый рәхәт тәтиме икән әле?* А.Хәсәнов

**АТА́-БАБА** *җый. и.* Өлкәннәр, борынгылар. *Һәм шунда ул, ата-бабалары турында: «Каян килгән аларга мондый көч, мондый рух?» – дип уйлап алды.* Р.Вәлиев. *Борынгы ата-бабаларыбыз: «Азны аяган күптән коры калыр», – дип тә әйткән.* С.Поварисов. *Шуларның һәммәсен бергә туплагач, яшьләрнең ата-баба туфрагында төпләнүләре хакындагы сорауга җавап табылды да төсле.* Б.Камалов

◊ **Ата-бабадан калган (килгән)** Буыннан буынга күчкән, борынгыдан килгән, борынгылардан калган. *Ата-бабадан килгән тәҗрибә аңа бу мәсьәләдә ачык аңлаешлы сабак бирә алган.* Г.Нигъмәти. **Ата-бабасы(ның кабере) белән сүгү** Бик яман сүзләр әйтеп

тиргәү. *[Ул тегеләрне:] «Китегез, хулиганнар! Үзегезгә эләкмәгәч, ачудан, кеше исеме пычратып йөрисез!» – дип, ата-бабалары белән сүгеп таратты.* Г.Ибраһимов. **Ата-бабасына җитү** Бик начар сүзләр белән сүгү

**АТА́ БӘПКӘ** *и. к.* **ата кайчы**

**АТАВИЗМ** *и. лат. биол.* Бик борынгы, инде югалган билгеләрнең тереклек һәм үсемлек организмында яңадан килеп чыгуы. *Сугышуда нииндидер атавизмга бәйле кабахәтлек ята.* М.Юныс

**АТАЙ** *и. сөйл.* 1) Әти, ата. *Ялгыз бала атайга баш.* Мәкаль

2) Атага эндәшү сүзе. *Атай! Сөйләшми торган абыйның килгәне бармы?* М.Хуҗин

◊ **Атай булып әйтү** Ата урынына калган яки аның урынында торырлык өлкән кеше буларак киңәш бирү

**АТАК** *и.* 1) *сөйл.* Кушамат. *Атның атагы өлкән.* Мәкаль

2) Дан, шөһрәт, мәртәбә. *Ир үлсә дә, атагы үлми.* Мәкаль. *Нинди атак, нинди олы эшләр көтә аны...* З.Зәйнуллин

◊ **Атак чыгу** Атакка алып сөйләү

**АТА́КА** *и. фр.* 1) Фронтның кечкенә бер өлешендә кыска вакытлы кискен һөҗүм. *Немецларның сигезенче атакасын кире кайтарганда, бер сугышчы Миргәйгә беренче пулемёт расчёты командирының яралануын әйтә.* В.Казыйханов. *Әмма шул ук «нечкә күңелле» солдат, атакага барганда, дошман өстенә дәһшәт булып, өермә булып ташлана.* Г.Бәширов

2) *күч. сөйл.* Билгеле бер максатка ирешү өчен яки берәр кешегә каршы эшләнгән тәвәккәл эш, хәрәкәт. *Салих бу минутта тегеләргә психик атака ясап алды.* К.Кәримов

**АТАКАЙ** *и. сөйл.* **1**. 1) Атаны яратып телгә алу яки ялварып, ялынып, аңа мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе. *Бу минутта Митьканың атакайга ошарлык берәр сүз әйтәсе килә иде.* З.Фәтхетдинов. *Бу дәрәҗә белән бергә атакаемны дворян итәләр.* Р.Батулла

2) *сөйл.* Өлкән яшьтәге ир кешегә мөрәҗәгать сүзе

3) Христиан динендә: рухани. *Өлкә җитәкчесе инициативасы белән оештырылган бу чарада Түбән Новгород һәм Арзамас митрополиты Николай атакай катнашты.* Мәдәни җомга

**2**. **атакаем**, **атакайларым** *ы. мәгъ. тарт. форм. сөйл.* Кинәт булган берәр эшкә гаҗәпсенүне, шаккатуны, ис китүне, куркып калуны белдерә. *– Атакаем, ах! – дип кычкырды ул, күкрәген тотып.* Ш.Маннур. *Карасазга кердең дә чумдың, атакаем! Үлде дип, авыл җыйдым мин, йолдызым күршем.* Н.Гыйматдинова

**АТА́ КАЙЧЫ** *и.* Өй түбәсе кыегы (киртләнмәгәне; киртләнгәне – ана кайчы)

**АТА́КАЛАУ** *ф. хәрби спорт* 1) Һөҗүм итү, һөҗүм ясау. *Гвардия майоры Ермиловның батальоны – авылга маңгайдан һөҗүм итү, өченче батальон төньяктан атакалау бурычын алды.* Г.Әпсәләмов. *Бу операция буенча, Нева елгасын боз өстеннән үтеп, биек ярыннан менеп, яр өстендәге немец траншеяларын атакалап блокаданы өзү, Волхов фронты сугышчылары белән кушылу бурычы куела.* Т.Нәҗмиев

2) *күч.* Сүгү, ачулану

**Атакалап алу** Берникадәр, бераз вакыт атакалау

**Атакалап бетерү** Бик нык, тәмам атакалау

**Атакалап китү** Кинәт атакалый башлау

**Атакалап тору** Һәрвакыт, әледәнәле атакалау

**АТА́ КАПТЫРМА** *и.* Ыргаклы каптырма

**АТАКЛЫ** *с.* **1.** 1) Билгеле бер өлкәдә танылган, күренекле, дан-шөһрәт казанган. *Алексей Пешков (Горький) булачак атаклы җырчы Шаляпин белән танышып, аның белән бергә чиркәү хорында җырлап йөри.* З.Зәйнуллин. *Тагын берничә ай үткәч, быелның гыйнвар аенда Берлинга ике атаклы татар кешесе бара: армия генералы Мәхмүт Гәрәев һәм шул ук профессор Абдулхан Әхтәмҗан.* Р.Мостафин

2) Берәр вакыйга белән танылган, киң таралган, билгеле булган. *Әтисе авылда нәселле айгыр тәрбияләве белән атаклы булды, ат ярата иде.* Ш.Галиев

**2.** *и. мәгъ.* Билгеле, танылган, даншөһрәт казанган кеше. --- *сандугач җырын музыкада биреп карарга тырышканнар, хәзер дә тырышалар. Әмма иң атаклылары да биреп җиткерә алганнары юк...* Г.Әпсәләмов

**АТАКЛЫЛАНУ** *ф.* Дан-шөһрәт казану, атаклыга әйләнү

**АТАЛАНДЫРУ** *ф.* 1) *биол.* Серкәләндерү; ата җенес күзәнәге белән кушу. *Ата кортлар булмаса, ана кортлар үрчеми. Ата кортлар запаста тора, алар яңа чыккан ана кортларны аталандыра.* Н.Хәсәнов

2) *сөйл.* Ана җенестән булган хайванны шул төрнең ата җенесеннән булган хайван белән кушылдыру, кушу, йөгертү, каплату

**Аталандырып бетерү** Барысын да аталандыру, аталандыру эшен төгәлләү. *Сездәге налуговой инспекторлар сизеп алганчы, бөтен сыерларыгызны аталандырып бетерәсез әле сез.* Т.Миңнуллин

**Аталандырып тору** Әледән-әле, еш аталандыру

**АТАЛАНУ** *ф.* 1) *бот.* Серкә күзәнәге белән күкәй күзәнәкнең үзара кушылуы, серкәләнү

2) *сөйл.* Хайваннарда җенси кушылу

**АТАЛА́РЧА** *рәв.* 1) Ата буларак

2) Ата кебек якын итеп, кайгыртып. *Кыскасы, үз кешеләре турында аталарча кайгырта ул.* М.Хәбибуллин

**АТАЛГЫ** *и.* 1) Колаша кебек итеп юна торган йомры ышкы

2) *диал.* Чапкы, тәпке

3) Тәгәрмәч ясаганда, тәгәрмәч бүкәненең эчен бораулап тишә, эчен ала торган зур борау

**АТАЛМА** *и. иск.* Атама. *Хәзер «обломовщина», «бюрократизм», «оппортунизм» кебек аталмалар бирсә дә калмады.* М.Әмир

**АТАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **атау** I (*1 мәгъ.*). *Мин – Хәсән Вәгыйзович Иштирәков – фәннәр кандидаты; «галим» дип аталырга хакым бар.* Т.Миңнуллин. *Белемле кеше аларда «беләр» дип атала, шуның өчен бу илне «Беләр» дигәннәр, аның мәгънәсе «галим кеше». Шуны гарәп теле аһәңенә яраклаштырып, «Болгар» дип йөртә башлаганнар.*

Татар халык иҗаты. *Кенәриләр, күгәрчен, тутый кошлар асрала торган гаиләләрдә балалар бронхларның кискен ялкынсынуы белән еш газапланалар. Бу авыру «тутый кош авыруы» дип атала да инде.* Хокук һәм хәят

2) Багышлану. *[Хәмдия:] Хатымда мин аны ачык әйттем. Миңа бирәчәк тартуың – үземә аталган көй, дидем.* Ә.Фәйзи. *Җәй көне каз-үрдәкне кайдан табып булыр соң, дип, Мәрфуга абыстай, аларга аталган аларга булсын, дип, кош-кортны суймый калдырды.* Г.Исхакый

**АТАЛЫ́-АНАЛЫ** *с.* **1**. 1) Атасы да, анасы да булган. *Миннән ерак түгел генә урында аталы-аналы бер оя үрдәк балалары үзләренчә шатланышып, шаулап йөзеп йөриләр.* А.Шамов

2) Парлы. *Аталы-аналы ике карчыга бер тау башында урын тота иделәр. Вә дәрәҗәләренә карап лаек кәсеп итеп, куанычлыкта гомер итә иделәр.* Татар халык иҗаты

**2**. *рәв. мәгъ.* Ата белән ана икесе бергәләп

**АТАЛЫ́-БАЛАЛЫ** *рәв.* Ата белән бала икесе бергәләп

**АТАЛЫК** *и.* 1) Ата булу. *[Таһир:] Совет иленең һәрбер намуслы карты эшләргә тиешле булган аталык бурычымны гына үтим.* Т.Гыйззәт. *Шәмсинең күңеленең бер кырыенда Анна аның бәхетене урлаучы, аның аталыгын урлаучы, аны мәңгегә өйләндермәенчә, никяхсыз калдыручы кебек иттереп килеп басты.* Г.Исхакый

2) Ата җенестән, нәсел өчен калдырылган кош-корт яки хайван

3) *биол.* Чәчәкләрдә ата җенестән булган серкә күзәнәк

**АТАЛЫ́-КЫЗЛЫ** *рәв.* Ата белән кыз икесе бергәләп. *Без аталы-кызлы кавышырбыз, Яшь аралаш көлеп, шатланып.* М.Җәлил

**АТАЛЫ́-УЛЛЫ** *рәв.* Ата белән ул икесе бергәләп. *Аэродромдагылар, исләре китеп, аталы-уллы шул пәһлеваннарга карап тора.* Ә.Галиев

**АТАМА** *и.* 1) Күренеш, предмет, вакыйга һ.б.ш. исеме

2) Термин. *[Семагин] Инженерлар сөйләшкәндә, күп нәрсәне аңламый иде. Техник атамаларны, төзү материалларының исемнәрен әйткән дә юк.* Р.Кәрами. *Законны кабул итәргә кирәк, ә татарча атамасы табылмаган.* Хокук һәм хәят

3) *к.* **атама исем**. *Институтта һәр укытучының артында авыз тутырып әйтелә торган кушаматы бар. Әмма олы баш, шуңа тиң гәүдә һәм тавыш студентның болай да мең мәшәкать белән тулы миенә --- күпме өстәмә хәсрәт алып килде. Иза чикте студент халкы бер атамага да туктала алмыйча: «акбаш», «барабан», «кабак», «патефон», «карт төлке»...* Т.Галиуллин

**АТАМА ИСЕМ** *и.* Кушамат; псевдоним

**АТАМАЛЫ** *с. сөйл.* Атап әйтелгән, аталган. *Мондый атамалы тостлар эчкәндә нишләргә соң?* Ш.Маннур

**АТАМАН** *и.* **1.** 1) Борынгы ирекле казакларда: дружиналарының сайлап куелган җитәкчесе

2) Инкыйлабка кадәр казак гаскәрләрендә һәм авылларында: төрле хәрби эшләрне, администрация һәм полиция эшләрен башкару өчен билгеләнеп яки сайланып куелган башлык. *Мондый атаманы булган казачий гаскәргә хәзер бернинди дошман алдында да куркыныч түгел иде.* Ә.Фәйзи

3) Юлбасар шайкасы башлыгы. *Анда инде бандитларның атаманнары үз дуслары белән кәефләнә булыр.* Н.Дәүли

4) *сөйл. күч.* Берәр эшне оештырып, башлап йөрүче кеше, башлык

5) *күч. ирон.* Сугыш чукмары, канечкеч. *Яшүсмер чагын сары мыеклы тупас урядниклары, кара сакаллы кулак атаманнары белән агулап узган иске тормышны ул яшьтән үк күралмас булды.* Г.Бәширов

**2.** *с. мәгъ.* Берәр эшне, берәр нәрсәне оештырып, башлап йөри торган. *[Айдаров] Бездә банкет оештыру [эшләрендә] иң атаман кеше иде.* Х.Сәлимҗанов

**АТАМАНЛЫК** *и.* 1) Атаман булу. *Сораштыра башлагач, купедагы малайлар беравыздан Азатны яклап чыгалар, күрәсең, ялт та йолт күзле, атаманлыкка омтылган үсмер боларга электән таныш булган, каннарына тоз салып өлгергән инде.* А.Тимергалин

2) Атаман вазифасы

**АТАМАНЛЫК ИТҮ** *ф.* 1) Атаман вазифасын башкару; атаман булу. *Аны моннан ике ай элек кенә Казаннан китерделәр, ул беренче көненнән үк атаманлык итә башлады.* Б.Камалов

2) Нәрсә дә булса оештыру, нәрсәгә дә булса җитәкчелек итү. *Хәзер шул Малик авыл өстеннән атаманлык итеп ята, имеш.* И.Гази

**АТАН** *и.* Печелгән дөя. *Алтмыш көн атан булганчы, алты көн бура [үгез дөя] бул.* Мәкаль. *Ябагалы яшь тайлак Ярдай атан булган йорт, Ятып калган бер тукты [бер яшьлек куй], Җәйлеп, бең куй булган йорт.* Җыр. *Җикмәгә бирсәң атан бир – Арышы [тәртәсе] сынмый мыгаймас [хәлдән таймас], Саумага бирсәң кысрак [кысыр бия] бир – Кукрайга [үләнгә бай җиргә] --- тими суалмас [сөте кимемәс].* Дастан. *Барган эзе бармактай, Атлаган эзе атандай.* Табышмак (*чалгы, печән чабу*). *Атан дөя исерсә, үз тайлаклары белән уйный.* Ч.Айтматов

**АТА́П ӘЙТКӘНДӘ** *кер. сүз* 1) Исемләп әйткәндә, исеме белән әйткәндә, аныклап күрсәткәндә. *Атап әйткәндә, Равилнең әнисенә Оренбур шәле, ике күлмәклек ситсы, бер бик һәйбәт көзге пальто алып кайткан иде.* В.Нуруллин

2) Аерым алганда

**А́Т-АРБА** *и.* Ат белән арба-чанадан торган транспорт, тарту көче. *Кем белә, бәлки, ата күңеле йомшарып китәр дә, ат-арбасын да биреп куяр.* Г.Минский. *Боярга урак-печән эшләсәк, икенче җәйгә ат-арба алырбыз.* Г.Ибраһимов

**АТА́(СЫЗ)-АНАСЫЗ** *с.* Ятим, үксез. *И-и Абу, син үзең беләсең бит. Ата-анасыз үсүләрне Алла күрсәтмәсен.* Б.Сөләйман. *Кышкар авылында яшьли ата-анасыз калган Шәмсетдин исемле ятимне тәрбияли.* Р.Батулла

**А́Т-АТ УЙНАУ** *ф.* Берсе икенчесен бау белән яки итәгеннән тотып, шулай ук, чыбыкка атланып, атта йөргән сыман йөгерүдән гыйбарәт балалар уены. *Авылларның урамнарындагы яшел чирәмнәрендә бер туктамаенча ат-ат, куян куышы, ат карагы уеннарыны уй-*

*ный торган балалар һәм дә, яшел чирәмнәргә корсаклары берлә сузылып ятып, елның матурлыгыннан, яхшылыгыннан шатланып, иске елларны, иске эшләрне, авылларның януларыны, атларның үлүләрене --- сөйләп, иске хатирәләрене яңарта торган агайлар, --- бу манзараны тагы матурлата, аңар тагы күбрәк мәгънә бирә иде.* Г.Исхакый

**АТА́У** I *ф.* **1.** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса исем кушу, исем, ат бирү. *Ул тыкрыкны аның исеме белән атап, «тешсез Ибрай тыкрыгы», дип йөртәм.* М.Әмир

2) Кем яки нәрсә дип исемләү, нинди дә булса ат, исем йөртү. *Якташкаем, ул --- «кычыткан тавыгы» дип яратып атый бит мине.* Ә.Айдар

3) Кешенең яисә нинди дә булса күренешнең төп сыйфатын билгеләп әйтү. *Мин аларда [мәкаләләрдә] Шәүкәт абыйны, дүрт әдипне бергә туплаган язучы, дип атаган идем: --- ул – бердән, балалар шагыйре, икенчедән – лирик шагыйрь, өченчедән – юмор остасы.* М.Галиев. *Бу урам кешеләрен чиркәүгә гыйбадәт кылырга чакырып, поп килеп йөргән, һәм ул килә торган юлны «Урыс юлы» дип атаганнар.* Ф.Гарипова

**2. атап** *рәв. мәгъ.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса махсус билгеләп, багышлап. *Методик ярдәмлек Казан дәүләт университетында татар филологиясе һәм тарихы факультетының көндезге һәм читтән торып уку бүлегендәге студентларга атап төзелде.* Г.Нәбиуллина

2) Багышлап, төбәп. *Бибкәй Солтанга атап, шәһәрдә бәет чыккан икән, сезне шуны әйтергә чакырды.* Н.Исәнбәт

3) Адреслап. *Һич югы Гыйрфан мулланың үзенә атап хат язсыннар.* С.Поварисов

4) Исемен әйтеп, күрсәтеп. *Атап әйтүле тагын бер кешегә рәхмәте бар әле аның.* Б.Камалов. *Аны Дәфгый дип атап йөртәләр.* Татар халык иҗаты

5) Анык, төгәл, алдан билгеле. *Элеонора апайның атап кына барыр җире дә юк икән.* А.Хәсәнов

**Атап бетерү** Атауны тәмамлау; барысын да атау

**Атап йөртү** Һәрвакыт, даими атау. *Татар, гомер бакый, сабак алучы җан иясен «шәкерт» дип атап йөртте.* Ф.Сафин

**Атап кую** 1) Кинәт атау; алдан ук атау

2) Билгеле бер максаттан чыгып, алдан ук билгеләп кую, шуның өчен дип багышлап саклау. *Гөлбану моңа [кияүгә чыгарга] әзерләнеп килә иде. Яшерен акча җыйнады. Үзенең иң яхшы бер сөлгесен аерып атап куйды.* Г.Ибраһимов

**Атап тору** Әле берсен, әле икенчесен бер-бер артлы атау

**Атап узу** Сүз арасында, башкалар белән беррәттән атау

**Атап чыгу** Барысын да атау, берсен дә калдырмый, башыннан ахырына кадәр берсе артыннан берсен атау

**АТА́У** II *и. сөйл. к.* **утрау**. *Бер минутта барып чыктың Мадагаскар атавына, икенче минутта менеп бастың Һималай тауларына!* Ш.Маннур. *Шәмси көннең һәйбәтлегенә кызыгып, җәйге пальтодан атауларга китте вә анда кызуланып йөри-йөри тирләсә дә, диңгезгә кояш батканны көймә өстендә күрер өчен, көймә берлән суга керде.* Г.Исхакый

**АТА́У ҖӨМЛӘ** *и. грам.* Бер составлы исем җөмлә (баш кисәге төп килештәге исем яки сүз тезмәсе белән белдерелә); номинатив сөйләмнең бер төре. *Әйберләрнең, билгеләрнең яки төрле күренешләрнең исемнәрен атау юлы белән, аларның булу-булмауларын хәбәр итә торган җөмләләр «атау җөмләләр» дип атала.* М.Зәкиев

**АТА́У КИЛЕШЕ** *и. иск. лингв. к.* **баш килеш**

**АТАУЛЫ** *с.* 1) Исем бирелгән, исемле. *Бу Федоров Андрей атаулы төлкенең, елмайган булып, кирәксә-кирәкмәсә дә хан балаларына уенчыклар, бикәчләргә күлмәклекләр бүләк иткән булып, астан эш йөрткәнен хан сизә, яхшы белә иде.* Р.Батулла

2) Кемгәдер билгеләнгән, билгеләп куелган, кемгәдер исемләнгән, аталган, хасланган. *Олуг кенәз белән олугхан атаулы имзаларын салган солых битеген күрде дә ханбикә Зөбәрҗәт ире күкрәгенә капланып елап җибәрде.* М.Хәбибуллин

3) *сөйл.* Кая да булса махсус билгеләп, атап чакырылган

**АТА́ ЯГЫ** *и.* Ата ягыннан туганнар, ата кардәшләре

**АТБАГАР** *и.* Ат караучы. *Иярлиләр чабышны атбагарлар, Ишекчеләр тора – олпат агайлар.* Котб

**А́Т БАЗАРЫ** *и.* 1) Атлар белән сату-алу итү урыны, махсус базар. *Ат базарыннан берәр Сембер тае алырга ниятләп торам.* Г.Гыйзэт

2) *күч.* Шау-шулы, тавышлы урын. *Тукта, дим, ат базары ясама син безнең утырышны.* К.Тинчурин

**АТ БАРЫШНИГЫ** *и. иск.* Атлар белән сату итүче, ат алу-сату белән шөгыльләнүче кеше, маклер. *Янә бер ат барышнигы – Мөхәммәтша исемле мишәр кушылып, шәкертләрне урысча сүкте.* Ш.Мөхәммәдев

**А́Т БАШЫ** *и.* 1) Тарантаста кучер урыны. *Ә мин, кучер булып, ат башына [утырдым].* Р.Ишморат

2) Атны йөртүче кеше. – *Була ул, – диде Чуртан, – ат башында йөрергә малае да үсеп килә бугай.* Ш.Камал

**А́Т ВРАЧЫ** *и. к.* **ат докторы.** *Халыкта «ветеринар» дигән сүз юк, «ат врачы» дигән сүз генә бар.* М.Мәһдиев

**А́Т ДОКТОРЫ** *и.* Атларны дәвалау буенча белгеч, ветеринар, байтар. *Ат докторы кендекне берничә кат ябыштыргыч тасма белән беркетеп куйды.* З.Хөснияр

**АТЕИЗМ** *и. фр.* Аллага, дингә ышанмаучылык, Алланы динне инкяр иткән караш, алласызлык. *Ул гомере буе университетта фәнни коммунизм һәм атеизм укыткан.* З.Хөснияр. *Ул үз эченә динне, ислам мәдәниятен, атеизмны да ала.* Мирас

**АТЕИСТ** *и. фр.* Алласыз, динсез, дәһри, Аллага ышанмаучы, атеизм тарафдары. *Көчсезлек минутларында мин атеист булып үсүемә үкенәм.* М.Юныс

**АТЕЙСТИК** *с.* Аллаһны инкяр иткән, дингә каршы булган, атеизм юнәлешендәге. *Атеистик әдәбиятта кайчагында «мәхәлләдәшләр» дигән сүз очрый.* Казан утлары

**АТЕИСТЛЫК** *и. к.* **атеизм.** *Ә башыңа төшкәч, башмакчы буласың. Кочагыңда нибары ике-өч атналык*

*тансыгың ыңгырашканда, атеистлык онытыла, егетләр.* А.Хәсәнов

**АТЕЙСТ-ПРОПАГАНДИСТ** *и. рус* Халык массалары арасында дингә каршы пропаганда алып баручы кеше

**АТЕЛЬЕ** *и. фр.* 1) Сынчы, фотограф яки рәссамның остаханәсе; киностудия павильоны

2) Өс яки аяк киемнәре тегә, төзәтә торган остаханә. *Ательега тегәргә биргән күлмәгемне Әхәт белән Иделгә чыкканчы өлгертәсе иде, дип уйланды ул.* З.Фәйзи. *Көнкүреш хезмәте күрсәтү ательесы*

**АТЕРОСКЛЕРОЗ** *и. гр. мед.* Кан тамырлары эченә холестерин утырудан барлыкка килгән йөрәк һәм кан тамырлары системасы авыруы. *Атеросклероз – кан тамырлары авыруы, матдәләр алмашы, аерым алганда майлар алмашы бозылудан килеп чыга ---.* Татар халык ашлары

**А́Т ЗАВОДЫ** *и.* Нәсел атларын үрчетү белән шөгыльләнә торган хуҗалык. *Гөлчәчәк бәхетенә, урман буенда иң яхшы юртаклардан гына торган ат заводы да ачылган иде.* З.Хөснияр

**А́ТКАЗАНУ** *ф.* **1.** Дан казану, данхөрмәт яулау, данга ирешү

**2. атказанган** *с. мәгь.* 1) Зур хезмәт күрсәткән, хезмәте белән данланган, хөрмәткә лаек. *Атказанган колхозчылар галереясы эшләтте.* Х.Хәйруллин. *Сәхабетдин абзыйның бик тә хәтере калган телефондагы атказанган туташның нахак сүзенә.* Т.Нәҗмиев

2) Төрле өлкәләрдә яхшы, алдынгы хезмәт күрсәткән өчен, дәүләт тарафыннан бирелә торган мактаулы исем составында кулланыла. *Америка турында күп сөйли торгач, аның инде үзен дә «Американың атказанган артисты» дип йөртә башлаганнар.* Ватаным Татарстан. *Икътисади эшчәнлек өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен, --- Чирмешән муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе Гатин Шәүкәт Фатыйх улына «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирелде.* Ватаным Татарстан

**А́Т КАРАГЫ** *и.* 1) Кәсебе ат урлап сату булган кеше. *Киткәндә, ул ат карагы белән исәпне бетереп китәргә кирәк.* К.Тинчурин

2) Бик оста ялганчы, хәйләкәр кеше

3) *диал.* «Ат урлап» уйнау белән характерлана торган уен. *Авылларның урамнарындагы яшел чирәмнәрендә бер туктамаенча ат-ат, куян куышы, ат карагы уеннарымы уйный торган балалар --- бу манзараны тагы матурлата, аңар тагы күбрәк мәгънә бирә иде.* Г.Исхакый

**АТКАРУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса тиз һәм файда белән сатып җибәрү. *Утми торган итеңне шул арада аткарып биргәнгә рәхмәт әйт!* З.Фәйзи // Кемгә дә булса артык яки кирәкмәс нәрсәне биреп җибәрү, биреп котылу

2) *сөйл.* Нинди дә булса эшне тиешле дәрәҗәгә җиткерү, үтәү, эшләү, башкару. *Ләкин безнең илдә гаиләне коры ижат белән генә тәэмин итеп булмый. Шул сәбәпле, саф иҗатка кагылмаган эшләр аткарып, төрлечә сибелгәләргә дә туры килде.* Ф.Фәтхи. *Бай абый, Нух – мәчеттә, ахшам намазын аткара*... Р.Камал

3) *диал.* Ташлау, ыргыту. *Фатихын ул үлеп сагынганда, Алып, аның фронт хатларын, Җылый-җылый укый торган булган, Бар эшләрен читкә аткарып.* Р.Харис // Кая да булса олактыру, урнаштыру, җибәрү, озату. *Аның начальнигы бик тәвәккәл кеше иде, хәлне шундук аңлады, газетаны авылларга таңнан аткару, Болынкырның үзендә дә иртүк тарату хәстәрен күрергә сүз бирде.* Ф.Садриев

**Аткарып бетерү** Барысын да аткару, аткаруны тәмамлау. *--- әле күп авыллар кулакларны җыеп бетерә алмый иза чигә, кулагын җыйсалар, муллалары кала, аларын да аткарып бетерсәләр – гаиләләрен сөрә алмый интегәләр.* Ф.Сафин

**Аткарып кую** Алдан ук аткару

**Аткарып ташлау** Тиз арада, һич көтмәгәндә, уйламаганда аткару. *Акбабай алар өчен ихлас күңелдән шатланды, Кызыл Хакимгә дә күңеленнән рәхмәт яудырды, ул, үзенең бер чыгышы белән, Акбабай айлар буе уйлаган эшне аткарып ташлады.* М.Кәбиров

**Аткарып тору** Әледән-әле, булган берсен, бер-бер артлы аткару

**Аткарып чыгу** Барысын да аткару, башыннан ахыргача аткару

**Аткарып яту** Даими рәвештә, берсе артыннан икенчесен аткару. *Затондагы бөтен әйбәт частьларны иллешәр, йөзәр тәңкәгә аткарып яткан.* Г.Мөхәммәтшин

**А́Т КӘМИТЕ** *и. иск.* Цирк. *Хәсәнша, --- ат кәмитенә барам, диеп чыгып киткән иде.* Ш.Мөхәммәдев

**А́Т КОРМАСЫ** *и.* Ат өстенә каплый торган махсус япма. *Гайнулла ямщикның ат кормасы Чамбар болынында талларда.* Бәет

**А́Т КӨЧЕ** *и.* 1) Атның тарту көченә тигез булган үлчәү берәмлеге, егәрлек. *Гадәттә, төрле машиналарның эшләү егәрлеген ат көче белән үлчиләр.* Физика

2) Авыл хуҗалыгында: «атлар» мәгънәсендә. *Оланнар, орлык ташырга ат көче җитешми, чәчү сузыла; чәчү сузылган саен, туфракта дым кими.* Г.Бәширов

**А́Т КУЗГАЛАГЫ** *и.* Карабодайчалар семьялыгыннан, зур озынча яфраклы һәм себеркәч чәчәкле, орлыгы карабодайныкына охшаган үлән үсемлек. *Сестра, урыныннан кузгалмый гына, сузылып, башка үләннәрдән зур булып, аерылып үсеп торган ат кузгалагын сындырып алды һәм шуның белән чебеннәрне куарга тотынды.* А.Шамов

**АТКЫ** *и.* 1) Кузна, ашык, бура уеннарында кузна яки шакмакларга төбәп ыргыта торган таяк; шәмәй. *Аткы, томырылып, тезелгән ашыкларның нәкъ буена туры килә.* Ә.Фәйзи. *--- үз аткыңның коры җир өстенә «дөп» итеп сугылу тавышыннан тыш берни ишетелми.* Ә.Фәйзи

2) Ату өчен балалар уенчыгы; рогатка

**АТКЫЙ** *и. сөйл.* 1) *к.* **ат кузгалагы; атлык** II. *[Гаязның] Әтисе белән әнисе, колхоз болынына печән җыярга киткәндә, табыкларга аткый белән көрпә болгатып бирергә кушып калдырдылар.* Г.Галиев

2) Зур шәмәй, аткы

**АТКЫЧ** I *с.* Ата торган. *Һич көтелмәгәндә, күпер астыннан кинәт*

*күтәрелеп чыккан төсле, тиз аткыч ике пушка, туры бәрдереп, бульвардагы юнкерларга юл ачты.* К.Нәҗми

**АТКЫЧ** II *и. к.* **аткы** (*2 мәгъ.*). *Тәүфыйк, урта һәм имән бармагына резина тагып, аткыч ясады.* М.Юныс

**АТЛАВЫЧ** *и.* Гөбе пешкәге. *Савытына күрә каплавычы, маена күрә атлавычы.* Мәкаль

**АТЛАГЫЧ** *и. к.* **атлавыч**. – *Маема кашык та тидермәм, – дип көлеп куйды Газинур һәм, учларын бер-берсенә ышкып, атлагычка тотынды.* Г.Әпсәләмов

**АТЛАМ** I *и.* 1) *сөйл.* Адым. *Беренче атламнар бер ел сыман озын тоелды Кәбиргә.* А.Хәлим

2) Тегү машинасы энәсенең адымы, материя өстендә бер атлаткан ара. *[Тегелә торган] Детальләрнең бер-берсе белән тоташу урыннарына билгеләр куела, ягъни бер-берсенә капма-каршы 2–3 атлам атлатыла.* Йорт эшләре

**АТЛАМ** II *с.* Гөбедә бер атлауда алынган (май турында)

**АТЛАМА** I *и.* 1) Ишек һәм капка кебек әйберләрдә аша (аркылы) салып кагыла торган тимер беркеткеч

2) Бәпкә, кайчы

**АТЛАМА** II *и.* Сарафан, итәк кебек киемнәрне тотып тору өчен, җилкә аша үткәрелгән тасма. *Атламаларны тукыманың буй җебе буйлап кисәләр.* Йорт эшләре

**АТЛАНДЫРУ** *ф.* **1**. 1) Ат (дөя, ишәк һ.б.) аркасына, өстенә утырту, атланырга ярдәм итү. *Үзе янына мине дә [атка] атландыра торган иде.* Ә.Гаффар

2) Үз өстенә менгереп утырту, җилкәсенә, аркасына күтәрү. *Теге бик шәп йөгерә торган батыр, кызны үзенә атландырып, бик тиз генә илтеп куя.* Әкият. *Хәсән Гайшәне җилкәсенә атландырды.* М.Юныс. *Җилкәмдә генә атландырып йөртермен үзеңне, зинһар, үтермә генә.* Аманулла

3) Аякларны берсе өстенә икенчесен салып утыру. *Бәһрам абзыйның өстәле янына да бик эре кыяфәт белән узды, тезен тезгә атландырып, бүреген салып, тезе өстенә чәпәп куйды.* М.Хәсәнов

**2**. **атландырып** *рәв. мәгъ.* Берсе өстенә икенчесен аркылы китереп, чалыштырып. *Кабыкны өй кыегына, атландырып, берничә кат тезеп чыгалар да очларын озын киртәләр белән бастырып куялар.* Г.Рәхим. *Мин --- [иске фанер чемоданны] дүрт ягыннан нечкә сүс бау белән атландырып бәйләгәч, икеләнеп-нитеп тормыйча, авылдан Бөгелмәгә чыгып киттем.* Ф.Садриев. *Айрат Бәдретдинович белән Галим абзый, аякларын чана кырына атландырып, төшәргә омтылганнар иде дә тик, Рәфиснең урыныннан кузгалмавын күреп, кире уйладылар.* А.Вергазов

**Атландырып йөрү** Һаман, һәрвакыт атландырган булу. *Бүре башың белән сарык бәрәнен атландырып йөр инде...* Т.Миңнуллин

**Атландырып карау** Атландырырга омтылу. *Әти мине өч атналык чагымда ук атка атландырып караган.* К.Миңлебаев

**Атландырып килү** Әллә кайдан ук, әллә кайчаннан алып хәзергә кадәр атландыру

**Атландырып кую** Атландырган хәлгә китереп калдыру; кинәт атландыру. *Хәзер үзен ташбакага атландырып куйыйм әле.* Л.Лерон. *Минһаҗ абзый кесәсеннән сапсыз күзлек алып, борынына атландырып куйды.* Т.Миңнуллин

**Атландырып тору** Әле, хәзерге вакытта атландыру

**Атландырып чыгу** Барысын да берәм-берәм атландыру, атландырып бетерү

**АТЛАНМАЙ** *и.* Ак май, атлап ясаган май. *[Мәрьям] Улына дип, юлга атланмай яккан икмәк төрде.* М.Рафиков. *Шәмгун карт, кечкенә таш табакка салган атланмайны китереп, аның өстендәге кәгазьне ачты.* А.Шамов

**АТЛАНУ** *ф.* Берәр нәрсәнең өстенә менеп, аякларны ике якка салындырып утыру. *Мәккәлеләр атларына атландылар.* Ф.Яхин. *Балыкларны юып салгач, Одик, мотоциклына атланып, авылга Әдиләне алырга элдертте.* Р.Сибат. *Башта аяк терәп каршы торсам да, хур кызлары, затлы исерткеч эчемлекләр белән вәсвәсәли башлагач, үзем дә сизмәстән, муенына менеп атландым.* З.Мәхмүди

◊ **Атланып талау** Бик нык талау; оятсыз рәвештә талау. *Авылның старосталары һәм аның тирәсендә йөрүче куштаннар юаш, фәкыйрь халыкны атланып талыйлар.* Ш.Әхмәдиев

**Атланып бетү** Тәмам атлану

**Атланып тору** Әле, хәзер атланган хәлдә булу

**АТЛА́С** *и. гар.* **1**. 1) Уң ягы шома, ялтыравыклы булган ефәк тукыма. *Ак атласым җитмәде, Алмаз кайчым үтмәде.* Җыр. *Асыл киемнәргә өртелеп, атлас ефәкләргә төренгән.* М.Гафури

2) Ефәк җепнең бер төре. *Атлас белән кайый ул якасын, Ука белән тота җиң очын.* М.Җәлил

**2**. *с. мәгъ.* 1) Шундый тукымадан булган, шуннан тегелгән. *Шул чакта Равил белән миңа, бүләк итеп, ялтырап торган атлас тукыма да алып кайткан иде.* В.Нуруллин. *Асыл киемнәргә өретелеп, Атлас ефәкләргә төренгән.* М.Гали

2) Шундый җептән эшләнгән. *Балдак булсын, алтын булсын, Атлас бавы ал булсын.* Җыр

**А́ТЛАС** *и. гр.* 1) Географик карталар җыентыгы

2) Төрле мәгълүматларның картага төшерелгән җыентыгы

**АТЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **атлау** I (*1 мәгъ.*). *Богау салды дошман куллрыма һәм хурлыклы юлдан атлатты.* М.Җәлил

2) Аркылы салып кагу, беркеткеч белән уратып ныгыту. *Дегете тамып торырлык итеп майланган, таза тимер кыршаулар белән атлатылган тәгәрмәчләр.* Ж.Рәхимов

**АТЛА́У** I *ф.* **1.** 1) Аякларны әле – берсен, әле икенчесен күчереп адымнар ясау, адымлап хәрәкәт итү. *Кара, нинди матур кыз, пөхтә киенгән дә нинди матур атлап бара.* Г.Исхакый. *Ишетеп белүемчә, комиссар Вахитовның хәрбиләрчә аяк атлавын Мәскәү Кремле сакчылары ике борылыштан таныган, диләр.* Ә.Гаффар. *Юлга бик нык салган, атлар әкрен атлыйлар, яшь кар өстеннән чана табаннары үкереп шаулап бара.* Ф.Хөсни. *Илсөяр калтыранып куйды, гәүдәсе авыраеп китте, ул алга атларга теләде, ләкин кузгала алмады.* Г.Гобәй

2) Нәрсәне дә булса аркылы үтү, аша үтү. *Ни эшләгәнемне белмәдем, ашъяулыклар, табаклы бәрәңгеләр өстеннән атлап, йортка чыктым*. Г.Ибраһимов. *Бүген исә бусаганы аеруча дулкынланып атлады.* М.Маликова

3) Билгеле бер тарафка, кая да булса аяк басу, килеп чыгу. *Битләремне сөртә-сөртә залга атлавым булды, кухня ягыннан Галимҗан тавышы килде!* Ф.Баттал

4) Бару, китү, юнәлү. *Ярга төшкән ике ир авыл ягына атладылар*. Р.Сибат. *Без дә алар артыннан ашыкмый гына атлый торабыз.* Н.Дәүли

5) *күч.* Аерым бер юнәлештә алга бару, үсү. *Әгәр бәндәләр, «әйбер» дигән гыйфриттән котылып, яңа цивилизациягә таба атласалар, кеше затының «әйбер» дип гомерен юкка яндырган эпохаларны тетрәнеп искә алачаклар*. Ф.Садриев

6) *күч.* Күчү, керү. *Берсе – картлыкка кереп баручы ир, икенчесе исә карчыклык ишеген атлап узган хатын иде болар*. К.Йосыпов. *Тиздән кыштан язга атларбыз*

**2**. *и. мәгъ.* Йөреш, хәрәкәт. *Югары очтан берәү килә, Хафизәләм-иркәм атлавы*. Җыр

◊ **Атлаган саен** Бик күп, еш очрый торган

**Атлап керү** 1) Кайтып җитү, килү, күренү. *Бусагасын атлап кергәч кенә белдең ич син дәү апаңның исәнлеген.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Яңа бер чорны, дәверне башлап җибәрү

**Атлый бирү** Атлауны дәвам итү. *Рабига, башын түбән иеп, тын гына атлый бирде.* Ф.Сафин

**АТЛА́У** II *ф. диал.* **1.** Сыек яки бөртекле нәрсәләрне (гадәттә берәр нәрсә катнаштырып) болгату; туглау. *Сумса камыры катырак кеби булганга, аңар иртәгге сөтнең имчәк төбене кушып атлады*. Г.Исхакый. *Мәрфуга абыстай үзе казан асты. Яшь тәкәнең тутырмасыны, каймак, дөге, бавыр атлап, үзе тутырды*. Г.Исхакый

**2. атлаган** *с. мәгъ.* Шундый юл белән әзерләнгән. *Өстәл өсте булкилар, --- сырлар, консервалар, атлаган майлар, сөтле конфетлар, шоколадлар, савытлы конфетлар, кәрәзле баллар белән тула*. Ф.Әмирхан

**АТЛЕТ** *и. гр.* **1**. 1) Цирк артисты, профессиональ көрәшче

2) Атлетика белән шөгыльләнүче спортчы. --- *бу юлы да аңа штанга күперчегенә чыккан авыр атлетлар арасында тиңнәр булмый*. А.Гафиятов

3) *күч. сөйл.* Таза гәүдәле, физик яктан бик көчле кеше. *Геркулес кебек, атлет егет ул.* Х.Туфан

**2.** *с. мәгъ.* Таза, нык бәдәнле, көчле. *Ул үзенең атлет гәүдәсенә Килешеп торган гади киемне Кагыштырды, перчаткасын салды, Папиросын алды*. Х.Туфан. *Заһидулла атлет гәүдәсен ләүкәгә салды, Мәкчим аны котырып чаба башлады.* Р.Сибат

**АТЛЕ́ТИК** *с.* 1) Егәрлек, көч, чыдамлык тәрбияли торган (физик күнегүләр системасы). *Атлетик күнегүләр*

2) Атлетларга хас булган, атлетларныкына охшаган. *Атлетик гәүдә*

**АТЛЕ́ТИКА** *и. гр.* Организмда егәрлек, көч, чыдамлык тәрбияли торган физик күнегүләр системасы. *Гали, солдатта чакта, үзе дә авыр атлетика белән шөгыльләнгән иде.* Г.Мөхәммәтшин. *Армиядә хезмәт иткәндә, җыелма команда составында, волейбол, җиңел атлетика, көрәш буенча хәрби частьларының данын яклый.* Н.Максимов. *Фирдәвис Шәемов бүләкләренә зур җиңел атлетика кроссы узды.* Сабантуй

**АТЛЫ** I *с.* **1.** 1) Ат тоткан, ат асраган. *«Табигать балалары»нда төп каһарман – өч атлы, ике сыерлы, ун баш сарыклы, ару көн итә торган Хафиз*. Г.Нигъмәти

2) Ат менгән, атка атланган. *Барып җитәр алдыннан, алар теге яктан чыгып килүче атлы яугирләрне күрделәр*. Т.Нәбиуллин

3) Ат җигелгән. *Атлы чаналар, берәм-берәм кереп, сыйганнары – бөркәүле лапас эченә, сыймаганнары ачык ишегалдына гына тезеләләр*. М.Гали

4) Ат җигеп эшли торган. *Яшүсмер чагыңда атлы эштә йөргәнсең*. Э.Шәрифуллина

5) Ат көче ярдәмендә эшләнә, башкарыла торган. *Өч ташлы әнә шул тегермәне, ике атлы яргычы, өч сугу станы, бер йон тетү машинасы бар иде.* Т.Гыйззәт. *Бер елны Сәхәп картка атлы молотилка белән [ашлык суктык].* С.Рафиков

6) *күч.* Сыешмыйча, бәрелеп-сугылып, юлындагы әйберләрне бәреп егып, бәреп төшереп, каударланып йөри торган. *Шунлыктан ул үзеннән бер кеше аркылы яткан кызылармеецка ачуланып: – Атлы... – дип кычкырырга өлгермәде.* Ш.Усманов

**2.** *и. мәгъ.* Җигүле атка утырган яисә ат менгән кеше, җайдак. *Полк командиры шундый маневр ясады – дошман атлылары кинәт ярым алка эчендә калдылар.* А.Шамов. *Сагышлы, шәфкатьсез җилләргә йөз куеп, Бер төркем атлылар үр менә*. Ф.Гыйззәтуллина

◊ **Атлы килеп, җәяү кайту** Күп чыгым тотып, буш кул белән кайту, бернәрсәсез, бернигә дә ирешмичә, буш кайту. **Атлы уйнау** *к.* **ат-ат уйнау**. *Малайлар белән атлы уйнаган булып, урманга алып барсыннар.* Г.Гобәй

**АТЛЫ** II *с. сөйл.* **1.** 1) Исемле, кем яисә нәрсә дип исемләнгән. *Ибраһим атлы булам мин.* Р.Вәлиев. *Асафлар подъездында беренче катта яшәүче Ибраһим атлы балта остасы шундый гади кешеләрнең берсе иде.* Р.Батулла

2) ... дип атала торган, дигән. *Туган телем минем – тиңсез диңгез, Аргы яры – Ходай катында. Мәдәт бир син, маяклары аның Татар атлы дәрьял халкымда.* М.Галиев. *Иделнең таулыташлы, урманлы биек ярлары эчендә, «Байрак» белән «Хезмәт» арасында, Яманкул атлы озын, тирән чокыр бар.* Г.Ибраһимов

**2.** *бәйл. функ. сөйл.* Нинди дә булса эш-хәлгә, сыйфатка, үзлеккә, рәвешкә охшатып башкару, мәгънәсендә; кебек, шикелле, сыман. *Район каршында яхшы атлы булырга тели, мине начар итеп күрсәтмәкче була.* И.Гази. *Иптәшләрем йоклый. Дөресрәге, йоклаган атлы булып яталар.* М.Әмирханов

**АТЛЫ́ АРМИЯ** *и. к.* **атлы гаскәр**. *Семён Будённый һәм Ока Городовиков командалык иткән 1 нче һәм 2 нче Атлы армия, Юшунь ныгытмаларын пехота ачкан урыннардан үтеп, тук-*

*тамас ташкын булып, Кырымга бәреп керәләр*. З.Зәйнуллин. *Безнең атлы армиябез, дошманны эзәрлекләп, урманнарны, далаларны, ком сахраларын кичте*. Г.Бәширов

**АТЛЫ́-АТСЫЗ** *с.* Төрле дәрәҗәдәге һәм матди хәлдәге. *Алар, бөтен авыл берләшеп, бер сүздә булып, тирә-юнь авыллардан җыелган атлы-атсыз кунакларга, капкаларын, түрләрен генә түгел, күңелләрен дә ачып җибәрәләр*. А.Гыйләҗев

**АТЛЫ́ ГАСКӘР** *и. тар.* Кавалерия. *Советларның атлы гаскәреннән Азмы дошман куркып тетрәде*. М.Гафури

**АТЛЫГУ** *ф.* **1.** 1) Нинди дә булса эш башкарырга, кая булса да барырга ярсу, дәртләнү, ашкыну. *Тик бик яхшы белегез: авылга атлыгу – миндә бер идеал*. М.Фәйзи. *Туган якларына атлыгып кайткан Галимҗан түшәккә егылды.* С.Поварисов

2) Ташлану, һөҗүм итү. *Аның шулай икеләнеп торуын куркуы дип белдеме, качарга ният итүе дипме, нәфрәтен басарга ярсып атлыккан дәү тәкә аңар җан-фәрман китереп төртте*. Р.Мөхәммәдиев

3) Ыргылу, томырылып чабу. *Атын ул камчылап, Атлыга тагын караңгы, Тын урамнарга табан*. Һ.Такташ

**2. атлыгып** *рәв. мәгъ.* 1) Сабырсызлык күрсәтеп, түземсезләнеп. *Шофёр кайтырга атлыгып көтеп тора иде*. Х.Камалов. *Атлар, бәйге якынлашкан саен, атлыгып тыпырдашалар*

2) Бик ашыгып, кабаланып. *Муса, поляк партизаннары белән килешкәннән соң, бик атлыгып, Едлинога кайтты*. Ш.Маннур. *Малай атлыгып килеп тә керде, юрган астына чумды да*. М.Мәһдиев

**Атлыгып алу** Берникадәр вакыт атлыгу, озакка сузылмаган вакыт аралыгында атлыгу

**Атлыгып йөрү** Хәзер, әле, күз алдында атлыгу; ашыгуы, дәртләнүе бөтен кешегә дә аңлашылып тору. *Мин ул чакта – дөньяны кузгатырлык эш майтарам, дип атлыгып йөргән беркатлы исәр кеше*. А.Гыйләҗев

**Атлыгып китү** Кинәт атлыга башлау

**Атлыгып кую** Кыска вакытка, азга гына атлыгу

**Атлыгып тору** 1) Һәрвакыт, гел атлыгу. *Вакыт узган саен, аның уйлары ныграк чуала, моңа кадәр һәр каникулда кайтырга атлыгып торган, һәр җәйдә аны чәчәкле болыннары, җиләкле аланнары белән каршы алган авылы күзгә күренеп ерагая, читләшә бара иде*. Р.Вәлиев. *Шамил --- тау кәҗәсе шикелле атлыгып тора.* Г.Әпсәләмов. *[Без] Алдыбызга алган эшебезне чиксез дәрт белән башкарып чыгарга атлыгып тора идек*. М.Әмир

2) *юкл. форм.* Бик үк теләмәү; бөтенләй дә теләмәү, теләге булмау. *[Заһит] Алай бик атлыгып тормаса да, авылдагы бөтен җан иясе катнаша, дигәч, каршы килмәде*. М.Әмирханов

**АТЛЫК** I *с.* 1) Бер ат сатып алырлык, бер ат сатып алырга җитәрлек. *Бөтен ният: көн-төн эшли-эшли, Атлык акча җыю кирәк.* Ш.Маннур

2) Бер атлык, бер атка җитәрлек (мәс., *азык*)

**АТЛЫК** II *и. сөйл. бот.* 1) *к.* **ат кузгалагы**

2) Ат кузгалагының чәчәкләре кипкәннән соң хасил була торган орлыгы. *Бәләкәй чакларымда җимешкә дә йөрмәдем, йорт кошлары өчен атлык та җыймадым.* Г.Галиев

**АТЛЫКСА** *и. диал.* Ат араны

**АТЛЫ́-САНЛЫ** *с. к.* **атлы-тунлы**

**АТЛЫ́-ТУНЛЫ** *с.* Хәлле, урта хәлле. *Атлы-тунлы дөнья тоткасы кешеләр өчен ишек яңагы ни дә, Шәмсетдин ни – икесе дә бер иде.* Г.Бәширов

**АТМЕНӘР** *и. сир.* Атка атланган кеше, җайдак. *Кырыкка якын кораллanган атменәр ияртеп, хан баскак «Йөрәклеләр иле»нә килеп җитте.* Әкият

**АТМОСФЕ́РА** *и. гр.* 1) Җир шарын һәм кайбер башка планеталарны чолгап алган газсыман тышча. *Алар, әлбәттә инде, --- К.Я. Кондратьевның зур галим, атмосфера һәм аның состав өлешләренең Җир климатына тәэсирен өйрәнү өлкәсендә зур хезмәтләрнең авторы икәнен беләләр*. Ф.Углов. *[Фохис:] Бу планета җиргә караганда якынча өч тапкыр зуррак. Монда да атмосфера һәм яшеллек бар.* Р.Мөхәммәдиев

2) *сөйл.* Һава, һава торышы. *Атмосфераны атналык күзәтү нәтиҗәләре*

3) *физ.* Газсыман җисемнәрнең басымнарын үлчәү берәмлеге. *Әллә шул ярдәм итте, көчәнә торгач, пар басымын тиешле атмосферага күтәрдем.* М.Юныс

4) *күч.* Чолганыш, мохит, шартлар. *Ә чынлап әйткәндә, әдәби атмосфераның тәэсире булмый калмады.* С.Сөләйманова

**АТНА** *и.* 1) Бер дүшәмбедән алып икенче дүшәмбегә кадәр исәпләнә торган, җиде тәүлеккә тигез булган вакыт аралыгы (беренче тапкыр Борынгы Көнчыгышта кертелә; 7 көн ул вакытта билгеле булган 7 планета белән тиңләштерелә). *Атна ахырында әни май яза*. Ә.Салах. *Борынгы мәҗүсиләрдә атнаның өченче көнендә корбан чалу йоласы була, һәм шушы йола керәшеннәрдә көн исеме буларак сакланып калган.* Мирас

2) Нинди дә булса бер көннән алып исәпләгәндә 7 тәүлеккә тигез булган вакыт үлчәү берәмлеге. *Бу югалу, бара торгач, атналарга, ун көннәргә сузылып, ахырдан ул бөтенләй гаип булды*. Г.Ибраһимов. *Өстәлдә, инде атна буе, юылмаган тәлинкәләр өелеп ята.* Р.Вәлиев

3) *к.* **атналык** (*1 мәгъ.*). *Бер атнага чамалап алган сохари, галет һәм консервалар запасы ашалып бетте*. Ә.Маликов

**АТНА́КИЧ** *и. диал.* Атнаның дүртенче көне; пәнҗешәмбе. *Ул һәр атнакич ком берлән, сап-сары итеп, самавырны ача, айда бер өйнең ярыкларыны ямар өчен сылаган балчык өстеннән акбур белән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына җылы су сала иде.* Г.Исхакый

**АТНА́КӨН** *и. диал.* Атнаның бишенче көне; җомга

**АТНАЛАП** *рәв.* Бер яки берничә атна дәвамында; атналар белән исәпләп. *Әнисе белән әбисе авылда өч атналап кына тордылар да кырык беренченең август башында ук Казанга күчеп киттеләр*. М.Хуҗин

**АТНАЛЫК** *с.* **1.** 1) Бер атнага җитәрлек, бер атнага билгеләнгән. *Атналык акча*

2) Бер атна дәвам итә торган, бер атнага сузылган. *Мәнә яз көне тимер юлның мастерскоенда, металл җитешмәү сәбәпле, слесарьларның бер өлешенә үз хисапларына бер атналык отпуск тәкъдим иттеләр.* Ш.Камал

3) Атна эчендә булган, атна дәвамында эшләнгән, алынган. *Минем атналык доходым – бер сум.* М.Гафури

4) Атна саен чыга торган, атнага бер чыга торган. *Казан университеты профессоры Запольский урыс һәм татар телләрендә атналык газета чыгару мәсьәләсен күтәрә.* Р.Батулла

5) Атна буена шунда яшәп укый торган (*мәктәп, интернат*). *Рәхимнең күңеленә, балаларны интернатка – атналык мәктәпкә урнаштырырга кирәк, дигән уй килде.* А.Расих

**2.** *и. мәгъ.* Нинди дә булса эшкә, вакыйгага багышланган җиде тәүлек арасы. *Татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгыннан соң, мари дуслар үзләренең шундый ук атналыкларын Татарстанга килеп үткәрделәр.* З.Нури

**АТНА́-УН КӨН** *и.* Чама белән 7–8, 8–9 көн, якынча, атнадан үткән, ун көнгә җитмәгән вакыт арасы. *Әткәсенең кырыгын үткәреп атна-ун көн вакыт үткәч, авылга кайткан иде.* Ф.Сафин. *Безнең әниләр үзләре салган ипиләрне тастымалга төреп, шүрлекләргә тезеп, атна-ун көн саклыйлар иде.* Ватаным Татарстан

**АТОЛЛ** *и. мальдив.* Боҗра рәвешендәге коралл утравы. *Атоллны, боҗралап, рифлар урап алган.* М.Юныс

**А́ТОМ** *и. гр.* Химик элементның төш һәм электроннардан торган, аның төп сыйфатларын саклаган иң кечкенә кисәге. *Эйнштейн, атом бомбасы шартлау хәбәрен ишеткәнчегә кадәр, атомның таркалуына ышанмаган.* Казан утлары

**АТОМИЗМ** *и. гр. филос.* Левкипп һәм Демокрит тарафыннан нигезләнгән, материя аерым кисәкчәләрдән – бүленмәс һәм үзгәрмәс мәңгелек атомнардан тора, дип исбатлаган, XIX гасыр ахырына кадәр яшәп килгән материалистик караш

**А́ТОМЛАШТЫРУ** *ф.* Атом энергиясеннән файдалану, атом энергиясе белән эшләтүгә кору

**Атомлаштыра бару** Акрынлап, атом энергиясе көченә күчә бару; аз-азлап, барын да атомлаштыру

**Атомлаштырып бетерү** Барын да атомлаштыру; ахырга кадәр атомлаштыру

**Атомлаштырып килү** Эзлекле рәвештә, аз-азлап атомлаштыру

**А́ТОМЛЫ** *с.* 1) Атом бомбалары булган (*ил*)

2) Атом көче белән, атом ярдәмендә эшли торган

**АТОМОХОД** *и. рус* Төп ягулыгы атом булган корабларның уртак атамасы. *Атомоходлар сәүдә, балык тоту, пассажир корабларына бозлар арасыннан юл салып баралар. Авыр бозларны вата-вата, Төньяк полюска барып җиттәләр.* Кем ул? Нәрсә ул?

**А́ТОМ-ТӨШ** *с.* Атом төшенә мөнәсәбәтле, атом төшенең энергиясен файдаланган. *Һәр акыллы кешегә мәгълүм: атом-төш коралларын куллануны күздә тоткан сугышта җиңүчеләр дә, җиңелүчеләр дә була алмый.* Казан утлары

**А́ТОМЧЫ** *и.* 1) Атом энергиясе өлкәсендәге белгеч, галим

2) Атом бомбасын куллануны яклаучы кеше. *Атомчылар, онытмагыз, Атомчылар, уйлагыз: Юл куймабыз коллыкка без, Үлемгә юл куймабыз.* З.Нури

**АТРИБУТ** *и. лат.* 1) *филос.* Нинди дә булса объектның бик мөһим, әһәмиятле, аерылгысыз һәм үзенә генә хас булган төп билгеләре. *Столыпин реакциясе чорында студент фуражкасы, Горький эшләпәсе, озын чәч, кызыл күлмәк полициянең нервысына тия торган атрибутлар иде.* И.Рәмиев

2) *сир.* Кемгә яисә нәрсәгә дә булса хас булган үзенчәлекле билгеләр

3) *лингв.* Аергыч

**АТРИБУТИВ** *с. лат. грам.* Аергычка караган, аергыч буларак кулланыла торган

**АТРОПИН** *и. лат.* Эт җиләге, тилебәрән орлыгы кебек үсемлекләрдән алына, медицинада авыртуны баса торган дару буларак кулланыла торган агулы матдә; алкалоид. *Атропин бронх спазмнарын киметә һәм күз карасын (бәбәген) зурайта*

**АТРОФИ́Я** *и. гр.* 1) Туклану начарлану яки озак вакыт хәрәкәтсез тору аркасында, аерым органнарның яисә тукымаларның кечерәюе яки бөтенләй сафтан чыгуы, шулай ук аларның функцияләре үзгәрү, бозылу күренеше

2) *күч.* Нинди булса хисләрнең кимүе, бетүе, томанлануы

**АТРОФИ́ЯЛӘНҮ** *ф.* Атрофиягә дучар булу, дучар ителү. *Бер ишесе, мәсәлән, телне тумыштан ук белми, аны инде, үгетләү түгел, дегетләсәң дә берни чыкмый; кайберсенең тел тою хисе атрофияләнеп, үлек җыелган – ул хәзер кайсы дөрес, кайсы ялгыш икәнлеген дә аермый.* Х.Сарьян

**Атрофияләнеп бетү** Тәмам, бик нык атрофияләнү

**Атрофияләнеп калу** Ниндидер тышкы тәэсирдән, сәбәптән соң атрофияләнү

**АТСЫЗ** *с.* Исеме булмаган, исемсез. *Атсыз күлдә беренче тапкыр боз күренүне сөннәр изгегә юрыйлар.* Н.Фәттах

**АТСЫ́З БАРМАК** *и.* Урта һәм чәнчә бармак арасындагы бармак. *Баш бармак баш кашый, Имән бармак имән ташый, Урта бармак утын яра, Атсыз бармак ат куа, Чәнти бармак чәй эчә.* К.Закирова. *Сөембикәнең атсыз бармагына көмеш йөзек кигән кара тутлы кулын кысты да ашыкмыйча гына китеп барды.* Ә.Еники

**АТСЫЗЛЫК** *и.* Ат булмау, атлар җитмәү, атларга кытлык. *Гомергомергә ата-бабадан мирас булып килгән атсызлык, җирсезлек аның тәмам кешелек иркен алды.* Г.Минский

**А́Т ТАБИБЫ** *и. к.* **ат докторы**

**А́Т ТАРТЫМЫ** *и.* Бер ат йөге, бер ат тартырлык йөк. *Ул элекке көннән үк ат тартымы ике йөк китереп аударды.* Г.Ибраһимов

**АТТАШЕ** *и. фр. махс.* 1) Илчелектә махсус хезмәт йөкләтелгән хезмәткәр, консультант-белгеч. *Аны [Г.Исхакыйны] бу күңелсез хәлдән Төркиянең Япониядәге хәрби атташесы Рөштү Әрдәлһүн коткарып кала.* Х.Миңнегулов

2) Чит ил эшләре ведомствосында кече дипломат рангы

**А́Т ТЕГЕРМӘНЕ** *и.* Ат көче ярдәмендә эшли торган тегермән

**АТТЕСТАТ** *и. лат.* 1) Урта белем бирә торган уку йортын тәмамлау турында рәсми документ. *Зәңгәр кәгазьгә алтын хәрефләр белән басылган аттестат конверт эчендә иде.* М.Юныс. *Шатлыкларның беренчесе – урта белем турында өлгергәнлек аттестаты алу.* Н.Фәттах *Бердәм дәүләт имтиханын «2»легә тапшырган бала, әлбәттә инде, аттестатсыз кала, дигән сүз.* Шәһри Казан // Гыйльми звание яки дәрәҗә бирелү турындагы таныклык. *Академиклык аттестаты*

2) *иск.* Хәрби хезмәткәрләргә яки аларның гаиләсенә акча, кием һ.б. әйберләр алырга хокук бирә торган документ. *Ул вакытта кече абый җибәргән аттестатка акча алырга, әнкәй айга бер мәртәбә хәрби комиссариатка бара иде.* К.Йосыпов

3) *иск.* Отставкага чыкканда, офицерларга хәрби хезмәттә булганлыгы турында бирелә торган таныклык

4) *иск.* Хезмәт иткән урыннан бирелә торган тәкъдимнамә, бәяләмә, характеристика

5) Нәселле хайваннарның токымы күрсәтелгән таныклык

**АТТЕСТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Аттестацияләү (*1 мәгъ.*) эше

2) Характеристика, бәяләмә. – *Аттестация кыска, әмма ышандырырлык язылган, – диде подполковник, кәгазьдән күзен алмыйча.* В.Казыйханов

**АТТЕСТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Белгечлек дәрәҗәсен билгеләү, исем бирү

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса характеристика, бәяләмә бирү. *Техник контроль бүлегенең барлык эшчеләрен һәм контролёрларын яңадан аттестацияләделәр.* Социалистик Татарстан

**АТТРАКЦИОН** *и. фр.* 1) Цирк яки эстрада программасында тамашачылар өчен эффектлы чыгыш

2) Паркларда, бакчаларда һ.б.ш. ял итү урыннарында карусель, тир, таган кебек төрле күңел ачу уеннары

**А́Т-ТУАР** *җый. и.* Ат һәм җигүгә яраклы башка хайваннар. *Пример, без колхозга кергәч, ат-туарлар һәммәбезнең күмәк ителде.* Һ.Такташ

**А́Т-ТУН** *җый. и.* Мал-туар; байлык. *Галимә апаң һаман борынгыча... Ат-тун исән булса, калага алып барып кайтырга исәпләп торабыз.* М.Гафури

**АТТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ату** (*1–5, 7–8 мәгъ.*). *Без аның агасын, бер заговорга катнашканлыгы өчен, хөкем белән аттырдык.* Г.Ибраһимов

2) *махс.* Җир астындагы нефть торбага бәреп керсен өчен, торбаның стеналарын эчтән тиштерү. *Кич белән 214 нчене аттырырга барам.* И.Гази

3) Көч белән бәреп, читкә, өскә атылдыру. *Хуҗа, бер шешәнең төбенә учы белән сугып, бөкене аттырды да, шалт, табынга куйды.* И.Гази

**АТУ** *ф.* **1.** 1) Кулда булган әйберне ыргыту, ташлау. *Ул һөнәрханә ишеге янагына тотынып, уйга калды, бераздан, борылмыйча гына, кулындагы пүләнне эчкә атты.* М.Хуҗин. *Мәхмүтов урыныннан ук сикереп торды, күзләген, салып, өстәлгә үк атты.* Р.Кәрами // Берәр әйберне, игътибарсыз гына, кискен хәрәкәт ясап ыргыту, ташлау. *Тормыш йөген, артык кием итеп, Ярларына салып атмадыкмы...* Р.Рахмани

2) Кемнең дә булса өстенә берәр нәрсә ыргыту. *Сезне [кошлар], без курkытмабыз һәм Таш, агач та атмабыз.* М.Гафури

3) Кемне дә булса көч белән күтәреп алып читкә ташлау яки егып салу. *Я телеңә салынмыйча гына утырасың, я сине тәрәзәдән атам.* Ф.Хөсни

4) Мылтык, автомат һ.б.ш. утлы кораллардан ядрә, пуля, туп, снаряд кебек нәрсәләр җибәрү. *[Әсләф:] Алар маңгайга ата.* Д.Салихов. *Митричев, атып егачак иң беренче корбанын эзләгәндәй, зәһәрләнеп ялтыраган күзләрен кыскан килеш, тешләрен шыкырдатып, пулемётның көпшәсен уңнан сулга, аннары сулдан уңга боргалый башлады.* Г.Бәширов

5) Утлы коралдан файдалана белү. *Мин төз ата идем.* Ә.Гаффар. *Туры аткан өчен алган знакны, матурлап, күкрәккә кададым.* Г.Исхакый

6) Аулау. *Узган ел, сезонны ябар алдыннан, бер куян аттым.* М.Галиев

7) Җәза бирү төре буларак, утлы корал ярдәмендә үтерү. *Сәлимгәрәйне тау ягына чыгарып аттылар.* Х.Хәйруллин. *Менә Татарстан да, барча республикалар һәм өлкәләр кебек үк, 1937 елның август аенда, 500 кешене атарга, 1500 кешене ун елдан да ким булмаган вакытка ябарга, дигән контроль саннар ала.* Мирас

8) Эчке көч белән бәреп, ташып чыгу, югарыга ургу яки читкә чөю, ыргыту. *Ватан өчен безнең йөрәкләрдә Диңгез ярындагы таш тауларны Җимереп аткан вулкан көче бар.* Ф.Кәрим. *Сөннәтче бабай, сул яки уң кулының терсәкене бөкли торган җиреннән кара тамырны табып, тагы: «Бисмилла!» – дип, салават әйтеп, балтасы берлән чаба, кан чәчрәп чыгып, фонтан булып түшәмгә таба ата башлагач та, җиз тазга хәзрәтнең кулыны бора...* Г.Исхакый. *Мичкәң кыршау аткан, юл буена суы агып килә, ник аны карамадың?* М.Гали

9) *күч.* Коралдан аткан кебек, өзек-өзек һәм көчле тавышлар чыгару. *Болыт чыгып, күк күкрәп, атты яшен!* М.Гафури. *Күктә, ялтырап, галәмәт зур камчы уйный да, шундук, чытырдап, яшен ата.* Д.Гайнетдинова

10) *күч. гади с.* Сорап алу. *[Вәли] Төпчек атарга бик ярата.* А.Расих

11) *күч. сөйл.* Үзенә каратырга тырышу. *Ул – пудра ягынган, һәрбер яшь егетне атып йөрүче ханымнардан түгел.* Һ.Такташ

12) *күч. сөйл.* Бик кызу сөйләү. *Сүзеңне сорап бетмисең, ул, ут кебек чәчрәтеп, әллә кайчан җавабын аткан була.* Г.Ибраһимов

13) *күч. сөйл.* Кемгә дә булса яла ягу, гөнаһсызга кемнең дә булса яман атын чыгару. *Битеңне ярып әйтсәләр, бер хәл иде. Үзеңне яклап, сүз дә кыстырырга булыр иде. Болай – җайсыз: сүз дә әйтеп булмый, бәлки, сиңа төбәп тә атмаганнардыр.* К.Йосыпов

**2.** *ярд. ф. функ.* Фигыльнең тизлеккинәтлек һәм тәмамлану дәрәҗәләрен ясый. *Сакалны кырып аттым.* М.Җәлил

**Ата башлау** Атарга керешү, атарга тотыну. *Таш артыннан ташны ватып ата башлый.* Г.Тукай. *Этна вулканы яки бүтән берәр янартау ата башлау белән, дөньяның төрле почмакларында*

*янәдән Сицилияне телгә алалар*. Р.Фәйзуллин

**Ата бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы ату

**Ата бирү** Атуны дәвам итү

**Атып бетерү** Берсен дә калдырмый ату; барысын да ату

**Атып җибәрү** Кинәт ату. *Заһидулла мылтыгыннан атып җибәрде*. Р.Сибат. *[Бикташ карт] Берданкасын һавага күтәрде һәм курыкканнарның котын алу өчен, тарсылдатып атып та җибәрде*. Г.Минский. *Шул вакыт ул, иелеп, җирдән таш алды һәм, өненнән чыгып, безне карап торган йомранга атып җибәрде*. Р.Сибат

**Атып калу** Атарга өлгерү. *Ятып калганчы, атып кал. Ярмөхәммәт бәхетен сынап карарга булды*. Р.Батулла

**Атып карау** Төз һәм төгәл ата алуын сынау; сынау максатыннан ату. *Тупны утырткач та, янә авылга атып карадылар. Җиткерә алмадылар*. З.Зәйнуллин

**Атып кую** Уйламаганда, көтмәгәндә кинәт ату. *Берәр кызурагының кулына эләксәң, атып та куяр*. Ш.Усманов

**Атып тору** Бертуктаусыз ату. *Янар таулар ут атып тора*. Һ.Такташ

**Атып яту** Әле, хәзерге вакытта бертуктаусыз ату. *Иң төп бурыч – тирә-юньгә берөзлексез радиация ташкыны атып яткан реактор коесын томалау*. Ә.Салах

**АТЧАБАР** *и*. Атлы хәбәрче, ат белән чабып, хәбәр йөртүче; атлы йомышчы. *Байтүрәнең җеназасына чакырып атчабар чыккан, диделәр, бу хәбәрнең асылы бармы?* Г.Ибраһимов

**АТЧЫ** *и*. Ат караучы. *Ул Ерак Себердә, Байкал буйларында юл салучыга атчы булып ялланып йөри*. Г.Ибраһимов

**АТЧЫЛЫК** *и*. Ат асраучылык, ат үрчетүчелек. *Элегрәк атчылык буенча күпме әдәбият бар иде*. М.Мәһдиев. *Ул кайтканда, авылда икенче кампания – татар авылын сарыкчылык, атчылык һәм кошчылыктан коткарып, дуңгызчылыкка күчерү бара иде*. А.Хәлим

**АТЫЛА́-БӘРЕЛӘ** *рәв*. Ашыгып, кабаланып, атылып. *Менә монтёр, атыла-бәрелә, чәй кайнату бүлегенә килеп керде, электр үткәргечләрен тикшерә башлады*. К.Йосыпов

**АТЫЛУ** *ф*. **1.** 1) *төш. юн. к.* **ату** (*1–5 мәгъ.*). *Әйтерсең лә бу минутлар, сәгатьләр, еллар – атылган аккошның җан бирү мизгелләре*. К.Йосыпов

2) *кайт. юн. к.* **ату** (*3 мәгъ.*). *Ничек соң ул, элек сине атмакчы булып, соңыннан үзе атылды?* М.Фәйзи

3) Ташып, бәреп чыгу, ургылып чыгу. *Бер-бер артлы, түшәмгә бөкеләр атылды*. Р.Кәрами

4) Бик ашыгып, зур тизлек белән кая да булса юнәлү, ташлану. *Ал чәчәккә кунган бал корты кук, синең кочагыңа атылдым*. М.Җәлил. *Ә мин ашык-пошык киендем дә, атылып, тышка чыктым*. Н.Дәүли. *Яшь яугир Илбарис атына менде, алга атылды*. Р.Фәизов. *Мине күрү белән, тәрәзәләргә кызлар атылалар*. Г.Исхакый. *Хыялымда юкса мең мәртәбә Гыйсъян булып җиргә атылдым*. Г.Гыйльманов

5) Төнлә йолдыз булып күренгән күк җисемнәренең Җир атмосферасына эләгеп янып төшүе. *Йолдыз атылганда теләк теләү*

6) *куч*. Кемгә дә булса барып сарылу, ташлану

**Атыла тору** Бертуктаусыз атылу, бер-бер артлы атылу. *Баткак өстендә пычрак фонтаннары һаман атыла торды*. Ш.Маннур

**Атылып чыгу** Кинәт атылу, кинәт бәреп чыгу. *Ул килеп утыруга, үч иткән кебек, күзләремнән яшь атылып чыкты*. Р.Хафизова. *Алан уртасында гомердә уйламаган уйларыма чумып утырганда, аяк астындагы җәлпәк таш астыннан бер кәлтә еланы атылып чыкты да, үчләшкән кебек, койрыкларын болгый-болгый, үлән өстендә бормалы эз калдырып, йөгереп китте*. Г.Гыйльман

**АТЫЛЫ́П-БӘРЕЛЕП** *рәв*. **атыла-бәрелә**. *Атылып-бәрелеп, очрашу урынына чаптык*. Р.Хафизова

**АТЫНГЫЧ** *и. сөйл. к.* **атынчык.** *Җилнең шаян малайлары, тал ботакларын атынгыч итеп, арыганчы тирбәлгәннәр*. Ф.Яруллин

**АТЫНДЫРУ** *ф*. 1) Тирбәтү, әле – бер, әле икенче якка хәрәкәтләндерү, тирбәндерү. *Фәнис, моңга бирелеп, Зареманы таганда атындыра*. Х.Ибраһимов

2) Бер яктан икенче якка йөртү, чайкалу, селкенү. – *Әйдәгез, эшне танышудан башлыйк, – диде ул, гәүдәсен аяк очларында атындырып*. Р.Зарипов. – *Ни җаның белән алып чыктың аны? – дип чәрелдәде проводник хатын, зур, сыек күкрәкләрен атындырып*. А.Гыйләҗев

**Атындыра башлау** Атындырырга тотыну. --- *тизрәк йоклап китсен дип, шу-шу иттереп, биектәге агач башларын атындыра башлый...* Г.Бәширов

**Атындырып алу** Тиз генә, кыска вакыт арасында атындыру

**Атындырып җибәрү** Атыну ноктасыннан кузгату, атындыра башлау

**Атындырып кую** Бер тапкыр гына атындыру хәрәкәте ясау. *[Иван Илларионович] --- бүтән врачлар кебек үк, күтәрелеп карамады, җилкәсенә авыр йөк салган йөкче кебек иелеп, нидер мыгырдады, берсен берсенә чәнчегән тезләрен атындырып куйды*. А.Гыйләҗев

**Атындырып тору** 1) Әле, хәзер, күз алдында атындыру. *Урамда баласын атынчыкта атындырып торган хатынны күргәч, ирексездән, балачагым искә төшеп китте*. З.Мәхмүди

2) Бертуктаусыз, әледән-әле атындыру. *Мин, аны яхшырак күрер өчен, торып бастым, ә диван үзе бик йомшак, даган шикелле, атындырып тора*. А.Алиш

**АТЫНУ** *ф*. 1) Әле – бер, әле икенче якка таба авышу, төрле якка селкенү, тирбәлү. *Әнисе ияр өстенә аркылы яткан, чәчләре асылынып төшкән, ике кулы, ат тилпенгән уңайга җансыз нәрсәдәй атына иде*. Г.Бәширов. *Ә ишек янындагы түбәсе түшәмгә тигән зур читлектә Маймыл кызы таган атына иде*. Р.Хафизова

2) Тирбәнү. *Бик текәлеп күзәтә торгач, ниһаять, үзен дә күрдем мин аның ---. Дүртәр-бишәр метрлы дулкыннар гарасатында, икәүләп, арлыбирле атыналар*. М.Вәли-Барҗылы

**Атына бару** Торган саен ныграк атыну

**Атына төшү** Тагы да бераз атыну

**Атынып алу** Аз гына, берничә тапкыр атыну. *Биш-алты мәртәбә мәтәлчек атынып алды.* А.Мельников. --- *ике каен арасына тартылган таганга утырып, көлә-көлә, атынып та алды.* Р.Вәлиев

**Атынып карау** Атыну мөмкинлеген сынау. *Баш түбән, бауга тотынып, Таган атынып карый.* Ф.Мөслимова

**Атынып китү** Ниндидер сәбәптән соң кинәт атына башлау. *Шатлыктан, бер мәтәлчек тә атынып китәсе килгән иде, тыелып калды.* Н.Хәсәнов

**Атынып кую** Бер тапкыр атыну хәрәкәте ясау. *Дөрес, аның бер аягы какшаган, тиктомалдан атынып-атынып куя.* А.Гыйләҗев. *Кыл урталай ярып, ике толым итеп үрелгән авыр чәч толымнары хәрәкәтләнгән саен атынып-атынып куялар.* М.Хәсәнов

**Атынып тору** 1) Әле, хәзер, күз алдында атыну. --- *карт өянке ботагына башта куллары белән асылынды, аннары, бераз атынып торгач, ботакны аяклары белән кочаклап алды да, мәче җитезлеге белән, җәһәт кенә өскә менеп басты.* Р.Вәлиев

2) Гел, бертуктаусыз атыну. --- *насослар, нефть суырып, бервзлексез әлли-бәлли атынып тора.* Ш.Галиев

**Атынып утыру** Әле, күз алдында атыну. --- *аның каршысында гап-гади бер чүп үләне – һиндыба чәчәге – искән җилдә салмак кына атынып утыра иде.* Р.Батулла

**АТЫНЧЫК** *и. сөйл.* Ни дә булса асып кую өчен аркылы салынган таяк, колга һ.б.; таган. *Урамда баласын атынчыкта атындырып торган хатынны күргәч, ирексездән, балачагым искә төшеп китте.* З.Мәхмүди

**А́ТЫ-САНЫ** *и. к.* **аты-чабы**

◊ **А́ты-саны чыгу** *к.* **аты-чабы чыгу**

**А́ТЫ-ЧАБЫ** *и.* Берәүнең халык арасындагы даны, авторитеты

◊ **А́ты-чабы чыгу** Яманаты чыгу, начар эше, начар гадәтләре фаш булу. *Әнә егетләр белән тотылып аты-чабы чыккан Бәдрелхаят.* Г.Ибраһимов. *Кызының, яман телләргә азык булып, аты-чабы чыкмагае, дип гел сагаеп килгән ана мондый хат алышуны яхшы күрмәде.* Г.Минский

**А́ТЫ-ЧУТЫ** *и. к.* **аты-юлы**

◊ **А́ты-чуты белән** Әшәке сүзләр әйтеп

**АТЫШ** *и.* Берьюлы төрле яктан яки кара-каршы атышу. *[Марат:] 26 нчы ноябрь 15 сәгать 45 минутта «Майнила» тирәсендә урнашкан безнең гаскәрләргә, көтелмәгәндә, Финляндия артиллериядән атыш башлаган.* Т.Гыйззәт

**АТЫШУ** *ф.* Бер-берсенә яки берьюлы төрле яктан күмәкләп ату. *Туплар да шартламый, атышмыйлар да, «ура» да кычкырмыйлар.* М.Әмирханов. *Егетләр, ук атышкан вакытта: «Кяфирне менә шулай атарбыз, башкортлар белән берегербез», – дип сүлиләр, – диде Габделсаттар, һаман да сакалын угалап.* Җ.Рәхимов

**А́ТЫ-ЮЛЫ** *и.* Кешенең исеме, кушаматы, әйбернең атамасы

◊ **А́ты-юлы белән** 1) Кешене, әйберне чын исеме белән атап; 2) Әдәпсез, оятсыз сүзләр белән (*сүгү, сүгену, кычкыру*). *Аты-юлы белән тиргәгәнне әйткән дә юк.* Х.Камалов

**А́Т ЯЗУЫ** *и.* Ат таныклыгы; аның яше, төсе, кыяфәте, кайдан алынганлыгы һәм токымы күрсәтелгән карточка, паспорт

**А́У** I *и.* 1) Тоту яки үтерү максаты белән, кыргый җәнлек яки кошкортларны эзләү, эзәрлекләү, аулау эше; сунар. *[Шәмсун:] Менә иртәгә иртүк, икәүләп, ауга барырбыз, үзең беләсең, монда – кыр тавыгы, куян...* А.Вергазов. *Ләкин көннең иң һәйбәт, кызу вакытында, зур өметләр баглап, дөнья күкрәтеп, җыр-көй белән тартылган бу ау шатландырмады.* Ш.Камал. *Шер-Хан – Олуг Юлбарыс ау урынын алыштырды.* Р.Киплинг. *Еланнар ау белән башлыча төнлә шөгыльләнәләр.* З.Фәйзи

2) Аулана, эзәрлекләнә торган хайван, җәнлек, кош-корт һ.б. *Ау артыннан кырдан кырга узып йөргәндә, җир сөреп, иген игеп торган бер сукачыга очрадым.* Дәрдемәнд. *Күктән миңа бүген бәхет иреште: Тозагыма нинди тансык ау төште!* Ә.Фирдәүси

3) *күч. сөйл.* Сугыш вакытында әсир төшерелгән дошман солдаты, «тел». *Сугышчылар, актан киенеп, ау артыннан киттеләр*

4) Җәнлек, хайван һәм кош-кортларны тотар өчен корып куела торган махсус җайланма, тозак. *Арыслан киек баласын ау белән тоталар.* Мәкаль. *Аю, күп тартыла торгач, ауны өзде дә котылды.* Г.Тукай

5) Балык тоту өчен җептән үрелгән төрле зурлыктагы җәтмә. *Балыкчылар иң нечкә капроннардан үрелгән аулар, җәтмәләр сала.* М.Хәсәнов. *[Фәрит:] Беләсең килсә, ау белән сөзү – законга сыймый ул.* Р.Сибат

6) Үрмәкүч үргән пәрәвез. *Үрмәкүч корган ауга чебен эләккән*

7) *күч.* Кемгә карата да булса начар, явыз уй белән корылган хәйлә, тозак. *Йомшак сүзләр, йомшак җөмлә аулары берлә ул, акыртын гына, Аннаның психологиясенә кереп китте.* Г.Исхакый

◊ **Ау кору** Кемгә карата булса да хәйлә тозагы әзерләү. *Ачуым кабарса – сүрелде, Кешегә мәкер, ау кормадым.* Р.Хисамиев. **Ауга чыгу** Сугышта «тел», әсир артыннан бару. *Дүрт ай госпитальдә яттым, дүрт ай ауга чыкмадым, иптәш командир.* А.Әхмәт

**А́У** II *иярт.* Эт өргән тавышны белдерә. *Бала, иренен бөрештереп: – Ау, ау, – диде. – Өйдәш йонлачны сорыйсыңмы, улым?* Н.Гыйматдинова

**АУ́ (АУУУ)** III *ы.* Урманда адашканда, эзләгәндә кычкырып бирелгән аваз. *Ерактан, әллә кайдан «Аууу!» дигән аваз да яңгырап куйгалый.* Ф.Әмирхан. *Балачакка кайтып аваз салам! Ау-у! Дәш, урман!* И.Юзеев

**АУДАРМА** *с. к.* **аудармалы**

**АУДАРМАЛЫ** *с. махс.* Үзлегеннән аударыла, үзе аудара торган

**АУДАРУ** *ф.* 1) Үсеп утырган яисә утыртып, бастырып, кадаклап, беркетеп куелган берәр нәрсәне көч белән бер якка таба әйләндереп ташлау, егу. *Шулай без көне буе тайгада агач аударабыз.* А.Хәсәнов. *Җитмәсә, терсәге тиеп китеп, утүкне идәнгә аударды.* К.Йосыпов

2) Кайсы да булса ян якка кыегайту, янтайту. *Давыл өермәсе ---*

*корабны чак кына сул якка аудармады.* Ә.Хәбибуллин

3) Егу. *Ул хатынны, җилтерәтеп, диван янына алып килде дә дорфа гына төртеп аударды.* З.Хөснияр. *Аты Елгырның, иртәнгә дип әзерләп куелган бер чиләк солыны аударып, мыш-мыш килеп ашый башлавын да сизмәде хәтта.* Г.Гыйльман

4) Берәр нәрсәне икенче урынга бушату, илтеп ташлау. *Җитез, үткен малайлар, атларны дилбегә белән җитәкләп, балчыкны кирәкле урынга аударып китәләр.* А.Алиш. *Биек итеп ком, вак таш өйгәннәр, кайбер урыннарга рельслар китереп аударганнар, кара шпал өемнәре ята.* Р.Кәрами. *«Бригадир Ибрай малае машинасы белән колхоз бәрәңгесе кайтарып аударган», – дисәләр, оятын кая куям мин аның?* Р.Вәлиев

5) *сөйл.* Тәрҗемә итү. *Ник балаларга театр язмый Мирхәйдәр, диләр, Бар икән русчаң язарлык, әйдә, тик аудар, диләр.* Ш.Бабич. *Тылмач ат башыннан тоткан йөзбашка --- Дәянның сүзләрен аударып бирде.* М.Хәбибуллин

6) Күчерү, ыргыту. *Көчәеп бара торган җил ялкын баганасын Хәйриләрнең салам түбәләренә аударды да, күз ачып йомганчы, аны ут камап алды.* М.Гали

7) *сөйл.* Исерткеч эчемлек эчү. *Галәү белән Гайнетдинов, күк киемнәре тышыннан пальто кия-кия, тагын берәрне аудардылар.* Г.Ибраһимов

8) *куч. сөйл.* Кемгә дә булса кайгы, борчу, ачу һ.б.ш. сөйләү, күңелне бушату, күңелендә йөрткән бөтен серне чыгарып салу

9) *күч.* Кемнең дә булса фикерен үзгәртеп, икенче як файдасына юнәлтү, авыштыру. *Арабызга безнең өченче берәү килеп керде. Ул Камилне, үз ягына аударып, миннән тартып алды.* Г.Тавлин. *[Бикмураев:] Син нәрсә, мине дә үз ягыңа аудармакчы буласыңмы?* М.Хуҗин. *Туйга, мәһәрләрдән тыш мең сум акча вәгъдә итеп, Бәдрине бик тиз үз ягына аудара.* М.Фәйзуллин

10) *күч.* Икенче берәүне гаепле итеп күрсәтү, гаепне икенче кешегә ягу, сылтау. *Ах, тагын кайсыдыр яманатымны сата, тагын кемдер үз гөнаһларын минем өскә аудара.* М.Миншин. *Әхмәтов Яббаровның гаепне үз өстеннән аударырга тырышу өчен шулай әйткәнен белде.* Р.Кәрами. *[Батырша] --- утлы тимерләр кыздырып басканда да, ничек кенә җәзалаганда да, үз җанын аяп, бер кешене сатмый, гаебен беркемгә аудармый.* Г.Хөсәенов

**Аударып бару** Берсе артыннан икенчесен аудару, бер-бер артлы аудару. *Җитмәсә, алар бит әле башкаларны да безгә каршы котырталар, инде кыргыз-кайсакларны үз якларына аударып баралар.* Ф.Бәйрәмова. *Ә сынауларны шпаргалка белән генә аударып баручы кайберәүләр, университетны бетергәч, наданлыкларын гына капларлык диплом алачак.* М.Юныс. *Чибәр егет мин сөйләгәнне аударып бара, Келинтен елмаеп тыңлый.* Т.Миңнуллин

**Аударып бетерү** Тулысынча аудару; барысын да аудару. *Катырак селтә, катырак. Чалгың чабылган җиргә хәтле үләнне аударып бетерсен.* Ә.Баян. *Аһ! Нинди сылу каеннарны аударып бетергәннәр!* М.Шаһимәрдәнов. *Җаһил Майбәдәр, күрәсең, аны үз ягына аударып бетергән.* Гөлшәһидә

**Аударып җибәрү** Кинәт аудару. *Ишегалдына килеп кереп, атны туктатып, чылбырдагы этне ычкындырып, арбаны аударып җибәрүгә, чыбык астыннан төлке килеп чыга.* Х.Гатина

**Аударып калдыру** Башка кешегә күчерү, башка кешене гаепле итү. *Ул бөтен гаепне авыруның үзенә аударып калдырырга тырыша.* Л.Гыйззәтуллина

**Аударып кую** 1) Ауган хәлгә китереп калдыру

2) *күч.* Гаепне кем өстенә булса да аудару. *Сталин, колхозлаштырудагы бөгелешләрне күрсәтеп, бөтен гаепне урындагы җитәкчеләр өстенә аударып куйган иде.* Ф.Сафин

3) *күч.* Түбәнә кадәр эчеп бетерү. *Кәлимуллин ---, агач тамыры кебек каралып, сөялләнеп беткән кулына стаканны алып, ярый, сыйлаганда – су эч, ди, дип, бик тиз аударып куйды.* Х.Камалов

**Аударып салу** Аварга, җиңелергә мәҗбүр итү. *Көтүдәге үгез качкач, Милиционер Ханнан, Аны мөгезеннән тотып, Җиргә аударып салган.* Р.Миңнуллин

**Аударып ташлау** 1) Кинәт, астынөскә китереп туздырып аудару. *Менә хәзер ни дә булса булыр: йә безне җир йотар, йә коточкыч җил-давыл кубып өермә чыгар да урманны аударып ташлар кебек тоела иде.* Г.Бәширов. *Җил аударганмы Такташыбызны, әллә кем дә булса юри аударып ташлаганмы, кем белсен?* Р.Батулла

2) Ялгыш аудару. – *Әлә-лә-лә-лә...– Кинәт бордың, энем, аударып ташлама!* Ә.Еники

**Аударып тору** Әле берсен, әле икенчесен, бер-бер артлы аудару; бертуктаусыз аудару

**Аударып чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да аудару. *Машинистка кызлар татарчадан аударып чыга да кульязмагызны – башкортча текст әзер.* Р.Вәлиев

**АУДИЕ́НЦИЯ** *и. лат.* Югары дәрәҗәле дәүләт эшлеклесенең рәсми кабул итүе. *[Адъютант:] Аңламый калдым, гаеплемен, полковник әфәнде. Аудиенция сорадылар.* Ә.Гаффар

**АУДИО-** *гр.* Кушма сүзләрдә мәгънәсе белән тавыш яздыру җиһазларына, яздырылган тавышка бәйләнешле беренче кисәк (мәс., *аудиодиск, аудиоҗыентык, аудиокитап, аудиосистема, аудиотасма, аудиофайл*)

**АУДИТО́РИЯ** *и. лат.* 1) Лекция, доклад, һәртөрле чыгышлар сөйләү, уку өчен билгеләнгән зал яки зур бүлмә. *Без университетның җиденче аудиториясенә җыелдык.* М.Хуҗин. *Без, йөгерешеп, аудиториягә кердек тә, конспектларыбызны җыеп, ишеккә ташландык.* М.Юныс

2) *җый. и.* Лекция, доклад, чыгышны тыңлаучылар, залда тыңлап утыручылар. *Айхенвальд, җавaптан канәгать калып, аудитория алдында, ике кулын артка кушырып, әрле-бирле йөри башлады.* Ф.Сафин. *Һәртөрле аудиториядә ул [Айрат Арсланов] үзен бердәй иркен тотты.* Р.Заһидуллина

**АУКАН** *с. диал.* Иркен. *Каңгылдап, аккош йөзә аукан күлдә.* Дәрдемәнд

**АУКЦИОН** *и. лат.* Берәр мөлкәтне яки әйберне халык алдында иң югары бәя бирүчегә сату. *Хәер, юк, тире аукционында җиңелрәк, күңелеңә ошаганын кул сугасың да аласың.* М.Зарипов. *--- ул, башка дәлилләр белән бергә, аукционнарның ел саен кайсы илләрдә һәм шәһәрләрдә үткәрелүен санап чыкты.* Р.Мирхәйдәров

**АУЛАГӨЙ** *и. сөйл. к.* **аулак өй.** *Егетләр белән йөрисегез килә икән, клубка барыгыз. Аулагөй ясап ятарга анда!* Н.Фәттах

**АУЛАК** *с.* **1**. 1) Тыныч, кеше-кара йөрми торган, кешесез. *Кичен ул, Ксения белән саубуллашкач, аулак тыкрыклар буйлап, Бишбалтага кайтып китте.* К.Нәҗми. *Зиһен изүен шәрран ачма, уйсыз җилгә сыенырга калсын аулак почмагың.* М.Галиев. *Дөнья кызык: күрше-тирә татар авылларына мәет куярга йөргән, Болгардан килгән нәселле Сәхип Зәкиевнең үзен, керәшен зиратының бер почмагында аулак урын бүлеп алып, керәшеннәр җирләде.* Р.Батулла

2) *күч.* Икәүдән-икәү генә калган, янда башка кеше булмаган. *Дөрес, яшьрәк илгәзәк хатыннар Асаф Сәхиповичны игътибарсыз калдырмыйлар, сүз белән дә, күз белән дә аңа ярарга тырышалар, аулак мизгелләрдә елышалар да.* Р.Батулла. *Сандра чыннан да аулак вакытта килеп керде.* Ә.Салах

3) *диал.* Сер итеп әйтелгән, яшерен. *Сезгә аулак сүзем бар*

4) *диал.* Киң, иркен. *Аулак якты ызба. Аулак кием*

**2**. *и. мәгъ.* 1) Кешесез, кеше-кара булмаган, кеше-кара йөрми торган тыныч урын. *Сезнеңчә, шулай нәмәхрәм белән аулакта төнлә утырырга ярый?* М.Гафури. *Шаһин-шаһ чапкынын озатып җибәрүе хакында әйтте дә Омырзакны аулакка чакырды.* Б.Рафиков. *Менә йорт урыны матур икән, дим... Тып-тын. Трамвайлар да йөрми. Аулак.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **аулак өй**. *Авыз күтәреп, урам буйлап җырлап йөргәнем, аулакларда вакыт үткәргәнем бармы минем?* А.Шамов. *Байтирәк абый, бүген безнең мәдрәсәдә аулак булырга тора.* Т.Гыйззәт

**3**. *рәв. мәгъ. диал.* Берүзе, ялгыз, бер кешесез. *Шул усал сүзләрегезне уйлап, аулак калган чакларда, үзем ислах өчен планнар корып маташам.* М.Фәйзи

**АУЛАКЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Үзләре генә калу, бергә-бер ялгыз калу. *[Гашия һәм Әхмәтша] Икәүдән-икәү, үзләренчә аулаклап кына булса кирәк, өйалдында сөйләшеп торалар иде.* М.Әмир. *Карт белән карчык, аулаклап кына, чәй эчәргә ниятләделәр.* Казан утлары

2) Аулак өйгә йөрү

**АУЛА́К ӨЙ** *и.* Өлкәннәр, ата-ана берәр җиргә киткәч ялгыз калган йорт; шундый йортта кич утыру яки, егетләр-кызлар чакырып, бергә оештырылган уен мәҗлесе. *Берәрсе кунак-төшемле мәҗлес үткәрсә, гармун уйнарга мине дәшәләр, аулак өйләргә мине чакыралар.* В.Нуруллин. *Асаф бик яшьли аулак өйләргә йөри башлады.* Р.Батулла. *Аулак өйләрдә уйнаганда, бигрәк тә «Авыллы уеннары»нда, ул өйалдына гел Миңнешне чакырып чыгара торган иде.* Р.Батулла

**АУЛА́У** *ф.* 1) Нинди дә булса җәнлекне, кош-кортны, эзәрлекләп, ау корып кулга төшерү, тоту, эләктерү. *Солтан бабайның атасы Әсфәндияр бабай гомере буена --- кышын бүре һәм төлке ауларга йөргән.* В.Нуруллин

2) *күч. сөйл.* Урлау. *Төннәрен, сал туктап торганда, усалрак бурлаклар, якын-тирәдәге авылларга барып, бераз кәсепләнеп: тавык-чебеш, каз-үрдәк аулап кайталар.* М.Гали

3) *сөйл.* Эзәрлекләү, кулга төшерү максатыннан сагалап йөрү, сагалап эләктерү, юкка чыгару. *Бер хатында ул ничек итеп немец снайперын аулавын язган.* И.Гази

4) *күч.* Хәйлә белән үзенә карату, үз ягына аудару. *Зифа буйларың, явыз уйларың белән ауладың – мине алдадың.* К.Нәҗми

**Аулап алу** 1) Тиз арада аулау; аулап тоту

2) Ау, хәйлә белән җәлеп итү, үзенә карату. *Рабиганың матур тавышы моңлы, назлы; Назы белән аулап ала ир-шаһбазны.* Ш.Бабич

**Аулап бетерү** Аулау эшен тәмамлау; күп итеп, барысын да аулау

**Аулап йөрү** Күп вакытлар дәвамында аулау. *[Флорид] Тау-таш арасында җәнлек аулап йөри.* Д.Салихов. *Бу мәлдә аның күңелендә кыргый аучылык дәрте кузгаламы, үсмер чагын Кытайда үткәргәнгә, Хинган тауларында сайгак аулап йөргән чаклары исенә төшәме – анысы безгә нәмәгълүм.* М.Галиев

**Аулап килү** Элек-электән, күп вакытлардан бирле аулау

**Аулап тору** 1) Даими, әледән-әле, еш аулау. *Заһидулла мулла ул – татар Распутины, хатыннарга вәгазь сөйләү сылтавы белән, аларны акрынлап аулап тора.* Ш.Камал

2) Әле, хәзер, сөйләү моментында аулау. *Аның ана йөрәге улы турындагы һәрбер сүзне, улына булган һәрбер карашны, ычкындырмыйча, аулап тора иде.* Ә.Еники

**Аулап утыру** Әле, хәзер, күз алдында аулау. *Күңелемне аулап утырганмын Ахшам тулган аулак ашханәдә.* Г.Сәлим

**Аулый башлау** Ауларга тотыну. *Хәзер монда мине аулый башладылар.* Г.Ибраһимов

**Аулый бирү** Аулауны дәвам итү. *Тимәде, [керпене] тычканнарны аулый бирсен, дип, иркендә калдырды.* Н.Хәсәнов

**АУМА** *с. к.* **аумакай**. *Барысы да – аума халыклар.* Г.Камал

**АУМАКАЙ** *с.* **1**. Үзенең анык фикере булмаган, тотрыксыз, принципсыз, әле – бер, әле икенче кеше фикеренә кушыла торган. *Бер Рухия генә шушылай кыйбласыз, аумакаймы, әллә кызларның бөтенесе дә бер чыбыктан сөрелгән микән?* В.Нуруллин. *Гайнулла – аумакай кеше түгел, ишеткәнен кат-кат төпченә.* М.Хуҗин

**2**. *и. мәгъ.* Принципсыз, тотрыксыз кеше. *Аумакайлардан, ялагайлардан, Тинтәк ялкаудан Арыныйк, туган.* К.Тинчурин

**АУМАКАЙЛАНУ** *ф.* Аумакайлык күрсәтү, икенче капма-каршы фикергә, карашка тиз бирелү. *– Утырып тор, апаем, – диде Ниса, аумакайланып.* А.Гыйләҗев

**Аумакайлана бару** Аумакайлыгы, акрынлап, тагын да көчәю

**Аумакайлана бирү** Аумакайлыгы дәвам итү

**Аумакайлана төшү** Бераз аумакайлану, аумакайлык күрсәтү

**Аумакайланып алу** Берникадәр, бераз аумакайлану

**Аумакайланып бетү** Тәмам, бөтенләй аумакайлану

**Аумакайланып йөрү** Күп тапкырлар аумакайлану. *Бер карасаң – мулла, икенче карасаң, «дәһри»ләнеп, аумакайланып йөргән Чыгтай диган принципсыз бер кеше Тукайның --- дошманнарыннан берсе булды.* С.Кудаш

**Аумакайланып китү** Кинәт аумакайлана башлау

**Аумакайланып тору** Әле, күз алдында аумакайлану; һәрвакыт яки әледән-әле аумакайлану

**АУМАКАЙЛЫК** *и.* Аумакай булу, тотрыксызлык, принципсызлык. *Мин --- һәртөрле аумакайлыкка рәхимсез сугыш ачам.* Ф.Сафин. *Ул Харисның, яшьлек аумакайлыгы белән, балалы хатын янында болгануын һич тә хуплый алмый иде, билгеле.* Б.Камалов

**АУМАЛЫ** *с. сөйл.* 1) Кеше фикеренә тиз иярүчән, кеше сүзенә тиз ышанучан. *Безнең әти – бик аумалы кеше ул.* М.Фәйзи

2) *диал. к.* **аумакай**. *Бу каршылык эчендә Бәдринең аумалы табигате, байлыкны үз кызы бәхетеннән дә өстен куюы ачыклана.* М.Фәйзуллин

◊ **Аумалы да тәүмәле** Принципсыз, әле – теге, әле бу якка тиз авучан

**АУНАКЛАТУ** *ф.* Бер яктан икенче якка тәгәрәтеп йөртү, әйләндергәләү. *Әйтерсең лә өстенә һавадан көчле өермә килеп төште дә аны, аунаклата-аунаклата, яфрак кебек каядыр очыртып алып китте.* Ф.Садриев

**АУНАКЛА́У** *ф.* 1) Әле – бер, әле икенче якка тәгәрәү, әйләнгәләү

2) Хәрәкәт вакытында як-якка чайкалу, алпан-тилпән килү. *Ишектән, зур кулларын кая куярга белми селтәнгәләп һәм аунаклап, Талипның атасы килеп керде.* Ә.Фәйзи. *Ул да, Иданы уятудан куркып, тавыш чыгармыйча гына басарга тырышты, ләкин як-якка аунаклаган авыр гәүдә белән, күрәсең, иплән кенә атлап булмый иде.* Н.Фәттах. *Нерв системасының --- зарарлануы нәтиҗәсендә хәрәкәт координациясе бозыла, йөреш тотрыклылыгы бетә, кеше тигезлеген югалта, аунаклап йөри башлый.* Сәламәт яшәү нигезләре

**Аунаклап алу** Берникадәр вакыт аунаклау, бераз аунаклау

**Аунаклап китү** Кинәт аунаклый башлау

**Аунаклап тору** Әле, күз алдында аунаклау

**Аунаклый башлау** Аунакларга тотыну

**Аунаклый төшү** Бераз аунаклау

**АУНАЛУ** *ф. диал.* 1) Бер яктан икенче якка тәгәрәү, әйләнү. *Анна Васильевнаның шул арада эшләп бетерә торган, мөддәтләп алган эше булганга, авыруны дүртенче көн генә ишетте вә урында аунала, тәгәри торган Шәмсине күреп коты очты.* Г.Исхакый

2) Тәртипсез хәлдә булу, анда-монда чәчелеп яту

**Ауналып яту** Әле, хәзер төрле урыннарда, төрлечә ауналу. *Илай, урамда йөргәндә, җирдә ауналып яткан һичбер нәрсәне, тотып, әйләндерә-әйләндерә карамыйча китми иде.* Ак юл

**АУНАТУ** *ф.* 1) Бер яктан икенче якка тәгәрәтү, әйләндергәләү

2) Нәрсәне дә булса, кадерсезләп, аяк астында, тузанда яткыру, туздыру, кадерсезләү

**Аунатa башлау** Аунатырга тотыну. *Эт, ялт борылып, Маратны чанасыннан төртеп төшереп, карда аунатa башлый.* Г.Гобәй

**Аунатып алу** Берникадәр вакыт, бераз аунату

**Аунатып бетерү** Бик нык аунату

**Аунатып кую** Бер тапкыр аунату; кинәт аунату

**Аунатып тору** Һәрвакыт, гел аунату

**АУНА́У** *ф.* **1.** 1) Яткан килеш, бер яктан икенче якка боргалану, тәгәрәү. *Урам тулы нәни балалар иде: куышлы уйныйлар, юл тузанында ауныйлар...* Хәйдәр. *Ярга йөзеп чыккач, апарада аунаган чучка кыяфәтенә кергән Иннокентий, шәпләп кенә, муен тамырыма бирде.* З.Мәхмүди. *Җирдә ауныйауный үкергән Гыйммран яралы бүрегә охшаган иде.* Н.Гыйматдинова

2) Тиешенчә файдаланылмыйча, тәртипсез, кадерсезләнеп яту. *Аяк астында кып-кызыл алмалар ауный.* И.Гази. *Бәрәңге җирендә кем тарафыннандыр чыгарылган буй-буй тышлы зур ястык ауный.* А.Гыйләҗев. *Мин, үз-үземне белештермичә, аңа иярдем. Күзлек юл тузанында аунап калды.* Т.Миңнуллин

3) Тәртипсез таралып яту. *Бу дөньяга без яр – сыңар-сыңар, Чуерташлар ауный җанда шуңар...* Р.Рахмани

4) *күч. сөйл.* Авырып яки ялкауланып, берни эшләмичә яту. *Ул, өйдә вакытта, көн буе йомшак түшәкләр өстендә ауный.* Г.Тукай. *Ир урын өстендә шактый гына аунады.* Р.Сибат. – *Их, энекәш, койкада ауный торган кеше идеммени мин? – дип, авыр көрсенеп куйды.* Г.Галиев

5) *күч.* Кадерсезләнү, түбәнлеккә төшү. *Сәләмә генә дә түгел, шул кулга алгысыз чүпрәк-чапрак арасында адәми зат гәүдәсе дә ауный бугай.* Җ.Рәхимов

**2. ауный-ауный** *рәв. мәгъ.* Тәгәрәп, бик каты, хәлдән тайганчы. *Елларны чишенеп ташла да, Яшел чирәмгә маңлып, ауный-ауный көл, әйдә!* М.Галиев

**Аунап алу** Берникадәр, бераз аунау

**Аунап тору** Бертуктаусыз аунау

**Аунап яту** Нинди дә булса урында аунау, кирәксез аунау. *Әнә анда ниндидер металл тотка аунап ята.* Ф.Углов. *Әти – укытучы, РОНОдан инспекторлар килеп чыккан, әти аларны чәйгә алып кергән, шунда очлы күзле инспекторларның берсе минем кучкарда аунап яткан комсомол билетын күргән.* Р.Батулла

**Ауный башлау** Аунарга тотыну. *Мөхетдин сыгылып төшә, эчен тотып, җирдә ауный башлый.* Т.Мөбарәков

**АУРО́ПАЛАНУ** *ф.* Европалашу. *Менә мин – әллә нинди яңлыш-йоңлыш аңлаган фикерләре берлә Ауропаның тормышына гашыйк булган, ауропаланыр өчен, актык биш тәңкәсенә пальто алган, бурычка алган акчасына исле майлар, кершәннәр алган, үзене француз романнарының каһарманы иттереп хисап иткән бер Дон Кихот!* Г.Исхакый

**АУРО́ПАЛЫ** *с.* Европалы

**АУРУ́ПАЛЫ** *с.* Европалы

**АУРУПОЦЕНТРИСТ** *и. рус* Европоцентризм карашлары тарафдары; европоцентрист. *Традициядән аерыла алмауның сәбәбе нәрсәдә соң? Теләк булмаудамы, әллә аурупоцентрист галимнәргә ярарга тырышудамы?* М.Зәкиев

**АУРУПОЦЕНТРИСТЛА́РЧА** *рәв.* Европоцентрист буларак эш йөртеп, аурупоцентристлар кебек, аурупоцентрист буларак; европоцентристларча. *Шуннан соң авторлар, этник тарих фәнен кайгыртып, аны аурупоцентристларча саклау максатыннан чыгып: --- «Борынгы скифләрне, сарматларны --- һәм аланнарны, башлыча төрки телле булганнар, дигән фикер белән килешүе кыен», – дип язалар*. М.Зәкиев

**АУЧЫ** *и.* Ау итүче, җәнлек аулау белән шөгыльләнүче, сунарчы. *Шәмсүн караваты ягындагы таш стенада – аучылар тормышын чагылдырган рәсемнәр*. А.Вергазов. *Аучы, ару-талуны белмичә, алга барды*. Ә.Гадел. *Тик Чекушкин күпме генә боргаланмасын, тәҗрибәле аучыны эз яздыра алмый*. М.Насыйбуллин

**АУЧЫЛЫК** *и.* Аучы һөнәре, аучы шөгыле. *Шул сезоннан Абу баба аучылык эшен ташларга мәҗбүр булды*. Б.Сөләйман. *Аучылык – аның гомер буе иң яраткан шөгыле икән*. М.Галиев. *«Тау дуңгызы» дигән сүзне ишетү белән, Идриснең аучылык тойгысы кайнап, ул урыныннан сикереп торды*. Ә.Айдар

**А́У ЭТЕ** *и.* Ау вакытында ярдәм итә алырлык күнекмәләргә махсус өйрәтелгән, яхшы нәселле эт. *Мөнә мондый гаҗәп вакыйга күрдем: бер төлкене бер ау эте куып китте*. Татар халык иҗаты

**АФӘРИН** *ы. гар.* **1**. Бик шәп, бик яхшы, яшә, мәгънәсендәге хуплау сүзе. *Афәрин, балакай! Әйтеп бак, кем булыр әлеге тетрәткеч юлларны язган шагыйрь?* Ф.Сафин. *Озын сүзнең кыскасы, афәрин, егетләр! Без исән, без яшибез!* К.Йосыпов

**2**. *и. мәгъ. иск.* Иң югары билге, «бишле» билгесе

**АФӘТ** *и. гар.* Зур фаҗига, һәлакәт, бәла-каза, зур бәхетсезлек. *Рамайның кайтырына санаулы гына көннәр калганда, ил өстенә афәт килде – сугыш чыкты*. Х.Хәйруллин

**АФӘТЛЕ** *с.* Фаҗигале, һәлакәтле, бәла-каза китерә торган. *Хәер, бу афәтле елларда, сарык бәрәннәренең генә түгел, бик күп адәм балаларының да мие туңган --- иде*. Р.Кәрами

**АФЕ́РА** *и. фр. сөйл.* Мәкерле, хыянәтле алдауга, хәйләгә корылган эш

**АФЕ́РАЧЫ** *и. к.* **аферист**. *Әлегә аферачы хатынның эзенә төшмәгәннәр.* Татарстан яшьләре

**АФЕРИСТ** *и. рус* Афера белән шөгыльләнүче кеше. *Безнең гамьсезлегебез аркасында, Мортаза кебек аферистлар безнең заводта урын таба алган икән, диверсантлар, шпионнарның да урын табулары мөмкин түгелмени?* Р.Ишморат. *[Жоржик] Инженер түгел, ә аферист. Ялган документлар белән яшәүче бер кеше ул*. А.Расих

**АФЕРИ́СТКА** *и. рус* Аферист хатын-кыз. *[Сатира:] Син, Миләүшә, алай димә, аферисткалар нәкъ шулай булалар алар*. Д.Салихов

**АФЕРИСТЛЫК** *и.* Аферист булу. *Алар эчәләр, кәеф-сафа табалар, жуликлык һәм аферистлык юллары белән махинацияләр коралар, халыкны алдыйлар...* М.Гали

**АФИ́ША** *и. фр.* Кино, концерт, спектакль һ.б. турында язма белдерү, игълан. *Ул афишалар тактасындагы «Шүрәле» балетына юлыкты*. Н.Хәсәнов. *Урам чатларында татарча язылган бик зур афишалар, ялт итеп, узган-барганның дикъкатен тартып тордылар*. Ш.Камал

**АФИ́ШАЛАУ** *ф.* Берәр нәрсәне күп тапкырлар сөйләү, халыкка мәгълүм итү. *Бу турыда язуым Мөнирнең чын ирләрчә күп ашавын афишалау өчен түгел, журналист халкына нәрсәләргә түзәргә туры килүен аңлатуым гына.* Акчарлак

**АФОРИЗМ** *и. гр.* Гомумиләштерелгән, төгәлләнгән фикерне кыска итеп әйтә торган тирән мәгънәле тәгъбир, хикмәтле сүз. *Афоризм! Үзегез уйлап тапканмы?* З.Фәтхетдинов. *Алга китеп, шуны да искәртик: без өйрәнгән VIII – XVII йөз ядкярләрендә 700 дән артык мәкаль, әйтем, табышмак һәм башка төр афоризмнар очрый.* Х.Мәхмүтов

**АФОРИ́СТИК** *с.* Афоризм характерындагы. *Табигый ки, ташъязмалардагы афористик гыйбарәләрнең бер өлеше нәкъ менә шушы аллаларның исемнәре һәм кылган гамәлләре белән бәйләнгән*. Х.Мәхмүтов. *Автор [Хәмит Ярми] афористик иҗат төрләренең халык тормышында тоткан ролен, ясалу юлларын, шигъри үзенчәлекләрен бай фактик материал җирлегендә ачып биргән*. С.Галин

**А́ФРИКАЛЫ** *и.* 1) Африкада яшәүче. *Ә көн эссе, филгә ни эшләргә? Ул юынырга шуннан тотынды. Колагын һәм башын югач та, Лаканда су бетте, бушады. Африкалы безнең кунакка Су коену чиксез ошады*. М.Җәлил

2) *сөйл.* Кара тәнле кеше, негр. *Кызның сүзе тәмамлангач, гарәп илләреннән килгән мөселманнар да, ялтыратылган хром итектәй йөзле африкалылар да фотоаппаратларын чалт-чолт китереп алалар, һәйкәлгә сокланып карап торалар, үзара нидер сөйләшәләр иде*. Р.Гарипов

**АФФЕКТ** *и. лат. махс.* Кеше үзе кылган гамәлләренең мәгънәсен аңламау, алар белән идарә итә алмау белән билгеләнә торган, кинәт барлыкка килгән артык каты ярсу халәте. *И.П.Павлов карашынча, кешенең эмоциональ, аффект халәт кичерүе физиологик нигезгә, ул да булса, динамик стереотипның җимерелүенә һәм яңа стереотипны урнаштыруның читенлегенә бәйләнгән*. К.Гыйззәтов. *Аффект вакытында, кеше үзе кылган гамәлләре өчен җавап бирми. Аффект халәтендә кылынган җинаять өчен чагыштырмача азрак җәза бирү каралган*

**А́ФФИКС** *и. лат. лингв.* Нигез сүзгә яки тамырга, тамырлашкан сүзгә алдына яисә артына ялганып, грамматик яки сүзъясагыч мәгънә белдерә торган сүз кисәге, кушымча. *Термин сүзләр тәрҗемә ителми, әмма, контекстта кулланганда, татар теленә хас аффикслар кабул итә*. Мирас

**АФФИНАЖ** *и. фр. махс.* Югары сафлыктагы затлы металларны табу ысулы. *Аффинаж затлы металларны*

*рафинацияләүнең бер төре буларак билгеле*

**АФФРИКА́ТА** *и. лат. лингв.* Шартлаулы аваз (йомык тартык) һәм өрелмәле аваз (ярык тартык) элементларыннан торган тартык аваз; ике тартык авазның кушылуыннан барлыкка килгән тартык аваз (мәс., *«ц» һәм «щ» авазлары*). *Рус аффрикатасы – «ч», ягъни [тш'] авазы, татар телендә юк диярлек. Ул бары тик рус теленнән кергән алынмаларда һәм кайбер диалектларда гына кулланыла.* Татар теле

**АХ** *ы.* 1) Үкенү, ачыну, кайгыру кебек хисләрне белдерә. *Аптырый, ботка суга, ах, дип куя, «Ах, юләр мин, ах, мин ахмак!» – дип куя.* Г.Тукай. *Ах... валлаһи, нинди яман, нинди күңелсезлек! Бик зур балык көткәндә, буш кармак килеп чыксынчы!* Г.Ибраһимов. *Ах, никадәр хаклы булган икән ул!* Хәйдәр. *Ах, урынсызга кыен ашаган, чарасыз калган чакларым...* Р.Низамиев

2) Әрнү, газаплану, сызлану, сагышлану кебек хисләрне белдерә. *Ах, минем сайрар җирем урман иде, Анда һәртөрле кызык тулган иде.* Г.Тукай

3) Берәр кешедән яисә нинди дә булса әйбердән яки эштән ризасызлыкны аңлата. *Ах, менә ничек! Серкәбез су күтәрми, диген.* Р.Ишморат. *Ах, сасы чикмән, син әле мондамыни?* М.Хуҗин

4) Шатлану, куану, соклану, таң калу кебек хисләрне белдерә. *Ах, ничек гүзәл син, Сания!* Х.Хәйруллин. *Ах, хәйләкәр абый! Җирне, кешеләрне яраттырып, яраттырган икән үзен дә.* Р.Гаташ

5) Куркып китүне, кинәт кенә өркүне, шомлану, шөбһәләнү, аптырап калуны белдерә. *Ах, аяклар да калтырый!.. Хәзер көзән җыера башлый ахры... Ах! Җитеп кенә булса ярар иде.* Ш.Камал. *Ирләр, «ах» дип, артка чигенделәр.* М.Мәһдиев. *Яр буенда хатын-кызлар «ах» итте, кулларыннан юган керләре төште.* А.Хәсәнов

6) Ачулану, тиргәү, шелтәләү, зарлану, сукрану кебек хисләрне белдерә. *Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул; Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул.* Г.Тукай

◊ **«Ах» итү** 1) Ару, талчыгу; чарасызлыктан газаплану. *Фатыйма эшкә ат җигеп йөри, иртән атның дилбегәсен тапмыйча «ах» итте.* З.Кадыйрова; 2) Кинәт куркып китү, аптырап калу. *Менә аның кул-бармаклары йөзенә менеп җитте... Тагын бер «ах» итте Хәлим. Аның йөз-битен сакал-мыек баскан иде...* Г.Гыйльманов

**АХАК** *и.* **1.** 1) Берничә катламнан гыйбарәт булган төрле төстәге каты минерал; кыйммәтле таш. *Хатыннар ягында эш тагы башкача иде: анда киң җон күлмәк, бөтен тәңкәләрдән, ахаклардан тулган киң хәситә кигән, өр-яңа зур җон яулык бәйләгән Мәрфуга абыстай әлгәреге Мәрфуга абыстайга – ире юк вакытта ит үлчәп бирә торган, тавык йомыркалары өчен күрше хатыннары белән оршыша торган Мәрфуга абыстайга бөтенләй башка иде...* Г.Исхакый

2) Кызыл, кызгылт сары, алсу төс. *Ак якага җәелә акрын гына Ал шәфәкънең алсу ахагы.* М.Әгъләмов. *Шушы чын ахак төсендәге шәрабта – диңгез һавасының сафлыгы, кояш нурларының рәхимле җылысы.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул асылташтан эшләнгән, шуннан гыйбарәт. *Йөзегеңә ахак кашлар тапмадым, Нахак сүзләр кем сөйләде, аппагым?* Т.Миңнуллин

2) Ахакка охшаган, ахак төсле (нурлы, ялтырап торган). *Без барыр юлларны яктыртып Яндылар чын ахак йолдызлар.* М.Җәлил. *Ирләр әле абзарда, коры такта идәндә басып торган кара ялтыравыклы ахак күзле, озын торыклы, чиста гәрәбә тояклы, чыгынкы маңгайлы юеш борын [пошибаласы] янында әйләнгәләп йөриләр, бу мәхлукка якын килергә, муенын сыпырырга тырышалар иде.* М.Мәһдиев

**АХАКЛАНУ** *ф. шигъ.* Ахакка охшап китү, ахакка охшап тору, ахак төсенә керү. *Менә тиздән, таң офыгын ярып, Кояш янартавы атылыр, Ахакланган чыклар белән юылып, Чәчәкләрнең күзе ачылыр.* Ш.Маннур

**А́Х-ВАХ ИТҮ** *ф.* Ахылдау, зарлану. *Ярдагы хатын-кызлар ах-вах итештеләр.* А.Вергазов. *Ах-вах итеп, зар елап, канлы яшьләрен түгеп утырмады [Нәфисә], Гөләшне кочагына алды да, сәкегә менеп, бөгәрләнеп ятты...* Г.Гыйльманов

**А́Х-ВАХ КИЛҮ** *ф. к.* **ах-вах итү.** *– Китте бит, җен алгыры, китте... Беләк буе иде, беләк буе! – диде ул, ах-вах килеп.* Э.Касыймов. *Няня ялалының бик яшь – бары малай гына булуына шаккатып, ах-вах килеп, тумбочкага өелгән ризыкларны җыештырырга кереште.* Х.Камалов

**АХИР** *и. сөйл. к.* **ахирәт** *(2, 3 мәгъ.).* *И ахир, сиңа гына түгел, миңа да якын, кадерле ул Май апа!* Г.Гыйльманов. *Бу синмени, ахир?* Р.Батулла. *Ахир, синнән 3 яшькә олырак булыр ул хатын, Минҗамал исемле.* Шәһри Казан

**АХИРӘТ** *и. гар.* 1) *дини* Ислам динендә: үлгәннән соңгы тормыш, «теге дөнья»; *киресе*: **дөньялык**. *[Хәзрәт:] Сез өч көнлек дөнья өчен бөтен ахирәтне онытмагыз.* Ф.Әмирхан. *Кайвакытта ахирәтне дә уйлап җибәрәмез, намаз укыймыз.* Г.Тукай

2) *сөйл.* Үлгәнче якын дуслар булырга ант иткән кеше. *Инде васыятькә калган, ахирәтем биргән чүлмәкне дә ваткач, тагын әллә нинди гөнаһ шомлыклары китерер.* А.Шамов

3) Якын дусларның бер-берсенә мөрәҗәгать сүзе. *Ничек булсын, ахирәт, бик рәхәт яшибез.* Р.Хисмәтуллин

◊ **Ахирәт сәфәренә китү** Үлү, вафат булу

**АХИРӘ́Т КҮЛМӘГЕ** *и.* Беренче кат кәфен

**АХИРИ** *и. сөйл. к.* **ахирәт** *(2, 3 мәгъ.).* *[Фәттах:] Королёв аның якын ахирие булган.* Д.Салихов

**АХМАК** *с. гар.* **1.** Юләр, аңгыра, акылга сыймаган. *[Таһир:] Куй, Шәмсия, ахмак сүзне сөйләмә.* Т.Гыйззәт. *Сыер дигәнең бик ахмак нәрсә бит ул, яхшылыкны белми, аңарга ашарга гына булсын; корсак өчен кырык мәртәбә үләргә әзер.* Һ.Такташ

**2.** *и. мәгъ.* Юләр, аңгыра, акылы булмаган кеше. *Шушы хәтле алдашып та хәзер дөресен әйтсә – кыз алдында ахмакның да ахмагы булып кала бит инде ул!* В.Нуруллин. *Ләкин, күпме азапланмасын, беләзекнең кыршылмыйча калган урынындагы «...гәүһәр даш улмаз...» һәм «...кадрене ахмак белмәз...» дигән сүзләрне генә аера алды.*

*Башкалары инде ашалып беткән, танырлык түгел иде.* Ф.Латыйфи

**АХМАКЛАНУ** *ф.* Акылсызлык, ахмаклык эшләү, юләрләрчә, ахмакларча кылану. *Анда зур артисткалар, дәү апалар җыелгандыр, дип уйладым мин, ахмакланып кереп, игътибарларын үземә җәлеп итмим әле, янәсе!* Ә.Еники

**Ахмаклана башлау** Ахмакларча кыланырга тотыну. *Бәлки, ак халат кына зифа итеп, матур итеп, яшь итеп күрсәтәдер? Әчтән генә сүгенеп куйдым – әллә ахмаклана башладым инде.* Т.Миңнуллин

**Ахмакланып алу** Азга гына ахмаклану, берникадәр вакыт ахмаклык эшләү

**Ахмакланып бетү** Тәмам, бөтенләй ахмаклану

**Ахмакланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта ахмаклык күрсәтү. *Далада очкан мамык куып йөрүче тинтәк кебек, бөкрәйгәнче, шушы бина тирәсендә ахмакланып йөрмәячәк ул.* С.Поварисов

**Ахмакланып китү** Нindидер этәргеч белән, берәр төрле хәлдән соң ахмаклану

**Ахмакланып кую** Кинәт ахмаклану

**Ахмакланып тору** Әле, күз алдында ахмаклык күрсәтү

**АХМАКЛА́РЧА** *рәв.* Юләр, акылсыз, ахмак кешеләргә хас булганча. *Менә ул, юләр кешегә охшап, ахмакларча тавышлар чыгарып көлә башлады.* Р.Сибат

**АХМАКЛЫК** *и.* Ахмак булу, юләрлек, аңгыралык, акылсызлык. *Шуңа күрә дә шушындый бәрәкәтле яшәеш тәҗрибәсеннән баш тарту – үзе үк ахмаклык һәм, һичьюгы, беркатлылык булыр иде.* Н.Гамбәр. *Турыдан-туры «ахмак» дип әйтергә кирәк иде миңа. Һәм, ахмаклыгын, аңгыралыгын исбатлап, тиз генә чыгып китәргә иде.* Т.Миңнуллин

**АХРЫ** *кер. сүз* **1.** Сөйләмгә икеләнү, шикләнү, төгәлсезлек төсмерләрен өсти; ихтимал, бугай, шулай булса кирәк. *Карт та моны сизде, ахры, тиз генә капчыгына үрелде...* А.Алиш. *Шуңадыр, ахры, үлем түшәгенә яткан карчык, тәмам савыгып, аягына басты.* Э.Касыймов

**2.** *кис. мәгъ.* Шикләнеп, чамалап әйтүне белдерә. *Бу газаплы күңел бушлыгы, бу рухи кибегү яшьлек антларыбызга хыянәт иткәнем өчен җәза иде ахры.* Р.Хисмәтуллин

**АХРЫСЫ** *кер. сүз к.* **ахры**. *Язгы кояш нуры минем күзләремә карый, ул, ахрысы, минем шатлыкны сизәдер, бераз елмайган кебек тоела.* Г.Ибраһимов. *Тик Сәфәр генә – күршелек хакы өчендер, ахрысы – кешеләргә юнәлтеп, каты-каты гына сүзләр әйткәләде.* Ш.Камал

**АХУН** *и. фар. дини* Мөселманнарда: югары дәрәҗәле дин әһеле; өлкән рухани. *«Тәрҗеман» иясе байларның тарелкасын ялап, ахуннарның гаебен яшереп азапланды.* Г.Тукай

**АХУНЛЫК** *и. дини* Ахун булу дәрәҗәсе, ахун вазифасы. *Котлымөхәммәт исә – патшалар, санатлар, аннан да битәр илчеләр арасында кайнаган морза – төрле сөйләшүләрнең рәтен белә, хуҗаның кыюсыз каршылыкларын берсеннән-берсе саллырак сүзләр белән томалый торды, Яңа бистәдә дә ахунлык дәрәҗәсендә калачагы белән кызыктырды...* Җ.Рәхимов

**АХУ́Н ХӘЗРӘТ** *и. дини к.* **ахун.** *Югары оч мәчетендә мулла вазифасында – Рәҗәп хәзрәт, 1883–1929 елларда – Ахун хәзрәт Мөхәммәтзариф һәм 1934–1939 елларда – Зыятдин хәзрәт, ә мәзин вазифасында Мөхәммәтшакир тора.* К.Йосыпов. *Эшләремне җиренә җиткереп, намус илә эшләгәнем өчен, 1898 елда, Духовное собраниенең указы илә, Ахун хәзрәт исеме бирделәр.* К.Йосыпов

**А́Х-УХ ИТҮ** *ф.* Уфылдау, көрсенү, ризасызлык белдерү. *Ул, котырынып, уңга ташланды, ах-ух килде.* Ф.Садриев. *Менә ул сәкедән тәгәрәп диярлек идәнгә төште. Биле сынган сыман арт санын сөйрәп, ишеккә таба шуыша башлады. Ах-ух итсә итте, әмма пар ат җигелгән чанага кадәр үзе чыкты.* М.Хәсәнов

**А́Х-УХ КИЛҮ** *ф. к.* **ах-ух итү**. *Ул тәмәке төтененнән саргая башлаган ак сакалына тагын бер кагылап алды, аннары, ах-ух килеп, Елгыр түккән солыны чиләккә тутыра башлады.* Г.Гыйльман. *Мин сөйләгәнне шофёр ах-ух килеп тыңлады.* Т.Миңнуллин

**АХШАМ** *и. фар.* 1) Кичке эңгер-меңгер вакыт. *Көннең иң яманcу чагы – икенде белән ахшам арасы, ди торган иде Динәнең әбисе.* М.Маликова

2) *иск.* Кичен уздырыла торган мәҗлес, бәйрәм, кичә. *«Сәйяр труппасы», һәр җиргә йөреп, театрлар уйный, төрле шәһәрләрдә әдәбият ахшамнары да булдыргалый.* Г.Ибраһимов. *Кызыл Крест файдасына театрлар уйнап, ахшамнар ясап йөргән әфәнделәрнең, медаль алыр өчен, «спасибо» ишетер өчен генә йөргәннәрдер, дигәнгә ышанасым килми.* Г.Исхакый

3) *дини* Кичке намаз. *Кояш баеганмы, диеп, Моңсу гына багамы? Кыйбла ягына юнәлеп, Намазлыгын җәяме? Ахшам укырга җыенып, Ул зиһенен җыямы?* Ф.Әһлиуллина. *Кеше ахшамны укып чыкканда, караңгылык төшә башлаган иде инде.* Р.Гали

4) *диал.* Кичке азан. *Ахшам тыңларга җыелу (кичке азанны шулай дип атый идек) – үзе бер күңелле эш.* Ә.Еники

5) *күч.* Ахыр, азак. *«Күрәсем килми. Кит!» Хатын аның тавышын сүз әйтелешеннән аңлады: бу, чынлап та, икеелык матур бер тормышның көтелмәгән ахыры, ахшамы иде.* Х.Миңнегулов

◊ **Ахшам күләгәсе** Бик озын буйлы, чандыр гәүдәле кешегә карата әйтелә

**АХША́М МИЛӘҮШӘСЕ** *и.* Әвернәчәчәкләр семьялыгыннан, төнлә чәчәк ата торган хуш исле гөл. *Яп-яктыда ахшам чәчәген балкытырга синең генә көчең җитә.* М.Хуҗин. *Төп серкәләндерүче бөҗәкләр – чебен, умарта корты, төклетура. Кайбер төрләрен, мәсәлән, шеббуй, ахшам миләүшәсен төнге күбәләкләр серкәләндерә.* Л.Мәүлүдова

**АХШАМ НАМАЗЫ** *и.* Биш вакыт намазның дүртенчесе, кичке эңгер-меңгер вакытта укыла торган намаз. *Сөннәтче бабай ахшам намазына барыр өчен тәһарәт алырга комган эзләргә тотынды.* Г.Исхакый. *Икенде намазын укыгач, Хәят әби малларны карагач, ахшам намазын укыды.* А.Таһиров

**АХШАРУ** *и. диал.* Яз көне балалар уйный торган күмәк җырлы әйлән-

бәйлән уены. --- *арадан берсе, каршыларына басып, чираттан һәрберсенең күкрәгенә төртеп такмак әйтә: Кисәк-кисәк болыт килә, Киселмәгән арыш килә. Ахшару-Ахшару, Ахшару атлы. Суган алдым – суганым татлы. Туганыма бер кыз алдым, Каләмкаш атлы. Каләмкашка тун тектердем – Үзенә чаклы* ---. М.Мәһдиев

**АХЫЛДА́У** *ф.* 1) Сызлану, сыкрану; борчылу, кайгыру; чарасызлыктан ни эшләргә дә белмәү. *Хәтмулла картның күзенә йокы кермәде. Карчыгы Хәмдияне сукрандыра-сукрандыра, ахылдап, ятагында әйләнеп ятты да төн уртасында урамга чыгып китте.* Г.Гыйльман. *Егетебез юл буе ахылдап, йөткереп барды, кирәкмәгән эш эшләвеннән уңайсызланып, ахры, елап та алды.* Г.Галиев

2) Арып, хәлсезләнеп зарлану. *Дүртенче тәүлеккә чыкканда, Фәхринең күптәнге юлдашы Акбай, арып, ахылдап, телләрен салындырып кайтты.* Г.Ибраһимов

3) Гаҗәпләнү, соклану. – *Бар икән безнең мөселманнардан да шундый мәһабәт кешеләр! – дип ахылдадылар шәкертләр.* Ә.Фәйзи

**Ахылдап алу** Аз гына, бераз ахылдау. *Кемдер: – Тәңрем, сакла! – дип ахылдап алды.* М.Хәбибуллин

**Ахылдап йөрү** Әле, хәзер андамонда йөренеп ахылдау. *Сепаратта сөтеңне аерта алмыйсың. Ойый инде, харап була инде, дип, ахылдап йөрисең.* Г.Мөхәммәтшин

**Ахылдап кую** Бер тапкыр ахылдау. *Булмәгә кергәч, утны кабызды, кинәт күзенә ыргылган яктылыктан башта берни дә күрми торды. Күргәч ахылдап куйды: «Бала-ам...».* Р.Зәйдулла

**Ахылдап тору** Бертуктаусыз ахылдау

**Ахылдап чыгу** Билгеле бер вакыт аралыгында ахылдау; шул вакытның башыннан ахырына кадәр ахылдау. *Төн буена, боргаланып, ахылдап чыкты*

**АХЫР** *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәнең азаккы өлеше, чиге, беткән, тәмамланган урыны. *Аллаһымның барлыгына, әүвәл, ахыр юк аңа, Бету дәхи юк аңа – бердер Аллаһым бәнем.* Мөнәҗәт. *Йосыповның шигырьләрендә форма-бетем – юл ахырларының охшашлы сүзләр белән бетү ягы да аксый.* М.Җәлил

2) Билгеле бер вакыт арасының беткән чагы, соңгы моменты, азагы. *Җәй аеның иң хуш вә иң хозур чагы – сәратан ахырлары иде.* Җ.Рәхимов. *Июнь ахырына госпиталь корпуслары бушап калды.* Ә.Маликов

3) Нәрсәнең дә булса, берәр эшхәлнең нәтиҗәсе, азагы. *Җизнәң әйтә: марҗа кызына ияләнсә, ахыры яхшыга бармый инде аның, ди.* Ф.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* Ахыргы, соңгы, азаккы, актыккы. *Улыгыздан сезгә кайнар сәлам, --- Улыгыз сезнең ахыр сулышта да Чыгармады сезне уеннан.* Ш.Маннур

**3.** *кер. сүз функ.* Ниһаять. *Ахыр, без аш ашап утырган чакта, кызышып, үзен-үзе югалтты, аш куйган табынга төкерде дә каргап, рәнҗеп чыгып китте.* Г.Ибраһимов. *Ахыр, Габделгаллэм, аз гына вакытка булса да кереп, күреп чыгарга карар бирде.* Г.Ибраһимов

◊ **Ахыр барып** *к.* **ахыр килеп**. **Ахыр гомерендә** Ахыргы көннәрендә, соңгы көннәрендә, үләр алдыннан. *Ахыр гомерендә булса да шуларга ирешә алуы өчен, язмышның каһәрләре белән телгәләнгән карт йөрәгә эчендә бер дулкын ята. Г.Ибраһимов.* **Ахыр җан** *кимс.* Әшәке җанлы, начар кеше; адәм актыгы **Ахыр заман** 1) *дини* Кыямәт көне, дөнья ахыры: дөньялыкта кылган гамәлләре өчен үлгәннәрдән хисап алып, ярлыкау яисә җәза бирү көне. *Дәҗҗал – «Ялган мәсих»; алдакчы, ялганчы, мәгънәсендә; имеш, ул ахыр заман җиткәч, ишәккә атланган килеш, Иблис коткысы белән, Аллага һәм аңа ышанучыларга каршы чыгачак, аны күргән мөселманнар һәлак булачак. Христиан динендә аны «ялган Христос» – антихрист дип атыйлар. Мөселман хәдисләрендә, Дәҗҗал диңгез буендагы кыяга кадакланган, дип күрсәтелә.* Ислам дине турында белешмә. *Ахыр заман җитә, дип сүли-сүли, кайберәүләрнең авыз сулары гына корымады...* Г.Әпсәләмов; 2) *күч.* Бик зур тәртипсезлек, талаш-кычкырыш, ыгызыгы. *Ахыр заман анда, кыямәт, үзара талаш, кычкырыш бара!* Т.Гыйззәт. **Ахыр заман баласы** Бар нәрсәне дә белүгә, аң-белем дәрәҗәсенең югары үсешенә ишарә итеп кулланыла. *Сәфәр бабай да шакката: «Вәт ахыр заман баласы нишли бит!» – ди.* Ә.Фәйзи. **Ахыр килеп** 1) Ниһаять. *Ахыр килеп, хезмәтен башлый, Петербургка китә, әдәбиятка хезмәт итә башлый – цензор булып китә.* Г.Нигъмәти; 2) Ахырда, соңыннан. *Ахыр килеп, сез мине матур итеп озаттыгыз.* М.Җәлил. **Ахыр сәгатьтә** 1) Иң азаккы, иң соңгы мизгелдә; 2) Үлем сәгатендә, җан биргәндә. **Ахыр сулуларында** Үлгән вакытта, җан биргәндә. **Ахыр чиккә җитеп** 1) Бик нык, үтә, тәмам. *Ул үзенең ахыр чиккә җитеп арыганын һәм йокысы килгәнен белде.* Г.Гобәй; 2) Түзә алмаслык хәлдә, бик авыр хәлдә **Ахыр чиктә** 1) Нәтиҗәдә. *Ярый, ахыр чиктә, сул кулың скрипкада уйнарлык булып тазармасын да, ди.* Г.Бәширов; 2) Бик нык, үтә, тәмам. *Ахыр чиктә, борчылган партизан өчен айның тууымы булды ни дә, кимүеме булды ни: әлбәттә, барыбер иде.* Г.Гобәй; 3) Соңыннан, ахырда. *Хәлем бетәр дә иң кирәген әйтә алмый калырмын, дигән кебек, бик сакланып, ахыр чиктә әкрен итеп сөйләде.* Г.Гобәй. *Ахыр чиктә соңгы хөкемне һәркем үзенә үзе чыгара.* Р.Батулла. **Ахырына җиткерү** Тәмамлау, төгәлләү, эшләп бетерү. **Ахыры хәерле булсын** Нинди дә булса көтелмәгән хәл килеп чыкканда, уңай теләк рәвешендә әйтелә

**АХЫРГА́ЧА** *рәв.* Азакка кадәр, актыгына чаклы, ахырына кадәр. *Поэма текстның үзенә баштан ахыргача ун һәм тугыз иҗекле мисалларының аллы-артлы кабатлануы рәвешендә китерелгән.* Г.Нигъмәти. *«Тирән тамырлар» әсәре баштан ахыргача өч момент, ягъни хуҗалык, сәясәт, шәхси моментларны төрле катлаулы вакыйгалар җебенә чолгандырып гәүдәләндереп бирә.* Г.Нигъмәти

**АХЫРГЫ** *с.* Азаккы, актыккы, соңгы, актыктагы. *Августның ахыргы көннәреннән берендә безнең артельгә совхоздан трактор килергә, артельнең Яшел Елга тамагындагы чирәмен сөреп бирергә тиеш иде.* Ф.Әмирхан. *Якты-*

*сы күзләрне чагылдыра торган ачык вә үзенә бертөрле эсселекле язгы кояш кичә явып киткән яңгырның калдырган ахыргы юешлекләрен дә инде киптереп бетерә башлаган*. Ф.Әмирхан

◊ **Ахыр(гы) сүз** Соңгы сүз, йомгак, нәтиҗә буларак әйтелгән өлеш. *Аның драмаларында алынган типлар, чынлап караганда, үзләре көлкеле типлар булып чыгалар. «Бәхетсез егет»нең беренче басмасына язган ахыр сүзендә Г. Камал үзе дә шуны аңлата*. М.Гали

**АХЫРГЫСЫ** *и. сөйл. к.* **ахыргы**. *Әхмәт, хәзрәтнең сүз ахырын көтмәенчә: – Әүвәлге җөмләнә ышанам, ләкин ахыргысы – яңлыш, алар гыйлемне очсыз итмәделәр, бәлки тәгассыпны очсыз иттеләр, – диде*. Ф.Әмирхан

◊ **Ахыргысы булсын** Башка кабатланмасын, соңгы мәртәбә булсын (кисәтү йөзеннән әйтелә). **Ахыргысы-соңгысы булсын** *к.* **ахыргысы булсын**

**АХЫРДА** *рәв.* 1) Соңыннан, азакта, билгеле вакыт үтү белән. *Иң яраткан яшь хатыны Кәримә, ирен тентүгә булышчылык кылып йөри дә, ахырда инвалид кызылармеецка кияүгә чыга*. Г.Нигъмәти

2) Ахыр чиктә, башка чара калмагач; ниһаять. *Ахырда Сабир абзый түзмәде, башын борып, тимер читле күзлеген салды һәм яшьләнгән күзләрен кул сырты белән сөртеп алды*. Ә.Еники. *Карчык ни әйтергә белми, иреннәрен кыймылдата, ахырда тизрәк чыгып китү ягын карый*. Ә.Фәйзи

**АХЫРДАН** *рәв.* Берникадәр вакыт үткәч, азактан, соңыннан. *Ахырдан мәгълүм булды: бу ике, кемнәндер Садыйкның мондалыгын ишетеп, эләктерү өчен кергән булганнар икән*. Г.Ибраһимов. *Аның иптәшләре, ишегалдында саклап торган шикелле көтеп торалар да, аны үзләре белән алып китеп эчертәләр, исертәләр дә ахырдан ямщик белән өйгә китереп ташлыйлар*. Г.Камал

◊ **Ахырдан килеп** *к.* **ахыр килеп**

**АХЫРЫНА́ЧА** *рәв. к.* **ахыргача**. *Гайшә исә алдагы айларда ахырынача тынычланды*. К.Йосыпов

**АХЫРЫНДА** *рәв.* Ахырда, ахырдан, ахыр чиктә. *Ахырында чыдамадым, дәштем: – Ягез, абыйлар, алай теш белән уйнарга яраткач, уйнашып карыйк алайса*. Ф.Хөсни

**Аһ** *ы.* **1**. 1) Шатлык, кинәт гаҗәпләнү, соклану һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Аһ, нинди могҗиза!* Ш.Маннур

2) Түземсезлек, сабырсызлык, канәгатьсезлек, ачулану, шелтәләү, шулай ук дулкынлану һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын, Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын*. Г.Тукай. *Җиңел тоям хәзер үземне, Аһ, тиз, аһ, тиз сөйлә*. Н.Исәнбәт. *Аһ, хәзер дә ул, элекке кебек, ялкынланып, дәртләнеп уйнап җибәрсен иде!* Г.Бәширов. *Аһ, ичмасам, шунда утыртмасыннар иде*. Р.Хисмәтуллин

3) Зур кайгы-хәсрәттән, тирән борчылу, кайгырудан, авыртудан ахылдауны белдерә. *Аһ! дигәндә якын торма, янарсың ялкыныма*. Җыр. *И җаным, аһ, минем солтаным, сиңа ни булды?* К.Насыйри

4) Үкенү, көчле теләк, зарлану һ.б.ш. хисләрне белдерә. *Ни газизрәк – бу Ватанмы? Аһ, туган каумем газиз*. Дәрдемәнд. *Тынма әле, Тынма әле, яңгыр. Син туктасаң, җанга, аһ! Авыр...* Р.Аймәт

**2**. *и. мәгъ.* Кайгы-хәсрәт, газап; моңзар. *Син үзеңә туплагансың --- Безнең бөтен аһларны, Аһларны, аһ-зарларны*. Г.Рәхим. *Тимә арган хисләремә! – Шуңа шагыйрьнең аһы...* Р.Гаташ

◊ **«Аһ» итү** *ф.* Кайгыру, борчылу, нәрсә эшләргә дә белмәү. *Син «аһ» итсәң, яна йөрәгем; Кулым тотсаң, яна беләгем*. Н.Исәнбәт. *Бу да, гүя, бүген озатылган Садыйкның китүе өчен еглаган йөрәкнең «аһ» итеп куюы кебек тоела иде*. Г.Ибраһимов. **Аһ ору** Бик нык кайгыру, өзгәләнү, шундый кайгыдан тирән сулап уфтану. *Союзниклар аһ ора, чәчләре үрә тора, Кычкырганга безнең Мәскәү һәрбер мәйданда «ура!»*. Г.Камал. *Бөтен барлыгымны бер мәхрүмлек тойгысы каплап ала; аһ орасы, елыйсы килгән шикелле була*. Ф.Әмирхан

**АҺА** *ы.* 1) Кемнеңдер булдыклылыгына, тапкырлыгына соклану, гаҗәпләнү, канәгатьлек белдерү өчен кулланыла. *[Әҗәл:] Аһа! Ошый башладың әле син миңа, картлач*. Т.Миңнуллин

2) Кемнең дә булса уңышсызлыгына, кайгысына, һ.б.ш. куану, киная белән тәртеп күрсәтү, канәгатьлек белдерү өчен кулланыла; әһә. *Аһа! Узына торгач җиттеңме?*

3) Нәрсәгә дә булса төшенүне, нәрсәне дә булса аңлап алуны, нәтиҗә ясауны белдереп кулланыла; әһә. *Әгәр ул минем болай язганымны белсә: «Аһа, контр икән ул!» – дип, тегендә ябарга кушар иде*. Г.Бәширов. *[Мөхәммәт:] Аһа, зур эшләр майтарып йөрисең икән әле син*. З.Хөснияр

**АҺА-ҺА-ҺА-ҺА** *иярт.* Адашып, югалып, эзләгәндә, тавыш бирүгә җавап аваз иярteme. *Ул аргы яктан кабат «көймә» дигән тавышка, кулларын авыз кырыена куеп, «Аһа-һа-һа-һа-а!» дип эндәште*. Г.Гобәй

**АҺӘҢ** *и. фар. шигъ.* 1) Төзек, ятышлы яңгыраш, гармония. *«Ана теле» дип тикмәгә әйтмиләр – карында чакта ук шул аһәңгә көйләнә бала*. Ш.Галиев. *Җир-Су-Кояш тылсымыннан бар ителеп, илаһи камиллеккә ирешкән гөлләр нинди телдә сөйләшә икән? --- Без ишетә алмаган аһәңнәр телендәме?* М.Галиев

2) Моң, көй; ләззәтле кичереш, тойгы. *Аннан соң, печән өстенең, элек-электән, кабатланмас үз аһәңе, үз моңы бар*. М.Әмирханов. *Үзе җырларга бик яратмаса да, туганының әлегә моңарчы ишетелмәгән бер моң-аһәңне көйләп баруы аны әсәрләндереп җибәрде*. Р.Сибат

3) Тон, тавыш, авазларның ярашканлыгы. *Белемле кеше аларда «беләр» дип атала, шуның өчен бу илне «Беләр» дигәннәр, аның мәгънәсе – «галим кеше». Шуны гарәп теле аһәңенә яраклаштырып, «Болгар» дип йөртә башлаганнар*. Татар халык иҗаты

**АҺӘҢДӘШ** *с.* 1) *муз.* Яңгырашлары бердәй, бер төрле яңгырашлы, яңгырашлары белән охшаш. *Аһәңдәш булып чишмәгә, Таудан тауга ургылып, Йөрәгемә килеп тула Теләкләрем, җыр булып...* С.Муллагалиев

2) *к.* **аваздаш** (*2 мәгъ.*). *[Равил Фәйзуллин] --- тулы бер халыкның ничәмә-ничә гасырлар буена тупланган*

*зирәклеген вә тәҗрибәсен чагылдырган борынгы Кытай мәкаләнә аһәңдәш күзәтүләр ясады.* Н.Гамбәр

**АҺӘҢДӘШЛЕК** *и.* Аһәңдәш булу. *Рифмасыз шигырь бер-ике табышмакта гына күренеп китә. Бу очракта аһәңдәшлек аллитерация һәм ассонанс хисабына хасил була.* Х.Мәхмүтов

**АҺӘҢЛӘШТЕРҮ** *ф.* Аһәңле итү. *Рус музыкант вә композиторлары тарафыннан татар көйләрен аһәңләштерү турында азмы-күпме уңышлы тәҗрибәләр ясалган иде.* Татар театры

**Аһәңләштерә бару** Акрынлап аһәңләштерү; тагын да аһәңле итү

**Аһәңләштерә төшү** Берникадәр, бераз аһәңләштерү

**Аһәңләштереп бетерү** Тәмам, тулысынча аһәңләштерү

**Аһәңләштереп тору** Аһәңләшкән халәткә китерү; даими яки әледән-әле аһәңләштерү

**АҺӘҢЛЕ** *с. шигъ.* 1) Аһәңе булган; моңлы. *Шигырь ул – күңел кылларыннан Раббы сулышына көйләнеп үрелгән аһәңле читлек.* М.Галиев

2) Дулкынланулы, тирән кичерешле. *Никадәр югары аһәңле сүзләр, Әбүзәр абый!* Ш.Маннур

**АҺӘҢЛЕЛЕК** *и.* Аһәңле булу. *Сөйләмнең музыкаль җегәрен, колакны иркәли торган аһәңлелекне ул сирәк куллана.* Р.Әхмәтҗанов

**А́Һ-ВАҺ** *и. к.* **аһ-зар**. *[Автор] Кешеләрнең аһ-ваһларын, газаплы тормышларын ачып сала алмый.* М.Җәлил. *--- ишек төбенә җыелганлыктан, кысылып, кабыргалар сынарга җитешә, һәм ул арада туннарын, аяк киемнәрен югалткан кешеләрнең аһ-ваһлары да, үзенә бер төрле булып, гомуми күренешкә фаҗигале халәт бирә иде.* Ф.Әмирхан

**А́Һ-ВАҺ ИТҮ** *ф.* 1) Борчылу-кайгыру, бертуктаусыз зарлану. *Әбу-Кабис тавына җыйналышкан җеннәр, диюләр, шайтан ыруы, аны бу хәлдә очратып, аһ-ваһ иттеләр.* Ф.Яхин

2) Бик нык ашыгудан яки арудан хәл бетү, аһылдау. *Чуар тавык, чебешләрен генә ияртеп, аһ-ваһ итеп кайтып керде.* А.Алиш

3) Кем өчен дә булса өзелү, өзгәләнү

**А́Һ-ВАҺ КИЛҮ** *ф.* 1) *к.* **аһ-ваһ итү.** *Бөтен бригада, аһ-ваһ килеп, печән эзләп йөри.* Г.Бәширов. *Соңгы елларда Илдус, аһ-ваһ килеп, электрик саву аппаратлары көйләтеп йөрде.* К.Тимбикова

2) Гаҗәпләнү, шаккату. *Поезддан төшкәч, Әхәт, аркасындагы биштәре авыр булуга карамастан, Казанның танымаслык булып үзгәрүенә аһ-ваһ килеп, җәяүләп кенә, энесе яшәгән Ерганак урамына юл тотты.* З.Мәхмүди

**АҺ-ВАҺЛА́У** *ф. сөйл. к.* **аһылдау.** *Пар өсти дә чак кына, сары себеркесен селтәп, аһ-ваһлап чабына.* Р.Харис

**А́Һ-ЗАР** *җый. и.* **1.** 1) Кайгы-хәсрәт. *Һәм ул бөтен гаделсез эшләтүләрне, аһзарларны ярып салды.* Р.Хисмәтуллин. *Әйтерсең аның маңгай өстеннән күтәрелгән бу чал бөртекләре – эченнән бөркелеп чыккан аһ-зар сөреме иде.* Ш.Маннур. *Аһ-зарларны куып, кочагымны Туар шатлыкларга шар ачам.* Р.Идиятуллин

2) Зарланышу, зар. *Вокзалга җитәрәк, аларга сөрелгән гаиләләре дә килеп кушыла, китә елаш, китә аһ-зар.* Ф.Бәйрәмова. *Сиңа аһ-зар, Ыңгырашу ят булды. Караңгыны ерганда да, Күңелең якты, ак булды.* К.Булатова

**2.** *рәв. мәгъ.* Зарлану белдереп. *Зәгыйфь колны нахак еглатма аһ-зар.* Котб

**А́Һ-ЗАРЛЫ** *с.* Кайгы-хәсрәтле. *Ул яшьтән үк халык арасында була, --- халык иҗатының аһ-зарлы әсәрләре белән беррәттән, киң хыяллы, якты киләчәккә өмет --- белән сугарылган әсәрләрен күңеленә ятлый, аларны дәфтәрләренә терки бара.* Х.Мәхмүтов

**АҺЛА́У** *ф. к.* **аһылдау**. *Аһлыйсың: «Яшьлек үтә!» – дип, Син минем хәлне кара: Кая яшьлек! Минем инде Картлыгым үтеп бара.* Ә.Исхак

**АҺЛЫ** *с. к.* **аһ-зарлы**. *Инде менә ничәмә еллардан соң да Җиһанның мең аһлы сүзләре, ялварулары аермачык ишетелә.* Ә.Баян. *Күп тә үтмәде, мич артыннан: – Ай Аллам! Юк бит! Юкка чыккан бит!.. – дигән шомлы, аһлы аваз ишетелде.* Г.Гыйльманов

**АҺЛЫ-ЗАРЛЫ** *с. к.* **аһ-зарлы**

**А́Һ-УХ** *и. к.* **аһ-зар**. *Сез аһ-ух киләсез, бәйрәм, дисез.* Т.Миңнуллин. *Азатлар тезмәсе буйлап: «Сәлим хан соңгесен ташлады. Сәлим хан орышырга теләми», – дигән аһ-уһ узды.* М.Хәбибуллин

**АҺЫЛДА́У** *ф.* 1) Кайгыру, борчылу. *Акыру-бакыру, дәртле өн салу, куркынып аһылдау, хәтта илереп көлү тавышлары яңгырап торды.* Р.Фәизов. *Дастанның тетрәндергеч кыллары, матәмле сүзләрнең аһылдавы...* М.Галиев

2) Рәхәтлек, ләззәт кичерүдән аһылдаган авазлар чыгару

**Аһылдап алу** Бераз, берара аһылдау. *Ихтыярга сузмак булып кулын күтәрә башлаган иде, ләкин, никтер, кире уйлады бугай, күтәрелгән кулының аркасы белән маңгай тирен сөртте дә аһылдап алды: – Шамкаев белән бәйләнмәскә ничә тапкыр ант иттем инде.* Р.Вәлиев

**Аһылдап җибәрү** Кинәт аһылдый башлау. *--- тәрәзә төбендә шау чәчәктә утырган тамчы гөл янына килде дә беренче мәртәбә күргәндәй аһылдап җибәрде, иснәп карады.* Н.Фәттах

**Аһылдап кую** Аһылдау авазы чыгару, бер тапкыр аһылдау. *Шулчак халык аһылдап куйды. – Канатлы елан! – дип кычкырды кемдер.* Р.Батулла

**Аһылдап тору** Берөзлексез яисә әледән-әле аһылдау

**Аһылдап чыгу** Билгеле вакытның башыннан ахырына кадәр аһылдау. *Ул төннәр буе ыңгырашып, уһылдап, аһылдап чыга иде.* Ф.Бәйрәмова

**Аһылдый төшү** Бераз аһылдау

**АЦЕТАТ** *и. лат. хим.* **1.** Серкә кислотасының катлаулы эфирлары яисә аның тозлары. *Ацетат сүсеннән эшләнгән, вискоза, штапель тукымаларны температурасы 40 градустан югары булмаган суда гына юарга мөмкин.* Өегез ямьле булсын

2. *с. мәгъ.* Шул матдәдән эшләнгән. *Ацетат ефәк*

**АЦЕТИЛЕН** *и. лат. хим. тех.* Табигый газ яисә кальций карбиды эретмәләреннән алынып, углерод һәм водород катнашмасыннан торган, янучан, агулы төссез газ. *Ацетилен --- металларны кисү һәм эретеп ябыштыру эшендә ягулык буларак кулланыла.* Химия

**АЦЕТОН** *и. лат. хим. тех.* Органик кушылма рәвешендәге төссез сыекча. *Ацетон күп кенә мөһим химия продуктларын синтезлауда – чимал; төрле дарулар, лак, шартлаткыч матдәләр җитештерүдә эреткеч буларак кулланыла*

**АЧ** *с.* **1**. 1) Тамагы ачкан, ачыккан, ашыйсы килгән. *Ач бүре арысланга ташланыр.* Мәкаль. *Юл өстеннән ач каргалар көтүе кузгалып очып китә.* Ә.Фәйзи

2) Ашарына булмаган, ачка интеккән, даими рәвештә азыкка тилмергән. *Гөлсем апа, чемоданында пәрәмәч, акмай, шоколад кебек нәрсәләре булса да, ач кешеләрнең берьюлы күп ашап үлгәннәрен ишеткәне булганга, берсен дә бирмәде.* Г.Гобәй

3) Күпмедер вакытлар ашамау сәбәпле, ачлык аркасында була торган, ачлыктан туган. *Баланы ач үлем дәһшәтеннән йолып калгансыз, алай гына да түгел, бала өчен аяныч күңел китеклеге – аның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез.* Г.Гобәй

4) *күч.* Ярлы, фәкыйрь, мескен, хәерче. *Җәберләнде күп кеше, Талау иде бар эше, Елаганда ач кеше, Көлеп торды, бәдәвам.* Г.Камал

5) *күч.* Өлгермәгән, тук түгел, эче буш булган (*орлык*). *Кәгазь көшелен җил җилгәрә, кибәк арасында ач бөртекләр генә шайлана.* М.Галиев

6) *күч.* Комсыз. *Күпме еллар суырды, дустым, ач сөлекләр каныңны, каның илә туймас алар, алачаклар җаныңны.* Г.Камал

7) *күч.* Рухи канәгатьсезлек аркасында туган, рухи канәгатьсезлектән барлыкка килгән. *Кашың кара, күзең кара, Сара туташ! --- Күтәрелеп, бичараңа кара, туташ! Синең өчен өзелә эчем көнен-кичен, Ач үзәктә гыйшык уты яна, туташ.* Ш.Бабич

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Хәерче, мескен булып, интегеп. *Бай йортында кол булуга караганда, ярлы йортта ач яшәвең артыграк, дим.* А.Шамов

2) Ашамыйча, авыздан өзеп, ачыккан хәлдә. *Үзләре ач торып, миңа күлмәк сатып алып бирделәр алар!* А.Әхмәт

3) Ашатмыйча, ачлык белән интектереп. *Кизиль мулласы хезмәткә 12 яшьлек ятим кызларны алып, өчәр көн ач тотып, күгәргән икмәкне суга җебетеп ашатып, вә иdәнен яхшы юмаса куып чыгара, дип язалар.* Ш.Маннур

**3.** *и. мәгъ.* Фәкыйрь, ярлы, хәерче кеше. *Ямьсез, канлы фаҗигаләр белән Төркем-төркем ачлар тарала.* М.Гафури. *И калын корсаклы бай, корсаклы һәм «инсафлы» бай. Ай буенча ач торып, ачлар хәлен сизденме, әй?* Ш.Бабич

**4.** *хәб. функ.* Яшәү шартлары түбән, мохтаҗ. *Аңа кайда да бер: --- төрмәдә дә ач, монда да ач.* И.Гази

◊ **Ач бет** Ачлы-туклы яшәүче, фәкыйрь, ярлы кешегә карата кимсетеп әйтелә. *Кем белән сөйләшкәнебезне бик яхшы беләбез, ач бет! Хәерче!* Г.Камал. **Ачка каклану** Ачлыктан ябыгу, кибү. **Ачка тук** Ачлыктан йөдәгән, даими ачка интеккән **Ачка (ачтан) үлү** Өзлексез ач тору, даими рәвештә ашау җитмәүдән үлү. *Ул ачка үлсә үләр – теләнергә бармас!* И.Гази. *Сыерларыбыз да ачтан үлгәне юк, үзебез дә ач тормыйбыз.* Һ.Такташ. **Ач күз** 1) Бик ябык кешегә хас эчкә баткан күз турында. *Йортның ялчылары, хатыннары, ач күз бала-чага, берәм-берәм, шул керәсе зур тирмәгә таба юл тоттылар.* Г.Ибраһимов; 2) Үтә комсыз, канәгатьләнүне, туюны белми торган (кем, нәрсә). *Капиталның нигезләре Череде, калмады эзләре, Ләхет туфраклары белән Туйсын инде ач күзләре.* Г.Камал. **Ач күзле** *к.* **ач күз** (*2 мәгъ.*). *Бүре мескен куйны ертып, өзгәләп, үзенең табигый ач күзлеге илә ашый башлады.* Г.Тукай. **Ач тору** 1) Озак вакытлар буена туйганчы ашамау. *И калын корсаклы бай һәм «инсафлы» бай, Ай буена ач торып, ачлар хәлен сиздеңме, әй?* Ш.Бабич; 2) Берәр максат белән ашамый яшәү, азыктан, ашамлыктан баш тарту. *Гыйззәт, ач торып, аяк бозып, солдаттан калды да шул арада гына үлгән атасы урынына указ алды.* Г.Ибраһимов; 3) Кешеләрнең, нәрсәгә дә булса протест белдергән сәяси чара буларак, ашаудан баш тартулары. **Ач яңаклы** Ябык яңаклары эчкә батып, ияккә таба очлаеп килгән, озынча битле. *Ач яңаклы, зур борынлы, сакалмыекларын кырып йөри торган бу немец бернәрсәгә катнашмый.* Ә.Галиев. *Уртачадан зуррак гәүдәле, ач яңаклы, сирәк сакаллы, өстенә камалы тун, башына кондыз бүрек, аягына ак киез ката киеп, муенына ак шарф ураган урта яшьләрдәге бу кеше --- табын тирәсендә утыручыларга карап сәлам бирде.* М.Гали

**АЧАЛА́К-ЙОМАЛАК** *с.* **1.** 1) Күзләре, челт-челт килеп, әле ачылып, әле йомылып торган. *Аның каршында утырган Йөзлебикә түзмәде, Сәйфинең ачалак-йомалак күзләренә текәлеп: «Күпертмәсәнә инде, Сәйфи абый!» – диде.* Г.Бәширов

2) *күч.* Көне әле аязып, әле болытлап торган, аязучан-болытлы. *Сентябрьнең ачалак-йомалак бер көне иде.* З.Мәхмүди

3) *күч.* Бер – якты, бер караңгы чырайлы

**2.** *рәв. мәгъ.* Күзләрен, челт-челт китереп, әле ачып, әле йомып. *[Әнисенең] Бер күзе мендәргә күмелгән, икенче күзенең акларына сары йөгергән, ачалак-йомалак киләләр.* Х.Камалов

**АЧАМАЙ** *и. диал.* **1.** 1) Өй, нинди дә булса бина, каралты түбәсендә кушылап утыртылган авыш терәүләр; кайчы, атлама. *Уй арасында, каерылып, каралты өстендәге ачамайга карый. Куерган болытлар бу иртәдә шул кайчылар өстеннән ага.* М.Рәфыйков

2) Аркылы-торкылы, әвернә формасындагы сызык. – *Тамгаң «ачамай», йәгъни әвернә тамга булсун, – тиди.* М.Әхмәтҗанов

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Бер-берсенә кыйгач, үзара чатлаш; аркылы-торкылы. *Ачамай торалар алар Корбан әзиләр белән.* Д.Рамазанова

◊ **Ачамай килү** Эш уңмау, кирегә китү, уңай бармау

**АЧАРБАК** *и. диал. к.* **ачәрвах.** *Ун Зәлияне уздырырга мөмкин ул ачарбак. Болай уйлагач, Әхнәфтә хатынына карата нәфрәт катыш җирәнү тойгысы уяна ---.* Ф.Садриев. *Тагын шалтыраттым. Җитмәсә, ике тиенне йотты, ачарбак!* А.Гыйләҗев

**АЧӘРВАХ** *и. тат.-гар. диал.* 1) *миф.* Догасыз үлгәннәрнең явыз өрәге. *--- йөрисең догага туймаган ачәрвах кебек. Тотып суктырырга кеше юк...* Т.Миңнуллин. *Кермә, кермә, абзыкаем, ачәрвах бар анда! Ачәрвах, ачәрвах; ул үзен, бичара Том, ди.* У.Шекспир

2) *миф.* Арыш өлгергән вакытта игеннәргә зыян сала торган мифик зат. *Аннары, биш еллап була инде, Ачәрвах атлы күп ашар бирәни зат арыш өлгерер алдыннан килә дә, һавадан төшеп, бөтен игенне ашап китә. Арышның иң сөтле чагында гына ашый икән ул Ачәрвах. Менә, олан, иртәгә арыш серкә очыра башлый инде. Ачәрвах быел тагын килер, дип, котларыбыз чыгып тора инде.* Р.Батулла

3) *күч.* Үтә ябык, бик хәерче, бик ярлы кеше

4) *күч.* Комсыз, туймас, канәгатьләнүне белми торган кеше. *Атасы бар – ат сорый, анасы бар – тун сорый, Бер ачәрвах җиңгәсе бар – бер салырлык он сорый.* Такмак

5) *күч.* Сүгү, ачулану сүзе. *– Илсез-догасыз зобаныйлар, ачәрвахлар, ачы каргышым төшсен сезгә!.. – дип бәддога укыды.* М.Хәсәнов. *Дөрес санамагансыз бит, ачәрвахлар! Себер китә сезнең белән газиз башлар!* Д.Гыйсметдин

**А́Ч КЕРНӘ** *и. к.* **ачәрвах**. *Ак сакаллы картлач Таганай [тавы] да аннан куркып торгандай тора: «Бу ач кернә минем ташларны да йотар», – дигән төсле утыра.* М.Гафури

**АЧКҮЗ** *с.* **1.** Канәгатьләнә белми торган, комсыз. *Безнең монда һәртөрле ачкүз контрабандистларның, хәерче жуликларның бетәсе юк.* М.Галәү. *Кырым, Әстерхан, Себер ханнары нәрсә караганнардыр, туган халыкларын ачкүз мәскәүлеләрдән талатырга юл куйганнар.* Ш.Алпар

**2**. *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия кеше. *Бетмәс монда синең кебек ачкүзләр, барыгызга да булышырга мине кем дип белдегез.* И. Нуруллин

**АЧКҮЗЛӘНҮ** *ф.* Канәгатьләнә белмәү, туймастай кылану, комсызлану

**АЧКҮЗЛЕК** *и. сөйл. к.* **ачкүзлелек**

**АЧКҮЗЛЕЛЕК** *и.* Канәгатьләнә белми торган сыйфатлар, комсызлык. *--- һәрберсе матурлыкны, байлыкны үзенә буйсындырмакчы була. Мин-минлек, тәкәбберлек, ачкүзлелек хөкем сөрә башлый.* С.Поварисов. *--- бай баласында тагын нинди мөнәсәбәт булсын, билгеле инде: комсызлык, ачкүзлелек, мал-мөлкәткә ябышып яту.* Ф.Хатипов

**АЧКЫЧ** *и.* 1) Йозакны ачу-бикләү җайланмасы. *Менә сиңа өстәл тартмасы ачкычлары.* Ш.Камал. *Әминә, сумкасыннан ачкыч алып, ишектәге йозакны ачты.* Т.Миңнуллин

2) Гайкаларны, болтларны бору, ныгыту өчен файдаланыла торган төрле үлчәмдәге корал, җайланма. *Мин ишегалдына чыкканда, Сәгыйть, аптырап, автомобильнең арткы көпчәгенә карап басып тора иде. Җирдә насос, күтәрткеч һәм ачкычлар таралып ята.* А.Шамов. *Ә физкультура укытучысы кешелек дөньясында кабул ителгән әхлакый сөземтәнең нәкъ киресен сукалый, ягъни орышкан, әрләгән сүзләрне, имеш-мимешләрне колагына алмый. Уңөчле ачкыч белән көпчәк төзәтүен белә.* Т.Галиуллин

3) Консерв, шешә кебек әйберләрне ачу өчен махсус ыргаклы корал, җайланма. *Хәзер консерв ачкычларының күптөрле вариантлары бар*

4) Арфа, фортепьяно, гитара кебек кыллы музыка уен коралларының кылларын тарттыру өчен файдаланыла торган махсус корал, җайланма

5) *хәрби* Әһәмиятле урын яулап алуга юл ача, җиңүне тәэмин итә торган пункт, нокта. *Донбас капкасының ачкычлары безнең кулда [бит].* И.Гази

6) *махс.* Радио-телеграф элементәсендә электрны тиз генә тоташтыру яки өзү җайланмасы. *Телеграфист морзе ачкычын бер-ике мәртәбә шакылдатып алган иде, эштән туктады.* Ш.Усманов

7) *муз.* Һәр нота юлының башында ноталарның югарылыгын шартлы рәвештә күрсәтү өчен куела торган билге, тамга

8) *күч.* Шифрлар белән бирелгән текстны уку өчен ярдәмче булып хезмәт итә торган, хәреф һәм цифрлардан гыйбарәт билгеләр, тамгалар системасы

9) *күч.* Билгеле бер нәрсәне аңлау, ачыклау, сизү, чишү чарасы. *Ярышны кабындырып җибәрү өчен, колхозчының күңел ачкычын табарга кирәк.* Г.Бәширов. *Шушы изге эштә сезгә Коръән гыйлеме бәхет ачкычы булып торсын иде...* Ф.Бәйрәмова // Нәрсәгә дә булса ирешү әмәле. *Пушкин дөньясына да Тукай теле ачкыч булды – Пушкинны иң әүвәл татарча укыдык.* Ш.Галиев. *Мә, энем, бераз йотып куй. Тел ачкычы булыр үзеңә.* Ф.Яруллин

10) *күч.* Кемнеңдер күңеленә үтеп керерлек җылы мөнәсәбәт, ышаныч, уртак фикер

◊ **Ачкыч ярату** 1) Йозакка башка ачкыч туры китереп ачып урлашу; караклык итү. *Келәт янына киләләр, ачкыч яратып, йозакны ачалар.* Т.Гыйззәт; 2) Кемнең дә булса җаена төшенү, ышанычын казану, уртак фикергә килә алу. *Берәү шыпырт кына эчә – аңа да ачкыч яратырга кирәк! Кемдер хатынкызга хирыс, аны да истә тот! Саран бар, мокыт бар, надан да янәшәңдә яши, ул да синең кебек үк чиннарны эләктергән.* Р.Батулла. 3) Кемнеңдер күңеленә юл табу, аны үзенә карату. *Рабиганың җанына ачкыч яратты бу кеше.* Н.Гыйматдинова

**АЧКЫ́Ч БАЛТАСЫ** *и.* Ачкыч очында чыгып торган өлеш, ачкыч очындагы чыгынты

**АЧКЫ́Ч ҮЛӘН** *и. бот.* Елан абагачалары семьялыгыннан, кыска вертикаль тамырчалы үлән үсемлек

**АЧКЫЧЧЫ** *и.* 1) Ачкыч ясаучы, йозакчы

2) Нинди дә булса рәсми оешмаларда ачкыч йөртүче, ачкычлар хуҗасы. *Минем тынычлыгымны монда сүгешергә яратучы ачкыччы берлән старшинадан башка бер кеше дә бозмый иде. Ачкыччы үткән-барганда сүгеп китә иде ---.* Г.Исхакый

**АЧЛАЙ** *рәв.* Ач көенчә, ачтан интегеп. *Байлар өчен берни түгел ялчыларның ачлай үлгәне.* Бәет

**АЧЛЫЙ** *рәв. к.* **ачлай**

**АЧЛЫК** *и.* **1**. 1) Озак ашамый тору сәбәпле яисә авыру нәтиҗәсе буларак бик нык, өзелеп ашыйсы килү, гомумән, ач булу. *Теге абзыйның: «Ничә?» –*

*дигән сөаленә, үземнең карыным ачлыгыны исәпкә алып: – Йөз, – дидем.* Г.Исхакый. *Ачлыктан интеккән халык арасында аннан да бәхетле кеше юк иде бүген.* Ә.Галиев

2) Иген уңмау аркасында ризыкка, азыкка мохтаҗлык, кытлык. *Былтыр имчәкләреннән сөт ага-ага кайта торган сыерлар да быел ачлыктан зарланган тавышлары берлә бөтен дөньяны шаулаталар.* Г.Исхакый. *Кырылып, ачлык киләсе көздән үк беленде.* Р.Хисмәтуллин

3) Ризык, азык, ашамлык җитмәү сәбәпле, озак вакытлар ач тору, туярлык итеп ашамау. *Шулай Мәче карчыкның өендә күп ачлыклар вә михнәтләр чикте, бик арыкланып, урак кебек бөгелде.* Әкият. *Аның сөйләвенә караганда, эш болай торган: ул блокада вакытында һәм аннан соң бик тә ачлыктан интеккән.* Ф.Углов. *Аның картлыктан һәм ачлыктан суырылган, тиресе җыерчыкланып, сөяккә ябышкан куллары калтыранып, бармаклары саксаул ботакларыдай катып, бөгелә алмыйча, бер-берсенә кушыла алмыйча, тырпаеп дерелдиләр.* И.Салахов

4) *күч.* Күңел бушлыгы, рухи бушлык, рухи мохтаҗлык. *Менә бу ясалма бикләнү Хәятнең бөтен кызлык вакытын күңел ачлыгында үткәрде.* Ф.Әмирхан

**2**. *с. мәгъ.* Иген уңмаган, азыкка мохтаҗлык зур булган. *Әгәр ачлык елны Фәтхулла булмаса, бу сабыйлар исән кала алган булырлар идеме микән, Шәмсия ачык кына җавап бирә алмый.* Ф.Сафин

◊ **Ачлык игълан итү** Җәмәгатьчелек фикерен, игътибарын үзенә тарту өчен, кискен ризасызлык белдереп, ач тору белән билгеләнә торган сәяси алым, акт

**АЧЛЫ́К-ЯЛАНГАЧЛЫК** *җый. и.* Зур фәкыйрьлек, мохтаҗлык, ач һәм ялангач булу халәте. *Шулай итеп, елгачылар арасында да патша политикасына, сугыш китергән газапларга, ачлык-ялангачлыкка ризасызлык күзгә күренеп көчәя бара.* И.Низамов

**АЧЛЫ́-ТУКЛЫ** *с.* **1.** Ачтан үлмәслек, туяр-туймас ашап яши торган, ярым ач булган. *Бу сый-хөрмәттән соң мин, авырып китмәс өчен, бернич көн ачлы-туклы диета тотарга мәҗбүр булдым.* Ф.Углов. *Соңгы вакытларда тулай торакны җылыту өчен утын табу бер бәла булса, озак вакытлар ачлы-туклы яшәү дә үзен нык сиздерә.* Ф.Сафин

**2.** *рәв. мәгъ.* Аз-маз гына ашап, туяр-туймас, ярым ач хәлдә. *Өс-баш алама булып, ачлы-туклы йөрсәләр дә, бәхетле булганнар.* Р.Мөхәммәтҗан. *Авыр сугыш еллары иде әле. Алабута оны кушып пешерелгән кәтеркәй кимереп, ачлы-туклы яшәгән еллар.* Ф.Зыятдинов

**АЧТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ачу** I. *Тагын ике көн үткәч, профессор яңадан, бәйләвечне чиштереп, Абдулланың күзен ачтырды ---.* Э.Касыймов

2) Агач төпләп ачыклык ясау. *Бервакытны урыстан Богдан дигән җанарал Казанга киләсе булгач, Габдерәзакка әмер булып, урман эченнән юл ачтырганнар.* К.Насыйри

3) Багу, бактыру. *[Әбием] Бер генә таба төче коймак пешерә дә, аны каз мае белән майлап, югары очтагы багучы, китап ачучы Әсмакамал апайларга менеп китә. Шәйдулла абыйга китап ачтыра.* А.Хәсәнов. *Минем сөюемә ышанмасаң, Абыстайга барып, фал ачтыр...* М.Хәсәнов

**АЧУ** I *ф.* 1) Берәр нәрсәнең ачыла, ябыла торган капкачын яки өстенә томалап куйган әйберсен күтәреп, читкә алып куеп, этәреп, шудырып, эчен карарга, әйбер алырга яки салырга мөмкинлек булдыру. *Гөлйөзем әбисенең сандыгын ачты.* М.Әмирханов. *Кайткан чакта, нәкъ шул тирән чокырның төбендә, комганны янә бер кат ачып карадык.* К.Йосыпов

2) Нәрсәнең дә булса ябылган, печатьләнгән капкачын, бөкесен һ.б.ш. алу. *Альберт, як-ягына карангалап, тиз генә шешәне ачты.* Р.Кәрами. *Һич югында лимонад булса да ачыгыз.* И.Зарипов

3) Ишек, капка, тәрәзә кебек җайланмаларны як-якка яки үзеңнән читкә этәреп, шуыштырып, ачыклык барлыкка китерү. *Роза, җәһәт кенә торып, ишекне барып ачты.* Р.Мөхәммәтҗан

4) Бик салынган, йозакланган капка, ишек кебек җайланмаларны биктән, йозагыннан азат итү, ачып керә алырлык итү. *Әминә, сумкасыннан ачкыч алып, ишектәге йозакны ачты.* Т.Миңнуллин

5) Бәйләнгән, төйнәлгән, кысып җыелган нәрсәне чишеп, ычкындырып, җәеп салу; язу. *Сара йомарланган учын ачып караса, уч төбендә – әтисенең алмазын, янында ефәк яулыгын күрә.* Д.Аппакова

6) Як-якка турайтып җибәрү, җәю (канатны, кочакны). *Карчыга, канат ачып, һава йөзенә чыкты һәм як-ягына каранып очып йөргәндә күрде: бер кыр бүдәнәсе дигән көяз кош, төрле көй вә наз белән ары-бире әйләнеп йөреп очадыр вә шаңгырап көлүе белән, таутавшны яңгыратадыр.* Әкият

7) Күз кабагын күтәрү һәм иреннәрне бер-берсеннән аеру. *Солтания сәке йөзлегенә утырып, салкын кулын маңгаена тидерүгә, Байтирәк күзләрен ачты.* М.Галиев. *Менә ул авызын ачты, аның кара тешләре ыржайды ---.* Г.Исхакый

8) Ышыклап, каплап торган нәрсәне читкә этәреп җыю. *Аш өстәле торган аралыктадыр, минем белән качышлы уйнамакчыдыр, дип, карчык, каплап торган чаршауның бер кырын ачып, мич буена узгач, шатлыгыннан елмаеп җибәрде.* Рифә Рахман

9) Китап яисә дәфтәрнең кирәкле битен, тиешле урынын укырлык, язарлык итеп җәеп салу. *Хәсән, --- тиз генә әүвәлге урынына утырып, тарих китабын ачып салды.* Ф.Әмирхан. *Менә китапны кулыңа аласың, аннары, ашыкмыйча гына, эчтәлекне ачып, үзеңә бик күптәннән таныш әсәр исемнәре буйлап тагын бер кат үтәсең.* Р.Мостафин

10) Чәчне як-якка аеру, як-якка аерып тарау. *Гади генә киенгән, чәчләрен урталай ачып, иңбашына ак шәл салган урта яшьләрдәге хатын килде.* А.Шамов

11) Билгеле бер нәрсәгә тоткарлыксыз үтеп керергә яисә алга барырга мөмкинлек, ирек бирү. *Чикне ачу* // Хәрәкәткә киртә булып, хәрәкәтне буып, туктатып торган нәрсәне алу, юл бирү. *Газны ачу*

12) *сөйл.* Ялтыратып чистарту, агарту, тоныклыгын алу, пычрактан арындыру, үз төсенә кайтару (кер һ.б.ш. нәрсәләр турында). *Ул һәр атнакич ком берлән сап-сары итеп самавырны ача, айда бер өйнең ярыкларыны ямар өчен сылаган балчык өстеннән акбур белән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына су сала иде.* Г.Исхакый

13) Нинди дә булса оешма, учреждение, предприятие һ.б.ш.ның эшчәнлеген башлап җибәрү. *Аннары, кабат райздравка барган идем, үзебезнең авылда пункт ачарга куштылар.* Р.Кәрами. *Икенче курста укыганда, университет каршында Шәрекъ институты ачтылар.* М.Юныс. *Ул әлеге дә баягы шул «Галия» мәдрәсәсен ачу, укыта башлау, шәкертләрне вакытлыча булса да яхшы урнаштыру эшләре белән ут йотып йөри икән.* С.Поварисов. *Кырлайда Г.Тукайның мемориаль комплексын төзетү, мәркәзебездә шагыйрьнең музеен ачу --- – эшләрнең иң күзгә күренеп торганнары.* Мирас

14) Җыелыш, киңәшмә кебек нәрсәләрне башлау, башлап җибәрү. *Мәҗлесне әти ачты.* Ә.Галиев. *Хәйрулла картка утырышны ачарга кушты.* Х.Хәйруллин

15) Яшермәү, күренерлек итү. – *Биләмгә чапкансыңдыр әле! Ир-атка йөзеңне ачкансыңдыр! – дип кычкырды «әти» кеше.* Ә.Фәйзи

16) *күч.* Башлангыч булу, нәрсәне дә булса беренче булып башлап җибәрү. *Син коллыкка каршы көрәш ачтың, Яшәү нурын сөя идең син.* Ә.Ерикәй

17) *күч.* Нәрсәне дә булса берәр кешенең аңына җиткерү, аңлатып, ачыклап, төшендереп бирү. *Татар прозасы --- бүгенге эшче образын ачарга, кызыклы типлар булдырырга тырыша.* М.Мәһдиев

18) *күч.* Элек билгесез яки яшерен сер булган нәрсәне билгеле итү, сәбәбенә төшенү, ачыклау; билгеләү, аныклау. *Абыйның эчен яручы доктор аның эчү-эчмәвен ачачак.* Һ.Такташ. *Астрономнар Галлей исемле комета ачканнар.* И.Юзеев. *Находка култыгын 1859 елда ачалар.* Ә.Хәбибуллин. *Мин аны, күңелемнән мең кат уйлый-уйлый, очын-очка ялгый-ялгый, ялгызым йөргән чакларда ачтым.* Р.Низамиев

19) *күч.* Фаш итү, җинаятьне ачыклау. *Аның Уралда ике экспроприациягә катнашкан Әхмәт Хәйруллин исемендә йөргән кеше икәнен монда ачтылар.* Г.Ибраһимов. *Үз гомерендә әллә никадәр, әллә ни төрле җинаятьләр ачкан зур тәҗрибәле милиционер да, [бу хәлгә] шаккатып, гел башын чайкап торды.* Г.Гобәй

20) *күч.* Аң-карашын үстерү, аңлы, тәҗрибәле итү. *Им, бала, им! Шул кырларны гөл бакчаларына әверер өчен --- зиһен ачарга көч ясар өчен им!* Г.Исхакый

21) *күч.* Аерым бер темага сөйли башлау, нәрсә турында булса да сөйләргә тотыну. *Җәмәгать мәсьәләләре, әдәбият хакында сүзләр ачты.* Г.Исхакый

22) *күч.* Күңелен табу, кәефен күтәрү. *Матур кызга гашыйк булсам, Гармун ача күңелемне.* Ә.Ерикәй

**Ача тору** Һәрберсен рәттән, бербер артлы ачу. *Учак фантастик китап битләрен бер-бер артлы ача тора.* Р.Сәлимҗанов

**Ача төшү** 1) Бераз ачу. *Әмма, авызын ача төшеп, үзенә текәлгән, җавап көткән хуҗаның күзләрендә балаларча ихлас кызыксыну күргәч, дәшми булдыра алмады.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Күбрәк сөйләтү, үзенә кирәк сүзләрне алу, серләрен ачтыру. *Аның берлән сөйләп, авызын да ача төшмәкче булды.* Г.Исхакый

**Ачып алу** Тиз арада ачу, кыска вакытка ачу. *Гасыр капкасы, ябылыр алдыннан, безнең татар милләтен салып бәйләгән «капчык»ның авызын ачып алды.* З.Хөснияр

**Ачып бирү** 1) Ябыкны, биклене ачарга ярдәм итү

2) *күч.* Барысын да ачу; ачыкларга ярдәм итү. *Алар һәркемнең яшәү рәвешен, яшәү мәгънәсен ачып бирә.* Хокук һәм хәят

**Ачып җибәрү** 1) Кинәт ачу. *Болар Жирнең беренче ясалма иярченнәре – космик чорның башы, космик киңлекнең физик үзлекләрен өйрәнүдә яңа чор ачып җибәргән күпсанлы иярченнәр.* А.Романов

2) Ачык хәлгә китерү, ачык итү. *Апасы алга таба тарап төшергән кара шома чәчен маңгай турысыннан ачып җибәрде.* И.Гази

3) *күч.* Күңелен күтәрү, күңеленә хуш килү. *Газизә башта хәзер торып китәргә генә уйлаган төсле аптырап торса да, сүзнең соңгысы аны бераз ачып җибәрде.* Ш.Камал

**Ачып кую** Гомумән ачык итү, ачык торышка китерү. *Гадәттә, Хәлим, сыерларыннан алданрак кайтып, капканы ачып куя.* Хәйдәр

**Ачып салу** 1) Кискен хәрәкәт белән ачылган хәлгә китерү

2) *күч.* Тасвирлап ачыклау, сурәтләү. *Чехов үзенең әсәрләрендә тормыш каршылыкларын зәһәрле көлү аша ачып салган.* Г.Нигъмәти

3) *күч.* Сөйләп бирү, яшермәү. *Иптәшләр судына үзенең йөрәктәге барлык нәрсәләрен ачып салырга уйлады, һаман сер саклап йөрергә теләмәде.* А.Алиш. *Әзһәм шунда Галя белән тагын да ныклабрак сөйләште, үзенең эч серләрен аңа ачып салды.* Р.Кәрами

4) Аңлатып, төшендереп бирү, ачыклык кертү. *Безнең мишәр җырларының да ни икәнлеген асыл йөрәгең белән ачып сал, перәме үзәкләре өзелсен.* Э.Касыймов. *Г.Камал иҗатын киң рәвештә ачып салырлык зур тәнкыйть мәкаләләре бөтенләй күренми.* М.Гали

**Ачып тору** Ачык хәлдә тоту; әледән-әле яисә даими ачу. *Нидер сизенеп чыккан әнисе, үзе күренмичә генә, ни булганын да аңышмыйча, ишекләрне ачып торды.* М.Галиев

**АЧУ** II *и.* Нәфрәтләнү хисе, ярсу тойгысы. *Ул аны, ачу белән, җиргә ташлады.* Х.Хәйруллин // Ризасызлык, үпкәләү хисе, эчтәге үпкә, нөктә. *Фазыйл хакында бу кызның теге вакыттагы ачуы – үзен алырга теләмәве – йөрәгендә нык саклана булса кирәк.* Г.Ибраһимов

◊ **Ачу алу** Ачуны басарлык берәр җавап эш эшләү, явызлыкка каршы явызлык итү, үч алу. *Миңа хыянәт кылганлыгы өчен аннан ачуымны алдыммы?* Г.Камал. **Ачу басылу** Ачу хисе онытылу; берникадәр күләмдә кимү. *Городовойның ачуы тиз басылды.*

Г.Исхакый. **Ачу итү** Үч алырга теләү, үчләнү, үч итү. *Беткә ачу итеп, тунны утка якмыйлар.* Мәкаль. *Дустының һаман җыенмавын күреп, кая барасыларын әйтмичә, нәни генә ачу итте.* М.Хуҗин. *Нәфисәгә бу явыз бәндә бөтенесен дә белә, аны, усал ният белән, ачу итеп, юри шулай үчекли кебек тоела башлады.* Г.Бәширов. **Ачу йоту** Ачу килгәндә, аны кешегә белдермәү, кешегә сиздермәү. *Ачу йоту – тау йоту.* Мәкаль. **Ачу кабару** Берәр кешегә яки нәрсәгә карата, бик нык ярсып, көчле ачу тойгысы кичерү, көчле ачу белән яну. *Ачуы кабарып җиткән Акбүз ят кешенең каршысына сикереп килеп басты.* Г.Гобәй. **Ачу килү** Берәр сәбәптән, ачу тойгысы барлыкка килү, ачулану. *Көзгедән карыйм да җиде бармак иңлеге текә маңгаема ачуым килә.* М.Галиев. **Ачу китерү** Ачуны кузгату, ачуланырлык итү. *Ныгытма төзү, кораллану урынына, рязанлыларның, бала-чага шикелле, икона белән азапланулары минем ачуымны китерә иде.* М.Юныс. **Ачу кубу** *к.* **ачу килү**. *Бригадир апабызның ачуы купса, игенә китерүге яман авыр икәнлеген без, сугыш еллары малайлары, шәп беләбез.* М.Хуҗин. **Ачу куу** Ачу итү, ачу итеп эшләү. *Аның белән ул хакта сөйләшә башласаң, ачу куа, үч ала, диячәк.* Ә.Баянов. **Ачу саклау** Озак вакытлар ачуланып йөрү. *Шушы кадәр гүзәл табигать куенында булганнан соң, кеше күңелендә ачу тоту, үч алу яки үзе кебек үк кешене юк итү кебек хис уяна алырмы икән?!* М.Хәсәнов. **Ачу тоту** *к.* **ачу саклау**. **Ачуым – ачу** Кемнәндер үч алырга кызып, ашкынып торуны белдергәндә әйтелә. *[Нәфисә:] Ачуым – ачу, интектерәм әле мин аны, дип әйтеп әйтәдер, ди.* Г.Бәширов. **Ачуым килмәгәе** *сөйл.* Бик ачуланып, ярсып, ризасызлык белдереп сөйләгәндә сүз арасына кыстырыла. *Ачуым бер килмәгәе, хакын министр окладына җиткерделәр бит инде.* Ж.Рәхимов. *Көн дә тикшерү, көн дә ревизия, ачуым килмәгәе.* З.Мәхмүди

**АЧУ** III *ф.* 1) Органик матдәләргә ачы тәм керү, бозылып әчешү, таркалу, тәмсезләнү. *Суытылмаган сөт сауганнан соң 1–2 сәгатьтән үк ачый башлый.* Йорт эшләре

2) Махсус ачыткы яки чүпрә салып, ачы хәлгә китерү. *Камырны чүпрә салып изгәч, өстенә чиста сөлге яисә тастымал каплап, ачу өчен, җылы урынга куярга кирәк.* Йорт эшләре

3) Ию, черү (тире, йон турында). *Аның тез буыннары калтырый, аяклары ачыган йоннан басылган киез катаны чак кына өстери иде.* А.Шамов. *Ачыган тире исе дә, тагын әллә ниләр исе дә килә иде.* Г.Бәширов

**АЧУЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Кемнең дә булса ачуын китерү. *Шуңа күрә дә аны мыскыл итү, ачуландыру өчен, безгә бу кушамат өстенә тагын бер кушамат табарга туры килде.* М.Әмир. *Алай-болай берәрсен ачуландырсаң, дуэльгә чакырырга да күп сорамаслар.* Ф.Абдуллин

2) Үпкәләтү. *Картны бер дә кирәксезгә ачуландырырга теләмичә, ул сүзне икенче якка борып җибәрергә тиеш тапты.* Ш.Камал. *Безне бит әбиләр дә тыңлый – ачуландыра күрмә үзләрен!* Л.Лерон

**Ачуландыра бару** Ачуын акрынлап арттыру

**Ачуландыра тору** Тагы да ачуландыру

**Ачуландыра төшү** Бераз ачуландыру

**Ачуландырып алу** Берникадәр вакыт ачуландыру

**Ачуландырып бетерү** Тәмам, бик нык ачуландыру

**Ачуландырып тору** Бертуктаусыз, еш ачуландыру

**АЧУЛАНУ** *ф.* 1) Кемгә яисә нәрсәгә дә булса ачу килү, ачу чыгу, кызып китү. *Май сатучылар, [әлеге кешенең] комсызлыгына ачуланып сүгенделәр, китә башладылар: – Кара син аны, бушка [май] җыеп китмәкче!* Г.Бәширов. *Түләрлек әйбер булмаганга ачуланган җен Әхмәй Сания әбине чәченнән сөйрәп йортта башлый.* К.Йосыпов

2) Үпкәләү. *Миһриҗиһан белән дә сөйләшмим, ул миңа ачулангач, мин дә аңа ачуланган булдым.* М.Гали. *Минем, әнкәй, сиңа беркайчан да ачуланганым юк һәм ачуланмам да.* Р.Ишморат

3) Тиргәү, әрләү, орышу. *Хатыннарның берсе төкерекләрен чәчә-чәчә ачулана.* З.Хөснияр. *Харис абый яхшылык белән дә, ачуланып та сорап карады.* Р.Хафизова

**Ачулана төшү** Бераз ачулану, ачуланган тон бирү. *– Нинди уртак юрган? Бу хакта сөйләшүләр булдымыни соң? – диде ул, ачулана төшеп.* Ф.Сафин

**Ачуланып алу** Аз гына ачулану, кыска гына шелтә белдерү. *[Миша абый] Кысык күзле Зайцевның тагын эшкә соңга калып килүен күргәч, ачуланып алды.* Н.Хәсәнов

**Ачуланып йөрү** 1) Бик озак вакытлар ачулы булу. *Ул көне буе нәрсәгәдер ачуланып йөрде.* Р.Кәрами. *Әни бүген көн буена миңа ачуланып йөрде.* Г.Камал

2) Әле – берсен, әле икенчесен ачулану

**Ачуланып карау** Ачуланып, туры юлга бастырырга омтылу. *Ачуланып та карадым, йөрәгемне тыңламады.* Т.Миңнуллин

**Ачуланып кую** Кинәт кенә ачулану; бераз ачу белдерү. *Ул үзенең халкын эчке ярату белән ярата, тарихыннан гыйбрәт алырга чакыра, үпкәләп тә, ачуланып та куя.* Һ.Атласи. *Әни ачуланып куя: – Өреп кап, улым, пешәсең!..* Ф.Яхин

**Ачуланып ташлау** Кинәт пыр туздырып ачулану. *Кирәк чакта каты да итеп әйтә белә торган әнкәй ул чагында миңа бер авыр сүз дә әйтмәгән... Гомер буе шул сорауга җавап эзлим. Үзеннән сорарга нигәдер һаман да уңайсызланам. Ачуланып ташлар кебек.* Р.Миңнуллин

**Ачуланып тору** 1) Һәрвакыт, гел ачулану. *Җиңги шулай пыр китереп ачуланып торгач, мәктәп кайгылары китте миннән.* В.Нуруллин

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда ачулану. *Таҗи когяшны ачуланып торганда, кинәт җил күтәрелде.* А.Алиш. *Анда аның әнисе чирләп ятсын, ә син аңа ачуланып тор, имеш!* Н.Фәттах

**АЧУЛАНЫШУ** *ф.* Үзара тиргәшү, үпкәләшү, кычкырышу, ызгышу. *Аның*

*соңгы көннәрдә генә бу адәм белән ныклап ачуланышасы килми иде.* Ф.Сафин

◊ **Ачуланыштан булмасын** Ачу саклап, ачуланып йөрмик, мәгънәсендә

**Ачуланышып алу** Аз гына ачуланышу. *Егет Бабай белән Искәндәр, икесе дә абруйлы, танылган кеше булсалар да, бер-берсен бик ихтирам итәләр, вакыт-вакыт бәхәсләшеп, хәтта ачуланышып алсалар да, авырлык килгәндә, бер-берсенә җил-яңгыр тидермәскә тырышалар иде.* М.Кәбиров

**Ачуланышып бетү** Бик нык ачуланышу, ачуланышу дәрәҗәсенә җитү. *Көн саен көрешеп торсак, кем белә, бәлки, без үпкәләшеп-ачуланышып та бетәр идек инде.* В.Нуруллин. *Культура министрлыгында да, драматурглар белән дә ачуланышып беткән.* Л.Ихсанова

**Ачуланышып йөрү** Һаман, искә төшереп, кабат-кабат ачуланышу, озак вакыт ачуланышу. *Хәер, карчык тавышланып, ачуланышып йөрми, бәлки, үз гаебен – баланы рәнҗетүен аңлаган булгандыр.* Ф.Тарханова

**Ачуланышып китү** Кинәт ачуланыша башлау, нindидер сәбәп белән ачуланышырга тотыну. *Ачуланышып киткән сурәттә, син эшсез каласың.* Ф.Садриев. *Ә ничек ачуланышып китәргә, шул ачуны сугышка чаклы җиткерергә?* Х.Камалов

**Ачуланышып тору** Әледән-әле, еш ачуланышу. *Синдәй алдынгы карчык белән тәбә өчен ачуланышып торалармы?* А.Гыйләҗев

**АЧУЛЫ** *с.* **1.** Ачуы булган, кемгә яки нәрсәгә дә булса ачуланган, ачуы килгән; усал. *Ачулының күзенә түгәрәк әйбер дүрт кырлы булып күренә, имеш.* Мәкаль. *Кинәт әйләнсәм, ни күрим, ике кондуктор, бер күз карашы белән ашарга торгандай ачулы йөзле контроль безне ике яктан кысып алганнар.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* Усал итеп, усалланып, ачу белән. *Ләкин кызый, башлыкта открытка юклыгын күреп, тагын да ачулырак кычкырды.* И.Зарипов // Усал, куркыныч. *Аның йөзе ачулы иде.* Ф.Садриев

**АЧУТАШ** *и. хим.* Марганец, алюминий кебек күкерт тозларының исеме; составында шундый тозларның кристаллары булган, дезинфекцияләү һәм кан туктату өчен кулланыла торган таш. *Шушы известь камырын 2,5 кг үлчәп алып, кайнап торган 5 литр суда эретәләр, аңа 50 – 100 г аш тозы, яки 200 грамм ачуташ салып, эремәнең күләме 10 литрга җиткәнче су өстиөсти болгаталар.* Өегез ямьле булсын

**АЧЫ** *с.* **1**. 1) Лимон, миләш, балан, мүк җиләге, серкә кебек нәрсәләрнең тәмен хәтерләтә торган, шундый кискен тәмгә ия булган. *Атасы ачы алма ашаса, улының теше камашыр.* Мәкаль. *Җир җиләге ачы була, Үз вакытында пешмәсә.* Җыр

2) Әрем, борыч, хинин тәме кебек. *Ачы дару*

3) Сизү органнарына бик начар тәэсир итә торган, агулы. *Парпылый дәдәй, дилбегәне чанадагы саламга ташлап, тәмәкесен төрде, чакма чагып ут кабызды, җил тау битенә ачы тәмәке исе таратты.* Р.Батулла

4) *диал.* Бозылган, искергән, ачыган. *Ачы катык кирәк булса, асраулардан сорарсың.* Т.Гыйззәт

5) *диал.* Махсус ачытылган. *Саҗидәләрнең авылларына баручы бер-бер хатынны ишетсә, ул кичтән үк, авыл сатучысыннан гына он алдырып, ачы күмәчләр сала, биш-алты гына вак бәлеш ясый...* Г.Исхакый

6) *диал.* Кислотасы артыграк булган (*җир, туфрак*). *Безнең үз колхозыбызда гына да әллә ничә төрле туфрак бар. Берсе ачы аның, берсе төче, дигәндәй, берсе структуралы, икенче төрлесе – тузан гына.* Г.Бәширов

7) *күч.* Кайгы-хәсрәтле, моң-зарлы, бик күңелсез, бик авыр. *Муса аны үзенең ачы хисләр тулган йөрәге белән, яртысын ярып бирердәй үз җаны белән тергезде.* Ш.Маннур // Кайгы аркасында булган, кайгы китергән. *Элеккеге ачы күз яшьләре хәзергенең тәмле ашларына таммасыннар әле.* А.Әхмәт // Каты авыртулы, үзәккә үтәрлек. *Тик Борисов шул минутта ук күкрәгендә кинәт бер ачы сызлау сизде.* Г.Бәширов

8) *күч.* Физик һәм рухи яктан зур түземлек сорый торган. *Шул афәттән соңгы беренче елларны ук без, ачлыктан кая барып бәрелергә, кемгә сыенырга белмичә, аптырашып, ачы ятимлекнең ни икәнен татый башладык.* Р.Хисмәтуллин

9) *күч.* Бик үзәк өзгеч, ярсулы. *Аның җеназасын күтәреп чыкканда, нинди ачы тавыш белән: «Бәхил бул, бәхил бул!» – дип кычкырган иде.* Г.Исхакый

10) *күч.* Бик көчле, үтә яңгырап торган. *Авыл һаман үзенең тирән вә тыныч йокысында; тик сирәк кенә кайдадыр берәү ачы сызгырып җибәрә, кемдер өзек кенә җыр көйли дә музыка тартып куя.* Г.Ибраһимов

11) *күч.* Ачулы, усал, үткен. *Назыйр кереп китүгә, Җиһангир тагы ачы сүзләр ата башлады.* Г.Ибраһимов

12) *күч.* Үткен, көчле. *Г.Камал, ачы сатирасы аркылы, буржуа-мещан тормышындагы ваклыкларны, җитешсезлекләрне, тискәрелекләрне рәхимсез тәнкыйть уты астына ала.* М.Гали

**2**. *и. мәгъ.* 1) Билгеле бер нәрсәләр составында булып, сизү органнарына начар тәэсир итә торган тәм, ис һ.б.ш.

2) Кислота, селте. *Без эшләп чыгарган сабынның ачысы ашаган [синең кулыңны].* Ә.Фәйзи

3) Кискен авырту, сызлану. *Әй казак камчысы, Сыртка тия ачысы.* Җыр

4) *күч.* Кимсетелүләр тәэсирендә туган халәт, бәхетсезлек, уңышсызлык аркасында булган авыр хис. *Илаһының юмарт бүләге – Чатыр тау тәхете бирелгән, Бөеклекнең данын, ачысын Тоемлау бәхете бирелгән.* М.Галиев. *Вакыт үткән саен, көндәшлек ачысы кимемәсә дә, Сәгыйдәнең ачыга чыдавы арта барды.* Г.Исхакый

5) *күч.* Төрле газаплар, михнәт, кайгы-хәсрәт тәэсирендә булган авыр хәл. *Ачыны татымаган – татлының тәмен белмәс.* Мәкаль. *Ярый, туган, дөньяның ачысы да булды, төчесе дә булды.* Г.Ибраһимов

**3**. *рәв. мәгъ.* 1) **ачыга** *диал.* Ачытып, чүпрә салып. *Мәләкәс сөйләшендә «йывача – раштуага каршы кичтә, сарыклар күп булсын дип, арыш оныннан ачыга мич төбендә пешерелә торган бавырсак» дип күрсәтелә.* Г.Мөгътәсимова

2) Үзәк өзгеч итеп. *Шулвакыт кинәт Алтынчәчнең ачы кычкырган тавышы ишетелә.* М.Җәлил

**4**. *хәб. функ.* Зәһәр, усаллык, явызлык белән тулы. *Келт-келт итеп, Гөлкәй көлеп куйды: «Ай-һай телең ачы, Харис!» – дип.* М.Җәлил

◊ **Ачы белән авызлану** 1) Авыр, газаплы, михнәтле тормышта туу, үсү. *Василий ачы белән авызланды. Шактый озак татыды ул ачыны.* А.Гыйләҗев; 2) Телгә ачы, усал булу. **Ачы сабак** *к.* **ачы тәҗрибә**. *Киртә ватып алга ыргылырга маташканнарны, җәмгыятьнең язылмаган законнарын бозып, серне читкә чәчкәннәрне, телләренең урыннарын белмәгәннәрнең чәчрәп егылып төшүләрен Асаф күреп торды, күрде дә ачы сабак алды.* Р.Батулла. **Ачы су** Күңелдәге ачу, үпкә, рәнҗү. *Алай да малайның күңел төбендә бүген ачы су тора: кемдер кергән дә ятим хатын Пиклана талап, Миңнешне матур күлмәксез калдырып чыгып киткән.* Р.Батулла. **Ачы тәҗрибә** Баштан үткән нәрсәләр, яшәештә булган авыр хәлләр аша килгән тормыш тәҗрибәсе. **Ачы телле** Усал, чәнчеп, «йөрәккә кадап», төрттереп әйтә торган кеше турында. *Гөлләр, ап-ак сакаллы картның бу кадәр ачы телле булуына гаҗәпләнеп, сүзен дәвам иттерде.* Г.Әпсәләмов. **Ачы тир** *к.* **эче тир**. *Безнең күпме ачы тир сыгылып салынган ул сабынга.* Ә.Фәйзи. **Ачы-төчене тату** *к.* **әчесен-төчесен тату**

**АЧЫ́ БАЛ** *и. к.* **эче бал**. *[Озерцов:] Соңыннан, Үрледә сез, клуб кырыендагы Ибраһимовларда, Гореловның дуслары өендә, ачы бал да эчкәнсез.* Р.Мөхәммәтҗан. *Ачы бал телләрен тиз эретте кунакларның, бер яшь егет җыр башлады.* Ә.Галиев. *Ачы бал пары очып бетү белән, кыюлыгы да кими, өмет чаткылары учак күмерләре төсле берәмберәм сүнә ---.* Т.Галиуллин

**АЧЫГАВЫЗ** *и. к.* **ачык авыз**. *Аның бер гаебе дә юк, барысына да ачыгавыз җайдак гаепле.* М.Әмирханов. *Юлдан язган кызын ачыгавыз татар малаена сылагач, Биктимер ага озак яшәмәде, фани дөньяны ташлап китте.* Т.Галиуллин

**АЧЫГАЙТКЫЧ** *и. махс.* Фотопластинкаларда, тасмаларда, фотокәгазьләрдәге сурәтләрне ачыкландыра, күренә торган итүче состав. --- *ачыгайткыч машина операторы Олеся Власова да хезмәтен җиренә җиткереп башкара.* Туган як. *Фотоларның сыйфаты ачыгайткычның нинди булуыннан да тора.* Мәгариф

**АЧЫГУ** *ф.* 1) Ашыйсы килү. *Шундук әлеге солдатка чәй китерергә кушты, юл кешесе ачыккандыр, янәсе.* Ш.Маннур. *Ачыгудан да бигрәк, сусады малай.* А.Хәлим

2) *күч.* Нык мохтаҗлыкта яшәү; ач яшәү; ачлыкка дучар булу. *Узган җәй күп кенә җирдә ашлык булмаган, халык ачыккан.* М.Гали. *Әзмәвердәй таза ирләр сугышка китте. Кырда икмәк урылмый калды. Халык ачыга.* С.Поварисов

**Ачыга бару** Тора-бара, тагын да ачыгу, торган саен ныграк ачыгу

**Ачыга башлау** 1) Ачыгу тою, ачыгырга тотыну. *Беренче хикәядә, Чикерткә кушаматлы шәкерт, җәй көне мәдрәсәдә ялгызы калып, ачыга башлагачтын, хәйләгә керешә.* М.Вәли-Барҗылы

2) Ачлык башланып китү. *Ерак, әмма мал-туар ачыга башласа, анда да барып җитәргә була, дип, күңеленә салып куйды Аюхан.* Г.Якупова. *Әмма ничә еллар сугыштан интеккән, чәчмәгән һәм урмаган халык ачыга башлый.* Ф.Бәйрәмова

**Ачыга төшү** Бераз ачыгу. *Аннары сәгать 12 ләрдә, ачыга төшкәч, университет буфетында ул тагын җиңелчә генә бер тамак ялгап алачак әле.* Ә.Еники. *Бераз шулай юангач, тамаклар ачыга төште.* Н.Хәсәнов

**Ачыгып бетү** Бик нык ачыгу

**Ачыгып җитү** Ачыгу ахыр чигенә, ахыр ноктасына җитү

**АЧЫК** *с.* **1.** 1) Ябык булмаган, ябылмаган, ачылган. *Ачык тәрәзә каршындагы сәрби агачында чыпчыклар чыркылдаша.* Р.Хафизова. *Машина туктаган, ишек ачык, һәм Тәлгать каядыр киткән иде.* Р.Батулла

2) Йомылмаган, йомык түгел. *Сатый, гаярьләнеп, капканы ачкан иде, Асафның күзе этнең ачык авызын, ыржайган тешләрен күреп өлгерде.* Р.Батулла. --- *Асаф, өй түбәсенә менеп, гармун тартырга ярата, кыек башында нәни генә тәрәз бар, ул шуны ачып куя, ачык тәрәзәдән гармун тавышы бакча янынннан үткән тыкрыкка барып ишетелә.* Р.Батулла

3) Ачып калдырылган. *Алар, ачык капкадан фабрика ишегалдына кереп, контора тирәсенә барып туктадылар.* М.Гали

4) Бикләнмәгән, йозаксыз, биксез, биге булмаган

5) Түбәсез, ябусыз; каплавычсыз. *Тере куйны ботыннан тотып кимерерлек дәрәҗәгә җитеп ачыккач та, фин ашханәсенә кереп, фин ысулынча, ачык өстәлдә ашадылар.* Г.Исхакый

6) Бернәрсә белән дә ышыкланмаган, капланмаган, урман-болыннары, тау-чокырлары булмаган. *Ачык кырга чыгып бераз баргач, Хәдичәнең түземлеге бетте.* М.Хәсәнов // Иркенлек, сахра. *Ак чәчәкле ачык җирләрдә янып-пешеп тора икән лә чыпчык башы хәтле җиләкләр.* Ш.Маннур. *Ачык ялан, ямьле тугайларда бик күңелле үтәр гомерләр.* Ш.Бабич

7) *махс.* Дошман һөҗүменнән саклану өчен чаралар күрелмәгән, яшеренмичә, турыдан-туры көрәшә торган. *Батарея хәзер ачык позициягә күчте.* К.Нәҗми. *Дүрт йөз метр киңлектәге ачык коридор – нейтраль зона аша күпме шуышканбыздыр, әйтүе кыен.* Ә.Маликов

8) Тәннең кайбер өлешләре (муен, күкрәк, җилкә тирәләре һ.б.) бераз күренерлек итеп тегелгән, ябык түгел. *Рәзифә, кыска итәкле, ачык изүле юка күлмәк киеп, чәчен ясаттырган һәм өстәвенә тәмле хушбуй сөртенгән.* З.Хөснияр // Ябылмаган, төймәләнмәгән, шәрә. *Мәгыйзь авызын ачарга җыенганда, теге чибәр, ачык пальтосын яба төшеп, муенын җыйды.* М.Мәһдиев. *Пальтосын, пирчәткәләрен өйдә калдырган иде, үткер октябрь җиле аның ачык муенын, кулларын чеметкәләде.* Р.Батулла

9) Болыты булмаган, аяз. *Көн ачык чакта, ул Олы күл янындагы утрауны бизәп торган ике талга турылар иде ---.* Р.Батулла. *Яктысы күзләрне чагылдыра торган ачык вә үзенә*

*бертөрле эсселекле язгы кояш кичә явып киткән яңгырның калдырган ахыргы юешлекләрен дә инде киптереп бетерә башлаган.* Ф.Әмирхан

10) Бик яхшы аңлашыла, таныла торган, яхшы күренә торган, аңлаешлы. *Гәзитәләрне, ачыграк язылган китапларны аңлыйм.* Г.Исхакый

11) Сер булмаган, беркем өчен дә яшерен түгел, ачыктан-ачык. *Без беренче мәртәбә дәүләт заказы системасы буенча эшли башлаган 2002 елда нибары 20 ачык конкурс уткәрелсә, 2004 елда инде 104 ачык конкурс уздырылды.* Мирас. *Дәрәҗәңне горур саклый идең, Ачык иде кылган гамәлең...* Р.Рахмани // Шиксез, шөбһәсез; билгеле, анык. *Кеше шундый кояш шикелле ачык нәрсәләрне аңламый азапланса, минем каным кыза башлый.* Ф.Әмирхан

12) Бик дөрес, төгәл, хакыйкатькә туры килә торган; конкрет. *Казан Кремле, мәдәни мирасны саклау, аны өйрәнүгә комплекслы якын килү, саклап калу һәм реставрацияләү өлкәсендә, Россия дәүләт мәдәни сәясәтенең бер ачык мисалы булып тора.* Мирас

13) Керергә теләге булган барлык кеше керә ала торган, катнашырга мөмкин булган. *Ачык суд* // Легаль, яшерен булмаган. *Татар эшчеләренең беренче зур ачык митингларында ул меньшевикларга, эсерларга каршы сугыш ача.* Г.Ибраһимов

14) Бүтән төсләр белән катнашмаган, буталмаган, тонык булмаган, саф төс. *Тышкы яклары да яшел, сары, зәңгәр кебек ачык төсләргә буялган.* Р.Кәрами. *Аларның төсләре дә былтыргы кеби ачык түгел.* Г.Исхакый // Яңгырап торган, чиста, тонык булмаган. *Ачык яңгыравыклы тавыш белән, ул җыр башлап җибәрә, аны бүтәннәр күтәреп ала.* Ф.Сафин

15) Киң һәм чәч белән капланмаган. *Нәфисә кояш белән язгы җилдә алсуланган озынча битен һәм ачык маңгаен яулык чите белән сөрткәләп алды.* Г.Бәширов

16) Конвертсыз, почта карточкасына гына язылган, конвертланмаган. *Хәсән матур күренеш яки матур хатын-кыз рәсемнәре төшерелгән ачык хатларны тезде.* Ф.Әмирхан

17) Киң җәмәгатьчелеккә аталган, нәрсәне дә булса аңлатып, ачыклап, кемгә дә булса аталып, газета-журналда басылган. *[Г.Камал] «Кызыл Татарстан» газетасының 1929 елда чыккан 93 нче номерында ачык хатны бастыра.* М.Гали

18) Материктан, утрау, сайлык кебек урыннардан ерак, су киңлеге генә булган. *Ачык диңгез. Ачык океан*

19) Җирнең тарту көче булмаган, галәмара. *Болар: Җирнең беренче ясалма иярчене – космик чорның башы --- һәм дөньяда беренче тапкыр кешенең космоска очуы, кешенең беренче тапкыр ачык космоска чыгуы.* А.Романов

20) *лингв.* Сузык авазга бетә торган (*иҗек*). *Соңгы елларына чаклы Тукай үз шигырьләренең күпкенәсендә ачык һәм ябык иҗекләрнең билгеле бер тәртиптә нәүбәтләнүләренә игътибар итте.* Г.Нигъмәти

21) *күч.* Мөләем, көләч, ягымлы, кунакчыл. --- *каш астыннан гына бабайларга, Ибраһимга күз төшерде: көлмиләрме? Юк, һәммәсе дә үтә җитди, бер-берсенә хөрмәтле һәм ачык чырайлы иделәр.* Р.Батулла. *Сукыр солдат бик ачык кеше булып чыкты.* А.Хәсәнов. *Ул, ачык чырай белән, сарык ите турап пешергән бер савыт дөгене иренең алдына китереп куя.* Э.Касыймов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Япмыйча, бикләмичә. *Кладовой ишеген ачык калдырганнар.* Г.Камал

2) Капланмыйча, ябылмыйча. *Силос базының өсте ачык калган да, ул бозылган.* Г.Бәширов

3) Төймәләмичә, япмыйча; ачык, шәрә. *Тәне эсселәнеп китте, кулы якасын ычкындырырга сузылды, – ул яканы ачык йөртергә ярата иде.* Г.Әпсәләмов

4) Яхшы, аңларлык итеп. *[Хәмдия:] Хатымда мин аны ачык әйттем. Миңа бирәчәк тартуың – үземә аталган көй, дидем.* Ә.Фәйзи

5) Нык яхшы, аермачык (*күрү, ишетү, хәтерләү һ.б.*). *Әмма бер нәрсәне бик ачык хәтерлим: безнең фатирның һавага чыгып торган иркен генә балконы бар иде.* Ә.Еники. *Музыка залның иң аргы почмакларына кадәр ачык ишетелеп тора.* Р.Мирхәйдәров. *Теләсә кайсы аек фикерле сәясәтче, дәүләт эшлеклесе шуны ачык аңлый: Татарстан белән Россия аеруча тыгыз мөнәсәбәтләрдә булдылар һәм булачаклар.* Мирас

6) Дөрес итеп, яшермичә, ихлас күңелдән, турыдан-туры. *Болай ачык бер дә әйткәне юк.* Ф.Әмирхан

7) *күч.* Күтәренке күңел белән, мөлаем булып, кәефле итеп

**3.** *хәб. функ.* Арымаган, үз зиһенендә, фәһемле. *Тән арган, кул-аяк кузгалырга теләми, ләкин ми ачык, якты, күңел шат.* Г.Ибраһимов

◊ **Ачык авыз** 1) Җебегән, булдыксыз. *Мин сез уйлаганча ук гамьсез һәм ачык авыз булып чыкмадым.* А.Шамов; 2) Бернәрсәдә дә гаме булмаган, игътибарсыз. *Мин, ачык авыз, сәяси аңымның тарлыгы аркасында, карганың күзен карга чукымаганлыгын аңламаганмын.* З.Бәшири; 3) Алдын-артын уйламыйча күп сөйләүчән, беркатлы. *Мин аны шактый «бикле малай» санап йөри идем, ә ул шактый ачык авызлы булып чыкты.* Ш.Маннур. *Мидхәт, ачык авыз, түкми-чәчми сөйләгән дә биргән.* Ә.Галиев. **Ачык итеп** 1) Турыдан-туры, дөрес итеп, бернәрсә дә яшермичә. *Җыелышта син барын да ачык итеп әйт, ялгышыңны төзәтергә сүз бир һәм төзәт.* Р.Ишморат; 2) Гади һәм аңлаешлы итеп. *Ул тиз һәм ачык итеп җавап бирде.* М.Әмир; 3) Бернәрсәне дә бутамыйча, буташтырмыйча. *– Ачыграк итеп әйт, Нуретдин абзый, – диде арткы рәттән кемдер, каты гына кычкырып.* Ә.Еники. **Ачык йөзле** Ягымлы, бик мөлаем, сөйкемле; көләч. *Күзлек кигән, гаҗәп ачык йөзле, сүзгә һәвәс карт доктор килеп керде.* Г.Минский. **Ачык калу** Карар чыгарылмаган, хәл кылынмаган килеш калу, чишелмәү. *Хәзергә аны коммунадан чыгару-чыгармау мәсьәләсе ачык калды.* Ш.Камал. **Ачык карашлы** 1) *к.* **ачык йөзле;** 2) Алдынгы карашлы, белемле, укымышлы; аңлы. **Ачык кына** *к.* **ачык итеп**. *Тагы нәрсә кергән ул үзе дә ачык кына белми.* В.Нуруллин. *Кешенең кем*

*булуын бирәү дә ачык кына белми.* Р.Батулла. **Ачык фикерле** *к.* **ачык карашлы** (*2 мәгъ.*). **Ачык һава** 1) Урам, тыш, саф һава; 2) Бушлык, ялан, кыр. – *Ачык һавада яшәү уңайсыз түгелме соң? – дип сорады Аткин.* М.Юныс. **Ачык чырайлы** *к.* **ачык йөзле**

**АЧЫ́ КАКЫ** *и. бот.* Әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан, кырда, уҗым арасында, төрле ачыклыкларда үсә торган, озынча яфраклы, вак кына сары яки ак чәчәкле, яшь сабаклары ашарга яраклы үлән үсемлек; *русчасы*: **свербига.** *Хәтфә үләнле, кояшлы аланнарда балтырганнар өлгерә. Балтырганнарга ияреп, ачы какылар, кәҗә сакаллары күтәрелә.* А.Гыйләҗев

**АЧЫКЛАМА** *и.* Ачыклык, төгәллек; өстәмә аңлатма, мәгълүмат. *Эчтәлеге сишәмбе көнне билгеле булган бу хатка Киевтагы рәсми затлар баштарак берниндди дә ачыклама бирә алмады.* Ватаным Татарстан

**АЧЫКЛАНУ** *ф.* 1) Беленү, билгеле булу, хәл ителү. *Хәер, соңрак нинди максат белән килеп чыгуы ачыкланды аның.* Г.Кашапов. *Палаткаларның, командаларның бизәлеше буенча призлы урыннар ачыкланды.* Т.Нәҗмиев. *Ә бит язучының иҗат лабораториясе, иҗат процессына кагылышлы күп мәгълүмат әдип үзе исән вакытта гына ачыклана ала.* Р.Фәтхрахманов

2) Яхшырак, ачыграк ишетелү яки күренү

3) Ачылу, яктыру, ачыграк, яктырак хәлгә килү, яктырып, ачылып китү. *Төсе уңа төшкән күк көймәсе тагын да биегәйде һәм ачыкланды.* Г.Бәширов

**Ачыклана бару** Акрынлап, тагын да ачыклану, торган саен ныграк ачыклану. *Аның зиһене әз-әз ачыклана барды.* Ш.Маннур. *Көй якынайган саен ачыклана барды.* Г.Бәширов. *Хәсәннең тавышы ачыклана бара.* К.Нәҗми

**Ачыклана тору** Акрынлап, бар да ачыклану

**Ачыклана төшү** Бераз ачыклану. *Ул да түгел, әлеге җырның мәгънәсе ачыклана төште.* Г.Кашапов. *Болгарларны ассимиляцияләү процессында татар кабиләләренең катнашуы эпитафик язмаларда сакланган «мең», «катай», «табын» этнонимнарында да ачыклана төшә.* М.Әхмәтҗанов

**Ачыкланып бетү** Тулысынча ачыклану, бар да ачыклану

**Ачыкланып җитү** Тәмам ачыклану, тиешенчә ачыклану

**АЧЫКЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса ачу, ачык, билгеле итү; ачыклык кертү. *Хөрмәтле сэр, күрсәтмәләрегез буенча, Бохара әхвәлләрен ачыклауны һәм кайбер ашыгыч чаралар күрүне дәвам итәм.* Т.Әйди. *Урау-урау юллар белән сораша торгач, кияүдә түгеллеген дә ачыкладым.* Р.Низамиев. *Ташка баштанаяк дикъкат биреп караганнан соң, гасырлар сулышын кичергән рәсемнең коралы сугышчы икәнен ачыкладым.* Мирас

2) Кемне яки нәрсәне дә булса төгәл, анык белү. *Исерекне айнытып чыгару пунктына озаттылар, шиклене, ачыклау өчен, милициягә тапшырдылар.* Г.Минский

3) Нәрсәне дә булса өйрәнү, белү. *Чыннан да, түшәмне аграк итәргәме әллә зәңгәррәкме, обойларны нинди биеклеккә күтәрергә, нindirәк бордюр алып, аны ничегрәк итеп ябыштырырга – боларны күп очракларда эш барышында гына ачыкларга мөмкин була.* Өегез ямьле булсын

**Ачыклап алу** Тиз генә ачыклау

**Ачыклап бетерү** Барысын да ачыклау; ахырга кадәр ачыклау, ачыклауны тәмамлау. *Урында ачыклап бетереп, исәп-хисап ясар өчен, сиңа күпме вакыт кирәк?* Ә.Гаффар. *Безнең эшне ашыктырырга, пароход затонда торган вакытта ачыклап бетерергә кушылган икән.* С.Сабиров

**Ачыклап җиткерү** Тиешенчә ачыклау. *Беләсезме, галиҗәнап, --- кечкенә генә --- ачыклап җиткерәсе бер нәрсә бар иде әле.* Ә.Гаффар

**Ачыклап килү** Электән үк даими ачыклау. *Хәтта әле соңгы вакытта галимнәр шуны да ачыклап килә: безнең гасырлар буена «җан» диеп сөйләшә торган хикмәтебез үзе дә кешенең йөрәге тирәсенә тупланып яши икән.* М.Вәли-Барҗылы

**Ачыклап китү** Рәттән, бер-бер артлы, сүз уңаенда ачыклау. *Аның язма әдәбияттан аермалы, үзенә хас үзенчәлекләре, асыл сыйфатлары бар. Хәзер шуларны берәм-берәм ачыклап китик.* М.Бакиров

**Ачыклап кую** Алдан ачыклау. *Маһибәдәрне чакыртып, әллә нәрсә тапкыр йомышчы җибәртте, тик карчык идарәгә бармады. Анда барырдан элек, ул барын да үзе ачыклап куярга тиеш иде.* А.Гыйләҗев

**Ачыклап тору** 1) Даими яки әледән-әле ачыклау

2) Әле, хәзерге вакытта ачыклау. *Мәгънәгә нинди хилафлык килүен ачыклап тору кирәкмидер.* И.Низамов. *Карт, үз күңеленең иң тирән чоңгылларына төшеп, бу галәмәт күренешнең серле хасиятләрен ачыклап тормады.* Г.Гыйльманов

**Ачыклап үтү** Сүз уңаенда, бердән ачыклау. *Бу урында бер мәсьәләне ачыклап үтү кирәк.* Г.Нәбиуллина

**Ачыклап чыгу** Һәрбесен бер-бер артлы ачыклау. *Пугачёв явына кушылган крестьяннарның милли составын һәм урыс булмаган милләтләрнең бу яуда ни өчен катнашуын берникадәр ачыклап чыктык кебек.* В.Имамов

**Ачыклый бару** Акрынлап, тагын да, барысын да ачыклау

**Ачыклый башлау** Ачыкларга тотыну, ачыкларга керешү. *[Каршылык тудыра торган алынмалар исемлегенең] Сәбәпләрен ачыклый башласаң, берьюлы берничәгә юлыгасың.* И.Низамов

**Ачыклый тору** Һәрберсен берәм-берәм ачыклау. *Яннарыннан узып баручы кешеләр турында Наилдән сораштыра, ачыклый торды.* Т.Галиуллин

**Ачыклый төшү** Берникадәр күләмдә, тагы да ачыклау. --- *Халиков белән Баһавиның яшәеш драмасын тагын да тирәнәйтә, Солтан белән Ифратның кешелекле характер сыйфатларын ачыклый төшә.* Р.Зарипова

**АЧЫКЛЫК** I *и.* **1.** 1) Ябылмаган, капланмаган, томаланмаган булу, ачык булу. *Биектән, түбәдәге зур ачыклыктан, бүлмә эченә, бөркелеп, яктылык төште.* Н.Фәттах

2) Урмансыз, агачсыз урын, алан, аланлык. *Урман алдындагы ачыклыкка бура бурап куйганнар.* З.Хөснияр. *Бәрелә-сугыла шулай бераз баргач,*

*калкулык кебек җиргә менеп җиттеләр һәм ачыклыктан аска карадылар.* Ф.Бәйрәмова

3) Ачык урын, бушлык, аралык. *Болыт арасыннан, ара-тирә, ачыклыклар күренеп китә.* М.Юныс

4) Билгеле бер нәрсәләр арасындагы ярык, бушлык, аралык

5) Бер яки берничә әйбер арасында нәрсә дә булса сыярлык урын, аралык. *Асаф ишкәккә үзе утырды һәм әле бер якка, әле икенче якка, алга, артка тартылып карады, су сай, бер якта да үтеп китәрлек ачыклык юк иде.* Р.Батулла

**2**. *с. мәгъ*. Ачык булган, ябык булмаган, томаланмаган; күз күреме еракка төшәрлек булган, беленеп торган. *Бер ачыклык җирдән каравылчы безне күрде дә аты белән безгә таба килә башлады.* М.Гали

**АЧЫКЛЫК** II *и.* 1) Билгеле бер нәрсәнең мәгънәсенә, торышына карата – аңлаешлылык, аныклык. *Күтеп-күтеп тә, Сәгыйрь авызыннан «а» ягына да, «б» хәрефе тарафына да җылы сүз чыкмагач, кыз томанлырак әйтелгән кинаяләренә ачыклык кертергә булды.* Т.Галиуллин

2) Ачык, якты төсләр. *Басыйрның җәенке табак битендәге кабарынкы кашлары мөгез ясап биешеп алды, йөзенә бераз ачыклык биреп, киңчә сирәк тешләре ялтырап китте.* Н.Хәсәнов

3) Болытсызлык, аязлык

4) Нәрсә дә булса калдырган эз, тамга һ.б.ш. ачык булуы күренеп-беленеп торган галәмәтләр

5) Ягымлы булу, мөлаемлык, ачык йөзлелек. *Бу кешедә ачыклык күрмәде, нииндидер яшертенлек сизде.* Н.Хәсәнов. *Аннаның ачыклыгы, тәмле кофены оста итеп ясап бирүләре вә чәй янындагы сыйлар шул фәлсәфәләрне оныттырды.* Г.Исхакый. *Мондый риясыз ачыклыкка өйрәнмәгән Сәгыйрь тәмам югалып калды.* Т.Галиуллин

**АЧЫКТА́Н-АЧЫК** *с.* **1.** Яшерен булмаган, күренеп торган, җәелеп яткан, билгеле. *Ачыктан-ачык ялган*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Яшермичә, бар кеше алдында. *Безнең бюро анда ачыктан-ачык эшли.* З.Фәтхетдинов

2) Кыенсынып тормыйча, оятсыз рәвештә. *Ул башта, дөнья күргән, күпне белгән адәм, дип, Сабирдан тартынып торса да, моның һәр турыда ачыктан-ачык бәргәнен күргәч, берьюлы үзенең Җаббарлыгына төште дә, табам, үзем табам, дип, бөтен тирә-якның кызларын саный башлады.* Г.Ибраһимов

3) Бик яхшы, ачык күңел белән, ихластан

**АЧЫ́К-ТИШЕК** *с.* **1.** *сөйл.* Искереп, тузып, тишелеп беткән; тишек-тошык

**2.** *җый. и. мәгъ.* 1) Билгеле бер нәрсәләрдәге (*каралты, җиһаз, кием-салым һ.б.ш.*) ватылып ачылган-тишелгән, ертылган-сәләмәләнгән урыннар

2) *күч.* Җитмәүчелек, мохтаҗлык

◊ **Ачык-тишекне ямау** 1) Ватылган, ачылган-тишелгән, ертылган-сәләмәләнгән урыннарны рәтләү, ямау, иске-москыны төзәтү, ямаштыру; 2) Матди җитмәүчелекне нинди дә булса юллар белән рәтләү, каплау, бетерү

**АЧЫКТЫРУ** *ф.* 1) Ашыйсы килү халәте кичерү, ашыйсыны китерү

2) Ачлык белән җәфалау, интектерү; тилмертү. *Алар, исәрлегемне күреп, акыл бирәләр миңа: этне күзеңә карatып торасың килсә, аны ачыктырып тотарга кирәк.* Ф.Баттал

**Ачыктырып бетерү** Бик нык, тәмам ачыктыру. *Көне буена берни ашатмадылар, тәмам ачыктырып бетерделәр*

**АЧЫЛМАЛЫ** *с.* Ачыла-ябыла торган итеп эшләнгән, ачыла торган. *Хафизов, --- кешеләрнең чыгып беткәнен дә көтеп тормыйча, бердәнбер ачылмалы тәрәзәне ачып җибәрә.* Г.Кашапов. *Каршыда – коридор, сулда – кухняга уза торган аралык, ә уңда – ике якка ачылмалы ак ишек.* Ә.Еники

**АЧЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **ачу** I (*1–9, 13, 14, 18 мәгъ.*). *Капкачы ачылган үтүктән утлы күмерләр бөтен бүлмәгә диярлек чәчелде.* К.Йосыпов. *Аш алыштырылды: бәлеш чыкты, өсте ачылды*. Г.Исхакый

2) Күз алдында булу, киңәеп күренү. *Айҗан үренә менеп баскач, каршыларында искиткеч манзара ачылды.* Хәйдәр // Күз алдына басу, күз алдына килү

3) Төзәлмәү, яңадан начарлану, көчәю, төзәлүдән туктау. – *Яраң ачылдымы әллә? – Ачылмады ачылуын, аз гына сыкрап тора.* Р.Ишморат

4) Үсемлекләрнең яфрак яруы, чәчәк атуы турында. *Чәчәкләргә шунда ук җан керә, яфраклары күтәрелеп, таҗлары ачыла.* М.Хуҗин

5) *сөйл.* Чистару, агару, пычрактан арыну, үз төсенә кайту (кер һ.б.ш. нәрсәләр турында). *Ләкин шул чәй, шул ачылган самавыр, шул ялтырап торган чынаяклар тагы аңар карчыгыны исенә төшерде.* Г.Исхакый

6) Башлану. *Энҗенең тормышында кичә яңадан якты сәхифә ачылганы инде бәхәссез иде.* Г.Тавлин

7) Болытлардан арыну, аязу. *Әллә нидә бер генә бөтен тирә-юньне болыт каплап, иләктән генә вак яңгыр сибәләсә дә, икенче көнне үк күн ачылды.* Г.Исхакый

8) Җирнең – кардан, елганың боздан арынуы турында. *Ишек төбендә чыпчык эчәрлек су җыела башлау белән, авыл өстендәге Ясмык тавы кардан ачыла.* Х.Хәйруллин

9) *күч.* Яктыру, ачыклану (уй, фикер турында). *Саф һавага чыккач, уйлары ачылгандай булды*

10) *күч.* Күңеле, кәефе күтәрелү, күләчләнү. *Ул тагы ачылды, тагы кунакка килде.* Г.Исхакый

11) *күч.* Яхшыру, рәтләнү, рәтләнеп китү. *Аппетит ачылу*

12) *күч.* Таралу, бетү, үтү. *Тәне җиңеләйгән, ул әле һаман оча кебек, йокысы тәмам ачылган, күңеле, әлеге гаҗәеп төштәгечә, биеккә-биеккә очу тәэсиреннән канатланган.* Г.Әпсәләмов

13) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса киртә, каршылыклар бетү турында (*мөмкинлек, юл* һ.б.ш. сүзләр белән килә). *Нихәтле күп продукция бирсәк, шулхәтле безгә иркен сулыш алырга мөмкинлек ачыла.* Ш.Камал. *Бәлки, иртәгә юлым ачылыр да, бәлки, тагын рәхәт-рәхәт яши башлармын.* Г.Камал

**2. ачылып** *рәв. мәгъ.* 1) Ачыктан-ачык, эчкерсез, бернәрсә дә яшермичә. *Женя Илфатның, төпченеп, хәл-әхвәл сорашуына ихлас күңелдән сөенеп, барысын ачылып сөйләде.* Б.Камалов. *Үзе*

*нинди мәгънәле итеп әйтте бит: ник ачылып сөйләшмисең, ник елмаймыйсың, әллә безне тиңсенмисеңме, янәсе.* Ш.Маннур

2) Билгеле булып, ачыкланып. *Искәндәр, контрреволюцион эше ачылып, кулга алынды.* Г.Нигъмәти

3) *күч.* Ачык, якты чырай күрсәтеп

**Ачыла тору** Акрынлап ачылу; торган саен ныграк ачылу. *Шәрәфи сөйли, аның алдында авыл белән каланың бәгланышлы моментлары ачыла торалар.* Г.Ибраһимов

**Ачылып алу** Азга гына, берникадәр вакытка ачылу. *Әллә аз гына вакытка тавышы ачылып алдымы – хәзергәчә үзем дә төшенмим.* М.Хуҗин

**Ачылып бетү** Тулысынча, ахырына кадәр ачылу. *Йокыдан иртә тору сәбәпле, җир күрсәтергә барганда башымны җыя алмасам да, кайтырга чыкканда, кәеф тәмам ачылып беткән иде.* Г.Исхакый

**Ачылып китү** Кинәт ачылу. *Әлбәттә, бу палатаның ишеге үзеннән-үзе ачылып китәргә тормыйдыр.* З.Фәтхетдинов. *Су – бер сулышлык сүз. «С» – көмеш аваз, чыңлап ачылып китә.* М.Галиев. *Хәлим, кайтырга кирәк инде, килмәс, дип, мич куышыннан аякчуларын алып чыгарга торганда, капка әкрен генә, бер дә шыгырдамыйча гына ачылып китте.* Г.Гобәй

**Ачылып яту** Ачылган хәлдә булу. *Бердән, күзе күршесендәге Үлмәснең ялтырап ачылып ята торган күзенә очрады.* Г.Исхакый

**АЧЫЛЫК** I *и.* Нинди дә булса химик элементның кислород белән кушылмасы; оксид. *Күл төбен карарга кирәк. Күл төбе тимер ачылыгы бүлеп чыгара.* Г.Ахунов

**АЧЫЛЫК** II *и.* 1) Тәме ачы булу. --- *Җаен ачы миләш, Кыраудан соң киткән балланып. Кырау аның алган ачылыгын, Кырау аны шулай өлгерткән.* Г.Афзал

2) *җый. мәгъ. күч.* Кайгы-газаплар, түбәнсетү-кимлекләр. *Син, бәгырькәй, миңа моның [вакыйганың] бөтен ачылыгын йоттырдың.* Ш.Маннур

**АЧЫЛЫК** III *и. диал.* Аякны сөртеп керү өчен, ишек төбенә җәелгән әйбер, җәймә

**АЧЫЛЫКЛЫ** *с. махс.* Кислоталы, составында кислота булган

**АЧЫ́ЛЫ-ТӨЧЕЛЕ** *с.* **1.** 1) Ачы һәм төче тәмнәрдәге. *Өстәл ачылы-төчеле нигъмәтләр белән тулы*

2) Каты һәм йомшак, тупас һәм ягымлы. *Ачылы-төчеле сүз*

**2.** *рәв. мәгъ. күч.* Тупас та, йомшак та кыланып, төрле сүзләр әйтеп. *Ачылы-төчеле сөйләшү*

◊ **Ачылы-төчеле булу** Вакыты-вакыты белән ачуланышу. **Ачылы-төчеле яшәү** Тигез, тату яшәмәү, ачуланышып та алу. *Ачылы-төчеле яшәү, иртәме-соңмы, бөтен кешене дә туйдыра*

**АЧЫЛЫШ** *и.* Нәрсәнең дә булса ачылу вакыты, ачылу ноктасы, мизгеле

**АЧЫЛЫШЛЫ** *с.* Ачыла торган. *Ике якка ачылышлы тәрәзә*

**АЧЫЛЫШЛЫ БУЛУ** *ф.* Кем белән дә булса ачуланышу, сүзгә килү, мөнәсәбәтләрне өзү. *Кемнәр беләндер ачылышлы булырга да туры килә.* Р.Кәрами. *Билгеле, өлкән дусты белән ачылышлы булу Маннурның җанын шактый кыерсытты.* М.Хәсәнов. *Эче тулы вәсвәсәдән юньле йокы күрмәгәнгә, сеңлесе Зәкия белән сүзгә килеп, ачылышлы булганга, Бибиҗамал апа ялыккан һәм йончыган иде.* Ш.Хөсәенов

**АЧЫНДЫРУ** *ф.* Бик нык көендерү, борчу, мыскыллау. *Күзе аша миенә чәнчер дәрәҗәдә ачындыру өчен, кешене ничек мыскылларга мөмкин икән?* Р.Батулла

**АЧЫНУ** *ф.* 1) Нык борчылу, кайгыру, газаплану. *Җә Ходаем, үзең ярлыка, дип ачынды Гөлйөзем.* М.Әмирханов. *Резеда Фәритовна, бу ике кешегә каршы тора алмавына ачынып, эчтән сызды.* М.Маликова

2) Нәрсәгә дә булса үкенеп, нәрсәне дә булса кызганып, бик нык борчылу, көенү, өзгәләнү. *Ләкин минем Фәхренур апаның кыз булып туганына ачынганын да, зарланганын да ишеткәнем булмады.* Г.Тавлин. – *Кадрлар җитми, кадрлар! – диде ул, ачынып.* Ф.Сафин

**Ачынып йөрү** Озак вакытлар дәвамында ачыну. *Тынгысыз җанлы, эзләнүчән Г.Хөсәенов татар драматургиясендә эпистоляр жанр юклыгына байтактан ачынып йөрде.* А.Гыйләҗев. *Кич буе диярлек ул, Газинурга әйтәсе шелтәләре турында уйлап, ачынып йөрде.* Г.Әпсәләмов

**Ачынып кую** Кинәт ачыну, кыска вакыт эчендә ачыну хисе тою. --- *эшгамәлләребездә, тормышыбызда, язганнарыбызда шагыйрь сөймәгән нәрсәләр буа буарлык. Кайвакыт, шулар хакында уйланып: «Их, Тукай булса!» – дип ачынып куясың.* Х.Миңнегулов. – *Юкка исенә төшердем хатынын, – дип ачынып куйды Мәрфуга, аны кызганып.* Д.Бүләков

**АЧЫНУЛЫ** *с.* 1) Кызгандыра торган, йөрәк өзгеч. – *Канга тоз сала инде! – Сергейның тавышы ачынулы, шелтәле иде.* Х.Камалов

2) Борчылу, көенү катнаш. *Беркадәр вакыттан соң, ачынулы хисләр Мортазинны халәт диңгезенең бөтенләй капма-каршы ярына алып атты.* В.Имамов

**АЧЫНЫШ** *и.* Олы кайгы, авыр хәсрәт. *Ачынышлы ел булды шул бу безнең өчен, ачынышлы...* Сөембикә

**АЧЫНЫШЛЫ** *с. сөйл. к.* **ачынулы.** – *Караул! – дигән ачынышлы тавышка Гөлбикә, сискәнеп уянып, урыныннан сикереп торды.* Г.Иделле

**АЧЫРГАЛАНУ** *ф.* **1.** Бик нык өзгәләнү, нык ачыну. *[Малай:] – Мин урламадым! – дип ачыргалана. – Абыйлар! Мин угры түгел!* М.Хуҗин

**2. ачыргаланып** *рәв. мәгъ.* 1) Өзгәләнеп; ярсып, үксеп. *Бу хакта безнең бүгенге шагыйрьләр дә шактый еш һәм ачыргаланып язалар.* Ф.Урманче. *Аюханның зиһене (инде ничәмә кат!), ачыргаланып, җавап эзләде.* Г.Якупова. *Тик Рәния, аның саен, бозауны кочаклап, еларга җитешеп, ачыргаланып кычкыра иде.* А.Вергазов

2) Ярсып, усалланып. *Апа инде ачыргаланып сорап куйды: – Нигә әле, Касыйм, син дә сакау әтәч кебек интегәсең?* К.Йосыпов

3) Ачы тавыш белән, бик нык җилкенеп. *Хәлим ачыргаланып кычкырган әтәч тавышына уянып китте.* Г.Гыйльманов

**АЧЫ́ СУ** *и. сөйл.* 1) Составында углекислота булган минераль су

2) *күч.* Аракы, гомумән исерткеч эчемлек

**АЧЫСЫ́-ТӨЧЕСЕ** *җый. и.* Ачы һәм төчедән торган, ачы һәм төче нәрсәләр. *Өстәлдә бар да бар: кайнары, салкыны, ачысы-төчесе.* Казан утлары

◊ **Ачысын-төчесен күрү** Яхшысын да, яманын да, рәхәтен дә, михнәтен дә, шатлыгын да, кайгысын да күп кичерү.

**Ачысын-төчесен тату** *к.* **ачысын-төчесен күрү**. *Тормышның ачысын-төчесен татыган ана, хәбәрне читкә таратып, агач башында эт улату юлына басмый.* Т.Галиуллин

**АЧЫТКЫ** *и. сөйл.* Чүпрә; камыр башы. *Кайчан гына барып кермә, аның мотлак камыр ачыткысы булыр, сине күрү белән камырына тотына, һәрчак мин, гаҗәпләнеп: – Әллә көн дә камыр пешерәсең инде? – дим.* Ф.Чанышева

**АЧЫ́ ТОЗ** *и.* Эч йомшарткыч тоз; *русчасы:* **английская соль**

**АЧЫ́ ТОРМА** *и. бот.* 1) Әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан, орлыгыннан май җитештерелә торган тамыразыклы бакча үсемлеге; яшелчә; *русчасы:* **редька**

2) Шул үсемлекнең ашарга яраклы, зәһәр исле һәм ачы итләч тамыры. *Йөткерүне бетерү өчен, ачы торманы пешереп ясалган дару да файдалы.* Р.Биктимерова. *Ачы торма С витаминына бай*

**АЧЫТТЫРУ** *ф.* 1) Үзәккә үтәрлек итеп, нык әрнетеп, бик нык ачытып авырту. *Доктор биргән вазелин да ярдәм итмәде, һаман ярыла. Су тигәч, ачыттырып сызлый башлый.* М.Юныс

2) Кисү, кискен тәэсир итү. *Чәчтырнак буявы исе борынны ачыттыра иде.* Н.Гыйматдинова. *Әче төтене заманның күзләрне ачыттыра!* И.Вәлиуллин. *Мич янында эссегә түзүе кыен, гарәп сахралары бер якта торсын. Шуның өстенә, ашыгасың, кабаланасың, тозлы тир күзне ачыттыра.* Т.Галиуллин. *Әллә нинди черек көкәй исе чыгарып ята торган ләпек газы борынны ачыттыра.* Х.Камалов

3) *күч.* Әрнетү, күңелгә авыр тәэсир итү. *Сүзләр, ничектер, һәрберсе сыек чыбык суккан кебек, укыган саен җанын ачыттыра, йөрәген чеметтерепчеметтереп алалар.* Х.Камалов

**Ачыттыра бару** Торган саен ныграк ачыттыру

**Ачыттыра төшү** Берникадәр, бераз ачыттыру

**Ачыттыра тору** Бертуктаусыз, гел ачыттыру. *Яңгыравыклы малайлар тавышын аерым-аерым танып җиткереп булмады, ләкин болай колакларны ачыттыра торган итеп, «ультратавыш катнаштырып», Торналыда берәү генә сызгыра: Әбүзәр.* А.Тимергалин

**Ачыттырып бетерү** Бик нык ачыттыру; бөтен җирен дә ачыттыру

**Ачыттырып җибәрү** Кинәт ачыттыра башлау

**Ачыттырып тору** Әле, хәзерге вакытта ачыттыру

**АЧЫТУ** I *ф.* 1) Ачыткы салу, ачы хәлгә китерү. --- *һәрвакыт кесәсендә йөрткән җәен кабыргасы белән тешләрен казый-казый: – Нәби кияү, сарык суеп, бер мичкә бал ачытып, кунакка чакырды әле [диде].* Г.Мөхәммәтшин

2) Искертеп бозу, ачы халәткә китерү. *Кайчан гына әле бездә ипине туп итеп тибеп уйнап йөриләр, ачытып, ашлама урынына, яшелчә түтәлләренә сибәләр иде.* Г.Афзал

**Ачыта башлау** Ачытырга тотыну. *Колхозлар оешкач, сабан туйларын язгы эшләр беткәннән соң уздыру гадәте кереп киткәнлектән, балны да чәчү бетүгә ачыта башладылар.* Г.Бәширов

**Ачытып алу** Тиз генә ачыту. *Әйтер сүзең – бал; төчесе ярамаса, авызыңда ачытып ал!* Н.Исәнбәт

**АЧЫТУ** II *ф.* Үтә нык әрнеп, үзәккә үтәрлек итеп авырту. *Хәлимнең күкрәк турыннан нидер өзелеп киткәндәй булды, күз тирәләре ачыта, тамак төбе яна башлады.* Хәйдәр. *Корбангалинең авыз эче ачытып, башы әйләнә башласа да, сыйдан баш тартырга яхшысынмады.* Г.Афзал

**Ачытып кую** Кинәт ачыту тою. *Көймәгә бәрелеп чапылдаган дулкын тавышын ишетүгә, күзләре ачытып куйды.* Ф.Латыйпов. *Бу хакта уйлагач, Сөембикәнең йөрәге ачытып куйгандай булды, куллары калтыранып китте.* Ф.Садриев

**Ачытып тору** Бертуктаусыз ачыту *Күздән яшь агып тора, Борыннан тамып тора. Тамак ачытып тора.* В.Хәйруллина. *Агач тамырларына бәрелә-бәрелә чылтырап аккан кечкенә инешнең салкын суын кушучлап алып, --- маңгайларын, бераз ачытып торган күзләрен, кызарып, бакыр төсле булган кайнар беләкләрен юарга тотынды.* Г.Бәширов

**АЧЫШ** *и.* 1) Тикшеренүләр, эзләнүләр нәтиҗәсендә ачылган, билгеле булган нәрсә, фәнни яңалык, яңа фәнни нәтиҗә; казаныш. *Медицина фәненә ачыш ясый, ди.* Р.Хафизова. *Атаклы галимнең әлеге ачышы тере организмнарның миллионлаган еллар дәвамындагы эволюцион үсешенең асыл сәбәпләрен аңлата.* К.Гыйззәтов

2) Яңа җирләрне үзләштерү. *XVI–XVII йөзләрдәге бөек географик ачышлар нәтиҗәсендә, европалылар күп төрле телләр белән танышалар.* Ф.Сафиуллина

3) *күч. ирон.* Кем өчендер көтмәгәндә, уйламаганда билгеле булган нәрсә. *Халидәнең ул өлкәдәге яңалыклар белән танышып баруы һәм төпле фикер йөртүе Әзһәм өчен көтелмәгән ачыш һәм шатлык иде.* Р.Кәрами

**АЧЫШУ** *ф. к.* **ачу** III (*3 мәгъ.*). *Аралык мич башына ташланган киез итекләр, иске туннарның ачышкан исләре белән аңкып тора иде.* Ә.Фәйзи

**А́Ч-ЯЛАНГАЧ** *с.* **1.** Ач һәм ялангач, фәкыйрь, кием-салымга, азык-төлеккә бик мохтаҗ. *Зыкы суыкларда урманнан ач-ялангач килеш утын тартып ташулар --- аны түшәккә екты.* Н.Хәсәнов. *Анда фәкыйрь юк, ач-ялангач, теләнчелек иткән зәгыйфь юк, актык сулышында авызына су салырга кешесе булмаган авыру юк, золым юк, җәбер юк, һәр җирдә – тигезлек, һәр җирдә – гадаләт.* Г.Исхакый

**2.** *рәв. мәгъ.* Үтә мохтаҗлыкта, бик нык фәкыйрьлектә. *Шуннан соң мәнә бер ел буена балаларым белән ач-ялангач тордым!* Г.Ибраһимов

**3.** *и. мәгъ.* Ярлылар, ярлы халык. *Тук торып рәхәткә күнгән эчләрең кыйналдымы, Ач-ялангачларга шәфкать хисең уйгандымы?* Ш.Бабич

**А́Ч-ЯЛАНГАЧЛЫК** *и. к.* **ачлык-ялангачлык.** *Ач-ялангачлыктан сак-*

*лау өчен ирек һәм җир алыгыз безгә.* Ш.Мөхәммәдев

**АШ** I *и.* 1) Нинди дә булса юл белән (пешереп, кыздырып), ашау өчен махсус әзерләнгән ашамлык, азык. *Ашның тәмле, кызыктыргыч күренүе нинди табак-савыт белән бирелүенә дә бәйле.* Н.Исәнбәт. *Ләкин, кыз алганда, кукраеп, кодагый булып, түрдә утырасың, кодагый, кодачаларның ашларыны, бик яхшы булган, дип, ятратмаганны күрсәтеп тора торган төсле мактыйсың.* Г.Исхакый

2) Гомумән нинди дә булса ашарга яраклы ашамлык; ризык, азык. *Арпакөрпә аш булмый, надан кеше баш булмый.* Мәкаль. *Ә монда – кытай, япун ашлары, чукча кулинариясе...* Ф.Баттал. *Гомәр, тансык аш итеп, катык та сорап алды.* Ә.Еники

3) Беренче итеп бирелә торган шулпалы ризык. *Байконурда туган ханымның камыр салырга, бәлеш, гөбәдия түгел, гадәти шулпалы аш пешерергә дә теләге юк.* Т.Галиуллин. *Яңа гына күлдән чыккан табан балык ухасын --- ашамаган кешеләр бу ашларның ләззәтен барыбер тоя алмаячаклар.* Ш.Маннур

4) Гомумән ашау, ризык кабул итү процессы. *Аштан соң, көймәгә төшеп, күлнең яр башындагы елга берлән әллә никадәргә барып, андагы балыкчы финдә чәй эчтеләр, балыклар алып кайттылар.* Г.Исхакый // «Иртәнге», «көндезге», «кичке», «төшке» сүзләре белән килеп, шул вакыттагы ризык кабул итүне белдерә. *Бервакыт төшке аш вакытында, Магнитогорск кешесе Виктор Дурманов консервланган мидияләр банкасын ачты. Моллюскларның ите ярыйсы иде.* Чаян // «Иртәнге», «көндезге», «кичке», «төшке» сүзләре белән килеп, шул вакытларга билгеләп әзерләнгән ашамлыкны белдерә. *Андый вакытта, көтүчегә көндезге ашны илтү гадәте бар иде.* К.Йосыпов. *Театрдан чыккач, Шәмсетдин, бу юлы бер дә курыкмаенча, кичке ашка чакырды.* Г.Исхакый

5) Кунак мәҗлесе. *[Финан:] Чәлдер абзый, бүген кич скрипкаң белән безгә ашка бар әле!* К.Йосыпов. *Кичә, кунаклар янына дип, авылның байгураларыны ашка чакырдык.* Г.Исхакый. *Әткәй белән әнкәй, ниндидер бер бәйрәм уңаеннан, аш мәҗлесе уздырырга булганнар.* К.Йосыпов

◊ **Аш алды (ясау)** Ашау алдыннан, «аш сеңдерү» өчен дип, исерткеч эчемлек эчеп кую. **Аш арты** 1) Ашау ахырында бирелә торган җимеш суы яисә башка берәр ашамлык; 2) Кеше сөйләгәнне кабатлап әйтү турында. **Аш бармау** Ашыйсы килү теләге булмау, ашауга күңел тартмау. **Аш белән атканга таш белән ату** Яхшылыкка яманлык белән җавап кайтару. **Аш белән каршы алу** Ачык йөз күрсәтү. **Аш белән озату** *к.* **аш белән каршы алу.** *Кызың киткәч, киявең килер, Озат, әнием, син аш белән.* Җыр. **Аш бирү** Кемгә дә булса якты йөз күрсәтү, аны ашату-эчертү. **Аш булсын** Гадәттә, сый-хөрмәткә рәхмәт белдергәннән соң, каршы әйтелә торган сүз. **Аш булу** 1) Кемгә дә булса дөрес, кирәкле җәза турында әйтелә. *Шушы җирдә авызыңны ямьшәйтеп җибәргәндә дә аш булыр иде инде сиңа.* М.Фәйзи; 2) Файдалы ризык булу, күңелгә хуш килү. *Аш буладыр миңа чәчәкләр хуш исе.* Г.Тукай. **Аш бу сиңа** Сиңа шул кирәк, мәгънәсендә. *Минем Ибраһимымны бөтенләй үзеңә багындырып бетердең, Ибраһимны сарыга сабыштырып бетердең! Аш бу [хурлыклар] сиңа!* Г.Камал. **Аш кайтару** 1) Кунакка барып кайтканнан соң, хуҗаларны үзеңә кунакка, мәҗлескә чакырып алу; 2) Ашап туюю билгесен белдереп, кунакның ашъяулык читен бөкләп куюы; аштан соң дога кылу, амин тоту. **Ашка (кара) таракан булу** 1) Нинди дә булса эш вакытында, планнарны җимереп, чит кеше килеп керү; 2) Мәҗлескә, көтмәгәндә-уйламаганда, чит яисә яратмаган кеше килеп керү. **Ашка (кара) таракан булып төшү** *к.* **ашка (кара) таракан булу.** *Җәмилә җиңгинең акылы үзе белән, тәки ашка төшкән таракан булыр.* М.Хәсәнов. **Аш талымлау** Ашны-ризыкны бик сайланып ашау. **Аштан калу** Аш үтми, ашый алмый башлау белән характерлы авыру. *[Патша кызы] Көннән-көн сула, саргая, йокысызлыкка бирелә, аштан кала барадыр.* Аң. **Аштан олы булу** Ризыкны хөрмәт итмәүгә карата әйтелә. – *Аштан олы түгелсең бит, Шәрифулла туган, – диде карчык, – утыр, безнең нигъмәттән дә авыз итеп кара.* А.Шамов. **Аштан язу** *к.* **аштан калу**. **Аш төрләндерү** 1) Ризыкларны аралаштырып, төрләндереп әзерләү; 2) Йөкле хатынның ризык талымлавы, ризык сайлавы. *Ильясы белән авырлы чакта һич алай булмады, аш төрләндермәде.* Г.Якупова; 3) *ирон.* Бозык ирләргә, бозык хатыннарга карата әйтелә. *Шулай, кызым, ирләргә бер вакытта да ышанып бетәргә ярамый, аш төрләндерергә яраталар алар.* Ә.Еники. **Аш төрлеләтү** *диал.* *к.* **аш төрләндерү** (*2 мәгъ.*). *[Саҗидә] Кияү килгәч торып чыкса да, ул аш төрлеләтә, кайвакыт коскалый да башлады.* Г.Исхакый. **Аш үзгәләү** *к.* **аш талымлау**. **Аш үтмәү** 1) *к.* **аш бармау.** *Гөлнарымның хаты башымнан чыкмый. Тамагыма аш үтми башлады, ябыктым.* Ә.Айдар; 2) Үңәчтән аш үтмәү яисә ризык ашказанына кабул ителмәү белән бәйле авыру. *Анасы Мәргыя карчыкның авыруы – кылтамак чирен, ашы эченә үтмәвен, капкан бер нәрсәсе кире чыга торуын Мәрхәб тегендә чагында ук ишеткән иде.* Г.Ибраһимов. **Ашым аш түгел** Бик каты борчылу нәтиҗәсе буларак, рухи тынычсызлыкны аңлата. *Ашың аш түгел, йокың йокы түгел – һәммәсе дә йөрәгеңә агу булып урнаша.* М.Гали. **Ашын ашаган, яшен яшәгән** 1) Бик озак яшәгән, бик карт. *Безнең инде ашыбыз ашаган, яшебез яшәгән, кызым, авырлыклар күрергә Алла сезгә боермасын!* М.Гали; 2) Бик иске, тузган, искергән. *Бик иске завод; ашын ашаган, яшен яшәгән, димәк.* Ш.Камал

**АШ** II *и. сөйл.* Тукыма яки җепләрне ныклы бер формага китерү өчен файдаланыла торган, бәрәңге яки башка нәрсә онынннан ясалган җилемле-крахмаллы эремә. *Эскәтернең ашы беткән, ашлыйсы бар*

**АША** *бәйл.* 1) *к.* **аркылы** II (*1–9, 11 мәгъ.*). *Ул инде шуннан соң ничә койма аша сикергәнен хәтерләми.*

З.Фәтхетдинов. *Ара-тирә, кырыс йөзе аша ягымлы елмаюын сирпүгә, балалар аны шунда ук аңлап алалар.* К.Йосыпов. *Аннары, Казанга кайткач, шушы ук теманы кузгатып, СССР Фәннәр академиясендәге союздаш республикалар академияләре эшчәнлеген координацияләү комиссиясенең җаваплы секретаре Николай Пшерков белән телефон аша сөйләшә.* Мирас

2) *к.* **аралаш** (*3 мәгъ.*). *Ул минем кулларыма ябышты, күз яшьләре аша миңа текәлеп карады.* Ә.Айдар

3) Кайбер абстракт исемнәр янында килеп, эш-хәлнең үтәлү рәвешен, характерын белдерү өчен кулланыла. *Гасырлар аша торып кычкырасы, оран саласы килде.* З.Фәтхетдинов. *Тартышлар аша без чын иреккә киләчәкбез.* Ф.Сафин

◊ **Аша китү** Нәрсәнең дә булса тиешле нормадан, нормаль хәлдән, чигеннән артып китүе турында. *Әмма ул оятсызның [Алтынбайның] бүгенге эше инде Сабираның башыннан аша китте.* Г.Ибраһимов. **Аша узу** *к.* **аша китү. Аша суккан җил** Үтәли җил

**АШАДА́Н-АША** *рәв. сөйл.* Бер ягыннан икенче ягына, бер кырыеннан икенче кырыена кадәр, үтәли. *Урманны ашадан-аша үтү*

**АШАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ашау** (*1 мәгъ.*). *Хәзрәтләр – шактый күп алган түй сәдакасыннан, авыл кешеләре – тәмле иттереп ашалган ашлардан, кода-кодагыйлар – яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлеснең муллаларча затлы үтүеннән разый калдылар.* Г.Исхакый

2) Кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү (йөзкыяфәт, кием-салым һ.б.ш. турында). *Җил-яңгыр белән калай түбәләренең буяулары ашалган, үзе җиргә сеңәргә әзерләнгән күн заводының корпуслары янынннан, култыкланып, Миләүшә елгасы ага.* А.Алиш

3) Кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. *Ботинканың ашалган үкчәләрен дә төзәткән иде ул.* А.Шамов

4) Агымсу, яңгыр тәэсиреннән юылу, яргалану, җимерелү (су яры, тау токымы турында). *Ерганаклар теләтекә тауны, Яр ашала ел да ташудан.* К.Булатова

5) *күч.* Юкка чыгу, бетү, үлү. *Бердәнбер баласының башын ашадылар*

**Ашала бару** Торган саен ныграк ашалу. *Елгасы хәзер бик сай, ә ярлары тирән һәм һаман ашала бара.* Ф.Гарипова

**Ашала төшү** Бераз ашалу

**Ашалып бетү** Бик нык, тәмам ашалу; тулысынча, бөтенләй ашалу. *Аннары сәләмә атка җигелгән, үрәчә баулары өзелеп, табаннары ашалып беткән сәләмә чанасына өч кыз төяп, Равил юлга чыга.* В.Нуруллин. *Ләкин күпме азапланмасын, беләзекнең кыршылмыйча калган урынындагы «... гәүһәр даш улмаз ...» һәм «... кадрене ахмак белмәз ...» дигән сүзләрне генә аера алды. Башкалары инде ашалып беткән, танырлык түгел иде.* Ф.Латыйфи

**Ашалып килү** Акрынлап, күптәннән ашалу, ашалуын дәвам итү. --- *шовинистлар тарафыннан «милләтчелек» дип аталып килде һәм шул «милләтчелек» күпме кешенең башын ашады, ул һаман да ашалып килә, кешеләрнең башын ашамаса да, милләтләрне сепаратизмда гаепләү өчен яшн бирә.* К.Нәҗми

**Ашалып тору** Даими яки әледәнәле ашалу

**Ашалып чыгу** Тәмам ашалу, ашалу дәрәҗәсенә җитү. *Киндер сукканда, бармак тиресе ашалып чыга.* М.Юныс

**АШАМА́К-ЭЧМӘК** *и. диал.* Ашау һәм эчү әйберләре, ризык, азык-төлек. *Бер Устиясендә генә әллә ничә мең, бәлки йөз меңнәр кешегә ашарга-эчәргә җитәрлек ашамак-эчмәк, йөз мең кешегә җитәрлек тәмле нәрсәләр бар.* Г.Исхакый

**АШАМЛЫК** *и.* Ашый торган, ашарга яраклы, ашау өчен әзерләнгән, ашарга ярарлык хәлгә китерелгән нәрсә; азык, ризык. *Галия апа минем кулыма кәгазьгә төргән нindидер ашамлык тоттырды.* Н.Дәүли. *Өстәл өстенә куелган ашамлыклар, сугыш вакытына карата, бик сирәк кешедә була торган үзе бер байлык иде.* Б.Сөләйманов. *Сугышка кадәр әти Казаннан, нindидер, үзе озынча, үзе түгәрәк бер кызгылт ашамлык алып кайткан иде.* Ә.Салах

**АШАМЛЫК-ЭЧЕМЛЕК** *җый. и.* Ашарга-эчәргә яраклы әйберләр; азык, ризык. *[Мәрфуга:] Карт, тагы ашамлык-эчемлектән тәмлерәк, затлырак нәрсәләр булса, саклап тотарга гына азрак алырсың.* Г.Исхакый

**АШАМСАК** *с.* 1) Тәмлетамак, тәмле ашарга ярата торган. *Кайбер кеше шулай ашамсак була инде ул.* Г.Бәширов

2) Туя белмәгән, күп ашый торган. *Шилов бик ашамсак, ахры, урды гына, ашагач, йөзенә елмаю чыкты, хәрәкәтчән һәм уенчан булып әверелде.* Х.Камалов

**АШАМЧАК** *с. к.* **ашамсак.** *Бу кеше, Убырның үзе кебек үк, комсыз, бик азгын, бик ашамчак була – күпме ашаганын да, туйганын да белми.* Фольклористика

**АШАРГА** *и. диал. к.* **ашамлык.** *Чарасызлыктан, ашарганы балалардан чыгарттылар – кагылмады да.* К.Йосыпов

**АШАРДАЙ** *с.* Ашарга яраклы. *Сыерлар, комсызланып, җирдә үзләренең зур авызларына тутырып ашардай нәрсә булмаганга, --- кызу-кызу, бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүдән бушый алмадылар.* М.Галәү

◊ **Ашардай (ашарлык) булып карау** 1) Ачуын, усаллыгын яшермичә текәлеп карау, нәфрәтләнеп карау; 2) Күзен ала алмыйча, кызыгып карау. *И, бар иде Бибиҗамал апаның яшь вакытлары! Узган-барган егетләр ашардай итеп карап узалар иде.* Ш.Хөсәенов

**АШАРЛЫК** *с. к.* **ашардай**. *Әйдәгез, башка җирдә әле кыяр чәчәк атарга да өлгермәгән, ә миндә ашарлыклары да бар инде аның.* М.Әмир

**АШ АРТЫ АШЛАРЫ** *и.* Шулпалы аштан соң икенчегә бирелә торган, пешереп, кыздырып яки бүтәнчә әзерләнгән балык, ит, бәрәңге, яшелчә, ботка һ.б. ашамлыклар һәм чәй ризыклары. *Гадәттә, шулпадан соң аш арты ашлары бирелә.* Социалистик Татарстан

**АШАСЫННАН** *рәв. сөйл.* **1**. Бик күп иттереп, биек, түбәләмә итеп, артырып (*тутыру, төяү*)

**2**. *бәйл. функ.* Аша, аркылы. *Төн матур булганга, иртәгә, бәйрәм мөнәсә-*

*бәте белән, икесенә дә кибеткә чыгарга булганга, Невскийны җәяүләп үтеп, Нева ашасыннан гына арбачы алып кайтып киттеләр.* Г.Исхакый. *Тәме озакка барсын өчен, эссе көндә салкын ширбәтне салам ашасыннан эчкән кеше кебек, нечкәләп-нәзеклэп эчтеләр.* Г.Исхакый

**АШАТУ** *ф.* 1) Ашарга ашамлык, ризык, азык бирү. *Син, кызым, дәү әниең белән тау астына казлар ашатырга киттең, мин өй эшләре белән кайнаша калдым.* Ә.Галиев. *Юлга чыгар алдыннан әнкәй үзебезне дә ашаткан булса да, иписез умач ашы әллә кая бара алмады.* К.Йосыпов

2) Авызына ашамлык каптыру, үзкуллап ризык бирү. *Бакчадагы тиеннәр кулдан ашатуга ияләшкән*

3) Күкрәк сөте имезеп, яшь баланы тукландыру. *Әгәр ананың билгеләнгән сәгатьтә баланы имезергә мөмкинлеге булмаса, бу сәгатьтә ашату өчен, ана сөтен савып калдырырга тиеш.* Өегез ямьле булсын

4) Тәрбияләү, карау, багу. *--- бер колхозда эшләп яткан студентлар янына барып кайтырга кирәклеген әйтте. Ничегрәк эшлиләр, ничегрәк ашаталар, колхоз канәгатьме, – гомумән, барысын да белеп, ярдәм кирәк булса, ярдәм итеп кайтырга кирәк иде.* Х.Сарьян

5) Симертү, көрәйтү. *Ул әнә теге матур кызларны пешереп ашар өчен чикләвек ашатып симертә торган пәри карчыгының тавышы иде.* Г.Исхакый. *Казларны ашата, симертә белү тагы осталык сорый.* Э.Шәрифуллина

6) *күч.* Туену чарасы, табыш, яшәү чыганагы булып тору. *Һөнәр ашата да, киендерә дә.* Әйтем. *Белем белен ашата.* Мәкаль. *Әле шул сүзләр дә аны ашата, яшәтә.* Ш.Галиев

7) *күч.* Зыян салу, зарарлау; җәрәхәтләү. *Шул ук вакытта аның карашында «аягыңны курадан ашатып та мине таба алмадыңмы, канатым» дигән кинаяле мыскыллау да бар кебек.* Т.Галиуллин // Юкка чыгарту, бетертү. *Ләкин, ни кызганыч, татарлыгын яһүд кебек саклап калырга хәйләсе җитми. Бигрәк тә урыска үзен «ашата». Яһүд марҗага өйләнсә дә, татарга кияүгә чыкса да – яһүд туа, татардан – урыс туа.* Р.Фәйзуллин

8) *күч.* Кыйнау, суктыру. *Аның [хатынның] урыны – арткы бүлмәдә. Ире еш кына аңа каеш камчы ашата.* Ә.Рәшит

**Ашата бару** Берсе артыннан икенчесен ашату

**Ашата башлау** Ашатырга тотыну. *Шул чакта малларны, картына, яшенә, көренә, арыгына аерып, рацион төзеп ашата башлаган булабыз.* Ә.Еники. *--- күзен каплаган чүпрәкне чиштем дә иркенрәккә чыгардым, кулдан ашата башладым – мине хуҗа итеп тоя хәзер. Хәлемнән килерме аны чын сунар кошы итәргә, юкмы?* Г.Якупова

**Ашата бирү** Ашатуын дәвам итү

**Ашата төшү** Бераз ашату

**Ашата тору** Һәрвакыт, гел ашату. *Башыбыз авыртканда, әнкәй безгә миләш ашата торган иде.* Г.Галиев

**Ашатып алу** Тиз генә ашату. *Хәер, башта нидер ашатып алдылар шикелле.* Ә.Еники

**Ашатып бетерү** Барысын да тулысынча ашату; ахырына кадәр ашату. *Йомыркаларны каргадан ашатып бетерде, әллә ничә тавыгымны оясыннан биздерде.* Г.Исхакый. *– Күз-колак булмасаң, бригаданың икмәген ашатып бетерәчәк, – диде Митька.* А.Чурбанов

**Ашатып җибәрү** Ашатырга өлгерү. *Вахит, әйт әле шуңа, блат буенча, бәлки, ашатып җибәрер, син, ни әйтсәң дә...* Т.Миңнуллин

**Ашатып йөрү** Әле, хәзерге вакытта ашату белән мәшгуль булу. *Әби ишегалдында үрдәк ашатып йөри иде.* Г.Мөхәммәтшин

**Ашатып килү** Элек-электән, даими ашату

**Ашатып кую** Алдан ашату. *Тәүлек буе аяк өсте йөрерлек, шәп, ләззәтле итеп ашатып куя ул председательне.* М.Мәһдиев. *Мин аны, Илдус белән бергә, әйбәтләп ашатып куйдым инде.* М.Маликова

**Ашатып тору** 1) Һәрвакыт, гел ашату. *Армияне шулай ашатып торырга кирәк инде аны, юкса көчсезләнә ул.* Аманулла. *Бөркет балалары аңарга үзләренең үпкәләрен белдереп болай дигәннәр: «Үзең без үсеп җиткәнче ашатып торырга вәгъдә бирдең, үзең вәгъдәңне үтәмисең. Безгә бит инде оча башларга күп калмады. Ике-өч көнгә түз».* Ф.Яруллин

2) Әле, сөйләү моментында ашату

**Ашатып утыру** Әле, хәзерге вакытта ашату белән мәшгуль булу. *Бу вакыт патша кызы, кырык кыз-кыркыны белән, үз бакчасына махсус ясалган күл янында аккошлар ашатып утыра иде.* К.Насыйри

**Ашатып чыгу** 1) Билгеле вакытның башыннан ахырына кадәр ашату, шул вакыт дәвамында ашату. *Безнең әти узган ел көз, кыш ашатып чыгарга печән дә, салам да юк, дип, чаптар бияне сатты.* М.Гали

2) Барысын да, һәрберсен ашату

**Ашатып яту** Озак вакыт дәвамында ашату. *Кара инде син аны, ә! Үз сыерына, сарыкларына да безнең печәнне ашатып яткан ич бу, болай булгач...* В.Нуруллин

**АШАТУ́-ЭЧЕРТҮ** *ф.* Ашату һәм эчертү, ашарга-эчәргә бирү. *Авыруны төннәрдә дә ашату-эчертү өчен вә бөтен карау өчен һәрвакыт янында булырга кирәк булганга, Анна Васильевна шул ук өйдә бушаган күрше бүлмәгә күчеп килде.* Г.Исхакый

**АША́У** *ф.* 1) Ашамлык, ризык кабул итү. *Тавышсыз-тынсыз ашарга тотындылар.* М.Әмирханов. *Атлары, --- борыннарын пошкырта-пошкырта, солы яисә башак ашыйлар.* Р.Сибат. *Артыгын тәкәллефләнмичә генә эчеп куйдылар да ирләрчә эшлекле кыяфәттә ашарга тотындылар.* Җ.Рәхимов. *Корсак тутырып, «пух» иткәнче ашап чыгасың да эшләп торып җибәрәсең, әй, якын-тирәңдә бураннар гына уйный!* Г.Бәширов

2) Азык, ашамлык буларак файдалану. *Кайтты, дуңгыз, бөтен авызы сыра исе берлә тулган. Аның өстенә тагы канәфер кадагы ашаган булган.* Г.Исхакый

3) Аппетиты яхшы булу. *Ашаган кешенең нервысы нык була аның.* Р.Ишморат

4) *сөйл.* Чагу, кимерү, тешләү. *Ул, минем нинди халәттә идекемне белүдән*

*булырга кирәк, көлде дә: «Кандала ашадымыни?» – диде.* Г.Исхакый

5) Кискәләп, тишкәләп бетерү (көя, җимеш кортлары һ.б. турында). *Посылкасы эченнән тарак, канат, күзлек, көя ашаган фуфайкалары чыкты.* Ш.Мөхәммәдев

6) Химик реакциягә кереп (яки башка нәрсә тәэсирендә) кисү, эретү, тишү. *Кислота белән селтеләр өс һәм аяк киемнәрен ашыйлар.* Химия. *Элемтә өзелде, Сиваш суы телефон кабелен ашый.* Г.Бәширов

7) *күч.* Юк итү, юкка чыгару. *Ә җир исә моның үчен тиз кайтарды: әле уҗым чагында ук арпаны сарут басты, булачак уңышны ашады.* Р.Фәизов

8) *күч. сөйл.* Ашау-эчү әйберләренә, азык-төлеккә тотып бетерү. *Алар актык әйберләрен сатып ашадылар.* Г.Ибраһимов. *Болары тапкан акчаларын ашап бетереп баралар.* Г.Камал

9) *күч.* Үзләштерү, әрәм-шәрәм итеп бетерү, урлау. *Директор ОРС малын кая куйган, кем белән ашаган – ул аны инде үзе генә белә.* Ә.Еники

10) *күч.* Нинди дә булса чыганак, килер-керем исәбенә яшәү

11) *күч. сөйл.* Исраф итү, сарыф итү, бетерү, күпләп куллану. *Безнең бюджетны кием ашый.* М.Юныс. *Роман язарга уйлады – Башлады да ташлады. «Төчкерек мәзәкләр» язып, Күпме кәгазь «ашады»!* Л.Лерон

12) *күч.* Тәннең һәм киемнең кояш, җил һәм көн яктылыгы тәэсирендә төсе үзгәрү турында. *Аларның каршысына, яулыгын артка чөереп бәйләгән, битен, беләкләрен кояш ашаган, озын керфекле яшь кенә бер кыз килеп керде.* Г.Бәширов

13) *күч.* Юу, җимерү, таркату. *[Чишмә] Җир асты караңгылыгыннан, андагы ташларның кысрыклавыннан туеп, якты дөньяга чыга да яңадан шул караңгылыкка чума. Димәк, анда кыласы гамәлләре калган. Бәлки, җир астындагы ташларга үзенә күрә берәр үче бардыр, аларны ашарга телидер.* Т.Миңнуллин. *Су елга ярындагы кыяны ашый*

14) *күч. сөйл.* Авыру, кайгы, сагыш басу; борчу, интектерү, тынычлыгын алу. *Бала сагышы ашады инде бу ананы.* Казан утлары

15) *күч.* Кыйналу, җәбер күрү. *Кол булу берәүгә дә күңелле түгел. Ләкин адәм, табигате белән хөр булып та, коллыкта яшәргә мәҗбүр булса, үз хуҗасыннан таяклар ашаса, аның трагедиясе дөньяның иң зур каһәрләреннән саналырга тиеш.* Г.Ибраһимов. *Күпме тал чыбыгы ашадык.* Һ.Такташ

16) *күч. гади с.* Тиргәү, орышу яки урынсыз таләпләр белән җанын борчу, газаплау; җавапка тарту, җәза бирү. *– Аннары мине инспектор ашаячак, – ди [Әнвәр абый].* Ә.Хәбибуллин. *[Шәмсүн:] Әйе, күпме газап чиктем, шелтәләр ашадым.* А.Вергазов

17) *күч.* Нинди дә булса кызыктырган әйбергә бик нык бирелеп, текәлеп карау. *[Ханым] Табында ят булган егетне, каерыла-каерыла, күзе белән «ашарга» тотынды.* А.Вергазов. *Батталовның кысылган күзләре, яшертен генә, Хасбулатованың шома, төз аякларын ашыйлар иде.* Ф.Садриев. *--- күзләре зур булып ачылган... Алар, әллә ни күрергә теләгән кебек, әллә ни ашарга теләгән кебек, бер җиргә текәлгән.* Г.Исхакый

◊ **Ашаганнарын ничек косарга белмәү** Кеше милкен урлап, аны туздырып бетереп тотылгач, ничек котылырга белмичә аптырау. **Ашаганнарын чыгару** Байлыкны урлаган, үзләштергән өчен нык үкенерлек итү. *Тикшерергә иң принципиаль инструктор Фәрвәз Нурмөхәммәтова китә. Барганчы ук: «Ашаганнарын чыгарам мин аларның», – дип яный ул.* Т.Нәҗмиев. **Ашаганны кире костыру** Эшләгән яхшылыгын гел искәртеп, җанга тиеп торучы кешегә карата әйтелә. **Ашаган табынына төкергән** Яхшылыкның кадерен белми торган, игелексез кеше. **Ашаганы эченә йокмый** Бик ябык, ашаганы-эчкәне тәненә сеңми, тазармый, симерми. **Ашаламы әллә** Саранланып, нәрсәне дә булса биреп тормауга карата әйтелә. **Ашап үтерү** Бик каты тиргәү, җанына тиеп бетү. **Ашарга сорамый** Бәлки, кирәге чыгар әле дип, нәрсәне дә булса ташламый саклау

**Ашап алу** Тиз-тиз генә, бераз ашау. *Өскә менеп, теге пыяладан гына җиткерелгән ашханәдә ашап та алдылар.* Х.Хәйруллин. *[Галимҗан:] Утыр, күрше, ашап алыйк.* Ф.Баттал

**Ашап бару** Һәммәсен рәттән ашау; булган берсен ашау. *Ул үзе тук булу сәбәпле, һәммәсен дә улы ашап барган.* Ф.Углов

**Ашап бетерү** Тулысынча, барысын да ашау; ашауны тәмамлау. *Үзебез белән алган икмәкләрне дә ашап бетердек.* Р.Хафизова. *[Марҗа апа] Кулындагы бәрәңгесен күз ачып йомган арада ашап бетереп, икенчесенә үрелде.* А.Хәсәнов

**Ашап җибәрү** Тиз генә ашау, ашап кую. *[Салих:] Бу бананны үзең ашап җибәрсәң иде.* Мирас

**Ашап йөрү** Һәрвакыт, һәр урында ашау, анда-монда ашау. *Безнең исәптән ашап йөргән икән бит, мур кыргыры!* Ф.Баттал. *Без өйдән-өйгә кымыз эчеп, сарык ите ашап йөрдек.* Г.Исхакый

**Ашап кую** Алдан ашау; ашаган булу

**Ашап ташлау** Ашарга өлгерү, үзе дә сизмәстән ашау. *Бик нык ачыкканнан соң, ул, үзе дә сизмәстән, артыгын ашап ташлый, ә йокы алдыннан кабул иткән ризык бик тиз майга күчә.* Ф.Углов

**Ашап тору** 1) Әле, хәзерге вакытта ашау. *Ашап торамы соң кеше мондый вакытта!* Ш.Маннур

2) Бертуктаусыз, еш ашау. *Кайбер кешеләр бертуктаусыз ашап торалар*

**Ашап утыру** Әле, күз алдында ашау. *Ахыр, бер аш ашап утырган чакта, кызышып, үзен-үзе югалтты, аш куйган табынга төкерде дә каргап, рәнҗеп чыгып китте.* Г.Ибраһимов

**Ашап чыгу** Һәрберсен ашау, барысын да ашап, татып карау

**Ашый бирү** Ашауны дәвам итү

**АША́У-ЭЧҮ** *ф.* Тамак туйдыру, туклану, ашау. *Башлыча, алар ашау-эчү, киптерү-җилләтү, җылытуга бәйле.* М.Әмирханов. *Хәер, ашап-эчкәч, йорт хуҗасы үзе дә ялындырып тормады, шушы ике көндә күргәннәрен сөйләп бирде.* Ф.Сафин

**АШАЯК** *и. диал. к.* **аяк** II. *Мин тарелкада җәйрәп яткан шул пилмәннең кай төшеннән башларга аптырап торганда, нинди корал белән һөҗүм*

*кылырга хәйран булып торганда, теге абзый тагы бер ашаяк бәрәңге берлә бер башкорт тустагы шурпа да алып керде.* Г.Исхакый

**АШБАЗ** *и. иск.* Пешекче, ашчы, повар. *Фәсхи, гаҗәп оста бер ашбаз шикелле, җиңнәрен сызганып, шашлык әзерләргә тотынды.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**АШ БҮЛМӘСЕ** *и.* Аш әзерли торган бүлмә, ашау-эчү бүлмәсе. *Ул аш бүлмәсендәге ашамлык нәрсәләрне күзеннән кичерде.* М.Гафури

**АШ ҖӘЙМӘСЕ** *и.* Ашъяулык, эскәтер. *Бик матур аш җәймәсе сатып алу*

**АШКАЗАНЫ** *и. анат.* Кеше һәм хайваннарда ашкайнату, азык эшкәртү әгъзасы. *Ә инде профессор ашказаны белән каты авырып алгач, аны җиңел ризыклар белән тукландыру мәсьәләсен кайгыртты.* Р.Фәизов. *Ул үзенең бик озын гомер яшәгәнлегенә хатынын, сукыр эчәгесе белән ашказанының яртысын, тыңлаусыз маңгай чәчләрен һәм бөтен тешләрен югалтып бетергәч тә ышанмады.* Рифә Рахман. *Ашказаннары барысының да шактый авыр булганга, төрлесе төрле нечкәлектә, төрле озынлыкта мышнарга, мырылдарга керештеләр.* Г.Исхакый

**АШКАЗАНЫ АСТЫ БИЗЕ** *и. анат.* Ашказаны артында урнашкан, ашкайнату өчен махсус сыекча бүлеп чыгара торган озынча биз (үзеннән чыккан ике канал аны унике илле эчәк белән тоташтыра). *Хроник панкреатит (ашказаны асты бизенең хроник ялкынсынуы) белән авыручы кешеләрне дәвалауда диетик туклану мөһим роль уйный ---.* Татар халык ашлары

**АШКАЙНАТУ** *и. мед.* Ашказаны-эчәк системасында азыкны эшкәртү һәм үзләштерү процессы. *Татарстанда ашкайнату органнары авырулары һәр икенче балада очрый.* Мәдәни җомга

**АШКЫН** *с.* 1) Ашкынып, җилкенеп торган; ярсу. *Мин ашкын йөрәкле, бу көннәрдә инде якын дустым булып киткән Кутуйны бик ярата, хөрмәт итә идем.* Р.Ишморат. *Мине яңа җирләргә, яңа кешеләргә булган тыелгысыз ашкын сусау биләп алды.* Р.Хисмәтуллин

2) Алга омтылып торган. *Арыкның ашкын суы, кояшның тире салдырырлык эссесе, Тянь-Шаньның болытларга өстән караган чал башлары күңел төпкелендәге бөтен хисләрен тергезде Сылуның.* Рифә Рахман

3) *күч. шигъ.* Биеккә омтылган, югарыга күтәрелгән, күккә ашкан. *Ашкын йортлар*

**АШКЫНДЫРГЫЧ** *с.* Ашкындыра торган. *Шул чакта тәнгә ашкындыргыч дулкыннар таралган, тын кысылган иде.* М.Юныс

**АШКЫНДЫРУ** *ф.* Дәртләндерү, җилкендерү, йөрәктә нәрсәгә карата да булса омтылу хисе тудыру. *Моңлы сигнал җыры яшь йөрәкне Ашкындыра никтер жу-у итеп.* Ш.Маннур. *Каяндыр агылган дәртле көй үзенә чакыра, күңелләрне ашкындыра иде.* М.Маликова

**Ашкындыра бару** Торган саен ныграк ашкындыру

**Ашкындыра башлау** Ашкынуга этәргеч бирү

**Ашкындыра бирү** Ашкындыруын дәвам итү

**Ашкындырып бетерү** Тәмам, бик нык ашкындыру

**Ашкындырып җибәрү** Кинәт ашкындыра башлау

**Ашкындырып тору** Даими яки әледән-әле ашкындыру. *Шул ак дөнья, торган саен ешрак искә төшеп, билгесез ераклыкларга алгысытып, ашкындырып торды.* Р.Мөхәммәдиев

**АШКЫНУ** *ф.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса җилкенү, омтылу, дәртләнү, дулкынлану. *Кәримәнең йөрәге ашкынып тибә.* Р.Хафизова. *Күңел гел каядыр ашкына.* Р.Төхфәтуллин. *Хәер, кеше нәрсәгә булса да ирешү теләге белән ашкына икән, ул ялгышлардан азат була алмый.* Ф.Сафин

2) *диал.* Тәртипсезләнү, азу. *Бәхетсезлегенә ашкыну*

**2.** *и. мәгъ.* Омтылыш, җилкенгәнлек. *Күңелдә – ашкыну, өмет, җыр, канатлар.* Р.Хисмәтуллин. *Шушы җанлы манзара, төнге пароход тавышы кебек, күңелгә нindидер ашкыну, күтәренкелек, ышаныч өсти.* М.Әмирханов

**Ашкына башлау** Ашкынырга тотыну. *Рудольфның әле генә каядыр ашкына башлаган күңеле тагын сүрелде.* Р.Вәли

**Ашкына төшү** Бераз ашкыну

**Ашкынып йөрү** Озак вакыт дәвамында ашкыну. *Ул булып узган вакыйгалар шаукымыннан ашкынып йөрүен белде*

**Ашкынып кую** Кинәт кенә, азга гына ашкыну

**Ашкынып тору** 1) Бертуктаусыз ашкыну

2) Нәрсә дә булса эшләргә теләге зур булу, атлыгып тору. *Илфат --- ат җигеп эшләргә дигәндә дә ашкынып тора.* Б.Камалов

**АШКЫНУЛЫ** *с.* Ашкындыра, җилкендерә торган, дәртле, ярсулы, үтә көчле, кайнар. *[Заһит] Ашкынулы өметләр белән йокларга ятты.* М.Әмирханов. *Бу юлы өйдәге күләгәләр каядыр таралган, ул яктыра төшкән, дәртле һәм ашкынулы төсләр өстенлек итә иде.* Ф.Сафин

**АШКЫНУЧАН** *с. к.* **ашкынулы**. *Ашкынучан йөрәк*

**АШЛАМА** *и.* Үсемлекләрне тукландыру һәм иген уңышын күтәрү максатыннан туфракка кертелә торган органик яисә минераль матдәләр; черемә (тирес, компост, минераль тозлар). *Агулы ашламадан көйгән чирәмлекләр, тирә-якны корытып яткан химикат калдыклары – агрономнарның ак төшкән, сукырайган күңел күзләредер ул.* И.Низамов. *Тәрбияләп, ашламалар белән сыйлап тормасаң, орлыкның иң әйбәтен чәчмәсәң, уңыш алырмын, димә.* Казан утлары. *Хәзер исә, белгечләр, инспекторлар киңәшмәсе ашламалардан яңача файдалану тәртибен эшләделәр...* Совет әдәбияты

**АШЛА́У** I *ф.* Туфракка (җиргә) ашлама кертү, туфракны (җирне) ашлама белән туендыру. *Моның өчен кукуруз җирләрен, шикәр чөгендере һәм кузаклы культуралар чәчеләчәк мәйданнарны кимендә икеләтә арттырып, һәйбәтләп ашларга кирәк.* М.Хәсәнов. *Рәмзи җиләк-җимеш, яшелчәләрне ашлар өчен тирес китертте, дүрт аякланып, чүп утады.* Р.Фәизов

**Ашлап алу** Тиз арада, тиз генә ашлау

**Ашлап бетерү** Барысын да ашлау; ашлау процессын тәмамлау

**Ашлап җибәрү** Бераз ашлау, ашларга да өлгерү

**Ашлап җиткерү** Тиешле күләмдә ашлау

**Ашлап карау** Тәҗрибә куеп, сынап ашлау. --- *быел ике йөз гектар җирне шулай ашлап карарга исәп...* В.Нуруллин

**Ашлап кую** Алдан ашлау

**Ашлап тору** 1) Әле ашлау, хәзерге вакытта ашлау

2) Һәрвакыт, даими ашлау. *Аларның җире – иң уңдырышлы кишәрлекләр. Чөнки безнең бабаларыбызның һәм әбиләребезнең бабалары аларны даими ашлап торганнар.* Я.Шәфыйков

**Ашлап чыгу** Билгеле бер мәйданда башыннан ахырына кадәр барысын да ашлау

**АШЛА́У** II *ф.* 1) Тукыма, киндер яисә буйлык җепне, агарту өчен, махсус җеп ашында кайнатып, кояшта тотып киптерү юлы белән эшкәртү; аш II сеңдерү

2) Агачны бөгеп әйберләр ясау, агачка сыгылмалылык бирү өчен, аны пешекләү, парлау

**Ашлап алу** Тиз генә ашлау; берникадәр вакыт ашлау

**Ашлап бетерү** Барысын да ашлау; ашлау процессын тәмамлау

**Ашлап җибәрү** Бераз ашлау

**Ашлап җиткерү** Тиешенчә ашлау

**Ашлап кую** Ашлап, әзер итү; тиз генә ашлап алу

**Ашлап тору** 1) Әле, хәзерге вакытта ашлау

2) Һәрвакыт, гел ашлау

**Ашлап чыгу** Барысын да ашлау; башыннан ахырына кадәр ашлау

**АШЛАУ** III *ф. диал.* **1.** 1) Озынайту, ялгау (мәс., колганы)

2) Сап кую, саплау. *Көрәкне ашлау*

**2**. *и. мәгъ.* Сап, ялгау өчен әзерләнгән таяк. *Старшина арттырган киң агач караватка бирнә малы – ястыктүшәкләр, юрганнар өелде, алар чыбылдык белән капланды, сынык аягына ашлау кадакланган өстәлгә кизҗеле ашъяулык җәелде.* Җ.Рәхимов

**АШЛАУ** IV *и. диал.* Агачтан уеп ясалган зур кашык

**АШЛАУЛЫ** I *с.* Ашлама кушылган, ашлама кертелгән

**АШЛАУЛЫ** II *с. диал.* Озынайтылган, ялганган

**АШЛЫ** I *с.* Ашы (*2 мәгъ.*) булган; файдалы, туклыклы нәрсәләре булган, уңдырышлы. *Идел суы ашлыдыр, Ашлы түгел, ташлыдыр.* Җыр. *Бер авыл, әйтик, Ык елгасы буендагы әрәмәләрне кисеп, болын ясады, әмма уңмады, шәрәләндерелгән җирнең иң ашлы катламын язгы кар һәм ташу сулары алып китте.* М.Хәбибуллин

**АШЛЫ** II *с.* 1) *к.* **ашлы-сулы**

2) Төрле ашамлык, азык-төлек калдыклары белән аралашкан юынтык су (гадәттә малга бирелә). --- *көнгә өч тапкыр ишектәге тишектән бирелә торган бер кәнди ашлы су һәм ипи кыерчыгы аны бөтенләй үк истән чыгарып бетермәүләре хакында сөйлиләр иде.* Җ.Рәхимов

**АШЛЫ** III *с.* Крахмал, аш II белән эшкәртелгән

**АШЛЫК** *и.* 1) Орлыгы он һәм ярма әзерләүдә кулланыла торган башаклы үсемлекләр, үсеп утырган иген. *И Ходаем, бир, Ходаем, барчабызга тынычлык. Басуда чәчкән ашлыкка бир, Ходаем, уңышлык.* Такмак. *Бу ел Россиянең бәгъзы тарафларында ашлыклар яхшы булса да, башка тарафларында начар, диләр.* Ш.Мөхәммәдев

2) Шундый үсемлекләрнең азык итеп файдаланыла торган орлыгы; орлык хәлендәге икмәк. *Галәү мунча салуның, ашлык сугуның мәгънәсе нәрсә икәнене аңлаган кеби булды.* Г.Исхакый. *Ул Мәккәгә ашлык китерергә тиеш иде.* Ф.Яхин. *Ашлыгымны бастырдым, хәйран уңган ашлыгым, Хәзер илтәм кооперативка Ашлыгымның артыгын.* М.Җәлил. *Машиналар борылып кергәнче, ашлык төягеч тә эшли башлады.* Х.Хәйруллин

**АШЛЫ́К-ТАРУ** *җый. и.* Ашлык, иген. *Мин бит, иген игә торган, я булмаса, ашлык җыеп, ашлык-тару белән сату итә торган кеше дә түгел.* Г.Камал

**АШЛЫ́ СУ** *и.* 1) Крахмаллы су, һәртөрле эремәләр катнаштырылган су

2) *диал. к.* **аш суы**

**АШЛЫ́-СУЛЫ** *с.* Матди яктан яхшы, иркен тормышлы, барлыкта яши торган, хәлле. *Кодагый булган кешенең ашлы-сулы, бай булганы күңелле.* Г.Камал

**А́Ш МӘҖЛЕСЕ** *и.* Берәр бәйрәм уңае белән кунаклар чакырып үткәрелә торган сый өстәле. *Татар халкында барлык бәйрәмнәр дә диярлек аш мәҗлесе белән тәмамлана*

**А́Ш ӨЕ** *и.* Азык әзерләү бүлмәсе, кухня. *Сүрән генә иттереп, аш өенең миче дә ягылды.* Г.Исхакый

**А́Ш ӨСТӘЛЕ** *и.* Аш-су әзерләү, ризык кабул итү өчен махсус өстәл. *Аш өстәле торган аралыктадыр, минем белән качышлы уйнамакчыдыр, дип, карчык, каплап торган чаршауның бер кырын ачып мич буена узгач, шатлыгыннан елмаеп җибәрде.* Рифә Рахман

**А́Ш ПЕШЕРҮЧЕ** *и.* Аш-су әзерләү остасы, пешекче, повар. *– Газизә кайда? – Әнә ул теге якта – кухняда аш пешерүче хатын янында, аңар булыша* ---. Ш.Камал

**А́Ш-СУ** *җый. и.* Табынга кую өчен әзерләнгән ризык, сый. *Аш-суны шушында әзерлиләр, шунда ук ашыйлар.* М.Хуҗин. *Ак халат кигән мөлаем ханым аш-су ташый башлады.* А.Вергазов. *Очрашкан чакларда, Батталов --- шулкадәр ихлас сөйләшкән булып кылана, хуҗалыгына барсаң, аш-су әзерләтә.* Ф.Садриев. *[Энҗе бикә:] Чит ил сатучылары, болгар сатучылары, галим-голәмә, шагыйрьләр бүген миңа аш-суга килсеннәр.* Н.Фәттах

◊ **Аш-судан калдырмау** Һәрвакыт ашка чакыру, кунак җыйганда калдырмау, ашка дәшү. **Аш-су төрләндерү** *к.* **аш төрләндерү**

**А́Ш-СУЛЫ** *с. к.* **ашлы-сулы.** *Әңгәмә ашлы-сулы өстәл янында барган.* К.Йосыпов

**А́Ш-СУЧЫ** *и.* Пешекче, ашчы. *Кешеләрнең алларына аш-сучы Мәрфуга җиңги китереп куйган борчак боткасы да, куе чәй дә суынып бетте.* Ш.Маннур

**АШСЫЗЛЫК** *и.* Ашарга азык булмау; ризыксызлык. *Ләкин өйгә кайтканда аш булмау, шул ашсызлыкның җәй буена баруы аны көчсезләтте ---.* Г.Исхакый

**АШУ** I *ф.* **1.** 1) Билгеле бер чиктән, күләмнән узып китү, чыгу; ташу; канәгать булу. *Аңарда [председательдә] «Волга» икән, миңарга «Жигули» да җитеп ашкан.* Р.Мөхәммәдиев

2) Чиксез күп булу, артып китү. *Мондый очракларда аның җавапсыз калмаячагы көн кебек ачык, аңарда үҗәтлек тә, әрсезлек тә, зәһәрлек тә ашып арткан.* М.Хәсәнов

3) *шигъ.* Югарыга күтәрелү, менү, җитү. *Наратлар да шәфәкъ ягын Карыймы каерылып? Аларга хасмы җан ашу Урманнан аерылып?* М.Галиев. *Рухым гәүдәмнән аерылгач, Иблис, мине муенына атландырып, күккә ашты.* З.Мәхмүди. *Күкрәтеп, гүләп, сайрап, өзелеп Килде, курай, уйнар мизгелең. Якты уйлар салып дәртен кузгат, Күккә ашыр йөрәкләр сизгерен.* Ш.Бабич. *Ашмый күңел күккә, ташмый йөрәк. Кайтмый яшьлек гомер, бер үткәч.* Х.Кәрим

4) Юнәлеш килешендә чынбарлыкка мөнәсәбәтле сүзләр белән килгәндә: үтәлү, башкарылу, чынга әйләнү. *Балачак хыялы шулай көтмәгәндә генә тормышка ашкан иде.* Р.Мирхәйдәров

5) Дәрәҗә яки максат мәгънәләрендәге сүзләр янында: ирешү, җитү. *Теге ятим Салих зур мәртәбәгә ашкан икән.* Г.Ибраһимов

**2. ашып** *рәв. мәгъ.* Нәрсәдән дә булса артып, каплап китеп. *Су буаны ашып ургый, аннары ишә дә алып китә.* Ә.Гаффар. *Камышлы су ярларыннан ашып, бөтен болыннарны су басты.* З.Фәйзи

**Ашып бару** 1) Торган саен ныграк ашу, тагын да ашу. *Әллә күккә ашып барасыңмы, Болытларда йөзә уйларың.* Р.Сәлах

2) Бер-бер артлы ашу. *Гаҗәп түгелмени: төнге күккә ашып баручы йолдызлар кәрванын Киек Каз Юлы итеп күр әле!* М.Вали-Барҗылы. *Чөнки һәр көнне, һәр сәгатьне аның теләге тормышка ашып бара.* М.Юныс

**Ашып бетү** Тулысынча ашу, барысы да ашу. *Ул хыялларның барысы да тормышка гына ашып бетми.* Г.Шәйхиева

**Ашып килү** Аз-азлап, акрынлап ашу. *Көрт коймаы ашып килә.* М.Хуҗин

**Ашып китү** 1) Кинәт артык дәрәҗәдә ашу, артыгын кылану. *Власов хәтта чамадан ашып китә: «Бирегез миңа бер миллионлы армия», – ди.* Ш.Маннур

2) Билгеле бер чиктән, нормадан, урыннан узу, тагын да арту. *Безгә якынракларыннан – заманында дан-шөһрәтләре Татарстан чикләреннән ашып киткән Фарис Галләмов, Наил Хәким, Инзим Наил...* Ж.Дәрзаман. *Бермәл, ярты төн уртасында температурасы кырыктан ашып китте.* Х.Камалов

3) *күч.* Тиешле дәрәҗәдән бик күпкә арту, артып китү. *Шакир турындагы һәртөрле шикле-микле уйларының кайвакытта нигезсез булуын да, артык күп уйлый торгач, чамадан ашып китүен дә яхшы белә иде Әминә.* Г.Минский

4) *күч.* Артыгы белән җитү, артык күп булу

**Ашып кую** Кинәт ашу. *Йөкләмәләр өсти-өсти үти торгач, Процент ягы йөз илледән ашып куйгач, Ялтырады кара кояш – шомарды таш.* Ә.Баян

**Ашып тору** 1) Әле хәзерге вакытта ашкан булу. *Һаваларга ашып торган агачлар арасын тутырып аркылы-торкылы үскән куаклар юлыбызны киртәлиләр.* А.Шамов. *Диңгез төпкеленнән калыккандай, Күккә ашып тора Кара Тау.* Х.Әюпов

2) Бертуктаусыз, бер-бер артлы ашу

**Ашып узу** *к.* **ашып китү**

**Ашып чыгу** Бик нык ашу, чамадан тыш ашу. *Әминәнең кичерешләре түзем чикләрен ашып чыкты.* Ш.Маннур

**АШУ** II *рәв. диал.* Билгеле бер чиктән, чамадан артык

**АШУГ** *и. төрки* Кавказ халыкларында: халык шагыйре, җырчы; җырчы шагыйрь

**АШХАНӘ** *и. тат.-фар.* 1) Җәмәгать туклану урыны, җәмәгать туклану өчен махсус бина. *Сәйрин ашханә янына җыелган ач балаларга карамаска тырыша иде.* М.Юныс. *Ашханәдәге балык кәтлитен поварлар үзләре ашасын, рестораннарда да сагынып кына сөйләсеннәр – моннан соң ике аягымның берсен дә атлыйсым юк.* Ф.Баттал. *Ашханә, башка биналар шикелле үк ак кирпечтән салынып, совхоз идарәсе янына урнашкан иде.* А.Вергазов. *Ашханә ---, күз ачып йомганчы, студентлар белән шыгрым тулды.* Ф.Сафин

2) Квартирада, өйдә ашау-эчү бүлмәсе. *Әйберләрне кертеп куйдым да, ашханәгә менеп, каты чәй эчтем.* Ә.Хәбибуллин

**АШХАНӘЧЕ** *и.* Ашханә хезмәткәре, ашханәдә эшләүче кеше

**А́Ш ЧАНАСЫ** *и. этн.* Туй белән килгәндә, күчтәнәчләр, гомумән азык-төлек төялгән чана. *Туйга килә торган кодалар аш чанасын алдан җибәрәләр.* Г.Ибраһимов

**АШЧЫ** *и.* Пешекче, аш пешерүче, аш-сучы. *Мине – Мәгъруфә карчык, ә бабайны Мансур байның ашчы хатыны Сабира апай үз яннарына сыйдырганнар.* Ә.Айдар. *Учак янында кайнаша торган ашчыларны таптап үтәрдәй чабып килгән ат, шулай, шәм кебек басып, тыелып калды.* Р.Батулла

**АШЪЯУЛЫК** *и.* Аш өстәленә, табынга җәю өчен махсус җәймә, эскәтер. *Анда зур кызыл ашъяулык өстенә, өлеш-өлеш итеп, кабыклы икешәр бәрәңге тезеп чыкканнар.* М.Әмирханов. *[Әтинең] Кулында – ашъяулыкка төрелгән ниндидер зур гына төенчек.* В.Нуруллин

**АШЫГА́-АШЫГА** *рәв.* Бик нык ашыгып. *Ашханәдән чыгып, ашыга-ашыга, тулай торакка күтәрелгәндә, Әхмәтсафаны Мусаның көр тавышы туктатты.* Ф.Сафин

**АШЫГА́-ЙОТЛЫГА** *рәв.* Ашыгудан, сүзләрне, авазларны йотып, каударланып. *Боларны, ашыга-йотлыга, Николай сөйләде.* Ә.Галиев

**АШЫГА́-КАБАЛАНА** *рәв. к.* **ашыга-ашыга**. *Чәйләп алгач, Сөембикә ашыга-кабалана киенергә тотынды.* Ф.Садриев. *Мәрьям ---, ашыга-кабалана, утарга чыкты.* М.Рафиков

**АШЫГУ** *ф.* **1**. 1) Кабалану, тизрәк эшләргә омтылу. *Кич клубта һинд киносы буласын белеп, кызлар да эшләрен тизрәк тәмамларга ашыктылар.* Р.Мөхәммәтҗан

2) Вакыт тар булганда, өлгерергә тырышу, кабалану. *Ашыгам, ә бозау*

*кәҗәләнә, сыртын кытыклаганны көтәдер: койрыгын селкетеп куйды да артын атып уйнаклап китте.* Ш.Галиев

3) Кая да булса тизрәк барып җитү, вакытына өлгерү максатыннан, тиз-тиз бару, тизрәк хәрәкәтләнү. *Ул да булмады, апаларны сәламләп, җырчы кыз Гөлсинә Галиасфарова кызлар төркеменә ашыкты.* Р.Хисмәтуллин. *Солдат, таллыкны ерып, Тонык чишмә буена ашыкты.* Р.Сибат. *Хәсән башын югары күтәрде, тормыш кайнап, яшәү шатлыгы бөркеп торган туган авылына, җылы, якты өенә, елмаеп торган Әсмасы янына ашыкты.* Х.Хәйруллин

4) Килеп туган хәлне, шартларны уңай якка үзгәртергә тырышу; яхшы якка борып җибәрергә омтылу. *Карлен кирәгеннән дә артык яңалыклар ишетте, хәзер, тыныч фикер йөртеп, нәтиҗәләр ясарга вакыт иде, шуңа күрә ул сүзен йомгакларга ашыкты.* Р.Мирхәйдәров. *Мәдинә сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыкты.* М.Хәсәнов. *Беркемнең дә сүзен аяк астына салмыйча, куәтләп ала торган Рафат та үз фикерен әйтергә ашыкты.* Хәйдәр

**2. ашыгып** *рәв. мәгъ.* Тиз арада, иртә һәм ахырын уйламыйча. *Мин хәзер ашыгып өйләнгәнгә үкенә дә башладым.* М.Гали

**Ашыга башлау** Ашыгырга тотыну. *– Әнә мәйдан ачылган! – дип, шул якка ашыга башлыйлар.* Г.Бәширов. *Кыям абзый, ашап чыккач, кинәт кенә ашыга башлады.* Х.Сарьян

**Ашыга бирү** Ашыгуын дәвам итү

**Ашыга төшү** Тагы да ашыгу; бераз ашыгу. *[Гөлҗиһан] Урамда, эшкә барганда, кайтканда да, кеше белән сөйләшергә туры килсә, бер-ике кәлимә сүз әйтә дә, ашыга төшеп китеп бара.* Ф.Сафин. *Халык ашыга төште: «Әйдә тизрәк! Хөррият урманын да кисәсе бар бит әле!»* Л.Гыйззәтуллина

**Ашыгып тору** Һәрвакыт, гел ашыгу

**АШЫГУЧАНЛЫК** *и.* Ашыгып эшләү, тиз башкару рәвеше. *Хәтердә, мин аңа язган хатымның азагын әдипнең миңа юллаган язмаларының бик кызыклы булуы, үземнең бер дә хат яза белмәвем, ягъни ашыгучанлык күрсәтүем турысында борчылу белән тәмамлаган идем.* Г.Гомәр

**АШЫГЫЧ** *с.* **1.** 1) Ашыгып эшләүне, тиз башкаруны таләп итә торган, тиз эшләнергә тиешле. *Чөнки ашыгыч эш монысы.* М.Хуҗин. *Сөйгәне Зәйтүнә белән ашыгыч туй ясарга гына өлгерделәр.* Р.Хафизова. *Шулай, берчак, ашыгыч хәбәр китерделәр.* Р.Низамов

2) Ашыгулы, кызу, җәһәт, тиз-тиз. *Ул, ашыгыч адымнар белән, текә яр читенә үк килде.* Р.Сибат. *Студентлар ---, әлеге ашыгыч җыйналу хакында фаразлап-гөманлап, икенче катка ашыгалар иде.* Ф.Сафин

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз арада, кыска вакыт эчендә, ашыгып. *Зәнфирәгә төштән соң, бик ашыгыч, район үзәгенә барып кайтырга кирәк булды.* Ф.Садриев. *Мин аның гаять дәрәҗәдә дулкынланган икәнен хәрәкәтеннән һәм ашыгыч кына әйтеп ташлаган шушы бер сүзеннән үк сизеп алдым.* А.Шамов

**3.** *хәб. функ.* Кичектергесез булу, тиз арада хәл итүне таләп итү. *Әйе, бик ашыгыч, сеңел, бик!* Г.Бәширов

◊ **Ашыгыч рәвештә** *к.* **ашыгыч** (*2 мәгъ.*). **Ашыгыч түгел** Ашыгасы юк, көтәргә мөмкинлек бар

**АШЫГЫЧЛЫК** *и.* 1) Тизлек, җитезлек

2) Ашыгыч булу, ашыгып, уйлап бетермичә эшләү. *[Хәмидә:] Менә син, ә, мин дә ашыгычлык белән ачуланып ташладым, оятлы булдым.* Г.Камал

◊ **Ашыгычлык белән** 1) Кичекмәстән, тиз, ашыгып. *– Язгыз, – диде Фролов, нииндидер ашыгычлык белән.* Х.Камалов. *Хәят, берничә минутлар шул хәлендә калганнан соң, хәтеренә кинәт бер нәрсә килеп төшкән кешенең ашыгычлыгы белән тәрәзә яныннан китте дә ридикюленнән зур төргәк хатлар чыгарды.* Ф.Әмирхан; 2) Шунда ук, уйлап тормыйча. *Бармасаң да ярамый, тегге чакта, ашыгычлык белән, ризалык биреп ташладым.* Ә.Хәсәнов; 3) Үз-үзен белешмичә, кызып китеп. *Ашыгычлык белән булган инде бу.* Ш.Маннур

**АШЫГЫ́Ч ЯРДӘМ** *и.* Кеше тормышына, аның сәламәтлегенә куркыныч янаган урында ук тиз арада медицина ярдәме күрсәтү төре һәм системасы. *Төнлә мине «ашыгыч ярдәм» белән алып киткәннәр.* Ш.Маннур. *[Сакманов:] Милиция, ашыгыч ярдәм килеп җиткәндер инде анда?* Т.Галиуллин. *Әледән-әле «ашыгыч ярдәм» чакыралар.* Ф.Садриев

**А́Ш ЫЗБАСЫ** *и. к.* **аш өе.** *«Аш ызбасы» дип йөртәләр иде аны, миче бик зур иде, кочак-кочак салам кертеп ягалар иде.* Ә.Еники

**АШЫК** *и. диал.* 1) Аякның балтыр сөяге белән табан сөякләре тоташкан һәм ике яктан кабарыбрак торган урыны (аркылы сөяк). *Ашыкканның ашыгы чыккан.* Мәкаль

2) Тез башы, тез

3) Сарык, кәҗә, ат, сыер кебек хайваннарда бәкәл сөяге. *Баласы күп – кашык җыяр, балалары ашык җыяр.* Мәкаль. *«Эт күңеле – бер ашык» мәкаленчә, тегеләрнең күңеле булсын өчен, аларга бүләкләр дә җибәрде.* Һ.Атласи. *Бу уенда, башлыча, терлекнең ашык сөяге уйнатылган.* Р.Әхмәтьянов

4) Шул сөяк белән уйнала торган уен; кузна. *Аткы, томырылып, я тезелгән ашыкларның нәкъ буена туры килә һәм, күңелләргә ләззәт бирә торган, сөяккә сөяк сугылу, шыкылдау, кырылу тавышлары чыга, я, ашыклар кырылу урынына, үз аткыңның коры җир өстенә «дөп» итеп сугылу тавышыннан тыщ берни ишетелми.* Ә.Фәйзи

**АШЫ́К-ПОШЫК** *рәв.* **1.** 1) Ашыгып, каударланып, кабаланып, бик тиз. *[Саимә] Ашык-пошык киенеп, ишек ачуга, калын тавышы белән бүлмә эчен гөрләтеп, иң элек Гриша керде.* К.Нәҗми. *Ашык-пошык кына шешәне ала да авызыннан гына бер-ике йотым эчеп куя.* Н.Дәүли. *Аны болай ашык-пошык кына хәл итеп булмый.* М.Маликова. *Ирек директор белән ашык-пошык исәнләште дә клубка керде.* Ф.Садриев

2) Аннан-моннан. *Кайберләренең җиңнәре ярылган, якалары ертылган, сыңар итекләре салдырылган һәм яралары, канлы бинтлар белән, ашык-пошык кына уратылган иде.* Ш.Маннур. *Дәресләрен ашык-пошык кына әзерләде дә урамга уенга чыгу ягын карады.*

Р.Хафизова. *Нык, таза егет күренә, авызы гына җимерек, осколка эләккән, ди, ашык-пошык кына ямап куйганнар.* М.Әмирханов

**2.** *с. мәгъ.* Бик тиз арада, бик ашыгып, ашыгыч эшләнгән. *Ашык-пошык төзәтмәләр*

**АШЫКТЫРУ** *ф.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса тизрәк башкарырга мәҗбүр итү. *Миләүшәнең эшкә Казанда калуын хәл итәр өчен, никахлашуны ашыктырырга кирәк.* Б.Камалов

2) Кая да булса тизрәк кузгалырга, китәргә, барырга, тизрәк хәрәкәтләнергә әйдәү. – *Кызурак, кызурак! – дип ашыктырды ул тракторчыны.* А.Вергазов. *Саклап баручы гаскәриләр исә һаман ашыктыралар.* Ф.Сафин

**2. ашыктырып** *рәв. мәгъ.* Вакыты җитмичә, алдан. *Захаров аларны, ашыктырып, әрәмәлек авызына алып чыгып китте.* А.Шамов

**Ашыктыра бару** Торган саен ныграк ашыктыру

**Ашыктыра башлау** Ашыктырырга тотыну. *Якында гына милиция сыбызгыларын ишеткәч, күңелле компания тагын болгана, берсен-берсе ашыктыра башлады.* З.Фәтхетдинов. *Малай, бабасы кулыннан ычкынып, уйнаклый-уйнаклый, алга йөгерде, аннары, кире килеп, ашыктыра ук башлады.* Р.Хафизова

**Ашыктыра бирү** Ашыктыруны дәвам итү. *Яңгыр сибәләп үтте. Ул озакка сузылмады, шулай да әти безне ашыктыра бирде: «Әнә тегеннән яңасы килә, күк күкри, ишетәсезме? Анысы килеп коендырганчы, кайтып калыйк».* Г.Сәгыйров

**Ашыктыра төшү** Бераз ашыктыру. *Менә кояш, менә икмәк, килённең беләге сыдырылып беткән иде. Шуннан туйны ашыктыра төштек.* Р.Камал. *Тәвәккәлләп, Ильяс үгезне ашыктыра төшкән иде, үгез юыртып та китте.* Ә.Баян

**Ашыктырып алу** Аз гына, кыска вакыт аралыгында ашыктыру. – *Каманы күрдеңме? Күрсәң, квартирага төшик, әйдә! – дип, абый мине ашыктырып алды.* Р.Бәшәр

**Ашыктырып йөрү** Әле, хәзерге вакытта барысын да ашыктыру. *Туй бәйрәмен ашыктырып йөргән бәхетле көннәрнең берсендә, Күкчәчәккә әллә нинди сәер чир йокты.* Н.Гыйматдинова. --- *склад территориясенә йөзләрчә машина килеп тула, көне-төне анда кешеләр кайнаша, зур гына начальниклар, сүгенеп, тиргәп, берөзлексез ашыктырып йөриләр.* Ә.Еники. *Уразаев партиягә керер өчен эшне ашыктырып йөри иде.* Х.Камалов

**Ашыктырып карау** Ашыктырырга омтылу. *«Акчаңны чыгар!» – дип, ир-ат мине ашыктырып та карады. «Нәрсә, нәрсә? Нинди акча?» – дип, аңламаган кешегә сабышмакчы, вакытны сузмакчы булдым.* Борынгы Калатау итәгендә

**Ашыктырып килү** Алдан ук, күптәннән бирле ашыктыру; һаман да ашыктыру

**Ашыктырып кую** Бер тапкыр ашыктыру

**Ашыктырып тору** 1) Бертуктаусыз, әледән-әле ашыктыру. *Ә киләчәк, матур киләчәк, мине үзенә чакырып, ашыктырып тора.* Ф. Әмирхан. *Ә үзләре гел ашыктырып тордылар.* М.Юныс. *Батальон командиры, бер кырыйда туктап, колоннаны ашыктырып торды.* Г.Бәширов

2) Әле, хәзерге вакытта ашыктыру. *Баш миенең исереп бетә алмаган күзәнәкләре, тиздән эшкә, дип ашыктырып торганга, алар мөмкин кадәр тизрәк атларга тырыштылар.* Н.Әхмәдиев

**АШЫНУ** *ф. диал.* Үзсенеп узыну, кыланып, артык үзсүзләнү

**Ашына бару** Торган саен ныграк ашыну

**Ашына бирү** Тагы да ашыну; ашынуын дәвам итү

**Ашынып бетү** Бик нык, тәмам ашыну

**Ашынып китү** Кинәт ашына башлау; кирәкмәгәндә ашыну. *Җиткер фәрман баш нәчәлник Раббыңа: Бөекмен, дип, бик ашынып китмәсен, Кайнар чүлгә салкын бозын түкмәсен!* Р.Идиятуллин

**Ашынып тору** 1) Бертуктаусыз ашыну

2) Әле, хәзерге вакытта ашыну

**АШЫП-ТАШЫП** *рәв.* Күп булып, мул булып. – *Бәхетегез ашып-ташып торсын, балалар, бер-берегезнең сүзен тыңлап, хөрмәтләшеп яшәгез, – дип озатты аларны әбиләре.* Казан утлары

**АШЫРУ** *ф.* 1) Арттыру, уздыру. *Шул ук вакытта ул Вахитов заводында эш нормасын 100дән ашырып үтәүче ударник эшче иде.* М.Җәлил

2) *шигъ.* Күтәрү. *Берәүләргә кирәк почёт, орден, фамилиясен күккә ашыру.* Ш.Маннур

3) Юнәлеш килеш формасындагы «эш», «тормыш» кебек исемнәр белән янәшә килгәндә: нәрсәне дә булса башкару, үтәү; барлыкка китерү. *Ике көн үткәч, чебешләр һәм бәпкәләр бары да чыгып беткәч, Җамал әби күптәнге уен эшкә ашырды.* А.Алиш. *Колхоз басуы уртача бирә торганнан ике өлеш артык – һәр гектардан йөз пот уңыш алуны үзләренең карарларына язып куйдылар һәм, шуны тормышка ашыру буенча, җиң сызганып эшкә керештеләр.* Г.Гобәй

**Ашыра бару** Акрынлап, бер-бер артлы ашыру. *Үткән һәрбер минут мине күтәрә, куәтемне, урынымны югары ашыра бара иде.* Г.Ибраһимов. *Без, әкрен-әкрен, үзебез корган планнарны тормышка ашыра бардык.* И.Гыйләҗев. *Ә идеяне, практика белән сыный-сыный, бик саклык белән генә чынга ашыра бару тиешле.* Х.Камалов

**Ашыра башлау** Ашырырга керешү. --- *коточкыч рәхимсезлек белән, кырым татарларын тарихи ватаннарыннан сөрүе татар халкын юкка чыгару, аннан тарихи үч алу сәясәтен тормышка ашыра башлавы иде.* Г.Галиева

**Ашыра килү** *к.* **ашырып килү.** *Мин җиңелергә күнекмәгән. Әлеге көнгә чаклы уйлаганнарымны тормышка ашыра килдем.* Т.Миңнуллин. *«Тормышымда телгә алырлык вакыйгалар булмады» дип яза торганы, үзенең авыр һәм җаваплы эше белән партиянең бөек идеяләрен көн саен тормышка ашыра килеп, илдәге зур вакыйгаларны үз кулы белән тудыручы иң гади совет һәм партия эшчесе иде.* Г.Бәширов. *Институтта укыган чагында кая барырга, нәрсәләр күрергә дип хыялланган*

*булсам, әкрен-әкрен, һәммәсен дә чынга ашыра kилəм.* М.Вәли-Барҗылы

**Ашырып бетерү** Уйланылганның, тиешнең барысын да ашыру

**Ашырып килү** Акрынлап, барысын да ашыру; бер-бер артлы даими ашыру. *Аның [КамАЗ заводы] җитәкчелеге, совет бюрократиясенең иң югары казанышларын үзләштереп, үзен бик эре, тәкәббер тота, әмма кесәсенә файдалы һәр ниятен гамәлгә ашырып килә.* Т.Галиуллин

**Ашырып тору** 1) Даими, әледәнәле, берсе артыннан икенчесен ашыру

2) Әле, хәзерге вакытта ашыру

**А́Ш ЮЛЫ** *и.* Кеше һәм хайваннарда ашкайнату трактының йоткылык белән ашказанын тоташтыра торган көпшә формасындагы бер өлеше; үңәч

**АЭРА́РИЙ** *и. лат.-гр.* Һава ваннасы кабул итү өчен җайлаштырылган махсус бүлмә, мәйданчык

**АЭРО-** *гр.* Кайбер кушма сүзләрдә «авиация», «һава» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *аэроклуб, аэромаяк, аэронавигация*)

**АЭРОБ** *и. гр. биол.* Ирекле кислород булган шартларда гына яшәргә сәләтле организм, *киресе:* **анаэроб**

**АЭРОБИКА** *и. ингл.* Тын алу хәрәкәтләргә ярашкан булуны таләп иткән, музыка белән башкарыла торган тиз ритмлы гимнастика. *Даими рәвештә, V–VIII һәм IX–X класс малайлары өчен ике группа милли көрәш, ә хатын-кызлар өчен аэробика түгәрәге эшли.* Борынгы Калатау итәгендә

**АЭРОВОКЗАЛ** *и. гр.-ингл.* Һава транспорты пассажирларына хезмәт күрсәтү, транспортларның хәрәкәте белән идарә итү өчен махсус билгеләнгән корылма, бина; аэропорт вокзалы. *[Самолёт] Бернича мәртәбә җиңелчә генә сикереп куйгач, менә бит мин, күктә генә түгел, сезнең җирегездә дә бик яхшы йөри беләм, дип һавалангандай, канатларын туп-туры тотып, аэровокзалга таба элдертте.* Ф.Шәфигуллин. *Аэровокзал янына килеп туктаган авиалайнердан җиргә пассажирлар коела башлады.* М.Юныс

**АЭРОДИНА́МИК** *с.* Аэродинамикага караган, шуңа кагылышлы, шуңа хас. *Биеклекне, самолётның тизлеген, җил юнәлешен, ыргытасы бомбаның аэродинамик сыйфатларын исәпләп, --- «боевой» кнопкага басасың.* М.Юныс. *Иярченнең «гомере» аның аэродинамик сыйфатларына да бик нык бәйләнгән.* В.Казневский

**АЭРОДИНА́МИКА** *и. гр. физ.* Һава һәм башка газларның хәрәкәтен, шулай ук үзләре чолгап алган каты җисемнәргә һава һәм газларның каршылык күрсәтүен тикшерә торган фән. *Күп кенә студентлар аның аэродинамика клубын оештыру өчен җилкенеп йөрүләрен дә онытмаганнар икән.* Ф.Сафин

**АЭРОДРОМ** *и. фр.* Очкычлар һәм башка очу аппаратларының очып китүе, очып төшүе, шулай ук аларны сыйдыру һәм ремонтлау өчен дә махсус җиһазландырылган, һава киңлеген дә үз эченә алган җир мәйданы. *Әнә читтәрәк хәрби аэродромга самолётлар, вертолётлар кунаклаган.* Н.Хәсәнов. *Гөлсем апа, аэродромнан кайтышлый Нариман урамында булган вакыйга исенә төшеп, мөмкин кадәр Марат әнисе кебегрәк киенеп йөрде.* Г.Гобәй. *Аэродромның тирәсен тимер рәшәткә белән әйләндереп алганнар.* А.Алиш

**АЭРОЗОЛЬ** *и. гр. махс.* 1) Бик вак кисәкчәләрдән торган, газ сыман яки сыек халәттәге матдә. *Бу баллоннарда нарат-чыршы исе, чәчәкләр исе чыгара торган аэрозольләр була ---.* Өегез ямьле булсын. *Бу аэрозоль күзгә эләкмәскә тиеш.* Өегез ямьле булсын

2) Шундый матдә тутырылган баллон. *Торак йортларда була торган --- бөҗәкләр белән көрәшү өчен, шактый күп химик препаратлар – инсектицидлар бар. Аларны порошок-дустлар, --- аэрозольләр итеп тә чыгаралар.* Өегез ямьле булсын

**АЭРОКЛУБ** *и. гр.-ингл.* Очучылык, авиация спорты өлкәсендә эш алып бара торган, шулай ук һава спорты белән шөгыльләнүче кешеләрне бергә туплаган иҗтимагый оешма. *Ул икән – аэроклубта укучыларның берсе.* Ә.Исхак

**АЭРОЛИТ** *и. гр. астр.* Күктән җир өслегенә төшкән ташсыман масса, таш метеорит

**АЭРОЛО́ГИК** *с.* Аэрологиягә мөнәсәбәтле. *Аэрологик күзәтүләр*

**АЭРОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Метеорологиянең ирекле атмосферадагы (атмосфераның югары катлаулары) физик, химик һәм башка үзенчәлекләрне өйрәнә торган тармагы. *Аэрология станциясе*

**АЭРОМЕХА́НИКА** *и. гр.* Механиканың газсыман тирәлекләрнең тигезлеген һәм хәрәкәтен, шулай ук әлеге тирәлекнең үзендә хәрәкәт итүче каты җисемнәргә механик тәэсирен өйрәнә торган тармагы

**АЭРОНАВИГА́ЦИЯ** *и. гр.-лат.* Очкыч аппаратларны билгеләнгән һава юлы буенча йөртү турындагы фән; һава навигациясе

**АЭРОНАВТ** *и. гр.* Очучы

**АЭРОНА́ВТИКА** *и. гр.* Очкыч аппаратларның һавада хәрәкәт итүләре теориясе һәм практикасы

**АЭРОПЛАН** *и. фр. иск.* Үзочкыч, самолёт. *Әй, әйдә, кармак дип торып, аэропланны күрми калмассың бит инде.* Р.Хафизова. *Хәнәфи абый аэроплан эченә үк кертмәде кертүен, әмма тышыннан тотып караганга бер сүз әйтмәгән иде.* В.Нуруллин. *Аэроплан ниндидер зур шәһәр читендәге аэродромга килеп төште.* А.Алиш

**АЭРОПО́НИКА** *и. гр.* Үсемлекләрне, туфраксыз хәлдә, дымлы һава шартларында үстерү. *Аэропоника вакытында, үсемлекләрнең тамырларына, даими рәвештә, туклыклы сыекча сибәләр*

**АЭРОПОРТ** *и. лат.* Пассажирларны, һәртөрле йөкләрне, почта һ.б.ш. авиация чаралары ярдәмендә даими күчерү белән шөгыльләнә торган аэровокзал, аэродром һ.б.ш. транспорт предприятиесе; һава порты. *Пароходта ике тәүлек әлсерәгәнче, сәгать ярымда барып җитәм, дип, аэропортка юл тотты.* З.Моталлапов. *Ирек бүген иртән аңа аэропорт киоскысыннан бик матур медальон алды.* Ф.Садриев. *Давыл чыгу сәбәпле, аларга Атланта аэропортына вакытында төшәргә рөхсәт итмиләр.* Ватаным Татарстан

**АЭРОСТАТ** *и. гр.* Һавадан җиңел очкыч аппарат; һавадан җиңел газ ту-

тырылган һава шары. *Төн иде, --- бер ут юк, күктә ай да күренми, бары аэростатлар гына.* Г.Әпсәләмов. *Аэростатны тутыру өчен, водород, гелий газлары кулланыла*

**АЭРОТЕРАПИ́Я** *и. гр.* Саф һавада, озакка сузылган, шул ук вакытта чикләнгән һава ванналары; саф һавада булу (дәвалау һәм чыныктыру чарасы буларак кулланыла). *Дәвалаучы врачларның күрсәтмәсе нигезендә, аэротерапияне медицина сестрасы уздыра.* Яшәү яме

**АЭРОФИЛЬТР** *и. гр.-лат.* Агым суларны биологик чистарту өчен махсус корылма, җайланма. *Аэрофильтр биологик фильтрдан фильтрлаучы катламнарының биеклеге (4 м кадәр) белән аерыла*

**АЭРОФОТОСЪЁМКА** *и. рус.* 1) Нинди дә булса җирлекне, берәр урынны, җир өстен, билгеле бер пунктны самолёттан фотога төшерү

2) Шундый юл белән алынган рәсем

**АЭРОЧАНА** *и.* Кар һәм боз өстеннән һава винты ярдәмендә хәрәкәтләнә торган, эчке янулы двигатель ярдәмендә эшли торган пропеллерлы чана. *Язучылар берлеге рәисе көн саен килеп тормый, чәй янына Рафаэльне дә китертик әле, дип, улы Марсельне, аэрочана белән, өч чакрымдагы Түбән Шөнгә җибәрде.* Ф.Галимуллин. *«Амфибия» маркалы аэрочаналар кар өстеннән сәгатенә 100 км тизлек белән хәрәкәт итә алалар*

**АЮ** *и.* **1.** 1) Имезүчеләр семьялыгыннан, буй озынлыгы 1,5 – 3 метрга, авырлыгы 60 – 1000 килограммга кадәр җитә торган, куе йонлы, авыр гәүдәле, кыска юан аяклы имезүче ерткыч хайван. *Аюлар кышкы йокыга җыенды.* Р.Кәрами. *Күпмедер баргач, каршыма әсәрләнгән, чыраеннан иман нуры качкан аю килеп чыкмасынмы!* Р.Низамиев. – *Аюмы? – диде ул минем соравыма каршы. – Аю урманда патша инде ул.* А.Хәсәнов

2) *куч. сөйл.* Бик олпат гәүдәле, озын буйлы, таза, нык бәдәнле кеше

**2.** *с. мәгъ.* 1) Әлеге хайван тиресеннән тегелгән. – *Менә, дустым, сиңа аю бүрек! – диде [Чернозубов] һәм бүрекне дустының башына чәпәп тә куйды.* Ә.Маликов

2) *куч. сөйл.* Зур гәүдәле, таза (кеше турында). – *Уйлап карасаң, түзәрлек түгел: аю-аю ике улы сугышка бармады, заводта калды.* А.Шамов

◊ **Аю аяк** Бик тупас аяклы, аюга охшатып, лап-лоп, алпан-тилпән басып йөрүче кеше. **Аю баш** Миңгерәү, аңгыра, берни дә аңламый торган кеше. **Аю башы да чыдамас** Бик саксыз, әйберне бер дә саклап тота белми торган кешегә карата әйтелә. **Аю беләк** Бик калын, бик таза, аю кебек көчле беләкле кешегә карата әйтелә. **Аю биетәләрме әллә?** Кешеләр бик гаҗәпләнеп, әсәрләнеп карап торганда әйтелә. *[Нәҗия Гобәевна:] – Нигә шушылай ыржаеша бу класс, комсорг? Кайда аю биетәләр? – диде.* В.Нуруллин. **Аю егарлык (егет)** Бик зур, таза гәүдәле, таза беләкле, аю кебек көчле яшь кеше. **Аю кул** 1) Бик тупас, көчле, авырттырып тота (суга) торган кешегә карата әйтелә; 2) Юылмаган, шапшак, аюныкына охшаш йонлач кул. **Аю күрдеңме әллә?** *к.* **аю биетәләрме әллә? Аю мае сөртү** 1) Сорамыйча, урлап алып китү; 2) Куркыныч, хәтәр нәрсәне әйләндерү, кузгату. **Аюныкын – бүрегә** Нинди дә булса урындагы кешенең, яисә физик яктан бик көчле кешенең гаебен гадирәк, көчсезрәк кеше өстенә аудару. **Аю талаган кебек** Өс-башы бик тузган, сәләмәләнгән, йолкыш кыяфәтле кешегә карата әйтелә. **Аю хезмәте күрсәтү** 1) Белмичә, яхшылык эшлим, дип, урынсыз ярдәм күрсәтеп, күңелсезлек китереп чыгару, зыян салу. *Алар иптәшләренә «аю хезмәте» күрсәтергә теләмиләр.* А.Әхмәт; 2) Гомумән зыян салу. *Кем дә кем үзенең ял көнен домино яки преферанс уйнап уткәрсә, яисә көн буе тынчу бүлмәдә телевизор карап утырса, ул үзенең йөрәгенә һәм миенә аю хезмәте күрсәтә.* Ф.Углов

**А́Ю БАЛАНЫ** *и. бот.* Арчанчалар семьялыгыннан, зур булмаган агач яки куак үсемлек; кыргый балан, мәрҗән куагы; *русчасы*: **бузина.** *Аю баланының кайбер төрләрен дару үләне буларак үстерәләр*

**А́Ю БАЛЫГЫ** *и. зоол. иск.* Тюлень; су эте

**АЮБАШ** *и. махс.* Туку станында буй җепне ныгытып кую һәм сугылган киндерне, паласны урап бару өчен кечкенә вал, йомры агач

**А́Ю БИЕТҮ** *ф.* Мәзәк күрсәтү максатыннан, тамашачылар алдында аюдан төрле хәрәкәтләр ясату. *Аннан Вәлишә кордаш кубызда уйнар, аннан камыр бит күрсәтү, аю биетүләр булыр.* Т.Гыйззәт

**А́Ю БИЕТҮЧЕ** *и.* Кулга ияләндерелгән, өйрәтелгән аю белән кәмит күрсәтеп йөрүче кеше. *Аю биетүче юктыр бит!* М.Гафури

**АЮКАМЫР** *и. диал.* Дүләнә; *русчасы*: **боярышник**

**АЮКОЛАК** *и. бот.* Нәүрүз чәчәклеләр семьялыгыннан сары чәчәкле үлән үсемлек; *русчасы:* **медвежье ушко.** *Аюколакның тамыры бөтенләй тармакланмый диярлек, ул бик тирәнгә үтеп керә.* Робинзон эзләреннән

**А́Ю КӨПШӘСЕ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, эре, озын, куе яшел яфраклы, юан көпшәле, ашарга ярамый торган үсемлек; *русчасы:* **борец жёлтый**. *Бала-чага да аю көпшәсен кисеп насос ясый да су сибешә, нәниләр күбәләк куа.* И.Рәмиев

**А́Ю ТАБАН** *и. мед.* Аяк табанының җәенке булып торуыннан, биле булмаудан гыйбарәт физик кимчелек; *русчасы:* **плоскостопие.** *Мөхәммәтҗан белән Шәймәрдәнне [солдатка] алмаганнар. Мөхәммәтҗанның күкрәгендә бар, ди, Шәймәрдәнне, аю табан, дип әйтәләр, ди.* М.Әмир

**А́Ю ТАБАНЫ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, күбесенчә вак сары чәчәкле, суты агулы үлән үсемлек; *русчасы:* **аконит**

**АЮЧЫ** *и.* 1) Аю аулаучы, аю сунары белән шөгыльләнүче, аю аучысы

2) *иск. к.* **аю биетүче.** *Безнең эти – аючы, эшләмичә баючы.* Н.Исәнбәт. *Юлда дәү генә кара Һималай аюларын ияркән аючылар очрый.* М.Мәхмүтов

**АЯ** *и. этн.* Кәҗә мамыгын, дебетне аялау, тетү, тазарту өчен кулланыла торган махсус тарак

**АЯГОЧТА** *рәв. диал.* Аягүрә, аякка баскан килеш. *Утыр, кәбәм, айагочта торма*

**АЯГҮРӘ** *рәв.* 1) Аякка басып, аякка баскан, аяк өстендәге килеш. *Аягүрә басып килгән ир, шундук, артлы чанадан сикереп төште*. Р.Кәрами. *Сария бераз үрмәләп барды да аягүрә басты*. Р.Хафизова

2) Вертикаль торышка килеп. *Бу – синдәме, шигъријат, ак кәгазь аланында каләм аягүрә басуга, яшәү суты өртелгән сүзләрнең, кысан шәкелгә буйсынып, хөр фикер күгенә сибелүе?!* М.Галиев

3) *күч.* Ихтирам күрсәтеп, зурлап, шулай ук хөрмәтләү билгесе буларак яки куелган тәртип буенча, яшь яки чин ягыннан үзеңнән зурларны каршылаганда һәм алар белән сөйләшкәндә баскан килеш. *[Сәлмән:] Брежнев трибунага күтәрелә. Сез, үзегез дә сизмичә, аягүрә басасыз, шатланып, кул чабасыз.* Д.Салихов. *Аягүрә басып торган тамашачы ун сәгать буе чит ил кунакларын алкышлап, танылган җырларга кушылып җырлады.* Ватаным Татарстан

4) *күч.* Ашыгып кына, эш арасында бик тиз генә, ашыгыч рәвештә. *[Чеховның] Аягүрә генә дәфтәргә теркәп куйган язмалары да әдәби яктан эшләнгәннәр, кызык итеп бирелгәннәр.* Г.Нигъмәти

◊ **Аягүрә йоклап йөри** *к.* **аяк өсте (өстеннән) йоклый.** *Аягүрә йоклап яшәгән бу пошмасны нәрсәдер сискәндереп уятырга тиеш ләбаса.* Н.Гыйматдинова. **Аягүрә төш күрү** Саташып, аңгыраеп, аңгы-миңге булып йөрү. *Ашаганым аш түгел, йоклаганым йокы түгел, аягүрә төш күреп йөрим.* А.Шамов

**АЯЗ** *с.* **1.** 1) Явым-төшеме, болыты булмаган, ачык, томансыз. *[Сәлмән:] Җәйнең матур аяз таңнарында җанга рәхәт Идел ярларында*. Җыр. *Май аяз булды диярлек, июнь дә аяз тора, әгәр шуннан июль дә аязга китсә?* Ә.Еники. *Атнадан артык әле иләкләп-чиләкләп койган, әле пыскып кына сибәләгән яңгырлардан соң, чалт аяз көннәр башланды*. Р.Төхфәтуллин

2) *күч.* Кайгы-хәсрәте булмаган, тыныч. *Шулай да Васфиянең күзләре аяз, аларны кучкыллы болытлар һичкайчан капламастыр...* М.Хуҗин. *Күңелнең дә күге җиде катлы. Иң тирәндә калган аяз гөмбәзлесе – балачак күге.* М.Галиев

**2.** *и. мәгъ.* Тыныч һәм иректә көн, тынычлык. *Куркытма син, Алла, яшен белән, Барыбер мин курыкмый яши беләм. Куркытсаң да курыкмыйм мин: Аязымны сатып алдым яшем белән.* Г.Тукай

◊ **Аяз көндә яшен суккандай** *к.* **аяз көндә яшен суккан кебек**. *Аяз көндә яшен суккандай, кинәт башына төшкән бу фаҗигане Мостафин гаять авыр кичерде.* Ә.Еники. **Аяз көндә яшен суккан кебек** Көтмәгәндә килеп чыккан бәла-каза, кайгы-хәсрәт, күңелсезлек турында. *Барысына да аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте бу хәл.* М.Хәсәнов. *Миңнеруйны кияүгә бирергә җыенулары турындагы хәбәр бары аның иптәшләре өчен генә аяз көнне яшен суккан кебек көтелмәгән яңалык булды*. Р.Хафизова. **Аяз көндә яшен сукты диярсең** *к.* **аяз көндә яшен суккан кебек**

**АЯЗЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **аязу** (*1 мәгъ.*). *--- алтын көзләре искитмәле дә матур булып тоела торган иде. Чебен-черки бетә, көннәр чат аязлана.* М.Хәсәнов

**Аязланып китү** Кинәт аязлану, бераз аязлану. *Чулман өстеннән үткән карлы-маяклы юлга килеп төшкәндә, көн тәмам аязланып киткән сыман булды*. М.Хәсәнов

**АЯЗЛЫК** *и.* 1) Аяз булу. *Халык, көннең аязлыгыннан файдаланып калырга дип, кырга ашыга.* А.Шамов

2) *күч. шигъ.* Кайгы-хәсрәт булмау, тынычлык. *Бүгенге җыелыштан чыкканда, Шәвәли, моңарга хәтле һич булмаганча, җилкәсендә – җиңеллек, күңелендә аязлык сизде.* С.Рафиков

**АЯЗУ** *ф.* 1) Болыт, томан таралып, явым-төшем бетеп, күк йөзе ачылу. *Иртә аязмаса, кич аязмас, кич аязмаса, һич аязмас.* Мәкаль. *Көн күптән аязган инде, хәтта бераз туңдырып та җибәргән.* Д.Бүләков

2) *күч.* Кайгы-хәсрәт таралу, күңелсез хисләрдән арыну

**Аяза бару** Акрынлап аязу; торган саен ныграк аязу. *Кара болыт үтеп киткәннән соң, күк йөзе аяза барган кебек, Газинурның да күңел күге әкренләп аяза барды*. Г.Әпсәләмов

**Аяза башлау** Аязырга тотыну. *Иртә белән көн аяза башлады.* А.Алиш

**Аяза төшү** Берникадәр аязу, бераз аязу

**Аязып бетү** Бөтенләй аязу, тулысынча аязу

**Аязып җитү** Тәмам аязу. *Ул да булмады, күкнең бер чите болытлардан арынып, аязып та җитте.* М.Хәсәнов

**Аязып калу** Аяз хәлгә килү

**Аязып китү** Кинәт аязу; бераз аязу. *Мусаның үз башындагы авыр һәм чуалчык уйлары --- төрле якка тарала, акыл гөмбәзе аязып китә.* Ш.Маннур

**Аязып тору** Әле, хәзерге вакытта аязу

**АЯК** I *и.* **1.** 1) Кеше, кош һәм кайбер җанварларның басып йөрү өчен хезмәт итә торган әгъзасы; очлык. *Хәлимнең --- аякларында менә дигән солдат итекләре иде.* Г.Гобәй. *Шулчак --- башына кара кәпәч, аякларына күн итекләр кигән базык гәүдәле берәү, төркемнән аерылып, кунаклар янына ташланды.* Җ.Рәхимов. *Рахит бик азып киткәндә, баланың хәтта тышкы күренеше дә үзгәрә: башының формасы бозыла, күкрәк читлегенең түбәнге өлеше киңәя төшә, аяклары кәкрәя*. Өегез ямьле булсын

2) Ясалма аяк, протез. *Күннән, агачтан, резиннан миңа аяк ясадылар*. Г.Ибраһимов. *Ике якка асылынып торган җирән мыегы, киң кырыйлы салам эшләпәсе, вак шадрасы, хәтта агач аягы да килешле булып күренде аңар*. Г.Гобәй

3) Урындык, өстәл, кәнәфи кебек җиһазларның, суыткыч, телевизор кебек электр приборларының, төрле механизмнарның идәнгә, җиргә һ.б.ш. бастырып, терәп куя торган җайланмасы. *Шунда хуҗа кеше өченче өстәлдән тегү машинасын идәнгә куйды да, аякларын тиз генә кисеп, ике өстәл арасына китереп куштылар.* И.Зарипов

**2. аягында**, **аякта** *хәб. функ. сөйл.* 1) Аяк өстендә

2) Йөри алырлык, йөрерлек хәлдә

◊ **Аягы авыр** *к.* **авыр аяклы**. **Аягы җиңел** 1) Бик җиңел хәрәкәтле, йөреше җитез булган кеше турында әйтелә; 2) Бер кеше килгәннән соң, аның артыннан тагын кеше яисә кешеләр килеп кергән очракта әйтелә. **Аягы җиңел булсын** Яңа эш башлаганда, я берәр эш вакытында, яисә авыру янына кем дә булса килеп киткәндә, яхшы теләк формасында әйтелә. *Эшнең башы әйбәт күренә, аягың җиңел булсын, килен!* Г.Бәширов. **Аягы җиргә тимәү** 1) Бик тиз, бик кызу йөрү; 2) Дәртләнеп, күтәренке күңел белән йөрү. **Аягы кабер якасында** Үлеме якынлашкан, үлем алдында. **Аягы кая басканны белмәү** 1) Бик зур куанычтан, сөенечтән сикереп, йөгереп, атлыгып йөрү; 2) Эш бик күп, кызу булганлыктан, тиз-тиз йөрү, очынып-атлыгып тору. **Аягына егылу** 1) Кемне дә булса олылау, аны ихтирам итү, аңа табыну; 2) Ялыну-ялвару, гафу үтенү. **Аягына сыер басмаган** Яшь, бернинди тәҗрибәсе дә юк, дөнья күрмәгән. *Шуннан соңгыларын инде малай хәтеренә нык сеңдергән булса кирәк, калганнарын адәм аңларлык итеп сөйли. Аягына сыер баскан шул.* Җ.Рәхимов. **Аягын дагалау** Нинди дә булса эшкә тарту, эшләргә ризалату, күндерү. **Аягын кыскарту** Кемне дә булса даими йөргән җиреннән туктату; кая да булса йөрүен тыю, биздерү. **Аягыннан алып (тотып) селексәң дә, бер тиен төшми** *к.* **аягыннан алып (тотып) селексәң дә булмый**. **Аягыннан алып (тотып) селексәң дә булмый** 1) Бик надан, томана, юньсез кеше турында әйтелә; 2) Ач хәерче. **Аягыннан алып (тотып) селексәң дә чыкмый** *к.* **аягыннан алып (тотып) селексәң дә булмый**. **Аягын санап атлый** Бик салмак йөрешле, атлар-атламас йөрүче, ялкау. **Аягың төкле булсын** Килен төшкәндә, йортка бәрәкәт, муллык, бәхет һ.б.ш. алып килсен, дигән теләк белән әйтелә. – *Килен, аягың төкле булсын, гомерең озын булсын, бәхетең мул булсын,* – *дип каршы алды аны каенанасы Гайнисә түти.* М.Хәсәнов. **Аягы уңу** Кемнең дә булса эш башлавыннан, эшкә килеп кушылуыннан әлеге эшнең уңуына, уңайга китүенә ишарә ясап әйтү. *Киленнең аягы уңмады, ахры, ел да яңгырлы туры килде, эшләр дә бәрәкәтсез.* А.Шамов. **Аягы черегән** Абынып, бәрелеп-сөртенеп, бик әкрен йөри торган кешегә карата әйтелә. *[Сәхипҗамал абынып егылгач, Җамали:] Һәй, аягың черегән нәрсә!* А.Әхмәт. **Аяк асты** 1) Атлап бара торган юл, бара торган җир. *Аяк асты чистартылган, шар тәгәрәтерлек тигез.* Х.Хәйруллин. *Яз җиткән булуга карамастан, иртәнге суыкта аяк асты коп-коры, айгыр җилдертә, аягы җиргә тияр-тимәс оча.* И.Гази; 2) Кеше күп йөри торган ыгы-зыгылы урын, юл өсте, кеше күз алды. *Кайсы анда аяк астына көлтә ташлады?* Г.Бәширов; 3) Кимсетелгәннәр турында. *Гареп-шәрык милләтенә караганда, безләр булып торып калдык аяк асты.* М.Гафури. **Аяк астына салу** 1) Кемнең дә булса үтенечен, сүзен, киңәшен, кисәтүен игътибарга алмау, тыңламау; кемне дә булса санламау. *Аннары, үзегез беләсез, әни сүзен дә аяк астына салып булмый.* Ф.Хөсни. *Яшем җитмештән ашты, бер генә баламның да сүземне аяк астына салганы юк.* К.Тимбикова; 2) Кемне дә булса бәхәстә һ.б.ш., хурлыклы рәвештә җиңеп, өскә чыгу; 3) Берәр нәрсәне әрәмшәрәм, исраф итү; нәрсәнең дә булса кадерен белмәү. **Аяк астына салып таптау** *к.* **аяк астына салу**. *Ирләрне ир иткән дә хатын, аяк астына салып таптаган да хатын, дип дөрес әйткәннәр.* Б.Камалов. *Бер көнне ул сине куккә чөя, икенче көнне аяк астына салып таптый.* Н.Фәттах. *Минем мәхәббәтемне аяк астына салып таптаган Әминә, бәлки, мине оныткандыр.* Т.Миңнуллин. *[Бәдри:] Микалай [патша] тарталага киткән. Аның сурәтләрен аяк астына салып таптадык.* Х.Кәрим. **Аяк астына салып калдыру** *к.* **аяк астына салу. Аяк астына тезләнү** Нәрсә дә булса сорап, нинди дә булса үтенеч белән бик нык ялыну, ялвару турында. *[Мәҗит:] Мин ул «КамАЗ»ны главаның аяк астына тезләнеп, ялварып сорап алдым.* Д.Салихов. **Аяк астында аунау** Буйсыну, бәйле булу. *Әгәр дә мәгәр егетең минем аягым астында аунап ятмаса, исемем Хәдичә булмасын, минәйтәм.* М.Хәсәнов. **Аяк астында (арасында) буталу** Кемгә дә булса комачаулау, эшсез буталып йөрү. *Хатын-кызлар табын әзерләргә керештe, ә бала-чага, үзләренә урын чамалап, аяк астында буталды.* И.Зарипов. *[Мәрхәбә] Иң элек шунда аяк арасында файдасызга буталып йөргән назлы килен Гыйззелбанатны моннан матурлап куды.* Г.Ибраһимов. **Аяк астында гына** Якында, ерак яшерелмәгән булу. *Салихларга нәрсә, алар әле Тиле бояр хәзинәсенең аяк астында гына икәнен белмиләр.* Р.Хафизова. **Аяк астында (арасында) йөрү** *к.* **аяк астында (арасында) буталу**. **Аяк астында (астына) таптау** *к.* **аяк астына салу**. *Шайтан абый, сүземне аяк астында таптамагыз инде, бүгенгә китеп торыгыз инде.* М.Миншин. *Аларның барысының да сәбәбе, «низам» дигән булып, башка падишаһларга ияреп китеп, шәригатьне аяк астына таптау, имеш.* Г.Исхакый. **Аяк астында туфрак булу** Берәр нәрсә хакына үзеңне корбан итү, баш иеп, буйсынып яшәү. *Кызым, иреңнең сүзеннән чыкма, аяк астында туфрак бул!* Ф.Әмирхан. **Аяк астыннан чыгу** Уйламаганда килеп чыгу, юк кына сәбәп аркасында, көтмәгәндә барлыкка килү (бәла, бәхетсезлек). *Ул бәлаләр дә көтелмәгән җирдән – --- тәмам аяк астыннан килеп чыкты.* Ак юл. **Аяк асты нык булу** Тотрыклы позициядә тору, шик, икеләнү туарлык сәбәпләр булмау. – *Аллага шөкер,* – *диде [Шәмгун], аяк астының ныклыгын сизеп һәм шатланып.* А.Шамов. **Аяк атларга да ирек бирмәү** Бернәрсә эшләргә дә ирек бирмәү, юл куймау, бик каты әзәрлекләү. **Аяк атлау** 1) Кая да булса бару, кая да булса керү, каян да булса чыгу. *Менә шулай сәфәргә аяк атлаган сәгатьтә, тагын хат килеп төшмәсме!* Г.Ибраһимов; 2) Билгеле бер вакыт арасы бетеп, икенчесенә күчү, икенче вакыт арасына чыгу турында; 3) Нинди дә булса эштә, өлкәдә нәрсәгә дә булса ирешү, билгеле бер эшчәнлек күрсәтә башлау. *Фән дөньясына аяк атлау.* **Аяк атлар урын юк** Кеше бик күп булып

җыелу яисә теләсә нәрсә таралып яту аркасында, бик тыгыз, кысан булу. **Аяк атлар хәл булмау** Бик нык ару, бик нык хәлсезләнү. **Аяк (та) атлатмау** Кемнең дә булса килеп йөрүен туктату, кемне дә булса кертмәү, китермәү, кем белән дә булса араны тәмам өзү. **Аяк әрәм итү** Бушка, кирәкмәгәнгә аяк талдырып йөрү. *[Хәтмулла карт:] Әй карчык, шунда аяк әрәм итеп йөримме соң! Инде моңа кадәр дә кеше көлдереп йөрдем...* Г.Гыйльман. **Аяк баскысыз** 1) *к.* **аяк атлар урын юк;** 2) Аяк асты пычрак, баткак булу. **Аяк (та) бастырмау** *к.* **аяк (та) атлатмау**. – *Әллә нинди мимеч хатынны ияртеп кайтса, йортыма аяк бастырмыйм! – диде Мәрьям әби, кодрәтләнеп.* Хәйдәр. *Анысы, тәртипкә салып бетергәч, монда чит кешедән кадак кактыру түгел, аяк та бастырмаячаксың.* М.Хуҗин. **Аяк басу** *к.* **аяк атлау.** *Аның тирма тотуына, аяк басуына кадәр ниндидер бер нәфислек, үзенең җырларындагы шикелле бер матурлык бар.* Г.Бәширов. *Алдагы ел өчен азык әзерләү хәстәренә язга аяк басу белән үк керешербез.* Ә.Еники. *Урамга аяк басу белән, Шамил очрады.* Х.Хәйруллин. *Әтиебез сугыш ярасыннан үлгән иде, әнидән калган иске йортка аяк бастык.* Р.Низамиев. *Иң югары дәрәҗәгә аяк басты.* М.Гафури. **Аяк җиргә тимәү** 1) Җитез булу, кызу-кызу йөрү, йөгерү турында. *Сулы вә пычрак урамнардан кайтып килгәндә, гүя аякларым җиргә дә тими очып барам.* Ш.Камал; 2) Билгеле бер эчке дәрт, күтәренке күңел белән йөрү. *Күзләре ут яна, аягы җиргә тими, очып кына йөри инде менә.* М.Хәсәнов. *Йөргәндә ялкын арта, Бер дә кимеми иде. Атлаганда, аяклары Җиргә дә тими иде.* М.Җәлил. **Аяк ите ашалу** Бик күп йөреп, аяклар ару, тәмам эштән чыгу. *Күпме телефон шалтырады, күпме аяк итләре ашалды, күпме нервы кырылды, ләкин нәтиҗә булмады.* Социалистик Татарстан. **Аяк итен туздыру** Бушка, файдасызга, кирәкмәгән эш артыннан йөрү. *Юк, җаным, йөрмә фалчыга, Туздырма аяк итең. Ышан син! Хатлар алдамый; Аерылу, беләм, читен...* Г.Латыйп. **Аякка бастыру** 1) Авырудан терелтү, сәламәтләндерү. *Әй апа, фермада эшләмәсәк тә, без бит аңгыралар түгел, бер сыерның елга бер генә бозау китерүен беләбез, әле анысын да аякка бастыруы кыен.* К.Тимбикова. *Әле балалар да кечкенә, аякка бастырасы бар, дип уйлый.* Рифә Рахман; 2) Тормышны материаль яктан яхшырту, эшне юлга салу, нормаль хәлгә китерү. *Закир, бәхетең зур икән, башкортның бурлы биясе атаңны аякка бастырды.* Г.Ибраһимов; 3) Төзекләндерү, торгызу, нормаль эшләтә башлау. *Тегеләргә тиз генә куян фермасын аякка бастыру өчен такта кирәк булган.* М.Хәсәнов. *Соңыннан --- яңа эшләр, яңа бурычлар: хуҗалыкны аякка бастыру, авыл хуҗалыгын күтәрү, яңа шәһәрләр, яңа заводлар салу.* А.Шамов; 4) Нинди дә булса эшкә кузгату, оештыру. *Мин капчыкларны тулай торакка илтеп куйгач, милицияне аякка бастырам.* М.Юныс. *Монда --- яңа типлар да аякка бастырылган, болар – һәрбер яңалык хәрәкәте вакытында консерваторлык карашларын алга сөреп килгән картларның яшәрүе, Октябрь дулкыннары белән чайкалып, аларның да көрәш диңгезенә керүләре...* Г.Нигъмәти; 5) Кузгату, тынычлыкны бозу, борчу. *– Кыңгырау тавышы ишетелүгә, «Николай Иванович килә» дип, Арсланбигебез бөтен өйне аякка бастырды, – дип көлә-көлә сөйләде өй хуҗасы.* Җ.Тәрҗеманов. **Аякка басу** 1) Авырудан соң сәламәтләнеп йөри башлау, аяклану. *Дустының шулай тиз аякка басуына шатлану хисе йөрәген биләп алды.* Ф.Латыйфи. *Ләкин бүген, генә әле терелеп аякка баскан Мөршидә апа өендә сыйланырлык нәрсә бар соң?* Н.Дәүли; 2) Материаль яктан тормыш яхшыру; авырлыкларны җиңү. *Илле өченче елда безнең колхоз, мәсәлән, чынлап торып аякка басты.* Х.Хәйруллин; 3) Нинди дә булса әһәмиятле эшне үтәү өчен актив кузгалу, күтәрелү. *Берме, икеме кешенең колагына салынган бу сүз, яшен тизлеге белән, телдән телгә күчә, бөтен татар аякка баса.* Ә.Фәйзи. **Аякка бәйләгән таш кебек** Алга китәргә, үсәргә мөмкинлек бирми, бәлки артка гына сөйри торган берәр кеше яки нәрсә хакында әйтелә. *[Сәйфи] Колхоз аягына бәйләгән таш кебек, гел шулай артка сөйри, аның аркасында оятка калырга туры килә.* Г.Бәширов. **Аякка егылу** Ялынып, ялварып, гозерләнеп, нәрсәдер сорау, гафу үтенү яки хисләрен белдерү. *Мин елаганмын, Шаһбазның аягына егылып, гафу үтенгәнмен.* Г.Ибраһимов. *Мескеннәр, шатлыкларыннан нишләргә белмичә, елыйелый рәхмәтләр әйтеп, безне кочарга, үбәргә тотындылар, хәтта аякларыбызга егылдылар.* А.Шамов. **Аякка калку** Басу, аякка күтәрелү. *Утырыштагы кешеләрнең күпчелеге, аякка калкып, ораторның фикерләренә кушылуларын белдереп, бик озак кул чаптылар.* К.Тинчурин. **Аяк калмау** *к.* **аяк ите ашалу**. *[Хәдис:] Трактор частьлары эзләп аягым калмады, кайсыгыз күрде?* А.Вергазов. **Аякка торгызу** *к.* **аякка бастыру**. **Аяк киенеп кую** Алдан ук әзерләнү, әзерлек чарасы күрү. **Аяк киенү** *к.* **аяк киенеп кую.** *Эшнең җитди төс алуы мөмкин. Моны белеп торыгыз һәм алдан аяк киенегез.* А.Расих. **Аяк кыздыру** Чабышкыны йөгерткәләп, ат чабышына әзерләү. **Аякны озын сузу** Иркенәю, иркен яшәү. *Чөнки Шәвәлинең чүлмәк сатудан килгән барлы-юклы акчалары аякны ул кадәр озын сузарга мөмкинлек бирмиләр.* С.Рафиков. **Аяк очына гына басып** Бик әкрен генә, сиздермәскә тырышып. *Һәнүз, аяк очына гына басып, ачык ишек кырыена килде дә Заман картның сүзенә колак салды.* Х.Хәйруллин. *Ул, кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады.* М.Әмир. **Аяк өсли** Ашык-пошык, утырмыйча, аягүрә генә (*сөйләшү, эшләү*). *Эш безгә килеп терәлгән икән, димәк, мәсьәлә аяк өсте генә хәл ителә торган түгел.* Ф.Сафин. – *Ә мин көттем, – диде нарком, аяк өсли калган килеш миңа югартыннан карап.* Ә.Гаффар. **Аяк өсте** 1) Аякка басып торган хәлдә, аяк өсте торып. *Ирләрнең бер өлеше, утырып та, аяк өсте дә, сыра, коньяк, аракы тәмен татыйлар.* Ш.Камал; 2) Гел дә утырып тормыйча, ашык-пошык. *Ека-*

*терина Павловнаның эш вакыты булганга, аяк өсте генә сөйләштеләр.* Г.Әпсәләмов. **Аяк өсте (өстеннән) генә** *к.* **аяк өсли**. **Аяк өсте (өстеннән) йоклап йөри** *к.* **аяк өсте (өстеннән) йоклый.** *Кешнәгезче, кешнә, тулпарларым, Аяк өсте йоклап йөргәннәрнең Куркуыннан Ярылыплар китсен йөргә.* Р.Ягъфәров. **Аяк өсте (өстеннән) йоклый** 1) Акрын кымшанып, эше юньле килеп чыкмый, таркаулыгы, булдыксызлыгы күренеп тора; 2) Артык ваемсыз, гамьсез, пошмас булу. **Аяк өстенә тору** 1) Басу; 2) *к.* **аякка калку**. **Аяк өстендә булу** 1) Йокламау, йокыдан тору, уяу булу; 2) Бар нәрсәгә әзер тору, һәрнәрсәне әзер хәлдә көтү. *Рәгыйнә генә һаман аяк өстендә булды, өстәл тирәсендә кайнашты, ашарга кыстады.* Р.Хисмәтуллин. **Аяк өстендә йөрү** Гел аякта булу, йөреп тору, утырмау, ял итмәү. *Тәүлек буе аяк өсте йөрерлек, шәп, ләззәтле итеп ашатып куя ул председательне.* М.Мәһдиев. **Аяк өстендә килеш** *к.* **аяк өсли.** *Анасы белән икәү капка төбендә аяк өстендә килеш кенә сөйләшеп торганда, Мәликә, тәрәзәдән башын чыгарып, Рәүфәне чакырды.* А.Шамов. **Аяк өстеннән** *к.* **аяк өсте. Аяк сузу** Үлү, вафат булу. *Инде аяк сузам, дигәндә, чып-чын зәмзәм суы булды ул миңа.* Р.Вәлиев. *Сәлимҗан мин кайткан көнне үк аягын сузачак.* Т.Миңнуллин. *Монда синең әнкәң ачтан аяк сузды, атаң исән, әле генә, сукрана-сукрана, тимерлеккә китте.* Г.Ибраһимов. **Аяк суыту** Чабыштан соң, чабып килгәннән соң, атны арлыбирле йөртү. **Аяк табанын ялау** Бик нык ялагайлану. *Сез райкомда, райисполкомда эшләүчеләрнең аяк табаннарын ялыйсыз.* Т.Миңнуллин. **Аяктан егарлык** Шаккатырырлык, искиткеч. *Шуңа күрә, аны телдән яздыру өчен, бик аяктан еккыч фактлар кирәк булачак иде.* Ш.Маннур. *Ә син бик матурлап, аяктан егарлык итеп, эскизыңны яса.* М.Маликова. **Аяктан егу** 1) Хәлсезләндерү, хәлдән тайдыру. *Моннан берничә ел элек, авылга кайткач, авыру аяктан екты мине.* Р.Вәлиев; 2) Материаль яктан авыр хәлгә төшерү. *Аның теге мактаулы мөгезсез сыерының – тизәк авыруыннан, сабан туйларында иң шәп сөлгене эләктерә торган ак кашкасының эч авыруыннан үлүләре дә аны аяктан екмады.* К.Тинчурин; 3) Рухи төшенкелеккә бирелергә мәҗбүр итү, мораль яктан авыр хәлгә төшерү. *Ләкин фронтның бик авыр һәм мәкерле шартлары аны аяктан ега.* Р.Ишморат; 4) Эшне бозу; артка сөйрәү. *[Сәлахиев:] Син бөтен Волга буенда беренче үрнәк саналган совхозны аяктан егарга маташасың.* Г.Ибраһимов; 5) Үлемгә сәбәп булу турында. --- *ачлык, иң башлап, аны аяктан екты.* К.Нәҗми; 6) Зур комачау булу, эшли алу мөмкинлегеннән мәхрүм итү. *Ул тагын да яхшы уйнар иде, телсезлеге аяктан ега.* М.Гафури. **Аяктан еккыч** *к.* **аяктан егарлык. Аяктан калу** 1) Берәр төрле сәбәп аркасында аяксыз калу, аяклар параличлану; 2) Күп йөреп, аяклар бик нык ару, тәмам йөри алмаслык хәлгә килү. **Аяк тартмау** Кая да булса барырга яисә берәр эш башларга җыенганда, уңышсызлык, күңелсезлек булыр кебек шик туу, башларга икеләнеп тору. *[Заһитның] Нигәдер, пристаньга да аягы тартмады.* М.Әмирханов. *Габдулла абзый, аягы бик үк тартмаса да, башка йөкчеләрдән калмады.* Ф.Хөсни. **Аяк тарту** Кая да булса барырга теләү. *Аяклары кардәшләренә таба тартты, ә күзләрен Микәйнең көмеш ука сыман елык-елык килеп торган мамыкка төрелгән, гайрәтле гәүдәсеннән аера алмады.* Р.Мөхәммәдиев. **Аяк терәп** Бик нык каршы торып, артык нык каршылык күрсәтеп. *Тик Гата аяк терәп каршы тора.* Р.Хафизова. *Мөнирә бүләкне алмаска аяк терәп каршы тора.* М.Хәсәнов. *Үзе дә, аяк терәп, өйләнмәскә тырыша: «Яшь гомерләр ике килми, белегез кадерләрен!» – дип, авызын гына ера.* Ф.Шәфигуллин. **Аяк терәп сөйләшү** Курыкмау, үз сүзендә нык тору; үзеңнең дөреслегеңә тулысы белән ышанып сөйләшү. *Шәкертләр мәдрәсәдәге уку һәм тормыш тәртипләрен, кычкырып, курыкмый тәнкыйть итә башлыйлар. Хәмидулла абзый белән аяк терәп сөйләштеләр.* Ә.Фәйзи. **Аяк төбе** Бик якында, ерак түгел. *Биш-ун адым атласаң, аяк төбеңнән генә иген кыры башлана.* Р.Низамиев. **Аяк үрә** *к.* **аяк өсте**. *Анда кереп, аяк үрә генә төрле нәрсәләр капкаладылар, аяк үрә генә марҗа шоколад [ашады], Шәмсетдин чәй дә эчте.* Г.Исхакый. **Аяк хакы** *к.* **аяк ялы**. **Аяк чалу** 1) Атлап яки йөгереп барган кешенең аягына аркылы берәр әйбер яки аякны куеп абындырып егу. *Әмма Шамил аннан җитезрәк булып чыкты: --- күз ачып йомган арада, аны аяк чалып екты.* З.Фәтхетдинов. *Нәкъ шул чакта «Стриж», киң иттереп атлап баручы Әшрәфкә аяк чала да, үзе күздән дә югала.* Казан утлары; 2) Кемнең дә булса эшенә аркылы төшү, эшенә комачаулык ясау, төрле тоткарлыклар барлыкка китерү. *Ләкин язмыш аяк чала һәрчак безгә.* Н.Фәттах. *Иптәшләренең һәр уңышыннан көнләшә, төртмә телләнә, кешегә аяк чалырга гына тора.* Р.Хафизова. *Бергә гомер иткән дусларны да, Аяк чалып йөргән дошманны да Бәяләргә тормыш өйрәтә.* М.Галиев. **Аяк ялы** Берәр җиргә барып йомыш үтәгән, эш башкарган өчен бирелә торган акча яки берәр әйбер, «чәйлек»

**АЯК** II *и. иск.* Чәй чынаягы яки шуңа охшашлы тоткасыз савыт, касә; гомумән савыт. *Төнләр торып имезгән, Аякдин каймак йидергән Анамдин һәм бизәем!* Дастан. *Шул арада, ишегалдына чыгып, Сөннәтче бабай да, зур аякларда сосла күтәреп кереп: «Бәлки, хәзрәт, яратырсыз», – дип, хәзрәтләр өчен ясаган сосласын суза иде.* Г.Исхакый

**АЯ́К БИТЕ** *и.* Аякның өсте

**АЯ́К ЙӨЗЕ** *и. к.* **аяк бите**. *[Эт] Әле берсенең, әле икенчесенең аяк йөзен исни-исни, бик зәгыйфь, бик кызганыч чинады.* Г.Гобәй

**АЯ́К КИЕМЕ** *и.* Аякны корыда, җылыда тоту, җәрәхәтләнүдән саклау өчен, аякка киелә торган, күннән, резинадан яки башка төр материаллардан эшләнгән итек, ботинка, чүәк һ.б.ш. нәрсәләр. *Ичмаса, хатыныңа берәр юньлерәк аяк киеме алып бирерсең.* З.Мәхмүди. *Төштә көзгегә карау яки яңа аяк киеме кию – тормышка чыгу.* Төш юрау

**АЯ́К-КУЛ** *җый. и.* Аяклар һәм куллар. *Көзге яңгырларда, ташу вакытларында аяк-куллары таш булып ката да, әти мескен урынынан тора алмыйча интегә.* М.Юныс. *Әйтерсең кемдер рәхимсез тукмап ташлаган – аяк-кулларны кыймылдатып булмый.* Ф.Сафин. *Аркасы чымырдап китте, аяк-кулларына каз тәне чыкты.* З.Фәтхетдинов

◊ **Аяк-кул бәйдә (бәйле) булу** Ниндидер сәбәпләр аркасында, кемне дә булса ташлап китә алмау, котыла алмау, кемгә дә булса бик нык бәйле булу. **Аяк-кулны бәйләү** Берәр сәбәп аркасында, бик мөһим, кирәкле эшкә тотына алмау

**АЯКЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Авыру кеше, мал һ.б.ш. йөрерлек хәлгә китерү, аякка бастыру, тернәкләндерү. *Чөнки «әни», «әби» дигән сүзләр аларны аякландырды.* Р.Сибат

2) Тормышны материаль яктан яхшырту, үстереп җибәрү, алга этәрү. *Бу хуҗалыкны аякландыру өчен, күп хезмәт кирәк булачак*

3) *күч.* Кемне дә булса берәр кешегә каршы котырту, үчләндерү. *[Искәндәр] Ахыр килеп, сеңлесе Галияне Рәүфкә каршы тәмам аякландыра.* Г.Нигъмәти. *[Таһир] Үзен-үзе тотышы белән, җыелышны үзенә каршы аякландырган булып чыкты.* Г.Ахунов

4) *күч.* Берәр нәрсәне урлау, чәлдерү

**Аякландырып җибәрү** Аякланырга этәргеч бирү, ярдәм итү. *Мин, әйтик, үзем – бик борынгы төркиләрдән. Нәсел тамырым Идел буе Болгарын аякландырып җибәргән Кодрак ханга барып тоташа.* М.Хәбибуллин

**Аякландырып кую** Алдан ук аякландыру

**АЯКЛАНУ** *ф.* 1) Аякка күтәрелү, аякка басу; гәүдә вертикаль торыш алу. *Сине күрсәләр, таналарыңны әйтәм әле, тынычлыкларын тәмам җуялар, шунда ук урыннарыннан дәррәү кубып аякланалар.* М.Хәсәнов. *Оеган тәнне уятырга, күзләрне ачарга, ничек кенә булса да аякланырга, аякланырга аңа [урманчыга] хәзер.* Р.Мөхәммәдиев

2) Кечкенә бала, яңа туган мал-туар, авыру кешеләр аякка басып йөреп китү, йөри башлау. *Дөрес, яңа гына аякланган бала шикелле, ул әле гармун телләренә кыюсызрак, ялгышрак та баса.* М.Әмирханов. *Яңа туган баһбай кебек и ята идәндә, аяклана алмыйча!* Р.Вәли

3) Йокыдан уянып йөри башлау, йокыдан тору. *[Көн яктырып] Халык аяклангач, мин клубка йөгердем.* М.Әмир

4) *күч. к.* **аякка басу** (*1,2 мәгъ.*). *Ике-өч көн аунап ята да аяклана.* А.Хәсәнов

5) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә карата булса да каршы чыгыш ясау, кирелек эшләү, баш күтәрү. *[Габдулла] Бүген үз чорының алдынгы кешесе икәнен күрсәтте. Традициягә каршы аякланды бит ул бүген.* Ә.Фәйзи

6) *күч.* Нәрсә дә булса югалу, кем дә булса рөхсәтсез алу. *[Закуан:] Шунысы кызык та шул. [Капчык] Аякланып килмәгәе дибез шул.* Р.Хафизова

7) *күч.* Таралу, бер кешедән икенче берәүгә күчү (сүз, хәбәр турында). *Начар хәбәр тиз аяклана.* Н.Гыйматдинова

8) Йөрү, хәрәкәткә килү, хәрәкәт итә башлау. *Алачак кичексә, бурычка бирүче аякланыр.* Мәкаль

◊ **Аяклана алмаслык** 1) Аяк асты баса алмаслык пычрак булу. *Көне буе тоташтан сибәләгән явым-төшем үзенекен эшләгән – адәм аяклана алмаслык пычрак.* М.Хәсәнов; 2) Таушалу, тузу, җимерелү, юкка чыгу. *Аяклана алмаслык хәлгә җитеп җимерелә барган тормыш, нәтиҗәсез эшчәнлек заманы килә.* М.Гайнетдинов

**Аяклана бару** Акрынлап аяклану

**Аяклана башлау** Тору, кузгалу, аякларына баса алырлык булу. *Кыр буенда хәл җыеп яткан шайтан өере, бердәй кузгалып, кайсы – туңкаеп, кайсы ава-түнә аяклана башлады.* Г.Гыйльманов

**Аяклана төшү** Бераз аяклану

**Аякланып алу** Аз гына вакытка, беразга гына аяклану

**Аякланып бару** *к.* **аяклана бару**. *Ире, эш эзләп, Бакуга киткәч, беренче балалары үлде. Шуның кайгысыннан [Нәгыймә] яңа аякланып бара иде.* Г.Ибраһимов

**Аякланып китү** 1) Кинәт аяклану

2) *күч.* Бик тиз таралу, мәгълүм булу. *Яралар, имеш, яргач, кем үтергәнен шунда ук беләләр, имеш, белгәч, тотып алалар, имеш --- дигән хәбәрләр, урамның бер башыннан кузгалып, Рәгыя аркылы аякланып киттеләр.* Г.Ибраһимов

**АЯКЛА́У** *ф. сөйл.* Хайванны ураклап сую, суйгач, аны аяк санынча дүрткә бүлү

**АЯКЛЫ** *с.* 1) Аяклары сәламәт булган; йөрерлек хәлдә, йөри ала торган. *Димәк, алай икән: аяклы артистлар күп иде бу дөньяда, хәзер менә аяксыз бер артист та өстәлде булып чыга.* Ф.Хөсни

2) Аякларына бастырып, утыртып куела торган, махсус шулай итеп эшләнгән. *– Шулай булгач... шулай булгач, – дип кабатлап торды да, кинәт, янәшәсендәгеләрне сискәндереп, һич көтмәгәндә, чалышма аяклы өстәлнең утызлы такталарына авыр йодрыгын төшерде.* Г.Кашапов. *Җәмил, алыйк, диде бит, киленнәр кайтышына аяклы көзге алыйк, диде.* Т.Миңнуллин

3) Аяк ярдәмендә эшли торган. *Укытучы кызлары ак шарлы, сыгылма челтәрле тимер кровать белән аяклы тегү машинасы кертеп утырттылар.* Г.Бәширов

◊ **Аяклы бәла** Булдыксыз, эшкә яраксыз, ялкау яисә зәгыйфь, кешегә салынып яшәүчән. **Аяклы бәлеш** Симез гәүдәле, көр хатын-кыз турында әйтелә. **Аяклы бәхет** Үзе үк мәҗбүри кулга килеп кереп торган уңыш, табыш, казаныш. *Кыскасы, ал капкадан кертмәсәң, арт капкадан үзе бәреп керә торган аяклы бәхет иде, югыйсә.* Ф.Хөсни. **Аяклы җәфа** *к.* **аяклы бәла. Аяклы каза** *к.* **аяклы бәла.** *Һәй-й, Мортаза! Мортаза түгел син, ә аяклы каза!* М.Хәсәнов. *Бик ямьсез, бик аңгыра булып, аяклы каза булса, мин нишләрмен?* Г.Камал. **Аяклы келәт** 1) Баганалар өстенә утыртып, астын ачык калдырып салынган келәт, амбар; 2) *күч.* Бик күп ашатсаң да, нәрсә генә ашатсаң да симерми торган арык ат. **Аяклы китапханә** Бик күп укыган һәм бик күп нәрсәләрне хәтерли торган кеше. **Аяклы мал** Терлек, мал-туар,

йорт хайваннары. *Ишегалдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тыз-быз сикерешәләр. Димәк, бернинди аяклы мал да юк.* Ә.Еники. **Аяклы мәет** Ни үле, ни тере кыяфәттә, аптырап торуны белдерә. *Син нәрсә, Асыл, әллә телеңне калдырып кайттыңмы анда? Һаман аяклы мәет кебек.* Х.Хәйруллин. **Аяклы реклама** Урамда өстенә реклама щиты киеп йөрүче кеше. *Шуңа күрә җәмгыять театрында бирелгән аяклы реклама роленә риза булырга туры килде.* М.Юныс. **Аяклы тарих** Бик күп тарихи истәлекләр, күп фактлар белә торган яхшы хәтерле кешегә карата әйтелә. *Әптери агай фабриканың язылмаган аяклы тарихы инде. Аның хәтере яшь егетнеке төсле, һичнәрсәне онытмаган.* Ш.Усманов. **Аяклы хәзинә** *к.* **аяклы мал. Аяклы энциклопедия** Бик укымышлы, теләсә нинди мәсьәлә буенча белешмә алырга мөмкин булган, һәрьяклап белеме булган кеше. *Идрисне, аның белән беренче кабат таныштырганда, китапханә мөдире «Аяклы энциклопедиябез» дип әйткән иде.* Х.Сарьян

**АЯКЛЫ́-ОЧЛЫ** *рәв.* Баш-аягы белән, тәмам, тулысынча. *Колхоз салам бирми, кышын, утынсыз да калсак, Алла сакласын, таракан урынына аяклы-очлы катып үләрбез.* Ф.Хөсни

**АЯ́К ОЧЫ** *и.* 1) Аякның бармаклар булган тирәсе, аяк башланган урын. *Икенче көнне Мәрфуга абыстай иртүк торды. Аяк очына гына басып, киленне уятып, мунча ягарга кушты.* Г.Исхакый

2) Сузылып яткан кешенең аяк ягы, аяк тирәсе. *Кемнеңдер үҗәт күз карашын тоеп, куркып уянып киттем. Ни күзем белән күрим, аяк очымда, тәлинкә кадәр күзләрен елтыратып, йонлач бер җан иясе утыра.* З.Мәхмүди

3) Хуҗалыкта, йорттан ерак булмаган, бакча яки каралты-куралар артындагы урын. *Мунчасы аяк очында гына*

**АЯ́К-САЯК** *с.* Акылга бик үк тулы булмаган, җиңел акыллы; бик үк уйлап бетерми эш итә торган. *Нигә әле, аяк-саяк Әтәлге Фәрдүскә нәфрәтләнеп, тынычлыгын бимазаласын Багдасар?* М.Хуҗин

**АЯКСУ** *с. диал.* Урынында утырып, басып тора алмый, гел каядыр барырга, чабарга омтылучан (*кеше*)

**АЯКСЫЗ** *с.* **1.** Аягын өздергән, кистергән, бер яки ике аягы да булмаган, аягы юк. *Әле тачанкага утырган аяксыз пулемётчы, әле Лениннан килгән матрос күз алдына килеп баса.* Г.Әпсәләмов

**2.** *и. мәгъ.* Аягы булмаган кеше. *Болай да дөньяда аяксызлар бик күп хәзер.* А.Шамов

**АЯКСЫЗ-КУЛСЫЗ** *с.* 1) Аяклары һәм куллары булмаган. *Мәнә мин сине, аяксыз-кулсыз утырсаң да, ташламам!* Р.Камал. *Безнең макталган армиядә кыйнап үтерәләр, имгәтәләр, аяксыз-кулсыз калдыралар – боларның барысын кемнәр башкара?* Ф.Урманче. *Аяксыз-кулсыз түгел, сугыш күрмәгән, тора-бара рәтләнеп китәр, дип өмет иткән иде.* Сөембикә

2) *куч.* Бер ярдәмчесез. *Башкача андый ханымнарны аяксыз-кулсыз итү ярамый!* Ф.Яхин

**АЯКСЫЗЛАНУ** *ф. сир.* 1) Берәр нинди сәбәп белән аягын өздерү, кистерү һ.б. аркасында аяксыз калу, гарипләнү

2) Аяклар авырту, авыру булу сәбәпле, йөри алмаслык хәлгә килү

3) *куч.* Берәр нинди хәвефле хәл яисә хәвефле хәбәрдән соң аяк буыннары йомшару, хәлсезләнү. *Тәкъва кинәт аяксызланды.* М.Әмир

**АЯ́К-ТОЯК** *и.* Аяк һәм тояк. *Юл бозлы, шуңа күрә олаучы --- атын бик куаламаска тырыша – ат хөкүмәтнеке, кантон кәнүшниеннән бирелгән, аяк-тоягын имгәтеп кайтсаң, көт тә тор, мәхкәмәсез-нисез, Минзәлә төрмәсендә ике-өч ай яткырып, сохари кимертеп чыгарырлар.* Ф.Сафин

**АЯ́К ЧОЛГАВЫ** *и. к.* **аякчу.** *Мөселман кызы булып, аяк чолгавы да, тәһарәт чүпрәге дә чикмәсә, үзе дә килешмәс иде.* Ф.Әмирхан

**АЯКЧУ** *и.* Аяк чолгавы, ыштыр. *Хәлим, кайтырга кирәк инде, килмәс, дип, мич куышыннан аякчуларын алып чыгарга торганда, капка әкрен генә, бер дә шыгырдамыйча гына ачылып китте.* Г.Гобәй

**АЯКЧЫ** *и. тар.* Аш-су мәҗлесендә килгән кунакларга эчемлек таратып йөрүче, шул эшнең җаваплы кешесе («савыт» мәгънәсендәге «аяк» сүзеннән). *Кич җитүгә, мәҗлес өстәле әзер була. Ул шулкадәр зур ки, күрәгәче белән аякчы гына кияү ягыннан килгән кунакларны сыйларга өлгерерлек түгел.* К.Йосыпов

**АЯЛА́У** *ф.* Кәҗә мамыгын каты кылларыннан тарап арындыру

**Аялап алу** Тиз генә аялау; кирәк кадәр аялау

**Аялап бетерү** Ахыргача, барысын да аялау; аялауны тәмамлау

**Аялап кую** Алдан аялау, аялап әзер итү

**Аялап тору** Әле, хәзер аялау

**Аялап чыгу** *к.* **аялап бетерү**

**Аялый төшү** Тагы да әйбәтрәк аялау

**АЯНУ** *ф.* Аяныч хәлгә килү, төшенкелеккә бирелү. *Тыны кысылу, купмас ютәл белән газаплану, төннәрен суык тиргә бату һәм саташып йоклаулардан, үзенең нинди хәлдә икәнен аянып аңлый иде ул.* Ш.Маннур

**АЯНЫЧ** *с.* **1.** 1.) Мөшкел, кызганыч, бик начар. *Авылны тау башына салуның аяныч нәтиҗәсе иде бу.* В.Нуруллин

2) Күңелсез, үзәк өзгеч, йөрәк әрнеткеч, авыр. *Баланы ач үлем дәһшәтеннән йолып калгансыз, алай гына да түгел, бала өчен аяныч күңел китеклеген – аның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез.* Г.Гобәй

**2.** *и. мәгъ.* Аяныч хәл, аяныч вакыйга. *Иң аянычы шул булды: алар буанагына куян төшүгә, аның исән калуына беркем дә ышанмады.* А.Гыйләҗев

**3.** *рәв. мәгъ.* Үтә дә начар, бик мөшкел. *Мин үзем фермабызның хәлен, кайберәүләр кебек, бик аяныч итеп күрмим.* Ә.Еники

**4.** *хәб. функ.* Хәлнең бик кызганыч, начар булуы. *Сөйкемле әнкәсенең хәзер әнә шулай вак сүзле, кырыс чырайлы, көнче һәм бәйләнчек каенанага әверелә баруы бик аяныч иде.* Г.Бәширов

**5.** *кер. сүз функ. сөйл. к.* **аянычка**

**АЯНЫЧКА** *кер. сүз* Берәр вакыйга, күренеш уңае белән үкенү белдергәндә

әйтелә; кызганычка. *Әткәсе язмышы хакында уйлап, ул бер нәрсәгә төшенде: кешегә игелек күрсәтеп, аннан рәхмәт өмет итү, аянычка, бу дөньяда иң зур тилелек бугай...* Ф.Сафин

**АЯНЫЧЛЫ** *с.* 1) Аяныч, кызганыч. *Бу, мәсәлән, үз дәүләтчелеген югалтып, Кытайга коллыкка төшкән төрекләрнең аянычлы-үкенечле хәлен тасвирлаган яки халыкны каганга тугрылыклы, бердәм, уяу булырга чакырган юлларда аеруча ачык күренә.* Х.Мәхмүтов. *Әни катнашында башыбыздан кичкән бер аянычлы хәлне дә искә төшерәм.* Ф.Хөсни. *Шушы мизгелдә аларның хәтерендә гасырлар, чорлар гөрселдәде, бер-берсен алыштырып килүче котылгысыз һәм аянычлы һәлакәтләр өермәсе дулап узды.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Туган туфрагын, азатлыгын югалткан халыкларның язмышлары шундый аянычлы.* М.Юныс

2) Йөрәк әрнеткеч, үзәк өзгеч, күңелсез. *Мәдинәнең аянычлы тавышы йокыга талган урам буйлап китте дә кайтаваз булып яңгырады.* Ш.Хөсәенов

**АЯНЫЧЛЫК** *и.* Аяныч булу халәте

**АЯ́ТЕЛКӨРСИ** *и. гар. дини* 1) Ислам динендә: сихердән саклый торган дога. *[Бәдретдин] Авыру-сырхауларга догалыклар, аятелкөрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде.* Ә.Еники

2) *сөйл.* Шул яки башка төрле дога язылган шамаил

**АЯТЬ** *и. гар.* 1) Билге, күрсәтмә

2) Могҗиза

3) *дини* Коръәндәге сүрәләрнең җөмләләре, шигъри юллары. *Бик озак белгән догаларын, аятьләрен укыды.* Г.Исхакый. *Соңра мулла бер аятьме, догамы укыды да аминга кул күтәрде.* Г.Ибраһимов. *Яшел ефәк өстенә укалар белән ай, йолдыз һәм әллә нинди аятьләр, яңа чәчәкләр тегеп куйганнар.* Ш.Камал

**АЯ́У** *ф.* **1.** Кызгану, жәлләү, аңлау, хәленә керү. *Дустын аяп, Марат аңа шалтыратып тормаска карар бирде.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Борынгы ата-бабаларыбыз: «Азны аяган күптән коры калыр», – дип тә әйткән.* С.Поварисов. *Шул тушның теге ягында калган хәзрәтен, моның матур сүзенә мохтаҗ хәзрәтен кызганды, аяды.* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ. к.* **аяулы**. *Аяу күзләрен тутырып, йөзенә ихлас елмаю җәеп, моңга чумган тавышы белән җыр башласа, аның горурлыгына сокланасың.* М.Хуҗин

**Аяп тору** Һәрвакыт аяу, гел аяу. *Ут беркемне дә аяп тормый, инде алар йортыннан күрше-күләнгә җәелә.* Ф.Сафин

**АЯУЛЫ** *с.* Кызгану, жәлләү, аңлау катыш, әлеге тойгыларны үз эченә алган. *Җаным да аяулы.* М.Юныс. *Укымышлылыгың да зур, әмма ата-анаңа аяулы түгелсең.* Б.Камалов

**АЯУСЫЗ** с. **1.** 1) Рәхимсез, шәфкатьсез. *Күкрәк сөтен имезеп үстергән анаң төсле туган илең дә сине хыянәтче итеп санагач, бу аяусыз дөньяда мөкатдәс булган нәрсә калсын?* Ш.Маннур. *Ә инде, гомумән алганда, бигрәк тә кыз баланың язмышы – җиргә төшкән орлык кебек: йә уңдырышлы туфракта гөрләп чәчәк атып китә, йә аяусыз сәмум җилләренә эләгеп юкка чыга.* Т.Нәҗмиев. *Шушындый гайре табигый шартларда армиядән исән-сау әйләнеп кайту күп көч, сабырлык таләп итә, чөнки армиянең үзенең катгый һәм аяусыз законнары бар.* Н.Гамбәр. *Гариф – сугышлардан исән-имин кайтып, үз эшен оештыра башлаган, озын гәүдәле, сүздә дә, кыланмышларында да тупас һәм аяусыз адәм.* Ф.Сафин

2) Дәһшәтле, каты, коточкыч. *Һәр карыш җир, һәр урам, һәр йорт өчен аяусыз көрәш бара.* Р.Хафизова. *Фашизмга каршы аяусыз көрәшүчеләр булarak, алар үз исемнәрен, Татарстан, татар халкы тарихына гына түгел, бөтендөнья тарихына да язып калдырдылар.* Р.Мостафин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик, үтә, чиксез, туктаусыз, чамадан тыш. *Моның өстенә, күңелне аяусыз телгәләгән, бәгырь итен көйдергән тагын бер четерек бар иде.* Б.Камалов. *Инде эш бетеп килгәндә, кинәт ишек каерылып ачылып китте, аяусыз тавышланып, кулларына күсәк тоткан берничә ир килеп керде.* Ф.Сафин. *Кояш иртәнге сәгатьтән башлап кыздырырга тотына, көнозын аяусыз яндыра.* Ә.Еники

2) Рәхимсез рәвештә. *Әсәрдә капитализм системасында үз кул көче белән көн күрүче ярлының нинди авыр шартларда яшәве, аның киләчәгенең никадәр өметсез булуы, аның аяусыз изелүе гәүдәләндерелгән.* М.Җәлил

**АЯУСЫЗЛАНУ** *ф.* Аяусызга әверелү, рәхимсезләнү, шәфкатьсезләнү. *Мирвәли аларның, аяусызланып, авырттырып тешләүләрен бөтенләй сизмәде, кулларын төкерекли-төкерекли, очлы таяк белән йомшак җирне чокыды.* А.Гыйләҗев

**Аяусызлана бару** Торган саен ныграк аяусызлану. *Әмма Россия патшасының сәясәте торган саен аяусызлана бара.* Д.Сабирова

**Аяусызлана төшү** Тагы да аяусызлану

**Аяусызланып бетү** Бик нык аяусызлану, аяусызлануның соңгы дәрәҗәсенә җитү

**АЯУСЫЗЛЫК** *и.* Аяусыз булу, рәхимсезлек, шәфкатьсезлек. *[Таһир] Аяусызлык белән алдырып килде.* Б.Камалов. *Власть аяусызлыгыннан сине беркем коткара алмый.* М.Юныс. *Бу – синдәме, шигърият, аксакал Шәрекъның дастани олпатлыгы; илләр язмышын сөңге очына алып биетә алу аяусызлыгы; тәхет тоткан илханның, кылыч сабыннан арыган кулына каләм алып, сүзгә сәҗдә кылу сәләте?* М.Галиев

**АЯУЧАН** *с.* Миһербанлы, шәфкатьле, кызганучан

**АЯУЧАНЛЫК** *и.* Аяучан булу; миһербанлылык, шәфкатьлелек, кызганучанлык

# Ә

**Ә** I *терк.* 1) Бер-берсенә каршы мәгънәдәге тезмә кушма җөмләләрне яки тиңдәш кисәкләрне бәйләү өчен кулланыла; ләкин, әмма, киресенчә. *Юк бездә андый закон, ә менә мине алып ташладылар.* Р.Ишморат. *Әмма, дүрт-биш көн артыннан, атна узып китте, ә акча килмәде.* Ф.Яруллин. *Барысы да ошады, ә менә «картлык» дигән сүзләрне күңелем кабул итмәде.* Н.Дәүли. *Композиторның эчке газаплар эчендә янганы күренеп тора, ә мондый чакларда читтән бирелгән киңәш ярдәмче түгел инде ул.* Казан утлары

2) Тезмә кушма җөмләләрдә бер үк вакытта булган вакыйгаларны, эш-хәлләрне каршы куеп чагыштыру өчен кулланыла; шул ук вакытта, шул арада. *Син теге кара йөзне сөйләндерәсең, ә мин --- бәрәңге бакчасына чыгам...* Я.Зәнкиев. *Рафаил – дәрәҗәле академик, профессор, сәнгать белгече, Ташкентта яши, ә Аван Казанда гомер итә.* Н.Гыйматдинова. *Сәгъдиев, мавыгып китеп, без әле синең белән ---, дип сөйли башлый, ә тегесе куаклыклар аша мышный-мышный атлавын белә.* Казан утлары

3) Тезмә кушма җөмләләрнең берсендә аңлашылган эш-хәлнең икенчесендә логик нәтиҗәсе булмауны һәм көтелгәннең киресе килеп чыгуны белдерә; шулай да, шуңа да карамастан. *Нәсимә түти дә Хөснуллага ике туган баласы түгел ич, ә шулай да Хөснулла өчен кайгыра, дисең.* Ш.Камал. *Гөлгенәне яшен сукмады, ә ул менә урыныннан торалмый ята.* Н.Дәүли. *Сине артиллериядән дөмбәслиләр, ә син исән.* Г.Бәширов

4) Тезмә кушма җөмләләрдә эзлекле күренешләр тасвирланганда, җөмләләрне яки җөмлә кисәкләрен каршы куеп бәйләү өчен кулланыла. *Төлке, үрдәк ите ашыйм, дигәндә генә, капкынга эләккән, ә хуҗа, кайткач, аның кергән биргән.* А.Алиш. *Ул үзенең рюмкасын ялт итеп бушатып куйды, ә Соняның кулы белән күтәрә-күтәрә эчертеп бетерде.* Ф.Садриев. *Кешеләр әнә еллар буе бил бөгә, баш күтәрми эшли, сберкнижкасына акча җыюын белә, ә бераз акча туплагач, ял ала да иң кыргый җирләргә китеп бара.* Казан утлары

5) Сорау куелып, сөйләмне, фикерне икенче бер темага борып җибәрү, юнәлтү өчен кулланыла. *Без күп вакыт шигырьнең үзе турында сүз йөртәбез. Ә шигырьне тудырган кеше, шәхес үзе?* С.Хәким. *Сезнең, ичмасам, хозяйствогыз бар... Ә бездә нәрсә?* Ш.Камал. *Туктале, ә синең мәктәбең?* Ф.Садриев

**Ә** II *кис.* 1) Кемнең дә булса игътибарын җәлеп итү өчен, кабат мөрәҗәгать итеп эндәшкәндә кулланыла. *Ә бит, дөрестән дә, мин сине кыйнаштыргалый идем, кызый, ә?* Һ.Такташ

2) Сөйләм башында сөйләмнең кирәше, сүз җилеме буларак кулланыла. *Ә Тәслиманең күңеленнән куаныч ташый иде.* М.Маликова. *Ә үрмәкүч бу хәлдән нык файдаланды.* А.Алиш. *Ә Шәйхи карт, бер дә әллә кемгә түгел, үз нәселләренә әйтеп калдырган икән.* М.Мәһдиев

3) Сорау һәм өндәү җөмләләр башында килеп, тәэсирлелекне тагын да көчәйтү, куәтләү, шул фикерне раслау өчен кулланыла. *Ә бит ул – батыр хатын икән!* М.Маликова. *Ә нинди матур!* Д.Аппакова. *Ә чибәрлеге, байлыгы!* Ю.Әминов

4) Ишетми калган сүзне яки җөмләне кабатлап сораганда, сорау сүз буларак кулланыла. *– Галя, дим бит, ничә мәртәбә әйтергә була! – Ә?!* Р.Кәрами. *– Сиңайтәм, тордыңмы? – Ә? Нәрсә?* Н.Фәттах

5) Җавап раслау таләп иткән сорау җөмләләрдә сорауны көчәйтү өчен кулланыла. *Миңа ачуланмыйсыз бит, ә?* М.Гафури. *Шулай да, Борисов, кайтып килсәң ничек булыр икән, ә?* Г.Бәширов. *Аларның да кыйбла бар диген, ә?* М.Мәһдиев

6) Сорау яки өндәү җөмләләрдә килеп, үтә гаҗәпләнүне, соклануны яки ачу килүне тагын да көчәйтү өчен кулланыла. *Шундый чибәр кыз да ир кешегә кул күтәрер икән, ә?!* А.Хәлим. *Мине хәзер Гөлнар җаный күрсә иде, абый, ә?* Ә.Айдар. *Әле син Шүрәледән дә курыкмыйсың, ә?* Д.Аппакова

7) Сузып әйткәндә, шулаймыни, шулай булмый ни, шулай була ул, мәгънәләрендә раслауны көчәйтү өчен кулланыла. *Ә-ә-ә, халыкны кыйнаганда яхшы идеме?* Г.Коләхмәтов. *Ә-ә-ә, курыктыңмы, курыктыңмы, ата күркә куркытты!* М.Фәйзи

8) Кемгә дә булса эндәшкәндә, аның тизрәк җавап бирүен таләп итә. *Кирьян, ә, Кирьян!.. Ни булды сиңа?* Р.Ишморат

**Ә** III *ы.* 1) Нәрсәне дә булса искә төшергәндә, аптырагланда әйтелә. *Ә, кара әле кем, Хафиз, сәгать ничә булган?* Г.Камал. *Ә-ә, әйе шул. Грипп чоры бит.* Ф.Яруллин. *– Ә, кстати, мин бит онытпым, Ирек Хәйриевич, китабыңны алып кер әле, – диде Арсланов.* Ф.Садриев. *– Ә-ә, аны әйтәсең икән! – диде Фаиз.* Х.Сарьян

2) Нәрсәгә дә булса төшенүне, нәрсәне дә булса аңлауны белдерә; алай икән. *Комбат, мине акылга утыртмакчы буласыңмы? Ә-ә, аңладым мин сине!* Х.Камалов. *– Шамилләр анда бит. – Ә-ә, – диде председатель.* Х.Сарьян. *Ә-ә-ә... Алай икән.* А.Хәлим. *– Ә-ә-ә, сез журналистлармыни? – дип сорады кыз...* Казан утлары

3) Кем белән дә булса очрашкач, аны таныганлыкны белдерә. *Ә, син бит әле бу!* А.Гыйләҗев. *Ә, Сәхәп, син икәнсең.* Ә.Фәйзи. *Ә! Бу – Кушлавыч, ә тавыш – Бәдри абзыйныкы!...* Ә.Фәйзи. *Ә-ә-ә! Каениш бу минем, каениш! Казан кунагы!* Ә.Фәйзи

4) Кемне яки нәрсәне дә булса күргәч туган шатлык, куану хисләрен белдерә. *– Ә-ә, Фира Касыймовна, шулаймы?* Х.Камалов

5) Шаккату, гаҗәпләнү, соклану, канәгатьлек, хуплау, мактану һ.б.ш. хисләрне белдерә. *Нинди кеше булгансыз бит, ай-яй?! Тегермәнче малае дип кем әйтер, ә?* Х.Камалов

6) Үтенүне, теләкне белдерә. *Ничек булган, барча нечкәлекләренә кадәр искә төшереп, безгә язып бирсәңче, ә?* Х.Камалов

7) Санга сукмау, ис китмәү, нәфрәтләнү, җирәнү һ.б.ш. хисләрне белдерә. *– Ә-ә, пустяк! – диде Алексей һәм тагы кулын селтәде.* Х.Камалов

8) Ачынуны, ризасызлыкны, куркытуны һ.б.ш. хисләрне белдерә. *– Югары белемле егет, тарих укытучысы. Яшь коммунист, комсомол райкомы члены, ә? Хәзергә тикле шуны укымадыңмы әле? – ди.* Б.Камалов. *– Чын-чын! Эш башын хатыннар кулына бирсәләр, бернинди сугыш булмас иде. – Ә? Юк, барыбер булыр иде.* Х.Камалов. *Елап беткәнсең, Роза. Бу ниткән эшең, ә?* Б.Камалов

9) Кемне дә булса мыскыл итеп, аннан көлеп, аны кимсетеп, үртәп, ирония белән көлеп әйтүне белдерә. «*Ә-ә! Бирештең, бирештең!*» *– дип ирештерсәләр, еламый калу бик кыен иде...* Н.Измайлова. *– Ә, Сафина... – диде ул Гөлшаһидәгә, мыскыллы тавыш белән.* Г.Әпсәләмов

◊ **«Ә» дә димәү, «җә» дә димәү** Сөйләүченең фикеренә карата бер сүз әйтмәү, эндәшмәү; үз мөнәсәбәтен белгертмәү. *Шәвәлиев «ә» дә димәде, «җә» дә димәде, башын игән хәлдә кызарып утыра бирде.* Ф.Садриев. **«Ә» дигәнче** Бик тиз арада. *– Кулыңны авырттырып куйма, белмәгән эшкә тотынма! – дип әйтүләренә карамастан, түшәк зурлыгындагы печәнне «ә» дигәнче күтәреп, югары ыргытты.* М.Гафури

**Ә-ӘҺ** *ы.* Ачыну, үкенү, борчылу, зарлану хисләрен белдерә. *Ә-әһ, чирек сәгатькә генә алдарак кайтып өлгермәделәр шул...* Т.Нәбиуллин

◊ «**Әһ» дигәнче** Бик тиз, күз ачып йомганчы, бер тын алырга да өлгермичә. *«Туфан синдәй имәнне дә екса, бүтәннәрне «әһ» дигәнче таптап узачак!» – дип Наилә елый.* А.Гыйләҗев. *Тик шунда ук, «әһ» димәс борын зарлана башлавына уңайсызланып, сүзне тизрәк икенчегә борды.* М.Хәсәнов

**ӘБ** *и. гар.* Ата, әти (ялгызлык исемнәре ясаганда, *әба, әбү, әби* формаларында йөртелә: *Әбубәкер, Әбүхәнифә, Әбидәламә һ.б.*)

**ӘБӘД(А)** *рәв. гар. иск. кит. к.* **әбәдән.** --- *тозны ике генә бармак белән кабучылар – көллесе кяфер булып, җәһәннәмдә әбәда калачаклардыр...* Ф.Әмирхан. *Мәңгегә калсын азатлык, мин калыйм шунда әбәд.* М.Гафури

**ӘБӘДӘН** *рәв. гар. иск. кит.* Мәңгегә, гомер-гомергә; беркайчан да. *Ике нәрсә әбәдән аерылмыйлар: хирыс вә оятсызлык.* К.Насыйри

**ӘБӘДИ** *с. гар. иск.* Мәңгелек, һичбер бетми торган; соңы булмый торган. *Эшләп калдырган зур вә гали эшләрең синең һичбер вакытта да үләчәк түгелләрдер. Эшләп калдырган гали эшләрең синең – әбәди, намың әбәдидер.* С.Рәмиев

**ӘБӘК** *и.* 1) *к.* **әбәк уены**. *Кәҗә, кәҗә, тукта, сөзмә мине юкка, уйныйк әйбәт кенә! Бу бит «әбәк» кенә...* Р.Харисов. *Без – карсак өйләр арасында әбәк уйнап үскән малайлар.* Р.Зәйдулла

2) Уенда кул белән кагылганда кулы җитүне, шул уенда рольләр алмашуны белдереп әйтелә торган сүз. *– Әбәк! – дип, Мулланурның башына сугып алды да су буена йөгерде.* М.Әмирханов. --- *«әбәк!» дип кычкырып, берәрсенә кагылып узу...* М.Мәһдиев. *Әбәк, әбәк, тота алсаң – майлы көрәк, тота алмасаң – кара әпәй!* Н.Исәнбәт. *– Син – ак куян, Йомшак куян, Әбәк, әбәк! – Мин күк куян, йөгерек куян, Әбәк, әбәк! – Син тот, куян!* Гөлбакча

**ӘБӘК ИТҮ** *ф. к.* **әбәкләү**. *Мусага әбәк итү*

**ӘБӘКЛӘҮ** *ф.* Әбәк уйнаганда, берәрсен куып җитеп, аңа җиңелчә сугу, куып тотарга тәкъдим итү. *Әбәк-чәбәк, көрәк-сәнәк, Тота алсаң, булыр әйбәт. Әбәкли дә йөгереп китә. Икенче бәти аны тота, ул да әбәкли.* Ф.Яруллин

**Әбәкләп алу** Кемне дә булса тиз генә әбәкләү. *Хәлим, йөгереп килеп, Алсуны әбәкләп алды*

**Әбәкләп китү** Яныннан узышлый, кемне дә булса кинәт әбәкләү. *Иптәшен әбәкләп китү*

**ӘБӘКЛЕ** *и. к.* **әбәк уены**. *– Хәтеремдә, – диде хатын. – Без анда синең белән әбәкле уйный идек...* М.Кәбиров. *Энем кайтып җитсә, шахмат чиртешле уйныйсы бар, әбәкле, качышлы, тәкмәч атышлы, парланган тәрәзә пыялаларына бармак белән сызып рәсем төшерешле.* Д.Булатова. *Аерма шунда: өлкән буыннарның балачагы «чукрак телефон», «12 таяклы», «әбәкле» кебек урамда уйналган хәрәкәтле уеннар белән истә калса, бүгенге заман баласына телефон, компьютер, Интернет уеннары кадерле.* Сабантуй

**ӘБӘК УЕНЫ** *и.* Куышлы уены; уйнаучыларның берсе (әби) кемне дә булса куып җитеп, аңа җиңелчә генә сугарга һәм «әбәк» дип әйтергә тиеш, шул сүздән соң рольләр алмашынудан гыйбарәт уен. *Әнә озын тәнәфесләрдә әбәк уены уйнаганда да Рафика белән уйныйбыз, ул, башка берәүгә дә түгел, «әбәк!» дип, минем аркама сугып йөгерә.* Г.Галиев

**ӘБӘК-ЧӘБӘК** *и.* Балаларның кулларын чәбәкләп уйнавы. *Җыр башласа – кошлар туктап тыңлаганнар, кырга чыкса – күбәләкләр аның белән әбәк-чәбәк уйнаганнар.* А.Әхмәтҗанова

**ӘБӘК-ЧӘБӘКЛЕ** *и.* Әбәк-чәбәк уены. *Укытучылар да бергә «Әбәк-чәбәкле» уйный, Тик нигәдер Хәким генә Аңлый алмый һич шуны!..* Л.Лерон

**ӘБӘЛӘК** *с. диал.* 1) Бик түземсез, бик чыдамсыз. *Әбәләк кеше*

2) Бәлачел, бәла китерүче

**ӘБӘЛӘКЛӘҮ** *ф. диал.* Юк кына эш-хәл яисә сүз өчен дә тавыш күтәрү

**Әбәләкләп йөрү** Һәр җирдә, төрле урыннарда үзен җәлләтеп йөрү

**ӘБӘТ** *и. сөйл. рус* 1) Гадәттә кыр эшләре вакытында көн уртасында кырда ашау. *Көндезге әбәттән соң, Габделкаюм да җиң сызганып урырга керешә.* М.Гафури. *[Солы чыпчыгы:] Әбәткә дип килсәм, шаклар кат-*

*тым. Бөтен җимне җил сыпырган да төшергән.* Н.Сладков

2) Төш вакыты, көн уртасы. *Габделкаюм, көндезге әбәткә кадәр, яңадан бер түбәтәй җиләк җыеп китерде.* М.Гафури. *Җиңелчә генә яңгыр явып узганга, әбәт вакыты үтүгә караңгыланып өлгергән күзге көн тымызыкланып киткән иде.* З.Фәйзуллин

**ӘБӘ́Ү** *ы.* 1) Нәрсәгә дә булса гаҗәпләнү, соклану, ис китү, шаккатуны белдерә. – *Әбәү, Гөлшаһидә бәгырем, йөрәгемне өзден бит! – дип, Гөлшаһидәгә башын чайкап карап тора...* Г.Әпсәләмов. – *Әбәү, җаным, костюмың бик матур икән, үзең тектеңме?* Ф.Яруллин. --- *тиешле турыга килеп җитүләрен Асылбикә дә соңлабрак абайлады: – Әбәү, кызым.* Р.Вәлиев

2) Нәрсәдән дә булса куркып, өркеп, сискәнеп киткәндә әйтелә. – *Галя! – Әбәү, котым калмады.* Я.Зәнкиев. – *Әбәү, шулкадәр куркытмасаң! Йөрәгемне яра язды, җен! – дип [кызлар], тиргәнә-тиргәнә, өс-башларын кагарга керештеләр.* Ф.Шәфигуллин

3) Нәрсәне дә булса ошатып, яратып бетермәүне яки җирәнеп карауны белдерә. *Әбәү! Нигә бик ямьсез, карт?* Г.Исхакый. *Кирәкми, әбәү, бармаклары, үләм, ха-ха-ха!* Н.Исәнбәт. – *Әбәү, әчәч! – диде Фатихәттәй, нәфрәтләнеп.* Г.Әпсәләмов

**ӘБЕКӘЙ** *и. ирк.* Туганлык буенча үз әбисенә яки өлкән яшьтәге хатын-кызга эндәшү сүзе. *Бер уйласаң, гаҗәп инде бу эшләр, әбекәй.* Г.Ибраһимов. *Елама, әбекәй, елама, Бибизәйния.* Г.Ибраһимов. *Чишмә суы белән юынырсың, әбекәй.* А.Әхмәт

**ӘБЕЛХАЯТЬ** *и. фар. к.* **әбелхәят.** *Үр итәгендә җәйрәп яткан түгәрәк күл!.. Этләр, куйлар, атлар – барысы да, абына-сөртенә, әбелхаятька ташландылар. Ниһаять!* И.Салахов

**ӘБЕЛХӘЯТ** *и. фар.* Мәңге яшәтә торган су, тереклек суы; тормыш, яшәү чыганагы (су турында). – *Тәңрем минем, йирдән алып менгән чиләкле суларымны бер шифалы әбелхәятка әйләндерсәнә, – дигән дә чиләкле көянтәсен иңе өстенә куйган.* Ф.Әмирхан

**ӘБЕЛХӘЯ́Т СУЫ** *и. к.* **әбелхәят.** *Баш калкытып куйды Нуриман карт, Гүя эчте әбелхәят суын...*Ф.Яруллин. *Китер әбелхәят суын – бер генә йотым китер.* Р.Гаташ. *Әйе, мәңге яшәргә теләүчеләр, мәңгелек су – әбелхәят суын эзләүчеләр аз булмаган бу дөньяда...* Ф.Урманче

**ӘБЕЛХӘЯ́Т ЧИШМӘСЕ** *и. күч.* Яшәртә, сафландыра, көч-дәрт бирә торган чыганак. *Юкка гына борынгылар тереклекне әбелхәят чишмәсенә охшатмаганнар икән.* Ә.Еники

**ӘБЕ́Р-ЧӘБЕР** *җый. и. сөйл.* 1) Кыйммәте, әчтәлеге түбән булган, зур әһәмияткә ия булмаган әйберләр; вак-төяк. *Без бик риза түгел сиңа, Вак-төяк, әбер-чәбергә күп урын бирә «Шура».* Ш.Бабич

2) Кече яшьтәге бала-чага. *Авылда карчык-корчык та безнең кебек әбер-чәбер калган.* Ә.Айдар

3) Дәрәҗә, абруй, байлык ягыннан түбән саналган катлау кешеләре. *Җыелышка әбер-чәбер килгән иде*

**ӘБЕРЧЕН** *и. зоол.* Күгәрченнәр семьялыгыннан, күгәрченнәргә караганда кечкенәрәк башлы, озынчарак койрыклы, җыйнаграк гәүдәле, зәңгәрсу көрән төстәге урман күгәрчене; *русчасы:* **горлинка, горлица**. *Кышкы җимлеккә бер әберчен килеп кунды*

**ӘБҖӘД** *и. гар.* 1) Борынгы гыйбрани (яһүд) әлифбасындагы хәрефләр тәртибен күрсәтү өчен кулланылган сигез уйланма сүзнең (*әбҗәд, һәүвәз, хоттый, кәләмән, сәгъфәс, коришәт, сәхоз, зазог*) беренчесе һәм шул сүзләр тезмәсенең гомуми исеме. --- *җәмгыять «Иман шарты» һәм «Әбҗәд» укыла торган мәдрәсәләр ачарга, кичке дәресләр ясарга --- тырышачактыр.* Г.Исхакый. *Әбҗәд, һәүвәз, көтеб сәләфтә бармы, юкмы?* Г.Исхакый. *Дөрес, монда «прак», «бәдәвам» кебек, әбҗәдтәгечә, аңлаешсыз сүзләр дә бар...* Ә.Фәйзи

2) Шул сүзләр белән белдерелгән саннар һәм шул сан-хәрефләрне кулланып хисаплау ысулы. *Әйтик, әбҗәд – 1 һәм башкалар шул тәртиптә – 2, 3, 4 кә туры килә.* Татар мөселман календаре

3) *күч.* Дога; бисмилла. --- *безнең әни, йокларга ятканда, ишек-тәрәзәләрне, мич капкачларын әбҗәд укып яба...* Г.Гобәй. *Имансыз эш булмый. Әбҗәд кирәк.* Г.Исхакый

◊ **Әбҗәдкә төшү** Әбҗәд өйрәнә башлау

**ӘБҖӘДЛӘ́Ү** *ф.* Һәр хәрефне әбҗәдтәгечә атамасы белән укып (әйтеп) чыгу

**Әбҗәдләп җибәрү** Әбҗәд тәртибенчә укып бирү. *Әйдә, әбҗәдләп җибәр булмаса.* Ф.Бурнаш

**ӘБҖӘ́Д ТӘРТИБЕ** *и.* 1) Хәрефләрнең әбҗәдтәгечә тәртибе

2) Хәрефләр белән санаганда, шул тәртиптән файдалану

**ӘБҖӘДХАН** *и. гар.-фар. иск. кит.* 1) Укырга яңа өйрәнә башлаучы кеше

2) *күч.* Нинди дә булса берәр фәнне өстән-өстән генә белүче, аның әбҗәде (әлифбасы) белән генә таныш кеше

**ӘБҖӘ́Д ХИСАБЫ** *и.* Әбҗәд хәрефләре белән санау

**ӘБҖӘДЧЕ** *и. иск.* Әлифбаны «Иман шарты» дигән борынгы китаптан уку – дөрес, әбҗәдне иҗектән башка уку дөрес түгел, дигән караштa торган кеше; иҗекче

**ӘБЗӘЙ** *и. диал.* Абый, абзый (эндәшү сүзе). *Өч-дүрт гаилә башлыгының берсе дә «быел мин түлим әле, әбзәй» дип авыз ачып әйтми, укулар шул көе бара да бара.* К.Миңлебаев

**ӘБИ** *и.* 1) Әтисенең яки әнисенең әнисе. *Фаягөл исән-сау йөрсен, әбисе йорты белән әтисе арасында тик чабып йөри торгандыр, балакаем...* Я.Зәнкиев. *Бу уңай белән, әтием ягыннан булган әбием искә төшә.* Ә.Борһанов. --- *балалар, атылып килеп, әбиләренең кочагына ташланалар.* Ф.Яруллин

2) Иргә хатынының әнисе. *Төркмәнстаннан кайткан баҗасы Шәһит булмаса, кем белә, бәлкем Илһам әбиләренә барган да булыр иде әле.* Ф.Садриев

3) Һәрбер өлкән яшьтәге хатын, карчык (гадәттә исемгә кушылып әйтелә) – *Күренә, Нуриасма әби, – диде кыз, бармагы белән комлыкка төртеп күрсәтеп.* Ф.Садриев --- *Мәүлихә әбинең исән калган ярты өен тәмам тырылык хәлгә китерде.* Ә.Фәйзи. *Бер*

*аягы – түрдә, икенчесе гүрдә булган әби янына керәбез.* К.Латыйп

4) *сөйл.* Олы яшьтәге кешенең хатыны һәм аңа иренең эндәшү сүзе

5) Бала тапканда ярдәм итүче кеше; кендек әби, кендекче. *Инде бала туар вакыт җиткәч, бер карчык китерәләр. Аны «кендек әбисе» диләр. Ул әбинең ярдәме белән, бала туа.* К.Насыйри. *Тугач та кендек әбисе Гарәфине шушы нигез белән беркетеп куйган иде ич.* Д.Гайнетдинова. *[Хатын] Сагызлан-ган үтмәс урак алып, үзе «әби» булды үзенә.* Ф.Кәрим

6) Әбәк (качышлы, куышлы, почмак алыш һ.б) уеннарында эзләүче яки куучы, уенда катнашучы. *Егетләр, шаяра-шаяра, әбидән суктырмый качып йөриләр.* М.Фәйзи. *Дүрт бала, дүрт әби исемен алып, дүрт почмакка баса. Идән уртасындагы бишенче бала, әбиләр янына килеп, алардан мунча сорап чыга. Әбиләр, төрле сылтау тапкан булып, мунча бирмиләр.* Гөлбакча

**ӘБИ́-БАБА(Й)** *җый. и.* 1) Әтисенең яки әнисенең ата-анасы. *Ата-ана, әби-баба кара кайгыда.* Р.Әмирхан

2) Гомумән картлар һәм карчыклар; ата-баба. *Ураза вакытларында әби-бабайлар тау түбәсеннән иң соңгы нур китми торып авыз ачмаганнар.* Х.Сарьян

3) Борынгылар, өлкән буын кешеләре. *Бу китапны укып, мәктәп балалары --- хәтта ике-өч буын әби-бабалары да белмәгән, ишетмәгән вакыйгалар --- дәрьясына чумачаклар.* Р.Әмирхан. – *Безнең заман, әлбәттә, әби-бабайлар заманы түгел.* Г.Әпсәләмов. *Хәзерге татар повестьлары арасында --- әби-бабаларыбызның йолаларына --- хөрмәт белән карарга чакырганнары да булуы куандыра.* Казан утлары

◊ **Әби-баба(й) бишеге** *к.* **әби-бабай туфрагы**.--- *әби-бабаларының бишеге булган авыл җирен бер дә сагына белми.* М.Максуд. **Әби-бабай туфрагы** 1) Туган җир, туган ил; 2) Ата-ана йорты, туган йорт. *Тарта тамыр, тарта кан, тарта әби-бабайлар туфрагы, дип, юкка гына әйтмиләрдер шул.* Т.Нәҗмиев. **Әби-бабаларына җитү** Кемне дә булса затсыз сүзләр белән сүгү. *Шулай да әби-бабаларына хәтле үк җитәргә ярамый бит? Ничек уйлыйсың?* Ш.Камал

**ӘБИ́ КАБАСЫ** *и.* Тегү теккәндә, эләктереп, кадап куя торган булавка, түбе чукмарлы энә

**ӘБИЛӘ́Р АТНАСЫ** *и. к.* **әбиләр чуагы**. *Җылы, яңгырсыз көннәр. Бу көннәрне авылда «әбиләр атнасы» диләр.* Г.Исхакый

**ӘБИЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Әбиләргә хас булганча; әбиләр сыман. *Тик, кызларча түгел, әбиләрчә матур ул.* Н.Дәүли

**ӘБИЛӘ́Р ЧУАГЫ** *и.* Көзнең соңгы җылы, матур, кояшлы көннәре. --- *Әбиләр чуагы – Җимешнең мул чагы, Дөньяның моң чагы...* Г.Афзал. *Берничә көн яңгыр явып маташты да, кинәт, яктырып, кояш чыкты, әбиләр чуагы килде.* Ф.Садриев. *Сентябрь урталарындагы көзге вак яңгырлар туктальп, әбиләр чуагы башланган чак була бу.* Я.Зәнкиев. --- *янә күңелле, җылы көннәр, яңгырсыз һәм салкын төннәр җитте. Әбиләр чуагы шул була инде.* Г.Хәсәнов

**ӘБИЛЕК** *и. сөйл.* Әби булу, әби вазифасы

**ӘБИЛЕ́К ИТҮ** *ф. сөйл.* Бала тудырганда ярдәм итү. *Аллага шөкер, егерме биш ел әбилек итәм, бер генә дә ялгышканым юк.* А.Шамов

**ӘБИЛЕ́К КЫЛУ** *ф. сөйл. к.* **әбилек итү**

**ӘБИ́ ПАТША** *и.* Екатерина IIнең халык телендә йөргән исеме; патшабикә. *Әби патша гаскәрен Пугач шунда дөмбәсләгән.* М.Әмирханов

◊ **Әби патшадан калган** *к.* **әби патша заманыннан калган**. **Әби патша заманыннан калган** Бик күптәнге, борынгыдан калган, искергән. *Әби патша заманыннан ук калган, бәйрәмнәрдә матур ал эскәтер җәелә торган озынча өстәл.* Сөембикә

**ӘБИ́-СӘБИ** *җый. и. сөйл. к.* **әби-чәби.** – *Уйнашчы Галимә йорты! – дип үтәләр карт әби-сәбиләр.* М.Гафури

**ӘБИ́-ЧӘБИ** *җый. и. сөйл.* Гомумән әбиләр, карчыклар, олы яшьтәге хатын-кызлар. *Әби-чәбине үз артыннан ияртхән Гөлнур: – Миннән алдан кая очасыз? – ди.* Н.Гыймматдинова. *Эңгермеңгердә әби-чәбиләр, бисмиллаларын кат-кат укып, ишек-капкаларның келәләрен төшерәләр...* Я.Зәнкиев. *Хәлсез хатын-кызлар, әби-чәбиләр, иртә таңнан барып, шул тауларда казыналар...* Р.Мирхәйдәров

**ӘБИ́ ЧӘЧЕ** *и. сөйл.* Кыяклылар семьялыгыннан, яфраклары озын тар кыяклардан гыйбарәт булган, йомшак себеркәч чәчәкле дала үләне; кылган; *русчасы:* **ковыль**. *Бабай башын мин күрдем, әби чәчен мин үрдем.* Табышмак. *Әби чәчләрен тузгытып, көмешләнеп торган куе кылганлыкка карагач, Госманның елыйсы килеп китте.* И.Салахов. *Алар узган елгы кылганнар – әби чәчләре җилфердәп торган тау түбәсенә янәшә утырдылар.* Ф.Садриев. *Сәвәләйдә казаяклар үсә, Әби чәче тузгып утыра.* К.Булатова

**ӘБРӘКӘЙ** *и. фар. гади с.* 1) Табигый йомышны үти торган урын; бәдрәф. *Әбрәкәйгә дә комган белән йөри.* И.Шиһапов. *Хыялым белән, мөртәтне – сабантуйлар батырын – мин айгыр булып таптадым, әбрәкәйгә батырдым.* Р.Харис

2) *тар.* Канализация

◊ **Әбрәкәй сандугачы** *туп.* Буш лыгырдык. *Хәзер, шул әбрәкәй сандугачы янына гына барасым калды...* Л.Лерон

**ӘБРӘСХАНӘ** *и. фар. иск. к.* **әбрәкәй**

**ӘБҮҖӘҺЕЛ** *и. гар.* 1) *тар.* Мәккәдә Мөхәммәд пәйгамбәрнең иң явыз дошманы – Әбү Хәким ибне Һишам кушаматы – гарәп кабиләләренең элекке тормыш тәртипләрен, дини ышанууларын саклап калу өчен көрәшүчеләрнең берсе. *Сезнең сыерыгыз – хайваннарның кяфире икән. Алла сакласын, Алла сакласын. Ягъни мәсәлән, Әбүҗәһел сыерының нәселеннән килгән сыер икән.* К.Тинчурин

2) *күч.* Үтә хәйләкәр, бик явыз, надан кеше. *Китапча итеп әйтсәк инде, минәйтәм, таштан су чыгар, усак агачы алма бирер, ә әбүҗәһел акылга килмәс.* Г.Ибраһимов. *Әбүҗәһел Лысенко килү белән, академиядә наданнарга, ялагайларга юл ачылды.* Т.Мөбарәков

**ӘВӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нинди дә булса куе массаны (камыр, балчык һ.б.ш.ны) бе-

рәр савыт эчендә яки яссылык өстендә әйләндерә-әйләндерә тәгәрәтү. --- *куна такта өстендә камырны зур-зур икмәкләр ясап әвәләде, онлады да кызу мичкә тыкты.* Г.Ибраһимов. *Кар астында калып өшегән черек бәрәңгене, изеп, аз гына арыш онында әвәләп кыздырсаң – телеңне йотарлык кәлҗемә була иде!* Казан утлары

2) Төрле катнашмаларны бергә кушып, куллар белән болгата-болгата укмаштыру, нинди дә булса бер рәвешкә китерү, бербөтен итеп оештыру. *Хуҗа хатын әпе-төпе китереп ипи әвәли.* М.Мәһдиев. *Менә өч-дүрт йомыркага гына кош теле пешермәкче булам, кулыңны юып кына камыр әвәлә әле…* Г.Исхакый

3) Нәрсәне дә булса кулда яки авызда әрле-бирле йөртү. --- *авыруның йөрәген кулына алды да, камыр әвәләгән кебек әвәли-әвәли, аны ясалма рәвештә эшләтә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Кешеләр, көлешеп, дымлы туфракны кулларына алдылар, бармак араларында әвәләп, иснәп карадылар…* Н.Фәттах

4) Йонны тәгәрәтә-тәгәрәтә, уа-уа оештырып укмаштыру, берәр төрле форма бирү, басу. *Йоннан әвәләгәндәй, баштанаяк кара мехка төренгән оныгын профессор, сары кайры тунының итәге белән каплап, башын игәләде.* Г.Бәширов

5) Вак-төяк әйберләрне катыштырып, нәрсә дә булса ясау, берәр нәрсә барлыкка китерү. *Үрдәкләр ояларын түмгәк араларына ясыйлар. Үлән йолкып, йонкаурыйлары белән әвәлиләр дә – менә дигән оя килеп чыга.* Н.Сладков

6) Тәгәрәтә-тәгәрәтә хәрәкәтләндерү, шуыштыру. *Ул мичтәге утлы күмерне кисәү таягы белән әвәләп китерә дә тәмәкесенә ут ала.* М.Мәһдиев

7) *куч.* Холык-фигылен үзгәртү, йогынты ясау. *Әнисе, аның да битараф түгеллегенә сөенеп: – Кызым, Рәмзил – начар егет түгел, үзеңә нинди ир кирәк, аннан шундый ирне әвәләп була.* З.Дәүләтов

8) *куч.* Аннан-моннан гына, җиренә җиткерми, өстән-өстән генә эшләп ташлау. *Әгәр кемнәрдер әвәләгән шушы ике брошюрага берәр төрле әдәби премия биреп куйсалар?* Ф.Садриев. *– Моны кем язды? – дип сорады Сәгыйтов. – Башын мин әвәләдем, койрыгын Шәяхмәт ябыштырды, ярармы?* С.Рафиков. *Укулар, ни сәбәпледер, бик нык кыскартылып, курсантлардан ашык-пошык кече офицер әвәләп, Гарифулланы Алма-Атадагы яңа хәрби училищега укытучы-тылмач итеп җибәрделәр.* А.Хәлим. *Илгә яңа кадрлар, яңача фикер йөртә алырлык гыйлем ияләре әзерлибез, дип мактанабыз. Асылда, еш кына, Сәгыйтов ишеләрне әвәләп бирәбез.* Ф.Сафин

9) *куч.* Гаепләү өчен, юк эшне дә күпертеп күрсәтү, ялган гаеп тагу, уйдырмалар уйлап чыгару. *Янчурин «Сельхозтехника»да эшли торган бер комсомолецыбызны төрмәгә тыкты. Гел юктан җинаять эше әвәләп.* Ф.Садриев

10) *куч.* Кемне дә булса кочаклап, куллар белән каты кысып иркәләү. *Кайчагында, элекке гадәтләремә буйсынып, сине кочарга, үбәргә, күкрәгемдә әвәләргә теләп, кулларыма ирек бирәм…* Ф.Яруллин

11) *куч.* Бер сүзне һаман кабатлап тору, бер нәрсәне кабат-кабат сөйләү

12) *куч.* Сүзләрне чак оештырып әйтү; авыз эченнән мыгырдау. *– Менә үләм, иптәш командир, – диде ул, сүзләрен көчкә әвәләп.* Х.Камалов. *Яңагым сизелерлек күпереп чыккан, шешкәне күземә үк күренеп тора, авызым сүз әвәләп чыгара алмый башлады.* Г.Сәгыйров

13) *куч.* Бик озак, кат-кат, төрле ягын уйлау. *Каюм мәсьәләне үзенең башында бөтен яктан әвәләгән иде, күрәсең.* Ш.Камал

14) *куч.* Эшне тәмамлый алмыйча, кабат-кабат төзәтү, озаклап эшләү. *Башкалар бер кибәнне әвәләп маташканда, алар, Мөхәммәт белән, икене салып куялар.* Р.Сибат

**Әвәләп алу** Кыска вакыт эчендә тиз генә әвәләү. *Теге кеше, өенә кайткач, хатынына мактана икән: «Итекче Җәлилне очраттым, сөйләштем, иртәгә йон илтәм, бастыручылар күбәйгәнче, әвәләп алырга кирәк», – ди икән.* И.Гази

**Әвәләп бетерү** Барысын да яки ахырына кадәр әвәләү. *Ипине әвәләп бетерү*

**Әвәләп йөрү** Һаман да, бертуктаусыз әвәләү. --- *авыз эченнән әллә нинди аңлашылып бетмәгән реклама сагызлары әвәләп йөрүләре турында искәртте.* Н.Гариф

**Әвәләп кую** 1) Тиз генә әвәләп әзер итү. *Минем инде ул вакытта баш эшли, тел әйләнә. Кемне дә булса хурлап, минут эчендә берәр такмак әвәләп куям…* Ә.Рәшит

2) Алдан, әвәләп, әзер хәлдә тоту. *Әни алты олы ипи, бер бәләкәй ипи әвәләп куйды.* Н.Кәримова

**Әвәләп ташлау** 1) Тиз-тиз генә, җәһәт рәвештә әвәләү

2) *куч.* Берәр эшне аннан-моннан гына, җиренә җиткерми ашыгып эшләү. *Бу эшне ашыгыч рәвештә әвәләп ташлаган өчен, бюро членнарына ризасызлык белдергәнен ишеткән иде.* М.Мәһдиев

**Әвәләп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта, күз алдында әвәләү. --- *бу соравыннан уңайсызланган кебек, сүзен, әзрәк, авызында әвәләп торды.* Н.Гыйматдинова. *Камыр изә торган рычаг кеше кулы сыман әйләндереп, әвәләп тора.* Ш.Галиев

2) Күпмедер вакыт, бераз әвәләү. *Аны [тәмәкене] бармаклары арасында бераз әвәләп торгач: – Синең янда тарту килешмәс, – дип, тәмәкесен кабына кире салды.* Р.Бәшәр

3) Бертуктаусыз нәрсә дә булса әвәләү. --- *буржуйлар фәлән, буржуйлар төгән, имеш! Шушы сүзләрне әрле-бирле әвәләп торудан башка белгән нәрсәгез дә юктыр, ахрысы.*Ш.Камал

**Әвәләп чыгару** Аннан-моннан, җиренә җиткерми генә эшләү. *Татар телен гамәлгә кертү курсы татар кызларыннан, татар егетләреннән бер кыш эчендә бухгалтерлар, счетоводлар әвәләп чыгарып бирә.* И.Гази

**Әвәләп чыгу** 1) Нәрсәне дә булса башыннан ахырына кадәр, һәрберсен берәм-берәм әвәләү

2) *куч.* Нәрсәне дә булса ахырына кадәр эшли алу, эшләп башкару. *Белмим, боларны әвәләп чыгарга баш җитәрме?* Г.Әпсәләмов

**ӘВӘРӘ** *и. фар.* **1**. Бик буталчык хәлләр, вакыйгалар. *Аның ул әвәрәгә*

*ничек катнашып китүен һич аңлап та булмый, юкса, ирекккә чыгарына да нибары өч ай гына калган булган.* Казан утлары

**2**. *хәб. функ.* Бер нәрсәгә бирелеп китү, мавыгу. *Нинди эшкә башың әвәрә?* Н.Исәнбәт

**ӘВӘРӘ́ БУЛУ** *ф.* 1) *к.* **әвәрә килү**. *Шушы мөбарәк Мәдинәи Мөнәвәрә шәкертләре «Русия мөселманнары иттифакы» оештыру эше белән әвәрә булалар.* Г.Исхакый. *Ике маржа карчыгы чәй белән әвәрә булалар: берсе --- чәй коя, икенчесе вак кына алмалар кисеп, чынаякларга салып маташа...* Ш.Камал. *Үз эше белән әвәрә булган ана улының иркәләнәсе килеп йөрүен аңламады.* Р.Мөхәммәдиев

2) Берәр нәрсәгә юлыгу, дучар булу. *Булмас эшкә әвәрә булма, яшең китәр, Хөкемсез илгә баш булма, башың китәр.* Мәкаль

**ӘВӘРӘ́ ИТҮ** *ф.* Кирәкмәгән нәрсә белән кемне дә булса аптырату, йөдәтү. *Файдасыз нәрсәләр укытып, яшьләрне әвәрә генә итәләр.* Ш.Камал

**ӘВӘРӘ́ КИЛҮ** *ф.* Берәр эш, шөгыль, мәсьәлә белән мәшгуль булу, маташу, кайнашу; мәш килү. *Я саташа, я бастырыла, я төшендә дә көндәлек больница эшләре белән әвәрә килеп алҗып бетә.* Г.Әпсәләмов. *Иң элек шул билгеле булды: гел эш белән әвәрә килү аны иптәшләреннән аерган булып чыкты.* Ф.Садриев. *Кибеткә гармуннар кайткан иде, ирләр шул тирәдә әвәрә килде.* М.Мәһдиев

**ӘВӘРӘЛӘНҮ** *ф.* **1.** *к.* **әвәрә килү.** *Һәрхәлдә, Мирзаҗанның болай әвәрәләнүе шәп түгел...* Б.Камалов. *Элегрәк бу табигый санала иде, хәзер бер генә дә шулар белән әвәрәләнәсем килми.* Б.Камалов

**2. әвәрәләнеп** *рәв. мәгъ.* Берәр нәрсә белән нык мавыгып, шуның белән мәш килеп. *Кем белсен, әтисе янында әвәрәләнеп, борынына машина исе кергән Госманның зур мәгънәдә хезмәт сукмагына басуына шул лобогрейкага кагылышы сәбәп булгандыр?* Б.Камалов

**ӘВӘС** *хәб. сүз гар. сөйл.* Нинди дә булса эшкә, һөнәргә оста булу, шул эшне, һөнәрне бик ярату, шуның белән мавыгу. *Хат язарга артык әвәс түгел иде Шамил солдат...* Я.Зәнкиев. *Сеңлебезнең бер һөнәре артырга тора бит әле, Ибраһим абзый, Нурия музыкага әвәс булып чыкты бит.* Г.Ахунов. *Әй, яшь вакыт! Күперләрне яккан вакыт, Җимерергә әвәс, күпне ваткан вакыт, Синме әллә үз-үзеңне тапкан вакыт?!* Р.Гаташ

**ӘВӘСЛӘНДЕРҮ** *ф.* Нәрсә белән булса да мавыктыру, нәрсәгә дә булса кызыктыру

**Әвәсләндерә бару** Торган саен ныграк әвәсләндерү

**Әвәсләндерә башлау** Әвәсләндерергә керешү

**Әвәсләндерә төшү** Бераз әвәсләндерү

**Әвәсләндереп алу** Берара, кыска вакытлы әвәсләндерү

**Әвәсләндереп бетерү** Тәмам, бөтенләй әвәсләндерү

**Әвәсләндереп җибәрү** Әвәсләнергә этәргеч бирү, кинәт әвәсләндерү

**ӘВӘСЛӘНҮ** *ф.* Нәрсә белән булса да мавыгу, нәрсәгә дә булса кызыксыну уяну. *Аның белән танышкач, үзем дә рәсем ясарга әвәсләндем.* Идел

**Әвәсләнә бару** Торган саен ныграк әвәсләнү

**Әвәсләнә башлау** Әвәсләнергә керешү

**Әвәсләнә төшү** Бераз әвәсләнү

**Әвәсләнеп алу** Берара, кыска вакытлы әвәсләнү

**Әвәсләнеп китү** Нинди дә булса вакыттан яки сәбәптән соң әвәсләнә башлау

**ӘВӘСЛЕ** *рәв. сөйл. к.* **әвәс**. *Гөлшаян бәйләргә әвәсле булды*

**ӘВӘСЛЕК** *и. сөйл.* Нинди дә булса һөнәргә, эшкә оста булу; шул эшне, һөнәрне бик ярату, шуның белән нык мавыгу. *Әйбер җыярга әвәслек юк иде безнең.* Э.Шәрифуллина

**ӘВЕН** *и.* 1) Көлтәләрне киптерү һәм сугу өчен төзелгән корылма. *Ләкин, явым башланганда, колхозның арыш көлтәләре әвенгә ташып куелган иде инде.* М.Әмирханов. *Әвенне бер кат әйләнеп чыга, мич алларын тикшерә.* М.Мәһдиев. *Әвен ишегеннән кереп, һичбер шөбһәсез-нисез, сукыр лампасын кабызып җибәрде.* Я.Зәнкиев. *Йосыф карт әвененнән, бөтерелеп, төтен чыга иде.* М.Галәү

2) Шул корылмага киптерү өчен бер тапкыр түшәлгән көлтәләр саны; әвенлек (*2 мәгъ.*). *Бер әвеннән утыз пот чамасы арыш чыга...* М.Мәһдиев

◊ **Әвен базарына китү** Йокыга талу; *чаг.* **нәвем базарына китү**. --- *йомшак һәм шаукымлы да иде ул юрган... Астына чумып, күзеңне йомдыңмы – әвен базарына китеп тә бардың диген сүз.* А.Хәлим. *Әвен базарына киткәндә, кеше күпмедер вакыт уяулык белән йокы арасында була.* М.Кәбиров. **Әвенә ут кабу** Берәр нәрсә артыннан бик каты чабып йөрүче кешегә карата әйтелә. **Әвене янган адәм (кеше) кебек (төсле, шикелле)** Нәрсәгә дә булса бик нык борчылып, кайгырып йөргән кеше турында. – *Нәрсә син, әвене янган адәм кебек торасың? – диде Кәшифә.* Г.Ахунов. **Әвене яну** Нинди дә булса борчу килү, бәлагә тару. **Әвен кебек** Бик зур, таза гәүдәле. *Авылда иген кырларында эшләп чыныккан әвен кебек иратның исәнлегеннән зарлануы, ничектер, күңелгә шом сала иде.* М.Макаров

**ӘВЕ́Н БАЗЫ** *и. тар.* Көлтәләр киптерү өчен, ягып җылытыла торган, тирә-ягы гадәттә ташлар белән нygытылган баз. *Кендекләр, камытлар – мунча башында... Тәгәрмәчләр – әвен базында.* Г.Ибраһимов. --- *сугыштан соңгы елларда ашлыкны әвен базларында киптерәләр иде.* С.Зыялы

**ӘВЕ́Н КУЮ** *ф. тар.* Көлтәләрне әвенгә өю. *Ындыр табагын, әвен куюны – --- беренче тапкыр күрде егет.* М.Хуҗин

**ӘВЕНЛЕК** *и.* 1) Кырдагы ашлыкны урып бетергәннән соң сугу, аңа кадәр көлтәдәге ашлыкны яңгыр яки кардан саклау өчен, ындыр табагындагы өсте ябулы лапас. *Тукта әле, бу каракучкыл нәмәрсә, серле шәүлә, ферма, әвенлек тирәсенә килгән бүре-мазар, эт-кош булып чыкса?* В.Нуриев

2) Әвенгә бер тапкыр түшәлгән биш меңгә якын көлтә

3) *иск.* Элекке вакытта бөртекләләрне, сабакта чакта ук, якынча чама белән үлчәү берәмлеге

**ӘВЕ́Н СУГУ** *ф.* 1) *тар.* Әвендә киптерелгән ашлыкны сугу. – *Син әвен сугарга чыкмадыңмыни? – диде дә, озын гына иттереп, кызын сөзде.* Г.Исхакый. *Егет гомере байларга әвен сугып, машина әйләндереп, кышын урманнан утын ташып үтте.* Г.Бәширов

2) *күч.* Кыйнау, суккалау. *Икенче көнне Нурислам хаҗи минем тетмәмне тетте: кичә фәсемне сугып яньчегән чыбык сынып беткәнче, аркамда әвен сукты.* Г.Гобәй

◊ **Әвен сугып кайту (килү)** Бик нык ару, алҗу һәм ачыгу. *Сәхипҗамал күрше, син безне әллә әвен сугып килде дип белдеңме?* А.Әхмәт. **Әвен суккан кеше кебек (төсле, шикелле)** Бик нык арыган, алҗыган. *Сорур чынлап сөешергә өлгерә алмады, ул өч көн бербуйдан әвен суккан кеше кеби йокыга китте.* Г.Исхакый

**ӘВЕРӘТҮ** *ф. сөйл.* 1) Кемнең дә булса башын әйләндереп бетерү, тинтерәтү, әвәрә китерү

2) Кемне дә булса үзенә карату, җәлеп итү

**Әверәтеп бетерү** Тәмам, бик нык әверәтү

**ӘВЕРЕЛДЕРҮ** *ф.* Бер хәлдән икенче хәлгә әйләндерү, нәрсәне дә булса үзгәртү, аңа бөтенләй үзгә төс бирү. *--- колхозны шәхси хуҗалыкларга хезмәт күрсәтүче оешмага гына әверелдерергә туры киләчәк, диделәр.* Ф.Садриев. *Арадагы ераклык вә салкынлык боздай эреп юкка чыксын, безне бурадәрләргә әверелдерсен иде.* В.Имамов. *Авыл, әти-әниләребезне әби-бабайларга әверелдереп, үзе дә картайган инде.* Казан утлары

**Әверелдерә бару** 1) Акрынлап, азазлап әверелдерү. *[Гөлзиләне] --- максатын, мәхәббәтен, күңел сафлыгын онытырга мәҗбүр итте, аны, исертеп, мескен бер колга әверелдерә барды.* М.Кәбиров

2) Бер-бер артлы әверелдерү. *--- Әбүгалисина аларның кайсын – шакалга, кайсын – филгә, кайсын башка хайванга әверелдерә бара.* К.Насыйри

**Әверелдереп бетерү** 1) Бөтенләй, тулысынча әверелдерү. *Өй хозяйкасына әверелдереп бетердең бит инде хатыныңны.* М.Хәбибуллин. *Университетны --- полиция оясына әверелдереп бетерделәр.* Г.Әпсәләмов

2) Барысын да әверелдерү. *Ул бөтен авыл халкын үзенең колына әверелдереп бетерә язган.* Ф.Яруллин

**Әверелдереп җиткерү** Нәрсәне дә булса билгеле бер хәлгә җиткереп әверелдерү

**Әверелдереп калдыру** Башка әйбергә, күренешкә, хәлгә әверелдереп, шул торышны саклау. *Сөйләүчеләребез эстрада сәхнәсен гел кәмиткә, гел арзан шаяруга гына әверелдереп калдырмагайлары, дигән шөбһә бар.* Р.Батулла

**Әверелдереп кую** Кинәт әверелдереп, шул хәлдә калдыру. *Серле чишмә суы әбине матур кызга әверелдереп куйды*

**Әверелдереп ташлау** Кинәт кенә әверелдерү. *Ә инде Явыз Иван җиребезне канга батырып, тамырларыбызга балта чабып, ханлыгыбызны тоташ ГУЛАГ лагерьларына әверелдереп ташлагач, Сталин безнең кан кардәшләребезне Кырымнан кугач, без, гомумән, тукталып, тыныч кына яшәүдән мәхрүм калдык.* Р.Вәлиев

**Әверелдереп тору** Һәрвакыт, даими әверелдерү. *Ташландык җирләрне гөлбакчага әверелдереп тору*

**ӘВЕРЕЛЕШ** *и.* Икенче шәкел, рәвеш, төс алу, икенче төрлегә әйләнү күренеше. *Актёрның сәхнәдәге әверелеше.* Р.Батулла. *Сәхнәдә әверелеш даһие мин.* Р.Батулла. *Эш, энергия, җылылык зурлыкларын, аларның үзара әверелешләрен --- өйрәнүче фән «термодинамика» дип атала.* Физика

**ӘВЕРЕЛҮ** *ф.* 1) Бер кыяфәттән, рәвештән, әхвәлдән чыгып, икенче бер кыяфәткә, рәвешкә керү; бөтенләй икенче шәкел, икенче төс алу. *Тау-тау ак болытлар, куерып, салынкы каракучкыл яңгыр болытларына әверелделәр.* М.Галәү. *Врачлар, аллергия диделәр, салкыннан бик нык саклагыз, астмага әверелә күрмәсен, диделәр.* Ф.Садриев. *Әйтерсең ул [Мансур] тораташка әверелгән иде, әйтерсең ул төш күрә иде.* Г.Әпсәләмов. *--- Әверелә кура курайга...* Зөлфәт

2) Икенче бер сыйфатка күчү, башкача эчтәлек алу. *Эш акча мәсьәләсенә килеп терәлсә, аны сүзе законга әверелә безнең өйдә.* К.Кәримов. *Спектакльнең ахырына алар арасындагы бердәмлек хисе куәтле революцион омтылышка әверелә.* М.Арсланов. *Шагыйрьләр дуслыгы әдәбиятлар дуслыгына, халыклар дуслыгына әверелә.* Р.Миңнуллин

3) *миф.* Тылсым, сихри көч ярдәмендә, бер әйбердән икенче бер әйбергә яки җан иясенә әйләнү; кыяфәтен, сыйфатын үзгәртү. *Кыз егетне куа, егет, кыз килгәнен сизеп, биек тауга әверелә.* Әкият. *Күгәрченнәр, кайтып керәләр дә, бик чибәр өч егеткә әвереләләр.* Әкият. *Икәвесе дә адәм сурәтендәге кара таш булып әверелделәр.* Мирас

**Әверелә бару** Акрынлап, аз-азлап, көннән-көн арта төшеп әверелү. *Гөлзадә аның бөтен уен били торган тормыш мәгънәсенә әверелә барды.* Ф.Садриев. *Проза шигырь кебек оператив төргә әверелә бара.* Ф.Галимуллин

**Әверелә башлау** Әверелгәне сизелү. *--- аның сүнәр-сүнмәс кенә җемелдәгән өмете ышаныч булып әверелә башлады.* Г.Әпсәләмов

**Әверелә килү** Эзлекле рәвештә һәрберсе, булган берсе бертуктаусыз әверелү. *Антымны боздырырга җыенган һәр адәм дошманыма әверелә килде.* Ә.Баян

**Әверелә төшү** Бераз әверелү

**Әверелеп бару** Эзлекле рәвештә әверелүе акрынлап арту. – *Шыксыз үрдәк бәпкәсе аккошка әверелеп бара түгелме? – диде ул Ләйсәнгә...* Ф.Яруллин. *--- элек бу – элита дине булса, хәзер гавамныкына әверелеп бара.* Р.Сафин

**Әверелеп бетү** Тәмам, тулысынча, ахырына кадәр әверелү. *Тик бу кытыршылыклар озакка сузылмый, ялының азагында Рәмзи чыкылдаган авыл кешесенә тагы әверелеп бетә иде.* А.Расих. *Котырыгы басылганчы гына да җитмеш җидегә әверелеп бетә.* Б.Камалов. *Ниһаять, деформация юкка чыга, һәм потенциаль энергия тулысынча кинетик энергиягә әверелеп бетә.* Физика

**Әверелеп җитү** Тиешле дәрәҗәгә җитешеп әверелү. *Шул ук вакытта*

*алар [татар мохитеннән читтә туып-үскән кешеләр] чын руска, казахка яки үзбәккә дә әверелеп җитмиләр кебек*. Ә.Еники

**Әверелеп калу** Нинди дә булса сәбәп белән яки вакыйгадан соң, нәрсәгә булса да әверелү һәм шул торышын саклау. *[Дәвис] --- минем «Жигули»ның яныннан гына узып, Насыйриның «УАЗ»ына барып сыланды. Болай да кечкенә «Ока»сы бөтенләй дә коймакка әверелеп калды*. Ф.Яхин

**Әверелеп килү** 1) Үзенең чигенә, соңгы дәрәҗәсенә җитеп әверелү. *Суның бозга әверелеп килүе*

2) Акрынлап әверелү, әверелеше күренә, сизелә башлау. *--- үткән чорларны каралтып күрсәтү белән мавыгу, «шул чор хәлләрен» бүгенгедән чыгып каһәрләү прозабызның төп тенденцияләренең берсенә әверелеп килә*. Ә.Закирҗанов. *Хәтер көнен үткәрү халкыбызның көчле, гыйбрәтле традициясенә әверелеп килә*. Р.Вәлиев

**Әверелеп китү** 1) Көндәлек, еш кабатлана торган күренешкә (эшкә) әверелү, гадәтигә әйләнү. *Аның өстенә, һәркемнең дип әйтерлек, баласы, атасы, ире яки берәр кардәше, берсе артыннан берсе алынып, китеп торганга күрә, аерылулар, озатулар гади эшкә әверелеп китте.* М.Гафури

2) Көтмәгәндә, кинәт әверелү. *Шул мәлдә бака кызга әверелеп китте.* Әкият. *Аның, тиз арада бөтен татар-төрки дөньясына таралып, миллионлаган йөрәкләрне җилкендерерлек канатлы җырга әверелеп китүе һич очраклы түгел.* Р.Рахмани

**Әверелеп тору** Даими рәвештә, әледән-әле әверелү. *Сыеклыкның элементар күләменең хәрәкәте вакытында, бу күләмнең тулы энергиясе үзгәрешсез калса да, аның энергиясе, бертуктаусыз, бер формадан икенче формага әверелеп тора.* Физика

**Әверелеп яту** Билгеле бер вакытта нәрсәгә дә булса әверелү

**ӘВЕРНӘ** *и.* 1) Бер-берсенә аркылы куеп тоташтырылган, ныгытылган нечкә ике борыстан гыйбарәт әсбап (туку эшендә). *Ә хатын-кызлар --- машинаның --- тәгәрмәчләре, әвернәләре кебек, ашыга-ашыга хәрәкәтләнәләр.* Ф.Садриев

2) Киләпле җепне йомгакка урaганда кулланыла торган, аркылы ике такта әйләнерлек итеп урнаштырып эшләнгән җайланма; *русчасы:* **вороб.** *Әбиемнән калган әвернә*

3) *тех.* Уру машиналарының, комбайнның, үлән яки иген сабакларын бөгеп, кискеч аппаратка тапшыра, кискәндә, аларны тотып тора һәм тагын да эчкәрәк этәрә торган детале; *русчасы:* **мотовило**. *Ургычның әвернәсе урыла торган культураның сабакларын кисү аппаратына тапшыру һәм киселгәннәрен ургычның шнегына бирү өчен хезмәт итә.* Урып җыю машиналары

4) Гомумән кушу билгесе (тәре) рәвешендәге әйбер. *Рама әвернәсе*

**ӘВЕРНӘ́ АГАЧЫ** *и.* Киләпле җеп урнаштырыла торган әвернәнең төбе, аяклары

**ӘВЕРНӘ́ КАШЫГЫ** *и.* Әвернә такталарының башларына җепне тотар өчен кертеп куелган агачлар

**ӘВЕРНӘЛЕ** *с.* Әвернәгә охшаган яки әвернәсе булган. *--- бу участокны, әйләнеп йөрү ысулы белән хәрәкәтләнеп, эксцентрик әвернәле ургыч белән чабып алырга мөмкин.* П.Макаров

**ӘВЕРНӘЛЕ́ КАТКЫЧ** *и.* Орчыксыман таякчыкка кидерелгән аркылы ике юка планкадан гыйбарәт булган җеп кату җайланмасы. *Әбиемнең әвернәле каткычы бар иде*

**ӘВЕРНӘЛЕ́ КОҢГЫЗ** *и. зоол.* Сары төстәге канат өслекләрендә әвернә сыман сурәте булган, бөртекле ашлыкларга зарар китерә торган бөҗәк; *русчасы:* **жук-крестовик**

**ӘВЕРНӘЛЕ́ ҮРМӘКҮЧ** *и. зоол.* Түгәрәк пәрәвез үрүче үрмәкүчләр семьялыгыннан, аркасындагы ак төрткеләре әвернәне хәтерләткән бизәкле, агулы зур үрмәкүч; *русчасы:* **крестовик, паук-крестовик.** *--- кайбер әвернәле үрмәкүч төрләре ау ятьмәләренең зурлыгы һәм төзелеше белән аерылып торалар.* А.Халидов. *Әвернәле үрмәкүч, иртүк, пәрәвез уртасына чыгып утырса, көн әйбәт булачак.* Сынамыш

**ӘВЕРНӘ́ СӨЯГЕ** *и. анат.* Кеше гәүдәсенең умыртка баганасына береп үскән һәм оча сөягенә килеп тоташкан биш умырткадан гыйбарәт иң түбәнге өлеше; сигезкүз сөяге, оча башы сөяге; *русчасы:* **крестец**. *Әвернә сөяге авырту*

**ӘВЕРНӘ́ ТАКТАСЫ** *и.* Әвернә агачының өстенә аркылы кидереп куелган ике такта, әвернә канатлары. *Сылу карчык, өйалдыннан әвернә тактасы алып кереп, идән уртасындарак киләпне сүтеп чолгарга утырды.* М.Галәү

**ӘВЕРНӘ́ УТЫ** *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, шәрә яки төкчәле сабаклы, төрле төстәге чәчәкле үсемлекләр төреннән бер үлән; *русчасы:* **крестовник**. *Республиканың Кама һәм Идел алды төбәкләрендә йорт янарында, юл буйларында, бакчаларда, чүп үләне буларак, гади әвернә уты киң таралган.* Ботаника

**ӘВЕРНӘ́ ЧӘЧӘКЛЕЛӘР** *и. бот.* Ике орлык өлешле, бер-берсенә аркылы урнашкан дүрт таҗ яфракчыклы чәчәге булган үсемлекләрнең семьялык атамасы; *русчасы:* **крестоцветные.** *Әвернә чәчәклеләр төрле яшәү шартларына җайлашырга сәләтле.* Ботаника

**ӘВЕРҮ** *ф. сөйл.* 1) *к.* **әвереледерү.** *Мин ничек шул, дине өчен гомере буе күргән җәзаларына шатлана торган анамны, дине өчен корбан булган атамны ташлап, шул, чиркәүне – кибеткә, гыйбадәтне сату-алуга әвергән батюшкага угыл булыйм?* Г.Исхакый. *Суны парга әверү*

2) Нәрсәне дә булса икенчегә бору, юрау (мәс., сүзне). *Син сөйлисең хаклыкны, ә кешеләр аны дошманлыкка әверә.* Ш.Камал

3) Кемне дә булса берәр явыз ният белән урап алу яки аны җыйнаулашып кыйнау. *Милиция егетләре аны дүртәүләп-бишәүләп әвереп кенә җиңәләр.* А.Хәсәнов

4) Нәрсәне дә булса куллар белән кочакка алу

**Әвереп алу** Кинәт әверү. *Бердән Шәфыйк бабай өстенә ташландылар. Тиз генә аны әвереп алдылар.* М.Гали. *[Тимри] Дәү кочагына берьюлы ярты чүмәләне әвереп алып эчкә йөгерде.* Г.Бәширов

**ӘВЕС** *и. к.* **әвеслек**

**ӘВЕСЛЕК** *и.* Кояштан, җилдән яки явым-төшемнән саклау өчен, баганалар өстенә түбә ябылган корылма; төз лапас. *Нигә юк соң бу ипи, әнә бит басу-кырлар, әнә бит әвеслек янында салам эскертләре, алардан бит инде ипи чыккандыр?* М.Мәһдиев. --- *күтәрмә әвеслек эченнән резин көпчәкле, хромланган ике күчәрле җиңел арба тартып чыгарды.* Р.Мирхәйдәров. --- *түрдәге әвеслектә сөт бидоннары тезелеп тора.* Т.Әйди

**ӘВЕ́Ш-КЫЕШ КИТЕРҮ** *ф. к.* **әвеш-түеш китерү.** *Әллә ни артык эшләр булмаса да, тамагың тук булып, көннәрне әвеш-кыеш китерерлек булса, риза инде шунда, ---.* Г.Камал

**ӘВЕ́Ш-ТӘВЕШ ИТҮ** *ф. к.* **әвеш-түеш китерү**. *Мин белә башлаганда ул, имгәнгән-сугылган мал алып, мал суеп әвеш-тәвеш итә иде.* М.Кәрим

**ӘВЕ́Ш-ТӘВЕШ КИТЕРҮ** *ф. к.* **әвеш-түеш китерү.** *Пычрак мамыксыман йолкыш болытларны әвеш-тәвеш китереп, җил күкне арчый.* М.Госманов. *Нәрсәләрендер сатып, әвештәвеш китереп, бу ниятен тормышка да ашырды: бер пот мөнә дигән чын бодай оны сатып алды.* М.Әмир

**ӘВЕ́Ш-ТҮЕШ БАШКАРУ** *ф. к.* **әвеш-түеш китерү** (*2 мәгъ.*). *Эшен, әвеш-түеш кенә түгел, уйлап, җиренә җиткереп башкара ул.* Ә.Салах

**ӘВЕ́Ш-ТҮЕШ ИТҮ** *ф. к.* **әвеш-түеш китерү**

**ӘВЕ́Ш-ТҮЕШ КИТЕРҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса теләсә ничек болгату, аркылы-торкылы урнаштыру. --- *ата кеше учактагы утыннарны әвеш-түеш китерде.* Н.Фәттах. *[Кош] Башта бу төзү нәрсәсенә куе селәгәен сеңдерде, аннары, аны әвеш-түеш китергәч, томшыгы белән баскаларга кереште.* Г.Хәсәнов

2) Аннан-моннан, җиренә җиткерми, тиз-тиз генә эшләп кую, оештыру; әтмәлләү. *Җырның сүзләре шундый котсыз, мәгънәсез бер такмаза булса, «көй» дигәне дә төрле халык көйләрен әвеш-түеш китереп укмаштырган зәвыксыз бер тугылама иде.* Г.Бәширов

3) Фактларны бутау, чынбарлыкны бозып күрсәтү. *Фәсхетдин абзый бөтенесен әвеш-түеш китереп, бозып күрсәткән!* Г.Бәширов

4) Сату-алу белән эш итү, алып сату белән шөгыльләнү

5) Нәрсәне дә булса бер урыннан икенче урынга кат-кат күчереп йөртү; тегеләй-болай китерү. *Йоклаучыларны уятмас өчен, ул, мөмкин кадәр саграк кыланырга тырышып, буш караватөстендәге үз әйберләрен әвеш-түеш китерде...* Н.Фәттах. *Директор исә берни әйтмәде – башын иештереп, өстәлдәге аттестатларны әвеш-түеш китергән булды.* Н.Фәттах

6) Бер кулыннан икенче кулына күчерү. *Дәрҗия үзе сорап алмасмы икән, дип, Гайнан, мәкаләне кулында әвеш-түеш китереп, таптанып торды.* Г.Бәширов

7) Нәрсәне дә булса бер савыттан икенче савытка бушату. *Күз алдына, елмаеп, Гөлбиби килде, нидер вәгъдә итеп, аңа күз кысты, көлде һәм, матур беләкләрен җитез хәрәкәтләндереп, табын янында нәрсәнедер әвеш-түеш китерде.* Н.Фәттах

8) Очын-очка чак ялгау, ничек тә үткәрү, тартып-сузып җиткерү; көнне көнгә авыштыру. --- *үзе дә озак еллар буенча шул якларда тегү тегеп йөргән, эше өзелеп торган арада, тегесен-монысын әвеш-түеш китергән.* Г.Бәширов

**ӘГӘР** *терк. фар.* **1.** 1) Реаль мөмкин булган шартны белдергән иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Әгәр дә кыз үзе риза булса, мин сезнең никахыгызга каршы түгел.* Н.Исәнбәт. *Әгәр Йосыф карт хасталабрак торса яки вакыты булмаса, ирләр хәленнән генә килердәй эшләрне Саҗидә эшли.* М.Галәү. *Әгәр дүшәмбе көн кайтып җитмәсә, тотарлар да башка берәүне кертерләр.* Г.Ибраһимов

2) *да/дә* кисәкчәсе белән килеп, теләк, уйланылган яки чынбарлыкка каршы булган шартны белдергән иярченле кушма җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Әгәр дә тагын, елап, ачуны китерсәгез, мәңге кайтмам.* Ф.Бурнаш. *Әгәр дә Әхмәтне бик осталык белән алдыйсыгыз килсә, бүген төнлә өенә барыгыз.* Д.Аппакова

3) Гадәттә *икән* модаль сүзе белән килеп, баш җөмләдән аңлашылган эшхәлнең сәбәбен яки нигезен тәшкил иткән шартны белдерә торган иярчен шарт җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Әгәр аларны кайгырталар икән, ул чагында бик хуп.* Г.Бәширов. *Әгәр сөйлисез икән, сөйләргә мөмкин.* А.Шамов

4) Гади җөмләдә бик көчле теләкне белдерү, көчәйтү өчен кулланыла. *Ах, әгәр булсачы Бер генә тамчы су!* М.Җәлил. *Әгәр Хәйдәр булса!* Г.Бәширов

5) Гади җөмләдә үкенү хисен белдерү өчен кулланыла. *Эх, әгәр шул чакта Акбүз белән мин булган булсам!* Г.Гобәй

6) Кисәтүне, шелтәне белдергән иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. – *Әгәр Рөстәмгә икенче тисәң, шушы таяк сынып беткәнче кыйнармын, – диде мыеклы абый.* А.Шамов. *Әгәр тагын шулай, эш эшләмичә, ялган хәбәр таратып йөргәнеңне күрсәм, мин сине ни эшләтергә белермен!* Р.Ишморат

7) Риторик сораулы хикәя җөмлә башында килеп, эш-хәрәкәтнең интенсивлыгын көчәйтә. *Әгәр «ул» ертылган булса? Штык аны да тишеп чыкса?!* Г.Бәширов. *Әгәр дә мин бу сорауларны аңа биреп карасам, ә?* Н.Исәнбәт. *Әгәр дә Хафиз бу көйне үзе ишетсә, бер дә урынында басып калмас иде.* Г.Камал

**2.** *кис. функ.* Каргаганда яки ант иткәндә, ант сүзе янында килеп, аның һичшиксез үтәләчәгенә басым ясау өчен кулланыла. *Билләһи менә әгәр мин ялганласам.* Ш.Камал. *Үз гомеремдә әгәр аны хур итмәсәм, исемем Шөҗаг булмасын.* Г.Камал

**ӘГӘ́Р ДӘ МӘГӘР** *кер. сүз* Төрле ихтималлыкны белдергәндә яисә фараз иткәндә әйтелә. *[Гайнулла:] Әгәр дә мәгәр, кызым, без әниең белән менә бүген – җомга көнне – «чәршәмбе, чәршәмбе» дип биесәк, син ни әйтер идең?* Т.Миңнуллин

**ӘГӘ́РЕНКИ** *терк. диал. к.* **әгәр.** *Әгәренки таш гасырда хат ташучылар йөрсә, бу хәтле хәбәрне җиткерер өчен Тянь-Шань тауларының ташы да җитмәс иде...* К.Кәримов. *Әгәренки колак салсаң, төннәрен ул яктан*

*«дөп-дөп» иткән фашист аяк тавышын ишетерсең.* Г.Бәширов. *Әгәренки рәсми властьларга үземне белдерсәм, үземне алар карамагына тапшырсам, беләсеңме, нинди хәлдә калачакмын мин?!* Р.Фәизов

**ӘГЕ́-ҖӨГЕ КИЛҮ** *ф. к.* **әҗе-гөҗе килү**

**ӘГЪВА** *и. гар.* **1.** Үзенә ияртеп аздыру, юлдан яздыру; кызыктырып котырту. *Дөресен әйтим, Мөхәммәт абзый, шәһәр җирендә яшь кешегә әгъва зур, күңел азындырырлык нәрсәләр күп.* Т.Мөбарәков

**2.** *с. мәгъ.* Үзенә ияртеп аздыра, юлдан яздыра торган, кызыктырып котырта торган. *Син мине Зифа белән мәңгегә дошманлаштыру өчен, шундый әгъва сүзләр уйлап чыгарасыңмы?* Н.Исәнбәт

**ӘГЪВА́ КЫЛУ** *ф. к.* **әгъвалау.** *Шайтан, килеп, әгъва кыйлды.* К.Насыйри

**ӘГЪВАЛАНУ** *ф.* 1) Кеше коткысына бирелү, ихтыярсыз булып, кемгәдер ияреп китү

2) Нәрсә белән булса да мавыгып китү, мәшәкатьләнү. *Янгураз, бер костюм, икешәр күлмәк, чалбар, бер пар туфлидән һәм ашамлыклардан тыш, берни дә алмады. Шуларны чемоданына тутырып, вак-төяк мәшәкатьләр белән әгъваланып, төн уртасын җиткерде.* Т.Әйди

**ӘГЪВАЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса ышандырып, кызыктырып котырту, үзенә карату. --- *урыс күңелен «итекләрен Һинд океаны суларында юарга» әгъвалый.* М.Әхмәтҗанов. *Адәм галәйһиссәламне әгъвалаган шайтан сине генә әгъвалый да әгъвалый инде ул...* Г.Гобәй. *Күңелне кытыклый торган күренеш, ирләрне ымсындыра торган гүзәллек иде бу. Нәрсә, Софи ханым Янгуразны шулай әгъваларга ниятләгәнме?* Т.Әйди

2) Кемне дә булса җайлау, көйләү; нәрсә белән дә булса ризалашырга мәҗбүр итү. *Ә син, әпсенләп-төпсенләп, әгъвалап, шул бюрократия туарлык ярык тишәсең.* А.Расих

**Әгъвалап йөрү** Кемне дә булса даими рәвештә әгъвалау. *Зиннәт Гомәрне үзе белән читкә китәргә әгъвалап йөри*

**Әгъвалап карау** Әгъваларга омтылу, әгъваларга тырышу. – *Әйдә, кырларны, су буйларын әйләнеп, саф һава сулап кайтыйкмы әллә? – дип әгъвалап карады.* В.Нуруллин

**Әгъвалап килү** Даими рәвештә, электән үк кемне дә булса әгъвалау. *Егетне әгъвалап килү*

**Әгъвалап тору** Әле, сөйләү моментында әгъвалау; озак вакыт әгъвалау. *Ул заманнарда озын-озак сөйләшеп, әгъвалап тормыйлар иде.* Г.Ахунов

**ӘГЪВАЧЫ** *и.* Әгъвалап котыртучы, әгъвалауның остасы

**ӘГЪЗА** *и. гар.* 1) Тере организмның билгеле бер функция үти торган өлеше; орган. *Боларның баш-күзләре бәсләнгән, һәммә әгъзалары дерелди.* Г.Ибраһимов. *Ул председательнең, ник болай, диюен аңлый алмады, курку-шикләнүдән, бөтен эчке әгъзалары суынып киткәндәй тоелды.* Ф.Садриев. *Чөнки кешенең бик әһәмиятле сизү, сиземләү әгъзаларының берсе – кул бармаклары – бу очракта бөтенләй эшкә катнашмый.* М.Насыйбуллин

2) Берәр җәмгыять, оешма, төркем составына кергән кеше; член. *Җәмгыятьнең калган өч әгъзасы килделәр.* Ф.Әмирхан. --- *ул һаман дерелдәде, бюро әгъзаларына аның саен кыен була башлады.* М.Мәһдиев. *Үткән якшәмбе көн, җәмгыятькә әгъзалар сайлау өчен, бер мәҗлес булган иде.* Ш.Мөхәммәдев

**ӘГЪЗАЛЫК** *и.* Әгъза (*2 мәгъ.*) булу. *Шәрәфи әгъзалык билетын күрсәткәч, ишек ике якка аерылды.* Г.Ибраһимов

**ӘГЪЛА** *с. гар. иск.* 1) Бик яхшы, затлы, кыйммәтле; бик матур; югары сыйфатлы. *Бик матур булмә, уртада – өстәл, аның тирәсендә – калфаклы урта яшьле бер хатын, өстенә бик әгъла һәм бик килешле халис ефәк җөббә кигән...* Ф.Әмирхан. *Күрәсең, Рамазан дус бик ярата үзеңне, күлмәкнең әгъласын алып биргән.* Г.Әпсәләмов. *Һәртөрле әгъла мехлар, камчат, камалар, якалык һәм бүреклек каракүлләр --- Казанда, Печән базарында мәсҗеткә каршы --- [урнашкан].* Г.Әпсәләмов

2) Югары, күркәм, сокландыргыч. --- *исерткеч йогынтысына бирелмәү, дәртне тышаулый алу – кешене шәхес итеп күтәрә торган әгъла сыйфат.* Т.Әйди

3) Бик тәмле, телеңне йотарлык, затлы. *Шурпада пешкән ит бик әгъла.* К.Насыйри. – *Минем мондый әгъла нигъмәтләрне күргәнем дә юк, – диде агай, исе китеп.* Г.Әпсәләмов. – *Минем мишәр пәрәмәчләрен ашаганым бар, бик әгъла.* Г.Әпсәләмов

4) Әйбәт, яхшы. *Май аеның иң әгъла, җылы көннәренең берендә хәзрәт мәсҗедтән --- чыгып килә иде.* Г.Камал. *Бүлмәмдә аннан калган әгъла хуш исе акрын гына --- тойгыларымны рәхәтләндерә.* Г.Ибраһимов

**ӘДА́ ИТҮ** *ф. гар.-тат. иск.* 1) Нинди дә булса эшне башкару, үтәү. *Шәкерт биш вакыт намазны мәсҗиддә әда итәр.* Ф.Әмирхан

2) Бурычны түләү. *Бәдри шул бурычны әда итеп, җиренә җиткерер өчен, иртән торгач, капчык тотып теләнергә чыгып китте.* М.Гафури

**ӘДА́ КЫЛУ** *ф. гар.-тат. иск. к.* **әда итү.** *Инша аллаһеррахман, акрынлык белән булса да, шәйхелисламлык вазифасын да әда кыларга иҗтиһат кылмакдамыз...* Н.Исәнбәт. *Вә хаҗны әда кыйлып кайткач, мәзкүр кешедән үзенең әманәт куйган алтыннарын барып сорады.* К.Насыйри

**ӘДАТ** *и. гар. иск.* Грамматикада кисәкчәләр, кушымчалар, ярдәмлекләр. *Хәрефләр тәбдил итеп, чит ләһҗәдән алма әдат.* Дәрдемәнд

**ӘДӘБИ** *с. гар.* 1) Матур әдәбиятка караган. *Күпчелек әдәбиятны укымый, аңа төкереп кенә карый, әдип сүзенең зарурлыгын тоймый, ул әдәби сүзгә бөтенләй мохтаҗ түгел!* А.Гыйләҗев. --- *әдәби әсәр – иң яклаучысыз җисем, җирдә үсеп утырган үлән кебек.* Х.Камалов

2) Матур әдәбият әсәрләрен язуга бәйләнешле. *Ул юл әдәби уңышка һәм дәрәҗәгә китерә.* Х.Камалов. *Г.Рәхимнең инкыйлабка кадәрге әдәби иҗатының тагын бер юнәлеше – әдәби тәнкыйть һәм әдәбият теориясе.* Мирас

3) Матур әдәбият әсәрләрен өйрәнүгә бәйләнешле. *Берникадәр әзерлекле һәм тәҗрибәле либреттистлар, тәр-*

*җемәче кадрларны тудыруда [студия] әдәби бүлегенең хезмәте бәхәссез зур булды.* М.Җәлил. --- *аларны моның өчен әдәби тәнкыйтьтә хөкем итәргә кирәк.* М.Мәһдиев

4) Матур әдәбият әсәрләрендә сурәтләнгән, матур әдәбиятка хас булган. --- *студент Галиуллин Лев Николаевичның мәшһүр романнарындагы графларны, бароннарны, сыйнфый ноктадан алмыйча, бары тик кеше, әдәби образ булу ягыннан алып сөйли...* И.Гази. --- *үзенчәлекле бер әдәби образга прототип була алыр иде Сабира абыстай.* М.Әмир

5) Гомум кабул ителгән язма тел нормаларына туры килә торган. *Татарстанның берничә районында эшләгән, ниһаять, республика башкаласына килеп төпләнгән кеше булса да, телен әдәби сөйләшкә көйли алмаган иде.* Б.Камалов. *Журналда басылып чыккан әсәрләрнең әдәби эшләнешләре төрлечә...* Казан утлары

6) Матур әдәбият әсәрләре туплап бирелгән. *Моңа әдәби журналларыбызның оештыру эшчәнлеге дә этәргеч ясый.* Ф.Галимуллин

7) Матур әдәбиятка багышланган. *Без аның белән әдәби җомгаларга йөрибез.* Р.Кәрами. --- *әдәби кичә һәм әдәби очрашуларның саны 150 дән артып китте.* В.Имамов. *...Бер әдәби кичә хәтеремдә нык уелып калган.* М.Госманов

◊ **Әдәби караклык** Икенче кешенең хезмәтен күчереп язып үзләштерү, үз исеменнән чыгару; плагиатлык. *Иҗатчы өчен әдәби караклыкта, плагиатлыкта гаепләү һәм шикләнүдән дә түбәнрәк мыскыллау юк...* М.Мирза

**ӘДӘБИЛӘШТЕРҮ** *ф.* Әдәби тел нормаларына яраклаштыру, әдәбигә әйләндерү. *Мәктәптә исә сүзләрне, әдәбиләштереп, кагыйдә буенча язарга кушалар иде.* М.Маликова

**ӘДӘБИЛӘШҮ** *ф.* Әдәби телгә кереп китү, әдәбигә әйләнү

**Әдәбиләшеп килү** Әдәбигә якынаю

**Әдәбиләшеп китү** Ниндидер вакыттан, сәбәптән соң әдәбигә әйләнү

**Әдәбиләшеп җитү** Тәмам әдәбигә әйләнү

**ӘДӘБИЛЕК** *и.* Әдәби булу, әдәби булу дәрәҗәсе. *Иң мөһиме, яхшылыкка, матурлыкка, аның гармониясенә омтылу бар. Чиста, саф әдәбилек тә күренеп тора.* Р.Сибат

**ӘДӘБИЯТ** *и. гар.* 1) Теге яки бу халыкның, чорның яки бөтен кешелекнең фәнни, әдәби, фәлсәфи һ.б. әсәрләренең барлык җыелмасы. *Шул уңай белән, ике-өч көн эчендә, үземдә булган бөтен әдәбиятны яңадан карап чыктым.* Г.Кутуй. --- *әдәбият тормышны көйләргә ярдәм итә.* Казан утлары

2) Әдәби образларны нәфис сүз, тел ярдәмендә барлыкка китерү белән аерылып торган сәнгатьнең язма төре. *Матур әдәбиятның ике төре --- арасында торган бу жанрның үзенә генә хас үзенчәлекләре бар.* А.Әхмәдуллин. *Әдәбият, фән, техника китапларын, тарих-политика журналларын һәрвакыт күздән кичереп бардым.* Г.Кутуй. *Матур әдәбият та билгеле бер уңышларга ирешә.* Татарстан

3) Матур әдәбият әсәрләре. *...Толстойлар, Пушкиннар, Тукайлар әдәбияты янында --- әлеге поэзия чепуха, дип йөрүчеләр, машина булып кыланучылар шушы үлгән, көйгән агачны хәтерләтәләр иде.* И.Гази

4) Нинди дә булса махсус тармак, тематика буенча тупланган яки нинди дә булса белем өлкәсенә багышланган басма әсәрләр җыелмасы. *Дөнья халыкларының календарь системасы буенча бай әдәбият бар.* М.Әхмәтҗанов. *Элегрәк атчылык буенча күпме әдәбият бар иде.* М.Мәһдиев. *Эш шунда ки, тарихи әдәбиятта ханлыкның оешу дәвере --- күп еллар дәвамында ясалма рәвештә буталып килде...* Р.Әмирхан. *Медицина әдәбиятында авыру кешеләрнең электромагнитик нурланышларны тавышлар рәвешендә ишетүе турында да мәгълүматлар бар.* Могҗизалар энциклопедиясе

5) Мәгариф системасында махсус предмет. *Ә беркөнне, әдәбияттан «дүртле» алгач, сөенеченнән күзләре яшьләнде.* Ф.Яруллин. *Югыйсә, бар шундый кызлар – йә була ул университетның әдәбият бүлегеннән, геологиядән, журналистикадан...* М.Мәһдиев. *Әдәбият укытуның дәрәҗәсен билгеләгәндә, класстан тыш әдәбиятның китапханәдә булу-булмавы --- буенча тикшерелә.* Казан утлары

**ӘДӘБИЯ́Т БЕЛЕМЕ** *и.* Матур әдәбиятны, аның килеп чыгышын, тарихын, әдәби иҗатның гомуми законнарын өйрәнә торган фән. *Әдәбият белеме буенча да шактый дәреслекләр иҗат ителә.* Р.Әмирхан

**ӘДӘБИЯТЧЫ** *и.* Әдәбият белгече. *Такташны Такташ итеп формалаштырган традицияләрне ачыклаганда --- әдәбиятчылар, педагоглар, иң элек, шагыйрьнең лирикасына мөрәҗәгать итәргә тиешләр.* Г.Гыйльманов. --- *әдипне бары тик киләчәк буын вәкилләре генә, анда да тар мохит вәкилләре, белгечләр, намусы саф кала алган әдәбиятчылар гына тулаем аңлый вә аңлата алачак.* А.Гыйләҗев. --- *Иван Алексеевич, шулай ук, Казанда танылган әдәбиятчы һәм китап сөюче була.* Мирас

**ӘДӘМ** *и. кит.* 1) *к.* **адәм**

2) Кеше, шәхес, зат. *Мине, «паспортсыз әдәм» дип, ятап белән Казанга озаттылар.* М.Галәү. *Ну, бар шундый әдәмнәр, кушканнан артык тырышалар, медаль алырга уйлыйлармы?* Г.Әпсәләмов

3) *к.* **әдәми зат**. *Мин Дию карчыгы булам, син әдәм баласы икән.* Әкият

**ӘДӘМИ́ ЗАТ** *и. кит.* 1) Әдәм баласы, кеше заты (дию, җен, пәриләргә каршы мәгънәдә). *– Әй, әдәми зат, монда нишләп йөрисең, сине бит Дию ашар, – ди.* Әкият

2) Кеше, бер-бер кеше, нинди дә булса кеше. *Хәзер без бер пәмиччик корсагын гына калынайтучы әдәми зат түгелбез.* С.Поварисов

**ӘДӘМЛЕК** *и. иск.* Кеше булу; кешелеклелек. *Яманнарның эшедер кинә тотмак, Әдәмлек шул – яманлыкны онытмак.* Н.Исәнбәт

**ӘДӘ́МЧӘ** *рәв.* 1) Башка кешеләр кебек үк, кешечә; яхшы гына, тәртипле итеп. *Әдәмчә яшәү*

2) Кеше телендә, кеше кебек; кешегә аңлаешлы итеп. *Әй, егет, йомышыңны әдәмчә генә аңлат әле.* А.Гыйләҗев

**ӘДӘП** *и. гар.* 1) Җәмгыятьтә гомум кабул ителгән әхлак кагыйдәләре; яхшы

гадәтләр. *Янгураз, әдәп йөзеннән генә, юлдашын керергә чакырса да, Софи ханым капка төбеннән үк кире борылды.* Т.Әйди. *Яратыр өчен, бәхетле булып торыр өчен, Нәҗиптә бөтен сыйфатлар бар: акыл, әдәп, тәрбия...* Ә.Еники // Кеше арасында үз-үзеңне әхлак кагыйдәләренә туры китереп тота белү сыйфаты. *Алдагы тост – түрдә әдәп белән генә утырган, пенсиягә чыкмыйча җәмгыятьне иза чиктергән бер кафедра мөдире исәнлеге өчен.* М.Мәһдиев. *Ләкин хатын-кыз кызыксынуы иң гади әдәпне дә оныттыра икән кайчакта.* Г.Әпсәләмов

2) Яхшы гадәт, йола. *«Агачлыкка илтеп куйдык», – дип тә сөйлиләр. Агачлык – зират, әдәп белән генә, сак кына әйтәләр.* М.Мәһдиев

◊ **Әдәп йөзеннән** Йола һәм әдәп, әхлак кагыйдәләре кушканча. --- *ни өчен ул көн-төн бергә эшләгән өлкән иптәшенә яңа өйләнешкән хатынын, әдәп йөзеннән генә булса да, күрсәтергә теләми?* Ә.Еники. **Әдәп качу** Тупаслану, тәрбиясез кешегә әйләнү, кешеләрне үзеңнән биздерә башлау һәм шуңа күнегү. *Бу кешенең бөтенләй әдәбе качкан икән.* **Әдәпкә килү** Әдәплегә әйләнү, тыйнаклану, инсафлану, тәртипләнү. **Әдәпкә сыймау** Гомум кабул ителгән әдәп-әхлак кагыйдәләренә туры килмәү. *Университет ректоры Кремлёв әфәнде икеләнә, фән йортына полиция кертү – әдәпкә сыймый, ямanатыбыз бөтен Россиягә таралыр, ди.* Г.Әпсәләмов. **Әдәпкә утыру** *к.* **әдәпкә килү.** *Шундый вакытларда аңа әдәпкә утырырга кирәк иде.* **Әдәп киртәсенә сыю** Әдәп-тәртип кагыйдәләренә каршы килерлек гамәлләр кылмау; эшләгән эше, кыланмышы, сөйләгән сүзе белән әдәп нормаларыннан чыкмау, шуларга туры килү. **Әдәп саклау** Үзеңне гомум кабул ителгән әдәп-әхлак нормалары кысасында тота белү, тәртипле булу, этикет саклау. *Хатыннар узганда, егетләр дә әдәп саклый беләләр иде.* А.Шамов. *Васфикамал әдәп саклап кына сөйләште.* М.Мәһдиев. *Әнә, кешенеке дип, әдәп сакламыйлар, җае туры килү белән «кармак»ка эләктерәләр!* Н.Гыйматдинова

**ӘДӘПЛЕ** *с.* **1.** 1) Җәмгыятьтә үзен яхшы тота белә торган; инсафлы, тыйнак, тәртипле, тотнаклы; әдәп нормаларын саклый торган. *Әйе, башта шуны әйтергә кирәк, иптәш Андреев бик әдәпле һәм ипле кеше булып чыкты.* Ә.Еники. *Нинди әдәпле малай син!* Д.Аппакова. *Бу кадәр дә әдәпле, эшлекле гаилә булыр икән...* М.Мәһдиев

2) Итагатьле; ихтирамлы, инсафлы. *Ничектер, бик әдәпле телдә, бик китапча итеп, җинаятьче турында нидер сорый.* М.Әмир

**2.** *рәв. мәгъ.* Тәртипле, тыйнак, яхшы гадәтле булып. *Ул башта бик әдәпле күренде.* М.Насыйбуллин. *Егет кеше үзе яратып җиткермәгән хатынкызга карата да егетләрчә әдәпле булырга тиеш.* Р.Мингалим. --- *аны [баланы] саф күңелле, әдәпле, итагатьле, миһербанлы, белемле итеп тәрбияләячәк.* Ф.Садриев

**ӘДӘПЛЕЛӘНҮ** *ф.* Әдәпле булып китү, әдәплегә әйләнү, инсафлылану, тыйнаклану. *Күренеп тора, малай басынкыланган, әдәпләнгән*

**Әдәпләнә бару** Акрынлап, аз-азлап әдәплелеге арту, әдәпләнү юлына басу

**Әдәпләнә башлау** Әдәплегә әйләнергә омтылу, әдәплегә үзгәрүе сизелү

**Әдәпләнә төшү** Бераз әдәпләнү. *Ачулы командир, зур хәзинә табу шатлыгыннан, хәтта юашланып китә, әдәпләнә төшә.* С.Сабиров

**Әдәпләнеп китү** Кинәт, нинди-дер хәлдән, вакыттан соң әдәпләнү, соңгы вакытта әдәплегә әйләнү

**ӘДӘПЛЕЛЕК** *и.* Әдәпле булу. *Каян бу кадәр тәкәббер корылык, салкын әдәплелек, бәхәссез өстенлек аңарда?* Ә.Еники. *Кешеләре --- дорфа, башларында – җиңел акыллылык; нәфислек һәм әдәплелек юк, матур мәчетләр юк.* Җ.Ильясов. *Ислам дине хуплаган игелекле-изге сыйфатлар: --- тәрбиялелек, әдәплелек, дуслык-иптәшлек...* Ә.Борһанов

**ӘДӘПСЕЗ** *с.* **1.** 1) Кеше арасында үзен тота белми торган, тәрбиясез, тыйнаксыз; әдәп нормаларын санламый торган. *Алтын йөзек өчен ялланып китеп, тагы зуррак бүләккә кызыктыңмы, әдәпсез малай?* М.Фәйзи. *Пешкәкләнмичә генә аша әле, өстәл артында болай пешкәкләнү килешми, әдәпсез малай, дип әйтерләр...* Г.Әпсәләмов

2) Начар, әшәке. *Иң ахырда, ул яшь хатынга бер-ике әдәпсез сүз әйтеп авызын каплады да тышка чыгып китте.* Н.Фәттах. --- *ярым шыпырт сөйләнә торган әдәпсез сүзләрен ишетмәс өчен, юрган эченә томаланып --- йоклап китте.* Ә.Фәйзи

**2.** *и. мәгъ.* Әдәп-әхлак кагыйдәләрен сакламаган, тәрбиясез, тыйнаксыз кеше. *Бигрәк әдәпсезләре сызгырып калалар.* М.Гафури. *Алар да [кошлар да] юньлеләргә, юньсезләргә, тәртиплеәдәплеләргә һәм әдәпсезләргә бүленеп яши икән.* М.Мәһдиев

**ӘДӘПСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Үзеңне әдәпсез тоту, әдәп-әхлак кагыйдәләрен бозу, тәрбиясезләнү, тыйнаксызлану, тәртипсез кылану; әдәпсезгә әйләнү. *Көнбагыш ярганны яки сагыз чәйнәгәнне күрсә [Сәхәү карт]: «Әдәпсезләнеп, авыз күтәреп, урамда ашап йөрмәгез», – дип, колакны тартып киткән чаклары да еш була иде.* М.Әмир. *Кешеләр әдәпсезләнә. Бер-берсен ашый. Ерткычлана. Ай белән Чулпанның йөзе бүген шуңа кайгылы булгандыр.* С.Поварисов

**Әдәпсезләнә бару** Көннән-көн ныграк әдәпсезләнү, акрынлап, әдәпсезлеге арту

**Әдәпсезләнә төшү** Тагы да әдәпсезләнү; бераз әдәпсезләнә бару

**Әдәпсезләнеп бетү** Бөтенләй, тәмам әдәпсезләнү

**Әдәпсезләнеп йөрү** Озак вакытлардан бирле әдәпсезлек күрсәтү. *Үзе болай әдәпсезләнеп йөрми йөрүен, үзенчә сөйләшеп кенә йөри.* Ф.Бәйрамова

**Әдәпсезләнеп карау** Әдәпсез булып кылану. *Ә минем әдәпсезләнеп карыйсым килә.* Ф.Яруллин

**Әдәпсезләнеп китү** Кинәт әдәпсезгә әйләнү

**Әдәпсезләнеп тору** Әле, хәзер, күз алдында әдәпсезлек күрсәтү. *[Хәмидә:] Син дә, Габдуллаҗан, олы кешеләр алдында алай әдәпсезләнеп торма.* Г.Камал

**ӘДӘПСЕЗЛЕК** *и.* 1) Әдәпсез булу. *Түкәл белән Саттай, «бу нинди әдәпсезлек?» дигән сыман, усал гына итеп, Чура ягына карап алдылар.* Н.Фәттах. *Әле син әдәпсезлек белән дә дус икәнсең.* Д.Аппакова. *– Хәзер, – диде, авыр сулый-сулый, – әдәпсезлегем өчен яңагыма сук.* Г.Әпсәләмов

2) Тотнаксызлык, тәрбиясезлек, әдәп кагыйдәләренә сыймый торган эш. *Кияү мулладан элек чәй эчү әдәпсезлек булса да, Мәрфуга абыстай чәйсез түзә алмады.* Г.Исхакый. *--- ә бездә, үзең беләсең, төпченү-сораштыру әдәпсезлек санала...* Р.Мирхәйдәров

**ӘДЕП** *и. фар.* Итәк яки җиң очына, ертылмасын, сизрәмәсен өчен яки бөкләргә үз ише җитмәгәндә, беркетеп тегелә торган тар гына тукыма. *Күлмәк җиңенә әдеп тегү*

**ӘДЕ́П КАЮ** *ф. к.* **әдепләү.** *Киемгә әдеп каю*

**ӘДЕПЛӘ́Ү** *ф.* Итәк яки җиң очына әдеп тегү. *Күлмәкнең итәген әдепләү*

**Әдепләп бетерү** Нәрсәне дә булса тулысынча әдепләү, барысын да әдепләү. *Итәк очын әдепләп бетерү*

**Әдепләп кую** Алдан ук әдепләү, әдепләнгән, әзер хәлгә китерү

**Әдепләп чыгу** Бөтен тирәсен, башыннан-ахырына кадәр һәр ягын әдепләү яки барысын да әдепләү

**ӘДЕПЛЕ** *с.* Әдеп тоткан, әдепләнгән. *Элгәре җиләнне, чикмәнне әдепле итеп тегәләр иде; инде бу елда әдепле җилән, әдепле чикмән һичкемдә юк.* К.Насыйри

**ӘДЕ́П САЛУ** *ф. к.* **әдепләү**

**ӘДЕ́П ТОТУ** *ф. к.* **әдепләү**

**ӘДЕРНӘ** *и. тар.* Керешен берничә кеше яки ат белән тарта торган гаять зур сугыш җәясе. *Әдернә лә тартып ук атмаенча Талды гына бәнем беләккәем.* Җыр. *Менә, зәңгәр төтен чыгарып, туплар гөрселдәде, татарлар өстенә ядрәләр шаулап очты, менә әдернә җәяләр киереп тартылды һәм Искәргә таба уклар атылды...* Ф.Бәйрәмова

**ӘДИП** *и. гар.* Профессиональ рәвештә матур әдәбият әсәрләре язу белән шөгыльләнүче кеше; язучы. *Әдип – тырыш, мәңге ял белмәс бал корты ул.* А.Гыйләҗев. *Аннары Хөсәен бине Әмирхан күренекле әдибебез Фатыйх бине Мөхәммәдзарифның бабасы да бит әле.* Р.Әмирхан. *Алман әдибе Гёте кабатларга яраткан бер гыйбарә яши дөньяда, бакый хаклык булып яши.* Ф.Дулат

**ӘДИПЛЕК** *и.* Әдип булу, язучылык. *Әдәби хезмәтнең икенче дәверендә инде Горький реалист әдиплек нигезенә утыра бара.* Г.Нигъмәти. *Әдиплек шәәнеңне саклап, Әдәпле сирриять эзләп тап.* Дәрдемәнд

**ӘДРӘС** *и. фар.* **1.** Буйлыгы – ефәк, аркавы мамык булган ярым ефәк чуар тукыма. *Мәрфуга әби --- хәзрәттән калган әдрәстән казаки да тектерде.* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый тукымадан тегелгән, чуарлыгы белән аерылып торган. *Садыйк абзый, әдрәс казакиен киеп, капка төбенә чыкты, ак күлмәк, яңа чабата кигән хезмәтче капканы тотып тора башлады.* Г.Исхакый. *--- вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә --- билгеләп тора.* Ә.Еники

2) Шушы тукыма төсендәге; чуар. *Фәхерниса карчык ниндидер бер йөрәк рәхәте белән җылынып сискәнеп уянып китә, күзен ача – аһ, ул Миңлегали түгел, юрган өстенә аның бердәнбер иптәше – әдрәс мәчесе сикереп менгән икән.* М.Мәһдиев

**ӘДРӘ́С ГӨЛЕ** *и. бот.* Яфрак җепселләре кызыл төстәге бүлмә гөле; кычыткан гөл; *русчасы:* **колеос**. *Тәрәзә төбендә әдрәс гөле үсә*

**ӘДРӘСЛӘНҮ** *ф.* Әдрәс төсле чуар булу, берничә төрле төскә керү, чуарлану. *Ерак та түгел, әнә, әдрәсләнеп, күзгә урман күренә.* Ф.Хөсни

**ӘДРӘ́С ТАЛЫ** *и. к.* **әдрәс гөле.** *Тәрәзә төбе тулган гөлләр: бохар кынасы, зәйтүн гөле, әдрәс талы.* Г.Ахунов

**ӘҖӘЛ** *и. гар.* 1) Үлем вакыты, үлем, соңгы чик. *Кеше бәхетен читтә тапса да, әҗәлен илендә тапты.* Ә.Баянов. *Анда яшь кыз, аның сөйгәне, әҗәл белән тартышканда, нинди сораулар булуы мөмкин.* Я.Зәнкиев. *Әйтергә кирәк, авылга кергәндә, ул әткәсенең җайлы гына үлүен теләде, аның әҗәлен «ансат котылу» дип атады.* А.Гыйләҗев. *Шагыйрь кешенең кешелеклелеге, зурлыгы, аның мөмкинлекләре турында уйлана, фикри әҗәлдән, ваемсызлык чиреннән сагая.* Казан утлары

2) *дини сөйл.* Аллаһ кушуы буенча, кешеләрнең җаннарын алу өчен килә торган фәрештә; Газраил фәрештә. *Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте, мин суга барып җиткәнче, әҗәл мине килеп тотар, дип куркамын, диде.* К.Насыйри. *Эшләнеп бетмәгән алачык идәнендә Әлмәндәр белән Әҗәл утыралар.* Т.Миңнуллин

3) *куч.* Түзә алмаслык, чыдам җитмәслек хәл. *Кул-аяклары сызлый – тырнак астына энә кадаулары әҗәл иде.* Р.Сибат

◊ **Әҗәл авызыннан тартып алу** Үлемнән коткарып калу. **Әҗәл белән бер** Түзә алмаслык авыр. *Төптән уйлап караганда, аның өчен бу – әҗәл белән бер иде.* Ф.Садриев. *Төнлә йөрүдән куркалар иде, чөнки машиналар адым саен ватыла, четерекле урыннардан үтүе – әҗәл белән бер.* Казан утлары. **Әҗәл белән йөзгә-йөз килү** 1) Үлемгә китерерлек яман хәлгә, куркыныч хәвеф-хәтәргә юлыгу; 2) *куч.* Өметсезлек, төшенкелек; ямансулаулы рухи халәттә булу. *Бу фани дөньяда бөтен нәрсәгә ышанычыңны югалтып, әҗәл белән йөзгә-йөз килгәндә, ихлас күңелдән дога укы.* Татар календаре. **Әҗәл белән тартышып яту** Бик каты авырып, урын өстендә яту, үлем хәлендә булу. *[Зәнфирә:] Сине бит, салкын тидереп, әҗәл белән тартышып ятасың, дип сөйлиләр.* Ф.Садриев. **Әҗәл даруы** 1) Үлемнән коткарырлык әйбер, им; 2) Бик сирәк, җиңел генә табып булмый торган әйбер. *[Фәйрүзә:] Ә син минем бу «әҗәл даруын» каян алганны беләсеңме соң?* В.Нуруллин. *--- әҗәл дарулары иттеләр инде шул, билләһи, шайтан суын...* Р.Мөхәммәдиев. **Әҗәлем шушы икән** Нинди дә булса куркыныч янаганда, беттем, үлемем шуннан икән, дигән мәгънәдә кулланыла. *Миннән биш-алты гына сажин калышып, йомрылып, теге дә килә! Әҗәлем шушы икән, минәйтәм.* М.Хәсәнов. **Әҗәлен авызына тешләп** Үлемнән

курыкмыйча, тәвәккәлләп. **Әҗәлетдин якадан алу** *к.* **әҗәл якага ябышу.** *Әҗәлетдин якадан алганда бүтәннәр теленә ни киләдер, бүген ул бер сүзне тәкрарлады: «Ярамый! Иртә ич!»* А.Гыйләҗев. **Әҗәл җитү** Үлем вакыты якынлашу. *– Сакаллы сабый, тешсез исәр, әҗәлең җиткәнне көтәргә түземлегең калмадымыни, мине төрмәдә чертергәме исәбең? – дип, ул Сәлим бабайны, якасыннан эләктереп, аякларына бастырды.* Г.Тавлин. *Ахры, әҗәл җитмәгәндер инде, кичкә таба бераз хәл алдым, больницага илттеләр, өч көн шунда ятып чыктым.* Г.Ибраһимов. *[Әби:] Әҗәлең җиткән булса, улым, ул гына ярдәм итә алмас, әлегә борчымый торыйк.* А.Хәсәнов. **Әҗәл килү** Үлем вакыты җитү. *Нихәл итсен, әҗәл килү Булса да бик яман ачы ---.* З.Мансуров. **Әҗәл көтү** Үлем алдында булу. *Моны Берлин төрмәләренең берсендә ялгыз камерада әҗәл сәгатен көтеп ятучы, якты дөньядан тулысынча аерылган тоткын яза.* Д.Вәлиев. **Әҗәлсез китү** Бәхетсезлеккә, һәлакәткә дучар булу, вакытсыз үлү. *Ил халкы өчен җанын фида кылып, дошман кулыннан әҗәлсез киткән Хәкимулла улы Сибгатулла мәрхүмне дә шәфкатеңнән мәрхүм итмә.* Г.Бәширов. **Әҗәлсез үлү** *к.* **әҗәлсез китү**. **Әҗәл сызыгы** Бетү, юкка чыгу чоры. *Әнә шулай биш-алты гасыр буена гел чит җирләрне, чит халыкларны үзенә буйсындыра барган гаҗәеп зур ил әҗәл сызыгына килеп басты.* Р.Хисмәтуллин. **Әҗәл табу** Үлү, вафат булу. *Бәлки, суларга аккандыр алар, Әҗәлне шунда тапкандыр алар.* Ф.Яруллин. **Әҗәл тагарагы** Бик начар, иске, таралып төшәргә торган берәр нәрсә. *Тәки кузгаттылар әҗәл тагарагын, алар бәхетенә юл авыш иде, урыннан бер купкач, машина үз җае белән балчык чәчә башлады.* А.Гыйләҗев. *Нужа дисәң нужа: Утырып әҗәл тагарагына Кереп китте Кама тамагына.* Н.Исәнбәт. **Әҗәл хастасы** Үлемгә китерә торган авыру. **Әҗәл чолганышы** Үлемгә китерә торган көрәш, сугыш. *Сугыша-сугыша барып, Харьковны, Полтава, Краматорскины узды, Кременчуг тирәсендә Днепрны кичте, ә Ингулец елгасында әҗәл чолганышында калгач, сугыш Шәяхмәт Вәлиуллинга яңа исәп ачты.* Б.Камалов. **Әҗәл якага ябышу** Каты авырудан үлем белән яшәү арасында калу. *Тәнемне чуан басты, чирләшкә сарык күк чырык-чырык ютәлләдем, температурам кырык градуска җитте. Кыскасы, яшәү белән үлем арасында калдым – әҗәлем якама ябышты.* Г.Тавлин. **Әҗәл якасында яту** Үлем хәлендә булу. *Каенатa әҗәл якасында ята.* А.Гыйләҗев

**ӘҖӘЛГӘ́ЧӘ** *рәв.* Үлгән көнгә кадәр, вафат булганчы. *[Сөен тутайның] Хамаюн солтан никахыннан баш тартуы да, ахирәтләренең фаҗигале язмышы да аның бәгырендә гомер төзәлмәс җәрәхәт булып калыр, әледән-әле ачылучы иске яра кебек, әҗәлгәчә үзе белән йөрер.* Р.Батулла

**ӘҖӘТ** *и. гар.* 1) Берәр кешедән акчалата яки әйберләтә алынган бурыч. *Ул үтә ярдәмчел, әвене янганнарга зур процент белән акча биреп тора, рибачы әҗәтен түләүне ашыктырмый, процентын гына арттыра.* А.Гыйләҗев. *Әнинең гозерен тыңлагач, әйткән теге апа: – Әҗәткә бирә алмыйм, үпкәләмә, Мәгъсүмә, – диген.* В.Нуруллин. *Халык хак әйтә: әҗәтен яшергән – бөлгән, чирен яшергән – үлгән, ди.* А.Хәсәнов

2) Шартнамәдә күрсәтелгән таләпләр нигезендә, кире кайтару шарты белән банктан, оешмадан яки кибеттән алынган акчалата бурыч яки әйбер; кредит. *[Банктан] Әҗәткә акча сораган фирманың бөтен тарихы, бөтен эшчәнлеге, бөтен плюс-минуслары энәсеннән җебенә кадәр тикшерелә.* В.Юныс

3) Яхшылыкка яхшылык рәвешендә кайтарылган җавап. *Уйлап карасаң, фамилия буталу файдагадыр әле. Ходай бар бит ул! Һәм... башланды! Рәгыйдә – Хәмдиягә, ә Ильяс... Ильяс? Әйдә, әҗәт рәвешендә булса да, кыюрак булыйк, Ильяс Бакыйга әйләнде, диик.* Ә.Баянов

◊ **Әҗәт түләү** Әйтелгән төртмә сүзгә яки эш-гамәлгә җавап булырлык итеп, нәрсә дә булса әйтү, эшләү. *Ә басуларда нәрсә? Билчән дә әрем, сарут та шайтан таягы. Сәбәбе? Сәбәбе бер: җиргә әҗәт түләү җитмәүдә, ягъни җирне карый белмәүдә.* М.Хәсәнов

**ӘҖӘТЛЕ** *с.* Әҗәте, бурычы булган. *Әҗәтле [кеше] үлмәс, чирле үләр.* Әйтем. *– Шушыңынчы кешегә әҗәтле булып тораммы суң? – диде Мәрьям әби.* Ә.Гаффар. *Җир ул бервакытта да кешегә әҗәтле булып калмый.* Ф.Яруллин

◊ **Әҗәтле булып калмау** Әйтелгән төртмә сүзне яки эш-гамәлне игътибарсыз калдырмау, аңа җавап булырлык итеп ни дә булса әйтү, эшләү

**ӘҖӘТЛЕЛӘ́Р КЕНӘГӘСЕ** *и. гади сөйл.* Зур булмаган сәүдә нокталарында бурычка сатып алучыларның исемен, нинди товар һәм күпме данәдә алуын, хисабын теркәп бара торган кенәгә. *--- үрелеп, шүрлектән күн тышлы калын кенәгәләрен алды. Тузаннарын сөртештерде. Урта бер җирдәгесен – «Әҗәтләләр кенәгәсе» дип язылганын ачты.* М.Хәсәнов. *Андыйларның да хәленә керде Әгъдия: бурычка өләште, «әҗәтләләр кенәгәсе»нә исемнәрен, кушаматларын һәм шешә хисабын яза барды.* К.Кәримов

**ӘҖӘТХАНӘ** *и. гар.-фар. сөйл.* 1) Бәдрәф, туалет

2) Булдыксыз, яраксыз, кирәксез, начар, мәгънәсендә ачулану сүзе. *Бу юлы инде чынлап торып чукынып кайттыңмыни, әҗәтханә?! Үзеңне җир дә йотмый бит, ичмасам!* В.Имамов

**ӘҖЕ́-ГӨҖЕ КИЛҮ** *ф.* Озак итеп, дусларча сөйләшү. *Чекага ревком тәкъдиме белән урнашты урнашуын, тик, суллар белән болай урамда әҗегөҗе килеп торгач, белмәссең, бер авызга килеп кыймылдаулары да бик мөмкин.* Т.Әйди. *Һәрвакыт тезгә-тез куешып утыралар да әҗе дә гөҗе киләләр.* Г.Камал

◊ **Әҗе-гөҗе ае** Ширбәт ае

**ӘҖЕКӘЙ** *и. диал.* Кызарганчы кыздырылган коры эремчек; корт

**ӘҖЕР** *и. гар.* 1) Эшләгән эш, күрсәтелгән хезмәт өчен түләү; бирелгән хак. *Бельский, кызыксынып: – Ә әҗерен ничек кайтарырсың? – диде.* Ә.Мушинский. *[Фәһим:] Алайса, без болай итик, Максуд, йортны без колхоз исәбенә салып бирик. Кереп ур-*

*нашкач, сез аңа, шәһәр җирендәге кебек, ай саен әҗерен түләп барырсыз.* Г.Ахунов

2) Нинди дә булса эшкә яки яхшылыкка каршы җавап итеп бирелгән әйбер яки эшләнгән гамәл. *Күр менә, яхшылыгыңның әҗерен ал, син аңа мактаулы эш тәкъдим итеп, аның дәрәҗәсен күтәреп утырасың, ә ул кулы белән тизәк изә.* А.Гыйләҗев. *[Зөбәй:] Өйләдән соң, уенга килгәндә, әҗерен дә китерермен.* З.Зәйнуллин

3) *дини* Игелекле эшләр яки яхшылыклар өчен, Аллаһы Тәгаләдән иңдерелгән рәхмәт; савап. *Мәҗлес тә ясамадык түгел, ясадык инде, Алла әҗерен насыйп кылсын.* Ш.Мөхәммәдев. *Бу эшегезнең әҗерен, Алла боерса, кыямәттә күрерсез.* Г.Камал. *[Торна Зәйнәпкә:] Син мине картлык көнемә чаклы тәрбия иттең. Ходай әҗерен бирсен!* Г.Рәфикый

4) *күч. сөйл.* Гонорар, каләм балы (хакы). *[Сабакташ дусты:] Әсәрләре өчен тиешле әҗерен Р.Сибатка алып кайтып бирә.* Ф.Галимуллин

**ӘҖЕРЛЕ** *с.* 1) Түләүле, акчага эшләнелгән

2) Савап китерә торган. *Шулай итеп, зур мәдәният үзәге булган Багдадның хакимнәре, ислам динен бөтен дөньяга ирештерер өчен, гаять әҗерле эшләр башкаралар иде.* Т.Нәбиуллин

3) Бурычлы, тиешле хакын түләми калдырган. *Кенәз күнә икән, хан да әҗерле булып калмас калуын.* В.Имамов

**ӘҖНӘБИ** *и. гар. иск.* **1.** Чит ил кешесе. *Сумка тоткан берничә әҗнәби аның кибетенә килеп керә икән, аның үткен күзләре клиентларның кайсы илдән икәнен шундук хатасыз ачыклый: Польшаданмы, Румыниядәнме, Русиядәнме.* В.Юныс. *Бигрәк тә әҗнәбиләрне алдыйлар.* И.Нуруллин. *Минемчә, төрекнең үзен әҗнәби баскан.* А.Расих

**2.** *с. мәгъ.* Чит телдән кергән, чит илдән килгән, читтән кайтартылган

**ӘЗ** *рәв. к.* **аз**. *Мәдинә әз генә уйланып алды.* Ф.Садриев. *Ләкин «чокыр» дигәнең шундый да мәкерле нәрсә икән, әз генә күздән ычкындырдыңмы – шундук үз явызлыгын эшли!* Г.Ахунов

**ӘЗӘЛ** *и. гар.* Башлану вакыты булмаган борынгы заман, мәңгелек. *Сугышмыйча бармы чара, әзәлдә шулай язылган.* Бәет. *Гөрләп вә яшәреп утыра торган чирәмнәр вә мөнбит йирләр әзәлдән бирле сабан керми яталар.* Г.Ибраһимов

**ӘЗӘЛГЕ** *с.* Борынгы заманнан килгән, башлану вакыты билгеле булмаган. *Әзәлге дуслык*

**ӘЗӘЛДӘГЕ** *с.* 1) Әллә кайчан, чиксез борынгы заманда булган. – *Әзәлдәге хәлләрне кем хәтерләп бетерсен, булгандыр инде, – диде ул, башын да күтәрмичә.* Г.Чокрый

2) *к.* **әзәлге**

**ӘЗГӘРӘЙ** *и. тар.* Казан ханлыгы чорында сугылган тәңкәнең бер төре (Хаҗигәрәй исеменнән)

**ӘЗЕР** *с. гар.* **1.** 1) Файдаланырга, кулланырга яраклы хәлгә килгән, әзерләп куелган. *Әзер ипине дә киптерә алмагач, син ник кирәк анда?!* Ф.Садриев. *Аның әзер хаты да бар, бик матур, бизәкләр төшергән.* М.Галәү. *Былтырдан калган әзер кармак бар икән, шуны алдым да, кая басканымны белмичә, малайлар янына чаптым.* Г.Ибраһимов

2) Кем тарафыннан да булса алдан хәстәрләнгән, файдалану өчен яраклы хәлгә китереп куелган. *Син яхшы иттең, иптәш, әзер йортка, әзер байлыкка хуҗа булып алдың да рәхәтләнеп ятасың.* А.Таһиров. *Чикерткә җәй буе шатлык белән үткәрде көннәрне: --- Эссе көннәр, әзер өй бар, ашыйм дисә – азыклар мул.* М.Гафури

3) Кем тарафыннан да булса алдан уйланылган, билгеләнгән, тупланган (фикерләр, тәгъбирләр турында). *Ул, инде әллә ничә мәртәбә кабатлаган, барлык сорауларны да канәгатьләндерүче әзер җавабын әйтте...* Ф.Садриев. *Әзер материалдан шулай юмарт файдалануым өчен, Нил Юзиев иптәш мине гафу итәр дип беләм.* М.Максуд. *Андый кеше әзер фикерләрне, әзер догмаларны, әзер уй-фикерләрне куллананучы – файдаланучы, бары тик шулар аша гына эш итүче рәвешендә кала.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**2.** *хәб. функ.* 1) Хәзер, шушы вакытта файдаланырга, кулланырга яраклы, әзерләнеп куелган хәлдә. *Арба әзер, чәй эчеп чыгасы да атны гына җигәсе иде.* М.Әмир. *Ләкин план инде күптән әзер, мең кат уйланган, чигенү мөмкин түгел иде.* Ф.Садриев. – *Сиңа юлдаш әзер, йөгерегез урманга, – диде ул...* Н.Гыйматдинова

2) Нәрсә дә булса эшләргә, тиз генә башкарырга, үтәргә әзерлек хәлендә; каршы түгел. *Синең белән баллы сүзләреңне тыңларга мин әзер, туташ.* К.Тинчурин. *Хәзер инде тикшерүче үзе дә аның фикерен ахырынача ачыкларга өлгергән, кирәк була калса, сүзгә катнашырга әзер иде.* М.Насыйбуллин. *Кызыбыз Энҗе хәзер врач – минем өчен җанын бирергә әзер.* М.Мәһдиев

**3.** *рәв. мәгъ.* Нинди дә булса эшне башкарырлык хәлдә, аны үтәргә әзерлек хәлендә. *Хәзер, хәзер, ике минутта без әзер булырбыз...* Г.Ибраһимов

**4.** *и. мәгъ.* Файдаланырга яраклы итеп әзерләп, эшен бетереп куелган әйбер, ризык һ.б. *Әзерне ашый, әзерне эчә, әзер өйдә тора бит ул.* М.Гафури

◊ **Әзергә бәзер** Әзерне генә көтеп йөрүчегә, башкалар әзерләгән, эшләгән нәрсәләрдән файдаланучыга карата әйтелә. *Бу очракта, әзергә бәзер исәбенә генә яшәү хыялы хөкем ителәп түгелме соң?!* М.Бакиров. **Әзергә хәзер** *к.* **әзергә бәзер**. **Әзергә хәзер, хәзергә назир** Әзердән генә файдаланырга, әзерне генә көтеп торырга яраткан кешегә карата әйтелә. **Әзер кабер үлесе, әзер туйның тилесе** *ирон.* Гомере буе әзергә генә, ваемсыз булып яшәгән кеше турында

**ӘЗЕР БУЛУ** *ф.* 1) Алдан эшләп, көйләп куелган булу. *Кабер әзер булгач, бәләкәй чана тартып, энемне алырга киттем.* М.Әмир

2) Алдан ук әзерләнеп тору, көйләнеп тору. *Үзенең һәм энисенең бәхете өчен барысына да түзәргә, барысын да үз җилкәсенә күтәрергә әзер булып, бу йортның бусагасын атлап кергән иде.* А.Шамов. *Бары да әзер булгач, урманга китәргә җыендык.* М.Әмир

**ӘЗЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **әзерләү.** --- *калын такталар салып, машина батмаслык калку урын әзерләнгән...* Ф.Садриев. *Ә инде үзе урынына кадр күптәннән әзерләнә.* М.Мәһдиев

2) Нәрсә дә булса эшләргә җыену, әзер булу. – *Боярның ашлыгына ут төртергә әзерләнәләр икән! – дип бәйләнгән.* Г.Ибраһимов. --- *кухняны төяргә әзерләнеп, вагоннан сикереп төштем.* Ш.Усманов. *Аю өнгә ятарга әзерләнә...* Г.Әпсәләмов

3) Берәр эш өчен алдан әзерлек эшләре алып бару, нәрсәгә дә булса хәстәрлек күрү. *«Туйга әзерләнәм, әнкәй», – дигән була.* Р.Ишморат. *Никах хотбәсеннән соң сәдака өләшүгә дә, бу туй өчен муеннан бурычка батуына карамастан, бик нык әзерләнде.* Г.Ибраһимов. *Ул, мең бәла белән, гадәттән тыш зур ярлылык, мохтаҗлык астында, университет өчен аттестатка әзерләнә.* Г.Ибраһимов

4) Үзеннән алдагы фигыль белдергән эшне башкару өчен өлгереп килү, җитешү, вакыты җитү (күбесенчә, табигать күренешләре турында). *Буран чыгарга әзерләнә. Кошлар бала чыгарырга әзерләнә*

5) Берәр нәрсәнең буласын алдан белеп, сизеп, үзеңне шуңа әзер тоту (кешенең эчке халәте турында). *Хөкем алдыннан һәммәсен ярып сөйләп бирергә дип, үз эченнән әллә ни чаклы әзерләнде...* Г.Ибраһимов. --- *дустын коткармаган өчен, дөньяда кеше үйлап чыгарган барлык җәзаларны үзенә алырга әзерләнде.* З.Хәким

**Әзерләнә башлау** Әзерләнергә керешү. *Кичәгә инде күптән әзерләнә башлаганнар иде.* Н.Фәттах

**Әзерләнә бару** Акрынлап, нәрсәгә дә булса әзерләнү, торган саен әзерлеге арту

**Әзерләнә бирү** Бернәрсәгә карамастан әзерләнүне дәвам итү

**Әзерләнә тору** Акрынлап, алдан ук әзерлек күрү. – *Ничего, чират сиңа да җитә, әзерләнә тор, – диде Арсланов, аңа таба кул селтәп.* Ф.Садриев. *Сез хәзер әзерләнә торыгыз, юл уңаенда сугылып үтәрбез.* Н.Фәттах

**Әзерләнә төшү** Тагы да яхшырак әзерләнү; бераз әзерләнү. *Әйтеп килгән кунак булсаң, әзерләнә төшкән булыр идем...* Г.Әпсәләмов

**Әзерләнеп бетү** Тулысынча, барысын да әзер итү, тәмам әзер булу. *Бөтенесе дә әзерләнеп беткәч, Таран биек «С-80» кабинасына – Ислам янына менеп утырды.* Н.Фәттах. *Бу вакытта аның иптәшләре дә торган, өсләренә киенеп, сабан сөрергә китәргә әзерләнеп беткәннәр иде.* М.Гафури

**Әзерләнеп җитү** Ахырына кадәр әзерләнү, тиешенчә әзерләнергә өлгерү. *Ул хәтта туйга әзерләнеп җиткәнне дә көтмәскә булды.* Н.Фәттах

**Әзерләнеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта әзерлек эшләре белән мәшгуль булу. *Ул шулай, арлы-бирле килеп, һаман кичке ашка әзерләнеп йөрде.* А.Расих. *Мин Казанга укырга китәргә әзерләнеп йөрим.* И.Гази

**Әзерләнеп килү** Элektән, күптәннән акрынлап әзерләнү, алдан әзерлек күрү. --- *әмма ул, гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, Алла хозурына барам, дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән һәм, бөтен керсез күңеле белән, үлгәннән соң гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели* ---. Ә.Еники

**Әзерләнеп кую** Алдан әзерләнү, алдан әзерлек күрү. *Нарат төбенә әзерләнеп куелган коньяк бик хәтәр ымсындырып торса да, руль тотып Казанга кайтасы булганга, Фәләхкә бүген тамчы да кабарга ярамый.* В.Нуруллин

**Әзерләнеп тору** 1) Әзер булу; әле хәзер нәрсәдер эшләргә җыену. --- *ак чәчәкләргә күмелергә әзерләнеп торган шомырт агачлары – һәммәсе, яз, ди.* Г.Ибраһимов. *Алар, иртәнге салкыннан бөрешеп, юыныргамы, ашаргамы әзерләнеп торалар иде.* Н.Фәттах

2) Алдан әзерлек күрсәтү, әзерлек чараларын күрү

**Әзерләнеп яту** Әле, хәзерге вакытта ни дә булса эшләргә әзерләнү, әзерлек чаралары күрү. *Сабан туена әзерләнеп ятам әле менә.* Н.Фәттах. *Үзенчә туйга әзерләнеп яткан җиреннән, Һарун шундук Ташкичүгә чапты.* Н.Фәттах

**ӘЗЕРЛӘҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса файдаланырлык, кулланырлык хәлгә китерү; әзер хәлгә җиткерү; әзер итү. *Әтисе белән Әнсәрия апасы бакчада чәчәкләр утырттылар, түтәлләр әзерләделәр.* Ф.Яруллин. --- *Зиннур Зәйгә балык тотарга барырга кармак саплары әзерли иде.* Г.Ахунов. *Мин сиңа юл кирәкләре әзерлим әле...* Г.Ибраһимов

2) Төзү, кору, ясау. *Йорт салу өчен бура әзерләү. Төнәтмә әзерләү*

3) Билгеле бер эшкә, максатка, тәртипкә яраштырып әзер итү, хәстәрләү, алдан хәстәрен күрү. --- *булачак киявенә сөлгеләр, ашъяулыклар, күлмәкләр, чаршаулар, чыбылдыклар әзерләде.* Г.Ибраһимов

4) Нәрсәне дә булса кирәк булган кадәр күләмдә җыйлап, барлап, табып, тутырып кую. *Гөлүс кичтән бик күп итеп утын әзерләде, төне буе битум казанын якты.* Р.Кәрами. *Берсе самавыр куя, бүтәннәре юл кирәкләре әзерли...* Г.Бәширов

5) Сәләт, белем нигезендә ни дә булса үтәү, көч, хезмәт кую. *Сызымнар әзерлисе бар, ди.* Р.Хәмид. *Бу зур кичә өчен, мин «Тормыш турында җыр» әзерләдем.* Г.Кутуй. *Соңгы басманың текстын --- З.Шәйхелисламов әзерләде.* Шәһри Казан

6) Азык-төлекләрне пешереп, кыздырып һ.б. алымнар белән ашарга яраклы итү. --- *тизлек, җитезлек белән, салат әзерләделәр.* М.Мәһдиев. *Хәзер киез өй алдындагы учактан сыек төтен күтәрелә, анда – Лачынбай. Ул сөт кайната, эремчек, сыкма әзерли.* И.Салахов. *Хунза халкы үзенең «могҗизалы эчемлеген» нигездә абрикостан әзерли.* Сәламәт булыйм дисәң // Кирәкле нәрсәләрне табынга кую. *Миләүшә әллә нинди бер җиңеллек белән табын әзерләде.* Ф.Яруллин. *Зөбәрҗәт өстәл әзерләде.* Ф.Садриев

7) Билгеле бер максат белән тиешле белем бирү; белгеч итеп чыгару. *Бүген безнең ил, врачлар әзерләү буенча, мәсәлән, дөньяда беренче урында тора.* Г.Әпсәләмов. *Быелдан башлап, юриспруденция белгечлеге буенча укытучылар әзерли башладык.* Р.Юсупов. --- *фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләү --- билгеләнгән.* Г.Саттаров. --- *Түбән Камада өлкән сыйныф укучыларыннан шәфкать туташлары әзерлиләр.* Мәдәни җомга

8) Алдан нәрсәне дә булса күпләп алып кую, туплау, хәстәрен күрү, җитәрлек запас булдыру. *Иртә таңнан эшкә – урманга, кышлыкка утын*

*әзерләргә чыгып китәләр.* Г.Гыйльманов. *Мунчаның инде түбәсен генә ябасы калган, төзүчеләр калай әзерлиләр иде.* Ф.Садриев. *Мазаны белми ул, утын әзерлисе юк, печән чабасы юк, быкыр-быкыр кайнаган казан янында йөрү – рәхәт кенә ич ул!* Я.Зәнкиев. *Байтак май әзерләде.* М.Гафури

9) Нәрсә дә булса эшләргә җыену, берәр нәрсә эшләргә ниятләү. *Ниһаять, җитә бер көн, җәлилчеләр, бөтен лагерьлар буйлап, восстание әзерлиләр.* Г.Ахунов

10) Нәрсә дә булса әйтергә, сөйләргә, белдерергә алдан уйлап кую; әзерләнеп тору. *Хатның кайбер урыннарын күңеленнән әзерләгән дә иде инде. Ләкин хәзер бу зур, өр-яңа кайгы барлык борчуларны җиңде...* А.Расих. *Доклад әзерләү*

**Әзерләп алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә әзерләү. *Өстәл әзерләп алу*

**Әзерләп бару** Даими рәвештә, һәрберсен, булган берсен әзерләү. *Өй эшләрен һәрвакыт вакытында әзерләп бару*

**Әзерләп бетерү** Нәрсәне дә булса тулысынча әзерләү. *Өйгә бирелгән дәресен шулай озаклап әзерләп бетергәндә, инде йоклар вакыт килеп җиткәнен дә сизми кала иде.* А.Расих. *Янгуразга хәзер, чыннан да, легиончыларга ял йортында сөйләргә ниятләгән нотыкларын гына әзерләп бетерергә кирәк иде.* Т.Әйди

**Әзерләп бирү** Кем өчендер әзерләү, әзерләргә ярдәм итү. *«Н»ның икенче басмасын әзерләп бирәм дә үземнең төп эшемә – икенче китапка тотынырга кирәк.* Г.Бәширов

**Әзерләп җибәрү** Тиз генә, җәһәт кенә әзерләү, әзерләргә өлгерү. *Хәзер чәй әзерләп җибәрербез.* Ф.Яруллин

**Әзерләп җиткерү** Нәрсәне дә булса тиешенча әзер итү, әзер хәлгә китерү

**Әзерләп йөрү** Хәзерге вакытта әзерлек эшләре белән мәшгуль булу, нәрсәне дә булса әзерләү эше белән шөгыльләнү. *Бәхетсезлегенә, өлгер Иван Матвеевич кайтып җиткән, озатасы почтаны әзерләп йөри.* И.Салахов. *Әнисе табын әзерләп йөри иде инде.* Г.Әпсәләмов

**Әзерләп калдыру** Әзерләргә өлгерү, алдан әзер итү. *Ихтыяҗ барында, телебез, әдәбиятыбыз буенча яшьләрне күбрәк әзерләп калдырыйк.* Т.Галиуллин. *Күзләрен ертып ачу белән, әниләре әзерләп калдырган ризыкларны ике кабып, бер йотып, ялт иттереп куялар иде ---.* М.Хәсәнов

**Әзерләп килү** Нәрсәне дә булса алдан, күптәннән, эзлекле рәвештә әзерләү. *Рамазан шыпырт кына барды, авылның очына җитәрәк, олы юлга күтәрелгәч кенә, әзерләп килгән сүзен әйтте.* Ш.Янбаев

**Әзерләп кую** Нәрсәне дә булса алдан әзерләү, әзер хәлгә китерү, хәстәрләү. *Урынны көндез үк, «бәет тыңларга киләбез!» дигәнне ишетеп, Җәфрәтил карт әзерләп куйган иде.* И.Салахов. *– Кунак кызга да тырманың җиңелен әзерләп куярбыз, – диде.* Ә.Еники. *Әлеге үзең әйткән баганаларны мин әзерләп куйдым.* Ш.Камал

**Әзерләп тору** 1) Нәрсәне дә булса алдан әзерләү, әзер итеп тоту. --- *ул --- кабаланмыйча гына, яндыргыч сыекча тутырылган шешә белән шырпы әзерләп торды һәм, танк узып китү белән --- шешәсен, җан-фәрманга кизәнеп, арт ягыннан танкка тондырды.* М.Әмир. *Шәрифулла, алар чыгуга, өстәл әзерләп торды.* И.Салахов

2) Даими рәвештә берсе артыннан икенчесен әзер хәлгә китерү, әзерләү эшен башкару

**Әзерләп чыгару** Башыннан ахырына кадәр эшләп әзер итү. *Корректура, басма продукцияне әзерләп чыгару барышында, грамоталы һәм игътибарлы булу өстенә, зур җаваплылык, түземлек һәм тырышлык таләп итә.* М.Вәлиев

**Әзерләп яту** 1) Озак вакыттан бирле, күптәннән нәрсә булса да әзерләү. --- *безнең өчен урыс телендә сөйләүче миссионерлар әзерләп ятканнар икән.* Б.Рәхимова

2) Әле, хәзерге вакытта әзерләү

**Әзерли башлау** Әзерләргә тотыну. *Мин аны юлга әзерли башладым.* Г.Кутуй

**Әзерли килү** Һәрвакыт, гел, даими рәвештә әзерләү

**ӘЗЕРЛЕК** *и.* 1) Нинди дә булса вакыйгага яки чара уңаеннан алдан башкарыла торган эшләр, шөгыльләр, хәстәрлек. *Хәзер Г.Кутуйның 100 еллыгына шундый ук әзерлек алып барабыз.* Ф.Галимуллин. *Моның гаять зур әзерлек таләп итә торган алым икәнен дә аңлый Ибраһимов.* М.Насыйбуллин. *Үзе берәр туй барганда, язгы чәчүгә әзерлекне барлаганда, Сабантуй көннәрендә генә гармун белән күңел ачып ала.* Г.Ахунов. *Казанның 1000 еллыгына әзерлек ---.* Татарстан

2) Кемнең дә булса уку дәверендә, эшчәнлек барышында туплаган белеме, күнекмәсе, тәҗрибәсе. --- *Ватан турында сүз әйтергә бик зур талант, әзерлек кирәк...* М.Мәһдиев. *Аннары кыска вакытлы курсларга җибәреп, анда хәрби белемен, әзерлеген күтәреп, кече лейтенант итеп шул ук ротасына кайтардылар.* Т.Әйди. *Сезнең армиядә алган әзерлегегез бик төпле, нигезле.* Р.Мирхәйдәров. --- *хәрби әзерлеген пулемётчы булып башлап, миномётчы булып тәмамлаганнан соң, --- малайны сугышка да ыргыттылар.* А.Хәлим

**ӘЗЕРЛЕКЛЕ** *с.* Тиешле әзерлеге (*2 мәгъ.*) булган. *Тыйнак, зыялы, эрудицияле һәм зур әзерлекле --- профессор Марсель ага Бакировның бу титаник хезмәте – --- инкыйразга ныклы киртә куйган монографияләрнең берсе.* Ә.Сәхапов. *Педагогик эшчәнлек махсус әзерлекле белгечләр, укытучылар катнашында бара...* Мирас. --- *безнең югары әзерлекле оештыручы җитәкчеләребез азаеп киткән.* Казан утлары

**ӘЗЕРЛЕКСЕЗ** *с.* **1.** Әзерлеге булмаган. *Нәтиҗәдә, балалар гаиләдән ир-хатын булып яшәүгә әзерлексез булып чыгалар, гаилә тормышын алып бара алмыйлар.* Р.Һади. *Бүген әдәпсез, әзерлексез кешеләрнең, хакыйкый остаздан башка Коръән тәфсирләрен, хәдис китапларын укып, алардан ашыгып нәтиҗә ясаулары, агулы казанда аш әзерләү кебек, үзләренә генә түгел, башкаларга да зыян китерә.* Татар заманы

**2.** *рәв. мәгъ.* Әзерләнмичә, әзерләнмәстән. *Сабирҗан абзый әзерлексез алып чыкты аларны олы юлга.*

Р.Батулла. *Югыйсә, күбесе урамнан килеп керә дә, туп-туры сәхнәгә менеп, берниндиәзерлексез җырлый башлый.* Р.Вәлиев. *Чанасын аның бер утыргач кем дә шуар, ә менә чаңгы һәм тимер-аякта әзерлексез генә шуа башлармын димә.* Шәһри Казан

**ӘЗЕРЛЕКСЕЗЛЕК** *и.* Әзерлексез булу. *Мондый әзерлексезлекне күреп, мин ни уйларга белмәдем, тик, башка чара юк, җиң сызганып эшләргә кирәк иде.* Казан утлары

**ӘЗЕ́Р ТОРУ** *ф.* Нинди дә булса эш өчен даими әзерлектә булу, кирәклек чыкканны, зарурлыкны көтеп кенә тору. *Соңгы чиккәчә өметләнә, мәхәббәте хакына сугышырга әзер тора!..* И.Салахов. --- *Гыйзелниса әбинең бәләкәч кенә йомышын да зур итеп башкарырга әзер торабыз.* М.Кәрим

**ӘЗИ** *и. диал.* 1) Үзеннән өлкәнрәк туганга яки гомумән өлкән яшьтәге ир кешегә эндәшкәндә, аның исеме янында кулланыла; абый. *Без, тирә-күрше малайлары, үзебездән аз гына өлкәнрәк булса да, «Габделхак әзи дә, Габделхак әзи!» дип, һәрвакыт ат караучы тирәсендә әвәрә килә идек.* Ш.Маннапов

2) Үлгән кешене исемләп искә алганда әйтелә; изге кеше

3) Мөрәҗәгать итү сүзе; дускай, туганкай. *[Илһам:] Бак, әзи, Ринат, чуваш авылы күрәсем килә, алып бар әле мине чуваш авылына, ди.* Р.Батулла

**ӘЗМӘВЕР** *и. фар.* **1.** Алып гәүдәле, көчле кеше. *Аһ бу авыл әзмәвере!* Р.Харис. *Әзмәвернең борын астына сеңгән мыеклары кыймыл-кыймыл килде...* Я.Зәнкиев. *Шундый җилле тибә ки, теге әзмәвер өйалды баскычыннан мәтәлеп төшә...* Р.Фәизов. *Икенче көнне эшкә барырга чыгуым булды, каршыма кара күзлек кигән бер әзмәвер килеп тә басты.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Зур гәүдәле, көчле. --- *үзенә ике әзмәвер егетне яллады...* Р.Мирхәйдәров. *Әзмәвер адәм, мышный-мышный, боргаланып кыланган арада, бүлтерек бәндәң, аны-моны уйлап тормастан, нәселен үрчетеп тә өлгерә.* Э.Касыймов

**ӘЗМӘВЕ́РДӘЙ** *с.* Әзмәвер кебек, бик зур, бик таза һәм бик көчле. *Әзмәвердәй өч ирдән ун ятим бала, өч тол хатын һәм ике карчык әниләре торып калды авылда...* З.Зәйнуллин. *Үз улларың шикелле әзмәвердәй ике-өч егетне фатирга кертмисеңме соң, бабай?* Р.Вәлиев. *Әбигә аның әзмәвердәй улы Геннадий белән рәхәтләнеп сөйләшү мөмкинлеге дә юк.* М.Кәбиров

**ӘЙ** *ы.* **1.** 1) Кемгә дә булса эндәшкәндә, аны чакырганда, кисәтеп мөрәҗәгать иткәндә әйтелә. *Әй, әй... исемең ничек әле?* Д.Аппакова. *Әй, Ефим агай!* Г.Гобәй. *Аңа исеме белән дәштеләр: – Әй, Гайфуллин!* Г.Бәширов // *сөйл.* Хатын кешенең иренә эндәшү сүзе. *[Хатын] Әй, сиңайтәм, кеше алдында алай бөһтаннар ягып, мине харап итмә инде!* Г.Камал

2) *шигъ.* Эндәш сүзләр алдында кулланылып, сөйләмнең эмоциональлеген арттыра. *Әй чәчкәләр, сезгә кемнәр дуслар?* М.Гафури. *Әй яшьлегем, яшьлегем, Яшьлегем – гүзәллегем...* Н.Исәнбәт. *Әй бүрекле баш, шушындый куе урманда япа-ялгызың гына, курыкмыйча, батырланып ничек йөрисең?* А.Алиш

3) Нәрсәне дә булса искә төшергәндә яки ялгышны дөресләп, төзәтеп әйткәндә кулланыла. *Шәмсия карчыкның малае өйләнеп башка чыкты. Әй, син аларны белмисең бит әле...* Ә.Фәйзи. --- *Хисами кода, әй, ялгыш әйтәм, Хисами бай ---.* Г.Камал

4) Үкенү, көенү, борчылу, газаплану, кайгыру, сызлану, әрнү һ.б.ш. хисләрне белдерә. *Әй туган! Син тагы кан түккәнсең икән!* Г.Ибраһимов. *Әй бала, бала, үзегемә үтәсең лә!..* А.Шамов. *Әй, хәзер Садретдиным исән булса иде! – дип көрсенгән иде бит.* Ә.Фәйзи. *– Әй! – диде кыз, нык әрнү белән. – Бер машина бәргән иде...* Ф.Яруллин

5) Көчле теләкне белдерү өчен кулланыла. *Әй, шуның, ичмасам, бер учы гына минеке булса, ә?!* А.Әхмәт. *Әй җырлыйсы килә шушы җырны...* Һ.Такташ

6) Шатлану, шатлыклы гаҗәпләнү, күңел күтәренкелеге, куану, шаккату, соклану, канәгатьлек хисен белдергәндә, мактанганда кулланыла. *Әй, халык шат! Һәммәсе уйный, көлә.* М.Гафури. *Әй, рәхәт җәйләре!* Н.Исәнбәт. *Әй, арышы, бодае Дулкынланып тора бит...* Г.Гобәй. *Әй, алтын да инде минем хатын.* А.Әхмәт

7) Курку, кот очу, шүрләү, шомлану, шикләнү, шөбһәләнү хисләрен белдерә. *[Бәдига:] Әй илаһым, алты бала белән, шулай ук, суда гарык булырмынмы икәнни!..* К.Тинчурин

8) Кемне дә булса кызгану, юату, теләктәшлек хисләрен белдерә. *– Әй балакай, балакай! – диде Фәтихәттәй, аны кызганып.* Г.Әпсәләмов. *Әй мескенкәем, кем кыйнады?* А.Әхмәт. *Әй карт, бер дә кайгырма...* Һ.Такташ

9) Санга сукмау, искитмәү, нәфрәтләнү, җирәнү хисләрен белдерә. *Әй, бөтен кешене кызгана башласаң...* Ф.Яруллин. *Әй, чукынып китсәң иде шул казнаң белән!..* Т.Гыйззәт. *Әй тавык баш! Шуны да белмисеңме?* Г.Ибраһимов. *Әй, булган – беткән.* З.Хәким

10) Кемне дә булса кимсетеп, аннан көлеп, ирония белән әйткәндә кулланыла. *Әй җебегән!* И.Гази. *Әй хәчтерүш. Кеше рәтендә йөрисең шунда.* Ф.Яруллин

11) Уңайсызлану, оялу, курку һ.б. сәбәпләр аркасында берәр нәрсә эшләргә каршы булганда әйтелә. *Әй лә, җырламыйм ла --- оялам.* М.Гафури. *Әй лә, кайтмыйм, әти ачулана, ул бит мине кыйнар, мине куар.* М.Гафури

12) Кемгә дә булса шелтә, ризасызлык белдергәндә, аны оялтып әйткәндә кулланыла. *Әй хәзрәт, хәзрәт, Оят кирәк иде әзрәк.* Т.Гыйззәт. *Әй, теш корты булдың ич...* Г.Бәширов

13) Әйтелгән фикернең дөреслегенә ышанмауны, бу хакта әйтелгән сүзне кирәксенмәүне белдерә. *Әй, юкны сөйләп тормасана.* Д.Аппакова. *Әй, юк әйбер сөйлисең.* Ш.Камал

14) Җырларда ялгаучы иҗек буларак кулланыла. *Әй бөдрә тал, бөдрә тал, җанкаеңны каршы ал!* Я.Зәнкиев. --- *ай, уймаккай кебек сызылып ага Ашказаркай суның агышы, Әй-й, --- Ашказаркай суның агышы...* Г.Әпсәләмов

**2.** *кис. функ.* Кабатланып әйтелә торган һәр сүз алдыннан килеп, эшнең, хәлнең интенсивлыгын арттыра, аңа көчәйтү төсмере өсти. *Әй пешерде, әй пешерде, Әй пешерделәр, туган!*

Ф.Бурнаш. *Туктауга, әй китте шау-шу, әй китте шау-шу!* Г.Гобәй. *Әй шуам, әй шуам.* Ф.Яруллин. *Әй тотына кайгыртырга, әй кыштырдый, әй сөйләшә башлый ана каз! Бер әкәмәт инде.* Г.Бәширов

**ӘЙБӘТ** *с. гар.* **1.** 1) Уңай сыйфатларга яки тиешле таләпләргә җавап бирә торган; яхшы; *киресе:* **начар**. *Язылып бетмәгән бик әйбәт ике балладам бар...* М.Җәлил. --- *үзенең өйдә калган әйбәт китапларын сагына...* И.Гази. *Әйбәт музыка ишетсә, сабыйларча канатлана, дулкынлана.* Б.Камалов

2) Уңай әхлакый сыйфатларга ия булган, яхшы холыклы, әдәпле, итагатьле. *Менә бу – авылдан килгән бик әйбәт егет белән дус бул, яме?* Ә.Фәйзи. *Бу якта да әйбәт икән кешеләр.* А.Әхмәт. *Ул кеше күз алдында бик диндар, әйбәт «бабай» булып күренергә тырыша иде.* М.Галәү

3) Үз эшен тиешле дәрәҗәдә алып баручы, тәҗрибәле, оста; яхшы белгеч. – *Әйбәт хирург булачак, – диделәр өлкән хирурглар...* Г.Әпсәләмов. *Шундый әйбәт начальниктан Аерылу да бик читен.* М.Җәлил. *Безнең әтинең дусты – бик әйбәт бакчачы.* Ф.Яруллин

4) Югары сыйфатлы; затлы. *Рәхмәт, Гыймади абый, Бик әйбәт итекләреңң.* М.Җәлил. *Берсе – теге базарда минем белән сугышкан сары башлы, черек тешле, әйбәт киемле малай.* Г.Ибраһимов. *Әйбәт пальто кигән унбер-унике яшьлек малай атылып килеп керде.* Р.Төхфәтуллин

5) Акыллы, төпле, ныклы уйланылган, уңышлы. *Теле такылдаганда, башына әйбәт фикерләр килә Тәслимәнең.* М.Маликова. *Әйбәт, әйбәт үгет бирәләр.* Ш.Маннур. *Җир ашлау турында әйбәт киңәшләре бар икән.* Г.Бәширов

6) Шатлыклы, күңелле, яхшы, шәп, кәеф күтәрерлек. --- *авылда, мәктәп тормышында нинди әйбәт яңалыклар бар, шуларны яз син, ярыймы.* Ф.Сафин. *Синең дәфтәрләрең әйбәт хәбәрләр белән тулсын...* Ф.Яруллин. *Ниндидер әйбәт: күңелгә – көрлек, сулышка – иркенлек, аңга уяулык бирә торган үзгәреш тойды ул бу минутта.* Я.Зәнкиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Күләме ягыннан күп, җитәрлек, мул. *Уңыш әйбәт кенә булды.* М.Мәһдиев. --- *әйбәт түләп килделәр, алар кешене кызыксындыру кирәклеген белә иделәр.* Р.Мирхәйдәров. *Менә мин ул Тарзаннан, бик әйбәт итеп, ремонт хакын кисеп алып калам әле, понимаешь!* Х.Сарьян

2) Җиренә җиткереп, яхшы итеп, тиешле дәрәҗәдә. *Шундый әйбәт теккән иңнәрен.* Һ.Такташ. *Әлегә хәтле ул иске түрәләр белән дә эшне әйбәт итеп алып барды.* И.Гази. *Әти-әниләр әйбәт кенә яшиләр.* М.Җәлил

3) Югары сыйфатлы, шәп. – *Мә әле, Уразбикә, татып кара: балы бик әйбәт күренә, – ди.* Г.Ибраһимов. – *Ну, каймагы әйбәт икән, – диеп мактады.* Һ.Такташ

4) Канәгатьләнерлек, яхшы, ярыйсы. – *Иптәш командирның болай төшендереп бирүе бик әйбәт булды әле, – диде.* Г.Бәширов. *Озын сүзнең кыскасы, күңелгә әйбәт булып китте әле.* А.Әхмәт

**3.** *хәб. функ.* 1) Нәрсә белән дә булса тулысынча канәгатьләнүне, килешүне, нәрсәне дә булса хуплауны, аңа риза булуны белдерә. *Эчә белми икән, бик әйбәт!* Ә.Фәйзи. *Син пенсиягә чыктың, анысы әйбәт, ә менә миңа кем пенсия бирер икән?* Н.Дәүли. *Авырый дияр идең, әнисенең хәрәкәтләре элеккечә җитез, ашавы әйбәт.* Ф.Садриев

2) Яхшы кәефле, рәхәт, тыныч, күтәренке күңелдә булу. *Аңа ни, аның кәефләре әйбәт.* Ш.Камал. – *Кәефләре әйбәт, – дигән иде әни.* М.Җәлил

3) Гомумән һава торышы җылы, аяз булу турында. *Һава әйбәт бугай, ә, Сафия иптәш?* Ш.Камал. *Төн бик әйбәт, кызлар белән егетләр сөйләшеп утыра торган төн...* Ф.Хөсни. *Көн әйбәт иде.* Г.Ибраһимов

**ӘЙБӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) Әйбәт булып китү, уңайга үзгәрү, рәтләнү. «*Борчылмагыз, Маратның хәле әйбәтләнә, үсә, күңелен алгысытып йөрмәгез», – дип җавап язды.* Ф.Садриев

2) Яхшылану, әйбәткә әйләнү. *Җил дә тынган. Һава әйбәтләнә, болай булгач.* А.Гыйләҗев

**Әйбәтләнә бару** Акрынлап, аз-азлап әйбәтләнү; торган саен әйбәтләнүгә арту. *Авыруның хәле әйбәтләнә баруын әйттеләр, ләкин үземне янына кертмәделәр.* Г.Гомәров. --- *ярчыкларны, көнбагыш төшедәй вак ядрәләрне чүпләп алган саен, аягы әйбәтләнә барды.* Х.Камалов

**Әйбәтләнә башлау** Әйбәтләнүгә сизелү, әйбәтләнергә керешү. – *Кәефләрегез ничек? – ди дәвалаучы табибыбыз. – Бүген күзгә күренеп әйбәтләнә башлады шикелле, – дим мин, шатлыгымны яшерә алмыйча.* Э.Шәрифуллина

**Әйбәтләнә төшү** Бераз әйбәтләнү. *Автор минем рецензия нигезендә либреттосын шактый үзгәрткән, шуның нәтиҗәсендә, кайбер пәрдә һәм күренешләр әйбәтләнә төшкән.* М.Җәлил. *Шәфкать туташыннан Фәүриянең хәле әйбәтләнә төшүе турында ишетү балаларга әйтеп бетергесез шатлык иде.* М.Хуҗин

**Әйбәтләнеп бару** Берникадәр, бераз әйбәтләнү, акрынлап, торган саен ныграк әйбәтләнү. *«Ашыгыч ярдәм» белән китереп салдылар. Йөрәккә приступ булды. Хәзер инде әйбәтләнеп барам.* Н.Нәҗми

**Әйбәтләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча әйбәтләнү

**Әйбәтләнеп җитү** Ахыргача, тиешенчә әйбәтләнү

**Әйбәтләнеп калу** Ниндидер вакыйгадан, сәбәптән соң әйбәтләнү

**Әйбәтләнеп килү** Соңгы вакытта, бераз, аз-азлап әйбәтләнү. *Яралары инде төзәлеп, Әйбәтләнеп кенә килгәндә, Килде кинәт бүген исенә, Ишетеп, ул яман бер хәбәр ---.* Х.Камалов

**Әйбәтләнеп китү** Билгеле бер моменттан, сәбәптән соң әйбәтләнү, кинәт әйбәт якка үзгәрү. *Ике-өч көннән без клуб янындагы ике бүлемле бер өйнең буш бүлмәсенә күчендек. Хәлләребез әйбәтләнеп киткәндәй булды.* К.Миңлебаев

**Әйбәтләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта әйбәтләнү

**ӘЙБӘТЛӘ́Ү** *ф.* **1**. 1) Әйбәт итү, яхшырту, җайлау. *Эшләрне әйбәтләү*

2) Төзәтү, рәтләү, тәртипкә китерү. *Юлларны әйбәтләү*

**2. әйбәтләп** *рәв. мәгъ.* 1) Җиренә җиткереп, тиешле дәрәҗәдә. *Камилә, син хаҗи әфәндене әйбәтләп сыйла...*

Ш.Камал. --- *бәрәңге алды да кое төбендә ялгызы әйбәтләп юа башлады.* Г.Ибраһимов. *Фәрит әнисенең одеалыннан чыгып торган аягын әйбәтләп ябып куйды.* Ф.Садриев

2) Яхшылап, аңлашылырлык итеп; анык, ачык итеп. *Аннары дүрт пьесаны санап чыга да бик әйбәтләп кенә кисәтә...* М.Максуд. *Сафа, мактанмыйча, күргән-белгәннәрен әйбәтләп сөйләп бирде, белмәгәнен, белмим, диде.* М.Галәү. *Иртәгә әйбәтләп кучерербез дә дүшәмбе көн кертеп тә чыгарбыз.* И.Гази

3) Яхшылап, пөхтә итеп, матур итеп. *Калага баргач, әйбәтләп киендерделәр.* А.Таһиров

4) Җай гына, ашыкмыйча, рәхәтләнеп. --- *Гафият башта, әйбәтләп, симез сарык итеннән пешергән токмач ашап, чәй эчүне яклады.* И.Гази. *Кайнар килеш әйбәтләп кенә эчәрсең дә бөркәнеп ятарсың.* Р.Ишморат

5) Ипләп, җайлы, уңайлы итеп. *Мачтаның башына менеп җиттем дә әйбәтләп кенә аякларны салындырып утырдым.* Ф.Яруллин. --- *ауган карт тал агачы бар иде, менә шуның өстенә әйбәтләп кенә утырдык.* Ә.Айдар

**Әйбәтләп бетерү** Бөтенләй, тәмам әйбәтләү

**Әйбәтләп килү** Билгеле бер вакыттан башлап әйбәтләү; әйбәтләүне дәвам итү

**Әйбәтләп кую** Тиз генә әйбәтләү. *Әхмәди, мыекларын бөтергәләп, кыскарып калган сакалын сыйпап, әйбәтләп куйды.* Г.Бәширов

**Әйбәтләп тору** 1) Һәрвакыт, әледән-әле әйбәтләү

2) Әле, хәзерге вакытта әйбәтләү

**Әйбәтләп чыгу** Һәрберсен берәмберәм әйбәтләү

**ӘЙБӘТЛЕК** *и.* Әйбәт булу. *Фәрит әнисенең зиһенлелегенә, хәтеренең әйбәтлегенә --- сокланып утырды.* Ф.Садриев. *Каршы очраган һәр кешенең күзендә ул үз пальтосының әйбәтлеген күрде, барлык кешеләр аның яңа пальтосына карыйлар кебек.* И.Гази

**ӘЙБЕР** *и.* 1) Көнкүрештә кулланыла торган нинди дә булса бер предмет, нинди дә булса хезмәт башкаруга җайлаштырылган кирәк-ярак. --- *сандыгында --- түбәтәй, исле сабын, тасма, чәй кебек әйберләр дә саклана.* М.Галәү. *Этнең муенында, үзенә күрә, портфель кебек әйбере бар.* М.Әмир

2) *күпл.* Берәр җиргә җыелып, төелеп куелган нәрсәләр. *Носильщикка ишарәт итеп, әйберләребезне вагонга кертергә булдык.* Ф.Кәрими. *Фәтхия әби, менә болар – мәрхүм Шәйбәк бабайның әйберләре.* Г.Ибраһимов

3) *күпл.* Кием-салым. *Хәзер замштан тегелгән әйберләр модада, торабара, тирегә күчәчәкләр.* Р.Кәрами

4) Гомумән азык-төлек, ашамлыклар. *Тәмле әйбер күп булмый.* А.Хәлим. --- *базга да төшә, андагы сөт өсте, эремчек кебек әйберләрдән авыз итеп, яланып-ялманып чыга.* Ә.Фәйзи. *Әниләрне тәмле әйберләр сорап та тинтерәтмәдек.* Казан утлары

5) Әдәбият, сәнгать, фән әсәрләре. *Тырышсаң була бит ул – уйлана торгач, язарлык әйберләре дә табылды.* Г.Мөхәммәтшин. *Сездә талант бар икән, минемчә, кешеләргә шатлык бирә торган әйберләр иҗат итәргә кирәк.* Г.Әпсәләмов. *Язган әйберләремнең дә иң күбесе шул чакларга туры килә.* Ф.Хөсни

6) Нинди дә булса фикер, хәбәр, сүз, имеш-мимеш, күренешләр. --- *шикләндерерлек әйберләр сөйләдең.* Г.Кутуй. *Көннәрнең берендә исереп кайтты. Бу – Нәгыймә өчен бөтенләй яңа әйбер иде.* Г.Ибраһимов. *Хакыйкать, я дөреслек дигән әйбернең төрле рәвештә һәм төрле зурлыкта булганлыгын Солтан яхшы белә иде.* А.Расих

7) *сөйл. сир.* Нинди дә булса нәрсә; нәрсәдер, нindидер предмет. *Безнең әйләнә-тирәбездәге һәр әйберне һәм күренешне төрле яклап ачыклап килә торган бик күп сүзләр бар.* В.Хаков. *И, гомер буена бер пот авырлыгы әйбер дә күтәрмичә үскән мескен кулларым!* Г.Камал

8) *филос.* Тормышта безнең аңнан тыш яши торган матди предмет, объектив чынбарлык күренешләре

◊ **Әйбер әйтмәү** Каршы сүз әйтмәү, тиргәмәү; ризасызлык күрсәтмәү. *Улы соң кайтса да, анасы әйбер әйтмәде.* Г.Рәхим

**ӘЙБЕ́Р-КАРА** *җый. и.* Төрле кирәк-яраклар. *Бибинур бер акылга килде: «Әйе, мин аларга серне ача да алам, әйбер-караларын бер көнгә сорап тора да алам».* А.Гыйләҗев

**ӘЙБЕРЛӘТӘ** *рәв.* Әйбер белән; акчалата түгел, натуралата. *Дөрес, ул моны бик озак ялындырып эшли, коры үтенүләргә генә эреп төшми, баерак, хәллерәк малайлар, акчалата булсын, әйберләтә булсын, төрле бүләкләр вәгъдә итә башлагач кына бераз йомшаргандай була...* М.Әмир

**ӘЙБЕРЛӘШҮ** *ф. филос. икът.* Нинди дә булса реаль әйбердә чагылыш табу, әйбердә гәүдәләнү, әйбер формасын алу. *Кыйммәт – товар җитештерүчеләрнең товарда әйберләшкән иҗтимагый хезмәте ул.* Политэкономия

**ӘЙДАМАН** *и.* **1.** *к.* **вожатый.** --- *күзгә-күз карашкач, мин югалып калдым. Теге вакытта, аларның классында әйдаман булган чакта, гел башкача иде бит.* Ә.Гадел

**2.** *с. мәгъ.* Әйдәп бара торган. *Монысы да – Әхәт Мушинскийның киң эрудицияле, тыйнак, әмма кирәк чакта әйдаман әдип булуы хакында сөйли.* Н.Гамбәров

**ӘЙДӘ́** *ы.* **1.** 1) Кемне дә булса үз янына чакырганда әйтелә. *Әйдә, кер, Тәнзилә!* Р.Ишморат. *Әйдәгез өйгә, өйгә керегез, түрдән узыгыз.* Т.Гыйззәт

2) Кемне дә булса берәр сүздән туктатып, эштән аерып, кая да булса иярттеп алып барырга чакырганда әйтелә; киттек. – *Әйдә, Ильяс, бераз һава алып кер,* – диде. М.Әмир. *Һәммәгез әзерме? Әйдәгез, киттек!* Г.Ибраһимов

3) Берәр нәрсә эшләргә чакыруны, өндәүне, теләкне белдерү өчен әйтелә. *Әйдә, нәнәм, рәсем ясыйбыз.* Г.Гобәй. *Әйдәгез, малайлар, кызлар, урманга киттек.* Н.Гыйматдинова. *Әйдә, бахбай, тарт сабанны, на-на-на!* К.Әмири. *«Әйдәгез, Мөдәррис картның берәр тавыгын тотып, пешереп ашыйбыз», – диде.* Ә.Айдар

4) Нәрсә белән дә булса ризалашуны, хуплауны белдерә. *Әйдә, яшәсеннәр, тормышларын үзләренчә корсыннар...* Б.Камалов. *Әйдә, йөрсен, сәламәтлек өчен файдалы, диләр ич.* Т.Гыйззәт

5) Кискен таләп иткәндә, әмер, боерык биргәндә, берәр халәтнең, эшнең дәвам итүенә ризасызлык белдергәндә кулланыла. *Әйдә, торыгыз, маегызга чыдый алмыйсыз икән, торыгыз, дидем!* М.Мәһдиев. *Ярар, җитте, әйдә, эшкә кучик.* Ә.Фәйзи. *Әйдә бар, юлыңда бул, алдыңнан артың матур!* М.Твен

6) Нинди дә булса эшкә өндәп дәртләндерүне, әйдәкләүне, үтенечне белдерү өчен әйтелә. *[Галимҗан] Гыйрфан мулла җайлап менеп утыргач, дилбегәне кулына алып: – Әйдә, малкай, әйдә, уңган, – диде дә Солтанморатка кайтып китте.* С.Поварисов

7) Кемгә дә булса киңәш биргәндә яки кемне дә булса тынычландырганда кулланыла. *– Әйдә, кадерен белеп, йоклап кал, – диде.* Р.Кәрами

**2.** *кис. мәгъ.* Җөмләдә белдерелгән хәл-әхвәл, фикер белән килешүне, килешүгә чакыруны белдерә. *Әйдә, бер туйганчы балавыз сыгар да башкача әрнеп йөрмәс...* Д.Бүләков. *Әйдә, безнең авылдан да укыган кешеләр чыксын әле!..* Х.Сарьян

**3.** *хәб. функ.* Киттек, элдердек, чаптык мәгънәсен белдерә. *Күзне генә кыстык бер-беребезгә. Борылдык та әйдә артыннан!* К.Нәҗми

**ӘЙДӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бик нык әйдәү, куалау. *Асылгәрәй ничек кенә атны әйдәкләп караса да, ат барырга теләмәде, башын түбән иеп, чыбыркы очы тигән саен тәне тартышып, баскан җиреннән купмады.* Д.Каюмова. *Мин атымны әйдәкләдем, малайлар эткәлитөрткәли башладылар.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **әйдәү** (*1 мәгъ.*). *--- үзе аны Нуриасма янына керергә әйдәкләде...* Ф.Садриев

3) Ихтыярына буйсындыру, мәҗбүр итү. *Кушканны үтәү, кемнеңдер әйдәкләвенә буйсыну – балачактан ук аның өчен үлем белән бер иде.* Ф.Садриев

4) *күч.* Алга омтылдыру, дәртләндерү. *«Үлем тырнагыннан ничә тапкыр ычкынганны гриппка бирешеп тору җебегәнлек булыр» дип, үз-үзен әйдәкләү ягын карады Вәсим.* Ә.Моталлапов

**Әйдәкләп алу** Кинәт кенә, вакыт-вакыт әйдәкләү; берникадәр вакыт әйдәкләү. *Бары Андрей гына, атны кызулатырга теләп, еш кына чөңгереп, әйдәкләп ала.* Р.Сибат

**Әйдәкләп бару** Күптәннән, электән үк, даими әйдәкләү. *Профессор абый миңа өмет баглый, сиздерми генә мине әйдәкләп бара.* Гөлшаһидә

**Әйдәкләп карау** Әйдәкләргә омтылу, әйдәкләргә тырышу. *Егетләр атларын чыбыркылап та, юмалап та, чөңгерә-чөңгерә әйдәкләп тә карадылар.* Р.Батулла. *– Әйдәкләп кара, энекәш, кузгалмасмы, – диде ул миңа.* А.Гыйләҗев

**Әйдәкләп тору** Бертуктаусыз әйдәкләү; әледән-әле, еш әйдәкләү. *--- элек-электән, очраштыра торган сәер кешеләр – илгизәрләр каны тынгы бирми, күңелен кытыклап, юлга, сәфәргә, офык артына әйдәкләп тора иде.* А.Тимергалин

**Әйдәкли башлау** Әйдәкләргә керешү, әйдәкләргә тотыну. *Бабай арба аратасына кыстырган чыбыкны суырып алды да атны әйдәкли башлады.* Р.Батулла

**Әйдәкли бирү** Әйдәкләвен һаман да дәвам итү

**Әйдәкли төшү** Тагын да ныграк әйдәкләү; бераз әйдәкләү

**ӘЙДӘЛӘ́Ү** *ф.* Бертуктаусыз «әйдә-әйдә» дип чакыру, кыстап мәҗбүр итү. *Әрсез бригадир исә, ачу китереп, юлына аркылы төште һәм, әйдәләп чыгармасаң, үзе белеп һич тә чыгар төсле күренмәде.* Н.Фәттах

**Әйдәләп бару** Һәрвакыт, гел әйдәләү. *Авыр хәлдә калган абыйларына – аталары кебек кешегә ярдәм итү буенча эшне Дамир үзе әйдәләп барды.* Н.Газизов

**Әйдәләп чыгу** 1) Һәрберсен, берәмберәм әйдәләү

2) Әйдәләп, үзләре белән алу, үзләреннән калдырмау. *Фәрит җавап кайтарырга өлгергәнче, кызларның Маратны култыклап һәм әйдәләп чыгуын күргәч, икесенең дә эчләренә җылы керде.* Ә.Баянов

**ӘЙДӘ́П БАРУЧЫ** *с.* 1) Юнәлеш бирә торган, башкаларга үрнәк булган. *Дөньяның әйдәп баручы барча театрлары шушы принципка таянып эш итәләр.* В.Шәрипов. *Институтка нигез салганда, халыкара мөнәсәбәтләр буенча бик күп югары уку йортларының, әйдәп баручы белгечләрнең фатихасын алдык, килешүләр төзедек.* Э.Шәрифуллина. *Мөнип абый, сез бит – балалар әдәбиятында әйдәп баручы шагыйрь ---.* К.Миңлебаев. *[Николаев Олег Викторович] 1976–1988 елларда Днепропетровск опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты [була].* Татар театры

2) Өстенлекле, алдынгы. *Жанрның --- җинаятьләрне тасвирлаган өлкәсе соңгы елларда аеруча көчәеп китте, һәм ул детектив жанрны әйдәп баручы --- тармакка әверелде.* М.Сәхапов

**ӘЙДӘ́Ү** *ф.* 1) Кемне дә булса үзең белән барырга чакыру яки ияртеп алып китү. *Салчак алып, урыныннан кубып, Сылукызны тупас кына беләгеннән тотып алды һәм аны ишеккә таба әйдәде.* Н.Фәттах. *Исмаев аны култыгыннан эләктереп алды да алга таба әйдәде.* Г.Бәширов. *Гөлнурны, котыртып, күл буена әйдәгән өчен берне тамызасы иде дә...* Н.Гыйматдинова // Ишарә, ым белән үз янына чакыру. *Шәмгун, бармагы белән генә әйдәп, мине үз янына чакырып китерде.* Г.Гобәй. *[Старшина] --- сүзсез генә, баш ымы белән әйдәп, блиндажга ияртеп керде.* Х.Камалов

2) Куып алып бару; чабып барырга мәҗбүр итү, ашыктырып куалау (күбесенчә терлек-туар турында). *--- мена хәзер инде ул Балтаханның җылкыларын Куянды ярминкәсенә әйдәп килә иде...* И.Салахов. *Каюм бабай, таң иртән, кызы Зәйнәп илә углы Сәлимне ияртеп, сыерларны әйдәп чыгып китте.* А.Таһиров. *Шул рәвешчә кайнар күз яшьләрен коеп, атын әйдәп, Туман тархан калкулык тирәли кузгалып китте.* Н.Фәттах. *--- атын әйдәде дә, кош кебек очып, бая килеп әйләнгәннәрнең каршысына барып чыкты...* Г.Ибраһимов

3) Өндәү, берәр эшкә, максатка чакыру. *Тәүге тәнәфескә әйдәп, Җиз кыңгырау шылтырый.* Б.Хәлимов. *Әйтик, һәрбер эшне оештыруда, аны үткәрүдә укучы балалар үзләре теләп катнаша, үзләре башлап йөри, үзләре үк башкаларны әйди икән ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов

4) *күч.* Алга омтылдыру, дәртләндерү, рухландыру. *Әлеге белем һәм күнекмәләр --- иҗтимагый тормышта һәм производство эшчәнлегендә иҗатка этәрә, әйди.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Тирә-яктагы котырынган кар өермәләре аны никадәр генә --- алга әйдәмәсеннәр, ул артык кабаланмады.* А.Расих

5) *күч. сир.* Дәвам итү, тугры булып калу. *Карт әткәгез юлын әйдәп, мулла булсагыз гына фәтва чыгар*. Ә.Баян

**Әйдәп бару** 1) Бертуктаусыз әйдәү. *Икенче бер карчык, сабанның сабыннан тотып, кызларны ат тоткан шикелле дилбегә белән тотып, камчы белән кыйный-кыйный әйдәп бара.* К.Насыйри. *Сөембикә исеме, моңсу бер әләм булып, әнә шул тарихны әйдәп бара.* Ф.Урманче

2) *күч.* Өстенлек итү, төп урынны алып тору. *XX гасырның буеннан-буена татар прозасында реализм әйдәп барды*. Д.Заһидуллина

**Әйдәп йөрү** 1) Һәркайда һәрберсен әйдәү. *Татар, башкорт, мари, чуваш, удмурт, калмык, казакъ фетнәчеләрен исә, бөтен яу барышында, нигездә, старшиналар, тарханнар, солтаннар әйдәп йөри*. В.Имамов. *Унбер генә яшьтә идең ул елларда. Олы апа! Өч апаеңны син әйдәп йөрдең*. К.Булатова

2) Әле, хәзер, сөйләү моментында әйдәү. *--- әйтерсең лә аның [Күчем хан] рухы, әйләнеп кайтып, оныкларын басып алучыларга каршы изге сугышка әйдәп йөри...* Ф.Бәйрәмова

**Әйдәп карау** Әйдәргә омтылу, алып китәргә тырышу. *Аптырагач, Ибрай сыерга атланып та әйдәп карады.* М.Кәрим

**Әйдәп килү** Күптәннән, элек-электән, даими рәвештә кая да булса әйдәү. *Язгы кичтә яңа чыккан аем, Күккә карап йолдыз юл яра. Шул юллардан, айкап-чайкалмыйча, Мине әйдәп килгән Клара*. М.Шиһапов

**Әйдәп тору** Кемне дә булса даими чакыру, һәрвакыт әйдәү, үзенә тарту. *Моңа шул чорның идеологиясе дә бик зур йогынты ясады, чыбыркылап әйдәп торды.* Л.Шагыйрьҗан. *Үзенең аклыгы белән алгысытып, офык читеннән берөзлексез үзенә таба әйдәп торган урман булып урман да, күрән төскә кереп, авылга якыная төште.* Р.Мөхәммәдиев

**Әйди башлау** Әйдәргә тотыну

**ӘЙДӘҮЧЕ** *и.* **1.** 1) Көтүне яки берәр хайванны, куып, әйдәп баручы, куучы кеше. *Шуны гына көтеп торган арткы сафтагы җылкычылар, малчылар, юлга чыгарга җыенган куй әйдәүчеләр, ыгы-зыгы килеп, ашыгып, берберсен этеп-төртеп, сәҗдәдән тордылар.* И.Салахов

2) *күч.* Берәр нәрсәгә юнәлеш бирүче, юл күрсәтүче, киңәш бирүче. *Сәнгатьле фикерләүнең һәр ике тибы --- әдәбиятта зур урын ала һәм хәтта әйдәүче булып китә.* А.Әхмәдуллин

3) Нинди дә булса җыелышка, сөйләшүгә һ.б.ш.га чакырып йөрүче кеше; өндәүче

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төп, әһәмиятле. *Комитетның төп, әйдәүче көчләрен Ф.Әмирхан тирәсенә тупланган Р.Алуши, В.Бәхтияров --- тәшкил иткән булса кирәк.* Р.Әмирхан. *Шәхесендәге әйдәүче сыйфатларга һәм үз-үзен тотышына караганда, каһарман гадел патша булган.* Н.Хисамов

2) Юнәлеш бирә торган, башкаларга үрнәк булган. *Г.Камал театрында да, К.Тинчурин театрында да, ягъни әйдәүче сәхнәләрдә, комедия өстенлек итә.* Казан утлары

**ӘЙДҮК** *ы. сөйл.* Ихтирам белән «рәхим итегез!» дигән мәгънәдә үзенә чакыруны, килгән кешене якты чырай белән каршы алуны белдерә. *Әйдүк, кояш иптәш! Бергә-бергә бәйрәм итәрбез.* Х.Туфан. *Әллә кайчан килү кирәк иде, әйдүк, председатель, әйдә, бик мактап та йөрисең икән...* М.Әмир. *Әйдүк, Газинур улым, әйдүк.* Г.Әпсәләмов

**ӘЙДҮКЛӘП** *рәв.* Ачык чырай белән, теләп, үз итеп, якты йөз күрсәтеп. *Әйдәгез, апай-сеңелләр, ягез, егет-энекәшләр, дип, әйдүкләп, хуплап-җөпләп кушты инде халыкны эшкә, кайберәүләр шикелле акырып-бакырмады.* Ш.Янбаев. *Кунакларны әйдүкләп каршылау*

**ӘЙЕ** *хәб. сүз* **1.** 1) Ризалыкны, раслауны белдереп җавап биргәндә кулланыла; *киресе*: **юк.** *– Китәсеңмени? – Әйе.* Р.Кәрами. *– Шул җитмәгәнмени? – Әйе, шул җиткән.* Г.Бәширов. *– Сиңа бүген урманга барасыңны әйткәннәр идеме? – Әйе...* Ф.Садриев. *– Әлфия, кызым, синме бу? – Әйе, бабай.* А.Хәлим

2) Алдан әйтелгән фикергә игътибарны арттырып, аны катгый рәвештә кабатлап раслауны белдерә. *Озакламый, атака башланыр, әйе, атака.* Г.Бәширов. *Чөнки безнең барыбызның да, әйе, барыбызның да бу тормышта урыныбыз бар.* Н.Дәүли

3) Мөстәкыйль җөмлә башында килеп, тема үзгәргәндә, нәрсә турында булса да уйлануларның, искә алуларның нәтиҗәсен белдереп хикәяләгәндә кулланыла. *Әйе, аларның сүзендә хаклык бар сыман.* Ф.Яруллин. *Әйе, кызыккан идем!..* М.Хәсәнов. *Әйе, син матур идең.* Г.Кутуй. *Әйе, Захарыч, синең белән бергә эшләү рәхәт иде...* Т.Гыйззәт

4) Берәр онытылган фикерне искә төшергәндә, нәрсә дә булса кинәт хәтергә килгәндә кулланыла. *– Ә, әйе, – диде Кадыйр абый, хәтерләп...* Г.Минский. *– Ә-ә, әйе бит әле!..* К.Тимбикова. *Әйе, әйе, онытa да язганмын. Мин бит беренче шигыремне каурый каләмне корымнан ясалган тоньк карага мана-мана язган идем.* Ә.Рәшит

5) Ышанмау, киреләнү, каршы килү һ.б.ш. хисләрне белдерә. *– Дуэльдә атышкандыр, – дип шаяртты берсе, чирәмгә кырын ятып ашаган килеш. – Әйе, дуэльдә. – Әнвәр үчекләүгә үчекләү белән җавап кайтарырга булды.* Х.Камалов

6) Сорау җөмлә ахырында килеп, сөйләшүчене үз фикере белән килештерү, үз фикерен раслату, хуплату теләге белән кулланыла. *– Икенче ул алай эшләмәс. Әйе бит, улым? – ди.* Н.Дәүли. *Сүз канәгатьләндерми сине, әйеме?* М.Әмир. *– Дөрес түгел бит? Әйе?* Ш.Камал

7) Берәрсе эндәшкәндә җавап буларак кулланыла (гадәттә телефон аша сөйләшкәндә). *Әйе, Центральный, ни кирәк?* Ш.Мөхәммәдев. *Исәнләшеп, утырырга да өлгермәделәр, телефон шалтырады: – Әйе, профессор Таһиров, әйе.* Г.Әпсәләмов

**2.** *кис. мәгъ.* Әйтелгән сүзне җиңелчә раслауны яки сорауны белдерә. *Әнә син тегендә бас, әйеме?* Т.Миңнуллин. *Булган һәммә нәрсә – рабучийлар, коммунистлар кулында, шулар авызында. Аларга – шалканы, безгә – яфрагы, әйе?!* С.Рафиков

**ӘЙЛӘНӘ** *и.* **1.** 1) *геом.* Һәр ноктасы үзәктән тигез ераклыкта урнашкан яссылыктагы йомык кәкре сызык. *Индуслар бушлыкны «сунья» дип, ә гарәпләр «сифр» дип атаганнар һәм бушлыкны кечкенә әйләнә рәвешендә сурәтләгәннәр.* Р.Батулла. --- *әйләнә эче – бер бәйләнешле өлкә, әйләнә тышы һәм боҗра – күп бәйләнешле өлкәләр.* Комплекс үзгәрешле функцияләре теориясе нигезләре. *Ләкин ике әйләнәнең икедән күбрәк уртак ноктасы булуы мөмкин түгел.* Геометрия

2) Нәрсәне дә булса әйләндереп, уратып алган чите, кырые. *Тәрәзәләрнең әйләнәсе һәм башлары нәфис, матур итеп, бизәкләп эшләнгән.* Ә.Еники. *Тәрәзәләргә эчке кат рамнар ясалмаган, лапас түбәсен ябасы, әйләнәләрне ныгытасы бар...* Р.Төхфәтуллин. *Әйләнәсен (өйнең) уникешәр аршиннан, ундүрт ниргәле итеп, яңаны күтәрәсе иде...* Ю.Әминов // Озынча түгәрәк әйбернең аркылы кисеме тирәли озынлыгы. *Бу алыпларның (эвкалиптларның) биеклеге – йөз илле метрга, ә әйләнәсе утыз метрга җитә.* Могҗизалар энциклопедиясе

3) Кемне яки нәрсәне дә булса урап, чолгап алган чик; кыр, ян. *Шәйхи карт --- сарай әйләнәсендә каз-үрдәкләрне куыштыргалап йөри иде.* М.Мәһдиев. *Җитмәсә әле тагын, ак каен төбендә, аның бар әйләнәсен чуарлап, күпсанлы аксыл канатлар ята иде.* Г.Хәсәнов. *Сез күрәсез, мин бер чокыр төбендә утырам, әйләнәмдә, биек тау булып, коры ком өеме ята.* Ә.Еники

4) Тирә-як, мохит, тирәлек. *Бөтен әйләнәдә күңелсез бертөрлелек: су да су, ярлар ерак, җәйге матур яшеллекне якыннан күреп тә булмый.* Ә.Еники. --- *әйләнәңдә ал күбәләкләр оча...* Ш.Бабич. --- *үз әйләнәсендәге иптәшләреннән нәрсә белән булса да аерыла торган кешедер, дип уйламагыз.* А.Шамов

**2.** *бәйл. функ.* «Ел», «тәүлек» сүзләре янында килеп, башыннан ахырына кадәр, буена, дәвамында дигән мәгънәне белдерә. *«Ризык» дип зурдан кубып әйтсә дә, ел әйләнәсендә җанны асрарлык кына рәте бар аның...* Н.Гыйматдинова. *Ел әйләнәсенә нибары илле хезмәт көнең бар.* Р.Ишморат. *Хәзерге вакытта кешедә функцияләре тәүлек әйләнәсендә периодик рәвештә башкарыла торган йөздән артык физиологик система барлыгы ачыкланды.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ӘЙЛӘНӘЛИ** *рәв. к.* **әйләнә-тирәли.** --- *чокыр әйләнәли тыраклап йөрдем.* Г.Гобәй. *Малайлар учак әйләнәли тезелешеп утырганнар.* Г.Гобәй

**ӘЙЛӘНӘ́-ТИРӘ** *и.* 1) Нәрсәне дә булса урап алган тирәлек, нәрсәнең дә булса тирә-ягы, тирә-юне, чолганышы. *Әнә теге кашка байтал әйләнә-тирәдә бер атны да чыгармый, ди.* Ф.Хөсни. --- *чабыштан килгән атны, менә ни өчен, мәйдан уртасына керткәнче, әле бераз әйләнә-тирәдә чаптырып, аягын суыталар икән!* М.Мәһдиев. *Әйләнә-тирәдә уҗым тапталган, кара балчык чыккан, йоннар, тире кисәкләре чәчелгән иде.* М.Мәһдиев

2) Тирәлек, мохит, даирә. *Әйләнә-тирәдә сүз боткасы пешерүчеләр дә җитәрлек.* Л.Шагыйрьҗан. *Ә әйләнә-тирәңдә тормыш элеккечә үк кайнап тора.* Ф.Садриев. *Безнең әйләнә-тирәбездәге һәр әйберне һәм күренешне төрле яклап ачыклап килә торган бик күп сүзләр бар.* В.Хаков

**ӘЙЛӘНӘ́-ТИРӘЛИ** *рәв.* Берәр нәрсә тирәсендә, тирәли, әйләнә-тирәләп. *Озынлыгы зур булмаган яки дөрес булмаган формалы басуларны, гадәттә, әйләнә-тирәли йөреп уралар.* Урып җыю машиналары

**ӘЙЛӘ́Н-БӘЙЛӘН** *и.* Кулга-кул тотынышып, түгәрәк буенча әйләнеп, җырлап-биеп уйнала торган күмәк уен. *Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар.* А.Әхмәт. --- *кичен – кунаклар, ёлка, әйлән-бәйлән, уен-көлке, сый-хөрмәт.* Г.Гобәй. --- *аннары, бакча балалары кебек тотаклашып, җырлый-җырлый, әйлән-бәйлән уйнау.* Ф.Хөсни. *Яшьләр --- моңлы көйләр уйнаганда, әйлән-бәйләнгә җыелып, түгәрәк ясап җырлап йөриләр иде.* Г.Ахунов

**ӘЙЛӘНГЕЧ** *с. к.* **әйләнеч**. --- *авыраеп алгач, әйләнгеч юл белән авылга кайта.* М.Мәһдиев

**ӘЙЛӘНДЕРГЕЧ** *и.* Кул белән тотып әйләндерә торган сап, тотка (мәс., тегү машинасында). *Әйләндергечне майлау*

**ӘЙЛӘНДЕРЕ́П-ТУЛГАНДЫРЫП** *рәв.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса төрле якка борып, боргалап. *Якуб, үрелеп, булавканы кулына алды, әйләндереп-тулгандырып карады.* М.Хәбибуллин

2) *куч.* Ерактан уратып, читләтеп, кинаяләр белән. *Рабига әйләндереп-тулгандырып маташмады: – Сәмәрия апа үлде, бүген генә күмдек, – диде.* Н.Гыйматдинова

**ӘЙЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне үз көчәре буенча хәрәкәткә китерү. *– Тегермән әйләндерәбез! – дип кычкырды Әптелбәр.* Ә.Фәйзи. *Алар чар әйләндерә, мин үткенлим.* Я.Зәнкиев. *Ун елдан артык баранка әйләндерәм...* Т.Галиуллин

2) Берәр әйберне, кулда тотып, төрле якка бору, боргалау. *Ул шкафтан хәтфә янчык алып килде дә, шул янчыгын кулында әйләндерә-әйләндерә, сүзен дәвам итте...* Г.Әпсәләмов. --- *башы яртылаш янган табагачны, тотып, озак кына кулында әйләндерде.* Ф.Яруллин

3) Кемне яки нәрсәне дә булса бер яктан икенче якка каратып кую, икенче якка бору. *Кеше җиргә капланып яткан. Госман, тезләнеп, гәүдәне йөзе белән әйләндерде.* И.Салахов. *Башта кызның кул аркасын, аннары, әкрен генә әйләндереп, уч төбен, бармак битләрен үбеп чыкты.* Р.Кәрами

4) Нәрсәнең дә булса астын өскә каратып кую, салу, астын өскә чыгару. *Ике көн явып, бер көн аязса, бөтен халыкны борчак әйләндерергә кудылар.* Ф.Садриев. --- *печән өстендә аның кулыннан тырма төшми, әйләндерә, җыя, чүмәләгә куя.* Я.Зәнкиев. *Габит, буш әрҗә эченә бастырып куйган шешәсен алып, стаканын мөлдерәмә тутырды ---. – Шул гынамы?.. – Теге*

*ягын әйләндереп сала алмыйм ла инде!* Б.Камалов

5) Берәр киемнең сул ягын уң итеп яңартып тегү. --- *бу кадәр олы пальтоны минем кебек кеп-кечкенә кыз ничек әйләндереп чыксын, ди.* Ф.Яруллин

6) Кием-салымның эчен, җөйле ягын, тышкы якка чыгару. *Сабирҗан башындагы зур тимер юлчылар фуражкасын салды да астарын әйләндерде.* И.Салахов. *Татар хатыннары кием-салымның эчен тышка әйләндереп --- эләләр.* А.Хәлим

7) Нәрсәне дә булса уратып, камап алу, уртада калдыру. *Патша моны (егетне) аякка бастырды да тирәсен таш белән әйләндерде.* Әкият. *Урам ягы рәшәткә белән әйләндереп алынган гади генә авыл өенең ачык тәрәзәсе...* Казан утлары

8) Кем белән булса да берәр җирдә йөреп чыгу, уратып йөрү. – *Әй, Фәйзулла! Әйдә, гармун уйнап, урам әйләндер әле!* Г.Бәширов

9) Нәрсәнең дә булса кыяфәтен, тышкы күренешен, эчке формасын һ.б. үзгәртеп, башка әйбергә, күренешкә, хәлгә әверелдерү. *Аның суын парга әйләндерергә кирәк.* Ф.Яруллин. *Себер ягыннан өшеткеч җил исә, ул хәтта җир өстендәге карны да тотмый, һәрнәрсәне каткан бозга әйләндерә.* Ф.Бәйрәмова

10) Нәрсәнең дә булса эчтәлеген, үзгәртеп, башка нәрсәгә бору, икенче төрле мәгънә бирү, бүтәнчә итеп күрсәтү. *Ул, сүзне кызыкка әйләндереп, «кети-мети» дип, бармакларын минем тирәмдә уйнаткаларга тотынды.* Ф.Яруллин

11) Нәрсәне дә булса билгеле бер калыпка салып, теркәп, язып кую. --- *гади генә тоелган нәрсәләрне дә күңелләрне тибрәндерер җырга әйләндерү җиңел түгел шул.* Казан утлары

12) *фольк.* Тылсым, сихри көч ярдәмендә, нинди дә булса башка бер кыяфәткә, төскә, хәлгә, кемгә яки нәрсәгә дә булса әверелдерү (гадәттә халык авыз иҗаты әсәрләрендә). *Шул вакытта, бер әфсен укып, сихер куәте белән, Бәһрам белән Диләрәмнең икәвен дә кара ташка әйләндерде.* Мирас

13) Нәрсәнең дә булса кыйммәтен шуңа бәрабәр икенче нәрсә кыйммәте белән алмаштыру. *Акчасын, барын да алтынга әйләндереп, бер җиргә җир астына күмеп куйды.* К.Насыйри. *Без, кичен эштән кайткач, тагы шул алтын турында сүз башладык һәм акчага әйләндергәндә күпме булачагын исәпләргә керештек.* М.Гафури

14) Бер үк сүзләрне кат-кат әйтү, кабатлау. *Син торасың да, әйләндереп, бер сүз әйтәсең: ашлык, ашлык. Миндә Әндри казнасы юк лабаса!* С.Рафиков

15) *күч. сөйл.* Сүзне, текстны һ.б.ш.ны бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү. *Мин аңа кайбер сүзләрне әйләндереп бирәм.* Н.Фәттах *Банхуа аның сүзләрен чин теленә әйләндерде.* Н.Фәттах. *Ул үзе безнең белән ике төн утырды, безгә русча сүзләрне чәйнәп салды, без татарчага әйләндердек.* Г.Ибраһимов. *Соңра, безнең төрекчә белгәнне аңлагач, төрекчәгә әйләндерде.* Мирас

16) *күч.* Теләр-теләмәс кенә яки көчхәл белән, нәрсә дә булса әйтү. – *Сагынам дым, – диде Вәсилә, телен көчкә әйләндереп.* Н.Гыйматдинова

17) *күч.* Эшне оста, шома алып бару, хәл итү, эшләү, булдыру, башкару. *Менә күрерсез, эшне әйләндереп йөреп кайтыр.* С.Рафиков

**Әйләндерә бару** *к.* **әйләндереп бару.** *Якуб, русча укып, татарчага әйләндерә барды.* И.Гази. --- *бу нәрсә [колхозларның авырлык белән оешуы] – күбрәк ул иптәшләрнең, колхозның эчтәлеген бик нык өйрәнеп, һәрбер директиваны реаль фактка әйләндерә барырга күнекмәгәнлекләреннән.* Һ.Такташ

**Әйләндерә башлау** Әйләндерергә керешү. *Зиһене кызның һәр ымын, хәрәкәтен теркәп барган икән, ялгызы калды исә шуны, кинолента кебек, кире әйләндерә башлый.* Х.Камалов

**Әйләндерә бирү** Әйләндерүен дәвам итү. *Сугыш каһарманы, нибары унтугыз яшеннән сыңар аякка калган гвардияче, агач аягын кулында әйләндерә бирде.* А.Хәсәнов

**Әйләндерә язу** Чак кына, аз гына әйләндермичә калу. *[Гази ага] Элеккечә, соргылт бүреген, алдын артка әйләндерә язып, җайсыз итеп кигән.* М.Галиев

**Әйләндереп алу** 1) Нәрсәне дә булса тиз генә әйләндерү. --- *уң кулының имән бармагын, элмәк салгандай ишарәләп, муены тирәли әйләндереп алды...* М.Насыйбуллин

2) Берәр нәрсәне, урап, уртага алу, аны як-яктан тулысынча камау, чолгап алу. *Без, Үтәш мәдрәсәсенең ишегалдына кереп, атны туктатып та өлгермәдек, безне эреле-ваклы берничә дистә шәкертләр әйләндереп алдылар.* М.Гафури. *Кайбер вакыт ялгыз бүрене аучылар ерактан әйләндереп алалар.* Г.Ибраһимов. *Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илән, япун мәмләкәтен һәр әтрафтан су әйләндереп алган.* Мирас

3) Нәрсәне дә булса уртада калдырып, бөтен тирәсенә берәр нәрсә тоту; тирәләп, уратып алу. --- *йорт-җирен биек кирпеч койма белән әйләндереп алды...* Ә.Сафиуллин

**Әйләндереп бару** Шунда ук, рәттән әйләндерү. *Башту углы Габдулла, шундук, аның сүзләрен болгар теленә әйләндереп барды.* Н.Фәттах

**Әйләндереп бетерү** Тулысынча әйләндерү, үзгәртү, бөтенләй икенче төс, күренеш бирү. *Болай да монахка әйләндереп бетердең, дуадак каз сыман ялгыз йөри, мескен.* Ф.Садриев. --- *үзенең шул хикмәтле «ж» хәрефе белән бөтен укытучыларның башын әйләндереп бетермәгән булса, ихтимал, Сания аны бүген тәки күз алдына китерә алмаган булыр иде.* М.Әмир

**Әйләндереп җибәрү** Кинәт әйләндерә башлау, әйләнергә этәргеч бирү, әйләнә торган хәлгә китерү. --- *Каһир граммофонның тавыш чыгаргычын янга кайтарып, боргычын борды да тагын әйләндереп җибәрде һәм урындыгына утырды.* Ә.Гаффар. --- *ишек ярыгыннан күз салса, әби шулай сәке башына кабага утырган да, ди, бармак очына төкереп, орчыгын әйләндереп җибәрә икән.* Н.Исәнбәт

**Әйләндереп калу** Тиз арада нәрсәне дә булса әйләндерергә өлгерү. *[Мөфти:] Болар кәгазь чүбенә әйләнеп калганчы, тизрәк алтынга әйләндереп калырга кирәк.* Н.Исәнбәт

**Әйләндереп карау** Әйләндерергә омтылу

**Әйләндереп килү** Бөтен тирә-яктан уратып әйләндерү. *[Атны] Сикертеп чаптырып, базарны бер әйләндереп килде.* А.Гали. – *Әйдә, Гөлйөзем, бер әйләндереп киләм, – дидем мин, телемә шундый сүз килүенә үзем дә сөенеп.* З.Хөснетдинов

**Әйләндереп кую** 1) Әйләнгән хәлгә китереп калдыру

2) *күч.* Төбенә кадәр эчеп бетерү. – *Яле, тикшереп карыйк әле без аны, – дип сөйләнә-сөйләнә, бер стакан шәрабны әйләндереп тә куйды.* Р.Сәгъди

**Әйләндереп салу** 1) Икенче ягына әйләндерү

2) *күч.* Кемне дә булса аяктан егу (мәс., көрәштә). *Сабан туенда булсын, җыенында булсын, барысын әйләндереп сала идем.* А.Расих

3) *күч.* Эчемлекне төбенә кадәр эчеп яисә салып бетерү. *Тик дүртенче чокыр [сөтне] әйләндереп салганда гына бераз тынычлана төштем.* А.Шамов

**Әйләндереп ташлау** 1) Нәрсәне дә булса кинәт астын өскә әйләндерү. *Шундый көннәрне Язидә, таулар әйләндереп ташлардай дәрт белән, армый-талмый, уйнап кына эшли торган иде.* Г.Бәширов

2) Җай гына барган тормышны юкка чыгару, авырлыклар, бәла-казалар китерү. *Меңнәр-миллионнарның җаннарын айкап, тормыш-мәгыйшәтен җимереп, бар дөньяның астын-өскә әйләндереп ташлаган сугыш имгәтте аларның язмышын.* М.Гафури

**Әйләндереп тору** 1) Бертуктаусыз әйләндерү

2) Әле, хәзерге вакытта әйләндерү. *Сепарат әйләндереп торган Фатыйма һәм аның янындагы --- Нәсимә күзләренә чалынды.* А.Расих

**Әйләндереп төшерү** 1) Җиңү, җимерү, алып ташлау. *Әле Минай хәтле Минай ханны әйләндереп төшерергә үрелә бу, әле Балык кебек эт-бетне дә кабып йотарга әзер.* В.Имамов

2) Үткәрмәү, уздырмау, кире тавыш бирү. *Сайлауда кандидатурасын әйләндереп төшерделәр*

**Әйләндереп чыгару** Берәр авыр проблеманы, эшне башкарып чыга алу. *Берничә сарык һәм ике йөк утын эшли алмаган эшне ике такта чәй әйләндереп чыгарды.* М.Мәһдиев

**Әйләндереп чыгу** 1) Башыннан ахырына кадәр һәрберсен әйләндерү

2) Барлык ягыннан да уратып, тирәләп әйләндерү

**Әйләндереп яту** *к.* **әйләндереп тору** (*2 мәгъ.*)

**ӘЙЛӘНЕЧ** *с.* **1**. Урап, әйләнеп йөри торган, туры булмаган. *Әйләнеч юлдан булса да, берәр станцага барып чыгарга уйлады.* И.Низамов. *«Җәмилә җиләклеге» дигән урынга җиткәч, ул атын туктатты, укытучыга ат белән әйләнеч юлдан барырга кушты...* Г.Әпсәләмов

**2**. *и. мәгъ.* Урау юл. *Әйләнечтән юл туры.* Әйтем. *Әйләнеч булса да юл яхшы, сукыр булса да кыз яхшы.* Мәкаль

**ӘЙЛӘНЕШ** *и.* 1) Берәр нәрсә тирәсендә яки йомык әйләнә буенча хәрәкәт. --- *алар [тәрәзә рамнары], кояш әйләнеше буенча, һәр сәгатьтә остаханәне тигез яктыртып тора иде.* Р.Мирхәйдәров. *Самолёт шәһәр өстеннән бер әйләнеш ясап алды.* Г.Ахунов. *Бал кортлары тәбрик әйләнеше ясады.* Г.Хәсәнов

2) Барып, кире әйләнеп кайту хәрәкәте. *Син сменада утыз дүрт әйләнеш ясарга тиешсең.* Ф.Хөсни

3) Берәр процесста кабатлана торган тулы цикл. *Чәчү әйләнешен мәҗбүри керттеләр, җиренә карап чәчү бетте.* М.Мәһдиев. *Илгә әйләнешкә чыккан акча беркая да китми, юкка чыкмый, шул килеш әйләнеп йөри бирә.* Р.Фәизов. *Икенчедән, сәүдә эшендә «товар әйләнеше» дигән нәрсә бар...* Ф.Яруллин

4) Нәрсәнең дә булса билгеле бер өлкәдә кулланылу процессы. *Күпме өрнәңа тәгъбирләр, сүзләрне әдәби әйләнешкә кертә.* Х.Камалов. --- *халкыбызның күп гасырлык тарихи-мәдәни мирасын эзлекле рәвештә кайтару һәм фәнни әйләнешкә кертү белән махсус шөгыльләнгән.* Мирас

5) Үзгәреш, үсеш, алга китеш. *Әмма аннан соңгы дәвердә тарих куласасы төрле фасылда әйләнеш кичерде...* Казан утлары

**ӘЙЛӘНЕШЛЕ** *с. к.* **әйләнмәле.** *Тигез әйләнешле хәрәкәт.* Физика

**ӘЙЛӘНМӘ** I *с.* **1**. 1) Әйләнә торган. *Әйләнмә хәрәкәт өермә белән тыгыз бәйләнештә.* Физика

2) *к.* **әйләнеч**. *Ул, бераздан, төп юлга килеп чыга чыгуын, ләкин ул чагында инде күңелдә «Теге әйләнмә юлны үтү бик кирәк идеме соң әле?» дигән сорау туа.* М.Вәли-Барҗылы

3) Җепселләре уралып-уралып үскән. *Әйләнмә агач*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Әйләнеч урын. *Алмагачтан алма алдым, Әйләнмәдән юл салдым.* Җыр

2) Төрле юнәлештәге ике агым кушылудан барлыкка килгән суның өслектәге бүрәнкә сыман әйләнеп торган хәрәкәте; бөтергеч, чоңгыл; упкын. *Гарип уйлар-сүзләр кычкырдык, Озак шулай аңга килмәдек. Тормыш диңгезендә – әйләнмә, Хәлебезне шунда шәйләдек.* Р.Мингалим

**ӘЙЛӘНМӘ** II *и. грам.* Үзара синтаксик яки семантик бәйләнештә торган сүзләр тезмәсе. *Жилфердәүче флаг, әләмнәр әллә кайчан фразеологик әйләнмәгә әверелгән иде инде.* А.Яхин

**ӘЙЛӘНМӘЛЕ** *с.* 1) Бөтерелә торган, уралма. *Әйләнмәле карама, бәйләнмәле карама, соры бүре куып килә, яшерсәнә, карама.* Әкият

2) Әйләнә торган, әйләнеп торган. *Әйләнмәле витринада – кичә уйналган спектакльгә афиша.* Н.Исәнбәт

3) *күч.* Бик катлаулы, авыр. --- *үз юлында төрле әйләнмәле борылышлар, зигзаглар ясаганлыгын исбат итә...* Ф.Хөсни

**ӘЙЛӘНҮ** *ф.* 1) Үз күчәре тирәсендә йөрү, әйләнә буенча хәрәкәт итү. --- *балчык сарган тарантас тәгәрмәчләре авыр гына әйләнәләр...* Я.Зәнкиев. *Еллар узды – Җир шары һаман әйләнә бит...* М.Мәһдиев. *Ләкин ул белә, сәгать телләре кояш белән бергә әйләнә.* Н.Дәүли

2) Берәр нәрсә тирәсеннән йөреп, урап чыгу. *Без бакчага кердек, мунча тирәли әйләндек...* Г.Гобәй. *Ханым палубаны бер әйләнде, ике әйләнде...*

Ә.Еники. --- *үзе һаман йөренә-йөренә, коридордан, кухнядан әйләнде.* М.Мәһдиев. --- *аланны бер әйләнербез, бәлки?* Н.Гыйматдинова

3) Берәр кеше яки әйбер тирәсендә күбрәк булырга тырышу, янында йөренү, тирәсендә бөтерелү. *Ирекле-ирексез, гел Вәли Сафиуллин тирәсендә әйләндем.* Г.Кутуй. *Энем белән сеңлем әби янында әйләнәләр, берсен-берсе бүлдереп, бакчада өйрәнгән уеннары турында сөйлиләр.* Н.Дәүли. *Ул, выжылдый-выжылдый, үзе йөгерде, үзе туктаусыз беләкләрен әйләндерде, кырын-кырын карап, гел алар тирәсендә әйләнде...* Ф.Садриев. *Егет, һавада йодрык уйнатып, иманнәр тирәсендә әйләнде.* Н.Гыйматдинова

4) Берәр әйбер тирәсендә нидер эшләү, нәрсәнеңдер янында ыгы-зыгы килү. *Сафа моңар җәберсенде: ул бит күптәнрәк промыслолар тирәсендә әйләнә.* Ш.Камал. *Буфетчы әрмән шешәләрне җыештырып маташа, дүлмән бүрекле бер кеше лампалар тирәсендә әйләнә.* Ш.Камал

5) Кая да булса барып, кире борылып йөреп кайту, барып килү. *Спирт заводын, пар тегерменен әйлән.* И.Салахов. *Ялгыз йөрү дә кайчак күңелле: болыннарны-кырларны иңлисең, урман буйларын әйләнәсең, табигать матурлыгына сокланып туймыйсың.* Н.Хәсәнов. *Сәгыйдулла, дежур көнем, фермаларны әйләнәм, дип чыгып китте.* Ф.Садриев

6) Бер яктан икенче якка борылып яту. *Әле бер як белән яттылар алар, әле икенче якка әйләнделәр.* Г.Гобәй. --- *Вәли абзый, нигәдер, ыңгырашып, бер ягыннан икенче ягына әйләнә.* Ә.Фәйзи. --- *Айрат, йоклап китә алмыйча, яшел сандык өстендә зыр-зыр әйләнә.* Ф.Яруллин

7) Нәрсәгә дә булса йөз белән борылу. *Чәчәкләр һәр иртә кояшка таба әйләнделәр.* Һ.Такташ. *Авыру яткан җирендә кунакка таба әйләнде...* Г.Ибраһимов. *Әйләнеп карасам, теге гаепле малай Шаһбаз да минем арттан чаба.* Г.Ибраһимов. *Хәзрәт --- ишекнең Америка системасында эшләнгән биген ачып, ишектән яртылаш кереп, мосафирга йөзе илә әйләнде.* Г.Камал

8) Даими йөрү, йөреп тору. *Төннәрен бик рәхәт икән, нәкъ безнең янда гына машиналар әйләнә.* Т.Гыйззәт

9) Гәүдәне икенче якка бору, борылу. *Ул, күз яшьләрен карчыгына сиздермәс өчен, аңа аркасы белән әйләнде.* А.Шамов. *Сәгыйдә, аны күреп, тиз генә арты белән әйләнә.* Һ.Такташ. *Менә ул көчхәл белән үргә күтәрелде, туктады, җилгә арты белән әйләнде.* И.Салахов

10) Берәр нәрсә өстеннән, очып, түгәрәк ясау. *Немец самолёты, бәйләнчек шөпшә шикелле, әйләнеп-әйләнеп, берничә тапкыр поезд өстеннән очып узды.* М.Әмир

11) Һавада очу, бөтерелү. *Гөлләр гөлгә бәйләнә, Күбәләкләр әйләнә.* Н.Исәнбәт. *Үрдәкләрнең байтагысы күл өстеннән пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр...* Я.Зәнкиев

12) Башка нәрсәгә әверелү, сыйфаты, халәте үзгәрү, башкача күренеш, төс алу. *Ул чагында инде Сиваш кереп булмастай сазга әйләнә.* Г.Бәширов. *Җир йөзе гөл бакчасына әйләнер...* Г.Ибраһимов. *Завод, шәм шикелле янып, күмергә һәм көлгә әйләнде.* Ә.Фәйзи

13) Түгәрәк буенча биеп-җырлап йөрү. *Ул --- вакыты белән салмак кына, ә вакыты белән бөтерелеп-бөтерелеп, вальс әйләнде.* Р.Кәрами. – *Әйдә, гел боегып кына торма, Нәҗметдинов, бер рәхәтләнеп вальс әйләник әле!* – дип, *аны тинтерәтергә тотынды.* В.Нуруллин. *Уртада калучы җырлый, аңа кушылып, түгәрәктә әйләнә яшьләр.* Я.Зәнкиев. *Яшьләр яңадан күңел ачарга – түгәрәкләнеп җырлый-җырлый әйләнергә тотындылар.* А.Шамов

14) *фольк.* Тылсым, сихри көч ярдәмендә нинди дә булса башка бер кыяфәткә, төскә, хәлгә, кемгә яки нәрсәгә дә булса әверелү (гадәттә халык авыз иҗаты әсәрләрендә). *Шул сәгать җанварлар һәммәсе ташка әйләнгәннәр. Егет тә ташка әйләнгән.* Әкият. *Йөзек, җиргә бәрелгәч, ярмага әйләнә.* Әкият. *Әбүгалисина үзенең таянып йөри торган таягына: «Ат бул!» – диде, таяк иярләгән аргамак атка әйләнде.* К.Насыйри

15) *күч.* Һаман бер үк нәрсә күңелгә, искә килү, борчып тору. *Аның миендә һаман бер уй әйләнде.* Г.Ибраһимов. *Ә тел очында һаман шул бәйләнчек такмак әйләнде.* Г.Әпсәләмов

16) *күч.* Нәрсәгә дә булса артык игътибар итү, һаман да бер үк сүзне кабатлау. *Барысының да сүзләре чама белән бер тирәдә әйләнә.* М.Мәһдиев

◊ **Әйләнеп кайту** Яңару, яңадан керү. *Сугыштан соң, авылларга Сабантуй үткәрү гадәте әйләнеп кайтты.* Г.Ахунов. **Әйләнеп чыга алмассың** Киң, иркен, күп бүлмәләрдән, каралтылардан торган. *Аның ишегалдына килеп керсәң, әйләнеп чыга алмассың.* Н.Фәттах

**Әйләнә бару** Бер-бер артлы әйләнү, акрынлап, икенче сыйфат алу. *Иң элек, тау, менә башлагач, шактый биек булып чыкты, аннары, югарырак күтәрелгән саен, ул текәрәккә әйләнә барды.* Ә.Еники. *Йолкынган һәр бөртек чәч алтын кылга әйләнә бара – тот та бау иш.* М.Кәрим

**Әйләнә башлау** Әйләнергә тотыну. *Пароходның тәгәрмәчләре акрын гына әйләнә башлыйлар.* К.Нәҗми. *Хәдичә түти, каушавы һәм куанычы белән бөтен өйне тутырып, почмак белән олы як арасында әйләнә башлады.* Г.Бәширов. *Бу инде, иптәшләр, талашка әйләнә башлады.* Г.Әпсәләмов

**Әйләнә төшү** Тагы да бераз әйләнү, беркадәр әйләнү

**Әйләнеп алу** Кыска вакыт эчендә, тиз-тиз, бер генә тапкыр әйләнү. *Кәримә ахирәтен килеп кочаклады, кызлар бүлмәдә зырлап әйләнеп алдылар.* М.Хәбибуллин. *Ике-өч секунд эчендә магнитофон кәтүкләре тызбыз әйләнеп ала.* Ф.Баттал

**Әйләнеп бару** Акрынлап, аз-азлап әйләнү. – *Революция шәүләсе белән обывательне куркыту шулай ук традициягә әйләнеп бара,* – *диде Чернов.* И.Гази. *Үзең күреп торасың, алар хәзер шәһәр өчен куркыныч көчкә әйләнеп баралар.* Ф.Бәйрәмова. *Әллә бер хыялыйга әйләнеп барам инде?* М.Кәрим

**Әйләнеп бетү** Бөтенләй башкага әйләнү, тулысынча башка эчтәлек алу. *Ул «азатлык, бәйсезлек, ирек» дигән төшенчәләр, чәйнәлә торгач, чүбеккә әйләнеп бетеп, бер тиенсезгә калган*

*иде.* Н.Измайлова. *XVII йөзгә алар* [*Романов татарлары һәм кенәз Юсуповлар*]*, барысы да диярлек, чукындырылып, урысларга әйләнеп беткәләр.* Р.Әмирхан. *Шулай үзен-үзе ашап, минем дә җаныма тиеп, тәмам бабайга әйләнеп бетте хәзер.* В.Нуруллин

**Әйләнеп йөрү** Бер тирәдә әйләнгәләү. *Турыларында карчыга әйләнеп йөри иде.* И.Гази. *Мичкә тирәсендә әйләнеп йөри торгач, бер бүренең койрыгы мичкә эченә керде.* К.Насыйри. *Иманкулов... Бу фамилия каядыр күктә әйләнеп йөрде дә сүнде.* И.Салахов

**Әйләнеп калу** Бөтенләй башкага әйләнү, соңгы вакытта, хәзер икенче рәвешкә керү, башкача эчтәлек алу. *Җиңеннән тарткач, сискәнеп борылып карый... Ниндидер механический кешегә әйләнеп калды.* И.Гази. *Солтан --- янә авыл малаена әйләнеп калды.* Г.Ахунов

**Әйләнеп китү** 1) Кинәт әйләнә башлау. *Тәгәрмәчләр кинәт зырлап әйләнеп киттеләр.* И.Салахов. *Башы бик нык әйләнеп китсә дә, егылмады, кризисны койка иңсәсенә ябышып уздырды.* Ф.Шәфигуллин

2) Башкага әверелү, акрынлап үзгәрү. *Кем уйлаган, дөньялар болайга әйләнеп китәр, дип...* А.Гыйләҗев. *Бара-тора, җыелыш гади сөйләшеп утыруга әйләнеп китте.* И.Гази

3) *күч.* Кешесен туры китерә алмыйча яки бикле ишеккә килеп, йомышын йомышламыйча кире кайту

**Әйләнеп кую** 1) Бер тапкыр әйләнү, икенче ягына әйләнү

2) Кинәт нәрсәгә дә булса әйләнү, әверелү. *Болай, эш ташлап, собраниеләргә еш йөри башлагач, бичәкәй, Гыйзелниса кәҗәсенә әйләнеп куймасаң ярар да...* М.Кәрим

**Әйләнеп тору** 1) Бертуктаусыз әйләнү, озак әйләнү. *Машина бертуктаусыз --- выжылдап әйләнеп тора.* Г.Ибраһимов. *Аннан бирерәк зур арба тәгәрмәче әйләнеп тора.* К.Нәҗми. *Магнитофон тасмасы ике сәгать буе әйләнеп торды...* М.Насыйбуллин. *Бер зур машинаның лентасы әйләнеп тора.* А.Алиш

2) *күч.* Бертуктаусыз үзгәрү, яңару

**Әйләнеп төшү** 1) Өстән аска таба салынып тору. --- *чалбар балагы, хохолларныкы төсле, өске яктан бераз әйләнеп төшәр.* Г.Ахунов

2) *күч.* Егылып төшү. *Атарчылар утырган җирдән кузгала да алмадылар, чалкан әйләнеп төшеп, гырлый да башладылар.* И.Салахов. *И, кыен да була инде кайчагында үз-үзеңне җиңү! Үзең сугасың үзеңә, үзең әйләнеп төшәсең, торып, тагын үзеңне кабыргалап әйләндереп саласың.* Ф.Шәфигуллин

**Әйләнеп узу** 1) Тирәсеннән, яныннан әйләнеп китү, урау. *Кайчак, ачы елый-елый, өстебездән бибекләр әйләнеп уза.* А.Расих. --- *рота алдыннан берничә мәртәбә әйләнеп узса да, теле ачылып китмәде...* Г.Бәширов

2) Читләтү, читләтеп китү. *Килдеме соң аңа үзе көткән бәхет? Нигә ул әйләнеп узды, аңардан читтә, еракта йөрде?* Н.Хәсәнов

**Әйләнеп чыгу** 1) Тулысынча, бөтен җирне урап карап йөрү. *Габбас мулла тарантастан төште, кара күмер булып калган йорт урынын бер әйләнеп чыкты...* Г.Ахунов. *Икенче көнне Арсланов районның барлык хуҗалыкларын әйләнеп чыкты.* Ф.Садриев

2) *күч.* Төрле якка таралу, ишетелү, барысына да билгеле булу. *Бу хәбәр дә Кара Чыршы белән Ташлы Тау арасын ике-өч көн эчендә әйләнеп чыкты.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Нәрсә дә булса бик күп, артыгы белән булу, өелеп тору. *Аның йортында утыны әйләнеп чыккан*

**ӘЙЛӘНЎ КҮЧӘРЕ** *и. физ.* Әйләнә торган җисемнең үзеге аша үткән туры сызык. --- *а – авырлык үзәгеннән әйләнү күчәренә кадәр ераклык* ---. Физика

**ӘЙЛӘНҮЛЕ** *с.* 1) Әйләнә торган, әйләнмәле. *Әйләнүле хәрәкәт*

2) *филос.* Кайтулы. *Әйләнүле һәм әйләнүсез мөмкинлекләр*

**ӘЙЛӘНЎ ПЕРИОДЫ** *и. физ.* Бер әйләнеш ясау вакыты. --- *планетаның Кояш тирәсендә әйләнү периоды – траекториянең ярымкүчәренең кубына пропорциональ.* Физика

**ӘЙЛӘНЎ-ТУЛГАНУ** *ф.* 1) Кайда да булса яки кемнең дә булса тирәсендә тиз-тиз йөренү, бөтерелү. *Иван Матвеевич Госманны, кочаклап диярлек, түргә китереп утыртты, бертуктаусыз сорашты --- кыстады, әйләнде-тулганды* ---. И.Салахов

2) *күч.* Берәр эш белән мәшгуль булу, ыгы-зыгы килү. *Йөрисең шунда, әйләнеп-тулганып, бик гади генә эшләр башкарып.* А.Расих

3) *күч.* Берәр нәрсәгә артык игътибар итү, һаман бер әйбергә тукталу, шуннан читкә чыкмау турында. *Әйләнә-тулгана торгач, сүзләре гаилә хәлләренә кайтып төште.* Б.Камалов. *Баягы сорау тагын да авыраеп, һаман күңелне биләп әйләнде-тулганды: «Нигә?!»* И.Салахов

**ӘЙЛӘНЧЕК** *и.* **1.** 1) *сөйл.* Үзәк багана тирәсендә әйләнеп торган баскычлардан яки ат, дөя һ.б. сыннар рәвешендә ясалган утыргычлардан гыйбарәт аттракцион корылма; карусель. *Аннан соң әйләнчек акрын гына туктала.* Ә.Фәйзи

2) Терлекләрнең (бигрәк тә сарык һәм кәҗәләрнең) бер урында әйләнеп торуы белән характерлы авыру. *Кәҗәбез безнең гел бер урында әйләнеп торырга ярата. Әни әйтә, аңа әйләнчек булган, ди.* И.Гази

3) *бот.* Дала һәм чүлдә үсә торган, чәнечкеле, кыска тамырлы ярым куак яки үлән үсемлек (орлыгы өлгереп җиткәч, тамырыннан аерылып, җил уңаена тәгәрәп йөри); дүңгәләк; *русчасы:* **перекати-поле.** *Бүрек кадәр булып, башкалардан бөтенләй аерым урында әйләнчек атлы үлән урнашкан иде.* Г.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) *к.* **әйләнеч.** *Әйләнчек юл белән бару*

2) Әйләнчек (*2 мәгъ.*) авырулы кебек. *Аның күз карашы мәгънәсез, төссез, әйләнчек сарыкныкы кебек.* Г.Әпсәләмов. *Әйләнчек сарык кебек әйләнеп йөри торгач, биек бер койма буйлап, Воскресенский урамына менә башладылар.* Г.Ахунов

**ӘЙЛӘНЧЕ́К КОҢГЫЗЛАР** *и. купл.* Су өстендә әйләнеп йөзә торган коңгызлар; *русчасы:* **вертячки.** *Ялтырап торган кечкенә әйләнчек коңгызлар да юк хәзер суда. Алар --- су төбендәге ләмгә күмеләләр.* Ф.Ибраһимова

**ӘЙЛӘ́Ү** *ярд. ф. иск.* Кылу, итү. *Җир йөзендә көчле, бай империалистлар, җыелышып, Бәйләгәннәр дә Шәрыкның күзләрен ныклап кысып, Үзләре читтән тамаша әйлиләр, мыскыл итеп...* М.Гафури. *Ташларда язулар, --- догалар һәм --- «Фәлән углы фәлән --- фәлән кызы фәлән --- сәнәдә дарелфанига килеп --- сәнәдә дарелбакыйга рихләт әйләделәр --- җаны җәннәттә улсын...» һ.б.лар язылган.* И.Салахов

**ӘЙЛЕ́-ШӘЙЛЕ** *рәв.* 1) Нәрсә эшләргә белмичә, аптырап, икеләнеп; ышанычы бетеп; шикләнеп. *Шуңа күрә ул хәзер бу карточканы стенага элү белән элмәү арасында әйле-шәйле калды да, бераз уйлап торгач, элмәскә булды.* Ф.Әмирхан. *Рәшит, әйле-шәйле бераз торганнан соң, пенснесен уңайлап куйды да сөйләргә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Берничә көн Әбелмәних әйле-шәйле йөрде.* Г.Әпсәләмов

2) Аңкы-миңке, иләс-миләс, аңгыра, тиле. *Соңыннан, үз палатасында аңга килгәч тә, беркадәр вакыт әйле-шәйле булып ятты.* Г.Әпсәләмов. *Шул көннән соң Исмәт әйле-шәйле булып китте.* Г.Әпсәләмов

3) Сәер, шикле, шик тудыра торган. *Кысан, җитешсез тормыштан кинәт иреккә чыккан хатын-кызның күңеле әйле-шәйле яңа фикерләр белән тула.* А.Гыйләҗев

4) Күңел салмыйча, аннан-моннан, теләсә ничек. *Башта әйле-шәйле эшләп йөргән Каюм ага --- хезмәт армиясенең чыныккан солдатына әверелде.* М.Шабай

**ӘЙРӘН** *и.* 1) Катыкка салкын су кушып болгатып ясалган эчемлек. *Егетләр, өйалдына чүмәшеп утырган килеш, әйрән эчәргә керештеләр.* С.Җәләл. *[Рәйхан] Кулында – савыт, аяк өстендә әйрән сыеклый, Бикбулат алдына китереп куя.* Н.Исәнбәт. *Мин авылдагыча салкын әйрән әзерләп куярмын, күңелне ачарга яхшы була ул.* Г.Әпсәләмов

2) Май язганда аерылып чыккан әчкелтем сыеклык. *Теге, хәрби кеше, нанын әйрәнгә манчый-манчый, комсызланып ашый, йота башлады.* И.Салахов

◊ **Әйрән баш** Аңгыра, тинтәк

**ӘЙРӘНЛӘНҮ** *ф.* Әйрән бүленеп чыгу; әйрәнгә әверелү

**Әйрәнләнеп бетү** Тәмам, тулысынча әйрәнләнү

**Әйрәнләнеп чыгу** Әйрәнләнгән хәлгә килү

**Әйрәнләнеп тору** Әйрән сыман булып күренү

**ӘЙТӘМ** *кер. сүз* Берәр сәбәбе бардыр дип уйлаган идем, нәрсәдер сизенгән дә идем, мәгънәсендә; эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алганны белдерү өчен кулланыла. *Әйтәм, бу арада күренми тордың.* А.Әхмәт. *Әйтәм, өйдән әйберләр югала да югала, менә кем урлый икән аны!* А.Шамов

**ӘЙТӘ́М АНЫ** *кер. сүз к.* **әйтәм**. *[Мирзәки:] И малакаем, и Акмал сабакташ, әйтәм аны, балта остасы Зиятдинның улы кайткан, --- дип, авыл ду-чат килә.* Г.Ахунов. *Әйтәм аны, беркайда юклар, ах, тиктормаслар, чуар оеклар.* Ш.Галиев. *Әйтәм аны, турыларыннан уза башладыңмы, тәрәзә кагалар, кул болгыйлар.* Т.Гыйззәт

**ӘЙТӘ́М БИТ** *кер. сүз* Сөйләүченең фикере белән килешеп, аның дөрес булуын раслаганда, үзенең күптәннән шул фикердә булуын белдергәндә кулланыла. *[Хуҗа:] Әйтәм бит, кеше безнең дәрәҗәгә менүне күтәрә алмый.* Н.Исәнбәт. *Әйтәм бит, халык бик килә эш сорап.* Ф.Сафин

**ӘЙТӘ́М ҖИРЛЕ** *кер. сүз к.* **әйтәм**. *– Әйтәм җирле, эт өргән сыман иде, – дип куйды Мотаһир үз-үзенә.* Р.Кәрами. *Әйтәм җирле, Таҗиеңа кыз таба алмыйсыз.* М.Фәйзи. *[Ата чыпчык ана чыпчыкка:] Кара әле, анасы, бу – безнең балабыз түгел, күке баласы бит: үз балабыз дип, күке баласын тәрбияләп үстергәнбез. Әйтәм җирле, яз көне безнең оя тирәсендә бер күке койрыгын боргалап йөргән иде.* Ак юл

**ӘЙТӘ́М ИЧ** *кер. сүз к.* **әйтәм бит**

**ӘЙТЕЛЕШ** *и.* 1) *лингв.* Сөйләм авазларының һәм сүзләрнең әйтелү рәвеше; фонетик яңгыраш. *Кайвакыт, аваз әйтелешендәге төп хәрәкәтләрнең аерылып көчәюе нәтиҗәсендә, яңа аваз барлыкка килә.* Ф.Сафиуллина

2) Әйтү, сөйләү интонациясе, тоны, әчке кичерешләр салынган төсмере. *Әмма сүзләренең әйтелеше ачты да салды эч серен.* Г.Бәширов

**ӘЙТЕЛЕШЛЕ** *с.* Билгеле бер әйтелеше булган. *Татар халкы, элек-электән, яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган, матур эчтәлекле, аһәңле, җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан.* Г.Саттар-Мулилле. *Кызганычка, барлык карталарда да шәһәр исемнәре итальян теленә яраклаштырып алынган яисә Европада гамәлдә булган әйтелешле исемнәр белән аталган.* Р.Фәхретдинов

**ӘЙТЕЛМӘ** *и. лингв.* Гыйбарә, тәгъбир. *Маркс белән Ленинннан да берәр әйтелмә алып, төрләндереп җибәрергә кулыннан килмәгән икән шул.* Ф.Яхин. *Берничәсен генә әйтеп китим: сүзләрне ялгыш, урынсыз куллану, --- төрле әйтелмә, тәгъбир, әйләнмәләрдә туган телнең сүзләр бәйләнеше кагыйдәләрен бозу, кытыршы, ясалма, аңлаешсыз сүзләр, җөмләләр куллану һәм башка күренешләр.* Ватаным Татарстан

**ӘЙТЕЛМӘЛЕ** *с. к.* **әйтелешле**

**ӘЙТЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **әйтү**. *Болар – Карышкан кызларының яңа шартларда әйтелгән асыл сүзләре иде.* Г.Әпсәләмов. *Тавыш белән түгел, кайнар сулыш белән генә әйтелгән бу сүздән Хәлимнең беркавымга хәтта тыны кысылды.* И.Гази

2) Тасвир ителү, белдерелү, теркәлү, язылу. *Борынгы китапларда әйтелгән: адәми зат – дөньяда иң хәйләкәр зат.* Г.Әпсәләмов. *XII съезд карарларын укыганыгыз бардыр, беләсездер ---, анда әйтелгән: татар белгечләрен үстерүгә шовинистлар, йомшак кына итеп әйткәндә, салкын карыйлар ---.* И.Гази

3) Исемләнү, аталу. *Тау иленең элгәреге исеме Тәвангир авылы дип әйтелгәндер, хәзердә Тау иле дип йөртәләр.* К.Насыйри

**Әйтелә бару** *к.* **әйтелеп бару**

**Әйтелә башлау** Әйтелергә тотыну. *--- борынгы формасы «төгүн» (кләймә), һәм ул, «адгу» (аю) сүзе кебек үк кыскартылып, «тиен» яки «тин» дип кенә әйтелә башлаган.* Ә.Мөхәммәдиев

**Әйтелә килү** *к.* **әйтелеп килү.** *Моннан биш-алты ел элек секциядә*

*дә, идарә һәм язучыларның күп җыелышларында да поэманың азрак язылуы, хәтта артта калуы, бу жанр, аның үзенчәлекләре турында зуррак сөйләшүләр кирәклеге әйтелә килде*. Р.Гаташ

**Әйтелә тору** *к.* **әйтелеп тору**. *Әмма язучының медицина хезмәткәрләренә, мәхәббәткә карата шәхси позициясе әледән-әле әйтелә тора*. Г.Әпсәләмов

**Әйтелеп бару** Еш кабатлану, һаман да әйтелү; берсе артыннан икенчесе әйтелү. *Язучының фәлсәфи карашлары, моңа кадәр без күрергә күнекмәгән рәвештә, ачыктан-ачык әйтелеп баралар*. А.Шәмсутова

**Әйтелеп бетү** Барысы да әйтелү. *Нәкъ менә серлелек, әйтелеп бетмәү әсәрне реализм мәйданыннан алып китә*. Д.Заһидуллина

**Әйтелеп йөртелү** Һәрвакыт, гел әйтелү. *Мәкальләр күп сыналган эмпирик тәҗрибә һәм дәлил урынына әйтелеп йөртелә*. Р.Шәймәрданов

**Әйтелеп килү** Һәрвакыт, күптәннән даими рәвештә әйтелү. *Әлеге төр алкышлар яшь киленне ак җәймәгә яки мендәргә бастырып, яисә, чаршау эченә кертеп, бал-май каптырганда әйтелеп килгәннәр*. М.Бакиров

**Әйтелеп тору** Әледән-әле, еш әйтелү; даими әйтелү. *Шуңа күрә микән, ул җырлар турында матбугат битләрендә фикерләр дә әйтелеп тора*. Р.Миңнуллин

**Әйтелеп узу** *к.* **әйтелеп үтү.** *«Фәвакиһел җөләса» китабында мәкаль текстлары алдыннан кечкенә генә кереш сүз дә әйтелеп уза*. К.Насыйри

**Әйтелеп үтү** Сүз уңаенда әйтелү; алдан, югарыда әйтелгән булу. *– Дәртле кояш удар ялкындай, Эш маршында коммун планы!!! – дигән бер пародия әйтелеп үтелгән иде*. Х.Туфан

**Әйтелеп чыгу** Һәрберсенә әйтелү

**ӘЙТЕМ** *и.* Мәкальдән аермалы буларак, төгәлләнгән фикер тәшкил итмәгән тотрыклы һәм, гадәттә, образлы тәгъбир. *Мишәрдә бер әйтем бар: аең-көнең уртак булса да, ирең уртак булмасын, диләр.* Г.Әпсәләмов. *Үзенең мәгълүм әсәренә Пушкин «Береги честь смолоду» дигән әйтемне эпиграф итеп юкка гына китергәндер дисеңме?* Ф.Шәфигуллин. *1880 елдан башлап, К.Насыйри татар халык авыз иҗатының төп жанрларыннан булган җырлар, мәкаль, әйтемнәр һәм бәетләрне бастырып чыгару эшенә керешә.* М.Гайнуллин

**ӘЙТЕНҮ** I *ф. эвф.* Сүгенү; әшәке, тәүфыйксыз сүзләр әйтү

**ӘЙТЕНҮ** II *и.* Фольклор жанры: кош-кортларга, бөҗәкләргә карата яки көнкүрештәге берәр вакыйга, шөгыль уңае белән башкарыла торган шигъри әсәр (мәс., *Тилгән, тилгән, Чеби урларга килгән!*)

**ӘЙТЕРГӘ́ КИРӘК** *кер. сүз* Фикернең әһәмиятен күрсәтү, ассызыклау максатыннан кулланыла. *[Изаил Харисович] Өр-яңа өлкәдә эзләнүләр алып бара һәм, әйтергә кирәк, шактый уңышлы алып бара.* М.Маликова. *Әйтергә кирәк, бүгенге көндә мәхәббәт хакына дуэльгә дә чакырмыйлар, упкынга да ташланмыйлар.* Ә.Мушинский

**ӘЙТЕ́РСЕҢ (ЛӘ)** *терк.* **1.** 1) Иярчен рәвеш җөмләне баш җөмләгә ияртү өчен кулланыла; гүя, гүяки. *Кыр буйлап, җәяүле буран себерелә, әйтерсең күренми чапкан аргамакның яллары дулкынлана.* Г.Әпсәләмов

2) Төрле әйберләрне, күренешләрне үзара охшатып чагыштыруны белдерә; гүя, гүяки, …дай; кебек, сыман. *Елга аркылы – мәһабәт озын басмалар, әйтерсең ике дәүләт чиген узасың.* М.Мәһдиев

3) Эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен шартлы яки якынча чамалап чагыштырганда кулланыла; …-ган (-гән) шикелле, кебек. *Әйтерсең күрше авылга сабан туена бара!* Г.Бәширов. *Чу! Бу нәрсә? Әйтерсең лә Хәлимнең башына имән күсәге белән тондырдылар.* Д.Гыйсметдинов

4) Эш-хәрәкәтнең ихтималлыгына ишарәләү өчен кулланыла. *Барис, берсүзсез, барырга риза булгач, Рәшит үз комбайны өчен кинәт бөтенләй кайгырмый, борчылмый башлады, әйтерсең аның бер күз карашы гына да моторны терелтеп җибәрә алачак иде.* Н.Фәттах. *Әйтерсең лә менә хәзер-хәзер эшләрен бетерәчәкләр дә, маңгай тирләрен сөртеп, тынычлап, әкрен генә өйләренә кайтып китәчәкләр.* И.Гази

5) Текстта күрсәтелгән эш яки хәлнең һичшиксез киресенчә эшләнгәнлеген, киресенчә булуын белдерә. *[Мөһимә] Шундый шартлатып сөйли, әйтерсең лә Алтынчәчне, монда чакырып китереп, Линар белән үзе таныштырмаган, әйтерсең лә хәзерге минутта Алтынчәчнең кыяфәтен күрми, аның хәлен бөтенләй белми!* М.Маликова. *Искәндәр кергәндә, ул инде әйтерсең кузгалып та бакмаган, әүвәлгечә изелеп йоклый.* Г.Гобәй

6) *Шундый* мөнәсәбәтле сүзе белән килеп, иярчен аергыч җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла. *Шундый җаваплар бирде, әйтерсең атналар буе әзерләнгән.* М.Кашапов

7) *Шундый* мөнәсәбәтле сүзе белән килеп, иярчен күләм җөмләне баш җөмләгә ияртКәндә кулланыла. *Ә күге шундый матур, шундый зәңгәр, әйтерсең Ягетнинең зәңгәр күлен алып килгәннәр дә, бик-бик югарыга менгезеп, йөзтүбән асып куйганнар.* Г.Гобәй. *Аның кыяфәте шундый мескен, әйтерсең күнне, Габдулла түгел, ул үзе кискәләгән.* Ә.Фәйзи

8) Җөмлә башында һәм боерык фигыль белән килгәндә, субъектның кемнең дә булса уй-фикерен, ниятен белергә, чамаларга теләгәнен белдерә; дигән кебек. *Әйтерсең, бу теләгенә дә ирешмәсен, аныңча булмасын әле, дип, юри минем сул кулга төзәп җибәргәннәр.* Г.Бәширов

**2.** *кис.* 1) Кемнең дә булса берәр нәрсә турында әйтелгән фикеренә ышанмауны яки ышанып бетмәүне, шикләнеп карауны белдерә; имеш, янәсе. *Әйтерсең полиция аңа хәбәр иткән дә, ул шуннан соң гына безне, килеп, куып чыгарган.* Ә.Фәйзи

2) Реаль булмаган, чын булмаган берәр нәрсә турында юмор белән әйткәндә кулланыла; имеш, янәсе. *Әйтерсең бөтен колхоз шул бер Газинурдан тора.* Г.Әпсәләмов

**ӘЙТЕШ** *и.* 1) Әйтү. *Әллә, кызларыгыз, уларыгызны Гыйфрит харап иткән, диеп әйтеш кирәкме?* Р.Батулла.

*Булган хәлне бер кешегә әйтеш юк.* Безнең гәҗит

2) Сорау-җавап яки бәхәс рәвешендә барган ярыш (җыр, такмак, шигырь әйтеп ярышу). *Тик ул вакытны бу әйтеш урам такмакларыннан торган, ә хәзер ул, Габдулла, ни әйтсәң дә, гыйлем исе иснәгән, күп китаплар укыган шәкерт...* Ә.Фәйзи. *Ул --- чәчән-акыннар белән әйтеш бәйгесенә төшәрлек дәрәҗәләрдә мөкәммәл рәвештә җанлы казакъ телен дә үзләштергән.* Татарстан яшьләре

**ӘЙТЕШЛЕ** *с.* Сораулы-җаваплы (җыр, такмак мәҗлесе)

**ӘЙТЕШҮ** *ф.* 1) Үзара, бер-берсенә кара-каршы берничә сүз әйтеп алу. *Сәүдә дус кызлары янына барыр, кызыкайлар, төртмә сүзләр әйтешеп, үртәшеп шау-гөр килерләр.* Г.Ахунов

2) Гаепләшү, тиргәшү, ачуланышу. *Ачуланышмыйлар, әйтешмиләр дә, шул ук вакытта ачылып сөйләшмиләр дә иде [каенана белән килен].* М.Маликова. *Җитмәсә, кичә клубта шул хакта мактанырга, Бәшировлар белән әйтешергә туры килде.* М.Фәйзи

3) Күмәк уеннарда, мәҗлесләрдә, һ.б.ш. халык җыелган урыннарда сүзгә, җырга осталыкта ярышу. *Кызык та инде. Егет белән кыз булып такмак әйтешүләр җыелганнарга аеруча ошады.* И.Нуруллин. *Яшелчәләр турында табышмаклар әйтешү.* Казан утлары

**Әйтешә башлау** Әйтешергә тотыну. *Әле генә кайгырышып, куяннар кебек посып кына утырган бу кешеләр инде мәзәкләр дә әйтешә башладылар.* Н.Дәүли

**Әйтешә бирү** Әйтешүен дәвам итү

**Әйтешеп алу** Аз гына, берничә сүз генә әйтешү. *Атасы белән тагы берничә каты сүз әйтешеп алды.* Г.Исхакый. *Алар [егетләр-кызлар] шулай бер-берләренә төртмә сүзләр әйтешеп алдылар.* Ф.Яруллин

**Әйтешеп бетерү** 1) Барысын да әйтү; әйтергә өлгерү. *Ярты сәгать эчендә дөньядагы бөтен ямьсез сүзләрне әйтешеп бетерергә була.* Т.Миңнуллин

2) *күч.* Авыр сүзләр әйтешү дәрәҗәсенә җитү

**Әйтешеп йөрү** Һәрвакыт, даими әйтешү; билгеле бер вакыт эчендә әйтешү. *Ике-өч көн шулай кочаклашып, җылы сүзләр әйтешеп йөрисең дә тагын һәркайсың үз фатирыңа кайтып бикләнәсең, дигәндәй.* Ф.Фаткуллин

**Әйтешеп китү** Кинәт, уйламастан бәхәскә керү, нинди дер бер моменттан соң әйтешә башлау. *Матур гына сөйләшеп торган җирдән, Фәридә белән Мансур әйтешеп китте*

**Әйтешеп кую** Кинәт, аз гына әйтешү. *Алман әсирләре нәрсәдер әйтешеп куйдылар, капка төпләренә чыккан карт-коры намазлыкларына ныграк ябышты.* Р.Гарипов

**Әйтешеп ташлау** Кинәт яки көтмәгәндә, уйламыйча, үзара хәтер калдырырлык итеп әйтешү. *Аларның, үзара шаярышып, бер-берсенә шактый ук кыю сүзләр әйтешеп ташлаган чаклары да булмады түгел, булгалады.* М.Хәсәнов

**Әйтешеп тору** 1) Әле, сөйләү моментында кара-каршы әйтешү; әле, хәзер бер-бере белән әйтешү

2) Һәрвакыт, әледән-әле әйтешү

**ӘЙТИК** *кер. сүз* Сөйләмдә яңа мәгълүматлар, дәлилләр китергәндә, әйтеләсе сүзгә игътибарны юнәлтү, басым ясау өчен кулланыла; мисал өчен, мәсәлән, фараз иттек. *Әйтик, Котбетдиннәр көрәк белән тир түгеп казыган нигезләрне, коеларны, балта белән төзегән агач йортларны бүгенге Марсельләр, ансат кына, бульдозер белән ишеп-күмеп, таш йортлар, колонкалар төзеп чыга.* Д.Гыйсметдинов. *Әйтик, бүгенге көндә хәл шактый әйбәт, иртәгә инде тагын да яхшырак булачак.* Н.Акмалов. *Нәрсә булыр, әйтик, сезгә карап, Каш ясыйбыз, дип, күзне чыгарсак?* Ш.Маннур

**ӘЙТКӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **әйтү.** *[Равил абыйсы] Ара-тирә, үтеп киткәндә, шаян сүзләр дә әйткәли.* Ф.Гыйльми

2) Искәрмәләр, кисәтүләр ясау; үгетнәсыйхәт бирү. *[Тәслия:] Әйткәнең юк шул. Әйткәләргә кирәк. Яхшыны яманнан аера белсен. Нәрсә яраганын, нәрсә ярамаганын ишетсен. Монда аның әтисе-әнисе урынына – синең белән без ләбаса...* Т.Миңнуллин

**Әйткәләп алу** Бераз, сирәк кенә әйткәләү. *Нинди дер төзәтү ясарга кирәген күреп өлгергәннәр дә ифрат та ипле иттереп кенә әйткәләп алдылар.* К.Тимбикова. *– Син бит әле яшь!.. Соңыннан үкенмәссеңме?.. – дип, каты гына әйткәләп алдым.* Х.Сарьян

**Әйткәләп җибәрү** Әйткәләп исенә төшерү, исенә төшерергә ярдәм итү. *Ялгышкан җирендә әйткәләп җибәрәбез.* Ф.Яруллин

**Әйткәләп йөрү** Еш, мөмкинлек булган саен әйткәләү. *Мин, Мазлуманың әйләнә-тирәсендә тегеләй-болай әйләнгәләп, узганда-барганда сүз әйткәләп йөрдем.* Г.Бәширов

**Әйткәләп карау** Әйтергә, җиткерергә омтылу, нинди дә булса фикерне үткәрергә тырышу. *Соңгы вакытларда Җәмилә Закировна бу кешегә карата фикере үзгәрүе хакында әйткәләп караса да, ире аларны зурга алмады.* М.Маликова

**Әйткәләп китү** Нинди дер вакыттан, моменттан соң әйткәли башлау, еш әйткәләү. *Мөфти «хәзрәтләрнең бәгъзеләренә» шелтә сүзләре әйткәләп китә.* М.Гайнетдинов

**Әйткәләп кую** Тиз һәм кыска гына арада, берничә сүз генә, ара-тирә әйткәләү. *Аның сине тыңлаганда башын аска иебрәк утыруы, күзлек өстеннән генә сөзеп карап алуы, аратирә «әйе, эһем, әйе» дип әйткәләп куюы күпләрне каушата иде.* Ә.Еники. *Бары тик Гөлсем генә ара-тирә берәр сүз әйткәләп куйды да, Хәбирәттәй генә, ашын мактый-мактый, туктаусыз ашарга кыстап йөрде.* Н.Фәттах

**Әйткәләп ташлау** Әйтелергә тиеш булмаганны ялгыш, кызып китеп әйтү. *Юктан гына да кабынып китәм, әнигә дә каты-каты гына әйткәләп ташлыйм.* Х.Камалов

**Әйткәләп тору** Һәрвакыт, гел, еш әйткәләү. *– Балам, син – минем күзләрем, синсез – дөнья миңа сансыз, – дип еш әйткәләп тора.* Н.Каштанов

**Әйткәләп үтү** Сүз уңаенда, җае туры килгәндә әйткәләү. --- *форсат барында әйтеп кую яхшы булыр, дип, шигырьнең ритмик яклары турында*

*да кайбер карашларымны әйткәләп үттем.* И.Юзеев

**Әйткәләп чыгу** 1) Кайсыларына булса да, кайберләренә әйткәләү

2) Һәрберсенә нәрсә дә булса әйткәләү

**ӘЙТКӘЛӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **әйтү.** *Ашап туйгач, печәнчеләр урыннарыннан авыр гына кузгалдылар да, үзара бер-ике сүз әйткәләшеп, шулай ук әкрен генә, иренеп кенә таралышып та беттеләр.* Н.Фәттах

2) Берәр кешенең фикере белән риза булмыйча, сүзгә килү, җиңелчә ачуланышу. *Әйткәләшү озакка сузылып, татар илчеләре – тирләп, хәлсезләнеп, урыслар – тагын да катырак әйтү өчен, тын алырга туктадылар.* Р.Батулла. *Заһидә апа белән әйткәләштек. Үзе әнә әләкләшеп йөргән юк-барны...* Н.Фәттах

**Әйткәләшә башлау** Әйткәләшергә керешү, әйткәләшергә тотыну

**Әйткәләшеп алу** Кыска гына вакытта, бераз гына, кинәттән әйткәләшү. *Элегрәк тә бу хакта аңа Василий Михайлович белән әйткәләшеп алырга туры килгәне бар иде.* Н.Фәттах. *Бу ике егет, бер-берсе белән дус булуга карамастан, кайчак үзара каты гына әйткәләшеп алалар иде.* А.Шамов

**Әйткәләшеп бетү** Әйткәләшү дәрәҗәсенә җитү. *Көлмәкче тәкъдим иткәннәр аңа ошамый, ул якын иткәннәрне көлмәкче кабул итми. Әйткәләшеп беттеләр.* М.Әмирханов

**Әйткәләшеп китү** Кинәт, нindидер моменттан соң әйткәләшә башлау. *Баягынак болынга барырга чыккач, алар – Җәмилә белән Сәкинә – әйткәләшеп киткәннәр.* Н.Фәттах. *Ул әйтә, мин уң якка утырам, ди. Мин әйтәм, мин уң якка утырам, дим. Киттек шуннан әйткәләшеп.* Р.Батулла. *Әле хатын белән чүт әйткәләшеп китмәдек.* Казан утлары

**Әйткәләшеп кую** Тиз һәм кыска гына арада берничә сүз әйткәләшү

**Әйткәләшеп тору** 1) Һәрвакыт, еш әйткәләшү

2) Әле, сөйләү моментында әйткәләшү

**Әйткәләшеп утыру** Әле, күз алдында әйткәләшү. *Янәшәмдә, өч яшьләрдә генә булыр, әбисенең алдына менеп кунаклаган да бер малай чәт-чәт килеп әйткәләшеп утыра.* Илһамлы каләм

**ӘЙТКӘНДӘЙ** *кер. сүз к.* **әйткәнчә 2**. *Юк, дип башын чайкап уйлануында булды Бәйрәмхан, әти әйткәндәй, ишәкне колагын кисеп кенә чапкын итеп булмый.* М.Хуҗин

**ӘЙТКӘ́НЧӘ** *рәв.* **1.** Әйткәненә туры китереп; кемнеңдер өйрәтүе буенча, кемдер таләп иткәнчә. *[Гаптерәшит:] Мин нәкъ сез әйткәнчә эшләдем.* М.Фәйзи. *Ул ире әйткәнчә эшләде.* Ф.Садриев. *Һәм шулай, хатын әйткәнчә, солы салып куйганнар.* Чакма ташы

**2.** *кер. сүз функ.* Фикернең чыганагын күрсәтү өчен кулланыла. *Күңел иреген яуламыйча, Мирсәй ага Әмир әйткәнчә, «мокытлык дәрәҗәсендәге тыйнаклык»та утырып калсаң, эт сикертә торган көйгә такмак язудан ары китә алмавың да бик мөмкин.* М.Галиев. *[Рәхим:] Ярый, алар әйткәнчә, мин ялгышканмын да, ди, шуның аркасында цехлар берничә сәгатькә туктап та торганнар, ди.* Р.Ишморат. *Әйткәнемчә, абыйдан безгә хат килми иде.* В.Нуруллин

**ӘЙТМЕШЛИ** *кер. сүз к.* **әйткәнчә 2**. *Вергилий Никофорович Дикопольцев, зур төзелешләрдә эшләп һәм яшәп, кем әйтмешли, энә күзеннән кереп, җепнең очыннан чыккан кеше.* Г.Кашапов

**ӘЙТТЕ́М БИТ** *кер. сүз к.* **әйтәм бит**

**ӘЙТТЕ́М ИЧ** *кер. сүз к.* **әйтәм бит.** *[Нәфыйк:] Әйттем ич, танымыйсыз, дип.* А.Әхмәт

**ӘЙТТЕРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **әйттерү** (*1 мәгъ.*). *Ләкин үгет-нәсыйхәт, өндәү-чакыру сүзләре өлкәннәр (автор) исеменнән түгел, ә үсмерләр авызыннан әйттерелә.* Д.Нигъмәтҗанова

2) *күч. этн.* Ярәшелү. *Тик әйттерелгән балалар гына үзләренең кайната-кайнаналарына күренмәскә, --- яшәренергә тиеш булалар.* Г.Ибраһимов

**ӘЙТТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн к.* **әйтү**. *Хатларның мәгънәләре әйттереп яздыргандай бер иде: бик дөрес язгансыз, күптән кирәк иде.* Ф.Садриев

2) *сөйл.* Вакытны уен-көлке белән, җырлап, биеп яисә уен коралында уйнап үткәрү; күңел ачу. *Сары башлы, чыпчык борынлы бу ике кыз – икесе дә җырга бик оста булып чыктылар. Русча җырларны да күп беләләр, татарчасын да әйттерәләр генә.* А.Хәсәнов. *[Хәниф абый:] Җырлый да белсәң, Сабирулла, без хәзер парлап әйттерер идек.* Н.Дәүли

3) *күч. сөйл.* Исерткеч эчемлекләр эчеп, кәеф-сафа кору, типтерү. *И кая ул көн, ки бездә шәп торулар бар иде. Ду китереп дөньясын тик әйттерүләр бар иде.* Ш.Бабич

4) *күч. гади с.* Җиңел, җайлы, рәхәт тормыш итү. *Үзләре халык җилкәсендә әйттереп яшиләр.* Казан утлары

5) *күч. этн.* Ике гаиләнең ризалыгы белән, балаларны өйләндерү, кияүгә бирү турында үзара килешү; ярәшү. *Ничә көннәр, ничә төннәр дигәндә үз шәһәренә кайтып җитеп, яхшы җирдән кыз әйттереп, бу да, яхшы йортлар, матур өйләр салдырып, агалары кебек рәхәт тора башлады.* Әкият. *Сарсынбайның туган энесе Асылжегет исемле берәүгә баладан үземне әйттергән булганнар.* Г.Ибраһимов

**Әйттерә бару** Һәрберсен, булган берсен әйттерү

**Әйттерә башлау** Әйттерергә керешү, әйттерергә тотыну

**Әйттереп алу** Кыска вакыт эчендә, аз гына әйттерү. *Әнә куралар да өлгергән. Әйдә әле, көчеккәем, курай ясап, бер әйттереп алыйк.* Р.Хафизова

**Әйттереп бетерү** Барысын да, ахырга кадәр әйттерү. *Баягынак әйттереп бетермәдең, Укмастагы батыр асты Кара чутыр Сәгъдия, дигәнием ич әле, име. Менә шул хатында икән ул куәт, гайрәт, малай!* Р.Гаффар. – *Уф! – диде тегүче, аның сүзен әйттереп бетермичә, – үтерәсез инде, кая, алып килдеңме?* Ф.Яруллин

**Әйттереп җибәрү** Көтмәгәндә, уйламаганда әйттерә башлау. *[Сибгат:] Әйдәгез әле, килен хөрмәтенә, үз көе белән бер әйттереп җибәрегез!* М.Фәйзи. *Афәрин, сукыр шайтан, зирәклегеңә! Җә, берне әйттереп тә җибәр инде.* Г.Камалетдинов

**Әйттереп йөрү** Әле, хәзерге вакытта, төрле урыннарда әйттерү. *Бераз колак*

*алкасы астына чиертеп алган егетләр, җилкәләрдән кочаклашып, гармун тартып әйттереп йөриләр*. Р.Зарипов

**Әйттереп калу** Әйттерергә өлгерү. *Син дә үләсе, Фазулла туган, без дә үләсе! Давай, агай-эне, бер әйттереп кал әле*. Г.Бәширов

**Әйттереп карау** 1) Әйтергә мөмкинлек бирү. *Ләкин ни өчен мәкальне «динчеләр» авызыннан гына әйттереп карарга?* Н.Исәнбәт

2) Әйтә белүен, әйтә алуын сынау. *Бая җизни, син әйтә белмәссең, дип, мине яңадан әйттереп карап маташа*. Г.Камал. *Йөз меңләгән яугирне бер тынга буйсындырырдай сүз әйттереп кара – әйтә аламы?!* М.Галиев

3) Җиткерү, җиткерергә тырышу. *Кеше аркылы әйттереп карадым*. Т.Гыйззәт

**Әйттереп ташлату** Кирәк, тиеш булмаганны, ялгыш әйтергә мәҗбүр итү. *Әй, менә бу Зиннәт абыйны! Кешенең серен әйттереп ташлатты*. Ә.Фәйзи

**Әйттереп тору** Һәрвакыт, гел әйттерү; бертуктаусыз әйттерү. *Хәер, егетләр кат-кат әйттереп тормадылар, бер дә тартынмыйча гына, ханымның сыйларын «ура» башладылар*. Ә.Еники. *Доцент булды. Бу исемне күтәреп йөрү бик рәхәт, бик ләззәтле иде, кешеләрдән ул исемне үзенә карата гел генә әйттереп торасы килә, шуны әйтергә үзе дә җай эзли иде*. М.Мәһдиев

**Әйттереп утыру** Күпмедер вакыт әйттерү; әле, хәзер, күз алдында әйттерү. *Юк, уянмый. Димәк, алар монда гармуннар белән әйттереп утырганнар да, исергәч, ятып йоклаганнар*. Т.Гыйззәт

**Әйттереп чыгу** Һәрберсенә кем аркылы булса да әйттерү

**Әйттереп яту** Сөйләү моментында, хәзер әйттерү. *Умартаның янында тыңлап тордым. Әйттереп яталар, ди, кубыз белән*. Ш.Бабич

**ӘЙТҮ** *ф.* 1) Уй-фикер, хис-тойгы, кичерешләрне сөйләп белдерү; сөйләү. *Бу юлы да җикеренеп, ачуланып түгел, бик якын кешесенә яхшы киңәш биргәндәй әйтте [көймәче]*. З.Хөснияр

2) Бәян итү, тәгъбирләү; хәбәрне язма яки басма рәвештә белдерү. *Китап әйтә, аның һәрбер көнендә җитмеш мең хасият бар, ди*. Ш.Камал. *Егерме бишләреннән соң почтага ешрак кергәләп йөр: кайчан Ферганәгә киләсемне һәм кая тукталасымны әйтеп, телеграмма сугармын*. В.Нуруллин

3) Кемнең дә булса сәламен, үтенечен, йомышын яки әмерен тәгаенләнгән иясенә икенче берәү аша тапшыру. *Ә сез барыгыз, бар, егетләр, Шаһгәрәй абзыйга сәлам әйтерсез*. Г.Гобәй. *[Шәмсия:] Улым Шәүкәт, Гөлшатларны күреп әйтерсең, самавырым өлгерде, чәйгә кайтсыннар*. Т.Гыйззәт. *[Әхмәт:] Зинһар, тагын, алай булса, баеңа барып, тагын бер мәртәбә минем сүзләремне әйтеп, ялынып сорап кара*. Г.Камал

4) Берәр нәрсә турында аңлату, өйрәтү

5) Нәрсәнең дә булса билгесенә яки сыйфатына нигезләнеп, берәр нәрсәне ачыклау, аңлау; шулар буенча нәтиҗә ясау яки фаразлау. *Сентябрь урталарында яңгыр да яварга тиеш: сынамышлар шуны әйтә*. Г.Ахунов

6) Дини текстларны көйләп уку. *Иң ахырда, [картларның] дүртесе кабернең дүрт почмагына чүгәләп, салават әйтте*. Ф.Садриев. *Мәзин иртә намазына азан әйтергә яңа гына манарага чыккан иде*. Г.Ибраһимов

7) Шигъри әсәрне көйгә салып сөйләү яки яттан уку. *Рамазан ае кичләрендә ул малай, мәчет манарасына менеп, яшь егетләр белән, сузып-сузып, «әлвидаг» көйләде, мәдрәсәдә кичләрен, хәлфә абзый кайтып киткәч, «Сак-Сок» бәетен әйтте*. Г.Бәширов. *Арадан берсе: «Сираҗетдин, Әхмәдулла! Әйдә, гармун илә скрипканы парлап уйнагыз әле, без сугыш бәетен әйтәбез», – диде*. Ш.Мөхәммәдев // Җырлау. *Нәҗип, өзеп-өзеп, бер җыр әйтте: «Айһай, дөнья... Шушы яшьләремә җитеп, ни рәхәт күрдем синнән?!»* А.Гыйләҗев

8) *-ырга/-ергә* формасындагы фигыльләрдән соң килгәндә: нәрсә дә булса эшләргә талпыну, маташу, тырышып карау // Нәрсәгә дә булса теләк белдерү, ниятләү

9) Әләкләү, кемнеңдер өстеннән сөйләү. *Синең урында булсам, бер сәгать тормый, барып әйтер идем мин*. А.Шамов. *Шаһгәрәй абзый үзе әнигә кереп әйткән бит*. Г.Гобәй

10) Җиткерү, сөйләп бирү. *Өчесенең дә күңеленә бик тирән сеңеп калды: ни генә булса да, командирларга әйтү ярамый икән*. З.Хөснияр. *Арадагы илче Айбала боларның барын да кызга шул көндә үк әйткән иде*. Г.Ибраһимов

11) Юнәлеш килешендәге исемнәр белән килгәндә: кая да булса барырга сорау, үтенү; чакыру, өндәү. *Имеш, Әүхәт эниле-кызлы яшәгән Әсма белән Бикәгә эшкә әйтергә тиеш*. Ф.Сафин. *Походка әйтү*

12) Халык алдында чыгыш ясау. *Остазларына ияреп, Гафур да, Заһит та тост әйттеләр*. М.Әмирханов. *Аннары Әхнәф Иреккә тост әйтергә кушты*. Ф.Садриев

13) Игълан итү. *Судья хөкемне әйтте*

14) Гадәттә күплек сан кушымчалары белән килгәндә: кешеләрдә фикер булу, хәбәр йөрү; шулай сөйләү, шулай дию. *Әти, колхоз быел йөзәр пот ала, дип әйтәләр*. Ф.Бурнаш. *Җете кызыл тиз уңа, дип, белеп әйткәннәр икән*. В.Нуруллин

15) Чыганагын сөйләүче үзе төгәл белмичә, кешедән ишеткән сүзне җиткергәндә, еш кулланыла торган гыйбарәләрне кабатлаганда яки расланмаган сүз, имеш-мимеш сөйләгәндә кулланыла. --- *ул [авыл] XVII гасыр ахырында оешкан булырга тиеш. Аны Алпар исемле кеше нигезләгән. Алпарны, морза булган, дип тә әйтәләр*. Ф.Гарипова. *Ходай язмаган эш булмас, сабырлык – сары алтын, дип әйтәләр бит*. С.Поварисов. *Шулар арасында,* --- *Солтан абзый кәләпүшен култык астына кыстырып кына хезмәт итте, дип әйтәләр*. Ш.Мөхәммәдев

16) Кемне яки нәрсәне дә булса башка исем, башка сүз белән атауны, йөртүне белдерә. *[Сәмитне] «Саескан» дип белеп әйткәннәр*. Р.Низамиев. *Шуңа күрә монда самавырны «куйдым» дип әйтәсе урынга «астым» дип сөйлиләр*. Ә.Фәйзи

17) *күч.* Нәрсә дә булса хис-тойгыларга тәэсир итеп, хәтерне уяту, искә төшерү. *Бу исем безгә күп нәрсә турында әйтә*

◊ **Әйтә алу** Белү, хәбәрдар булу. *Бер дә әйтә алмыйм шул, наным.* В.Нуруллин. **Әйтәсе дә түгел** *к.* **әйтәсе дә юк. Әйтәсе дә юк, әйтеп тә торасы юк** 1) Сөйләүченең сүзе, фикере белән тулысынча килешүне белдерә. *Әйтәсе дә юк, карап торырга бик шәпләр.* Ә.Еники; 2) Берәр нәрсәнең булуына, эшләнүенә өмет булмаганда әйтелә. *Әйтеп тә торасы юк, ул бүген барыбер килми*; 3) Берәр нәрсә турында, артык сүз сөйләп торуның кирәге юк, дигән мәгънәне аңлата. *Әйтәсе дә юк, һичкемнең аты минем Алмачуарга якын да килә алмады – кузгалып китү белән мин очам, башкалар күз күреме җир артта калалар.* Г.Ибраһимов. **Әйтәсең бармы** *к.* **әйтмә инде.** – *Чөй өстенә тукмак дигәндәй, ичмаса, Гөлниса киленнең дә сәламәтлеге чамалы. – Әйтәсең бармы.* М.Хәсәнов. **Әйт дигәнче тайт** Әйтеп бетергәнче әзер дә булу. **Әйтеп, адәм ышанмас** Әйтеп, кеше ышанырлык түгел, бик сирәк, гаҗәп хәл. *Читек балтырында – кырык тугыз мең, диген, ә? Әйтеп, адәм ышанмас.* Г.Камал. **Әйтеп бетергесез, әйтеп биргесез** 1) Нindидер нәрсә турындагы уй-фикерләрне, хистойгыларны сүз белән генә аңлатып, телдән әйтеп бирә алмауны белдерә. *Зәгыйфь кулларында алманың авырлыгын тою, аның татлы исен иснәү әйтеп бетергесез рәхәт иде.* А.Сафин. *Күңел тетрәткеч хикәя. Укып чыккач, миндә тел белән әйтеп биргесез авыр уйлар кузгалды.* Җ.Тәрҗеманов; 2) Бик күп, чамадан тыш, чиксез зур. *Элекке ышанулар белән хәзерге ышанулар арасында аерма – әйтеп бетергесез.* Н.Кәримова. **Әйтеп үтәргә кирәк** Сөйләмдә әйтеләсе сүзгә фикерне юнәлтү, игътибарны көчәйтү өчен кулланыла. *Бу чуар публиканың тагын бер характерлы ягын әйтеп үтәргә кирәк: анда күпчелек – кыз-хатыннар.* Г.Гобәй. *Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, утыз җиденче елда бу китапларны Татарстан китапханәләреннән җыеп алдылар.* Ә.Галиев. **Әйтергә генә ансат** Берәр нәрсә турында сөйләгәндә, аны шулай дип әйтүе генә җиңел, чынлыкта, бу мәсьәлә – бик авыр һәм катлаулы, дигәнне аңлата. *Әйтергә генә ансат: күз алдында йөгереп йөргән бала кинәт, көпә-көндез, суга чумгандай, юкка чыксын, имеш.* Г.Кутуй. *Әйтергә генә ансат: биш ордены, алты медале бар!* З.Зәйнуллин. *[Арабей:] Әйтергә генә ансат. Моннан сугышка чыгып киткәнгә илле ел тула бит.* З.Зәйнуллин. **Әйтергә дә түгел, әйтергә дә юк** *к.* **әйтәсе дә юк. Әйтергә йөз бармый** *к.* **әйтергә тел бармый**. *Әйтергә йөзем бармый, дип, җыен яланаякны ашатып ятуы – үзе җинаять!* Һ.Такташ. **Әйтергә тел бармый** Кемгә дә булса берәр нәрсә турында әйтә алмауны белдерә (мәс., оялудан, кыенсынудан, тарсынудан, хәбәрнең авыр тәэсир итүеннән, хөрмәт йөзеннән һ.б.). **Әйтер идем** Билгеле бер эшне башкарып чыга алмаган кешегә ачу килгәндә, әлегә нәрсә дә булса әйтүдән тыелып торам, югыйсә, аның турында әллә нәрсәләр әйтеп ташлавым бар, дигән мәгънәдә кулланыла. *Хәер, Галимулласын да әйтер идем, кеше түгел икән.* Р.Газизов. *Боларын да әйтер идем инде.* Т.Гыйззәт. **Әйткән дә юк** Кем яки нәрсә турында әйтеп торуның кирәге дә юк, болай да билгеле, мәгънәсендә. *Килгән кунакны әйткән дә юк, хәтта күрше-күлән генә керсә дә, йөзең якты сыман.* Р.Кәрами. *[Гобәй:] Киемнәрен әйткән дә юк – ефәк өстенә ефәктән киенгәннәр.* З.Зәйнуллин. *Ә кызлар турында әйткән дә юк: яннарыннан үткәндә, [Әнәс] ялгыш та орынмыйча яки чеметмичә үтми.* В.Нуруллин. **Әйтмә (дә) инде** Сөйләүченең фикере белән тулысынча килешкәндә, ризалашканда әйтелә. *Бер нәфесен тыя алмаган кешене аны әйтмә инде.* Г.Бәширов. *[Сәхибә:] И, анысын әйтмә дә инде. Без, карт, үзебез дә шулай идек бит.* А.Әхмәт. *Әйтмә инде, читтән караганда, ике тиен тормаслык йолкыш малай иде.* Ш.Камал. **Әйтмәгәнем булсын** 1) Андый хәлнең моңарчы булганы юк, моннан соң да була күрмәсен, дигән мәгънәдә. *Бер тапкыр, яндыргыч пуля тиеп, чабуыма ут капты, ә үзем, әйтмәгәнем булсын, һаман исән.* И.Гази; 2) Мин әйткәннән, күз тиеп, начарлык килмәсен, кирегә китмәсен, мәгънәсендә. *Бүген, әйтмәгәнем булсын, йөрәгем тынычланды.* А.Шамов. **Әйтмәс җиремнән әйтү, әйтмәс җиреңнән әйтерсең** Нәрсә дә булса, нинди дә булса шартларның серне, көндәлек йөрткән уй-теләкне һ.б.ны әйтергә мәҗбүр итүе; теләмәгән килеш, шулар турында әйтергә, сөйләргә мәҗбүр булу. *Әйтмәс җиремнән әйтергә туры килә ---.* М.Хәсәнов. *Авылга җитеп килгәндә, янә сорап куйды әти кеше. Йомшак итеп, ягымлы итеп дәште бу юлы, әйтмәс җиреңнән әйтерсең.* Р.Мөхәммәдиев. **Әйтсәм әйтим (инде)** Моңарчы әйтмичә торган берәр нәрсә турында хәзер әйтергә мәҗбүр булу, мәгънәсен белдерә. *Әйтсәм әйтим инде, мин бит үзем дә – моннан элек Нәбирәгә кармак салып караган егет.* Ә.Фазылҗанов. *[Шәвәлиев:] Инде әйтсәм әйтим: берәр көн занятиесеннән дә калырсың.* Ф.Садриев. *[Әхмәт:] Әйтсәм әйтим. Минем чын атым – Былтыр.* Д.Аппакова. **Әйтсәң, адәм ышанмас** *к.* **әйтеп, адәм ышанмас.** *Ә беркөнне, әйтсәң, адәм ышанмас, җиде төн уртасында балык ашыйсы килүдән уянып китте.* М.Әмирханов. **Әйттем исә кайттым** Тыңлаучыга әйтелгән фикер ошамаган очракта, сүземне кире алам дигән мәгънәдә кулланыла. *[Кузьмин:] Бигайбә, туган, әйттем исә кайттым.* З.Садыйков. *[Рухия:] Әгәр без иртәгә үк бер-беребезгә үпкәләшеп яки бөтенләй дошманлашып китсәк тә – тьфү, тьфү, алай булырга язмасын, әйттем исә кайттым!... Минем серемне саклый алырсыңмы, Равил абый?* В.Нуруллин. **Әйттең әле син** *гади с.* Сөйләүченең фикере гаҗәпләндергәндә, шаккатырганда әйтелә. *[Әсләф:] Әйттең әле син. Син креслога кызыкмаган берәр кешене беләсеңме?..* Д.Салихов. **Әйттең сүз** Сөйләүченең фикере белән риза булмаганда кулланыла. **Әйттерерсең әллә ни** Сөйләүченең фикеренә кискен каршы килгәндә, юк сүз сөйләмә, югыйсә әллә

нәрсәләр әйтеп бетерермен, мәгънәсендә кулланыла. *[Хәмдүнә:] Намус? Әйттерерсең әллә ни!* Д.Салихов. **Әйтүе ансат** *к.* **әйтергә генә ансат.** *[Батталов:] Әйтүе ансат ул, Миңзаһит Усманович. Ничә ел халык белән эшләп, нервысы калганмыни инде аның?!* Ф.Садриев. **Әйтүе ни тора** Җөмләдән аңлашылган нәрсә турында әйтүе үзе генә дә югары бәяләнә, дигән мәгънәне белдерә. *Персидәтель кияве, дип әйтүе генә ни тора бит, малай!* Р.Сафин

**Әйтә бару** 1) Берәр нәрсә турында даими рәвештә әйтү. *Куркуның моңа ни катнашы бар? Кирәкле чакта, кирәкле урында әйтә барам.* Т.Миңнуллин

2) Берсе артыннан берсен әйтү; һәрберсен, булган берсен әйтү. *Мәрдәнша бабай агрономлыкны мактады һәм, сүз арасында, патронны ничек ясарга икәнен, гильзага нәрсәне, ничек салырга икәнен әйтә барды.* Г.Гобәй

**Әйтә башлау** Әйтергә тотыну, әйтергә керешү. *Гозерен ялварулы сүзләр белән әйтә башлый.* Х.Камалов. *--- картлар тәкбир әйтә башладылар, аларның бәхилләшкән авазлары поезд тавышларын да күмеп китте.* Ф.Бәйрәмова

**Әйтә килү** *к.* **әйтеп килү**. *Мин аңа әйтә килдем: сез боларны законсыз эшлисез, дидем.* Р.Ишморат

**Әйтә кую** *к.* **әйтеп кую**. *Кайгыртучанлык күрсәтеп әйтә куйды.* С.Рафиков. *Сиражи, ишектән чыкканда, итекчегә барып әйтә куйды.* Г.Ибраһимов. *Галәк бабай аны, башын иеп, тыңлап торды һәм, Газинур җырлап бетергәч, әйтә куйды.* Г.Әпсәләмов. *Ир кешеләр, дип, сузып кына әйтә куйды.* Н.Дәүли

**Әйтә салу** *сир. к.* **әйтеп салу.** *Гайрәт чәчеп әйтә салды егет: «Миннән – гөнаһ, синнән – изгелек!»* С.Сөләйманова. *Вәли, кулындагы картаны өләшәөләшә, әйтә салды.* Г.Ибраһимов. *Бу юлы әлеге тавыш, үпкә белдергән сыман итеп, илереп әйтә салды.* М.Хәсәнов

**Әйтә тору** 1) Даими рәвештә, һәрвакыт әйтү. *[Рөстәм:] Һәр көн саен иртә белән: – Тагын биш кенә көн калды, тагын дүрт кенә көн калды! – дип әйтә торды.* Г.Кутуй

2) Кат-кат әйтү, әйткән өстенә әйтү; кисәтеп, берничә тапкыр әйтү. *Мин шулай кычкыра торам, ә укытучым: «Авызыңны тагын да зуррак итеп ач, зуррак», – дип әйтә тора.* Н.Дәүли. *Әби, елан дошман була, дип әйтә торган иде.* Х.Гатина. *Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә, дип...* Ә.Еники

**Әйтә язу** Чак әйтмичә калу

**Әйтеп алу** Бер-ике сүз белән, кыска гына әйтү. *Ничектер, тел очына килеп, быел беренче класска укырга кергән балаларның саны дүрт-биштән узмаганын әйтеп алды.* Н.Акмалов. *Ә сөйләшергә туры килгән чакларда инде, бик кыска-кыска гына, өзек-өзек кенә әйтеп ала.* А.Шамов

**Әйтеп бару** 1) Рәттән, бер сүзен дә калдырмый, эзлекле рәвештә әйтү. *Надан иде ул, катып калган бүкән иде. Миңа үчләшеп бәйләнгән саен, мин аңа кем икәнлеген әйтеп бара идем.* Т.Миңнуллин

2) Һәр билгеле булган мәгълүматны тапшыру, даими җиткереп тору

**Әйтеп бетерү** 1) Уйлаганны, күңелдә булганны тулысынча әйтү. *Әти бер кызса, хәтер саклыйм дип тормый, күңелендәгесен ахрынача әйтеп бетерә.* Г.Тавлин. *– Ярар инде, – диде Мәлс, савытын этеп куеп. – Әйтеп бетерсәм, якалап кына калмассың, дип куркам.* Ф.Садриев

2) Артык, кирәкмәс сүзләр, әллә ниләр әйтү. *Хуҗа тагын әллә нәрсәләр әйтеп бетерде. Янады, куркытты.* Н.Дәүли

**Әйтеп бирү** 1) Аңлаешлы, анык, төгәл итеп әйтү, фикерне җиткерү. *Уңай герой. Аның тормыш өчен, укучы өчен булган әһәмиятен, кыска гына итеп, ничек әйтеп бирергә соң?* Казан утлары

2) Һичнәрсә яшермичә, ачыктаначык дөресен әйтү. *Зәнфирә бүген хисләрен яшермичә әйтеп бирде, тәүге мәртәбә аны аркасыннан кочты, күкрәгенә кысты.* Ф.Садриев. *Нургали, Саҗидә җиңгәсенең шул хәлен сизгәндәй, аз гына тынып торды да туптуры әйтеп бирде.* Ә.Еники

3) Аңлату, өйрәтү, белергә ярдәм итү. *Сафа карт, яз чыккач ук, әткәйгә моның юлларын өйрәтте: нәрсә ашатырга, ничек эчертергә, көн саен ничек аз-аз гына йөртеп кайтарырга – һәммәсен әйтеп бирде.* Г.Ибраһимов

**Әйтеп җибәрү** 1) Кинәт кенә кискен итеп берәр нәрсә әйтү. *Кызның тиктормас теле: – Кирәгең юк! Эчәсем килми! – дип әйтеп җибәрмәсенме.* Д.Аппакова. *Шул минутта башыма килгән бер нәрсәне әйтеп җибәрдем.* Ф.Әмирхан

2) Кемгә дә булса, сөйләмендә тоткарланып торганда, кирәкле сүзне әйтеп, фикерен дәвам итәргә булышу

3) Кем аркылы булса да әйтү, ишеттерү. *Безгә әйтеп җибәрүенә караганда, Гыйлемдар үзе, иртәгә иртә белән, дәрес башланганчы ук кайтып җитәргә тиеш иде.* Х.Сарьян

**Әйтеп йөрү** *к.* **әйтеп чыгу** (*2 мәгъ.*). *[Авыл малайлары] «Сабир кайткан, Сабир!» – дип, бөтен авылга әйтеп йөрерләр.* Н.Дәүли. *Аннары үзе кебек иптәшләре белән, өйдән өйгә кереп, колхозчыларга җыелыш буласын әйтеп йөрде.* Г.Әпсәләмов

**Әйтеп калдыру** 1) Эшләнергә тиешле эшне яки әйтеләсе сүзне кем аша булса да хәбәр итү, җиткерү

2) Үзенең милкен мирас итеп тапшыру турында васыять итү яки ни дә булса эшләү, я булмаса, эшләнү мөмкинлеген үләреннән алда әйтү. *Ә Шәйхи карт, бер дә әллә кемгә түгел, үз нәселләренә әйтеп калдырган икән.* М.Мәһдиев

**Әйтеп калу** 1) Берәр нәрсәне мөмкинлектән файдаланып, вакыт булганда яисә җае чыкканда әйтү, әйтергә өлгерү. *Хатын-кызлар әнә шулай, берберсен бүлә-бүлә, үз карашларын әйтеп калырга ашыгалар.* М.Галиев

2) Артыннан әйтү, китеп барганда әйтү. *Хизбулла исә, никах укыткан кәләшеннән колак кагу хурлыгын күтәрә алмыйчамы, Идрисне күргән саен, шкаф хәтле кибетеннән башын чыгарып, берәр усал сүз әйтеп кала иде.* К.Нәҗми

**Әйтеп карау** Әйтергә омтылу, әйтеп аңлатырга тырышу. *Бер генә түгел, йөз әйтеп караган инде аңа – яхшылык белән дә, усалланып та.* В.Нуруллин. *Асылгәрәй карт аларга бу эшләренең*

*дөрес түгеллеген әйтеп карады, чөнки Сталин мәкаләсендә дә колхозга көчләп кертергә кушылмаган иде.* Ф.Бәйрәмова

**Әйтеп килү** Күптәннән, алдан ук, кат-кат әйтү. *[Мәрьям:] Мин дә картка күптән әйтеп киләм инде.* Ф.Әмирхан

**Әйтеп китү** Сүз уңаенда әйтү. *Мисалга шуны әйтеп китик: Сабитның гомерендә дә төш күргәне юк, ята, мендәргә башы тиюгә йоклап китә, кай ягына ятса, шул хәлдә уяна, селкенми дә, кыймшанмый да!* А.Гыйләҗев. *Дөрес, шагыйрь көчкә каршы көч куелу кирәклеген әйтеп китә.* Г.Нигъмәти. *Парижда извозчиклар юклыгын әйтеп киттем.* Г.Гобәй. *Ләкин ул чакта, көн салкын булуга карамастан, күпер төбендәге Казанка бозының нигә шулай, ереп, боткага әйләнгәнен әйтеп китүне кирәк дип саныйм.* В.Нуруллин

**Әйтеп кую** 1) Көтмәгәндә, уйламаганда яки кинәт әйтү. *Гафият, ярты юлны, бер сүз дәшмичә, әллә нидә бер башын чайкаштыргалап, үзалдына сөйләнгәләп барды да кинәт әйтеп куйды.* И.Гази. *Кай мизгелләрдә [Хәлил абый] аерым сүзләрне кычкырып-кычкырып әйтеп куя.* А.Шамов

2) Алдан әйтү; кисәтү; искәртү. *[Зифа:] Кичтән әйтеп куймагач, мин белмәдем.* М.Фәйзи. *Бары мин сиңа алдан әйтеп куям.* Ф.Әмирхан

**Әйтеп салу** 1) Уйлаган, кичергән, күңелдә булган нәрсәләрне турыдан-туры, ачыктан-ачык әйтү. *Васильеваның өен карагач ясалган нәтиҗә турында берни дә яшермичә әйтеп салдылар.* Ф.Галиев. *Әле уй-хисләремне туры гына әйтеп салырга телем әйләнмәсә дә, ияреп кайтуымның тикмәгә генә түгеллеген чамалады Нәбирәм.* Ә.Фазылҗанов

2) Һич уйламаганда арттырып, ялганлап әйтү, берәр нәрсәне уйламыйча әйтү. *Җитмәсә, тагы аңа, ялганлап, «заводта эшлим» дип әйтеп салдым.* М.Гали

**Әйтеп ташлау** Кинәттән яки көтмәстән әйтү, әйтелергә тиеш булмаганны ялгыш әйтү. *Ярый әле, Сашаның аккордеонын алгач, моны миңа ефрейтор Кузин үзе дә сизмәстән әйтеп ташлады.* Ж.Тәрҗеманов. *[Ханым] Сүз югыннан – сүз, дигән шикелле: «Сезгә өстәге урыннар гына калды, монда минем ирем утыра», – дип әйтеп ташлады.* З.Садыйков

**Әйтеп тору** 1) Әле, хәзер әйтү. *Мәрдән абзый каршы әйтеп торуның файдасыз икәнен белә иде, эндәшмәде.* Г.Гобәй. *Сүзсез йөрәгендә күпме сагыш, борчылу таш булып ятканлыгын аның җитди, моңсу кара күзләре үк әйтеп тора иде.* Ә.Еники

2) Әйтеп яздыру, язып барырлык итеп әйтү. *[Сабит телефоннан Иван Иванович белән сөйләшә] Теге якта язып алырга ниятләделәр бугай, ул иҗекләп әйтеп тора башлады.* А.Гыйләҗев. *Мин, папирос тартмасы өстендә арлы-бирле йөренгәләп, профессорга ниләр кирәклеген әйтеп торам.* А.Расих. *Күктән аңа кемдер әйтеп тора да, шуны әдип кәгазьгә генә төшереп барадыр кебек.* Ә.Еники

3) Берәр нәрсәне кабат-кабат әйтү. *[Бәдри:] Әйтеп торам ләбаса сиңа, ут яктысында укый алмыйм, дип.* М.Фәйзи. *Әйтеп торам бит мин сезгә: мондый хәлнең булуы мөмкин түгел.* Ф.Садриев

4) Әйтелгәннәргә, алдан билгеле булганга өстәп әйтү. *Будкага килгәне бар... ләкин ул кадәресен әйтеп тору кирәк микән?* Г.Гобәй

5) *күч.* Нинди дә булса берәр эшнең яки гамәлнең билгесен чагылдыру, шуның нәтиҗәсен ап-ачык итеп күрсәтү. *Аның кыюлыгын, фидакярлеген түшендәге югары хөкүмәт бүләкләре – ике хәрби орден гына да әйтеп тора.* Г.Тавлин. *Бу исә аның озак вакыт тышта, кояшта булуы турында әйтеп тора иде.* Н.Фәттах. *Челтәрле тимер рәшәткәләр, биек таш коймалар, бизәкле авыр капкалар – барысы да монда эшлекле һәм мул тормышлы сәүдәгәрләр рәхәт чиккәнен әйтеп тора.* Р.Кәрами

**Әйтеп үтү** *к.* **әйтеп китү**. *Колхоз рәисе --- колхозга искиткеч зур ярдәм күрсәтүебезне әйтеп үтте, кат-кат рәхмәт белдерде.* С.Хафизов. *Соңга таба бер зенит пулемёты бирделәр, ул турыда бераз түбәндәрәк әйтеп үтәрмен әле.* Ә.Галиев

**Әйтеп чыгу** 1) Башыннан ахырына кадәр әйтү, тулысынча әйтеп бетерү. – *Әптелбәр, ...иһиэ ...иһиэ ...синең ...ә ...ә ...әтиең юк, диде миңа! – дип көчкә әйтеп чыга Габдулла, һәм күз яшьләре аны әүвәлгедән дә ныграк буалар.* Ә.Фәйзи

2) Һәрберсенә, барысына да берәмберәм әйтү

**Әйтеп яту** Хәзерге моментта әйтү, әйтергә кирәк табу. *Бәхетенә – һава хәлен әйтеп яталар икән.* М.Мәһдиев

**ӘЙТҮЛЕ** *с.* Чакырулы, өндәүле. *Әйтүле кунак мәҗлесе*

**ӘКАЛЬ** *гар. иск.* Азрак, иң аз, аз дигәндә, иң азында. *Әкаль укырга вә язарга үгрәнмәк лязим.* К.Насыйри

**ӘКӘ** *и.* Төрки халыкларда (казакъ, кыргыз, үзбәк), Себер татарлары диалектында һ.б.да очрый торган сүз; *к.* **ага.** *Хафиз әкә, атын капка төбенә куеп, йортка кереп килгәндә, Шамил Сәрвәрне кулларына күтәреп алган да нишләргә белми шаккатып тора иде.* Я.Зәнкиев. – *Вай, Искәндәр әкә, сезме соң бу? – диде Нәркизә.* Г.Үзиле

**ӘКӘЙ** *и.* 1) *тар. к.* **әкә**

2) *тар.* Старшина бүреге

3) *диал.* Мари хатын-кызларының баш киеме (старшина бүрегенә охшаш булган). *Нижгород һәм Сембер губерналарының мишәр хатыннары аскы яулыкны «сылапцау» (сылавыч), «әкәй» дип тә атаганнар.* Р.Мөхәммәдова

4) *диал.* Мари хатын-кызы үзе. – *Синең әбиең әкәй булган, шуңа мокыт син! – дип кычкырды ул, ниһаять.* Р.Зәйдулла

**ӘКӘЛӘ** *и. фар.* 1) Озынчарак чикләвек; имән чикләвеге. – *Бер мин генә имән әкәләсе ашап йөрмәдем инде...* М.Галәү. *Әкәлә җыюдан башы чыкмас!* Р.Батулла. *«Имәндә икән әкәлә!» – дип уйлап куйдым мин.* Р.Гаязетдин

2) Ылыслы агачларның озынча җимешлеге; күркә. *«Әкәлә» – нарат күркәсе, чикләвек агачы бөресенә дә, «әкәлә» дип, керәшен татарлары телендә әйтелә.* Р.Батулла

**ӘКӘМӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Моңарчы белмәгән яки күрелмәгән нәрсә, сәер хәл. *Чит илләрдә йөри-йөри бик күп әкәмәтләр күргән --- илче Феофан,*

*гомерендә беренче тапкыр, коты алынып, чокырга үрелде.* М.Хәбибуллин. *Бу ниткән әкәмәт – алтмыш яшен тутырып узган, кырык ел буена колхозны җилкәсендә тарткан фронтовик Айтугановны таларга җыенабызмы?* Г.Ахунов

2) Искиткеч, искитәрлек вакыйга, гаҗәп нәрсә. *[Аттаукай] Җитез бер грузинның алар торагына килеп керүен һәм Кыминә әбине урлап китүен күз алдына китерә. Әкәмәт тә булыр иде соң!* А.Мифтахетдинов. *[Мияссәр:] Баланы, яшьләрне тәрбия итү – һай авыр, әкәмәт икән ул!* А.Гыйләҗев

3) Мәзәк; кызык нәрсә, көлкеле хәл. *Хафизә «чабата» көенә такмак әйтеп тора: «Тәлә-лили-тә-тә, тәлә-лилитә-тә...» Класс моңа күнеккән инде. Адгамов абый гына бу әкәмәткә исе китеп карап тора...* Т.Мөбарәков

**2.** *с. мәгъ.* 1) Искиткеч, гаҗәп. *Гомер бакый кешеләрнең өннәрендә түгел, төшләрендә дә күрмәгән бу әкәмәт мәшәкатьтән читтә, калса да, бер Әмин генә калгандыр.* Ж.Рәхимов. *Ул белә: авылның әкәмәт бер гадәте бар, күпертергә ярата авыл – икәүдән-икәү сөйләшеп торсаң, «үбешеп тордылар» ди авыл, тол хатынга кереп, чәй эчеп чыксаң, «кунып калды» дип сөйли.* Г.Ахунов

2) Көтелмәгән, уйламаган; ят. *[Зәйтүнә] Документларын алырга дип, кабул итү комиссиясенә барса, әкәмәт хәл килеп чыкты.* Ф.Гыйльми. *Силос, печән төягән йөк машиналарына, «Беларусь» тракторларына ияләнгән сыерларның мондый әкәмәт нәмәрсәне бөтенләй күргәннәре юк иде, шуңа күрә аны тансык иттеләр, иснәп, ялап карарга ымсындылар.* Ф.Гыйльми

3) Башкалардан аерылып торган, үзенә күрә аерым бер төрле, гаҗәеп, мәзәкчән. – *Кызык. Кара әле син аны, әкәмәт егет икәнсең бит син дә... – дип кенә чикләнде.* Р.Мөхәммәдиев. *[Лаборант кыз:] Әкәмәт сәер кеше икәнсез, абый! Ничек инде без көн дә саен агылып торган биш йөз олауның пробасын саклап асрый алыйк, ди?* Г.Ахунов

4) Кыяфәте, формасы гадәти булмаган, үзенчәлекле. *Укытучыны тынлыйм, күктә йөзгән әкәмәт болытларны күзәтәм.* Ж.Тәрҗеманов. *Матур саплы пәкеләр, портсигарлар, зажигалкалар, мундштуклар, бизәнү әйберләре – әллә нинди әкәмәт нәрсәләр ясыйлар иде алар.* М.Юныс. *Ә океан тирәнлекләрендә --- кальмарлар, креветкаларның кайбер төрләре, әкәмәт формалы балыклар яши.* Табигать белеме

**3**. *рәв. мәгъ.* Бик нык, әйтеп бетергесез. *Әкәмәт зур чүмечләрдән чәчрәп торган кайнар, сыек металл агыздылар.* Н.Фәттах. *Миңнурыйга әкәмәт шәп туй күлмәге таптым.* Ф.Латыйфи. *Әкәмәт үткер бу җавапны ишеткәч, ирексездән, Рудольф көлеп җибәрде.* Р.Вәли

**4**. *ы. мәгъ.* Гаҗәпләнүне, сәерсенүне, аптырап калуны белдерү өчен кулланыла. *Ни сәбәптер, ни өметтер, картларның да кызларга матур күренәсе килә бит, әкәмәт.* Ш.Галиев

◊ **Әкәмәт капчыгы** Төрле кызык хикмәтләр корып, мәзәкләр сөйләп йөрүче, үзенең сәерлеге белән танылган кеше. **Әкәмәткә калу** Көтелмәгән, көлкеле хәлгә калу. **Әкәмәт төенчеге** *к.* **әкәмәт капчыгы**

**ӘКӘ́М-ТӨКӘМ** *и. зоол.* 1) Корсагаяклылар классына караган, бик әкрен хәрәкәт итә торган каты кабырчыклы моллюск; *русчасы:* **улитка**. *Алар [вак балыклар] савыт төбенә салынган ком, чуерташчыклар, әкәм-төкәм кабыклары өстеннән, нәзек сабаклы яшел үләннәр арасында ялт та йолт йөриләр.* Н.Хәсәнов. *Әкәм-төкәм кабырчыклары белән чуарланган сайлыкта, сызгырып, озын сыйраклы ике тәлләтәвеч йөгерешеп йөри.* М.Хәсәнов

2) *анат.* Эчке колакта тавыш кабул итү аппараты урнашкан өлеш, спираль бормача; *русчасы:* **улитка**

3) *күч.* Бикләнеп, йомылып, үз дөньясында гына яшәүче кеше. *Әкәмтөкәм ише, һәркайсы үз кабыгына бикләнеп яшәде, береңнеке икенчеңә артмады.* Ә.Гаффар. *И, мин томана да булганмын соң, таш кабыкта яткан әкәм-төкәм!* Ш.Маннур

**ӘКЕРТЕН** *рәв. сир. к.* **әкрен.** *Гарәпләр бары тик Шәрыкка гына хас салмак, әкертен ритмда яшиләр.* В.Юнысов. *Шамил тарантаска менеп утырды һәм, атларны әкертен генә атлатып, --- Зиннур Бекшеновлар йортына таба юл алды.* Я.Зәнкиев

**ӘКИЯТ** *и. гар.* **1.** 1) Гадәттә тылсымлы көчләр һәм сихерчеләр катнашында барган могҗизалы, маҗаралы хәлләрне, халыкның көнкүрешенә бәйләнешле хыялый вакыйгаларны сурәтләгән халык авыз иҗаты әсәре. *Моны күргәч, кайчандыр укылган әкият искә төшә.* М.Галиев

2) Аерым язучы тарафыннан иҗат ителгән шундый эчтәлектәге һәм формадагы әдәби әсәр. *Балыкчы һәм Алтын балык турында әкиятне А.С.Пушкин иҗат иткән. Г.Тукайның «Шүрәле», «Су анасы» һ.б. әкиятләрен балалар яратып укый*

3) Искиткеч, шаккатарлык, хәйран калырлык, гаҗәеп, гадәти булмаган нәрсә, хыялый чынбарлык. *Тик телләрдә генә аның баһадирлыкларын әкият итеп сөйләргә калды.* Г.Ибраһимов. *Дәниф Мотаваловлар төнлә тугайда учак та ягып җибәрсәләр, дөнья әкияткә әйләнә.* М.Мәһдиев. *Арыш саламы ябылган «алтын түбәле» өй, бала чакның бөек әкияте булып, хәтер утравына кучкән.* М.Галиев

4) *сөйл.* Уйлап чыгарылган хәл, ялган, юк сүз; уйдырма; чынбарлыкта булмаган нәрсә. *Тик миңа ышанмадылар, әкият сөйлисең, әллә ниләр уйлап чыгарасың, диделәр.* М.Галиев. *Даниял исә, башын дәрвишлеккә салып, аның каршында әкият сөйләп тора, фәлсәфә сата.* Б.Камалов. *Башкалар, ялгыз нарат янында кара эт күрдек, дигәндә, борчак чәчә болар, әкият сөйлиләр, дип йөри идем моңарчы.* Г.Тавлин

5) Үзенчәлекле, башкаларга бер ягы белән дә охшамаган кеше турында әйтелә. *[Рәшидә:] Билләһи, картлар йортында бер әкият булдың.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Ялган, уйлап чыгарылган, дөрес булмаган. *[Әмин] Мәгәр көлмәде, ярым чын, ярым әкият сүзнең мәгънәсен аңларга тырышып, бераз басып торды да, кулын селтәп, алачыгына кереп китте.* Ж.Рәхимов

◊ **Әкият сату** Ялган сүз сөйләү, уйдырма, чынбарлыкта булмаган нәрсә

турында бәян итү. *[Тикшерүче:] Мин монда сине әкият сатарга чакырмадым, тагын кабатлыйм, син миңа, бернинди боргаланусыз, үзеңнең совет властена каршы контрреволюцион эшчәнлегең турында сөйлә.* Г.Тавлин. *Әкият сатма! Антын бозып, никах яңартмый, ире белән тора башлаган хатын керсез буламы?* Х.Сафина

**ӘКИЯТИ** *с.* 1) Әкияттә генә була торган, әкиятләрдәге кебек. *Алдында әкияти затларга охшап басып торган ат караучыны күреп, инде аптырамады Рифкате.* Г.Гыйльман. *Кыяфәте белән ул бер әкияти кошка тартым.* Ә.Гаффар

2) Искиткеч, гаҗәеп, тылсымлы. *Әкияти бизәкләр аңа яңадан нindидер рәхәт, бәхетле һәм бүтән чакларын исенә төшергәндәй булды.* А.Сафин. *Һәм шул ук мизгелдә гавамга гаҗәеп матур әкияти моң тарала.* Р.Хәмид

**ӘКИЯТЛӘШҮ** *ф.* Фантастик элементлар өстәлү, әкияткә әверелү. *Тема конкрет булса да, чамадан тыш әкиятләштерелгән, кайбер фантастик моментлар балаларның хыялына сыя алмый.* Ф.Кәрим. *Тарихи вакыйгалар әкиятләшү*

**Әкиятләшә бару** Әкияткә хас элементлар торган саен арту

**Әкиятләшә төшү** Бераз әкиятләшү

**Әкиятләшеп бетү** Тәмам, тулысынча әкиятләшү

**ӘКИЯТТӘГЕ́ЧӘ** *рәв.* **1.** Әкияттә генә була торган итеп, әкияттәге шикелле итеп. *Гарәпләрдә тормышны әкияттәгечә күз алдына китерү --- бик көчле.* В.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* Әкияттәге кебек, әкияттә генә була торган. *Болай да әкияттәгечә бай табынның шәптин-шәп сыйлары аның алдына куелды.* Ф.Яруллин

**3.** *хәб. функ.* Әкияттәге кебек булу. *Әкияттәгечә, ул «туй»да Габдрахманның авыз-борыны май булып, башкаларның «мыек очы»на һәм «ирен читe»нә генә эләкте.* Р.Сибат

**ӘКИЯТЧЕ** *и.* 1) Әкиятләрне күп белүче, әкиятләр җыючы; әкиятләр сөйләүче. *Карлы авылында Гарифҗан исемле әкиятче барлыгын район үзәгендә үк ишеткән идек инде.* Х.Мәхмүтов. *Балалар әкиятче әбигә рәхмәт әйтәләр ---.* Казан утлары

2) Әкиятләр уйлап чыгаручы кеше, язучы. *Бу сорауга мин Батулланың 60 яшь тулу уңаеннан уздырылган бәйрәмендә сәхнәдән Илһам Шакиров әйткән сүзләр белән җавап бирәм: «Батулланы аны, әкиятче дә, хикәяче дә, мәзәкче дә, драматург та, укытучы да, режиссёр да, диләр».* Ф.Хатыйпов

**ӘКРЕН** *рәв.* **1.** 1) Кечкенә тизлек белән, гадәти тизлектән түбән, сүлпән; *киресе*: **тиз**. *Шул чакта район үзәге ягыннан олы юл буйлап әкрен генә килгән бер малай күренде.* Г.Гобәй. *Нәкъ шул вакыт юл өстендә, еракта, авылга таба кайтып килүче чаналы кеше күренде: аның аты, башын чайкыйчайкый, әкрен генә юырта иде.* И.Гази. *Тигез дулкыннар өстендә күтәрелгән парус илә безнең көймә әкрен генә бара.* Г.Коләхмәтов. *Теләк бар, сәләт тә бар, техника да бар, ә эш әкрен бара.* Р.Ишморат

2) *гына/генә* кисәкчәсе белән килгәндә, уртачадан кимрәк булуны белдерә; ашыкмыйча, җай гына. *Алай да Алтынчәч әйбер-кара алмады. Нәни күлмәкләргә сокланып карап торды да әкрен генә атлап китеп барды.* М.Маликова. *Пәрдә әкрен генә күтәрелә, Зур пәрдәнең ике ягында Ике тормыш күренә.* Һ.Такташ

3) Талгын, салмак, җиңелчә, аз гына тирбәнеп, дулкынлангандай итеп. *Тышта кырау белән капланган ботаклар әкрен генә тирбәнәләр.* К.Нәҗми. *Исәр-исмәс җил белән әкрен генә тузанланып, тынгысызланып торган юл да --- бу тынлыкны һәм хәрәкәтсезлекне боза алмыйлар иде.* Ә.Фәйзи

4) Саклык белән. *Кайткач, әкрен генә кагар идем Синең йоклап яткан тәрәзәңне.* Ә.Ерикәй. *Үзе авыруны торгызып, билләреннән тотып, әкрен генә шалашка кертеп салды.* Г.Гобәй. *Каюм, кыюлыгын җыеп, парта астыннан, алдагы малайга әкрен генә тибеп алды.* Г.Гобәй

5) Сөйләгәндә, уен коралында уйнаганда, җырлаганда һ.б.да тавышның көче түбән булуын яки аз гына ишетелүен белдерә; ишетелер-ишетелмәс, тын гына. *Стенадагы репродуктордан, әкрен генә, Сәйдәшнең «Шәрекъ биюе» ишетелеп торыр.* А.Сафин. *Ләкин Илсөяр шулхәтле әкрен әйтте, ят бабай аның сүзләрен бөтенләй ишетмәде.* Г.Гобәй. *Тимербулат, морҗа ышыгына утырып, әкрен генә гармун уйный башлады.* К.Нәҗми

6) Тавышсыз итеп, тавыш чыгармыйча, шыпырт кына. *Билгеле, эт аңар кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган.* А.Алиш. *Аны уятмаска теләп, әкрен генә кердем.* А.Шамов

7) Озакка сузылып, озак тоелып, көттереп. *Ә вакыт әкрен, авыр уза иде.* А.Шамов. *Минутлар бер-бер артлы әкрен генә тезелеп үттеләр.* Г.Гобәй. *Ләкин кыш үтте, яз җитте, төзелеш бик әкрен барды.* М.Маликова. *Шул рәвеш, әкрен-әкрен, гомер үтә.* Ш.Бабич

8) Вакыт үткән саен аз-азлап, эзлекле рәвештә үзгәреп бара торган (гадәттә табигать күренешләре); акрын-акрын, акрынлап, салмак кына. *Әкрен генә иңеп килгән тымызык язгы кич, безнең аерылышуны сизгәндәй, ничектер, аеруча моңсу, сагышлы иде.* Ч.Айтматов. *Үзәннәр, кырлар буенча Көз килә әкрен генә.* С.Хәким. *Днепр өстеннән, әкрен генә, беленер-беленмәс кенә булып, нечкә вуаль шикелле үтәли күренә торган җиңел томан күтәрелә иде.* А.Шамов // Эзлекле рәвештә көчәя яки кими барып; акрын-акрын, акрынлап. *Бүген ул гадәттәгедән дә хәтәррәк сөйләшә, сүзе белән кунакларын күмеп ташлап, әкрен-әкрен, үз ихтыярына буйсындыра бара иде.* А.Гыйләҗев

9) Авырлык белән, начар. *[Айтуганов Сәүбәновка:] Ә менә бураларда озак яткан орлык, кеше кебек үк, картая, авыруларга бирешә, әкрен үсә, гомумән дә уңышны аз бирә.* Г.Ахунов

10) Кемнең дә булса кәефенә туры китереп, җайлап, ипләп, йомшак кына, әдәпле итеп. *Галинур әкрен генә сүз башлады.* Г.Ахунов. *Рамилә әкрен генә сорады, чөнки үзе дә аңлый: егет юкка еламаган, бу мәхәббәтнең ахыры булган...*. М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Талгын, салмак; йомшак. *Кич иде, шатлык белән нурлар чәчеп, ай ялтырый, Искән әкрен*

*җил белән яфрак, агачлар калтырый.* Г.Тукай. *Спасс сырты ягыннан искән төнге әкрен җил авылга болын печәннәренең хуш исләрен алып килә.* Г.Әпсәләмов

2) Көчсез, зәгыйфь. *Нурханова председательнең үзе хакында сүзне озайтмады, аны котырткандай, әкрен тавыш белән әйтте.* М.Маликова. *Арадан берсе --- әкрен генә тавыш белән җырлап җибәрде.* Ә.Фәйзи

3) Тыныч, басынкы, юаш. *Мәҗлестәгеләр, яше җитмешләрдән узып, зур биек маңгае тагын да зураебрак калган, калын кара кашлы, әкрен һәм сабыр холыклы әдипкә төбәлделәр.* Г.Ахунов

**3.** *ы. мәгъ.* Берәр нәрсә эшләргә рөхсәт итмәгәндә, тыйганда, сак булырга үтенгәндә әйтелә. *– Әни! Әкрен! Әни... – дип, Хәлим пышылдый башлады.* И.Гази. *Бер-ике атлауга, Алмас, колхозчыларга борылып: «Тс-с, әкрен!» – ди.* А.Әхмәт

**ӘКРЕНӘЙТҮ** *ф.* 1) Хәрәкәт тизлеген киметү. *Бер сәгать чамасы бик кызу барганнан соң, төркем адымын әкренәйтте.* Т.Әйди. *Хәтта чылтырап аккан чишмә дә үзенең агышын әкренәйткән кебек.* Г.Әпсәләмов. *Порт каршысындагы рейдка җиткәч, пароход баруын әкренәйтә, кемнедер чакырып, басынкы тавыш белән гудок бирә.* М.Юныс

2) Нәрсәнең дә булса хәрәкәт көчен киметү, азайту, кысу. *Су кайнап чыккач, утны әкренәйтеп, тагын 10 минут пешерәбез.* Файдалы киңәшләр

3) Нәрсәнең дә булса тавышын бераз киметү, баса, киметә төшү. *Гәләви гармунын әкренәйтте.* М.Гали

4) Йомшак тавыш белән, ярым пышылдауга якын итеп сөйләү. *Укытучы тавышын әкренәйтә, пауза ясый.* З.Хисамов. *Овчинников шуннан соң тавышын әкренәйтте.* Н.Акмалов. *– Тукта әле, – диде Гаяз, тавышын әкренәйтеп, миңа якын килде, – нигә соң син мине һаман үләргә тиеш итеп кенә саныйсың?* М.Әмир

**Әкренәйтә бару** *к.* **әкренәйтеп бару.** *Булат, машинасын әкренәйтә барып, юл читенә чыгып туктады.* М.Әхмәтшина

**Әкренәйтә башлау** Әкренәйтергә тотыну

**Әкренәйтә бирү** Әкренәйтүне дәвам итү. *Тизлекне әкренәйтә биребрәк, безнең полосага басарга маташкан «Жигули»га юл бирдең дә миңа борылдың: – Өлгермәсәм, син көтәсең инде...* М.Кәбиров

**Әкренәйтә төшү** Бераз әкренәйтү, әкренрәк итү. *Ул, ирексездән, адымнарын әкренәйтә төште.* Ә.Еники. *– Аннан беләсеңме нәрсә, Сөембикә! – диде ул, сер әйткәндәй, тавышын әкренәйтә төшеп. – Кичә сессиядә сөйләнгән сүзләр алар, бер Нургали абыеңа гына түгел, ферманың барлык кешеләренә дә кагыла бит.* Ә.Еники

**Әкренәйтеп алу** Кыска вакытка, бераз әкренәйтү

**Әкренәйтеп бару** Әзлекле рәвештә, акрынлап, аз-азлап әкренәйтү

**Әкренәйтеп кую** Әкренәйгән хәлгә китерү

**Әкренәйтеп тору** Әлегә, хәзергә әкренәйтү; вакытлыча әкренәйтү. --- *сулышым кысылды, ләкин адымны әкренәйтеп тормадым, үтәр әле, дидем. Беренче тапкыр гына түгел.* Ә.Еники

**ӘКРЕНӘЮ** *ф.* 1) Хәрәкәт тизлеге кимү. *Юл озын, әңгер-меңгер, --- ат пошкырып ала да таучыкларда әкренәя, менеп җиткәч, куалаганны да көтеп тормыйча, иңен уңайтып юыртып китә.* Я.Зәнкиев. *Бер үрле җирдә, юл борылып, машиналарның тизлеге әкренәйгән урында, засадага яттык.* З.Зәйнуллин. *Пароходның барышы әкренәйде.* К.Нәҗми. *Машина бу юлы да туктамады, ләкин бик әкренәйде.* Г.Гобәй

2) Нинди дә булса берәр нәрсәнең темпы, ритм интенсивлыгы кимү. --- *ә давыл артыннан килгән бәрәкәтле яңгыр, тәүлек буена, бер әкренәеп, бер шәбәеп, туры гына яуды да яуды.* Ә.Еники

3) Нәрсәнең дә булса тавышы кимү, чак кына ишетелерлек хәлгә килү, тынычлана төшү. *Күк күкрәү әкренәя.* Һ.Такташ. *Ләкин Имәлинең тавышы әкренәймәде, ---.* М.Әмир. *Кәүсә эченнән, бер көчәеп, бер әкренәеп, тонык кына гүләү ишетелә иде.* Ф.Шәфигуллин

4) Азаю, саны кимү. *Кичкә таба эшелоннар килү әкренәйде.* Ш.Усманов

5) Вакыт сузылу, озак кебек тоелу. *Фидаяның күз алдында бу минут әкренәйде, сузылды кебек: «Әти-и!..»* М.Маликова

**Әкренәеп алу** Кыска вакытка, бераз гына әкренәю

**Әкренәеп бару** Аз-азлап, акрынлап әкренәю

**Әкренәеп бетү** Ахыр чиккә җитеп әкренәю; тәмам әкренәю

**Әкренәеп калу** Ниндидер сәбәптән, мизгелдән, күпмедер вакыттан соң әкренәю

**Әкренәеп килү** Аз-азлап, акрынлап әкренәю. *Кинәт ул вакытның аз калуын, йөрәктәге тойгыларны тел белән сөйләп өлгерергә мөмкин түгеллеген, разъездга туктарга дип, әкренәеп килгән тәгәрмәчләрнең моңа мөмкинлек бирмәүләрен аңлады.* Һ.Такташ

**Әкренәеп китү** Кинәт әкренәю. *Тик пулемётны җыюга килеп җиткәч кенә, эш әкренәеп китте.* Г.Гобәй. *Аның адымнары әкренәеп китте, йөзенә гамьсезлек билгесе чыкты.* М.Юныс

**Әкренәеп кую** Кыска вакыт эчендә, кинәт әкренәю

**Әкренәеп тору** 1) Соңгы вакытта, бераз, берникадәр әкренәю

2) Әлегә, вакытлыча әкренәю

**Әкренәя башлау** Әкренәергә керешү, әкренәюе сизелү. *Шулай да үргә каршы йөгерү җиңел булмады. Йөрәкләр ешрак типте, куллар ныграк селтәнде, адымнар әкренәя башлады.* Н.Фәттах

**Әкренәя бару** *к.* **әкренәеп бару.** *Зыятдин бабайның тавышы сөйләгән саен әкренәя барып, озакламый ул бөтенләй пышылдауга күчте.* Р.Вәлиев

**Әкренәя төшү** Бераз, беркадәр әкренәю. *Буран – чак кына басыла, җил чак кына әкренәя төшкән кебек.* Г.Әпсәләмов. *Әз генә әкренәя төшеп, Гөлсем апаны читләтеп үтә башлады.* Г.Гобәй

**ӘКРЕНЛӘНҮ** *ф. сир. к.* **әкренәю**

**ӘКРЕНЛӘТҮ** *ф. к.* **әкренәйтү**. *Ул минем белән тиңләшәте, мин бер дә аңар карамыйча, аны алдан җибәрер өчен, йөрешне азрак әкренләткән идем.* Ш.Камал

**Әкренләтә бару** Аз-азлап, акрынлап әкренләтү

**Әкренләтә башлау** Әкренләтергә тотыну

**Әкренләтә төшү** *к.* **әкренәйтә төшү.** *Мин укуымны әкренләтә төштем.* М.Гали

**ӘКРЕНЛӘ́Ү** *ф. сир.* **1.** *к.* **әкренәю.** *[Сабит] Чишмә авызыннан эчәргә теләп иелсә, аның сулышы тиюгә, су тибеше әкренли, юынырга керешсә, тына, туктала.* А.Гыйләҗев

**2. әкренләп** *рәв. мәгъ.* 1) Тизлекне, темпны яки тавышны аз-азлап әкренәйтә барып, озакка сузып. *Хор әкренләп туктала.* Һ.Такташ

2) Кабаланмыйча, ашыкмыйча; җай гына. *Әкренләп кенә аның янына кешеләр җыела башлады.* Ш.Усманов. *Шулай итеп, бераз яткач, без, көтүне ерак түгел бер күлгә алып китеп су эчертәбез дә күл кырыенда бераз туплап тотып, әкренләп, авылга таба кайтырга чыгабыз.* М.Гали. *Шул, егетем, теләгең булса, өйрән – әкренләп, барысын да төшендереп бирермен.* Г.Әпсәләмов

3) Әкренлек белән, эзлекле рәвештә күчәя барып. *Ул шулай күңелем бозларын эретте, әкренләп, оялу-тарсынуларымны оныттырды.* М.Маликова. *Байназар, менә шулай, әкренләп, күккә – бердәнбер ышаныч булырлык изге затка, үзе генә күзаллаган газиз рухка табына башлады.* М.Әмирханов. *Ләкин тормыш аның фикерләренә, әкренләп, төзәтмәләр кертә башлады.* Ф.Садриев. *Өйгә, әкренләп, караңгы иңде.* С.Хафизов

4) Талгын, салмак кына. *Кар һаман әкренләп ява.* Ш.Камал

5) Алдан, җай гына, аз-маз. *Безнең геройлар әкренләп юлга әзерләнә башладылар.* Р.Мөхәммәдиев

6) Белгертмичә, сиздермичә; әкрен-әкрен. *Шунлыктан иң элек – Гыйльмулла, аның артыннан Сәхип белән Фәрхи карчык, әкренләп, бер-бер артлы, тавышсыз-тынсыз гына, өстәл яныннан шудылар.* Ш.Камал. *Безнең көннәр киренке хезмәт белән әкренләп үтә тора.* Җ.Тәрҗеманов

7) Ипләп, җайлап; йомшак итеп, тыныч кына. *Талаштан кызарган Хәйдәр аңа таба борылды, татарча әкренләп әйтте.* Г.Ибраһимов

8) Ашыкмыйча, асылын аңлап, җаена-рәтенә төшенеп. *Сез, яшьләр, әкренләп өйрәнегез.* Т.Гыйззәт

9) Күпмедер вакыттан соң, вакыт үтү белән. *Әкренләп, кыз үз күңеленә дә егетнең бик якын булып китүен тоя башлады.* М.Маликова. *Ләкин йөзе шундый тыныч күренсә дә, аның да күңелен борчыган уйлар булган икән, әкренләп кенә әйтә башлады ул аларны.* М.Әмир. *Ул шулай, әкренләп, телдән төште.* К.Нәҗми. *– Нәрсә соң бу? – дип уйлыйм мин, акылымны җыярга тырышып һәм булып узган вакыйгаларны әкренләп-әкренләп хәтерли башлыйм.* А.Расих

10) Хәл-әхвәл, сәламәтлек сорашып исәнләшкәндә, кыска җавап булarak кулланыла: бер көе, үз җае белән, ярыйсы. *– Хәлләр ничек? – Әкренләп*

**ӘКРЕНЛЕК** *и.* Әкрен булу. *Атның салмак атлавыннан җаным өшеп, кан катты... Әкренлектән йөрәк сызлый, кучеремнең – янбашы...* З.Мансуров. *Авырлык һәм әкренлек белән генә караңгылык пәрдәсе төшә иде.* Ш.Камал

**ӘКСӘРИЯТ** *и. гар. иск.* Күпчелек. *Ул инде ялгыз инсаниятнең бер кисәгенә, үзе илә гайн каннан, гайн диннән булган бер кыйсменә генә түгел, бөтен мәзлум --- ач-ялангач әксәриятенә хезмәт итмәк булды.* Й.Акчура

**ӘЛ** *и. бор.* Кул. *Нә гәүдәсе, нә азакы, нә әле, Бер кисек башдыр, һаман сүзләр теле.* Г.Тукай

**ӘЛӘК** *и.* 1) Оешма җитәкчеләренә, хөкүмәт вәкилләренә һ.б.ш. югары органнарга, кемне дә булса берәр нәрсәдә гаепләп, яла ягып язылган яки телдән хәбәр ителгән яшертен шикаять. *Шымчылык итү, яла ягу, әләк язу – болар аның [Шоманың] канына сеңгән, яшәү рәвешенә әйләнгән.* Ф.Сафин. *Нәҗес куллар тарафыннан язылган күпме әләк!* И.Юзеев. *Ксенофонтов, үзенә алиби өчен, әти өстеннән әләк яздырта.* Х.Камалов

2) Берәр кеше яки нинди дә булса вакыйгага яисә гамәл турында ризасызлык белән җиткерелгән сүз, хәбәр. *– Әлеге әләкне актив утырышында тикшерик! --- – Бик хуп. Тик менә «әләк» диюегез генә ошап бетми. Әләк түгел, үтенеч бу.* Г.Бәширов

**ӘЛӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Оешма җитәкчеләренә, югары органнарга, берәр кешене нәрсәдә булса да гаепләп, яла ягып, яшертен хәбәр җиткерү, сүз сөйләү; донос ясау. *Әмма кемдер --- түбәнлекләргә дә бара, сата, «гаебеңне» табып әләкли.* Н.Хәсәнов

2) Берәр нәрсә турында кемгә дә булса әйтү, аның эшен фаш итү. *Класста һәм мәктәптә булган хәлләрне минем өйдә сөйләгәнем юк. Сөйләсәм, әләкләү була бит ул.* Г.Тавлин. *Хәзер инде каенесе, шөбһәләнсә дә, абыйсына аны әләкли алмаячак иде.* Т.Әйди. *Кибетче Зәйнәп, берне – биш, койрыгы белән куш итеп, кибеттә очрашуларын, үтә ямьсез итеп, Ихласка әләкләгән иде инде.* А.Гыйләҗев

**Әләкләп алу** Кыска гына итеп әләкләү, әләкләргә өлгерү

**Әләкләп бару** Һәрберсен, һәр очракны даими әләкләү. *Нинди булсын, менә шушында синең соңгы ризыгыңны бүлешеп ашап, аннан соң син сөйләгән бөтен нәрсәне начальникларга әләкләп барулар.* К.Булатова

**Әләкләп йөрү** Бертуктаусыз, барысына да әләкләү. *Бер хатын әләкләп йөргән иде, нәчәлник аны эштән үз теләге белән китәргә мәҗбүр итте.* Х.Камалов. *Шул чөгендерен колхозга илтеп аудартып, [җиңгәчәй] идарәгә әләкләп йөрде.* Ф.Садриев

**Әләкләп тору** Һәрвакыт, гел әләкләү. *[Барсуков:] Күрмисеңмени? Лохмачев безнең һәр адымыбызны, һәр әйткән сүзебезне, түкми-чәчми, капитанга әләкләп тора.* М.Юныс. *Кыямәт көнендә, фәрештәләр сорау алганда, өстеңнән әләкләп торалар икән алар.* К.Кәримов

**Әләкләп чыгу** Һәрберсенә әләкләү; берсен дә калдырмыйча, һәрберсен әләкләү

**Әләкли башлау** Әләкләргә тотыну. *[Вафа] – Пешекче хатын чүлмәк ватты, – дип әләкли башлады.* М.Галәү

**Әләкли бирү** Әләкләвен дәвам итү

**Әләкли төшү** Тагын да әләкләү

**ӘЛӘКЛӘШҮ** *ф.* 1) *к.* **әләкләү** (*1 мәгъ.*). *Бик кызса да, өлкә җитәкчеләренә әләкләшеп, [Заманов] үзенең*

*абруен төшерәсе килмәде.* Ф.Сафин. *Әләкләшеп, иптәшләре өстеннән язганы өчен, моны укудан куып чыгарганнар.* Т.Миңнуллин

2) Бер-берсеннән зарланып, кемгә дә булса сөйләү, әйтү, сүз җиткерү. *Уенга мавыккан балалары, аны күргәч, шундук янына йөгереп килеп, бер-берсен әләкләшергә тотынды.* Т.Әйди

**Әләкләшә бирү** Бернәрсәгә карамыйча, әләкләшүен дәвам итү

**Әләкләшә башлау** Әләкләшергә тотыну

**Әләкләшеп йөрү** Әле – берсенә, әле икенчесенә әләкләү. *Зәһидә апа белән әйткәләштек. Үзе әнә әләкләшеп йөргән юк-барны...* Н.Фәттах

**Әләкләшеп тору** Гел, һәрвакыт, даими рәвештә әләкләшү

**ӘЛӘ́К-ОШАК** *җый. и. к.* **әләк-чалак.** *– Нигә мин рәис булырга, ди? Әнә... – диде дә капылт тукталды Бәйрәмхан, колхозүзәк вәкиле алдында кемне дә булса тәгаенләп атавының әләк-ошак булып аңлашылуы башына китереп сукты.* М.Хуҗин

**ӘЛӘ́К-ЧАЛАК** *җый. и. к.* **әләк-чәләк**

**ӘЛӘ́К-ЧӘЛӘК** *җый. и.* Һәртөрле әләкләр, яла ягулар, гайбәтләр. *Борчулар да, тавыш-гауга да юк, Юк кимсетү, әләк-чәләк тә.* Э.Шәрифуллина. *Үз ире өстеннән әләк-чәләк килеп йөрү җиңел түгел иде аңа.* Ә.Моталлапов. *Морат Әхмәт абзыйның, йомыштан битәр, әләк-чәләк белән күбрәк йөргәнен белеп бетергән иде инде.* Р.Батулла

**ӘЛӘКЧЕ** *и.* **1.** Кеше өстеннән сөйләп йөрүче, әләк белән шөгыльләнүче кеше. *Үз иптәшләре дә яратмый әләкчеләрне.* З.Хөснияр. *Бариевич елак һәм әләкче иде, хәзер тавышы көрәйде, сүзләре бөердән генә чыга.* А.Гыйләҗев. *Алар карьеристлар һәм әләкчеләр, һәртөрле җинаятьчеләр өчен уңай шартлар, җирлек тудырдылар.* Н.Гамбәр

**2.** *с. мәгъ. к.* **әләкчел**. *Үз-үзен саткан әләкче колда Иман да булмый, намус та.* Г.Афзал

**ӘЛӘКЧЕЛ** *с.* Әләкләргә ярата торган. *Аны урам чатында саклап торып тәпәләштерүчеләр дә булды, әмма Шәкүр әләкчел гадәтен мәктәптә дә куймый иде.* Х.Камалов

**ӘЛӘКЧЕЛЕК** *и.* Әләкләп йөрү гадәте. *Куркак, көнче, байлыкка омтылучы бу кешеләрне яңа тормышның нигезенә салынган куркыту, алдау, икейөзлелек, явызлык, әләкчелек һәм коллык психологиясе җинаятьче ясый.* Д.Заһидуллина

**Ә́ЛӘЛӘ** *ы. к.* **әллә-лә**. *Юл буе шым утырган, барлыгы да беленмәгән Әхмәтзыя бу юлы чыдамады: «Әләлә!» – дип куанып ычкындырды.* А.Гыйләҗев

**ӘЛӘ-ЛӘ-ЛӘЙ** *ы. к.* **әллә-лә**. *Алдыма-артыма карамый ашыгып бара идем, шак иттереп, Хәтмулланың маңгаена килеп бәрелдем. – Әлә-ләләй!.. Күзең тонганмы әллә, башны яра яздың бит!* М.Сәлим

**ӘЛӘМ** *и. гар.* 1) *к.* **байрак**. *Күп тә үтми, олы тугайлыкта мәйдан булдырылды, урта бер төбәккә колга кадалды. Болгарның зәңгәр төстәге әләме эленде.* М.Хәбибуллин. *Ширәмәтовлар йортының ташландык коесында җил елый, ә төсе уңган кызыл әләм, шуны котыртып, шапы-шопы кул чаба.* Ә.Гаффар

2) Байрак шикелле дулкынланып, җилфердәп торган берәр нәрсәгә ишарәләп әйтелә. *Арырак – шәһәр читендәрәк – ниндидер торбалардан чыккан ялкын кызыл әләм булып тирбәлә.* Н.Хәсәнов

**ӘЛӘМӘН** *и. фар.* 1) *тар.* Профессиональ гаскәри булмаган, ирекле кешеләрдән җыелган сугышчылар төркеме; ополчение

2) *к.* **әтрәк-әләм**

**ӘЛӘ́М-СӘЛӘМ** *с.* 1) Сәләмә, тузып беткән. *Әләм-сәләм кием*

2) *куч.* Тоташ булмаган, теткәләнгән, кисәк-кисәк. *Төнге күк йөзен алама болыт кисәкләре камап алган, шул әләмсәләм болыт арасыннан, сирәк кенә, ай карап ала.* Ф.Сафин

**ӘЛӘ́Н-ШӘЛӘН** *рәв. сөйл.* Теләмичә генә, ашыгып, аннан-моннан; әпентөпен

**ӘЛӘҢГӘСӘР** *и.* 1) *миф.* Кешеләргә дошман булган явыз әзмәвер; дию

2) *диал.* Аңгыра, ахмак (*зур гәүдәле дә булган кешегә карата*)

**ӘЛӘШӘ** *и. тар.* Ут, учак аша сикерү белән характерлана торган язгы мәҗүси бәйрәм (хәзерге вакытта балалар уены буларак сакланган)

**ӘЛӘШӘЛЕ** *и.* Әләшә сикерү

**ӘЛБӘ** *и. гар.* Кыздырылган онга бал, май кушып болгатып әзерләнгән чәй ризыгы. *Кеше белән бер казаннан мин, итле аш түгел, әлбә ашап торырга да риза түгел.* М.Гали. *Әлбә югары сортлы бодай онынnan пешерелә.* Татар халык ашлары

◊ **Әлбә ашадыңмы әллә?** Тәмле ризык ашап, әллә телеңне йоттыңмы, дигән мәгънәдә, эндәшмичә янда торган кешегә карата әйтелә

**ӘЛБӘТ** *кер. сүз гар. иск. к.* **әлбәттә.** *Мин барам, әлбәт, барам; Бармасам, дөнья йөзе булсын хәрам.* Г.Тукай. *Сөембикә әйтте: – Әлбәт, әлбәт, син акларсың кылмышыңны.* Р.Батулла

**ӘЛБӘ́ТТӘ** *кер. сүз гар.* Әйтелгән фикернең дөрес булуын катгый рәвештә раслау өчен кулланыла; һичшиксез, шөбһәсез, шиксез. *Габделрахман да, Абдулла да болар турында белмиләр иде, әлбәттә.* Җ.Рәхимов. *Әлбәттә, һичберсеннән үзе теләгән җавапны таба алмады.* Г.Гобәй. *Аермачык: эш хәлфәдә түгел иде, әлбәттә.* Ә.Фәйзи. *Әллә шулай түгелме? Шулай, әлбәттә.* З.Фәтхетдинов

2) *Инде* кисәкчәсе белән килгәндә, бәяләү объектына карата сөйләүченең фикере дөрес һәм бәхәссез булуын көчәйтеп белдерә. *Һәм, әлбәттә инде, бу хәбәр атасы Йосыф бәккә дә барып ирешә.* М.Хәбибуллин. *Трамвай, автобус көтеп, әлбәттә инде, соңга калдым.* М.Мәһдиев

3) Сөйләүченең фикерен раслау өчен җавап биргәндә кулланыла; әйе, сүз дә юк. *– Әлбәттә, – диде ерак юл килүдән тәмам талчыккан майор.* Җ.Рәхимов. *– Әлбәттә, тәмәке, – диде Габделвәли.* Ә.Фәйзи

**ӘЛВИДАГ** *и. гар.* 1) *дини* Уразаның соңгы көннәрендәге кичке мәҗлес һәм шунда әйтелә торган мөнәҗәт (изге рамазан ае белән саубуллашу буларак). *Рамазан ае кичләрендә ул малай, мәчет манарасына менеп, яшь егетләр белән, сузып-сузып, «әлвидаг» көйләде.*

Г.Бәширов. *Манара башыннан «әлвидаг» көенә бөтен авылга җыр таралды.* М.Мәһдиев

2) *этн.* Мишәрләрнең кайбер төркемнәрендә: кызның, кияү йортына күчкәндә, ата-анасы белән хушлашу җыры

3) *иск. кит.* Мәңгегә аерылу; мәңгегә аерылганда әйтелә торган хушлашу сүзе; хуш, сау бул

**ӘЛЕ** *рәв. гар.* **1.** 1) Шушы вакытта, хәзерге моментта, хәзер. *[Буран] Элеккечә үк әле нык себерә иде.* А.Мифтахетдинов. *Әле беренче мәртәбә сугышка чыгучы яшьләр, сизелерлек каушап, картраклардан төрле киңәшләр сорый башладылар.* Ш.Усманов. *Әле менә тагын фронтка китеп барам.* М.Җәлил

2) Хәзер дә, хәзерге вакытта да; һаман да (дәвамлы эш-процесс турында). *Авыл, инде яктырып көн туса да, әле уянмаган, тирән йокыда сыман.* Г.Тавлин. *Лейтенант җилкапкага чыкты, тәнендәге киеренкелек әле сүрелмәгән иде.* З.Фәтхетдинов

3) Моңарчы, моңа кадәр, бу көнгә кадәр. *Татар театрының әле беркайчан да кешеләрне бозыклыкка өйрәткәне юк.* Т.Миңнуллин. *Тукаебызның да әле әллә никадәр серләре ачылмыйча ята булыр*. Р.Батулла

**2.** *кис.* 1) Боерык фигыль янында килеп, кемнән дә булса берәр төрле эш башкаруны сорау, кушу, үтенү яки берәр нәрсә эшләргә тәкъдим итү, мәгънәсен белдерә. *[Сатучы Наиләгә:] Аларга лаек бүләк монда булмас, әйдәгез әле, үзем сайлашыйм.* А.Гыйләҗев. *Кәримҗан, Кәримҗан! Шул икраны, бик калын итеп, булки өстенә салып бир әле!* Ф.Әмирхан. *Мә әле, Сөләйман абзый, бусы – синең өлеш.* М.Фәйзи

2) Теләк фигыль белән килеп, берәр нәрсә теләүне, үтенеп сорауны, ялваруны, нинди дә булса эшне бергә башкаруны һәм җиңелчә кушуны белдерә. *Мин тагын: – Тагы бераз гына, бик аз гына торыйк әле; монда шундый рәхәт, шундый матур, – дидем.* Ф.Әмирхан. *Бераз йөреп керим, һавада булыйм әле, дип, урамга чыккан идем.* А.Шамов

3) Сорау, хикәя җөмләләрдә үткән заман хикәя фигыль һәм *соң* кисәкчәсе янында, килеп чыккан нинди дә булса бер хәлдән аптырап, каушап калуны, төрле сораулар белән бимазалануны, сәбәбен ачыкларга теләүне һәм ни эшләргә белмичә торуны белдерә. *Нигә соң шулай булды әле бу? Нигә соң бүген генә Искәндәр аның төшенә килеп керде әле?* Г.Үзиле. *Ни өчен соң әле без туп-туры ут нокталары өстенә килеп чыктык?* И.Гази. *Безнең кунагыбыз кайда соң әле?* Р.Ишморат. *Нишли соң әле ул сездә?* А.Шамов

4) Үткән заман хикәя фигыльнең барлык формалары янында килеп, эш яки хәлнең яңа гына башкарылуын белдерә. *Нечкә бармаклар, дигәннән, күңелгә килде әле.* Ш.Камал. *Әнә аның аяк эзендә үләннәр дә калкып өлгермәгәннәр әле.* Г.Бәширов

5) Хәзерге заман яки үткән заманның юклык формасындагы фигыльләр белән килеп, җөмләдә хәбәр ителгән эш-процессның дәвам ителүен, ахырына кадәр тәмамланмаган булуын белдерә. *Өянке бүгенгедәй хәтерли әле: бәйрәмгә ике көн кала, төне буе, гарасатлы давыллап, яшенле яңгыр яуды.* М.Галиев. *Ә доцент һаман сөйли иде әле, ак башлыгын түгәрәк башына кыңгыр салып, бүлмә буйлап йөренә-йөренә сөйли иде.* М.Маликова

6) Киләчәк заман хикәя фигыльләр белән килеп, эшнең киләчәктә булу-булмавын, үтәлү-үтәлмәвен, ихтималлыкны белдерә. *– Басылып чыккач, үзеңә берне бирермен әле, Әет абзый, дип йөргән иде, бирә алмады, – диде Әет.* М.Гали. *Анысы өчен бер дә хафаланма, дөнья булгач, аларның да әче вакытлары булыр әле.* Г.Камал. *– Безнең очта да яңадан бәйрәм булыр әле! – дип кычкыра-кычкыра, мине коткардылар.* Г.Ибраһимов

7) Исем, сыйфат, алмашлык, вакыт рәвешләреннән соң чикләү яки тыю мәгънәсен белдерә. *Ул [илаһи рәссам] «табигать» дип аталган олы картинасына һәр мизгелнең берәр яңа төсмерен кертеп тора. Бу үзгәрешләр әле зур останың иҗаты вакытында күзгә чалынмый, алар, бары тик эш тәмамланып беткәч кенә, бөтен матурлыгы белән күзгә ташлана.* Ф.Яруллин. *Син яшь әле, постта тору – синең эшең түгел.* Г.Гобәй. *Юк, юк, гаилә турында уйларга иртә әле, дөнья көрәсе бар.* А.Мифтахетдинов

8) Вакыт рәвешләре алдыннан, җөмләдәге хәбәрнең вакытына басым ясап, көчәйтү төсмере белән әйткәндә кулланыла. *[Садрый:] Әле иртә икән, берсе дә килмәгән.* Г.Камал. *Әле кичә генә балалар ул ояны ашыга-ашыга эшләп бетерделәр.* А.Алиш

9) Төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр янында килеп, эшнең тәмамланган булуына ишарә итә; инде. *1942 елда ук әле Хуҗа Насретдин мәзәкләре аерым китап булып басылган булган.* Татар иле

10) *Бит, ич* кисәкчәләреннән соң килгәндә, җөмләнең экспрессив-эмоциональ әйтелешен тагын да көчәйтү чарасы буларак кулланыла. *Аларның бөтен гомере алда бит әле.* М.Маликова. *Гөлгенә кайтып кына төште бит әле.* М.Җәлил. *Шуның өстенә бит әле ул йорт эшләрен дә алып бара.* Р.Ишморат

11) Нинди дә булса фактны ассызыклау, әйтелә торган фикернең тәэсир итү көчен арттыру яки бер төрле предметлар, билгеләрнең, бер һөнәр ияләре арасыннан берәрсенең нинди дә булса сыйфаты белән аерылып торуын күрсәтә. *Уянып күз салсам, бүлмәм якты – Кай арада әле таң аткан?* Ш.Галиев. *Сугышта ул пулемётчы булган икән. Һәм нindие генә әле!* Ә.Гаффар

12) Хәбәрлек сүзләр, *ләкин* теркәгече белән килгәндә, җөмләнең экспрессивлыгын көчәйтү чарасы буларак кулланыла. *Ул сезнең өйдән күчеп киткәч, аның янына барганыгыз да юк әле, ахры.* Р.Ишморат. *Боларның тын калуын көпшә күплеккә юрап, ярый әле малайлар ябырылды.* Ә.Баянов. *Чаллылардан китүемә байтак вакыт узды инде, ләкин әле нindидер бер тойгы һаман да андагы эшләр, анда кичергәннәр белән яшәргә мәҗбүр итә.* Г.Кашапов

**3.** *терк. мәгъ.* Тезмә кушма җөмләләр яки тиңдәш кисәкләр алдыннан килеп, вакыйгаларның, күренешләрнең яки предметларның бер-бер артлы, берсе икенчесен алыштырып, чиратлашып торуын яки кабатлануын белдерә.

*Матушкин әле – елга аръягына, әле – кояш баешына, әле Аняның йөзенә, кояш баешы чагылган күзләренә карады.* Ә.Мушинский. *Әле аръяктагыларның җырлап таралуы ишетелә, әле түбән очныкылар сыздырып җибәрә.* К.Тимбикова. *Бу юлдан байтак кешеләрне әле – сугышка, әле, бәхет эзләргә, Пермь, Ярослау якларына озатканым бар.* А.Гыйләҗев

◊ **Әле алай, әле болай** Төрлечә, төрле рәвештә; тегеләй дә, болай да. *Йөзен кара сакал-мыек баскан рум базарганы, юан, симез куллары белән, аларның билләреннән, беләкләреннән тотты, әле алай, әле болай боргалап, ханга аларны яхшырак карарга булышты, тегесен-монысын әйтеп торды.* Н.Фәттах. **Әле (дә) булса** Шушы вакытка (көнгә, сәгатькә) кадәр, әлегәчә. *Василий Михайловичның формалы кием яратуы һич тә аның элекке хәрби кеше булуына һәм, шуңа күрә, әле дә булса, хәрби тормыштан аерылып җитә алмавына кайтып калмый иде.* Н.Фәттах. *Аның нечкә хәтфә шикелле йөрәккә ягылган тетрәүле матур тавышы, әле дә булса, Мохтарның исеннән чыкмый иде.* Ш.Камал. **Әле генә** Яңа гына, хәзер генә, күптән түгел; шушы арада (булып үткән эш-хәл, вакыйга турында). *[Кызларның] Икенчесе әле генә өзелгән каен себеркесе белән --- идәнне себереп йөри иде.* Г.Гобәй. *Бик күптәнге танышлар яки каядыр еракка китеп торган һәм әле генә очрашкан кешеләр кебек, бер-берсенә сыенышып утырдылар.* Г.Кашапов. **Әлерәк кенә** *к.* **әле генә**. *Әлерәк кенә Хәнифә апаны алып кайтып киттеләр.* А.Гыйләҗев. *Фәрханә апа, әлерәк кенә үзенең укучылары янында уңайсыз елмаеп торган кебек, бу юлы да елмаеп тик торды.* Н.Фәттах

**ӘЛЕГӘ** *рәв.* 1) Хәзерге вакытта, әле. *Эш күләме әлегә, Чаллыярдагы белән чагыштырганда, гел юк тирәсендә.* Г.Кашапов. *Багатыр әлегә өченче булып килә.* М.Хәбибуллин

2) Хәзергә, вакытлыча. *«Минем эш түгел», – дип, әлегә тана, шайтан.* Ф.Сафин. *Ачуланма, әти, әлегә сиңа әйтә алмыйм.* Г.Каюмов

3) Моңарчы, моңа кадәр. *Барысы да ул уйлаганча бара иде әлегә.* М.Хәбибуллин. *Абзар-курага, мал-туарга әлегә тимәгәннәр.* М.Хуҗин. *Бер генә легендада, бер генә сүзлектә дә бу исемгә әлегә аңлатма табылганы юк...* М.Мәһдиев

**ӘЛЕГӘ́ЧӘ** *рәв.* Бу көнгә кадәр; хәзерге вакытка кадәр, моңарчы. *Әмма барыбер аның күңелендә әйтелмәгән, әлегәчә сизелмәгән ниндидер бер тойгы бар иде.* Г.Кашапов. *Моңа әлегәчә төпле җавап юк диярлек.* Л.Хәмидуллин. *Гыйлемханның җылы өй түренә узганына ни гомер, ә рәтле-башлы хәл белешкәне дә юк әлегәчә.* Р.Мөхәммәдиев

**ӘЛЕГЕ** *а.* 1) Югарыда искә алынган, сөйләшүчеләргә билгеле булган, элек әйтелгән предмет һәм күренешләргә төбәп күрсәтү алмашлыгы буларак кулланыла; шул, бу, теге. *Нәби Дәүли истәлекләрендә әлеге заман турында шактый тәфсилле языла.* Р.Зәйдулла. *Р. Батулланың әлеге хакта махсус кисәтеп язган мәкаләсе бу яктан бик вакытлы чаң сугу буларак кабул ителгән иде.* Ф.Галимуллин. *Фаrукҗан, мондый тынычландырудан соң да, пуля белән маузерны күздән кичерү уеннан сүрелмәде, тик әлеге үтенечен яңадан кабатлаудан тыелды.* Т.Әйди. *Шул чактан калган икән ул аның әлеге гадәте.* Р.Әхмәтҗанов

2) Иң якын арага ишарәләп күрсәтү алмашлыгы буларак кулланыла; хәзерге; шушы. *Узган гасырның 20 нче еллар азагында ук башланган шушы күренеш әлеге замангача шулай дәвам итте.* Ф.Фәтхи. *Билгеле, әлеге вакыт эчендә төрле чорлар булып, театрның бер урында таптану, эзләнүләр, саегу, хәтта ирешкән позицияләрен югалту кебек вакытларны кичерүен беләбез.* Ә.Закирҗанов

◊ **Әлеге дә баягы** Һаман кабатланган, һаман да шул. – *Ничек? Ул «һавада йөрү» дигәннәре нәрсә тагы? – дип, әлеге дә баягы, Гаташ өлгерлек күрсәтте.* Р.Мөхәммәдиев. *Әмирхан авызыннан ишетелгән, әлеге дә баягы, сәер шикаять турындагы сүз --- ниндидер шом уяткан иде аның [Әхсәннең] күңелендә.* Н.Акмалов. **Әлеге-баягы** *сөйл. к.* **әлеге дә баягы**. *Җайлап кына машинасыннан чыгып, капотын күтәрде дә, әлеге-баягы, бензин насосының «колагын» селкеткәләде.* Т.Нәҗмиев

**ӘЛЕГЕ́ДӘЙ** *рәв.* **1.** 1) Әле генә, бүген, хәзер булган кебек. *Әтисенең чыгып киткән көне дә әлегедәй күз алдында.* Л.Гыймадиева

2) Шундый. *Дөрес, син моңарчы тормыш-яшәешнең әлегедәй борылыш ясауларына әзер түгел идең.* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Моның ише, моңа охшаш. *Әлегедәй җинаятьләр көн саен булып тора.* А.Хәсәнов. *Ә нигә күнекмибез соң, нигә әлегедәй үгет-нәсыйхәт безнең аңга барып җитми?* И.Низамов

**Ә́ЛЕ ДӘ** *рәв.* 1) Бүгенге көнгә, шушы вакытка кадәр, әлегәчә. *«Ачлык баскан елда...» – дип, әнкәем әле дә сөйләр.* Р.Идиятуллин. *Мин сине бик чакырыр идем дә, син килмисең ич, әле дә чакырам, кил, алайса!* М.Галиев. *Андагы сыман оста җырчылар һәм биючеләр башка бер илдә дә булмаган һәм әле дә юк икән.* В.Юныс

2) Һаман да, хәзер дә, хәзерге вакытта да. *Аны монда әле дә беләләр.* Н.Фәттах. *Әле дә миңа каршы киләсеңме?* Н.Исәнбәт. *Әле дә исемдә: яңа гына каты сугыш булып үткән, хәрабә хәленә килгән урам буйлап пычрак сөрә-сөрә барам.* А.Шамов

◊ **Әле (дә) ярый** Җөмләдән аңлашылган берәр нәрсәнең булуына канәгатьлек хисен белдерә. *[Арбай:] Әле ярый мин туры килдем, юкса, бу хулиганнар...* Т.Миңнуллин. *Әле дә ярый бүре юк бу тирәдә.* Р.Кәрами

**ӘЛЕДӘ́Н-ӘЛЕ** *рәв.* 1) Ара-тирә, вакыты-вакыты белән. *Элгрәк Дикопольцевның --- куе саргылт кашлары, әледән-әле, икесе бергә кушылып-кушылып куя иде.* Г.Кашапов. *Бүлмә ишеген әледән-әле ачып карыйлар, әмма, милиция кешесен күргәч, шунда ук кире ябып куялар иде.* З.Фәтхетдинов

2) Вакыт-вакыт, торып-торып. *Ул, әледән-әле башын күтәреп, ирен күзәтә.* М.Маликова. *Ул, әледән-әле, кармагын алып карады.* Г.Гобәй

**ӘЛЕП** *и. иск. к.* **әлиф.** *Әни, мине тапшырып, үзе киткәч, мин, кызлар белән бергә, «әлеп, пи, ти, си, җымы-*

*кый»ны бер дә тартынмыйча кычкырып укый башладым.* Г.Тукай

◊ **Әлепне таяк дип белми** *к.* **әлифне таяк дип белми.** *Финанс мәсьәләсендә ул, билгеле, әлепне таяк дип тә белмәде.* Н.Фәттах

**ӘЛЕП-БИ** *и. иск. к.* **әлифба** (*1, 2 мәгъ*). *Ничек кенә итеп, ул үзенең язмышында якты сын булып төсмерләнгән шундый әйбәт йөрәкле хатынны – беренче әлеп-би өйрәткән укытучысын оныта алды соң?* Г.Минский

**ӘЛЕПБИ** *и. иск. к.* **әлифба** (*1, 2 мәгъ*). *Беркөн Сабит әткәсен күреп әйтә әйтәсен: «Әти, миңа әлепби кайчан алып кайтасың?»* Г.Тукай

**ӘЛҖЕЛЕ́-МӨЛҖЕЛЕ** *с.* Икелемикеле, шикләндерә торган, икеләндерә торган, ышанычсыз. *[Халык] Кар астында кышлаган ашлыкның афәтен белгән килеш, бәлки, әле зыяны тимәс, дигән әлҗеле-мөлҗеле өмет белән --- чиләк-чиләк бодай җыеп кайтачаклар...* Ә.Баянов

**ӘЛҖЕ́-МӨЛҖЕ** *с.* Нинди дә булса психологик яки физиологик хәлдән томанланган, тоныкланган. *Нәҗипнең әлҗе-мөлҗе күзе урман тунаучыларның иң кайнашкан ноктасына җитте дә туктады.* А.Гыйләҗев

◊ **Әлҗе-мөлҗе утлар уйнау** Хәлсезлектән яки башка сәбәптән, күз алдында очкынсыман утлар җемелдәү. *Тәнемне таяклар белән каезлаганнармыни, сулыгып авырта, --- алдымда әлҗе-мөлҗе утлар уйный сыман.* Г.Тавлин

**ӘЛҖЕ́-МӨЛҖЕ КИЛҮ** *ф.* Күз аллары караңгылану; дулкынлану. *Шатлыктанмы, әллә нидән генә Азатның күз аллары әлҗе-мөлҗе килде.* Р.Мөхәммәдиев

**ӘЛИП** *и. иск. к.* **әлиф.** *Яңа әлип беләм? Ә, беләм-беләм, үзем дә укып йөргән идем.* А.Алиш

**ӘЛИФ** *и. гар.* 1) Гарәп алфавитында беренче хәрефнең атамасы. *Авыл мәдрәсәсендә «әлиф, би, ти, си»дән башлаган да, тора-бара, шундый биеккә күтәрелгәнме?* Г.Бәширов

2) *к.* **әлифба** (*1 мәгъ.*). *Бамбыр Гобәйдулла яңа әлифне танымый иде әле...* З.Зәйнуллин

◊ **Әлиф йоткан** 1) Алфавит белгән, укый-яза алган, гомумән укымышлы. *Әлиф йоткан – тилмермәс, укыган кеше хур булмас.* Мәкаль; 2) *мыск.* Йөргәндә дә, утырганда да сыны төп-төз булган кешегә карата әйтелә. **Әлифне таяк дип белми** Белемсез, укый-яза белми торган, надан. *Әнә әлифне таяк дип белмәгән надан Динислам улы Заһит батальон белән җитәкчелек итәр, дип кем уйлаган?* М.Әмирханов. **Әлифне таяктан аера алмый** *к.* **әлифне таяк дип белми** *Яңалифнең авырлыгы турындагы фикерне ул кемнәндер ишеткән булырга тиеш, әлифне таяктан аера алмаган кешегә башкача ул кайдан килсен?* Г.Тавлин. **Әлиф яту** Берсенә-берсе арка белән тезелеп яту. *Әлиф яткач, урын киңәйде, теге алты малай да арага сыйдылар.* Г.Ибраһимов

**ӘЛИФБА** *и. гар.* 1) Нинди дә булса телнең язуда кабул ителгән һәм билгеле бер тәртиптә урнашкан хәрефләр системасы: алфавит. *Искечә язуны – гарәп әлифбасы нигезендә язуны – ныклап таный белүчеләрдән авылда ул хәзер бердәнбер ир-ат санала иде.* Н.Акмалов. *Чөнки урысча нигездә төзелгән әлифба татарларга яңа гына кереп килә иде әле.* Ә.Галиев

2) Хәрефләр танырга, сүзләрне кушып укырга өйрәтә торган китап, башлангыч сыйныф дәреслеге. *Дөрес, ул инде эре хәрефләр белән язылган әлифбаны шактый иркен укый.* Ә.Фәйзи

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса нигезе, асылы; аны таный белү, өйрәнү өчен кирәк булган гади күнекмәләр. *Туган якның төсле «әлифба»сын өр-яңадан мин ачам гына. Бик таныш бу көзнең «әлифба»сы – куралар да җирдә, камыллар.* Э.Мостафин. *[Сало] Никрутларга һаман хәрби тормыш әлифбасын өйрәтә торгандыр.* З.Хөснияр. *Сугыш шартлары аны лейтенант дәрәҗәсенә күтәргән, тик культура әлифбасын өйрәтмәгән.* Х.Камалов

**ӘЛКЫЙССА** *кер. сүз гар. кит.* Бер сүз белән әйткәндә, кыскача гына әйткәндә, озын сүзнең кыскасы. *Әлкыйсса, хәлвәфрүш нигә очраганын белде, Әбүгалисина ниндәен адәм икәнен аңлады.* К.Насыйри. *Әлкыйсса, инде шигырь язудан туктыйм.* Г.Тукай

**ӘЛЛӘ** *кис.* **1.** 1) Хикәя һәм сорау җөмләләрдә ялгыз гына килеп, билгесезлек мәгънәсен белдерә һәм сорауның катгыйлыгын йомшарту өчен кулланыла. *Әллә инде, хәвеф-хәтәрдән саклангандай, капкаларны эңгер-меңгердә үк шартлатып бикләү гадәткә керде.* Т.Әйди. *Матайның да җаныттыны юк. Аны кабызгалап карадым: әллә көч җитмәде, әллә тимер тәкәм киреләнде – кабынмады.* Ф.Яруллин

2) *-мы/-ме икән* (*микән*) сорау кисәкчәләре белән бергә килеп, фараз итү, гөманлау, чамалау мәгънәләрен белдерү өчен кулланыла. *Тәңре үзе шулай яздымы икән әллә аңа?* М.Хәбибуллин. *Кешегә мәхәббәт шулай сиздерми килеп, сөю ялкыны шулай искәрмәстән кабынамы икән әллә?* Г.Тавлин. *Күпме күрдек инде без дә, алай зурлап яратуны күргән булмады, гомере кыска икәнен сизде микән әллә күңеле бичараның!* М.Маликова

3) *Кем, нәрсә, нинди* һ.б.ш. сорау алмашлыклары алдыннан килеп, билгесезлек алмашлыклары ясау өчен кулланыла (*әллә кем, әллә нәрсә, әллә нинди һ.б.*) *Әллә нәрсә сизенә күңелем, әллә ниләр уйланам.* Һ.Такташ. *Ул Хисами Галимҗаныннан әллә ни көтәргә була, юаштан юан чыгар, диләр.* А.Гыйләҗев

4) Җөмләдә бирелгән сорауга, бу турыда бернәрсә белмим, мәгънәсендә җавап кайтарганда, *инде*, *тагы(н)* сүзләре белән кулланыла. – *Композиторы кем? – Әллә тагы.* Г.Әпсәләмов. *Әллә инде, Мәгъфүрә апа.* Р.Төхфәтуллин. *[Нургаян:] Телеңә чыдый алмагач, малайларың киленнәреңне берәм-берәм алып качты. [Әнвәрия:] Әллә тагын, телең бик яман, диләр шул.* А.Гыйләҗев

**2.** *терк. мәгъ.* Тезмә кушма җөмләдә һәм тиңдәш кисәкләр янында килеп, бүлүче теркәгеч функциясен үти һәм җөмләнең эчтәлегенә икеләнү, ышанып бетмәү төсмерен өсти, саналып киткән берәр нәрсәнең булуына яки үтәлүенә шикләнү белдерә. *Кара инде, өн микән бу, әллә төш микән?* Р.Төхфәтуллин. *1956 елның әллә җәй ахыры, әллә көз башы иде, минем шәһәр*

*читендәге кечкенә агач өем алдына Язучылар Союзы машинасы килеп туктады.* Ә.Еники. *Ләкин сүз кушарга өлгерә алмадыммы шунда, әллә көндәлек ыгы-зыгы йотты, әллә теге вакытта, депутат чагында, беркадәр масаебрак йөргүеннән күңелдә юшкын утырып калганмы – төгәл генә белмим.* Г.Кашапов

**ӘЛЛӘГЕНӘМ** *ы.* Соклану, гаҗәпләнү, шаккату хисләрен белдерә. *«Француз яулыгы»н малайлар арасыннан беренче булып Папай Нигъмәте ишетеп алды: – Әлләгенәм! Ибрай бабай әйттерә бит теге көйне!* З.Зәйнуллин

**ӘЛЛӘЗИ** *с. монг. сөйл.* Артык басынкы, юаш; җебегән. *Шуның өстенә әле бик тә инде басынкы, юаш бер әлләзи зат иде, мәрхүмә.* М.Хәсәнов

**ӘЛЛӘ́ КАЙ** *а.* 1) *к.* **әллә кайсы** (*2 мәгъ.*). *Чын суыклар әлегә булмаса да, төньяктан яки төньяк-көнчыгыштан исә торган җилләре, киемнең әллә кай җирләреннән үтеп кереп, туңдыра башлый.* Серле сандык

2) Үзе яисә аңа иярген сүз күплектә килеп, урыны яисә ераклыгы билгесез булуга ишарәли торган билгесезлек алмашлыгы; әллә кайдан, әллә кая. *Әллә кай тирәнлекләрдән үзенә эз салып килгән су [коены җир белән тигезләп китүләрен] күтәрә алмады, кешеләргә рәнҗеп, үз юлыннан кире чигенде, еракка качты.* М.Галиев. *Баягы скрипка һаман моңлана, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә, дулкынландыра, уеңны әллә кайларга алып китә.* Р.Кәрами

◊ **Әллә кай арада** Бик тиз вакыт эчендә, көтмәгәндә. *Әллә кай арада гына аш як бүлмәсе чүмеч-коштабактыр, комган-тагарактыр ише тормыш өчен кирәкле нәрсәләр белән тулды.* Җ.Рәхимов

**ӘЛЛӘ́ КАЙДА** *а.* 1) Эш-хәлнең нindидер билгесез урында башкарылуына ишарәли торган билгеселек алмашлыгы; кайдадыр, кайсыдыр якта. *Әллә кайларда тамчылар тама.* Ә.Гаффар. *Синең өчен Бәеш хәсрәте – кысыр хәсрәт кенә, бүген монда син, иртәгә – әллә кайда, арба ватылса утын, үгез үлсә ит сиңа, диләр.* Г.Тавлин

2) Берәр нәрсәнең еракталыгына яки берәр вакыйганың күптән үткән булуына, хәтердә генә саклануына ишарәли торган билгесезлек алмашлыгы; кайчандыр. *Бу хатыннар әллә кайларда торып калган тук һәм тыныч тормышның кадерле бер кисәге иде.* З.Зәйнуллин

**ӘЛЛӘ́ КАЙДАН** *а.* **1.** 1) Эш-хәлнең кайдан икәне билгесез урыннан, нindидер билгесез чыганактан булуына ишарәли торган билгесезлек алмашлыгы; кайдандыр. *Тышта һаман, шаулап, яңгыр ява, әллә кайдан тирәнтен гөрләп килеп, күк күкри* ---. Ш.Камал. *Әллә кайдан гына – Мәскәү тарафларыннан кара болытлар йөзеп килеп чыктылар да аның якты нурлы күген караңгылык белән тутырдылар.* Р.Вәли

2) Кемнәндер, теләсә кемнән, каяндыр. *Бүген генә ул, яшьләребез, милли мәдәнияттән аерыла башлап, яңа форманы әллә кайдан алып кайталар.* Т.Миңнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик ерактан, ерак арадан, ерактан ук. *Тирә-күршеләре дә, зират яныннан үткән кебек, әллә кайдан урап узарга тырышалар иде.* З.Фәтхетдинов. *Вәкил айгырының тавышын әллә кайдан таный.* Н.Әхмәдиев. *Мисалны әллә кайдан – Каф тау артыннан эзлисе юк.* С.Поварисов

2) Сизелеп, күренеп торырлык дәрәҗәдә; ап-ачык, аермачык. *Теге сөйләшеп торучылар – исерекләр, әллә кайдан билгеле.* Т.Миңнуллин

**ӘЛЛӘ́ КАЙСЫ** *а.* **1.** 1) Кем булуы ачыкланмаган затка ишарәли торган билгесезлек алмашлыгы; кемдер, кайсыдыр. *Әллә кайсы миңа кычкыра: – Кач! – ди.* М.Әмир

2) Билгесез юнәлеш, сәбәп, чыганакка һ.б.ш.га ишарәли торган билгесезлек алмашлыгы; кайсыдыр. *Шулай, Таһир дускай... Дөнья әллә кайсы тарафларга бөтереп җибәрмәгән булса, мин дә сезнең брамат арасында йөрер идем.* Н.Акмалов. *Кая ул бүгенге «дискотека» диган, әллә кайсы чит-ят илләргә ияреп чыгарылган нәмәрсәләренә безнең чын халыкчан мәҗлесләрдәге җыр-биюләр белән тиңләшү!* К.Тимбикова

**2.** *с. мәгъ. куч.* Ярамый торган, тыелган. *Ул әллә кайсы төшләрдән тота.* Аманулла

**ӘЛЛӘ́ КАЙЧАН** *рәв.* Күптән, күптәннән бирле. *Тау өстеннән караганда, авыл әллә кайчан йокилаган төсле...* Я.Зәнкиев. *Кич булды, караңгы төште, итле ашлары дүрт чиләкле зур казанда әллә кайчан пешеп, әллә кайчан суынып, куерып, бәрәкәте китеп бетте.* З.Зәйнуллин. *Фазыйлдан башка безнең компания әллә кайчан таралган булыр иде.* Г.Ибраһимов

**ӘЛЛӘ́ КАЙЧАНГЫ** *с.* 1) Күптән булган, әллә кайчан үткән. --- *көзен томалаган яшь пәрдәсе аша Вәзирә, нигәдер, әллә кайчангы бер кичне искә төшерде.* Ә.Гаффар. *Хәер, анысы – әллә кайчангы хәл.* С.Шәрипов

2) Күптәнге, күптән белгән, якын. *– Рәхим итегез, үтегез! – дип, әллә кайчангы танышын күргәндәй, ихлас елмаеп, Рәхиләгә эчкә үтәргә юл бирде.* Ш.Янбаев

3) Борынгы, күптән яшәгән. *Әллә кайчангы кешеләр уйлап тапкан.* Т.Миңнуллин. *Шулвакыт пьесада ике ана пәйда була: берсе – әллә кайчангы Болгар дәвереннән, икенчесе – крестьяннар заманыннан.* Татар театры

**ӘЛЛӘ КАЙЧАННАН** *рәв.* Күптән, моннан бик күп элек, бик озак вакыттан бирле. *Белә бит инде югыйсә, үләрдәй булып яратканы әллә кайчаннан сизә!* Г.Бәширов

**ӘЛЛӘ́ КАЯ** *а.* Урыны билгесез яисә ерак булуга ишарәли торган билгесезлек алмашлыгы; кая да булса, каядыр. *Тиздән бу соңгы уйлар да әллә кая китте, башта соң дәрәҗәдә аңгыралык билгесе – томан гына утырып калды.* Ә.Мушинский. *...Кошлар әллә кая китеп югалды.* И.Гази

**ӘЛЛӘ́ КАЯН** *а.* **1.** *к.* **әллә кайдан**. *Хәбирдән телеграмма килгәч, Әхсәннең күңеле күтәрелеп китте, әллә каян яңа көч табып, дәртләнеп, ашкынып яши башлады.* Н.Акмалов. *Әллә каян гына чыккан җил Сәрвәрнең толымын, җилфердәтеп, егетнең коңгырт чәчләренә китереп чорнады, җил аңа чак кына хәл кертте.* Я.Зәнкиев. *Куе яшел агачта аларны [чыршы күркәсен] әллә каян шәйлисең.* Р.Кәрами

**2.** *рәв. мәгъ.* Һич уйламаган, көтелмәгән урыннан. *Инде бу адашкандыр,*

*кайтырга юл табалмыйдыр, дип хафаланып торганда, «күк-кү» дип, әллә каян куак астыннан атылып чыгар иде.* Ф.Яруллин

**ӘЛЛӘ КЕМ** *а.* **1.** Билгесез затка ишарәле торган билгесезлек алмашлыгы; кемдер, берәү, теләсә кем. *Әллә кемнең, йомшак кына, идән буйлап атлау тавышы колакка керде.* Г.Исхакый

**2.** *и. мәгъ.* 1) Җәмгыятьтә абруе, дәрәҗәсе булган, игътибарга лаеклы кеше. *Ул инде Майяның күзләренә карамый да, чөнки лифтта менгәндә ук аңа үз бәясен биргән иде: үз теләгенә каршы килеп булса да, «юк, әллә кем түгел» дияргә урынга, «әллә кем шул, бик әллә кем» дигән иде.* Ә.Мушинский. *Киеменә карaганда, керүченең әллә кем булырга тиеш түгеллеге сизелә иде.* С.Поварисов. *«Их, азрак кына укыган булсаммы?! Чүт кенә, базар урыслары белән аяк терәп сөйләшерлек кенә урысча белсәмме, мин әллә кайларда әллә кем булып утырыр идем!» – дип җибәргәли [Гыйззәтбану түти].* Я.Зәнкиев

2) *ирон.* Бик шәп, зур дәрәҗәгә ия сыман кыланган кеше. --- *дуамал яшьлек елларында син, үзеңне «әллә кем»гә куеп, булыр-булмас акчаңа кәеф-сафа корасың ---.* Р.Батулла

◊ **Әллә кем булу** Үзен-үзе зурга куюю, борын чөю, масаю, тәкәбберләнү. *Әллә кем булып, колхоз эшенә дә чыкмыйча яткан иде. Барыбер шайтаныма да китә алмады, дип көләрләр шикелле тоела.* В.Нуруллин. *Унны бетерде, бүген-иртәгә армиягә китәм, дип, әллә кем булып йөри.* К.Тимбикова. **Әллә кемләнү** *к.* **әллә кем булу**. *Солдаттан инде егет бөтенләй зураеп, әллә кемләнеп кайтып керә.* С.Шәмси. **Әллә кем түгел** 1) Кешенең абруйлы, дәрәҗәле булмавын белдерә. *[Сәркәтип кыз:] Кем, дип... Миңнурый исемле яшь кенә бер кыз инде. Әллә кем түгел әле.* Ф.Латыйфи; 2) Башкалардан артык аерылмый, шаккатырлык ни дә юк, мәгънәсендә. *Мөдәррис, сабакташлар арасында үткенлегең белән аерылып торсаң да, буйга-сынга әллә кем түгел идең.* Ватаным Татарстан

**ӘЛЛӘ́ КҮПМЕ** *а. к.* **әллә никадәрле.** *Вагоннан чыгасы булмаса, шушылай бер-берсенә сыенып, иркәләп-иркәләнеп, әллә күпме торсалар да тансыклары басылмас иде.* Ш.Янбаев. *Эшеннән арып кайта. Өйдә тагын әллә күпме эш көтә.* Г.Гыйльманов. *Күз ачкысыз ыжгыр-ачы бураннарда әллә күпме юлчылар адашып үлде.* С.Поварисов

**Ә́ЛЛӘ-ЛӘ(-ЛӘ)** *ы.* 1) Шәп, әйбәт булуына ис китүне, гаҗәпләнү, соклануны белдерә; нәрсә өчен булса да мактап әйткәндә кулланыла. *Кояш, югартын, боларның бөтенесенә: «Әллә-лә, нишләтте абзаң!» – дигән төсле итеп мактанып, көлеп карый.* С.Җәлал. *Диләрә дә чыкты чанасын өстерәп. Әллә-лә! Моңа яңа чана алганнар икән.* Н.Кәримова

2) Авыртуның, сызлауның кинәт көчәюен белдерә. *Әмма шул вакыт әлеге фәррашның, кереп, шау-шуны басар өчен, кулындагы пеше чыбыгы белән шәкертләр өстеннән уңлы-суллы чажлатып, селтәнеп алуы, берничә шәкертнең, «әллә-лә-лә!» дип, чын күңелдән әрнеп куюлары белән, Габдулла мәсьәләсе онытылды.* Ә.Фәйзи

3) Хәлнең мөшкел булуын, авыр хәлдә калганлыкны кинәт абайлап алуны, искәрүне белдерә. *Әллә-лә-лә, ике яктан да арттан төшкәннәр болай булгач [ике фланг та нык чигенгән], без «капчык» эчендә калабыз була түгелме соң?!* И.Низамов

4) Күп кешеләрнең төрле тавышлар белән кычкыруларын белдерә. *Килеп җитүгә, Шаһбазның мең ямаулы пычрак, ертык күлмәген салдырмыйча ук өстеннән өзгәләп, тарткалап алып бетердек тә: «Һау... әллә-лә... һау әллә-лә... әллә-лә...» – дип, уратып-уратып, суга ыргыттык.* Г.Ибраһимов. *Әйтеп тә бетермәдем, әллә йөз җирдән үземә каршы кычкыра башладылар. – Әллә-лә-лә!* Л.Ихсанова

5) *к.* **әллә-ли**. *Нигъмәтҗан, Фагыйлә басмадан төшкәндә, кызга булышмакчы булып, кулын сузды. Әмма Фагыйлә: – Әллә-лә! – дип, кулларын артка яшергәч, рәхәтләнеп көлде егет ---.* М.Хуҗин

**Ә́ЛЛӘЛЕКИ** *ы. к.* **әллә-ли**

**Ә́ЛЛӘ-ЛИ** *ы.* Кемне дә булса үчекләп, ирештереп яки берәр нәрсәгә кызыктырып, мактанып әйтелә. *[Рокыя:] Тимәде, әллә-ли, бәллә-ли, тимәде!* К.Тинчурин

**ӘЛЛӘ НӘРСӘ** *а.* **1.** Билгесез әйбергә ишарәле торган билгесезлек алмашлыгы; нәрсәдер, әллә ни, берәр нәрсә. *Тик җиккәне – арба дисәң, арба түгел, ике тәгәрмәчле әллә нәрсә шунда.* М.Хәсәнов. --- *күңеле --- Фукс бакчасына тарта иде. Ләкин ул анда бармый, курка, гүя анда барса, әллә нәрсә булыр төсле иде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Никтер, нигәдер, ни сәбәптәндер. *Ләкин кияү килер алдыннан Саҗидә, әллә нәрсә, авырып китте.* Г.Исхакый. *Әллә нәрсә, бик эсселәп торам мин бүген.* М.Әмир

**3.** *и. мәгъ. күпл.* Юк-бар, кирәкмәс, артык әйберләр, сүзләр; имеш-мимеш. *Бәлки, үги әти аңа тагын әллә нәрсәләр сөйләп бетергәндер теге чакта.* Н.Дәүли

◊ **Әллә нәрсә түгел** *к.* **әллә ни түгел** (*1 мәгъ.*) – *Киттек, әллә нәрсә түгел икән бу. Чытыр арба, – дип, Зәбир теш арасыннан «черт» итеп төкереп куйды.* М.Галиев. *Картның кигән киеме дә әллә нәрсә түгел – сырган тән җылыткыч, чалбары да калын, ботинкасын йон оекбаш белән кигән.* Р.Кутуй

**ӘЛЛӘ́ НИ** *а.* **1.** *к.* **әллә нәрсә.** *Тавышларында әллә ни бар: куркалармы, кайгыралармы, нәрсәдәндер, кемнәндер яшерергә телиләрме?* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик, бигүк, артык дәрәҗәдә. *Еракtан ишетелгәндәй тоелганга күрә, бу авазлар күңелне әллә ни борчымады.* Ә.Мушинский. *Шунлыктан, җитәкчелеккә быел Халидә апа әллә ни дәгъва да кылмады – телгәтешкә килмичә, сүзсез генә, Фәрхәнә апага юл бирде.* Н.Фәттах. --- *сыйныфтагы егерме дүрт баланың унбере – әтисез. Шуңа күрә Зөһрәне әллә ни кимсетүче, кыерсытучы юк.* Г.Гыйльманов. *Дикопольцев акылының ниндидер яшерен кузәнәкләре белән аерымачык төшенә: теләсә нинди, хәтта әллә ни олы булмаган төзелешне җәелдереп җибәрү – гади нәрсә түгел.* Г.Кашапов

2) Искитәрлек, гаҗәпкә калырлык. *Әти үзе әллә ни көчле дә кеше түгел иде. Уртача буйлы, какча гына.*

Т.Миңнуллин. *Кибеттә әллә ни товар күренми – күлмәкләр, янавычлар, күсе тәбеләре һәм балта саплары гына иде.* М.Мәһдиев

**3.** *с. мәгъ.* Саны, микъдары күп булмаган, ишле, зур күләмле түгел. *Мондый күзәтүләр әллә ни вакыт сорамый.* Левитан. *Ә инде ул морза-бәкләрнең ярлырак кардәшләре, югалтырлык әллә ни мал-мөлкәте һәм биләмәләре булмаганнары, үз диннәрендә калган, күпмедер вакытка чаклы --- вактөяк дәүләт эшләрен үтәп килгәннәр.* Л.Хәмидуллин

**4.** *и. мәгъ.* 1) Төрледән-төрле әйберләр. *[Рәукыя апаның] Бер кергәндә – кулында йолкынмаган, канлы муенлы әтәч булса, икенчесендә – кар базыннан алган каймаклы сөт, әллә ничә мәртәбә казан асып, әллә ниләр пешереп бетерсә дә, ул һаман канәгать түгел, талкынган җанын эш белән тынычландырырга тели.* Я.Зәнкиев

2) Әйтеп бетергесез зур эш; игътибарга алырлык, игътибар итәрлек әйбер, гаҗәеп хәл. *Әйтерсең лә әллә ни эшләгән, мине рәхмәт белән коендыралар гына.* Ф.Хөсни. *Әллә ниләр белеп торсам да, берәүгә дә авыз ачканым юк.* А.Гыйләҗев

3) Әһәмият бирерлек, игътибар итәрлек нәрсә; кыйммәтле, кирәкле әйбер. *Өйне эчке яктан карау да әллә ни бирмәде.* З.Фәтхетдинов. *Ашыйсылар килә әлбәни, Әлбәләрне ашау – максат түгел, Бер утырулары әллә ни.* Жыр

◊ **Әллә ни арада** *к.* **әллә кай арада.** *[Әбием] Әллә ни арада гына суын ташып, әллә ни арада гына мичен тергезеп җибәрде.* А.Хәсәнов. *Мәктәп кыңгыравы шалтырады, һәм әле генә балалар белән тулы класс бүлмәсе әллә ни арада гына бушап та калды.* Р.Фәизов. *Ганиев әллә ни арада торып баскан иде инде.* Ф.Садриев. **Әллә нигә бер** Ара-тирә, сирәк очракта. *Бөтен кеше андый түгел бит. Әллә нигә берсе генә.* А.Шамов. *Әллә нигә бер, килешле генә итеп, Мирсәеткә аңлашылмый торган урыс сүзләре кыстырып җибәрүләрен әйтәсеңме.* Р.Мөхәммәдиев. *Дәфтәр бите хәтле генә газета кисәгеи дә Васфия апа әллә нигә бер китерә.* А.Хәсәнов. **Әллә ни гомер** Озак, шактый, ярыйсы күп вакыт. *Юлны таба алсам, кире Чүкәйгә генә кайтырмын, дип әллә ни гомер эзләп караса да, юк, тәки таба алмады Равил юл катысын.* В.Нуруллин. **Әллә нидә бер** *к.* **әллә нигә бер.** *Әнә шул бәхет чүкеченең әллә нидә бер ялгышып сугуы бер йөмсезнең – бер йөмсез белән, бер матурның да бер матур белән кавышуына сәбәп булып куя.* Н.Исәнбәт. **Әллә ни тора** 1) Бик кадерле, бик кыйммәтле булу; 2) Авыр, мәшәкатьле, борчулы эш булу. **Әллә ни түгел** 1) Искитәрлек, яхшы сыйфатлы булмау, югары дәрәҗәдә булмау. *Өйләренең эче әллә ни түгел.* Ә.Гаффар. *Өстемдәге бишмәтемнең рәте әллә ни түгел: итәк-җиң очлары чукланып беткән, тирсәк турылары ямалган иде.* В.Нуруллин. *Әнә атаклы химик, профессор Нурый Садыйковның да русчасы әллә ни түгел.* В.Нуруллин; 2) Артык мөһим, әһәмиятле булмаганда әйтелә; 3) Мәшәкать тудырмау, бик кыен булмау; 4) Ышанырлык нигез булмауны белдерә. *[Хикәямнең] Басылырына өметем әллә ни түгел.* В.Нуруллин

**ӘЛЛӘ́ НИК** *а. диал. к.* **әллә нишләп.** *Тукта, мин юлдан адашканмын икән бит, күр әле; Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит: «Шүрәле».* Г.Тукай

**ӘЛЛӘ́ НИКАДӘР(ЛЕ)** *а.* **1.** Саны, микъдары билгесез булуга ишарәли торган билгесезлек алмашлыгы; күпмедер. *Алар ишек катында тагын әллә никадәр сөйләшеп тордылар.* Р.Гали

**2.** *рәв. мәгъ.* Шактый, ярыйсы күп, байтак кына. *Башта ул [Искәндәр] үзенең кайда икәнлеген төшенә алмыйча аптырап торды, шул аз гына вакыт эчендә аның тынган, саф мие төрле урыннарны уйлап, әллә никадәр эшләп алды.* К.Тинчурин. *Бүрегә кагылышлы әллә никадәр хәвефле хәлләр ишетеп үсте Гыйззәтуллин.* М.Мәһдиев

**3.** *с. мәгъ.* Саны, микъдары күп булган, шактый ишле. *Шулар өстенә, аның әнисе тагын әллә никадәр --- эшләр уйлап таба.* Ф.Садриев. *Моның аркасында, әллә никадәр талант гадәт илә күмелә ---.* Җ.Вәлиди. *Ләкин, барыбер, ревизия, килгән саен, эшеннән әллә никадәр җитешсезлек таба.* В.Нуруллин. *Әбүгалисина белән Әбелхарис шушы вакыт эчендә, күп тырышып, күп көч куеп, әллә никадәрле белем алдылар.* К.Насыйри

**ӘЛЛӘ́ НИНДИ** *а.* **1.** 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса сыйфатын, үзенчәлекле якларын аңлатып булмауны белдерә торган билгесезлек алмашлыгы; ниндидер. *Аларның бу тилелегендә әллә нинди тирән мәгънә бардыр кебек.* Ә.Баян. *[Сабый] Кесәсеннән тары бөртекләре, икмәк валчыклары, әллә нинди мин белмәгән кош җимнәре чыгарып, аны кошка сузды.* Г.Гыйльман

2) Берәр нәрсәнең авырлыгын, катлаулылыгын яки көчлелеген, гадәттән тыш булуын билгесезлек төсмере белән белдерә торган билгесезлек алмашлыгы. *Белмәссең, дөньяның әллә нинди хәлләре булыр.* Г.Исхакый. *Шул «береңнеке – береңдә» дигән фикер әллә нинди авырлыклардан да йолып калыр кебек тоела иде.* К.Тимбикова. *Гаярь шәхес калкына икән, ул, әллә нинди астыртын, мәкерле юллар белән, аның рухын кыркый, юлын кисә.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Таныш булмаган, билгесез. *Әллә нинди карчыклар, яшь кенә кызлар һәм зур киез итек кигән бер аксак малай, чыр-чу килеп, аларны каршы алдылар.* Ә.Фәйзи. *Ә гөлчәчәкләрнең ниндиләре генә юк монда – елга бер чәчәк ата торган чәнечкеле кактус дигәннәре дә, кып-кызыл роза гөлләре, ап-ак кашкарыйлар, тагы адәм баласы исемнәрен дә белмәгән әллә нинди гөлчәчәкләр.* Ф.Бәйрәмова

2) Төп-төгәл, һич арттырусыз. *[Азамат карт малайлары] Чәч йөртәләр, дүртесе дә мыеклы, кара җилән, яшел сатин чалбар, читек, кара кәләпүш киеп җибәрсәләр, әллә нинди укымышлыларга охшап калалар.* Ә.Гаффар

3) Гаҗәп, гаҗәеп, искитәрлек. *Синдә әллә нинди бер сер бар.* Х.Камалов

4) Эчпошыргыч, аңлаешсыз. *Дөньясы әллә нинди шунда.* Ф.Сафин

**ӘЛЛӘ́ НИТКӘН** *а. к.* **әллә нинди.** *Мин бит әллә ниткән күтәренке-романтик хыяллар, куәтле җырлар патшалыгыннан кайтып килем.* М.Мәһ-

диев. *Керфекләрен йомды исә, күз алдына әллә ниткән сурәтләр килә.* Н.Хәсәнов. *Узган елны --- бюро членнарының --- Галинур Айтугановка ташланулары, әллә ниткән җәзалар белән куркытулары исенә төшкәч, Тимергалиев үзен, ничектер, уңайсыз сизә башлады.* Г.Ахунов

**ӘЛЛӘ́ НИХӘТЛЕ** *а. к.* **әллә никадәр(ле).** *Тегермән стенасындагы, кәрниз астындагы бихисап тишек-тошыклардан әллә нихәтле күгәрчен, чәүкә, чыпчык тузгып чыкты.* Ә.Гаффар

**ӘЛЛӘ́ НИЧАКЛЫ** *а. к.* **әллә никадәр(ле)**. *Полина Ивановнаның аз хезмәт хакы ала торган семьядагы балаларга түләүсез материаль ярдәм күрсәтүе турында әллә ничаклы мисал китерә алам.* Ф.Галиев. *Менә шушы кыска гына ара эчендә ул әллә ничаклы хисләр кичерде.* Р.Низамиев

**ӘЛЛӘ́ НИЧӘ(МӘ)** *а. к.* **әллә никадәр(ле)**. *Кайтасы юл хәзер, танышлыгы, озынлыгы белән, хатыннар өчен әллә ничә тапкыр авыррак күренә.* З.Зәйнуллин. *Малайның моны әллә ничә тапкыр сокланып күзәткәне бар.* Р.Низамиев. *Ул, кайтмаган малын эзләгәндәй, басу буйларын, тау итәкләрен әллә ничә урады.* З.Дәүләтов. *Җырлыйм! Булдырам мин җырларга. Көтү көткәндә, бер җәйдә дә әллә ничәмә җыр уйлап чыгардым мин.* М.Хуҗин

**ӘЛЛӘ́ НИЧЕК** *а.* **1.** Нинди дә булса эш-хәлнең, халәтнең, күренешнең ничек икәнен аңлатып булмауны белдерә торган билгесезлек алмашлыгы; ничектер. *Мин алданудан комачтай кызарсам да, Сафуан абый, буасы ерылган инеш кебек, шаулап-шаркылдап көлә башлагач, әллә ничек, җиңел булып китте.* М.Галиев. *Әллә ничек шунда, күңел тыныч түгел.* Г.Каюмов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Сәеррәк, гаҗәбрәк, аңлап һәм аңлатып булмаслык итеп; әллә ни рәвештә. *Чәпелдекне төшермәс өчен, аягын әллә ничекләр кәкрәйтеп шуыштыра-шуыштыра, ул Гарифҗан ята торган палатага керде.* Ф.Садриев. *Безнең беренче очрашуыбыз да әллә ничек килеп чыкты бит.* З.Хәким

2) Ни өчендер, ни сәбәпледер, сәбәбе билгесез хәлдә. *Алардан ерак йөрергә кирәклеген дә беләм бит югыйсә, әллә ничек зиһенем чуалды, аякларым җиргә беректе, тукталдым да калдым шуның янында, ди.* М.Маликова. *Кызларга ул [Әхмәдулла абый] әллә ничек оялып карый.* Ф.Яруллин

**ӘЛЛӘ́ НИШЛӘП** *а.* **1.** Нинди дә булса эш-хәлнең, халәтнең, күренешнең барлыкка килү сәбәбен ачыклап булмауны белдерә торган билгесезлек алмашлыгы; ни өчендер, нигәдер, ни сәбәпледер. *Әллә нишләп, төне буе уйлап чыккан, күңелдән йөз тапкыр кабатланган сөйләшүне дә эзлекле итеп --- алып баралмады --- Чыңгыз.* З.Садыйков. --- *авторы да тел очында гына, тик, әллә нишләп, әйттем дигәндә генә телдән ычкына.* Ә.Баян. *[Зөмәрә:] – Уф, әллә нишләп арып киттем, – диде.* Х.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* Үзгәреп, аңлап булмаслык хәлгә килеп, башкачага әйләнеп. *[Гүзәлия:] Син әллә нишләп кайткансың... Каты бәгырьлеләнеп, Ильяс.* З.Хәким. *Аны күрүгә үк, мин әллә нишләп киттем.* Х.Ибраһимов

◊ **Әллә нишләп бетү** Киеренке рухи халәттән ни кыланганын да аңышмау. *Хәер, бу машинага утырганчы ук әллә нишләп беткән булыр иде инде ул. Таштимерованың якасына ябышыр, битен тырнар иде...* М.Маликова. **Әллә нишләп йөрү** Ярамаган эшләр эшләү. *Ә алар әллә нишләп йөриләр, безнең башка да килмәгән явызлыклар кылалар.* Ф.Яруллин

**ӘЛЛӘ́ НИШЛӘТҮ** *ф.* 1) Үзе бәйләнештә килгән фигыльгә өстәмә ачыклык биреп, игътибарны көчәйтү, сорау, гаҗәпләнү төсмере өстәү өчен кулланыла. *Клара шактый сүзсез калып утырды, әллә нишләтте аны бу кечкенә хикәя, әйтерсең бәгырен туңдырып җибәрде.* Ә.Еники

2) Аңлатып биреп булмаслык дәрәҗәдә тәэсир итү, йогынты ясау. *Шунысы белән дә ул күңелне әллә нишләтеп җибәрә сыман.* Р.Хисмәтуллин. *Борһанның шулай, мыскыл иткәндәй, үзүзенә артык ышанып, масаеп, җитмәсә тагын, әллә кем булып кыланып сөйләшүе [Мәдинәне] әллә нишләтте дә куйды.* М.Хәсәнов. *Шушы җырлары белән Әхмәт бөтен халыкны әллә нишләтте.* Г.Бәширов

**ӘЛЛӘ́ НИШЛӘҮ** *ф.* 1) *к.* **әллә нишләтү** (*1мәгъ.*) *Әллә нишли – мәш килә, әйтерсең өйгә зур кунак килә.* Х.Ибраһимов. *Уф, йөрәгем әллә нишли, читлектәге кош шикелле бәргәләнә.* Ф.Яруллин

2) Күңелдәге кичерешләрне аңлатып бирә алмау. *Ул чакта да, Чәчкәнең кулы уч төбенә керүгә, әллә нишләп китәр иде Илбарыс.* М.Хәбибуллин

3) Бик нык үзгәрү, аңлый, таный алмаслык дәрәҗәгә җитү. *Адәм баласы әллә нишли, бозыла.* Ә.Баян

**ӘЛЛЕ́-МӘЛЛЕ** *рәв.* Бик аз, чамалы, юк дәрәҗәсендә. *[Фәния:] Әле синең акча мәсьәләсе дә әлле-мәлледер?*

◊ **Әлле-мәлле дөнья(сы)** Рәтсез, ышанычсыз, җае булмаган яшәеш. *Авыр ялгыз хатынга, бик авыр әлле-мәлле дөньясын алып баруы.* Ф.Сафин

**Ә́ЛЛИ-БӘЛЛИ, Ә́ЛЛИ-БӘҮ** *ы.* **1.** Бала йоклату өчен бишек җырларының башламы. *Әлли-бәү, бәлли-бәү! Нәнекәчем-кошчыгым! Әлли-бәү, әлли-бәү, Йомшак сары томшыгым.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* Бишек җыры. *Әлли-бәлли әйтермен*

**Ә́ЛЛИ-БӘЛЛИ ИТҮ** *ф.* Бала йоклатканда әйтелә: йокыга китү, йоклау. --- *дөньяга инә күзе аркылы гына карый торган каты куллы хәзрәтнең һәм дөньяны чапан астыннан гына күргән бер бала җанлы абыстайның «әлли-бәлли итәр бу, Бохарага китәр бу» диеп тирбәтеп үстергән баласы.* Җ.Вәлиди. *Әлли-бәлли ит, балам, Сине йокыга салам, Син йокыга киткәнче Үзем яныңда калам.* М.Маликова

**Ә́ЛЛҮ-БӘЛЛҮ(-ЛҮ)** *ы. к.* **әлли-бәлли**. *Татарда да нәкъ шулай: «Әллү-бәллү-лү...» Гөләш тә ишетә бу җырны. Әнә ничек изрәп йоклый ул.* Г.Гыйльманов

**ӘЛЛҮКИ** *ы.* Баланы йоклатканда «бәллүки» сүзе белән аралаштырып, тирбәтә-тирбәтә көйләп әйтелә. *Әнкә карынында «Әллүки»не тыңлап яткан яралгыдан бөек татар тумас, димә!* М.Галиев

**ӘЛЛҮР** *ы.* Эш тәмам, китәргә була, дигән мәгънәдә әйтелә. *Иртәгә*

*институтка барып документларны алырга да – әллүр!* Ф.Садриев

**ӘЛМӘШЛӘНҮ** *ф. диал.* Нәрсә белән булса да артык мавыгу; әвәрә булу. *Инде без генә, чана шуучы малайлар гына калдык. Аларның да, уенга әлмәшләнеп, күзенә ак-кара күренми башлаганнары гына.* Г.Бәширов

2) Үзгәрү, артык шаяру, кылану. *Әлмәшләнә бала, кеше килгәч кылана, артык шаяра башлый.* Г.Бәширов

**ӘЛМИСАК** *и. гар.* Яралу, яратылу. *Шушы бөек тетрәнүләр көчешенең мәңгелек дәвамын тәшкил иткән яшәеш чылбыры – әлмисактан бирле бар һәм булачак илаһи дастан.* М.Галиев. *Әйе, әлмисактан бирле татарларда (һун-сөн, төрки, скиф, хәзәр, кыпчак) «Минем җирем!», «Җир-Ана», «Илҗир» дигән төшенчә Күк Тәңредән бирелгән мәңгелек бүләк итеп кабул ителгән.* М.Галиев

**ӘЛПИ́-ТИСИ** *и.* 1) Гарәп алфавитында беренче дүрт хәреф *к. шулай ук* **әлифба** (*1 мәгъ*)

2) Чикләнгәнлек, артталык. *[Фарукҗан:] Көрәк-сәнәктән, әлпи-тиси, бисмилладан ерак китә алмаганбыз.* Т.Әйди. *Барлык татар авыл мәктәпләрендә «әлпи, тиси» дип искечә укыткан, муллалар, өшкереп-төкереп, авыруларны дәвалаган вакытта, алдынгы фикерле шәхесләр дөньяви мәктәпләр ачу, уйдырма-ышануларны бетерү юлына басалар.* С.Алишев

**ӘЛСЕРӘТЕРЛЕК** *с. к.* **әлсерәткеч**

**ӘЛСЕРӘТКЕЧ** *с.* Әлсерәтә торган. *Буй-буй тышлы ул җимешне телеп җибәреп, бер-ике кабым авыз итүгә, көннең әлсерәткеч эсселеге, һаваның тынга кабарлык бөркүлеге онытыла.* Л.Хәмидуллин

**ӘЛСЕРӘТҮ** *ф.* 1) Эсселек яки арыганлык нәтиҗәсендә хәлсезлек басу. *Әлсерәтте әле, тамак кибеп китте.* М.Маликова. *Төшлеккә җиткән кояш бар нәрсәне әлсерәтү хәленә китергән.* Ә.Гаффар

2) *күч. диал.* Ардыру, хәлен, көчен алу. *Җәйге орышта Мәскәүнең куәтле явын, әлсерәтеп, кире кайтарып җибәрү җиңү белән бер булса да, Казанның эшләре куанырлык түгел.* Р.Батулла

**Әлсерәтә башлау** Әлсерәтергә тотыну

**Әлсерәтә төшү** Тагын да әлсерәтү

**Әлсерәтеп бетерү** Тәмам хәлдән тайганчы әлсерәтү. *Еланны биетә-биетә әлсерәтеп бетергәч, курайчы егет туктый.* Р.Батулла

**Әлсерәтеп җибәрү** Кинәт әлсерәтә башлау

**Әлсерәтеп йөртү** Озак вакыт төрле урыннарда йөртеп әлсерәтү, файдасызга ардыру. *Миргазыян да, шуны сизгәндәй, мине озак әлсерәтеп йөртмичә, үзенең кайсыдыр тарафтагы ерак торагына алып китте...* Ә.Еники

**Әлсерәтеп тору** Һәрвакыт, гел әлсерәтү

**Әлсерәтеп чыгу** Һәрберсен, берсен дә калдырмыйча әлсерәтү

**ӘЛСЕРӘ́Ү** *ф.* 1) Эсседән талчыгу, бик нык ару, хәлдән таю (кеше турында). *Эсседән әлсерәгән, арба тартып арыган алты хатын Карамалы авылына килеп кергәндә, өйлә җитеп килә иде инде.* З.Зәйнуллин. *[Мәрдән абзый] Җәйге чилләдә берәр кайдан әлсерәп кайтса, шунда кереп ял итә.* Г.Гобәй

2) Эсседән, кызудан башларын түбән иеп, авызларын ачып яки телләрен чыгарып тын алу (хайваннар турында). *Икешәрләп, өчәрләп укмашкан сарыкларда инде ашау кайгысы беткән, берберсенең күләгәсенә сыенып, әлсерәгән хәлдә, үләнгә битараф карап торалар.* М.Галиев

3) Эсседән сусыллыгын югалту, шиңү, кибүгә якынлашу (үсемлек турында). *Җир-анага, һай, авыр. Әлсери кырда игеннәр...* Р.Вәлиев

**Әлсерәп бетү** Бик нык, тәмам әлсерәү. *Актүш кырда сукыр тычкан оялары туздырып йөреп әлсерәп беткән.* Г.Гобәй. *Ә аста, ишегалдының өч почмагында, карда аунап, әлсерәп беткән өч малай басып тора.* Р.Мөхәммәдиев

**Әлсерәп йөрү** Әле, хәзерге вакытта әлсерәгән хәлдә төрле урыннарда булу

**Әлсерәп китү** Кинәт әлсерәү

**Әлсерәп тору** Әле, хәзерге вакытта әлсерәгән булу

**Әлсерәп чыгу** Нindidер сәбәптән әлсерәгән хәлгә килү

**Әлсерәп яту** Әле, күз алдында әлсерәгән хәлдә булу. *Күренә, сугыш газапларыннан соң ул да бу киң даланы, кояш астында әлсерәп яткан бу тынлыкны үлеп сагынган.* Н.Дәүли

**Әлсери бару** Торган саен ныграк әлсерәү

**Әлсери башлау** Әлсерәргә тотыну. *Эсседә йөреп әлсери башлагач, без ике карт – мин дә Равил әфәнде Үтәбәй – пароходка алданрак төшеп киттек.* Ә.Еники

**Әлсери төшү** Бераз әлсерәү

**ӘЛҮ** *и. к.* **әлүчә.** *Мунчадан соң – әлү как.* Әйтем. *«Әйдә әле, әлү кагы белән чәй эчеп карыйк, сусадым», – ди.* Р.Мулланурова

**ӘЛҮН** *и. сөйл. к.* **әлүчә**

**ӘЛҮЧӘ** *и. бот.* 1) Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, каралҗым кызыл яки саргылт төстәге әчкелтем җимешләре булган, Кавказда үсә торган җимеш агачы (сливаның бер төре); *русчасы*: **алыча**. *Бу авыру «җимеш касәсе», яки «өрдерелгән җимешләр» исемендә билгеле. Ул шулай ук чия, шомырт, әлүчә, күгәндә дә бик еш очрый.* Л.Мәүлүдова

2) Шул агачның әчкелтем җимешләре

**ӘЛФИРАК** *и. гар. иск.* Аерылу. *Барасы юл, һай, ерак, Сүнсә кулда шәм – чырак, Ясиның чыгу, ай – урак, Җан – югары, тән – түбән, Әлфирак аһ, әлфирак!* Р.Сүлти

**ӘЛХАСИЛ** *мод. с. гар. иск. к.* **әлхасыйль**. *Әлхасил, озын сүзнең кыскасы шул кем, бүре бу җиде бәҗәнең һәммәсен дә берәм-берәм ашап бетергән, имеш.* Әкият. *Без гаҗәпләнә калдык: йөзгә җитеп килгән әдип нәкъ искечә – сөйләшүе дә бик әйбәт, гәүдәсе дә гадәттәгечә төп-төз, аяк атлаулары да нык – әлхасил, бернинди картлык зәгыйфьлеге сизелми иде аңарда...* Ә.Еники

**ӘЛХАСЫЙЛЬ** *мод. с. гар. иск.* Гомумиләштереп әйткәндә, җыйнап әйткәндә; гомумән, кыскасы. *Ничек булса булган, әлхасыйль, халык һичкемгә мохтаҗ булмыйча, үз хиссиятен үзе мәйданга чыгарган, «җырның җыртыгы юк» дигән дә җырлый биргән.* Г.Тукай

**Ә́Л-ХӘЛ** *җый. и.* Физик көч, көчкуәт, егәр. *Әни бераз әл-хәл алып торды.* С.Хафизов. *Мөгаен, бераз әл-хәл алыйм, дип тә әйткәндер.* Г.Хәсәнов. *Бераз әл-хәл алып, абзарга чыккан инәсе бу сүзләрне ишеткәннән соң --- өйгә кереп китте.* А.Хәлим

**Ә́Л-ХӘЛ БУЛУ** *ф.* Хәл туплау, хәлләнү, көч җыю. *Ичмасам, лазаретка кереп, әзрәк әл-хәл булыр идем.* Ф.Хөсни

**ӘЛХӘМ** *и. гар. дини* Коръәннең беренче сүрәсе (Фатиха сүрәсенең беренче сүзеннән кыскартып ясалган). *[Матә:] Тәсфирәмне күмгән чакта, Бәкернең биш яше тулып килгән оныгы да «әлхәм» дигән доганы укыды.* З.Зәйнуллин

◊ **Әлхәм сүрәсен укыту** Кыйнау, физик җәзалау. *Укытканнар икән әлхәм сүрәсен.* Ф.Бурнаш. *Әһ-һә! Каптыңмы, чибәр егет! Менә хәзер кәҗә мае чыгарабыз! Укытабыз әлхәм сүрәсен!*

**ӘЛХӘ́МДЕЛ** *и. гар. дини к.* **әлхәм.** *Матурым Наиләнең, конфет бирәм, дигәч, минем ике битемне үбүләре һәм, шуның өстенә, «әтием, конфет бирсәң, әлхәмдел өйрәтәм» диюләре...* Ә.Гаффар

**ӘЛХӘ́МДЕЛИЛЛӘ** *кер. сүз гар. дини к.* **әлхәмделилләһи шөкер**. *[Галиәсгар:] Җиде ятим асрасам да, дәүләтем бар, әлхәмделиллә!* Ә.Фәйзи

**ӘЛХӘ́МДЕЛИЛЛӘҺИ ШӨКЕР** *кер. сүз гар. дини* 1) Сәламләшү сүзе буларак, хәл-әхвәл сораучыга җавап итеп, мактау – Аллаһка, Аллаһка шөкер, дигән мәгънәдә әйтелә

2) Аллага шөкер; булганына канәгать, риза. *Әлхәмделилләһи шөкер, нәселдә яманат чыгаручылар булмады, анысы.* Ф.Латыйфи

**ӘЛХӘРӘЙ** *и. гр. иск. сөйл.* 1) Архиерей. *Ядгәр, Шинбикә өчен, Болакның кояш батыр ягында күлгә каршы әлхәрәй күмелгән йирдән күп ары бер зур бакча кылдырып, --- өйләр вә гыймарәтләр ясаткан икән.* Риваять

2) *күч. кимс.* Бик сүлпән, дәртсез, сүрән (кеше турында)

◊ **Әлхәрәй кебек бай** Чиксез бай

**ӘЛЧЕ** *и.* 1) Ашыкның (кузнаның) кырын ятуы – икенче дәрәҗәдәге отышлы яту

2) *тар.* Зур түрәгә бүләккә әзерләнгән сылу һәм матур кыз; билгеләнгән кыз

**ӘЛЧЕБИКӘ** *и. тар. к.* **әлче** (*2 мәгъ.*)

**ӘМАН** *и. гар. иск.* **1.** Куркынычсызлык, иминлек, тынычлык

**2.** *хәб. функ.* Гафу үтенгәндә, мәрхәмәт күрсәтергә сораганда кулланыла. *Әман, падишаһым, балама тимә, минем баламдыр.* К.Насыйри

**3.** *ы. мәгъ.* Тыю, тыеп калу, саклык күрсәтү, мәгънәсен белдерә; берүк. *Әман серeңне халыкка фаш итмә.* Ф.Әмирхан. *Әман, йа Раббем, кырык мең тәңкә! Курчак туена кырык мең тәңкә?!* Г.Исхакый

◊ **Әман булу** Нәрсәдән дә булса котылу, авыр хәлдән чыгу. *Әгәр дә булса бик бай, Эчкәне булыр яхшы чәй, Бурычтан булыр әман, Шулай кирәк бәдәвам.* Ш.Мөхәммәдев. **Әман табу** Куркынычтан, афәттән качарга мөмкинлек табу, посып калу, яшеренә алу. *Кошлар оча алмый, маллар, йөрәк бәгырьләренә ярып төшкән бу салкыннан кайда әман табарга аптырап, абзар ышыкларына сыеналар.* Г.Ибраһимов

**ӘМАНӘТ** *и. гар.* Кешене ышандырып, өстенә бурыч итеп алган, һичшиксез үтәлергә тиешле булган эш яки тапшырылырга тиешле сүз (әйбер яки йомыш). *Рәнҗемәссең, әти, башны иеп, Зират буйлап үтәм, Авылыңнан синең әманәтне Үти алмый китәм.* И.Юзеев. *Сандугачлы соңгы таңым бүген, әманәтне, зинһар, аңлагыз. Күкеләрне, димим... хет күкеле Сәгатьләрне, улым, саклагыз!..* Т.Шәмсуаров

◊ **Әманәт бозу** *к.* **әманәткә хыянәт итү**. *Искәндәр абыйсының әманәтен бозу булса да, Равил аккордеонын Йосыф абый белән велосипедка алыштыру хакында сөйләшеп карарга булды.* В.Нуруллин. **Әманәткә хыянәт итү** Кешенең үтәлергә яки тапшырылырга тиешле сүзен (әйберен яки йомышын) эшләмичә калу; ышанычны акламау

**ӘМАНӘ́Т ИТҮ** *ф.* Ышанып тапшыру. *Ул диңгездәге балыклар һәм урмандагы хайваннар дөньясы, җир астындагы файдалы казылмалар – болар барысы да адәм баласына әманәт итеп бирелгән нигъмәтләр.* Шәһри Казан

**ӘМАНӘТЛЕК** *и.* 1) Әманәткә дип бирелгән әйбер

2) Тотык, рәһен. *Әманәтлектә чакта, бу кеше Римда булган хәлләр белән якыннан таныша, римлыларның колларга карата кылган кабахәтлекләрен үз күзе белән күрә.* М.Хәбибуллин

**ӘМӘЙЛЕК** *и. гар. этн.* Тәңкәләр, асылташлар белән бизәлеп, бер иңбашыннан икенче култык астына киелә торган киң тасма; путемар, хәситә. *Әмәйлек тагу*

**ӘМӘЛ** *и. гар.* 1) Берәр эш башкару яки берәр хәлдән чыгу өчен уңайлы ысул, чара. *Әнисен авылдагы авыр тормыштан, мәшәкатьләрдән коткару өчен яхшы әмәл иде бу.* Ф.Садриев. *Нишлисең, кешенең елгаларны кирегә борырга, тауларны бер урыннан икенче урынга күчерергә көче, осталыгы, кодрәте җитсә дә, табигать канунын үзгәртерлек, газраил балтасына каршы торырлык әмәле юк.* А.Шамов. *Анналары, йомшаклыгым беленмәсен, дип тә ул шундый әмәл сайлады.* Х.Камалов

2) Берәр теләкне тормышка ашыру өчен уйлап табылган сылтау, хәйлә. *«Мәдәни» дигән даирәләрдә исә, гомумән, динне логикасыз, реаль дәлилләрсез «фаш итү», әтәчләнеп сүгү бик күпләрнең көн итү – тамак туйдыру әмәленә әверелде.* Ф.Дунай

3) Нинди дә булса эшне башкару ысулы, тәртибе. *Юк менә Чырык, мәет куйганда ярап тора иде әле, әмәлен белә иде, оештыра ала иде, хәзер инде нишләргә дә белмиләр: кеше кулыннан киткән җанны зиратның кайсы төшенә куярга?* Я.Зәнкиев. *Әнием өйрәткән әмәл белән пешерелгән, шуңа күрә бары бездә генә авыз итәргә мөмкин булган татлы бәлешне өлешләргә бүләм.* К.Тимбикова. *Врачлар сугыш вакытында бала таптыру әмәлләрен онытканнар иде.* Х.Камалов

4) *күч.* Физик көч, егәр. *[Мирсәетнең] Гәүдәсен урындыктан күтәреп, авызын ачарлык та әмәле юк.* Р.Мөхәммәдиев. *«Кышка баз казырлык кына әмәл бар әле», – дип уйлады Каһир ачу белән һәм, ухылдый-ухылдый, агач баскычтан түбән төшеп китте.* Ә.Гаффар

◊ **Әмәлгә калгандай** Кызганычка, бәлагә. *Әмәлгә калгандай, өйдән чыкканда, паспортымны алып чыгарга онытканмын.* Н.Исәнбәт. **Әмәлен күрү** Берәр нәрсәгә карата нинди дә булса эш-хәрәкәт башкару, чара куллану. *Фатир табу әмәлен күрү.* **Әмәлен табу** Җаен чыгару, мөмкинлектән, форсаттан файдалану; хәйлә кору. *Ширәмәтов Булганинны чыгырыннан чыгарган ниндидер гамәл кылмакчы, тегесе аңа ирек бирмәү әмәлен дә табар иде, әмма мин аларның кайсыныңдыр картасын тетелеп беткәнче бутадым бугай.* Ә.Гаффар. *Резедабыз тагын безнең фикерне аңлату әмәлен тапты.* К.Тимбикова

**ӘМӘЛЛӘНҮ** *ф.* Кул астындагы әйберләр белән аннан-моннан гына эшләнгән булу, тиз-тиз генә корыштырылган булу, сыйфатлы итеп эшләнмәү. *Өстәл, урындыклар – һәммәсе монда вакытлыча гына яшәү өчен әмәлләнгән.* Р.Кәрами. *Калкурак урынга ышкыланмаган такталардан тиз-тиз генә трибуна әмәлләнгән, микрофон куелган иде.* Р.Кәрами

**ӘМӘЛЛӘ́Ү** *ф.* 1) Җаен, юлын табып, берәр нәрсә булдыру, көченнән килгән кадәр рәтләү, төзәтү; оештыру. *Зәкиулла абый гына, өлкән кешеләр алдында мактанырлык акча әмәлләп, өсбашын карап кайта алмавыннан кыенсыныптырмы, күбрәк бала-чага белән аралаша.* М.Юныс

2) Көчкә, авырлык белән, тегеннән дә, моннан да табып булдыру, оештыру. *Ә хәзергә тоткыннар үзләренә тактадан барак әмәлләделәр.* Р.Кәрами. *Бар булган аермалары шунда гына: күбесенең тирә-ягына такта-токтадан яссы түбәле бәләкәй генә куышлар әмәлләгәннәр дә шуларга морҗа чыгарганнар.* В.Нуруллин

3) Тиз-тиз, җәһәт кенә нәрсә булса да эшләп ташлау. *[Мөсәмирә:] – Мин берәр нәрсә әмәллим әле, – дип, учак тирәсендә чуала башлады.* Р.Кәрами. *[Гадел:] Минем хатын бик шәп әмәлли пилмәнне.* Ш.Маннап. *Кичен Пётр Трофимович кичке аш әмәлләү белән мәшгуль булды.* Ф.Әгъзамов

**Әмәлләп алу** Аз вакыт эчендә, тиз арада әмәлләү. *[Бабасы Илсөяргә:] Ят, йокла, ә мин ашарга берәр нәрсә әмәлләп алыйм.* Г.Гобәй

**Әмәлләп бетерү** Ахырына кадәр, тулысынча әмәлләү. *Сату-алу кәгазьләрен әмәлләп бетергәч, тегеләрдән – алдым, Сәеттән – бирдем, дип, соңгы журналга кул куясы калды.* Т.Галиуллин

**Әмәлләп бирү** Кем өчендер әмәлләү. *Кызлар без – егетләргә идәнгә урын әмәлләп бирделәр дә, кухняга кереп, савыт-саба юарга керештеләр.* З.Фәйзуллин

**Әмәлләп йөрү** Әле, хәзер нинди дә булса эш белән мәшгуль булу. *Ә замполитның кирәк булып куюы бар. Бигрәк тә гражданкада укырга теләүчеләр характеристика әмәлләп йөргән вакытта.* С.Шәрипов

**Әмәлләп карау** Әмәлләргә тырышу, ни дә булса эшләп башкарырга омтылу. *Шуннан соң миндә, әллә чыннан да симфоник оркестрга берәр нәрсә әмәлләп карагамы, дигән уй туды.* М.Макаров

**Әмәлләп кую** 1) Тиз-тиз генә эшен бетереп әзер хәлгә китерү. *Сөембикә ханымга, тәмле ризыклар пешереп, әчесен-төчесен әмәлләп куярга гына кала...* Г.Ахунов

2) Булдыра алганча, мөмкинлекләрдән чыгып эшләү, ясау. *[Гарәпләрдә] Чатырлар – иске кара сукнодан әмәлләп куйган торак йортлар.* М.Мәһдиев. *--- иске такталар белән әйләндереп, койма ише нәрсә дә әмәлләп куйгандай иттеләр.* М.Хәсәнов

**Әмәлләп ташлау** Һич уйламаганча, көтмәгәнчә әмәлләү; тиз-тиз, аннан-моннан әмәлләү. *Хәтта бер әкәмәт аппарат та әмәлләп ташладым.* Л.Лерон

**Әмәлләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр әмәлләү. *Әллә, минәйтәм, верандасы да яңартып җибәрик микән? Такталары бик каралган, тәрәзәләре дә кечкенә. Язгы эшләр башланганчы, бәлки, әмәлләп чыгып булыр.* Ф.Яруллин

**Әмәлли башлау** Әмәлләргә тотыну

**ӘМӘЛЛЕ** *с.* Һәрвакыт җаен, мөмкинлеген таба торган, елгыр, булдыклы. *--- кичә Ишмиләр кебек кадим гөруһларга каршы көрәшкән «җәдиди»ләр бүген яңа идеаллар, яңа фикерләр белән янган яңа әмәлле буыннарга каршы үзләре шул кадим булып калалар икән шул.* Г.Ибраһимов

**ӘМЕР** *и. гар.* 1) Хакимият органнары, оешма җитәкчеләре һ.б. тарафыннан бирелгән рәсми боерык. *Фарукҗан бу әмерләрнең берсенә аеруча игътибар итте.* Т.Әйди

2) Билгеләнгән тәртиптә телдән бирелгән кыска боерык; команда

3) Катгый кушу, таләп; сорау, үтенеч. *Командирның әмере бик тиз үтәлде, яшьләрне кузгатып, Нәби агага урын таптылар.* М.Галиев. *[Мөнәвәрәнең] Әмере кыска булды: бу хәлдә, Краевкага кереп, ирләр күзенә күренмәскә!* З.Зәйнуллин. *– Бүген – туган көнем. Кер әйдә, Шура! – диде хатын. Тавышына үтенү белән бергә әмер дә катнашкан сыман.* З.Хөснияр

4) *күч. дини* Аллаһның боеруы, кушуы турында дини караш; язмыш, күрәчәк, тәкъдир. *Аллаһе Тәгаләнең әмере шундый.* Ф.Садриев

**ӘМЕ́Р БИРҮ** *ф.* Кемгә дә булса берәр нәрсә эшләргә боеру. *[Әти] Агач мылтыкларны иңнәрдән төшерергә кушып, «К ноге!» әмерен бирә.* Г.Тавлин. *Бир әмер, туганым, берничә атны суярга.* М.Хәбибуллин. *Конвойның өлкәне әмер бирде: – Туктарга!* Р.Кәрами

**ӘМЕ́Р ИТҮ** *ф.* Кушу, берәр нәрсә эшләргә катгый теләк белдерү. *[Әти] Кергәч тә әнигә: «Хатын! Бар, балага катык белән ипи китереп бир», – дип әмер итте.* Г.Тукай. *Башымны игәннән-ияргә әмер итте.* Г.Исхакый

**ӘМЕРЧЕ** *и. сир.* Әмерләр бирүче. *Шиһабетдиновны хәрби назыйрлыкка Төркестан фронты әмерчесе Фрунзе белән иптәш Куйбышев беравыздан тәкъдим итүе расмы?* Т.Әйди

**ӘМИР** *и. гар. кит.* 1) Боеручы. *Ләкин аны каяндыр килеп чыккан җансакчысы туктатты: – Кирәкмәс, әмирем!* М.Мәһдиев

2) Берәр дәүләт яки өлкә башлыгы. *«Яшь бохарачылар», күп михнәтләр чигеп, Бохара әмиренә каршы көрәш җәелдергәннәр.* Ф.Сафин

3) Хан, шаһзадә. *Әмир үзенең тәхетен ташлап качарга мәҗбүр булды.* Т.Әйди

**ӘМИРЛЕК** *и. тар.* Дәүләт яки өлкә. *Бохара әмирлеген Европа дәүләтләре шикелле иркен тормышлы, алдынгы вә хөр республикага әйләндерү – безнең иң мөкатдәс бурычыбыз.* Т.Әйди. *Менә ул Бохара! 2000 яшьлек шәһәр бу. Уналтынчы гасырдан Бохара әмирлегенең башкаласы.* Р.Сибат

**ӘММА** *терк. гар.* **1.** 1) Җөмләдә тиңдәш кисәкләрне яки тезмә кушма җөмләдәге гади җөмләләрне терки һәм аларның эчтәлеген бер-берсенә капма-каршы куя; ләкин, шулай да. *Нурлыбикә, куллары белән диванга тотынып, кискен генә күтәрелде, әмма, хәзерге минутта нәрсә эшләргә тиеш икәнлеген исенә төшерә алмыйча, басып тора бирде.* Г.Кашапов

2) Җөмлә башында килгәндә, аның мәгънәсе алдагы җөмләдә хәбәр ителгән фикергә каршы булуны белдерә. *Мәхәббәт – кеше өчен иң кадерле, иң бөек хис. Әмма замана шаукымы кайчакларда бу олы хисне дә үзгәртмиме икән?* М.Вәли-Барҗылы. *Документларда әтинең туган елы 1903 дип язылган. Әмма, әтинең туганнан-туганы мәрхүмә Зөләйха апаның әйтүенә караганда, ул 1901 елларда туган булырга тиеш.* Т.Миңнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик, үтә, чиктән ашып. *Әмма тупас кеше дә соң син, Фәйзи!* Ш.Камал

**ӘММА (ДӘ) ЛӘКИН** *терк. сөйл.* Каршылык мәгънәсен көчәйтеп күрсәтү өчен кулланыла. *Әмма дә ләкин моның сәбәбе тиздән ачыкланды.* Р.Батулла. *[Галиәкбәр оста:] Нәселебезгә тап төшермәячәгеңне беләм анысы, әмма дә ләкин, кара аны…* Ф.Латыйфи

**ӘММА КИ** *терк. к.* **әмма ләкин.** *Әмма ки шунысын тәгаен беләм: бар ул бәхет җире, һәм һәркем аны үзе табарга тиеш.* М.Хуҗин

**ӘНӘ** *а.* **1.** 1) Чагыштырмача иң ерак аралыкны, еракtагы берәр нәрсәне төбәп күрсәткәндә кулланыла торган күрсәтү алмашлыгы. *[Мәдинә апа:] – Бүген-иртәгә миранус сарыгым бәрәнләргә тора. Әнә муенына кызыл чүпрәк бәйләгәне… Күз-колак бул әле шуңа, үскәнем, – дип, китеп барды.* М.Галиев. *[Актамыр кызы:] Билгеләп куй: әнә көмеш ай-бөркет, канатларын җәеп, Кызылтау башындагы иң биек агачның очына кунарга бара!* Р.Хәмид. *Әнә чүлмәк: аңа катык тутырылган; Әнә карга: мәчет өстенә кунган.* Г.Тукай

2) Алмашлыклар һәм рәвешләр алдында килеп, алда әйтелгән фикергә ишарә итеп, җөмләнең мәгънәсенә ачыклык кертү, конкретлаштыру өчен кулланыла. *Тормышның әнә шундый җайсыз бер көнендә мине военкоматка чакырдылар.* М.Мәһдиев. *Чит илгә алар, әнә шулай, ата-ана фатихасын алып киттеләр.* Н.Акмалов. *Менә хәзер, палатада берүзем генә хат язып утырганда, балачагымның әнә шул онытылмас көннәре турында уйлыйм да, күзләремә яшь килә.* Җ.Тәрҗеманов. *Уттай янып торган тәлгәш-тәлгәш миләшләр бакчага, ишегалдына, келәт һәм койма буйларына әнә ничек ямь биреп тора!* Р.Низамиев

**2**. *кис. мәгъ.* Берәр нәрсә турында раслау, ышандыру төсмере белән, басым ясап, ассызыклап, игътибарны юнәлтеп әйтергә теләгәндә кулланыла. *Әнә ич, бер килсә килә бит ул бәхет дигәнең.* Р.Мөхәммәдиев. *Хәтта шәһәр егете Роберт та әнә башка кызлар белән китеп барды.* Г.Гыйльман. *[Гаяров:] Әнә азык чөгендере бөтенләй тишелмәде әле.* М.Маликова. *Тик алар класс җитәкчесе кебек үк теңкәгә тимиләр, химия укытучысы әнә бөтенләй бәйләнеп утырмый.* Л.Исханова

◊ **Әнә барыр юлың** *туп.* «Кит моннан!» мәгънәсендә. **Әнә терә(к)** Менә сиңа кирәк булса. *Әнә терә, кызың нишләп йөри, чишмә башында җегетләр белән әүмәкләшеп, җаулыгын җыртып кайткан.* Ш.Маннур

**ӘНӘЧ** *и. диал.* Тавык буласы билгеле булган чебеш

**ӘНӘЧӘ** *и. диал.* 1) *этн.* Беренче урылган көлтәне тартып, яңа арпа уңышыннан пешерелгән изге күмәч. *Беренче көн урылган яңа арпа аерууча изге санала. Урылган башакларны уып, шул ук көнне беренче он тарталар һәм изге күмәч – әнәчә пешерәләр.* Н.Фәттах. *Вәлия әнәчә күмәч, бер банкы сөт өсте, берничә шакмак шикәр хәстәрләде.* Р.Батулла

2) Чәкчәк төше, чумар ясау өчен әзерләнгән озынча камыр яисә шуннан өзелгән яки киселгән камыр кисәге. *Кактөш дигәннәре шул: әүвәл камырны басалар, йомырка, сөт, май белән катнаштырып, ул камырдан, вак итеп, әнәчә ясыйлар.* К.Насыйри

3) *сир.* Көнбагыш, киндер һ.б.ш. үсемлекләрнең орлыкларыннан маен яисә җиләк-җимешнең суын сыкканнан соң калган түп

**ӘНДРИ ӘБӘТЕ** *и. сөйл.* Иртәнге аштан соң төшке ашка кадәр булган ашау, аз гына капкалап алу

**ӘНДРИ КАЗНАСЫ** *и. сөйл.* Исәпсез-хисапсыз байлык, мал-мөлкәт чыганагы. *[Хатыннарның берсе:] Әнекәем! Юк, юк, гомердә дә ачтырасым юк ул фалны. Турыдан-туры: «Үләсең!» – дигән кешегә өч тәңкә акча чыгарып тотырырга монда! Әндри казнасы юк!* Н.Кәримова. *Хәмер сорый башлаган иде: «Әнә хатының эчертсен, миндә әндри казнасы юк!» – диде.* З.Мәхмүди

**ӘНЕ(И)КӘЙ ГЕНӘ(Е)М** *ы. к.* **әнекәем.** *[Сәүдә:] Бәррәч, әнекәй генәем! Акмал абый түгелме соң бу?!* Г.Ахунов. *[Миңнури] Беркавем сихерләнеп, миңа төбәлеп торды да кычкырып җибәрде: – Әникәй генәем, Таһирның күзендә сәдәф бар!* С.Хафизов. *– Әнекәй генәм! Күлмәге нинди матур! – дип сокланып пышылдады Ольга.* Р.Мирхәйдәров

**ӘНЕКӘ(ЙЛӘР)ЕМ** *ы.* Кемне яки нәрсәне дә булса күргәч яки нинди дә булса хәбәр ишеткәннән соң туган гаҗәпсенү, шаккату, ис китү хисләрен белдерә. *– Әнекәйләрем! Әллә син дә бар идеңме ул көймәдә, абыкаем! – диде әни, шаккатып.* Н.Кәримова. *Әнекәйләрем лә! Рәхәтләнеп, күзен йомып, әчкелтем тәмле суны йотып җибәргән бу, минсиңайтим.* Л.Ихсанова. *«Әнекә-ем!» – дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.* Н.Хәсәнов

**ӘНЕЧ** *и. бот. сөйл. к.* **энис.** *Улым, Марат, тиз генә колхоз бакчасына барып, бер-ике пот әнеч алма алып кайт.* Т.Гыйззәт

**ӘНИ** *и.* 1) Үзеннән туган балаларга ана булган хатын-кыз (анага мөрәҗәгать иткәндә яки аның турында сөйләгәндә кулланыла). *Хатны Әминәнең*

*әнисе язган иде.* Р.Вәлиев // **әнисе** *тарт. форм.* Ирнең хатынына эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. – *Көрәш, улым, көрәш. Әхмәдулланыкы дисеннәр, име, картым! – Үзләре беләләрдер, әнисе. – Әхмәдулла абзый кырт кисте.* Р.Бәшәр

2) Ирнең әнисе, каенана

3) Үзенең балаларына карата ана мөнәсәбәтендә булган хайван, кош-корт һ.б. *[Бүре балалары] Мөлдерәмә күзләрен безгә төбәп калганнар да: «Нигә безне әнисез калдырдыгыз?» – диләр сыман.* Н.Хәсәнов

**ӘНИЛЕ́-КЫЗЛЫ** *рәв.* 1) Әнисе һәм кызы бергәләп, әнисе белән кызы икәүләшеп. *Шулай итеп, әниле-кызлы Күкчәтауга әтиләре Сәлахетдин янына чыгып китәләр.* Ф.Тарханова

2) *күч.* Әни белән кыз сыман, әни белән кыз булып. *Шулай итеп, Серафима әби белән «гүзәл паночка» әниле-кызлы кебегрәк яшәделәр.* Р.Сибат

**ӘНИС** *и. фр. бот.* 1) Чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан, ак төстә чәчәк ата, эфир мае бирә торган хуш исле үсемлек. *Юлда чишмәләр очратып, берничә тапкыр, каткан ипиләрен шунда җебетеп ашадылар, аланлыклардан әнис, какы кебек үләннәрне җыеп каптылар.* Ф.Бәйрәмова

2) Шул үсемлекнең төчкелтемрәк кискен исле орлыклары (аш тәмләткеч буларак файдаланыла). *Кишердән тыш, кәбестәгә алма, лавр яфрагы һәм әнис кушалар.* Яшелчәче белешмәсе

3) Алмагачның бер сорты. --- *карт кадерләп һәм хөрмәтләп үстергән алмагачлары – Мәскәү грушёвкасы, алсу әнис – бөтен бакчаны хуш ис белән тутырды.* Г.Ахунов. *Аның иң яратканы – әнис алмасы.* А.Гыйләҗев

**ӘНИ́С МАЕ** *и.* Әнис орлыкларын сыгып эшләнә һәм гадәттә дару буларак файдаланыла торган хуш исле май

**ӘНИ́С ҮЛӘНЕ** *и. бот. к.* **әнис** (*1 мәгъ.*). *[Рәхимова] Икенче кулы белән, кыярны мәтрүшкә, әнис үләне һәм бөтнек орлыкларыннан арындырды да кетердәтеп тешләде.* М.Хәсәнов

**ӘНКӘ** *и. сөйл.* **1.** 1) *к.* **әни** (*1, 2 мәгъ.*). *Шумахеры белән, иртәгәсен әнкәләре ягып керткән мунчадан соң кайтып киттеләр.* Ә.Гаффар. *Рөстәм утырган урыныннан сикереп торды, әнкәсенең муенына сарылырга, йөгереп барып, әнкәсен кочарга, күп-күп итеп үбәргә теләде.* Г.Кутуй // **әнкәсе** *тарт. форм. к.* **әнисе.** *[Габдрахман:] Дөнья – ул үзе дә зур бер оя, әнкәсе.* Ф.Яруллин

2) *к.* **әни** (*3 мәгъ.*). *[Колыннар] Әнкәләреннән аз гына калсалар, үзләренең яшь, көмеш тавышлары белән бөтен тауны, урманны яңгыратып кешниләр.* Г.Ибраһимов. *Шуларның [этләрнең] яртысы, ягъни ике меңе генә әнкә булып, елына ике тапкыр бишәрдән унны бәбиләсә, тора-бара, егерме мең эт була.* Т.Нәҗмиев. *Сарык фермасында бәрәннәр караучы кызлар, бәтиләр әнкәләрен имгәч, аларны җылы торакка ябып куялар иде.* Ф.Сафин

**2.** *с. мәгъ.* Ана мөнәсәбәтендә булган, балалары булган. *Димәк, әнкә кошчык моның сайравын да, торган урынын да ярәтты.* Г.Хәсәнов

**ӘНКӘЙ** *и. к.* **әни** (*1, 2 мәгъ.*). *Андый эшкә оста ул, ни кирәк буласын алдан чамалап, Казаннан ук бер чемодан тутырып киткән иде, хәзер менә әнкәй чемоданына да никадәр әйберкара төяде.* М.Маликова. *Йөзеңдә – әнкәй чалымнары, өлгерлегеңдә әнкәй уңганлыгы бар.* Г.Гыйльман

**ӘНМУЗӘҖ** *и. гар. иск.* Кыска һәм аңлаешлы тезис, үрнәк, мисал

**ӘННӘ** *и.* Балалар телендә: бәби, нарасыйның әнисенә эндәшү сүзе. – *Әннә, әннә! – дип, бала әнисенең тезләрен кочаклагач кына, Фәез хатынына туры карады.* Ә.Баянов. *Ул ишектән күренүгә, малай, «әннәм!» дип, әнисенә ташлана.* Ф.Сафин

**ӘНСАР** *и. гар.* 1) *дини* Мөхәммәд пәйгамбәрнең ярдәмчеләре, сәхабәләре; Мәккәдән күчеп килгән мөселманнарга ярдәм иткән Мәдинә кешеләре. *Тауис әйтте: «Минем анам әнсар хатыннары арасында иде. Рәсүлуллаһ вафат булган кич мине тудырды» [диде].* К.Насыйри

2) Ярдәм күрсәтүчеләр

**ӘНЧЕК** *и.* 1) Ана эт, кәнтәй. *Биеп торган чаптарларга авыр йөк тарттырмыйлар, бөдрә йонлы әнчекләрне бүрегә өстермиләр.* М.Маликова

2) Токымы буенча кечкенә гәүдәле эт; эт баласы. *Әнчекләре Найла исемле, песиләренә Мартын дип кушканнар.* З.Фәтхетдинов. *Әнчекнең, филгә өреп алгач, мактанып куюы --- гаҗәпләндерми.* И.Нуруллин

3) *махс.* Бүре көчеге

4) *күч.* Ирләр тирәсендә бик еш сырпаланып, чытлыкланып йөрүче (хатын-кыз турында)

5) *күч. мыск.* Үзеннән өстен торган кешеләргә ярарга тырышучы, икейөзле ялагай. *[Кияү:] Бәк табыныннан калган сынык-саныкны көтеп, арт аягына басып ялагайланучы, аның һәр пычрак телгән койрык болгый-болгый үтәргә атылучы әнчек.* Т.Әйди. *Булат бәк әнчекләренә ымлады: тегеләре, түргә узып, тәрәзәләрдәге коруларны каерып ачты, йолкып та төшерде.* Р.Батулла

**ӘНЧЕКЛӘНҮ** *ф. сөйл.* 1) Ирләр тирәсендә сырпалану, чытлыклану (хатын-кыз турында)

2) Ялагайлану, ярарга тырышу. *Краснов, әнчекләнеп, теге кенәгәне аңа [особый отдел башлыгы булган капитанга] төртте.* Х.Камалов

**ӘҢГӘМӘ** *и. фар.* Ике яки аннан да күп кешеләрнең нинди дә булса бер темага фикер алышуы, үзара сөйләшүе. *Кызын сагынган ата йөрәге йомшак кына, җылы гына әңгәмә көтә иде.* Ә.Мушинский. *Талгын гына аккан әңгәмә вакытында, әби Виолеттага егерме ике яшь тулуын, аның Анадырьдан килүен белә.* А.Мифтахетдинов

◊ **Әңгәмә куерту** Сүзне сүзгә ялгап, әңгәмәне дәвамлы итү, озаклап сөйләшеп утыру. *Кичке аш күңелле үтте, табынга эчемлек кунмады, татарча, бер-берсенең күңелен табып, җай гына әңгәмә куертып чәйләделәр.* А.Гыйләҗев. **Әңгәмә кызу** Фикер алышу көчәеп китү; бер-береңне бүлә-бүлә сөйләшү, аралашу. *Әңгәмә кызгач, алар, диванга күчеп, янәшә утырганнар иде.* А.Гыйләҗев. **Әңгәмәне өзү** Сөйләшүне туктату яки бүлдерү. *Әңгәмәне өзеп, ишек тоткасына ябышты, алъяпкыч астына кыстырган нәрсәсен яшереп, шәүлә кебек, [ашчы] өй артына кереп югалды.* А.Гыйләҗев

**ӘҢГӘМӘДӘШ** *и.* Бер-берсенә карата: үзара әңгәмәләшеп утыручы

кешеләрнең берсе. *Җәмилә Закировна сораулы карашын әңгәмәдәшенең күзлегенә төбәде.* М.Маликова. *[Тау Капланының] Чалара башлаган чәчләре кашына кадәр төшеп тора, ә каш астында бик эчкәртен кереп урнашкан үткен күзләре я әңгәмәдәшенә төбәлә, я уйчанланып кала.* Ә.Мушинский

**ӘҢГӘМӘ́ ИТҮ** *ф. к.* **әңгәмәләшү**. *Чүл һәм үсемлекләр, йолдызлар һәм бүреләр, арыклар һәм коелар, кышлак тормышы һәм үзенең егет чагы, яңа туган бәрәннәрне саклау һәм учак тергезү, чаяннар һәм ташбакалар турында дөньяның үзе белгән барлык серләрен әңгәмә итә иде ул.* Т.Әйди

**ӘҢГӘМӘ́ КОРУ** *ф. к.* **әңгәмәләшү.** *Ул уртача ике егетне чакырып, аларга химик элементлар хакында әңгәмә корырга тәкъдим итте.* М.Маликова. *Без --- Нургали абый Миңнеханов белән бик еш очрашып, төрле-төрле темаларга әңгәмә кора идек.* Т.Нәҗмиев

**ӘҢГӘМӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **әңгәмәләшү**. *Итне ашап, кымызны эчеп, папиросны тартып бераз әңгәмә кылдылар да Сарсымбай җәйләвенә карап, дүрт егет, ат әйдәп, бер буш аргамакны иyәртеп, якты ай астында киң дала буенча киттеләр.* Г.Ибраһимов

**ӘҢГӘМӘЛӘШҮ** *ф.* Күмәкләп, әңгәмә алып бару, сөйләшү, фикер алышу. *Аннан да бигрәк, монда, үзеңә охшаганрак урын табып, ят колаклар ишетер, дип кыенсынмастан, әшнәләрең белән тәмләп әңгәмәләшергә, төрле-төрле планнар корырга мөмкин иде.* Т.Әйди. *Айбала байның тукалы белән чәчле егет үз балалары белән әңгәмәләшеп йөрде.* Г.Ибраһимов

**Әңгәмәләшеп алу** Кем белән дә булса бераз әңгәмәләшү. *Саранскида очрашканда, без үз телебездә синең белән әңгәмәләшеп алдык – саф татар телендә сөйләштек.* Т.Миңнуллин

**Әңгәмәләшеп карау** Киңәшләшү, киңәш итү. *Ә менә Шиһабетдин Мәрҗәни, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхретдин кебек дин белгечләре, мәгърифәтчеләр, татар фәйләсуфлары белән сөйләшеп, әңгәмәләшеп карарга нигәдер кыенсынды ул.* Р.Сибат

**Әңгәмәләшеп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта әңгәмәләшү

2) Әледән-әле, еш әңгәмәләшү

**Әңгәмәләшеп утыру** Әле, хәзер, билгеле бер вакыт дәвамында әңгәмәләшү. *Без әңгәмәләшеп утырган арада, боларның туганы Резидә исемле кызда саклана торган гаҗәеп бер хат алып кайттылар.* Р.Хисмәтуллин. *Ияргә утырырга өлгермәде, ирләр җыелды. Алар белән әңгәмәләшеп утыру байтак вакыт алды.* Б.Рафиков

**Әңгәмәләшеп чыгу** Һәрберсе белән дә әңгәмәләшү

**ӘҢГӘМӘ́ ҮТКӘРҮ** *ф.* Кемнәр белән дә булса берәр темага багышланган сөйләшү алып бару

**ӘҢГӘМӘЧЕ** *и.* Әңгәмә оештыручы яки әңгәмәдә катнашучы. *Хәзер инде уенчылар һәм әңгәмәчеләр генә түгел, хәтта хезмәтчеләр дә, чәй һәм кәһвә кайнатуларын туктатып, хуҗаның авызына карап каттылар.* В.Юныс

**ӘҢГӘМӘ́ ЯСАУ** *ф. к.* **әңгәмәләшү**. *Бүген Рахманкол белән әңгәмә ясау да акланыр иде үзе.* Т.Әйди

**ӘҢГЕРӘК** *и. фар.* 1) *зоол. иск.* Далада яши торган агулы елан; гөрзә; *русчасы:* **гюрза**

2) *бот. диал.* Елан көпшәсе

**ӘҢКЕ́-МӘҢКЕ КИЛҮ** *ф. сөйл.* Нинди дә булса сәбәптән баш аңгыралану, миңгерәүләнгән сыман булу. *[Бамбыр] Кире килеп урынына утырды, кесәсеннән янчыгын чыгарды: – Син, адаш абзый, миңа рөхсәт ит инде, бу нәрсәне азрак төтәтеп җибәрим, югыйсә, баш әңке-мәңке килә сыман.* З.Зәйнуллин

**ӘП-** *кис.* «Ә» авазына башланган кайбер сыйфат һәм рәвешләргә ялганып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган алкисәкчә (мәс., *әп-әз, әп-әкрен, әп-әче*)

**ӘПӘ** *и. диал.* Телсез-чукрак кеше. *Хәлим, телсез әпә янына килеп, кулын болгый-болгый, кычкырып-кычкырып, кабат аңлата башлады.* Г.Гыйльманов

**ӘПӘ́-ЧӘПӘ** *рәв.* Дусларча, гөж килеп. *Утырсын Наилә ахирәтләре белән әпә-чәпә сөйләшеп…* А.Гыйләҗев

**ӘПЕ́Н-ТӨПЕН** *рәв. сөйл.* 1) Кабаланып, бик ашыгып. *Барысы да сикерешеп тордылар. Әпен-төпен киенә башладылар.* З.Зәйнуллин. *Әбекәй: «Ай Аллам!..» – дия-дия, әпен-төпен сәкедән төшеп, селкенә-селкенә чыгып китә.* Ә.Еники

2) Ава-түнә, авырлык белән. *Монысы артыннан, тагын алты топкын әпен-төпен атлап керде.* Р.Кәрами

3) Җиренә җиткермичә, аннан-моннан гына, аяк өсте генә. *Бу яклардан тизрәк таярга кирәк, дип хәл кылынды. Алган эшләрне әпен-төпен эшләп бетерергә дә ычкынырга!* Т.Мөбарәков. *Элек заманда сала белгәннәр шул. Хәзер генә ул әпен-төпен өяләр дә куялар.* Г.Зәйнашева

**ӘПЕ́Н-ЧӘПЕН** *рәв. сөйл.* Барысын бердән төрле якка чәчеп. – *Ә ничек сөйләмисең, ди? – Сабир башын күтәрә төште, күз аклары елтырап китте. – Икәвесен берьюлы әнә шулай әпен-чәпен туздырып ташласын да сиңа!* Э.Касыймов

**ӘПЕ́-ТӨПЕ** *рәв. сөйл.* Әвәләп, әле бер якка, әле икенче якка тәгәрәтеп. *Хуҗа хатын, әпе-төпе китереп, ипи әвәли.* М.Мәһдиев

**ӘПЕ́-ЧӨПЕ КИЛҮ** *ф. к.* **әҗе-гөҗе килү**

**«ӘП» ИТҮ** *ф. сөйл. шаярт.* 1) Үбү, үбеп алу (еш кына балалар телендә кулланыла). *Ә ул миңа җавап биреп тормады, үрелеп, битемнән бер генә тапкыр «әп» итте дә көлә-көлә кире йөгерде.* Ш.Маннур. – *Һо, Гомәр туганым! Кая, җанкисәгем, бер «әп» итеп күрешик әле! – Һәм Гомәрне кочаклап, ике яңагыннан да үбеп ала.* Ә.Еники

2) Егылу, егылып китү, егылып төшү (балаларга карата әйтелә)

**ӘППӘ́Р ИТҮ** *ф.* Балалар телендә: ашаганнан соң амин тоту. *Ашагачтын әппәр итсәң, Оҗмахка керерсең, балам…* Г.Афзал

**ӘПСЕ** *и. мед.* Тире күгәрү һәм авызборын куышлыгы шешү белән характерлы йогышлы авыру; *русчасы*: **рожа**

◊ **Әпсе ашау** *к.* **әпсе тибү**. **Әпсе тибү** *диал.* Үләр алдыннан, тәндә күгәргән таплар барлыкка килү. *Хәлем начарланганнан-начарлана барды. Дүрт көннән соң, тәнемнең һәр күзәнәгеннән яшькелт шәмәхә төрткеләр тибеп чыкты. Халык телендә аны «әпсе типкән» диләр.* Р.Хәбибуллина

**ӘПТӘЧИ** *и. диал.* Йолачы, имтомчы, *к.* **әпчи карчык**. – *Бәтәч, күрше авылдан әптәчине чакырабыз, – диде әзмәвер, шуңа да башың җитмимени, дигәндәй гаҗәпләнеп.* Н.Гыйматдинова

**ӘПТИЯК** *и. сөйл. дини к.* **әфтияк.** – *Әптияк сүрәсен син дә укыган идеңме, абый? – диде ул.* М.Гали

**ӘПТЧХИ** *ияpт. к.* **әпчи**

**ӘПЧИ** *ияpт.* Нәрсәнең дә булса борын куышлыгын ярсытуыннан ихтыярсыздан төчкереп җибәргәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *[Шәйхулла:] Инде хәзер, бик әйбәтләп кенә төчкер! (карчыгына төчкерергә булышып) Әәә, әп-әп-... әп... [Байбикә:] Әп, әпчи, әп-әп-әпчи, әпчииии!..* Д.Аппакова

**ӘПЧИ́ КАРЧЫК (КАРЧЫГЫ)** *и.* 1) Мәҗүсилек динендә: йола үтәүче рухани карчык

2) Имче, им-томчы. *Сугыш башланган көннән күрәзәләр, багучылар, әпчи карчыклар, ногыт борчаклары күбәеп китте.* А.Гыйләҗев. *Әпчи карчык сиңа ни төреп биргән булса, син шуны Болакка чыгарып ташладың.* Р.Батулла

3) Биләмче; кирәгеннән артык күп сөйләшүче хатын-кыз. *Әнинең малтуар карарга чыгып киткәнен генә көтеп торам да, әпчи карчык шикелле, колак төпләрендә авыл борчуларын сөйләргә тотынам.* Рифә Рахман

4) Яучы, димче. --- *ошаган егет очрамый икән, нишлим – уйнарга кала, Лилия. – Уен – һәрвакыт уен. Ахыры яхшылык белән бетми, Гөлнара. – Әпчи карчык син, Лилия.* Т.Миңнуллин

5) *күч.* Үлем; Газраил. *Әпчи карчык алып китте*

**ӘР** *и.* 1) Ачуны китерә, хурландыра, кимсетә торган сүзләр. --- *алар [Тәлгать һәм Лотфи], туктаусыз лыгырдап, укытучылардан әр ишетә торган булып киттеләр.* Ә.Мушинский. --- *үзен изгән председательләргә әр сүзе әйтә аламы?..* А.Гыйләҗев

2) Моң-зар, хәсрәт; шелтә. *Хатын-кыз, тукран шикелле, ирләр башына үз әрен тукып тормаса, миләре кортлый ич аларның.* Ә.Гаффар

3) Әрнү тойгысы (күңелдән рухи газаплар кичерү турында)

**ӘРӘМ** *с. гар.* **1.** Юкка тотылган, файдасызга киткән, кирәкмәгәнгә сарыф ителгән (мәс., *акча, мал, хезмәт һ.б.*). *Беркөнне, чәйләрен эчертеп, урамга озатып калганда, үз-үзенә: – Әрәм гомер инде! – дип офтанып куйды.* Н.Хәсәнов. *Әнинең теге чакта «әрәм гомер» дип ычкындыруы юкка гына булмаган.* Н.Хәсәнов

**2.** *хәб. функ.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса икенче бер кешегә яки әйбергә тиң, лаеклы булмавын белдерә. *Юк, утыз өч яшькәчә тормышын көйли алмаган Нәҗипкә әрәм мондый затлы мал!* А.Гыйләҗев. *[Рәйсә әбисе Сәрвиягә:] Моназыйрга абый сүзе әрәм. Барлык әйбәт сүзләр әрәм аңа!* М.Хуҗин. *«Беркөн Әхмәтҗанның хатынын күрдем, бигрәк матур икән, иренә бөтенләй әрәм икән», – ди.* Г.Камал

2) Кызганыч, җәл. *Ә йорт әрәм. Нинди буласы иде бит!* Г.Ахунов

**3.** *рәв. мәгъ. к.* **әрәмгә**. *Аһ, әрәм ычкынды, дуслар, бозҗрабыз...* Ш.Бабич. *Юк, яхшылыгында гына түгел, яхшы җирләр күп ул, төп хикмәт – шундый җирләрнең әрәм ятуында.* М.Әмир. *Мостафага кол булып, гомереңне әрәм үткәрерсең.* Г.Коләхмәтов

**ӘРӘМӘ** *и.* Гадәттә елга буйларында, дымлы уйсу җирләрдә вак агачлар һәм куаклар күп үскән урын; ешлык. *Шул киңлектә, әрәмәләр, урманнар, болыннар, кырлар белән бергә, Сарсаз, Иске Чурай элеккечә бөтен, шаулы хәлендә кайтты.* Ә.Баянов. *Мизхәт, җил-җил атлап, авылны чыкты, Ык яры буйлап, әрәмәгә таба борылды.* Ф.Садриев

**ӘРӘМӘЛЕК** *и. к.* **әрәмә.** *Безнең авыл тирәсендәге болыннар, әрәмәлекләр сагынып сөйләргә генә калды.* М.Маликова. *Безнең йортларыбыз – әрәмәлек башында, кара-каршы.* М.Хуҗин. *Ир-атлар агымның өске өлешенә, елга уратма ясап аккан урынга, хатын-кызлар исә куе әрәмәлек каплаган култык артына, сары комлы кашлак ягына китеп бардылар.* М.Хәсәнов

**ӘРӘ́М БУЛУ** *ф.* 1) Файдасызга тотылу, юкка-барга сарыф ителү

2) Тиешенчә файдаланылмыйча, нәтиҗәсез юкка чыгу. *Безнең үзара әңгәмәләребез нефтькә ияреп чыккан газның бушка янып әрәм булуы турында бара иде.* Г.Тавлин. *Ничә еллар тырышып укыган гыйлем әрәм булмасын иде.* М.Гафури. *[Мотаһир] Шундаен галим кешеләрнең монда әрәм булып ятуларына офтана.* Р.Кәрами

3) Вакытсыз вафат булу. *Алты гына яшьтә иде, мескен, әрәм булды балам – Саматым.* М.Җәлил. *Күпме гаепсез җаннар әрәм булды?!* Р.Кәрами. *Нинди егет әрәм булды.* Р.Сибат

4) Мал-туар кырылып, үлеп яки азык-төлек бозылып зыян килү. *Яңгыр бит... Иген әрәм булачак.* Г.Гыйльман. *Эленке-салынкы эшләргә өйрәнгән колхозларның ярты печәне череп-мурып әрәм булды.* Г.Ахунов

5) *күч.* Үз урынын таба алмау, эзсез югалу. *[Дәүләтгәрәй абзый Габделхәйгә:] Әдәм булгач әрәм булмассың, Алла боерса.* Н.Фәттах. *Борчылма, әнием, мин дөньяда әрәм булмадым.* Н.Дәүли. *[Мөбин абый:] «Укы, энем! Укысаң, әрәм булмассың», – дип хуплап тора иде.* В.Нуруллин

6) *күч.* Тиешсез, кирәкмәгән, тиң булмаган кешегә туры килү

**ӘРӘМГӘ** *рәв.* Юкка, бушка, кирәксезгә. *Әрәмгә кан түктек без.* Г.Ибраһимов. *Ә менә бу дөньяда күпме җан әрәмгә чыкты, күпме корбан бирдек без бу дөньяда?* Н.Дәүли. *Әгәр хисләр уртак булмаса, мәхәббәтнең бер кадере дә юк. Әрәм яну, әрәм өзгәләнү, йөрәкнең әрәмгә телгәләнүе.* М.Маликова. *Ләкин әрәмгә узачак бу гомер турында ул кайгырмый.* Уртак түшәк

**ӘРӘ́М(ГӘ́) КАЛУ** *ф. к.* **әрәм булу** (*2 мәгъ.*). *Уйлаштык-уйлаштык та кинәт кенә югга җыендык шулай. Быелның ялы барыбер әрәмгә кала иде.* Н.Акмалов

**ӘРӘ́М(ГӘ́) КИТҮ** *ф.* 1) *к.* **әрәм булу** (*1–2, 6 мәгъ.*). *Биреп караган идек тә, халыкның акчасы гына әрәмгә китте.* И.Гази. *Берәү, өзелгән аягымның итегендә 21 сум акчам бар иде, шул әрәм китте, дип хафалана.* Г.Ибраһимов. *Әле тик, шундый уңган кызың әллә кемнәргә әрәм китмәсен, дигән идем.* Р.Ишморат

2) *к.* **әрәм булу** (*3 мәгъ.*). *Сызланды күпме йөрәкләр: – Әрәм китә, – дип, –*

*Сабир!* Ә.Исхак. – *Бик боевой егет булгандыр бу, әрәм киткән, терелсә ярар иде мескен, – дип, моны чын күңелдән кызганып куйды.* М.Гали

**ӘРӘ́М(ГӘ́) УЗУ** *ф.* Вакытның, гомернең нәтиҗәсез артта калуы, бетүе. *Бу бер сәгатьне без бик әрәм уза торган вакыт итеп санадык.* А.Шамов

**ӘРӘ́М(ГӘ́) ҮТҮ** *ф. к.* **әрәм(гә) узу.** *Минем яшьлегем әнә шул син әйткән киләчәктәге бәхетне көтеп үтте түгелме соң инде?! Әрәм үтте.* Н.Акмалов

**ӘРӘ́М ИТҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса бушка, кирәк булмаганга тоту, исраф итү, юкка-барга сарыф итү. *Минем өч ел тегермәнгә дип җыйган бүрәнәләремне кистертеп, әрәм итеп ыргыткансыз.* К.Насыйри. *Бәхәсләшеп, вакыт әрәм иткәнгә күрәме, бүтән малайлар ул юлы көпшәне күп җыя алмадылар.* Ә.Баянов. *«Әрәм итмә хисләреңне шул тәкәббергә!» – диләр икән аңа дуслары.* М.Маликова. *Тик аларга пуля әрәм итәсе килми.* В.Юныс

2) Кемне дә булса бер дә гаепсезгә, сәбәпсез юк итү, һәлак итү яки бәхетсезлеккә төшерү. *Сафа бабай килеп җитте: – Солтан балакай, – ди, – сине барыбер әрәм итәрләр... Бер минут торма, хәзер кит! – ди.* Г.Ибраһимов

**ӘРӘМТАМАК** *и.* Беркайда да эшләмичә, кемнеңдер хезмәтеннән файдаланып, кеше исәбенә яшәүче, бушка ашап ятучы кеше. *[Әсма:] Ә кайда тормыш бик җиңел, бик ансат? Тормыш итү – әрәмтамакларга һәм имгәкләргә генә җиңел!* А.Гыйләҗев. *Ул әрәмтамаклар үзләрен колониянең төп хуҗалары итеп саныйлар.* Г.Тавлин. *Эшләгән кешене Гайсә күтәрде, әрәмтамакларга, ялкауларга көн күрсәтмәде, адәм мәсхәрәсе итеп сүкте.* Ф.Садриев. *Без әрәмтамаклар тәрбиялибез, җилкуарлар.* Г.Ахунов

**ӘРӘМТАМАКЛЫК** *и.* Әрәмтамак булу. *Рухи әрәмтамаклык милләтнең телен дә, рухын да саектыра һәм бетерүгә китерә.* Н.Сафина

**ӘРӘ́М-ШӘРӘМ** *и.* Акчаны, малны кирәксезгә таратып, туздырып юкка чыгару, урынсыз сарыф итү күренеше. *Исәпкә алынган малны уттан, талаудан, әрәм-шәрәмнән саклау өчен чаралар күрелде.* И.Гази

**ӘРӘ́М-ШӘРӘМ БУЛУ** *ф.* 1) Юкка чыгу, әрәм булу. *[Әнисе:] Таралмыйча, әрәм-шәрәм булмыйча, исән-имин үсеп җитегез.* Н.Фәттах

2) Максатсыз яки файдасыз тотылу. *Узган ел иген эшләре бик соңга калып, ашлыкның байтак өлеше әрәм-шәрәм булуга карамастан, партия оешмасы фронтовик гаиләләренә ярдәм фонды оештырган иде.* Г.Бәширов

**ӘРӘ́М-ШӘРӘМ ИТҮ** *ф.* Нәрсәне дә булса урынлы файдаланмау, максатсыз тоту, нәтиҗәсез, кирәксез таратып бетерү. *Бүген мин [Хәлил абый] ипине әрәм-шәрәм итү турында бик ачынып, яньп-көеп сөйләгәндә дә, аннары, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсенә күчеп, шул турыда фикер йөрткәндә дә: «Шөкер, сәламәтлеге яхшыра икән», – диеп, куанып утырдым.* А.Шамов. *[Хасият:] Мин уңышны әрәм-шәрәм итүгә юл куя алмыйм.* М.Маликова. *Без, илнең гасырлар буе тупланган малын-байлыгын әрәм-шәрәм итеп, бер мәртәбә нык ялгыштык бит инде.* Казан утлары

**ӘРӘ́М ЯТУ** *ф.* Нинди дә булса әйбер тиешенчә яки гомумән файдаланылмау. *Ул әйтә, шәһәрләрдә дә бер генә карыш җир дә әрәм ятмаска тиеш, газоннарга арыш чәчәргә кирәк, ә скверларда алмагачлар, чияләр үстерергә күптән вакыт, ди.* М.Маликова. *Их-хи-хи-хи, убыр кулында никадәр мал әрәм ята бит?!* К.Тинчурин. *Беләсезме сез, безнең Агыйдел буенда никадәр җимеш, никадәр яшелчә бирерлек җирләр әрәм ята?* М.Әмир. *Әрәм ята батырлыгым – Уйланам шул хакта гына.* Р.Миңнуллин

**ӘРӘТӘ** *и.* 1) Умарта эчендә кәрәз җимерелеп төшмәсен өчен куела торган аркылы агач

2) Тарантаста: арт күчәрдән ал күчәрнең терәгенә (мендәренә) тоташтырылган, колга шикелле агач

3) Бүлмәнең түшәмгә якын урыныннан аркылыга сузылган тимер яки агач; балка. *[Байназар:] Иң элек ике сүс арканны корыч боҗра ярдәмендә матчага беркетте, аннан соң бакның кырындагы уемнарына кертеп, арканнарны түшәмдәге тимер әрәтә аша үткәрде, очларын, ныклап, тәрәзә янындагы баганага бәйләп куйды.* М.Әмирҗанов

**ӘРБӘ** *и.* Ашлык сукканда, көшел өстенә җыелып барган башаклар, салам кисәкләре; суктырылган көлтә (терлек азыгына кушып бирелә). *Каядыр бер икенче өяздә «әрбә» «башак» мәгънәсендә истигъмаль кылына икән. Хәлбуки Тәтеш өязендә «әрбә» дигән сүз бөтенләй юк, бәлки «әрбәлек» дигән сүз генә бар.* Җ.Вәлиди

**ӘРБӘЛЕК** *и.* Ындырның бер почмагында яки лапас астында әрбә саклана торган урын, әрбә салынган өсәк, бүлем. *Сафа тиз генә кулындагы иләген куйды һәм, нindидер эчке көчкә буйсынып, үзе дә сизмәстән, әрбәлеккә барып керде.* А.Шамов

**ӘРВАХ** *и. гар. дини* 1) Мәрхүм кешенең рухы. *Намаздан соң, ул әтиәнисенең, әби-бабаларының, вафат булган карт хатыны белән сабый чагында бәхилләшкән кызчыгының әрвахлары рухына – һәркайсына бирәр генә аять булса да укып багышларга онытмый.* К.Миңлебаев. *Төн уртасы. Зират тып-тын. Әрвахлар да йоклый күптән.* Ф.Яруллин. *Инде әрвах үзен хурлаганнарын ишетсә, үзенә начар сүз әйтүчене каргап әрләр, ди.* Р.Сибат. *[Сәетморат] Теле озынайган аксакалларның янә берсен акылга утырткан, иманга килмәгән яшь әтәчләрне исә әрвахлары янына озаткан!* Т.Әйди

2) Өрәк. *Бөтен дөньяны тар итеп йөргән бәндәләр дә --- үз туфрагына кайта. Кайтмаса, ул җирне тапмаса, догасыз ач әрвахка әверелеп, тузан бөртекләренең берсе булып, өермәләр эчендә мәңге себерелеп йөрер.* Ә.Баянов

◊ **Әрвахлар шат булсын** Мәрхүмнәрне искә алып, аларның рухына багышлап кылган гамәлләр (укыткан догалар, бирелгән сәдакалар һ.б.) кабул булсын, мәгънәсендә әйтелә

**ӘРГӘН** *и. гр.* 1) Клавишлар һ.б. җайланмалар ярдәмендә төрле зурлыктагы торбалардан һава өрдереп торган, катлаулы тынлы музыкаль инструмент

2) *тар.* Тоткасын әйләндереп уйный торган, автоматлаштырылган төрле музыка коралларының гомуми атамасы

3) *иск. сөйл.* Гармун. *Зур тальян гармунын ул «әргән» дип йөртте.* У.Альмеев. *[Әтисе:] – Урам буенча әргән тартып, авыз күтәреп җырлап йөргән малайдан җүнле кристиән чыкмый тек чыкмый, – дип кистереп әйтте.* Ф.Сафин

**ӘРГӘНЧЕ** *и. тар.* Әргән (*1, 3 мәгъ.*) уйнаучы. *Атаклы әргәнче Гани Җәмлихан, авылларда гастрольләрдә йөргәндә, гел бер кешеләргә фатирга төшә торган булган.* Р.Батулла

**ӘРДӘНӘ** *и.* 1) *иск.* Запас, запаслар

2) Кисеп, ярып, кышка әзерләнгән, тигез итеп, берсе өстенә берсен куеп өелгән утын өеме. *Алпамша, бәтиен җуйганнан соң, берара боегып йөрде. Утын әрдәнәсенә дә ышкынмый, ярдан-ярга да сикереп уйнамый, койма башына да үрелми, башын иеп, бер урында тик басып тора.* М.Галиев. *Чаңгылар, тимер таяклары-ние белән бергә, утын әрдәнәсенә сөяп куелган иде.* Р.Низамиев. *Ул ишекне тибеп кенә ачты да өй янындагы әрдәнәдән бер кочак утын алып керде.* Р.Сибат

3) Берәр нәрсәнең тигез итеп өелгән рәте (мәс., *бүрәнә, төзү материаллары һ.б.*). *Әле кичә генә барысы да ал да гөл, җырлап баргандай күренә, ә бүген бура ишелә дә төшә. Сипләнмәгән, балта тимәгән әрдәнә, диярсең.* Т.Галиуллин

◊ **Әрдәнәсе җимерелү** Бик каты итеп кикереп кую

**ӘРДӘНӘ́-ӘРДӘНӘ** *с.* Бик күп, берничә әрдәнәгә өелгән. *Алдагы көндә ук, анда әрдәнә-әрдәнә бүрәнә белән такта, берничә зур тимер казан, таутау чылбырлар һәм үткен ыргаклар ташып куйдылар.* С.Горский. *Генерал, һич югында, әфисәр йә су капитаны булсаң иде хет. Синдәй матрослар, ефрейторлар аның ишек төбендә әрдәнәәрдәнә өелеп яталар. Берсенә дә карамый.* Т.Галиуллин

**ӘРДӘНӘЛӘ́Ү** *ф.* Нәрсәне дә булса, тигез итеп, берсе өстенә берсен кую. *Тәлгать җәй көне утын китерде, аны дуслары белән кисеп ташлады, ярып, әрдәнәләп өеп куйды.* Ә.Мушинский. *Лапаста әрдәнәләп өелгән утынны «Дружба» пычкысы белән ул [Таһир Айтуганов] кисте.* Г.Ахунов. *Әрдәнәләп өелгән он капчыклары күренеп тора.* И.Гази

**Әрдәнәләп бару** Артыннан ук, бер үк вакытта әрдәнәләү, һәрберсен әрдәнәләү

**Әрдәнәләп бетерү** Әрдәнәләү эшен төгәлләү

**Әрдәнәләп кую** Әрдәнәләнгән хәлгә китереп калдыру. *Моның уңайсызлыклары аңлашыла, мәгәр шул ягы әйбәт – «әрдәнәләп куярга» эшләмибез, ягъни һәр китап ихтыяҗны исәпкә алып кына планлаштырыла.* М.Вәлиев

**Әрдәнәләп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта әрдәнәләү

2) Һәрберсен, булган берсен әрдәнәләү

**Әрдәнәләп чыгу** Ахырына кадәр, барысын да әрдәнәләү

**ӘРДӘНӘЛЕК** *и.* **1.** Әрдәнәләп, утын өелгән урын. *Госман, юк эшен бар итеп, лапастагы әрдәнәлеккә керде.* Р.Низамиев

**2.** *с. мәгъ.* Утынга яраклы

**ӘРЕ** *и.* 1) *диал.* Бал корты

2) *зоол.* Кыргый бал кортының бер төре. *Әре балы әр (һәр) чирдән дәва.* Мәкаль

**ӘРЕКМӘН** *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, киң итләч яфраклы һәм ябышкак чәнечкеле орлык тартмасы булган икееллык үсемлек; *русчасы*: **репейник, лопух**. *Чокыр эче котырып үскән әрекмән, ат кузгалагы, шайтан таягы, кычыткан, билчән шикелле эре сабаклы, күләгәле үләннәр белән капланган.* Г.Тавлин. *Тик, ни булса була, мунча саласы урында, җәй саен, котырып, әрекмән үсә.* Г.Бәширов

◊ **Әрекмән боламыгы** *тирг.* Оешмаган, булдыксыз. **Әрекмән колак** 1) Зур һәм кайтарылып торган колак яфрагы. *Әрекмән колак – хыялый, шундый чакта нәрсә дә булса уйлап чыгара.* Н.Хәсәнов. *Әрекмән колаклы ап-ак эт малае шартлатып җаваап бирә: өч тапкыр өреп куя, ягъни «өч» ди.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш; 2) Кеше сүзен читтән тыңлап торучы; кирәк булса-булмаса да, кешеләрнең сөйләшкәнен тыңлап йөрергә яратучы. *Бу сүзеңне, миңа түгел, әрекмән колакларга сөйлә.* Н.Акмалов. **Әрекмән шулпасы эчү** Төрле мохтаҗлыклар кичерү, авырлыклар күрү, кыенлыклар кичерү. *[Алчын:] Әрекмән шулпасы эчмәгәнсең икән әле, егет.* Н.Исәнбәт

**ӘРЕКМӘНЛЕК** *и.* Әрекмән күп үскән урын. *Әрекмәнлек эчендә: «Килегез әле, килегез, мин сезне!» – дигән сыман, сугышчан кыяфәт белән, башын күтәреп, зур чуар тавык утыра иде.* Ә.Фәйзи

**ӘРЕМ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, бик көчле әчкелтем исле ярымкуак үсемлек (медицинада дару буларак кулланыла); *русчасы*: **полынь**. *Давыт үлән арасыннан көмешсу әрем баш төрткән турга килеп басты.* М.Галиев. *Ул утка сентябрьнең өлгергән әремен сындыргалап салсаң, шул вакытта Чөн аръягыннан – башкорт ягыннан – зур кызыл табак булып ай да күтәрелсә, күлләр дөньясында сихри тормыш башлана.* М.Мәһдиев

◊ **Әремгә таянып калу** Алдану, ялгышу. *Әйдә, җаным, сәхрәләргә, Таянырсың әремгә, Таянырсың да калырсың, Мин булмамын яренгә.* Җыр. **Әрем тел** Чәнчеп, зәһәрле сүзләр әйтеп сөйләшүче, усал телле кеше. *[Апасы Сәвиләгә:] Әрем телне әрем юа, димени, кит!* Н.Гыйматдинова. *Сәкинә Сәйфигә күп сөйләшергә ирек бирмәгән, үзенең «әрем тел Сәкинә» дигән исеменә тугрылыклы булып, кыдрачланып килгән Сәйфине бер җөмлә белән адәм хурлыгына калдырган икән.* Ф.Сафин

**ӘРЕМЛЕК** *и.* Әрем күп үскән урын. *Тирә-юньдә төзелеш бара, биек краннар – хәрәкәттә, янәшәдә – кара әремлек.* Безнең гәҗит

**ӘРЕ́М-БИЛЧӘН** *җый. и.* Әрем һәм билчән кебек төрле чүп үләннәре. *Сөрелмәгән, чәчелмәгән җир, хуҗасыз байтак ятты-ятты да, куе үлән, әрем-билчән белән капланды.* А.Гыйләҗев

**ӘРЕ́М ГӨЛЕ** *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, яфрагы һәм исе белән әремгә охшаган чәчәк; *русчасы*: **хризантема**

**ӘРЕП** *и. гар.* Җәнҗал, ызгыш-талаш

**ӘРЕПЛӘШҮ** *ф.* 1) Тарткалашу, сүз көрәштерү, каршы сүз әйтү. *[Укытучы:] Шулай тел озайтасың, әрепләшәсең, мине өйрәтәсеңме әле син?*

Г.Тавлин. *Үзеңнән түбәннәр белән әрепләшү, хәтта бәхәсләшү дәрәҗәсенә төшәргә һич тә ярамый иде аныңча, чөнки бу хәл ике якның тигезлегенә ишарә булыр иде.* М.Хуҗин

2) Тарткалашып, бер-берсенә йодрык белән бәргәләшү, сугышу. *Егет белән әрепләшкәнне нәкъ менә алар күрде дә инде!* Г.Гыйльман

**Әрепләшә башлау** Әрепләшергә тотыну. *Касыйм, ни әйтсәм дә тыңлап кына утыра ул, сүз дәшми, ди. Дөрес эшли. Хатын-кыз белән әрепләшә башласаң... Хатын-кызны, әрепләшеп кенә түгел, кыйнап та җиңеп булмый аны.* Т.Миңнуллин

**Әрепләшеп алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә әрепләшү. *Әгәр чит-ят кеше күреп тормаса, кызлар шактый бәйсез кыланалар, үзләрен үчекләп маташкан егет аламалары белән әрепләшеп алырга да күп сорамыйлар.* Ф.Сафин

**Әрепләшеп бетү** Әрепләшү дәрәҗәсенә җиту, бик нык әрепләшү. *Кызык артыннан куасыз, баланың язмышы турында уйларга кирәк. Әле туганына кайчан – сез инде ничә мәртәбә, пыран-заран килеп, әрепләшеп беттегез.* К.Тимбикова

**Әрепләшеп йөрү** Озак вакыт дәвамында, төрле урыннарда, һәрберсе белән әрепләшү. *Ире соң дәрәҗәдә юаш һәм тыйнак булып, хатынының чәрелдәвек тавыш белән әрепләшеп йөргәне хәтердә.* К.Миңлебаев

**Әрепләшеп китү** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт әрепләшә башлау. *Без тагын әрепләшеп китәргә әзер идек, шулвакыт, үзенең «бобигы» белән, әти килеп төште.* Ф.Яруллин. *Тормыш булгач, гел үбешеп, сөешеп кенә дә яшәп булмый, һич уйламаганда, хатының белән әрепләшеп китүең дә мөмкин.* С.Поварисов

**Әрепләшеп тору** 1) Һәрвакыт, гел, бертуктаусыз әрепләшү

2) Әле, хәзер, күз алдында әрепләшү *Шулай әрепләшеп торганда, әлеге кешеләрнең берсе, куеныннан телефон чыгарып, кем беләндер сөйләшеп алды.* З.Фәйзуллин

**Әрепләшеп чыгу** Берсен дә калдырмыйча, һәрберсе белән дә әрепләшү. *«Ялгызаклар» арасында талашып, әрепләшеп чыкмаган бер кешесе дә калмады диярлек.* В.Имамов

**Әрепләшеп яту** Әле, сөйләү мизгелендә әрепләшү. *Карасана, бу мөгаллим кисәге үзенә күрә түгел, әрепләшеп яткан була бит!* Г.Бәширов

**ӘРҖӘ** *и. фар.* 1) Нәрсәне дә булса урнаштыру, саклау яки бер урыннан икенче урынга күчереп йөртү өчен, агачтан, каен тузыннан, кайрыдан яки йомычкалардан һ.б.ш.лардан ясалган дүртпочмаклы, өсте ябулы яки ябусыз тартма; кызау. *Ирләр китәргә ярты сәгать кала, һәр вагон эченә бәйләме чишелмәгән шинельләр ыргыттылар, икешәр әрҗә консерва куйдылар.* З.Зәйнуллин. *Кәҗә, минем кулны каерып, он әрҗәсенә тагын борынын төртеп ала.* М.Галиев. *Җиләк-җимеш һәм яшелчә матур, җыйнак әрҗәләрдә тышка тезеп куелган.* И.Нуруллин. *Осталар ашыкмый гына җиргә төште, балта, чүкеч, кадак ише нәрсәләр тутырган әрҗәне куеп, өсләренә ябышкан йомычка, пычкы чүбен каккаладылар.* Ф.Латыйфи

2) Йөк автомобиле, чана һ.б.ш.ның арбасы; кузов. *[Рәмзи] Безне күрүе булды, уңга борыласы урынга, сулга каерып, капка төбенә килеп тә туктады, без күтәрә башлаган агачны, уртасыннан эләктереп, машина әрҗәсенә дә очырды.* Ф.Садриев. *Урам якта машина гүләп килеп туктаганы ишетелде, олы капка каерылып ачылып, әрҗәсенә берничә озын торба салган «КамАЗ» әкрен генә керә башлады.* М.Маликова

3) Нәрсәне дә булса рамлау өчен, дүртпочмаклы, озынча түгәрәкле яки башка формада булган кыса. *Дивардагы рәсемнәрне әрҗә белән кыршаулаганнар.* Р.Батулла

4) *күч. сөйл.* Телевизор. *Ә бермәлне түргә, иң дәрәҗәле урынга, шкаф чаклы әрҗә – «телевизор» дигән әкәмәт менеп кунаклады, минсиңайтим!* Ә.Баянов. *Байназар – телевизорга мөкиббән киткән бер бәндә, – буш вакыты чыктымы, шул әрҗәгә каплана.* М.Әмирханов

◊ **Әрҗә тегү** Каты гырылдап йоклау

**ӘРҖӘ́-ӘРҖӘ** *с.* Күп сандагы әрҗәләргә тутырылган. *[Бу аланлыкта] Әрҗә-әрҗә граната, санап бетергесез винтовка һәм карабиннар.* Ә.Галиев

**Ә́Р-ҖӘБЕР** *җый. и. к.* **әр** (*1 мәгъ.*). *Теге чакта, гает көннәрендә яшьләр кичәсе үткәреп йөргәне өчен, мәчет картларыннан әр-җәбер сүзләре ишетеп, җаны аз бәргәләнмәде.* Ф.Сафин

**ӘРҖӘЛЕ** *с.* Әрҗәсе булган, әрҗә куелган. *Солдатка китүче егетләр төялгән әрҗәле машина инде кузгалып маташа иде.* З.Хөснияр. *Бу көтелмәгән хәлдән Камалиның аты дулап, әрҗәле чанасын әйләнә-тирәдәгеләргә бәрдертә-бәрдертә, Печән базарына сөйрәтеп китте.* К.Нәҗми

**ӘРҖӘЛЕК** *с.* Әрҗә ясарга яраклы, әрҗә ясарга җитәрлек

**Ә́Р КҮРҮ** *ф.* Әрләүгә, хурлауга дучар булу

**ӘРЛӘН** *и. зоол.* 1) Кимерүчеләр отрядыннан, бөртекле үсемлекләр белән тукланып (шул рәвешле иген культураларына зыян китереп), җиргә өн казып яши торган җәнлек. *Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, пошы.* Г.Тукай. *Укытучы әйтүгә, балаларның күбесе, башак өеменнән утыз-кырык адым читтә бер әрлән күреп, шаулаша башладылар.* Г.Гобәй. *Еракта ялгыз җайдак шәүләсе күренеп кала, әллә кайда гына әрлән сызгыруы ишетелгән кебек була...* Ә.Еники

2) *күч. ирон.* Югары урында эшләүче һәм, урыныннан файдаланып, үзенә мал-мөлкәт туплап яшәүче кеше. *Ах, бик тә вакытсыз килеп төште бу Мәскәү әрләннәре!* А.Гыйләҗев // Гомумән үзен генә кайгыртып яшәүче кеше. *Хәзерге заман кешесе кәҗә түгел, аны бүре белән генә куркытып булмый! Хәзер әрләннәр заманы.* М.Маликова

**ӘРЛӘ́Н БАЛЧЫГЫ** *и. а. х. к.* **әрлән туфрак**. – *Трактор җирнең әрлән балчыгын чыгарып сөрә, – диде яшь бабай.* Н.Фәттах. *Ялгандырмы, чындырмы, алар каз-үрдәкне, тотып, каурыйлары-ние белән әрлән балчыкка төрәләр дә утка ыргыталар, имеш.* К.Кәримов

**ӘРЛӘ́Н ТУФРАК** *и. а. х.* Сөргәндә яки казыганда, җирнең аскы катламыннан

чыккан ярмалы, эре бөртекле кызыл туфрак

**ӘРЛӘНҮ** *ф.* Хурлану, оят санау; гарьләнү. *Мәдинә, елап җибәрүдән әрләнеп, сбордан чыгып йөгерде.* Ш.Хөсәенов. *Үзенең көчсезлегеннән, хатын-кыз башы белән ире кулына җәфа булып калуыннан әрләнеп яшь сыга карчыгы.* А.Вергазов

**Әрләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта әрләнү. *Әрлеләр әрләнеп торганчы, әрсезләр ашап туя.* Мәкаль

**ӘРЛӘ́Ү** *ф.* Берәр кешене яки нәрсәне дә булса ачулану; кешенең күңелен үпкәләтә, рәнҗетә торган сүзләр әйтү, хурлау. *Еларга җитешеп, артист профессиясен әрлим.* Р.Батулла. *Абыйның әрләвеннән оялып, башымны идем.* С.Хафизов

**Әрләп алу** Аз вакыт эчендә, бераз әрләү. *Таныш булмаган инсани затка сәгатьләр буена текәлеп карап утырмыйлар, дип, эченнән тегене әрләп алып, профессор юантык ханымга игътибар беләнрәк карады.* Т.Галиуллин

**Әрләп бетерү** Бик нык әрләү. *Әни әрләп тә бетерә үземне.* Ф.Шәфигуллин

**Әрләп калу** Әрләргә өлгерү. *Колхоз рәисенең кәнәфие ике сайлау арасына гына түзә, әрләп кал.* К.Кәримов

**Әрләп карау** Ачуланып, әрләндерергә омтылу. --- *эшче куллар кайда да кадерле чакта, тегермәндә бурсаеп ятудан ни ямь табасың, дип, еш кына үпкәләп, әрләп тә карады.* А.Гыйләҗев

**Әрләп китү** Ниндидер вакыттан, сәбәптән соң әрләргә тотыну

**Әрләп кую** Кинәт, аз гына әрләү. *[Муса:] «Моннан соң мин сезне тегермән буасына алып бармыйм!» – дип әрләп куйды.* Р.Мостафин

**Әрләп ташлау** Кинәт, көтмәстән, үтемле итеп әрләү. *Үзенә бүләк юллап йөрүемне белгәч, Габделнур мине әрләп ташлады.* М.Хуҗин. *Әбелхарисны да бик каты әрләп ташлады.* К.Насыйри. *Гаяз юл буе шулай тегеләр белән күңеленнән бәхәсләшеп кайтты. Хатынга әйтергәме, юкмы? Әйтсә, Миңзифа үзен әрләп ташламасмы?* И.Гази

**Әрләп тору** 1) Гел, һәрвакыт әрләү. *Үги әни гел әрләп торды, бала гына көемә бабайга тоттырып җибәрде...* Г.Якупова. *Якыннарны төрткәләп һәм әрләп торуы читен.* Г.Афзал

2) Әле, хәзерге вакытта әрләү. *Секретарь кыз боерык арты боерык ташый; Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый. Замначальник тәрәзәдән карап тора, Ялкаулар, дип әрләп тора, янап тора.* Г.Афзал

**Әрли башлау** Әрләргә тотыну

**Әрли төшү** Тагын да ныграк әрләү

**ӘРЛӘШ** *и.* Үзара тиргәш, кычкырыш, талаш

**ӘРЛӘШҮ** *ф.* Бер-береңне тиргәү; талашу, кычкырышу. *Кыз Сәкинә апасы белән әрләшмәде, моның көчсезлек билгесе икәнен аңлый иде.* Н.Гыйматдинова. *Үзе әрләшкән була.* Г.Сабитов. *Аның артыннан, кызарынып, бүртенеп, букча таккан бүрексез малай әрләшә-әрләшә чыгып йөгерде.* Ә.Фәйзи

**Әрләшә башлау** Әрләшергә тотыну. *Ә безнең хатыннар ирләре белән әрләшә башласамы?.. Татар алфавитының 39 хәрефе дә җитми...* К.Кәримов

**Әрләшә бирү** Һаман, бертуктамыйча, бернәрсәгә карамастан әрләшүне дәвам итү. *Һаман да ире белән әрләшә бирде.* Г.Ибраһимов

**Әрләшеп алу** Кыска вакыт эчендә, бераз әрләшү

**Әрләшеп йөрү** Озак вакыт дәвамында, төрле урыннарда, берөзлексез әрләшү

**Әрләшеп китү** Кинәт, көтмәгәндә, уйламаганда әрләшә башлау. *[Олы килен] Кычкырып, кул болгап әрләшеп китте.* Г.Ибраһимов

**Әрләшеп чыгу** Һәрберсе белән дә әрләшү

**Әрләшеп яту** Әле, хәзерге вакытта әрләшү. *[Хуҗа:] Бөтен халык эшли. Болар монда эшсезлектән әрләшеп яталармы?* Н.Исәнбәт

**ӘРЛЕ** *с.* 1) Үпкәчел, гарьләнүчән; горур, тәкәббер. *Ярлы башым – әрле башым.* Әйтем. *Әрленең йөрәге әрем.* Әйтем

2) Оялчан, кыюсыз. *Әрле әрләнгәнче, әрсез ашап туйган.* Әйтем

**ӘРЛЕ́-БИРЛЕ** *рәв.* 1) Әүвәл бер юнәлештә, аннан шул юнәлешкә каршы (хәрәкәт итү турында). *Корычбай, күн перчаткалы кулын билендәге пистолет сабына салып, рәт алдыннан әрле-бирле йөренгән була.* М.Галиев. *Бераз вакыт, асылынган килеш, аякларын әрле-бирле селкетеп, җиргә төште.* Ш.Камал. *Анда асраулар әрле-бирле әйбер чыгарып йөриләр иде.* Г.Исхакый. *Ялгыз паровозлар әрле-бирле чабышып, манёвр ясап йөриләр.* Г.Гобәй

2) Әле монда, әле тегендә; тегеннән монда, моннан тегендә. – *Больницадан баш врач квартирына җибәрделәр. Анысын алып килгән идек, теге, хатыннарны карый торган кенәз Юсуповны алып килергә кушты. Әрле-бирле чаптык шунда, – дип аңлатты Гариф.* М.Маликова. *Дамба өстендә әрле-бирле куышкан эт көтүенә оятсыз сүзләр кычкырып, җан иясе күренмәгәч, кыеклап, олы юлга чыктылар.* К.Нәҗми

3) Әле бер якка, әле икенче якка. *Газетаны әрле-бирле әйләндерә башладым.* Ш.Камал. *Бәдрикамал карчык, уйларыннан арынып, эчкә баткан күзләрен әрле-бирле йөртүче Хәбибкә төбәде.* Р.Гыйззәтуллин

4) Аннан-моннан, өстән-өстән генә, җиңелчә. *[Мәдинә:] Баланы мәктәпкә озатып, өйне әрле-бирле генә җыештырган идем.* Ш.Камал

◊ **Әрле-бирле сугылу (сугылып йөрү)** Эшсезлектән, берәр төрле күңелсез хәлдән, нәрсәгә дә булса борчылудан, күңел төшенкелегеннән һ.б.ш. сәбәпләрдән, эч пошып, нишләргә белмичә аптырап йөрү. *Әрле-бирле сугылып йөри торгач, Сафаның авыруы да узып китмәсме?* Ю.Әминов

**ӘРМӘК** *и.* Калын, тупас тукымадан тегелгән җылы өс киеме; чикмән. *Аның өстендә – бөрмәле сатин әрмәк, билендә – киң каеш.* Г.Гобәй

**ӘРМӘН** *и.* Телләре һинд-европа телләренең аерым бер тармагын барлыкка китергән, Әрмәнстанда яшәүче төп халык (үзатамалары – *хай*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Шунда бер егет яклап чыкты. Әрмән егете Гурген Атаян.* Җ.Тәрҗеманов. *Без хезмәт итәргә тиешле часть шәһәрдән бераз читтәрәк, әрмән зираты янындагы хәрби шәһәрчектә иде.* Ә.Галиев. *[Саркис:] – Мин сиңа әрмән табышмагы әйтәм, шуны чишсәң, тулы акыллы*

*кеше санала аласың, – диде миңа.* Г.Тавлин

**ӘРМӘ́НЧӘ** *рәв.* **1.** Әрмән телендә. *Хатны әрмәнчә язу*

**2.** *с. мәгъ.* Әрмән телендә булган, әрмәннәргә караган. *Атлаган саен – әрмәнчә язылган кибет.* В.Юныс

**ӘРНЕТКЕЧ** *с.* 1) Ачытып авырттыра, сызлый торган. *Әрнеткеч, төзәлмәс авырудан, иле, тәхете язмышы хәсрәтеннән интеккән Мөхәммәт Әмин хан, тагын берәр ел яшәп, бар планнары җимерелгәнне сизеп, 1518 елның декабрендә вафат була.* М.Гайнетдинов

2) *күч.* Күңелне әрнетеп торган, тирән газаплы борчуга салган. *Дәуран би кызы белән ярәштерелгән яшь морзаның күз яшьле, маҗаралы, газаплы һәм әрнеткеч мәхәббәт кыйссасы ишетәсе килә иде.* Ф.Латыйфи. *Габдулла җизнәсенең соңгы битәрләүләрен инде оныткан, тик аннан элекке «атаңа нәләт!» дигән сүзе генә, һаман, аның кечкенә йөрәгендә әрнеткеч төер булып тора иде.* Ә.Фәйзи. *Аннары – китап тышлыгындагы әрнеткеч язу: «Язмышның корбаны буласым килми».* А.Вергазов

**ӘРНЕТҮ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса берәр әгъзаны яки тән җәрәхәтен ачытып авырттыру, сызлату

2) *күч.* Рухи газаплау, күңелне борчу. *Кайчагында, ул тойгы акрынлык белән көчәя, куера, аның йөрәген бик нечкә сызландырып суыра, күңелнең үзәген нык кына әрнетеп кимерә башлый.* Ш.Камал. *Юк, хәзергә ярамый әле, ул районга аяк басып, йөрәгемдәге иске яраларны әрнетү.* Г.Тавлин. *Шулай да күзләрен әлеге зәһәрле сорау һаман әрнетә иде.* Ә.Баянов. *Бу борчылу, Кырлайны, Казанны сагыну тойгылары белән кушылып, Габдулланың күңелен әзме әрнетте?* Ә.Фәйзи

**Әрнетә башлау** Әрнетергә тотыну. *Якынайган саен ныграк сизелә барган салкынча һава агымы, манма тиргә баткан тәнгә рәхәтлек бирсә, терсәк һәм тез башларындагы кан укмашкан яраларны исә ачыттырып әрнетә башлады.* М.Галиев

**Әрнетә бирү** Әрнетүен дәвам итү

**Әрнетә төшү** Тагы да әрнетү; бераз әрнетү

**Әрнетеп алу** Аз гына, кыска вакыт эчендә әрнетү. *Йөрәкне югалту тойгысы әрнетеп алды.* М.Юныс

**Әрнетеп җибәрү** Кинәт әрнетергә тотыну. *Бу сүзләр Мәдинәнең күңелен әрнетеп җибәрде.* М.Хәсәнов

**Әрнетеп карау** Бик нык әрнетү

**Әрнетеп килү** Күптәннән, электән үк әрнетү

**Әрнетеп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз әрнетү. *Танклар килгәнче өлгерә алмаслар инде, дигән борчу эчен әрнетеп торды.* Х.Камалов. *Бу дата ананың йөрәген, өзеп, әрнетеп тора инде.* Х.Камалов

**Әрнетеп узу** Бераз, тиз арада әрнетү. *Үкенү хисе, ачык ярага тоз салган кебек, тагын бер кат әрнетеп узды.* Ф.Латыйфи

**ӘРНЕШ** *и.* Әрнү хисе, әрнү тойгысы. *Фатих үзен, эчтән генә: «Гап-гади бер очрашу булып чыкты бу», – дип ышандырырга бик теләсә дә, аның күңелендә тел белән аңлатып булмый торган ниндидер үзгәреш, әрнеш уянып килә иде.* Р.Низамиев

**ӘРНЕШЛЕ** *с.* Газаплы, рәнҗүле, интегүле. *Шуны аңлады: ялгызлык аңа үз-үзе белән сөйләшү, әрнешле уйларын тәртипкә китерү өчен кирәк иде.* Р.Низамиев. *Хан атының тезгенен шулкадәр гайрәт белән тартты ки, аты арт аякларына басты, авызы каерылудан, әрнешле кешнәп җибәрде.* М.Хәбибуллин

**ӘРНЕШҮ** *ф. сир.* 1) *к.* **әрнү** (*1 мәгъ.*). *Эчтән әрнешеп-әрнешеп елаган бала һәм эчке аһәңле моң белән баласын юаткан ана авазы ишетелә.* Ә.Айдар

2) *күч.* Рухи газап кичереп ачыну, пошыну. *Инде Төхфәтнең, терелеп баргада гына, болай тиз арада авырып аяктан егылуы Газизәнең күңелендә Төхфәтне әрнешеп кызгану хисләре тудырды.* Ш.Камал. *Кубрат хан әрнешеп үкенү тойды.* М.Хәбибуллин

**Әрнешеп тору** Әле, хәзерге вакытта әрнешү. *[Мәдинә:] Мин бармак һәм тезем белән әрнешеп тора идем.* Ш.Камал

**ӘРНҮ** *ф.* **1.** 1) Берәр әгъза яки тән җәрәхәте чәнчеп, кысып, сызлап яки ачытып авырту. *Ә язгы сулар белән бергә чыккан шул «чебиләр»нең әрнүенә төне буена елап чыккан малайлар.* З.Зәйнуллин. *Җиңелү әчесе дә, тезенең әрнүе дә берьюлы, сызлану булып, биткә чыкты.* Р.Батулла. *[Кыз] Аягы, тез капкачлары әрнүгә түзә алмыйча, торып утырды.* Ф.Гыйльми

2) *күч.* Ачыну, өзгәләнү, рухи газап кичерү. *Хәтта менә шушы соңгысы янында була алмау да ниндидер бер әйтеп биргесез әрнү, мәңгелек үкенеч булып калды.* Н.Акмалов. *Председатель әйткән хәбәр башта аны аптырашка салса, хәзер ул бәйләнгән яраны чишеп, ертып җибәргәндәге шикелле әрнү белән алышынды.* Ф.Садриев. *Үзенең бу наданлыгына әрнеде, хурланды.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Ачы тойгы, көенү, пошыну хисе. *Габделхәйнең күңелендә яшь бабасына карата кызгану һәм әрнү хисе калкып куйды.* Н.Фәттах

**Әрнеп алу** Бераз, аз гына, кыска вакыт эчендә әрнү

**Әрнеп бетү** Тәмам, соңгы чиккә җитеп әрнү. *Ул, төннәрдә ялгызы саташып, әрнеп --- бетте.* Г.Ибраһимов

**Әрнеп йөрү** Озак вакытлар әрнү кичерү. *Менә шуларга йөрәгем бик әрнеп йөри.* Ә.Айдар. *Үзем, һаман, бөтен дөньясына ләгънәт укып, әрнеп йөрим.* Г.Ибраһимов

**Әрнеп калу** Нинди дә булса вакыйгадан соң әрнегән халәт кичерү. *Кабереңне кочып еласам да, Калды мәңге әрнеп йөрәгем.* Ш.Маннур

**Әрнеп китү** Кинәт әрнү. *Әллә кайсы урыны әрнеп китте.* М.Гафури. *Шуны уйлагач, йөрәк әрнеп китә.* А.Шамов. *Күргәч, минем дә җаным әрнеп китте.* Г.Ибраһимов

**Әрнеп кую** Кинәт бераз әрнү хисе барлыкка килү. *Мондагы итләрне бездәге итләр белән чагыштырасың да, күңелләр әрнеп куя.* М.Юныс. *Фәтхия әби туй кирәгенең актык әзерлекләрен бетерергә ашыгып йөри иде, кунак хатынны күргәч, бөтенләй әрнеп куйды, өстенә көтелмәгән шомлы күңелсезлек капланган кебек булды.* Г.Ибраһимов

**Әрнеп тору** Әле, хәзер әрнү кичерү. *Йөрәк ашыгыбрак тибә, нервлар әрнеп тора.* М.Юныс

**Әрни башлау** Әрнергә тотыну

**Әрни төшү** Тагы да әрнү; бераз әрнү

**ӘРНҮЛЕ** *с.* **1.** 1) Чәнчеп (сызлап, кысып-кысып) авырта торган. *Аның кайчандыр әрнүле булган яралары төзәлгән.* А.Шамов

2) *күч.* Сагышлы, ачынулы, кайгылы; күңелсез. *Шулай да кайчак ул күңелемдәге әрнүле уйларны баса алмый.* А.Шамов. *Бу тойгы аның ялгыз вакытларында була; күбесенчә, ул мондый вакытларда авыр һәм нечкә әрнүле хәсрәт белән елыйдыр иде.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Әрнү белән; әрнү белдереп. *Ул, башын чайкап, әрнүле елмайды.* Ф.Галиев

**ӘРРӘ** *и. диал.* Борынгы пычкының бер төре; чылбыр пычкы. *Әррә белән кисү*

**ӘРСЕЗ** *с.* 1) Бернәрсәдән дә тартынмаган, үз-үзен артык иркен тоткан. *[Нәркисә:] Гөләп чәчәге кебек чәнечкеле, чегән кызы кебек әрсез була ул.* С.Хафизов. *Әрсез кеше – сумала, алдыңнан булмаса, артыңа сылана.* Н.Исәнбәт. *Абыйсын күптәннән күргәне булмаса да, Сабитның яшь чактан ук һавалы, комсыз һәм әрсез икәнен онытмаган Нәҗипнең күргәннәренә әллә ни исе китмәде.* А.Гыйләҗев

2) Тәкәллефсез, әдәпсез. *Моңарчы юньле өс-баш күрмәгән, тамагы туя ашамаган, шулай да оятсыз тәкъдимнәрне, әрсез күз карашларын шактый очраткалаган Наилә, «гашыйк» сүзен ишеткәч, түзә алмады: «Кем ул алай?!» – дип сорады.* А.Гыйләҗев

3) Ямьсез, күңелгә ятышсыз. *Тик менә аның үзен дә мыскыллап телгә алучы бу әрсез тавыш Камали йөрәгенә тагын борчу салды.* К.Нәҗми

4) Күңелгә килеп бертуктаусыз борчып, газаплап торган. *[Чыңгызның] Җанын суырып торган әрсез сорауларның берсе кинәт юкка чыкты.* З.Садыйков. *Тик, ни өчендер, ул әрсез һәм ябышкак хисләреннән бөтенләй үк котыла алмый.* А.Вергазов

5) Авырлыкларга бирешми торган, чыдам; берәр эш-хәлне сабырлык белән уздыра торган, түземле. *Ат, мескен, болай да бик әрсез нәмәрсә ул, егылганчы эшли.* Г.Гобәй

6) Аш-суга талымсыз, нәрсә туры килсә, шуны ашый торган. *Миңа ярый бу су да, мин бит әрсез.* М.Гафури

7) Шартларның нинди булуына карамастан, төрле урыннарда үсә ала торган, күп булып һәм тиз үрчи торган. *Әмма май аенда инде болай да сирәк үсемлекләрнең күбесе корып бетә, талымсыз саксавыл белән әрсез янтак кына анда-санда күзгә чалына.* Т.Әйди

8) Кешегә, мохиткә игътибар итмичә, табигый инстинкт яки яшәү өчен кирәкле ихтыяҗларны үтәүне дәвам иткән. *Колак төбендә генә әрсез черкиләр безләп торды.* Я.Зәнкиев. *Теге зур күлнең суы һаман азая, кибә барып, берәр дистә әрсез вә җәнҗаллы бакаларга шаулашып, кычкырышып торырлык кечкенә бер сазлык булып калган иде.* Ш.Камал. *Әрсез тавыклар, аның тирәсендә бәргәләнеп йөреп, берберсенең авызыннан өзеп орлык чүплиләр, ә ул һаман сөйләнә.* Ә.Еники

9) Көн дә киелә торган. *Һәркайсы өстенә, бизәкле итеп, үзләре бәйләгән йон фуфайка яисә сугыш вакытында иң әрсез һәм талымсыз кием – яшел тәнҗылыткычлары кигән кызлар, киленнәр Нәфисәнең Хәйдәр белән берүзе баруын елмаешып карап калалар.* Г.Бәширов

◊ **Әрсез алабай** Әрсез, оялу, кыенсыну, уңайсызлану белми торган кеше турында. *Чынлап та, әгәр бу әрсез алабай синең койрыкка чын-чынлап тагыла калса, нишләрсең син, бичара?* Ф.Хөсни. *[Җамал:] Өйрәледә – бер кич, боткалыда ике кич гомер үткәреп йөрүче әрсез алабай сыман инде үзем.* Ф.Сафин. **Әрсезгә кия торган** Һәркөн эшкә, көндәлеккә кия торган

**ӘРСЕЗЛӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Әрсезгә әйләнү, оялып тормыйча эш итү, әдәп сакламау. *Аяк-кулларын бәйдән бушаткан арада, бете котырган басмачы аңа чамадан тыш сыланып әрсезләнсә дә, Балҗан чыгымламады, хәлдән тайган кеше сыман, бөтен күкрәге белән, аның өстенә үзе ишелеп төште.* Т.Әйди. *[Сәүдә:] Син бит – егет кеше, синнән калырга ярамый миңа. Шофёрлар әрсезләнде.* Г.Ахунов

2) Бөтен җиргә таралу, басып китү. *Елдан-ел биегәя, әрсезләнә, куера барган шайтан таягы урманына өчәүләшеп карап торалар.* А.Гыйләҗев

**2. әрсезләнеп** *рәв. мәгъ.* Оялып тормыйча, әдәп сакламыйча. *Әрсезләнеп, кадеремне югалтып, бүтән озата кайтмадым.* Ә.Фазылҗанов. *Безнең көндәлек тормышыбызга әрсезләнеп кергән зур гаугалар, төрле гайбәтләр, акча табу мәшәкате каядыр китеп югалды.* М.Юныс

**Әрсезләнә бару** *к.* **әрсезләнеп бару.** *Һич көтмәгәндә, Рөстәм, әрсезләнә барып, «һөҗүм»гә күчте.* З.Дәүләтов

**Әрсезләнә башлау** Әрсезләнергә тотыну. *Әсирләр, үз кешеләренең якын икәнлекләрен сизеп, әрсезләнә башлыйлар.* Г.Әпсәләмов

**Әрсезләнә төшү** Тагы да әрсезләнү; бераз әрсезләнү. *Хәтирә, уйга калып дәшмирәк торганны күрсә, тагын да әрсезләнә төшә.* М.Әмир. *Мин, кочаклап, тоткынга егылырга һич тә ирек бирмәсемне аңлагач кына, аз-маз кыюлана, әрсезләнә төште.* К.Миңлебаев

**Әрсезләнеп бару** Аз-азлап, көннән-көн әрсезлеге көчәю

**Әрсезләнеп җибәрү** Кинәт әрсезлек күрсәтү

**Әрсезләнеп йөрү** Хәзерге моментта яки озак вакыт дәвамында әрсезләнү. *[Равил Рухияга:] – Ул үзе генә әрсезләнеп йөриме, әллә син үзең дә аны якын итәсеңме? – [диде].* В.Нуруллин. *Бу бит – Борһан эше түгел, ә Мортаза коткысы, дип уйлады Мәдинә. Борһан үзе болай әрсезләнеп йөрмәс.* М.Хәсәнов

**Әрсезләнеп карау** Бик нык әрсезләнү

**Әрсезләнеп китү** Билгеле бер вакыттан соң, кинәт әрсезгә әйләнү

**Әрсезләнеп тору** 1) Әле, сөйләү моментында әрсезләнү

2) Бертуктаусыз, озак әрсезләнү

**ӘРСЕЗЛЕК** *и.* Әрсез булу. *Чырыкның юкка йөрмәвен сизенә Йомабикә, ләкин, һичничек, аның төтене кая таба борылганны аңлый алмый, әрсезлеген, оятсызлыгын белә, әйтер сүзенең юньсезлек буласын да чамалый, ләкин һич аңыша гына алмый.* Я.Зәнкиев.

*Сез минем әрсезлегемне кичерегез.* Ә.Еники

**ӘРТИЛ** *и. сөйл. к.* **артель.** *Улы Ташкәй дә чалгычылар арасында шәйләнмәде, гәрчә ул әртилдә эшләсә дә, авылның язылмаган законы буенча, печән өстендә уртада булырга тиеш.* Я.Зәнкиев. *Бүген сызгыр – [балта осталары] әртилләре белән килачәкләр.* Г.Ахунов

◊ **Әртил мунчасы** Кычкырып-кычкырып көлүләр, бер-берсен бүләбүлә нәрсә дә булса сөйләүләр, каты бәхәсләрдән торган һәм тәмәке төтене белән тулган бүлмә. *Тәмәке төтененә буыла-буыла ютәлләүләр дә кушылгач, бүлмә эче әртил мунчасына охшап китте.* К.Тинчурин

**ӘРТИС** *и. фр. сөйл.* 1) Һәрвакыт уңайсыз, көлкеле вакыйгаларга тарып, тирә-юньдәгеләрдә елмаю уята торган беркатлы кеше. *[Мәхмүт Бикмәткә:] – Кем дип... шул инде, бар бит безнең авылның әртисе.* Ә.Баянов

2) Тормыш вaклыкларын кызыкка әйләндерүче, кыенлыкларны мәзәк, уен белән үткәрергә тырышучы кеше. *Тормышта да кайвакыт уйнарга туры килү турында сөйләгәндә, аңлау катыш көлү мөнәсәбәтен белдерү өчен, үзгәртелгән «әртис» сүзе файдаланылган.* Р.Абдуллина

**ӘР-ХУР** *җый. и.* Төрле ачуланулар, тиргәүләр. *Хәер, әр-хур һәммә кешегә дә эләкми.* М.Маликова

**ӘРЧҮ** *ф.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса кабыгын, тышчасын берәр корал яки кул ярдәмендә чистарту, салдыру. *Тәлгать газга су куйды, тиз-тиз бәрәңге әрчеде, суган турады, макароннар вaклады.* Ә.Мушинский. *– Җиңги, дим, пылауга ничә баш суган әрчим соң? – диде әле һаман җавап ишетмәгән үсмер.* Т.Әйди. *Хәмидә белән, икәүләп, балык әрчергә тотындылар.* Ш.Камал. *Сабадан кукәй пешереп алып барган идек. Шуны әрчеп ашадык хатын белән...* Т.Нәҗмиев // *сөйл.* Төргән әйберне ачу, таратып салу. *Апа кеше, кәгазьне әрчеп, кучтәнәчне кабып карарга кушты.* Ф.Дунай

2) Берәр урынны комачаулап торган яки артык булган төрле чүп-чардан, пычрактан, кардан һ.б.ш.дан арындыру, чистарту. *Аттаукай, әледән-әле, нартадан төшеп янәшә атлый, иелеп, куллары белән карны әрчи, сопка төбләрен күрергә тырышып, як-ягына карана.* А.Мифтахетдинов. *[Хуҗа:] Дүртегез дә бүген кырыгар чиләк су чыгарып, шул коены әрчеп, тазартып, эшкә кертегез.* Г.Исхакый. *Бераздан, башын чайкап, чәч дулкыннарыннан маңгаен әрчеде дә, озын керфекләрен тибрәтеп, сәгатенә карап алды.* М.Юныс

3) Берәр нинди урында үсеп утырган агач-куакларны тамырлары белән йолкып алу, шулардан арындыру. *Бер гектар чамасы җирдән тал-тирәк әрчү.* Ш.Камал. *Шулай итеп, тиз генә җирне әрчеп, шалканны чәчеп тә куялар.* Х.Гатина

4) *күч.* Илне, коллективны яки нинди дә булса урынны корткычлардан, дошманнан һ.б.дан азат итү, аларны куып чыгару. *Ничек кенә булса да Олы Ширмә авылын аклардан әрчергә!* Һ.Такташ // Берәр урынга кереп тулган, кирәкле дип саналмаган кешеләрдән арыну, аларны куу. *Каравылчы Габделвәли каравыл йортын әңгәмә вакытында оеп ауган малай-шалайдан әрчергә тотынды.* М.Юныс

5) *күч.* Басу, урлау, бернәрсә калдырмый алып чыгу

6) *күч.* Күпме булган, шуларның берсен дә калдырмый оту

7) *күч.* Күп чыгым тоту; тотып, файдаланып бетерү

**2.** *и. мәгъ.* Урманда агач һәм куаклардан чистартылган ачыклык. *Икенчедән, иртәгәдән башлап, һәр йорт, өч көн буе, үз әрчүләреннән мал-туарга кышлык печән әзерләячәк.* Р.Сибат. *Әнә агачлар арасыннан яктысы күренгән алан – Моратай әрчүе инде ул.* Г.Бәширов

**Әрчеп бару** Бер-бер артлы, рәттән әрчү

**Әрчеп бетерү** Ахырынача, тулаем, барысын да әрчү. *Шәһәрдән кайткан яшьләр учак янына килгән чакта, болар бәрәңгене әрчеп бетерәләр.* Ш.Камал. *Әлифә әнә кәбестәнең кабыкларын әрчеп бетерсә дә, һаман эченнән кәбестәсен таба алмый интегә.* Ш.Галиев *Гобәйдулла абзый, ышнаңны әрчеп бетердем, төпләрен кагып, ызанга өеп куйдым.* Т.Гыйззәт

**Әрчеп бирү** Кем өчендер әрчү, әрчергә ярдәм итү. *Аннан Зәйнәп тышта уйный, Әнисенә булыша: Йөри иркен һавада. Йә бәрәңге әрчеп бирә, Рәхәтләнеп чана шуа, Йә савытлар юыша.* Ш.Маннур. *И-и, Сәләхетдин абзый, бәрәңге пешерергә җыенасың, ахры, кая, үзем әрчеп бирим бәрәңгеңне.* М.Ибраһимов

**Әрчеп карау** Әрчергә омтылу, нәрсәне дә булса әрчергә тырышу. *Менә хәзер ул унны бетерә, аның әле бәрәңге әрчеп караганы да юк.* Ф.Яруллин

**Әрчеп кую** Алдан әрчү; әрчелгән хәлгә китереп әзерләп тору. *Илсөяр хәзер өйдә дөнья көтә: әтисе белән әнисе мәктәпкә киткәч, өстәл җыештыру, савыт-саба, идән юу, бәрәңге әрчеп кую аның вазифасына әйләнде.* Р.Хәбибуллина. *Әнвәр, пәкесен алып, ялт итеп, кабель очын әрчеп тә куйды.* Х.Камалов

**Әрчеп ташлау** Тиз-тиз, кыска вакыт эчендә әрчү

**Әрчеп тору** Әле, хәзер, күз алдында әрчү; һәрберсен, булган берсен әрчү

**Әрчеп утыру** Әле, хәзерге вакытта әрчү. *Берзаман кияве кайтып керсә, бабай кешебез инде, җиңен сызганып, бик матурлап кына, бәрәңге әрчеп утыра, ди, икән шул.* Н.Исәнбәт

**Әрчеп чыгу** Һәрберсен, барысын да ахырынача әрчү

**Әрчи бару** *к.* **әрчеп бару**

**Әрчи башлау** Әрчергә тотыну

**ӘСАРӘТ** *и. гар. иск.* 1) Әсирлек, тоткынлык; коллык. *Төште куллардан, аяклардан әсарәт чылбыры.* М.Гафури

2) *күч.* Ирексезлек

**ӘСАС** *и. гар. иск.* Берәр нәрсәнең нигезе, фундаменты. *Алтын Урда заманындагы мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән Болгар мәдәнияте Казан ханлыгы һәм аннан соңгы дәверләрдәге мәдәниятнең дә гомуми әсасе һәм аның дәвамы булып тора.* Ш.Абилов. *[Таштимер]: Шәмгун кардәш – Бохара компартиясенә әсас салучыларның берсе.* Т.Әйди

**ӘСА́СӘН** *рәв. гар. иск.* Асылда, нигездә; гомумән. *Мин синең крестьян*

*булуыңа әсасән каршы бармыйм.* Г.Ибраһимов

**ӘСАСИ** *с. гар. иск.* Берәр нәрсәнең асылы, нигезе булган. *Беренче карашка, бу ике мәкаләнең эчтәлеге ике төрле кебек, әмма, игътибар беләнрәк укысак, аларның әсаси уртаклыгы булуын абайлау һич тә кыен түгел.* Р.Вәлиев

**ӘСАСЛЫ** *с. иск.* Нигезле, дәлилле. *Казан муллаларын этрафлыча вә бик әсаслы тәнкыйть иткәннән соң, мәдрәсәләрне шулар корпорациясенә тапшыру ислахны артка гына калдырачак.* Ф.Әмирхан

**ӘСӘД** *и. гар.*1) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган йолдызлык атамасы һәм шул йолдызлыкның тамгасы; арыслан йолдызлыгы

2) Кояш календаре буенча унике айдан торган йолдызлыкның бишенче ае исеме (23 июльдән 23 августка кадәр) һәм шул айда туган кеше. *Әсәдтә туган бала батыр була.* Әйтем

**ӘСӘР** I *и. гар.* Фән, сәнгать, музыка, матур әдәбият һ.б.ш. өлкәләрдә кеше тарафыннан уйлап чыгарылган, күргән-белгәннәрен, хис-тойгыларын чагылдырган, шул өлкәнең таләпләренә җавап бирерлек итеп үтәлгән иҗади хезмәт, иҗат җимеше. *Нәби ага үзенең ятимлектә, детдомнарда үткән үсмер чагы турында яңа әсәр башлавын сөйли.* М.Галиев. *Кулыма төсле буяулар алып, чиста киндер каршына киләмме, зур галереяларда борынгыдан алып бүгенгегә килгән рәссамнарның әсәрләрен карап йөримме – шушы хикмәтле сүз искә килә дә төшә.* М.Галиев. *Сәйдәшев үз әсәрләрен үзе фортепианода уйный.* Казан утлары. *Искәндәр – үзе тотынган һәр әсәрнең фәлсәфи аһәңен ачып бирә ала торган җырчы.* Казан утлары

**ӘСӘР** II *и. гар. тарт. форм.* 1) Нәрсәгәдер хас сыйфат, шуның чагылышы, эзе, билгесе; тәэсир, йогынты. *Шаушулы вә мәшәкатьле көнне үткәреп, тын төнгә якынаю әсәре бөтен тирәякны каплаган иде.* Г.Ибраһимов. *Хан кызының иң тирән, иң саф калебеннән җан ачысы илә чыккан сүзләре, ялварулары бар да җилгә китте, шаһзадәгә һичбер әсәр кылмады.* Ш.Мөхәммәдев

2) Кешеләргә хас психик һәм физиологик күренешләрнең йөздә, күздә, гәүдәдә һ.б.да чагылышы. *Кульяулыгы белән күпме генә сөрткәләсә дә, Хөснуллинның керфексез күзләрендә, яшь тамчысы түгел, дым әсәре дә юк иде.* Ф.Садриев. *Йөзендә елмаю да, шатлык әсәре дә юк иде.* Н.Акмалов. *Ә ул остазының йөзенә туп-туры карап тора, аның агы зәңгәрсуланып торган коңгырт күзләре төбендә борчылу, үкенү, кыенсыну кебек хисләрнең әсәре дә чагылмый иде.* М.Маликова

3) Кечкенә генә кисәк, өлеш; ачыкланган сүздәге мәгънәгә туры килердәй берәр әйбер. *Тутайның тәнендә һичнинди кием әсәре юк: колак очындагы алкалар, муенындагы мәрҗән муенса, ике беләгендәге беләзек, бармакларындагы йөзекләр генә.* Р.Батулла. *Язын Мирзәки дә, Акмал да ипи әсәре күрмәделәр.* Г.Ахунов. *[Самат] Күк йөзенә күтәрелеп карады. Анда «болыт» дигәннең әсәре дә күренми, апаяз.* Г.Гыйльман. *Ник бер болыт әсәре булсын!* Ф.Латыйфи

4) «Тереклек», «җан» сүзләре янында килеп, заты, иясе, мәгънәсен белдерә. *Тау башындагы гаять зур ташка менеп күпме генә карансам да, тирәюньдә җан әсәре чалынмады.* Ә.Гаффар

**ӘСӘР** III *и. гар. иск. кит.* Кешенең рухи халәтендә чагылыш тапкан төрле күренешләр, предметлар яки сүзләр тәэсире, йогынтысы. *[Әти-әнинең] --- бу орышлары зәһәрле, йөрәк әрнетә торган әсәр калдырмый торган иде.* М.Гафури

**ӘСӘРӘЮ** *ф. сөйл. к.* **әсәрү**. *Зариф тәмам әсәрәйде.* И.Низамов

**ӘСӘРЕНКЕ** *с. сир.* Берәр нәрсәнең йогынтысына дучар булган; вәсвәсәле, шөбһәле кыяфәттә булган

**ӘСӘРЕНҮ** *ф.* 1) Берәр төрле тәэсиргә бирелү, нәрсәдән дә булса куркып китү. *Нәҗип, әсәренеп, калтырап диярлек тыңлады карчыкны.* А.Гыйләҗев. --- *авылда, берәр кешенең хуҗалыгында күсе бар, дигән хәбәр ишетелсәме? Аңа бөтен авыл әсәренә иде.* М.Мәһдиев

2) Нәрсәнеңдер тәэсиреннән хискә бирелү, хисләнү, дулкынлану. *Ләкин шул вакытта тонык кына бер моң колакка бәреп керә. Без әсәренәбез.* М.Мәһдиев. --- *дөньяда тиңе булмаган шәһәр нигезләрен эзли, чагыштыра, үкенечле сызлана, сабыйларча әсәренә; үткәннәрне уята, бүгенгебезне уйландыра, киләчәгебезгә кисәтүле караш ташлый.* М.Галиев

**Әсәренә бару** Торган саен ныграк әсәренү; әсәренүгә акрынлап күчәю

**Әсәренә башлау** Әсәренергә тотыну

**Әсәренә төшү** Бераз әсәренү

**Әсәренеп йөрү** Озак вакытлар дәвамында әсәренү. *Шактый вакыт әсәренеп йөргәч, чиксез горурлык, хәтта кәпрәю хисе кимеп, әз-әзләп, канәгатьсезлек хисе туа башлады.* М.Маликова

**Әсәренеп калу** Ниндидер сәбәп белән яки берәр вакыйгадан, вакыттан соң әсәренү; кинәт әсәренү. *Чу! Үз күзләремә, үз колакларыма ышаныргамы, юкмы, дигәндәй, кинәт әсәренеп калам.* Э.Шәрифуллина. *Табында тынлык туа. Барсы да әсәренеп кала.* С.Сабиров

**Әсәренеп китү** Кинәт, көтмәгәндә әсәренү. *«Олы юлга!» дип уйлады да, Галимҗан әсәренеп китте.* А.Гыйләҗев. *Мылтык күргәч, мин әсәренеп киттем, аны тотып та карыйсым килгән иде – горурлыгым комачаулады.* З.Хөснетдинов

**Әсәренеп тору** Әле, хәзерге вакытта әсәренгән булу

**Әсәренеп чыгу** Әсәренгән халәт кичерү

**ӘСӘ́Р ИТҮ** *ф. иск.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса йогынты ясау. *Миңа бу бик каты әсәр итте.* Г.Ибраһимов

**ӘСӘРЛӘНДЕРҮ** *ф.* Көчле кичерешләр уяту, артык нык дулкынландыру. *Көймә әсәрләндерде мәйдан халкын?* Р.Батулла. *Атаклы очучының сөйләгәнен тыңлау да, җырлары илгә таралган хатын-кыз композиторның үзен күрү дә Миләүшәне әсәрләндерде.* Р.Кәрами. *Аны, көтмәгәндә, шундый яшьнәп торган егет, дәрәҗәле командир хәлендә күрү – күңелемне әсәрләндереп кенә калмады, йөрәгемне үкенеч, югалту тойгысы да чеметте.* Т.Әйди

**Әсәрләндерә бару** Торган саен ныграк әсәрләндерү

**Әсәрләндерә төшү** Тагы да әсәрләндерү

**Әсәрләндереп бетерү** 1) Тәмам, бик нык әсәрләндерү

2) Барысын да әсәрләндерү

**Әсәрләндереп җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә әсәрләндерү. *Үзе җырларга бик яратмаса да, туганының әлегә моңарчы ишетелмәгән бер моң-аһәңне көйләп баруы аны әсәрләндереп җибәрде.* Р.Сибат. *Әнисә, һаман йокыга тала алмыйча, мендәрен кочаклап, бәргәләнеп ятты. Гаепле кеше «квартиранты» булдымы, шул күңелен әсәрләндереп җибәрдеме, әйтә алмый.* Т.Галиуллин

**Әсәрләндереп тору** Һәрвакыт, даими әсәрләндерү. *Балачактан ук мине ул [әбидән калган Коръән кисәкләрендәге язулардагы] серле хәрефләр үзләренә тартып, күңелне әсәрләндереп тора иде.* Н.Гамбәров

**Әсәрләндереп чыгару** Кинәт әсәрләнгән хәлгә җиткерү

**ӘСӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) Ниндидер билгесезлек тойгысы кичерү, вәсвәсәләнеп, нидер көтү. *[Ул] Йөрәгенең уч төбендәге кош баласы кебек талпынып тибүенә әсәрләнеп, палубага чыкты.* К.Нәҗми

2) Нәрсәнең дә булса йогынтысына бирелү, тәэсирләнү. *Бу күренештән әсәрләнеп, малай экранга тагын да ныграк беректе.* Р.Низамиев. *[Сәхи Гафуров:] – Син, аннан, бу тозакка күптән капмаганга охшыйсың, бүрегең чәч алдыргач чәчтарашлар сипкән хушбуй исен гаип итәргә өлгермәгән, бөркелеп тора, – дип сөйләнде, әсәрләнеп.* Г.Тавлин

**Әсәрләнә бару** Әсәрләнүе, акрынлап, тагы да арту

**Әсәрләнә башлау** Әсәрләнергә тотыну

**Әсәрләнә калу** *к.* **әсәрләнеп калу.** *Кишектин югалды, карт тәмам әсәрләнә калды.* М.Хәбибуллин

**Әсәрләнә төшү** Тагын да әсәрләнү

**Әсәрләнеп йөрү** Озак вакытлар дәвамында әсәрләнгән халәт кичерү. *Ә инде Төркиядә сәяхәттә булып кайткач, ул, тәмам бу илгә гашыйк булып, әсәрләнеп йөрде.* Р.Гатауллин. *Ә җанымда Болгарстан күргән һәлакәтнең тоям газабын... Әсәрләнеп йөрим мин Болгарда – Әйтерсең лә мин үз куышымда.* Р.Миңнуллин

**Әсәрләнеп калу** Нинди дә булса вакыйгага тәэсирендә, берәр төрле хәлдән соң кинәт әсәрләнгән халәт кичерү. *Күгәне сыкрап ачылган ишектән керүгә, ул, өстәл тирәсендә ят ир утырганын күреп, әсәрләнеп калды.* Р.Шакирова. *Аппакның мондый сихри манзараны беренче тапкыр күрүе иде, тәмам әсәрләнеп калды.* М.Хәбибуллин

**Әсәрләнеп китү** Кинәт, көтмәгәндә әсәрләнү. *Байкучатов хуҗа ханымның әсәрләнеп китүенә гаҗәпләнмәде.* Т.Әйди. *Ул, әсәрләнеп китеп, очарга талпынган аккош шикелле, кулларын җәеп җибәрде.* В.Нуруллин

**Әсәрләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта әсәрләнгән халәт кичерү. *Сәер һәм кызганыч иде бөтен районга «усал» дип аты таралган кара мыеклы бу озын кешенең, япа-ялгыз, урман уртасында шулай әсәрләнеп торуы.* Ф.Шәфигуллин

**ӘСӘРЛЕ** *с.* 1) Тарихлы, үзенә аерым бер урын тоткан, эзле. *Рус җирендә без әсәрле, эзлебез.* Г.Тукай

2) Нык тәэсир итә алырлык, дулкынландыргыч. --- *күңелне сафламак вә нәфсене тәрбия итмәк бабында иң әсәрле улган дәвадыр.* Р.Фәхретдинов. *[Анарның] Карлыгандай кара күзләре өздереп карый, керфекләре, кашлары исә шундый назлы, әсәрле – таң калырлык.* Т.Әйди

3) Нечкә күңелле, йөрәгенә якын кабул итә торган

**ӘСӘРҮ** *ф.* Гаҗәпләнү, аптырашка калу. *Гармун тавышына, әсәреп, Хәкимҗан килеп керде. – Уһу, болай булгач, музыкантлар күбәйде, – диде ул.* М.Мәһдиев

**Әсәрә бару** Торган саен ныграк әсәрү

**Әсәрә башлау** Әсәрергә тотыну

**Әсәрә төшү** Тагы да әсәрү

**Әсәреп китү** Кинәт, көтмәгәндә бик нык әсәрү. *Бөтенесе әсәреп киттеләр, башларын читкә борып, ишек тарафына чигенә башладылар.* М.Маликова

**Әсәреп тору** Күпмедер вакыт дәвамында әсәрү халәте кичерү

**ӘСБАП** *и. гар.* 1) Нинди дә булса эштә файдаланылган техник җайланма, прибор, аппарат, ярдәмлек һ.б.ш. кирәкяраклар. *Андагы бөтен экспонатларны, күргәзмә әсбапларны, гербарийларны, укытучыбыз җитәкчелегендә, без үзебез әзерләдек.* Г.Тавлин. *Ләкин планетаның температурасын турыдантуры да билгеләргә мөмкин, моның өчен, аның инфракызыл нурланышын җирдәге аппаратлар һәм автомат планетаара станцияләргә урнаштырылган әсбаплар ярдәмендә тикшерергә кирәк.* Астрономия

2) Берәр нәрсәнең комплектына кергән әйберләр җыелмасы. *Эштән кайтып, тамак туйдырабыз да, уку әсбапларын алып, паркка китәбез.* З.Фәйзуллин. *Төп максат – табак-савыт, табын әсбапларын рекламалау.* Р.Батулла

**ӘСИР** *и. гар.* **1.** 1) Сугышта дошман тарафыннан кулга алынган кеше. *Ул, барган төшкә, мылтык көпшәсен әсирнең калак сөягенә тигезеп-тигезеп ала, янәсе, син – мушкада, фашист.* М.Әмирханов. *Әмма ул – «Хәрби әсирләрнең сугышчан бердәмлеге»ндә элемтәче... Кем белә, бәлки, ул – бердәнбер каналдыр.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Хис-тойгыларның йогынтысына бирелгән кеше. *Бүлмәдәге һәркем – музыка әсире.* Ф.Сафин

3) *күч.* Вакытлыча кемнеңдер карамагында булган кеше яки берәр нәрсә. *Син – минем әсирем бит бүген, мин сиңа бары тик сәяхәтең турында гына уйларга әмер бирәм.* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* Кулга төшкән, сак астында булган. *Ачтан яшелләнеп, таланыпялангачланып беткән әсир качаклар урман буендагы хуторга җитеп туктадылар.* М.Галиев. *Колшәриф мулла әсир егеткә Зөннар дип ат кушты.* Р.Батулла. *Аның командасы астында, шул яктан илбасарлар әсир кызларны алып чыгып китәләр.* Н.Исәнбәт

**ӘСИ́Р БУЛУ** *ф.* 1) Кулга алыну, дошман кулына бирелү. *Атылу, кимендә әсир булуны көткән солдатлар үзара пышылдаша башладылар.* Г.Гобәй

2) *күч.* Хис-тойгылар йогынтысында булу. *Матур да соң [мәхәббәт ялкыны*

*белән] яну! Бигрәк тә чын мәхәббәт белән янсаң. Әйе, чын мәхәббәтнең әсире булсаң.* Г.Минский

**ӘСИ́Р ИТҮ** *ф.* 1) Сак астына алу, төрмәгә ябу, кулга төшерү. *Угры Чалбай хан өске кирмәнне алган, андагы кардәшләребез болгар-грекларны әсир иткән.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Кемнеңдер күңелен яулау; үзенә җәлеп итү, карату. *Сөйгәнемнең күзләрендә мин беренче мәхәббәтемнең утлы, тере карашын күрдем. Шул мине әсир итте, шул миңа сөю тылсымы бирде.* Г.Гыйльман. *Шундый ирләргә генә хас таләпчәнлеге, ирләрчә үзенә тарту көче мине әсир итте.* Г.Кашапов. *Бәлки, Шәмгунның сүзе эшеннән аерылмавы, искиткеч кыю һәм тәвәккәл булуы Баһаветдинны әсир иткәндер?* Т.Әйди

3) *күч.* Кемнеңдер ихтыярын сындыру, үзенә буйсындыру. *Закон дәүләттә тәртип булдыру өчен чыгарылса, дин кешенең рухын әсир итә, җанын били.* М.Хәбибуллин. *Күр әле, күр! [Елан] Бичара баканы әсир иткән.* Н.Хәсәнов

**ӘСИ́Р КЫЛУ** *ф. сир. к.* **әсир итү** (*1 мәгъ.*). *Шаһ Гали ханны бәйрәм табынында ук әсир кылып, үз өенә бикләп, каравыл куйдылар.* Р.Батулла

**ӘСИРЛӘГЕЧ** *с.* Үзенә җәлеп итә торган, үз тәэсиренә бирелдерә торган

**ӘСИРЛЕК** *и.* 1) Әсир булу, дошман кулында булу. *Тулы бер полк белән чолганышта калып, сугышның икенче елында ук әсирлеккә эләккән гап-гади солдатның бәргәләнгән җаны коллыкны күтәрә алмый иде.* М.Галиев. *Газаплы әсирлек елларының кара шәүләсе, илгә кайткач та, артыннан калмый аның.* М.Галиев

2) *күч.* Изелеп яшәү, ирексезлек

3) *күч.* Уйлар, хис-тойгылар тәэсиренә бирелгән халәт. *Бу сихерле музыка әсирлегеннән йөрәгемне тартып алып, үзен-үзе оныткан залга карадым.* М.Әмир. *Соңгы вакытта аны сагыш басты, хәтта көннән-көн сагыш әсирлегенә әлгә барганын үзе дә toймый иде инде.* Р.Газизов. *Ул әле йокысы кочагыннан, бүген күргән төшләре әсирлегеннән чыннан да айнып бетмәгән.* Т.Әйди

4) *күч.* Кемне дә булса үз янында калдыру, үзеннән читкә җибәрмәү; нәрсә дә булса икенче бер әйберне ура-тып алу. *[Ләйлә:] Әни, мин сине үземә әсирлеккә алам бүген.* М.Маликова. *Тау битендә тамырланып яшәүче кәрлә чикләвек куаклары да – кар әсирлегендә.* Р.Низамиев

**ӘСИ́Р ТӨШҮ** *ф.* Дошман кулына бирелү, тоткын булу. *Безнең ятим угланыбыз да әнә каган кулына әсир төшкән.* М.Хәбибуллин. *Ире Хикмәтулла турында, немецларга сатылган, үзе теләп әсир төшкән икән, дигән хәбәр бөтен авылга таралган.* М.Галиев

**ӘСИ́Р ЯТУ** *ф.* Иректән мәхрүм ителеп, сак астында яшәү. *[Зариф] Австриядә өч ел диярлек әсир ятып, әле генә кайтып төшеп, авылдагы-илдәге хәлләрдән хәбәрдар булмыйча, караңгы урманда япа-ялгызы торып калган кеше хәлендәрәк иде.* А.Гыйләҗев

**ӘСПЕ** I *и. иск. мед.* Тәнгә кызыл таплар чыгудан гыйбарәт йогышлы авыру; кызамык (гадәттә кече яшьтәге балаларда күзәтелә); *русчасы:* **краснуха**

**ӘСПЕ** II *и. бот.* Лалә чәчәклеләр семьялыгына керә торган, юка, нәфис, вак кына яфраклы үләнчел үсемлек (аксыл тамыры, яшь үрентесе аш-су әзерләгәндә файдаланыла); *русчасы:* **спаржа**

**ӘССӘЛАМЕГАЛӘ́ЙКЕМ** *ы. гар.* Очрашканда сәлам бирү, исәнләшү сүзе («Сезгә иминлек телим!»). *Әссәламегаләйкем, нихәл? Исәнме, балам?..* Г.Ибраһимов. – *Әссәламегаләйкем, егетләр,* – *дип сәлам бирде ул.* Р.Мөхәммәдиев. *[Бәйрәмхан] Шыгырдавык ишекне каерып ачты, эчкә тиз генә кереп, юка киез эшләпәсен салды: – Әссәламегаләйкем!* М.Хуҗин

**ӘСТАНӘ** *и. гар.* 1) *архит.* Кирпечтән, таштан салынган терәк

2) *архит.* Триумфаль капка

3) Башкала, пайтәхет

**ӘСТӘГЪФИРУЛЛА(һ)** *ы. гар.* 1) Берәр яман (гөнаһлы) яки кеше булдыра алмаслык эш (сүз) турында ишеткәндә, кире уйларга кирәк, Алла ярлыкасын, мәгънәсендә әйтелә. *[Карчык:] Әстәгъфирулла, килен, тәүбә диген. Ничек телең әйләнә?* А.Гыйләҗев. *Әстәгъфирулла, диген, Ибраһим, ничек миллион кешене ашатып була?* В.Юнысов

2) Аптырау катыш шаккатуны, гаҗәпләнүне, хәйранга калуны белдерә. – *Әстәгъфирулла!* – *Гөлчирәтти битен яулык очы белән каплап көлде. – Әле син, оялмыйча, шушы йорт искергәнгә тиклем яшәмәкче буласыңмы әллә?!* Н.Акмалов. *Күк йөзендә бер кара тап пәйдә булды. Менә ул чәүкә чаклы булды, торна зурлыгына җитте. Әстәгъфирулла, һаман зурая.* М.Юныс. *Ботын кисә! Ашый! Әстәгъфирулла, нишли, ахмак!* Н.Исәнбәт. *Әстәгъфируллаһ, ул турыда уйламавың, төшне юрамавың хәерлерәк.* Р.Батулла

**Ә́СТӘГЫМ** *ы. гади сөйл. к.* **əстәгъфирулла(һ)**. – *Әстәгым! – Хатын, кабаланып, кызчыкны баскычка аударды. – Бер карау белән чиреңне әйтә, дигәннәрие, әстәгым!* Н.Гыйматдинова

**ӘТӘЙ** *и. диал. к.* **әти.** *[Флорид:] Минем әтәй карт белән әнкәй үз йортлары белән бергә яшиләр.* Д.Салихов

**ӘТӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса тиз-тиз эшләргә тырышу, ашыгу, кабалану. – *Тукта, туган, бик әтәләнмә! – дип әйтте, ди, дөньяның акыллы диванасы Хуҗа Насретдин.* Г.Ахунов. *Үч алырга теләсәм дә, моны әтәләнеп кылмас идем.* М.Хуҗин

2) *диал.* Кемгә дә булса бик нык ошарга, ярарга тырышу. *[Кызлар] Нигә бу хәтле әтәләнәләр, нигә бик ягымлы сүзләр әйтәләр?* Г.Бәширов

**Әтәләнеп алу** Аз гына, кыска вакыт эчендә әтәләнү

**Әтәләнеп тору** 1) Әле, хәзерге мизгелдә әтәләнгән булу

2) Һәрвакыт, даими әтәләнү

**ӘТӘЛГЕ** *и.* 1) *зоол.* Бөркетләр семьялыгыннан, кошлар һәм вак җәнлекләр белән туклана торган зур ерткыч кош; лачынның зур гәүдәле төрчәсе; *русчасы:* **балобан обыкновенный.** *Әтәлге, мактанса, тычкан тоттым, дир.* Әйтем. *Әтәлгене куй, карчыганы чөй.* Мәкаль. *Әтәлге – аучы кошларның дансызрагы.* Н.Исәнбәт

2) *күч. тирг.* Юньсез, явыз, холыксыз кеше. --- *табын артындагы ягым-*

*лылык, итагатьлелек, мөлаемлык кебек сыйфатлар ирдә дә, хатында да юкка чыга, персонажларның телендәге «сандугачым-карлыгачым»ны «Сбулыч! Падлы! Сбинжә! Әтәлге!» сүзләре алмаштыра.* А.Хәлим

3) *куч. шелт.* Берәр нәрсә өләшкәндә беренче булып ташлана торган әрсез кеше

**ӘТӘМБИ** *и. диал.* **1.** 1) Ата-бабадан нәселдән-нәселгә күчеп килгән кыйммәтле сыйфатларын югалткан, чит кавемнәр, килмешәкләр белән кушылып каны сыекланган кеше; адәм актыгы. *Асаба башкортлар бик күп җирле булганнар. Мәсәлән, Каңны Төркәй, Кобаулар – нәстәяшни башкорт алар, әтәмби түгел.* Риваять. *Мине ниндидер әтәмби дип белдегезме?!* Р.Риян

2) Коелган орлыклар һәм шул орлыклардан үскән иген. *Язын икмәк икмәгән әтәмбигә моң булыр.* Мәкаль

3) *куч. тирг.* Кабахәт, азман, бәдбәхет

**2.** *с. мәгъ.* Көзен туган. *Безнең әтәмби тәкәбез үсми калды*

◊ **Әтәмби бәрән** Чирләшкә, зәгыйфь бала

**ӘТӘ́М-СӘТӘМ** *с. сөйл.* Таркалган, бетү хәленә килгән, җимерек, иске. *Шушы әтәм-сәтәм хуҗалыкны сиңа сылап, Ихлас Сабит абый авылына китеп барачакмы?!* А.Гыйләҗев

**Ә́ТӘ-ТӘ-ТӘ(Т)** *ы. к.* **әлә-лә.** *– Әтә-тә-тә... Никадәр байлык, – дип тел чартлатты кемдер.* Ф.Латыйфи. *– Әтә-тә-тәт! Үзеңне баш белгечкә хисаплап йөрисеңмени?* Ф.Сафин

**ӘТӘЧ** *и.* **1.** 1) Тавыклар семьялыгыннан булган, ураксыман каурый койрыклы, зур кызыл кикрикле, аякларында шпорлары булган, ата җенестәге йорт кошы. *Абзар куначасыннан, сузып кына, карлыккан әтәч кычкырды.* Я.Зәнкиев. *Әтәч – авылның байрагы, таңның шаһиты.* А.Гыйләҗев

2) *астр.* Борынгы Көнчыгыш йолдызнамәсендә алтмыш еллык календарь циклның 12 төрле хайван белән билгеләнгән унынчы билгесе; шул билгегә туры килгән елда туган кеше. *Әтәч елы килде... Гомум отыш, Ачышларга тулып үткәч ел. Яшә, халкым, бәхет кочагында, Хәерле юл сиңа, Әтәч ел!* Р.Батталов

3) *куч.* Сәбәпсезгә кинәт кызып китүчән кеше; юкка-барга да кызып китеп сугышырга гына торган кеше. *Ул соңгы сүзен әйтеп өлгерә алмады, Нәҗипкә тибәргә азапланган ахирие, мәтәлеп китеп, «әтәч»нең аягына сыланды.* З.Фәтхетдинов. *Ләкин ул арада ике «әтәч» чын-чынлап эләгешеп киттеләр. Рамус Габделхәйне ике куллап тотып күтәреп алды да баш аркылы ыргытмакчы булды.* Н.Фәттах. *[Иван сәүдәгәр:] Йә, җитте сезгә, көзге әтәчләр.* Ф.Латыйфи

4) *куч.* Мактанчык, бәйләнчек, тәкәббер кеше. *Чеканың Фарухҗан Байкучатов дигән бер яшь әтәче иснәнә башлаган икән.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* Мактанчык, шапырынучан, тәкәббер. *Син миңа әтәч егетлегең белән масайма әле монда, йомышың ни, Шакир?* Н.Гыйматдинова

**3.** *ы. мәгъ.* Гаҗәпләнү, шаккату, аптырап калу хисләрен белдерә. *[Беренче бала:] Әтәч, бу бит – кичә без битенә төкергән абый. [Икенче бала:] Ул халык дошманы, кабахәт, сатлыкҗан булган.* Р.Батулла

◊ **Әтәч азан әйткәндә** Гомумән тормышка ашмаячак, булмастай берәр нәрсә. **Әтәч баш** Теләсә нинди эшкә яки кешеләр төркеменә баш булырга яраткан яки шуңа омтылган кеше турында әйтелә. **Әтәч булу** Җитәкчелек вазифасын башкару, кемнәргәдер баш булу. *«Алын, әнисе, син бу эшкә, – диде Мәгъсүм миңа [Фидаяга]. – Гел тавык кына булып яшәмәссең, әтәч булып кылан беразга».* М.Маликова. **Әтәч булып куну** Ябырылу, ташлану, сүз әйтергә дә бирмәү. *Ул председатель өстенә, очынып килеп, әтәч булып кына кунмады.* М.Хәсәнов. **Әтәч булып кычкыра** Кулына аз-маз акча килеп керсә, шунда ук аны кирәкмәгән әйберләргә тотып бетерергә әзер торган кешегә карата әйтелә. *Кесәсендәге акчасы әтәч булып кычкырмаган түбән катлау кешесе, гадәттә, үзенә кирәк әйберне гади халык базарларыннан ала.* В.Юныс. **Әтәч гомере** Гомере бик кыска, аз вакытта гына була, мәгънәсендә. **Әтәче дә күкәй сала** Берәр кешенең бәхетле, мул тормышына көнләшеп яки сокланып әйтелә. **Әтәч итү** Берәрсен, юри мактаган булып, көлкеле хәлгә калдыру. **Әтәч кычкырту** Зурдан кубып, күпертеп сөйләү, артык шау-шу тудыру. *Тик үзәк матбугат кына «Казан феномены» дигән уйдырма тирәсендә шактый вакыт әтәч кычкыртты.* Т.Галиуллин. **Әтәчләр белән** Иртән иртүк, иртә таңнан, таң белән. **Әтәч тәпие** *сөйл.* Штопор. *Бир әле шул әтәч тәпиеңне, бөкесен ачып булмый моның.* Н.Исәнбәт. **Әтәч тиресе** Бик юка һәм чыдамсыз тукыма. *Әйдәле, әйдә, синең бу әтәч тиресеннән эшләнгән портфелеңне суга салып карыйк әле!* З.Хөсniяр. --- *синең ул әтәч тиресеннән теккән нәмәстәң белән күшегеп бетәрсең.* Т.Миңнуллин. **Әтәч шикелле сикереп куну** *к.* **әтәч булып куну**. *[Хәбир:] Нигә әтәч шикелле сикереп кунарга гына торасың әле [Рәсим] син?* Ф.Шәфигуллин

**ӘТӘ́Ч ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Кызгылт сары төстә, өсте тигезле-тигезсез, читләре кайтарылып торган бүрәнкәсыман эшләпәле гөмбә; *русчасы:* **лисичка**

**ӘТӘЧЛӘНҮ** *ф.* 1) Сугышырга, талашырга, бәйләнергә сәбәп эзләү, кирәксезгә әрепләшү. *Ярый, әтәчләнмә! Һәм абыеңны мыскыллама да!* З.Хөсnияр. *Ул үз-үзен ачулана башлый: «Мескен көчсез хатынга барып, нигә әтәчләнергә инде!» – ди.* С.Җәләл. *Кулына озын, штыгы дүрт кырлы «трёхлинейка» дигән мылтык та килеп кергәч, Габдерәхим әтәчләнергә тотынды.* З.Зәйнуллин

2) *куч.* Урынсыз кәпрәю, һавалану; нигезсез бәйләнү. *[Тавис] Кабинеттан чыкканда әтәчләнә иде әле: «Һе, кара син аны! Синнән куркып торган, ди! Мин синең үзеңне көл итәм!»* М.Маликова. *«Мәдәни» дигән даирәләрдә исә, гомумән, динне логикасыз, реаль дәлилләрсез «фаш итү», әтәчләнеп сүгү бик күпләрнең көн итү – тамак туйдыру әмәленә әверелде.* Ф.Дунай

**Әтәчләнә башлау** Әтәчләнергә тотыну. *– Гафу үтен хәзер үк! – дип әтәчләнә башлаган иде, эчен тотып,*

*бөгелеп төште. Ул минем самбист икәнлегемне белми иде шул, мескен.* Т.Миңнуллин

**Әтәчләнә бару** Торган саен ныграк әтәчләнү

**Әтәчләнә бирү** Әтәчләнүне дәвам итү

**Әтәчләнә төшү** Бераз әтәчләнү. *Шулчак Дәүран, әтәчләнә төшеп: «Мин аны даулап алырмын, анам бәгърем!» – дигән иде.* М.Хәбибуллин

**Әтәчләнеп алу** Кыска вакыт эчендә, бераз әтәчләнү. --- *егетләр арасында аның [Сәхилә] өчен әтәчләнеп алулар да булгалады.* Д.Каюмова

**Әтәчләнеп йөрү** Шактый вакыт әтәчләнү. *Ялга каршы көнне көн буе, бүген утыртып алып кайтммыйм мин аны, нигә шул хыянәтче белән бер чанада утырып йөрергә тиеш, ди, әле мин, дип, күңеленнән бик нык әтәчләнеп йөри.* В.Нуруллин

**Әтәчләнеп карау** Әтәчләнергә омтылу. *Иленә иминлек теләүчеләр барыр, ә инде кан теләүчеләр әнә әтәчләнеп карасын!.*.Б.Рафиков. – *Ә бит безнең әбиләребез бәбиләрен ат өстендә тапканнар, – дип әтәчләнеп карады Айбиби.* М.Хәбибуллин

**Әтәчләнеп китү** Көтмәгәндә, кинәт әтәчләнә башлау. *Артист – артист инде: үз мәсәленең персонажлары әтәч булса, «әтәчләнеп» китә, тавык икән – кытаклый.* Т.Миңнуллин

**Әтәчләнеп тору** Әле, күз алдында, хәзерге вакытта әтәчләнү. *Рәхмәт әйтәсе урында, әтәчләнеп тора, ичмасам...* К.Кәримов

**ӘТӘЧЛЕК** *и. сөйл.* Кемнеңдер холкындагы юктан кызып китүчәнлек, үтә гайрәт күрсәтергә, юк кына эштән дә мактанырга яратучанлык; тәкәбберлек сыйфаты. *Бөркетләрем! Әтәчлектән куркаклыкка – бер адым.* З.Мансуров. *Түбән очның Әтәч Закиры икән... Бернинди әтәчлеге юк, бу кушаматы аңа әтисеннән күчеп калган.* Р.Низамиев. *Кыяфәтендә бераз гына яшь әтәчлек тә бар бугай.* Ч.Айтматов

**Ә́ТЕКӘ(ЙЛӘР)ЕМ** *ы.* Нәрсәгә дә булса бик нык шаккату, гаҗәпләнү, соклану хисләрен белдерә. *Әтекәйләрем! Бакча хуҗасы аның озын колаклырыннан эләктереп алган да борыны төбендә бармагын янап тора, ди.* Л.Ихсанова

**ӘТИ** *и.* 1) Үзеннән туган балаларга ата булган ир-ат (атага мөрәҗәгать иткәндә яки аның турында сөйләгәндә кулланыла). *[Гөлйөзем] Әти, минем карыным ачты*. Т.Гыйззәт. *Әти, һәркөнне иртән, лампа куыгын бәллүр кебек җемелдәрлек итеп чистартып куя иде.* М.Галиев. *Менә ачык ишектән әти тавышы колакка чалынды*. Г.Бәширов // **этисе** *тарт. форм.* Хатынның иргә эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. *Ирек башын аска иде. Гөлҗамал, алар янына килеп: – Ярар инде, әтисе, кайтып кермәс борын, баланың йөрәгенә яра ясама, – диде*. Ф.Садриев

2) Хатынга ирнең атасы; каената

3) Үзенең балаларына карата ата мөнәсәбәтендә булган иркәк яки ир җенесендәге хайван, кош-корт һ.б.

**ӘТИ́-ӘНИ** *җый. и.* Әти һәм әни. *Өйдә минем әти-әнием һәм апамнан башка берәү дә юк.* А.Расих. *Ничекләр итеп әти-әнине яратмыйсың, ди!* З.Хөснияр. – *Кинога, – ди Аллида, – унсигез яшькә кадәр бары тик әти-әниләре белән генә йөриләр.* М.Мәһдиев

**ӘТИ́-ӘНИЛЕ** *с.* Әтисе дә, әнисе дә булган. *Әти-әниле кешеләрдән дә бәхетле бала дөньяда юктыр* ... Р.Вәлиев

**ӘТИЛЕ́-ӘНИЛЕ** *с. к.* **әти-әниле.** --- *үги балаларның бөтен җаннары белән аңа [үги анага] тартылулары – мактауга лаек. Кайберәүләр үз балаларыннан баш тарткан заманда, әтиле-әниле ятимнәр белән балалар йортлары шыгрым тулган вакытта – шундый хәл...* Т.Миңнуллин. *Керосин лампасы, кышкы озын кичле, әтиле-әниле, казан өстеннән пар бөркелеп торган итле шулпа исле балачак...* М.Мәһдиев

**ӘТИСЕЗЛЕК** *и.* Әтисез үсү, ятимлек. *Әй, бу әтисезлек! Әтисезлек аркасында, рухым да гарип булып киткәнме әллә минем?* С.Хафизов

**ӘТКӘ** *и. сөйл.* **1.** *к.* **әти** (*1, 3 мәгъ.*). *[Үги әни:] Болай булса, әткәгез кайтканчы, өйне ишеп төшерәсез сез.* Ф.Сафин. *Без икәү: Әткә куян, Әнкә куян, Яшь куянчыклар янә бездән туган*. Г.Тукай // **әткәсе** *тарт. форм. к.* **әтисе.** *Сүзгә әнисе Хәсәнә абыстай да кушылды: – Әткәсе, йә, җитәр, әллә Сабантуйдагы көрәшче кебек ыргытып бәрмәкче буласыңмы аны [Галимҗанны]?* С.Поварисов // **әткәм, әткәчем** *тарт. форм.* Балаларының, яратып, иркәләп, әтиләренә эндәшү яки әтиләрен атау сүзе. *И туган тел, и матур тел! Әткәм, әнкәмнең теле!* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* Әти (*4 мәгъ.*) булган, үз балалары булган. *Һәм әткә кошкай да шундый дәртле итеп, шундый онытылып сайрады.* Г.Хәсәнов

**3. әткәчем** *ы. мәгъ. к.* **әтекә(йләр)ем**. *Әткәчем, моннан исән-сау котылып кайтсам, ярты ел ураза тотарием, ди.* Ф.Шәфигуллин

**ӘТКӘЙ** *и. к.* **әти** (*1 мәгъ.*). *[Марат:] Әнкәй, анысын әткәй дә эшли ала, нигә тагы миңа кушасың инде?* Т.Гыйззәт

**ӘТМӘ** *и. диал.* 1) Тукыманың, тиренең һ.б. ике кырыеннан бергә беркетеп торган җөй

2) Су кошларының тәпиендәге йөзү ярысы

**ӘТМӘЛЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Нәрсә бар – шуның белән, җиткәне белән, тегеннән-моннан табып оештыру, рәтләү. *«Җирмазар алсак, палатка куеп булса да җәйне үткәрер идек, көзгә кадәр вакыт бар, ни булса да, куыш әтмәлләрбез!» – дип сөйләштеләр Нәҗип белән Наилә.* А.Гыйләҗев. *Колхоз идарәсе ярдәме белән, шунда утар сымаграк нәмәрсә әтмәлләделәр.* Ә.Баянов

**Әтмәлләп алу** Тиз арада әтмәлләү. *Китеп тор, мин аны хәзер үзем әтмәлләп алам!* Х.Ибраһимов

**Әтмәлләп кую** Тиз генә әтмәлләп әзер итү. *Кара, ничек җыйнак, ыспай итеп әтмәлләп куйды!* М.Хәсәнов

**Әтмәлләп ташлау** Тиз-тиз әтмәлләү. *Докладын да «һә» дигәнче әтмәлләп ташладым.* М.Сәлим

**ӘТНЕК** *и. диал. бот.* Кыңгырау чәчәкле суганчыл үсемлек. *Әтнек барда, ачтан үлмиләр.* Мәкаль

**ӘТРАФ** *и. гар.* **1.** 1) Тирә-юнь, әйләнә-тирә. *Әтраф тын, көймә тын, әлбәттә, күңел дә тын!* Җ.Вәлиди. *Чиксез иркен булган бу яклардагы башкорт җирләре – сөзәк кенә үрләр күтә-*

*релгән, үрләр төшкән, бөтен әтрафта тирән тынлык хөкем сөргән.* Ә.Еники. *Алай да бездә сезнең әтраф кебек үк түгел!* Г.Исхакый

2) Тирә, ян, кыр. *Оренбургның әтрафы һәм коры икән, һичбер яшел нәрсә юк, ләкин эчендә бакчалары күп икән.* К.Насыйри. --- *бөтен Дәүләкән әтрафын айкап йөрүдән дә туктап тормадык.* Ә.Еники. *Күрәсең, Хумаюн шаһзадә Хәйбәр тарлавыгы әтрафындагы җәйләүгә сунар чыкканын да, дошманы әфгани Сур токымы Шерхан тозагына эләгеп, күп дусларының үлгәнен дә тәфсилләп сөйләгәндер.* Р.Батулла

3) Чолганыш, даирә. *Мәскәүгә сыенган хаин татарлар да, Казандагы сатлыклар да, тәхет әтрафындагы шымчылар да, бу дошманлыкны көчәйтеп, Казанны астан кайната башлады.* Р.Батулла

4) Урын, як, тараф. *Шушы елгадан шәһәр һәм бөтен әтраф «Казан» дип аталмыштыр.* Һ.Атласи. *Бу әтрафтан китәргә кирәк!* Р.Сибат

**2.** *рәв. мәгъ.* Як-якка, тирә-юньгә. --- *яңадан бер мәртәбә әтрафына карап алып, чит кеше юк икәнлеккә күңеле кәмаль карар тапкач, --- өстәл өстенә дүрт-биш данә күгәргән алтын һәм җиде-сигез данә күгәргән көмеш акчаларны чыгарып салды.* Г.Камал

**3. әтрафына, әтрафында, әтрафыннан** *бәйл. функ.* Тарафына, ягына; тарафында, ягында; тарафыннан, ягыннан

**ӘТРАФЛЫ** *с.* Киңкырлы, күпьяклы. *Әтисе Миңнемөхәммәт агай инкыйлабка кадәр үк мәдрәсәдә әтрафлы белем ала.* Н.Гамбәр. *Анда киләкле курсәткечләр дә сайлап алынган, профсоюзлар белән эшләү буенча шактый әтрафлы белешмә дә бар иде.* Ф.Садриев

**ӘТРАФЛЫЛЫК** *и.* Күпьяклылык, киңлек, тирәнлек. *Шулай да Риза Фәхретдиннең куәтле сәләте, иҗтимагый, фәнни интересларының әтрафлылыгы, колачы, барыннан да калкурак, аның тарихи эзләнүләрендә чагылыш тапты.* Р.Әмирхан

**ӘТРАФЛЫ́ЧА** *рәв. сир. Казан муллаларын әтрафлыча вә бик әсаслы тәнкыйть иткәннән соң, мәдрәсәләрне шулар корпорациясенә тапшыру ислахны артка гына калдырачак.* Ф.Әмирхан

**ӘТРӘК** *с. сөйл.* **1.** Иске, алама, сәләмә. *Агай безне баштанаяк сөзеп карап алды да: – Бишмәтләрегез бик әтрәк күренә, һава салкынча, туңарсыз бит! – диде.* М.Галәү

**2.** *и. мәгъ.* Чүпрәк-чапрак, чүпрәк кисәге. *[Сауфия:] Тутакаем, табаныңда туфрак булаем, тирләгәндә әтрәк булаем, ятканыңда түшәк булаем, кисмә чәчемне.* Р.Батулла

**ӘТРӘ́К-ӘЛӘМ** *и. фар. сөйл.* Җәмгыятьтә абруйга, хөрмәткә ия булмаган, булдыксыз, хәерче, мескен кеше. *[Мияссәр:] Әй, Рәсим!.. Синең кызган чак, минем кайнаган вакыт, икебез дә – коры куык кияү егете, әйдә, теге әтрәк-әләмнәрне интернат тирәсеннән өшкереп җибәрәбез.* А.Гыйләҗев. *Хатын-кызлар төрле яктан кычкыра башладылар: – Ул әтрәк-әләм дә бүген монда булырга тиеш!* С.Зыятдинова

**ӘТРӘ́К-ӘЛӘМӘН** *и. гар. тар.* 1) Шәрыктә: ялланган гаскәрләр отряды

2) *күч.* Сугышта үлгәннәрне талаучы; мародёр

**ӘТРӘ́К-МӘТРӘК** *с. сөйл.* Вактөяк, килделе-киттеле. *Янәсе, Кашпировскийлардан һәм шуның сымак үрчегән җыен әтрәк-мәтрәк кооператорлардан кай җирең ким?* Н.Хәсәнов

**ӘТРӘ́К-ЧҮПРӘК** *җый. и.* Төрле чүпрәкләр, чүпрәк кисәкләре. *Тутай, төн буе, хаста хуҗаның башындагы әтрәк-чүпрәкләрен алыштырып, чылатып торды.* Р.Батулла

**ӘТТӘ** *и.* Әти (балалар телендә кулланыла). – *Әттә! Әттә! – Бала караватка таба тупылдап килде дә үзен әтисенең күтәреп алуын таләп итте. – Әттә, ыһ-ыһ. – Елап та җибәрде.* Ә.Баянов. *Өстәвенә «әттә» дип тә әйтә әле ул минем йөрәккәем. Яле, улым, «әттә» диген әле, сабыем…* З.Зәйнуллин

**Ә́ТТӘ ГЕНӘ ЛӘ** *ы. к.* **эттәгенәсе**

**Ә́ТТӘГЕНӘСЕ** *ы.* Әйтелү интонациясенә карап, мактану, масаю, горурлану, гаҗәпләнү, соклану, канәгатьлек һ.б. хисләрне белдерә. – *Кекин йортындагы ашханәдә эшләүче бер кызны каптырды бүген абзаң, әттәгенәсе! – дип шар ярды ул.* В.Имамов. *Менә әттәгенәсе! Киштәнең бер почмагында чып-чын гармун посып утыра иде.* Р.Низами

**Ә́Т-ТӘ-ТӘ** *ы.* Шаккату, гаҗәпләнү, соклануны белдерә. – *Әт-тә-тә, карагыз гына әле, карагыз, ничек бөтереләләр!* Г.Бәширов. *[Сәгыйтов:] Әт-тә-тә, акыллы баш табылды!* Ф.Сафин

**ӘТТӘХИЯТ** *и. гар. дини* 1) Намазның икенче һәм соңгы рәкәгатьләреннән соң тезләнеп утырып укыла торган дога. *Мөхәммәтҗан җизни аңа карап торды да шап иттереп тезләренә сугып алды: әттәхият – намаз укыганда тезләнү.* Г.Бәширов

2) *күч.* Тәртип, гадәт, кагыйдә; үзенчәлек. *«Мәчет саен – бер әттәхият» дигәндәй, квартал саен – бер храм, храм саен – бер дин.* М.Мәһдиев

◊ **Әттәхияткә утырту** *к.* **әттәхият укыту** *Без аларга «әһ» итәргә дә бирмәбез, әттәхияткә утыртырбыз.* Р.Хафизова. **Әттәхият укыту** Бик каты ачулану, җавапка тарту, нинди дә булса җәза бирү

**ӘТТӘХИЯТСЕЗ** *рәв.* Саубуллашмыйча, хушлашмыйча; рөхсәт-фәлән сорамыйча

**Ә́Ү** *ы.* Кемнең дә булса мөрәҗәгатен, эндәшүен ишетүне белдерү өчен, җавап яки сорау төсмере белән әйтелә. – *Әү, нәрсә дисең? – дип, икенчесе кулын колагына куйган булды.* З.Фәтхетдинов. – *Әүкәй, Исмәгыйль? – диде Наҗия, эт кояшыдай ялтырап.* Н.Фәттах. *[Сачтараш: (килеп керә)] Әү, ханым!* Н.Исәнбәт

**ӘҮВӘЛ** *рәв. гар.* **1.** 1) Саннар белән килгәндә: шулкадәр вакыт алда, элек. *Өч йөз еллар әүвәл, имештер, бөрҗән башкортлары яшәгән шушы төбәккә, җир эзләп, дүрт татар килеп чыгалар.* Л.Хәмидуллин. *Шубинның судтагы эшләре бер атна әүвәл генә беткән иде.* Ш.Мөхәммәдев

2) Күп еллар элек, элекке заманда, элегрәк. *Әүвәл ничек тордык?* Ә.Гаффар. *Әүвәлдә бу фәнне махсус кешеләр вә зур галимнәр өчен генә дип уйлаганнар.* Ф.Әмирхан. *Әүвәл өстәл янында дус булып бергә йөргән кешеләрнең һичберсе дә хәзер әйләнеп тә карамыйлар.* Г.Камал

3) Нинди дә булса бер эшне башкару алдыннан, башлап, башта, иң элек, иң беренче итеп. *Кеше, әүвәл, китапның тышлыгын тартып карады – нык икән, тиз үк умырылырга теләмәде, карышты.* Ә.Баянов. *Фарукҗан, шәһәрне чыгып, су буенда үскән бер агач ботагына кесәсендәге бер гәзит кисәген элеп куйды да, кулын күнектерер өчен, шуңа әүвәл – илле, аннары йөз адымнан атып карады.* Т.Әйди. *– Әбигә, әүвәл әбигә! – дип кычкыра башлады Рөстәм.* Г.Кутуй. *Башын иеп, йокымсырап, нарда утырган карт әүвәл аңышмыйча торды.* Р.Кәрами

4) Беренче, тәүге. *Әүвәл мәртәбә килгән кодаларыңнан чәй дә кызганып утырган шикелле сүз сөйлә, имеш!* Ф.Әмирхан. *Хадимәнең «комган» сүзен әүвәл мәртәбә ишетүе булганлыктан, «Иске татар сүзләре» исемле лөгать китабын карамаенча, бер җавап та бирә алмады.* Ф.Әмирхан

5) Беренче булып, алдан. *[Шаров Сәйдәргә:] Ачык ишеккә кем дә керә аны. Әмма әүвәл кергәннең хакы күбрәк була.* Г.Үзиле. *Тарантастан иң әүвәл Галәү сикереп төште, аның артыннан кечкенә, ябык кына кияү мулла төште.* Г.Исхакый. *Кемнәр ертыр бозык тәгълиматны, әүвәл үзем башлап ертмасам.* М.Гали

**2.** *с. мәгъ.* Баштагы, элеккеге; борынгы. *Әүвәл вакытларда аларга йөрсәң дә, ичмасам, аннан шатланып, күңелең күтәренке килеш кайта идең.* Г.Камал. *Әүвәл елларда ничек булса, бу ел да Мәкәрҗәдә халык бик күп иде.* Ш.Мөхәммәдев

**3.** *и. мәгъ.* Башланган вакыт, башланыш. *Әүвәлен беркем белмәс, ахырын да шулай ук, Әүвәле юк, ахыры юк, бер сәләмә дөнья бу.* Кол Шәриф. *Һәр нәрсәнең әүвәле һәм ахыры бар*

◊ **Әүвәл башта** Иң элек. *Әүвәл башта туп-туры Айтуган картка барып кердек.* Г.Бәширов

**ӘҮВӘ́Л-ӘҮВӘЛДӘН** *рәв.* Борын-борыннан, элек-электән, гомер-гомергә. *Финляндия татарлары әүвәл-әүвәлдән базар дөньясына якын булган.* И.Надиров

**ӘҮВӘЛГЕ** *с.* 1) Баштагы, башланган вакыттагы. *Шулай итеп, менә инде уенybыз яңадан әүвәлге дәртле хәленә кайта, дип торганда гына, тәрәзәдән тагын: – Гомәр! – дигән тавыш ишетелде.* Ф.Әмирхан // Алдагы, элеккеге. *Нинди дәрт белән каләм сызсам да кәгазь өстенә, Очмый әүвәлге юләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.* Г.Тукай. *Имеш, байның әүвәлге хатыны карт икәнме, авыру икәнме, нидер булган, ул инде әҗәл көтеп ята, имеш.* Г.Ибраһимов. *Тегеләр дә хәзерге Садыйк – әүвәлге Садыйк түгел икәнен сизенгән кебек.* Г.Исхакый. *Хәзер язучы исә укучыларга әүвәлге – имгәтелмәгән нөсхәсен тәкъдим иткән.* Р.Мостафин // Шул ук, элеккеге. *[Отряд] Икегә аерылып, бер пары көнчыгышка таба томырылды, икенчесе юлын әүвәлге юнәлештә дәвам итте.* Т.Әйди

2) Борынгы, борын замандагы, бик күптәнге. *Бик күп җырләрдә әүвәлге Шәрыкның халәтенә өстерәргә тырышу күренә.* Ф.Әмирхан

3) Күпмедер вакыт элек булган, элекке. *Ара-тирә, яңа байлар аны искә алсалар да, үзләренчә, зур мәҗлесләр ясап, карчыкны чакыртсалар да, болар, әүвәлге заманныкына караганда, көлке генә иде инде.* Г.Ибраһимов. *Әүвәлге заманнарда без, салкын кибеттә, иртә белән сәгать биштән башлап кара төнгә кадәр сату итәдер идек, алай да байга тиз генә ярап булмыйдыр иде.* Г.Коләхмәтов

4) Элек узган, элек үткән. *Әсма белән әүвәл танышкан мәҗлеснең кадерле хатирәләре искә килделәр: моннан ике ел әүвәлге корбан гаетенең өченче көне иде.* Ф.Әмирхан

5) Үткәндәге кебек. *Аякта, әүвәлге чабата урынына, өр-яңа җәйге резинка булуы дәртле никрутның башын тагы да югарырак күрсәтә.* Г.Ибраһимов

6) Беренче, тәүге. *Мондый нурлы көнне мин әле гомерем эчендә әүвәлге мәртәбә күрәм.* Ф.Әмирхан

**ӘҮВӘЛГЕ́ДӘЙ** *рәв. к.* **әүвәлгечә**. *Аның белән әүвәлгедәй дуслык бәхетендә йөзәргә күңелем тели.* Г.Ибраһимов

**ӘҮВӘЛГЕДӘН** *рәв.* 1) Элеккегә караганда. *Сугыш башлангач, әүвәлгедән дә яхшырак тора башладылар.* Г.Гобәй. *Парикмахер, әүвәлгедән дә килешле итеп: – Извольте-с Вас получить! – дип, безгә мөрәҗәгать итте.* Һ.Такташ

2) Элек-электән, борынгыдан. *Әүвәлгедән килгән йола*

**ӘҮВӘЛГЕСЕ́-АКТЫГЫ** *рәв. к.* **әүвәле-ахыры.** *Зиннәткә әйт, әүвәлгесе-актыгы шул булсын!* Г.Бәширов

**ӘҮВӘЛГЕ́ЧӘ** *рәв.* Элеккечә, баштагы кебек, элек булганча. *Ул һаман да лекцияләрен укыды, әүвәлгечә конференцияләрдә, симпозиумнарда катнашты.* Ә.Мушинский. *[Ашханәдә] Ул пилмәнне, әүвәлгечә чүмече белән генә тондырмыйча, иренен дога кылгандай кыймылдатып, кашык белән санап кына салды.* Ә.Гаффар. *Бу бала тугач, әтинең мине сөюе әүвәлгечә бөтен калса да, әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды.* Г.Тукай

**ӘҮВӘЛДӘН** *рәв.* Элек-электән, күптәннән, борын-борыннан. *Мәскәүдә әүвәлдән белеш-таныш байлар, фабрикантлар очрап, «Амур», «Эрмитаж», «Золотой якорь» вә гайре ресторуннарны һәммәсен зиярәт кылдылар.* Ш.Мөхәммәдев

**ӘҮВӘЛЕ** *рәв. к.* **әүвәл** (*3 мәгъ.*). *Әүвәле кабул итү булмәсендә бер-ике сәгать тозланасың, пешәсең, җитлегәсең, өлгерәсең.* Р.Зарипов

**ӘҮВӘЛЕ́-АХЫРЫ** *рәв.* Бөтенесе, бар булганы; беренчесе һәм соңгысы, башы һәм ахыры. *[Мәрәс:] (Кесәсеннән акчалар чыгара) И матри, башканы өмет итмә, аң бул! Әүвәле-ахыры шушы булсын!* Р.Хәмид

**ӘҮВӘЛТЕН** *рәв. сөйл.* 1) *к.* **әүвәл** (*3 мәгъ.*). *Нәкъ тугызда станция уты сүнә, карашымны иң әүвәлтен станция ягына юнәлтәм.* Ә.Гаффар

2) Элек, кайчандыр. *Әүвәлтен монда базарлар гөрләп торган*

**ӘҮКАТ** *и. гар. иск.* 1) Ризык, азык; мал, байлык. *Әүкате бар кеше теләгән вакытында ашар.* К.Насыйри

2) Яшәеш, тормыш. *Инде кабул күрмәсәң, Кайлардан кая китием? Арбакаш булып, су ташып, Әүкатемне итием.* Дастан

3) *күч.* Рухи азык, җан азыгы. *Җанга әүкат алырдай кеше дә юк...* Х.Сарьян

**ӘҮКАТЛЕ** *с.* Ризыклы, байлыгы, мал-туары күп булган. *[Сәхилә:] И ба-*

*лам, болар – бар да әүкатле кешеләр.* Н.Исәнбәт

**ӘҮКАТЛЕЛЕК** *и. иск. кит.* Әүкатле булу

**ӘҮЛАД** *и. гар. иск. к.* **әүляд**. *Баягы Тимгән шул җирдә истикамәт итеп, аның Чаныш дигән углы әүлады белән Бәләбәйгә күченгән.* Риваять

**ӘҮЛЕ** *и. гр. иск. диал.* 1) Биек койма белән әйләндереп алынган ишегалды

2) Тантаналы төс биреп эшләнгән зур капка

3) Ишектән керү алдындагы кечкенә бүлмә

**ӘҮЛЕ́-ТӘҮЛЕ БУЛУ** *ф.* Икеләнеп, аптырап тору, нәрсә эшләргә дә белмәү. *Әнә шулай әүле-тәүле булып торганда, кинәт ишек үзе ачылып китте.* В.Нуруллин

**ӘҮЛИЯ** [әүлийа] *и. гар. дини* **1.** 1) Ислам диненә чын күңелдән бирелгән, шул диннең нигезләрен халыкка тараткан, Аллаһның кодрәтенә инандырган изге кеше. *Елар идем, күздә яшьләр кипкән, Таулы-ташлы барыр юлыбыз... Беркемне дә алдамыйча китәм, әүлияләр, дога кылыгыз!* Г.Афзал

2) Изге күңелле, күңеле гел яхшылыкта булган кеше, изге җан, изге зат. *Чыннан да, берәү үзе турында шундый итеп тел тегермәне тарта, дус-дошман арасында шундый кече күңелле итеп күрсәтә, «чын әүлия» дип уйлыйсың.* Н.Хәсәнов. *Мәдәниятле теге әүлия янында ферма исе сеңгән күлмәк-ыштаннан утыру дөрес булмас иде.* Ф.Садриев. *Болар бәрәңге ашап яши торганнардан түгелдер – әүлиялардыр.* Ә.Баянов

3) Киләчәкне әйтеп бирүче, күрәзәче; нәрсә буласын алдан белүче. *Аның хакында электән үк «әүлия икән, кешенең күңелендә ни барын белә икән, алдан биргән хәбәрләре дөрес чыга икән» дип сөйлиләр иде.* Г.Ибраһимов. *Күңел – әүлия диләр бит, дөрес сүз икән.* Г.Ибраһимов. *[Вәзир:] Юк, падишам, мин сихерче дә, тылсымчы да, әүлия да түгел.* В.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* Кешелекле, ярдәмчел, шәфкатьле. *[Балыкчы:] Малтабар булса да, әүлия кеше.* Ф.Латыйфи. *Теге чакта баш рольне уйнаган әүлия егетне таный язса да, Ильяс үзе аңа әллә ни игътибар итә алмады.* Ә.Баянов

**ӘҮЛИЯЛАНУ** *ф.* Яхшы, изге кеше булып кылану; изге кешегә охшарга тырышу

**Әүлияланып йөрү** Кешеләр, халык алдында үз-үзен әүлия итеп күрсәтү. *Ләкин асылда алай инсафлы булмаган, Равилнең башын-күзен әйләндерер өчен генә шулай әүлияланып йөргән икән ул.* В.Нуруллин

**ӘҮЛИЯЛЫК** *и.* Әүлия булу. – *Һәр кешедә тары бөртегедәй әүлиялык бар, дип әйтәләр, ә бу абыйда әүлиялык бар да бар, – диде әни.* Н.Кәримова. *Бу нәрсә? Әүлиялык кылумы, үз язмышыңны аермачык сизү, тою, күрүме?* Д.Вәлиев

**ӘҮЛЯ** *рәв. гар. иск.* **1.** Артыграк, өстенрәк, алдынгырак, яхшырак. *Болай сайрау кавышканнан соң булыр әүля.* М.Гафури. *Кемнәргәдер бер сыныкка баш игәнче, Үз җаныңның, үз бәгъреңнең каны әүля.* Х.Туфан

**2.** *хәб. функ.* Яхшы. *Газанфәр ага күрде, ул егет килә. Каршы чыгып, хуш, әүля, боерыңыз, дип, өенә алып керде.* К.Насыйри

**ӘҮЛЯД** *и. гар. иск.* 1) Ул, угыл; бала. *Иң сөекле эшче әүлядым быел ач калды, дип, Изге, шәфкатьле анабыз – мәрхәмәтле җир җылый.* Г.Тукай

2) Токым, нәсел. *Чыгтай әүлядыннан падишаһлыкка лаек кеше калмады.* Әбелгази Баһадир

**ӘҮМӘК** *и.* Берсе өстенә берсе егылып өелгән кешеләр күче (уенда)

**ӘҮМӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) *к.* **әүмәкләү** (*1 мәгъ.*). *Аның чәчләре битенә төшкән, ул авыр гәүдәсе белән әүмәкләнеп шуыша иде.* Г.Бәширов

2) Берсе өстенә берсе өелү. *[Аю балалары] Әле аяк астында аунап, әүмәкләнеп, кешегә йөрергә ирек бирмиләр, әле сәке өсләренә менеп чүлмәкләрне аударалар да әйберләрне түгәләр иде.* Р.Гали. *Көзге күктә болыт бар, әүмәкләнеп агышы.* К.Сибгатуллин

**Әүмәкләнә башлау** Әүмәкләнергә тотыну

**Әүмәкләнеп китү** Кинәт әүмәкләнә башлау

**Әүмәкләнеп тору** 1) Әүмәкләнгән хәлдә булу

2) Бертуктаусыз әүмәкләнү

**ӘҮМӘКЛӘҮ** *ф.*1) Әле – бер, әле икенче якка янтаеп, бер яктан икенче якка авып хәрәкәтләнү. *Яшел «газик», тракторлар сырлап бетергән тигезсез юлда як-якка тирбәлеп, әүмәкләп, Күктугай ягына китеп барды.* Н.Фәттах

2) Аунату, тәгәрәтү (җирдә, карда). *Без аны үзебез дә әүмәкләр идек шунда.* А.Алиш

**Әүмәкләп бетерү** Тәмам, озаклап тәгәрәтеп әүмәкләү

**Әүмәкләп салу** Кинәт әүмәкләү, аягыннан егу. *Берәүне ничек кирәк алай әүмәкләп салгач, әтәчләнеп, тагы кереп баскан иде, икенче бер йомры гына адәм моны баш аркылы шундый томырды, мәйдан халкы «Ма-ла-дис!» дияргә генә өлгереп калды.* Ф.Хөсни

**ӘҮМӘКЛӘШҮ** *ф.* **1.** Бер-берсен тарткалап, берсе өстенә берсе егылып аунашу; берсе өстенә берсен өем ясап, егып уйнау; егылып, күчкә өелү. *Әүмәкләшкәндә ялгыш атылган пуля Булганинның яңагын кисеп үтте.* Ә.Гаффар. *Юк, Матушкин сөрлекмәгән, абынмаган һәм аны җил дә бәреп екмаган иде: ул ниндидер күзгә күренмәс бер дошманның бугазына ябышкан да, имеш, аның белән кар өстендә әүмәкләшә иде.* Ә.Мушинский

**2.** *рәв. мәгъ.* Берсе икенчесен узауза, берсе икенчесен каплап, өсте-өстенә өелеп. *Әүмәкләшә-әүмәкләшә, өсте-өстенә өерелешеп килгән болытларга күзем төште.* Ә.Гаффар

**Әүмәкләшә башлау** Әүмәкләшергә тотыну. *Икәүләшеп йолкыйбыз, тегермәнче малае егәрле, Рәфгатьне кагып кына җибәрде, без әүмәкләшә үк башладык.*А.Гыйләҗев

**Әүмәкләшә тору** Әле, хәзер әүмәкләшү; озак вакыт әүмәкләшү. *Малайлар, әүмәкләшә торгач, ике карлыган куагын изеләр ---.* А.Гыйләҗев. *Шулай алар, шаярышып әүмәкләшә торгач, кочаклашкан килеш, түшәк-мендәрләре белән бергә, идәнгә – йомшак келәм өстенә килеп төштеләр.* Г.Гыйльманов

**Әүмәкләшеп алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада әүмәкләшү. *Окопташ*

*дуслар, кочакланышып, яшел чирәмдә әүмәкләшеп алалар.* Р.Төхфәтуллин. *Наилә алгы өйдән кер бавы табып чыкканчы шактый вакыт үтте, тегеләр тагын әүмәкләшеп алдылар бугай, шакылдау, дөбердәү көчәеп алды.* М.Маликова

**Әүмәкләшеп бетү** Барысы да әүмәкләшү. *Малайлар, кызлар бергә җыелабыз да көлешә-көлешә узышабыз, бер-беребезнең өсләренә егылып, әүмәкләшеп бетәбез.* Н.Хәсәнов

**Әүмәкләшеп китү** Кинәттән яки көтмәстән әүмәкләшә башлау. *Заһит шул ук секундта биюче өстенә ыргылды, ләкин эләктерә алмады, чыр-чу килеп, аның үзен камап алдылар, кайсы – муенына, кайсы аяк-кулларына асылынды. Әүмәкләшеп киттеләр.* М.Әмирханов

**Әүмәкләшеп кую** Кинәт кенә әүмәкләшергә тотыну; кыска гына вакыт әүмәкләшү

**ӘҮМӘ́К-ТӘҮМӘК** *рәв.* Көч-хәл белән, ава-түнә. *Әүмәк-тәүмәк килеп, самолёттан чыктым да, үрмәләп барып, үлән арасына кереп яттым.* М.Юныс

**ӘҮМӘЛӘ** *и. диал.* Кайнап торган каймакка он салып, болгата-болгата, зур казанда пешерелә торган боламык. *Бөтенесе шунда утырып, матур итеп ашыйлар әүмәләне*

**ӘҮМӘЛӘНДЕРҮ** *ф.* Әвәләү, тәгәрәтү

**Әүмәләндереп бетерү** Тәмам, бик нык әүмәләндерү

**Әүмәләндереп җибәрү** Нәрсәне дә булса әүмәләндерә башлау

**Әүмәләндереп тору** Һәрберсен, булган берсен әүмәләндерү

**ӘҮМӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Әле – бер, әле икенче якка янтаеп, бер яктан икенче якка авып хәрәкәтләнү

2) Әвәләү, аунату

**Әүмәләп китү** Кинәт, уйламаганда әүмәләү. *Әүмәләп китте читән дә, Мин дә йөзтүбән киттем.* Н.Исәнбәт

**Әүмәләп тору** Әле, хәзерге вакытта әүмәләү

**ӘҮМӘЛӘШ** *и.* Бөтенесе бергә буталып тәгәрәшү һәм, шул ук вакытта, бер-беренә төрткәләп суккалашу. *Әз генә вакыт дәвам иткән буталыш, чуалыш һәм әүмәләш, ябырылып, кеше кыйнауга әверелде.* М.Галәү

**ӘҮМӘЛӘШҮ** *ф. к.* **әүмәкләшү**

**ӘҮМӘЛҮ** *ф. диал.* 1) Күңелгә килгән, тел очына килгән сүзне әйтә алмыйча тору. *[Ул ятимнең] Әүмәләдер тел очында ошбу сүз: «И Ходай, үстерсәнә бәхетем белән, Мин барырмын инде изге юл белән: Барча кошларны сөярмен җан белән.* З.Ярмәки

2) Тәгәрәп, егылып китү

**ӘҮМӘ́Н-ТӘҮМӘН** *рәв.* Ян-якка авып, як-якка чайкалып; алпан-тилпән, ава-түнә. *Үрдәк кебек чүгеп, әүмән-тәүмән атлап барган хатыннарның чиләге яртылаш кына калган, ә аның – мөлдерәмә тулы.* М.Маликова

**ӘҮМӘ́Н-ТӘҮМӘН КИЛҮ** *ф.* Әле – бер якка, әле икенче якка янтаю, авышу. *Машина, дымлы караңгылыкны фаралары белән ертып, әүмән-тәүмән килеп, авылдан чыгып китте.* М.Маликова

**ӘҮМӘШТЕРҮ** *ф. сөйл. к.* **әмәлләү**

**Әүмәштереп кую** *к.* **әмәлләп кую.** *Үзебезгә кечкенә генә саман өй дә әүмәштереп куйдык.* Н.Дәүли

**ӘФӘНДЕ** *и. төрек < гр.* 1) Хөрмәт йөзеннән, ир-ат исеменә кушып әйтелә торган сүз. *[Хөсәен:] Хәтерлисезме, унынчы елны Галиәсгар әфәндене́ң әдәби эшчәнлегенә ун ел тулу юбилеен уздырган көннәрне?* А.Расих. *Хөсәен әфәнде европача киенгән.* В.Юныс

2) Ир-атларга мөрәҗәгать итү сүзе. *– Әфәнделәр, – дип башлады сүзен прапорщик Ильяс Алкин.* Р.Мөхәммәдиев

3) Исеме билгеле булмаган ир-ат, ир кеше. *Әчтерханда бер югарыдагы әфәндедән законлы кәгазь юнәттем.* Ә.Гаффар. *Упкынның бөтен тирәнлеген аңлагач та, Иоланта чит илдән килгән әфәндегә --- гаять кискен сүзләр әйтә.* Б.Камалов

**ӘФӘРИН** *ы. к.* **афәрин**. *– Мәрхәбә вә мәртәбә! – диде Бабур падишаһ. – Әфәрин!* Р.Батулла

**ӘФГАН** *и.* Әфган телендә сөйләшүче, сөнни мөселман динендәге, Әфганстанда яшәүче төп халык (үзатамалары – *пуштун*); шуның бер кешесе. *[Фарукҗан]: – Шәмгун абый, Рахманколның әфган сәүдәгәре Габделшөкерхан белән танышлыгы нәрсәгә нигезләнә икән?* Т.Әйди

**ӘФГА́Н ҖИЛЕ** *и. геогр.* Амударья елгасының югары агышында көньяк-көнбатыштан исә һәм үзе белән бик күп ком, тузан алып килә торган җил. *Үзбәкстанның Термез районында ел саен 30–70 тапкыр әфган җиле күзәтелә.* География

**ӘФГАНЛЫ** *и. к.* **әфган.** *Әфганлы тагын башын селекте.* Ш.Усманов. *Өч мең әфганлы безнең алты йөз солдатны кырып китә.* Р.Хисмәтуллин

**ӘФГАНЧЫ** *и. сөйл.* Әфган сугышында катнашучы. *– Нәрсә, сез әфганчымы әллә? – Әйе, әйе… мин анда ике ел сугыштым.* Н.Хәсәнов

**ӘФЛӘТУН** *и. гар.*<*гр. сөйл.* 1) Укымышлы, гыйлемле кеше (борынгы грек философы Платон исеменнән).

2) Дөньядан ваз кичкән, дәрвиш табигатьле кеше

**ӘФЛИСУН** *и. голл.* 1) Рутачалар семьялыгыннан, тропикларда һәм субтропикларда үсә торган мәңге яшел җимеш агачы. *Без, хөрмә һәм әфлисун бакчаларын карый-карый, сәяхәтне дәвам итәбез.* В.Юныс

2) Шул агачның кызыл сары төстәге, түгәрәк яки озынчарак формадагы, шадраланып торган кабыклы, эче сусыл өлешләрдән гыйбарәт әчкелтем баллы җимеше; *русчасы*: **апельсин**. *Әнә бит тәмле-тәмле ризыклар, өстәлләрдә – әфлисун тутырылган савытлар, аракы, шәрап, сыра салынган бокалларны теләр-теләмәс кенә иреннәренә тигереп утыручы тук бәндәләр.* Ф.Садриев. *Ун-унбиш данә генә әфлисун да ал.* Г.Исхакый

**ӘФЛИСУ́Н ТӨСЛЕ (ТӨСЕНДӘГЕ)** *с.* Кызыл сары. *Ә анда, ял көне булуга карамастан, әфлисун төсендәге җиңсез куртка кигән юан-юан хатыннар асфальт ватарга керешкән иде.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш

**ӘФСАНӘ** *и. гар. иск.* 1) Фантастика

2) Язма әкият. *Ул, милли вазифа башындагы гаскәр кеби, берсе артыннан берсе, балалар өчен, кыйраәт китаплары өчен йә тәрҗемә, йә оригиналь бик күп шигырьләр, әфсанәләр, хикәяләр мәйданга китерәдер.* Г.Исхакый

**ӘФСЕН** *и. фар.* 1) Сихерләү яки өшкерү сүзләре, сихри көчкә ия дога. *Жирең янса, Кояш улы янган төсле яшендә, – көлгә җан-рух өрер өчен ярдәм итмәс әфсен дә...* З.Мансуров. *Канатланып киткән Иблис борын астыннан гына әфсен әйтте.* З.Мәхмүди

2) Сер, тылсым. *[Әниләре Мотахара апа:] Мирсәет бал кортларының әфсенен белә бугай ул.* Г.Тавлин

◊ **Әфсен өреп** *к.* **әфсен укып**. *Чәчәк атмый быел минем гөлләр. Тик табигать – үзе могҗиза: Чәчәк сыман сулган чакларыңда, Әфсен өреп, тартып торгыза.* Ф.Мөслимова. **Әфсен укып** 1) Сихер белән, сихри көчкә ия сүзләр белән тәэсир итеп. *Ишнияз бабай әйтә: «Әкияттәге Әбүгалисина сыман, әфсен укып кына эшләде ул аны», – ди.* Р.Ишморат. *Артларыннан дию пәрие куып килүен белгәч, диюдән качып өенә кайтып баручы патша кызы, әфсен укып, үзе тегермән булган, аны коткаручы батыр егетне тегермәнче иткән бит.* Г.Бәширов; 2) Тылсым белән; җиңел, җайлы итеп. *Кәслегә иртәгәдән калмый, ишетәсеңме, иртәгәдән калмыйча, җитмеш биш чана чыгарырга кирәк. Ә ул җитмеш бишне әфсен укып җыясыңмы?* А.Гыйләҗев

**ӘФСЕНЛӘТҮ** *ф.* Нәрсәне дә булса сихри көчкә буйсындыру, әфсен-төфсен укытып җиңү

**Әфсенләтеп бетерү** Тәмам, бик нык әфсенләтү; барысын да әфсенләтү

**Әфсенләтеп җибәрү** Бераз әфсенләтү

**Әфсенләтеп кую** Алдан ук әфсенләтү

**Әфсенләтеп тору** Әледән-әле, еш әфсенләтү

**ӘФСЕНЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Әфсен ярдәмендә йогынты ясау; теләсә ничек алдау, ялганлау. *Яңа эрага кадәр 90 нчы еллар тирәсендә һуннар, Кытай гаскәрләрен әфсенләп, алар киләсе юлларга, елга кичүләренә ырымланган тәкә һәм үгез түшкәләрен күмгәннәр.* А.Мөхәммәдиев. *Бик күп кешеләрнең күңеленә үтеп кереп, алдап-йолдап, әфсенләп, Елантауга әсирлеккә алып китteләр.* Р.Батулла

2) Әфсен укып, илаһи көчләрне ярдәмгә чакыру. *Ул кармакны үзенчә әфсенләп сала: «Әпсен-төпсен, балык чиртсен, җимне тапсын, килеп капсын», – ди дә кармагына берничә мәртәбә төкереп куя.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ. күч.* Законсыз оештырылган. *Үзегез әфсенләгән язу гына түгелме бу?* Т.Әйди

**Әфсенләп бетерү** Әфсенләү дәрәҗәсенә җитү, бик нык әфсенләү

**Әфсенләп кую** Алдан ук әфсенләү

**Әфсенләп тору** Һәрвакыт, гел әфсенләү

**Әфсенләп чыгу** Һәрберсен, бер-бер артлы әфсенләү; башыннан ахырына кадәр әфсенләү

**ӘФСЕ́Н(ЛӘҮ)-ТӨФСЕНЛӘҮ** *ф.* 1) Әфсен-төфсен уку, шулар ярдәмендә, кемгә яки нәрсәгә дә булса тәэсир итәргә тырышу. --- *кәнфиттән әвәләгән булсын, прәннектән катырган булсын, дип, әфсенләп-төфсенләп, малай үстереп ята, дисеңме?* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Җайлау, көйләү. *Кунакны шашлыкка алып киттем. Әфсен-төфсенләп, «норма»ны «шапылдаттык».* Т.Нәҗмиев

**ӘФСЕ́Н-ТӨФСЕН** *җый. и.* 1) Һәртөрле әфсеннәр, сихерләү сүзләре, өшкерү догалары. *Аның әфсен-төфсене файда бирмәде.* З.Зәйнуллин

2) Әфсенгә охшатып әйтелгән ырымлау, өшкерү сүзләре. *Әфсен-төфсен, бетсен, дөмексен, бүрәнә бассын, җил алсын.* Әйтем-теләк

**ӘФСЕНЧЕ** *и.* Тылсымлы догаларны, өшкерү яки сихерләү сүзләрен белүче; шулар ярдәмендә нәрсәгә яки кемгә дә булса тәэсир итәргә сәләтле кеше; сихерче, им-томчы

**ӘФТӘРЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Юк итү, юкка чыгару, яшерен үзләштерү. *Менә шуларның бихисап күп йомыркалары тулмый икән. Кыскасы, әллә әфтәрләгәннәр, әллә «аю мае сөрткәннәр» инде.* Т.Нәҗмиев

**ӘФТИЯК** *и. фар. сөйл.* 1) Җиделән бер өлеш; һәфтияк

2) *дини* Коръәннең еш укыла торган сүрәләрен, аятьләрен үз эченә алган китап. *Мин укыганмындырмы, юкмы – ул кадәресен белмим, – әмма, һичбер язу танымаган көйгә, мулланың, аркага камчылар төшергәләп, әфтияк сүрәләре бикләткәнен һәм, кичке сабак кереп, шуларны тыңлатканын беләм.* Г.Камал

3) *күч.* Коръән; гомумән китап. *Мин беләм, синең күңелең – мәгърифәт юлында. Кулларың, кылыч түгел, әфтияк тотарга өйрәнгәннәр.* Т.Миңнуллин

◊ **Әфтияк калынлыгы** Бик юка. *Алачагы Әфтияк калынлыгы, бирәчәге Коръән калынлыгы.* Н.Исәнбәт

**ӘФТИЯ́К ИҖЕГЕ** *и. иск.* Иске ысул белән язылган хәрефләрне танырга өйрәнгәннән соң, иҗекләп уку дәресе. *Гайшә берничә еллар буенча абыстайга сабакка йөргән иде. Ләкин әфтияк иҗегеннән үтә алмады.* Г.Ибраһимов

**ӘФЬЮН** *и. гр.* Өлгереп җитмәгән мәкнең сөт сыман сыгынтысыннан киптереп ясалган көчле наркотик матдә (фармакологиядә төрле дарулар ясау өчен дә файдаланыла); *русчасы*: **опиум**. *Ләбихәвез әрбаб мәхәлләсендәге шундыйрак бер оя әфьюн тартучылар аркасында туздырылганнан соң, Бохараның кайбер әһелләре Газәлидә күңел ача башлаган.* Т.Әйди. *Әйе, үзен агулаган әфьюннан авыз иткәч, тele ачылды [Тынчуринның].* Г.Үзиле. *Аның эчүен һәм әфьюн белән мавыгуын да сизмәмешкә салышалар иде.* Ә.Фәйзи

◊ **Әфьюн бизмәне белән** Кат-кат, граммын граммга туры китереп, нечкәләп. *Мә, түгә-нитә күрмә, әфьюн бизмәне белән үлчәнгән.* Н.Исәнбәт

**ӘФЬЮНЛЫ** *с.* 1) Әфьюны булган

2) Наркотик

**ӘФЬЮНЧЫ** *и.* 1) Әфьюн кулланучы кеше, наркоман

2) Әфьюн сатучы кеше. *– Хәзрәт, синең әфсеннәреңнән ут тагы да шәбәеп китте шикелле, – дигән була һаман да шул әфьюнчы Һидият.* Т.Мөбарәков

**ӘХ** *ы.* 1) Ис, тәм тоюдан яки көндәлек тормыштагы башка уңайлыклардан канәгатьлек кичерү, ләззәт алу хисләрен белдергәндә әйтелә. *Нуриман, кайнап чыккан суга бер чеметем чәй салып, хуш ис иснәгәндәй, «әх!» дип куйды.* Ә.Мушинский. *«Әх, шәп тә соң мунчасы», – ди-ди, пар өстәп, тагын чабынырга тотынды Шиһап.* Заман

2) Күңел күтәрелү, дәртләнү, соклану, шатлану һ.б.ш. хисләрне белдерү

өчен кулланыла. *Уйный ые да соң, әх, уйнап та күрсәтә ие соң!* Ә.Гаффар. *Әә-әх, әни, суык. Кар шыгырдап тора. Чана шәп шуачак бүген.* Р.Мөхәммәдиев

3) Кайгыру, ачыну, үкенү, ачулану һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен әйтелә. *Әх, заманасы шундый иде бит, Мотаһир.* Р.Кәрами. *Әх, минәйтәм, баш китте, харап булдык, минәйтәм.* Г.Ибраһимов. *Әх-х, картлач, күрәзәлек итеп утырудан башка чараң калмады, дип, үз-үзен битәрләде Габдуллин.* Ш.Шәйдуллин

4) Кызыгу, көнләшүне яки көчле теләкне белдерү өчен кулланыла. *Әх, ди, әгәр саулыгым булса, ди, хәзер белер идем мин ничек эшләргә, ди.* А.Шамов. *Әх, күзне ачып булсын иде.* Х.Камалов

**ӘХВАЛЕ́ РУХИЯ** *и. гар. иск.* Психик халәт, эчке кичерешләр, рухи торыш. *Бу кешедә, болай караганда, һичкемгә изгелек итү, кешенең әхвале рухиясенә төшенү, башкаларның положениясенә керү ихтималы юк кебек күренә иде.* М.Гафури

**ӘХВАЛЬ** *и. гар. иск. к.* **әхвәл.** *Калебеңдә ни сер бар, гаян ит, Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.* Дәрдемәнд

**ӘХВӘЛ** *и. гар.* Билгеле бер эшкә, мәсьәләгә, шәхескә бәйле торыш, халәт. *Хөрмәтле сәр, күрсәтмәләрегез буенча, Бохара әхвәлләрен ачыклауны һәм кайбер ашыгыч чаралар күрүне дәвам итәм.* Т.Әйди. *Халыкка һәртөрле әхвәлне аңлата торган китапларны укырга кирәк.* Л.Хәмидуллин

**ӘХКАРЬ** *с. гар. иск.* Түбән, хур ителгән. *Җиһанда миннән әхкарь һич кеше юк, мине кызган!.. Мине кызган, туганым!..* М.Гафури

**ӘХЛАК** *и. гар.* Җәмгыятьтә һәм кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, мөнәсәбәтләр нормасы һәм принциплар җыелмасы. *Шулар арасында иң аянычлысы – халкыбызның милли педагогикасы, күп гасырлар буе камилләштерелгән гаилә кануннары һәм дин тәрбияләгән әхлак кагыйдәләре.* Ә.Юнысов. *Урта гасыр әдәби мирасы бүгенге кешенең сәламәт әхлагын тәрбияләүдә зарури һәм алыштыргысыз чара буларак бәяләнә.* Н.Хисамов

**ӘХЛАКЛЫ** *с.* Әдәпле, тәртипле, үз-үзен культуралы тота белгән, яхшы тәрбия алган. *Егермеләргә җиткәч, һәйбәт әхлаклы хәлфә кыяфәтендә уйларга өйрәнгән.* Г.Ибраһимов. *Әхлаклы булган булып азапланасызмыни инде?* Ф.Әмирхан

**ӘХЛАКЛЫЛЫК** *и.* Әхлаклы булу. *Җирдә иң зур, иң бөек әхлаклылык бар. Ул – җан иясен ярату, җанны ярату.* З.Садыйков

**ӘХЛАКСЫЗ** *с.* Әхлак кагыйдәләрен үтәмәгән, тотнаксыз, тәрбиясез, әдәпсез. *Колхозның үзендә картлар йорты булдыру кирәклеген башлап ул күтәрде һәм моның әти-әниләрен багарга теләмәгән әхлаксыз яшьләрне тәрбияләүдә төп чара икәнлеген исбат итә алды.* Г.Ахунов

**ӘХЛАКСЫЗЛАНУ** *ф.* Әхлак нормаларын бозу, үз-үзен әхлаксыз тоту, әхлаксызлык сыйфатлары күрсәтү

**Әхлаксызланып бетү** Бөтенләй, тәмам әхлаксызга әйләнү

**ӘХЛАКСЫЗЛЫК** *и.* Әхлак кагыйдәләренә туры килмәү, аларны бозу күренеше. *Чыннан да, Мирхуҗинны әхлаксызлыкта гаепләргә ни хокукы бар аның.* М.Маликова. *Дөньяга чисталык кына дәгъвалаган уйларым әхлаксызлык булып эшкә ашты.* Ә.Гаффар. *Бюрократларга, әшнәлеккә, әхлаксызлыкка каршы көрәш дәвам иткән чорда, әдәбият мәйданында сугышчан жанрлар алга чыга.* Казан утлары

**ӘХЛАКЧЫ** *и.* Әхлак кагыйдәләренә өйрәтүче, алар турында башкаларга җиткерүче

**ӘХЛАКЧЫЛЫК** *и.* Әхлакка өйрәтү, әхлак, тәрбия эше. *Шуның белән бергә, бу әсәрдә заман модасы буреләп, әдәбиятта әхлакчылык тенденцияләрен үткәрү дә шактый ачык сизелеп тора.* М.Гали

**ӘХЛАКЫЙ** *с. гар.* Әхлакка бәйләнешле, әхлакка мөнәсәбәтле. *Сагындырганы, бөтен вөҗүдемне биләп тартып торганы – халыкның бердәмлеге, адәм баласы чыдамаслык авырлыкларны җиңеп, күңел сафлыгын, әхлакый бөеклеген саклау көче.* К.Тимбикова. *Халык иҗатында, кешегә акыл бирү нияте белән, теге яки бу хәлгә бәйләп, гыйбрәт итеп сөйләнә торган һәм әхлакый мәсьәләләргә багышланган кыска хикәяләр бар.* Казан утлары

**ӘХТӘРИ** *и. гар. сөйл.* 1) Рәсемле китап («Әхтәрикәбир» дигән сүзлек исеменнән)

2) Кәрт

3) Кәрт уенының бер төре

**ӘХ-ТИ** *ы. к.* **әх**. *Әх-ти, тагын бераз йокы симертеп алсаң ни була инде, ә!..* Ф.Сафин

**ӘҺӘ** *ы.* 1) Сөенү, куану, канәгатьләнү хисләрен белдерә. *Лейтенант идәнгә чүкте. – Эзләп карыйк әле… Әһә, мин инде икесен таптым, – дип сөенде, – кара, топаз ич бу!* З.Фәтхетдинов. *Әһә, менә, [бау] шикәр капчыгы артына төшкән икән…* М.Маликова

2) Нәрсәне дә булса тиз генә төшенеп алганны белдерә. *Фәһим абзый бераздан гына аңына килде: – Халык минем хакта ни әйтер? Ә-һә, дияр, алты почмаклы нарат йортны булачак киявен өчен тырыштырган икән. Ә-һәә, баш ветеринар урынын да киявенә саклап тоткан, дияр.* Г.Ахунов. *Әһә, менә нинди ят тавышлы кеше бар икән монда, – дип уйлады Габделхәй, чыраен сытып.* Н.Фәттах

**ӘҺӘМИЯТ** *и. гар.* 1) Мөһимлек, зарурилык; актуальлек. *Бер Семагин өчен генә түгел, ә Мәхмүтов өчен дә бу җыелышның әһәмияте бик зур иде.* Р.Кәрами

2) Нәрсәнең дә булса җәмгыятьтә тоткан роле, урыны, кыйммәте. *Экспедициянең тәрбияви әһәмияте хакында әйтеп тә тормыйм инде.* Ә.Мушинский. *Байлык белән ярлылык та гашыйклар арасында шундый ук киртә иде, ә хәзер аның ни әһәмияте бар?* Ә.Еники. *Ләкин, беренче карашка, шулай һәркемнең эчке эше генә булып тоелса да, әлеге мәсьәлә зур иҗтимагый әһәмияткә ия.* Казан утлары

3) Берәр нәрсәнең мәгънәсе, кирәклеге, аңа ихтыяҗ булу. *Байкучатов җырның бөтен сүзләрен ишетеп бетермәде, хәер, моның инде хәзер әһәмияте дә юк иде.* Т.Әйди

4) Игътибар, дикъкать. *Рота командиры, бөтен әһәмиятен картага биргән булып, башын күтәрмичә генә әйтеп куйды.* Г.Гобәй

**ӘҺӘМИЯ́Т БИРҮ** *ф.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса игътибар итү, дикъкать белән карау. *Бераздан, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алгач, моңа артык әһәмият бирми башладык.* Ә.Галиев. *Тик сәндерәдән озын аякларын салындырып утырган бер киң кара кашлы, ачулы зур күзле таза шәкерт кенә бу эшкә әһәмият бирде.* Ә.Фәйзи

**ӘҺӘМИЯТЛЕ** *с.* Мөһим булган, кирәкле саналган. *Шуңа күрә ул хәзер үзе бик әһәмиятле дип санаган уйларын уртаклашырга теләде.* Т.Әйди. *Мөгаен, бригада, терлекче, механизатор йортларына таралгандыр, шушындый мөһим, әһәмиятле вакытта монда ятмаслар, дип уйлады кыз.* Ф.Гыйльми. *Әмма алар, бала турында гына түгел, зуррак, үз тормышлары өчен әһәмиятлерәк нәрсәләр хакында сөйләшәләр иде шикелле.* М.Маликова

**ӘҺӘМИЯТЛЕЛЕК** *и.* Әһәмиятле булу, мөһимлек. – *Кичә төнлә бүре килгән! – дип, иртәгәсен сөйләнгән хәбәр, шом катыш серлелек, зурлык, әһәмиятлелек белән, йорттан йортка йөри иде.* М.Мәһдиев

**ӘҺӘМИЯТСЕЗ** *с.* Әһәмияте булмаган, кирәксез саналган, кирәге булмаган; мөһим түгел. --- *бер карауга әһәмиятсез күренгән хәрәкәт шактый тамырлана бара иде.* Ф.Сафин

**ӘҺӘМИЯТСЕЗЛЕК** *и.* Әһәмиятсез булу, кирәксез булу

**ӘҺЕЛ** *и. гар.* 1) Нинди дә булса катлау яки берәр эшчәнлек өлкәсенең вәкиле. *Дин әһеле – ил әһеле, хан. Дин әһеленең илче белән булуы каганны тәмам инандырачак.* М.Хәбибуллин. *Әдәби тел культурасын күтәрү, иң элек, безгә – язучыларга, журналистларга, фән һәм культура әһелләренә кагыла.* Н.Фәттах

2) *иск.* Билгеле бер эшнең, һөнәрнең остасы. *Ул – укыту әһеле*

**ӘҺЕМ(М)** *иярт.* 1) Тамак кырганда чыккан тавышны белдерә; ыһымыһым, һемм, әһ-м-м-м. *Ул [Гайшәтти], гаепле кеше сыман, башын түбән игән дә, әтигә карамыйча гына: – Анысы инде Ходай эше... Әһемм... Ие, анысы Ходай эше, – ди икән.* М.Мәһдиев

2) Елаганда чыккан тавышны белдерә. *[Гайни әби:] – Алланың каһәре төште, әһем-м-м, соңгы кәҗәмне алырга килделәр, инде нишләрбез, майкушларым, әһем-м-м, – дип, яшьләрен җиң очына сөртә-сөртә сөйләнеп китте.* Һ.Такташ

**ӘҺ-ҺӘ** *ы. к.* **эһә**. – *Мин ул Тансык исемле малай. – Әһ-һә, киенеп үк куйгансың икән. Молодец. Әйдә, киттек.* З.Зәйнуллин. *Әһ-һә! Фән каршында, барыбер, горур башыгызны имичә булдыра алмадыгыз!* Г.Бәширов. *Әһ-һәә, белдем инде: --- алар берәр күмелгән хәзинә беләләрдер...* Г.Гобәй

**ӘЧӘЧ** *ы.* Нык гаҗәпләнү, шаккату, аптырап калу, җирәнү, нәфрәтләнү хисләрен белдерә. – *Әбәү, әчәч! – диде Фатихәттәй, нәфрәтләнеп.* Г.Әпсәләмов

**ӘЧЕ** *с.* **1.** 1) Әчетеп әзерләнгән ризык тәмен белдергән, әчешкән ис чыгарган. *Атаклы кымыз аңа бик әче әйрән кебек тоелды.* Ә.Мушинский. *[Агач яфракларының, үлән сабакларының] Меңнәрчә сизгер тамырлары Ык суының яр туфрагына сеңгән дымын --- суыралар, әлсерәп сусаган яфракларга, сабакларга әче сүл китерәләр.* Ф.Садриев

2) Тәмсез, бозык тәмдәге. --- *авызымда әллә нинди ят, әче тәм тойгач, йөзем чытылды.* Л.Ихсанова

3) Чүпрә, оеткы салып махсус әчетелгән, әчегән. *Хурлыгаян агач касәгә салынган әче катыкны ала керде.* Р.Батулла. *Вак бәлешне әче камырдан ясыйлар.* Ю.Әхмәтҗанов

4) Составында әчелеге (I, *2 мәгъ.*), кислотасы артык булган. *Әче реакцияле торфлардан торф-известь яки торфкөл компостлары ясыйлар.* Яшелчәче белешмәсе. *Әче туфрак*

5) Тынны кисә, сулыш юлларына авыр тәэсир итә торган. *Таш-бетон панельләрдән җыеп салынган терлек абзарының волейбол мәйданы чаклы ишекләрен ачып керүгә, төче силос, әче сидек исе белән туенган җылымса һава борынга бәрелде.* А.Вергазов. *Харара җиле көйдергеч кызу һава белән вак борычтай әче тузан алып килә.* М.Юныс

6) Зәһәр, зәһәрле, күзләрне ачыттыра торган. *Алардан ургылып чыккан әче төтен койрыклары, ТЭЦ торбаларыннан бөркелгән сөрем болытларына кушылып, кояшны капладылар.* А.Гыйләҗев. *Агачлар арасыннан саркып, инде межага килеп җиткән әче ылыс төтене борынны, тамак төпләрен кычыттыра, күзләрдән яшь агыза.* Т.Мөбарәков. *Мондый саф һавада әче тәмәке төтене үзен аеруча сиздерә, тамакларны ярып керә.* М.Хәсәнов

7) *күч.* Ачуланышкан, тиргәшкән, үпкәләшкән. *Анысы өчен бер дә хафаланма, дөнья булгач, аларның да әче вакытлары булыр әле.* Г.Камал

8) *күч.* Ямьсез, күңелгә ятышсыз; ачулануны белдерә торган. *Ул, башта тонык кына булып, аннары бөтен тән күзәнәкләрен уятырлык итеп, Кочураның катлы-катлы әче сүгенүен ишетте һәм, кинәт хәле кайтып, башын күтәрде.* М.Галиев. *Моназыйр ишетсә, һич тә җавапсыз калмас иде, Сәрвияне үзеннән өлкән дип тормас, әче сүзен тапкан булыр иде.* М.Хуҗин

9) *күч.* Көчле, чеметтереп ала торган, салкын, үзәккә үтә торган; ачы. *Әче җил юл буе үзәкләренә үткән иде, юка плащларының якаларын тартып томалаганда, күшеккән куллар төймә каптыра алмыйча интектеләр.* А.Гыйләҗев. *Бер елны Ташый елга кырындагы шушындый эскерттә, әче суык январь аенда, унлап чегән бер атна яшәп киттеләр.* В.Нуруллин. – *Ох, җиле әче, каһәр суккыры. Прямо битне ялап ала, – дип сөйләнде сакалбай.* Б.Сөләйман

10) *күч.* Зәһәр, чәнчүле. *Мәкаләдә ризасызлык куптара торган субъектив урыннар байтак, ләкин тәнкыйть әче иде, күп өлешендә гадел иде, әдәбият өчен ачыну ята иде.* Р.Батулла

11) *күч.* Әрнетүле, әрнеткеч. *Нәрсә генә турында сөйләшеп китсәләр дә, сүз шуңа – булмаган хыянәткә барып терәлде, әче җәнҗал белән тәгәлләнде.* Н.Хәсәнов

12) *күч.* Аянычлы, авыр, катлаулы. --- *тормышның әче мәктәпләрен үткән, «акыл утыртып кайткан» Аяз беркайчан да нәшрият җитәкчеләре*

*һәм редакторлары алдында даулашып, тәмсезләнешеп йөрмәде.* Г.Шәрәфетдинов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кайгы, хәсрәт, әрнүле хәл. *Шулай итеп, үземә тигән эш агачының җимешен әкренләп өзеп бетереп киләм. Дөресен әйтергә кирәк, татлысы да, әчесе дә күп булды.* Ә.Еники

2) Исерткеч эчемлек. *Сәхрәгә чык, күңелең бушар, балның мул төшкән чагы, әчесе дә табылыр.* Мирас

**3**. *рәв. мәгъ.* 1) **әчегә** Әчетеп, чүпрә салып. *Җаныкайларым, әллә коймак та куеп җибәрәбезме, әчегә.* А.Хәмзин

2) **әче итеп** Ямьсез, әшәке сүзләр әйтеп. *Әмма дөяләләрнең берсе, бик тиз аңына килеп, хәвефсезрәк тоелган арт якка борылды, әче итеп сүгенә-сүгенә, Фарукҗан тавышы килгән якка ут ачты.* Т.Әйди

3) Бик көчле, яңгыратып. *Теләсәң – кыргый ташларга исемеңне язып кит, теләсәң – кычкырып җырлап җибәр, теләсәң, ике бармагыңны кабып, әче итеп сызгырырга була – җил чыгарырсың дип, берәү дә бәйләнмәс.* М.Галиев. *Денис әче итеп сызгырып җибәрде, шундук өскә унике алып менеп басты.* М.Хәбибуллин. *Мотаһир, әче итеп, үзәкләрне өзеп паровоз кычкыртуга түзә алмыйча, елар дәрәҗәгә җитеп башын тота.* Р.Кәрами

4) Әрнеп, үпкә катыш рәнҗеп. *Нәҗип сүз әйтмәде, әче көлемсерәп, Гөлгенәгә карады.* А.Гыйләҗев. *Ибраһим әче генә елмайды: – Белсәң дә, язарга йөрәгең җитмәс иде.* Ә.Еники

◊ **Әче икмәк булу** Авыр физик хезмәт белән табылган булу. **Әче тамыры белән (утырып) калу** Газаплы, күңел әрнеткеч, михнәтле вакыйга (хәл) булып, күңелдә, хәтердә, истә саклану. *Аннан соң инде күпме сулар акты, ничәмә-ничә тапкыр бәрәңгеләр чәчәк атты, аны туйганчы, рәхәтләнеп ашарлык вакытлар да җитте, тик Сәрия карчыкның күңелендә әлеге вакыйга шул килеш – әче тамырлары белән утырып калды.* Р.Газизов. **Әче таңнан** Кояш чыкмас борын, бик иртә. *Карале, карале син боларны --- әче таңнан урман кисеп кайтканнармыни!* Т.Нәҗмиев. **Әче телле** Төртмә, усал, чәнчүле итеп сөйләшә торган. *Абау, бигрәк тә әче телле икән Фәнилә.* К.Кәримов. *Төртмә холыклы, әче телле Тукай жандармериянең «авырткан сөяле» булган.* Р.Батулла. **Әче тир** Авыр физик хезмәт, авыр физик эш башкару турында

**ӘЧЕ́ БАЛ** *и.* Баллы, шикәрле суга чүпрә яисә башка ачыткыч салып әчетелгән исерткеч эчемлек. *[Вәликәй абзый] Бер кичне куйган әче балына Гобәй Бамбырны чакырды да аның белән кич буе бал эчә-эчә сөйләште.* З.Зәйнуллин. *Бер ярты ак, бер шешә кызыл, әллә ничә төрле әче бал эчү сәбәпле телләре көрмәкләнгәнлектән, аларның сүзләрен юньле-башлы аңларлык түгел иде.* Ф.Садриев. *Суюрга, кырык казагы белән, шәхсән үзе олау-олау икмәк, кисмәк-кисмәк әче бал төяп, хәвефле юлга чыкты.* Р.Батулла

**ӘЧЕ́ КАКЫ** *и. бот. к.* **ачы какы**

**ӘЧЕЛЕК** I *и.* 1) Әче булу

2) *а. х.* Составындагы водород ионнары микъдары белән билгеләнгән туфрак үзлеге. *Әчелекне бетерү яки аны киметү өчен, туфракка көзен, тирес белән бергә, доломит оны, мич яки урман агачы көле кертәләр.* А.Девятков, А.Макаревич

**ӘЧЕЛЕК** II *и. иск.* 1) Мәдрәсәдә аяк киемнәрен калдыра һәм комганнар саклый торган аерым бер урын. – *Әдәпкә, дингә өйрәтә торган җирдә карак буламыни?! – дип, Фәтхетдин шәкерт малайны ачулана башлаган иде, әчелек ягыннан бер хатын чыкты.* М.Гафури

2) Бәдрәф

**ӘЧЕЛЕ́-ТӨЧЕЛЕ** *с.* 1) Әче, төче, татлы тәмнәр бергә катышкан

2) *күч.* Төрле, катнаш, бертөрле булмаган. *Шәһәргә кайтып йитеп, тагы шул тар бүлмәгә кергәч кенә, тагы шул әчеле-төчеле шәһәр исен исни башлагач кына, Шәмси айнып китте.* Г.Исхакый. *Тәрәзәне пәрәвез каплаган, борынны әчеле-төчеле ис кытыклый.* Яңарыш

**ӘЧЕЛЕШ** *и.* Тиргәш, ызгыш-талаш, гаугадан килеп чыккан үзара бозылышу. *Һәм шуның өчен президент Д.Медведев белән махсус рәвештә әчелешкә кергән.* Татарстан яшьләре

**ӘЧЕЛЕШЛЕ** *с.* Тиргәшүчән, бәйләнчек, гаугачыл. *Соңгы вакытта ул, гомумән, еш кына кызып китүчән, әчелешле кеше кебек, юкка-барга бәйләнүчән булып китте.* С.Сабиров

**ӘЧЕЛЕШЛЕ́ БУЛУ** *ф.* Берәрсе белән ачуланышу, ачуланышып, мөнәсәбәтләрне өзү, аралашмый башлау. --- *һәркем белән алай әчелешле булып, бәйләнешеп йөрсәгез, мин сезгә үзем зур итеп штраф салам.* А.Хәсәнов. *Әйткәнең берәүгә ошар, берәүгә ошамас та, каршы төшәр, шулай итеп, агай-эне белән әчелешле булып китүең бар.* М.Әмир

**ӘЧЕЛЕШҮ** *ф.* Тарткалашу, сүзгә килешү, ачуланышу. *[Ольга Ирекква:] Без, үз уйларыбызга бирелеп, бер-беребезгә битараф атласак, очраган кешеләр, болар нәрсәдер бүлешә алмаганнар, Яңа елны әчелешеп башлаганнар ахры, диюләре бар.* Г.Тавлин

**Әчелешеп алу** Кыска вакыт арасында әчелешү

**Әчелешеп кую** Кинәт, уйламаганда әчелешү

**Әчелешеп тору** Еш, әледән-әле әчелешү

**ӘЧЕТКЕ** *и. сөйл.* 1) Чүпрә урынына файдалану өчен калдырылган әчегән камыр кисәге; камыр башы. *Әчеткесене, чүпрәсене инде Галәветдин генә алыр.* Г.Исхакый

2) *диал.* Бәрәңге, ашлык, көрпә катыштырып, болгатып, кош-корт өчен әзерләгән азык

3) *күч.* Эшләнеш дәрәҗәсе; алынган тема. *Әчеткенең сыйфатына бәйләнә башлады мөхәрриребез: «Булмаган бу! Әчүе дә җитмәгән, үзе – сыек...» – дип тезә башлады.* Т.Нәҗмиев

**ӘЧЕТКЕЛЕК** *и.* **1.** *диал.* к. әчетке

**2.** *с. мәгъ.* Камыр өчен баш ясарга җитәрлек. *Әчеткелек камыр*

**ӘЧЕТКЕЧ** *и. к.* **әчетке**

**ӘЧЕ́-ТӨЧЕ** *с.* **1.** Авызны, борын куышлыгын ярып керә торган, төрле исләр катнашкан. *Бу эчемлекләрнең --- әче-төче исләре Габделкаюмның борынын ярып керде.* М.Гали

**2.** *и. мәгъ.* 1) Исерткеч эчемлекләр. *Элек Мәҗит, чыннан да, хатыны йортына күчтәнәчнең әче-төчесен курыкмыйча алып кайта иде.* Н.Акмалов

2) Тәмле, тансык, төрле-төрле ашамлыклар. *Соңгы вакытларда әчесен-төчесен ашыйсы килеп тора*

◊ **Әчесен-төчесен тату (күрү)** Тормышта күптөрле хәлләр күрү, яхшысын да, яманын да кичерү, шул сәбәптән, җитәрлек дәрәҗәдә тәҗрибә туплаган булу. *[Гобәйдулла абзый] Дөньяның әчесен-төчесен күп күргән.* З.Зәйнуллин. *Аның геройлары – тормышның әчесен-төчесен татыган --- урта һәм өлкән буын кешеләре.* Казан утлары

**ӘЧЕТТЕРҮ** *ф.* Тәнне, күзне, җәрәхәтне яндырып әрнетү, чеметтереп ачыттыру. *Маңгайдан аккан тир күзләрне әчеттерә, юешләнгән күлмәкләр тәнгә ябыша.* З.Зәйнуллин. *[Ильяс] Ут телләре аның бияләен көйдерәп, беләзек турын ялап әчеттергәнгә, кинәт читкә тайпылып, таяк-фәлән юкмы, дип эзләнде.* Ә.Баянов

**Әчеттерә башлау** Әчеттерергә тотыну. *Татарча җыр гына ишет – сагыш сөреме күзләрне, борыннарны, тамак төпләрен әчеттерә башлый.* Ф.Садриев

**Әчеттереп алу** Кинәт әчеттерү. *Әмма шунда ук ник капканыма үкендем – әчеттереп алды ла!* К.Миңлебаев

**Әчеттереп кую** Кинәт кенә бераз әчеттерү

**Әчеттереп тору** 1) Хәзерге моментта бераз әчеттерү

2) Бертуктаусыз әчеттерү. *Сәкинәнең сүзләре йөрәген тырмап, әчеттереп торды.* Н.Хәсәнов

**ӘЧЕТҮ** I *ф.* Тән, күз, җәрәхәт, әрнеп, яндырып тору. *Аның култык аслары ярып тоз сипкәндәй әчетте, пышлыкты, чиләнеп чыкты.* Ф.Садриев. *Аннан соң Илсөяр будка моржасыннан төтен чыкканын күрде һәм, йокысы килүдән күзе әчетсә дә, озаклап, шул якка карап торды.* Г.Гобәй

**Әчетә башлау** Әчетергә тотыну. *Судан чыккач, малайның тәне ап-ак тоз белән капланды, һәм бетчәле урыннары йөрәккә тиярлек булып әчетә башлады.* М.Юныс

**Әчетеп алу** Кинәт, кыска вакыт аралыгында әчетү. *Тез башы зәһәр әчетеп алды.* Н.Хәсәнов

**Әчетеп китү** Кинәт әчетә башлау. *Кырлы-кырлы күмерләргә бәрелгән куллары әчетеп-әчетеп китте.* Н.Хәсәнов

**Әчетеп кую** Кинәт, кыска вакыт аралыгында әчетү

**Әчетеп тору** Бертуктаусыз әчетү

**ӘЧЕТҮ** II *ф.* Әчегән хәлгә китерү, әче итү. *Әмма ул гаять тыныч кына, хәтта дустанә бер кыяфәттә, сөтне дуңгызлар фермасына илтеп тапшырырга кушты, кайнатыпмы яки анда әчетепме, терлекләргә бирү чарасын күрсеннәр, диде.* М.Хәсәнов. *Әчетү алдыннан, кәбестәне өске яшел яфракларыннан чистарталар.* Яшелчәче белешмәсе

**Әчетә төшү** Бераз, берникадәр, тагы да әчетү

**Әчетеп җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә әчетү, җиренә җиткереп әчетү

**Әчетеп кую** Алдан, әчетеп, әзер хәлгә китерү

**Әчетеп тору** Даими рәвештә әчетү

**Әчетеп чыгару** Әчегән хәлгә җиткерү

**ӘЧКЕЛТ(ЕМ)** *с. ким. дәр.* Бераз әче тәме булган. *Саф су исе, әчкелтем яфрак исе килә.* М.Маликова. *Мин, коймә аша гына керәм дә, әчкелтем исле тәмәке түтәлен үтеп, усак астындагы ятагыма киләм.* М.Галиев

**ӘЧКЕЛТЕ́М ТАТЛЫ** *с.* Төрле әчкелт һәм баллы исләр, тәмнәр катнашмасы. *Силосның әчкелтем татлы исе борынны ярып керде.* Г.Ахунов. *Җирана аңар тәмле-тәмле тамырлар, яшел яфраклар, агачларның әчкелтем татлы кайрыларын үстергән.* Л.Ихсанова

**ӘЧКЕЛТЕ́М-ТӨЧКЕЛТЕМ** *с.* 1) Төрле әче-төче исләр һәм тәмнәр катнашкан. *Әчкелтем-төчкелтем аш-умач исләрен куалап, чебен безелдәвен томалап, өй эченә җылы, тәмле исләр таралды.* Н.Фәттах. *Хәзер, камерам белән берлектә өстәл тартмасына барып эләккәч, борынга, әчкелтем-төчкелтем булып, шул акча исе керде.* А.Расих

2) *күч.* Усал булган, усаллык күрсәткән. *Торса бит, син алай кәнфит шикелле баллы гына түгел идең бит, синең әчкелтем-төчкелтем чакларың да бик күп буладыр иде.* Г.Камал

**ӘЧМУХА** *и. рус сөйл.* 1) *иск.* Кадакның сигездән бер өлеше (үлчәү берәмлеге). *Бер сөлгә, бер пар чынаяк, әчмуха чәй, бер чирек чамасында шикәр салынды.* М.Гали

2) *күч.* Бик аз күләмдә. *[Егетләрнең берсе:] Оялтты, ди, хәзерге яшьләрдә аның әчмухасы да юк.* Р.Кәрами. *Әчмуха хезмәт хакы алып, шуңа ризабәхил булып яшиләр.* Н.Акмалов

**ӘЧТЕ́К-ПӨЧТЕК** *рәв. сөйл.* 1) *к.* **әчмуха** (*2 мәгъ.*)

2) *к.* **эштер-өштер**

**ӘЧҮ** *ф.* 1) Әче тәм керү, бозылу, таркалу (органик матдәләр турында). *Кешеләр тегермән астын актара иде, ахрысы, – һаваны тагын әчегән он исе тутырды.* Ә.Гаффар

2) Чүпрә, оеткы салганнан соң әчегән хәлгә килү

3) Иеп исләнү (мәс., *эшкәртү өчен иетергә салынган тире*)

4) Кеше тәненең тирдән бозылуы, исләнүе. *Көне буе, саллы-саллы тартмалар күтәреп, астан өскә – дүртенче, бишенче катларга чабып йөреп кайткач, тез буыннары йомшый, иң өсләре чиләнә, култык аслары тирдән әчи.* А.Гыйләҗев

◊ **Әчегән йон** Бернәрсә дә булдыра алмаган, кулыннан эш килми торган кеше

**Әчеп бетү** Бөтенләй, тулысынча әчү; бик нык әчү. *[Кадыйр:] – Фу, – диде, – [сөт] әчеп беткән.* Н.Дәүли. *Мин аларны, тәмсезләнеп, кыркуланып әчеп бетмәсен, дип, базга төшереп куйган идем.* Г.Камал

**Әчеп җитү** Тиешле дәрәҗәгә җитеп әчү. *Танюша, теге яшь виноград суы әчеп җитмәдеме икән?* М.Юныс

**Әчеп калу** Нинди дә булса сәбәптән әчегән хәлгә килү

**Әчеп китү** Артык әчү. *Чуен кою – ипи пешерү белән бердер, әчеп китсә дә начар, төче булса да әйбәт түгел.* М.Хәбибуллин

**Әчеп тору** Әле әчегән хәлдә булу

**Әчеп чыгу** Тәмам әчегән хәлгә килү. *Сөт, каймак әчеп чыга, кәбестә, алма чери.* Й.Шәрәпова

**Әчеп яту** Әле, хәзерге вакытта әчү. *– Сипарат әйләнми, өйдә сөт әчеп*

*ята! – дигән ачулы тавышлар яңгырый башлады*. И.Хәйрулин

**Әчи башлау** Әчергә тотыну

**Әчи төшү** Тагы да бераз әчү

**ӘШӘКЕ** *с. фар.* **1.** 1) Начар тәэсир итә торган, авыр, яман. *Әшәке иде бу боздай салкын бушлык, йөрәгенә сарылып, бөтен уй-хисләрен туңдыра кебек иде...* Ә.Еники

2) Ямьсез, шыксыз. *Этнең танавы – йодрык белән дөмбәсләп җәлпәйткән шикелле шөкәтсез, әшәке.* М.Юныс

3) Пычранган, керле, юылмаган, шакшы. *Алар барысы да әшәке, сәләмә киемнәр киенгәннәр, алар коточкыч ямьсезләр иде*. Н.Фәттах

4) Сасы, бозык, ачыган. *Аның тамагы кипкән, башы коточкыч шаулый, ул авызында күңел болгаткыч әшәке тәм сизә.* Г.Бәширов

5) *күч.* Явыз, усал, холкы бик начар булган. – *«Картлач»лар бик әшәке безнең, – дип куйды соңыннан сержант.* З.Хөсният. *Бу шәһәрнең патшасы бик усал, бик әшәке бер кеше булып, халыкны җәберләп кенә тора иде.* К.Насыйри. *Җитмәсә, бер бик әшәке әфисәр бар иде.* Н.Хәсәнов

6) *күч.* Оятсыз, тупас, әдәпсез. *Мине хурлап, әшәке сүзләр белән сүгенүен ишеткәч, күкрәгем таш кебек катты, сүз әйтә алмаслык, урынымнан кузгала алмаслык хәлгә җиттем.* А.Шамов. *Рөстәм якынлашканда, алар нәрсә турындадыр бик әшәке сүзләр кушып сөйләшәләр иде.* Г.Кутуй. *Шул чакта минем... «Безнең мөгаллим турында әшәке сүз әйтәсе булмагыз! Сез – тупас, явыз кешеләр!» – дип кычкырасым килә иде.* Ч.Айтматов

7) *күч.* Начар, хәерсез; астыртын ниятләргә корылган. *Юк, юк, мондый әшәке уй белән йөри торган кеше түгел бит Гаяр.* Г.Камал. *Аның туймый торган комсыз, әшәке күңелле икәнлеген дә белә идем югыйсә.* Ф.Галиев. *Юк, үзең чиста булсаң да, алар куллана торган әшәке алымнар белән эш итмичә булдыра алмыйсың, ахрысы.* Ф.Садриев. *[Нәҗипкә] Акчаны тизрәк җыярга, мая тупларга кирәк иде, ул Вафаның иң пычрак, иң әшәке йомышларын үтәде.* А.Гыйләҗев

8) *күч.* Ямьсез, күңелсез; коточкыч авыр. *Язмышымдагы иң-иң әшәке көннәрем турында сөйләргә өлгермәмен дип куркам.* Җ.Тәрҗеманов. *Бәлкем, ул безне мондый әшәке хәлдән коткарган булыр иде.* М.Әмир. *Берәр әшәке хәбәр әйтергә җыена торганнардыр.* Т.Галиуллин

9) *күч.* Аерым максатларга туры килми торган, сыйфаты түбән, начар булган. *Аның бәрәңге җире бик әшәке кызыл балчыклы булып, ул күптәннән Мәһибәдәрнең кара туфраклы ындырына күз кыздырып йөри иде.* А.Гыйләҗев. *Иң әшәке юлдан да курыкмый торган «газик»та без күп җирләрне әйләндек.* Ә.Еники

10) *күч.* Әхлак кагыйдәләренә сыймаган, тискәре хис уята торган, тупас, дорфа. *Бик әшәке гадәт бу.* Г.Бәширов. *Тагын әшәке бер көлү белән кычкырып көлә башлады Хәдичә.* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кабахәт, хәсис, адәм актыгы, хәшәрәт кеше

2) Төрле ташландыклар, шакшы әйберләр. *Дөнья чистарсын, дидең, юньсезлек белән көрәштең, ә үзеңә әшәке йоккандай тоелды – кулларны кат-кат юасы килә*. Ш.Галиев

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Ямьсез, тупас итеп. *Өй артында аяк тавышлары, кемнеңдер калын, карлыккан тавыш белән бик әшәке сүгенгәне ишетелде.* Г.Тавлин. *[Зәһлүл:] Чынлап әйтәм. Алар әшәке сөйләшә.* Р.Кәрами

2) Табигый шартлар начар хәлдә, юеш, явым-төшемле булып. *Моннан берничә ел элек, яңа урынга күчеп килгән елны, көз бик әшәке килде. Хәтереңдәдер, сентябрь буенча коеп түкте, октябрьдә дә иркәләмәде*. А.Гыйләҗев

◊ **Әшәке дан** Кемнең дә булса башкаларга мәгълүм булган начар ягы. *Хәзер инде әшәке даны бөтен шәһәргә билгеле.* К.Нәҗми

**ӘШӘКЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Әшәке булып китү, әшәкегә әйләнү, сыйфаты начарлану. *Юллар әшәкеләнү*

2) Холыкта, үз-үзен тотышында әшәкелек сыйфатлары барлыкка килү, холыксызга әверелү. *Болай әшәкеләнеп сугышып йөрсәң, төрмәгә дә килеп эләгүең бар бит*. Н.Хәсәнов

**Әшәкеләнә бару** *к.* **әшәкеләнеп бару**. *Син күзгә күренеп әшәкеләнә барасың, Роберт*. З.Хәким

**Әшәкеләнеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә әшәкеләнү

**Әшәкеләнеп бару** Әшәкелеге көннән-көн арту; әшәкеләнгәннән-әшәкеләнү

**Әшәкеләнеп бетү** Бөтенләй әшәкеләнү, соңгы чиккә җитеп әшәкеләнү

**Әшәкеләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында, төрле урыннарда әшәкелеген күрсәтү. – *Ай Алла, мин сиңа әшәкеләнеп йөрергә кушмыйм лабаса, – диде Кәүсәрия.* М.Маликова

**Әшәкеләнеп китү** Кинәт әшәкеләнә башлау. *Хатыны Әпипәнең ире югында әшәкеләнеп китүе, каралтыларының да яртысын сатып бетерүе исенә төшкәч, Хәдичә бөтенләй каушап төште*. Г.Бәширов

**Әшәкеләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта әшәкеләнү

**ӘШӘКЕЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бозу, пычрату, шакшылау

2) Начар якка үзгәртү, ямьсезләү

**Әшәкеләп бетерү** Тулысы белән, бөтенләй әшәкеләү

**Әшәкеләп кую** Кинәт әшәкеләү

**ӘШӘКЕЛЕК** *и.* Начарлык, явызлык; барлык әшәке сыйфатлар. *Син әле саф, сабый, Әшәкелек күреп, дөньяны тарсынма, Өйрәтә алырсың барсын да – Сафлыкка, Намуска, Хаклыкка – Яхшылыкларның барсына, барсына.* С.Хәким. *Әшәкелек, мең төрлегә бөгәрләнеп, арттан китереп суга, диген, ә?* Г.Гыйльман. *Юк. Юк, Нуриман андый кеше түгел... әшәкелек эшли ала торган кеше түгел ул.* Ә.Мушинский

**ӘШӘКЕЛЕ́К КЫЛУ** *ф.* Начар гамәлләр эшләү, явызлык күрсәтү. *Бәйрәмхан әйткәндәй, әшәкелек кылуда җәһәтлеккә һәм үҗәтлеккә кем шушылай ныклап өйрәтте икән бу бәндәне?..* М.Хуҗин

**ӘШӘЛЧЕ** *и. бот. диал.* Кыяклылар семьялыгына караган, им-том, дару буларак кулланылган хуш исле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы* **зубровка**

**ӘШЕ́Р-ӨШЕР** *рәв. диал. к.* **әштерөштер**. *Өй эшен җиңелдән генә әшерөшер китереп ташлаган Әлтафи*

*караватына ята да кеше канына тоз сала башлый.* М.Мәһдиев

**ӘШКӘРӘ** *хәб. сүз фар. кит.* **1.** 1) Бөтен мәгълүматлар буенча күпчелек халыкка билгеле. *Бу балаларның бу кадәр җәфа күрүләрен карасагыз, күзләрдән яшь урынына кан агачагы әшкәрәдер.* Т.Биктимирова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Билгеле, ачык. *Син яшерен нәрсәләрне дә вә ачык әшкәрә нәрсәләрне дә белүчесең ---.* Ногмани

2) *диал.* Бик күп; масса

**ӘШКӘРӘ БУЛУ** *ф.* 1) Күпчелеккә мәгълүм булу. *Яшерен эшләрне вә әшкәрә булган эшләрне белүчедер, куәтле, һәр эштә өстен вә хөкем итүчедер.* Ногмани

2) Хур булу

**ӘШКӘРӘ ИТҮ** *ф.* 1) Ачыктан-ачык, һәркемгә мәгълүм итү

2) Халык алдында хурлау

**ӘШКӘРТҮ** *ф. кит.* 1) Нинди дә булса чаралар белән (мәс., мистик фикерләрне – төш аркылы) белгертү, искәртү, мәгълүм итү. – *Үтенечегезне кире кага алмыйм, кардәшләр, ачып карыйк, Хак Тәгалә әшкәртсә, изге китап алдамас,* – *ди дә ишан, өелеп торган китаплар арасыннан бер яшел тышлысын тартып ала.* Ә.Еники

2) Кыеклатып, төрттереп, кыек юл белән кисәтү

**Әшкәртеп тору** Гел, даими әшкәртү. *Аллаһы Тәгалә үзе аңа барсын да әшкәртеп кенә тора икән шул!* Ә.Еники

**Ә́Ш-МӘШӘ КИЛҮ** *ф.* Нинди дә булса эш белән бик нык мавыккан булу, мәшгуль булу; кызу-кызу, әле – монысын, әле тегесен эшләү. *Кызын тазда коендырганда, Лилия, уенчыклары белән әш-мәшә килеп, суда чыркылдаганда яки ясле ишегеннән көне буе сагынып көткән кызы аңа каршы йөгереп чыкканда куана иде ул.* Ә.Мушинский

**ӘШНӘ** *и. фар.* 1) Якыннан аралашкан, эш-шөгыльдә бергә йөргән кеше, компаньон, дус. *Әшнәләре биргән ялган белешмә белән Хөснуллин хәзер үз җинаятен яшереп калмакчы була.* Ф.Садриев. *Әй карчыгым, карчыгым, онытмыйсың ла син әшнәләреңне!* А.Шамов. *Мин, иректәге әшнәләрем белән, алдан килешүем буенча, бер читтәге ташландык сарайга юл тоттым.* Г.Тавлин

2) Агай-эне, кода-кодагый. *Ул, туганкаем, горкомның беренчесе белән дә санга санамыйча гына сөйләшә. Сөйләшмәс иде, тагын да өстәрәк әшнәсе утыра.* Р.Мөхәммәтҗан

**ӘШНӘЛӘНҮ** *ф.* Шикле нигездә якыннан аралаша башлау, ниндидер кыңгыр эшләрдә якын бәйләнешкә керү

**Әшнәләнеп бетү** Бик күп кешеләр белән әшнәләнү; бик нык әшнәләнү. *Татар сәүдәгәрләре белән аралашып, әшнәләнеп беткән карт, Саньканың Угличтагы татар бистәсендә аунап үсүен белсә дә, үз максатында әзлеклелек күрсәтте.* Ф.Латыйпов

**ӘШНӘЛӘ́РЧӘ** *рәв.* 1) Артык тәкәллефсез мөнәсәбәттә. *Кылый авызны Муханың аны, тәкәллефсез төстә, әшнәләрчә Сёмка дип атавы чыгырыннан чыгарды.* Г.Тавлин

2) Агай-энеләрчә, кода-кодагыйларча; туган итеп

**ӘШНӘЛӘШҮ** *ф. к.* **әшнәләнү.** *Рәмзи кандидатлык диссертациясе белән мәшгуль чакта, директор Саматов базада эшләүче Акчурин белән әшнәләшкән.* К.Латыйп. *[Мин] Ир-атлар белән дә дуслашырга, аралашырга, әшнәләшергә атлыгып тормыйм.* Г.Тавлин

**Әшнәләшеп бетү** Тәмам, бик нык әшнәләшү. *Ләкин без өч ай эчендә һәрберебез белән әшнәләшеп беткән кешене кулга алудан баш тарттык.* К.Латыйп

**Әшнәләшеп китү** Ниндидер вакыйгадан, хәлдән соң әшнәләшү, якыннан аралаша башлау. *Җитәкчеләр авыл мәктәпләрендәге рус теле укытучылары белән әшнәләшеп киттеләр.* Ф.Сафин

**ӘШНӘЛЕК** *и.* 1) Әшнә булу; эштә-шөгыльдә бергә булу. *[Байкучатовның] Ташкент мәктәбеннән килүчеләр белән дә әшнәлеге сизелә.* Т.Әйди

2) Агай-эне, кода-кодагыйлык. *Әшнәлеге дә бар иде.* М.Хәсәнов

**ӘШНӘЧЕЛЕК** *и. к.* **әшнәлек** (*1, 2 мәгъ.*). *Мәсәлән, әшнәчелек нигезендә, күрше фабрикага ике вагон пиломатериал җибәрелгән.* Р.Ишморат

**ӘШТЕ́Р-МӨШТЕР** *рәв. сир. к.* **әштер-өштер**

**ӘШТЕ́Р-ӨШТЕР** *рәв. сөйл.* Ашыгып, аннан-моннан, өстән-өстән генә. *[Газдал] Әштер-өштер капкалагач, Әпсәләмнән ферма хәлләрен белешеп кайтам әле, диде дә, теге банканы эләктереп, дусты янына очты.* Ф.Садриев. *[Сафаның] Әштер-өштер генә сыгып кигән чалбарында һәм пинҗәгендә – юеш ком.* Ю.Әминов

**ӘЯ** *ы. гар. иск. к.* **әй 1.** (*1, 2 мәгъ.*). *Әя, агач, яшең күпме? Түгелгән яфрагың кукме?* Җыр. *Хатун әйдүр: «Әя дая, разый улдым, бән сәнең үгүдиңә ---».* Кол Гали

# Б

**БА** I *и.* 1) Гарәп алфавитында әлиф хәрефеннән соң килә торган икенче хәрефнең атамасы һәм язуда ب (bā) билгесе белән күрсәтелгән тамга. *Монсы «әлиф», монсы «ба», бу хәреф «җим», монсы «та».* Г.Тукай

2) Әбҗәд хисабында 2 санын белдерә

**БА** II *бәйл. фар.* Белән. --- *туплар кирәклекне тәкрар ба тәкрар бәяле --- иттеләр.* Г.Тукай

**БА** III *ы.* Кинәт барлыкка килгән эш-хәлгә, килеп чыккан ситуациягә нык гаҗәпләнүне, аптырап калуны, шаккатуны белдергәндә әйтелә. *Ба! Әтәч! Нәгыйм түгелме соң бу?!* Ш.Камал. *Галәү абзый укый. Һәм шунда ук: «Ба!» – дип куйды кинәт, түзмәде.* Ш.Маннур

**БАБ** *и. гар. кит.* 1) Әдәби әсәр, китап, җыентык бүлеге, бүлекчә, параграф. *Лисане гарәпнең сарыф, нәхүен вә шул бабта тагы әлләниләр язды.* Г.Тукай. *Әсәрнең 25 бабы совхозның көндәлек тормышын, бер яктан – Вәли бай һәм иярченнәре, икенче яктан – батраклар, Фәхри һәм башка шундый совет, партия активы арасында көрәшне, ызгышны яза.* Г.Нигъмәти

2) *иск.* Сөйләшү өчен сүз, тема. *Аның җаваплары садә, ләкин үз бабында бик характерный нәрсәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Майсәрәләрнең читәне буенда өелгән бүрәнәләргә авыл агайлары җыелып, төрле бабтан кызык-кызык хәлләр сөйләшеп утыралар иде.* М.Әмир

3) *иск.* Нәрсәгә дә булса караган эшчәнлек өлкәсе; мәсьәлә, эш. *Синең берлә барча тәрбия бабында белгән гыйлемнәремне, осталыкларымны уртаклашырга әзермен.* Г.Тукай. *Мин буламын шулвакыт бу бабта Мәҗнүннән тиле.* М.Гафури. *Уку бабында ул үзенең апасы Фатыйма белән бөтенләй капма-каршы табигатьтә булган.* Г.Ибраһимов. *Әнә шулай тел бабында авторитет казанып, ул [Х.Сарьян] ахырда Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» дигән даими тапшыруларын алып бара башлады.* Ә.Еники

4) Төр; кыяфәт, рәвеш. *Юк, бер әфәнде шулай, әллә ничә бабка кереп, кайда төшемлерәк, шуннан чумарить итеп китә.* З.Фәйзи

5) *иск.* Капка, ишек. *Ачылды язар өчен безләргә баблар.* М.Гафури. *Бездән дә фәйзъ бабы бикләнгән юк.* Акмулла. *Шагыйрь: «Гыйшык бабын Мәүләм ачты», – дип белдерә.* Казан утлары

6) *лингв.* Гарәп телендә фигыль юнәлешләре (залог). *III баб фигыльләренең мәгънәсе татар телендәге уртаклык юнәлешенә күбрәк туры килә.* Гарәп теле грамматикасы. *Гарәп телендә фигыльләр унбиш бабка бүленәләр.* М.Мәхмүтов

**БАБА́** I *и.* 1) *к.* **бабай** (*1–3 мәгъ.*). *Икенче көнне иртән Габдулла, уянып, күзләрен ачты һәм, кайда ятканын төшенеп җитмәстән, үзен бабасы өендә ятадыр кебек тойды.* Ә.Фәйзи. *Миңа хәтта әткәмнең әтисе Минһаҗетдин бабамны да күрү насыйп булмады.* Р.Ишморат. *Бу шәфкать нурын булачак бабасы оештырганны егет соңрак абайлады.* Т.Галиуллин. *Зыяның бер бабасы (атасының агасы) бар. Исеме – Ярулла.* Г.Ибраһимов

2) *юг.* Өлкән яшьтәге ир кеше; үткән буыннарның билгеле, хөрмәтле вәкиле. *Исмәгыйль баба, утыз өч ел буе илләр гизеп, дөнья айкап кайткан илгизәр җан, үзе генә дә ни тора!* Ф.Сафин. *Мәсәлән, минем унберенче бабам, Болгар якларыннан килеп, шушы авылда мәдрәсә тоткан кеше икән.* М.Госманов. *Бу бабаларның арасында Кураешта мәшһүр булганы Нәзер бин Кинәнттер.* Татар мөселман календаре

3) Нәселнең, халыкның борынгы чыгыш нигезен тәшкил иткән кабилә, ыруг һ.б. *Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр.* Г.Тукай. *Күз алдына, ирексездән, Болгар дәүләте чорындагы бабаларыбызның киемнәре килеп төшә: алар да бит мехлы камзул һәм шундый бүрек киеп йөргән.* В.Юныс. *«Болгар» дигән, бабамнардан мирас булып калган йорт.* К.Тәхау. *Мәҗүси болгарлар исә чуваш халкының төп бабалары булып калганнар.* М.Әхмәтҗанов

4) Биологик ыругның (семьялыкның, классның) борынгы бер вәкиле. *Бер үк төргә кергән үсемлекләр үзара якын кардәшлектә булалар; алар уртак бабалардан килеп чыкканнар.* Ботаника

5) *сөйл.* Сөннәткә утыртучы. *Ә бит бар иде заманнар – аның ул авылдагы урыны түр башы иде. «Сөннәтче бабай килгән», «Бабачы килгән», «Гали баба килгән» дип, үлеп торалар иде ул килгәч.* Ф.Хөсни

6) **бабаң, бабасы** *сөйл.* Өлкән яшьтәге кешене атау яки эндәшү сүзе. *Бабаңның бәясен бабай булгач белерсең.* Мәкаль. *Алайса, бабаң кайткач, кунакка кил, яме, чикләвеккә барырбыз.* Г.Гобәй. *Хөсәен бабаң белән алар бик якын дус иделәр.* М.Гали

7) Чиертлек уенындагы чиертлекләр. *Чиертлекләрнең утызлабы тек басып торалар. Аларны «баба» дип йөртәләр.* З.Бәшири

◊ **Баба шулпасы эчерү** 1) Коры су эчерү; 2) Кыенлыклар күрсәтү. **Баба шулпасы эчү** Дөньяны тану, тормышта төрле авырлыклар, кыенлыклар кичерү. **Баба шулпасын эчмәгән** Тормышы әлегә кадәр җиңел булган, җитешсезлекләр, кыенлыклар күрмәгән

**БА́БА** II *и. рус махс.* 1) Төзелештә җиргә баганаларны кагып, сугып кертү өчен кулланыла торган субай тукмагы (субай каккыч); *русчасы:* **копёр.** *– Менә син мондагы субай суга тор-*

*ган бабаны күздән югалганчы күккә чөйсәң, ашлыгыңны тартырмын, – ди җен.* Әкият

2) *тех.* Багана кага торган механизмнарның бәрмә өлешләре

**БАБА́ГӨЛ** *и. бот.* Оешма чәчәкләр семьялыгыннан, уентыклы яфраклары тамыр яны таралгысы ясап үскән, сары чәчәкле, тамырчалы күпьеллык үсемлек; *к.* **гөлбаба**

**БАБАЙ** *и.* 1) Балага карата әтисенең яки әнисенең әтисе. *Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи – безнең өйдә без җидәү.* Г.Тукай. *Әтигә бер яшь тулганда, аның әтисе, ягъни минем бабай, үлеп китә.* Ф.Мөхәммәтшин. *Аннары минем бабай ундүртенче елны пленда биредәге Письмянка авылында бер байда эшләгән.* Х.Камалов // Оныгы булган кеше. *[Әти] Синең күк ук, бабай булырмын бер, Әни булган көнне кызларым.* Р.Корбан. – *Тиздән үзем бабай буласы бит, җегетләр! – диде ул [Мәгънәви] дусларына ---.* Рифә Рахман

2) *диал.* Атаның яки ананың өлкән ир туганы (абый, абзый, ага). *Миңа, [Гайнулла абзый] беренчедән, бабай тиешле, икенчедән, үз кардәшең белән сатулашу яхшы түгел.* Т.Гыйззәт. *Әтиемнең олы абыйларыннан берсен, Нурулланы, без – нәселнең балачагасы – «яшь бабай» дип йөрттек.* Ф.Тарханова

3) *диал.* Кияү өчен хатын атасы. *[Кияү] Мостафин аптырый калды: ай-һай, бабайлар бердәнбер кызларын [кияүгә] әзерләгәннәр икән! [Бирнәдә] Җиз таз белән җиз комганнан кала бөтенесе бар.* Ә.Еники

4) Нәселнең, халыкның борынгы чыгышына нигез салган кабилә, ыруг башы кешесе. *Югыйсә, биредә Спартакның бер катнашы да юк инде: безнең бабайлар атаклы болгар читекләрен унынчы гасырда ук теккәннәр.* Казан утлары

5) Өлкән яшькә җиткән ир кеше. *Барысын да: сагыну-юксынуларын да, җыр-әкиятләрен дә бабай үзе белән бергә кабергә алып китте.* Ә.Еники. *Олаучым Мөстәкыйм бабай да шулай ук, көрсенеп: – Замана! – дип өстәде.* М.Әмир. *Минем белән бер чиратта утырган бабайга киңәшләр бирүенә колак салам.* Сөембикә

6) *сөйл.* Өлкән яшьтәге кешене, хатынының әтисен атау яки эндәшү сүзе. *Я, бабай, сөйлә тизрәк.* М.Фәйзи

7) *сөйл. к.* **баба** I (*5 мәгъ.*). *Ә бит бар иде заманнар – аның ул авылдагы урыны түр башы иде. «Сөннәтче бабай килгән» --- дип, үлеп торалар иде ул килгәч.* Ф.Хөсни. *Әле Гаяз әфәнде рисаләсендәге «Сөннәтче бабай», аркасы туңганлыктан гына, арка җылытырга бер хатын алган, ди.* Г.Тукай

8) Тарихта билгеле шәхесләргә хөрмәт, ихтирам белдерү өчен, аларның исемнәре артыннан кулланыла. *Каюм бабайдан соң тел тикшерү хәрәкәте байтак еллар тукталып торды.* Г.Алпаров. *Без Ленин бабай белән Сталин бабайның балалары идек бит.* Т.Миңнуллин. *Такташ бабай: – Символлардан, күкләрдән мине сөрсәгез, мин җирдә дә шигырь падишаһы була алам, – ди кебек.* Р.Батулла. *Яшьрәк чагымда мин, галимнең ике томлыгын басмага әзерләү уңаеннан, Каюм бабай эзләреннән ул авылларда булган идем.* С.Алишев

9) Профессиясе, эшенең төре, үзенчәлеге белән аерылып торган өлкән яшьтәге кеше. --- *җиде бабай бар иде, җидесе дә бер дигән! Умартачы бабай да, берсе гармунчы бабай. Тегерменче, кыярчы, аннан кавынчы бабай.* Р.Мингалим. *Саба районыннан Минһаҗ Хәбибуллин дигән бер әкиятче бабайны белә идем.* С.Ибраһимова. *Олаучы бабай чакырып карый, колын килми.* А.Гыйләҗев

10) *куч.* Борынгы, күптәнге булуына ишарә. --- *катлаулы тарих шаһиты бит ул Чулман бабай! Бу төбәктә яшәгән борынгылар аның турында күпсанлы дастаннар чыгарганнар, хәзер дә бу гүзәл елга турында бихисап җырлар җырлана.* М.Хәсәнов. *Хикәя геройлары – балалар урман эчендәге серле Бабай-тауны эзләп баралар. Бабай-тауда, имеш, кайчандыр һәлак булган борынгы кешеләрнең алтын-көмешләре күмелеп калган.* Н.Фәттах

◊ **Бабайнык[ы] – илнеке, дип әйтте, ди, бер кияү** Үзе эшләп тапмаган, ата-баба малларын туздыручы яшь-җилкенчәктән көлеп әйтелә

**БАБА́Й БАШ** *и. диал.* Оешма чәчәкләр семьялыгыннан булган зур тузганак. *Бабай башын мин күрдем, әби чәчен мин үрдем.* Әйтем

**БАБА́ЙКА** *и. махс.* Салда, паромда, баркаста зур ишкәк. – *Бабайка сугуны син аны, ат өстенә менеп, туп арбасы тарттырып, манёврга бару дип белдеңмени, синең шикелле тел бистәсе хөрәсәннәрне бабайка сугарга кушмыйлар да аны, көлгән буласың тагын, – ди.* М.Гали

**БАБА(Й)ЛАР** *и. күпл.* Тормыш тәҗрибәсен буыннан-буынга күчерә барган, милләтнең, халыкның элгәре булган ирләре, борынгылар. *Янса янган, калса калган, Җан сатмаган бабайлар.* Н.Исәнбәт. *Бабайлар әйтмешли, күктә укылган никах җирдә укылмый калмас инде.* Н.Хәсәнов. *Рәхмәт яусын бабайларга, авыл өчен урынны белеп сайлаганнар.* Р.Ишморат. *Ат башын дугадан биек итеп күтәртеп йөрү әнә шулай бабайлардан килгән матур бер гадәт икән.* М.Мәһдиев

◊ **Баба(й)лар баласы** Борынгыдан килгән йолаларны, гореф-гадәтләрне саклап, аларны дәвам иттерүче, традицияләргә тугрылыклы яшь буын вәкиле. **Баба(й)лар йоласы** Борынгыдан килгән гореф-гадәтләр. **Баба(й)лар йорты** Туып үскән җир; ил. **Баба(й)лар сукмагы** Алдагы буын вәкилләре тоткан, алар кулланган гореф-гадәтләр, йолалар, яшәү рәвеше. **Баба(й)лар сүзе** Буыннан-буынга күчеп бара торган канатлы сүзләр, гыйбарәләр, әйтемнәр, афоризмнар. **Баба(й)лар тамыры** Шәҗәрә баганасы, ата-уллык буенча буыннар теземе. **Баба(й)лар юлы** *к.* **баба(й)лар сукмагы**

**БАБА(Й)ЛА́РЧА** *рәв.* 1) Элеккеге вакытлардан килгән тәртип белән, кабул ителгән таләпләр буенча, әүвәл вакытлардагы кебек, борынгы гореф-гадәтләрне, йолаларны саклап. *Күңел тели, ерак бабайларча, Күктән иңгән табигыйлекне – күк күкрәвен, кошлар тавышын, яңгырлар шавын...* Р.Фәйзуллин. *Берзаман, бабайларча, алар да төзәлер – акыл җыяр әле.* Ш.Галиев.

*Ата-баба яшәгән, имеш! Яшә! Бабаларча түгел, маймулларча яшәгез!* А.Гыйләҗев

2) Олы яшьтәге ир кешеләр кебек. *[Бабай:] Куй боларны читкәрәк; Минә сәнәк тә кирәк, Минә балта да чалгы – Без авылча, бабайларча Оештырырбыз ялны!* Ш.Галиев

3) Акрын, салмак. *Бабайларча йөрү*

**БАБАЙЛЫК** *и.* Өлкән яшькә җиткән чор; картлык. *Бабайлыгыңны күңелеңнән чыгарма.* М.Гафури

**БАБАКАЙ** *и.* Бабай кешегә иркәләп эндәшү сүзе. *Ярый, бабакай, чәйдән соң барырмын.* Т.Гыйззәт. *Бабакай, ә безнең нәселдә ничә сулагай?* К.Латыйп

**БАБА́ КОШ(Ы)** *и.* Ишкәгаяклылар отрядына кергән, киң һәм озын томшыгы астында яры капчыгы булган су кошы; *русчасы:* **пеликан**. *Тирәнгә чумып, балыкны томшыклары белән эләктерүче баба кошлардан (пеликаннардан да) аерыла: ул балыкны тик тәпие белән генә тота.* Кызыклар дөньясында

**БАБАЛЫК** *и. сир.* 1) Баба кеше булу чоры. --- *бабайларыбыз безнең искедән килгән байлыгыбызны саф көенчә безгә бирә алмаганнар, урыннары оҗмахта булсын! Димәк, вазифаларын – бабалык вазифаларын үти алмаганнар.* Г.Исхакый

2) Сөннәткә утырту шөгыле. *Әмма бу сөннәткә утыртмак гамәлен кыйлырга һәркемгә ярамый. Бу сөннәткә утыртучыны «баба» дип әйтәләр. Аңа бабалык атадан-бабадан кала килгән булмак кирәк, нәсел буенча.* К.Насыйри

**БАБАСЫР** *и. гар.* Йомры паразит суалчаннар ырыгыннан, туры эчәктә була торган вак паразит корт. *Сукыр эчәктә һәм нечкә эчәкнең түбәндәге өлешендә тереклек итәргә җайлашкан күрән ак төстәге суалчаннарга «бабасыр» дип әйтәләр.* Юлдаш. *Бабасырны куу өчен, чистартылган һәм иттарткыч аша чыгарган кабак орлыгын сөткә салып болгаталар, бал яки варенье кушалар.* Серле сандык. *Ул шулай ук косасыны китермәү, авыртуны басу вә бабасыр зәхмәтеннән дәвалау, ягъни эчтәге суалчаннарны бетерү үзлегенә ия.* Мирас. --- *[инжир] соңгы елларда бабасырга, җәрәхәтләргә каршы чара буларак та кулланыла башлады.* Тәмле тамак

◊ **Бабасыр кергән (мәллә)** Бер урында гына утырып тора алмаган, урынында гел кыбырсып торган, тиктормас кеше турында. *Нигә тыныч кына утырмыйлар соң [әсирләр]? Бабасыр кергән мәллә?* Ш.Маннур

**БАБАСЫ́Р УТЫ (ҮЛӘНЕ)** *и.* Гентианачалар семьялыгыннан, тоташ таҗлы зәп-зәңгәр чәчәкле, каршыдаш яфраклы, таулы урыннарда үсә торган күпьеллык үлән (бабасырдан арыну өчен кайнатып эчәләр); *русчасы:* **горечавка**

**БАБА́ ТЕЛ** *и.* Соңыннан берничә кардәш телләргә бүленеп киткән, хәзерге милли телләрнең нигезе дип саналган борынгы тел

**БА-БАХ** *ияrт.* Кинәт шартлау авазын белдерә. *Шул уйлар белән ут йотып барганда, кинәт бер тавыш ишетелеп куйды: ба-бах!* Ф.Галиев

**БАБАЧЫ** *и. диал.* Балаларны сөннәтле итүче кеше, сөннәтче. *Кошман – әүвәлдән килгән бабачылар авылы буларак атаклы.* Ф.Гарипова

**БАБАЧЫЛЫК** *и. сир. к.* **бабалык**

**БАББИТ** *и. ингл.* **1**. Бакыр һәм сөрмә катнашкан кургаш эретмәсе (ул машина кисәкләренең ышкылучан өсйөзләренең ашалуын киметү өчен файдаланыла). *Подшипниклар кою өчен, аккургаш нигезендәге баббит һәм каракургашлы бронза кулланыла.* Хәзерге тракторлар

**2**. *с. мәгъ.* Баббиттан коелган, баббиттан эшләнгән. *Баббит подшипник*

**БАБЕР** *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, шуышма яки туры сабаклы, сабаклары агачланучан, эфир маена бай булган үсемлек; чабыр; *русчасы:* **чабрец, тимьян**

**БАБЛА́У** *ф. иск.* **1**. Бүлекләргә аеру, бүлекләү; классификацияләү. *Үз арабыздан телебезне башлап тикшергән, татар теленең сарыф-нәхүләрен баблап төзегән кеше – Каюм бабай.* Г.Алпаров

**2**. **баблап** *рәв. мәгъ.* Эзлекле итеп, бәйнә-бәйнә, җиренә җиткереп. – *Ә, син солдатмыни әле? Әйтәм сүзне бик баблап сөйлисең?* М.Гали. *Картлар, сабанчыларга карап, берәм-берәм, тәртип белән, бик баблап сөйли башладылар.* М.Җәлил

**Баблап кую** Бабларга аерылган хәлгә китереп калдыру

**Баблап чыгу** Тоташтан, башыннан ахырына кадәр бабларга аеру

**БАБУИН** *и. фр.* Үзәк һәм Көнчыгыш Африкада яши торган павианнар ырыгыннан бер маймыл төре. *Белмәгәннәр өчен искәртик: бабуин – маймылның бер төре.* Татарстан яшьләре

**БАБУНӘ** *и. фар.* Оешма чәчәклеләр семьялыгына караган, түгәрәк кәрзингә тупланган сары төстәге чәчәкләрен телсыман ак ялган чәчәкләр уратып алган болын үсемлеге; ромашка. *Бабунә – бабунәш – пападия чәчәге (ромашка), гарәпчә бабунәш һәм тагы акхуан диләр.* К.Насыйри. *Читән кырыйларында инде ак таҗларын койган пеләш бабунәләр, карт кычыткannар, саргая башлаган бака яфраклары үсеп утыра.* Тәмуг чәчәге

**БАВЫР** *и.* 1) Кеше һәм хайваннарның үт бүлеп чыгару, ашкайнату, кан әйләнеше һәм матдәләр алмашуда катнаша торган эчке органы. *Бу чаклы сикерүеңә, бүсереп түгел, үпкә, бавырың өзелер.* Т.Гыйззәт. *Әгәр организмда бакыр булмаса, бавырда тупланган тимер гемоглобинга әверелә алмый.* Татар мөселман календаре. *Бавырны алганда, үте сытылмасын өчен, бик сак булырга кирәк.* Татар халык ашлары

2) Түш, күкрәк; гәүдәнең алгы өлеше. *Елан бавыры белән ил гизәр, койрыгы белән кое казыр.* Мәкаль. *Баланы бавырга кысып күтәрәләр (үстерәләр).* Мәкаль

3) *күч.* Йөрәк; күңел, бәгырь. *Изге урын буш тормас, кешесе табылыр, моңа борчылмый хатын, Галигә ачылмады – шул бавырын талый иде.* Н.Гыйматдинова

4) Үзәк, эч. *Кыш бавыры бик озын.* Мәкаль. *Иң гаҗәбе шул: урман бавырына беркеп яшәсәләр дә, үзләренең йортлары кечкенә, кысан.* Г.Гыйльманов

◊ **Бавырга керү** Эч серләрен белергә тырышу; эч серләрен белү. *Дус хәлеңә керер, дошман бавырыңа керер.*

Мәкаль. **Бавырга (бавырына) таш булып утыру** Эч пошырып, һаман борчып, авыр хәсрәт төене булып торган рухи халәт. *Әби исә Фәриткә бавырына таш булып утырган кайгысын, иң ачы хәсрәтен сөйли.* Ф.Шәфигуллин. **Бавырга төшү** Бик нык җәфалау, үзәккә үтү; бик йөдәтеп, нәрсә дә булса сорау, таләп итү, теңкәгә тию. *Авыр эш бавырга төшә.* Мәкаль. **Бавыр ите** Күңелгә бик якын, кадерле нәрсә. *Ярый, бу гыйшык уты минем бавыр итемә кадәр барып төште, ди, аннан сиңа ни файда?* Ә.Айдар. **Бавырына бала басмаган** Дөнья күрмәгән, тәҗрибәсез (хатын-кыз турында)

**БАВЫРГАЛЫК** *и.* Атны җиккәндә, корсак астыннан үткәреп, бер тәртәдән икенче тәртәгә бәйләп куела торган каеш, бау. *Аркалык белән бавыргалыкны китереп бирде.* М.Гафури. *Текә тау бармы? Шуннан төшеп килгәндә, атымның бавыргалыгы өзелде.* Г.Ибраһимов

**БАВЫРЛАНУ** *ф.* Куеру, укмашу, оеган кебек хәлдә булу

**Бавырлана башлау** Бавырланырга керешү

**Бавырлана төшү** Тагын да бераз бавырлану

**Бавырланып бару** Акрынлап бавырлану

**Бавырланып бетү** Тәмам бавырлану

**Бавырланып җитү** Ахыргача, тиешенчә бавырлану

**Бавырланып килү** Бераз гына бавырлана башлау

**Бавырланып китү** Кинәт бавырланган рәвеш алу

**Бавырланып тору** Әле, хәзер бавырланган сыман булып күренү

**БАВЫРЛЫ** *с.* 1) Бавыр катыштырылган, бавыры булган. *Кырык төрле салат, җиләк-җимеш, бавырлы, итле, балыклы «второйлар» тезеп куялар да... Күзгә күренгәч, аласы килә.* Т.Нәҗмиев

2) *күч.* Үзенә бик нык ышанган, тамак төбеннән чыккан, көр. *Артур бавырлы тавыш белән әйтте.* Тәмуг чәчәге

**БАВЫ́Р МҮГЕ** *и.* Мүкнең шул исемдәге класска караган, вегетатив җенесле һәм җенессез үрчи торган төре. *Яфрак формасы белән бавырга охшаган бавыр мүкләре бавыр авыруыннан терелтә, дип уйлаганнар.* Робинзон эзләре

**БАВЫРСАК** *и. махс.* Төче камырны вак-вак турап, кайнап торган майга салып пешерелә торган чәй ризыгы. *Аның майлары тулып торган ике симез казы белән симез күркәсе, --- читләре кәнфит белән чәчәкләнгән ике савыт бавырсагы – тагы әллә ничаклы оста əзерләгән аш бүләкләре мәҗлеснең күзләрен уйнаттылар.* Г.Ибраһимов. *Төштә бавырсак күрсәң – мал һәм балалар булыр, диелгән «Төхфәтел-мөлек»тә.* Төшлек. *Бавырсак юлга алу өчен әйбәт.* Татар халык ашлары

**БАВЫ́Р ТАВЫШЫ** *и.* Көр атларның юыртканда чакта эчке органнары селкенүдән чыккан тавыш. *Бераз гына чана чыжлавын һәм туктаусыз гөртгөрт итеп торган бавыр тавышын тыңлап барганнан соң, Солтан сорашмый түзмәде.* А.Расих

**БАВЫ́Р ТУТЫРМАСЫ** *и.* Үпкәбавырны тапап, ярма һәм тәмләткечләр катнаштырып, эчәккә тутырып әзерләнгән ашамлык. *Борынгы язмаларда «сукта» дигән сүз бар, мәгънәсе – тутырма, ягъни эчәккә ит яки башка продукт тутырып пешерелгән ашамлык.* Л.Җәләй

**БАВЫРЧЫ** *и. тар.* Аш-су остасы, хан сараендагы ашчы, пешекче. – *Атың ничек? – Егорка мин, Яким Степанович, ашчы, болгарлар әйтмешли, бавырчы.* М.Хәбибуллин. *Бавырчы булса кирәк, каханга баш иде дә чыгып китте һәм, күп тә үтми, ике кулына ике көмеш бокал тотып килеп тә керде.* М.Хәбибуллин

**БАГ** *и. фар. иск.* Җимеш бакчасы. *Матур гөлләргә бул былбыл, нәзакәть багына сакчы.* Дәрдемәнд. *Багны юк киртләүчеләр, Кәҗәне күп тиргәүчеләр.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Яшьлек безнең багыбыз, гөлләр үпкән чагыбыз.* М.Фәйзи. *Мин кереп адаштым, ахры, чын мәхәббәт багына.* М.Гафури

**БАГА** *и. тар.* Хан белән карачыдан кала дәүләт идарәсендә зур түрәләрнең берсе. *Яңа җирдә Албуга атасы биргән киез өен корып куйды, меңбашлары, карачылар, торгак агалары, багалар билгеләде һәм, үзенә буйсынган аксөякләрне җыеп, һәркемгә көтүлекләр бирде.* Н.Фәттах

**БАГАВЫЛ** *и.* 1) *иск.* Опеканы үз өстенә алган кеше

2) *тар.* Каланчадан яки күзәтү пунктыннан тирә-якны күзләп торучы, күзәтче. *Яманны багавыл итсәң, яу килә, дип кычкырыр.* Мәкаль

**БАГАЖ** *и. фр.* 1) Юлчының юлда үзе белән алып бара торган әйберләре, йөге. *Ишектән асрау белән Закир багажларын күтәреп керәләр.* Г.Камал. *Багажың авыр булмаса, илле тиенгә алып менәрмен.* М.Гали. *Усиянең Челкашларга яхшы таныш сукмакларыннан багажларыбызны мең бәла белән ташыдык.* К. Миңлебаев

2) Махсус вагоннарда, самолёт, теплоход һ.б.ш.да йөк җибәрү ысулы. *Атна-ун көннән багажы килде. Син эш киемнәреңне Әҗәкүл пристаненә багаж белән җибәрдең мәллә?* К.Кәримов. *Аның артыннан, зур гына багаж белән, апельсин сарысы төсле юка гына кәгазьгә басылган тышлыкта, кечкенә генә күләмдә «Бәхетле Мәрьям» китабының тиражы кайтты.* Ә.Фәйзи

3) *күч.* Күп укып тупланган гыйлем, аерым кешенең белем хәзинәсе; рухи байлык. *Ә милли багажы бик сай, хәтта юк диярлек.* С.Гарифуллин

**БАГА́ЖНИК** *и. рус* Әйберләр куеп йөртер өчен автомобиль, велосипед, мотоцикл һ.б. транспорт берәмлекләрендә махсус ясалган җайланма. *Велосипедның көпчәк өстендәге кысалары хромланган, кул тормозы да, матур фарасы да бар, утыргычы күннән, звоногы, багажнигы, арткы көпчәге канатында, кып-кызыл булып, стопсигналы янып тора.* Р.Мирхәйдәров. *Бу көтелмәгән бәхеттән әле һаман айнып җитә алмыйча, Равил багажнигына ымлады.* В.Нуруллин. *Әйберләрне багажникка урнаштырганнарын доцент Мәрдиев, пәрдә читен лезвие калынлыгы гына ачып, тәрәзәдән карап торды.* М.Галиев

**БАГАЛМА** *и.* 1) Алсу төстәге, иртә өлгерә торган алма сорты. *Мин*

*яраткан җимеш, дигәнсеңдер, Багалмалар куйдың табынга.* Ш.Маннапов

2) *күч.* Чибәр, матур, гүзәл яшь кеше. *Минем багалмасы төсле кызым алай егетләр белән йөрмәс.* Г.Камал. *--- дәү улың Баһаветдин әнәтерәк, нинди гайрәтле нәсел айгырлары үрчетеп, тирә-юньдә дан алды, минем ике кызыма – багалмаларыма булышса, матур күлмәкләр алып бирсә, яңа капка ясаса, кулы корымасые.* Г.Ахунов. *Иң олы шатлыклары булып, өч улы – өч багалмасы – Әнвәр, Алмаз, Азат дөньяга килде.* Татарстан

3) *күч.* Кадерле, сөекле, якын кешегә иркәләп әйтелә торган сүз (гадәттә тартымлы формада). *Юк, җаным, багалмам, үлгәндә дә мин башка ярны сөймәм, дим.* Ф.Әмирхан. – *Кем рәнҗетте икән минем багалмамны? – дип, бер гөнаһсыз коңгырт күзләрен үземә төбәде.* К.Миңлебаев. *Хатыма каршы хат язмасаң, бик рәнҗермен, багалмам.* Татар халык җырлары

**БАГАНА** *и.* 1) Җиргә кузгалмаслык итеп туры бастырып утыртылган бүрәнә. *Багана артына посып, кул изәп кенә торыр идең бугай.* И.Гази. *Ике юл чатындагы күрсәткеч баганага аркылы-торкылы кадакланган ике такта кисәге кемгә кайда китәргә кирәклекне әйтеп торалар.* Ш.Камал. *Капка баганасы төбендә яшерендем дә торам.* Г.Ибраһимов

2) Фронтоннарны, бинаның эчке ягын һ.б.ш.ны терәтеп торыр өчен, архитектура корылмасының бер өлеше буларак ясалган биек терәк; *русчасы:* **колонна.** *Чыршылар арасыннан университетның ак баганалары күренә*

3) *күч.* Тигез, тоташтан хәрәкәт итә торган нәрсәнең дә булса (су, төтен, тузан, чебен-черки һ.б.ш.лар) агымы. *Галимнәр, шундый ук диаметрлы абсолют чиста су баганасын өзү өчен, 95 тонна чамасы көч кирәк булачагын исәпләп чыгарганнар.* Р.Шаһморатова. *Шуннан куе ак төтен чыгып, салкын тыгыз һавада аз гына да җәелмичә, таралмыйча, зур калын багана кебек, туры күккә менеп тора.* Г.Ибраһимов. *Якуб су баганасының шау итеп коелып төшүен карап торды.* И.Гази. *Бер кизәнсәң, черки «баганасы» юкка чыга, аннары, күз ачып йомганчы, янә пәйда була.* Р.Батулла

4) *күч.* Яссылык өстендәге буй-буй төшкән юллар, сызыклар, тасма сыман фигуралар. *Су өстенә сузылган алтын баганаы җимереп узды да, икенче яктагы пристань каршына җитәрәк, сузып-сузып кычкырып җибәрде.* Г.Бәширов. *Йолдызларның шәүләләре Агыйдел төбенә алтын багана булып сузылган.* Г.Гобәй. *Җемелдәп торган түм-түгәрәк салават күпере уртасыннан чиксез галәм тирәнлегенә утлы баганалар сузыла... искиткеч күренеш!* М.Галиев

5) *күч.* Газета-журнал, китап-дәфтәр битләрендәге аркылыга яки буйга язылган цифр, сүзләр, текстлар рәте яки шулар язылачак урын. *Әмма минем игътибарны җәлеп иткән нәрсә өр-яңа өстәмә текст түгел, бәлки XIX йөз башындагы яшькелт кәгазьгә ике багана итеп язылган шигырьләрнең аерым юллары иде.* М.Госманов. *Айсылу Тимеринең температура кәгазе янынннан озын-озын цифрлар баганасы тезелеп төшкән икенче бер кәгазь алды.* Г.Бәширов. *Беренче баганага «б» авазына, икенче баганага «в» авазына башланган сүзләр булсын.* М.Мәһдиев

6) *күч. ирон.* Озын буйлы кеше. *Аның тилиграм баганасы шикелле озын, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы кызын алмасам да, дөньяда киленсез калмам әле.* Г.Камал. *Багана өчен иң кулай кеше – син инде ул.* И.Гази

7) *күч.* Үз чорының күренекле вәкиле, берәр иҗтимагый, фәнни һ.б. эшчәнлек өлкәсендә танылган шәхес. *Шуңа күрә Галиәсгар Камалны, Каюм Насыйридан кала, татар милли культурасының тарих җебе барып бәйләнгән төп багана, дип атарга туры килә.* М.Гали. *Татарстан музыка өлкәсендәге алтын багана булган Салих Сәйдәшев үзе дирижёрлык иткән оркестрны тыңлау бәхетенә ия бит без.* Сөембикә

◊ **Багана булып (баганадай) кату** *к.* **багана шикелле катып калу**. **Баганага сәлам бирү** 1) Бик түбәнчелекле булырга мәҗбүр булу. *Югыйсә күрсәтермен мин сиңа балак бетен. Баганага сәлам бирерлек итәрмен!* М.Хәсәнов. *Семьяда булып үткән фаҗига Саҗидәкәйнең күтәрелгән борынын түбәнрәк төшерде. Замана үз җырын җырлатты, баганага сәлам бирдерде.* Г.Иделле; 2) Багана белән кешене аера алмаслык дәрәҗәдә исерү. **Баганага сөяү** Кешене алдап, авыр хәлгә калдырып китү. *Рәхәтләнә кяфер, сине шулай баганага сөяп киптерә.* Г.Тукай. **Багана саклау** Эшсез басып тору, тик тору. *Бөтен кешенең үзенә күрә эше бар, ә менә Нәҗиянең бер эше дә юк: капка төбендә, багана саклап торгандай, тик басып тора.* Ф.Хөсни. **Багана шикелле катып калу** Аптыраудан, куркудан, гаҗәпләнү һ.б.ш. хисләрдән хәрәкәтсез калып басып тору. *Таш багана шикелле катып калды.* М.Гафури. *Озак карап тордым... баганадай катып калып баскан урынымда.* Ш.Маннур. *Менә, баскычтан менеп, өйалды ишегенә барып җитте һәм, нидер күреп, баганадай катып калды.* Г.Бәширов

**БАГАНА́-БАГАНА** *с.* Күпсанлы баганаларның бергә торуына охшаган, тоташ; берничә баганадан торган. *Багана-багана хәдисләр дәреш итә.* Г.Тукай. – *Күрәсеңме, – диде ул, аңлату рәхәтенә бирелеп китеп, – багана-багана су күтәрәләр, балыкны кыралар, ә пароходларга якын да төшми.* И.Гази

**БАГАНАЛАНЫП** *рәв.* Баганага охшап, багана сыман, багана рәвешендә, багана кебек булып, өермәләнеп. *Урамда, баганаланып, тузан күтәрелә.* А.Шамов

**БАГАНАЛАП** *рәв.* 1) Баганалар утыртып, бер-бер артлы баганалар бастырып. *[Хуторчылар] Имән баганалап, рус капка кордылар.* Г.Толымбай

2) Баганалар рәвешендә, буй-буй ясап, багана сыман яки багана-багана итеп. *Ни өчендер бит уртасы сызык белән баганалап бүленгән ---.* Н.Исәнбәт. *Кенәгәләргә баганалап тезелгән очсыз-кырыйсыз саннарга карап, аның күзләре тона.* Г.Иделле. *Саннарны баганалап тапкырлыйбыз.* Р.Нуруллин. *Сүз басымы беренче, икенче, өченче, дүртенче иҗекләргә төшкән сүзләрне баганалап языгыз.* Р.Шәмсетдинова

**БАГАНАЛЫ** *с.* 1) Баганасы булган, баганалап эшләнгән. *Менә ул --- ак ба-*

*ганалы университет йорты яныннан узып, чаттан уңга борылды да кирпеч стена буйлап түбән төшеп китте.* И.Гази

2) Багана төсле бастырылып куелган. *[Хәмидә:] Күзгесе --- шкафлы булсын, хәзер инде баганалы күзгенең мудысы бетте, дип әйтәләр, ди.* Г.Камал

3) Читенә баганалар утыртылган, маяклар тезелгән; олы, төп. *Гыйльметдин адашудан курыкмый иде: аты юлны белә, ара ерак түгел, озакламый баганалы юлга, шәһәр юлына алып чыгарлар, аннан соң инде күзне бәйләп тә кайтып җитеп була.* И.Гази // Билгеле, төп таләпләргә туры килгән. *Такташ --- социалистик реализмның баганалы юлына аяк басты.* Х.Госман

4) *күч.* Уңышка илтә торган, сыналган, нык. *Аның ихтыяры, теләк-нияте кебек үк, тимер баганалы булып чыкты.* Т.Галиуллин

**БАГАНАЛЫК** *и.* **1**. Баганага яраклы материал. *Сәфәр --- урман аша үткән чакта баганалыклар карый.* С.Баттал

**2**. *с. мәгъ.* Багана итеп файдаланырлык, багана өчен әзерләнгән. *Дүрт баганалык агачны бәләкәй арбага салып бәйләгәч, икәүләп, зиратка киттеләр.* Ә.Баян

**БАГАНА́ УМАРТА** *и.* Куыш агачның эче киңәйтелеп ясалган умарта. *Бабай шушы таш белән багана умарта башын каплап куя торган булган.* Г.Галиев

**БАГАНАЧЫК** *и.* 1) *сир.* Зур булмаган, кечкенәрәк багана

2) *бот.* Җимешлекнең авызчык белән җимшән арасындагы өлеше. *Җимешлек киңәеп киткән һәм «җимшән» дип аталган аскы өлештән, озынча баганачыктан һәм авызчыктан тора. Кайбер үсемлекләрнең чәчәкләрендә баганачык булмаска да мөмкин.* Ботаника

**БАГБАН** *и. фар. иск.* Бакчада эшләүче, бакчаны карап, аны тәрбияләп торучы; бакчачы. *Монда төрле багбаннарыбызның хәссась күңелләрендә җитешкән әдәбият гөлләреннән берәр-берәр чәчкәләр алынды.* Г.Тукай. *Мән җарияңезнең белүенә күрә, шаһым, гүзәл багбан тәрбия кылган шәфталыга тугъры килмәгән дийү зан итәрмен.* Дастан. *Гүзәл бакчада яхшы багбан тәрбия кылганнар.* Дастан

**БАГБОСТАН** *и. фар. иск.* Җимеш яки чәчәк бакчасы, гөлбакча. *Тәхте пайның йоклый һәр багбостаны, Йоклый хәсрәтле шәһәр каберстаны...* С.Сүнчәләй. *Нинди матур, шулай чәчкә, гөлләр, Багбостаннар кочса гомерне.* Ф.Бурнаш

**БАГЕТ** *и. фр.* **1**. Картина, портрет рамнары һәм кәрнизләр ясау өчен кулланыла торган, бер ягы бизәкле тар гына сырлы такта. *Багет, гадәттә, алтынланган килеш сатыла, ләкин, кирәк булганда, аны спиртлы көрән яки кара лак, яки эмаль буяу белән буярга мөмкин.* Файдалы киңәшләр

**2**. *с. мәгъ.* Шундый тактадан ясалган. *Багет рам*

**БАГЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **баглау** (*1–3 мәгъ.*). *Кайсысында зәңгәр күзле, сары чәчле славян кызлары, кайсысында каракучкыл Дагстан кызлары утыралар, таза ир колларның аяклары зәнҗирләр белән бер-берсенә багланганнар.* Г.Гобәйдуллин

2) *юг.* Үзара якын бәйләнештә тору. *Галимҗан Ибраһимовның революциягә хәтле булган хикәяләрендәге бу төр сурәтләр авыл тормышының киңлеген, туклыгын күрсәтү тойгысы һәм уйлары белән багланганнар.* Г.Нигъмәти. *Мәгариф эше, халыкның әхвәле икътисадиясе социальное положение белән бик нык баглангандыр.* Ф.Әмирхан

3) *кит.* Берәр нәрсәгә бәйле булу, буйсыну, карамагында булу. *Соңыннан озын рәвештә күрсәтелгән әсәрнең берен алган суд барышын язу да әнә шуңа багланган.* Г.Нигъмәти. *Ләкин кыпчак иленең Монголиядә булган мәркәзгә баглануы акрынлап зәгыйфьләнә башлап, Мәнги ханнан соң бөтенләй бетте.* Г.Гобәйдуллин

4) *сир.* Беркетелү, раслану. *Польша сәүдә җәмгыяте, солых баглану мөнәсәбәте белән, Польшадан Россиягә нинди маллар кертергә мөмкин икәнлек хакында сорый.* Ф.Әмирхан

5) Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендә булу, мөнәсәбәтле булу. *Бик күп хатирәләрем багланган бу күлне бик күптән күрмәгәнгә --- миңа бүген аерым бер якынлык таныталар.* Г.Ибраһимов

6) Туганлык мөнәсәбәтендә булу. *Болар --- моның өстенә кодалык, һич булмаса, башкодалык кебек җепләр белән сарманнарга багланган кабиләләрнең башлыклары – байлары иде.* Г.Ибраһимов

**Баглана бару** Акрынлап, торган саен ныграк баглану

**Баглана башлау** Багланышлар барлыкка килү

**Баглана төшү** Беркадәр баглану

**Багланып алу** Беркадәр вакытка, бераз баглану

**Багланып бару** Акрынлап баглану

**Багланып бетү** Тәмам, бик нык баглану. *Шул сабакны бөтенләй онытмаганга, аннан шул милли программаның мәдәни моментлары – һәммәсе сәяси яклар белән бөтенләй багланып беткәнгә күрә, алар хәзер сүздә ачык чыкмыйлар, чыгарга теләмиләр дә.* Г.Ибраһимов

**Багланып китү** Ниндидер сәбәптән, вакыйгадан соң баглану. *Шаһбаз шул базардагы сугыштан бирле миңа бик багланып киткән иде.* Г.Ибраһимов

**Багланып кую** Кинәт баглану

**Багланып тору** Һәрвакыт, даими багланган хәлдә булу. *Кайчан авылның язмышы күктән тамган яңгыр тамчысына багланып торудан чыгар?* Г.Ибраһимов

**БАГЛАНЫШ** *и.* 1) Бәйләнеш, элемтә. *Тик совхозның безнең авылданерактарак булуы тыгызрак багланыш тотарга уңайсызлады.* М.Әмир. *Анда ата-бабаларының үткән гасыр азагында Идел буендагы Әби авылыннан күчеп китүен, илдә аларның кардәшләре калганлыгын, хәзер шуларның балалары белән багланышка керергә теләвен әйтеп, булышуымны үтенгән иде.* Т.Әйди. *Тарихи багланышлар яңара.* Казан утлары

2) Аралашу, катнашу, ярдәмләшү бәйләнеше, үзара якын мөнәсәбәттә булу. *Аларның даими алмашынып торуы, серле-тылсымлы багланышы борынгылыкта бик күп уйдырма-ышанулар, риваятьләр тууга сәбәп булган.* Г.Гыйльманов. *Татар һәм каракалпак*

*әдәби багланышлары үзенең тамырлары белән бик ерак дәверләргә китә.* Казан утлары

3) Үзара эчке бәйләнеш, мөнәсәбәт. *Хәзер менә Шәяхмәтнең әйткәннәре белән шул нәрсәләр арасында нииндидер багланыш бар кебек сизелә.* Г.Ибраһимов. *Бу икәүнең эше, тормышы, революция көрәшендә тоткан урыннары һәм бер-беренә багланышлары нидә?* Г.Нигъмәти. *Бу багланыш «Эшче» поэмасына килеп тоташа.* Г.Нигъмәти

4) *күч.* Ир-ат белән хатын-кыз арасында якын дуслык, хисләр барлыкка килү мөнәсәбәте. *Ул, гомерендә беренче мәртәбә, үзенең аңа мөнәсәбәте бер кызның бер егеткә булган багланышы рәвешенә керә башлаганын сизенде.* Г.Ибраһимов

**БАГЛАНЫШЛЫ** *с.* 1) Бәйләнеше булган. *Ахун, халык авызында үзенә каратып сөйләнгән кайбер гайбәтләр белән багланышлы бу эшне бер якка калдырып, сүзне туйлар, никахлар, мәҗлесләр тирәсенә күчерде.* Г.Ибраһимов. *Курбе – Франция революциясе чорларында барбизонецлар «Париж янында Барбизон исемле авылга багланышлы» дип аталган художникларның иң алдынгыларыннан.* Г.Гобәй

2) Нинди дә булса берәр нәрсәгә караган, мөнәсәбәте булган. --- *әсәрдәге төп фабула үсеше белән бертөрле дә багланышлы түгелләр.* Г.Нигъмәти. *Имән, башын җиргә таба авыштырып, дөнья белән хушлаша, әтисенә багланышлы чор истәлекләрен үзе белән алып, ул киткән якка ава.* Н.Хәсәнов

**БАГЛАНЫШЧЫ** *и.* Нинди дә булса оешманың әгъзалары белән элемтә булдыру эше йөкләтелгән кеше, элемтәче. *Кызыл гвардия багланышчылары юлдагы отрядларга әйтә узганнар, күрәсең, дугасына зур ак флаг эленгән сәер тарантасны берәү дә туктатмады.* К.Нәҗми

**БАГЛА́У** I *ф. кит.* 1) Бәйләү, бау белән, берәр әйбергә яки бер-берсенә беркетеп кую. *Йосыфның кулын баглап, каты беркеттеләр.* Кол Гали

2) Тоташтыру, кушыру. *Языңыз да фикереңезне, фикри фикрә баглаңыз.* Г.Тукай. «*Аллаһу әкбәр» дип бетергәч тә, хатын-кызлар кулларын күкрәккә баглыйлар, ә ирләр кулларын кендек өстенә куялар.* Г. Исхакый. *Әгәр җавап бирсә, без дәхи тәхетне аңар ризалыгымыз белән тапшырырмыз вә каршысында кул баглап торырмыз.* К.Насыйри

3) Буу, уратып бәйләү. *Сөләйман итәкләре каюлы ак күлмәк киеп, өстеннән зәңгәр зинар баглаган.* Ф.Әмирхан. *Шундый дәртләр, шундый уйлар белән, һәркем, бил баглап, җиң сызганып, изү чишеп уракка төште.* Г.Ибраһимов. *Алтын белән баглаган.* Н.Исәнбәт

4) Тоткарлау, каршылык тудыру. *Шул тәэсир гүя аның [Зыяның] тавышын каплаган, телен баглаган.* Г.Ибраһимов

5) *күч.* Уй-кичерешләрне нинди дә булса берәр ниятәкә яки сәбәпкә, сәбәпчегә юнәлтү. *Без, моннан егерме биш ел борын, ак күмәч булмаганда ипи ашаган һәм кыйбатлы тәмәке булмаганда махорка чорнап тарткан төсле генә, «Тәрҗеман»ны укыдык һәм ихлас багладык.* Г.Тукай. *Ул да, күрәсең, борчыла һәм бу разведкага зур өмет баглый иде.* А.Шамов. *Сабирга кул селкә дә бөтен өметен, барлык хыялларын икенче угылына баглый.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Якын, тыгыз мөнәсәбәт урнаштыру, якынайту. *Бу хәл аны, анасыннан каядыр читкәрәк, ераккарак җибәргән кебек, теге «берәү»гә тагы ныграк баглый, аның белән араны тагы ныграк якынайта бара иде.* Г.Ибраһимов

7) *сир.* Беркетү, раслау. *Солых баглау*

**Баглап алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз генә баглау

**Баглап бирү** Кемгәдер багларга ярдәм итү

**Баглап йөрү** 1) Багланган хәлдә тоту. *Борынгы татарларның ирләре, чәчләрен алдан колакка кадәрен алып, артта калган чәчләрен кытайлар шикелле үреп салындырып яисә баглап йөргәннәр.* Г.Гобәйдуллин

2) Һәрвакыт, күптәннән баглау, өметләнеп йөрү. *Аллага шөкер, Әмирҗан улым, үзен күрмичә үләрмен микәнни, дип, соңгы өметләремне баглап йөри идем инде.* З.Фәйзи

**Баглап кую** 1) Багланган хәлдә тоту. *Бөтен кодрәтеңне баглап куймас Идең җирдә алтын-көмешкә.* М.Гафури. *Гүя Тәңре, үз кулы белән, Зыяны аңа [Мәрьямгә] баглап куйды.* Г.Ибраһимов

2) Алдан ук баглау. *«Атасыннан уңган идек, аңа алмашка үсә!» – дип, авылдашлар Харраска өмет баглап куйды.* Ш.Янбаев

**Баглап тору** 1) Баглаган хәлдә булу. *Кайгылы гына сурәттә ике кулын баглап торган булды.* М.Гафури

2) Әле, хәзерге вакытта баглау. --- *унбиш чакрым ераклыкта гына газ торбасы үтә, билгеле, авылларга эләкми. Халык, алай да, безгә дә булмасмы әле, дип, ышаныч баглап тора...* Б.Рәхимова

**Баглый башлау** Багларларга керешү. *Әбисе өй эшләрен гел «биш»кә эшли иде! Укытучылар, малайдагы бу үзгәрешкә шаккатып, аңа инде зур өметләр дә баглый башлады.* А.Әхмәтгалиева

**Баглый тору** Һәрвакыт баглау. --- *сихри серлелек төсмере булган һәм кешеләр өметләрен баглый торган шул бердәнбер бәйрәм төне алдыннан алар икесе дә, Светланка әйткәнчә, «кире кагылган ике бәхетсез җан» иделәр.* Р.Мирхәйдәров

**Баглый төшү** Тагы да ныграк баглау

**БАГЛА́У** II *ф.* Кайбер аңлашылмаган җирләрен аңлатып, озын итеп язу. *Болгар галимнәре тыйб гыйлеменнән дә әсәрләр язганнар, кайсылары башка мөселман галимнәре тарафыннан язылган китапларга шәрехләр баглаганнар.* Г.Гобәйдуллин

**БАГЛЫ** *с. кит.* 1) Бәйләп куелган, богауланган. *Анда [дию бүлмәсендә] биш йөзләп мөселманнар тулы, Баглыдыр һәрберсенең аяк-кулы.* Г.Тукай

2) Кемгәдер бәйле булган, буйсынган; үзара бәйләнеше булган. *Алар белән баглы имтиханнар да җуелганнар иде.* Ф.Әмирхан. *Пролетариат революциясе ул катлауларның бер өлешен икенче сыйфаттагы – икенче төрле сыйныф мәнфәгатьләре белән баглы булган башка өлешенә каршы куйды ---.* Г.Нигъмәти

3) Эчке бәйләнештә булган. *Кем яраткан? Ник яраткан? Нинди сергә баглы мин?* Һ.Такташ

4) Кагылышлы, мөнәсәбәтле. *Аның бу темага баглы берничә мәкаләсе һәм Ф.Хәкимҗанов белән берлектә язылган монографиясе басылды.* М.Әхмәтҗанов. *Хәзер инде революциядән көткән өметләрнең, халык һәм ил язмышы белән баглы теләкләрнең корал көченнән башка хәл ителмәячәге көн кебек ачык иде.* К.Нәҗми

5) *күч. сир.* Кайгы-хәсрәт һ.б. нәтиҗәсендә боеккан, басынкыланган. *Гүя бу минутларда табигать бәйрәм итә, баглы күңелләр дә аңа кушылалар.* Г.Ибраһимов

**БАГОР** *и. рус* Озын агач сапка утыртылган тимер ыргак. *Безнең авылның каравыл өендә искереп беткән бер насос, ике мичкә, өч багор, биш-алты көрәк, бер-ике балтадан башка бернәрсә дә юк.* М.Гафури. *– Егетләр, түбәне каерып ташлагыз, түбәне! Багорлар белән! – дип кычкырды Гафиятулла бабай.* Г.Әпсәләмов. *Багор белән ваклап, ваткалап, җибәрик кышны агызып.* М.Җәлил

**БАГРЫ** *и.* Сөләйман балыклар семьялыгына караган, төче сулыкларда яши торган кызыл һәм кара таплы балык; керкә, форель. *Күлдән тотып алып кына учакта кыздырылган багрыдан, өстенә сыр һәм акмай сылап пешерелгән абхаз көлчәсе – хачапуридан авыз итте, шәраб уртлады.* Д.Булатова

**БАГСТАН** *и. фар. шигъ.* Бакчаларга күмелгән як; бакчалары күп булган җир, ил. *Үзбәкстан – багстан ул, ә аның чибәрләрен күрсәң, һушыңнан язарсың.* Ә.Еники

**БАГУ** I *ф.* **1**. 1) *диал.* Карау, күз карашын юнәлтү, күз салу. *Бакма тышына, Бак кулыннан килер эшенә.* Мәкаль. *Урамнарга баксам – җансыз өйләр.* Н.Исәнбәт. *Егет күзен күтәреп кызга бакты, Ничек бакты, тораташ төсле катты.* А.Нәваи. *Йолдызларга йодрык күрсәтмиләр, Сокланып, таң калып багалар.* Р.Фәйзуллин

2) Ашатып, эчертеп, тәрбияләп тору, карау. *Рәхмәт, әнкәй, сиңа, Ярый әле мине тапкансың, Озын төннәр буе, йокламыйча, Җырлар җырлый-җырлый баккансың.* Һ.Такташ. *Үзен тагын да ун ел бактык.* Д.Аппакова. *Малларын үзенчә, искечә бага торган кеше бит ул.* Ә.Айдар. *Сау-сәламәт кешедән дә бик күп көч сорый торган, бала багудан да саваплырак башка гамәл юктыр.* Ватаным Татарстан

**2.** *ярд. ф. функ.* Сынап карау, тырышып карау мәгънәсендә кулланыла. *Аны селкетеп карады, капкачын ачып күз салды, иснәп бакты.* Ф.Әмирхан. *Малайлар яхшылык белән дә сорап карадылар: «Берне генә, Гарәфи малай, кечкенәсен генә»--- дип тә бактылар.* Г.Гобәй. *Кабул күрсәң – укып бак, күрмәс булсаң – ертып утка як.* Т.Гыйззәт. *Ыру шаманы Акай күз өшкереп-төкереп бакты.* Тәмуг чәчәге

**3**. **бак, баксана** *ы. мәгъ.* Кара син аны, кара әле мәгънәсендә, игътибар итәргә кирәклекне, гаҗәпкә калуны белдерә. *Баксана! Бөтен күлем айкала!* Н.Исәнбәт. *Гөлҗамал абыстай, ишеткәнең бармы әле, менә бу кем малаеннан, баксана, аты коргыры, үләме әллә югыйсә...* М.Гали

**4**. **баксаң, бактың исә** *кер. сүз мәгъ.* 1) Чын-чынлап уйласаң, игътибар итсәң. *Баксаң, шунда бер матур кыз тынып калган.* Н.Исәнбәт. *Бактым исә, бер дә катлауландырасы юк, барысы да мөмкин икән.* Ф.Хөсни

2) Соңыннан билгеле булганча, чынлыкта, чынбарлыкта. *Бактың исә, «дөнья» дигән нәрсә ул бер генә түгел икән әле.* Ф.Фәизов. *Баксаң, әле генә китерелгән сан да «соңгы сүз» булмаган икән.* М.Госманов. *Кичә кичтән күпме тоткан, күпме йоткан? Баксаң-күрсәң, бар да оныткан.* Совет Татарстаны

**Бага төшү** Тагын да әйбәтрәк багу

**Багып алу** Нәрсәгә дә булса тиз генә багу. *Менә вакыт ирешеп килә. Китәргә, ашыгырга кирәк, дип, тәрәзәдән тышка багып алдым.* Ф.Яхин

**Багып бару** Нәрсәгә дә булса игътибар итеп, даими багу

**Багып бетерү** Барысын да багу

**Багып калу** Багырга өлгерү. *--- бакча уртасындагы түгәрәк түтәлдә соң чәчәк ата торган тюльпаннар, аяз күк гөмбәзенә түйганчы багып калырга тырышкандай, кызыл керфек таҗларын киң итеп ачканнар ---.* М.Маликова

**Багып карау** Белергә тырышу, сынау, тикшерү. *Баягы теләнче: – Духтыр багып караган, өч көн үмере калган ---.* Р.Батулла

**Багып килү** Электән, күптәннән үк багу

**Багып кую** Тиз генә, бер тапкыр багу

**Багып тору** 1) Һәрвакыт, гел багу. *[Аймәт:] --- Минем күзләрем сиңа гына багып тора.* Т.Миңнуллин. *Урманның аргы ягында күккә багып торган наратлар артыннан таң атып килә.* Г.Гыйльманов

2) Әле, хәзерге вакытта багу. *Алмаш килгәнче, мин багып торырмын...* Р.Батулла

**Багып чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында багу, шул вакытның башыннан ахырына кадәр багу. *Төне буе бала багып чыгу*

**БАГУ** II *ф.* Кеше язмышындагы вакыйгаларның үткәнен яисә булачагын әйтеп бирү; күрәзәлек итү. *Аннан ул, бик теләп, борынгы Сөн гадәтләрен, йолаларын белеште, күрәзәчелек, багу, төш юрау серләренә төшенергә тырышты.* Н.Фәттах

**Багып бетерү** Барысын да багу; багу эшен төгәлләү

**Багып йөрү** Һәрберсен багу; әле, хәзер багу белән мәшгуль булу. *Чегән хатыны, өйдән өйгә кереп, багып йөри.* Ш.Галиев

**Багып карау** Багып сынау, багып, белергә омтылу. *Йә күрәзә, багып кара.* Ә.Баян

**Багып тору** Һәрвакыт, гел багу

**БАГУ** III *и.* Күрәзәдән соң туган хөкем; күрәзәнең нәтиҗәсе. *Соры кортлар гомер итә Багу багып, фал ачып.* Ә.Исхак. *Бу кеше дә халыкны дәвалау, им-том итү, багу белән шөгыльләнгәнгә, Сәгыйдне үзенең авызыннан аш алучы бер дошманы итеп карады.* Г.Гобәйдуллин

**БАГУЧЫ** I *и.* Кемне дә булса караучы, хезмәт күрсәтүче, аны тәрбияләүче. *Мал багучыга бер сыер өчен шулкадәр күп инә бирерләр ки, ул аларны гомер буе*

*тегү өстендә утырса да бетерә алмас.* Г.Тукай. *Багучыларга әйт, тәкә суйсыннар, кичкә юраугa килэм.* Р.Зәйдулла

**БАГУЧЫ** II *и.* 1) Кеше язмышындагы вакыйгаларның үткәнен яисә булачагын әйтеп бирүче; күрәзәче. *Багучының «ак юлыңа яткан кара җылан» дигәне шул Алтынчәч булмасын да, кем булсын, чичәм?!* Г.Ибраһимов. *Әллә үзем дә мәҗүс булам инде бу багучы белән.* Н.Исәнбәт. *Иң шомлы һәм, әйтергә мөмкин, хакыйкатькә дә якын сүзне, үзе дә тау астындагы ялгыз йортта ялгызы яшәп ятучы, әллә нинди серле, күңел түрләренә үтеп керә торган үткер карашлы багучы хатын Сара әйтте.* Р.Фәизов

2) Им-том итүче, өшкерүче, авыруларны төрле ырымнар белән дәвалаучы; сихер кайтаручы. *Малай күңеленә җирәнгеч булып күренә торган имче-томчы, багучыларга охшаган муллалар, хаҗилар аз түгел.* М.Ауэзов. *Барып җиттек, эзләп таптык багучыны.* Ф.Сафин. *Бибиса багучы ихтыярына буйсынгандай тора иде, кинәт айныгандай булды.* С.Сөләйманова

**БАГУЧЫЛЫК** *и.* 1) Күрәзәчелек, ырымнар белән эш итү; хиромантия. *Кайбер кешеләр моны «багучылык бу, иске хорафатлар калдыгы» дип күләчәк кенә.* Г.Бәширов. *«Багучылык – Коръәндә тыелган эш, дип карала бит», – дим.* Сөембикә

2) Им-том итүчелек; өшкереп, авыруларны төрле ырымнар белән дәвалау, сихер кайтару шөгыле. *Йә илдән ерак урман эчендә, юлдан язганнарны үзенә тартып китерә торган булып, багучылык кыла, им-том итә башлый.* Риваять

**БАГЧЫ** *и. иск.* Бакчачы. *– Бакчаңыз харап булган, һәлак булган! [диделәр]. – Бу сүздән багчыларда тәкать бетә, Авыздан утлы ачу чәчрәп китә.* Ш.Бабич

**БАГЫМ** *и. к.* **багу** III. *Бакчыдан багым бактырдым, Фалчыдан фалым ачтырдым, Сынчыдан сыным сынаттым, Анда белдем бу эшне.* Дастан

**БАГЫНДЫРУ** *ф.* 1) Үзенә каратып, буйсынырга мәҗбүр итү. *Икенчесе – Габдулла Зәбир углыдыр, аннан саклан. Аны үзеңә багындыра күр, буй итсә, хуш.* К.Насыйри

2) Игътибарны үзенә тарту, җәлеп итү, сокландыру. *Казан яклары, матур Агыйделләре, Кама, Волгалары, шәһәрләре, зур авыллары мине багындыралар.* М.Фәйзи

**Багындыра бару** Торган саен ныграк багындыру

**Багындырып алу** Билгеле бер вакыт аралыгында багындыру

**Багындырып бетерү** Тәмам, бик нык багындыру. *Минем Ибраһимымны бөтенләй үзеңә багындырып бетердең.* Г.Камал

**Багындырып килү** Һәрвакыт, күптәннән багындыру

**Багындырып кую** Кинәт, уйламаганда багындыру

**Багындырып тору** Бертуктаусыз багындыру, үзенә тарту

**БАГЫНУ** *ф.* 1) Кемгә, нәрсәгә дә булса артык мөкиббән китеп, нык мавыгу; табыну. *Багынма юк хыялларга.* Н.Исәнбәт. *Ә Илһам исә, кирә-керешенә, нәкъ менә шул ямьсез картинага багынды.* Тәмуг чәчәге

2) Буйсыну, бәйле булу. *Алар Иванга багынды, бөтен өлешләре белән ясак түләргә булып, Иванга сүз бирде.* Казан ханлыгы

**Багынып алу** Кыска гына бер вакыт аралыгында кемгә яки нәрсәгә дә булса бик нык багыну

**Багынып килү** Электән, күптәннән, даими рәвештә кемгә яки нәрсәгә дә булса багыну

**Багынып тору** Һәрдаим кемгә, нәрсәгә дә булса багыну. *Николай дигән поляк бик батыр, көчле, куәтле, хәйләкәр кеше булган. Тирә-як кешеләре аңар күбесе баш биреп, багынып торганнар.* К.Насыйри

**Багынып үткәрү** Билгеле бер вакыт арасында үзен тулысынча берәр шөгыльгә багышлау. *Дәресләргә ныклап әзерләнеп йөри ул, төнен китапка багынып үткәрәчәк, таң беленми йокларга ятмаячак...* Ф.Сафин

**БАГЫ́Р-БОГЫР** *иярт.* Сыеклык бик көчле кайнаганда чыккан тавышны белдерә. *Каз миңа күкәй бирде; Ул күкәйне казанга салдым, Багыр-богыр кайнарга. Үзем киттем базарга.* Такмак

**БАГЫШ** *и.* Караш, күз карашы. *Буйларыдыр – Идел камышы, Бәгыремнең якты багышы, колагымда, аһ, былбыл түгел, аһ, Яңрап калды аның тавышы.* Н.Исәнбәт. *Күзең – күлдер камышлы, багышларың сагышлы.* Җыр

**БАГЫШ-КҮРЕШ ИТҮ** *ф.* Булачак кода-кодагыйлар белән якыннан танышу, бүләк багышып (электә), туй хәстәрләре хакында сүз куешу

**БАГЫШЛАНУ** *ф.* Аталу, кемгә яки нәрсәгә дә булса игътибар юнәлтелеп, махсус атап эшләнү. *Бу концертыбыз Алмас иптәш Сафинның туган көненә багышлана.* А.Әхмәт. *Фәйрүзәгә багышланды Шагыйрьләрнең җырлары.* М.Җәлил. *Урта гасыр төркиләрдә дә (мәсәлән, сабирларда) ат иң олы Алла – Тәңреханга багышлана торган була.* Г.Гыйльманов

**БАГЫШЛА́У** *ф.* **1**. 1) Атау, билгеләү, хаслау. *Менә шуны җеназаң өстендә синең исемеңә мәңгелек бүләк итеп багышлыйм.* М.Фәйзи. *[Гыйззәтуллин] Үз гомерендә беренче тапкыр җыр чыгарды. Ул аны Гайшә Баязитовага багышлады.* М.Мәһдиев

2) *юг.* Матди яки рухи теләктәшлек күрсәтү, бүләк итү, билгеләү; сарыф итү, бирү. *Гаптерәшит бәхетеннән генә Ходай безгә багышлады бит.* М.Фәйзи. --- *пакь яшь хатын бөтен дәртен, җан көчен балаларына, балаларының әтисенә багышлады.* Т.Мөбарәков

3) *сир.* Карар чыгару, нәтиҗәгә килү; фараз кылу. *Купеда – бер симез гәүдәле абый (нигәдер, мин аны сәүдә кешесе дип багышладым) һәм мин.* Б.Камалов

4) *дини* Укыган доганы әрвахлар рухына, тереләр саулыгына, аларның бәрәкәтле тормышына атап, теләк теләп йомгаклау. *Шул вакытта ук, җиде газизләр рухына җиде ясин чыгып багышларга, суфи абзыйга садака җибәрткән идем.* Г.Камал. *Узган Мәскәүгә баруында да: «Мә, әби, Хуҗа Баһаветдин рухына багышлап дога кылырсың», – дип, илле тиен сәдака биреп киткән иде.* Г.Камал. *Шуннан соң без, җомга намазын тәмам иткәч, җыелышып, иң элек зиярaтка барып,*

*әрвахларга, мәетләргә Коръән укып багышладык.* М.Гали

**2. багышлап** *рәв. мәгъ.* Алдан махсус билгеләп, атап, хаслап, исемләп, тәгаенләп. *Аны Кояшка, Күккә багышлап биргәннәр.* Г.Гыйльманов. *Вак акчаларым юк иде, кесәдән, актарына торгач, җиңү көненә багышлап чыгарылган тимер берлек таптым.* Р.Сибат

**Багышлап алу** Махсус атап багышлау

**Багышлап килү** Даими багышлау

**Багышлап кую** Алдан ук багышлау

**Багышлап тору** 1) Һәрвакыт, даими багышлау

2) Әлегә, хәзергә багышлаган булу

**Багышлап чыгу** Һәрберсенә багышлау

**БАДӘМ** *и. фар.* Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, көрән, кызгылт сары кабыклы, бәбәкләре өскә тырпаеп торган кыска ботаклы, яфракларыннан алда чәчәк ата, көньякта үсә торган куак үсемлек һәм аның каты төшле, майлы җимеше; *русчасы:* **миндаль**. *Бадәм ике төрле була. Берсе – татлы бадәм, икенчесе – ачы бадәм.* К.Насыйри. *B15 витамины (пангале кислотасы) күп үсемлек орлыкларының бәбәнәк рәвешендә һәм шытымнарында, бадәмдә һәм каты төшле башка җимешләрнең төшләрендә була.* Юлдаш календаре

**БА́ДЕ САБА** *и. фар.-гар. иск.* Саф, йомшак җил. *Сөйләшкән сүзләре гөлдәй тамадыр, Сулаган сулышы – баде-сабадыр.* Г.Тукай

**БА́Д ИТҮ** *ф. иск.* Җилгә очыру. *Безнең публика исә шул азан әйтүдән ниндидер кызык табып, кычкырып көләргә тотына да бөтен тәэсирне бер бад итә, юкка чыгара.* Корылтай

**БАДМИНТОН** *и. ингл.* Койрыклы кечкенә шарны җиргә төшермичә, челтәр аша ракетка белән бәреп уйнала торган спорт уены. *Алып кайттым шәһәрдән Бадминтонны, теннисны, Эспандерны, гантельне Һәм ике потлы герне.* Ш.Галиев. *Рәшит абыең гел бадминтон уйный синең яшьтәге вактөяк кызлар белән.* М.Мәһдиев

**БАДМИНТОНЧЫ** *и.* Бадминтон уйнаучы (спортчы)

**БАДРАН** *и. фар. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, яфраклары абага яфрагына охшаган, көпшә сыман сары чәчәк ата торган, чәчәк кәрзиннәре зонт кебек урнашкан дару үсемлеге; гөлбадран; *русчасы:* **пижма**

**БАДЪЯ** *и. к.* **бадъян** I. *Бетон төяп, ашыкмый гына, беренче бадъя төшә.* Ә.Айдар

**БАДЪЯН** I *и. фар. диал.* 1) Чокып ясалган зур булмаган агач савыт. *Кияүкәем, сиңа, ал, сиңа, Бадъяннар белән бал сиңа. Бадъянда балың бетмәсен, Башларыңнан дәүләт китмәсен.* Җыр. *Карчык күкәйләрне салкын сулы агач бадъянга батырды, кечкенә савыт белән тоз китерде.* С.Рафиков. *Хуҗа хатын, тулы гәүдәле булса да, йөгереп кенә дигәндәй, агач бадъян, агач кашык алып килде.* Р.Кәрами

2) Агачтан эшләнгән кое чиләге. *Рәхилә коеның зур һәм авыр бадъянына үрелгән җирендә тукталып калды.* И.Туктар

3) Шахта чиләге. *Миңа да җир өстенә чыгарга чират килеп җитте. Икенче берәү белән мине салмак бадъян әкрен генә югары күтәреп алып менеп китте.* М.Гафури

**БАДЪЯН** II *и. фар. бот.* Бадъянчалар семьялыгыннан, жимешләрендә составы буенча әниснекенә охшаш эфир мае булган, хуш исле куак яки тиречел яфраклы мәңге яшел тәбәнәк агач. *Бадъян чәчтем, уңсын, дип, бупазналар тулсын, дип.* Җыр. *Шомырт бөдрәләнгән чакта, Бадъян чәчәк ата икән.* Г.Тукай. *Бадъян исләре аңкып тора.* Ш.Камал

2) Шул үсемлекнең аш тәмләткеч итеп кулланыла торган орлыгы. *Канәфер ачы, бадъян төче; Яшем унбишетән кече.* М.Фәйзи. *Дөге, май, үрдәк ите, суган һәм сарымсактан башка, аңа канәфер, бадъян, кардамон, борыч һәм әллә нинди үләннәр салып пешерәләр.* В.Юнысов

3) Әнис алма агачы. *Басмас идем баскычыңа, Баскычларың – бадъян агачы.* Җыр

**БАДЪЯ́Н ГӨЛ** *и.* Бүлмәдә чүлмәктә үстерелә торган әнис үләне. *Бадъян гөлләр чәчәк ата, Кояш көлеп караса, Күңелләрдә ялкын арта, Кызлар сөеп караса.* М.Җәлил

**БАДЪЯ́Н ТӨС** *с.* Саргылт көрән төс. *[Әсир Мөхәммәт] Уңып, кызыл төстән бадъян төсенә әверелгән --- башлыгын, купшылап, җилкәсенә салды.* К.Тинчурин

**БАДЫМҖАН** *и. фар. бот.* 1) Эт җиләге сыманнар семьялыгыннан, озын туры сабаклы, эре яфраклы, чук чәчәк төркеменә караган, миләүшәсыман чәчәкле берьеллык яшелчә үсемлек; *русчасы:* **баклажан**. *Безнең шартларда бакчачылар бадымҗанны үрентедән үстерәләр*

2) Шул үсемлекнең куе зәңгәр яки шәмәхә төсендәге кыярсыман озынча җимеше

**БАЕК** I *и. этн.* Башкорт халык биюе

**БАЕК** II *рәв. иск.* 1) Анык, төгәл билгеле; һичшиксез. *Йосыф --- һич гөмансыз, баек колдыр.* Кол Гали

2) Тәмам, бөтенләй. *Остазым бу җиһандин баек бизде.* М.Колый

**БАЕКЛАНУ** *ф. иск.* **1.** Анык, төгәл билгеле булу, анықланган, ачыкланган булу

**2. баекланган** *с. мәгъ.* Үзенә хас булган. *Г.Тукайның характерын сөйләгәндә, аның кайбер үзенә генә баекланган берничә төрле кызыклы табигатьләреннән берничәсен язып китәм.* Г.Камал

**БАЕКЛА́У** *ф. иск.* 1) Кемгә дә булса тәгаенләү, атау

2) Ачыклау, аныклау, алдан билгеләп кую. *Йөгерергә ике кешене баекладылар. Берсе – патшаныкы, икенчесе – Аю-Әппәзнеке.* Әкият

**Баеклап бетерү** Барысын да баеклау

**Баеклап кую** Алдан ук баеклау

**Баеклап тору** Даими, һәрвакыт баеклау

**Баеклап чыгу** Рәттән, һәрберсен баеклау

**БАЕКТЫРУ** *ф. диал.* 1) Баету, файдалылыгын арттыру. *Тау рудаларын баектыру комбинаты*

2) *күч.* Тынычландыру, ачыклык кертү. *Бу шаһлык шәүкәтен, Хөсрәү, куеп тор, Оныт тәнне, элек җанны баектыр.* Котб

**Баектыра төшү** Бераз баектыру

**Баектырып бетерү** Тулысынча кирәкле компонентларын арттыру

**Баектырып кую** Алдан ук баектыру

**БАЕТКЫЧ** *и.* 1) *тех.* Катнашма кертергә ярдәм итә торган җайланма, механизм. *Двигательне җибәргәндә, цилиндрларга ягулыкны күбрәк бирү өчен, регуляторның баеткычы хезмәт итә.* Хәзерге тракторлар

2) Катнашманың файдалылыгын күтәрә торган матдә

**БАЕТУ** *ф.* 1) Матди байлык өстәү, байлык арттыру, бай итү. *Хуҗалыгымны баетыр өчен түгел, колхозны, илне баетыр өчен.* Р.Ишморат

2) Рухи байлык өстәү, мәгънәле, эчтәлекле итү, тулыландыру. *Димәк, узган тарихны гыйльми объектив рәвештә тулы белер өчен, аны төрле яктан яктырткан чыганакларның да саннарын ишәйтергә, баетырга кирәк икән.* М.Госманов. *Дөнья классикларының иҗатларын өйрәнү һәм югары музыка культурасын үзләштерү нигезендә эшләнгән бу әсәрләр татар музыкасын яңа жанр һәм яңа үрнәкләр белән баеттылар.* М.Җәлил. *Шуңа күрә, аның белән очрашулардан соң, безнең укучыларыбыз, аның җырларын концертларда башкарып, үзләренең репертуарларын баеталар иде.* Л.Моратова. *Алар эчтәлеге белән дә, тышкы кыяфәте белән дә баланы җәлеп итә, аның күңелен, зиһенен баета.* Казан утлары

3) *махс.* Катнашмага тагы да кирәкле компонентлар өстәү, катнашманың файдалылыгын арттыру. *Күрәсең, биредә югарыдан сикергән агымсу, меңләгән куыклар белән богырдатып, агып килгән суны өстәмә һава, азык микъдары белән баета...* А.Хәлим. *Тау эшләре институтында профессор В.Классен рудаларны баетуны камилләштерү эшләре белән җитәкчелек итә.* Могҗизалар энциклопедиясе

**Баета бару** Торган саен ныграк баету. --- *көзгеләргә тынгы бирмичә, «мин дөньяга ничек күренәм» дип түгел, ә «мин дөньяны ничек күрәм» дип, үзен рухи баета барып, тумыштан бирелгән сәләтен һәрдаим сугарып, аңа белем нектарлары өстәп яши белгән укымышлы, чын актриса.* М.Галиев

**Баета килү** Электән үк, эзлекле рәвештә баету. *Тату, күңелле, ишле гаиләнең җырлы-моңлы хезмәт тулы бу кичләре, мөгаен, булачак шәхеснең күңелен әллә нинди тәэссоратлар белән баета килгәндер.* Э.Шәрифуллина

**Баета тору** Баетуны дәвам итү. --- *бүгенге көннең актуаль мәсьәләләрен яктырткан, көннең кадагына суга торган шигырьләр язып, Марска җибәргән кулъязмаңны баета тор.* Ф.Яруллин

**Баета төшү** Тагын да баету. *Алар, үзләренең гүзәл күренеше, матур сайраулары белән, тирә-якны, бигрәк тә урманнарны, болыннарны нәфасәти яктан баета төшәләр.* К.Гыйззәтов. --- *эстетик тәҗрибәңне баета төшкән саен, синең зәвыгың да отыры нечкәрә бара.* Л.Шарова

**Баетып алу** Тиз генә баету. *Игенченең аңын ансат кына үстереп, колхозларны тиз генә баетып алырга да, тизрәк, коммунизмның ишеген кагарга ашыга идек.* Г.Бәширов

**Баетып бару** Акрынлап арта барып баету; бертуктаусыз баету. *Гомерем буена әнә шул Талисман минем күкрәгемне җылытып, рухымны саклап, язмышымны баетып бара.* М.Галиев. *Җыр-көй Ә.Еникинең күп кенә хикәя, повестьларына үзенчәлекле моң сирпи, аларны хис-кичерешләргә баетып бара.* Ф.Хатипов

**Баетып бетерү** Тәмам, бик нык баету; барысын да баету

**Баетып җибәрү** Баерга этәргеч бирү, тагын да баету. --- *чит ил тормышыннан алынган киң полотнолы әсәр буларак, репертуарны, артистларның уен стилен баетып җибәрде.* Д.Гыймранова. *Әлеге китапта да чуваш, калмык, бурят, әрмән, литва поэзияләреннән кайбер матур үрнәкләр бирелгән. Алар шагыйрь иҗатын тулыландыра, баетып җибәрә.* Р.Миңнуллин

**Баетып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә баету

**Баетып килү** Даими рәвештә, системалы баету. *Сөйләмнең аһәңен, эмоциональ тонын баетып килгән риторик сорау җөмләләр мәкальләрне формалаштыруда гаять уңышлы файдаланыла.* Г.Нәбиуллина

**Баетып тору** Даими, һәрвакыт баету. --- *драматургларыбыз әле 20–40 нчы елларда ук татар театрын һәрдаим яңа пьесалар, инсценировкалар, тәрҗемәләр белән баетып торганнар.* М.Сәлимҗанов

**Баетып яту** Һәрвакыт кемне дә булса баету. *Ә менә синең байыйсың килми, сукса тимер өзәрлек Тәкъвә Сәхәүне баетып ятасың.* М.Әмир

**БАЕТУЧЫ** *и.* 1) Файдалы казылмаларга кирәкле компонентларны өстәүче, шушы өлкәдәге белгеч

2) Матди яки рухи байлык өстәүче; мөлкәтне тулыландыручы. *Сара апа минем җыр иҗатымны баетучы дустым булды.* Р.Тимерханова

**БАЕШ** *и.* 1) Күк җисемнәре байый торган як; көнбатыш. *Кояш баешында тоташ кара болыт күренде.* Г.Гобәй. *Бу вакытта кояш баешы ягындагы тирән караңгылыктан, сирәк-мирәк, күк күкрәгән кебек тавышлар ишетелә.* М.Гафури. *Мин кояш баешына юл тоттым, ә Рафис кояш чыгышына киткән иде.* М.Маликова

2) Күк җисемнәренең офыктан югалу күренеше. *Кояш баешын күзәтү*

**БАҖ** *и. фар. тар.* Пошлина. *Ул, базарда әйбер саткан-алган өчен, сатучы-алучылардан салым (баҗ) җыя.* М.Гайнетдинов. *Баҗ кереме*

**БАҖА** *и.* Бертуган кызларның ирләре. *Нигә син, баҗа, шул иң кадерле кунагыңны ялгызын гына чакырмадың?* М.Кәрим

**БАҖАЙ** *и. к.* **баҗа.** *Әйдә әле, баҗай, бераз һава сулап керик.* Н.Хәсәнов. *Бу сүзне Татарстанның халык шагыйре, сатира-юмор остасы, «Чаян» журналының якын дусты Шәүкәт ага Галиевнең шунда яшәүче балдызы белән баҗае да расладылар.* Т.Нәҗмиев. *Баҗаең эш куа, җүнле эшләр генә аңа тоттырмый.* Ф.Яруллин

**БАҖАНАК** *и. тар.* Төрки телләр төркеменә караган, IX–XI йөзләрдә Европаның көньяк-көнчыгыш өлешендә яшәгән борыңгы төрки кабилә. *Мәсәлән, тарихта атаклы этноним – рус елъязмаларындагы «печенег», төрки*

*чыганаклардагы «бажанак», «бәҗәнәк» – асылда, «баҗалар» дигән сүз (азәрбайҗан телендә «бажанак» – «баҗа»). Димәк, бу халык – үзара баҗалык мөнәсәбәтендә торган ыруглар һәм кабиләләр.* Р.Әхмәтьянов

**БАЗ** *и.* 1) Өйдәге идән асты чокыры. *Күрше кызы Сәрвәр базда иде, Ишетеп чыкты бала тавышын.* М.Җәлил. *Аннары, базга төшеп, бәрәңге алып менде, әрчеде, юды, турады.* И.Гази. *Фәрит, өйләренә алып кереп, бәрәңге базларын ачып күрсәтте.* Г.Гобәй

2) Азык-төлек саклау, нәрсә дә булса урнаштыру өчен, җирне казып, стеналарын кирпеч, таш белән әйләндереп яки агачтан бурап, өстен ябулы итеп эшләгән махсус чокыр; нәүрәп. *Безнең халыкның базында да меңәр литрлы шәраб мичкәләре утырсамы?* Ә.Хәбибуллин. *Ул, ак яулыгын колак артына бәйләгән, җиңнәрен сызганган, күлмәк итәген кыстырган килеш, кар базыннан иртәнге сөтне алып чыга иде.* Г.Әпсәләмов

3) Казып ясалган зур, тирән чокыр. *Бер юньсезе кирәкмәскә баз казып куйган.* А.Алиш. *Анда тирән базлар булыр, Каршы ягы сазлар булыр.* Н.Исәнбәт. *Төнге агач ботакларына битләрен тырната-тырната йөгергән Сәгыйдә, үзе дә сизми, базга килеп егыла.* Һ.Такташ

4) Җир өстендәге чокыр-чакыр, казылма. *Минем, ул баздан үтәрмен, дип өмет итәсем һәм дә тынычланасым килә.* Ш.Камал

5) *иск.* Җирне казып ясалган тирән чокыр; борынгы зиндан. *Койрыгын кырт чаптылар (да) Караңгы базга яптылар!* Дәрдемәнд. *Тоткыннар --- юеш, сасы базларда көн үткәргәннәр.* Г.Әпсәләмов

6) *этн.* Тирән чокыр өстенә чыбык-чабыклар белән каплап ясалган ау корылмасы; тозак. *Бүре базларын беләм, төрлечә була. Кайсына бүре төшә торган юл да ясала, баз уртасына ишек куеп, эчкә, казыкка сарык та бәйләп куялар.* Н.Исәнбәт

7) Балчык, ком, таш, руда һ.б.ш. казылмалар ала торган чокыр; мәгъдән (шахта, штольня). *«Татар егетләрен Донбасска, күмер базларына көчләп җыялар икән», – дигән хәбәр авылдан-авылга чабып кына йөри торган чаклар.* А.Гыйләҗев. *Үзләре тау төбәсенең буеннан-буена сузылган җимерек шахта базын карарга баралар.* Р.Хафизова

◊ **Базда үскән бәрәңге сабагы** Кояш күрми үскән бәрәңге сабагы кебек сузан, озын буйлы, ябык, чандыр һәм чырайсыз кеше. **Баз казу** Хәйлә, мәкер кулланып, кешегә бәла-каза китерү. *Дус-иш аша гаебеңне ябып калырга тырышу – үзең өчен дә, дустың өчен дә баз казу ул.* Р.Ишморат. **Баз яндыру** Нарат, каен кебек агачларны яндырып, күмер, сумала, дегет алу. **Баз яндыручы** Сумала, дегет һ.б. кудыручы

**БА́ЗА** *и. гр.* 1) *архит.* Багана яки колоннаның аска таба киңәебрәк торган өлеше; корылма нигезе

2) Нәрсәнең дә булса эшчәнлеге, үсеше өчен мөһим булган кирәкле матди шартлар яки рухи байлык, җирлек. *Әгәр шундый хәбәрләр күбрәк җыелса, тарихыбызның чыганак базасы тагын да көчәя төшәр иде.* М.Госманов. *Пенсиянең база өлеше хөкүмәт тарафыннан гарантияләнә, һәм ул бөтен кеше өчен бертөсле.* Сөембикә. *Урта Пошалым мәктәбе, реструктуризацияләнгәч, база мәктәбенә әверелачәк.* Ватаным Татарстан

3) Җитештерелгән матди байлыкны туплау һәм бүлү урыны, склад. *Чукотка автономияле округы хакимиятендә хәбәр итүләренчә, 5 мең тонна күләмендәге соңгы йөкне «Усинск» танкеры Певекка китерде, һәм ул андагы нефть базасында бушатылды.* Шәһри Казан

4) Кораллы көчләр тупланган төп пункт. *Алар кулы белән, гаскәри базалардан, складлардан теләсә нинди байлыклар читкә «ага».* Н.Хәсәнов. *Базага һөҗүм иткән булсалар кирәк.* А.Шамов. *Нижний Новгородта база туплау, аны хәрби кораблар, корал, белгеч, моряклар белән ныгыту өчен кирәкле чаралар күрелә.* И.Низамов. *Амур флотилиясенең базасына мине автобус илтеп куйды*. М.Мәһдиев

5) Аерым бер физиологик процесс-ны башкара торган органнар системасы. *Артикуляцион база*

6) Зурлык, габарит. *Тракторны авыр асылма машиналар белән эшләтергә кирәк булганда, аның буй базасын озынайтып, тотрыклылыгын арттыру яхшырак.* Хәзерге тракторлар

7) Хезмәт күрсәтү, тәэмин итү үзәге. *Без аның белән бер концерт бригадасында эшләдек, «Скумбрия» дигән йөзмә базада яшәдек.* З.Нурмөхәммәтов. *Шуны да бел: бездә быел чаңгы базасы аерым ачыла*. С.Шәрипов

**БАЗАЛЬТ** *и. лат.* **1.** Вулкан атылганда бүленеп чыга торган кара төстәге тау токымы (төзелеш материалы буларак файдаланыла). *Суынган лава төрле төстәге кристаллик гранит, каракучкыл базальт катламнары хасил итә.* Үткән заманнарга сәяхәт

**2**. *с. мәгъ.* Шул токымнан торган. *Ул кабык ике катлы, өске өлеше гранитлардан тора, ә аскы кат – базальт токымнары.* Р.Фәизов

**БАЗАР** *и. фар.* 1) Ваклап сату, сатучы һәм алучыларның алыш-биреш башкару бинасы, урыны, мәйданы. *Беркөн ул базарга алып чыккан читек-кәвешләрен кире алып кайтты да сәкегә күтәреп бәрде.* Ә.Фәйзи. *Миңа сиздермичә генә, сәнгатькәр дусты Халит Кумысников белән, колхоз базарына барып, күңелләренә хуш килердәй роза чәчәкләрен сайлап алып, букет ясаганнар.* К.Миңлебаев. *Сөтнең чиреге – өч сум, базарда – бер сум илле тиен.* М.Мәһдиев

2) Нәрсә дә булса сату яки алу максаты белән, сәүдә урынына җыелган халык. *Базар белә, базар бирә Һәр товарның үз хакын.* К.Булатова. *Сәяси вакыйгаларның һәммәсе турында хәбәрләр, алаймы-болаймы, ничек тә базарга, агай-эне арасына ирешеп тора.* Ш.Камал. *Хәер, без килгәндә, базар диярлек җире калмаган, халык таралган --- иде.* Ф.Хөсни

3) Зур масштабта сәүдә-товар әйләнеше; сату-алу мөмкин булган географик өлкә яки хуҗалык тармагы. *Урта Азия базарларына бер генә урыс купецы да аяк баса алмас, андагы барлык базарлар татар сәүдәгәрләре кулына кереп бетәр, татарның милли сәүдәсе гөрләп торыр, милли промышленносте үскәннән-үсәр.* И.Гази. *Бары тик, Идел*

*ташып, пароходлар йөри башлагач кына, Астрахань аша Казан базарына су юлы белән өрек-җимеш алып килгән Бохар сәүдәгәрләре Юныс Вәлишинны эзләп таптылар.* К.Нәҗми. *Европа базарларында – чыдый алмаслык конкуренция.* Урал

4) Базардагы бәя, хак. *Син тагын бигрәк базарын төшерәсең.* Ф.Бурнаш // Сату табышы. *Чөнки кучерүче – зур базар өчен эшләүче мәшһүр хәттат түгел.* М.Госманов

5) Бәяләнерлек, бәя куелырлык кыйммәт. «*Үлегенә карап мазары, товарына карап базары», – дигән бабайлар.* Т.Гыйззәт. *Кара таш чаклы булмастыр базарың.* М.Гафури

6) *күч.* Халык күп җыелган ыгы-зыгылы, гаугалы урын, шау-шулы, тәртипсез күренеш. *Ике хатын – базар, өч хатын – ярминкә.* Мәкаль. *Әллә шау-шулы базар каракны яшерә торган очрак булдымы бу?* М.Насыйбуллин

7) *күч.* Абруй, дәрәҗә; кирәклелек, хаҗәт. *Байга исә бу эш аның базарын төшерер, дәрәҗәсен киметер кебек тоелган.* Г.Ибраһимов. *Тик шулай да, базарын күтәрү өчен, ул тагын бераз киреләнеп торды.* И.Гази. *Ә мондыйларның [иске динчеләрнең] базары үтте инде.* К.Нәҗми. – *Кайгырма, сиңа шәбрәкләре дә табылыр әле. Хәзер аларның базары төшенке, – диде Мөстәкыйм бабай.* М.Әмир

8) *күч.* Кемнең дә булса берәр әйберен, «базар» дип кычкырып, кисәк тартып алып, бирмичә, уртада этеп-төртеп йөртү уены

◊ **Базар бозу** 1) Урнашкан бәяләрдән түбәнрәк хакка сатып, базар хакын төшерү. *Базымсыз базар бозар.* Мәкаль; 2) Тәртипле, көйле генә барган эшне бозу; җәнҗал, тавыш, таркаулык тудыру. **Базар йөрү** *диал.* 1) Базарда тамаша кылып йөрү. *Колхозчылар йокларга, базар йөрергә калдылар.* К.Басыйров; 2) *иск.* Базарда йөреп сату. **Базар кору** Эшсез, максатсыз җыелып тору. **Базар көнне ике тиен тормый** Мохтаҗлыктан гына кыйммәт торган әйбер турында. **Базар теле** Дорфа тел, базар жаргоны. **Базар тору** 1) Базарда сәүдә итү. *Ул [Шәвәли], көне буе базар торып, бары өч-дүрт кенә чүлмәк саткан...* С.Рафиков; 2) Кешенең яшь, көчле, дәрәҗәле чагы. *Клубка быелларда гына йөри башлаган кыз-кыркын, тәрәзә яктысына кызыккан ут күбәләгедәй, баянчы янына елышкан. Яктылык килеп җитә алмастай читтә – базар торырдай яшьтәгеләр.* К.Кәримов. **Базар тоту** 1) Базарда уңышлы сәүдә итү; 2) Базарлыклы, үтемле булу (товар турында); 3) Исем, дәрәҗә яки иҗат белән дан тоту; абруйлы, бәяле булу. **Базар төшерү (төшереп йөрү)** Үз кадерен үзе төшерү, үзен дәрәҗәсеннән түбән тоту. *Бүген дә карт ишек төбендәге калын таякка, чөйдәге каеш чыбыркыга берничә күз төшереп алды; ләкин үзен көчлек белән тыйды. Яңа катнашкан кодалар алдында, туй көннәрендә базар төшерү була, дип уйлады.* Г.Ибраһимов. **Базар хәбәре** Базар халкы арасында таралган хәбәр, имеш-мимеш. **Базар чабу (йөрү)** Базар буйлап, базардан-базарга йөреп сәүдә итү. *Сәлмән --- йөк өстенә утырып базар чаба.* Ф.Хөсни. **Базары калмау** Абруе югалу, авторитеты бетү. **Базары күтәрелү** Даны таралу, шөһрәт казану, сорау зур булу, ихтыяҗ арту. **Базары күтәренке** Даны, дәрәҗәсе бар; бәясе югары. **Базарын торган** Исем, дәрәҗә, дан тоткан чагы үткән, абруе, бәяләнгән чоры узган. *Буласы булган, базарын торган.* Мәкаль. **Базары төшү** Исеме-даны, бәясе төшү, абруен югалту, кадерсезгә калу. *[Раян] Кайчаннан минем сүзләрнең базары төште?* А.Гыйләҗев. **Базары узу (үтү)** 1) Әйбернең кирәкле, кыйммәтле чагы узу, модасы чыгу. *Ә мондыйларның [иске динчеләрнең] базары үтте инде.* К.Нәҗми; 2) Кешенең яшь, дәрәҗәле чагы узу. *Базарың үткәч, ялкының беткәч, Тагын бер кат килми яз.* М.Максуд. **Базар ясау** Шаулашу, барысы бердән сөйләү. *Иргалине танып алулары булды, янә барысы берьюлы телгә килде, берсен берсе уздырып, янә базар ясап алдылар.* М.Хәсәнов

**БАЗА́Р АВЫЛЫ** *и.* Даими рәвештә базар була торган авыл. *Менә ул [Гарифның әтисе] Базар авылыннан пар ат яллап --- җырлап кайта.* Ш.Камал

**БАЗАРБАШЫ** *и.* Базар хуҗасы. *Чин дәүләте чикләреннән салкын диңгез буйларынача исеме билгеле, даншөһрәтле, каты куллы һәм гадел базарбашының чакыруы Сәетне сөендерде дә, шомландырды да.* Ф.Латыйфи

**БАЗА́Р БӘЯСЕ (БӘҺАСЕ)** *и.* Сорауга, ихтыяҗга карап куелган хак, гомумән, базарда йөри торган уртача бәя. *Аның явымы да төрлечә, базар бәяләре дә әллә ничә төрле.* Ә.Фәйзи. *Базар бәһаләре яхшы иде.* Г.Ибраһимов

**БАЗАРГАН** *и. фар. к.* **базаркән.** *Базарганнар кунак сыман Хис итәләр үзен бар да.* Ф. Дунай

**БАЗАРГА́Н УРТАКЛАРЫ** *җый. и.* Ширкәт. *Алар «базарган уртакларына, ягъни товариществоларга (бу сүз «туар иш»тән килеп чыккан) бүленгән.* Г.Дәүләтшин

**БАЗАРКӘН** *и. фар. иск. кит.* 1) Алыш-биреш итүче, сатучы, сәүдәгәр. *Бусы «Сәмәрканд базаркәннәре ни-нәрсә төягән» дип сорау иде.* Ф.Латыйфи

2) Базар салымы җыючы

**БАЗА́Р КИЧ** *и.* Базар көненнән алдагы көн, иртәгә базар буласы көн. *Көтеп алынган базар алды көнне «базар кич» дип йөртәләр.* С.Рәфиков

**БАЗА́Р КӨН(Е)** *и.* Элек базар оештырыла торган якшәмбе көннең атамасы. *Ярар, базар көн артыннан килерсез, Алла теләсә!* Ә.Фәйзи. *Базар көнне җыенысына өч тиен – бер акча бирмәсләр иде.* Г.Гобәй. *Борчылма, базар көнне авыл казаклары белән берәр йөк китерергә сөйләшермен, гозеремне кире какмаслар әле.* Р.Мирхәйдәров. *Авыл базар көннәрендә корт аеручы умарта сыман гөжләп торган.* Р.Газиз

**БАЗАРКЯН** *и. фар. кит. к.* **базаркән**. *Берзаман, берничә базаркян берләшеп, зур кәрван белән Һиндстан ягына җыенуларын ишеткәч, ул ханнан үз иленә җибәрүен үтенде.* Т.Нәбиуллин

**БАЗАРЛАНУ** *ф. сир.* Җыелып шаулашып тору

**Базарланып тору** Әле, күз алдында, сөйләп торганда базарлану. *[Агайэнеләр] Гөж килеп, кайнарга, шауларга, алдарга, алданырга тотыналар. Шулай базарланып торганда, ерактан*

*берәр атлы, кораллы адәм күренә.* Г.Ибраһимов

**БАЗАРЛА́У** *ф. сир.* Базарга бару, базарда әйбер алып йөрү

**БАЗАРЛЫ** *с.* 1) Даими рәвештә базар була торган. *Хазар диңгезеннән күтәрелгән һәр сәүдәгәр юл өстендәге базарлы калага туктамый калмас.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Үтемле, сорала торган. *Ул базарлы китап булырмы? Сатылырмы?* Г.Исхакый

**БАЗАРЛЫК** *с.* **1**. 1) Базарда сатарга билгеләнгән; базарда сатылырлык. *Байныкы – базарлык, ярлыныкы – казанлык.* Мәкаль

2) Базардан сатып алырга билгеләнгән. *Шәйхел --- атасы белән туптуры: – Үзең базарлык бер тиен бирмәгәч, урламый ни эшлим? – дип теләште.* Г.Ибраһимов. *Базарлык акча*

**2**. *и. мәгъ.* Базарда сату өчен билгеләнгән әйбернең сыйфаты; товарның тышкы күренеше. *Сабагыннан сыдырып [алганда] --- карлыган сытыла, аның базарлыгы китә.* Г.Галиев

**БАЗАРЛЫКЛЫ** *с.* Үтемле, базарда тоткарлыксыз, тиз сатыла торган, базарда сатылырдай. *Карабодай чәчәргә уйлап торам әле. Әйе, уңа-нитә калса, базарлыклы да нәрсә үзе.* М.Шабай

**БАЗА́Р ХАКЫ** *и.* 1) Базарда урын алып сату иткән өчен, базар идарәсенә түләнә торган акча, урын хакы

2) *к.* **базар бәясе.** *Итекләрнең кыйммәте әүвәлгечә калды, ягъни дүрт тәңкә – ике көн хезмәт, әмма аларның базар хакы төрле-төрле булды.* Г.Тукай

**БАЗАРЧЫ** *и.* 1) Базарда сату-алу белән шөгыльләнүче; сәүдәгәр. *Бу вакыт теге базарчылар симез ит пешертәләрдер, ак күмәч ашыйлардыр, әбезгә нәрсә.* Г.Ибраһимов

2) Сату-алу өчен базарга килгән кеше. *Аннан һәр атнакич басу капкасына чыга да, базарчыларга утырып, Карагюргага китә иде.* Г.Ибраһимов. *--- ерак җирнең базарчылары кичтән үк безнең авылга килеп куналар.* Г.Ибраһимов

3) Базар салымы җыеп йөрүче

**БА́З БАКАСЫ** *и.* Койрыксыз җирсу хайваннары отрядына караган, башка бакалардан өске казналыгында тешләре булмавы, арткы аякларының кыскарак булуы белән аерылган, кара төстәге тәне лайлалы бизләр белән капланган, куркыныч янаганда, шул бизләрдән зәһәр сыекча бүлеп чыгара торган зур җир бакасы, гөберле бака

**БАЗИЛИК** *и. фр. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, төп сабакка урнашкан яшел я шәмәхә төстәге башак сыман зәңгәр чәчәкле, хуш исле берьеллык үсемлек, рәйхан (парфюмериядә һәм аш тәмләткеч буларак кулланыла). *Базиликның тәме һәм хуш исе башка тәмләткечләр белән бергә тагын да яхшырак беленә.* Сөембикә

**БАЗИ́ЛИКА** *и. гр. архит.* Эчке якны икегә бүлеп, урталыктан, рәт булып, баганалар тезелгән озын турыпочмаклык рәвешендәге антик һәм Урта гасыр корылмасы

**БА́ЗИС** *и. гр.* 1) *мах.* Колоннаның төбе, төрле архитектура бизәкләренең аскы өлеше

2) *геом.* Геометрик фигураларның аскы өлеше, нигезе

3) *геол.* Җир өстендәге торышы (координатлары) анык билгеләнгән һәм озынлыгы төгәл үлчәнгән туры сызык; тирә-юньдәге башка пунктларның координатлары шул линиягә нисбәтән хисаплап чыгарыла яки билгеләнә

4) *филос.* Иҗтимагый стройдагы җитештерүче көчләр белән җитештерү мөнәсәбәтләренең органик берлектәге икътисади нигезе. *Галә Ходаяров марксизмның базис һәм өскорма турындагы өйрәтмәсенә мөрәҗәгать итте.* Х.Госман

**БАЗЛЫ** *с.* 1) Базы, идән асты булган

2) Чокыр-чакырлы, сикәлтәле, казылмалы. *Ә аннары – ялларын тузгытып чапкан партизан атлары, базлы, чокырлы юллар, кара урман.* Г.Әпсәләмов

**БАЗЛЫК** *и.* Казылып, күпсанлы чокыр-чакырлар ясалган урын. *Ә аюлар сазлыкларны, Баткаклык һәм базлыкларны Таптап йөргәннәр.* Ә.Исхак

**БА́З ӨСТЕ** *и.* Баз (*2 мәгъ.*) өстенә ясалган корылма. *Силос базының өсте ачык калган да, ул бозылган, солы саламына су үткән дә, аның да күбесе черегән.* Г.Бәширов. *Безнең әткәй «Хезмәт»тә, көнлек белән, кар базының өстен төзәтә иде.* Г.Ибраһимов. *Алар, абзарларны, печәнлекләрне, бәрәңге бакчаларын, баз өсләрен, тавык кунаклый торган урыннарны карап бетереп тә әтәчне таба алмагач, өйгә керделәр.* М.Гали

**БАЗУ** I *ф.* Батыраю, кыюланып китү, батырчылык итү. *--- шулай да байларга һәм властька каршы ачыктан-ачык чыгарга базмыйлар.* М.Җәлил. *«Ә син тормышыңнан тулы канәгатьме?» – дип сорарга базды Наилә.* А.Гыйләҗев. *Җаны карышса да, малаеның сүзен аяк астына салырга базмады.* Ф.Латыйфи. *Мин, аларның шундый карашларын күреп, Васяның кем икәнен сорарга базмадым.* А.Шамов

**Базмый йөрү** Озак вакытлар дәвамында базмау, кыюлыгы җитмәү. *Гаять чибәр кызга күптән гашыйк булган Ямгуҗа бу турыда хыялланырга да базмый йөргән икән.* Т.Нәбиуллин

**Базмый тору** Бераз кыюлык җитмәү, тукталып калу, тоткарлану. *Солдат миналанган җиргә ничектер зарарланмыйча кергән дә, хәзер генә куркынычны абайлап, кузгалырга да базмый тора*. Х.Камалов

**Базып кую** Кинәт кыюланып китү

**БАЗУ** II *с.* **1**. Артык кыю, тартыну белмәс. *Бик базу икәнсез. Я Хода...* Б.Камалов

**2**. *рәв. мәгъ.* Үзен артык иркен тотып, әдәпсез кыланып. *Мирзахан абзый да, бәлки, хатыны сүзенә эченнән кул куйгандыр, чөнки төзелештәге яшьләрнең беришесе чамасыз базу кыланганны ул да хупламый.* Б.Камалов

**БАЗЫК** *с.* Тәбәнәк буйлы, таза гәүдәле, карсак; эре сөякле, киң җилкәле. *Базык гәүдәле, киң күкрәкле, зәңгәр күзле бу егетнең чын күңелдән аңа ярдәм кулы сузарга җыенуын аңлап алган Зиннәт, үз-үзен белештермичә, сыйныфташын кочаклап алды.* Ф.Сафин. *Аның теләгән аңлагандай, ишек ачылып китте, һәм мәктәп директоры Заһит Фәхруллинның базык гәүдәсе күренде.* Ф.Садриев. *Муса ишекне ачып өлгермәде, базык гәүдәле, зур кара күзле яшь егет керде.* Идел

**БАЗЫКЛАНУ** *ф.* Эре сөякле, киң җилкәлегә әверелү

**Базыклана бару** Акрынлап, базыкка әверелү

**Базыклана төшү** Бераз базыклану. *Тик Ләйләнең әле коеп куйган сын төсле гүзәллегенең камил чагы, Мөслимә исә ничектер базыкланарак төшкән.* Г.Бәширов

**Базыкланып бетү** Тәмам базыкка әверелү

**Базыкланып калу** Вакытлар үткәч, ниндидер вакыттан соң базыклану

**Базыкланып китү** Бераз, берникадәр базыклану

**БАЗЫКЛЫК** *и.* 1) Төптән юан булу яки җәенке калынлык

2) *күч.* Ныклык, какшамаслык, көчле булу. --- *бирешмәс базыклык белән, реакцион схоластикага каршы көрәшә.* Казан утлары

**БАЗЫМЛЫ** *с.* Тәвәккәл, йөрәкле, кыю. *Колонналар! Адымнарны базымлырак!* Ф.Бурнаш

**БАЗЫМСЫЗ** *с.* Кыюсыз, тартынучан, артык тыйнак. *Бер читтә базымсыз гына кызыгып басып торуымны күрә белгән дә күңелемә хуш килердәй сүзне тапкан бит әле!* К.Миңлебаев. *Берсе – базымсыз, икенчесе – чая, әмма хезмәттә үзләре бигрәк тә пар килгәннәр.* М.Шабай

**БАЗЫМСЫЗЛЫК** *и.* Кыюсызлык, тартынучанлык

**БАЗЫМЧАК** *с. к.* **базымчан**

**БАЗЫМЧАН** *с.* Кыю, тәвәккәл. *Базык булганчы, базымчан бул.* Мәкаль. *– Базымчан икәнсең, – дип, дерелди башлаган көчекне, пәлтә изүен чишеп, җылыга кертте ул [карт].* М.Хуҗин

**БАЗЫМЧАНЛЫК** *и.* Кыюлык, тәвәккәллек

**БАЗЫМЧАНЛЫ́К ИТҮ** *ф. к.* **базыну**. *Алар [Хөсәен мирза һәм яраннары] шулкадәр күп халык җыелган җиргә килергә базымчанлык итәрләрме икән?* Ф.Бурнаш

**БАЗЫМЧЫЛЫК** *и. к.* **базымчанлык**

**БАЗЫМЧЫЛЫ́К ИТҮ** *ф. к.* **базыну.** *Кара син безнең оялчан егетне! Ничек базымчылык иттең?* Н.Исәнбәт

**БАЗЫНУ** *ф.* 1) Артык кыюлык күрсәтү, кыюланып китү. *Чөнки минем белән көрешү аның өчен күңелле булмавын ачык аңлый алмый идем дә аны ул кадәр тәнкыйть итәргә базынмый идем.* Ш.Камал

2) Әрсезләнеп китү, артык әрсезлек күрсәтү. *Юк инде, ансы булмас! Син инде артыграк базынасың --- диде [Зөһрә].* Ш.Камал

**Базына бару** Торган саен ныграк базыну

**Базына төшү** Бераз базыну

**Базынып алу** Аз гына, кыска вакыт аралыгында базыну

**Базынып бетү** Тәмам базыну

**Базынып җибәрү** Кинәттән генә базыну

**Базынып китү** Кинәт базыну. *Гәүһәрия, артык кыюланып китеп, Вариска шундый итеп томырылып карады, әйтерсең таш ыргыткандай булды. Варис та базынып китте. Базынмаган бозга басмас, диләр бит.* Д.Гайнетдинова

**БАЙ** *с.* **1.** 1) Зур мал-мөлкәткә, байлыкка, күп акчага ия булган. *Келәтендә берничә тонна запас бодайлы, бура тикле сыер-таналы, йөзләгән кошкорт асрап яшәүче бай колхозчы ул.* М.Мәһдиев

2) Мул, күп, күп санда булган. *Бай табигать уйларыбызны тирәнгә җибәрде.* М.Әмир. *Сара ханым Садыйкова музыкабызга бай мирас калдырды.* Г.Бәширов

3) Кирәкле, файдалы компоненты күп булган (төрле катнашмалар, минераллар турында)

4) *сир.* Яхшы, затлы; кыйбат торган, зиннәтле. *Баярак кояш бар иде, ул диңгезгә дә, күккә дә бөек бер бай төсен бирә иде.* Г.Ибраһимов. *Чын затлылык, бай декор, нечкә кул эше аның әйберләренә илаһи төсмер бирә.* Сөембикә

5) Сый-хөрмәте мул булган, тәмле һәм күп ризык куелган. *Казанда фәнни-гамәли форумнарны сагынам. Йөзләп кунак, бай банкетлар!!! Белмим, кем хисабына?* Р.Харис

6) Рухи кыйммәте зур булган. *Аның вөҗданы һәм киләчәккә ышанычы кулыннан килгән изге гамәлләрнең һәммәсен кылырга, күңелендәге бай хәзинәдән башкаларга да өлеш чыгарырга куша.* Б.Камалов. *Без, бу китапны төзегәндә, Сара Садыйкованың зур, бай иҗатына галимнәрчә музыкаль анализ ясауны максат итеп куймадык.* Г.Зәйнашева. *Бай эчтәлекле утызга якын альбомнан нинди генә мәгълүмат алмыйсың?!* Сөембикә

7) Эчтәлекле, киң колачлы, зур нәтиҗәле, күп тупланган. *Гомумән, аның иҗатына – бай тематика, җырларына төрле характерлылык хас.* Г.Зәйнашева

**2.** *и. мәгъ.* 1) Зур милеккә хуҗа кеше. *Бай бай өчен тырышыр, ярлы ярлыга булышыр.* Мәкаль. *Байлар сала белгәннәр йортларын!* Г.Ахунов. *Шикәр – байлар азыгы, аны алыр өчен акча кирәк.* Казан утлары. «*Без сезгә заказ биреп, китаплар яздырыр идек, әйбәт түләр идек», – дияр өчен, бүгенге байларның бөтен мөмкинлекләре бар.* Татарстан яшьләре

2) Хуҗа. *Ашау – байдан, үлем – Ходайдан.* Мәкаль. *Үз бәхеткәйләрең, ай, булмаса, Байга хезмәт итеп кем ярый.* Җыр

3) Элекке вакытта зур мөлкәткә ия булган кешенең исеменә өстәп әйтелә торган сүз. *Бигрәк тә Әсәдулла бай мәктәбе дан тоткан.* Р.Салихҗанов. *Караватын да Хисами кода, әй, ялгыш әйтәм, Хисами бай, Мәкәрҗәгә барганда, йөз егерме тәңкәгә алып кайткан.* Г.Камал

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Бай кешеләр кебек. *Өйләнәсе булгач, бай булып күренергә тырышмыйча ярамый бит!* Г.Камал

2) Күпсанлы, шактый сандагы; зур күләмдә. *Безнең тормыш гыйбрәтле хәлләргә бик бай бит ул.* Г.Бәширов. *1986 елның көзендә Апаска кайтуым бик күңелле һәм хәтеремдә калырлык хатирәләргә бай булды.* М.Гыйниятова. *Инде шул вакытларда ук төбәкнең нефть ятмаларына бай икәнлеге мәгълүм була.* Татарстан

3) Мул тормышлы. *Аңа, дуслашу өчен, кешенең бай булуы да, данлыклы булуы да, зур урыннарда эшләве дә кирәкми иде...* Һ.Идиятуллина

4) *күч.* Телдән файдалану алымнарының күптөрлелеге, күп сүзләр кулланып. *Табигате белән базымсызрак*

*идеме, алманчасы аралашыр өчен җитәрлек бай һәм камил булмаудан кыенсындымы – Алла белсен.* Т.Әйди

**4.** *хәб. функ.* Байлыкка ия. *Табигать – бай, үз баласын ул ничек тә саклый.* М.Мәһдиев

◊ **Бай баесынга түгел, кояш баесынга (йөрү), бай баесын дип түгел, кояш баесын дип (эшләү)** Элек көнлекчеләрнең эшне, көн узсын, эш хакы килсен дип кенә, өстән-өстән генә эшләүләренә ишарә. **Байга керү** Байга хезмәткә яллану. **Бай икмәге килешү** Байга эшкә кереп, тазарып, тулыланып киткән хезмәтчегә карата кинаяле әйтем. **Байлар телеме** Бик юка итеп теленгән икмәк-күмәч телеме. **Байлар төсе (чырае)** Кызарып киткән тук кыяфәтле йөз. *Кунакка да байлар төсе керде, йөзенә чак кына алсулык кунгандай булды.* М.Хәсәнов. **Бай малына баш ору** Маллы-хәлле кешеләргә, түрәләргә ярарга тырышу

**БАЙ-БА́Й АГАЧЫ** *и. диал.* Зелпечәләр семьялыгыннан, караңгы төстәге кәүсәле, катлаулы яфраклы, кара яки кызыл җимешле куак агач; аю баланы; *русчасы:* **бузина**

**БАЙБАК** *и.* Сөркәләр семьялыгыннан, кыш көне тирән йокыга тала торган кимерүче дала хайваны; *русчасы:* **сурок**. *Байбак – типик дала хайваны.* Биология. *Елның җылы вакытында хәрәкәтчән йомраннар, байбаклар һәм кайбер башка җәнлекләр салкын чорда йокыга талалар.* Социалистик Татарстан

**БАЙБӘТЧӘ** *и. сөйл.* 1) Байның үсеп җиткән улы. *Байның улы – байбәтчә, Ашау-эчү – гадәтчә.* Г.Камал. *Атасы никадәр иске фикерле борынгы кеше булса да, анасы бик сөеп иркәләгәнлек сәбәпле, байбәтчә, бара-бара, атасының сүзенә күп колак салмаенча, үзе теләгәнчә, «заманча» йөрергә өйрәнеп, һәртөрле яңа чыккан мода киемнәрне киенә башлады.* Ш.Мөхәммәдев

2) Кеше хезмәтеннән файдаланып баеган кеше, бай. *Әхмәтсафаның этисе Мостафа да байбәтчә иде.* Ф.Сафин. *Шулай инде ул, туры әйткән, байбәтчәгә түгел, туганыңа да ярамый.* Ф.Сафин. *Байбәтчә үзен хет бер минутка минем урынга куеп карасын.* Р.Низами

3) Бай, тәкәббер һәм, гадәттә, азгын яшь кеше. *Караучылар: байлар, байбәтчәләр, Пудраларга чумган кырчаклар Көлә иделәр миннән.* Һ.Такташ. *Яшь байбәтчә цирктагы фәкыйрь кызларга биргән 200 сум.* Ш.Мөхәммәдев

4) Элеккеге вакытта интеллигентларны мыскыллап атау сүзе. *Дутов, Колчак әйтә: законнарны Байбәтчәләр язып торсын, дип: Ярлы, эшче халык, әүвәлгечә, Байбәтчәгә хезмәт кылсын, дип.* Ш.Бабич

**БАЙБӘТЧӘЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Байбәтчәләр кебек, кәпрәеп

**БАЙБИКӘ** *и.* Бай хатыны, бикә. *Ашау-эчү, кәеф кору – байбикәнең уйлары.* Г.Камал. *Аларны күпертмә җилкәле ак алъяпкыч япкан, зур һәм таза гәүдәле чибәр генә хатын каршы алды. «Шушы икән байбикә», – дип уйлады Габдулла. Ләкин бу – байбикә түгел, аның асравы гына иде әле.* Ә.Фәйзи. *Зиннәтле сарайлардагы байбикәләр аның крахмалын кершән итеп ягыналар.* Р.Фәизов

**БАЙБИЧӘ** *и.* 1) *диал.* Бай хатыны, байбикә. *Кафия түти – юантык, алтын тешле, көмеш калач алкалы, сәхнәдәге байбичәләр сыман бер хатын иде.* М.Мәһдиев. *Революциягә кадәр татарларда да байлар кибетләрендә – приказчик, байбичәләр өйдә асрау тотканнар, эшләрен хезмәтчеләргә эшләткәннәр бит.* Сөембикә

2) *этн.* Казакъ яки кыргыз баеның хатыны; байның хатыннары арасында өлкәне. *Бу тирмә йортның ак өе санала, байбичәнең даими торуы шунда була.* Г.Ибраһимов. *Егет җавап биреп өлгермәде, сабыр белән, вәкарь белән атлап, салкын караш белән, байбичә килеп керде.* Г.Ибраһимов

**БАЙГУРА** *и. сөйл.* Зур мал-мөлкәтле һәм, байлыгы белән кәпрәеп, үзен бик эре тотучы; бай, әмма саран кеше. *Икенчедән, иске авыл тормышыбызда байгураларның, хәлле муллаларның ике-өч хатын асраулары, аларның бары тик җенси азгынлык нәтиҗәсе генә түгел, бәлки, күп очракта, хуҗалык интересыннан чыгып эшләгәнлекләре ап-ачык күренеп тора.* М.Госманов. *Вулкан булып кузгал, кызыл халык, Байгуралар муенын борырга!* Х.Туфан. *Юл хәрәкәте иминлеге инспекторы яңа байгураны өйрәтә.* Юлдаш

**БАЙГЫШ** *и.* **1.** 1) Ябалаклар семьялыгыннан, башында, колаксыман булып, йоннары тырпаеп торган, чуар, кабарынкы йомшак каурыйлы ябалак; чырайсыз ябалак; мәче башлы ябалак; *русчасы:* **филин.** *Байгыш – чын урман ерткычы: керпе һәм көзәннәргә каныга.* Н.Хәсәнов. *Читтән килгән байгыш башыңа кунса, сәмруг кош булыр.* Ф.Сафин. *Аның [шагыйрьнең] бөркете кояш яктысыннан качучы --- байгышка (ябалакка) каршы куелган.* Н.Хисамов

2) *күч.* Ярлы, юаш, мескен кеше. *Бу сәер кеше, үз тирәсендәге йөзләгән инсанны санламыйча, адәм улларына күз дә салмыйча, үз уена үзе батып, байгыш сыман яши бирде.* А.Гыйләҗев. *Карт көнендә, шулай гөнаһ җыеп, Калдымыни ялгыз, байгыштай?!* Ә.Рәшит. *Атсыз-нисез, бер байгыш хәлендә калып йөрүе авыр, һай, авыр икән!* Ф.Сафин. *Сугыш тараткан адәм балалары әле җыелып бетмәгән, минем сыңарлар – кая барып бәрелергә белмәгән байгышлар – Рәсәйнең бөтен тарафында кайный иде.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Кичтән йокламый, бик соңга калып йокларга ята торган кеше. *Байгыш ләбаса мин – кичтән йоклап китә алмыймын.* К.Миңлебаев

**2.** *с. мәгъ.* Артык беркатлы, аңгырасыман. *Байгыш бала, ул ничек өметсез!* М.Фәйзи

**БАЙГЫ́Ш КҮБӘЛӘГЕ** *и.* Ябалакчыклар семьялыгыннан төнге күбәләк; ябалакбаш, ябалакчык; *русчасы:* **совка**

**БАЙГЫШЛАНУ** *ф.* 1) Күңелсезләнеп, сүзсез һәм хәрәкәтсез хәлдә уйга калу

2) Аңгыралану, мәгънәсезләнү

**Байгышланып тору** Әле, хәзер, күз алдында байгышлану

**БАЙГЫШЛЫК** *и.* 1) Күңел төшенкелеге

2) Беркатлылык, сүлпәнлек; ачыгавыз булу. *Байгышлыгы аркасында авырлык күрә*

**БАЙДА́РКА** *и. төрки* Ике очында да калаклы ишкәгә булган, борыны һәм арты ябык, тар, озынча ярыш көймәсе. *Минем Кабан күлендә байдаркада берике мәртәбә йөреп караганым бар иде.* Э.Касыймов. *– Кабан күлендә көймә ярышлары була. Шуннан әйләнербез. – Нинди ярышлар? – дип сорый. – Каноэ, байдарка ярышлары, – дим.* Г.Мөхәммәтшин

**БАЙДА́РКАЧЫ** *и.* Байдаркада йөрүче спортчы

**БА́ЙКА** *и. голл.* **1**. Тукыманың тыгыз һәм йомшак бер төре

**2**. *с. мәгъ.* Шушы тукымадан тегелгән. *Ап-ак простынялы, калын байка одеяллы кроватьларга каршы почмакта, радиоприёмник өстәле тирәсендә утырган кызылармеецлар Хәмитне күрү белән елмайдылар.* К.Нәҗми

**БАЙКА́У** *ф. диал.* Игътибар белән карау, бөтен тирә-ягын җентекләп карап чыгу. *Батман алсаң, сайлап ал, эчен-тышын байкап ал.* Мәкаль

**Байкап йөрү** Әле, хәзерге вакытта һәр тарафны байкау. *Алды-артыңны байкап йөр.* Н.Исәнбәт

**Байкап чыгу** Барысын да бер-бер артлы байкау. *Баш очында – портфеле Ул әйтмешли, «карт филе». «Карт фил» эчендә байлык: Хәлең җитсә, байкап чык!* Б.Хәлимов. *Хәсән Туфан – үзе бер дөнья. Бу дөньяны санаулы минутлар, сәгатьләр эчендә генә байкап чыгуы мөмкин түгел.* Н.Нәҗми

**БА́ЙКЕР** *и. ингл.* Мотоциклда зур тизлектә йөрү белән мавыгучы

**БАЙЛА́РЧА** *рәв.* Байларга охшарга тырышып, байлар кебек, байлар сыман. *Кыска гына әйткәндә, бәбәй туен үткәрүне дә үз өстенә алды, исемен дә, хәер-сәдакасын кызганмыйча, байларча итеп, зурлап куштырды.* М.Шабай. *Безгә караганда тормышлары мулдан, холык-табигатьләре дә байларча.* Ә.Хәбибуллин. *Ахырда, бу яклардагы халыкның фәнгә, гыйлемгә, галим-голәмәгә хөрмәтләре, ихтирамнары зурдан икән, дигән нәтиҗәгә килеп, байларча кикерә-кикерә, өстәл яныннан тора башладык.* М.Госманов

**БАЙЛЫК** *и.* 1) Күп күләмдә тупланган мал-мөлкәт, милек, кыйммәтләр, акча. *Өлкән улы Атласка атабыз --- изге тауны, андагы барлык байлыкны мирас итеп калдырган.* Н.Фәттах. *Яу уңышлы булганда, әсирләр кайта, байлык ишәя, халык та беразга тынып тора ---.* М.Хәбибуллин. *Имеш, бик зур байлык ята Кабан күле төбендә.* И.Гыйләҗев

2) Җитешлек, муллык, иркенчелек; *киресе*: **ярлылык, мохтаҗлык**. *Аллага шөкер, өебездә байлык җитәрлек.* Ф.Яруллин. *Мал-туар, дип инде, Ярмөхәммәтләрнең бер баш кәҗәсе, биш-алты тавыгы, дүрт бала казы бар инде. Шунысы да – зур байлык.* Р.Батулла. *Безнең үзебезнең дә ул чакта байлык ярыйсы, әти-әни исән, бер җиребез дә кешедән ким түгел иде.* Р.Гали

3) Мәгънәви, рухи кыйммәте булган нәрсәләр җыелмасы. *Әгәр дә Корея кешесеннән хәзер: «Синең өчен иң зур байлык нәрсә?» – дип сорасаң, ул женьшень тамырын да, алтын-көмешләрне дә атамас, ә: «Иң кадерле байлыгым – туганнарым», – дип әйтер.* Әкият. *--- табышканнары – җыйган кульъязмалары – фән байлыгына, халык хәзинәсенә әверелә, киләчәк буыннарга да кучә.* М.Госманов. *--- һәркемне көнләштерерлек иде мондагы байлык: озын-озын китап киштәләре бозау тиресеннән йә кытай кәгазеннән тегелгән калын китаплар күплегеннән сыгылып төшкән ---.* Б.Рафиков. *– Бу җирләр, бу байлык, бу матурлык – синеке дә, минеке дә, менә бу авыл халкыныкы да...* Ф.Бәйрәмова

4) Берәр нәрсәнең күп микъдарда, санда булуы. *Озынлыгы – өч, киңлеге ике метрлы келәмнең өслеге чиккән кульъяулыклар белән тула. Менә никадәр байлык! Моның кадәр байлык тагын кайсы язучыда бар икән?* Ф.Яруллин. *Икмәккә байлык – зур шатлык.* М.Мәһдиев. *Шәмси кулында бер пачка махорка күргәч, Даниловның йөзе берьюлы яктырып китте: – О, менә байлык!* Г.Бәширов

5) Бар булган запас, ресурс. *Барча байлыкны җыячаклар, имеш. Һич һөнәрсез бай булачаклар, имеш.* Г.Тукай. *– Президент булсаммы?! Бөтен байлыкны имә торган сугышларны бетерер идем.* Ф.Баттал

6) Күптөрлелек, күпьяклылык; эчтәлеклелек. *Мондагы торак йортларның төрлечә төзелүе, архитектура байлыгы безне янә гаҗәпләндерде.* Сөембикә

7) Нәрсәнең дә булса өстенлекле, кыйммәтле ягы. *Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.* Мәкаль. *Яраткан эшеңнән ләззәт алу – ул байлык.* И.Мәхмүтова

◊ **Байлыгы кикертә (сикертә)** Байлыгына, эш урынына, дәрәҗәсенә аркаланып, артык кылану. **Байлыкка чуму** Зур мал, байлык, дәүләт иясе булу

**БАЙЛЫКЛЫ** *с.* Зур мал-мөлкәткә ия булган, күп микъдарда, санда байлыгы булган. *Казакъның уртача байлыклы, күп адәмле ике ыругы бар иде.* Г.Ибраһимов. *Элек бу авылда төп хуҗа – күп җирле, зур байлыклы Әхмәтҗан булган.* Г.Иделле

**БАЙРАК** *и.* 1) Дәүләт яки нинди дә булса оешманың билгесе буларак, аның үзенә генә хас төсе, бизәге, эмблемасы төшерелгән һәм сапка беркетелгән тукыма кисәге; әләм. *Урмай, берничә кеше белән, Җик янына килеп, тау башына байрак кадый.* М.Җәлил. *Биреп канлы кызыл байрак кулларына, Ачам сугыш, салам киртә юлларыңа!* Һ.Такташ. *Биек текә койманың Көнчыгыш капкасы янында байраклар күтәрелде, капка ачылды.* Н.Фәттах

2) *күч.* Иҗтимагый идея. *Тукайны без бүген байрак итеп кадерләп күтәрәбез.* Ә.Хәбибуллин. *Мәһабәт гәүдәң, вөҗдан байрагыдай чал чәчләрең идарә утырышыннан, юбилейлардан, күренердәй башка урыннардан югалгач, миңа әллә ничек бик моңсу, бик ямансу булып китте.* Р.Хисмәтуллин

◊ **Байрак күтәрү** Берәр максат юлында көрәш башлау

**БАЙРА́К ЙӨРТҮЧЕ** *и. к.* **байракчы**

**БАЙРАКЧЫ** *и.* 1) Байрак күтәреп йөрүче кеше, байрак йөртүче, байрак тотучы. *Байракчылар трибунага юнәлделәр һәм үзләренең байракларын утыртып куйдылар.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Иҗтимагый идеянең башында торып әйдәүче, юлбашчы. *[Мәскәү]*

*Унбер Республика байракчысы, Илебезнең яшәү чаткысы.* М.Җәлил

**БАЙРОНИЗМ** *и. рус* 1) XIX гасыр башында, шәхси һәм милли азатлык идеяләре белән бергә, пессимизм, төшенкелек белән дә характерлана торган әдәби-иҗтимагый агым. *Менә шушы бөтен дөньяга «байронизм» мәзһәбен тудырган --- кешенең кулга алырлык бирәр әсәре безнең татар теленә күчерелгәне бар идеме?* Г.Тукай

2) *күч.* Күңел төшенкелеге, өметсезлек, җәмгыятьне санга сукмау һәм үз-үзеңә бикләнүчәнлек

**БАЙСА** *и. тар.* Аерым хокук бирелүе турында язылган тактачык. *Төлке Тимернең боларга бик эче янса да, берни кыла алмый, кулларында – хан байсасы.* Р.Зәйдулла

**БАЙТ** *и. ингл. информ.* 8 битка тигез булган мәгълүмат күләмен билгеләү берәмлеге

**БА́ЙТАК** *рәв.* **1**. Шактый, шактый зур, шактый күп. *Кичкә таба өй тәмам туздырылып, аннары тау башындагы күрше авылга ташылып беткәч тә, капка һәм койма баганалары белән байтак изаландык әле без.* М.Вәли-Барҗылы. *Күрәшеп кенә яшәп була, дип санаган Рамазан Закировның текә тау менәселәре байтак иде.* Н.Гыйматдинова

**2**. *с. мәгъ.* Шактый санда булган, күп. *Инде байтак гомер яшәлгән, байтак һава суланган, су эчелгән, дөнья күрелгән, дигән сүз.* Ф.Латыйфи. *Клубта кино бетеп, халык таралганга да байтак вакыт булды бит.* Э.Касыймов. *Ул клубта минем байтак кына бүтән җырларым да яңгырады.* М.Яруллин. *Изгенең изгесе булган ислам серләренә төшенергә теләүче байтак кешеләргә гомерләре белән саубуллашырга туры килгән.* Могҗизалар энциклопедиясе

**3**. **байтагы, байтагысы** *и. мәгъ. тартымлы форм.* Зур өлеш, зур кисәк, зур төркем; бөтеннең зуррак өлеше. *Үрдәкләрнең байтагысы күл өстендә пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр.* Я.Зәнкиев

**БА́ЙТАКТАН** *рәв.* Әллә кайчаннан бирле, моннан күп элек, әллә кайчан булган. *Су өсте байтактан бирле инде алсу нурга коена, күзләрне камаштыра.* М.Хәсәнов

**БАЙТАЛ** *и. монг.* **1.** 1) Өч яшьтән узмаган бия (әлегә колынламаган). *Сабыр, тыенкы байталларның кәгелләренә, ялларына яшь кызлар аллы-гөлле тасмалар үреп бәйләгәннәрдер.* Р.Зәйдулла. *Кәбирнең уйларын сизенгәндәй, байтал утлыктан үлән чемчүеннән туктады һәм аңа таба борылды.* А.Хәлим. *Кызгылт сарыга анда-санда чабата-чабата ак таплар төшкән байталлары да гаять юаш булып исемдә калган.* К.Миңлебаев

2) Эшкә җигелә торган бия (колынламый башлаган). *Байтал, чабып, бәйге алмас.* Мәкаль. *Майның беренче көнендә, авылның иң шәп байталы җигелгән, яшел дугасы җиз кыңгырау, ялыклар белән бизәлгән сыгылмалы тарантаска утыртып, гармуннар уйнап, киленне төп йортка алып кайтканнар.* Г.Сәгыйров

**2.** *с. мәгъ.* Яшь, өч яшьтән узмаган. *Байтал ат*

**БАЙТАР** *и. гар.* 1) *иск.* Атларны дәвалау белгече. *Байтарлар, корчаңгы булган атны, усак кайрысын кайнатып, суы белән юалар.* К.Насыйри

2) Терлек-туарны дәвалау белгече, дәвалау белән шөгыльләнүче; ветеринар, мал табибы. *Табиб әйтте: «Син байтарга бар, мин ишәккә дару итә белмәймен», – диде.* К.Насыйри. *Ветсанитар булдым. Ул вакытта «байтар» дип йөртәләр иде.* М.Мәһдиев

**БАЙТАРЛЫК** *и.* Хайван, терлек-туар авыруын өйрәнә, дәвалый торган белгечлек; байтар вазифасы

**БАЙТИРӘК** *и.* 1) *миф.* Тамырлары белән җир асты дөньясына җиткән, биеклеге белән күккә терәлгән юан һәм биек мифологик агач. *Бар икән, ди, дөньяда бер байтирәк, Гәүһәрдән дүрт ботагы аңа терәк.* Ф.Урманче

2) Йортта, нигезгә утыртылган, гадәттә, биек карт тополь агачы (борынгы бабалардан калган изге агач). *Байтирәкнең чайкалуы – җилдән.* Мәкаль. *Безнең борынгы бабаларыбыз – кабиләнең, ыругның, йортның символы итеп, байтирәк, караулы тирәк (тополь) утырткannар, аны изгеләштергәннәр. Безнең бабайларда байтирәккә сәлам бирү йоласы яшәгән. Караулы (хуҗасы бар) тирәккә тию (кисү, чабу, сындыру) тыелган. Байтирәк ата-баба нигезе дип кабул ителгән.* Татар милли педагогикасы

3) *бот. диал.* Кара тирәк, өянке. *Дачаларның күпчелеге исә икешәр катлы. Пальма, мәҗнүн (еламсар) таллар, байтирәкләр, кәрнизләргә үрелгән йөземнәр ышыгында.* Т.Әйди

**БАЙЧӘЧӘК** *и. бот.* 1) *диал.* Лаләчәләр семьялыгыннан күпьеллык үсемлек, төркестан лаләсе (тюльпаны)

2) *фольк.* Быел күргән беренче чәчәк. *Байчәчәкне бәхет китерә торган чәчәк дип санаганнар, аның буенча елның ничек киләсен күрәзәлек иткәннәр; кызыл чәчәк булса – бәхеткә, сары чәчәк булса – сагышка һ.б.*

3) *этн.* Апрель азагында үткәрелә торган беренче чәчәк бәйрәме, мәҗүси бәйрәм; җимчәчәк; нарынҗа

**БАК** I *и. фр.* 1) *махс.* Сыеклык салу өчен кулланыла торган, куб яки цилиндр формасындагы зур металл савыт; двигательдә ягулык савыты. *Бакка биш шешә аракы салдым – мотор үкереп эшли башлады.* В.Юныс. *Абый машина карый, Кирәк булса «дәвалый». --- Бензин салынган багын, көпчәген, тирә-ягын.* М.Садри. *Биш-ун минут эчендә, яшереп җыйган әйберләремне салга төядем, бакны тутырып ягулык салдым да матурны кабызып җибәрдем.* Тәмуг чәчәге

2) Хуҗалыкта сыеклык саклау өчен кулланыла торган калай, металл яки полиэтилен савыт. *Әмма су бакларының берсе генә исән калган.* А.Тимергалин. *Зур бакка бәрәңге юып тутырып куялар да кара-каршы утырып әрчергә тотыналар.* Ә.Фәйзи. *Аннары өстәл өстендә кичә кич егетләрдән калган шәраб шешәсен идәнгә алып куйды, су багын ачып карады, су юк иде.* Н.Хәсәнов

**БАК** II *и. голл. махс.* Судноның югары палубадагы борын өлеше. *Бүген вахтаның урыны бакта түгел, ә капитан күпере янында.* Ә.Хәбибуллин. *Ярый, Саня көтәдер, дип, бакка киттем.* Ә.Хәбибуллин

**БАКА** *и.* 1) Койрыксызлар отрядының җир-су хайваннары классына караган, бармак чуклары арасы ярылы һәм арткы очлыклары озын булып, сикерер һәм йөзәр өчен җайлашкан, сай, җылы сулыкларда үрчи, коры җирдә дә, суда да яши ала торган тереклек иясе. *Аның аяк астыннан вак бакалар чокыр төбенә, кибеп бетмәгән суга сикерештеләр.* М.Маликова. *Елганың аръягында, сазлыкларда бакалар кычкыра.* И.Гази. *Төнге тынлыкны Ишкәй буйларыннан килгән бака тавышы һәм койма-читән артларына поскан чикерткәләр сайравы гына боза.* Э.Касыймов

2) Умырткасы булмаган, кабырчыклы тереклек заты, моллюск

3) Ялкынсынудан барлыкка килгән шешенке авыруларның гомуми атамасы. *Күкрәк бакасы. Тамак бакасы. Теш бакасы*

4) Үз күчәрендә әйләнеп, ишекне терәп бикли торган бик, келә

5) Торыкны эләктереп кую өчен, капка баганасына беркетелгән кискә

6) Тегермәндә: аскы ташка кагылган орчыкка кидерү өчен, уртасында тишеге булган һәм баш-башы өске ташка беркетелгән металл пластинка. *Тегермәндә таш тешәү, бака утырту дисеңме – барысын да ул [Гайнан] берүзе эшләп җиткерә торган иде.* Ш.Маннур

7) Лампа челтәренең асты

8) Пыскып яна торган, челтәрсез, куыксыз кечкенә керосин лампасы. *Яңа эзгә басты тормыш та, Бака белән бетмәс күз нурлары, Аяклар да талмас тормозда.* М.Крыймов

9) Сул кул бармаклары белән басканда калын тавыш чыгара торган гармун клавишасы. *Габдрахман аны җыр китабындагыча өч кенә куплет итеп түгел, ә баянының бакалары ягындагы каешы өзелгәнче уйный...* К.Кәримов. *Гармунның теле – бер якта, бакасы икенче якта аунап, тапталып калды.* Ф.Хөсни

10) *сөйл.* Газ балоннарына куела торган яссы редуктор

◊ **Бака башлы** Киң, тупыйк башлы. *Хәзер Гарәфи абзагыз – курьер. Бака башлы штиблет бирделәр.* Г.Гобәй. **Бака ботыннан гына** Бик сай, бик тәбәнәк, кечкенә үлчәмдә. **Бака йоткан еландай** Комсызлыктан берьюлы күп ашап күбенгән кебек. **Бака күк симез (җәелгән)** Билсез, юан кыяфәткә кереп симергән. **Бака күле** Тәртипсез шау-шу; аңлаешсыз сөйләм. **Бака телле** Күп һәм аңлаешсыз сөйләүче; такылдык, лыгырдык. **Бака туе** 1) Язгы буаларда, күл һәм күлдәвекләрдә бакаларның хор белән бакылдаулары; 2) Шау-шулы, ыгы-зыгылы, кычкырышлы урын. *Бака туе – баткакта.* Мәкаль. **Бака туе (күле ясау)** Кешеләрнең, бер-берсен тыңламыйча, аңламыйча, барысы бергә кычкырып сөйләшүләре. *Туктагыз әле, бака туе ясамагыз өйдә.* К.Нәҗми. **Бака «үгез булам» дигән кебек** Кешедән күрмәкче, көченнән артык – көч, хәленнән артык шәплек күрсәтәм дип көчәнүдән көлеп әйтү

**БАКАБАЛЫК** *и. зоол.* 1) *диал.* Чукмарбаш

2) Тритон

**БАКА́ ГӨЛЕ** *и. бот.* Бегонияләр семьялыгыннан, яфраклары төрле төстә, юан тамырчалы яки бүлбеле күпьеллык гөл; *русчасы:* **бегония**

**БАКА́ ЕФӘГЕ** *и. бот.* Субуярчалар семьялыгыннан, акмый торган сай сулыкларда түшәлеп үсә торган яшькелт төстәге суүсем; бака түшәге; *русчасы:* **нитчатка.** *Ә «инеш» дигәненең суы күренми, бака ефәге белән капланган.* С.Зыялы. *Арыклар сусыз, аларны Бака ефәге сарган* К.Булатова. *Саимә килбәтсез салынкы җилененнән бака ефәкләре асылынып торган ала күзле кәҗәнең сыртын сыйпап узды.* К.Нәҗми

**БАКАЙ** *и.* Атның тояк өсте сөяге, ат ашыгы

**БАКАЙЛЫ** *и.* Бакай сөякләре белән уйнала торган уен; ашык уенының бер төре. *Бакайлы уйнап баемассың.* Әйтем

**БАКА́ КАБЫРЧЫГЫ** *и.* Умырткасыз су хайваннарының тышкы каты кабыгы. *Аның [Рәшитнең] бер кулында – чәчәкләр, бер кулында – әкәм-төкәмнәр, бака кабырчыклары.* Р.Ишморат

**БАКА́ КАЗАНЫ** *и. к.* **бака кабырчыгы**. *Бер чумганда, кулыма бака казаннары эләкте. Бездә моллюсклар калдырган перламутр кабырчыкларны шулай атыйлар.* М.Рафиков

**БАКАКА, БАКА-КАК** *иярт.* Бакаларның төрлечә бакылдау авазларын белдерә. *Куе камыш арасыннан бака: «Бакакака-бакакака», – дияр имди.* Г.Тукай. – *Бака-как! – дип куйды бака һәм, шунда ук, бакалар ишетә күрмәсен дип, тирә-якка карады.* В.Гаршин

**БАКА́ КАШЫГЫ** *и. к.* **бака кабырчыгы**

**БАКА́ КҮЛЕ** *и.* Бакалар уылдык сала торган сай һәм җылы тыныч күл яки елга култыгы; бакалары күп булган күл, буа

**БАКАКЫЙ** *и. диал. зоол.* Кабырчык эчендә яши торган су хайваны, моллюск-анадонта; *русчасы:* **перловица.** *[Гәрәй] Тар гына елганың баткаклы ярларын, бакакыйлар белән чуарланган күпер төбен --- күрде.* А.Гыйләҗев

**БАКАЛАВР** *и. лат.* 1) 1896 елга кадәрге Россиядә: дини академия укытучысы

2) Россиядә 1917 елга кадәр һәм 1991 елдан соң: университет һәм башка югары уку йортлары тарафыннан өстәмә имтихан тапшырганнан соң бирелә торган беренче гыйльми дәрәҗә. *Мәктәптә ике ел эшләгәннән соң, кайтып, колледжның соңгы ике курсын тәмамлыйлар. Шуннан соң гына студентка бакалавр дәрәҗәсе бирелә.* М.Мәхмүтов. *Альфред та шул ук гыйлем йортында гел «5»кә генә укый, быел бакалавр дипломы алачак.* Мәгърифәт

3) Шушы дәрәҗәне алган кеше

4) Франция һәм кайбер башка илләрдә: урта мәктәпне уңышлы тәмамлаган кеше

**БАКАЛАВРИАТ** *и. рус* 1) Кайбер югары уку йортларында: белгечләр әзерләүдә база программасы буенча диплом яклау белән төгәлләнә торган беренче баскыч укыту; шул рәвешле белгечләр әзерләү системасы

2) Кайбер югары уку йортларында: аны тәмамлаучылардан бакалавр гыйльми дәрәҗәсе алырга теләүчеләр өчен өстәмә белем бирү программасы

**БАКАЛЕ́Я** *и. гар.* 1) Төрле коры ашамлык товарлар (мәс., *чәй, шикәр,*

*он, ярма, борыч, тоз һ.б.*). *Складларда саклап торган аракы-виноларны, азмы-күпме кондитер, бакалея нәрсәләрен тизрәк точкаларга чыгарырга кирәк.* Ә.Еники

2) Шундый товарларны сата торган кибет. *Җамали агайның Тегәрҗеп урамына бакалея кибете ачарга мәхәлли мәэмүрләрдән рөхсәт алуы кеби, һәрвакыт мәйданга килә ала торган приютны сорарга уйлаганнар иде.* Г.Тукай

**БАКАЛЕ́ЯЧЫ** *и.* Бакалея товарлары белән сату итүче

**БАКАЛЫ** *с.* 1) Бакага бай булган, бакасы күп булган. *Бакалы күл буйларында Йөрмә, батып калырсың.* Шаян җыр

2) Бакалары (*9 мәгъ.*) булган, бакалары тезелеп киткән. *[Егет] Һәр кич, үзенең өч бакалы тальянын шыңгырдатып, боларның капка төбендә була.* Казан утлары

**БАКА́ ПӘРӘВЕЗЕ** *и. бот. к.* **бака ефәге**

**БАКА́ САКАЛЫ** *и. бот.* Су өстен төрле төсләргә буйый торган вак сүсемнәр, бака ефәгенең бер төре, субуяр, *русчасы:* **водокрас**

**БАКА́ ТӘҢКӘСЕ** *и. бот.* Нәрсенчәләр семьялыгыннан, вак яфраклы йөзмә су үсемлеге; нәрсен; *русчасы:* **ряска.** *Яр буен бака тәңкәләре баскан, яшел һәм озын кылыч үләннәр дә каплаган.* Г.Хәсәнов. *Шулай да кәрлә каеннар һәм таллар, бака тәңкәсе үсемлеге белән чагыштырганда, гигант үсемлек булып тоела. Бака тәңкәсе шулкадәр кечкенә, хәтта ул баш бармак тырнагына бик иркен урнашып бетә.* Ботаника

**БАКА́ ҮЛӘНЕ** *и. бот. к.* **бака яфрагы**

**БАКА́ ЯФРАГЫ** *и. бот.* Бака яфрагычалар семьялыгыннан, гадәттә юл кырыйларында җиргә түшәлеп үсә торган, киң яфраклы һәм нечкә генә сабакта башак сыман вак чәчәкле үлән; *русчасы:* **подорожник**

**БАК-БАК** *иярт.* 1) Үрдәкләр кычкырганда чыга торган кискен тамак авазын белдерә. – *Бак-бак! Әле очасы бик ерак. Тамак ялгап алырга кирәк!* – *ди үрдәкләрнең берсе.* – *Бак, бак, инде салкыная башлады бу як! Тизрәк көньякка очарга кирәк!* – *ди икенче үрдәк. Башкалар да аның сүзенә кушылалар.* – *Бак, бак, көньяк, көньяк!* – *диләр.* В.Гаршин

2) Бакаларның өзек-өзек кычкыру авазын белдерә

**БА́КЕН** *и. голл.* Сай җирләрне һәм фарватерны күрсәтер өчен, калкавычка беркетелгән фонарьле маяк. *Төннәрдә, хәзерге бакеннар урынына, 3–4 метрлы металл пирамидалар аларга юл күрсәтерләр.* Г.Лотфи. *Озакламый, без элекке «Шәймәрдән бабай бакены» дип аталган урынга килеп туктадык.* Р.Ишморат. *Әнә Шәяхмәт бакены...* Х.Сарьян

**БАКЕНБАРД** *и. нем.* Чигәдән яңакларга кадәр тар тасма сыман калдырып кырылган сакал; чигә-яңак сакалы. *Ә бит бакенбардлы егет аны, бер айдан сәхнәгә чыгарам, диде.* М.Мәһдиев. *Болай ул үзе – матур егет. Тик менә артык озын чәчләренә бераз кайчы белән кереп чыгасы бар, ә бөдрә бакенбардлары өстеннән әтинең кырыну машинасын йөртеп чыксаң, зыян итмәс иде.* Ф.Яруллин

**БА́КЕНЧЫ** *и.* Маякны карап торучы, маякчы. *Хәлим, бакенчы карт һәм аның ике иптәше белән, Иделнең аръягына чыкты.* И.Гази

**БАКЛА́ГА** *и.* Бөкеле яки капкачлы яссы калай савыт, фляга («баклак» сүзеннән). – *Әй, шайтаннар!* – *дип көчкә кычкырып җибәрә алды Хәнҗәров ---. Самакат тыныч, кымшанмады – баклаганы имә иде.* Х.Камалов

**БАКЛАЖАН** *и. к.* **бадымҗан.** *Җылыны яратучы кыяр, помидор, борыч һәм баклажан үрентесен кыраулар зарарлау куркынычы үткәч утырталар.* Йорт эшләре. *Помидор, баклажан һәм борыч орлыклары, температура 22–25 градус җылы булганда, тиз тишелеп чыгалар.* Йорт эшләре. *Үсә баручы айда: рассадага помидор, ташкабак, баклажан, кабак, борыч утырту башлана.* Татар мөселман календаре

**БАКЛАК** *и. иск. төрки* Су савыты; *к.* **баклага**

**БАКЛАН** *и. төрки* Пеликансыманнар отрядының бер семьялыгын тәшкил иткән, озынча гәүдәле, озын муенлы, суда йөзәргә һәм чумарга җайлашкан, күбесенчә балык белән тукланып яши торган кара төстәге кош; диңгез козгыны. *Шулай ук бакланнар, диңгез үрдәкләре, күпчелек акчарлаклар, яр буйларында яшәсәләр дә, беркайчан да төче су эчмиләр.* Б.Сергеев. *Бу ашламаны баклан, пеликан, олуш кебек кошлар җитештерә.* Кызыклар дөньясында

**БАКРА** *и. бот.* 1) Канәферсыманнар семьялыгыннан, куе алсу чәчәкле, берьеллык үләнчел үсемлек; чүп үләне; *русчасы:* **куколь**. *Безнең уйчан авыл кырларында Бакралар чәчәк атканнар.* Н.Баян

2) Шул үсемлекнең кара көрән төстәге агулы орлыгы. *Сукыр тавыкка бакра да – бодай.* Мәкаль

**БАКРАВЫК** *с.* Күп бакырып, бертуктаусыз кычкырып торган. *Ялгыз бәрән бакравык була.* Мәкаль

**БАКРА́ ГӨЛ** *и. бот.* Канәферсыманнар семьялыгыннан, төрле төстә чәчәк ата торган бүлмә гөле

**БАКРАЧ** *и.* 1) *иск.* Бакыр шлем. *Томан эченнән, борынгы батырлар киемендә, башына – бакрач, өстенә кирәүкә кигән берәү шәйләнә.* Н.Исәнбәт

2) *диал.* Озын саплы зур чүмеч. *Фәлән җирдә казан бар, барып карасаң, бакрач та юк.* Мәкаль. --- *чуеннан кушйодрык хәтле ит калҗасын бакрач белән сөзеп алып, тәлинкәмә китереп тә салды.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Каратут йөзле кеше. *Чуенның унбишенче кичәсе төсле кара булганга, егеткә «бакрач» кушканнар.* И.Гази

**БАКС** *и. ингл.* Америка акчасы; доллар. *Бишәр мең бакс алырсыз!* Казан утлары

**БАКТЕРИАЛЬ** *с.* Бактерияләр белән бәйле, бактерияләргә бәйләнешле, бактерияләр булган. *Лишайниклардан бактериаль авыруларны, шул исәптән туберкулезны дәвалау өчен, төрле антибиотиклар ясыйлар.* Л.Мәүлүдова. *Ул [прополис] организмның саклану функциясен көчәйтә, күп кенә антибиотикларның тәэсирен арттыра, кайбер бактериаль агуларны нейтральләштерә, авыртуны басу һәм яраларны төзәтү тәэсиренә ия.* Татар балы

**БАКТЕРИЗА́ЦИЯ** *и. рус* Бактерия йоктыру, бактерияләр белән тәэсир итү

**БАКТЕРИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Бактерияләр тәэсиренә дучар итү, бактерияләр йогынтысында тоту

**Бактеризацияләп алу** Бераз бактеризацияләү

**Бактеризацияләп бетерү** Бактеризация ясауны төгәлләү

**Бактеризацияләп килү** Даими рәвештә бактеризация ясау

**Бактеризацияләп тору** Һәрвакыт бактеризацияләү

**Бактеризацияли бару** Тоташтан, рәттән бактеризацияләү

**БАКТЕРИОЗ** *и. нем.<гр.* Бактерияләр тәэсирендә үсемлекләрдә килеп чыккан авыру, күгәрек. *Кыярларның аеруча күп таралган авырулары – сары тап, ончыл чык, бактериоз...* Җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы

**БАКТЕРИО́ЛОГ** *и. рус* Бактерияләрне өйрәнү фәне белән шөгыльләнүче белгеч. *Бер үк вакытта, ул Казан микробиология һәм эпидемиология институтында – инженер, ит комбинатында өлкән бактериолог булып та эшли.* Татарстан яшьләре

**БАКТЕРИОЛО́ГИК** *с.* 1) Бактериологиягә бәйләнешле, бактерияләрне өйрәнә торган. *Бактериологик тикшеренү*

2) Бактерияләр кулланган, бактерияләрдән файдаланган. *Бактериологик сугыш*

**БАКТЕРИОЛО́ГИЯ** *и. нем.<гр.* Бактерияләрне өйрәнә торган фән, микробиологиянең бер бүлеге

**БАКТЕРИОФАГ** *и. гр.* 1) Бактерияләрне юк итүче вирус (иң вак микроорганизм)

2) Бактерияләрне юк итүче матдә, препарат

**БАКТЕРИЦИД** *и. гр.-лат. биол.* Бактерияләргә каршы иммунитетны арттыра торган матдәләр. *Яңа савылган сөттә бактерицид үзлеге, ягъни сөтне әчетә торган микроорганизмнарның үрчүен тоткарлау сәләте бар.* Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә

**БАКТЕ́РИЯ** *и. гр.* Микроскоп аша караганда гына күренә торган бер күзәнәкле тереклек. *Ә кайбер бактерияләрне көчсез магнит кырына урнаштырсаң, аларның саны бик нык кими.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Бактерияләр, барыннан да бигрәк, туфракта күп.* Ботаника. *Шунысын да онытмагыз: изелгән сарымсак, парга әйләнгәндә, 20 сантиметр радиустагы бактерияләрне үтерергә сәләтле.* Тәмле тамак

**БАКЧА** *и. фар.* 1) Кеше тарафыннан агачлар, куаклар, чәчәкләр утыртып үстерелгән җир. *Урман эчендә, Иделдән ерак та түгел урнашкан бакчабызны, бакча эчендәге зәңгәргә буялган дача йортыбызны бик яратты.* Г.Зәйнашева. *Бакчада эшләү шундый ошады, колхоздан үзебезгә җир сорадык.* Г.Хәсәнов. *Мин бакчага – чәчәкләр янына чыгам, ашыгып, һәрбер иртәдә.* Казан утлары

2) Җир җиләге, яшелчәләр, бәрәңге үстерелә торган җир участогы. *Яшелчә бакчасында да эшләдек, кыр эшләре дә, башлыча, үз өстебездә иде.* М.Әмир. *Помидорлар үстергәнемне, җир казыганымны, башка төрле бакча эшләре белән шөгыльләнүемне, бакчага ук чыгып утырып, бик кызыксынып күзәтә иде.* Ю.Сафиуллин. *Абзар артындагы бакчада бәрәңгеләрнең, тишелеп, тернәкләнеп, яфракка узган чагы иде.* Казан утлары

3) Ял итеп йөрер өчен махсус булдырылган җир; парк, сквер. *Бакчада йөргәндә тәкәббер яшь кызлар, Тынгы юк егетләр күңеленә һич кенә.* Казан утлары

◊ **Бакчага таш ату (ыргыту)** 1) Кемгә дә булса төбәп, исемен атамыйча гына, төрттереп әйтү. *Синең бакчаңа таш аталар, Мәдияр, икәүләшеп, ашыгыч ярдәм күрсәтерсез агрегатка.* К.Кәримов; 2) Кыеклатып зыян эшләү. *Мортаза түгел син, ә акылы каза! Үз бакчасына үзе таш аткан нәрсә.* М.Хәсәнов. **Бакчада үсми** Бушка килмәгән, җиңел генә табылмый, җирдә ятмый; акчага табылган әйбер, кадерен бел, дигән мәгънәдә. **Бакча җимеше** Үз бакчасында үстерелгән, акча тотып сатып алынмаган җиләк-җимеш яки яшелчә. **Бакча җимеше түгел, акча җимеше** Бушка һәм җиңел генә табылмаган, ә акча түләп алынган әйбер турында (әрәм-шәрәм итүгә каршы әйтелә). **Бакча карачкысы** 1) Кошларны өркетү өчен, кеше кыяфәтле итеп киендереп куелган аркылы таяклы казык; 2) Ямьсез, алама киемле кеше. **Бакчасына кәҗә кергән** Гыйффәтсезлек турында

**БАКЧА́ ГӨЛЕ** *и.* Бакчада үстерелә торган, культуралаштырылган декоратив үсемлек. *Менә аның [Салихҗан абзыйның] үз кулы белән утыртылган бакча гөлләре: кашкарый, хәтфә гөл, алтын керфек.* Р.Төхфәтуллин

**БАКЧА́ КАЙЧЫСЫ** *и.* Бакчада агачларны, куакларны кырку өчен кулланыла торган зур кайчы; секатор

**БАКЧАЛЫК** *и.* **1**. 1) Бакчалар күп булган урын. *Карталиния буйлап бара юлым: Бакчалыклар монда, болыннар.* Ш.Маннур

2) Бакча урнашкан урын, участок. *Иң элгәре каш өстендә мулла белән бай өйләре бакчалыкка күмелгәндә, көләкөлә фәрман бирә.* Н.Исәнбәт

**2**. *с. мәгъ.* Бакчага яраклы, бакча утыртырлык. *Минем үземнең дә шәһәр читеннән бакчалык җир сорап язган гаризамның Шикаятуллин кулында ятуына, җиде булмаса да, бер дүрт ай бардыр.* Г.Минский

**БАКЧАР** *и. зоол. диал.* 1) Сыерчык

2) Миләш чыпчыгының бер төре; *русчасы:* **чёрный дрозд**

**БАКЧА́ ТӘМӘКЕСЕ** *и.* 1) Паслёнчалар семьялыгыннан, себеркәч чәчәк төркемле, төнлә чәчәк ата торган хуш исле бакча үсемлеге, тәмәке. *Бигрәк тә бакча тәмәкесе чәчәк аткан чакта кәефе шәп була Мәсәлимнең.* Д.Бүләков

2) Шул үсемлекнең яфрагын киптереп төйгән ачы өй тәмәкесе; махорка. *Шул арада Талип кесәсеннән кечкенә итеп кәгазьгә төргән бакча тәмәкесе һәм шырпы чыгарып күрсәтте.* Ә.Фәйзи

**БАКЧАЧЫ** *и.* 1) Бакча үстерүче белгеч. *Минем әти – бакчачы, Җиләк-җимеш үстерә. Көньяк үсемлекләрен Ул бу якка күчерә.* Г.Латыйп. *Син бит, улым, бакчачы Кәрим малае.* Казан утлары

2) Яшелчә үстерүче, яшелчә бакчасында эшләүче. *Коллектив Зиннур дигән балалар язучысын бакчачылар*

*идарәсенең рәисе итеп сайлап куя.* К.Миңлебаев. *Көн кичкелеккә авыша башлаганда, Назыймны, юату сүзләре сөйли-сөйли, авылга озаттылар бакчачылар.* Казан утлары

**БАКЧАЧЫЛЫК** *и.* Җимеш агачлары, куаклар, яшелчә үрчетү һәм үстерү белән шөгыльләнә торган хуҗалык тармагы. *Бәгъзе нугайлар бераз гына игенчелек, бакчачылык белән шөгыльләнәләр.* Г.Гобәйдуллин. *Авылда бакчачылык белән шөгыльләнеп көн күрүче карт иде ул.* Г.Гыйльман. *Чыбыкчалардан үрчетү бакчачылыкта һәм чәчәкчелектә киң кулланыла.* Ботаника

**БАКЧА́ ЧЫПЧЫГЫ** *и.* Чебенчеләр семьялыгыннан, бакчада оя ясап яши торган соры, коңгырт, яшел төстәге кош

**БАКЧА́ ШИРКӘТЕ** *и.* Бакчачылар җиләк-җимеш үстерү белән шөгыльләнә торган урын; бакчачылар берләшмәсе. --- *без, «Каләм батырлары» исемле, тату гына, күркәм генә бакча ширкәте төзеп җибәрдек.* А.Гыйләҗев

**БА́КЧИ** *ы. к.* **бакчы** II. *Колхозда да тормыш бер дигән хәзер, бакчи, налукфәләннәр дә бетте.* Г.Мөхәммәтшин. *[Күгәрченнәр] Бакчи, нинди бөтерелә, канатларын нинди итенә!* Г.Бәширов

**БАКЧЫ** I *и. к.* **багучы** II. *Бакчыдан багым бактырдым, Фалчыдан фалым ачтырдым, Сынчыдан сыным сынаттым, Анда белдем бу эшне.* Дастан

**БА́КЧЫ** II *ы.* Нәрсәгә дә булса игътибарны юнәлттерер өчен, күрче, карачы мәгънәсендә кулланыла. *Бакчы, бакчы, ул утырды яткан урыныннан торып.* Н.Исәнбәт. *Туганым! Бакчы, Хәдичә ничек елый.* Дәрдемәнд. *Ибраһим агай, калын тавышы белән, гөрелдәп, аны бүлдерде: – Бакчы, алдан кычкырган күке нишли, ди?* Г.Бәширов

**БАКЫЙ** *с. гар.* **1.** Мәңге, мәңгелек; *киресе*: **фани**. *Мескенләнмә, бакый гомер килгән тел байлыгын итмә кадерсез.* Р.Фәйзуллин. *Юк икән, бакый мәгарә ишеге алай җиңел генә ачылмый икән шул.* М.Галиев. *Мулла бабайның олы җаны, озакламыйча, бакый дөньяга күчә.* Шәһри Казан

**2.** *рәв. мәгъ.* Мәңге. *Мәкреңә җаныңны якмагыл, сакыйн, Сиңа бакый калмаячактыр заман.* Г.Тукай. *Кеше Ут тәңресеннән гомер бакый куркып кына яшәмәгән.* Г.Гыйльманов. *Син сыгылма, дөньяда мин бакый калаем, дип.* Н.Сафина

**3.** *и. мәгъ.* Бөтен булган гомер, мәңгелек. – *Бакыйга бергә булыгыз, озак яшәгез, бәхетле яшәгез! – диде.* Ш.Биккол

◊ **Бакый дөньяга (йортка) күчү** Вафат булу, үлү

**БАКЫ́Й ЙОРТ** *и.* Ахирәт дөньясы, теге дөнья, үлеләр дөньясы. *Бәгъзеләребез – нәкъ аның тигезлегеннән, бәгъзеләребез – югарырак торып, аның Арча төбәгендә Гөберчәк зиратындагы бакый йортына карарбыз.* Ә.Гаффар

**БАКЫЙЛЫК** *и.* **1.** Мәңгелек. *Гомер бакыйлыгы – балада.* Мәкаль. *Китүләре дә бергә, бер-бер артлы булган икән – 60 яшьләрен тутыруга, бакыйлыкка күчтеләр.* Г.Садә

**2.** *с. мәгъ.* Мәңгелек булган. *[Туганнар] Хат язып җибәрсәң, алмыйлар; Ат җигеп җибәрсәң, кайтмыйлар; Чыгарга ишек тә юк, диеп, Бакыйлык йортларда йоклыйлар.* Г.Сәмитова

**БАКЫЛДАВЫК** *и.* Бака. *Моны җирле аучылар күптән белә һәм бакылдавыкларга беркайчан да тими.* Мәдәни җомга

**БАКЫЛДА́У** *ф.* 1) Үрдәкләрнең һәм бакаларның «бак-бак» иткән аваз чыгарулары. *Ишектән дә кер, котым, Тишектән дә кер, котым! Каз кебек какылдап, Үрдәк кебек бакылдап.* Йола һәм уен җырлары. *Бака – бакылдап, яман такылдап туймас.* Мәкаль. *Арада ниндиләре генә юк: нечкә тавыш белән исләреңне китәргәннәре дә, калын тавышларын гөлдерәтеп чыгару осталары да, саңгырауланып беткән басынкы авазлар чыгарып, бакылдауга дучар ителгән картлары да бар.* К.Миңлебаев

2) *күч.* Бертуктаусыз тавышланып күп сөйләү; шаулашу. *Иннокентий, бертуктаусыз бакылдаган Пычракбайны куен кесәсеннән чыгарып, әһле базар кешеседәй бар көченә кычкыра башлады.* З.Мәхмүди

**Бакылдап алу** Кинәт кенә, аз гына вакыт эчендә бакылдаган аваз чыгару. *Агай шундук, ике бармагын авызына кабып, үрдәк булып бакылдап алды.* Р.Хафизова. *Үзми дә, куймый да үзенең көен сузарга ясап куйганнары янында ук, әллә нигә бер бакылдап алудан узмаганнары да гомуми «симфония»гә катнашуны үзләренең төп вазифалары дип саныйлардыр, мөгаен.* К.Миңлебаев

**Бакылдап җибәрү** Кинәт кенә бакылдый башлау

**Бакылдап йөрү** Бертуктамый бакылдау. *Йорт үрдәкләре бакылдап йөри, һаман аяк астында.* Ш.Галиев

**Бакылдап кую** Кыска гына, бер тапкыр кинәт бакылдау. *Балаларының шундый беркатлылыгын күргән ата үрдәк белән ана үрдәк эре генә бакылдап куйдылар...* А.Шамов

**Бакылдап тору** 1) Бертуктаусыз бакылдау

2) Әле, хәзер, күз алдында бакылдау. *Тавыклары күп, келәт алдында үрдәкләр бакылдап торалар...* А.Гыйләҗев

**Бакылдап утыру** Әле, хәзер, күз алдында бертуктаусыз бакылдау. *Өмете өзелгәч, үз-үзен дә орышып ташлады: «Бака түгел ич сазда төн буе бакылдап утырырга».* М.Рәфиков

**Бакылдый башлау** Бакылдарга керешү. *Боз киткәнче үк бакылдый башлыйлар.* Г.Хәсәнов

**Бакылдый бирү** Бакылдавын дәвам итү

**Бакылдый төшү** Тагын да көчлерәк бакылдау

**БАКЫЛДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **бакылдау**. *Кайдадыр бакалар бакылдашты, колак төбемнән генә нindидер кошлар пырлап очып китте.* Ф.Яруллин**.** *Түбәндә, елга буенда, бакалар бакылдашканы гына ишетелә.* Р.Хафизова. *Ул сазлыктагы бакаларның искиткеч гүзәл тавыш белән бакылдашканнарын ишетсәгез икән!* Юлдаш

2) Бер-берсен ишетмичә, берничә кеше берьюлы сөйләп тору. *Уз телләрендә бакылдашып, люкны ачарга маташалар.* Р.Хафизова

**Бакылдашып алу** Бераз, берникадәр бакылдашу

**Бакылдашып тору** Берөзлексез бакылдашу

**БАКЫЛДЫК** *с.* **1**. Туктаусыз бакылдый торган. *Бакылдык бака яки үрдәк*

**2**. *и. мәгъ. сөйл.* 1) Бака яки үрдәк. *Соскы борын – бакылдык, күп сөйләшә такылдык.* Табышмак (үрдәк). *Аккош --- чукып алды бакылдыкның бөереннән, Чак котылып, чумды бака күл төбенә.* Ш.Маннур

2) *күч.* Күп сөйләүче кеше. *Бакылдамый торса, бакылдыкның эче поша, кеше «бакылдык» димиме дип, үзенең коты оча.* Мәкаль

◊ **Бакылдык бака** Ямьсез тавыш белән бертуктаусыз сөйләүче

**БАКЫР** *и.* **1**. 1) Көрәнсу кызгылт төстәге бөгелүчән, чүкелүчән металл; химик элемент. *Бары тик Мартукка бакыр комбинаты һәм башка комбинатларның гомер бетмәслек булып сеңгән күкерт һәм аммиак исләре генә аны һаман эзәрлекләп тора шикелле.* Р.Мирхәйдәров. *Саф бакыр электр техникасында кулланыла.* Химия

2) *күч. сөйл.* Бакырдан коелган тәңкә, вак акча. *Ике-өч тиен бакыр урлап тотылган ач шәкертләрне дә чыбык белән суктырган.* Г.Мөхәммәтшин. *Менә мин биш тиен бакырны алга ыргытам, син, шуңа җиткәнче, җыр җырлыйсың, барып җиткәч, акча үзеңә була.* М.Кәрим. *Аятелкөрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде.* Ә.Еники

3) Көрәнсу кызгылт төс, бакырны (*1 мәгъ.*) хәтерләткән төс. *Көндез юмарт кояш нурларын эчеп кызарган бодай ай яктысында бакыр сыман булып күренә.* Г.Гобәй

**2**. *с. мәгъ.* 1) Бакырдан торган, бакырдан эшләнгән. *Иске бакыр самавырның конфоркасы өстендә таныш кытай чәйнеге кукраеп тора.* Р.Мирхәйдәров. *Асылгәрәйне иң кызыктырганы – бакыр һәм көмеш акчалар.* М.Шабай. *Бакыр чыбыкны каян тапканымны һич хәтерләмим, тик инде карап торышка скрипкәгә беркадәр охшаган бернәрсә килеп чыкты бугай.* К.Миңлебаев

2) Бакыр төсендәге, җирән. *Ә үзләре кояшта кызынып, каралып, бакыр төсенә кергәннәр.* Г.Лотфи. *Нишләп Әнисә янына иң алдан ул үзе түгел, ә бакыр баш Идмас барып җитте?* А.Хәсәнов

3) *күч.* Сыйфаты түбән, бик үк яхшы яки артык әһәмиятле булмаган. *Үзең бакыр булсаң да, сүзең – алтын.* Мәкаль

◊ **Бакыр бугаз(лы)** 1) Көчле тавыш белән күп сөйли торган кеше. *Сизеп торам, Кондаковка, бакыр бугазлы, корыч куллы егетләр генә түгел, чын кешеләр кирәк.* А.Гыйләҗев; 2) *күч.* Гауга, тавыш чыгарырга яратучы, җәнҗалчы. **Бакыр күз** Тонган, ямьсез карашлы күз. *Зур борынлы, ямьсез бакыр күзле исерек майор өскә калыкты.* М.Җәлил. **Бакыр маңгай** Үзсүзле, тискәре, кирebеткән. *Бакыр маңгай Чемберлин «Сәнәк»кә хат күндергән ---.* Сәнәк

**БАКЫРА** *и. к.* **бакра**

**БАКЫ́Р-БОКЫР** *иярт.* Сыеклык кайнаганда чыккан тавышны белдерә. *Бакыр-бокыр ботка пешә, Килгән кунак безгә төшә.* Такмак

**БАКЫРДА́У** *ф.* 1) Бакыр-бокыр килгән тавыш чыгару. *Куркынып тайчану кайда ул! Бакырдап кабарды, күтәрелде, Белмимен, ниндәен уйда ул?* Р.Гайфуллин

2) Сай суда коену, быкырдау, чупырдау

**Бакырдап алу** Бераз бакырдау

**Бакырдап китү** Кинәт кенә бакырдый башлау

**Бакырдап кую** Бер тапкыр бакырдаган тавыш чыгару

**Бакырдап тору** Туктаусыз бакырдау

**Бакырдап яту** Иркенләп, үз уңаена бакырдау. – *Әйдә монда, юләр кызый, нигә бака шикелле анда бакырдап ятасың! – дип кычкыра иде.* Г.Бәширов

**Бакырдый башлау** Бакырдарга тотыну

**Бакырдый бирү** Бернигә карамыйча, бакырдавын дәвам итү

**Бакырдый төшү** Тагы да ныграк бакырдау

**БАКЫ́Р ЕЛАН** *и. зоол.* Тузбашсымаиннар семьялыгыннан, җылы якларда яши торган, көрән яки соры төстәге зур булмаган агусыз елан, җизбаш; *русчасы:* **медянка**

**БАКЫ́Р КӘЛТӘ** *и. зоол.* Җизбаш кәлтәләр семьялыгыннан, орчыксыман гәүдәле, аркасы бакыр төсендә ялтыравыклы, кайберләренең аяклары бик кыска яки бөтенләй булмаган, башка кәлтәләр кебек койрыгын өзеп калдыра торган кәлтә төре; җизбаш; *русчасы:* **веретеница ломкая.** *Җизбаш, яки бакыр кәлтә – аяксыз кәлтәләрнең Татарстанда очрый торган аз санлы вәкилләреннән берсе.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**БАКЫ́Р КЫЗЫЛ** *с.* Ачык җирән яки кызгылт көрән. *[Каюмның] Бакыр кызыл чәчләре тагы да кызарыбрак киткән.* Г.Гобәй

**БАКЫРЛА́У** *ф.* Әйбернең өстен бакыр белән каплау, бакыр йөгертү

**Бакырлап алу** Бераз гына бакыр белән каплау

**Бакырлап ату** Тиз генә бакырлау

**Бакырлап бетерү** Тоташ бакыр белән каплату; бакырлау эшен төгәлләү

**Бакырлап җибәрү** Аз гына бакыр йөгертү

**Бакырлап тору** Әле, сөйләп торганда бакырлау

**Бакырлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр бакырлау

**Бакырлый төшү** Тагы да ныграк бакырлау

**БАКЫ́Р-ТАШ ГАСЫРЫ** *и.* Кешелек җәмгыяте үсешендә кораллар башлыча таштан һәм табигый хәлендә табылган бакырдан эшләнгән дәвер

**БАКЫРУ** *ф.* 1) Көчле, калын, тупас тавыш чыгару (гадәттә хайваннар турында). *Сагынган ул әнкәсен, Бакырып, шуны чакыра* М.Гафури. *Сиздe эшне Шүрәле дә, кычкыра да бакыра.* Г.Тукай

2) *күч.* Тупас тавыш белән кычкырып сүгү, җикеренү. *Аждаһадай бакыра бит ул.* Я.Зәнкиев. *Ат үләксәсенә җыелган козгыннар кебек хахылдашалар, акыралар, бакыралар.* Р.Хафизова

**Бакыра башлау** Бакырырга тотыну. *Иделнең сахралы ягында дөяләргә, атларга атланган озын сөңгеле халык яр буена чабып төшеп кычкыра, бакыра башлап, боларның туктауларын сорый торган галәмәтләр күрсәтә башладылар.* Г.Гобәйдуллин. *Бик зур шәһәр алып кайткан гаскәр кеби, олысы-кечесе сөенә, сикерә, кычкыра, бакыра башлады.* Г.Исхакый

**Бакыра бирү** Бернигә карамый бакыруын дәвам итү

**Бакыра төшү** Тагын да ныграк бакыру

**Бакырып алу** Бераз бакыру

**Бакырып җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә көчле тавыш белән бакыра башлау

**Бакырып йөрү** Әрле-бирле килеп, бертуктаусыз бакыру. *Әле анда, әле монда чабып бакырып йөргән зур ак ана сарыкны кечкенә абзарга кертеп япканнар иде.* Г.Ибраһимов

**Бакырып кую** Кинәт, бер тапкыр бакыру. *Янә ул арада бу кеше ишәк кебек бакырып куйды.* К.Насыйри

**Бакырып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз бакыру. *Сурәт кенә хәлендә дә колак пәрдәләрен ертырлык тавыш белән бакырып тора.* Ә.Баянов

**БАКЫРХАНӘ** *и. иск.* Бакырдан һәм җиздән төрле әйберләр коела, ясала, төзәтелә торган остаханә. *Бакырханә эче тузан вә бакырчы хезмәткәрләр илә тулмыш.* М.Акъегетзадә

**БАКЫРЧЫ** *и.* 1) Бакырдан һәм җиздән көнкүреш кирәк-яраклары ясый һәм төзәтә торган һөнәрче, оста. *Бакырчының өе XIV гасырның беренче яртысында төзелгән булса кирәк.* С.Айдаров

2) Бакыр рудасы чыгаручы

3) Бакыр эретү, бакыр эшкәртү белән шөгыльләнүче белгеч яки эшче. *Бакыр тамчылары ябышкан тигель, күпсанлы бакыр пластинка кисәкләре, бакыр әйбер ватыклары һәм бакыр шлагы кисәкләре табылу монда бакырчы яшәгәнлеге һәм эшләгәнлеге турында сөйли.* С.Айдаров

**БАКЫРЧЫЛЫК** *и.* Бакырдан әйберләр ясау, бакыр белән эшләү шөгыле. *Хисаметдиннең якын дусты, «ислам вә рус, гыйлем вә һөнәр» китапларын укымага һәвәскяр Гайсә Зурколаков бакырчылык эше белән мәшгуль.* М.Акъегетзадә

**БАКЫРЫНУ** *ф.* Тупас тавыш белән җикеренү, көчле тавыш белән кычкырып сүгү. *Бакырдан көмеш булмый, бакырынып, эш булмый.* Мәкаль

**Бакырына башлау** Бакырынырга тотыну. *Килеп керүгә үк ул акырына, бакырына башлады.* Г.Афзал

**Бакырынып алу** Бераз бакырыну

**Бакырынып җибәрү** Кинәт бакырына башлау

**Бакырынып кую** Көтмәгәндә, кинәт бакырыну

**Бакырынып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз бакырыну

**БАЛ** I *и.* 1) Чәчәкләрнең баллы суларын җыеп, бал кортлары эшләп чыгара торган куе, татлы сыекча. *Бал – ару, җитмеш төрле авыруга дару.* Мәкаль. *Бер оя умарта корты биш-алты килограмм табыш алып кайта, ягъни бер гектар юкәлек бер тонна бал бирә.* Г.Хәсәнов. *Умарта корты фәкать алсуына куна, мул итеп, татлы балын җыя.* Г.Хәсәнов

2) Чәчәкләрнең, җиләк-җимешнең татлы сыекчасы, нектар. *Күбәләк һәм умарта корты чәчәкләрдән бал имәләр.* Г.Тукай. *Алма болай ал булмас, Хөрмә болай бал булмас.* К.Булатова. *Шулардан да бал тәмнәре сизеп, Татлы каклар коям миләштән.* К.Булатова // Үсемлекләрдән таралган хуш ис. --- *һавага өлгереп килгән арыш исе – бал катыш яшел башак исе таралган.* М.Мәһдиев

3) Кәрәздән әчетелгән исерткеч эчемлек, хәмер. *Аю урманчы, кызмача булса да, ләх исерек түгел иде, бал исертмәгән иде аны – улының калага китү хәсрәте исерткән иде.* Н.Гыйматдинова. *Атилла агач чәркәдән балны бер уртлап куйды.* Р.Зәйдулла. *Әче балдан авыз иткәләп, Шәйхи карт шуларны сөйләде.* М.Мәһдиев. *Хуҗа кеше, рәхмәт һәм хөрмәт йөзеннән, тагы берәр тустаган әче бал чыгарды.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Бал авыз** Ягымлы сүзле, татлы телле кеше. *Яхшы эшне мактап сөйлим – бал авыз мин.* Г.Тукай. **Бал ае** Кияү белән кәләшнең өйләнешкәннән соң беренче ае. *Өч атнадан соң, егетемне тагын очратам. Я, минәйтәм, ничек бал ае?* Р.Ишморат. **Балга каныккан чебен кебек** Нәрсәгә дә булса ташланган, ябырылган булу турында. **Балга чумып, майда йөзү** Рәхәт, мул, бай тормышта яшәү. **Бал гына** 1) Нык татлы, баллы. *Ишеккә сыймый кабаклар, Бал гына карбызлары.* Н.Гайсин; 2) Якын, кадерле (яратканны белдерү). *Куеннары – җәннәт түре, Иреннәре – бал гына.* Җыр. **Балда-майда йөзү** *к.* **балга чумып, майда йөзү** *Балда-майда йөзеп, ата-ана назында иркәләнеп үскән кеше сине аңлыймы соң?* Ф.Яруллин. **Балга сарылган чебен кебек** *к.* **балга каныккан чебен кебек**

**БАЛ** II *и. фр.* Биюле, зур бәйрәм, күңел ачу кичәсе. *Берсе сөйли: Нинди киемнәрне киярмен, Әнкәем, зур бал була. Балда гаскәри офицерлар, Комиссарлар була.* Һ.Такташ. *Алар «Петербург»ның зур рестораннарының берсендә рәсми балда булганнар.* Г.Гобәй. *[Мансур белән Гөлшаһидә] Октябрь, Май бәйрәмнәрендә, Яңа ел балында бергә биеделәр, кайчак, бергәләп, киного, катокка баргаладылар.* Г.Әпсәләмов

**БАЛА** *и.* **1.** 1) Балигъ булмаган, туып, үсмерлек чорына кадәр аралыктагы малай һәм кыз. *Ниһаять, ишек ачылды, һәм балалар ташкыны ишекне бәреп кереп китте.* Ә.Фәйзи. *Тупырдап торган балалары, берсеннән-бере таза, берсеннән-бере чибәр булып, кече яшьтән кул арасына керә баралар.* К.Миңлебаев. *Мин балаларда матурлык тойгысы тәрбияләргә телим.* Казан утлары. *Прозаиклардан Л.Ихсанова, Ш.Рәкыйпов, Ф.Яруллин, Батулла кебек язучылар күп кенә бәхетле сәгатьләр бүләк иткәндер балаларга.* Казан утлары

2) Яңа туган бәби; нарасый, сабый. *Минем колагымда – сабый бала елавы.* А.Ганиев. *Яшь хатын, имчәк баласын бишеккә иплән кенә яткыза да, keләт ишеген, сызык кына калдырып, ябылып бетмәслек иттереп, тупсасына чүпрәк ише нәрсә кыстыра.* К.Миңлебаев. *Йолдыз атылды, Сабый бала форточкадан кулын сузды.* Р.Фәйзуллин

3) Яңа туган һәрбер җан иясе. *Яшел үлән арасына Былбыл баласы качкан.* Җыр. *Башта мин аны төлке баласы дип торам.* Г.Хәсәнов. *Озын колагыбыз исә, эз бутап, әйләнгәләп йөргән арада, куян балаларын очраткан.* Г.Хәсәнов. *Үзе чүгәләп утырган да үлән арасында очарга талпынып тыпырчынган кош баласына караган.* Г.Зәйнашева

4) Нәсел, токым, халык, милләт яки чорның, социаль катламның төп билгеләрен үзендә чагылдырган шәхес. *Крестьян баласы, ир малай булса, җиде яшьтән атка, тырмага, сабанга йөри башлый.* Г.Ибраһимов. *Ата-анаңнан туры сүзле, гадел кеше булырга тәрбия*

*алган эчкерсез татар баласы, мондый җавапсыз сораулар, акылга да сыймый торган гаделсезлекләр белән очрашуларың алда әле, сынма, сыгылма гына.* Я.Зәнкиев. *Без – кырык беренче ел балалары.* М.Мәһдиев. *Авыл баласы булганга күрә дә, бәлки, шулкадәр табигать җанлымындыр.* Юлдаш

5) Әле үсеп җитмәгән, тормышта тәҗрибәсе булмаган, беркатлы кеше. *Хәят – моңа кадәр бала иде бит әле ул.* Ф.Әмирхан

6) Ничә яшьтә булуына карамастан, ата-ананың улы я кызы. *Кол Гали исә баласын югалткан ата кайгысын гаять көчле тасвирлый.* М.Госманов. *Атадан бала яшь кала, Бик күп эшләр башкара...* Халык җыры

7) **балам, балакаем** *тартымлы форм.* Малай һәм кызларга, иркәләп, яратып эндәшү сүзе. – *Балам, әйдә, тор, бүген таңда Кояш бабаң безгә бәләкәй генә нур йомгаклары – сары, йомшак бәпкәләр бүләк иткән, әйдә, тор... – дип уята торган иде.* Г.Гыйльманов

**2**. *с. мәгъ.* 1) Үсеп җитмәгән, житлекмәгән. *Бала кошның авызы зур булыр.* Мәкаль. *Басма астында – бала үрдәк, Сибик бодай, симерсен.* Җыр

2) Үз ишләреннән әле кечкенәрәк булган. *Бүленү нәтиҗәсендә, яралгы тамырчыгының һәр күзәнәге ике яңа бала күзәнәк хасил итә.* Ботаника

◊ **Бала акылы кергән** Бик картаеп, үзен балаларча тота башлаган кеше турында. **Бала акылы чыкмаган** Буйга үссә дә, акыл ягыннан балигъ булып җитмәгән, балаларча уйлап эш итә торган. **Бала йонын кабарту** Бер дә юкка кычкырыну, дулау. **Бала каз** Өлкәннәр рәтенә кереп тә, әле төпле акылы, тәҗрибәсе булмаган кеше турында. **Балалар экияте** Беркатлы уйдырма, ялганлыгы күренеп торган сүз, хәбәр

**БАЛА́ АРБАСЫ** *и.* Баланы утыртып йөри торган арба, коляска

**БАЛАБАН** *и. фар.* Лачыннар семьялыгыннан, өске томшыгының очында теше булган эре ерткыч кош

**БАЛАВЫЗ** *и.* **1**. 1) Умарта кортлары кәрәз ясау өчен эшләп чыгара торган аксыл сары пластик матдә. *Бал корты балавыздан эшләнгән матур күзәнәкле бал савытын күтәреп очып киткән.* А.Алиш. *Бал корты, балавыз сараеннан чыгып, канаткайларын төзәтте.* Дәрдемәнд. *Көзен умарта кортлары оя тишеген балавыз белән бөтенләй диярлек ябыштырсалар – кыш салкын булыр, ачык калдырсалар – кыш җылы булыр.* Ә.Халидов. *Европа коньяк һәм тоньяк диңгез юлларыннан чит илгә икмәк, май, бал, балавыз озата.* М.Мәһдиев

2) Бөртекле ашлыкның сагызланып торган куе хәле. *Суы чыкмаса, бармакка бертөрле ябышып торса, шул инде игеннең балавыз хәле була.* Г.Гобәй

3) Үзлекләре буенча балавызга охшаган органик һәм минераль матдәләр. *Тау балавызы*

**2**. *с. мәгъ.* Балавыздан торган, балавыздан ясалган. *Балавыз китаплар да булган.* Г.Лотфи

◊ **Балавыз кебек (шикелле)** 1) Балавыз төсендәге, сап-сары. – *Кырып юмый ни. Балавыз кебек булсын идәне дә, түшәме дә, – диде Шәмсенур апа.* Э.Касыймов; 2) Йомшак, тыңлаучан, күндәм. – *Хатының балавыз кебек булыр, аягыңа олтан булыр, йөргән җиреңдә туфрак булыр, – диде.* Г.Ибраһимов. **(Гүя) Балавыз сөяк(ле)** Зифа, бик сыгылма гәүдәле кеше турында. *Галиулла абзый да кереп биеп чыккалый. Ну бии картлач! Гүя балавыз сөяк.* М.Фәйзи. **Балавыз сыгу** Мышык-мышык елау. *Балавыз сыгарга оят.* Г.Мөхәммәтшин. *Аның каләменнән төшкән хатын-кыз заты, балавыз сыгып, алманың авызына төшкәнен көтеп утыра торган, җебеп калган кеше түгел.* Т.Галиуллин. *Әнә элекедән дә купшырак чыкты, ә син балавыз сыгасың.* М.Кәрим

**БАЛАВЫ́З КАПЧЫГЫ** *и.* Эченә баллы кәрәз тутырып, балын сыгу өчен кулланыла торган капчык

**БАЛАВЫЗЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **балавызлау.** *Паларусов картузын киде. Балавызланган киндер кожанны җилкәсенә салды.* Г.Ибраһимов. *Өч көн үткәннән соң, кич белән, Тарасов бөтен отрядны балавызланган идәнле озын коридорга тезде.* К.Нәҗми

2) Ашлыкның балавыз кебек ябышкак куе сыекча хәленә җитеп өлгерүе

3) Майланып, катып ялтырау

**Балавызлана бару** Акрынлап балавызлану

**Балавызлана башлау** Балавызлану чорына керү

**Балавызлана төшү** Тагын да балавызлану

**Балавызланып бетү** Тәмам, бик нык балавызлану. *Исламгали агай исә яныпяткан келәткә кереп, нәрсә алырга белми аптырап торгач, майланып, балавызланып беткән бер иске бишмәт тотып, авыл башына чыгып йөгергән.* М.Мәһдиев

**Балавызланып җитү** Тәмам балавызлану

**Балавызланып килү** Балавызсыман хәлгә якынаю

**Балавызланып тору** Балавызланган сыман ялтырап күренү

**БАЛАВЫЗЛА́У** *ф.* Ныклык, чыдамлык өчен, балавыз белән ышку, балавыз сеңдерү. *Озынрак төпчекләрне шәм урынына яндырдылар, ә кыскалары белән карчык, әйбер теккәндә, җепне балавызлый иде.* Г.Андерсен

**Балавызлап алу** Тиз генә балавыз сеңдерү

**Балавызлап бетерү** Тоташ, барысын да балавызлау; ахырга кадәр балавызлау

**Балавызлап җибәрү** Бераз балавызлау

**Балавызлап җиткерү** Тиешенчә балавызлау

**Балавызлап кую** Алдан ук балавызлау, күптән балавызланган хәлгә китерү

**Балавызлап тору** Вакыт-вакыт, әледән-әле балавызлау. --- *сызгычны көйләп, майлап-җайлап, балавызлап торырга кирәк, җил-яңгырдан саклар өчен, тартма-футлярда йөртү дә шарт.* Р.Әхмәтҗанов

**Балавызлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, барсын да балавызлау

**Балавызлый бару** Рәттән балавызлау

**Балавызлый башлау** Балавызларга керешү

**Балавызлый төшү** Бераз, беркадәр балавызлау

**БАЛАВЫЗЛЫ** *с.* 1) Балавызы булган. *Балавызлы рам*

2) Балавызланган, балавыз сеңдерелгән. *Алма өзсәң, җепкә тезсәң – Балавызлы җепкә тез.* Җыр

**БАЛАВЫЗЛЫК** *и.* Кош балаларының томшык читендә балавыз төсендәге яры. *Балавызлыгы кипмәгән бәпкә*

**БАЛАГАН** *и. фар.* 1) Элекке заманнарда ярминкәләрдә күрсәтелә торган уен, тамаша, кәмит. *Мин кече яшьтән үк балаганнар һәм курчак театрларын яратып карый идем.* Г.Камал

2) Шул уенны күрсәтү өчен, тактадан ясалган җиңелчә генә корылма, зур чатыр. *Җен төсле булып киенгән дураклар [клоуннар], шундагы балаганнарның башына чыгып, әллә нинди, дөньяда булмаган тилелекләр күрсәтәләр, имеш.* Г.Ибраһимов. *Монда цирк артистлары үзләренең уеннарын күрсәтәчәкләр икән. Ләкин балаган тирәсендә, хәзергә, шаулашкан бала-чагадан башка халык юк диярлек...* Ә.Еники

3) Гомуми кирәк-ярак өчен төзелгән, еш кына төзек күппочмак формасындагы корылма. *Без каравыл өенә барып җиткәндә, насослар, пожар мичкәләре куя торган балаганга байтак кына халык җыелып, кышка ачлык булу куркынычы турында сөйләшеп утыралар иде.* М.Гали

4) *сөйл.* Кыланып, тиле-миле сөйләнгән сүз; тәртипкә салынмаган, җитди булмаган эш. *Казаннан килгән ректор гына бу балаганга чик куйды. Соңрак Әхмәров иптәш, бер дә исе китмичә: – Җыелышларны мин бары коллектив үтенече буенча уздырдым [диде]*. Т.Галиуллин. *[Рамазанов:] Булды! Кәмит уйнарга балаган түгел бу*. Т.Миңнуллин

5) *кимс.* Сәнгатьлелек ягыннан түбән дәрәҗәдәге театр тамашасы. *Ул анда әлеге әсәр авторын һәм спектакль куючыларны татар театрын «балаган дәрәҗәсенә китерү»дә гаепли.* К.Миңнуллин

6) *диал.* Саманнан яки кәстән корылган алачык. *Калын-калын кәсләрдән әйбәтләп салынган балаган эче такталар белән икегә бүленгән.* И.Туктар

◊ **Балаган кору** Уен-көлке, шау-шулы кәмит оештыру

**БАЛА́ ИТӘК** *и.* Күлмәкнең аскы ягына матурлык өчен тотылган өстәмә итәк. *Бала итәкнең кырыен төрлечә эшлиләр: кулдан яки машинада тар гына итеп бөгәләр, артык тукыманы тигезләп кисәләр.* Йорт эшләре

**БАЛА́ ЙОН** *и.* 1) Кеше тәнендәге вак-вак төкләр. *Бала йоннарым кабарды.* Г.Хәсәнов

2) Яшүсмерләрнең булачак сакалмыек урыннарына чыга торган йомшак төкләр. *Юлаучыларның икенчесе – борын төбендәге бала йоны яңа каралып килгән яшь кенә бер егет.* Г.Гобәй

3) Йомыркадан яңа чыккан кош тәнендәге бик йомшак, нечкә йон

4) *күч.* Җитлекмәгән, ныгымаган, дөнья күрмәгән яшь кеше. *[Гафиятулла карт] «Син буяулы чебешкә нәрсә сөйләп торган булам соң мин, ни аңлыйсың син, бала йон» дигән кыяфәт белән, урындыкка барып утырды*. Ф.Хөсни

**БАЛАК** *и.* Һәрбер аякка аерым тоташ яки яртылаш киелә торган, ыштанның, чалбарның бот төбеннән түбәнге өлеше. *Менә сәке-сәхнәгә, озын кармак сабы тотып, тишек эшләпә кигән, чалбар балагын тез тиңентен сызганып куйган яланаяк берәү чыкты.* М.Маликова. *Шул балак читеннән кара ботинка борыны ялтырап күренә.* М.Кәрим. *Чалбар балакларын, пөхтәләп, итек балтырына тыккан.* Р.Хафизова

◊ **Балагына абынган** Юньсез, җыйнаксыз, үз сәләмәсенә үзе абынып йөрүче кеше турында. **Балагын җыя алмаган (җыя белмәгән)** Бик җыйнаксыз, үзен-үзе карап йөртә алмый торган

**БАЛА́ КАРАУЧЫ** *и.* Бала карарга махсус билгеләнгән яки ялланган кеше. *[Мәрьям] Үзләрендә бала караучы булып торган Бәдри әбинең шома вә килешле рәвештә сөйләгән әкиятләрен бала чагында бик яратып тыңлый.* Г.Ибраһимов

**БАЛА́ КАРЫНЫ** *и.* Ана карынындагы яралгының тышчасы

**БАЛАКЛЫ́ ТАВЫК (ӘТӘЧ)** *и.* Ботына каурый йоны үскән тавык (әтәч). *Кәкре койрыклы, балаклы, кылыч кикрикле, кызыллы-яшелле салават күпере төсле әтәчне чырылдатып күтәреп чыктылар.* М.Гали

**БАЛАКЛЫ́ ТӘРЕ** *и.* Гайсә сурәте төшерелгән яки чигелгән чиркәү байрагы. *Керәшен ягының побы, балаклы тәреләр белән чыгып, бик озак, игеннәр арасында улап йөрде.* Г.Бәширов

**БАЛА́ КОРТ** *и. диал.* 1) Яңарак аерылып чыккан яшь умарта күче һәм шул күчтәге кортлар. *Карт кәрәзле бал алып керде. Ни җитте бал гына да түгел, бала корт балы иде.* М.Әмир

2) Кыргый умарта кортларының бер төре

**БАЛА́ КЫЧЫТКАН** *и. диал.* Вак яфраклы, тәбәнәк кычыткан

**БАЛАЛА́ЙКА** *и. рус* 1) *муз.* Резонатор куышлыгы өчпочмак формасында булган өч кыллы, чиртмә уен коралы. *Җәйге тымызык төн. Якында гына кемдер балалайка чиртә.* А.Расих. *Балконда уйнаган балалайка бердән тынды.* К.Нәҗми. --- *оркестрда иң беренче урынны мандолина тота иде. Балалайка, гитара шикелле музыка кораллары икенче дәрәҗәдәге рольне үтәделәр*. Татар театры

2) *күч.* Сөрелгән җирнең башында өчпочмак рәвешендә чи калган урын. *Хәйдәров сөргән участокта --- башбашлары аркылыга йөрелгән, чи калган урыннар, тракторчыларның үз сүзләре белән әйткәндә, «балалайкалар» күренми иде.* Ф.Хөсни

**БАЛАЛА́ЙКАЧЫ** *и.* 1) Балалайкада уйнаучы музыкант. *Мәетне озатканда, Шәфигулла агай, юл буе балалайкачылардан уйнатып, үзе берттуктаусыз «Күмү маршы» җырлап барды*. Ф.Әмирхан

2) Балалайкалар ясаучы оста

**БАЛАЛАНУ** *ф.* 1) Балалар кебек кылану, үзен балаларча тоту, бала булу. *Ир йөрәк үзе белән гомер үткәргән хатынының бу чаклы балалануына чыдый алмады.* Г.Гали

2) Үсемлек төбеннән яңа үсентеләр чыгу, яңа сабаклар чыгарып үрчү, курпылау. *Игеннәр, буыннан буынга сикереп, һаман саен буйга омтылып үсәләр, балаланып, төптән куера баралар.* М.Шабай

**Балалана башлау** Балаланырга керешү

**Балалана бирү** Балалануын дәвам итү

**Балалана төшү** Беркадәр балалану

**Балаланып алу** Бераз балаларча кылану

**Балаланып бару** Бер-бер артлы яңа сабаклар чыгып үрчү

**Балаланып җибәрү** Артык балалану

**Балаланып китү** Кинәт кенә балаларча кылана башлау

**Балаланып кую** Кинәт кенә, бер тапкыр балалар кебек кыланыш ясау

**Балаланып тору** Әле, хәзер балалану

**БАЛАЛА́Р БАКЧАСЫ** *и.* Мәктәп яшенә кадәрге балаларны карау-тәрбияләү учреждениесе һәм шуның бинасы. *Бәләкәчләрне балалар бакчасына гына җитәкләп илтәләр.* М.Кәрим. *Ул – озак еллар балалар бакчасында эшләгән тәрбияче, педагог, балалар өчен хикәяләр язган язучы, тәрҗемәче Гыйльмия апа Таһирова иде.* Г.Зәйнашева. *Балалар бакчасында матур гына эшләп йөргәндә кыскартты да атты.* Татарстан

**БАЛАЛА́Р БҮЛМӘСЕ** *и.* 1) Өйдә балалар өчен билгеләнгән бүлмә

2) Зур шәһәрләрдә, вокзалларда адашкан яки җинаять эшләгән балаларны вакытлыча җыю, урнаштыру белән шөгыльләнә торган, полиция оешмасының эш бүлмәсе

**БАЛАЛА́Р ЙОРТЫ** *и.* Ятим калган, ташланган балаларны тәрбияләү йорты. *Ярлылар эш башына менгәч, өч елдан артык приютта – балалар йортында яттым, анда мине тәрбияләп, дарулап, тәмам кеше ясадылар.* Г.Толымбай

**БАЛАЛА́РЧА** *рәв.* **1**. Балаларга охшатып, балалар кебек, балаларга хас булганча. *Әткәем исән булмаганга, үземне бик бәхетсез итеп тоя идем, балаларча, бик газапланып, әткәемне сагына идем.* Ә.Айдарская. *Әңгәмәдәшләремнең борынгы дастан геройлары язмышлары өчен чынлап көенеп, балаларча сөенеп утырулары тагын да гыйбрәтле.* М.Госманов. *Тезләнгән җиреннән ул кинәт сөрлегеп китте һәм балаларча кычкырып җыларга тотынды.* Н.Фәттах

**2**. *с. мәгъ.* Балаларга охшаган, балаларга хас. *Бөтен тәнемне балаларча шатлык каплады.* М.Әмир. *Ул бик ыспай гәүдәле, җиңел атлый, яшькелт күзләреннән сирпелгән балаларча соклану хисе аны яшәртә иде.* М.Маликова

**БАЛАЛА́У** *ф.* 1) Бала тудыру. *Мәрхүм бай беркөн мине чакырды да, бар әле, яшьтәш, ди, минем хатын балаларга итә бугай, ди, Фәхри карчыкны чакырып кил әле, ди.* Г.Ибраһимов

2) Мал-туар үрчем китерү. *Күпчелек хайваннарның иртә язда балалавы, ерак Африка һәм Һиндстанда яшәүче кошларның төньякка килеп бала чыгаруы да, бәлки, тикмәгә генә түгелдер?* Б.Сергеев. *Балаларга ике-өч көн кала, ана дуңгызны бокска урнаштыралар.* Терлекче-механизатор белешмәсе

3) *күч.* Үсә башлау, үсеш алу. *Кояш җылыта башлау белән, бу таллар шундук балалыйлар – сап-сары песи башлары чыгарып чәчкә аталар.* А.Хәлим

4) *күч. сөйл.* Арту, ишәю, күп булу. *Бер теләк ун теләкне балалый.* Мәкаль. *Менә ул икегә бүленде, аннан ул кисәкләр тагын балаладылар.* М.Мәһдиев

5) *күч. туп.* Тиз генә җыена алмау, мыштырдап, вакытны сузу. *Хатын [миңа] килеп төртә: – Җә, тизрәк, бик озак балалыйсың, малларны карап кер, – ди.* М.Әмир

**БАЛАЛЫ** *с.* Баласы булган; бала ияртkән. *Балалы хатын чират сакларга калды.* Мирас

**БАЛАЛЫК** *и.* **1.** 1) Балачак, бала вакыт. *Бүген мин, балалыктан чыгып, ирләр чорына уздым, акылга утырдым.* М.Кәрим. *Әле яңа гына балалыктан аерылып килүче тәҗрибәсез кеше икәнен дә исәпләү юк.* Ә.Фәйзи. *Балалыкта ул да, Гүзәл кебек, курчак уйнарга ярата иде.* Н.Хәсәнов

2) Үз-үзен тотышы белән балаларга охшау, балаларча кыланыш, беркатлылык. *Куркышыннан юкны әйткәндерме, әллә, чынлап та, тиле балалык мавыгуы белән, зурларга охшарга тырышып, ураза тотып азапланган булганмы, безгә, зуррак класс укучыларына, бик кызык тоелды бу.* М.Әмир. *Шулай дидем дә чыгып киттем. Балалык инде.* Сөембикә

3) Кемгә дә булса ул яки кыз булу хәле. *Балалык рәхмәтем җырымда чагыла.* Җыр

**2**. *с. мәгъ.* 1) Бала булган, балага хас. *Минем балалык аңымда, томан эчендә генә кебек булып, әткәйнең сурәте гәүдәләнә иде.* Ә.Айдарская

2) Күпме дә булса сандагы бала өчен исәпләнгән. *Безнең урын – йөз алтмыш балалык, бирегә инде ике йөздән дә артып китте.* Г.Гобәй

◊ **Балалыкка бару, балалык күрсәтү** Зур булса да, үзен балаларча тоту, балаларча эшләү, беркатлылык күрсәтү

**БАЛАЛЫ́К КАПЧЫГЫ** *и.* Соңгылык сүрүе

**БАЛАМУТ** *и. монг. гади с.* Болганып, тәртипсез кыланып, теләсә нәрсә сөйләшеп йөрүче кеше. *Бәлки, әти мактагандыр: «Минем балам – ут!» – диеп, Башкалар кул селти иде: «Беләм – баламут», – диеп.* Ш.Галиев

**БАЛАН** *и.* 1) Зелпечәләр семьялыгыннан, аксыл кайрылы, ак чәчәкләре һәм ачы кызыл җимешләре чатырсыман тәлгәш хасил итә торган куак; *русчасы:* **калина.** *Яшен күп булса, баланны кырау алыр.* Сынамышлар. *Күзнең нурын алып, баланның зур, куе тәлгәшләре пешеп җитте.* Г.Хәсәнов. *--- малай чагында җиләк җыйган урман аланнарын, балан белән миләшкә, шомыртка, карлыганга, кыргый чиягә, чикләвеккә йөргән урыннарын караганнар иде.* Г.Ахунов

2) Шул агачның ачы, кызыл җимеше. *Миләш диеп капкан идем, балан булып чыкты бу.* Мәкаль. *Ачы булса да гашыйк мин Миләш белән баланга.* Җыр. *Аланнарда кызыл баланнарны Җыеп йөргән нәни балаларны Үстерегез тизрәк!* Р.Әхмәтҗанов

◊ **Балан бәлеше** Булдыксыз, пешмәгән, оешмаган. *Ник дип әле син авызыңа су кабып утырасың, балан бәлеше кебек изелеп?* Г.Ахунов. **Балан кабу, балан капкандай, балан капкан кебек (балан каптыңмы әллә?)** Төксе, чытык чырайлы яки нәрсәгә дә булса ачуланудан йөзе караңгыланган

**БАЛА́Н БАРМАК** *и.* Баш бармактан соң икенче бармак; имән бармак, ишарә бармак. *Солдат, балан бармагын маңгаена куеп, тагын нәрсәдер уйлады.* Х.Госман

**БАЛА́НДА** *и. рус гади с.* Туклыксыз, су кебек сыек шулпа, өйрә. *Ит, колбасадан өзелмиләр, тоткынга җан асрар өчен бирелгән сыек баландага борын да төртмиләр.* Н.Хәсәнов

**БАЛАНЛЫК** *и.* Балан куаклары күп булып үскән урын. *Аргы якта – аланлык, Тирә-ягы – баланлык.* Җыр

**БАЛАНС** *и. фр.* 1) Тигезлекне саклау; үлчәү көянтәсенең тигез торышы

2) *тех.* Тигезләгеч авырлык – балансирның хәрәкәтчән өлеше. *Әгәр дә балансны рычагның башынарак күтәрсәң, ул вакытта, клапанны күтәрер өчен, көч күбрәк кирәк була.* Т.Госман

3) *бух.* Керем һәм чыгым суммаларын эченә алган ведомость

4) Керемне һәм чыгымны чагыштырганнан соң килеп чыккан нәтиҗә. *Налог һәм бюджет мәсьәләләрендә балансның федераль үзәк файдасына үзгәртелүе республиканы чишендереп ташлауга тиң булды.* М.Фарукшин. *Компаниянең 2004 ел нәтиҗәләре буенча баланс кереме, 2003 елгы 16,5 млрд сум урынына, 36,1 млрд сум булды.* Татарстан

5) *икът.* Чит илләрдән кертелә һәм чыгарыла торган товарлар арасындагы мөнәсәбәт

6) Предприятие, учреждение исәбендә торган средстволар. *Әлеге предприятие балансында 52463 урам яктырту нокталары бар.* Шәһри Казан. *Чаллы җылылык челтәрен без үз балансыбызга бик начар хәлдә алган идек, инде менә киләсе кышта шәһәр югарырак температура белән җылытыла башлаячак.* Ватаным Татарстан

7) Нинди дә булса ике арадагы тигезлек; тигез торыш. *Анда кислота, селте, тоз балanслары бозыла.* И.Халис. *Татарстандагы төрле этник һәм конфессия төркемнәренең мәнфәгатьләре балансын бозмауга юнәлдерелгән сәясәтебезгә тугрылыклы булган хәлдә, без, алга таба да, вөҗдан иреген булган хокукны яклыйбыз.* Татарстан. *Сул беләзектә организмның кешегә яшәү сәләте бирә торган көче балансына турыдан-туры тәэсир итүче өч мөһим энергетик нокта бар икән.* Серле сандык

**БАЛАНСИР** *и. фр.* 1) Арканда биюче циркачның тигезлек саклау өчен кулына тоткан колгасы

2) Вак судноларның тотрыклылыгын арттыру өчен, суднога параллель торышта колга ярдәмендә беркетелгән озынча зур калкавыч

3) Кесә һәм диңгез сәгатьләрендә маятник хезмәтен үти торган регулятор

4) Үлчәүләрдә, үлчәү приборларында, насосларда һ.б.да авырлыкны һәм хәрәкәтне механизмның аерым буыннарына тапшыру көянтәсе. *Балансир, астан өскә, өстән аска тирбәлеп, гаять зур кош кебек, җирне чукыган.* Нефть турында хикәя

**БАЛА́НСЛАУ** *ф.* 1) Керем белән чыгымны бердәйлеккә китерү, тигезләү. *Малларны карау технологиясе түбән, нәсел эше начар, фермаларда белгечләр җитми, азыкны балансслап бирү тәртибе кертелмәгән иде.* Ватаным Татарстан

2) Баланс ясау яки баланс чыгару. *Мондый язучылар бухгалтерия ысулынча (формасынча) монтазам дәфтәрләр йөртеп, һәр айда баланс ясап, хуҗаларының эше ни дәрәҗәдә бара, --- дәфтәрләрдә хата юкмы, һәммәсен белеп вә күреп баралар.* Ш.Мөхәммәдев

**Баланслап бару** Даими, системалы баланслау

**Баланслап кую** Балансланган хәлгә китерү, алдан баланслау

**Баланслап тору** Керем-чыгымнарны һәрвакыт тигезлектә тоту

**Баланслап чыгу** Башыннан ахырына кадәр баланслау

**БАЛА́ СУГАНЧА** *и.* 1) Сугансыманнарның орлыктан үскән һәм бер җәйдә генә җитлекми торган вак суганчалары. *Гладиолуслар бүлбе – суганчалардан һәм бала суганчалардан үрчиләр.* Җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы

2) Бер зур суганчадан бүленеп, укмашып үскән вак суганчаларның берсе

**БАЛАСЫТУ** *ф.* 1) Тәҗрибәсезгә, беркатлыга, балага санау. *Нәфисә бу картның аңа ышанып бетмәвен, баласытып каравын сизә.* Г.Бәширов

2) Баласымак төс бирү. *Берсен – аркасына, икенчесен күкрәгенә төшереп салган озын толымнары, буяу әсәре күрмәгән түгәрәк чиста йөзе аны баласытып күрсәтә кебек.* А.Әхмәтгалиева

**Баласытып алу** Бераз, җиңелчә генә, уен ясап кына баласыту. *Сез бу сүзләрне мине бераз котыртып, баласытып алу өчен генә әйтәсез.* Ф.Яруллин

**Баласытып бетерү** Тәмам баласыту

**Баласытып җибәрү** Көтмәгәндә баласыту

**Баласытып килү** Һәрвакыт, электән үк баласыту

**Баласытып тору** Даими баласыту. *[Павлик] Бирелә үзе өчен чиксез авыр, гарьлекле, аны кимсетә, баласыта торган бер хәйлә барлыгын аңлап алгандай булды.* М.Әмир

**БАЛА́ ТУЕ** *и.* Бәби тугач, ата-ананың туган-тумачалары, дуслары җыелып, гаиләне бәби туу белән котлау мәҗлесе

**БАЛА́ УМАРТА** *и.* Аерылып чыккан күчтән гыйбарәт яшь кортлар умартасы. *Бала умарталар – ярлы умарта, Бал кушыек аның кортына.* Җыр

**БАЛАХАНӘ** *и. фар. иск.* 1) Балкон. *Үзе шунда балаханәгә чыкты Вә шундый манзарага ул юлыкты.* Котб

2) Өстәге бүлмә

**БАЛА-ЧАГА** *җый. и.* 1) 14–16 яшькә кадәрге малайлар һәм кызлар; күп бала. *Ыбыр-чыбырлы бала-чага да бу тәүлектә тынып тора.* М.Мәһдиев. *Урамда шаулашкан бала-чагаларның тавышы, каршыдагы тауга бәрелеп, яңгырап, кире кайта башлый.* А.Шамов. *Ә бит әле киенәсе, бала-чагасын үстерәсе һәм башкасы бар.* Сөембикә

2) Өлкән кешеләрне балалар белән беррәттән куймыйча, каршы куеп сөйләгәндә кулланыла; үз гамәлләренә җавап бирерлек, балигъ булган кеше. *Житте, без бала-чагалар түгел.* М.Гафури. *Мөхәммәтгариф, димен, көлмә, шаярырга бала-чага түгел инде мин.* Г.Мөхәммәтшин. *Әләкләшеп торырга, бала-чагамы әллә мин?* Р.Ишморат

**БАЛА-ЧАГАЛАНУ** *ф.* Балаларча кылану. – *Менә шулай бала-чагаланып үтә гомеркәйләрем,* – *дип зарлангандай итте.* Ф.Сафин

**Бала-чагаланып йөрү** Озак вакытлар дәвамында бала-чагалык күрсәтү. *Исбатлап кара син аларга күргән*

*төшеңне генә тикшереп, бала-чагаланып йөрүеңне.* Җ.Дәрзаман

**Бала-чагаланып китү** Кинәт кенә балаларча кылана башлау

**БАЛА́-ЧАГАЛЫК** *и.* Беркатлылык, тәҗрибәсезлек, балаларга хас гамәл, сыйфат. *Юк, бу һич була торган эш түгел, бу – бер бала-чагалык.* Ш.Мөхәммәдев. *Ә син шушы матурлыкны, шушы елганы, шушы шәһәрне ташлап, әллә кая китмәк буласың. Бала-чагалык чыгып бетмәгән әле синнән, Ихтыяр.* Р.Вәлиев. *Мин анысына каршы килмим, ләкин үз-үзеңне бөкәй белән куркытуларга һәм бөтен әйбердән контрреволюция эзләп маташуларга мин, бала-чагалык һәм үз көчебезгә үзебез ышанмаучанлык, дип карыйм.* Ш.Камал

**БАЛАЧАК** *и.* **1.** 1) Сабый чактан балигъ булганчыга кадәр аралыктагы чор, бала булган еллар. *Кыска шигырьләрне балачактан бирле язып килəм.* Р.Фәйзуллин. *Зур соры күзләрендә инде балачак гамьсезлегеннән берни калмаган.* Ә.Фәйзи. *Туган якта калган балачакка Чакырып, ул җанга кагыла.* Ф.Сафин

2) *күч.* Башлангыч, яңа барлыкка килгән вакыт яки урын. *Кешелекнең балачагы – язу туган, димәк, Фикер туган, җырлар туган, көйләр туган төбәк.* Г.Афзал

**2.** *с. мәгъ.* Яшьтән килгән, яшьлек. --- *балачак дустым – яшьтием Газины ничек тә булса күрергә тырышачакмын, дип, күңелемә беркетеп куйдым.* М.Хәсәнов

**БАЛА́ ЧҮБЕ** *и.* Ана карынындагы яралгының тышчасы, соңгылык

**БАЛАЧЫЛ** *с.* 1) Балаларга хас. *Фәррахбануны яшьләргә хас балачыл тойгылар басып алдылар.* К.Насыйри

2) Балаларны ярата торган. *Балачылга – бала, бәлачелгә – бәла.* Әйтем

**БАЛАШАР** *и. к.* **балимәр**

**БАЛА́ ЯТКЫЛЫГЫ** *и. к.* **бала чүбе**

**БАЛБАГАР** *и. зоол. диал.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан, бал кортлары белән туклана торган кечкенә кош; корташар; *русчасы:* **щурка**

**БАЛБАЛ** *и. фар.* Ритуаль таш, тораташ. *Шулай ук борынгы төрекләр таш, агачтан кеше вә хайван сыннарын бик оста вә чын төсле итеп ясыйлар, төрекләргә охшатып, агач вә таштан кеше сыннары ясап, каберләренә салганнар вә аларны «балбал» дип атаганнар.* Г.Гобәйдуллин. *Ә үзәккә кагылган чөй башында – әллә үзле балчыктан изеп, әллә таштан кыеп ясалган сын, кечкенә балбал кисәге.* Г.Гыйльманов. *Буар елан, ниһаять, Рамайның балбал таштай катып калган гәүдәсен акрын-акрын гына үлем божрасыннан бушатты, җиргә кадәр шуып төште.* Идел

**БАЛГА** *и. иск.* Хәрби балта, гөрзи; зур чүкеч, кувалда. *Туң тимергә балга бар, туң кешегә хөкем бар.* Мәкаль

**БАЛГА́ БАШ** *и.* Арткы якка озынаебрак үскән баш

**БАЛДА** *и. төрки* Мәгънәсез, тилемиле, юләр кеше

**БАЛДАК** *и.* 1) Халыкара мифологиядә мәңгелек, берлек-бердәмлек, ышаныч, хакимият һәм көч символы. *Балдак ярдәмендә элек-электән әманәт тапшыра торган булганнар.* Ф.Урманче. --- *югалган ярны, кыйммәтле, затлы әйберне, хакимият һәм көчне табуда балдак иң җитди һәм ышанычлы ярдәмчегә әверелә.* Ф.Урманче

2) Бизәнү әйбере буларак, бармакка киелә торган кашсыз йөзек. *Гармунчының гармуны бар, Кулында балдагы бар.* Җыр. *Кызлар кия калфагын, Егет кия балдагын.* Г.Камал

3) *сөйл.* Гомумән һәртөрле йөзек. *Актык балдакларын сата-сата, Томскига килә дә бер рус офицеры белән тора башлый.* Г.Ибраһимов. *Кызлар, карагыз әле, нинди матур балдаклар!* А.Әхмәт. *Никах балдагы якут (мәхәббәт һәм ут) ташы белән бизәлә.* Юлдаш

4) Техникада һәм көнкүрештә кулланыла торган алка; божрага охшашлы деталь. *Аның аты башын чайкый, йөгән балдакларын чылтырата иде.* Г.Бәширов. *Бакыр балдак белән кыршаулаган кечкенә челемен генә күреп калган иде.* Г.Бәширов. *[Сафа:] Җиде данә цилиндр, йөз илле данә поршень балдаклары, кырык данә поршень бармаклары --- дип, запас частьларны санап китте.* Х.Госман

5) Божра, йомры түгәрәк, әйләнә. *Бюро членнары өстәл янында түгәрәк балдак ясап утырганнар.* А.Алиш. *Чыннан да, су өстендә, зур балдак кебек түгәрәкләнеп, тимгел-тимгел булып, нефть ага иде.* А.Әхмәт

6) *диал.* Куныч, балтыр. *Итекләрнең балдаклары киңрәк булган*

**БАЛДА́К АЛЫШУ** *ф. этн.* Егет белән кызның, кавышырга вәгъдәләшеп, балдак яки йөзекләрен (егетнең – чәнчә бармагыннан, кызның урта бармагыннан алып) бер-берсенә бирү гадәте. *Идел буе – камышлык, килеп, балдак алыштык, унҗидедә гашыйк булдык, унсигездә кавыштык.* Җыр

**БАЛДА́К-БАЛДАК** *с.* Түгәрәк-түгәрәк, берничә балдактан торган, бер-бер артлы тезелгән балдакларга охшаган. *Балдак-балдак төтен, чәчне ыслап үтеп, форточкага барып асылына.* М.Җәлил. *Шул беретка астыннан балдак-балдак булып чыгып торган чәч очларында, төшәм, төшәм, дигәндәй, күбәләк кар асылынып тора.* Х.Госман

**БАЛДАКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **балдаклау**

2) Балдак кебек түгәрәкләнү, божралану, балдак рәвешенә керү. *Елтыр чабаклар башларын судан чыгарып алалар да, балдакланган дулкыннар ерракларга таралып югалалар.* Ф.Кәрим

**Балдаклана төшү** Бераз балдаклану

**Балдакланып калу** Кинәт кенә балдак рәвешен алу. *Уймакланып ага тирән су, Балдакланып кала эзләре.* Ш.Маннур

**Балдакланып китү** Кинәт балдаклану

**Балдакланып тору** Әле, хәзер балдакланган рәвеш алу

**БАЛДАКЛА́У** *ф.* 1) Күчеш юлларын өйрәнү максатыннан, кош-кортның, кыргый хайваннарның һәм вак җәнлекләрнең – аягына, балыкларның саңагына махсус балдак кидереп тамгалау. *Кыргый кошларны тотып, аякларына җиңел алюминий балдак кидертәләр; балдакка номер куелган һәм балдаклаучы учреждениенең исеме күрсәтелгән.* Зоология

2) Агачны җирдән менә торган корткыч бөҗәкләрдән саклау өчен, кәүсә әйләнәсен билгеле бер киңлектә махсус сыекча белән сылау яки шул сыекча

сеңдерелгән чүпрәк белән урап кую. *Агачларны балдаклау*

3) Балдак рәвешенә китерү, бөжралау. *Тимерчыбыкны балдаклап бөгү*

**Балдаклап алу** Тоташ, тирәли балдаклау

**Балдаклап бару** Рәттән һәрберсен балдаклау

**Балдаклап бетерү** Барысын да балдаклау

**Балдаклап кую** Алдан ук балдаклау, балдакланган хәлгә китерү

**Балдаклап тору** Һәрвакыт, һәрберсен балдаклау; әле, хәзерге вакытта балдаклау

**Балдаклап чыгу** Барысын да, һәрберсен берәм-берәм балдаклау

**БАЛДА́К САЛЫШ** *и.* Балдак салу уены; йөзек салыш. *Аулакта инде, билгеле, җырлыйсың, арка сугыш, балдак салыш уйныйсың, ә мунчада – карта.* А.Шамов

**БАЛДЫЗ** *и.* Иргә – хатынының сеңлесе. *Ә соң синең үз кәләшең балдызларыңның кайсына охшаган?* Г.Ибраһимов. *Төпчекә торгач, эшне сузучы кеше, командующий да түгел, Хәрби Шура рәисенең балдызы булып чыкты.* К.Нәҗми. *Балдыз кешенең, уналтыдан узгач, җизнәсенең өеннән ераграк торуы яхшы...* Ә.Фәйзи

**БАЛЕРИ́НА** *и. ит.* Балетта биюче артистка; балетта биюче хатын-кыз. *Балерина, Җир тартымын җиңеп, югары атылды да, канат-кулларын җилпеп, салмак кына түбән төшә башлады...* А.Тимергалин. *Болардан тыш, чакырып китерелгән иптәшләрдән театрның прима балеринасы В.Н.Алееваны һәм солистлар И.В.Карый, Н.С.Козлова, В.Е.Романюк, А.П.Ярославцев, Т.Михайлованы әйтеп үтәргә кирәк.* М.Җәлил. *Кызы Әлфия Айдарская – М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры балеринасы – татарларда балет сәнгате турында китап язган икән...* Г.Ахунов

**БАЛЕРУН** *и. рус* Балетта биюче артист; балетта биюче ир-ат. *Бу ОБХССтан түгел, хәтта фининспектор да түгел, минем дустым Рушан бу – Балерун белән Аптекарьның да иптәше...* Р.Мирхәйдәров

**БАЛЕТ** *и. фр.* 1) Театрлаштырылган бию сәнгате. *Өзек журналда басылып чыкты, аннары инде балет сәнгате турындагы бу кульязма китап булып та басылып дөнья күрде.* Г.Ахунов. *Әлфия минем 10 яшь тулган туган көнемдә балет башмагы бүләк иткән иде.* Л.Моратова. *Нинель Юлтыева – татар балет сәнгатендә танылган шәхес.* Татарстан яшьләре

2) Биюдән һәм тән хәрәкәтләреннән гыйбарәт булган музыкаль сәнгать әсәре – театр тамашасы. *Бу балетны сәхнәгә Гай Таһиров куя.* М.Җәлил

3) Хореография труппасы. *Театрның балет составы башкара.* М.Җәлил. *Театрның балет цехы, башлыча, читтән чакырылган балет артистларыннан төзелде.* М.Җәлил

**БАЛЕТМЕ́ЙСТЕР** *и. нем.* Балетны сәхнәгә куючы, балет биюләренә өйрәтүче, балетта биюләр җитәкчесе. *Театрның балет цехына балетмейстер Гай Таһиров җитәкчелек итә.* М.Җәлил. *Хореография училищесының балетмейстерлар бүлеген «отлично» билгесе белән тәмам итте.* Ш.Хөсәенов. *Ә безнең мәктәптәге тәрбия эшенә ул зур игътибар бирде: хореография түгәрәген җитәкләргә балетмейстер Таһировны чакырды.* Сөембикә

**БАЛЕТМЕЙСТЕРЛЫК** *и.* Балет биюләренә өйрәтү эше, балетмейстер вазифасы. *Ләкин 1970 елда шушы ук театрдан Нуриев үрнәгенә ияргән икенче бер балет йолдызы Наталья Макарованың чит илдә калуы Сергеевны, ниһаять, баш балетмейстерлыктан алып ыргытты.* Р.Вәли

**БАЛИГЪ** *с. гар.* Балалык дәвереннән чыккан, балигълык чорына кергән, өлгереп җиткән, җитлеккән (рухи, җенси, рәсми яктан). *Җәләл мулла, бу мәҗлестә сезнең ни эшегез бар, ул инде балигъ ---, теләсә кем белән торыр, минем анда эшем юк, дип махы бирмәскә тырышса да, кайткач, икенче төрле кыланды.* Г.Ибраһимов

**БАЛИ́ГЪ БУЛУ** *ф.* Җитлегү, өлгерү, үсеп җиту. *Шуңа күрә эш тоташ ялганды: балигъ булмаганнар, авыру хатыннар бәпкә утыртты; әби-бабайлар көлтә бавы ишеп торды.* К.Кәримов. *Я, әйтегез, балигъ булган мөэмин-мөселман кешегә көн дә ничә намаз фарыз?* М.Гали

**БАЛИГЪЛЫК** *и.* Балигъ булу, җитлеккәнлек, өлгергәнлек. *Төнге Мадридта мин, балигълык дәверемдә беренче тапкыр, әнә шулай итеп, җан ирегэн тойдым, хөрлек тәмен татыдым.* М.Галиев

**БА́Л ИКМӘГЕ** *и.* Бал кортларына ашар өчен, кәрәз күзәнәкләрендәге чәчәк серкәсе, чаршын. --- оядагы күп кенә урын кортларның азык запасы – бал һәм чәчәк серкәсеннән ясалган бал икмәге (чаршын) белән тулы була. Умартачылык

**БАЛИМӘР** *и.* Сайрар чыпчыклар семьялыгыннан, тонык көрән яки яшел төстә, тел очында чәчәкләрнең баллы суын суырырга махсус щёткасыман әгъзасы булган кечкенә көньяк кошы; *русчасы:* **медосос**

**БАЛИТӘК** *и. сөйл. к.* **бала итәк.** *Аклы ситсы күлмәгемнең Балитәге өч кенә.* Җыр. *Өстенә туй күлмәге кебек итеп тегелгән, балитәкләр тоткан озын ап-ак күлмәк, башына энҗеле калфак кигән Сара апаны сәхнәгә берничә тапкыр чакырып чыгаралар.* Р.Ильясов. *Балитәкнең кырыен төрлечә эшлиләр: кулдан яки машинада тар гына итеп бөгәләр, артык тукыманы тигезләп кисәләр, аннан соң яңадан машинада тегәләр яки кырыена икенче төрле тукыма тоталар.* Йорт эшләре

**БАЛКАЛАК** *и. диал. к.* **балкашык**. *Садыйк балкалагы белән чәйне суытасуыта үзенең тартып чыгарган кәгазьләреннән берсен укырга тотынды.* Г.Ибраһимов

**БАЛКАР** *и.* Кабарда-Балкарда яшәүчеләрнең бер өлеше булган төрки телле халык атамасы һәм аның бер кешесе. *Без менә комык, балкар, карачай, ногай белән рәхәтләнеп сөйләшә алабыз.* Д.Исхаков

**БАЛКАРАГЫ** *и.* Тәңкәканатлылар отрядына караган, йонлач юан гәүдәле, саргылт кара бизәкле, килеп кунганда канатларын түбә рәвешендә арка ягына җыя торган төнге күбәләк. *Бу үсемлек нектары белән хортумчыгы 35 см озынлыгындагы балкарагы күбәләге генә*

*туклана ала.* Ә.Халидов. *Төнге күбәләкләрнең мыекчалары еш кына каурыйсыман, йөнтәс һәм аларның тагын бер аермалы үзенчәлеге бар: килеп кунганда, канатларын түбә рәвешендә арка ягына җыялар. Мәс., балкараклар, җирән төнге тавискүз һ.б.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**БАЛКА́РЧА** *рәв.* **1.** Балкар телендә; балкарларга охшатып, балкарлар кебек, балкарларга хас. *Бу сүз башка төрки телләрдә дә очрый: башкорт телендә «аяк» – «зур миски»; балкарча «аякъ» – «миски, рюмка» ---.* Г.Мөгътәсимова. *Балкарча киенү*

**2.** *с. мәгъ.* Балкар телендә булган, балкарларга караган. *Балкарча дәртле җыр*

**БА́Л КАШЫГЫ** *и. к.* **балкашык.** *– Я, Газинур, колхозга кайтабызмы? – диде Павел Иванович, бал кашыгы белән үтә куе чәйне болгатып.* Г.Әпсәләмов

**БАЛКАШЫК** *и.* Аш ашый торган кашыктан кечкенәрәк кашык, чәй кашыгы. *Килен-кыз бер балкашык чәй салды, ике балкашык чәй салды, өченче балкашыкны тутырырга чәй савытына кашыкны тыкты, Сәмигулла абзый чыдый алмады.* Ф.Әмирхан. *Һәм әниең, балкашык белән генә, синең авызыңа су сала...* Х.Сарьян. *Газизов исә, боларның берсен дә ишетмәгәндәй, сүз һич тә аның турында бармагандай, үзалдына уйланып, балкашыгы белән чәен болгата.* А.Шамов

**БАЛКОН** *и. фр.* 1) Бина стенасына култыкса яки рәшәткә белән киртәләп беркетелгән мәйданчык. *Берәр кварталга сузылган, бишәр-алтышар катлы, балконлы, ак, сары таш биналар кояш яктысында күз явын алырлык матур булып күренәләр иде.* Г.Әпсәләмов. *Киң балконлы тын бүлмәләр анда. Ризык белән тулы өстәлләр.* Ш.Маннур

2) Тамаша залында урта яки югарыгы ярус. *Үз урынын эзләү сылтавы белән, залны да йөреп чыкты, югары катка – балконга да менеп төште.* Г.Минский. *«Рәхмәт инде бу кечкенә егет Альфредка!» – дип, көлешә-көлешә, театрның балконына менеп кунаклыйбыз.* М.Гыйниятова

**БА́Л КОРТЫ** *и.* Элпәканатлылар отрядыннан, чәчәк нектарын – балга, ә серкәсен бал икмәгенә эшкәртә торган бөҗәк; умарта корты. *Зәгыйфь кырмыскамын мин, юлда яткан, Түгел балкорты мин, чагып елаткан.* Дәрдемәнд. *Бал корты гөлләр өстендә әйләнде дә, бер мизгел һавада туктап торгач, күңеленә хуш килгән чәчәккә төште.* А.Тимергалин. *Тырыш бал кортлары нектарны эчеп туймыйлар.* Г.Хәсәнов

**БАЛКУ** *и.* 1) Ялтырау, яп-якты булып күренү. *Кайчан, балкып, җиһанга тулды якты. Килеп нур агълаган тауларны бакты.* Дәрдемәнд. *Кояш чыкты, ул калыкты, Тәрәзәдән нур балыкты.* Р.Корбан. *Кичләрен күкләрдә балкыса йолдызлар, Әй уйный ажгаган каналлар өстендә.* Казан утлары

2) *күч.* Эчке хисләрдән йөз яктырып, ачылып китү, нур чәчү. *Йөзендә беркемдә булмаган ягымлы елмаю, наз балкый.* М.Маликова. *Һәркемнең йөзендә, кулы белән тотып, кармагына каптыру мәртәбәсенә җитешкән бер теләк балкый.* Г.Ибраһимов. *Мин күргән иң чын матурлык – хатын-кыз бәхетле булганда, йөзенең тулышып балкуы!* Р.Фәйзуллин

3) *күч.* Ачык төс булуы белән аерылып тору, күзне җәлеп итү; җемелдәү, елкылдау. *Күзләреңнән, беләм, нур сибелгән – Зәңгәрләнеп балкый күлмәгең.* Ә.Баян

**Балкый бару** Торган саен ныграк балку. *Вакытлар узу белән, әдәбият тарихындагы күп исемнәр тоныклана төште, ә Тукай исә, киресенчә, яңадан-яңа яклары һәм төсмерләре белән балкый гына бара.* Ф.Бәшир

**Балкый башлау** Балкырга тотыну. *Мондый чакта, кызның күзләрендә, ярдәмчесез калган зәгыйфь җанны назлап юатырга теләгәндәй, шәфкатьлелек балкый башлый.* А.Вергазов

**Балкый төшү** Тагы да балку, бераз балку. *Әгәр дә төзү дәвамында кирпечләр кими барса, тел байлыгы, киресенчә, куллану нәтиҗәсендә арта, ишәя тора, үз халкына тугрылыклырак, нәтиҗәлерәк хезмәт итә, сүз бизәкләре яктыра, балкый төшә.* Ф.Хатипов

**Балкып алу** Кыска гына, бераз вакытка яп-якты булып күренү; балку. *Кинәт, бер мизгелдә, Җәмитнең күңел түренә иңгән зәгыйфь кенә яктылыкта Зөлфия сурәте балкып алды...* Н.Хәсәнов. *Ләкин, бәхеткә, Сара ханымга сәнгать дөньясында тагын бер балкып алырга, тагын бер бәхетле иҗат гомере кичерергә насыйп булды.* Г.Бәширов. *Учак сискәнеп киткәндәй булды, көл катыш утлы күмер, күккә – биеккә күтәрелеп, тирә-юньгә чаткылар чәчрәтеп, балкып алды.* Р.Хафизова

**Балкып җибәрү** Кинәт балкый башлау

**Балкып йөрү** Һәрвакыт көләч, ачык йөзле булу. *Уйчан гына балкып йөрсә дә шул, Көчле рухлы булган Сибгат ага!* Л.Шагыйрьҗан. *Мудрыйның күңеленең иң ерак упкынында Наилә исеме һаман янып, балкып йөри иде.* А.Гыйләҗев

**Балкып калу** Үзеннән соң эз калдыру, озак вакытлар билгеле булу. *Ә шулай да тарих ераклыкларында исемнәре балкып калган азамат ил уллары бәхет турында бәя җитмәс сүзләр калдырганнар.* Р.Фәйзуллин. *Аурупа Ренессансы кебек үк җимешле булыр, гүзәл нәтиҗәләр бирер, иле, халкы тарихында ул нәтиҗәләр иң якты сәхифәләр булып балкып калыр иде дә бит...* М.Гайнетдинов

**Балкып китү** Кинәт балку. *Менә хикмәт – бөтен дөнья гаҗәеп матур манзарага әверелде, яктырып, балкып китте.* Г.Гыйльманов. *Гомәр абзыйның, инде андагы җитдилекне, тәвәккәллекне күреп алгач, эченә җылы йөгерде, йөзе балкып китте.* Ф.Сафин

**Балкып кую** Кинәт кенә, кыска вакытка, бер тапкыр балку

**Балкып тору** 1) Һәрвакыт, бертуктаусыз балку. *Минем сиңа булган хисләрдән, Ак чәчәкләр балкып торсын, дип.* Ф.Кәрим

2) Әле, хәзер, сөйләү моментында балку. *Идел камышы кебек зифа, йөз дисәң, тулган ай кебек, нур уйнап, балкып тора.* Г.Ибраһимов. *Дөнья якты бүген! Ә мин карыйм Балкып торган зифа сынына.* Казан утлары

**Балкып утыру** Яп-якты булып, аермачык күренү. *Кара син аны, ничек бал-*

*кып утыра яңа йорт!* М.Насыйбуллин. *Матур вазаларда күз явын алырлык нәфис чәчәкләр балкып утыра.* Г.Әпсәләмов

**Балкып яту** Әле, күз алдында киң булып җәйрәп балку. *Кояш яктысында балкып яткан киң аланда күңелле шау-шу әз генә дә тукталып тормады.* Н.Фәттах

**БАЛКЫЛДА́У** *ф. сир.* Бер артып, бер кимеп, җемелдәп үзгәреп торган балку

**Балкылдап алу** Тиз генә ял-якты булу

**Балкылдап китү** Кинәт, аз гына вакыт балкылдау

**Балкылдап кую** Бер тапкыр, бик аз гына балкылдау

**Балкылдап тору** Бертуктаусыз балкылдау. *Зур өлгеле киң тәрәзәләрнең һәммәсе ерактан балкылдап торалар.* Г.Ибраһимов. *Нинди гүзәл, Нәкъ кояш күк балкылдап тора!* Х.Туфан

**БАЛКЫТУ** *ф.* 1) Нурландыру, якты итү, яктырту. *Тимергали йорты. Ятмаганнар. Нур балкыта тышта утлары.* Ш.Мөдәррис

2) Яктылыкны көчәйтү, тагы да якты яна торган итү. *Камәр, йөгереп барып, кучкардагы лампа утын балкытыбрак чыгарып куйды.* Р.Төхфәтуллин. *Яз кояшы җирне балкыта.* Х.Ягъфар

3) *күч.* Ямьләндерү, ямьле итү, матурлау. *Гади генә түгел, ә серле бишек. Күңелләрне яктылыкка төреп, рухыңны балкыта торган сихри бишек.* М.Кәбиров

4) *күч.* Үзен уңай яктан күрсәтү, һәрьяктан аерылып тору. --- *Галимҗанның, башка балалары белән чагыштырып караганда, болай якты дөньяда үзен тиз балкыта алуы, шөбһәсез, матур күңелле, сәләтле анасының тәрбиясе җимеше.* С.Поварисов

**Балкыта бару** Торган саен ныграк балкыту

**Балкыта төшү** Беркадәр, бераз балкыту

**Балкытып алу** Тиз генә, кыска вакыт арасында балкыту

**Балкытып җибәрү** Кинәт балкыта башлау

**Балкытып кую** Балкыган хәлгә китереп тоту

**Балкытып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз балкыту. – *Бу ташлардан өй салып куйсаң, бөтен урамны балкытып торыр иде, – дип уйлый Гыймай.* Ф.Яруллин

**БАЛКЫШ** *и.* 1) Көчле яктылык кабынып китү күренеше. *Кояшның сихри балкышы бермәлгә аның бар дөньясын томалап куя, күрәсең – ихтыярсыздан, күзләрен бармак очлары белән уып ала...* Г.Гыйльманов. *Бераздан, бар галәмне иңләп, нурлы балкыш пәйда булды.* Ф.Дунай. *Әмма ажаганның --- салкын балкышы, күзләремне чытырдатып йомганда да, керфекләрем аша үтеп керә.* М.Хәсәнов

2) Нәрсәдән дә булса таралган нурлы чагылыш, төсләрнең яктылыгы. *Хәния бу балкышны таңга ачыла барган чәчәк таҗына охшатты.* Н.Хәсәнов. *Рәмин Нәфыйковның төсләр балкышын тәшкил иткән «Түтәл» картинасы язу өстәлем турысына эленгән булса, Илдар Зариповның махсус язган «Габриэла»сы, мулат чибәркәенең гарәп егете Нәсипне үзенә каратырга исәп тотып, бөтен зифалыгын күрсәткән чагын гәүдәләндергән әсәре – караватым өстендә.* К.Миңлебаев. *Нурлы җирем минем, моңлы җирем, Яшә мәңге тыныч балкышларда!* Н.Касыймов

3) Талантның күркәм чагылышы, югары дәрәҗәдәге ачылышы. *Әлегә кадәр бу залда булмаган балкыш: Сәйдәш бии!* К.Латыйп

**БАЛЛ** *и. фр.* 1) Табигатьтәге берәр стихияле күренешнең: җилнең, давылның, җир тетрәүнең, су дулкынлануының көчен үлчәү берәмлеге. *Каспий диңгезенә салкынның үтеп керүе ун баллы шторм тудырды.* Социалистик Татарстан

2) Укучы белеменең дәрәҗәсен билгеләү берәмлеге, бәя, билге. *Немец теленнән «5»ле ала да конкурсантларын ике баллга узып китә Иске Ибрай мәктәбендә бу телне су кебек эчәргә өйрәткән педагог.* Т.Нәҗмиев. *Тавыш – искиткеч, әгәр Юрий Левитан тавышы – бер балл, дип исәпләсәк, М.Галинеке бер ярым балл иде.* М.Мәһдиев

3) Төрле ярышларда осталыкны бәяләү берәмлеге. *Спортсмен чыгышы өч балл белән бәяләнде.* Р.Ишморат. *Әзерлек, сайлау ярышларында җыйган баллар буенча билгеләнүче рейтинг көрәшченең кем белән алышачагын ачыклый.* Татарстан

4) Тавыш биргәндә кулланыла торган бәяләр күрсәткече

5) *күч.* Иҗтимагый күренешләрнең җәмгыятькә йогынтысын билгеләү күрсәткече. *Берсе – татар музыка тәсбихының бисмилласы, икенчесе – театрыбыздагы искелекне дер селкетеп алган тугыз балл көчендәге дулкын, дип куйды.* Ш.Рахманкулов

**БАЛЛА́ДА** *и. фр.* 1) Риваять яки әкият темасына язылган сюжетлы шигырь. *Язылып бетмәгән бик әйбәт ике балладам бар.* М.Җәлил. *Ул балладаның герое – ун яшьлек кытай малае Чанжи батырларча һәлак була.* М.Кәрим. *Нинди жанрда гына язмый алар! Гади шигырьдән башлап, баллада, бәет һәм поэмалар да иҗат итәләр.* Казан утлары

2) Романтизм чорында: уен коралы өчен язылган музыкаль әсәр. *Юбилей концертын Сара Садыйкованың «Өченче көн тоташ кар ява» балладасы белән ачтылар.* Г.Ахунов

3) Роман халыкларында биюле җыр

**БАЛЛАНУ** *ф.* 1) Бал тәме керү, татлылану; шикәрләнү, тәмләнү. *Ирем, дисә ирене бөрелеп кала, Балам, дисә... теле баллана.* С.Гәрәева. *Әле тик печән өсте генә булса да, балланып өлгергән.* Г.Хәсәнов. *Баллансын, дисәгез, төнгә астын өскә каратып калдырырга кирәк.* Тәмле тамак

2) Кәрәзләр бал белән тулу. *Зәки йөридер бакча буенча: Умарталар җитмәгән балланып.* Бәет

3) *күч.* Төчеләнү, куштанлану. *Дөньяда бар бит оятсыз кешеләр: ирен көтми китеп барган, ә хәзер балланып каршы алган була.* М.Максуд

**Баллана башлау** Балланырга керешү

**Баллана төшү** Беркадәр, бераз баллану

**Балланып бару** Акрынлап баллана башлау

**Балланып бетү** Тәмам баллану

**Балланып җитү** Тәмам, тулысынча баллану

**Балланып китү** Күпмедер дәрәҗәдә, беркадәр баллану

**Балланып тору** Баллы хәлгә килү, баллы тәм алу

**БАЛЛАП** *рәв.* 1) Бал белән, бал кушып, бал ягып, бал яки шикәр катнаштырып, татлы итеп. *Килгәч, башта бал ашый, баллап чәй эчә бу.* З.Фәйзи

2) Бал җыеп, бал биреп. *Умарталар һәр ел яхшы гына үрчеп, баллап килгәннәр.* М.Гали

3) *күч.* Татлы тел белән, күңелгә ятышлы итеп; төчеләнеп, ялагайланып, куштанланып. *Шул баллап язылган төрек романнарын уку --- [Мәрьям] рухының бертуктаусыз теләп торган бер ризыгы.* Г.Ибраһимов

**БАЛЛА́СТ** *и. нем. тех.* 1) Тотрыклылыкны саклау өчен корабльләргә, аэростатларга салынган махсус авырлык. *Бер ай була инде менә Самарадан чыкканыбызга, һәркөн бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр өстерибез инде шул балластны.* М.Гали

2) Тимер юл шпалларын күмеп ныгыту өчен салынган вак таш, ком. *Хәзер рельслар, шпаллар тирәсендә – су кебек ару балласт, шпаллар, шөрепләр, костыльләр яңартылганнар; вагон, сикерми, төз бара.* Г.Гали

3) *күч.* Кирәксез, файдасыз яки артык йөк, мал; берәр оешмада, эштә һ.б. урыннардагы артык кешеләр. *Юк, дисең син, әйләнәсем килми Үлгәндә дә андый балластка.* З.Мансур. *[Хикмәт:] И-и-и, синең татарлыгың минем агроном булуым шикелле генә бит: исәпкә бар, санга юк. Балласт... Шпаргалкасыз... кызларга татарча хат та яза алмыйсың бит син...* Р.Вәлиев. *Клетчатка балласт матдәләрдән тора.* Файдалы киңәшләр

**БАЛЛИ́СТИК** *с.* Баллистикага караган, баллистика фәнендә карала торган

**БАЛЛИ́СТИКА** *и. гр. махс.* Пуля, туп снарядларының көпшә эчендә һәм аннан чыкканнан соң хәрәкәт итү законнарын өйрәнә торган фән (теоретик механиканың бер бүлеге). *Батарея командиры булу өчен, математика, баллистика һәм механиканы белергә кирәк.* А.Шамов. *Баллистика законнарыннан тыш, аларның радио тарафыннан юнәлтелгән булулары ихтимал, дип санаганнар.* С.Баттал

**БАЛЛОН** *и. фр.* 1) Тар муенлы, шарсыман яки цилиндр формасындагы савыт. *Моның өчен баллонны югары таба күтәрәләр, суы күренерлек итеп, баллонны аз гына кысалар.* Йорт эшләре

2) Газ һ.б. ягулыклар, кислота саклау өчен, герметик ябыла торган савыт. *Гыйльметдин, нык-нык басып, баскычтан күтәрелде, өйалдына кергән уңайга иңбашындагы газ баллонын җай гына төшереп, почмактагы плитә янына куйды.* Ф.Сафин

3) Һава тутырылган шин (автомобиль көпчәгендә). *Табаны машина баллоныннан әмәлләнгән, мамыктан эчлек ясалган олы ботинкалар астында өзлексез кар шыгырдый.* Р.Кәрами. *Баллоннан чыгарылган кислородның массасын табыгыз.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Көпчәк баллонының күләме 155 л булса, һава насосының күләмен хисаплап чыгарыгыз.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

4) Аэростатның газ үткәрми торган тышы, кабыгы

**БАЛЛУТ** *и. к.* **баллы баба**

**БАЛЛЫ** *с.* 1) Бал салынган, балы булган; татлы тәм килгән. *Буткаң бик майлы, чәең бик баллы булды.* Ш.Маннур. *Бәлеш пешерү өчен, өлгереп җиткән, каты, баллы кабак алына.* Татар халык ашлары. *Кеше аңына килгәч тә, аңа баллы чәй эчертәләр, җылы юрган ябалар.* Йорт эшләре. *Исегездә тотыгыз: сыйфатлы ананас баллы исле һәм каты кабыклы була.* Тәмле тамак

2) Бал белән тулган. *Маннап чыгып китүгә, өйгә, баллы кәрәзләрен күтәреп, Минзөфәр килеп керде.* Н.Хәсәнов

3) *күч.* Күңелгә ята торган, йомшак, ягымлы, татлы. *Торса бит, син алай кәнфит шикелле баллы гына түгел идең бит, синең әчкелтем-төчкелтем чакларың да бик күп буладыр иде.* Г.Камал. *Гөлнар җаный, баллы чәк-чәгем, – дип кочаклап алдым үзен.* Ә.Айдар

◊ **Баллы күл** Кешенең иркен, мул тормыш турында хыяллануына карата; *русчасы:* **молочные реки**

**БАЛЛЫ́ БАБА** *и.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, туры сабаклы, ак, кызыл, алсу төсләрдәге кыңгырау сыман көпшәле чәчәкле, күпьеллык чүп үләне; пәри кычытканы; *русчасы*: **яснотка.** *Аларга үссендереп үстерә торган сүз тылсымы салынган... Укъяфрак, канәфер, умырзая, кашкарый, гөлбадран, тамчы гөл, яушан гөл, тайтояк, баллы баба, еланбаш, ташкуран, сарана, абага, төнбоек, тузганак, сарут, текәнәк, нәркиз, таҗгөл, раушан...* М.Галиев

**БАЛЛЫ́ ГӨМБӘ** *и.* Киселгән агач төпләрендә оя-оя булып үсә торган, соры, кызгылт сары кабырчыклы эшләпәле, ашарга яраклы берничә төр гөмбәнең уртак исеме; *русчасы*: **опёнок.** *Баллы гөмбә сабагында элпә бoҗра бар. Тонык төстә, эшләпә асты аксыл.* Совет мәктәбе

**БАЛЛЫК** *и.* Чәчәктә бал ясала торган урын

**БАЛЛЫ́ КАКЫ** *и.* Әвернә чәчәкләләр семьялыгына керә торган, сары яки ак чәчәкле үсемлек, какының ашый торган төре. *Балтырганнар, баллы какылар... Бер-берсеннән тәмлетатлылар. Алар өчен ризык булганнар.* Ш.Маннур

**БАЛЛЫ́ КУЗАК** *и.* Кузаклылар семьялыгыннан, субтропик климатта үсә торган агач һәм шуның татлы борчагы; *русчасы:* **царьградские стручки.** *Ярминкәдә --- балалар төрле уенчыклар алып кычкырталар, сыбызгылар сызгырталар. Кайберләре баллы кузак, прәннекләр ашыйлар.* Х.Садри

**БАЛЛЫ́ ЧӘЧӘК** *и.* Канәферсыманнар семьялыгыннан, туры сабаклы, күгелҗем шәмәхә яки аксыл чәчәкле үлән үсемлек, ала миләүшә; *русчасы:* **Иван да Марья.** *Җир өстенә берәү исләмай сипкән шикелле, әллә кайдан баллы чәчәк исе килә.* Ш.Усманов. *Борынына печән, баллы чәчәк исе килеп бәрелгәндер, ә күктән кояш үзенең нурларын сузгандыр ---.* Ф.Җамалетдинова

**БАЛЛЫ́ ЧЫК** *и. бот.* Үсемлекләрдә гөмбә авыруы; *русчасы:* **медвяная роса**

**БА́Л-МАЙ** *җый. и.* Бал һәм май, баллы-майлы ризыклар. *Тимеркәй са-*

*мавырны кертә. Шкафтан чынаяклар, чәйнекләр, кумәчләр, бал-майлар алып куя.* Г.Ибраһимов. *Баязитның әнисе ишек төбендә каушап басып торган киленнең иреннәренә кашык белән балмай тидерде.* Р.Зәйдулла

◊ **Бал-май гына ашап тору** Сыйлы, тук тормышта яшәү. *Алар нигә язылсыннар, алар анда язылмый да бал-май ашап торалар.* Һ.Такташ. **Бал-май эчендә генә тоту** Рәхәттә яшәтү. *Вузга? Ташла, зинһар, мин сине болай да бал-май эчендә генә тотачакмын.* Р.Ишморат. **Бал-май эчендә йөзү** Рәхәттә, муллыкта яшәү. *Юма тел белән куштанлык аны кеше итте, ул аны, маңгай тирен агызмыйча гына, бал-май эчендә йөздерде.* Г.Бәширов

**БА́Л-МАСКАРАД** *и.* Бер-берсен үзара танытмаска тырышып, махсус киемнәр һәм маска киеп күңел ача торган кичә, бал

**БАЛПАН** *и. төрки* 1) Ауга өйрәтелгән ерткыч кош баласы (бөркет баласы)

2) *диал.* Тилгәннең бер төре, әтәлге; *русчасы*: **балобан**

**БАЛТА** *и.* 1) Агач эшендә кулланыла торган, яссы, үткен йөзле, агач сапка утыртылган чабып кисү коралы. *Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу.* Г.Тукай. *Мәктәпне тәмамлагач та Фазыллар утыртып йөргән диләнкәдә балта чапкан тавыш ишетелде.* К.Кәримов. *Балтасын әйтер идең, утынлыкта эшсез ятып йөзе тупасланган.* Н.Гыйматдинова

2) Тышкы формасы белән шул эш коралына охшаган әйбер. *Ачкыч балтасы*

◊ **Балта асарлык (асып куярдай)** Бик куе, катлам-катлам, яктылык үтеп кермәслек. *Җыелыш барган бинада Балта асарлык төтен.* С.Баттал. **Балта белән агач арасы** Бик хәтәр урын, хәтәр эш. **Балта белән агач арасына бармак тыгу** Хәвефле эшкә алыну. *[Минһаҗ:] Балта белән агач арасына бармак тыгарга картлар кушмаганнар.* К.Тинчурин. **Балта биреп, шөшле алу** Алдану. **Балта кермәс (кермәгән, керерлек түгел)** Бик куе, бик еш. *Балта кермәгән кара урманнар бар бит безнең бу якларда.* Г.Галиев. **Балта күтәрү** Дуамалланып кычкырына башлау, тыныч кына сөйләшә алмау. **Балта мае ялату** Дөнья күрмәгән кешене, кызык итеп, көлкегә калдыру. **Балта сабы кыска** 1) Тиз ачуланучан; тиз кызып китүчән; 2) Тәҗрибәсе, белеме, булдыклылыгы түбән булган. **Балта суга төшү, балтасы суга төшкән кебек (диярсең)** Бәла-казага очраган, авыр хәлгә калган кебек боегып, күңел төшеп йөрү турында. *Моңа хәтле балтасы суга төшкән кеше шикелле йөри идем.* Г.Мөхәммәтшин. *Балтасы суга төшкән, диярсең.* Н.Фәттах. **Балта тоту** Балта эшен белү. *Акман нәселе балта тотарга тиеш!* Х.Сарьян. *Ат менә дә кырга чаба, ат менә дә кырга чаба. Ир-атка бераз балта тотса да ярар иде.* Н.Гыйматдинова. **Балта чабу** Нинди дә булса планлаштырылган берәр эшне, ниятне җимерү, тар-мар итү, юкка чыгару. **Балта элеп куярлык** *к.* **балта асарлык**. *Сикерә-сикерә бии башлагач, балта элеп куярлык тузан күтәрелмәсен өчен, башта әнә шул суны сәхнә идәненә сибеп чыгарга кирәк икән!* Р.Вәли

**БАЛТА́ ОСТАСЫ** *и.* Балта эше белән шөгыльләнүче кеше; балтачы. *Кулыннан килмәгән эше юк, балта остасы, ташчы, буяучы…* А.Гыйләҗев. *Үги әтисе, бер аяксыз булса да, Мартукта билгеле балта остасы иде.* Р.Мирхәйдәров

**БАЛТА́ ТҮТӘСЕ** *и.* Балта сырты

**БАЛТАЧЫ** *и. к.* **балта остасы.** *Ул анда Олы Шырданның балтачы Әхмәтҗанны күреп сөйләшкән.* М.Гали. *Тагы берничә балтачы белән ташчыны куштылар да, иген-тару җыелып бетүгә, эшкә тотындылар.* Г.Ибраһимов

**БАЛТАЧЫЛЫК** *и.* Балта эше, балтачы һөнәре. *Балтачылык һөнәре яңадан кайта*

**БАЛТА́ ЭШЕ** *и.* Балта остасы һөнәре

**БА́Л ТӘТӘЙ** *и. диал.* Әнисенең сеңлесе яки кардәше

**БАЛТЫР** *и.* 1) Аякның тубыктан тезгә кадәр булган мускуллы ягы. *Мәүлиха түти Сәйфинең, олы башы белән, Әпипәнең шәрә балтырларына шулай күзен челәйтеп торуын һич ошатмады.* Г.Бәширов. *Кайсысы балтырымнан эләктерә, кайсысы арт санымнан тешләп ала.* Ә.Айдар. *Бер шина балтырның тышкы ягына, икенчесе эчке ягына куела.* Йорт эшләре. *Бала, вакыт-вакыт, стена янына басып, үкчәсен, балтырын, башын стенага тидерсен.* Сөембикә

2) Аяк киеменең кунычы. *Ул чын дегет исе аңкытып торган күн итегенең балтырына шап итеп сугып алды.* А.Шамов. *Кара әле, син минем акчаны читек балтырына батырганны бер кешегә дә сөйли күрмә.* Г.Камал. *Аның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле, балтырыннан тотып кия торган, шнурсыз резиналы ботинка иде.* М.Гали

**БАЛТЫРГАН** *и.* Чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан, бәбәкләре һәм яшь көпшәләре ашарга яраклы, эре яфраклы биек үлән; бәпчек; *русчасы:* **борщевик.** *Балтырганнар ашап ныгыдык без Ык буенда – туган якларда.* А.Гыйләҗев. *Һәм… һәм һич көтмәгәндә-уйламаганда, җиргә иелә-иелә, юл буенда үсеп утырган кыргый юа белән балтырган җыя башлады.* Х.Низамов. *Сугыш вакытында байтак ашадык инде балтырганын да, кычытканын да, башкасын да.* К.Миңлебаев

**БАЛТЫРДАН** *рәв.* Балтыр турысыннан, балтырга кадәр. *Алга китте [Карәхмәт] бата-чума балтырдан.* Ә.Исхак

**БАЛТЫ́Р СӨЯГЕ** *и.* Бер-берсе белән янәшә урнашкан, аякның тубыктан тезгә кадәрле өлеше; сыйрак сөяге

**БАЛЧЫ** *и.* 1) *тар.* Кунакларга әче бал өләшүче; аякчы. *Балны, башлап, балчы авыз итә.* Мәкаль

2) Умартачы. *Малчы мал карар, балчы бал карар.* Мәкаль

**БАЛЧЫК** *и.* **1.** 1) Кызгылт төстәге, су белән чылатканда үзләнә, ә кипкәндә ката торган токым. *Төрле механизмнар ярдәмендә, су көче белән балчыкны җебетәләр.* Г.Лотфи. *Элек 40 чакрымнан балчык ташый идек, ә хәзер үзебезнең Бизмән тау балчыгы хутка китте.* А.Әхмәт

2) Сылау эшләре өчен махсус әзерләнгән измә. *Хәлим стена ташларына сыланган кызыл балчык өстендә имән бармагын йөртә башлады.* Г.Гобәй. *– Иллә шәп таш пулат та соң безнең йорт! – диде Газинур, шаяртып, һәм кечкенә тәрәзәле, тыштан да, эчтән дә кызыл балчык белән сыланган тәбәнәк өйнең ишеген ачты.* Г.Әпсәләмов. *Балаларын тездән сызганып, иртәдән кичкә кадәр аягы белән кызыл балчык изә.* Г.Гобәй

3) *диал.* Җир, туфрак. *Урамнарда инде балчык ярыла, тузан чыга.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Балчыктан эшләнгән, балчыктан торган. *Ул үзен мәгънәсез, буш бер кешегә генә түгел, хәтта суы агызылган балчык кувшинга тиңли башлады.* Ф.Латыйфи. *Рәхмәт төшкере Зурәптәйләрдә беркадәр яшәгәч, көннәр, акрынлап, җылыга борылгач, үзебезнең балчык ызбабызга күченү ягын кайгырта башладык.* К.Миңлебаев. *Ниһаять, магнетизм гасырлар һәм меңнәрчә еллар буена балчык савытларда һәм төзелеш кирпечләрендә сакланып кала.* Могҗизалар энциклопедиясе

◊ **Балчыктан әвәләмәгән (ясалмаган)** Җансыз түгел, үзен яклый алырлык. *Мирза, син дә балчыктан ясалмаган.* М.Фәйзи

**БАЛЧЫКЛАНУ** *ф.* 1) Балчык кебек үзлеләнү, балчыкка әйләнү

2) Балчык ябышып буялу, балчык сылану. *Аракы балчыкланып каткан шакшы идән ярыкларына тулган, аска тиз генә акмый иде*. Н.Гыйматдинова

**Балчыклана бара** Торган саен ныграк балчыклану, үзлелеге арта бару

**Балчыклана төшү** Бераз балчыклану

**Балчыкланып бетү** Тоташ балчыклану. *Хәбиб, --- сикереп торды да, балчыкланып беткән ыштырларын кагып, аягына киенде*. Т.Госман

**Балчыкланып җитү** Тәмам үзләнеп балчыклану

**Балчыкланып тору** Балчыксыман булып күренү

**БАЛЧЫКЛЫ** *с.* 1) Составында күп балчык булган, балчык катнашкан. *Тагын да читкәрәк китеп казысаң – кызыл балчыклы ак таш...* К.Кәримов. *Үлән баскан иске каберләр арасыннан кызыл балчыклы яңа каберне эзләп табу кыен булмады.* И.Гази. *Балчыклы туфрак тыгызрак та, авыррак та.* Ботаника

2) Балчык ябышып буялган, балчык сыланган. *Ишек бусагасына утырып, балчыклы итеген салды, чолгауларын чиште.* Г.Мөхәммәтшин

**БАЛЧЫКЛЫК** *и.* Сылау һәм керамикага яраклы балчык казып алу урыны яки шундый балчык ятмасы

**БАЛЧЫКСЫЛ** *с.* Аз гына балчык катыш. *Известьне тирес белән яки тирес һәм минераль ашламалар белән куллану --- балчыксыл һәм балчыклы туфракларда яхшы нәтиҗә бирә.* Социалистик Татарстан

**БАЛЫК** I *и.* 1) Умырткалылар классына караган, очлыклары канат рәвешендә һәм саңаклары белән сулый торган салкын канлы су хайваны. *Һаман шулай Күлләрендә йөзә балыклар.* Һ.Такташ. *Дөрес, осталыгы җитмиме, бәхете юкмы, балыкны әллә ни күп эләктерә алмый Ибраһимов.* М.Насыйбуллин. *Алсуланып таң атканда, кызарып кояш чыкканда, минем Идел яры буенда бик күп утырганым, балык тотканым бар. Шул балыклардан уха пешереп ашаганым бар.* Г.Лотфи // Азык буларак әзерләнгән ризык хәлендәге балык. *Бөҗра булып урнашкан урыс гаскәре өстенә, җил искән саен, пешкән икмәк, кыздырган суган, ит, балык исе килә.* Ф.Латыйпов. *Кызып алгач, унлап кеше өчен өстәлгә әзерләп куйган балыкны тәлинкәсе белән тартып китерде дә җимереп ашап бетерде.* М.Мәһдиев. *Балыкта иткә караганда май бик аз булса да, аның кеше өчен файдасы күбрәк.* Идел

2) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган, шул исемдәге йолдызлык

3) Зодиак системасына керә торган, шул исемдәге йолдызлык тамгасы

4) Кояш календарена караган унике айдан торган йолдызлыкның соңгы уникенче ае исеме; 20 февральдән 20 мартка хәтле булган чор. *Йолдызлыклар мифологиясенең безнең көннәргә кадәр сакланып калган җитди үзенчәлекләренең берсе шунда: бездә ай исемнәре йолдызлык исемнәре белән аталган: «Гыйнвар – Сукояр (Водолей); Февраль – Балык (Рыба); Март – Кучкар (Овен) ---*. Ф.Урманче

5) Кояш шул йолдызлыкта чакта туган кеше. *Балыклар – хәзер романтик мөнәсәбәтләрдә барысы да сезнең инициативага бәйле.* Мәдәни җомга

◊ **Балык башыннан чери** Җәмгыятьтәге кимчелекләр җитәкчелектән килә, дигән мәгънәдә. *Иң яманы шул – балык башыннан чери.* Н.Фәттах. **Балык кебек йөзү** Нинди дә булса өлкәне бик яхшы белү, белеме, тәҗрибәсе зур булу

**БАЛЫК** II *и. төрки >рус* 1) Тозлап ысланган яки какланган мәрсин я сөләйман балыгының сырт өлеше, деликатес

2) Ысланган сырт итеннән гыйбарәт деликатес ашамлык

**БАЛЫ́К АГЫ** *и. к.* **балык сөте**

**БАЛЫККӘЛТӘ** *и.* Күптән үлеп беткән борынгы сөйрәлүче хайваннарның бер төре. *Җирнең урта эра чорындагы диңгезләрдә балыккәлтәләр яшәгәннәр.* Зоология

**БАЛЫ́К КОЙРЫГЫ** *и. тех.* Бораулау скважинасы боравының очы калаклы булган төре. *Токым йомшак булган көньяк районнарда «балык койрыгы» дип атала торган борау белән боралар.* Нефть турында хикәяләр

**БАЛЫКЛЫ** *с.* 1) Балык күп үрчегән, балыкка бай. *Су буенда гаҗәеп матур җирләр, шунда ук әрәмәлек, балыклы күлләр, җәй көне бер тамаша инде менә.* Ш.Камал. *Таҗи Кама буендагы бер авылны белә икән, каршысында гына – иң балыклы урын, ди.* М.Әмир

2) *сөйл.* Балык исе сеңгән, балык исе килә торган. *– Башыңа ни килә, быр-рат, яза барырга кирәк. Уйлап утырсаң булмый ул! – дип, Әхәт Гаффар балыклы сыра тәме килгән мыек чылгыен авызына капты*. М.Галиев

**БАЛЫ́К МАЕ** *и.* Тәрәч бавырыннан алына торган витаминлы май. *Аңа [көчеккә] гөлҗимеш яисә ылыс төнәтммәсе ясап бирик. Аз гына балык мае, витаминнар да өстик*. Н.Каштанов

**БАЛЫ́К СӨТЕ** *и.* Ата (иркәк) балыкның сөт кебек ак төстәге орлык сыекчасы

**БАЛЫ́К ТҮНЕ** *и.* Зур сулыкларда киң күләмдә балык сөзү сезоны

**БАЛЫКЧЫ** *и.* 1) Төп хезмәте балык тоту булган кеше яки һәвәскәр балык тотучы. *Шуңа да бит ул, моннан ике ел элек, муллалыгын ташлап, үзенең туган-үскән авылы Уразайга кайтып, гади игенче һәм балыкчы булып көн күрә башлады.* Р.Ишморат. *Менә, ниһаять, балыкчы, кискен хәрәкәт белән киң селтәнеп, кармагын тартып алды.* М.Маликова

2) Балыкчылык тармагында эшләүче кеше

**БАЛЫКЧЫЛЫК** *и.* 1) Балык үрчетү, тоту белән шөгыльләнә торган хуҗалык тармагы. *Күл буена килеп туктадык. «Чишмә» колхозының мәшһүр балыкчылык хуҗалыгына килеп җиткәнлегебезне Мөхәммәт абый тиз абайлап алды.* Х.Низамов. *Районнардагы ау күзәтүе инспекторлары, экология милициясе, ниһаять, ветеринар һәм фитосанитар күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан идарәсендәге балыкчылык бүлегендә эшләүчеләр өчен табигатьне саклауның нәтиҗәле бер ысулы түгел микәнни бу?!* И.Диндаров

2) Балык тоту шөгыле. *Урчем һәм уңдырышлылык культына нигезләнгән йолалардан, барыннан да элек, сунарчылык һәм балыкчылык белән бәйләнгән архаик йолаларны күрсәтергә кирәк.* М.Бакиров. *Татарларда балыкчылык бик тәрәкъкый иткән булган.* Г.Гобәйдуллин. *Бу вакытта, аучылык белән беррәттән, балыкчылык та бик киң таралган.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**БАЛЫ́К ШУЛПАСЫ (ӨЙРӘСЕ)** *и.* Балык салып пешерелгән шулпа; уха. *Бик тәмле балык өйрәсе пешерәм.* Ш.Камал. *Станислав Михайлович беренче көнне үк, яшь дуслары исеменнән, Дамирны балык шулпасыннан авыз итәргә чакырды.* Р.Мирхәйдәров. *Балык шулпасы сүрән генә утта пешерелә.* Татар халык ашлары

**БАЛЬНЕОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Медицина фәненең, профилактика-дәвалау максатыннан, минераль суларның кеше организмына тәэсирен өйрәнә торган бүлеге

**БАМБУК** *и. малая* **1.** Кыяклылар семьялыгыннан, буын-буын куыш сабаклары биек һәм сыгылмалы булып, бик тиз үсә торган агачсыман тропик, субтропик үсемлек; һинд камышы (агач сыман каты камыш). *Ә субтропикларда үсә торган бамбукның биеклеге 40 метрга җитә.* Ботаника. *Милли ризыкларның нигезен төрле продуктлардан – ярма, он, яшелчә, ит, балык, диңгез хайваннары, суүсемнәр, кош, бамбуклардан әзерләнгән ризыклар тәшкил итә.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ.* Бамбуктан ясалган. *Урелгән бамбук креслога утырып, Зөбәрҗәтне күзәтә башлады.* Х.Мөдәррисова. *Рус хезмәтендә булган кызыл киемле кытай полицийскийлары, кулларындагы бамбук агачы белән, тимер юл буенда рельс өстендә папирос, шырпы, квас, чикләвек сатып йөрүче кытайларның аркасына һич тәкәллефсез сукмакта иделәр.* Ш.Мөхәммәдев. *Ә Кытайда беренче китапларны юка бамбук пластинкаларга язганнар һәм аларны нык-лы җепкә тезгәннәр.* Юлдаш

**БАМБУ́К АЮЫ** *и.* Янутсыманнар семьялыгыннан, кыяфәте белән янутка да, аюга да охшаган, ак һәм кара төсләре үзенчәлекле аралашкан мехлы (аяклары, колаклары, койрык очы һәм җилкә өлеше – кара, калган өлеше ак булган), җылы якларда яши торган җәнлек

**БАНАЛЬ** *с. фр.* Күптәннән билгеле булган, күп сөйләнелгән, искергән, тәэсир көчен югалткан. *Гыйбарәсе баналь булса да, кабатлап әйтәм: берни дә буш урында тумый.* Р.Кадыйров. *Баналь фикерләр, теләсә нинди үткен соуска кушып бирелсәләр дә, барыбер баналь булып калалар.* Совет әдәбияты

**БАНАН** *и. баконго* 1) Сүс һәм җимеш бирә торган, эре яфраклы күпьеллык тропик үсемлек. *Шунысы кызык, тропик үләнчел үсемлек булган бананның биеклеге 6–7 метрга җитә.* Ботаника

2) Шул үсемлекнең рәт-рәт укмашып үсә торган, сусыл татлы озынча җимеше. *Чәйгә берәр алма, апельсин, банан да бар иде.* Ә.Хәбибуллин. *Анда өрек, йөзем, мандарин һәм банан гына түгел, Кәшифә әбинең гомерендә бер генә дә күргәне, кулына тотып караганы да булмаган ананас, арахис һәм кивиләргә кадәр бар иде.* З.Фәйзи. *Банан йомшагында туклыклы матдәләр һәм витаминнар күп.* Серле сандык

**БАНАРАС** *и. иск.* **1.** Ярым ефәк юка ак тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Бүлмә тәрәзәсе алдыннан --- банарас чапанлы бер кешенең җәһәтләп үткәнен күргәч, Закир ниһаять дәрәҗәдә куанды.* Ф.Әмирхан

**БА́НДА** *и. ит.* Талау белән шөгыльләнүче, тәртипсез, шикле, усал ниятле, сугышчан төркем; шайка. *Әгәр ул өлгерә алмаса, бу авылны таңда чех бандасы килеп басачак.* Г.Ибраһимов. *Сатучылар белән кулак малайларыннан банда оештырдылар.* Г.Бәширов. *Бандага каршы көрәшү өчен, Ашыт һәм Уинск заводы эшчеләреннән кораллы отрядлар төзелде.* Р.Хафизова

**БАНДАЖ** *и. фр.* 1) *мед.* Берәр органның нормаль торышын саклау өчен киелә торган махсус биләүсә. *Йөклелекнең алтынчы-җиденче аеннан алып, бандаж кияргә киңәш итәлә, әгәр бандаж булмаса, корсакны сөлге белән бәйләргә мөмкин.* Йорт эшләре. *Ә кызыйга бандаж кидерегез, бөере төшкән кызыгызның!* Сөембикә

2) *тех.* Машина, вагон яки паровоз көпчәгенең корыч тугымы, шины. *Мең сигез йөз егерме җиденче елларда Вуд дигән кеше паровозларның тәгәрмәчләренә бандаж кидерергә тәкъдим иткән.* Т.Госман

**БАНДАЖЛА́У** *ф.* 1) Гәүдәне кысып торган бандаж кию. *Имиләрен матур итеп күпертеп, билләрен, бандажлап, бермә-бер нечкәртүләренә игътибар итмичә, чәчләренә генә карасаң да «аһ» итмәле.* З.Фәйзи

2) Көпчәкләргә корыч тугым утырту яки аны салдыру. *Минем хәзер сезнең контрольгә барыш, бандажларга дип.* Н.Хәсәнов

**Бандажлап кую** Бандажланган хәлгә китерү

**Бандажлап тору** Һәрвакыт бандажлау, бандажланган хәлдә тоту

**БАНДАЖЧЫ** *и. мед. тех.* 1) Бандаж ясау остасы; бандаж тегүче

2) *тех.* Паровоз яки вагон көпчәгенә корыч тугым утыртучы һәм аны салдыручы

**БАНДЕРОЛЬ** *и. фр.* Документларны, китап-журналларны почта аша йөртә торган төргәк. *Бүген сиңа да, ачык бандероль илә, бер данә «Яңа бәдәвам» китабы җибәрдем.* Ш.Мөхәммәдев

**БАНДЕРОЛЬЛӘ́Ү** *ф.* Бандероль итеп төрү. *Гәзитләрне, бандерольләп, почта аша җибәрү җайлырак түгелме?* Х.Туфан

**Бандерольләп куюя** Алдан ук бандерольләү

**БАНДИТ** *и. ит.* 1) Коралланган җинаятьчел төркемдә йөрүче. *Ә күн киемле студентлар үзләре нindидер бандитлар өерен хәтерләтте.* В.Шәрипов. *[Һөҗүм итүче] Нокта Вәли дигән кушамат белән йөртелә торган мәшһүр угры, бандит.* Ш.Камал. *Милләт буларак яралганбыз икән, бандиты да, профессоры да үзебезнеке.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Баскынчы; басып алучы гаскәр солдаты. *Бандит безнең юлны бумакчы, безнең илгә хуҗа булмакчы.* Ә.Ерикәй. *Көнен дә, төнен дә җилкапка янында кораллы бандитлар сакта тора.* Р.Хафизова. *Бандитлар яңадан һөҗүм итәргә әзерләнәләр булса кирәк.* А.Шамов

**БАНДИТЛА́РЧА** *рәв.* Бандитларга хас булганча, бандитлар кебек. *Ә инде кайчандыр дус булып саналып та, хәзер комсомол оешмасы секретаре вазифасын үтәүче Кәтмән Харисның: «Клубка бандитларча бәреп кереп, колхоз яшьләренең ямьле ялын бозды», – дип язып биргән аңлатмасын укып чыккач, Һадиның күзләре шар булды.* М.Хәсәнов

**БАНДИТЛЫК** *и.* Юлбасарлык, талау шөгыле; бандит булу. *Әгәр Садыйк каты бәйләнә башласа, элекке кебек, бандитлыкка кайтмак буласызмы?* Г.Ибраһимов. *Алыш-биреш, коррупция, бандитлык отыры арта*… Н.Хәсәнов

**БАНДУ́РА** *и. пол.* 1) Украина халкының чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы. *Шулар янында, тагын шул ук Кәтүшәгә мәдхияләр укып, Тарас Шевченко – Кобзарь – бандура чиертеп утыра иде, ди.* Г.Бәширов. *--- мин, Донбасста вакытта ук, аккордеонда, бандурада, балалайкада, думбрада уйный белә идем.* Т.Нәҗмиев

2) *сөйл.* Зур, күләмле әйбер. *«Бандура» дип, алар фатирында, күченәкүченә, ташланмыйча бишенче тапкырында да торган борынгы бер дәү имән шкафны атап йөртәләр иде.* Ә.Гаффар

**БАНДУ́РАЧЫ** *и.* 1) Украинада: бандурада уйнап җырлаучы

2) Бандурада уйнаучы музыкант

**БАНИ** *и. гар. иск.* Төзүче, архитектор. *Дая әйтер: Банилар хазыйр кәлсен, сәңа лаек бер сарай бина кылсын.* Кол Гали

**БАНИЛЫК** *и. иск.* 1) Төзүче яки архитектор һөнәре

2) Мәчет, мәдрәсә кебек дини учреждениеләрнең биналарын төзү, ягулык һ.б.ш. белән тәэмин итү, чыгымнарын күтәрүдә катнашучылык. *Мәдрәсәгә банилык итеп, бүген тышкы идарәгә килгән байлар да аңа [Кадыйр байга] иярделәр.* Г.Ибраһимов

**БАНИЯТ** *и. гар. иск. к.* **архитектура**

**БАНК** *и. фр.* 1) Акча алу, бурычка бирү, туплау һәм акча бүлү эшләрендә арадашчылык вазифасын башкара, саф акчаны үзәкләштереп әйләнешкә кертә торган учреждение; эре кредит учреждениесе. *Шунсыз колхоз акчасын банк күчерми, һәм безнең оешма зыян күрә.* К.Кәримов. *Дөнья банкыннан долларлар көтәбез.* Ә.Хәбибуллин. *Бүгенге көндә Республикадагы 28 коммерция банкының 22 се табышлы эшли.* Татарстан

2) Шул учреждение бинасы. *Соңгы план илә салынган казённый йортлар, Чин шәркый тимер юл правлениесе, Русско-Китайский банк зданиесе, киң урамнар, гүзәл бакчалар бу Яңа Харбинны матур итмәктәдер.* Ш.Мөхәммәдев. *Талия банкка киткән иде. Мөгаен, килеп тә өлгермәс.* Р.Габделхакова

3) Нинди дә булса үзәктә берәр нәрсәнең системалы тупланмасы. *--- компьютерда җыр текстлары банкы булдырылды.* К.Миңнуллин. *Милли рух банкы булган авыл турында сөйлибез дә шәһәр хакында хыялланабыз.* Р.Шәрәфиев. *Кан банкы. Мәгълүматлар банкы*

4) *күч.* Отышлы карта уенында конга куелган акчалар суммасы

5) *күч.* Отышлы карта уенының бер төре; шул уенның бер уйналышы (туры)

◊ **Банк сугу** Карта уенында: банкка җыелган акчаны отып алу. – *Бер сугуда 20 тәңкәлек банк сугып алдым, шулай да кесәдә 1 тиен акча юк, уйнамыйм моннан соң, нәләт төшсен, – дип, ертып ыргытты.* М.Гали. **Банк тоту** Акчаны банкка куеп, уенда катнашучыларның һәрберсенә каршы уйнау

**БА́НКА** *и. пол.* 1) Пыяладан яки калайдан ясалган цилиндрик савыт. *Анда башланмаган бер банка җилем бар иде.* А.Шамов. *Лапаста әбинең литрлы банкасына безләп сөт ага: «Без-з-зк! Без-з-зк! Без-з-зк!»* Р.Сибат. *1 литрлы банкага 600–650 грамм кәбестә һәм 400–350 грамм маринад суы сыя.* Йорт эшләре

2) *мед.* Дәвалау максатыннан, эчендә һавасыз бушлык (вакуум) хасил итеп, аркага авызы белән ябыштырыла торган пыяла савыт. *Банка салу*

**БА́НКАЛЫ** *с.* Банкага тутырылган, банкага салынган. *Сабын белән кадак урынына, нindидер озынча түгәрәк калай банкалы әйберләр килеп чыкты.* К.Нәҗми. *Александра Ивановна кулындагы сумкасыннан, берничә пакет белән, лимон, әфлисун, алма, конфет, печенье, банкалы варенье чыгарып, сәкенең буш урынына таратты.* М.Гали

**БАНКЕТ** I *и. фр.* Нинди дә булса тантанага багышлап үткәрелгән сый мәҗлесе. *Мәскәү татарлары Сара апаны үз җырчылары итеп саныйлар, чәчәкләргә күмәләр, истәлекле бүләкләр тапшыралар, концерттан соң банкетларга чакыралар.* Г.Зәйнашева. *Банкетлары да шул бүлмәдә узды, шунда ук, ай-ваема карамыйча, кунарга да калдырдылар.* К.Миңлебаев. *Урман эчендәге чишмәле елга буенда зур банкет булды.* Х.Низамов

**БАНКЕТ** II *и. фр. махс.* Балчык һәм таш, ком өеп ясалган калкулык,

вал. *Иделнең көчле агышы Юлын бора без теләгән якка, Банкет салгач елга төбенә.* С.Урайский

**БАНКЕ́ТКА** *и. фр.* Аркасыз, зур булмаган йомшак утыргыч

**БАНКИР** *и. фр.* 1) Банк хуҗасы яки аның акционеры. *Урамнар купецлар, банкирлар, фабрикантлар, вояжерлар, алып-сатарлар, исерекләр, караклар, аферистлар, авантюристлар, фахишәләр белән тулган.* К.Тинчурин. *Эшендә уңышларга ирешкән бай банкирның гомумиләштереп әйтелгән фикере бик ис китәрлек түгел иде, шулай да ул минем өчен көтелмәгәнрәк булды.* М.Зарипов

2) Банк уенында карта таратучы, банк тотучы

**БАНКИРЛЫК** *и.* Банкир хезмәте; банк хуҗасы буларак эшчәнлек. *Шул рәвешчә, ярты Аурупага тиң район базарын Хөсәеневләр үз кулында тота. Бер үк вакытта алар банкирлык хезмәте белән дә шөгыльләнәләр.* М.Гайнетдинов

**БА́НК КАПИТАЛЫ** *и. махс.* Банк биләгән капитал. *Феодаль җәмгыятьтән капитализмга күчү, ягъни мануфактура чорында сәүдәгәрләр катламы әйдәп барса, промышленность үсү, индустрияләштерү тамыр җәя башлагач, алгы планга фабрикантлар, завод хуҗалары, банк капиталы белән бәйләнгән акционерлар чыга.* Ф.Җәүһәрова

**БА́НК КРЕДИТЫ** *и. махс.* Банклар тарафыннан эшмәкәрләргә сәүдә килешүләре һәм гамәлләре алып бару, җитештерү эшләрен киңәйтү өчен бирелә торган акчалата ссуда, кредит. *Һәрберсенең эшенә карап, банк кредиты ачалар, эшләре ходка киткәннән соң, байлыкны һәр тарафка сачәләр.* Ш.Мөхәммәдев

**БАНКНОТ** *и. нем.* 1) Банклар чыгара һәм алыш-бирештә акча урынына йөри торган кредит билетлары. *Шуңа күрә кайбер яңа дәүләт банкнотларында хайван сурәте төшерелә.* Кызыклар дөньясында. *Төркиянең милли валютасы – төрек лирасы. 1, 5, 20, 50, 100 лиралы банкнотлар әйләнештә йөри.* Мәгърифәт

2) Эмиссия банклары чыгара торган кредит акчалары

**БАНКОМАТ** *и. ит.-гр.* Кредит карточкасы белән кулга акча алу өчен эшләнгән автомат җайланма. *Әгәр дә сез, банкта чиратта торулардан азат буласыгыз килеп, кредитны, банкомат аша, кредит карточкасы ярдәмендә түләргә уйласагыз, банкоматтан наличный акча алганда нинди процент түләнүе белән кызыксыныгыз, чөнки кредит түләү срогында мондый процентлар бик күп җыелырга мөмкин.* Татарстан. *Банкомат янындагы камера язмаларын өйрәнеп, милиция бу адәмнең эзенә төшә.* Кәеф ничек

**БАНКРОТ** *и. нем.* Үз бурычларын түли алмый бөлгенлектә төшкән хуҗалык, предприятие, кеше. *Бай хатыннары симерә; Ирләре банкрот булгач, Кара икмәк кимерә.* Ш.Мөхәммәдев. *Коммунистлар партиясенең шапырынкы планнары, нәтиҗәсез эшчәнлеге, банкрот сәясәте һәм идеологиясе әлеге төп юлбашчысы белән кузаллана.* Т.Мөбарәков

**БАНКРОТЛЫК** *и.* 1) Бөлгенлек; банкрот булу хәле. *Кострома өлкәсе администрациясе үтенече белән, банкротлыкка чыгу алдындагы Красносельск ювелир заводын сатып алалар.* Сөембикә. *Компания банкротлыкка чыккан очракта, Россия Федерациясенең Пенсия фонды аның белән килешүне өзә...* Сөембикә. *Ләкин, төзелеш конторасы банкротлыкка чыкканнан соң, хыялларның барысы да җимерелә.* Юлдаш

2) Идея ягыннан тулы һәлакәт. *Абстракцион сәнгать капитализмның кризисын, аның рухи банкротлыгын күрсәтеп тора.* М.Хәсәнов

**БАНТ** *и. пол.<нем.* Күбәләксыман итеп элмәкләп бәйләнгән тасма. *Электкечә тройкадан бик фырт киенгәннәр дә күренеп кала, зур бант тагып, озын блузадан йөрүчеләр дә күренгәли, ---.* Ә.Еники. *Тик шинелен салгач күрделәр – күкрәгенең сул ягындагы ике орден янында кызыл бант белән уратылган Кызыл Байрак ордены кызыллы-аклы булып ялтырап тора.* З.Зәйнуллин. *[Валяның] Артка җыеп куйган чәче өстендә – ялтыравык муар бант, ул ачык бизәкле эре тропик күбәләккә охшап тора.* Р.Мирхәйдәров

**БАНТЛАНУ** *ф.* Бантка охшау, икегә бүленгән сыман булып, бөлтәеп (күпереп) тору. *Иреннәре бантлану*

**БАНТЛАП** *рәв.* Бант рәвешендә, бант ясап

**БА́НТУ** *и.* Үзәк һәм Көньяк Африкада яши торган һәм үзара кардәш телләрдә сөйләшүче этник төркемнәрнең гомуми атамасы. *Дөньяда һинд-европа, семит, фин-угор, дравид, кытай-тибет, банту, кавказ һ.б. тел семьялары бар дип исәпләнелә.* Н.Фәттах

**БАОБАБ** *и. амхар* Бомбаксчалар (баобабчалар) семьялыгыннан, Африкада үсә, ярканатлар ярдәмендә серкәләнә торган, нык юан кәүсәле, киң ябалдашлы, хуш исле зур чәчәкле агач; маймыл агачы. *Баобаб яфрагын кыш көне түгел, ә җәй көне коя.* Р.Фәизов. *Баобаблар ашарга яраклы җимеш бирәләр, ә сусле кайрылары тупас тукымалар әзерләү өчен кулланыла.* Дөнья кисәкләре географиясе

**БАП** I *и.* гар. *к.* **баб**

**БАП** II *рәв. сир.* Бик ярашлы, таман, туры килгән. *Кәҗәнең сөте – агып торган болак, эче тулы ылак, Ите – тамагыңа бап, тиресе – аягыңа кап, Мөгезе – пычагыңа сап, эчәгесен аршынга тарт, скрипкәчегә сат.* Н.Исәнбәт

◊ **Бап килү (төшү)** Ярап кую, уңай туры килү. *Бу исә тел егәрлеген саклауда иң кирәкле нәрсәләрнең берсе – кыскалык принцибына бап килә.* Р.Әхмәтьянов

**БАПТИЗМ** *и. фр.<гр.* Протестантларда бары аңлы рәвештә, балигъ булганнан соң гына суга чумдырып чукындыру һәм чиркәү аша түгел, ә турыдан-туры Алланың үзе белән элемтәдә булу таләп ителә торган юнәлеш; христиан диненең бер мәзһәбе

**БАПТИСТ** *и. рус* Баптизм таләп иткән йолаларны үтәүче ир кеше. *Раштуа (Рождество) бәйрәмен христиан динен тотучы күптөрле агымнарның барысы да: православие, лютеран, англикан, баптист, католик, протестант, кальвинист һәм башкалар*

*бик зурлап билгеләп үтә.* Н.Максимов. *Соңыннан укытучылар әйтте, әлеге малаебыз баптистлар йогынтысына эләккән икән, дип...* Ш.Галиев

**БАПТИ́СТКА** *и. рус* Баптист хатын-кыз

**БАР** I *хәб. сүз* **1.** 1) Әйбернең булганлыгын, барлыгын, булуын белдерә (гадәттә бу сүз ярдәмендә раслау җөмләсе формалаша); *киресе*: **юк**. *Үз-үзем белән гел мавыгып, Керешсәм чәчәргә очкыннар; Яңгырый шулвакыт бер аваз: Онытма, Пушкин бар, Пушкин бар.* С.Хәким. *Һәрбер көннең аерым төсе бар, Һәрбер көннең аерым эзе бар.* Х.Туфан. *Әле дә ярый бетмәс эшләрем бар! Әле дә ярый юрар төшләрем бар!* Р.Фәйзуллин. *Теле барның иле бар, иле барның җире бар.* Шәһри Казан

2) *исем фигыль белән килгәндә* Мөмкин, ихтимал мәгънәсен белдерә. *Аның шулай кирәгеннән артык кыстап кунакка чакыруы безгә ошап бетмәде. Берәр бәйләнчек кеше, ахры, бу, артык сылана, юк-бар сөйләп алҗытып бетерүе бар, дип уйладык.* Т.Миңнуллин. *Күрше-коланның әллә нәрсә уйлавы бар.* Р.Ишморат

3) *фигыльнең -ган формасы белән килгәндә* Эш-хәрәкәтнең үткән заманда үтәлүен, күптән башкарылуын белдерә, *-ган* морфемасы үзенең билгесез (сөйләүче күзәтмәгән) үткән заман мәгънәсен югалта һәм билгеле (сөйләүче үзе күзәткән) үткән заман мәгънәсен ала. *Минем колхоз председателен озак йөрткән шофёр белән кырлар-басулар буйлап узганым бар.* С.Хәким. *Ничә тапкыр күргәне бар: һәйбәт тачанкалар, бер-берсеннән шәп кара атлар.* Г.Бәширов

4) *фигыльнең -асы формасы белән килгәндә* Киләчәктә үтәлергә тиеш эшне, башкарылырга тиешлекне белдерә. *Сентябрь аенда бәрәңге, чөгендер, кукуруз басуларын сукалыйсы бар – вәт акча кайда ята ул!* К.Кәримов. *Безнең яшьләрне уңыш алуның нечкә серләренә өйрәтәсебез бар.* Г.Бәширов. *Иртәгә демонстрациягә барасы бар бит!* И.Салахов

**2**. **барда** *рәв. мәгъ.* Булганда, булган очракта. *Акча барда, бар да дус шул, бар да яр; акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр.* Г.Тукай

◊ **Бар дип тә белмәү** 1) Игътибар итеп тормау, ис китмәү. *Мәрьям абыстай --- поездларга күптән ияләшкәнгә күрә, аларны бар дип тә белми.* Ә.Еники. 2) Санга сукмау, исәпләшмәү. **Бар икән** 1) Гаеп итүне белдерә. *Алла, бар икән кылану, ансы да ярамый, монсы да ярамый, белмим, боларга нәрсә генә ярый торгандыр.* Г.Камал; 2) Гаҗәпләнү һәм соклануны белдерә. *Ну, көч бар икән соң малның [атның] үзендә!* Г.Ибраһимов; 3) Каткат йөдәткән кешегә ачу белән әйтелә. *Бар икән туймас кеше.* **Бар итү** Булдыру, барлыкка китерү. *Бюрократны кем бар иткән юктан, Кемнәр аны басып үстергән?* Н.Арсланов. **Бары белән** Барынча, булган хәтлесе белән, булган кадәренчә, булганы белән. *Бары белән – базар, бары белән – бай.* Мәкаль

**БАР** II *и* **1**. Байлык, барлык. *Барга бәла күренмәс.* Мәкаль. *Бар өстенә бар яхшы, бал өстенә май яхшы.* Мәкаль

**2**. *с. мәгъ.* 1) Бик кирәкле, ихтыяҗ булган, зарур. *Станцияләрдә бар кирәк-ярак булган.* Г.Дәүләтшин

2) Булган, очрый торган. *Бар нәрсә балдан татлы.* Мәкаль

**БАР** III *а.* Предметларның җыелмасына бербөтен итеп күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; бөтен. *Бар җир карланган, Сулар бозланган...* Г.Тукай. *Бар җырымны илгә багышладым, Гомеремне дә бирәм халкыма.* М.Җәлил. *Сафа, бер кулын бутап, бар куәте белән кычкырып җырлый башлады.* Ш.Камал. *Кешедәге бар яхшылык табигатьтән килә.* Ә.Фәсхетдинов. *Ашарга утырса, ни гаҗәп, бар тәмле моның алдында иде.* М.Мәһдиев

◊ **Бар белгән** Нибары, тик, бары (чикләнгәнлекне белдерә). *Егетләрнең, яшь-җилбәзәкләрнең, беләсең инде, аларның бар белгәннәре – кыз гына.* Г.Камал. **Бар булган** Бөтен, җыен; барлык, барча. *Бар булган киемнәрне киеп алдым.* М.Гафури. **Бар кебек** Бөтен булган, барлык. *Ананың бар кебек шатлык вә өметләре җимерелгән, бигрәк тә Газизә өчен кайгыра, аны кызгана иде.* Ш.Камал. **Бар көчкә (хәлгә, тынга)** *к.* **бар куәткә**. *«Соңга калам, ахры!» дип, бар көченә йөгереп, Нечкәбил тышкы якка чыкты.* А.Алиш. **Бар куәткә** Бөтен көчен куеп

**БАР** IV *и. ингл.* 1) Зур булмаган ресторан. *Ричард аны беренче тапкыр төнге барда күрде.* Тәмуг чәчәге

2) Эчемлекләр куя торган шкаф, сервант, буфетның махсус, аерым бер бүлемтәсе

**БАР** V *и. гр. физ.* Атмосфера басымын үлчәү берәмлеге (750,1 мм терекөмеш баганасы авырлыгына тигез)

**БАРАБАН** *и.* 1) *муз.* Ике ягы да (төбе һәм өсте) тире белән тарттырылган куыш цилиндр; бәрмә музыка коралы. *Автобустан, иң соңгы булып, быргы һәм барабан күтәргән ике малай белән яшь кенә кыз төште.* Р.Хафизова. *Яшел тышлы китапта язылган ич: ахырзаман җиткәч, шайтаннар, музыка уйнап, сыбызгы сызгыртып, барабан кагып, урамнан узачаклар.* К.Нәҗми

2) *тех.* Төрле машина һәм механизмнарның куыш цилиндр рәвешендәге детале. *Машина калын тавыш белән үкерә башлады, барабан тешләре, ялт-йолт килеп, зырылдап әйләнергә тотындылар.* Г.Бәширов. *Тагын бер кнопканы басуга, корыч барабан әйләнә башлый.* Г.Лотфи. *Аны ындыр табагына, барабанга көлтә бирү эшенә куйдылар.* Р.Кәрами

3) Револьверда: патрон кую өчен оялары булган әйләнмәле магазин, соса. *Галләм, тун якаларын ычкындырып, чабу астыннан, кайдандыр, иске системадагы барабанлы һәм барабанында алты патроны да булган револьвер чыгарды.* Ф.Хөсни

4) Лото, лотереяда һәм башка шундый уеннарда: эченә номерлар салып, аларны буташтыру өчен көйләнгән әйләнмәле ябык савыт. *Клубның бер бүлмәсе. Өстәлләр, урындыклар тезелгән. Бер почмакта лото барабаны куелган.* Г.Камал // Цилиндр рәвешендәге үз күчәрендә әйләнеп торган уенчык аттракцион (вак җәнлекләр өчен). *Ул ишектән кергәнче үк, пыяла витрина эчендә юан гына ботаклы агачта бер тиеннең ялт та йолт сикереп-сикереп*

*уйнавын, агач барабанны күчәрендә әйләндереп чабуын гаҗәпләнеп карап торды.* Н.Хәсәнов

5) *архит.* Бинаның цилиндр яки күпкырлык рәвешендәге купол нигезен тәшкил иткән югары өлеше

◊ **Барабан кагу (сугу, бәрү)** 1) Тавыш, шау-шу күтәрү, кирәксә дә, кирәкмәсә дә сөйләнеп йөрү. – *Берәү тәмле ашамаса, йөри дә алмый, – дип, урам чаты саен барабан сугып йөрде.* Г.Толымбай; 2) Эшне эшләгәнче үк алдан шаулап кую, алдан белдереп, эшне бозу

**БАРАБАНЛА́У** *ф.* 1) Барабанга махсус таякчыклар белән тактлы бәрү

2) Барабанга суккан кебек шакылдату, дөбердәтү, барабанга суккан шикелле тиз-тиз, еш-еш сугу. *Бүген Тимер түбәләрне Барабанлап үтте ак болыт.* Х.Туфан

**Барабанлап алу** Тиз-тиз, кыска гына барабанлау

**Барабанлап тору** Бертуктаусыз барабанлау

**БАРАБА́Н ПӘРДӘСЕ** *и. анат.* Колак эчендәге яры. *Тавыш юлының түрендә эластик тоташтыргыч тукымадан торган барабан пәрдәсе тартылган.* Анатомия

**БАРАБАНЧЫ** *и.* 1) Барабан кагучы; барабанда уйнаучы музыкант. *Барабанчы Альфред соңгы чиккә җитеп шаша, Искәндәрнең пианино авазы тау елгасына килеп кушылган кечкенә чишмә кебек югалып кала.* Р.Вәлиев. *Ул үзен тантаналы маршта баручы отряд барабанчысы итеп хис итте...* Р.Хафизова

2) *тар.* Ашлык сугу машинасы барабанына көлтә биреп торучы. *Барабанчыдан башлап салам өючеләргәчә җанланып киткәндәй булдылар.* К.Басыйров

**БАРА́-БАРА** *рәв.* 1) Тукталмыйча, баруны дәвам итеп, озак барып, күп мәртәбә барып. *Уфаларга бара-бара, Аягымны талдырам.* Җыр. *Барабара, шактый ерак киткән.* К.Сибгат. *Бара-бара да Мотаһир тагын урман яңгыратып сөрән сала.* Р.Кәрами

2) Тора-бара, яши торгач, вакытлар узгач. *Күп эшләде иренмичә; бара, чыгарды ул [карлыгач] матурматур балалар да.* Г.Тукай

**БАРАБУС** *и. тар. к.* **барабыз.** *Извозчикларның күбесе татар авылларыннан акча эшләргә килгән, «барабус» сүзе шуларның урамда чакыру авазыннан килеп чыккан.* А.Тимергалин

**БАРАБЫЗ** *и. тар.* 1) Авылдан акча эшләргә килеп, Казан урамнарында артсыз чана белән кеше ташып йөрүче. *Тик чаттагы бабай – «барабыз»ның Бик үк әйбәт түгел тормышы.* Һ.Такташ. *Егерменче елларда атлы извозчикларны Казанда «барабыз» дип атый торган булганнар.* Казан утлары. *Бу төнне Хисами Гафурларда кунды, ә иртәгәсен авылдашларын, үзе кебек үк «барабыз»лар туктаган квартирны эзләп, шәһәргә китте.* Казан утлары

2) «Барабыз» чанасы. *Кыш көннәре «барабыз»да йөрергә барыбыз да яратабыз: үзе трамвайдан очсыз, үзе өйгә кадәр үк китереп куя.* Казан утлары

**БАРАБЫЗЧЫ** *и. тар.* «Барабыз»да кешеләр ташучы. *Чана юлы төшүгә, атлыларның --- зур гына күпчелеге, сукага хәтле ат асрап чыгу өчен, Казан урамнарында барабызчы булып йөрергә ашыгалар.* К.Нәҗми

**БАРАК** *и. фр.* 1) Уңайлыклары булмаган, вакытлы торак. *Шәһәрдә баракта үскән егет күңелләргә керерлек җыр сүзләре иҗат итә алмый.* М.Мәһдиев. *«Өй» дигәне – педагогия институтының барак тибындагы тулай торагында бер бүлмә иде.* М.Кәрим. *Ә хәзергә тоткыннар үзләренә тактадан барак әмәлләделәр.* Р.Кәрами

2) *махс. иск.* Хастаханәнең аерым бер бүлеге, гадәттә йогышлы авырулар өчен булган бүлек

**БАРА́НКА** I *и. рус* Камырдан бөҗра рәвешендә пешерелгән ашамлык; зур клиндер

◊ **Баранка итеп бөгү, баранка ясау** 1) Кемнән дә булса көч ягыннан бик өстен булу; 2) Каты җәзалау, кирәген бирү

**БАРА́НКА** II *и. рус гади с.* Һәртөрле транспортның руль тәгәрмәче. *Ун елдан артык баранка әйләндерәм.* Т.Галиуллин

**БАРА́-ТОРА** *рәв.* Бераздан, бераз вакыт үткәннән соң; күпмедер яшәгәч. *Яңа хатын элгәре кыскарак җавап биргәләсә дә, бара-тора, сүзнең эченә кереп китте.* Г.Исхакый

**БАРБАРИС** *и. фр.<лат.<гар.* 1) Барбариссыманнар семьялыгына караган, вак яфраклы, тәлгәшкә тупланган чәчәкле чәнечкеле куак. *Бакча ышыклау утыртмаларына имән, барбарис һәм дүләнә агачларын утыртырга ярамый.* А.Вәлиуллин

2) Шул куакның куе кызыл төстәге ачы, вак, озынча җимешләре. *Барбарис – әмир ярысы – эссе авыруга, эссе бизгәккә, тир сырхавына дәва.* К.Насыйри

**БАРБЕКЮ** *и. фр.* 1) Утлы күмер белән кыздырып яки төтен белән ыслап ризык әзерләү өчен махсус мич

2) Махсус мичтә утлы күмер өстенә куелган рәшәткәләрдә кыздырылган ит кисәкләре

3) Шул ризыкны кыздырганда кулланыла торган баллы-әчкелтем махсус соус

4) *сөйл.* Шундый ризык әзерләп үткәрелә торган пикник

**БАРГУЗИН** I *и. бурят* Байкал күлендә исә торган төньяк-көнчыгыш җиле

**БАРГУЗИН** II *и.* Машина маркасы

**БАРД** *и. кельт* 1) Борынгы кельтларда шагыйрь һәм җырчы

2) Шигырен, көен үзе язып, үзе үк башкаручы. *Алар кичтән Казандагы атаклы бард Борис Львовичның афишасын эзләп алып кайтканнар икән.* М.Сәлимҗанов

**БАРДА** *и.* 1) Куерык; спирт һәм сыра ясаганда кала торган түп. *Кешеләр Ташлытаудагы крахмал заводыннан бәрәңге бардасы ташыдылар.* М.Мәһдиев

2) Бөртекле ашлыкларны һәм бәрәңгене – крахмал, чөгендерне шикәр алу өчен кайнатканда калган масса (мал азыгы сыйфатында кулланыла). *Ифрат, кара айгырын җиктереп, Тараклы спирт заводына барда алу мөмкинлеген белешергә китте.* А.Расих

**БАРДАК** *и. фр.* 1) *иск. тупас сөйл.* Фәхешханә, бордель. *Аның белән генә дә чикләнми: «Чабата Җанаш үз өендә бардак оештырып ята», – дип, авыл советына барып әйтә.* М.Хәсәнов

2) Тәртипсезлек, хаос. *Юк, мин сезгә Шаһсуарзадә түгел. Анархияне, бардак ясап йөрүегезне тиз бетерермен!* М.Юныс. *Иле белән бардак, яшәү әмәле калмады...* Х.Ибраһимов

3) *күч. гади с.* Бүлмәдәге пычраклык, тәртипсезлек, җыйнаксызлык. *Кухняда, өелеп, савыт-саба ята, буш шешәләр, сигарет калдыклары. – Бу нинди бардак?! – мәйтәм.* Д.Гыйсметдин

**БАРДА́ ПЫЧЫРГЫСЫ** *и.* Еш барда ашату нәтиҗәсендә, терлекнең арт аякларына чыга торган чуан

**БАРЕЛЬЕФ** *и. фр. сәнг.* Яссылык өстенә күпертеп ясалган скульптур сурәт, сын. *Монда грек һәм рим колонналары да, Бабил стилендә ясалган капкалар да, Ассирия ысулында эшләнгән барельефлар да күрәсең.* В.Юныс. *Без --- кызыл ташларга уеп ясалган Ленин барельефына тын гына карап тордык.* Г.Мөхәммәтшин. *Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендә бертөркем каләм әһелләре шагыйрьнең 1 Май мәйданындагы һәйкәленә һәм җәлилчеләр барельефына быел да чәчәкләр салды.* Мәдәни җомга

**БА́РЖА** *и. фр.<лат.* Күп йөк сыйдырышлы яссы төпле судно. *Унлап кеше, муеннарына элмәк кигәннәр дә, Иделнең комлы яры буйлап, нindидер сәүдәгәрнең йөк төялгән баржасын агымга каршы өстерәп баралар.* Г.Лотфи. *Аның май, нефть белән зәңгәрләнгән суы өстендә пароход, пароходчыклар, баржалар, моторлы көймәләр арлы-бирле йөреп торалар.* Г.Толымбай

**БА́РЖАЧЫ** *и.* Баржада эшләүче матрос. *Арматур илтә баржалар, Турбиннар илтә; Баржачының төнге җыры Еракка китә.* С.Уральский

**БА́РИЙ** *и. гр. хим.* 1) Көмешсыман төстәге химик актив йомшак металл. *Поливинил хлоридтан ясалган кайманың эченә барий ферритыннан эшләнгән магнит урнаштыралар.* Суыту машиналары һәм криоген техникасы

2) *сөйл.* Эчәк, ашказаны һ.б.ш. авыруларны рентгент белән тикшергәндә кулланыла торган шушы элемент тозы

**БА́РИН** *и. рус* 1) 1917 елга кадәрге Россиядә: җәмгыятьнең өстен катлавына кергән шәхес (дворян, алпавыт, чиновник). *[Сөләйман:] Коллык психологиясе!.. Барин шәп... һәммә нәрсә баринныкы, яхшы!* Ф.Әмирхан

2) *гади с.* Шул катлауга гади халыкның мөрәҗәгать итү сүзе: хуҗа, бай. *Ярый, ярый, барин, гражданин, ул чагында әбзәтельне барырмын.* Т.Гыйззәт. – *Утыр, барин, өеңә илтеп куям, – диде.* Т.Миңнуллин

3) *күч. сөйл.* Үз-үзен тәкәббер тотучы, үзен хөрмәтләгәнне, үзенә хезмәт иткәнне яратучы кеше. *[Касыймхан:] Син тәмам барин булдың, Мирзахан.* Т.Гыйззәт

4) *күч. сөйл. кимс.* Аксөяк, кеше җилкәсен кимерүче, эшлексез, тик ятучы. *Чыксам, чыннан да Мәдинә апа, сукрана-сукрана, кызыл туфлиләрне юып ята! – Хәшәрәт! – ди, үртәлеп. – Барин булган, әрәмтамак!* Н.Фәттах

**БА́РИНЛЫК** *и.* 1) Баринга хас сыйфатлар. *Ләкин ул [Мохтар Мутин] бу образның баринлыгын бирә алмады.* Х.Сәлимҗанов

2) Тәкәбберлек, мин-минлек. *Үзәк Комитет язучылар алдында «әдәбияттагы баринлык гадәтләрен бетерү» кебек сугышчан бурычлар куйды.* Х.Госман

**БА́РИННАРЧА** *рәв.* Бариннар кебек, бариннарга охшарга тырышып, эре генә. *Бер чыгып йөреп керәбезме? Бариннарча гына, кесәгә кулны тыгып кына, кеше эшләгәнне карап кына?* Г.Гобәй

**БАРИСФЕ́РА** *и. гр. геол.* Җир шарының авыр үзәк ядрәсе

**БА́РИТ** *и. гр. махс.* Барий сульфаты, ак бөртек-бөртек кристалл минерал

**БАРИТОН** *и. фр.<гр. махс.* **1.** 1) Тенор һәм бас урталыгындагы ирләр тавышы. *Тик шунысын гына беләм: ул елларда безгә Япония җырчылары килгән иде, триомы, әллә күбрәкме, ирләр, алар тенор, баритон, бас белән «На Ангаре» дигән җыр җырлыйлар иде, һәм бу бездә соклану уята иде.* М.Мәһдиев. *Матур тенор, баритон белән җырлаучылар да, гитарада уйнаучылар да, чечётка биючеләр дә булды.* А.Хәсәнов. *Баска якын баритон белән ул, салмак итеп, җырлаган һәр сүзен мәгънәви хис белән сугарып, тамагы авазын җаны белән тыңлап җырлый иде.* Р.Харис. *Бу җырчы киң диапазонга ия, шунлыктан операларда һәм баритон, һәм тенор партияләрен башкара алган.* К.Таҗи

2) Шул тавыш белән җырлаучы. *[Җырчы] Ф.Маннапов – баритон.* М.Җәлил. *Башта баритон чыгып җырлады.* Х.Миңнегулов

3) Түбән югарылыкта яңгырый торган тынлы музыка коралының бер төре. *Саксофон – баритон*

4) Виолончельләр төркеменнән булган кыллы-сызгычлы уен коралы

**2**. *с. мәгъ.* Шул тавышка ия булган. *Г.Кариев гөрләп торган матур баритон тавышка ия иде.* Х.Сәлимҗанов. *Аның ягымлы баритон тавышы, микрофон аша көчәеп, бөтен залны биләп алды, күрше күршесен ишетмәс булды.* М.Маликова

**БАРК** *и. голл.<лат.* Койрык мачтасында – кыек, ә калганнарында туры җилкәнле, йөк ташучы диңгез судносы. *Кеше башы чаклы таш баркны өстән аска үтәли тишеп чыга.* Кызыклар дөньясында

**БА́РКА** *и. ит.<лат.* Кечкенәрәк яссы төпле йөк көймәсе

**БАРКАС** *и. фр.<лат.* 1) Берничә пар ишкәкле зур каек, йөк көймәсе. *Су юлы белән йөриләр бит викинглар, яссы төпле баркаслары белән елга комлыгына кадәр чыгалар.* М.Хәбибуллин

2) Тоткан балык, йөк һ.б.ш.ны ташу өчен файдаланыла торган, зур булмаган үзйөрешле судно. *Биредә тирән – пароход, буксир, баркаслар ярга якын гына уза.* Г.Гобәй

3) Күн производствосында кулланыла торган махсус бак

**БАРЛАМА** *и.* Берәр нәрсәнең барлыгына ышану өчен, яңадан тикшереп карау эше, барлыгын билгеләп чыгу, барлау эше. *Кабул итү вакытында мөлкәт барламалары буенча югалган әйберләр булмаса да, мөлкәт барламасында әйберләрнең бары тик исеме, даңәсе кертелгәнлеге беленде.* Л.Шәех

**БАРЛА́У** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса барлыгын тикшереп чыгу. *Каршыма килеп чыккан солдатларны күргәч, ымсынып куям: араларыннан сине эзлим,*

*сине барлыйм.* Н.Хәсәнов. *Вакыттыр җандагы дәрманны барларга.* Р.Фәйзуллин. *Милли китап репертуарын барлау --- аерым теоретик мәсьәләләрнең хәл ителмәгәнлеге үзен сиздерә башлады.* Ә.Кәримуллин. *Барлый торгач, ике дистәгә якын төрдәге агач үскәнлеге беленде.* Ф.Яруллин

2) Гаскәрдә яки төркемдә составның тулылыгын ачыклау; аныклау. *Микола, командирның приказын алу белән, тиз генә взводны җыя, тезә, барлый.* М.Җәлил

3) Булдыру, бар итү, табу. *Бу хакта хөкүмәтебез уйлана, яңа мөмкинлекләрне барлый.* И.Сафиуллин. *Быел без, бер төркем «Сөембикә»леләр, язның ак чәчәкләргә төренгән ямьле бер чорында, журнал укучыларыбызны барлап, Самарага бардык.* Сөембикә

**Барлап алу** Кемнең яки нәрсәнең дә булса барлыгын тиз генә аныклау. *--- шул ук вакытта үз артымнан килүче Шаһбазны да тиз генә борылып барлап алдым.* М.Вәли-Барҗылы. *Мин күңелемнән үзем белгән әкиятләрне барлап алам.* Т.Мөбарәков

**Барлап ату** Тиз генә, ашыгыч барлау

**Барлап бару** Системалы рәвештә, вакытында барлау; һәр очракны барлау. *Урман эченнән рәссамны йөзләрчә шүрәле күзәтеп тора сыман. Ул да аларны күрә, мөгезләренә кадәр барлап бара.* Р.Зәйдуллин

**Барлап бетерү** Ачыклау эшен тәмамлау; барысын да барлау. *Шәяхмәт белгән бөтен нәрсәне күңеленнән барлап бетергән иде инде – аны чакырып алдылар.* М.Мәһдиев

**Барлап йөрү** Һәрдаим барлау, барлау белән мәшгуль булу. *--- ул анда үзенә чын мәгънәсендә лаек урын алгандыр да, хәзер инде, бик сагынганда, Җиргә кайткалап, җыелмый калган ризыкларын барлап йөридер...* Җ.Дәрзаман. *Ул көн буе печән кибәннәрен барлап йөри.* Г.Мөхәммәтшин

**Барлап карау** *к.* **барлап чыгу.** *Ләкин, үткәннәремне тагы бер кат барлап карагач, бу миңа ул тиклем үк түбәнлек тә, пычраклык та булып тоелмады.* М.Кәбиров

**Барлап килү** Электән үк, һәрвакыт, эзлекле рәвештә барлау. *--- исемдә калган сәхифәләрне, күңелемдә эз калдырган кешеләрне берәм-берәм барлап килә башладым.* З.Фәйзуллин

**Барлап китү** Сүз уңаенда, беррәттән барлау. *Бу юлда торган каршылык-киртәләрнең кайберләрен инде барлап киткән идек.* И.Низамов

**Барлап кую** Берәр нәрсәне алдан ук барлау. *Кичектерми хәл итүне көтеп яткан эшләремне барлап куйдым.* Ф.Дунай. *Авылдан китәсе көнне кичтән үк Гөлчирә --- төйнисен – төйнәп, барлыйсын барлап куйды.* С.Рафиков

**Барлап тору** 1) Нәрсәне дә булса даими рәвештә барлау. *Эшне, уй һәм фикерне Мансур Хәсәнов башлады, әйтеп торды, эш барышын күзәтеп һәм барлап торды.* Г.Ахунов

2) Әле, хәзер, сөйләү моментында барлау. *Аларны сафка тезеп озатканда, Айбакты барлап торды.* Ш.Маннур

**Барлап утыру** *к.* **барлап яту.** *Сәнгать вакчыл түгел, акчаның сукыр тиенен барлап утырмый.* Т.Галиуллин

**Барлап үтү** *к.* **барлап китү.** *Юл уңаеннан цензорларның да ничек эшләүләрен барлап үтәргә уйладымы икән?..* М.Шаһимәрдәнов

**Барлап чыгу** Бар булганны, бөтенесен дә берәм-берәм, башыннан-ахырына кадәр барлау. *Ә нигә дип, мин сезнең биографиягезне инәсеннән җебенә тикле барлап чыкты дип беләсез?* Г.Ахунов. *Капитан барысын да барлап чыкты.* Тәмуг чәчәге

**Барлап яту** Әле, хәзерге вакытта барлау. *Самохин исә, көнче җан, аның кара тапларын барлап яткан була.* Х.Камалов

**Барлый бару** Һәр очракны барлау

**Барлый башлау** Барларга тотыну. *Ул, Оренбур ягыннан күзен алмыйча, күңеленнән шәһәр белән бәйле истәлекләрен барлый башлады.* Ф.Сафин

**Барлый бирү** Барлауны дәвам итү

**Барлый тору** Һәрберсен бер-бер артлы барлау. *Ул, берәм-берәм, әйберләрен әйтә, ә лейтенант аларны барлый торды.* Н.Әхмәдиев

**Барлый төшү** Бераз барлау

**БАРЛА́У** II *и. к.* **барлама.** *Төн үтеп, яңа көн тугач, безне гадәттәгечә тагын сафка тезеп, барлау үткәрергә булдылар.* М.Әмир

**БАРЛЫ** *с.* **1.** Матди яктан тәэмин ителгән, барлык белән яши торган; малы күп булган. *Хәлле кеше – хәленчә, барлы кеше – барынча.* Мәкаль

**2.** *и. мәгъ.* Бай. *Барлы – барлы белән, ярлы – ярлы белән.* Мәкаль

**3.** *рәв. мәгъ.* Бай, җитеш булып. *Барлы яшәү*

**БА́РЛЫГЫ** *а.* Предметларның җыелмасына бербөтен итеп күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; барысы, барчасы, һәммәсе. *Бу ике полкта барлыгы биш меӊ кеше бар.* Ш.Усманов

**БАРЛЫ́К** I *и.* 1) Берәр нәрсәнең булуы, бар булу сыйфаты; *киресе:* **юклык.** *Тукай үзенең миңа сөйлисе сүзләре барлыгын әйтте.* Ф.Әмирхан. *Ул биеклекләрне яулауда үз хезмәтенең дә өлеше барлыгын сизде.* Н.Хәсәнов. *Мин шунда Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә, кодрәтенең киңлегенә тулысынча ышандым.* Сөембикә. *Россия Федерациясе Пенсия фондыннан күпме акчагыз барлыгы, дөресрәге, пенсиягезнең тупланма өлеше турында мәгълүмат язылган хат-кәгазьләрне инде барыгыз да алгандыр, мөгаен.* Сөембикә

2) Байлык, җитешлек, муллык. *Шушы гаиләнең һәр баласы тормышта үз юлын тапты, матур гаилә корды, өй җиткезде, барлыкта, муллыкта яшиләр.* Ә.Галиева

3) Нәрсәгә дә булса бөтен көчне, белемне, тәҗрибәне һәм тырышлыкны бергә туплаган булдыклылык. *Эшкә бөтен барлыгын бирү*

4) Чынбарлык, яшәеш. *Тормыш өзгәләнә, кайный бөтен барлык. Мин генә тик юаш, тып-тыныч.* Н.Исәнбәт

5) *күч.* Җан, тән, эч, күңел. *Бөтен барлыгым белән сизеп торам.* Р.Ишморат. *Әй Туган җир! Туган җир! Барлыгыма сыйган кадәр бар яхшылык җыйган җир!* Р.Фәйзуллин. *Сөю хисе, йөрәк төбеннән күтәрелеп, аның бөтен тәненә таралды, бөтен барлыгын яулап алды.* М.Хәсәнов

6) *лингв.* Әйтелгәннең булганлыгын, булуын раслый торган грамматик форма; *киресе*: **юклык**. *Барлыкта төрләнү*

**БА́РЛЫК** II *а.* Предметларның җыелмасына бербөтен итеп күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; бар, барча, һәммә. *Көлемсәрне тирә-яктагы барлык нәрсә иркәли, ихтирам итә иде кебек.* М.Хәсәнов. *Шуңа күрә дә монда барлык төр ерткычлар, киек кошлар, курыкмыйча, үзләренә оя ясыйлар, бала чыгаралар, бала үстерәләр иде.* Н.Фәттах. *Анда Россиянең барлык төбәкләреннән һәм алтмыштан артык илдән меңнән артык делегат катнашты.* Сөембикә

◊ **Барлык педальләргә басу** Бөтен көчкә тырышу, барлык мөмкинлекләрдән дә файдалану

**БАРЛЫККА́ КИЛҮ** *ф.* Яралу, туу, ясалу; хасил булу. *Барлыкка килгән катнашманы 1 см калынлыкта марля-салфеткага ягып, тәнгә бәйләгез.* Сөембикә. *Йөзләрендә бәхет чаткылары барлыкка килә.* Мәйдан

**БАРЛЫКЛЫ** *с.* Хәлле, маллы, бай. *Барлыклы кеше*

**БАРЛЫ́-КӨРЛЕ** *с.* Хәлле, бай тормышлы. *Ул көнне солдатларга бу дөньяда ук җәннәт булды. Җомгадан чыгышка, байлар, барлы-көрлерәкләр бөтенесен чәйгә алдылар.* Г.Гобәй

**БАРЛЫ́К-ЮКЛЫК** *и. лингв.* Сүздән аңлашылган төшенчәнең чынбарлыкта булу-булмавын белдерә торган грамматик категория. *Фигыльдә барлык-юклык – гомуми грамматик категория, ул, кайбер искәрмәләрне исәпкә алмаганда, барлык фигыль формалары – һәм затланышлы, һәм затланышсыз фигыльләр өчен хас.* Ф.Хисамова

**БАРЛЫ́-ЮКЛЫ** *с.* 1) Игътибар итмәслек, кечкенә, аз, җитәрлек булмаган; аз-маз. *Башының үтереп чатнавы гына барлы-юклы акылын җыярга мәҗбүр итте.* К.Миңлебаев. *Ул аны тапкан, үстергән, үз авызыннан өзеп, барлы-юклы ризык-нигъмәте белән туендырган, үзе кимичә киендергән.* Н.Хәсәнов. *Җитмәсә тагын, шул барлы-юклы өч бәпкәне сакларга әни мине китереп тыкты.* Ф.Хөсни

2) Начар, бердәнбер, бик тузган. *Җитмәсә, нәкъ шул вакыт үзебезнең барлы-юклы орудиебез дә атудан туктады.* А.Шамов. *Дулкын ничә тапкыр күмеп киткәндер, барлы-юклы кием чыланды, колакларга су тулды.* Тәмуг чәчәге

**БАРМАК** *и.* 1) Кешенең аяк, кул очында, хәрәкәтләндереп була торган бишәр капшау һәм тоту әгъзасы. *Бармак белән иҗек санамадым, Утырмадым каләм кимереп.* К.Булатова. *Тырнагы каерылып төшкән, бармакларының тиресе-ите суелып беткән.* З.Фәтхетдинов. *Баш бармак бау ишә, Имән бармак имән кисә, Урта бармак утын яра, Атсыз бармак ат җигә, Чәнти бармак чәй эчә.* Бармак уены

2) Умырткалы хайваннарның аяк, тәпи очларындагы өч-биш данәдә тырнаклы чуксыман әгъзалары. *Билгеле булганча, тавык дүрт бармаклы. Ә картайган саен, бишенче бармак үсә башлый.* С.Рәфиков

3) Бияләйнең, перчатканың кул бармагына кидерелә торган өлеше; бармакча. *Алар [күзләр] урынына, уң яктагы энәгә соры йомгактан яңадан 10 күз җыялар. Шулай итеп, баш бармак урыны ясала.* Йорт эшләре

4) Музыка коралындагы тел, төймә, клавиш. *Анда мин беренче мәртәбә пианино күрдем һәм, музыка мәктәбенең мөдире күрмәгәндә генә, пианино бармакларына баса башладым.* Һ.Такташ

5) *тех.* Машина һәм механизмнарның төрле таякчыклар рәвешендәге детале. *[Сафа:] Җиде данә цилиндр, йөз илле данә поршень балдаклары, кырык данә поршень бармаклары --- дип, запас частьларны санап китте.* Х.Госман

6) Мулине, тамбур җебе кебек җепләрне үлчәү берәмлеге итеп йөртелгән кечкенә киләп. *[Галиябану:] Әтигә ике генә бармак тамбур җебе алырга кушсам, орышыр микән?* М.Фәйзи

7) *күч.* Кагылышы булу, мөнәсәбәт, кемдер ясаган йогынты. *Бу афәтләрне тудырган иблис мәлгуньнең каһәрле бармагы талды.* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Мәкерле эш. *Аларның [Бәйдек байларының] бармагы шулай советка каршы тәмәке белән кызыктыруга хәтле барып җитте.* Г.Толымбай

◊ **(Үз) бармагы аркылы карау** Үзенчә уйлап эш итү, үзе белгәнчә эшләү. *Бөтен нәрсәне үз бармагы аркылы гына карарга өйрәнгән Галимә киңәше Хәлимгә йогармы?* Г.Гали. **Бармагы батмау** Нинди дә булса эшкә көче җитмәү, аны башкарып чыга алмау. **Бармагын чәйни** Эше барып чыкмаганнан, уңышсызлыктан үзен-үзе «ашау», үкенү. **Бармагыңны йотарсың** Бик тәмле. **Бармагы уйнау** Астыртын эш йөртү. *Ул [Яңгура] үзе беркайчан да көрәшнең алгы планына чыкмады, әмма һәр җирдә аның бармагы уйнады.* Г.Әпсәләмов. **Бармагы үзенә кәкре, бармагы үз ягына бөгелә** Иң элек үз мәнфәгатен алга сөрү, үз хәстәрен генә күрү, үз файдасына эшләү турында. *Менә тагын бер тип – Сибгатуллин. Бармагы үзенә таба кәкре, шәхси интереслар – беренче планда.* Г.Иделле. **(Үз) бармагы шикелле белү** Бик якын таныш булу, яхшы белү. *Мин аларны [кулакларны] бармагым шикелле беләм.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Бармак арасыннан агып бетү** Кысып кына тотканда да, акчаның яки берәр нәрсәнең күзгә күренмичә юкка чыгуы. **Бармак арасыннан кысу** Бик чамалап тоту, саранлану. *Сәхап --- ашлыкны азлап-азлап, бармак арасыннан кысып чыгарып кына --- тапшыра иде.* С.Рафиков. **Бармак аша (үтә) карау** Бер-бер эшкә салкын, илтифатсыз карау, аны әһәмияткә алмау, игътибарсыз калдыру. *Ул эшкә дә хәзер бармак аша карый башлады.* М.Җәлил. **Бармак башыдай, бармак башы кадәр (хәтле)** Кечкенә, вак; аз гына. *Хәлим --- ипигә тоз сипте, бармак башы кадәр генәсен сындырып капты.* Г.Гобәй. **Бармак белән дә чиртмәү** Кыерсытмау, җәберләмәү. **Бармак белән санарлык** Күп түгел, бик аз санда. *Авыл бәләкәй иде, андагы торак йортлар бармак белән генә санарлык иде.* Н.Фәттах. **Бармак буе (буйлыгы)** Бик кечкенә, бик кыска. *Зыя үзе бармак буе гына булса да, куллары [кубыз уйнарга] бик җиңел килә.* Г.Ибраһимов. **Бармак имеп (суырып) яту** Эшсез, тик яту. **Бармак исәбен (дә) белмәү** Үтә надан, аңсыз. **Бар-**

**мак йөртү (йөрү)** Берәр яшерен йогынты ясау (ясалу); астыртын эш итү. *Вәли бай, җир эшләре идарәсендәге агентлары аркылы бармак йөртеп, [совхозның] бөтен байлыгын --- суырып яткан.* Г.Ибраһимов *Соловкига озатырлар, дип куркышып торганда, Салахиев кайлардадыр бармак йөртте дә, бай котылып калды.* Г.Ибраһимов. **Бармакка бармак та сукмау** Бернәрсә дә эшләмәү, тик яту. *[Ялкау] Уңыш көтеп, тыныч ятмакта, Бармакны да сукмый бармакка.* Г.Афзал. **Бармакка (бармак башына) урарлык (чорнарлык) та юк (урарга да җитми)** Бик аз күләмдә, җитәрлек түгел. – *Кырыкка җиттең инде, бармакка чорнарлык та акылың юк икән, – дип сөйләнә-сөйләнә, Гөлҗамал кибетнең ишекле ягына юнәлде.* Г.Сәгыйров. **Бармакка урау (чорнау)** Алдау, юләргә калдыру. **Бармакны авызга кабу** Аптырап яки хәйран калып карап тору. *Бу мунчаны күргән һәрбер кеше, гаҗәпләнүдән нишләргә белмичә, бармакларын авызларына кабып, хәйран булып торырлар иде.* К.Насыйри. **Бармак селкү, бармак янау** Кисәтү, куркыту. *Милиционер, бәйрәм көн булмаса, штраф чәпи идем, ярый, бу юлга калып торсын, миннән булсын яхшылык, дигәндәй, елмаеп, бармак янады.* Р.Вәлиев. *[Татар] Бармагын селкеп, сүгеп: «Кайтып керерсең өйгә!» – ди.* М.Гафури. **Бармак сыймас җиргә сыйрак тыгу** Мөмкин булмаган җиргә көч белән керергә, баш тыгарга тырышу. **Бармакта (бармак очында) биетү (уйнату)** Кешене тәмам буйсындырып тоту, үзе теләгәнчә йөртү. *[Исмәгыйль:] Мин Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсезме?* М.Фәйзи. **Бармактан суыру** Уйлап чыгарып, юкны бар итеп сөйләү яки язу. **Бармак тешләп калу** Табышны, уңышны кулдан ычкындыруга үкенү. **Бармак тешләү** Аптырап тору, үкенү, белмәгәнлектән, эндәшми тору, аптырап калу, нишләргә белмәү. *Белгән – белгәнен эшләр, белмәгән – бармагын тешләр.* Мәкаль. **Бармак төртеп күрсәтү** Мыскыллап күрсәтү, хурлыкка калдыру. *Беләм, хәзер бар да бармак төртеп Көлә торгандыр... «Гәрәй – бозау», «Гәрәй – җебегән хатын» Дия торгандыр.* М.Җәлил. **Бармак уены уйнау** Кешене шаярту. **Бармак чуты** Кара хисап. *Зур-зур каралтыларны, артезиан коесы кебек катлаулы биналарны бармак чуты һәм күз чамасы белән генә эшләп булмый.* Г.Ахунов. **Бармак хисабына да тулмый** Бик аз. **Бармак шартлатып** Курыкмыйча, искә дә алмыйча, һич шикләнүсез. *Бу шахтада сикерә-сикерә, бармак шартлатып эшләргә була. Менә җир асты челтәрләнгәч, хәтәргә әйләнә.* М.Гафури

**БАРМА́К БАСЫМЫ** *и.* Бер бармак баскан урын кадәрле ара озынлыгы үлчәме. *Ике кашың арасы – Бармак басым арасы...* Жыр

**БАРМА́К БАШЫ** *и.* 1) Бармакның өске беренче буыны. *Кул коралы – бармак, Бармак башы – тырнак, Тырнак башы – уймак, Аны да оста тапкан уйлап.* Н.Исәнбәт

2) Бик аз, кечкенә генә күләмле. *Кунак шуннан коймакка кулын да суза алмаган. Билгеле инде кемнең, бармак башы хәтле коймак ашап, бирән исемен аласы килсен.* Н.Исәнбәт

**БАРМА́К БИТЕ** *и.* Бармакның тырнакка каршы кабарынкы ягы. *Башта – кызның кул аркасын, аннары, әкрен генә әйләндереп, уч төбен, бармак битләрен үбеп чыкты.* Р.Кәрами. *Җамал апа тиз-тиз орчык эрли, Төкереп ала бармак битенә.* Н.Баян

**БАРМА́К ИЛЛЕ** *и.* Бер бармак киңлегендәге озынлык үлчәме. *Шуннан егет өстәл янына утыра да машинаны борып җибәрә. Ярты сәгать эчендә ике бармак илле генә [акча белән] тулмый кала тартма.* Әкият

**БАРМАКЛАНДЫРЫП** *рәв.* Бармаклар рәвешенә китереп, бармаксыман, бармаклар шикелле итеп, бармакларга охшатып. *Каргалыда тышкы яктан бармакландырып буена сырган, көмеш каптырмалы бишмәт әзерлиләр.* Ш.Мөхәммәдев

**БАРМАКЛЫ** *с.* 1) Бармакчалары булган; бармагы булган. *Шуның өстенә укытучысы – нечкә аяклы, чандыр яңаклы, шүрәле бармагыдай нәзек озын бармаклы ир уртасы бер кеше.* М.Мәһдиев

2) Бармакка, киләпкә салынган. *Бармаклы мулинене --- кәтүккә урау өчен, башта аны кулга киертеп сүтәләр.* Йорт эшләре

**БАРМА́К САНАШ(ЛЫ)** *и.* Кулдагы бармакларны бөгеп, такмаклап саный торган уен. *Яшь килен (Гөлйөзем) сәкегә утырган, бармак санаш уйнаган кызларны карап утыра.* Ф.Бурнаш

**БАРМА́К ХИСАБЫ** *и.* Унтугыз иҗекле силлабик шигырь үлчәме. *Безнең төрки телләренең төп хосусияте буенча, бармак хисабы вәзеннәрен тоту белән бергә, Бабичта, вәзен туры китерү өчен, басымнарны --- күчерү бөтенләй юк диярлек.* Г.Ибраһимов

**БАРМАКЧА** *и.* 1) Бияләй һәм перчатканың бармакка аерым кидерелә торган өлеше. *Имән бармак өчен, юри шулай иң азакка калдырып, берүзенә аерым бармакча бәйләнә.* Р.Төхфәтуллин

2) *сир.* Уен коралының клавишы, теле, бармагы. *Бертөркем яшьләр мәйдан уртасында алка ясаганнар да, сигез бармакчалы гармун көенә кушылып, вак ташлы җир битен таптыйлар.* Р.Ильяс

**БАРМАКЧЫК** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан, яфраклары эллипс формасында булган, эре чәчәкле, сары, кызыл сары, җете кызыл төсләрдәге күпьеллык яки ике еллык дару үсемлеге; уймак чәчәк; *русчасы:* **наперстянка, дигиталис**

**БА́РМЕН** *и. ингл.* Биек өстәл артында торып, кабымлыклар, эчемлекләр сатучы; барда хезмәт күрсәтүче; бар хуҗасы. *Жаннага ым какты, шундук бармен, подноста, йөгертеп кенә, «Абсолют» китерде.* Х.Мөдәррисова

**БАРНАГЫЛ** *и. тар.* Екатерина II заманында Барнагыл (Барнаул) шәһәрендә сугылган өч тиенлек бакыр тәңкә. *Эш хакын атлыга – өч барнагыл, җәяүлегә – ике барнагыл, заводта үз гомеренә эшче булып калучыларга берәр барнагыл артыграк бирәләр.* А.Таһиров

**БАРНА́У** *и. сөйл. к.* **барнагыл** *[Иван Иванович:] Әле яңадан бер барнау акча җитми.* Ә.Фәйзи

**БАРО́ГРАФ** *и. гр.* Атмосфера басымы үзгәрешен автомат рәвештә язып

бара торган прибор. *Барограф текә итеп аска төшеп килгән атмосфера басымын сыза иде*. М.Юныс

**БАРОКА́МЕРА** *и. гр.-лат.* Атмосфераны сыегайту яки куерту өчен җайланган герметик камера. *Соңгы чиккә җиткән физик күнегүләр, барокамерада узган..., парашюттан сикерү, хәрби самолётларда йөзләгән..., космоста очраячак бөтен кыенлыкларны татып карау...* Р.Миңнуллин

**БАРО́ККО** *и. ит.* XVI–XVIII йөзләрдә, Көнбатыш Европа сәнгатендә артык купшы, бизәкләр белән чуарланган архетиктура стиле. *Барокко тибында эшләнгән тәрәзәләрдән чиркәүнең алтын гөмбәзе күренә.* М.Галиев. *Бер ягыннан соңгы готика стиле карап торса, икенче ягы – классик барокко.* З.Фәтхетдинов

**БАРО́МЕТР** *и. гр.* 1) Атмосфера басымын үлчәү приборы. *Вәзыйх сумкасындагы приборны кат-кат карады. Барометр теле төшә, әмма болытлар бик сирәк.* Б.Камалов. *Һава шартларын барометрдай сизгән кебек, йөрәге кага башлады.* Н.Хәсәнәв

2) *күч.* Нинди дә булса бер тирәлекнең гомуми хәлен характерлаучы атама. *Уйлап карасаң, «Җидегән чишмә» җәмгыятебезнең алдан күрә торган сизгер бер барометры булган түгелме соң?!* Р.Хисмәтуллин

**БАРОН** *и. фр. тар.* 1) Урта гасырларда Көнбатыш Европада корольнең турыдан-туры вассалы. *Бароннар йорты башына Батраклар байрак кадый.* Х.Туфан

2) Көнбатыш Европада дворяннарның графтан түбәнрәк титулы. *Барон кебек, урынына барып утыра да бармагы белән генә чакыра.* Ә.Хәбибуллин

**БА́РРЕЛЬ** *и. ингл.* АКШ, Англия һәм кайбер башка илләрдә бөртекле һәм сыек әйберләрнең үлчәү берәмлеге. *Чит илдән кергән баррель, фут һ.б. һәм «иске» пот, кадак кебек үлчәү берәмлекләрен бүгенге укучыга аңлатып бирү хәерлерәк.* М.Вәлиев

**БАРРИКА́ДА** *и. фр.* 1) Урам сугышлары вакытында төрле әйберләрдән өеп ясалган оборона тоту, һөҗүмне тоткарлау ныгытмасы. *Халык баррикадаларда кан койган, революция өчен үзенең иң батыр улларын корбан иткән.* И.Гази

2) *күч.* Юлдагы тоткарлык, киртә. *Бик күп йортлар җимерелгән, урамнар баррикадалар белән буылган.* Г.Әпсәләмов

◊ **Баррикаданың каршы ягында** Дошманнар лагеренда, дошманнар ягында

**БАРС** *и. к.* **барыс**. *Бәлкем, барс яки бүре тотып ашагандыр?..* М.Госманов. *Барслар исә җилкәгә ятып тау шуа.* Кызыклар дөньсында

**БА́РСЫ** *а. к.* **барысы**. *Кара урман... Бишәр гасыр үскән великаннар, барсы калын, барсы мәһабәт.* Ш.Мөдәррис. *Әмма Кремль администрациясендә әлеге юнәлештәге эшләрнең барсы да ал да гөл генә бармый.* Татарстан

**БА́РТЕР** *и. ингл.* Сәүдә итүнең, акча түләмичә, үзара әйберләр алмашуга нигезләнгән төре; товарга товар алмашы. *Дөрес, сездән бартерга алган тауарларның күбесе, ихтыяҗ тапмыйча, складта яталар.* Т.Галиуллин. *Завод кибетеннән, шулай ук яздырып, ипи, яшелчә, консервы ише ризык алып була. Аларны җитәкчеләр бартерга, ягъни станоккамы, башка кирәк-яраккамы алыштырып ала.* М.Маликова

**БАРУ** *ф.* **1.** 1) Аяклар белән атлап, юнәлешле хәрәкәт итү. *Юл читендә ялгыз нарат кебек калдың басып, Кайтыр өчен китеп барам синнән саубуллашып.* Ш.Таһирова. *Җәяү бару. Арба артыннан бару*

2) Гомумән хәрәкәт итү; пространствода хәрәкәт итү, күчү. *Торналар китеп бара.* Р.Фәйзуллин

3) Берәр җиргә юнәлү, шуңа җитү, шуның янына килү. *Шулай итеп, Тимер Буга малай чакта ук әле, Иләмән, ат менеп, Болгар каласына китеп барды.* Р.Зәйдулла. *Нәрсәгә «скорый»... Врачка үзем дә бара алам. Кирәксә...* М.Маликова

4) Кемнең дә булса каршына (янына) килү. *Чикерткәнең карыны ачкач, күршесе кырмыскага барды.* М.Гафури. *Шуннан тавыш чыгаралар, бөтен авыл белән, карт алпавытка баралар.* Т.Гыйззәт

5) Нинди дә булса эш башкару; билгеле бер нәрсәне, мөмкинлекне файдалану максаты белән, берәр якка юнәлү, юлга чыгу. *Мин хәзер дә барам шул урманга, сандугачлар тавышын тыңларга.* Ә.Ерикәй. *Мин кар суына барам.* М.Маликова

6) Дәвамлы рәвештә башкарылу, сузылу. *Өч-дүрт гаилә башлыгының берсе дә, быел мин түлим әле, әбзәй, дип авыз ачып әйтми; укулар шул көе бара да бара...* К.Миңлебаев. *Кыскасы, без монда төп кыйссага якынайганнан-якыная барабыз...* Ф.Хөсни. *Таулар бар, сулар бар дөньяда, Еракка-еракка юл бара...* Г.Афзал

7) Нинди дә булса эш башкарылу, эшләнү, булу, үтәлү. *Батырның маҗаралары Ак елан патшалык иткән еланнар дөньясында – Җир асты патшалыгында бара.* Ф.Урманче. *Мөхәммәтшакирның сәүдә эшләре әйбәт бара.* Р.Гали

8) Ярау, килешү; ярарлык яки килешерлек булу; йөзгә килешү, туры килү. *Син укытучылык эшен ташла, туган, син аны булдыра да алмыйсыңдыр, анңары бармый да ул синңа.* Г.Галиев. *Эшләпәсе йөзенә бара. Күлмәге гәүдәсенә бара.*

9) Гаилә кору, тормышка чыгу. *Бармасаң – барасы була, барсаң – баласы була. Баласы булгач, багасы була.* Такмак

10) Башкалар әйткәнгә карамый, үзенә ошаганча гына эш итүен дәвам итәргә тартынмау, кыенсынмау; ярамаганны эшләргә батырчылык итү. – *Ни өчен сез, персонально җаваплы кеше, шундый эшкә бардыгыз? – диде Мөхәммәтҗанов.* А.Расих

11) Кемне дә нәрсәгә дә булса тәмам ышандырып, уйлаганын, билгеле бер караштa торуын икърар итеп яки киресенчә раслап, кат-кат әйтеп тору. *– Димәк, сез «Будринны күрмәдем дә, сөйләшмәдем дә» дип барасыз инде? – диде прокурор.* А.Гыйләҗев. *Син бу эшне «булмый» дип барасың инде*

12) *-лык/-лек кушымчалы сүзләр белән килгәндә* аерым гадәт, холык, характер галәмәтләре күрсәтүне белдерә. *Ай энем, яшьлегеңә барасың.* М.Фәйзи

13) Ничә дә булса яшькә якынлашу, җитү, шул яшьтә булу. *Унсигезенче яше белән бара*

14) Билгеле бер вакытта (сезонда) сәхнәдә, экранда фильм, пьеса, спектакль һ.б. куелу, уйналу. *«Булмас димә, дөнья бу» комедиясе ике ел Әлмәт татар дәүләт театрында уңыш белән бара.* Д.Салихов

15) *куч.* Нинди дә булса ашамлыкның, эчемлекнең организм тарафыннан кабул ителүе, үтү. *Ул [Фәрит] бик аз ашады. Аш тамагына бармады.* А.Шамов

**2. бар** *кер. сүз мәгъ. боерык ф. форм.* 1) Шулай ит, шулай эшләп кара, мәгънәсендә. – *Бар, белеп керегез әле берәрегез, – ди ул.* К.Миңлебаев

2) Һич булдырып булмый, мәгънәсендә. *Ул юләр хатын, кыйбат саттым, дип, сөенеп йөргән була тагын, алдарсың, бар, Малик карунны.* И.Гази

**3.** *ярд. ф. функ. хәл фигыльләрнең -ып, -еп, -п формасы белән килеп,* төп мәгънәгә түбәндәге яңа төсмерләр өсти: 1) Күбесенчә хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр белән килеп, юнәлешле яки нәтиҗәле хәрәкәт төсмере бирә. *Урамнан узып бара, кашыннан күзе кара.* Җыр

2) Күчемле фигыльләр белән килеп, эзлеклелек, дәвамлылык төсмере бирә. *Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем Була миңа юл күрсәтүче йолдызым.* Г.Тукай

3) Нindидер бер моментка, чиккә якынлашуны белдерә. *Ә үзе япа-ялгыз, җитмәсә тагын, көн кичкә авышып бара, нык кына буранлап та тора иде.* Ф.Хөсни

4) *-а/-ә һәм -ый/-и формасы белән килеп,* көчәеп дәвам итү. *Арта бара бүрәнәләр, зурая бара бура.* Ә.Ерикәй // *-ганнан... -а, -ый, -гәннән... -и парлы формасыннан соң да* шул ук мәгънә төсмерен көчәйтеп килә. *Юл начарланганнан-начарлана барып, чиге күренмәгән баткаклыкка әверелде.* К.Нәҗми. *Авылга якынайганнан-якыная барабыз.* Ф.Хөсни

5) Даими кабатланып дәвам итүне белдерә. *Дөнья малы – дуңгыз каны, килә бара, китә бара.* Мәкаль

6) **барып** *хәл ф. форм.* Хәрәкәт фигыльләре белән килгәндә, күрсәтелгән эш-хәрәкәтнең билгеле бер юнәлештә башкарылуын белдерә. *[Чабышкы ат] Ычкынып киткән дә улакка салып куйган [калган] суны барып эчкән.* М.Гали

◊ **Барып әйтү** Әләкләү, җиткерү, сүз йөртү. *Иртәгә үк волостька барып әйтәм мин бу эшләрне, алай итеп, чәчү кампаниясенә аяк чалмасыннар!* М.Гали. **Барып егылу** Ярдәм сорап мөрәҗәгать итү. *Василий белән Юрий да ханның аягына барып егылалар.* М.Әмирханов. **Барып керү** Хәтәр эшкә тап булу, ярамаган эшкә эләгү. *Сизми калсаң, көячәгеn белми, Барып керә хәзер ялкынга ул.* Х.Әюп. **Барып сугылу** Аптырап йөргән вакытта, ярдәм өмет итеп, тәвәккәлләп барып керү. *Авыр тойгылар белән, мин бу йортның капкасына барып сугылдым.* Ф.Әмирхан. **Барып терәлү** Нәрсәгә дә булса бәйле булып, тоткарланып калу. **Барып тию** Берәр кешенең күңеленә кагылу. *Кар, дисәң, каргага барып тия, тор, дисәң – торнага.* Мәкаль. **Барып тоташу** Билгеле эш яки кеше белән бәйләнешле булу. *Шулай итеп, автор (хикәяләүче) кайгысы милләтнең караңгылыкта яшәвенә барып тоташа.* Ф.Әмирхан. **Барып чыгу** 1) Азу, соңгы чиккә җитеп тәртипсезләнү; начарлыкның соң дәрәҗәсенә җитү. *Ай энем, энем! Шул Әптелмән малаена иярсәң, барып чыгарсың әле.* С.Шакир. 2) Булдыру, булдыклылык җитү. *Әгәр инде бу эш барып чыкмаса, алтын биреп, үзләрен сатып алырга гына кала безгә...* З.Зәйнуллин. *Барып чыкмаса, бик ачуланмассың, яме?* Т.Галиуллин. *Барып чыга торган эш бу...* Ә.Еники

**Бара башлау** Барырга керешү. *Такырны артта калдырып, үзәннән бара башлагач, машина тагын шып туктады.* А.Гыйләҗев

**Бара бирү** Үз уңаена баруын дәвам итү. *Пошынма син, башың имә борчудан, Бара бир нык басып туры юлыңнан.* Г.Бәширов. --- *«татар» дип бирелгән исмебез тарихның бу тикшерүләренә илтифатсыз (рәвештә) бара бирә.* Г.Ибраһимов

**Бара төшү** Бераз бару. *Олы юлдан бара төшкәч, сулга киткән басу юлы булыр*

**Барып җитү** 1) Билгеле юл, билгеле ара үтеп, максат итеп куелган урынга килү. *Көн бара, төн бара егет, бара торгач, зур бер калага барып җитә.* Әкият. *Барып җиттек, эзләп таптык багучыны.* Ф.Сафин. *Ашыкмыйча гына, бакчага барып җиттек.* К.Миңлебаев

2) *куч.* Ишетелү, билгеле булу, ирешү. *Фронтта бит бер солдатта бер бет табылса, хәбәр шундук Генштабка барып җитә, һәм приказ чыга иде.* М.Мәһдиев. *Тыштан юка күренсә дә, асылы калын бу китап рус һәм башка халыкларның зыялыларына да барып җитте.* В.Имамов

3) *куч.* Аңлашылу, ачыклану. *Бу фикер халыкка тиз барып җитте.* Г.Әпсәләмов. *Ул көнне күңеле дулкынланган иде шул Аюханның. Шуңадыр әбиләренең хәбәре дә аңына ук барып җитмәгән, ә кагылып кына киткәндер.* Г.Якупова

4) *куч.* Начар якка китү; начар эш эшләү. *Менә шушы канәгатьлек, баратора, матур ялганга барып җитте.* Т.Миңнуллин. *Шул ачуында ул хәтта Аллага тел тидерүгә хәтле барып җитә.* Г.Камал

**Барып йөрү** Берәр җиргә баргалап тору, һәрвакыт, гел бару. *Имеш, Шабаев язганча ук түгел инде. Имеш, онытмаганнар, барып йөргәннәр...* Ф.Яруллин. *Казан педагогия институтының чит телләр факультетында төзелгән «Шәфкать» отряды 2 нче балалар йортына барып йөри.* Р.Миңнуллин

**Барып карау** Төрлечә сынау, мөмкинлекләрдән файдалану. *Хәмәт янына барып карау телә ге аның башына да килмәдe.* М.Вәли-Барҗылы. *Башына әрекмән яфрагы каплап та карады, хәрби полигонда йөргәндәге кебек, аркасындагы юл капчыгына агач ботаклары кадап та барып карады, барыбер чиләнең утлы сулышыннан котыла алмады.* Г.Гыйльманов. *Башта исән булган, юлдагы кешеләр больницага да алып барып караганнар.* Д.Бүләков

**БАРХАН** *и. төрки* Чүлләрдә, ярымчүлләрдә һәм далаларда җил күчереп

йөрткәннән барлыкка килгән, дулкын сыман ком калкулыклары. *Җил барханнарны бик тиз күчерә бит.* А.Тимергалин. *Барханнарда йөрдем – көймәдем, өшемәдем бозлар иләндә.* Р.Фәйзуллин. *Тау астыннан елгага таба, яшел барханнар кебек тигез сырлар ясап, печән покослары сузылган.* Р.Хафизова

**БА́РХАТ** *и. нем.<гар. к.* **бәрхет.** *Бархат күлмәккә кыска итәк килешми, дидем. Җитмәсә, сез юан, дидем, өлкән, дидем.* Т.Миңнуллин

**БА́РЧА** *а.* 1) *к.* **барлык.** *Дөньяның әйдәп баручы барча театрлары шушы принципка таянып эш итәләр.* В.Шәрипов

2) Предметларга, затларга яки аларның төркемнәренә аерып, аерым-аерым күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; һәммәсе, һәркем, һәрнәрсә. *Туй – тиешленеке, бәйрәм – барчаныкы.* Мәкаль. *Күк, җир, тереклек, үсемлекләр – барчасы аның иркенә буйсынып ята.* Ә.Гаффар

**БАРЧУК** *и. рус гади с.* 1) Бай баласы, яшь барин. *Аның улы Аскәр – барчук, генерал малае.* Р.Батулла

2) *күч.* Эш сөймәс аксөяк, ялкау кеше. *Гөлсем апа балаларын япь-яшьтән эшкә күнектерде: «Әйдә, барчук булып үсмәсеннәр әле».* Г.Гобәй

**БА́РЩИНА** *и. рус тар.* 1) Алпавыт хуҗалыгында крестьяннарның мәҗбүри һәм түләүсез хезмәте. *Алар [вак чиновниклар] «дәүләт дисәтинәләре»ндә барщина эшләрен оештыралар, крестьян йөкләмәләре күләмен билгелиләр, натуралата оброк җыялар.* А.Әминов. *Барщина вакытында крестьян, атнаның билгеле бер өлешен, үзенең җитештерү кораллары белән – хуҗа имениесендә, ә атнаның калган көннәрендә үз хуҗалыгында эшләгән.* Политэкономия

2) *күч. сөйл.* Хезмәт хакы аз түләнелә торган мәҗбүри хезмәт турында

**БАРЫ** I *а. к.* **барысы**. *Хуҗаның анда эше юк. Барыннан йөри күлеп.* Ш.Маннапов

**БАРЫ** II *терк.* Каршылык мөнәсәбәтен чикләү төсмере белән белдерә; нибары, бары тик, фәкать; тик. *Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары, аз гына җылына төшкән күзләрен тугашка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.* Ә.Еники. *Бары тик наратлар, чыршылар һәм ак чыршылар гына яшел ылысларын коймыйлар.* Г.Әпсәләмов

**БА́РЫБЕР** *рәв.* 1) Бернәрсәгә дә карамастан, берничек тә тукталып калмыйча, ничек тә. *Атларын да бирде Мисбахетдин карт, сыерын да тапшырды, шулай да аны, барыбер, авылдан сөрделәр.* Р.Батулла. *Барам, Сания! Кара Ком чүлен җәяү кичәсе булса да, барыбер китәм!* Г.Бәширов. *Ә чынлыкта авырайдым, Уй-исәп барыбер басты.* Р.Фәйзуллин. *Ләкин тамак барыбер үзенекен итте.* М.Әмирханов

2) Аермасыз, бертөслерәк. *Мөселман булмагач, бәрфараз, һәммәсе урыс инде, барыбер.* Ф.Әмирхан. *Мифтах белән Гобәй, – барыбер, Мәхмүтнең койрыклары.* Ш.Камал. *Ак булса да, кара булса да – минем өчен барыбер.* Казан утлары

**БАРЫМТА** *и. тар.* Күчмә төрки кабиләләрдә бер-берсенең көтүләрен әйдәп кайту максаты белән ясалган талау походы. *Барымта карулы, кире кайтарулы.* Мәкаль. *Калада ул ханның ат абзарына керде, малай чагында ук барымтага йөреп, шаулага әверелә белгән егетнең исен ят атлар сизмәде дә...* Р.Зәйдулла

**БАРЫНДА** *рәв.* Бар чагында, әлегә бар булганда, булган вакытта. *Батыр мәйданда ятмас җан барында.* Н.Исәнбәт

**БАРЫ́НЧА** *рәв.* Күпме бар; мөмкинлек булганча, күпме мөмкин, хәл кадәренчә. *– Өй котлап, мин дә сиңа хәлдә барынча әз-мәз нәрсә китергән булдым, – ди.* Г.Ибраһимов

**БА́РЫНЯ** I *и. рус иск.* 1) Бикә, байбикә

2) Алпавыт хатын

3) *күч. кимс.* «Бикә», җиңел тормыш итүче хатын-кыз турында

**БА́РЫНЯ** II *и. рус* Рус халык биюе һәм көе

**БАРЫС** *и.* 1) Мәчесыманнар семьялыгыннан, Африка һәм Азиядә таралган берничә төр ерткыч хайваннарның гомуми атамасы (юлбарыс, пантера, селәүсен, каплан) // Чуар юлбарыс

2) Татарстан Республикасы гербы: канатлы барыс

3) *астр.* Борынгы Көнчыгыш йолдызнамәсендә алтмыш еллык календарь циклның 12 төрле хайван белән белдерелгән өченче билгесе; шул билгегә туры килгән елда туган кеше. *Барыс елны барын чәч, һич булмаса, тары чәч.* Әйтем. *Барыс елының сигезенче ае, икенче көне иде.* Н.Фәттах

**БА́РЫСЫ** *а.* Предметларның җыелмасына бербөтен итеп күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; бөтенесе, һәммәсе, барчасы. *Һәм бу нигъмәтләр барысы да – Гөлнара өчен, сөеклесен сыйлау өчен иде!* Н.Гыйматдинова. *Барысының да күкрәгендә – бишәр-алтышар йолдыз.* Ә.Исхак. *Барысының да статусы тигез: фәкыйрьләр, эшсезләр, киләчәккә ышанычын югалтканнар.* Мирас

**БАРЫШ** I *и.* 1) Хәрәкәттә булу; йөреш, атлап бару. *Кызның үзенчә купшы итеп, кәз-кәз басыбрак барышында да күңеллелек сизелгән шикелле булды.* Ф.Әмирхан. *Кем икәнлекләре миңа мәгълүм түгел юлчыларның, вакыты-вакыты белән ашыгып-ашыгып вә, вакыты-вакыты белән, ялкау, акрынлап барышлары бу рәхәт онтылуның кайбер дәкыйкаләренә тәртипсезлек кертеп җибәрәләр.* Ф.Әмирхан. *Ул миңа карап алды да мотоцикл барышын әкренәйтте.* Р.Ишморат

2) Юл тоту, юлда булу. *Шаһгалинең төньяктагы сөргеннән кайтып барышы.* Р.Зәйдулла. *Үтеп барышы, имеш.* Ф.Хөсни. *Качып барышлары икән.* Г.Гобәй

3) Процессның характеры, башкарылыш. *Әлеге куелган мәсьәләнең чишелеше Урта Иделдә XIII–XIV гасырларда булып узган этник процессның барышын ачыклау өчен мөһим.* М.Әхмәтҗанов. *Әйе, тикшерү барышы үзенең хәлиткеч ноктасына якынлашып килә.* Р.Мөхәммәтҗан. *Ул һәркөнне эшнең барышларын, чуен чыгышларын тикшерә.* Ш.Маннур. *Гомумән, быел, уку башланганнан бирле, мәктәпкә кергәнегез, дәресләрнең ничек барышы турында сорашканыгыз да юк.* Т.Гыйззәт

4) Эзлеклелек, эзлекле дәвам итү; агыш. *Алар – шул вакыттагы тормышның барышын аңламаган, тормышның агышын иске гореф-гадәтләр белән туктатып була, дип ышанган наданнар.* М.Гафури. *Бөтен дөньяның барышы шушы фольклорга бәйләнгән булып тоела иде.* Юлдаш

5) Нинди дә булса эш яки гамәл дәвамында, шул вакыт эчендә. *Киңәшмә барышында ук, аерым губернаторларны хакимияттән дә читләштерә ул.* Татарстан. *Әлеге очрашу барышында Башкортстан Президентының халык алдында белдерү ясавы аның кандидатурасының яклау табуы турында гөманнарга җирлек тудыра.* Татарстан

6) *Бару* сүзенең, фигыль буларак, башкарулы бәйләнешендә торган, ләкин исемләшкән формасы. *Әйе, әйе, зур гөнаһ эш, Хакның әмеренә каршы барыш.* М.Фәйзи. *Туган җиребезнең алга барышына зур өлеш керткәнегез өчен, барыгызга да чын күңелдән рәхмәт сүзләре җиткерәм.* Мәгърифәт

**БАРЫШ** II *и. сөйл.* Табыш, файда

**БАРЫ́Ш-КЕРЕШ** *җый. и. сөйл.* Хәл белешеп, аралашып, бер-береңә кереп йөрү. *[Бәдриянең] Бибигөл белән алыш-биреше, барыш-кереше юк.* Ш.Мөдәррис

**БАРЫШЛЫ** *рәв.* Барырга мөмкин булган, барырлык. *Кемгә дә ярдәм сорап барышлы түгел: элекке сәүдәгәргә, ярдәм кулын сузам, дип торучы булмаячак.* Ф.Сафин

**БАРЫШЛЫЙ** *рәв.* Узганда, барган уңайда, үткәндә, яныннан узып барганда, юл уңаенда, юл өстендә. *Үтеп барышлый гына дыр, безнең авылга кайтучы түгелдер бу, дип гөманлады печәнчеләр.* М.Әмирханов. *Тирән белемле кеше иде, мәрхүм; Мәскәүгә барышлый, безгә дә кереп кунак булганы бар.* М.Гафури. *Һәрберсенә җылы хисләр белән Елмаямын, үтеп барышлый.* Һ.Такташ

**БАРЫ́ШНИК** *и. рус сөйл.* 1) Файда алу өчен, әйбер хакын арттырып сату белән шөгыльләнүче; алыпсатар. *Барышниклар алар, өстәү бирсәң, хатыннарын да алмаштырырлар.* Г.Толымбай

2) Атлар сату белән шөгыльләнүче. *Янә бер ат барышнигы, Мөхәммәтшага кушылып, шәкертләрне урысча сүкте.* Ш.Мөхәммәдев

**БАРЫ́ШНИКЛЫК** *и. сөйл.* Алыпсатар кәсебе

**БА́РЫШНЯ** *и. рус иск.* 1) Бариннның кияүгә бармаган кызы, бай кызы. *Барышняның әйберләрен күчерергә кирәк, ике егет килсен!..* Г.Ибраһимов

2) *гади с.* Җиткән кыз, чибәр кыз; туташ. *Барышня да бик арыган, йокласын.* А.Шамов. *Ике студент белән бер барышня узып баралар.* Г.Камал. *Монда барышнялар [кызлар] бар бит; алар күрерләр.* Ф.Әмирхан

**БАРЫ́-ЮГЫ** *и.* Бөтен булган әйбер, барлык булган нәрсәләр. *Сине мин яр иттем, барын-югын синең белән бүлешәм, түшәгемә дә бүтән берәүне һич яткырасым юк.* К.Миңлебаев. *Бөтен барым-югым – сезнең күз алдында бит, нишләргә миңа?* Р.Хафизова

**БАРЬЕР** *и. фр.* 1) Спорт ярышларының аерым төрләрендә кулланыла торган нинди дә булса комачау, киртә, планка һ.б.ш. *Спортчы, бөтен барьерларны да үтеп, алга чыкты*

2) Бүлмә эченең бер өлешен аерып куйган, биек булмаган корылма. *Почта хезмәткәре барьер аша бланк бирде. Барьер артына күз салам – өч урындыкны бергә тезгәннәр.* М.Мәһдиев

3) Һәртөрле чикли, тоткарлый торган нәрсә. *Анда, дебаркадер барьеры аша, һаман әле пароходка сикерәләр.* Н.Исәнбәт. *Рәис ни эшләргә белми катып кала, халык шаша, мәҗлеснең тәртибе югала, гөҗ килә, исерек татар сәхнәгә килеп җитә дә бер кулы белән барьер тактасына суга-суга кычкырырга тотына.* Г.Ибраһимов

4) *тар.* Атыш вакытында дуэльдә катнашучылар алдындагы үтеп чыгарга ярамаган чик. *Ул [Мартынов] тиз генә барьерга якынлаша һәм атып җибәрә. Лермонтов бер сүз дә әйтергә өлгерә алмый, --- – киселгән агач кебек, үлән өстенә ава.* Г.Мөхәммәтшин

5) *күч.* Нәрсәне дә булса хәл иткәндә килеп чыккан каршылык, комачау, тоткарлык. *Шушы җаваплы эшне үтәр өчен, аңар никадәр барьерлар кичәргә, никадәр комачауларны үтәргә туры килә.* И.Лобашева

6) *күч.* Демократиягә, иҗтимагый аралашуга комачау тудыра торган рәсми законнар, кагыйдәләр

**БАС** *и. ит.* 1) Ирләрнең иң калын (түбән) тавышы. *Әнә шул тынлыкта әлеге малахай бүрекле, килешсез зур гәүдәле кешенең бас тавышы яңгырады: – Сөйлә, Касыйм дус!* Ф.Хөсни. *Безнең татарда бас – бик сирәк очрый торган байлык.* М.Мәһдиев

2) Күптөрле тавышлы музыкаль әсәрдә иң калын тавыш. *Бас партиясен яшь җырчы башкарды.* Сөембикә

3) Шундый тавышлы җырчы. *Хорның беренче басы*

4) *махс.* Калын регистрлы музыкаль инструмент яки музыкаль инструментның калын регистрлы клавишлары. *Баслары әллә унсигез, әллә егерме дүрт.* М.Мәһдиев. *Соңрак яңа мавыгу – бас-гитара барлыкка килде.* Мәдәни җомга

**БАСА** *и.* 1) Орлык бирми торган ир чәчәкле, аксыл башлы, нәзек сабаклы, сүс ясый торган киндер; ата киндер; *русчасы:* **посконь.** *Ата даны белән кыз китә, баса даны белән сүс китә.* Мәкаль. *Киндер арасына кереп --- киндер басаларының бик шәпләрен генә йолыктык та аларның сүсләрен салдырырга тотындык.* Г.Галиев

2) *диал.* Киндер (үсемлекнең үзе). *«Җәйгә чыксаң, баса җибетергә, җитен чылатырга тилмереп торасың: су табып булмый», – диде бер ак сакаллы карт.* И.Гази

**БАСКАК** *и. тар.* Алтын Урда чорында хан биләмәләрендә салым җыярга куелган отряд башлыгы. *Татарларга буйсынган, татардан башка халык торган олус башындагы кешеләрне «баскак» диләр иде.* Г.Гобәйдуллин. *Баскаклар буйсынган җирләрдәге халыкның санын язып чыгалар, халыктан салым, гошер (малның 1/10 берсе) алалар иде.* Г.Гобәйдуллин. *Болгарилар бирегә монннан җиде йөз еллар элек, татар-монгол баскаклары җәфасыннан чара эзләп килделәр.* Тәмуг чәчәге

**БАСКЕТБОЛ** *и. ингл. спорт* Билгеле бер биеклектә урнаштырылган

тактага беркетелгән челтәрле төпсез кәрзингә туп ташлаудан гыйбарәт командалы спорт уены. *Күрше мәктәптән, баскетбол командасында уйнап йөри.* Р.Вәлиев. *Ниһаять, мин «Уникс» баскетбол командасының баш тренеры белән күзгә-күз очрашып сөйләшә алдым.* Татарстан яшьләре

**БАСКЕТБОЛЧЫ** *и.* Баскетбол уйнаучы спортчы. *Йөртүчесенең буе дисәң – негр баскетболчыларың бер якта торсын!* Т.Галиуллин. *Русия гражданлыгы да булмаган баскетболчыга, әлбәттә инде, түбә кирәк.* Юлдаш

**БАСКЫН** *и. тар.* 1) Талау нияте белән ясалган һөҗүм. *Һиндстан чит ил баскыннары тарафыннан күп мәртәбә талана.* М.Мәхмүтов. *Өч пәһлеван һәрвакыт Ала малымны тартып. Тагын алар иртәнчәк Баскын ясап китәчәк.* Ш.Маннур

2) *диал.* Баскынчы. *Канатланып очкан акбүз атта Баскыннарны кырган.* Н.Арсланов

**БАСКЫНЛЫК** *и.* 1) *к.* **баскын** (*1 мәгъ.*)

2) Золым, җәбер-кысу. *Моннан соң, билгеле, реакция баскынлыгы, жандарм, урядниклар кысрыклыгы башлана.* Ш.Камал

**БАСКЫНЧАК** *и.* 1) *к.* **баскынчы.** *Гражданнар сугышы вакытында Колчак баскынчакларымы, кызыл зәхмәтләрме, хәзер ул хәтлесен бераү дә әйтә алмый...* Т.Галиуллин

2) *диал. к.* **басымчак**

**БАСКЫНЧЫ** *и.* 1) Талау-басу белән шөгыльләнүче бандит, юлбасар. *Баскынчылар, әүвәлгечә, бездән хәрам мал көтә. Табан ялап, сый куймыйбыз – аларны шул өркетә.* Р.Шәфи. *Санаулы минутларда килеп җиткән милиционерлар төркеме баскынчының кулларына богауны бик тиз салалар.* Юлдаш

2) Басып алучы, илбасар. *Илнең бәйсезлеген кайтару өчен, Көнбатыш баскынчыларына – тәре йөртүчеләргә каршы көрәш башлап җибәрә.* С.Сөләйманова. *Мең ел үткәч (дөреслеге шикле), Баскынчылар яла язарлар!* Г.Афзал. *Җирле халык, берничә гасыр дәвамында төрекләр изүе астында яшәп, баскынчылардан яшерен эшләрен, тегеләре сизмәслек итеп, оста гына хәл кылырга өйрәнгән.* Юлдаш

**БАСКЫНЧЫЛЫК** *и.* 1) Баскынчы булып йөрү. *Юлбасарлар алар, безнең кебек, гаделлек эзләп килмәгәннәр. Баскынчылык белән көн күрүчеләр. Казак исемен хурлаучылар.* Т.Нәбиуллин

2) Басып алу, талау, юлбасарлык. *Тулаем алганда, дастанда урыс кенәзләренең баскынчылык сәясәте фаш ителә.* Ф.Урманче

**БАСКЫЧ** *и.* 1) Менгәндә яки төшкәндә басарга рәт-рәт беркетеп тезелгән басма яки аратадан ясалган җайланма. *Өйалдына аяк басу белән, озын баскыч күземә чалынды.* К.Миңлебаев. *Алар, бик матурлап эшләнгән агач баскычтан менеп, өйалдыннан икенче катка күтәрелделәр.* Р.Кәрами. *Гыйльметдин йөгерә-атлый тышка чыкты һәм, бермәлгә баскычта тукталып, тирә-якка күз салды.* Ф.Сафин // Менү һәм төшү өчен бер басмалы җайланма. *Машина баскычы*

2) Текә яки авыш өслектә, менәргә яки төшәргә уңайлы итеп, басмага охшатып ясалган чыгынты, киртләч. *Яр кырыена җиткәч, баскычлы сукмаклардан, калтырана-калтырана, инешкә килде...* Н.Хәсәнәв

3) *күч.* Үсү, үзгәрү, катлаулана бару, кыенлашу, дәрәҗәгә күтәрелүнең аерым этаплары, бер өлеше. *Сүзлекчелек өлкәсендә яңа баскыч – татар теленең яңартылган 4 томлык аңлатмалы сүзлеге.* Н.Хисамов. *Олы алдану кичергәннән соң, ул инде чираттагы шаукымга сагаеп карый, тормыш баскычларыннан күтәрелү өчен, икейөзлелек кылып уйнарга мәҗбүр була.* М.Галиев. *Кәбир әфәнде «Мәгариф»не, инде үтелгән баскыч, шәкертлек мавыгуы, дип кенә карый.* Ә.Фәйзи. *Әхмәтсафа, бераз урысчасы сынату сәбәпле, әзерлек сыйныфының икенче баскычына кабул ителде.* Ф.Сафин

**БАСКЫ́Ч-БАСКЫЧ** *с.* **1.** Киртләчләре бер-бер артлы тезелеп, баскычланып торган, басмалары күп булган. *Чыннан да, алда, еракта ук, баскыч-баскыч биек йортлар, иңнәрен иңгә терәгәндәй, күккә ашканнар.* Н.Хәсәнов. *Чишмәгә баскыч-баскыч юл төшә*

**2.** *рәв. мәгъ.* Баскыч кебек, баскыч рәвешендә, баскыч булып. *Баскыч-баскыч булып түбәнәя барган тауларның маңгайлары шәрәләнгән.* М.Шәрифуллин

**БАСКЫЧЛАНУ** *ф.* Үзеннән-үзе, табигый рәвештә баскычка охшаган киртләр ясалу, киртләчләнү. *Ерак та түгел, комташны киртләп, баскычланып күтәрелгән сукмакны күреп алды һәм алга ыргылды.* Ф.Латыйфи. *Өч яклап тезелгән таулар, катлау-катлау баскычланып, югарыга – болытларга сузылалар.* Г.Ибраһимов

**Баскычлана бару** Торган саен ныграк баскычлану

**Баскычлана башлау** Баскыч сыман киртләчләр барлыкка килергә тотыну

**Баскычлана төшү** Бераз баскычлану

**Баскычланып бетү** Тәмам баскычлану, күп булып, баскычлар ясалу

**Баскычланып тору** Баскычланган хәлгә килү; әле, хәзерге вакытта баскычланып күренү. *Менә ул тау битенә салынган шәһәрнең баскычланып торган өй түбәләре өстеннән түбән – диңгезгә таба очып китте.* С.Баттал

**БАСКЫЧЛА́У** *ф.* Нинди дә булса өслектә, баскычларга охшатып, тезеп, басмалар ясап чыгу, киртләчләү. *Берсеннән югарырак менгезеп, баскычлап беркетелгән такталар өстендә кешеләр тезелешеп утыралар.* Ә.Фәйзи

**Баскычлап бару** 1) Рәттән, бер-бер артлы баскычлау

2) Чылбыр рәвешендә, бер-бер артлы. *Күп нигезле кислоталар диссоциациясе баскычлап бара.* Г.Хисамиев

**Баскычлап бетерү** Тоташ баскычлау

**Баскычлап кую** Алдан ук баскычлар ясау

**Баскычлап тору** Һәрвакыт баскычлау

**Баскычлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр баскычлау

**Баскычлый төшү** Бераз баскычлау

**БА́СМА** *и.* Бизәк төшерү, чәч, каш буяу өчен кулланыла торган, үсемлек-

тән ясалган махсус кара буяу. *Басма белән чәчне буяу*

**БАСМА** I *и.* 1) Баскычның менәргә, төшәргә җәйләнгән аратасы яки киртләче, басмача. *Бер адәм килде дә шул чакта әйләндерде баскычны, Түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште.* Г.Тукай. *Юкарак гәүдәле бу кыз басмага җәһәт кенә менеп басты һәм, ян тәрәзәнең ачылып бетүен дә көтмичә: – Абый, син Казанга барасыңмы? – дип сорады.* М.Хуҗин. *Шуңа күрә текә җиргә һәм баскычтан күтәрелгәндә, туктап, тирән тын алырга, аннары һаваны әкрен генә чыгара барып, 3–4 басмага күтәрелергә кирәк.* Татар мөселман календаре

2) Өйалды баскычы. *Басма астында бала үрдәк, Сибик бодай, симерсен.* Җыр

3) Басып яки утырып тору өчен, бер генә тактадан торган җайланма. *Трактор кыр буенча чәчү машиналарын өстери. Орлык тутырылган ящикның артындагы басмада – чәчүчеләр.* И.Салахов. *Көймә басмасы*

4) Сулык, инеш, баткак, пычрак, сазлык һ.б.ш. җир аша салынган аркылы такта, агач түшәмә; озын булмаган тар күперчек. *Ялт-йолт каранып, капканы ачты да баскыч төбенә хәтле сузылган такта басмадан атлады.* Р.Кәрами. *Кайчандыр тибрәнеп кенә чыккан басма урынындагы күпергә җиткәч, туктамыйча калып буламы соң?!* М.Галиев

5) Ярдан суга кертеп корылган күперчек. *Суга сикерә торган басма өстендә камыш сабагыдай кыз басып тора.* С.Сөләйманова. *Кайсындыр син басма өсләрендә Кер чайкаган чакта кигәнсең.* Ә.Баянов. *Тар басмада ак сөлгеләр юдым.* С.Гәрәева

6) *иск.* Авылларда, кечкенәрәк шәһәрләрдә олы юлның кырыена агачтан салынган түшәмә

7) Көймәдән, пароходтан ярга чыгу өчен куела торган җайланма. *Басмадан күтәрелеп, бер читкә китте дә чемоданын җиргә куйды.* Р.Кәрами

8) Биналар, корылмалар, зур кораблар төзегәндә, төзүчеләргә басып эшләү өчен ясалган корылма. *Ул [Нуруллин], буш вакытларда, төзелеш басмаларының иң югары күперенә менәргә, шуннан торып, тирә-юньне карарга ярата.* А.Шамов

9) Музыка коралының теле, бармак, клавиш. *Гармунчы егетнең бармаклары гармун басмаларында алмашып-алмашып биештеләр.* Т.Госман

**БАСМА** II *и.* **1**. 1) Китап, журнал һ.б.ш. бастырып чыгару эше. *Басманың элекке баш мөхәррирләре – Владимир Шевчук, Римма Ратникова, Әнбәр Кармиев телефон аша «турыдан-туры элемтәдә» басманың, ничек итеп, төрле чорда үз йөзен саклап калуы хакында сөйләделәр*... Татарстан. *Һәр басманың, һәр журналның – үз биографиясе, үз язмышы.* Казан утлары

2) *к.* **басмаханә.** *Мәскәүдә татар телендәге 9 үзәк басма яшәүдән туктый.* Идел

3) Берьюлы бастырып чыгару өчен билгеләнгән яки бастырылган текст. *Хезмәтләре искә алынган галимнәрнең басмаларыннан бу мәкаләдә 161 эпитафия тексты файдаланылды.* М.Әхмәтҗанов. *Басмабыз халык теленә кергәч, кайбер галим-голяма журналга дәгъва белдерә башлады.* Мирас

4) Вакытлы матбугат төрләренең берсе. *Ә теләсә нинди тәнкыйть мәкаләсен, ягъни рецензияне, берәр басмага тәкъдим иткәнче, Олы йорт белән килештерүнең мәҗбүрилеген инде әйткән дә юк*... Р.Әмирхан. *Еллык басма. Айлык басма*

5) Бастырылган әйбернең һәр басылышы. *«Бәхетсез егет»нең беренче басмасы белән икенче басмасы арасындагы кебек, «Өч бәдбәхет» белән «Уйнаш» драмалары арасында да үзгәрешләр бар.* М.Гали. *Эшеннән дә бик чыгарасылары килми: энциклопедия сүзлегенең татарчасын эшли башлаганнан бирле көчең керде, шул басма дөнья күргәнче генә түз инде, диләр икән.* К.Миңлебаев

6) Тукымага төшерелгән бизәк; шундый бизәкле тукыма. *Ачылыр ла кибет, ачылыр, Бохарларда басма басылыр.* Җыр. *Алъяпкычка ике аршын басма алдым*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Басылган, нәшер ителгән. *Үзе язган әйбернең басма китап рәвешендә чыгуы Габдуллада «мөхәррирлек» горурлыгы тудырып өлгерде.* Ә.Фәйзи. *Татар басма китабы XIX йөзнең башларында Казан университеты типографиясендә һәм шәхси басмаханәләрдә дә дөнья күрә.* З.Мөхәммәтшин

2) Басып төшерелгән бизәкле. *Басма бүз*

**БАСМА** III *и.* 1) Ике чөй арасына сарып уралган киләп; шулай уралган җепне үлчәү берәмлеге (гадәттә, җиде карышлы киләпкә – алтмыш, ун карышлы киләпкә кырык ике тапкыр салынган җеп)

2) *иск.* Буйга ничә басма җеп керүдән чыгып билгеләнгән тукыма үлчәме. *Биш басма бүз*

**БАСМАК** *и. сир.* Гармун, музыка коралларының теле, клавиш. *Гармунчы Коля алдына эре ак басмаклы аккордеон китереп куйдылар.* Н.Фәттах

**БАСМАЛА́У** *ф. сир.* Һәр басмага, киртләчкә басып менү, һәр басмага берәм-берәм басу. *Баскычка берәр басмалап меңәләр.* Мәкаль

**БАСМА́ СҮЗ** *и.* 1) Матбугатта чыккан, матбугатта басылган фикер, бәяләмә яки хәбәр. *Матбугатта Лев Толстойның вафатына дүрт ел тулу көне билгеләп үтелде, һәм ул, аерым очракларда, сугышка каршы басма сүз әйтеп калу өчен бер җай булды.* Х.Госман

2) Вакытлы матбугатның үзе

**БАСМА́ ТАБАК** *и.* Китап, газета-журнал бастыруда кулланыла торган стандарт зурлыктагы кәгазь табагы. *Беренче әлифбаның күләме ярты басма табак була.* И.Рәмиев

**БАСМАХАНӘ** *и.* Газета-журнал, китап басыла торган урын; типография; матбага. *Ул догалык 1870 елда Казан университеты басмаханәсендә Түбән Масра (Арча районы) авылының кешесе Вәлит Ишмөхәммәт улы Харәҗәттән алып басылган*... Ф.Дәүбаш

**БАСМА́ ХӘРЕФ** *и.* Нәшрият эшендә кулланыла торган хәреф

**БАСМАЧА** *и.* 1) Бер генә тактадан торган тар басма; көймәдә утырып тору өчен утыргыч. *Сания, кызларга гына хас бер тыйнаклык белән, күлмәк*

*итәкләрен җыештырып, басмачада утырып килә.* Г.Ахунов

2) Басып су алыр өчен, елга, күл читендә эчкәрәк кертеп ясалган басма, күперчек. *Басмачага килеп кереп, Зифа буен бөгелдереп, Көянтәсен сыгылдырып Ак чишмәдән сулар алса – Шундук гашыйк булырсың.* Ш.Маннур

**БАСМАЧЫ** *и. үзб. тар.* Урта Азиядә Совет хакимиятенә каршы милли хәрәкәттә катнашучы. *Басмачыларның зур отрядларын тар-мар итүне төгәлләгән Михаил Фрунзенең Кызыл Төркестан фронты составында, мәсәлән, ике «кызыл мөселман атлы полкы» да була.* Идел

**БАСМАЧЫЛЫК** *и.* Басмачылар хәрәкәте. *Басмачылык хәрәкәтен бәяләүдә фикерләр төрле-төрле иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Кораллы антиколониаль каршылык – басмачылык әнә шул чакта барлыкка килә дә инде.* Идел

**БАССЕЙН** *и. фр.<ит.* 1) Су җыю өчен ясалган урын, сусаклагыч, ясалма сулык, ясалма күл. *Зиннәтле сарайлар салдырам, бассейннар казытам, гөлбакчалар эшләтәм дә шунда гына яшәтәм мин аны.* Р.Фәизов. *Машинаны тиз генә бассейн янына урнаштырып, «эчәгеләр» суздылар.* Р.Кәрами. *Фонтанлы бассейннары белән ул бөтен бер кварталны биләп тора.* С.Сөләйманова. *Бассейнның мәрмәр ярына чыгып басу белән, Зөбәрҗәт резин башлыгын салды.* Х.Мөдәррисова

2) Диңгезне, күлне яки елганы һәм аларга коя торган барлык елгаларны эченә алган территория. *Идел һәм аның кушылдыклары бассейнындагы җирләрне рус һәм Болгар дәүләтләре тарафыннан ике яктан үзләштерү бер-беренә якыная барган саен, әлеге сугышлар һаман саен ешаялар һәм көчәяләр.* В.Иванов, А.Халиков. *Сарайчык шәһәре дәүләтнең башкаласы була, Урданың төньяктагы чикләре киңәя барып, XVI гасыр башларында Кама елгасының сул яры буенча сузылып, аннан соң Уфа һәм Буй елгалары бассейнына килеп терәлә.* М.Әхмәтҗанов

3) Казылма байлыклар ята торган өлкә. *Идел-Урал нефть бассейны*

**БАСТИОН** *и. фр.<ит. хәрби* 1) Бишпочмак формасында төзелгән крепость, хәрби ныгытма. *Иң яхшы хәрби инженерлар тарафыннан салынган немец бастионнары безнең полкларның ярсулы һөҗүмен туктата алмады.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Таянырлык терәк, ышаныч. *Советлар Союзын кешелек дөньясының маягы һәм авангарды дип, тынычлык һәм прогресс бастионы дип атыйлар.* Социалистик Татарстан

**БАСТРУК** *и. рус иск.* Төрмә. *Баструк белән янаган.* Р.Хафизова. *[Кызбикә:] Бер-бер хәл булып, үземне баструкка ябып куймасыннар тагы.* М.Фәйзи

**БАСТЫРГЫЧ** *и. к.* **бастырма** I. *Ярый, булды бу, бастыргыч та табылды.* Кызыклар дөньясында

**БАСТЫРМА** I *и.* Салам, печән өемнәре өстенә бастырып салынган агач. *Кибән астында – тычкан, бастырма астында чыпчык үлми.* Мәкаль

**БАСТЫРМА** II *с.* Басып торган, бастырып куелган. *Бастырма яка*

**БАСТЫРМАЛЫК** *и.* Бастырма өчен яраклы агач. *Шәрәфи белән Зәйнулла --- сап-сары саламнар белән кибән өсләре ябалар, әвеннәр куялар, себерке бәйлиләр, бастырмалыклар юналар.* Г.Галиев

**БАСТЫРУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **басу** II. *Себермәгән идәнгә бастырмам, өрмәгән җиргә утыртмам.* Әйтем

2) Нәрсәне дә булса туры торышка китереп кую, туры хәлдә тоту, үрә торгызып кую. *Арбага ике яклап тезелешеп утырган егетләрнең бастырып торкан чалгылары ара-тирә чагылып киткәли.* Ә.Еники

3) Кемгә дә булса аягына басарга ярдәм итү яки нәрсәгә дә булса басып торган итеп урнаштыру. *Мидхәт мышык-мышык килгән Рамиләне җиргә бастырырга мәҗбүр булды.* М.Маликова. *Гыйльметдин абзый үзенең уч төбенә кечкенә икенче бер планета кешечеген алып бастырды һәм, күзләренә якын ук китереп, дикъкать белән карый башлады.* Р.Мөхәммәдиев. *Шунда өлкән абыстай лып итеп артына утырды, икенчесе аны күтәреп бастырырга керешә.* М.Хәбибуллин

4) Нинди дә булса вазифа тапшыру, берәр эш башкарырга бирү, эшкә билгеләү. *Штурвалга бастыру*

5) Газета-журнал, китап һ.б.ш.ны басып чыгару, нәшер итү. *Үзе аткан леопард башына аягын куеп төшкән фоторәсемен --- Португалиянең ниндидер бер журнал тышлыгында бастырып та чыгардылар.* М.Галиев

6) Җиңел әйбер чәчелеп таралмасын яки очып китмәсен өчен, өстенә авыр әйбер салу // Өстенә авыр әйбер кую. *Кисмәк яисә мичкәнең өстенә кәбестәнең яшел яфракларын һәм чиста ак чүпрәк куеп, агач капкач белән каплап, өстенә авыр әйбер (гадәттә таш) бастыралар.* Йорт эшләре

7) *иск.* Таптату, бөртекле ашлыкны башагыннан яки бәрчәдән төшерү, кою өчен, көлтәләрне таратып җәеп, өстеннән ат яки үгез йөртү. *Без көн буенча басуда тары бастырдык, мин көн буенча ат куаладым, салам кагыштым.* М.Гафури. *Әнисә --- ындыр эшләренә бер көн дә калмастан катнашып йөрде. Бергә арыш суктык, басым бастырдык, бәрәңгеләр казыдык.* З.Бәшири

8) *сөйл.* Үтүкләү, өтеләү. *Күлмәкне үтүк белән бастыру* // Пресс белән кысу

9) Берәр процессның интенсивлыгын, көчен киметү; сүндерү, кысу. *Патша яшәгән сарайны ничек кенә җиллә тсәләр дә, төрле үлән төнәтмәләре белән начар исне бастырырга тырышсалар да, Иван патша булган урында тын алып булмый иде.* Ф.Бәйрәмова. – *Тагынниләр майтардым инде мин? – диде егет, эчендәге гарьләнү, үкенү сөремен бастырырга тырышып.* Т.Галиуллин

10) *иск. диал.* Аборт ясату, бала төшертү. *Бик авыр ачлык вакытта дүртенче бала булып дөньяга килергә тиешлегең ачыклангач, әтиең белән киңәшеп, халыкча әйтсәк, бастырырга, ягъни төшерергә булган идек. Әмма син бирешмәдең, үҗәтлек күрсәттең, туасы иттең. Ярабби Ходаем, озын гомер телим!* Т.Нәҗмиев

11) *күч.* Көч кулланып каршылыкны җиңү, тар-мар итү; буйсындыру.

*Шаһбаз исә Урта Азиядәге милли азатлык хәрәкәтен бастырырга җибәрелгән Кызыл Армиянең экспедицион корпусында татар хәрби берәмлеге командиры була.* М.Сәхапов. *Родимцев дивизиясе полклары, дошманның каршылыгын бастырып, акрынлап, Харьковка таба баралар.* Казан утлары // Җиңдерү, көчсезлек күрсәтү. *[Фәрхиназ:] Әллә аңардан бастырып торыргамы? Җитәр инде, яшь чагымда бик күп кыйнады.* Т.Гыйззәт

12) *күч.* Эчке кичерешләрне, тойгыларны тынычландыру. *Агыйделнең --- салкын сулары белән янган йөрәкләремне бастырдым.* Г.Ибраһимов. *«Бала минеке генә түгел бит, Рамазанныкы да...» – дип, күңелендә кабарган ризасызлыгын бастырырга теләгән иде дә көче җитмәде.* Ш.Янбаев

13) *күч.* Кузгалту, хәрәкәткә китерү, уяту, киң күләмдә эшне оештырып, башлап җибәрү. *Г.Ибраһимов --- үз милләтен тәрәккъыять юлына бастырырга, аны бәхетле, ирекле итәргә омтыла.* Х.Миңнегулов

**2. бастырып** *рәв. мәгъ.* 1) Эзәрлекләп, артыннан ук эзләренә басып. *Икенче көн азагында христиан гаскәрләре кача башлый, Аттила гаскәре аларны Рим шәһәренә кадәр бастырып куа, кыра.* Р.Батулла. *Хәтәр озак күзәтеп яткannaр иде дә, аларның эзенә бастырып килүчеләр барыбер күренмәде.* В.Имамов. *Арыслан йөрәкле, узаман холыклы Кучак батырның дошман явы өскә бастырып килгәндә кинәт «качып» китүенә ул чакта, никтер, бөтен Казан ышанган.* Равил Вәли

2) *күч.* Ныгытып, кире кага алмаслык итеп. *Күршеләренең бик кыйммәтле күп кенә маллары юкка чыкты. Турыдан-туры бастырып әйтерлек бернинди дәлил булмаса да, малайдан күрделәр.* Г.Бәширов

**Бастыра бару** Бер-бер артлы, һәр булган берсен бастыру

**Бастыра төшү** Тагын да бастыру; бераз бастыру

**Бастырып алу** Тиз генә бастыру. *Шул арада үтүк кыздырып, Хәсәннең күлмәкләрен бастырып алырга да өлгергән иде Сания.* М.Әмир. *Кысрыклап килә-килә, кәрзине белән өстенә бастырып алам дигәндә генә, балык кул астыннан шуып узды.* Н.Хәсәнов

**Бастырып бару** Берсе өстенә икенчесен, бер-бер артлы бастыру. *Бер куркыныч хәбәрне икенчесе бастырып кына барды.* М.Мәһдиев

**Бастырып бетерү** Барысын да бастыру

**Бастырып җиткерү** Басып торырлык итү

**Бастырып килү** Системалы, берсе артыннан икенчесен бастыру. *Шул ук әтрәт хәзер безнең Чәрмәсән буендагы авылларны бастырып килә икән.* В.Имамов. *Бертуган Кәримовларның сәүдә компаниясе акчасына чыгарыла торган бу газиттә Тукай, гомеренең соңгы көннәренә тикле, үзенең мәкаләләрен бастырып килде.* К.Мостакаев

**Бастырып кую** 1) Басып торган хәлгә китереп калдыру. *Габит, буш әрҗә эченә бастырып куйган шешәсен алып, стаканын мөлдерәмә тутырды.* Б.Камалов. *Өйләренең ишек төбенә барып җиткәч, Тәлгатьне җиргә төшереп янына бастырып куя да, ике кулын күтәреп, кычкырып, дога укый башлый.* З.Зәйнуллин

2) Кузгалмаслык итеп өстеннән бастыру. *Бурлашканы өчен, Кашап абзыйны, эт итеп кыйнап, биниһая юан бүрәнә белән биленнән бастырып куйганнарын хәтерлим.* М.Галиев

3) Дәрестә дәресен сөйләргә, укыган темасы буенча җавап бирергә чакыру. *Рәсем дәресендәге вакыйгадан айнып та җитмәдек – зоология дәресендә тагын Әркәшәне бастырып куйдылар.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Төзеп әзер итү, төзеп бетерү. *Әле быелгы җәй уртасында гына бастырып куйган алачык тирәли ничәмәничә кабат урап чыкты инде.* В.Имамов

**Бастырып тору** Даими бастыру

**Бастырып чыгу** Рәттән, һәрберсен берәм-берәм бастыру. *[Габденнасыйр] Умарталарның башларына юан агач кабыгы ябып, аларның кайберләрен ак таш белән --- бастырып чыкты.* М.Гали

**БАСТЫРУЧЫЛЫК** *и.* Китап бастыру эше. *Мәкаләдә татар халкы тарихы, аның әдәбияты, китап бастыручылык турында да кыйммәтле мәгълүматлар бар.* Татар теле лексикологиясе һәм лексикографиясе мәсьәләләре

**БАСТЫРЫК** *и.* 1) Бер башында ыргаклы бавы булган, салам, печән кебек йөкләрне, таралып, ишелеп төшмәсен өчен, өстән бастырып куя торган агач яки озын колга. *Машинага күкләргә терәлерлек итеп печән төялгән; аны озын бастырык белән бастырып, төрле яктан аркан баулар белән бәйләп куйганнар.* Р.Мирхәйдәров. *Малайлар исә, атларын чаптырып килеп, өемне бастырыкка эләктерәләр дә эскерткә алып китәләр.* М.Хуҗин. *Артта – иң олы татар зыялыларын каберғә алып киткән, чит-ят җирләргә бастырыксыз салам кибәне төсле тараткан сталинчылык ...* Т.Галиуллин

2) Нәрсәне дә булса бастырып торган авырлык. *Җир бастырыгы – тау, тау бастырыгы – таш.* Мәкаль

3) Бикнең бер төре буларак, башбашлары ишек яки капка элмәкләренә тыгыла торган, аркылыга салынган агач. *Билгеле җирдән кәкре башлы кәшәкә таягын алып, өйалды ишегенең эчтән салынган бастырыгын төшердем.* Ф.Хөсни

**БАСТЫРЫ́К БАВЫ** *и.* Йөк өстенә салынган бастырыкны арба-чанага тарттырып бәйләү өчен кулланыла торган ыргаклы бау. *[Нәби] Бастырык бавына эләктереп куелган сәнәкне алып, якяктан тартkaлап куя.* Р.Төхфәтуллин

**БАСТЫРЫКЛА́У** *ф.* 1) Салам, печән йөгән бастырык белән тарттырып бәйләү. *Мотаһир, йөге бәләкәй булса да, аның бастырыклап төяләүенә игътибар итте.* Р.Кәрами. *Хисамук --- салам алып килде, биек иттереп, минем арбама өйде, аннан соң: – Моны бастырыкларга кирәк инде, – диде.* З.Бәшири

2) Нәрсәне дә булса авыр әйбер белән бастырып кую. *Киндер сабакларын юан киртәләр белән бастырыклап, күл төбенә салырлар.* В.Имамов

3) Ишекне яки капканы бастырык белән бикләү. *[Мәрьям] Капканы нык итеп бастырыклады.* А.Расих

4) *күч.* Тыю, үзен кулга алып тыелу. *--- эчендә котырынган давылны ихтыяр көче белән бастырыклап, йөзенә елмаюга охшаш җыерчыклар чыгарып, кул биреп исәнләште*. Т.Галиуллин

**Бастырыклап алу** Тиз генә бастырык салу. *Керфекләрен авырайтып, күгелҗем күзләрен бастырыклап алды да оешытыру эшләрен дәвам итте*. Т.Галиуллин

**Бастырыклап бетерү** Бастырык салу эшен тәмамлау; барысын да бастырыклау. *Элекке заманның арбалары булса, эш озакка тартылыр, бер кеше төяп, бастырыклап беткәнче, әллә ничаклы вакыт үтәр иде; хәзерге фурман арбаларга көлтә төяве – уен гына*. Г.Ибраһимов

**Бастырыклап килү** Электән үк, күптәннән бастырыкланган хәлдә тоту. *--- шушы кыска гына сөйләшүдән, Гашурә Галимҗановнаның күңелендә моңа хәтле җиде йозакка бикләнгән, дистә еллар авызлыклап, бастырыклап килгән хис-тойгылар иркенлеккә чыкты, уй-зиһенен биләп алды*. Ш.Янбаев

**Бастырыклап кую** 1) Бастырык салган хәлгә китерү

2) Нәрсәне дә булса өстән бастыру; алда ашаган өстенә тагын ни дә булса ашап кую. *Өстән каты чәй белән бастырыклап куйдык*. Ә.Хәбибуллин. *Каз ботын Мамадыш спирт заводында махсус куылган бодай мае белән бастырыклап куйды да акрын гына сүз башлады*. Т.Галиуллин

**Бастырыклап тору** Берсе артыннан икенчесен бастырыклау

**Бастырыклап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, барысын да бер-бер артлы бастырыклау

**Бастырыклый бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы бастырыклау

**Бастырыклый башлау** Бастырыкларга тотыну

**БАСТЫРЫКЛЫ** *с.* 1) Бастырыклап куелган, бастырыкланган

2) Эчтән бастырыклап бикләнгән. *[Жандармнар] Мәктәп капкасының бастырыклы икәненә хәтле белгәннәр*. Г.Гобәй

3) *күч.* Басынкы, боек. *Бераз уйланып торды. Хәрәкәтчән, җегәрле, тормышчан ханым өчен артык басынкы, сөремле, бастырыклы тавыш белән өстәп куйды: «Икебезне дә язмыш җитәрлек сынады»* . Т.Галиуллин

**БАСТЫРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бастыру.** *1919 елда бу әлифба сигезенче тапкыр бастырыла*. Ф.Вәлиева

2) *күч.* Авырып яки авыр төш күреп куркыныч саташу, буылу. *Ач – төшендә оча, тук – төшендә бастырыла*. Мәкаль. *«Әни, ник саташасың, ул газраил түгел, безнең врач бит», – дип ялвара... Һушыннан китеп ятканга, шулай көн-төн бастырыла иде ул*. Х.Камалов

**Бастырылып тору** Хәзергә, вакытлыча бастырылу. *Бары совет дәверендә генә, башкарак идеологик максатларга мәҗбүри хезмәт иттерелүләре сәбәпле, аларның милли омтылышлары бераз тоткарланып яки бастырылып торды*. Ф.Мусин

**БАСУ** I *и.* 1) Урмансыз тигез җир, кыр. *Яланнар, басулар, болыннар, таулар, урманнар, кырлар – һәммәсе, киң күкрәкләрен ачып, көчле яңгырның рәхәтенә чумдылар*. Г.Ибраһимов. *Башта, мотоциклның сибе өзелеп, ярты көн басу буенда ятты*. Г.Гыйльман

2) Иген культуралары чәчеп үстерелә торган, сөрелгән җир мәйданы, игенлек, чәчү җире. *Сабаннар үткән актарып, Басулар җәйрәп ята*. К.Булатова. *Дөньяда безнең авылның урманга таба җәелеп яткан басуында борчак кузакланган кояшлы көннәре кадәр --- матурлык тагын кайда бар икән?!* М.Мәһдиев

3) Иген кыры һәм аның аерым культуралар үсә торган өлеше. *Күпмедер ара үткәннән соң, ул, соңгы буынга сикереп, серкә очыра башлаган арыш басуына килеп керде*. З.Фәйзи. *Алмазны Солтанов чөгендер басуына, эш белән мәшгуль хатын-кызлар янына алып барды*... Ф.Сафин. *Ун-унбиш минут үтмәгәндер, без инде «Таулар» колхозының күкрәп үсеп торган бодай басуына килеп җиттек*. Р.Ишморат

**БАСУ** II *ф.* **1.** 1) Гәүдә туры торыш алып, аякка калкыну; аяк өстенә калкыну. *Төлке әйтте: «Әй, Кәҗә, аягүрә бас син элек!»* М.Гафури. *Чын көрәшче кебек, аякларын аерып, әзрәк алга иелебрәк, нык итеп басты*. Р.Хафизова

2) Нинди дә булса урында тукталып, аяк өсте тору. *Ишек шакылды, ачылды, ике кулына чемоданнар тоткан, артына ике бала ияркән бер хатын килеп басты*. Г.Исхакый. *Менә ул – егет солтаны – сәхнәгә Хәйдәр Бигичев чыгып баса*. М.Галиев. *Әни үзе дә әтием алдына нәкъ шулай итеп килеп баса торган иде*. Э.Шәрифуллина. *Балалар бер урынгарак тупланып басалар*. Кабыргалы-камчылы: Татар халык уеннары

3) Билгеле бер эшкә, шөгыльгә керешергә әзер булу, эш урынын алу. *Отделение бер тәүлеккә дежурга басты*. Р.Кәрами. *Ил намусы, саф тойгылар белән Солдат булып сафка бастык без*. Ә.Ерикәй

4) Адымлау, атлау, адым ясау. *Акрын гына басып, карана-карана, сакланып кына, Хәлил керә*. М.Фәйзи

5) *дини* Намазлык өстендә намаз, дога уку. *Иртә белән, яңадан-яңа бәлаказалар килмәсен, дип, ярлыкау догасына басалар*. М.Әмирханов. *Шул сүзләрдән соң бу адәм, тиз генә тәһарәт алып, намазга баса*. Р.Кадыйров

6) Бию адымы ясау; бию. *Бас, бас эзенә, күз тимәсен үзенә!* Җыр. *Бас, кызым, Өммегөлсем, Баскан җирең өзелсен; Баскан җирең өзелмәсә; Минем дустым түгелсең*. Җыр

7) Кул көче белән аска таба этү. *Рәүф сикереп тора да лампочканың төймәсенә баса*. М.Маликова. *До-ре-ми-фа-соль-ля-си-до... Укытучы хатын күгәргән бармаклары белән пианино клавишаларына баса да шулай җырлый*. М.Мәһдиев

8) Аралаштырып, катнаштырып, изеп үзле итү. *Ул «как-төш» дигәннәре шул: әүвәл камырны басалар йомырка белән, сөт белән, май белән катыштырып*. К.Насыйри. *Шуңа күперткән йомырка агын һәм калган онны өстәп, камыр басарга кирәк*. Йорт эшләре

9) Йон массасын махсус ысуллар белән әвәләп, кирәкле форма һәм тыгызлык бирү. *Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли, Өмәләрдә тула басабыз*. Җыр. *Сездә тула басалармы? Бездә тула басалар! Сездә ничек, бездә шулай*

*Биеп күңел ачалар.* Җыр. *Киез, тула басу, көнкүрештә шулардан эшләнгән әйберләрне файдалану төрки халыкларда, шул җөмләдән татарларда да, киң таралган булган.* Мәдәни җомга

10) Кош-корт, бала чыгарганда, йомырка өстендә утыру. *Үрдәк йомыркасын тавык басар, бәпкәсе суга качар.* Мәкаль

11) Нәрсәне дә булса уч, бармаклар белән каплау, томалау. *Зифа, сикереп торып, колагын басып йөгерә.* М.Фәйзи // Нәрсәне дә булса яссы ягы белән билгеле бер урынга китереп кысу. *Дошман тәнгә кызу тимер басты.* М.Гаяз. *Кемдер әзер, өстәп, уртасына кызган тимер белән басарга.* Р.Фәйзуллин

12) Язу техникасы ярдәмендә өслеккә билгеләр, хәрефләр төшерү. *Фазыл Шәех язу машинкасының клавишаларын үзенең бармаклары сиземләвенә көйләп чыкты һәм үз шигырьләрен машинкада үзе баса иде.* Ә.Шәрипов

13) Китап, газета-журнал һ.б.ш.ны нәшер итү. *Мең еллар элек, хәтта соңрак та әле, китап басу станоклары да булмаган. Ул чорда китаплар кулъязма хәлендә йөргән.* Г.Бәширов. *Татарстаннан читтә – Идел-Урал буйларында, Себердә, Урта Азиядә, Мәскәүдә, Петербургта, ниһаять, чит илләрдә татар китабын басу тарихы өйрәнелмәгән әле.* Сөембикә

14) Язуны яки рәсемне, төрле җайланмалар ярдәмендә, башка өслеккә төшерү яисә чигеп, каеп күчерү. *Риваять буенча, бер баланың кулына мөһер басалар, һәм ул, үскәч, шушы мөһер аркасында төрле михнәтләр күрә.* Т.Гыйззәт. *Хисмәт Кәримовның рәсемен дә Газет уртасына басканнар.* Ш.Маннур

15) Авырлык яки көч белән тәэсир итү, басым ясау. *Сулы көянтә-чиләкләр иңнәрне баса.* Ф.Яруллин. *Җәяүлегә янчык та авыр, Бара-бара баса ул.* Р.Идиятуллин. *Аннан соң, бармакларны тырпайтып, кулны тез өстенә куегыз, чәнчә бармак янындагы атсыз бармак белән тез астында кырыйдарак урнашкан батынкы урынны табып шуңа басыгыз һәм 5 минут дәвамында түгәрәк хәрәкәт белән массажлагыз.* Файдалы киңәшләр

16) Сусынны кандыру, эчәсе килүне канәгатьләндерү. *Бу дөньяда шулай – кемнәр сусый, Сусын басар өчен кизләү бар.* Б.Рәхимова

17) Авырлык, җайсыз урнашу нәтиҗәсендә, тән тиресе суелу, чиләнеп чыгу. *Атларның күбесенең муеннарына камыт тигән, җилкәләрен ыңгырчак баскан.* Г.Галиев

18) Нинди дә булса авырлык өскә ишелеп төшеп имгәтү, һәлак итү. *Гомерем булса, таш басмаса, Ташламам, җанкисәгем.* Җыр

19) Ию, бөгү, түбәнәйтү, тәбәнәкләндерү. *Әтинең бу сүзләрен ишеткәч, башымны түбән бастым.* М.Гафури

20) *иск. к.* **бастыру** (*7 мәгъ.*) *Иген басу*

21) Үлчәү тәлинкәләренең авыррак ягы аска төшү. *Кеше рухы үлчәү табагында тартышып тирбәлә: әле яхшылык ягы баса, әле – яманлык...* Ш.Галиев

22) Карта уенында: көчлерәк карта белән каплау, ябу. *Уен тузы белән басу*

23) Нинди дә булса явыз көчләр яки ерткыч хайваннар һөҗүм итеп, корбанын үтерү, җиңү. *Албасты көчсезләрне баса.* Мәкаль

24) Талау нияте белән, илгә, чит җирләргә килеп керү, үзенең хакимлеген урнаштырырга, буйсындырырга омтылу. *Кинәт дошман килеп басты, Хәйран калды бөдрә тал.* Ә.Ерикәй

25) Тыю, тынычландыру. *Хатынкызның, бала-чаганың елашуыннан ярсыган йөрәкне аз гына булса да басу өчен, шактый гына салып алган агайларның җырлавыннан авыл гөр килеп торды.* М.Хәсәнов. *Мебикар алкоголизм белән авыручыларның ярсучанлыкларын баса*... Серле сандык календаре

26) Авазны, тавышны акрынайту. *Икешәрләп-өчәрләп, Әхмәдулланың ак өенә җыелалар да, тавышларын басып кына, нәрсәдер сөйләшәләр.* Н.Гыйматдинова. *Телевизор тавышын басу*

27) *күч.* Нинди дә булса әгъзаның авыртуын киметү, тоймаслык итү, тынычландыру. *Бар ул андый дару ---. Тик ул да шул, ахыр килеп, авыртуны вакытлыча гына баса торган дару бик кенә тәэсир итә.* Ф.Абдуллин. *Теш сызлавын басу*

28) *күч.* Арттан куып җитеп килү, эзәрлекләп килү. *Эзенә басу. Үкчәсенә басу*

29) *күч. сөйл.* Урлап, талап чыгу. *Лесхозның кассасын басканнар иде.* Т.Нәҗмиев. *Моннан бер атна элек безнең шәһәрдә квартира басу җинаяте булган иде.* М.Насыйбуллин. *Милициядә балигъ булмаган балалар бүлегендә исәптә торучы Илсур исемле шук малай аны, акча табарга өйрәтәм, дип, үзе белән бергә гәҗит киоскын басарга өнди.* Юлдаш // Кеше бакчасына кереп, хуҗа рөхсәтеннән башка, анда үскән яшелчә, җиләк-җимешне җыеп чыгу. *Шаярган булып, авыл малайлары бакча баса.* С.Шәрипов

30) *күч. сөйл.* Бар нәрсәдән дә әһәмиятлерәк булып, беренче планга чыгу, кичектергесез хәл итү бурычы туу. *Әлбәттә, татар режиссёрлары алдына, кичекмичә, жанр чишелешен эзләү проблемасы килеп баса.* М.Арсланов. *--- шигърият һәм нәсернең милли йөзен саклап калу әдипләребез алдына иң мөһим бурычларның берсе булып баса.* З.Мөхәммәтшин

31) *күч.* Өстенлек алу, өскә чыгу. *Каратамак бакалары никадәрле генә бердәм бакылдашмасыннар, барыбер баса алмыйлар кошлар хорын.* Ф.Шәфигуллин. *Шулай, җыр белән, авыр тормышны басабыз.* М.Мәһдиев

32) *күч.* Кешенең төс-кыяфәтенә, фигыленә тискәре йогынты ясау, юашландыру, көчсезләндерү. *Картлык басу. Тормыш басу*

33) *күч.* Тормышта, яшәештә авырлыклар, кыенлыклар алдында калу. *Кыз баланың җилкәсен кайбер өлкәннәр дә күтәрә алмаслык авыр тормыш йөге баскан.* Р.Хафизова

34) *күч.* Күпме дә булса хакка туры килү, бәягә төшү. *Агачны ташыту, агач бәяләрен кушсаң, мунча 800–900 сумга менә дә баса.* Т.Миңнуллин

35) *күч.* Каплау, каплап алу, томалау, күмеп китү. *Тик беркөнне күкне болыт басты.* Ә.Ерикәй. *Габдел Латыйф хан идарәсендә Кабан күле хәттин ашып ташый, тирә-як авылларны,*

*бистәләрне су баса, халык бик күп каза күрә.* Р.Батулла. *Бер генә атна чистартма – тирес бөтен абзарыңны баса.* А.Хәсәнов. *Урамны кар басты, коймалар әллә кайчан аста калды.* Г.Ибраһимов // Күп булып үрчү. *Йомшак агачны корт баса.* Мәкаль. *Кытай башкаласы санэпидемиологлары шәһәрне таракан басуы турында белдерәләр.* Шәһри Чаллы // Күп булу, еш үсү, куерып каплау. *Бөтен бер басулар кысыр калып, әрем-алабута, төрле чүп үләне басты.* Ф.Хөсни // Күп кабатлану, еш очрау, ешаеп китү. *Ата-бабаларын уллары таныса, изгеләр зираты өстенә клуб салдырамы? Имансызлык, сәрхушлек, зиначылык баса дөньяны.* Р.Батулла

36) *күч.* Санга сукмау, кимсетү, җәберләү. *Усал булсаң – асарлар, юаш булсаң – басарлар.* Мәкаль

37) *күч.* Авыр бер тойгы, хис биләп алу, чолгап алу, изү. *Шәяхмәтнең тәбәнәк өен кара кайгы басты.* М.Мәһдиев. *Газаплы уйлар баскангамы, карчыкның ансыз да бәләкәй гәүдәсе тагын да куырыла, сыгыла төшкән иде.* М.Хәсәнов. *Әтисен хәсрәт ташы басты.* Н.Хәсәнов

38) *күч.* Бик нык ардыру, йончыту, хәлсезләндерү. *Очы юк юешлек тәнне баса иде, албасты пәрисе баскан кебек изә иде.* Г.Исхакый. *Хезмәт, авыр хезмәт басты аларны.* Р.Ишморат

39) *күч.* Шөгыльләнә башлау, нәрсә дә булса эшләргә керешү. *Логик таянычын югалтса, ул хәйлә, мәкер, алдашу юлына баса.* Казан утлары. *Шулай итеп, ундүрт яшендә ул беренче мәртәбә җинаять юлына баса.* Юлдаш

40) *күч. сөйл.* Билгеле бер яшькә керү, олырак яшькә таба бару. *Яшең алтмышка басканда, алты яшьлек оныгың булсын.* Мәкаль. *Фарук абый белән Гөлсем җиңги генә чамасыз картаеп киткәннәр – җитмешнең өстенә басу белән, ягадагы уллары-кызларының кайтып булышканнарын көтеп яшәр хәлгә төшкәннәр.* К.Миңлебаев

41) *күч.* Күз алдына килү, пәйда булу, искә төшү. *Һәм янә күз алдына мич аралыгындагы теге елгы бәрәңгеләр килеп басты.* Н.Хәсәнов. *Шул ук секунд күз алдыма аның әтисе – шушы нигездә яшәп, Ватан сугышында һәлак булган энем Һади Ишморатов килеп басты.* Р.Ишморат. *Ниһаять, алар кечкенә ачыклыкка чыктылар, һәм күз алларына биек, калын, тәкәббер сынлы имәннәр, наратлар һәм чыршылар килеп басты.* Ә.Фәйзи

**2**. **басып** *рәв. мәгъ.* 1) Тыгызлап. *Капчыкны басып тутыру*

2) Узып китеп, калдырып

3) Эзәрлекләп, артыннан ук. *Бу телчән хатынның басып килеп керүе аеруча Хәдичәгә ошамады булса кирәк.* М.Хәсәнов

◊ **Баскан да каткан** *мыск.* Бер дә кузгалмыйча, тик басып торган кеше турында. **Баскан җиреннән ут чыгара** Бик гайрәтле, дәртле, нык-нык басып йөрүче, уңган, булдыклы кеше турында. **Баскан эзеннән ут чыгара** *к.* **баскан җиреннән ут чыгара.** *Баскан эзләреннән ут чыгара.* М.Әмир. **Басса – бакыр изәрдәй, типсә – тимер өзәрдәй** Гайрәтле, көче-куәте ташып торган, яшь, сау-сәламәт. *Басса – бакыр изәрдәй, типсә – тимер өзәрдәй егет кешегә, сырхантай баш кебек, өйдә ябылып утыру килешәмени ул?* Г.Әпсәләмов. **Басып калдыру** 1) Кеше хакын үзләштерү, бирәчәкне бирмәү; 2) Эшне фаш итмичә, йомып калдыру. *8 нче ротаның солдатлары бу эштә фельдфебельне гаепләп, аны полк штабы аркылы җавапка тарттырырга дип йөрсәләр дә, ротный командир, аны яклап, бу нәрсәне басып калдырды.* М.Гали. **Басып калу** *к.* **басып калдыру.** *Хезмәт хакын басып калалар.* И.Гази. *Мин үскән Кырлайда, шулай, Хафиз дигән бер бай Җаббар дигән ялчының хакын басып калырга маташкан иде.* Ә.Фәйзи. *Салаватны --- юлда үтергәннәр. Менә шушы канлы эзне волостьта эшләүче кулак иярченнәре басып калдылар.* К.Нәҗми. **Басып керү** Кеше иленә, кеше йортына көчләп килеп керү, һөҗүм белән килү. *Шул ук көннең төнендә, яман дөбердәтеп, өйгә басып керделәр дә, Иргалине атка утыртып, кораллы конвойлар арасына алып, район үзәгенә – Чаллыга алып киттеләр.* М.Хәсәнов. *Көнбатыштан кинәт фашист явы Басып керде тыныч Ватанга.* Ә.Исхак. **Басып килү** Артыннан куып җитү, артыннан ук керү. *Менә Байдекнең артыннан ук басып килделәр тентү белән.* К.Насыйри. **Басып китү** Өстенлек алу, беренче планга чыгу. *Атна-ун көн дигәндә, икенче бервәүнең күзе кислотага януы --- Егорка вакыйгасын басып китте.* Г.Гобәй. **Басып яткыру** Яшереп тоту; кулланмыйча яки файдаланмыйча саклау

**Баса бару** 1) Һәрберсенә бер-бер артлы басу

2) Торган саен ныграк басу. *Бу картны да ярлылык баса бара.* Әкият. *Гомер уза. Баса бара йок-таш, Тирәнәя бара һәм эзем...* Җ.Сөләйманов

**Баса башлау** Басарга тотыну. *Пожар насосының баш-башына, икешәр кеше, корсаклары белән ята биреп, тырышып-тырышып баса башладылар.* Ф.Хөсни. *Ашаганнан соң, аларны йокы баса башлады.* З.Зәйнуллин

**Баса бирү** Басуын дәвам итү. --- *ул, үз-үзен белештермичә, түземсезлек белән, бер-бер артлы, звонок төймәсенә баса бирде.* А.Сафиуллин

**Баса төшү** 1) Беркадәр, бераз басу. *Исемнәре үк җанга җылы бирә --- ди башлаган иде, Хатыйпның алдагы сүзләре аны бераз баса төште.* Г.Ибраһимов. *Хәдичәнең әйтәсе сүзе бетмәгән икән. Ул, ничектер, тавышын баса төшеп дәвам итте: – Ни өчен миңа кирәргә булдың, дип сорадым мин синнән.* М.Хәсәнов

2) Тагы да ныграк басу. – *Петька, давай, Шәлегә ку! Туйганчы катык белән сыйланып кайтыйк бер! – дигән Василий Иваныч. – Есть, товарищ главнокомандуший! – дип, Петька газга тагын да баса төшкән.* Л.Лерон

**Баса язу** Чак кына басмыйча калу. *Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, күршеләр турыннан узганда, кош баласының өстенә баса язды тагын...* М.Маликова

**Басып алу** 1) Көч белән тартып алу. *Византия империясе һәлакәт алдында. Аның Сүрия, Кече Азиядәге барлык биләмәләрен сәлҗүкъ төрекләре басып ала.* М.Гайнетдинов

2) Биләү, биләп алу, яулау. *Фәррахбануны яшьләргә хас балачыл тойгылар басып алдылар.* К.Насыйри

**Басып ату** Тиз генә басу

**Басып бетерү** 1) Басу эшен тәмамлау

2) Тоташ каплап алып басу. *Алар заманында атлылар йөргән, ләкин хәзер үлән басып бетергән ташландык тар гына юлдан урман эченә кереп киттеләр*. В.Нуруллин

**Басып җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә басу. *Иркәләнүгә өйрәнгән песи Җиһанша җизнинең: «Хайванкай, юлга ятып торма, әйдә, өйгә кер», – дип күтәреп алып керүен көткәндә, ачуыннан күзенә бернәрсә күренмәгән Җиһанша җизни, үзе дә белмичә, аның койрыгына басып җибәрде*. Һ.Такташ

**Басып җиткерү** Тиешенчә, ахырына кадәр басу

**Басып йөрү** Озак вакытлар басу эше белән шөгыльләнү. *Җәй көне үзләре кебек ирләр, егетләр белән, кыр эшенә китәләр, урманга йөриләр, тырма, сәнәк күтәреп, кибән салалар, --- көз килсә, таза, көчле беләкләрен сызганып, җырлаша-җырлаша, тула басып йөриләр*. Г.Ибраһимов

**Басып кую** 1) Бер тапкыр басу хәрәкәте ясау

2) Лампа, самавыр кебек нәрсәләрнең утын киметү, томалау. *Басып куйган самавырын үрләтеп, чәй урыны әзерләде*. А.Шамов

**Басып тору** 1) Әле, күз алдында, хәзер баскан булу. *Хатын-кыз ыгызыгы килде, әмма ирләр, карт-коры, түбән карап, карасына коелып басып торды*. М.Мәһдиев. *Ә кайсылары палуба кырыенда басып торалар*. Г.Лотфи

2) Баскан хәлдә калу, баскан торыш алу. *Абдулла, бөтен күңелен кошлар моңына биреп, дөньясын онытып басып торды*. Э.Касыймов. *Бүгенге көндә Баязит Аллаяров яшен тизлеге белән галәм гизми, сәгатьләр буе бер ноктада басып тора*. С.Сөләйманова. *Егетләр, телсез калып, бермәл сүзсез генә басып тордылар*. Н.Хәсәнов

**Басып чыгу** Тиз генә һәрберсенә берәм-берәм басу

**БАСУ́ КАПКАСЫ** *и. иск.* Авылдан кырга чыгу юлында корылган капка, кыр капкасы. *Басу капкасын чыккач та, Уңга киткән юл булыр*. Җыр

**БАСУ́ КАРАВЫЛЧЫСЫ** *и. иск.* Иген басуларын кош-корт, терлек-туардан саклау эше йөкләтелгән кеше. *Шулай да басу каравылчысы Фәхри картның абруе белән исәпләшми торган бер оя тинтәк каз бар*. Ф.Хөсни

**БАСУ́ КИРТӘСЕ** *и. иск.* Авылны иген басуыннан аерып торган һәм ашлыкларны мал-туардан саклау өчен тотылган киртә. *Авыл чите. Уң якта басу киртәсе һәм кыр капкасы күренә*. А.Алиш

**БАСУ́ ЮЛЫ** *и.* Басу буйлап салынган юл, кыр юлы, басу аша салынган сукмак. *Күз үзәге җиткәндә, аяк аслары кипте, пыяла кебек шома сукмаклар, басу юллары төште*. Г.Галиев

**БАСЫК** *с.* Киң һәм җәенке. *Кар белән яртылаш күмелгән басык һәм тәбәнәк өйләрнең кечкенә тәрәзәләреннән төшкән саргылт шәүләләр урам аркылы сузылып-сузылып киткәннәр иде*. Ш.Камал

**БАСЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **басу** II (*1, 5–9, 12–16, 18, 20, 21, 27, 31 мәгъ.*). *«Чаян» журналында басылган бер карикатураның да мәгънәсен ялгыш аңлаганмын булып чыкты*. М.Әмир

2) Тыгызлану, утыру. *Май кисәкләре басылсыннар өчен, аның өстенә авыр әйбер бастыралар, бу исә тигез тозланырга ярдәм итә*. Йорт эшләре

3) Бәхәс, дау, хәрәкәт, шау-шу, ыгызыгы әкренәю, кискенлеге яки зыяны бетү, тынычлану. *Безнең Бохара әмире белән конфликтыбыз әле булса басылганы юк*. Ш.Усманов. --- *бераз кысыла төшеп, Фәгыйльгә дә урын бирә. Шуның белән шау-шу да басыла*. С.Сабиров. *Авылдашларының да өне басыла*. Р.Камалов

4) Хисләр, тойгылар, кичерешләр, күңел ярсуы бетү, кимү. *Чыңгызның әрнүләре басылмый*. Н.Хәсәнов. *Фатыйма чәчен йолкый-йолкый елый башлый. Ачуы әзрәк басыла*. А.Алиш

5) Боегу, юашлану, басынкылану. *Элегрәк, басылып яшәгән чорында, шикләнеп-шикләнеп куйса да, хәзер үзенең җиңеп чыгачагына ышанычы артты*. М.Кәбиров. *Әмма Кенәленең иң матур, иң гүзәл чагы язгы ташкыннар ярсуы бераз басылып, ярларына кайтып тынычланган вакытта була...* М.Хәсәнов

6) *күч.* Сүрелү, кимү, сүнү, бетү, тукталу. *Бераздан инде җил басыла*. М.Хәсәнов

**2. басылып** *рәв. мәгъ.* Бөтен игътибарны, сәләтне, көчне биреп. *Белүебезчә, әдәбият, бигрәк тә аның проза тармагы, автордан язу өстәле янында озаклап һәм басылып утыруны, язган әйберeңне кат-кат укуны һәм җентекләп төзәтүне, аннары тагын әллә ничә мәртәбә күчереп язуны таләп итә*. М.Вәлиев. *Илдарның барыбер минем белән килешәсе килмәде: – Басылып кына укысын. Егетләр качмас, – дип кырт кисте*. Э.Шәрифуллина

**Басыла бару** 1) Акрын-акрын басылу, торган саен ныграк басылу

2) Һәрберсе, булган берсе басылу

**Басыла башлау** Басылырга тотыну. --- *шагыйрьнең, бер-бер артлы, шигырь җыентыклары басыла башлый*. Р.Даутов

**Басыла килү** Даими басылу. *Сиксәненче елларның ахырыннан башлап, уңышлы рәвештә яза һәм басыла килүче икенче яшь прозаик – Флүс Латыйфи*. М.Вәлиев

**Басыла тору** *к.* **басылып тору** (*1 мәгъ.*). *Аның [Мәсгуд аганың], бер-бер артлы, мәкаләләре басыла торды*. Р.Кадыйров. *Шуннан соң барлык шигырь һәм поэмалар Сибгат ага кулы аша узды һәм басыла торды*. Ә.Баян

**Басыла төшү** Берникадәр, бераз басылу. *Саф һавада йөреп керсәң, баскычтан йөгереп менеп төшсәң, кеше арасына чыксаң, йөрәк ярсуы басыла төшә*. М.Маликова. *Аның тавышы йомшарган, ярсуы басыла төшкән иде*. М.Хәсәнов. *Йөрәкнең гөрс-гөрс тибүе басыла төшкәч, мин аякларымның туңа башлаганын сиздем*. Ә.Хәсәнов

**Басылып бетү** Тәмам басылу; барысы да басылу. *Сагышларын басты Рәшидә ---. Ай-һай, белмим – Басылып ук бетте микән соң?* М.Шабаев

**Басылып җитү** 1) Билгеле бер вакытка басылырга өлгерү

2) Тулысынча, ахырга кадәр басылу. *Басылып җитмәгән ярсуы кинәт гөлт итеп кабынып китте, һәм, шул ук*

*секундта, аңа бөтенесенә дә бары ул гына – Фәридә генә гаепледер шикелле тоелды*. Н.Фәттах

**Басылып калу** 1) Үзеннән-үзе басылу, кинәт басылган хәлгә килү. *Буранның иртәсендә бөтен дөнья тынып, басылып калды*

2) Басылырга өлгерү. *«Аң» журналында Сәетгәрәй Еникеевнең, кызганычка, бик иртә үлеп киткән өметле шагыйрьнең, берничә шигыре басылып кала*. Ә.Еники

3) Бастырылу, нәрсәнең дә булса астында калу. *Ул зур масса астында берүзе басылып калгандай була*. М.Вәли-Барҗылы. *Бигрәк тә бабасының агачка басылып калуы турындагысы ошый малайга*. Ф.Яруллин

**Басылып килү** 1) Әкренләп, аз-азлап басылу. *Җил басылып килә. Дулкыннар әкрен-әкрен басылалар*. М.Җәлил

2) Электән үк, даими рәвештә басылу. *Газета битләрендә, һәр сан саен диярлек, күләмле фельетоннар басылып киләләр*. Ф.Җәүһәрова

**Басылып китү** Бераз, аз гына басылу. *Миндә ишан өшкергән тоз бар, шуны изеп эч, йөрәгең басылып китәр*. Г.Камал

**Басылып кую** Кинәт кенә басылу

**Басылып тору** 1) Еш, һәрвакыт, әледән-әле басылу. --- *әдипнең әсәрләре бер-бер артлы басылып тора*. Х.Миңнегулов

2) Вакытлыча тынган булу, хәзергә генә басылган булу. *Ютәле басылып торган чакларда да күңеле күтәрелми, ахрысы*. С.Сабиров. *Көндез басылып торган җил-яңгыр төнгә каршы тагын көчәеп китте*. М.Әмир. *Халыкның аңарчы басылып торган --- иҗади куәсе тормышның һәр өлкәсендә ургылып, бәреп чыкты*. Казан утлары

**Басылып чыгу** Басылган булу, дөнья күрү. *«Шаһмаран» һәм «Салсал» исемле дастаннар Казан университеты басмаханәсендә басылып чыга*. И.Салахов. *Журналда басылып чыккан әсәрләрнең әдәби эшләнешләре төрлечә ---*. Казан утлары

**Басылып яту** Йокымсыраган халәт кичерү, актив булмау. *Тора-бара, бу моң иң каты йөрәкләрне дә ярылырга мәҗбүр итәрдәй булып үсте, күңелләрнең моңа кадәр басылып яткан иң нечкә, иң газиз хисләренә барып тиде*. Н.Фәттах

**БАСЫМ** I *и.* 1) Аяк басу, адым. *Биючеләрнең аяк басымнарыннан идәннәр дер селкенә*. К.Нәҗми

2) Бер аяк баскан, бер адым озынлыгындагы ара үлчәме. *Үзебезнең совет җирен бер басымын да бирмәбез*. М.Җәлил

3) Нәрсәгә дә булса авырлык яки көч белән басу, төшерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән сурәт, эз, уем

4) *физ.* Механик тәэсир көче. *Бу хәлне күргән Брим, йөгереп барып, торбадагы краннарны ачты, һәм су, басым астында ургылып, базга ага башлады*. Р.Мөхәммәдиев. *Көзге сыман ялтырап яткан юка кар элпәсе тыгыз, дымык җил басымына түзә алмый, челтер-челтер уала; чана эзләренә кар суы тибеп чыккан*. Ф.Сафин. *Газ басымы белән газ температурасы һәм молекулалар концентрациясе бәйләнеше түбәндәгечә белдерелә*. Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

5) Этү, кысу, кысрыклау. *Дошман безнең басымга түзә алмады*. Ә.Айдар

6) *күч.* Көч, хакимлек белән тәэсир итү, мәҗбүр итеп, көчләп эшләтү. *Әмма ул үзгәреш милли мәдәниятләрнең хәлен яхшырту юнәлешендә түгел, бәлки әле югарыдан басым ясап, ул басымны елдан-ел көчәйтү һәм барысын да бер калыпка сыйдыру юлында эшләде*. К.Миңлебаев. *Ләкин нинди генә сәясиэкономик басым астында булмасын, хезмәт ияләре гаделлек өчен аяусыз көрәш сафына бастылар*. Казан утлары. *Мондый хәлне сәясәтчеләрнең бер өлеше «административ басым нәтиҗәсе» дип бәяли*. Шәһри Казан

7) *лингв.* Сүздәге иҗекне яки сөйләмдәге сүзне көчлерәк тавыш белән әйтү. *Басым сөйләмнең бер кисәген (иҗекне, сүзне, сүзләр тезмәсен) башкаларыннан аерып куя*. Ф.Сафиуллина. *Газинурга карап ала-ала, басымнарны һәм авазларны мөмкин кадәр ачыграк бирергә тырышып, кычкырып әйтеп тора*. Г.Әпсәләмов. *Паузаларда көчле басым китерелә, һәм басым үз якынындагы иҗекләр басымының ничек оештырылуына йогынты ясый*. Г.Нигъмәти

8) *иск.* Бастырырга таратып җәелгән ашлык, җәем. *Әнисә --- ындыр эшләренә бер көн дә калмастан катнашып йөрде. Бергә арыш суктык, басым бастырдык, бәрәңгеләр казыдык*. З.Бәшири

◊ **Басым ясау** 1) Нәрсәгә дә булса аеруча әһәмият биреп, игътибарны шуңа юнәлтү. *Директор Чечнядагы банда оешмаларының кылган гамәлләрен, ничә солдатны яралавын бәян итә, сугыш операцияләре барышына бәя бирә, басым ясап, бәйсезлеге өчен кулына корал алган чечен сугышчыларын бандитлыкта гаепли*. Н.Хәсәнов. *Команда的 яшь әгъзалары исә, Рим Шәфыйковичның, «начальник» кына булып калмыйча, остаз һәм тәрбияче икәнлегенә дә басым ясадылар*. Татарстан; 2) Янап, үгетләп, үпкәләп яки рәнҗеп, көч, хакимлек белән, башкаларның фикеренә тәэсир итү. *[Миңниса җиңгинең] Бу төртмәле сүзләре, баягыча көчле басым ясау теләге белән түгел, бәлки үзсүзләнеп әйтелгән көчсез каршылык кына иде*. Ә.Фәйзи. *Әмма ул үзгәреш милли мәдәниятләрнең хәлен яхшырту юнәлешендә түгел, бәлки әле югарыдан басым ясап, ул басымны елдан-ел көчәйтү һәм барысын бер калыпка сыйдыру юлында эшләде*. К.Миңлебаев

**БАСЫМ** II *и.* Гармун һ.б. уен коралларының клавиатурасы урнашкан өлеше, «колагы». *Гармуныңның басымы – алтын, Мехы – кытай ефәге*. М.Фәйзи

**БАСЫМ** III *с. диал.* Басынкы, тыйнак. *Үзең, тегеләй, басым гына, дәрвиш кенә, дип әйтимме инде*. Ш.Камал

**БАСЫМЛА́У** *ф. сир.* 1) Үлчәм алып яки башкача үзенчәлекле хәрәкәт ясау. *Басымлап үлчәү*

2) Һәр басмасына басып менү. *Баскычка берәр басымлап менделәр*. Г.Бәширов

3) *күч.* Игътибарны юнәлтү, басым ясап әйтү. *[Һ.Такташның] --- төп фикерне басымлап әйтүе тыңлаучыларга ифрат зур поэтик тәэсир ясый иде*. Р.Заһидуллина. *Сүзенең һәр иҗеген сузып, басымлап, елый-елый ялынган бер*

*тавыш белән, миңа сабак бирә башлады.* Х.Сарьян

**БАСЫМЛЫ** *с.* 1) Басым куелган; үзенә басым төшкән. *Басымлы сүзнең үзеннән соң килгән басымсыз сүз белән бергә әйтелүе энклиза була.* Тел белеменә кереш

2) Авырлык китерә торган. *Патша Россиясендәге бу атмосфера милли өлкәләрдә аерата авыр басымлы булды.* М.Гали

3) Авыр адымлы, салмак йөрешле. *Фәхри --- бу киң җилкәле, каты басымлы, чандыр йөзле эшче егетнең эшен күзәтеп килә.* Г.Ибраһимов

**БАСЫМЧАК** *с.* Артык тыйнак, бик юаш, басынкы, кагу-сугуларга түзә торган. *Арык кеше – алчак, базык кеше – басымчак.* Мәкаль

**БАСЫМЧА́К ИТҮ** *ф.* Санлашмау, санга сукмау. *Сез үзегезне бик алай басымчак иттермәгез. Аулак өйне көн дә ясамыйлар аны.* Казан утлары

**БАСЫМЧАКЛЫК** *и.* Артык тыйнаклык, юашлык, кагу-сугуларга түзү. *Пырдымсызланыр вакытларда да Луиза басымчаклык күрсәтеп килде.* А.Гыйләҗев

**БАСЫМЧЫЛЫК** *и. к.* **басымчаклык**

**БАСЫМЧЫЛЫ́К ИТҮ** *ф. к.* **басымчак итү.** *Кыз өстеннән андый басымчылык итү егет кешене бизәми.* Р.Зәйдулла

**БАСЫНКЫ** *с.* **1.** 1) Тыныч холыклы, юаш, бик тыйнак. *[Себер татарлары] Чак кына киңчә йөзлеләр, сабыр, басынкы холыклы, тыйнак табигатьлеләр.* М.Хәсәнов. *Көне-төне башы эштән чыкмаган басынкы татар кызының гүзәллеген ни белән аңлатырга?* М.Әмирханов. *Бәлки, бу – Сәкинәнең холкы басынкы, характеры юашлыктан киләдер, әмма, күрә белгән кешегә, Сәкинәдә матурлык җитәрлек.* Казан утлары

2) Күңелсезлек төсмере бирә торган, салынкы. *Аның басынкы моңсу карашы эчендә сагыш-хәсрәт ятканны сиздереп тора.* З.Фәйзи

3) Тыенкы, әкрен. *Җыр әкрен генә тынуга, басынкы һәм киеренке тавыш белән, Актабанов кайнар сүзләрен бер-бер артлы тезәргә тотынды.* Ш.Маннур

4) *диал.* Тәбәнәк, карсак

5) Салынкы, түбән төшеп торган. *Жандарм офицеры --- басынкы кашлары астыннан бер тапкыр гына күз салды.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ. к.* **басынкылык** (*2 мәгъ.*). *Шул басынкыдан рухыны издермәс өчен кебек, татлы хыяллар дөньясын сөйли торган җылы китап эченә чумган иде.* Г.Исхакый

**3.** *рәв. мәгъ.* Тыенкы гына, салмак, әкрен генә. – *Менә чыгып та җиттек, кызым, – диде карт, басынкы гына.* Н.Фәттах. *Яннарыннан, сөйләшеп, басынкы көлешеп, үзләренчә чикылдашкан булып, кызлар үтеп китте.* Ә.Хәбибуллин

**БАСЫНКЫЛАНУ** *ф.* Уйчанланып, җитдиләнеп калу, басынкы булып китү. *Борһанны әйтәм әле, ай-һай үзгәргән. Сүз-өне дә басынкыланган.* М.Хәсәнов. *Нәзирә, сөйләгәндә, йә дәртләнеп, канатланып киткәндәй була, йә кинәт басынкылана.* Г.Сабитов. *Хәзер инде үзе дә олыгая бара, холкы да басынкылана торгандыр.* Р.Миңнуллин

**Басынкылана бару** Торган саен ныграк басынкылану

**Басынкылана төшү** Беркадәр басынкылану. *Ул инде бераз басынкылана төшкән.* Т.Миңнуллин

**Басынкыланып бетү** Тәмам басынкылану

**Басынкыланып калу** Беркадәр вакыт узгач,ниндидер сәбәптән соң басынкылану. *Шәмсия чыгып киткәч, Хәлфетдин бөтенләй басынкыланып калды.* Ф.Сафин

**Басынкыланып килү** Акрынлап басынкылану

**Басынкыланып китү** Кинәт басынкылану. *Заһидә, ниһаять, ярсудан талчыгып, басынкыланып киткәндәй булды.* М.Маликова

**Басынкыланып тору** Әле хәзер, күз алдында басынкылык күрсәтү

**БАСЫНКЫЛЫК** *и.* 1) Басынкы булу. *Шәрифуллин, --- үзен сабыр тотарга тырышып, баштагы күтәренке тавышын басынкылык белән алмаштырды.* С.Рафиков

2) Авыр тойгылар, күңелсезлек, боеклык. *Шыбыр-шыбыр ява торган вак яңгыр күзгә төртсәң күренмәс караңгы төнгә тагы караңгылык куша, авыр һавага тагы басынкылык бирә иде.* Г.Исхакый

**БАТА** *и. диал.* Фатиха, изге теләк; бәрәкәт, кот. *Атасыз йорт – батасыз йорт.* Мәкаль

**БАТА́-КАЛКА** *рәв.* Бер батып, бер калкып. *Калкавычлар су өстендә бата-калка уйнаклап торалар иде.* Ф.Хөсни. *Су өстендә бата-калка тибрәнгән түшләреннән ике «ут шары» өстемә тәгәрәп килә кук.* Н.Хәсәнов

**БАТАЛИСТ** *и. фр.* Сугыш күренешләрен ясаучы рәссам. *Ә менә атаклы рус баталисты В.В.Верещагин (1842–1904) сугыш михнәтләре кичергәндә дә рус солдатларының какшамас, түземле булуларын сурәтли.* К.Гыйззәтов

**БАТАЛЬОН** *и. фр.* Полктан түбәнрәк булган, берничә махсус взвод һәм ротадан торган хәрби берләшмә. *Оренбургта төзелгән мөселман батальоны комиссары буларак әйтәм – көч безнең якта, халык безнең якта.* Ф.Сафин. *Хисмәт белән Хәкимулла бер батальонда сугышка керделәр.* М.Мәһдиев. *Башка командирлар кебек тырт-тыртланмыйча, егет белән, иплә, үз малае белән фикерләшкән кебек сөйләште күрше батальон хуҗасы.* Т.Галиуллин

**БАТАРЕ́Я** I *и. фр. хәрби* 1) Берничә орудиядән торган миномёт яки артиллерия берләшмәсе. *Батарея Сталинградка якынлашып килә.* С.Сөләйманова

2) Шушы берләшмәне урнаштырыр өчен махсус җайлаштырылган урын. *Кызыл гвардия һәм матрослар Дутов юнкерларын җиңеп, аларның Сырт тавына урнашкан батареяларын алу белән, шәһәрдәге атаман диктатурасына чик куелды.* Ш.Усманов

**БАТАРЕ́Я** II *и. фр. мах.* 1) Гальваник элементлар яки аккумуляторлар җыелмасы – ток чыганагы. *Айда яшәүчеләр аны кояш батареяларыннан алачаклар.* Р.Фәизов

2) Аерым секцияләрдән җыеп ясалган, пар яки кайнар су белән биналарны,

бүлмәләрне җылыта торган җайланма. *Соңгы елларда күмер хәстәрләү мәшәкате белән чиләнгән авыл халкының өйләрен, шәһәрдәге шикелле үк, батареялар җылыта.* К.Миңлебаев

3) *махс.* Йорт кошларын асрау өчен, җылытыла торган, махсус конструкцияле, күп катлы читлек. *Кошчылык фабрикаларында күп этажлы читлекләрдә – батареяларда – ун меңнәрчә һәм йөз меңнәрчә тавык асрыйлар.* Зоология

4) *шаярт.* Нинди дә булса бертөсле әйберләр рәте

**БАТАТ** *и. исп.* Җылы якларда үсә торган, бәрәңге сыман ашарга яраклы бүлбеләре булган тамыразык үсемлек. *Бататның бүлбеләрен ашамлык, терлек азыгы буларак, техник спирт, патока алу өчен кулланалар.* Ботаника

**БАТА́-ЧУМА** *рәв.* 1) Ләмгә, суга һ.б.ш.га батып, бата-бата. *Көзге суык пычракларда яланаяк, яланөс, балчык эчендә бата-чума, безнең отрядка патроннар ташып йөрдең.* Ш.Камал. *Без, бата-чума, ташулар карап йөргән урында, ни күзең белән күрерсең, тирәк күләгәсендә, «әттәгенәсе» дип кинәнәкинәнә, балык каптырып утырмассыңмы?* Г.Сәгыйров. *Алга китте [Карәхмәт] бата-чума балтырдан.* Ә.Исхак

2) *к.* **бата-калка**

**БАТИСТ** *и. фр.* **1.** Киҗе-мамыктан яки җитен җептән тукылган юка, үтә күренмәле тукыма. *Мин көн буе хыялларга чумып ятам: тизрәк үссәм, кеше булсам, акча эшли башласам, күп итеп, апак батист белән чигү җебе алыр идем.* М.Маликова. *Эстәдеңне ки: асылынмы, йонмы, сатинмы, батистмы, ситсымы – минем өчен бар да бер.* Г.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Батистан тегелгән. *Батист кофта. Батист яулык*

**БАТКАК** *с.* **1**. Пычрак, былчырак, бата торган, сазлыклы. *Рифкать --- соры тасма булып сузылган баткак юлга чыкты.* Р.Вәлиев. *Тупыл янында баткак саз бар икән.* Г.Гыйльманов. *Сусыз чүлләрдә һәм баткак сазлыкларда да алар шактый киң мәйдан алып тора.* Ботаника

**2**. *и. мәгъ.* 1) Бата торган сыек балчыклы, пычрак урын; сазлык. *Бер йөз ярым чакрым кадәр җирне баткак буенча китте.* Г.Тукай

2) *диал.* Ябышкак, үзле балчыклы урын. *Егылды ул кисәктән, чөнки баткактан аяк тайды.* Г.Тукай

3) *күч.* Төрле мәшәкатьләр, чуалчыклар. *Кешеләр --- тормыш баткагыннан чыгу юлын бергә эзлиләр.* Һ.Такташ

**БАТКАКЛАНУ** *ф.* Изелү, бата торган хәлгә килү, баткакка әверелү. *Кырысланды һава, Көн-төн яңгыр ява, Каралдылар кырлар, Баткакланды юллар.* Ә.Исхак

**Баткаклана бару** Торган саен ныграк баткаклану

**Баткаклана төшү** Беркадәр баткаклану

**Баткакланып бетү** Тәмам, бик нык баткаклану. *Коридорның идәне җир икән. Ул да баткакланып беткән.* С.Поварисов

**Баткакланып китү** Нинди дә булса тәэсир итүләр нәтиҗәсендә, кинәт баткаклану

**Баткакланып тору** Баткакланган хәлдә булу

**БАТКАКЛЫК** *и.* 1) Сазлык, бата торган, сыек балчыклы урын. *Борынгы заманда биек таулар, калын урманнар, тау аралары йөри алмаслык баткаклыклар, сазламыклар белән капланган булган.* Г.Гобәйдуллин. *Һич булмаган Бу сазлыкны-баткаклыкны Ерып чыгарлык.* Ә.Исхак

2) *күч.* Тормышта була торган төрле кыенлыклар, мәшәкатьләр, комачаулар, җитешсез яклар. *Кемлегебезне, яшәү рәвешебезне чагылдырган шушы дөнья баткаклыгыннан, чүп-чарлар арасыннан алтынга тиң хакыйкатьне эзләп кара син!* Н.Хәсәнов

**БАТКАЛАК** *и.* 1) Елга, күл читләрендәге ләмле, балчыклы баткак урын. *Бака туе – баткалакта.* Мәкаль

2) Яз көннәре карны казып, сизелмәслек итеп өстен кар белән каплап ясалган алдавыч. *Гали әнә кар ташый, Энҗе баткалак ясый.* М.Укмасый

**БАТМАЛЫ** *с. диал.* Бата торган, баткаклы. *Батмалы, мүкле, сазлы Сарс елгасының дамбасы да, күпере дә күп эшләр көткәнлектән, тимер юл төзү участкасының конторы --- читтәге авылда билгеләнде.* Т.Госман

**БАТМАН** *и.* 1) Тар биек кисмәк, бал тәпәне. *Диим бер сүз, бүтән бер сүз дә катмам: «Хатын алсаң, кирәк ит көн дә батман!»* Г.Тукай

2) *иск.* Чәчелә торган, бөртекле әйберләр өчен күләм яки авырлык үлчәү берәмлеге (төрле җирдә төрлечә: унике кадак, дүрт пот; ун пот чамасы). *Бер батман кургашын салгандай башын кыймылдатып маташты, әмма хәленнән килми иде.* К.Миңлебаев. *Орчык башы хәтле генә сөйкемле марҗа, аху килеп, ухватка утыртып, киң авызлы юмарт мичтән бер батман су сыешлы чуенны тартып чыгарды.* А.Гыйләҗев

**БАТМАНЛАП** *рәв.* 1) Батман белән үлчәп

2) *күч.* Батман үлчәме кадәр; күпләп. *Авыру батманлап керә, мыскаллап чыга.* Мәкаль

**БАТРАК** *и.* 1) *тар.* Шәхси хуҗалыкта тамак хакына авыл хуҗалыгы эшләрен башкарырга ялланган хезмәтче, ялчы, көнлекче. *Батракларның хәле белән танышып йөрим.* М.Маликова. *Әхмәтханны укырга алып китеп булмады – ул Бөкре Бәдертдингә батрак булып урнашты.* Ф.Сафин. *Германиянең Югары Силезия дигән җирендә, бер байда батрак булып эшләргә туры килә әтигә.* Сөембикә

2) *кыек килешләрдә к.* **батраклык**. *Матур сүзгә юмарт, ягымлы кешеләр дә очрады. Яшьтән үк батракта яшәгән Хәким абзый Сәйфуллин шундыйларның берсе булды.* И.Туктар

**БАТРАКЛЫК** *и.* Батрак хезмәте, батрак булу хәле. *– Муллада батраклыкта йөргән кеше кайдан килеп әйбәт язсын? – Гөлчирә авыр сулап куйды.* С.Рафиков. *Балачак батраклыкта узган.* Г.Гыйльман

**БАТРА́ЧКОМ** *и. рус тар.* Ярлылар комитеты. *Тимерче Бикбай да партиягә керде. Аны батрачкомга председатель итеп сайладылар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**БАТУ** *ф.* 1) Авырлык көче сыеклыкныкыннан зуррак булу сәбәпле, өслектән үзеннән-үзе төпкә төшеп китү. *Сыек сөт бит, бата, һич тә табактан ычкынып булмый.* Г.Тукай. *Әмма аның*

*саен төпкәрәк батты.* Г.Бәширов. *Авыздан су агу тукталганнан соң, суга баткан кешене чалкан әйләндереп яткыралар һәм ясалма сулыш алдырырга керешәләр.* Йорт эшләре

2) Көпшәк, йомшак, үзле һ.б.ш. масса эченә кереп урнашып калу, кереп чуму. *Каты буранның икенче көнендә, безнең авыл башында, остабикәсе белән кунактан кайтучы бер мулла аты белән карга баткан иде.* Г.Тукай. *Һәр чанага, юрганнар, мендәрләр эченә батып, ирле-хатынлы икешәр кеше утырган.* Г.Ибраһимов. *Фәрит машинаны тагын да кискенрәк бордырып та алды – су тулы чокырга төштек тә баттык.* К.Миңлебаев

3) Су яки үзле масса эченә күмелеп, тончыгып үлү. *Күгәрчен, суда бер кырмысканың батып һәлак булырга җиткәнен күргәч, дәрхаль, авызына бер яфрак капты да суга ташлады.* Г.Тукай. *Тукта әле, мин бит суга батмаган.* А.Әхмәт

4) Юл яки баскан җир, көпшәк, сулы, үзле һ.б.ш. булу сәбәпле, уелып керү. *Аяк асты тубыктан бата, кайбер җирләрдә кыска кунычлы итек бөтенләй чумып-чумып китә.* Г.Ибраһимов. *Исмәгыйль, комга тездән бата-бата, җәяүләп китте.* Г.Тукай *Сукмак тар, аякларны туп-туры басарга кирәк, юкса, батасың.* М.Маликова

5) Эчкә уелып керү, чокырланып тору. *Яңак итләре батып, битенең эре-эре сөякләре калкып чыктылар.* Г.Ибраһимов. *Аның бик аз гына эчкә баткан моңсу күзләре йомылды, һәм кара күз керфекләре аша, сыгылып, яшь бөртекләре чыкты.* А.Әхмәт. *Шушы берничә сәгать эчендә ул күзгә күренеп ябыкты, күзләре батып, күз төпләренә күләгә төште, яңак сөякләре калыкты, ике каш арасындагы сызыгы тирәнәйде.* И.Гази

6) Бик нык чылану яки буялу. *Сезгә кем соң мал таба, эшләп йөреп, тиргә батып?* Н.Исәнбәт. *Бердәнбер көнне бу әтәчләр шулай бик каты кычкырышканнар һәм канга батканчы сугышканнар.* А.Алиш. *Тырыша-тырмаша торгач, тирләп, ап-ак күбеккә батты.* Тәмуг чәчәге

7) Бик мул, куе булган берәр нәрсә белән каплану, томалану. *Барысы караңгылыкка баш игән, барысы да болыт астына баткан иде.* Г.Исхакый. *Кияү бүлмәсе ак, кызыл, кара, яшел, саргылт, зәңгәр, күгелҗем кара, сыек миләүшә төсләре дулкыны эченә батты.* Г.Ибраһимов

8) Күк җисемнәре офык артына төшеп күмелү, баю. *Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата; Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.* Г.Тукай. *Менә шәфәкъ батты, төн булды, Күләгәләр җирдән сөрелде.* Н.Исәнбәт. *Без авылга кергәндә, кояш баткан иде инде.* М.Әмир

9) *күч.* Берәр нәрсәнең артык күбәюенә, басып китүенә дучар булу. *Бурычка баткандыр, я әйберен саткандыр.* Г.Ибраһимов. *Җиргә ябышып каткан ясмыкларым. Ак әремгә баткан солылар.* Ш.Маннур

10) *күч.* Нәрсәгә дә булса ирешергә һичнинди мөмкинлек күренмәүдән, нәрсәнеңдер ишәюеннән котылу чараларын таба алмаудан, авыр хәлдә калу; эчке кичерешләрнең тирәнлеген чагылдыру. *Берничә генә секундка дәвам иткән бу хәлдән соң, кинәт, йөрәк үзенең үткәннәреннән, сикереп, читкә китте дә авыр өметсезлеккә батты.* Ф.Әмирхан. *Гомумән алганда, шушы сәбәпләр аркасында, ул, наданлык, фәкыйрьлек чокырына батып, башка милләтләрдән бик күп артка калган.* Ш.Камал

11) *күч.* Нинди дә булса халәт биләп алу, шул халәт чолганышында калу. *Вокзал юлларында туктаган ике эшелон, үлгән шикелле, тынлыкка баткан.* Ш.Усманов. *Бикбулат, калын каш-ларының бөркәве астында посынган кечкенә күзләре белән идәнгә текәлеп, авыр тынлыкка батты.* Г.Бәширов

12) *күч. гади с.* Каядыр китеп, озак кайтмый тору, китеп югалу, көттереп зарыктыру. *Берегез Мәскәүгә китеп батып торды, икенчегез өлкәткомга барып ябышып калды.* Ш.Камал. *Батып калма Дубки ягында!* Ш.Маннур

13) *күч. гади с.* Ярау, яраклы булу, кабул ителерлек булу. *Хикмәт – сүзнең рәтен белүдә, рәтен белеп сөйләсәң, ни турында булса да бата.* М.Әмир. *Миңа нәрсә сөйләсәң дә бата.* Р.Мөхәммәтҗан. *Әнә шундый җирдә хикәят бик бата инде ул, әкият!* К.Миңлебаев

14) *күч.* Аш-суның үзләштерелүе, кабул ителүе. *Безгә ни бирсәң дә бата, талымланып тормыйбыз.* Ә.Еники

15) *күч. гади с.* Үзләштерелү, урлану. *Тирә-якта, кооперацияне таласалар, андагы мал да Батыршаларда бата, имеш, дигән хәбәр тарала иде.* Ф.Сәйфи-Казанлы

16) *күч. гади с.* Начар юлга басу, бәлагә тару, төрле авырлык, кыенлыклар күрү. *Кешенең бата башлавын белә торып, аңа ярдәм кулыңны суза алмавың – нинди гаҗизлек!* Г.Бәширов. *Ил батырны сыный батканда.* М.Җәлил

◊ **Баткан аяк чыланган** Ярамаган эшкә бер катнашкансың икән, аннан ваз кичү мөмкин түгел, мәгънәсендә. **Батканнан, саламга тотыну** Кыен хәлдә калганда, аптырап, юк чарага ябышу. **Баткан тайганнан көлгән** Үзе дә шул хәлдә булуга карамастан, кешедән көлгән; икесе дә бер хәлдә булган. **Батмастан, күбеккә (саламга) тотыну** *к.* **батканнан, саламга тотыну**

**Бата бару** 1) Торган саен ныграк бату

2) *күч.* Булган берсе, һәрберсе бату. *Ләкин җибәргән берсе – боларда бата барды.* Г.Ибраһимов

**Бата башлау** Батарга тотыну

**Бата төшү** Тагы да бераз бату

**Батып алу** Бераз вакытка бату. *Ике тапкыр тәнәфес ясалды, ирләр тәмәке төтененә батып алды.* М.Мәһдиев

**Батып бару** Акрынлап бату. *Ә яр буендагы кафеның тәрәзәсе исә шулхәтле көчле балкый, әйтерсең диңгезгә бер кырые белән батып барган кояш, икенче кырые белән, шул тәрәзәдән мең мәртәбә артык ялтырап чыгып килә.* Г.Әпсәләмов

**Батып бетү** Тәмам, бик нык бату. *Канга батып беткән гәүдәсен чак-чак кыймылдатып, Шәрифулла янә ерак юлга чыга.* В.Имамов

**Батып йөрү** Әле, хәзерге вакытта баткан булу. – *Син нәрсә, түли алмаслык бурычың булгандай, кара кайгыга батып йөрисең? – диде ул иренә.* И.Хәйруллин

**Батып калу** Чыга алмаслык булып, тәмам бату. --- *әүвәл заманнарда гөрләп, шаулап торган бу ишегалды хәзер әллә нинди серле тынлык – җанны авырайта торган тынлыкка батып калган иде.* Ф.Әмирхан

**Батып килү** Баткан хәлдә булу. *Тешләре кысылып-кысылып килгәндә, яңаклары батып килде.* Н.Хәсәнов.

**Батып китү** Кинәттән тоташ, тулысынча бату. *«Разия» дигән сүзне ишеткәч, карчык нур эченә батып китте.* Ф.Әмирхан

**Батып кую** Кинәт, уйламаганда бату

**Батып тору** Һәрберсе, булган берсе бер-бер артлы бату

**Батып утыру** Әле, хәзер баткан хәлдә булу. *Бу шәһәр бакча эченә батып утыра.* Г.Гобәйдуллин. *Кышларын үтә алмаслык кар-бураннарга батып утырган, җәйләрен тирән тау елгалары һәм төпсез сазлыклары белән сагалап торган кырык сырт.* Ф.Бәйрәмова

**БАТУН** *и. рус* Лаләчәләр семьясыннан, яшел кыяк өчен үстерелә торган күпьеллык суганның бер төре. *Батун суганны сентябрь уртасында кисүдән туктыйлар, ул шулай кышка ныгып кала.* Татарстан яшьләре. *Батун суган – бик тармакланучан, салкыннарга бик чыдам булган күпьеллык үсемлек.* Җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы

**БАТУТ** *и. фр.* Спортта, циркта: сикерү өчен тарттырып куелган эластик челтәрдән гыйбарәт спорт җиһазы

**БАТЫК** *с. диал. к.* **батынкы.** *[Мәрьямнең] Борын уртасы батыграк, ирennәре – калын...* Ш.Камал

**БАТЫМ** *и.* Эчке якка батып кергән урын. *[Терлек] Тимпания белән авырганда, бил янындагы ач батым тулып, күпереп чыга.* Сөт терлекчелеге турында белешмә

**БАТЫНКЫ** *с.* 1) Өслек өсте бераз эчке якка батып, уелып кергән. --- *Исхакны «аз гына ял итегез» дип, интернатның батынкы панцирь ятагына кертеп салганда --- интернат келәтенең стенасына кара халат кигән гаҗәеп чибәр җиде-сигез яшь хатын тезелеп сөялгән һәм, Әнвәр Бакиров скрипкасына кушылып, яңа җыр җырлыйлар иде.* М.Мәһдиев. *Җисемнең батынкы сферик көзгедәге сурәте, җисемнең үзенә караганда, ике тапкыр зуррак.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

2) Тирән урнашкан, батып торган. *Батынкы күз куышлыгыннан өметсезлек рухы бөркелә.* Н.Хәсәнов. *Батынкы кара күз төпләре күләгәләнеп, җыерчыкланып калган.* Н.Хәсәнов

**БАТЫНКЫЛЫК** *и.* Өслеккә батып кергән уем. --- *сабакның тышкы яктан кырлы булуы күренә, ягъни калку урыннар батынкылыклар белән чиратлаша.* Л.Мәүлүдова

**БАТЫР** *и.* **1.** 1) Кыю йөрәкле, тәвәккәл, көчле кеше. *Ул миңа хәзер «кара малай» булып түгел, ә колхоз кырында трактор, комбайн йөртүче батыр булып күренде.* Р.Кәрами. *Батырларның чиксез батыры, Егетләрнең тиңсез асылы.* Ф.Бурнаш. *Хәрәмша акыллым, син – батыр, Дәүләтша сөеклем, син – матур.* К.Тинчурин

2) Сугыш кырында батырлык күрсәтеп дан алган кеше; баһадир, каһарман. *Батыр үлә, үлмәс ат алып.* М.Җәлил. *Алар да батырлар үлемсезлеген сөйли.* Н.Хәсәнов. *Батырларны хөрмәтләгән халык: Дастаннарга кадәр күтәргән.* Х.Әюп

3) *спорт* Көрәштә, барлык башка көрәштәшләрен җиңеп, иң көчле булып калган кеше, көчле һәм оста көрәшеп җиңүче. *Һич батыр каршы тора алмаганнан соң, Пәһлеваннар барчасы калды таңга.* М.Гафури. *Улыска ничәмә-ничә галава биргән, типсә тимер өзәрдәй егетләре бөтен төбәктә үткәрелгән сабантуйларында батырга кала килгән --- Кече Чынлы халкы берни эшли алмый, паралич суккандагыдай, аптырап-югалып кала.* К.Миңлебаев. *Сабан туе батырыдай ныk бәдәнле, киңчә җилкәле Потапов торып баскач, аның янында Ринат кечерәеп калгандай булды.* Н.Хәсәнов

4) Мифологик әсәрләрнең, әкият һәм дастаннарның баш каһарманы (герое). *Чын мәгънәсендәге эпик-мифологик Батыр образының килеп чыгышы һәм формалашуы борынгы чорлардагы рухи процесслар белән бәйләнгән.* Ф.Урманче. *Иң әүвәлге мифологик Батырлар – Аллалар яки шулар дәрәҗәсендә торган затлар булган, дип уйларга мөмкин.* Ф.Урманче

**2.** *с. мәгъ.* Гайрәтле, курыкмас, кыю, тәвәккәл. *Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»* Г.Тукай. *Кая китте синең балаларың? Арыслан күк батыр улларың?* А.Алиш. *Дошман гаскәрләренә каршы танк белән барган, Кызыл Йолдыз, Дан орденының өченче дәрәҗәсен алган батыр сугышчы хәзер нишләр?* М.Мәһдиев

**3.** *рәв. мәгъ.* Куркусыз йөрәкле, тәвәккәл. *Гражданнар сугышында батыр булганы өчен, Рөстәмнең бабасына командиры бүләк итеп биргән ул шахматны.* Тәмуг чәчәге. *Аякларын көчкә сөйрәп йөрсә дә, тавышка батыр иде ул: карт сөйләшә башласа, урман яңгырый иде.* Казан утлары. *Фәния эшкә батыр булып чыкты: башта өй, абзар тирәсен рәткә кертү белән мәш килде.* Юлдаш

**БАТЫРАЙТУ** *ф.* Кемне дә булса үзенең батырлыгына ышандырып, көч-куәт кертү, батырлык, кыюлык эшләргә этәрү. *Һәм, дүртенчедән, Рахмановның, башта бик әтәчләнеп тә, хәзер гаебен сизгән төсле юашланып калуы мине батырайтты.* М.Әмир

**Батырайта бару** Акрынлап, торган саен арттыра барып батырайту

**Батырайтып алу** Кыска гына вакытка батырайту

**Батырайтып бару** Тагы да батырайту. *Эчтән хәтәр кыҗрап, үз-үземне батырайтып барам.* Х.Камалов

**Батырайтып җибәрү** Бераз, берникадәр батырайту. *Павел белән Павлик үрнәге Сәлимәне батырайтып җибәрде.* Г.Гобәй. *Минем уйга талып, икеләнеп калуым Идеалны тагын да ныграк батырайтып җибәрде.* М.Шаһимәрдәнов

**Батырайтып тору** Һәрвакыт, гел батырайту

**БАТЫ́Р АСТЫ** *и.* Көрәштә, беренчедән соң, икенче урын

**БАТЫРАЮ** *ф.* Кыюлану, үзендә көч-куәт, батырлык сизү. *Мин, диде, авылда җавап алган вакытта, диде, авыл хатыннарының миңа төрле яла*

*ягуларыннан куркып, диде, дөресен сөйләргә курыккан идем, диде, соңыннан --- бөтен куркуларымны, оятларымны бер якка ташладым да, дөресен сөйләр өчен, батыраеп, монда судка килдем.* Г.Камал. *Кайтып җитәрәк батырайдык.* Н.Хәсәнов

**Батыраеп алу** Кыска вакытка беркадәр батыраю

**Батыраеп җибәрү** Кинәт батыраю

**Батыраеп йөрү** Әле, күз алдында үзен батыр итеп күрсәтү. *Әле моңарчы тавыклары алдында сер бирәсе килмичә батыраеп йөргән чуар әтәч иманеп китте*. Т.Мөбарәков

**Батыраеп китү** Кинәт кенә, ниндидер моменттан, сәбәптән, шарттан соң батыраю. *Бер-береңне сөйсәң, кызык икән ул; әллә нинди авырлыкларны да онытып, батыраеп китәсең.* М.Фәйзи. *Бригадирның бу уеннан кире кайтмаячагын күреп, үзе дә бераз батыраеп китте.* Г.Гобәй. *Йөзем суының алтынчы чынаягын эчкәч, Вәли абзый батыраеп китте…* Ә.Фәйзи

**Батыраеп кую** Көтмәгәндә бераз батыраю

**Батырая бару** Вакыт узган саен батырлануы көчәю

**Батырая башлау** Батырланырга тотыну, батырчылык итү

**Батырая төшү** Беркадәр батыраю

**БАТЫР(ГА́) КАЛУ** *ф.* Көрәштә, башка көрәштәшләрен җиңеп, иң көчле булып танылу. *Әйе, типкәч – тимер өзәрлек егет идем, мин шул сабан туйларында ике ел рәттән батыр калдым.* А.Шамов

**БАТЫРГЫЧ** *и.* Нәрсәне дә булса тагы да тирәнгәрәк батыру өчен, махсус тагылган авырлык, йөк. *Бикмүш бабай белән Илсөяр бауның бер очын кармакка тактылар, батыргыч куйдылар.* Г.Гобәй

**БАТЫ́Р КЫЧКЫРУ** *ф.* Көрәштә, җиңеп, беренче урынны алган кешене игълан итү. *Мөхәммәдулла абзагыз, таягын һавада уйнатып, Нурулланы батыр кычкырды.* Мәдәни җомга

**БАТЫРЛАНУ** *ф.* 1) Кыюлану, батырчылык итү. *Ләкин күңелемдә туган тискәре мин-минлек тагын котыртты мине, батырланып, кычкырып җибәрдем.* М.Әмир. *Бер башлангач, Госман да батырланды.* Г.Ибраһимов. *Бара-бара, яшел урманга барып җиттеләр, бернигә карамый, батырланып, куе урман эченә кереп тә киттеләр.* А.Алиш. *Балалар, үзара сөйләшкәләп, башта кыймыйча, соңыннан, батырланып, кайсы – койма өстенә, кайсы капканың аръягында үсеп торган агач ботакларына менеп атланалар.* Д.Аппакова

2) Бик кәпрәеп, кыланып, батыр булып күренергә тырышу. *Югыйсә, бер дә юкка батырланып, берничә мең эшченең һәлак булуына сәбәпче булырбыз.* Ш.Усманов. *Эчкәч, батырланып сындырырга тотына, алмалы ботак шартлап сына.* А.Алиш

**Батырлана бару** Торган саен ныграк батырлану

**Батырлана төшү** Беркадәр батырлану. *Кадыйр батырлана төште һәм кинәт: – Фатыйх абый! – дип куйды.* А.Алиш. *Җинаять кылырга җыенучыларның бөтен мускуллары киерелде, алар батырлана төштеләр*. Р.Фәизов

**Батырланып алу** Бераз гына, кыска гына вакытка батырлану

**Батырланып җибәрү** Көтмәгәндә батырлану

**Батырланып йөрү** Кеше алдында батыр булып кылану. *Артыгын кыланып, батырланып йөрүне ташларга кирәк!* С.Сабиров

**Батырланып китү** Кинәт батырлану. *Әби бер – куркып, бер батырланып китте.* Г.Ибраһимов. *Шундый уйлар астында, мин кинәт кенә батырланып китәм.* М.Әмир

**Батырланып кую** Уйламаганда, кинәт батырлану

**БАТЫРЛА́РЧА** *рәв.* 1) Батырлар кебек, батырларга хас булганча. *Батырларча сугышып, берничә җәрәхәт алган…* Ф.Хөсни. *Тик ул радистка Кәримәнең кара төндә, япа-ялгыз, самолёттан дошман тылына сикерәчәген, партизан отрядында җитди сынаулар узасын, дошман белән бер бәрелештә батырларча һәлак буласын белми иде.* Р.Хафизова. *Бары тик сугыш бетәр алдыннан гына, Солтанның, ниндидер бер елганы кичкәндә, батырларча һәлак булуы турында әти-әниләренә язу килде.* Н.Фәттах

2) Йөрәкләнеп, батырлыгын җыеп. *Сара Гарифовна операцияне чын батырларча үткәрде.* И.Харитонов

**БАТЫРЛЫК** *и.* 1) Батыр булу. *Бронядан да ун кат ныграк булган Гвардияче кыю егетләр; Батырлыгы белән таң калдырган Газинур һәм Муса кебекләр.* С.Шакиров. *Батырлыгы аның мәңге калыр, Телдән – телгә, җырдан җырга барыр.* Ш.Маннур. --- *җан дустым Кашшаф Фәттаховның соңгы батырлыгы турында сөйләргә дип килдем, – диген Әшнәкле абый, кайнар күз яшьләрен тыя алмыйча.* Г.Гомәров

2) Кыюлык, тәвәккәллек, гайрәт. *Батырлык дигәндә, малайларны куш инде син.* К.Миңлебаев. *Патый әби үзе рөхсәт биргәндер, югыйсә, әнисе карап торганда, айгыр кебек егетләр алдына чыгып баш иярргә нинди җиткән кызның батырлыгы җитсен дә, ничек итеп, шуңа анасы елмаеп кына карап торсын, дип уйладым мин.* М.Әмир. *Кара акылым белән аңлавымча, сәүдә – батырлык, тәвәккәллек, тапкырлык сорый торган, Мөхәммәд пәйгамбәрдән калган изге һәм игелекле шөгыльдер ул.* М.Хәсәнов

◊ **Батырлык җиту (җитмәү)** Нинди дә булса эшкә тотынырга яки кемгә дә булса бер-бер сүз әйтергә кыюлык җитү, җөрьәт итү, тәвәккәлләү (яки шуның киресе). *Аңа кыеп әйтергә шунда батырлыгым җитмәде.* Г.Рәхим

**БАТЫРМА** *с.* Батырып куела торган. *Әлмәттәге батырма насослар заводыннан – 13000 сум --- ярдәм керде*. Р.Миңнуллин

**БАТЫРСЫНУ** *ф.* Батырларга хас хис кузгалу, батырчылык итү, йөрәксенү, тәвәккәллек күрсәтү. *Шулай да куштаннар үз фикерләрен ачык әйтергә батырсынмыйлар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**БАТЫРУ** *ф.* **1.** 1) Кемне яки нәрсәне дә булса су төбенә төшереп җибәрү. *Житен кибеп өлгергәннән соң, башларындагы төеннәрне кисеп, көлтәләрне елга эченә суга батырдылар.* Дәрдемәнд. *Су уртасына җиткәч, үзен бер батырыйммы, дип уйлаган*

*идем.* Ф.Әмирхан. *Бу Кыз-Алла үзенә ошаган кешеләрне, исән-имин килеш, елга аша чыгарып куя, ошамаганнарын батыра ала.* Т.Нәбиуллин // Сыеклык өстенә калкып чыкмасын өчен, өстән авыр әйбер белән бастырып кую. *Юкәне батырсаң, аңардан, ичмасам, менә диган мунчала чыга.* Ш.Камал

2) Көпшәк, тарала торган, йомшак һ.б.ш. әйбер эченә күмеп яки төшереп кую, яшерү. *Кара әле, син минем акчаны читек балтырына батырганны бер кешегә дә сөйли күрмә.* Г.Камал. *Төймәсен, инәсен кунычка, кесәгә батыра, һәммә нәрсә яшерелә, бетә, юк була.* Г.Ибраһимов. *Инженер Аббасов авыз эченнән мыгырданды да авыр башын мендәргә батырды.* М.Галиев

3) Нинди дә булса үткен, очлы әйберне эчкә, тирәнгә кадап кертү, чәнчү. *Көмеш сабына кадәр кылычны йөрәгенә аның батырды.* М.Җәлил. *Кадакны бер сугуда төбенә кадәр батыра аласыңмы?* Г.Әпсәләмов. *Үз җирләредәй күреп, әле тырышып-тырышып җир сөрде, әле көрәкне тирән-тирән батырып, чи калган урыннарны казыды.* Г.Гобәй

4) Баш киемен каш һәм колакларга кадәр төшереп кию. *Гашыйк абзый, кисәк кенә сүзен бетереп, өстәл ягыннан китте һәм скамьяда калдырган колаклы бүреген сыңар кулы белән башына батырып киде дә урынына утырды.* Ә.Еники. *Тора-торуга, ашык-пошык, сәләмә тунын киде, башына кыршылып беткән колакчынын батырды, мылтыгын эләктерде дә тышка атылды.* Г.Минский

5) Бик нык чылату яки буяу. *Анда Заһирәне канга батырып эштән чыгарган, монда – сине.* К.Тинчурин. *Ә иртәсен, ямый-ямый яңа тунымны, Инә белән чәнчеп, канга батырып, Җәрәхәтләп беттем кулымны.* Һ.Такташ

6) Җыеру. *Газинур, башын иңнәренә батырып, ихтыярсыздан, артка тайпылды.* Г.Әпсәләмов

7) *күч.* Дучар итү, нинди дә булса хәлгә төшерү. *Әнә хәлфә килә сукмактакырдан, Шәкертләрне наданлыкка батырган.* Н.Исәнбәт. *Учительнең русчалатып сораган сорауларына рус телендә тоткарсыз җавап бирүләре аны, бер яктан, сокландырды, икенче яктан, кайгыга батырды.* Ә.Фәйзи

8) *күч.* Кемне дә булса бәлагә калдыру, төшерү, хыянәт итү, сату. *Сез, ди, Вәли байны батырып, Садыйк Миңлебаевны коткарырга йөрисез, ди...* Г.Ибраһимов. *Их егет, егет, нигә мине батырырга телисең, сиңа ни усаллыгым тиде?* Һ.Такташ. *Саматов --- берәүләрне күтәреп, берәүләрне батырып эш итүче профессорны да бөтен дөньяга фаш итәсен әйтте.* Г.Әпсәләмов

9) *күч.* Күңелне яулап алу, әсир итү, биләү кебек хис уяту. *Аларны тирән уйга батырды.* М.Гафури. *Нигә серле гыйшкың упкынына алып кереп мине батырдың?* М.Җәлил

**2. батырып** *рәв. мәгъ.* 1) Текәп, текәлеп, төбәп. *Давыт аңа, әле ачык билгеле түгел, дип, бер генә сүз белән җавап кайтарды да, билennән кочаклап, кызны янына утыртты, үзе кебек үк батырып карап әйтте.* Г.Ибраһимов. *Исерек кеше кебек чайкалгалап һәм, үзенең дошманнарын хәтерләп калырга теләгән кебек, зур кара күзләре белән батырып карап бераз торгач, аның күгәргән иреннәре кыймылдап куйды.* И.Гази. *– Абау, күзләре, – диде Гашия, йөзен читкә борып. – Нигә шулкадәр батырып карыйсың, Хәйрулла абый?* М.Әмир

2) Бар көченә тырышып, күп тырышлык куеп, иренмичә. *Миңниса ялан эшләрен батырып эшләде.* Г.Ибраһимов

**Батыра бару** Торган саен күбрәк, ныграк батыру. --- *халыкны эшкә урнаштыруның барлык проблемалары безнең җилкәгә авыр таш булып утырачак, ә ул таш Татарстан экономикасын һаман батыра барачак.* Р.Хәкимов. *Туфан яза, бүлмәне кәгазь туфанына батыра бара.* Р.Батулла

**Батыра башлау** Батырырга тотыну. *Иртән әле сирәк-мирәк чеметкәләп киткән җил дә үзенең очлы сөңгеләрен, рәхимсез рәвештә, Юлчының битенә батыра башлады.* Н.Әхмәдиев

**Батыра бирү** Бернигә дә карамый батыруын дәвам итү

**Батыра килү** Электән үк, күптәннән бирле, даими рәвештә батыру. *Чәчкә Ана кебекләрне, шәех Игнәй кушуы буенча, мөтәгассыйб мөридләр елгага батыра килделәр.* М.Хәбибуллин

**Батыра тору** Берсе артыннан икенчесен батыру. *Андый бәдбәхетне, камчы белән ярганнан соң, тере эт, әтәч, елан, маймыллар белән бергә күн капчыкка салып, суга батыра торган булганнар.* М.Насыйбуллин

**Батыра төшү** Бераз батыру; тагын да батыру. *Бу суыкта озак басып торырлык түгел иде, Шәйхулла абзый, ике куллап бүреген батыра төшеп, китәргә җыенды.* Ә.Еники

**Батыра язу** Чак кына батырмый калдыру. *Тугызынчыда чакта... көймәне чайкалдырып, мине Кабан күленә батыра язды.* Г.Әпсәләмов

**Батырып алу** Тиз генә батыру. *Су алганда акрын ал ла, Батырып алсаң – болгана.* Ф.Бурнаш

**Батырып бетерү** 1) Барысын да батыру, төбенә кадәр батыру

2) Тулысынча батыру. *Безнең өйне нәҗескә батырып бетерделәр, ул якка карый да алмыйм хәзер.* Ф.Бәйрәмова

**Батырып җибәрү** Кинәт кенә батыру

**Батырып җиткерү** Тәмам, күмелгәнче, төбенә төшкәнче батыру

**Батырып йөрү** Батыру белән мәшгуль булу. --- *мин кит тоту флотилиясе «Советская Украина»ның китларны кырып, Антарктида тирәсендәге суларны канга батырып йөргәнен күрдем.* М.Галиев

**Батырып калу** *к.* **басып калу** (*2 мәгъ.*). *Беркөнне миңа, алмаштырырга дип, егерме биш тәңкә акча биргән иде, шул вакытта мин, бераз батырып калыйм әле, дип, бер өчлекне кесәгә яшергән идем, хәзер сиздe.* Г.Камал

**Батырып кую** Батырган хәлдә калдыру. *Үз ишләре тирәсенә якынлаша башлагач, бүрекне ул [Әгъләм] тагын да батырыбрак куйган иде шикелле.* Ф.Хөсни. *Кабалану хикмәтедер инде: малай, аңар ярдәм итү нияте белән, камытны алып, кире ягы белән кысрыклап, алмачуарның муенын буып батырып куйган.* М.Хәсәнов

**Батырып тору** Әле, хәзерге вакытта батыру

**БАТЫРЧЫЛЫК** *и.* Кыюлык, тәвәккәллек (күбесенчә *итү, кылу, җитү* кебек ярдәмче фигыльләр белән килә). *Ул әле – бер якка, әле икенче якка сугылды, арыш арасын ташлап, бушлыкка – урган җиргә чыгарга батырчылык итмәде.* Н.Хәсәнов. *Тик инде, анкеталарын тутыргач, профессорларның кикрикләре тиз шиңә: «халык дошманы»ның улын берәү дә үз канаты астына алырга батырчылык итми.* К.Миңлебаев. *Барысы да, ашыгып-ашыгып, сагыз чәйниләр, тик берәү дә әңгәмәгә аерым гына керергә батырчылык итми.* Р.Мөхәммәтҗан

**БАТЫШ** *и. сир.* Күк җисемнәренең баю күренеше, бату. *Беребез кояш чыгышында, беребез – батышларында.* Җыр. *Кояш чыгышы ягыннан исеп киткән йомшак җил игеннәрне кояш батышы ягына бөкрәйтте.* Ф.Әмирхан. *Арган кояш урман артларында Юнәлгән батышка.* Ә.Ерикәй

**БА́У** I *и.* 1) Бәйләү өчен файдаланыла торган, төрле материалдан ишелеп яки үрелеп ясалган тасмасыман предмет: лента, каеш һ.б. *Бер мужикның сәфәрдә камыт бавы өзелгән.* Г.Тукай. *Ачык өсле учак чокырындагы тимерләрне кыздыру өчен, бер ягы түшәмдәге сиртмәгә бау белән тагылган --- җирән өрдергечне күргәч, аптырап калды.* К.Нәҗми. *Мөгезенә бау бәйләгән сыер да ишегалдыннан чыгарга теләми, аякларын тери.* Н.Хәсәнов

2) *күч.* Җепкә үреп, эләктереп тезелгән тезем. *Шүрәле, иңенә бер бау крендель асып, капкадан кайтып керә.* Д.Аппакова

3) Көлтәләү, бәйләм ясау өчен кулланыла торган әйбер (печән, утын һ.б.ш.ны). *Ике якта – көлтәдәй итеп, бауга бәйләнгән печән өемнәре. Өч бавы – биш тиен.* Г.Минский. *Әнә икенчесе, бау ясап, учмаларын шул бауга җыйды да, тезе белән кысып, бер көлтәне бәйләп ташлады.* И.Гази

4) *кыек килешләрдә к.* **бәй** I. *Карчыганың баласы, бәйләнеп торып, бауда үләр.* Мәкаль. *Ярый әле, теге вакытта баудан коткардык үзен.* К.Нәҗми. *Терлекләр абзарында унҗиде сыер бауда тора.* Г.Ахунов

◊ **Баудан ычкыну** Тәртипсезләнү, узыну. *Нигә баудан ычкынган шикелле чабасың?* Л.Гыйльми**. Бау урынына ишү** Кемне дә булса тәмам буйсындыру, ни теләсә, шуны эшләтү. *Һи, син аның кулына төшсәң, ул сине бау урынына ишә.* Казан утлары

**БА́У** II *и. гади с.* Басма, киндер җепне үлчәү берәмлеге. *Җиде бау эрләсәң, бер киләп була*

**БА́У-БАСКЫЧ** *и.* Ике арканга аркылы бау басмалар беркетелгән җиңел баскыч. *Разведчиклар бау-баскычның очын ташка беркеттеләр дә бер-бер артлы төшеп тә киттеләр.* Г.Әпсәләмов

**БАУЛ** *и. төрки* Кырые түгәрәкләнеп эшләнгән озынча юл сандыгы. *Чемоданнар. Киплар. Bауллар.* Ә.Ерикәй

**БАУЛАП** *рәв.* Бауга тезелгән, бәйләгән рәвештә, шул рәвештәге бау санынча. *Бистәнең кәҗә асраучылары, баулап, печән сатып алалар.* Г.Минский

**БАУЛА́У** *ф.* Бауга салу, тезү. *[Йорт салучылар] Суган баулаган кебек, акрын кыймылдыйлар.* А.Гыйләҗев

**Баулап алу** Тиз генә баулау

**Баулап ату** Нәрсәне дә булса җитез генә, аннан-моннан баулау

**Баулап бетерү** Барысын да ахырына кадәр баулау

**Баулап җибәрү** Беразын бауга салу, бауларга өлгерү

**Баулап кую** Бауга салынган хәлгә китереп калдыру

**Баулап тору** Бертуктаусыз баулау

**Баулап чыгу** Башыннан ахырына кадәр баулау

**Баулый бару** Рәттән баулау

**Баулый тору** Хәзергә, бераз баулау

**БАУЛЫ** *с.* 1) Бавы булган. *Башына мескен бүрек киеп алган, Юкә баулы чабагачын аска салган.* М.Гафури

2) Бауланган, бауга тезелгән, бауга салынган. *Бар да таныш, бары да туган: мич янында – баулы суган, соры песи, калай комган.* Г.Афзал

**БАУЛЫК** *с.* **1.** 1) Бау булырга яраклы, бау итеп үреп була торган. *Урак өстендә әтием белән әнием миннән бала караталар, көлтәгә баулык тарма йолкыталар һәм учма җыйдыралар.* С.Кудаш

2) Бау ишәргә җитәрлек. *Бер баулык юкә*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Көлтә бәйләү өчен бөтереп ясалган салам яки үлән. *Авыл яныннан тимер юл салып узганда, Бибиәсма җитеп килгән кыз иде. Баш түбәсенә көлтә баулык утыртып --- урак җиреннән кайтканда, тимер юл будкасы яныннан узыла иде.* М.Мәһдиев

2) Бауны яки каешны беркетеп куя торган урын (аел, тишек һ.б.ш.) *Камытның баулыгы кыек булган, Каерып җигеп булмыйдыр.* Җыр

**БА́У СИКЕРЕШ** *и.* Бауны әйләндереп, аркылы сикереп уйный торган уен. *Тәрбияче хатын, өйалды баскычына чыгып утырган да, оекмы-нәрсәме бәйли, балалар исә, бөтен дөньяларын онытып, дөп-дөп бау сикерәләр, чынаяк тәти уйныйлар, балчыктан коймак пешерәләр.* Г.Бәширов

**БА́У-ШУ** *җый. и.* Бау, аркан ише әйберләр. *Кайбер эшләрне булдыра алам, әгәр эшләтүче булса... Бау-шу ишү, утын кисешү кебек нәрсәләр.* Ә.Еники

**БАХ** I *иярт.* Көтмәгәндә, кинәт шартлау авазын белдерә. *Бах та бах без аларны.* Г.Гобәй. *Бах, бах мин аңар.* Г.Гобәй

**БАХ** II *ы. к.* **баһ**. *Берничә тапкыр: «На, бах-бах!» – дип кычкырды.* Г.Гобәй

**БАХБАЙ** *и. сөйл. ирк.* 1) Ат яки тай. *Базардагы, кара яу булып, гөҗ килеп оча торган чебен көтүен койрыгы белән кугалап, бахбай мәйдан уртасындагы агач кибетләр почмагыннан сулга борылды.* Ә.Фәйзи. *Олаучылар атларны куаламаска тырышалар, бахбайларны алҗытасылары килми.* Ф.Сафин. *Түбән булганга аю исен сизмәгән бахбай йөкне җайлы гына тартып бара башлады.* Я.Зәнкиев

2) Кул арбасы тартып баручының үзен шаярып атау сүзе. *Мөзәкиләрнең кул арбасы зур, солидол белән мул майлагач, тартырга да үтә җиңел, юл такыр, әйдә, бахбай.* А.Гыйләҗев

**БАХШИ** *и. төрки иск.* Язу-сызу эшен башкаручылар. *Хан илчыларының зур катламы казнага акча кертүне кайгыртып торган: ясак, гошер ---*

*җыючылар, тамгачылар ---, үлчәүчеләр, бахшилар ---.* Р.Мостафин

**БАХЫР** *и. диал. ирк.* Мескенкәй, бичаракай. *Өметләнеп яши, бахыр, Умырып аласына.* М.Закир. *Бераз гына да башы эшләмәде микән бахырның?* Ф.Сафин. *Бакырларын «алтын-көмеш» дип Исәпләүче бахыр күбәйде.* Р.Идиятуллин. *Бахыр, үлгәненә дә үкенмәгән икән.* М.Фәйзи. *Өстендә – бер күлмәк белән юка ыштан, трусигы, майкасы да юк иде бахырның.* А.Гыйләҗев

**БАХЫРКАЙ** *и. диал. к.* **бахыр**

**БАҺ** *ы.* Ат чакырганда, берничә мәртәбә кабатлап, «баһ-баһ» дип әйтелә. *Андрюша айгырны барыбер тота алмады. Картузына солы уып салып: – Баһ-баһ! – дип чакырып та карады.* К.Латыйпов

**БАҺАДИР** *и. фар.* **1.** Пәһлеван, батыр, алып батыр. *Шулай дип, үзем-үзем ант иттем дә Салават баһадирның мәрхүм юлдашының башы очыннан тагы алга – Уралның эченә таба кереп киттем.* Г.Ибраһимов. *Кемнең аты шәп уза, Кем иң җитез, иң баһадир – Хан кызы шуңа чыга.* Н.Исәнбәт. *Баһадирларыннан язган халык Үз илендә төшә коллыкка...* Эзоп. *Сагына сине татар-болгар иле, Баһадирлар иле исәндер.* Г.Афзал

**2.** *с. мәгъ.* Бик куәтле, гайрәтле, көчле һәм нык. *Шулай да, баһадир Батикәнең терсәкләре белән халыкны ерып баруы аркасында, алар, бераздан, кирмән капкасына кадәр килеп җиттеләр.* Р.Зәйдулла. *Берничә мизгелдән, бер-берсенә ике тамчы судай охшаш, баһадир гәүдәле бу кешеләр, үз-үзләрен белештермичә кочаклашалар, аркаларына шап-шоп бәрешәләр иде.* Ф.Латыйфи. *Аның сызгыртуының корыч баһадир тавышы бөтен Иделне, бөтен тирә-якны яңгыратты.* Г.Ибраһимов

◊ **Баһадирдай (баһадир йокысы белән) йоклау** Бик каты, тирән йоклау. *Ул баһадирлар йокысы белән йоклый, көн ачылышына нужа камытына җигелергә көч җыя.* К.Кәримов.

**БАҺАДИРЛАНУ** *ф.* Баһадир булып кылану, баһадирларча булырга тырышу. *Хатын-кызны әйтмисең дә инде, ир-арсланнарның да күбе, иртән бик баһадирланып керешсәләр дә, төшкә таба ыңгыраша башладылар.* Г.Ибраһимов

**Баһадирлана бару** Торган саен баһадирлыгы арту

**Баһадирлана төшү** Бераз баһадирлану

**Баһадирланып алу** Берара үзен баһадирларча тоту

**Баһадирланып китү** Кинәт баһадирлану

**БАҺАДИРЛА́РЧА** *рәв.* Баһадирлар шикелле, баһадирлар кебек. – *Гвардия сержанты Шакиров илебез өчен баһадирларча сугышты, барыбыз да аның кебек булыйк, – диде.* А.Әхмәт. *Берүзе ат хәтле эшләр, башы көлтәгә тисә, баһадирларча, өч тәүлек йоклар.* Г.Бәширов. *Мин дустымның кеше җаны күтәрә алмаслык газапларны, әрнүләрне күтәрүен, үзен әкияттәге баһадирларча горур һәм батыр тотуын күрдем.* А.Шамов

**БАҺАДИРЛЫК** *и.* 1) Баһадир булу; баһадирга хас сыйфат. *Бу баһадирлыгын үзенең татарлыгыннан, диеп уйлый.* Ф.Әмирхан

2) Кыюлык, батырлык, гайрәт. *Гүя, ул, үзенең тискәрелеге белән юри кыланып яисә булдыксыз абзаларының инсафсыз мөгамәлә вә тәрбиясезлекләренә ачуланып: «Әйдә, чәнчелегез! Ханлыкка да минем исем китми, миңа шул егетлегем, шул баһадирлыгым җиткән!» – ди.* Ш.Камал

**БАҺАНӘ** *и. фар. иск. кит.* Сылтау, сәбәп. --- *кунаклар атларына атландылар да, юк-бар баһанәләр табып, төрлесе-төрле җәйләүгә, теге уртадагы кабилә кисәкләренә таралдылар.* Г.Ибраһимов. *Каюм баба, халыкның завыгына каратып, шул заманның материалы буенча, шул тупас, ямьсез хыялларны тартты. Боларның бердәнбер тарихи баһанәсе – әнә шул халыкны, кызыктырып, укырга таба тартудыр.* Г.Ибраһимов

**БАЦИ́ЛЛА** *и. лат. биол.* Авыру тудыра торган, таякчык формасындагы бактерия. *Табигатьне сукыр димәссең. Аңа фил дә, таракан да кирәк, Бацилла да кирәк, күрәсең.* Г.Афзал. *Көмеш мыеклы, көмеш сакаллы галактика башлыгы җитәкчелегендә, бүген Җир планетасының язмышы тикшерелә. Җирдә ниндидер бацилла таралды, дип чыгыш ясый берсе.* Ф.Садриев

**БАШ** *и.* **1.** 1) Ми, чәч, йөз, күзләр, авыз, борын (яки танау), колаклар урнашкан кеше яисә хайван әгъзасы. *Ә инде, сәҗдәдән торганда, аягы таеп, башы шкаф почмагына бәрелгәч, Сәлимә түтинең тәмам кәефе кырылды.* Г.Мөхәммәтшин. *Камил, аларның сүзләрен тыңлап, башын селки.* Һ.Такташ. *Зәбиров, башын кагып, елмаеп куйды.* Г.Әпсәләмов

2) Баш киеме. *Бай утырганда – башын салган, ярлы узганда – көлеп калган.* Мәкаль. *Аның башы матур, синең башың төсле, ярты пот чүпрәк чорнамаган.* Г.Тукай. *Батыргали агайга бәгъзы белеш-таныш руслары очрап, баш салсалар да, Батыргали агай, бүркен салмаенча, солдатлар кебек честь биреп кенә үтә иде.* Ш.Мөхәммәдев

3) Баштагы чәч, причёска. *Җанкайҗанаш, пумала баш, чыкма урамга яланбаш.* Г.Тукай. *Ә аннан соң тауга чыгып басты. Башына кадап алтын тарагын.* М.Җәлил. *Яши халкыма хезмәттә Үз башкаен чалартып, Борынгы татар мохитен Тылсым белән яңартып.* М.Сафин

4) Баш күләмендәге биеклек, бер башка туры килгән озынлык. *Җыелыш уртасында Зариф агайның саргылт көрән сакалы чагылды. Ул буйга башкалардан бер баш озынрак иде.* Ш.Усманов

5) Гомумән кешеләр. *Мең-мең башлар киңәш кордылар, Илнең хәлен алга куйдылар.* Ф.Бурнаш. *Бюрократларга, тоттыра язып кына калган тиречегә вә аңар ияргән берничә салам башларга быел да алданмаганнары өчен, без Уральск мөселманнарына күңелдән тәшәккер итәбез.* Г.Тукай

6) Үсемлекләрнең өске өлешләре, чәчәклек һәм җимешлекләр; башак, бәрчә, себеркәч. *Әмма яшел чагында, мәкнең башында (орлык савытында) бу сөт күбрәк була.* К.Насыйри. *Карлар эреп, чәчәкләр башларын суза башлаганда, Мөттү белән Нәҗүк күптән инде казлар саклаганда, төймә уйнап*

*утыручы кызлар янында шаяралар иде.* Һ.Такташ. *Камылларда, тулышып, башларын асылындырып утыручы иген басуы әле генә күзләрне әрнетерлек дәрәҗәдә ялкыткан урман яшелләнгән каплап, томалап куя.* Г.Гыйльманов

7) Үсемлекләрнең азык матдәләре җыела торган шар, конус рәвешендәге өлеше. *Мәкнең кулланылган җире – күбрәк башы белән орлыгы.* К.Насыйри. *Җәүдәт зур тәлинкәдәге колбасаны һәм бер баш сарымсакны Хәлимгә якынрак куйды.* Р.Кәрими. *Алар --- яшелчәләр тирәсендә әйләнгәләп, берәр бәйләм суган, биш-алты бәрәңге, яртышар баш кәбестә, кружкалап, сөт күтәреп кайталар.* М.Гали. *Кәбестәнең башы формалаша башлаганда, су сибү нормасын 3–4 литрга кадәр арттыралар.* Йорт эшләре

8) Биеклеккә сузылган әйберләрнең өске, югарыгы өлеше. *– Атыңны гына биреп котылуың өчен рәхмәт әйт, теләсәм, мин сине багана башына да күтәртә алам, – дигән.* И.Гази. *Гүя, җил түгел, шул болыннар агач башларын төрле тавышлар чыгарып чайкалдыралар.* Г.Әпсәләмов. *Селкеп калды башын каеннар, Озатканда безне туган ил.* Ә.Исхак

9) Түбә, кыек. *Яшел буяулы рәшәткәле капка башында чыпчыклар чыр-чу киләләр.* Ш.Камал. *Кайбер өйләрнең башы тимер белән ябыла башлап та, бер почмагы бетми калган.* Г.Ибраһимов. *Мәнә безнең үз йортыбызның да тирәсе җил белән генә әйләндереп алынган, башы, калын итеп, күк белән ябылган, ди.* Г.Гобәй. *Иртә белән, өй түбәләрен, каралты башларын, урамнарны агартып, ап-ак кырау төшә, инеш кырыйларына, пыяладай юка гына булып, боз ката.* Г.Бәширов

10) Озынлыкка сузылган әйбернең кайсы да булса очы яки ике очның берсе. *Алар, һәркөн авылның бер башыннан бер башына йөгереп йөреп тә, бу көнгә кадәр мине күрмәгәнгә, --- бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.* Г.Тукай. *Мәнә таң атты; әнә Кабанның икенче башындагы урман, авыл, аның кечкенә-кечкенә йортлары күренә башладылар.* Ф.Әмирхан. *Ындырның аргы башыннан Шәмсетдиннең «әү» дигәне ишетелде.* Г.Бәширов

11) Аяк киеменең бармаклар урнаша торган алгы өлеше, очы һәм шул оч тирәсендәге өлеше. *Ә кан ага итек башыннан.* Ш.Маннур. *Нажия итек башы түши, Ул шундый җитез эшли.* Ш.Маннур

12) Авылның, урманның, корылманың буйга таба сузылып, башланып киткән урыны. *Исламгали агай исә, янып яткан келәткә кереп, нәрсә алырга белми аптырап торгач, майланып, балавызланып беткән бер иске бишмәт тотып, авыл башына чыгып йөгергән.* М.Мәһдиев

13) Әйбернең күзгә күренеп яки чыгып торган чите, кырые, очы. *Хәзрәт --- кесәсеннән яулык башын күрсәтебрәк куйды да кунаклар ягына чыгарга әзерләнде.* Ф.Әмирхан

14) Нинди дә булса бер күренешнең, фасылның, вакытның башлангыч чоры, башланган дәвере. --- *XX йөз башында Урал промышленность мәркәзләрендәге эшчеләр тормышы мисалында күрәбез.* Г.Нигъмәти. *Бигрәк күңелле май башларында, Каеннар яфрак ярган чагында.* М.Җәлил. *Шушы яшенә җитеп, Якупның яз башында урманда булганы юк иде.* И.Гази. *Быел яз башында мин, ниндидер бер кичәдә Хөршит белән танышып, ярты гына сәгать аның нурында йөзгән, сихерле очкыннар чәчә торган күзләренең ялтыравы астында нурланган идем.* М.Әмирхан

15) Башланып киткән урын, беренче өлеш, чыганак. *Мәнә шуңа күрә дә, «Эшче» поэмасының башындагы бүлекләрендә, художество бөтенлеге өчен, табигать күренешләрен дә бирүне көтү урынсыз эш булмас иде.* Г.Нигъмәти. *Инешләрнең башы чишмә булыр.* Р.Фәйзуллин

16) Барлыкка килү күренеше, башлангыч. *Халык күтәреп алырга лаеклы тәкъдим булса, ул инде үзе – хәрәкәтнең башы, дигән сүз.* Р.Ишморат. *Үзенең үлемгә хөкем ителүеннән һәм бу һөҗүм – җәзаның башы икәненнән аның хәбәре юк иде.* Ф.Әмирхан. *Бөтен начарлыкның башы – эшкечелектә.* Ә.Хәбибуллин. *Журналыбызның чишмә башы булып, 1922 елда чыга башлаган «Безнең юл» санала.* Казан утлары

17) Әдәби әсәр, мәкаләгә бирелгән исем. *Гәзиткә тиз генә яңа баш беркеттеләр.* Г.Мөхәммәтшин. *Күрәсез, мәкаләнең башы алай котны алырлык түгел, хәтта, бик әдәби баш, дип әйтергә була.* Ф.Хөсни

18) Ачыткы, оеткы салынган камыр, сөт, бал һ.б. *Баш күперә тора, бераздан, мич башындагы җилпучта он да җылына, хуҗа хатын он иләргә әзерләнә.* М.Мәһдиев

19) *күч.* Җитәкче, башлык, хуҗа, түрә. *Бу юлы, яшерен тавыш белән, болар сайлады баш.* М.Гафури. *Шулай, хан көнчыгышка бихисап гаскәр рәвән кылды, олуг углын шуларга баш, беренче пәһлеван кылды.* Г.Тукай. *Төмән һәм меңбашлары, ел саен, килеп, ханга доклад (белек) ясарга тиеш.* Г.Гобәйдуллин. *Явыз Иван гаскәр башларына яуга әзерләнергә әмер бирә.* Сөембикә

20) *күч.* Гаилә башлыгы, хуҗа, ир. *Мәнә шушы тирә-якны дер селкетеп яшәгән кешенең бер генә йомшак ягы пәйда булды: хатыны Зөбәрҗәт, ул аңа баш була алмый, чөнки – ярата.* Х.Мөдәррисова

21) **башында** *күч. тарт. һәм кыек килеш форм.* Төп җитәкче, оештыручы урынында, башлык дәрәҗәсендә. *Хөкүмәт башында залимнәр утыра, халык акчасын кесәсенә тутыра. Шундый хыянәтләрне әйтеп булмый, илерәдер алар һәм котыра.* Ш.Мөхәммәдев. *Авылны яңабаштан үзгәртеп кору эшләренең башында торган.* Т.Гыйззәт. *Бу хәрәкәт алга сөргән төп идеяләрнең берсе – башында мәгърифәтле монарх торган дәүләт концепциясе.* Мирас

22) *күч.* Санаганда, данә, исәп-хисап берәмлеге итеп кулланыла. *Бу зобаниның һәрвакыт ун-унбиш баш эте була торган иде.* Г.Гобәй. *Узган елдагыча булса – кыйбат, сыер башына – бер пот, сарык башына биш кадак он бирер хәл юк сезгә.* М.Гали. *Хәзер бу ил сыерлар саны буенча дөньяда беренче урында: анда алар – якынча 200 миллион баш.* Кызыклар дөньясында

23) *күч.* Конус яки шар формасында әзерләнгән шикәр, сыр һ.б.ш. ашамлыкларга карата кулланыла

24) *күч. -лык/-лек кушымчалы сүзләр янында килеп,* урын мәгънәсен көчәйтә. *Һәр шәһәрдә үзенә күрә чүплек башы була бит.* Г.Тукай

25) *күч.* Акыл, аң, зиһен, фәһем. *Башың эшләмәсә, аякларыңа тынычлык булмас.* Мәкаль. *Авылдашларының үлгән хәбәре килгәндә дә, Газизнең үлеп калу мөмкинлеген башына да китерә алмый иде.* Г.Бәширов. *Эшемнең рәте булмады, башымда бер генә уй: март азагында, бу бәләкәй шәһәрдә нинди дә булса чәчәк сатып алырга мөмкинме?..* Җ.Тәрҗеманов

26) *күч.* Җан-тән, шәхес. *Баш булса – мал, аш булса, казан табылыр.* Мәкаль. *Баш сау булса, башка бүрек табылыр.* Мәкаль. *Әдәм башы таш түгел.* Мәкаль. *«Башлар исән булса, кайтырбыз», – диде ул киткән чакта.* Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Беренче, беренче урында торган. *Ул шигырьне баш сәхифәгә керттермәдем.* Г.Тукай. *Баш батыр өчен көрәш башланды.* Т.Нәҗмиев

2) Иң төп, әһәмиятле. *Җәмгыяте хәйрияләрнең эшсезлекләренә баш сәбәп – сәяси вабаларның хәзерге хәләте икәненә без ышансак та, ләкин хокуклары даирәсендә эш итәргә теләмәгәнлекләре вә иң күп әһәмиятне үлек күмүгә иганә бирер өчен сарыф иткәнлекләре – күз алдыбыздадыр.* Ф.Әмирхан. *Татар әдәбияты укытылмавы – иң баш сәбәпләрнең берседер.* Ф.Әмирхан. *Яшел куллы кыз юбилей спектаклендә баш рольне уйнауны «чүп утау» дип белде, ахрысы.* Г.Бәширов. *Биредә F – системага тәэсир итүче тышкы көчләрнең баш векторы.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

3) Өлкән, билгеле бер даирәдә башлык булган. *Кинәт баш врач, аның сөйләп бетерүен дә көтмичә, башында бер яңа уй туганын сиздергән төсле итеп елмайды да бүлмәдән чыгып та китте.* Г.Минский. *Клапаннарны алмаштырырга кирәклек турында цех начальнигы Закиров иптәшкә әйтәм, баш инженерга әйтәм.* Р.Ишморат. *Баш мөхәррирләр арасында мөһим урын алган – Галиәсгар Камалдыр.* М.Гали. *Ялтаның баш начальнигы Думбадзе --- аларның язып торучыларын Ялтадан чыгарырга әмер биргән.* Урал

4) Үзәк урында урнашкан, иң зур, төп. *Шул сәбәпле, безнең Зингер ширкәтенең Америкадагы баш идарәсе сиңең безгә булган хыянәтеңнән хәбәрсез торды.* Г.Тукай

**3**. **баштан, башыннан** *рәв. мәгъ.* Хәл(ен)дә, халәттә. *Хәйри, аңла, авылдаш --- исерек баштан сөйли, димә.* Г.Минский

◊ **Баш аву** 1) Башның бер ягы авырту, ми бер якка авышкан кебек тоелу. *Теге көнне бик миен дә селкеттеләр, башы ауса да ауганды́р. Тастымал салып үлчәргә кирәк.* Н.Исәнбәт; 2) Эш күплектән, борчулардан һ.б.ш. аптырап калу, фикерләү сәләтен югалту, югалып калу. **Баш авыраю** Фикерләр томаланып, йокыга тарту, баш авыртудан күз аллары караңгыланып, кәефсезләнеп тору. *Миңлениса карчык исерекне тагы бер кат җентекләп карагач, куркудан, күз аллары караңгыланып, башы авыраеп китте.* С.Рафиков. **Баш авырттыру** Хәл итәргә авыр булган мәсьәләне уйлау, кирәксез, әһәмиятсез эшне башкарырга тырышу. *Без --- баш авырттырып маташмыйбыз...* Г.Тукай. **Баш алгысыз** Тыгын, ерып чыккысыз тыгыз. **Баш алмастан** Бик нык, бирелеп. **Баш(ны) алып китү (качу, олагу, таю)** Читкә китеп, башыңны коткару, качып котылу. *Баш алып, кулны селтәп качар идем, Дөньяда бер ялгызым гизеп булмас.* Н.Думави. **Баш алып чыккысыз** Буталчык, рәтсез, тәртибе булмаган, ыгы-зыгылы. **Баш аркылы (аша) егу (ыргыту, алып ату)** 1) Татарча көрәш алымы – бер көрәшченең, тиз генә аркага ятып, икенчесен баш аркылы атып егуы. *Теге, «ектым» дип, минем өскә ятарга теләгәндә генә, мин аны баш аркылы ыргытып та җибәрдем. Үзенең дә исе китте.* М.Гали; 2) Атланган атының башы аша очып китеп егылып төшү. *– Минем белән куышканда, аты сөртенде аның, баш аркылы төшеп, аты басмаган булса ярар иде, – диде бер малай.* М.Гали. **Баш арты килү** Йөгерештә яки башка ярышларда икенче урында килү, төп җиңүчедән соң килү. **Баш астына баллы кашык кую** Йоклау. *Ә баш астына баллы кашык куярга ярамый.* Б.Камалов. **Баш аша** Арадагы җитәкче белән исәпләшмичә – үзең буйсынган җитәкчене кисәтмичә, аннан узып, зуррак дәрәҗәдәге җитәкчегә турыдан-туры мөрәҗәгать итү хакында. **Баш ашау** 1) Яла һәм бәлаләр ягып я тыштан дус булган булып, җае туры килгәндә зыян салу, һәлак итү. *«Ала чагыр» дигән ала үрдәк Ак күлләргә төшеп таш ашый; Ышанмагыз һәрбер дус-ишләргә, Вафасыз ук дуслар баш ашый.* Җыр; 2) Тәҗрибәсез кешене аңлы рәвештә аздыру, җинаять юлына бастыру, начар эшләргә этәрү. *Ул кара җан аркасында, бер гаепсез кешенең башын ашаулары мөмкин иде бит.* Г.Әпсәләмов. **Баш әйләндергеч** 1) Төрле хуш исләрнең, башны чуалтып, кәефләндерә торган тәэсире. *Елга аръягыннан йомшак җил шомырт һәм болын чәчәкләре исен китерә, алар киндер капчыклардагы йөзем, өрек, күрәгә, исемнәрен белеп бетергесез башка җимешләрнең хуш исе белән аралашалар да баш әйләндергеч бер ымсыну, шушы муллыкка чуму теләге уяталар.* Ф.Латыйфи; 2) Тынычсызлап, борчып торган, тынгы бирми торган. **Баш (башын) әйләндерү** 1) Кешене эшеннән бүлдереп, кирәкмәгәнгә йөдәтү. *Бар әле, кит, башымны әйләндермә;* 2) Фикерне чуалту, буталдыру. *Этаж саннары белән 7–8 гә үрләп, киңлек, зурлык исәбе белән бөтен кварталлар өстен каплаган бу магазиннар, чынлап та, башны әйләндерәләр.* Г.Гобәй; 3) Кешене уйга-дәрткә дучар итү, иләс-миләс китерү. *Ай-һай кара кашларың, Әйләндердең башларым; Уйсу җирдә дәрья булыр Минем түккән яшьләрем.* Җыр. **Баш әйләнү** 1) Берәр чуалчык эштә баш буталу, фикер чуалу, аптырау. *Шушы бөек сергә кушылуыннан, сүзләре теләсә кайсы йортка үтеп керердәй кешеләр арасына алынуыннан, бу мизгелләрнең җаваплылыгыннан һәм яшерен тантанасыннан башы әйләнеп китте.* Ф.Латыйфи. *Күзләрем яшь бе-*

*лән тулды, башым әйләнеп китте.* Г.Гобәй; 2) Хисләр тәэсирендә фикер чуалу, хисләрнең өстенлек итүе; 3) Фикер чуалу, аптыраштa калу. *Бик озын, бик буталчык тел белән язылган инструкцияне алгач, Фәсхинең чынлап та башы әйләнде.* Ф.Сәйфи-Казанлы; 4) Кәефләнүдән я мактаудан исерү, масаю. *Батырыбызның бу мактаудан башы әйләнеп, үзенең көчен, кырмыскаларга гына түгел, шәһәрдәге адәмнәргә дә күрсәтергә булды.* Г.Тукай. **Баш әллә кайда йөрү** Кеше бер нәрсә хакында сөйләгәндә, бөтенләй башка нәрсә хакында уйлап тору; кеше сүзен игътибарсыз тыңлау. *Аның башы әллә кайларда гизеп йөри.* Г.Гобәй. **Баш бармак кебек (шикелле), баш бармактай** Бик яхшы. **Баш бәйләнү** 1) Нинди дә булса тыелган эш, шикле компания белән бәйләнештә булу. *Башың начарга бәйләнсә, Хур булуың билгеле.* Җыр; 2) Берәр нәрсә белән артык мавыгу, гел шуның белән генә мәшгуль булу. *Бармагымда – алтын балдак Уңга-сулга әйләнә. Егет күңеле кызга төшсә, Башы шуңа бәйләнә.* Җыр. **Баш белән җавап бирү** Зур җаваплылык алу, нинди дә булса эшне үтәмәгәндә, каты җавапка тартылачакны искәртү. *[Микитенко] Менә бу кошны губчекага илтеп тапшыр, яхшы кара, аның өчен без барыбыз да башыбыз белән җавап бирәбез.* Ф.Хөсни. **Баш белән уйлау** Ныгытып, ахырга кадәр уйлап бетерү, бик җентекләп, барлык ихтималларны да күздә тотып эш итү. *Кулың белән башлаганчы, башың белән уйла.* Мәкаль. **Баш белән уйнау** Артык мавыгып китү аркасында, һәлак итәрлек азартка бирелү. **Баш белән эшкә чуму** Бар нәрсә турында да онытып, бөтен игътибарны эшкә генә юнәлтү. **Баш беткеч** Бик күп; бик буталчык; бик хәтәр. *Усаклыда ун-унбиш кенә өй булса да, магазинында китаплар баш беткеч икән, ун меңләп бардыр.* Г.Мөхәммәтшин. **Баш бетү** 1) Һәлак булу, юкка чыгу. *Алай булса, харап булдык! Малайның башы бетте! Читек балтырында – кырык тугыз мең, диген, ә! Әйтеп, адәм ышанмаслык сүз!* Г.Камал. *Башы беткәннәрнең саны – өч йөз мең, диме шунда...* Ш.Маннур. *Кызыл Тауның иң сөзәк җиреннән төшәсе булса да, йөкле чананы күсәк белән тыймасаң – баш бетте.* Р.Батулла; 2) Авыр хәлдә калу, уңышсызлыкка очрау. *– Безнең башлар беткән инде, – дип шыңшыды ул юл буе.* Г.Әпсәләмов. **Баш бирмәү** Буйсынмау, күнмәү, тыңламау. *Кара айгыр, малайга баш бирмичә, әллә кая – чит якка таба бәреп алып кереп киткән.* Г.Ибраһимов. *Ә үзе берсенә дә баш бирмәскә тырышты ул.* З.Фәйзи. *Бабаеңны баш бирмәс усал кеше булганга шулай дип атаган булганнар.* М.Хәсәнов. **Баш бирү** 1) Буйсыну, баш ию, тыңлау. *Җансыз, йонсыз, шәрә «козёл» – Сәгыйрьнең шәхси дошманына, барыбер баш бирергә тиешле Памир пигына әйләнде.* Т.Галиуллин; 2) Ризалашу, килешү. *Тик шулай да баш бирәсе килми, Сындырасы килми күңелне.* Ш.Маннур. **Баш бөгү** Буйсыну, баш ию. *Баш бөгәргә өнди башлый инде ул яшьләрне дә.* Г.Тукай. **Баш булу** 1) Җитәкчелек итү; 2) Хуҗа булу, ия булу. *Үзенә-үзе баш булмаган кешеләрдә баш булмас, булса да, озак тормас.* Мәкаль; 3) Кулда тота алу, буйсындыру, тыю. *– Ай Алла, бер телеңә баш була алмадың лабаса, – диде әни.* М.Әмир; 4) Биләп алу, басып алу. *[Куян:] Кем ул, кем минем урманыма баш булмакчы була?!* А.Алиш. **Баш – бүрек өчен түгел, ә белер өчен** Ныгытып, ахырына кадәр уйлап бетерү, бик җентекләп фикер йөртү турында. **Баш вату** Нәрсәне булса да хәл итәргә тырышып, кабат-кабат уйлау, нәрсә эшләргә белми аптырау. *Кызның хәлен кем аша белергә дип, озак баш ватты.* А.Гыйләҗев. *Мин бик күп уйладым; бик күп баш ваттым; елап-елап, Ходайдан сорадым – булмады.* Ф.Әмирхан. *Аның ул гадәте берәр авыр мәсьәлә өстендә бик озак баш ватып утырган чакларында күренә торган иде.* М.Әмир. **Баш җитмәслек** Аңлый алмаслык, акыл ирешмәслек. **Баш җитү** Төшенү, аңлау, акыл ирешү. *Юлда ул тагын бер кат: «Ничек башың җитеп киләсе иттең, Равил абый?» – дип, Равилне мактап куя.* В.Нуруллин. **Баш(ы) ике булса, баш ике түгел** Үлем куркынычы белән янау яки шуңа сылтап әйтү. *Без бай балалары түгел, Камалы тун кияргә; Безнең башлар ике түгел, Кеше ярын сөяргә.* Җыр. **Баш имәс** Буйсынмас, күнми, тыңламый торган, дуамал. *Ирек сөюче, баш имәс холыклы --- Кылычбай җырлый иде моны.* Ш.Маннур. **Баш исән (сау) булса, мал табылыр** Сау-сәламәт булсаң, барысы да булыр. **Баш исәндә, баш исән чакта** Яхшы чакта; сау-сәламәт булганда. **Баш исән дә җан исән** Бәла-казалы җирдән ераграк торуны тиеш тапкан очракларда әйтелә. **Баш ию** 1) Ризалашу яки берәр эшкә, хезмәткә әзер тору. *Ул арада Александра Андреевна да, киенеп чыгып, иренә баш иде.* М.Гали; 2) Рәхмәт яки хөрмәт, сәлам бирү яки алу билгесе итеп, башны бөгеп алу. *Бик телиләр икән, ихтирам итәләр икән, әнә егетләр үзләре беренче булып баш исен!* Г.Бәширов. *Шунда аңар баш иделәр бакчада һәрбер агач.* Г.Тукай. *Читтән карап торганда, нәкъ менә бер-берсен сәламләп башияләр кебек.* Кызыклар дөньясында; 3) *күч.* Буйсыну, ялыныч, үтенеч белдерү, ихтыярында булу. *Нишләргә хәзер? Аңарга [Фазылга] барып баш иярргәме?!* С.Баттал. **Баш йөртеп карау** Бераз фикер йөртү, уйлап карау. **Башка ат (ишәк, тай) тибү** Аңгыраланып калу, юләрләнү, кисәк дуамалланып ташлау. **Башка (башына) ат типмәгән** Үз акылында, уйлап эшләү сәләтен югалтмаган. **Башка атлану** Узыну, санламау, кыенсынмау. **Башка бәла булу** Кешегә бәхетсезлек, күңелсезлек китерү. *Ялган акча ясаучы, диеп, башка бәла тактылар.* Т.Гыйззәт. **Баш кагу** Кеше сүзен җөпләп, ризалашып, хуплап яки хәбәр биреп баш селкү. *Берәр нәрсә кирәк булса, Бик күп сөйләп тормыйм мин: Я кул белән ишарәлим, Я баш кагып ымлыйм мин.* Ш.Галиев. **Башка дәүләт кошы куну** Көтелмәгән бәхеткә, байлыкка ирешү. **Баш каеру** Читләшү, тайпылу; ятларга карау, йөз чөерү, бизү. *Әллә син дә баш каердыңмы миннән?* К.Тинчурин. **Башка йөгерү, башка китү** Исерткеч эчемлекләрнең, шулай ук, көчле хиснең тәэсире баш миенә таралу. **Башка кабу**

Истән, төтеннән, эсседән, шау-шудан (һ.б.ш.дан) баш авырту, ми ару. *Атларның, купшы чабып, дагалар белән урам ташларын сугулары – һәммәсе ачык ишетелеп, Хәятнең башына каба башлады.* Ф.Әмирхан. **Башка керми** Аңлап булмау, төшенмәү. **Башка килү** Кинәт кенә берәр уй, фикер туу, ният барлыкка килү. **Башка китерү** Фараз итү, күз алдына китереп, уйлап карау. *Хәтта уйлап та карамас, башына да китермәс.* А.Шамов. **Баш калкытмыйча** Бик тырышып, бер дә туктамыйча, күтәрелеп тә карамыйча. *Шәрифҗан да, башкалар кебек үк, башын да калкытмыйча эшләде.* И.Гази. **Баш калкыту** 1) Башны күтәреп тору, күтәрелеп карау; 2) Тишелеп чыгып, югарыга үсә башлау. *Чыгып, баш калкыта сахрада уҗым.* Г.Тукай. *Кояш бераз кызурак итеп карый башлау белән, Көмешле күлнең саерак урыннарында камыш баш калкыта башлый.* Г.Галиев; 3) Буе, озынрак булып, аерылып тору; 4) Баш күтәрү, буйсынмау; 5) Кузгалу, уяну, борчый башлау. *Әмма, Казанга кайтып төшүгә, шул тойгы баш калкыта, әкрен генә, сиздерми генә җанын кимерә, Гөлйөзем янында, бабалары арасында узган кадерле сәгатьләрнең тәмен агулый иде.* Ф.Латыйфи. **Баш калкытырга да бирмәү** Кешегә гел боерып тору, зиһен җыярга да ирек бирмәү, туктаусыз тынычсызлау. **Башка менү** *к.* **башка атлану.** *Йомшаклык күрсәтсәң, башыңа, мәсәлән, менеп утыралар!* Ф.Әмирхан. **Баш каңгыру** Төгәл бер нәтиҗәгә килә алмыйча аптырау, уй-фикер буталу. *Яман хатын үлсә – түшәк яңарыр, яхшы хатын үлсә – баш каңгырыр*. Мәкаль. **Башка сугу** 1) Көтелмәгән берәр хәлдән яки хәбәрдән сискәнеп китү, күңелгә авыр тәэсир итү; 2) Берәр сүз яки эшне катгый туктатып калу, ни дә булса эшләү теләген сүндерү. *Һәр сүземә киртә куеп, башыма сугып торма.* **Башка (башына) сыймау (сыешмау, сыйдыра алмау)** Төшенә алмау, кабул итә алмау, ышанып бетә алмау. *Ләкин синең андый караштa булуың һич тә минем башыма сыймый.* Ш.Камал. *Алты иптәшнең берсе дә бу фаҗигане башына сыйдыра алмый иде.* Г.Бәширов. *Комсомолец өендә мондый күренеш булуын берничек тә башыма сыйдыра алмый идем мин.* М.Әмир. **Башка тай типмәгән** Тормыш тәҗрибәсе бай, акыллы булу. *Башыма тай типмәгән. Авылда сүз таралгач, Шакир абзыйларга үзем бардым, үзем карадым ул баланы.* Г.Галиева. *Бу малай сүзенә ышанма, Мирсәет туган, колхоз милкенә кагылырга, Габтеләхәтнең башына тай типмәгән.* Р.Ишморат. **Башка таяк белән суккандай булу** Кинәт ишетелгән, билгеле булган авыр хәбәр, хаксыз сүз күңелгә авыр тәэсир итү. **Башка тию** Авыр тәэсир итеп, башны авырттыру. *Машинада хәрәкәтсез утырганга, аның болай да сызланган аяклары оеп киткән, бензин исе башына тигән иде.* М.Маликова. **Башка төшү** Бәлагә, кайгы-хәсрәткә дучар булу. *Башыңа төшсә, башмакчы буласың.* Мәкаль. **Баш кату** Авыр, сагышлы уйлардан, кат-кат борчылудан баш арып, ми талу. *Белмим инде, башым каткан.* М.Фәйзи. **Башка туку** Бертуктаусыз әйтеп, һаман исенә төшереп, искәртеп, өйрәтеп тору. **Баш катыру** Кирәкмәгән сораулар биреп яки вак мәсьәләләр белән аптыратып бетерү, йөдәтү. *Андый юк-бар сораулар белән бабаңның башын катырма инде син, улым.* М.Гали. **Башка ут кабу** 1) Нык гашыйк булу; 2) Нык борчылу. **Баш кашу** Аптырап, нишләргә дә белмәү. *Хәзер ул озын, кәкре агач янында, башын кашып, уйланып басып тора иде.* Г.Әпсәләмов. **Баш кашырга да вакыт юк** Бик тыгыз, эш бик күп чак, вакыт бик тар. *[Мостафа:] Вакыты шундый, туганкай. Баш кашырга да вакыт юк.* Ш.Камал. **Баш килү** Сабантуй, җыен ярышларында беренче булып килү. *Менә болар арасында әле узган ел калада да баш килгән Янил егете бар.* М.Гали. *– Кайсыгыз баш килде? – дип сорадылар*. М.Гафури. *Ул көнне чабышта бабай аты баш килгән, җәйдәгы әтием булган.* К.Латыйп. *Ат чабышларында баш килүен күрү аны бик кызыктыра.* Ф.Хөсни. **Баш китәрлек** Куркыныч яный торган, хәвеф китерерлек; хөкемгә тартырлык. *– Баш китәрлек сүз әйттең бит! – диде дә киселде.* Г.Ибрагимов. **Баш киткәндә, каш кайгысы** Зур бәла-каза килгән вакытта, вак-төяк белән маташу. **Баш китү** Үлемгә яки башка каты җәзага хөкем ителү. *Мин, дип әйтә, ди, патша кешесе, минем башым киткән.* Г.Газиз. **Баш кушу** Берәрсенә уртакка керү, союз ясау. *Сезнең белән инде баш кушабыз Гомер буйларына кирәккә.* Җыр. **Баш кую** 1) Бераз ял итеп, тынычланып алу. *Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә, Ашамый, эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә.* Г.Тукай; 2) Корбан булу, көрәшеп үлү. *Күпләребез вакытсыз баш куйдылар.* Г.Гобәй. **Баш күккә (түбәгә) тию (тия язу)** Көчле шатлык хисе кичерү, бик каты шатлану. *Зурларның башы күккә тиде: инде аларның дошманы мәдрәсәдән куылачак.* Г.Ибраһимов. *Ул арада, улының эше белән рухланып, башы күккә тиеп, әтисе кайтып керде.* Г.Гобәй. *Каз бәпкәсен очратсам да Балкый йөзем, Шатлыгымнан башым күккә тия минем.* З.Мансур. **Баш күрсәтү** Орлык тишелеп чыгу. **Баш күтәреп, тамак кырып, мыек борып (йөрү)** Байлыгы яки дәрәҗәсе белән масаеп, тәкәбберләнеп йөрү. **Баш күтәреп чабу** Тиз һәм гайрәтле чабу (атка карата әйтелә). **Баш күтәрмичә (күтәрмәстән)** Бик бирелеп, ал-ял белми, бертуктамый, тырышып. *Ләкин яшьләр бернәрсә дә ишетмиләрме, әллә ишетеп тә аңлап җиткермиләрме, башларын да күтәрмичә эшли бирәләр.* И.Гази. **Баш күтәрү** 1) Башны югары күтәреп карау. *Берничә минутлардан соң башымны күтәреп карасам, татар укып утыра иде.* Ф.Әмирхан; 2) Тишелеп чыгу, җир өстендә шытым күренү. *Яз килә --- җирләр ачыла, язның беренче котлаучылары – умырзаялар баш күтәрәләр.* Г.Әпсәләмов; 3) Ышаныч туу, башкалар алдында өстенрәк булып күренү. *Аталарыннан кар ерып кайту белән, хуҗа хатынның мондый зур эш тапшыруы аның башын күтәрде, ул, тиз-тиз йортка чыгып, кияү бүлмәсенә йөгерде.* Г.Ибраһимов; 4) Иҗтимагый тәртипкә каршы чыгу, фетнә оештыру. *Ул да түгел, Себердә баш күтәргән акларның Новосибирск, Томск, Чиләбе*

*шәһәрләрен алулары һәм үз кулларына эләккән барлык авылларда, шәһәрләрдә, совет властен бетереп, алпавытлар властен куеп барулары турында хәбәрләр йөри башлады.* И.Гази. *Баш күтәргән кавем белән сугышырга хөкүмәткә 14 миллион сум акча бирелде.* Урал. **Баш мие аркылы уздыру** Исенә төшерү, хәтердә яңарту. *Исламгали агай --- секунд эчендә, үзенең сугыш алды һәм сугыштан соңгы еллардагы тормышын баш мие аркылы уздырды.* М.Мәһдиев. **Башны ашау (җую, җыю)** Һәлакәткә дучар итү; үтерү, бетерү; юк итү, харап итү, хур итү. *Карама дуга, җиз алка – байлар җигә дан өчен; Күп егетләр башын җуя Алалмаган яр өчен.* Җыр. **Башны бутау** Бер эш арасына икенче бер эш я сүз белән тыгылып, уй-фикерне чуалту, эзлеклелекне бетерү. **Башны катыру** Юк-бар вак сүз, вак мәсьәлә белән башны мәшгуль итү, аптырату, йөдәтү. *Юк-бар белән башымны катырма әле, зинһар!* К.Нәҗми. **Башны кая куярга белмәү** Кайгыдан, мәшәкатьтән я пошынудан өзгәләнү, борчылу. **Башны комга яшерү** Җаваплылыктан качу, катнашмыйча, качып калу. **Башны кырын салу** Уйга бату, боегу яки үпкәләү. **Башны мескенгә (диванага) салу** Ярдәмгә мохтаҗ кыяфәт күрсәтеп, бичарага салышып, үзен кызгандырып йөрү. *Синең гыйшкың уты белән яну аркасында, укуга да күңел бирә алмадым, ахырысында, башымны диванага салып, кайтырга мәҗбүр булдым.* Т.Гыйззәт. **Башны салу** 1) Авыру, ару яки кайгыдан боегу, төшенкелеккә бирелү; 2) Буйсыну, ялынып, баш ию, багыну; 3) Корбан булу, көрәшеп үлү. *Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре халкыбызның азатлыгы өчен башларын салдылар.* **Башны ташка бәреп (орып) булмый** 1) Бик кыен, авыр, кайгы-хәсрәт, бәхетсезлекләргә, котылгысыз хәлләргә дучар булганда, сабыр итүдән башка чара юк, берни эшләр хәл юк, мәгънәсендә; 2) Эш (вакыт) үткәч, үкенүдән файда юк. *Башыңны орып булмый каты ташка.* М.Гафури. *Нишләсен, башын ташка орсынмыни!* Г.Бәширов. **Башны ташка бәрер (орыр) хәлгә җитү** Чара таба алмаслык хәлгә, бәлаләргә дучар булу, тәмам аптырауга калу. **Башны ташка бәрү (ору)** Ярсу, ярсыну; бик нык үкенү. *Тәмам башны ташка бәрер хәлгә җиттем.* **Башны тилегә (аңгырага) салу** Аңламаганга салышу, җитди сөйләшмәү. **Башны элмәккә тыгу** Үзеңне һәлакәткә китерү; бәлале, хәвефле эшкә килеп керү, тыгылу. **Башны этлеккә салу** Кечкенә генә файда алу өчен дә төрле түбәнлекләргә төшү, әрсезләнү, мутлану, усаллану. **Башны югалту** Уйламый, аңламый хәрәкәт итү, башкарган эш-гамәлләрен бәяләрлек дәрәҗәдә булмау; нәрсә беләндер мавыгып, чыга алмаслык бәлагә дучар булуын аңышмау. **Баш олагу, башны олактыру** Кая да булса ерак җиргә китү (җибәрү), шуннан, хәбәрсез булып, кайта алмый яту. **Баш орган башны кылыч чапмас** Рәхим-шәфкать сорап иелгән башны җәзаламаслар. **Баш ору** 1) Буйсынып, баш бөгү. *Баш органнан муен сынмас.* Мәкаль; 2) Башны бәргәләү, баш белән сугу; 3) Кемгә дә булса үтенеч-ялыныч белән яки ярдәм сорап бару. *Эшчеләрнең хатыннары һәм бала-чагалары да, үзләре белән ияреп, Арча кырына патшага баш орырга киткәнлектән, ул көн базарда да рәтле кеше юк иде.* М.Гали. **Баш очына болыт җыелу (куеру)** Бәхетсезлек килү, кайгы, борчу күбәю. **Баш өсте** Үтенечегезне, боерыгыгызны үтәргә әзермен, боерыгыгыз башымнан югары, мәгънәсендә (элек, хан фәрманын үтәүче кеше, хан алдына тезләнеп, фәрман язуын баш өстенә куйдырып алудан). *Бөтен нәрсә бар, «ашау – байдан, үлем – Ходайдан» дигәндәй, кием-салым зиннәтле, гаражда бер түгел, өч машинасы тора, өйдәге хезмәтчеләр һәр теләген, «баш өсте» дип, үтәп кенә баралар.* Х.Мөдәррисова. **Баш өстеннән йөрү** Артык узыну, тыйнаксызлану, буйсынмау, тәртип-кагыйдә бозу. **Баш өстеннән карау** Башкаларны санга сукмау, масаю, һавалану. **Баш(ны) салу** 1) Авыру, ару яки кайгыдан башны түбән ию, боегу; 2) Буйсыну, ялынып баш ию, багыну; 3) Якын ук килеп башны кую; тоташу. *Соң мәртәбә күрәм, диеп, башың салма җилкәмә.* Җыр. *Башын салган авыл урманга.* Н.Баян; 4) Корбан булу, көрәшеп үлү. *Сугышның дүртенче елы. Яуда башын салган ирләрнең санын счёт төймәләре белән дә санап бетерерлек түгелдер.* Н.Гыйматдинова. *Безнең газиз ирләребез «шул байга бил бөгүне бетерик, юк итик» дип, каннарын коеп, башларын салдылар түгелмени?!* М.Хәсәнов **Баш Себер китү** Хөкем ителеп, Себергә сөргенгә җибәрелү. **Баш суккан якка** Кайсы якка булса да, билгеләп тормыйча, теләсә кайсы юнәлешкә. **Баш та – баш, бүрәнә башы да баш (шалкан башы да баш)** Баш белән башның аермасы бар, дип, берәр кешенең аңгыралыгына төрттерү. **Баш та, күз дә** Берәр эштә башкаручы да, үзе үк өстән карап күзәтеп торучы да булу. **Баштан ашу** Артык күбәю, тулып яту, чиктән тыш күп булу. *Минем үз эшем дә җитәрлек, башымнан ашкан.* Г.Камал. **Баштан бәс кичкән** Чал төшкән, чәче агарган, дәрәҗәгә җитеп, күп тәҗрибә туплаган. **Баштан кичү (узу, үтү)** Үз гомерендә авыр хәлләргә дучар булу, кыенлыкларга очрау. *Мондый хәлнең тагы берничә хатын башыннан кичкәнлеге турында колакка кереп калган.* М.Әмир. **Баштан салкын су койган (сипкән) кебек (булу)** Кинәт бер курkыныч я күңелсез хәбәрне ишетүдән сискәнү, чирканып китү. *Баштан салкын су сипкән төсле калтыранып алдым, йөрәгем жу итте, акылымны җуйгандай булдым.* Г.Минский. **Баштан сыйпау** Йомшак мөнәсәбәттә булу (күбрәк *баштан сыйпамаслар* юклык формасында, гафу итмәсләр, хупламаслар, ризасызлык белдерерләр мәгънәсендә йөри). **Баштан үтү (үткәрү)** Авыр хәлләргә дучар булу, кыенлыклар күрү, кичерү. **Баштан чыгару** 1) Алдан уйланган фикердән баш тарту яки ул хакта онытып җибәрү; 2) Чынлыкта булмаганны уйлап чыгару. **Баштан чыгарып ташлау** Берәр нәрсә хакында уйлауны оныту, хәтта уйларга тиеш дип тә тапмау. *«Уен» дигән нәрсәне хәзер бөтенләй башымнан чыгарып ташладым.* М.Гафури. **Баштан чыгу (чыгып китү)** Оныту, истән чыгу.

**Баштан чыкмау** Һаман бер нәрсә хакында уйлау, гел шуны хәтердә тоту. **Баш тарту** Каршы килү; эшне, бурычны, вазифаны я биргән сүзне үтәргә теләмәү, кире кагу, нинди дә булса эшкә алынмау. *Нишлим, сугыш дустым-пистолетым соңгы сүздән кинәт баш тартты.* М.Җәлил. *Бервакыт, үзем укыта торган студентларның диплом эшләрен тикшергәндә, бала табу йортларында нарасыйларыннан баш тарткан хатын-кызлардан социологик сораштыру нәтиҗәләренә юлыктым.* Татарстан яшьләре. *Дөньяның иң күп шоколад җитештерүче компанияләрнең берсе булган Mars 12 яшькә кадәрге балаларга атап реклама чыгарудан баш тартты.* Ватаным Татарстан. **Баш та, түш тә** Барысына берүзе генә башлык, төп хуҗа. *Райсоюз складында асыл малның исәбе-хисабы юк. Анда баш та, түш тә – мин.* Б.Камалов. **Баш ташлап** 1) Бар дөньясын, үз-үзен онытып, бирелеп. *Хәдичәсе аны [Сәләхине] баш ташлап сөйгән.* С.Хәким; 2) Киреләнеп, үҗәтләнеп. **Баш та юк, аяк та юк** Тәртипсезлек, хуҗасызлык хөкем сөрә, дигән мәгънәдә. **Баш тирбәтеп утыру** Нишләргә белмичә, аптырап утыру. **Баш тоту** *гади с.* Жирәбә салу, шобага тоту. **Баш төзәтү** Эчкечеләрнең иртән яңадан өстәп эчеп, шуннан кәефләнүләре. *Монсын базга төшереп куйыйм әле. Монда торып, кыркуланып бетмәсен. Иртәгә тагы, килеп, баш төзәтергә сорарлар әле.* Г.Камал. **Баш төртерлек тә урын юк** Беркайда торыр-ятар урын юк, бик тыгын. **Баш төртү** 1) Ятып, бераз йоклап алу. *Хәер, ерак юлдан соң чак кына баш төртеп алу зыян итмәс.* Ә.Еники; 2) Тишелеп чыгу. **Баш тубал булу** Озак укудан, уйлаудан яки ыгы-зыгыдан баш ару. *Көн эчендә кырык кырланам, Башым тубал була уйлардан.* Ш.Маннур. **Баш тубалланып бетү** Баш юк-бар уй белән тулу, зиһен чуалу, кирәген уйлый алмау. **Баш түбәтәйгә сыймый** Борчу-мәшәкатьтән, күп уку яки уйлаудан баш шешкән кебек тоелу, баш ару. **Баш түнү** Нәрсә эшләргә дә белмичә, гаҗиз булу. *Шәйхетдиновның судтан соң атна буе башы түнеп йөрде.* И.Гази. **Баш тыгар урын юк** Бик күп булып туплану; тыгыз, кысан булу. **Баш тыккысыз (тыга алмассың, тыгарлык түгел)** 1) Бик тыгыз, җайсыз. *Сыеп булмый хәзер иске клубка, нефтьчеләр дә килсә, бөтенләй баш тыга алмассың.* Р.Төхфәтуллин; 2) Кышкы каты суыктан, көчле буран вакытында яки эсселектән, бөркүлектән, тышта йөрерлек булмау. *Кырда – буран, урамга баш тыгарлык түгел, есерә.* А.Гыйләҗев; 3) Үтеп булмаслык куе, чытырманлы (урман турында). **Баш урынына – колак, аяк урынына – тояк** Зур югалту урынына кечкенәсен биреп котылу. **Баш чатнау** Бик каты баш авырту. *Минем баш чатный, колак шаулый, күз алдым караңгыланып тора, алга барырлык хәл юк иде.* М.Гафури. **Баш черетү** Юкбар мәсьәләне дә, артык күпертеп, зур итеп уйлап йөрү. **Баш читкә китү** Туган илдән, туган җирдән еракларга, чит җирләргә китү. *Сөям сине, сөям сине, Башым читкә китсә дә.* Җыр. **Баш чуалу** Ни эшләргә дә, уйларга да белмәү, фикер чуалу, таркау фикер йөртү. **Баш чүмече йомры, сүзе туры** Акыллы, туры сүзле. **Баш чыкмастай** Бик катлаулы, мәшәкатьле, артык буталчык. **Баш чыкмау** 1) Берәр эшкә, хуҗалыкка бәйләнеп, гел шуның белән генә мәшгуль булу, шуннан арына, бушый алмау, котыла алмау. *Җәен – печән ташудан, көзен урманда себерке кисүдән баш чыкмады.* Г.Ахунов; 2) Берәр бәладән, озакка сузылган кыенлыктан котыла алмау. *Тик бервакыт аның [Мишаның] башы кара тактадан чыкмый башлаган.* Г.Бәширов. **Баш шешү** *к.* **баш түбәтәйгә сыймый. Башы белән** 1) Бөтенләе, тулысы белән, кире кайтарып алмаслык итеп. *Бүрегә бирсәң – башы белән.* Мәкаль. 2) Кемдер булуына карамастан, шундый кеше булуына карамастан. *Гөлшаһидә, хатын башы белән, больница салдыра.* Г.Әпсәләмов. *Адмирал башы белән, кәрзинкә үреп утырсын инде!* М.Кәрим. *Карт башың белән юкны юрап утырма әле син анда, яме!* Г.Гобәй. *Мәчтүрә башың белән өмәләргә килеп эшләп йөре, имеш.* М.Фәйзи. *Көтүче башың белән шундый нәфис көйләр тудыра алуыңа ышанырлар, дип уйладыңмы?* М.Фәйзи. **Башы белән чумган** Тулысынча, баштанаяк эшкә бирелгән. **Башы йомры** Акыллы, зиһенле; бик хәйләкәр. *[Бәкер:] Ничек, әтиең кайда эшләгән, дип сорадыларммы? Сорарлар. Аларның [завкомның] башы йомры.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Башы кайтмау** 1) Мәҗбүри берәр эшкә китеп, төп йорт-җиренә, туган иленә кайтмау; 2) Бер чыгып китсә, әйләнеп кайтырын онып турында. **Башы керсә, аягы кермәгән** Әле яхшылап урнашып та җитмәгән. **(Үз) башына** Эшләнгән эшләре үзенә начарлык булып кайтырлык, артык тәвәккәл; үтә явызлык белән. *Тимерче Соловьевның үз башына чүкеч булмаса гына ярар иде.* Г.Тукай. **Башына бәрү** Күп уйланудан, күп укудан яки артык борчылудан, акылын, уйлау сәләтен югалту, мәгънәсендә. *Кирәкмәгән нечкә күңелле нәрсә, уза китеп, башына бәрмәгәе, дип тә куркып куям шунда.* Г.Бәширов. **Башына җитү** 1) Кешене бәлагә тарту, һәлак итү. *Сүз – сүзгә китәр, сүз башка җитәр.* Мәкаль. *Бары тик акчамны алыр өчен генә минем башыма җиткән икән.* Г.Камал. *Сугышты ул батыр юлбарыс күк, Күп дошманның башына җитте ул.* Ш.Маннур; 2) Әйбер-карага, табигатькә һәлакәт китерү, корыту, юк итү. **Башына тау төшкән кебек (шикелле)** Бәла-казага очрап, үтә борчылган хәлдә. *Солдат, башына тау төшкән кебек, каты сулап куя.* Г.Ибраһимов. **Башында (башта) җил уйнау** Акыл белән эш итә белмәү, җитди уйлый белмәү. *Юләр кыз син, синең башыңда җил уйный.* Г.Әпсәләмов. **Башын харап итү** Кешене һәлак итү; гомерен, бәхетен, киләчәген кисү. **Башыңа төшсә – башмакчы булырсың** Бәла-каза, кыенлык, михнәт һ.б.ш. мәсьәләләр туганда, чарасыздан, үзең эшкә керешергә туры килер, эшкә алынырсың. *Башыңа төшкәч, башмакчы да буласың икән.* Г.Сәгыйров. **Башың яшь** Тәҗрибә яки дәрәҗә җитенкерәми, ул эшкә хакы юк, мәгънәсендә әйтелә. *Башың яшь икән – күп эш алма.* Мәкаль. *Шулай да бит, кодача, башың яшьрәк шул!* Г.Бәширов.

**Башы тишек** Бөтенесен дә аңлый, төшенә; икенче телдә сөйләшкәнне аңлый. **Башы түбән дөмеккере, дөмегепләр киткере** *карг.* Кемгә дә булса үлем теләү. **Башы юк** Дөрес фикер йөртми, акылы эшләми. *Аның бер дә баш юк шул, мие черегән аның.* Г.Камал. **Баш әләгү** Кулга алыну, тотылу, хөкемгә тартылу. **Баш югалту** Уйлау-фикерләү сәләте бетү; ни кыланганын аңламау. **Баш югалу** Гомер киселү, һәлак булу, баш бетү. *Егетләрдән берсе, авыр гына көрсенеп: – Баш югала торган юлга чыктык, – [диде].* К.Нәҗми. **Баш юк, аяк юк** *к.* **баш та юк, аяк та юк**. **Баш ярылып, күз чыкмаган** Ул хәтле зур бәла килмәгән, артык куркыныч түгел, борчылырга кирәкми, мәгънәсендә. *Әйдә, баш ярылып, күз чыкмаган әле, кызчак ике килми ул.* Ф.Хөсни. **Баш ярылып, күз чыкмас** Куркырлык бернәрсә дә булмас. *Бер көннән баш ярылып, күз чыкмас. Килгән-килгән, җиренә җиткереп кайтырсың.* А.Гыйләҗев. **Баш ярып, күз чыгарып** Ни эшләгәннәрен, нигә эшләгәннәрен дә белмичә, ахыры ни булып бетәсен уйламыйча, дуамалланып

**БАШАГАЧ** *и.* Үлгән кешенең каберендә баш очына утыртылган агач. *Кайсыларының ташлары кыйшайган, төссезләнеп, саргаеп калганнар, кайсыларының башагачлары бөтенләй җиргә ауган.* Г.Иделле

**БАШАК** I *и.* Кыяклы үсемлекләрнең сабак очында озынча булып укмашып утырган орлыклар теземе. *Яңгыркаем, яу, яу, яу! Иген-ашлык күп булсын, Башаклары тук булын.* Теләү. *Богдайларның барысы да башакларын җиргә карый игәннәр.* Дәрдемәнд. *Карачкыл күк йөзен телгәләп-телгәләп, еракта яшен ялтырап ала, һавага өлгереп килгән арыш исе – бал катыш яшел башак исе таралган.* М.Мәһдиев. *Хәлим арыш башакларына игътибар итте: алар да, әллә каян гына килеп чыккан җил уңаена, әле – бер якка, әле икенче якка дулкынланып утыралар.* Г.Гыйльманов

**БАШАК** II *и.* Туралган саламны кайнар су белән пешекләп, он яки көрпә белән болгатып әзерләнгән терлек азыгы. *Алар Ибрай белән, зур тагаракка салып, башак болгаттылар.* Г.Гобәй. *Шулай итә торгач, инде башактан да баш тарткан Шәехтай, алдында бетсә, түбә саламына да үрелә башлады.* Г.Гобәй. *Аннан соң аклы-кызыллы сыерга башак бирергә сарайга кереп китәр.* Р.Сибат. *Хәзер атларга башак бирәм дә ындырга менәм.* Р.Ишморат

**БАШАК** III *и.* Борынгы ук, сөңге кебек сугыш коралларының үткен тимер очы. *Тимер ук башаклары табыла.* М.Гафури. *Укларның башына башак кадаганнар.* М.Гафури. *Сөнге башагы*

**БАША́К ҖЫЙГЫЧ** *и.* Комбайнда башак җыю өчен көйләнгән җайланма

**БАШАККА́ ТУЛУ** *ф.* Башактагы бөртек өлгерү

**БАШАККА́ УТЫРУ** *ф.* Башак җибәрү, башак формалаша башлау

**БАШАКЛАНУ** *ф.* Башак чыгару. *Башакланып, өскә калыктылар.* М.Җәлил. *Беркөнне «Кызыл маяк» колхозының завфермасы Хөснуллин сөйләп торды: башакланмас борын, яшел көе чабып ашатсаң, сыерларың пряме пух итеп йөриләр, ди.* Ә.Еники. *Арышлар башаклануга, урманнан чакырылмаган кунаклар – кыр тычканнары килеп җитә.* Г.Хәсәнов

**Башаклана башлау** Башакланырга тотыну. *Казлар, игеннәр башаклана башлау белән, шул басудан төшми инде.* С.Зыялы

**Башакланып бетү** Тәмам башаклану

**Башакланып җитү** Тиешенчә, тәмам башаклану

**Башакланып килү** Башаклар барлыкка килә башлау

**Башакланып тору** Башакланган хәлдә булу. *Безнең иген хәзер башакланып тора, ә боларныкы әле яңа гына җирдән күтәрелеп бара.* Г.Иделле

**Башакланып утыру** Башаклары өлгергән хәлгә җитү

**Башакланып яту** Иңләп-буйлап, башакланган ашлык күренү. *Җәелә кырда, иркен океан сыман, башакланып яткан арышлар.* Ш.Мөдәррис

**БАШАКЛА́У** *ф. иск.* Ашлыкны, урмыйча, башакларын өзеп кенә җыю

**Башаклап алу** Башагын гына өзеп җыю. *Элек уңышны да, урудан бигрәк, башаклап алганнар.* Р.Әхмәтьянов

**Башаклап бару** Рәттән башаклау

**Башаклап бетерү** Тәмам, ахыргача башаклау

**БАШАКЛЫ** *с.* Башагы эре, тук булган. *Кура җиләге эре булса, киләсе елга ашлык башаклы булыр.* Сынамышлар. *Нәфисә кул астында таралып яткан эре башаклы беренче көлтәне, селкетә-селкетә, барабанга бирде.* Г.Бәширов. *Артларында тук башаклы Көлтәләр тезелеп кала.* Ә.Исхак

**БАШАКЛЫЛАР** *и. мәгъ.* Кыяклылар семьялыгына караган, башаклана торган кыяклы үсемлекләрнең гомуми атамасы (*арыш, бодай, арпа һ.б.*)

**БАШАНТАЙ** *и. диал.* Кыска оекбаш

**БАШАРКАН** *рәв.* 1) Артка таба мәтәлеп китеп. *Атлар кешнәп җибәрәләр, чабып барган җирдән, пуля тиеп, авып калалар, башаркан егылалар.* М.Гафури

2) *спорт* Баш аша чөеп (татарча көрәш алымы). *Бермәлне халык аһ итә. Кодрәт Хәкимне, күтәреп, башаркан чөя.* Ф.Яруллин

**БА́Ш-АЯК** *җый. и.* 1) Бөтен сын, сан, гәүдә

2) *кулин.* Азык әзерләгәндә бергә катнаштырып әзерләнә торган, терлекнең баш һәм аяк ите, үпкә-бавыры, эчәкләре. *Өйдә баш-аяк боткасы пешкән иде инде.* А.Расих

◊ **Баш-аягы белән** Бөтен барлыгы, җаны-тәне белән. *Усманов, беренче мәлдә, баш-аягы белән каршы килде.* Ф.Сафин. *Әни болай да баш-аягы белән мәшәкатькә чумган, минем өчен дә күз яше түкмәсен, дип кенә, мәктәпне тәмамлап чыгарга вәгъдә бирдем.* К.Миңлебаев. *Соңгысы мине бераз гаҗәпкә дә калдырды, чөнки майор Ильин музыкага бик исе китми торган, баш-аягы белән сугыш эшенә чумган бер кеше иде.* И.Гази. **Баш-аягың – бер казан** Кирәгең шул хәтле генә. *Чыксаң, уракка чаклы ябышып чыгасың, Сәрби, ә чыкмасаң... Чыкмасаң, баш-аягың – бер казан.* Ф.Бурнаш. **Баш-аяк бәлеше** Бар нәрсә дә асты өскә килгән, бернәрсә аңларлык түгел

**БАШАЯК** *рәв.* **1**. 1) Тулысынча, тәмам, бөтенләй, тулысы белән. *Шул*

*китүдән югалды, Гайнулла абзый әйтмешли, башаягы белән юк.* Р.Кәрами. *Зөлхәбирә башаягы белән юкка чыгар.* Р.Зәйдулла

2) Бөтен барлыгы белән, тулысынча. *Башаяк эшкә чумган. Мин башаяк риза булдым.* Г.Ибраһимов

**2**. **башаягы (башы-аягы)** *кис. мәгъ. сөйл.* Бөтен булганы, бар кадәре; бары тик, бары, нибары. *Язгы кояш белән имтиханнар башлыйсың... Аларны бетерәсең дә тизрәк качасың, кесәңдә башы-аягы барлыгы йөз сумлап акчаң бар.* Г.Ибраһимов

**3**. *хәб. функ.* Читтәрәк тору яхшы, шуннан тизрәк котылырга кирәк, мәгънәсендә. *Бәласеннән башаяк, дип уйлый иде ул.* И.Гази. *Бәласеннән башаяк, тизрәк илтеп ташлагыз бүре балаларын, диләр.* Н.Хәсәнов. *Соңыннан, бу өйдә рәт булмасын аңлап, бәласеннән башаяк, дигән кебек, ишек яңакларына бәрелә-сугыла, ишегалдына чыгып чаба...* Г.Гыйльманов

**БАШАЯКЛЫЛАР** *и. зоол.* Моллюскларның иң югарыгы классы; кальмар, каракатица, сигезаяк кебек гәүдәсе, нык мускуллы кармавычлы башы булган диңгез хайваннары кергән класс; *русчасы:* **головоногие**. *Бу моллюскларның баш тирәли кармавычлар үскән, шуңа күрә аларны «башаяклылар» дип атаганнар.* Үткән заманга сәяхәт

**БА́Ш БАРМАК** *и.* 1) Дүрт бармакка каршы куела торган кыска юан бармак. *Баш бармак балан ияр, Урта бармак балан тияр.* Такмак. *Ике баш бармагыңны билбавыңа тык*! М.Фәйзи. *Каюм хәлфә, шундук, Габдулланы сизеп, кинәт әйләнде дә «вет!» дип сызгырып алды, баш бармагы белән аның корсагына төрткәндәй итеп, талпынып куйды.* Ә.Фәйзи. *– Boh! – диде ул, болар янына килеп җитүгә, уң кулының баш бармагын күрсәтеп.* М.Гали

2) *күч. сөйл.* Бер дигән, бик булдыклы, менә дигән шәп, егәрле кеше. *Көтүчесе кем бит әле, баш бармак ич! Яшь булса да, көтүне кайда күпме вакыт йөртергә кирәклекне бөтенебездән яхшырак белә.* Г.Галиев

**БАШБАТА** *и. диал.* Үлгән кешенең каберенә язып куелган кабер ташы. *Мазар зиратына барып, башбаталарны укып кара, анда әкәмәт ташлар бар.* Э.Касыймов

**БА́Ш БАУ** *и.* Бастырыкның бер башына бәйләнгән аркан. *Баш бавың өзелмәсен, бастырыгың сынмасын.* Мәкаль

**БАШБАШТАК** *с.* Үз белдеге белән йөреп, теләсә нәрсә эшләүчән, тәртипкә буйсынмаучан. *Әйе, хакимият – аяусыз көч, усал, явыз, башбаштак көч.* Ф.Сафин

**БАШБАШТАКЛАНУ** *ф.* Тәртипкә буйсынмау, үз белдеге белән генә эш итү, сансыз кылану. *Әгәр син, агаларың котыртыгы белән, безне ата-ана итми башласаң, алар шикелле башбаштакланып, үзең белгәнчә йөрсәң, безгә кайгыбыздан үләргә генә кала.* Ф.Әмирхан. *Безгә бер сүздә булып эш йөртергә кирәк, әгәр дә әти киләчәктә дә шулай башбаштаклана калса, аның тәхетеннән ваз кичүе бездән көлүгә генә әйләнеп калачак.* У.Шекспир

**Башбаштаклана бару** Торган саен ныграк башбаштаклану

**Башбаштаклана башлау** Башбаштакланырга тотыну

**Башбаштаклана бирү** Башбаштаклануын һаман да дәвам итү

**Башбаштаклана төшү** Тагын да башбаштаклану

**Башбаштакланып алу** Берара, бераз вакытта башбаштаклану

**Башбаштакланып бетү** Тәмам, бик нык башбаштаклану

**Башбаштакланып җибәрү** Көтмәгәндә башбаштаклану

**Башбаштакланып йөрү** Озак вакытлар башбаштаклану. *Кайтыгыз, башбаштакланып йөрмәгез!* М.Гали. *Көлсу җансызлык иңгән йөзенә саран алсулык җәелгән, яшькелт төстәге сусыл күзләре явыз тантана белән яна иде. – Башбаштакланып йөрүенең җәзасын алды ахыр чиктә! – дип кычкырды ул, гөрелдәвек тавыш белән.* А.Вергазов

**Башбаштакланып килү** Башбаштакка әйләнә бару

**Башбаштакланып китү** Кинәт башбаштаклану. *Сафиулла абзыйның Габделбарые да сирәк катнаша – ул әдәпле һәм тыйнак малайларның кайвакытта артык башбаштакланып китүләрен яратмый иде.* Ә.Еники. *Председатель Сөләймановка кинәт болай кулдан ычкынып, башбаштакланып киткән җыелышны яңадан кулга алу, эзгә төшерү ансат булмады.* Ә.Еники

**Башбаштакланып кую** Тик торганнан, кинәт башбаштаклык күрсәтү

**Башбаштакланып тору** Һәрвакыт башбаштаклану

**БАШБАШТАКЛЫК** *и.* 1) Башбаштак булу. *Кызганыч ки, Расыйхыбызның дуамаллыгы, башбаштаклыгы еллар үтү белән дә һич кимеми, шуның нәтиҗәсендә, киң күңелле дустыбызның язмышкае бик тә инде аянычлы рәвештә очлана...* К.Миңлебаев. *Революциянең --- мәгънәсе – халыкны аерым шәхесләрнең башбаштаклыгыннан азат итүдә.* А.Расих

2) Тәртипсезлек, рәтсезлек. *Халкыбызның гаилә институты җилкапка кебек шыр ачык, аңа чит кавемнәр кереп-чыгып йөри, милләтебезнең 30 проценты – катнаш никахта, кайсы халык шундый башбаштаклыкка юл куя?!* Р.Ягъфәров. *Улының шундый башбаштаклык эшләвенә колхоз председателе Гафур Шәяхмәтов сәбәпче, билгеле.* Р.Кәрими. *Әмма дә ләкин гаиләбездә башбаштаклыкка юл куелмый.* Илһамият

**БА́Ш-БАШЫ** *җый. и.* Озынча әйбернең ике очы, ике башы (икесен берьюлы әйткәндә). *Гайниҗамал ике тастымалны бергә үреп, баш-башларын әйбәтләп төйнәде.* И.Гази

**БАШБИРМӘС** *с.* Үзсүзле, куркусыз, үгетләп булмый, сатылмый торган. *Аучыларның берәрсе мылтыгын иңбашыннан ала башлады исә, урман мәчесе елгырлыгы белән мылтыгын тегеләргә төбәп тә куя патша хәзрәтләренең башбирмәс солдаты.* Я.Зәнкиев

**БАШВАТКЫЧ** *и.* **1**. 1) Фикер күнекмәләре сыйфатында уйлап чыгарылган һәм тапкырлык, зирәклек таләп итә торган төрле табышмаклар, мәсьәләләр, сораулар. *Кайчагында бабай, үзе эш белән киткәндә, безгә дә башваткычлар биреп калдыра иде.* Г.Гобәй. *Газета актара торгач, башваткыч табып, каләм алып, түр якка – гаилә янына чыкты.* Татарстан яшьләре

2) *куч.* Ныклап уйлап кына хәл ителә торган авыр мәсьәлә, проблема, четерекле хәл. *Үзегез дә минем өчен шактый катлаулы табышмак булдыгыз... Башваткыч, дисәм, дөресрәк булыр.* М.Хәсәнов. *Шуның белән бергә, планетаның магнетизмын өйрәнгәндә, галимнәр бик күп башваткычларга юлыгалар.* Могҗизалар энциклопедиясе

**2.** *с. мәгъ.* Зирәклек күрсәтүне, уйлауны таләп иткән. *Мин бу юлы да аны, берәр башваткыч табышмак бирер, дип уйлаган идем, ләкин табышмакның башы белән ахыры бөтенләй бәйләнешсез булып чыкты.* А.Шамов. *Хәер, нинди генә кыенлыклар кичерергә туры килмәсен, нинди генә башваткыч мәсьәләләр чишәсе булмасын, Нәфисә барысына да әзер иде.* Г.Бәширов

**БАШИМӘС** *с.* Буйсынмый торган, үз сүзендә нык торучан, горур. *Чөнки Бикбулат картның кызы турында да үз уе бар, ул аның, абыйсы Сәръян шикелле, үзсүзле башимәс булуын ошатмый иде.* Г.Бәширов. *Озакламый, аны этапка кудылар, шунда, зоналарның берсендә, төзелеш басмасында кәефләнеп кенә ялкау симертеп ятканда, тук һәм башимәс Юраның башын кисеп ыргытканнар, дигән хәбәр килеп ирешә.* А.Гыйләҗев

**БАШКА** I *с.* **1.** 1) Бөтенләй икенче төрле; бу түгел. *Ошамаса, башка көйләрне уйнарга өйрәтерсез.* К.Нәҗми. *Инде минә Сиваш – бөтенләй башка нәрсә.* Г.Бәширов. *Нәгыймнең башка кульязмасын кайдан табарсың икән, Мостафа?* Ш.Камал. *Татар халкының да, башка халыклар кебек үк, үзенең күптөрле милли ашлары бар.* Татар халык ашлары

2) Аерылып торган, икенче төрле, үзгә, бүтән. *Шәһәргә килгән кешеләр телен дә югалта башлый, аралашааралаша, русчага да, башка телгә дә күчәләр, катнаш гаиләләр коралар.* Ф.Мөхәммәтшин. *Күз ияргесез җитезлек белән башка киемнәрен киенде.* М.Әмир. *Сәнгатьлелек кимәле белән, ягъни иҗатның иң асыл күрсәткече җәһәтеннән, аның әсәрләре, башка күренекле роман, повесть, хикәяләребез кебек үк, дөнья классикасы дәрәҗәсендә язылганнар.* Мирас

**2. башкалар** *и. мәгъ. күпл.* Бүтәннәр, икенчеләр, бүтән, икенче кешеләр. *Үз гонаһын башкалар өстенә аудару – иң мордар, иң әшәке кешеләрнең эше.* Дәрдемәнд. *Әнә Софья Павловна белән Сергей Павлович Шестериннар кул болгый, башкаларның да яулык, эшләпәләре чайкала.* И.Низамов. *Үзе тыныш кеше башкалардан да шуны таләп итә.* Р.Яхина. *Син башкалар әле әйтергә генә җыенган сүзне әйтергә тиеш.* Казан утлары

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Аерым, үзе генә, ялгызы гына. *Эт тапса – башка ашар, егет тапса – бергә ашар.* Мәкаль

2) Аерымлы, икенче төрле; бөтенләй бүтән. *Инде, кияү, ул вакытта сезнең коммунга язылган булсак, эш башка булыр иде.* Һ.Такташ. *Һәм хакыйкатән, бу яшь әсирнең ачык йөзе, нечкә бармаклары, әдәпле сүзе городской адәмгә башка иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Ничектер, башкарак булып чыкты.* Г.Ибраһимов

**БАШКА** II *бәйл.* Чыгыш килешендәге исем белән килеп, исемдә күрсәтелгән төшенчәне чикләүне белдерә; тыш, бүтән. *Уяныр-уянмас, әнкәеңнең йөзенә карап көлүдән башка һич эшең юк.* Дәрдемәнд. *Аның гүзәллеген, эчке бер сөйкемлелеген, Ярмөхәммәттән башка, бер генә кеше белә иде – Альберт.* Р.Батулла. *Ник бу болай Шаярта икән мине? Шаяртырга миннән башка Егетләр беткәнмени?..* М.Җәлил. *Бөтенләй дини гадәтләрдән башка күмделәр, кеше аз иде.* Г.Ибраһимов

**БАШКА́-БАШКА** *с.* Бөтенләй бүтән; һәрберсе үзенә аерым, һәркайсы үзенчә. *Такылдамак белән мәүзүн сүз сөйләмәк – икесе башка-башка булырга кирәк.* Г.Тукай. *Теләкләре башка-башка булса да, бу ике карендәш дус иделәр.* Г.Тукай. *Әбиләр дә безнең башка-башка, Бабайлар да безнең башкадыр.* Х.Туфан

**БАШКА́-БАШКАЛЫК** *и.* Үзгәлек, аерымлык. *Моннан соң җырләрнең башка-башкалыгы һәр кавем эчендә, аерым-аерым горуһлардагы төсле үк, хезмәтне бүләргә мәҗбүр итте.* Г.Тукай

**БАШКАЛА** *и.* 1) Дәүләтнең, илнең административ-сәяси органнары урнашкан үзәк, баш шәһәр, мәркәз. *Мәскәү безне төксе каршы алды, күпмиллионлы башкалада безне беркем дә көтеп тормый иде.* Й.Хәлиуллин. *Казан каласы – таш кала, Безнең сөйгән башкала.* Ш.Маннур. *Бүген башкалабызның 29 сәүдә ноктасында чыршылар белән сату итү башланды.* Шәһри Казан

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса тупланган урыны, үзәк; өлкәнең, крайның һ.б.ш.ның үзәк шәһәре. *Ул, Беломорск, Лоухи, Кандалакша аркылы, төньякның башкаласы Мурманскига – төньякта бердәнбер булган һәм ел әйләнәсендә туңмый торган порт шәһәренә бара.* Г.Әпсәләмов. *Ярына Себернең борынгы башкаласы Тубыл урнашкан Обь елгасы кушылдыгы булып чыкты.* М.Хәсәнов. *Кыска гына вакыт эчендә, Әлмәт нефть төбәге башкаласына әверелде.* Татарстан

**БАШКАЛАНУ** *ф.* 1) Башка төрлегә әйләнү, үзгәрү, башка сыйфат, үзлекләр алу. *Бозылган чәчкә исе – башкаланган, Үләрсең, болай барса, мәсхәрәңнән!* Ш.Бабич. *Сәфәрдән кайткан кеше беркадәр башкаланып, яңарып кайта, сәфәр кешегә дәрәҗә бирә.* Н.Исәнбәт

2) *диал.* Ата-ана йортыннан аерылып чыгып яши башлау. *Ахыр чиктә Гыйлемдар, үзенә тигән өлешен дә әтисеннән тулысынча даулап алып, бөтенләй башкаланды.* М.Шабай

**Башкаланып чыгу** *к.* **башка чыгу.** *Гайнулла карт аңа итек ямау өчен кирәкле корал бирде, сумала җеп бирде, һәм көннәрдән бер көнне Солтангәрәй башкаланып чыкты.* Ә.Еники. *Көктугайда чакта, Сәлим, өйләнгәч тә, әткәсеннән башкаланып чыккан иде, ләкин монда – кеше өстендә – алар бөтенесе бергә торалар иде.* Н.Фәттах

**БАШКАЛЫК** *и.* 1) Башка төрле булу, аерма, үзгәлек. *Ул малайлар уены белән бу уенда башкалык барлыгын да әйтим инде...* М.Гали. *Башкалык – тик фәсләре!* Г.Тукай

2) Каршылык; ризасызлык; төрлелек. *Аннан соң Габделкаюмны укыту турында да семьяда фикер башкалыклары килеп чыкты.* М.Гали

**БА́Ш КАПКАЧЫ** *и. анат.* Баш түбәсе сөяге. *Баш капкачын алып, баш*

*миенә операция ясарга җыендылар.* Сөембикә

**БАШКАРМА** *с.* Берәр эшне, планны, законны үти торган. *Кайсысын-берсен я военкоматка, я районның башкарма комитетына җибәрә иде.* Г.Бәширов. *Советларның өяз конференциясендә Якубны өяз башкарма комитетына член итеп сайлаганнар иде һәм башкарма комитет аппаратына эшкә алырга карар чыгарганнар иде.* И.Гази. *Ул чагында башкарма хакимият закон чыгару органына сайлаулар нәтиҗәләре буенча төзеләчәк.* Татарстан. *25 февраль көнне Уфада Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының күчмә утырышы булып узды.* Сөембикә

**БАШКАРУ** I *ф.* 1) Эшләнәсе эшне үтәү, тормышка ашыру, гамәлгә ашыру. *Булат ишетсә, әйтер инде, гомердә бер эш тапшырдым – шуны да башкара алмадың, дияр.* Г.Ибраһимов. *Һәркем илдә гүзәл эш башкара.* Ә.Ерикәй. *Театрның икенче дирижёры Пазовский «Фауст» операсын һәм «Файдасыз саклык» балетын әзерләде, һәм ул бу эшләрне аерым мәхәббәт белән башкара.* М.Җәлил. *Калганын үзем башкарырмын.* Ш.Маннур

2) Тамашачы алдында чыгыш ясау. *Алла Сизова белән Рудольф Нуриев Адольф Аданның «Корсар» балетыннан атаклы па-де-де вариациясен башкарып дан казандылар.* Р.Вәли. *Менә берсе хор кырыена чыгып игълан итте, хор «Амур дулкыннары»н башкарачак икән.* М.Мәһдиев. *Үзебезнең яшь һәм талантлы музыкантларыбыздан Мәхмүт иптәш үзенең, арзанлы гына булса да, ифрат яхшы тавышлы гармунында Көнчыгыш Азия һәм Көнбатыш Европа классикларының мәшһүр әсәрләреннән арияләр башкарачак.* Ш.Камал

**Башкара бару** *к.* **башкарып бару**

**Башкара бирү** Башкаруын дәвам итү

**Башкара килү** Дәвамлы һәм даими рәвештә, нинди дә булса эш башкару. *[Айрат Арсланов] --- язучы белән укучы, шагыйрь белән тамашачы арасында, инде ярты гасыр, үзенә бер вәкаләтле илче ролен башкарып килә.* Р.Әхмәтҗан

**Башкарып алу** Аз гына, кыска вакытлы башкару. *Сугыштан соңгы елларда биредә А. Шамов та мөхәррирлек вазифасын башкарып ала.* Р.Гыймадиева

**Башкарып бару** Һәрберсен, берберартлы башкару. *Һәрбер авылда, туктап, үзләренең кара эшләрен башкарып баралар, ди.* Т.Нәбиуллин. *Аның беркайчан колы-карасы булмаган, хуҗалыктагы барлык эшне алар шулай үз көчләре белән башкарып барганнар.* Н.Фәттах

**Башкарып бетерү** Барысын да башкару. *Безне ирекле ихтыярдан һәм данның безгә тиешле өлешеннән аермас өчен, Алла барысын да үзе башкарып бетерми.* Н.Макиавелли

**Башкарып бирү** Башкарырга ярдәм итү, эшләргә ярдәм итү

**Башкарып җиткерү** Вакытына башкару, башкарырга өлгерү

**Башкарып йөрү** Һәрберсен, булган берсен, анысын-монысын башкару. *Шуннан соң Газизә апа байбикәнең өендә аның өй эшләрен, тегү-чигүләрен башкарып йөрде.* Ә.Фәйзи. *Әти, Госмановларның приказчикларына самавыр куеп, ашамлык-эчемлек ташып, төрле йомыш башкарып йөри.* Р.Мостафин

**Башкарып кайту** Нәрсә булса да эшли алу, булдыру. *Шул йөкне башкарып кайтканда гына, мин сине кичерә алырмын.* М.Хәбибуллин. *Мин, әби, ерактан... Бер эш башкарып кайтып киләм. Хәзер менә ничек тә, исән-сау килеш, үзебезнекеләр ягына чыгарга кирәк.* Ф.Кәрим

**Башкарып калу** Башкарырга өлгерү

**Башкарып карау** Нәрсә дә булса эшли алу мөмкинлеген ачыклау өчен, ни дә булса эшләп, сынап карау. *Сәләтне ачыклау өчен, баланың шул юнәлештәге эшне башкарып каравы кирәк.* А.Низамов

**Башкарып килү** Электән үк, озак еллар даими башкару. *Әнә ничә колхозның эшен башкарып килә бит ул!* Г.Бәширов. --- *Балтыйк буе республикаларында, ерак чит илләрдә гастрольләрдә булып, үзенең милли-мәдәни вазифасын зур фидакярлек белән башкарып килә.* Татар театры

**Башкарып кую** Алдан башкару; башкарырга өлгерү. --- *ул – ярдәмчел, теләсә нинди эштә дә, болай итсәм, ничек булыр икән, дип уйланып тормый, башкарып та куя.* Д.Бүләков. *Сез, милли мәсьәләне Сталин, Брежнев хакимияте тиз арада башкарып куйды, дисез.* Р.Низами

**Башкарып ташлау** Бик тиз генә башкару. *Тавыш-низаг чыгарып торганчы, теләсә нинди эшне, җиң сызганып, үзе башкарып ташлый.* Т.Галиуллин. *Дуамал да, тапкыр да, җор да син, яшьлек! Кызулыгың, дуамаллыгың аркасында, аек акыл белән эшләп булмастай эшләр башкарып ташлыйсың.* Ф.Яруллин

**Башкарып тору** 1) Һәрвакыт, гел башкару. *– Дөрес, синең эшең минекеннән авыр. Эшеңне, зарланмыйча, ирләрчә башкарып торасың син, – дидем мин, кокның күңелен күреп.* М.Юныс

2) Әле, хәзерге вакытта башкару. *Мәктәп-мәсҗетләр, гариплəр йорты һәм мөсафирханәләр салдыра башладым. Килгән-киткәнгә нигъмәт куйдым. Шул эшне башкарып торыр өчен, махсус кешеләр билгеләдем.* К.Насыйри

**Башкарып чыгару** Ахырга кадәр башкару, булдыру. *Бу эшне башкарып чыгарырга тирә-якка даны таралган ат карагы Зәйдүк алынды, бәясен – бер егерме бишлек һәм, өстәвенә, бер чирек аракы, дип килештеләр.* М.Гали

**Башкарып чыгу** Җиренә җиткерү, тиешенчә, ахырына кадәр башкару. *Берәр задание алсам, башкарып чыкмый торып, рәтләп тамагыма да капмыйм.* И.Гази. *Боларның бөтенесен берьюлы гына Әбүгалисина да үзенең гыйлеме белән башкарып чыга алмас иде.* Ә.Фәйзи. --- *тик алар «милләт» дип шауларга, астан ут үрләтергә яратсалар да, бер генә эшне дә ахырына кадәр башкарып чыкмыйлар.* Ф.Сафин

**БАШКАРУ** II *ф. диал.* Бүтән төрлегә әйләнү, үзгәрү. *Тукай үлгәннән соң, аңар мөнәсәбәт бераз башкарды.* Җ.Вәлиди

**БАШКАРУ** III *ф. лингв.* Иярүче сүзнең, ияртүче сүзгә бәйле рәвештә, билгеле бер грамматик формада килүе.

*Татар телендә ияртүче сүз белән ияручe сүзләрнең үзара бер-берен башкару очраклары да бар.* В.Хангилдин

**БАШКАРЫЛЫШ** I *и.* Сыйфат ягыннан үтәлеш. *Таргын угълы Колынтай бәк Кошчак угълан, атлы гаскәр белән каладан чыгып һөҗүм итү – синең башкарылышта.* Р.Батулла. *Программаның башкарылышы. Эшләнгән эшнең башкарылышы*

**БАШКАРЫЛЫШ** II *и. лингв.* Башкару бәйләнеше. *Башкарылыш белән бәйләнеп тезелгән тезмәләрдә җитәкче сүз яки ияртүче сүз – «башкаручы» дип, ияручe сүз «башкарылучы» дип атала.* В.Хангилдин

**БАШКАРЫНУ** *ф. сир.* Читтән ярдәм алмыйча, эшне үзе генә үтәп чыгу. *Мәрьям абыстай, көндәге гадәте буенча, [иренең] аякларын салдырырга, киемнәрен чишендерергә «баш өсте» дип каршысына барып басса да, Сафый абзый --- дәшми-нитми, үзе генә башкарынды.* Г.Толымбай

**БАШКАТЫРГЫЧ** *с.* 1) Бик катлаулы, четерекле, башваткыч, кыен чишелешле. *Ике йөрештән соң, мин «кәррә шаһ» игълан иткәч тә, ул һаман елмаюында булды, чөнки Нәҗметдиновның башкатыргыч комбинациясе башлана гына иде әле.* А.Тимергалин. *Әмма хәзер юлга чыгу минем өчен иң авыр, иң башкатыргыч мәсьәләгә әйләнде.* Ә.Еники

2) Бәйләнчек, йөдәтүчән, теңкәгә тиючән, теңкә корыткыч. *Берсенә берсе бәйләнешсез бу башкатыргыч уйлар кайдан килеп болай сарылды соң әле?* Ф.Хөсни

**БАШКА́ЧА** *рәв.* Икенче төрле итеп, бүтәнчә, башка төрле, үзгәчә. *Әсәр барышы өчен кирәксез яки башкача итеп үзгәртелүе артык булган урыннар да юк түгел.* Г.Нигъмәти. *Бөтен дөньясына булган ачуын башкача баса алмаган өчен, барлык рәнҗү-үпкәләрен тышка чыгарыр өчен, җан көченә кычкыра.* Р.Кәрами. *Минемчә, Кәрахмәтне бөтенләй башкача – Тукайча эшләргә кирәк.* М.Җәлил

**БАШКА́ЧАЛАНУ** *ф. диал.* Үзгәрү, башка төрлегә әйләнү

**Башкачаланып калу** Вакыт үткәч яки нindидер сәбәптән соң башкачалану

**Башкачаланып китү** Кинәт башкачалану. *Галимәнең --- иреннәре күгәреп, күзләре башкачаланып китте.* М.Гафури

**Башкачаланып тору** Башка төрле рәвеш алу

**БАШКА́ ЧЫГУ** *ф.* Аерым йорт салып, ата-ана йортыннан аерылып чыгып, мөстәкыйль яши башлау. *Аның башка чыккан бер абыйсы бар иде.* Г.Бәширов. *– Башка чыгам, – диде ул ---.* Ш.Камал. *Аннары тагын Нәсиб бабайның Нурулла атлы җитү улы, каяндыр читтән килгән Мәрьям исемле чибәркәйгә өйләнеп җибәрде дә, әтиләреннән башка чыкты.* К.Миңлебаев

**БА́Ш КИЕМЕ** *җый. и.* Башка киелә торган кием. *Ул, баш киемен кулында йомарлап, аягүрә баскан килеш гозерен сөйләде.* И.Гази

**БА́Ш КИЛЕШ** *и. лингв.* Кушымчасы булмаган, бәйлекләрдән башка гына кулланыла торган, субъектны билгеләгән төп килеш

**БАШКИСӘР** *и.* 1) Кеше талап, үтереп йөрүче, юлбасар; бандит. *Испаннарның данлы культурасын Таптаганда кыргый фашистлар, Чапкан чакта халыкларның башын Франко дигән сатлык башкисәр.* Ә.Исхак. *Йодрыгыма бөтен илаһи көчемне җыйдым да чигә төбенә тондырдым каршымда торган башкисәрнең.* В.Юныс. *Шундук кабинадан алыптай зур гәүдәле, таш бәбәкле дүрт башкисәр сикереп төште.* З.Мәхмүди

2) *күч.* Бик чая, үтә тәвәккәл, дуамал кеше. *Иллә башкисәр икәнсең.* Т.Гыйззәт. *Гайрәтләнеп, көяз башкисәр Каты ябып керде ишекне.* М.Җәлил. *Илдар, бу башкисәрләргә якын бармаса да, киләчәктә тәҗрибәләре кирәгер, дип, аларның гамәл-кыланышларын, үзләрен читтән генә карап, күзәтеп йөри башлады.* З.Фәйзи

**БА́Ш КИЧ** *и. иск. диал.* Ял көне

**БАШКОДА** *и.* Кемгә дә булса кияүгә сорап, җиткән кызларны димләп йөрүче; яучы. *Башкодаларның вә яучыларның күбесе тәрбия вә гүзәл холыкның нинди нәрсәдән гыйбарәт икәнлеген үзләре дә ачык аңламавы --- боларның сүзләренә ышану гына булыр.* Р.Фәхретдин. *– Үзе булган, үзе уңган Ләйлиҗамалны братыма алып кайта алмасам, атым Фатыйма булмасын! – дип, әңгәмәгә чик куя башкода, күзләрендә ялкын уйнатып.* К.Миңлебаев. *Кияү егет тә, башкода да булдым, кыз да урлаштым.* Г.Әпсәләмов

**БАШКОДАЛЫК** *и.* Яучы булу, димче шөгыле. *Башкодалык вазифаларын да үз өстемә алам.* К.Латыйп

**БАШКОРТ** *и.* Башлыча Башкортстанда яшәүче төрки телле милләт атамасы һәм шул милләтнең бер кешесе. *Әле генә күрсәтелгән «өчпочмакта» исә Урта гасырларда кыпчак телле кабиләләрдән хәзерге татарларның, башкортларның, нугайларның һәм казакъларның бабалары составына кергән ырулар, этник группалар яшәгән.* М.Госманов. *Урал төбәгенең төньяк-көнбатышындагы башкорт төркемнәре монда «иң электән үк булган» ---.* Д.Исхаков. *Шунысы ачык: башкорт халкы, татар халкы кебек үк, аерым милләтне тәшкил итә.* Казан утлары

**БАШКОРТЛАШТЫРУ** *ф.* Башка милләт халыкларын башкорт милләтенә күчерү. *Ул, 1855 елның 19 апрелендәге патша указына таянып, мишәрләрне башкортлаштыра.* Казан утлары

**БАШКО́РТЧА** *рәв.* **1.** 1) Башкорт телендә. *Җәйләрен, авылга кайткач, авылым урамнарында йөрим дә адым саен башкортча сөйләшү ишетәм...* М.Әхмәтҗанов. *1959 елны чыккан «Башкорт халык иҗаты» китабының икенче томындагы текст, 1843 елны В.И.Даль бастырган варианттан башкортчага кире тәрҗемәдә китерелеп, «Тылсымлы әкиятләр» бүлегенә урнаштырыла.* М.Госманов. *Үзең, энем, башкортмын, дисең, үзең башкортча сөйләшә белмисең.* М.Кәрим

2) Башкортларга охшашлы итеп, башкортларга хас булганча. *Ул, башка вакытта, саф татарча сөйләшә торган булса да, бүген күп сүзләрне башкортчага тартып әйтә-әйтә, үзенең кем икәнлеген белдерә башлады.* М.Әмир. *Бик моңлы иттереп, башкортча җырлый белә [Буләков Мөбарәк].* З.Зәйнуллин.

**2.** *с. мәгъ.* Башкорт телендә булган, башкортларга караган. *Башкортча әдәбият. Башкортча бию көйләре*

**БАШКОРТЧАЛАШТЫРУ** *ф.* Башкорт теленә күчерү, тәрҗемә итү

**Башкортчалаштыра бару** Әзлекле рәвештә башкортчалаштыру

**Башкортчалаштырып бетерү** Барысын да, тулысынча башкортчалаштыру

**Башкортчалаштырып җибәрү** Берара, бераз башкортчага да күчү

**Башкортчалаштырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр башкортчалаштыру

**БА́Ш КОСУ** *ф.* Башак чыгару. *Арышлар баш косып, серкәгә утырды.* Г.Ибраһимов

**БАШКӨЛЛӘЙ** *рәв. диал.* Алдан ук һәм бөтенләйгә. *Шәфинең бөтен татар-башкорт җирен башкөлләй немецка сатып җибәрүе – көн кебек ачык.* Ш.Маннур

**БА́Ш КӨН** *и. иск. диал.* Дүшәмбе

**БА́Ш-КҮЗ** *җый. и.* Баш һәм күзләр, йөз, чырай (бергә әйтелгәндә). *Балык бирсәң – бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир.* Мәкаль

◊ **Баш-күз акаю (тону)** Иләсләнү, ашкыну, җилкенү, үз-үзен белештермәү, шашыну, котыру. *Башы-күзе тонган Шакир килеп керде.* Ә.Фәйзи. **Баш-күз алгысыз** Ыгы-зыгылы, тәртипсезлектән, буталчыклыктан торган. **Баш-күз алмыйча (эшләү)** Баш күтәрмичә, ял итмичә, бирелеп (эшләү). **Баш-күз алу** Беркадәр җайлану, тынычлану, үзеңне иркен хис итә башлау, иркенәю, ыгы-зыгылы, мәшәкатьле эштән бераз тыну, бушау. *Шул ук сәгать үземнән, башкалардан баш-күз алдым да сөйләргә башладым...* Г.Тукай. *Юлын гына белмибез, юл күрсәтүче булып, баш-күз алганчы, хөкүмәт машиналар биреп торса...* М.Әмир. *Аннары инде, баш-күз алгач, ниндирәк юл белән китәргә икәнен үзең хәл итәрсең.* К.Миңлебаев. **Баш-күз әйләнү, баш-күз әйләнеп йөрү** Берәр кеше я берәр нәрсә белән мавыгып, иләсләнеп, шуның артыннан чабу, кызыгу, багыну. **Баш-күз чыгару** Буталыш тудыру, кая барып бәрелгәнне белмәү, дуамаллану. **Башны-күзне ташлау** Аңга килергә, уйлап карарга тырышмау, белештермәс дәрәҗәгә җитү. **Башын-күзен әйләндерү** Үзен яратырга мәҗбүр итү, яраттыру, үзенә каратып иләсләндерү, ашкындыру, җилкендерү. – *Минем кызның башын-күзен әйләндермәкче булып йөри ул, – диде.* А.Әхмәт

**БАШКУКРӘК** *и. зоол.* Буынтыгаяклылар классына караган тереклек ияләренең гәүдәсендәге баш һәм күкрәк бергә кушылган өлеш (ул корсак өлешеннән кискен рәвештә аерымланып тора); *русчасы:* **головогрудь.** *Башкукрәктә буынтыклы ике пар (озын һәм кыска) мыекча, күзләр, авыз органнары һәм биш пар буынтыклы аяк була.* Зоология

**БАШКУНӘК** *и. бор. диал.* Ат башы яки сыер башы тиресеннән ясалган күн савыт. *Теге башкунәкне ачып, балчыкны буяп ясаган бер яшелле-зәңгәрле җамаякны алып, элек Сәгыйдкә сонды, соңра кунакларның һәммәсенә сондырып чыкты.* Г.Гобәйдуллин

**БАШЛАМ** *и.* Әдәби әсәрнең башлангыч өлеше. *Шуңа күрә дә әдипләр башламны мөмкин кадәр яңгырашлы, музыкаль эшләнешле, күп мәгънә сыйдырышлы, фәлсәфи егәрлекле итәргә, аңа күп көч салырга тырышалар.* Р.Фәтхерахманов. *Көй башламы уйналып бетәр-бетмәс, сәхнәгә милли киемнәрдән ике кыз атылып килеп чыктылар һәм җитез җиңел хәрәкәтләр белән биеп тә киттеләр.* Ф.Сафин

**БАШЛАНГЫЧ** *с.* **1.** 1) Иң баштагы, алдагы, беренчел. *Ул кешеләрне йортлар, гыйбадәтханәләр салырга, законнар язарга өйрәтте, аларга геометрия фәненең башлангычларын бирде.* Кызыклар дөньясында. *Әхмәтхәсән башлангыч белемне әтисеннән ала, Чистай мәдрәсәсен, аннары Казанда һөнәр училищесын тәмамлап, совнаркомда эшли.* Мәдәни җомга

2) Түбәнге, беренче баскычтагы. *Берсеннән берсе кечкенә ике баласы булу өстенә, ире сугышның беренче көннәреннән бирле фронтта йөри, үзе исә бер башлангыч мәктәптә укыта һәм, читтән торып, педагогия институтында укый.* Г.Гобәй. *Утызынчы елларда шундый зур авылның очларында өч башлангыч һәм бер җидееллык мәктәп бар иде.* К.Миңлебаев. *Ул авыл мәктәбенең башлангыч классларында балалар укытырга керешә.* Татарстан яшьләре

**2.** *и. мәгъ.* 1) Түбәнге класслар. *Әнисе укытучы бит аның, башлангычларны укыта.* Р.Хафизова

2) Яңалык, килеп кергән үзгәреш. *Коммунистлар һәм комсомоллар һәр хезмәт батырлыгының үзәгендә булдылар һәм яңа башлангычны хуплап, рухландырып тордылар.* Р.Беляев

3) Төп чыганак. *Сәяси һәм мәдәни башлангыч та Җучи олысыннан килә.* Г.Дәүләтшин. *Алар акыллы җан ияләре түгел, алар бернәрсә дә эшли белмиләр, аларда хәтта акылның башлангычы да юк.* Р.Мөхәммәдиев. *Аның Декарт координатларын һәм координатлар башлангычының ераклыгын табарга.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

**БАШЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **башлау.** *Өстәлдәге тәртипсезлек белән Нияз бер караудa ук танышып алды: берсе бушаган, икенчесе башланып куелган аракы шешәләре, икмәк сыныклары, тозлы балык, кәбестә, кыяр, хәзер урыныннан китәргә торучы йоклаган самавыр, чәнечкеләр ---.* Х.Габдүш

2) Беренче билгеләре күренү, керешү, керешеп китү. *Озын төннәр башланды.* Дәрдемәнд. *Төнлә белән беренче ярсулы контратакалар башлана.* И.Гази. *Чөнки бу язгы матур көннәрдә барлык тереклек дөньясында хәрәкәт башлана.* А.Алиш. *Ә бит безнең гомер матур урманнарда, Май аедай матур башланды.* Һ.Такташ

**Башланып калу** Башланырга өлгерү. *Без киткәндә, тулай торакта ремонт эшләре башланып калган иде.* З.Фәйзуллин

**Башланып килү** Бик тиздән, озаклямый башлану алдында тору; акрынлап башлану. *Бу – әле үзгәртеп кору башланып кына килгән еллар.* Р.Нуруллина. *Әле яңа гына башланып килгән гомерендә, күпкә иртә өлгереп, ул, беренче тапкыр, кеше хатасы өчен кешене түгел, инде турыдан-туры үзен, бары тик үзен гаепләде.* А.Хәлим

**Башланып китү** Бер ноктадан кузгалу, башлангыч алу, этәргеч булу. *Аннан үзара исәнлек-саулык сорашу башланып китә.* А.Алиш. *Эш ничә кеше булуда гынамыни, яңа сугыш, скандал башланып китә иде бит.* Г.Бәширов. *Тәүфикъ абзый Вахитов белән танышу минә шулай бик гади башланып китте.* М.Госман

**Башланып тору** Әле генә башлану

**БАШЛАНЫШ** *и.* Башлану дәвере, башлангыч чор, беренче адымнар. *Бу әле – тик башланышы гына.* Ә.Ерикәй

**БАШЛА́У** *ф.* **1.** 1) Берәр эш яки шөгыльгә тотыну, керешү. *Алар, батыр егет башлаган эшне дәвам итәргә ант итеп, эчләреннән янып, бу мескеннәр өчен сызланып торсалар да, кузгала да алмадылар, ди.* А.Алиш. *Хәзер генә табадан төшкән коймакларны кунаклар алдына таратып, чәй ясый башладылар.* Г.Ибраһимов. *Бераздан, бакчада сандугач сайрый башлый.* М.Фәйзи

2) Бөтенлеген бозу, тулылыгын киметә барып куллану. *Беркөн алып кайткан Кузнецов чәен башларсың микән, әллә өченче көн алып кайткан Ытәмиш чәен башлап карарбыз микән?* Ф.Әмирхан

3) Җитәкләп бару, юнәлеш бирү. *Башлаган башчылар булмаганда, Милләт хәле – суга төшкән тоздай эри.* М.Гафури

**2**. **башлап** *бәйл. функ.* 1) Нинди дә булса эш-гамәл яки вакыйга тәмамлангач, шул вакыттан алып, мәгънәсен белдерә; шуннан бирле, шуның артыннан. *Иртәдән башлап, яңгыр яварга җыена иде.* Ш.Бачурин. *Мин, шул көннән башлап, үз-үземне әкрен-әкрен һаман үзгәрттем.* Ш.Маннур

2) Нинди дә булса бер дәвамлы рәттә торган күренешләрне яки андагы кешеләрне, я әйберләрне санап киткәндә кулланыла, еш кына, *-га кадәр* (*чаклы*), *-гача* кебек формалар белән парлашып килә. *Менә хәзер дә, рота командирыннан башлап иң арттагы сугышчыга кадәр бөтен полк, авыр йөген күтәреп, тиз-тиз алга атлый, әммә арулары җиткән иде инде.* Г.Бәширов

**3. башлап** *рәв. мәгъ.* 1) Иң алдан, иң элек; беренче чиратта. *Башлап, әнә теге нәрсәләрне бир.* И.Гази

2) Башта, алдан. *Мәликә, башлап, бик тузынды, шулай да рөхсәт бирде.* А.Шамов

**4. башлап** *с. мәгъ.* Башлангыч, яңа башлаган. *Илшат Вәлиулла бу китабында, бүгенге татар шигъриятенең әйдәп баручы шагыйрьләре белән беррәттән, башлап язучыларның иҗатына да игътибар итә.* И.Вәлиуллин

**5.** *ярд. ф. функ.* Тезмә фигыль булып килгәндә, теге яки бу эшнең башлануын белдерә. *Бертуган кебек тату яшәп килгән кешеләребез арасында низаглар чыга башлады.* М.Әмир. *Халык, тоткын егетләр азат ителгәч, бу тирәдә чуалуның кирәге калмады, «бәладән башаяк» дигәндәй, тарала башлады.* Ф.Сафин. *Үсә төшкәч, ул милицияне – прокурордан, судьяны адвокаттан аера башлады.* А.Гыйләҗев

**Башлап алу** Бераз гына эшли башлау

**Башлап ату** Кызу гына башлау

**Башлап бирү** Кемгә дә булса берәр төрле шөгыльгә керешергә булышу

**Башлап җибәрү** Эшләргә керешү, башлангыч бирү. *Илнең бәйсезлеген кайтару өчен, Көнбатыш баскынчыларына – тәре йөртүчеләргә каршы көрәш башлап җибәрә.* С.Сөләйманова. *Октябрь инкыйлабыннан соң, большевиклар илдә, астыртын рәвештә, репрессияләрне башлап җибәрделәр.* Рәмзи Вәлиев

**Башлап йөрү** Яңа эш яки мәсьәләне беренче булып кузгатып йөрү; җитәкчелек итү; башкаларны да шул эшкә өндәү. *Шаһгали кебек котсыз кыяфәтле, ямьсез һәм гарип рәвешле бу бәндә авылда коммун төзүдә башлап йөри.* Ф.Бәйрәмова. *Башлап йөрүчеләр кирәк булачак...* Ә.Еники

**Башлап калдыру** Башларга өлгерү. *Син алдан төсмерләгән киләчәк көннәр менә шундый бүген, Такташ. Син башлап калдырган шигърият кыры, поэзия кыры шау чәчәктә бүген.* Х.Туфан

**Башлап карау** Башларга омтылу. *Элегрәк үзем дә берничә тапкыр шундый [көндәлек] дәфтәр башлап караган идем.* Ш.Галиев

**Башлап китү** Эшкә керешү. *Якуб бик гади генә итеп башлап китте.* И.Гази. *Татар театр техникумында татар әдәбияты укытканда, үзенең дәресләрен [Ф.Әмирхан] «Без – реалистлар» дип башлап китә иде», – ди Р.Ишморат.* Р.Әмирхан

**Башлап кую** Башлаган хәлгә китереп калдыру, башлангыч биреп калдыру

**Башлап тору** Хәзер генә башлау

**БАШЛАШ** *с.* Җир участогы билгеле бер мәйданга яки урынга чиктәш, ызандаш булган, янәшә. *Гапсаттарга [җир] Биби күленә башлаш иң әйбәт урыннан эләкте.* И.Гази

**БАШЛЫ** *с.* 1) Алдында килгән ачыклагыч сүзе белән: башы шул үзенчәлеккә ия булган. *Зур башлы, кызыл билле кырмыскалар нәрсәнедер сырып алганнар.* А.Алиш. *Тота алмаслар, мин аларны шундый хәйлә җепләре белән чорныйм, мең башлы дию, хәйләкәр гыйфрит үзе дә чишә алмас.* Т.Гыйззәт. *Зур имән өстәл артында ак чырайлы, пеләшрәк башлы бер кеше утыра.* И.Гази

2) Очы булган. *Хәлим сурәт ясау өчен ике башлы карандаш алып кайтканны көтеп ятканда, Галиулла чак кына үлемнән калды.* И.Гази

3) Түбәле. *Әгәр ул җанлы булса, элек елларда ишегалдындагы такта башлы келәтләрнең буш булмаганлыкларын, көз көннәрендә аңа килгән юллар эскертле ындырлар белән тоташканлыкларын, ә ындыр көпчәк эзләреннән салынганлыкларын – барысын да, барысын да сөйләр иде.* А.Шамов. *Авылдан бер читтә, агачлар арасыннан, яшел башлы лазарет күренеп тора.* А.Шамов

4) Күп һәм эре, тук башаклы. *Арыш үзе буйга озын, үзе бик башлы, әти бик шат.* М.Гафури

5) Өслектән калкып, күтәрелеп күренгән. *Ак башлы дулкыннар, бер-берсен куышып килеп, яр буендагы зур ташларга бәреләләр, үзләре белән алып китәргә теләгән кебек, ташларны кочып алалар.* Г.Гобәй

6) Җимеше йомры формада булган. *Башлы кәбестәнең калын һәм кыскарган сабагы була. Аны «кучән» дип атыйлар.* Ботаника. *Кычытканны һәм*

*кыяклы суганны салкын суда юып, --- турарга; итне башлы суган белән иттарткычтан чыгарырга һәм, табага бераз сыек май салып, кыздырып алырга.* Сөембикә

7) Ике очы да чигелгән яки челтәрләп бизәлгән. *Мин кызыл бишмәтемне киеп, кызыл башлы тастымал белән билемне буып алдым.* М.Гафури. *Якуб, кара куе чәчләрен, кояшта пешкән муенын, колакларын су астына куеп, бөтен күбекне юдыртып төшерде дә, тураеп, билендәге кызыл башлы сөлгесен чишеп алды.* И.Гази

8) *куч. сөйл.* Акыллы, зиһенле, зирәк, башы яхшы эшли, уйлый торган. *Булса да була икән башлы кешеләр.* Г.Мөхәммәтшин. *Алай түгел, Дәүләтша, малаең бик башлы, җибәр укырга.* Н.Хәсәнов. *Карл Марксны әйтәм, башлы малай булган булуын --- аның хакында җазганнарны укып җатам әле.* Казан утлары

**БАШЛЫК** I *и.* 1) Баш киеме. *Ак халат, ак башлык кигән Гөлнәзирә табиблар кебек пакь, аккош кебек нәфис иде.* З.Фәйзи

2) Тышкы киемнәрнең якасына беркетеп куелган һәм яланбашка яки баш киеме өстенә киелә торган каплама; капюшон. *Яңгыр булса-нитсә дип, башлыклы плащ киеп утырган ике юлчының берсе тарантасның сул ягына сикереп төште дә плащ төймәләрен чишеп җибәрде; икенчесе, уң якка төшеп, плащының башлыгын кайтарып салды.* И.Гази. *Герметик башлыкның күзлекләре тирли.* А.Тимергалин

**БАШЛЫК** II *и.* 1) Җитәкче, хуҗа, түрә, баш кеше. *Карт, күчеп йөри торгач, Идел буена килеп чыккан кыпчак төрекләренең бер кабилә башлыгы икән.* Г.Гобәйдуллин. *Төбәк хакимиятләренең зур шәһәрләр башлыкларын билгеләнеп куела торган хакимият системасына кертү өчен тырышулары 2005 елда дәвам итәчәк.* Татарстан. *Хәзер, шуның нигезендә, хөкүмәт әшлеклеләре, галимнәр, депутатлар, хакимият башлыклары катнашында комиссия эшли.* Сөембикә

2) Башлап йөрүче; узаман, лидер. *Кычкыралар: Яшәсен башлык! – диеп, – Тилмереп көткәнне без таптык, – диеп.* Ш.Бабич

3) Гаиләдә төп вазифа башкаручы кеше (гадәттә, әти кеше). *Ул тирәюньдә уңган гаилә башлыгы буларак та билгеле.* Шәһри Казан

4) Башчылык, хакимлек. *Ягъни менә бүген, иптәшләренә башлык кылуы таләп ителә башлагач, ул шактый уңайсызлык хис итте.* Ш.Камал. *Фетнәдә башлык кылган, теге, күкрәге калайлы Хәйрулла староста үзалдына җилләнде.* Г.Ибраһимов. *Алар кулына башлык күчкәндә дә, халыкның җөге җиңеләячәк түгелдер.* Урал

**БАШЛЫКЛА́РЧА** *рәв.* Башлыкларга охшатып, баш кеше сыман. *Түрә булып алгач, Кармак сизелеп үк үзгәрде. Үзен, чын-чынлап, башлыкларча җитди тота башлады.* Ә.Еники

**БАШЛЫ́-КҮЗЛЕ** *с.* 1) Башы һәм күзе булган. *Кеше кебек кеше, башлы-күзле*

2) *куч.* Өйләнгән, гаиләле. *Туган авылына кайтса – ике энекәше дә инде башлы-күзле.* Т.Мөбарәков

◊ **Башлы-күзле булу** Өйләнү, гаиләле булу. *Аңа да башлы-күзле булырга вакыт җиткән.* Р.Ишморат. *Үзенең уллары зур шул инде, башлы-күзле булырга да җыеналар, озакламыйча, оныклары җыелыр, боерган булса...* К.Миңлебаев. *Башлы-күзле булгач, тагын да иҗтиһад кылып тотыначак сәүдәгә.* Ф.Сафин. *Яралы әтидән өч бала яралып, үсә-үсә, башлы-күзле була торгач, ниһаять, иң иске өйдә Фазыл әнисе белән генә яшәп калды.* К.Кәримов. **Башлы-күзле итү** Өйләндерү. *Өлкән балаларны кайтарып булмый инде, төпчегебезне, янibызда калдыру өчен, башлы-күзле итү дәртенә керешә башлау кирәк.* Я.Зәнкиев

**БАШЛЫ́ЧА** *кер. сүз* **1**. Нигездә, гомумән алганда, асылда, төбендә. *Татар оригиналь музыкасы бу елларда, башлыча, җырлар, бик артык мөкәммәл булмаган маршлардан торды.* М.Җәлил. *Нургали, башлыча, хатыны Миңсылудан ишетеп, аларның үзара бик тату торуларын һәм гади, тыйнак кына көн итүләрен белә иде.* Ә.Еники. *Башлыча, суыткычларны бер яки ике компрессор белән чыгаралар.* Сөембикә

**2**. *рәв. мәгъ.* Күпчелек очракта, күбесенчә. *Бөтен расход – хезмәткәрнеке, ә кибеттә башлыча туган-тумача сату итә.* В.Юныс. *Әйтик, дәүләт идарә итү компаниясе тупланма өлешне башлыча дәүләт тарафыннан чыгарылган кыйммәтле кәгазьләргә инвестицияли.* Сөембикә

**БАШЛЫ́ ШИКӘР** *и.* Элек бер пот яки ярты пот авырлыгында, конус формасында коелган, махсус зәңгәр кәгазьгә пөхтәләп төрелеп бәйләнгән каты шикәр. *Башлы шикәр төрә торган кәгазьне тигезле-тигезсез бишпочмаклап, җилем булмагач, ак җеп белән типчегән бер пакет...* К.Нәҗми // Зур кисәкле, вакланмаган шикәр. *Сәмигулла абзый беразы ватып алынган башлы шикәрне күтәреп карады.* Ф.Әмирхан

**БА́ШМА-БАШ** *рәв.* Бергә – бер, бер данәгә – бер данә, бер әйбергә – бер әйбер. *[Хәсәен:] Булса – башма-баш, булмаса – кирәкми.* Ф.Бурнаш

**БАШМАК** I *и.* Икенче яшькә киткән мөгезле эре терлек. *Урамның ике ягыннан да көтүгә сыерлар, башмаклар кушыла торды.* Ә.Еники

**БАШМАК** II *и.* 1) Өйдә кию өчен, җылы йомшак табанлы, кунычсыз аяк киеме. *Ричард, урыныннан торып һәм аны-моны уйлап тормыйча, аягындагы башмагын салып экранга томырды.* Тәмуг чәчәге. *Әтисе аңа матур җырлаганы өчен башмак бүләк итә.* Сөембикә

2) Гомумән аяк киеме. *Нигә, балам, юллар уртасында Башмагыңа карап баш идең?* Р.Әхмәтҗанов. *Үкчә – без әле, аяк – төз әле, Үкчәсез башмак кимибез әле.* К.Булатова. *Атлый-атлый тузды башмакларым, Аякларым сызлап, аксадым.* И.Сабиров

◊ **Башмак булу** Хатын кубызына бию, хатын иркендә булу

**БАШМАК** III *и. тех.* Вагоннарны туктату өчен, тәгәрмәч астына куела торган җайланма

**БАШМА́К ТАНА** *и.* Шушы елда беренче мәртәбә бозаулыйсы яшь сыер. *Су чыгара алсагыз, башмак тана да*

*чалыныр, каклаган казны коймакка төреп, каймакка манып ашарсыз, боерган булса.* К.Кәримов. *Ишегалдында бура хәтле бер сыер белән башмак танасы, бер көтү сарыклары күренә.* Г.Бәширов. *Шулай да, Карлыгач хәтле булгач, шефка алырга дип, үзенә «Кызым» исемле бер башмак тана билгеләп куйды.* Г.Гобәй

**БАШМА́К ЧАБАТА** *и.* Аяк йөзен капларлык итеп, юкәдән үрелгән, тирән эчле аяк киеме. *Ул тула чикмән, юкә башмак чабата, ыштырың.* Н.Исәнбәт. *Насыйр бабайдан өр-яңа башмак чабата ясатып бирделәр.* М.Гафури

**БАШМАКЧӘЧӘК** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан, яфраклары житен яфрагына охшап, чиратлашып урнашкан, хуш исле чәчәкле күпьеллык үсемлек, башмак тәтәй; *русчасы:* **льнянка обыкновенная**

**БАШМАКЧЫ** *и* 1) Башмак тегү, ясау остасы, шул һөнәргә ия кеше. *Безнең күрше читекче Вәлидә, башмакчы Кәбирдә, каләпүшче Миңсылуда, тагын кемнәрдәдер булган идегез.* М.Гали. *Ни генә димә, пенсиягә чыкканчы, башмакчылар артелендә ударник булган кеше, әнә стенадагы Мактау язулары шаһит, төшеп калганнардан түгел иде Баязит абзагыз.* Ф.Хөсни. *– Миңа корал гына табып аласы, мин үзем башмакчы, – дип көлде ул.* Ә.Фәйзи

2) *иск.* Мәчеткә килгән кешеләрнең башмакларын саклап, мәчеттән чыгучыларга биреп торучы кеше. *Башыңа төшсә, башмакчы булырсың!* А.Шамов

**БАШМАКЧЫК** *и. зоол.* Башмак табанына охшаган инфузория төре. *Инфузорияләр – гади организмнар арасында иң катлаулылар, моңа инфузория-башмакчык мисалында ышанырга мөмкин.* Биология

**БАШМАКЧЫЛЫК** *и.* 1) Башмаклар ясау, тегү эше

2) Башмакчы һөнәре

**БАШМА́К ШӘРИФ** *и.* 1) Тәһарәт алганда, мәчеткә барганда киелә торган махсус аяк киеме

2) Пәйгамбәр башмагы төшерелгән шамаил

**БА́ШНЯ** *и. ит.* 1) Төрле максатларда, түгәрәкләп яки берничә кырлы итеп төзелгән биек архитектура корылмасы; манара. *Менә ул тау башындагы Кремльнең ак стенасын, таш пулатларын, башняларын яктыртты.* Г.Әпсәләмов. *Боларның уң яктагысы Византия стиленә тартым, куполлап эшләнгән, сул яктагысы, тешләк башнялары белән, готик стильне дәгъвалап маташа иде.* Ш.Камал. --- *әйләнеч булса да, күбесенчә, мәктәпкә тимерчелек, ферма, силос башнялары янынннан үтеп йөрде.* Г.Гобәй. *Абыйларым, җаннарым, ярдәмгә, ярдәмгә, әйдәгез, силос башнясына су керә!..* К.Тинчурин

2) *хәрби* Суднода, танкта һ.б.ш. хәрби объектларда ату коралы урнаштыру өчен бронялап эшләнгән корылма. *Башнясын артка таба борган танк трактор сабаны белән йөз илле гектар җирнең астын өскә китерде.* М.Мәһдиев

**БАШНЯЛЫ** *с.* 1) Башнясы булган

2) Биек, тар итеп, башняга охшатып ясалган. *Солдат хезмәтеннән кайтуга, армиядә өйрәнгән һөнәре буенча, шәһәрдә урнашып, башнялы краннарның берсендә кранчы булып эшли башлаган вакытлар иде бу.* Н.Хәсәнов

**БА́Ш ОЧЫ** *и. анат.* 1) Гәүдәнең баш түбәсе турысы, баш тирәсе

2) Баш түбәсе турысындагы биеклек, һава; баш өсте. *Кергәндә, бүрегем баш очында гына тора иде, чыкканда, күзләремә чаклы батты.* Ф.Хөсни. *Баш очында ай калкыр, --- әтәчләр кычкырыр, --- бакчада сандугачлар, чыпчыклар чыкырдашыр.* Ф.Бурнаш. *Миңнулланың күз алдында дага ялтырап китте: ул, кулын баш очына күтәреп, чак кына тайчанып өлгерде.* И.Гази

**БА́Ш САБУ** *ф.* Ямау салып яки бәйләп, тузган аяк киеменең, бияләйнең башын яңарту

**БА́Ш СӨЯГЕ** *и.* Башның үзара береккән сөякләрдән торган төп өлеше. *Сержантның баш сөяге челпәрәмә килгән.* С.Сөләйманова. *Мондый бала туганда баш сөяге яки ми травмасы алганлыктан, аның нерв системасы нейрон инфекция нәтиҗәсендә какшаган була.* Татарстан

**БАШСЫЗ** *с.* 1) Җитәкчесез калган, әйдәүчесез. *Башсыз калган гаскәр – Көтүчесез калган көтү төсле.* М.Җәлил

2) Баш өлеше, башлангыч өлеше булмаган, керешсез. *Карт Днепр – Таш кыялар юлчысы – Ник кинәт башсыз җырын өзде?* Н.Исәнбәт. *Югыйсә, без бу көннән игъланны туктатабыз вә башсыз чыккан игъланнарны ләгу санап, акчаны суд белән кире сорыйбыз.* Г.Тукай

3) *күч.* Теләсә нинди хәтәр эшкә бара торган, үтә тәвәккәл, куркусыз, гаярь. *Ләкин аның хәлен бик тиз сизеп алып, андый башсыз кыюлыкның чын кыюлык түгеллеген аңа шул вакытта ук әйттеләр.* И.Гази. *Мин һаман башсыз батыр булдым. Кешеләр хөкеменә гомремдә буйсынмадым.* Н.Исәнбәт. *Бик башсыз нәрсә, кәтер китүдән дә һич курка торган түгел.* Г.Камал. *Ул инде яшьтән үк бик башсыз кыз иде.* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Аңгыра, миңгерәү, томана. *Минем пәһлуаным Кулупай бу башсыз егетне тиз акылга утыртыр.* М.Җәлил

**БАШСЫЗЛАНУ** *ф.* Ахырын уйламыйча эш итү, кирәкмәгән урында тәвәккәллек күрсәтү. *Башсызланып кылануы гына түгел, явызланып үрсәләнүе, чәбәләнүе иде бу аның.* А.Вергазов

**Башсызланып алу** Кинәт кенә, кыска вакыт эчендә урынсыз башсызлану

**Башсызланып бетү** Тора-торып, тәмам башсызлану, башсызлану дәрәҗәсенә җитү

**Башсызланып җибәрү** Кинәт башсызлык күрсәтү

**Башсызланып йөрү** Хәзер, озак вакытлардан бирле башсызлану. *Ни пычагыма кирәк булды аңа шулай башсызланып йөрү?* В.Нуруллин. *Шулай башсызланып йөрергә ярыймы соң инде синең шикелле җаваплы эштә эшли торган кешегә!* В.Нуруллин

**Башсызланып кую** Уйламаганда, кинәт башсызлану

**БАШСЫЗЛЫК** *и.* 1) Ахмаклык, акылсызлык, тинтәклек, юләрлек, аңгыралык. *Кая гына карама – башсызлык, кая гына карама – башбаштаклык.* Ш.Камал. *Бу – юләрлек, башсызлык булачак.* Г.Ибраһимов. *«Ялт-йолт», әлбәттә, бу хезмәтне, Зингергә файда*

*булсын, дип түгел, фәкать башсызлыктан көлү үз вазифасы булганга гына ифа итте.* Г.Тукай

2) Чаялык, уйламыйча эш итүчәнлек, урынсыз тәвәккәллек. *Ә ул, ярсыганнан-ярсый барып, үзенең шушы ярсуы һәм «башсызлыгы» белән сокландырып ата да ата иде.* Г.Бәширов. *Ильин, башсызлык күрсәтеп, нәрсә дә булса эшләмәдеме --- икән, дигән уй мине борчый.* Ә.Айдар

**БАШТА** *рәв.* 1) Иң элек, беренче нәүбәттә, алдан. *Башта сөйләгән хикәям белән моның аермасы – шул гына.* Г.Тукай. *Башта ук шуны әйтим: без пессимист булабыз, дөнья сүгәбез, хәятта ямь юк, кызык юк, дибез, – бар да юләрлек, бар да сукырлык икән.* Г.Ибраһимов. *Киндер башта соры төсле иде, инде ап-ак булды.* Дәрдемәнд. *Башта ферма мөдире Ибәтулла абзый көнлек савымның нәтиҗәләрен укыды.* Н.Гыйматдинова

2) Элек, әүвәл, борынгы заманда. *Мәмләкәтнең төрле җирендә башта хан тарафыннан аксөякләрдән куелган баскак яисә «даругай» дигән бәк торган.* Г.Гобәйдуллин

**БАШТАГЫ** I *с.* Башта булган, башындагы. *Я, ни булыр тагы, дип, баштагы авыр вә билгесез мәсьәләләр белән чуала бирде.* Г.Ибраһимов. *Бара торгач, аңа бу дару авырткан сөякләрне язар өчен генә түгел, баштагы кара уйларны тарату өчен дә файдалы кебек тоела.* М.Гали

**БАШТАГЫ** II *с.* Алдагы, беренче булган, иң элек. *1939 елның баштагы биш ае эчендә Татар театры күпсандагы артистларны квартирларга урнаштырып бетерде.* М.Җәлил. *Ләкин ул баштагы ике пәрдәдә бөтенләй күренми.* М.Гали. *Самавырның гөжләве, бәрәңгенең буланып торуы баштагы кәефләрне җуйдылар.* Г.Ибраһимов

**БАШТАК** *с. диал.* Тәртипсез, оятсыз, әрсез. *Хан олы солтан булмаса, халкы алай баштак булмасмы?* Җыр

**БАШТАКТА** *и.* Кабернең баш очына куелган такта. *Кабер өсләрендәге баштактага, буяу белән, аларның исем-фамилияләрен һәм дело номерын язып куя.* Р.Кәрами

**БАШТАН** *рәв.* 1) Алдан, иң элек, элгәре. *Баштан – театрга, ди, киногa барыйк, ди, аннан, загска барыйк, ди башлый.* Р.Ишморат

2) Башыннан башлап, яңадан башлап. *Бездән алда булган җәмгыятьнең Тормыш шартларына яраган Һәрбер караш, һәрбер проблеманы Без төзибез баштан, яңадан.* Һ.Такташ

**БАШТАНАЯК** *рәв.* 1) Баштан алып аякка кадәр. *Камилнең җилкәләренә кулын куеп, баштанаяк аны карый.* Һ.Такташ. *Газинур бер караштa Мисбахны баштанаяк күздән кичерде.* Г.Әпсәләмов. *Карт, сынаулы караш белән, егеткә баштанаяк күз йөгертеп чыкты.* З.Фәйзи. *Ирем ул көнне базардан баштанаяк киенеп кайтты.* Юлдаш

2) Башыннан алып ахырга кадәр, тулысынча. *Чөнки Айдардан аерылып калуым белән мин баштанаяк бәхетсез идем.* Ф.Хөсни. *Мин бу вакыйганың ничек булганын, бернәрсәсен дә калдырмыйча, баштанаяк тагын бер кат сөйләп бирдем.* А.Шамов. *Баштанаяк кара сарык йонына уранган.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Бөтенләй, тулысынча, мөкиббән китеп. *Кайтып төшкән көне белән, баштанаяк эшкә, көрәшкә, солдат арасына, крестьян арасына, завод-фабрик пролетариаты арасына чумды.* Г.Ибраһимов. *Баштанаяк гыйшык сорый торган, теге матур, тәмле романнар да туйдырган…* Г.Ибраһимов. *Бу эшне баштанаяк уйлаганга, Тәэсир иттем дөньядагы барча җанга.* М.Гафури

◊ **Баштанаяк кораллы** Яхшы һәм нык коралланган. *Йөз мең кеше, имеш, баштанаяк кораллылар, имеш, Самараны алганнар, имеш, аннан башка калаларга китәләр, имеш.* Г.Ибраһимов. *Тирә-ягы – баштанаяк кораллы кешеләр.* М.Гафури

**БА́Ш ТАШЛАУ** *ф.* Урылмыйча озак утырган ашлыкның башагы бөгелеп сыну, орлыгы коела башлау. *Арпабыз баш ташларга тора, борчак та өлгергән.* Г.Бәширов

**БАШТИ́НАЯК** *рәв. иск. к.* **баштанаяк**. *Үз эшебезгә баштинаяк бирелеп, зур файда китерүебезгә чын күңелдән инанып эшләдек.* К.Миңлебаев

**БАШТУК** *рәв. сөйл.* Баштан ук, иң элек, беренче чиратта. *Баштук шулай дип әйтергә кирәк иде.* Г.Коләхмәтов. *Ник аны баштук яшереп куймаган? Ник мәләкләр урлаганны тоймаган?* Ш.Бабич. *Ул Нәфисәнең үзен санламавын баштук сизенгән иде.* Г.Бәширов

**БА́ШТҮБӘН** *рәв.* 1) Башы белән түбәнгә таба әйләндерелгән хәлдә. *--- баткаклы елгага килеп җиттек, ләкин ярның янында күк бия белән минем Алмачуар гына иде, өченче иптәш – җирән чабышкы – малае белән баштүбән шунда чумган булса кирәк.* Г.Ибраһимов. *Батыргали агай үзенең азрак хата эш эшләгәнен соңыннан аңласа да, нә файда, бичара, һичбер гөнаһсы булмаган Абрамның, баскычтан баштүбән төшкәндә, бәрелеп, ике теше сынган һәм югарыгы иреннән бармак башы кадәр ите, өзелеп, салынып тормакта иде.* Ш.Мөхәммәдев

2) Асты өскә әйләнү

3) Мәтәлеп, мәтәлчек атып. *Колларны җәеп, баштүбән суга ташлану*

◊ **Баштүбән килү** Әйләнү, кискен үзгәрешләр булу. **Баштүбән китү** Вафат булу

**БА́Ш ТҮБӘСЕ** *и. анат.* 1) Башның өске, түбә өлеше. *Ул, үзенең буе җитмәслегенең күренеп торуына да карамыйча, «фәлән агайның авызына менеп төштем әле», «фәлән кешенең баш түбәсен төйдем әле» дип, үзен әллә нинди зур гәүдәле итеп күрсәтергә тели.* Ф.Әмирхан

2) Баш өстендәге биеклек, һава

**БАШЧА** I *и.* Әдәби әсәрнең яки әсәр бүлегенең төп атамасыннан соң язылган өстәмә атама. *Газетаның тышкы формасы укучыга тәэсир итәрлек булырга тиеш. Монда баш һәм башчалар (заголовки, подзаголовки), хәреф төрләре ярдәмгә килә.* Ш.Рамазанов

**БАШЧА** II *и. бот.* Үсемлекләрнең югары өлешендә яралган кечкенә баш. *Тузганакның сары башчасы – аерым чәчәк түгел, ә тулы бер чәчәкләр төркеме ул.* Робинзон эзләреннән

**БА́Ш ЧҮМЕЧЕ** *и.* Башның арткы өлешендәге калку урын. *Баш чүмече йомры – сүзе тугры.* Әйтем

**БАШЧЫ** *и.* Баш булып йөрүче, оештыручы, җитәкче, башлык, башлап йөрүче. *Дин эшендә башчы иттек без аларны.* Г.Тукай. *Табынның башчысы Гәйшә иде: ул ябыккан, суырылган.* Г.Ибраһимов. *Таһир исән, безнең башчыбыз! Мең гомерләр сиңа, халкыбыз!* Ф.Бурнаш

**БАШЧЫЛЫК** *и.* Башчы булу, җитәкчелек. *[Сугышчы:] Гаскәр күтә синнән башчылык, әйдә, улым, ачык ишектән!* Ф.Бурнаш

**БАШЫ́-АКТЫГЫ** *с.* Бөтен, бар булганы, бөтен булганы, иң соңгысы. – *Я, улым Ташъякның башы-актыгы түгел, тагын килербез, арысланның иң зәһәренә атланып әйләнерсең, – дип юатты әнисе Габдулланы.* Ә.Фәйзи

**БАШЫ́-АХЫРЫ** *и.* Беренчесе һәм соңгысы, бары бер генә тапкыр (бүтән кабатланмасын, мәгънәсендә). *Өйләнүең уң булсын, башы-ахыры шул булсын.* Әйтем

**БАШЫБОЗЫК** *и. төр.* 1) Төрек сугышчысы, регуляр армиядә хезмәт итмәгән солдат. *Мансур Салихка карап үртәде: – Менә чалмалы башыбозык булдың.* Ш.Усманов

2) *күч.* Тиле батыр, шәрә батыр

**БАШЫННА́Н-АЯК** *рәв. к.* **баштанаяк.** *Шәрәфетдин – башыннан-аяк Европача киемдә, Хөснулла иске суфый байларча киенгән, Ләля – калфаклы.* М.Фәйзи

**БАЮ** I *ф.* Күк җисемнәре офык артына китү, бату. *Кояш байый, кереп комач төскә, Текәп кырга соңгы карашын.* Ш.Маннур. *Эзли башлаганда, кояш яхшы ук кыздыра иде әле, әнә ул баеды да.* Г.Гобәй. *Кич була, кояш байый, эңгер-меңгер җитә.* М.Гали. *Кояш баерга якынлашкан, һава беркадәр салкынча иде.* Ш.Камал

**Баеп бара** Акрынлап баю. *Эскертендә карап ята күккә туры, йөзләрендә – баеп барган кояш нуры.* К.Сибгатуллин. *Әллә абыйга баеп барган кояш нурында гына шулай агарып күренгәнме аның маңгае?* Ф.Шәфигуллин. *Тонык, тымызык һава, алсуланып баеп барган кояш бар дөньяны талгын рәхәтлеккә күмә.* Р.Мулланурова

**Баеп бетү** Тәмам, тулысынча баю. *Икенче көнне, кояш та баеп бетмәгән иде әле, төялеп килеп төштеләр.* К.Кәримов

**Баеп килү** Күк җисемнәре, үз вакыты җиткәч, акрын гына баю. *Кич. Кояш баеп килә. Офыкка кадәр җәелеп киткән диңгез өсте тимгелләнеп тора.* Г.Әпсәләмов. *Кояш инде баеп килә иде, Ял итәбез барак янында.* Х.Туфан

**Байый бару** Акрынлап баю. *Кояш баеп бара, чират та сыегайды.* Р.Батулла

**Байый төшү** Беркадәр баю

**БАЮ** II *ф.* 1) Байлык туплау, бай булу. *Камилнең атасы, --- сәүдә итеп, яхшы ук баеган.* Һ.Такташ. *Тимуш агай, берәр фараз закон чыгып, безгә авылга кайтырга рөхсәт булса, син чынлап та баесаң, син миңа бер мең сум биреп торырсыңмы?* К.Тинчурин. *Ул вакыттагы байлар ничәшәр буыннар җыйган байлыкның хуҗасы булса, бүгенге байлар – төн эчендә баеган караклар.* Ә.Хәбибуллин

2) Тулылану, күбәю, ишәю. *Татар музыка әдәбияты бик күп төрле яңа жанр әсәрләренә баеды, яңа тәҗрибәләр ясады.* М.Җәлил. *Дәрт белән дәрманга баеп кайттык без, Җиңүче булып, бәхеткә ирешеп.* Ә.Ерикәй

**Баеп алу** Тиз арада баю. *Хәким абый революциядән соң НЭП заманында баеп алган Зәйнетдин атлы татарны уйный.* Т.Миңнуллин. *Аңар нәрсә? Староста булып баеп алды да минем белән ярышып сату итә.* Т.Гыйззәт. *Җир актарып, таш күчереп, мая туплап, баеп ал!* И.Ибраһимов

**Баеп бару** Акрынлап баю. --- *бигрәк тә дөресе эшләнеп, баеп бара торган* [әдәби] *тел туа иде.* Җ.Вәлиди

**Баеп бетү** Бик нык баю. --- *махоркасы белән дуңгыз мае салган боткасын шикәргә алыштыра торгач, баеп бетте бит!* Г.Бәширов. *Минъяров, җирләр сатып, тәмам баеп беттең, ә нәфсең һаман төкәнми, парин.* Х.Камалов. *80 нче еллар ахырында Рәсәйгә эш эзләп килгән вьетнамлылар бүгенге көндә инде баеп беттеләр.* Татарстан яшьләре

**Баеп җитү** Тәмам, бик нык баю

**Баеп калу** Кемнән, нәрсәдән дә булса файдаланып баерга өлгерү. *Шулардан туган, баеп калудан башканы белмәгән һәм һичбернинди мораль кагыйдәләрне танымаган яңа «эшкуарлар» аркасында, халык өзелеп көткән, халыкка муллык белән иркенлек китерергә тиешле булган реформаның ахырын без, мөгаен, күрә дә алмабыз.* Ә.Еники. *Вакытында, заманасының кая барганын тоеп, баеп калган.* Н.Гариф

**Баеп килү** Акрынлап баю. *Бу әсәр – татар совет драматургиясендә комедияләр жанрының баеп килүен күрсәтә торган уңышлы адым.* М.Җәлил

**Баеп китү** Кинәт баю. --- *үзенең зирәклеге һәм булдыклылыгы аркасында, ничектер, баеп киткән, имеш.* Ә.Еники. *Көтмәгәндә баеп китү мөмкинлеге туды, ләкин бернишли дә алмый.* Р.Сәгъди. --- *сандык эче – туптулы алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, кыйбатлы ташлар! Кыз шуннан баеп китте.* К.Насыйри

**Баеп кую** Кинәт баю. --- *үзе дә басу, ындыр юлларына сукмак сала. Шулай җайлы гына баеп куя.* Ф.Яруллин

**Баеп тору** Бертуктаусыз баю. *Хәерле көн, газиз милләттәшләр! Кояшлырак булсын турыгыз! Мәрхәмәтле күңел җылылыгы, Нуры белән баеп торыгыз!* Ф.Шәехов

**Баеп яту** Тыныч кына, җай гына баюын дәвам итү. *«Ничек инде ул алай? Мин каракларны, хөкүмәт исәбенә баеп ятучыларны фаш итәм», – ди синең «ахирәтең».* Т.Галиуллин. *Ату, сез монда баеп ятканда, Россия дөнья дәүләтләреннән вак-төяк акча теләнеп сансызлана.* Ф.Баттал

**Байый бару** Торган саен ныграк баю. *Мөхәррир булырга теләүчеләр күбәйгән саен, матбугатыбыз да әллә нинди мәҗһүлел хакыйкать (хакыйкать белгесез) нәрсәләргә байый бара-дыр.* Ф.Әмирхан

**Байый төшү** Бераз баю

**БАЯ** *рәв.* Күптән түгел генә, берникадәр вакыт алдан, аз гына элегрәк. *Чөнки, бая әйткәнебезчә, халык әдәбияты дип, --- авыздан авызга сөйләнеп йөртелгән нәрсәләргә генә әйтеләдер.* Г.Тукай. *Кара инде, оныткамын да,*

*бая ук чакырган иде ич ул мине.* Р.Ишморат. *Бая синнән чыгып киткәч тә барып, әйбәтләп, динамит кисәген урнаштырып куйдым.* Ш.Камал

**БАЯГЫ** *с.* Әле генә булган, яңа гына, күптән түгел генә. *Кучергән, ләкин баягы кирәкмәгән шәрехне төшереп калдырырга хәтереннән чыккан.* Г.Тукай. *Ләкин баягы хәл әкияттән ерак иде.* Н.Гыйматдинова. *Солтанның чыраенда баягы куанычы күренми иде инде.* Г.Бәширов

**БАЯ́ГЫНАК** *рәв. сөйл. к.* **бая.** *Баягынак, Габдулла килмәдеме, дип сораган идең...* Ш.Камал. *Баягынак ул, эшкә җибәрүләрен сорап, Хәнәфи абый янына кергән иде.* Г.Әпсәләмов. *Без, баягынак, Сөләйман әфәнде белән сүз куешкан идек.* Ф.Әмирхан

**БАЯГЫ́ЧА** *рәв.* Әле, күптән түгел генә булганча, бая булган кебек. *Рахманов инде безнең сүзләрне баягыча тыныч кына тыңлап утырмый иде.* М.Әмир. *Аның каршысында, берни булмагандай, тагын баягыча төче елмаеп, Сәйфи басып тора.* Г.Бәширов. *Ләкин аның бу төртмәле сүзләре, баягыча көчле басым ясау теләге белән түгел, бәлки соңгы сүз минеке булсын, дигән сыман үзсүзләнеп әйтелгән көчсез каршылык кына иде.* Ә.Фәйзи

**БАЯЛЫЧ** *и. диал. бот.* Тал ыругыннан, ефәкләнеп торган көмешсыман озынча яфраклы ак өянке, ак тал; *русчасы:* **белолозовик.** *Унҗиде дус, син үлсәң, Җеназаңны чыгарып, Баялычтан ут ягып, Таза-арулап күмәем.* Дастан

**БАЯЛЫШ** *и. диал. бот. к.* **баялыч**

**БАЯН** *и. рус* Клавишлар (телләр) системасы катлаулы булган зур гармун. *Ул сандык өстендә торган баянны үрелеп кенә алды да Таһирга сузды.* Х.Сарьян

**БАЯНИСТ** *и. руск.* **баянчы** (*1 мәгъ.*). *Аннары сәхнәгә баянист чыкты һәм, сөяк телләре җем-җем итеп торган зур баянда, «Фронт янындагы урманда» көен башкарды.* Г.Әпсәләмов

**БАЯНЧЫ** *и.* 1) Баянда уйнаучы, музыкант. *Бу җырны танылган баянчы Рокыя Ибраһимова белән җырчы Зифа Басыйрова, гастрольдә йөргәндә, халыктан отып алып кайтканнар икән.* Ә.Афзалова. *Хорның баянчысы халыкка бик күп җырлары белән танылган Фәтхерахман Әхмәдиев иде.* М.Яруллин. *Әмма, икенче яктан, талантлы композитор, баянчы Бәхти ага Гайсин белән тормыш һәм иҗат юллары бергә үрелеп, аларның мәхәббәтле гомер кичерүләре дә моңа этәргеч биргәндер.* Сөембикә

2) Баян ясау остасы

**БӘ** *иярт.* Гадәттә сузып яки һәмзә белән әйтелә: сарык, бәрән кычкырганда ишетелгән тавышны белдерә. *Ике олы сарык, ул бүлемтекнең киртәсенә ал аяклары белән басып, өстән карап тора башладылар, чиратлашып, «бә-бәбә», дип кычкырып алдылар.* Ф.Садриев

**БӘБӘЙ** *и. к.* **бәби**. --- *Рәйсә, бәбәй артыннан бәбәй табып, кураны балачага белән тутырып ташлады.* Р.Батулла. *Бәбәй туганда «дүрт саны исән булсын» диләрме?..* А.Гыйләҗев

**БӘБӘЙЛӘ́Ү** *ф. к.* **бәбиләү.** *Бу газаплардан соң кыргыйлана күзәнәк, Куырыла тере орлык, Хатыннар бәбәйли алмый!..* А.Хәлим

**БӘБӘК** I *и.* 1) Күз алмасының эченә яктылык туры үтеп керә торган, мөгез катлауга урнашкан тишек; күз карасы. *Иң элек иреннәрең нурлана, аннары керфекләреңә дәртле якты сибелә, шуннан соң гына күз бәбәкләреңдә очкыннар уйный башлый.* М.Маликова. *Кешенең күзе караңгыга ияләшкәндә, күз бәбәгенең диаметры 8 миллиметрга җитә...* Кызыклы физиология

2) *гади с.* Күз. *Җинаятьче аткан ераклыктан, өстәвенә төн уртасында, урамдагы хәлләрне күрү өчен, ким дигәндә, мәче бәбәкләре кирәк.* З.Фәтхетдинов. *– Тсс.., – ишектәге «күз» ачылды. Бүренекедәй кан баскан бер яман бәбәк карады.* И.Салахов

**БӘБӘК** II *и.* 1) Үсә торган һәр нәрсәнең башлангыч яралгысы

2) Яңа чыккан сабак, яшь ботак. *Болары – балтырган белән төкле көпшәләр. Бик тәмле, бик файдалы, ә инде бәбәкләреннән, йомырка катып, сөтле аш пешереп җибәрсәң, иллә дә шәп була...* Ш.Маннур. *Аларга дигән гөлләрен ул [әби] карты ясап калдырган эреле-ваклы тырысларга күчереп куя, иң матур чәчәк ата торган яраннарының яшәргә, үсәргә ашкынып торган бәбәкләрен генә сайлап утырта.* Т.Мөбарәков. *Тамырча, бүлбе һәм суганча – үзгәргән бәбәкләр алар.* Биология

3) Чәчәк бөресе. *Аның керфек очларында яшь бөртекләре үлән бәбәкләренә кунган чык тамчылары кебек елтырый иде.* Х.Камалов

**БӘБӘКЛӘНҮ** *ф. гади с.* Карау, күз салу. *Чәй – бер сылтау гына ул, шул катынга бәбәкләнәсең син.* Н.Гыйматдинова

**БӘБӘ́К ЯРУ** *ф.* 1) Орлыктан борын төртеп, шытып чыгу

2) *күч.* Башлангыч алу, барлыкка килү

**БӘБИ** *и.* **1.** 1) Яңа туган бала. *Хатын-кызның иң назлы, иң мөлаем вакыты – больницадан бәби алып кайткан көннәре.* М.Мәһдиев. *Курыкма, бәбием, әниең янында чакта, бернәрсәдән дә курыкма.* М.Маликова

2) Кечкенә бала. *Бәби карыйм, уйнатам, Елаганда юатам. Җилкәмә дә менгерәм, Шырык-шырык көлдерәм.* Ф.Яруллин. *– Тукта әле, тукта, кызмый гына сөйләшик. Син бит бәби түгел, аңла. – Бәби түгел шул. Әнә бәбиләрне җибәрегез детдомга.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Кечкенә балалар кебек беркатлы, эчкерсез кеше

4) *балалар телендә* Курчак

5) *диал.* Бәпкә. *Каз-үрдәкләр майның беренче яртысында бәбиләр чыгардылар.* Г.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Яңа туган бала; җитлекмәгән; бер еллык (кошлар турында). *Гаиләләре дә нык, бәби казлар әле, үскәч тә, әти-әниләрен ел буена ташлап китмиләр.* Кызыклар дөньясында

**БӘБИ́ (БӘБӘ́Й) АШЫ** *и. этн.* Бала тапкан хатынны котлап, туганнары, якыннары тарафыннан китерелә торган тәмле ризыклар, бәби киемнәре һ.б. *Авылда берәр хатын бәби тапса да – зур вакыйга иде. Аңа күрешетирәсе, үз авызыннан өзеп, бәби ашы кертә, бәбие белән котлый.* Ф.Яруллин

**БӘБИ́ (БӘБӘ́Й) ИТӘК** *к.* **бала итәк**. *Алар [кызлар], бәбәй итәкләрен тотып, җилпи-җилпи, болын буйлап*

*әйләнергә --- тотынды...* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Бәби итәк, чигүле изү, укалы камзул, чәч япмасы, хәситә... Болары – курчакның миллилеген билгеләүче детальләр җыелмасы.* Шәһри Казан

**БӘБИ́ КОЙМАГЫ** *и. к.* **бәби ашы**. *Авылда, гомумән, гадәт шулай инде: берәрсенең баласы туугa, күршетирә бәби коймагы пешереп кертә.* Ф.Яруллин

**БӘБИЛӘНҮ** *ф.* Бәбиләрчә кылану. *Үсеп килә. Бәбиләнеп, Йөрми хәзер Нәниләнеп...* Л.Шәех

**Бәбиләнеп тору** Күз алдында, әле хәзер бәбиләнү

**Бәбиләнеп утыру** *к.* **бәбиләнеп тору**

**Бәбиләнеп яту** *к.* **бәбиләнеп тору**

**БӘБИЛӘ́Ү** *ф.* Бала табу, тудыру. *Бервакытны бәбәйли бу [хатын].* Әкият. *Үә-үә, үә-үә... Бала елый... Рокыя бәбиләде.* Н.Гыйматдинова. *Бәбиләгән хатын белән үлгән бәндәдән курыкма.* Н.Гыйматдинова

**БӘБИТӘК** *и. к.* **бала итәк**. *Кукәбелҗәннәтнең үз гомерендә бу кадәр чуар чәчәк һәм борчак төшкән, буйлы һәм шакмаклы итәкләр, җиңсәләр, күкрәкчәләр, бәбитәкләр, төрле-төрле бөрмәләр, складлар, киң һәм тар, аеллы һәм аелсыз путалар, ызмалар һәм аркалыклар күргәне юк иде.* Ф.Садриев

**БӘБИ́ (БӘБӘ́Й) ТӘПИЕ ЮУ** *ф. этн.* Бәби туу хөрмәтенә сыйлану. *Менә мин кайткач, туган-тумачаларны җыеп, бәбәйнең тәпиләрен юарбыз, кеше белән бергәләп.* Казан утлары

**БӘБИ́ (БӘБӘ́Й) ТУЕ** *и. этн. к.* **бәби чәе.** *Бәбәй туена ни белән бармакчы буласың?* Г.Исхакый. *Өй туен бәби туе белән бергә үткәрербез дигән идек.* М.Маликова. *Бәби туенда Миңнулла алты тапкыр үзе башлап җырлады.* М.Мәһдиев

**БӘБИ́ (БӘБӘ́Й) ЧӘЕ** *и. этн.* Бала туу хөрмәтенә туганнарны, якыннарны җыеп уздырыла торган чәй мәҗлесе. *Икенче көнне, бөтен барак җыелып, бәбәй чәе уздырдык.* Ә.Галиев. *Хуҗа кеше бәби чәе үткәрә.* Ф.Баязитова

**БӘБРИЯ** *и.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, декоратив, баллы дару үсемлеге; *русчасы:* **розмарин.** *Кайбер бүлмә үсемлекләре, мәсәлән, хлорофитум, бәбрия (розмарин) һәм цитруслар микробларны үтерергә сәләтле.* Идел. *Лимон, грейпфрут, розмарин (бәбрия) исләре күңелгә ятышлы.* Мәдәни җомга

**БӘВЕЛ** *и. гар. кит.* Сидек. *Бишенче сәгать. Бөерләр ял итә, бәвел бик аз бүленеп чыга.* Кызыклар дөньясында

**БӘВЕ́Л КУЫГЫ** *и. анат.* Сидек туплана торган куык, сидек капчыгы. *Су басымы колак пәрдәсен ерту белән генә чикләнми, буыннарны катыра, бәвел куыгын эштән чыгара.* М.Юныс

**БӘВЕ́Л ТОТМАУ** *и.* Бөер һәм сидек юллары авыруы

**БӘВЕЛЧӘ** *и. биол.* Җир-су хайваннары, имезүчеләр һәм кеше организмында аксымнар таркалганда хасил була торган матдә; *русчасы:* **мочевина.** *Ач торырга туры килгәндә, дөянең бөерләреннән бәвелчә бүленеп чыкмый диярлек.* Кызыклы физиология

**БӘ́ГЪЗӘН** *тер. гар. иск. к.* **бары** II. *[Йосыф] Зарланмый да, ачынып җыламый да. Бәгъзән һушыннан яза да керфекләрен калтыратып, каны каччкан иреннәре белән елмаеп, сезнең исемне пышылдый.* Р.-Н. Гүнтәкин

**БӘ́ГЪЗЕ** *а. гар. к.* **бәгъзы.** *[Мәмле-Гомәр:] Мәгәр пайтәхетне, аңа тиклем, безнең гамәлләргә аяк чалырдай бәгъзе хакимнәрдән арындыру фарыз.* В.Имамов. *Кайтучыларның бәгъзеләре әрсез таксистларның татлы сүзенә алданды.* Казан утлары

**БӘ́ГЪЗЫ** *а. гар. иск.* Төркемнән атап аерып куелмаган, шуларның берсе булган билгесез әйбергә, затка ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; кайсыдыр, кайсыбер, кайбер. *Бәгъзы кибетләрдә икмәк җитми калган икән ---.* А.Толстой. *Көндез эшләп арган бәгъзы берәүләр, утыргыч артына сөялеп, оеп та китте.* М.Кәрим. *К.Нәҗми ---, шундый фикерләрне яклап, «хәзерге көндә яңару юлына борылган бәгъзы бер шагыйрьләрнең (шигырьләре) вәзеннән, кафиядән котылып бара» дип язып чыккан иде.* Н.Юзиев. *Бәгъзы елларда мондый күренешне август урталарында ук күзәтергә мөмкин.* Идел

**БӘГЫРЬ** *и. уйг. шигъ.* 1) Йөрәк (кешенең хис-кичерешләрен бергә туплаган, бергә төенләгән әгъза, төшенчәсендә). *Бала – бәгырь җимеше.* Мәкаль. *Йа Илаһым! Ник минем бәгърем суынды?* С.Сүнчәләй. *Карт моны бик яхшы белә, әйе, онытасы юк, сугышның аның бәгыренә салып калдырган тирән ярасы хәзер дә әле кул белән капшап карарлык җөй булып саклана.* Ә.Еники. *Нәрсә бу? Бәгырьләрнең катуымы? Тәрбиясезлекме?* Р.Батулла

2) Төп, үзәк; эч. *Һәр өянкенең тамыры – нәселегез бәгыре сурәте.* Р.Фәйзуллин. *Бу караш, Габдулланың уртасыннан үткән ук кебек, аның бәгырьләрен кайната башлады.* Г.Исхакый

3) **бәгырем** *тартымлы форм.* Яраткан, сөйгән яр, кадерле якын кеше. *Сине уйлап саргайды, дип әйтерсез бәгыремә.* Җыр // **бәгырем** *тартымлы форм.* Сөйгән кешегә мөрәҗәгать итү сүзе. *Сандугачка карап тордым – Бер бәләкәй кош икән. Башка күрешүләр булмас, Хуш, бәгырем, хуш, иркәм.* Җыр

4) Эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. *Әйдә, бәгырь, син дә кушылып җырла, йөрәк ярсулары басылмасмы?..* К.Латыйп

◊ **Бәгырьгә тию (кадалу, төшү, телгәләү, үтү)** 1) Бик каты өзелеп ярату; бик нык сагыну; 2) Йөдәтү, бәйләнү, аптыратып бетерү, газаплап интектерү. *Авылда хәзер Зөлфәткә каршы төшәр кеше юк. Бәгыреңә кадалып интектерер ---.* А.Гыйләҗев. *[Чукаева] --- иң элек, «жалоба язам» дип, әллә ничә мәртәбә сине үрти, шомландыра, бәгыреңә төшә.* Ф.Садриев. *Баласы янына килеп бер иркәли дә алмавы аның [ананың] бәгырен телгәли булса кирәк, ул, үзен-үзе тыяр өчен, чытырдатып, коймага тотынган.* Ф.Яруллин; 3) Бик нык истә калдырырлык итү. *[Иван Васильевич Фролов] Эшләмәгән кешегә ул каты бәрелми, ләкин бәгыренә үтәрдәй итеп оялта белә.* Ә.Камалов. **Бәгырьне телү (өзү, талау)** Күңелнең иң нечкә кылларына тию, рухи газаплау, бик нык әрнетү. *Бәгырьне телмә, кит, тиле Хәтимә, кит!* Н.Гыйматдинова. *Ак өметләр чәчәк ата, Бәхетләр килеп кенә. Бала кайгысы саргайта, Бәгырьне телеп кенә.* Г.Афзал. *Болай да*

*үз-үзен кая куярга белми каңгырып йөргән Халисәне егет сулардан алып утларга салды, бәгырьләрен телде, җаннарын айкады.* М.Хәбибуллин. **Бәгырь телгәләнү (көйрәү)** Вөҗдан газабы кичерү, тетрәнү, әрнү. *Әлеге шыксыз уй йөрәгенә капты, бәгыре көйрәүгә тәкать тота алмас хәлгә килде.* М.Хәсәнов. *Бәгырь телгәләнеп тыңлыйм – үкенеч калды, шәп чакта кадерен белмәдек.* Мәйдан

**БӘГЫРЬСЕЗ** *с.* Каты күңелле, кешелексез, рәхимсез. *Әллә Вәсиләне таштан яралган дип уйлыймы, бәгырьсез!* Н.Гыйматдинова

**БӘДӘВАМ** *рәв. гар. иск.* Дәвамлы рәвештә, һаман, өзлексез. *Тәнемез аерым булса да, бер җан булыйк бәдәвам.* Г.Тукай

**БӘДӘВИ** *и. гар.* Күчмә тормышлы чүл гарәбе. --- *барыбыздан да катырак бәдәвиләр кычкырына.* А.Расих. *Күп кенә бәдәвиләр, акча эшләп алыр өчен, дөя куып баручы булып ялланалар.* Урта гасырлар тарихы

**БӘДӘЛ** *и. гар. иск.* **1.** 1) Билгеле бер хакка ялланып, кеше өчен хаҗга барудан гыйбарәт гамәл. *Моңарчы Шәпеш кебек карт пишкадәмнәр кәсебе булып килгән бәдәлнең яшь хәлфәләрне кызыктыруы Габдуллага сәер тоелды.* Ә.Фәйзи

2) Хаҗга барырга ялланган кешегә бирелә торган акча. *[Габдулланың] --- Казанда бәдәл акчасына кибетләр ачкан татар бәдәлчеләре күңеленә килде.* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* Кеше яллап җибәргән. *Гаптулла хаҗи беренче мәртәбә хаҗга үзе өчен барган. Аннан соң тирә-якның байларыннан берничә бәдәл хаҗ алып киткән.* Г.Ибраһимов

**БӘДӘЛЧЕ** *и. иск.* Икенче берәү урынына, ялланып, хаҗга баручы кеше. *Бәдәлчеләр, мәккәчеләр йөри Казан шаулатып.* Г.Тукай. *Үзләре бара алмаган черек байлар хаҗга, шәхесләре өчен сәҗдә кылырга, ярлыларны яллап җибәрә торган булганнар. Аларны «бәдәлчеләр» дип атаганнар бугай.* Т.Галиуллин. *Октябрь революциясенә кадәр Казанга һәм илебезнең башка шәһәрләренә, күпләп-күпләп, бәдәлчеләр килә торган иде.* Мәдәни җомга

**БӘДӘН** *и. гар. кит.* 1) Тән, гәүдә, җәсәд. *Бәдәне белән шактый юан һәм итләч булган гөнаһсыз әдипне әле җилекләрне пешерерлек кайнар «мунчага», әле бозлы камерага ташлап интектерәләр.* Ф.Дунай

2) Кәүсә; төп сабак. *Олы яшьтәге алмагач --- башка карендәшләре арасында үзенең куәтле бәдәне белән аерылып тора.* Җ.Дәрзаман

**БӘДӘНЛЕ** *с.* Таза тәнле, буйчан. *Чөнки, туксанга таба узып та, сәламәт акыллы, таза бәдәнле ул карт авылда да, бөтен тирә-юньдә дә мәшһүр иде.* М.Госманов. *Мич янында ялкыннан бите пәрәмәч булган юан беләкле, таза бәдәнле яшь бер хатын табагач, таба белән матавыклана.* М.Мәһдиев

**БӘ́ДБӘХЕТ** *с. фар.* **1.** *гади с. тирг.* Мәлгунь, ләгыйнь. *Вәлиулла хәзрәт эченең әллә кай җиреннән чалбарга аеруча дошманлык сизә иде: дәһрилек, остазга илтифатсызлык, наданлык – һәммәсе дә, һәммәсе дә шул бәдбәхет чалбардан килә төсле иде...* Г.Газиз

**2.** *и. мәгъ.* Әшәке, начар кеше. *Җанымны да син ала алмыйсың, бәдбәхет.* Ә.Еники. *Кая калды икән ул бәдбәхет?* Н.Гыйматдинова. *Чык өемнән, бәдбәхет, чык өемнән!* Г.Исхакый

**БӘДДОГА** *и. фар.* Каргау догасы, явыз дога; начар теләк, каргыш, ләгънәт. *Ананың бер догасы җиде мулланың бәддогасын җиңә.* Мәкаль. *Сөйләмә, остазбикә, карчык бәддогасы --- дип еглап, кайгысыны чиште.* Г.Исхакый. *Кинәт аның [Мәфтуханың] ире рухына яудырган рәхимсез, усал бәддогасы исенә төште.* Г.Бәширов. *[Коръән хафиз] --- бәддога кылганда гына ике кулының сырты белән битен сыпырып куя.* Ә.Еники

**БӘДДОГА́ УКУ** *ф.* Кычкырып-кычкырып каргау, явыз теләкләр теләү. *Кара аны, бәддога укымасыннар үзеңә.* М.Хәсәнов. *Хәзрәтнең яшелгә буялган чукмар башлы таягыннан, бөтен авыл халкына ишетелерлек итеп кычкырып каргавыннан, бәддога укуыннан шүрлиләр иде.* М.Хәсәнов

**БӘДЕР** *и. гар.* Тулган ай, ундүрт көнлек ай. *Бәдер көнне өэргә кирәк аны, чәчкәсе айга карап ачылган көнне.* С.Сөләйманова

**БӘДНАМ** *и. фар.* Начар исем, яманат. *Үзе теләсә ни эшләсен инде шунда, аның өчен без монда кеше арасында бәднам булырга кирәк.* Г.Камал

**БӘДРӘФ** *и. фар.* Хаҗәтханә, әбрәкәй. *Китапларны [халык] кадерләп, җыеп, төреп саклаган. Ә бүген гәҗитә – бәдрәфтә, журналлар – таба астында, чүлмәк өстендә.* Р.Батулла. *Директор, булдыра алганча тиз атлап, бәдрәф янындагы такта сарайга керде дә тимер көрәк алып чыкты.* Ә.Баян

**БӘЕТ** *и. гар.* 1) Халык авыз иҗатының лиро-эпик төрләреннән берсе: аерым шәхес яки халык тормышындагы төрле вакыйгаларны, күренешләрне сурәтләгән поэтик әсәр. *Фаразларга караганда, тимер – алтын бәһасенә торган, бронза гасырын кичеп, тимер гасырга күчкән чорда иҗат ителгән бу бәет.* Асылъяр. *Нинди жанрда гына язмый алар! Гади шигырьдән башлап, баллада, бәет һәм поэмалар да иҗат итәләр.* Казан утлары

2) Көнчыгыш халыклары поэзиясендә: ике юллы шигырьдән торган строфаның бер төре. --- *Галим хаҗи да --- «хөббелһирәти минәл-иман» дигән, әллә кайчан ишеткән бер хәдисне дә көйләп-көйләп әйтеп, ахырдан «Мәснәви шәриф»тән берничә бәетне дә, тезеп, ялгыш кына җырлап куя иде.* Г.Газиз. *Бу сүзләрдән соң, мин, аларны екмас өчен, --- түбәндәге бәетләрне борчак кебек тездем.* Г.Тукай

**БӘЕТЧЕ** *и.* Бәет чыгаручы һәм бәет әйтү остасы. *– Бер-берсе белән кавышып, бала чыгарыр алдыннан, кошлар да башта оя кора, – дип аңлата моны аларга күз-колак булып кич утыручы ыру карчыгы, бәетче һәм мөнәҗәтче, им-томчы Асылбикә.* М.Маликова. *Бу бит – авыл бәетчесе, Такташча үк булмаса да, шул чама фикерле, дигән сүз.* Н.Вахитов. *Бәетченең тамагыннан карлыгып чыккан тавышка барабан дөпелдәве кушыла.* М.Юныс

**БӘҖӘНӘК** *и. тар. к.* **баҗанак.** *Мәсәлән, тарихта атаклы этноним – рус елъязмаларындагы «печенег», төрки чыганаклардагы «баҗанак», «бә-*

*җәнәк» – асылда, «баҗалар» дигән сүз (азәрбайҗан телендә «баҗанак» – «баҗа»). Димәк, бу халык – үзара баҗалык мөнәсәбәтендә торган ыруглар һәм кабиләләр.* Р.Әхмәтьянов

**БӘЗ** *и. гар.* **1.** Тыгыз киҗе-мамык тукыма. *Сатин үлчим, бәзен үлчим – Үлчәве кулларымда.* Җыр

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән. *Бәз япма. Бәз эчлек*

**БӘЙ** I *и.* 1) Бәйләп, арканлап куя торган нәрсә (мәс., *бау, чылбыр*). *Пароход, бәйләреннән ычкынды да, яр буеннан шым гына кузгалып китте.* И.Гази

2) *к.* **бәйләвеч** (*1 мәгъ.*). *[Старшина] Гимнастёрка-чалбарларыбызны, итекләребезнең ничек куелышын тикшереп йөргән һәм шунда минем балак очымдагы бәйләрне чишмичә йоклаганымны күреп алган.* Ф.Хөсни

3) *кыек килешләрдә* Бәйләп тоту, бәйдә килеш асрау халәте (хайваннар турында). *Бәйдәге эттән бурлар курыкмый.* Мәкаль

◊ **Бәйгә кую** *к.* **бәйдә тоту**. **Бәйдә тоту** Күзәтеп тору, контрольдә тоту. *Теләңне бәйдә тот, этеңне бауда тот.* Мәкаль. **Бәйдән ычкынган эт кебек** Котырган, шашкан кешегә карата әйтелә. **Бәйдән ычкыну** 1) Тәртипсезләнү, тыела алмас хәлгә килү. *Күңелең бер бәйдән ычкынса, аны берничнди фәлсәфи кануннар белән дә урынына утыртып булмаячагын аңламыймыни ул?* З.Хөснияр; 2) Билгеле бер күзәтүләрдән, контрольдән азат булу. *Бәйдән ычкынырга вакыт инде безгә, вакыт, вакыт...* В.Имамов

**БӘЙ** II *и.* 1) *тар.* Ислам динендәге феодаль Кавказ ханлыкларында: аерым олыс яки шәһәр белән идарә итүче кеше. *Бу көйләр – ханнар, бәйләрнең сарайларында әсирә чиркес җарияләренең көйләре дә түгел.* Г.Газиз

2) Якын Көнчыгыш дәүләтләрендә нәсел-ыру титулы, нәселдән килә торган хакимлек титулы, хәрби титул

3) Шул халыкларда ирләр исеменә кушылып әйтелә торган сүз; әфәнде. *Ихсан бәйнең ярасы әллә ни куркыныч түгел, --- Хәйруллаһ бәй аның бәйләвен алыштырган чакларда, мин чыгып торам.* Р.-Н. Гүнтәкин

**БӘЙ** III *ы.* Баланы көйләп, тирбәтеп йоклатканда, «әлли-бәлли» сүзе белән бергә әйтелә

**БӘЙ** IV *ы.* Көтмәгәндә килеп чыккан хәлдән нык гаҗәпләнүне белдерә. *– Бәй, үзе түгелме соң? – диде берсе, кычкырыбрак.* Ш.Маннур

**БӘЙГАТЬ** *и. гар.* Берәүнең хакимиятен тану һәм, аңа буйсынуыңны белдереп, сүз бирү; ант. *Ил булсагыз, атайга барыгыз, бәйгать бирегез, диде.* К.Насыйри. *Әгәр дә, мине үзеңнең ханың дип танып, бәйгать бирсәң, гомереңне саклап калу гына түгел, чал башыңнан бер чәч бөртеге дә төшмәс.* С.Шәмси

**БӘЙГЕ** *и.* 1) Ат чабышы, атта узышу. *Бәйгеләр җиткәч Минем аргамак Тоягы белән утларга баса.* Р.Әхмәтҗан

2) Ат чабышлары үткәрелә торган мәйдан

3) Көрәш; ярыш; узыш. *Мондагы тормыштан һәрвакыт бәйрәм тәме, бәйге тавышы килеп тора.* М.Юныс. *Бәйгенең җыр һәм бию белән үрелеп баруы аны аеруча җанландырып җибәрде.* Сөембикә. *Озын сакал йөртүчеләр арасында бара торган бәйгедә норвегияле Ханс Лангхет дөнья чемпионы булган.* Шәһри Чаллы

4) Ярышта җиңгән атка яки кешегә бирелә торган бүләк. *Байтал, чабып, бәйге алмас.* Мәкаль. *[Егет] Бәйгене бүтәннәрдән алдырса, Хәмдиясенә үпкәләмәс.* М.Фәйзи

**БӘЙГЕЧЕ** *и.* Бәйгедә катнашучы. *Шуннан соң залга бәйгечеләр чакырылды.* Сөембикә

**БӘЙ ИТҮ** *ф. к.* **бәү итү**. *Җырлыйҗырлый кыз бала Энекәшен йоклата. ...Әлли-бәлли бәй итә, Энем йокыга китә.* М.Мазунов

**БӘЙЛӘВЕЧ** *и.* 1) Бер бөтеннең очларын, ян-якларын (мәс., *изүне, балак очларын һ.б.*) тоташтыру, бәйләү өчен кара-каршы тагылган бауларның берсе. *Ул [лейтенант], сөйләшү тәмам дигән шикелле, папкаларын ябып, бәйләвечләрен бәйли башлады.* Х.Камалов

2) Җәрәхәтне, тайган буыннарны һ.б.ш.ны урап бәйләү өчен кулланыла торган бинт яки башка әйбер. *Ситдыйк абзый маңгаендагы бәйләвечен өскәрәк тибәрде.* К.Нәҗми

3) Маска. *Әгәр бала имезүче хатын грипп белән авырса, ул, бала янына килгәндә, марля бәйләвечләр киеп, авыз-борынын капларга тиеш.* Йорт эшләре

4) Кайсы да булса хезмәт яки вазифа төренең символын белдергән рәсем төшерелгән тукыма. *Ак яка, кульяулыкларны сыйныфта Зөлфия үзе тикшерә. Шәфкать туташы кебек, беләгенә кызыл бәйләвеч тагып.* З.Әһлиева

**БӘЙЛӘВЕЧЛЕ** *с.* 1) Бәйләвечләре (*1 мәгъ.*) булган, шуның белән бәйләнә торган. *[Шәрәфи] Күлмәгенең бәйләвечле изүен чиште.* Г.Галиев

2) Бәйләвеч (*2 мәгъ.*) белән бәйләнгән. *[Бабай] Минем бәйләвечле кулымны, өзелгән балак-җиңнәремне күрде.* Н.Исәнбәт

**БӘЙЛӘГЕЧ** *и.* **1.** 1) *к.* **бәйләвеч**

2) Ике араны үзара тоташтырып торган шартлы халәт. *Әгәр бу – аналитик, бәйләнеш-мөнәсәбәтләрне бүлгәләүче һәм гомумиләштерүче Аурупа фикерләве булса, ул – мелодияне капшап карап, ике арадагы бәйләгечләрдән котылырга тырышыр иде.* Фәнни Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* Бәйләү, тоташтыру, теркәү өчен кулланыла торган. *Бәйләгеч җепләр*

**БӘЙЛӘМ** *и.* **1.** 1) Бергә бәйләп куелган бертөрле әйберләр җыемы. *Югарыдагы аркылы киртәгә, икешәр-икешәр бәйләп, быелгы каен себеркеләрен элгәннәр, ә бүрәнә стенага мәтрүшкә бәйләмнәре асып куйганнар.* Ә.Еники. *Кадакка эленгән ачкычлар бәйләме. Ике бәйләм чәчәк*

2) Бер бәйгә сыярлык күләм. *Җыйган дару үләннәрен бәйләмнәргә аерып кую*

3) Бәйләү, кул эше. *Үткән тормыш, җеп очыннан тартып сүткән бәйләм сыман, алга өелә тора.* С.Сөләйманова. *Баксаң-күрсәң, бәйләм бәйләү, тегүчигү – ул гади эш кенә түгел, ә бөек сәнгать икән.* Ф.Яруллин

4) Бәйләү рәвеше, узор (бизәк). *2 нче номерлы энәгә кара җептән – 20 һәм аксыл сары җептән 20 күз алалар да, оек бәйләме белән 19 сантиметр бәйлиләр.* Йорт эшләре

5) *сир. к.* **бәйләвеч** (*2 мәгъ.*). *[Яралы солдат] Башын тотып, ыңгырашырга*

*тотынды; маңгаендагы ак бәйләм кызара башлады.* Ш.Усманов

6) Цикл, җыентык. *Аның [Н.Арслановның] «Робагыйлар», «Афоризмнар» кебек шигъри бәйләмнәренә кергән фәлсәфи-лирик характердагы дүрт, икеюллыклар тарихи шәхесләр, ил-ватан, яшәү, үлем, мәңгелек, туган табигать турында җитди уйлануларны, сөземтә-күзәтүләрне эченә ала.* Т.Галиуллин

7) *күч.* «Бер» сүзе белән бергә килгәндә, күп итеп тупланган бериш әйберләр. *Кулына бер бәйләм «Личный знак» тоткан старшина, күз йөртеп чыккач, кемнең кая барырга җыенуын сорады.* К.Латыйп. *Атның маңгаена бер бәйләм тавис каурыеннан ясаган чук беркеткәннәр.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ. диал.* 1) Бәйләнгән, бәйләп эшләнгән. *Мин инде өстә бәйләм күлмәк белән генә басып тора идем.* Н.Исәнбәт. *Мәдәния апа, Сарай тавы ягына төбәлеп, сүзсез калды. Бәйләм күлмәгенең сәдәфен бөтергәли башлады.* М.Галиев. *Әнә сез аның --- йөк арбасы кебек канатлы иңнәреннән тезләренә кадәр салынып төшкән бәйләм кофтасына игътибар итегез.* А.Хәлим. *Бәйләм әйберләрне төсле җепләрдән ясалган бизәк бик матурлый.* Йорт эшләре

2) Аерып бәйләп куелган, җепкә үреп тезелгән. *Алар --- яшелчәләр тирәсендә әйләнгәләп, берәр бәйләм суган, биш-алты бәрәңге, яртышар баш кәбестә, кружкалап, сөт күтәреп кайталар.* М.Гали

**БӘЙЛӘМЛӘ́Ү** *ф.* Бәйләм-бәйләм итү, бәйләмнәр ясау. *Тора-бара, бу җыр мәҗмугалары серия рәвешендә дәфтәрләп, кисәкләп, бәйләмләп тә басылалар.* К. Миңнуллин

**Бәйләмләп алу** Тиз генә бәйләмләү

**Бәйләмләп ату** Бик тиз, аннан-моннан бәйләмләү

**Бәйләмләп бетерү** Барысын да бәйләмнәргә аерып бәйләү

**Бәйләмләп ташлау** *к.* **бәйләмләп ату**

**Бәйләмләп чыгу** Һәммәсен бер-бер артлы бәйләмнәргә аеру

**Бәйләмли бару** Һәммәсен бер-бер артлы яки эзлекле рәвештә рәттән бәйләмләү

**Бәйләмли төшү** Тагын да күбрәк бәйләмнәргә бүлү

**БӘЙЛӘМЛЕ** *с.* Бәйләм-бәйләм итеп куелган, бәйләмнәргә аерып төрелгән. *Бәйләмле китаплар*

**БӘЙЛӘМЛЕЛЕК** *и.* Бәйләнгән булу. *Әмма шунысы бар: шигъри бәйләмлелек төрле шагыйрьдә төрле эчтәлектә, төрле рәвештә гәүдәләнә.* Н.Юзиев

**БӘЙЛӘНЕШ** *и.* 1) Бер-берсе белән бәйле булганлык, үзара шартлы мөнәсәбәтләр. *Үсемлек органнарының үзара тыгыз бәйләнештә булуы һәрбер чәчәкле үсемлекнең бербөтен организм икәнлеген күрсәтә.* Биология

2) Турыдан-туры аралашу; тыгыз багланыш; якын мөнәсәбәт. *Авыл белән шәһәр бәйләнеше*

3) Гадәттә ир кеше һәм хатын-кыз арасындагы яшерен якынлык. *Ул чакта мин сиңа Фатихның Зөләйха белән әле һаман бәйләнештә торганлыгын сиздермәгән идем.* Э.Касыймов

4) Хәбәрләшү, үзара элемтә. *Әллә шул хис аңа [Асяга] бүтәннәр белән бәйләнешкә керергә киртә салып торамы?* Х.Камалов. *[Ильяс] Бабалары белән бәйләнешкә кереп карамады түгел.* Ә.Баян

**БӘЙЛӘНЕШЛЕ** *с.* **1.** 1) Нәрсәгә яки кемгә дә булса мөнәсәбәтле, кагылышлы, үзара бәйле, нисбәтле, бәйләнеше булган. --- *һәр жанр тоташы белән үзенә багышланган аерым бер бүлектә генә бирелә һәм аның чорларга бәйләнешле үзгәрешләре, конкрет әсәрләре дә шул бүлек эчендә карала.* М.Бакиров

2) *махс.* Логик яктан эзлекле, грамматик яктан дөрес; төзек (сөйләм, язу турында). --- *китапны төзегәндә, югарыда күрсәтелгән педагогика кагыйдәләренә туры китереп төзүен, берберенә бәйләнешле һәм эчтәлекле текстлар алуын һәм фәнни якка да әһәмият итүен әйтә.* Ф.Вәлиева

**2.** *рәв. мәгъ.* Логик яктан эзлекле итеп. *Салих [кызның] чая икәнен бик күптән белсә дә, болай килешле итеп, укытучылар шикелле бәйләнешле итеп сөйләвен беренче тапкыр ишетә иде.* Г.Мөхәммәтшин

**БӘЙЛӘНЕШЛЕЛЕК** *и.* Бәйләнешле булу

**БӘЙЛӘНЕШСЕЗ** *с.* **1.** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса бәйләнеше, нисбәте булмаган. *Темага бәйләнешсез хикәя*

2) Логик эзлеклелек сакланмаган; буталчык; аңлаешсыз. *Шәмсия карчык йокы арасында Вафинның соравын аңламый калды булса кирәк, бәйләнешсез бер-ике сүз мыгырданды да янә тынды.* Ф.Хөсни

**2.** *рәв. мәгъ.* Бутап, эзлеклелек сакламыйча. *Фәрит, сагынып көткән анасын үбә-коча, балаларча бәйләнешсез итеп, күргән-белгәннәрен сөйләргә тотынды.* Г.Минский

**БӘЙЛӘНЕШСЕЗЛЕК** *и.* Буталчыклык; эзлексезлек; аңлаешсызлык. *Хәзер минем уйларым таркау. Мин аларны бер үзәккә җыйный алмыйча газапланам. Шуңа күрә сүзләремдә дә беркадәр таркаулык һәм бәйләнешсезлек килеп чыга бугай.* Ш.Камал

**БӘЙЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бәйләү** I. *Торналар чылбыры чайкала, Ярга бәйләнгән көймәне Тотып торган шикелле...* Н.Вәли

2) *сир.* Элемтә урнаштыру, үзара бәйләнешкә кереп, хәбәрләшеп тору. *Штурмчылар полкы командиры --- белән бәйләндем һәм алардан фронттагы хәлләр турында безгә хәбәр итеп торуны үтендем.* Казан утлары

3) *шелт.* Гашыйк булу, мәхәббәт белдерү. *Беркөнне алар палубадан Идел ярларын карап барганда, теге матрос тагын килеп бәйләнде. Әнисәне җилкәсеннән кочаклап: – Моя красавица! Мин бит сезгә гашыйк булдым. Сез игътибар да итмисез, – ди.* А.Хәсәнов // Өйләнү яки иргә чыгу. --- *минем язмышым да икенче берәүләр белән бәйләнде һәм мәхәббәтнең «әчесен-төчесен» башкалар белән татырга туры килде.* Ә.Еники. – *Фәхри кебек өтеккә бәйләнмәсәң, сиңа үз тиңең табылмас дип белдеңме? – дип [Гайшәне] шелтәләделәр.* Казан утлары

4) Рухи якынлык тою; якын, үз итү. *Гөлгенә бу дусларына инде йөрәге белән бәйләнде.* Н.Дәүли

5) Башланып китү, уңышлы бару (сүз, әңгәмә турында). *Таныш булып*

*чыктыгыз бит, сүзегез бәйләнер инде.* Н.Исәнбәт

6) Керешү, алыну (күңел ятмаган эш турында). *Кирәкмәгән эшкә бәйләнү* // Берәр эш яки әйбер белән артык мавыгу. *Балачактан атка бәйләнде. Ат дигәндә, җанын фида кылып, Җир читенә барып әйләнде.* А.Хәлим

7) Вак кимчелекләрне күпертеп күрсәтү һәм шулар өчен ачулану. *Усал кеше! Бәйләнмәгән чагы гел юк, көзге чебен кебек.* А.Гыйләҗев. *Шушы вакыйгадан соң, юк-бар гаепләрем өчен дә миңа бәйләнә торган булып китте.* Ә.Рәшит

8) Артык еш мөрәҗәгать итеп яки төпченеп борчу. *[Малайның] Кечкенәсе велосипедны күргән саен бәйләнә: әти, утыртып йөрт әле, ди.* И.Гази

9) Тешләргә, таларга чамалап ээәрләкләү (усал хайван, кош-корт турында). *«Фу! Чатан! Фу!» – дип, ни тыярга тырыштык. Овчарка безгә үзе килеп бәйләнде.* А.Хәсәнов // Каныгу, үчегү. *Шунда миңа партадашым Нур бәйләнде бит. Әле төртә, әле бишмәт җиңемнән тарта, мыскыллы сүзләр әйтә, көлә.* М.Маликова

10) *гадәттә үткән заман хикәя ф. форм.* Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендә булу, мөнәсәбәтле булу. *Муса теләсә кайда чыгып йөри ала, аның эше кәнсәләр сәгатьләре белән бәйләнмәгән.* Ш.Маннур. *Кешенең кешелеклелеге профессиягә бәйләнмәгән...* Ф.Яруллин

11) *лингв.* Синтаксик мөнәсәбәтне белдерү, ияру. *Әйтик, «сөйләү», «әйтү», «уку», «язу» фигыльләре, үзләренә ияргән сүзләр белән, «турында» бәйлегеннән тыш, төшем килеше кушымчасы ярдәмендә дә бәйләнә ала.* Р.Юсупов

12) *күч.* Начар күрү; күрмәс булу; күз алды томанлану. *Галәмнән һичбер шәйне күреп булмый, Бәйләнә күзләр, – һава чуалган ич!* Н.Думави. *Караңгы төште, күз бәйләнде, Нурания генә юк та юк.* Р.Камалов

13) *күч.* Гаҗәпләнүдән, аптыраудан сүз әйтә алмый тору. *Барып җиткәч дәрьяга, китерделәр кимәгә, Газиз телләрем бәйләнде, белмим ни сүз димәгә.* Җыр

**Бәйләнә бару** Торган саен ныграк бәйләнү

**Бәйләнә башлау** Бәйләнергә тотыну. *«Тинчурин капиталистлардан ярамаган хатлар-журналлар алып укып ята» дип, дөньяны бутап бетерделәр. Шуннан соң инде Тинчуринга гел бәйләнә башладылар.* Р.Батулла

**Бәйләнә бирү** Бәйләнүен дәвам итү. *Әйдә, бәйләнә бирсен!.. Апай кеше бик чая тотынса да, әти белән әни алдында аның кул белән шаяра алмасын әллә каян белеп торам.* Г.Бәширов

**Бәйләнә китү** Бәйләнә башлау, кинәт бәйләнергә тотыну. *Чит авыл малайлары бәйләнә китсә, Нурулла бер генә кычкыра.* Р.Батулла

**Бәйләнә төшү** Бераз бәйләнү; тагы да бәйләнү

**Бәйләнеп алу** Бераз вакыт эчендә, тиз арада бәйләнү. *Кайберәүләр аңа бәйләнеп тә алдылар. Ләкин бу бәйләнеш озакка бармый басылды.* М.Гафури

**Бәйләнеп бетү** Тәмам, бик нык бәйләнгән булу. *Монда эт – эткә, эт койрыкка бәйләнеп беткән.* Ә.Еники. *Шуңа су салып, утта кайнатабыз да, беребез – агач савыт, икенчебез, әллә ничә җиреннән сыланып, бәйләнеп беткән касә белән чәй эчәбез.* И.Салахов

**Бәйләнеп йөрү** Әле – бер, әле икенче кешегә бәйләнү. *Әмма коридорда «Марсельеза» җырлауга каршы бәйләнеп йөрү – сезнең эш түгел, бу – жандармлык.* Г.Ибраһимов

**Бәйләнеп китү** Кинәт бәйләнә башлау. *Ни өчен бәйләнеп китте соң әле ул Асия белән?* Г.Иделле. *Бераздан кызу әңгәмә бәйләнеп китте.* М.Юныс

**Бәйләнеп тору** 1) Һәрвакыт, гел бәйләнү

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында бәйләнү. *Кунак ич ул, бәйләнеп тору аңа килешәмени?* Ә.Еники

3) Бәйләнгән хәлдә булу. *Карчыганың баласы, бәйләнеп торып, бауда үләр.* Мәкаль

**Бәйләнеп утыру** Бертуктаусыз бәйләнү. *[Саҗидә:] Йә инде, Низам, кунак кешегә бәйләнеп утырма.* Ә.Хәсәнов

**Бәйләнеп яту** Әле, хәзер бәйләнү. *Ләкин малай-шалайга бәйләнеп яту килешми иде.* Г.Бәширов

**БӘЙЛӘНЧЕК** *с.* **1.** 1) Вак, әһәмиятсез җитешсезлекләргә артык игътибар итүчән, шуларны сылтау итеп, бәйләнергә яратучан. *Әхмәтсафа бу бәйләнчек кеше белән сүз көрәштереп тормады, читкә тартылды.* Ф.Сафин

2) Төпченүчән, артык сораулар биреп борчый торган. *Бәйләнчек дустыннан котылу өчен ул: – Диплом спектакләндә генә уйныйм инде, яме? – диде.* Н.Гыйматдинова. *Урамга чыктым исә, анда иясез йөргән дәү этләрдән, усал ата казлардан, бәйләнчек малайлардан шүрли төшәм.* Р.Фәизов

3) Һәркемгә бәйләнеп, тешләргә, таларга торган, усал (кайбер хайваннар, кошлар, бөҗәкләр турында). *– Ярар, монысы ачыкланды, – диде Сәрия, бәйләнчек шөпшә кебек тагы безелдәп.* Х.Камалов. *[Әлмәндәр] Бәйләнчек эт булдың. Куйсам куярмын инде, чуртуматыр, мәтәлеп кит.* Т.Миңнуллин

4) Бертуктаусыз борчып торган, тынгы бирми торган. *Бәйләнчек уй, ешрак керә башлап, ми түренә хуҗа булып бөтенләйгә калмасмы?* Р.Батулла. *Тик бәйләнчек чир кырмавыктан да зәһәррәк иде.* Н.Гыйматдинова. *Идел аръягыннан һаман соргылт, ямьсез болытлар агылды, җәй көне булганга бигрәк тә күңелгә нык тия торган бәйләнчек ачы җил исте.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ.* Артык бәйләнүчән кеше. *Мин, танышырга дип, хатын-кызга сүз каткан бәндәләрне яратмыйм. Бигрәк тә менә шундый җебегән, таралган вакытта эндәшсәләр, бөтен ачуымны бөркім: «Бәйләнмәгез, зинһар! Олагыгыз яныннан! Сез генә кирәк, ди, монда!» «Бәйләнчек»не дорфалыгым өркетмәдә.* Н.Гыйматдинова

**БӘЙЛӘНЧЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) Бәйләнчек булып китү. *Бу кыяфәте миңа ошамаганын әйтергә җөрьәт иттем. Доктор, үртәлеп, кулларын җәйде: – Бәйләнчекләнмә.* Р.-Н. Гүнтәкин

2) Бәйләнчек булып кылану. *[Егетнең] Куанычы сүрелде. Ул гадәттәгечә бәйләнчекләнә, ризасызлык күрсәтә башлады.* А.Расих

**Бәйләнчекләнә бару** Торган саен ныграк бәйләнчекләнү

**Бәйләнчекләнә төшү** Бераз бәйләнчекләнү

**Бәйләнчекләнеп алу** Бераз, күпмедер вакыт аралыгында бәйләнчекләнү

**Бәйләнчекләнеп бетү** Тәмам бәйләнчекләнү

**Бәйләнчекләнеп китү** Кинәт, көтмәгәндә бәйләнчекләнә башлау

**Бәйләнчекләнеп тору** Һәрвакыт, әледән-әле бәйләнчекләнү

**БӘЙЛӘНЧЕКЛЕК** *и.* Бәйләнчек кешегә хас сыйфатлар. *Көлүче – бәйләнчеклеге өчен Черки кушаматы алган Ибраһим исемле малай иде.* Г.Гобәй. *Швейконың мәкергә дә булдыклылыгы беленеп тора. Каменский взводындагы солдатларга бәйләнчеклеге дә артты – моны ул сиздерми генә эшләде.* С.Шәрипов

**БӘЙЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Бау һ.б.ш. нәрсәләрнең оч-очларын кара-каршы китереп, бер-берсенә яки башка нәрсәгә төенләп тоташтыру. *[Җәя дугасы] --- сеңер белән урап, бәйләп, җилем белән катырылган.* Н.Фәттах. *Элмәкләп бәйләү*

2) Нәрсәне дә булса бау белән икенче бер нәрсәгә тагу, эләктерү; арканлау, беркетеп кую. *Вокзал каршында атлы казаклар тора; папахаларын артка чөйгәннәр, ияр артларына печән бәйләгәннәр.* А.Толстой. *Җомгадан элек түшәк, ястык, сандык төягән бер арбаның артына сыер бәйләп, Хәлимнәргә озатылды.* Г.Исхакый. *Хәтта чыбык очына бәйләп биргән җимнәребезгә дә кагылмады кош балалары.* Ф.Яруллин

3) Бау, җеп яки махсус декоратив бәйләгечләр белән кысып төрү, төргәк ясау. *Колхоз басуында чабып киптерәләр печәнне, тюкка бәйлиләр.* И.Сирматов

4) Авызын, бөреп, бау белән уратып төенләү, каплау, томалау. *[Әгъдия] Яңадан аягына баса алмады, алай да, үрмәләп барып, карбыз сатудан җыелган акчалы капчыкның авызын бәйләп өлгерде.* К.Кәримов. *Мендәр тышларының ярылган җирләрен, нәрсә туры килсә шуның белән, капчык авызын бәйләгән шикелле бөреп бәйләп, һәркем үз урынына сузылды.* Г.Садри

5) Нәрсә белән булса да урап каплау (күз, авыз һ.б. турында). *Салкын үтмәслек итеп, баланың авыз-борынын бәйләү*

6) Җәрәхәтләнгән урынны махсус бәйләвеч белән каплау, урап кую. *Бер аягын әллә ниләр белән бәйләп, урап бетергәннәр.* А.Гыйләҗев. *Янә мин сине яныма утыртам һәм җәрәхәтләреңне бәйләп, хәл алгач, төзәлгәч, Мәскәвеңә кайтарып җибәрермен.* Р.Батулла

7) Бөркәнеп, очларын, почмакларын кара-каршы китереп төйнәү. *Әнә Сөмбел белән ни булды. Шундый чибәр чәчләрен күрсәтмичә, ак яулык бәйләп килгән иде беренче көнне.* Ф.Яруллин. *Катерина дигән бер карчык, хәтта, татарча яулык бәйләп, татар авылына ашка да бара һәм, Хәтирә булып, бит сыпырып, татар карчыклары белән бергә дога да кыла, ди.* М.Мәһдиев

8) Очларын яки бәйләвечләрен каршы тоташтырып кую, тагу, ябыну. *Ак алъяпкыч бәйләсәләр, өзелеп тора кызлар биле.* Н.Нәҗми. *Галстук бәйләү*

9) Буу, тагу. *Кара күлмәк өстеннән билгә каеш бәйләгән хуҗа егет килеп чыкты.* Г.Ибраһимов

10) Кузгала алмаслык итеп кысып чорнау; хәрәкәтләнү мөмкинлеген чикләү. *Разведчиклар бик тиз генә аның [часовойның] кулларын бәйләп, капчыкка салдылар да куаклыкка кереп югалдылар.* А.Әхмәт. *Кул-аягын бәйләп, үзләре белән алып китәләр.* А.Хәсәнов. – *Мине түгел, сине арбага бәйләп салырга кирәк, психопат! – дип кычкырды.* Р.Сибат

11) Йоннан, җептән махсус инәләр белән үрү. --- *кыш буе намазлыклар, өстәл япкычлары, кулъяулыклар чигә, һәммәбезгә дә пирчәткәләр, оекбашлар бәйләп бирә.* Г.Бәширов. *Кыш буе ул [Нурдидә] шәл бәйләр.* Р.Батулла. --- *ул оекбашларны Гөлфиягә әбисе бәйләп китергән иде.* Ф.Яруллин

12) Бәйләмгә оештыру, бәйләм ясау; бер-берсенә беркетеп ныгыту. *Чыбыкларны аерым-аерым сындырып була, әмма себерке итеп бәйләгәч, сындырып булмый.* И.Сирматов

13) *лингв.* Иярүче кисәк белән ияртүче кисәк арасында синтаксик бәйләнешләр булдыру. *Иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйләп килүдә төрле чаралар катнаша.* Ф.Сафиуллина

14) *күч.* Үзара элемтә, аралашу чарасы булу. *Асфальт җәелгән һәм төзекләндерелгән бу юл шәһәр белән авылларны бәйли.* Социалистик Татарстан

15) *күч.* Нәрсә дә булса оештырырга, берәр эшкә алынырга мәҗбүр итү. *Тукта әле, абый, андый баш китәрлек эшкә нигә бәйлисез?* Т.Гыйззәт

16) *күч.* Үзенә нык җәлеп итү, тарту. *Бу кызчык белән ни эшләргә инде? Аны ни белән шөгыльләндерергә һәм ничек аны үземә бәйләргә?* Г.Тукай

17) *күч.* Нәрсә белән дә булса артык мавыгу, шуңа тулысынча бирелеп китү. *Рәсимә яшь бит әле, чибәр. Бөтен гомерен шушы балага гына бәйләмәс.* Ф.Яруллин. *Җирдәге тормышның мәгънәсен аңлап, рухын малга һәм байлыкка бәйләмәгән инсан гына ахирәттә җан рәхәте табачак.* Ф.Хәкимов

18) *күч.* Тыгыз мөнәсәбәт, бәйләнеш урнаштыру. *Мин, бүгеннән алып, тормышымны институт белән бәйләдем.* М.Хөсәен. *Китапта, татар тормышына нигезләнеп, урман дөньясы белән бәйләп, сихер-магия алымнары кулланып, бер ел хәтерен югалтып торган егетнең хәтеренә кайтуы сурәтләнә.* Г.Гыйльман

19) *күч.* Нәрсәнең дә булса сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендә булуын күрсәтү. *Безнең монда күчүне дә шушы вакыйга белән бәйләргә азапланучылар бардыр.* Ш.Камал. *Монда да Казан каласының исемен аш пешерә торган казан белән бәйләп аңлаталар.* Р.Мостафин. *XX йөз башы татар прозасындагы психологизмны, соңрак, берәүләр башлыча рус әдәбияты, бигрәк тә Тургенев һәм Толстой йогынтысы белән бәйләп карадылар.* М.Хәсәнов

20) *күч.* Җәлеп итү, якын рухи мөнәсәбәт урнаштыру. *Бу вакыйга Габдулланы Әптелбәргә тагын да ныграк бәйләде.* Ә.Фәйзи

◊ **Бәйләп тоту** Ирексезләү, көчләү. *Соңгы сүзне Василий Фомич әйтә: «Кем тели – бәйләп тотучы юк, юллык ризык та алсыннар. Әмма бүгенгә шушында калу – акылга муафыйк».* А.Ти-

мергалин. *Китү турында башына уй кергән кешене бала белән генә бәйләп тотып булмый.* Э.Һүдин

**Бәйләп алу** Тиз генә бәйләү; бәйләгән булу. *Пионерлар һәммәсе дә Галстуклар бәйләп алган.* Ш.Галиев. *Мотаһар ашыкмый гына килеп чыкты. Дөрестән дә, биленә чәчәкле ак алъяпкыч бәйләп алган иде, үзе чалбардан гына.* Д.Бүләков

**Бәйләп ату** Аннан-моннан, ничек кирәк шулай бәйләү

**Бәйләп бару** Эзлекле рәвештә бәйләү; бер-бер артлы бәйләү. *Төп персонаж Нәҗип вакыйгалар җебен бәйләп бара, әлбәттә.* А.Гыйләҗев

**Бәйләп бетерү** Тулысынча бәйләү; бәйләү эшен тәгәлләү. *Оекбаш бәйләп бетерәсем бар.* Г.Каюмов. *Аларның барысын да бәйләп бетергәч, ятьмәнең беренче рәт күзләре барлыкка килә.* Файдалы киңәшләр

**Бәйләп йөрү** 1) Әле, хәзер бәйләү белән шөгыльләнү

2) Даими, һәрвакыт бәйләү. *Парк саклаучы карт күрше таганнарны бәйләп йөри...* Н.Гыйматдинова. *Ирләрнең дә күлмәге фасоны буенча хатын-кызларныкыннан аерылмаган. Ирләр күлмәкне, ыштан эченә тыкмыйча, эчке эзәр белән бәйләп йөргәннәр.* П.Ибаев

**Бәйләп кую** 1) Алдан, бәйләп, әзер итү. *Аннан-моннан капкалап, өсбашка киендем дә кичтән үк бәйләп куйган төенчекләрне кулыма алдым.* Э.Касыймов

2) Бәйләнгән хәлдә калдыру, бәйләнгән хәлдә тоту. *Бал кортлары кереп беткәч, бабай тубалның авызын бәйләп куя.* А.Алиш. *Чыннан да курчагым бик матур. --- чәчләрен укучы кызлар кебек артка бәйләп куйган. Зәңгәр ефәк күлмәк кигән.* Ә.Бикчәнтәева. *[Гөлəндәм:] Син мине үз хуҗалыгыңа бәйләп куйдың.* Х.Вахит. *--- авыл халкын, суд юлы белән, шушы бөек төзелешләргә мәңгелеккә бәйләп куялар.* Ф.Бәйрәмова

**Бәйләп ташлау** Тиз-тиз генә бәйләү. *Кеше, кесәсеннән бау ала да, бик әйбәтләп кенә, Юлбарысның аякларын бәйләп ташлый.* Әкият

**Бәйләп тору** 1) Булган берсен, һәрберсен бәйләү

2) Сөйләү моментында, әле бәйләү белән мәшгуль булу

3) Һәрвакыт, гел бәйле итү. *Тоталитар хакимият ач, ялангач крестьянны җиргә мәҗбүри бәйләп тору юлын тапкан – крестьянга паспорт бирелми.* Н.Фәттах

**Бәйләп утыру** Әле, хәзерге вакытта бәйләү белән мәшгуль булу. *Кичтән капка төпләрендә оек бәйләп утырган әбиләр, бакча сукмакларында йөгерешеп йөргән нәни балалар, йокыларыннан уянырга да өлгермичә, хәрабәләр астында күмелеп калдылар.* Ә.Еники. *Әткәй, утынлыктагы бер бүкәнгә чүгәләгән дә, ишегалды себеркесе бәйләп утыра.* Н.Гамбәров

**Бәйләп чыгу** Һәммәсен бер-бер артлы бәйләү; һәрберсен бәйләү

**Бәйләп яту** Әле, хәзер бәйләү. *[Әти] Көлтә бәйләп ята иде.* Т.Галиуллин. *Ни күрим, янымда әле генә бер яралыны бәйләп яткан удмурт малае Константин Матюхин, күзләрен акайтып, тын да алмыйча, гөрселдәп, җиргә ауды.* З.Мәхмүди

**Бәйли бару** Һәммәсен тоташтан яки эзлекле рәвештә бер-бер артлы бәйләү

**Бәйли башлау** Бәйләргә тотыну. *Ниндидер үтә күренмәле җепләр бу карт белән икесен әкрен генә бәйли башлаган иде.* Н.Гыйматдинова

**Бәйли төшү** Тагын да кысыбрак, тыгызрак бәйләү

**БӘЙЛӘ́Ү** II *и.* 1) Гадәттә кыек килешләрдә: бәйләп, арканлап куя торган нәрсә, бәй. *Борын хәзрәтнең кысынкы кагыйдәләре эчендә яшәгән шәкертләр, ул китү белән, бердәүнең тәгъбиренчә, бәйләүдән ычкынган этләр кебек дулый, тилерә.* Г.Ибраһимов

2) Җепләрдән бәйләп, үреп эшләнә торган яки эшләнгән әйбер, кул эше. *Екатерина Дмитриевна, бәйләвен алдына куеп, тыныч кына төшүче кар бөртекләренә карап торды.* А.Толстой. *Бәйләү бәйләүче кызлар, шүрләп, тәрәзә янына утырмый.* Р.Батулла

3) *к.* **бәйләвеч** (*2 мәгъ*). *Ихсан бәйнең ярасы әллә ни куркыныч түгел, --- Хәйруллаһ бәй аның бәйләвен алыштырган чакларда, мин чыгып торам.* Р.-Н.Гүнтәкин

**БӘЙЛӘҮЛЕ** *с.* Бәйләп куелган. *Ул, шулай бәргәләнеп, бәйләүле кулаяклары белән идәнне кыйнарга керешә.* Ш.Шәйдуллин

**БӘЙЛЕ** *с.* **1.** 1) Бәйләнгән, бәйләп куелган. *Урам як койма буенда чанада бәйле яткан бүре һаман селкенә икән – үлем белән тарткалаша, мөгаен.* Ә.Баян

2) Мөстәкыйльлеге булмаган: ирексез; буйсынган; хокуксыз. *Идел буе Болгар дәүләтләренә вассал рәвештә бәйле булган каханат X йөзләрдә сүтелә, таркала башлый.* М.Хәбибуллин

3) Кемгәдер, нәрсәгәдер мөнәсәбәтле, шуның белән бәйләнешле, аңа караган. *--- татар халык дастаннарының да нигезендә яткан каһарманнар белән бәйле сюжетлар шул ук Кытай яки Орхон-Енисей язмаларында сакланган.* Ф.Урманче

4) Кем яки нәрсә белән булса да сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендә торган, шуңа бәйләнешле. *Яңа урамнарга – яңарак исемнәр, әйтик, шушы якларның үзенә бәйлерәк исемнәр куясы иде бит.* Р.Төхфәтуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Мөстәкыйль булмыйча, буйсынып. *– Приказчик булып, кешегә бәйле булып торырга теләмим мин, – диде Габделнасыйр.* М.Гали

**БӘЙЛЕК** *и. лингв.* Барлык исем һәм исем мәгънәсендә килгән мөстәкыйль сүзләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерә һәм аларны берберсенә бәйли торган ярдәмлек лексик берәмлек. *Бәйлекләр синтетик чара исәпләнә, чөнки алар, кушымчалар кебек үк, үзеннән алда килгән сүз белән тыгыз бәйләнештә карала.* Татар грамматикасы

**БӘЙЛЕ́К СҮЗ** *и. лингв.* Аерым грамматик формалары, лексик мәгънәсен югалтып, бәйлек функциясен үти торган мөстәкыйль мәгънәгә ия сүз. *Бәйлек сүзләрнең икенче төр бәйләүче чараларны формалаштыруда бик актив катнашуларын әйтеп үтәргә кирәк.* Татар грамматикасы

**БӘЙЛЕЛЕК** *и.* 1) Бәйле булганлык, бәйле булу хәле. *М.Бертло фәнгә «молекуляр рефракция» төшенчәсен кертә, матдәнең яктылык сындыру*

*үзлеге белән аның составы арасындагы бәйләлекне өйрәнә.* Фән һәм тел

2) Буйсынганлык, мөстәкыйльлеккә ия булмау, кемнең яки нәрсәнең дә булса карамагында булу. *Янартау кебек гүелдәп, Эче ут янган, диләр! Бәйлелек кулы һәр минут Бугаздан алган, диләр.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Ул Җучи Олысына вассаллык бәйлелегендә, ягъни югары хакимгә буйсынган кебек булган.* Г.Дәүләтшин

**БӘЙНӘ́-БӘЙНӘ** *рәв.* Җентекләп, тәфсилләп, түкми-чәчми. *[Алмаз] --- кайчаннан бу чир белән интегә башлавын, нәрсәләр белән дәвалануын, канның кайчан тукталып торуын бәйнә-бәйнә сорашты.* Э.Шәрифуллина

**БӘЙНӘЛӘП** *рәв. к.* **бәйнә-бәйнә.** *Хәер, Фәттах бабай мирасын бәйнәләп тасвирлар өчен, махсус мәкалә генә түгел, зур китап язу кирәк булыр иде.* М.Госманов

**БӘЙНӘЛМИЛӘЛ** *и. гар.* Интернационал. *Бәйнәлмилəл ирек таләп итә, Кан коймаган кайсы инкыйлап?* Н.Әхмәдиев. *Татар халкы үзе өчен генә яшәми, башка халыкларга гомуми мәдәниятка күтәрелергә, --- аларга биегрәк баскычка менәргә чын күңелдән, бәйнәлмиләл күзлектән чыгып булыша.* Г.Бәширов

**БӘЙРӘМ** *и.* **1.** 1) Җәмәгать тормышында берәр вакыйгага багышланган тантана. *Гади көн дә бәйрәм төсле балкып үтсен; Фәрештәләр өстемезгә бәхет сипсен!..* Ш.Бабич. *Матур күлмәгеңне бәйрәмнәрдә генә киярсең, һәркөн киеп кадерсезләмә.* Ф.Яруллин

2) Йола буенча үткәрелә торган махсус көн(нәр). *Бәйрәм юкта да, йортка иман иңсен, дип, әледән-әле, бабай Коръән укый.* Ш.Галиев. *Нәүруз ул – игелек бәйрәме, ул кешеләрне берберсенә якынайта.* Татар календаре

3) Берәр вакыйгага багышлап үткәрелгән махсус чара. *Әлифба бәйрәмен үткәрү. Уңыш бәйрәме. Кышны озату бәйрәме*

4) Зур шатлык, куаныч, тантана. *Бу көнне безнең тормыш бәйрәмгә әйләнә.* М.Гафури. *Иркә бала бәйрәме – яңа күлмәк кигәндә, ятим бала бәйрәме – авызы ашка тигәндә.* Әйтем

**2.** *с. мәгъ.* Берәр вакыйгга уңаеннан үткәрелә торган. *Бу гүзәл бәйрәм көндә [Нәүруз көннәрендә] кешеләр иске үпкәләрен оныталар, бер-берсен гафу итәләр.* Татар календаре

**БӘЙРӘ́М ИТҮ** *ф.* 1) Бәйрәмләү, бәйрәм буларак билгеләп үтү, бәйрәм ясау, шунда катнашу

2) *күч.* Шатлану, куану. *Әсми иптәш, әйдә, рәхим ит, моннан элек, Хафизга яла яккан чакларда, Кәримнәр бәйрәм иткән булса, хәзер инде без бәйрәм итәбез.* Г.Камал

**БӘЙРӘМЛӘ́Ү** *ф. сир.* Бәйрәм итү. *Бүген колхоз үзенең героен бәйрәмләп каршы ала.* М.Җәлил

**Бәйрәмләп алу** Кечкенә генә бәйрәм ясау

**Бәйрәмләп йөрү** 1) Әле, хәзерге вакытта бәйрәм итү

2) Һаман, бертуктаусыз бәйрәмләү. *Бер-ике ел эчеп, бәйрәмләп йөрде дә тап-таза көе китеп барды...* Ш.Галиев

**БӘЙРӘМЛЕ** *с.* Шатлыклы, куанычлы. *Таң кирәк, бәйрәмле таң!* С.Сүнчәләй

**БӘЙРӘМЛЕК** *с.* 1) Бәйрәм үткәрү, бәйрәмдә тоту өчен булган, билгеләнгән. *[Нәҗми агай] Үзенең таныш бер приказчигы аркылы Низами байдан бәйрәмлек акча соратты.* С.Рәмиев

2) Бәйрәмдә кию өчен. *Бу ни, кызым, бәйрәмлек күлмәкләр белән эшкә йөрисен?* Һ.Такташ

**БӘЙРӘ́МЧӘ** *рәв.* 1) Бәйрәмдәге кебек. *Бөтенесе дә шат, бөтенесе дә бәйрәмчә киенгән.* М.Кәрим. *Көмеш кебек самавыр күңелле, бәйрәмчә кайнап тора.* С.Сүнчәләй. *Бәйрәмчә киенгән кешеләр арасында ул чыннан да сәеррәк күренгәнгәме, табынчылар башта аптырабрак калды.* Р.Батулла

2) *күч.* Купшы, чамадан тыш иркен. --- *артык бәйрәмчә яшәргә өйрәнелде бугай ахры.* Ш.Маннур

**БӘЙРӘМЧЕ** *и. сир.* Бәйрәм итүче, бәйрәмдә катнашучы; бәйрәм оештыручы. *[Бригадир] Шофёрга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н.Фәттах

**БӘЙРӘМЧЕЛ** *с.* Бәйрәм итәргә ярата торган. *Бәйрәмчел халык*

◊ **Бәйрәмчел чикерткә** Җиңел холыклы кеше. *Менә шундый реаль уйлый белүче кыз кирәк аңа. Фәнүзә кебек бәйрәмчел чикерткә түгел.* Х.Камалов

**БӘЙСЕЗ** *с.* **1.** 1) Мөстәкыйль, азат, иреклe; суверен. *Ничек телибез – шулай кыланабыз, дип фикер йөртә бу чибәр кызлар һәм, чәчәкле болындагы бәйсез күбәләкләр сымак, теләгән тарафларына очып киткәлиләр дә...* З.Хөснияр. *Бәйсез дәүләт*

2) Бәйсезлек сизелеп, күренеп торган. *Кулындагы портфелен урынсыз бутап, бәйсез кыяфәт белән [Энҗе] ишеккә йөгерде.* Г.Тавлин

**2.** *рәв. мәгъ.* Ирекле, мөстәкыйль рәвештә. *Эченнән генә ул үзен Андреевтан бәйсез тотарга, үзенчәрәк яшәп, үзе белгәнчә эшләргә булды.* Ә.Еники

**БӘЙСЕЗЛЕК** *и.* Мөстәкыйльлек, ирeклелек, кемгә яки нәрсәгә дә булса буйсынмаганлык. *Бәйсезлек өчен канкойгыч көрәш хакында, никадәр тырышып эзләсәк тә, бер кәлимә сүз дә таба алмадык.* Ф.Әмирхан. --- *Мансур дигәне, каршы килмәвен аңлатып, мускуллы кулларын ялангач күкрәге өстенә кушырып куйды да, нәфрәт һәм бәйсезлек күрсәткән бер кыяфәт белән, стенага сөялде.* Ә.Еники. *Иң изге бурыч – үзебезнең бәйсезлегебезне, мөстәкыйльлегебезне күз карасыдай саклау.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**БӘК** *и.* 1) *тар.* Феодаль ханлыкларда берәр олыс, шәһәр белән идарә итүче. *Хан үзенең вассалларына – бәкләргә, морзаларга, үзенә карусыз, яхшы хезмәт бәрабәренә, вакытлыча җиргә һәм андагы халыктан үз файдасына салым җыярга хокукны раслаган ярлыкязма документ биргән.* Г.Дәүләтшин. *Олыс бәге титулына Ак һәм Күк урда, ә Бөек әмир титулына Харәзем, Кырым, Болгар, Мордва хакимнәре ия булган.* Г.Дәүләтшин

2) Әфәнде (ирләр исеменнән соң әйтелгәндә). *Хөршит бәк үзенең туганнары һәм дуслары белән сыйлана.* М.Әмир

3) Морзалар нәселендәге фамилияләрдә һәм кайбер кушма исемнәрдә

сакланган компонент (мәс.: *Раинбәков, Солтанбәков*). *М.Казимбәк Казанга 1826 елның башында килә.* Казан утлары

**БӘКАМ** *и. гар. биол.* Сандалчалар семьялыгыннан, еш кына шикәр камышы, бамбук, пальма һ.б.ның тамырыннан сүлен суырып, паразит булып яши торган, үзагачы эфир майларына бай булган мәңге яшел тропик агач; *русчасы:* **сандал**. *Әрем, кычыткан, артыш, бәкам (сандал), кипарис, бергамот исе тынычлап йоклап китәргә булыша.* Мәдәни җомга. *Мандарин, бәкам, кипарис исе эч пошудан коткарыр.* Мәдәни җомга. *Сулыш күнегүләре ясау, бәкам, розмарин (бәбрия) исләрен иснәү файдалы.* Мәдәни җомга

**БӘКӘЙ** *и. диал.* Бәрән. *Малайлар, кәҗә бәкәйләре күк, юл читенә сибелде.* Р.Бәшәр. *Ләкин апа пианиноны, алып кайткан көннән үк, [аны] үзенең кан дошманы санады. Сарыкка имәргә кушылган кәҗә бәкәедәй, гел читләде.* Ф.Яруллин

**БӘКӘЙЛӘ́Ү** *ф. диал.* Бәрәнләү

**БӘКӘЛ** *и.* Тояклы хайваннарда: тояктан өстәрәк чокырланып торган урын, буынтык. *Бу айгырың синең республика сабан туенда да беренчелекне бирмәячәк, валлаһи! Күр әле син: ул аның бәллүр ваза кебек бәкәлләре!* М.Галиев. *Яхшы атлар үргә чабып менә, Томырылып үрнең башларына. Бәкәлләре канап-канап кала, Бәрелә-бәрелә үрнең ташларына...* Н.Акмалов. *Микәйнең түзәр хәле калмады, йөгерәсе-чабасы килүдән бәкәл очлары сызлагандай итеп, тынгылык бирмәде.* Р.Мөхәммәдиев

**БӘКЕ** *и.* Сулык өстендәге бозны тишеп ясалган уем. *Түгәрәккәй күлгә бәке уйдым, Бәкеләрем тирән булсын, дип.* Җыр. *Бәке суын кыйнасаң да, бәла китерә ул.* Г.Гыйльманов

**БӘКЛӘ́Р БӘГЕ** *и. тар.* Өлкән бәк, ханнан кала иң зур гаскәр башлыгы. *Бәкләр бәге, ханнан кала, иң зур гаскәр башлыгы саналган.* Г.Дәүләтшин. *Дүрт олыс әмиренең өлкәне «бәкләр бәге» дип йөртелгән.* Г.Дәүләтшин

**БӘЛА** *и. гар.* 1) Бәхетсезлек, күңелсезлек. *Аһ, бәла! Безне казый күргән, имеш.* Г.Тукай

2) Тормыш иминлеген бозган кайгылы хәл; афәт, фаҗига. *Кешенең бәласе турында авыз чайкау – начар гадәт.* Х.Камалов

3) Кимчелек, җитешсезлек, йомшак як (холык турында). *Бөтен бәлам дә шунда: мин эшне уйлап эшли алмыйм.* Ф.Хөсни

4) *тарт. форм.* Шаукым, начар тәэсир, аянычлы нәтиҗә. *Әнвәр иптәш, синең хыялларың – болар барысы да яшьлек бәласе!* Ш.Мөдәррис

5) Хәл итүе авыр мәсьәлә, эш. *Эшкә чумган кеше өчен вакыт җитмәве – зур бәла.* Г.Кутуй

6) Кемгәдер тагылган гаеп, яла, нигезсез гаепләү. *Яманга юлдаш булсаң – бәла йогар, Еланга ярдәм итсәң – кулны чагар.* М.Гафури. *Әткәй кебек зур, таза, баһадир абзамны нахак бәлагә эләктерделәр.* Г.Ибраһимов

7) Мәшәкать тудыручы, имгәк. *Уйладым-уйладым да шуны аңладым: кешегә акылы – бәладер.* Р.Мирхәйдәров

◊ **Бәладән (бәласеннән) баш-аяк** Бәйләнмәү хәерле, кирәге юк. *Бәласеннән баш-аяк дип, [Кантюков] качарга исәпләде.* Х.Камалов

**БӘЛА́-КАЗА** *җый. и.* Төрле бәхетсезлек, кайгы-хәсрәт, кайгылы хәл. *Бу бәла-каза шул каһәрдән башланды да инде!* Г.Бәширов. *Татарга кабатланган тарих югалган дәүләтчелеген дә, ирек кояшын да алып килмәс шул инде, бәла-казалар гына өеп китерер кебек.* Р.Сверигин. *Бәла-казалардан догалар гына коткара алса, барысы да шулай итәр...* Р.Габделхакова. *Чебен һәм бетләр китергән бәла-казалар хакында инде моннан 4 мең еллар элек, борынгы грек папирусларында язып калдырылган.* Кызыклар дөньясында

**БӘЛА́-КАЗАЛЫ** *с.* Бәла-каза китереп чыгара торган; хәвефле. --- *аҗаган күргән кешене гомере буена ачы язмыш, зур афәтләр, көтелмәгән газап-михнәтләр, фаҗигале хәлләр эзәрлекләр, тормышы тоташтан бәла-казалы, зар-интизарлы булыр, ди.* М.Хәсәнов

**БӘЛАЛӘ́Ү** *ф.* Әһәмиятсез нәрсә өчен, кимсетелгән санап, шуннан бәла ясау, юк-бар өчен тавыш чыгару. *Бозавымны түгел, танамны бирәм, бәлали генә күрмәгез, Ирек туган!* Х.Камалов

**БӘЛАЛЕ** *с.* 1) Бәлагә китерә торган. *Шулай ук бәлале эшкә уралдыммы?* Н.Исәнбәт. *Ниһаять, бәлале бүләктән котылдым!* М.Сәлим

2) *к.* **бәлаче**. *Казан егетенең дә әнә шул бәлале хатыннан соң ук үле хәбәре килгән иде.* Х.Камалов

**БӘЛАЧӘН** *с. к.* **бәлаче**. *– Нишлисең, андый кешеләр бәлачән була, – дип, Әүхәдиев Тавил турында бер дә яманлау сүзе әйтмичә генә фәлсәфә сатты.* Х.Камалов

**БӘЛАЧЕ** *с.* Әһәмиятсез нәрсә өчен, кимсетелгән санап, юк-барга тавыш чыгаручы, гауга куптаручы. *Бәлаче хатын*

**БӘЛАЧЕЛ** *с. к.* **бәлаче**. *Хәзер инде, вак җанлы, бәлачел, мыжгы кеше, дип кенә дә чикләмиләр.* М.Хуҗин

**БӘЛӘК** *и. рус* Кер чайкаганда – тукмаклау, кипкәч, йомшарту һәм шомарту өчен кулланыла торган, бераз яссы, сырлы агач тукмакчык. *Динә түрдәге өстәлдә сырлы бәләк белән керләр тәгәрәтә иде.* К.Кәрим. *Кер күтәрә алмас ак бүз кабат ничек агара? Бәләк һәм таш арасында мең кыйналып агара...* З.Мансуров. *Бервакыт шул тәрәзәләрдән оча башламасынмы: ир бала, кыз бала, сырлы бәләк, самавыр торбасы, табак, аш тәлинкәсе...* М.Мәһдиев

**БӘЛӘКӘЙ** *с.* **1.** 1) Кечкенә. *Бәләкәй тәгәрмәч алдан тәгәри.* Мәкаль. *Газаплы уйлар басканмы, карчыкның ансыз да бәләкәй гәүдәсе тагын да куырыла төшкән иде.* М.Хәсәнов. *Гади генә күрештек, кулы да кызлар кулы кебек бәләкәй, йомшак икән, дип уйлап куйдым мин.* Таныш өянкеләр

2) Яшь. *Бәләкәй чагында – баланың хәсрәте дә бәләкәй, ә үскәч, кайгысы үзеннән дә зур була икән.* М.Насыйбуллин

3) Араларында яшь ягыннан кечерәге, иң кечесе. *Быел көз минем бәләкәй абый солдат хезмәтенә алынды.* М.Гафури

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Әз, чак кына. *Инде хәзер исән калу чамалары бәләкәй.* Ф.Яруллин. *Исхак килеп кергәндә, ул*

*бәләкәй генә елмайган төсле була иде.* А.Гыйләҗев. *Банкага башы белән керә торган ул ахмакларыңа ышаныч бәләкәй.* Ф.Садриев

2) Балачактан, кечкенәдән, яшьтән, яшь вакыттан. *Мин, бәләкәйдән үк, бер кап шырпы югалтсам да, бәргәләндем, зуррак әйбер булса, минем төн йокыларым кача иде.* Ф.Садриев. *Ишморза – бәләкәйдән үк чәй эчеп үскән кеше, аның кадерен белә.* Р.Солтангәрәев

**БӘЛӘКӘЙЛӘНҮ** *ф.* 1) Кечерәю, кечкенәгә әйләнү. *Әллә чәчәк зурая, әллә Ярмөхәммәт бәләкәйләнә.* Р.Батулла. *Кеше картая, йөзен җыерчыклар каплый, чәч сирәгәя, агара, тырнаклар ярыла, тешләр сирәгәя, колак катылана, тезләр йомшый, буе бәләкәйләнә...* А.Гыйләҗев. *Тора-бара, ул тишек бәләкәйләнгән, аннары бөтенләй күмелгән.* И.Сирматов

2) *күч.* Элеккеге әһәмиятен, бөекләгән югалту; вагаю; бәясе төшү. *Киресенчә, табигать котырынганда, чынлап торып дулаганда, мактанчык җир уллары, бәләкәйләнеп, утырган эт биеклеге генә калалар.* А.Гыйләҗев. *Таркалдык без, кешеләр, бәләкәйләндек.* Н.Гыйматдинова

**Бәләкәйләнә бару** Торган саен бәләкәйләге арту, кечерәю. *Кайгы-хәсрәт кешене изә, ваклый, кеше, ихтыярын җуеп, һаман бәләкәйләнә бара.* А.Гыйләҗев

**Бәләкәйләнә башлау** Бәләкәйләнергә тотыну. *Алагаем зур кызыл ай калыкты һәм күз алдында, саргаеп, бәләкәйләнә башлады.* Б.Рафиков

**Бәләкәйләнә тору** Торган саен ныграк бәләкәйләнү. *Порт краннары һаман ерагая, һаман бәләкәйләнә торгач, офык артында калдылар.* М.Юныс

**Бәләкәйләнә төшү** Азрак, бераз бәләкәйләнү

**Бәләкәйләнеп бетү** Бөтенләй кечерәю, бәләкәй булып калу. *Еники фонында бик кечкенә булып калмыйбызмы? Бүгенге «зыялы» дигәннәребез, олы шәхеслеккә дәгъва итүчеләребез бәләкәйләнеп беткәч, халкыбызның киләчәге нинди булыр?* Р.Миңнуллин

**Бәләкәйләнеп калу** Кечерәеп, шул хәлне-торышны саклау. *Гаиләләр таш ачтан үлде, озак вакытлар буена ризык заты күрмәгәнлектән, кешеләрнең эчләре аркасына берегеп, авызлары бәләкәйләнеп калды.* М.Кәбиров

**Бәләкәйләнеп килү** Акрынлап, азазлап бәләкәйләнә башлау

**Бәләкәйләнеп китү** Бераз кечерәю, бәләкәйләнү. *Ул тагын да бөрешеп, бәләкәйләнеп китте.* Р.Вәлиев. *Эссе мунчада бик озак чабынгандай, изрәп, хәлсезләнеп калган сабыем. Агарынган, сулган, бәләкәйләнеп киткән...* Э.Шәрифуллина

**БӘЛӘКӘЙСЕТҮ** *ф.* 1) Кечкенәгә, яшькә санау

2) Кечкенә итеп күрү. *Агыйдел булып Агыйделне бәләкәйсетеп җыру чыгарганнар бит әнә...* М.Галиев

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса әһәмиятен, бәясен киметү, төшерү

**Бәләкәйсетеп җибәрү** Урынсыз бәләкәйгә санау, бәләкәй итеп күрсәтү

**Бәләкәйсетеп ташлау** Кинәт бәләкәйсетү

**Бәләкәйсетеп тору** Һәрвакыт, гел бәләкәйгә санау

**БӘЛӘКӘЧ** *с.* **1.** Кечкенә, бәләкәй. *Минем каршыда бәләкәч кенә бабай утырган да үзенең аһ-зарын сөйли.* М.Кәрим. *Барыбыз да шул бәләкәч малайга карап торабыз.* Г.Гыйльманов. *Ишек янындарак тигез акшарланган мичнең залга караган ышыгында бәләкәй генә бильярд булып, шуның янында ике бәләкәч малай --- үлле-мәлле шар сугып ятуда иде.* Э.Касыймов. *Патронташның бер бүлегеннән бәләкәч кенә сыбызгы тартып чыгардым.* С.Шәрипов

**2**. *и. мәгъ.* 1) Яңа туган яшь җан иясе; яңа туган бала, бәби. *Уйнасын-уйнасын, шуннан соң, абзар тутырып, бәләкәчләрен үстерермен.* Н.Гыйматдинова. *Өйдә бәләкәчкә исем эзлиләр.* Мәдәни җомга

2) *эвф. сөйл.* Аракы шешәсе. *Теге заманнан калган бер бәләкәчем дә утыра, бозыла башламасын.* А.Гыйләҗев

3) **бәләкәч, бәләкәчем** *ирк.* Иркәләп, яратып әйтә торган мөрәҗәгать сүзе. *Әхәзергә йокла, бәләкәчем, төшеңә бәхет керсен.* М.Каипов. *Мөгаен, «бәләкәчем», «алтыным», «күз нурым» дип сөйгәндер әле әнисе.* Д.Бүләков

**БӘЛӘ́К-БӘЛӘК** *с. сөйл.* Бик зур, бәләк хәтле. *[Ул] Кызыксынып, күршесенә ияреп керә һәм кухня өстәлендә яткан бәләк-бәләк симез корбаннарны күреп шакката.* А.Гыйләҗев. *Бик уңайлы ел икән, бәрәңгебез бәләк-бәләк булды.* М.Хуҗин

**БӘЛӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Юганда, чайкаганда керне бәләк белән тукмаклау; кипкән керне тукмаклап йомшарту. *--- әнә сиңа ике сандык кием, күңелеңә охшаганын сайлап ал да үземә бирерсең, бәләкләп кертермен.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Кыйнау

**Бәләкләп алу** Аз гына, берничә тапкыр тиз-тиз бәләкләү. *[Хәкимә] Әле яңа гына сабын суына басып кибәргә куйган мамык перчаткасын бәләкләп алды.* Г.Галиев

**Бәләкләп ату** Тиз генә бәләкләү

**Бәләкләп бару** Һәммәсен тоташтан бәләкләү

**Бәләкләп бетерү** 1) Һәммәсен, барысын да ахырына кадәр бәләкләү

2) *күч.* Бик каты кыйнау

**Бәләкләп җибәрү** Бераз, азрак бәләкләү. *Шуны аңлатсаң, мендәр тышың да чайкалыр, кая, Хәдичә, бәләкләп җибәр әле!* Н.Кәримова

**Бәләкләп ташлау** Тиз генә бәләкләү

**Бәләкләп тору** 1) Хәзер, сөйләү моментында бәләкләү

2) Бертуктаусыз, әледән-әле бәләкләү

**Бәләкләп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм, башыннан ахырына кадәр бәләкләү

**Бәләкли төшү** Тагы да бераз бәләкләү

**БӘЛЕШ** *и.* **1.** Эченә бер яки берничә төрле эчлек салып пешерелгән камыр ашы. *Кияү сыйларга алган мискидә элгәре пилмән китте, аның артыннан – тавык бәлеше, аның артыннан – дөге бәлеше...* Г.Исхакый. *Бәлеш илә гыйлем бергә җыелмас ---.* Г.Тукай. *Бөтнекле чәй бик тә тансык, алма бәлеше ашап туйгысыз, ә инде җир җиләге кайнатмасын әйтеп тә торасы юк.* М.Маликова

**2. бә́леш** *ы.* Көтелмәгән күренештән, хәлдән, гамәлдән кинәт туган ризасызлык, борчылу һ.б.ш. төсмер катнаш гаҗәпләнүне белдерә. *Бәлеш, әллә Фәһим абый инде?* Г.Бәширов

**БӘЛЕШӘЮ** *ф. гади с. к.* **бәлешләнү**

**БӘЛЕШЛӘНҮ** *ф. гади с.* Ямьсез булып җәелү, чалшаю (гадәттә иреннәр, авыз турында). *Көтелмәгән сүздән иреннәр бәлешләнү*

**Бәлешләнә бару** Торган саен ныграк бәлешләнү

**Бәлешләнә төшү** Бераз бәлешләнү

**Бәлешләнеп килү** Ниндидер сәбәптән бәлешләнгән торыш алу

**Бәлешләнеп китү** Көтмәгәндә, кинәт бәлешләнү

**Бәлешләнеп тору** Бәлешләнгән хәлдә булу. *[Нәсимәнең] Нечкә иреннәре бәлешләнебрәк тора, ләкин ямьсез түгел.* Ш.Камал

**БӘЛҖЕРӘ́Ү** *ф.* 1) *сөйл.* Артык дымнан җебеп йомшару яки җәелү. *Гүя алар да нәкъ җиләк-җимеш кебек: берсе саф һава җитмәүдән әлсерәгән, икенчесе дымсызлыктан кипшенгән, өченчесе артык дымнан бәлҗерәгән, караеп черегән.* А.Хәлим

2) *куч. гади с.* Хәлдән таю, ару, мәлҗерәү. *Рульне каты тота алмаган куллар, юнәлеш бирә алмаган беләк мускуллары, үзләренең ирек бәясен югалтып һәм чокыр булмаган җирдә чокыр табып, әлсери һәм бәлҗери иде...* А.Хәлим. *Карт өянке, бәлҗерәп, Җиргә чүккән, әлсерәп.* Б.Хәлимов

3) Чалшаю (авыз, ирен турында)

4) Югалып калу, кырыслыгын югалту, җебеп төшү. *Ә балалары да барлыгы исенә төшкәч, бәлҗерәдең.* И.Низамов

5) Булдыксызлану, көч-сәләте, ихтыяры җитмәү, булдыра алмау. *Ләкин ул берничә елга озынайган картлык изасыннан бәлҗерәп тереклек итүгә әйләнер иде.* Г.Хөсәенов

**Бәлҗерәп китү** Азрак яки көтмәгәндә бәлҗерәү. *Ильяс та күңел кылларына йомшап, бәлҗерәп китәргә ирек бирмәде.* И.Низамов

**Бәлҗерәп төшү** Көтелмәгән хәлләрдән бәлҗерәү. *Мәсьәләнең болай җиңел хәл ителүеннән Өммегөлсемнең куллары үзен тыңламас булып бәлҗерәп төште.* А.Хәлим

**БӘЛЗӘМ** *и. гар.* **1.** 1) Гадәттә, субтропик һәм тропик үсемлекләрнең орлыклары составындагы сумалалар, эфирлы майларның хуш исле куе сыеклыгы. *Кара тирәк бөреләреннән бәлзәм (сумала) күп аерылып чыкмый, шулай да аны парфюмерия промышленностендә кулланалар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы // Дару үсемлекләреннән ясалган хуш исле төнәтмә

2) Файдалы матдәләрдән ясалган, тән, чәч өчен косметика чарасы. *Кондиционер, бәлзәм[не] чәч --- юган саен сөртергә кушалар.* Акчарлак

3) *куч.* Күңелне юату, тынычландыру чарасы. *Кинәт кенә әйткән җылы сүзләр Бәлзәм булып назлый күңелем.* Ф.Солтан. *Үз-үзеңә ышанычтан да көчлерәк, шифалырак бәлзәм юк.* Б.Камалов. *Алып, кире китерсәләр нишләр идең? Ул вакытта инде бала күңеленә салынган яраны дәваларлык бәлзәмнәр табып булмас иде.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ. куч.* Файдалы, күңелне күтәрә торган. *Вәләкин «өч мең» дигән, йөрәккә бәлзәм сан тиздән башкасы белән алыштырылды.* Т.Галиуллин. *Җырчының бәлзәм җырлары Тәннәргә дәвалар сыман, Сырхау җаннарга тылсымлы Моңы саф һавалар сыман.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**БӘЛЗӘМЛӘ́Ү** *ф.* 1) Череп таркалудан саклау өчен, махсус матдәләр сеңдерү (мәеткә). *Аякларының тез тирәсе черегән булган, ләкин соңыннан бик яхшылап бәлзәмләгәннәр.* Г.Әпсәләмов. *Борынгы Мисырда мәчеләрне махсус зиратларга гына, махсус табутларга салып күмгәннәр. Нәкъ кеше кебек итеп, бик әйбәтләп бәлзәмләгәннәр, киндер яулыкка төргәннәр.* Кызыклар дөньясында

2) Косметик максатларда тәнгә, чәчкә бәлзәм сөртү

3) *куч. сөйл.* Җайлау-майлау; килештерү, ризалату

**Бәлзәмләп алу** Тиз арада бәлзәмләү

**Бәлзәмләп бетерү** Тулысынча бәлзәмләү

**Бәлзәмләп җибәрү** Азрак бәлзәмләү

**Бәлзәмләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр бәлзәмләү

**Бәлзәмли килү** Электән, күптән бәлзәмләү традициясе булу

**Бәлзәмли төшү** 1) Тагын да бәлзәмләү

2) Бераз, азрак бәлзәмләү

**БӘ́ЛКЕМ** *кер. сүз сөйл. к.* **бәлки 2**. *Кешенең, бәлкем, атна эчендә чәче агаргандыр, әмма бәгыре аның, тирән сызланудан соң, эретеп куйган чуен шикелле катып калды.* Ә.Еники

**БӘ́ЛКИ** *терк.* **1.** Компонентлар арасындагы каршылык нисбәтен белдерүче теркәгеч; ә, ләкин. *Аның йөзендә һичбер шатлык әсәре күренми, бәлки, киресенчә, аның чырае гадәттәгедән караңгылана төшкән, иреннәре бербәрсенә ныграк кысылган.* Ш.Камал

**2.** *кер. сүз функ.* Ихтималлыкны, мөмкинлекне белдерә. *Бәлки, деннән язмас идем, Гел изге юлда булсам.* И.Юзеев. *Бәлки, егет белән кыз да, бербәрсен яратырга теләгәнгә күрә генә, бал корты белән чәчәк төсле, бергә кушыла торганнардыр.* Ә.Еники

**БӘЛЛИ** *ы.* **1.** Кабатлап яки «әлли», «бәү» ымлыклары белән парлап, бәбине көйләп йоклатканда әйтелә. *Тирбәтәләр күп-күбәү Әлли-бәлли, бәлли-бәү.* Р.Хисмәтуллин. *«Әлли-бәлли, әлли-бәлли бәү», – дип, Газиз әнкәй аны көйләгән.* Р.Корбан. *Бәлли-бәлли-бәү итә, Улым йокыга китә. Аңа әле ябынырга Бер кульяулык та җитә.* Р.Фәйзуллин. *Әлли-бәлли көйләрмен, Хикәятләр сөйләрмен.* М.Садри

**2.** *и. мәгъ.* Балалар телендә: бишек

**БӘЛЛИ́ ИТҮ** *ф.* 1) «Әлли-бәлли», «бәлли-бәлли» һ.б.ш. сүзләр белән көйләп тирбәтү

2) Йоклау (көйләп тирбәтелгән бәби турында). *Вагон тәгәрмәчләре дә, үч иткәндәй, «бәлли-бәлли итәр бу» дигән сыман тирбәндереп баралар, башны түбән идерәләр.* Г.Кутуй. *Әлли итәр бу бала, Бәлли итәр бу бала, Әткәсенә, әнкәсенә Хезмәт итәр бу бала.* Җыр

**БӘЛЛИЛӘ́Ү** *ф. сир.* 1) *к.* **бәлли итү** (*1 мәгъ.*). *«Бай, бай, бай» --- дип сузып бәллили иде [ана].* Ә.Айдар

2) *куч.* Көйләү, кадерләү

**БӘЛЛҮ** *ы.* **1.** Бәбине көйләп йоклатканда, кабатлап яки «әллү», «бәү» ымлыклары белән парлап, я аралаштырып әйтелә. *Син еларга башласаң, чү-чү, балам, чү-чү, дигән; Тирбәтеп, көйләп кенә, Әллү, дигән, бәллү, дигән.* М.Гафури

**2.** *и. мәгъ.* Бишек. *Йоклый алмау белән бергә зиһенне томалаган әрнү*

*аркасында, бишекне дә катырак тартып җибәргән иде, бермәлне, түшәмдәге ыргактан ычкынып, бәллү идәнгә лап итеп төште куйды.* Ә.Баянов. *Искән җилләр кебек Үтәр-үтмәс бер ел, Матур аваз салыр Бәллүдәге былбыл.* Г.Афзал. *Безне әниләр бәллүдә тирбәтеп үстергән.* Ф.Яруллин. *Әллидер дә бәллидер, Бәллүдәге бәллүдер; Тирбәлә дә тирбәлә, Күләгәсе – тирәндә.* Табышмак (*көймә*)

**БӘЛЛҮКИ** *ы.* Баланы көйләп йоклатканда әйтелә. *Тибрәткәндә бишек җырын анам, бүлдермәгез, зинһар: «Әлли-бәлли» ... яраларга дәва – «Әллүки лә, бәллүки лә ...»* Л.Шагыйрьҗан

**БӘЛЛҮЛӘ́Ү** *ф. диал.* Бәбине көйләп йоклату

**БӘЛЛҮР** *и. гар.* **1.** Ачык җемелди, яңгыравыклы чыңлый торган, составында кургаш яки барий оксиды булган пыяла төре. *Алар бокалларын чәкештергәндә, бәллүр чыңына караңгы залдагы суккан тавыш кушылды.* Р.Мирхәйдәров. *Әгәр дә михнәттән укмашып, күкләргә ашкан тау булса, һәм шунда Аллаһның бәллүргә әйләнгән күз яше табылса?!* З.Мансуров

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бәллүрдән эшләнгән, бәллүрдән ясалган. *Саклык белән генә шешәне ачып, бәллүр рюмкаларга шәраб койдым.* Таныш өянкеләр. *Уртага куелган бәллүр вазадагы вак роза чәчәкләре аеруча җете күренәләр.* Р.Мирхәйдәров. *Ул, үзе теләп, нинидер чаралар ярдәмендә тагын да күтәренкерәк халәткә ия буласы килеп, шәраб салынган бәллүр касәгә үрелә.* Татарстан

2) *күч. шигъ.* Чиста, саф. *Килер, килер ерактагы йолдызлар, Бәллүр хисләр салып күңелгә.* Г.Мөхәммәтшин. *Бәллүр суны күз яшенә Нигә тиңлиләр икән?!* Ә.Гадел. *Җем-җем йолдыз тамчылары, чыңлап, күлгә коелалар, бәллүр тавышлар чыгарып...* Р.Харис

3) *күч. шигъ.* Йомшак. *Сабый бала күк иярәм Таңның бәллүр җиленә.* Г.Мөхәммәтшин

**БӘЛТЕРӘ́Ү** *ф.* 1) Тузып беткәнлектән таралырга тору. *Бәлтерәгән каралты-кура* // Селкенеп-калтыранып тору

2) *күч.* Хәлсезләнү. *Бу коточкыч хәбәрнең дөреслегеннән дә бигрәк, аның барлык тирә-якка таралып өлгерүе тәмам бәлтерәткән ата белән ананы.* М.Садыйков

**Бәлтерәп бетү** Тәмам бәлтерәгән хәлгә килү. *Бәлтерәп беткән калтыравык Ираида Никифоровна «акча» дигәндә тернәкләнеп китте һәм аяк терәп карулашты.* А.Гыйләҗев. *Ак сакаллы Шәймәрдән бабамның [карчыгы да] --- үзе кебек үк бәлтерәп беткән.* А.Расих

**Бәлтерәп йөрү** Анда-монда, төрле җирдә, озак кагылып-сугылып йөрү; нәрсә эшләргә дә белми аптырау. *Хәзер дә Габделхәй перронда озак кына бәлтерәп йөрде дә станциядә туктамыйча, җилләнеп кенә узып киткән товарный вагоннарын санап басып торды.* Н.Фәттах. *Бу шимбәдә Ирек көне буе үзенә беркетелгән колхозда бәлтерәп йөреп, эт булып арып-алҗып, ачыгып кайткан иде.* Ф.Садриев

**Бәлтерәп тору** Бәлтерәгән хәлдә булу. *«Күпер» дигәннәренең «күпер» димәсәң хәтере калыр: су өстенә резинка мендәр тезеп чыкканнар, бәлтерәп кенә тора.* М.Әмир. *Хирургларга әнә кешеләрнең эчен ярып, әллә нинди операцияләр ясарга туры килә. Мәлҗерәп төшеп, бәлтерәп торсалар, ни булыр иде?* М.Маликова

**Бәлтерәп төшү** 1) Кинәт бәлтерәү

2) *күч.* Куркудан коелып төшү. *Бүре күргән сарык бәрәне шикелле бәлтерәп төшсә, ышаныч юк моңа.* В.Имамов

**Бәлтерәп утыру** Әле, хәзерге вакытта бәлтерәгән хәлдә булу. *Йокламый иде Алмабикә. Мең төрле уйның кайсын тотарга белми бәлтерәп утыра иде.* С.Поварисов

**БӘ́ЛФАРАЗ** *кер. сүз гар. иск.* Уйлап караганда, мисал итеп алганда. *Бәлфараз, бу хәзрәт безне ни өчен чакыртты икән?* Т.Гыйззәт

**БӘЛШӘЮ** *ф. сөйл. к.* **бәлешләнү**. *[Үпкәсе көчәйгән] Луизаның турсайган иреннәре бәлшәйде.* А.Гыйләҗев

**Бәлшәеп бетү** Тәмам, бик нык бәлшәю. *Хәмәтдин карт кырык җирдән тишелгән, бәлшәеп беткән киез эшләпәсен салып, аны, шуның белән киңәшләшеп алгандай, учында кат-кат йомарлады.* С.Поварисов

**Бәлшәеп калу** Нинидер сәбәп белән яки вакыттан соң бәлшәйгән хәлгә килү. *Бәлеш ашарга яраткан авыз бәлшәеп калучан була, ди.* Н.Исәнбәт

**Бәлшәеп килү** Аз-азлап, акрынлап бәлшәю

**Бәлшәеп тору** Әле, хәзерге вакытта бәлшәйгән хәлдә булу

**Бәлшәя бару** Торган саен ныграк бәлшәю

**Бәлшәя бирү** Бәлшәюен дәвам итү

**Бәлшәя төшү** Тагын да бәлшәю

**БӘН** *а. иск.* Мин. *Әйдәдем гарзы мәхәббәт бән сәңа, и милләтем.* Г.Тукай

**БӘНДӘ** *и. фар.* 1) Кеше. *Бәндәгә ниләр язган, шуны татыр, Бу адәм дә тәкъдиреннән башка булмас.* Акмулла. *Бу атлы – теге вакытта Хәлим белән Майяны авылга алып кайткан изге бәндә иде.* Г.Гыйльманов. *Бәндә якты дөньяга аяк басар-басмас ук бозып язылган документ аны үлгәнче, ягъни каберенә, зиратка кадәр озата килә, дидек.* Р.Әмирхан

2) Буйсынган кеше. *Бәндәгә бәндә булганчы, Аллага бәндә бул.* Мәкаль. *Ходай Тәгаләгә мең рәхмәтләр инде, без бәндәләренә шушындый асыл урын яратып биргәненә.* З.Зәйнуллин

3) *кимс.* Начар, ихтыярсыз, булдыксыз кеше. *Чын күңелең, ихлас җаның белән, ул мәнсез бәндәләрне кичер.* Г.Гыйльманов. *Өйрәтте ул безне кыюлыкка, Бәндә түгел, адәм булырга.* Х.Туфан

**БӘНДӘЧЕЛ** *с.* Кешелекле. *Ул сөйләшергә бик тә ярата, ифрат түбәнчелекле, ярдәмчел, бәндәчел инсан.* Казан утлары

**БӘНДӘЧЕЛЕК** *и.* Кешегә хас кимчелекле сыйфатлар. *Бәндәчелек инде, андый эшләр генә була ул. Тәүбә кылгач, бетәр.* Г.Камал. *Соңрак, фәлсәфи нигез арткарак күчеп, реальлеккә омтылыш, бәндәчелек, җир акылы, яшәеш мотивлары өстенлек алгандыр кебек.* Ф.Әмәк

**БӘ́П-** *кис.* «Б» авазына башланган «бәләкәй» сыйфатына ялганып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Бәп-бәләкәй генә булып калган ул [Әнвәр].* Х.Камалов. *Шом – ул тәннең аңсыз уе. Нишлисең бит, уйлана – Бәп-бәләкәй Үлем кергән җан яшәгән ояга.* Р.Харис

**БӘПЕЛДӘ́Ү** *ф.* Пипелдәү. *[Канәгать] Тәрәзә аша елгасыз-сусыз, тар ишегалдында үлән чеметеп бәпелдәгән каз бәпкәләренең тавышын ишеткәч, айнып киткәндәй булды.* А.Хәлим

**Бәпелдәп кую** Бер тапкыр бәпелдәү

**Бәпелдәп тору** Бертуктаусыз бәпелдәү

**БӘПКӘ** I *и* **1.** 1) Су кошларының (каз, үрдәк) баласы. *Баш очында – Идел буе казының, кыйгылдап-кыйгылдап, җәйләр буе җыеп, киләсе елга йомыркасын җылытып, бәпкәләрне суыктан сакларга әзерләгән ак мамыгы.* Г.Исхакый. *Әле казлар гына күренми, алар, үзләренең бәпкәләрен чыгарырга, ояларында утыралар...* Ф.Садриев. *Монда без – ялантәпиле балалар – яшел чирәм белән капланган Өчбүлә елгасы буенда каз бәпкәләре карап үстек.* Ә.Бәйрәмов. *Бүген төш күреп уяндым. Имеш, мин су буенда каз бәпкәләре саклап йөрим. Бәпкәләрне суга төшерергә кирәк.* Ф.Яруллин

2) **бәпкәм (бәпчегем)** *ирк.* Олы кешенең яшьләргә, кечкенәләргә иркәләп эндәшү сүзе. *Бәпкәм, акыртын! Кияү мулладан оял!* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* Бер яше тулып җитмәгән (каз, үрдәк турында). *Бәпкә каз*

**БӘПКӘ** II *и.* Яшь үсенте. *Яңгырдан соң ачылалар Яшь бәпкәләр.* Ә.Ерикәй

**БӘПКӘ** III *и. рус. махс.* 1) Тугызы – башлары белән эчкә таба салынып, унынчысы аларның өстенә утыртылган көлтә өеме. *Бригадир Мәрьямниса: «Борыныңа җиткән корсагың белән урак уруы кыендыр, бәпкәләргә тезеп торсаң да бик җиткән!» – диде.* К.Кәрим. *Ул, җигүле ат белән, бәпкәдәге көлтәләрне эскерткә ташый.* Н.Булатов. *[Сара:] Тилгән тавы кырында көлтә бәйли идек. Төшлеккә туктап, бәпкә төпләренә хәл алырга яттык.* Ә.Гаффар

2) Көлтә кую ысулы. *Ул кичкә кадәр биш көлтә урып, дүрт көлтәне җиргә утыртып, бишенчесен башы белән өскә каплап бәпкә ясап, үзенә бер өем куйды.* М.Гали

**БӘПКӘ** IV *и. рус махс.* Өй түбәсен ябу өчен, кара-каршы итеп, ярым ятма рәвештә куелган ике агач. *Күз алдында кыелып кына очып кереп, туган абзарың бәпкәләренә оя корган карлыгач канатларын, әрекмән яфракларын тикшереп утыр инде шунда!* А.Хәлим

**БӘПКӘ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Роза чәчәкләләр семьялыгыннан, җиргә түшәлеп үскән озын сабаклы, вак катлаулы яфраклы үлән үсемлек; кош икмәге; *русчасы:* **травка-муравка**, **птичья гречиха.** *Бәпкә үләне белән капланган урамны әллә нинди төсләргә манып, күктән нур сибелә...* Т.Таһиров. *Тыгыз бөреләре шартлап, агачлар яфрак ярды, капка төбендә, яшел хәтфә булып, бәпкә үләне шытып чыкты.* Р.Хәбибуллина

**БӘПКӘ́-ЧЕБЕШ** *и.* Каз, тавык һ.б.ш. йорт кошларының балалары. *Бәбкә-чебеш болай да читенсенми, таный, ярата.* Ә.Баян

**БӘПЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Баланы көйләп, аркасыннан йомшак кына кагып йоклату. *Талгын музыка, бәпләп йоклаткандай, һаман урынга сеңдерә, кайдадыр кемнәрнеңдер матур тормышын сурәтләгән кәртинәләр аңын томалагандай була.* Ф.Латыйпов. *Нәнә тамак кырып куйды һәм, алай да җавап ала алмагач, Гөлйөземнең аркасыннан бәпләп, сөйләнә-сөйләнә, үзенчә уятырга керешә.* Ф.Латыйпов

**БӘПЧЕК** *и.* Бәбәк, бөре яралгысы. *Су буендагы тал бәпчекләренең баллы исләре [картның] борынын кытыклагандай тоелды.* Г.Бәширов

**БӘПЧЕ́К БАЛТЫРГАНЫ** *и. бот.* Чатырчәчәкләләр семьялыгыннан, терлек азыгы буларак та, медицинада да кулланыла торган, җимешләре эфир майларына бай булган эре яфраклы, биек үсемлек; балтырганның бер төре; *русчасы:* **борщевик сибирский**. *Бу урыннарда бәпчек балтырганы да үсә*

**БӘРАБӘР** *с. фар.* **1.** Бердәй дәрәҗәдәге, тиң булган, лаек. *Үзенә бәрабәр ана арыслан белән юлдаш булып, сахрада кунды.* Дастан. *Фроловка бәрабәр замполит булу җиңел түгел иде.* Х.Камалов. *Болар белән бәрабәр: «Мөхәррирләр вә каләм», «Аллы гыйшкына» дигән кебек һәр җәһәтләреннән зәгыйфь шигырьләр дә ара-тирә очраштыргалыйдыр.* С.Исәнбаев

**2.** *рәв. мәгъ.* Бердәй, тиң. *Ә бит, чыдамлык белән сабырлык – фатихага бәрабәр, дигән китап.* М.Хәсәнов

**3. бәрабәренә** *бәйл. функ.* Хакына, исәбенә. *Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан, дөньядагы афәтләрнең берсен – фашизмны җиңеп чыктык.* А.Гыйләҗев. *Ул акчаны чечен егетләре ирektән мәхрүм булу бәрабәренә табалар.* Р.Мирхәйдәров. *Нәрсә өчен кеше шулчаклы канга батып җәфа чигә? Ни бәрабәренә? Туган җире өчен генәме?* Х.Камалов. *Ул мине әнә ничек түзеп тора, шуңа бәрабәр дигәндәй, мин дә түзәргә һәм сер бирмәскә тиешмен.* Х.Камалов

**БӘ́РӘКАЛЛА(һ)** *ы. гар.* Мактау, гаҗәпләнү һәм сокклануны белдерә. *– Һай, бәрәкалла! Әйдәгез, хуш килдегез! – дип каршы алды ул кунакларны.* Ә.Еники. *Яхшы, Закир, бәрәкаллаһ, өйләнмәкче булган икәнсең.* Ф.Халиди. *Бәрәкалла, шактый ипле кеше булып чыктың бит әле син, шаех.* М.Хәбибуллин

**БӘРӘКӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Муллык, барлык, матди җитешлелек. – *Хәерле булсын, хәсрәтең зур иде, --- бурлы бия бу йортка җиңел аяк белән килде, бәрәкәт китерде, – диде.* Г.Ибраһимов. *Шушындадыр бу дөньяның Бәрәкәтләр ятар җире.* Х.Әюп

2) Файда, уңыш, табыш. *Әйт, Акыл, әйт соңгы сүзең: Хәрәкәтең – бәрәкәтме? Әллә инде... һәлакәтме?* Ә.Рәшит

3) Кадер, кадерлелек. *Өстәлдә бәрәңге суынды, бәрәкәте китте.* Ш.Бикчурин. *Хәрам нәфесне киңәйтә, бәрәкәтне ала.* Н.Гыйматдинова

**2. бә́рәкәт** *ы.* Кинәт килеп туган нык гаҗәпләнүне белдерә. *Бәрәкәт? Ни дигән сүзең бу, әни?* Р.Хәмид. *Бәрәкәт, Әхмәтҗан улым, син түгелме соң бу?!* Г.Галиев. *Бәрәкәт... Әллә китәсең дә инде?!* Т.Гарипова

**БӘРӘКӘТЛЕ** *с.* **1.** 1) Мул, озакка җитә торган. *Печән, ару азык саламнары көтелмәгән дәрәҗәдә бәрәкәтле булып чыкты.* Ф.Хөсни

2) Уңыш, файда китерә торган, игелекле. *Ә давыл артыннан килгән*

*бәрәкәтле яңгыр, тәүлек буена, бер әкренәеп, бер шәбәеп, туры гына яуды да яуды.* Ә.Еники. *– Туйлар елы килә, муллык елы, бәрәкәтле ел, – дип куаныштылар Күктау кешеләре.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик саклап, кадерен белеп. *Акчаны бәрәкәтле тоту*

2) Нәтиҗәле, файдалы. *Гүзәл булды, бәрәкәтле булды – Җил-давылсыз булды тормыш.* Ә.Гадел. *Өлкән буын артистларның драматургиягә килүе дә бәрәкәтле булды.* Р.Мирхәйдәров

**БӘРӘКӘТЛЕЛЕК** *и.* Муллык. *Коньякның хакына карап градусы артмый, бары тик тантанага затлылык, нәзакәтлелек, бәрәкәтлелек кенә өстәлә.* К.Кәримов

**БӘРӘКӘТСЕЗ** *с.* 1) Файдасыз; файда, уңыш китерми торган. *Илке-салкы йөреп җыкка калдык, Бәрәкәтсез булды бу нигез.* Г.Афзал. *Кармак белән балык тоту – бик бәрәкәтсез эш, дигән карарга килдем.* Ш.Камал

2) Тиз бетә торган. *Монда авыз тутырып ашарга ипи җитми, булганы да, саргылт күбек кебек, бәрәкәтсез иде.* М.Маликова

3) Эчтәлексез, мәгънәсез. *[Бу фильм] Хәрәкәтсез һәм бәрәкәтсез өзлексез бер лирика шунда.* Идел

**БӘРӘКӘТСЕЗЛЕК** *и.* Уңышсызлык. *Соңрак ул аңлар: бу бәрәкәтсезлекнең дә нигезе бар.* Р.Батулла

**БӘ́РӘКӘЧ** *ы. диал. к.* **бәрәкәт 2.** *– Бәрәкәч, мин сине күрмәдем дә бит, малай! – дидем, куркып.* Ш.Маннур

**БӘРӘН** *и.* **1.** Сарык яки кәҗә баласы. *Көтүдән калган бәрән бүрегә тап булыр.* Мәкаль. *Бәрәннәрнең үз әнкәләре дә, нәкъ безнең әни шикелле, бик тә бала җанлы.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бәрән йоныннан бәйләнгән, басылган, бәрән тиресеннән тегелгән. *Бәрән бүрекне артка чөеп, тыныч кына ипи ашап торучы эшче аны каш сикертеп кенә сәламләде.* А.Толстой. *Ул өстенә кара бәрән якалы озын сырма, аягына актан карайган киез итек кигән.* Х.Сарьян. *[Егетләрнең] Өсләрендә – бәрән эчле билле бишмәт, башларында – кама читле бүрек, муеннарында – ак шарф, кулларында – ак перчатка...* Ә.Еники

2) Бер яше тулмаган, яшь. *Бәрән сарык*

**БӘРӘ́Н ГӨЛЕ** *и. бот.* Көнбагыш ыругыннан, чәчәкләре һәм яфраклары кечкенә көнбагышка охшаган, бүлбесыман тамырлы (гадәттә, тәме белән шалканны хәтерләтә торган) күпьеллык үсемлек; җир грушасы; *русчасы:* **топинамбур.** *Бәрән гөле үстерү*

**БӘРӘНЛӘ́Ү** *ф.* Бәрән китерү (сарык, кәҗә турында). *Болар тагын дүртәрне бәрәнләп, кәҗәләр күбәеп киткәч, аларның барысын да сатармын да --- рәхәтләнеп торырмын [дип уйлаган].* Әкият. *Безнең кәҗә бәрәнләгән, Игез бәрән китергән.* Ф.Садриев. *[Нәсел сарыгы] Ел саен икене бәрәнли, үзенең җоны озын, нечкә.* З.Зәйнуллин

**БӘРӘҢГЕ** *и.* Паслёнчалар семьялыгыннан, калын сабаклы, катлаулы яфраклы, йолдызсыман вак чәчәкле, эре бүлбеле күпьеллык куак үсемлек. *Бәрәңге – ярты икмәк.* Мәкаль

2) Шул үсемлекнең крахмалга бай бүлбесе. *Бераз ит, бәрәңге тәмен тойды Хәлим.* Г.Гыйльманов

◊ **Бәрәңге ашау белән бер** Берәр эшне җиңелгә санау. **Бәрәңге ашаудан да җиңел** *к.* **бәрәңге ашау белән бер**. *Егерме биш атлы кеше өчен җәяүле җиде бәндәне җиңү – бәрәңге ашаудан да җиңел булачагы билгеле.* М.Галәү. **Бәрәңге баш** *гади с. кимс.* 1) Акылсыз; 2) Хәтерсез. *Солдат киемендәге тракторчы аның касыгына төртеп алды: – Бәрәңге баш син, Вакыйф абый! – диде.* Ә.Гаффар. **Бәрәңге корсак** *гади с. кимс.* Бәрәңге ашарга яратучы. **Бәрәңге суы** Сыек һәм туклыксыз бәрәңге шулпасы. *Их, иптәшләр, азмы изелдек, инде монда тагы изәләр – мәдрәсә тыгыз, сасы, юеш, мөгаллим – надан. Ашарга юк, булса – бәрәңге суы белән чи арыш икмәге!* Г.Ибраһимов

**БӘРӘҢГЕ ЙОМЫЧКАСЫ** *и. неол.* Түгәрәкләп, бик юка итеп турап, майда кыздырылган бәрәңге; чипсы. *Соңрак бәрәңге йомычкалары – чипсыларны капларга тутырып сата башлыйлар.* Кызыклар дөньясында

**БӘРӘҢГЕЛӘ́НҮ** *ф.* Бәрәңге бүлбеләре яралу, үсемлек тамырына бәрәңге төшү

**Бәрәңгеләнә төшү** Бераз бәрәңгеләр барлыкка килү

**Бәрәңгеләнеп килү** Бәрәңгеләнә башлау

**БӘРӘҢГЕЛЕ** *с.* Бәрәңге салынган, бәрәңге белән пешерелгән. *Сабира җиңги суган исе бөркеп торган бәрәңгеле ит китереп куйды.* Х.Сарьян

**БӘРӘЧ** *ы.* 1) Сарык чакыру өчен кулланыла. *Капкадан чыккач, үзен тынычландырырга теләпме, әллә үзенең монда икәнлеген белдерепме: «Бәрәчкәй, бәрәчкәй...» – дип, берничә тапкыр кычкырган булды [Мәгъфия].* Р.Ханнанов

2) **бә́рәч** Гаҗәпләнүне белдерә. *Бәрәч, Габдрахманныкы булмый, кемнеке буласың соң син?* Р.Сибат. *– Бәрәч, син тагы кая бармакчы буласың? – дип сорады.* Г.Әпсәләмов. *Бәрәч, күрми торам – адаш абзый да монда икән.* Р.Хәмид. *Бәрәч, мин әллә тема сатып йөрүчеме?* Таныш өянкеләр

**БӘ́Р-БӘР** *ы.* **1**. Сарыкны чакыру сүзе

**2**. *и. мәгъ.* Балалар телендә: сарык

**БӘРГӘЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. кбт. дәрәҗ. к.* **бәрү** (*1 мәгъ.*)

2) Кул-аякларын бәрә-бәрә тыпырчыну // Кая барырга, нәрсә эшләргә белмәү. *Ядрә бушлыкка очмады, үлем тоеп бәргәләнгән ябалакка тиде.* Н.Гыйматдинова

3) Ярсу, өзгәләнү. *Бәгыремдә өннәр бәргәләнә, дөрес яңгырамый кайтаваз.* З.Мансуров. *Лигачев ишеләр, эшлексез Ивашкалар һаман тырпылдый, бәргәләнә.* А.Гыйләҗев. *Мин генәме бәргәләнәм, Мин генәме әзләнәм; Мин генәме, мин генәме – аягүрә тезләнәм...* Л.Лерон

**Бәргәләнә башлау** Бәргәләнергә тотыну. *Каны белән бергә җаны да күкрәк читлегендә бәргәләнә башлады.* Ф.Бәйрәмова

**Бәргәләнә тору** Бертуктаусыз, озак вакыт дәвамында бәргәләнү. *Бәргәләнә торгач, анда-монда сугылып тәмам сөмсере коелган Нәҗип мебель кибетенә грузчик булып эшкә керде.* А.Гыйләҗев

**Бәргәләнеп алу** Кыска вакыт эчендә, бераз бәргәләнү. *Ә бу хәбәрне ишеткәч, бугазын чалып җибәргән мал*

*кебек тыпырчынып, бәргәләнеп алды да хәлсезләнеп калды.* Х.Сарьян. *Вахит турындагы уйлануларым өмет белән шик-шөбһә арасында бәргәләнеп алган иде.* М.Галиев

**Бәргәләнеп бетү** Тәмам бәргәләнү, бәргәләнү дәрәҗәсенә җитү. *Хат-хәбәр көтәрсең син. Бәргәләнеп бетәрсең син, Тәгәрәп китәрсең син!* Р.Закиров

**Бәргәләнеп йөрү** Озак, дәвамлы рәвештә бәргәләнү. *Хәлимнең уйлары яшен тизлегендә бәргәләнеп йөрде.* Г.Гыйльманов. *Бер Рәмзия генә түзәргә тиеш тә, бер ул гына ике арада бәргәләнеп йөрергә мәҗбүр булып чыга...* Г.Гыйльманов

**Бәргәләнеп кую** Кинәт, аз гына бәргәләнү. *Менә озын кара керфекләр дерелдәп куйдылар, кыз тирән итеп сулыш алды, башын икенче якка борып, ыңгырашып, бәргәләнеп куйды.* Х.Ширман

**Бәргәләнеп тору** Әле, сөйләү моментында бәргәләнү. *Тагын берничә мизгел төш белән өн арасында бәргәләнеп торды да фани дөньяга --- кайтты.* Г.Гыйльманов

**Бәргәләнеп чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында, шул вакытның башыннан ахырына кадәр бәргәләнү. *Тән белән җан төне буе бәргәләнеп чыктылар.* А.Гыйләҗев

**Бәргәләнеп яту** *к.* **бәргәләнеп тору.** *«Һау-һау» кечкенә ачыклык уртасында тырпаеп утырган агач төбе янына сузылган да, башын селки-селки, шыңшыпчинап, бәргәләнеп ята.* Г.Гыйльманов

**БӘРГӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) *кбт. дәрәҗ. к.* **бәрү** (*1, 2 мәгъ.*)

2) Кыйнау

**Бәргәләп алу** Тиз арада яки җиңелчә генә бәргәләү. *– Үзебезгә дә җитми бит, – диде Илфир һәм, фуражкасын салып, баганага бәргәләп алды.* Р.Кәрами. *Рашат квартира мәсьәләсен Әхнәфнең ачуын китерергә, ызгыш-талаш чыгарырга, куркытырга, җае чыкса, бераз аны типкәләп, бәргәләп алу нияте белән генә кузгаткан иде.* Ф.Садриев

**Бәргәләп ату** Бик тиз арада каты кыйнау. *Нәрсә булганын аңлап өлгергәндә, малайларның берсе – бер, икенчесе икенче якта егылышып ята иде. Кире борылып килеп, Эдуард бәргәләп аткан икән.* Л.Гыйймадиева

**Бәргәләп бетерү** Каты гына төрткәләү, кыйнау, бәргәләү. *Кайбер баянчылар гастрольләр вакытында артыгын «кәефләнә», баянын бәргәләп бетерә, онытып калдыра, урлата.* Р.Батулла

**Бәргәләп йөрү** Әле, хәзерге вакытта төрле урыннарга бәргәләү. *Ике кулына ике чемодан тоткан Хуҗа тимер юл платформасындагы поезд вагоннарына башы белән бәргәләп йөри икән.* Ш.Маннапов

**Бәргәләп кую** Тиз генә бер-берсенә бәреп алу. *Хәтта шушы очышы вакытында --- аякларын, вак-вак кына итеп, бер-берсенә бәргәләп куярга да онытмады.* Р.Вәли

**Бәргәләп ташлау** Кинәт, каты итеп бәргәләү. *Күзләрен кан баскан берничә [фетнәче] мужик әбине бәргәләп ташладылар.* Г.Ибраһимов. *Ышан Шәйхигә! Ул зерә юкка да бәргәләп ташлый.* Г.Бәширов

**Бәргәләп тору** Әледән-әле, бертуктаусыз бәргәләү. *Кояш әле җылыта җылытуын, әмма теге җил гел бәргәләп тора: – Мин – төньяктан! Мин – төньяктан! – ди.* М.Мәһдиев. *Исхак кече капканы ачык калдырып чыгып киткән, яңгыр җиле капканы шапышопы бәргәләп тора иде.* А.Гыйләҗев

**Бәргәләп чыгу** Башыннан ахырына хәтле һәрберсен бәргәләү. *Өчебез өч яктан... Тотабыз да... Бәргәләп чыгарабыз!* И.Юзеев

**Бәргәләп яту** Әле, хәзерге вакытта бәргәләү

**Бәргәли башлау** Бәргәләргә тотыну. *Кара пантера калкулыкка тавышсыз гына йөгереп менде дә, тешләшеп тә тормыйча, Маугли тирәсендә иллеалтмыш рәт булып тезелеп утырган маймылларны уңга-сулга бәргәли башлады.* Р.Киплинг

**Бәргәли бирү** Бәргәләүне дәвам итү

**Бәргәли төшү** Тагы да бераз бәргәләү

**БӘРГӘЛӘШ** *и. сөйл.* Кыйнаш, йодрык сугышы. *Мин дә читтә кала алмадым, шул бәргәләшнең эченә кереп, уңга-сулга яңаклый башладым ---.* Г.Ибраһимов

**БӘРГӘЛӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **бәргәләү**

2) Йодрык белән бәрешү, төрткәләшү; сугышу. --- *күпер асларында, әвеннәрдә, печәнлекләрдә, очырмаларда кайнаша торгач, аяк бармакларың каный, балтыр итләрең, терсәкләрең суела, «җан дусларың» белән бәргәләшә торгач, иреннәрең ертыла, борыннан кан китә.* Г.Бәширов. *Торып, сикергәләп, үзара бәргәләшеп тә карадылар, ләкин, эчкә салкын үткәнлектән һәм аяк-куллар бик яман туңганлыктан, ул аларга бертөрле дә ярдәм итмәде.* М.Гали

**Бәргәләшә башлау** Бәргәләшергә тотыну. *Гадәтенчә, Идмас мәсьәләне йодрык белән чишмәкче булды. Алар бәргәләшә башлаганнар иде, бригадир килеп аерды.* А.Хәсәнов

**Бәргәләшә бирү** Бәргәләшүне дәвам итү

**Бәргәләшеп алу** Кыска вакыт эчендә яисә җиңелчә генә бәргәләшү. *Кайбер вакыт юк-бар өчен талашып китәбез. Бәргәләшеп алган чаклар да була.* Г.Ибраһимов. *Мөрәле малайлары, кесәләрен әйләндереп, бер төрерлек тәмәке эзлиләр, шул арада ду килеп бәргәләшеп алалар.* М.Мәһдиев

**Бәргәләшеп китү** Кинәт бәргәләшергә тотыну. *Юктан да ачу чыга, егетләр белән бәргәләшеп китәргә генә торам.* Ф.Яруллин

**Бәргәләшеп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз бәргәләшү

**Бәргәләшеп чыгу** Барысы белән дә бәргәләшү

**Бәргәләшеп яту** Әле, хәзерге вакытта бәргәләшү

**БӘРДЕ** *и. фин-угор зоол. к.* **бәртәс.** *Агым суда аҗау йөзәр, салкын суда бәрде йөзәр.* Мәкаль. *Икенче балыкны мин алдым. Ләкин кечкенә һәм иң кадерсез бер яман бәрде иде.* Г.Ибраһимов. *Елгаларында, күлендә – балык:, ул аҗау, ул шамбы, ул бәрде!* З.Зәйнуллин

**БӘРЕЛӘ́-СУГЫЛА** *рәв.* 1) Кат-кат, өсте-өстенә бәрелеп. --- *пенсия яшендәге авыр гәүдәле әби, коридордан барганда да, ике як стенага бәрелә-сугыла, алпан-тилпән, кыскасы, бик авыр атлый.* З.Хөснияр. *Тутый исә читлек*

*рәшәткәләренә бәрелә-сугыла чыркылдады да чыркылдады.* Г.Гыйльман

2) Ашыгып, кабаланып. – *Инә-әй! – Рәхимҗан, йокысыннан да айнып бетмәгән килеш, аягына зур галошлар элеп, бәрелә-сугыла, абзарга йөгерә.* А.Әхмәтгалиева

**БӘРЕЛЕШ** *и.* 1) Сугыш, көрәш. *Кариб диңгезе култыгының яр буйларын --- күрсәтеп, кайда нинди бәрелешләр булганын, күпме дошман үтерелгәнен сөйләп йөрделәр.* М.Маликова. *Ниһаять, без бөек бәрелешләрдә алар, яулап, безнең кулга тоттырган бөек бәхетнең, икмәкнең кадерен аңлау өчен дә үткәннәрне белергә тиеш.* Х.Сарьян. *Узган атнада шәһәрдәге җинаятьчел төркемнәр арасында янә канлы бәрелеш булды.* М.Маликова

2) Талаш, бәхәс. *Яшьлек белән яшьлекне чагыштыру кешеләр арасындагы бик күп бәрелешләрнең сәбәбен фаш итә.* К.Кәримов. *Инсаниятә әнә шул вакыттан бирле бәрелеш бара.* Р.Сибат. *Эштә вакытта да кешеләр белән бәрелешкә керү, аларны үзе әйткәнчә күндерү, сындыру аңа көч бирә.* Ф.Садриев

3) Авария. *Ослан тавындагы машиналар бәрелешенең – булырга тиеш һәлакәтнең – күптәннән уйланылган бер гамәл икәнен киллер-шофёр һәм тагын берничә кеше генә белә иде.* Т.Галиуллин

**БӘРЕЛЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн.* Ике яки аннан да күп нәрсәләр бер-берсе белән бәрелү, тиешү. *Тегеләр янына барганда, бизгәк тоткан кеби, тешләрем берсенә берсе бәрелешеп сөйләшәләр иде.* Г.Исхакый. *Машиналар бәрелешү*

2) Кыйнашу; көрәшү; сугышу. *Үрмәкүч белән чебен бәрелешкәндә, көрәш ничек тыгыз, киеренке булса, монда да шулайрак иде.* Таныш өянкеләр

3) Бәхәсләшү, ызгышу, талашу

**Бәрелешеп алу** Кыска вакыт аралыгында яки җиңелчә генә бәрелешү. *Ул иртән әнисе белән бәрелешеп алды, укырга кермим, тизрәк эшкә урнашам, ди.* М.Юныс

**Бәрелешеп бетү** 1) Әледән-әле я берничә тапкыр бәрелешү

2) Бик каты бәрелешү

**Бәрелешеп килү** Билгеле бер вакыт дәвамында, эзлекле рәвештә, һаман саен бәрелешү

**Бәрелешеп тору** Даими рәвештә, әледән-әле бәрелешү. *Хәзәр иле һәм Болгарстан икесе дә Бөек Идел юлында урнашкан, һәм аларның мәнфәгатьләре һәрвакыт бәрелешеп торган.* Р.Хәкимов

**БӘРЕЛҮ** *ф.* **1.** 1) Берәр нәрсәгә көч белән килеп сугылу, орыну. *Мескен кошчык бәрелде, харап булды, дип торганда гына, тургай канатларын җәеп җибәрде дә солы арасына әкрен генә килеп төште.* И.Гази. – *Диңгездә йөзгәндә тормышны шулкадәр ачык, җаваплы итеп тоясың, ул синең һәр күзәнәгеңә бәрелеп үтеп торган шикелле, – дидем мин.* М.Юныс. *Әмма егетнең башы нык бәрелгән.* Г.Гыйльманов

2) Сизү органнарына кискен тәэсир итү. *Котелогыннан Бу күтәрелә, Борычлы ашның Исе бәрелә.* Ф.Кәрим. *Биткә пешереп ала торган һава дулкыны, ком, балчык бураны бәрелде.* Ш.Рәкыйпов. *Корт чаккандай башын борып, читкә сикергәндә, аның борынына таныш ис бәрелеп калды.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Ачулану, авыр сүз әйтү. *Ләкин аңа каты бәрелүдән курка, ничек тә кәефен бозмаска тырыша.* Ә.Еники. *Әбисенең аңа болай каты бәрелгәне юк иде әле.* М.Әмирханов

4) *күч.* Күңелгә авыр тәэсир итү. *Бу тавышлар Габдулланың тагын бәгыренә бәрелеп, аның тагын кызгану хисен уятты.* Г.Исхакый

**2.** *и. мәгъ. к.* **бәрелеш.** *Бәрелүне оештыр, һәм, кешеләр аңына килгәнче, ычкын, диде.* Т.Галиуллин. *[Табындагыларның] Сүз елгасы самолётларның егылуы, поездларның бәрелүе, газларның шартлавы, җирләрнең тетрәве кебек утрауларга кагылып узды.* Ф.Садриев

**3. бәрелеп** *рәв. мәгъ.* Күкрәккә-күкрәк, кара-каршы. *Менә алар, ике көндәш, бер-берсенә бәрелеп үк басып торалар.* Н.Гыйматдинова

**Бәрелә төшү** Бераз, җиңелчә бәрелү

**Бәрелә язу** Чак кына бәрелми калу. *Рәфис, икенче бүлмәнең тәмәке төпчекләре дә себерелмәгән ишеге төбендә, өйдән чыгып килүче, ябыгып, коры сөяккә калган, Хәдиснең хатыны Нәсимәгә бәрелә язды.* А.Вергазов

**Бәрелеп алу** Тиз генә, бик кыска вакыт эчендә бәрелү. *Тәрәз рамнарының шак итеп бәрелеп алуы, идән сайгакларының шыгырдап куюлары гына, бүлмәдә кемдер йөри, дигән шик тудыра.* Д.Гайнетдинова

**Бәрелеп бетү** Берничә җирдән яисә берничә тапкыр бәрелү

**Бәрелеп йөрү** Анда-монда бертуктаусыз бәрелү. *Киң күкрәкле, ялтырап торган соры йонлы зур дустыбызга әйләнде. Аның анда атылып, монда бәрелеп йөрүен күргәч, икебез дә сөендек.* Г.Мөхәммәтшин

**Бәрелеп китү** Нәрсәгә дә булса аз гына кинәт бәрелү, бәрелергә өлгерү. *Корылмага, гөрселдәп, боз бәрелеп киткәндә сискәнеп куябыз.* М.Юныс. *Рәфитнең борынына көлдә пешкән бәрәңге исе бәрелеп киткәндәй булды.* Р.Бәшәр

**Бәрелеп кую** Кинәт бәрелү. *Тәрәзә төбендәге сәрби куагы талгын җилдә тибрәлә, аксыл сары чәчәкләре пыялага бәрелеп куя.* Ф.Латыйпов

**Бәрелеп тору** 1) Бертуктаусыз, әледән-әле бәрелү. *Битемә җиңел генә җилләр бәрелеп торды.* Р.Фәизов. *Бөтенесе кара янган, бөтенесенең кулы бирчәйгән, һәрберсеннән чыршы сагызы исе бәрелеп тора.* М.Мәһдиев

2) Әле, хәзерге вакытта бәрелү. *Зәвыксызлык та күзгә бәрелеп тора.* Р.Мирхәйдәров. *Гүзәллеге, тазалыгы күзгә бәрелеп тора иде.* Н.Фәттах

**Бәрелеп узу** Узышлый бәрелү. *Берсе хәтта, ачыктан-ачык тупаслык белән, Таһирга бәрелеп узды.* М.Кәбиров. *Кемнәргәдер бәрелеп узды, кемнәрдер аны ачуланып калды.* А.Әхмәтгалиева

**Бәрелеп үтү** *к.* **бәрелеп узу**. *Әллә кайдан гына килеп чыккан дуамал җил агач башларына орылып, бәрелеп үтте.* Г.Сабитов

**БӘРМӘ** *с.* 1) Көч белән килеп бәрелә торган. *Кинәт бөтен өйгә гөлт итеп ут кабына, тәрәзә пыялалары чылтырап коела, яшьтинең чәчләре, кашлары, керфекләре көеп чыга, бите*

*пешә, үзен бәрмә дулкын өй ишеге аша өйалдына атып бәрә.* Г.Рәхим

2) *күч.* Һөҗүм итүдә төп роль уйнаган

**БӘРМӘНЧЕК** *и.* Иртә язда талда барлыкка килгән йомшак, йөнтәс чәчәк бөреләре; песи. *– Дәдәй, нигә бүтән агачларның да шундый песиләре юк соң? – Бәрмәнчек талда гына була ул...* А.Филиппов

**БӘРМӘНЧЕ́К АТНАСЫ** *и.* Христианнарда пасхадан бер атна алда үткәрелә торган дини бәйрәм (бу көнне тал ботаклары алып кайтып, алар белән өйдәге кешеләрне, мал-туарны исәнлек, бәхет, артым теләп бәргәлиләр); *русчасы:* **вербное воскресенье.** *Олы көнгә бер атна калган якшәмбене бездә «бәрмәнчек («верба» сүзеннән) бәйрәме», ә ике якшәмбе арасын «бәрмәнчек атнасы» диләр иде.* А.Филиппов

**БӘРМӘНЧЕ́К СУГУ** *и. диал.* Бәрмәнчек көнне яшьләр уеннары

**БӘРМӘЧТЕКИ́** *и. диал. к.* **бәрмәнчек.** *Бәрмәчтеки чыбыка, Олы көндә бирерсеңме миңа кызыл җомырка.* Такмак

**БӘРТӘС** *и. фин-угор зоол.* Карпсыманнар отрядыннан, төче сулыкларда яши торган, йөзгеч очлары кызгылт төстәге, ялтыравык тәңкәле балык; *русчасы:* **язь.** *Гадәттә, мурдага чуртан, алабуга, бәртәс, сыла балыклары керә.* Р.Сибат. *Көймәдән төшкән кеше көрән сыртлы сулакларга, кызыл канатлы бәртәсләргә кәефләнеп карап торды ---.* Ә.Гаффар. *Дөрес, алар – бармак буе чуртаннар, нәни генә ялтыр бәртәсләр, олырак сәдәф кадәрле алтынсу кәрәкәләр генә әле.* Р.Сибат

**БӘРҮ** *ф.* **1.** 1) Аяк-кулны, башка әгъзаларны берәр нәрсәгә көч белән каты орындыру. *Кулны бәрү. Башны бәрү*

2) Сугу, суккалау; кыйнау; сугып салу. --- *Таһир, бер селтәнүдә, аны идәнгә бәрде.* М.Әмирханов // Керәштә оста алым кулланып егу, аркасына салу; җиңү. *[Николай белән Шәрәфи картның көрәшен карап торучылар:] – Бирешмә, Шәрәфи абзый! – Бәр таза гына!* Ш.Камал. *Куәт биреп торгангамы, Тубыктай батыр Карабаш батырны әйләндерде-әйләндерде дә, ниһаять, бәрде.* М.Хәбибуллин

3) Кеше агымында, кысанда алга үткәндә эткәләү, төрткәләү. *Сәгадәтне бәрделәр, суктылар, тагы артта калдырдылар.* Г.Исхакый

4) Кулга тотып, берәр тарафка ыргыту. *– Мә! – диде дә алдындагы өч-дүрт хатны [Габдулланың] битенә бәрде.* Г.Исхакый // Ташлау, юк итү

5) *сөйл.* Ату, атып төшерү; өстен чыгу; юк итү (хәрби хәрәкәтләр вакытында). *Арина, кара әле, безнең самолётлар тегеләрне бәрделәр.* Т.Гыйззәт // Корал кулланып егу, ату, атып төшерү (аучылыкта). *Бер бик матур куяшлы көнне иртә белән, ике урман тавыгы бәреп алганнан соң, мин урман авызына чыктым.* А.Шамов

6) Һава агымы белән килеп орыну, бөркелү (җылылык, ут һ.б.ш. турында). *Трактор тере җан ияседәй калтырана, аннан аркага җылы бәрә.* М.Маликова

7) Көчле аңку (ис турында)

8) Сәламәтлеккә зыян китерердәй итеп, көтмәгәндә тәэсир итү. *Хәлимгә ток бәргән кебек булды.* Г.Гыйльманов

9) *күч.* Берәр органның авыртуы икенчесенең эшчәнлегенә тәэсир итү, икенчесенә күчү. *Берсенең авыртуы аякка бәрә – атлап булмый кайсыбер көннәрне.* З.Зәйнуллин. *Аның күзләре әчетә, колагы шаулый, сулык-сулык, башына кан бәрә.* Р.Кәрами. *Ангина – бик начар авыру, ул йөрәккә дә, бөергә дә бәрә.* Р.Хәбибуллина

10) *күч.* Тәэсир итү, йогынты ясау (исерткеч эчемлекләр турында). *Әче бал пары бәрдеме --- караңгы төшкәч, Заһидулла лапас артындагы тирескә ятып елады.* Р.Сибат. *Коньяк башларына бәрде.* М.Әмирханов. *– Һәй! – диде Туктар, чүпрә суыннан тәмам кәефкә чумып. – Бәрмәгән кая ул.* Х.Ибраһим

11) *күч.* Кинәт, көтмәгәндә көчле башлану (табигать күренешләре турында). *Кинәт бәрде ямьле-тәмле, рәхәтле-ләззәтле, хәтта аңгырайтырдай яңгыр.* Р.Сибат

12) *күч.* Каты бөртекләр белән кискен сугып яву. *Тоз сыман каты, эре бөртекле кар яңгыры, шапылдап-шапылдап, берөзлексез киез түбәгә бәрде, бит-аркага бәрде, ат сыртларын камчылады.* Н.Фәттах. *Тәрәзәгә шыкшык бәреп, көзге яңгыр ява иде.* Н.Гыйматдинова

13) *күч.* Кискен кагып-этәреп җибәрү. *Дулкыннар, гөрс-гөрс килеп, ташларга китереп бәрәләр дә кире чигенәләр.* М.Әмирханов. *Идел үзенең йомшак дулкыннарын бетонга төренгән яссы ярга чәпелдәтеп бәрә дә бәрә.* Р.Кәрами

14) *күч.* Астан өскә көчле агым, ташкын булып агып чыгу // Көтмәгәндә саркып үтеп керү, бүленеп чыгу. *Маңгайга салкын тир бәрү*

15) *күч. сөйл.* Һөҗүм итү. --- *немец оборонаны өч катлы итеп төзегән булса кирәк, һөҗүм җиңел булмаячак. Әгәр дә менә коры үзәннән килеп бәрсәк ---.* Х.Камалов

16) *күч.* Каты, турыдан, яшермичә әйтү, сөйләү. *Мондый [үземә ошамаган] мәсьәләдә минем дуслык-танышлык юк. Мин турыдан бәрәм.* А.Шамов. *Кешенең чыраена бәреп, син – шымчы дип әйтеп буламыни?* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Каты, кискен; тупас рәвештә. *Шул арада, казарма ишеген бәреп, Насрый чыкты.* Ш.Камал

2) Кискен, интенсив, көчле агым булып. *Бу кеше, ишек ачылу белән тыштан бәреп кергән суыкның басылганын көтеп, бераз бер урында басып торды да табын тирәсендә утыручыларга карап сәлам бирде.* М.Гали

3) *күч.* Яшермичә, турыдан-туры. *Дасаев берсендә тыелып кала алмады: «Мартук Мәскәү түгел әле», – дип, бәреп әйтте.* Р.Мирхәйдәров. *Хәзер син барысына күз йомасың, ә соңыннан бәреп әйтәчәксең.* Г.Әпсәләмов

◊ **Бәреп егу** 1) Урыныннан алу, эш башыннан төшерү. *Бөтен Путилов заводы эшчеләре Керенскийны бүген яисә иртәгә бәреп егарга торалар.* Ш.Камал; 2) Күпкә яхшырак, өстенрәк, шәбрәк булу. *Әле хәзер дә ул [җырга оста карчык] кайбер артисткаларны бәреп ега.* Ш.Хөсәенов. **Бәреп үтерү (үтередәй булу)** *тирг.* Бик каты ачуланганда, куркытып, янап әйтелә торган сүз. *Йә икебез дә армиягә язылабыз,*

*йә мин сине бәреп үтерәм, дидем.* Ф.Сафин

**Бәреп алу** 1) Җиңелчә бәрү, тидерү. *Аширов, хәрбиләрчә, үкчәләрен үкчәгә бәреп алды.* Ә.Мушинский. --- *ул үзенең авыр чүкече белән тимергә дүрт тапкыр суга да, чүкечен күтәрмичә генә, кулын ял иттереп, сандалын өч тапкыр бәреп ала.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Тиз арада, аз гына уйнап алу. *Әйдә, менә теләсәң, карта бәреп алабыз.* Ф.Әмирхан

**Бәреп җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә бәрү; читкә этәрү. *Әтинең: – Җебегән! – дип кычкыруы булды, сәнәк белән бәреп җибәрүе булды. Абый дөпелдәп ишегалдына килеп төште.* Г.Бәширов

**Бәреп керү** 1) Кискен рәвештә башланып китү, башлану, барлыкка килү. *Билгесез яңа дөнья кошчыкның җайлы, яшерен оясына ташкындай бәреп керде.* Н.Сладков

2) Көтмәгәндә һөҗүм итү. *Шуңа алар Чехословакиягә бәреп керде.* А.Гыйләҗев. *Биредәге тау сукмакларын биш бармагыдай яхшы белгән әфган мөҗәһитләре, күрәсең, кинәт кенә бәреп кергәннәр.* Р.Низами

**Бәреп тору** 1) Бертуктаусыз, өзлексез бәрү. *Вак ташларны уйнаклатып, чишмә бәреп тора.* К.Нәҗми. *Якорь берничә секунд, доң-доң китереп, бортка бәреп торды.* Ф.Шәфигуллин. *Бу матурлык сулмасын өчен, шул матурлыкның – халык матурлыгының чишмәләре бәреп торырга тиеш.* М.Хуҗин. *Анда – диңгез төбендә бик көчле чишмәләр бәреп тора икән.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Җил нык сизелү, беленү. *Егетнең йөзеннән, бөтен торышыннан үзенә шундый ныклы ышаныч, шундый килешмәүчән кискенлек бәреп тора иде.* Г.Бәширов

**Бәреп төшерү** Хакимият башында торучы(лар)ны, властьны алып ташлау. *Менә шушы катлау кешеләре теләсә кайсы хакимиятне бәреп төшерергә сигнал гына көтә.* Р.Мирхәйдәров

**Бәреп чыгару** 1) Кирегә этү, тышка чыгарлык итеп бәрү. *Ниндидер каты токым бурны кирегә этәрә, бәреп чыгарырга теләгәндәй, сиртмәләндерә.* Ә.Айдар

2) *күч.* Куу. *Өч арада күзгә күренми торган пружина кысылган, әгәр урынсызга ялгыш сүз ычкындырсаң, шул пружина кунакны бәреп чыгарыр сыман.* К.Кәримов

**Бәреп чыгу** 1) Һәрберсенә, бер-бер артлы бәрү

2) Көтмәгәндә, көчле ташкын булып, астан – өскә, эчтән тышка бәрү. *Җир астыннан, бик еракатан бәреп чыккан кара фонтан.* Г.Афзал. *Баягыдан да көчлерәк һәм ачыграк яңа тавыш өйдән тышка бәреп чыкты.* М.Кәрим. *Аның күңеле тулды, чынлап та, күзләреннән берничә бөртек яшь бәреп чыкты.* Г.Гыйльманов

**Бәреп яту** Әле, хәзерге вакытта бәрү; билгеле бер вакыт дәвамында бәрү. *Анда тәгәрмәч төпләреннән, ягъни боз арасыннан, фонтан булып, су бәреп ята!* Э.Касыймов

**БӘ́РФАРАЗ** *кер. сүз гар.-фар. к.* **бәрфәраз.** *Разбуйник булмасаң син, мәсәлән, мөселман белән урысча да сөйләшеп ятмас идең, бәрфараз.* Ф.Әмирхан

**БӘ́РФӘРАЗ** *кер. сүз гар.-фар.* Ягъни, мәсәлән, уйлап караганда, фараз итсәк. *Мөселман булмагач, бәрфәраз, һәммәсе урыс инде, барыбер.* Ф.Әмирхан. *Тимуш агай, бәрфәраз, закон чыгып, безгә авылга кайтырга рөхсәт булса, син чынлап та баесаң, син миңа бер мең сум биреп торырсыңмы?* К.Тинчурин

**БӘРХЕТ** *и. гар.* **1.** Уң ягы йомшак, куе төкле ефәк яки киҗе мамык тукыма. *Ялтыравык кара буяу белән буялган, кызыл бәрхет белән тышланган утыргычлар.* М.Юныс. *Матбугатта габардин, коверкот, бостон, шевиот, драп, бәрхет ише чын табигый тукымаларны китте яманлау, китте яманлау!* Р.Мирхәйдәров

**2**. *с мәгъ.* 1) Бәрхеттән эшләнгән, тегелгән. *Озын гына буйлы җырчы хатын – үкчәләренә үк төшеп торган, чия төсендәге бәрхет күлмәктән.* Р.Мирхәйдәров

2) *күч.* Йомшак; ягымлы. *Ал бәрхет ирене Аз гына суланган.* М.Җәлил. *Юан, куе, бәрхет тавышлы иде ул [Мохтар Мутин].* Р.Батулла. *Күмер исе таралган зәңгәрсу класс бүлмәсендә Мәскәү татарының көчле бәрхет тавышы яңгырап-яңгырап китә...* М.Мәһдиев. *Айзат уйнаган көйгә бераздан аның бәрхет тавышы килеп кушылды.* Р.Вәлиев

3) *күч. шигъ.* Матур. *Гомер язы – бәрхет яшьлек!* Р.Фәйзуллин

◊ **Бәрхет инкыйлаб** Короллы көчләр кулланмыйча гына хакимиятне алмаштыру. *Нәтиҗәдә ил болганды һәм тулганды. Тагын бер селкенеп алу – 1991 елгы канкоешсыз бәрхет инкыйлаб кирәк булды.* Татарстан

**БӘРХЕ́Т АГАЧЫ** *и. бот.* Рутачалар семьялыгыннан, үзенә хас исе булган каурыйсыман яфраклы, вак чәчәкле, җимешләре каты төшле кара төстә, кайрысы калын бөке катламыннан торган агач; *русчасы*: **бархат, бархатное дерево.** *Монда субтропик урманнарның лианалары, бәрхет агачы (амур бәрхете) һәм башка көньяк үсемлекләре, себер чыршылары һәм карагайлары белән, барысы бергә үрелеп һәм аралашып беткән* ---. География. Россиянең табигате

**БӘРХЕ́Т ГӨЛ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, үзенчәлекле исле, кызгылт сары чәчәкле, куак сыман тармакланып үсә торган бакча гөле; *русчасы:* **бархатец**. *Әнә цехның бетон тартманы хәтерләткән яңа бинасы каршындагы түтәлләрдә --- фәкать кашкарыйлар, кызгылт сары бәрхет гөлләр генә балкып утыра.* М.Маликова. *Колорадо коңгызы латин чәчәге, бәрхет гөл --- кебек үсемлекләрне яратмый.* Мәдәни җомга. *Кара аю баланы куагы, бәрхет гөл исе корткычларны куркыта.* Мәдәни җомга

**БӘРХЕТКАНАТЛЫЛАР** *и. зоол.* 2000 нән артык төрне берләштергән, күбесенең канатларында аксыл таплары булган, вак һәм уртача зурлыктагы күбәләкләр семьялыгы; *русчасы:* **бархатницы**

**БӘРХЕ́Т(ЛЕ́) СЕЗОН** *и.* 1) Көньякта ял итү өчен тыныч айлар (август, сентябрь, октябрь)

2) Иң кулай, отышлы вакыт. – *Бәрхетле сезон, – дип чәнчеп алды Кащеев.* А.Мифтахетдинов

**БӘС** I *и.* 1) Җир өслеге $0^0$ С ка кадәр суынганда, төн аяз һәм җилсез булып,

җирдән җылы пар бәреп торганда, туфракта, үләннәрдә һ.б.ш. әйберләр өстендә барлыкка килә торган боз кристалларының калын булмаган катламы. *Төнлә белән өй түбәләренә, капка башларына – бөтен җиргә җем-җем иткән ап-ак кырау төшә, агачларга бәс бәйләнә.* Г.Бәширов. *Бәс бозлары эрегән электр чыбыклары гүләүдән тынып калды.* Р.Мирхәйдәров. *Җиләкле аланнарны бәс сарды.* К.Кәримов. *Юньләп якмаганга, бүлмә һәрвакыт салкын була, ә бер почмакны бәс сара иде.* Мирас

2) Һавада җиңелчә томан булып күренгән сыкы бөртекләре. *Күктә йөзәдер Бәс белән томан.* Дәрдемәнд

3) *күч. кит.* Чал; көмеш. *Аның каракучкыл йөзенә, җыйнак кына җибәрелгән мыегына, ак бәс куна башлаган чәчләренә, иң мөһиме, якты нур бөркеп торган чем-кара күзләренә карап, Әнизә тагын бер уйлап куйды.* Г.Гыйльманов. *Күгәрченнәрнең чәлтерләре, сабый чагындагы шикелле, зәңгәр камәрдән чигелгән, ә менә чыпчыкларның күзләре бәс төртке белән бизәлгән булырга тиеш.* А.Хәлим

**БӘС** II *кер. сүз фар. иск.* Димәк, шулай булгач. *Бәс, шулай булгач, яшел эшләпәңне батырыбрак ки дә, алдыңа карап кына, үз юлың белән йөри бир!* Ә.Еники. *Бәс, бу өч дус кызышып-кызышып сөйләшмәктә иделәр.* М.Акъегет. *Бәс, шулай булгач, изге китапларда бәян ителгән кануннар да камил түгелләр.* Ш.Абдуллин

**БӘС** III *и. сөйл. к.* **бәз**. *Мин аның кызыл бәс тышлы тунын, озын гәүдәсен ерактан ук күрдем.* Г.Бәширов

**БӘСӘРӘЮ** *ф.* 1) Өстендә ак кунык барлыкка килеп искерү. *Бәсәрәеп каткан сохарый, Мунчала чәйнәп тора.* Г.Афзал

2) *к.* **бәсләнү**

3) *күч.* Күп тапкыр кабатлану, тапталу, актуальлеген югалту. *Бәсәрәйгән фразалар*

**Бәсәрәеп бетү** Бик нык бәсәрәю; тулысынча бәсәрәю. *Ул күптән утыра, ахрысы, бүреге, калын мыегы ап-ак булып бәсәрәеп беткән.* Ф.Садриев. *--- нинди эше бар аның? Кырын ятып, шул радиосын, нindидер бәсәрәеп беткән җыр язмаларын тыңлаудан башка.* А.Хәлим

**Бәсәрәя бару** Торган саен ныграк бәсәрәю

**БӘСӘРҮ** I *ф.* 1) *к.* **бәсләнү.** *Бәсәргән агачларны, ак наратларны, бүген тәмам гашыйк булган ак каеннарны кызгандылар бугай.* А.Гыйләҗев. *Йөзе күм-күк күгәргән, чәчләре тузган, күлмәге бәсәреп, шакыраеп каткан иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Каты чык төшүдән, ул баш бәсәргән, аксылланган сыман.* М.Пришвин

2) *күч.* Агару. *Тырнак төпләре канаганчы, чигә чәчләре бәсәргәнче, шайтан таяклары белән сугышыр.* А.Гыйләҗев

**Бәсәрә бару** Акрынлап бәсәрү, бәсәрүе артканнан-арту

**Бәсәрә башлау** Бәсәрергә керешү. *Син, чигәләре бәсәрә башлаган өметле яшь журналист, кунак кабул итә беләсеңме?* А.Гыйләҗев

**Бәсәрә төшү** Азрак бәсәргән булу; тагын да бәсәрү

**Бәсәреп бетү** Тәмам бәсәргән булу. *Ишектән өс-башы бәсәреп беткән Шакир Галимуллин керә.* Т.Миңнуллин

**Бәсәреп калу** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң бәсәргән хәлгә килү. *--- тешләре һаман ап-ак булып күренеп тора, керфекләре бәсәреп калган, ак керфекле кызга әверелгән.* Л.Гыйззәтуллина

**Бәсәреп китү** Бераз бәсәргән булу. *Әмма мондый рәхәткә мин күп түзмәдем, очып чыктым бәсәреп киткән чоланга, йөрәгемне ачулана-ачулана...* Р.Харис

**Бәсәреп тору** Бераз бәсәргән хәлдә булу, бәсәргән булып күренү

**Бәсәреп чыгу** Бәсәргән хәлгә килү. *Рашатның мыеклары, яка очлары, бүреге бәсәреп чыккан иде.* Ф.Садриев. *Монда бытбылдык түшкәләренең сүле агу түгел, фирмач Гыйльминең дегет төсле кара сакалы бәсәреп чыкты, ап-ак булды.* Р.Гаффар

**БӘСӘРҮ** II *ф.* Искереп, нык югары, тузу (тукыма һ.б.ш. турында). *Бер кат бәсәргән шпагат белән аннан-моннан типчелгән кыска кунычлы бу итек аларның һәркайсына бик яхшы таныш.* К.Нәҗми

**Бәсәрә бару** Акрынлап бәсәрү, бәсәрүе артканнан-арту

**Бәсәрә төшү** Азрак бәсәргән булу

**Бәсәреп бетү** Тәмам бәсәргән булу. *Һава бөркү булуга карамастан, ул кырпшылып, бәсәреп беткән иске плащтан иде.* З.Хәким

**Бәсәреп китү** Азрак бәсәрү

**Бәсәреп тору** Бераз бәсәргән хәлдә булу, бәсәргән булып күренү

**Бәсәреп яту** Озак вакытлар дәвамында кирәксез ятып бәсәргән булу. *Мәдрәсәдә унар ел бәсәреп ятып, күп ышкудан сүсәргән баудай булып калган ахмак шәкертләр шулай юньсез кылана.* С.Поварисов

**БӘСЛӘНҮ** *ф.* 1) Бәс куну, бәс сару, бәс белән каплану. *Саламның башы төнлә бәсләнсә, арыш яхшы булыр.* Сынамыш. *Үләннәр бәсләнгән, ә сукмак кырыенда яткан бер күл кырыйлары нечкә генә боз белән капланган иде.* В.Обручев. *Боларның баш, күзләре бәсләнгән, һәммә әгъзалары дерелди.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Агару, чал төшү

**Бәсләнә бару** Тагын да күбрәк бәсләнү, бәсләнүе артканнан-арту

**Бәсләнә башлау** Бәсләнергә керешү. *Миннән ике яшькә генә олы, чәчләр чигәдә генә бәсләнә башлаган.* Г.Афзал

**Бәсләнә төшү** Беркадәр бәсләнү; тагын да бәсләнү

**Бәсләнеп бетү** Тәмам бәскә төренү. *[Рәхим] Суыктан бәсләнеп беткән трамвайдан төште.* А.Расих. *Бичаракай тәмам бәсләнеп беткән, инде калтыраудан узган, үлеп бара иде.* Р.Гаффар

**Бәсләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта бәсләнгән хәлдә булу

**БӘСЛЕ** *с.* 1) Бәс сарган, өстенә бәс утырган. *Кояш җирнең эченнән яктыртып тора бугай – бәсле агачлар аның нурлары сыман.* Ә.Гаффар. *Бәсле куакларны кошлар сарган.* Ф.Мөслимова. *Менә син дә бәсле тәрәзәдән сыкылы урманга карап утырасың.* М.Рәфыйков

2) Бәсе булган, бәс катнашкан, шуның белән аралашкан. *Томанлы, бәсле тын гына декабрь иртәсе иде.* Таныш өянкеләр. *Бәсле кышка карап тора Яшьле күз.* Ф.Яруллин

**БӘ́ТӘЧ** *ы. гади с.* Нык гаҗәпләнү, шаккату хисләрен белдерә. *Бәтәч, син өйдәмени әле, Мәгъсүмә?* В.Нуруллин. *– Әюпов, син учак яга беләсеңме? – Бәтәч, коймада икән әтәч! Нишләп белмәскә, ди.* Н.Гыйматдинова

**БӘТИ** *и.* **1.** *к.* **бәрән** (**1.**) *Менә шунда инде бәтине кем ашаганлыгы беленер.* Ф.Яруллин. *Сыерлар, бозаулар, сарыклар, бәтиләр, ерагайган саен, ак томанга уралып, күздән югалалар.* А.Иванов. *Ирекнең бакчасыннан ерак түгел бер сарык, ике бәтиен ияртеп, үлән чемченә.* Ф.Садриев. *Аязның әтисе кәҗә бәтие сатып алды.* Н.Каштанов

**2.** *с. мәгъ.* Бәти йонынннан эшләнгән. *Ничә елдан соң, менә хәзер, иягенә таянып, берьялгызы ян бүлмәдә утырганда, бәти йонлы кәвеш эчендәге аягы сыкрап куйды, бите чәнчеште.* Ш.Рәкыйпов. *Тәти бүрек эләкмәде, бәти бүрекне мин яратмыйм.* Н.Исәнбәт

**БӘТИЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **бәрәнләү.** *Хәйрулла: «Бүген төнлә безнең сарык бәтиләде», – дип хәбәр бирсә дә, мин, артык әһәмият бирмичә, тыныч кына мәктәпкә киттем.* Ф.Әмирхан

**БӘ́Ү** *ы.* Гадәттә, бәбине көйләп йоклатканда кабатлап яки «бәүкәй», «бәллү» сүзләреннән соң әйтелә. *Кыйгач кашым, Асыл ташым! Йоклаек икәү, Йокла, иркә, Йокла бәпкә, Бәүкәй, бәлли-бәү!* Дәрдемәнд. *Бәпкәсе, бәү-бәүгә җыенып, Пар канат астына сыена. Син дә, кереп кочагыма, Йокла инде, газиз балам.* Ф.Каюмова

**БӘ́Ү ИТҮ** *ф.* 1) Бәбине көйләп тирбәтү. *Әлли-бәлли бәү итә, балам йокыга китә.* Җыр

2) Йоклау (көйләп тирбәтелүче бала турында). *Бәү-бәү итеп, күз йомып, Изрәп кенә китәр ул.* К.Әмири

**БӘҮКӘЙ** *ы.* Бәбине көйләп йоклатканда, «бәлли-бәү» сүзләре белән аралаштырып әйтелә. *Колынкаем, кил, җанкаем, Йоклаек икәү. Йокла, иркә, Йокла бәпкә, Бәүкәй, бәлли-бәү!* Дәрдемәнд

**БӘҮКИ** *ы. к.* **бәүкәй**

**БӘХӘС** *и. гар.* **1.** 1) Үзенең хаклыгын исбатлап сүз көрәштерүдән гыйбарәт низаг; дәгъва. *Фәнияр баштарак аның [Миша] белән бәхәскә керә, шигырь – шигырь генә түгел, иҗат – күңелнең канаты, кешене шул күтәрә, дип, иҗат итүнең газаплы ләззәтен аңлатырга теле иде.* Ф.Яруллин. *Ләкин гаилә бәхәсе шуның өчен «бәхәс» дип атала инде ул, анда, һичшиксез, хатын җиңеп чыга.* М.Мәһдиев. *Боз белән тоз бәхәсендә тоз эрегән... Егет белән кыз бәхәсендә кыз эрегән...* Ш.Галиев

2) Оттырган очракта, нәрсәне булса да үтәү, эшләү шарты белән ясалган килешү. *Шулай итеп, бабай, бәхәстә җиңеп, сыерны үзенә ала, ә мактанчык бай хур була.* Әкият. *Кайсыдыр бәхәсен оттырган, имеш!* Ә.Еники

**2. бәхәстән** *рәв. мәгъ.* Бәхәсләшеп, бәхәс итеп. *[Бәдри] Бәхәстән, җиде төн уртасында мәзин мунчасыннан таш алып чыгуын сөйләде.* И.Гази

**БӘХӘСЛӘШҮ** *ф.* **1.** 1) Берәр нәрсә турында үз фикереңне дәлилләп сүз көрәштерү; дәгъвалашу. *Алар әледән-әле бәхәсләшеп, үртәшеп алалар.* Ф.Садриев. *Гомумән, ул – аз сүзле кеше, тигез, тыныч холыклы, сүз көрәштерергә, шаулап бәхәсләшергә яратмый.* Ә.Еники. *Консенсус табыйк, бәхәсләшмик.* Р.Мөхәммәдиев. *Олылардан узып, күкрәк сугып Бәхәсләшмә, җиңмәк дәрт белән.* Э.Шәрифуллина

2) Оттырган очракта, нәрсә булса да эшләү шарты белән килешү төзү. *Бераздан, оттырышны кайтарырга теләп, Гадел тагын бәхәсләште һәм тагын оттырды.* Ш.Рәкыйпов. *Бер әрҗә коньякка бәхәсләшә алам.* Р.Мирхәйдәров

3) Нәрсә беләндер көрәшү, нәрсәгәдер каршы төшү. *Язмыш белән бәхәсләшеп, без үсә бардык.* М.Кәрим

**2.** *и. мәгъ. к.* **бәхәс.** *Бәхәсләшүнең мәгънәсе юк иде.* М.Әмирханов

**Бәхәсләшә башлау** Бәхәсләшергә тотыну. *Шулчак урамдагы малай-шалайлар бик каты бәхәсләшә башлады.* Р.Батулла

**Бәхәсләшә бирү** Бернигә карамыйча, бәхәсләшүне дәвам итү. *Колхозчылар, берсен-берсе уздырырга тырышып, узара бәхәсләшә бирде.* Р.Айзатуллин

**Бәхәсләшеп алу** Кыска вакыт эчендә, аз гына бәхәсләшү. *Дөрес, табында утырганда, алар кайчак бәхәсләшеп тә алалар.* К.Латыйп. *Шау-шулы укучылар төркеме тирә-яктагы табигатькә карап сокланырга да, ара-тирә бәхәсләшеп алырга да өлгерә иде.* М.Насыйбуллин. *Алар, кулларын болгап, нәрсәдер турында бәхәсләшеп алдылар.* Р.Зәйдулла

**Бәхәсләшеп бетү** Бик нык бәхәсләшү; бәхәсләшү дәрәҗәсенә җитү. *Үзебезгә репертуар туплаганда, Илнар, еш кына: «Нигә катлаулы җыр яздың? Моны кеше бер тыңлауда аңламый», – ди. Хәтта бәхәсләшеп бетәбез.* Акчарлак

**Бәхәсләшеп карау** Бәхәсләшергә омтылу. --- *бәхәсләшеп кара син Мочтакбай белән, гомерең буе ник туганыңа, нигә аның белән ядәч аерганыңа үкенеп бетә алмассың.* Р.Батулла

**Бәхәсләшеп китү** Уйламаганда, кинәт бәхәсләшә башлау. *Барысы да берьюлы диярлек кычкырып, бәхәсләшеп киттеләр.* Ш.Бикчурин. *Людмила Герасимовна белән бәхәсләшеп киттек. Ләкин аны ышандыра алмадым.* Ф.Яруллин

**Бәхәсләшеп тору** Әле, хәзерге вакытта бәхәсләшү. *Тикшерүче бәхәсләшеп тора алмый.* М.Насыйбуллин. *Кибетче бәхәсләшеп тормады...* Ә.Мушинский. *Яңадан туып, дигәндәй, эшли башлавына айлап вакыт үтмәгән килеш, «Әҗәл хәбәрчесе» белән көрешеп, бәхәсләшеп торырга әзер түгел иде әле ул.* К.Кәримов

**Бәхәсләшеп утыру** *к.* **бәхәсләшеп тору**. *Әллә оның-кызына җавап булды бу сүз, әллә председатель Сабир белән эчтән генә бәхәсләшеп утыра, Факиһәгә ул «мунча шулай кызу кирәк» булып аңлашылды.* Р.Батулла

**Бәхәсләшеп яту** *к.* **бәхәсләшеп тору.** *Одик белән Хак чөгә балыгы турында бәхәсләшеп яталар.* Р.Сибат

**БӘХӘСЛЕ** *с.* 1) Бәхәсләр белән үтә торган. *Әңгәмә бәхәсле булган саен кызыграк.* Ф.Әмирхан

2) Бәхәс чыгара торган, төгәл ачыкланмаган. *К.Тинчурин театры бу бәхәсле әсәргә яңадан әйләнеп кайтып, аны «Яңадан мәхәббәт турында» исеме белән сәхнәгә чыгаргач, фикерләр яңарды.* А.Әхмәдуллин. *Кыскасы,*

*мәгънәсе бик үк ачык булмаган бәхәсле җөмлә бу.* М.Маликова // Хуҗасы төгәл билгеле булмаган, дәгъвалы. *Бәхәсле территория*

**БӘХӘССЕЗ** *с.* **1.** 1) Бәхәсле булмаган, бәхәстән башка үтә торган

2) *күч.* Дөреслеген исбатларга кирәк булмаган, дөреслеге төгәл расланган. *Хакыйкатьнең бу кадәресе – бәхәссез.* А.Хәсәнов. *Ә инде мәҗлесләргә килгәндә... Ул – анда алыштыргысыз һәм бәхәссез тамада.* Т.Галиуллин. *«Туктале, шундый бәхәссез хакыйкать булгач, аны нигә тәкрарлап торырга?» – диярсез.* И.Низамов

**2.** *кер. сүз функ.* Һичшиксез. *Бәхәссез, XX гасыр башы татар әдәбиятының үсеш юнәлешен билгеләүчеләрнең берсе булган әлеге олы әдипнең мирасы --- дистәләгән язучыга таныш.* Ә.Закирҗанов. *Бәхәссез, ат шәп, Алмачуар кебек ат Болгарда бер иде, ат караучысы хаклы, әмма бу дөньяда аттан кадерлерәк әйберләр дә бар – тынычлык, дуслык, татулык.* М.Хәбибуллин

**3.** *хәб. функ.* Шик тудырмаслык, һичбер шөбһәсез. *Аның яшерелүе – бәхәссез.* М.Насыйбуллин. *Телебезнең авыр хәле – бәхәссез, киләчәге – шактый хәвефле, әкренләп югалу куркынычы да юк түгел, билгеле, моңа күз йому гафу ителмәслек сансызлык булыр иде.* Ә.Еники

**БӘХӘСТӘШ** *и.* Бәхәстә катнашучы икенче кеше, икенче як. *Шом – ул кешенең табигый бәхәстәше!* Р.Харис

**БӘХЕР** *и. гар. әд.* Шигырь үлчәве, шигырь төзелеше. *Бәхерләрнең үз эчендәге үлчәмнәре «вәзен» дип атала. Бәхерләр төренә карап, вәзеннәрнең дә саны төрлечә була.* Х.Курбатов. *Гарәп бәхерләренең күпчелеге гарәп поэзиясенең татар әдәбиятына күчле йогынтысы чорында да татар классик поэзиясендә аз урын алуы --- татар шигырь үлчәмнәренең мөстәкыйль тууын дәлилләргә булышалар.* Н.Юзиев

**БӘХЕТ** *и. фар.* **1.** 1) Тормыштан тулы канәгатьләнү хисе; яшәүгә һәрвакыт канәгатьлек биргән тормыш хәле. *Бөтен сәгадәт – минә шул Коръәндә, бөтен бәхет – шул моң гына укыла торган аятьләрдә, шул бар йирдә куркыныч та, кайгы да юк кеби тоелды.* Г.Исхакый. *Вакытны дөрес файдалану – бәхет, вакытны җилгә җибәрү – бәхетсезлек.* С.Поварисов. *Бәхеткә лаеклылар бәхетле булсыннар, яхшы кешеләрне бәхет кошы читләтеп үтмәсен.* Р.Сверигин

2) Эштәге, тормыштагы һәртөрле уңыш, шатлык. *Бәхет матурлыкка карамый.* Мәкаль. *Бәхетләрен арттырсыннар иде.* Г.Гыйльманов. *Шәһәрдә кыр казлары килгәнен ишетү, күрү – сирәк очрый торган бәхет.* М.Мәһдиев // Яхшы язмыш, тәкъдир. *Йа Рабби, бәхет бир!!!* Г.Исхакый. *Алла сиңа изге бәхет бирсен.* Г.Исхакый

3) Шатлык, уңыш, куаныч китерүче. *Аның бәхете Язилә булып гәүдәләнде.* К.Кәримов. *Кара төндә нур иңдергән нинди бәхетем бар!* Р.Фәйзуллин. *Аның аша ук сине – бәхетемне таптым.* Т.Галиуллин. *Бәхетемнән, тәхетемнән аерылдым, – Синең гыйшкың шулай тәэсир итте имди!* Кол Гали

**2.** *кер. сүз функ.* 1) *тарт. форм.* Бәхетле (*2 мәгъ.*) очрак. *Күрсәткән булыр иде, бәхетең әле, әтисенә әйтмәгән.* Г.Гобәй. *Бәхетең, югыйсә икегез дә күккә оча идегез.* Т.Таһиров

2) **бәхеткә** Нинди дә булса эш яки хәлгә карата канәгатьләнү хисен белдерә. *Бәхеткә, егерме елдан соң булса да, шагыйрь үзгәртеп кору таңын күреп өлгерде ---.* Таныш өянкеләр. *Ләкин, бәхеткә, күпчелекне башкалар – иске язмаларны «дин галәмәте» генә дип түгел, бәлки узган тарихның өйрәнелергә лаек истәлеге, бабайларның тарихтагы тирән эзләре, дип, фәнни дөрес бәяләүчеләр тәшкил итә.* М.Госманов. *Бәхеткә, җанварлар патшасы башка ерткычлар төсле вакланмый, бүтән терлекләргә тими.* Кызыклы дөнья

◊ **Бәхет ачкычы** Бәхет китерүче, бәхетле итүче. *Бәхет ачкычы ул, сез уйлаганча, әллә кайларда, диңгез артларындагы утрауларга күмелмәгән.* Ф.Яруллин. **Бәхет басу** Очраклы рәвештә бәхеткә, уңышка ирешү. *Минем бәхет басты: укытучы абый хәзер үз өебездә тора.* Ф.Хөсни. *Сенаторның бәхете басты.* Р.Мирхәйдәров. **Бәхете кара булу** Күп бәхетсезлекләр күрү. *Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен; Ядыма Тәңрем төшә, бәхетем кара булган саен.* Г.Тукай. **Бәхет елмаю** Уңышка ирешү. *Миңа да бәхет елмаер икән.* М.Хәсәнов. **Бәхет ишелеп төшү** Көтмәгәндә, шатлык-куанычлар килү. *Йөзе балкыпмы балкый, әйтерсең лә күктән бәхет ишелеп төшкән.* М.Әмирханов. **Бәхет иясе** Бәхетле кеше. *Тукта, ә менә Нурул, асылда, ул кадәр үк бәхет иясе микән әле ул?* Р.Фәизов. **Бәхет кошы** *шигъ.* Бәхет символы; бәхет китерүче. *Бәхет кошы чая оча бит ул, Сыңар канат куып җитә алмый.* Ш.Галиев. *Рамил, бәхет кошын ауларга чыккан оста мәргән төсле, гел очынып йөрде.* В.Имамов. *Әйтерсең лә ул тотасы һәрнәрсәгә бәхет кошы кунып, ак каурыен салып киткән иде.* Х.Сарьян. **Бәхет сәгате сугу** Бәхет күрү насыйп булу. *Бу самими ялгышу хәзер бигрәк еш искә төшә: җиңел генә кергән зур акчалардан һәм җәзага тартылмауларыннан башлары әйләнгән җинаятьчеләрнең бәхет сәгате сукты.* Р.Мирхәйдәров. **Бәхет сынау** Уңыш өмет итеп тәвәккәлләү. *Йә Харис, бәхетеңне сына, курыкма, курыкма! Отырсаң, үзебез түләшербез.* Ә.Еники. *Бәхетен сынап карарга булды егетебез.* Т.Галиуллин. **Бәхет ташу** Үзүзеңне бик тә, чиксез бәхетле хис итү. *Бәхете ташудан һәм әсәрләнүдән дөпдөп типкән йөрәге сикереп чыгар төсле тоелган иде.* Р.Мирхәйдәров. **Бәхет тәтү** Бәхет күрү насыйп булу, бәхетле булу. *Мондый бәхетнең тәтегәне юк иде әле.* Р.Мирхәйдәров. **Бәхет эзләү** Яхшы язмышка, уңышка өметләнеп, чит җирләргә чыгып китү. --- *төпчек улы, үзе әйтүенчә, ягада, ягъни читтә бәхет эзли иде.* К.Латыйп. *Бәхет эзләп чыгып киткән балаларның күбесе инде синеке түгел, ят җир кешесе булып китә, ят нәселгә әйләнә, балалары җиде яттан да ятрак булып үсә.* Р.Батулла. *Без күргәннәр бер гомергә Җитә микән, аз микән? Бәхет эзләп җик чигүләр Сагыш микән, наз микән?* И.Гыйләҗев

**БӘХЕТЛЕ** *с.* **1.** 1) Шатлык, бәхет хисләрен кичергән, шул хисләрне чагылдырган. *Белмим, кемдер, нинди бәхетле җандыр ул?!* А.Хәсәнов. *Җанда егетне көткән бәхетле көннәр һәм әрнү белән катышкан сөю чаткылары гына сибелеп калды.* Н.Гыйматдинова

2) Бәхет, уңыш, шатлык китерә торган. *Иң бәхетле мизгелләргә бәрабәр музыканы, өйгә кайткач, бер генә тапкыр да уйната алмады, ичмасам.* Ә.Баян. *Наҗарның тәкъдиргә бераз үпкәләргә хакы бар кебек – ул бәхетле йолдыз тыныч җемелдәгән чакта тумады, ә бөтен җирне калтыраткан залплар, шартлаулар, дөбердәүләр һәм елашлар белән бергә дөньяга килде.* Ә.Баянов

**2.** *и. мәгъ.* Бәхете булган. *Бәхетленең көймәсе корыдан йөри.* Мәкаль

◊ **Бәхетле авыз** Табында затлы, тәмле ризыклар булганда килеп кергән кешегә әйтелә. *Бәхетле авыз икәнсең әле, Кәбир якташ.* А.Гыйләҗев

**БӘХЕТЛЕЛЕК** *и.* Бәхетле булу, бәхетле мизгелләр кичерү халәте. *Бер кайгының – бер шатлыгы, бер бәхетлелекнең – бер бәхетсезлеге турында янә уйланды ул.* С.Поварисов

**БӘХЕТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Бәхете булмаган, бәхеттән мәхрүм булган; кайгы-хәсрәт кичергән. *Әмма үзем, Инессаны күрү белән, ай бичара, бәхетсез күбәләгем, дип тормадым.* А.Хәсәнов

2) Бәхетсезлек китерә торган. *Бәхетсез тормыш аның кешегә булган ышанычын көннән-көн какшата, ягымлы күңел хисләрен көннән-көн тупасландыра, саектыра бара иде.* З.Фәйзи. *Бәхетсез җир өстеннән поезд чаба.* Ф.Садриев

**2.** *и. мәгъ.* Бәхете булмаган кеше. *Бәхетсезне ат өстендә эт талар.* Мәкаль. *Бәхетле дә, бәхетсез дә Вакытны саный.* Ә.Мәхмүдов

◊ **Бәхетсезгә җил каршы** Уңышсызлыкка очрау, уңай туры килмәү**.** *Ләкин, бәхетсезгә җил каршы, дигәндәй, чиртми генә бит балык.* Таныш өянкеләр

**БӘХЕТСЕЗЛЕК** *и.* **1.** 1) Бәхетсез булу, бәхеттән мәхрүм калу. *Гаҗәпләнә, соклана белмәү – бәхетсезлек.* Ф.Сафин. *Бөтен бәхетсезлек синең азгынлыктан башланды.* Н.Гыйматдинова. *Матурлык, сөйкемлелек бәхет булган кебек, ямьсезлек тә – зур бәхетсезлек шул.* Ф.Яруллин

2) Аерым бер уңышсызлык; күңелсез хәл. *Мин, гарьләнүдән ут кебек кызышкан йөземне бәхетсезлектән калтыраган кулларым белән каплап, тын, караңгы урамнар буенча ялгызым киттем.* Ю.Әминов. *Ләкин ни өчен мин безнең арада булган бөтен --- ямьсезлекне, бәхетсезлекне фаш итеп торырга тиешмен?* Ә.Еники. *Ә, бәлки, ул, берәр бәхетсезлеккә дучар булып, больницага эләккәндер?!* М.Маликова. *Бәхетсезлек булмый калу – үзе бәхет.* Ш.Галиев

**2. бәхетсезлеккә** *кер. сүз функ.* Берәр эш яки хәлгә карата канәгатьсезлек хисен белдерә. *Бу кошчыкларның бәхетсезлекләренә, беркөнне сыерлары югалган, эзләп-эзләп тә таба алмаганнар.* Риваятьләр һәм легендалар. *Бәхетсезлеккә, салның койрыгында Әхмәтсафа, ничектер, үзе генә калып, ишкәкне нәкъ вакытында кирәгенчә чумдырып, каерып ала алмый калды.* Г.Толымбай

**БӘХЕ́Т ЧӘЧӘГЕ** *и. диал. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, сары чәчәкләре себеркәчкә тупланган озын сабаклы үләнчел үсемлек; алтын камчы; *русчасы:* **золотая розга, золотарник.** *Бәхет чәчәге – бу үсемлекнең чәчәккә бөреләнгән ботагын, өзеп, стенага яки түшәмгә кыстырып куялар. Бөреләре ачылса, бу йортка да бәхет ачыла, имеш.* Ырым

**БӘХИЛ** *хәб. сүз фар.* 1) Гафу итү, кичерү. *Без китәбез, бәхил, без китәбез, Китәргә без хөкем ителгән.* Ә.Гадел. *Мин әзермен, әзер бәхилгә дә, Мин әзермен, әзер тәүбәгә.* Ә.Гадел

2) Риза булу, ризалашу. *Мәңге дә бәхил түгел, – Бәхетсез булсаң әгәр!* Х.Туфан. *Сөю – дәрья ярларына тулмый, Аккан суга кабат кереп булмый, – Ярда калам... Бәхил шушыннан.* Н.Гамбәр. *Шушы вакыйганы яңадән тәфсилләп язмасаң, һич тә бәхил түгел.* Ш.Камал

**БӘХИ́Л БУЛУ** *ф.* 1) Кемнеңдер эш-гамәленнән риза булу; гафу итү, кичерү. *«Кайтуыма ышанмыйм, бәхил булыгыз»,– дип яза. Кайта алмый, шундагы газаплардан мантый алмый, мәрхүм.* Р.Әхмәтҗанов

2) Саубуллашу. *Бул бәхил, нурлы Казаным! Айрылам, Синдә бар сөйгәннәремне калдырам.* С.Сүнчәләй. *Хушыгыз! Кабат күрә алмасам, бәхил булыгыз! Менә соңгы йортлар, соңгы өянке башлары күренмәс булды.* Г.Сабитов

**БӘХИЛЛӘТҮ** *ф.* Өстәге бурычны кайтарып, ризалату; канәгатьләндерү. *Җаныемның хәтере калган, ничек бәхилләтергә?* Г.Тукай. *Су анасы Сылубикә, Су атасы Сарысакал, Кагылма, сугылма, Шушының белән бәхилләтәм.* Ырым

**Бәхилләтеп җибәрү** Тиешлесен, әҗерен бирү. *Кызга пәлтә аласы бар иде. Тиз генә бәхилләтеп җибәр әле, энем.* Ф.Абдуллин

**Бәхилләтеп йөрү** Һәрвакыт, гел бәхилләтү. *Догаларыңны укып, урман иясен бәхилләтеп йөр... Бөтиләрең яныңда булсын...* Г.Гыйльман

**Бәхилләтеп килү** Электән үк, күптәннән бирле бәхилләтү

**Бәхилләтеп тору** Әледән-әле бәхилләтү. *Туганнарыгызга, якын кардәшләрегезгә игътибарлы булыгыз, аларны кадерләгез, бәхилләп-бәхилләтеп торыгыз, яныгыздан ерак җибәрмәгез.* Г.Гыйльман

**БӘХИЛЛӘ́Ү** *ф.* 1) Гафу итү, кичерү. *Их, соңгы вакытта үзем барып карый алмадым – Зөбәерем бәхилләрме икән...* М.Хуҗин. *Ә ул моны үзенең яшьлеге, Даниялга кайнар күңел җылысы белән бәхилләргә тиеш.* З.Фәйзи. *Кичер, гафу ит син мине, остаз, бәхиллә син мине!..* К.Латыйп

2) Риза булу, ризалык белдерү

**Бәхилләп бетерү** Тулысынча бәхилләү. *Болай да игелегегезне ничек бәяләп, бәхилләп бетерербез?* Н.Әхмәдиев

**Бәхилләп йөрү** Әле, хәзер бәхилләү. *Аның баласын бәхилләп йөр син, ә ул, күзен дә йоммый, ажгырып, өстеңә килә.* Р.Низами

**Бәхилләп кую** 1) Алдан бәхилләү

2) Тиз генә бәхилләү. *Кайтуыгызны белдереп, өй нигезен бәхилләп куйыйк.* Г.Гыйльманов

**Бәхилли бару** Һәрберсен һәм һәр очракны бәхилләү

**Бәхилли килү** Әлегәчә һәммәсен бәхилләү

**БӘХИЛЛӘШҮ** *ф.* 1) Бер-береңне бәхилләү, гафу итү. *Югалган дусларыңны эзләү – үзеңне эзләү ул. Әгәр кеше кечкенәдән уйнап үскән, бергә укыган, эшләгән, яшәгән, бәхилләшкән дусларын, якыннарын һәм туганнарын, яңадан исән-имин җыеп, зур очрашу оештыра алса, аның бөтен биографиясе, энәсеннән җебенә чаклы, югалмыйча, әйләнеп кайтыр иде.* К.Кәримов

2) Бөтенләйгә аерылышканда саубуллашу. *Нишләп алай бәхилләшәсең, нәрсә булды, бу – нинди халык?* Т.Таһиров. *Бәхилләшкән сыман баш иям мин, Дулкынланган яшьлек дөньяма.* Һ.Такташ

3) Вафат булу, якты дөньядан китү. *Миңзифа инәебез бу дөнья белән йөз дә өчне ачып бәхилләште.* М.Кәрим

4) *күч.* Араларны өзү, аралашудан туктау. *Өйгә исән-сау кайтырмын, дип өмет тә итеп килмәдем, балаларымны, соңгы тапкыр, дип сөеп, бәхилләшеп килдем.* Л.Гыймадиева

5) *күч.* Мәңгегә югалту, мәхрүм калу. *Кара аны, Хуҗага әләклисе булма. Югыйсә дөнья белән бәхилләшәсеңне көт тә тор.* Ф.Яруллин

6) *күч.* Башка алынмау, нәрсәдән дә булса баш тарту, башкача эшләмәү. *Ул зимагурлык, бурлык тормышы белән мәңгегә бәхилләшергә уйлый.* М.Гали

**Бәхилләшеп калу** Бәхилләшергә өлгерү. *Менә алар, җитәкләшеп, берәмберәм, Маһинур абыстай каршыннан үтәләр, гүя аның белән күрешеп, бәхилләшеп калырга телиләр.* Ф.Бәйрәмова

**Бәхилләшә башлау** Бәхилләшергә тотыну. *Тәкъдиренә буйсынып, укытучы, елый-елый, үзенең дөньяда иң газиз, кадерле кешеләре белән бәхилләшә башлады; балаларым Алия, Хәнәфи, Асия, Хәлил... хушыгыз, бәгырь кисәкләрем, игелекле булып үсегез...* Т.Мөбарәков

**Бәхилләшеп тору** 1) Әле, әйтү вакытында бәхилләшү

2) *күч.* Хәзергә, әлегә баш тарту, вакытлыча читкә куеп тору

**Бәхилләшеп чыгу** 1) Һәммәсе белән, һәрберсе белән берәм-берәм бәхилләшү. *Күз карашым бәхилләшеп чыгар, ярлыкаулар сорап һәммәгездән.* Г.Сәлим. *Михаил Ярославич боярлар һәм дин әһелләренең һәркайсына кул биреп бәхилләшеп чыкты: – Мәңгелеккә аерылу шушы булсын!* Р.Вәлиев

2) Аерылыр алдыннан, якыннар белән бәхилләшергә өлгерү

**Бәхилләшеп яту** Әле, хәзерге вакытта бәхилләшү. *Төнлә белән хәлем хәл булды, мин инде, кеше буласыма тәмам өметем өзеп, газизләрем белән, фани дөнья белән бәхилләшеп яттым.* К.Миңлебаев

**БӘХИЛЛЕК** *и.* Ризалык; гафу итү, кичерү. *Ире Мортазаның бәхиллек соравына, эндәшмичә, күзләрен йомды.* М.Хуҗин. *Беренче ире үлгәндә, бу бәхиллек сораган иреннән.* М.Мәһдиев. *Ичмасам «хуш» дип әйтергә, бәхиллек сорарга берәр якын кешем дә юк...* Н.Гыйматдинова

**БӘҺА** *и. фар. к.* **бәя.** *Мисыр малы аңа бәһа булалмады....* Кол Гали. *Бәһасе нәкъ шулай – ун алтын.* Ф.Латыйфи. *Үз бәһасен үзе белмәгән хатын-кызның, кайчан да булса, күзләре бер ачылырга тиешлер ләбаса.* Г.Галиева. *Антошкага һәр язган юлы өчен бәһане арттырдылар, ә бер атнадан аны редактор чакырып алды.* А.Толстой

◊ **Бәһасе – сукыр бер тиен** Кыйммәте, кадере булмаган. --- *минем ише климатологларның бәһасе – сукыр бер тиен.* А.Тимергалин. **Бәһа төшү** Кыйбатка төшү. – *Биш тиеннән – кыйбатрак булыр бит, әй. Бу мал болай да бик бәһа төште безгә, – дип бетәшеп азаплана купец.* Ф.Хөсни

**БӘҺАЛӘНҮ** *ф.* Бәяләнү. *Ә бу кавем арасында андый «чәчәклечуклы» сүзләр бик кыйммәт бәһаләнә.* Р.Мирхәйдәров

**БӘҺАЛЕ** *с.* Кыйбат. *Биле бөрмәле, Чите укалы, Үзе бәһале.* Табышмак. *Бәс, һич хәйранга калмагыз ки, милләтпәрвәрлек чабаталы илә бәһале киемнәрне дус әйләде.* М.Акъегет. *Иң кадерле, иң бәһалесе – ак тәнле яван, болгар, урыс кызларыдыр.* М.Хәбибуллин. *Бәһале бүләк бәһале сүз сорый.* М.Хәбибуллин

**БӘҺАР** *и. фар. иск.* Яз. *Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарың! Качан китәр кичең, килер нәһарың?* Г.Тукай

**БӘҺАСЕЗ** *с.* Бәя биреп бетергесез, бик кадерле. *Үз тавышын ишетүе хәзер дә бәһасез сөенеч иканлеген яшерми Мисбах солдат.* М.Хуҗин. *И яшьлек, син – бәһасез энҗеләрдән торган таҗсың!* Р.Әхмәтҗан. *Шундый бәһасез югалтудан соң, тәгаен, күз яше түгәдер Хак-Тәңре!!!* К.Латыйп. *М.С.Кузнецов югары сыйфатлы, бәһасез дәрәҗәдә кыйммәтле фарфор эшләп чыгарган.* Сөембикә

**БӘЭ** *ирт.* 1) Сарык, бәрән тавышын белдерә. --- *әмма Тата үзе, тиз генә базга чумып, бәрәнне алып чыкты, һәм сарык булып сарык шунда биегәндәй итте, «бә-бә!», «бәэ-э!» дип шатланды.* Ә.Баян

2) *шаярт.* Балалар телендә «сөзәм» дигән мәгънәне белдерә

**БӘЭЛДӘ́Ү** *ф.* «Бә-ә», «бәэ» сыман тавышлар чыгарып кычкыру. *Бәэлдәп, сарыклар, теркелдәп йөгерә-йөгерә, бәрәннәр ишегалдына килеп керделәр.* Р.Кәрами. *Урам тарафыннан бәэлдәп һәм мөгрәп ихата эченә килеп кергән малның ачык тәрәзә аша үҗәтләнеп кергән тавышы белән кайнаша иде ул хәзер.* А.Хәлим

**Бәэлдәп алу** Бераз гына бәэлдәү

**Бәэлдәп йөрү** Әле, хәзерге вакытта, төрле урыннарда бәэлдәү. *Сарык битлеге кигән Бүре Бүртәй бәэлдәп йөри.* Л.Лерон

**Бәэлдәп кую** Бер тапкыр бәэлдәгән тавыш чыгару. *Эңгер-меңгер иңеп килә, урам арты каралтыларында сыерлар мөгри, сарык бәрәне бәэлдәп куя.* М.Хәбибуллин

**Бәэлдәп тору** Бертуктаусыз бәэлдәү

**Бәэлди бирү** Һичнәрсәгә карамыйча, бәэлдәүне дәвам итү

**БӘЭЛДЕК** *с.* Күп бәэлди торган (бәрәннәр турында)

**БӘЯ** *и. фар.* **1.** 1) Әйберне, мөлкәтне сатып алу өчен билгеләнгән акча суммасы, хак. *Мәкәрҗәдән килгән кызыл товар, Бәяләре алай зур түгел.* Җыр. *Бәясе ун тапкырга арткан егерме тиенлек тә күптән инде беркемне кызыктырмый ---.* Р.Мирхәйдәров. *Барлык товарларның бәясе күтәрелгәндә, хакыйкать бөтенләй бәһасен югалтты.* Ф.Садриев. *Нефтькә*

*бәяләр һәркөн диярлек сикереп тора.* Юлдаш

2) *сөйл.* Эш өчен түләү, хезмәт хакы. *Шәрифулла мичне төзәтергә кирәк тапты, шунда ук алар бәясен дә килештеләр.* А.Шамов. *Ул да шатланды, ләкин, тәрҗемә бәясенә килеп җиткәч, бу икенче төрле сөйли башлады.* Т.Гыйззәт

3) Укучыларның белем һәм күнекмәләрен бәяләүдә: билге. *Практикага бәяне шуңа карап куячаклар, киләсе кышка стипендияне дә шул хәл итә.* И.Низамов

4) Кешенең яки берәр нәрсәнең уңай һәм тискәре яклары, әһәмияте турындагы фикер, хөкем; бәяләмә. *Синең сынау узган, басылган, әйбәт бәя алган әсәрләрең бар.* Таныш өянкеләр. *З.Мансуровның бу әсәре турында матбугатта бәяләр аз булмады.* М.Мәхмүтов. *Һәрбер әйберне үземчә укып барам, укыйм да, шундук, читенә үземнең бәямне, фикеремне яза барам.* Х.Туфан

5) *күч.* Кадер, дәрәҗә. *Сез үзегезнең бәягезне белеп эш итегез.* А.Расих. *Егет үз бәясен белә.* Ю.Әминов

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Кыйммәт, югары хактан. *Юләр бәя сорый, акыллы юнь бирә.* Мәкаль. *Ләкин Питер кебек шәһәрләрдә, аңлавымча, мондый бүләк бәя тормый – татарча укырлык кешеләре бик чамалы.* Идел

◊ **Бәя каеру** Нәрсәнең дә булса бәясен күпкә арттырып сату. *Әнә теге профсоюз башлыгы тәмам азды – һәр тауар өчен икеләтә бәя каерды.* Ф.Баттал. **Бәя күтәрү** Дәрәҗәсен, абруен күтәрү. *Күрче әле моны, үз бәясен ничек күтәрә!* А.Иванов. **Бәя тору** Кыйммәт булу, хакы югары булу

**БӘ́Я БИРҮ** *ф.* Бәяләү, берәр төрле фикер әйтү. *Чынбарлыкка дөрес бәя бирелде.* Г.Толымбай. *Мирсәй Әмир романга югары бәя бирү белән генә чикләнмәде.* Таныш өянкеләр

**БӘЯЛӘМӘ** *и.* Нинди дә булса хезмәтнең, эшнең сыйфаты, үзенчәлекле яклары, әһәмияте турында язмача бирелә торган рәсми белешмә. *Аны нинди дә булса хәлгә, күренешкә бәяләмә дип атыйбызмы, – барысы да, үз вакыты җиткәч, барыбер, мәгънәви калыпка салына икән.* З.Хөснияр

**БӘЯЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бәяләү.** --- *бу дәүләт бик түбән мәдәниятле, күчмә дәүләт дип бәяләнә.* М.Мәхмүтов

2) *күч. сөйл.* Кыйбатлану, бәясе күтәрелү

**Бәяләнә бару** Бәяләр көннән-көн күтәрелү

**Бәяләнә тору**. 1) Һәрвакыт, гел бәяләнү. *Ә менә Кояш борынгы төрки халыклар өчен «Гөл анасы» дип бәяләнә торган булган.* К.Гыйззәтов

2) Әледән-әле бәяләр күтәрелү

**Бәяләнә төшү** Бераз бәя күтәрелү

**Бәяләнеп бару** Бер-бер артлы бәяләнү; һәр очрак бәяләнү. *Аерым урыннарда казанлыларның холык-фигыле автор-хикәяләүче авызыннан да бәяләнеп бара*. Д.Заһидуллина

**Бәяләнеп бетү** Бәяләр бик югары булу

**Бәяләнеп җитү** Тиешле бәя алу. *Үз вакытында бәяләнеп җитмәгән, ләкин киләчәктә чын бәя алучы язучылар белән ничек? Андыйлар да бар бит*. Т.Миңнуллин

**Бәяләнеп килү** Күптәннән, электән үк, системалы бәяләнү. *Әле генә без, бу төшенчә гомумән уңай бәяләнеп киленде һәм бүген дә шулай булырга тиеш, дидек*. И.Низамов. *А. Әхмәдуллинның гыйльми, тәнкыйди, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге җәмәгатьчелек, рәсми оешмалар тарафыннан һәрчак уңай бәяләнеп килде*. Х.Миңнегулов

**Бәяләнеп тору** Һәрвакыт, гел бәяләнү. *Бу елларда Ш.Маннурның һәр адымы тикшерелеп, идеология күзлегеннән бәяләнеп тора*. Р.Зарипова

**БӘЯЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Бәя (*1, 2 мәгъ.*), хак кую, бәясен билгеләү. *Ишан, исәпләп карап, бүлмә ясауны биш мең алтынга бәяләгән.* Э.Касыймов

2) Берәр эш, хезмәт турында, аның уңай һәм тискәре якларын, әһәмиятен күрсәтеп фикер әйтү. *Ә үзебез яшәгән табигатькә мөнәсәбәт, аны ерткычларча туздыру, күрәләтә агулауны, суларга һава булмаган шәһәрләрдә, халыкны алдап-йолдап, тагын, тагын, тагын яңа химия гигантлары торгызуны ничек бәяләргә?!* Г.Үзиле

3) *күч.* Кадерен белү. *Ачыны белмәгән татлыны бәяли алмас, диләр.* А.Гыйләҗев. *Асылда, дөрес бәяли белгән яшь галим, аның хезмәтен тәкъдим итәргә ярый...* Ә.Еники

**2.** *и. мәгъ. икът.* Бәя (*1 мәгъ.*) кую эше, бәясен билгеләү эшчәнлеге (товарның, милекнең). *Биш көндә торакны бәяләү үткәрелә икән – 3,5 мең сум, ә ашыгыч рәвештә бер тәүлектә үткәрү 4,5 меңгә төшәчәк.* Мәгърифәт

**Бәяләп бетерү** 1) Әйберләрнең һәммәсенә бәя куеп чыгу; тулысынча бәяләү

2) *к.* **бәяләп җиткерү**. *Сине Казанда бәяләп бетермәгәннәр, дип уйлыйм.* Татарстан

3) *күч.* Әһәмияте искиткеч зур, мөһим, төгәл бәя кую мөмкин түгел, мәгънәсендә. *Бу нәрсә [кенәзлекләрне берләштерү] Новгородның хәрби-сәяси хәлен бәяләп бетергесез дәрәҗәдә нығыта*. М.Гайнетдинов. *Г. Кариевның режиссура гына түгел, ә гомумән татар театрының барлыкка килүе һәм үсешендәге ролен бәяләп бетерү дә кыен*. М.Арсланов

**Бәяләп җиткерү** Тиешле бәя бирү, тиешенчә бәяләү. *Алар бәяләп җиткермәделәр, адәм баласының күңеле – нәкъ көзге кебек ул: эчтәге хисләр икесенең дә гамәл-кыланышларыннан ук чагылып тора ---*. З.Хөснияр

**Бәяләп кую** Алдан бәяләү. *[Сәвилә:] Аның күңеле керсез, апа. [Сәрвәр:] Керсез, диме? И бәяләп куйды.* Н.Гыйматдинова

**Бәяләп тору** Даими рәвештә бәя бирү. *Шуның аша Сөенбикә образына салынган мәгънәләр тагын да күбәя, ә Ай кызы вакыйгаларны күзәтеп һәм бәяләп торучы кебек кабул ителә.* Д.Заһидуллина

**Бәяләп узу** 1) *к.* **бәяләп чыгу**. *[Җәмилә] Җантимернең сынын карашлары белән бәяләп узды.* Ф.Яхин

2) Билгеле бер төрдәге нәрсәләр белән беррәттән, сүз уңаенда әйтеп, билгеләп үтү

**Бәяләп үтү** *к.* **бәяләп чыгу**. *Шулай да элек игътибар үзәгенә алынмаган, «вак-төяк» саналган, өстән-өстән генә*

*бәяләп үтелгән кайбер күренешләрне яңачарак тәфсилләү ихтыяҗы көн үзәгендә тора.* Т.Галиуллин

**Бәяләп чыгу** Билгеле бер чорны, тирә-юньне, һәрьяклап, башыннан алып ахырына кадәр, тоташтан бәяләү. *Сал-Сал сәүдәгәр шул чагында гына тирә-юньне күзләп, бәяләп чыкты.* В.Имамов. *Төрки халыклар тарихын, фольклорын, күпсанлы чыганакларны өйрәнеп, борынгы кулъязмаларны барлап язылган хезмәт милли сәнгать тарихын чишмә башыннан алып күзәтеп, бәяләп чыгуны күз алдында тотып уйланыла.* Д.Заһидуллина

**Бәяли бару** Һәммәсен, булган берсен бер-бер артлы бәяләү

**БӘЯЛӘҮЧЕ** *и. икът.* Мал-мөлкәткә бәя (*1 мәгъ.*) бирү эше белән шөгыльләнүче хезмәткәр. *Чынбарлыкта исә һәр банкның «дустанә» мөгамәләдәге үз бәяләүчеләре була, һәм, әлбәттә инде, банк сезгә шуларны тәкъдим итәчәк.* Мәгърифәт

**БӘЯЛЕ** *с.* 1) Бәясе билгеләнгән, хакы күрсәтелгән (сатучылык эшендә)

2) *күч. сөйл.* Кыйммәт, хакы югары. *Әллә шулкадәр галәми тәртип, әллә шулкадәр бәяле мохит күреп, Җәүдәт үзен очыш хәлендә тоя башлады.* А.Хәлим. *Бар булган бәяле җиһазларны, финанс кәгазьләрен, керем-чыгымнарны тикшереп чыккач, миннән художник ясаган плакатларны таптыра башлады [ревизор Таҗи].* Н.Хәсәнов

3) *күч.* Кадерле

**БӘЯН** *и. гар. кит.* **1**. Телдән яки язмача бирелгән аңлатма. *– Сиңа бай булу мөмкиндер, – дип, бәянга кереште Әбүзәр бәк...* М.Акъегет

**2**. *с. мәгъ. әд.* Булган хәлләрне, вакыйгаларның сюжет җебен нык тотып, эзлекле сөйләп чыккан. *Аның беренче ике китабы – тасвир-проза, соңгысы – бәян әсәр.* Р.Сибат

**3**. **бәянында** *бәйл. функ.* Турында, хакында. *[К.Насыйри] 1871 елга «Календарь»да «Халык арасында тәҗрибә буенча көн вә һава үзгәрүнең галәмәтләре бәянында» дигән баш астында, күк җисемнәренең, хайваннар һәм кошларның үз-үзләрен тотышларына карап, һава торышының нинди булачагын билгеләүче 81 сынамыш кителгән.* Х.Мәхмүтов

**БӘЯ́Н ИТҮ** *ф.* Телдән яки язмача аңлату, төшендереп бирү. *Йосыф сәүче кыйссасын без тәмам иттек, Гарәбфарсы телләречә бәян иттек ---.* Кол Гали. *Шагыйрь: «Бәян ит!» – диде.* М.Болгари. *Мансур [аны] балерина ясарга мәслихәтлеген, театрның балет башлыгы берлә шул хакта күреп сөйләшү кирәклеген бәян итте.* Г.Исхакый. *Үзен борчыган фикерләрен бәян итте ул.* М.Кәрим

**БӘЯСЕЗ** *с.* **1.** 1) Бәясе билгеләнмәгән, хакы күрсәтелмәгән. *Бәясез товар*

2) *күч.* Бик арзан. *Ул елларда акчаның бәясез чагы булса да, Әбүзәр абзый, уйлый-уйлый да, кыйбатсынып, [киекне] алмый китә.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Бәя биреп бетергесез; бик әһәмиятле; мөһим. *Бәлзәмле бу суның бихисап шифасы, Сатылмый ул су тик, бәясез бәһасе!* Ә.Синугыл-Куганаклы

**2.** *кис. мәгъ.* Бик, гаять, чиктән тыш. *Дөньядан ул карт берничә сәгатькә яки тәүлеккә генә китеп торган да тормышның бәясез кыйммәт икәнлегенә төшенгән.* С.Сөләйманова

**БӘЯСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Әйберләрнең, хезмәтнең бәясе төшү, арзанлану. *Доллар бәясезләнү*

2) *күч.* Бәясен, кыйммәтен югалту

**Бәясезләнә төшү** Бераз бәясезләнү

**Бәясезләнеп алу** Кыска гына вакыт эчендә нәрсәгә дә булса бәя төшү, аннан яңадан күтәрелү

**Бәясезләнеп бетү** Бөтенләй бәясезләнү

**Бәясезләнеп китү** Кинәт бәясезләнү. *Гаиләсе, үзенекеләр белән тупасрак тота, нервылары уйный, ничектер бәйсезләнеп, хәтта бәясезләнеп китә.* Г.Хөсәенов

**Бәясезләнеп тору** Әледән-әле бәясезләнү

**БӘЯЧЕЛ** *с.* Товарның бәясен кыйммәт сораучан. *Бәячел сатучы*

**БЕГЕМОТ** *и. бор. яһүд* Күшәүче партояклылар семьялыгына караган, Африканың төче сулыкларында яши торган, зур гәүдәле һәм кыска аяклы имезүче хайван; гиппопотам. *[Зоопарка] Беркөнне Шукбай да килгән, Уйнарга дип туп тоткан. Шул тубын ул читлек аша Бегемотка ыргыткан.Ә бегемот нишләгән соң? Тупны капкан да йоткан. Шукбай өйгә кайтып киткән, Бегемотны оныткан.* И.Юзеев. *Гадәти бегемот белән чагыштырганда, кәрлә бегемотны «сусөяр» дип атап булмый.* Кызыклар дөньясында

**БЕГО́НИЯ** *и. лат.* (ботаника белән кызыксынучы француз М.Бегон исеменнән алынган). Бегониячәләр семьялыгыннан, эре, чуар яфраклы, матур чәчәкле тропик һәм субтропик үсемлек; миңле гөл; карабодай гөле. *Әнә теге бегония --- яфрактан үрчи.* Г.Мөхәммәтшин. *– Роза, ландыш, сирень, гладиолус, пион, эдельвейс, бегония... – Рәхмәт сезгә, җирдә утыз мең төрле чәчәк үсә, барысын да санап бетерә алмассыз.* К.Кәримов

**БЕЖГӘК** *с. диал.* Сукранучан, мыжык, бәйләнүчән

**БЕЖГӘКЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Сукрану, мыгырдау

**Бежгәкләп алу** Бераз бежгәкләү

**Бежгәкләп йөрү** Бертуктаусыз бежгәкләү

**Бежгәкләп тору** Һәрвакыт бежгәкләү

**БЕЗ** I *и.* 1) Тишек тишү өчен кулланыла торган, сапка утыртылган, үткен энә сыман нәзек очлы металл чыбык

2) Төрле коралларда: очлы штоклар, тишкечләр

◊ **Без белән кырыну** Бик гади корал белән дә эшне үтәп чыга алу. **Без белән чәнечкән кебек булу, без булып кадалу** 1) Кинәт бик каты авырттыру, кинәт көчле авырту тою; 2) Күңел әрнү, күңел рәнҗү. **Без борын(лы)** Очлы борын(лы). **Безгә бастыру (баскандай итү)** Бик нык ачулану; җәзага тарту. **Без каккан** Бер урында тик утыра белмәүче турында. **Без күз** Күзәтүчән, игътибарлы кеше

**БЕЗ** II *а.* 1) Беренче зат алмашлыгының күплек формасы; сөйләп торучының үзе белән бергә бертөрле үк уйлый, фикерли, сөйли, нәрсәне дә булса бергә эшли торган затларның берлеген белдерә. *Без, акны-караны күрмәстән, кая басканны белмәстән, Зәңгәр*

*Чишмәгә чаптык.* Г.Ибраһимов. *Әгәр кешене яхшы итү безнең кулдан килә торган булса иде, без инде аны алтыннан ясап куйган булыр идек.* Г.Камал. *– Безнең мәрхүм әткәй әйтә торган иде, – диде Гарәфи абзый, тәмәкесен суыра-суыра, – алтынны – тоткан таныр, дияр иде.* Г.Әпсәләмов

2) Үз эшләреңне башкалардан аерып күрсәтү өчен кулланыла. *Без – җиде егет, җиде сугышчы, аның салмак, ләкин аз гына гыжлап чыккан картларча тавышын сулуларыбызны алмыйча тыңлап тордык.* А.Шамов. *Әле без татарларда --- гармонияләр төрлечә булса да зарар юк.* Совет әдәбияты

3) Иҗтимагый-сәяси һәм фәннипублицистик әсәрләрдә автор сөйләмендә авторның үзен белдерә. *Менә без хәзер шул кешеләр ясаган тәртипләрнең турылыгы, кәкрелеге хакында сүз сөйләмәкче булабыз.* Г.Тукай. *Ш.Камалның беренче әсәре булган «Уяну»да ук инде без аңа чаклы татар әдәбиятында сирәк чагылган эшче тормышын очратабыз.* М.Җәлил

4) *юг.* Кайбер очракларда сөйләүченең үз дәрәҗәсен, үз абруен белеп сөйләвен белдерә. *Без, җиде икълимнең ханы, боерабыз.* Әкият

**БЕЗ** III *иярт.* Югары дулкындагы авазларны белдерә

◊ **Без-без килү** Үзалдына сөйләнгәләп, юк сылтаулар эзләп, бәйләнеп, вакланып йөрү

**БЕЗГӘ́ЧӘ** *рәв.* 1) Без булганчыга кадәр, бездән алда. *Тарихтагы юллар буенда Ташбилгеләр – ядкарь каберләр, Безгәчә дә килеп киткәннәр, Бездән соң да килер дәверләр.* Х.Туфан. *Тукай, Исхакый, Гаспралы, Әмирханнар чорыннан безгәчә арада башлар алты тапкыр киселгән. Алты тапкыр без талантсызрак, алты тапкыр без наданрак, алты тапкыр кыюсызрак...* Р.Батулла

2) Безнең янга кадәр

**БЕЗГЕЛДӘК** *и.* Дүдәкләр отрядыннан, арка ягы кара тимгелле ком төсендә, корсак асты ак, ата төрләре ике ак юлы булган кара муенлы, нык шаулашып оча торган зур дала кошларының бер төре; *русчасы:* **стрепет**

**БЕЗДӘГЕ́ЧӘ** *рәв.* Бездә ничек булса – шулай, бездә булганча, анда да нәкъ бездәге кебек. *Швециядә балаларын тудыру йортында калдырып чыгу яки, бездәгечә, ятимнәр йортына бирү дигән нәрсә бөтенләй юк икән.* Г.Афзал

**БЕЗЕЛДӘВЕК** *с.* **1**. *сир. к.* **безелдек**. *Кешегә кан суыручы ике канатлыларның шактый төрләре һөҗүм итә, алар – безелдәвек озынборыннар.* И.Рәхимов. *Чебеннәр, афодийлар һ.б. урынына тире-йон коңгызлары (кожееды), шыртлавык коңгыз личинкалары (проволочники), безелдәвек коңгызлар (жужелицы) килә.* Ә.Халидов

**2**. *и. мәгъ. диал.* Озынборын, черки

**БЕЗЕЛДӘ́Ү** *ф.* «Без-без» итү, «без-без» итеп тору; югары дулкында яңгырашлы нечкә озын аваз чыгару. *Ә хәзер аңа кубыз тавышы очкан чебен канатының безелдәве сымак кына тоела.* Г.Ибраһимов. *Безне чынлап та немецлар күреп алды: ике пуля, безелдәп, безнең яннан ук үтеп китте.* И.Гази. *Орчык һаман күңелле итеп безелди, мич артындагы чикерткә чер-чер итеп тора, ә Фатыйма, көйгә салып, сөйли дә сөйли.* И.Гази

**Безелдәп алу** Бераз гына, аз гына вакыт эчендә безелдәү. *Трубка башта нигъдер чыелдап-шыелдап торды, үрмәкүч пәрәвезенә эләккән кигәвен кебек усал безелдәп алды.* Г.Мөхәммәтшин. *Комендант ханымның нечкә тавышы, пәрәвез ятьмәсенә эләккән чебен кебек, безелдәп алды.* М.Галиев

**Безелдәп җибәрү** Кинәт безелди башлау

**Безелдәп йөрү** Якын-тирәдә генә туктаусыз безелдәү. *Бөтен җирдә күбәләкләр уйный, бал кортлары, төклетуралар безелдәп йөри.* Г.Бәширов. *Теләсә нәрсә сөйләнеп, чебен кебек безелдәп йөрмәсен, маңка!* Н.Фәттах

**Безелдәп кую** Кыска гына вакыт эчендә бер тапкыр безелдәү

**Безелдәп тору** 1) Бертуктаусыз, гел безелдәү. --- *колак төбеннән, сазлы болын озынборыннары кебек, «кәтүк», «кәрлә», «карсак» дигән эчпошыргыч сүзләр китмәде, гел безелдәп торды.* Р.Сибат

2) Әле, хәзерге вакытта безелдәү. *Әле балкортлары, кигәвен-черкиләр тирә-юньдә безелдәп торса да, инде урмандагы элекке җанлылык сүнеп бара.* Ф.Садриев

**Безелдәп узу** Яннан безелдәгән тавыш чыгарып үтеп китү. --- *колагына бодай кыякларының, нечкә мыеклары белән бер-берсенә кагылып, чикерткә сайраган сыман чыңлаулары, өстән бал кортларының безелдәп узуы ишетелә.* Г.Бәширов

**Безелдәп үтү** *к.* **безелдәп узу**. --- *бернинди хәрәкәт, бернинди тавыштын юк. Колак яфрагыма орына язып, ялгыз бал корты гына безелдәп үтте.* Ф.Шәфигуллин

**Безелдәп яту** *к.* **безелдәп тору. –** *Тор, тор, хәзер безелдәп ятма, алдан уйларга кирәк иде, – диде.* Ф.Тарханова

**Безелди башлау** Безелдәргә тотыну. *Нәзек, эчпошыргыч тавышлары белән, черкиләр безелди башлады.* Д.Гайнетдинова

**Безелди төшү** Бераз безелдәү; тагын да безелдәү

**БЕЗЕЛДЕК** *с.* 1) Берөзлексез безелди торган. *Йокламый икән үзе. Безелдек черкиләр тынгы бирмидер инде.* С.Шәрипов. *Без-без-безелдек, Җилбәзәктәй тезелдек.*Ә.Фәйзи

2) *күч.* Мыгырдык, мыгырданучан, сукранучан

**БЕЗЕЛТЕ** *и.* Туктаусыз безелдәп торган аваз. *Бөтен юл буе һәм өйгә кайткач, Гомәрнең колагында һаман шул «ә-ә-ә» дигән тавышы вә кайгылы бер безелте белән чыңламакта иде.* Ш.Камал

**БЕЗЕРӘК** *с. диал.* Бераз, бик аз гына, аз гына күләмдә. *Ансын син безерәк арттырасың инде кем, Миңнулла, яхшылап эшкәртсәң, тирес түксәң, шайтан таягы гына үсмәс иде.* И.Гази

**БЕЗ-З-ЗК-БЕЗ-З-ЗК** *иярт.* Өсте-өстенә яңгыраган кыска көчле юнәлешле агым тавышын белдерә. *Лапаста әбинең литрлы банкасына, безләп, сөт ага: «Без-з-зк! Без-з-зк! Без-з-зк!»* Р.Сибат

**БЕЗКОЙРЫК** *и.* Үрдәкләр семьялыгыннан, койрык очында ике нечкә

озын каурые булган кыр үрдәге төре; *русчасы:* **шилохвостка.** *Якынча шулкадәр үк [15 төр] язгы яки көзге очып килү яки очып китү вакытында, безнең сулыкларга ял итәргә төшүләре күзәтелә. Бакылдык чүрәкәй, сызгырак чүрәкәй, безкойрык, киң томшыклы үрдәк, аккүз чумгалак, кызыл башлы чумгалак – бездә гадәти үрдәкләр, ә менә диңгез чумгалагы, зур чумгалак, турпан безнең территория аша үтешли генә очрыйлар.* И.Рәхимов

**БЕЗЛӘҮ** I *ф.* 1) *к.* **безелдәү**. *Чаңнар чыңы яуга чакырганда, Чебен булып безләр үлем.* З.Нури

2) *күч.* Колак төбендә бертуктаусыз ризасызлык белдереп сөйләнеп тору

**Безләп йөрү** Якын-тирәдә бертуктаусыз безләү. *Арзу тамбур белән чиккән алъяпкыч бәйләде исә, Кәримә дә кигәвен чорындагы симез тана кук безләп йөри башлый.* А.Гыйләҗев

**Безләп тору** Бертуктаусыз безләү. *Ә янәшәсендә – Эч пошырып һаман безләп тора; Әйтерсең лә йөрәксенгән шөпшә: Тешләргә дип, бер җай эзләп тора.* Г.Сәгыйров. – *Колак төбендә туктаусыз безләп торуыңны ишетмәс өчен эчәм дә, – ди эти.* Э.Шәрифуллина

**БЕЗЛӘҮ** II *ф. сир.* Озын койрыклы хайван койрыгын туры катырып тору, чәнчү. *Чапты үгез койрыгын чәнчеп, безләп.* Г.Афзал

**Безләп кую** Безләнгән хәлгә китерү

**БЕЗЛӘ́Ү** III *ф.* Бик нык сынап карау. *Менә сиңа мә! Телепатия! Ул безләп карамаса, мин дә борылмаган булыр идем.* А.Хәсәнов

**БЕЗЛЕ** *с.* Үткен, сыный торган. *Җитди күзләр, елмайган күзләр, Сөрмә тарткан серле соры күзләр, Усал уйлар уелган күзләр, Нурлы күзләр, үткен безле күзләр.* Г.Афзал. *Шагыйрьләрнең уе елгыр, теле безле, һәрнәрсәне күрә торган үткен күзле.* Р.Хисамиев

**БЕЗНЕКЕ** *а.* **1.** Беренче зат, күплек сандагы зат алмашлыгыннан ясалган тартым алмашлыгы; предметның аның хуҗасы булган безгә нисбәтләнүен белдерә. *Аннары дөнья, беләмсез, безнеке! Аннары рәхәт – Ходайсыз йөзнеке!* Ш.Бабич. *Ерактан караганда, түбәнең уң кыегына орынып күренгән йорт – безнеке.* Ә.Гаффар

**2.** *и. мәгъ.* Безгә караган әйбер(ләр), кеше(ләр), безгә мөнәсәбәте булган күренеш. – *Анда безнекеләргә әйт!* – *диде.* Г.Бәширов. *Шулай да аңа бу картина бик ошады: безнекеләр фашистларның кирәкләрен бирделәр.* А.Шамов. *Безнекеләр кайда да югалмас, янәсе.* Татарстан

**БЕЗНЕ́ҢЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Без уйлаганча, без теләгәнчә. *Тегенең намазлык өстендә думбра чиртүен бик еш уйнавыннан киная итеп алуы бер дәрәҗәдә яраса да, намазның безнеңчә түгеллеген, юри, Газизәне шикләндерер өчен сөйләде.* Ш.Камал. *Әүвәл заманда пәйгамбәрләрне дә, кавемнәре азган кешеләр, безнеңчә тормыйлар, безнеңчә йөрмиләр, дип гаеп иткәннәр.* Ф.Әмирхан

2) Үзебезнең телдә. *Алманнар түгел, әмма безнеңчә ярыйсы гына бытылдыйлар инде.* Т.Әйди. «*Мадам*», *дип әйткән сүз, безнеңчә, «абыстай», дигән сүз була.* Ш.Камал. *[Хатын:] Урыс халкы дисәң – безнеңчә сөйләшә беләләр, мөселманнар дисәң – аңламыйлар, охшамыйлар.* Ф.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Безгә фикердәш, безгә иш, без теләгән. *Чын безнеңчә матур милли көй.* Г.Тукай

**БЕЗРИК** *с. диал. к.* **безерәк.** *«Оят» дигән нәрсә булырга тиеш бит инде безрик кенә!* Г.Бәширов

**БЕЙДЖ** *и. ингл.* Кайсы да булса берәр оешма хезмәткәренең, конференциядә катнашучының, күргәзмәләрдә оештыручыларның исеме, эш урыны, вазифасы һ.б.ш. мәгълүмат язылган, өс киеменә беркетелә торган карточка. *«Оргкомитет» дигән бейдж таккан Сильвия белән Венера исемле кызлар чара булачагын распады раславын ---.* Шәһри Казан

**БЕ́ЙДЖИК** *и. ингл. к.* **бейдж**. *Шул чагында, минем бәхеттәндер инде, коридор буйлап, түшенә бейджик тагылган (димәк, шунда эшләүче) бер егет килә.* Татарстан яшьләре

**БЕКАС** *и. фр.* Шөлдиләр семьялыгына караган, озын томшыклы, аркасы чуар, түше ак төстәге, зур булмаган саз кошы; чуллык

**БЕКА́С ЯДРӘ** *и.* Бик вак ядрә. *Аларны [чикерткәләрне] бекас ядрәсе белән корылган мылтыктан атып куркыталар.* Умартачылык

**БЕКОН** *и. ингл.* Махсус симертелгән дуңгыз итеннән тозлап яки ыслап әзерләнгән ит ризыгы я ярымфабрикат. *Алар килгәч, тирә-якта чиләк-чиләк сөт бирә торган голланд токымлы сыерлар һәм бекон дуңгызлары үрчеп китте.* Р.Мирхәйдәров

**БЕЛӘ** *бәйл. диал. к.* **белән**. *Бәгъзеләр аларны, Кучүм белә бергә килгән, дип гөман итәләр.* Һ.Атласи. *Икенче җәйдә алар гаиләләре белә күрше авылга күчтеләр.* Казан утлары

**БЕЛӘЗЕК** *и.* 1) Беләк белән кул чугы тоташкан буын тирәсе. *Аңа этидән беләзеккә эләрлек итеп элмәк куйдырдым.* Г.Ибраһимов. *Ниһаять, Пахомов, авыз эченнән генә нидер сөйләнеп, кул сәгатен күзләренә китерде, беләзегендә зәңгәрсу чаткы җемелдәп китте, аннары күк йөзенә каранды.* Г.Бәширов. *Исламгали – колхозның менә дигән тракторчысы – сугышта ике кулын беләзектән өздереп кайткан иде.* М.Мәһдиев

2) Беләккә кия торган бизәнү әйбере, беләк йөзеге. *Әлфия, диван кырыена сөялер-сөялмәс, вак мәрҗәннәр тезелгән беләзеген шудыргалап, бер – стенага, бер беләзегенә карый-карый сөйли, аның чибәр йөзе бик тиз үзгәреп тора иде.* Г.Бәширов *Әбинең ике кулында да – көмеш беләзекләр.* Р.Мирхәйдәров. *Хатын-кызлар кулларына – беләзекләр, балдак, йөзекләр, муеннарына төрле ташлар асарга яратканнар.* Г.Гобәйдуллин

3) Кул сәгате бавы. *Ферма эшчесе Хәбирәгә беләзеге-ние белән саф алтын сәгать тоттырып куймасыннармы!* М.Хәсәнов

4) Кул, өс киемнәренең кул чугы белән беләк тоташкан буынны каплый торган өлеше, җиң очы, манжет. *Барлык размерлар өчен дә үлчәүдәге беләзек әйләнәсенә 4 сантиметр кушарга.* Йорт эшләре

**БЕЛӘК** *и.* Кулбаш белән беләзек арасы. *Бервакытны сул беләгем тартышып китте.* Ә.Айдар. *Әгәр берәрсе*

*аларның каршыларына барса, бу күләгәләрнең хатын-кызлар булуын, аларның беләкләрендә – ак җиңсәләр, алларында – ак алъяпкычлар, иңбашларында ураклар булуын күрер иде.* И.Гази. *Нәфисә үзенең беләгендә аның ирләрчә нык кулын, чәченә сулышы бәрелгәләп китүен тоеп бара.* Г.Бәширов

◊ **Беләк талдыру** 1) Кул ару. *Беләкләрем талды, йорт таланды.* Н.Исәнбәт; 2) *күч.* Гомумән эшләү

**БЕЛӘКСӘ** *и. сир.* Беләкне һәм беләзекне – җәрәхәтләнүдән, күлмәк җиңен пычранудан саклау өчен, беләккә киелә торган эш киеме, җиңсә. *– Безнең Сәлимә бик җиңел куллы, ул [ура] башласын, – ди әни, үзе беләгенә беләксә кия.* М.Гафури

**БЕЛӘМӘН** *и. сөйл.* 1) Күпне белүче, укымышлы, белекле кеше

2) Үзен белемлегә санаучы, минбеләмлекле кеше. *Сәмигулла белән сөйләшү колхоз председателенең ачуын кузгалтты. Менә шуның ише беләмәннәргә күрә колхоз алга бармый да.* Г.Минский

**БЕЛӘМЛЕК** *и.* Күп нәрсәдән хәбәрдар булу сыйфаты. *«Мин беләмлек» дәгъвасы – бер мең вагон.* Г.Тукай. *Әмирҗан үсмер чагында һәм ул егет булгач та, Хөснулла аны яратмый, бигрәк тә, аның артык иркәләнүләре, мактанчыклыгы һәм бөтен кешедән күп беләмлек дәгъвасында булуы Хөснуллага ошамый иде.* Ш.Камал

**БЕЛӘН** *бәйл.* **1.** 1) Бергәлек, бердәй эш итү, юлдашлык, янәшәлек, катнашлык нисбәтен белдерә. *Ул әтисе белән әйбәтләп кенә, матур гына сөйләшергә тиеш.* Г.Рәхим. *Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән.* Г.Тукай. *Снаряд кыйпылчыгы Хисмәтнең тез башын чәлпәрәмә китерде, иптәшләре белән йөгереп барган Хисмәт нарат астындагы чокырга гөрселдәп барып төште.* М.Мәһдиев

2) Берәр объектка карата яки үзара мөнәсәбәтне ачыклаганда кулланыла. *Күбрәк эш белән танышырга, киңрәк практика алырга кирәк әле сиңа.* Ш.Камал. *Дулкыннар ике яклап сал белән уйныйлар.* Г.Ибраһимов. *Низамый үз бакчасының матурлыгы белән безнең каршыбызда мактанган төсле, минем дә Гаяз каршында мактанасым килде.* М.Әмир

3) Эш яки хәрәкәтнең нәрсәдән чыгып, нәрсәгә бәйләп, нәрсә нигезендә эшләнүен белдерә. *Рушадның киңәше белән, ул инде флот турында күпме китап укыды.* М.Мәһдиев. *Аз гына булса да, үз тормышының эчпошыргыч якларыннан аерылды, хәтта аларны онытты да, күзләре алдындагы матурлык белән генә гомер сөрә башлады.* Ф.Әмирхан

4) Эш яки хәрәкәтнең башкарылу рәвешен белдерә. *Түземсезлек белән көтеп тора башлады.* Ф.Хөсни. *Талчыккан аякларны көч-хәл белән атлап, --- чәнәшкәләрне тау башына сөйрибез.* Г.Бәширов. *Галиәсгар Габдуллага мөмкин хәтле каты кагылмаска, йомшак сүзләр белән генә сеңдереп әйтергә теләгән иде.* Ә.Фәйзи

5) Нинди дә булса эшнең яки гамәлнең сәбәбен белдерү өчен кулланыла. *Яшь кызларның алсу йөзе саргаядыр хәсрәт-уй белән.* Җыр. *Сикерәсикерә чабып килгән атын, безне күрү белән, кинәт тартып туктатты ул.* М.Әмир. *Сездә гореф шулай икәнен яшьлегем белән белмәдем.* С.Хәким. *Бу җавап – сыныкка сылтау гына түгел, чыннан да, Гәрәйнең сәбәбе бар, һәм ул, авыр истәлекләр белән, күңелдә утырып калган.* А.Гыйләҗев

6) Шартны белдерә. *Үсемлекнең тереклеге – су белән.* Мәкаль. *Кылыч белән түгел, турылык һәм чынлык белән көчле кешеләр.* М.Җәлил

7) Эш яки хәрәкәтнең максатын белдерә. *Сәгыйтьҗан, ихтыярсыз бүленгән юлын тизрәк дәвам иттерү теләге белән, урынында түземсез генә кузгалып куйды.* Ә.Фәйзи. *Шушы максат белән --- мин мисалларны үземнең тик бер әсәремнән китергәләп үтәм.* Ф.Хөсни

8) Эш яки хәрәкәтнең нинди корал ярдәмендә башкарылуын белдерә. *Суккалыйдыр балта белән кыстырылган чөйгә бу.* Г.Тукай. *[Фәүзия килен] --- озын сәнәк белән чүмәлә зурлыгында чәнчеп бирелгән печәнне тырма белән тартып ала.* Г.Ибраһимов. *Өйалдына чыгып, чиләк белән бозлы су алып керде, нәни генә шешәгә салынган спиртын чыгарды.* Р.Мөхәммәдиев

9) Материалны белдергән сүз янында кулланыла. *Алар урынына, сирәксирәк кенә, корыч белән өртелгән броневиклар үтеп китәләр.* Ш.Усманов. *– Печән өстендә элек тана суя торган иделәр, җә, сыйлагыз әле бер авыл ите белән, – диде ул, учын-учка угалап.* М.Әмирханов. *Бөтен өй алды сарык йоны белән түшәлгән, алты-җиде карчык аларны таратып, тигезләп йөриләр...* Ә.Фәйзи

10) Эш-хәрәкәтне башкару чарасын белдергән сүз янында кулланыла. *Ул көн буе авызы белән балчык ташый.* Г.Тукай. *Ә бит аның иртәнге самолёт белән очасы бар.* Л.Ихсанова. *Шәрәфи бер мең тугыз йөз егерменче елда Мәскәүдән Төркестанга шәрык поезды белән җибәрелде.* Г.Ибраһимов. *Аннан соң океанның һавасы да икенче, тозлы су белән тамагыңны да чайкап җифәрсәң, тавышлар ачылып китә, бер дә Илһам Шакировныкыннан ким түгел.* Тәмуг чәчәге

11) Эш-хәрәкәтнең башкарылу урынын, юнәлешен белдергән сүз янында кулланыла. *Якуб әкрен генә чыгып китте. Килгән сукмак белән кайтасы килмәде аның.* И.Гази. *Ул яңадан күзләрен ачканда, юлдаш абыйлар юк, ат нининдер авыл урамы белән бара иде.* Ә.Фәйзи. *Урманнан юл белән килеп чыккан турыда Идел зур борылыш ясап ала.* Г.Ибраһимов

12) Эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын белдерә. *Иртә белән кайнамакта бу базар, Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.* Г.Тукай. *Иделнең текә ярында ялгыз карт имән бар. Гомере ничә йөз еллар белән санала.* Г.Ибраһимов. *Бер көнне шулай, ай яктысы белән таң яктысы бергә кушылган вакытта, бәпкә үләне өстенә сузылышып яткан-быз да газетны сукалыйбыз.* М.Әмир

13) Эш-хәрәкәтнең тиз генә алмашынуын белдерә. *Апрель числосы керү белән, мәдрәсәдәге бай шәкертләр таралып бетәләр.* М.Гафури. *Гыйлемхан абыйсы турында уйлый башлау белән, Сөмбел җырлавыннан туктап калды.*

М.Хәсәнов. *Йортка килеп керү белән үк, ул өйдә ниндидер күңелсез бер хәл барлыгын сизеп алды.* Ә.Фәйзи. *Теге кеше ишектән керү белән, Халыйк карт, маңгай уртасында бер күз һәм бер генә мөгезе булган хайван күргән төсле, гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде.* Ш.Камал

14) Эш-хәрәкәтнең кире нәтиҗәсен белдерү өчен кулланыла. *Шушы зифалыгы белән ялгыз яшәде микәнни?* Г.Ахунов

15) Чагыштыруны, бердәйлек, тиңлек, тәңгәллекне белдерә. *Саклар өчен зифа буен яман күздән, Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан.* Дәрдемәнд. *Югарыда, көмеш болытлар белән бер биеклектә --- бер бөркет оча.* Ш.Усманов. *Караңгыда без – чәйдә эрегән шикәр белән бер.* Ә.Гаффар. *Сарай астында җиңел тарантаска бәйләнгән зур кара айгыр гына, солы сораган тавыш белән, әкрен генә кешнәп куйды.* М.Әмир

16) Тышкы күренешне бирү өчен кулланыла. *Йокларга ята идем аклы күлмәкләр белән.* Бәет. *Өй түрендәге киезле сәке өстенә сары белән чуптарлап чиккән кизҗеле ашъяулык җәелде.* Ә.Фәйзи

17) Эш-хәрәкәт булган урынның күләмен белдергәндә кулланыла. *Без тоткан фронт сызыгы 40–50 километр белән исәпләнә.* Х.Мөҗәй. *Хуҗаның кодасы, бер чама белән, сайлауда үз ягына аударыр өчен, кемгә нәрсә бирергә тиешле булачагын исәпләп карады.* Г.Ибраһимов

18) Гомумиләштерүне, барысы җыелышып, һәммәсе бергә, дигән мәгънәне белдерә. *Алар нәсел-нәсәпләре белән гаскәри кеше булганнар.* Д.Зөбәерова. *Йортның түрендә балалар белән уйнап йөрүче ябык кына, сипкелле бер малайны чакырып алды.* Ә.Фәйзи

19) Тулылык төсмере бирү өчен кулланыла. *Очрый һаман миңа юлларда илһам белән тулы йөрәкләр.* Х.Туфан

20) Төшем юнәлеше белән белдерелгән эш-хәрәкәтнең үтәүчесен күрсәтү өчен кулланыла. *Карак карак белән тотылыр.* Мәкаль

21) Ничәнче яшькә чыгу, ничәнче яшькә җитүне белдерә. *Җиде яшькә җиту белән, малайны мәдрәсәгә бирделәр.* Г.Ибраһимов

22) Иярүне, катнашып китүне белдерә. *– Кодаларым да килә, сезнең белән бергә киңәш итмәсәк, хәлебез яман, – диде.* Г.Ибраһимов

23) Ким җөмләләрне оештыруда катнаша. *Агач – җимеше белән, адәм – эше белән.* Мәкаль

**2.** *терк. мәгъ.* Бер үк дәрәҗәдәге, уртак мөнәсәбәттәге бер пар, бербөтен була алырлык тиңдәш кисәкләр арасына куела. *Госман, тиз арада, Кәрим белән Мәдинәгә Машаның кем булуын аңлатып бирде.* И.Салахов. *Керсәм, абзыкай белән җиңгәчәй өсләренә киенгәннәр, чыгып утырырга гына торалар.* Ә.Еники. *Кыз белән Харис арттарак калдылар.* Ә.Еники. *Кыз белән ана арасында тулы эчке ышану, сердәшлек, дуслык яши иде.* Т.Галиуллин

**БЕЛӘ́Ү** *и.* 1) Үткенли торган шома таш, кайрак

2) Беләүсыман шомарган, ялтырап торган әйбер. *Будённый районы эчендә йөргән машина һәм арба тәгәрмәчләре күпергә төшә торган юлны шомартып, тәмам беләүгә әйләндереп бетерә торганнар иде.* К.Миңлебаев

◊ **Беләүгә сызу** Беләү белән үткенләү, янау

**БЕЛӘҮЛӘНҮ** *ф.* 1) Беләү шикелле шома, тигез, ялтырап тору. *Ак ватман кәгазь өстеннән узган карандашның кара графит эзе, тәрәзәдән төшкән кояш нурларында, беләүләнеп, шомарган таштай ялтырый.* Н.Хәсәнов

2) Майланып ялтырап кату. *Якасы беләүләнгән күлмәк, ямаулы чалбар кигән.* Ю.Әминов. *Фәргиз аны [пычакны] беләүләнеп каткан фуфайка чабуына ышкыштырып алды.* З.Фәйзуллин

**Беләүләнеп бетү** Тәмам майланып кату, беләүләнү. *Өстендә --- фронттан кайткан вакытта киеп йөри торган зәңгәр галифе чалбар белән зәңгәр гимнастёрка түгел, ә иске гражданский чалбар да беләүләнеп беткән пинжәк. Аягына да, элекке ялтырап торган хром итекләр урынына, кыршылып беткән кирза итек кигән.* В.Нуруллин

**Беләүләнеп калу** Күпмедер вакыт узгач, ниндидер сәбәп белән беләүләнгән хәлгә килү

**Беләүләнеп тору** Беләү кебек күренү

**БЕЛӘҮЛӘ́Ү** *ф.* Беләү белән үткенләү, кайрау

**Беләүләп алу** Тиз генә беләүләү

**Беләүләп ату** Ашыгыч кына, аннанмоннан беләүләү

**Беләүләп бетерү** Барысын да ахырга кадәр беләүләү

**Беләүләп җибәрү** Бераз беләүләү

**Беләүләп җиткерү** Тиешенчә беләүләү

**Беләүләп кую** Алдан ук беләүләү

**Беләүләп тору** Даими, әледән-әле беләүләү

**Беләүләп чыгу** Барысын да рәттән, бер-бер артлы беләүләү

**Беләүли төшү** Беркадәр, бераз беләүләү

**БЕЛГӘ** *бәйл. иск. к.* **белән**. *Уенчак, яшь иде яшьлек көнемдә, Бүген – карт белгә карчык бу замана!* Дәрдемәнд

**БЕЛГЕРТҮ** *ф.* 1) Читләтеп кенә булса да әйтеп сиздерү, аңлату, яшереп калдырмау. *Юк, юк, аңарга әйтергә һәм белгертергә ярамас, башкача бер хәйлә табарга кирәк.* Ш.Мөхәммәдев. *Катыга бәрелеп, азрак тез башы яңгыраган булса да, белгертмәдем, тиз генә чыгып киттем.* М.Гали. *Гомәрнең бу сүзе бетүгә, арада иң кечкенәбез булган Сара да бару турында уйга калганлыгын белгертте: – Әнине сагынмый чыдый алмам шул мин! – диде ул.* Ф.Әмирхан. *[Йортта калган хайваннар үрдәккә:] «Ләкин, берүк, нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!» – дигәннәр.* А.Алиш

2) Сизелер-сизелмәс я аерым билгеләре күрсәтеп тору. *Элек җиткән кеше, үзенең элек җиткәнлеген белгертер өчен, кояшның тап уртасында, кадак кагып, бүреген элеп куярга тиеш.* Ш.Камал. *«Самолёт» конторында пароход килгәнен белгертү өчен флаг та күтәрелде.* Ш.Мөхәммәдев. *Балаларга бу: «Мин сез наяннарны беләм бит», – дигән сыман хәйләкәр, шуның белән бергә дусларча сердәшлекне белгертә торган караш иде.* Ә.Фәйзи. *–Һо-һо-һо,–*

*дип, ымлык белән генә белгертә алды Мөхәммәдәмин үзенең тәүге тәэсирләрен, теленә бу гүзәллеккә бәрабәр сүзләр килми торды.* М.Әмирханов

3) Билгеле итү, күрсәтү, белдерү. *Һәммә урам һәм тыкрыклар бергә килеп кушылган чатта, көтүнең кайда җыелуын белгертеп, чыбыркы шартлады.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу факт Асоевның үз хакын яхшы белүче, эшлекле, кешене погонына карап кына бәяләми торган киң күңелле булуын белгертә иде.* Х.Камалов

4) *сөйл.* Аңлату, җиткерү. *Ата-бабаның Еллар көч түгеп Тапкан гыйльменнән Безгә син белгерт!* Н.Исәнбәт

**Белгертә башлау** Белгертергә тотыну. *Татарлар ушбу заманда үзләренең дөньяда барлыкларын белгертә башладылар.* Г.Тукай

**Белгертә төшү** Тагы да бераз белгертү

**Белгертеп алу** Бераз, кыска гына белгертү. *Ул, башын чайкап, гаҗәпкә калуын белгертеп алды.* Х.Камалов

**Белгертеп бетерү** Күп кешегә яки барысын да ахырга кадәр белгертү. *Юк, дусты гына түгел иде Хәмәт! «Дус» дигән бер кыска гына сүз аларның берберсе өчен кем булганлыгын әйтеп, белгертеп бетерә аламы соң?!* М.Вәли-Барҗылы

**Белгертеп калу** Белгертергә өлгерү, белгертергә ашыгу. *Әйтерсең ул элек үзе дә аңлап, белеп бетермәгән һәм әйтеп өлгермәгән хисләрен белгертеп калырга теләгән.* Р.Нуруллина

**Белгертеп кую** Алдан белгертү. *Икенче көнне, ашханәдән кайтып, чәй эчәргә утырыр алдыннан, Сабир белгертеп куйды: – Җегетләр, чәйдән соң беркая чыгып китмәгебаз, сөйләшәсе сүзләр бар.* А.Алиш

**Белгертеп тору** 1) Әледән-әле, еш белгертү; бертуктаусыз белгертү. *Безнең матбугат чаралары да аңа битараф калмады, үз фикерләрен белгертеп тордылар.* М.Әмирханов. *Әлеге истәлекле бүләкләре белән Бакый Урманче бүген дә үзенең барлыгын белгертеп тора.* У.Альмеев

2) Әле, хәзер белгертү. *Шартлау утлары гына төн караңгылыгында зилзиләнең кай төштә икәнен белгертеп тора...* Х.Камалов

**Белгертеп үтү** Сүз уңаенда белгертү. *Соңгы сүз итеп, аның иҗатын һәм исемен киләчәк буыннарга саклау кирәклеге турындагы фикерләремне дә белгертеп үтим.* Л.Хәмидуллин

**БЕЛГЕЧ** *и.* 1) Фәннең, техниканың яки хуҗалыкның бер тармагы буенча махсус белемгә ия булган кеше. *Музыка белгечләре, тәнкыйтьчеләр, педагоглар һәм барлык укучыларыбыздан бу беренче тәҗрибә турында фикерләрен әйтүләрен сорыйбыз.* М.Җәлил. *Фрунзе – тәҗрибәле хәрби белгеч, ни кылганын яхшы белә, Көнчыгыш фронтта хәлиткеч җиңүләргә ирешәчәге көн кебек ачык.* Ф.Сафин. *Сәясәт белгече Л.Поляков әлеге темага карата болай яза.* Татарстан. *Үземне фольклор белгече дип саныйм һәм халык иҗатын бик яратам.* Юлдаш

2) Нинди дә булса эшнең остасы. *Соңбит, абый, бишьеллыкны үтәү өчен дә шахтадан күтәрелгән белгечләр кирәк.* Һ.Такташ

**БЕЛГЕЧЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Белгечләргә охшатып, белгечләр кебек. *Яшь бакчачы көйләне, төрле ягыннан әйләнеп, белгечләрчә игътибар белән карап чыкты.* М.Әмир

**БЕЛГЕЧЛЕК** *и.* Фән, техника, халык хуҗалыгының берәр тармагында эшләү өчен аерым һөнәргә махсус әзерлек; махсус әзерлек таләп итә торган эшчәнлек. *Тикмәгә генә тар белгечлекне уйлап чыгармаганнардыр.* В.Шәрипов. *Тора-бара, хәлләр туктаусыз камилләшә барган шушы производствода аңа башка белгечлекләр дә үзләштерергә туры килде.* Н.Хәсәнов. *Чөнки табиб, фармацевт һәм повар белгечлекләре Кытайда бер-береннән әллә ни аерылмый.* Татарстан яшьләре

**БЕЛДЕК** *и.* Минбеләмлек, акыл, сиземләү. *Ул – ихтыярсыз, үз белдеге белән берни дә хәл итәрлек түгел иде.* Р.Зәйдулла. *Нәфисә алтыным, карап кына йөри күр, берүк, сугыш җире ләбаса, әллә кем әйтмешли, җайлы-җайсыз, үз белдегең белән читкә тайпыла күрмә.* Г.Бәширов. *Үз белдекләре белән генә эшлиләр.* И.Гази

◊ **Белдек сату** Минбеләмлек күрсәтү, кешедән үзен өстен итеп күрсәтергә, артык акыллы булып күренергә тырышу

**БЕЛДЕКЛЕ** *с.* **1**. 1) Күп белгән, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, тирән белемле. *Кай арада без малайлары белән дуслашып та алабыз, белдекле һәм эшем кешеләредәй, аларга урманны күрсәтеп тә йөрибез.* К.Миңлебаев. *– Белдекле кешеләр әйтәләр, – диде Якуб, бераз дәшми торганнан соң, – бу тормышны өр-яңадан корырга кирәк, диләр.* И.Гази. *Белдекле әни беркайчан да баласын гел кулда гына йөртмәс.* Сөембикә

2) *куч.* Бик белемле булып күренергә тырышкан. *– Аларның Алласы – Маркс, – диде фрау Ева, белдекле төстә.* Т.Әйди. *Бу инде, элекке кебек, беркемгә дә ышанырга һәм охшарга теләмичә, үз идеалына гына табынып өйрәнгән, үз белдекле, җиңел холыклы ярым малай, ярым егет түгел.* Г.Бәширов

**2**. *и. мәгъ.* Белеме булган, күп белгән кеше, галим. *Кайбер бик белдекленәр, магнит ир белән хатынны татулаштыра, гаиләне бәхетле итә, дигәннәр.* Могҗизалар энциклопедиясе

**3.** *рәв. мәгъ.* Белемле булып күренергә тырышып, күп белгәндәй булып. *Бөтенесен алдан белеп торырга, белеп җиткермәсә дә, бик белдекле булып, үзеннән өстәп сөйләргә яратучы Митричев монда да түзә алмады.* Г.Бәширов. *Яшь председательнең аңа караганда да белдеклерәк булып, җитмәсә төзәтмәләр кертүе аның ачуын кабарткаsuccessful-кабарта.* Ә.Еники. *– Аннан гына бура утыртабыз, – диде Шамил, белдекле кыланып.* Ф.Сафин

**БЕЛДЕКЛЕК** *и.* Мәгълүматлылык, хәбәрдарлык, үз акылы белән генә эш итү. *Үз белдеклегегез белән дәвалый күрмәгез, зыяны күбрәк булуы бар.* Мәгърифәт

**БЕЛДЕКЛЕЛӘНҮ** *ф.* Белдеклелек күрсәтү, күп белгәндәй булырга омтылу. *Мусаның иң сөймәгәне – фикерен тыңлап бетермәстән, аны бүлдерү, белдеклеләнеп, әңгәмәнең кызуын сүрелдерерлек сүз кыстырып кую.* Ф.Сафин

**Белдеклеләнеп алу** Бераз, бик кыска вакытта белдекле булып күренергә тырышу

**Белдеклеләнеп җибәрү** Артык белдеклелек күрсәтергә тотыну

**Белдеклеләнеп йөрү** Озак вакытлардан бирле үзен күп белгәндәй күрсәтү

**Белдеклеләнеп китү** Кинәт кенә белдеклеләнә башлау

**Белдеклеләнеп кую** Көтмәгәндә, бераз, аз гына белдеклеләнү

**Белдеклеләнеп тору** Әле, күз алдында белдеклеләнү

**БЕЛДЕКЛЕЛЕК** *и.* Белдекле булу. *--- старосталар үзләрен бик эре, бик һавалы тотучан булалар, үзләрен бөтен авылның хуҗасы итеп, барлык законнарны белүче, укымышлы кеше итеп саныйлар. Мактану, тәкәбберлек, белдеклелек – аларга хас сыйфат.* М.Җәлил

**БЕЛДЕКСЕЗ** *с.* Белемсез, надан. *Өченчесе: «Яшьләр тәмам азып-тузып, бозылып бетте. Явыз һәм белдексез алар» [диде].* Ш.Галиев. *Белдексез кеше бала-чага белән утырдаш булыр.* Н.Исәнбәт

**БЕЛДЕКСЕЗЛЕК** *и.* Наданлык, белемсезлек, хәбәрдар булмау. *Беренче игътибар иткән мәлдә, белдексезлек кәсафәте, дип кенә уйлаган идем.* Ф.Сафин

**БЕЛДЕРМӘ** *и. сир.* Игълан, махсус белдерү, хәбәр

**БЕЛДЕРҮ** I *ф.* 1) Кемгәдер берәр нәрсәне хәбәр итү, әйтү, белгертү, җиткерү. *Син әтиләргә белдерә күрмә, мин, бернечә тапкыр, үз теләгем белән Кызыл Армиягә язылырга барган идем, яшең җитми, дип алмыйлар.* Т.Гыйззәт. *Ә син алданганыңны Белдермәскә теләп тынасың.* Һ.Такташ

2) Игълан итү, әйтү. *Мине, бу елдан башлап, шәһәр мәктәбенә җибәреп укытырга теләвен белдерде.* М.Гафури. *Моңарчы тыныч кына утырган кыз да безгә катнашырга теләгәнлеген белдерде.* М.Әмир. *Җыелышны ябык дип белдерәм.* Т.Гыйззәт

3) Күрсәтү, аңлату, эчтәлеккә салынган мәгънәне бирү. *Ул [барс] хакимлекнең шаһият тарафыннан бирелүен, аның изгелеген, кагылгысызлыгын белдерә.* Г.Дәүләтшин. *--- бу урында [сүзләр] уңышсыз кулланылганнар, һәм алар тиешле мәгънәне белдерә алмыйлар.* Р.Юсупов. *Эчтәлекне максималь тулы саклау өчен, сүз сайлаганда бик игътибарлы булырга, оригиналдагы һәр сүзнең, бигрәк тә иң әһәмиятле фикер белдерә торган сүзләрнең мәгънәләре төгәл бирелергә тиеш, дип санаганнар.* Р.Юсупов

4) Ишарә яки мимика белән нидер аңларлык итеп сиздерү, күрсәтү. *Без, үзебезнең авылда концерт оештырырга уйлавыбызны әйтеп, аның да катнашуын үтенгәч, килергә ризалыгын белдереп елмайды.* М.Әмир. *Үзе миңа тегене үртәвен белдереп күз кыса.* М.Гали. *Шуңар күрә туганымнан дәлил-фәлән сорап тормады, йөзенә яңлыш вә салкын бер ачыклык чыгарып, җиңел генә башын селкеп, туганымның сүзенә ышанганлыгын белдертте.* Ф.Әмирхан

5) *сөйл.* Төшендерү, аңлату. *Түзмәдем бит, Гөлнарга, гыйшык тотканымны белдереп, озын хат яздым.* Ә.Айдар. *Минем кесәдә бер сум гына барын парикмахерга белдергәч, безнең арада озак диалог, монологлар булып алды.* Һ.Такташ. *Пахомов, «тегендә»нең кайда булуын белдереп, башы белән артка таба ымлады.* Г.Бәширов

**Белдерә башлау** Белдерергә тотыну. *Заманында «ике» иң зур сан булып исәпләнгән. Аның иң борынгы тамыры – [и]. Тора-бара, аңа күплекне белдерүче [к] авазы өстәлгән. Шуннан соң ул «күк» төшенчәсен белдерә башлаган.* С.Поварисов

**Белдерә төшү** Яхшылабрак, аңлаешлырак итеп белдерү

**Белдереп алу** Тиз генә белдерү; берара белдергән булу. *«Тукай турында опера язабыз» дип, җәмәгатьчелек алдында вәгъдә биргән, хәтта үзара конкурентлык дәгъвасы да белдереп алган хөрмәтле композиторларыбызның иҗат нәтиҗәсе әлегә күренми.* Р.Фәйзуллин

**Белдереп бару** Һәрберсенә, һәр очракны даими белдерү. *Өйдәге карчыклар аның сөйләменә, «Сөбханалла!», «Тәүбә-тәүбә!», «Ходаем сакласын!» кебек сүзләр кыстырып, үз мөнәсәбәтләрен белдереп баралар.* Г.Гыйльманов

**Белдереп җиткерү** Тиешенчә белдерү

**Белдереп килү** Даими рәвештә, күптәннән үк белдерү. *Россиядә Казан татарларына карата бу рәсми тарихи теориянең дөрес булуына шикне узганның һәм бүгенгенең байтак күренекле кешеләре белдерде һәм белдереп килә.* Т.Кәримов

**Белдереп китү** Сүз уңаенда, бердән белдерү. *Галимнәрнең өлешенә кермәстән, сүз уңаеннан үз фаразымны белдереп китим.* М.Вәлиев

**Белдереп кую** Кинәт белгертү. *Вокзал тышындагы колокол да үзенең дөньяда барлыгын белдереп куйды.* К.Нәҗми. *Йозеф Пацкерт, бу табылдыкка карата, Урта гасырлар фальсификациясе җимеше, ягъни ялган акча түгел микән, дип, шик тә белдереп куйды.* Р.Вәлиев

**Белдереп тору** Әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда белдерү. *Правление ишегалдына бәйләп куелган, күбеккә баткан иярле ике ат көтелгән хәбәрчеләрнең дә килеп җиткәнен белдереп тора иде.* Ш.Усманов. *Дөньяның бетмәс мәшәкәтләрен белдереп тора иде.* М.Гафури

**Белдереп чыгу** Барысына да, һәрберсенә аерым-аерым белдерү

**БЕЛДЕРҮ** II *и.* 1) Язма игълан. *Иргәгәсен инде чаттагы баганага зурзур хәрефләр белән бик тырышып язылган бер белдерү ябыштырылган иде.* А.Шамов. *Узган-барганнарның кайберләре, багана янына туктап, белдерүне укыйлар да елмаялар.* А.Шамов

2) Катгый рәвештә мәгълүм ителгән рәсми хәбәр. *Бу хакта хөкүмәт белдерүе бар*

**БЕЛЕК** *и.* 1) Белем, гыйлем, акыл. *Өстеңә яу килсә, батырлыгың китәр, башыңа яу килсә, белегең китәр.* Мәкаль

2) Мәгълүмат, хәбәр. *Белгәнгә – белек, белмәгәнгә – көлек.* Мәкаль

◊ **Белек сату** *к.* **белдек сату**

**БЕЛЕКЛЕ** *с.* 1) Белемле, гыйлемле, хәбәрдар. *Ул кадәр белекле түгел,*

*ләкин үзебезнең борынгы философларыбызның китапларында укыганым бар: әгәр бер-бер халык сәүдә юлы өстенә килеп утырса, ул халык чит халыклар белән катышу вә сәүдә аркасында байый...* Г.Гобәйдуллин. *Дошман белекле, зиһенле икән, безгә дә ахмак булу ярамый.* Ф.Сафин. --- *сарайда бар нәрсәдән дә хәбәрдар вә белекле кеше – кәтиб иде.* М.Хәбибуллин

2) Аңлап эшли торган, әйткәнне тиз төшенә торган. *Белекле дошманнан курыкма, белексез дустан курык.* Мәкаль. – *Күрән бине башлы, белекле дип сөйләгәннәре – чын булмады бу, – диде илче карт.* Н.Фәттах

3) *шелт.* Артык күп белемле булып күренергә тырышкан, акыл саткан

**БЕЛЕКСЕЗ** *с.* **1.** 1) Аңсыз, белемсез, мәгълүматы булмаган. *Белексез дустан белекле дошман артык.* Мәкаль. *Күрән би, башка барлык ырудашлары кебек, аңсыз, белексез бер кешегә әйләнде.* Н.Фәттах

2) Билгесез, мәгълүм түгел. *Анам сорсаң – никяхсыз, Атам сорсаң – белексез.* Хикәят

**2.** *рәв. мәгъ.* Аңсызлык, белемсезлек күрсәтеп. *Зурәптәй исә, әниләрне, колхозга кермәгән өчен, белексез булып мал-мөлкәтебезне вәйран иткән өчен, кабат-кабат битәрләп ала да,ниләрдер туплап, шуны сеңлесенә биреп җибәрә икән.* К.Миңлебаев

**БЕЛЕКСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Белексезлек күрсәтү. *Аның, белексезләнеп, бер дә Гомәр абзыйсын рәнҗетәсе килми иде.* Ф.Сафин

**БЕЛЕКСЕЗЛЕК** *и.* Наданлык, мәгълүматсызлык, белемсез булу, томаналык. – *Белексезлек харап итәчәк безне! – Айхенвальд Сәгыйтов ярым ачык калдырган ишекне барып япты.* Ф.Сафин. *Ходай биргән зиһеннең, укып җыйган белемнең чиген үтеп, белексезлек ягына чыкма.* Ф.Сафин

**БЕЛЕКЧЕ** *с.* Им-томчы, дәвалаучы. *Әгәр син «җан» дигән серле дөньяның могҗизалы ачкычын убырдан алып калмасаң, Тәминдарны күптән югалтыр идең. Ә бит аны терелтүче – син! Син – белекче кыз!..* Н.Гыйматдинова

**БЕЛЕМ** *и.* 1) Чынбарлыкны танып белүдә кеше акылы ирешкән фәнни ачышларның, фикер һәм хөкемнәрнең тупланмасы. *Ап-ачык тор һәрвакытта, И китап, багам сиңа: Чын, асыл нигезле җирдән Күп белемнәр бир миңа!* Ш.Бабич. *Бу мәсьәләдә коры тойгы белән эш итү генә җитми, белем кирәк.* М.Әмир. *Белемгә омтылыш булмау – бу инде рухи байлыкның «б» хәрефен дә калдырмый...* Ватаным Татарстан

2) Тәҗрибә нигезендә, бөтен табигать, җәмгыять турында буыннан-буынга тупланып килгән мәгълүмат; гыйлем. *Туган тел аша яшь буынга халыкның бай рухи мәдәнияте, аның дөньяны танып белүе, идеаллары, халыкның озак еллар буе тупланган белеме һәм тормыш тәҗрибәсе тапшырыла.* Ә.Хуҗиәхмәтов

3) Ниндидер өлкәдә тупланган мәгълүмат. *Урта махсус һәм югары һөнәри белем бирү уку йортларында, аз санда булса да, татар телендә белем бирүче төркемнәр барлыкка килде.* А.Низамов. --- *армиягә алынырга тиешле 30 меңләп үсмер техник белем алу курсларында укыган.* Г.Шакиров

4) Фәннең берәр тармагы, гыйлем. *Ул [стилистика фәне] үзенең беренче адымнарын тел белеме белән әдәбият белеме арасында башлап җибәрә.* Х.Курбатов. *Әмма фән ул – тарих, әдәбият, табигать белеме генә түгел.* М.Гайнетдинов. *Р.Фәхреддин – педагогика, әдәбият, тел белеме, тарих, фәлсәфә, этнография, хокук белеме һәм башка фәннәр буенча бик күп хезмәтләр язган шәхес.* Татар халык педагогикасы

**БЕЛЕМЛЕ** *с.* **1.** 1) Зур белемгә, мәгълүматка ия; укымышлы, гыйлемле. *Белемле кеше югалмас.* Мәкаль

2) Нинди дә булса күләмдә махсус белеме булган. *Син дә урта белемле, мин дә урта белемле.* Г.Афзал. *Әлтафи шул вакытта үзенең – училище студенты, ә янындагы кешенең югары белемле укытучы, үзенең остазы икәнен онытты.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* Белемле булган, гыйлемле кеше. *Белемле үлсә, кәгазьдә хаты калыр; оста үлсә, эшләгән заты калыр.* Мәкаль. *Белемле үлмәс, белемсез көн күрмәс.* Мәкаль. *Тубылгы зур булмас, белемле хур булмас.* Мәкаль

**БЕЛЕМЛЕЛЕК** *и.* Укымышлылык, гыйлемлелек. *Кызларының ул чибәрлеген, ул инсафлылыгын, ул белемлелеген кат-кат сөйлиләр.* Тәмуг чәчәге

**БЕЛЕМСЕЗЛЕК** *и.* Белем булмау, наданлык, томаналык. *Белемсезлек аркасында Ни күрмәде бу башлар, Тәрбиясез ир кулында Түгәбез канлы яшьләр.* Ш.Мөхәммәдев. *Белемсезлек һәм монафикълык эчендә булучыларның төшләре дә шул тарлыклардан уза алмый.* Төшлек

**БЕЛЕН** *и. рус.* 1) Әче сыек камырдан юка гына итеп пешерелгән коймак. *Менә мин мичкә ягам да белен пешерәм.* Г.Ибраһимов. *Белене дә булыр, өйрәсе, итле бәрәңгесе дә булыр, кызларның да, киленнәрнең дә, Гайнияләр, Гыйльминур җиңгиләр кебек, ана арысланнарын җыярмын, – иллә мәгәр эшләүгә беләкләрегез түзсен.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Тигез су өслегенә нинди дә булса авыр әйбер төшүдән барлыкка килгән бөҗралар. *Анда, ташып килә торган --- өстенә, ташлар ыргытып, «беленнәр» ясарга тотынды.* Ә.Фәйзи

3) *күч.* Кояшта кипкән сыер, бозау тизәге. *Чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, авылның үз бозаулары салып калдырган «беленнәр» күпме генә соң ул?* Ә.Еники

**БЕЛЕНЕ́Р-БЕЛЕНМӘС** *с.* **1**. Сизелер-сизелмәс, аз гына сизелерлек, аз гына төсмерләнерлек. *Алар әле, Габдулла өчен, ачылып бетмәгән ерак, матур дөньяның беленер-беленмәс серле маяклары булып калдылар.* Ә.Фәйзи. *Күк фонында беленер-беленмәс кенә сызылган үрләрне, чокырларны, бер читтәрәк торган ташландык кирпеч сарайларны күрә.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Сизелер-сизелмәс булып. *[Газизнең] Иреннәре беленер-беленмәс кенә тетри.* Ш.Камал

**3**. *и. мәгъ.* Эңгер-меңгер вакыт. *Берничә сәгать үтүгә, таң беленер-беленмәстә, Марат инде әнисеннән әллә кайда еракта, зур самолётта көнчыгышка таба оча иде.* Г.Гобәй

**БЕЛЕНҮ** *ф.* 1) Ачыклану, билгеле булу, аныклану, мәгълүм булу. *Батыр яуда беленер, телчән дауда беленер.* Мәкаль. *Һәм конвертта ниндидер бер рәсем дә барлыгы беленде.* А.Әхмәт. *Туган җир! Аның нәрсә икәнлеге аерылгач беленә.* Ә.Баян. *Якыная төшкәч, аның шәһәр кебек нәрсә икәнлеге беленде.* Р.Мөхәммәдиев // Фаш ителү. *Ләкин, халыкка беленеп, хәзрәткә җиткерүләре бар.* Т.Гыйззәт

2) Сизелү, сизелеп килү, төсмерләнү, шәйләнү. *Таң беленү белән, эшкә киттем.* К.Тимбикова. *Платонча, гүзәллек кешеләрнең хисләренә бирелми, ул фәкать акыл белән генә танып беленә ала.* К.Гыйззәтов

3) Күзгә ташлану, күренү. *[Гөлҗиһан:] Юк, алай зарарлы түгел, бик беленми.* Г.Камал. – *Киленкәем, инә белән җеп тап, бер-ике урыннан чәнечсәң, тора бирер, мондый ак әйбердә беленми ул, – диде.* Г.Ибраһимов

**Беленә башлау** Беленү билгеләре барлыкка килү. *Соңгы тапкыр уянуымда, таң беленә башлаган иде.* Г.Әпсәләмов

**Беленә төшү** Бераз беленү

**Беленеп җитү** Тулысынча беленү. *Кичке очрашуда, Киек Каз Юлы аермачык беленеп җитәрәк, Байназар --- кыз моңарчы уйларга да курыккан сүзне әйтте: – Өйләнәм.* М.Хуҗин

**Беленеп калу** Нәрсәдәндер, ниндидер сәбәптән беленергә өлгерү. – *Ефимовта Сәлим эше белән кызыксыну, җинаятьне ничек тә ачарга омтылу чалымы беленеп калды.* Х.Камалов

**Беленеп килү** Аз-азлап, акрынлап беленү. *Җәйге кыска төннең таңы беленеп килгәндә, кинәт, сискәндереп, каты итеп, йорт капкасын шакыганнар.* Г.Сәгыйров

**Беленеп китү** Кинәт кенә, беркадәр беленү

**Беленеп кую** Көтмәгәндә беленү

**Беленеп тору** Шактый беленү, әллә кайдан күренү. *Киемнәре, йөреше-торышы белән үк тәрбия һәм дөнья күрмәгәнлеге беленеп тора.* М.Фәйзи. *Аның кабыргалары беленеп торган арык тәне камчы эзе белән тулган, бите тырналып беткән, сулышы еш һәм зәгыйфь иде.* Г.Гобәй

**Беленеп яту** Аермачык булып беленү. *Аннан соң кар явып киткән китүен дә, ә барыбер чаңгы эзләре беленеп ята.* И.Хуҗин

**БЕЛЕ́Р-БЕЛМӘС** *рәв.* Төгәл белмәстән, белмичә, аңламыйча. *Бәлкем, аның әйткәннәре бөтенләй үк нигезсез түгелдер, белер-белмәс сөйләсә дә, бәлкем, дөреслеккә туры киләдер?* Ә.Еники

**БЕЛЕШ** *и.* **1.** Сөйләшеп, берникадәр аралашып йөргән кеше, белешлек иткән кеше, таныш кеше. *Мондагы гаиләләрнең баераклары, һәммәсе диярлек, Рәсимә абыстай белән белешләр икән: аннан да, моннан да аңар баш иядәр, кайсылар озак-озак сөйләшеп тә китәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Мин гүр иясе булгач, белешләремне йөреп чык...* Г.Бәширов. *И-и, чынласаң, без белешләрдер дә әле.* М.Хуҗин

**2**. *с. мәгъ. сир.* Таныш булган. *Ләкин хәзрәтнең үзе белән белеш кешеләр моңар бер дә гаҗәпләнмәсләр.* Ф.Әмирхан. *Үземнең белеш казакъларда гына бар ул.* Ш.Камал

**БЕЛЕШЛӘНҮ** *ф. сир.* Танышу. *Әптерәшит белән дә белешләнсәң, бик күңелле булыр, бер дә эчеңне тишмәс.* Г.Камал. *Иң әүвәл, ничек итеп булса да, синең белән белешләндем, аннан соң, бу ирен ярата микән, юк микән, дип, синең җәяңне тартып карадым, ирең белән бик тату тормаганлыгыңны белгәч, аннан соң, барып, сиңа серне сөйләдем.* Г.Камал

**Белешләнеп китү** Тора-бара, ниндидер вакыйгадан соң белешләнү

**БЕЛЕШЛЕК** *и.* Бер-берсен яхшы белгән кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, танышлык, әшнәлек. *Сәүдәгәр руслар белән белешсәң дә, бу белешлекләрдән миңа кызык булачак түгеллеген анык белә идем.* Ф.Әмирхан

**БЕЛЕШМӘ** *и.* **1.** 1) Махсус тупланган мәгълүматлар җыелмасы. *Ләкин соңгы 50 елда мондый гигант чуртаннарны тоту турында белешмәләр юк.* Кызыклар дөньясында

2) Эш-хәл хакында кыскача бирелгән мәгълүмат, таныклык. *Чынлыкта инде иреккә чыгарылган Янгуразга Вустрау Зондер лагере коменданты аның кемлеген раслый торган белешмә язып тапшырды.* Т.Әйди. *Заһидә ничә курс тәмам итүе хакында белешмә алды да Такташ артыннан Ташкентка китеп барды.* Ф.Сафин. *Республика Социаль яклау министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, җылылык субсидиясен алу өчен, элегрәк тапшырган белешмәләр ярый.* Ватаным Татарстан

3) *к.* **белешмәлек.** *Собчакның өстәленә бихисап белешмәләр өелде.* М.Галиев.

**2**. *с. мәгъ.* Фактлар, мәгълүматлар тупланган. *Һәркем үз эше белән мәшгуль: кайсы сыза, кайсы белешмә китапларны актара, исәп-хисап ясый.* Н.Хәсәнов

**БЕЛЕШМӘ́ БЮРОСЫ** *и.* Мәгълүмат бирә торган учреждение. *Илгизәр кулында – уч төбе кадәр генә кәгазь, белешмә бюросыннан бирелгән адрес.* Н.Хәсәнов

**БЕЛЕШМӘЛӘ́Р БҮЛЕГЕ** *и. к.* **белешмә бюросы**

**БЕЛЕШМӘЛЕК** *и.* Белешмәләр, фактлар, мәгълүматлар тупланган кулланма ярдәмлек. *Өйләрендә булган белешмәлекләрдә дә алар хакында хәбәр теркәлмәгән булып чыкты.* Т.Әйди

**БЕЛЕ́ШМИЧӘ** *рәв. сөйл. к.* **белештермичә**. *Үлеп сусаган кеше су күреп капланган кебек, үз-үзен белешмичә, дөньясын онытып, мәхәббәт иркенә бирелде.* М.Хәсәнов

**БЕЛЕ́Ш-ТАНЫШ** *җый. и.* **1.** Белгән, күргән, үзара таныш кешеләр. *Габделгалләмнең эчендә әдәбият кичәсенә бару-бармау фикерләре сугыша иде: белеш-танышка очрасаң әллә ни?* Ф.Әмирхан. *Синең белеш-таныш бик күп бит.* Ш.Камал. *Белеше-танышының карашларыннан качарга теләгән сымаграк.* Ф.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* Белгән яки таныш булган. *Трактирдан трактирга йөргәндә, менә Галиәкбәр агайга үзенең белеш-таныш руслары тугры килеп, моны үзләренең компанияләренә чакырып утырттылар һәм коньяк заказать иттеләр.* Ш.Мөхәммәдев

**БЕЛЕШТЕ́РМӘСТӘН** *рәв. к.* **белештермичә**. *Равил, ни эшләвен белештермәстән, кызны күтәреп алды да*

*зыр-зыр әйләндерергә тотынды*. В.Нуруллин

**БЕЛЕШТЕ́РМИЧӘ** *рәв.* Аңсыз рәвештә, уйламыйча. *Шуннан Мәдинәнең: «Үземне-үзем белештермичә, бик озак ярсып еладым», – дигән сүзе исенә төште.* Ш.Камал. *Җырлап бетергән саен, яңабаштан куям да, сабый бала кебек, үз-үземне белештермичә, сокланып тыңлыйм.* И.Гази. *Ул көнне Рәүфә, кинәт үзгәреп, сүзсез калып, үзен-үзе белештермичә эшләп йөрде.* А.Шамов

**БЕЛЕШТЕРҮ** *ф.* 1) *сир.* Таныштыру. *Мине аның белән, әүвәл мәртәбә, үзебез торган дачаның тимер юл станцасында белештерделәр.* Ф.Әмирхан

2) Тиз генә белешеп алу, сорашып, танышып чыгу. *Киленем эшкә килгәндә дә үзен сынатмый. Шушы йортта дүртбиш ел гомер иткән кебек, барын да белештереп, җиренә җиткереп эшли.* Г.Толымбай. *Иртәгәсен көтү куганда, Галимҗан, бер карчыктан Улак чишмәсе юлын белештереп, урманга кереп киткән, ләкин адашкан.* Т.Нәбиуллин

3) **белештермәү** *юкл. форм.* Үз-үзенә, үз эшенә хисап бирмәү, аңсыз рәвештә, аңышмыйча эшләү. *[Габдулла] Үзенең кая барганын белештермәстән, урам буйлап китте.* Ә.Фәйзи

**Белештереп бару** Даими, системалы белештерү. *Калада яшәсәм дә, «югарыдагылар» хәленнән хәбәрләрне шул ук гәзитләрдән генә белештереп барам, алар да ул мәкаләләргә күз салалардыр, тәгаен.* Ф.Яхин

**Белештереп бетерү** Тулысынча, барысын да, ахырга кадәр белештерү. *Авылда чакта, сазлыкка баткан кеше бәргәләнгәндәй, үзе кылган гамәлләрнең яхшымы-яманмы икәнен белештереп тә бетермәде.* Ф.Садриев

**Белештереп җиткерү** Тиешенчә белештерү. – *Әлбәттә, --- – ди ул, нәрсә әйткәнен үзе дә белештереп җиткермичә ---.* И.Гази

**Белештереп йөрү** Кем яки нәрсә турында булса да, күп итеп, һәркемнән белештерү

**Белештереп тору** Һәрвакыт, даими белештерү

**БЕЛЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **белү.** *Ләкин егетләр-кызлар, барыбер, берберсен яратышканнар, бер-берсенең мәхәббәтләрен белешкәннәр.* Г.Әпсәләмов

2) Кирәкле нәрсә турында мәгълүмат туплау, артыннан йөрү, сораштыру; барып яки сорап белү. *Нәфисә кайчанрак туктарга уйлавын белешергә баргач, Гөлсем, узып барышлый, әллә чынлап, әллә шаярып: «Чулпан калыккач!» – дип кычкырды.* Г.Бәширов. *Нәкъ шул чакта будкага таба килә торган юлда отряд турында белешергә киткән кызылармеец һәм тагы өч кеше күренде.* Г.Гобәй. *Ул башта мандат комиссиясеннән белешмәкче булды.* А.Шамов. – *Соңга каласың, дип торам. Белешеп кайттым, машина хәзер килә, – диде ул.* А.Гыйләҗев

3) Эзләү, эзләп табу. *Түбәгә шифер белешәм, буяулар алып кайтам.* Р.Төхфәтуллин

4) Сораштыру, кемнең дә булса хәле, яшәеше, сәламәтлеге белән танышу. *Минем һәм әниемнең хәлләрен сорашты, нинди дарулар кирәк, дип белеште.* Г.Сәгыйров. *Ярым сәгатьтән соң мин, хәлен белешеп китмәкче булып, әби янына килдем.* Ф.Әмирхан. *Мышнап беткән Сөләйманов, берничә секундка гына ялт итеп күренеп, Коненконың хәлен белеште дә, чыраен сытып, камыш эченә кереп югалды.* И.Гази

5) Хәбәрләшү. *Идел алкын, суы салкын, ишеп булмый салларны; Беребез анда, беребез монда, белешеп булмый хәлләрне.* М.Фәйзи. *Аннан тагы Карамалы остага чапканнар, бер кире китсә китә бит, гөнаһ шомлык: бу, ди, өендә юк, ди, калада берәүнең кулымы, аягымы чыккан икән, ди, шуны докторлар төзәтә алмагач, Карамалы остасын алдырткannar, ди, инде менә хәзер, көненә ничә белешеп, шуларның кайтканнарын көтәләр, ди.* Г.Ибраһимов

6) Танышу. – *Хатын-кыз белән белешер өчен, үз-үзенең кем икәнен яшереп йөри, мужик... – ди-ди сөйләнеп, беренче класска кереп китте.* М.Фәйзи

7) Белеш булып яшәү, танышлык тоту. *Шушы өйдә үзенең якын туганы булып та, хәзергә хәтле белешми тору, бу хәлнең хәзер сәер рәвештә ачылуы аңа кызык тоела.* Ш.Камал

8) *к.* **белештерү** (*3 мәгъ.*). *«Ул бит хәзер акылдан шашкан, белешеп әйтми ул, аның хатыны Гөлҗиһан синең Әсмаңнан мең өлеш артык, синең йөз Әсмаңны бәреп егар», – дим.* Г.Камал. *Төнлә белән ялангач көенчә чыгып китеп, белешмичә, әллә кайларга китеп, суга барып төшүе ихтимал.* Г.Камал

**Белешә башлау** Белешергә тотыну. *Инде хәл-әхвәлләрне белешә башлаганбыз икән, бер сорау мөмкинме?* Ф.Садриев

**Белешә төшү** Тагы да өстәп белешү

**Белешеп алу** Тиз генә белешү. *Нәшриятның планы әле көз айларында гына кысаларга керәчәк икән, моны белешеп алдым да Вахитның кульъязмасын күз уңыннан читкәрәк тыгып куйдым.* М.Галиев

**Белешеп бару** Һәрберсен, булган берсен, даими белешү. *Газета укып, белешеп барсалар да, үзе күргән – үзе күргән инде.* М.Галиев

**Белешеп бетерү** Тулысынча, барысын да белешү. – *Юк, – дип каршы төште күңеле түреннән бер аваз. – Гөлнара турында белешеп бетер!* С.Зыялы

**Белешеп йөрү** Барып, сорашып белешү. *«Мансур Хәсәновның ишеген тибеп кенә ачып керәбез...» – дип «төтен җибәрәм». Министрлыкның кайда икәнен белешеп кенә йөргән чагым, югыйсә...* М.Галиев. *Ял саен шәһәргә чыгып, корырак, яктырак бүлмәгә фатир кертүче булмасмы, дип белешеп йөрибез.* Л.Ихсанова

**Белешеп калу** Вакытында кемнәндер белешергә өлгерү

**Белешеп кую** Алдан белешү. *Безнең әнкәй Хәят әбине белешеп куйганга, ул безгә килде*. А.Таһиров

**Белешеп тору** Һәрвакыт, даими белешү. *Безгә гел күрешеп, белешеп торырга ышанычлы бер урын кирәк.* Г.Минский. *Фәтхине күрдем, ул һәркөн Сәләхинең хәлен белешеп тора.* Ш.Камал

**Белешеп узу** Сүз уңаенда, бер уңайдан белешү. *--- йомшак тел белән җавап кайтарып, бер-ике сүз белән генә аларның да хәлләрен сораша, улларының, кияүләренең сугыштанниләр язуын белешеп уза.* Г.Бәширов

**Белешеп чыгу** Тиз генә һәрберсеннән берәм-берәм белешү. *Ике кызының ник берсе күрше-күләннең хәлен белешеп чыксын!* Ф.Сафин. --- *төгәл белмәгәч, алар, бәлки, меңгә якын булыр. Ничек барысын да йөреп, белешеп чыгарсыз?* Р.Мостафин

**БЕЛЛЕТРИСТ** *и. рус* Беллетристик әсәрләр язучы. *Әйтергә кирәк, ул [А.Гыйләҗев] бу очракта гади беллетрист буларак кына чыгыш ясамый, бәлки тарихи процессларны җентекләп анализлаган тарихчы, социаль күренешләрнең асылын тикшергән социолог, --- һәм шул чорның иҗтимагый фикерен өйрәнгән философ буларак чыгыш ясый.* М.Сәхапов

**БЕЛЛЕТРИ́СТИК** *с.* Беллетристикага караган, беллетристикага бәйләнешле. *Менә шул очрашулар вакытында --- без, татар зыялылары, фәнни-популяр һәм беллетристик әдәбиятны чыгару өчен нәшрият төзү кирәклеге турындагы уртак бер фикергә килдек.* Р.Вәлиев

**БЕЛЛЕТРИ́СТИКА** *җый. и. фр.* 1) Матур әдәбиятның тасвирый төре, проза белән язылган роман, хикәя, повесть һ.б. *Бу нисбәттән ул [А.Гыйләҗев], беллетристика авторы булудан битәр, җәмгыятьне һәм кешеләрне тирәнтен өйрәнүче тарихчы һәм галим-социолог буларак чыгыш ясый.* М.Сәхапов. *Гомумән, бу әсәр тарихи әдәбиятка түгел, ә беллетристика бүлегенә карый.* И.Гафаров

2) Әдәби әсәрнең мавыктыргыч сюжеты. *Кыңгыр эш йә җинаять турында язганда, факт дөреслегенә гади беллетристика белән дә ышандырып була.* Х.Сарьян

3) Төрле тасвирлар, укучыны мавыктырырлык итеп язу ысуллары

**БЕЛЛИ ДАНС** *и. ингл.* Корсак биюе. *Шул рәвешле биюнең яңа төре – белли данс барлыкка килә.* Мәйдан. *Бүгенге хатын-кыз өчен белли данс, ял итү, күңел ачу чарасыннан бигрәк, сәламәтләндерү гимнастикасы булып тора.* Мәйдан белли данс

**БЕЛЛУР** *и. гар.* **1**. Зөбәрҗәт ташының зәңгәрсу яшел төре; берилл аквамарин. *Бу кыйммәтле ташлар белән эш итә белүче оста, үзенең җитез куллары белән, беллурларны матурлап очлый.* Д.Аппакова

**2**. *с. мәгъ.* Шушы асылташтан ясалган

**БЕЛМӘКИ** *и. сир.* Белмәмешкә салышучы, нәрсә сорасаң да «белмим» дип җавап бирүче кеше. *Белмәкинең беләге авыртмый.* Мәкаль

**БЕЛМӘМ** *кер. сүз* Сөйләнелгән әйберләрнең әле әйтелеп тә яки белеп тә бетмәгән булуын белдерә. *Крестьяннар бүген алпавытның җирен талый, утарын яндыра, урманын кисә, белмәм, тагы ниләр кыла.* Г.Ибраһимов

**БЕЛМӘМЕШ** *и.* Мәгълүматы булмаган, берни белми торган кеше. *Ялчы, белсә дә, белмәмеш булып, йөрәге сызланып, тешләре кайралып, үз эшендә йөри, ди.* Әкият

◊ **Белмәмешкә салыну** Үзен белмәгән, аңламаган, танымаган итеп күрсәтү. *Кара, кара, белмәмешкә салынган була.* К.Әмири. *Малай дөрестән дә сугып куйды, Белмәмешкә башта салыштым.* Һ.Такташ. *Ул илләр, үзләре белеп, әҗәтләрен кайтарырга ашыкмый, хәтта белмәмешкә, күрмәмешкә салыша...* Мәдәни җомга

**БЕЛОРУС** *и. рус* Белоруссиядә яши торган көнчыгыш славян халкы һәм аның бер вәкиле. *Белорус кызы ул, әни.* А.Әхмәт

**БЕЛОРУ́СЧА** *рәв.* Белорус телендә, белорусларга хас. *Фатыйма русча, украинча, белорусча җырлады.* Г.Әпсәләмов

**БЕЛҮ** *ф.* **1**. 1) Нәрсәне дә булса өйрәнеп, шуннан хәбәрдар булу; махсус өйрәнеп үзләштерү, мәгълүматлы булу. *Кайсыгыз сезнең гарәпчә яза белә?* Ш.Маннур. *Ул үзе дә инде татар, мөселман булуын күптән оныткан, басурманның телен дә, динен дә белми.* Р.Зәйдулла

2) Берәр нәрсә яки шәхес турында белешмә туплау, мәгълүмат җыю; аерым билгеләрдән тою, сиземләү. *Элек йөрик әле, бер-беребезне белик, аннан туй ясарбыз.* Ә.Айдар

3) Сорашу, кемнең дә булса хәле, яшәеше, сәламәтлеге белән кызыксыну. *Янәшәсендә биш кызы яшәсә дә, буш кул белән карчыкның хәлен белеп чыгудан ары узмыйлар.* Ф.Җамалетдинова

4) Асылын, мәгънәсен, эчтәлеген аңлап алу, төшенү. *Җилләр иссен, назлы гөлләр үссен, – Чишмәләрнең кадерен белегез!* Х.Туфан. *Минем китап укырга яратканымны да, концертларга барасы килүемне дә белде.* Н.Хәсәнов

5) Чамалау, сизенү. *Ярый әле, әтиләре бик кыса башлагач, Сылу Бариевна янына килә белде.* Р.Хафизова

6) Өйрәнү, күнекмә туплау. *Бала егыла-егыла егылмаска белер.* Мәкаль

7) Күреп тану, таныш булу. *Аны Рөстәм үзе дә, бер-ике дус малае гына белә.* Тәмуг чәчәге. *Тимеркәй – минем иптәш, мин аны яхшы беләм.* И.Гази

8) Нәрсә турында да булса ишетү, белешү. *Беркөнне Мотаһир электән таныш доктор Золотиловның да монда икәнен белде һәм, тәвәккәлләп, аның янына китте.* Р.Кәрами

9) Яттан өйрәнгәнне хәтерләү. *Балачакта ятлаган шигырьләрне әле дә беләм.* Мәдәни җомга

10) ... *дип* сүзе белән килеп, санау, исәпләү, уйлау, чамалау. *Үзеңне яхшы дип белсәң, башканы әүлия (фәрештә) дип бел.* Мәкаль

11) Үз-үзеңә исәп бирү, үз-үзеңне аңлау, белештерү. *Җәмәгать, үзен-үзе белми, ватык тәрәзәдән качарга ташлана.* Г.Ибраһимов

12) Билгеле бер нәрсәне күргән булу, кичерү, кичереп үткәрү. *Мәхәббәтнең нәрсә икәнен белү. Уенны белми үсү*

13) Нинди дә булса эш яки шөгыль белән генә чикләнү, шуның белән генә мавыгу, шуннан читкә тайпылмау, бөтән эш белән кызысынмау. *Күбәләк тик ямьгә кавышуны белә. Нә усал уй, нә дә шау-шуны белә.* Ш.Бабич. *Һаман шул укуын гына белә* // *юкл. форм.* Кайгыртмау, катнашмау. *Менә биатаң да гомере буе өйнең нәрсә икәнен белмәде.* Ф.Садриев

14) *-(ы)рга, -(е)ргә, -маска, -мәскә* кушымчаларына тәмамланган фигыльдән соң: шул сүздә белдерелгән эш-шөгыльне бик яхшы башкару, бик шәп итеп булдыра алу. *Мин бандитлар белән ничек көрәшергә белермен.* Т.Гыйззәт

15) *-(ы)рга, -(е)ргә, -маска, -мәскә* кушымчаларына тәмамланган фигыльдән соң килеп: аптырап калу, нәрсә әйтергә дә белмәү, югалып калу; икеләнү. *Шакир сүзенә ышанырга да, ышанмаска да белмиләр иде.* А.Алиш

16) *-а (-ый) / -ә (-и)* фигыль формалары белән килеп: булдыра алу, көче, акылы, зиһене, осталыгы җитү. *Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк.* Мәкаль

17) Шарт һәм боерык фигыль формасы кара-каршы куелганда: шелтәләү, таләп кую. *Ала белсәң, бирә дә бел.* Мәкаль

**2**. **белеп** *рәв. мәгъ.* Тәҗрибәгә нигезләнеп, күреп, аңлап. *Үксез бозау асрасаң, авызың-борының май булыр, дип, белеп әйткәннәр.* Д.Аппакова

**3. белмим, белмәссең** *кер. сүз мәгъ.* Фикернең бик үк төгәл булмавын, ышанып бетмәүне белдерә. *Белмим, әллә гайбәт, әллә чындыр инде [бу сүз].* Һ.Такташ. *[Үтәш:] Акбирдин бервакытны миңа, теләсәң, картларны да яшәртә алабыз, дигән иде. Белмәссең, минәйтәм, кап-кара сакаллы ир уртасы ясар да куяр.* К.Тинчурин

◊ **Белә белгәннән бирле** Инде күптәннән белгәнчә, күпме белсәм, шулкадәр. *Мин белә белгәннән бирле, савытта бакыр-көмеш өзелми.* М.Кәрим. **Беләсең (беләсегез) килсә** Син (сез) уйлаганча түгел, бөтенләй башкача. *[Шәйхулла:] Без хәзер, беләсең килсә, авылның падишасы булдык.* Д.Аппакова. *Дәү абыйга, беләсең килсә, өряңа машина биргәннәр. Үзбушаткыч, беләсең килсә...* Р.Мөхәммәдиев. **Беләсеңме (беләсезме) нәрсә** Игътибарны җәлеп итү, игътибар ит(егез), дигән мәгънәдә. *Беләсеңме нәрсә, Гөлнарый җан, мин өркебрәк торам.* Ә.Айдар. **Бел(егез), белеп тор аны** Әйткәнне онытма, исеңдә тот (кисәтү сүзе). *Сиңа моннан соң ташлама булмаячак, аны белеп тор.* Г.Галиев. **Белмәссең тагы** Икенче төрле булу ихтималы да бар, өзеп кенә әйтеп булмый, мәгънәсендә. *Белмәссең тагы, ихтимал, сезнең мондагы үрдәкләр, сызгырып җибәрүгә, аучының кулына килеп куна торганнардыр.* М.Шабаев. **Белмим шул** Төгәл җавап бирмәү, җаваплылыктан качу. *[Байтирәк:] Белмим шул, миннән ни генә чыгар икән?* Т.Гыйззәт. **Белми тору** Бермәлгә аптырап калу, вакытлыча нәрсә эшләргә дә белмәү. *Хәлим, беркадәр вакыт, үзе дә нишләргә белми торды.* Г.Гобәй. **Белсәң (белсәгез) иде** Хәлне аңласаң, аңлый алсаң иде, мәгънәсендә. *Их, иптәш, минем ни хәлдә икәнемне белсәң иде!* Ф.Әмирхан

**Белә башлау** Танышу, якыннан белү. *Мин Гаяз Исхакыйны «тотып карап» дигәндәй белә башладым.* Р.Батулла

**Белә төшү** Тагы да белү, күбрәк белү. *Шәмси, үз дәрәҗәсен белә төшеп: – Хикмәт күрсәткечләрдә түгел, – диде.* Н.Хәсәнов

**Белеп алу** Тиз арада белү,ниндидер чыганактан белешү. *Акъәби шунда ук кем килгәнен белеп алды һәм, ни өчен икән бу, дип, борчылып уйлап куйды.* Ә.Еники. *Дәү әтиемнең мине сөннәткә утыртуын белеп алгач, әти җикеренде инде. Бер дә галәмәт.* А.Хәсәнов

**Белеп бару** Даими, һәрбер яңалыкны, үзгәрешне белү; һәрберсен белү. --- *аның төп халкының этнографиясен, тарихын, фольклорын, әдәбиятын, сәнгатен, мәдәниятен һәрвакыт, күпмедер өйрәнеп, белеп барырга тырыштым.* Г.Хөсәенов

**Белеп бетерү** Тәмам ахырына кадәр, барысын да белү. *Безнең авылда Наилләр генә җидәү, каян белеп бетерәсең аларны, кушаматларын белмәсәң.* Н.Кәримова. *Безнең урысча бик чамалы инде, җырның мәгънәсен дә белеп бетермибез.* Т.Миңнуллин

**Белеп бирү** Аңлап эш итү. *Димәк, Сәлим хан илче яки сәүдәгәр булган Садакка ярлыкны белеп биргән булып чыга?..* М.Хәбибуллин

**Белеп җиткерү** Ахырга хәтле, тулысынча белү. *Бөтенесен алдан белеп торырга, белеп җиткермәсә дә, бик белдекле булып, үзеннән өстәп сөйләргә яратучы Митричев монда да түзә алмады.* Г.Бәширов. --- *башкалар белеп җиткермәгән сере бар иде шул.* Ф.Сафин

**Белеп йөрү** 1) Әкрен генә, сиздермичә, эченнән генә белү; аннан-моннан белешү. *Беренче көннән үк барын да күреп, белеп йөрүең хәерле.* С.Поварисов

2) Белешеп тору, белешү. *Кайтып, хәлен белеп йөрү, булышып тору – ул онытмау дигән нәрсә...* Г.Гыйльман

**Белеп калу** Белергә өлгерү, очраклы рәвештә кайдандыр белү. *Шәкертләр тәрәзәдән күреп калып, аңардан хәйлә белән белеп калу өчен, берсе аңа: – Әй, тозлы әлбә! – дип кычкырган.* Н.Исәнбәт. *Аның бу галәм кунагы турында мөмкин кадәр күп белеп каласы килә иде.* Р.Фәизов

**Белеп килү** Элек-электән һәрвакыт белү

**Белеп кую** Алдан белү, сорашып белү

**Белеп тору** 1) Даими, һәрвакыт белү. *Бүген таңда бозауларга торган сыерларны сакларга, бозаулаганнарының хәлен белеп торырга, --- бигрәк тә яшь үрчемнәрне күз алмасыдай сакларга кирәк.* Ә.Еники. *Дусың булса, сукмагына үлән үстермә. Барып, хәлен белеп тор.* Н.Исәнбәт

2) Алдан ук белү, барысын да белү. *– Ә мин синең шулай кыләсеңне белеп тордым! – диде Гасимә, карусыз гына төрттереп.* В.Нуруллин

**Белеп чыгу** Һәрберсеннән сорашып белү

**БЕ́ЛЬГИЯЛЕ** *и.* Бельгия халкы һәм шул халыкның бер кешесе. *Шунда кеше ышанмаслык хәл хәтердә калган: бельгияле хатыннар, кәрзин-кәрзин алма, җиләк-җимеш күтәреп, безнең колоннага ыргылалар, әмма аларны, ЭСЭС сакчылары, автоматлары белән этә-төртә, безгә таба үткәрмиләр.* Шәһри Казан. *Аннан соң, К.Симонов ярдәмендә, бельгияле А.Тиммерманс белән элемтә булдырыла.* Мәдәни җомга

**БЕЛЬЭТАЖ** *и. фр.* 1) Берничә катлы яки күпкатлы йортларның икенче каты

2) Театрда тамаша залының партер, амфитеатр өстендәге балконнарның беренче ярусы. *Бельэтажда утырганлыктан, такыр башыннан маңгаенача Курил утрауларына охшап сибелеп төшкән миң тапларын аермачык күрәм, имеш.* Ж.Дәрзаман

**БЕНЕФИС** *и. фр.* Артистның талантын олылау йөзеннән, аның исеменә куелган спектакль яки оештырылган кичә. *15 январьда Г.Камал театрында Ә.Афзалова бенефисы була.* Мәдәни җомга

◊ **Бенефис бирү** Үзенең көчен күрсәтү, бер-бер кыенлык, мәшәкать китереп чыгару. *Кыш әле шаяртыр төсле генә. Ул, берәр атнага үз дилбегәсен йомшарткан булып күренсә дә, яшеренеп калган суыгын берьюлы чыгарып, соңгы бенефис бирер.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**БЕНЗИН** *и. нем.<лат.<гар.* Нефтьтән куып алынган, янучан, төссез сыек ягулык. *Пристань тавын көчкә менеп, өйгә җитәр-җитмәс, бензины бетеп, арттан чатыр-чытыр атып, чаткылар чәчеп кайтса да, бу «Победа» минем өчен иң изге машиналар рәтендә калды.* Т.Галиуллин. *Ул, кереп, утның өстенә капланмаса, бензин мичкәсен саклап калып булмый иде.* Ә.Фәйзи

**БЕНЗИНЛАП** *рәв.* Бензин белән, бензин кулланып. *Махсус эшләнгән автомобильләр бу урамнарны щёткалап, бензинлап юалар.* Г.Гали

**БЕНЗИНЛЫ** *с.* 1) Бензин белән эшли торган. *Ике танк таранда бәрелешсә, немецның бензинлы танкы яна башлаячак.* З.Зәйнуллин. *Кыш көне исә иртәләрен бензинлы машина кабынмаска да мөмкин.* Татарстан яшьләре

2) Бензинга буялган, үзенә бензин сеңгән. *«Аэроклуб» дию белән үк, күз алдыгызга бары бензинлы комбинезоннар, пилоткалар, зур перчаткалар гына китермәгез.* К.Басыйров. *Әгәр дә таплар калса, аны бензинлы тампон ярдәмендә чистартырга була.* Ватаным Татарстан

3) Бензины булган, бензин салынган. *Үзең белән машинада бензинлы канистр йөртү*

**БЕНЗО-** *рус* Кушма сүзләрдә бензинга бәйләнеше булуны белдерә торган беренче кисәк (мәс., *бензоколонка, бензопычкы*)

**БЕНЗОВОЗ** *и. рус* Бензин ташый торган автоцистерна. *Бензовоз ыңгырашып, гүләп үргә менде дә яр астына бензоколонкага төшеп китте.* И.Салахов. *Техника – бензовоз, сөт машинасы, аммиак сыекчасы ташый торган машиналар – тыкрыкка бөялгән.* М.Мәһдиев

**БЕНУАР** *и. фр.* Театр залында партерның ян-якларындагы аерым ишекле ложалар

**БЕР** *сан* **1**. 1) Унарлы санау системасында 1 санын һәм цифрын, шул сан исәбендәге микъдарны белдергән атама. *Шуннан мин, җаен туры китереп кенә, беркем күрмәгәндә, әтинең сул як кесәсендәге янчыктан, бер уч тутырып, тәмәке алдым.* К.Миңлебаев. *Ерак түгел – бер көнлек юл.* К.Тинчурин. *Бер ел үтүгә, яшь белгечне мәктәп директоры итеп куялар.* Татарстан

2) Парның сыңары. *Бер кулы белән күкрәгенә нәрсәдер кысып тоткан кебек.* Ф.Сафин. *Чирәм арасында аңын югалтып, ыңгырашып яткан тавыкны алып караса хуҗа хатын – теге тавыкның бер күзе сукырайган.* М.Мәһдиев

3) *Бер – икенче, берсе – икенчесе, берәүләр – икенчеләр* кебек тезмәләрдә каршы куюны, санап китүне белдергәндә кулланыла. *Бер аягында – ката, икенчесендә – чабата, эндәшми дә тик ята.* Такмак. *Бер караңгыдан икенче караңгыга шулай тир түксә дә баемады.* М.Кәбиров. *Нәзнинәнең бер кулында – курчак, икенчесендә – аю.* И.Юзеев

4) Бердәнбер зат, бердәнбер очрак, ялгыз, үзе генә. *Егет атага бер булганга, солдат куркынычы юк иде.* Г.Ибраһимов. *Чөнки фронтка баручы – бер алар гына түгел, андый эшелоннар бик күп, аның өстенә, фашист самолётлары көндез йөрергә һич мөмкинлек бирмиләр иде.* Г.Бәширов

5) Фигыль алдыннан килеп, нинди дә булса эшнең, гамәлнең бер тапкыр гына үтәлүен белдерә. *Бер кабынган газаплы уйлар тынмады да, басылмады да.* Н.Хәсәнов. *Кулын сузып килгән хәчтерүшкә уң кулының сырты белән генә берне селтәп җибәрде.* К.Миңлебаев. *Үзәннәргә төшеп бер еладым, – Аңламадылар, Кызгандылар гына, ә үземне Санламадылар.* И.Юзеев

6) Юклык төшенчәсен көчәйтеп, бөтенләй, аз гына, мәгънәсен белдерә. *Ул, сызымнан сызымга күчкәндә, бер дә тырышмыйча гына, әллә никадәр саннарны хәтеренә сеңдереп өлгерә иде.* А.Гыйләҗев. *Ул, кайберәүләр кебек, «кирәкми, мәшәкатьләнмәгез» дип суфыйланмады да, гаҗәпләнүен дә күрсәтмәде, аның йөзендә бер генә төк, бер генә сызык та үзгәрмәде.* Ф.Садриев

7) Арада иң шәбе, тиңдәшсез, бердәнбер. *Әгәр мин, «Спартак» аяк киемнәре – дөньяда бер, дисәм, мыскыллы елмаеп куячаксыз.* М.Галиев. *--- бу – Гали бай йорты, чардаклы, яшел түбәле, авылда бер шәп, матур йорт.* Ә.Еники. *Кыз чагында ук авылда бер оста җырчы иде.* Г.Бәширов

8) Үткән заман фигыльләреннән соң килеп: барысы, һәммәсе, һәркайсы, мәгънәләрендә йөри. *Бу вакытта акча каян булсын? ...Кергән бер акча бетеп тора!* М.Гафури. *Миңлевафа абзый һаман чабата ясый, тапкан бер акчасын аларга [балаларга] җибәреп тора икән.* Н.Исәнбәт. *Шәмсениса түти бу хатны өйләренә килгән бер кешегә укып елый.* М.Мәһдиев

**2**. *с. мәгъ.* 1) Бертөсле, бер-берсенә охшаган, бертөрле, кебек, шундый ук. *Бер очтан кискән.* Әйтем. *Аның чәче – үзе бер болыт.* Н.Исәнбәт

2) Уртак. *Иярсез-нисез генә атның сыртына атланганда, гүя син аның белән бер гәүдәгә әвереләсең, бер тән, бер җан буласың да куясың.* К.Миңлебаев. *Әнә алар, бер урам малайлары, язын Камадан су кереп калган уйсулыкка – Кече күлгә килеп туктадылар.* Н.Хәсәнов. *Без бит – бер ишектән йөреп өйрәнгәннәр.* Т.Миңнуллин

3) Бердәнбер. *Инде менә бер үкенеч йөри Күңелемдә минем, эчкәре.* Х.Әюп. *Һәм кызга тик бер чара гына калган.* М.Кәбиров. *Ничегрәк сүз кушасы, Ничегрәк танышасы? Язмассызмы, дигәннәр, Сез «Мәхәббәт Уставы»? Әйтерсең лә бу эшнең Мин мәшһүр бер остасы!* Ш.Галиев

4) Бердәм, оешкан (төстә). *Туган илеңә мәхәббәт – синең күңелеңне баетып, бөтен тормышыңның мәгънәсен, тәмен, ямен шундый чакта тагын да ачыграк хис иттерә торган тиңсез бер куәт икән ул.* Г.Бәширов. *Домначылар,*

*тирән дулкынланып, бер көч белән эшкә тотынды.* Ш.Маннур

5) Бөтеннән аерып алынган, аерып куелган. *Автор Себер татарлары тарихын бөтен татар тарихының бер өлеше итеп карый.* Г.Фәйзрахманов

6) Тулысы белән, бөтен. *Ике чабата – бер кием.* Мәкаль. *Әй, бар иде бер Рәсәй, ди, Беткән икән ул Рәсәй.* Н.Исәнбәт. *Мәңгелек бер ял бирермен мин сиңа!* Н.Исәнбәт

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Тиң, бәрабәр. *Казанда чират торып сыра алу – Измаил кальгасын алу белән бер ул.* З.Мәхмүди

2) Кайчан да булса, бервакыт. *Бу хакта бер сөйләр әле ул сезгә.* Г.Гыйльманов. *Ялгышканлыгыңа үзең үк бер төшенерсең, мин монысына ышанам.* Ф.Җамалетдинова

3) Бердәм рәвештә, берьюлы. *Әгәр дә алар бөтенесе бер булыпябышса, сезнең кебек юкагач сыйраклар нишли генә алырсыз?* Т.Гыйззәт

4) Вакыт берәмлеген белдергән сүзләр алдыннан килеп: шул вакыт эчендә, шул вакытта. *Бер ярты сәгатьтән, Аллага тапшырып, эт тончыга.* К.Тинчурин. *Бар, кайт та уйла, тагын бер атнадан килеп әйтерсең җавабыңны.* К.Миңлебаев. *Әйе, бер язны Йөзлебикә апасы Нәфисәнең кемгәдер кияүгә чыгуы турында хат та язган иде шикелле.* Г.Бәширов

5) Һич, һич тә, бөтенләй дә, аз гына да. *Бер дә ишетәсе килми бу сүзне.* Н.Хәсәнов. *Әнисе көнозын мәктәптә, абыйсы да быел көздән укырга керде; бер өйдә тормый, мәктәбеннән кайта да уйнарга чыгып чаба яки, иптәшләрен җыеп кереп, дәрес карый...* Г.Гобәй

**4.** *а. функ.* 1) Билгесез зат, предмет, эш-хәлгә ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; ниндидер. *Бер тавыш килде колакка ---.* Г.Тукай. *Ни күзем белән күрим, аяк очымда, тәлинкә кадәр күзләрен елтыратып, йонлач бер җан иясе утыра.* З.Мәхмүди. *Яннарында тугызын яшьлек бер кызчык та бар иде.* Г.Әпсәләмов

2) Бөтенләй булмауга, табылмауга, юклыкка ишарәләп, юклык алмашлыгы буларак кулланыла; һич, һичбер, беркая. *Бер җирдә юк андый ак каеннар, Бер җирдә юк андый урманнар...* Һ.Такташ

**5.** **бере**, **берләре** *и. мәгъ.* 1) Кайбере, кайберсе, беришләре. *Бу илнең һич чиге юктыр, Биниһая адәм чуктыр, Бере – ач, юк-бары – туктыр...* Г.Кандалый. *Бу юлы, карасам, янымда гына, ямьяшел чирәмлектә, бик матур, берләре чуар-чуар, берләре сап-сары тавык чебешләре йөри.* А.Хәсәнов

2) *к.* **берсе** (**2**). *– Агайлар, җиңгәйләр, без сезгә кунак булып кына килмәдек, – дип башлап китте дә, муенсасындагы гәрәбәләр кебек, бере артыннан берен тезеп, «Аланбаш» белән «Чулпан» арасындагы күпьеллык дуслыкны күз алдына китереп бастырды.* Г.Бәширов. *Бере уң тарафта вә бере урталыкта – ике ишек, урталыктагы ишек янында – бер шкаф.* Г.Камал. *Аларның килгәне бере, билетларын күрсәтеп, эчкә кереп китәләр.* А.Шамов

3) *к.* **берәүсе** (*2 мәгъ.*). *Озатырга дип килеп, мондый әңгәмә чыгуын бере дә көтмәгән иде.* Г.Ибраһимов

4) Алда телгә алынган кеше яки әйбер. *Ничек үлим, Берләр – меңнәр өчен, Меңнәр берләр өчен торганда.* Һ.Такташ. *Колак төбеңә берне кундырсам, биш булыр.* А.Гыймадиев

5) Укучыларның өлгерешен бәяләү өчен кертелгән биш баллы системада иң начар билге

**6**. *кер. сүз мәгъ. чыг. килеш форм. к.* **беренчедән.** *Бердән, кызының укытучы булып китүен, әлбәттә, дәрәҗә саный.* Ф.Хөсни

**7.** *терк. мәгъ.* 1) Тиңдәш кисәкләр янында кабатланып килеп, бүлүче теркәгеч буларак кулланыла; әле, я. *Күз язмыйм: бер – гөмбәзгә, бер – кызларга, бер егетләргә карап алам.* Ш.Галиев. *Госман Әхмәров тәрәзә форточкасының көзге җил белән бер ачылып, бер ябылып торуына уянып китте.* А.Шамов. *Урман өстенә сузылган күз камаштыргыч шул нурда, бер күренеп, бер качып, җем-җем килеп, вак кына кар энҗеләре уйнаша.* Г.Бәширов

2) Шарт фигыль янында *әгәр* теркәгече мәгънәсендә килә. *Алай димә, Минһаҗ агай. Бер дулап китсәм, ай-яй мин!* К.Тинчурин. *Инде атларын көйли торгач, туктап-туктап, бер иркен сулап куя икән, син анда тыныч инде.* Г.Бәширов

3) Бары, нибары, тик. *Кичә генә ул бер кызчык иде. Бүген аны «җиткән кыз» диләр.* Н.Исәнбәт. *Аның күңелендә үзе туып үскән бер тирәлек, ул тирәлекнең дә аерым бер урманы, яланы, чишмәсе, я булмаса тар гына бер авыл инеше яши.* Г.Сабитов. *Чулпанның бер-ике көн эчендә шулкадәр артка калуы бер Тимерине генә борчымый иде.* Г.Бәширов

**8.** *кис. мәгъ.* 1) Шатлану, соклану, горурлану тойгыларын көчәйтеп килә; менә ичмасам. *Паровоз фронтка «выж» итеп барып керсен әле бер.* Г.Гобәй

2) *-гач* кушымчалы хәл яки шарт фигыль алдыннан килеп, аңа көчәйтү, игътибарны юнәлтү, ассызыклау төсмере өсти. *[Хәллә] Әйткән эшне ялтыратып эшләп куя, бер кулы кызгач, әйтмәгәнен үзе күреп тә эшли иде.* Ф.Хөсни

◊ **Бер авыз сүз сөйләшмәү (әйтмәү)** Сөйләшмичә тору. *Кешеләр [Мостафинга] туры карарга уңайсызландылар, ул үзе беркем белән дә бер авыз сүз сөйләшмәде.* Ә.Еники. **Бер агач җимеше** Бер үк төрле тәрбия алган, бер уйдагы кешеләр. **Бер адым** 1) Бик якын, янәшәдә. *Театр – моннан бер адымда гына;* 2) Аз гына, чак кына. *Мин әле хәйран һаман да, белмәдем ни булганын, Нәрсәгә артка карыйсың, утка калгач бер адым?* Г.Тукай. **Бер адым алга, ике адым артка** Кечкенә уңышларга ирешеп, соңыннан шул уңышларны юк итә торган һәм тагын да арткарак чигенергә мәҗбүр итә торган ялгышлык ясау турында. **Бер акча** *иск.* Кыйммәт түгел, арзан, берни тормый. *Әстерханда сыер – бер акча, киләкилә – мең акча.* Мәкаль. **Бер акыл килү** Башына бер уй, бер әмәл килү, әмәлен табу. *Бармаклары белән туфракны казыштырып уйланып йөри торгач, аның башына бер акыл килде.* Г.Бәширов. **Бер – алга, биш артка карап** Бик сакланып, үткән тәҗрибәне исәпкә алып; бик уйлап, сак. *Җиһан*

*апа, чынлап та, бер – алдына, биш артына карап эш итәргә ярата иде.* М.Шабай. **Бер – алдына, бер артына төшү** Берәүнең ризалыгын, рөхсәтен алу яки аны берәр нәрсәгә күндерү өчен ялагайлану, тирәсендә сырпалану. **Бер апара, бер камыр – барысы да бер камыр** Бөтенесе бер нәселдән: барысы да бер уйдагы, бер-берен яклый торган, бертөрле, бериш кешеләр. **Бер атка ике камыт кидерү** Бер кешегә, үз эшен эшләү өстенә, икенче мәшәкать йөкләү, йөкләтү. **Бер атканда – ике куян, бер атуда – куш куян** Бер эштә берьюлы ике уңышка, ике нәтиҗәгә ирешү. **Бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә** *тирг.* Карт яки каты авыру. *Үзеңнең бер аягың җирдә, икенче аягың гүрдә, картайган көнеңдә сиңа мәчет түрендә генә утырырга кирәк иде.* Г.Камал. **Бер аягы кабердә** Картайган, үләргә җитешкән. **Бер аягым монда, берсе – анда** Бик тиз барып кайтам, мәгънәсендә. **Бер аягын алганчы (атлаганчы), икенчесен эт (корт) ашый** Бик авыр кузгалучы, аягын теләр-теләмәс кенә атлаучы, эленке-салынкы гына йөрүче, мыштыр, ялкау һәм үшән кешегә яки атка карата әйтелә. **Бер аякка атлау (басу)** Ярашу, яраклашу; калышмау. **Бер әйтер – берәгәйле әйтер** Сүзне урынына китереп, бер генә тапкыр, җиренә җиткереп әйтә торган. *Бер әйт – берәгәйле әйт.* Мәкаль. **Бер әйттем, ун кайттым** Кеше алдында җайсыз, урынсыз ычкындырган сүзне кайтарып алу. *Ә юк, болай гына әйтәм лә, бер әйттем, ун кайттым, әйтеп кенә бактым.* Г.Газиз. **Бер әлиф тә танымау** Бөтенләй надан, чепчи надан. **Бер бакча җимеше** Бер үк төрле тәрбия алган, бер уйдагы кешеләр. **Бер (үк) балык башы** Гел бер үк сүз, күп кабатланган, артык күп сөйләнгән, туйдырып бетергән фикер. *Тагы да шул ук бер балык башымы?* Г.Иделле. **Бер балык башын чәйнәү** Һаман бер әйберне, бер сүзне кайта-кайта сөйләп тору. *Уйлап кына карагыз, утызынчы елга кереп барабыз, һаман бер балык башы чәйнибез.* Ф.Сафин. *Кадыйров һаман бер балык башын чәйнәп торды да китеп барды.* А.Гыйләҗев. **Бер башы да бер тамагы** Ялгыз, буйдак, берүзе. *Әле болай, ичмаса, бер башың да бер үзең.* Г.Камал. **Бер башына урын тапмау** Тормышта үзенең юлын, урынын таба алмау, беркайда да үзенә тынгы тапмау, тыныч кына яши алмау. **Бер без генә түгел, ил белән** Бер сиңа, миңа гына төшмәгән, ил белән күргән хәл, дигән мәгънәдә. *Биеккәй тауның башында Самавыр кайный җил белән; Җыламачы, җаный, ник җылыйсың, Бер без генә түгел, ил белән.* Җыр. **Бер борча өчен бер юрган яру** Кечкенә җәфага түзмичә, ачуын алам, дип, холыксызланып, тагын да кыйммәткәрәк төшкән зарар ясау. **Бер булса да берәгәйле (булыр)** Гел булып тормаса да, бер булганда күбрәк, яхшырак, бәрәкәтлерәк булыр. **Бергә бишне кушу** Ялганлау, алдау, арттырып сөйләү. **Бергә бишне кушып сөйләү** Бер дөрес сүзгә биш ялган сүз катыштыру, арттырып сөйләү, ялганлау. **Бер генә (бер), бер генә дә, бер дә генә, бер дә** 1) Бөтенләй, һич (тә), аз гына да (юклык төшенчәсен белдерә); 2) Беркайчан да, һичкайчан да. **Бер дә ата-анасы юк** Сөйләвенең, эшенең рәте-чираты юк, очы очка ялганмый, аңлаешсыз, мәгънәсе юк. **Бер дә бер заман, бер дә бер көнне** Берәр вакытны, кайчан да булса бер. **Бер дә булмаганда** Һичьюгы, юк дигәндә, ахыр чиктә, һич булмаса. **Бер дә гаҗәп (нәрсә) түгел** Булуы да мөмкин, бернинди катлаулылыгы юк, бик гади. **Бер дә галәмәт (инде)** 1) Бер дә булмаганча күп, зур; тәмле, затлы; бөтенләй ят, сәер нәрсә, тамаша. *Бер дә, бер дә галәмәт инде, җаный. Ул кәрәзле баллар дисеңме, башлы шикәрләр дисеңме.* А.Расих; 2) Гаҗәпләнерлек бернәрсәсе дә юк, мәгънәсендә. **Бер дә килмәгән җире юк** Бик чибәр, сылу, уңганбулган, үз-үзен тотышы, буе-сыны, бар җире дә килешле. *Йөзе-бите, буе-сыны дисеңме, бер генә дә килмәгән җире юк иде аның.* Ә.Еники. **Бердән генә** Тиз генә, шул арада. **Бер дә сөйләп килештерә торган түгел** Шул дәрәҗәдә ки, сөйләп, тасвирлап бирүдән телләр гаҗиз. **Бер дә төс түгел** Килешми, лаек түгел. *Ул эш бер дә төс түгел инде сиңа.* Н.Исәнбәт. **Бер дә харап** Гаҗәп, искиткеч. *Күмәч шундый тәмле булган, бер дә харап, ашап туйгысыз икән.* Н.Исәнбәт. **Бер дә харап икән** Ис китәрлек урын юк. **Бер дә хәтәр** *к.* **бер дә харап.** *[Тирәк агачы] Бер дә хәтәр ерелләнеп, башын тиешеннән артык күккә күтәреп тотынган, ди, үсәргә.* Н.Исәнбәт. **Бер дә юкка (юктан)** Бернинди сәбәп булмаган килеш, бернинди нигезсез. *[Галимәне] Бер дә юктан харап иттеләр.* М.Гафури. **Бер дә ялгансыз** Һич алдаусыз. *Бер дә ялгансыз, кукайдән зур таш ул, Дөньяда юк, булса да тик бер таш ул.* Г.Тукай. **Бер дигән** Бик шәп, менә дигән. **Бер елда ун еллык картаю** Берәр мәшәкать, борчу я буталчык эшкә тарып, арып, йончып, сәламәтлеген какшату. **Бер җан, бер тән булып** Бер үк максат, бер үк теләк белән, бердәм, дус булып. *Тәнемез аерым булса да, бер җан булыйк бәдәвам.* Г.Тукай. **Бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк** Аерылмас дуслар. *Нариман – Айдарның ярты кабым икмәкне икегә бүлеп каба торган, бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк шикелле яшәгән дусты.* Г.Мөхәммәтшин. **Бер җирдә ике Сөләйман, берсенә әйтсәң, берсе сөмәйгән** Берсенә бер сүз әйтсәң, икенчесенең хәтере кала торган, үзләрен эре тоткан ике кеше турында. **Бер җырны җырлау** Һаман бер сүзне сөйләү, бер сылтауны сәбәп итү. *Аның белән сөйләшүдән файда юк, ул һаман бер җырны җырлый.* **Бер-ике рәт ману** Йодрык яки башка берәр нәрсә белән кешегә каты итеп сугу. *«Патша хөкүмәте бит ул, телеңне тый, сакла, җүләр!» Дип, «өтек»кә бер-ике рәт мандылар.* Ш.Бабич. **Бер исәпләгәндә** Бер уйлап караганда. *Бер исәпләгәндә, өйләнү – күңелле нәрсә.* Г.Камал. **Бер итеп** 1) Билгеле бер урынны, мәйданны һ.б.ны иңләп, аның бер башыннан (почмагыннан) икенче башына (почмагына) кадәр (йөрү, чабу һ.б.ш.). *Авылны бер итеп икәү без, Нурларга коена-коена серләшеп, гөрләшеп үтәрбез Урамның буеннан буена.* Ә.Ерикәй; 2) Бик җентекләп, бер урынны да калдырмыйча. **Бер йодрык белән** *к.* **бер**

**йодрык булып.** *Бер йодрык белән бәрергә иде дә, диварларын изеп, манараларын аударып, төнге ташкындай ыргылып керергә иде.* Ф.Латыйфи. **Бер йодрык итү** Берләштерү. *Илгә килгән бәла бер йодрык итә.* Б.Камалов. *Аларны бер йодрык итү өчен, Болгарга бердәмлек кирәк.* М.Хәбибуллин. **Бер йодрыкка туплау** Төп максатка ирешү өчен, көчләрне берләштерү, бер урынга җыю. *Аның ирекле булуын телибез икән, бу – барлык төрки халыкларны берләштерү, бер йодрыкка туплау, көч җыю юлы белән генә мөмкин.* А.Расих. *Фильмнар һәм программалар җәмгыятьне бер йодрыкка туплау идеяләрен халыкка җиткерүнең нәтиҗәлелеге, материалның сыйфаты, проблеманы максималь колачлау күзлегеннән чыгып бәяләнгән.* Ватаным Татарстан. **Бер йодрыкка укмашу** Үз-үзенә җыелу, җыерылу. *Директор кешенең – шундый чиста, пөхтә итеп киенгән кешенең – бу рәвешчә сөйләнүе Габделхәйгә чиктән тыш ят һәм кыргый булып тоелды. Бөтен тәне, бөтен әгъзалары белән бөрешеп, ул бер йодрыкка укмашып калды.* Н.Фәттах. **Бер кабарлыгым да юк, бер кабар (кабасы) җирем калмады** Берәр кешедән тую, бизү, һич күрәсе килмәү. *Туйдым синнән, бер кабар җирем калмады.* Н.Исәнбәт. **Бер казанга – ике тәкә башы** Бер-берсе белән тынышмый торган ике каршылыклы кешене бергә урнаштырырга тырышу, мәгънәсендә. – *Бер казанга ике тәкә башы туры килә түгелме соң, җәмәгать? Алар, үзара сөзешеп, казанның стенасын ватмаслармы?* – *дип, ике председательгә киная ясап, барысын да көлдереп куйды.* Ф.Хөсни. **Бер кайчыдан кырыккан** Бер үк кыяфәттә чәч-сакал үстергән, бертөрле киенгән, бер үк сүзләрне кабатлый торган һ.б.ш. мәгънәсендә. **Бер капкага да сыймый** Бернинди тәртип-низам, кагыйдәләргә сыешмый. **Бер каптырмалы** Артык гади, примитив. *Алар дөньяның, син уйлаганча, бер каптырмалы гына булмавын, яшәешнең күп катламнардан торуын, адәми затның күзгә күренмәгән реаль энергияләр, затлар, төрле көчләр камалышында яшәвен даими сиздереп тордылар.* С.Шәмси. *Мәсьәлә, кемнәрдер уйлаганча, бер каптырмалы гына түгел шул.* Р.Фәйзуллин. *Бер каптырмалы хикәя, повесть, романнар укучыбызның вакытын гына үтерәчәк!..* Казан утлары. **Бер караганда – ал да гөл, бер караганда – җил-давыл** Характеры тиз үзгәрүчән, каршылыклы кешегә карата әйтелә. **Бер карга туярлык ите юк** *кимс.* Үтә ябык, арык гәүдәле. **Бер кашык су белән йотарлык** Бик чибәр, сылу, сөйкемле. *Кыз чибәр иде, сүз юк. Буе да, сыны да килгән иде. Ул күз дисеңме, ул каш дисеңме... Кыскасы, бер кашык су белән йотарлык иде.* А.Шамов. **Бер кашык суда батып яту (батып калу)** *кимс.* Кечкенә генә бер мәсьәләне дә хәл итә алмау, буталу. **Бер кашыктан ашап йөргән (үскән)** Кечкенәдән бергә уйнап үскән, кайгыхәсрәтләрне бергә кичергән. **Бер кашыктан ашау** *к.* **бер табактан ашау**. **Бер кәлимә сүз** Бер авыз сүз. *Кеше кадере белмәгән андый эткә бер кәлимә сүзем әрәм.* Г.Бәширов. **Бер кәррә** Бер тапкыр. --- *безгә түземлек, түземлек һәм тагын бер кәррә түземлек кирәк.* Ф.Латыйфи. --- *бу фикереннән бер кәррә дә артка чигенмәде...* Р.Сибат. **Бер кеше икегә ярылырдай вакытта** Бик тыгыз вакытта, кызу эш өстендә. **Бер кисмәк балга – бер тамчы дегет** Тигез, тату, матур барган тормышны, түгәрәк мәҗлесне, эшне җимерергә бик аз гына нәрсә дә җитә, мәгънәсендә. **Бер колактан кереп, икенчесеннән чыгу** 1) Игътибарсыз гына, әйтелгәннәрнең мәгънәсенә төшенергә тырышмыйча гына тыңлау. *Гөлбану бу турыда сүзләрне тыңлады, ләкин аңламады, бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга тордылар.* Г.Ибраһимов; 2) Игътибар итмәү, игътибарсыз калдыру, һаман үзенчә эшләү. **Бер көе (көенчә), бер килеш** Уртача, ярыйсы гына. **Бер көрәккә сап булу** Бер эшкә дә яраксыз, артык җан булганчы, аз булса да файда китерү, бер-бер эшкә ярау. **Бер кулга җыю** Бергә туплау, берләштерү. **Бер кулга – кырык эш** Бер кеше берьюлы күптөрле эш эшләгәндә әйтелә. **Бер кулдан тоту** Өй-йорт хуҗалыгында ир-хатын яки балалар, һәркайсы аерым кесәдән тотмыйча, бер баш хуҗа кулыннан алып тоту. **Бер кулсыз калу** 1) Ярдәмчесез калу, төп таянычны югалту; 2) Иң кирәкле әйбер булмау сәбәпле, гаҗиз хәлдә калу, аптырап калу. **Бер кулы – балда, икенчесе – майда** Мул һәм тук тормышта яшәү, мәгънәсендә. *Бөтен җире җитешкән, кияве, кыр кәҗәсе кебек, тирәсендә сикергәләп йөри, үзе тоташ ефәктән төренгән, бер кулы – балда, икенчесе майда булачак.* Ф.Хөсни. **Бер күз белән карау (бер күрү)** Һәммәсен тигез күрү, гадел карау. **Бер күлмәк белән калу** Бернәрсәсез калу. **Бер күрергә зар булу** Бик нык сагыну. **Бер күрмәскә әллә ни бирерсең (бирер идем)** Бик ямьсез, имәнеч, котсыз нәрсәгә карата яки кемнән дә булса бик каты бизү турында әйтелә. **Бер күрүдән егылып төшү** Бер күрү белән, сокланып, күз төшү, сихерләнеп мавыгу, гашыйк булу. **Бер мичкә балга – бер кашык дегет** Эшнең, сүзнең тәмен җибәрү, яраксызга чыгару, күңелне кайтару, ямьсезләү. **Бер нәфесен тыя алмау** Тиешсез эштән тыела алмау; аздан гына канәгатьләнә белмәү, комсызлану. *Бер нәфесен тыя алмаган кешене аны, әйтмә инде. Ни үгетләдек, ни әйттек. Ачуланып карадык, оялтып карадык, юк!* Г.Бәширов. **Берне биш итеп** Бик нык арттырып, күпертеп, асылын үзгәртеп. *Корбангали абзый, гадәтенчә, бик нык кодрәтләнеп, берне биш итеп сөйләде.* М.Мәһдиев. **Бер сүз белән (генә) әйткәндә** Кыскасы, гомумирәк итеп, нәтиҗә ясап, җыеп әйткәндә. **Бер сүзгә – биш сүз** Гел җаваплашып, сүз көрәштереп тору, карулашу. **Бер сүзгә килү** Аңлашу, килешү, бер карарга, бер киңәшкә, бер фикергә, бер уйга килү. *Юк, бездә бер сүзгә килү юк.* Ә.Фәйзи. **Бер сүздә булу** Уртак бер фикердә тору, тулысынча килешеп эш итү. *Шул инде сезнең... мин сизеп ятам, сез – барыгыз да бер сүздә.* Г.Бәширов. **Бер сүзенә – мең җавап** 1) Җавапка, сүзгә оста булу. *Бер сүзенә мең җавап табып, Фәхриҗамал абыстайны да авыз ачарга урын калдырмаган иде.* М.Вәли-Барҗылы; 2) Гел җаваплашып, сүз кө-

рәштереп тору, карулашу. **Бер сүз юк (булмау, әйтмәү)** Каршы тормау, тулысынча килешү, ризалашу. **Бер табактан ашау** Һәр эшне бергә хәл итеп, аралашып, дус, тату яшәү. *Кайтса, бик шәп булыр иде дә, барыбыз да бер табактан ашар идек.* Г.Ахунов. **Бер тавыкны унга бүлү** Шул дәрәҗәдә саран. **Бер тамчы су кебек (шикелле)** Бер-беренә бик нык охшаган, нәкъ бертөсле. **Бер фикергә килү** Үзара аңлашу, килешү. **Бер чыбыктан сөрелгән** Барысы да бер үк төрле, бериш. *Бер Рухия генә шушылай кыйбласыз, аумакаймы, әллә кызларның бөтенесе дә бер чыбыктан сөрелгән микән?* В.Нуруллин. **Бер(әр) яры** *диал.* Кая булса да бер урынга

**БЕ́РАВЫЗДАН** *рәв.* 1) Бердәм рәвештә, берьюлы. *Без дә Гаяз белән, сүз берләшкән кебек, бер үк җырны беравыздан сузып җибәрдек.* М.Әмир. *Балалар беравыздан җырлап җибәрделәр.* Г.Гобәй

2) Бертавыштан, каршылыксыз. *Минем бригада членнары аның тәкъдимен беравыздан күтәреп каршы алдылар бит, син дә хуплап ал.* Р.Ишморат. *Резолюцияне Шихрай тавышка куйды, һәм җыелыш аны беравыздан кабул итте.* Ш.Камал

**БЕ́РАВЫК** *рәв.* Аз гына вакыт арасы, бераз вакыт. *Беравык баргач, туктап, үзенә-үзе көлеп куйды.* Г.Бәширов. *Бирдебәк беравык уйланып торды.* Р.Зәйдулла. *Беравык Нургалигә, чынлап әйтәме бу, дигән төсле сынап карап торды да кыюсыз гына сорау бирде.* Ә.Еники

**БЕРАДӘР** *и. фар. иск к.* **борадәр.** *Берадәр, сезгә үтенәм сәлам язып, Күзең сал: Мәрҗани – ул Тимер казык! Булмаса, кыйбла тапмай адашырсың, Караңгыда җүн белмәй, юлдан язып.* М.Акмулла

**БЕРАЗ** *рәв.* 1) Аз гына күләмдә, берникадәр генә, күп түгел, беркадәр, өлешчә генә. *Шулай да әле, кызлар, Алла хакы өчен, Миннән бераз читтә йөрегез.* Һ.Такташ. *Комбайннарның барысын да борчакка кертергәме, әллә беразын арыш басуына җибәрә торыргамы?* Г.Гыйльманов. *Умарта күчен без юлдан бераз уң кулдарак күреп алдык.* К.Миңлебаев

2) Аз вакытка, озак түгел, кыска вакыт эчендә. *Анысы шулай, Мәрфуга түти, тик анда баруны бераз соңга калдырып тору да зарарлы түгел.* Һ.Такташ. *Тимери бераз соңгарак калган булып чыкты.* Г.Бәширов

3) Беркадәр, аз-аз гына, җиңелчә генә. *Шушы уйлар егетнең күңелен бераз күтәреп җибәрсә дә, янгын сүндерү командасында хезмәт итүе турында язарга кулы күтәрелмәде.* Р.Кәрами. *Минем бу эшкә бераз кәефем китсә дә, аның үзенә белдермәскә уйладым.* Ф.Әмирхан. *Бик җиңел сөякле күренде ул безгә, битләре кояшта янган, яңак сөякләре бераз чыгынкы, сакалы сирәк кенә, тәбәнәк кенә гәүдәле бер карт.* М.Мәһдиев

**БЕРАЗГА** *рәв.* Берникадәр вакытка, кыска вакытка. *Тик ул, тыкрыктан узышлый, беразга туктап, шомырт агачлары арасыннан аның тәрәзәсенә генә карап торсын иде.* Г.Бәширов

**БЕРАЗГА́ЧА** *рәв.* Күпмедер вакытка кадәр. *Аның әле бу «холкына» Беразгача түзеп була.* Х.Туфан

**БЕРАЗДАН** *рәв.* Берникадәр вакыттан соң, күпмедер вакыт узгач, озакламыйча, соңрак. *Тик бераздан җәяүлеләрнең яшьрәге, арбада утыручы малайга игътибар итеп, шаяртыбрак сорау бирде.* Ә.Фәйзи. *Бераздан гына бригадир кызы Ләйләнең ачы кычкыруына берьюлы сикереп тордылар.* Г.Гыйльманов. *Бераздан соң инде алар, бер-берсенә бик якын килеп, кулларыннан тотышып утыралар иде.* А.Шамов

**БЕ́РАРА** *рәв.* 1) Кайчандыр, бервакыт (узган хәл турында). *Әле кайчан гына --- Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлаган, берара Апас мәдәният йортында методист булып эшләп, халык театрында уйнап йөргән ---.* Л.Лерон

2) Ниндидер бер вакыт эчендә, билгеле бер вакытта. *Әбәттән соң, бакчада берара электр ышкысының гөжләгән тавышы яңгырап торды.* Н.Хәсәнов. *Берара кузгалмыйча да ятты, фәкать җилкәләре генә дерелдәп торды.* М.Әмирханов. *Берара зәп-зәңгәр күк йөзенә караган хәлдә хәрәкәтсез ятты.* Тәмуг чәчәге

3) Кайчан да булса, ничек тә булса, киләчәктә бер. *[Карчык:] Энҗенең бик яхшылары бар иде, бик эресе! Монда алып килмәгән идем шул, берара китерермен!* Г.Исхакый

**БЕ́РАРАДА** *рәв. к.* **берара**. *Кайсыдыр берарада Әхнәф Сөембикәгә бик якынайды, Фәһимә алар янына килми торган булып китте.* Ф.Садриев

**БЕ́РАРАНЫ** *рәв. сөйл. к.* **берара.** *Берараны Нәфистә «Их, шушындый җирдә яшәсәң...» дигән адаштыргыч уйлар да туып куйды.* Л.Гыймадиева

**БЕ́Р АТОМЛЫ** *и. физ.* Бер атомга ия булган. --- *бер атомлы молекуланың иреклелек дәрәҗәсе өчәү, ике атомлы молекуланың (һәм теләсә нинди икедән зур атомлы сызыкча молекуланың) – бишәү* ---. Техника термодинамикасы

**БЕРӘГӘЙЛЕ** *с. сөйл.* **1.** Саллы, бөтен таләпләргә дә җавап бирә алырлык, югары сыйфатлы, арада иң яхшысы. *Ике булганчы бер булсын да, берәгәйле булсын.* Мәкаль

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиешле дәрәҗәдә, җиренә җиткереп. *Күп сөйләми ул, ләкин, бер әйтсә, берәгәйле итеп әйтә.* Г.Ахунов

**БЕРӘ́М-БЕРӘМ** *рәв.* 1) Берсе артыннан икенчесе тезелеп, бер-бер артлы, аерым-аерым. *Трап салынуга, пассажирлар, берәм-берәм, ярга агыла башлады.* Р.Кәрами. *Ул арада чәй әзерләнеп, әллә ничә айлар сагынып йөргән сыйлар, берәм-берәм, өстәлгә тезелде.* Г.Ибраһимов. *Креслоларын саклап калу бәрабәренә, милли мәктәпләрне берәм-берәм бетерү юлына бастылар.* К.Миңлебаев

2) Берәрләп, берәмтекләп. *Йолдызлар башта тоныкланды, аннары берәм-берәм сүнә башлады.* Р.Хафизова. *Туйганчы коендылар егетләр, аннары берәм-берәм ярга чыгып, ком өстенә аудылар.* Р.Хафизова

3) *куч.* Җентекләп, тәфсилләп, җиренә җиткереп. *Илгизәр фотокарточкаларны берәм-берәм күздән кичерде.* Н.Хәсәнов

**БЕРӘМЛӘП** *рәв.* Берәм-берәм, берсе артыннан берсе, берәмтекләп,

аерып-аерып. *Һәм, берәмләп, кулларыгызны күтәреп чыга башлагыз.* Р.Мөхәммәдиев. *Берәмләп-берәмләп тотарга кирәк.* Ф.Хөсни

**БЕРӘМЛЕК** *и.* 1) Үлчәнә һәм исәпләнә алырлык, исәпләргә мөмкин булган төрдәш, бер типтагы нәрсәләрне микъдар, күләм ягыннан чагыштыру өчен кабул ителгән зурлык, үлчәм итеп билгеләнгән күләм. *Ана күңелендәге изгелекне үлчәү өчен берәмлекләр җитәрме икән?!* Р.Хафизова. *Ул инде һәрби берәмлек буларак берни тормый, бик акрынлык белән, алга гына бара ала.* Кызыклар дөньясында. *Тик галимнәр аны авырлык яки көчәнеш кебек берәмлекләрдә үлчи генә белми әле.* Юлдаш

2) Данә. *Язылу тарихлары сакланган ташларның саны 49 берәмлеккә җитә.* М.Әхмәтҗанов. *Татарстан Президенты киңәшчесе Татьяна Ларионова әйтүенчә, Казанның медицина җиһазлары заводында инвалидлар өчен электр арбаларын елына 1670 берәмлек җитештерү планлаштырыла.* Шәһри Казан

3) Бердәмлек, бергә тупланганлык, бөтенлек. *Һәр фәннең төп берәмлеге, үзәк мәсьәләсе була, шуның тирәсендә, тагын да хосусыйрак мәсьәләләргә тармаклана-тармаклана, тулы бер фәнни өлкә барлыкка килә.* М.Кашапов

4) *лингв.* Лексема. *Ә морфологияне сүз төркеменә оеша торган берәмлекләр һәм шулар белән бәйле мәсьәләләр кызыксындыра һ.б.* М.Кашапов

5) *мат.* Күп урынлы саннарның нуль һәм бердән тугызга кадәрге цифрлары. *A векторы x күчәренең уңай ягына юнәлгән һәм модуле 3 берәмлеккә тигез.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

**БЕРӘМЛЕКЛӘП** *рәв.* 1) Берәрләп, берәм-берәм. *Тотыш би, санап, берәмлекләп, көмеш акчалар ташлады.* Н.Фәттах. *Хәбибулла абзыйны военкоматка чакырдылар. Алтынчы дистәнең актыккы көннәрен берәмлекләп чүпләп барган бу картка нинди йомышлары төште икән?* Г.Әпсәләмов

2) Аерым бер сыйфатлары буенча аерып, бик җентекләп. *Мансуров, районга килгән көннән башлап, кыйммәтле асылташ кебек берәмлекләп җыйган талантлы яшьләр гвардиясенә тагын бер солдат табылуына чын күңелдән куанды.* Г.Бәширов

**БЕРӘ́М-СӘРӘМ** *рәв. к.* **берән-сәрән.** *Алар барып урнашканда, берәм-сәрәм эшчеләр җыела башлаганнар иде.* А.Таһиров

**БЕРӘМТЕКЛӘП** *рәв.* 1) *к.* **берәмләп.** *Тик инде эскерт кырыеннан берәмтекләп җыеп кайткан бодайны туфрагыннан арындыру белән генә чикләнмәде.* К.Миңлебаев. --- *нәкъ абыстай шикелле итеп, бармак очлары белән, берәмтекләп, тәсбих төймәләрен тартырга тотынды.* Ф.Бәйрәмова

2) Бик җентекләп, тәфсилләп, игътибар белән. *Рәфгать белән, берәмтекләп, һәр җан иясен инә күзеннән үткәрербез...* А.Гыйләҗев. *Ул, яхшылап, кәгазьләрне тикшерде, хәрефләренә хәтле берәмтекләп карап чыкты кебек.* Р.Сәгъди

◊ **Берәмтекләп кенә санарлык** Бик аз күләмдә

**БЕРӘ́Н-СӘРӘН** *рәв.* Кайбер урыннарда гына, бик сирәк, әле анда, әле монда, әллә нигә бер. *Урамнарда, төнге фонарьлардан, берән-сәрән җиңел машиналардан, җәяүлеләрдән кала, берни дә күренми иде.* З.Мәхмүди. *Анда, он тарттырырга килгән берән-сәрән агайлардан гайре, көнен дә, төнен дә бер җан иясе булмый.* Р.Хафизова

**БЕРӘР** *сан* **1.** Һәркемгә (һәрнәрсәгә) бер, һәрберсенә бертигез күләмдә бер булуны белдергән бүлү саны. *– Әйдәгез, менә шушы уңайдан, күрше авылдагы мәчетебезгә утын илтик – берәр агачтан да җыела бит, кисеп тә кайтырбыз, бәйрәм булгач, саваплы булсын, – диде.* М.Әмир. *Эшелоннарны берәр сәгать, икешәр сәгать семафор алдында тоту өчен сәбәп табылып кына тора.* И.Гази

**2.** *а. функ.* 1) Билгесез зат, предмет, эш-хәлгә ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; ниндидер, нинди дә, кайсыдыр. *Моның астында берәр хәйлә бардыр.* Г.Ибраһимов. *Ә Клара урынында берәр дөнья күргән олы кеше булса, ул, бу өйләргә карап, авылның үткән тарихын да, бүгенге хәлен дә китаптан укыган шикелле укыр иде.* Ә.Еники. *Моның өчен аңа берәр якты хатирәне, берәр шатлыклы вакыйганы күз алдына китерергә кирәк иде.* М.Хәсәнов

**3.** *рәв. мәгъ.* Вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр белән, чамалап әйткәндә, якынча шул вакыт эчендә, мәгънәсендә кулланыла. *Авария-фәлән булмаса, берәр айдан нефть яткан катлауга барып җитәчәкбез.* А.Әхмәт

◊ **Берәр яры** Кая да булса; кайда да булса. *Ничек уйлыйсыз, Батырхан әфәнде, миңа монда берәр яры урнашырга булырмы икән?* К.Тинчурин

**БЕРӘ́Р-БЕРӘР** *рәв. к.* **берәм-берәм.** *Монда төрле багбаннарыбызның хәссась күңелләрендә җитешкән әдәбият гөлләреннән берәр-берәр чәчәкләр алынды.* Г.Тукай

**БЕРӘРЛӘП** *рәв.* 1) Берәр итеп. *Алмаларны берәрләп төрү*

2) Берәрдән бүлеп, берәр-берәр булып. *Сафка берәрләп басу*

**БЕРӘРСЕ** *а.* Билгесез затка ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; кем дә булса, кайсы да булса. *Ай, берәрсе килеп чыкса!* А.Әхмәт. *Берәрсе катырак кычкырып җибәрсә йә, шакылдап, капка ябылса, колын дерт итеп сискәнеп китә.* Г.Бәширов. *Әллә берәрсе, сиздерми генә, куаклар арасыннан күзләп торамы аны?* Тәмуг чәчәге

**БЕРӘ́Ү** *сан* **1.** Барысы, бөтенесе бергә бер генә булуны белдергән җыю саны. *Минем йөрәгемне әрнетүче син генә, берәү генә.* Ә.Ерикәй

**2.** *а. функ.* 1) Билгесез затка ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; кемдер, әллә кем. *Чал төшкән түгәрәк сары сакаллы, каракүл бүрекле берәү белән озын чәчләре тирәле кырт киселгән, бөрмәле кафтан кигән бер кара чандыр кеше якынлашты.* Ә.Фәйзи. *Аның ачулы тавышын ишетеп, борылып карасалар – алыптай гәүдәле берәүнең, күккә тартә күтәреп, өсләренә килүен күрәләр.* К.Миңлебаев. *Соң, Нурислам абыйсыннан да лаеклырак дөньяда икенче берәү бармы икән әле!* Р.Хафизова

2) *дә* кисәкчәсе белән берлектә, бөтенләй табылмауны белдереп, булу-

ын, барлыгын кире кагып, юклык алмашлыгы буларак кулланыла; һичкем, беркем, кем дә. *Бу вакытта әле берәү дә йокламый.* Ә.Айдар. *Аның арткы ишектән шым гына килеп керүен берәү дә сизмәде.* Ш.Маннур. *Без, һичбер комачаусыз-нисез, берәү дә берни әйтмичә, корыч йөрәкле дустыбызның кабере алдына тезләндек.* А.Шамов. *Берәү дә бу дөньяга матур буй-сын белән тумый.* Сөембикә

**3.** *и. мәгъ.* 1) Сөйләүчегә билгеле булган кеше. *Әни, минем күз бутәнгә төште шул, икенче берәүгә.* К.Миңлебаев. – *Әби, атны бераз ял иттерик, үзебез дә җылыныйк. Монда берәүгә кереп чыгарбыз, – диде Низами.* Г.Ибраһимов. *Авылыбызда Темарук дигән кушаматлы Әхмәтҗан исемле берәү бар иде.* К.Миңлебаев

2) **берәүләр** *күпл.* Кайберәүләр, кайсыберләр, кайсыбер кешеләр. *Күп күрдем сандугач оясын, Берәүләр күралмый гомергә! Әнә шул берәүләр еш кына өйрәтә – кай төштә күрергә.* Р.Фәйзуллин. *Бу дөньяга без барыбыз да кеше булып туабыз, әмма, үсә төшкәч, табигать кануннарына каршы төшеп, берәүләребез – үрдәккә, икенчеләребез – төлкегә, өченчеләребез юха еланга әверелә, һәм гел шулай, елдан-елга, гасырдан-гасырга дәвам итә.* З.Мәхмүди

3) **берәүләр** *эвф. күпл.* Кемгә дә булса кинаяләп әйткәндә. *Берәүләр зур кеше булган икән*

4) Кемдер, билгесез кеше, бер кеше. *Ишеттем мин кичә: берәү җырлый, чын безнеңчә матур, моңлы көй.* Г.Тукай. *Аңа өстән берәү күрсәтмәләр биреп тора.* Н.Хәсәнов.

**БЕРӘҮСЕ** *а.* 1) *сөйл.* Билгесез затка ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; кемдер, әллә кем. *[Яралылардан] Берәүсе, солдатларга карап: «--- сез кемнәргә каршы мылтык күтәреп килеп, кемнәрнең йөрәк каннарын агызуыгызны беләсезме?» [диде].* М.Гафури

2) *дә* кисәкчәсе белән берлектә, бөтенләй табылмауны белдереп, булуын, барлыгын кире кагып, юклык алмашлыгы буларак кулланыла; һичкем, беркем, кем дә, һичберсе. *Берәүсе дә икмәк китерми, өйгә дә якмый.* М.Җәлил

**БЕ́Р-БЕР** *рәв.* **1.** 1) Нәкъ, әйтерсең (охшатып әйткәндә). *Айлар үттек, еллар үттек, гөл кебек, Бер-берен көнләүче пар былбыл кебек.* Ф.Бурнаш

2) Кайчан да булса (бер). *Бу арада сораганым да юк, ул Закир дигәннәрен табалармы инде --- бер-бер, юкмы?* Г.Камал

3) Берәмтекләп, аерым-аерым. --- *вә солдатка тотып бирүен, вә башка золымнарын да бер-бер бәян итте.* Г.Тукай

**2.** *а. функ.* 1) Билгесез зат, предмет, эш-хәлгә ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; ниндидер, нинди дә, кайсыдыр. *Булмас ахры, диде, бер-бер хәйлә кормый.* Г.Тукай. *Үзе кире борылды, егетләргә бер-бер бәла була күрмәсен, дип, авылга чапты.* Ф.Сафин. *Ә эштән кайтканда, ул миңа сыкраган тавыш белән генә әйтте: – Әллә соң миңа бер-бер үпкәң бармы?* Н.Гыйматдинова. *Кайда булса да башка бер-бер җиргә куйган булырга кирәк.* Г.Камал

2) Затларга, предметларга яки аларның төркемнәренә аерып, аерым-аерым ишарәләп, билгеләү алмашлыгы буларак кулланыла; һәрбер. *[Колхозчыларның] Кайсылары бер-бер арбага бишәр-алтышар кеше төялгән, урам буйлап көлешә-көлешә, кырдан кайталар.* Ш.Камал. *Бер-бер көн итегенә дә өч егетнең аягы шыплап кына кереп утырыр сыман.* Ф.Сафин

◊ **Бер-бер артлы** Берсе икенчесенә ияреп, берсе артыннан икенчесе. *Хабаровск әйтерсең бер-бер артлы куышкан өч дулкын рәвешендәге тауда утыра.* Н.Хәсәнов. *Шунысы гаҗәп, Мәскәү аларның бурычларын бер-бер артлы гамәлдән чыгара тора.* М.Абдуллин. *Еллар бер-бер артлы узар, ә мәктәп тәмамлаганда истәлек өчен төшкән фотолар гомерлек ядкяр булып калыр.* Мәгърифәт. **Бер-бер вакытта** Кайчан да булса, кайчандыр бер. **Бер-бер җирдә** Кайдадыр, ниндидер берәр билгесез урында. *Ул бу кәгазьгә һәрбер күргән гаҗәп нәрсәсен яза бара торган бер яхшы гадәт ясаган; бер-бер җиргә туктап ял иткәндә, кешеләр ял иткәндә, Сәгыйд карт, утырып, язарга яратадыр иде.* Г.Гобәйдуллин

**БЕ́Р-БЕРЕ** *а. к.* **бер-берсе**. *Тик икебез ике дөнья кебек, Бер-беребезне белми яшибез.* К.Булатова. *Бер-беребезгә кергәләп йөрибез.* К.Миңлебаев. *Бер-беренә бик тиз ияләшеп китәләр.* К.Миңлебаев

**БЕ́Р-БЕРСЕ** *а.* 1) Предметларга, затларга яки аларның төркемнәренә, аерып, аерым-аерым күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; һәрберсе, һәркайсы. *Шулай булса да, кешеләр, бер-берсе белән танышу, йөрешү, алыш-биреш итү аркасында, акрынлап берләшәләр, күплектән берлеккә таба баралар.* Г.Гобәйдуллин. *Бер-берсе мең сумлык --- бар бу атларның.* Г.Ибраһимов

2) *кыек килештә* **бер-беребезне, бер-береңә, бер-берегездән, бер-берсенә, бер-берсеннән** Берсе икенчесен. *Кызы да, кияве дә, югары белем алган зыялыларга хас тыенкы гаҗәпләнү аша, бер-берсенә караштылар.* М.Галиев. *Күпме яшь йөрәкләрнең бер-берсенә биргән кайнар вәгъдәләренә шаһит булгандыр ул.* Ф.Сафин. *Әнә шул сансыз-исәпсез урманнарда бер-берсенә тәмам охшаган ике --- агач юк, диләр.* А.Гыйләҗев

**БЕ́РБӨТЕН** *с.* Бердәм, тоташ. *Казан ханлыгы халкы, Кырым ханлыгы, башка татар ханлыклары һәм Нугай Урдасы халкы белән этник яктан бербөтен кавем тәшкил итә.* М.Әхмәтҗанов. *Береннән бере уңган ике затның кушылуы, бербөтен тәшкил итүе була.* К.Миңлебаев

**БЕ́РБУЫН** *и.* 1) Бер чорда яшәгән халык. *Сугыш бер аларны [чит илдә ятып калган солдатларны] гына түгел, тагын бербуынны – менә бүген Күктау инеше буйларында көлеп-уйнап йөрергә тиешле буынны да харап иткән...* А.Гыйләҗев. *Хәзер бу Сталинсыз рәсемдә тагын бербуын тәрбия алды.* Р.Батулла

2) *мат.* Тапкырлау һәм дәрәҗәгә күтәрү гамәленнән торган алгебраик аңлатма. *Өч үзгәрешле ниндидер бербуын бирелгән булсын.* Күпбуыннар: Югары уку йортлары өчен уку ярдәмлеге. *Бербуынны дәрәҗәгә күтәрү*

**БЕ́РВАКЫТ** *рәв.* 1) Күптән булган, әллә кайчан, кайчандыр бер. *Икенче бервакыт, күзгә көндә, товар поезды станциягә килеп туктауга, кондуктор белән уртак тел таптым.* К.Миңлебаев. *Моның шулай икәнен дә Мотаһир бервакыт үзе дә ышанды.* Р.Кәрами. *Бервакыт шулай, аны олы малайлар кыерсыткач, ул әтисенә кайтып зарланган иде.* Н.Хәсәнов

2) Кайчан да булса бер (киләчәктә). *Дәҗҗал белән Мәһди дигән затлар, иске игътикатлылар әйткәнчә, бервакыт килеп чыгарлармы?* Г.Тукай. *Коега төкермә, бервакыт суын эчәргә кирәк булыр, диләр.* Г.Тукай

**БЕ́РВАКЫТНЫ** *рәв. к.* **бервакыт.** *Менә шулай бервакытны яңа кар төшкән чаклар иде.* Р.Гали. *Гайса морза бервакытны Уфадан безгә (Дәүләкәнгә) дә килеп киткән иде.* Ә.Еники

**БЕ́РВАКЫТТА** *рәв.* 1) *к.* **бервакыт.** *Иң кирәкле бервакытта әһәмиятле «тел» алып кайтуны тәэмин итте.* А.Әхмәт

2) Беркайчан да, нинди генә очракта да, һичкайчан. *Без бервакытта да бабайның эшенә комачаулык китерми идек.* Г.Гобәй. *Ул кешегә бервакытта да усаллык кыла алмас.* Н.Хәсәнов

**БЕРГӘ** *рәв.* 1) Үзара берлектә, бергәләп, бергәләшеп. *Аның белән бергә көймәдә диңгезгә балык сөзәргә чыгам...* Ә.Фәйзи. *Сезнең белән бергә без дә саф һава урынына тузан йотып утырдык.* Г.Камал. *Су китерә, утын кертә, кызлар белән бергә каз йолка, аннан икешәр-икешәр дүрт казны, көянтә башына элеп, елгага алып төшә.* Ә.Еники. *Никадәр авыр булса да, бергә булгач түзәрбез.* Р.Ишморат

2) Кушылып, кушып, катнаштырып, катнашып. *Бик сирәк кешедә менә шундый бер-берсенә капма-каршы сыйфатлар бергә сыеша.* Т.Галиуллин. *Борчак белән солыны, я булмаса, вика белән солыны бергә кушып чәчәргә кирәк икән.* Ә.Еники

3) *белән* бәйлеге янында килгәндә: бер үк чакны, бер үк вакытта, шул ук вакытта, рәттән. *Чирмешәндә торган чакларында, Мәрьям, әниләре авыруыннан машинада кайтып килешли, авариягә очрап, өч яшьлек кызы белән бергә һәлак булды.* Ә.Еники. – *Әгәр мин сезнең белән бергә хезмәт итмәгән булсам, – диде ул.* А.Шамов. *Үзе белән бергә очкан таныш түгел адәмнәрне күргәч, ул бик нык гаҗәпләнде.* З.Мәхмүди

◊ **Бергә булсын** «Тәмле булсын», «эшләр уңсын» һ.б.ш. теләкләргә каршы җавап итеп әйтелә

**БЕРГӘ́-БЕР** *рәв.* 1) Бер данәгә – бер данә. *Бергә-бер алмашу*

2) Ялгыз, үзе генә. *Табигать белән бергә-бер калганда, кешедә матур уйлар гына туа.* Ш.Галиев. *Бөек әсәрләрне – җырмы, көйме, рәсемме – исегезгә төшерегез, күбесен талантлы Шәхес ялгызлыкта – Дөнья белән бергә-бер калып, серле тынлыкта иҗат иткән бит!* Р.Фәйзуллин. *Онытылып язар өчен, өстәлең белән бергә-бер калу кирәк бит.* Р.Зәйдулла. --- *һәр иҗатчы үзенең намусы, вакыт һәм халык алдында япа-ялгыз, бергә-бер бит!* А.Хәлим

3) *к.* **бермә-бер** (*2 мәгъ.*). *[Май] Безда озак торган, каксыган, базарлыклы түгел! Әйдә, миннән булсын яхшылык, бергә-бер.* Г.Бәширов

4) Бер үк төрле, бертигез дәрәҗәле. *Хисап әзер: бергә-бер, Син дә бер һәм мин дә бер.* Б.Рәхимова. *Ярыш нәтиҗәләре: бергә-бер*

5) Бер кешегә (төркемгә) каршы бер кеше (төркем). *Ахыр, бергә-бер юлыгышып, каты орыш кылдылар.* Әкият. *Менә шунда Мостафин тупчылары немец танклары белән бергә-бер калды.* Х.Камалов

**БЕРГӘ́-БЕРГӘ** *рәв.* Һәммәсе бергәләп, җыйнаулашып, бергәләшеп. *Өйгә генә алып кайтыйм үзен, гөрләшеп, янә дистәләрчә ел бергә-бергә гомер кичерергә насыйп кына булсын!..* К.Миңлебаев. *Аларның яшьлеге һәм кайнар мәхәббәтләренең онытылмас истәлеге булып, бергә-бергә яши башлаган шушы өйләре калган.* Р.Ишморат. *Алга таба да шулай бергә-бергә хезмәттәшлек итәргә насыйп булсын!* Казан утлары

**БЕРГӘЛӘП** *рәв. к.* **бергә-бергә**. *Ул турыда Газизәне бергәләп тәрбияләү өчен, мин сиңа һәртөрле булышлыклар күрсәтергә әзермен.* Г.Тукай. *Аннары алар, бергәләп, камышлы Мишә буена төштеләр.* Н.Хәсәнов. *Рәмис суынсын өчен алдан ук ясап куелган чәйне эчкәч, бергәләп, бакчага барырга чыктылар.* С.Кашапова

◊ **Бергәләп тоз ашау** Авыр хәлләрне бергә кичерү, бергә кыенлыклардан чыгу. *Ихтимал, тора-бара, бергәләп тоз ашагач, барысы да булыр.* Ә.Еники

**БЕРГӘЛӘШЕП** *рәв. к.* **бергә-бергә.** *Җәйнең ямьле көннәреннән берендә, алты-җиде малай, бергәләшеп, тыкрык башыннан ук күлмәкләрне салa-сала, Агыйдел буена төшеп барабыз.* М.Әмир

**БЕРГӘЛЕК** *и.* **1**. 1) Бердәмлек, татулык. *Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып, Без шаярыштык вакытлар алмашып.* Г.Тукай

2) Уртаклык. *Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.* Г.Тукай. *Шулай итеп, үзеннән-үзе, һәр ике як өчен дә кулай бергәлек барлыкка килде.* Р.Мирхәйдәров

**2**. *с. мәгъ. сөйл.* Бергә узган, бергә булган; уртак, күмәк. *Ике ел бергәлек якты тормыштан соң, Нәфисәнең кияве тиф авыруыннан үлеп китте.* Ш.Камал

**БЕРДА́НКА** *и. ингл. иск.* 1) Америкалы Бердан исеменнән: XIX гасырның икенче яртысында рус армиясендә кулланылган бер корулы мылтык. *Винтовкалар бик төрле һәм ике системадагылар иде, – анда рус берданкалары да, --- немец винтовкалары да бар иде.* А.Шамов. *Каушый-каушый, берданканы алды һәм, начальникның кире уйлавыннан куркып, бер читкә китте дә, берданка белән эш итә алганын күрсәтәсе килеп, йозагын оста итеп шалтыратып куйды.* Г.Гобәй

2) Бер көпшәле ау мылтыгы. *Ә Фәритнең кече абыйсы Госман берданка алып чыккан арада, әллә шул ук, әллә икенче бер тилгән, һавадан койрыклы йолдыздай атылып килеп төште дә, беренчесенең коелып калган каурыйлары тирәсендә чырылдап йөргән икенче кошны да эләктереп менеп китте.*

Г.Гобәй. *Нургали абзар ишегенә китте, Хисмәт абзый, сүс бау таккан берданкасын бер иңбашыннан икенчесенә күчереп, аның артыннан иярде.* Ә.Еники

**БЕ́РДӘЙ** *рәв.* 1) Бертигез, бертөсле, тәңгәл. *Бары да бердәй яшел булып утырган агачларны табигать нинди генә төсләргә бизәмәде!* Г.Гобәй. *Бердәй сөеп азат хезмәтне, Бердәй сөеп газиз Ватанны, Алга куеп бер үк максатны, Каршыладык һәркөн ал таңны.* Ә.Исхак. *Аннары без, көрәкләребезне алып, беребез бер сүз эндәшмичә, һәркайсыбыз бердәй уйга батып, кабер туфрагын тигезләп күтәрдек.* А.Шамов

2) Искиткеч, менә дигән; бик яхшы. *Киленнең болай иркен күңелле, ачык чырайлы булып, ачу сакламавы, аның өстенә, бөтен районда бердәй бодай үстереп, район башлыклары һәм олылар каршында гел уңганлыгы һәм тырышлыгы белән генә телгә алынуы Хәдичәнең дә күңелен йомшартмый калмый иде.* Г.Бәширов

**БЕРДӘЙЛЕК** *и.* 1) Бертөслелек, охшашлык, тәңгәллек. *Мәсәлән, Платон биш төп категорияне атый: асыл (төп нигез), хәрәкәт, тик торыш, бердәйлек (тождество) һәм аермалык.* К.Гыйззәтов. --- *уен-ритуалларын бу – безнеке, бу – славяннарныкы, дип әйтүе дә кыен, чөнки бу охшашлык һәм тәңгәллекләр фольклор үсешендәге типологик бердәйлек булып формалашканнар.* Р. Ягъфәров

2) *мат.* Кыйммәтләре үзара бер үк булган алгебраик аңлатмалар тигезлеге. *Бу тигезлек бердәйлек булу сәбәпле, үзгәрешлеләр урынына аерым кыйммәтләр куйганда килеп чыккан тигезләмәләр системасы А, А1 коэффициентларын табарга мөмкинлек бирә.* Күпбуыннар: Югары уку йортлары өчен уку ярдәмлеге

**БЕРДӘМ** *с.* **1**. 1) Үзара килешеп, бергәләп башкарыла торган; бер уй, ният белән оешкан; үзара дуслыкка нигезләнеп тупланган. *Язучылар союзы һәм Композиторлар союзы бердәм иҗат эшен көчәйтергә тиешләр.* М.Җәлил. *Бар да тигез – читләр һәм ятлар юк Безнең тату, бердәм семьяда.* Ә.Исхак. *Тигез, бердәм тавыш белән, чикерткәләр кычкыралар.* А.Әхмәт

2) Уртак, барлык кешеләр өчен дә бер дәрәҗәдә булган. *Баскониянең ташлы юлларында Бердәм байрак тотып кулларына, Ялкынланып бердәм хис белән, Җимерелмәслек ныклы көч белән Саклый алар анда Испаниянең Хезмәт яңгырап торган җирләрен.* Ә.Исхак. *Бердәм дәүләт имтиханында укучылар үз билгеләрен аклый.* Ватаным Татарстан. *Бердәм таләп, бердәм кагыйдә булмаудан, мөгаллим дә, бала да, милләт тә зыян күрә.* Татарстан яшьләре

3) Бербөтен. --- *милли хәрәкәтнең иң төп изге бурычы – татар халкын бөтен, бердәм, бер милләт итеп саклау иде.*Ә.Еники. *Сәламәт яшәү рәвешен оештыруда акыл белән эш итү һәм үзебезнең рухи-интеллектуаль үсешебезне тагын да камилләштерү – бердәм процесс ул.* А.Низамов

**2**. *рәв. мәгъ.* 1) Бергәләшеп, һәркем бер булып. *Колхозчыларыгыз өмәдә, зур тырышлык күрсәтеп, бердәм эшләделәр.* А.Әхмәт. *Кызыл мәйдан аша яшьлек бара, Бердәм атлый сезнең аяклар.* Ә.Ерикәй. *Әнвәр бервакытны аңар: – Барлык мөселманнар бердәм һәм тату яшәсәләр генә бәхеткә ирешәчәкләр, – дигән фикер әйткәч, Булат көтелмәгән соравы белән аптырашта калдырды.* К.Нәҗми

2) Барысы бергә, бер үк вакытта, дәррәү. *Кинәт өч кеше бердәм көлеп җибәрделәр.* А.Әхмәт. *Килешмәгән очракта, аны инкяр итеп, бердәм рәвештә: «Азатлык!» – дип кычкыра, сызгыра башлый.* З.Мәхмүди. *Бик кызып киткәч, бердәм кычкырышып, җырлашып, ресторанның эчен дер селкетүләр бар иде.* Ш.Бабич

**3.** *хәб. функ.* Һәркем бер булуны, тупланганлыкны белдерә. *Өстәвенә, авыл кешесе бик бердәм.* Ватаным Татарстан

**БЕРДӘМЛӘШҮ** *ф.* Берләшү, бергә оешу. *Җитмәсә, 1927 елда барлык крестьяннарның өчтән бере инде кооперацияләргә берләшкән иде. Димәк, халык авылда бердәмләшеп эшләүгә, яшәүгә каршы түгел.* Ф.Сафин

**Бердәмләшә бару** Акрынлап бердәмләшү

**Бердәмләшә төшү** Бераз бердәмләшү; тагын да бердәмләшү

**Бердәмләшеп алу** Бергә тупланган хәлгә килү

**Бердәмләшеп бетү** Барысы да тәмам бердәмләшү

**Бердәмләшеп җибәрү** Бердәмлеккә ирешү

**Бердәмләшеп китү** Нииндидер этәргеч, сәбәптән соң бердәмләшү; бердәмлеккә ирешү. *Ш.Анак иҗатының бер күркәм ягы шул: ул үз халкының гасырлар буе чарланып килгән рухи җәүһәрләрен, бүтән халыкларда булган шундый ук аналогик рухи байлыклар белән кушылып, бердәмләшеп китә алырлык яссылыкка куя белә.* Р.Фәйзуллин

**Бердәмләшеп кую** Алдан бердәмләшү

**БЕРДӘМЛЕК** *и.* Бергәлек, бергә тупланганлык, оешканлык. *Ә сез, «милли бердәмлек» дигән булып, казахның ярлы күпчелеге өстеннән бер төркем казах солтаннарының һәм байларының камчысын уйнатмакчы буласыз?* Ә.Фәйзи. *Житеш тормышта яшәүнең тагын бер сере, мөгаен, әнә шул бердәмлеккә дә барып тоташадыр әле.* Ватаным Татарстан. *Төркиләрнең бердәмлеген ныгытуга, көч-куәтен арттыруга зур өлеш кертә.* Юлдаш

**БЕРДӘН** *рәв.* **1.** 1) Бөтенесе бергә, бер кешедәй, бер булып. *Бөтен шәкерт бердән кабынып китә.* Т.Гыйззәт. *Мәргәннең исән-сау икәнен күргәч, халык, бердән, шөкер сүзләре кычкыра башлады.* Р.Батулла. *Барыбыз бердән сикереп торып, тиз генә киемнәребезне кидек.* Мирас

2) Кинәт, көтмәгәндә. *Радионың морзе белән сөйләве бердән өзелде.* Ә.Айдар. *Хисами моңарчы да эчкән иде, шуңа күрә бу эчкәне аның кыюлыгын кызган мунча ташыдай чыжлатып җибәрде, һәм егетнең бердән теле ачылды.* Г.Минский. *Шаяруларга урын юк, дигән төсле, бердән җитдиләнде һәм бөтенләй башка тонда әйтте.* Г.Минский

3) Тулаем, тулысынча. – *Нишләп соң алай иттең? – дигәч, Халикъ, чыраен да сытмыйча: «Син бит, Фәхрелислам абзый, акчасын кирәк саен ала барырсың, дигән идең. Ә теге кеше бердән чыгарып бирде», – дип җавап кайтарды.* Ш.Камал. *Кашки, бу кадәр газаплаганчы, җанымны рәнҗеткәнче, башымны кылыч илә бердән чабып өзсәләр, мең мәртәбә шөкер кылыр идем!* Ш.Мөхәммәдев. *Кичке эңгер күләгәсе белән караңгыланган йорт эче бердән тынлыкка чумды.* К.Нәҗми

4) Бер толымлап. *[Әсманың] Бердән генә үреп салган калын сары чәч толымы гимназия формасы --- өстендә бик ачык бер төс белән ярылып тора иде.* Ф.Әмирхан

**2**. *кер. сүз функ.* Беренчедән, иң элек. *Бердән, үзеңә эссе, икенчедән, унбиш көннән бирле капрал солдат булып йөрисеңне яратмыйм.* Т.Гыйззәт. *Бишенче ел революциясе, бердән, буржуаз демократик революция булса, икенчедән, ул пролетариат революциясе дә [иде].* Г.Нигъмәти. *Бердән, көннең эсселеге, икенчедән, һич йокысыз юл зәхмәте хан кызы илә шаһзадәне тәмам хәлдән тайдырган, арыткан иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Бердән, үзара татулашып-берләшеп китүдән куркалар.* Р.Кәрами

**БЕРДӘ́НБЕР** *с.* **1**. Бары берәү генә, башка юк, бер генә. *Тәңре дә бер, бердәнбер түгелмени?!* Р.Зәйдулла. *Гыйззәтнең төп йорттагы бердәнбер сеңлесе Сөембикә гомере буе үпкә туберкулезы белән иза чикте, санаторийларга бармады, врач дәвасын санга сукмады.* М.Мәһдиев. *Ул – әтисенең бердәнбер кызы.* Тәмуг чәчәге

**2**. *и. мәгъ.* Башкалар арасында иң якын, иң газиз, иң кадерле, барыннан да өстен кеше. *Баламны – бердәнберемне – миңа күрсәтмәс өчен, әллә ниләр кыланалар.* Ә.Рәшит. *Бердәнберем бит ул минем, бердәнберем.* Р.Ишморат. *Ана үзенең сырхап киткән бердәнберен ничек караса, Хәлим белән Гөлгенә Шәехтайны шулай карады.* Г.Гобәй

**БЕРЕГҮ** *ф.* 1) Оешу, берләшү. *Анри Барбюс, эшчеләр массасы белән берегеп, революция дошманнарына көрәш ачты.* М.Җәлил. *Бөтенебез бер булып, диде, урысы-татары, үзбәгеәрмәне, дигәндәй бертугандай берегеп, фашистны кырып ташлыйк, диде.* Г.Бәширов

2) Бербөтен булып кушылу, ныгытып урнашу, бергә нык тоташу, бер-берсенә ябышу, ябышып ныгу. *Алар, үзләре үк аңлап, култык аша бер-беренең куллары кысышып, бик дәү һәм тәвәккәл эшкә тотыныр алдыннан, бергә берекәндәй тыгызланышып, тантаналы бер хәлгә килделәр.* Ш.Маннур. *Ялган, бар булган һәрнәрсә акылга сүз булып берегә. Сүз генә бу фани дөньяда бирешми януга, черүгә.* Р.Харис. *Төрле сәбәп белән, термин телдә берегә алмый, ул кабат карала, гамәлдән чыгарыла, аның урынына башкасы тәкъдим ителә.* И.Низамов. *Җиргә берекәән кеше ялгызак калса, башы михнәттән чыкмаячак.* Б.Камалов

3) Үзара килешеп, бердәмлеккә килү, уй, фикер һ.б. ярашу, килешү. *Һәм шул көнне үк күңелләре белән беректеләр.* Р.Хафизова. *Теләгем кабул булды, кавыштык, тик берегә алмадым, һаман да икегә бүленгән хәлдәмен.* Ш.Янбаев

4) Бик нык ияләшү, үзләшү. *Хәтта хайваннар да, үзара берегеп, бер-берсен аңлап яшиләр.* Г.Коләхмәтов

**Берегә бару** Торган саен ныграк берегү. *Аның күңелендә шуларның барысы өчен дә үч алу уе берекәннән-берегә бара иде.* Г.Исхакый. *[Айсылу] Шушы җиргә көннән-көн ныграк берегә барды.* Ә.Моталлапов

**Берегә башлау** Берегергә тотыну

**Берегә төшү** Бераз берегү; тагын да берегү

**Берегә язу** Берегергә аз гына калу. *Йокы качты, бер-берсенә берегә язган күз кабаклары ачылып китте.* Н.Фәттах

**Берегеп бетү** Тәмам, тулысынча берегү. *Дөрес, татарның сөйләм термины, әлегә хәтта фәндә дә, тәмам берегеп бетмәгән, башлыча сөйләмнең бер төре – телдән сөйләүгә генә кайтып кала.* И.Низамов.

**Берегеп җитү** Ахырга кадәр, тәмам берегү. *Кызлыкка алырга теләмәсә дә, Гөлнара аңа тәмам күнегеп, кая ул күнегеп кенә, берегеп җитте.* Г.Гыйльманов. *Әллә Мостафа белән җаннары берегеп җитмәгәнне аңлап, шушы сәбәп белән араны өзү, өйдән чыгып китү җаен карыймы?* Ф.Сафин

**Берегеп калу** Нинди дә булса моменттан, вакыттан соң, үзгәрмәслек булып, нык берегү. *Сабый чакта ишеткән хикәят кебек, яшьлек иртәсендә тыңлаган моң кебек күңелгә сеңеп, хәтергә берегеп калганнар алар.* М.Госманов. *Без очы линомётка берегеп калган нечкә нейлон бауны, судан сөйрәп чыгарып, палубага җыя башладык.* М.Юныс

**Берегеп килү** Акрынлап, аз-азлап берегү

**Берегеп китү** Тора-бара, кинәт берегү. *Разия киявен мөкиббән китеп яратмый, ә бары тик «ошата» гына, яши башлагач берегеп китәрбез әле, дип әйтә икән, дигән сүзләр дә җиткереп алган иде.* А.Хәлим. *Кеше язмышында катнашалар, сердәш булалар, кадерле истәлекләренә кушылалар. Кайберсе, еш кабатланып, телдә йөри, яшәү гамәленә берегеп китә.* Ш.Галиев

**Берегеп кую** Берекәән хәлгә килү; кинәт берегү

**Берегеп тору** Даими, һәрвакыт, бөтенләйгә берекәән булу. *--- даганы, учакта кыздырып, атның тоягына басарга кирәк, шулай иткәндә генә, дага тоякка сыланып, берегеп торачак.* Т.Мөбарәков

**Берегеп яту** Тәмам берекәән булу. *--- бәлки, Аккош күле аурасы гаепледер? Бәлки, шулай, кораб түшенә ябышкан кабырчык кебек, бер җиргә берегеп ятуның иҗатта үзгә мәгънәсе – нәтиҗәлелеге бардыр?* Р.Фәйзуллин

**БЕРЕК** *и. сөйл.* **1.** Берләшмә, союз

**2**. *рәв. мәгъ.* Бердәм. *Берек булсаң, терек булырсың.* Мәкаль

**БЕ́Р ЕЛГЫ** *с.* Яшьтәш. *Бер-берсенең тормыш баскычлары белән танышалар: икесе дә бер елгы – 1947 дә туганнар, ---.* Т.Нәҗмиев

**БЕРЕННӘ́Н-БЕРЕ** *рәв. к.* **берсеннән-берсе**. *Береннән-бере кечкенә бу ятимнәр, әле канат та ярмаган зәгыйфь кош балаларыдай, үзләреннән аз гына калкурак булган апаларына күзлә-*

*рен тутырып карыйлар, аңа таяналар, аңа сыеналар иде.* Г.Бәширов

**БЕРЕНЧЕ** *сан* **1.** 1) Бер-бер артлы санаганда, урыны иң башта булуны белдергән тәртип саны. *Беренче кат күзем кояш күргән Җирләр ерак калды.* А.Алиш. *Һәрнәрсәгә исем китеп йөри, Беренче кат күргән шикелле, Һәр яхшыга әзрәк сөенеп китәм, һәр начарга «сытам үтемне».* Ш.Маннур

2) Санап үтелгәннәрнең иң башта аталганына күрсәтү өчен кулланыла. *Боларның беренчесе баштанаяк романтиклыкка нигезләнеп язылган.* Г.Нигъмәти. *Әсәрнең икенче басмасында Казан бае Кәрим белән Уфа бае Сәгыйть образлары, нык кына эшләнеп, беренчесе – реакцион буржуа, икенчесе либераль буржуа вәкилләре итеп бирелгәннәр.* М.Гали

**2**. *с. мәгъ.* 1) Башлангыч, башлангыч чордагы. *Революциянең беренче канлы көрәш елларында ул бала булды.* Г.Ибраһимов. *Таһирның гаилә тормышында җимерелү тудырган әнә шул беренче, җиңел һәм кечкенә генә «сил ташы» аның кандидатлык диссертациясен яклый алмый йөрүе булды.* Н.Акмалов. *Булачак шагыйрьнең беренче укытучылары әтисе һәм әнисе була.* Л.Габдрахманова

2) Берәрсенең билгеле бер юнәлештә, өлкәдә күрсәткән башлангыч эше, тәҗрибәсе булган, тәүге мәртәбә башкарылган. *Икенчедән, безнең авылда әле бу – беренче тәҗрибә.* Ш.Камал. *Туфанның эшчеләр тормышыннан алып язган бу беренче җитди әсәренең кыскача мөндәриҗәсе әнә шуннан тора.* Г.Нигъмәти. *Бу – минем Вәсиләгә беренче мәртәбә ялганлавым иде...* Ф.Хөсни

3) Булачак, чираттагы вакыйгаларның, күренешләрнең иң баштагысы, тәүге, вакыт ягыннан иң якындагысы. *Җебеп төшмәдем, аның беренче әтәч кычкыруга ук юкка чыгачагына өмет итеп, хәйләгә керештем.* З.Мәхмүди. *Беренче чаңгымны да үзем ясадым.* К.Миңлебаев. *Мин, беренче мөмкинлек булу белән, бу турыда республика прокурорына хәбәр иттем.* Һ.Такташ

4) Бер елда, сезонда, билгеле бер вакыт эчендә иң башта барлыкка килгән, күренгән. *Тәгәрмәч тырнакларына, тугым ярыкларына сырышкан карларны тузгытып, беренче арбалар узды урамнан.* Г.Гобәй. *Беренче кар, белмим, кайчан явар, Тик Үләрмен мин ул көнне. Бүген әле, тиздән кыш килә, дип, Ямап куйдым ертык бүркемне...* Һ.Такташ

5) Моңарчы булмаган; күренмәгән; яңа барлыкка килгән. *Якты, шат дөньяда, пакь, яшь, матур, нәфис баланың йөрәгенә беренче авыр яра булып, аның турында, Хәлим хәлфә исеме белән бәйләп, пычрак гайбәт туа.* Г.Ибраһимов

6) Моңа кадәр кичерелмәгән. *Язда булса иң беренче мәхәббәтнең ялкыны, Көздә – сөешеп каушуның эчкә сыймас шатлыгы.* М.Җәлил. *Яки мәктәптә күргән беренче хисләрегезне әнкәгезгә, кайтып, очына-очына сөйләгәнегезне, әнием, «әни» менә болай языла, дип, әниегезгә тагын да матуррак булып күренгән кыек-мыек хәрефләр белән дәфтәр битенә язып күрсәткәнегезне исегезгә төшерегез!* Г.Гобәй. *Һәм ул, яралanганнан соң беренче мәртәбә, газиз тойгыларын музыка теленә салып уйнап җибәрде.* Г.Бәширов

7) Нинди дә булса бер ягы, сыйфаты белән башкалардан өстен, алдынгы. *Ә соң тирә-якта гыйлеме вә әхлагы белән беренче урын тоткан Зөләйха остабикәнең тәрбияле мәхдүменә – мулла булырга якынлашкан угылына – бу килешәме?* Г.Ибраһимов

8) Төп, иң мөһим. *Берләшүнең иң беренче файдасы уларак, бу вәхши инсаннар, иң әүвәл, бик зур бер кыр кәҗәсе үтерделәр.* Г.Тукай. *...Мин, берникадәр, балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итүне беренче максат итеп тотсам да --- әдәбият Россия мөселманнары арасында тиешле кадәр таралып китмәсме, дигән өметем дә бар иде.* Г.Тукай

9) Иң яхшы, иң югары сыйфатлы, иң югары дәрәҗәгә ия булган, иң шәп. *Уездный шәһәрнең берсенә читтән бер кием тегүче килеп, базарга якын бер урамда фатир алып, капка башына «бу шәһәрдә иң беренче яхшы тегүче» дип вывеска яздырып куймыш.* Ш.Мөхәммәдев. *Мин сине, дөньяда беренче сайраучы, дип ишетә идем...* Г.Тукай. *Ләкин, үзенең архитектура стиленең матурлыгы, нечкәлеге белән, шәһәрдә иң матур йортлар арасында беренче урынны тота, дип әйтергә мөмкин.* Ш.Камал

10) Сайлап алынмаган, кайсы туры килсә – шул; иң башта очраган, очраклы. *[Нәфисәгә] Күз атып йөрүче егетләр аз түгел иде. Ул, озак сайламаса да, беренче күзенә юлыккан кешегә чыкмады.* Г.Бәширов. *Кафил, бик каты сусаганлыгын тоеп, беренче очраган чәйханәгә керде.* Тәмуг чәчәге

11) *муз.* Баш партияне башкаручы

**3.** *рәв. мәгъ.* Барысыннан да алдарак, башта, әүвәл. *Малайларны беренче Якуб абзалары күреп алды.* И.Гази. *Татар телендә шактый шома сөйләшүче карт следователь, беренче күрүдән үк, Мостафага әллә кайчангы танышы кебек эндәште.* К.Нәҗми. *Әмма моряклар монда үз өлешләрен беренчеләрдән булып керткәннәр.* Ә.Хәбибуллин

**4.** *и. мәгъ.* 1) Җитәкче, оештыручы. *Хәзер үк, бөтенесен җыеп, кайнар табага бастырырга ниятләде, чөнки аңа беренче тарафыннан барлык хокуклар бирелгән, ул аларны, сөт арттырмаган өчен, иң начар сүзләр белән сүгә ала, мыскыллый ала...* Ф.Садриев

2) Баш бала. *Беренчегез белән тәбрик итәм, иптәш.* Г.Гобәй

3) Ризыкның иң башта бирелә торганы (аш: борщ, щи һ.б.ш.). *Сез нинди нәрсә телисез, беренчегә суп әйтикме, борщмы?* Г.Камал

◊ **Беренче адым(нар)** Баштагы, башлангыч вакыт, чор. *– Беренче адым атланды! – дип, Якуб рәхәтләнеп әйтеп куйды, – хәзер Казанга язып җибәрсәң дә була.* И.Гази. **Беренче булып** 1) Алдан, иң элек, иң әүвәл. *Иң беренче булып, умырзая Баш күтәреп чыга дөньяга.* Ә.Ерикәй; 2) Алдынгылар рәтендә, алдынгы булып. *Бөтен фәннәр буенча университетны беренче булып бетерә.* М.Гали. **Беренче карлыгач (сандугач)** Башлангыч билгеләр; берәрсенең билгеле бер юнәлештә, өлкәдә башкарылган башлангыч эше, тәҗрибәсе, уңышы. **Беренче кул оста** Иң шәп, иң яхшы эшләүче. *Вәй белән Дәй --- үз эшләренең беренче*

*кул осталары булырга омтылып яшәгәннәр.* Р.Төхфәтуллин. **Беренче кулдан** Төп чыганаклардан

**БЕРЕНЧЕДӘН** *кер. сүз* Санап киткәндә, тәртип ягыннан иң беренче урында торганны белдерә. *Беренчедән, сорау алуга табиб белән йөрмиләр, икенчедән, комендатура бөтенләй икенче якта урнашкан.* З.Мәхмүди. *Беренчедән, биредә тавышын яздырган башкаручы җырын компаниянең сәнгать советына тәкъдим итә ала.* Сөембикә

**БЕРЕНЧЕЛ** *с.* Иң баштагы, әүвәлге, башлангыч. *Ул җирне төрле афәтләрдән саклый, беренчел ноктага әйләнеп кайтучы күк җисемнәрен туктату юлларын эзли.* Тәмуг чәчәге

**БЕРЕНЧЕЛЕК** *и.* Иң алдагы урынга чыгу; алдынгылык, өстенлек. *Гер күтәрү буенча авылда да, районда да беренчелекне бирми.* Н.Хәсәнов. *Өченче ел аларга кара күзле бер башкорт малае килеп кушылды да моның белән беренчелектә ярыша башлады.* Г.Ибраһимов. *Гәрчә безнең заманда ир-егетләр, беренчелекне яулап, кыргый җанварлардай бугазга-бугаз ябышмасалар да, бер-беренең кимчелеген күрсәтүдә һич кимен куймыйлар иде.* К.Миңлебаев. *Моннан җитмеш еллар чамасы элек, мин һәр эштә беренчелекне саклап килә идем, ә хәзер...* З.Мәхмүди

**БЕРЕНЧЕ́ ЯРДӘМ** *и.* Башлангыч медицина ярдәме. *Яралысына беренче ярдәм күрсәтегез, ничек тә исәнимин сакларга тырышыгыз анысын.* Ф.Сафин

**БЕРЕТ** *и. фр.* Түгәрәк, йомшак баш киеме. *Башта – кырын салынган берет, авыз ерык.* Р.Вәлиев. *Береткасын салып, чәчләрен рәтләде.* М.Мәһдиев. *Ул да түгел, урамда башларына карт хатыннар кебек итеп кара берет кигән инглиз солдатлары күренә башлый.* Г.Гобәй

**БЕ́Р ҖЕНЕСЛЕ** *с. бот.* Я җимшәне, я серкәләре генә булган. *Өйрәнгән асклассларда бер җенесле чәчәкләрнең килеп чыгышы нинди?* Л.Мәүлүдова

**БЕ́РЗАМАН** *рәв.* 1) Бервакыт. *Тыелып торган күзәнәкләр, берзаман, ни сәбәптәндер, үзләренең хуҗаларына каршы баш күтәрәләр.* С.Сөләйманова. *Берзаман, ул үзенә дәшкән сынык тешле Әсма тавышын ишетте.* Н.Хәсәнов. *Эчендәге сөенече ташый-ургый, тыны кыса иде, берзаман, аны тыеп торуы авырлаша башлады...* Н.Гыйматдинова. *Кырык бишенче елның җәендә, самурайларга каршы сугышканда, берзаман, чүлдә калдык.* Тәмуг чәчәге

2) Кайчан да булса бер. *Болар артыннан, берзаман, симфонияләр, хәтта опералар туа башлар!..* Ә.Еники. *Олы хисне бер бүлмәгә алмаштыручы кыз өчен болай йөрүегез, берзаман, үзегезгә дә көлке тоелыр әле.* К.Тимбикова

**БЕРИЛЛЕ** *к.* **бармак илле.** *Көн эссе булса да, аягында – калын табанлы ботинка, билендә – берилле киңлектәге каеш.* А.Тимергалин

**БЕРИШ** *с.* **1.** 1) Күплек сандагы исемнәр белән килгәндә: бер үк төрле, бер-берсенә охшаш. *Советлар Союзы бериш дәүләтләргә корал сатты.* Мәдәни җомга

2) Дәрәҗәләре, яшьләре белән бертөсле, бер-берсенә иш булган

3) *мат. физ.* Бертөсле. *Гибридлашканда, әүвәлге орбитальләрнең формалары һәм энергияләре үзгәрә, бериш формалы һәм энергияле яңа орбитальләр хасил була.* Г.Хисамиев

**2.** *и. мәгъ.* Кайберләре. *Беришеләр кипкәнен тегермәндә тарталар.* Г.Толымбай. *Беришләре, үзләренең җир пайлары белән, «Вахит» ширкәтенә кергән, берише пайларын фермер авылдашлары Павел Дмитриевка биргән, ә беришләре үзләре аерылып чыккан.* Ватаным Татарстан

**3. беришесе** *а. функ.* Төркемнән атап аерып куелмаган, шуларның берсе булган билгесез әйбергә, затка ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; кайсыдыр, кайсыбер, кайбер. *Мирзахан абзый да, бәлки, хатыны сүзенә эченнән кул куйгандыр, чөнки төзелештәге яшьләрнең беришесе чамасыз базу кыланганны ул да хупламый.* Б.Камал

**БЕ́РКАВЫМ** *рәв. к.* **беравык**. *Тагы беркавымга аптырап калдым.* Р.Сибат. *Беркавым вакыттан соң Иблис, масаеп китеп, музыкантларга, учлап, алтын акчалар ыргыта башлады.* З.Мәхмүди

**БЕ́РКАДӘР** *рәв.* 1) Бераз, зур булмаган, аз күләмдә, аз-маз гына. *Бары тик аның тавышында гына беркадәр моңсулык бар иде.* А.Шамов. *Беркадәр төзәтелгән хәлдә, соңгы исеме белән, ул 1926 елда сәхнәгә куела башлады.* Ф.Бурнаш. *Тик френчнең якасы шактый керләнгән булуы Садыйк хаҗиның дикъкатен тартып, аңар беркадәр авыр тәэсир ясады.* Ш.Камал

2) Өлешчә, билгеле бер дәрәҗәдә. *Командирның: – Сержант Бикбулатов, нишләп соң сез хөкүмәт бүләкләрен тагып йөрмисез? – дигән соравына Бикбулатов беркадәр тартыныбрак һәм гафу үтенгән тавыш белән җавап бирде.* А.Әхмәт. *Маша, Гөлгенә һәм Ипай образлары беркадәр уңышлырак эшләнгән.* М.Җәлил. *Нәгыйм яшьтән үк балык тотарга ярата, һәм бу эштә беркадәр сәләте дә бар.* Ш.Камал

**БЕ́РКАЙДА** *а.* **1.** Бер җирдә дә, бер урында да бөтенләй булмауга, табылмауга ишарәләп, булуын, барлыгын кире кагып килә торган юклык алмашлыгы; һичкайда. *«Гаделлек» дигән нәрсә беркайда да юк.* М.Гафури. *Беренче карашка кар бик нык ята әле, беркайда да чүмечләп-чиләкләп алырлык су күренми.* М.Маликова. *Газинурның Шөгердән, Бөгелмәдән ары беркайда да булганы юк.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бер җирдә дә, бер урында да. *Ләкин минем беркайчан да, беркайда да бүгенгедәй дулкынланганым, бүгенгедәй тирән хискә бирелгәнем юк иде.* А.Шамов

2) Беркая да, һичбер урынга. *Өскә – җылы кием, аякка яхшы итек бирмиләр икән, землянкадан беркайда да чыкмаска кирәк.* М.Гали

**БЕ́РКАЙЧАН** *а.* **1.** Бервакытта да булмауга, табылмауга ишарәләп, булуын, барлыгын кире кагып килә торган юклык алмашлыгы; һичкайчан. *Варис белә: яңалык беркайчан җиңел юл ярмый.* М.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* Кайчан да, һичнинди очракта да, һичбер вакыт, бер вакытта да. *Мисбах бүтән беркайчан да кулына каләм алмаска ант итте.* З.Мәхмүди. *ГАИ хезмәткәрләре аның машинасын туктатырга беркайчан да җөрьәт*

*итмиләр.* М.Галиев. *Кешенекенә беркайчан да тимәде ул.* Н.Хәсәнов

**БЕ́РКАТЛЫ** *с.* 1) Хәйләсез, тәҗрибәсез, гади, тиз ышанучан, эчкерсез. *Бар иде бездә Сафи атлы кеше, Бик юаш, бичара, беркатлы кеше.* Г.Тукай. *Шофёр, беркатлы бәндә, кабинадан чыгып, аның янына килгән иде.* Р.Кәрами. *Их әнкәй, әнкәй, нигә шулкадәр беркатлы син, дип уйлады Искәндәр.* Р.Вәлиев. *Авыл малайлары, гадәттә, беркатлырак булучан бит.* К.Миңлебаев

2) Җиңел уйлый торган, акылга җиңел, юләр сыман. *Ләкин тегесе, Кәримәне беркатлыга санап, көлде генә.* Р.Хафизова. *Беркатлы, сәер кешеләрдән, диваналардан кызык табу, гомумән, Көнчыгышта таралган хәл.* Н.Исәнбәт. *Мин бит шуның өчен генә синең алдыңда мәхәббәттән башы әйләнгән беркатлы кыз ролен уйнарга мәҗбүр булдым.* Тәмуг чәчәге. *Мин андый беркатлы кеше түгел.* Тәмуг чәчәге

3) Эшләнеп җитмәгән, үтә гади, схематик. *Ләкин, нәтиҗәдә, әсәр – беркатлы.* М.Җәлил. *Карп Васильевич Газинурның үзе турындагы кыска һәм беркатлы хикәясен тыңлагач, кун кепкасын бармагы белән күтәреп, башын кашып куйды, кырыс карашы әз генә йомшарып киткәндәй булды.* Г.Әпсәләмов

**БЕ́РКАТЛЫЛАНУ** *ф.* Беркатлы (*1, 2 мәгъ.*) булу, беркатлылык күрсәтү. *Мин тагын, беркатлыланып, М.Шиһапов янына торып йөгердем.* М.Мәһдиев. *Ара-тирә беркатлылана шул минем Миһриҗамал да, тегенең шаяртып, мыскыллап сөйләгәнен белми, аңа чынлап җавап биреп маташа.* М.Гали

**Беркатлылана бару** Торган саен ныграк беркатлылану

**Беркатлыланып калу** Беркатлыга әйләнү. *Шул рәвешле, хатыны алдында кечерәеп, арзанаеп, үтә беркатлыланып калгандыр.* Д.Гайнетдинова

**Беркатлыланып китү** Кинәт беркатлылану

**БЕ́РКАТЛЫЛЫК** *и.* Беркатлы булу, шул сыйфатларга ия булу; җиңел ышанучанлык. *Мотаһир риясыз, сабыйларча беркатлылык белән авызын ерды.* Р.Кәрами. *Ул, балаларча беркатлылык белән, очынып-очынып, нидер сөйли.* М.Галиев. *Егетнең беркатлылыгыннан Кылыйның иярченнәре шыркылдап көлеп куйды.* Н.Хәсәнов

**БЕ́РКАЯ** *рәв.* 1) Һичбер урынга, һичбер җиргә. *Син – минем колым, мин сине беркая да җибәрмим.* Т.Гыйззәт. *– Курыкма, Актүшкәй, мин инде хәзер синнән башка беркая да китмим, – диде Илсөяр.* Г.Гобәй

2) Берәр җиргә, бер-бер урынга, кая булса да. *Нәрсә, әллә шул мәтәлчек арбаларда ташны ярган шарлавыклар аркылы беркая үтмәк булалармы?* Н.Исәнбәт

3) *диал.* Бер урында да, һичбер кайда, бер җирдә дә. *Кәҗә тыкрыгына кадәр төштеләр, беркая бер җан әсәре очрамады.* И.Гази. *--- зәһәр дала кояшыннан беркая качар урын юк.* Ф.Бәйрәмова

**БЕ́РКЕМ** *а.* **1.** Бер затның да булмавына, табылмавына ишарәләп, булуын, барлыгын кире кагып килә торган юклык алмашлыгы; бер кеше (дә); һичкем. *Ишекне беркем дә таба алмаслыгына ышангач, Брим бакчага таба юнәлде.* Р.Мөхәммәдиев. *Артыма борылып карадым – килүче күренмәде, алда шулай ук беркем юк иде.* К.Миңлебаев. *Безгә беркем дә гаскәр төзеп бирмәячәк.* Ф.Сафин. *Мәктәпкә барам – беркемдә эшем юк, бар күңелем укуда.* М.Әмир. *Миннән башка беркем эшли алмый бу эшне.* Сөембикә

**2.** *и. мәгъ.* Якын кеше (дус яки туган). *– Мин хәзер япа-ялгыз, – диде Рабига, – беркемем юк.* А.Шамов. *Бабаемнан башка беркемем дә юк бит инде минем хәзер.* Г.Гобәй. *Тып-тыныч, кодача, беркемем юк.* Г.Бәширов

◊ **Беркем түгел** Дуслык, хакимият, көч, вәкаләт, нәрсәгә дә булса хокук яки туганлык мөнәсәбәтләре булмаганлыкны күрсәтә. *«Ә мин хәзер үк беркем дә түгел», – дигән дәрвиш.* Т.Әйди

**БЕРКЕТКЕЧ** *и.* **1.** 1) Аерым предметларны, нинди дә булса әйбернең аерым өлешләрен бер-берсенә беркетү өчен кулланыла торган җайланма. *– Нәрсә, чаңгыңның беркеткече ватылдымы әллә? – диде аның янына килеп баскан Таһирҗан, булышырга әзерләнеп.* З.Фәйзуллин

2) Фотода ачыкландырылганнан соң, сурәтне беркетү, ныгыту өчен кулланыла торган химик состав; фиксаж

**2.** *с. мәгъ.* Беркетү өчен кулланыла торган. *Авышлыкка агач һәм тимер беркеткеч ныгытмалар төялгән вагон һәм «кәҗәләр» таккан электровоз килеп туктады.* Ф.Зариф

**БЕРКЕТМӘ** *и.* 1) Утырышның, сорау алуның барышын күрсәткән язма документ; протокол. *Аның янында – сипкел төшкән озынча битле, саргылт чәчле укытучы Гөлзәбәр, каләмен тиз-тиз кыштырдатып, беркетмә яза.* Г.Бәширов. *Ашыкмый гына беркетмәне укый башлады.* Ф.Сафин. *Майор кулындагы җавап алу беркетмәсен тикшерүчегә бирде.* М.Насыйбуллин. *Стенографистка-мазар чакыртуның, беркетмә-фәлән алып баруның кирәге юклыгын, гап-гади сөйләшеп утыру икәнен төшендереп бирә.* К.Миңлебаев

2) Нинди дә булса вакыйганың дөреслеген тикшереп раслау документы. *Беренче – Галимҗан Салихҗанов белән Бөстан Ханҗанова арасында беркетмә.* Ф.Бурнаш. *– Беркетмәгә авылны бандадан саклау турында язмакчы булып торганда гына, сез килеп кердегез, – диде Салих.* Г.Минский

3) Җәмәгать тәртибен бозу турындагы акт. *Гаврилково авылы янында сез шул ук Пахомовка беркетмә тутырасыз.* Мәгърифәт

**БЕРКЕТҮ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса бер-берсенә кузгалмаслык итеп беркетеп кую. *Ул якта стена буйлап һәм арт як диварга беркетеп, киң сәке ясалган.* Ф.Бурнаш. *Бүтән атлардан аерып, такта белән бүленгән аранда торучы алмачуар айгыр күк күкрәгән саен ярсып дулый һәм стенага беркетелгән тимер чылбырны өзәргә, абзарны ватып чыгарга азаплана иде.* Г.Ибраһимов. *Ике тәрәзә арасында кызыл материя өстенә чын урак белән чын чүкеч беркетеп, чын ашлык башаклары белән бизәкләп куелган.* М.Фәйзи. *Алсу яулыгын баш түбәсенә генә беркеткән колхоз хисапчысы урам уртасыннан каядыр бик ашыгып бара иде.* Г.Әпсәләмов

2) Нәрсәне дә булса берәрсе карамагына, файдалануына тапшыру. *Колхозда*

*хәзер инде язгы чәчүгә әзерләнгәннәрдер, дип уйлап алды Газинур һәм отделениесенә беркетелгән окопларны карап чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Менә шушы өч шофёрны ашату-эчертү, туйдыру якларын балалар бакчасы кухнясына беркеткәннәр, имеш.* Ф.Хөсни. *Кыр бригадиры аларны --- алдынгы уракчыларга беркетте.* Г.Гобәй

3) Эш йөкләү, эшкә, урынга тәгаенләү, шул эш өчен аны җаваплы итү. *Безне, коммунистларны, иң җаваплы участокларга беркеттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Ә терелеп чыккач, үзе әйтмешли, үлемне тагын алдап-йолдап озаткач, шат күңелле бу бабайны, Хәлим һәм иптәшләре соравы буенча, колхоз идарәсе кыр бригадасына агротехник итеп беркетте.* Г.Гобәй

4) Теркәп язып кую, теркәү. *Старостаның мөһере белән кәгазе дә кесәсендә икән, аштан соң чәй эчкән вакытта ук, урынны безнеке ясап беркеттеләр.* Г.Ибраһимов. *Партия ячейкасы аны үзенең вәкиле итеп беркетте.* М.Җәлил. *XX гасырның урталарында, Н.Хрущев идарә иткән заманда, төрле чегән колхозлары оештырып карадылар, хәзерге вакытта да аларны җиргә беркетү чаралары күрелми түгел.* А.Тимергалин

5) Ныгыту, онытылмаслык итү; хәтергә сеңдерү; уйга алу. *Кирәк төсле булыр күңелеңә «Ул юк» дигән уйны беркетү.* М.Җәлил

6) Юнәлтү; төбәү. *Еракларга күз беркетеп, юл гизәмен, Ал бөркелгән томаннарны коча уем.* Ш.Маннур

7) *күч.* Нәтиҗә ясау, хәтердә калдыру. *Бу уйны «изге уй» дип күңеленә беркетте.* М.Гафури. *Мостафа, каткат, бу хатынга ачу күзен ташлады: – Тилергәндер, куркудан шашкандыр! – дип беркетте.* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Нәрсәне дә булса башкарырга ниятләп кую. *Ләкин күп белдермәделәр, киленне ярattылар, инде ни күрсәк тә, Сарсымбай ничаклы адәм җибәрсә дә, каршы торып якларга тиешлекләрен эчләреннән беркетеп таралдылар.* Г.Ибраһимов. *Садыйк карт, баганаларны тизрәк әзерләп кую турында Галләметдингә биргән вәгъдәсен чынлап та үтәргә кирәк, дип, күңеленә беркеткән иде.* Ш.Камал

**Беркетә бару** Һәрберсен, булган берсен беркетү, берсе артыннан икенчесен беркетү. *Хәятның иң соң укыган китабы «Дөррәтен-нәсыйхин» абыстайның бу тәрбиясен бигрәк нык беркетә бара иде.* Ф.Әмирхан. *Һәммәсе татарча бирелгән җавапларны протоколга рус телендә беркетә барды.* Г.Ибраһимов

**Беркетә башлау** Беркетергә тотыну. *Шул вакыттан бөтен ахмаклар төркеме татар кызын «Биктимернең уенчыгы» дип күңел беркетә башлады.* Ф.Әмирхан

**Беркетә төшү** Беркадәр беркетү; тагы да ныграк беркетү

**Беркетеп бару** Рәттән беркетү, берсе артыннан икенчесен беркетү. *Шуңа күрә алтын җепне бизәкнең ике ягыннан беркетеп кенә баралар, һәм ул тукыманың уң ягында була.* Н.Сергеева

**Беркетеп бетерү** Барысын да беркетү; ахырга кадәр беркетү. --- *ул әле палатканың казыкларын да беркетеп бетермәгән иде.* В.Нуруллин

**Беркетеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта нәрсәне булса да беркетү белән мәшгуль булу. --- *алар бит – баганаларга язулы такталар беркетеп йөргән кешеләр!* Т.Мөбарәков

**Беркетеп калу** Беркетергә өлгерү. *– Мохит, диләр хәзер, мохит, – дип ярдәмгә килде Әлифә. – Хәтереңә беркетеп кал, мохит!* М.Маликова

**Беркетеп китү** Рәттән, бер уңайдан беркетү. *Фәйрүзә Әхмәтҗанова иптәшне дә гомуми җыелыш карары белән беркетеп китик инде, иптәшләр.* В.Нуруллин

**Беркетеп кую** 1) Алдан ук беркетү, беркетелгән хәлгә китереп калдыру. *Балалар комачны ике чүмәлә өстенә беркетеп куйдылар.* Г.Гобәй. *Ике яктан да эләктереп, «стопор»га беркетеп куйдык.* Ә.Хәбибуллин. *Барасы юл ерак та, пычрак та икәне беленгәч, караңгыда төшеп-нитеп калмагае, дип, ботинка олтаннарын телефон чыбыгы белән беркетеп куйдылар.* Г.Бәширов

2) Закон нигезендә теркәлгән хәлгә китерү, законлаштыру. *Мондый сәясәтне 1992 елгы референдум вакытында халык яклады, һәм ул Татарстан Конституциясендә беркетеп куелды.* М.Шәймиев

3) *күч.* Хәтергә салу, уйлап әзерләнү. *Мин синнән җавапны ала белермен әле, дип күңелдән беркетеп куйдым.* Ш.Усманов. *Тыңлагыз, оланнар, күңелегезгә беркетеп куегыз.* Р.Хафизова. *Бәя турында инде ул күптән киңәшләшеп, фәлән кадәр сорармын, дип, фәлән кадәр сорасалар, риза булырмын, дип, бер бәягә күңел беркетеп куйган.* И.Гази

**Беркетеп тору** Даими, һәрвакыт беркетү. *Ир белән хатынны никах беркетеп торыр.* Р.Фәхретдинов

**Беркетеп чыгу** Һәммәсен дә, барысын да бер-бер артлы беркетү. *Хәзер шул тезмәнең һәрбер сәйлән арасындагы җебен беркетеп чыгарга кирәк.* Н.Сергеева

**БЕ́РКӨЕ** *рәв.* Акрын гына, җайлап, ярыйсы, үз җае белән. *Егет күзләрен ачты. Янә бер мәртәбә хатның кечкенә хәрефләрдән тезелгән тыгыз юлларын укып юанды: «Үзем беркөе генә яшәп ятам. «Аһ» итәрлек үзгәрешләр юк».* Р.Кәрами

**БЕ́РКӨН** *рәв.* 1) Берничә көн элек, күптән түгел, үткән көннәрнең берсендә, шушы көннәрдә. *Көннәрдән беркөн газетада дусты Ногманның зур гына батырлыгы турында укыгач, кызарып китте.* Г.Гобәй. *Беркөн бер солдат, үтеп барышлый, Гапсаттар абзыйларда кунып чыккан.* И.Гази. *Беркөн Гыйззебанат җиңгәгез ачуымны китергән иде.* Тәмуг чәчәге

2) Кайчан да булса бер, бервакыт, киләчәктә. *Әби, зинһар, утырмыйк ла, әллә нишләп бик куркам, кеше күрер, зинһар, бүгенгә кайтып торыйк ла, икенче беркөн килербез.* Г.Камал. *Нурланып, беркөн күңелле яз коящы ялтырар.* Н.Исәнбәт

**БЕ́РКӨНГЕ** *с.* Моннан берничә көн элек булган, күптән түгел булган. *Беркөнге яңгырдан соң, җиргә җан керде.* К.Тинчурин

**БЕ́РКӨННЕ** *рәв. к.* **беркөн.** *Беркөнне ул, янган өйгә барып, сәләтле куллары белән, Мәүлихә әбинең исән калган ярты өен тәмам торырлык хәлгә*

*китерде.* Ә.Фәйзи. *Беркөнне Наил, үзе ясаган чаңгыга басып, япа-ялгыз чыгып китте.* Ф.Хөсни. *Беркөнне, эшкә киткәндә, әнисе аңа: «Өйдән чыкма, кызым, әйбәт кенә уйнап утыр, яме!» – диде.* Н.Хәсәнов

**БЕ́РКҮЗӘНӘКЛЕЛӘР** *и. бот.* Бер генә күзәнәктән торган организмнар

**БЕРЛӘ** *бәйл. иск. к.* **белән**. *Бераздан бер рус егете берлә бер рус кызы кул тотышып керәләр.* Г.Коләхмәтов. *Тик нәфес берлә икәүсе дус болар, «Нәфес шайтан» дип шуңа ат куштылар!..* Ш.Бабич

**БЕРЛӘН** *бәйл. иск. к.* **белән**. *Иртә берлән кайнамакта ул базар.* Г.Тукай. *Сөямен чын күңел берлән Үземнең әткә-әнкәмне.* М.Гафури. *Ак гөл берлән кызыл гөл, Былбыл берлән тутый кош.* Ф.Бурнаш

**БЕРЛӘЧ** *и. диал.* Ялгыз, бер генә, игезе булмаган терлек баласы. *Шуның өстенә – менә Тәүгиз тагы. Артык иркәләдек, ахры, «берләч бәрәнне», бик узынып бара.* Х.Камалов

**БЕРЛӘШЕП** *рәв.* 1) Бергәләп, бергә, күмәк рәвештә, тупланып, оешып. *Актырнак әйтә: – И дустым! Бу дөньяда сөешү-дуслашудан да татлырак бар микән, ике җанның, берләшеп, берсен-берсе тәгъзыйм вә ихтирам итүеннән дә күңелле эш бар микән?* Г.Тукай. *Ул башка кешеләр белән берләшеп көрәшәсе, сугышасы урында --- авылына кире кайтып китә.* Г.Нигъмәти. *Безгә хәзер композитор белән авторның, берләшеп, бер проблема өстендә эшләп, бергә оперетта тудыру гадәтен тәҗрибәгә кертергә кирәк.* М.Җәлил

2) Бер сүздә булып, бер булып; сүз куешып, бер фикердә торып. *Билгеле инде, Җүчи һәм Толой йортлары, берләшеп, төрле сылтаулар белән, корылтайны биш ел буе диярлек үткәрми торалар.* М.Гайнетдинов

**БЕРЛӘШКӘН** *с.* 1) Оешкан, кушылган, бердәм, оеш. *Сүз уңаеннан шуны да әйтим, Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясы, күптән түгел, бала хокукы турында Конвенция кабул итте.* Р.Миңнуллин

2) Тупланган, күмәкләшкән. *Барыннан да элек, ул – максатның һәм аңа ирешү эшчәнлегенең уртак булуы арасында гына берләшкән коллектив түгел, аны кан-кардәшлек бәйләнешләре берләштерә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**БЕРЛӘШМӘ** *и.* 1) Бергә тупланган оешма, берлек, ширкәт, ассоциация. *Зур сәяси берләшмәләр юкка чыгар, алар урынына илләр, ниндидер, кеп-кечкенә берәмлекләргә бүленерләр...* Татарстан

2) *махс.* Эре гаскәр берәмлеге, берләштерелгән хәрби оешмалар. *Ул меңнәрне эченә алган гаскәр берләшмәләре бер-бер артлы кузгала башладылар.* Г.Бәширов

**БЕРЛӘШМӘК** *и. к.* **берләшмә.** *Менә шундый берләшүне, шундый җыелышуны «берләшмәк» (сотрудничество) дип атыйлар.* Г.Тукай

**БЕРЛӘШҮ** *ф.* **1.** 1) Бергә кушылу, бербөтен булу. *Сәхнә белән зал, ничектер, күңелдән берләшәләр кебек: бергә уйныйлар, бергә җырлыйлар, бергә бииләр кебек иде.* Г.Ибраһимов

2) Бергә туплану, бергә оешу; бердәм булу. *Ни өчендер, монда докладчы да һәм башка сөйләүчеләр дә руслар белән көрәшергә, аларга каршы берләшергә чакыралар.* М.Гали. *Ике татар булган җирдә өч партия була, дигән мәзәк юкка гына чыкмагандыр. Әлбәттә, ул мәзәк үзебездән көлеп, мыскыллабрак әйтелә: янәсе, без берләшә алмыйбыз.* Т.Миңнуллин. *«Тугыз татар» халкы дошман яуга каршы көрәштә «тугыз угыз»лар белән берләшә торган була.* М.Әхмәтҗанов

3) Туплау, бер тирәгә җыю

**2**. **берләшеп** *рәв. мәгъ.* Бергәләшеп, күмәкләшеп, бергә көч куеп. *Яңа гына әле клубка да Радио алган идек, берләшеп.* М.Җәлил

**Берләшә башлау** Берләшергә тотыну. *– Бүре эзләре, каян килгән болар? – Кич йөргәндә, берсенең улаганын ишеттем, әти. – Тагын берләшә башлаганнармы, хәерсезләр.* М.Рафыйков

**Берләшә килү** Акрынлап, аз-азлап берләшү. --- *шәхси хыял-өметләрем дә, гомеремнең соңгы юл чатларына җиткәндә, бер юлга, бер сукмакка берләшә киләләр.* Р.Вәлиев

**Берләшә тору** Даими рәвештә, һәрвакыт берләшү

**Берләшә төшү** Тагын да тыгызрак, күбрәк берләшү

**Берләшеп алу** Берләшүгә ирешү, тиз генә, кыска вакыт эчендә берләшү. *Кубрат хан чорларында ук инде Хазар каханаты белән берләшеп алган Кубрат ханның баш улы Батбай аксакаллары кахан сараендагы табыннарда утыралар.* М.Хәбибуллин. *Хатын белән читләшеп беттек. Уртак сөенечләребез юк, диярлек. Оныклар килгәндә генә бер гаиләдәй берләшеп алабыз.* Т.Галиуллин

**Берләшеп бетү** Барысы да бергә берләшү; тәмам берләшү. *Буйларның төсләре генә түгел, уйлары да берләшеп беткән иде.* Г.Исхакый. *Әле моңа кадәр дөньядагы бер генә мафиягә дә дәүләт башында утыручылар белән шулкадәр тыгыз үрелеп, берләшеп бетү мөмкинлеге юк иде.* Р.Мирхәйдәров

**Берләшеп җибәрү** Берләшүгә этәргеч бирү

**Берләшеп җитү** Тиешенчә дәрәҗәдә берләшү. *Бу мәүзугъләрдә, барын санасаң, илле-алтмыш китап бар. Ләкин аталмалар турысында болар – берләшеп җитү кайда – һәр яңа чыккан китап үзенә төрле аталмалар тудыра.* Г.Ибраһимов

**Берләшеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта берләшү эшләре белән мәшгуль булу

**Берләшеп калу** Вакыттан, вакыйгадан файдаланып, шартлар тугач берләшү, берләшергә өлгерү

**Берләшеп китү** Күпмедер вакыттан яки ниндидер вакыйгадан, сәбәптән соң берләшү. *Лирик герой, автор белән берләшеп китеп, җан дустын романтик пафос белән зурлый.* А.Закирҗанов. *Совет елларында, Сабантуй җәй чорында бәйрәм ителә башлагач, әлеге ике бәйрәм [җыен белән Сабантуй] күпмедер дәрәҗәдә үзара берләшеп киткәннәр.* М.Бакиров

**Берләшеп кую** Алдан ук берләшү. *Юк, Тубыкбай, ярамас. Икесе дә дала ханнары – берләшеп куюлары бар.* М.Хәбибуллин. *Әйтерсең алдан ук сүз берләшеп куйганнар – барысы да бертөрле сөйли.* В.Нуруллин

**БЕРЛЕ** *и.* 1) Бер санын күрсәтә торган уен шакмагы. *[Домино*

*уйнаучыларның берсе:] Капламадың шул берлене, менә хәзер ала инде ул, син бер дә йөри белмисең.* Г.Камал

2) Биш баллы системада өлгерешне бәяләүдә иң түбән билге, «бик начар» билгесе

**БЕРЛЕК** I *и.* 1) *тар.* Бер сумлык акча. *Ава-түнә килә дә, әле теге кылый күз Гыймадидан, әле Вәли байдан акча сорый: бай абый, берлек бир!.. Гыймади абый, берлек бир, ди.* Г.Ибраһимов. *Контролёр хатын иске сумкасыннан бөгәрләнеп беткән берлекләр, көмеш-бакыр тиеннәр чыгарып, кат-кат озаклап санады.* Р.Вәлиев

2) Тыгыз, ныклы бәйләнеш. *Бөтен шул күрсәтелгән кисәкләрнең органик берлеге булуы ягыннан, поэманың стиле шома.* Г.Нигъмәти

3) Бер, бердәнбер, үзе генә, ялгыз. *Алланың берлеге, рәсүлнең хаклыгы өчен җавап бирегез: безнең Мәкәрҗәдә өргән куыклар (Центральный комитет) кайда?* Ш.Мөхәммәдев

4) *лингв.* Бер кешене яки бер предметны белдергән грамматик категория. *Сан категориясенең берлек төре һәрвакыт нуль формада була, берлекнең үзенә аерым формативы юк.* В.Хангилдин

**БЕРЛЕК** II *и.* 1) Бердәйлек, бергәлек, уртаклык, тәңгәллек; тулы охшашлык. *Татар алпавыты, татар промышленнигы, рус алпавыты һәм рус промышленниклары арасында туганнар берлеге юкмы?* Ш.Камал. *Тигез сафлар булып атлап бара Күңелләрнең тирән берлеге.* Ш.Маннур. *Дуслык кирәк, идея берлеге, профессия берлеге яки якынлыгы.* Р.Ишморат

2) Тупланганлык, бердәмлек. *Кырым ханы белән нык берлек ясагыз.* Г.Гобәйдуллин. *Йөрәк берлеге тик Бәхет тудыра.* М.Җәлил

**БЕРЛЕК** III *и.* Оешма. *Баксаң, Казан сәүдәгәрләренең үз кануннары, кагыйдәләре, Бөтендөнья малтабарларыннан аерым үз берлекләре бар икән.* Ф.Латыйфи. *Профессиональ берлекләргә хезмәт ияләре файдасына, Татарстанда гражданнар тынычлыгын һәм татулыгын ныгыту хакына принципиальлек һәм эзлеклелек күрсәтүләрен, нәтиҗәле эшләүләрен телим.* Ватаным Татарстан. *Татарстан Республикасының Матбугат, телетапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары эшләре министрлыгы, Журналистлар берлеге, Республика ветераннар советы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 55 еллыгына багышланган конкурс игълан иттеләр.* Татарстан

**БЕРЛЕКТӘ** *рәв.* Бергә, бергәләп. *Булып дуслар белән берлектә даим, Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм.* Дәрдемәнд. *Атаклы драматургыбыз Кәрим Тинчурин да, композитор Салих Сәйдәш белән берлектә, колхоздагы кискен көрәшне уңышлы чагылдырган «Кандыр буе» музыкаль драмасын дөньяга чыгарды.* Р.Ишморат. *Хакимият башлыгы белән берлектә мәчетне яңартырга, финанс мәсьәләләрен чишеп, хәтта 17 мәхәлләдәге имамнарга эш хакы түләргә мөмкинчелек туды.* Р.Юнысов. *«Единая Россия» сайлаучыларның илдә, ниһаять, реаль властьны кулына алып, президент белән берлектә хөкүмәтне формалаштыручы һәм илдәге реформалар, җәмгыятьтәге хәлләр өчен җавап бирүче партия барлыкка килсен иде, дигән өметләрен аклый.* Татарстан яшьләре

**БЕРМӘ́-БЕР** *рәв.* 1) Бер кешегә каршы бер кеше (*көрәшү, ярышу, сугышу һ.б.ш.*). *Бермә-бергә чакырам! Чык мәйданга!* Н.Исәнбәт

2) Ике мәртәбә, икеләтә, ике тапкыр, ике өлеш (*арту яки киму*). *Биредә Инсафның кызыксынуы бермә-бер артты.* Н.Хәсәнов. *Шушы хакыйкатьне аңлау аны үз күз алдында да, башкалар каршында да бермә-бер күтәреп җибәрде.* Р.Кәрами. *2012 елга дөньяда шизофрения белән чирләүчеләр саны бермә-бер артачак.* Мәдәни җомга

3) Төп төгәл, сүзгә-сүз, һич үзгәртмичә. *Тәрҗемәче Вахитның бу сүзләрен бермә-бер тәрҗемә итеп бирде.* М.Гафури

**БЕ́РМӘЛ** *рәв.* Берара, бераралыкта, күпмедер вакыт. *Телевизорны сүндереп, ятарга әзерләнгән Ринат, җәелгән урынга күз салуга, бүгенге үзгәрешкә бермәл аптырап калды.* Н.Хәсәнов. *Ул, курчакны кая куярга белмичә, бермәл уйланып торды, тәрәзә төбенә утырткан иде, авып төште, өстәлгә дә, урындыкка да, шифоньер башына да куеп карады, ләкин бер кулсыз курчак кызы кайда да ятышмый сыман иде.* Р.Вәлиев

**БЕ́РМӘЛГӘ** *рәв.* Бик кыска вакытка, бертынга. *Йөреш-кыяфәтендә үк чиксез нәзакәт һәм мөлдерәп тулган гүзәллек күреп, сарайдагылар, бермәлгә, ханбикәдән күзләрен ала алмый тордылар.* М.Хәбибуллин

**БЕ́РМӘЛНЕ** *рәв.* 1) Бервакытны, кайчандыр, кайчандыр бер. *Бермәлне, урам уртасыннан гармун чыңлатып баручы егет белән янәшә атлаучы Гөлҗиһан гына кала.* Ф.Сафин. *Бермәлне ул, кышын-җәен, зәңгәр кырпулы студент фуражкасы киеп йөрде.* И.Рәмиев

2) Кинәт, уйламаганда, көтмәгәндә. *Әрле-бирле сугылып, тагын күпмедер вакыт узды... һәм бермәлне, бөтен болынны яңгыратып, гармун сыздырып җибәрде!* М.Вәли-Барҗылы

**БЕ́РНӘРСӘ** *а.* **1.** Бер әйбер дә, һичбер төрле нәрсә булмауга ишарәләп, булуын, барлыгын кире кагып килә торган юклык алмашлыгы; һичнәрсә, һични, берни. *Әгәр ул аллы-гөлле зур резина туп күтәреп чыкмаган булса һәм аның белән бөтен малайларны кызыктырып уйнамаган булса, бернәрсә булмаган булыр иде.* А.Шамов. *Менә, минәйтәм, быел көз авылда тагын нихәтле чәчелмәгән җир кала инде, авыл советы аның турында бернәрсә дә кайгыртмый.* М.Гали. *Тик бернәрсә дә чыкмый, уйларымның сукырлыгын күреп, йөрәгем генә әрни.* М.Әмир

**2.** *и. мәгъ.* 1) Нәрсәдер, ниндидер билгесез әйбер. *Иртән торып, кайтмагачтын, Агай йорттан юнәлсә, Аты үзе кайтып килә – Атландырган бернәрсә.* Н.Исәнбәт. *Ул арада аэропланнан ташбаш балык шикелле юан башлы, нечкә генә койрыклы бернәрсә аерылды да, елан шикелле сузыла-сузыла, нәкъ боларның өстенә төшә башлады.* М.Гали. *Аннан соң алар алтын-көмеш чуклар белән бизәлгән һәм күз камаштыргыч елкылдап әйләнә торган зур бернәрсә алдына килеп туктадылар.* Ә.Фәйзи

2) Сөйләүчегә билгеле булган нинди дә булса бер конкрет әйбер, вакыйга,

фикер, эш, хәл һ.б.ш. *Ул сөйләгән арада, Габдулла бүлмәнең эчен, җиһазын күзәтеп чыкты һәм бернәрсәгә гаҗәпләнде.* Ә.Фәйзи. *Авылда төпләнеп калса, бернәрсә дә килеп чыкмас иде.* Н.Хәсәнов. *Әлеге сихри сүзләр тәэсир итте бугай, сөеклем дерт итеп китте, күзләре зуррак булып ачылды, аларда җанлану кебегрәк бернәрсә сизелде.* К.Миңлебаев

3) Берәр төрле хәбәр, нинди дә булса сүз яки әйбер, нәрсә дә булса. *Ул Рабиганы очратмады да, аның турында яңа бернәрсә дә ишетмәде дә.* А.Шамов. *Казаннан бернәрсә дә язмыйлармы?* М.Җәлил. *Мәгәр ул, көне буе йөрсә дә, бернәрсә дә атып ала алмаган.* Г.Гобәй

4) Бер үк әйбер, бер үк фикер. *Һәркем бернәрсә турында уйлый. Киләчәккә зур уйлар йөртә.* Г.Ибраһимов. *Турыдан-туры бернәрсәгә карап сөйләгәндә, гадәттә, хәзерге заман фигыльләрен кулланалар.* Г.Нигъмәти

5) Кешегә кимсетеп яки шаяртып әйткәндә кулланыла: ниндидер кимчелеге булган кеше, башкалардан ни беләндер аерылып торган кеше. *Бу кулларыңа караганда, мин сине бөтенләй көчсез бернәрсә, дип йөри идем.* Ә.Айдар

**БЕ́РНӘРСӘСЕЗ** *рәв.* Бернисез; буш. --- *ә мин җүләр, лыгырдык Хәмзин, һәрвакыт дөресен сөйләп, «туры әйткән – туганына ярамаган» дигәндәй, бернәрсәсез калдым.* А.Хәмзин

**БЕ́РНИ** *а.* **1.** *к.* **бернәрсә**. *Серне чишмим әле, үзләре дә берни сизенмиләр.* К.Миңлебаев

**2.** *и. мәгъ.* Берәр нәрсә, нәрсә дә булса. *Шайтан Шакирга һәм талаучыларга берни булмады, ә Асылгәрәй хәзрәтне Бөгелмә төрмәсенә ябып куйдылар...* Ф.Бәйрәмова. *Күн тужурка кигән район агенты, күркәдәй, түшләрен киергән дә, бернигә игътибар итмәстән, үзен ил хуҗасыдай тоеп, ишегалдында басып тора...* Н.Хәсәнов. *Ләкин әле ул берни эшләргә дә өлгермәде.* Р.Хафизова

◊ **Берни әйтер хәл юк** 1) Гаепкыек итәр урын юк; 2) Бернинди сүз күтәрми торган. **Бернигә дә карамый, бернигә дә карамастан** Бернинди авырлык, комачау, мәшәкатьләргә карамыйча, бернинди каршылык белән дә исәпләшмичә. **Бернигә (дә) санамау** Бик җиңелгә санау, берни урынына да күрмәү, исәпкә алмау. **Берни дә булмагандай** Сер бирмәү, эчтән начар булса да, тышка чыгармау. *Тик урманның төнге тынычлыгын Җимереп килгән поезд тавышына Ул, сискәнеп, берни булмагандай, Үз урынына табан авыша...* Һ.Такташ. *Шәмсия, берни булмагандай, Әхмәтсафаны чәйләп алырга чакырды.* Ф.Сафин. **Берниемә дә ярамый** Бөтенләй яраксыз. **Берни кыра алмый** Бернәрсә дә булдыра алмый. **Берни (дә) тормый** Эшнең җиңеллегенә яки әйбернең арзанлыгына карата. *Намус тормый аларга берниең дә, Кешелекне изәләр бер тиенгә.* Н.Исәнбәт. *Аннары, мондый ләззәтле минутларда, аңа бу вәгъдәне тормышка ашыруы берни тормый төсле иде.* А.Шамов. *Бер чиләк су түгеп килү аның өчен берни тормый иде.* Н.Фәттах. **Берни урынына да күрмәү** Исәпләшмәү, санламау, кимсетү, түбәнсетү. **Берни эшләп булмый; берни эшләр хәл юк** Теләк була торып та, эшләргә мөмкинлек булмау, чарасыз калу. *Мин моны үзем дә аңлыйм, Сәләхетдинов иптәш, ләкин күңел бит – берни эшләр хәл юк.* А.Шамов. *Бөтен солдатлар, коралларын ташлап, сугышмасалар, берни дә эшли алмаслар иде.* Т.Гыйззәт. *«Инде хәзер сезнең дөнья – берни эшләр хәлең юк» дигән сыман, тирән итеп бер суланды да, кулларын юрган астына яшереп, тагын күзләрен йомды.* Г.Гобәй

**БЕ́РНИКАДӘР** *рәв.* 1) Аз гына, күп түгел, бераз. *Бара-тора, яшь йөрәкләрендәге ялкынлы, дәртле һәм берникадәр җилле-буранлы мәхәббәтләре бер-берсенә гадәтләнү көче белән гадиләшкәч, тормышлары көйләнде.* Г.Минский. *Берникадәр натурализм элементлары булуга карамастан, татар әдәбиятында кыйммәтле бер әсәр.* М.Җәлил. *Коммунаның оештыру эшләре турында, орлык, ат көчләре һәм иген кораллары турында Фәхри тарафыннан бирелгән сораулар буенча, коммунаның председателе Һидият берникадәр мәгълүмат бирде.* Ш.Камал

2) Кыска гына вакыт, бераз. *Хәлим берникадәр вакыт үзе дә нишләргә белми торды.* Г.Гобәй. *Шушы сөйләшүдән берникадәр вакыт элек, Имай хатыны Гөлбикә Мәдинәгә Тырнаксыз Фәхринең энесе Галәүне димләгән һәм каты кире кагуга очраган иде.* Ш.Камал

**БЕ́РНИНДИ** *а.* Берәр төрле әйберләрнең, хәлнең, үлчәмнең барлык төрен дә кискен кире кагып килә торган юклык алмашлыгы; һичнинди, һич. *Бернинди уен сүзне күтәрми идем.* К.Миңлебаев. *Гата вакыйгасында да аның бернинди гаебе юк.* Р.Хафизова. *Аның кадере бернинди үлчәмнәргә дә сыймый.* Н.Хәсәнов. *Аның өчен бернинди чикләр дә юк.* З.Мәхмүди

**БЕ́РНИХӘТЛЕ** *рәв. к.* **берникадәр**. *Аю кая барырга тишек тапмыйча атылып чыккан да, Бүре белән, артларына борылып карамыйча да чапканнар, ди. Бернихәтле җир киткәч, Бүре: «Нәрсә бар анда?» – дип сораган.* Әкият

**БЕ́РНИЧАКЛЫ** *рәв.* Күп түгел, күп булмаган күләмдә, аз гына. *[Шәрәфи] Алгарак үтте, --- берничаклы эшчеләр, крестьяннар, хатыннар, кызыл гаскәрләр белән сүз алышты.* Г.Ибраһимов

**БЕ́РНИЧӘ** *рәв.* 1) Бераз, аз гына, берникадәр күләмдә, бернихәтле. *Берничә көн күзәтүләрдән соң, мин песнәкләрнең ашау-эчү, үзара мөнәсәбәт мәсьәләләре, бөтен бер системага салынып, аерым кагыйдәләргә корылганына төшендем.* М.Мәһдиев. *Корабль экипажы, берничә ел инде өзлексез сәяхәттә булганлыктан, бик арыган.* Р.Мөхәммәдиев. *Берничә атнадан, офицерлар белән бергә, казармага үтәбез.* Н.Хәсәнов

2) Төрле, әллә ничә. *9600 сумлык хезмәт хакына гына яшь гаиләгә яшәү авыр, дип, берничә җирдә эшли.* Юлдаш

**БЕ́РНИЧӘЛӘП** *рәв. к.* **берничә.** *«Әлеп-пи»гә керүче бер ул гына түгел, Фәрихә түти, алар берничәләп бар.* М.Гали

**БЕ́РНИЧЕК** *а.* Күпчелек *тә* кисәкчәсе белән килеп, берәр эш-хәлне башкара алу мөмкинлеген кискен кире

кагып килә торган юклык алмашлыгы; һичничек, һич тә, бөтенләй дә. *Янып торган мичкә керде дә: «Берничек тә алып булмый!» – дип кычкырып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Урысның: «Закон – дышло, куда повернул, туда и вышло», – дигәнен берничек тә тибәреп булмыйдыр шул.* Н.Хәсәнов. *Сездән берничек тә котылмак юк икән...* Ф.Садриев

**БЕ́РОЧТАН** *рәв.* **1.** *к.* **беррәттән** (*3 мәгъ.*). *Шунда берочтан ашларга да өлгерербез.* Р.Ишморат. *Сизгер йөрәк белән дус-дошманны Аерам һәм таныйм берочтан...* С.Гәрәева. *Аннары, берочтан, «Инженер Гаринның гиперболоиды» дигән романын да, ике-өч хикәясен дә эшләдем.* К.Миңлебаев. *Берочтан анысын да әйтеп китик: каенана да язмыш белән килешкән.* Г.Гобәй

**2.** *с. мәгъ.* Бериш, бер үк төрле. *[Галиәскар] Галекәй белән икесенә берочтан камзул белән чалбар, читек белән кәвеш, күлмәк, кәләпүш тектереп кидерде.* Ә.Фәйзи

**БЕ́РӨЗЛЕКСЕЗ** *рәв. к.* **бертуктаусыз**. *Ике көн, берөзлексез, вокзал юлында арба тавышы гөрләде.* Ш.Усманов

**БЕ́РӨЙЛЕЛӘР** *и. бот.* Төрле женесле чәчәкләре бер үк төптә (сабакта) була торган үсемлекләр классын белдергән атама; *русчасы:* **однодомные**

**БЕ́РӨЛЕШЛЕЛӘР** *и. бот.* Яралгыларында бер генә орлык өлеше булган үсемлекләр классын белдергән атама; *русчасы:* **однодомные.** *Берөлешлеләр, төр составы буенча, безнең республикада азрак үсә, ләкин, болын һәм далаларда, сулык яр буйларында, гадәттә, кыяклылар һәм күрәннәр күп булуын исәпкә алып, берөлешлеләрне өстенлек итүче үсемлекләр рәтенә кертү гаҗәп түгел.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**БЕ́РРӘВЕШЛЕ** *с.* Бертөсле, охшаш, рәвешләре белән бер-берсенә туры килгән

**БЕ́РРӘТТӘН** *рәв.* 1) Янәшә, бер үк рәттә. *Кирәге булмаса, аны ак кәгазь өстендә кара белән, китап сүзләре белән беррәттән ташка басып чыгарырлар идеме?* Ә.Фәйзи. *Имеш, мөдәрислеккә, ахунлыкка якынаеп барганда, шул мәртәбәне ташлап, әллә нинди мәгънәсез юлларга кереп китүе генә җитмәгән кебек, инде тагы, авылга кайтып, егерме сум торган ялчылар белән беррәттән сабан сөреп йөр, имеш!* Г.Ибраһимов. *Безнекеләр өстәл тирәсендә бергә Утырырлар беррәттән алар берлә.* М.Гафури

2) Бер-бер артлы, өзлексез, туктамастан, тоташтан. *Шуның артыннан ук Нәгыйм тагын, шушындый ук көч белән, беррәттән ике тапкыр сугып җибәрде.* Ш.Камал

3) Беруңайдан, бербуйдан. *...Беррәттән, су эчергән кеби, укытып чыгарсалар да, өсләреннән бурычларын төшерерләр, дип хисап итәм.* Г.Тукай. *Шул рәвештә Кызыл гаскәрне, беррәттән карт-коры, хатын-кыз, бала-чагаларын, суык белән, ач үлем белән газаплап үтерергә теләде.* Г.Гобәй. *Хатын-кызга бирелгән эш белән канәгатьләнә белмичә, ирләр белән беррәттән, кавалерия атакаларына бара.* И.Гази

4) Бертигез дәрәҗәдә, бер үк күләмдә. *Эшкә килгәндә, ул, кемне дә үзеннән алда җибәрмичә, ирләр белән беррәттән эшләп, беррәттән дүрт-биш җамаяк аш ашап, аштан соң әле тагы дәү генә тустаган белән мөлдерәгән катыкны да ялтырата торган булган.* Г.Минский. *Рюмкалар тагын берничә тапкыр күтәрелеп төштеләр, хатын-кызлардан бары Сафин хатыны Рокыя белән мөгаллимә Мөслимова гына ирләр белән беррәттән диярлек эчтеләр.* Ш.Камал

5) Бергә, бер үк вакытта. *Чабата туку белән беррәттән, чыбыркы ишү Җаббар абзыйның гадәтенә кереп киткән һөнәре иде.* Ә.Фәйзи. *Шуның белән беррәттән, фикерләр, уйлар да тынып тормый, алар да эшли, алар да туктаусыз ага, өзлексез дулкынланалар.* Ш.Камал. *Шул ук күренешләр белән беррәттән, Берлинның бөтен-бөтен кварталларын каплап алган кафелар, рестораннар, кабаклар, фәхешханәләр яшиләр.* Г.Гобәй

6) *күч.* Сыйфаты, әһәмияте һ.б. белән бердәй, бер дәрәҗәдә. *Эйфель манарасын музейлар белән беррәттән сөйләү урынлы булмас, шулай да азрак тукталып китү зарар итмәс.* Г.Гобәй

**БЕРСЕ** *а.* **1.** 1) Арадан сайлап алганда, төркемнән, берничәсе арасыннан аерылган билгесез затка яки әйбергә ишарәләп, билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; кайсыдыр, берәүсе. *Менә араларыннан берсе күктән ычкына вә, безгә таба атылып, үзенең артында бер генә секундлык ут юлы калдыра.* Ф.Әмирхан. *Су сораучы – офицерларны саклап торучы кызылармеецларның берсе иде.* Г.Гобәй. *Әмма ул – --- Колчакны Читага кадәр куып барган, авылда яңа тормыш төзү өчен күп көч куйган, колхозны башлап оештырып йөрүчеләрнең берсе.* Ә.Еники. *Кафил, йөгереп килеп, сумкадагы дәфтәрләрнең берсен кулына алды.* Тәмуг чәчәге

2) Үткән заман сыйфат фигыль формалары белән килгәндә: предметларның, затларның, төркемнәреннән аерып, аерым-аерым ишарәли торган билгеләү алмашлыгы буларак кулланыла; һәркем, һәркайсы, һәрберсе. *Килгән берсе ауды чокырга.* М.Җәлил

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кем дә булса берәү, берәр кеше. *Берсе укый, башкалары тыңлый шунда.* М.Гафури. *Милләтчеләрнең берсе байларны хезмәтчеләр җәбереннән коткару обществосына [җәмгыять] устав ясый икән.* Ф.Әмирхан. *Вокзал... Берсе китә, берсе кайта, Башка берәүләре озата.* Ә.Ерикәй

2) Кабатланып яки *башка*, *икенче* һ.б.ш. сүзләр белән бергә килгәндә, санап киткәндә, исемнән башка килеп, сөйләмнән аңлашылган төркем, зат, предмет, күренеш. *Яфракның арасында сандугачлар Берсеннән соң сайрарга берсе башлар.* М.Гафури. *Ул бүлмәдә, апа һәм Мәрфуга ападан башка, берсе – җиткән, берсе – минем кордаш һәм алардан башка тагын ике кыз утыралар иде.* Ф.Әмирхан. *Аларның берсе – итекче, икенчесе – тегүче, өченчесе Иван повар иде.* Ә.Еники

**БЕРСЕ́-БЕР** *а.* 1) Бөтенләй табылмауны белдереп, булуын, барлыгын кире кагып, юклык алмашлыгы буларак кулланыла; һичкем, һичбере, һичберсе, беркем, кем дә. *Яшь чагында ямьсез эз калдырган Эшләр күренмиләр берсе-бер.* М.Гафури

2) Предметларның җыелмасына бербөтен итеп күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы буларак кулланыла; бөтенесе, барсы, һәммәсе, барчасы. *Кулга нинди җан иясе килеп капса, шуны ризык иттем. Бака, күсе, әрләң, кыр кәҗәсе, тиен – берсе-бер калмады.* В.Имамов

**БЕРСЕ́-БЕРСЕ** *а.* Предметларга, затларга аерым-аерым, берәм-берәм күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; һәрберсе, һәркайсы. *[Алманың] Берсе-берсе кушйодрык кадәр була аның, үзе, язга кадәр сакласаң да, бакчадан гына өзеп алгандай.* Р.Төхфәтуллин. *Йодрыклары берсе-берсе бишәр потлы герләр хәтле иде, ди.* А.Алиш

**БЕРСЕ́КӨН** *рәв.* Алдагы көннән соңгы көн, иртәгәнең иртәгәсе. *Инде беләсең нәрсә: безгә иртәгә үк яисә берсекөннән дә калмыйча, авылда җыелыш үткәрергә кирәк.* Ш.Камал

**БЕРСЕ́КӨНГӘ** *рәв.* 1) Алдагы бер көннән соң, иртәгәнең иртәгәсенә. *Иртәгә йә берсекөнгә барып күрерсең үзең дә.* Р.Ишморат. *Ул чагында мин волость большевикларының җыелышын берсекөнгә үткәрәм, син шунда июль вакыйгалары, шәһәр хәлләре турында сөйләсәң яхшы булыр иде.* Т.Гыйззәт. *Ә берсекөнгә берсен-берсе талый, суя, үтерә башлаячак.* И.Гази. *Берсекөнгә берьюлы ике басуга уракка төшәбез...* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Якын киләчәктә, озакламый. *Бүген ышанмасаң – иртәгә, берсекөнгә, ул көнне дә ышанмасаң, аның икенче көненә ышанырсың әле.* Г.Камал. *Бүген булмаса – иртәгә, ә иртәгә булмый икән, берсекөнгә Бизмән тауның сере ачылыр.* А.Әхмәт

**БЕРСЕ́КӨНГЕ** *с.* Берсекөндә булачак; берсекөнгә билгеләнгән. *Берсекөнге очрашудан соң, бу турыда тагы бер кат яхшылап уйларбыз*

**БЕРСЕ́Н-БЕРСЕ** *рәв.* Берсе икенчесен. *Алар, очып китәрдәй булып җилпенеп, берсен-берсе уздырырга теләгәндәй, киндер талкыйлар.* М.Хәсәнов

**БЕРСЕННӘ́Н-БЕРСЕ** *рәв.* Бары да бериш, бер үк дәрәҗәдәге. *Аның алдында берсеннән-берсе таза, берсеннән-берсе төз буйлы, баһадирдай егетләр тезелгән.* Р.Хафизова. *Тау башындагы тегермәннәр берсеннән-берсе узышып әйләнә башладылар.* А.Алиш. *Контратака артыннан контратака: берсеннән-берсе усалрак.* И.Гази

**БЕ́РСҮЗДӘН** *рәв.* 1) Бертавыштан, бердәм рәвештә, барысы да бер үк төрле. --- *тагын яныңа кайта калса, хаста булгандай, башыңны авыруга сал. «Хәлең ничек, кәефең ни төрле?» – дип сораса, әйт: «Табиблар берсүздән әйттеләр: «Бу авыруга һичбер төрле дару юк, мәгәр Маймыл йөрәге файда бирер».* Әкият

2) Барысы бергә, бер булып, дәррәү. *Илбарыс якынаюга, кунакларны каршы алучылар, сөйләшкәндәй, берсүздән бил бөктеләр.* М.Хәбибуллин

**БЕ́РСҮЗСЕЗ** *рәв.* 1) Һичнинди каршылыксыз, тоткарсыз, карышмыйча. *Берсүзсез алып китәргә вәгъдә бирде һәм иртәгә шушы авыл аркылы үтәчәген белдерде.* М.Гафури. *Теге хулиганнар килер булсалар, берсүзсез чыгарыр да бирер идем.* Ш.Камал

2) Бернинди шиксез, һичшиксез. *Ул яманламаган булса, әлбәттә, берсүзсез алырга мөмкин булыр иде.* Ш.Камал. *Янгын сүндерү командасыннан берәрсе өенә кайтып китсә, иртәгә берсүзсез куылачак.* Ә.Хәбибуллин

3) Бер сүз дә сөйләшмичә. *Андый чакларда, башын ике кулы белән кысып, берсүзсез утыра-утыра да күңеленә килгәнне кычкырып әйтә дә җибәрә иде ул.* М.Әмир. *Берсүзсез кесәсенә тыгылып, илле тиен акча чыгарды да карчыкка бирде.* Г.Ибраһимов. *Хәлим, берсүзсез, ишек төбендә басып торды.* И.Гази. *Газинур исә, күзләрен ала алмыйча, аңа берсүзсез карап торды.* Г.Әпсәләмов

**БЕ́РТАВЫШТАН** *рәв.* 1) Бер үк вакытта, бердәм рәвештә, барысы да берьюлы, каршылыксыз. *Кызлар бертавыштан күтәреп алдылар.* Г.Гобәй. *Кызлар, бертавыштан: кайсы – үпкәләгәндәй булып, кайсы ихлас күңелдән ышандырырга тырышып, шауларга тотындылар.* Ә.Еники

2) Бердәм яклап тавыш бирү юлы белән; бер сүздән, беравыздан. *Югыйсә бертавыштан карар да кабул итә алмас идек.* К.Миңлебаев. *Комиссия әгъзалары, бертавыштан, Сүнчәләев аттестация үтмәде, дип кул күтәрделәр һәм беркетмә яздылар.* Н.Хәсәнов

**БЕ́РТИГЕЗ** *с.* **1.** Бер-берсенә охшап торган, бер үк төсле, бер үк дәрәҗәдәге; бер-берсенә тиң. *Ай икегез, икегез, Икегез дә бертигез.* Ш.Маннур. *Бертигез бай ярлы белән, юк аның артыклыгы. Булса тик артыклыгы – он кытлыгы һәм мутлыгы!* Ш.Бабич. *Нәкъ менә XX йөздә без, татарлар, Европа һәм Азиянең башка халыклары белән бертигез дәрәҗәдә конкуренциягә сәләтле булырлык итеп үстек.* М.Сәхапов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тигез итеп, һәрберсен бертөрле итеп. *Билгеле, композиторлар барысы да бертигез һәм бер юнәлештә, бер жанрда үсмәделәр.* М.Җәлил. *Ул аларның икесен дә бертигез ярата икән.* А.Алиш. *Поезд, откос астында калган ике-өч катлы йортлар белән бертигез булып, Берлин эченә оча.* Г.Гобәй

**3.** *хәб. функ.* Бер үк хәлдә, бер үк хокукта, бер үк дәрәҗәдә. *Гафифә дисәң Гафифә: бер җиргә бара башладың исә, кеше күрә, дип коты чыга; аның каршында «ир кеше» дигән сүз «ерткыч җанвар» дигән сүз белән икесе бертигез.* Г.Камал. *Байлар икәвесе дә гәүдәгә бертигез.* М.Гафури. *Артыбызда юл киселү – җиңелү белән бертигез.* Ш.Усманов

**БЕ́РТИҢ** *с.* Тәңгәл, бертөрле. *Авылын да, шәһәрен дә бертиң язганнары да бар.* Х.Сарьян

**БЕ́РТОТАШТАН** *рәв.* Берөзлексез, бер дә туктамыйча. *Ул, артык кызу темп белән эшләмәсә дә, армый-талмый, бертоташтан озаклап һәм пөхтәләп эшләп утыра ала иде.* М.Гали

**БЕ́РТӨРЛЕ** *с.* **1.** 1) Сыйфаты, үзлеге белән аерылып тормаган, бер-берсенә бик охшаш. *Тагын шул ук бертөрле тормыш белән торырга.* М.Гафури. *[Гөлсем] Бар да бертөрле, шул ук вакытта һәркайсысы үзенчә матур өйләргә, читән коймаларга, капкаларга карады.* Г.Гобәй. *Ну бит, Шәмсия килен, бөтен кеше бертөрле булмый.* Г.Гобәй

2) Үзенә аерым бер, махсус, үзенә генә хас. *Берзаман ачсам күзем,*

*бертөрле яп-ят кыр күрәм.* Г.Тукай. *Бөтен диңгез өсте үзенә бертөрле тоныклык белән яктырды.* Ф.Әмирхан. *Аларда менә шушылай беләккә кия торган бертөрле мылтык бар, ди, бер минут эчендә ике йөз тапкыр ата, ди.* Г.Камал. *Кем белә, гамьсез була белү – үзенә бертөрле бәхетләр дә...* М.Хәсәнов

3) *диал.* Тигез, бердәй, бер үк дәрәҗәдәге урта хәлдә. *[Сабир:] Синең кебек бертөрле тормышлы кешеләр дә кергәннәр иде [колхозга].* Һ.Такташ

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Үзенчәлекле, мәгънәле. *Хәятнең, кечкенә аякчыкларын җиңелчә генә ике тарафка каратып, нечкәрәк, ләкин бик зифа буен (фигурасын) иркә тотып барышын карап торганда, Михаилның йөзе бертөрле серле җыерылып китте: – Тупас Мамайның монгол йөзле нәселендә – шундый кыз!..* Ф.Әмирхан

2) Беркөе, беркөйгә. *Яңа тормыш, яңа хәлләр булганга, көннәрем бертөрле, сизелми генә үтәләр инде.* Г.Ибраһимов

**3.** *а. мәгъ.* 1) Бөтенләй булмавына басым ясап, юклык төшенчәсен көчәйтеп белдерә торган юклык алмашлыгы буларак кулланыла; бернинди дә, нинди дә. *Мин бертөрле срок белән дә хисаплашып тормыйм.* Ш.Усманов. *Бертөрле дә юаныч әйтә алмады, киресенчә, үзе йомшарды, күзләренә яшь тулды: – Бәгырем, балам, ни генә эшлим соң?!* Г.Ибраһимов. *Җөмһүрият эчендә бертөрле поезд-мазар йөрми иде.* К.Миңлебаев. *Ә Сафа, бернәрсә дә булмаган, бертөрле дә куркынычлы, дәһшәтле сүз әйтмәгән кеше кебек, идән уртасында басып тора иде.* А.Шамов

2) Күпчелек *дә* кисәкчәсе белән килеп, берәр эш-хәлнең мөмкинлеген кискен кире кагып килә торган юклык алмашлыгы буларак кулланыла; бөтенләй дә, берничек тә, һич тә, һичничек. *Әмма менә Садыйк кебек бер кешегә советның кул салуы бабайның зиһененә бертөрле дә сыймый.* Г.Ибраһимов

3) Кемнең яки нәрсәнең дә булса сыйфатын, үзенчәлекле якларын аңлатып булмауны белдерә торган билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла; ниндидер, әллә нинди. *Менә шул вакыттан безнең тормышыбызда бертөрле үзгәрү сизелә башлады.* Ш.Камал. *Бертөрле йомшак, ягымлы дулкыннарга чорналып, әллә кайларга китте.* Ш.Камал. *Ләкин буй-сынында ук бертөрле горурлык сизелә.* Н.Хәсәнов

**4. бертөрлесе** *и. мәгъ. тарт. форм.* Кайберсе, кайбере. *Россиядә көчле пролетариат революциясе дулкыннары күтәрелгәч, бу язучыларның бертөрлесе, ак эмиграциягә китеп, фашизм ялчысына әйләнде, бертөрлесе, совет туфрагында калып, астыртын рәвештә контрреволюцион көрәш алып барды; ә бертөрлесе, совет платформасын танымыйча, үз язмышы өчен сыкрап, елап, тынарга мәҗбүр булды.* М.Җәлил. *Ул арада сукачыларның бертөрлесе, атларына атланды да, арбаларын ташлап, сукаларын һәм хәтта капчыктагы чәчүлекләрен ташлап, авыл юлына таба чапты.* И.Гази. *Халыкның бертөрлесе аның хәлендәге кешенең гайбәтен сөйләргә ярата бит ул.* Ә.Еники

**БЕ́РТӨРЛЕЛЕК** *и.* Кабатлана торган бер үк төрле хәл, күренеш. *Балалар китапларының темаларындагы бертөрлелек – сыйфатын төшерә.* М.Җәлил. *Бертөрлелек – --- әсәрнең художество әсәре булып сиземләнүенә зәгыйфьлек китерә.* Г.Нигъмәти. *Монда эчпошыргыч тигез бертөрлелек юк.* Ш.Камал. *Малайларны бертөрлелек туйдыра башлады.* Р.Хафизова

**БЕ́РТӨСЛЕ** *с.* 1) Төсләре белән бер үк төрле булган. *Туның белән бертөсле булыр, әллә кайдан ук күренеп торыр.* А.Алиш. *Син миңа икесен дә бертөслене биргәнсең.* Г.Камал. *Бөтәрләнә һаман бертөсле, Кара чәчәк аткан гөл төсле.* Н.Исәнбәт

2) Охшаш, аерылып тормаган. *Аннан соңгы елларда дөнья кайнады, моңарчы гел бертөсле генә, тыныч кына агып торган тормыш диңгез кебек дулкынлана башлады.* Г.Ибраһимов. *Өчесе дә бертөсле бу матур атларның бертигез һәм купшы чабышлары минем үземдә дә инде, шулай, кычкырып җибәрәсе килү сыман бер теләк тудыра башлаган иде.* Ф.Әмирхан

**БЕ́РТӨСЛЕЛЕК** *и.* 1) Төсләре белән бертөрле булганлык

2) Кабатланып торган бердәйлек, бер үк хәл, бер үк торыш. *Психологлар аңлатуынча, шушы бертөслелек кешене шулкадәр туйдыра икән, үз-үзеңне туктаусыз күреп тору, берзаман, җәзага әверелә башлый.* Р.Низами

3) Охшашлык, тиңдәшлек. *Монда – «Бүзләрем мана алмадым» шигырендә – Дәрдемәнд строфалар арасындагы симметрик бертөслелекне җимерә.* Х.Госман. *Дөрес, бередә дә системалылык, бертөслелек була алмый.* Р.Фәтхрахманов

**БЕ́РТУГАН** *с.* **1.** 1) Бер ата-анадан туган. *Мин исә, Мәрьям апам кияүгә киткәч, бертуган апам белән, ызгышмый-талашмый гына, турсаеп, сөйләшмичә йөргән чакларым булгалады.* К.Миңлебаев. *Соңыннан сүзен бертуган сеңелләре Ләйсән белән Динәгә кайтарып калдырды, аларның кайда гомер итүләрен сораштырды.* Н.Хәсәнов. *Рабига белән Җамал һич кенә дә апалы-сеңелле бертуганнар була алмый, дигән нәтиҗәгә килде.* Ф.Сафин. *Бу егет – Мәдинә ханымның бертуган сеңлесенең улы иде.* Г.Әпсәләмов

2) Үзара якын, тату, ярдәмчел мөнәсәбәттәге. *Ш.Камалның, авыр эш шартларында бер кайгы, бер теләк белән, бертуган булып бер-берсенә үзләшкән эшче геройлары – дөньяга карашлары һәм тойгылары ягыннан яңа тип кешеләр.* М.Җәлил

**2.** *и. мәгъ.* Бер ата-ана балалары. *Ә бит Атилла аны «бертуганым» дип саный иде, аңа ышана иде.* Р.Зәйдулла. *Яшь аермабыз шактый булуга карамастан, без аның белән бертуганнар шикелле якыннар идек.* К.Латыйп

**БЕ́РТУКТАМЫЙ** *рәв. к.* **бертуктаусыз.** *Аның калай вентиляторлары бертуктамый зырлап әйләнеп торалар.* А.Алиш

**БЕ́РТУКТАМЫЙЧА** *рәв. к.* **бертуктаусыз.** *Станоклар бертуктамыйча әйләнәләр.* А.Алиш

**БЕ́РТУКТАУСЫЗ** *рәв.* Бер дә туктап тормыйча, тоташтан, өзлексез. *Исәнтәй, бүген дә бертуктаусыз барырга, тизрәк барырга һәм кояш бае-*

*мыйча торып туктамаска, дигән боерык бирде.* Н.Фәттах. *...Бераздан бу тын дөньяга җан керә, тавыш иңә, һәм баштарак – саңгырау гына бер чың, аннары бертуктаусыз көчәя барган дөнья шавы ишетелә башлый...* Г.Гыйльманов. *Егетләр учакка бертуктаусыз коры-сары өсти торалар.* Р.Хафизова. *Ут – ул кеше түгел, аны аз-азлап, әмма бертуктаусыз ашатып торырга туры килә.* Тәмуг чәчәге

**БЕ́РТУМА** *с. диал. к.* **бертуган.** *Без – күбәү, безнең тагын бар Бертума – алтмыш туган. Шуларның уртанчысы – син, Ә зурысы, вәт – мин булам!* Х.Туфан

**БЕ́РТЫН** *рәв.* 1) *к.* **бераз.** *Мондый да умырылып гырлауны гомерендә ишетмәгән композитор, ушын җуеп, бертын утырды да, ятагына өметсез сузылып, башын мендәр астына тыкты.* М.Галиев. *Бакчалар артыннан бертын баргач, зур булмаган уйсулык башлана.* Р.Мөхәммәдиев. *Йомшак түшәгендә ул, ярыйсы борсаланып, әле – бер, әле икенче ягына әйләнде, җитмәсә, бая бертын оеп, шул арада яман саташып та өлгерде.* Мирас

2) Кыска бервакыт арасында, бер мизгелдә. *Рәшәткә ишеген ачып керде, бертын, Фәезе утырткан миләш агачына карап торды.* Н.Хәсәнов. *Гөрләп торган клуб бертын эчендә бушап та калды.* Ф.Сафин

**БЕ́РҮЗЕ** *рәв.* Үзе генә, берьялгызы, башкалардан аерым рәвештә. *Шулай итеп, мин егетләр арасыннан берүзем Мәскәү университетына кабул ителдем.* Н.Хәсәнов. *Мин дә эш урынында, күбесенчә, берүзем бит...* Р.Кәрами. *Мин ничек яшәрмен берүзем, яшьләргә күз көеге булып?* К.Миңлебаев. *Һуннар белән ул берүзе идарә итә башлый.* Р.Зәйдулла

**БЕ́РҮК** *модаль сүз* **1.** *сөйл.* Борчылу катыш кисәтү-үтенү, теләкне белдерә; зинһар. *Нәфисә, алтыным, карап кына йөри күр берүк, сугыш җире ләбаса, әллә кем әйтмешли, җайлы-җайсыз үз белдегең белән читкә тайпыла күрмә.* Г.Бәширов. *«Ләкин, берүк, нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!» – дигәннәр.* А.Алиш. – *Берүк күп итеп якмагыз, әкрен-әкрен кипсен, шулай яхшы була ул, – дип киңәш итте.* А.Шамов

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Бигрәк. *Әмма тискәре карт икәнсез берүк!* Г.Ибраһимов. *Юкса җимерелеп төшәргә дә бик тиз, берүк кирпечләре черек булган.* Ш.Камал

**БЕ́РЧАК** *рәв.* 1) *к.* **бервакыт**. *Кайсы чакта артык шаян булып китеп, Берчак юктан гына ямансылауларым.* Г.Тукай

2) Бераз вакыт, аз гына кыска вакыт. *[Шәйхаттар бабай] Узган кыш урманда артыграк тырышып ташлаган, ахрысы, кайткач, берчак, биленә зарланып ятты.* Г.Гобәй

**БЕ́РЧАКНЫ** *рәв.* 1) *к.* **бервакыт.** *Берчакны аңа ниндидер конференциядәме, тарихчылар форумындамы Никита Сергеевичның үзен тыңларга туры килде.* Р.Нуруллина. *Берчакны син минем җәямне көйләп биргән идең.* М.Хуҗин

**БЕ́РЬЕЛЛЫК** *с. бот.* Орлыктан тишелеп, орлык бирүгә кадәрге бер ел эчендә була торган бөтен үсеш циклы. *Еланбаш яки «баллы чәчәк» дигән үлән – иренчәчәклеләр семьялыгыннан, күгелҗем шәмәхә яки ак чәчәкле, эфир мае исе бирүче берьеллык үсемлек.* Умартачылык

**БЕ́РЬЮЛЫ** *рәв.* 1) Бер үк вакытта, барысы бергә, бердән. *...Әти дә, әни дә икесе берьюлы авырый башлаганнар.* Г.Тукай. *Шулай күңелле генә килгәндә, пассажирлар бар да, сүз куешкан кебек, кинәт тынып калдылар, сөйләшкән, көлешкән тавышлар берьюлы тынды.* Г.Гобәй. *Минзөфәр велосипедта килеп туктауга, егетләр икесе дә берьюлы артларына борылып карады.* Н.Хәсәнов. *Рәзиядән берьюлы ике хат килеп төште.* И.Гази

2) Шунда ук, шул вакытында ук, бик тиз арада. *Халык җырлары стилен үстереп, шул нигездә, берьюлы халык арасына кереп китәрлек җырлар иҗат итү – опера өчен ят әйбер түгел.* М.Җәлил. *Малайның барын да берьюлы беләсе килә иде.* Р.Хафизова. *Әллә, бөтен рәхәтне берьюлы биреп ташламагаем, дип шөбһәләнә.* К.Миңлебаев

3) Бер үк вакытта, барысын бергә, берсен дә калдырмыйча. *Әмма, никадәрле ашаса да, берьюлы ашап бетерә алмыйча, итне икенче ашарга калдырып, үзе, көчкә генә сулыш алып, кибән төбенә ятты.* Г.Тукай. *Ул аларның барын берьюлы селкеп бушатмый, тәмләп кенә сөйли...* Н.Хәсәнов. *Берсекөнгә берьюлы ике басуга уракка төшәбез...* Г.Гыйльманов

4) Бер уңайдан, юл уңаенда; беррәттән; берочтан. *Ә нигә берьюлы чәчәргә дигәнен дә ярдырып куймый?* Г.Гобәй. *Шуннан берьюлы каенатаң Биктимер картны чакырып кайтырсың.* Т.Гыйззәт. *Имеш, берьюлы ике көймәнең койрыгын тотмак буласың.* Г.Ибраһимов

**БЕ́РЬЯКЛЫ** *рәв.* **1.** 1) Мәсьәләнең бер ягына гына игътибар итеп, башка якларны исәпкә алмыйча. *Кешенең тормышка – субъектның объектка мөнәсәбәтен революцион практика рәвешендә аңласак кына, тарихта шәхеснең ролен дөрес аңлаган булырбыз, дигән карашны онытсак, мәсьәләгә берьяклы, механистларча караган булыр идек.* Г.Нигъмәти. *Милли мәктәпләр кичергән фаҗигане башка халыкка, үзәккә сылтап калдыру берьяклы булыр.* Т.Галиуллин

2) Бер сүздә, бер фикердә булу. *[Атасы да] Тагы, улы белән берьяклы булып, миннән көлгән булып маташа.* Г.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Мәсьәләнең бер ягына гына игътибар иткән, бер ягын гына искә алган. *Бу хәл анда белгечләрне берьяклы – тискәре рольдә генә күрсәтүгә дә илткән.* Г.Нигъмәти. *Бәс, мәсьәлә берьяклы гына түгел икән.* М.Госманов

**БЕ́РЬЯКЛЫЛЫК** *и.* Мәсьәләнең бер ягына гына игътибар итеп, башка ягына игътибар итмәгән, чикләнгән караш. *Бу мисаллардан соң [шатлык кичерүче, сагыну хисләре белән тулышкан горур ана да, шул ук вакытта кичерешләрен кулда тотарга күнеккән кырыс җитәкче дә була алуын күрү] авторны һәм артисткаларны берьяклылыкта гаепләү бик үк ышанычлы яңгырамый. Г.Арсланов*

**БЕ́РЬЯЛГЫЗЫ** *рәв.* Бер кешесе дә булмаган хәлдә, берүзе генә, ялгыз.

*Саниянең баласын Тәңребез үзе кабул итеп алган, югыйсә, берьялгызы урман юлында бала китерә алыр идеме ул?* Г.Гыйльманов. *Чалбар балакларын сызганып, берьялгызы кәрзин белән балык сөзеп йөри.* Н.Хәсәнов. *Эскәмиядә Рөстәм бүген дә берьялгызы гына түгел.* Тәмуг чәчәге

**БЕ́РЬЯРЫ** *рәв.* Кая булса да, башка бер урынга. *Менә сиңа – төн йокларга урын, әгәр дә син шуннан берьяры кузгалсаң, өстеңә дөп итеп тукмак төшәр дә башыңны ярыр.* Н.Исәнбәт

**БЕ́Р ЯШЬЛЕК** *с.* Бер үк елда туган, яшьтәш. *Әнә Хантимировларның Марат белән бер яшьлек Чыңгызлары, анасының рөхсәтеннән башка, комлыкка да чыкмый.* Т.Гыйззәт

**БЕСЕ́ДКА** *и. рус* Бакчада ял итеп утырыр өчен ясалган, түбәсе ябулы җиңел корылма; күшәк; айван. *Кичләрен Рушан белән үги әтисе уллары үзбәкчәләтеп ясап куйган айванда – урысча әйтсәк, беседкада утыргалыйлар...* Р.Мирхәйдәров. *Ашыкмыйча гына бакчага барып җиттек, өебез дә, аерым-аерым кукраешып торган кухнябыз да, беседкабыз да тыныч кына торалар, алмагачларга да куяннар зыян салмаган.* К.Миңлебаев. *Бичара Овсеюк, беседкага утырып, кулларын каната-каната, ярты көн буе якорь җәпләкәсен кайрады.* М.Мәһдиев. *Иртән йокыдан торып ашагач, шушы аулак беседкага төшеп утыра.* Тәмуг чәчәге

**БЕСКОЗЫ́РКА** *и. рус* Кырыена уратылган кара тасмасының очлары артка асылынып торган, козырёксыз баш киеме. *Сафлар дулкынланды, бескозыркаларның ленталары җилдә җилфердәп, сафлар буенча ефәк дулкыннар хасил итте.* Ф.Шәфигуллин. *Ә бит ул бескозырка тасмалары белән кызларның йөрәгенә ут кабызмакчы иде!* М.Маликова

**БЕТ** *и.* 1) Бөҗәкләр классыннан, кеше һәм хайван тәненә кадалып кан суыручы канатсыз кечкенә паразит бөҗәк. *Монда инде туксан алты мең әсир, ачка шешенеп, тиф бетләренә талanып һәлак булган, диләр.* Ш.Маннур. *Бетнең авыз аппараты, тишеп, кан суыруга җайланган.* Биология

2) Үсемлекләргә төшә торган корт, үлән корткыч; гөблә, телә. *Камка – файдалы бөҗәкләрнең берсе. Алар күп санда үлән бетләрен юк итәләр. Личинкага, тулы үсеше өчен, меңгә якын үлән бетен ашарга кирәк ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

◊ **Бет ачуын туннан алу, беткә ачу итеп, тунны утка ягу** Ачуны гаепсез кешедән алу яки, юк-барга хәтер калып, зуррак эшләрне бозып ташлау. *Әлбәттә, моның, мондый хәрәкәтләрнең дин өчен булмаганлыгы, Ильядорның --- беткә ачу итеп, тунны утка ягуыннан күренә.* Г.Тукай. *Миңа, мин юләр башка, Украинадан үпкәләп качмаска, беткә ачу итеп, тунны утка якмаска, ә немец илбасарлары белән исәп-хисапны өзәргә кирәк иде.* А.Шамов. **Бет(ен) ашаган** Бик саран. **Бете котыру** *гади с.* Азу, узыну. *Бетләре бик котырса, кибеттән кайткач, ишегалдына кар көрәргә чыгар.* Ш.Мөхәммәдев. **Бет кебекябышу** Аерыла алмау, каныгу. **Бет симертү** *мыск.* Берни эшләмичә, ашап кына яту. **Бет чәйнәгән** *гади с.* Бик вак сүзле, бәйләнчек, вакчыл кеше. *Бет чәйнәгән журналистның Ав(ы)зын яптырыр идем...* Р.Рахмани

**БЕТӘҮ** *с. диал.* Озак вакыт буена төзәлми торган. *Кайвакытларда гына бетәү ярага әйләнеп китсә дә, чебенчерки чыкканчы төзәлми калмый иде.* Г.Исхакый

**БЕТӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Аннан-моннан ямау, ялгау, төзәткәләү. *Ә култык асты, терсәк кебек артыграк көч килә торган урыннарны Лукьян иске ямаулыклар белән бетәштереп өлгертә алмас булган.* Ш.Камал

2) Күз нурын түгү, күзнең күрүен киметү. *Кибеттән кергәч, бераз чыгып керә дә, ди, синең шикелле, күзен бетәштереп, әкият китаплары укып ятмый, ди.* Г.Исхакый

**Бетәштереп ату** Тиз-тиз бетәштерү

**Бетәштереп бетерү** Бик күп һәм төрле урыннардан бетәштерү; тулысынча бетәштерү

**Бетәштереп кую** Бетәштергән хәлгә китерү; алдан бетәштерү

**Бетәштереп чыгу** Тишек-тошыкларның барысын да яки берничә киемне башыннан ахырына кадәр бер-бер артлы бетәштерү

**БЕТӘШҮ** *ф.* 1) Төзәлү; йомылу; яра, җәрәхәт, төзәлә башлаганда, җыерылып кибү. *--- һәрвакыт салават, бисмилла берлән эш башлаганга, балаларның җәрәхәтләре тиз бетәшә, тиз төзәлә иде.* Г.Исхакый. *Агачларда бетәшкән «җәрәхәт» эзләрен күргәнегез бардыр.* Яшен һәм аннан саклану

2) Күзләр картаюдан нурсызланып, кечерәеп, күз кабагы җыерчыклар белән чуарланып калу. *Габдулла яңа урында алты почмаклы зур өйнең ак бүлмәсендә түгел, зур-зур ләгәннәр, комганнар, сөлгеләр, иске туннар белән тулган кара ягында, күзләре бетәшкән бик карт бер әби белән бергә яшәде.* Ә.Фәйзи

3) Картаю, арыкланып, бөрешеп бетү; ябыгып, хәлсезләнеп, кечерәеп калу. *Шул чакта каршы капкада бик бетәшкән бер әби күренде.* Г.Гобәй. *Хәзерге шикелле көчсез, бетәшкән карт түгел идем.* А.Шамов

4) Авырып яки ачлыктан бетеренү. *Инде кияү буласы кеше Зиннәт шикелле бик бетәшеп кайтса, иртәсен-кичен җылы сөт эчерәсе булыр, дип әйтеп, узган яз мүкләк кенә булса да бер кәҗә дә алдылар.* Г.Бәширов. *Аннары бик бетәшкән бит, ни гомер татлы нәрсә күрмәгән, ә үзенекеләргә әледән-әле шикәр, конфет кереп торды.* Г.Гобәй. *Көзге караңгы кичләрнең берсендә, станциядән кайтучы күрше авыл олаучылары сыңар куллы, ябык, бетәшкән Нурулланы Бәнатлар өенә ташлап киттеләр.* Казан утлары

5) *күч.* Тузу, искерү; бетү, юкка чыгу. *[Өй] Бик бетәшкән шул, җылы тормый.* Г.Гобәй

6) *күч.* Бик ваклап, җентекләп, тәфсилләп эшләү

7) *күч.* Саранлану, вакчыллану. *– Биш тиеннән кыйбатрак булыр бит, әй. Бу мал болай да бик бәһа төште безгә, – дип, бетәшеп азаплана купец.* Ф.Хөсни

◊ **Бетәшкән нәрсә** *мыск.* Бик саран, вакчыл. *– Бигрәк бетәшкән нәрсә икән. – Юха елан. – Алай димә. – Дию.* Т.Миңнуллин

**Бетәшә бару** Аз-азлап, акрынлап бетәшү. *Хәер, бәлки, бу моңсулык-сагыш торгынлык елларының сәяси атмосферасыннан да, милли яшәешебезнең әкрен генә сүнә-сүрелә, бетәшә баруын аңлаудан да тугандыр.* И.Вәлиуллин. *Алар да көннән-көн йончый, бетәшә баралар.* Т.Нәбиуллин

**Бетәшә башлау** Бетәшү билгеләре күренү. *Ашын – ашаган, яшен – яшәгән Гаяз ага, җиде дистәне тутыргач, йончый, бетәшә башлый.* Т.Галиуллин

**Бетәшеп бетү** Тәмам бетәшү. *Габдулла бу бетәшеп бетә язган карчыкның җиләк кебек кыз чагы булуын күз алдына китереп бетерә алмады.* Ә.Фәйзи. *Куәтле ир Альберт бетәшеп беткән карттан үч алса, хаклы булса да, гадел булса да, үзен түбәнәйтер иде.* Р.Батулла

**Бетәшеп йөрү** Һаман да, бик озак вакытлар дәвамында бетәшү; үтә вакчыллык күрсәтү. *Син бетәшеп йөр киреңә, Мин, тотам да, үзем барып язылам Һәм аяк та басмыйм өеңә.* Ш.Маннур. *Халык куырылып, корышып, бетәшеп йөрде.* Т.Нәҗмиев

**Бетәшеп килү** Акрынлап, аз-азлап, күзгә күренеп бетәшү. --- *их, бу да бетәшеп килә икән инде, моның да картаюы җиткән икән, дип, елыйсыларым килә башлады.* Г.Бәширов. *Йөрәк яралары да бетәшеп килә.* М.Әмирханов

**Бетәшеп утыру** Әле, хәзер, бик вакланып, нинди дә булса эш белән шөгыльләнү. *– Ничек түземлегең җитә синең шундый вак-төяк эш белән бетәшеп утырырга?! – дип гаҗәпләнделәр ул чакта бүлмәдәш кызлары.* Ә.Сафиуллин

**БЕТЕК** *и. иск.* Рәсми язу; хат. *Мөхәммәд Әминнең татарча язылган рәсми хаты, ягъни бетеге (битиге), Хәким Бирде исемле илчесе аркылы 1506 елда Польша хөкемдары Александрга җибәрелә.* Х.Миңнегулов

**БЕТЕМ** *и.* 1) Әдәби әсәрнең соңгы – тәмамлану өлеше; драматик, ә кайвакыт хикәяләү характерындагы әсәрләрдә – эпилог, лирик шигырьләрдә – соңгы юл яки строфа; мәсәлдә – соңгы сүз, мәсәлнең мәгънәсе, мораль өлеше. *Шагыйрьнең әйтергә теләгән фикерләре, бирергә уйлаган тойгылары вәзен, бетем, строфалар эчендә кысылып калмаска тиешле.* Г.Нигъмәти

2) Текстны күчереп язучының күчермәгә язган аңлатмасы, «паспорты». *Менә бу хәлләр барысы да татар каллиграфлары тарафыннан күчерелгән китапларда «колофон» дигән бетем язуының, ягъни күчермәгә аны эшләүче тарафыннан бирелә торган махсус «паспортның» сирәк булуына китерәләр.* М.Госманов

3) *иск.* Кушымча. *Ярдәмлек сүзләрне, хәбәрлек бетемнәре белән төрләнүләренә карап кына, фигыль дип уйларга тагын юл юк.* Г.Алпаров. *Йосыповның шигырьләрендә «чакырганда – салырга» төсле ятышсыз бетемнәр күп кенә.* М.Җәлил

**БЕТЕП** *рәв. диал.* Бик бирелеп, йотылып, бөтен күңелен, игътибарын юнәлтеп. *[Ифрат] Башта иртәнге табигать белән мавыгып, кечкенә кошчыкларның бетеп сайрауларын тыңлады.* А.Расих. *Иванов [Вәлинең] күзләренә бетеп карады.* Г.Ибраһимов

**БЕТЕРГЕСЕЗ** *с. сөйл.* Артык күп, бик күп, исәбе юк, санап бетермәслек, чик-чамасыз (искиткеч күп санны белдергәндә кулланыла). *Безнең өчен күргән михнәтләре, Санап бетергесез эшләре.* М.Гафури. *Иҗат эше – әйтеп бетергесез катлаулы бернәрсә инде ул.* К.Миңлебаев. *Без, беренче мәртәбә икәүдән-икәү генә калуыбыз белән, әйтеп бетергесез бәхетле идек.* Ә.Еники. *Шул юнәлештә Мәскәүдә бер-ике ел эшләп алсаң, Россия буенча бәяләп бетергесез белгеч буласың инде аннары.* Р.Мирхәйдәров

**БЕТЕРГЕЧ** *с. сир.* **1.** 1) Хәлиткеч, җимергеч. *Сугышка, иптәшләр, заводлар, калалар, кырлардан Килегез, ясыйбыз дошманга Җимергеч, бетергеч ударлар.* Ә.Ерикәй

2) *күч.* Тетмәсен тетеп язган, нык тәнкыйтьләгән. *Бетергеч рецензия*

**2.** *и. мәгъ.* Язылган язуны ышкып бетерә торган резина кисәге, бозгыч. *[Варис] Бит кырыйларына карандаш белән язылган искәрмә-күрсәтмәләрне бетергеч белән аннан-моннан чистарткалады да --- кире нәшриятка җибәрде.* М.Хәсәнов

**БЕТЕРЕНҮ** *ф.* 1) Картаюдан, я булмаса авырудан хәлсезләнү, какшау; зәгыйфьләнү, өшәнү. *Берәрегез күргәндә-чыкканда аның йөзен күрә алмадымы? Күргән булса, ул кеше минем ябыгуларның, минем бетеренүләрнең төп сәбәбен берьюлы аңлар.* Г.Ибраһимов

2) Борчылу, кайгыру, хәсрәтләнүдән өзгәләнү. *Икесе дә, шул бала хәсрәте белән булса кирәк, бик бетеренделәр.* Ә.Фәйзи. *Минем өчен бетеренмә. Көтегез...* Н.Хәсәнов. *Ник бетеренәсең әле син болай?* Мәдәни җомга

**Бетеренә бару** Торган саен ныграк бетеренү

**Бетеренә башлау** Бетеренергә тотыну. *Әмма, тора-бара, бу [яшь килен] көннән-көн сула, бетеренә башлаган.* Р.Зарипов

**Бетеренә төшү** Беркадәр, бераз бетеренү; тагын да бетеренү. *Тәрәзәңдә ут яна, әле йокламагансың икән, Сөмбелем!.. Күрәм, тагын да бетеренә төшкәнсең.* Н.Хәсәнов

**Бетеренеп йөрү** Соңгы вакытта, хәзер нәрсә дә булса кайгыртып йөреп бетеренү. *Кайчан канатланырын белми. Төшенкелектә, бетеренеп йөри.* Ш.Галиев

**Бетеренеп калу** Ниндидер бер сәбәптән, вакыттан соң бетеренү. *Әле яңа гына очынып йөргән, бөтен җаны-тәне белән тантана иткән Фабарисов югалып, бетеренеп калды.* Ф.Бәйрәмова

**Бетеренеп китү** Берарада, кинәт бетеренү. *Әллә бигрәк бетеренеп киткәнсең, әни?* Н.Исәнбәт

**Бетеренеп утыру** Әле, хәзерге вакытта өзгәләнеп тору. *Болай җәфаланып, бетеренеп утырма.* *Сөйләш.* Г.Гыйльман

**БЕТЕРЕРЛЕК** *с.* Хәл фигыльнең *-еп/-ып* формасы белән бергә килгәндә: чиксез-чамасыз, һич бетми торган, бик күп. *Шулай ук монда сугыш каһарманнары һәм корбаннарының фоторәсемнәре дә бик күп – берәмләп карап бетererлек тә түгел.* Ә.Еники

**БЕТЕРЕШЛЕ** *с. к.* **бетererлек.** *Иң әүвәл аны Мәскәү таң калдырды – шәһәр шундый галәмәт зур, һич аңлап бетерешле түгел, анда яшәү дә әкәмәт кыйммәт икән.* Р.Мирхәйдәров

**БЕТЕРЕШҮ** *ф.* 1) *к.* **бетеренү**. *Гариф бу елларда бетереште инде ул, былтыр да, Мортаза белән ярыша алмагач, мәйданга җитәр алдыннан юри егылып калган булды.* М.Гали

2) *мат.* Вакланмада яки тигезләмәдә билгеле бер саннарның кыскаруы

**Бетерешә бару** 1) Вакыт үткән саен ныграк бетерешү

2) Бер-бер артлы бетерешү

**Бетерешә төшү** Бераз бетерешү; тагын да бетерешү

**Бетерешеп бару** *к.* **бетерешә бару**

**Бетерешеп калу** Нindидер хәлдән, сәбәптән соң бик нык бетерешү

**Бетерешеп китү** Кинәт бетерешү

**БЕТЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Тәмамлау, төгәлләү, очлау, тәмам итү; эшне, хәлне ахырга кадәр китереп җиткереп туктату, йомгаклау. *Үз хикәясеннән үзе куркып, теге Гыймадиларны, Низамиларны, трактор Шәяхмәтләрне, Фәхриләрне, Шәңгәрәйләрне сөйләде дә: – Бу ничек булды икән! Әйтәм бит, ике тамчы су кебек охшыйлар, – дип бетерде.* Г.Ибраһимов. *Рәүфә сүзен әйтеп бетерә алмады, тамагына күз яшьләре тыгылды.* А.Шамов

2) Кайда да булса укуны төгәлләү. *Әткәләренең сөйләвенә караганда, ул «биш сыйныф» мәктәпне бетергән.* Ш.Камал. *Ул соңгы елларда, очучылар мәктәбен бетереп, очучы булып хезмәт итә.* М.Җәлил. *Чехов, гимназияне бетереп, 1879 нчы елда, Мәскәүгә барып, университетка керә.* Г.Нигъмәти. *[Газиз:] Безгә ишмени? Университет бетергән кыз ул.* А.Әхмәт

3) Юкка чыгару, китәрү, юк итү. *Фашизмны бетерергә булышыйк, иптәшләр, Булышыйк, иптәшләр!* Г.Гобәй. *Мондый лосьон тирене чистарта, төрле ялкынсынуларны да бетерә.* Мәдәни җомга

4) Кыскарту, ябу, яшәүдән, эшләүдән туктату. *Корткычлар заводны бетерү юлында беркадәр эшләп тә өлгерәләр. Мәсәлән: күкерт ачысы эшли торган ике камераның берсен бетереп, аның урынына өч өлеш ким продукция чыгара торган контакт цехы төзиләр.* Ш.Камал. *Район лабораторияләре үзләрен акламаулары сәбәпле бетерелгәннәр.* Чаян

5) Акча, азык-төлек, материал һ.б.ш. ларны тоту, сарыф итү

6) Эшләп өлгертү, торгызу, салу. *Ире сугышларда йөргәндә дә, илдән урын сорап алды да, агай-эненең, күршекүләннең булышлыгы белән, менә шул хәзерге өйне бетереп керә алды.* Г.Ибраһимов. *Алган бурабыз тора, түбә калае, түшәмлек-сайгаклык – барысы да әзер, өй бетерәсебез бар.* Ф.Хөсни

7) *сөйл.* Өлгереш буенча түбән билгедән соң югары билге алу; төзәтү. *Гомеремдә беренче тапкыр алган икелене бетерәсе.* Р.Төхфәтуллин

8) *куч. сөйл.* Үтерү; тар-мар итү; юк итү, җиңү. *Биш волостьтагы крестьяннар күтәрелешеннән файдаланып, кулакларны кырып бетерергә кирәк.* А.Гыйләҗев. *Элекке нужа эзләрен Бетерергә тотынган.* Н.Исәнбәт. *«Тотып маташма, җибәр, юкса, сине дә бетерәм, фәлән-төгән», – дип, миңа һөҗүм башлады.* Ш.Камал. *[Тимеркәй:] Кәҗә Якуп белән Карун Вәлине үз кулым белән бетерермен, дигән идем.* Г.Ибраһимов

9) *куч. сөйл.* Нәрсәгә дә булса кайгырып, сагышланып, үз-үзеңне авыруга сабыштыру; үз-үзеңне битәрләү. *Кешене эш бетерми, кайгы бетерә.* Мәкаль. *Сабыр ит, --- елап, үз-үзеңне бетермә, юкка гына үз-үзеңне бетерәсең.* М.Гафури. *Нәфесле кешеләр үз-үзләрен бетерәләр.* Юлдаш

**2. бетереп** *рәв. мәгъ. куч. сөйл. к.* **бер итеп.** *Нишләп кыр бетереп йөгереп йөрисең, кызый?* Р.Гарипов

**3.** *ярд. ф. мәгъ.* 1) Нәтиҗәле эшхәрәкәтне, эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануын белдерә. *Кыз, сөйли-сөйли, төймәне тагып бетерде.* А.Шамов. *Чәчүебезне вакытында башкардык, менә әле бәрәңгене дә утыртып бетерәбез инде.* Г.Бәширов. *Һәм бу да – инде ерак хыял түгел, сез үсеп буйга җиткәндә, аны төзеп тә бетербез.* Г.Гобәй. *Йорт-җирне төзеп бетердегезме?* Ф.Бурнаш

2) Эш-хәрәкәтнең соң дәрәҗәгә җитүен белдерә. *Сәкедән чынаякларны җыеп алгач, Фәтхия карчык тагы, әллә нинди сөлгеләр, ашъяулыклар турында сүз кузгатып, баш әйләндереп бетерде.* Г.Ибраһимов. *Кайчан кертәсең, Вильдан абый, дип, җөдәтеп бетерделәр.* Ф.Бурнаш. *Без, колхозчылар, колхоз милкен әрәм-шәрәм итеп, туздырып бетерсәк, җиңә алмаган булыр идек бит ул бәдбәхет дошманны.* А.Шамов. *Кырык хатын, җыелып, бөтен өйләрдәге утларны сүндереп бетергәннәр.* А.Гыйләҗев

3) Эш-хәрәкәтнең күп предметларга таралуын белдерә. *Ул кадәр җимешне кая куеп бетерәбез?* И.Гази. *[Галимҗан:] Ай-яй, Кәрим абзый, үзең әйткәндәй, бу кошларны каян җыеп бетердең?* Т.Гыйззәт. *«Йогышлы», «йогышсыз», «вакытлы», «вакытсыз» дигән төрле категорияләргә бүлгәләп бетерәләр.* Ш.Камал. *Менә инде тәмам бер ел булды, үзенең алган жалуниясеннән бер тиенен дә китергәне юк, һәммәсен үз юлына тотып бетерә.* Г.Камал

◊ **Бетереп эзләү** Бер җирне дә калдырмыйча, актарып эзләү. *Су ташучы булып эшләргә, авыл бетереп, кеше эзләргә туры килә.* Р.Төхфәтуллин. *--- дала бетереп, Күчем ханны эзләү башланды...* Ф.Бәйрәмова

**Бетереп алу** Тиз генә бетерү. *[Бәдри:] Аннары бу мунчасын да тиз генә бетереп алырга кирәк... Идәнгә үзебезнең такталар да ярар...* М.Фәйзи

**Бетереп ату** 1) Тиз-тиз, аннан-моннан эшләп бетерү

2) *к.* **бетереп ташлау** (*3 мәгъ.*). *Кемнәрнедер тиргибез, Күз ачарга бирмибез һәм Бетереп атабыз.* Р.Миңнуллин

**Бетереп бару** Рәттән, тоташ бетерү. *Мондый тәртипле конторларда һәркем, үзенә тәгаен кыйлынган эшкә вакытында килеп, эшләп бетереп барадыр.* Ш. Мөхәммәдев

**Бетереп йөрү** Берәр эшне төгәлләп килү

**Бетереп килү** Берәр эшне тәмамларга якынлашу. *Уңда, Кырынды тавы өстендә, тракторлар борчак җирен сөреп бетереп киләләр.* А.Гыйләҗев. *Зәй чокырдагы чәен эчеп бетереп килә иде.* Х.Камалов

**Бетереп кую** Алдан ук бетерү, бетереп әзер итү. *Бәхет басып, эш җайга тәгәрәсә, бәлки, кич белән яисә төнлә белән, без аның эшен дә бетереп куярбыз...* И.Гази

**Бетереп ташлау** 1) Тиз арада бетерү

2) *күч.* Тулысынча юкка чыгару. *Фаяз тиешлесен йөз процентка үти килде. Әмма язмыш – үги ана – тез астына сукты, барысын бетереп ташлады.* Х.Камалов

3) *күч.* Кешене артык каты битәрләү, хурлау, юкка чыгару. *Әмма шул мәлне күкрәгенә Герой йолдызы таккан, ничектер крестьян чырайлы, таза, базык гәүдәле лейтенант сүз сорады. Бетереп ташлый икән, дип, Мостафинның йөрәге дөп-дөп типте.* Х.Камалов

**Бетереп тору** 1) Әле, күз алдында бетерү, төгәлләүгә якынлашу

2) Бертуктаусыз бетерү. *Моның җылысын, брезент палаталардагы шикелле, җил алып бетереп тормый иде.* Х.Камалов

**Бетереп чыгу** 1) Эшне төгәлләп бетерү; тәмамлау. *Дүрт ел элек кенә техникумны отличнога бетереп чыктың.* Р.Ишморат

2) Һәрберсен бер-бер артлы бетерү

**Бетереп яту** Эшнең ахырына якынлашу. *Шулай итеп, соңгы шөрепне генә кысып бетереп ята идем, минсиңайтим, кемнеңдер төбәлеп карап торуын күреп сикереп куйдым.* Р.Сәгъди

**БЕТЕШ** *и. иск.* 1) Төрле организм тукымаларының сыйфат ягыннан үзгәреше; үсеш, өлгереш. *Бетеше яман камышны су эчендә үрт алыр.* Мәкаль

2) Организмның яшәүдән тукталу хәле

**БЕТЕШҮ** *ф. сөйл. к.* **бетәшү** (*3 мәгъ.*) *[Әниең] Бик бетешкән иде, улым, күзләре дә начар күрә иде... Нургалидән хәбәр килү белән, бөтенләй үзгәреп китте.* Т.Гыйззәт

**Бетешә бару** Аз-азлап, акрынлап бетешү

**Бетешә башлау** Бетешергә тотыну

**Бетешеп йөрү** Һаман да, соңгы вакытта бетешү

**Бетешеп калу** Нинди дә булса сәбәптән, вакыйгадан соң кинәт бетешү. *Чиста итеп кырынган, өстендә – бераз кыршылган көзге пальто, аягында – күн итекләр. Ул ничектер кечерәеп, бетешеп калган шикелле...*Т.Мөбарәков

**Бетешеп килү** Акрынлап, күзгә күренеп бетешү

**БЕ́ТКӘНЧЕ** *рәв.* 1) Соңгы чиккә җиткәнче, үлгәнче. *Әйдә, җаный, озат бәни уйсу җиргә җиткәнче; «Яшен» сугар, татарларда сугарлык җир беткәнче.* Г.Тукай. *Минем бу сөйләгән сүзләремне син тагы кодагыйларга барып әйтә күрмә, алар – усаллыкны беткәнче белә торган явыз, начар кешеләр.* Г.Камал

2) *күч.* Бөтен барлыгың, бөтен җаның-тәнең белән. *Беткәнче үзенеке генә булган яшь хатынның кайнар дәрте аны тарта кебек.* Ә.Еники. *Укытучылык начар эш буламы соң? Тик аны яратып, җаның-тәнең белән бирелеп эшләргә генә кирәк. Беткәнче бирелергә кирәк ул эшкә.* М.Әмир

**БЕТКЕСЕЗ** *с. сөйл.* Иксез-чиксез, бик күп, санап бетерерлек түгел. *Тургай даласының киңлегенә, яшел болыннарның матурлыгына, камышлы күлләрнең суына, печән эскертләренең беткесез муллыгына ияләшеп үскән үгезләрне вагонга тутырганнар да, капка хәтле ишекне ачып куеп, аркылы такталар белән кадаклаганнар да, Мәскәүгә озатканнар.* К.Нәҗми

**БЕТЛӘ́Ү** *ф.* Бет басу, бет үрчү. *Бетләп, тиф таралды. Сугышка җибәрегез, дигәннәрне маңгайларына тәрәп аталар, парин.* Р.Батулла

**Бетләп бетү** Тәмам, бик нык бетләү. *Яз килгәчтен, [Фриц] язган хатынына: – Белмим, кайтып булыр микән, – дип, – Бетләп беттем үзем, хәзер инде җәй килгәнен генә көтәм, – дип.* Ә.Ерикәй. *Чәче генә түгел, бишмәте дә бетләп беткән иде. Ярый әле үзендә беткә каршы шампунь булды, юкса югалып калган булыр иде.* З.Мәхмүди

**Бетләп яту** Озак вакытлардан бирле, күптәннән бетләгән булу. *Минем Әнәс абыйның амбарында узган елгы ашлык бетләп ята.* Р.Зарипов

**БЕТЛЕ** *с.* 1) Бете булган, бетләгән, бет баскан. *Без – бүдәнәләрне --- әллә нинди хәйлә тозаклары илә тотып, атналап, үзләренең кырык катлы бетле чапаннарының җиңнәре эчендә ач асрап --- үләр дәрәҗәгә җиткәч, чапан җиңеннән чыгарып, алдыбызга юри биш-алты бөртек арпа яки тары салып, ага-энеләребез илә канга баткан-чы сугыштырып --- кул чабып көлешеп торалар.* Ш.Мөхәммәдев

2) *күч.* Мыскыллап әйтелә торган сүз. *– Кит әле моннан, бетле кандала! – дип куя торган иде.* Г.Гобәй. *Бер бетле шахтёрга сасыган ит биргәннәр, имеш.* Г.Сабитов

◊ **Бетле йөрәк** Гамьсез, дәртсез, ялкау кеше. **Бетле күз** *мыск.* Чепи күз, кысык күз

**БЕТЛЕ́ БӘЗ** *и.* Кара төрткеләре булган һәм төерчекләнеп торган тукыма, бәз. *Чирек шырпы кабы хәтле сабын тоттырдылар, --- адәмнең арык, кырда, җилдә-яңгырда какланган кап-кара тәненә бетле бәздән күлмәк-ыштан кунды.* А.Гыйләҗев

**БЕТМӘС** *с.* 1) Һич бетми торган, озак вакытларга сузылган. *[Тәкъвә Сәхәу:] Мондый изге таңда нинди бер бетмәс улау бу?! Гаеткә барыр вакыт җиткән, мөселманнар!* М.Әмир. *Тукал: «Ай балам, йөрәгеңә бетмәс ут төшкән икән», – дип кызганып куйды.* Г.Ибраһимов

2) Бик күп, чамадан тыш күп. *Туганыгыз кебек батырларга Һәйкәл булыр җиңгән токымнар. Онытмаслар һич тә һәм аларга Мәңге бетмәс рәхмәт укырлар.* Ә.Исхак. *[Шәриф] Биш тиененә он алса, ике тиен акча дәхи артып кала, менә бетмәс акча!* М.Гафури

3) *күч.* Бик көчле, билгеле бер дәрәҗәгә җиткән, тирән, дәвамлы. *Басып килгән кара дошманга Егет йөрәгендә чиксез ачудыр, Күкрәгендә – бетмәс ярсудыр.* Ш.Маннур

**БЕТМӘ́С-ТӨКӘНМӘС** *с.* Һич бетми торган, иге-чиге юк, санап бетерерлек түгел. *«Ак бабай китергән аш аеруча тәмле була, бетмәс-төкәнмәс җегәр бирә», – ди торганнар иде.* Г.Гыйльманов. *Инде ике елдан артык дәвам иткән, Татарстанның законнарын Россиянеке белән тәңгәлләштерү процессы, бетмәс-төкәнмәс прокурор протестлары, тамчы ташны телгәләгәндәй, суверенитетыбызны акрынлап юкка чыгаруга юнәлтелгән.* И.Таһиров. *Аңа яхшы хатын булуы кыен, чөнки вакытының 80 процентын мәктәптәге бетмәс-төкәнмәс эшкә сарыф итә.* Мәгърифәт

**БЕТОН** *и. лат.* **1.** Ком һәм вакланган ташны цемент белән катнаштырып, шул массаны коеп катырган төзү материалы. *Аннары бетон сыйфатын бик нык тикшереп барырга, андагы өзеклекне бетерергә кирәк иде.* А.Шамов. *Завод корпусларын төзегәндә, әтинең көче-сәләте бик тә ярап куя: ул бетоннан фундамент сала, гаять авыр эштә була.* К.Миңлебаев

**2**. *с. мәгъ.* Шул материалдан эшләнгән. *Аның иптәшләре, тотынырлык бер генә нәрсә дә булмаганлыктан, шуып барып, йөз метр тирәнлегендәге бетон базга очтылар.* Р.Мөхәммәдиев. *Тигезлеген югалткан тоткын, бетон баскыч буйлап, бәрелә-сугыла, караңгы подвалның юеш идәненә тәгәрәде.* З.Мәхмүди. *Аның су ялап шомарткан бетон тәне, тия язып, яныбыздан узды.* М.Юныс. *«Магнитлы» суда әзерләнгән бетон измәсе тизрәк ката, ә бетонның ныклыгы шактый арта.* Могҗизалар энциклопедиясе

**БЕТОНЛА́У** *ф.* Бетон салу; бетон кою, нәрсәне дә булса бетон коеп ныгыту. *Төзүчеләр яңа гигантларның Бетонлыйлар нигез ташларын.* Г.Хуҗиев. *Плотинаның урта өлешенә гади балчык салынып, кырыйлары гына бетонланачак.* К.Фәсәхов, А.Сәлахетдинов

**Бетонлап алу** Тоташтан, бар яктан бетонлау

**Бетонлап бару** Рәттән бетонлау

**Бетонлап бетерү** Бетонлау эшен тулысынча тәмамлау. *Ничек кенә булса да, язга кадәр су алгычны эшләп, төбен бетонлап бетерергә кирәк, ә язга ерак түгел.* А.Алиш

**Бетонлап кую** Бетонлаган хәлгә китерү. *Теге сиксән метрдан соң, борауланган өлешне бетонлап куясыз, тозлы су үтеп кермәсен.* К.Кәримов

**Бетонлап тору** Һәрвакыт бетонлау

**Бетонлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр бетонлау

**БЕТОНЧЫ** *и.* Бетон коючы. *Завод төзелешендә әтиебез бетончы булып эшли.* К.Миңлебаев. *Аларны бетончы кызлар тиз генә бушаттылар.* Р.Кәрами. *Биредә ул Красноярск шәһәре тирәсендәге хәрби төзелешләрдә ташчы, җир казучы, бетончы һөнәрләрен үзләштерә.* Мәдәни җомга

**БЕТТЕ́-КИТТЕ** *кер. сүз* Җөмлә ахырында килеп, нинди дә булса эшне җиңел генә башкарырга мөмкин икәнлекне белдерә; шуның белән эш тә бетте; бу турыда башка сөйләшеп тә торасы юк, вәссәлам, мәгънәсендә. – *Хәл иттек инде, бетте-китте, – диде Карагаев, җитди итеп.* Т.Әйди. *Монда инде зур акыл кирәк түгел, тирләгән икәнсең, салкын су белән юынырга да бетте-китте, вәссәлам!* Ф. Хөсни. *Аннан янә пыж белән томалап куясың да, бетте-китте, вәссәлам.* Г.Гобәй

**БЕ́Т УТЫ (ҮЛӘНЕ)** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, бөтерелмә сабаклы, куш чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; чүп үләне; тычкан борчагы; *русчасы:* **мышиный горошек**

**БЕТҮ** I *ф.* 1) Тәмам булу, тукталу, тулысынча төгәлләнү, ахырына җитү, азакка кадәр килеп җитү. *Ул [эш] бетмәскә тиеш, эш бетте исә, тормыш бетә, дигән сүз.* Ш.Камал. *Ә беркөнне сугыш бетте. Сугыш бетеп, бер ел торгач, абый армиядән кайтты.* М.Мәһдиев. *Чуваш-мари бу эшкә кушылмый, чөнки, кушылсалар, гел аларны кыйнау белән бетә.* Ф.Бәйрәмова

2) Тотылу, сарыф ителү, тәмам булу. *Бер ел мин кара белән яздым – карам бетте.* Г.Исхакый. *Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш.* Г.Тукай. *Өйдә су беткән, чиләкләрне ал да чәйгә чишмә суы алып мен.* Т.Гыйззәт

3) Юкка чыгу, юк булу. *Тауларның бетте эреп салкын кары.* Дәрдемәнд. *Йөрәкләрнең эчтән генә сызланулары бетмәде.* М.Гафури. *Алгы яктагы яшел урманнарда да, хәтфә болыннарда да тормыш бетә.* М.Гафури

4) Нәрсәнең дә булса пространство яки вакыт ягыннан чиге булу, шул чиккә килеп җитү. *Бәрәңге бакчалары бетеп, бераз баруга, текә яр башлана.* Г.Гобәй. *Бураннар бетеп, аяз көннәр, ачык һавалар, кышкы чилләдәге кебек чатнама суыклар башланды.* Г.Ибраһимов. *Агач яфрак ярып беткәч, бетә яз, инде җәй башлый.* М.Гафури. *Көн бетеп, кояш иңәр вакытлар.* Һ.Такташ

5) Бик зур бәла-казага дучар булу. *Берәү дә сине юксынып килеп йөрми икән – беттең.* А.Гыйләҗев. *Ләкин андый эштә ашыктың – беттең.* И.Гази. *Аһ, беттем!* Г.Камал

6) *диал.* Үлү, һәлак булу. *Менгәне берсе бетә... корбан була.* Ш.Бабич. *Үзегез изге юлда бетсәгез дә, Изге теләгегез бетмәде.* М.Гафури. *Җир сөрдем – алга китмәдем, таш казыдым – тамагым туймады... хәзер сизәм: бетәм мин.* И.Гази. *Ул бар булса, Гәрәй дә бетми, иске тормышны җимереп ыргытачак революция дулкыннары эчендә аның да бер тамчы каны булачак.* Г.Ибраһимов

7) Картаеп, ябыгып хәлсезләнү, арыклану, авыр кайгыдан бетеренү. *Берничә елдан әти картая һәм көче бетә.* Ә.Фәйзи. *Әле бит мин аңа «ясин» чыгарга барган идем, бик беткән, бик беткән, бичаракаем.* Г.Ибраһимов. *Тик беткәнсең, сулгансың шул син, бичара.* М.Җәлил

8) Искерү, тузу, таушалып, яраксызга чыгу. *[Кашшаф:] Бигрәк беткән икән синең абзар.* Р.Төхфәтуллин

**2**. **бетте** *ы. мәгъ.* 1) Бүтән кабатламаска сүз бирү. *Бетте, бетте, инде мин еламыйм.* А.Әхмәт. *Бетте, Габтелмән абзый, алай дисәң, бетте, бер сүзем дә юк.* Р.Ишморат. «*Бетте, бетте*» *булмас моннан ары.* Н.Исәнбәт. *Кил, уйнамыйм, бетте... Кил инде!* Һ.Такташ

2) Вәссәлам, берни эшләр хәл юк, мәгънәсендә. *Күңелеңә шундый бозык уй, бозык исәп кенә керсен, аннары инде бетте, кешелегеңне җуйганыңны бел дә тор.* М.Хәсәнов

**3.** *ярд. ф. функ.* Төп фигыль белдергән эш яки хәрәкәтнең кабатланып яки көчәя барып, билгеле бер дәрәҗәгә яки ахырына җитү төсмерен белдерә. *Шулай аның алты хатыны төрлесе төрлечә таралып беттеләр.* Г.Ибраһимов. *Адым саен светофор, ялыгып бетәсең.* М.Мәһдиев. *Өченче көнне дә әнисе ауга киткән. Песи баласы аны көтә-көтә арып беткән.* А.Алиш. *Үтә күренмәле юка чынаяк китегенең нәфис бизәкләре өстенә оста куллар, бик килештереп, алтын белән нәрсәдер язган булган, ләкин, за-

*ман үтү белән, сүзләре ашалып беткән иде.* Г.Гобәй

◊ **Бетәсе булмады** Очы-кырые булмады, ялыктырды, туйдырды, мәгънәсендә. *Синең иртәң бетәсе булмады.* М.Фәйзи. **Беткән баш беткән** Тәвәккәлләп, берәр хәтәр эшкә тотынганда әйтелә. *Әйдә, Мингулов, безгә хәзер барыбер, беткән баш беткән, Себергәме, каторгагамы, киткән баш киткән!* Т.Гыйззәт. **Беткән кеше** Малы, хәле, барыр юлы, кылыр чарасы калмаган, бөлгән кешегә карата әйтелә. **Беттегә санау** Эшне беткәнгә исәпләү, тәмам булганга санау. *Шуның белән үзенең эзләү эшләрен беттегә санап, туптуры өенә кайтып китте.* Ф.Хөсни

**Бетә бару** Акрынлап, аз-азлап бетү, торган саен кими барып бетү. *Юк шул, алдавыч өметләр бетә бара шикелле.* Х.Камалов. *Инде бабайлар гына түгел, әтиләребез дә, кайтмаска китеп, җәйге сулар кебек саега, бетә баралар.* Х.Сарьян

**Бетә башлау** Бетү билгеләре күренү. *Ләкин соңга таба, рус дәүләте зурайгач һәм көчәйгәч, татар морзаларының хәрби көч буларак кирәге бетә башлый.* Ә.Еники

**Бетә төшү** Беркадәр, бераз бетү. *Күңелләрдәге курку да бетә төште.* М.Гафури

**Бетә язу** Бетүгә якынлашу. *Үзе кырылып бетә язып та көрәшкән, горур рухын саклаган халык.* Ш.Галиев

**Бетеп бару** Аз-азлап бетү, акрынлап бетү. *Пар күтәрү эше бетеп бара иде инде.* Ш.Камал. *Рамазан ае бетеп бара.* Ш.Камал

**Бетеп җиту** Төгәлләнеп бетү, ахыргача бетү. *Таралып китүләре аркасында, кешеләрнең күңелләрендә торган ачы тәэсир әле бетеп җитмәгән.* Ш.Камал. *Альбин Васильевич өстәл артына барып утырды, йөзендә карарсызлык бетеп җитмәгән иде.* Х.Камалов

**Бетеп килү** Бетүгә якынлашу, аз гына калу. *Соңгы көннәрдә аларның акчалары бетеп килә иде.* А.Шамов. *Тәмәкеләре дә бетеп килә, хәер, ач корсакка тартып та булмый, хәзер үк укшыта башлый.* Ә.Еники. *Лобогрейка актык үзәнне кыркып чыкканда, чүмәлә салучыларның эшләре дә бетеп килә иде инде.* Ш.Камал

**Бетеп китү** Кинәт бетү. *Авылда алучы күп, бу арада чәй генә бетеп китте.* Г.Камал. *Әй, менә такта чәй генә бетеп китте.* Р.Әхмәт. *Мәрьямбикәләрнең, Сираҗиларның шаукымы кагылудан гына башланган ул чир шулай ук тиз бетеп китте.* Г.Ибраһимов

**Бетеп кую** Көтмәгәндә, кинәт бетү. --- *кул төзәлгәнче, сугышның бетеп кую ихтималы да бар иде, киләчәкне кайгыртырга кирәк иде.* М.Мәһдиев

**Бетеп тору** 1) Һәрвакыт, даими рәвештә бетү. *Кергән бер акча бетеп тора.* М.Гафури

2) Берникадәр, бераз бетү. *Салкын тигәнмедер, нидәндер, бераз тыннарым гына бетеп тора.* Г.Камал. *Авылда эш бервакытта да бетеп тормый – иртә яздан кара көзгәчә.* Ә.Еники

**БЕТҮ** II *ф. диал.* Үсү. *Тәбәнәк агач ботакка беткән була.* Мәкаль

**БЕТЧӘ** *и.* Тәнгә чыккан эренле кабырчык; сыткы. *Керү имтиханнары барган көннәрдә нинди генә алтын таулар вәгъдә итмиләр, институтка эшләячәк изгелекләре турында телләренә бетчә чыкканчы сөйлиләр.* Т.Галиуллин. *Рина, күзге алдына утырып, тагын бер мәртәбә иягендәге бетчәләрне күздән кичерде.* Т.Әйди. *[Мазь] Төрле эренле бетчәләрне яхшы дәвалый.* Мәдәни җомга

**БЕТЧӘЛӘ́Ү** *ф.* Күп булып, бетчәләр чыгу, бетчә басу. *Берничә көн йөткергәләп, укуын калдырса калдырды, әмма бетчәләмәде ләбаса.* Т.Әйди

**Бетчәләп бетү** Тоташ бетчәләү. *Күземне күреп, котым чыкты. Бөтенләй бетчәләп беткән.* Г.Лотфи. *Үлән ашыйбыз, көн дә – кузгалак, Җаннар әчеде, беттек бетчәләп.* Т.Кәримов

**БЕТЧӘЛЕ** *с.* Бетчәләре булган, бетчә баскан, бетчәләгән. *[Кызның] Бетчәле йөзе каракучкылланып кызарды.* А.Расих

**БЕФСТРО́ГАНОВ** *и. фр. кулин.* Сыер итен вак кына турап әзерләнгән, табынга соус һәм гарнир белән бирелә торган ашамлык. *Бефстроганов өчен, итне чапкы яки уклау белән суккалап йомшартырга һәм, аннан соң, токмач кебек озынча итеп турарга кирәк.* Йорт эшләре

**БИ** I *и. тар.* Морза, түрә, хуҗа. *Сарай әһелләре аңа ят: биләр, карачылар Сәет-сәүдәгәр белән аралашырга бик атлыгып тормый. Эре халык!* Ф.Латыйфи. *Хәзер Азымбай, чыннан да, телгән илгә би булып сайлана алырлык хөрмәтле бер аксакал иде.* Г.Ибраһимов. *Елкынбинең җиде улы – җидесе дә би булган.* Н.Исәнбәт. *Алар барысы да затлы би, илтабар, тархан угланнары иде.* Р.Зәйдулла

**БИ** II *и.* Гарәп графикасына нигезләнгән татар әлифбасында икенче хәреф һәм язуда астына бер нокта куелган ب (bā) билгесе белән күрсәтелгән тамга. *«Әлиф»тән «би»гә кадәр, йөгердем өйгә кадәр.* Такмаза. *Балалар «әсен ә, бигә сәкен би...» дип, ике юллык әбҗәтне һәм иман кәлимәләрен шактый йөгерек һәм шома иҗекли башладылар.* Ә.Фәйзи

◊ **Би астында бер нокта** Бу сүздә икенче – яшерен мәгънә бар, дигәнне аңлата

**БИ-** III *фар.* **1.** 1) Фарсы теленнән кергән сүзләрдә *-сыз/-сез* кушымчалары мәгънәсендәге, ягъни юклыкны белдерә торган алкушымча. *Әмма ләкин хаҗи әфәнде сиңа аларны биреп тормас инде, Нәсимә туташ, бигайбә.* Ш.Камал. *Монда эшче тамак өчен хезмәт итә төнката, Бай тегендә – «шаһ бигамь» йомшак урында ята.* Г.Камал

**БИ-** IV *лат.* Ике кисәктән торганны, ике билгегә ия булуны күрсәткән алкушымча. *Биметалл, биплан, билингвизм, биквадрат*

**БИАГА(Й)** *и. диал.* Каенага. *Гани агай, биагай, Кәҗә туның ки, агай. Тунын киеп туңган, Идәннәрен юган, Трубкасын капкан, Мичено дә яккан.* Р.Ишморат

**БИАНА(Й)** *и. диал.* Каенана. *Нәсимә бианасын кочаклап алды, җилкәсеннән сөйде, Фәрит аңа өнәмичә карап торды.* Ф.Садриев. *Нәсимә бианасына кызыл бәрхет камзул кидерде, кулына бик матур кулмәклек товар тоттырды.* Ф.Садриев. *Бала – туганнан бирле бианасы кулында, дигәч, ис-акыллары китте, малайкаем.* Ф.Сафин

**БИАТА(Й)** *и. диал.* Каената. *Мәнә биатаң да гомере буе өйнең нәрсә икәнен белмәде.* Ф.Садриев. *Шәмсия элек тә Фәтхулланың инде олыгаеп барган әти-әнисен, ягъни биатасы белән бианасын ташлап бетерми иде.* Ф.Сафин. *Хәтта килен булып төшкәч тә, җиде ел килен камзулы кидереп, биатай, бианай кебек иң якыннарыбыздан да тел яшерергә киңәш бирдегез!* Т.Гыйззәт

**БИАТЛОН** *и. лат.-гр.* Кышкы спорт төре – чаңгыда шуу һәм шунда ук винтовкадан ату ярышы. *Бөгелмәдә туып үсеп, спортка беренче адымнарын Әлмәттә ясаган Ольга Данилова – чаңгы һәм әтисе Кукмара районыннан булган Альбина Әхәтова – биатлон белән бәйле.* А.Гафиятов

**БИБЕК** *и. зоол.* Шөлдисыманнар отрядыннан, тавышы елаугa охшаган кечкенә саз кошы; тәкәрлек; *русчасы:* **чибис.** *Кайчак, ачы елый-елый, өстебездән бибекләр әйләнеп уза.* А.Расих

**БИБЕШ** *и.* Каз канаты астындагы кечкенә каурыйлар (балалар бу каурыйларны очлы агачка икешәрләп кадап, ук ясыйлар). *Миндә бибеш булса, бөтен иптәшләргә ук була.* Г.Лотфи

**БИБИ** *и диал.* Каз яки үрдәк бәпкәсе. *Бакылдашып, үрдәк бибиләре су буеннан тезелешеп кайтып килә.* Р.Төфхәтуллин

**БИ-БИИП** *иярт.* Машина сигналы тавышын белдерә

**БИБЛИО́ГРАФ** *и. рус* Библиография белгече. *Идрис Хөрмәтуллин шушы ук китапханәдә библиограф булып эшли иде.* Х.Сарьян. *Галимнең уртанчы балалары өенә мине күптәнге дусларым – атаклы шагыйрә Фәния Чанышева-Рамазанова белән Зәки Вәлиди исемендәге Республика милли китапханәсенең абруйлы библиографы Рәйсә Тимергалина алып бардылар.* Сөембикә

**БИБЛИОГРА́ФИК** *с.* Библиографиягә караган, библиография белән бәйләнешле. --- *1967 елда ук дөнья күргән һәм, идеология штамплары басымы астында язылуына карамастан, бик сирәк библиографик басмага әйләнгән иде.* Р.Миргазизов

**БИБЛИОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Китапларның эчтәлеге һәм аерым билгеләре буенча системага салып, санап чыгарылган фәнни язма. *Китап басу эше Казанда оешканнан алып, Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр чыккан китапларның тулы библиографиясен бирү бурычын куймый автор.* З.Рәмиев

2) Билгеле бер авторның әсәрләре исемлеге һәм аның иҗаты турындагы тәнкыйть әсәрләренең библиографик күрсәтмәләре. *[Әбрар ага Кәримуллин] --- язучы һәм шагыйрьләрдән М.Җәлил, Н.Исәнбәт, Х.Туфан һәм башкаларның персоналияләрен төзи. Бу библиография чит ил белгечләре игътибарын да җәлеп итте.* Т.Нәҗмиев

3) Аерым мәсьәләләр, темалар буенча төзелгән әдәбият исемлеге. *Биредә төрле гыйльми цитаталар, өземтәләр китерелмәүгә --- укучыларым, шаять, гаҗәпләнмәсләр. Аерым санап күрсәтерлек библиография дә юк.* Н.Исәнбәт

4) Басылып чыккан әсәрләрне өйрәнә торган фән. *Җыентык тарих, әдәбият, китап белеме, китапханә эше һәм библиография өлкәсендә эшләүче киң даирә белгечләргә, шулай ук басма сүзебезнең үткәне белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.* М.Госманов

5) Журналның яки газетаның яңа чыккан китапларга рецензия язып бара торган бүлеге

**БИБЛИОГРА́ФИЯЛӘҮ** *ф.* Библиография төзү. *Р.Таһировның «Татар телендә басылган матур әдәбият, аның тарихы һәм тәнкыйть библиографиясе» дигән белешмәсе татар әдәбиятын библиографияләүдә беренче тәҗрибә булып тора.* Ә.Кәримуллин

**БИБЛИОМА́НИЯ** *и. гр.* Китаплар җыю белән мавыгу

**БИБЛИОТЕ́КА** *и гр.* Укучылар файдалансын өчен, китап, журнал һ.б.ш.ны үзендә туплый һәм саклый торган урын; китапханә. *1930 елда библиотекада шул китапны эзләгәндә, «Туфан шигырьләре» дигән җыентыкка очрадым.* Х.Туфан

**БИБЛИОФИЛ** *и. гр.* Сирәк очрый торган кыйммәтле китаплар җыюга һәвәс кеше. *Ул кадәр китапны, бик теләсәң дә, укып бетереп булмас иде. Ә Гаташ – эрудит, библиофил. Кайсы нәшриятта нинди яңа китап чыкканын, кайсы кибеткә кайтканын да аның аша белә идек.* Р.Миңнуллин

**БИ́БЛИЯ** *и. гр.* Христианнарның Инҗил белән Тәүраттан гыйбарәт изге китабы. --- *үзе тәрҗемә итеп һәм аңлатмалар язып, ул 1517–1519 елларда Библия бастыра.* М.Вәлиев

**БИВАК** *и. фр. иск.* Гаскәрнең, куну яисә ял итү өчен, ачык һавада тукталыш урыны. *Кем юына, кайсы учакта Аш пешерә, чолгау киптерә. Привалларда, төнге бивакта Шулай, дуслар, тормыш ителә.* Ә.Маликов

**БИВАФА** *и. фар.* Ышанычсыз, сүзендә тормаучан, ялганчы, алдакчы кеше. *Актыгы: мин бар вөҗүдемне сиңа иттем фида; Белмәдең лә белмәдең кадрем! гөнаһ! и бивафа!* Г.Тукай

**БИВУАК** *и. фр. иск. к.* **бивак**

**БИГАЙБӘ** *кер. сүз гар.-фар.* Гаепләштән булмасын, гаепләмә, гафу ит. *– Сезгә рәхмәт егетләр, бигайбә! – дип, алыш-бирешкә нокта куйды.* К.Миңлебаев. *Бигайбә, менә саный башласаң, шулай бит ул, һич тә баштагы исәп барып чыкмый.* Ф.Сафин. *– Тик аерылган хатын белән яшәүче – мин түгел, бигайбә, – дип, төшендереп тә бирдем.* К.Миңлебаев

**БИГА́ЯТЬ** *рәв. гар.-фар. иск.* Чамадан тыш, гадәттән тыш; чиксез. *Атай – кылычны төргән бигаять озын киндерне чишә-чишә тәмам итеп, кылычны кынысыннан чыгарып, бик гайрәт белән чаж итеп селкеп җибәрде.* Г.Газиз

**БИГРӘК** *рәв.* **1.** 1) Артык, артык дәрәҗәдә, чамадан тыш, тагын да. *Бигрәк тә үтә кызыл булып киттең, кордаш.* Р.Ишморат. *Җилбәзәкләп теккән зәңгәр бәрхет Зифа буйга бигрәк килешкән.* Ш.Бабич

2) Иң мөһиме, барыннан да элек, иң элек; ул гына да түгел. *Барыннан да бигрәк Урта Иделнең XIII–XIV гасырдагы этносәяси тарихы өчен, алар бердәнбер җирле язма чыганаклар хезмәтен үтиләр.* М.Әхмәтҗанов. *Шушындый кызу эш өстендә, бигрәк тә фронтлардан берсеннән-берсе дәһшәтле хәбәрләр килеп торганда.* Г.Бәширов. *Бигрәк тә яшь кадрларыбызның үсүе күзгә ташлана.* Р.Ишморат

**2.** *кис. мәгъ.* Сыйфат алдында килеп, артыклык дәрәҗәсен белдерә; иң, бик. *Нәкъ-нәкъ әтисе тасвир иткәнчә... бигрәк матур, бигрәк ягымлы.* Г.Гобәй. *Җаббар агай, син бигрәк кыска тотасың.* Г.Ибраһимов

**3.** *кер. сүз функ.* Нәрсә белән дә булса килешмәгәндә әйтелә. *Килешмәгәнне инде, бигрәк.* Ф.Әмирхан

**БИГУДИ** *и. фр.* Чәчне, бөдрәләтү өчен, тыгыз итеп урап куя торган, көпшә рәвешендәге әйбер. *Иңенә озын йонтәс халат кына элеп, чәчләрен бигуди кәтүкләренә чорный-чорный, йокы бүлмәсенә атлады.* Х.Камалов. *Бигуди болай ясала: 3–2,5 сантиметр калынлыгындагы мамык кисәген озынча итеп борып, өстенә марля чорнап тегәләр, ә марляның очларын, бәйләр өчен, 15 әр сантиметр текми калдыралар. Шундый 20 ләп бигуди ясарга кирәк.* Йорт эшләре. *Чәче озак вакытка бөдрәләтелгән хатын-кыз, чәчен эре бигудиләргә чорнап, үзенә теләсә кайсы прическаны ясый ала.* Сөембикә

**БИ́ГҮК** *рәв. сөйл.* Юклыкны белдергән җөмләләрдә: алай ук, алай ук түгел, әллә ни түгел. *Интернет, радио һәм телевидениенең «кайнар» яңалыклары итеп күрсәтелә торган вакыйгалар һәм сәяси күренешләр белән беррәттән, бигүк күзгә ташланмый торган, әмма гаять мөһим үзгәрешләр дә күзәтелә.* Татарстан

**БИДӘР** *и. иск.* 1) *к.* **бизәк**. *Аллыгөлле яңа күлмәкләрен киеп, бидәр-бидәр эре чәчәкле чуар алъяпкычларын ябып, капка төпләренә курчак шикелле кечкенә кызлар килеп чыга.* Г.Бәширов. *Ал бидәрле, гөл бидәрле кайсы байның чанасы? Бөгелә-сыгыла су китерә кайсы егет җанашы?* М.Фәйзи

2) Рельефлы бизәк, агачка уеп ясалган бизәк

**БИДГАТЬ** *и. гар.* **1.** 1) Шәригать законнарын бозучы, динне хөрмәт итмәүче, тәртипсез кеше. *Менә шушы бидгатьләр, мәсәлән, харап иттеләр дөньяны.* Ф.Әмирхан

2) Элеккесенә каршы килә торган яңа бер эш. *Кулымнан килмәслек булса да: «Һәрбер төрле бидгатьләрне, яңа укытуларны бетерермен», – дидем.* Г.Камал. *Ягъни, бу – безнең дине исламга батмый, дине ислам бу эшне «бидгать» дип таный.* Ә.Фәйзи. *Игътибар белән укысаң, аларның, киресенчә, гел дөньяви рух белән сугарылган, хәтта кешеләрне гыйш-гашрәткә, уен-көлкегә чакыручы «бидгатьләрдән» торган булуын күрәсең.* М.Госманов

**2.** *с. мәгъ.* Тыелган, ярамаган. *Шулкадәр зур хәрам, бидгать эшне мөселман бәндәнең күңеле ничек йөкләсен?* М.Гафури

**3.** *хәб. функ.* Тиеш түгел, ярамый. *Ул эшегез – бидгать, бусы – дөрес түгел, тегесе – ярамый, дип, бичара бабайәбиләрнең күз яшьләрен түктереп, бәддогаларын яудырырга тотыналар.* Гөлстан газетасы

**БИДЕ́** *и. фр.* Тәһарәт алу, тәһарәтләнү җайланмасы

**БИДОН** *и. фр.* 1) Сыекчаларны йөртер яки саклар өчен кулланыла торган, ике яктан тоткычлы һәм капкачлы металл яисә пластмасса савыт; фляга. *Гадәттә, сөт бидоннарына пломба салына.* Р.Кәрами. *Әрдәнәгә бидон белән су ташырга көйләнгән ике тәгәрмәчле арба сөялгән.* Н.Хәсәнов. *Буш бидоннар белән ерактан ук дөбер-шатыр килеп, заводка сөт илтергә киткән атлар да кайтып җиттеләр.* Р.Төхфәтуллин

2) Шундый ук формадагы, көнкүрештә кулланыла торган кечерәк савыт. *Рәмиләнең ак бидон төбе әле дә күренеп тора, ә Людмила исә бидонына бер генә бөртек тә җиләк төшермәде: ул, очраган берен, вагына тикле, авызына озата бара иде, талымсыз.* Э.Касыймов

**БИЕГӘЮ** *ф.* Биеклеккә, өскә, югарыга таба күтәрелү, биеклеге арту, үсү. *Төсе уңа төшкән күк көймәсе тагын да биегәйде һәм ачыкланды.* Г.Бәширов

**Биегәеп бару** Торган саен ныграк биегәю

**Биегәеп бетү** Иң югары ноктасына кадәр җитеп биегәю

**Биегәеп калу** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң биегәю. *Елга яры бер – сөзәкләнеп, бер биегәеп калды.* Н.Хәсәнов

**Биегәеп килү** Аз-азлап, акрынлап биегәю. *Рәфис, көннән-көн үсеп, биегәеп килүче таш йортларны тамаша кылып, казылып ташланганнан соң өелеп калган балчык өемнәре өстеннән атлый-атлый, төзүчеләр янына китте.* А.Вергазов

**Биегәеп китү** Кинәт биегәю. *Әле генә бик шыксыз булып тоелган дөнья – Галимә өчен бик күңелле, вак-вак йолдызлар белән чуарланган галәм күге яктырып, биегәеп киткәндәй тоелды.* М.Шаһимәрдәнов. *Таулар да куанычларыннан биегәеп китте.* А.Гыйләҗев

**Биегәеп кую** Бераз биегәю. *Калдык кар астыннан килеп чыккан барча агач-куак, койма-читән, күкрәк тутырып сулыш алган сыман, бер карышка үсеп, биегәеп куя.* В.Имамов

**Биегәеп тору** 1) Һаман арту, вакыт үткән саен биеклеген арттыру

2) Әле, хәзерге вакытта биек булып күренү. *Аннары, башын артка ташлап, янында биегәеп торган егетнең йөзенә бераз сокланып карап торды да: – Гел әниең төсле икәнсең, – дип өстәде.* М.Маликова. --- *биек каеннар һәм тирәкләр арасында, кызыл кирпечтән салынган борынгы чиркәү кинәеп, биегәеп тора.* М.Маликова

**Биегәя бару** *к.* **биегәеп бару.** *Тегендә биек кибәннәр югала торса, монда алардан әллә ничә өлеш зур салам эскертләре, баскыч-баскыч булып, күккә таба үрмәлиләр, озынаялар, киңәяләр, биегәя баралар.* Г.Ибраһимов. *Ә менә яр буена, сай җиргә якынлашкан саен, бу дулкын биегәя бара...* Кызыклар дөньясында

**Биегәя башлау** Биегәергә тотыну. *Тәбәнәк кенә үрләр дә биегәя башлады, юл кантарлары да эреләнеп китте.* М.Юныс

**Биегәя төшү** Тагы да бераз биегәю. *Баштарак түбән генә бөркеп яткан учак әкренләп кыюлана, хәл җыя бара, аның ялкыннары да тора-тора зурая, озыная, биегәя төшә.* М.Вәли-Барҗылы

**БИЕК** *с.* Нәрсә дә булса икенче бер әйбергә карата югарырак, өстәрәк булган, озынлыгы гадәттәге чамадан, уртачадан узган. *Биек тауга менгән чакта Таянам тезләремә.* Уен җыры. *Үз кулым белән ясаган биек өстәлгә җәеп салам кулъязманы, карандаш алып, үз*

*вариантларымны теркәргә керешәм.* К.Миңлебаев. *Авылның агач күпере кырыенда, биек манарасында көмеш ай утырган, иске, әмма әле нык сакланган мәчет бар иде.* Р.Сибат

**БИЕККӘ** *рәв.* Югарыга, өскә. *Гел биеккә менмәсәк тә, Түбәнлектән кача белдек.* Ф.Яруллин

◊ **Биеккә очса да, сай йөзә** Дәрәҗә, карьера ясый алса да, акыл, мәгънә ягы сай булу

**БИЕКЛЕК** *и.* **1**. 1) Нәрсәнең дә булса нигезеннән алып югарыга кадәр булган арасы, озынлыгы. *Менә чик баганасы – сажень ярымнар биеклегендә цемент багана.* Г.Гобәй. *Эйфель биеклеге турында тулырак картина алыр өчен, дөньяның башка берничә «биек» дип саналган нокталарын күрсәтергә, чамаларын әйтергә кирәк.* Г.Гали. *Нечкәрәк бер бүрәнәне, бергәләшеп күтәреп, җирдән ярты аршин биеклектә бауга эләләр.* Г.Камал

2) Җир өстендәге нинди дә булса ноктаның океан өсте тигезлегеннән вертикаль сызык буенча югарылыгы. *Ул диңгез өстеннән 290 метр биеклектә тора.* Г.Әпсәләмов

3) Җирдән шактый югарыда булган аралык, киңлек. *Самолёт, шәһәр өстендә бер-ике тапкыр әйләнде дә, биеклеккә омтылды.* К.Фәсәхов, А.Сәлахетдинов. *Юлның ике ягындагы өянкеләр, зөбәрҗәттәй яшькелт нурга коенып, төннең гаҗәеп яктылыгына, күк йөзенең биеклегенә һәм сафлыгына хәйран калып, тынып утыралар.* Г.Бәширов. *Кыр казлары артыннан Биеклеккә тартылам.* И.Юзеев

4) Кашлак урын, калкулык, күтәренке, калку булып торган урын, кечкенә тау. *Дисталәрчә хуторларны азат иткәннән соң, элмә, өрәңге һәм башка шундый яфраклы агачлар белән капланган шушы биеклектә туктадылар.* А.Шамов. *Шунда зур биеклек өчен Көрәшкәндә елга буенда, Җаным кебек якын күргән дустым Һәлак булды сугыш кырында.* З.Мансур. *Ә Сабировны исә шул биеклек өстендәге ялгыз каен төбенә күмеп куйдылар.* А.Әхмәт

5) *астр.* Кояшның горизонттан күтәрелү югарылыгы. *Кояш, офыктан аерылып, нарат биеклеге күтәрелгән вакытта, Кама өсте чуп-чуар иде инде.* Татарстан яшьләре

6) *мат.* Фигураның түбәсеннән нигезенә төшерелгән перпендикуляр һәм шул перпендикулярның озынлыгы. *Өчпочмакның берәр түбәсеннән ул түбәгә каршы яткан якка перпендикуляр төшерсәң, өчпочмакның биеклеге килеп чыга.* Геометрия. *Бер нигезнең теләсә кайсы ноктасыннан икенче нигез яссылыгына төшерелгән* $OQ_1$ *перпендикуляры призманың биеклеге дип атала.* Геометрия

7) *күч.* Дан, шөһрәт; нәрсәнең дә булса югары дәрәҗәсе, нинди дә булса үсешкә җитү югарылыгы, нинди дә булса эшчәнлекнең, осталыкның югары ноктасы. *Ил башын җиңүле яулар гына караш җитмәслек биеклеккә күтәрә.* Р.Зәйдулла. *Туган илем белән бергә мине Данлы биеклеккә мендерә.* Ә.Ерикәй. *Вокаль сәнгатьтә үз урыныңны эзләп тап, камиллек биеклегенә күтәрел – шул чагында сине таныйлар.* В.Шәрипов

**2**. **биеклеге(ндәге)** *бәйл. функ.* Бер әйбернең вертикаль озынлыгын икенче бер әйбер белән чагыштырганда кулланыла; кадәр(ле), озынлыгында(гы). *Алдыбызда дүрт-биш метрлар чамасы биеклектәге кызыллы-каралы балчык өеме калкып чыкты.* Р.Ишморат

**БИЕКЛЕ́К ҮЛЧӘГЕЧ** *и. тех.* Биеклекне үлчәү әсбабы

**БИЕКТӘ** *рәв.* Югарыда, югары урында. *Дөньяның вөҗданы булып, Кал биектә, бул тыныч.* Ә.Баянов

**БИЕКТӘН** *рәв.* Югары урыннан, өстән, югарыдан. *Менә мин тау өстеннән, биектән торып, аста җәйрәп яткан гаскәремә карыйм.* М.Галиев

**БИЕМ** *и. диал. к.* **каенана.** *Ике биемгә – бер килен, Көйли алсын кем көен?* Мәкаль

**БИЕННА́ЛИ** *и. ит. к.* **бьеннале**

**БИЕНҮ** *ф. сөйл.* Аяклар белән биюгә охшаган хәрәкәтләр ясап йөрү, үзалдына сикергәләп тору

**Биенеп алу** Тиз генә биегән кебек хәрәкәтләр ясау

**Биенеп кую** Тик торган җиреннән, кинәт кенә, биегән кебек хәрәкәтләр ясау. *Җамали аяк баскан җирендә, үзалдына селкенеп, биенеп куйды.* Г.Ибраһимов

**Биенеп тору** Бертуктаусыз биегән кебек хәрәкәтләр ясау

**БИЕТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **бию.** – *Бүген клубта кызларны әйбәт биеттең,* – *диде.* Н.Хәсәнов. *Тәнәфесләрдә аларны көләч йөзле Нурҗиһан апа «Барыня» көенә такмаклап биетә.* М.Маликова. *Аны биетә алмый калдылар.* Г.Гобәй

2) Иңбашны, аяк-кулларны төрлечә җитез хәрәкәтләндереп, биегән сыман сикертү, уйнату. *Озын мыеклы, киң иякле берсе, иңбашларын биетеп чабып килгән уңайга, атын кырт туктатты.* И.Гази

3) *күч.* Кем дә булса, икенче башка берәүне үз ихтыярына буйсындырып, аны бары үзенчә генә эшләргә мәҗбүр итү. *Урак өстендә, анысы, күз күрер әле, кем кемне биетер бит!* Г.Бәширов. *Мин сезнең киявегез Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсезме?* М.Фәйзи

4) *күч.* Эшне җитез, җиңел һәм булдыклы итеп башкару. *Без барыбыз – бетон күкрәкләрдә Эш биетеп үскән егетләр.* М.Җәлил

5) *күч.* Кемне дә булса берәр ярамаган эше өчен бик каты шелтәләү, сүгү, ачулану. *Бу мактанчык малайның үзен дә бик һәйбәтләп кенә биет әле.* Д.Аппакова

6) *күч. гади с.* Астан гына сатып җибәрү. *Теге брушкаларны ике йөз тәңкәгә биеттем.* Г.Камал

◊ **Биетеп карау** 1) Куллану мөмкинлекләрен сынау, кулланылышын күзәтү. *Менә мин ата-бабаларыбыздан мирас булып килгән тел хәзинәсеннән фәкать бер сүзне мисалга алып, учымда биетеп карадым.* М.Галиев; 2) Үзенең ихтыярына биергә мәҗбүр итү. *И биетеп тә карый тормыш бабай!* Р.Әхмәтҗанов

**Биетә башлау.** Биетергә тотыну. *Хуҗа конторщикларны үзе теләгәнчә биетә башлады.* Ш.Мөхәммәдев

**Биетә бирү** Биетүен дәвам итү

**Биетә төшү** Тагын да бераз биетү

**Биетеп алу** Тиз, кыска гына вакыт эчендә бераз биетү. *Башлык, ни-*

*дер уйлана-уйлана, үзенең ялтыр эш өстәлендә бармакларын биетеп алды.* Р.Низами

**Биетеп бетерү** Барысын да биетү; ахырга кадәр биетү

**Биетеп җибәрү** Кинәт биетә башлау

**Биетеп йөрү** Һәммәсен һәм һәрвакыт биетү. --- *кыңгыраулы саратский түгел түгелен, шулай да шәп – ярым аккордеон. Шуның белән олы гына кызларны җырлатып, биетеп йөргән булам.* Ф.Яруллин

**Биетеп калу** 1) Биетергә өлгерү

2) *куч. юклык форм.* Чикләнү. *Бу юлы Шәйдулла абыйны «утлы табада» гына биетеп калмадылар, «каты шелтә» сылап чыгардылар.* Р.Батулла

**Биетеп кую** Ара-тирә биетү. *Бер, тарткалап читен, Уйнаткалап-нитеп, Дерелдәтеп биетеп куйгалый.* М.Җәлил. *Газинур кара кашын биетеп куйды: – Туйга бик әзерләнер идем дә, Гарәфи абзый, каз өмәләре вакыты җитмәгән шул.* Г.Әпсәләмов

**Биетеп тору** 1) Әле, хәзер биетү. *Чәбәк-чәбәк эткәсе, Биетеп тора әнкәсе.* К.Закирова

2) Һәрвакыт, гел биетү. *Мин авылның идарә капка төбендәге, алгы аякларын биетеп торган райком айгырын күз алдына китерәм.* М.Галиев. --- *ике яшенә җиткән этләрен акыртып суеп торалар, тиресен иләп, бүрек тегеп, иллешәр сумга «биетеп» торалар.* М.Мәһдиев

**Биетеп яту** Әле, хәзер биетү. --- *мин яшьләрне дәртле көйгә биетеп ятканда, син килдең дә: «Берәр салмаграк көй уйнагыз әле», – дидең.* Ф.Яруллин

**БИЕШҮ** *ф.* 1) Бер-бер артлы бию яки берьюлы берничә кеше бию. *Бүтәннәр дә аңа ияреп биешкән булалар.* Г.Коләхмәтов. *Җәүдәтнең энесе бик каты кычкырды, әнисе, аны кочаклаган килеш, ничектер, котырып биешкән бик күп аяклар арасына барып төште.* Г.Бәширов. *Әйдәгез, суны болгатып бетергәнче биешәбез.* Н.Хәсәнов

2) *куч.* Берәр кеше тирәсендә тызбыз килеп чабышып йөрү

**Биешә башлау** Биешергә тотыну. *Җиһангир керфекләрен йомды исә, күз алдында янә аллы-гөлле тәңкәләр биешә башлый.* Н.Хәсәнов

**Биешә бирү** Биешүен дәвам итү

**Биешеп алу** Бераз биешү. --- *яңа халаты җайсызрак булды, бөгелгәндә, иелгәндә, гел шуышып төшә, шул мәлдә, җитешеп тулган күкрәкләре ачылып, биешеп алалар.* Т.Галиуллин

**Биешеп йөрү** Озак вакыт биешү. *Уйнап туктагач та әле авазлар, сүнәргә теләмичә, стеналар арасында биешеп йөрделәр.* М.Галиев

**Биешеп калу** Биешергә өлгерү. *Берзаман күлдәвектә кара куыклар гына биешеп калды!* Г.Андерсен. *Каршыңда саннар баганасы, ук һәм түгәрәкләр тезмәсе әлҗе-мөлҗе биешеп кала иде.* Р.Низами

**Биешеп кую** Кинәттән, биегән сыман итеп, берничә хәрәкәт ясау. *Мөдирнең мыеклары биешеп куйды.* Д.Бүләков

**Биешеп тору** 1) Бертуктаусыз биешү. *Бу җыен вакытында урман-сазлыклардан миллионлаган черки көтүе күтәрелә, һәм алар бәйрәм итүчеләр өстендә җанлы кара болыт булып биешеп торалар.* Р.Сибат

2) Әле, хәзерге вакытта биешү. *Без дә, салкын тын урамда бераз биешеп тордык та, әкренләп, өйләребезгә таралыштык.* Ә.Еники

**Биешеп яту** Әле, хәзерге вакытта биешү. *[Клубларында] Аяк басар урын да юк – дыңгычлап тутырганнар, диярсең. Шулай булса да, ничектер, җаен табып, биешеп яткан була үзләре.* В.Нуруллин

**БИЖУТЕРИЯ** *и. фр.* Кыйбатлы ташларга охшатып, ясалма таш яки металл, пластмасса һ.б.ш.дан ясалган бизәнү әйберләре. *Барысы да бөек, барысы да даһи! Чөнки минә монысы – бижутерия, ә менә монысы – асылташ, дип аралап бирүче тәнкыйтьче юк.* Р.Нуруллина

**БИЗ** *и. анат.* Организм эшчәнлеген тәэмин итәр өчен, гормоннар яки башка кирәкле матдәләр бүлеп чыгара торган әгъза. *1933 елның җәендә Г.Камал, Казаннан Түбән Услондагы үзенең дачасына кайтканда, эчәк бизләрендә булган авыру пристубы аркасында, гомерлеккә безнең арадан югалды.* М.Гали. *Бу төр кырмыскаларның «тегү машиналары» булып, пәрәвез бизләре көчле булган курчаклары хезмәт итә.* Кызыклар дөньясында. *Койрыгы үсеп чыккан төшендә хикмәтле бизе бар.* Кызыклар дөньясында

◊ **Биз-биз авырту** Төрле урында көчеп-көчеп авырту. *Аягым менә биз-биз авырта, менә шушы теземнән төшеп китә дә, балтырыма җитеп, яңадан, чәнчешеп, ботыма менә.* Г.Газиз

**БИЗӘК** *и.* 1) Карандаш, каләм, күмер, буяу һ.б.ш. белән ясалган рәсем. *Җитен чәчәге төсле вак-вак кына бизәкләр төшкән.* Ф.Хөсни. *Бик пөхтә итеп, аллы-гөлле бизәкләр белән чиккән булыр идем мин ул кулъяулыкны.* М.Маликова. *Мәчет диварларын бизәгән сырлар, бизәкләр, нишләптер, бик таныш сыман тоела.* Илһамият

2) Рәсемне хәтерләткән табигый күренешләр. *Күктә, зәңгәр ефәк өстендәге серле ак бизәкләр булып, болытчыклар сирпелеп торалар иде.* Ә.Фәйзи. *Көтелмәгәндә карлы-буранлы чана килеп кергәч, ул да бераз гаҗәпсенде, ат чанасы түгелме, дип, төрле бизәкләр белән бозланып туңган тәрәзәнең бер читеннән йортка күз ташлады.* Г.Ибраһимов

3) Кемне яки нәрсәне дә булса бизәү өчен кулланыла торган затлы, матур әйбер, бизәнү әйберләре. *Кызның колакларына, түшләренә миннән алтын бизәкләр вәгъдә ит.* М.Фәйзи

4) *куч.* Нәрсәне дә булса белдерә торган, сиздерә торган, бизи торган төсмерләр, хәрәкәтләр. *Аның кунак кешегә хас тыйнаклык белән ихтирам сизелеп торган йөзендә һәм авыз кырыйларында хәзер дә шаянлык бизәге бар кебек иде.* Г.Бәширов

5) *куч.* Нәрсәнең дә булса күрке, яме, мактанычы. *Укый-яза белү – шул тормышның Гәүһәр төсле матур бизәге.* М.Гафури. *Бу тирәләрнең бизәге генә булмыйча, куанычы да, юанычы да булган Кеңәле елгасының башы балта тимәгән куе нарат урманнарыннан башлана, дип сөйлиләр.* М.Хәсәнов. *Кыш авылга үз бизәген, үз ямен алып килде.* Г.Гобәй

**БИЗӘКЛӘ́П-СЫРЛАП** *рәв.* 1) Бик күп бизәкләр ясап, чуарлап. *Бишек-бишек, Үргәннәр ничек? Бизәкләп-сырлап, Төпләп һәм кырлап.* В.Хәйруллина. *Ул арада бизәкләп-сырлап эшләнгән җилкапка ачылып китте.* Ф.Сафин

2) *күч.* Сөйләмне экспрессив чараларга баетып, купшы сүзләр кушып, артык күп төрле чагыштырулар, эпитетлар белән чуарлап. *Бизәкләп-сырлап тормады.* Ф.Хөсни

**БИЗӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бизәк төшерү, бизәк ясау, бизәкле итү. *Тәрәзә капкачлары, өй кыеклары күпләрне сокландырырлык итеп бизәкләп, агачны киртләп эшләнгән.* Я.Зәнкиев. *1333 елда Гранада тәхетенә менгән Йосыф Әбел Хаҗи гасырлык төзелешне – Әлһәмра кальгасын төзетеп, бизәкләп бетертә.* М.Галиев

2) Төрле-төрле бизәкләр белән чуарлау, матурлау. *Ирек мәйданына, бик матур итеп бизәкләп, ёлка ясаганнар.* А.Шамов

3) *күч.* Бизәксыман сырлар барлыкка китерү, бизәкне хәтерләтә торган эзләр ясау. *Кырык җиде имза һәм бер тамга бизәкләде бу хатны.* Г.Гобәй. *Төн уздырыр өчен, чуртаннан куркып, сайга чыккан ташбашлар төркеме, Идел читен вак кына дулкыннар белән бизәкләп, тирәнгәрәк китте.* М.Әмир

4) *күч.* Телне, сөйләмне экспрессив чаралар ярдәмендә баету; купшы сүзләр кушып матурлау

**Бизәкләп алу** Бераз бизәкләү

**Бизәкләп ату** Тиз, ашык-пошык бизәкләү

**Бизәкләп бару** Беррәттән бизәкләү, рәттән бизәкләр дә өстәү. --- *Коръәннән аятьләр, бәетләр һәм шигъри юллар белән бизәкләп бара.* С.Алишев

**Бизәкләп бетерү** Тәмам, тоташ, күп итеп бизәкләү

**Бизәкләп җибәрү** Бераз, берникадәр бизәкләү. *Монысы – бераз бизәкләп кенә җибәрүдер, чөнки егетләр, кызлар янына йөгереп барсалар да, кайтканда, адымнарын санап атлыйлар.* М.Хуҗин

**Бизәкләп карау** Бизәкләргә омтылу

**Бизәкләп кую** Алдан ук, бик яхшылап, тәфсилләп бизәкләү. *Ике тәрәзә арасында кызыл материя өстенә чын урак белән чын чүкеч беркетелеп, чын ашлык башаклары белән бизәкләп куелган.* М.Фәйзи

**Бизәкләп тору** Әле, хәзерге вакытта бизәкләү; әледән-әле, еш бизәкләү

**Бизәкләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, тоташ, бөтенесен дә бизәкләү

**Бизәкли бару** Бер-бер артлы бизәкләү

**Бизәкли башлау** Бизәкләргә тотыну

**Бизәкли төшү** Беркадәр, бераз бизәкләү

**БИЗӘКЛЕ** *с.* 1) Бизәкләр (*1 мәгъ.*) төшерелгән, бизәк ясалган, бизәге булган. *Кижеле ашъяулык җәйгән өстәлдә, бизәкле поднос өстендә самавыр шаулый.* Г.Әпсәләмов. *Нажия кыска жакетын киеп, матур бизәкле ефәк косынкасын бәйләгән чакта, Майпәрвәз ханым аңа сокланып карап тора.* Ә.Еники

2) Табигый бизәкләрдән торган, ямьле, күрекле. *Тыныч иртәгә, ил-төякнең кабатланмас бизәкле манзарасына адарынып, шактый торды ул.* Ф.Сафин

**БИЗӘКЧӘ** *и.* 1) *к.* **бизәк**

2) *шигъ.* Җырларда, мәкальләрдә төп фикерне әйтү өчен фон итеп китерелгән беренче өлеш. *Мәкальләрнең куш юллы яки күп юллы булганының башында, гадәттә, табигатьтән яки тормыштан алынган бер бизәкчә бирелә дә, аннан төп мәгънәне аңлаткан буыны әйтелә.* Н.Исәнбәт

**БИЗӘКЧЕ** *и.* 1) Бизәк төшерүче, бизәк ясаучы. *1966 елда бу училищены тәмамлагач, мәктәптә рәсем һәм сызым укытучысы булып эшли, төрле оешмаларда бизәкче – художник хезмәтләрен башкара.* Казан утлары

2) Агачка, сөяккә һ.б. материалга кисеп, чокып яки сырлап бизәк ясаучы, оста; нәкышче. *Көннәрнең берендә, әлеге Багдад шәһәренең патша кызы да, менә шундый урамда, шундый йортта чит илдән килгән бизәкче бар икән, дигән хәбәрне ишетә.* Әкият

**БИЗӘЛЕШ** *и.* Нинди дә булса әйбергә ясалган бизәкләр, бизәлү дәрәҗәсе, бизәү техникасы. *Үзе ап-ак затлы кәгазьдән эшләнгән, бизәлеше дә теләсә кемне таң калдырырлык.* З.Мәхмүди. *Бу төзелештә катнашкан эшчеләргә – Арча егетләренә рәхмәт: аларның зур осталыгы йортның һәрбер элементында, бизәлешендә чагыла.* Сөембикә

**БИЗӘНЕШ** *и. к.* **бизәнчек**. *Өсләрендәге киемнәре, бизәнешләре һәм чәчүрешләре татарныкына да, урысныкына да охшамаган.* З.Мәхмүди

**БИЗӘНҮ** *ф.* 1) Бит, ирен, кашларны махсус буяулар белән тулыландырып, йөзне матурлау. *Пәрдә ачылганда, Сәрвәр көзге алдында бизәнә.* Т.Гыйззәт. *Көзгегә килеп карый, бизәнә, күлмәк кесәсенә кулын тыгып, ирен помадасы ала.* Г.Камал // Матур киемнәр киеп, бизәкләр тагып, төзәтенеп, үз-үзеңне матурлау, купшылану

2) *күч.* Матурлану, ямьләнү. *Бизәнде тау, бизәнде кыр, гөлләр үсте.* Дәрдемәнд. *Җир йөзе тәмам бизәнгән Чәчкәләр, гөлләр белән. Төрле агачлар, елгалар һәм Чишмәләр, күлләр белән.* М.Гафури. *Без аның белән – һәртөрле шәһәрнең чәчәкләр белән бизәнгән әгъла бакчасы эчендә.* Г.Ибраһимов

**Бизәнә бару** Торган саен ныграк бизәнү

**Бизәнә башлау**. Бизәнергә тотыну. *Менә ул көзге каршына килеп утырды да бизәнә башлады.* Н.Хәсәнов

**Бизәнә бирү** Бизәнүне дәвам итү. *– Кайтып җитеп бик яхшы иттең әле, – диде ул, һаман да көзге каршында бизәнә биреп.* М.Хәсәнов

**Бизәнә төшү** Бераз бизәнү

**Бизәнеп алу** Тиз-тиз генә бизәнү. *Хәзер үк китәбез, тукта, бераз бизәнеп алыйм да.* Г.Гомәр. *Табынга куярлык аш-су рәтләгәч, бизәнеп тә алам.* К.Тимбикова

**Бизәнеп бетү (бетерү)** Ахыргача бизәнү. *Бер шәһәр бәйрәмгә бизәнер, Бер кыз бизәнеп бетә алмас.* Н.Исәнбәт

**Бизәнеп җибәрү** Бераз бизәнү. *Әгәр дә бизәнеп җибәрсә, җитмеш яшьлек карчык та унҗиде яшьлек кыз кебек була.* М.Сәлим

**Бизәнеп кую** Алдан ук бизәнү. *Кичләрен бизәнеп куй да иреңне елмаеп- көлеп каршы ал.* М.Маликова

**Бизәнеп йөрү** Һәрвакыт бизәнгән булу. *Бу байлыклар шәһәргә, аның кие-*

*неп, бизәнеп йөргән халыкларына китә икән.* Г.Нигъмәти

**Бизәнеп тору** Һәрвакыт бизәнү; әледән-әле, еш бизәнү. *Гел бизәнеп торсын иде, Каршыма басып, көлеп. Нидер пышылдасын иде, Бөтенләй якын килеп.* Х.Бәдигый

**Бизәнеп утыру** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында бизәнү. *Ниһаять, Габдулла Кырлайдагы Фазылның Сабан туенда Галимҗанны җиргә күтәреп салганда каян көч алганын, Гөләнвәрнең Фазылга хат яздырганда ни өчен яңа күлмәкләрен киенеп, бизәнеп утыруының мәгънәсенә төшенде.* Ә.Фәйзи

**БИЗӘНЎ-ТӨЗӘНҮ** *җый. ф. к.* **бизәнү-ясану.** *Алар арасында – үрдәкле һәм имән чикләвеген хәтерләткән асылмалары булган, бөртекләп һәм үреп бизәкләнгән бөҗра алкалар, бизәнү-төзәнү кирәк-яраклары, ачкычлар һәм йозаклар, ук очлыклары, кылыч һәм сугыш балтасы, асылташлардан тезелгән төймәләр һ.б.* И.Гафаров

**БИЗӘНҮ-ЯСАНЎ** *җый. ф.* Бит, ирен, кашларны буяп, өс киемнәрен тәртипкә китереп, матур бизәкләр асып, үз-үзеңне бизәү, матурлау; купшылану. *Бары тик наратлар, чыршылар, ак чыршылар гына үзләренең яшел ылысларын коймый, алар җәй көннәрендәгечә бизәнеп-ясанып утыралар, тик бераз карасулана гына төшкәннәр.* Г.Әпсәләмов. *Чыкмаган кая, бизәнде, ясанды да, Гөлмиләргә барам, дигән булып чыгып китеп, кояш баегач кына кайтты.* М.Фәйзи

**БИЗӘНЧЕК** *и.* **1.** Матурлану, бизәнү кирәк-яраклары, бизәкләр, бизәнү әйберләре. *Алтын бизәнчекләр. Бизәнчекләр тагу*

**2.** *с. мәгъ.* Бизәнергә ярата торган. *Ире чыкса, киенер, Ире кайтса, көенер. Бизәнчек хатынның уе – башкаларны шаккатыруда, дигәннән.* Н.Исәнбәт

**БИЗӘ́Ү** *ф.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса матурлык бирү, төрле бизәкләр төшереп матурлау, буяу, бизәкләп бетерү, бизәкле әйберләр белән матурлау. *Көзгеләрне рәсемнәр белән бизәделәр.* Ә.Хәбибуллин. *Аны алтыннар, бриллиантлар белән бизәде, атласлар, ефәкләр эченә күмде.* Г.Ибраһимов. *Чыбылдыгың бизәген Ука белән бизәдең...* К.Тинчурин. *Сәлах Камиленнән, Газиз Гадиленнән сбруйлар, чуклы шөлдерле шлеялар, кыңгыраулар алып, атларны бизиләр.* Сөембикә

2) Матурлау, ямьләү, сафлык бирү. *Җирне һәм күкне яшенле яңгырлар, кабат-кабат юып, тагын үтә күренмәле зәңгәрлек белән бизәп китте.* Ә.Баян

3) *күч.* Телне, сөйләмне әдәби экспрессив чаралар, купшы сүзләр белән баету. *Кави, курыкмыйча, теманы сайлый яки, курыкмыйча, шуны киңәйтеп, оригиналь, матур тасвирлар белән бизәп яза, сөйләп бирә белә.* Г.Нигъмәти. *Укытучы, ялгышмасам, «белән», «шикелле»не җөмләсен бизәү өчен әйтте.* Г.Гобәй

4) *күч.* Мәгънәлерәк итү, эчтәлеген баету. *Дөрес, Шакир һәр язган хатын «сине бик күрәсе килә, яныңда буласы, кочасы, үбәсе килә» кебек сагыну хисләренә бизәп язса да, Әминә аларны, бары тик юату өчен, авыр көннәр кайгысыннан ярсыган йөрәкне басу өчен генә язылганнар, дип уйлады.* Г.Минский

5) *күч.* Тормышта онытылмаслык вакыйгалар, бөек эшләр белән танылу. *Ул әкиятнең соңгы битләрен син зур исем, мәңге онытылмаслык эшләр белән бизәп китмәдең...* Һ.Такташ. *Хезмәт бизи шулай матур итеп Тормышны һәм кеше язмышын.* Г.Хуҗиев

**Бизәп алу** Бераз, тиз генә бизәү

**Бизәп бетерү** Күп итеп, бөтен яктан бизәү, бик нык бизәкләү; бизәү эшен төгәлләү. *Тагы җепләр үткәрде, шулай өйнең бөтен ялангач стеналарын кизҗеле сөлгеләр, чигүле намазлыклар белән бизәп бетерде.* Г.Ибраһимов. *Койманы үтеп керүгә, ак таштан ясалган, бизәп бетергән матур өйләр алдыңа килеп басалар.* Ш.Әхмәдиев

**Бизәп җибәрү** Бераз бизәү, бизәкләр дә кушу. *Син миңа менә бу бүлмәдәге әйберләрне дә сат әле, мин алар белән кабинетымны бизәп җибәрер идем.* Т.Гыйззәт. *Авыл осталары аның өстен япкан, улаклар куеп, бизәп җибәргән.* Ф.Гарипова

**Бизәп йөрү** Әле, хәзерге вакытта бизәү белән шөгыльләнү. *Мин салкыннан курыкмыйм, Мин кар-буран ятам. Бизәп йөрим бар дөньяны, Кар бөртеге таратам!..* К.Закирова

**Бизәп кую** Алдан бизәү. *Аны пионерлар, Казаннан укытучы апа килә, дигәч, шулай бизәп куйганнар.* Г.Гобәй

**Бизәп тору** 1) Даими, һәрвакыт бизәү. *Заманында ул йорт бар урамны бизәп тора иде.* Н.Хәсәнов. *Зирәк акыл һәм үлемсезлек символы булган, оча торган елан Идел Болгарларының гербын бизәп торган.* Р.Мостафин. *Гаҗәеп үзенчәлекле күрән сары гамма – юлбашчының сурәттәге образы характеристикасына туры килгән, сабыр, җылы гамма да бизәп тора аны.* Казан утлары

2) Әле, хәзерге вакытта бизәү. *Өстендәге тоник зәңгәр кыска күлмәге гәүдәсенең матурлыгын, биленең нечкәлеген, аякларының тиешле төзлеген ассызыклап күрсәтеп, бизәп тора.* Т.Галиуллин

**Бизәп үтү** Тоташ бизәү, бер уңайдан барысын да бизәү. *Яшел җәйгә алмашка Алтын көз килеп җитте. Пумаласын алды да Дөньяны бизәп үтте.* Ә.Вәлиуллина

**Бизәп чыгу** Бөтен җирне, бер җирне дә калдырмыйча бизәү; һәрберсен бербер артлы бизәү, башыннан ахырына кадәр бизәү. --- *каен яфракларын авылга алып кайтып, тәрәзә капкачларына кыстырып, өйләрне бизәп чыга торган булганнар.* Р.Ягъфәров

**Бизи бару** Рәттән, бер-бер артлы бизәү

**Бизи башлау** Бизәргә тотыну

**Бизи бирү** Бизәвен дәвам итү

**Бизи килү** Күптәннән, элек-электән дәвамлы бизәү. *Бу сыйфатлы татарлар башкорт тормышын, аның яшәешен бизи килделәр.* И.Таһиров

**Бизи төшү** Тагы да бизәү; бераз бизәү

**БИЗӘҮЛЕ** *с.* Бизәкләр төшерелгән, бизәлгән. *Сәхтиян читек лә, ай, бизәүле, Болгарныкы икән олтаны шул.* Җыр

**БИЗӘҮЧЕ** *и.* Йортларны, торакларны һ.б.ш.ны бизәү, матурлау эше белән шөгыльләнүче; декоратор. *Мин бит, егеткәем, төзелештә бизәүче, сылаучы, буяучы булып эшлим.* Р.Юнысов

**БИЗГӘК** *и.* Талакның һәм бавырның зураюы белән характерлы, туңдырып

калтырата торган йогышлы авыру. *Ике авыл арасындагы шул бака ефәге белән капланып, күпчеп беткән бу күлдән бер елны бизгәк чире тарала.* К.Нәҗми. *Рәүф әткәсенең элекке бизгәк авыруы белән хәзерге «исле авыруы» арасында шундый охшашлыкны күргәч, бик шатланып китте.* Г.Иделле. *Ул елны кар сулары акканын тәрәзәдән генә карап яттым, чөнки бик озак вакыт бизгәк белән авырдым.* М.Маликова

◊ **Бизгәк булсаң, үтерми китмәссең** Бәйләнчек, йөдәткеч кешегә карата әйтелә. **Бизгәк булу** Кешене йөдәтеп бетерү, аптырату. *Син, Гыйззәт, булма бизгәк, Шулай да эшне тизләт, Мине яучы итеп җибәр, Мәми авыз булсаң, кызлар бизәр!* Г.Бәширов. **Бизгәк кызулыгы белән** Бик тиз, ашыгыч рәвештә

**БИЗГӘКЛЕ** *с.* Бизгәк йоккан, бизгәк белән авырый торган. *Фәтхи, бизгәкле кеше шикелле, калтыравык тавыш белән [җырлап җибәрде].* Ш.Камал

**БИЗГӘ́К ТОТУ** Бизгәк белән авыру. *Бизгәк тоткан төсле калтырана Куркуыннан кайбер кешеләр.* М.Гафури. *Мине тагы бизгәк тота башлады. --- Байтак вакыт дерелдәп яткач, миндә кызулык башланды.* Г.-Халикъ Садри. *Ул бизгәк тоткандагы кебек калтыранып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**БИЗГӘ́К ҮЛӘНЕ** *и.* Сыраҗчалар семьялыгыннан, кабырчык белән капланган, буынтыклы шуышма тамырчалы, дымлы урыннарда үсә торган ак яки ал чәчәкле үлән үсемлек. *Бизгәк үләне – вак кына киртле яфраклы күңелле бер үлән. Бизгәктән яфрагын кайнатып эчәләр.* Г.Бәширов

**БИЗДЕРГЕЧ** *с.* **1.** Үзеннән этәрә, читләштерә торган. *Бөкре, гомергә исерек, майланып каткан киемле, үзеннән-үзе биздергеч тышкы кыяфәте артында, актёр түбәнсетелгән һәм мәсхәрәләнгән кешеләрнең драматизм тулы тормышын күрергә ярдәм итә.* И.Илялова. *«Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел» дигән гыйбарәне ишеткәнең бардыр, Сәрвәретдин, әллә нинди биздергеч сүзләр әйтәсең, сүгенәсең, мәдрәсә ямен җибәрү була бит бу...* С.Поварисов

**2.** *и. мәгъ.* Нинди дә булса күнегелгән гадәттән аралау чарасы. *Сөйдергеч ясату бар, диләр. Биздергеч тә була икән.* Ш.Галиев

**БИЗДЕРҮ** *ф.* Кемнең дә булса кызыксынуын бетерү, яратмаслык итү. *Биздергән дә тел, сөйдергән дә тел.* Мәкаль. *Шәймәрдән абзыйны мәктәп бусагасыннан биздерү өчен әйтелгән бу сүзләр аның йөрәгенә ук кебек кадалды.* К.Нәҗми. *Мондагы хәлләр бер кереп чыккан арада да күңелемне биздерде.* Н.Хәсәнов. *Хәтердә уелып калган ачы мизгелләр исә яшәү ямен качыра, бу дөньядан биздерә...* Ф.Фәтхелислам

**Биздерә бару** Торган саен ныграк биздерү

**Биздерә башлау** Биздерергә тотыну. *Чит җирнең кичке шәфәгы, иртәнге таңы биздерә башлады.* А.Хәлим

**Биздерә төшү** Тагын да биздерү. *Ничек булса да Каюмнан күңелен тагы биздерә төшеп, кибетләрне үз исемемә яздыра алсам, аннары минеке дә [тормыш хәлләре] рәтләнер иде.* Г.Исхакый

**Биздереп бетерү** Тәмам, бик нык биздерү. *Хәтта ул җир, бүген, гомерен җиргә багышлаган авыл кешесенә дә кирәкми. Аны, атна саен реформа ясап, җирдән биздереп бетерделәр.* Т.Миңнуллин

**Биздереп кую** Кинәт биздерү; алдан ук биздерү. *Артыграк көлеп, егетне эшеннән биздереп куя күрмәсеннәр тагын.* М.Хәсәнов. *Йә, сөйдереп куймас өчен, Биздереп куйган булсаң!..* Н.Измайлова

**Биздереп тору** Гел, һәрвакыт биздерү. *--- шушылай үзен белдеклегә санап йөрүеме, мактанчыклыгымы, танавыннан аңкып торган тәмсез исеме, иренен бөреп сөйләшүеме – нәрсәседер күңелне биздереп тора.* С.Зыялы. *Соң, нәрсәсе белән ул миңа ошамый, мине үзеннән этәреп, биздереп тора иде?* Ә.Еники

**БИЗЕНҮ** *ф.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса мөнәсәбәт үзгәрү, яратмый башлау, салкынаю, читләшү. *Йа Ходаем, бизенсә дә бизенә икән күңел ир-ат затыннан...* Ш.Бикчурин

2) Нәрсәдән дә булса тую. *Анда ничаклы куркынычлар-фәләннәр сөйләнсә дә, бер дә бизенми иде.* Г.Ибраһимов

**Бизенә бару** Торган саен ныграк бизенү

**Бизенә башлау** Бизенергә керешү

**Бизенә төшү** Беркадәр бизенү; тагын да бизенү

**Бизенеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә бизенү

**Бизенеп бетү** Тәмам, бик нык бизенү

**Бизенеп калу** Нинди дә булса вакыттан, сәбәптән соң бизенү

**Бизенеп китү** Кинәт бизенү

**Бизенеп кую** Кинәт, аз гына вакытка бизенү

**Бизенеп тору** Берникадәр вакытка, әле, сөйләү моментында бизенгән булу

**БИЗЛЕ́ АШКАЗАНЫ** *и. анат.* Кошларның ашкайнату юлындагы бүксә белән бүтәкә арасындагы урын. *Кошларның бизле ашказаны алдында шактый зур куык бүксә була, ә ашказаны артында бик итләч бүтәкә була.* А.Расих

**БИЗМӘН** *и.* 1) Бер башында чукмарлы авырлык, икенче башында үлчәнеләсе әйберне элү җайланмасы булган шкалалы күчәрле үлчәү яки ике ягында да тәлинкәләр булып, үлчәнәсе әйберне герләр салып тигезли торган көянтәле үлчәү, яисә кул белән күтәреп тотып үлчәнелә торган пружиналы үлчәү. *Ирек, хөрлекне бизмәнгә салып үлчәп, күпме кирәк, шуның кадәр алып буламыни инде?!* Ф.Сафин. *Бизмәнгә, үлчәүгә сыймаган йөгенең авыры, җиңеле.* К.Булатова. *Ул авыл читенә олы бизмән ясаган да бер ягына үзе авырлыгында таш куйган, икенче як тәлинкәгә алтын-көмеш салырга кушкан.* Г.Гыйльманов

2) *куч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса үзенчәлекле әһәмияте, кыйммәте турындагы фикер; бәя, хак. *Кыерсытылган җаннар хөкемдарлар бизмәненең хаклык, дөреслек ягына авышуын, хакыйкать сакчысы – иманнарына тугры калуын тели.* Н.Хәсәнов. *Һәр чорның – үз зәвыгы, һәр кешенең – үз бизмәне.* Кәеф ничек

◊ **Бизмәнгә салып үлчәү** 1) Һәр ягын тикшереп, уйлап, чамалап эш итү. *Шулай да, сүз халык турында барганда, сак эш итәргә, һәр сүзне бизмәнгә салырга кирәктер.* Татарстан яшьләре;

2) Саранлану, вакчыллану, бар ягын исәпкә алып кына эш итү. **Бизмәне авыр тарта** 1) Яхшылыгы, хезмәте күп тигән булу; 2) Төпле, акыллы кеше булу. **Бизмәне билгеле булды** Берәр кешенең акыл-белем чамасы тирән түгеллеге сөйләшүеннән мәгълүм булу. **(Үз) бизмәненә салып үлчәү** Үз карашларыннан чыгып, үзенчә фикер йөртеп, нәтиҗә ясау. *Шәһәр дөньясын ул һаман әле, авыл бизмәненә салып, чагыштырып карарга ярата.* М.Галиев. **Бизмәнен үз ягына каеру** Үз файдасына эшләү. *Бизмәнен үз ягына каера...* Н.Хәсәнов. **Бизмәне тартмый** Акыл ягы ким, белеме сай, эшне белеп җиткерми. **Бизмәне тулмый** *к.* **бизмәне тартмый**

**БИЗМӘНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Әйберне бизмәнгә салып үлчәү

2) *күч.* Саранлану; вакчыллану, бар ягын исәпкә алып кына эш итү

3) *күч.* Бик уйлап, алдан чамалап эш итү. *Димәк, хуҗабикә барысын да алдан ук үлчәп, бизмәнләп, әүвәл Зифаны үз йортына керткән, аннары, ярәшелгән кыз хәленә куеп, аны саклап яткан була түгелме соң?* В.Имамов

**Бизмәнләп кую** Алдан ук бизмәнләү

**Бизмәнләп тору** Даими, һәр очракны бизмәнләү

**Бизмәнләп чыгу** Берәм-берәм һәрберсен бизмәнләү

**Бизмәнли бару** Һәрберсен, булган берсен бизмәнләү

**Бизмәнли башлау** Бизмәнләргә тотыну

**БИЗМӘНЛЕ** *с.* 1) Үлчәп сатыла торган, үлчәүле

2) *күч.* Бик вакчыл, саран

3) *күч.* Алдан уйлап, бөтен ваклыкларын чамалап эш итә торган

**БИ́ЗНЕС** *и. ингл.* Табыш алуга нигезләнгән эшчәнлек; үз акчаңны салып башлаган эре сәүдә. *Кече бизнес сферасында 160 меңгә якын кеше эшли.* М.Шәймиев. *Бизнес дөньясында аның исеме бик тә билгеле, һәм хөрмәт казыш курку беләнрәк телгә алына иде.* Х.Мөдәррисова. *Аның гаиләсе тәмәке бизнесы белән шөгыльләнә.* Асылъяр. *Беләсезме, бизнесның мәгълүм бер стандартлары белән билгеле бер сату базары челтәре бар.* Татарстан. *Бизнес мәктәбе. Бизнес план. Бизнес проект. Бизнес үзәге*

**БИЗНЕСМЕН** *и. ингл.* Бизнес белән шөгыльләнүче, эшмәкәр. *Бишалты елдан киң колачлы бизнесмен булачак.* В.Юныс. *Чөнки бу изге эшкә ниндидер бер бизнесмен тотынганны ишетте ул.* Казан утлары. *Хәзер дә, кая карама, Украинада, Белоруссиядә, Урта Азиядә, Себердә татар бизнесменнары, байлары баш калкыта тора.* Татарстан яшьләре

**БИЗОН** *и. лат. зоол.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан, Төньяк Америкада яши торган, озын яллы кыргый үгез (зубрга якын тора). *Зоопарклардагы бизоннар аранына бүрәнә ташыйлар.* Кызыклар дөньясында. *Нәтиҗәдә, миллионлаган кыргый үгезләрдән, сыерлардан хәзер берничә йөз бизон гына калган, алары да тыюлыкларда гына әле.* Татарстан яшьләре

**БИЗҮ** *ф.* Кешедән, нинди дә булса әйбердән, күнегелгән эштән, гадәттән тую, ошатмый башлау; ышаныч югалып, хисләр суыну. *Тар кабернең куенына кердем, Котылдым дөньядан, Чөнки биздем дөньядан, Артык торасым килмәде.* Ш.Бабич. *Аларның мәдрәсәләреннән бөтенләй биздем.* М.Гафури. *Йортыңнан син шулай биздеңме?* Н.Исәнбәт. *Хәзер инде мин иңемә көянтә асудан күптән биздем.* М.Маликова

◊ **Бизәр булу** Кемнән яки нәрсәдән булса да тәмам тую, күңел суыну. *Белсәң иде шул Сирайдан бизәр булганымны.* М.Фәйзи

**Бизә бару** Торган саен ныграк бизү. *Бергә уйнадык, бергә укыдык, күбрәк бергә булган саен, бизә генә бардым, җитмәсә, малай-шалай да үзенчә үртәгән була.* Рифә Рахман. *Без моңлы, эчтәлекле җырны тыңлаудан бизә барабыз.* Г.Ибушев

**Бизә башлау** Бизәргә тотыну. *Әгәр Россиянең төрле төбәкләрендә яшәгән татарлар бер-берсеннән аерылган икән, әгәр үзләренең туган телләреннән бизә башлаганнар икән, аңа да Казан гаепле түгел, ул – әлеге дә баягы Россиянең имгәк милли сәясәте нәтиҗәсе.* Т.Миңнуллин

**Бизә бирү** Бизүен дәвам итү

**Бизә төшү** Бераз бизү

**Бизә язу** Чак кына бизмәгән, бизүгә якынлашкан. *Заманында конфликтсызлык баткагына бата барган милли театрны тартып чыгаруга күп өлеш керткән, театрдан бизә язган тамашачыны залларга кире кайтарган, 60 яшендә арабыздан китеп барган драматургның [Хәй Вахитның] бу юбилее сизелми дә диярлек үтеп китте.* А.Әхмәдуллин

**Бизеп бару** Акрынлап бизү. *Ата – улдан, ана кыздан бизеп бара.* Р.Вәлиев. *Шул тиле аркасында, яраткан эшеннән дә бизеп бара бугай инде.* Р.Габделхакова

**Бизеп бетү** Тәмам бизү. *Соң, әйтмичә, оланнар үзеңнән бизеп бетәр.* К.Миңлебаев

**Бизеп җитү** Бөтенләй бизү. *Алладан бизеп җиттек.* М.Әмир. *Мәгәр анда да әле җаны ул хәтле бизеп җитмәгән иде.* М.Хәбибуллин

**Бизеп йөрү** Әле, хәзер, гомумән бизгән булу. *Чын яшәүдән бизеп йөрелгән...* Р.Рахман. *Дөрес, баштарак мин хатын-кыздан, ничек дим, гайрәтем чигеп, бизеп йөрдем.* Ә.Еники

**Бизеп калу** Кайсыдыр бер вакыттан, сәбәптән соң бизү. *Биеклектән курыккан, көлүдән бизеп калган әнием аларны артык санады.* Рифә Рахман

**Бизеп килү** Акрынлап бизү

**Бизеп китү** Көтмәгәндә, ниндидер сәбәп белән бизү

**Бизеп кую** Кинәт бизү

**Бизеп тору** Әле, хәзерге вакытта бизү; вакытлыча бизү. *Гаделсез мөнәсәбәтләр аркасында «бизеп тору» да булырга мөмкин.* Р.Низами

**БИЗЧЕЛ** *с.* 1) Бизе булган, бизле. *Яфракларның өске өслегендә һәм читендә бизчел башчалы төкчәләр урнашкан.* Л.Мәүлүдова

2) Биз кебек, бизгә охшаган, биз сыман. *Бизнең стеналары агу бүлеп чыгаручы бизчел күзәнәкләр белән түшәлгән.* Татар балы

**БИК** I *и.* 1) *иск. кит. к.* **бәк**

2) Морзалар нәселендәге фамилияләрдә һәм кайбер кушма исемнәрдә сакланган компонент: *Биктимер, Бикбулат, Ханбиков*

**БИК** II *и.* 1) Бикләп кую җайланмасы; йозак, келә, бастырык, бикләвеч. *Егетнең җавап сүзен дә көтмәстән, кортка, кискен хәрәкәтләр белән, ишеккә аркылы бик тә салып куйды.* Я.Зәнкиев. *Шулай бу табышмаклы хәлне берничек тә чишә алмыйча торганда, эчтән ишекнең биге алынган тавыш ишетелде, аннары ишек тә яртылаш ачылды.* Г.Минский

2) *күч. гади с.* Төрмә, зиндан. *Җиде кат бик астында, бер минутын төрмә күзеннән ычкындырмыйча сакларлык куркынычлы гайрәтле шәхесме ул?..* А.Гыйләҗев. *Тәүлек узгач, ата-ана, Ак сакаллы картлар килеп, Гозер итеп яшь морзага, Итәкләрен аның үбеп, Коткарып алган биктән.* Ш.Маннур

**БИК** III *рәв.* **1.** 1) Гаять, көчле дәрәҗәдә, гадәттән тыш, чиктән ашкан, югары дәрәҗәдә, искиткеч, искитмәле. *Хатын, акча күп чыкмаганлыгы өчен мин дә бик шатланам.* Г.Камал. *Кәрим бай, Кәрим бай! Эшең хәзер бик уңай!* Т.Гыйззәт. *Шулай бик озак барганнан соң, алда, бик еракта, кыр өстендә аз гына калкып, соры карамчык кына булып, бер авыл күренә башлады.* Г.Бәширов

2) «Әйбәт», «яхшы» сүзләре төшеп калганда, шул сүзләрне алмаштырып килә, җитәрлек дәрәҗәдә яхшы, мәгънәсен бирә. *Олы кызың Хәмдия туташ бик сәламәтме?* Ф.Әмирхан. *Бик исән, иптәш командир.* А.Әхмәт. *Нихәл, кызым, бик сәламәт кенә торасыңмы?* Г.Камал. *Үземә-үзем җавап бирә башлыйм: тукта, нәрсәдән куркып торам соң мин, үземне-үзем белмиммени мин, беләм, бик беләм...* М.Әмир

3) *сөйл.* Фикергә катгыйлык төсмерен өсти: һичшиксез, әлбәттә. *Аның фронтка үз кешесен җибәрергә бик хакы бар!* Г.Бәширов. *Бик дөрес әйтә.* К.Нәҗми. *Көттең, бик рәхмәт, ләкин мин ике генә көнгә кайттым.* Г.Ибраһимов. *Алам, бик алам.* Г.Ибраһимов

**2.** *кис. мәгъ. сөйл.* Искитмәү, ризасызлык белдерү, кире кагу, мәгънәсендә. *[Сафура:] Бик исем китте.* А.Әхмәт

**БИКАСАП** *и. фар.* **1.** 1) Ярым ефәк буй-буй тукыма. *Ул чапан әдрәстән, бикасаптан, саранчыдан, бәнаристан була.* К.Насыйри

2) Шул тукымадан тегелгән кием. *Ул әле оялмас, шушы бикасапны да үзенеке дияр.* Н.Исәнбәт

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Моның хәлфәсе дә --- озын мәһабәт буйлы, сөрмә тарткан җитди күзле, ак бикасап чапан кигән кеше.* Ә.Фәйзи. *Сафа карт – аягында читеккәвеш, чалбарсыз, тезенә төшеп торган аксыл буйлы бикасап камзул, башында Бохара кәләпүше, кулында комган булган хәлдә ---.* Г.Ибраһимов

**БИКАСӘП** *и. фар. к.* **бикасап.** *Өсләренә исә чит илләрдән килгән ефәк, бикасәп, әдрәс вә сукнолар, хәзерге татар агаеның кыска җиңле камзолы өстеннән җилән кигәннәр.* Г.Гобәйдуллин

**БИКӘ** *и. иск.* 1) Бай, би(к) хатыны. *Бикә бизәнгәнче, туй беткән.* Мәкаль. *Бу хәрәкәт эчендә, гәрчә, ярлы мөгаллимәләр бик күп булса да, алар да, шул дәвернең теләвенчә, һәртөрле бикәләрнең биргән тонлары буенча бардылар.* Г.Ибраһимов. *Буржуй хатыны бикә Ничек итеп көн итә? Актык көннәре җитә.* Г.Камал

2) Бай хатыннарын олылап, аларга мөрәҗәгать итү сүзе. *Кая, бикәм, менә монда утыр әле.* Д.Аппакова

3) Исемнәргә ялганып, туташ, ханым, мәгънәсен белдерә. *Зыя Мәрьямне сөя, өйләнергә дә әзер, ләкин шул хакта ата-аналарына яки Фатыйма бикәгә, барып, бер сүз әйтә алмый.* Г.Нигъмәти. *Шәмсеҗиһан бикәләргә куркулык коярга барган идем дә, шуннан кайтышлый, тукта, керәп, хәлләрен белеп чыгармын, ни эшләп торалар икән, дип кергән идем.* Г.Камал

4) *сөйл. ирк.* Кушма сүзләрдә иркәләп әйтү яки берәр сыйфатка ия булуны ишарәли торган икенче кисәк (мәс.: *мыраубикә, сөтбикә, иркәбикә*). *Бүген сиңа, кечкенә мияубикә, контролёр кыз Равилә юк шул, отгул алган.* Н.Хәсәнов. *Бу юлы да икенче яктагы өстәл янында китаплар биреп торучы хуҗабикәгә табан китеп бардым.* К.Миңлебаев

**БИКӘБАШ** *и. бот.* Киндерчәләр семьялыгыннан, күп тармаклы, яфрак читләре тешләнеп торган, майга бай техник үсемлек; ана киндер. *русчасы:* **конопля посевная** (матерка)

**БИКӘР** *с. фар.* Түләүсез, файдасыз; буш, нәтиҗәсез. *Юк, телне балага алай «кашыклап кына бирү» – бикәр эш.* Ә.Еники

**БИКӘРГӘ** *рәв.* 1) Бер дә юкка, сәбәпсезгә, нигезсезгә, тиктомалга. *«Чыбыксыз телефон» дип, бикәргә атыйлар алайса үзеңне, Әнвәрия.* А.Гыйләҗев. *Син дә безне бикәргә харап итмә!* М.Фәйзи

2) Бер дә файдасызга, мәгънәсезгә, бушка. *Актык сәгатеңдә ирек бирәм, сөйлә, сөйлә, егет, бикәргә.* Ф.Бурнаш

**БИКӘЧ** *и.* 1) Димләнгән, ярәшелгән кыз; кәләш. *Мин үземнең бикәчтән хат алдым.* Ш.Камал. *Күтәр, күтәр, касәң күтәр Яшь бикәчләр хакына.* Ф.Бурнаш

2) *сөйл.* Кияүгә әле яңа гына барган яшь хатын. *Котлы булсын яшь бикәч!* Н.Исәнбәт. *Әмма яшь бикәчкә ярты дәүләтемне яздырам, Алла боерган булса.* Ш.Камал. *Шәһәр бикәче булса да, инде юкарыбрак калган чәчләре толымга үрелгән, аңардан исә, җыйнаклandырып, причёска ясалган.* Мәдәни җомга

3) *диал.* Теше, инәк. *Бикәч бәрән*

◊ **Бикәчкә керү** Кияүнең беренче кич кыз янына керүе. *Шакир бикәчкә керде һәм аның янында дүрт көн торды.* Ш.Әхмәдиев

**БИКӘЧЛӘҮ** *ф.* Туйдан соң кияүнең, киленне үз өенә алып кайтканчыга кадәр, кыз өенә килеп йөрүе; кияүләп йөрү. *Болар бикәчкә беркөнне чыгып киттеләр. Бикәчләделәр дә берничә көннән соң кайттылар.* Әкият

**Бикәчләп алу** Билгеле бер вакыт аралыгында бикәчләү

**Бикәчләп йөрү** Әле, хәзерге вакытта бикәчләү

**Бикәчләп яту** Озак вакытлардан бирле бикәчләү. *Үлем куркынычы борын төбендә торган бер заманда, мөселман комитетының президиум әгъзалары бикәчләп яталар.* К.Тинчурин

**БИ́КВАДРАТ** *и. лат. мат.* Нинди дә булса санның яки зурлыкның дүртенче дәрәҗәсе

**БИ́КВАДРАТ ТИГЕЗЛӘМӘ** *и. мат.* Чишелеше квадрат тигезләмә чишелешенә кайтып кала торган тигезлек. *Дүртенче дәрәҗә тигезләмә --- җөп дәрәҗәле билгесезләрдән генә төзелгән булса, «биквадрат тигезләмә» дип атала.* Алгебра

**БИКЛӘВЕЧ** *и. сөйл. к.* **бик** II. *Аны кем дә булса язып чыгарга тиеш кебек шикелле тоела сыман миңа --- дип, сак кына кагылып, дипломатының бикләвечен тикшереп алды.* М.Вәли-Барҗылы

**БИКЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бикләү.** *Тоткыннар, үзләренең алданганлыкларын сизеп, ишеккә килгәндә, тимерле калын ишек бикләнеп өлгергән иде инде.* Г.Гобәй

2) Үзең эчке якта калып, башка кеше кермәсен өчен, ишекне бикләп кую. *«Батырның тавышы-тыны юк, өенә бикләнде, ахры», – дип көлделәр.* А.Алиш. *Келәткә Вәсилә янына кереп бикләндем.* Ф.Хөсни. *Күз-колак салып кайтыйм бер, дип барсам, кызлар торагы ишеге төбендә, кулларына тоткан чүпрәк-чапракларын берсе икенчесеннән ничек тә яшерергә тырышып, өч-дүрт данә егет шыбырдашып йөри, ә ишек эчке яктан бик нык-лап бикләнгән.* Ф.Хөсни

3) Үткәрмәү, тоткарлау, ябылу. *Чат саен милиция, юллар бикләнгән.* И.Таһиров

4) *күч.* Нинди дә булса урынга яки эшкә бәйләнеп, мавыгып, шуннан китә алмау; аралашмау, тар эшчәнлек белән чикләнү. *Һиммәтсезләр, сәүдәләренә бикләнәләр дә, гомуми эшләрнең һәммәсеннән качалар.* Ф.Әмирхан. *Ул болай да авыл тормышыннан суынып, үз гаиләсе эченә бикләнү ягына ауган кызы Мәрьямне, бар көче белән, шул тупас мужик кызлары белән катыштырмаска, уйнатмаска тырыша.* Г.Ибраһимов. *Татар элек үз дөньясына бикләнеп яшәгән.* Т.Миңнуллин

5) *күч.* Кичерешләрен белдермәү, хисләрен, уйларын үз эчендә саклау. *Ул үз-үзенә кереп бикләнә, тимер ишеккә артын куеп баса да тыгыз такталар белән томаланган, пыяласы зәңгәрсу карага әйләнгән сукыр тәрәзәгә карап тора.* А.Гыйләҗев. *Тора-бара, үз-үземә бикләндем, уйчанландым.* Р.Вәлиев. *Без наданнарның эче – тышта, ә сезнең тышыгыз да эчкә бикләнгән.* Р.Сибат

**2. бикләнеп** *рәв. мәгъ.* Ялгыз калып, беркемне дә катыштырмыйча. *Серебряковның кысан каютасына бикләнеп, алар бик озак сөйләшеп утырдылар.* И.Гази

**Бикләнә бару** *к.* **бикләнеп бару**

**Бикләнә төшү** Тагын да ныграк бикләнү

**Бикләнә язу** Чак бикләнми калу

**Бикләнеп алу** Тиз генә бикләнү, эчтән бикләнү

**Бикләнеп бару** Торган саен ныграк бикләнү. *Кәшиф уйларына бикләнеп барган Ринатка дәште.* Н.Хәсәнов

**Бикләнеп бетү** 1) Бөтен бикләргә дә бикләнү

2) Бөтенләй, тәмам бикләнү

**Бикләнеп йөрү** Озак вакытлар, гел үзалдына бикләнгән булу. *Озынчарак аксыл йөзле, үз уйларына бикләнеп йөрергә ярата торган кыз Әхмәтсафаның бөтен күңелен биләп алды шул.* Ф.Сафин

**Бикләнеп калу** 1) Ача алмаслык булып, эчтә калып бикләнү, бикләнгән хәлдә калу. *Котсыз-шыксыз караңгы базда бикләнеп калуын башына сыйдыра алмады.* В.Нуриев

2) *күч.* Алга үтәргә, китәргә мөмкинлекләр булмау, көтелмәгән тоткарлыклар килеп чыгу. *Инде, бер-ике адым атлар-атламас, Оренбур өязеннән дә үтә алмый, шушы авылда бикләнеп калсам, атамның үзеннән дә, малыннан да, фатихасыннан да ваз кичеп чыгуымның күпме генә әһәмияте кала!* М.Фәйзи. *Эчтә – күңелдә бикләнеп калган, хәрәкәткә әверелмәгән күпме талпыну борчый безне.* Ш.Галиев

**Бикләнеп кую** 1) Алдан ук бикләнгән хәлгә китерү

2) Ялгыш бикләнү

**Бикләнеп тору** Вакыт-вакыт бикләнү, бикле хәлдә булу. *Кичә килдем, кичә ишегеңне ачмадың, бүген килсәм, бүген, дәшмичә, бикләнеп торасың.* К.Тинчурин

**Бикләнеп яту** 1) Бикләнгән хәлдә булу. *Бетсен инде киң җиһанда тар каберләр тарлыгы! Бетсен инде бикләнеп яткан каруннар сандыгы!* Ш.Бабич. *– Нәрсә син кояш батмас борын бикләнеп ятасың? – диде Шәмсүн, керә-керешкә.* А.Вергазов

2) Озак вакытлар бикләнү, кеше белән аралашмау. *[Габбас] Төннәр буе үзенең бүлмәсендә шешәләре, бүрәнкәләре арасында бикләнеп ята.* Ш.Камал

**БИКЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Ачыла, ябыла торган нәрсәне йозак, бикләвеч һ.б.ш. ярдәмендә ачылмаслык хәлгә китерү, биккә кую, биктә тоту, йозаклау. *Каюткомпанияне бикләгәннәр.* М.Юныс. *Аннары, һәр кеше үзе бара да, алып кайтып, келәтенә бикли.* И.Гази. *Мәдинә, иртәгә китсәм – яхшырак буласы икән, дип уйласа да, Гатаулла капканы бикләп өлгергән иде.* К.Нәҗми

2) Юлны, каналны һ.б.ш.ны нәрсә белән дә булса томалау, каплау, ябу. *Тишекне берәү дә бикләмәгән, су бикләгән булып чыкты.* И.Гази

3) Кемне яки нәрсәне дә булса, чыга алмаслык итеп, эчке якта калдыру яки беркем дә ачып ала алмаслык итеп урнаштыру, бикләнгән нәрсә эчендә калдыру. *Салкын базга бикләр салып, Каравыллар куелган.* Т.Гыйззәт. *Менә бу кәгазьләрне шкафка биклә.* Г.Камал

4) Нәрсәнең дә булса эшчәнлеген, яшәвен туктату. *Ә биш айдан, ячейканы бикләп, Кузгалдык без туган авылдан.* Ш.Маннур

5) *күч.* Каян да булса үтеп керергә, алга китәргә мөмкинлек бирмәү, киртәләү, тоткарлау, кыенлаштыру. *[Сандецкий] Кайсы төбәккә нинди көчләр беркетеләчәген аңлатты: – Менә бирегә – елга аръягына – юнкерларны чыгарам. Прапорщиклар школасы дамбаны бикли.* К.Нәҗми

6) *күч.* Берәр сәбәп белән тоткарлану, нәрсә булса да комачаулау. *Язгы ташу юлларны бикләде*

7) *күч.* Кисү, юк итү, бетерү. *Юк сиңа кешечә көн итү, Бикләдең син гомер юлыңны, Дошманың алдында, егетем, Бер, куркып, күтәргәч кулыңны.* М.Җәлил

8) *күч.* Үзләштерү, кеше малын үзенә алу, үз милке итү. *Алпавыт малы – синең малың түгел ул, ә халыкныкы!*

--- *Алып кайтып, үз келәтеңә яисә үз абзарыңа бикләргә хакың юк синең.* И.Гази

9) *күч.* Теләк, хис, омтылышларны тыю, ирек бирмәү, юл куймау. *Салкын яңгырлар да, аяк астының пычрагы да, җилле-яңгырлы болытлар да революция белән ашкынган халыкларны өйләренә бикли алмадылар.* Г.Ибраһимов

**Бикләп алу** Бик тиз, кыска вакыт эчендә бөтен яктан да бикләү. *Әсфәндияр капканы бөтенләй бикләп алырга боерды.* Б.Рафиков. *Бүлмәсен эчтән бикләп алды.* Х.Камалов

**Бикләп бару** Рәттән, бер-бер артлы бикләү

**Бикләп бетерү** Барысын да, бар яклап бикләү, бөтен бикләвечләргә дә бикләү

**Бикләп йөрү** Һәрвакыт бикле тоту. *Урынны сезгә өйгә җәябез. Тәрәзәләр ачык, ишек тә ачык. Без бикләп йөрмибез.* А.Гыйләҗев

**Бикләп калу** Артыннан ук бикләү. *Суси эчтән капканы бикләп калды.* Н.Фәттах

**Бикләп калдыру** Бикләнгән хәлдә тоту. *Мондый чакта эч пошырып буталып йөрмә, дип, өйдә бикләп калдырсалар да, берни эшли алмыйсың.* Т.Миңнуллин

**Бикләп китү** Үзеңнән соң бикләнгән хәлдә калдыру; өстән бикләү. *Юләр нәрсә, аны алдан сандыкка салып, кладавайга бикләп китәргә ярамаган икән.* Г.Камал. *Соңыннан, йөрәге кага башлагач, йоклаган кызының битеннән үпте дә ишегалдына чыкты. «Район үзәге зур, бикләп китәргә кирәк», – дип уйлады ул.* З.Мәхмүди

**Бикләп кую** Ача алмаслык итү, бикләнгән хәлдә тоту. *Элек Гыйльметтиннәр Фатыйманы бикләп куйган кебек, мине бикләп куярлар.* М.Фәйзи. *Һәм китапны, хәзрәт кулыннан алып, шкафларына бикләп куйды.* Ф.Әмирхан. *Проводница, Искәндәрнең иске елда төшеп калуыннан курыккандай, вагон ишеген бикләп куйды.* Р.Вәлиев

**Бикләп тору** 1) Һәрвакыт, гел бикле тоту. *Шатлыкларның искеләрен саклап, Көч-хәл белән җанны бикләп торам.* Н.Сафина

2) Әле, хәзерге вакытта бикләү; вакытлыча бикләү. --- *терлекләреңне дә, Равилеңне дә килендәшең Нәсихага калдырасың, ул карый торыр. Ә өеңне бикләп торасың.* В.Нуруллин

**Бикләп утыру** *к.* **бикләп яту.** *Соңгы вакытларда җырчыбыз грим бүлмәсенең ишекләрен бикләп утыра башлады.* К.Кәримов

**Бикләп яту** Әле, хәзерге вакытта эчтән бикле итү

**Бикли башлау** Бикләргә тотыну. *Өстәлдәге әйберләрен җыеп, тартмаларын бикли башлады.* Х.Камалов

**БИКЛӘ́Ү** II *ф.* 1) Сүз, шигырь, җыр һ.б.ш.ны күңелдә калдыру, ятлау, каткат кабатлап, истә, хәтердә калдыру. *Шигырьләрнең иң кәттәләрен яттан белә, Некрасовны, Һейнены күңеленә бикләгән, урысчаны су кебек эчә.* А.Гыйләҗев. *Бу поэманы без яттан бикләдек.* М.Мәһдиев

2) Истә калдыру, онытылмаслык итеп, хәтердә саклау. *Әхмәтсафа, көттереп тормыйча, кайчандыр күңеленә бикләгән юлларны яңартты.* Ф.Сафин. *Ә ул барысын да күңеленә бикләгән.* Г.Әпсәләмов. *Инде карт кешенең биргән киңәшләрен өстән генә укып үтмәгез, Күңелегезгә алып бикләгез!* Һ.Такташ

**Бикләп алу** Тиз генә бикләү, бикләргә өлгерү. *Бик күп тапкырлар әйтелә торган гади сүзләр --- һөҗүм алдындагы сәгатьтә бөтенләй башкача --- яңгырадылар, һәм Газинур аларны, яхшы җыр кебек, күңеленә бикләп алды.* Г.Әпсәләмов

**Бикләп бару** Һәрберсен, булган берсен бикләү. *«Бигрәк кызык икән, әни», – дип, исе китеп, сөйләгән бер китабымны хәтеренә бикләп бара.* Ф.Шәфигуллин

**Бикләп бетерү** Онытылмаслык итеп бикләү, тулысынча, ахырга кадәр бикләү

**Бикләп җиткерү** Онытылмаслык итеп, ахырга кадәр бикләү

**Бикләп йөрү** Кат-кат кабатлап бикләү

**Бикләп карау** Бикләргә омтылу

**Бикләп кую** Алдан ук бикләү, мәңге онытылмаслык итеп бикләү

**Бикләп тору** Даими рәвештә бикләү

**Бикләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр бикләү

**Бикли бару** *к.* **бикләп бару**. --- *газета-журналларда укыган яки берәр төштә ишеткән һәр мәгълүматны хәтеренең аерым бер кирәгрәк түренә бикли бара, кызыксынуы торган саен көчәя төшә.* Р.Фәйзуллин

**Бикли башлау** Бикләргә тотыну

**Бикли язу** Шактый бикләү, бикләп бетерерлек булу

**БИКЛЕ** *с.* 1) Йозак белән бикләнгән; нәрсә белән дә булса, керә алмаслык итеп ябылган, йозакланган. *Капка бикле иде, [Камали] авыр гәүдәсе белән, ятып, күпме этәрсә дә ачылмады.* К.Нәҗми

2) *күч.* Үзалдына йомылган, аралашмый торган, читләшкән. *Миңа унҗиденче яшь бара инде; Күңел бикле, баян – сандыкта.* Ә.Баян

**БИКРӘ́ БАЛЫК** *и. зоол.* Мәрсин балыклар семьялыгына караган, уылдык чәчәр өчен күчеп яки өлешчә күчеп йөри торган, ите һәм уылдыгы кыйммәтле саналган эре ау балыгы; *русчасы*: **осётр**

**БИКСЕЗ** *с.* 1) Бикләнмәгән, ачык. *Биксез ишек янында тукталып калдык.* Казан утлары

2) Биге булмаган, бик куелмаган

**БИКЯР** *с. фар. к.* **бикәр.** *Шулай булгач, безнең менә хәзер Ленинга нигдидер төгәл, гади бәя бирергә тырышуыбыз, иләк белән су ташыган шикелле, бикяр эш түгелме?* Ә.Еники

**БИЛ** *и.* 1) Гәүдәнең күкрәк белән янбаш арасындагы нечкәреп торган өлеше. *Буе зифа, биле өзелә алырдай нечкә.* Г.Әпсәләмов. *Гел иелеп торатора, Галиулланың биле сызлый, күз аллары караңгылана башлады.* И.Гази. *Валия бер кулын Ярмөхәммәтнең муены астына куеп, икенчесен аның биленә салып, изрәп йоклый.* Р.Батулла. *Аның югалып калуыннан файдаланып, Көяз мыек Машаны биленнән эләктерде һәм, өертеп, уртага алып кереп тә китте.* И.Салахов

2) Киемнең билгә туры килгән урыны. *Зифа, озын буйлы хатын-кызларга җыйнак тегелгән күлмәк – туры*

*итәкле, кысасы тәнгә сыланып торган яки иркен күлмәк, шулай ук итәк тотылган киң юбка, клешлап «тулы клеш» яки «ярым клеш» тибында, билен бөреп теккән һәм плесселы, гофрелы юбкалар киярга тәкъдим ителә.* Йорт эшләре

3) Озынча әйберләрнең нечкәреп яки башка төс белән аерылып торган урта бер җире. *Аяк табаны билсез. Армиягә ярамый.* М.Җәлил. *Кызыл билле ак машина мине әкрен генә этеп алып бара башлады.* Г.Гомәр

4) *махс.* Хайван (гадәттә атның) аркасының ияр куела торган батынкы җире. *Ә мин әйтәм: – Малай булсын, исемен анда табарбыз, әле тумаган тайның билен сындырып куяр хәл юк, – дим.* Казан утлары

5) *геогр.* Ике тау түбәсе арасындагы батып торган урын

◊ **Бил бәйләү** *к.* **бил буу. Бил бөгү** 1) Бик тырышып, барлык көчен куеп эшләү; 2) Кемгә дә булса эшләү, хезмәт итү. *Ялланып, кемгәдер бил бөгү беркайчан да тиешле нәтиҗәгә ирештерә алмый.* М.Юныс; 3) Буйсыну, ихтыярында булу; 4) Ялыну, ялвару. **Бил буу** Нинди дә булса эшкә ныклап керешергә әзер булу (тору). **Билгә сугу** Кыен хәлгә калдыру. **Бил кузгалу** Кинәт бил авырта башлау; радикулиттан интегү. **Билсез калу** *сөйл.* Авыр эштән, бик күп йөрүдән бил сызлый башлау, янбаш сөякләре бик нык авырту, турая алмау. **Бил тиңентен** Бик тирән. *Төнге юлдаш, карга бил тиңентен бата-чума, зиратка кереп китә.* В.Нуриев

**БИ́Л АЛЫШУ** *ф.* 1) Бил турыннан кочып алып көрәшү. *Мәйданнан читтә, комда бил алышалар икән монда.* Т.Нәҗмиев

2) *күч.* Көрәшү, каршы тору. *Газазил көчләр бил алыша*

**БИЛӘВЕЧ** *и. к.* **биләү** III

**БИЛӘМ** *и.* Бер эшсез, максатсыз, өйдән-өйгә кереп, сөйләшеп утырып, бушка уздырылган вакыт. *Биләм бозау имезә.* Мәкаль. *Кичә Халисә урамга, бераз һава сулап кайту теләге белән, биләмгә чыкты.* Ә.Гадел. *Ул – иң ялкау, иң диндар, биләмгә, кунакка йөрүне генә ярата торган карчык.* А.Гыйләҗев

◊ **Биләмдә йөрү** Өйдән-өйгә кереп, кеше хәлләрен белеп, үз эчен бушатып, бер эшсез, максатсыз вакыт уздырып йөрү. *[Касыймхан:] Ирен көткән хатын биләмдә йөрми ул.* Т.Гыйззәт. *Дөресен генә әйткәндә, тиктомалдан каядыр биләмгә йөрүне ул өнәми дә.* Р.Кәрами

**БИЛӘМӘ** *и.* 1) Аерым кеше кулындагы күчми торган хосусый милек. *Бер җилкапканы кыю гына ачып, биләмә түрендәге ике катлы виллага кереп китте.* Т.Әйди. *Чокырның аргы ягында, Адиҗаннар турысында, Хәят әбинең биләмәсе иде.* К.Миңлебаев. *Егет, хәтта, үзенең булачак биләмәләрен карап, билгеләп йөри башлый.* Г.Гыйльман

2) Аерым илгә, өлкәгә, оешмага караган урыннар. *Мәскәү хөкүмәте әлеге Нугай Урдасы биләмәләренә 1650 елларга кадәр керергә җөрьәт итми.* М.Әхмәтҗанов. *Президентыбыз китүгә, район биләмәсенә урнашкан предприятиеләрдә, оешмаларда, акционерлык җәмгыятьләрендә, мәгариф, мәдәният йортларында һәм авылларда иң яхшы Яңа ел чыршысына игълан ителгән район конкурсына йомгак ясагач, акчалата премияләр билгеләнде.* Т.Нәҗмиев. *Мондагы кайбер авылларның аларга биләмәгә бирелүе дә язма истәлекләрдә шактый ачык чагылмана.* М.Госманов

**БИЛӘМЧЕ** *и.* **1**. Биләмдә күп йөрүче кеше; кешедән-кешегә йөреп, көнен бушка уздыручы кеше. *Тәртә башын яндырган Яндык-көйдек Теләнче Кара китән Биләмче.* Н.Исәнбәт. *Өйдә микән әле ул биләмче Миңнурый?!* А.Гыйләҗев

**2**. *с. мәгъ.* Биләмдә йөрергә ярата торган. *Кайдандыр ике-өч биләмче кырыкмыш килеп чыгып, байтал тирәсендә өерелеп, зур гауга чыгардылар, тешләшеп тибештеләр.* А.Хәлим

**БИЛӘН** *и.* Агач агызу өчен көйләнгән, яссы төпле, буялмаган баржа. *Галиулла абзыйны, білән куганда, бүрәнә басып үтерде.* Т.Гыйззәт

**БИЛӘНКЕ** I *и. сөйл.* 1) Авыр йөк күтәргәннән барлыкка килгән бил авыртуы, бил язылмау чире

2) *күч.* Биләмче. *Әйт, бәдбәхет, кайда --- йөрдең, әйт тизрәк, тәүфыйксыз, биләнке!* Ф.Сәйфи-Казанлы

◊ **Биләнке булу (биләнкегә сабышу)** Артык авыр күтәрү аркасында, хатын-кызның йөреше авыраеп, билен яза алмас хәлгә килү

**БИЛӘНКЕ** II *и. диал.* Алсу көрән төстәге, тозлап ашау өчен яраклы гөмбә; йөнтәс гөмбә; *русчасы:* **волнушка.** *Быел гөрездә булмады, биләнке генә тозладык.* Татар иле

**БИЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса ия булу, хуҗа булу. *Олыслар биләгән эре феодалларны «бәкләр» яки «биләр» һәм «әмирләр» дип йөрткәннәр.* Г.Дәүләтшин. *Югыйсә, шундый байлык биләп тә ярлы-ябагай белән туганлаша микән ул...* Г.Минский

2) Яулап, басып алу; буйсындыру. *Мәйдан ачылды яңа көчләргә: Кызыл байракны Бердәм кулга алып, Җирне биләргә...* М.Гафури

3) Нинди дә булса урынга урнашу, вазифа тоту, урынга хуҗа булу. *«Бердәмроссиялеләр» Россия Президенты Владимир Путинга партия рәисе вазифасын биләргә тәкъдим итәчәк.* Акчарлак. *Сөт-ит тапшыру буенча алдынгы урыннарның берсен билиләр.* Татарстан яшьләре. *Безнең ил тәмәке тартучылар буенча дөньяда 4 нче урынны били.* Мәдәни җомга

4) Билгеле бер территорияне алып тору. *Инде без төпләнәсе урынга килсәк, --- дүрт тарафлардан да адәм баласы үткесез тайга биләгән.* М.Хәсәнов. *Ул уникегә уналты метр чамасындагы мәйданны били.* Т.Нәҗмиев. *Республикада кышка чәчеп калдырган җир 790 мең гектардан артык мәйданны били икән.* Татарстан яшьләре

5) *күч.* Үзенә җәлеп итү, буйсындыру, чолгап алу (уйлар, хисләр һ.б.ш.). *Зәңгәр күктән җир йөзенә әйтерсең лә, кояш нурлары түгел, шатлык түгелә һәм бөтен тереклекнең күңелен били.* Р.Хафизова. *Яшь тән кайнарлыгы бөтен барлыгын били.* М.Галиев. *Тынтын өй эчен әнисенең рухы биләгән.* Н.Хәсәнов

6) *күч.* Үтмәскә, кермәскә тиеш урыннарга, акрынлап, аз-азлап үтү, үтеп

керү, чорнап алу. *Суык иң әүвәл аркаңы биләде, астан – өскә, өстән аска йөрде дә күзәнәкләрдән җылыны куып чыгарды, үзе җылы урынына оялады.* А.Гыйләҗев

**Биләп алу** Тоташ чолгау, тулысынча биләү. *Гаҗиләне кинәт курку хисе биләп алды.* Ә.Гаффар. *Мостафаны моңсу уйлар биләп алды.* Ф.Сафин. *Аның күңелен ниндидер ярсулы көй биләп алды.* Р.Хафизова

**Биләп бару** Аз-азлап, акрынлап биләү. *Зәңгәр күзле бу егет аның бөтен күңелен биләп бара иде...* Ф.Бәйрәмова. *Инглиз теле бөтен дөньяга ургылып тарала, яңадан-яңа илләрне һәм халыкларны биләп бара.* Р.Хәкимов

**Биләп бетерү** Күп җирне, тоташ басып алып биләү

**Биләп килү** Хәзерге вакытка кадәр биләү, еллар дәвамында биләү. *Ш.Галиев иҗатында яшьлек һәм мәхәббәт темасы һәрвакыт зур урын биләп килде.* Т.Галиуллин

**Биләп кую** Алдан биләү. --- *шулвакыт кырларның шәбрәкләрен һәм зурракларын, сайлап, үзләре өчен биләп куялар...* Х.Хәмидулла

**Биләп тору** Хәзерге вакытта, әле биләү; тирә-юньгә таралган булу. *Бу аның игътибарын һәммәсеннән озаграк биләп торды.* Ә.Фәйзи. *Фонтанлы бассейннары белән ул бөтен бер кварталны биләп тора.* С.Сөләйманова

**Биләп утыру** *к.* **биләп тору**. *Алексеевск – Кама буендагы тигез уйсулыкта ярыйсы ук зур мәйданны биләп утырган матур гына посёлок икән.* Г.Тавлин

**Били башлау** Биләргә тотыну. *Иябашның Әсәт бай белән алар Кырлай тегермәнен бергә били башлаганнар.* Ә.Фәйзи

**Били бару** *к.* **биләп бару**

**Били төшү** Тагын да бераз биләү

**БИЛӘ́Ү** II *ф.* 1) Сабыйны биләүгә урап, кысып бәйләп кую. *Ефәк нурын биләү итеп, Кояш мине биләгән.* Ә.Ерикәй. *Биләү – баланың тәртипле, тәрбияле булуының шарты.* С.Шәрипова. *Әниең сине тапкач, сөя-сөя, Апак биләүләргә биләгән.* Б.Рәхмәт

2) Гомумән бала табып, тәрбияләп үстерү. *Әниебез өч бала били: Зәйнәп исемлесе бик бәләкәй чакта ук дөнья куя; апам Фәүзия исән-сау; без фәкыйрегез, шыгырдап алгаласа да, яши бирә.* К.Миңлебаев

3) Гомумән урау, кысып бәйләү. *Комач белән биләде дә Алып китте елгага.* Ф.Әмирхан

**Биләп алу** Тиз генә биләү

**Биләп бетерү** Биләү эшен төгәлләү; нык итеп биләү

**Биләп кую** Биләнгән хәлгә китерү; алдан биләү. *Мине кемдер --- биләп куйды ирексезләп.* М.Гафури

**Биләп тору** Әле, хәзерге вакытта биләү

**Били башлау** Биләргә тотыну

**Били бирү** Биләвен дәвам итү

**БИЛӘ́Ү** III *и.* 1) Яшь баланы төрә торган чүпрәк, җәймә. *Биләүгә төргән баланы беләгенә салып алган яшь ирне мин үзем күрдем.* М.Кәрим. *Мин җылысын тойдым сабыемның, – Биләвендә ята беләгемдә.* Н.Сафина. *Мин аның биләвен сүтеп, кечкенә гәүдәчеген җентекләп капшап тикшердем.* Ватаным Татарстан. *Мөдәррис абый белән Гөлүсә апа гаиләсендә төпчек – дүртенче бала булып аваз салган нәни Гүзәл исә, биләүдә чакта ук, әнә шул гармун моңына кушылып елый да елый, елый да елый.* Мәдәни җомга

2) *куч.* Биләүләп төрелгән яшь бала. *Өйгә кергәч ул [хатын], биләвен ике куллап кочаклаган килеш, ишек төбендә тукталып калды.* Азат хатын

**БИЛӘҮЛЕ́ ПАР** *и.* Уҗым чәчкәнче башка культуралар биләгән пар җире. *Шулай итеп борчак – игенчелекне интенсивлаштыруда, биләүле пар системасында алыштыргысыз культура.* Социалистик Татарстан

**БИЛӘҮСӘ** *и. к.* **биләү** III. *Иргә барганчы, биләүсә әзерләмә.* Мәкаль. *Өлгерерсең, Сания, сиңа да җитәр. Балаңны кара, дип, үз уйларына үзе җавап бирде дә биләүсәләрен кызурак итеп, тырышыбрак урарга тотынды.* М.Әмир

◊ **Биләүсәдән чыкмау** Кеше карамагыннан чыкмау, ата-анага, кешегә салыну. *Сакалы биленә җиткән, әле дә биләүсәдән чыкмаган, анасы эшләп туйдыра*

**БИЛӘҮСӘ́ БАВЫ** *и.* Баланы биләүгә төргәч, кысып урап бәйләп куя торган бау, тасма

**БИЛБА́У** *и.* 1) Киемне бил турысыннан бәйләп куяр өчен, каештан, тукымадан һ.б.ш. нәрсәләрдән эшләнгән тар һәм озынча тасма, пута, кушак. *Аптырабрак торган Габдулланың билбауларын чишкәләр, бишмәтен һәм бүреген салдырдылар.* Ә.Апуш. *Тирмә белән учак арасында ак җиләнле, билбауларына төрле пычаклар аскан бавырчылар чабып йөри иде.* Р.Зәйдулла. *Тикшерергә килүчеләр чын ясау булып киенгәннәр: өсләрендә – яхшы тун, аякта – һәйбәт күн итек, билләрендә – билбау.* Г.Бәширов

2) Юбка, чалбар кебек киемнәрнең, кысып торсын өчен, бил турысына беркетелеп тегелә торган озынча тукыма

3) *спорт* Спортның айкидо, каратэ һ.б.ш. төрендә спортчыларның, осталыгы арта барып, уңышка ирешкәннәренә бирелә торган төрле төстәге (зәңгәр, шәмәхә, кара) тасма. *Мин сине кара билбау дип ишеттем, дөресме?* Ә.Хәбибуллин

4) *спорт* Татарча көрәштә билгә салып алыша торган киң тукыма. *Бүген билбау көрәше буенча илледән артык илдә федерация төзелгән.* А.Гафиятов

**БИ́ЛБИРМӘС** *с.* Җиңелми торган, зур осталыкка ирешкән (татарча көрәштә)

**БИ́Л БИРМӘҮ** *ф.* 1) *спорт* Татарча көрәштә: билдән алып егарга мөмкинлек бирмәү, җиңелмәү

2) *куч.* Бирәүгә дә буйсынмау; бер кеше каршысына да ялынып бармау. *Үз гомерендә берәүгә дә бил бирмәде.* Я.Зәнкиев

**БИЛГЕ** *и.* 1) Аерылып торсын өчен салынган тамга. *Археологлар маңгай турысында билге тишек булган тәкә башы да тапканнар.* Г.Гыйльманов. *Салкын чишмә суын эчкән саен Билге ясап барган талым бар.* Ә.Ерикәй. *Айсылу, цифр баганалары белән янәшә, карандаш белән ясаган ниндидер билгеләр күреп, елмаеп куйды.* Г.Бәширов

2) Хәбәр, сигнал бирү чарасы, символ. *Таң әтәче кычкыра – Аерылуның*

*билгесе.* М.Фәйзи. *Бу – сугышка чакыру билгесе.* М.Җәлил

3) Нәрсәне дә булса белгертә, сиздерә торган күренеш; галәмәт. *Табигатьтә яз билгеләре күренә башлады.* Г.Гобәй. *Дугласның йөзендә бу юлы авыр уйлар билгесе сызылып калды сыман.* Р.Ишморат. *Сабыйларның күбесендә умыртка сөяге кыйшаю (сколиоз), сизелер-сизелмәс бөкре чыга башлау билгеләре күреп, йөрәгем әрни.* Сөембикә

4) Нәрсәне яки кемне дә булса танырга ярдәм итә торган характерлы сыйфат, үзлек, үзенчәлек. *Мансуров, гүя, Нәфисәнең йөзеннән үзе күрергә өмет иткән ниндидер бер яңа билге эзләгән сыман, аңа озаклап карап торды.* Г.Бәширов. *Француз телен белү, Париж шәһәрен күрүләр һәрбер алдынгы рус кешесе өчен культура билгесе итеп саналган.* Н.Исәнбәт. *Менә-менә хәтернең алгы ягында гына бу охшашлы сурәт тора, ләкин илле еллык үлем, кабер тереклеге ул сурәтнең исемен оныттырган, билгеләрен җуйган.* Ф.Әмирхан

5) Тышкы йогынты тәэсирен күрсәтә торган эз. --- *күгәрү билгесе төшә башлады.* Ш.Усманов. *Эштән кайткач та, [хуҗа] атларның ял асларын, муеннарын тотып карый. Әгәр дә гадәттән тыш тирләү яки камыт тию билгесе була калса, ул атны йөртүчегә яхшы сүз юк.* М.Гафури

6) Билгеле бер шартлы мәгънә белдергән тамга. *Вахит Хөҗҗәтович, әллә берниндиг дә тыныш билгесе куймыйм микән, ә?* М.Галиев. *Бара-тора, стеналардагы + билгеләре бозыла, төртеп күрсәтүләр бетә.* Г.Гобәй. *Язу билгесе икәнлеген белмәгән кешегә иероглифның йорт салыр өчен ясалган сызык булып тоелуы мөмкин.* М.Юныс

7) Келәймә, тамга. *Фирма, фабрика билгесе*

8) Биш баллы системада белем яки тәртип дәрәҗәсен билгели торган бәяләмә. *Ведомостька әле нибары унбер билге куелган.* М.Мәһдиев. *Хәзер менә, «начар» билгесе булгач, мине пионерга алмаслар инде, дип хафалана.* Р.Хафизова. *– Менә бабай, монда бер генә «урта» билгесе дә, «яхшы» билгесе дә юк, һәммәсе – «отлично», – ди.* М.Гали

9) Значок. *Иңбашындагы погоннарына һәм җиз билгеләренә караганда, егет танкист иде.* Ә.Еники. *Андыйларга, бөтен шартына туры китереп, честь бирергә, күкрәк билгеңнең номерын атап, үзең турында белешмә ирештерергә туры килә.* Ф.Хуҗин

10) Билгеле бер нәрсәнең тамга булып хезмәт итә торган сурәте, рәсеме. *Йортым ишеген саклап, сакчы йөри, җиңнәрендә – «сөңге» билгесе.* М.Җәлил. *Иткән тәҗәссем Халыкның көчен Бу Кызыл байрак – Шуның билгесе.* М.Гафури

11) *тар.* Укый-яза белмәүчеләр өчен имза ролен үти торган тамга, сурәт, рәсем. *Көрәк билгесе. Сәнәк билгесе*

12) Кемнең дә булса теләген, боерыгын белдереп, берәр нәрсә турында баш, кул хәрәкәте белән кисәтеп ясалган ишарә. *Вахит, үзенең алыну билгесе иттереп, кулын гына селки.* М.Гафури. *Миңа карап тор, мин сиңа билге бирермен.* Д.Аппакова

**БИЛГЕЛӘМӘ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса эчтәлеген, асылын, төп сыйфатын ачып бирә торган, төгәл һәм кыска итеп әйтелгән аңлатма. *Һәм тарихчыбыз да мондый билгеләмәдән, озакламый, баш тарта.* С.Алишев. *Вертикаль почмаклар турындагы мәсьәләне тикшергәндә, без --- вертикаль почмакларга билгеләмә бирдек.* Геометрия. *Грамматик билгеләмә. Математик билгеләмә*

2) Билге, тамга. *Бер төрдән булган мәкальләрне сайлап җыярга кирәк булса, --- бөтен китапны укып чыгарга, анда үзеңә билгеләмәләр ясап, --- меңнәрчә юлны күчереп алырга туры килә.* Н.Исәнбәт. *Муен һәм бил кебек билгеләмәләрне инкяр иткән шушы өч түгәрәк, коридор буйлап тәгәрәп кенә килде дә, бильярд өстәле янында туктап калды.* М.Галиев

**БИЛГЕЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **билгеләү.** *Билгеләнде сугыш җире итеп басу, Уңай булыр анда, диеп, көч сынашу...* М.Гафури. *Билгеләнгән җыелышны кичектерергә ярамый.* Т.Гыйззәт. *Иртәгәсе көнне, главный мастерской һәм тимер юл участогы эшчеләре, забастовка өчен билгеләнгән өч көнне көтмичә үк, эш ташладылар.* Ш.Камал

2) Фактлардан, хәлләрдән чыгып аңлатылу, ачыклану. *Көчләр билгеләнмәгән, Кем башкара, ни эшне?* Ш.Камал. *Туйга ничә чана, ничә кеше киләчәге билгеләнде.* Г.Ибраһимов. *Дөньяда ир-егетнең кешелеге, егетлеге, иң беренче чиратта, аның хатын-кызга мөнәсәбәте белән билгеләнә.* Р.Хафизова

3) Тоелып, беленеп тору. --- *анда әле зәгыйфь билгеләнгән темалар туды.* Г.Нигъмәти

4) Берәр эшкә куелу, вазифа йөкләтелү. *Легионның командирлыгына Белевич билгеләнде.* Ш.Усманов. *Ильченко икенче ротага билгеләнгән иде.* Г.Әпсәләмов. *Озак та үтмәде, әни Казаннан кырык чакрымнар чамасы арадагы Шәле авылының башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгеләнде.* А.Расих

5) Аерып куелу, аталу, багышлану. *18 нче елның дүртенче апрель көне Оренбург тарихында зур канлы тап белән билгеләнде.* Ш.Усманов. *Шәйхаттар бабай, Шәехтайны гына түгел, сабанга билгеләнгән өч атның һәркайсын тәрбияләүдә тырышлык күрсәтте.* Г.Гобәй. *Старостаның бер кулында яшел чапан – бусы беренче килгәнгә, икенче кулында зур сөлге – бусы икенче килгәнгә билгеләнгән.* Г.Ибраһимов

**Билгеләнә бару** *к.* **билгеләнеп бару**

**Билгеләнә башлау** Билгеләнергә тотыну. *Шул борылыш билгеләнә башлау белән, күрәсең, дипломатия өлкәсендә ниндидер җанлану күзәтелә.* М.Гайнетдинов

**Билгеләнә төшү** Тагын да билгеләнү

**Билгеләнеп алу** Кыска гына вакытка билгеләнү

**Билгеләнеп бару** Бер-бер артлы билгеләнү; һәрберсе билгеләнү

**Билгеләнеп бетү** Тәмам, ахырга кадәр билгеләнү. *Нәтиҗәдә, тикшерү объектының чикләре төгәл билгеләнеп бетми кала, бер үк әсәрне музыка белгечләре – бер аспекттан, ә филологлар икенче аспекттан чыгып тикшерәләр.* К.Миңнуллин. --- *җөп бетемнәр йомшак һәм көчсез булалар:*

*боларда строфадагы (төргәктәге) сүз сөреше белән икенче кисәк алдан билгеләнеп бетә.* Х.Туфан

**Билгеләнеп җитү** Тәмам ачыклану. *Күренгәнчә, 1921–1924 еллардагы эшчәнлек нәтиҗәсендә, ТТГКның юнәлешләре, бурыч һәм максатлары тулысынча билгеләнеп җитә.* З.Кириллова

**Билгеләнеп калу** Билгеләнергә өлгерү. --- *башы Урал тауларының көньяк районнарыннан – Түбән Иделгә, аннан Идел аша Тынга (Донга) кыпчак кабиләләренең кубарылып күчүе белән билгеләнеп кала.* Т.Кәримов

**Билгеләнеп килү** Һәрвакыт, даими билгеләнү

**Билгеләнеп китү** *к.* **билгеләнеп узу**

**Билгеләнеп куелу** Алдан ук билгеләнгән булу. *Ерткыч поручикның бармагын тешләп өзгәннән соң, инде аның алдагы үсеш юлы нык билгеләнеп куела.* Г.Нигъмәти. *Кеше тормышында барлык нәрсәләр алдан билгеләнеп куела, аның үзеннән гомер юлында очраган хәлләрдән дөрес һәм тиешенчә файдалана белү генә таләп ителә.* Г.Тавлин

**Билгеләнеп тору** Берсе беткәч, икенчесе билгеләнү; һәрвакыт билгеләнү

**Билгеләнеп узу** Билгеле итү, үткәрелү. *Юбилей, зур тантана белән, бөтен Русиядә билгеләнеп уза, Г.Ибраһимовка хәтта Хезмәт Герое дәрәҗәсе дә бирелә.* Рәмзи Вәлиев

**Билгеләнеп үтелү** Беррәттән, сүз уңаенда билгеләнү. *Казан арты сөйләшләреннән, ул тагын бары Лаеш сөйләшендә генә билгеләнеп үтелгән.* Д.Рамазанова

**БИЛГЕЛӘ́Ү** *ф.* **1**. 1) Билге, тамга салу. *Хәзер, һич кичекмәстән, аның каян кая кадәр сузылганлыгын билгеләргә кирәк.* Г.Әпсәләмов. *А ноктасыннан аска таба 33 сантиметр (үлчәү буенча арка ягының билгә кадәр озынлыгы) үлчиләр һәм Т хәрефе белән билгелиләр.* Йорт эшләре

2) Билгеле бер максат белән атап, аерып, бүлеп кую. *Ләкин, моның өчен, табигатьнең үзе билгеләгән, моның үзенә генә махсус кебек булган әллә нинди юлы бар шикелле тоела.* Г.Ибраһимов

3) Кемнең дә булса карамагына, җаваплылыгына, файдалануына бирү, тапшыру. *Атларны төнлә басуда саклар өчен, өч пионер билгеләргә.* Г.Гобәй

4) Нәрсәнең дә булса микъдарын, вакытын, урынын, максатын һәм бурычларын ачыклау; хәл кылу, чишү. *Иртәгә иптәшләрнең һәммәсен җыйнап, кайчан китерү һәм ничә ат белән бару кирәклекне билгеләрбез.* Ш.Камал. *Пленумда язучылар конкрет иҗат бурычлары билгеләделәр.* М.Җәлил. *Гөлнур Гөлләрне күз алдына китерде һәм, елмаеп, өстәде: – Без аның урынын да билгеләдек инде.* Г.Әпсәләмов

5) Исәпләү, чамалау, күз алдына китерү; нәрсәне дә булса күрсәтү, ачыклау. *Көнен билгеләп, чыгарган карарлары белән танышып китәрбез.* Т.Гыйззәт. *Мәскәүдә узган ике очрашуда җиңүчене соңгы минутларда гына билгеләргә туры килде.* Шәһри Казан. *Вузларның, укыту һәм тикшеренү эшләренә, аларның дөнья күләмендә казанган дәрәҗәсенә карап, рейтингларын билгеләү күптәннән килә.* Мәгърифәт

6) Нинди дә булса хезмәткә, эшкә, укуга һ.б.ш.га урнаштыру, вазифа йөкләү, кую, җибәрү. *Мине күрше авылга, сигезеллык Олы Бортас мәктәбенә директор итеп билгеләделәр.* З.Рәмиев. *Хәзер үзен Тәтеш шәһәренә татар балаларын русча укытырга билгеләгәннәр, берничә көннән шунда китәргә җыена.* Т.Гыйззәт. *Карлыгачны булачак бакчаның звено башлыгы итеп билгеләделәр.* Г.Бәширов

**2. билгеләп** *рәв. мәгъ.* Ачык кына, төгәл, тәгаен. *Ләкин ул турыда хәзер мин, билгеләп, бернәрсә дә әйтә алмыйм.* Ш.Камал

**Билгеләп алу** Тиз генә билгеләү

**Билгеләп ату** Ашыгып, тиз-тиз билгеләү

**Билгеләп бару** Берсен дә төшереп калдырмыйча, һәр очракны аерым-аерым билгеләү. *Гидравликага корылган насосларны күздән кичерде, кирәкле мәгълүматларны аерым кәгазьгә билгеләп барды.* Н.Хәсәнов. *Алар моны [җилсезлекне] ганимәт белеп, юлчылар артыннан берәм-берәм йокыга китәләр, тик, йолдызларга карап, көймәнең юлын билгеләп бара торган койрыкчы гына уяу кала.* Г.Ибраһимов. *Төп сыйфатларны язучы текстта да аерып билгеләп бара.* Д.Заһидуллина

**Билгеләп бетерү** Билгеләү эшен ахырга кадәр төгәлләү, барысын да билгеләү. *Мин синең шикелле --- түгел. Син генә ул һәммә шакмакларны билгеләп бетергән.* Г.Камал

**Билгеләп җиткерү** Тәмам, төгәл ачыклау. *Мәрфуга апага һәм үзем билгеләп җиткерә алмый торган әллә кемнәргә ачуым килде.* Ф.Әмирхан

**Билгеләп йөрү** Әлеге вакытта нәрсәне дә булса билгеләү белән мәшгуль булу. *Фәләхнең моңа кадәр дә соңга калып кайткан чаклары бар, хәтта бер тапкыр, үз урынбасарыннан берәүнең туган көнен «билгеләп» йөреп, төнге бер тулганда гына кайтып кергән иде.* В.Нуруллин

**Билгеләп килү** Электән үк дәвамлы рәвештә билгеләү. *Безгә каршы килүчеләр, шуны белеп, үзләренең шуңар карата мөнәсәбәтләрен билгеләп килергә тиешләр!* С.Баттал

**Билгеләп китү** Сүз уңаенда аерып күрсәтү. *Милли Мәҗлес рәисе академик М.Алескеров та, Премьер-министр урынбасары, күренекле язучы Элчин Әфәндиев та, сөйләшүләр вакытында, татар халкының латин графикасына күчү теләген берсүзсез хупладылар, бу мәсьәләнең, хәл ителгән очракта, Татарстан мөстәкыйльлеген ныгытуда зур бер адым булачагын билгеләп киттеләр.* Р.Миңнуллин. *Халык күңеленә яшь язучы Хәниф Хәйруллинның «Канатлар талмасын» дигән беренче әсәре дә хуш килгән икән. «Анысын да ничектер билгеләп китәргә иде бит!» – дигән сүз чыкты.* Х.Сарьян

**Билгеләп кую** Алдан билгеләү, билгеләргә өлгерү. *Әсәрдә ике «фикер»нең нинди характерда күрсәтеләчәген алдан билгеләп куйганнар.* Г.Нигъмәти. *[Бәдри:] Менә шуны билгеләп куясы иде.* М.Фәйзи. *Егетне, шунда ук, туган авылы Көмешлесу мәктәбенә укыту эше буенча мөдир итеп билгеләп тә куйдылар.* Я.Зәнкиев

**Билгеләп тору** 1) Даими рәвештә билгеләү

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләгән моментта билгеләү

3) Алдан планлаштыру. *Мәсәлән, үзенең ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын – Гөлбикәсенә, мәрҗәннән җыеп эшләнгән әдрәс астарлы кашмау белән чәч кабын – Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора.* Ә.Еники

**Билгеләп узу** 1) Мактауга, бүләкләүгә лаек, дип табу

2) Кемнең дә булса хөрмәтенә яки нәрсәне дә булса искә алып, тантаналы кичә үткәрү, бәйрәм итү. *Халыкка стимул ясап, намуслы хезмәтен билгеләп узсак, начар булмас, минемчә.* Г.Ахунов

3) Сүз уңаенда әйтү, язу. *Сүз уңаеннан билгеләп узыйк: сугыш чорында шигырь чаң булып кына яңгырамады, меңләгән укучылары аша дошман йөрәгенә ук булып кадалды, бәгырен ут булып өтте...* Р.Фәйзуллин. *Шулай да бу чорда, инде билгеләп узылганча, татар музыкаль фольклорын чын-чынлап өйрәнә башлауда рус һәм чит ил галимнәре зур роль уйнадылар.* К.Миңнуллин

**Билгеләп үтү** *к.* **билгеләп узу.** *Соңгы елларда күп кенә бакчаларда Белем көнен, Өлкәннәр көнен билгеләп үтү дә традициягә кереп бара.* К.Закирова

**Билгеләп чыгу** Берәмтекләп, һәрберсен билгеләү; башыннан ахырына кадәр билгеләү. *[Һәр җан иясе] Үзе яшәгән тирәлекнең чикләрен билгеләп чыга.* М.Галиев

**Билгеләп яту** Әле, хәзерге вакытта билгеләү. *Туган көнне билгеләп ятасызмы?* Т.Галиуллин

**Билгели бару** Һәрберсен, булган берсен, даими билгеләү

**Билгели килү** Элек-электән, һәрвакыт билгеләү

**БИЛГЕЛЕ** *с.* **1**. 1) Билге салынган, тамгасы булган. *Билгеле терлек-туар. Билгеле кош-корт*

2) Яхшы таныш, мәгълүм. *Ротмистр боларны туктатырга уйлады, ләкин --- һәммәсе билгеле, таныш байлар булганга, борчылырга сәбәп тапмады.* Г.Ибраһимов

3) Анык, ап-ачык, ачык аңлаешлы, исбатланган, һәркемгә мәгълүм. *Хәятнең бүгенге күренеше Михаилда тагын теге тойгыны уятты, һәм бу юлы инде кискенрәк һәм билгелерәк итеп уятты.* Ф.Әмирхан. *Шулай ук мәкальләрнең, сәнгать әсәре булулары белән бергә, тормышта да практик роль уйнаулары – билгеле мәсьәлә.* Н.Исәнбәт

4) Нинди дә булса берәр эш эзлекле рәвештә башкарылып килгән, махсус билгеләнгән (вакытка карата). *Билгеле бер тарихи чор алына.* М.Җәлил. *Шулай, көннең билгеле бер вакытында, төрле юллар, төрле хәйләләр белән, болынга, куе таллар эченә җыелалар.* Г.Ибраһимов

5) Мәгълүм (бер), аерым (бер), күпмедер, беркадәр. *Ул – билгеле заман, билгеле урын, билгеле халык, билгеле сыйныф кешесе түгел.* Г.Нигъмәти. *Шул нигездә аңарда бу чорда билгеле бер каршылыклар булуын да күрәбез.* М.Җәлил. *Бу хәл – билгеле бер даирәнең яман ниятеннән генә туган нәрсә түгел.* Ф.Әмирхан

6) Күренекле, атаклы, танылган, мәшһүр. *Оригиналь операларның партияләрен үтәүгә, С.Садыйкова, Г.Кайбицкая, М.Рахманкулова, А.Измайлова, Булат Маннапов кебек, электән сәхнәдә озак эшләгән билгеле җырчылардан тыш, Ф.Насретдинов, Сәйфетдинов, Бичурин, Зәбирова, Сакаева, Халитова һ.б. кебек яшь җырчылар да тартылдылар.* М.Җәлил. *Аксак Тимер – тарихта билгеле урын алган тарихи шәхес, бөек полководец.* Р.Әмирхан

**2.** *хәб. функ.* Аңлашыла, сизелеп тора, дигән мәгънәдә. *Кичә большевиклар өндәмәсен таратуда синең кулың уйнаганы миңа билгеле.* Т.Гыйззәт. *Иптәшләре арасында Баязитның соңгы заманда гадәттән тыш өметсезлеккә, пессимизмга чумуы билгеле иде.* Г.Ибраһимов. *Димәк, авыру икәне билгеле.* М.Җәлил

**3.** *кер. сүз* Үзеннән-үзе аңлашылганча, бәхәссез, әлбәттә. *Билгеле, шуларныкы, үзләренчә, миңа яманлык теләүләредер, ләкин алар ялгышалар.* Т.Гыйззәт. *Билгеле, мин капкынга төшкән күсе шикелле акыра, тыпырчына башладым.* М.Әмир. *Зарланып тормыйсың, билгеле.* Ф.Сафин. *Билгеле, алар үзләре яшәгән планетаны «Җир» дип атамыйлар иде.* Тәмуг чәчәге

**БИЛГЕЛЕ́ БУЛГАНЧА** *кер. сүз* Һәркем белүенчә. *Билгеле булганча, [әдәби образларны] иҗади файдалану – лектор, пропагандист, агитатор эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтүдә әһәмиятле шартларның берсе.* Социалистик Татарстан

**БИЛГЕЛЕЛЕК** *и.* 1) Билгеле булу. *Билгелелек дәрәҗәсе*

2) *линг.* Аерым грамматик чаралар белән белдерелгән билгеле булу мәгънә төсмере. *Эшнең туры объекты, шулай ук, төшем килешендәге исем белән дә белдерелә, бу очракта килешнең мәгънәсенә билгелелек мәгънә төсмере өстәлә.* Ф.Хисамова. *Татар теленең иялек килеше татарча өйрәнүчеләр өчен берникадәр кыенлык тудыра. Монда, төшем килешендәге кебек, килеш формасы билгелелек яки билгесезлек төсмеренә карап куела.* Р.Юсупов

**БИЛГЕСЕЗ** *с.* **1.** 1) Билге, тамга салынмаган, билгесе, тамгасы булмаган. *Кичке сигезләр тирәсендә, билгесез машина хуҗасы берьюлы дүрт җәяүлене бәрдереп китә.* Акчарлак

2) Таныш булмаган, чит, ят. *Мәрьям, бу билгесез адәмне тану өчен, кулы белән аның беләкләрен, йөзен капшый башлады.* Г.Ибраһимов. *Бер ягына – кызыл йолдыз, икенче ягына якорь төшерелгән бу зур соры таш астында Бөгелмә ревкомының членнары Петровская белән Просвиркин иптәшләрнең һәм янә бер билгесез матросның гәүдәләре ята.* Г.Әпсәләмов. *Билгесез яшь егетнең язмышы җырлаучыларга да, тыңлап торучыларга да чамасыз кызганыч иде.* А.Шамов

3) Билгеле булмаган, өйрәнелмәгән, тикшерелмәгән; мәгълүм түгел. *Боларда чит, билгесез галәмгә, «тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән» яшәргә омтылыш та бар.* Г.Нигъмәти. *Бу – моңарчы билгесез дөньяны ачу, шуның белән йотылып, онытылып яшәү.* Ә.Фәйзи. *Алар бу билгесез планетага төш вакытында килеп төштеләр.* Р.Мөхәммәдиев

4) Анык, ачык булмаган. *Аннары, йөк машинасына көрәк белән төягәндә чәчелгән акчаларны кесәләренә тутырып, билгесез юнәлештә китеп юк*

*булдылар.* З.Мәхмүди. *Бөтен тәнемне билгесез тревога чолгады.* М.Әмир

**2.** *хәб. функ.* Билгеле түгел, берәү дә белми. *Сахраларны яңгыратып, авыр туп арбалары кай җиргә барып тукталыр, әлегә билгесез.* Һ.Такташ. *Яңгырның күпмегә сузыласы билгесез, аяз булып килгән җәйдә аны көтмәгәннәр дә иде, синоптиклар да аны кичтән хәбәр итмәде.* Г.Ахунов

**3.** *и. мәгъ. мат.* Эзләнелә торган, табылырга тиеш булган зурлык. *Билгесезне билгеле (саннар) аркылы белеп була.* Һ.Такташ

**БИЛГЕСЕЗЛЕК** *и.* 1) Ачык, төгәл булмаган хәл, халәт. *Аякларым атлаган саен хәлсезләнә бара, бугазыма утырган аянычбилгесезлек, олы хәвеф төере сулыш алырга ирек бирми.* К.Миңлебаев. *Шул да җиткән – йотмас өчен Билгесезлек дигән упкын.* Н.Нәҗми. *Иң кыены – беренче адым: алда торган билгесезлек күңелгә бер минут тынычлык бирми.* И.Гази

2) *лингв.* Аерым грамматик чаралар белән белдерелгән билгесез булу мәгънә төсмере. *Баш килештәге исем туры объект мөнәсәбәтен билгесезлек төсмере белән белдерә һәм, һәрчак, үзе ачыклаган фигыль белән янәшә килә.* Ф.Хисамова

**БИЛГЕСЕЗЛЕ́К АЛМАШЛЫГЫ** *и.* Гомуми генә, якынча, төгәл ачыкланмаган, билгесез булуны белдерә торган алмашлык төре (мәс., *кемдер, нәрсәдер, кайдадыр, әллә кем, әллә нинди*). *Телебездәге билгесезлек алмашлыклары – барысы да төрле юллар белән ясалган алмашлыклар, һәм алмашлыкларның бу төре тел үсеше процессында шулай ук соңрак барлыкка килгән, дип уйларга нигез бар.* Ф.Хисамова

**БИЛДӘК** *и. диал.* Нәрсәнең дә булса нечкә, тараеп килгән җире, биле; билдәмә

**БИЛДӘМӘ** *и.* 1) Түшкәнең бил тирәсе; югары сыйфатлы ит. *Ардан ерак түгел ит кибетләре, симез сарык билдәмәләре белән тулы арбалар күренә.* Г.Ибраһимов. *Азык-төлек кибетенә кереп, сарык итенең билдәмәсен сайлатып алдым...* М.Мәһдиев. *Пешерү алдыннан, дуңгыз баласын кисәкләргә бүләргә: башын кисеп алырга, тушны бөер турысыннан (билдәмәсеннән) аркылыга кисәргә, һәр өлешне сырт сөягеннән тагын урталай ярырга кирәк.* Йорт эшләре

2) *диал.* Киемнең бил турысы

3) *диал.* Билбау. --- *үзара сөйләшә-сөйләшә, бер-берсенә булыша-булыша, эчке һәм тышкы күлмәкне, күкрәкчәне, билдәмәне тектеләр.* Гөлшаһидә

**БИЛЕК** *и. тар.* Би дәрәҗәсе, би урыны, би булу. *Иләмән, әлегә, билеккә күз кыздырмый бугай, тик алдагысын кем белә?* Р.Зәйдулла

**БИЛЕТ** *и. фр.* 1) Гадәттә, түләүле һәм нәрсә белән дә булса файдаланырга хокук бирә торган вакытлы документ. *Андыйларга 9 сум 30 тиенлек самолёт билеты – ул азатлык кәгазе.* К.Кәримов. *Барыбыз да эшкә җигелдек, безнең арада моңарчы булмаган татулык һәм бердәмлек хөкем сөрде: кем, билетлар язып, аларга мәктәпнең мөһерен суга, кемдер ул билетларны сатып торачак, кемдер ишек төбендә контролёр булачак, кемдер гардеробта киеем кабул итәчәк.* К.Миңлебаев. *Егет трамвайга керү белән билет алды да тәрәзә янына җайлабрак утырды.* Р.Кәрами

2) Нинди дә булса оешма, партия әгъзасы булуны күрсәткән, аерым бурыч һәм вазифаларны билгели торган документ. *Хәзергә күкрәк кесәсендә партия билеты йөртмәсә дә, йөрәге белән күптән чын коммунист инде [Габитов].* К.Фәсәхов, А.Сәлахетдинов. *Хәтта миңа, бераз вакыт, комсомол билетымнан аерылып торырга да туры килде.* М.Әмир. *Шәрәфи әгъзалык билетын күрсәткәч, ишек ике якка аерылды.* Г.Ибраһимов

3) Кәгазь акча билгесе; кыйммәте булган кәгазь. *Кыз өенә кәгазь алып кайта, тик ул акча булып чыкмый, бернигә ярамаган отыш билеты булып чыга.* Г.Нигъмәти

4) Имтихан тапшыручыга җавап бирү өчен сораулар язылган кәгазь. *Алган билетым икәү булып чыкканын абайлаганда, аскы билетны өстәлгә кире куйганда, профессор, катгый рәвештә: – Билетларның икесен дә куегыз. Икенче тапкыр килерсез, – диде.* К.Миңлебаев

**БИЛИНГВ** *и. лат.* Ике телне дә камил белгән һәм ике телдән дә файдаланган кеше. *Ике телне камил белгән кешеләр, заманча итеп әйтсәк – билингвлар, Җир шарындагы халыкның 50 процентын били икән.* Мәгърифәт

**БИ́Л КАЕШЫ** *и.* Билне буар өчен, каештан эшләнгән билбау. *Галимнең бил каешында, хәтта, ялтырап торган монте-кристо белән хәнҗәр дә бар иде.* Г.Әпсәләмов

**БИЛЛӘП** *рәв.* Бил турысын тар итеп, билле итеп. *Бүген императрица башында, таҗ түгел, бизәкләнеп бәйләнгән матур калфак иде, утыртма якасына энҗеләр тезелгән, билләп тегелгән алсу күлмәге – күзне камаштырырлык.* М.Хәбибуллин

**БИ́ЛЛӘҺИ** *ы. гар.* Нинди дә булса гамәлнең дөреслеген раслау өчен әйтелә торган ант сүзе, чыннан да. *Юк, Фәгыйлә, юк, моннан соң андый сүзләрне валлаһи сөйләмәбез, билләһи сөйләмәбез, җир упсын – сөйләмәбез...* М.Әмир. *Билләһи, дип әйтәм, бу консерваторияләр, театрлар, концерт заллары безнең авылда булса, мин шуларда, ыштан балагы белән инештә маймыч тоткан кебек, үз малай булып үссәм, кем чыгар иде миннән!* Р.Вәлиев. *Оят, билләһи! Яшь гомереңне җәлләмичә, сузыл да үләргә ят инде.* Н.Гыйматдинова. *Әй түгел, музей, билләһи.* Сөембикә

**БИЛЛЕ** *с.* 1) Киемнең бил турысы тарайтылган, билгә сыланып торган, билләнеп торган. *Аның башында – каракүл озынча бүрек, өстендә нечкә билле, күкрәге, якасы укалы бишмәт иде.* Г.Ибраһимов

2) Уртасы икенче төс белән аерылып торган. *Кайберсе – бармак сыман озынча кызыл билле прәннек, кайберсе – сәдака итеп, ярты тиен яки бер тиен бакыр тоттыргалап чыгардылар.* Ә.Фәйзи

**БИЛЛЕК** *и.* 1) Киемнең бил турысы яки бил турысына беркетеп куелган өстәмә тукыма кисәге. *Гадәте буенча, озын итәкле киң күлмәгенең бил-*

*леген ыштан бөрмәсенә кыстырган Миңлениса карчык, тәгәрәгән туп шикелле, идәндә йөрде.* С.Рафиков

2) Эшлеянең аркылы каешлары

**БИЛЛИОН** *сан фр.* Рус, француз, америка системасында – тугыз нульле, инглиз системасында унике нульле берәмлек. *Килеп чыккан яңа сан (мең миллион) аерым исем белән – биллион --- дип атала.* Арифметика

**БИЛТӘЛӘНҮ** *ф. диал.* Чуалып бетү, киезләнү. *Кызның чәче билтәләнгән*

**Билтәләнә бару** Торган саен ныграк билтәләнү

**Билтәләнә башлау** Билтәләнергә тотыну

**Билтәләнә бирү** Билтәләнүен дәвам итү

**Билтәләнә төшү** Беркадәр билтәләнү

**Билтәләнеп бетү** Тәмам, бик нык билтәләнү *Өй эчендә көтелмәгән кунакларны чырае качкан, чәчләре билтәләнеп беткән, яшь, ләкин йончыган бер хатын каршы алды*. А.Расих

**Билтәләнеп китү** Кинәт билтәләнү

**Билтәләнеп тору** Билтәләнгән хәлдә булу

**Билтәләнеп чыгу** Билтәләнгән хәлгә килү

**БИЛТЕР** *и.* 1) Аяк табанының урта өлеше; аяк киеменең шул урынны каплап торган өлеше

2) *бор*. Бау, бәй. *Билтердәге биш биям – Бишесе дә колынлый*. Ф.Урманче

**БИ́ЛФАРАЗ** *кер. сүз фар.* Ихтималлык, мөмкинлек турында уйлау, фараз итү; *к.* **бәрфараз**. *Ләкин, күңелендә мөселманлык гайрәте булган инсан өчен, коммунист кяфер Каган яисә яраннары, билфараз, яхшы әйтмәс, дип, уразаны калдыру – һич тә ярый торган эш түгел.* Ш.Камал

**БИ́ЛФИГЫЛЬ** *рәв. гар.* Чыннан да, чынлап торып. *Әхмәткә Диләфрүз хакынданиләр сөйләнгән булса, купшы бишмәт Габделбасыйр белән шул эшләрне билфигыль эшләп чыкты.* Ф.Әмирхан

**БИЛЧӘН** *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, чәнечкеле озынча яфраклы эре чүп үләне; *русчасы:* **осот.** *Мул булып үскән билчәннәрне, тигәнәкләрне ерып, ялантәпи үргә каршы йөгерү – үзе дә җиңел түгел.* Р.Хафизова. *Татарстанда яшелчә билчәне (каз билчәне), кыр билчәне, каклавыч, кытыршы билчән, саз билчәне үсә.* Ботаника

**БИЛЧӘЮ** *ф. диал.* 1) *к.* **бирчәю.** *Чибәр ханым Гөлнәзирәнең бераз билчәйгәнрәк кулын кысып, бу кем булды соң әле, дигәндәй, Дугласка карады.* Р.Ишморат

2) Буын чыгу, буын сөяге тоташкан урыныннан кузгалу, таю

**БИЛЬЯРД** *и. фр.<ит.* 1) Сукно тарттырылган махсус өстәлнең биегәеп килгән кырыйларындагы челтәр капчык кидерелгән тишекләргә шарлар бәреп төшереп уйный торган уен. *Газета-журнал караштырабыз, бильярд уйныйбыз, берәр партия шахмат сугабыз.* Р.Сибат. *Коллегалар һәм укытучылар белән, атнага ике тапкыр волейбол уйнарга йөрибез, бильярд уйныйбыз.* Илсаф. *Чит өлкәдән килгән кунаклар аның авызына гына карап тордылар. Бильярдта аңа гына җиңелделәр.* М.Галиев

2) Шул уен өчен махсус өстәл; шундый өстәле булган бүлмә. *Кичләрен иркен бильярд бүлмәсенә җыелышабыз.* Р.Вәлиев

**БИМАЗА** *и. фар.* Тынгысызлык, борчу, борчылу, мәшәкать. *Әкрен генә җылы мич башына менеп ята да, изрәп китеп, кемне дә бимаза кылмыйча, үзе дә белмичә, тыныч кына мәңгелек йокыга чума.* Г.Сәгыйров. *«Алга!» дибез яшәр өчен, Бимаза күрмәс өчен.* Ә.Ерикәй

**БИМАЗАЛА́У** *ф.* 1) Борчу, тынычсызлау; мәшәкать тудыру. *Төрле-төрле сораулар аның җанын бимазалады.* Н.Хәсәнов. *Ниләр бимазалый җаннарыңны. Ни әйтергә миңа телисең?* Ф.Тарханова

2) Комачаулау, мәшәкатьләү. *Аслары өскә килгерләре!.. Төн уртасында кеше бимазалап...* Ә.Фәйзи

**Бимазалап алу** Аз гына, кыска вакытлы бимазалау

**Бимазалап бетерү** Бик нык бимазалау. *--- үксез, каңгырып йөргән сабыйларны күз алдына китерә дә, күңеле әллә нишләп китә. Нигә шулай бу, дигән сораулар миен бимазалап бетерә.* Х.Камалов

**Бимазалап йөрү** 1) Туктаусыз, еш, әледән-әле бимазалау. *Юк-бар шигең белән олуг кешеләрне бимазалап йөрү килешерме?* Ф.Латыйфи. *Бу – аның, ишекне ябыгыз, бимазалап йөрмәгез, дигәнен аңлата иде.* М.Маликова

2) Җәфалау, тынычсызлау, борчу. *Көн буе сабан сөреп кайтып киләм, вакытсыз йөрмә әле, бимазалап.*М.Гафури

**Бимазалап кую** Кинәт бимазалау

**Бимазалап тору** Даими рәвештә, бертуктаусыз бимазалау. *Хәдичә кая баруын яшерә, димәк, кешене бимазалап торуның кирәге дә юк.* М.Хәсәнов. *Мине вәкил итеп җибәрделәр: күз-колак булырсың, янәсе, уңган-булган игенчеләрне бимазалап торырсың, ялкауланырга ирек бирмәссең.* К.Миңлебаев

**Бимазалап чыгу** Билгеле бер вакытның башыннан ахырына кадәр бимазалау; һәрберсен, һәркайсын бимазалау. *Ул [йорт иясе] бу өй хуҗаларын кич буе, хәтта төн буе бимазалап чыгарга мөмкин.* Г.Гыйльманов

**Бимазалый башлау** Бимазаларга керешү. *Наташаны соңгы арада бик еш бимазалый башлаган бу авыр уйлардан арындырырга кирәк икәнен яхшы аңлый ул.* А.Фәләхов

**Бимазалый бирү** Бимазалавын дәвам итү

**Бимазалый төшү** Тагын да бимазалау

**БИМАЗАЛЫ** *с.* 1) Тынгысыз; борчулы, тынычлыкны боза торган. *Авыл бимазалы йокыга талды.* А.Гыйләҗев

2) Мәшәкатьле, мәшәкать тудыра торган. *Кешеләр белән ачуланышмаска өйрәнгән Сөләйманга бу бимазалы урын һич тә кулай түгел иде*. Р.Батулла

**БИМЕТАЛЛ** *и. лат. махс.* **1.** Ике төрле металлдан торган, ягъни бер металлны икенчесе белән каплаган әйбер. *Төрле металлардан, мәсәлән, тимердән һәм җиздән ясалган ике озынча пластинканы заклёпкалар белән берберенә беркетсәк, биметалл пластинка хасил була.* Физика курсы

**2.** *с. мәгъ.* Икеләтә металлдан эшләнгән. *Биметалл акча системалары*

*вакытында, акча әйләнешенең гомуми эквиваленты һәм нигезе булып, бер үк вакытта ике металл – көмеш һәм алтын хезмәт иткән.* Политэкономия

**БИМЕТАЛЛИЗМ** *и. рус икът.* Бер үк вакытта ике төрле металлның (гадәттә алтын һәм көмешнең) әйләнештә йөрүенә нигезләнгән акча системасы

**БИНА** *и. гар.* 1) Төрле учреждениеләр, предприятиеләр һ.б.ш. урнаша торган зур йорт; шулай ук күп квартиралы торак йорт, архитектура корылмасы. *Бу көннәрдә, күрше колхозлар белән бер булып, җидееллык мәктәп бинасын эшләргә тотындылар.* Г.Бәширов. *Сугыш туктагач, 12 нче мәктәпне, төп бинасыннан госпитальне каядыр күчереп, янә үзебезгә бирделәр.* К.Миңлебаев. *Алда, аксыл рәшә эчендә, Бөгелмәнең биек таш йортлары, элеваторы, тегермән биналары, завод трубалары күренде.* Г.Әпсәләмов

2) Гомумән йорт, өй, корылма. *Иртәгәсен Муса, торып, ишегалдына чыгуга, һәр бинаның стеналарына, капка һәм тәрәзә башларына кара каймалы кайгы флаглары эленгән иде.* Ш.Маннур. *[Гәрәй байның] Әллә нинди буяп, чибәрләп салынган зур өйләре – авылның җиргә сеңеп юк булырга торган кебек мескен вә аяныч биналары уртасында башларын --- күккә күтәреп утыралар.* Г.Ибраһимов

**БИНАМАЗ** *с. фар.* Намаз укымый торган, намазсыз; гомумән дингә ышанмаучы. *Ул намаз укырга яратмый, сәҗдәгә бөгеләсе килми, аны «бинамаз» дип мыскыл итәләр.* Г.Ибраһимов

**БИНАХАК** *рәв. сөйл. гар.-фар.* Хаксызга, нахакка, урынсызга, гаепсезгә. *Якын кешемне бинахак рәнҗетүемә үкенү хисеме, тәгаен, ул мизгелдә дә әйтә алмаган булыр идем, хәзер дә әйтә алмамдыр...* К.Миңлебаев. *Бинахакка мине ябачакларын белмәдеңмени?!* Р.Кәрами. *Колхозлар оештыру эшендә активлык күрсәткән, сабый балалар белән уртак тел тапкан коммунист мәктәп директорының бернинди гөнаһсыз кулга алынганы, бинахак атылганы ачыклана.* Казан утлары

**БИНИҺАЯ** *с. гар.-фар.* **1**. Чиксез, очсыз-кырыйсыз, гаҗәеп зур яки санап бетергесез күп. *Менә алар белән берлектә, алар карамагында биниһая зур эшләр башкара алырсың син.* Р.Фәизов. *Хуҗаларның кайтып төшүе өйдә биниһая ыгы-зыгы кузгатты.* Ә.Фәйзи. *Хөрмәне өзеп кабарга теләүчеләр – кызымның артыннан сөйрәлүчеләр биниһая.* Т.Галиуллин

**2**. *рәв. мәгъ.* Бик, бик күп. *Биниһая зур башы, гөмбәз кадәр, Ни сәбәптәндер, башында фәс тә бар.* Г.Тукай. *Диңгездә бүген медузалар биниһая күп күренде.* К.Миңлебаев. *Әйтик, химик азык күрмәгән биниһая таза, сәламәт йөз ир берочтан гырлап йоклый, ди.* М.Галиев

**БИНОКЛЬ** *и. лат.* Ерактагы әйберне якынайтып, зурайтып күрсәтә торган оптик прибор. *Эскадрон командиры да бинокле белән шул калкулыкка таба карап тора иде.* А.Шамов. *Ул, нечкә каеш белән иңенә эленгән биноклен күзенә китереп, теге як ярга текәлде.* Г.Бәширов. *Ә аның янында кечерәк кенә бер малай үзе сөргән җирнең бер башына баскан да икенче башын бинокль аша күзәтә.* Г.Гобәй

**БИНОКУЛЯР** *с. лат.* Ике окулярлы, ике күз белән дә карый ала торган. *Алар дөньяны бинокуляр стереоскоп аша, ягъни күләмле итеп күрә.* Р.Фәизов

**БИНОМ** *и. лат. мат.* Ике алгебраик аңлатманың суммасы яки аермасы; ике буын. *Беренче буынның күрсәткече тапкырлана торган биномнар санына тигез.* Алгебра

**БИНТ** *и. нем.* Яра, шеш һ.б.ш. авырткан урыннарны бәйли торган, озын тасма рәвешендәге бәйләвеч марля. *Үзенә дип алган ак бинт белән Ул күкрәген бәйли Галимнең.* Ф.Кәрим. *Тәрәзә төбенә сөялгән агайның ачык якасыннан бинт белән уралган күкрәге агарып күренә.* Р.Вәлиев. *Ул эшен дәвам итте: авыруның кулын яхшылап чистартты, җәрәхәт тирәләренә йод сөртте, бинт белән бәйләде.* Р.Кәрами

**БИНТЛА́У** *ф.* Бинт белән тыгыз итеп урау, бәйләп кую

**Бинтлап кую** Бинтлаган хәлгә китерү

**Бинтлап тору** Әле, күз алдында бинтлау

**Бинтлап чыгу** Бөтен җирен дә, тоташ, башыннан ахырына кадәр бинтлау; барысын да бинтлау

**БИО-** *гр.* Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләргә ия беренче кисәк: 1) Яшәешкә, тормыш процессына караганлыгын күрсәтә, мәсәлән: *биогенетик, биосфера*

2) «Биологик» сүзе мәгънәсендә кулланыла, мәсәлән: *биофизика, биохимия, биостанция*

**БИО́ГРАФ** *и. рус* 1) Биографияләр төзүче. *Галимнәр, Демосфенның биографлары калдырган язмаларны җентекле өйрәнеп, борынгы Грециянең искиткеч ораторы --- тотлыгудан интеккән, дигән нәтиҗәгә килделәр.* Социалистик Татарстан

2) Кинематография үсеш алганчы, серияле фоторәсемнәр төшерә торган киноаппарат төре

**БИОГРАФИЗМ** *и. рус* Әдәби әсәргә биография элементларын күпләп кертү. *Романны биографизм белән куерак бизәүдән килеп чыгадыр.* М.Җәләлиева

**БИОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Кемнеңдер тормыш юлы тасвирламасы; тәрҗемәи хәл. *Һәм, шушы конкурсның шаукымы нәтиҗәсендәме, Англиядә чыга торган атналык бер газета минем кыскача биографиямне, фоторәсемемне һәм берничә шигыремне инглиз телендә укучыларга тәкъдим итте.* Ф.Яруллин. *Бу шәхеснең биографиясенә караган язма мәгълүматларны Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» һәм Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» исемле китапларыннан беркадәр табып була.* Татарстан. *Ул вакытта мин Гёте биографиясен беркадәр белсәм дә, гениаль шагыйрьнең тирә-юнендәге тормыш кызыкларын күрү өчен һич тә бушамаганын, гомеренең соңгы көннәрендә, шул сәбәпле, үкенеч белдерүен укымаган идем.* Казан утлары

2) *күч.* Үткән гомер, тормыш. *Кемнәр килеп кемнәр китми җиргә, Җир – ул биографияләр китабы. Язмышымны мин дә яздым шунда, Халкым куяр соңгы ноктаны.* Ф.Яруллин. *Дәүләт эшлеклеләренең, исән чакта, кешелекле*

*биографиясен киң массага җиткермәү – үрнәк алырдай гаилә коралмаган «халыклар атасы» чорыннан калган серлелектер, мөгаен...* М.Галиев. *Моңа, бәлки, Газинур белән Саша биографиясенең уртак урыннарының да беркадәр тәэсире булгандыр.* Г.Әпсәләмов. *1962 елдан башлап, аның биографиясе Казан педагогия институты белән бәйле.* Татарстан

**БИОГУ́МУС** *и. лат.* Төрле калдык-постыкларны кызыл суалчаннар эшкәртүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән черемә

**БИОКОРРЕ́КТОР** *и. лат.* Кеше әгъзасының биоэнергиясен көчәйтү өчен кулланыла торган препарат яки медицина приборы. *Хәзер больницаларда биокорректорлар кулланыла башлады*

**БИОКЫР** *и.* Парапсихология фәненә караган: махсус приборлар ярдәмендә генә балкып яки яктырып күренә торган, кеше гәүдәсе тирәсендәге кыр. *Биокырларны тотып алучы приборны көчәйткеч аркылы динамикка тоташтырдылар, һәм аларның тавышлары яңгырады.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Авырып киткән кешенең биокырында кара таплар (тишекләр) хасил була, төсләр тоныклана.* Мәдәни җомга. *Мәсәлән, хәзер инде бөтен кешегә дә мәгълүм: биокырлар барлыгы, кешеләрнең энергия белән бер-берсенә йогынты ясаулары, сүзләрнең гипнотик көчкә ия булуы һ.б.* Акчарлак

**БИО́ЛОГ** *и. рус* Биология белгече, биология фәнен өйрәнүче. *Физиклар һәм биологлар өчен су, гомумән, яртылаш онытылган проблема санала.* Б.Сергеев. *Биолог алар белән мәш килде, үзенең аппаратлары ярдәмендә, хәтта, аларның башларында ничә сыр булуын да исәпләп чыгарды.* Р.Мөхәммәдиев. *Ике кызыбыз да биологлар: Алсу – Чаллыда, ә Җәмилә Уфада яшиләр.* Ш.Галиев. *Америка биологы Браун җирнең магнит кырында моллюскларның, суалчаннарның һәм хәтта суүсемнәрнең ориентлашуын күрсәтә.* Могҗизалар энциклопедиясе

**БИОЛО́ГИК** *с.* 1) Биологиягә караган, биология белән бәйле (зоология, ботаника, анатомия, кеше физиологиясенә караган). *Бу биологик төрлелекнең бетүе планетадагы күп халыкларда зур кыенлыклар тудырачак.* Шәһри Казан

2) Тереклеккә хас процессларның, күренешләрнең интенсивлык дәрәҗәсен, сыйфатын билгеләгән. *Әдип, Җәләш һәм Зөләйха сурәтләрен бер-берсенә каршы куеп, һәр икәвесенең ике угыл язмышына «биологик» бағланышларын күрсәтмәкче була.* Г.Нигъмәти. *Һәрбер колакта 120 ләп биологик актив нокта бар.* Юлдаш

**БИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Органик дөньяны, табигать кануннарын өйрәнә торган фән. *Тормышта үзенә бер юл сайлап өлгермәгән һәм сайлап өлгерү өчен әле бик яшь булган бу матур кыз, бер үк вакытта, биология факультетында да, балет мәктәбендә дә укый, ат өстендә йөрергә дә өйрәнә, парашют белән дә сикерә, пулемёттан да ата һәм шунысы гаҗәп: аралары ерак, аермалары зур булган шушы эшләрнең һәркайсын ул яшьлеккә генә хас ялкын белән, энтузиазм белән башкара.* И.Гази. *– Әгәр кешенең биологиясе үзгәрсә, ул инде кеше булмаячак! – диде шагыйрь, кайнарланып.* А.Тимергалин. *Ләкин ул вакытта табигать турындагы фән – биология – әле аз үскән иде.* Н.Верзилин

**БИОЛОКА́ЦИЯ** *и. гр.-лат.* Хайваннарның пространствода үзләренең урынын, хәрәкәт итү юнәлешен билгеләү сәләте. *Шунысын гына әйтик, әлеге күренеш фәндә «биолокация» дип атала.* Кызыклар дөньясында

**БИО́НИКА** *и. нем.* Кибернетиканың органик дөньяны (тере табигатьне) өйрәнә торган бер бүлеге. *Бионика тереклекияләренең һәм аларның аерым әгъзаларының төзелешен, шулай ук ничек эшләвен өйрәнә.* А.Тимергалин. *Терек организмнарның үз-үзен регуляцияләвен өйрәнә һәм бу белемнәрне техникада файдалана торган махсус юнәлеш – бионика барлыкка килде (грекча «биос» – «тереклек» дигән сүздән алынган).* Гомуми биология

**БИОПСИЯ** *и. фр.<гр.* Диагноз кую максатыннан, әгъза тукымасының кечкенә генә кисәген микроскопик тикшерүгә алу

**БИОСТА́НЦИЯ** *и. гр.-пол.* Хайван һәм үсемлекләр биологиясен өйрәнү үзәге

**БИОСФЕРА** *и. гр. геогр.* 1) Җир шары өстендә тереклек таралу өлкәсе. *Мәгълүм булганча, биосферада аңлатып бирүе шактый кыен булган һич көтелмәгән катастрофалар булгалап торган.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Җирдәге бөтен тереклекнең җыелмасы. *Урман – биосфераның бер компоненты. Биосфера кешенең һаваны пычратуын чистартып өлгерә алмый.* Мәгърифәт

**БИОТОК** *и. гр. мед.* 1) Тере организмнарның күзәнәкләрендә барлыкка килә һәм аларның эшчәнлеген чагылдыра торган электр импульслары. *Ә күңел сиздә бүген. Иртәдән бирле. Юк, кичәдән бирле. Син кайчан килдем дисең? Кичәме? Менә биотокларны без белеп бетермибез әле...* М.Мәһдиев. *Якынрак торган кешенең биотоклары безгә тәэсир итәме, әллә, кыймылдаганда, аның гәүдәсе һава дулкыны кузгатамы?* М.Юныс

2) *күч.* Ике кеше арасында булган бер-берен аңлау, сизенү сәләте, рухи элемтә. *«Биоток» дигән нәмәстәкәйне, күрәсең, галимнәр тикмәгә генә әйтмиләр икән.* Г.Ахунов

**БИОФИ́ЗИК** I *и. рус* Биофизика өлкәсендә эшләүче белгеч, шушы фән белән шөгыльләнүче галим. *Биофизик А. Чижевский, 30 нчы елларда ук, кеше организмы өчен иң файдалы витаминнарны электр тогы ярдәмендә җитештерү проблемасын хәл иткән була.* К.Гыйззәтов

**БИОФИ́ЗИК** II *с.* Биофизика белән бәйләнешле, биофизикага караган. *--- тереклек дөньясында барган биофизик оешу-таркалу процессларын өйрәнү мине проблемаларның чишелешен элементар кисәкчекләр дөньясында эзләүгә этәрде.* И.Әмирханов

**БИОФИ́ЗИКА** *и. гр.* Биологиянең бер бүлеге; организмнарда була торган күренешләрне ачуда физика законнарын куллана торган фән. *Физика казанышларын биологиядә куллану яңа*

*фән – биофизиканың туууына китерде.* Гомуми биология

**БИОХИМИК** I *и. рус* Биохимия белгече, шул фән галиме. – *Ә мин – майор. – Ә мин – биохимик. – Мин – утыз ел сызган сызымчы – бәхет проектлары күпме сыздым, ә бәхетем булды узгынчы.* Р.Харис

**БИОХИ́МИК** II *с.* Биохимия белән бәйләнешле, биохимиягә караган. *Башка төрле биохимик реакцияләргә нигезләнгән булганга, аларның исе дә, тәме дә үзгә.* А.Тимергалин

**БИОХИ́МИЯ** *и. гр.* Тере организмнарның химик составын һәм организмнарда бара торган химик процессларны өйрәнә торган фән. *Болардан тыш, Россия Фәннәр академиясенең Уфа фәнни үзәге Биохимия һәм генетика институты галимнәре кешедә үз-үзенә кул салуга этәрүче алты ген булуын ачыклаганнар.* А.Низамов

**БИПЛАН** *и. лат. авиа.* Аслы-өсле ике канатлы самолёт. *--- җәен су өстенә дә, корыга да, кышын кар өстенә утырырга сәләтле, күпне күргән кечкенә биплан АН-2 яки «Аннушка», гади тел белән әйткәндә, «Кукурузник», кедр башларына тия язып, нәкъ алар өстеннән очып узды.* И.Хуҗин

**БИРӘН** *и.* **1**. 1) *гади с.* Күп һәм теләсә нәрсәне талымсыз ашый яки исерткеч эчемлекләр эчә торган кеше, гуҗ, туймас тамак. *Юк, мин бирән кебек тыгынганына кызыкмыйм.* М.Фәйзи. *Үзең беләсең, безнең бирән бөтен тапкан-табынганын эчеп бетереп бара.* Ф.Яруллин. *Тфү. Бу бирәне дә монда икән әле. Һай, һай-һай!* Д.Аппакова. *Бу бөҗәкләр, тупас итеп әйткәндә, – коточкыч бирәннәр.* Кызыклар дөньясында

2) Йөрәк, бөер һ.б. авыртканда, организмдагы төрле куышлыкларга сары су җыелудан эче күпкән, зур корсаклы кеше

**2.** *с.* Комсыз, нәфесле. *Әти-әниләрнең гомер буе шул «дәүләт» исемле бирән алпавытка бил бөккәннәре дә җиткән.* Ф.Фәтхелисламов

◊ **Бирәнгә сабу** *сөйл.* Сары су авыруына дучар булу. *Хода күрсәтмәсен байларның, елкы итен ашап, бирәнгә сабуын.* Ш.Мөхәммәдев. **Бирәнен чыгару** Күп мал бирүдән гаҗиз булу. *Ул бурычларны түли-түли, колхозның бирәне чыгар әле.* Ф.Бурнаш. **Бирән корсак** *гади с.* Ашап туймый торган, комсыз кеше турында. *[Сәрби:] Син кайдан нәрсә ишеттең, бирән корсак?* Ф.Бурнаш. *Күп халык, театр уеныннан артыграк, безнең бирән корсак татар байларының сәрхушланып кыланышларыннан кәефләнделәр.* Ш.Мөхәммәдев. *Бик күп илләрне, бирән корсак, кабып йоткан идең, – Костырырлар йотканыңны, тотса Мәскәүләр якаң!* Ә.Исхак. **Бирән тамак** *к.* **бирән корсак**

**БИРӘ́Н ЗӘХМӘТЕ** *и.* Матдәләр алмашы бозылудан барлыкка килгән, чамасыз күп ашау белән характерлана торган авыру. *Сугыш – бирән зәхмәте кебек комсыз бит.* К.Нәҗми

**БИРӘСЕ** *и. к.* **бирәчәк**. *[Алмага] – Миннән дә шул бәя булыр, – диде Малик, – ләкин Галиулланың бирәселәрен шул акчадан тотып калырмын.* И.Гази

**БИРӘЧӘК** *и.* Түләү шарты белән алып торган бурыч. *Бай бирәчәген – мал белән, ярлы тир белән түләр.* Мәкаль. *Бирәчәгең бирми, гүргә кереп булмый.* Мәкаль

**БИРГЕ** I *с.* 1) Берәр нәрсәнең сөйләүчегә якынрак торган ягы; *киресе:* **аргы.** *Бирге якта аксыл чәчәккә күмелгән алмагач бакчалары күренә.* М.Җәлил. *Бирге яктан аргы якка маякчы көймәсе йөзеп китте.* Г.Гобәй

2) Якындагы, сөйләүчегә иң якын урнашкан. *Капканың бирге ягына озын мыеклы, кызыл борынлы стражник чыгып басты.* К.Нәҗми. *Юка такта белән икегә бүленгән бу өйнең бирге өлешендә иске сандык, чөелдерексез камыт, ярты тубал солы аунап ята.* К.Нәҗми

**БИРГЕ** II *и. иск.* Ясак

**БИРГЕСЕЗ** *с.* Кем яки нәрсә белән дә чагыштыргысыз яхшы; бертөсле булмыйча, аерылып торган. *Әдәбият мөгаллимнәренә биргесез белемгә ия бу инсан, җөмләсен саф татарча --- сөйли.* А.Хәлим. *Ишмөхәммәт бабайның балык шулпасы әүвәлгеләренә биргесез тәмле иде.* Ә.Гаффар

**БИРГЕЧ** *и. тех.* Механизмның, тере организмның эшчәнлеген тикшерә торган прибор; *русчасы:* **датчик**. *Иярченнәрдә, башка аппаратлар белән беррәттән, иярчендә бара торган үзгәрешләрне теркәүче биргеч приборлар да бар иде.* В.Казневский

**БИРДЕРТҮ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **бирү.** *Дустың гылава абзый бирдерткән бүләктән кем баш тарта, ди.* Н.Гыйматдинова

2) Машина, механизм һ.б.ш.ны азрак алга яки артка таба күчерү, кузгалту. *Тагын бераз алгарак бирдерт.* Н.Хәсәнов

**БИРЕ** *рәв.* **1.** 1) Алдарак, якындарак, нинди дә булса урыннан, әйбердән якынрак. *Аннан бирерәк, сабан туендагыча киенгән егетләр, кызлар – кайсы «Әпипә», кайсы «Барыня» көенә биибии, бая гына – үтерелгән көтүче, хәзер инде колхоз оештыручы булып уйнаган Батыршаны әйләндереп алдылар.* К.Нәҗми. *Ары басма, бире бас, кыек басма басмага; Күркә, күреп, көнләшмәсен күкрәктәге тасмаңа.* М.Фәйзи

2) *сөйл. к.* **бирегә.** *Ул, җен кызлары матурлыгын җыйган мәкерле кыз, мине сихерләгән алмасы белән бире китергән икән.* М.Фәйзи. *Бай җылкычыларга ала айгырны бире табарак китерергә кушты.* Г.Ибраһимов. *Нәфисә, Шәрифә, чыгыгыз әле бире.* Ф.Бурнаш. *Ишекле-түрле ары сугылды, бире сугылды.* Н.Хәсәнов

3) *сөйл. к.* **биредә.** *Аларны ул, әлбәттә, алып китә алмады, бар да бире калдылар.* Т.Гыйззәт. *Нинди аермалар икәнен бире сөйләп бетереп булмас.* Г.Гобәй. *Кыйблаи җан вә мөгаллим – әтиебез бире.* Кабер ташына язылган сүзләр

**2**. *а. функ.* Бу. *Ә сез бире квартирга кешеләр китерәсез икән.* Г.Камал

**БИРЕГӘ** *рәв.* Бире, бире таба, монда таба, бу урынга. *Кай арада һәм ничек соң әле аның карт хатыны бирегә килеп керә алган?* Г.Нигъмәти. *Кемдер, салмак кына атлап, бирегә таба килә.* И.Гази. *Бары бирегә килгәч кенә, яңа эштә, яңа кешеләр арасында бераз нормаль хәлгә кайткан кебек булдым, диде.* Ә.Еники

**БИРЕДӘ** *рәв.* 1) Монда, бу урында. *Ә биредә минем урынга кешеләр*

*табылыр.* Р.Ишморат. *Дөрес, биредә Сәлимнең колхозда чакта күзгә ташланмаган яңа, күңел кайтаргыч сыйфатлары да әз-әзләп ачыла башлады.* Г.Әпсәләмов. *Биредә гаҗәп җылы һәм, шул коры җылылыкка ямь биргәндәй итеп, арыш онының әчкелтемрәк исе аңкыган иде.* Г.Минский. *Эш биредә таң белән башлана, беренче савуны дүрт белән биш арасында ук үткәрәләр.* Ә.Еники

2) Нинди дә булса урыннан, предметтан якындарак. *Шул чакта өстә, будкадан шактый биредә, кычкырып сөйләшкән тавышлар ишетте ул һәм, дулкынланып, кычкырып җибәрде: – Ярдәм! Ярдәм!* Г.Гобәй

3) Бу очракта, бу мәсьәләне хәл иткәндә. *Хикәядә кешелектә булган «явыз» һәм «яхшы» холык көрәше, пассив күзәтүче карашыннан килеп, берберсенә каршы куелган булса, биредә ике сыйныф арасындагы көрәш коммунист драматург каләме белән сурәтләндерелгән.* Г.Нигъмәти. *Күпләр рухи яктан сына биредә.* Р.Кәрами

**БИРЕДӘН** *рәв.* Бу урыннан, моннан. *Биредән качып китүе бар аның.* К.Нәҗми. *Хәзер ул, хатыны һәм биш яшьлек улы белән өчәүләп, биредән еракта-еракта, Идел тауларына сыенып утырган бер татар авылында йөри.* И.Гази. *Биредән ерак түгел, ике урам аркылы гына, аның иске дусы Гыйльфан яши.* Г.Минский

**БИРЕЛГӘНЛЕК** *и.* Тугрылык, кемгә яки нәрсәгә дә булса турылыклы булу; фидакярлек. *Алар коммунистлар партиясенә үзләренең бирелгәнлекләрен күрсәттеләр.* М.Җәлил. *Шуның өстенә тагы Зарифулла, үз хуҗалары каршында, аеруча яшь хуҗа Хисами каршында, колларча бирелгәнлеге белән дә аерыла иде.* М.Гали. *Кайсы ил халкының, совет кешеләренеке кебек, үз юлбашчыларына бетмәс-төкәнмәс ышанычы һәм бирелгәнлеге бар?* Г.Әпсәләмов

**БИРЕЛЕШ** *и.* 1) Сурәтләнү, тасвирлану дәрәҗәсе, гәүдәләнеш, чагылыш. *Хикәяләрдә, романнарда булсын, объектив рәвештә, каһарманның, язылган тормышның, хәтта табигать сурәтләренең бирелешендә, аларга салкын карап кына язу күрмибез.* Г.Нигъмәти

2) *мат.* Мәсьәләнең билгеле өлеше. *Бирелешне билгеләү*

**БИРЕЛҮ** *ф.* **1**. 1) *төш. юн. к.* **бирү.** *Аңа шунда байрак бирелде.* Ф.Бурнаш. *--- Галиәсгар Камал исеме бирелде, ---.* М.Гали

2) Каршылык күрсәтүне туктату, җиңелү. *Беренче линия окопларында атнадан артык торганнан соң, резервка чыккан 8 нче ротага полк штабы урнашкан тау битендәге землянкаларның берсе бирелде.* М.Гали. *Безнең кызылармеецлар, электәгечә, нинди генә авыр шартларга эләкмәсеннәр, дошманга бирелмиләр, соңгы тамчы каннарына кадәр сугышалар.* А.Шамов

3) Бәхәстә, спорт ярышларында җиңелү. *Бу ике көчнең соңгысы җиңәчәген күңелем бик ачык сизсә дә, мин сүзсез генә бирелергә теләмәдем.* М.Әмир

4) Башка, чит кешенең йогынтысына буйсынып, шул кеше фикеренә ияреп эш итү, аның ягына чыгу. *«Ут» – семья мөнәсәбәтләренә керү аша чит сыйныф йогынтысына бирелгән, үзенең тормыш һәм көнкүрешендә шуны җиңеп чыга алмаган, үз коллективыннан аерылып таркалган «җаваплы эшче» драмасы.* Г.Нигъмәти. *Шулай булуга карамастан, аның беренче әсәрләре булган «Бәхетсез егет» белән «Өч бәдбәхет»тә, заман модасына бирелеп, беркадәр әхлак сату һәм вәгазьче тенденцияләре үткәрү юк түгел, ләкин алар нык кабартылып күрсәтелмиләр.* М.Гали

5) Үз-үзеңне онытып, бик нык кызыксынып, берәр эш башкару; нәрсә белән дә булса бик нык мавыгу. *Зур бәхетләр, сызганып, эшкә бирелгәннән килә.* Г.Тукай. *[Галләм] Эшен эшли, кушканны үти, ләкин сүзгә ул кадәр бирелеп катнашмый.* Социалистик Татарстан

6) Ниндидер халәттә, хәлдә калу. *Әсәрдә үзәк урын тоткан шәхесләр, гади психологик типлар, җәмгыять тормышында берәр төркемнең типик вәкилләре итеп бирелүдән бигрәк, индивидуаль эчке сыйфатларга ия булган, һәрберсенең берәр хирысы булган кешеләр итеп күрсәтеләләр.* Г.Нигъмәти. *Һәрвакыт күтәренке күңелле, бертөрле авырлыкка да бирелми торган нык кеше, көчле кеше булып күренсә дә, сугыш вакытында район белән җитәкчелек итүнең кыенлыгын үзе генә белә иде.* Г.Бәширов

7) Якын күрү, үз итү, җан-тән белән ярату, турылыклы булу. *Кавышкач, зөфафның беренче көненнән үк бөтен йөрәге белән аңар бирелде, аны яратып, сөеп китте.* Г.Ибраһимов

8) Үзләштерелү яки башкарылу. *--- әсәрнең аерым урыннарында бишенче ел революциясенең татар тормышының аерым катлауларында чагылышы тирән осталык белән бирелгән.* Г.Нигъмәти. *Көрәш корбансыз булмый, андый зур эшләр җиңел генә бирелми.* А.Алиш

**2. бирелеп** *рәв. мәгъ.* 1) Тырышып, чын күңелдән, ихлас белән. *Бирелеп, пианинода татар көйләрен уйнау*

2) Онытылып, йотылып, мөкиббән китеп. *Бирелеп, музыка тыңлау*

3) Якын күреп, үз итеп. *[Ул күзләр] Мәхәббәткә каршы шундый ук тирән, саф, намуслы мәхәббәт белән җавап бирергә теләп, синең күзләреңә сөеп, бирелеп карыйлар.* Ә.Еники

**Бирелә бару** Һәрберсе, булган берсе бер-бер артлы бирелү. *Әйе, мин «их, шул рольне уйныйсы иде» дип хыялланмадым яисә үкенмәдем, чөнки миңа кызыккан рольләрем бирелә барды.* М.Галиев

**Бирелә башлау** Бирелергә керешү. *Хәлимнәр палатасы да инде куркуга бирелә башлаган иде.* А.Шамов

**Бирелә төшү** Тагын да бирелү

**Бирелеп алу** Кыска вакыт эчендә, азга гына кемнең дә булса йогынтысына бирелү. *Берәр күренешне бәян иткәндә, чигенеш китереп, хыялга бирелеп алу, фараз кылу яисә истәлек-хатирә рәвешендә чигенеш ясаулар да очрый.* И.Низамов

**Бирелеп бару** Даими рәвештә, системалы бирелү. *--- ай саен бирелеп бара торган белешмәләрдә «Маяк» колхозы, гадәттәгечә, беренче урында тора бирде.* М.Хәсәнов. *Шагыйрьнең фоторәсемнәре, әсәрләренә иллюстрацияләр дә бирелеп бара.* Х.Миңнегулов

**Бирелеп җитү** Тулысынча бирелү. *--- озын, катлаулы җөмләләр киртәксезгә бүлгәләнеп бирелә һәм, нәтиҗәдә, оригиналдагы фикернең диалектик бердәмлеге, органик бәйләнеше йомшара, бөтенлеге, эзлеклелеге бозыла, шулай ук төп нөсхәнең ритмы, интонациясе бирелеп җитми.* Р.Юсупов

**Бирелеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта ниндидер йогынты тәэсирендә булу. *Бу күңелсез уйларга бирелеп йөрү Галимне туйдырды*. Г.Әпсәләмов

**Бирелеп китү** 1) Ниндидер бер моменттан, сәбәптән соң бирелү. *Шайтан котыртуына бирелеп киткәнлеген дә сизми калачак.* С.Поварисов

2) Нәрсә белән булса да мавыгу. *Мондый хәл, бер яктан, балның бик күп җыелганын күрсәтсә, икенче яктан, җир сатучының сәүдә эшенә бирелеп киткәнен дә раслый булса кирәк.* С.Алишев. *Без бу эшкә шулкадәр бирелеп киттек, хәтта урманга сыерыбызга печән чабарга барганда да кесәбезгә дәфтәр, каләм тыгып бардык.* Г.Галиев

**Бирелеп кую** Көтмәгәндә, ниндидер йогынтыга буйсыну. *Теләсәң-теләмәсәң дә, бу – очраклы булмагандыр, дип, мистикага бирелеп куясың.* Р.Сафин. *Минә шундый фәлсәфи уйларга бирелеп куя иде ир*. Р.Габделхакова

**Бирелеп тору** 1) Һәрвакыт, гел бирелгән булу. *Әмма хисләргә озак бирелеп тору мөмкин түгел иде монда*. Л.Ихсанова

2) Әле, сөйләү моментында ниндидер йогынтыга буйсыну. *Әнә шундый моңсурак уйларга бирелеп торганда, каршымда, җир астыннан чыккандай, башына, кырынрак салып, яшел пилотка, өстенә шундый ук төстәге толстовка кигән бер малай пәйда булды*. Ф.Шәфигуллин

**Бирелеп утыру** Әле, хәзерге вакытта нәрсәгә булса да бирелеп китү. *Шулай да хискә бирелеп утырыр чак түгел, юлчыларны кайнар чәй белән сыйларга кирәк, эчкә бераз җылы керсен.* Л.Ихсанова

**БИРЕЛҮЧӘН** *с.* **1**. Кемнең яки нәрсәнең дә булса йогынтысына буйсынучан, кеше коткысына тиз ияреп китүчән; мавыгучан. *Нәҗия хискә тиз бирелүчән...* Ә.Еники

**2**. *рәв. мәгъ. махс.* Авыруларга тиз бирешүчән, иммунитеты түбән

**БИРЕЛҮЧӘНЛЕК** *и.* Бирелүчән булу. *Минә бу сыйфатлар аның әдәби стильдә романтиклыкка бирелүчәнлеге белән бәйләнгән.* Г.Нигъмәти

**БИРЕМ** *и.* 1) Алдан билгеләнгән, тапшырылган, бирелгән эш, йөкләмә. *Ә коллектив социализм төзүче илнең биремен үтәп бара.* Г.Нигъмәти

2) Белемнәрне ныграк үзләштерү, алган күнекмәләрне ныгыту өчен бирелгән эш, күнегү. *Күнегүләр иң гади биремнәрдән башлана.* Р.Нигъмәтуллина

**БИРЕШ** *и. диал.* Кайтару, кайтарып бирү. *– Алай бурыч биреш уйнамыйк! – ди. – Тәмләп ашагыз.* К.Тимбикова

◊ **Биреше каты** Бурычын бик теләмичә генә кайтаручы кеше турында

**БИРЕШМӘҮЧӘН** *с.* Каршы тора алу сәләте зур булган, чыдам, нык, түземле. *Рухым минем әнә шундый: бирешмәүчән, килешмәүчән*. К.Латыйпов

**БИРЕШМӘҮЧӘНЛЕК** *и.* Каршы тора алучанлык, ныклык, түземлелек. *Хәзерге көндә организмның авыруга бирешмәүчәнлеген арттырырга нигезләнгән метод бик яхшы нәтиҗә бирә.* Социалистик Татарстан. *Балык, кандагы холестерин күләмен киметү белән бергә, йөрәк авыруларына бирешмәүчәнлекне ныгыта, кан оешуны да булдырмый.* Юлдаш

**БИРЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **бирү.** *Үрмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, безнең мондый дуслыктан көнләшеп, бүтәннәр дә бер-берсенә бүләк бирешеп карады, ләкин аларның әлеге гадәте кыска гомерле булып чыкты*. А.Гыймадиев

2) Эштә, уенда, спортта һ.б.ш.да җиңелү, өстен чыга алмау, калышу, ким булу. *Бер укымышлы кырык наданга бирешмәс.* Мәкаль. *Без – хатын-кызларның хокукларын дауларга чыккан кызлар, без барыбер сезгә бирешмәбез.* Т.Гыйззәт. *Анда французча, немецча, инглизчә, эсперанточа язылган китаплар күп, дип карасалар да, хәзрәт һаман бирешмәде.* Ф.Әмирхан. *Булган шәкертләрнең кыюлыгына һәм сүзгә бирешмәвенә соклана иде.* М.Гафури

3) Физик һәм рухи яктан хәлсезләнү, начарлану; каршы торырга көч калмау. *Күзе әйләнде, тончыга язды, шулай да бирешмәде ---.* Г.Ибраһимов. *– Нигә гел шәкерткә генә куәт биреп торасыз, әзрәк теге егеткә дә куәт бирегез, бирешмә, сары күлмәк, бирешмә! – диегез.* М.Гали. *Уйлы күңел генә сагышка бирешә ала*. М.Галиев. *Гафиятулла бабайның элеккеге гренадер солдат сыны хәзер бик нык бирешкән.* Г.Әпсәләмов

4) *сөйл.* Үзара бәргәләшү, бәргәләшеп алу

5) Үзара бәргәләшү, сугышу, кыйнашу вакытында җиңелү, көчсезлек күрсәтү. *Комсомоллар авылның икенче башыннан диярлек килеп җиткәнчегә хәтле, тәки бирешмәгән.* Ш.Камал. *Сөйләшә алмасам да, кулга киткәч бирешмим инде мин.* Ф.Хөсни

**Бирешә бару** *к.* **бирешеп бару**. *Хәйдәрнең күзгә күренеп бирешә баруы, бер мескенгә әверелеп калуы да шатлык китермәде*. М.Кәбиров

**Бирешә башлау** Бирешү билгеләре күренү. *Апам миннән мондый каршылыкны көтмәгән иде. Ул үзенең бирешә башлаганын сизде*. Э.Шәрифуллина

**Бирешә төшү** Тагын да бирешү. *Татар әдәбиятының болай да шактый сирәк булган яшь прозаиклар сафы алардан соң тагын да бирешә төште*. М.Вәлиев

**Бирешә язу** Чак кына бирешми калу

**Бирешеп алу** Тиз-тиз генә бирешү, кыска гына үзара биргәләшү

**Бирешеп бару** Акрынлап хәлсезләнү, көннән-көн бирешү

**Бирешеп бетү** Тәмам начарлану; каршы торырга көче калмау

**Бирешеп җибәрү** Очраклы рәвештә, кинәт, берәр эштә, уенда, бәхәстә бирешү

**Бирешеп килү** Элек-электән, даими рәвештә, системалы бирешү. *Минә ни өчен морзалар, элек-электән үк, бары үзара (аерым очракларны исәпләмәгәндә) кыз алышып, кыз бирешеп килгәннәр*. Ә.Еники

**Бирешеп китү** Кинәт, соңгы вакытта бирешү. *Картаеп, бирешеп кит-*

*кәнсең, әти җаным. Хәлләрең ничек соң?* Аманулла

**Бирешеп кую** Кинәт бирешү. – *Чынлап кыйнаша башлагач, ул әле Корбангали абзыйга бик ул хәтле бирешеп тә куймас, – диде Фәйзи.* Ш.Камал

**Бирешеп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз бирешү. *Зур урамнар чатында фаэтончылар гына тезелешеп торалар, анда-санда бер-берсенә хәбәр бирешеп торган городовойларның сызгыртулары, каланың көнчыгыш ягыннан ага торган суның ташу шаулаулары гына ишетелә иде.* А.Таһиров

**БИ́РЖА** *и. нем.* 1) Финанс өлкәсе эшләрендә акцияләрне, башка кыйммәтле кәгазьләрне һ.б.ш. зур күләмнәрдә сату-алуны тәэмин итүче һәм моның өчен килешүләр суммасыннан мәгълүм процент (комиссион табыш) алучы, даими эшләүче оешма. *Капиталистлар арасында биржа аша сатылган товарлар бер кулдан икенче кулга турыдан-туры күчмиләр.* Политэкономия

2) Эшче көчләр тәкъдим итә һәм яллый торган урын. *Аннан, базардагы агай-энеләргә, чаттагы извозчикларга, кибеттәге приказчикларга, биржадагы подрядчикларга, хәрчәүнидәге половойларга, йөк ташучы ломовойларга күз-колак булырга кушты*м. Т.Гыйззәт. *[Яучы:] Юк, биржа түгел, бу – безнең шәһәрнең могътәбәр кешеләре җыела торган җир.* Г.Камал

3) Биржа гамәлләре башкарыла торган махсус бина. *Менә ишет әле, Зәки абыең нәрсәләр ди: 27 гыйнварда Казанның Биржа залында Казан мөселманнарының юбилейга ядкяр калдыру эше буенча гомуми җыелышы булды.* Ф.Әмирхан

3) *махс.* Чи агач, урман материаллары склады

**БИ́РЖА АРАДАШЧЫЛАРЫ** Биржа килешүләре төзүдә катнашырга хокуклары булган биржа әгъзалары; *русчасы:* **биржевые посредники**

**БИ́РЖА БӘЯСЕ** Биржа сәүдәсе тәртибендә сатылган әйберләрнең хакы; *русчасы:* **биржевая цена.** *Биржа бәясе – мәгълүм бер төр әйбер хакының күпме булуын һәм ничек үзгәреп торуын чагылдырган иң ышанычлы мәгълүмат чыганагы ул*

**БИ́РЖАЧЫ** *и.* Биржа эшләре белән шөгыльләнүче, биржа эшкуары

**БИ́РКА** *и. төрки > рус* Товар төргәкләренә, багажларга һ.б.ш.га тагыла торган, номерлы яки язулы кечкенә такта, фанер, картон, калай һ.б. *Алмазның җәза алырлык сәбәпләре буа буарлык: исем-фамилиясе, беркетелгән отрядының номеры язылган биркасы юк, --- сырма фуфайка киюдән баш тартты.* И.Сираҗи

**БИРЛЕ** *бәйл.* Чыгыш килеш формасындагы сүзләр белән килеп, эш-хәлнең башлангыч вакытын күрсәтә, аның дәвамлылыгын белдерә. *Өстәвенә, гомум шигърият хәзинәсендә һәр халыкның меңәр еллардан бирле шомарып, үткенләнеп беткән тапкыр сүзләрен, мәкаль-әйтемнәрен, табышмак-сынауларын да онытмыйк.* Р.Фәйзуллин. *Кыштан бирле, быел җәй Кырымга – диңгез буена китәрбез, дип, алдан ук кычкырып килдек-килдек тә, көне җиткәч кенә кире уйлап, үзебезнең Башкортстанга – Илешкә генә кайтырга булдык.* Х.Сарьян. *Башка чыкканнан бирле саклап тоткан бердәнбер урагым иде.* Г.Мөхәммәтшин

**БИРНӘ** *и. этн.* Кияүгә чыккан кызның үзе белән кияү йортына алып килгән мал-мөлкәте, егеткә һәм егетнең кардәшләренә бирелә торган бүләкләре. *Ә килен буласы кыз үз өендә чигү чигеп, киндер сугып, бирнә әзерләгән.* Т.Миңнуллин. *Тик бирнәгә биреләчәк күлмәкнең, асыл булмыйча, йон булу хәбәре генә аның фикерен бик тиз үзгәртеп, улы белән ирен һәм үзен киләчәк бәхетсезлектән коткарып кала.* М.Гали. *Ике тәрәзәнең берсе өстенә башы чуптарлы бирнә сөлгесе атландырып эленгән иде.* Ә.Фәйзи

**БИРНӘЛЕК** *и. к.* **бирнә.** *Бөтен вөҗүденңе багышлаган, күз нурларыңны түккән бирнәлекләрне, тир түгеп тапкан калым малларын түгеп-чәчеп бетермәссең бит инде, аерылам, дип.* Т.Миңнуллин

**БИРТӘК** *и. диал.* Теле тотлыга торган кеше. *Язмыш безне тигез какты-сукты – Син дә биртәк, мин дә сакаумын. Бир кулыңны, иптәш – файдасы юк, Мәгънәсе юк үпкә саклауның.* И.Сабиров

**БИРТӘЮ** *ф. к.* **бүлтәю**

**БИРТЕК** *и. к.* **биртелеш** (*1 мәгъ.*)

**БИРТЕЛЕШ** *и.* 1) Тайган сөяк, каймыккан, чатнаган урын

2) *күч.* Рухи имгәнү, кайгы-хәсрәттән бетеренгәнлек

**БИРТЕЛҮ** *ф.* 1) Буыннар кузгалу, таю, каймыгу. *Аягы биртелеп, дүрт ай бүлнистә ятып чыкты малай.* Ф.Шәфигуллин

2) Авыр эштән имгәнү, бетеренү. *Алар бара торган эшелон Кавказ тауларында крушениегә очрый, һәм Гафиятулла абзый, тәмам имгәнеп, биртелеп, өенә кайтып егыла.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Рухи имгәнү, күңеле төшү. *Юкса, начар семья аркасында тормышлар ватыла, кешеләр биртелә, гарип тойгылар җәмгать эшенә начар тәэсир итә.* Г.Кутуй

**Биртелеп бетү** Тәмам, бик көчле биртелү. *Тәмам гарипләнеп, җәрәхәтләнеп, биртелеп беткән Габдулла, кургашындай авыр тойгылар белән, туган ягына юнәлә.* М.Сәхапов

**Биртелеп калу** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң биртелү

**Биртелеп кую** Көтмәгәндә, кинәт биртелү

**БИРТҮ** *ф. диал.* 1) Имгәтү, каймыктыру, тайдыру. – *Сез аның әнисен саклый белмәдегез, үлеменә сәбәпче булдыгыз, инде кызының кулын каерасыз, аны да биртеп, гарип итеп калдырмакчы буласыз! – дип кычкырды Роза һәм, куркып, елап җибәрде.* С.Баттал

2) *күч.* Кемнең дә булса күңелен төшерү. *Син бит тыныч, имин көндә үз балаларыңның күңелен биртәсең.* Социалистик Татарстан

**БИРҮ** *ф.* **1.** 1) Нинди дә булса бер әйберне икенче кешенең кулына тоттыру, бирәүнең үзенә тапшыру. *Гурий истәлеккә ике «сувенир» бирде: берсе балык кылчыгыннан ясалган шопшома, нык инә иде, икенчесе ипи йомшагыннан ясалган, ялтырап торган, корычтан да каты төймә иде.* А.Гыйләҗев. *«Авызыбызга бүген катрә дә азык алганыбыз юк!» – дип инәлә алар.*

*Бирдем. Итәкләренә, тутырып, помидор салдым.* А.Хәлим. *Байтирәк, өсләреннән йозак белән бикләп ал, ачкычларын миңа бирерсең.* Т.Гыйззәт

2) Нәрсәне дә булса берәүнең карамагына, файдалануына тапшыру. *Минем өскә кияргә булмаганга, иртәнге салкыннарда киеп йөрерсең, дип, әни әтинең иске тәвәккәл бүреген һәм, җиңнәрен, итәк очларын бераз кыскартып, аның искереп, кылкаланып беткән тула чикмәнен бирде.* М.Гафури. *Садыйк картның былчыранып беткән иләмсез зур ботинкаларын салдырып, аягына коры киез каталар китереп бирделәр.* Ш.Камал

3) Хәбәр итү, белдерү, җиткерү. *Нигә миңа мондый хәсрәт тулы Дәһшәт шомлы хәбәр бирдегез?* Ф.Бурнаш. *Мин сиңа балалар саны турында --- аларның исемлеген генә бирергә тиеш булам.* Ш.Камал

4) Тәкъдим итү (урын, юл һ.б.ш. турында). *Аннан, юл биргән халык арасыннан үтеп, сәхнәгә менде.* Г.Гобәй. *Гармунчыга чибәррәк урын бирегез, үпкәли башлар.* Ф.Бурнаш

5) Хак һ.б.ш.ны түләү. *Эш чиксез авыр, унике сәгать буена җир астында, тиргә батып, эштән чыгып азапланасың, ә тамак туярлык акча бирмиләр.* Ш.Камал. *Ярар, хәерле булсын алайса, вагың булгач бирерсең инде.* Ш.Камал. *Бер кием читекне каеган өчен биш тиен бирәләр, ди.* М.Гали. *Шәмсетдингә, утыз кадак он биреп, мичне дә чыгартты.* Г.Ибраһимов

6) Нинди дә булса берәр бәя белән сатып җибәрү. *Дадашов яхшы хак бирмәсә, Шагаловка барыгыз...* Ш.Камал. *Итекчеләр --- бер пар итекне, 20 аршинга түгел, 15 аршин киндергә дә шатлана-шатлана бирерләр иде.* Г.Тукай

7) Нәрсә белән дә булса бүләкләү, нәрсәне дә булса кемгәдер рәсми рәвештә тапшыру. *Балаларны башларыннан сөеп: «Әтиегез кебек батыр булыгыз, медальне бик зур батырлык күрсәткән кешегә генә бирәләр», – дип сөйләде.* Г.Әпсәләмов. *Бүләкләр бирү тантанасы башланды.* Ә.Айдар. *Узган сабантуенда бирделәр бит бу гармунны Хәлимгә.* Г.Гобәй. *Премияләр биргән булалар үзенә!* Ш.Камал

8) Үгет-нәсыйхәт, киңәш һ.б.ш сүзләр янында килеп, әдәп-тәртипкә, төрле күнекмәләргә һ.б.ш.га өйрәтү. *Безгә ул һәрвакытта акыллы киңәшләр бирә.* Т.Гыйззәт. *Киңәш бир, дип йөдәтмә һәм сөйләнмә!* Г.Тукай. *Кызылармеецлар да, аңа рәхмәтләр әйтеп, аның аталарча биргән киңәшләрен тотарга сүз биреп, госпитальдән җиңел атлап чыгып китәләр.* А.Шамов. *Гомумән, ул Газинурны ярата, аны һаман күзәтә, әледән-әле үзе янына чакырып яки правлениедә, клубта, кырда, абзарда очратып, аның белән вакыт сыйдырганча сөйләшә, аңа үзенең киңәшләрен бирә иде.* Г.Әпсәләмов

9) Эшкә билгеләү, берәр эш башкарырга кушу; эш йөкләү, вазифа тапшыру. *– Мин инде барысын да әйттем, иптәш секретарь, – диде Газинур, кулындагы кепкасын бөтереп, – безне бер-беребездән аермагыз, безгә элекке урыныбызда эш табып бирегез.* Г.Әпсәләмов. *--- кайбер эшләрне өлкән экономист биргән.* А.Шамов

10) Ашау-эчү әйберләрен табынга, алга китереп кую. *Кодаларның күчтәнәчләрен күрсәтергә чыгарганда да, мәҗлескә аш-су, шулпа, бәлеш, билдәмә, каз, үрдәк, ширбәт, чәй, коймак, каймак биргәндә дә, һичбер эш Мәрхәбәгә киңәшсез, Мәрхәбәнең ярдәменнән башка үтмәде.* Г.Ибраһимов

11) Кая да булса, берәр теләк белән, язма рәвештә мөрәҗәгать итү. *Теңкәмә тигәч, ахырда, барып, гариза бирдем шул.* Ф.Бурнаш. *Минем партиягә керергә заявление биргәнне ул белә.* Ш.Камал. *Крестьяннар, үзләрен хаклы санап, эшне судка биргәннәр.* И.Гази

12) Рәсми рәвештә берәр җиргә урнаштыру, билгеләү. *Яз килүгә, әниләре Яслегә аны бирделәр, Үзләре, тынычланып, Кырда эшләп йөрделәр.* Һ.Такташ

13) Кияүгә чыгарга рөхсәт итү яки мәҗбүр итү; ярәшү. *Менә хәзер инде шуңа, старшина Садыйкка, үзенең олы кызын бирә икән, дип пышылдады.* М.Гали. *Шушы вакыйгадан соң, Хәлимәне бер эчкече тегүчегә икенче хатынлыкка кияүгә бирделәр.* Ш.Камал. *Итче Хөснуллага өченче хатынлыкка бирергә уйладым, риза булмады.* Т.Гыйззәт. *Зур кызларын, бик байга бирәбез, дип, кайнишле йортта череткәннәр иде, инде бусын ялгызрак җиргә бирергә исәпли, ди.* Г.Ибраһимов

14) Тамашачы алдында чыгыш ясау, концерт, спектакль күрсәтү. *Шуңа күрә мин аның турында күп сөйләмим, әгәр рөхсәт итсәгез, мин сезгә аның турында бераз җырлап бирер идем.* Г.Әпсәләмов

15) Нәрсәне дә булса укыту, өйрәтү. *Хәзрәт миңа бүген «Төхфә»дән үзе сабак бирде.* М.Гафури. *Сабак бирүең өчен рәхмәт!* Г.Әпсәләмов. *Ул, куна-төнә диярлек, студентлары арасында яшәп, сәнгатькә бирелгәнлекнең үрнәкләрен шәкертләренә дә бирә иде.* А.Гыйләҗев

16) Тасвирлау, сурәтләү, чагылдыру, күрсәтү (әдәбият һәм сәнгать әсәрләре турында). *[Театрга] --- психологик образлар бирүгә күчәргә --- кирәк.* М.Җәлил

17) Кайбер исемнәр белән янәшә килеп, нинди дә булса эшне башкару, хәрәкәт ясауны белдерә. *Дежур сержант, ике отделениене дә сафка тезеп, янгын сүндерү командасы начальнигына рапорт бирде.* Р.Кәрами

18) Кем яки нәрсә өчен дә булса берәрсен яки берәр нәрсәне корбан итү. *Моның өчен җанын бирер ата баласы.* Ф.Бурнаш. *Сөйгәне куенында Соңгы кат талпынгач, Шат, мәгърур һәм батыр Җан бирә сандугач.* М.Җәлил. *Ил каршында тиздән ант итәр ул Халкы өчен утка керергә. Аның өчен канын кызганмаска, Кирәк булса, гомерен бирергә!* Ә.Исхак

19) Нәрсәгә дә булса багышлау. *Тагын менә нәрсә: җәй көне күбрәк вакытыгызны ял итәргә бирегез.* Г.Гобәй

20) Җиңелеп, каршы тора алмыйча, нәрсәне дә булса дошманга калдыру. *Рига өчен буржуазия матбугаты солдатларны гаепли, янәсе, алар дисциплинасыз, приказларны үтәмиләр, төрле комитетлар коткысына ияртәләр, чынында, Риганы генераллар бирделәр.* И.Гази

21) Хыянәт итеп яки ирексезләп, кемнең дә булса карамагына тапшыру

(кулга алырга ярдәм итү). – *Мине немецларга бирмәгез, – диде егет һәм, эзләнеп, капшанып, картның кулын тотты.* А.Шамов

22) Җитештерү, барлыкка китерү, эшләп чыгару нәтиҗәсе буларак килеп чыгу, хасил итү. *Мин ашасам аның чәчәкләрен, Сөт бирәм бит сөйгән кызына.* М.Җәлил. *Болар тамыр җәярләр, сабак, яфрак чыгарырлар, бай ашлык бирерләр, дигән өмет белән, якты тормыш дәрте белән тапшыралар.* Г.Ибраһимов. *Чәчәге коела җимеш бирер өчен.* Ә.Ерикәй

23) Нәрсәгә дә булса (белемнең ничек үзләштерелүенә, берәр нәрсә эшли алу сәләтенә) сынау, тикшерү үтү. *[Нәфисә] Бераз дулкынлана, үзен җидееллыкны тәмамлар алдыннан имтихан биргәндәге кебегрәк хис итә иде.* Г.Бәширов

24) Кешеләрне, учреждениене, предприятиене, оешманы һ.б.ш.ны аерым бер исем белән атау. *Бөтен кеше, сине яратып, сиңа Карчыга дип кушамат биргән иделәр.* Ш.Камал. *Мулла, өённән торып кына, аларга мөселманлык паспорты биреп: берсенә – Мифтах, икенчесенә Нәҗип дип исем бирде.* Г.Ибраһимов. *Без урамга яңа исем бирдек, Без урамга төс бирдек.* М.Җәлил

25) Нинди дә булса уңышлары, эшләре өчен, кешене мактаулы исемгә тәкъдим итү, дәрәҗәгә күтәрү. *Яхшы эш үрнәге күрсәткән колхозчыларга Социалистик Хезмәт Герое дигән исем бирү – беләсеңме ни дигән сүз?* Р.Ишморат

26) Тоташтыру. *Крестовниковны бирегез, завком белән тоташтырыгыз.* Т.Гыйззәт

27) Җитештерү, әзерләү, туплау, ясау. *Быелга, үткән елгыга караганда, планны ике өем арттырып биргәннәр.* Г.Әпсәләмов. *Сиңа шундый бер өй ясап бирим, бөтен Агыйдел буенда өең, якмыйча, май кебек җылы булсын, ди.* Г.Ибраһимов

28) Булдыру, тәрбияләп үстерү. *Җиһанша бабай, сокланып, үстергән егетләрен уйлый иде дә: – Мин Сәвиткә ике арыслан бирдем, --- дип, күңел эченнән тирән бер хак белән мактана иде.* Г.Ибраһимов

29) Нинди дә булса шәхес яки берәр нәрсә, хәл, күренеш турында, аерым максат белән, фактлардан чыгып, фикереңне белдереп, телдән сөйләү яки язу (бәяләмә, характеристика, рекомендация, белешмә һ.б.ш турында). *Кызыл постау белән капланган зур өстәл кырыендагы кафедра артына баскан ак сакаллы, күзлекле бер профессор бетереп чыгучы студентларга кыскача характеристика бирә.* М.Гали

30) *Күңел*, *игътибар*, *әһәмият* һ.б.ш. сүзләр белән килеп, барлык уйларыңны, фикерләреңне нинди дә булса бер объектка, эшкә юнәлтү. *Моңа асылда бер кеше дә юньләп әһәмият биреп карамады.* Г.Ибраһимов. *Шул кичтән башлап, Хәлим укуга артык күңел бирми башлады.* Г.Гобәй

31) Берәр нәрсәгә үзгәреш кертү, үзгәртү. *[Классик] Музыкаль әсәрләрнең текстлары, зур осталык белән, татар теленең үзенчәлекләрен саклап татарчага күчергән вакытта, аңа яңа төс бирәләр.* М.Җәлил

32) Билгеле кагыйдәләр нигезендә тупны уенга кертү яки партнёрга юнәлтү, тапшыру. *Туп бирү*

33) *юкл. форм.* Нәрсәне дә булса башкарырга, берәр нәрсәне булдырырга комачаулау, комачаулык тудыру. *Колхозга кермичә, ялгыз хуҗалыкта сүстән бау ишеп кәсеп итүче әти-әнисе Мөдәррискә пионерга керергә рөхсәт бирмәде.* Р.Хафизова. *Әгәр дә суда яки җир өстендә рөхсәт бирмәсәләр, һавага менеп куык очырмак булалар.* Ш.Мөхәммәдев. *Синең шул булыр инде, рәхәтләнеп сөйләшергә дә бирмисең.* Т.Гыйззәт

34) *сөйл.* Чамалап әйтү, якынча гына кешенең яшен билгеләү. *Егеткә, күп дигәндә, егерме-егерме бер яшь бирергә мөмкин.* Г.Әпсәләмов

35) *күч.* Кайбер абстракт исемнәр белән килеп: шул исемнән аңлашылган сыйфатларга, үзлекләргә ия итү. *Самолётлар оча киң күгеңдә, Көч һәм гайрәт биреп йөрәккә.* Ә.Исхак. *Усал бит хатыннар да, безнең яннан юлдан узып барганда, безнең азапланып ятканны күргәч, юри безгә куәт биреп, мыскыл итеп көлешеп китәләр.* М.Гали

36) *күч. гади с.* Кыйнау, сугу. *Икенче кат менә алгы яктан шул ук кендек белән биргәннәр.* Г.Ибраһимов

**2**. *ярд. ф. функ.* 1) Үзеннән алда килгән фигыль белдергән эшнең өзлексез, каршылыксыз дәвам итүен аңлата. *Жирдә, носилкаларында ята бирәләр.* Г.Гобәй. *Алар, сөмсерләрен коеп, тәрәзә башларына, лапас асларына кunалар да кукыраеп утыра бирәләр.* Р.Хафизова. *Рифкать тавыш килгән якка борылмакчы булды, ләкин башы тыңламады, тарттырып бәйләгән кебек, үз урынында ята бирде.* Р.Вәлиев

2) Үзеннән алда килгән фигыль белдергән эшкә интенсивлык төсмере өсти. *[Галия:] Күлмәккәме?.. Алайса, сез менә бу зәңгәр бизәклесен алыгыз, монысы сезгә килешәрәк бирә...* Р.Төхфәтуллин

◊ **Бирә-бирә бет басты** Һәр сораган саен, кешегә ни дә булса бирә-бирә, бөлгенлеккә төшү. *Миннән сукыр бер тиен юк. Болай да бирә-бирә бет басты инде.* К.Тинчурин. **Бирә-бирә бирән булу** Нәрсәне дә булса күп тапкыр биреп тә, һаман соранып йөдәтүне дәвам итүгә ризасызлык белдерү. *Бирә-бирә бирән булып бетәрсең әле.* А.Шамов. **Бирә-бирә бирәнгә сабышу** *к.* **бирә-бирә бирән булу**

**Бирә бару** Бер-бер артлы, берсе артыннан икенчесен бирү. *Алардан җыелган алтын, асылташ һәм червонецлар урынына, Шәфи һәртөрле имзанамәләр --- кәгазьләре бирә барды.* Ш.Маннур

**Бирә башлау** Бирергә тотыну. *Алар аша ул дин алган, хәреф алган, алардан күреп, иген игү эшенә дә ихлас бирә башлаган.* Х.Сарьян

**Бирә төшү** Тагын да бераз, беркадәр бирү

**Биреп бару** Һәр булганын, булган берсен бирү. *Хәзерге укучы өчен авыррак аңлаешлы гарәп, фарсы сүзләренең, терминнарның тәрҗемәсен астөшермәләрдә биреп бардык.* Н.Нәккаш-Исмәгыйль

**Биреп бетерү** Бик күп итеп бирү, барысын да бирү. *Үзе җентекләп, пөхтә, чиста, матур итеп киенеп йөрергә ярата. Фираяга да әллә никадәр бүләкләр,*

*кием-салымнар алып биреп бетерде.* Д.Бүләков

**Биреп җибәрү** Кеше аркылы бирү. *Миңа әманәт итеп кенә биреп җибәрделәр.* Ә.Фәйзи. *Менә бүген миңа Казанга чыгып китәргә кирәк иде дә, Шырданда җыен буласы булгач, почтаны малайга гына биреп җибәрдем дә, үзем монда килдем.* М.Гали

**Биреп калдыру** 1) Кемгәдер тапшыру өчен бирү; бүләк итеп бирү. *Ул кергән бер җирендә бүләккә йә затлы каләм, йә хуш исле сагыз, йә берәр ят сувенир биреп калдыра.* М.Галиев

2) Мирас итеп бирү. *Хафиз картның әтисе дә кулыннан балтасын төшермәде, һөнәрен улына биреп калдырды.* Н.Акмал

**Биреп калу** Нindидер хәл булганчы, алдан ук бирү, бирергә өлгерү. --- *сукыр калган һәм чукракланган әбиләребез, сугыштан соң, берүзләре балаларын аякка бастырып, ягъни үстереп һәм тәрбияләп, әле оныкларына да нәрсәдер биреп калырга өлгереп, дәшми-тынмый гына үз гомерләрен үткәрделәр.* Т.Кәримов

**Биреп карау** Сынау өчен бирү. --- *мин менә берничә ел инде, авыл аралап, улыма акыллы бер кыз эзләп йөрим, шушы сорауларны күп кенә кызларга биреп карадым, барысына да тезеп җавап бирә алганы син генә булдың, зиһенле кыз икәнсең, каршы килмәсәң, улыма сине йәрәшәм, киленем бул.* Н.Исәнбәт

**Биреп килү** Даими рәвештә, системалы бирү. *[Сәйяр] Драмтруппасы артистлары атнага ике тапкыр спектакль биреп килделәр.* И.Рәмиев

**Биреп китү** 1) Нindидер вакыттан башлап бирүне дәвам итү. *Җиңел генә дәрес биреп китә икән.* М.Гафури

2) Тапшыру өчен бирү, калдыру

**Биреп кую** Көтмәгәндә, кинәт бирү; алдан бирү. *Кем белә, бәлки, фатир да биреп куярлар әле.* Р.Вәли. *Хөкем әгъзаларының рәистән сул якта утырганы – гыйльми хезмәтчеләр секциясеннән язучы агроном һәммәсенең тел очында булган бу сорауны ашыгып биреп куйды.* Г.Ибраһимов. *Камәретдин, артык сүзгә урын калдырмаска тырышып, өйдәгеләрне кызыксындырган барлык сорауларга берьюлы җавап биреп куярга ашыкты.* М.Әмир

**Биреп тору** 1) Һәрвакыт, гел бирү. *Әгәр дә кирәк булса, без кирәкле норма билгеләячәкбез һәм токтарлыксыз биреп торачакбыз, ди.* Ш.Камал. *Шулай ук монда, фонтан кебек, көнгә уннарча мең пот җир асты байлыклары атып торган нефть вышкалары, меңнәрчә тонна күмер биреп торган шахталар да юк.* М.Гали. *Бу әлеге яңа чор, litterally коя́шлы һәм нурлы апрель иртәседәй, йөрәкләргә бетмәс-төкәнмәс егәр һәм ышаныч биреп тора.* М.Хәсәнов

2) Вакытлыча бирү. *Майтап әби, савыт-сабаларың биреп торсаңчы!* Т.Гыйззәт. *Менә син тот та сарык фермасына кайтарткан бүрәнәләреңне биреп тор.* А.Гыйләҗев

**Биреп узу** *к.* **биреп үтү.** --- *автор гражданнар сугышы чорында үз башыннан узган олы вакыйгалар, шул чорның узаманнары – Фрунзе, Врангель, Махноларга бәя биреп уза.* Т.Галиуллин

**Биреп үтү** Нинди дә булса эш, сүз уңаенда ни дә булса сөйләү. *Тик аларга кыскача билгеләмә генә биреп үтәргә мөмкин.* К.Миңнуллин

**Биреп чыгу** 1) Нәрсәне дә булса һәрберсенә дә бирү. *Валерикны алырга кергән апа барысына да берәр ландрин биреп чыкты.* Г.Гобәй. *Менә алар, яралыларга бер кат уколлар, дарулар биреп чыккач, сестралар бүлмәсенә кайттылар.* Х.Камалов

2) Тулысынча, башыннан ахырына кадәр биреп бетерү. *Өченче курсны тәмамлап, бар имтиханын да уңышлы биреп чыкты*

**БИРЧӘЮ** *ф.* 1) Тән тиресе тупаслану, кытыршылану, сөялләр чыгу. *Агач тамырлары сыман бирчәйгән, тамырлары бүртеп чыккан кулларын ул күккә суза.* Р.Мулланурова

2) Тупаслану, рухи матурлыгын югалту

**Бирчәеп бетү** Бик нык бирчәю. *Алар чынлап та яргаланып, бирчәеп беткәннәр.* Ә.Фәйзи. *Беренче тотыну белән, Ирек аның үзеннән көчле икәнлеген аңлады. Бу – эшләгән, бирчәеп беткән кул түгел, әмма ифрат та саллы, көчле иде.* Ф.Садриев

**Бирчәеп калу** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң бирчәйгән хәлгә килү. *Убыр кешеләргә дә төрле чирләр чыгара. Тәннең бер җирен суырса, имсә, шул урынга чуан чыга, йә сыткы чыга, бирчәеп кала.* Әкият. --- *ватык тракторын бер сүтеп, бер җыеп изалана торгач, ком гарәбе кебек каралып беткән, дегет сеңгән куллары рашпиль сыман кытыршыланып, бирчәеп калган.* Ф.Баттал

**Бирчәеп килү** Акрынлап бирчәю

**Бирчәеп тору** Әле, хәзер бирчәйгән булу

**Бирчәеп чыгу** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң бирчәйгән хәлгә килү. *Әнә буыннарыгыз да бирчәеп чыккан, кул-аякларыгыз да, минеке шикелле, кәкре-бөкре булып каткан.* Г.Бәширов

**Бирчәя бару** Торган саен ныграк бирчәю

**Бирчәя башлау** Бирчәергә тотыну. *Үз телеңдә озак сөйләшә алмый йөрсәң, бервакыт, күңелнең бирчәя башлавын тоеп аласың.* М.Юныс

**Бирчәя төшү** Тагын да бирчәю

**БИС** *ы. фр. < лат.* Артистның уңышлы, күңелгә бик ошаган чыгышын яңадан кабатлап башкаруын үтенү. *«Браво» һәм «бис» кычкырган тавышлар ишетелә.* Ф.Әмирхан. *Фатыйманың һәр җырыннан соң бөтен кешедән көчлерәк кул чапты, бөтен кешедән көчлерәк «бис» кычкырды.* Г.Әпсәләмов

**БИСКВИТ** *и. фр.* 1) Күпертелгән йомырка, сөт, май, он катнашмасыннан пешерелгән камыр; пирожное. *Шырпы кадап караганнан соң, аңа камыр ябышмаса, бисквит әзер, дигән сүз.* Татар халык ашлары

2) Печеньеның бер төре. *Аннары зур шоколад кисәген, җылытып, каймак кебек сыеклыйлар да торт өстенә сөртәләр, кырыйларына варенье яки джем ягалар һәм коры бисквит валчыгы сибәләр.* Татар халык ашлары

**БИСМИЛЛА** *и. гар.* 1) Теләсә нинди эшне башлар алдыннан яки ашарга утырганда әйтелә торган дога; мәгънәсе: Алла исеме белән. *Догаларны күп белә, аларны улларына әйтеп яздыра, бисмилла әйтмичә, бер эшне дә*

*эшләмәскә куша иде.* Г.Ахунов. *Әти үзе дә, Коръәнне кулына тотар алдыннан, әйбәтләп юына, аннары бисмилласын әйтеп кенә ала.* Ф.Яруллин. *Әткә-әнкәсе бисмиллаларын әйткәч, Зиннур инде кайчаннан бирле авыз суларын китереп торган коймакларны умырырга тотынды.* Я.Зәнкиев. *Бисмилласыз башланган сүз зиһенгә барып җитми, аны шайтан эләктереп ала да анда буталыш тудыра.* Ф.Сафин

2) *күч.* Башы, башлангыч өлеше. *Үзем бер китап язарлык хәлгә килгәч, иң әүвәл тәрҗемәнең бисмилласын әйтергә карар кылдым.* К.Миңлебаев. *Я, карышма әле; бусы – шул күңелле көннәрнең бисмилласы булыр.* М.Фәйзи

◊ **Бисмилласын укыту** Акылга утырту, тәүбәгә китерү, тәүфыйкка китерү; бик каты ачулану

**БИССЕКТРИ́СА** *и. фр. мат.* Почмакны ике тигез өлешкә бүлә торган туры сызык. *Почмакны урталай бүлүче нур почмакның биссектрисасы дип атала.* Геометрия. *Биссектрисада почмак очыннан a = 20 см ераклыгындагы С ноктасында магнит индукциясен табыгыз.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

**БИСТӘ** *и.* 1) *тар.* Россиядә, XI–XIII йөзләрдә, крепостной булмаган халык яшәгән зур авыл, шәһәрчек. *Шәһәр нигытмасының тышындагы бистәләрнең вак йортлары, рум бистәсенең чиркәү гөмбәзе күренде...* Г.Гобәйдуллин. *Ханнар булып ханнар көнләшерлек тамаша – сарайлардан тезелгән бай урамнар, үзәкнең күкрәгеп икегә ярып, бистәне көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләргә бүлә.* Сөембикә

2) Шәһәрнең эчендә яки кырыенда аерым урнашкан өлеш, район, шәһәрчек. *Зур-зур яңа йортлар салына безнең Әмәт тавы бистәсендә.* Ф.Хөсни. *Тавы белән бергә өскә авам-авам дип торган нарат кулагәсендә үлән дә шытмый, дип, күрше-күлән бистәгә үк күченде.* Н.Гыйматдинова. *Дәрвишләр бистәсендәге балалар интернат-йортында тәрбияләнүчеләр күңелле бүләк алды.* Ватаным Татарстан

**БИТ** I *и.* 1) Кеше башының алгы өлеше; йөз. *Адәмнең ояты – битендә.* Мәкаль. *Шәрран яра кычкырудан аның йөзе кызарып чыккан, битендәге сипкелләре нәни тәңкәләр кебек җемелдиләр.* Р.Хафизова. *Ярулла, хикмәт, битенә кояш төшкәнче йоклый торган иде, җитмәсә, уянгач та иренчәкләнеп, иркәләнеп ятар иде.* М.Хәбибуллин

2) Йөзнең яңак өлеше. *Күзеннән түбән сул битендә төзәлгән бер җәрәхәт эзе дә бер караштa ук күзгә ташлана иде.* Ш.Камал. *Битеңнең чокырларына карап һуштан язарлар дисеңме әллә?* М.Фәйзи

3) Өске өлеш, өскә карап торган, тышкы як. *Чалбар аяк битенә чаклы тип-тигез булып салына.* Г.Ибраһимов. *Хатыны белән җиткән кызы, бармак бите кадәр генә вак-вак тиреләрне ялгап, бүрек эчлеге әзерлиләр, ике кечкенә бала аларга капчыктан тиреләр сайлап алып биреп торалар.* М.Гали. *Бер офыктан икенче офыккача күкнең бите карачкыл күгелҗем пәрдәгә төренә.* Ә.Айдар. *Вак таш җәйгән урам битенә.* К.Нәҗми

4) Тау, калкулыкның һ.б.ш.ның авыш, сөзәк яны, өслеге. *Кафил ямьяшел тау битен, тау итәге буйлап аккан киң елганы, аның аръягында урнашкан гүзәл каланы, каладагы бихисап алтын мәчет манараларын күрде.* З.Мәхмүди. *Тау битенә таралган көтү әкренләп җыела төште.* М.Галиев. *Әрәмәлек битендәге чишмәне беләсеңме?* Казан утлары

◊ **Бит алмасы** Яңакның күпереп, калкып торган өлеше. *Фаягөлнең бу сөйләшүдән ризасызлыгы чыраена бәреп чыкты: бите – әлерәк кенә алсуга кабынган бит алмалары сулды, агарып китте.* Г.Ахунов. *Бит алмаңа коелыр яшьләрең.* Ә.Ерикәй. **Битеннән кан таму** Сәламәтлеге ташып тору, таза, тулы канлы булу. **Битен юмаган** Әрсез, оятсыз, намуссыз. **Бит ерту** Тупас кимсетү, дәрәҗәсен төшерү, хурлау; әрсезләнү. **Биткә бәрү, биткә бәреп әйтү** Хәтер сакламыйча, ачыктан-ачык әйтү. *Әле генә бөтен халык алдында хур итеп чыгардылар ич! Битемә бәреп әйттеләр.* Г.Бәширов. **Биткә кара (корым) ягу** *к.* **биткә кызыллык китерү.** *– Ни генә әйтим инде мин сиңа, Ибраһим, – ди бабасы. – Бөтен нәселнең битенә корым яктың бит син моның белән.* Г.Гобәй. **Биткә олтан (ыштыр) каплау** Оятсыз, намуссыз булу. *Зифа айныган. Шунлыктан, һәммәбез дә, битебезгә олтан каплаган хәлдә, сезне өйгә кабул итми торырга туры килә.* М.Фәйзи. **Биткә оят (оятлык) китерү** *к.* **биткә кызыллык китерү**. *Күз генә тия күрмәсен, болай булса әле, [Маһриҗамал] дус-дошман арасында биткә оят китермәс, дим.* М.Гали. **Биткә төкерү** Кеше алдында оятка калдыру, хурлыкка төшерү. *Инде син чәчкәнеңне урасың: бары да сиңа каршы баш күтәрде, синең үз балаң үзеңнең битеңә төкереп качты.* Г.Ибраһимов. **Бит кызару, биткә кызыллык китерү** Хурлыкка, оятка калдыру, уңайсыз хәлдә калдыру. *Район, беренче мәртәбә, дәүләткә ашлыктан бурычлы булып калды. Моның өчен, иң беренче, Мансуровның бите кызара, колхозлар эшендәге бөтен кыенлыкны, иң башлап, ул күтәрә иде.* Г.Бәширов. *Дөрес, биткә кызыллык китерерлек итмәс Исмәгыйль.* М.Фәйзи. **Бит очы** *к.* **бит алмасы**. *Сафаның бит очлары өшегәнен сизми калганбыз.* Х.Кәрим. *Киң кара чалбар, Итек шпорлы, Бит очы – алма, күзләре нурлы!* З.Мансур. **Бит пешү** Оятлы булу, уңайсыз хәлдә калу. *Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә – бит пешә.* Мәкаль. **Бит сыптыру** *к.* **бит сыпыру**. *Безнең тачкачылар, балыкны бик күп тотып та, кырыгар сум акча эшләү хыялларына инде бит сыптырган иделәр.* Ш.Камал. **Бит сыпыру (сыйпау)** 1) Дога кылу. *Мулла, тавыкны ашап, бер сумга ихлассыз гына бит сыйпап, мәһәр түләнгән, дип язып китте.* Г.Ибраһимов; 2) Исәптә ялгышу; алдан билгеләнгән уй-хыяллар тормышка ашмау. *Без алтыннарның урынын күрсәтәбез икән, аны рәхәтләнеп кенә сыпырып алачаклар. Синең белән безгә нәрсә кала: --- бит сыпырудан башка бер әйбер дә калмый.* Ш.Камал

**БИТ** II *и.* 1) Китап-дәфтәрдәге һ.б.ш. лардагы кәгазь табагының бер ягы. *Малай, башын аска иеп кенә, рәсемнәр белән чуарланган дәфтәр битен өстәлгә китереп салды.* З.Мәхмүди.

*Даруы табылса, тыйб китабының беренче битенә үк язып куяр иде Әбүгалисина галиҗәнапләре.* Ф.Сафин. *Шакмаклы дәфтәр битенә язылып, җыйнак кына итеп бөкләнгән дә өстенә «Р.И. абыйга» дип язылган.* Р.Ишморат

2) Китап-дәфтәрдәге һ.б.ш.лардагы кәгазь табагының тигез кисәкләргә бүлгәннән соң килеп чыккан өлеше. *Кая, бер бит кәгазь бир әле.* Р.Ишморат. *Сезнең журналның һәр битен укып, үземә җан азыгы алам.* Сөембикә. *Матбугат битләрендә аларның кемлегенә, ниндилегенә кагылышлы бәхәс кузгалды.* Шәһри Казан

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса аерым бер чоры, бер өлеше; сәхифә. *Карт тарихның меңләгән бите төсле мүкләнгән, Картайган, каралган, Ташланган, таушалган.* К.Тинчурин. *Гражданнар сугышының соңгы бите.* К.Нәҗми

**БИТ** III *и. инг. информ.* Информатикада мәгълүмат күләмен санау берәмлеге; компьютер хәтеренең иң кечкенә элементы

**БИТ** IV *кис.* 1) Хәбәрнең тыңлаучыга мәгълүм булганлыгына ишарә итеп, яңадан раслау төсмере өстәп, фикерне куәтләү өчен әйтелә; ич. *«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда бит – Казан».* Г.Тукай. *Чөнки ул белә – мин бит башкарма органда эшләмим.* Ф.Мөхәммәтшин. *Аннары шунысы да бар: Татарстанда, башка төбәкләр белән чагыштырганда, хезмәт хаклары түләү үзенчәлекләрәк бит.* И.Сафиуллин. *Бу – туган илем көе бит, Кем шулай җыр суза?* С.Хәким

2) Экспрессив әйтелешне өстәмә көчәйтү чарасы булып килә. *Ә бит, уйлап карасаң, ул вакыттан нихәтле сулар акты.* И.Гази. *Өлгерер әле, ул бит хәзер шушында яшәячәк, теләсә, атна саен, хәтта көненә әллә ничә килергә була.* Р.Кәрами. *Югыйсә, ул бит бары тик китапларда – тузан эчендә ята торган бер көй генә булып калачак иде.* И.Шакиров. *Әйтәм бит, яклана белми торган, әйбәт малай ул.* Тәмуг чәчәге

**БИТАРАФ** *с. фар.-гар.* **1**. 1) Бер якка да кушылмый, катнашмый торган, бер якныкы да булмаган, нейтраль. *Көннәрнең берендә немец ягын капшарга барган безнең разведчиклар битараф мәйданда бер немец лейтенантының үле гәүдәсенә тап булдылар.* Ш.Маннур

2) Гамьсез. *Карчыкның битараф сымак йөзендә, ниһаять, хәрәкәт барлыкка килде.* Г.Якупова.– *Менә, укы, – диде ул, битараф караш, төшенке күңел белән*. Р.Кәрами

**2**. *и. мәгъ.* Кеше хәленә керми торган, гамьсез, кешедә кайгысы булмаган, ваемсыз кеше. *Кызганыч, үзләрен татар баласы дип сизмәгән, милли аралашуга мохтаҗлык кичермәгән, үз милләтенә бөтенләй битарафлар да байтак.* Идел

**3**. *рәв. мәгъ.* Шул сыйфатка ия булып, гамьсезлек белән. *Ике йөздән артык йортлы, мәчетле, таза татар авылы битараф каршы алды аларны*. Т.Галиуллин. *Берәүнең дә кайгысына битараф калмады, хәсрәтен гүя үзе дә кичерде...* К.Миңлебаев. – *Кем ул? – диде Ричард, һәрнәрсәгә битараф рәвештә.* Тәмуг чәчәге. *Композиторның якты сагышлы, җиңел агышлы музыкасы тамашачыны битараф калдырмады, алар спектакльне дә яратып карадылар.* Идел

**БИТАРАФЛАШТЫРУ** *ф.* Битараф (катышмый торган) хәлгә китерү, битараф итү. *В.И.Ленин партияне урта хәлле крестьянны битарафлаштыру лозунгысыннан аның белән ныклы союз төзүгә күчәргә чакырды.* КПСС тарихы

**Битарафлаштыра бару** Торган саен битарафлыгын арттыру

**Битарафлаштыра төшү** Тагын да битарафлаштыру

**Битарафлаштырып бетерү** Тәмам битарафлаштыру

**Битарафлаштырып килү** Даими, күптәннән бирле битарафлаштыруны дәвам итү

**БИТАРАФЛАШУ** *ф.* Битараф хәлгә килү, кызыксынуын югалту, гамьсезләнү, гамьсез, ваемсыз кешегә әйләнү

**Битарафлашып бетү** Тәмам битарафлашу

**Битарафлашып бару** Акрынлап битарафлашу

**Битарафлашып калу** Нindидер сәбәптән соң битарафлашу

**Битарафлашып китү** Кинәт битарафлашу

**БИТАРАФЛЫК** *и.* 1) Бер якка да катнашмаучылык, нейтральлек. *Авыз ачып сүз әйтмиләр, күз йомып калу ягын карыйлар, битарафлык чиген атлап уза алмыйлар.* К.Миңлебаев. *Күрәсең, ул да аның битарафлыгыннан туйган иде.* Н.Хәсәнов. *Хәзер бездә – дәртсез, салкын күңел, ышанмау һәм өнсез битарафлык.* Г.Афзал

2) Кеше кайгысына битараф калу, гамьсезлек. *Кыяфәтенә битарафлык чыгарырга тырышып, сүзсез генә, кара киемленең йөзенә текәлде.* Ф.Латыйфи. *Аның зәңгәр күзләре мизгел эчендә гаҗәпләнүдән зурая да мизгел эчендә кысыла, һәм баягы гаҗәпләнү битарафлык белән алышына иде.* Н.Гыйматдинова

**БИТӘР** I *рәв. фар.* **1**. 1) Бигрәк, ныграк, артыграк. *Уку елы башлануга ул Әсгатьтән дә битәр дулкынланган кебек иде.* Р.Хафизова. *Бәяләр дә шашынды, бәяләрдән битәр, түрәләр азынды, майларына чыдаша алмый үтләделәр.* Н.Хәсәнов. *Кем икәнен үзең миннән дә битәр белеп торасың бит, ди.* Г.Мөхәммәтшин

2) Артыграк, күбрәк, көчлерәк. *Рәхимсез мәхәббәт аның йөрәген элеккедән битәр талый.* И.Гази. *Нигәдер кайбер кеше гомер буена, иҗаттан битәр, дан-шөһрәт ягын кайгырта.* К.Миңлебаев. *Кешеләребез, шөкер, әйбәтләр, фермановы, дип тормыйлар, әйе, үз терлекләреннән битәр карыйлар.* Ә.Еники. *Йотылып, әкият укыганнан битәр мавыгып укыдык без аларны*. М.Әмир

**2**. *бәйл. функ.* Аннан башка, башка, тыш. *Аның кара гына чәченнән битәр, көләч йөзенә рәхәтләнеп карады.* Г.Исхакый. *Акылдан битәр йөрәк бар...* Н.Гыйматдинова

**БИТӘР** II *и.* Шелтә, ризасызлык. *Яшьтән үк ирен югалтып, гомер буе авылдашларының битәрен ашап яшәгән бу хатынга Ходай Тәгалә тагын бер сынау җибәргән...* Г.Гыйльманов. *Әр – битәр, әрдән дә бигрәк наз – битәр.* Мәкаль

**БИТӘРЛӘ́Ү** *ф.* **1.** Ачулану, ризасызлык, шелтә белдерү, кимчелеклә-

рен күрсәтеп оялту, әрләү. *Такташны һич кенә дә күңелемнән куып чыгара алмыйм, аның өчен мине битәрләмә, зинһар.* Ф.Сафин. *Ә хәзер бар, керим инде... Әни битәрлидер анда.* Р.Зәйдулла. *Иртән пешереп китсәм, калган аш ашатасың, дип битәрлиләр.* З.Фәйзи. *Үзеңне битәрли алгач, төзәлергә өмет бар икән әле!* Х.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Ачулану, шелтә, ризасызлык. *Гата, әнисенең битәрләвен тыңлый-тыңлый, шыпырт кына сәке өстенә менеп утырды да бәрәңгене ура башлады.* Р.Хафизова. *Габдулла җизнәсенең соңгы битәрләүләрен инде оныткан, тик аннан элекке «атаңа нәләт!» дигән сүзе генә һаман аның кечкенә йөрәгендә әрнеткеч төер булып тора иде.* Ә.Фәйзи

**Битәрләп алу** Бераз битәрләү. *Моның өчен Газизә апа Габдулланы битәрләп ала...* Ә.Фәйзи. *Ул Габдулланың яшен сөртте, юатты һәм үзенең энеләрен бик нык битәрләп алды.* Ә.Фәйзи. *Хәкимҗанның иңрәүле тавышын ишеткәч, уеннан кире кайтты, ярамас сүз ычкындырдым бугай, дип, үзен битәрләп алды.* М.Хәсәнов

**Битәрләп бетерү** Бик нык битәрләү. *Сезне уйлап кына юанам, көнем-төнем, уем сезнең белән бит, сезгә болай озак язмый торуым өчен үземне битәрләп бетердем.* Ф.Сафин

**Битәрләп йөрү** Озак вакытлар буе битәрләү. *Ахырдан үз-үземне битәрләп йөрим.* Т.Миңнуллин

**Битәрләп кую** Кинәт, аз гына битәрләү. *Ул моңа кадәр аңа бөтенләй игътибар итмичә йөрүе, аның белән аралашмавы өчен, үз-үзен битәрләп куйды.* Р.Вәлиев

**Битәрләп ташлау** Кинәт кенә, кызулык белән бик каты итеп битәрләү. *Хөршидә Камиловнаның хаклы булуын күз алдына да китерми, киресенчә, аны ачуланырга, битәрләп ташларга әзер иде ул.* Ф.Яхин

**Битәрләп тору** Бертуктаусыз, һәрвакыт битәрләү. *Әтиләре, җае туры килгән саен, гел әниләрен битәрләп торды.* С.Поварисов

**Битәрләп утыру** Әле, хәзерге вакытта битәрләү. *Кич буе Фәрит белән үзебезне итагать белмәвебез, беркатлылыгыбыз өчен битәрләп утырдык.* Р.Вәлиев

**Битәрли башлау** Битәрләргә тотыну. *Хатыны бик битәрли башлагач, торыр да чукмардай йодрыгын эшкә кушар кебек тоелган иде Галимҗанга.* С.Поварисов

**БИТЕК** *и. тар.* 1) Шифалы тылсым көченә ия булган язулы догалык кәгазе, бөти, талисман, амулет

2) Хат, язу. *Болар өстенә каган Кубрат ханга, озын итеп, битек язган.* М.Хәбибуллин. *Битекне ул, ачу белән, идәнгә атып ормакчы булды.* Н.Фәттах

3) *иск.* Язма

**БИТЕКЧЕ** *и. тар.* Хат, документларны язучы. *Битекче Сымбат буйсынлы, аксыл йөзле чибәр бер кеше иде.* Р.Зәйдулла. *Диванда зур хакимлеккә ия битекче, ягъни дәүләт секретаре кебек урын да булган.* Г.Дәүләтшин

**БИТЕКЧЕ ОГЛАН** *и. тар.* Укучы бала, шәкерт

**БИТЕР** *и. ингл.* Ашлык сугу машинасында барабан төре. *Комбайн эшләп торганда, шнек һәм йөзмә транспортёр чабылган сабакларны берөзлексез өскә – кабул итү камерасында урнашкан алу битерына биреп тора, ә битер исә аларны суктыру җайланмасына юнәлтә.* Урып җыю машиналары

**БИТИГ** *и. иск.* 1) Китап; язма; документ, амулет. *Борынгы төркиләрнең «Ырк битиг» дип аталган әсәрендә дә космик һәлакәт турындагы риваять теркәлгән.* Н.Фәттах

2) Язу гамәле (процессы)

3) Хат. *Ул битиг эчендә йазылмыш кем: Йә Мөхәммәд, белгел, бу нәүбәт кем килдем, ул игътикад (ышаныч) берлә килдем.* М.Болгари. *Мөхәммәд Әминнең татарча язылган рәсми хаты, ягъни бетеге (битиге), Хәким Бирде исемле илчесе аркылы, 1506 елда Польша хөкемдары Александрга җибәрелә.* Х.Миңнегулов

**БИТИГЧЕ** *и. тар. к.* **битекче.** *Пәйгамбәр битигчегә бойырды кем: «Йәмән патшасы Нә Җашигә миндин битиг битигел (хат яз)!» – тиде эрсә, ул битигче әйде: «Йә Рәсуллаллаһи, нәтәк битигәйен (ничек языйм)?»* Мәхмүт Әл-Болгари

**БИТЛӘП** *рәв.* Һәр битен берәмтекләп, бит саен. *Мин Октябрь борылышына кадәр чыккан бөтен татар вакытлы матбугатын картотекага алып, битләп, авторлап укып чыктым.* М.Мәһдиев

**БИТЛӘ́Ү** I *и.* Тау бите, сөзәклек, авышлык. *Исламов --- чокыр битләвендәге яшел чирәм өстенә утырды.* Ф.Кәрим. *Нурыйҗан бабай, соңгы берничә ел инде, җәй буе, көн-төн, ерак битләүдә колхоз бакчасын саклый, ә ак кар явып, кыш кергәч, машина юллары өзелгәч, идарә атларын карарга керешә иде.* Казан утлары

**БИТЛӘ́Ү** II *ф.* Биткә салу, битләргә урнаштыру, вёрсткалау

**Битләп чыгу** Һәрберсен, барысын да битләргә аеру

**Битли бару** Бер-бер артлы битләү

**БИТЛЕК** I *и.* 1) Битне саклау өчен киелә торган, нечкә тимерчыбыктан, кылдан яисә капрон җептән үрелгән япма, каплавыч. *Саттар карт килеп кергәндә, битлек кигән Җамали, кулына төтәткеч тотып, дөнья бетереп, нидер эзләп маташа иде.* З.Фәйзуллин. *Ул урманга битлексез яки кыска җиңле күлмәк белән кереп, унбиш минут торсаң, һичшиксез үләсең!* М.Мәһдиев. *Минә аларның киеме: тәнгә сыланып торган кара костюм, битнең түбән өлешен каплаган битлек...* Кызыклар дөньясында. *Ул тоташ ап-ак киемнән, хәтта йөзе дә ак битлек белән капланган иде. Битлектәге уемнар артындагы күзләре белән ул сәяхәтчеләргә текәлеп һәм сынап карады.* Тәмуг чәчәге

2) Инфекциядән саклану өчен, авызборынны томалый торган каплавыч. *Ул, алгарак узып, ассистент белән янәшә басты да, битлек астында кызышып киткән иреннәрен авыр хәрәкәтләндереп: – Изаил Харисович, уң якны күтәреп, эчкәрәк карагыз әле, – диде.* М.Маликова. *Гаиләдә авыру булганда, кул астында 4–6 битлек тотарга кирәк, аларны 2–3 сәгать саен алыштырып торалар.* Татар мөселман календаре

3) Борын заманда, битне җәрәхәтләнүдән саклау өчен, сугышчылар,

рыцарьлар кия торган бит каплавычы. *Менә мәсәлән, рыцарьлар: алар махсус киемдә булганнар, битлекле кием кигәннәр. Исәнләшкәндә, кем белән исәнләшкәнне белү өчен, битлекләрен күтәреп карый торган булганнар.* Яшь ленинчы

4) Башкалар танымасын өчен, кеше яки җәнлек йөзенә охшатып, махсус эшләнгән каплавыч яки үтәли күренә торган, я булмаса күз, авыз, борын турыларында тишекләр калдырылган кара япма. *Аның [сәүдәгәр Крит] сөйләве буенча, Урта Азиягә сату итәргә барганда, иртәнге якта, көтмәгәндә, аларга йөзләренә битлек япкан бер көтү җайдаклар һөҗүм иткән.* Р.Сәгъди. *Борынгы башкорт курганнарында бүре бите формасындагы көмеш битлекләр очрый.* Г.Дәүләтшин. *Игезәкләрнең әти-әниләре, авылдан читкә чыгып, кечкенә шалаш ясаган, аның тирә-ягына агач сыннар, битлекләр куйган.* Кызыклар дөньясында

5) Косметикада: дәвалау максатында яки тукландыргыч буларак, биткә, муенга ягыла торган махсус состав

6) Сәгатьнең һ.б.ш. үлчәү приборларының цифр, язу яки башка төрле билгеләр төшерелгән пластинкасы; циферблат. *– Ярар, үзең теләгәнчә эшлә, – дип, Ает бай, муенына озын көмеш чылбыр белән асып, кыска җиңле бикасап камзулының күкрәк кесәсенә тыккан сары битлекле зур көмеш сәгатен алып карады.* М.Гали. *Бану җиңги белән Сиражи абзый, сәгатьнең битлегенә карый-карый, чәй эчә башлыйлар.* М.Галәү

7) *күч.* Чын асылын яшерә торган шартлар, ясалма тышкы күренеш, кыланыш, эшчәнлек. *Иң кулае, әлбәттә инде, караңгы төн: ул һәркемгә, шул исәптән җинаятьчегә дә, кара битлек кигезә.* К.Миңлебаев. *Еллар һәм томкыннар ялгышмый: надзирательләр бер кигән кабыкларын һәм битлекләрен салмыйлар.* А.Гыйләҗев. *Бер машинада утырып, шәһәр урамнары буйлап барган арада, битлек урынына киеп куелган корылыгы, таләпчәнлеге коелып төшкәндәй булды, фәлсәфә корырга, фикер үткерлеген чарларга омтыла торган төпле кеше икәнлеге беленде.* М.Маликова

◊ **Битлеген алып ташлау** *к.* **битлеген ерту**. **Битлеген ачу** *к.* **битлеген ерту.** *Чөнки Нуриәсманың күрше егетен – күз алдында үскән Гарифҗанның исерек булуын раславында колхоз рәисе Хөснуллинның ялган битлеген ачу һәм авылдашларының битарафлыгына каршы чыгуын аңлау гына җитми ---.* Ә.Закирҗанов. **Битлеген ерту** Фаш итү. *– Дөньяви фәннәр укыту идеясен башлап кем күтәреп чыкты? Һәм «Бохараи Шәриф»нең битлеген кем ертты? – Мәрҗани!* М.Госманов. **Битлек артына (астына) яшеренү** Чын йөзен яшерү, үзенең чынбарлыгын, карашларын, фикерләрен, тойгыларын яшерү, үзен икенче кеше итеп күрсәтү. *«Демократик» дигән хөкүмәтләр Яшеренеп битлек артына, Яклаганда дошманны күмәкләп, – Чын туганлык кулын без суздык.* Ә.Исхак. (**Йөзен) Битлек белән каплау** *к.* **битлек артына (астына) яшеренү. (Йөзенә) Битлек кию** *к.* **битлек артына (астына) яшеренү.** *Автор чыраена кара битлек кия, исемен яшерә...* А.Гыйләҗев

**БИТЛЕК** II *с.* Күләме битләрдә билгеләнгән, күпмедер биттән торган. *Муса дөрес әйтә: кызларның чак кына керфек сирпеп алуында да мең битлек китапка сыеп бетмәслек сер ята, аңлый гына белергә кирәк, ди ул.* Ф.Сафин. *Соңгы елларда фәнни вә иҗтимагый әсәрләрнең өч-дүрт йөз битлекләре еш-еш кына чыга башлады.* Г.Ибраһимов

**БИТ САБЫНЫ** *и.* Исле сабын

**БИТСЕЗ** *с. гади с.* Оятсыз, намуссыз. *Аш пешерүче мәчене вәгазьләргә башлап: «И оятсыз! Битсез! Син бу эшне эшләргә кешеләрдән генә түгел, хәтта стеналардан оялырга кирәк иде».* Г.Тукай

**БИТСЕЗЛӘНҮ** *ф. гади с.* Оятсызлану, намуссызлану

**Битсезләнә бару** Битсезлеге артканнан-арту

**Битсезләнә төшү** Тагын да битсезләнү

**Битсезләнеп бетү** Тәмам, бик нык битсезләнү

**БИ́ТУМ** *җый. и. нем. < лат.* Сумала яки дегетсыман углеводородлы катнашмаларның гомуми исеме (асфальт, гудрон, нефть, табигый газлар һ.б.). *Күмер, битум, торф, нефть, минераллар һәрбер төреннән бар икән.* Ә.Исхак. *Германиянең Магдебург шәһәрендә яшәүче 91 яшьлек бабай, битум белән яхшылап сылау өчен, өенең түбәсенә менгән.* Татарстан яшьләре

**БИ́ТУМЛАУ** *ф.* Битум салу, битум кою

**Битумлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, бар җирен дә тоташ битумлау

**БИ́ТУМЛЫ** *с.* Битум катнашкан, битумнан торган, битумы булган. *[Иванов:] Менә Бизмән тауда табылган битумлы комлы таш, известняк.* А.Әхмәт

**БИФШТЕКС** *и. нем.<ингл. кулин.* Ваклап турап яки тапап йомшартып, тоз, борычтан башка тәмләткечләр салмыйча кыздырылган сыер ите кисәге. *Бифштекс өчен итне агач тукмак белән суккалап йомшарткач, бераз гына тоз, борыч сибеп, мае нык кызган табага яки сай кәстрүлгә салырга һәм һәр ике ягы пешеп җиткәнче (10–15 минут) кыздырырга кирәк.* Йорт эшләре

**БИХӘБӘР** *рәв. фар.-гар.* Хәбәрсез, мәгълүматсыз, хәбәрдар түгел. *Бу хакта аннан башка беркем дә белмәде бугай, хәтта әтисе дә бихәбәр йөрде, ахры.* Ф.Сафин. *Базар дөньясы серләреннән бихәбәр меңләгән казанлылар өчен гадәти бер көй булып яңгыраган бу авазларның яшерен мәгънәсен белә иде шул Сәет.* Ф.Латыйфи

**БИХИСАП** *с. фар.-гар.* 1) Хисапсыз, исәпсез, бетмәс-төкәнмәс. *Сәгыйдәгә булган мәхәббәт ялкыны исә тормышының бихисап гүзәллекләрен ачты.* Н.Хәсәнов. *Кабан күлендә бихисап алтын ята, аны кулга төшерсәк, әллә ничә тәмуг ачарга була.* З.Мәхмүди. *Бихисап функцияләрне башкарган шәригать дөньявилык белән турыдан-туры бәйләнештә тора.* Р.Әмирхан

2) Бик, артык, гаять. *Кояш турындагы бихисап күп халык әйтемнәре дә аның сынландырылган сурәтен тудырырга ярдәм итәләр.* Г.Гыйльманов

**БИҺИШТ** *и. фар.* Җәннәт, оҗмах. *Аннан соң, Тәңренең әмере илән, Газраил килеп, Идрис галәйһиссәламне биһиштә алып очты.* Дастан

**БИҺУШ** *рәв. фар.* Һушсыз, сиземсез, аңсыз. *[Мәче сандугачка:] Синең сайравың һәртөрле музыкалардан матур булганлыктан, урмандагы көтүчеләр, ат ашатучылар – һәммәсе биһуш булганнар, имеш.* Г.Тукай. *Исенең тәмлелегеннән биһуш була яздым.* К.Миңлебаев. *Тумбочка эченнән күп укылудан таушалып беткән «Юксыллар сүзе» гәзитен алып, идәнгә җәеп салды һәм бишмәт кесәсеннән, барсын да биһуш калдырып, ап-ак он бушата башлады.* Ф.Сафин

**БИЧАРА** *с. фар.* **1.** 1) Чарасыз. *Кулларыннан тотылган бичара хәлендә.* Н.Исәнбәт

2) Ярдәмсез, мескен, бәхетсез, кызганыч. *Әллә кайдан китерелгән бичара колларны, чыбыркы тотып, кара, пычрак хезмәткә куып, шуңа башлык булган булып йөрү – егетлекмени ул?* Г.Ибраһимов. *Ахыр чиктә, нәкъ әнә шул үзе «уйлап тапкан» тәкъдиме бичара Баязит агайны бөтен бистәбез алдында көлкегә калдыра язды.* Ф.Хөсни

**2**. *и. мәгъ.* Кызганыч кеше. --- *абыстай бик кызганыч, бичара, болай да йөк-бардан яныл, көеп --- йөри торган кеше, артык сөйгән Зыясы алынгач, бигрәк тә хафалана инде.* Г.Ибраһимов. *Ул, бичара, катнашмаска, ирлек абруен саклап калырга, һичьюгы, битарафлык күрсәтергә тырышып караган.* Ф.Хөсни. *Арифметикадан беркем дөрес итеп эшли алмаган контроль эшне берүзе башкарып чыкса да, бүтән фәннәрне чит-ят телдә үзләштерүдән гаҗиз була шул, бичаракай.* К.Миңлебаев

**БИЧАРАЛЫК** *и.* Мескенлек, көчсезлек, чарасызлык. *Шуларның бичаралыкларын, кызганычлыкларын битләренә бәрергә, шуларның ваклыклары өстеннән, югарыдан торып, хихылдап көләргә миңа ул хәбәр ярдәм итте.* Г.Ибраһимов

**БИЧӘ** *и. диал.* Хатын. *– Көннәрнең берендә бичәкәй белән урманга кереп, печән чабып арбага төядек тә кайтып киләбез, – дип дәвам итте карт.* З.Фәйзи. *Авылда тол калган ялгыз бичәләр булса да, алар шушы хәлләрен артыграк күрәләр...* Ф.Сафин. *Серләреңне чишмә, эшне белмичә, Теләктәшлек күрсәтә, дип, бу бичә.* Ф.Тарханова. *– Син шул авыл бичәсеме? – ди. – Әйе, – дим.* Татарстан яшьләре

**БИЧУРА** *и. миф.* Йорт иясе, йорт хуҗасы, йорт пәрие. *Менә хәзер дә безнең авылларыбызда, бичура, абзар ияләре, су анасы бар, дип ышаналар бит әле.* Г.Гобәйдуллин. *Бичураларга, өрәкләргә ышанмаганыма карамыйча, мин бу куркыныч сүзләрнең коточыргыч мәгънәләрен күзем белән күргән шикелле булдым.* Ф.Әмирхан. *Бу өйне сакларга калдырып, әнкәңне бичура ясамакчы буласыңмыни, каһәр суккан!* Ш.Камал

**БИШ** *сан* **1**. 1) Унарлы санау системасында 5 санын, микъдарын һәм цифрын белдерә торган атама. *Һәм биш патронны сайлап алып, чәнечке очы белән эчләрен актарып ташлады.* А.Шамов. *Шуннан соң, патшадан азатлык өмет итеп җыелган халык өстенә, Апраскин солдатлары биш тапкыр залп бирәләр.* К.Нәҗми. *Илһам Шакиров – соңгы биш дистә ел дәвамында татарны татар итеп саклап калуда бинаһая өлеш керткән шәхес, халкыбыз рухының бөтенлеген тәшкил иткән Моң Иясе.* Мәйдан

2) **бишләр** *к.* **бишләп**. *Кечерәк кыз, сүз арасында, үзләренең иртәгә сәгать бишләрдә үз урамнарына йөрергә чыгачакларын да аңлатты.* Ф.Әмирхан

**2**. *и. мәгъ.* 1) Кул. *Зөфәр председательгә: – Чынлап сөйләсәгез, Урал абый, бирегез бишне.* Ә.Бикчәнтәева

2) *к.* **бишле** (**2.** *5 мәгъ.*). *[Солтан:] Чыннан да, кызым, «биш» алдыңмы?* А.Әхмәт. *[Солтан:] Рәйхана, бүген безнең Зөмәрә «биш» билгесе алып кайткан.* А.Әхмәт. *Гел «биш»кә генә укымаса да, башкалардан калышмый ул.* Тәмуг чәчәге

◊ **Биш бармагы кебек** Бик яхшы, анык, төгәл. *Ул бөтен авылның яланнарын, тауларын, чокырларын үзенең биш бармагы кебек белә.* Г.Ибраһимов. **Бише белән кайтару** Берәүнең яхшылыгына яки яманлыгына каршы, күп мәртәбә арттырып, яхшылык яки яманлык эшләү. *Ат --- ашарга бир, дип сорый белми ул. Ә син үзең бел, туйдыр аны, сыйла. Ат сиңа бише белән кайтарыр.* Р.Ишморат. **Бишкә ярылу** Эшнең күп, тыгыз булуы. *Бишкә ярылмассың бит инде.* К.Миңлебаев

**БИШАВЫЗ** *и. зоол.* Фәндә классы төгәл ачыкланып бетмәгән, гадәттә хайваннарның борын куышлыгында яки эчке органнарында яши торган суалчансыман паразит; *русчасы:* **пятиустка**

**БИШӘМ** *и.* 1) *тар.* Биш көлтәдән торган кибән кую ысулы, бәпкә, сослан

2) Балалар уены санамышларында борынгы формадагы бишенче тәртип санын белдергән сүз. *– Берәм-берәм, Икәм-икәм, Өчәм-өчәм, Дүртәм-дүртәм, Бишәм-бишәм, Алтан-алтан, Авыр балтам; – Кая китте? – Тозга китте. – Кайчан кайтыр? – Яз кайтыр. Үрдәк белән каз кайтыр* ---. Санамыш

**БИШӘР** *сан* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) биш, бертигез күләмдәге биш булуны белдергән бүлү саны. *Сезнең кайсыгызда булса да дүрт данә бишәр йөз сумлык акчалар бардыр бит.* Г.Камал. *Тагы фәкыйрь мәчет карты бар иде, аларга бишәр тиеннән ике бакыр төртте.* Г.Ибраһимов. *Ул инде бишәр потлы капчыкларны, «эһ» тә итми, үзенең калын таза җилкәсенә менгереп төшерә ала.* М.Гали. *Йодрыклары берсе-берсе бишәр потлы герләр хәтле иде, ди.* А.Алиш

**БИШӘРЛӘП** *рәв.* Төркемнәргә бишәр-бишәр аерып, биш берәмлекләп бүлеп. *Шахтага төшә торган эшчеләр, дүртәрләп, бишәрләп, клеткада шахтага төшәләр.* Ш.Камал. *Бишәрләп тезелергә команда булды...* А.Гыйләҗев

**БИШӘРЛЕ** *с.* Һәр рәтендә, буынында, һәрберсендә бишәр берәмлек, биш данә булган. *Хәтердә: вак яңгыр сибәли, без, балалар, урманда чикләвек куагының тәбәнәк ботакларын күтәреп-күтәреп карыйбыз, бишәрле, сигезәрле кишәнкеләрне шырт-шырт өзеп алабыз.* Р.Әхмәтҗанов

**БИШӘРЛЕК** *и. к.* **бишлек**. *– Менә миңа Җиһангир бай хәзер генә күпме акча бирде! – дип, кесәсеннән бишәрлек,*

*өчәрлек һәм бишәрлек бер уч кәгазь акчалар чыгарып күрсәтеп, хезмәтче ишеккә таба атлады.* З.Бигиев

**БИШӘ́Ү** *сан* **1.** Барысы, бөтенесе бергә биш булуны белдергән җыю саны. *Бу өчәүнең – хәер, нигә өчәү генә булсын, балаларны да кушып санаганда, бишәү бит инде...* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Биш зат бергәләп, бишесе берьюлы. *Алгы бүлмәдә көлгән, шаулаган тавышлар ишетелә башлый. Тагы кунаклар. Бишәү* берьюлы. Ф.Әмирхан

**БИШӘҮЛӘП** *сан* **1.** Чама белән биш, якынча биш булуны белдергән чама саны; бишләп.*Чиләгендәге балыгы бишәүләп булыр*

**2.** *рәв. мәгъ.* Бишесе бергә, бишесе берьюлы, бишәү булып, бишәү җыелып, бишесе дә. *Әниләре чәй әзерләде. Бишәүләп, өстәл янына утырдылар.* Г.Мөхәммәтшин

**БИШӘҮЛӘШЕП** *рәв. к.* **бишәүләп 2**. *Бишәүләшеп, озак кына гәпләшеп утырдылар, профессор рояльдә уйнады, Гөлшаһидәне җырлаттылар, Гөлчәчәкне биеттеләр, телевизор карадылар.* Г.Әпсәләмов

**БИШБАРМАК** *и.* 1) *кулин.* Шулпада пешерелгән, ваклап туралган ит белән шакмаклап киселгән токмачка суган һәм борыч сибеп бирелә торган, башкорт халкының милли ашы. *Без ашыйбыз бишбармак! Асыл палас тупсада, Әни ашны мул сала. Әтием көлеп карый: – Эшеңә күрә ярый! Биш бармакта – бер калак, Селкенә ике колак.* Б.Хәлимов. *Анда ике җирдә пылау, бишбармак, пилмән, икралар, кыздырылган тавык белән ике литрлы савытларда шәраб куелган.* Р.Сәгъди

2) Перчатка. *Ары баскан аягыңны Бире бассаң ни булган. Бишмармагым калган, диеп, Килеп китсәң ни булган.* Җыр

3) Башкорт хатын-кызлары биюе

**БИШБИЛЛӘП** *рәв. иск.* Бишбилле итеп. *[Габденнасыйр] Зөягә барып, ике улына да эче-тышы бер очтан сары төстә киҗеле казакилык алып кайтып, авылның Гайса тегүчегә биреп, аларны бишбилләп, кызыл төймәләп тектереп тә алды.* М.Гали

**БИ́ШБИЛЛЕ БИШМӘТ** *и. иск.* Бил турысы биш җирдән тарайтылып, итәккә таба киң чабулап тегелгән элеккеге татар бишмәте. *Өсләренә бишбилле елтыр кара бишмәт киеп йөриләр.* Г.Ибраһимов. *Бишбилле бишмәтләр, камзуллар, шинельләр, Украина жилетлары.* К.Нәҗми

**БИ́ШБЫЛТЫР** *рәв. сөйл.* Әллә кайчан, бик күптән. – *Бишбылтыр инде, хат алганым юк: әллә исән, әллә юк, – дип, Дәүләтшин тынып калды.* И.Гази. – *Әйдә, тәнәфес ич, берәр җиргә кереп, ашап алыйк, сөйләшеп тә утырырбыз, сине күрмәгәнгә бишбылтыр бит инде, – дип көлде Муса...* Ш.Маннур

**БИШЕК** *и.* 1) Яшь баланы тирбәтеп йоклату өчен ясалган асылмалы ятак, бәби йоклый торган урын. *Иң элек бу тел белән Әнкәм бишектә көйләгән.* Г.Тукай. *Бала вакытта ишеткән хикәяләрне эч өзгеч бер моң белән тәкрар итә, бала вакыт хатирәләрен, ана иркәләүләрен – бишек тирбәткән көй белән сөйли, искә төшерә.* Ш.Камал. *Ул, адәм булып, башта бишектә ята.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Башлангыч урын, туган җир, төп ватан. *Туып үскән илләр – алтын бишек, Никләр генә киттем илемнән?!* Ф.Сафин. *Әнә шулай итеп, байлыкка күмелгән, алтынга чумган Парижның – капитализм бишекләреннән берсенең – кыз-хатыннарын шундый юллар белән икмәк табарга мәҗбүр итүе ачык факт булып кала.* Г.Галиев. *Россияне революция әле бишектә чакта, немец кулы белән буып атмакчы булдылар.* И.Гази

◊ **Бишектән алып ләхеткә кадәр (бишектән – ләхеткәчә)** Туганнан алып үлгәнчегә кадәр, гомер буена. *Бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем эстә.* Мәкаль. **Бишектән бирле (алып)** Бик кечкенәдән үк. *Алар, бишектән алып, бик чын рәвештә дуслык җебе белән бәйләнгән; аларның җаннары берләшкән.* Г.Ибраһимов

**БИШЕ́К ҖЫРЫ** *и.* Баланы тирбәтеп йоклатканда, юатканда җырлана торган җыр. *Бишек җыры җырлап тирбәткән.* М.Җәлил. *Күптән инде, аның бишек җырын тыңлап үскән сабый чагымны, мөмкин булса, шушы минутта ук алыр идем кире кайтарып.* Г.Хуҗи

**БИШЕ́К КӨЕ** *и. к.* **бишек җыры.** *Тургай минем баш өстендә Бишек көен көйләгән.* Ә.Ерикәй

**БИШЕНЧЕ** *сан* **1.** Рәт, тәртип белән санаганда, биш урынында килә торган тәртип саны. *Ә безнең әбиләр бит бишенче катта торалар.* А.Алиш. *Ләкин аның ике тәүлек йоклаганы юк иде, менә шул бер төн эчендә генә дүрт җирдә тентү ясап, унбер кешене ябып, инде менә уникенче кешегә, бишенче квартирага килә иде.* Г.Ибраһимов. *Сәхаб ага, бишенче дистәсен дә җыя алмыйча, арабыздан китеп барды.* К.Миңлебаев

**2.** *и. мәгъ.* Алда, сан янында килгән кыскартылган сүз мәгънәсен ала. *Әллә сине тагы бишенчегә алыйммы?* Г.Камал. *Ярый, минем өчен бар да бер. Бишенчегә генә түгел, алтынчыга, җиденчегә алсын.* Г.Камал

**БИШИНӘ** *и.* Бияләй, оек, оекбаш һ.б.ны, түгәрәкләп, җөйсез бәйләү өчен кулланыла торган биш данә бәйләү инәсе. *Бишинәсен тотса да, таштай каткан бармаклары бөгелмәде.* Р.Мулланурова

**БИ́ШКУЛЛАП** *рәв.* Бик теләп, шатланып, чын күңелдән, зур ризалык белән. *Синдәй егетләрне, ике куллап кына түгел, бишкуллап алалар анда, бишкуллап! Бергә-бергә эшләве дә, яшәве дә күңеллерәк булыр.* Ж.Дәрзаман

**БИШЛӘП** *сан* **1.** Якынча биш, чама белән биш булуны белдергән чама саны; бишкә якын, биш тирәсе; дүрт белән биш яки биш белән алты арасы. *[Мәдрәсәдә] Дүрт яки бишләп, урысча укып торган балалар бар иде.* К.Насыйри. *Өстәлдә бер печать, дүрт штемпель, бишләп калын «эш»ләр уйнап торләнде.* М.Җәлил

**2.** *рәв. мәгъ.* Бишкә бүлеп, бишкә аерып, биштән. *Сибелә чәчем, сибелә чәчем, Сибелә, бишләп үрмәсәм. Сибелә чәчем, түгелә яшем, Нурлы йөзең күрмәсәм.* Ә.Ерикәй

**БИШЛӘТӘ** *рәв.* **1.** Биш тапкыр, биш мәртәбә, биш өлеш артык яки ким итеп, биш тапкырга арттырып яки

киметеп. *Өлкәннәр өчләтә, бишләтә артык газап чиккәннәр икән ул заманнарда!* А.Гыйләҗев. *Коллыгыбыздан котылмасак, тора-бара бишләтә, алтылата... [кимербез].* Ф.Латыйфи

**2.** *с. мәгъ.* Биш тапкыр, биш мәртәбә, биш өлеш артык яисә ким булган

**БИШЛЕ** *с.* **1.** 1) Биш кисәкле, биш компонентлы. *Шул ук унберлене, киресенчә, алтылы һәм бишле буыннар тәртибендә төзегәндә, тагы да салмаграк, җитди һәм мәһабәтрәк ритмик алымда мәкальләр килеп чыга.* Н.Исәнбәт

2) Күләме, номеры яки үлчәме биш булган. *Бишле лампа якты яна, эчендә мае булса.* Җыр. *Каюм, тиз генә бишле лампаны рәтләп, ут кабызып җибәрде һәм ватылып төшкән башына калай әйләндереп утырткан куыкны лампага кигезде.* Ә.Фәйзи. *Шулай да ул бишле лампа яктысында кәгазьләрне, бик җентекләп, тагын бер мәртәбә карады.* А.Шамов

**2.** *и. мәгъ.* 1) 5 цифрының исеме. *Миндә ике бишле, ике 17 ле, ике 36 лы, ике 49 лы бар.* Г.Камал

2) Биш яше тулган ат. *Бәйге алмаган йөгеректән Биле юан бишле артык!* Дастан. *Биле билтәк бишле айгыр алтысында ат булыр, ди. Ат кынамы, чын тулпар.* М.Әмирханов

3) Пычагының үлчәме биш уч озынлыгындагы чалгы

4) «Жигули» автомобиленең бишенче моделе. *– Бар, тегеләргә әйтеп кил, «бишле»не яисә «алтылы»ны [машинаны] карасыннар! – диде ул.* Ә.Сафиуллин

5) Биш баллы системада иң югары билге, «бик яхшы» билгесе. *Мәдрәсәдә ятып, мәтбагада эшләүче бер эшче, аны укыгач, астына «бишле» дә куйган иде.* Н.Исәнбәт. *[Солтан:] Менә кызык, үзе «бишле» алган, ә үзе күңелсезләнә.* А.Әхмәт. *Зәйнәпнең – «дүртле»ләр белән «бишле»ләр генә. «Бишле»ләре күбрәк тә бугай әле.* Х.Ибраһимов

**БИШЛЕК** *и.* **1**. 1) Биш сумлык акча. *[Нурислам бабай] Киенеп, бераз хәл алгач, кеңгәсе эченнән бишлекне алды да сестрага сузды.* Ф.Яруллин

2) Биш кешедән торган төркем

**2.** *с. мәгъ.* Биш сумга тәңгәл булган. *Әнвәр, бишлек кәгазь чыгарып, Мөгълифәнең кулына тоттыра.* Г.Камал

**БИШМӘТ** *и.* Мамык белән сырып тегелгән кышкы өс киеме. *Мәдрәсәне тиешенчә җылыта алмыйлар, шуңа күрә студентлар, хәтта йоклаганда да, өсләрендәге бишмәтләрен салмыйлар.* Ф.Сафин. *...Сәгъди абзый сандыгын ачты да үлгән улы Садриның күк киндер күлмәге белән бишмәтен, алып, Габдуллага киертергә теләде.* Ә.Фәйзи. *Бу көн төнлә купшы бишмәт инде, «матур кыз»га гына түгел, бәлки Диләфрүзгә әйләнде.* Ф.Әмирхан. *Карда аунагач, безнең инде бишмәтләребез шакырдап катты, авыз-борыннарыбыз туңды...* К.Миңлебаев

**БИШМӘТЛЕК** *с.* **1.** Бишмәт тегү өчен билгеләнгән, бер бишмәт тегәргә җитәрлек. *Вәли миңа биш, ун аршин күлмәклек, бишмәтлек кызыл мал бирде.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Бишмәт тегәргә яраклы тукыма. *[Ябалак Гыймаеның] Атасы кибеттән бишмәтлек алган да бермәлне [тегүче] Сафа абзыйны чакырырга килде.* Г.Бәширов

**БИШНИ** *с. диал.* Шәмәхә, куе кызыл, пешкән чия төсле. *Бишни карандаш эзләре, Уңып барган кәгазь, Яңа ауган чыршы исен Саклый соңгы вәгазь.* Җ.Сөләйман. *[Читекче кызларның] Яннарындагы бәләкәй әрҗәләрендә – зәңгәр, яшел, кызыл, алсу, бишни, миләүшә төсле нәни күн кисәкләре.* Г.Бәширов. *Аның колак артына җибәреп бәйләнгән ал батист яулыгы, бишни күлмәге тыкрыкларда, ишегалларында, баскыч төпләрендә күренеп уза.* Г.Бәширов

**БИШПОЧМАК** *и. мат.* Үзара тоташтырылган йомык сынык сызыклардан торган биш почмаклы геометрик фигура; күппочмак

**БИШТАШ** *и.* Биш кисәк вак түгәрәк ташны чүеп уйный торган уен исеме. *[Без малайлар] Пәке кадап та уйнадык, бишташ та туйдыра башлагач, йөгерешеп, качышып уйнарга тотындык.* Г.Бәширов. *Урамда түгел, өйдә дә ни бишташ, ни курчак уйнамадым.* К.Миңлебаев

**БИШТӘР** *и.* Капчыкның авызын һәм төбендәге ике почмагын аерып бәйләгән бауларын култык асларыннан җилкәгә алдырып, аркага асыла торган юл капчыгы. *Зур-зур чемоданнар, кәрзин-сумкалар тоткан, биштәрләр аскан, капчыклы арбачыклар тарткан мосафирлар, яшел вагоннардан сибелеп чыктылар да, соскыдан коелып тәгәрәшкән борчаклар сыман, кайсы кая таралыштылар – трамвайга, троллейбуска, такси ялларга...* Б.Камалов. *Кулындагы биштәр идәнгә шуды.* Н.Хәсәнов. *Салон Болгарстан, Румыния илгизәрләре, бигрәк тә яшь хатын-кызлар белән тулы иде, аларның һәммәсе алагаем зур биштәрләрен, бүселгән төргәк-чемоданнарын, ыгы-зыгы килеп, автобусның багаж бүлегенә тутырды.* Т.Әйди

**БИШТӘРЛӘ́Ү** *ф.* **1.** Аркага биштәр рәвешендә асарлык итеп әзерләү, биштәр рәвешенә китерү. *Мансур аркасындагы биштәрләп тагылган капчыгын рәтләде.* А.Расих

**2. биштәрләп** *рәв. мәгъ.* Биштәр итеп аркага асып, аркада күтәреп. *Без, малайлар һәм кызлар, Бишкурай авылыннан, атналык бәрәңгеләрне аркага биштәрләп, беренче таң әтәчләре тавышы белән, гыйлем юлларына омтыла идек.* Ә.Низаметдинов

**Биштәрләп алу** Биштәр итеп, аркага асып йөртү. *Чиләкләрен – көянтәләп, капчыкларын биштәрләп алган хатын-кыз, ярга менү белән туктап та тормыйча, иркендә кычкырып сөйләшә-көлешә, авыл ягына элдертте.* Х.Сарьян

**Биштәрләп кую** Алдан ук биштәр рәвешенә китерү

**БИШТӘРЛЕК** *с.* Бер биштәр белән алырлык күләмдәге. *Шундый зур ил өчен берничә биштәрлек бәрәңге аз була, билгеле.* Р.Фәизов

**БИ́ШУРЫНЛЫ** *с. махс.* Биш берәмлек белән билгеләнгән, биш берәмлектән торган. *Төгәлрәк исәпләргә кирәк булганда, бишурынлы таблицалар кулланыла.* Алгебра

**БИ́ШЬЕЛЛЫК** *с.* **1.** Биш елга исәпләнгән, биш елда үтәлергә тиешле. *– Без, яңа ел алды ярышында*

*катнашучылар, – дип башлады ул сүзен, – бишьеллык планны срогыннан алда үтәү өчен, вакыттан алда баруны үзебезгә бурыч итеп куйдык.* Г.Минский

**2.** *и. мәгъ. тар.* Халык хуҗалыгы үсешендә биш елга каралган план. *Бишьеллыкның бөек гигантлары һаман үсә, Һаман күккә таба үрелә.* Һ.Такташ. *Нәтиҗәләр озак көттермәде: һәр сыердан уртача савым бишьеллыкта 550 килограммга, ягъни сөт – 20, ит җитештерү 37 процентка арта.* Ватаным Татарстан

**БИЮ** *ф.* **1**. 1) Кул-аяк, гәүдәне, ритм белән, җиңел, нәфис рәвештә махсус көйгә хәрәкәтләндерү. *Юк, юк, җилбәзәкләнеп, кыланып түгел, үзенең сыгылмалы билләренең, калку күкрәкләренең бәясен, дәрәҗәсен белеп кенә бии ул...* А.Гыйләҗев. *Аңа кушылып, без дә такмаклыйбыз, биибез.* Р.Хафизова. *Сәхнә белән зал, ничектер, күңелдән берләшәләр кебек, бергә уйныйлар, бергә җырлыйлар, бергә бииләр кебек иде.* Г.Ибраһимов. *Тыпыр-тыпыр биергә Тимер идәннәр кирәк, Синең кебек уңган кызлар Бу дөньяда бик сирәк.* А.Әхмәт

2) *күч.* Биегән сыман хәрәкәтләр ясап уйнаклау, сикергәләү. *Ул чуар күбәләкләрнең иртәнге биюләрен һәм куаклыктагы пәрәвезләрдә, энҗе бөртекләре кебек, чык тамчыларының ялтыравын аермачык күрә.* К.Нәҗми. *Алар, үзләренә хас бер генә төрле тышкы хәрәкәт, бию һәм кылану белән, шул үзләре теләгән типны чагылдырырга тырышалар.* М.Җәлил

**2**. *и. мәгъ.* Кул-аяк, гәүдәне ритмлы хәрәкәтләндерү сәнгате. *Әхъяр белән Сәгыйтьнең әле татарча биюдә катнашасылары бар иде.* Р.Хафизова. *Аның биюләрен күрсәң, гомере буе биеп кенә йөргәндер, дип уйларсың.* Ә.Хәбибуллин

**Биеп алу** Бераз бию. *Минзөфәр, әллә ышанмыйсызмы, дигәндәй, тыпырдап биеп тә алды.* Н.Хәсәнов. *[Тәрбияче:] Әйдәгез, биеп алыйк. [Әтәч:] Сез миңа да өйрәтегез әле, мин бит бии белмим.* К.Закирова. *Ягез инде, кызлар, нишләп сез, без килгәч кенә, тукмаклаудан туктадыгыз? Әйдә, тыкырдатыгыз. Мин дә сезнең тукмак көенә басып, биеп алырмын.* Г.Камал

**Биеп җибәрү** Кинәт бии башлау; бераз биеп тә кую. *Әйдә әле, татулашыр өчен, бер биеп җиффәр!* З.Хәким

**Биеп йөрү** 1) Әле, хәзерге вакытта, күз алдында бию. – *Сәрби әбинең сарыгы Ике бәрән китергән. Сөенечтән биеп йөреп, Берсен таптап үтергән,* – *дип көләләр.* Р.Ягъфәров

2) *күч.* Бөтен кушканнарны үтәргә әзер булу. *Борчылма, Гөлшатыбыз янында биеп кенә йөрер.* Т.Миңнуллин

**Биеп калу** Биергә өлгерү. *Әйдә, бас, бас, әйдә, Биеп калыйк бу җәйдә.* Т.Миңнуллин. *Яшьлек яшьнәп үтәр-китәр, Яшьлегеңдә биеп кал.* Г.Зәйнашева

**Биеп карау** Бик күп бию. --- *өскә өр-яңа күлмәк кигән идем. Күрсеннәр. Зәп-зәңгәр бит, елкылдап тора. Ну биеп тә карадым ул көнне!* Ф.Яруллин

**Биеп китү** Кинәт, билгеле бер моменттан соң бии башлау. *Читеге җиңел икән, Җилдереп биеп китәм. Әткәң гармунчы булгач, Бигрәк күңелле икән!* Р.Вәлиева. *Ул чәбәкәй иткәндә, Беркөн биеп киткәнмен.* К.Закирова

**Биеп тору** 1) Хәзерге вакытта, күз алдында бию хәрәкәтләре ясау. *Көчен кая куярга белмичә бер урында биеп торган кара айгыр, Газинурның ирен чупылдатуын ишеткәч, элдереп алып та китте.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Кемнең дә булса бөтен кушканын үтәп йөгереп йөрү. *Сиңа хатының кубызына гына биеп торырга ярыймы?* Ә.Ягудин. *Киленең Өммия дә синең каршыңда биеп тора. Ни әйтсәң, шуны тыңлый.* Т.Миңнуллин

**Бии башлау** Биергә тотыну. *Аның йөрәгендәге кара уйлары таралды, анда шатлык бии башлады.* Г.Ибраһимов

**Бии бирү** Биюен дәвам итү

**БИЮЧЕ** *и.* Биюне башкаручы, бию остасы. *Дистәләгән күзләр биюче егетнең җитез йөргән аякларына текәлделәр.* М.Гафури. *Җырчы түгел, биюче буларак башлый ул иҗат юлын.* Сөембикә. *Актёрлар белән танылган биюче Клаудиа Ченчи шөгыльләнгән икән.* Юлдаш

**БИЯ** *и.* Ана җенестәге ат. *Тәртә янына бурлы бия бәйләнгән, ул бертуктамый кешни, кайдадыр китәргә, ычкынырга азаплана.* Г.Ибраһимов. *Ак колын ераккарак китә башласа, бия, сискәнеп, башын өскә чөя һәм, колынның арлы-бирле чабуы шаяру гына икәнен күргәч, тагын чирәмгә иелә.* М.Хуҗин. *Абзарга кердем, кола биям кешнәп тора.* М.Әмир. *Моның каршына алама гына бер биягә атланган кеше килеп чыкты, ди.* Г.Гыйльманов

**БИЯЛӘЙ** *и.* Баш бармак урыны аерым, калган бармакларныкы бергә бәйләнгән яки тегелгән кул киеме. *Оек һәм бияләй бәйлиләр, чигү чигәләр.* М.Җәлил. *Исән-сау йөреп кайтса, мае да табылыр, оекбашы белән бияләе дә табылыр, Алла боерса.* Р.Ишморат. *Кул җиткән кадәр, үрелеп, бияләй белән аркамны төям.* А.Гыйләҗев

◊ **Бияләй эчендә бармак кыймылдатканны да сизү** Үтә уяу, сизгер булу. *Татлы тормаң, дими бит, Миңнурыең, да дими, ә гөләп чәчәгең, ди! Һай хәйләкәр дә була бу картлар! Бияләй эчендә бармак кыймылдатканны да сизәләр.* Г.Әпсәләмов. **Бияләй эченнән йодрык (кукиш) күрсәтү** Кемгә дә булса, сиздермичә, арттан янау, эчтән ачу йөртү. *Син никадәр бияләй эченнән кукиш күрсәтсәң дә, һичнәрсә эшли алмассың.* Ш.Мөхәммәдев

**БЛАНК** *и. фр.* Аерым предприятие, учреждениеләргә караган, өлешчә басма тексты булган, документны төгәл бер тәртиптә тутыру өчен билгеләнгән стандарт кәгазь бите. *Кульязма белән эшне тәмам иткәч, Әхмәт бик күп сорауларны эченә алган бланк тутырды.* Г.Лотфи. *Кадрлар бүлегендә саклана торган бланкка аның тормыш юлы турындагы саран гына мәгълүматлар теркәлде.* М.Хөснимәрданов. *Аны редакциянең рәсми хат бланкына курьер аша тапшырттырдым – югала күрмәсен, янәсе...* Татарстан

**БЛАНМАНЖЕ** *и. фр. кулин.* Сөт өстенә, какао яки җимеш суларына шикәр һәм желатин кушып, суытып әзерләнгән һәм аш артыннан бирелә торган ашамлык. *Кунаклар килер вакыт җиткән, безнең аш артыннан*

*утыртырга бланманже да әзерләнмәгән.* Г.Камал. *Бланманже пешерү өчен, сөт, какао, шикәр һәм желатин алына.* Татар халык ашлары

**БЛАТ** *и. яһүд сөйл.* Әшнәлек, законга каршы үзара җинаятьчел бәйләнеш. *Андагы абзыйлар белән блат зур безнең.* Н.Гыйматдинова. *Академиягә блат белән кергән генерал уллары, шарлатаннар – штабларда, алар зур шәһәрләрдәге җылы урыннарга урнашып беттеләр.* Н.Хәсәнов

**БЛЕ́ЙЗЕР** *и. ингл.* Билләп тегелгән спорт пиджагы

**БЛЕ́НДЕР** *и. ингл.* Ашамлык әзерләгәндә, ризыкны болгату, изү, ваклап турау эшләрен башкара торган күпфункцияле җайланма. *Блендер куллансагыз, тизрәк булыр.* Сөембикә

**БЛИНДАЖ** *и. фр. хәрби* Сугышчыларны, шулай ук сугыш кирәк-яракларын артиллерия һәм миномёт утыннан саклау өчен ясалган хәрби корылма, яшеренү урыны. *Салкын көннәрдә, бураннарда солдатлар, окопны бөтенләй ташлап, көне буе блиндажларда, землянкаларда ята башладылар.* М.Гали. – *Иртәгә полковникка керербез, ә бүгенгә ял ит, – дип, ул сүзен дә бетерә алмады, блиндаж ишеген кагып, керергә рөхсәт сорадылар.* И.Гази. *Сугыш кыры тынып, солдатлар окопларга, блиндажларга таралышып, амбразуралар капланып беткәч, Каенлыкка алып кайта торган сукмактан үткән ат юлында ике иясез бәхет күзгә чалынды...* К.Кәримов

**БЛОК** I *и. ингл. тех.* Әйләнмәле күчәргә беркетеп куелган, уртасындагы улагына тарттырылган бауны шудырып хәрәкәткә китерә торган, иң гади йөк күтәртү һәм көч юнәлешен үзгәртү җайланмасы; чыгыр. «*Аннары сөйләрмен», – дип, корабның иң арткы ваер блогы янына киттем.* Ә.Хәбибуллин. *Корыч вышканың бураннан ышыкланмаган югары ягында таш блогының, әкрен генә, бер – өскә, бер аска йөреп торганы күренә.* Г.Ахунов. *Блоклар күтәрү кранында, экскаваторда, кранлы кибән салу машинасында һ.б.да кулланыла.* Физика. *Бау блок аша төшерелгәндә, ул йөкне йә өскә күтәрә яки аска төшерә ала.* Кызыклар дөньясында

**БЛОК** II *и. ингл.* 1) *сәяси* Дәүләт, партия, төрле оешмаларның бергәләп эш итү максатында оешкан берләшмәсе, үзара килешүе. *Ул программа – татар буржуа хәрәкәтен бер җиргә оештыру һәм русның кадетлар партиясе белән блокка кереп ---, Дума мөнбәрләренә хәтле менеп, үз теләкләрен әйтү һәм үткәрергә тырышудан гыйбарәт.* Г.Нигъмәти. *Европа һәм Азиядәге блокларда катнашмауны үзләренең тышкы политикаларының нигез ташы итеп алган тынычлык сөюче дәүләтләр төркеменең халыкара мәйданга чыгуы да тынычлык көчләрен --- ныгытты.* Политэкономия. *Илдә кайбер партия һәм партия блоклары арасында РФ Конституциясендәге үзгәрешләр хакында киң сәяси бәхәс җәеләчәк.* Татарстан

2) *махс.* Берәр төрле корылманың берничә кисәктән торган өлеше; секция. *Мусаны блок башлыгына илтүче немец солдаты, байтак барганнан соң, озынча бер такта барак янына килеп туктады.* Ш.Маннур. *Шуңа, чарасыздан, бөтен операция блогын миңа тапшырдылар.* Сөембикә

3) *махс.* Бетон катнашмасыннан эшләнгән төзү материалы. *Җил кубарып китмәсен өчен, тентны як-яктан цемент блоклар белән бастырганнар.* М.Юныс. *Кран алып килеп, стена блокларын каерасылары гына калган.* М.Маликова. *Киң блоклар бетон белән тулгач, Масаясы килә югартын.* Ш.Маннур

**БЛОКА́ДА** *и. ингл.* 1) *хәрби* Дошман кораллы көчләре тарафыннан камалу, тышкы бәйләнештән мәхрүм ителү. *Ленинград дошман блокадасыннан тулысынча азат ителде.* Г.Әпсәләмов. *Әнгелчән белән француз бөтен Россияне дүрт яктан камап алганнар ич. «Блокада» дигәннәре шул бит инде.* Ш.Камал. *Быел гел өметле хәбәрләр бирә радио: Ленинград блокадасы өзелгән, Сталинград янында Паулюс армиясе әсир төшкән.* Р.Кәрами

2) *сәяси* Берәр дәүләтне, аерым таләпләрне үтәргә мәҗбүр итү өчен, хәрби, сәяси яки иҗтимагый яктан изоляцияләүгә юнәлдерелгән чаралар системасы. *Бөлгенлеккә төшкән буржуа иле Теләсә генә ничек итсә дә, Безгә блокадалар ясау түгел, Борны белән чәнчелеп китсә дә, Без җиңәрбез!* Һ.Такташ

3) *физиол.* Кайсы да булса берәр эчке органның яки органнар системасының эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору. *Моның өчен без еш кына новокаин блокадасын, ягъни кара кан тамырына яисә корсак куышлыгындагы нервлар үрелмәсенә новокаин кертү алымын кулланабыз.* Ф.Әгъзамов

**БЛОКЛЕ́ЙТЕР** *и. нем. тар.* Фашистлар Германиясе национал-социалистлар блогы лидеры. *Тик син бу хакта теләсә кайда, бигрәк тә блоклейтер улы Паул алдында лыгырдама.* Т.Әйди

**БЛОКНОТ** *и. фр.* Битләрен ертып алырга да мөмкин булган кечкенә күләмле язу дәфтәре, (куен) кесә дәфтәре. *Ялга кайткач, минем куен блокнотына Әсрар абый язган юллар әле дә саклана.* Ә.Хәбибуллин. *Цех начальнигы биргән кадәресен блокнотына язып алгач, кайтырга ашыкты.* Г.Минский. *Ике дистәгә якын олауга капчыклар төялеп беткәч, Хәнәфи аларны тагын бер кат санап чыкты да, кечкенә блокнотына билге ясап, кулын күтәрде.* Г.Әпсәләмов. *Прогулкага чыкканда, гел бер карт янына килеп утыра да, блокнотын чыгарып, сораша да сораша.* М.Мәһдиев

**БЛУ́ЗА** *и. фр.* 1) *иск.* Ирләрнең билбаусыз киң күлмәк рәвешендә тегелгән өс киеме. *Кайтырбыз: Блузаны өскә кигәндә, Кайнап торыр тәндә эш уты!* Х.Туфан. *Заводның кызыл кирпеч стеналары капкасыннан эш киеме: блузалар, кепкалар, шәлләр, бүрекләр кигән эшчеләр чыга башладылар.* А.Алиш. *Озын чәчле, зәңгәр блузадан йөк ташучы таза егетне Идел һаман өзелеп сагына.* С.Хәким. *Ә үзе Маратка блуза тегеп киертте.* Г.Гобәй

2) Җиңел тукымадан тегелгән хатын-кыз кофтасы. *Нәгыймә алдында кыска күк юбка, күк блуза кигән, кыска киселгән чәч өстеннән кызыл яулык бәйләгән бер хатын шаркылдап көлеп*

*җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Кискәндә, блузаның итәген, теләккә карап, бил турыннан 12 сантиметрдан 15 сантиметрга кадәр озынлыкта алырга мөмкин.* Йорт эшләре

**БЛЮМИНГ** *и. ингл. тех.* Зур күләмле авыр корыч коелмаларны кирәкле формага китерү өчен кыса торган куәтле прокат станы

**БЛЯ́ХА** *и. нем.* Бизәү өчен кулланыла яки эләктергеч каптырма булып хезмәт итә торган металл пластинка. *Ул сиңа чалбарлар, ул сиңа ялтыравыклы бляха, ул сиңа, күзеңнең явын алырлык итеп, алтын бауу белән язылган ленталар: «Тихоокеанский флот».* М.Мәһдиев

**БО́БРИК** *и. рус* **1**. 1) Төкләре тырпаеп торган сукно. *Әүхәдигә биш айга ун сум илле тиен көмеш саф акчалата һәм шул фабрикада эшләнгән бобриктан бер чикмәнлек кисеп бирделәр.* К.Тинчурин

2) Маңгай өстендә тырпаеп торырлык кыска итеп киселгән ирләр чәче (причёскасы). *Михаил бобрик белән кыскартылган чәчләрен кирегә сыпырып куйды...* Ф.Әмирхан

**2**. *с. мәгъ.* Бобриктан тегелгән. *Өстенә – бобрик пиджак, аягына – күн итек, башына кепка киеп, бистә урамы буйлап олы гына атлап барган бу ак мыеклы, озын, төз буйлы карт эшче белән, очраган бер кеше, хөрмәт күрсәтеп, исәнләшеп узды.* Г.Әпсәләмов. *Ишекне ачып җибәрүгә, чуар киез итектән, бобрик чикмәннән, ак шарфтан, чикмән астына гармун кыстырган, озын гына буйлы, сызылып киткән кара мыеклы бер егет килеп керде.* М.Гали

**БОГА́У** *и.* 1) Гадәттә, сәяси яки аеруча куркыныч тоткыннарның кулаякларына кидерелә торган чылбырлы тышау; зынҗыр. *Алыгыз тизрәк чишеп кулларыннан богауларын.* Ф.Бурнаш. *Аякларындагы тимер богауны чак өстерәп, шатыр-шатыр, зур ташлар тирәсендә кыймылдашалар.* Г.Ибраһимов. *Санаулы минутларда килеп җиткән милиционерлар төркеме баскынчының кулларына богауны бик тиз салалар.* Юлдаш

2) *күч.* Бәйлелек, ирексез булу. *Курыктылар җырларыңа Богау салырга.* К.Фәсәхов. *Төн уртасы... эшче уйлап ята Җир өстендә җәннәт төзергә, Көчле кулы белән табигатьнең барлык богауларын өзәргә...* Һ.Такташ. *Гыйльмениса – әнә шул богаулардан арынып, яңа юл сайлаган һәм шунда бөтен көчен куеп хезмәт иткән хатын-кыз.* Ә.Мотыйгуллина

**БОГАУЛА́У** *ф.* 1) Кул-аякларга богау кидерү, богау салу, зынҗырлау. *Унбишен, тимер богаулар белән богаулап, җәяүләп, гомерлеккә ерак Себергә озатырга, ди.* М.Гали. *Башлыкларын Себер җибәргәннәр Аяк-кулларын богаулап.* М.Гафури. *Абзыйны шул сәгатьтә үк богаулап алып китәләр.* Г.Ибраһимов

2) Тышау салу, тышаулау. *Ул, кайсыдыр атның аягында богау чылтыраган тавышка колак салып, авыр сулап куйды: – Атны богаулап җибәрергәме икән әллә?..* Г.Бәширов

3) *күч.* Кешенең тойгыларын, теләкләрен, омтылышларын һәртөрле чикләү, тыю; ирексезләү. *Юк, әллә контузиядән аңгырайган башы эшләмәде, әллә Бессарабиядә атылган кыргыз иптәшләрен күзаллап икеләнде Янгураз – нидер аның ихтыярын богаулады.* Т.Әйди. *Ялкынлы яшьлекне богауларга телиләрме?* Г.Ибраһимов

**Богаулап алу** Кинәт, тиз арада богау салу. *Шул сәгате белән пристав үзе, өч полицейский белән килә дә, Вахитовны богаулап ала, участокка китерә дә: – Әйт, тагы кемнәр бар иде? Оештыручы кем иде? – дип, егетне кыйнарга тотына.* Г.Ибраһимов

**Богаулап бетерү** Һәрьяктан, тәмам богаулау; барысын да богаулау

**Богаулап килү** Электән, күптәннән даими богаулау. --- *һәр шәхесне бәхетле, азат күрү, милләтен богаулап килгән коллык психологиясеннән коткару рухы белән яшәгән.* Т.Галиуллин

**Богаулап кую** Богауланган хәлгә китерү, шул хәлдә тоту. *Ә богаулап куяр өчен сукбайлар бар, Җыен кесә караклары һәм башкалар...* У.Шекспир. *Савелий Кузьмич дигән исем аның бөтен ихтыярын богаулап куйган, аны үзенә чакыра, тарта, кара киемле артыннан теләсә кая барырга мәҗбүр итә иде.* Ф.Латыйфи

**Богаулап ташлау** Тиз арада богау кидерү. --- *минем кулларымны, аякларымны богаулап ташлый торган барлык йолаларга, инануларга төкерәм мин!* Н.Фәттах. *Юк, бәхәс кенәме, әҗәле җанын алырга килгәч, алышырга тотына һәм үлем алласы Танатның үзен богаулап ташлый.* Г.Хөсәенов

**Богаулап тору** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында богаулау. *Шигырьләрне әлегә богаулап торам, алар миңа бу эшләрне дәвам итәргә комачауламасын.* Ф.Чанышева

**Богаулап чыгу** Һәрберсенә рәттән богау салу

**Богаулый бару** Торган саен күбрәк, ныграк богаулау; һәрберсен рәттән богаулау

**Богаулый башлау** Богауларга тотыну

**Богаулый төшү** Тагын да ныграк богаулау. *Бу хәл мине тагы да богаулый төште, ләкин каушатмады, кешеләрнең миңа ят-дошман итеп карамауларын, ничектер, йөрәгем белән сизәм кебек.* Ә.Еники

**Богаулый язу** Чак кына богауламыйча калу

**БОГАУЛЫ** *с.* 1) Богауланган, богау кидерелгән, богавы булган. *Хәлсез куллары белән, богаулы тоткын улының муенына асылып, бичара ана да шул актык чарага сарылды, күз яшенә буыла-буыла: – Балам, – диде, – сине күз яше түгеп үстердем.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Чылбырга тагылган. *Мин идарәгә юаш кына атлап керәм, мич кырына куелган богаулы кружкадан күгәреп беткән җылы суны эчәм.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Ирексез, бәйле. *Мәңгелек төрмәгә ябылган Богаулы тоткыннар идек без.* М.Җәлил

**БОГАУЛЫЛЫК** *и.* Богаулы булу, богауланган булу

**БОГДАЙ** *и. иск. к.* **бодай**. *Мич башында – кисмәк тулы богдай оны.* Ф.Бурнаш

**БОГЕ́МА** *и. фр.* Тотрыклы матди чыганагы булмаган актёр, музыкант, рәс-

сам, әдәбиятчыларның гамьсез тормыш белән яшәү рәвеше. *Гамьсез тормыш алып баручы артистлар, рәссамнар, әдәбиятчылар һәм башка зыялылар төркемен, гадәттә, «богема мохите» дип атыйлар.* Р.Мирхәйдәров

**БОГЫЛ** *и.* Өскә таба очландырып, түгәрәкләндереп салынган печән, я салам кибәне. *Җыелган печән әрәм калмасын, яңгырга эләкмәсен, дип, уртада яңа богыл башлап куела.* Г.Хәсәнов. *Алия әбинең төп эше – түр тәрәзә янынарак богыл сыман утырып, узганбарган белән әңгәмә корудан гыйбарәт.* К.Миңлебаев. *Өчөйле богылы кадәр гәүдә иде үзендә.* М.Хәсәнов. *Аның гәүдәсе – богылдан юан һәм дәү...* Кызыклар дөньясында

**БОГЫРДА́У** *ф. к.* **бызырдау** (*1 мәгъ.*). *Парторгны борып җибәргәннәрмени: теле тегермән тарта, корсагы тук, кикереп тә куя, эче богырдый.* А.Гыйләҗев. *Күрәсең, биредә югарыдан сикергән агымсуны меңләгән куыклар белән богырдата, агып килгән суны өстәмә һава, азык микъдары белән баета...* А.Хәлим

**БОДАЙ** *и.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан, орлыклары, ике рәт булып, башакларга тупланган, ак он әзерләү өчен игелә торган ашлык үсемлек. *Җирнең эшләнүен, бодайның үсүен бик ошатты.* Г.Бәширов. *Бодайларга туктап шатланам мин, Арышларны сыйпап үтәм мин, Җитеннәрнең зәңгәр күзләреннән, Башым иеп, үбеп китәм мин.* Ш.Маннур. *$B_1$ витамины азрак күләмдә барча үсемлекләрдә дә очрый, әмма бодай бәбәнәкләре, дөге көрпәсе, солы һәм карабодай ярмалары, арахис һәм яшел борчак аңа бигрәк тә бай.* Юлдаш календаре

2) Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. *Икенче көнне үк, Малик егерме биш капчык бодайны китереп тапшырды.* И.Гази. *Бу үсемлек орлыкларының төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнү өчен, бодай орлыгын – аны «бөртекчә» яки бер орлыкны «коры җимеш» дип атыйлар – тикшереп карыйк.* Ботаника

**БОДА́Й ГӨМБӘСЕ** *и.* Үсемлекләрне зарарлый торган гөмбә авыруы; кисәү

**БОДИБИ́ЛДИНГ** *и. ингл.* Мускулатураны үстерү, сынны зифаландыру максатында, тренажёрларда махсус снарядлар кулланып ясала торган гимнастик күнегүләр системасы

**БОЕГУ** *ф.* Күңелсезләнеп калу, моңаю, моңсулану. *Теге мескен, бу хәлне күреп уңайсызлана, боега.* М.Гафури. *Ләкин --- нигә Тимербулат Бүген болай боеккан?* М.Җәлил

**Боега бару** Боегуы акрынлап арту, торган саен күбрәк боегу

**Боега башлау** Боегырга тотыну. *Бу караңгы чырайлы кеше янында Сөләймановның үзенең дә күңеле боега башлады.* И.Гази

**Боега төшү** Беркадәр боегу. *Улының күзләре моңсу, йөзе дә бераз тартылган, боега төшкән иде.* Г.Бәширов. *Авыл, авыл... нинди тын һәм нинди буш!.. Әллә ничек сәер генә. Искерә дә төшкән, чүгә дә төшкән, боега да төшкән кебек...* Ә.Еники

**Боегып алу** Бераз гына боегу

**Боегып бетү** Тәмам, бик нык боегу

**Боегып йөрү** Күптәннән, ниндидер вакыт арасында боеккан хәлдә булу. *Ни үле, ни тере, боегып йөри идем ләбаса, син миңа җан өрдең, Сәләхетдин.* К.Миңлебаев

**Боегып калу** Нинди дә булса сәбәптән боегу. *Берничә көн узгач, нишләптер, бүре балалары боегып калды.* Н.Хәсәнов. *Рәүфә бер-ике атна эчендә бөтенләй ябыгып, боегып калды.* А.Шамов. *Өйләр, каралтылар, кашларын җыерып уйга баткан чал картлардай, тын утыралар, урам буендагы шомырт һәм миләш агачлары, авырайган яфракларын койма өсләренә салындырган хәлдә, аның артыннан боегып калалар.* Г.Бәширов

**Боегып китү** Кинәт боегу. *Өчесе дә кинәт боегып киттеләр.* Г.Гобәй. *Рәүфә бишмәтен аркасына салды, кинәт боегып китеп, мич янына барып сөялде.* А.Шамов

**Боегып кую** Аз гына вакытка боегу, кыска гына вакытка боегу хисе кичерү

**Боегып тору** Әле, күз алдында боеккан хәлдә булу. *Җилкәем, син анда бар тагын, Боегып тормасын аппагым.* Ә.Ерикәй. *[Карлыгач (ат)] Иртәнге сәгатьләрдә шулай боегып торгач, көн эссесендә нишли инде бу...* Ф.Шәфигуллин

**Боегып утыру** Боеккан хәлдә булу. *Менә мәдрәсә кар астында боегып утыра.* И.Гази. *Камерада башка һичкем юк, ике ябык, саргылт шәкерт почмакта боегып утыралар.* Г.Ибраһимов

**БОЕК** *с.* Моңсу, сагышлы, төшенке күңелле, ямансу. *Хәзер күңелем боек чагы, Син кайткач – чәчәк атар.* Җыр. *Мин бит – боек җаннарның күңелен күтәреп йөрүче.* Г.Бәширов

**БОЕКЛЫК** *и.* Күңел төшенкелеге, боек булу. *Зөлфиягә шушы төн караңгылыгында, ниндидер боеклык кичергән йортта япа-ялгыз утырган Җәмит кызганыч булып китте.* Н.Хәсәнов. *Әллә инде иң якыннардан да якыннарына карата булган йөрәк хисләренең сабый чакта ук ятимлек боеклыгы белән югалып калуыннанмы?* Г.Минский

**БОЕЛЫК ТОТМАУ** *и.* Сидекне тота алмау авыруы. *Әгәр баланың боелыгы тотмауга сәбәпчел чире булса, врач ул чирне дәвалый. Әгәр инде боелык тотмау функциональ формада булса, врач аны ничек дәваларга кирәклеген ата-анага җентекләп аңлата.* Азат хатын

**БОЕНДЫРЫК** *и.* 1) Агачтан ясалган үгез камыты. *Үгез боендырыкка муенын үзе бирер.* Мәкаль. *Бер боендырык астында – ике үгез.* Табышмак

2) **боендырыгы** *күч. тартымлы форм.* Карамагында, хакимлегендә, изүендә, җитәкчелегендә, җаваплылыгында, мәгънәләрен белдерә. *Ул бик күп башларны азмы-күпме тәкълид боендырыгыннан коткарды.* Ш.Мәрҗани. *Губернатор үз боендырыгындагы чиновникларны үгетләргә ярата иде.* К.Нәҗми

**БОЕРУ** *ф.* Әмер бирү, боерык бирү, катгый кушу, таләп итү, приказ бирү. *Директор тиешле кешеләрне чакыртып алды, чыгарылыш кичәсен иртәгә үк уздырырга боерды.* Н.Фәттах. *– Кайтканның икенче көнендә үк безгә килегез! – дип боерды.* Г.Ибраһимов. *– Автоматчыларны алга чыгарырга боердыгызмы? – дип сорыйм.* И.Гази

◊ **Боерган булса** Насыйп булса, тәкъдирдә язылган булса. *Боерган*

*булса, бик бай, бик бәхетле булырсың.* Г.Камал. *Мәһәрсез-нисез, кызыбызны аңа бирәчәкбез, боерган булса.* М.Фәйзи

**Боера башлау** Боерырга тотыну. *– Бер! Ике! – дип боера башлады ул арада Стакай.* И.Хуҗин

**Боера бирү** Боеруын дәвам итү

**Боерып йөрү** Анда-монда барып, һәрберсенә боеру. *Алексей кайсы орудиеләргә пехота артыннан калышмый кузгалырга, кайсыларына, урында калып, ут нокталарына атарга әйтеп, боерып йөрде.* Х.Камалов

**Боерып кую** 1) Алдан ук боерыклар биргән булу

2) Кинәт, көтмәгәндә боеру

**Боерып тору** 1) Әле, сөйләү моментында боерыклар бирү. *Шуннан соң малайлар юлга кузгалдылар. Том аларга боерып торды.* М.Твен

2) Даими, һәрвакыт боеру.

**БОЕРЫК** *и.* Катгый рәвештә белдерелгән таләп; әмер. *Мин иртәгә кузгалып китү турында боерык алдым.* К.Нәҗми. *Чыгарга боерык булды, бер конвой тапшыра, икенчесе кабул итеп ала.* А.Гыйләҗев

**БОЕРЫ́К ФИГЫЛЬ** *и. грам.* Фигыльнең боеру формасын бирә торган наклонениесе. *Боерык фигыльнең махсус грамматик күрсәткече юк, ул нуль формада килә һәм тышкы яктан фигыль нигезе белән охшаш була.* Татар теле морфологиясе

**БОЖАН** *и.* Элпә канатлылар отрядына караган, бик каты авырттырып чага торган бөҗәк, шөпшәнең эре төре; *русчасы:* **шершень.** *Шөпшә белән божан, гадәттә, имәнгә, җәнлек ояларына, еш кына йортның түбәсе астына, агач баскычларга, шәһәр йортларында балконнарга кереп тә оя ясый.* Юлдаш. *Божан бик авырттырып чага, алар үзләренең шарсыман ояларын чәйнәп вакланган үзагачтан төзиләр.* Юлдаш

**БОҖРА** *и.* **1**. 1) Агачтан, металлдан яки башка материалдан ясалган йомык түгәрәк, әйләнә. *Көндезге чәйне эчкәч, чормадан чалгыны алып төшеп карады да, төзәттерәсе җирләре бар, муены бик йомшак, яңа бөҗра кирәк булыр, дип, тимерлеккә китмәк булды.* Г.Ибраһимов. *Биш пояс, һәрбер пояска – икешәр йомры тимер боҗра.* Ә.Хәбибуллин. *Университетта иллегә якын аудитория булса – шуның һәрберсенең ачкычы Пантелей картның кулындагы зур боҗрага тезелгәннәр иде.* М.Мәһдиев

2) Кошларның, җәнлекләрнең хәрәкәт итү юнәлешен, таралу тирәлеген өйрәнү өчен тагылган балдак; алка. *Аягында ниндидер боҗрасы бар.* Кызыклар дөньясында

3) *сөйл.* Бөгәлҗә; ярым боҗра формасындагы әйбер. *Алкасының боҗрасы ычкынган*

4) *спорт* Бертигез югарылыкта, баулга асып куелган ике түгәрәк гимнастика снаряды

5) Әйләндереп, урап баскан халык төркеме. *Аның тирәсендәге боҗра кысылганнан-кысыла бара иде.* Р.Вәлиев. *Солдатлар аны, боҗра ясап, ул-бу хәл килеп чыкмасын дип, әйләндереп алалар.* Р.Вәлиев

6) Камалыш, чолганыш. *Бөгелмәне камап алган дошманнар боҗрасыннан ул ничек үткәндер, анысын белмим.* Г.Әпсәләмов. *Биктимер аганың бердәнбере инде бу боҗрадан чыга алмый.* Т.Галиуллин. *Без Татарстан тирәсендә, суверенлыгыбызга бернинди сәяси технолог та кул суза алмаслык итеп, нык оборона боҗрасы ясап берләшергә тиеш.* Татар милләт календаре

7) *күч.* Берәр чыганактан таралган бик көчле нур, очкын, ут һ.б.ш. *Аның башы әйләнә, күз алларында боҗралар уйный...* Г.Бәширов. *Картның җиң очына бәйләнгән сәер ефәк үлән учмасы боҗраларыннан, кояш нурларында әлҗе-мөлҗе килеп, көмеш коела иде.* А.Хәлим. *Ул һәр елны агачларның кәүсәсенә бер сыр – боҗра өстәп тора.* Г.Гыйльманов

8) Трамвай, троллейбус, автобус маршрутының ахыргы тукталышындагы әйләнеш. *12 номерлы трамвайны вокзалдан Мәскәү районына йөртер өчен боҗра ясадылар*

9) Су өслегенә нәрсә дә булса чумганнан соң барлыкка килеп, таралып киткән дулкын түгәрәкләре. *Оча торган балык чумган җирдән, түгәрәкләнеп, су боҗралары тарала башлый.* М.Юныс

**2**. *с. мәгъ.* Әйләнә төсле, әйләнәгә охшаган. *[Сөләйман] Тагы тәмәкегә тотынды: «Туя алмыйм, валлаһи!» – дип сөйләнә-сөйләнә, түгәрәк боҗра төтеннәр чыгарып, тагы үзенең язмышын сөйли башлады.* Г.Ибраһимов

**БОҖРАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **боҗралау.** *Түгәрәк-түгәрәк сиртмәләр белән сиртмәләнгән, боҗралар белән боҗраланган, бөдрәләр белән бөдрәләнгән нәзек кыллы мамыклардан йомшак нурлар ургылып чыга...* А.Хәлим

2) Боҗра рәвешенә керү, боҗрага охшау. *Ул су Каменск шәһәренең төньягыннан килә иде, шәһәргә җиткәч, сулга каера, дугалана, бара торгач боҗралана, шәһәрне чолгап ала.* А.Таһиров

**Боҗралана бару** Торган саен ныграк боҗралану

**Боҗралана башлау** Боҗраланырга тотыну

**Боҗралана бирү** Боҗралануын дәвам итү

**Боҗралана төшү** Бераз боҗралану

**Боҗраланып алыну** Тулысынча, тоташ боҗралану. *Иң гаҗәбе: аркылы-торкылы яткан таяклар юл комы белән боҗраланып алынган иде.* Г.Гыйльманов

**Боҗраланып бетү** Тәмам боҗралану

**Боҗраланып калу** Ниндидер сәбәптән соң боҗра хәленә килү. *Озак та үтмәде, ул су куера да башлады – ак каен, түгәрәк алтын кыршау кигәндәй, боҗраланып калды.* Г.Хәсәнов

**Боҗраланып килү** Акрынлап боҗралану

**Боҗраланып тору** Боҗра сыман булып күренү

**Боҗраланып чыгу** Боҗралар барлыкка килү. *Гәрәй Рәхимнең төтене нәселле борын тишекләреннән иркен булып, боҗраланып чыга.* М.Галиев

**Боҗраланып яту** Әле, хәзерге вакытта боҗраланган хәлдә булу. *Алар аяк астында боҗраланып яткан тимер йомычкалары, тутыгып беткән машина кисәкләре арасыннан*

*үттеләр.* К.Нәҗми. *Төймәләре бертөрле зурлыкта, тезгән җебе кышкы ак keләм өстендә бормаланып, хәтта бошраланып ята.* М.Рафиков

**БОҖРАЛА́У** *ф.* 1) Божра кидереп ныгыту, божра кидерү. *Чалгыны божралау*

2) Божра сыман итү, божрага охшату, божра ясау. *Атоллны, божралап, рифлар урап алган.* М.Юныс. --- *сүз яки сүзтезмәләр бер юлның ахырында, икенче юлның башында кабатланып килсә, анэпифора – янәшә сүзтезмәләрне дә, җөмләләрне дә божралап, элмәкләп ала торган кабатлаулардан гыйбарәт.* К.Миңнуллин

3) *к.* **балдаклау** (*1 мәгъ.*)

**Божралап алу** Тоташ әйләндереп божралау. *Текстка керми торган төрле күрсәтмәләрне, аңлатма-шәрехләрне һәр очракта да түгәрәкләп, божралап алырга киңәш итеlә.* М.Вәлиев

**Божралап бетерү** Тулысынча божралау

**Божралап кую** Божра сыман хәлгә китерү. *Сатучы, өстәл өстенә кулын божралап куеп, йомыркаларны тәгәрәтмичә тотып торган.* Әкият

**Божралап чыгу** Рәттән барысына да божра кидерү; башыннан ахырына кадәр божралау

**БОҖРАЛЫ** *с.* Божра беркетелгән яки кидерелгән, божрасы булган. *Чаңгычы үзе алга иелгән, божралы таякларын карга да тидерми.* Г.Әпсәләмов

**БОҖЫР** *и.* Көртлекләр семьялыгыннан, Евразиянең урта зонасында яши торган, чуар каурыйлы урман кошы; *русчасы:* **рябчик**. *Ел буена бер генә җирдә яшәүче кошлар (чыпчык, саескан, боҗыр) «утрак кошлар» дип атала.* Зоология. *Урман кошларга да бай: боҗырлар, көртлекләр күп.* Физик география

**БОЗ** *и.* 1) Түбән температурада каты хәлгә килгән, туңган су. *Киң Иделдә, актарылып, бозлар актылар.* Ф.Кәрим. *Мөхәммәтләр авылы Гөберчәктә боз агардай зур елга юк.* Г.Ахунов. *Күл тоташ бозга әйләнгән, су юк.* З.Мансур

2) Туңган су өслеге яки шуу өчен, су сиптереп, махсус туңдырылган мәйданчык; шугалак. *Егет белән кызлар йөри шаркылдашып, Боз өстендә тимераяк белән шуып.* Г.Тукай. *Кәримә, бозның кар ятмаган уйдыкларын сайлап, бөтерелә-бөтерелә шуарга кереште.* Р.Хафизова. *Битләрне кытыклаган җиңелчә салкыннарда көзге кебек ялтыраган боз өстендә уйнаулар бигрәк тә күңелле була торган иде.* М.Гали

3) Салкын һавада түгәрәк бөртекләргә әйләнгән атмосфера явым-төшеме. *Бу төркемгә шулай ук боз яңгыры, җылы кышкы кар, җәйге вак яңгыр һәм башка табигать күренешләре белән идарә итүче тәңреләр керә.* Г.Гыйльманов. *Әле боз ява, әле давыллы яңгыр коя минем өскә, әле өермә алып ыргыта.* Г.Бәширов. *Карап торган арышыңны боз суксын, бердәнбер кәҗәңне яшен суксын, бердәнбер карчыгыңны каһәр суксын.* Ф.Бурнаш

4) *күч.* Үзара мөнәсәбәтләрдәге салкынлык, читләшү, хәтер калу. *Тик соңгы вакытта бүләкләр дә арадагы бозны эретә алмый башладылар.* Казан утлары

◊ **Бозга бозаулау** Киләчәкне алдан күрмәү, юк эш эшләү. *Аһ, дисбесе онытыла язган түгелме? – Җилгә җиленләп, бозга бозаулап йөрергә вакыт юк, – диде киенеп тә беткән карт.* А.Хәлим. **Бозга таяну (таяндыру)** Алдану (алдау). *Шул мәдрәсә өчен ялган договор төзеп, патша хөкүмәтен бозга таяндырган.* Х.Кәрим. **Бозга утырту** *к.* **бозга таяну (таяндыру). Бозга язган** Чынбарлыкта юк, мөмкин булмаган; ышанычсыз, таянычсыз, эзсез югала торган. *[Батырҗан:] – Ул – синең белән минем хисап түгел. [Ярулла:] – Бозга язган хисапмы? Таянып кара әле син аңа.* Ф.Бурнаш. **Боз йөрәк** Мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, хисләргә ярлы, каты күңелле кеше. *Сөю – ул шундый серле, тылсымлы, Боз йөрәкне үбеп эретә.* М.Җәлил. **Боз кузгалу** Озак тоткарланып торганнан соң, бер тармакта эш яки хәрәкәт башлану. *Тулуы җитте ачу диңгезенең, Боз кузгалыр, диләр, тиз көннән.* Г.Хуҗиев. *Бозның кузгаласы көне, шулай да, алдында булган икән.* Ф.Хөсни. **Боз салкыны** Салкын мөнәсәбәт, бернәрсәгә дә искитмәүчәнлек. *Мин, туктаусыз аккан күз яшьләремә каршы авыр таш катылыгы, боз салкынлыгы күрсәм, куркам ки: нәфесем җиңмәгәе иде!* Г.Ибраһимов

**БОЗА́У** *и.* 1) Сыер, болан, поши баласы. *Бозавы бик таза, бик көр, көтүдә бер бозау.* К.Тинчурин. *Бу хакта фән болай дип әйтә: сөтле сыер үстерәсең килсә, бозауга яшь чагында, мөмкин хәтле күп итеп, куе сөт эчерт, ди.* Ә.Еники. *Аз гына җаны бар кеше савымчыларны, бозау караучыларны, мал-туар симертүчеләрне, резин итек киеп, саз ерып йөрүдән коткарырга тиеш.* Г.Ахунов

2) *күч. гади с.* Булдыксыз, ихтыярсыз, йомшак холыклы, җебегән кеше. *Ул киң күңелле булырга тырыша, шәкертнең сүзсез бозау булуын яратмый иде, аларда тәнкыйть көче уянуга карышмый – авыр сүзләрен дә күтәрә иде.* Г.Ибраһимов. *[Сафура иренә:] Һи, бозау, синең һаман үз сиксәнең сиксән булыр инде.* А.Әхмәт

◊ **Бозау сыйрагы** Юан итеп төрелгән тәмәке. *Юан гына итеп, тагын берәр «бозау сыйрагы» төрдек.* Ә.Айдар

**БОЗАУЛА́У** *ф.* 1) Бозау тудыру (сыер, болан, поши турында). *Бияләр колынлый, сыерлар бозаулый, сарыклар бәрәнли, ягъни мал-туарның үрчем вакыты.* Ф.Сафин. *Соңлап бозаулаган коба сыерыбызны саттык.* М. Кәрим. *Алар туган көнне Зәйни байның сыеры бозаулады.* Һ.Такташ

2) *күч. гади с.* Әкрен кыймылдау, мыштырдау, озакка сузу. *Бозаулама инде, тизрәк бул*

**Бозаулап кую** Кинәт бозаулау *Күтәрәмгә калып бара торган сыер, әзмәз тернәкләнеп, исән-имин бозаулап та куйса, сөт-катыктан өзелмәсләр, «фәкыйрьлек» дигән хәерчене, алдапйолдап, адаштырып җибәрү насыйп булыр.* Р.Мулланурова

**Бозаулап тору** Әледән-әле, еш бозаулар туу. *Әмма, ничек кенә булмасын, фермага килүе, иң яхшы нәселле сыерларның шулай исән-сау бозаулап торуы Нургалинең кәефен бермәлгә яхшы якка таба шактый нык үзгәртеп җибәрде.* Ә.Еники

**БОЗВАТКЫЧ** *и.* Бозны ватып, башка судноларга бозлар арасыннан юл ярып бара торган куәтле судно. *[Кораб] Шаулап килгән, ул бозларны Бозваткычлар белән таптатып.* Ф.Кәрим

**БОЗГЫЧ** *и.* Язганны бетерә торган резина кисәге, бетергеч. *Артта калган юллары юк, алар язмыш дәфтәренә сызылып килеп, бүгенгесе көнне резин бозгыч белән сөртеп ташланган кебек юкка чыкканнар.* А.Гыйләҗев

**БОЗДЫРГЫЧ** *и.* **1.** Сихер

**2.** *с. мәгъ.* Бозу өчен кулланыла торган, бозу өчен билгеләнгән. *Шул ук фатирда һәртөрле сөйдергеч имнәр, боздыргыч тасмалар табарга мөмкин.* Г.Тукай

**БО́З КИСКЕЧ** *и. к.* **боз чапкыч**

**БОЗЛАВЫК** *и.* **1.** Яңгыр яки юеш кардан соң кинәт суыту нәтиҗәсендә, җирне тоташ каплаган боз кабыгы, тайгаклык. *Бозлавыклар очраганда, йөгереп килеп, шуып китә.* М.Хәсәнов. *Бу уңайдан утырышта, бозлавыкларны киметү максатында, ком-тоз урынына сыек химик матдәләр куллануга күчү кирәклеге дә искәртелде.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* Бозланган, боз кабыгы белән капланган, тайгак. *Язга таба юллар бозлавык чак иде.* З.Фәйзи. *Ышкылу аз булса, мәсәлән, бозлавык юлда, җирдән этелеп булмый, аяк тая.* Физика. *Бозлавык көнне, төзек булмаган машинага утыртып, йөк алып кайтырга станциягә җибәрәләр.* Татарстан яшьләре

**БОЗЛАНУ** *ф.* 1) Башта җебетеп, аннан кинәт салкынайту нәтиҗәсендә, боз белән каплану; боз булып кату. *Кӧтелмәгәндә карлы-буранлы чана килеп кергәч, ул да бераз гаҗәпсенде, ат чанасы түгелме дип, төрле бизәкләр белән бозланып туңган тәрәзәнең бер читеннән йортка күз ташлады.* Г.Ибраһимов. *Ишек төбе таеп егылырлык булып бозланган иде.* М.Гали. *Ләкин кар томалаган һәм бозланып каткан тәрәзәдән бернәрсә дә күренми иде.* А.Шамов

2) *күч.* Йөрәк, күңел кату, суыну. *Күңеле бозланган кешедер: Һич тагын бер кат сөймәс.* Г.Тукай. *Ә юкса – отыры гел арта кешеләр күңелендә бозлану.* Р.Фәйзуллин

**Бозлана бару** Акрын-акрын боз белән каплануы арту

**Бозлана башлау** Бозланырга тотыну. *Шартлатылган күпер кисәкләре бозлана башлаган суда батып яталар.* Г.Кутуй

**Бозлана бирү** Бозлануын дәвам итү

**Бозлана төшү** Беркадәр бозлану. *Әйе, кешеләр начар түгел монда, бары еллар буена сузылган салкынлыктан күңелләре генә бозлана төшкән.* А.Вергазов

**Бозланып бетү** Тәмам бозлану. *Бозланып беткән кое чиләгендәге суны үз чиләкләренә бүлеп салды да, көянтәсенә эләктереп, авыр чиләкләрне иңбашына күтәрде.* Н.Нотфуллина

**Бозланып җитү** Тәмам бозга әйләнү

**Бозланып калу** Билгеле бер сәбәптән соң, боз катламы барлыкка килү

**Бозланып тору** Даими рәвештә боз белән капланган булу

**БОЗЛЫ** *с.* 1) Боз катыш, боз белән аралаш. *Алда – юллар, биткә бәрер бозлы яңгырлар...* Р.Фәйзуллин. *Кичә туктаусыз карлы, бозлы яңгыр ява иде.* Г.Ибраһимов

2) Боз кебек салкын. *Нервлар шаярмасын, идарә көче йомшармасын дип, һәркөн иртә-кич бозлы су белән тәнен ышкыды.* Г.Ибраһимов. *Мин эссе көндә бозлы суга чумгандай булдым.* Г.Хәсәнов. *Бара торгач, бизгәк тоткан сыман, бер – кызышып, бер, өстенә бозлы су сипкәндәй, бөтен тәне бөрешеп килә дә, ул, бу фаҗигане аңлап җиткерүдән гаҗиз булып, урам уртасында туктап кала иде.* Г.Бәширов

3) Боз каткан, боз белән капланган, бозланган. *Кичке уннар булгандыр, казарма ишегե ачылып, бозлы итек үкчәләрен дөбердәтеп, бертөркем солдатлар кайтты.* К.Нәҗми. *Бураннарны, бозлы тайгаларны Йөрәк уты белән җылытып, Җимергәннәр үлем полкларын, Үлем барлыгын да онытып.* Ш.Маннур

4) *күч.* Бик салкын, гаять салкын. *Бирсәң, сүзсез чәйнәп йотлыгалар, булмаса, дәшми-тынмый, бозлы салкын почмакта, иске киемнәргә уралган килеш, бөгәрләнеп ята бирәләр.* Г.Ибраһимов. *Сөям барын: бозлы март аенда Язның тәүге горур адымын.* Ш.Маннур

◊ **Бозлы су сипкән (койган) кебек (төсле) булу** Бик нык сискәнү. *Башыннан бозлы су койган төсле, тәннәре чымырдап китте.* Ш.Камал

**БОЗЛЫК** *и.* Таулы яки поляр өлкәләрдә хәрәкәт итә торган тоташ, тыгыз боз массасы. *Олы кунак бүлмәсендәге ятакка Арктика бозлыгында атылган аю тиресе җәелгән иде.* М.Галиев. *Белеп тор: бу якларга да бозлык килсә, ул җәнлекләрнең берсе калмаячак.* Тәмуг чәчәге. *Әкренләп, климат җылына, бозлыклар эреп бетә.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**БОЗЛЫ́К ДӘВЕРЕ (ЧОРЫ)** *и геол.* Җир ясалу тарихында көчле салкынаю, җир өстенең зур мәйданын боз каплап алу белән аерылып торган дәвер. *Бу кече бозлык чорында бөтен Җир шарында уртача еллык температура бер градуска кимегән.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Бозлык дәверендә Көнчыгыш Европа тигезлегенең төньяк яртысының шактый өлеше гигант бозлык белән капланган булган.* СССРның физик географиясе

**БО́З СУГУ** *ф.* Боз явудан игеннәр һәлак булу. *Табигать аңа начар йөзен күрсәтмәгән, боз да игенен сукмаган.* Г.Нигъмәти

**БОЗУ** *ф.* 1) Яраксыз итү, начарландыру, файдалана алмаслык хәлгә китерү. *Фәтхи моңар каршы ләм-мим сүз әйтмәде. Май ботканы бозмас, дигәндер.* Ш.Камал. *Фабрика хуҗалары, аларның ярдәмчеләре, ярдәмчеләренең булышчылары, тегеп чыгарган спорт товарларының спортлылыгын бозып, чимал тирәсендә күз буяп, меңләгән акчаларны җыеп ятканнар да, берзаман яман шеш тишелгән.* А.Гыйләҗев. *– Бозар, дип курыкма, әнкәй, мин анда аш-су эчендә күп кайнаштым, – диде дә, хуҗа хатын өстендәге мәшәкатьләрнең яртысын үз җилкәсенә күтәрде.* Г.Ибраһимов

2) Вату, җимерү, эшләми торган итү. *Ул, анасыннан Зыяның кайтуын ишеткәч, бер хәйлә булсын өчен үз машинасын юри бозып, боларга кергән иде.* Г.Ибраһимов

3) Тигезлеген, төзеклеген юкка чыгару. *Яңгырдан бүртеп беткән салкын дилбегәне көчкә генә тотып баручы Шәрәфи карт, яңа йокысыннан уянган кеше төсле, күзләрен уып алды да сүзгә керешеп китте: – Көзге яңгырның юл бозудан башка бер файдасы да юк бит аның.* К.Нәҗми

4) Элеккене сүтеп, җимереп, кабаттан үзгәртеп эшләү. *Чөнки әнисе аны өлкән уларының искергән бишмәте белән кечерәйгән камзулыннан бозып тегеп бирде.* М.Маликова. *Синең искеңнән бозып теккән камзулга сыймый башладым, дидем.* Ф.Хөсни

5) Язганны сызу, бетерү, юкка чыгару. *Юк, хатны авылда ачканнар да усал ният белән бозганнар.* Т.Гыйззәт. *Ул, аны сызып ташлап, үзенчә башлады. Бер язды, бер бозды, башлап алып китә алмыйча, дәфтәр читләрен каләм белән сырлап, чуарлап бетерде, кош сурәтләре төшерде.* Ә.Фәйзи

6) Бөтен әйберне башлау, бүлеп алу, бөтенлегенә зыян китерү. *Әллә инде аның [Нәсимә] өчен участок бозарлар!* Ш.Камал. *Тик син аны өеңә кайтып җитмичә ачма, мөһерен бозма.* А.Әхмәт

7) Начар якка үзгәртү, ялгыш итеп үзгәртү, ялгышлыклар җибәрү. *Русчага ияреп тә сүзләрне бозып кулланулар бар.* М.Җәлил. *Шунда сизәм: скрипкамның авазы һаман тупаслана бара, имештер, мин көйнең иң назлы урыннарын бозып уйныйм.* Г.Бәширов

8) Килешенгән, алдан кабул ителгән тәртип, закон, кагыйдә һ.б.ш. таләп иткәнчә эшләмәү, аларны төгәл үтәмәү; өзү, гамәлдән чыгару. *Грамматика кагыйдәләрен бозулар очраштыргалый.* М.Җәлил. *Ләкин Сарсымбай, гаделлекне бозып, күбрәк төннәрен Алтынчәчкә бирә иде.* Г.Ибраһимов. *Ә инде сез санаган закон бозуларга килсәк, сайлауларның мондый нәтиҗәләреннән соң, җиңелгән як ни генә әйтмәс.* Татарстан яшьләре

9) Үзара һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, яшәп килгән тәртипне, халәтне юкка чыгару, үзгәртү, таркату, чуалту. *Ни булса да әйдә – чорт с ним! – Тыныч тормышымны боздылар, Хатыннарны урлап сыздылар, Әллүки...* Һ.Такташ. *Бервакыт сиңа, корган ояңны бозып, бик күп уңайсызлыклар чыгарырга яисә гомер буена шул тын, караңгы авылыңнан бизеп, мужиклыгыңа нәфрәт чигеп газапланырга туры килер.* Г.Ибраһимов

10) Логик эзлеклелекне сакламау, буталчыклыклар кертү. *Хәтере яхшы булырга тиеш аның, – кәгазь-мазарга карап тормастан, һаман шулай тигез тавыш белән, фикер агышын бозмыйча һәм кабатламыйча, күңеленнән сөйли бирде.* Ә.Еники

11) Берәр әгъзаны *(*колак, күз, аяк, кул һ.б.ш.ны*)* имгәтү; гарипләндерү. *– Бу Карамалы Елганың сугымчы Низами малае, аягын бозып, икенче ел йөри инде, быел да ычкындырмаганнар икән, – дип сөйләделәр.* М.Гафури. *Син, миңа да әйтмәстән, юрамалый күзеңне боздың.* Ш.Камал

12) Ямьсезләтү. *Ләкин аерым урыннарда цирк клоуннарын хәтерләтә торган кәмитчелек кенә бу матурлыкны боза.* М.Җәлил. *Ләкин бу аксаклык аның төз буен бозмый.* А.Шамов. *Акырганмын, имеш, җикергәнмен, Ямен бозып бөтен урамның.* З.Мансур

13) Баланы дөрес тәрбияләмәү, начар тәрбияләп, иркәләп азындыру. *Әнкәй, Рөстәмне үз тәрбияңә алырсың, бабайларга җибәрмә, иркәләп бозарлар.* Т.Гыйззәт

14) *күч.* Кәефсезлек, ачу, ризасызлык белдереп, йөзне, чырайны җыеру, сыту, чыту. *Бикмулла карт түзмәде, төсен бозып, тагын сыкранып куйды.* Г.Бәширов

15) *күч.* Борчу, тынычсызлау. *Тынлыкны чәчләрен иңенә таратып салган хатын бозды.* Н.Хәсәнов. *Әмма аруталуны белмәгән кибетче белән кайбер балыкчылар инде күптән үз эшләренә керешкән, Гүнҗәлленең тымызык тынлыгын бозарга өлгергән иде.* Т.Әйди. *Аның тавышы тынлыкны бозды.* Р.Хафизова. *Исәр-исмәс җил белән әкрен генә тузанланып, тынгысызланып торган юл да, шул юл буйлап ялкау гына атлаучы дөяләр кәрваны да тынлыкны боза алмыйлар иде.* Ә.Фәйзи

16) *күч.* Кемнең дә булса үз-үзен тотышын, холкын, дөньяга карашын начар якка үзгәртү, начар йогынты ясау. *Әле сөйләп туктаган бабай безне кешеләрне бозуда, диннән яздыруда гаепли.* М.Әмир. *Кешене артык иркәләү дә боза икән.* Ф.Хөсни. *Харам юллар белән килгән акча кешене боза.* Шәһри Казан

17) *күч.* Сихерләү, начарлык китерү. *Багучы: «Сине бозганнар», – дип әйтә.* Казан утлары

**Боза бару** Булган берсен, һәрберсен бозу; торган саен ныграк бозу. *Әмма шулай да «хезмәт күрсәтүчеләрнең» халыкка карата сансызлыгы әхлак кагыйдәләрен отыры боза гына бара.* Ә.Еники

**Боза башлау** Бозарга тотыну. *Ул, урынсыз сүз кузгатып, тагы кәефне боза башлавын төшенгән иде.* Р.Сибат

**Боза төшү** Тагын да бозу

**Боза язу** Чак кына бозмый калу. *Бөтен графигымны боза язды!* А.Гыйләҗев. *Бөтенләй эшне боза язды.* Г.Камал

**Бозып алу** Бераз гына яки тиз генә бозу

**Бозып ату** Барысын да берьюлы тиз-тиз бозу

**Бозып бару** Рәттән бозу

**Бозып бетерү** Тәмам, барысын да бозу. *Бар, бар, юлыңда бул, малай актыгы! Шул Мифтах хәлфә бозып бетерде сезне.* Ф.Сафин. *Бервакыт Тимергалинең сигез яшендәге Хәсән исемле бик шук, озорник угылы, уйнап, зәңгәр карандаш белән, бу кенәгәнең бер-ике битен сызгалап, бозып бетергән иде.* Ш.Мөхәммәдев

**Бозып җибәрү** Көтмәгәндә, кинәт бозу. *Залда урнашкан тынлыкны Нәсимә кинәт бозып җибәрде.* Ш.Камал

**Бозып җиткерү** Тәмам, ахырына кадәр бозу

**Бозып йөрү** Һәрвакыт бозу. *Шунда, тракторын үкертеп, урман бозып йөрүчеләр күз алдына килде дә Камил, кай җиредер авырткандай йөзен чытып, борылып карады.* Г.Бәширов

**Бозып кую** Бозган хәлгә китерү. *Алачак алынгач яки бирәчәк түләнгәч, бу кенәгәдә язылган җирне, Әхмәтсафа агай яисә приказчик Тимергали, зәңгәр карандаш илә аркылы-торкылы сызгалап, бозып куялар.* Ш.Мөхәммәдев

**Бозып ташлау** Кинәт, ялгышлык белән бозу. *Тешне, тазарттырам дигән булып, бозып ташладым.* Г.Бәширов. *Кунаклар килгәч, аны-моны аңышмыйча, бозып ташлавы бар.* А.Гыйләҗев

**Бозып тору** Әле, күз алдында бозу. *Нурга чумган матур табигатьне Ямьсезләтеп бозып тора ул.* М.Гафури. *Тик бер як җилкәсе бераз төшеп, аның гәүдә рәвешен чак кына бозып тора.* А.Салах

**Бозып чыгу** Берсе артыннан икенчесен, башыннан ахырына кадәр бозу

**БО́З ЧАПКЫЧ** *и.* Боз вата торган эш коралы. *[Альпинистларның] Кулларында – боз чапкычлар, аякларында – табаннарына очлы тешләр кагылган аяк киемнәре, аркаларында – җылы капчыклар.* Физик география

**БОЗЫК** *с.* **1.** 1) Бозылган, черегән, исләнгән. *Безгә ярамаган май Сыланды кыл-казанга. Бозык исләр бөркелә, Нинди балык салсаң да.* Ш.Гаделша. *Бозык йомырка*

2) Нәрсәнең дә булса берәр механизмы, ватылып, эшкә яраксызга әйләнгән; ватык. *Нәрсә бозык, дисеңме? Шул инде, молотилка бозык. Яңадан өч көн вакыт кирәк.* Р.Ишморат. *Пычрак, тайгак, күперләр бозык, көн саен диярлек камыт бавы, тәҗе өзелеп, арба ватылып теңкәне корыта.* Г.Ибраһимов

3) Дөрес булмаган, нормага туры килми торган, ниндидер кимчелеге булган; көйсезләнгән (уен кораллары турында). *Әй, музыкант, композиторның чыгарган моңнары; Әй талантсыз күп шагыйрьләрнең бозык саз кыллары.* Н.Исәнбәт

4) Төксе, сытык, караңгы. *Шулай да булса, бүген Галиәкбәр агайның чырае бозык күренә.* Ш.Мөхәммәдев

5) Явым-төшемле (һава торышы турында), юеш, пычрак (юл һ.б. турында). *Ерак җирләргә йөрүче юлчылар, язга таба яки кышын юл бозык вакытларда гына, Шырдан аша әйләнеп йөриләр.* М.Гали

6) Җәмгыять тарафыннан кабул ителгән әхлак нормаларына туры килми торган, тәүфыйксыз, тотнаксыз, начар. *Шулай ук син мине шундый бозык, түбән кеше дип уйладыңмы, Хәмит?* Р.Ишморат

**2**. *и. мәгъ.* Әхлаксыз кеше. *Җыен эшлексезне, җыен бозыкны, нәсел черетеп, син җыеп ятасың!* Г.Бәширов. *Сөйләрсең, егет ни сораса, шуны сөйләрсең, шайтан бозыгы.* Н.Гыйматдинова. – *Хәзрәт, эш зур! --- Бозыклар аяк астында яшиләр икән... Шуларны тотып, сездән шәригать сорарга килдек! – диде.* М.Гафури

◊ **Бозык юл** Җәмгыять тарафыннан тәнкыйть ителә торган, әхлак нормаларына туры килмәгән яшәү рәвеше. *Шайтан куәтле: Галиәкбәр агайны, аздырып, янә бозык юлга салды.* Ш.Мөхәммәдев. **Бозык юлда йөрү** Азып-тузып, яман кешеләр арасында булу, яман эшләр эшләү

**БОЗЫКЛЫК** *и.* Әхлак нормаларыннан тайпылыш, бозык булу. *Әнә бозыклыгы белән даны чыккан, шуның өстенә әле эшләп тә куандырмый торган Хәдичәдән ничә тапкыр котылырга теләп карады.* М.Хәсәнов. *Әбиләрнең «Йосыф вә Зөләйха» кебек хикәяләрен тыңлап, бозыклыктан азат, кешеләре дә фәрештәләр сыман саф Гарәбстанга хаҗ кылырга хыялланып үстек...* Ф.Фәтхелислам. *Харам байлык янында гел азгынлык, бозыклык, каргыш, үтереш-талаш булыр.* Шәһри Казан

**БОЗЫЛУ** *ф.* 1) Черү, куллану өчен яраксызга чыгу, сыйфаты начарлану. *Бөркәүле ындыр эченә ташып өлгермәсәң, тышка өйгән ашлыкның, яңгырда чыланып, сыйфаты бозылуы мөмкин иде.* Г.Бәширов. *Сабира апа башта балыкларны, барыбер, бозылып, әрәмшәрәм була, дип, күрше-күләнгә өләшкәләде.* М.Хәсәнов

2) Ватылу, төзеклеген югалту, эшләми башлау, җимерелү. *Машинасы бозылган яисә кирәкле берәр винты какшаган дисәң, ансы бер хәер.* Ш.Камал. *Тик Казанга җитәрәк кенә, тәгәрмәче бозылып, тәүлеккә якын су өстендә утырдык.* Т.Гыйззәт. *Әсхапҗамалларның сипараты бозылган.* М.Фәйзи

3) Бетү, юкка чыгу. *Аюларның өне актарылды, Бүреләрнең юлы бозылды.* Ә.Ерикәй. *Бара-тора, стеналардагы плюс билгеләре бозыла.* Г.Гобәй

4) Төгәл үтәлмәү, начар якка үзгәртелү (канун, кагыйдә һ.б. турында). *Декретлар турында халыкның белмәве, аларның «көчлеләр» тарафыннан бозылуы төп бәлаләрнең берсе булып тора.* М.Әмир

5) Кәеф китүдән, ачудан, ризасызлыктан яки нинди дә булса авыртудан, йөз, чырай җыерылу, сытылу. *Күз тирәләре, күгәреп, ямьсез шешкән: сөйкемле генә чырае тәмам үзгәргән, бозылган иде.* Ш.Камал. *Бибизәйниянең елаудан йөзе бозылган, яулыгы бер якка китеп, чәче тузгаланган, ул урам як тәрәзәгә таба авыр хыялый уйда акрын гына бара, сандык өстендә яткан гармунны, гүя үзе белмәстән, кулына ала, тәрәзәгә карый.* Г.Ибраһимов

6) Зарарлану, зыян килү, авыруга әйләнү, зәгыйфьләнү, җәрәхәтләнү, гарипләнү. *Авыз-иреннәр эштән чыгып бозылган, тел, бер чирек булыр, каралып, салынып тора.* Г.Ибраһимов. *Аксый-туксый килгән Хәйдәрне күрүгә, Мәүлихә түти, борчылып, бераз шелтәле тавыш белән: – Әй улым, бигрәк иртә йөрисең лә! Аягың бозылса, нихәл итәрсең? – диде.* Г.Бәширов. – *Мәрхүмә ашказаны бозылып үлде, – дип, хәзрәт Миңлесылуга якын ук килде.* Ф.Әмирхан

7) *Кәеф, күңел, йөрәк, нерв, теңкә* сүзләре белән килгәндә: начарлану. *Зәйнәпне күргәндә күңеле бозылганга күрә, моннан соң Зәйнәпне күрмәскә тырышырга карар бирде.* М.Гафури. *Бу өч запасной кереп утыргач та, Батыргали агайның кәефе бозылды.* Ш.Мөхәммәдев

8) Әхлаксызлану, начар гадәтләр алу, бозык юлга керү. *Закирның бозылуына шул типларны тудырган капиталистик төзелеш гаепле.* М.Гали

9) Начар гадәтләр үзләштерү, начар якка үзгәрү. *Аларның муллалары, үзләре шикелле, Мисырда укып, бозылып кайткан кеше икән.* Г.Камал

10) Чуалу, таркалу, рәте китү. *Шулай итеп, намаз тагын бозыла.* Г.Бәширов. *Революция белән бозылган тормыш гармониясен әдип, шәһәрдән түгел, табигатьтән, табигать балалары арасыннан эзли.* Г.Нигъмәти

11) Дуслык бетү, үзара мөнәсәбәтләр начараю, арага салкынлык төшү. *Рәмзия аның белән үткән көзне генә дуслашты, аннан, нигәдер, аралары бозылды.* И.Зарипов

12) Көн болытлау, явым-төшем башлану. *[Фәридә:] Ай-й, җил керә башлады; һава бозыла, дип әйтимме?* Р.Ишморат. *Мортаза көннең бозылуыннан да зарланып алды.* М.Хәсәнов. *Юк, һава тагы бозылган икән!* Г.Ибраһимов

13) Явым-төшемнән юллар пычрану, баткак хәлгә килеп, йөрерлек булмау. *Ләкин, Яуширмә җирләренә килеп җиткәндә, юл тәмам бозылып өлгерде.* Ә.Еники

**Бозыла бару** Акрынлап бозылу, торган саен ныграк бозылу. *Еллар үткән саен, табигать тә бозыла бара.* Сөембикә

**Бозыла башлау** Бозылырга тотыну. *Моңа тагын өстәп: – Вакытында өзмәсәң, кура җиләге дә бозыла башлый, – диде.* Г.Ибраһимов

**Бозыла бирү** Бозылуын дәвам итү

**Бозыла төшү** Беркадәр бозылу. *Тавышым да инде бозыла төшкән бугай.* Ш.Камал

**Бозылып алу** Тиз арада, кыска вакытка бозылу. *Әйе, узган ел, шундый бер кызый аркасында, «Кәлтәләр» белән аралар шактый бозылып алган иде.* Х.Ширман

**Бозылып бетү** Тәмам бозылу. *Газета укыган булып, бозылып беттеләр.* Г.Камал. *Алла тарафыннан яратылган табигый әхлаклары да бозылып беткән.* М.Сәхапов

**Бозылып җитү** Тәмам яраксыз хәлгә килү. *Табигатем тәмам бозылып җиткән иде. Аның бу карашы миндә күңел болгану төсле бер хис тудыра иде.* Р.Гали

**Бозылып йөрү** Бозык юлга кереп китү

**Бозылып калу** Нинди дә булса хәлдән соң бозылу

**Бозылып китү** Көтмәгәндә, кинәт бозылу. *Маневрга менә чыгу белән Һавалар да бозылып киттеләр.* Һ.Такташ. *Тик соңгы елларда дөньялар бозылып китте.* Ш.Камал

**Бозылып кую** Кинәт бозылу. *Планнар зурдан иде дә, бозылып куймагае.* Ә.Моталлапов. *Юк нәрсә белән эш бозылып куюы бар.* А.Гыйләҗев

**Бозылып тору** Әле, хәзерге вакытта бозылган булу. *Тик бит әле илдә дөньялар бозылып тора, абыстай...* М.Хәбибуллин

**Бозылып чыгу** Тәмам, ахырына кадәр бозылу. *Баш редактор яныннан Шәйхетдиновның да бөтенләй күңеле бозылып чыкты.* И.Гази

**БОЗЫЛЫШУ** *ф.* Дуслык, бердәмлек бетү, үзара мөнәсәбәтләр бозылу. *Ни эшкә шаулаштыгыз, ни эшкә бозылыштыгыз, әллә берәр хәл булганмы?* Г.Камал. *Хактыр инде, хак булмаса, бозылышмаслар иде.* Г.Камал. *«Кара айгырлар» белән бозылышудан, ике арада талаш чыгудан куркалар.* Г.Ибраһимов

**Бозылыша бару** Торган саен ныграк бозылышу

**Бозылыша төшү** Бераз бозылышу

**Бозылыша язу** Чак кына бозылышмый калу

**Бозылышып алу** Бераз гына, кыска вакытка бозылышу. *Шунда барысы да тавыш-гаугада бозылышып алганнар.* Ф.Яхин. *Беренче атнаны ук, Сөләйман аракы эчүчеләр белән бозылышып алды.* Р.Батулла

**Бозылышып бетү** Тәмам, бик нык бозылышу. *Шундый минутларда аның, колхоз җитәкчеләре белән бозылышып бетүе өчен, аеруча эче пошып куя иде.* Ә.Еники. *Шул гадәте аркасында, дусишләре, туганнары белән дә бозылышып бетте.* Ф.Тарханова

**Бозылышып йөрү** Бик озак вакыт дәвамында үзара бозылышкан булу. *[Сәлим] Ничә еллар атасы белән бозылышып йөргән иде.* Г.Ибраһимов. *Кияүгә чыкканда, иреңнең нәселен белеп чык, кызым. Инде, чыккачтын, аерылып, бозылышып йөрерлек булмасын!* Х.Ибраһимов

**Бозылышып китү** Кинәт, көтмәгәндә бозылышу. *Җәмилә җиңги белән дә Борһан әллә ничек кенә бозылышып киткән иде шул.* М.Хәсәнов. *Хатыны белән бозылышып китәр, дип уйламадыңмы?* Э.Яһүдин

**Бозылышып кую** Кинәт бозылышу

**Бозылышып тору** Һәрвакыт, даими бозылышу. *Беркем белән дә сүзгә килеп, бозылышып тормады.* Ә.Еники

**БОЗЫМ** *и.* Сихер, кара магия белән салынган зыян. *«Ак айга карасаң, кеше сихереннән, бозымыннан көчсезләнеп каласың...» дигән сүз йөри.* Г.Гыйльманов. *Бер карчыктан бозым эшләтеп, исерек чакта Закирҗанның кызыл аракысына салдырды.* Ф.Садриев. *Аңа йә күз тия, йә бозым эләгә, йә бүтәнебашкасы.* Ф.Дәүбаш

**БОЗЫШТЫРУ** *ф.* Котыртып, дошманлаштыру, кешеләр арасын бозу, ызгыш, гауга кертү. *Алар ара бозыштырыр өчен генә йөриләр.* А.Шамов. *Ул улы белән килене арасын бозыштыру юлында дөньяда булган пычраклыкларны эшләүдән кире тормый.* М.Гали

**Бозыштыра бару** Акрынлап бозыштыру

**Бозыштыра башлау** Бозыштырырга тотыну. *Орышның авырлыгы казанлылар белән нугайлар арасын бозыштыра башлады.* Һ.Атласи

**Бозыштыра бирү** Бозыштыруын дәвам итү

**Бозыштыра төшү** Бераз бозыштыру

**Бозыштыра язу** Чак кына бозыштырмый калу

**Бозыштырып алу** Вакыт-вакыт, бераз бозыштыру

**Бозыштырып бетерү** Һәммәсен дә үзара бик нык бозыштыру

**Бозыштырып йөрү** Бозыштыру белән шөгыльләнү, һәрберсен бозыштыру. *Арыслан анасы Арыслан белән Шакал арасын бозыштырып йөргән ялганчыларны каты газап белән газапларга үтенде.* Ибн әл-Мөкаффаг

**Бозыштырып карау** Бозыштырырга омтылу

**Бозыштырып кую** Көтмәгәндә генә, кинәт бозыштыру

**Бозыштырып тору** Һәрвакыт, гел, бертуктаусыз бозыштыру

**Бозыштырып чыгу** Һәрберсен рәттән, бер-бер артлы бозыштыру

**БОЙКОТ** *и. ингл.* 1) Аерым дәүләт, оешма, учреждениеләр белән мөнәсәбәтләрне тулысынча яки өлешчә өзеп, аңа икътисади һәм сәяси басым ясау

чарасы, буйсындыру ысулы. *Семья зур. Шәһәрдә дә эш юк, бойкот.* Г.Тукай. *[Тарихчы] «Англия товарларына бойкот» дигән төшенчәне дәрестә аңлатты да, шул минуттан, бойкотны Әлтафига карата куллана башлады.* М.Мәһдиев

2) Аерым кешене тулысынча читкә кагудан я игътибарсыз калдырудан гыйбарәт көрәш ысулы. *Рәйянга бойкот ясап, без бик зур хаталык кылабыз бит.* Г.Коләхмәтов. *Икенче мәхәлләнең имамын бу халык бойкот астында тотканга, анда да алар бармаганнар иде.* Г.Исхакый

**БОЙКОТ ЯСАУ** *ф.* Мөнәсәбәтләрне өзү, бойкот игълан итү, протест белдерү. *Өзделәр өметләрен һәм киттеләр бойкот ясап.* М.Гафури. *Алайга китсә, мин баскан урынымда унике сәгатьлек бойкот ясыйм!* К.Кәримов

**БОЙЛЫКСЫЗ** *с.* Сидеген тотмый торган

**БОЙНИ́ЦА** *и. рус хәрби* 1) Хәрби ныгытмаларда, кальга диварларында дошманга ату өчен махсус ясалган тар гына озынча тишек. *[Солдатлар] Тузан-туфрак арасыннан мылтыкларын алып, үзләренең бойницаларына барып басканнар иде.* Ф.Хөсни

2) *иск.* Рудникта, шартлату эшләре вакытында, эшчеләрне саклау өчен ясалган бура

**БО́ЙНЯ** *и. рус махс.* Терлек сую һәм итне беренчел эшкәртү белән шөгыльләнә торган махсус предприятие. *Тәбәнәк кенә таш бойня янындагы кешеләр [Габделбәрне] шаулашып каршыладылар.* А.Расих

**БОКАЛ** *и. фр.* Шәраб эчү өчен, зур рюмка рәвешендәге савыт. *Шәраб салынган бокалларда асыл төсләр уйный.* М.Галиев. *Бокал күтәргәндә, шат шәүләләр гел уйнаклап торды түшәмдә.* Р.Фәйзуллин. *Тик бәйрәмнәрдә, мәҗлесләрдә генә иптәшләр белән бергә бокал күтәрәм.* А.Шамов

**БОКС** I *и. ингл. спорт* Бау тарттырып бүлеп алынган мәйданчыкта, махсус перчаткалар кигән ике кешенең бер-берсенә йодрык белән бәрешүеннән гыйбарәт спорт төре. *Володя – бокстан мастерлыкка кандидат.* Ә.Хәбибуллин. *Әле бокс, йодрык сугышы белән җенләнде.* Ф.Сафин. *Тамара аның барлыгын, үзен яратканлыгын да белә ---, кайчакларда мәктәптәге кичәләрдән үзен озатып куярга да рөхсәт итә, аның белән бии, көтмәгәндә, Рушанның бокс ярышларына да килеп чыккалый һәм, бик дәртләнеп, аның җиңүен теләп утыра.* Р.Мирхәйдәров. *Әһә, бокс белән алдырырга, мишәр малаен тукматырга икән исәпләре.* К.Миңлебаев

**БОКС** II *и. ингл. махс.* Дәвалау учреждениеләрендә кайбер йогышлы авырулар өчен көйләнгән аерым бүлмә. *Ул аерым бокста ята, көн саен төрле тикшеренүләр үтә.* Мәдәни җомга // Бинаның бүлеп алынган өлеше. *Балаларга ике-өч көн кала, ана дуңгызны бокска урнаштыралар.* Терлекче-механизатор белешмәсе

**БОКС** III *и. ингл.* Ирләрнең чәчен баш түбәсендә кыска калдырып алу рәвеше

**БОКСЁР** *и. ингл. махс.* Бокс белән шөгыльләнүче спортчы. *Икенче берәү, Кремльгә керер алдыннан, беренче разрядлы боксёрдан изгеген күчерттергән.* М.Галиев. *Димәк, боксёр егет Гребенщиков дигәннәре – шул.* Н.Хәсәнов. *Ул арада боксёрыбыз, тыпыр-тыпыр биегән сыман, аякларын еш-еш алыштырып, кәмитче шикелле, тегенең өстенә килә дә башлады.* К.Миңлебаев

**БОКСЁРЛАРЧА** *рәв.* Боксёр кебек, боксёрга хас. *Юлда туктый-туктый, боксёрларча хәрәкәтләр ясап, һаваны төйгечләп алгалады.* М.Галиев

**БОКСИТ** *и. фр. махс.* Төп өлеше алюминий гидроокисе булган тау тогымы. *Бокситлар бу тау токымының төп минералы булып санала.* Химия дәреслеге

**БОКСЧЫ** *и. к.* **боксёр**. *Без бит аны, боксның нинди нәрсә икәнен дә белми инде, авыл гыйбады, дип тора идек, ә ул әнә, бер селтәнү белән, боксчыңны әллә кайларга чөеп кенә очырды.* К.Миңлебаев

**БОЛАГАЙ** *с. диал.* Урынсыз яки әдәпсез шаяртып сөйләнүчән. *Исеме матур булса да, кафе төбеннән болагай сәрхушләр өзелми, аларның хахылдап көлгән, ямьсез сүзләр кыстырып акырышкан тавышлары әллә кая кадәр ишетелә.* Л.Гыймадиева

**БОЛАГАЙЛАНУ** *ф. диал.* Кылану, әдәпсезләнү, урынсыз шаярту. *Кәрим (сузып, сыер мөгрәгән аваз белән, болагайланып): – Әби өйдәмәүүү? – [диде].* Г.Камал

**Болагайлана бару** Торган саен ныграк болагайлану

**Болагайлана башлау** Болагайланырга тотыну. *Эчсәң, буеңа сеңдер. Эчеп, болагайлана башлаучыларга әйтәләр.* Н.Исәнбәт

**Болагайлана бирү** Болагайлануын дәвам итү

**Болагайлана төшү** Тагын да болагайлану

**Болагайланып алу** Кыска вакыт аралыгында, бераз болагайлану

**Болагайланып бетү** Тәмам, бик нык болагайлану

**Болагайланып җибәрү** Кинәт болагайлана башлау

**Болагайланып йөрү** Өзлексез, бөтен урында да болагайлану. *Бинең килүен күреп, казан янындагылар да, ишегалдында бер дә юктан йөгерешеп, куышып, үзара болагайланып йөрүчеләр дә тынып калдылар.* Н.Фәттах. *Бездә эчеп-исереп яки болагайланып йөрү гадәте юк иде.* К.Миңлебаев

**Болагайланып китү** Ниндидер вакыттан соң болагайланырга тотыну

**Болагайланып кую** Көтмәгәндә болагайлык күрсәтү, кинәт болагайлану

**Болагайланып тору** Бертуктаусыз, һәрвакыт болагайлану

**БОЛАЙ** *а.* **1.** Эш-хәлнең үтәлү рәвешенә ишарәләп күрсәтү алмашлыгы; шулай, менә шулай, шушылай. *Болай эшләргә аны Сәлим өйрәткән иде.* Г.Гобәй. – *Бабай, кире башы белән тоткансың язуны, печатьле ягын өскә тотып укымыйлар аны, менә болай әйләндереп тот! – дип, минем кулымдагы язуның башын аска әйләндерде.* М.Гали. *Капитан булырга җыенган егеткә болай кают-компаниядә сөйләшеп утыру башбаштаклык булса да, шул көннән мин аны үземнең дустым итеп кабул иттем.* Ә.Хәбибуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Яхшырак итеп, артыграк. *Хатын-кызны әйтмисең дә*

*инде, ирләрдән дә болайрак эшлиләр.* Р.Ишморат

2) Монда, бу яккарак. *Йә, менла кем, шикләнмә, килче болайгарак.* А.Тимергалин

**3**. *с. мәгъ.* Ике әйбернең сыйфатларын чагыштырганда, яхшырак, зуррак, затлырак, күбрәк, мәгънәсендә. *Без яңадан килештек, элеккедән дә болайрак дус булдык.* Г.Ибраһимов. *Тәртә, имеш, тәртә сындырган, тәртәдән болайрак дәүләт бирдем мин аңа [Хафиз байга], сәламәтлегемне бирдем. Менә мин үзем сындым.* Ә.Фәйзи

**4**. *кер. сүз функ.* Беренче карашка, тыштан караганда. *Болай, читтән карап торырга, бик кәттә егетләр күренәләр.* М.Гафури. *Болай, үчем юк минем Иштирәковка.* Т.Миңнуллин

**5**. *кис. мәгъ.* Соң. *Әйе, дим, Тукай булам мин, сез үзегез кем болай?* Н.Исәнбәт. *Син бутама, карчык, эшне моннан болай, яме?* Ә.Фәйзи

◊ **Болайга борылу (борылгач)** *к.* **болайга китү (киткәч)**. *Шулай диде дә, эшнең болайга борылуына гаҗәпләнеп, нидер әйтергә җыенгандай, урыннан кузгала башлаган кунак хатынга борылды.* Г.Бәширов. **Болайга китү (киткәч)** Эш-хәлнең көтелмәгән юнәлешкә үзгәрүе, көтелмәгән юнәлеш алуы. *Болайга киткәч, үз бодаемны мин колагыннан тартып булса да үстерәм бит инде.* Г.Бәширов. **Болай гына** Аерым максат куймыйча, очраклы гына. *Бәлки, яшьрәге болай гына, көчен саклар өчен генә бирешә башлаган булгандыр?* В.Нуруллин. **Болай гына калдырмау** Истә тоту, онытмау. *Мин аны болай гына калдырмыйм.* Ш.Камал. **Болай да** Аннан башка да. *Исәнлек-саулык барында, мин болай да рәхәтләнеп торам, керен дә юасың, башкасын да эшлисең.* Ш.Камал. *Җәй көне Казанда болай да тын алыр хәл юк.* К.Нәҗми

**БОЛАК** *и. иск.* 1) Елгачык, инеш. *Болакның аргы ягында – әллә нинди, башларын кырдырган, җәй көне булуына карамыйча, бүрекләр кигән ирләр.* Ф.Әмирхан

2) Чишмә. *Диңгез башы – болак.* Әйтем. *Тау күрке – болак.* Мәкаль

3) Җыелган, болганчык су

◊ **Болак суы эчмәгән** Тәҗрибәсе юк, авырлык күрмәгән

**БОЛАМЫК** *и.* 1) Суга яки сөткә он болгатып пешерелгән ярым сыек ашамлык. *Боламыкка май кирәк, һәр нәрсәгә җай кирәк.* Мәкаль. *Әгәр дә боламыкны биргәннән соң балагызның эче «ката» икән, аны бәрәңге яисә җиләк-җимешнеке белән алыштырыгыз.* Сөембикә. *Җиде-сигез айларда нәниегезгә ит һәм яшелчә боламыгы бирә аласыз.* Сөембикә

2) *диал.* Суга яки сөткә изелгән бәрәңге, бәрәңге измәсе. *Боламык аш булмас, брамат ил булмас*. Мәкаль

3) *күч.* Пешмәгән, җебегән, булдыксыз кеше. *Шул инде, ни ир, ни хатын. Бер боламык шунда.* Р.Ишморат

◊ **Боламыкка әверелү** *к.* **боламыкка әйләнү.** *Тәмам боламыкка әверелгән урам пычрагын ера-ера, колхоз ашханәсенә барып килде дә парткабинетның иркен бүлмәсенә кереп утырды.* Җ.Рәхимов. **Боламыкка әйләнү** 1) Озакка сузылган явым-төшемнән соң, аяк асты йөреп булмаслык сыек баткак хәлгә килү; 2) Буталу, тәртибе бетү, чуалу, рәте китү. *Элек мәсьәләнең беренче өлешен чишкәннән соң, икенче өлешен чишү бик күп җиңелләр, дип беләм. Юкса, ике өлеше бергә буталып, боламыкка әйләнүе мөмкин.* Ш.Камал. **Боламыкны талкан итәр** Уңган, булдыклы

**БОЛАН** *и.* **1.** Партояклылар классының болансыманнар семьялыгыннан, тармакланып киткән мөгезле имезүче хайван. *Искиткеч матур, сын кебек зифа болан күренде.* Г.Хәсәнов. *Шулчак, боланга утырып, Әйнә белән Гайнә килеп чыккан.* Г.Гыйльманов. *Тундрада халык сирәк утырган. Халык болан асрау, аучылык белән көн күрә.* Физик география

**2**. *с. мәгъ.* Болан мехыннан тегелгән. *Садыйк карт, юрган кисәге өстенә утырып, болан бияләйләрен өстәл кыриена куйды.* Ш.Камал

**БОЛА́Н МҮГЕ** *и. бот.* Куаклы лишайниклар төркемендәге кладония ыругына кергән, җирдә, агачта, кыяларда үсә торган азык һәм дару үләне. *[Болан] Кыш көне «болан мүге» дип атала торган лишайник белән туклана.* Зоология

**БОЛАНЧЫЛЫК** *и.* Болан асраучылык

**БОЛАР** *а.* Күз алдындагы, үзенә якын торган әйберләргә яки кешеләр төркеменә күрсәтеп сөйләгәндә кулланыла торган, *бу* күрсәтү алмашлыгының күплек төре. *Көнен дә, төнен дә юлларны тикшерәләр болар.* М.Галиев. *Ул, боларны теле белән әйтергә кыенсынып, барды да барды...* Н.Хәсәнов. *Җылы якның иң сылу агачлары болар.* Ә.Еники. *Боларның бөтен нәрсә уртак иде: әтидә сирень бар, Кәрим абыйда – крыжовник.* М.Мәһдиев

**БОЛВА́НКА** *и рус тех.* Чимал буларак формаларга коеп тутырылган корыч яки чуен коелмасы, бүкән. *Тар каналлар буйлап [эрегән чуенны] чүмечләргә агызалар, аннары формаларга тутыралар, ул анда болванкалар (бүкәннәр) рәвешендә ката.* Химия

**БОЛГАВЫР** *с.* Буталчык, болганчык, ыгы-зыгылы. *Ичмаса, замананың да бик болгавыр чагы.* В.Нуруллин. *Бригадир Ибрай өстәл җыештырып маташа, әйтерсең өстәлдә тәртип урнашкач, үз күңелендәге болгавыр уйлар да тәртипкә килер, дип уйлый.* Р.Вәлиев. *Моннан ерак та түгел особнякта шашлык, сый-хөрмәт әзерләнә, рәхәтләнеп кинән, болгавыр шәһәр шавыннан онытылып ял итү өчен, урман куенында бар да бар.* М.Галиев

**БОЛГАВЫРЛЫК** *и.* Буталыш. --- *шәһәрдәге һәр вакыйга, төзелештәге болгавырлык хакында икесе дә бертигез борчылалар, әмма ләкин Сәбилә турында сүз кузгатудан, хәтта аның исемен әйтүдән дә куркалар иде.* Р.Вәлиев

**БОЛГАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **болгау** (*1 мәгъ*). *Яулык парадларда җилгә каршы бөтерелә торган байракларның берсе шикелле болгана.* А.Алиш

2) Ком, ләм һ.б.ш белән катнашу нәтиҗәсендә, болганчык хәлгә килү, төрле нәрсәләр белән аралашу. *Су алганда акрын ал ла, Батырып алсаң, болгана.* Җыр. *Ут ата аксыл төтеннәр, Болганып утлар белән, Нәкъ томан җиргә ята.* Һ.Такташ. *Болганып каралган Көмештәй саф суы.* М.Җәлил

3) Тәртипсез аралашу, чуалу, буталу. *Күк йөзен томалап өлгергән каракучкыл болытлар, тау-тау булып, берсе өстенә берсе актарылды, болганып кайнашырга тотынды.* Г.Бәширов

4) Әрле-бирле ике арада йөрү. *Егетләр шаулыйлар, котыралар, болганалар.* М.Фәйзи. *Кайчанга кадәр, үзеңә үзең хуҗа була алмый, ике уртада болганырсың?* М.Фәйзи

5) *Күңел* сүзе янында килеп, косасы килү, укшу мәгънәсен белдерә. *Сания көлә, әниләре дә елмая, ә Илдар, күңеле болганып, укшый башлый.* Г.Гобәй. *Күңелем болгануы бетми шул.* Д.Аппакова. *Күңеле нигә болгана соң әле аның?* И.Гази. *Бу чайкалудан бик күпләрнең башлары әйләнә, күңелләре болгана.* Н.Исәнбәт

6) *күч.* Үзара ызгыш-талашлар, чуалышлар килеп чыгу, татулык, бердәмлек бозылу. *Күл болганыр, бер тонар; Ил болганыр, бер тынар.* Мәкаль. *Бер болганмый су да тынмый. Болганмый булмый, булмый.* Җыр

**Болгана бару** Торган саен ныграк болгану, болганчык хәлгә килү

**Болгана башлау** Болганырга тотыну. *Әй, карасыннар ла! Күңелләре болгана башлагач туктарлар әле.* Т.Миңнуллин

**Болгана бирү** Болгануын дәвам итү

**Болгана төшү** Тагы да болгану

**Болгана язу** Чак кына болганмый калу

**Болганып алу** Кыска вакыт арасында бераз болгану. *Әйе, бер болганып алмый булмыйдыр шул инде.* А.Хәсәнов

**Болганып бетү** Тәмам, бик нык болгану. *Әллә ничәгә авышып, болганып беткән көннәр күбрәк.* Ш.Галиев. *Заманалар бетте болганып.* Ч.Мусин

**Болганып йөрү** Арлы-бирле килеп болгану; бертуктаусыз күренү. *Язучылар берлеге бинасында болганып йөрмичә, Таулар бистәсендә үз йорты белән яшәп, язып кына ятты да, ыгы-зыгысыз, [Нурихан абый Фәттах] тыныч кына бу дөнья белән хушлашты.* Т.Миңнуллин

**Болганып калу** Нинди дә булса сәбәп белән болганчык хәлгә килү. *Артларыннан су болганып калды.* Н.Хәсәнов

**Болганып китү** Кинәт болгану. *Бердән башым әйләнде, күңелем болганып китте.* Ә.Айдар. *Заманалар болганып китте.* Ф.Яруллин

**Болганып кую** Кинәт, уйламаганда, көтмәгәндә болгану. *Әрҗәсендәге мөгезле һәм мөгезсез терлекләр, кабинадагы юлдашлары бу көтелмәгән хәлдән болганып куярга өлгергән иделәр.* Ф.Яхин. *Күңелем болганып куйды шунда...* М.Хәсәнов

**Болганып тору** Бертуктаусыз болгану, еш болгану. *Бик күңелләрем болганып тора.* Г.Камал. *Күлнең астына гүя ут якканнар, ул кайнагандай болганып тора.* Р.Сибат

**БОЛГАНЧЫК** *с.* **1.** 1) Ләм, пычрак яки башка төрле нәрсәләр белән катнашып, чисталыгын, үтә күренмәлелеген югалткан. *Аның күзләре – ниндидер болганчык күл төсле.* Ф.Хөсни. *Стакандагы болганчык сыекчадан керосин исе килә.* Г.Бәширов. *Ул үзенең болганчык суын диңгезгә илтеп коя.* Борынгы заман тарихы

2) *күч.* Ыгы-зыгылы, тынычсыз. *Хәзерге заман кебек мәсләкләр чуалган бер вакытта, гаять болганчык сәясәт һәм фикер диңгезендә, без, үзара тату яшәп, барлык көчебезне җиңгәнче сугышу өчен тупларга тиешбез.* К.Нәҗми. *Күпме ара җыелып килгән болганчык уйлары берьюлы коелды да төште.* М.Галиев. *Бу адымны теге болганчык чорда колхозга керү белән чагыштырыр идем мин.* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Ызгыш, талаш, бәхәс; буталыш. *Кайвакытта мәмләкәттә болганчык вә фетнәләр булса, бу татулык сөючән, тирән гакыллы картны хәлифә дә киңәшкә чакыра иде.* Г.Тукай

◊ **Болганчык суда(н) балык тоту** Ыгы-зыгы, буталчык вакыттан файдаланып, үзенә файда эшләү, табыш ясау

**БОЛГАНЧЫКЛАНУ** *ф.* Болганчык хәлгә килү, болганчыкка әйләнү. *Известьле су болганчыклана.* Химия. *Известьле су аркылы углекислый газ уздырганда, кальций карбонаты хасил булу аркасында, эремә болганчыклана.* Химия

**Болганчыклана бару** Торган саен ныграк болганчыклану

**Болганчыклана башлау** Болганчыкланырга тотыну

**Болганчыклана бирү** Болганчыклануын дәвам итү

**Болганчыклана төшү** Тагын да болганчыклану

**Болганчыклана язу** Чак кына болганчыкланмый калу

**Болганчыкланып алу** Бераз гына болганчыкланып, элекке хәленә кире кайту

**Болганчыкланып бетү** Тәмам, бик нык болганчыклану

**Болганчыкланып китү** Кинәт болганчыклану. *Кайчан да булса, елга болганып, болганчыкланып китәр, дип, Исмәгыйль уйлый иде.* Г.Тукай

**Болганчыкланып кую** Болганчык хәлгә килү

**Болганчыкланып тору** Болганчыкланган хәлдә булу

**БОЛГАНЫШ** *и.* Чуалыш, кузгалыш

**БОЛГАНЫШУ** *ф.* Үзара тәртипсезлекләр килеп чыгу, ызгыш-талаш башлану, ыгы-зыгы килү, буталышу

**Болганыша бару** Торган саен ныграк болганышу

**Болганыша башлау** Болганышырга тотыну. *Махночылар бераз исләренә килмичәрәк тордылар да, аннары төркем кинәт чайкалып китте, кайнаша, болганыша --- башладылар.* Г.Бәширов

**Болганыша бирү** Болганышуын дәвам итү

**Болганыша төшү** Беркадәр болганышу

**Болганышып алу** Билгеле бер вакыт эчендә, бераз болганышу

**Болганышып бетү** Бик нык болганышу

**Болганышып йөрү** Әле, хәзерге вакытта болганышу. *Умарта кортлары болганышып йөрсәләр, һава бозылыр.* Сынамыш

**Болганышып китү** Уйламаганда, көтмәгәндә, кинәт болганышырга тотыну

**Болганышып тору** Һәрвакыт, гел болганышу

**БОЛГАР** I *и.* 1) Урта Идел буйларында, шул исәптән хәзерге Татарстан җирендә X гасыр башы – XIII гасыр

урталары арасында яшәгән төрки дәүләт. --- *Ибне Рәшид белән Гәззали исемле философлар арасындагы бер-берсенә каршы китаплар язышып кычкырышулар хакында сөйләшкән соңында, Сәгыйд мәсьәләне тагы Болгар иленә борды.* Г.Гобәйдуллин. *Бер мәхәббәткә адәмнең Күкрәге тар булмасын, Йорты Болгар булса булсын, Йодрык болгар булмасын.* Н.Исәнбәт. *Казан яки Болгар хәрабәләренә карата озын тарихи фәлсәфәләр китерү сәбәбен шуннан эзләргә кирәк.* Г.Нигъмәти

2) Шул дәүләттә яшәгән төрки телле халык һәм аның бер вәкиле. *Менә шушы заманнарда ук безнең бабайлар – болгарлар – Иделнең таулы һәм кыр якларында күп-күп калалар ясап торганнар.* Г.Гобәйдуллин. *Син шул вакытта, бер фәс белән бәргәндә ничә болгар егылачагын «фараз» итәсең, дисәң, мөхәррир әфәнде ни дип җавап бирер иде икән?* Г.Тукай. *Татарларның бабалары болгарлар да этник «чуарлык» ягыннан берничә мәртәбә үзгәргән булырга охшый.* М.Госманов

3) Болгариядә яшәүче көньяк славян халкы. *Әрмәннәр, юнаннар, болгарлар – һәммәсе төрекләр илә бер хокукта улачаклар...* Г.Тукай. *Рус, татары, болгары, Немец, французлары – Ярлы халыкның бары Берләшүдә, бәдәвам.* Г.Камал

**БОЛГАР** II *и.* **1**. Элек болгарлар җитештергән югары сыйфатлы кызыл күн

**2**. *с. мәгъ.* 1) Шул күннән тегелгән. *Болгар читек, сауры башмак, Синдер кызның солтаны.* Н.Исәнбәт

2) Сыер-үгез тиресеннән борынгы болгарлар ысулы белән махсус ясалган олтанлык. *Аягыңдагы читегең болгар икән олтаны.* Җыр

**БОЛГАРИ** *с.* **1**. Болгарга караган, болгарныкы

**2**. *и. мәгъ. к.* **болгар** II

**БОЛГА́Р ТЕОРИЯСЕ** *и.* Болгар милли конгрессы иҗтимагый-сәяси оешма эшчәнлеге белән бәйле булган, болгар халкының һәм аның мәдәниятенең милли дәүләт яңарышын максаты санаган юнәлеш (ул татарларга «болгар» атамасын кайтару, Татарстанны «Болгар иле», «Болгарстан» дип үзгәртү, башкортлар – мөстәкыйль халык түгел, ә «көнчыгыш болгарлар» дигән караштан чыгып, Татарстан һәм Башкортстан территорияләрен бергә кушып, бердәм дәүләт оештыру максатларын күздә тота)

**БОЛГАРЧЫЛЫК** *и.* Болгар теориясенә нигезләнгән караш. *Мәсәлән, аларның 1948 елда басылып чыккан хезмәтләре болгарчылыкны нигезләүдә, болгарларны татарларга каршы куюда абруйлы басмалар булып саналдылар.* М.Әхмәтҗанов

**БОЛГАТКЫЧ** *и.* Аралаштыру, катнаштыру, болгату өчен җайлаштырылган эш коралы, таяк, калак. *Болгаткычлар төрле конструкцияләрдә булалар. Аларга әйләнү хәрәкәте бирелә.* Химия технологиясенең процесслары һәм аппаратлары буенча үрнәкләр һәм мәсьәләләр җыентыгы

◊ **Болгаткыч таяк (таягы)** Кешеләрне бер-берсенә каршы котыртып, талаштырып, ара бозып йөрүче кеше

**БОЛГАТУ** *ф.* 1) Сыеклыкны, чәчелә һәм коела торган әйберләрне бергә кушып аралаштыру, туглау, катнаштыру. *Абый белән без, капчыкларыбыздан бәрәңге чыгарабыз да, аны көлгә күмеп, утны болгата-болгата, бәрәңге пешкәнен саклап ятабыз.* М.Гали. *Ибраһим, киндер бияләйләр киеп, сыекчаны зур агач көрәк белән болгата-болгата, борынын тартып иснәп торды.* Г.Гобәй

2) Тәртибен чуалту, аңлаешсыз итү, бутау. *Эшне үзең болгаттың, үзең очла.* М.Фәйзи. *Тукта инде, болгатма.* Р.Ишморат

3) *күч.* Үзара талаштыру, котырту, тәртипсезлекләр китереп чыгару, гауга барлыкка китерү. *Монысы кем тагы шулай болгата?* Р.Ишморат. *Гафифә апа юкка гына шулай болгатып маташа.* Г.Бәширов. *Әгәр Исмәгыйль чынлап торып эшне болгатса, шул ук төнне Көмешәр авылына качарбыз да никах укытырбыз.* М.Фәйзи

4) *сөйл.* Пешерү. *Боламык кына болгатырсың алайса, карчык.* М.Гали

**Болгата бару** Акрын-акрын, аз-азлап болгату

**Болгата башлау** Болгатырга тотыну. *Моңарчы төп гаепне мәрхүмнәрнең үзләренә аударып утырган җитәкчеләр, теге чәчбинең коткысына бирелеп, авызларындагы ботканы бүтән якка болгата башладылар.* М.Маликова

**Болгата төшү** Тагы да бераз болгату

**Болгатып алу** Тиз генә, бераз болгату. --- *кергән-чыккан һәрбер кеше, бала-чагага хәтле, гөбедәге кымызны, пешкәк белән, бер-ике тапкыр гына булса да болгатып ала.* Ә.Еники. *Куласа, бер-ике канаты белән генә артка ишеп, тигез су өстен болгатып алды да туктады.* Х.Сарьян

**Болгатып бетерү** Тәмам катнашканчы болгату; изелеп беткәнче болгату; бик нык болгату. *Әйдәгез, суны болгатып бетергәнче биешәбез. Аннары балыклар, тончыгып, өскә калка.* Н.Хәсәнов. *Салатка юмарт кеше май сала, саран кеше серкә сала, акыллы кеше тоз сибә, булмаган кеше болгатып бетерә.* Н.Исәнбәт

**Болгатып җибәрү** Болганырга этәргеч бирү, сәбәпче булу. *Рәсүл шул тавышка колак салды, аның тыныч кына аккан тормышын болгатып җибәргән песи баласы: «Гаебем юк минем, кешеләрнең миһербанлылыгына мохтаҗ сабый гына мин!» – дип ялварадыр сыман тоелды.* Ш.Янбаев. *Халыкны аны болгатып кына җибәр, аннан ник болгатканыңа үкенерсең.* Ф.Сафин

**Болгатып җиткерү** Тиешенчә аралашканчы болгату

**Болгатып йөрү** Әле, хәзерге вакытта болгату белән мәшгуль булу; бөтенесен дә болгату. *Бөтен эшне әнә шул Яхья болгатып йөри.* К.Нәҗми. *Бая әйткәнемчә, Батыршалар халыкны болгатып йөрмәсәләр, мин үземнең хуҗалыкны барысына да үрнәк булырлык итеп куяр идем.* К.Нәҗми.

**Болгатып карау** Бик нык болгату. *Дөньяны болгатып та карадың инде.* Р.Вәлиев

**Болгатып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан даими болгату. *Ни әйтсәң дә, ул миңа хәерхаһ түгел. Күптән инде болгатып килә.* Х.Камалов

**Болгатып кую** Бер мәртәбә болгату; алдан болгату. --- *ач балаларына күз сирпеп алган да, ә менә мин үскән авылда елга менә шушылай борылып-*

*борылып, болганып ага иде, дип, ботка∙ны болгатып куйган, ди*. Д.Салихов

**Болгатып ташлау** Кинәт, астын-өскә китереп болгату. *Зәһәр зилзилә куптарып, Болгатып ташлар илне*. Р.Зәйдулла

**Болгатып тору** Бертуктаусыз, гел болгату. *Кайнар су белән кушылган чималны гел болгатып торганда, эмульсия барлыкка килергә дә мөмкин*. Татар балы

**Болгатып яту** *к.* **болгатып тору**. *Бөтен авылны шул Якуб зимагур болгатып ята.* И.Гази

**БОЛГА́У** I *ф.* 1) Берәр нәрсәне һавада селкү, айкау, чайкау. *Кульяулыгын болгый-болгый елап калды, җанкаем.* Г.Тукай. *Ул һаман әле яулыгын болгый.* Г.Әпсәләмов. *Ул, фуражкасын бер артка этәрде, бер алга китерде дә, артларыннан, кул болгап, кире чакырды.* Г.Бәширов. *Чыбылдыгың бизәген Ука белән бизәдең, Бәхилләшеп аерылганда, елый-елый, Ал яулыгың болгап изәдең.* К.Тинчурин. *Яфраклар синең кебек яулык болгап калдылар...* Ш.Галиев

2) *диал. к.* **болгату (***1 мәгъ.***)** *Бәдри самавыр эченә чыбык тыгып болгый.* М.Гафури. *Боламык болгау*

**Болгап алу** Тиз генә, кыска вакытлы болгау. – *Менә мин дә – комсомол, билетым күкрәгемдә, йөрәк турымда йөри! – дип, Кәрим бишмәтенең түш кесәсеннән таныклык чыгарып, һавада болгап алды*. Ф.Сафин

**Болгап ату** Юкка чыгару, бетерү. *Киң кырларга чыгып йөрсәм генә, Якынаям моңга, чын җырга. Чын җырларны болгап атмак була, Ниләр генә булды бу чорга?* Б.Рәхимова

**Болгап җибәрү** Кинәт кенә болгый башлау

**Болгап кую** Бер тапкыр гына болгау

**Болгап тору** Бертуктаусыз болгау. *[Төлке] Көлтәдәй койрыгын болгап тора, елмайган килеш, татлы сүзләрен яудырырга тотына.* А.Алиш. *Иртәкичен, баш өсте, дип, койрык болгап торды, Түбән карап, сыртын ялап, мактау уйлап торды*. Г.Афзал

**Болгап узу** 1) Узышлый болгау

2) *күч.* Санлашмау, игътибар да итмәү. *Вак-вак балыклар, көтүләре беләң, аның аяк очларыннан гына ялт та йолт койрык болгап уздылар*. Н.Хәсәнов

**Болгый башлау** Болгарга тотыну. *Тау башындагылар аның тавышын ишеттеләр, барысы да кул болгый башладылар*. Г.Әпсәләмов

**Болгый бирү** Болгавын дәвам итү

**Болгый төшү** Тагын да көчлерәк болгау

**БОЛГА́У** II *и. диал.* 1) Кайнар суга башаклы салам турап, он яки көрпә болгатып әзерләнгән мал азыгы. *38 баш ат биш улакка бүлеп бәйләнгән, һәммәсе дә, йотлыгып, болгау ашыйлар.* М.Әмир

2) *диал.* Кош-кортка әзерләнгән азык. *Тавыкларыма кычыткан төеп, болгау сибеп керим әле, дип чыккан идем.* А.Хәлим. *Кулына болгау чүлмәге күтәреп һәм ике каш арасындагы кара төрткеле миңе белән бар тирә-якны яктыртып, бер апа килеп чыкты.* А.Хәлим

**БОЛДЫР** *и. диал.* Өйалды баскычы, басмасы. *Әкрен генә атлап, болдыр баскычына күтәрелде, гүя кулындагы кыр сумкасы, аска тартып, авыраеп калган.* Н.Хәсәнов. *Габдулла, сукмак төшмәгәнме әле, дип, оекчан гына болдырга йөгереп чыкты.* Ә.Фәйзи. *Алар, яртылаш җиргә ауган капка аша үтеп, болдырга күтәрелделәр.* А.Хәлим

**БОЛДЫРЫК** *и. зоол.* Болдырыксыманнар отрядыннан далаларда, ярымчүлләрдә һәм чүлләрдә яши торган, күгәрченгә охшаш күчмә кош (көньяк өлкәдә яшәгән төрләре күчмә түгел); дала күгәрчене, чуар күгәрчен; *русчасы:* **рябок**

**БОЛДЫРЫКСЫМАННАР** *и. зоол.* Кечкенә башлы, кыска муенлы, озын очлы канатлы, кыска аяклы, көрәнсу сары, чуар төсле, кайбер төрләренең кара яки көрән тимгелләре булган, күгәрченнәргә охшаш чүл һәм ярымчүл кошлары отряды; *русчасы:* **рябкообразные**

**БОЛЕ́РО** *и. исп.* 1) Испан халкының милли биюе һәм аның музыкасы. *Француз композиторы Морис Равельның «Болеро»сын куйдым мин Аңа! Үземнең иң яраткан көем булганга күрә куйдым инде мин аны, монысы билгеле*. М.Вәли-Барҗылы

**БОЛИ́Д** *и. фр.* < *гр. астр.* Бик зур һәм бик якты метеор. *Башта, зәңгәр күкне урталай телеп, җир өстенә зур утлы таш – болид атыла.* Ф.Бәйрәмова. *Бу яктыру күктә болид атылуга бәйләнгән була*. Ф.Урманче

**БОЛТ** *и. нем.* Бер башы эшләпәле, икенчесе сырлы кадакны хәтерләткән, детальләрне беркетү өчен хезмәт итә торган металл беркетмә. *Туп урнашкан платформаны аркылыга-буйга үлчәдек, болтлар әзерләп, палубаны табаклы тимер белән ямадык та куйдык.* С.Сабиров. *Йорт тәбәнәкләнеп һәм кечерәеп калган, бүселгән бүрәнәләрен болтлар һәм шөрепләр белән тарттырып куйган.* Г.Ахунов

**БОЛТЛА́У** *ф.* Болт борып беркетү, болт белән беркетеп кую; ныгыту

**БОЛЫН** *и.* Үлән белән капланган ачык тигез урын; печән чаба яки көтү йөри торган җир. *Безне котлап, иркен болында Назлы аккош моңы яңгырар.* Ф.Кәрим. *Агыйдел буйларының чакрымнарга сузылган болыннарында печән чаптым.* Р.Ишморат. *Еракта-еракта, яшел болыннарның теге тарафында, сыек кына сөремгә бөркәнгән таулар күренә.* Г.Исхакый. *Кулларымны баш астына куеп, биек зәңгәр күккә карап, болын тугаенда ятам.* Г.Ахунов

**БОЛЫНЛЫК** *и. к.* **болын.** *Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.* Г.Кутуй. *Болынлыкларны үтеп, бераз күтәрелгәч, тагы аю, бүреләр белән тулган кара нарат урманнары башлана.* Г.Гобәйдуллин. *Авылның тагын бер ягында – әрәмәле болынлык, сазлык.* Г.Толымбай. *Аның аргы тарафында яшел хәтфә сыман болынлык сузылып киткән.* Р.Мөхәммәдиев

**БОЛЫНЧЫ** *и.* Болында печән чабучы. *Кәҗә, салам кисәкләре ябышкан сакалын селкә-селкә, ялкау гына, урамга – болынчылардан коелып калган печән кыякларын чүпләргә чыгып китте.* И.Гази

**БОЛЫТ** I *и.* 1) Атмосфераның һавага күтәрелгән су парлары куерып

тыгызлануыннан хасил булган түбәнге катламы. *Җил кайдан исә, болыт та шуннан килә.* Мәкаль. *Күкне томалаган авыр болыт, җирне дә, суны да йотарга теләгән кебек, түбәннән-түбәнгә төшә бара иде.* Г.Исхакый. *Кара болыт белән давыл килгән вакытларда, камышлык арасыннан ыңгырашкан тавышлар ишетелә, ди.* М.Мәһдиев. *Яңгыр инде, болыты белән төшеп, бурый-бурый ява иде.* М.Галиев

2) Нинди дә булса массаның, очып, тузып, җирдән күтәрелгән катламы (тузан, төтен). *Малайлар урамның нәкъ уртасыннан, артларыннан тузан болыты тузгытып, җан-фәрманга аэродромга йөгерделәр.* Р.Хафизова

3) *күч.* Бәхетсезлекләр, борчу, кайгы-хәсрәт, зур күңелсезлекләр, хәвеф-хәтәр, кайгы. *Ярты сәгать моннан әүвәл, җанымны кара болытлар каплап торалар иде.* Ф.Әмирхан. *Көнбатыштан ябырылган кара болытка күкрәген калкан итеп куеп, илен-җирен һәм сөекле нарасыйларын фашист баскыннарыннан саклый алмый.* Р.Кәрами. *Уйлама син, вакыт үтәр, дип, Кара төндә кара болыт булып Җирне баскан зөлмәт китәр, дип.* Ш.Бабич. *Шул көннән башлап, аның тормыш күгендәге кара болытлар куерганнан-куера бардылар.* А.Шамов

**БОЛЫТ** II *и.* 1) Күп күзәнәклеләр семьялыгыннан, түбән төзелешле, хәрәкәтсез, диңгездә яшәүче тереклек иясе; *русчасы:* **губка**. *Диңгезләр төбеннән болыт (губка) --- чыгарыла.* Физик география

2) Шул хайванның мунчала итеп файдаланыла торган үле гәүдәсе

3) Шуңа охшатып, резинадан яки синтетик материалдан эшләнгән, суны үзенә җыя торган материал. *Тавышйоткычның колакка кия торган чашкалары тавышны йотучы материаллардан (--- болыт сыман резинадан) ясала.* Кеше анатомиясе

4) Тере организмның сөяк өстендәге көпшәк тукымасы. *Сөяк өслегеннән соң тыгыз матдә ята, ә аның астында болыт сыман (губка сыман) матдә була.* Кеше анатомиясе

**БОЛЫТЛАНУ** *ф.* 1) *сөйл. к.* **болытлау**

2) *күч.* Томанлану, караңгылану

**Болытлана бару** Торган саен ныграк болытлану. *Һава һаман болытлана бара.* А.Таһиров

**Болытлана төшү** Тагы да болытлану

**Болытланып бетү** Тәмам, тоташ болытлану

**Болытланып килү** Акрын-акрын болытлану

**Болытланып китү** Кинәттән, көтмәгәндә болытлану

**Болытланып кую** Болытланган хәлгә килү

**Болытланып тору** 1) Әле, хәзерге вакытта тоташ болытлану

2) Бераз болытланган булу

**БОЛЫТЛА́У** *ф.* 1) Күк йөзен болыт каплау, болытлар барлыкка килү, болытлы булу. *Көн җиләсләнеп, болытлап, бозылырга торган төсле.* М.Гали

2) *күч.* Борчылу, йөз караңгылану. *Кәеф кырылса да – бәгырь әле тыныч, Күңел генә әзрәк болытлый.* Сөләйман

**Болытлап алу** Вакытның бер арасында, кыска вакытка болытлау

**Болытлап бетү** Күк йөзе тоташ болытлау

**Болытлап җибәрү** Кинәт болытлый башлау. *Әле генә кояш, җылы иде. Кинәт салкынайтып, болытлап җибәрде, кот китте.* Ш.Галиев

**Болытлап килү** Акрынлап, күк йөзе болытлар белән томалана бару

**Болытлап кую** Кинәт болытлау

**Болытлап тору** Әле, хәзер, бераз болытлаган булу. *Күк йөзе болытлап тора, урман ягыннан дымлы җылы җил исә иде.* М.Мәһдиев. *– Күңел борчыламыни? – дип сорады Гали абый. – Әзрәк болытлап тора шул.* Г.Әпсәләмов

**БОЛЫТЛЫ** *с.* 1) Болыт белән капланган, болыт барлыкка килгән. *Идел бит ул, Тирән бит ул, киң бит ул, Караңгы төн, болытлы көн – Без аерылышкан көн бит ул.* Җыр. *Иртәнчәк һава салкын һәм болытлы иде.* Ш.Камал. *Бүген Казанда һәм Татарстанда – алмашынучан болытлы һава.* Шәһри Казан

2) *күч.* Күңелсез, кәефсез, ачулы. *Көнгә унбиш тапкыр кояшлы син, Көнгә унбиш тапкыр болытлы.* Казан утлары

**БОЛЬНИ́ЦА** *и. рус сөйл.* Авыруларны савыкканга кадәр үзендә тотып дәвалый торган учреждение; хастаханә. *Мәрданша бабайны, аның ай-ваена карамыйча, шалаштан туп-туры больницага илтеп салдылар.* Г.Гобәй. *Мондый хәлдән, мондый җәфалы ялгызлыктан котылу юлларын эзли торгач, Әминә шәһәр больницасына, медицина сестрасы булып, кичке сменага эшкә керде.* Г.Минский. *Ул хәзер больницада, имеш, доктор караганда, хәле начар, үләр, дип әйткән, имеш.* Г.Ибраһимов

**БОЛЬНИ́ЦАЧА** *рәв. сир.* Больницага охшатып, больницадагы кебек ак итеп. *Муса, комиссарны эзләп, шул таш йортка килеп керүгә, балчык идәндә больницача ак итеп җыештырылган берничә тар тимер карават күрде.* Ш.Маннур

**БОЛЬШЕВИЗМ** *и. рус* XX гасыр башында Ленин җитәкчелегендә Россиядә барлыкка килгән, марксистик теориягә нигезләнгән революцион хәрәкәт. *Сталинмы – совет режимын куралмаган, большевизмнан нәфрәтләнгән беренчеләрдән берсе булды ул изге грузин...* А.Гыйләҗев. *Союзниклар большевизмны телиләр буарга, ләкин үзләренә туры килә эчләрен уарга.* Г.Камал. *Мәскәү кебек, Петроград кебек, пролетариат күп булган урыннарда алар, ничек кирәк алай эләгеп торалар, әмма провинциядә халык инде большевизм чиреннән сәламәтләнеп килә.* И.Гази. *«Большевизм коткысы»на каршы көрәшү исә, хәзергә хәтле булган шикелле, моннан соң да, үзе үк большевизмны көчәйтүгә булышлык итәчәк.* Ш.Камал

**БОЛЬШЕВИК** *и. рус* Большевиклар партиясе әгъзасы, большевизм тарафдары. *Кайберәүләр аны, Казан ханлыгы җимерелү чоры хаины – сатлыкҗан Шаһгали белән чагыштырып, татар халкын большевикларга сатуда гаепләсәләр, икенчеләре аны милләтне инкыйраздан коткарып калырга омтылган каһарман дәрәҗәсенә күтәрәләр.*

Т.Галиуллин. *Оренбург ак бандалардан яңа әрчелеп, җимереклеккә каршы көрәш башлап торганда, ул, Оренбург большевиклары һәм пролетарлары белән берлектә, җаваплы постларда торып эшләде.* М.Җәлил. *Йөрәгенең бөтен ялкынын, бөтен сәләтен революция юлына биргән Дзержинский кебек батыр йөрәкле революционерлар, я булмаса, үзебезнең Сәръян абыйлардай нык большевиклар искә төшә.* Г.Бәширов

**БОЛЬШЕВИКЛА́РЧА** *рәв.* Большевикларга хас, большевиклар кебек. *Большевикларча хисле, яңа кешеләр Туып килә безнең бу кырда.* М.Җәлил

**БОЛЬШЕВИКЛАШТЫРУ** *ф.* Большевикларча караш тәрбияләү, большевик итү

**Большевиклаштыра бару** Эзлекле рәвештә, акрынлап большевиклаштыру

**Большевиклаштыра килү** Элек-электән, эзлекле рәвештә большевиклаштыру

**Большевиклаштыра тору** Даими, һәрвакыт большевиклаштыру

**Большевиклаштыра төшү** Тагын да большевиклаштыру

**Большевиклаштырып бетерү** Барысын да большевиклаштыру; тәмам большевиклаштыру

**БОЛЬШЕВИКЛАШУ** *ф.* Большевик булу, большевиклар ягына күчү, большевизм тарафдары булып китү. *Ләкин фронттан кайтучы казачийларның бик күбесе большевиклашып кайталар.* Ш.Камал. *Советларның бик тиз большевиклашу процессы башланды.* КПСС тарихы

**Большевиклаша бару** Торган саен ныграк большевиклашу

**Большевиклашып бетү** Тулысынча, тәмам большевиклашу

**Большевиклашып китү** Ниндидер моменттан соң большевикка әйләнү

**БОЛЬШЕВИКЛЫК** *и.* Большевик булу. *Монда большевиклык – коммунистлык мәсьәләсе теге бәләкәй Латвия һәм Литва почмакларыннан иркенрәк тора.* Г.Гобәй. *Булатовның большевиклык эше күренми, ни өчендер, сөргенгә җибәрелә, кайтып, яңадан шул ук эсерлар арасында чуала...* Г.Нигъмәти

**БОЛЬШЕВИКЧЫЛ** *с.* Большевикларга хас булган, большевизм карашларына туры килгән, большевизмга караган. *Без бу язда сиздек колхозчыда Большевикчыл хиснең кабынуын.* М.Җәлил

**БОЛЬШЕВИСТИК** *с. к.* **большевикчыл.** *Без, йөз еллар буенча сыйныфлардан сыйныфларга күчеп килгән бөтен кешелек культурасын өйрәнеп, аны большевистик тәнкыйть аша үзләштереп, шул нигездә яңа социалистик культураны тудырабыз.* М.Җәлил. *Ләкин шәһәрдәге большевистик комитетта бердәмлек юк иде, ул кулга алулар аркасында көчсезләнгән иде.* КПСС тарихы

**БО́МБА** *и. фр.* Эченә шартлаучан матдәләр тутырылган корыч тышлы снаряд. *Женяның әтисе, сугыш башланганнан бирле, бөтенләй диярлек кайтмыйча эшли, фашистлар өстенә яудыру өчен бомбалар ясый икән.* Г.Гобәй. *Каядыр бомбалар шартлый, йортлар, шәһәрләр яна.* Р.Хафизова. *Шунда бомбаларның берсе шартлый, аңа пар казаннары шартлавы өстәлә.* Кызыклар дөньясында

**БО́МБАГА ТОТУ** *ф. к.* **бомбалау.** *Немецлар бомбага тотканнан соң да, туфрак астыннан чыгып, өстендәге балчыкларын сыпырып ташлау белән, ул [Шакиров] кесәсенә тыгыла һәм үзенең сөекләләре төшкән рәсемне алып карап куя торган иде.* А.Әхмәт. *Балаларны, калаларны Утлы бомбага тота.* Ә.Ерикәй

**БОМБАЛА́У** *ф.* Һавадан һөҗүм итеп, самолёттан бомбалар ташлау. *Бомбалау объектына чаклы һәм аннан алып үзебезнең аэродромга чаклы – барысы ничә километр юл калган?* С.Баттал

**БОМБАРДИР** *и. нем. < фр. иск.* Иске заманда артиллериядә хезмәт итүче артиллерист солдат. *Кара диңгез флотында бомбардир булып хезмәт иткән икән.* И.Гази. *Патшабикәне куандыру өчен, бомбардирлар ул туплардан атып җибәрү җаен да табалар.* Кызыклар дөньясында

**БОМБАРДИРО́ВЩИК** *и. рус* 1) Бомбага тота торган хәрби самолёт. *Баш очыбызда бомбардировщиклар очуын да, туплар шартлавын да ишеткәнебез юк.* Р.Хафизова. *Ул арада Иделнең югары ягыннан, якын-тирәне шаулатып, бомбардировщиклар төркеме килеп чыкты.* Г.Бәширов. *Нәкъ шул чакта өстән, котырган эт шикелле усал үкереп, немец бомбардировщиклары узып китте.* Г.Гобәй

2) Бомбардировщиклар авиациясендә хезмәт итүче очучы. *Ул да очучы, тик истребитель түгел, бомбардировщик.* С.Баттал

**БОМБОВОЗ** *и. рус к.* **бомбардировщик.** *Бомбовозның пилоты, йөрәгенә пуля тиеп, кулыннан рульне ычкындырды.* Ш.Усманов. *Самолёт – Баймурзин әйткәнчә, элек бомбовоз булган, ә хәзер, сугышка яраксыз булып, искергән маркалы транспорт йомышын үтәүче машина.* С.Баттал

**БОМБОУБЕ́ЖИЩЕ** *и. рус* Бомбадан саклану өчен махсус эшләнгән корылма. *Аның кычкырганын госпитальдәге яки бомбоубежищедагы кешеләр түгел, түбәдә поста торган ПВХО солдатлары да, капка төбендәге часовой да ишетмәде.* Г.Гобәй. *– Ә син, исерекбаш, бар, тизрәк бомбоубежищега төшеп ят, – диде ул, көлә-көлә һәм сырган чалбар кесәсеннән зур ачкыч алды.* Г.Гобәй

**БОМБРАМСЕЛЬ** *и. гол.* Мачтада астан дүртенче рәттә торган туры парус. *Шторм вакытында, ванттан йөгереп менеп, бомбрамсель биеклегендә риф алу өчен, ай-һай, нинди акробат осталыгы кирәк!* М.Юныс

**БОМЖ** *и. рус* Төгәл яшәү урыны булмаган кеше. *Хәтта Минзәләнең бетле күзле бичлары һәм бомжлары да Чаллы, Түбән Кама мәрларының түрендә, күкрәк киереп, коньяк, ром, виски чөмерә...* Ф.Баттал. *Барыбер эчеп кенә бетерәләр, дип, акчаны урамда бомж булып йөрүче абыйсына да, гомер иткән иренә дә бирмәгән.* Татарстан яшьләре

**БО́НА** *и. фр.* Вакытлыча чыгарылган һәртөрле кәгазь акчалар атамасы

**БОНИ́СТИКА** *и. фр.* Тарихның кәгазь акчаларны тарихи документ буларак өйрәнә торган ярдәмче бүлеге

**БО́НУС** *и. лат.* 1) Премия, бүләк

2) Өстәмә ташлама; сатып алганнан соң, килешү шартларына нигезләнеп, сатучы биргән өстәмә файда

**БОР** I *и. лат. хим.* Минераллар катнашмасында була торган химик элемент. *Туфракта бор җитешмәсә, үсемлекләрнең үсү нокталары корый...* Химия

**БОР** II *и. нем.* Теш дәвалаганда кулланыла торган корыч борау, кыргыч

**БОРАДӘР** *и. фар. иск.* 1) Ир туган. *Борадәрләр шул рәвешчә үстеләр, гәрчә боларның табигатьләре вә теләкләре бөтенләй башка булса да, бу ике карендәш үз араларында бик дус вә берсе-берсенә тәмам багланган иделәр.* Г.Тукай. *Казан җире – минем йортым, Сафа Гәрәй хан – минем борадәрем.* Г.Гобәйдуллин. *Бәс имди Даһханә сонда калсын, Сәлимә ханым, Басрадан Багдадка сыйххәт вә гафият кайтып җиткәч, борадәре Габдулла хәлифәнең янына кергәч, сәламнан соң әйтте ---.* Мең дә бер сәхәр

2) Эндәшү сүзе; туганкай. *Борадәр, сезгә үтенәм, сәлам йазып, Күзең сал – Мәрҗани ул Тимерказык.* Акмулла

3) Дус, иптәш. *Имеш, Владимир, үз тирәләрендә таларга нәрсә беткәч, безнең шәһәрләребезне барып таларга кирәк дип, үзенең борадәре белән киңәш кылган.* Г.Гобәйдуллин

**БОРАЙ** *и.* 1) Бодайның бер төре булган бөртекле ашлык атамасы. *Яңа килгән колхоз председателенең борай белән бодайны аеруы чамалы, диләр диюен...* К.Тинчурин. *Селкенеп, дулкынланып тора матур ашлыклары, Ямь-яшел хәтфә кеби арыш, борай, солы, тары.* М.Гафури. *Басу-кырлардагы серкәләнеп утырган арышны, ипле генә калкынып-тернәкләнеп килгән бодай белән борайны, солы белән тарыны күреп сөенәләр картлар.* К.Миңлебаев

2) Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге яки оны. *Базарда арышы, бодае, тарысы, арпасы, дисеңме, ногыт яисә борай, дисеңме – барсы да бар.* Ф.Латыйфи. *Ул [ярма яргыч] ике бүлемнән гыйбарәт булып, бер бүлегендә – солы, борай, карабодай ярмалары, икенче бүлегендә тары ярыла икән.* М.Гали. *Мин авылга кайтып төшкәндә, солы, борайны чәчеп бетереп, тары, карабодайга яңа чыкканнар гына иде әле.* Г.Ибраһимов. *Бер авылда аларга колхоз борай ярмасы биргән. Сара апа шул борайдан ботка пешергән.* Х.Бигичев

**БОРА́У** *и.* 1) Агачка, тимергә һ.б.ш.га түгәрәк тишек тишә торган эш коралы. *Стенада әллә ничә төрле пычкы, өтерге, стамеска һәм эреле-ваклы бораулар тезелеп киткән.* Г.Бәширов. *Үткен очлы таш кисәкләрен тишкеч, өтерге, борау итеп кулланганнар.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) Скважина бораулау машинасы. *Җиргә борауны батырганчы, буровойның үзен төзи-төзи дә өч-дүрт ай чиләнергә туры килә безнең якташларга.* Ә.Маликов

**БОРАУЛА́У** *ф.* 1) Борау белән тишек ясау. *Без бораулап тапкан нефть.* Г.Рәхим. *Бораулыйм Җир шарын – Корыч, бакыр чыгарам.* Х.Кәрим. *Җирне әнә шул корыч долото бораулый инде.* А.Әхмәт. *Таштан эш кораллары ясаганда, алар юну, кисү, бораулап тишү кебек яңа алымнар куллана башлаганнар.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) Тау токымнарында, грунтта тирән тишекләр, скважиналар тишү. *Яңа бригада, үзе бораулаган беренче нефть скважинасын ташлап китәргә теләмичә, буровой янында бик озак шаулашты.* Г.Ахунов. *Аны чыгару өчен, скважиналар бораулыйлар.* Химия

3) *күч.* Тынычсызлау, борчу, әрнетү, тырнап тору. *Кыңгырау тавышы миләрне бораулап керә.* М.Галиев. *Шул сорау аларның миләрен бораулый иде.* Х.Кәрим

4) *күч.* Зур игътибар белән, текәлеп, бик нык сынап карау. *Урамында да кеше күзенә күренерлек түгел иде: һәммәсе яндырып, бораулап карый сыман.* Э.Касыймов. *Артыннан ничәмә ничә күз, нинди мыскыл белән карый торган күзләр бит әле, аның аркасын бораулап тишкәләгән сыман тоелды.* Ә.Фәйзи

**Бораулап алу** Аз вакыт арасында, тиз арада бораулау. *«Игезәкләр түгелме соң болар?» дигән уй Алып Бәргән зиһенен бораулап алды.* Р.Батулла

**Бораулап бару** Торган саен ныграк бораулау. *Юлда Җамалиның исерек миен бернәрсә һаман бораулап барды.* Г.Ибраһимов. *Аның ачынып әйткән сүзләре менә хәзер дә зиһенемне бораулап бара.* Р.Батулла

**Бораулап бетерү** 1) Бораулау эшен төгәлләү

2) Тәмам, бик нык бораулау

**Бораулап йөрү** Бертуктаусыз бораулау. *Аннан соң... аннан соң әле аның күңелен кытыклап, миен бораулап йөргән башка планнары да бар...* Җ.Дәрзаман

**Бораулап килү** Күптәннән, электән үк даими бораулау

**Бораулап тору** 1) Әле, хәзер, күз алдында бораулау

2) Бертуктаусыз, һаман бораулау. *Хат, гомере буенча, Халисәнең миен бораулап торды.* Т.Галиуллин

**Бораулап узу** Әле, хәзер, кинәт бораулау. *«Мич башыннан төшәсем калмаган икән лә!» дигән үкенечле уй шул мизгел эчендә миен бораулап узды.* З.Хөснетдинов

**Бораулый башлау** Бораулауларга тотыну. *Юк, иртәгәдән үк скважина салырга, җирне бораулый башларга кирәк.* А.Әхмәт. *[Сәхипҗамал:] Шул яңа мотор белән без хәзер көненә 6–7 метр бораулый башладык.* А.Әхмәт

**Бораулый килү** Күптәннән бирле, даими бораулау. *Фәгыйлә апайның авыр тормыш юлы, Г.Тукай турындагы хатирәләре минем башымнан чыкмады, һаман хәтердә сакланып, миемне өзлексез «бораулый» килде.* С.Сабиров

**Бораулый төшү** Тагы да бераз бораулау

**БОРАУЛАУЧЫ** *и.* Скважиналар бораулау белән шөгыльләнүче эшче. *Арслан шушы атнада бораулаучылар мәктәбенә – Уфага китәргә җыена.* Г.Ахунов. *Күршеләргә кунаклар килеп төште: бораулаучы Габделнур абый, аның хатыны Фирдәвес апа һәм аларның дүрт яшьлек уллары Ризван.* Э.Касыймов. *Бораулаучылар кәрваны чыгып киткәч, паром җиңеләеп, сикереп куйды.* К.Кәримов

**БОРГАЛАНА́-БОРГАЛАНА** *рәв.* Уйнаклап, төрле юнәлештә хәрәкәтләр

ясап. *[Чишмәдән аккан] Көмеш сулар, инешкә кушылганчы ялтырап калырга ашыккандай, чуер ташлар өстеннән сикерә-сикерә, боргалана-боргалана актылар...* Н.Хәсәнов

**БОРГАЛАНА́-СЫРГАЛАНА** *рәв.* 1) Борма-борма булып сузылып, төрле юнәлештә бормалар ясап; уралып, бормаланып-бормаланып. *Юлның уң ягында, яшел сыртын калкытып, озын тау сузылып ята; аңа сыенып, боргалана-сыргалана, тар гына су ага ---.* И.Гази. *Ә җәяүле буран басылган, күзне бумый, Юл да, ялтырап, боргаланып киткән бик ерак – Мин кайтасы якка ашыга.* Р.Харис

2) Гәүдәне төрле якка боргалап, бөтен гәүдә белән сыгылмалы хәрәкәт ясап. *Кызлар, саплы көзгеләр тотып, боргалана-сыргалана бии башлыйлар.* Н.Исәнбәт. *Тәңкә өрүеннән туктады һәм, боргалана-сыргалана, Мәдинә янына килде.* Ш.Камал

**БОРГАЛАНУ** *ф.* 1) Төрле якка борылу, юнәлешен үзгәртә-үзгәртә хәрәкәт итү. *Суалчан – оялчан, боргаланды да сыргаланды.* А.Алиш. *Ул боргаланган ямьле сукмак буйлары.* Н.Исәнбәт. *Ул ераккка – тәртипсез сибелгән шикелле берсе өстенә берсе өелгән йортларга, алар арасыннан, тар ачыклыклар булып, боргаланып, чәбәләнеп сузылган урамнарга карый.* А.Шамов. *Ул, башын түбән иеп, тузган чабаталары белән тузан күтәрә-күтәрә, олы юл буйлап атлый, артыннан, елан кебек боргаланып, озын чыбыркысы сөйрәлә.* Г.Әпсәләмов

2) Сыгылмалы хәрәкәтләр ясап атлау. *Әнә оялганлыгын юри белдерергә тырышкан төсле кыланып, боргалана-боргалана, алсу-ак кофталы бер кыз килә.* М.Әмир

3) Назлану, иркәләнү, кылану

4) *күч.* Фикерне төгәл итеп әйтмәү, хәйлә белән, туры җаваптан качу. *Бу карт төлке, дим, юкка боргаланмыйдыр.* Г.Ибраһимов. *Сөясеңме, сөймисеңме? Боргаланмый әйтсәнә.* М.Фәйзи. *Боргалану гадәтем юк, Булмагач, нишләтәсең.* З.Мансур

**Боргалана бару** Тагын да ныграк боргалану

**Боргалана башлау** Боргаланырга тотыну. *Алып Бәргән куркыныч зат Гыйфритне күзләре белән эзли, боргалана башлады.* Р.Батулла

**Боргалана төшү** Бераз боргалану

**Боргаланып алу** Кыска вакыт эчендә боргаланган хәрәкәт ясау. *Кәбир утырган урынында боргаланып алды да, кашларын җимереп, кулын селтәде.* Г.Бәширов

**Боргаланып бетү** Бик күп борылмалар ясау. *Үзе җилкәсе аркылы боргаланып-боргаланып беткән бер быргы таккан, ди.* А.Алиш

**Боргаланып йөрү** Бертуктаусыз, һәр җирдә боргалану. *Боргаланып йөргән булып, Кызлар үзен сөйдерә.* Т.Миңнуллин

**Боргаланып кую** Бер тапкыр боргаланган хәрәкәт ясау. *Яһүдә урындыгында боргаланып куйды: – Начар кеше димләмибез без сиңа, менә дигән хатын.* Д.Бүләков

**Боргаланып тору** Бертуктаусыз боргалану. *Иркә малай, үзенең ятлап алган җавабын берьюлы гына әйтми, боргаланып тора яки, кыланып, берәр тозсыз җавап кайтара иде.* Ә.Фәйзи

**Боргаланып утыру** *к.* **боргаланып тору**. *Доганың буеннан-буена, Том урынында боргаланып утырды.* М.Твен

**Боргаланып чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында боргалану, шул вакытның башыннан ахырына кадәр боргалану. *Төне буе урын өстендә боргаланып чыкты Сөмбелә.* К.Кәримов

**Боргаланып яту** Бертуктаусыз боргалану. *Шунысы яхшы: бүтәннәр кебек боргаланып ятмыйм.* Ә.Хәбибуллин

**БОРГАЛАНЫ́П-СЫРГАЛАНЫП** *рәв.* 1) Бормалар ясап; урала-урала, бормаланып-бормаланып. *Боргаланып-сыргаланып, сикереп-сикереп, су ага.* Ә.Ерикәй

2) *күч.* Гәүдәне боргалап, гәүдә белән сыгылмалы хәрәкәт ясап. *Тәлгәштәлгәш булып утырган чикләвекләр күрсәм дә, боргаланып-сыргаланып шуышучы еланга охшаган агач тамыры очратсам да, су буеннан матур ташлар тапсам да, сөенә-сөенә, таныш урынга алып киләм.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Ялагайланып, ярарга тырышып. *Иделгә балыкка баргач, үзең дә күреп тордың. Әхмәтең Марс Галиханович каршында боргаланып-сыргаланып кына йөрде. Билләһи, бу кадәр тормыш артисты булып яралыр икән! Өтәләнә генә.* Н.Хәсәнов

4) *күч.* Кыланып, уйнап, шаяртып. *Мин, Дилбәр туташ, боргаланып-сыргаланып, ике сөйләргә яратмыйм.* К.Тинчурин // Назланып, иркәләнеп. *Алайса, нигә боргаланып-сыргаланып торырга? Тотыгыз да җырлагыз!* А.Гыйләҗев

**БОРГАЛА́П-СЫРГАЛАП** *рәв.* 1) Төрлечә сырлап, чуарлап, борылмалы сызыклар ясап. *Кара ничек итеп боргалап-сыргалап язган!* Р.Ишморат

2) *күч.* Читләтеп, киная белән. *Боргалап-сыргалап тормыйча, авылча итеп туп-туры гына әйт тә, вәссәлам.* А.Әхмәт. *Боргалап-сыргалап сөйли белмим.* Т.Гыйззәт

**БОРГАЛА́У** *ф.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса төрле якка бору, кабат-кабат бору, төрлечә хәрәкәтләндерү. *[Сөләй] Салынкы иңбашын тагы да салындыра төшеп, станок тоткычларын боргалый.* Н.Хәсәнов. *Ләкин төш вакытларында һава үзгәреп, җил көчәеп китте, көймәне һәм җилкәнне төрле тарафка боргалый, уйната башлады.* К.Бикколов

2) Киная белән читләтеп сөйләү; дөресен әйтмәү, алдау. *Юкны боргалап маташкан буласың.* Ш.Камал. *Ә Әхмәй шаян, күзләре әле – миңа, әле – секретарьга, әле Лирага сикерәләр. Үзе көлә, туры гына җавап бирми, боргалый.* М.Әмир

**2. боргалап** *рәв. мәгъ.* Борылмалы сызыклар ясап, бормалы итеп, бормалап. *Имза «М» хәрефе, тагын «А»га башланган ниндидер фамилиядән гыйбарәт булып, танырлык түгел, бик боргалап язылган иде.* Г.Гобәй

**Боргалап алу** Кыска вакыт эчендә боргалау. *Башын як-ягына боргалап алды, бераз янга авыштырып кигән, шактый искергән күн фуражкасында кичке якка авышкан тонык кояш нурлары ялтырап китте.* Н.Хәсәнов

**Боргалап бетерү** Гадәттән тыш күп бормалар ясау. *Барча гайрәтен уң ку-*

*лына туплады, кул буыннарын шарт-шорт боргалап бетерде.* Х.Камалов

**Боргалап җибәрү** Бераз бормалар да ясау

**Боргалап кую** Бераз боргалап алу

**Боргалап тору** Әле, күз алдында боргалау. *Ата каз сыман, муенын як-якка боргалап торгач, бүреген күтәреб-рәк куйды, тәмәке кабызды.* Р.Вәлиев

**Боргалый башлау** Боргаларга тотыну. *Митричев, атып егачак иң беренче корбанын эзләгәндәй, зәһәрләнеп ялтыраган күзләрен кыскан килеш, тешләрен шыкырдатып, пулемётның көпшәсен уңнан сулга, аннары сулдан уңга боргалый башлады.* Г.Бәширов

**БОРГЫ** *и. к.* **быргы**. *Җиңү дәрте белән Кычкырттылар көрәш боргысын.* М.Җәлил

**БОРГЫЧ** *и.* 1) Борып, ныгытып куя торган эш коралы, җайланма. *Газинур ишек төбендәге Сабир бабайга: «Боргычны алырга онытма!» – дип кычкырды да әтисе белән энесе артыннан йөгерде.* Г.Әпсәләмов

2) Бора торган механизм (мәс., пружиналы сәгатьтә)

3) Скрипка кылын борып тарттыра торган җайланма

4) Капка яки ишек яңагына кагылган кадак тирәсендә әйләнә торган тубырчыктан гыйбарәт бик; бака

5) *күч.* Буйсындыручы, ирексезләп мәҗбүр итүче. *Кузгатмаулары хәерле, Черек кулдә боргычларның осталары утыра: «ә» дигәнне «җә» дип язып куярлар да, кәкре-бөкре имза салганыңны сизми дә калырсың!* А.Гыйләҗев

**БОРГЫЧЛА́У** *ф.* 1) Боргыч белән борып ныгыту. *Ул безнең комсомол секретаре иде, значокның шәбе икән анда: астан боргычлап беркетеп куя торганы.* М.Маликова

2) Ычкынмаслык итеп урап, каты итеп тарттырып яки чорнап кую. *Ул --- корзина үрергә дип кискән тал чыбыкларын бәйләмгә бәйләп маташканда, берәү аның сукыр як кырыеннан сиздермичә генә килеп, --- сап-салкын сүс бауны кинәт аның муенына салып, зур көч белән боргычлап кысып алды.* Ш.Камал. *Салкын бураннарда тукталып торган мәктәп ачылды, киез итекләренә тимерраякларын боргычлап бәйләгән малайлар авылның аргы башыннан да, бирге башыннан да дәрескә чабыша башладылар.* Р.Мирхәйдәров

3) Бармаклар белән эләктереп бору, чеметү. *Мин булсам, тәннәрен боргычлап-боргычлап чеметеп алыр идем (кулы белән боргычлап күрсәтә).* Г.Камал

4) *күч.* Үз ихтыярына, хөкеменә алу, буйсындыру. *Берсен тот та, боргычлап, үзеңнеке ит.* Г.Сәгыйров. *Кулын боргычлап, иманын үтүкләсеннәр ул бандитның!* Н.Гыйматдинова

5) *күч.* Зур таләпләр кую, үзеклеккә юл куймау. *Дисциплинаны яман боргычладылар, өйрәнүләр кызганнан-кыза, көне-төне – киңәшмә, утырыш...* И.Гази. *Чикерткәне шулай боргычлап өйрәткәннән соң, хәлфә, чатырдан чыгып, кәрван ягын күзәтергә тотына.* Ә.Еники

6) *күч.* Каты итеп ачулану, сүгү. *Карап-карап тордык та без Алдык үзен боргычлап, Син күр, мин күр, шуннан бирле Тора әле тынычлап.* Ш.Галиев

7) *күч.* Борчып, тынычсызлап тору; авырттыру. *Чигәсен боргычлап, уй артыннан уй туды.* Г.Минский

◊ **Боргычлап тоту** Кул астындагы яки гаиләсендәге кешене нык буйсындыру

**Боргычлап алу** 1) Нык итеп боргычлау. *Алар әүвәл минем озын чәчемне боргычлап алып, аннары култык асларыннан эләктереп, ярга чыгарып сузып салдылар, йоткан суларымны бушаттырып, аннан-моннан каккалап, җан өрделәр...* Р.Әмирхан

2) Кыска вакыт эчендә, бераз боргычлау. *Аны күрсәткәнгә үземне-үзем боргычлап алдым.* Ә.Хәбибуллин

3) *күч.* Бик нык буйсындыру, кемне дә булса үзенең ихтыярында, хөкемендә тоту. *Ә менә безнең байларның хатыннары бөтенләй моның киресенчә: ирләренең муеннарына тәмам менеп атланганнар да, ирләрен авызлыклап, боргычлап алганнар.* Г.Камал

**Боргычлап җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә, кузгалмаслык итеп боргычлау

**Боргычлап китү** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң боргычларга тотыну. *Инсафлар звенолардан юл салып, боргычлап китсәләр дә, «соңгы сүзне» барыбер кызлар «әйтә».* Ф.Абдуллин

**Боргычлап кую** Боргычланган хәлгә китереп калдыру. *[Бүрәнәләрне] Ишелмәсен өчен, чәнти бармак юанлыгы шып белән урап боргычлап куялар.* К.Кәримов

**Боргычлап ташлау** Кинәт кенә, тиз арада нык итеп боргычлау. *Әйе! Заманында артыграк боргычлап ташлаган идем шул.* М.Хәсәнов

**Боргычлап тору** Гел, һәрвакыт боргычлау. *Мужик халкы гел боргычлап торуны гына белә.* Г.Бәширов. *Күп очракта бер бичара ирне Гел боргычлап торса хатыны. Монда башка тормыш хөкем сөрә: Һәр кетәктә – әтәч законы.* Ч.Мусин

**Боргычлап чыгу** Һәрберсен берәм-берәм, башыннан ахырына кадәр боргычлау

**Боргычлый бирү** Боргычлауны дәвам итү

**Боргычлый төшү** Тагы да бераз боргычлау

**БОРГЫЧЛЫ́ БОРАУ** *и.* Кул белән әйләндереп тишек тишә торган эш коралы. *Шулай ук очы кайралган кечкенә без һәм, детальләрне тишү өчен, нәзек боргычлы борау (коловорот) кирәк.* Йорт эшләре

**БОРГЫ́Ч ТАЯГЫ** *и.* Туку станында тукыманы чорнап барган агачны беркетеп куя торган деталь

**БОРДЮР** *и. фр.* 1) Тукыма һәм обой кырыйларындагы бизәкле юл; кайма

2) Түшәм һәм стена кырыйлары буйлап төшерелгән бизәк

3) Транспорт йөри торган юлны җәяүлеләр йөри торган юлдан аерып куйган тар полоса. *Юл читләрендә бер исән бордюр юк. Ел саен юлларга ямау өстенә ямау салынган.* З.Дәүләтов. *Машина, алагаем тизлек белән гөрселдәп, алгы тәгәрмәче белән бордюр ташына килеп бәрелде.* М.Галиев

**БОРЖОМ** *и. груз. сөйл.* Составында минераль матдәләр булган һәм дәвалану максатында куллана торган шифалы су (Грузиядәге шул су чыганагы булган курорт исеменнән). *Хәлләр бик үк начар түгел, әни, боржом суы*

*эчәм. Бик файдасы бар. Син дә боржом эч, әни!* Р.Батулла

**БОРЛЫГУ** *ф.* 1) *диал.* Борчылу, кайгыру, көенү, тынычсызлану. *Гарьсенәм дә, борлыгам да Керәмен өйгә: Меңенче кат сорау белән Карыйм әтигә.* Ш.Маннур. *Күз төпләре караеп баткан килеш, борлыгып, niләр күрербез икән, дигәндәй көтеп, карап тора башладылар.* Х.Сарьян

2) Быгырдау, быгыр-быгыр итү, быгырдаган тавыш чыгару. *[Пәхри] Көлеп тә җибәрде, авызына су да борлыгып керде.* Х.Җәмил

**Борлыгып йөрү** Озак вакытлар дәвамында борлыгу. *Авылда Сөембикәне кызганучылар да табылды: «Әтиең булса, болай борлыгып йөрмәс идең, нинди кешене китәргә мәҗбүр итте бит, Алланың ачы каһәре төшкере», – диделәр.* Ф.Садриев

**БОРМА** *и.* **1**. 1) Дуга рәвешендәге бөгелеш, борылыш ясаган урын, борылма. *Агыйдел, безнең ындыр турында кинәт бер борма ясап, авылның эченә керә язып кала.* Г.Ибраһимов

2) Тавышның төшүе, күтәрелүе, озынлыгы белән бәйле аһәңдәге үзгәлек. *Аннары, тавышы белән әллә нинди бормалар ясый-ясый, шашынып сайрарга тотынды.* Р.Хафизова

**2**. *с. мәгъ.* Борылмалары булган, борылмалы, бормалы, боргаланган. *Син юк инде, Ләкин әле дә тора Син эшләгән борма забойлар.* Ш.Маннур

**БОРМАЛАНУ** *ф.* Күп бормалы булу, борма-борма булып сузылу, бормалар ясау. *Чыкты болыт, шомлы җилләр исте Бормаланып аккан су буйлап.* Ә.Ерикәй

**Бормалана бару** Торган саен күбрәк бормалану

**Бормалана башлау** Бормаланырга тотыну

**Бормалана төшү** Бераз бормалану

**Бормаланып бару** *к.* **бормалана бару.** *Ул [җәяүлеләр сукмагы] куе агачлыклар арасыннан, тау битенә бер күтәрелеп, бер төшеп, чокырлар аша салынган тар күперләрдән узып, бормаланып бара.* Ә.Еники

**Бормаланып бетү** Бик нык бормалану. *Язмышның үз юлы, үз сукмагы бар икән шул, аз гына саксызлык күрсәттеңме, уйлап җиткермәдеңме – ул сине бормаланып беткән әлеге сукмагына алып кереп китә, йә бөтенләй адаштыра ---.* Г.Гомәр. *Чабышлар да башка, «тайлар» башка, Бормаланып беткән тугайлар...* К.Сибгатуллин

**Бормаланып китү** Билгеле бер урында борылыш ясау; бормалары бик күп булу. *Басу капкасын чыгып бераз баргач, уңга бормаланып киткән юлга карыйм.* Рифә Рахман. *Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә.* Ә.Еники

**Бормаланып тору** Һәрвакыт, гел бормаланган хәлдә булу

**Бормаланып яту** *к.* **бормаланып тору**. *Ялгыш төшеп калган көмеш пута кебек, Идел бормаланып ята.* Л.Ихсанова

**БОРМАЛА́У** *ф.* Бормалар ясау, бормалы итү

**Бормалап бетерү** Бик күп бормалар ясау

**Бормалап җибәрү** Бераз бормалау

**Бормалап карау** Бик күп бормалар ясаган булу

**Бормалап кую** Бормалар ясап калдыру

**Бормалап чыгу** Башыннан ахырына кадәр бормалау

**Бормалый башлау** Бормаларга тотыну

**Бормалый төшү** Беркадәр бормалау

**БОРМАЛЫ** *с.* **1.** 1) Бормалары, борылмалары булган; борылмалы. *Рәтләре бормалы бер-ике участокны кабат чәчәргә туры килде.* Җ.Рәхимов. *Бормалы су буйларында Үскән зифа буйлары.* Н.Исәнбәт. *Аның күз алдына тагын агым су буйлары, аның яшел болыннары, бормалы тугайлары килеп басты.* Г.Бәширов. *Андый чакларда тәрәзәдән зәңгәр күлләр, бормалы инеш-елгалар күренеп кала.* Т.Әйди

2) Кинаяле, читләтеп әйтелгән. *Җиңел, уен-көлке һәм нечкә бормалы сүзләр сөйләүгә сәләте бик чамалы.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Тавыш тембрын үзгәртеп, бормалар ясап, бизәкләп, катлауландырып. *Ни дим? Хәй, өйрәт безне бормалырак итеп [җырларга].* М.Фәйзи

**БОРНАЙ** *с. диал.* Эре, тәкәббер, һавалы. *Университет лекторлары бераз гына борнай була, һавалы була...* М.Мәһдиев

**БОРНАЙЛЫК** *и. диал.* Эрелек, тәкәбберлек, һавалы булу. *Ходай кушса, шушы борнайлыгың белән кияүсез дә калырсың әле.* Г.Ахунов

**БОРНА́У** *ф.* 1) Шыту, тишелеп чыгу. *Таш койма өстендә борнап үскән кәрлә карама агачы турында туктап калам.* Н.Хәсәнов

2) *к.* **борынлау** (*2 мәгъ.*)

**Борнап килү** Акрынлап борынлау; яңа гына борынлау. *Тик шулай да айлар буена сузылган ачлык, эчкә төшкән салкыннар, әнисенең үз җылысын, үз сыныгын биреп саклап килүенә карамастан, аңар [балага] үзенең шаукымын тидереп өлгергән, яңа борнап килгән бу яшь үсенте, түзәр-түзәр дә, иртә килгән салкын кыраудан шиңеп калган гөлчәчәктәй, беркөн дәррәү сулып төшәр кебек иде.* Г.Гобәй

**Борнап чыгу** 1) Яңа гына тишелү, шыткан гына булу. *Урамда яшел хәтфә төсле чирәм борнап чыкты.* Р.Гарипов

2) Йомырка кабыгын томшыгы белән тишеп, кош баласы туу. *Быел минем, әллә нишләп, каздан бәхет булмады. Ике оядан барлыгы сигезе борнап чыкты.* К.Тинчурин

**БОРОВИ́НКА** *и. рус* Алмагач сорты һәм аның алмасы. *Зур, түгәрәк һәм каты боровинкалар, кара орлыклары үтәли күренеп торган ак алмалар.* И.Гази

**БОРСАЛАНУ** *ф. диал.* Борчылу, пошыну, үзенә урын тапмау, хафалану. *Кәримә, борсаланып, Әсгатьнең җиңенә кагылды.* Р.Хафизова. *Пәрдәләрен корып, йокларга яткач та, озак кына түшәгендә борсаланды ул.* Н.Гыйматдинова. *Еш кына шушы авыр халәттә, төннәрен, йоклый алмыйча, үзенә-үзе урын таба алмагандай, борсаланып уздыра ул.* З.Фәйзи

**Борсалана башлау** Борсаланырга тотыну. *Ниһаять, малайның йокысы сизгерләнде, ул борсалана башлады, ыңгырашып куйды.* А.Тимергалин

**Борсалана төшү** Бераз борсалану

**Борсаланып алу** Кыска гына вакытка тынычлыгын югалту. *Түп түрне Ирсан утырган җирендә борсаланып алды*. М.Хәбибуллин

**Борсаланып бетү** Бик нык борсалану

**Борсаланып йөрү** Озак вакытлар үзенә-үзе урын тапмый тынычсызлану. *«Юк инде! Юкка борсаланып йөрмә инде! Йоклый ич инде Вера!» – дип, үз-үземне тынычландырырга телим*. М.Вәли-Барҗылы

**Борсаланып кую** Кинәт борсалану, аз гына вакытка тынычсызлык кичерү. *Кыз борсаланып куйды: – Ә нигә Әмәткә барабыз?* Р.Зәйдулла. *Өлкән равва кәнәфиендә борсаланып куйды һәм, ишек сакчысына: – Миңа Рәшидә абыстайны дәш, – дип, урыныннан торып йөреп килде*. М.Хәбибуллин

**Борсаланып тору** Әле, хәзер, күз алдында борсалану

**Борсаланып чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында, шул вакытның башыннан ахырына кадәр борсалану. *Төн буена борсаланып чыктым. Коточкыч арыган булсам да, үлеп йокы килсә дә, бер генә мәлгә булса да черем итә алмадым*. Р.Батулла

**Борсаланып яту** Әле, хәзер тынычсыз хәлдә булу. *Малай, төне буе, йоклап китә алмый борсаланып ятты*. Л.Гыймадиева

**БОРТ** *и. нем.<фр.* 1) Оча торган аппаратның, судноларның, йөк машиналарының һ.б.ш.ның ян-як стеналары. *Берзаман күземне ертып ачсам, машина бортлары каерылган, иптәшләрем ак карга шыбыр-шыбыр коелалар.* А.Гыйләҗев. *«Лотос»ны уң борты белән амбарлар каршына куйганнар.* Ә.Хәбибуллин

2) Очкычның яки судноның эче. *Команда төн буе китның судно бортына --- беркетелгән гәүдәсен эшкәртә.* Кызыклар дөньясында

3) Бильярд өстәленең ян стенасы

4) Нәрсәнең дә булса кырые, ян-як стенасы. *Шайба бортка килеп бәрелде. Өстәлләрнең кырыйлары бәләкәй бортларга күтәрелгән.* Ә.Хәбибуллин

5) Каплама (киемнең төймәле яки элмәкле кырые)

**БОРТАК** *с.* Сак тота белүче, хәстәрле. *Бортак хатын йорт тотар.* Мәкаль

**БОРТМЕХА́НИК** *и. фр.-гр.* Очучылар экипажында җиһазларның, аппаратларның һәм приборларның торышы һәм эше өчен җаваплы кеше, механик. *Машинаны алып баручы пилот һәм бортмеханик яралана.* Кызыклар дөньясында

**БОРУ** I *ф.* 1) Нинди дә булса әйберне үз күчәрендә әйләндерү. *Ә лётчик, әйтерсең бу хәл тормышта түгел, кинода бара иде, әз генә дә каушамыйча, ләкин бик тә җитди кыяфәткә кереп, рульне әле – уңга, әле сулга борды һәм бертуктаусыз тирә-якны күзәтте.* Г.Гобәй. *Кирәк чакта шул трубаларның краннарын борасың да, балыклар, труба буйлата килеп, үзләре кастрюля эченә сикереп төшәләр.* Г.Гобәй

2) Хәрәкәт юнәлешен үзгәртү, икенче юнәлештә хәрәкәт иттерү; борылу. *Гомер юлын кая таба борган, Кай җырләрдә «атын» туарган?* Ш.Маннур. *– Мин, әни, сәгать стрелкасын дөрес бордым, сул якка, – дип, Камил бармаклары белән сул якка бору хәрәкәтен ясап куйды.* А.Әхмәт. *Ул, мәчет турысыннан үткәч тә, атны урам юлыннан Хөснулла капкасына таба борды.* Ш.Камал. *Сәлим түзмәде, кызның икенче беләгеннән дә эләктереп, үзенә таба борды.* Г.Әпсәләмов. *Бу арада аның хыялында гел: тауны тауга бәрү, җирне күккә сугу, дөньяның күчәрен икенче якка бору кебек, гел зур, гел гадәттән тыш олуг булган эшләр генә йөри иде.* Г.Ибраһимов

3) Бөтерү; бөтереп урау, төрү. *Һәм мыегының ике башын, борыбрак, югары каратып куйды.* Ф.Әмирхан. *«Әлфиянең туе булганга биш былтыр инде, соңга калгансың, егетем», – дип, икенче бүлмәдән, мыегын бора-бора, Хәнәфи килеп чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Кара бу мыекларны (мыекларын борып күрсәтә).* Г.Камал

4) Аяк, кул, баш һ.б.ларны нормаль булмаган торышка китереп каеру; тотып алып чеметү. *Кайгырма, Гайшә, мутлана башласа, мин бик тиз колагын борырмын.* Ф.Бурнаш. *Ашарга беткән, ягарга салам да тапмый, туңып утырган чак күп булды, ләкин шул җәйге байлык – тәмәке өзелмәде, эч ачлыктан бик бора башлаган чакларда, ул, үзенең иске дусты чуваш Емельян бүләк иткән чакма ташын чыгарып, чилем кабызып тарта, шуның белән карын бераз тынычланып киткән кебек була иде.* Г.Ибраһимов

5) Бау, аркан һ.б.ш. кебек нәрсәләрне, ныклык өчен, берничә катлы итеп үрү, катлап ишү. *Аркан бору*

6) *күч.* Мәсьәләне яки фикерне берәр якка юнәлтү. *Безнең янга килеп җиткәч, ул сүзен безгә борды.* М.Әмир. *Тарткан кебек ләкин кулыннан, Уйлар борды аны юлыннан.* Ә.Исхак. *Гафият мәсьәләне уенга борырга тырышты.* И.Гази. *– Бераз им-том итеп карадыңмы соң?– диде Шәмгун карт, яңадан сүзне авыруга борып.* А.Шамов

7) *күч.* Буйсындыру, карату. *Нәфесне яхшы юлга бору кирәк.* М.Гафури. *Әмма Мәликә авызын туктатырга да, борырга да, шулай ук тыярга да мөмкин түгел иде.* А.Шамов

8) *күч.* Яңа эчтәлек бирү, иҗтимагый үсеш, хәрәкәт һ.б.ш. га икенче юнәлеш бирү. *Ничаклы тырышсагыз да, Никадәр көч куйсагыз да, Тарихны боралмассыз.* Ә.Исхак. *Айнулла абзый, барысын политикага борасыз, ди.* Г.Әпсәләмов

**Бора бару** Акрын-акрын бору

**Бора башлау** Борырга тотыну

**Бора бирү** Боруын дәвам итү. *Көнбагыш кояшка гашыйк булып, аның артыннан көннең-көн буе башын бора биреп карап торган кебек, Газинур да һәрвакыт Гали абзыйга таба борылып-борылып карый.* Г.Әпсәләмов

**Бора тору** Һәрберсен, килгән берсен кире бору. *Әйтәм бит, халык бик килә эш сорап. «Ни бит, кем, туганкайлар, миңәйтәм, булмый, алдан ук вәгъдә иткән кешеләрем бар», – дип, күбесен кире бора торам*. Ф.Сафин

**Бора төшү** Беркадәр, азрак бору, икенче юнәлеш белән хәрәкәт иттерү. *– Төнлә бик курыкмадыгызмы? – диде Мостафин, каушавын яшерер өчен. – Булды әзрәк, – дип, кыз тагын, йөзен бора төшеп, күзләрен тутырып карап алды*. Х.Камалов

**Борып алу** 1) Тиз генә юнәлешне үзгәртеп бору. *Комга тидергән бармак очы белән самавырга, басып, бер борып алуы була, түгәрәк тәңкә килеп чыга, тагын борып ала – тагын тәңкә.* Г.Бәширов

2) Кинәт авырту тою. *Эчнең авыртуына түзәр хәл юк, борып-борып ала инде менә.* Т.Миңнуллин

3) Эләктереп тоту. *Ит беткәч, Царевичны якасыннан борып алып, чәченнән өй стенасындагы ярыкка кыстырып куя.* Әкият. *Малайның колагыннан борып алдым: – Нәрсә дидең, елан баласы?!* З.Мәхмүди

**Борып ату** 1) Тиз-тиз, аннан-моннан бору

2) *күч.* Җиңү, өстен чыгу

**Борып бетерү** 1)Ахырга кадәр бору, беткәнче бору

2) Тулысынча үзгәртү, икенче юнәлешкә бору. *Йомшак кына сурәттә, галимнең фикерләрен уңайга борып бетерә.* Х.Камалов

**Борып җибәрү** 1) Юнәлеш биреп, хәрәкәт иттерә башлау. *Караңгыда кулга эләккән беренче пластинканы куеп, патефонны борып җибәрдем.* И.Гази

2) *күч.* Кинәт үзгәртү, фикер, сүз барышын башка темага күчерү. *Сабир абзый исә – яшьләрнең шаяруын ярата торган кеше, Бикмулланың җитди сүзне уен-көлкегә борып җибәрүенә бер дә кәефе кырылмады.* Ә.Еники

3) *күч. к.* **борып чыгару** (*2 мәгъ.*). *Гидростройга барсагыз, борып җибәрмиләр инде. Үзләренең дә сезгә йомышлары төшә бит...* Р.Вәлиев. *Минһаҗ аны, сөйләшмичә, өч тапкыр кире борып җибәргән.* Г.Бәширов. *Җитмеш яшьлек карт, колхоз эше белән өч тапкыр бара, ә алар аны, алдалап, ишек төбеннән борып җибәрәләр.* Г.Әпсәләмов

**Борып җиткерү** Тиешенчә бору

**Борып карау** Борырга омтылу. *Тегеләй итте, болайга борып карады мәсьәләне, әмма Сакмановка каршы «эш» ача алмады.* Т.Галиуллин

**Борып кую** 1) Борылган хәлгә китереп калдыру. *Уникегә борып куйдым Куен сәгатьләремне.* Җыр

2) *күч.* Кинәт үзгәртү, фикер, сүз барышын башка темага күчерү. – *Тәки маллар көтүдән каладырые, – дип, сүзне шома гына борып куйды Хәдичә апа.* М.Маликова

**Борып салу** *к.* **борып ату**

**Борып тору** Даими рәвештә, һәрвакыт бору. *Башыгызны югары күтәрүдә, түбән салуда яки бер тарафка борып торуда гадәттән артык итмәгез.* Р.Фәхреддин

**Борып чыгару** 1) Төбеннән, борып, каерып алу

2) *күч.* Йомыш белән килгән кешенең үтенечен кире кагып кайтарып җибәрү, кабул итмәү. *Тагын тыңламыйча булмый, бик кыен елларда, хезмәт хакын бирмичә, борып чыгарырга тырышмады бит.* Т.Нәҗмиев. *Шабановларда күршене борып чыгару гадәте юк.* А.Гыйләҗев

**Борып чыгу** Барысын да рәттән бору

**БОРУ** II *с. сөйл.* Кәкрәеп торган, борылып киткән. *Берәр сарыкны сатсак инде – шунсыз булмый, улым, – тege бору мөгезлене.* Г.Гобәй

**БОРЧА** *и.* 1) Канатсыз бөҗәкләр отрядыннан, каты хитин япмалы, җитез хәрәкәтләнүчән, җылы кан суырып туклана торган паразит вак бөҗәк. *Бөтен төн буенча участокның тузанлы, борчалы, кандалалы каты сәке тактасында аунап, газапланып чыккан студентлар, төрле яктан баш күтәреп, сүгенергә, җырларга, ишек дөбердәтергә тотындылар.* Г.Ибраһимов. *Бакча ягыннан караганда, түбәндәге атлылар, дөяләр – ак чаршау өстендә кырмыскалар үрмәләгән төсле, җәяүлеләр борчалар кыймылдаган төсле күренәләр.* Ш.Камал. *Борчаның сикерү ысулы күбебез өчен сер булып кала.* Кызыклар дөньясында. *Әшәке эт – борчага, яман кеше сүзгә бай.* Казан утлары

2) *күч.* Бик елгыр, җитез, хәрәкәтчән кеше. *Ләкин тыштан җиңелчә күренгән бу кеше – борча, кандала кебек хәрәкәтчән, сугышучан бер хәшәрәт.* Г.Нигъмәти

◊ **Борча ашау, борча керү** Тынычсызлау, борчу

**БОРЧАК** *и.* Кузаклылар семьялыгыннан, яфраклары парлы-парлы булып, сабагы мыек рәвешендә очлана, чәчәкләре актан алып шәмәхә төсенә дә күчә торган, бер яки күпьеллык игүле үсемлек. *Көнен-төнен белмәде, арыдым, йокламадым, димәде, ары чапты, бире сугылды, җәен-көзен, бөкересен чыгарып, берүзе өч-дүрт эскерт куеп ташлады, борчак-ясмык чапты, әллә никадәр ашлык суктырды.* Г.Бәширов. *Борчак белән солыны, я булмаса, вика белән солыны бергә кушып чәчәргә икән.* Ә.Еники. *Ат башына да йөрде, урак та урды, борчак та, бәрәңге дә алышты, ашлык та сукты.* Г.Әпсәләмов. *Әхтәм бабай белән Гөләндәм әби бер елны шул урынга – шахмат тактасы зурлыгы гына бер җиргә борчак чәчкәннәр иде.* Г.Гобәй

2) Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге яки оны. *Әнисә, син, ялкау кыз, чормага менеп, борчакларымны гына таратып төшсәнә.* А.Әхмәт. *Борчак каты һәм тәмсез иде.* И.Гази

◊ **Борчагы пешү** Килешү, дуслык урнашу. **Борчак җәзасы** *иск.* Мәдрәсәләрдә гаепле кешене борчакка бастырып яки тезләндереп тоту җәзасы. *Ә сиңа, дин сабагын бозуың өчен, борчак җәзасы бирәм.* Т.Гыйззәт. **Борчак кадәр (хәтле)** Бик кечкенә, вак, бәләкәй. *Юк, аның һич тә исе сизелми, аны борчак кадәрле генә кабып, артыннан чәй кабып җибәрсәң, бөтенләй күз аллары яктырып китә.* Г.Камал. *Әфиун һ.б. дарулар катнаштырып ясалган, җанга рух биреп, борчак кадәресен генә капсаң да кәефләндереп җибәрә торган бер нәрсә.* М.Гафури. **Борчак пешмәү** Уртак фикергә килә алмау, татулык, дуслык булмау, үзара килешмәү. *Аннары Шәмгун карт, килеп кергәч тә, яшь егет белән председательнең борчаклары пешеп җитмәгәнен сизеп алды.* А.Шамов. --- *эшкә булдыксыз Камилә белән аның [Фәнзиләнең] борчагы пешми.* Г.Ахунов. **Борчак сибү** 1) Арттырып сөйләү, шапырыну. – *Шулайдыр, – дидең син, көлемсерәп. – Борчак сибәргә генә оста без.* Э.Касыймов; 2) Сүзне кабул итмәү, тыңламау, әйткәннең файдасы булмау. *Нәрсә генә сөйләсә дә, стенага борчак сибү белән бер буласын аңлый иде ул.* Ш.Камал. **Борчак чәчү** *к.* **борчак сибү.** *Илгиз*

*былтыр үзенең сабан туен кайда, ничек каршылавы турында борчак чәчәргә тотынды.* Н.Фәттах. **Борчак яру** *к.* **борчак сибү.** *Авыл җирендә кемнең кем икәнлеген бер чакрымнан үк күреп торалар. Шәфкать туташы Миңлеасия үзе янында борчакны бик эредән ярып барган фронтовикның нинди кеше малае икәнен ул кайтканчы ук белеп алган иде инде.* Г.Ахунов

**БОРЧА́К-БОРЧАК** *с.* 1) Эре тамчылар яки йомры борчак рәвешендәге, борчак хәтле. *Пешеп чыккан йөзеннән борчак-борчак тирләрен сөртеп алды.* Г.Гобәй. *Күз яшьләрем, борчак-борчак булып, Әни итәгенә түгелде.* Ә.Рәшит. *Йөзендә борчак-борчак тирләр чыккан иде.* Казан утлары

2) Борчакка охшашлы, борчак сыман, бөрчекле. *Әлеге хатын-кыз затының борчак-борчак ак төшерелешле зәңгәр күлмәгенең итәге сизелер-сизелмәс кенә күтәрелеп тора.* Ә.Гаффар

**БОРЧАЛА́У** *ф.* Борчалар күп булып үрчеп китү, борчалар барлыкка килү

**Борчалап бетү** Бик күп булып борча үрчү, тәмам борчага бату. *Безнең дә мәче бар иде. Ата мәче. Подвалда ана мәчеләр артыннан сөйрәлеп йөрийөри, борчалап бетте.* Р.Бәшәр

**Борчалап кую** Көтмәгәндә, кинәт борчалау

**БОРЧА́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, сабагы төбеннән үк тармакланган, кызгылт, йомшак бөдрә төкчәләр белән капланган, вак яфраклы, сабак очында берәрләп яки ике-өч кәрзин бергә урнашкан тонык сары төстәге агулы чәчәкле берьеллык үсемлек. *Су борычын --- борча үләне белән бутамагыз.* Н.Верзилин

**БОРЧУ** *ф.* **1.** Тынычсызлау, тынгылык бирмәү, хафаландыру, хафага салу; мәшәкатьләү. *Үләннәрне борчып, кырда Чикерткә дә сикерми.* М.Җәлил. *Бу көнгә кадәр, «минем өлешемә чыккан көмешем» дидем дә риза булып тордым, шул начар, күңелсез сүзләрне сөйләп, сезнең күңелегезне бозсам, сезне борчысам, сез миңа рәхмәт әйткән булыр идегезмени?* Г.Камал. *Аннан сыңар күн чүәкнең урланган булуы да, ни өчендер, сыңары гына урланган булуы да мине кызыксындырмады, борчымады.* М.Мәһдиев. *Бармы синең кәефең, юкмы – бу аны борчымый.* Ә.Хәбибуллин

**2.** *и. мәгъ.* Тынычсызлык; хафа; мәшәкать. *Борчу төшкән башына Безнең мастер Камалның.* Ә.Исхак. *Ире исән чагында бар хәсрәт-кайгысын җыргамузыкага тапшырырга өйрәнгән, нинди генә борчуларны да уен-көлке белән уздырып җибәрергә гадәтләнгән Диләфрүз апа хәзер үз эченә йомылды.* Р.Хафизова. *Шәхси борчулар артка чигенде, икмәк өчен көрәш, фронтны тәэмин итү өчен көрәш һәркайда беренче урынга килеп басты.* Г.Бәширов

**3.** *с. мәгъ.* Борчулы, борчылган, тынычсыз, хафалы. *Сез – һаман да борчу, кайгылы.* Ф.Бурнаш

◊ **Борчуга төшү** Борчылу, тынычсызлану, хафага төшү. *Берәр тавык салмый калса, Галиулла, борчуга төшеп: – Күрше-коланга ияләшә күрмәсен, караштырып йөрергә кирәк, – дип, тавыкның артыннан күзәтергә чыгып китә иде.* И.Гази. **Борчу салу, борчуга салу (төшерү)** Тынычсызлау, борчылырга мәҗбүр итү, мәшәкатьләү. *Маратның авыруы хакында әйтүең мине бик нык борчуга төшерде.* М.Җәлил

**Борчый башлау** Борчырга тотыну. *Йокы түшәгенә яткач, аны бер уй борчый башлады.* М.Әмир

**Борчый бирү** Борчуын дәвам итү

**Борчый төшү** Тагын да борчу

**Борчып алу** Бераз вакытка борчу. *Әле әнинең күз алдыма килеп басуы гына борчып алды.* Г.Бәширов

**Борчып бетерү** Бертуктаусыз, бик нык борчу. *Ул төнлә киленнәрне дә борчып бетерер.* Г.Камал. *Татарларның бичурасы – рус халкының «кикимора»сы белән бер нәрсә. Ул татарга бер дә зарарын тидермәсә дә, төнлә белән аны төрле рәвештә борчып бетерә: кычкыра, уйный, көлә, шаяра, йоклый торган кешене бер урыннан икенче урынга күчереп куя.* К.Насыйри

**Борчып йөрү** Озак вакытлардан бирле борчу. *Ихтыярның инде атна буе күңелен борчып йөргән уйларны тизрәк очлап куясы, бу туйдырган темадан читкә китәсе килә иде.* Р.Вәлиев

**Борчып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан даими борчу. *Ашап туйгач, иртәдән бирле мине борчып килгән соравымны бирдем: – Нигә сезнең союзның өченче члены күренми бүген?* Р.Сибат. *Шуның белән ханны озак вакыт борчып килгән сорау да ачыклана.* Ф.Урманче

**Борчып кую** Кинәт кенә борчу, көтмәгәндә генә борчу

**Борчып тору** Һаман, туктаусыз борчу. *Хәнифә апаның да йөрәген борчып тормасыннар.* Р.Ишморат. *Шәһәрнең ыгы-зыгысы мине өзлексез җәберләп, туктаусыз борчып тора.* Г.Бәширов

**БОРЧУЛЫ** *с.* 1) Тынычлыгы киткән, тынычсызланган, хафалы, дулкынлану белдергән. *Борчулы уйлар Гришаның да аяк адымнарын кызулаттылар.* А.Әхмәт. *Рәүфә, аның борчулы йөрәген тагын да борчымас өчен, газаплы төннәр турында бернәрсә дә әйтмәде.* А.Шамов

2) Мәшәкатьле, тынычсыз; шомлы, хәвефле, тәшвишле. *Менә авыр, менә борчулы, менә илаһи, әчпошыргыч заманнар!* Г.Ибраһимов. *Тик бик борчулы чакка очрадык.* Т.Гыйззәт

**БОРЧЫЛУ** *ф.* **1.** Тынычсызлану, кайгыру, хафалану. *Бу хатларның солдат кулына керүе – аларны бик куркытты, Разия да арага керде бугай, дип, үзара борчылдылар.* Г.Ибраһимов. *Без сакларбыз туган илне, Сез борчылмагыз.* М.Җәлил. *Сәлим шул турыда уйлап шатланды, ләкин бер үк вакытта борчылды да.* Г.Гобәй. *Ул, үзенең сорашуы, кызыксынуы белән, Рәүфәнең уяныр-уянмас яткан шикләрен уятып җибәрде һәм аңа борчылырга, газапланырга юл күрсәтте.* А.Шамов

**2.** *и. мәгъ.* Тынычсызлык, хәсрәт, хафа. *Сәмигулла абзый, гадәтенчә, моны бик эшлекле борчылу белән карап тикшереп тора иде.* Ф.Әмирхан. *Нурый карт йортына тулган халыкны күргәч, матур җиңги Мәфтуходан кияү турындагы хәбәрләрне ишеткәч, Мәрхәбә бөтенләй каушап калды, үги каенанасы Фәтхиянең болай теләр-теләмәс каршы алуын күргәч, аның бу борчылуы тагы да артты.* Г.Ибраһимов. *Бу сүзләрдә ниндидер*

*кызгану, ярашу, бик нык борчылу һәм күз яшьләре дә бар иде.* А.Шамов

**Борчыла бару** Торган саен ныграк борчылу

**Борчыла башлау** Борчылырга тотыну. *Йөзлебикә Нәфисәнең ялгыз китүенә борчыла башлады.* Г.Бәширов

**Борчыла төшү** Бераз борчылу

**Борчылып алу** Кыска гына вакыт эчендә, бераз борчылу. *Бу эш шулкадәр тиз башкарыла, лейтенант Сабитов «Победа» машинасының иясе белән хәтта саубуллашырга да онытa, ул бу турыда юлда гына исенә төшереп, бераз борчылып ала.* Г.Минский

**Борчылып йөрү** Бертуктаусыз борчылу. *Күпме яшерергә тырышсам да, борчылып йөргәнемне Лотфулла абзый белән Фатыйма апа да сизделәр.* Г.Галиев

**Борчылып тору** Әле, хәзерге вакытта борчылу. *Синең өчен борчылып тора идем.* Т.Гыйззәт

**Борчылып чыгу** Билгеле бер вакытны кичкәнче борчылу. *Төне-төне белән, йокламыйча, борчылып чыгам.* Ф.Хөсни

**БОРЧЫРЛЫК** *с.* Борчылырга, тынычсызланырга мәҗбүр итә торган, борчу уята торган. *Исәнмесез, минем сезне борчырлык йомышым юк.* Г.Бәширов. *Әйе, бер ана өчен генә түгел, Миңсылу өчен дә, егет хаты алу – көтелмәгән һәм борчырлык, ләкин, шул ук вакытта, йөрәкнең кай төшендәдер ниндидер бер ашкыну хисләрен уятырлык вакыйга булды.* Г.Минский

**БОРЩ** *и. рус кулин.* Чөгендер, кәбестә һәм төрле тәмләткечләр салып пешерелгән итле аш. *[Себер бае:] Сез нинди нәрсә телисез, беренчегә суп әйтикме, борщмы?* Г.Камал. *Хөрмәт моның белән генә бетмәде, өстәл өстенә кайнар борщ китерелеп куелгач, аңа иң түрдә урын бирделәр.* А.Шамов. *Борщны табынга биргәндә, аңа каймак та салырга кирәк.* Йорт эшләре

**БОРЫЛМА** *и.* **1.** Суның, юлның борылган урыны; *к. шулай ук* **борылыш**. *Һәрбер юлсыз, куе агачлык арасыннан шундый авыр кабыкларны китерү бик авыр була, төрле борылмада, агачларга эләгеп, кабыклар тәртәдән ычкынalар.* М.Гафури. *Авылыбызны яртылай әйләндереп алган Агыйдел озынайды, борылмалары ешайды.* М.Әмир

**2.** *с. мәгъ.* Борыла торган, борма. *Турбинаның эчке тәгәрмәче борылма калаклы юнәлткеч тәгәрмәч эченә урнашкан.* Физика

**БОРЫЛМА́-БОРЫЛМА** *с. к.* **борылмалы.** *Борылма-борылма баскычтан борылып менәр солдатлар.* Г.Тукай

**БОРЫЛМАЛЫ** *с.* 1) Борылмалары, борылышлары булган, бормалы. *Бишбалтага китүчеләр шул таллар арасыннан бара торган борылмалы һәм сикәлтәле юл буйлап киттеләр.* М.Гали

2) *күч.* Катлаулы, авыр, кыенлыклардан торган. *Аның иҗат юлы борылмалы һәм катлаулы булды.* М.Җәлил. *Киң зал көтәр үзенең җырчысын, Борылмалы озын юллар аша Безгә килгән хисле юлчысын!* Н.Баян

3) *күч.* Яшерен; астыртын, хәйләле. *Мирсәй Әмир, --- борылмалы, астыртын юллар аркылы, Миргалинең әшәке каршылыгын сурәтли.* М.Җәлил. *Хәзергә, болытлар таралганчы, борылмалырак юл тотарга кирәк, бүре дә тук булсын, сарыклар да исән калсын!* М.Галәү

**БОРЫЛУ** *ф.* 1) Хәрәкәт юнәлешен үзгәртү. *Юл, борылып, әле уңга керде, әле сулга ташланды, я көрәнсу төз тасма булып сузылды.* Г.Мөхәммәтшин. *Малайлар ындырга борылып керделәр.* Г.Гобәй

2) Чыккан урынга кире кайту. *Гафият абзыйның вакыты юк: мунча кирәм, дип барган кеше борылып кайтты.* И.Гази. *«Ягез, инде сез мине тотыгыз!» дигән сыман, шаян гына сикереш ясап кире борылды һәм урман куелыгы эчендә юк булды...* Ә.Фәйзи. *Буржуаз илләр өстеннән агулы яңгыр төяп килгән болытлар, безнең ил чигенә җитүгә, кире борылачак.* М.Галиев. *Эшләрен бетерделәр дә килгән яклaрына кире борылып китеп бардылар.* Г.Ибраһимов

3) Торышын үзгәртү; икенче якка әйләнү. *Күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, Газинур тиз генә читкә борылды.* Г.Әпсәләмов. *Кәгазьне сузганда, ул миңа борылды.* Ә.Хәбибуллин. *Ишектән, авызын ерып, күрше Талип абзыйның кара чутыр малае да чыгып килгәнен күрүгә, Алик аркасы белән борылды.* М.Галиев. *Илсөярнең ашап утырганын күргәч, артыннан килүче иптәшләренә таба борылды: – Уянган, – диде.* Г.Гобәй

4) *күч.* Икенче юнәлеш алу, башкачага әйләнү, игътибарны читкә юнәлтү. *Искәндәр сүзнең болай кинәт кенә үзенә борылуын көтмәгән иде.* Г.Мөхәммәтшин

5) *күч.* Игътибар итү, нәтиҗә ясау. *Биредә автор үзе үткән тормыш юлына борылып карый.* Ә.Мотыйгуллина. *Бөтен дөнья эшчеләре Байга таба борылган, Капиталга каршы бөтен Мылтыклар да корылган.* Г.Камал

6) *күч.* Тормыш агымы, яшәеш тәртибе үзгәрү. --- *ул [Аяз Гыйләҗев], Вакыт агышын тоеп, дөнья кайсы якка борыла, тормыш ничек үзгәрә, замана татар халкын, аның гасырлар буена килгән яшәү тәртибен ниндигә әйләндерде --- кешенең кыйбласы кайда, дип, фәлсәфи уйлана.* Ф.Ганиева

**Борыла бару** Акрынлап борылу. *Сапны гел тарта барасың, самолёт та артка, кирегә борыла бара.* С.Баттал

**Борыла башлау** Борылырга тотыну. *Сөйләшү бу юнәлешкә борыла башлагач, мин урынымнан кузгалдым.* М.Юныс

**Борыла төшү** Беркадәр борылу. *Әллә инде күреп тә дикъкать итмәде, мебель комбинаты вәкиле ягына борыла төшеп, сүзен дәвам итте.* М.Хәсәнов

**Борылып китү** Кинәт борылыш ясау. *Авылга ике чакрым кала, таш юл борылып китә.* М.Галиев

**Борылып кую** Кинәт, көтмәгәндә борылу хәрәкәте ясау

**БОРЫЛЫ́П-БОРЫЛЫП** *рәв.* 1) Берничә кабат борылыш ясап, берничә мәртәбә әйләнеп. *Ил-йорттан чыгып киткәч тә, шикләнебрәк, артларына борылып-борылып карадылар.* Р.Сәгъди. *Кайчак әле артыңа борылып-борылып карыйсың.* Сөембикә

2) Бик күп бормалар, борылышлар ясап. *Агачлар арасыннан борылып-*

*борылып киткән юл буенча азрак баргач, алда бер ак нәрсә күренә башлады.* Ш.Камал. *Борылып-борылып аккан Агыйделкәй Дәрья булмаганга киң түгел.* М.Гафури

**БОРЫЛЫШ** *и.* **1**. 1) Суның, юлның борылган урыны; борылма. *Борылышка җитәрәк, урман шикелле үсеп утырган киндер арасыннан ике кеше килеп чыкты.* И.Гази. *Ә мин, җырлый алмый бүгенгене, Шулай ярты юлда ардыммы, Зур елларның бөек борылышында, Ыргытылып, читтә калдыммы?* Һ.Такташ. *Юл чатларында «бөкеләр» барлыкка килде – егермешәр-утызар машина, бер борылышка бөялеп, алга да, артка да китә алмыйча азаплана торган булдылар.* Г.Ахунов. *Автобус җиңел генә кузгалып китте һәм, борылышка җитеп, күздән югалды.* Г.Мөхәммәтшин

2) Сын, фигурадагы чыгынты, керенте урыннар. *Ялтыравыклы яулык япкан, яктыга каршы торганга күрә, зәңгәр юка күлмәге үтәли күренеп, мул тәненең борылышлары шәйләнә, шәрә сыйрагындагы төк бөртекләре алтынланып җемелди.* Ә.Гаффар

3) *күч.* Күчеш, үзгәреш, яңа юнәлеш. *Тегесе, эшнең мондый борылыш алырга торуыннан бик үк риза булмыйча (кайсыбызның хатыны алай түгел!), мәгънәле генә бер карап куйды.* Ф.Хөсни. *Гагра шәһәре шулай минем тормышымда зур борылыш ясады.* М.Мәһдиев. *Чыннан да, мин тормышта кинәт борылышлар ясаудан курыкмыйм.* Р.Корбан. *Шушы ярты ел буе алып барган көндәлекләрендә герой үзенең бөтен яшәгән гомерен хәтеренә төшереп бетерә, үз гомерендә булган һәр мөһим күренешне, борылышны, вакыйганы, гыйбрәтне тәфсилләп яза.* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ.* Үзгәрешләрне, яңа юнәлешләрне билгеләгән. *1395 елда Аксак Тимер гаскәрләре яшәп килгән Алтын Урда дәүләтен җимергәннән соң, аның көнчыгыш төбәкләрендә барлыкка килгән Нугай Урдасы һәм Казан ханлыгы дәвере әлеге тарихи дәвернең иң әһәмиятле борылыш чоры булып тора.* М.Әхмәтҗанов

**БОРЫН** I *и.* 1) Кеше һәм хайван йөзендәге сулыш алу һәм ис сизү әгъзасы. *Бер көнне – борынын канатып, икенче көнне сыртын каезлап кайталар.* Н.Гыйматдинова. *Ул кулын борынына каплады, аннары, нindidер затлы әйбер тоткандай, канлы учын алга сузды.* Ә.Гаффар. *Эт, шаян һаулап, тычкан өстенә сикерде һәм инде оясына килеп җиткән корткычны борыны белән җиңел генә төртеп җибәрде.* Г.Гобәй. *Урманда ук хуш исе борынга бәрелә.* Г.Хәсәнов

2) Кош томшыгы. *Әйтерсең лә, бүрәнә башы белән яр кырыйларын ишеп, саллар агалар, дулкыннарга канатын тидермичә генә борынын чылатып, акчарлаклар очалар, иртәнге тынлыкта су өстендәге кояш шәүләсенә чабаклар сикерәләр.* К.Нәҗми. *Борыны, каз бәпкәсе борыны төсле, сап-сары булып очлаеп тора.* А.Шамов. *Шул арада каргалар, чәүкәләр әллә кайдан гына җиргә килеп төшәләр дә, сарыклар, сыерлар өстенә куныл, үзләренә оя ясау өчен, борыннары белән аларның йоннарын йолкый башлыйлар.* М.Гали

3) Көймә, пароход, судно, самолёт һ.б.ның алгы өлеше. *Ул арада, моныcы узып китәргә дә өлгермәде, Казан ягыннан, үткен борыны белән дулкыннарны ярып, гаскәр төялгән икенче бер пароход килеп чыкты.* Г.Бәширов. *Ул чакта корабның борынын җилгә, дулкынга перпендикуляр тотарга кирәк.* Ә.Хәбибуллин. *Безгә каршы чыккан крейсерларның Борыннарын кире борыгыз!* Һ.Такташ. *Ул арада пароход борынынннан ташланган озын бау, үзенең авыр төенле башы белән, шапылдап, дебаркадерның калай түбәсенә килеп төште.* М.Әмир

4) Сыеклык сала торган савыт-сабаның агызу өлеше, су җибәрү җайланмасы. *Хупҗамал җиңгәгез белән әрләшеп килдем әле, кабаланып йөргәндә, итәк очы белән эләктереп, самавыр борынын ачкан да бөтен суны агызган.* И.Гази. *Тып-тын, умывальник борынынннан чутылдап тамчы тамгалый да, келт-келт сәгать йөри.* Р.Төфхәтуллин. *Кара савытын барып алып, самавыр борынынннан су агызып илтеп бирә.* Г.Камал

5) Нинди дә булса әйбернең алгы очы, башы. *Аякларында исә борыннары күккә карап торган штиблетлар иде.* Ф.Әмирхан. *Ул соскыч борынына бераз ясмык оны элгән иде.* И.Гази. *Сиртмәнең җиргә тиеп торган башы, үзенә тагылган иске тәгәрмәч тугымын, борыны китек балта, тимер кыршау, тагын әллә нәрсәләрне шалтыршолтыр өстерәп, югары күтәрелде.* Г.Гобәй. *[Ана] Чишенмичә йокыга киткән кызының аягындагы борыннары агара башлаган туфлиләрне күргәч, гаҗәпкә калды.* Г.Минский

6) *сөйл.* Җир грушасы, бәрәңге кебек яшелчәләрнең күзчәсе (бөресе). *Бәрәңге, борнап, күпме җиргә борынын сузса да, фил булмас.* Мәкаль. *Бәрәңге борынын сындыру*

7) Урынның, җирлекнең ни белән дә булса аерылып, очлаеп чыгып торган кырые, очлы булып беткән чите. *Ләкин Калмаш урманы борынына таба сузылып төшкән һәм тез тиңентен үлән баскан ерганак-үзәннәрдә дә әллә ни уңмадылар...* Э.Касыймов

8) *күч. ирон.* Зур борынлы кеше, иң беренче булып, борыны күзгә ташлана торган кеше. – *Кара әле, Госман, бу борын нигә синең тирәдә бик күп ышкыла? – дип, чәнчебрәк сорады.* Г.Ибраһимов

◊ **Борын аркылы (астыннан, эченнән)** 1) Теләр-теләмәс, канәгатьсезлек белән сөйләү. *Галимуллин, күзлеген сөртеп, саргылт сакалын сыйпап, борын аркылы гына җавап кайтарды.* К.Нәҗми; 2) Ишетелер-ишетелмәс, аңлашылыр-аңлашылмас. *Кайчак ул, үзенең ләззәтле, яшерен уйларына чумып, борын астыннан гына нинди дә булса бер җыр җырлый, моңаеп, әрәмәлек эчендә йөри, палатадан чыга алмый торган иптәшләренә чәчәкләр җыя.* А.Шамов. *Украина егете, өй алдындагы бүрәнәгә утырды да, ике кулы белән яңакларын терәп, борын астыннан нindidер җыр көйләргә тотынды: аның ике бите дә – балаларныкы кебек, чибәр кара күзләре моңсу карыйлар.* И.Гази. **Борын асты кипмәгән (юеш)**

*к.* **борыны кипмәгән.** *Менә без эчик, ә аларның әле борын асты да кипмәгән...* Ф.Бурнаш. *[Садыйк:] Сез яшь әле, борын астыгыз кипмәгән әле сезнең, ди.* А.Алиш. **Борын астында** *к.* **борын төбендә**. *Борын астындагын алты ай эзләгән.* Мәкаль. *Борын астындагын белми, ботак башындагын белә.* Мәкаль. **Борын астындагыны күрмәү** Үз гаебен күрмәү. *Борын астындагын күрми, урман артындагын күрә.* Мәкаль. **Борын астыннан китү** Нәрсә дә булса кемнеңдер милкенә әверелергә торганда югалу, аңа эләкмәү. **Борын астыннан шудырту** Кемнең дә булса милкенә әверелергә, аңа булырга торган берәр нәрсәне яшертен алу. *Бер зур нефть җирен, инглизләрнең борын астыннан шудырып, Америка капиталистлары сатып алып өлгерделәр.* Ф.Әмирхан. **Борын астыңны (астындагын) бел, тикшер** Үз гаебеңне бел, кешедән гаеп эзләмә, мәгънәсендә. **Борын башына** Һәрбер кешегә, кеше саен, җан башына. *Әйт Коненкога, борын башына биш-алты фашистны дөмектермичә торып, берәүгә дә үләргә рөхсәт юк.* И.Гази. *Җиде кеше эшлибез икән, борын башына берәр мең бирәсең.* В.Нуруллин. **Борын белән бүрәнә тарттыру** Гырлап йоклау. *«Төнлә борын белән бүрәнә тарттыручылар» дигән данны тагып йөрү әллә мач килде дип уйлыйсызмы?* Ф.Хөсни. **Борынга борын** Кара-каршы килеп, йөзгә-йөз торып. *Тыкрык уртасында борынга борын Аю Әхмәте белән очраштылар...* Г.Сәгыйров. **Борынга борып (бөтереп, төреп) тыгарлык** Бик яхшы, әйбәт, югары сыйфатлы. *Ә һавасы нинди, борыныңа төреп тыгарлык, ди безнең әткәй.* А.Гыйләҗев. **Борынга ис керү** 1) Дәрт уяну, дәрт керү (яшүсмерләргә карата); 2) Тәҗрибә туплау, дөньяны, тормышны аңлау, аның турында фикер йөртә башлау. *Юк, хәзер безгә тәти идеаллар сөйләп алдый алмассың, безнең борынга да ис керде.* Н.Исәнбәт. **Борынга киртләп кую** Әйткәнне, ишеткәннәрне хәтердә калдыру, истә тоту. **Борынга сугу (суктыру, чиертү)** Өстенлеккә ирешү, каршы якны узу, җиңү. *Шунда, бер уңайда, моңарчы үзе белән исәпләшмичәрәк йөрүче --- командирның да борынына чиертәсе килә иде.* Г.Бәширов. *[Җәләш мулла] --- бар көче белән, тирә-як муллаларының «борынына сугарлык» киенергә тырыша.* Г.Ибраһимов. **Борын җимерү** Авыз-борынны канату (сугып яки бәреп). **Борын җыеру** Ризасызлык белдерү, баш тарту, килешмәү. **Борын күтәрү (чөю)** Масаю, тәкәббер кылану, эреләнү, минбеләмлек дәгъвасы белән йөрү. *Бәне ташлап, күтәрмә бер дә борның; Яшем төшсә ки, һич тә уңмас урның.* Г.Кандалый. *Бик мактап җибәрсәң, борынын күтәрүе бар.* Г.Мөхәммәтшин. *Безнең Омар ягының бер кыз, яшь кенә студентка, бай семьядан, борынын чөеп йөри иде.* Г.Ахунов. *Җәйгә чыксаң, җилләр өчен Җәй келәткә урыныңны; Миннән артык яр тапмассың, Бик күтәрмә борыныңны.* М.Фәйзи. **Борынны югары тоту** *к.* **борын күтәрү**. **Борыны белән боз тишү (чоку)** Бик үткен, чая кешегә карата әйтелә; теләсә нинди каршылыкны җиңеп чыгу, бирешмәү. **Борын салу (салындыру, төшерү), борын салыну (төшү)** 1) Йөздә канәгатьсезлек билгесе чагылу, кәеф китү, үпкәләү. *Кайнар ашсыз, яңгыр эчендә, дип, Борныгызны салып йөрмәгез, Өстегезгә төшкән бурычларны, Егетләрчә, барын эшләгез.* Һ.Такташ. *Нишләп, иптәш, монда, берьялгызың гына, әвене янган кеше шикелле, борыныңны салындырып, ни эшләп утырасың?* Г.Камал; 2) Мескен хәлгә төшү, элеккеге тәкәббер хәлен югалту. *Төшендеңме хәзер син, юлбасар, Ник борыныңны түбән төшердең?* Ф.Кәрим. **Борын сузу** Нәфесен сузу, өметләнеп, кызыгып йөрү. *Безнең часовойга маузер төзи, Борынын сузган, канга кызыгып.* Ф.Кәрим. **Борын төбендә** 1) Бик якында, янәшәдә, янында ук. *Сәер бит, Казан җиренә басып кергәндә, башкаласының борын төбенә китереп, Иван Грозный иң элек ныгытма корган, аннары Казан илен басып алган.* Ш.Маннур; 2) Күптән түгел. **Борын төртү (төртеп чыгу)** 1) Борынлау (бәпкә, чебеш). *Яңа гына күкәйдән борын төртеп чыккан чеби бик җылы сөючән була.* А.Расих; 2) Тишелеп чыгу, шыту, шытып чыгу (үсемлек орлыгы). *Аннары инеш аръягындагы тау кырыеннан кыяр-кыймас кына борын төртеп чыккан яшь чирәм исе килгәндәй, су буендагы тал бәпкәчекләренең исләре борынын кытыклагандай тоелды.* Г.Бәширов. *Ул кар астыннан яңа гына борын төрткән умырзаяларның, --- гүзәллеген тасвирларга сүзләр, чагыштырулар, эпитетлар хәзер дә таба алмыйм.* Т.Нәҗмиев; 3) *күч.* Барлыкка килү, туу (яңалык, үзгәрешләр). *Яшь шагыйрь С.Рәмиевтә, Дәрдемәндтә, Тукайда борын төрткән яңалыкларны үрчетеп җибәрде, үзеннән күп яңалыклар тудырды.* Х.Госман. **Борын төртер урын булмау** Бик тыгыз булу, басып торырлык та урын калмау. **Борын тыгу** Берәр эшкә, сүзгә кирәкмәгән җирдә урынсыз катышу, тыгылу, кысылу. *Бала-чагасына кадәр зурлар эшенә борынын тыгып йөри.* А.Алиш. *Аңа гел йөрергә, бөтерелергә, һәркемнең кесәсенә, кызыксынып, борын тыгарга булсын.* Г.Мөхәммәтшин. **Борын чәйнәшү** Үзара тарткалашу, даулашу, сугышу. *Мал өчен, корсак өчен берберсенең борыннарын чәйнәшәләр дә алар.* Һ.Такташ. **Борын чөерү** Кем белән дә булса мөнәсәбәтне өзү, кемнән-нәрсәдән дә булса читләшү. **Борыны белән күкне сукалый (сөрә)** *мыск.* Бик каты масаеп, борынын югары чөеп йөрү. **Борыны гына утырып калу** Бик нык ябыгу, тире белән сөяккә калу. *Соңгы вакытта болай да аның борыны гына утырып калган иде.* Г.Әпсәләмов. **Борыны кипмәгән** *кимс.* Тәҗрибәсе җитәрлек түгел, яшь-җилкенчәк, тәҗрибәсез. *Турысын әйткәндә, борының да кипмәгән.* Т.Гыйззәт. **Борынын тарту (тартып тору)** 1) Нәрсәдер өмет итү; 2) Кыюсызланып, гаебен танып тору. *Малай, борынын тартып, курка-курка, нәрсәдер мыгырдый, ләкин җавап бирә алмый.* С.Бакиев. **Борынын төшерү** 1) Күңелен төшерү; 2) Артык узынган, кәперенгән кешегә чик кую. *Бик күпне сыпырды инде, әзрәк борынын төшермәссеңме икән, шәкертләр көрәшергә оста булалар алар.* М.Гали

**БОРЫН** II *и. геогр.* Почмаксыман булып, елга, күл, диңгезгә кереп торган коры җир. *Гүнҗәлле пляжы Ялыкавакныкыдай купшы түгел, әмма монда кырыс табигатьнең үз яме – каршында иксез-чиксез зәңгәр диңгез киңлеге ачыла, даганың ике җәбе биек борын булып тәмамлана.* Т.Әйди

**БОРЫН** III *рәв.* **1.** 1) Элек, үткән заманда, бик күптән. *Борыннан мондый эшне күп күреп, бик күп ишеткәнгә, Батырның бик исе китми...* М.Гафури. *Аның борыннан да атлары бик яхшы, арба вә сбруе бик шәп иде.* Г.Ибраһимов. *Нинди нәсел дип тә булмый аларны, борыннан килгән вак нәсел дә, колхоз вакытында алынган кайбер эре нәселләр дә сугыш вакытында буталып беткәннәр.* Ә.Еники

2) Алдан, беренче булып. *Туйга барсаң, борын бар; борын барсаң, урын бар.* Мәкаль. *Икесе дә намазны истән чыгармыйлар, уразаны өч ай борын сөйли вә көтәләр.* Ш.Камал. *Теләгем күп, ләкин, һәммәсеннән борын, Җир йөзеннән алсаң иде кояш нурын.* М.Гафури

**2.** *бәйл. функ. -мас, -мәс* формалы фигыль белән килеп, баш җөмләнең хәбәрендәге эшнең иярчен җөмлә хәбәрендәге эштән алда үтәлгәнлеген белдерә. *Сикермәс борын «һоп» димә.* Мәкаль. *Казан тәхетенә Сәхиб Гәрәй чакырылмас борын ук, Кырым Казанны «үз йортыбыз» дип карый башлады.* Г.Гобәйдуллин. *Эченә кермәс борын каршы алып торган таныш каеннарны күрүгә үк, йөрәк, ничектер, шыгырдап киткән төсле булды.* М.Әмир. *Чанага утырыр-утырмас борын дилбегәне какты.* М.Хәсәнов

**БОРЫ́Н АВАЗЛАРЫ** *и. лингв.* Йомшак аңкау түбәнрәк төшеп, тавышның бер өлеше борын аша үтеп ясала торган авазлар (*м, н, ң*)

**БОРЫ́Н-БОРЫН** *рәв. сөйл.* Бик борынгы, элекке, күптән үткән. *Борын-борын заманда, кәҗә – команда, саескан – сотник, карга – урядник, бүре – патша, байлар түрә булып торган заманда...* А.Әхмәт. *Борын-борын заманда, юаш хайваннарның, ерткыч җанварларның койрыклары бөтенләй булмаган.* А.Алиш. *Борын-борын заманнарда, Монда болай бакча булмаган, Ул чагында монда һичбер кеше Килеп сарайлар да салмаган.* Ф.Бурнаш

**БОРЫ́Н-БОРЫННАН** *рәв. сөйл.* Бик борынгы заманнан, әллә кайчангы вакыттан, бик күптән, электән. *Телнең әдәби булмаган төре тарихи яктан борын-борыннан килә.* В.Хангилдин. *Бу еллар, тирә-юньдәге әйберләрне, борын-борыннан сакланып килгән гадәтләрне, шулай булырга тиеш дип каралган нык законнарны гына түгел, кешеләрнең үзләрен дә үзгәрттеләр.* К.Нәҗми. *Борын-борыннан, ата-баба заманыннан калган түр сәкене, астындагы каз оялары, тараканнары, шөшле, чабата калыплары белән бергә, ишегалдына чыгарып аттылар да, аның урынына, укытучы кызлары ак шарлы, сыгылма челтәрле тимер кровать белән аяклы тегү машинасы кертеп утырттылар.* Г.Бәширов

**БОРЫНГЫ** *с.* **1.** 1) Бик күптәнге, элекке замандагы. *Язгы чәчү алдыннан үткәрелә торган бу бәйрәмнең борынгы болгар ыруларында булуын тагын бер дәлил раслый.* Г.Гыйльман. *Безнең бик борынгы бабаларыбыз чиктән тыш кыен шартларда яшәгәннәр.* Г.Бәширов. *Тышкы кыяфәте белән борынгы хан сарайларыннан да гүзәлрәк безнең өй.* Р.Ишморат. *Борынгы йортлар, биеклекләре белән түгел, ә бизәлү рәвешләре белән генә ярыша алалар.* М.Галиев

2) Элекке, баштагы, әүвәлге. *Минем борынгы матурлыгым юк.* М.Гафури. *Борынгы шатлыгың юктыр сүзеңдә, Ничөн хәсрәт күренде йөзеңдә?* Дәрдемәнд

**2.** *и. мәгъ. к.* **борынгы заман.** *Җаныңны яңа сынауларга әзерләү борынгыдан ук кулланылучы йола һәм ырымнарның берсе булып тора.* Ф.Яхин. *Менде күккә шулай, төтен булып, Борынгының соңгы билгесе.* Ш.Маннур

**3.** *рәв. мәгъ.* Элеккечә. *Галимә апа белән борынгы кебек сөйләшәсем килә.* М.Гафури

**БОРЫНГЫДАН** *рәв.* Борын-борыннан; элек-электән, әллә кайчаннан; әүвәл заманнан

**БОРЫНГЫ́ ЗАМАН** *и.* Күптән үткән заман, элекке вакыт, иске заман. *Борынгырак заманнарда авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләре авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә йомырка да чәчә торган булганнар.* Г.Бәширов. *Борынгы заман булса, ул үзе мондый шөбһәләргә бирелмәс иде.* Г.Ибраһимов

**БОРЫНГЫЛАР** *и.* Ата-бабалар, нәсел башлыклары. *Әйләнеч булса да, юл яхшы, дип, борынгылар белмичә әйтмәгәннәр шул.* Р.Хафизова. *Язның бер көне ел туйдыра, дигәннәр борынгылар, чәчүгә әзерлекләр ничек бара, Гайфетдин Гайнетдинович?* М.Галиев. *Әлбәттә, борынгылар метеоритлар хакында берни дә белмәгәннәр.* Г.Гыйльман. *Борынгылар, кайгы-хәсрәтне дәваларга иң зур шифа – вакыт, иканен белми әйтмәгәннәр.* Р.Хафизова

**БОРЫНГЫЛА́РЧА** *рәв.* Борынгы кешеләр кебек. *Өс-башында вә бөтен тормышында борынгыларча булуны сөя.* Г.Ибраһимов

**БОРЫНГЫЛЫК** *и.* 1) Борын-борын заманда булган нәрсә, бик күптәннән, борынгы заманнардан ук килгән тарих. *Керсә монда берәү, меңәр еллык Борынгылык белән уралыр.* Ш.Маннур

2) Борынгы тәртип, йола, гореф-гадәт. *Үзеңне лаеклы тот, өйдәгеләр борынгылыкны ярата минем.* А.Гыйләҗев

3) Борынгы әйберләр, истәлекләр һ.б.ш. *Көн тәртибендә телдәге борынгылык-китапчылык калдыкларыннан, архаик элементлардан ничек котылу һәм халык сөйләме җирлегендәге әдәби тел нормаларын ничек аңлау мәсьәләсе торды.* XX йөз башында татар әдәбияты

**БОРЫНГЫ́ ТАРИХ** *и.* Тарихта, шартлы рәвештә, яңа эраның бишенче гасыры белән чикләнгән чор

**БОРЫНГЫ́ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ** *и.* Татар халкының феодализм һәм капитализм чорында иҗат иткән әдәби мирасы

**БОРЫНГЫ́ ТАТАР ТЕЛЕ** *и.* Милли әдәби тел формалашуга кадәр

булган татар халык теле. *Китап теле тәэсирендә, керәшен татарларының күбесе өчен уртак булган дини лексика барлыкка килә, борынгы татар телендә һәм татар сөйләшләрендә сирәк кулланылган яки онытылып бара торган кайбер сүзләр боларда, киресенчә, активлашып китә яки башка семантик үсеш ала.* Мирас

**БОРЫНГЫ́ЧА** *рәв.* Борынгы замандагы кебек; элеккечә, искечә. *Укуым борынгыча, шул заманга караганда шәп барды.* М.Гафури. *Беләкләренә җиңсә бәйләп, аякларына, эш кешеләредәй, оек-чабата кигән әбиләр; кайсы киндер алъяпкыч япкан, кайсы, билбау урап, башларына борынгыча ак эшләпәләр кигән бабайлар.* Г.Бәширов. *Ә шулай да минем сине, борынгыча, Сәйфүк дип кенә атыйсым килә.* Ә.Еники

**БОРЫНДЫК** *и.* Тиенсыманнар семьялыгына кергән, аркасында кара сызыклары булган, җирдә өн казып яши һәм кыш көне йокыга тала торган, имезүче кимерүче җәнлек; җир тиене; *русчасы:* **бурундук**. *Ә җирдә аунап яткан ботакларда яшькелт сары төстәге җәнлекләр – борындыклар йөгерешә. Сызгырырга бик оста икән үзләре.* Ә.Маликов. *Аучыларга еш кына --- борындык --- җыйган бик күп эрбет чикләвекләрен табарга туры килә.* СССР физик географиясе. *Кайчак талау-разбойга да бара, борындык оясын таба икән, аның запасларын тартып ала, җае чыкса, хуҗаның үзен тотып ашарга да күп сорамый.* Кызыклар дөньясында

**БОРЫ́Н ЗАМАН** *рәв. сөйл. к.* **борынгы заман.** *Борын заман бер авылда Җиде зирәк кыз булган.* Т.Гыйззәт. *Борын заман җырлаучылар, Чиерткәләп кылларын, Кайвакытны болай диеп Башлаганнар җырларын.* Ә.Исхак. *Борын заман һәлак булган Ханнар – батып туфанга.* Г.Камал

**БОРЫ́Н КАНАТЛАРЫ** *и.* Борын тишекләренең тышкы стеналары. *Хәйдәрнең кара бөдрәләрен җил тузгыта, матур уелган борын канатлары еш-еш селкенә иде.* Г.Бәширов

**БОРЫ́Н КУЫШЛЫГЫ** *и.* Борын эчендәге бушлык. *Борын куышлыгы баш сөягенең алгы ягына тишем белән ачыла.* Кеше анатомиясе

**БОРЫНЛА́У** *ф.* 1) Чәчелгән орлык тишелеп чыгып, җир өстендә күренү, шыта башлау, үренте чыгару. *Кар астыннан ала сыер төсле җирнең күренүе була, язгы суган яшәреп борынлый.* Ә.Галиев

2) Йомырка кабыгын томшыгы белән тишеп, кош баласы туу. *Өч атна дигәндә, йомыркалар борынладылар, берәм-берәм, чебешләр чыга башладылар.* А.Алиш

3) *күч.* Барлыкка килү, туу. *Аларның әле тормыш юллары борынлап кына килә.* Р.Хафизова

**Борынлап бетү** Барысы да тоташ борынлау

**Борынлап килү** Акрынлап, әле яңа гына борынлау. *Әдип, дусларча, Гайнанның иңбашына сугып алды: – Менә тагын бер көрәшче борынлап килә! – диде.* Г.Бәширов. *Тегеләрнең күңелендә борынлап килгән хисләрнең яралгысын ук күрә белергә тиеш ул.* М.Маликова

**Борынлап чыгу** Барлыкка килү; туу. *Бәпкәләр борынлап чыгуга, күршекүлән, якын-тирә авыллар әнигә каз белешә киләләр иде.* Д.Гайнетдинова. *Сөенечләрне арттыра-арттыра [бөртекләр] борынлап чыктылар да тирәяк киңлекләрне яшеллеккә күмделәр.* Н.Хәсәнов

**БОРЫНЛЫК** *и. к.* **борынчык** (*2 мәгъ.*). *Мин шулай, дуслар сөйгәнгә, Борынлык та кимәдем. Дускаем, миннән курыкма, Мин бит ауга килмәдем.* Б.Рәхимова

**БОРЫННАН** *рәв. сөйл.* Электән, элек-электән, күптәннән килгән, борынгы заманнан ук. *Борыннан мондый эшне күп күреп, бик күп ишеткәнгә, батырның бик исе китми.* М.Гали

**БОРЫ́Н ТӘМӘКЕСЕ** *и.* Насвай, иснә торган тәмәке. *[Сакчы] Борын тәмәкесе тарта.* Ф.Бурнаш

**БОРЫНТЫК** *и. к.* **борынчык** (*2 мәгъ.*). *Борынтык агачына бәйләгән сүс бавы тартылып, борыны авырткан дөяләр ямьсез тавыш белән акыргалап җибәрделәр.* М.Галәү

**БОРЫНЧА** *бәйл. сөйл.* Эш-хәлнең исемдә күрсәтелгән шундый әйберләрнең һәрберсендә кабатлануын белдерә; саен, буенча (*өй, йорт, капка* сүзләре белән). *Авыл төрле хәбәр белән тулды: хәзер алпавытның икмәк амбарларын таларга баралар икән; шуның өчен, өй борынча капчык җыялар икән.* И.Гази. *Әле син монда сасытып утырасыңмы? Көн буе өй борынча лыгырдап йөреп армадыңмыни?* Ф.Бурнаш

**БОРЫНЧАК** *и. к.* **борынчык** (*2 мәгъ.*). *Әгәр инде шул авылда кунып та калса, аңгыра хайваннар, мөгрәп, дәрәҗәле кешене вакытыннан элек уята күрмәсен, дип, сыерларга борынчак кигереп, көтүне аскы урамнан куа торган булалар.* Казан утлары

**БОРЫНЧЫК** *и.* 1) Кечкенә борын. *Курыкмагыз! Мин дә нәкъ шушындый Нәниемне киттем калдырып... Борынчыгы нәкъ шул... күзләре... А!!!* Ә.Фәйзи

2) Тешләмәсен яки анасын имә алмасын өчен, эт, бозау, колын, кәҗә бәтие һ.б.ш. хайваннарның борынына кидереп куела торган җайланма. *Аннан соң, бүрегә борынчык кигезәсең дә, җитәкләп, йә булмаса ат сыртына салып кайтасың.* Р.Батулла. *Дөрес, башта шофёр мыгырданган булды. Янәсе, этен борынчыксыз алып бара.* Я.Шәфыйков

3) Элпәканатлылар семьялыгына караган бөҗәкләр гәүдәсенең алгы өлешендә урнашкан озынча ук. *Төклетураның борынчыгы умарта кортыныкы ише генә түгел: шактый ук озын.* Г.Хәсәнов

**Борынчык салу** *к.* **борынчыклау**

**БОРЫНЧЫКЛА́У** *ф.* Хайван авызына борынчык кидерү

**Борынчыклап алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә борынчыклау. *[Бүренең өстенә] Сикереп барып төштем дә каеш белән авызын борынчыклап алдым.* Г.Галиев

**Борынчыклап кую** Борынчык кидерелгән хәлдә калдыру

**БОРЫ́Н ЯУЛЫГЫ** *и.* Гадәттә, кесәдә йөртелә торган махсус кечкенә яулык; кулъяулык. *Ул кеше, әллә кая – Идел аръягына карап, аның сүзләренә илтифат итмичә, кесәсеннән борын яулыгы алып, кояш эссесеннән кызарып, бөрчек-бөрчек тирләр чыккан битен җилпи...* М.Гафури

**БОРЫ́Н ЯФРАКЛАРЫ** *и. к.* **борын канатлары.** *Солдатта, Кавказ тауларында крушениегә эләккән чагында ярылган, һәм соңыннан яра эзе гомергә бетмәслек булып калган киң борынының эре яфраклары селкенергә тотындылар.* Г.Әпсәләмов. *Мәдинә яшь белән мөлдерәп тулган күзләрен кинәт Нурисламга борды, борын яфраклары, иреннәре калтырады.* Ф.Садриев

**БОРЫС** *и. рус.* 1) Ишек, тәрәзә яңагы һ.б.ш.ны ясау өчен махсус әзерләнгән дүрт кырлы агач материал. *Тагын да ышанычлырак булсын өчен, туп торган платформасын агач борыслар белән калынайттык.* С.Сабиров. *Столярлык мастерскоенда «рейсмас» дигән прибор бар. Ул борысның кырыйларын параллель итеп эшкәртү өчен кулланыла.* Геометрия. *Башта агач борысның бер кырыен тип-тигез итеп струклыйлар, ә соңыннан аның өстенә рейсмасны куялар һәм борыс буйлап йөртәләр.* Геометрия

2) *диал.* Ишек, тәрәзә яңагы. *Гәрәй ике куллап киерелеп тарткан иде, борыслары-ниләре белән ишекне кубарып чыгарды.* А.Гыйләҗев

3) *спорт* Горизонталь беркетелгән колгалар рәвешендәге гимнастика снаряды

**БОРЫСЛЫК** *и.* Ишек, тәрәзә яңагы һ.б.ш. ясау өчен яраклы, борыс буларак кулланырга мөмкин булган агач материалы

**БОРЫЧ** *и.* **1**. 1) Ике орлык өлешле үсемлекләр семьялыгыннан, җылылык ярата торган кузаклы үсемлек. *Колаклары кызыл борыч төсенә кергән мәзин бөтенләй бүртенде.* К.Нәҗми. *Заводтан чыкканда да колаклары кызыл борыч кузагы кебек яна иде.* Г.Әпсәләмов. *Кара борыч борычлылар семьялыгына керә.* Н.Верзилин

2) Шул үсемлекнең кузагы, кузак эчендәге орлыгы, шушы орлыктан төеп ясалган ачы аш тәмләткеч. *Йөземе дә бар, борычы да бар.* Ә.Фәйзи

**2**. *с. мәгъ. күч. сөйл.* Зәһәр, ачы. *Сүзләре – борыч: әйткән бере йөрәкне ачыттыра*

◊ **Борыч сибү** Әче, төртмә сүзләр әйтү. *Ир белән хатынның үпкәләшепәйткәләшеп алуы – ул бит ашка борыч сибү кебек кенә! Аның ише ачылышып алулардан соң, сөешү бигрәк татлы була, дияр.* М.Маликова

**БОРЫЧЛА́П-ТОЗЛАП** *рәв.* 1) Төрле тәмләткечләр кушып, тәмле итеп. *Борычлап-тозлап, суган салып кыздырылган бавыр итеннән хуш исләр бөркелә.* Х.Ибраһим

2) *күч.* Бик каты тәнкыйтьләп, үтемле итеп. *Андыйлар Локман Закировка күп тапкырлар «борычлап-тозлап» тал чыбыгы ашаттылар.* М.Әхмәтҗанов

**БОРЫЧЛА́У** *ф.* 1) Борыч салу, борыч сибү. *Фәрит, суганлап, борычлап, көнбагыш мае белән, примуста, чыжылдатып, бәрәңге котлетлары куыра.* Ш.Камал

2) *күч.* Каты итеп ачулану, әрләү. *[Боцман] Бердүнең эшен мактый, икенчесенең ялкаулыгын күреп, тозлап-борычлап сүгеп китә. Ләкин аңа беркемнең дә хәтере калмый.* М.Юныс

◊ **Борычлап әйтү** Ачы итеп, төрттереп әйтү

**Борычлап алу** Бераз, берникадәр борычлау

**Борычлап җибәрү** Бераз борыч сибү. *– Бир әле монда борыч савытын... Бераз борычлап җибәрик!.. – диде.* Ш.Камал

**Борычлап җиткерү** Тиешенчә борычлау

**Борычлап кую** Алдан ук борыч сибеп әзерләү

**Борычлый төшү** Бераз борычлау; тагы да борычлау

**БОРЫЧЛЫ** *с.* 1) Борычы булган, борыч сибелгән. *Итле, борычлы кайнар токмач исе, борыннарны кытыклап, авызлардан сулар китерде.* Г.Гобәй

2) *күч.* Ачы, зәһәр әйтелгән. *Хәер, көн болай да эссе иде, тик Шиловның борычлы сүзләре аны күбрәк тиргә батырды.* Х.Камалов

**БОСОНО́ЖКА** *и. рус* Башы һәм үкчәсе ачык калдырып эшләнгән җиңел җәйге аяк киеме. *Ком-таш арасында босоножки кияләр димени, менә минеке ише чүәк кирәк!* С.Сөләйманова

**БОСС** *и. ингл.* 1) Партия, предприятие, учреждение һ.б. хуҗасы. *Кая, ди, анда нindидер партия боссы, моның ишеләрне күренекле бертуган Стругацкийлар да уйлап таба алмас иде.* Р.Мирхәйдәров

2) Политика, профсоюз лидерларының рәсми булмаган атамалары

**БОСТАН** *и. фар. иск.* Бакча. *Кич кунамын бостанда ла, Җырлыйм эчем пошканда.* Ф.Бурнаш

**БОСТОН** I *и. ингл.* **1**. Бертигез калынлыктагы аркау һәм буй җепләреннән тукылган саф йон тукыма. *Дәүләтьяров юп-юка инглиз бостонынан теккән яңа кителе, яңа галифесы белән --- иптәшләреннән аерыла иде.* И.Гази

**2**. *с мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Өстендә – хәрби гимнастёрка белән зәңгәр бостон итәк, билдә – портупея.* В.Имамов. *Йөреше салмак, иңбашында – бостон костюм.* Н.Исәнбәт

**БОСТОН** II *и. ингл.* Вальсның бер төре; салмак йөрешле парлы бию. *Төрле бию көйләрен уйната. Фокстрот, вальс, бостон, арага, әнә шул «Гайнавал» кебек, үзебезнең татар көйләрен дә кыстырып җибәрә.* М.Әмир

**БОСТОН** III *и. ингл.* Карта уены, вистның бер төре. *Бостон уйнау. Бостон өстәле*

**БОСТО́НКА** *и. ингл. типогр.* Зур булмаган басу машинасы

**БОТ** *и.* 1) Аякның тездән башлап оча сөягенә кадәр булган өлеше; аякның тубыктан югары өлеше. *Табаның батса – тезең бата, тезең батса – ботың бата.* Г.Ибраһимов. *Аның бот башындагы ярасы инде күптән төзәлде, ләкин яңагындагы ярасы әле һаман төзәлеп җитми иде.* А.Шамов. *Безнең аюлар да шулай: йоклаганда, ояда, нәниләрен бот араларына салып яталар.* Р.Фәизов

2) Кошларда: аяк. *Красный крест больницасында тавык боты гына кимереп ята ул.* К.Нәҗми. *Пассажирлар, шул исәптән носилкадагы яралылар да, аның Гөлсем апа пешереп биргән тавык ботын, тозга манып, әз-әз кабып, әдәп белән ашап утырганына сокланып карап торалар.* Г.Гобәй

◊ **Бот буе** *гади с.* Кечкенә гәүдәле; бәләкәй генә (гадәттә балага карата әйтелә). *Урман кисәргә, я таш чыгарырга*

*бот буе малайны кем алсын?* Г.Бәширов. **Бот күтәреп яту** *гади с.* Эшләмичә яту, ялкаулыкка бирелү. *[Шәриф:] Чыкмый булмас, чыгып карарга кирәк, бот күтәреп, көтеп, буш ятсаң, ашарга китереп бирмәсләр.* М.Гафури. *Кыш буе, бот күтәреп, тик ятар иде Ибраең...* М.Әмир. **Бот чабу, ботка сугу** Шатлану, үкенү, борчылу, гаҗәпләнү, шаккату кебек хисләрнең бик көчле булуын белдереп, ботка сугып алу. *Низами, үрсәләнеп, ботына сугып куйды.* М.Әмир. **Бот чабып (бот чаба-чаба) көлү** Бик каты, тыела алмыйча көлү. *Шаулашып, бот чабып көләләр. Кыз, Хөрбануның кулын кагып җибәреп, кымызын түгә.* М.Фәйзи. **Ботыннан асып кую** *гади с. шаяр.* Җәза бирү; ачулану, тиргәү **Ботыннан тотып селексәң дә булмый (юк)** Берни белми, шыр надан, томана

**БО́ТА** *и. фр. сөйл.* 1) Юеш яки салкын һавада туфли яисә ботинка өстеннән киелә торган кыска кунычлы аяк киеме

2) Хатын-кызлар өчен резин итек. *[Әминә] Чемоданындагы боталарны, чыгарып, аягына киде.* Г.Минский

**БОТАК** *и.* 1) Агач кәүсәсеннән үсеп чыккан ян үсенте, тармак. *Яшь алмагачның ботаклары үзләренә сарылган эре-эре яшел алмаларны көчкә күтәреп торалар.* И.Гази. *Хәмдия, бераз вакыт, яр буенда тын гына басып торды, бары шуннан соң гына, агач ботакларына тотына-тотына, югары менеп китте.* Н.Фәттах. *Талгын җилдә Аккош күле чыршысы, ботакларына кунган карлардан кагына-кагына, тын гына утырып тора.* Шәһри Казан

2) Ягулык итеп файдалана алырлык чыбык-чабык, коры-сары; кәүсәсеннән аерылган тармак, үсенте

◊ **Ботакка атландыру** Алдау

**БОТАКЛАНУ** *ф.* Ян-якка яңа ботаклар чыгару, ботаклар җибәреп үсү, тармаклану. *Инде ул мәңге тамыр җәймәс, Ботакланмас тагын, икенче кәррә ярмас яфрагын.* Г.Тукай

**Ботаклана бару** Акрынлап, яңа ботаклар чыгарып ботаклану, ботаклары арту

**Ботаклана башлау** Ботакланырга тотыну

**Ботаклана төшү** Беркадәр ботаклану

**Ботакланып бетү** Күп ботаклар чыгарып тармаклану

**Ботакланып килү** Акрынлап, ботаклар чыгару

**Ботакланып китү** Кинәт ботаклану

**БОТАКЛЫ** *с.* Ботаклары булган. *Дүрт ягыннан каплап алган куе ботаклы, башларын югары күтәреп торган агачлар, бу бинаны, үзләренең челтәрле күләгәләре белән, кояшның башка каба торган эссесеннән саклап, җиңел вә рәхәт салкынлык һәм ял итү урыны ясыйлар иде.* Ф.Әмирхан. *Ботаклы-ботаклы кәкре таяк булды бу.* Р.Фәизов

◊ **Ботаклы көенчә (селтәү)** Ничек бар, шулай, булганынча (әйтү), күңелгә авыр тәэсир ясарлык итеп (сөйләү)

**БОТА́К ТИШЕГЕ** *и.* 1) Ботакны кисеп алганнан соң, бүрәнәдә, тактада калган эз, чокырлы яки тишек урын. *Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге.* Мәкаль

2) *этн.* Ботагы аерылып чыгып, күз сыман тишек булып калган, имләү өчен файдаланыла торган ботак төбе (каз бәпкәләрен, чебиләрне, умарта кортларын, күз тимәсен өчен, шуның белән имлиләр)

**БОТА́НИК** I *и. рус* Ботаника белгече. *Өлкән кызлары – ботаник. Уллары да ботаник булырга хыяллана.* Сөембикә

**БОТА́НИК** II *с.* Ботаникага караган, ботаникага мөнәсәбәтле, шуңа бәйләнеше булган. *Гаҗәеп аяз төннең тыныч һәм хуш исле кичен мин ботаник бакчадан ерак түгел бер җирдә каршы алдым.* Ф.Әмирхан

**БОТА́НИКА** *и. гр.* 1) Үсемлекләр дөньясын (төзелешен, үзенчәлекләрен һәм функцияләрен, Җир шарындагы таралышын, төркемнәрен, үзара бәйләнешләрен, килеп чыгышын) өйрәнә торган фән. *Бу үлән Татарстанның башка бер генә авылында да юк, бу үлән ботаника белешмәлекләрендә дә, мин йөргән Цейлон, Һиндстан, Сурия, Италия, Финляндия җирләрендә дә юк.* М.Мәһдиев

2) *сөйл.* Шул фәнне өйрәнә торган уку предметы. *Шәүкәт – укытучы. Бишенче сыйныфларда ботаника укыта.* Т.Миңнуллин

3) *сөйл.* Шушы фән буенча дәреслек. *Мәсәлән, ботаника дәреслегендә былбылны очратмассың.* И.Низамов

**БОТАРЛА́У** *ф.* 1) Санын санга аеру, сөяк-санагын аергалау (ит түшкәсе турында). – *Ник [ит] булмасын, – ди, ире әйтә, – амбарда бөтен дию бар, шуны сал, ул да җитмәсә, әнә түрдә тагын бер дию утыра, шуны ботарлап бирермен, – ди.* Әкият // Кисәкләргә аерып ташлау, рәхимсез тарткалап өзгәләү, ерту. *Ярасыннан сызланып, тагын даerткычланган бүре, Акбайны үткен тешләре белән ботарлап ук ыргытты.* Н.Гыйматдинова. *Бүреләр этләрне генә түгел, бер-берсен, хәтта үз балаларын да тотып ботарлыйлар.* Кызыклар дөньясында

2) *күч.* Ерткычларча кыйнап имгәтү; үтерү. *Кыскасы, дошман никадәр генә ботарлап ыргытырга тырышмасын, аңа үч итеп, мин һаман яшим, мин һаман исән әле!* Г.Бәширов. *Дәүләтьяров, үзен ботарларга торган кешеләрне күреп, кинәт шабыр тиргә батты, ни өчендер, борынындагы пенснесын, салып, учына йомарлады...* И.Гази

3) Ботакларын сындыру, өзгәләү, аергалау (үсемлекләрне, куакларны). *Шомырт агачын ботарлау*

4) *күч.* Авазларны, сүзләрне, гомумән, тел законнарын бозып сөйләү яки көйне бозып җырлау. *Ярым урыс буын алга чыкты, Әйтелешне шулар буталый. Миллилекне безнең саклап килгән Төп хәзинә – телне ботарлый.* И.Гыйләҗев

**Ботарлап алу** 1) Тиз генә ботарлау, саннарга аеру; бер өлешен каерып бүлү

2) *күч.* Өстенлекне алу, өстен чыгу. *Кияү буласы егет бит син, ату, кара аны, син аласы урынга, кыз үзе сине ботарлап алмасын.* Г.Минский

**Ботарлап ату** Тулысынча, аннан-моннан тарткалап, кисәкләргә ботарлау. *Аннан аңа өч тәгәрмәчле велосипед алып бирделәр. Малай аны да бик тиз ботарлап атты.* Ф.Яруллин

**Ботарлап бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы ботарлау. *Элеккеге елларда, сабыр гына*

*лифт күтәргә түземлеге җитмәгән үсмерләр, әрҗәләрне каерып, килгән почтаны ботарлап баралар иде.* К.Кәримов

**Ботарлап бетерү** Тәмам өзгәләп ботарлау. *Миләш, шомырт ботакларын кешеләр, каерып-сындырып, ботарлап бетергәннәр.* Ш.Галиев. *Бүтән ерткычлар исә үз корбаннарының бугазын чәйниләр, канын эчәләр, эчен актаралар, кыскасы, талап, ботарлап бетерәләр.* Н.Фәттах

**Ботарлап кую** Алдан ботарлау, ботарланган хәлгә китерү. *Өстәл тирәли хатын-кызлар тезелешеп утырганнар иде. Уртада казмы, үрдәкме ята – ул ботарлап куелган.* М.Вәли-Барҗылы. *Тавыкны да оста гына ботарлап куйды, аннары егетләрне чын ихластан кыстарга тотынды.* Ә.Еники

**Ботарлап ташлау** Кызу-кызу, аннан-моннан тарткалап ботарлау. *Саташып йөрүче шул шатун, юлында ни очраса, шуны ботарлап ташлый, хәтта ки кешене дә аяп тормый.* Р.Мулланурова. *Тәмам бар гәүдәмне ботарлап ташлыйсым килә.* Г.Камал

**Ботарлап тору** Даими рәвештә, һәрвакыт ботарлау

**Ботарлап чыгу** 1) Тулысынча, башыннан ахырына кадәр ботарлау; беткәнче ботарлау. *Шушындый гаҗәп хәлләр белән беррәттән, җимеш бакчаларын ботарлап чыгулар да ешая.* А.Алиш

2) *күч.* Аннан-моннан, сыйфатсыз итеп эшләү. *Үткән җәйдә яшьләр ботарлап чыктылар бакчаны.* Ф.Сафин

**Ботарлап яту** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында ботарлау. *Җик Мәргәннең тыны кысылды, үз күзләренә үзе ышанмый торды: анда-санда ишләренең мәетләре ауный, аларны унлап бүре ботарлап ята иде.* М.Хәбибуллин

**Ботарлый башлау** Ботарларга тотыну. *Тормыш бик ботарлый башласа, баганага сәлам бирердәй буласың.* М.Хәсәнов

**Ботарлый бару** Торган саен ныграк ботарлау

**Ботарлый төшү** Тагын да ныграк ботарлау

**БОТА́У** *ф. диал.* 1) Ботаклардан арындыру, чистарту. *Яшь каенның ботагын Балта бирсәң ботаем.* Җыр

2) Саксыз рәвештә өзгәләү, сындыру. *Клумбадагы гөлләрне ботау*

**Ботап алу** Вакытның бер аралыгында, бераз гына ботау

**Ботап ату** Тиз-тиз, аннан-моннан ботау

**Ботап бетерү** Бөтенесен дә ботау; бер нәрсә дә калдырмыйча ботау. *[Шомырт] Өлгереп тә җитә алмый иде, бәгырь! Ул корып аугандырмы, әллә сындырып, ботап бетергәннәрме?* Ф.Яхин

**Ботап ташлау** Берсен дә калдырмыйча, тоташ ботау. *Барысын да хәзер ботап ташлыйм, өзгәлим дә җилгә таратам...* Р.Харис

**Ботап тору** Даими рәвештә, әледәнәле ботау

**Ботап чыгу** Рәттән, барсын да бер-бер артлы ботау. *Әлбәттә, малайшалай җиләкләргә бер дә тынгылык бирми, ә чәчәкләрне, ел саен, беренче сентябрьгә каршы төндә ботап чыгалар.* А.Тимергалин

**Ботый башлау** Ботарга тотыну

**Ботый бару** Һәрберсен, булган берсен ботау

**Ботый бирү** Ботавын дәвам итү

**Ботый төшү** Беркадәр ботау

**БОТИ́НКА** *и. фр.* Кыска кунычлы шнур белән бәйләнә яисә замок, кнопка белән эләктерелә торган аяк киеме. *Трамвайдан төшүчеләр, ботинкаларын, туфлиләрен кулларына тотып, туп-туры суга сикерәләр иде.* И.Гази. *Ул заманнан бирле минем аякта нинди генә ботинкалар булмагандыр, барысы да онытылган, ә өсте яшел постау ботинкам – һаман күз алдымда.* И.Гази. *Безгә Казан пычрагында таралмаслык нык ботинкалар кирәк.* М.Галиев

**БОТКА** *и.* 1) Ярманы сөткә яки суга салып пешерелгән куе ашамлык. *Тоз салып, ботканы болгатырга керешә, өйгә тәмле ботка исе чыга.* И.Гази. *Балага тимергә аеруча бай булган солы боткасы ашатыгыз.* Сөембикә // Шул ашамлыкка охшаш катнашма. *Күгәрченнәр үз балаларын беренче 18 көндә «сөт», ягъни бүксәләрендә барлыкка килә торган ак төстәге ботка белән туендыралар.* Кызыклар дөньясында

2) Су, дым тәэсирендә изелеп йомшарган урын. *Аяк асты боткага әйләнгән*

3) *күч.* Берәр нәрсәнең буталган катнашмасы, күп булып өелгән өеме. *Кулларын иркәләп чәүмәшкән вак балык боткасын ул ике кулының бармаклары белән сөзгечләп укмаштырды да кушучын кояшка чыгарды.* А.Хәлим

4) *күч.* Буталчыклык, артык, кирәксез күп, тәртипсез яткан нәрсәләр. *Тәртипсез чуалып беткән, тузгыган кәгазь боткасы эченнән кирәкле кәгазьләрне табуы бик кыен булды.* Г.Иделле

◊ **Ботка булу, боткага әйләнү** Буталчыклану, аңлашылмаслык булу (сүз, эш). **Ботка(лары) пешү** Үзара уртак фикергә килеп, килешеп эшләү. *Шуңа күрә аларның боткалары бик пешми.* Ә.Хәбибуллин

**БОТКАЛАНУ** *ф.* 1) Артык куерып китү (аш турында)

2) Юешләнүдән, җебүдән йомшаган, баткакланган хәлгә килү (аяк астындагы җир, туфрак)

**Боткалана бару** Торган саен ныграк ботка хәленә килү, куеру

**Боткалана башлау** Боткаланырга тотыну

**Боткалана бирү** Боткалануын дәвам итү

**Боткалана төшү** Бераз боткалану

**Боткаланып бетү** Тәмам ботка хәленә килү. *Кайчандыр яшь кызлар, киленнәр йөзе чагылган коелар ләмләнеп, боткаланып беткән.* Р.Фәйзуллин

**Боткаланып килү** Акрынлап, боткаланганы сизелә башлау

**Боткаланып тору** Боткаланган хәлдә булу

**БОТЛЫ́-ЧАТЛЫ** *с.* Ботаклы, куе булып тармакланып торган, төрле якка тырпайган. *Кул-аягы ботлы-чатлы, Үзе адәм сынлы бу.* Н.Исәнбәт

**БОТФОРТ** *и. фр.* 1) *иск.* Гаскәриләрнең өскә таба киңәеп киткән, озын каты кунычлы итеге. *[Патша һәйкәлдә] Башына да кимәгән, чәчләре бөдрәләнеп тора (әллә парик микән), мыегы – нәкъ рәсемнәрдәгечә, тезенә хәтле җиткән*

*өс киеменнән; киеме, гомумән, катлы-катлы шикелле, уң иңеннән биленә тасма төшә, киң билбау, чалбар, берсен алгарак чыгарып баскан аякларында озын кунычлы, тез турында киңәеп киткән итек – ботфорт.* Р.Кәрами

2) Хатын-кыз итегенең озын кунычлы моделе

**БО́УЛИНГ** *и. ингл.* Махсус җиһазландырылган бүлмәдә, йөгереп килеп, кул белән авыр шар тәгәрәтеп җибәреп, озын юл очындагы кегельләрне бәреп аударудан гыйбарәт спорт уены. *Алар өчен супермаркет, боулинг, дискотека, төнге клублар кызыклырак.* Сөембикә

**БОХАР** *с.* Бохара ягындагыча эшләнгән, Бохара ягыннан килгән. *Мин караганда, [Ибраһим Хәлфиннең] башында – бохар кәләпүш, өстендә кара казаки иде.* М.Гали

◊ **Бохар йомшагы** Үзе чирләшкә, үзе оешмаган, пешмәгән, булмаган кеше турында

**БОХАРИ** *с. иск.* **1**. 1) Бохара мәдрәсәсендә укыган. *Мәдрәсәнең мөдәррисе – илле биш-алтмыш яшьләрендәге бер бохари хәзрәт иде.* Ф.Әмирхан

2) *к.* **бохар.** *Бу рәсемдә бер тәвәккәл бүрек, бер зур каракүл бүрек, бер бохари чалма төшерелгән.* Ф.Әмирхан

**2**. *и. мәгъ.* Бохара мәдрәсәсен тәмамлаган кеше. *Бохарилар мәҗлесенә һич тә бармам, и раббем.* Г.Камал

**БОХА́Р КАВЫНЫ** *и.* Кабакчалар семьялыгына кергән, кавынның түгәрәк, шарсыман төре. *Ул синең бохар кавыннарыннан да йомры башларың!* Г.Тукай

**БОХА́Р КӘЛӘВӘСЕ** *и. кулин.* Чәкчәкнең бер төре

**БОХА́Р КЫНАСЫ** *и. бот.* 1) Бальзаминнар семьялыгыннан, җете кызыл чәчәкләре сабак тирәли тыгыз булып урнашкан берьеллык үсемлек; *русчасы:* **бальзамин**

2) Шул үсемлектән әзерләнгән буяу. *Карчыкның ялагайланып кыставына һәм, бохар кынасы буялган кара озын тешләрен күрсәтеп, хәйләкәр елмаюына әһәмият бирмәстән, Сәгыйтов сүз ачты.* С.Рафиков

**БОХА́Р МӘЧЕСЕ (ПЕСИЕ)** *и. зоол.* Озын йонлы мәче. *Ишан сүз башлады: бохар песиемени – күз йомылган, муен сузылган.* К.Кәрим

**БОХА́Р МИЛӘШЕ** *и. бот.* Зелпечәләр семьялыгыннан, күпьеллык куакның бер төре; аю баланы, карга миләше; *русчасы:* **бузина**

**БОХАРЧЫЛЫК** *и.* Дини канун һәм өйрәтмәләрдә катып калган борынгылыкка таянган һәм шуңардан читкә чыкмауны таләп иткән иске тәртипләр. *Шулар белән беррәттән үк, бохарчылык, шәрыкчылык, феодалчылык идеологиясенә каршы, яңару – европалашу, Европа мәдәниятен урнаштыру хәрәкәтләре башланды.* Татар театры

**БО́ЦМАН** *и. голл.* Диңгез флотында: барлык хуҗалык эшләрендә матрослар белән турыдан-туры җитәкчелек итә торган иң кече рангтагы командир. *Боцман бер матроска себерке тоттырды да үзе кереп китте.* А.Хәбибуллин. *– Андый туфлиләрне без дә алган идек, – ди боцман, ләчтиткә кушылып.* М.Юныс

**БОЯР** *и. тар. төрки («бай әр» сүзеннән)* XVIII гасыр башына кадәр Борынгы Русь һәм Мәскәү дәүләтендә югары катлау вәкиле, эре җирбиләүче. *Европа байлары тырышалар Кол итәргә безне боярга.* Г.Камал. *Элек заманда бояр балалары гына офицер була торган иделәр бит!* Ш.Камал

◊ **Бояр егете кебек** *иск.* Купшы, матур, бай киенгән ир кеше турында. *Минем Алмачуар исә кунакка барырга ясанган бояр егете кебек чибәр булды.* Г.Ибраһимов

**БОЯ́РЩИНА** *и. рус тар. к.* **барщина**

**БӨГӘВЕЛ** *и. иск.* 1) *тар.* Патшаның, ханның яшерен сакчысы

2) Чит ил, дошман як шымчылыгына каршы эшчәнлек алып баручы кеше; контрразведчик

3) Продуктларның һәм эчемлекләрнең тәмен татып карап, аларның сыйфатын билгеләүче; дегустатор

**БӨГӘЛ** *и. диал.* Борылыш. *Кызык икән бу «дөнья» дигәнең! Бер бөгәле икенче бөгәл эченә кергә дә утыра.* А.Хәлим. *Әнә, аскы яклап, бөдрә таллар, карт өянкеләр һәм шомырт түйралыклары арасыннан бөгәлләр ясап, Усылы елгасы, үз дулкыннарын вак чуерташлар өстеннән --- Ырынбур далаларына тәгәрәтә-тәгәрәтә, күздән югала.* А.Хәлим

**БӨГӘЛҖӘ** *и. диал.* **1.** Гадәттә элү, эләктерү, тоташтыру өчен җайланган боҗра яки ярым боҗра формасындагы әйбер. *Сынган инде көмеш беләзекләр, Алкаларның сынган бөгәлҗәсе.* Л.Шагыйрьҗан

**2.** *с. мәгъ.* Шул формада булган, шул формада эшләнгән яки шул форманы алган. *Йорт уртасына бөгәлҗә артлы җиңел кара утыргыч чыгарып куйганнар.* М.Әмир

**БӨГӘЛЧӘН** *и. зоол.* Кигәвеннәр ыругыннан, личинкалары эре терлек тиресе астында паразит булып яшәүче, койрык өлеше нечкәреп бөкрәеп торган ике канатлы бөҗәк. *Атка җайсыз: кигәвен, бөгәлчән каныга.* Ә.Гаффар. *Бөгәлчәннәр йорт хайваннарына, кигәвеннәр кебек, тукланыр өчен түгел, бәлки йоннарына күкәй салыр өчен генә ташланалар.* Биология. *Кайбер бөҗәкләр, әйтик, «бөгәлчән» дигән кигәвен һәм су корты йомыркаларын су өстендә асылынып торган яфракларга салалар ---.* Кызыклар дөньясында

**БӨГӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бөгәрләү.** *Рәшидә пальтосының капчыкта ятып бөгәрләнгән икәнен исенә төшерде.* М.Маликова

2) Гәүдәне, аерым әгъзаларны бөгү, йомарлау. *Алга сузылган ике кулының бармаклары, төймә тоткан көе, бөгәрләнеп катып калды.* М.Кәрим. *Алабуганың тартышып бөгәрләнүе --- Ирекнең күз алдыннан китмәде.* Ф.Садриев. *[Керпе] Бераз бөгәрләнеп ятканнан соң, ул чирәм арасыннан башын чыгарып карады.* С.Әдһәмова

**Бөгәрләнә бару** Торган саен ныграк бөгәрләнү

**Бөгәрләнә башлау** Бөгәрләнергә тотыну

**Бөгәрләнә төшү** Тагын да бөгәрләнү

**Бөгәрләнеп бетү** Бөтенләй бөгәрләнгән хәлгә килү. *Погоннары бөгәрләнеп беткән.* М.Юныс. *Контролёр хатын, иске сумкасыннан бөгәрләнеп беткән берлекләр, көмеш-бакыр тиеннәр чыгарып, кат-кат, озаклап санады.* Р.Вәлиев

**Бөгәрләнеп калу** Бөгәрләнгән хәлгә килү. *Орлыктан бушагач, кузак кабыгы, ике якка аерылып, сырлы мөгез шикелле бөгәрләнеп калды*. Р.Батулла

**Бөгәрләнеп килү** 1) Үзеннән-үзе бөгәрләнү, җыерылу (тукыма, кәгазь турында)

2) Бик каты авыртудан бөтенләй бөгәрләнү, җыерылу

**Бөгәрләнеп тору** Бөгәрләнгән хәлдә булу

**Бөгәрләнеп төшү** Көтмәгәндә, көчле авыртудан, авыр сүзләрдән бөгәрләнү, бөгелү. *Арслан бөгәрләнеп төште, сулышы кысып алды*. Ф.Гыймалетдинов

**БӨГӘРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Өстенә басу, утыру нәтиҗәсендә нәрсәне дә булса җыерчыкландыру, чит-читен эчкә кайтару; тигезсез бөкләү, йомарлау. *Сылу гәзитләрне, бөгәрләп, тартмага тутырды, күлмәк итәкләрен сыпырып, чәчен төзәткәләде.* Н.Гыйматдинова

2) Буыннан бөкләү. *Садри абзый, бармакларын бөгәрләп, стакан авызыннан кечерәк түгәрәк ясап күрсәтә.* И.Сирматов

3) *күч. гади с.* Буйсындыру. *Сабырсыз шул хәзер хатыннар да, тиз арада гына, ирне, бөгәрләп, олтан астына тыгуны кулайрак күрәләр.* Р.Зәйдулла

**Бөгәрләп алу** Тиз арада, кинәт бөгәрләү

**Бөгәрләп ату** Кинәт, ачу белән бөгәрләү. *Ул күлмәк сайлавын карап торсаң, эчең поша башлый: берсен ала, берсен сала, берсен кия, берсен үтүкли, бөгәрләп ата, тагын бүтәнен эзли.* К.Кәримов

**Бөгәрләп бетерү** Тәмам бөгәрләгән хәлгә китерү. *Иске пәлтәдән бозып ясалган драп кепкасын бер салды, бер киде, тәмам бөгәрләп бетерде*. Рифә Рахман

**Бөгәрләп салу** Буйсындыру, җиңү. *Нык якаңнан тота, Өчкә бөгәрләп сала да Ач бүредәй йота*. Р.Шиһапов

**Бөгәрләп ташлау** 1) Көтмәгәндә яки ачудан тиз генә бөгәрләү. *Ә Фәйрүзәнең куе үлән арасына бөгәрләп ташлаган гаризасын берәү дә күрми калды*. К.Тимбикова

2) Көчен, хәлен алу, сәламәтлеген бетерү, бөгү. «*Дөнья» дигәнең нинди генә кешеләрне бөгәрләп ташламый.* И.Гази

**Бөгәрләп тору** Дәвамлы рәвештә яки әледән-әле бөгәрләү

**Бөгәрләп чыгу** Барысын да бөгәрләү

**Бөгәрли башлау** Бөгәрләргә тотыну

**Бөгәрли төшү** Бераз бөгәрләү

**БӨГЕЛӘ́-СЫГЫЛА** *рәв.* Нык бөгелеп; гәүдәне уйнаклатып. *Җирән атлар анда, бөгелә-сыгыла, Рельс буйлап күмер тарталар.* Н.Баян. *Кыз, көлүен башкаларга сиздермәскә тырышып, әйләнә эчендә бөгелә-сыгыла торучы егеткә ымлады.* К.Тимбикова. *Анатолий бөгелә-сыгыла гафу үтенде, рәхмәт әйтте.* С.Поварисов

**БӨГЕЛЕ́П-СЫГЫЛЫП** *рәв. к.* **бөгелә-сыгыла.** *Хәсәнә абыстайга – йөкле кешегә – бөгелеп-сыгылып, бер ятып, бер торып, элеккечә, мулласы белән ярыша-ярыша намаз уку бик кыен иде.* С.Поварисов

**БӨГЕЛЕШ** *и.* 1) Бөгелгән урын. *Тукта, каш бөгелеше дә, ирен почмакларындагы нечкә генә сызык кисәге дә, аскы тешләренең төзелеше дә аныкына охшаган түгелме соң?..* Ш.Маннур. *Монысы – рауза чүпләме. Якты, зиһенле сурәт, әйеме? Монысы – канәфер чүпләме. Бөгелешләренә игътибар ит!* А.Хәлим. *Кыяфәтенә кара: муенга кадәр төшеп, тыңлаучан яткан капкара чәч куелыгы, шакмаклы ияк белән тәмамланган озынча йөз, шул йөзне икегә аерып, кыю бөгелеш ясап төшкән ассирия борыны.* М.Галиев. *Олы кешенең умырткалыгында бөгелешләр бар. Тиз, кискен хәрәкәтләр вакытында, бөгелешләр пружина кебек сыгыла һәм бәрелү-сугылуларны йомшарта.* Биология: Кеше һәм аның сәламәтлеге

2) *диал.* Борылыш, борылма, чат. *Ул [юл] бөгелеш[ендә]тә күздән югалды.* Н.Исәнбәт

3) *күч. кит.* Эшне бозу, дөрес юлдан читкә тайпылу. --- *әмма аңлашылып җитми, күмәкләшү ирекле дә булсын, бөгелешләр дә булмасын, шул ук вакытта, партиянең, көзгә кадәр коллективлаштыруны тәгълләргә, дигән күрсәтмәсе дә үтәлсен.* Ф.Сафин. *Бу өч пәрдәлек комедия күмәкләшү вакытында булган кайбер бөгелешләрне җанландыруны да үз эченә ала.* Т.Гыйззәт // Законсыз юллар белән башкарылган эш. *Бу унга ун итеп салынган нарат сарайга Җәүдәтнең Уфада унбиш ел буе тир түгеп яулаган ике бүлмәне, аннан аны, шул ук кырык бөгелеш һәм кырык сыгылыш аша, Чаллының сигезенче катына алыштыра алган шул ук ике бүлмәле фатирын ун мәртәбә сыйдырып булыр иде.* А.Хәлим

**БӨГЕЛМӘ** *с. диал.* Бөгеп эшләнгән. *Беләзекләрең бөгелмә, Бөгелмәдән түгелме?* Җыр

**БӨГЕЛМӘЛЕ** *с.* Бөгелә, бөкләнә торган; җыелмалы. *Ләкин бу ни хәл – роботлар, аларның боерыкларын бар дип тә белмичә, үзләреннән тайпылырга маташып сикерешкән кешеләрне, тиз генә, бөгелмәле кармавычлары белән эләктереп алдылар, корабка таба өстери башладылар.* З.Мифтахов

**БӨГЕЛМӘЛЕ́-СЫГЫЛМАЛЫ** *с.* 1) Бөгелә-сыгыла хәрәкәтләнә торган (гадәттә, зифа, нәфис гәүдә турында)

2) Бөгелеп-сыгылып торган. *Бөгелмәле-сыгылмалы көянтәң бардыр әле.* Җыр

**БӨГЕЛМӘС** *с.* 1) Бөгелми торган. *Ә бөгелмәс каты имән ботакларының беришесе кабыргаларың аша үтү ихтималы да юк түгел...* Р.Зарипов

2) *күч.* Буйсынмаучан, башимәс, ихтыяр көче зур булган. *Әнә шундый бөгелмәс кеше булганы өчен, ул Әхмәрне яратты һәм язмышын аның белән бәйләде.* И.Абдуллин

**БӨГЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бөгү** (*1–5 мәгъ.*). *Борын-борын чакта, Мин бай чакта, Бер салмалык он бар чакта, Атай яшь чакта, Үзем карт чакта, Бөгелмәгән җәя белән, Юнылмаган ук белән Атып салдым саескан* ---. Такмаза

2) Иелү; сыгылу. *Бу фикерне раслагандай, сабырсыз Маруся, әкрен генә бөгелеп, иреннәрен кара туфракка тигезде.* Ш.Рәкыйпов

**Бөгелә бару** Торган саен ныграк бөгелү

**Бөгелә башлау** Бөгелергә тотыну

**Бөгелә бирү** Бераз бөгелү. *Туйда да бит аңа һәммәсе, бөгелә биреп, «туташ» кына дип дәштеләр.* Ә.Еники

**Бөгелә төшү** Бераз бөгелү. *Аның сыны, егылмыйм, дип куркып, бөгелә төште.* Г.Исхакый. *Айның туфрагы көпшәк һәм бераз тайгак булса да, Армстронг белән Олдрин башта көңгерә кебек сикергәләп маташалар да, тиз арада, бераз алга бөгелә төшеп, Җирдәгечә гади генә атлап китәләр.* Кызыклар дөньясында

**Бөгелеп алу** Тиз генә бөгелү, иелү хәрәкәте ясау

**Бөгелеп бетү** Бөтенләй бөгелгән хәлгә килү. *Койма башлары кителгәнче, алюмин таяк кәкрәеп, бөгелеп беткәнче, такталарны кыйнады.* Ф.Садриев

**Бөгелеп кую** Бер тапкыр бөгелү хәрәкәте ясау

**Бөгелеп тору** Сыгылган, бөгелгән хәлдә булу. *Шкафыбыз киштәләре Хәтта бөгелеп тора.* Г.Мөхәммәтшин. *Алар [тешләр] рәт-рәт булып урнашкан, очлары артка таба бөгелеп тора.* Кызыклы физиология

**Бөгелеп төшү** Көчле физик яки рухи авырлыктан хәлсезләнү, егылу. *Һәм Рабига җиңги, сәкесенә бөгелеп төшеп, үзе дә елый башлады.* А.Хәлим. *Егет «аһ!» дип башын тотты һәм бөгелеп төште.* Р.Кәрами. *Ләкин кинәт тавышы өзелде, бөгелеп төште һәм иңбашлары калтыранып китте.* Ә.Еники

**БӨГЕШТЕРҮ** *ф.* 1) Аннан-моннан, ничек җитте шулай гына бөккәләү, бөгү (*4 мәгъ.*), теккәләп чыгу

2) *күч. гади с.* Ялганлау. *Син, мөгаллим, бөгештермә!* Г.Бәширов. *Син, Шәрифуллин, бөгештермә! Без алай сөйләшмәдек.* Ф.Садриев

3) *күч. гади с.* Җайлау, җаен табу

**Бөгештерә килү** Электән, һәрвакыт бөгештерү

**Бөгештерә төшү** Азрак бөгештерү

**Бөгештереп ату** Бик тиз арада, аннан-моннан бөгештерү

**Бөгештереп бетерү** Бөтенләй бөгештерү

**Бөгештереп ташлау** Бик тиз, кыска гына вакыт аралыгында аннан-моннан бөгештерү

**Бөгештереп тору** 1) Әледән-әле, даими бөгештерү

2) Сөйләгән, әйткән, күргән һ.б.ш. вакытта бөгештерү

**Бөгештереп чыгу** Тукымадан эшләнгән нәрсәләрне башыннан ахырына кадәр бөгештерү

**БӨГҮ** *ф.* 1) Ян-якларын бер-берсенә якынайтып бөкләү. *Берничә тапкыр тирәнрәк итеп салып карасам да эш чыкмады: [балыклар] кармагымны бөгеп яисә сындырып качтылар, болар өчен теле очына якын корыч кармаклар кирәк.* Г.Ибраһимов // Дуга сыман итеп сыгылдырып ясау. *Элмә – тәгәрмәч тугымына, чана табанына китә, дуга бөгәргә.* М.Мәһдиев. *Гафиятулла колхозга тугым бөгә.* Ф.Хөсни // Чит-читләрен бөкләп, кирәксә, сырлар ясап эшләү. *[Фәридә Ферденантка:] Кияү пилмәнен дә бөгәрсең.* Х.Ибраһим

2) Әгъзаларны буыннан бөкләү. *Кыз да, башын аз гына яшь егет тарафына бөккән дә, күзе берлән, йөзе берлән тегенең сүзләренә чумып тыңлый.* Г.Исхакый. *Буын ул, кая бөксәң, шунда кәкерәя.* Ә.Гаффар. *Ул, бармакларын тырпайтып, аларны берәм-берәм үзенә таба бөгеп күрсәтте.* Г.Бәширов. *Кулны терсәктән бөгәләр.* Йорт эшләре

3) Ию, түбәнгә карау; сыгылдыру, салындыру. *Башыңны түбән бөгеп бар.* М.Гафури. *Йолдызлар боз ватыклары кебек төссезләнделәр, үләннәрне аска бөгеп, кинәт җил исте.* А.Гыйләҗев

4) Кирегә бөкләп, кайтартып тегү. *Зәйнәп, урындык өстендә утырып, бер яулыкның читләрен бөгә иде.* Дәрдемәнд

5) *күч.* Ныклыгын какшату, хәлсезләндерү, көчен алу. *Төзәлмәс авыру кешене бөгә*

6) *күч.* Тыңлату, буйсындыру, тез чүктерү; рухи яктан җиңү. --- *егетне фашистлар бөктеләр микәнни?* К.Латыйп. *Гашыйк ирләр – утта кызган тимер кебек: Бөгеп була, сугып, бөгәрләп.* И.Гыйләҗев. *Сыеныр куен, таяныр җилкә булмады, һәм аны кая кирәк – шул якка бөктеләр.* Р.Кәрами. *Тик мине ничек кирәк – шулай бөктеләр.* Ф.Садриев

7) *күч.* Үз белдеге белән эшләү, үзе белгәнчә фикер йөртү; артыграк кылану. *Күрмәмешкә салышсаң, җиңелрәк бит, шуңа турыны бөгә.* А.Гыйләҗев. *Кайнеш бит үзебезнеке, гаепкә бөкмәс.* Р.Мөхәммәдиев. *– Ә акчаны түләмәде, – дип, үзенекен бөкте Зиннәт, үҗәтләнеп.* З.Мирзануров

8) *күч. сөйл.* Ашау, эчү (тиз һәм күп итеп). *Бәлешләрне бөгеп, Балны сөзеп, «Әнвәр» диеп исем бирделәр.* Һ.Такташ. *Җыеннан ачыгып та кергәч, без аны, иркен сәкегә аякларны бөкләп утырып, сөтле чәйне эчә-эчә, әйбәтләп бөктек кенә!.. Шәп төште бер таба коймак.* Ә.Еники. *Шешәне мин ул имгәкләрдән башка да шәп бөгәм.* Н.Гыйматдинова

9) *күч. сөйл.* Күп, матур сөйләү. *– Син, Федоркин, философ икәнсең, белмәгән идек, – дип көлгән итте гаепләүче. Аннары, бераз уйланып яткач, өстәде: – Ну, бөктең үзең дә, Федоркин, җиңү генә булмый, имеш!* Х.Камалов

**Бөгә бару** Һәммәсен, һәркайсын бер-бер артлы бөгү. *Шул ук вакытта сул кул бармакларын бөгә барды. Санап бетерде дә: – Менә миңа тагын эш...* Н.Фәттах. *Авыз эченнән бер исем әйткән саен, берәр бармагын бөгә барды.* Ф.Яруллин

**Бөгә башлау** Бөгәргә тотыну. *Имән очындагы нечкә ботакны сайлады да, келәшчә белән йолкыгандай, боргалый, бөгә башлады.* М.Рәфыйков

**Бөгә тору** Даими рәвештә бөгү

**Бөгә төшү** Беркадәр бөгү. *Аякларын бераз бөгә төшеп, әкрен генә биеп китте.* Р.Кәрами

**Бөгеп ату** Бик тиз арада бөгү

**Бөгеп бетерү** 1) Барысын да бөгү. *Кул бармакларыңның барысын да бөгеп бетерәсең: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тәрәзәләреңең очына чыга алмыйсың.* А.Алиш

2) Төбенә кадәр бөгү

**Бөгеп җибәрү** Кинәт бөгү. *«Бик каты кыланмыйбызмы без кешеләр белән? Бөгеп җибәрмибезме икән? Кояш астында һәркемнең дә яшәргә хакы юкмыни?» – дип уйлый Сәрвәр.* Ф.Хатипов

**Бөгеп калу** Бөгәргә өлгерү. *Ягъни, баланы да яшьтән үк яхшы гадәтләргә, эшкә бөгеп кал, соңыннан авырга туры килер, дигәне.* Н.Исәнбәт

**Бөгеп кую** Бөгелгән хәлгә китерү. *Еллар аның төз гәүдәсен инде Бераз куйган бөгеп.* Р.Әхмәтҗан. *Дүртенче*

*бармагын бөгеп куйды Арам.* Р.Мөхәммәдиев

**Бөгеп салу** Җиңү; уздыру. *Карама беләккә, кара йөрәккә, диләр бит. Шулай булгач, син дә минем яшемә карама. Егерме яшьлек егетләрне бөгеп салам әле мин.* Р.-Н. Гүнтәкин

**Бөгеп ташлау** Тиз арада бөгү

**Бөгеп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм бөгү

**БӨДӘ́Ү** *ф. иск.* 1) Бирү. *[Байчура ишанга]: Сәдакасына күрә фатихаңны бөдә.* К.Тинчурин

2) *диал.* Искәрмәстән, йодрык белән төртү

**БӨДРӘ** *с.* **1.** 1) Көдрә, бөтерелеп торган, бөтеркәле (чәч, йон һ.б.ш. турында). *Бөдрә чәчле, зәңгәр күзле, дәртле егет-ирләр.* Г.Афзал. *Башындагы ак шапкасы астыннан кызның вак бөдрә чәчләре чыгып, күпсанлы кара алкаларны хәтерләтәләр.* Р.Кәрами. *Өстендәге таушалган костюмы белән бөдрә чәченнән башка берние дә юк, чөнки.* М.Маликова // Бөдрәләре булган, бөдрә чәчле, йонлы. *Лариса, киная белән, бөдрә башлы инженерга күз салды.* М.Маликова. *[Капитан] Аннары, каршына кәгазь бите шудырып, чал, бөдрә башын кырын салып, язарга кереште.* М.Маликова

2) *шигъ.* Кабарып, куе булып күренә торган, күперенке. *Җиз дагалар аның [атның] аягында, Ефәк тасма бөдрә ялында.* М.Җәлил. *Бөдрә тал да бер талпына Очкан кошлар артыннан.* Г.Мөхәммәтшин. *Су буйлары ямьле Бөдрә таллар белән.* Г.Афзал

**2.** *и. мәгъ.* Чәчтәге, йондагы бөтеркә, көдрәләр. *Маңгай бөдрәләрем әкрен генә җилдә тирбәлә.* М.Хөсәен

**БӨДРӘЛӘНҮ** *ф.* Бөдрәләр барлыкка килү, көдрәләнү, бөтеркәләнү; бөтеркәчләнү. *Кара төтен бөдрәләнә.* А.Шамов. *[Таңсылуның чәчләре] Дулкын-дулкын булып бөдрәләнеп, иңнәренә төшкән.* Г.Сабитов

**Бөдрәләнә бару** Торган саен ныграк бөдрәләнү

**Бөдрәләнә башлау** Бөдрәләнергә тотыну. *Бөдрәләнә башлаган болытлар яңгыр булып яварга җыеналар.* Г.Кутуй

**Бөдрәләнә төшү** Бераз бөдрәләнү. *«Бөдрәләнә» төшкән яшел тунын Астына ул җәеп ятучан.* Х.Туфан

**Бөдрәләнеп бетү** Тәмам бөдрәләнгән булу

**Бөдрәләнеп йөрү** Билгеле бер вакыт дәвамында бөдрә булу. *Тик бу Сәкинәне һич тә пошындырмый, чөнки сынган чәч, барыбер, бераз вакыт бөдрәләнеп йөри.* Ф.Яруллин

**Бөдрәләнеп китү** Бераз бөдрәләр барлыкка килү. *Саргылт чәче, үз иркенә чыккач, бөдрәләнеп үк киткән.* С.Сөләйманова

**Бөдрәләнеп тору** Даими рәвештә бөдрә хәлдә булу. *Атаманның әле генә бөдрәләнеп торган саламдай чәчләре күз ачып йомган арада көл төсенә кергән.* В.Имамов

**БӨДРӘЛӘ́Ү** *ф.* **1**. Махсус рәвештә бөдрә итү, бөдрәләр ясау. *Ул [чәчен] үзе бөдрәли булса кирәк.* А.Шамов

**2**. **бөдрәләп** *рәв. мәгъ.* Купшы итеп, матур сүзләр кыстырып. *Бөдрәләп сөйли белмим...* А.Гыйләҗев

**Бөдрәләп бетерү** Бөтенләй бөдрәләү; бөдрәләү эшен төгәлләү

**Бөдрәләп чыгу** Һәммәсенә бер-бер артлы бөдрәләр ясау; башыннан ахырына кадәр бөдрәләү

**Бөдрәли төшү** Беркадәр бөдрәләү

**БӨЕ** *и. биол.* Бүре үрмәкүчләр семьялыгыннан, зурлыгы 3,5 см чамасы булган, җирдә ояны вертикаль ясап яшәүче агулы үрмәкүч; *русчасы:* **тарантул русский.** *Бөедән куркып, дөягә менү.* Әйтем

**БӨЕК** *с.* **1.** Гадәттәгедән мөһим, әһәмияте, тоткан урыны зур булган. *Бу төшеңдә бөек бәхет күрнер имди...* Кол Гали. *Ул бит – Бөек Ватан сугышы ветераны, заманында данлыклы аучы, ударник булган кеше ---.* Ш.Бикчурин // Дәрәҗәсе югары, даһи; олуг. *Биеклек – ул бөек хисләр иле кебек.* Г.Афзал. *Баксаң, бөек шагыйрьнең дә үз борчулары, зар-моңнары, хәтта дошманнары да бар икән.* Таныш өянкеләр

**2.** *и. мәгъ.* Даһи, олуг кеше. *Бер бөеге, әгәр ышандыра алмасаң, алдаштыр, шомарт, анысын да булдыра алмасаң, дөресен сөйлә, дигән.* Т.Галиуллин. *XX йөз башы бөекләре Тукай, Исхакый, Ибраһимов һ.б. иҗатының яңачалыгын, татар әдәбияты үсешенең алтын чорына керүен аңлап, аңлатып бирердәй Җ.Вәлиди, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, соңрак Г.Нигъмәти, Г.Галиләргә ихтыяҗ туа.* Т.Галиуллин. *Чөнки ул бөекләр тарихны гадел ысул белән өйрәнгәннәр, төркемнәргә бүлешмәгәннәр.* М.Әмирханов. *Бөекләрнең мәетләренә дә тынгылык юк!* А.Гыйләҗев

**БӨЕКБРИТА́НИЯЛЕ** *и. к.* **британияле.** *Бөекбританияле йомгакларны квартирасыннан чыкмый гына сүтә, ә сез гел тегендә-монда йөренәсез.* Ф.Бәллүр. *Алай да мин көндәшләрем – Һиндстаннан килгән малайны һәм бөекбританияле кызны уза алдым.* Ватаным Татарстан. *ЮНЕСКОның музейлар комитеты әгъзасы бөекбританияле Ив Джонс юкка гына аны, Көнчыгыш Европаның иң яхшы музейларының берсе, дип белдерми инде.* Шәһри Казан

**БӨЕКЛЕК** *и.* 1) Бөек булу; даһилык. *Хуҗабыздан ярдәм иңәр синең өчен, – Сиңа хөрмәт һәм бөеклек килер имди.* Кол Гали. *Шул текә баскычлардан йөри-йөри, биеклеккә вә бөеклеккә менә-менә егылды ул.* К.Латыйп

2) Кешедә хөрмәт, олылау, соклану хисләрен тудыра торган сыйфат. *Исемеңдәге кебек, үзеңдә дә бөеклек мәгънәсе балкып торсын.* Г.Тукай. *Кайчагында түбән тәгәрәү дә Бөеклеккә илтә дөньялыкта.* Р.Зәйдулла. *Югарылыкны, колачлылыкны күңел биеклеге, күңел бөеклеге хәл итә.* К.Латыйп

3) Кешенең даһилыгы, үзенең, гадәттә, чиктән тыш кирәклеге турындагы уй-фикере, тойгысы. *Бөеклек, өстенлек тойгысы аның канына сеңгән.* Ф.Хатипов. *Шунда Чәмәтне капыл бөеклек өянәге борып алды ---.* Х.Сарьян

**БӨЕНТЕ** *и.* Су агымы белән килеп, бер җирдә бөялеп, җыелып торган нәрсәләр. *Җыелып торган бөенте менә кайчан кузгала.* Г.Ахунов

**БӨЕР** *и. анат.* 1) Умырткалыларда бәвел бүлеп чыгару функциясен үти торган әгъза. *Бәлки, бөер өянәге кузгалып, авыртуга чыдый алмагандыр да,*

*бөер ташы теткәләнсен, дип аткандыр.* Ә.Баянов. *Бүлеп чыгару функциясен бөерләр үти.* Зоология. *Чөгендер бавыр, бөерләр, үт куыгы эшчәнлеген яхшырта.* Мәдәни җомга. *Ә кызыйга бандаж кидерегз, бөере төшкән кызыгызның!* Сөембикә

2) Гәүдәнең бөер урнашкан урыны. *Әнә карчыгына игътибар ит, киң итәкле озын күлмәген бөеренә кыстырып куйган да олы табактан тирән эчле тустаганнарга бишбармак бүлә.* Ф.Мансуров

◊ **Бөергә таяну** 1) Гамьсез, илтифатсыз кыяфәт алу. *Әхәт аның кырына ук килеп баскан да, бөеренә таянып, һич тайчынмыйча, әңгәмәне тыңлап тора иде.* А.Гыйләҗев. *Кайгы инде аны, мәйдан тоткан батыр шикелле, бөеренә үк таянып көтеп тора.* Х.Сарьян; 2) Масаю, һавалану. *Бөеренә таянды да кечкенә генә ап-ак итек-читекләре белән юеш кар чәчрәтеп, бөтерчектәй бөтерелеп куйды, кыбырсык.* Г.Сабитов. **Бөергә тию (төшү, үтү)** Үзәккә үтү, теңкәне корыту, йөдәтеп бетерү. *Бу елны Мишель мәктәптә укымый иде инде. Булган булса, бөеремә үтеп кереп, хәсрәтемне арттырган гына булыр иде.* Р.-Н. Гүнтәкин. *«Өч бала атасы» Батталның бөеренә тиде.* Р.Сибат

**БӨЕРӘК** *и. диал. к.* **бөер** (*1 мәгъ.*). *Май эчендәге бөерәк кебек.* Мәкаль

**БӨҖӘК** *и. биол.* Буынтыгаяклылар тибының бер классына караган, төрле зурлыкта, төрле төстә булган, очуга җайлашкан ике җенесле җан иясе. *Бөтен нәрсә матур, бөтенесе күркәм, бөҗәгеннән башлап, һәр җан иясе сиңа елмаеп-көлеп карый кебек.* Ф.Садриев. *Бөҗәкләр – алты аяклы буынтыгаяклылар алар.* Биология. *Фән, шул исәптән бөҗәкләр турындагы фән дә, аларга хезмәт иткән төрле кешеләрнең гаҗәеп язмышлары белән тыгыз бәйләнгән.* Кызыклар дөньясында

2) *күч. гади с. хурл.* Бала яки дәрәҗәсе бик кечкенә булган кеше. *Әллә үзеңне минем белән чагыштырыр идеңме, гыйбад?! Утын түмәре! Бөҗәк!* А.Гыйләҗев. – *Лыгырдама, бөҗәк! – дип акырды Салих.* Чаян. --- *Парсегян «эшем кешеләре» арасында бер вак бөҗәк кенә булып, бүгенге абруе исә элек кылган җинаятьләренең «данлы» эзе генә икән.* Р.Мирхәйдәров. *Кеше түгел ул, бөҗәк!* А.Хәлим

**БӨКӘЙ** *и. к.* **бүки.** *Мин анысына каршы килмим. Ләкин үз-үзеңне бөкәй белән куркытуларга һәм бөтен әйберлән контрреволюция ясап маташуларга мин бала-чагалык һәм үз көчебезгә үзебез ышанмаучанлык дип карыйм.* Ш.Камал

**БӨКЕ** *и.* 1) *биол.* Кайбер агачларның (мәс., бөке агачының) калын җиңел кайрысы. *Бөке барлыкка килгәнче, тиречек катлавы астында кабыкның яшь күзәнәкләре була.* Биология

2) Кайбер савытларның авызын, шулай ук тишекне каплый торган әйбер; тыккыч. --- *Абу баба, ашыкмыйча гына, шешәнең авызына суккалады, сургычын ватып, бөкесен ачты.* Б.Сөләйман. *Уртада табын солтаны – бөкесе ярым ачылган шома кара пичәтле затлы коньяк.* Ш.Рәкыйпов. *Тишекләрнең һәр икесенә дә агач бөке кагылды.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Юлда, транспортның гадәттән тыш күп туплануы сәбәпле, хәрәкәт начарлану яки тукталу. *Аның туктавы аркасында, бу дөнья чылбырының бөтен рәте чуалыр, башкалар да туктар, тыгылыр, юл хезмәткәрләре теле белән әйтсәк, «бөке» ясалыр иде.* М.Мәһдиев. *[Камил белән Чәчкә] «Бөке»ләрдән атылып чыга-чыга, Мусин урамына килеп җиттеләр.* Ф.Яруллин

4) *мед.* Канда фибриноген хәлендә булган фибрин җепселләре аерылып чыгу сәбәпле, кан тамырлары тыгылудан гыйбарәт авыру. *Тромбоцитлар үзләре генә зур бөке хасил итә алмыйлар. Бөке канда фибриноген хәлендә булган үзенә бертөрле аксым-фибрин җепселләре аерылып чыгу аркасында ясала.* Кызыклы физиология

◊ **Бөке булып йөрү** Вакытлыча кирәк булу

**БӨКЕ́ АГАЧЛАРЫ** *и. күпл. бот.* Икеөлешлеләр классыннан, шома, ачык соры кайрылы, каты үзагачлы агачлар семьялыгы. *Имәннәр бөке агачлары семьялыгына керәләр.* Робинзон эзләреннән

**БӨКЕЛӘ́Ү** *ф.* Бөке тыгу. *Бар, кадерлем, ваннаны яхшылап ю да кайнар су белән йөгерт, тишеген бөкеләгәч, ярты кап чамасы порошок сал.* Ф.Баттал. *Бензин багын да чүпрәк белән генә бөкеләгәнсең бит!* Ф.Баттал. *Шешәләрне бөкеләгәч, кайнап торган суда 30 минут стерилизациялиләр.* Йорт эшләре

**Бөкеләп кую** Алдан бөкеләү, бөкеләгән хәлгә китереп калдыру. *Авылдашлар урманда берәүнең утынын урлыйлар икән. Утын хуҗасы кем икәнен белмәкче һәм ачу алмакчы. Утынны бораулап, дары тутыра, бөкеләп куя.* Ш.Галиев

**Бөкеләп тору** Билгеле бер вакыт аралыгында, вакытлыча бөкеләү

**Бөкеләп чыгу** Һәммәсен дә бөкеләү

**Бөкели бару** Берсе артыннан берсен бөкеләү

**БӨККӘН** *и.* Эченә кәбестә, бәрәңге, ярма һ.б.ш.лар салып пешерелә торган камыр ашы. --- *әллә Динә пешергән кәбестә бөккәне ошадымы, үз өйләрендә утырган кебек, телләре ачылды.* К.Кәримов

**БӨКЛӘМ** *и.* Тукымадан эшләнгән әйберләрдә: бөгелгән урын. *Таҗетдин бабай эшләпәсенең колак турындагы бөкләмнәрен түбән төшереп кия.* Ф.Яруллин

**БӨКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кәгазь, тукыма, тимерчыбык һ.б.ш. әйберләрне, почмакландырып яисә як-якларын каракаршы китереп, ике яки берничә катлы итеп бөгү. *Әхмәт, гасабиланып, кулындагы тәмәкесен бөкләп ташлады да ачулы күз белән Вәлигә карап алды.* Ш.Усманов. *Француз яулыклар киштәдә – Бөклә дүрткә-бишкә дә, шул, Сезнең белән күрешүләр Кермәс инде төшкә дә, шул.* Җыр. --- *барысын, бөкләп, портфеленә тыга да, өенә кайткач, ашыкмыйча, иркенләп карый.* Ә.Еники. *Кулындагы ручкасын сындыра язып, бармаклары белән бөкләргә маташкандай итте.* Ф.Садриев

2) Буыннан бөгеп, үзенә тарту (мәс., кулны, аякны). *Сәкегә, бер аягын бөкләп, икенчесен салындырып, егерме яшьләр чамасындагы бер хатын утырган.* С.Җәләл

3) *күч. к.* **бөгү** (*7 мәгъ.*). *Дүрт-биш сохари бөкләгәч, солдат тагын терелде.* Бәет. --- *күз ачып йомганчы, тавыкны бөкләде.* А.Гыйләҗев. *Әйдәгез, кайнар шулпага кадәр берәрне бөклик әле, күптәннән инде мондый шәп коньяк эчкән юк...* Р.Мирхәйдәров

4) *күч.* Буйсындыру. *Акыллы кеше хатынын үтерми, акыллы кеше хатынын, менә болай бөкләп, учында гына тота.* М.Маликова

5) *күч.* Төгәлләү, тутыру (яшь, гомер турында). *Күп булса, алтмыш-җитмеш ел яшисең. Хәзер икенче дистәне бөклисең.* А.Гыйләҗев

**Бөкләп алу** Тиз генә бөкләү. *Инде менә, бөкләп алып, допросларга олактырасылар, дип уйлаган гынаем, име, эчләр жу итеп китте.* Р.Гаффар

**Бөкләп ату** 1) Бик тиз, аннан-моннан бөкләү

2) *күч.* Кыйнау

**Бөкләп бару** Тоташтан, бер-бер артлы бөкләү

**Бөкләп бетерү** 1) Бик күп тапкырлар бөкләү. *Мондагы ят күзләрдән яшерер өчен, [хатны] ничәгә бөкләп бетергәнсең.* Н.Хәсәнов

2) Барысын да ахырга хәтле бөкләү. *Айгөл белән Таһир зал ягына кереп киттеләр, ә Сөембикә кыстыбыен бөкләп бетерергә ашыкты.* Ф.Садриев

**Бөкләп кую** 1) Бөкләнгән хәлгә китереп калдыру. *Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә, бисмилласын әйтеп, сырган юрган белән ябынып, бөгәрләнеп кенә ятты.* Ә.Еники

2) *күч.* Бик тиз ашап бетерү. *Ул [Ирек] бер коштабак ашны бөкләп кенә куйды.* Ф.Садриев. *Арка-җилкә калын, авырлыгы йөз егерме кило булыр, бер ашаганда сигез өчпочмак бөкләп куя торган ирләр затыннан бу.* М.Мәһдиев

**Бөкләп салу** 1) *күч.* Җиңү, өстен чыгу

2) *күч.* Бик тиз ашап бетерү. *Элгәре ярты казан бәрәңге белән өч-дүрт телем кара ипине бөкләп салыр идек тә, җәяүләп, биш аулны урар идек.* Н.Гыйматдинова

**Бөкләп ташлау** Тиз арада бөкләү. *Аш белән икешәр кадак күмәчне бөкләп ташладык.* Г.Гобәй. *Әмма ирдәүкә шул. Бөкләп кенә ташлаячак, тәмуг газаплары күрсәтәчәк.* Ф.Яхин

**Бөкләп чыгу** Һәрберсен, бер-бер артлы, ахырына кадәр бөкләү

**Бөкли бару** *к.* **бөкләп бару.** *Ул, кырт кисеп, үтә конкрет гәпләшергә күнеккән, кул бармакларын берәм-берәм бөкли барып сөйләүчән.* Б.Камалов

**Бөкли башлау** Бөкләргә тотыну

**Бөкли төшү** Тагы да бөкләү; бераз бөкләү

**БӨКРӘЮ** *ф.* 1) Бөкре шәкелгә килү, кәкрәю

2) Бөкрегә (*2 мәгъ.*) әйләнү, бөкре булу. *Шулай йөри торгач, кара сакалына кырау төшә. Биле бөкрәя.* С.Поварисов // Бөгәрләнү; йомарланып килү. *Тик болай бөкрәеп утырмаска, торырга, хәрәкәтләнергә кирәк.* Ә.Еники. *Фани дөнья белән алыш-биреше беткәндәй, ул, иртә таңнан бирле, карчыгының аягы очында бөкрәеп утыра.* Идел

3) Алга таба бөгелү, иелү. *Бабай, бөкрәйгән килеш, сөйләнә-сөйләнә, мич янында кайнашты.* А.Иванов. *Ләкин ул арада Яруллин дигәннәре, арткы чанадан төшеп, бөкрәеп һәм толып чабуларын җирдән сөйрәтеп, үзе Зөфәр янына килде.* Ф.Яруллин. *Бөтен кешегә баш ия-ия бөкрәйде.* Ф.Яруллин

4) *күч. сөйл.* Эшләү, хезмәт итү; газап чигү, чиләнү. *Мин бер пар итек өчен ике көн бөкрәйдем, ә син бер көндә ясаган ун аршин киндергә алыштырмакчы буласың.* Г.Тукай

**Бөкрәеп бетү** Тәмам бөкрәю. *Ткачлар, көнен-төнен эш өстендә утырып, бөкрәеп бетәләр иде.* Г.Тукай. *Ничә еллар буе кырда йөреп, Бөкрәеп беткән бер урак, Теше сынып, тәмам эштән чыгып, Чормада ятты бик озак.* М.Гафури. *Сафия апа ябык йөзле, эшли-эшли бөкрәеп беткән бер авыл хатыны иде.* А.Алиш. *Чөнки бөрешеп, бөкрәеп беткән кортканың, яшь бичәләр кебек, ир хыянәте турында сөйләве – үзе бер тузга язмастай хәл ---.* Ф.Баттал

**Бөкрәеп калу** Ниндидер эш-хәлләрдән соң бөкре барлыкка килү, бөкрелек саклану. *Шулай, дустым, әле кичә генә Бәләкәйләр идек, нәниләр. Олыгаеп, бөкрәеп калдык, Ташлап киткәч безне әниләр.* И.Юзеев. *Ануны сугышка алганнан бирле, аның кәефе китте, тагын да картаеп, бөкрәеп калды, сөйләшмәс булды, кырысланды.* Г.Гомәр

**Бөкрәеп килү** Бөкрәйгән торыш алу. *Апай, киергесенә иелгән килеш, бераз шулай чигеп утыра да, бөкрәеп килгән аркасын турайтып, әнигә карап ала.* Г.Бәширов

**Бөкрәеп китү** Бөкрәйгән торыш алу; кинәт бөкрәю. *Тырпаеп киткән мыеклар һәм югарырак башы; Нәкъ дуга күк бөкрәеп киткән песинең аркасы.* Г.Тукай

**Бөкрәеп тору** Билгеле бер вакыт дәвамында бөкрәйгән хәлдә булу. *Аның өенең алдында --- бер караганда, картайганнан арып, билен тота алмаенча, бөкрәеп тора кеби күренә торган миләш агачы да бар иде.* Г.Исхакый

**Бөкрәя бару** Торган саен ныграк бөкрәю. *Кеше, картайган саен, җирнең тарту көчен күбрәк тоя, тарту көченә бирешә – бөкрәя бара.* Ш.Галиев

**Бөкрәя башлау** Бөкрәергә тотыну. *Бөкрәя башлаган йортның ишегенә, ишелеп төшмәсен дип, билбау белән ныгыткандай, аркылы такта суккаңнар икән.* Р.Мулланурова

**Бөкрәя төшү** Бераз бөкрәю. *Ул, гадәтенчә, таягына таянып, бөкрәя төшеп, зираттан кайтып килә иде.* Ә.Еники. *Йосыф кахан аның бөкрәя төшкән аркасына карап калды.* М.Хәбибуллин. *[Сталинның] Муены алга таба бөкрәя төшкән сыман.* М.Мөхәммәдиев. *Сабир бабай исә шактый бирешкән, сакал-мыеклары тәмам агарган, гәүдәсе дә бөкрәя төшкән.* Г.Әпсәләмов

**БӨКРЕ** *с.* **1.** 1) Кәкрәйгән, бөгелгән. *Шуның [агачның] бөкре тамырына атланып, түбәндәге инешкә карап утырды ул.* М.Хуҗин // Гадәттәгедән чыгынкырак, алгы өлеше калкурак булган. *Казанлы утравының бөкре сырты инде офыкның дүрттән бер өлешен каплады.* В.Обручев

2) Умыртка сөяге яисә күкрәк читлеге зарарланудан, аркасы яки күкрәге

калкып чыгып торган; *русчасы*: **горбатый.** *Боголюбовкада аны бөкре Санька гына эшли.* М.Кәрим

3) Аркасы бераз бөкрәйгән һәм җилкәләре алга чыккан; *русчасы:* **сутулый.** *Давыллы кояш баешынан – батыр егетне, күгелҗем диңгез артынан – бөкре бабайны, алланып торган кояш чыгышыннан җитез егетне китерделәр.* А.Алиш

**2.** *и. мәгъ.* 1) Умыртка сөяге яки күкрәк читлеге зарарланудан кешенең аркасында яки күкрәгендә калкып торган җир. *[Ул] Сәләмә кием кигән ирләрнең арка бөкресенә карап берничә сәгать баргач, дәшми булдыра алмады.* Г.Гыйльманов

2) Умыртка сөяге яки күкрәк читлеге зарарланудан, аркасында яки күкрәгендә калкып чыккан җире булган кеше. *Бөкрене кабер генә төзәтә.* Мәкаль

◊ **Бөкре чыгару (алу)** Авыр эштә озак һәм артык күп эшләп газап чигү. *Бөкресен чыгарып, болдырда кошкортка болгау болгаткан картинәсе, гүяки, аңа үзе белеп эшли торган эшләрне дә исенә төшереп тору өчен яратылган җан иясе инде.* А.Хәлим. **Бөкре чыгу** Авыр эштә газап чигү. *Минем җилкә бөкреләрем чыкты, әлеге дә баягы, шул Сәхап картларга эшләп.* С.Рафиков

**БӨКРЕ́ БАЛЫК** *и. зоол.* Сөләйман балыклары семьялыгыннан, вак тәңкәле, кызыл итле, кызыл уылдыклы кыйммәтле промысел балыгы; *русчасы:* **горбуша**. *Бөкре балык ите*

**БӨКРЕЛЕК** *и.* 1) Бөкре әйбернең шул формасы, кәкре булу, кәкрелек

2) Бөкре булу хәле (кеше турында). *[Петрушканың бөкре булуы] кеше кулының физик үзенчәлеге белән, [артист] бармакларны бөкләгәндә хасил булган табигый бөкрелек белән бәйле.* Р.Игъламов

**БӨКТӘР** *и. монг. диал.* Төен, төенчек, төргәк. *Ишектән, инде зур ук бер бөктәр белән, Шәйхаттарның Майбәдәре чыга.* Г.Толымбай. *Берсе, зур бөктәрне чишеп, аш өстәленә кыйммәтле тун эчлеге китереп җәйде.* С.Җәләл. *Шушы төнне Гайфи, бөктәр белән, Ындыр артлап чыгып йөгергән.* Н.Баян. *Елга ярына баскач, үзебезнең печәнлек, шул киемнәр тутырылган бөктәр искә төште.* Ә.Рәшит

**БӨКШӘЮ** *ф. диал. к.* **бөрешү** (*2, 3, 4 мәгъ.*). *Картая-картая гына кулны артка куймаска, бөкшәймәскә, гәүдәне төз тотып атларга тырышыла икән.* К.Миңлебаев. *Кер инде, ябалак, яшь-җилкенчәккә урын бирмичә, капка төбендә бөкшәеп утырма!* Ф.Әмәк. *Ак кәгазьгә конфет кебек төрелгән көмешсу акчаларны оялудан бөкшәйгән учына берәм-берәм санап сала ---.* К.Кәрим. *Көчкә-көчкә бусаганы атлап кергәч: «Әһә, син дә ачлыктан бөкшәйгәнсең», – дип хихылдагандыр, мөгаен.* Н.Гыйматдинова

**Бөкшәеп бару** Акрынлап, аз-азлап көчәя барып бөкшәю. *--- ә хәзер шәбәргән тавык кебек бөкшәеп бара инде, – диде.* А.Таһиров

**Бөкшәеп бетү** Тәмам бөкшәю. *Нинди түземлек кирәк булгандыр бу кешегә, нинди газаплар күргәндер бу – бөкшәеп беткән сукыр кеше!* Р.Батулла

**Бөкшәеп калу** Билгеле бер хәлдән соң бөкшәйгән хәлгә килү. *Бәдретдин мелла чыгып киткәнче, шәех Игнәй аның бөкшәеп калган җилкәсенә карап торды.* М.Хәбибуллин

**Бөкшәеп тору** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында бөкшәйгән торышта булу. *Яңгыр шундый нык ява, хәтта шул шәп айгырның да гайрәтен сүндергән: ул да бөкшәеп тора.* В.Нуруллин

**Бөкшәя төшү** Бераз бөкшәю. *Безнең каршыга бөкшәя төшкән бер әби йөгерә, үзе бертуктаусыз нидер кычкыра, кулындагы кечкенә генә кәгазьне болгый. «Булатым исә-ән! Булатым акча салган, хат язган Булатым!» – дип, куанычыннан җылый әби, үзе сөенә.* Р.Батулла

**БӨЛГЕНЛЕК** *и.* 1) Зур мохтаҗлык; җитешсез тормыш; ярлылык. *Керем мулдан булмый, әлбәттә, кайда да – бөлгенлек, кыйммәтчелек.* Т.Әйди. *Бөтен халык хәерчелектә, бөлгенлектә яши.* Р.Фәизов

2) Мал-мөлкәтне югалту, зур матди югалтуларга дучар булу

**БӨЛДЕРГЕЧ** *с.* Бөлдерә торган, хәерчелеккә, фәкыйрьлеккә китерә торган. *Революция, ватандашлар сугышы, 1921 ел ачлыгы, кулакларның сыйныф буларак тамырын корыткан утызынчы еллар ахыры, Икенче дөнья сугышы афәте, соңгы дәвердәге шәһәрләшү хәрәкәте – һәммәсе авылга бөлдергеч эзен салган...* Т.Әйди. *Әйе, авыр, җәфалы, бөлдергеч сугыш беткәнгә кайчан гына бит әле!* А.Гыйләҗев

**БӨЛДЕРМӘ** *и. диал.* Кылыч, чыбыркы кебек нәрсәләрнең кулга кию өчен җайланган элмәге, чыбыркы элгече

**БӨЛДЕРЧЕН** *и. зоол. диал.* Бүдәнә, бытбылдык

**БӨЛЕКЛЕК** *и. иск.* Мал-мөлкәтне югалтып, нык ярлылану. – *Әй халаеклар, егетләр, бу бөлеклек, бу кыргын безләргә кемнәрдән булды? – диеп сорар иде.* Риваять. *Ул бөлеклектән соң, килеп, Казан елгасы өстендә кала ясадылар, шәһәр иттеләр.* Риваять

**БӨЛҮ** *ф.* 1) Ярлылану; бөлгенлеккә төшү, малдан язу. *Бөлгән бояр эчеп үләр.* Мәкаль. *Бәк көләр, бергә көлгән – бөләр.* Мәкаль. *Хәзер ул фабрикалар бөлде, тегүчеләре урамга чыгарып җибәрелде.* М.Маликова

2) *махс.* Оттырып бетерү (уенда)

**Бөлеп бару** Акрынлап бөлү, бөлүгә йөз тоту. – *Бөлеп barганыбызны күрмисеңмени! – дип кырт кисте [ул].* М.Маликова

**Бөлеп бетү** Тәмам, тулысынча бөлү. *Хатыннарын киендерә-киендерә, бөлеп беткән кешеләрнең очы-кырые юк.* Г.Камал

**Бөлә бару** *к.* **бөлеп бару.** *Хан бөлгәннән-бөлә бара.* Р.Батулла

**Бөлә башлау** Бөлергә тотыну. *Бөлә башлаган байның эте дә чыгып кача.* Мәкаль

**БӨРЕ** *и.* **1.** 1) Үсемлекләрдә ботак, яфрак яки чәчәк яралгысы; бәбәк. *Кызыл таллар бөреләрен ачты.* Г.Хәсәнов. *Ә сабакта – керфекләрен ачарга җыенган күпме чәчәк бөресе иде!* Н.Гыйматдинова. *Минзөфәр апельсин агачының чәчәк бөреләренә карап сокланды.* Н.Хәсәнов. *Бәбәк очында, гадәттә, өч бөре, ә яфрак куеннарында куен, ягъни ян бөреләр була.* Биология

2) Өлгереп җитмәгән җиләк-җимеш. *Җиләкне бөре килеш һич кенә дә әрәм*

*итмәм, дип, мәңгегә ант иттем.* Г.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Ачылып (чәчәк, яфрак һ.б.ш. турында), өлгереп (җиләк-җимеш турында) җитмәгән; яралгы хәлендә булган. *Бөре чәчәк*

**БӨРЕЛӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Бөре яралу, бөре чыгару. *Гөлләр дә бит чәчәккә бөреләнәләр дә, вакытында яңгыр яумаса, ачыла алмыйча, бик озак утыралар.* Ф.Яруллин. *Алмагач бүген бөреләнгән, Чәчәк атар, ахры, иртәгә.* М.Җәлил

2) *күч.* Яралу, барлыкка килү, уяну (хис-дәрт, теләк һ.б.ш. турында). *Шулай бервакыт, хисләрем бөреләнгән көннәрдә, мин дә, сезнең кебек, күңелсез минутлар кичергән идем.* Г.Минский. *Хәзрәтне өйләндерергә, дигән төскә кереп, [бу уй] тамырланды, бөреләнде, яфрак ярды.* Г.Исхакый. *Бу хисләрдән, бөреләнеп, яңа хыяллар, киләчәккә яңа өмет туды.* Г.Гыйльманов

**2.** *и. мәгъ. биол.* Кайбер гөмбәләрнең һәм хайваннарның җенессез үрчү ысулы. *Җенессез үрчүнең бу ысулын «бөреләнү» дип атыйлар.* Гомуми биология

**Бөреләнә бару** 1) Акрынлап бөреләнү. *Яңгыр җебе буйлап үрли уйлар, Үрли – югарыга, һаман биеккә! Менәменә алар, хыял-идеал булып, Яфрак яра, бөреләнә бара чәчәккә!* Р.Фәйзуллин

2) Торган саен көчәю, арту. *Туфайлов йөзендә ул совет власте сыйфатларын күрә, һәм аның күңелендә, әкрен-әкрен, яңа тормышка ышаныч бөреләнә бара иде.* Х.Камалов

**Бөреләнә башлау** Бөреләнергә тотыну. *Фатыйма, җир кибеп, агачлар яфракка бөреләнә башлаган чорда гына, Сәмигулла абзыйлар йортына икенче тапкыр килен булып төште.* Ф.Абдуллин

**Бөреләнеп алу** Кыска вакытка, азга гына бөреләнү. *Иреннән яшьли тол калган хатынның үзенең дә яз саен чәчәккә бөреләнеп алган чаклары.* З.Хөсният

**Бөреләнеп бетү** Тулысынча бөреләнү

**Бөреләнеп җибәрү** Тиз арада яки көтмәгәндә бөреләнү. *Яңа нигездә яран гөлдәй тирән тамыр җәй, гөлең дә, үзең дә пардан бөреләнеп җибәрегез, тигез яшәгез, тормышыгыз шау чәчәктә булсын.* Т.Мөбарәков

**Бөреләнеп җитү** Тиешенчә бөреләнү, ачылып китү дәрәҗәсенә җитү. *Йокы алмый, никтер, йөрәк ярсый, Төрле уйлар килә күңелгә. Бөреләнеп җиткәч, яши алмый Шиңәрмен күк инде гомергә.* М.Җәлил

**Бөреләнеп килү** Бөреләнергә җыену, акрынлап бөреләнү. *Яңа бөреләнеп килгән тал куаклары эченнән барабыз.* Г.Гобәй. *«Миндә аңлашылмаган бер куаныч бар. Йөрәк түремдә гаҗәеп бер хис бөреләнеп килә...» – дип язган Кәмран.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Бөреләнеп тору** Бөреләнергә әзерләнү. *Күңелдә бөреләнеп торган идеал, бәхеткә омтылу яңадан баш калкыта.* Ә.Закирҗанов

**Бөреләнеп утыру** Бөреләнгән хәлдә булу

**БӨРЕЛЕ** *с.* Бөресе яки бөреләре булган, бөре чыгарган. *Бөреле агач ботаклары гына бер-берсе белән чәбәкләшеп шаяралар.* А.Алиш

**БӨРЕШ** I *и.* Бөрелгән урын, җыерчык

**БӨРЕШ** II *и.* Боз тишә торган кечерәк лом. *[Балыкчы] Кулындагы боз вата торган бөреше белән, бүренең маңгаена бер-ике мәртәбә суккан.* Әкият

**БӨРЕШ** III *и. махс.* Бөҗрасыман мускул

**БӨРЕШЛЕ** *с.* Бөрешләре I булган, бөреп эшләнгән. *Ап-ак өй эче аслы-өсле кызыл башлы сөлгеләр белән бизәлгән, бер як стенага ак бөрешле ашъяулык элеп куелган.* Г.Әпсәләмов

**БӨРЕШТЕРҮ** *ф.* 1) Җыерып очлайту; бөрү. *Һайгануш була торып Һайгануш та, мине бар дип тә белми торган кыз, авызын бөрештереп, елап җибәрде.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Казак, авызын бөрештереп, егетне нәфрәт белән күздән кичерде дә, читкә борылып, капка төбендә йөренергә кереште.* А.Толстой. *Күзләрен кыса төште Фәлак, иреннәрен бөрештерде.* Р.Мөхәммәдиев

2) *сөйл.* Тиз-тиз, өстән-өстән генә җыергалап, бөрешләр ясап, ямап я тегеп кую. *[Әсхәпҗамал] Читегенең тишекләрен җеп белән генә бөрештереп, корым сөртте.* К.Нәҗми

3) Авыз эчен җыерып китерү (кайбер җиләк-җимеш турында). *Кара җиләкнең җимешләре сусыл, авызны җиңелчә генә бөрештерә торган, татлы тәмле.* Р.Рәхимов

4) Киптереп корыту, куырып китерү. *Көчле салкын агач яфракларын бөрештергән*

**Бөрештерә башлау** Бөрештерергә тотыну

**Бөрештерә төшү** Бераз бөрештерү. *Кыз, матур иреннәрен бөрештерә төшеп, чыраен сытты.* М.Шаһимәрдәнов

**Бөрештереп алу** Кинәт бөрештерү. *Куелыгы ягыннан сыек каймакны һәм төсе ягыннан шпинат пастасын хәтерләтә торган бу эчемлек авызны бөрештереп ала, хуш исле була.* Серле календарь

**Бөрештереп китерү** *к.* **бөрештереп алу**. *Аның каравы, күз карашлары йөрәккә сугарлык, бөтереп, бөрештереп китерерлек.* М.Хәсәнов

**Бөрештереп кую** Алдан бөрештерү, бөрештергән хәлгә китереп калдыру. *Нина, алгы яктан, итәк уртасын бил буена бөрештереп куйган.* В.Имамов

**Бөрештереп чыгу** Башыннан ахырына кадәр бөрештерү

**БӨРЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **бөрү** (*1 мәгъ.*)

2) Түгәрәкләнеп очлаю, бөрелү, җыерылып тартылу (иреннәр, авыз турында). *Ләйләнең иреннәре бөреште, --- күз кабаклары кысылды, җиз керфекләре бер-беренә тиеп, күзләре йомыла язды.* Р.Батулла. *Карчыкның җыерчыклар ермачлаган чырае кинәт караңгыланып китте. Иреннәре ачу белән бөреште.* Х.Камалов. *Әмма кыз янында Гайнанны күрүгә, аның иреннәре бөреште, күзләрендә усал чаткылар уйный башлады.* Г.Бәширов

3) Тартышып, җыерылып килү, кибеп корышу, куырылу. *Бөреләр суыктан бөрешә.* Ф.Яруллин. *Кыш көннәрендә инсаннарның каннары бөрешкән, куеланган хәлдә була.* Г.Исхакый. *Ашавы начар, әчкләре бөрешкәндер.* Н.Гыйматдинова

4) Кечерәю; корышу (салкыннан, картаюдан, кайгыдан һ.б.). *Ул бала кебек бөрешеп ятты.* Р.Батулла. *Мин, әкрен генә, кереп, мич буена бөрешеп ятам, йокыга китәм.* М.Мәһдиев. *Анда-санда бөрешкән солдат төркемнәре очрый.* Ә.Гаффар. *Матур гына җиңел пассажир паровозлары, салкыннан һәм җилдән бөрешеп, киң күкрәкле көчле йөк паровозлары «С.О»га елышканнар шикелле.* Р.Мирхәйдәров

5) Авыз эче җыерылган кебек булу (кайбер җиләк-җимешне, яшелчәләрне ашаганнан соң). *Бичараның әче алмадан иреннәре бөрешкән, саруы кайный башлаган.* Н.Каштанов

◊ **Бөрешкән куян** *мыск.* Кечкенә гәүдәле, мескен кыяфәтле кеше. *– Янымнан хәзер генә әзмәвердәй ир китте. Син ни пычагыма кирәк миңа, бөрешкән куян? – дип, йөрәксенеп, шапылдатып тәрәзәне ябып куйды ачулы хатын.* Г.Сәгыйров. **Бөрешкән тавык** *мыск.* Туңучан кеше турында

**Бөрешә бару** Торган саен ныграк бөрешү

**Бөрешә башлау** Бөрешү билгеләре күренү. *Җиләкнең яңа пешкәненең дә хәлсез чагы. Күбесе кипкән, куырылган. Бөрешә башлаганнары, көн эссесеннән качып, яфрак асларына елышкан.* Рифә Рахман

**Бөрешә төшү** Бераз бөрешү. *Ничектер, гәүдәгә дә чүгә, бөрешә төшкән кебек булды.* Ә.Еники. *Чигенер урыны беткән, инде почмакка кысрыкланган җәнлек сыман, Юлдыбаев, көтелмәгән сикерешкә әзерләнеп, бөрешә төште.* Ә.Баян

**Бөрешеп бетү** Бик нык бөрешү. *Заһидә, идән ярыгына төшеп кысылырдай булып, бөрешеп бетте.* М.Әмирханов. *Алар [чәчәкләр] төссезләнеп, ямьсезләнеп, бөрешеп беткәннәр.* И.Сирматов. --- *аның янына бер ар карты килеп басты. Бөрешеп беткән.* М.Әмирханов

**Бөрешеп калу** Нindidер вакыйгалар, хәлләр тәэсирендә бөрешү. *Хәйрулла абзый, берьюлы бөрешеп, хәлсезләнеп кала.* Һ.Такташ. *Заһидулла, ни куәтле, гайрәтле кеше булса да, ничектер, бөрешебрәк, кечерәебрәк калды шикелле.* Р.Сибат. *Егет янә бөрешеп калды.* Э.Касыймов. *Мин, шырыйлап, почмакка атылдым да, кулыма эләккән бер пәлтәгә төренеп, бөрешеп калдым.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Бөрешеп килү** Күз алдында, әле, хәзер бөрешкән, җыерылган торышны, форманы алу. *– Нишләдең син, ә?! – дип кычкырып җибәрдем мин. Кыз, үзен җилтерәтә башлармын дип куркып, бөрешеп килде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Бөрешеп кую** Кинәт, аз гына вакытка бөрешү. *Хәдичә, аркасы туңып киткәндәй булып, бөрешеп куйды.* Г.Бәширов

**Бөрешеп тору** Әле, сөйләү моментында бөрешкән булу, бөрешкән хәлгә килү. *Почмакка килеп күз салды: капка төбендәге фонарь яктысында мылтык тоткан сакчы бөрешеп тора.* Ә.Мушинский

**Бөрешеп төшү** Бөрешеп, сәлперәйгән хәлгә килү. *Ул вакытыннан алда картайган: аның йөзен җыерчыклар каплаган, чәчләре агарган, бит алмалары бөрешеп төшкән.* Х.Ибраһим

**БӨРИ** *и. диал. к.* **бөре** (*2 мәгъ.*). *Җиләкне бөрие белән җыю*

**БӨРКӘВЕЧ** *и.* Нәрсәне дә булса ябу, каплау өчен кулланыла торган япма, каплавыч. *Әлфия, тәрәзәләргә маскировка бөркәвечләре элеп, өстәл әзерли башлады.* Г.Бәширов. *Зәңгәр бөркәвеч эленгән ачык тәрәзә аша, пристань ягыннан, суны шапылдатып, пароходлар һәм буксирлар узып киткәне, халыкның шау-шуы ишетелеп тора.* Г.Бәширов

**БӨРКӘВЕЧЛЕ** *с.* Бөркәвече булган; өсте ябулы. *Без шунда Мөҗәй белән, чүмәлә төбендә, бөркәвечле кечкенә кабык арбада, имезлек кабып, тын гына ята торган булганбыз.* Г.Галиев

**БӨРКӘГЕЧ** *и. к.* **бөркәвеч**

**БӨРКӘНҮ** *ф.* 1) Баштанаяк төренеп, томаланып яту, өскә ябыну. *Шикле – шикләнер, чикмәнен бөркәнер.* Мәкаль. *Кайнар килеш әйбәтләп кенә эчәрсең дә бөркәнеп ятарсың.* Р.Ишморат. *Ильяс одеялын башыннан ук бөркәнде дә стенага борылып ятты.* И.Низамов. *Язидә, башыннан ук бөркәнеп, тынып калды.* Г.Бәширов

2) Йөзне генә ачык калдырып бәйләү, шәл яки яулык ябыну. *Ак яулык бөркәнгән берсе, «Чулпан» турында булса кирәк, зарланып бара иде.* Г.Бәширов. *Башын-күзен кешегә күрсәтмәстәй итеп шәл бөркәнгән Җәүһәрия кирә дә ишек янында басып катып кала.* Р.Ишморат. *Зәнфирә, тунын элеп, шәлен бөркәнде дә чыгып йөгерде.* Ф.Садриев

**Бөркәнеп алу** Тиз генә бөркәнү

**Бөркәнеп бетү** Күп катлап, кабат-кабат бөркәнү

**Бөркәнеп җибәрү** Тагын нәрсә дә булса өстәп бөркәнү, бөркәнгән булу. *[Хатын] Шуның [пальто] өстеннән шәл бөркәнеп җибәргән.* Р.Вәлиев

**Бөркәнеп йөрү** Һаман, һәрвакыт бөркәнгән булу. *Түбән оч Фәридун абзый хатыны Гыйльмиҗиһан түтигә: «Еллар буе башыңа бер яулык бөркәнеп йөрисең, туйдым бу яулыгыңнан!» – дип бәйләнә икән.* Г.Зәйнашева

**Бөркәнеп кую** Алдан бөркәнгән булу. *Дөбердәп, Фәрхәт килеп кергәндә, юрганын башыннан ук бөркәнеп куйган иде.* Л.Гыймадиева

**Бөркәнеп тору** Әле, хәзерге вакытта бөркәнү

**БӨРКӘНЧЕК** *и.* 1) Элек хатын-кызлар, йөз яшерү өчен, кием өстеннән бөркәнеп йөргән махсус җиңсез ябынча. *Әнә инде аларның кеше икәнлекләре дә шәйләнде ---. Кара бөркәнчек ябынганнар.* Г.Гыйльманов. *--- башкорт хатыннарыныкы кебек, билен, күкрәген тәңкәләтеп, бишмәт тектерде, кушъяулык – бөркәнчек ябынды.* Г.Ибраһимов. *Матур һәм тылсымлы итеп төргән Шәрык хатын-кызны. Һәр бөркәнчек эченә яшеренгән кыз җир йөзенең иң беренче сылуыдыр кебек тоела безгә.* М.Юныс

2) *сир.* Фата. *Ак бөркәнчек япкан кәләш – Шау чәчәкле алмагач...* Р.Низамиев

3) *диал.* Мәетне кабергә алып барганда, өстән каплый торган япма

4) *күч.* Ясалмалык. *Илнең эчендә, теге яки бу бөркәнчек астында качып калган контрреволюцион буржуазия --- үзенең зарарларын сала килде.* Ф.Хөсни

5) *күч.* Нәрсәнедер каплап алган япма (үлән, яфрак, бәс, томан һ.б.ш. турында). *Әле яңарак кына нәфис яшел бөркәнчек ябынган каен урманы артында, моңлы итеп, поезд кычкырта.* Ф.Шәфигуллин

**БӨРКӘНЧЕКЛЕ** *с.* Бөркәнчеге булган; бөркәнчек бөркәнгән. *Яшел бөркәнчекле больнис йорты – Тәкәнешнең урта урнында.* Ш.Маннур

**БӨРКӘ́Ү** I *ф.* Ябу, каплау, өретү. *Бу дөньяда озак яшәлде, дип Риялан-мый биргән көченнән. Атлый карчык, бөркәп ак яулыгын, Бисмилланы укып эченнән.* Р.Батталов

**Бөркәп бару** Һәммәсен, берсе артыннан берсен бөркәү

**Бөркәп бетерү** Барысын да бөркәү; тулысынча бөркәү

**Бөркәп йөрү** Һәрвакыт бөркәнгән булу

**Бөркәп кую** Бөркәлгән хәлдә калдыру. --- *урыныннан сикереп торып, нәрсәдер сөйләргә керешкән иде дә Рәшит, әнисе аның юрганын башыннан ук бөркәп куйды. – Йә, ярар, йокла, йокла...* Ф.Шәфигуллин

**Бөркәп чыгу** Һәрберсен, башыннан ахырына кадәр бөркәү

**Бөркәп тору** Вакытлыча бөркәү. *Ә хәзергә моның өстенә одеал-фәлән бөркәп торыйк.* Ф.Яруллин

**Бөрки төшү** Бераз бөркәү

**БӨРКӘ́Ү** II *и.* 1) Каплавыч, өртү, япма. *Бикбулат, калын кашларының бөркәве астына посынган кечкенә күзләре белән идәнгә текәлеп, авыр тынлыкка батты.* Г.Бәширов

2) *диал.* Лапас. *Иргали, ягар өчен сүтелгән өенең ныграк такталарын сайлаштырып, куыш алдына бөркәү сыман нәрсә дә әтмәлләп куйган иде.* М.Хәсәнов

**БӨРКӘҮЛЕ** *с.* 1) Бөркәве булган; бөркәнгән; өсте, ян-яклары ябулы. *Һади клубның яңа тактадан эшләнеп куелган бөркәүле баскычы төбенә килеп җитте.* М.Хәсәнов. *Тагы да бер айдан бөркәүле ак машина туктады аларның өй алларына.* Т.Гарипова. *Башы бөркәүле, өстендә – аяк йөзенә төшеп торырлык итеп тегелгән озын, авыр күлмәк.* М.Әмирханов. *Яралыларны, бөркәүле кузовларга төяп, кайсын кая ташырга керештеләр.* Х.Камалов

2) Бөркәү астында булган. *Бөркәүле ашлык*

**БӨРКЕГЕЧ** *и.* Сыекчаларны сиптерү өчен махсус җайланма; сиптергеч. *Кечкенәрәк участоклар өчен, ОРП маркалы, цилиндрик резервуарлы, ранецлы пневматик бөркегеч бик уңайлы.* Яшелчәчелек

**БӨРКЕТ** *и. зоол.* **1.** 1) Карчыга кошлар семьялыгыннан, киң канатлы, кәкре томшыклы, канат колачы зур булган эре ерткыч кош; сәмруг кош; *русчасы:* **беркут, орёл**. *Бөркет биектән курыкмас.* Мәкаль. *Булды пәйда әллә кайдан бер зур бөркет, Җил-җил иткән канатларын селкеп-селкеп.* Г.Тукай

2) *күч.* Кыю, куркусыз, йөрәкле кеше. *Аның каравы, син – хәзер бөркет.* Ә.Мушинский. – *Тылда озак ятмассыз, бөркетләр! – диде ул, тигез сафларны карап узганда.* Ш.Рәкыйпов. *Менә нинди бөркет ул безнең Сибгат!* Таныш өянкеләр

**2.** 1) *с. мәгъ.* Үткен, очлы. *Яшь, бөркет күз иңбаштагы яраны, кан тапларын күреп ала.* Т.Галиуллин

2) Бераз бөкресе булган. *Бөркет борыныннан гына шәйләдем.* К.Миңлебаев

**БӨРКЕТЧЕ** *и.* Бөркет тәрбияләүче, аны ауга өйрәтүче; бөркет белән ауга йөрүче. – *Дустың Буранбай нигә өйрәтми? – Әйе, ул белә, ул – бөркетче булып азау ярган.* Г.Якупова

**БӨРКҮ** I *ф.* 1) Вак тамчылар белән чәчрәтеп сибү. *[Ул] Бизәнеп беткәч, чәченә, түшенә «Ак сирень» хушбуен бөркеде ---.* Ә.Еники. *Җәүдәт чәчен сыпырып карады, чәче лычма иде аның, әллә кан, әллә су бөркегәннәр.* А.Гыйләҗев. *Гажилә җиңги чәйдән авыз итте... һәм кинәт, тончыгып, авызындагы чәен идәнгә бөректе.* М.Мәһдиев. *Өстемә пычрак су бөркеделәрмени ---.* Сөембикә // Вак тамчылап, сибәләп туктаусыз яву. *Көн буенча, төн буенча өскә яңгыр бөркәләр.* М.Гафури // Күп итеп чыгарып тору, тарату (газ, пар һ.б.ш. турында). *Самавыр пар бөркеп калтыранырга тотынды, казанда шулпа гөбердәп тавыш бирде, бүлмәгә тавык ите исе таралды.* А.Гыйләҗев. *Казанда пар бөркеп, быкырдап, аш кайный: Тоз каян алырга ул ашка?* Ф.Гыйззәтуллина

2) Чәчү, сибү, тарату (нур, яктылык һ.б.ш. турында). *Чү, күләгә! Нур бөркегән кояш Кергән кебек булды болытка.* Ф.Кәрим

3) Аңкыту. *Хуш ис бөрки гөлләр.* Ә.Ерикәй. *Урак урыр вакыт тагын җитте, Җилләр бөрки арыш исләрен.* Ә.Ерикәй

4) *күч.* Сизелеп, беленеп тору, биләп алу. *Нәфрәт уты бөркеп сулыш ала Я, онытылып, кинәт тынсыз кала, Көтә халык хөкем карарын.* Ф.Кәрим

**Бөркеп алу** Кыска вакыт, аз гына бөркү. *Юкәләр күләгәсендә калган яшел сукмак, салкын су бөркеп алгандай, җетеләнеп китте.* Г.Вәлиева. *Күз алмалары, инде туар кояшка әйләнеп, нур бөркеп алдылар.* Рифә Рахман

**Бөркеп бетерү** 1) Барысын да, ахырга хәтле бөркү

2) Чамадан тыш күп бөркү

**Бөркеп җибәрү** Кинәт бөрки башлау. *Бакчаларына оялаган кошчык әнисе киткәннән соң күңелдә туган салкынлыкка җылы нурлар бөркеп җибәргәндәй итте.* Ф.Яруллин. *«Бу тере су башка мөселманнар өчен дә булырга тиеш, улым...» Шулай диде дә әтисе шешәдәге соңгы тере суны җирдә яткан мәетләр өстенә бөркеп җибәрде...* Ф.Бәйрәмова

**Бөркеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта төрле урыннарга, һәрберсенә бөркү; су бөркү белән мәшгуль булу. *Сәкинә, авызына кабып, чәчәкләр өстенә су бөркеп йөри.* Р.Батулла

**Бөркеп тору** 1) Бертуктаусыз, һәрвакыт бөркү. *Туып-үскән нигезендә иман нуры бөркеп торган әти-әнисе бар бит әле.* К.Кәримов. *Урак өсте челләсендә кыр ягының кайнар җилләрен ышыкларлык бакчалар да, салкын җиләс җил бөркеп торган дымлы һавалы урманнар да юк иде якын-тирәдә.* А.Гыйләҗев. *Мичтә пешергәндә, ит өстенә су бөркеп торырга тырышыгыз.* Акчарлак

2) Әле, сөйләп торганда, күз алдында бөркү. *Аның ап-ак йөзенә үлек төсләре кергән, ә карашлары караңгылык,*

*салкынлык бөркеп тора.* Г.Гыйльманов. *Үзеннән әллә нинди дәрт бөркеп тора.* Г.Бәширов

**Бөркеп утыру** *к.* **бөркеп тору** (*2 мәгъ.*). *[Ул] Авызыннан сулар килсә дә, пар бөркеп утыручы өчпочмакларны этеп җибәргәләде...* Ф.Яруллин

**Бөркеп чыгу** 1) Һәрберсенә бер-бер артлы бөркү

2) Басым белән бөркелү, атылып тору. *Тау битендәге таш араларыннан чишмә бөркеп чыга.* Р.Хәйретдинова

**Бөркеп яту** *к.* **бөркеп тору** (*2 мәгъ.*). *Юллар, кырлар монда бүтәнчә иде, сөрелгән, чәчелгән җирләр, күз явын алып, пар бөркеп яталар.* А.Гыйләҗев

**БӨРКҮ** II *с.* **1.** Тынчу, дымлы эссе, сулыш алырга авыр булган. *Кышкы суыктан да әшәкерәк икән ул бөркү эсселек!..* Ә.Еники // Сулау өчен авыр һавалы. *Румын скрипкалары, хатын-кызларның хушбуй исләре, бөркү залның гөрләве нәтиҗәсендә, дулкынланган күңел түрендә тирә-яктан алган тәэссоратның күләгәсе пәйда булды, ул күләгәнең исеме – илһам иде.* А.Толстой. *Биш ел буе тулай торакның кысан, бөркү һавасыннан йончу гына җитмәгән, саф һавада йокларга тилмер инде син!..* К.Кәрим

**2.** *и. мәгъ.* Артык эссе вакыт; суларга авыр һава. *Бөркүдә спиртны күп эчкәнгә, шәмнәр дә сүлпән генә яктыртканга, шәфкать туташлары хәйран чибәр булып күренәләр.* А.Толстой

**БӨРКҮЛӘНҮ** *ф.* Бөркүгә II әйләнү. *Үзләрен үзләре өрдереп суытса да, тәүлекләр буе эшләп торгач, электромоторларның тәне җылына, һәм кизү торучы агайларның эш урыны бөркүләнә.* К.Кәримов

**Бөркүләнә бару** Торган саен ныграк бөркүләнү

**Бөркүләнә башлау** Бөркүлек барлыкка килү. *Һава монда да --- шактый гына җылына, бөркүләнә башлаган түгелме?* А.Хәлим

**Бөркүләнә төшү** Бераз бөркүләнү. *Кояш шактый күтәрелде, һава да бөркүләнә төште.* М.Шабай

**Бөркүләнеп килү** Акрынлап бөркүләнү. *Һава бөркүләнеп килә иде.* Г.Бәширов

**Бөркүләнеп китү** Кинәт бөркүләнү. *Өй эче бик бөркүләнеп китте.* И.Гази. *Баскычка чыгыйк булмаса, бик бөркүләнеп китте.* Г.Мөхәммәтшин

**БӨРКҮЛЕК** *и.* Эсселек, тынчулык. *Әгәр һава булмаса, кешеләр вә хайваннар бөркүлектән үләрләр иде.* Г.Тукай. *Бөркүлеккә чыдый алмыйча һәм, күрәсең, бүлмәдә үзе генә булудан файдаланып, ул өстендәге калын киемнәрен салып ташлаган ---.* Н.Фәттах. *Кичә генә бөркүлектән җәфа чиккән чәчкә һәм үләннәрнең күзләре һәм йөзләре тулаем ачылып китеп, һәр тарафка хуш ис тарата, күңелне җилкендерә.* А.Хәлим. *Кояшка караган бүлмәләрдә тын алгысыз эссе, күксел ефәк пәрдәләр бөркүлекне тагын да арттыра шикелле.* М.Маликова

**БӨРЛЕГӘН** *и.* 1) Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, туры сабаклы, яфраклары өчкә аерылып урнашкан, чәчәкләре ак, җимешләре кызыл төстә була торган үсемлек; *русчасы:* **костяника**. *Су буенда уңган бөрлегән Былбыл кошлар кунгач бөгелгән.* Җыр. *Ул безнең яклардагы бөрлегәнне күрсәң син!* Ф.Яруллин. *Кара җиләк һәм нарат җиләге, кызыл бөрлегән, ландыш, абага һәм плауннар – болар урман үсемлекләре.* Биология

2) Шул үсемлекнең аз гына бер-берсенә тоташкан кызыл төстәге әчкелтем сусыл җимеше. *Җыеп кырдан бөрлегән Килгән иркәм, бер генәм.* М.Җәлил. *Кайда соң кып-кызыл бөрлегәннәре белән янып, исерткеч исле колмакларына чорналып утырган әрәмәлек?!* Ф.Бәйрәмова. *Гомер-гомергә авыл халкы, бигрәк тә хатын-кыз, бала-чага Сөн буена карлыган, кура җиләге, бөрлегән, шомырт, балан җыярга төшә торган иде.* И.Абдуллин

3) Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, сабаклары һәм яфрак саплары чәнечкеле, үрмә сабаклы тугай үсемлеге; *русчасы:* **ежевика**

4) Шул үсемлекнең ашарга яраклы зәңгәрсу кара төстәге җимеше. *Бөрлегән җыеп кайткан көнне төне буе төшләреңә керә. Күзеңне йомдыңмы – күз алдыңда зәңгәрсу бөрлегәннәр.* Ф.Яруллин

**БӨРЛЕГӘНЛЕ** *с.* 1) Бөрлегән күп үскән. *Хәтеремдә чыклы ызаннарда Шаян тургайларның сайравы, Бөрлегәнле урман буйларында Чалгы тавышлары яңгыравы.* Р.Вәлиева

2) Бөрлегәннән ясалган; бөрлегән кушылган

**БӨРЛЕГӘНЛЕК** *и.* Бөрлегән күп үсә торган урын. *Әле менә бу тирәдә бөрлегәнлек тә булырга тиеш.* Ф.Бәйрәмова

**БӨРМӘ** *и.* **1.** Бөрелгән, бөреп тегелгән урын (киемнәрдә, янчыкта һ.б.ш.да). *Иске чалбарга – яңа бөрмә.* Әйтем. *Кызы пальтосын ыргытты да, гел әнисенә охшатып, җиңнәрен сызганды, итәген алгы яклап бөрмәсенә кыстырды һәм идән юарга кереште.* Ф.Садриев. *Яшь чагындагы кебек, озын күлмәк итәген сул яктан ыштан бөрмәсенә кыстырып, ике аягын тезенә хәтле ачып куйды.* З.Зәйнуллин. *Туйганчы ярганнан һәм ашаганнан соң, буш кул белән кайтмас өчен, итәкләрен бөрмәләренә кыстырып, чикләвекне күлмәк эченә тутырдылар.* Ә.Фәйзи

**2.** *с. мәгъ.* Бөрмәсе булган, бөреп тегелгән. *Аның өстендә – бөрмә билле җилән.* З.Бәшири

**БӨРМӘЛӘНДЕРҮ** *ф. сөйл.* Түгәрәкләп җыеру, бөрү (иреннәрне, авызны)

**Бөрмәләндереп кую** Җыерылган, бөрмәләнгән хәлгә китерү. *Лида кан сирпеп торган тулы иреннәрен бөрмәләндереп куйды.* Ә.Айдар

**БӨРМӘЛӘ́Ү** *ф.* Бөрмәле итеп тегү. *Күлмәкләрне, озын итеп, бөрмәләп, «бәби итәкләр» куеп тегәннәр.* К.Закирова. *Ул озын, таза; өстендә – кара бәрән тиресеннән билен бөрмәләп теккән тун.* Казан утлары

**БӨРМӘЛЕ** *с.* 1) Бөреп тегелгән, бөрмәсе булган. *Би хатыны өстендә – бөрмәле итәкле куе яшел төстәге күлмәк ---.* М.Хәбибуллин. *Петяның өстендә – тузып беткән, бөрмәле кәрән кафтан.* Г.Гобәй. *Аның [Садыйк абзыйның] артында, бөрмәле күлмәк кигән, Пенза шәле ябынган моң гына бер абыстай баскан.* Г.Исхакый

2) Бөрелгән, җыерып очлайтылган. *Булатовның да, кызларныкыдай бөр-*

*мәле ireннәрен җәя төшеп, янымда басып торуын хәтерлим.* Р.Төхфәтуллин

**БӨРТЕК** *и.* 1) Сибелә, чәчелә торган вак нәрсәләрнең берсе, бер данәсе, берәмлеге. *Я берәр шакмак шикәр, я дүрт-биш бөртек йөзем җимеше, я прәннек валчыгы, я кипкән шомырт, я куырылган борчак була.* М.Кәрим. *Мин, бер-ике бөртек миләш кабып, көчхәлгә чәйни башладым.* Г.Галиев. *Тузан бөртеге дә кунарга өлгермәгән ап-ак яулыгын көненә өчәр алыштырып, дәү әнием соңгы вакытларда төшемә бигрәк еш керә.* М.Авзалова. *Гап-гади кар бөртегенең дә, һәр җан иясенеке кебек, үз хыялы, үз омтылышы бар.* Г.Гыйльман // Вак, бик нечкә, озынча нәрсәләрнең бер данәсе. --- *карчыкның чәч бөртеге саен алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, асылташлар – туп-тулы!* Әкият. *Ул, печән бөртеге алып, йөзен сыта-сыта, тешен казырга кереште.* М.Шәрифуллин // Вак, кечкенә тамчы. *Талия әкрен генә кулын кыймылдатты, күзләреннән ике бөртек яшь агып чыгып, ябык яңаклары буйлап тәгәрәде.* Г.Әпсәләмов. *Кемдер сине ак мамыкка тиңли, Ябалакка охшаталар хәтта. Кар бөртеге!* Р.Габдулла

2) Үсемлек орлыгының бер данәсе. *«Бөртек» дибез, ә күз алдына бөтен бер капчык ашлык, бөтен бер келәт, элеватор ашлык килеп баса.* И.Низамов. *Бөртекләр бодай белән кукурузлан гына алынмый.* Биология. *Томшыклары --- ярдәмендә, каз үсемлекләрнең сабакларын кисеп ала, ә томшык читендәге киртләчләре белән бөртекләрне эләктерә.* Зоология

3) Ашлык, икмәк. *Бөртекләр өй түренә җыелган кояш җылысында көн эчендә кибә.* К.Кәрам. *Каршымда әниемнең ачка кибеккән, --- хәлсезләнүдән җилдә селкенеп торган гәүдәсен күрсәм, тәки, түзмәм, капчык авызын чишеп, аның алъяпкычына берәр кушуч бөртек салырга мәҗбүр булырмын, дип куркам.* М.Хәсәнов

4) Санау берәмлеге; данә. --- *кечкенә кулына берничә бөртек җир җиләге учлаган.* Ә.Еники. *Нәфисәбез, ут эченә кереп, берүзе дүрт бөртек җанны алып чыкты бит.* Г.Гыйльманов. *Унике бөртек энҗе – Берсеннән-берсе чибәр.* Сөләйман. *Без дүрт бөртек дус идек.* Н.Гыйматдинова

5) Нәрсәне булса да азайтып, кечерәйтеп күрсәтә торган нумератив сүз. *Бер бөртек хатирә, бер мизгел гомер, гөлт итеп кенә булса да кабынып алган берәр күренеш, манзара булсын иде дә бит...* Г.Гыйльманов. *Бер бөртек ярма белән ботка пешермә син!* Ә.Фәйзи. *Әмма өч бөртек кеше нишләсен?* С.Зыятдинова

**2.** *с. мәгъ. к.* **бөртекле** (*1 мәгъ.*). *«Такта чәем, якты чыраем» иде шул бу, тегендәге кебек «бөртек чәем, төртеп эчерәем» түгел иде!* Ә.Фәйзи

**3.** *рәв. мәгъ.* Әз генә дә; бер дә. *Курчак бөртек тә курыкмады йөнтәс маэмайдан.* Ф.Шәфигуллин. *Бөртек тә туңмадым.* Г.Мөхәммәтшин. – *Аннары син үзең, – диде ул... – Син бит бөртек тә үзгәрмәгәнсең, чистармагансың.* Г.Әпсәләмов

**БӨРТЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бөртекләү**

2) Бөртекләр өлгерү, өлгереп бөртек формасын алу (кыяклы үсемлекләр турында)

**Бөртекләнеп килү** Бөртекләр өлгерә башлау

**БӨРТЕКЛӘ́Ү** *ф.* **1.** Бөртекләргә аеру, бөртек-бөртек алып чүпләү

**2. бөртекләп** *рәв. мәгъ.* 1) Берәмләп, ләкин бик күп көч, тырышлык куеп. *Татарстан дәүләт музее хезмәткәрләре әлеге шәхес белән бәйле булган истәлекләрне, чыганакларны бөртекләп җыялар һәм җентекләп өйрәнәләр.* Л.Кариева. – *Бөртекләп җыйган малымны төяп кит! Оятсыз! – дип, тамак ярып кычкыра үзе.* М.Маликова. *Үткәнен шулай бөртекләп саклый алган халык – җиргә нык яшәргә килгән халыктыр инде ул.* М.Галиев

2) Җентекләп, бөтен ваклыкларына игътибар итеп. *Сорауларның барысына да Лиза алай бөртекләп җавап бирмәде.* С.Сөләйманова. *Комиссия бөртекләп җыя бит ул, мыскаллап.* Г.Бәширов. *Болай бөртекләп сайлауның нигә кирәген син үзең дә беләсең бит, Сәйфи абый.* Г.Бәширов. *Юлның озын, авыр буласын белә Хәлим. Шуңа күрә дә җентекләп, бөртекләп әзерләнде.* Г.Гыйльманов

3) Аз-азлап; акрын гына. *Аның кул яссуы калынлыгы уңдырышлы туфрагы миллион еллар буена бөртекләп җыела.* С.Поварисов. *Яңгыр һаман бер көе, бик вак бөртекләп кенә явып тора.* Ш.Камал

**Бөртекләп алу** Тиз генә бөртекләү

**Бөртекләп кую** Алдан ук бөртекләргә аеру

**Бөртекләп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта бөртекләү

2) *күч.* Нәрсәне дә булса нечкәләп эшләү; һәръяклап җентекләп уйлау. --- *яшь-җилбәзәк бөтенесен уйлап җиткерми, ишкә куш килү-килмәвен бөртекләп тормый.* Р.Кәрами

3) *күч.* Сак, экономияле булу, һәрнәрсәне исәптә тоту, урынлы файдалану

**Бөртекләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр бөртекләү

**БӨРТЕКЛЕ** *с.* **1.** 1) Бөртеге (*1 мәгъ.*) яки бөртекләре булган, бөртекләрдән торган. *Салкын яңгырлар да бөртекле кар булып ява башлады.* Х.Камалов. *Кыр кары каты бөртекле ком шикелле була, ә бу – ефәк кар, йомшак.* А.Гыйләҗев. *Чәче артык калын түгел, юка, тере вә эре бөртекле.* А.Гыйләҗев

2) *бот.* Бөртек (*2 мәгъ.*) бирә торган (ашлык, кыяклы үсемлекләр турында). *Без бит әле хәзер бөртекле ашлыкның гектарыннан 12–13 центнер уңыш алсак, шуның белән канәгать булабыз, мактанабыз.* М.Әмир

3) *күч. сөйл.* Бик аз, санаулы

**2. бөртеклеләр** *и. мәгъ. бот.* Орлыкларыннан он, фураж әзерләнә торган кыяклы үсемлекләр (бодай, арыш, дөге, арпа, солы һ.б.)

**БӨРТЕКЧӘ** *и.* 1) Кечкенә, вак бөртек (*1, 2 мәгъ.*). *Башка кыяклыларныкы кебек, кылганның да җимеше – бөртекчә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Бер данә бөртек. *Бөртекчә – коры җимеш, аның әлпәсыман җимешлек тирәлеге орлык кабыгына тоташып үсә.* Биология.

**БӨРҮ** *ф.* 1) Тигез җыерчыклар, сырлар ясап тегү. *Степан – билен бөргән*

*кара бишмәт, зур кара картуз киеп йөри торган таза гына карт.* Ә.Фәйзи

2) Түгәрәкләп җыеру, кысу (иреннәрне), йому (авызны). *Помидорын кабамы, кыярын авыз итәме – Руфинә, кызыл иреннәрен матур итеп бөреп, соклануын белдерде: «Шундый тәмле!»* Ф.Садриев. *Әнинең йөзендә елмаюның әсәре дә юк, авызын бөргән.* К.Миңлебаев. *Авызын матур итеп бөреп, озак итеп һава сулагач, Лохмачев дәвам итте: – Сер сыяр кеше икәнлегеңне белгәнгә күрә генә сөйлим.* М.Юныс

3) Авыз эчен җыеру, бөрештерү (кайбер җимеш, яшелчәләрне ашаганнан соң)

4) *куч. сөйл.* Талымсыз ашау. *Авызы зур – бөрер, күзе зур – сөрер.* Мәкаль

**Бөрә башлау** Бөрергә тотыну. *Әхнәф пилмән камырына савыттан калак белән фарш алып салды да бөрә башлады*. Ф.Садриев

**Бөрә төшү** Бераз бөрү; тагын да ныграк бөрү

**Бөреп алу** 1) Тиз генә бөрү

2) *куч. сөйл.* Нык итеп ачулану, тиргәү. *– Газетага нигә алдап яздың? – дип, аны бөреп алдым*. М.Сәлим. *– Син үзең бозауга охшагансың, – дип, бөреп алдылар әлеге малайны*. Ф.Яруллин

**Бөреп ату** Тиз генә, аннан-моннан бөрү

**Бөреп бетерү** 1) Тулысынча, беткәнче бөрү. --- *көтеп тор, энем, минә шушы бәлешемне генә бөреп бетерим, – диде ул, мич тирәсендә бөтерелеп*. Г.Гомәр

2) Бик күп бөрмәләр ясау

**Бөреп җиткерү** Тиешенчә бөрү

**Бөреп йөрү** Һәрвакыт бөргән булу. *Минә мин авызымны, бәләкәй итеп күрсәтер өчен, бөреп йөрмим.* Т.Миңнуллин

**Бөреп кую** Бөрелгән хәлгә китерү. – *Дуслар, – диде Җәвидә үрсәләнеп, һәм иреннәрен бөреп куйды.* Р.Айзатуллин

**Бөреп ташлау** 1) Тиз арада бөрү

2) *куч. сөйл.* Кыйнау. – *Онытма, мин – Әлки сабан туенда көрәшкән Хафиз (җиңен сызгана башлый). Хәзер моннан чыгып китсәң – китәсең, булмаса, бөрәм дә ташлыйм.* Н.Исәнбәт

**Бөреп чыгу** Тулысынча бөрү; башыннан ахырына кадәр бөрү. *Табикмәк камыры өстенә төйгән бәрәңге катлавын юка гына итеп җәеп чыккач, камырны кырыйдан җыеп, хатын-кыз бармагы гына булдыра ала торган хәрәкәтләр белән, пәрәмәч кырыен бөреп чыгасы.* М.Мәһдиев

**БӨРҮЛЕ** *с.* Бөрелгән, бөрмәле. *Биле бөрүле, җиң очлары чигүле коңгырт бәрән тун Зәйтүнәнең гәүдәсен тагын да озынрак күрсәтә.* К.Нәҗми

**БӨРЧЕК** *и.* **1.** 1) Әйбер өслегендәге тимгел; эз; төртке. *Хәлимнең бөтен тәнен, сызамык чыккан шикелле, кызыл бөрчекләр каплап алган.* Г.Гыйльманов

2) Берәр нәрсәнең өслегенә төшкән, башка төстәге, түгәрәк рәвешендәге бизәк. *Ул ак өстенә кара бөрчек төшкән күлмәгенең бәйләвечле изүен чиште.* Г.Галиев. *[Сапсан] Гәүдәсенең аскы ягы ачык төстә, күкрәгендә һәм корсагында кара бөрчекләр бар, баш, арка һәм канатларының өсте – кара күрән.* Кызыклар дөньясында

3) Вак кына тир, яшь бөртеге. *Хәмитнең битенә, маңгаена тир бөрчекләре тибеп чыкты.* К.Нәҗми

**2.** *рәв. мәгъ.* Аз гына. *Бөрчек тә май чыкмады.* М.Кәрим

**БӨРЧЕ́К-БӨРЧЕК** *рәв.* **1.** Бик вак. *Каратуткыллы хатынның да маңгаеннан тирләр бөрчек-бөрчек чыккан иде.* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* Бөрчекләр формасындагы. *[Үсемлекнең] Бөрчек-бөрчек таҗлары алсуланып янса да, сабаклары сусыл һәм аксыл иде.* Н.Гыйматдинова

**БӨРЧЕКЛӘНҮ** *ф.* Бөрчекләр барлыкка килү. *[Ташның] Өске ягы, умарта башында торганда яңгыр тамчылары тишкәнгә булса кирәк, бераз бөрчекләнгән.* Г.Галиев

**Бөрчекләнеп бетү** Өсте-өстенә бөрчекләр чыгу; күп булып бөрчекләнү

**Бөрчекләнеп тору** Әле, хәзер бөрчекләнгән хәлдә булу. *Бөрчекләнеп торган кара туфрак, эсседән кипкән сирәк үлән һәм ефәк чуклы кылганнар.* Ә.Еники

**БӨРЧЕКЛЕ** *с.* Бөрчекләре, бөрчеге (*1, 2 мәгъ.*) булган, бөрчек (*2 мәгъ.*) төшкән. *Мамык карлар ява, бөтен җиһан шушы өстән иңүче ак бөрчекле чуар пәрдә артында калган.* Ф.Садриев. *Кыз бүген ак якалы, ак бөрчекле зәңгәр күлмәктән.* Р.Хәбибуллина. *Артка җибәреп бәйләнгән зәңгәр бөрчекле ак яулыгы белән маңгае өстеннән узган киң зәңгәр тасма, кыйгачланып, чигәсенә үк сузылган ---.* Г.Бәширов

**БӨРШӘЙТҮ** *ф. диал. к.* **бөрештерү** (*1 мәгъ.*)

**БӨРШӘЮ** *ф.* 1) *к.* **бөрешү** (*3 – 5 мәгъ.*). *Бөршәеп кенә утырган Зәки күз алдында турая, йөзенә, кыланышына кыюлык керә башлады, тавышы шәбәйгәннән-шәбәйде.* Ә.Әминев

2) Гәүдәне, аяк-кулны җыеп йомарлану. *Сызлануыңны җиңә алмасаң, аңа күнегергә тырыш, дигән борынгы кагыйдәне хәтерләп, бөршәеп кенә ятты, тын алуын сирәкләтте.* Б.Рафиков

**Бөршәеп бетү** Тәмам бөршәйгән хәлгә килү. *[Нәҗип] --- иң соңгы акчасын мәрхәмәтсез язмыш хәер сорашырга куган ананың бөршәеп беткән учына салды.* А.Гыйләҗев

**Бөршәеп калу** Нинди дә булса берәр сәбәптән соң бөршәйгән хәлгә килү. --- *атнага якын хастаханәдә яткырып, эчен ак, сары, яшькелт дару төймәләре белән дыңгычлап тутырып, беләкләрен, ябыккач бөршәеп калган артын төрле зурлыктагы инәләр белән тишкәләп бетергәч, Нәҗипне чыгарып җибәрделәр.* А.Гыйләҗев

**БӨТӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бөтәрләү** (*1 мәгъ.* )

2) *сөйл.* Бөгәрләнү, йомарлану, җыерылу. *Бөтен тәненең туңганын күреп, юрганына тагы да бөтәрләнебрәк ятты.* Г.Исхакый

3) *сөйл.* Бөтерелү (*2 мәгъ.*)

4) *куч. сөйл.* Ялагайлык, куштанлык, ярарга тырышканлык күрсәтү. *Бөтәрләнә [немец] Безгә килгәч, нәкъ песи кук, әй бөтәрләнә.* М.Җәлил

**Бөтәрләнә төшү** Бераз бөтәрләнү. *Рәшидә, кулларын кушырып, шулар өстенә битен салып, бөтәрләнә төшеп, тыныч кына йоклый иде...* Ә.Еники

**Бөтәрләнеп бетү** Тулысынча, бөтенләй бөтәрләнгән хәлгә килү. *Даут сумка төбеннән бөтәрләнеп беткән кәгазь кисәге табып алды.* Ф.Яруллин. *Батыр чыккан Мансур, бөтәрләнеп беткән сөлгесен кутәрде дә, цирк көрәшчеләре кебек, әле – бер якка, әле*

*икенче якка карап баш иде, елмаеп җибәрде.* Н.Фәттах

**Бөтәрләнеп калу** Нindидер вакыттан, сәбәптән соң бөтәрләнгән хәлгә килү

**Бөтәрләнеп килү** Үзеннән-үзе бөтәрләнгән хәлгә килү. *Икенче көнне, яңа төкне алып, Гыйфрит таш бастырып карап та турайта алмый, ташларны алгач, йон бөтәрләнеп килә.* Р.Батулла

**Бөтәрләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта бөтәрләнгән булу. *Аларның [тауларның] түбәләре киңәя һәм бөтәрләнеп торган ак бүрек сыман хәлгә килә.* Дөньяда ниләр бар

**БӨТӘРЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* **1**. Бөгәрләү, йомарлау. *Кәли яулыкларны, бөтәрләп, кесәсенә тыкты.* Г.Сабитов

**2**. *рәв. мәгъ.* Кинәт, бөтереп алып. *Җиргә кара күләгә сикереп төште һәм, «эһ» дигәнче кызны, бөтәрләп, икенче күләгәнең аяк астына ыргытты, арбага сикерде.* Ф.Латыйпов

**Бөтәрли башлау** Бөтәрләргә тотыну. *Ул көтелмәгән яңалыктан теге реклама гәҗитен бөтәрли башлады.* К.Кәримов

**Бөтәрли төшү** Бераз бөтәрләү

**Бөтәрләп бетерү** Нәрсәне дә булса тәмам бөтәрләнгән хәлгә китерү

**Бөтәрләп салу** Көч белән бәреп егу. *Сәер сөйләшүче хатынны, эре гәүдәле, кайсыбер ирләрне бөтәрләп салырдай көчкә ия, кырык яшьләр тирәсендәге кеше итеп күз алдына китерде ул.* М.Хуҗин

**Бөтәрләп тору** Нәрсәне дә булса әле, хәзерге вакытта бөтәрләү. *Төп тимерче аның каршындагы түмәргә утырды, баш киемен салды, беравык, очлым астыннан кия торган мескен бүреген бөтәрләп торды.* М.Хәбибуллин

**БӨТӘШҮ** *ф.* 1) Җыерылу, җыелу

2) Кечерәю (мәс., гәүдә турында). *Әнисе үлгәннән соң, әтисе бик нык үзгәрде югыйсә, --- гәүдәгә дә шактый бөтәште, чатан аягы тагын да кыскарып, маятлавы көчәйде.* Р.Зәйдулла

3) *күч.* Фикерләү, аң-зиһенне туплый алу сәләте бетү. *Аның бөтен аңзиһене бөтәшеп каткан, көч-егәре ташлап киткән.* Г.Гыйльманов

**Бөтәшә башлау** Акрынлап бөтәшергә тотыну. *Күкрәгендәге ярасы ике-өч көннән бөтәшә башлады.* Г.Гыйльманов

**Бөтәшә бару** Торган саен ныграк бөтәшү

**Бөтәшә төшү** Бераз бөтәшү

**Бөтәшеп калу** Күпмедер вакыттан яки сәбәптән соң кинәт бөтәшкән хәлгә килү. *Булек мөдире ачулы үпкә сүзләрен бөтәшеп калган каурыйчының өстенә шактый яудырды.* Т.Галиуллин

**Бөтәшеп килү** Аз-азлап, акрынлап бөтәшү. --- *каты әйткән сүзләрегез ярасы ачык иде әле. Хәзер бөтәшеп килә инде.* Н.Нәҗми

**БӨТӘЮ** *ф. к.* **бөтенәю**. *Тормыш бөтәйгәч, йортка хафа килә ул.* М.Хәсәнов. *Тирә-як авыллар бөтәйгәндә дә, Суркино авылы өйләре әле һаман шул салам түбәле бөкре ызбалар белән тулы булды.* Г.Рәхим. *Бөтенесе кузгалган, бөтенесенең дә бөтәясе, ямалыпсипләнеп каласы килә.* Ф.Хөсни

**Бөтәеп калу** Билгеле бер хәлләрдән соң бөтәю, тулылану. --- *бәгърем бөтенләй бөтәеп калды.* А.Хәлим. --- *өсбашны юнәтербез әзрәк, бөтәеп калырбыз, – дип, әнисен юатты Мөкәррәмә.* М.Әмирханов

**Бөтәеп килү** Акрынлап, аз-азлап бөтәю. *Ул тормышның төрле вакыйгахәлләреннән көлдерә белә, зиһенне уйната, акылны уйлата торган сатирик хикәяләре белән хәйран итә: --- әсәрләрендә геройның детальләр белән эзлекле тулыланып, бөтәеп килә торган сатирик портреты көлү объектына әверелә.* М. Җәләлиева

**Бөтәеп китү** Кинәт кенә бөтәю. *Моңарчы тормышның тишек-тошыгын көч-хәл белән, аннан-моннан гына ямап барган гаилә кәҗә аркасында бөтәеп китте.* З.Хөснияр

**Бөтәя бару** Торган саен ныграк бөтәю. *Разил Вәлиев директор булып эшләгән соңгы дәвердә китапханә бинасының, тышкы кыяфәте генә түгел, эчке асылы да күзгә күренеп үзгәрә, бөтәя бара.* М.Галиев

**Бөтәя төшү** Бераз, берникадәр бөтәю. *Мәрхүмәнең гомере генә кыскарак булды, тормышлар бөтәя төшкәч кенә китеп барды.* Ә.Моталлапов. *Уңыш та яхшы булгач, тамак та тугая, өс-баш та бөтәя төште.* Л.Гыймадиева

**БӨТЕН** *с.* **1.** 1) Башланмаган, тулылыгына зыян килмәгән. *Әни, иң элек, ике бөтен икмәк илә бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кылдык.* Г.Тукай. *Сәхия, сумкасын дыңгычлап тутырганнан соң, кибеткә яңадан кереп, бер бөтен ипи күтәреп чыкты.* Ф.Яруллин

2) Ватылмаган, төзек; имин. *Тыштан бөтен генә күренгән йорт эченнән әйтерсең көчле җил исеп узган...* Ә.Еники

3) Тулы, тулаем (гадәттә күләмне, микъдарны һ.б.ш.ны белдергән сүзләр янында килгәндә). *Әмма, ни кызганыч, шуны, утырып, тәртипкә салырга, эшкә кертергә, бөтен бер язма хәленә китерергә вакыт та, мөмкинлек тә таба алмады.* Ә.Еники

4) Бар ягы да җитеш, һәр яктан килгән, тәэмин ителгән (тормыш, яшәү шартлары, кием-салым һ.б.ш. турында). *Детдомнан килгәннәрнең генә өсте бөтен дә тамагы тук иде.* Х.Сарьян. *Бөтен йир – тын; бөтен тормыш – бөтен.* Г.Исхакый. *Тоткыннарның тамаклары тукмы, өсләре бөтенме ---?* А.Хәсәнов

5) *мат.* Вакланмасыз. *Бөтен һәм вакланмалы саннар*

6) Бер сумлык. *Анлар кайсы – сөлге, кайсы – ашъяулык, кайсы әбисеннән калган бөтен тәңкә күтәреп килеп, ишанны шул әйберләр берлә күмәләр.* Г.Исхакый

**2.** *и. мәгъ.* Патша заманында: бер сумлык металл акча. *Нәгыймә (кесәсеннән акчасын алып карап:) Ярый, ярый, хәерле сәфәр булсын. Бөтенне яудырган икән.* Г.Камал

**3.** *а. мәгъ. к.* **бар** III. *Һава һич селкенмичә, шылт та итмичә, бөтен нәрсәне басып, изеп тик тора.* Ә.Еники. *Табигатьнең бөтен гүзәллеген җыйган Зур Көек авылы үзенә.* Ф.Гыйльфан. *Хәер, бөтен яктан да килгән мондый гүзәллектә бары тик гүзәл кешеләр генә яшәргә тиеш кебек.* Ф.Бәйрәмова

**4.** *рәв. мәгъ.* Бөтен көе, вакламыйча. *Бәрәңгене бөтен көе пешерү*

**БӨТЕНӘЮ** *ф.* 1) Тулы, бөтен, эшләнеп беткән хәлгә килү, бер-бөтенгә әйләнү, тулылану. *Бу вакыйга тирәсендә характерлар ачыла, кемнекедер формалаша, оеша, бөтенәя, ачыла, кимчелекләр фаш ителә, уңайлары раслана.* А.Әхмәдуллин. *Яшьлек эзләре буенча хыялларга бирелеп бер йөрсә, күңелләре – тулыланып, җаны – бөтенәеп, мәңге төзәлмәс йөрәк яралары чак кына язылып китәр сыман иде.* М.Хәсәнов

2) Яхшыру, җайлану, җитеш хәлгә килү; җитешкә әйләнү, бөтәю. *Кыскасы, чынлабрак акча табасы, вузга кергәнче, ничек тә бер бөтенәеп, яңарып аласы килде.* Ә.Еники. *Тормышлар бөтенәеп, җайланып кына бара бит әле.* Г.Гыйльманов

**Бөтенәеп китү** Кинәт кенә бөтенәю. *Тормыш күркен күреп, күңелеңнең бөтенәеп китүе шулай ук бәхетле мәлләрдән җыеладыр.* Г.Хөсәенов. *Тәскирә килгәч, тормышлары тагын да җанланып, бөтенәеп китте.* Г.Гыйльманов

**Бөтенәя бару** Бөтен булуга, бөтенлеккә якынлашу, акрынлап бөтенәю. *Җыелудагы сәгать [конвейер белән] бер эшче турысыннан икенчесе турысына килеп туктый. Секундлар саны тулуга, тагын сигнал була. Һаман бөтенәя барган сәгать үзенең сәфәрендә дәвам итә.* М.Максуд

**БӨТЕНДӨНЬЯ** *и.* Барлык илләр, дәүләтләр һәм анда яшәгән халык. *Шулчак бөтендөнья судьясы, стартка тезелгән спортчыларны, аларның мотоциклларын күзәтә-күзәтә, саф алдыннан йөри башлады.* Ф.Баттал. *Октябрь фетнәсеннән соң, бөекмәмләкәтчелек идеясе бераз тоныкланып, бөтендөнья революциясе шигаре өстенлек ала.* Р.Зәйдулла. *Бөтендөнья культурасыннан файдаланучы язучыларның әсәрләре, кагыйдә буларак, киң сулышлы, провинциаль чикләнгәнлектән, тар, вак темалылыктан азат була.* Идел. *Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, тәмәке тартудан дөньяда ел саен 5 миллион кеше үлә.* Мәдәни җомга

**БӨТЕНЛӘЙ** *рәв.* **1.** 1) Тулысынча, тулысы белән, тәмам. *Безнең әниләр заманында, башта аршын ярымлык калфак иде, өстә үзләре эшләгән күлмәк иде, камзуллары бөтенләй көмеш тәңкә, мәрҗән белән каелып беткән иде.* Г.Исхакый. *Хәзер исә бу ачу-нәфрәт, бик табигый буларак, минем эчемдә бөтенләй кайный башлады.* Ә.Еники. *Ә кичен, җиңги пешергән токмачлы ашны ашап җибәргәч, минем эшләр бөтенләй шәбәеп китте.* В.Нуруллин

2) Башка төрле, икенчеләй. --- *мәрхүмнең «Тормыш дәфтәре» аны бөтенләй үзгә яктан калкытып куя.* Г.Бәширов

3) Кабатланмас рәвештә, башкача булмаслык итеп. *Аңына килә алмас микәнни?! Бөтенләй китте микәнни инде?* М.Маликова

4) **бөтенләе** *форм.* Барлыгы, бар булганы. *Бөтенләе берничә сүздән гыйбарәт бу рольне кеше аңларлык дәрәҗәдә сөйләтер өчен, безгә мәзкүр артистны шактый газап чиктерергә туры килде.* Ф.Әмирхан

5) **бөтенләе белән** *форм.* Тулысынча. *Ләкин әсәр, бөтенләе белән шигъри, чиста әдәби телдә язылып, хикәяләүче аңлатмаларында шул шигърилекне сакларга омтыла.* Д.Заһидуллина

6) *к.* **бөтенләйгә** (*2 мәгъ.*). *Хәзер инде исән-сау бөтенләй кайтуын көтегез!* Ә.Еники

**2.** *кис. мәгъ.* 1) Инкяр җөмләләрдә юклык мәгънәсен көчәйтеп, куәтләп килә; һич тә, бер дә, һичнинди, һичбер. *Кайвакыт әйләнә-тирәгә күз салам да, шундый кешеләр күп булгач, «чын кеше» диярлекләр бөтенләй күренмәгәч, бик күңелсез дә, моңсу да, әшәке дә булып китә.* Г.Бәширов. *Ул әле укучыларга бөтенләй билгеле булмаган яисә аз билгеле булган батырларны барлый, аларның язмышларын ачыклый.* Р.Миңнуллин. *Әмма, Ләйсән очрагач, Рәүф күңелендә күрше кызына бөтенләй урын калмады.* М.Маликова

2) Вакытны яки урынны белдергән сүзләр алдында килеп: нәкъ, төгәл шул вакытта, шул урында, дигән мәгънә аңлата. *Карасалар, бөтенләй ямь-яшел урман янында гына икән буровойлары.* Ш.Бикчурин

**БӨТЕНЛӘЙГӘ** *рәв.* 1) *к.* **бөтенләй 1.** (*1, 3 мәгъ.*). *Бөтенләйгә мәктәптә укытуны ташлап, кышны башка эш белән уздыруны да уйлап карады ул.* М.Гафури

2) Мәңгегә. *Бер бөтен ипи һәм Коръән белән, алар юлга кузгалдылар... Зәйтуганнан бөтенләйгә чыгып китүләрен алар әле белми иде...* Ф.Бәйрәмова

**БӨТЕНЛӘНҮ** *ф. сир. к.* **бөтенәю** (*2 мәгъ.*). *Без дә күрдек бу көннәрне, Тормышлар бөтенләнде.* М.Фәйзи

**БӨТЕНЛӘТӘ** *рәв.* 1) Бөтен килеш, башланмаган, бүленмәгән хәлдә. *Җыйнап алыйк игеннең Бөтенләтә барысын.* М.Җәлил

2) *мат.* Вакланмасыз. *Без анда бүлүнең ике очрагын күрдек: калдыксыз бүлү, яки «бөтенләтә» бүлү һәм калдыклы бүлү.* Арифметика

**БӨТЕНЛЕК** *и.* 1) Бөтен, тулы, төзек. *Горурлык – рухның бөтенлеге, камиллеге, җанның иректә булуы ул.* Т.Миңнуллин. *Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, егерменче гасырның иң хәтәр, иң усал елларында милләт бөтенлеге сакчылары булып --- бастылар.* Идел

2) Муллык, байлык, бай булу. --- *алар гомер буе бик бөтенлектә яшәмәделәр. Әмма, Бәчүкнең бик нык тырышлыгы аркасында, соңгы елларда муллыкта яши башлаганнар иде.* Г.Рәхим

3) Килешеп, ярашып тору, камиллек, тулы гармониялелек. *Бөтенлектән безне Нигә болай иртә мәхрүм итә [дөнья]?!* Х.Әюп. *Темалары һәм проблемалары, күләмнәре һәм бөтенлекләре, сәнгатьчә эшләнешләре һәм тәэсир көче ягыннан, ул әсәрләр бик тә төрле-төрле.* А.Гыйләҗев

**БӨТЕНЛЕКЛЕ** *с. кит.* Өлешләре эзлекле ярашкан, эчке бердәмлектә булган; гармонияле. *Шул хезмәтләр --- милләтебезнең киләчәген ирекле һәм бәхетле итү юлында бөтенлекле караш буларак кабул ителә.* Ф.Галимуллин. *Ф.Латыйфи да, әсәренең буеннан-буена шушы элементларга укучының игътибарын юнәлтеп, татар тормышының бөтенлекле сурәтен барлыкка китерә.* Д.Заһидуллина

**БӨТЕНРЕСПУ́БЛИКА** *и.* Тулаем бер республика. – *Эскизларыңны күр-*

*сәт, – дип каршылады аны директор. – Син бөтенреспублика конкурсында катнашасың.* Н.Гыйматдинова

**БӨТЕНРОССИ́Я (БӨТЕНРУСИ́Я)** *и.* Бөтен Россия, Россиягә караган бөтен яисә күпчелек территория. *Казанда ел саен уздырыла торган ярминкә, элеккеге Болгар базарына яки, соңрак, Түбән Новгородтагы «Бөтенрусия сәүдәханәсе»нә хас булганча, галәмәт зур халыкара базар әһәмиятен яулый.* М.Худяков. *«Күмәч-кондитер комбинаты» ААҖ Бөтенроссия һәм республика бәйгеләрендә катнашып килә.* Татарстан

**БӨТЕНСОЮЗ** *и. тар.* Советлар Союзы Республикаларының берлеге. *Без --- ике-өч ел рәттән, Ялтада драматургларның Бөтенсоюз семинарларында катнаштык.* А.Гыйләҗев. *– Бөтенсоюз аренасына чыктым! – дип, лаф орып йөрүчеләр бар.* Мәйдан

**БӨТЕНТАТАР** *и.* Татарстандагы гына булмыйча, Җир шарында яшәгән барлык татарлар. *Бөтентатар җәмгыяте*

**БӨТЕНХАЛЫК** *и.* Билгеле бер территориядә яшәгән күпчелек яки бөтен халык. *Бәйсезлек өчен башланган бөтенхалык көрәшен, битараф буяуларга манчып, җирле крестьяннар күтәрелеше генә, дип тамгаларга күзне йомыйк та, ди.* Р.Әмирхан. *Бөтенхалык референдумыннан соң, Швейцария алдагы 5 елда илгә генетик модификацияләнгән ризыкларны кертүне тыя торган карар кабул иткән.* Мәдәни җомга

**БӨТЕРГЕЧ** *и.* 1) *к.* **бөтерчек** (*1 мәгъ.*). *Мин, бөтереп җибәргән бөтергеч шикелле, бөтереләм дә бөтереләм.* Ф.Садриев

2) *к.* **әйләнмә** I **2.** (*2 мәгъ.*). *Тар урыннарда су тирән, бөтергечләр ясап, ашкынып-ашкынып ага.* Р.Шәйхетдинов

3) Орчык. *Тик, сул кул белән, тәрәштән йон җепселләрен тартып чыгарырга, ә уң кул белән бөтергечне бөтереп торырга гына кирәк була.* Дөньяда ниләр бар

**БӨТЕРЕЛЕШ** *и. к.* **әйләнмә** I **2.** (*2 мәгъ.*)

**БӨТЕРЕЛМӘ** *и.* **1.** 1) Өермә. *Кар бөтерелмәсе*

2) *күч.* Зур тизлектән барлыкка килгән өермәле җил

3) *күч.* Шаукым. *КамАЗ бөтерелмәсе аударды аны.* Э.Касыймов

**2.** *с. мәгъ.* Әйләнмәле, бөтерелә торган. *Әнә бит, бер карасаң – күбекләнеп торган затлы күлмәк итәкләрен тавис койрыгыдай сузып, икенче карасаң, авыр, бөтерелмә итәкләрен диңгез дулкыныдай шаулатып, кызлар бии.* М.Галиев

**БӨТЕРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бөтерү** (*1–3 мәгъ.*)

2) Өермә булып хәрәкәт итү. *Ябалак кар бөтерелеп уйный.* М.Хуҗин. *Шаян җилләр бөтерелә Алар бөдрәсен тарап.* Г.Мөхәммәтшин. *Җил, сарык абзарына керә алмаган ач бүре шикелле, өй алдында бөтерелеп үкерә.* Г.Гобәй // Ургылу, көчле агым булып күтәрелү. *Йосыф карт әвененнән, бөтерелеп, төтен чыга иде.* М.Галәү

3) Әйләнү; җитез хәрәкәтләр ясау. *Өстәл өстендәге кечкенә лампа тирәсендә, зыр-зыр килеп, төн күбәләкләре бөтерелә.* Г.Бәширов

4) Бөҗраланып, түгәрәкләнеп, әйләнмәләр ясап хәрәкәт итү. *Ә таулар китереп кыскан урыннарда текә кыялар бөтерелеп аккан Сакмар өстендә таш стенадай басып торалар.* Ә.Еники. *Аның өстендә, елан төсле бөтерелеп, камчы чыжлады, Илсөяр җыерылып килде.* Г.Гобәй. *Башы – ике түбәле, ягъни чәче, түбә өстендә генә түгел, уң як маңгай өстендә дә бөтерелеп үсә.* М.Маликова. *Чигәләрендә кара бөдрәләр бөтерелә иде.* Б.Камалов

5) Нәрсәнеңдер әйләнәсендә булу, аны әйләндереп, уратып сарылу (табигать күренешләре турында). *Алар --- еракка-еракка китеп, карагылт сөрем эчендәге тауларга бөтерелгәннәр.* Г.Исхакый

6) *күч.* Кемнеңдер янында, тирәсендә әйләнгәләп йөрү, хәрәкәт итү; үзенә игътибар иттерергә тырышу; куштанлану. *Вагон тирәсендә дүрт-биш кеше бөтерелә.* Г.Гыйльманов. *Бөтерелмә, бөтерелмә, хром итекле егет, шәһәр кызы янында! Барыбер берни дә чыкмас.* М.Мәһдиев. *Кызларны күр син, ник берсе Фәһимәне якласын, «Миңа да бак, миңа да», – дип, бакылдашып, карчык тирәсендә бөтереләләр.* Н.Гыйматдинова

7) *күч.* Бимазалау, тынычсызлау. *Ә күңелдә ут өермәләре бөтерелә иде шул.* Р.Кәрами

8) *күч.* Ерып чыгу, булдыру. *Хәзерге тел белән әйткәндә, ихтимал, «Бөтерелгәндер, тапкандыр, алгандыр, саткандыр».* Р.Мирхәйдәров

**Бөтерелә башлау** Бөтерелергә тотыну. *Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көннең көн озын колын тирәсендә бөтерелә башладым.* Г.Бәширов

**Бөтерелеп алу** Бераз яки җиңелчә генә бөтерелү. *Камның муенында икеөч елан – терелләр, кыймылдыйлар, әле муенына уралалар, әле бөтерелеп алалар.* М.Хәбибуллин. *Киде-салды, киде-салды, Бөтерелеп алды, биеп. Гөлзифа кичен танцыга Шул тунны китте киеп.* Г.Сәгыйров. *Баш очында нииндидер авыр рух бөтерелеп алганын сизгәндәй, Ламиганың күзләре тартышып куйды.* Н.Хәсәнов

**Бөтерелеп йөрү** Һаман да, бертуктаусыз бөтерелү. *Зиһен савытында бөтерелеп йөргән бер фикер аңа йокларга ирек бирми иде.* Г.Гыйльманов. *Бер кеше дә «Укытучым!» дип аның тирәсендә бөтерелеп йөрми, атнаун көн саен мәҗлес җыеп күрешми.* М.Насыйбуллин. --- *официантка яннарында бөтерелеп йөри.* М.Мәһдиев

**Бөтерелеп килү** Кинәт бөтерелү. *Ул, фәкать эчендә бөтерелеп килгән өермәгә буйсынып кына, иҗат итәргә керешә.* К.Миңлебаев

**Бөтерелеп кую** Бер тапкыр бөтерелү. *Бөеренә таянды да кечкенә генә ап-ак итек-читекләре белән юеш кар чәчрәтеп, бөтерчектәй бөтерелеп куйды, кыбырсык.* Г.Сабитов

**Бөтерелеп тору** 1) Бертуктаусыз бөтерелү. --- *ул утырган каенның өстендә җиде койрыклы бер аждаһа кара болыт төсле бөтерелеп тора икән.* Ф.Яруллин. *Ул койрыклар дисәң, күз иярмәслек тизлек белән, бөдрә камчыдай бөтерелеп уйнаклап тора.* Г.Сабитов. *Алар [дулкыннар] әле бер якка агылалар, әле, шарлавык кебек ургылып, аска төшәләр, әле бер урында*

*бөтерелеп торалар.* Күп белергә теләсәң

2) Әле, күз алдында, сөйләп торганда бөтерелү. *[Буран] Килеп керә дә, урам уртасыннан узарга базмагандай, койма буйларына сырыша, капка асларында бөтерелеп тора, өй кыекларына менеп бии, морҗа төтеннәрендә ак итәкләрен җилфердәтә.* Ф.Шәфигуллин

**БӨТЕРЕНКЕ** *с. к.* **бөтеркә** (*2 мәгъ.*). *Олы суның иртәнге сәламен тыңлап, елга ягына колагын куеп торды, басма аша бүген җитезрәк чыкты, ашыкты, гарип, бөтеренке гәүдәле таллар янында да тукталып торды...* А.Гыйләҗев

**БӨТЕРКӘ** *и.* **1.** Бөтерелгән (*4 мәгъ.*), бөҗра сыман булып торган нәрсә. *Мисалга, кайсы кешенең [бармак төзелеше] элмәк, кайсыныкы дуга яки бөтеркә, бөҗрасыман була.* М.Авзалова

**2.** *с. мәгъ.* Бөтеркәле, бөҗра сыман торган; бөдрә. *Бу сүзне әлеге бөтеркә маңгайлы Нәсимә әйтте.* Ш.Маннур. *[Фәридә] Өстенә кыска матроска кигән, кырпулы кәпәче астыннан тыңлаусыз бөтеркә чәчләре чыгып тора иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Сарык йоныдай бөтеркә чәчне җенем сөйми.* Г.Сабитов. *Бөтеркә бизәк килеп чыксын өчен, көпшәләрне карандаш яки кыздырылган тимер кадакка урау җитә.* Иң шәп календарь

**БӨТЕРКӘЛӘНҮ** *ф.* Бөтеркәләр барлыкка килү; бөдрәләнү

**Бөтеркәләнеп бетү** Өсте-өстенә бөтеркәләр ясалу. *Бөтеркәләнеп беткән карама төбе шикелле [бу – сер саклаучы картлар]. Чөй сугардай җайлы җеген һичбер таба алмассың!* Ш.Маннур

**Бөтеркәләнеп тору** Әле, хәзер бөтеркәләр барлыкка китерү. *Фәүзия исә, әти кебек үк, «ике түбәле» – баш түбәсендә дә, маңгай турысында да чәчләре бөтеркәләнеп тора иде.* Ә.Рәшит

**БӨТЕРКӘЛЕ** *с.* Бөтеркәләре булган; бөдрә. *[Тикшерүче] Аның һәр җавабын, гаять бөтеркәле готик хәрефләр белән, бер дә ашыкмыйча гына язып алды.* Ш.Маннур

**БӨТЕРКӘЧ** *с. к.* **бөтеркә** (*2 мәгъ.*). *Бөтеркәч башлы, каш астыннан карап йөри торган үсмер малай ул.* Г.Ахунов. *Мәскүрә аны бөтеркәч кара чәченнән таныды.* С.Сөләйманова

**БӨТЕРКӘЧЛӘНҮ** *ф. к.* **бөтеркәләнү**

**БӨТЕРКЕ** *и.* Бөтерелгән, нык, тыгыз итеп бөтереп төрелгән әйбер (мәс., язулы кәгазь). *Шырпы хәтле генә бөтерке эчендә өзелеп сөю, мизгелләр белән саналган бәхет һәм озак еллар-га, бөтен гомергә сузылачак сагыну, сагышлану ятканын кем белгән соң ул чакта?* М.Маликова

**БӨТЕРМӘ** *с.* Көчле, өермәләнеп искән. *Тимер ташкын аша тояклар тупылдавын ишетәсе килүдән, ул, җилкенеп, бөтермә җил иркенә биреләп, алга каерылды.* М.Галиев

**БӨТЕРҮ** *ф.* 1) Бармаклар арасына алып, әрле-бирле тәгәрәтү, әйләндерү. --- *карт, чынлап та, әле аның пинҗәк төймәләрен бөтерә, әле җиңеннән тотып тарткалый иде.* Р.Мирхәйдәров. --- *яфракларны ике уч арасына салып, суы чыкканчы бөтерәләр.* Робинзон эзләреннән

2) Бер уңайга гына тәгәрәтеп әйләндерү; кату. *Җепне ике катлам бөтерү* // Көпшәсыман итү, ян-якларын әйләндереп китерү. *[Ул] Итне ала, вак-вак кына озынча телемләп турый, утка куеп, дуңгыз колагы итеп бөтереп кыздыра.* А.Гыйләҗев // Бөтеркәләр (*1 мәгъ.*) ясау, бөдрәләр ясап урау. *Сара, уңайсызланып, чәч толымының очын бөтерде.* Н.Гыйматдинова

3) Бөгәрләү, йомарлау. *Нәфисә сул кулы белән итәкләрен бөтереп тотты* ---. Г.Гыйльманов

4) Өермә ясап хәрәкәтләндерү, көч белән күтәреп алып, үз тирәсендә әйләндерү. *Январь таңы. Далаларда Кар бөтереп, буран дулый.* Г.Афзал. *Көчле җил ясмин чәчәкләрен һавада бөтереп йөртә.* Күп белергә теләсәң

5) *күч.* Үз дигәнен һаман-һаман әйтеп, эшләп тору. *– Алтынбайны алып китик үзебез белән Казанга, – дип бөтерә мине Алсу, прәме боргычлый.* А.Хәсәнов

**Бөтерә башлау** Бөтерергә тотыну. *Ул арада өермә Мәрьямбануны әләктереп ала да җир белән күк арасында бөтерә башлый.* Ф.Бәйрәмова

**Бөтереп алу** Көч белән, җитез генә күтәрү. *Билдән тотуына, ул [көрәшче] малай мине, бөтереп алып, бер якка ыргытты.* М.Гали

**Бөтереп ату** Юкка чыгару. *Кая соң шаулы елганың күкрәп аккан чагы? Юлны бүлгән буаларны бөтереп аткан чагы?* М.Галиев

**Бөтереп җибәрү** 1) Бөтерелә башларга, бөтерелергә этәргеч бирү. *Мин, бөтереп җибәргән бөтергеч шикелле, бөтереләм дә бөтереләм.* Ф.Садриев. *Аны [таякны] бөтергеч кебек бөтереп җибәрәләр.* Дөньяда ниләр бар

2) Бераз гына бөтерү. *Кара мыекларын югары таба бөтереп җибәргән бер матур гына егет белән йөриләр алар* ---. Ш.Камал

**Бөтереп кую** Бөтергән (*2 мәгъ.*) хәлгә китерү. *Кай арада чәчләрен артка җыеп, бөтереп куйган* ---. Г.Гыйльманов. *Алдаша башлаудан элек, мыекларын бөтереп куяр, егет-җилән җыелган урынга килеп туктар.* И.Юзеев

**Бөтереп салу** Көч белән, бәреп, аяктан егу. *Солдатның иптәшләре чабышып килеп тә җиттеләр, Миңнулланы бөтереп тә салдылар.* И.Гази

**Бөтереп тору** Бертуктаусыз бөтерү. *Тик, сул кул белән, тәрәштән йон җепселләрен тартып чыгарырга, ә уң кул белән бөтергечне бөтереп торырыга гына кирәк була.* Дөньяда ниләр бар

**БӨТЕРЧЕК** *и.* **1.** 1) Бөтерелеп, укмашып килгән төен, бәләкәй төерчек. *Әнинең алдында юрганга төргән ун көнлек бер бөтерчек була, ул – мин икәнмен.* М.Мәһдиев. *Йон киемдә бөтерчекләр тиз барлыкка килә*

2) Тиктормас, бик хәрәкәтчән бала, кеше

3) Кызу әйләнгәндә күчәре вертикаль торышны саклаган түгәрәк яки яньчелгән шар формасындагы уенчык, зырылдавык. *Имән чикләвеген урталай кисеп ясаган бөтерчек, зырылдый торгач, сәке астына төшеп китте.* Г.Бәширов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төрле юнәлештәге ике агым кушылудан барлыкка килгән, суның өслеге бүрәнкәләнеп әйләнеп торган, әйләнмәле. --- *елганың агымы*

*бик көчле, малай эләккән бөтерчек урын аны әчкә суырганнан-суыра бара иде.* Ф.Яруллин

2) Бик җитез, тере, һәрвакыт хәрәкәтләнеп торган. *Бөтерчек малай Шаһи, бик ышанасы килеп, әмма ышанып җитмичә: – И абый! Кайчан килеп җитә әле ул заманнар! [диде].* Г.Бәширов. *Шулчак, Ринатның уйларын бүлеп, бүлмәгә, атылып диярлек, бөтерчек Зайцев килеп керде.* Н.Хәсәнов

3) Бик бәләкәй, кечкенә генә. *Беркөнне, шулай, урам аша чыккан бөтерчек кенә йонлач этне машина бәреп ташлаган да, ул, чиный-чиный, юл читенә килеп егылды.* И.Низамов

**БӨТЕРЧЕКЛӘНҮ** *ф.* Бөтерчекләр (*1 мәгъ.*) барлыкка килү

**Бөтерчекләнә бару** Торган саен ныграк бөтерчекләнү

**Бөтерчекләнә төшү** Бераз бөтерчекләнү

**Бөтерчекләнеп бетү** Бик нык бөтерчекләнгән хәлгә килү, бөтерчекләре күп булу

**Бөтерчекләнеп калу** Билгеле бер сәбәптән соң бөтерчекләнү

**Бөтерчекләнеп тору** Бөтерчекләнгән хәлдә булу. *Ап-ак сакал-мыеклары, саргаеп, күңелне китәрерлек бер рәвешкә кергәннәр, ап-ак күкрәк йоннары берничә урында укмашкан, бөтерчекләнеп торалар...* Г.Гыйльман

**БӨТИ** *и. дини* Төрле бәхетсезлекләрдән, авырулардан саклану өчен тагып йөртелә торган догалык. *Көн елагач, төн елагач, өстенә өшкертергә хәзрәткә киттеләр, суфый абзыйдан күз бөтие яздырдылар.* Г.Исхакый. *Бөти итеп, муенына таксын!* С.Зыятдинов. *Югалтмас өчен, мин аны муеныма бөти төсле итеп тагып йөрим.* Р.Фәизов

**БӨТИЛЕК** *и.* Бөтине төреп яки салып йөри торган махсус әйбер. *Алар былтыр Уша башына җыенга кайтканнар иде, шунда [Фатыйма тудык], салып куйган җирендә, бөтилеген онытып калдырган.* Г.Камал

**БӨТНЕК** *и. рус.* 1) Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, дару үләне буларак үстерелә торган хуш исле үләнчел үсемлек; *русчасы:* **мята.** *Җәйне хәтерләтеп, мәтрүшкә, бөтнек исләре аңкыды: өйалды диварындагы кадакларга бәйләм-бәйләм дару үләннәре эленгән иде.* Н.Гыйматдинова. *Без калай кружкалардан кура җиләгенең таш борчагын, бөтнек яфрагы салып кайнаткан чәй эчәбез.* М.Мәһдиев. *Бөтнек борынгы заманнардан ук кыйммәтле үсемлек булып исәпләнгән.* Робинзон эзләреннән. *Бөтнек, мелисса, кычыткан, тузганак яфрагыннан әзерләнгән масса бит тиресен тукландыра, сафландыра һәм яшәртә.* Юлдаш

2) Шул үсемлекнең яфрагыннан төеп ясалган аш тәмләткеч. *Гомер буе без ашны бөтнек сибеп ашадык.* М.Мәһдиев

**БӨТНЕКЛЕ** *с.* Бөтнек салынган, бөтнек исе килеп торган. *Яраса, чәеңне тагын бир әле. Бөтнекле икән.* Ә.Гаффар. *Тәмәкечеләр кесәләрендә һәрчак бөтнекле кәнфитләр йөртәләр иде.* Идел

**БӨТҮ** I *и. тар.* Каен тузына язылган язу(лар). *Искечә бөтелгән бу бөтүләрдә искилләрнең ерак тарихы, алыпларның кылган батырлыклары язылган иде.* Р.Зәйдулла

**БӨТҮ** II *и. диал.* Муенса. *Чылбыркай чапуг, буй бөтү, Буй гынам үстереп элмәдем.* Җыр

**БӨҺТАН** *и. фар. иск.* Яла, кеше өстенә сөйләнгән ялган сүз. *Сөйләде өстемә күп ифтира, бөһтан усал телләр.* Г.Тукай. *[Хатын:] Әй, сиңайтәм, кеше алдында алай, бөһтаннар ягып, мине харап итмә инде!* Г.Камал

**БӨЯ** *и. диал. к.* **буа.** *Бөяне су иясе ашый.* Мәкаль. *Чат бөясеннән безнең бакча башына чаклы чит-читенә тал куаклары, үләннәр үскән тар сукмактан төшәсең.* И.Низамов

◊ **Бөя бөярлек** *к.* **буа буарлык.** *Беләсең килсә, андыйлар бөя бөярлек!* Г.Бәширов

**БӨЯЛҮ** *ф. диал.* 1) Бер җиргә килеп төртелү, җыелып өелү, шуннан үтә алмыйча, тоткарланып калу. *Ул арада капка янында бер көтү сарык бөялде.* М.Мәһдиев. *Ул хәтта өстәл артына, әйләнә торган кәнәфиенә барып бөялде.* Т.Галиуллин. *Теткәләнеп очкан йомычка кисәкләре битенә чәчрәде, иренenә кадалды, сыдырылып, җилкәсенә бөялде, бу мизгелдә Хаят җеннәре кузгалган убырга охшаган иде.* Н.Гыйматдинова. *Егетләр, хатын-кыз арасына катнашырга читенсенеп, идарә болдыры тирәсенә бөялеп, тәмәке көйрәтәләр.* А.Гыйләҗев

2) Авызга берьюлы күп ризык тутырып, йота алмый тору; тыгылу. *Хатын, бугазына бодай бөялгән үрдәк сыман, «ыйк-ыйк» диде.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Нык әсәрләнүдән, тәэсирләнүдән тулу, тыгылу, туктап калу. *Тамак төбенә утлы төер бөялгән иде.* Н.Гыйматдинова. *Күзгә яшь бөялү*

**Бөялә бару** Торган саен күбрәк бөялү. *Тамак төбенә авыр бер төер бөялә баруын тоеп, Лёва тамбурга чыкты.* И.Низамов

**Бөялә тору** Тагын да күбрәк бөялү, өсте-өстенә бөялү. *Чират бик акрын кыймылдады, һәрьяктан яңа төркем агыла, этешә-төртешә, касса янына килеп бөялә торды.* Р.Мирхәйдәров

**Бөялеп бетү** Тәмам тыгылган, бөялгән хәлгә килү

**Бөялеп тору** 1) Әле, сөйләү моментында бөялгән хәлдә булу. *Бүтән ишек төпләрендә, сәдака көтеп утырган хәерчеләрдәй, байтак халык бөялеп тора.* А.Гыйләҗев

2) Хәзергә, вакытлыча бөялү. *Әллә спирт тәэсир итте инде шунда, әллә чыдарлыгы калмаган идеме, баядан бирле бөялеп торган кайнар яшьләр кысылышып чыктылар.* А.Гыйләҗев

**БӨЯТ** *и.* 1) Камытның ат муенына һәм түшенә тиеп торган аскы өлеше (гадәттә, эченә салам һ.б. тутырып, киез, күн, киндер белән тышланган була); *русчасы*: **подхомутник**. *Агачы юк камытның – бөятен, ярты калган эшеңнең оятын кая куярсың?* Мәкаль. *Бакырлы тау буендагы хәвефле юлдан үтәргә туры килә һәм, кайчакларда, дугалар сынып яки бөят агачлары шартлап, арбаларны шунда калдырып, атларга атланып, өйгә кайтып килә иде.* Г.Галиев. *Аннары камыт бөятенә, яраның ике ягына ике бүлтәймә ясап куясың.* Х.Камалов

2) Суга батудан саклау һәм суга батучыны коткару өчен, җиңел материалдан

эшләнгән боҗра рәвешендәге махсус җайланма

3) *куч.* Богау, ирекне чикли торган нәрсә. *Алар җиңде... Безнең кулдан кылыч төште. Миңа – әсиргә – әзерләнде бөят.* Зөлфәт

**БӨЯТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Камытка бөят кую, бөятле итү

2) Бөят (*1 мәгъ.*) рәвешендә төрү. *[Мусаның] Җилкәсенә бөятләп кигән шинеле белән кыр сумкасы, автоматы да биш пот булып тоела.* Ш.Маннур

**Бөятләп бетерү** Ахырга кадәр бөятләү

**БӨЯТЛЕ** *с.* Бөяте булган, бөят беркетелгән. *Аларга кушылып, чөйдә асылынып торган аеры бөятле камытлар да көлде шикелле.* А.Хәлим

**БӨЯ́Ү** *ф. диал.* Махсус корылма ярдәмендә агым суларның юлын бүлү, буу. *Монда Урал елгасын ике чакрымнан артык озынлыктагы дамба белән бөягәннәр...* Р.Фәизов

**Бөяп бетерү** Тулысынча бөяү, бөяү эшен тәмамлау

**Бөяп кую** Бөялгән хәлгә китерү. *Бөяп куйгач, өеп таш иске юлга, Яңа юлга борылды көчле елга.* А.Нәвои

**БРА** *и. фр.* Стенага беркетелә торган яктырткыч. *Диван өстендә бра гына яна. Рәис китап укый.* М.Юныс. *Һәркайда – көзгеләр, рәсем-картиналар, идәнгә дә куелган, диварларга да эленгән яктырткычлар, бралар, торшерлар.* Р.Мирхәйдәров

**БРАДӘР** *и. фар. иск. кит.* 1) Ир туган

2) *кит.* Мөрәҗәгать сүзе: иптәш, фикердәш; дус, туган. *Сабыр, брадәрләр, «сабыр төбе – сары алтын» дигәннәр бабайлар.* К.Тинчурин

**БРАЗИ́ЛИЯЛЕ** *и.* Бразилия халкы һәм шул халыкның бер кешесе. *«Италия кубогы»ның финал уеннары вакытында, дөньяның атаклы футболчысы бразилияле Роналдоның уң аягы икенче мәртәбә җәрәхәтләнә.* Ватаным Татарстан. *Әйтик, мини-футбол буенча күптән түгел узган Европа беренчелегендә Русия гербы төшерелгән футболканы бразилияле Сирило Пула кигән иде.* Татарстан яшьләре

**БРАК** *и. пол.< нем.* **1**. 1) Стандарт таләпләргә туры килмәгән, куллану өчен өлешчә яки тулысынча яраксыз, я түбән сыйфатлы итеп эшләнгән әйбер. *Беркем берни исбатлый алмады: күрәләтә бракка чыгарырга берәү дә базмады, дөресен әйтергә түрәләрдән шүрләде.* К.Миңлебаев. *Алдагы көн брагын төзәтеп бетерегез, нормага да зыян килмәсен.* Шәһри Казан

2) Эшләп чыгарылган әйбернең сыйфатын төшерә яки продукцияне бөтенләй яраксызга чыгара торган кимчелек. *Җиңне утырткан да, брак җибәргәннәр*

**2**. *с. мәгъ.* Начар сыйфатлы итеп яки бозып эшләү нәтиҗәсендә, кулланышка яраксыз, кимчелеге булган. *Брак кирпеч. Брак такталар*

**БРАККА́ ЧЫГАРУ** *ф.* Начар сыйфатлы дип табу, эшне кабул итмәү, үткәрмәү. *Тәрҗемәмне теге чибәр апасы бракка чыгарган.* К.Миңлебаев

**БРАКОНЬЕР** *и. фр.* Аучылык, балык тоту, урман кисү белән рөхсәтсез шөгыльләнүче яки рөхсәт ителмәгән алымнар кулланучы кеше. *Әмма 1998 елда шушы сөйкемле, беркемгә усаллык кылмый торган җанварларны браконьерлар рәхимсез рәвештә атып бетерә.* Кызыклар дөньясында

**БРАКОНЬЕРЛЫК** *и.* Үрчем бирү һәм бала үстерү вакытында, тыелган урыннарда яисә тыелган ысуллар белән аулау; рөхсәтсез балык тоту; тыелган урында урман кисү шөгыле. *Алай икән, чәнечкеләре белән балык «атып» алучыларны браконьерлыкта гаепләү дөрес булырмы?* Ватаным Татарстан. *Ләкин, элегрәк кылган браконьерлык өчен, барыбер җавап бирергә туры килер.* Мәгърифәт

**БРА́К ЯСАУ** *ф.* Начар сыйфатлы продукция эшләп чыгару, әйберне бозып эшләү

**БРАМАТ** *и. гади с.* 1) Сукбайлык, зимагурлык, йолкыш булып йөрү, илдән-илгә йөрү; күчеп йөрү

2) Сукбай, йолкыш, зимагур. *Дөнья әллә кайсы тарафларга бөтереп җибәрмәгән булса, мин дә сезнең брамат арасында йөрер идем.* Н.Акмалов

◊ **Браматка чыгу** Берни эшләмичә ялкауланып йөрү, биләмдә йөрү

**БРАНДСПОЙТ** *и. голл.* Янгын сүндергәндә, суны көчле басым белән юнәлтеп сиптерер өчен, янгын насосының шлангысы очына киертелгән сиптергеч. --- *зур басым белән атылган суның көчен абайлап өлгермәде – брандспойт, кулыннан ычкынып, ком өстенә ташланган чуртан кебек, тоттырмас өчен бәргәләнә башлады.* К.Кәримов

**БРАСЛЕТ** *и. фр.* 1) Металлдан, сөяктән һ.б.ш. боҗра рәвешендә ясалган, беләзеккә киелә торган бизәнү әйбере

2) Кул сәгатендәге металл чылбыр. *Карлен «Золотой петушок» эмблемасы һәм вензеле төшерелгән салфетканы сак кына күтәрде – кардан да ак инглиз фарфоры өстендә авыр алтын браслетлы алтын сәгать ята иде.* Р.Мирхәйдәров

**БРА́УЗЕР** *и. ингл. информ.* Компьютер дисплеендагы информацияне карарга мөмкинлек бирә торган программа

**БРА́УНИНГ** *и. ингл.* Конструктор Джон Браунинг системасындагы автомат пистолетларның бер төре. *Кесәсенә тагын браунинг салып, гимнастёркадан гына урамга йөгереп чыкты.* А.Таһиров. *Беркадәр басып торгач, Ричард, акрын гына, өстәл тартмасын ачты һәм, зәвык белән бизәлгән браунингны кулына алып, аның салкын көпшәсен чигәсенә терәде.* Тәмуг чәчәге

**БРА́ШПИЛЬ** *и. голл.* Бәйләү арканын җыю яки якорьны күтәрү өчен кулланыла торган, ике барабанлы, валы горизонталь урнаштырылган судно бишеге. *Брашпильнең әйләнә башлавы палубаны дер селкетеп алды.* М.Юныс. *Рәсимне башта брашпиль тимерләренең салкын булуы гаҗәпләндерде.* Ф.Шәфигуллин

**БРЕЗЕНТ** *и. нем.* **1.** Су үткәрми, черетми торган катнашма сеңдерелгән тыгыз, тупас тукыма; парусина. *Брезент капланмаганнарының ялангач сыртларында кояшның иртәнге сүрән нурлары ялтырый...* Н.Хәсәнов. *Әрҗә өстенә брезент каплады, резинкага таккан ыргакларны әйләнәгә эләктереп чыкты.* М.Юныс. *Аның шофёры безгә туктарга ымлады, сәлам биреп: «Брезентың җилферди», – диде.* И.Низамов

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан эшләнгән. *Аннары ул башындагы кара фуражкасын салып какты, өстендәге брезент курткасыннан яңгыр тамчыларын сыпырып төшерде.* Р.Кәрами. *Кием дә татарча: өстендә – брезент тышлы бишмәт, аягында – олтанлы, манган итек.* М.Мәһдиев. *Иң алдан, юлны авыр дерелдәтеп, брезент түбәле мәһабәт «ЗИЛ» үтеп китте.* М.Галиев. *Вәли абый кулына брезент бияләйләрен киде, сарайны ачып, тиз генә эчкә үтте дә ишекне шап итеп ябып та куйды.* Н.Хәсәнов

**БРЕЙК** *и. ингл.* Акробатика һәм пантомима элементлары кертелгән һәм кискен хәрәкәтләрдән торган бию. *Теләсә нинди бию башкара алам: «хип-хоп», «рэп», «брейк»! Телисеңме, күрсәтәм?!* Х.Ибраһимов

**БРЕЙКДАНС** *и. ингл. к.* **брейк.** *[Әфләтун:] Аш дигәннән, корсакта җеннәр брейкданс бии башлады.* Р.Вәлиев

**БРЕНД** *и. ингл.* Фирманың, предприятиенең рекламасы буларак коммерция билгесе; шундый билге йөрткән югары сыйфатлы продукциясе; сәүдә маркасы, клеймо. *Күптән түгел генә, Walt Disney үзенең бренды астында сатыла торган азык-төлек калорияләлеген чикләде...* Ватаным Татарстан. *Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: татар бренды әлеге контекстта, күбесенчә, Россиянең эчке киңлекләренә кагыла.* Татарстан

**БРИГ** *и. ингл.* XVIII–XIX йөзләрдә кулланылган ике мачталы җилкәнле судно

**БРИГА́ДА** *и. фр.* 1) Билгеле бер эшне күмәкләп башкаручылар төркеме, коллектив. *Әле кичә генә Абдуллин, приказлар тактасы каршына килеп, өенче бригада операторларына: «Безнең бригада – идеал, һәр яктан алдын ---», дип, күкрәк кагып мактанып киткән иде.* Н.Әхмәдиев. *Мин плутниклар бригадасының башлыгы бит.* Г.Мөхәммәтшин. *Бу сүзләрдән аның бригадага башлык булырга ризалыгы да беленмәде, каршылыгы да сизелмәде.* М.Хуҗин

2) *хәрби* Ике-өч полктан торган гаскәри берләшмә яки берничә хәрби корабльдән торган флот берләшмәсе. *Әйдәгез, Петр Алексеевич, беренче чиратта латыш бригадаларына күрсәтмә бирдерик.* И.Низамов. *Мин Фәхрине күптән беләм. Без башта фронтта татар бригадасында бергә эшләдек.* Г.Ибраһимов. *Бригада әле тиешле сугышчан әзерлеккә җитмәгән, дип саный иде ул, ашыгып, фронтка китүне һәлакәткә тиңли иде.* Ф.Сафин

3) Поездга хезмәт күрсәтүче тимерьюлчылар составы

**БРИГАДИР** *и. нем.* 1) Бригада җитәкчесе. *Контораларга ул гына кереп, эшнең күләмен һәм хакын килешеп, соңыннан әҗерен алып, кыскасы, бригадир булып, ул гына йөрде.* К.Миңлебаев. *Бригадир күрше авылдан кунактан кайтып килә икән, безнең янга сугылды.* Р.Кәрами. *«Таулар» колхозының өч авылын --- берләштергән 1 нче комплекслы бригаданың бригадиры.* Р.Ишморат. *– Иптәш Хәйриев, миндә бер сорау бар, – дип күтәрелде бригадир Мәүлет.* М.Мәһдиев

2) XVIII гасырда рус армиясендә полковник белән генерал-майор арасындагы хәрби дәрәҗә; XVII–XVIII гасырларда Франциядә кайбер төр гаскәрләрдә офицер дәрәҗәсе; соңрак – кече унтер-офицер дәрәҗәсе; Германиядә артиллерия бригадасы командиры

**БРИГАДИРЛЫК** *и.* Бригадир вазифасы, бригадир булу. *Үткән язда аны күтәргәннәр бригадирлыкка.* М.Җәлил. *Юк, бригадирлыктан курыкмады ул.* Г.Гыйльманов. *– Колхозда әйбәт эшлисең, алай гына да түгел, ат кебек эшлисең, бригадирлыкны да булдырасың, – диде аңа колхоз рәисе.* М.Хуҗин

**БРИГАНТИ́НА** *и. ит.* Алгы мачтада – туры, арткы мачтада кыек парруслы, ике мачталы диңгез судносы. *Ул миңа хәзер, дидем, алсу җилкәнле бригантинаның палубасында басып тора.* М.Юныс

**БРИДЖИ** *и. ингл.* Тезгә таба тарайтып тегелгән кыска чалбар

**БРИЗ** *и. фр.* Көндез – диңгездән яр буена таба дымлы, төнлә – сүрелгән җирдән диңгезгә искән коры, йомшак яр буе җиле. *Яр буенда күлнең үз җилләре – йомшак бризлар хакимлек итә.* А.Муранов. *Менә сиңа – мәрҗән атауларында иртәнге бриз җиле белән пышылдап сөйләшүче зифа буйлы кокос пальмалары.* М.Юныс

**БРИКЕТ** *и. фр.* 1) Ташкүмер, пычкы чүбе, металл йомычкасы һ.б.ш кебекләрдән эскәнҗәгә кыстырып ясалган кирпеч, шакмак рәвешендәге материал, ягулык. *Бер машина торф брикеты җибәргән.* Х.Камалов

2) Шул рәвешкә кертеп әзерләнгән азык әйберләре. *Төрле ярмалардан эшләнгән ботка брикетлары*

**БРИКЕТЛАУ** *ф.* Брикет ясау, брикет сугу, брикет хәленә китерү. *Комбиазыкларны кәгазь капларга салалар я брикетлап чыгаралар.* А.Расих

**Брикетлап бару** Берсе артыннан икенчесен брикет хәленә китерү

**Брикетлап бетерү** Барысын да брикетлау; брикетлау эшен төгәлләү

**Брикетлап кую** Алдан брикетлау, брикет хәленә китереп калдыру

**Брикетлап тору** Өзлексез брикетлау

**Брикетлап чыгу** Барысын да бербер артлы брикетлау

**БРИЛЛИАНТ** *и. фр.* **1**. 1) Махсус ысул белән кырлап һәм шомартып эшкәртелгән алмаз. *Галина Мәскәү кибетләренең берсенә кереп, йөз алтмыш мең сумлык бриллиантны карап, шуны өенә китерергә кушып чыгып киткән...* М.Мәһдиев

2) Шундый асылташтан ясалган бизәнү әйбере. *[Ире] Һаҗәрдән дөньяны кызганмады. Аны алтыннар, бриллиантлар белән бизәде, атласлар, ефәкләр эченә күмде.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Бик зур кыйммәткә ия мөһим эш, нининдидер җитди эчтәлеккә ия хәрәкәт. *Һәрбер елмаюының, һәрбер каш селкетүенең, һәрбер күз сирпүенең бриллиант икәнлегенә төшенгән.* М.Әмир

**2**. *с. мәгъ.* 1) Шундый асылташ белән бизәлгән. *– Мин дә бирергә онытканмын, – дип, күзләрен идәнгә төшереп, кулындагы чылбыр беләзекнең бриллиант кашлы төймәләре белән уйнарга тотынды.* Ф.Әмирхан

2) күч. Ялтырап торган, җем-җем килгән, яктырып торган. *Сибелгән*

*бриллиант йолдызлар Бизәкли күкне. Бизәклиләр җир өстен матур кызлар – Чәчкәләр төсле.* М.Гафури

**БРИЛЛИАНТЛЫ** *с.* Бриллианты булган, бриллиант белән бизәлгән. *Алгы ложалардагы хатын-кызларның энҗеле калфаклары, бриллиантлы алкалары --- гаҗәп матур ялтырашалар.* Ш.Камал

**БРИЛЛИАНТЧЫ** *и.* Алмазны эшкәртеп, бизәнү әйберсе эшләү остасы

**БРИЛЬЯНТ** *и. фр. к.* **бриллиант**. *Кунакка дәшкән шикелле Куаклык эчләренә, Брильянт юллар суза ай Кичке күл өсләренә.* Х.Туфан

**БРИТА́НИЯЛЕ** *и.* Бөекбритания халкы һәм шул халыкның бер кешесе. *Тагын бер ел яшәгәннән соң, ике көн элек, британияле букмекерлык конторасыннан 5 мең фунт белән кайтып киткән.* Ватаным Татарстан. *Федерация ил территориясендә британияле Чисора һәм Хэй катнашындагы профессиональ алышлар уздыруны тыярга җыена.* Шәһри Казан

**БРИ́ТВА** *и. рус* Чәч ала, кырына торган корыч пәке яки кырыну аппараты. *Ул, яшен тизлеге белән, каяндыр бритва, сабын чыгарып, өстәлгә куйды.* М.Әмир. *[Аширов] Примуста бер чиләк су кайнатты, кулына бер кисәк сабын, бритва тоттырды.* Ә.Мушинский. *Ул һәр Ходай бирмеш иртәне, душ астына кереп, чәчен бритва белән кыра.* М.Мәһдиев

**БРИ́ФИНГ** *и. ингл.* Агымдагы сәяси мәсьәләләр хакында рәсми затларның матбугат чараларына биргән кыска пресс-конференциясе. *Әлеге сорауга җавапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының конференцзалында уздырылган брифингта бирделәр.* Татарстан

**БРО́ЙЛЕР** *и. ингл.* Алтмыш тәүлеклек ит чебеше; ит өчен үрчетелә торган тавык токымы. *Икенче көнне Туфан утыз ике бройлер чеби алып кайтты.* М.Галиев. *Теплица комбинаты, кош фабрикасы, бройлер фабрикасы, терлекчелек комплекслары кебек объектлар КамАЗ тизлеге белән корылды.* Казан утлары

**БРО́КЕР** *и. ингл.* Товар, фонд һәм валюта биржаларында арадашлык хезмәте белән шөгыльләнүче физик зат яки фирма (кагыйдә буларак, брокерлар килешүләрне клиентларның кушуы буенча, алар исеменнән, алар хисабына төзиләр). *Инженердан талантлы эшмәкәргә «әверелгән» ханым Россиядәге иң эре иминият брокерларыннан саналучы Генераль Агентлар Төркеменең Казан региональ бүлеге белән җитәкчелек итә.* Сөембикә

**БРОМ** *и. гр. махс.* 1) Галогеннар группасына караган химик элемент; куе кызыл төстәге, һавада төтәсләп торган зәһәр исле сыекча

2) *сөйл.* Бром кушып ясалган дару. *Ком өстеннән яланаяк бару нервыларны тынычландыра. Бром уколың бер якта торсын.* Г.Мөхәммәтшин

**БРОМЛЫ** *с.* Составында бром булган. *Бромлы көмеш. Бромлы тозлар*

**БРОНЕАВТОМОБИЛЬ** *и. рус хәрби к.* **броневик**

**БРОНЕВИК** *и. рус хәрби* Броня белән тышланган кораллы автомобиль

**БРОНЕЖИЛЕТ** *и. рус хәрби* Пуля үткәрми торган материалдан жилет рәвешендә эшләнгән хәрби кием. *«Атаман» дигәннәре кап-кара сакаллы, сыңар колаклы, бронежилет кигән, бил каешына өч пистолет, дүрт граната кыстырган, әзмәвер кадәр гәүдәле коточкыч бәндә иде.* Тәмуг чәчәге

**БРОНЕКА́ТЕР** *и. рус хәрби* Бронялап эшләнгән кораллы катер. *Дулкыннар өстеннән Идел флотилиясенең бронекатерлары уза.* Г.Әпсәләмов

**БРОНЕМАШИ́НА** *и. рус хәрби к.* **броневик**

**БРОНЕНО́СЕЦ** *и. рус хәрби* XIX йөз ахыры һәм XX йөз башларында кулланылышта булган бронялы сугыш корабле. *Вагоннар махсус сугыш өчен эшләнгән броненосец шикелле – бронялы.* Ш.Мөхәммәдев

**БРОНЕПО́ЕЗД** *и. рус хәрби* Бронялы, кораллы поезд. *Иделнең уң ягында – Казаннан чигенгән кызыл гаскәрләр; сул ярында – аклар, шәһәр белән Васильево арасында аларның бронепоездлары йөреп тора.* С.Сабиров. *Илебез, шул исәптән Татарстан хезмәт ияләре, фронттагы сугышчыларыбыз өчен җылы киемнәр, төрле бүләкләр җыялар, танк колонналары, бронепоездлар төзү өчен акчаларын бирәләр.* Казан утлары

**БРОНЕТАНК** *и. рус хәрби* Броня белән капланган танк

**БРОНЕТРАНСПОРТЁР** *и. рус хәрби* Җәяүле гаскәрне һәм сугыш кирәк-яракларын ташый торган бронялы автомобиль. *Зур паромнар килеп өлгерде, алар танклар, бронетранспортёрларны алып киттеләр.* Ш.Рәкыйпов

**БРО́НЗА** *и. фр.* **1.** Бакыр, ак кургашын һ.б. металлар эремәсе. *Вакыт каршында хәтта мәрмәр, бронза, гранитлар да мәңгелек түгел.* И.Низамов. *Янәшәсенә махсус тактага бронзадан коеп ясалган барельеф беркетеп, астына исем-фамилиясен язып куйдылар.* Н.Хәсәнов. *Швейцар, нәзакәтле елмаеп, бөгелә биреп, бронза белән нәкышьләнгән саллы ишекләрне ачты.* Х.Мөдәррисова. *Бронза – нигездә шул ук бакыр ул, тик, аны эреткәндә, төрле кушылмалар гына өстәгәннәр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**2**. *с. мәгъ.* Шул эремәдән эшләнгән. *Светлана торшер кебек үк авыр бронза шәмдәлдәге шәмнәрне кабызып җибәрде.* Р.Мирхәйдәров. *Бу бронза сыннарны мең еллар элек болгар бабаларыбыз ясаган.* Г.Гыйльманов. *ФИФА аны «Дөньяның иң яхшы капкачысы» дип атады. Һәм аңа бронза кубок тапшырды.* Татарстан

**БРО́НЗАЛАУ** *ф.* Өслекне бронза белән каплау, бронза төсенә буяу; бронза йөгертү

**Бронзалап җибәрү** Бераз бронза белән каплау

**Бронзалап кую** Бронзаланган хәлгә китерү

**Бронзалап тору** Һәрвакыт, еш, әледән-әле бронзалау

**Бронзалап чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр бронзалау

**БРО́НЗА ЧОРЫ** *и.* Кешелек тарихында, энеолиттан соң килгән, тимер билгеле булганга кадәрге, металл буларак бронза кулланылган иң борынгы чор. *Бронза чорында ук, алар [төрки кабиләләрнең борынгы бабалары – динлиннар] югары мәдәнияткә ия була, бу турыда Минуса*

*һәм Алтай каберлекләре хәбәр итә.* Г.Фәйзрахманов

**БРОНТОЗАВР** *и. гр.* Юра чорында яшәгән, гигант гәүдәле, үсемлек белән туклана торган динозаврлар ыруына кергән хайван. *Монда авырлыклары берничә дистә тоннага җиткән, буйлары да шуңа тәңгәл, аякларында искитмәле дәү тырнаклары булган бронтозаврлар гына яши алган.* Кызыклар дөньясында

**БРОНХ** *и. нем.< гр. анат.* Трахеяның һава үткәрү өчен альвеолалар белән тоташкан, көпшәсыман зур тармакларыннан берсе. *Күрше палатада каты авыру ята. Бронхлар... Тыны буыла...* И.Ибраһимов. *Чөнки бронхларда банка кую нәтиҗәсендә килеп чыккан киңәюләр эренләү процессын көчәйтә генә икән.* Юлдаш

**БРОНХИАЛЬ** *и.* Бронхка мөнәсәбәтле, бронхларга кагылышы булган. *[Үги ана яфрагының] Яфракларыннан һәм чәчәкләреннән ясалган сок туберкулёз, бронхит, бронхиаль астманы дәвалау өчен дә кулланыла.* Сәламәтлек нигезләре

**БРОНХИТ** *и. нем.< гр.* Көчле ютәл, югары температура белән барган кискен яки хроник авыру; бронхларның лайлалы ярысы ялкынсыну. *1937 елның 24 маенда бирелгән белешмәдә Г.Галинең бронхит белән авыруы турында язылган.* Р.Мостафин

**БРОНЬ** *и. рус* Аерым кешегә нинди дә булса хокуклар бирә торган һәм рәсми рәвештә беркетелгән махсус рөхсәт; шул хактагы рәсми язма документ. *Сугыш башлангач ук, Хәйруллинга бронь биргәннәр, дип сөйләделәр.* М.Мәһдиев. *Ихтимал, броньнарыннан колак кагу куркынычы да аларны җитезрәк булуга этәргәндер.* К.Миңлебаев. *Сугышның беренче көннәреннән үк әти, бронь кәгазе булса да, военкомат бусагасын таптый башлады, фронтка ашкынды.* Г.Кутуева

**БРОНЯ** *и. рус* Нык корыч яки башка төр материалдан эшләнгән саклану тышчасы, калканы. *Фрицлар һаман машинаның бронясын төяләр, рус солдатларына, тизрәк люктан чыгып, пленга бирелергә тәкъдим итәләр.* Р.Хафизова

**БРОНЯЛЫ** *с.* Бронясы булган, броня белән тышланган. *Вагоннар махсус сугыш өчен эшләнгән броненосец шикелле – бронялы.* Ш.Мөхәммәдев

**БРОНЯЛЫЛАР** *и. зоол.* Аркалары калкан сыман каты сөяк белән капланган, калкан өсте мөгез пластинкалардан торган, куркыныч янаганда, калкан астына яшеренеп, шар рәвешен ала торган имезүче хайваннарның семьялык атамасы; *русчасы:* **броненосцевые.** *Бронялыларның дөньяда 20–25 төре бар, алар Көньяк Америка, Чили һәм Аргентинада яшиләр.* Биология

**БРО́ШКА** *и. рус* Кадап беркетелә торган бизәнү әйбере. *Аның каравы, алтын яки көмештән эшләнгән чылбыр, муенса, брошка, алка, йөзек, запонкаларны һич шикләнми кияргә, туташханымнарга иннек-кершәнне җәлләмичә сөртергә була.* Ватаным Татарстан

**БРОШЬ** *и. фр. к.* **брошка**

**БРОШЮ́РА** *и. фр.* Иҗтимагый, сәяси, фәнни һ.б.ш. темага караган кечкенә күләмле басма әсәр, китапчык. *[Хәкимуллин] Ниндидер бер брошюра караштырып утыра.* М.Вәли-Барҗылы. *Бу кечкенә брошюрада намаз укырга өйрәнүчеләрне намаз уку өчен кирәк булган шартлар белән таныштыру --- максат итеп куелды.* Г.Хәйрулла. *Безнең тулай торактагы тумбочкабыз да сәнгать турында брошюралар, төрле открытка җыелмалары белән тулды.* Мәдәни җомга

**БРОШЮ́РАЛАУ** *ф.* Басма битләрне китапчык, дәфтәр сыман итеп тегү, китап, журнал рәвешенә китерү

**Брошюралап кую** Брошюраланган хәлгә китерү

**Брошюралап тору** Даими рәвештә, һәрвакыт брошюралау

**Брошюралап чыгу** Бөтенесен дә рәттән брошюралау

**БРУДЕРШАФТ** *и. нем.* Дуслыкны ныгыту өчен, эчемлекне чәркә тоткан кулларын чалмаштырып эчеп җибәрү, аннан соң үбешү һәм, шул мизгелдән башлап, бер-берсенә «син» дип эндәшүгә күчә торган өстәл арты йоласы. *[Лариса:] Беләсеңме, Анварчик, минем үз гомеремдә брудершафт эчкәнем юк бит әле.* М.Маликова

**БРУ́СТВЕР** *и. нем. хәрби* Окопның яки траншеяның алгы кырыена өеп ясалган калкулык. *Кар һәр җирдә чистартылган, бруствер өсләре әйбәтләп маскировкаланган иде.* Г.Әпсәләмов

**БРУ́ТТО** *и. ит.* 1) Товарның төргәге (мәс., савыты-әрҗәсе, тартмасы, банкасы һ.б.) белән исәпләнгән авырлыгы; *киресе:* **нетто**

2) Чыгымнарны исәпкә алмаган тулай керем

**БРУЦЕЛЛЁЗ** *и. лат. мед. вет.* Терлекләрдә йөрәк-кан тамырларын, нерв системасын, сөяк-буын аппаратын зарарлый торган йогышлы авыру (бөтен төрләре дә кешеләргә йога)

**БРЫ́НЗА** *и. рум.* Сарык яки кәҗә сөтеннән ясалган эремчексыман сыр. *Саугач, аны җылы килеш эчәләр, бездәге куе катык кебек «ләбән» ясыйлар, брынза эшлиләр.* М.Юныс. *Инде уйлап карыйк: кеше һәркөнне сау-сәламәт яшәрлек сөт һәм сөт ризыклары куллана алсын өчен, күпме терлек үрчетергә, күпме май, каймак, брынза, кефир, --- ясарга кирәк?* М.Зарипов

**БРЮНЕТ** *и. фр.* Кара чәчле, каратут йөзле ир кеше. *Кызның беренче чибәрләр рәтендә торырлык брюнет егет белән әңгәмәне өзәсе дә килмәгән кебек, түп-түгәрәк һәм йонлач беләкләрен сыпыргалап, көчөнә мактанучы егеткәйне үсендерергә теләмичә, битараф калмакчы булуы да сизелә кебек.* М.Хуҗин

**БРЮНЕ́ТКА** *и. рус* Брюнет хатынкыз. *Зәйнәп – Хөсәеннең кызы, брюнетка, йомшак табигатьле уйчан гына кыз.* Ф.Әмирхан. *Аңа җыйнак гәүдәле, чем-кара күзле брюнеткалар ошый.* Юлдаш

**БУ** I *и.* 1) Пар. *Бу бөркеп, моңлы көй сузып торган самавыр килеп кунаклады.* М.Хәсәнов. *Ярты сәгать тә үтмәде, ул өстендә булары чыгып торган бер чиләк күтәреп килде.* Р.Кәрами. *Пешереп, өстәлгә утырткан ярмалы бәрәңгенең буы кебек.* Р.Сибат. *Уф, эсселәп беттем, калын мамык юрганымны көч-хәл белән өстән төшердем, дигәндәй, тир күрсәтте җир, ягъни сизелер-сизелмәс кенә буларын чыгара башлады.* Г.Хәсәнов

2) Җылы һәм салкын һава аралашканда хасил була торган ак томан. *Ишекне әледән-әле киң итеп ачып, өйне буга күмә-күмә, әрҗә, төенчекләр ташылып беткәч, барчасы өйгә җыелып торган бер арада, Сафиулла сандыкка утырды...* Ә.Гаффар

**БУ** II *а.* (моның, моңа, моны, моннан, монда; *күпл.* болар; *тартымлы форм.* бусы, болары) 1) Күз алдындагы, үзенә якын торган кеше яки әйберне күрсәтеп сөйләгәндә кулланыла торган күрсәтү алмашлыгы; *киресе*: **теге.** *Бу – минем туган авылым.* И.Гази. *Әле күптән түгел генә бу атаклы галим Бәләбәй хакында фәнни хезмәтен төгәлләде.* М.Галиев. *Юл буйларында, арыш басуы эчендә үсеп утырган озын сабаклы, сирәк чәчәкле бу үсемлекне мең тапкыр күргән Ярмөхәммәт...* Р.Батулла. *Бер яктан, бу кеше – үз урынында түгел, дисәм, дөрес тә, дөрес түгел дә кебек.* Ә.Хәбибуллин

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса ишарә итү яисә ымлау өчен кулланыла. *Бу диверсияләрне бригаденфюрер СС Модель башкисәрләре башкара икән.* К.Латыйп. *Бу хәл Карлен өчен дә бик уңайлы – дусларының буш вакытлары җитеп арткан, төннәрен кәеф-сафа коруны яраталар, һәм иң мөһиме – акчалары бер букча иде.* Р.Мирхәйдәров. *Бу сүз Габдулланың аңына томанлы үткәннең ерак төпсезлегеннән әтисен төсмерләтә торган бердәнбер сүз булып сеңеп кала.* Ә.Фәйзи

**БУА** *и.* 1) Су юлын бүлеп, су җыеп тотар өчен эшләнгән корылма. *Бракка чыгарылган ап-ак бетон плитәләр кайтарып, буа алдына тезгәч, ул мәктәп дәреслекләрендәге ДнепроГЭС сурәтенә охшап китте.* А.Тимергалин. *Буасы да – искитмәле тирән сулы.* Р.Хафизова. *Буа бурасы да, каралып, зәңгәрсу бака үләне, су төбеннән калыккан куе яшел суүсемнәр --- белән тулды.* Ә.Гаффар

2) Шушы корылмада җыелып тупланган су, сулык. *Малайлар, киттек тегермән буасына!* Р.Хафизова. *Кош, кеше милкенә сузылганын төшенмичә, балык үрчетә торган буадан тимгелле балыкны (форель) чәлдерергә остарып киткән.* Кызыклар дөньясында

◊ **Буа буарлык** Бик күп, исәпсез. *Акыл аларның үзләрендә дә буа буарлык.* Т.Әйди. *Сабый чакта апамның бик яратып укырга йөргәне исемдә, чөнки анда ахирәтләре буа буарлык иде.* К.Миңлебаев. *Рус эстрадасында җырчылар буа буарлык.* Шәһри Казан

**БУАЗ** *с.* Карынында баласы булган (хайваннар турында); *киресе:* **кысыр.** *Буаз сыерны тәүлегенә өч тапкыр, бер үк сәгатьләрдә ашаталар.* Йорт эшләре

**БУАЗЛЫК** *и.* Буаз булу. *Бу угызны бәтиләргә эчертергә ярамый, чөнки анда авыру тудыргыч микроблар күп була, алар буазлык чорында имчәкләрнең сөт юлларына керәләр.* Йорт эшләре. *Буазлыкның соңгы аенда кәҗәгә туклыклы азыклар, мәсәлән, яхшы печән, көрпә һәм башкаларны бирергә кирәк.* Мәдәни җомга

**БУАНАК** *и. к.* **бугалак.** *Сине якягыңда йөз буанак корылган тәбе сагалый.* А.Гыйләҗев

**БУА́Р ЕЛАН** *и. зоол.* Ялганаяклы еланнар семьялыгыннан, башлыча чүлләрдә һәм ярымчүлләрдә яши торган, гадәттә корбанын гәүдәсе белән чорнап буа торган, агусыз эре ерткыч елан; *русчасы:* **удав.** *Ханикә дә, ханның күзеннән бөркелгән салкын зәңгәр уттан куырылып, буар елан авызына суырылып килгән куяндай дерелдәп, нәфис бармакларын изге китап өстенә куйды.* Р.Зәйдулла. *Икенче очракта, бер португалияле буар еланны үз иленә алып кайтмакчы була.* Кызыклар дөньясында. *Иң әүвәл король буар еланнары китерелә.* Кызыклар дөньясында. *Буар елан итеннән пешерелгән кәтлитләр, рагу Вьетнам рестораннары өстәлендә төп урынны алып тора.* Шәһри Чаллы

**БУ́БИ** *и.* Кәрт уенында кызыл ромб рәсеменнән гыйбарәт билге һәм шундый кәрт. *Әйтик, синең кулыңда буби алтылык белән черви туз калган,ди.* Т.Миңнуллин

**БУГА** *и.* Яшь, печтерелмәгән үгез. *Ерткыч хайваннарның һәм йорт кошларының күбесе – «күк уллары». Мәсәлән, татарча куй – сарык, буга – нәсел үгезе ---.* Н.Фәттах

**БУГАЗ** I *и.* 1) Муенның алгы өлеше; тамак төбе, авыз эченең арткы өлеше. *Әллә ничек, бугазларны чеметтереп төшеп киткән шикелле булды [эчемлек].* Г.Камал

2) Сулыш юлының өске өлеше. *Ул әйтмәкче булды – теле әйләнмәде, бугазыннан өне чыкмады.* М.Әмир. *Хатын, бугазына бодай бөялгән үрдәк сыман, «ыйк-ыйк» диде.* Н.Гыйматдинова

3) Шешәләрнең тар авызы, тамагы, муены

◊ **Бугазга бугаз килү (ябышу)** Берберсенең бугазыннан алып, аяусыз сугышу; үзара ярсып талашу, ызгышу. *[Муса:] Урлашып баедың! [Габдуллаҗан:] Син үзең – күмер карагы! (Бугазга бугаз киләләр.)* К.Тинчурин. **Бугазга килү** Эш яки вазгыятьнең ашыгычлык таләп итүе турында. **Бугазга терәлү** *к.* **бугазга килү.** *Монда эшләр тәмам бугазга терәлгән.* Ш.Камал. **Бугазга ябышу** Берәр нәрсә өчен кискен гаепләп чыгу; үтерү, бетерү. *Берәү булса, бу сүзләр өчен Насыйбуллага ташланыр иде, бугазына ябышыр иде.* Т.Миңнуллин. *Шушы коточкыч буран[да] --- ике йөз метрда берберсенең бугазына ябышырга әзер торган ике фронт яшеренгән.* Г.Әпсәләмов. **Бугаздан алу** Берәр нәрсәне эшләргә тупас рәвештә мәҗбүр итү; котылгысыз хәл алдында калдыру. **Бугаз ерту** *гади с.* Акыру-бакыру, гайрәт чәчеп кычкырыну, җикеренү. *Камали йөри, ди ич, «кемгә – война, кемгә – файда» дип, бугаз ертып.* К.Нәҗми. **Бугаз киерү** *к.* **бугаз ерту.** *Кычкырмагыз әле, нәрсә бугаз киерәсез?* Г.Ахунов

**БУГАЗ** II *и. геогр.* Ике диңгезне, күлне һ.б.ш.ны тоташтыра торган тар сулык. *Ленинград фронты гаскәрләре, Карелия бугазында һөҗүмгә күчеп, уннарча шәһәрләрне һәм халык яши торган йөзләрчә пунктларны азат иттеләр.* Татарстан

**БУГАЗЛА́У** *ф.* 1) *сөйл.* Сую. *Беркөнне болар икесе киңәштеләр дә, төнлә кунаклаган җиренә барып, әтәчне бугазладылар.* Г.Тукай. *Әгәр дә татарлар баш булган җирдә берәү мо-*

*ңар башка гадәт белән хайван бугазласа, үлем җәзасына мөстәхикъ була.* Г.Гобәйдуллин. *«Корбаныңны җәфалап өстерәп барма, азапламыйча бугазларга тырыш», – дигән.* Мәгърифәт

2) Бугазын чәйнәп өзеп үтерү, юк итү, бетерү (ерткычлар). *Бүре сарыкларны бугазлый.* Г.Тукай

3) *күч.* Ирексезләп, бик каты сорау, таләп итү. *Монда, бюллетень бугазлап, врачларны җәфалап бетергәч, Казанны яулап алырга булдыңмы?* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Үтерү, юкка чыгару, бетерү

**Бугазлап алу** Кинәт бугазлау; бик нык таләп итеп, ирексезләп, үз дигәненә ирешү. *Моның сәбәпләрен Әмир караңгы төн җиткәч, анда да әле Шәйсолтанны бугазлап алгандай сораштыргач кына ачыклады.* В.Имамов

**Бугазлап ату** Искәрмәстән, тиз арада бугазлау; ачудан юкка чыгарырга әзер булу. *Шушы минутта, әтисенә тел тигезгән өчен, Кәримне бугазлап атарга әзер иде.* Ф.Сафин

**Бугазлап бару** Һәрберсен бер-бер артлы бугазлау. *Аерылганны – аю булып, бүленгәнне, бүре булып, ашерен генә бугазлап бара.* Х.Сарьян

**Бугазлап бетерү** Барысын да бугазлау

**Бугазлап йөрү** Өзлексез, рәттән, озак вакытлар буе бугазлау

**Бугазлап ташлау** *к.* **бугазлап ату.** *Ерткыч җәнлекләр арасында бердәнбер бүре кавеме шундый: үзенә тиң дошманын җиңгәч, бугазлап ташламый, өстенә менеп, юешләп мыскыллый да исән калдырып китеп бара.* М.Галиев

**Бугазлап тору** Әле, хәзерге вакытта бугазлау

**БУГАЙ** *кис.* Билгесезлек, икеләнү, чамалауны һәм фактның дөреслегенә сөйләүченең ышанып җитмәвен белдерә. *Зыя исә, гомерендә беренче мәртәбә бугай, аның кулларын үбеп, күзендәге яшьләрне күрсәтмәскә тырышкан әдәм кебек, йөзе белән, Мәрьямнең калку күкрәгенә егыла.* Г.Ибраһимов. *Хатын туздырыр инде: казан астына утын ваклыйсы барые бугай.* И.Гази. *Бу яшәештә, Хак Тәгаләнең кануннар тәртибен бозмас өчен, кемнедер рәнҗетергә дә туры килер бугай.* Н.Гыйматдинова

**БУГАЙЛА́У** *ф. сөйл.* Икеле-микеле, *бугай* сүзен катнаштырып сөйләү, төгәл җаваптан качу

**Бугайлап тору** Һаман бугайлау

**БУГАЛАК** *и. диал.* 1) Җәнлек талпынган саен буыла яки, кысылып, эләгеп кала торган итеп, нечкә тимерчыбык я кылдан элмәкләп ясалган тозак

2) Кыргый яки өйрәтелмәгән хайваннарны муеныннан эләктереп тоту өчен, бер очы элмәкле махсус бау, аркан. *Ерак илләр күңелен алгысыта икән, олан бит – колан түгел, муенына бугалак ташлап, кырда гына тотып булмый.* Р.Зәйдулла

**БУГЫЧ** *и.* Кысып бәйләр өчен, сузылмалы тасма, бау. *Шул вакыт бүртеп чыккан чигә тамырын «чалт» иттереп кисә, әшәке кан, ага-ага да, бугычны ычкындыргач, туктап кала.* Н.Хәсәнов

**БУ́ДДА** *и. санскр.* Буддизм диненә нигез салучы зат. *Һиндстан җәмгыятен һәм дәүләтен рухи яктан берләштерүче Будда диненең Брахманизм тәгълиматы булган. Нигез салучысы – галим, реформатор, соңыннан Будда, ягъни «Якты рух иясе» дигән исем алган Сиддхартха Гаутама.* Ватаныбыз тарихы

**БУ́ДДАЧЫ** *и.* Буддизм динен тотучы. *Шулай итеп, буддачы калмыклар христиан урыслар кулында татарларга ислам диненә каршы корал булып торалар.* Ф.Бәйрәмова

**БУДДИЗМ** *и. рус* Б.э.к. 623–544 елларда Һиндстанда барлыкка килеп, Көнчыгыш илләрендә (Монголия, Кытай һ.б. илләрдә) таралган, Алланың бер булуын танымаган (күп аллага табынган) дин; христиан, ислам белән бергә, өч бөтендөнья диненең берсе. *– Теләсәгез, мин сезгә бер брошюра бирәм, – диде рухани. – Анда дөньяда иң киң таралган диннәр – христиан, буддизм, ислам, иудаизм турында кыскача гына мәгълүмат тупланган.* М.Маликова

**БУДИ́ЛЬНИК** *и. рус* Билгеләнгән вакытта шалтырап сигнал бирә торган сәгать. *Таң алдыннан гына йокымсырап киттем, һәм --- будильник шалтырады.* Ә.Хәбибуллин. *Аквариум торган өстәлгә будильник куегыз.* Кызыклар дөньясында. *Йоклап калмаска, будильник куегыз.* Мәдәни җомга

**БУ́ДКА** *и. рус* Яңгырдан, җилдән сакланырлык кечкенә генә корылма, алачык, каралты. *Җәйге караңгы төннәрнең берсендә, инде юллардагы машиналар хәрәкәте тәмам туктагач, бистә читендәге тимер юлны үтеп чыгу урынын күзәтү хезмәте сержанты үзенең будкасыннан чыга.* Р.Фәизов

**БУДУАР** *и. фр.* Байлар йортында хуҗабикәнең үзенә генә билгеләнгән бүлмә. *Бусы – күчереп йөртелә торган стена: кунаклар килгәч, алып куясың, киткәч, үз урынына урнаштырасың, бер якта зал, икенчесендә – минем будуар...* М.Маликова. *Вакыйга – Парижда, хәзерге заманда. Циля Фонкның бик шәп җыештырылган будуары.* Г.Камал

**БУДЫРГЫЧ** *с.* **1.** Сулыш алырга кыен булган, тынны кисә торган. --- *шундый җылы агымга килеп кергәч, әтисе аңа: «Бу җылы будыргыч һаваны шайтаннар җибәрә. Алар, колакларын шаңкәйтеп, әнә теге тирән чокырда утыралар да иманлы кешеләрне күргәндә көрсенәләр. Бу – аларның тыны», – ди.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Оекны, балакны һ.б.ны тарттырып, будырып куя торган сузылмалы тасма. *Оекны тотар өчен, будыргыч сатып алдым*

**БУДЫРУ** *ф.* Нәрсәне дә булса кысып урау, буып бәйләү. *Аит бабайны, тотып, чи каеш белән беләкләреннән, ботларыннан будырып, кырга чыгарып ташларлар.* К.Насыйри. --- *ул [кыз] путасын шулкадәр нык будырып бәйләгән ки – биле муены чаклы гына, юкюк, чәч толымы калынлыгы гына калган.* К.Кәримов

**Будырып кую** Будырылган хәлдә калдыру. --- *күперенке кара чәчләрен маңгай турысыннан ал тасма белән бәйләп куйган да биленә, алъяпкыч сыман, итәк сыман итеп, кыска гына киндер кисәге будырып куйган.* Н.Фәттах

**БУЕ** *бәйл.* 1) Буй юнәлештә барган эш-хәрәкәтне белдерә; буенча, буйлап. *Авылга кергәч, атыбыз урам буе*

*барды да кинәт кенә тыкрыкка борылды.* Сөембикә

2) Күләм ягыннан чагыштыруны белдерә; озынлыкта, буйлыкта; биеклектә. *Ай китте, ел китте, артына әйләнеп караса, энә буе җир китте.* Әкият. *Дагалау станогының астагы каен аратасы, ике җиреннән шартлап сынып, ярты җир буе ераклыкка очты.* М.Мәһдиев

3) Вакытны белдергән сүзләр белән килеп, эш-хәлнең барлык шул вакыт дәвамында башкарылуын белдерә. *Гүя ул гомере буе яшәмәгән, гүя ул гомере буе йоклаган да менә бүген кинәт кенә уянып киткән.* Р.Вәлиев. *Теге адәм моның сарыгын, тавык-чебешләрен суйдырып, каклаган казын ашап, төче коймакларны майда йөздереп, җәй буе сыйланып ята.* М.Галиев. *Әйтүең өчен, якын итүең өчен, сине гомерем буе искә алырмын.* Ә.Хәбибуллин. *Сөлчәдә юылган күлмәк төне буе тынгылык бирмәде.* Н.Гыйматдинова

**БУЕНА** *бәйл.* 1) Буй юнәлештә барган эш-хәрәкәтне белдерә; буйлап, буй юнәлештә. *Шундый тойгы белән яшим, гүя тормышымның буена күзгә күренмәс кыллар сызылган.* Б.Камал

2) Вакытны белдергән сүзләр белән килеп, эш-хәлнең барлык шул вакыт дәвамында башкарылуын белдерә. *Бала-чага, көннәр буена, бака кебек, суда быкырдый.* Р.Хафизова

**БУЕНЧА** *бәйл.* 1) Буй юнәлештә барган эш-хәрәкәтне белдерә; буйлап, буй юнәлештә. *Урам буенча болганчык сулар йөгерде.* И.Гази. *Төркем коридор буенча китте.* М.Маликова

2) Вакытны белдергән сүзләр белән килеп, эш-хәлнең барлык шул вакыт дәвамында башкарылуын белдерә; буена. *Гомере буенча башы бурлактан кайтмаган Гаделшаны үтерткәннәр.* Г.Толымбай. *Төннәр буенча китап өстендә күз бетәштереп, йөз саргайтып утырганчы, мин аны үзем йорт алып бару үнәренә өйрәтермен.* Казан утлары

3) Нәрсәдән булса да файдаланып, шуның ярдәмендә; белән, аркылы, аша. *Кемдер кыр телефоны буенча боерыклар тапшыра.* К.Нәҗми. *Эш, салымнар буенча җиңеллекләр ясапмы, ничек тә Әүхәдине күндерүгә тәрәлеп кала...* Ә.Фәйзи

4) Нәрсәгә дә булса нигезләнеп, шуңа таянып, шул җирлектә, шуны исәпкә алып, мәгънәләрен белдерә. *Эш шунда ки: тел, үзенең табигате буенча, бик тә сизгер, тере организмга охшаш.* Г.Бәширов. *Ниндидер шәҗәрә буенча, үзен уникенче буынга чыгара иде.* Х.Сарьян. *Аларның кулъязмасы нигезендә, урыс һәм Европа галимнәре эпитафия текстлары буенча фәнни хезмәтләр бастырып килләр.* М.Әхмәтҗанов

5) Эш-хәлнең максатын белдерә; өчен. *Ул, аеруча әһәмиятле бер участокны өйрәнү буенча, һәр төнне диярлек, разведкага йөрде.* И.Гази

6) Сәбәпле, аркасында, нәтиҗәсендә. *Бу алтын игеннәр табигать мәрхәмәте буенча гына үсмәгән бит, аларны кеше үстергән.* Г.Әпсәләмов

7) Кайсы да булса өлкәдә, юнәлештә. *Мин химия буенча яңа проблема өстендә эшлим.* Ш.Камал

8) Тиңләштерү, эш-хәлнең чыганагы мәгънәсен белдерә. *Хәзер аның доклады буенча бик кызу аңлаш бара.* Г.Ибраһимов

**БУЕР** *и. голл.* 1) Җилкәнле кечкенә көймә

2) *спорт* Бозда шуу өчен җилкәнле чана

**БУЗА** I *и.* Элек төрки халыкларда, солы, арпа яки бодай ярмасыннан кайнатып ясалган, җиңелчә исерткеч эчемлек. *Үзенә бирелгән бузаны ул тамчысын да калдырмый эчеп бетерде.* Н.Фәттах

**БУЗА** II *и.* Шау-шу күтәрү, җәнҗал, гауга. *Шагыйрь булган кеше «шагыйрь» булса, Кан кыздырып күпертәме буза?* Ә.Синугыл-Куганаклы

◊ **Буза кубару (куптару, кузгалту, күтәрү)** Дау кубару, шау-шу күтәрү, тавыш чыгару. *Без кузгалып киткәч, озак та үтми, конторда гауга чыккан, буза күтәрелгән.* Г.Хафизов. *Аларның беренчесе – Мәскәүнең аеру сәясәте, икенчесе – тарихны һәм милли үсешнең мәгънәсен аңлап җиткермәгән кешеләрнең буза кубарып йөрүе.* Татар мөселман календаре

**БУЗАРУ** *ф.* Ачудан, нәфрәттән бүртенеп кызару. *Азамат ир Туктамыш, Гайрәтеннән бузарып, Киң Җанбайга аны әйтте ---.* Дастан. *Бу сүзләрне ишеткәннән соң, карачылар, алданулары нннан кызарып, бузарып, хан алдында оятка калсалар да, карачылыкларын саклап калуларына куанып, тиз генә койрыкларын бордылар.* Т.Нәбиуллин

**Бузарып чыгу** Тоташ бузару. *Таза муены кызарып, бузарып чыккан иде.* Р.Камал

**БУЗЛА́У** *ф.* 1) Борчулы тавыш белән, сузып-сузып кычкыру, чакырып өн салу, үкерү (дөя турында). *Дөя килеп бузлайдыр, Бутасы аның юк микән?* Дастан

2) *күч. диал.* Иңрәү, шыңшу, сыкрану. *Исмәгыйль карт, Сәрби карчык бузлап елап йөриләр.* Бәет. *Йусефә тәвә бузлап зари кылди: «Бән Кәнгандән кәлүрмен», – дәюр имди.* Кол Гали. *Кыз чыгып киткәндә, анайлары бузлап кала.* Д.Рамазанова

**Бузлап тору** Бертуктаусыз бузлау. *Язмыш учакларын актарганда, Бузлап торган кузга үреләм.* М.Нәзиров

**БУЙ** I *и.* **1.** 1) *кыек форм.* Аркылыга перпендикуляр торган озын юнәлеш, нәрсәнең дә булса озын ягы; *киресе:* **аркылы.** *Нурыйның урамга буе белән салынып, салам белән ябылган алты почмаклы өе икегә бүленә.* Г.Ибраһимов. *Уф, ул дәрьяның тирәнлеге, киңлеге. Йөз бер – аркылы, бер – буй, чум төбенә, эзлән, кирәк энҗеләрне тапмый калма.* С.Поварисов. *Тауны аркылыга да, буйга да гизгәндер инде шулхәтле гомер эчендә.* Н.Гыйматдинова. *Келәмне, каютада яхшылап төреп, өске түшәмгә, бер кешегә дә комачауламый торган итеп, буе белән бәйләп куйдым.* Ә.Хәбибуллин

2) Озынлык; *киресе:* **иң.** *Каралты-кураларың белән теләсәң – буйга, теләсәң иңгә табан җәел.* Н.Гыйматдинова. *Шулай йөри-йөри, теге өстәлнең артына да кереп китә, арттан да берике буй буйлый, йөри торгач, ачык ишектән чыгып ук китә.* М.Мәһдиев

3) Гәүдә, сын (гадәттә аның озынлыгын, биеклеген күздә тотканда). *Бәс, әй угыл, «гыйлем вә мәгърифәт»*

*дигән нәрсә буйга вә кыяфәткә карап булмыйдыр.* К.Насыйри. *Югыйсә, буйга да озын үзе, тик буыны сыек.* Н.Гыйматдинова. *Тарихта исеме калган шәхесләрнең күбесе буйга нәкъ аның кадәр генә булган икән.* М.Галиев. *Бер-бер артлы барсалар, буйга карап, үзенең иң артта атлыйсын ул белә иде.* Р.Хафизова

4) Нәрсәнең дә булса янәшәсеннән сузылып киткән өслек; өслектәге ара. *Йә, ничек соң, Агыйдел буйларын күреп, күңелең хушландымы?* Р.Ишморат. *Тау итәгендәге бүген урылган арышны кичә күреп киткән идем, --- бу башы кичә үк балавыз хәлендә иде. Ә иртәгә бөтен буе шулай булачак.* Г.Гобәй. *Амазонка буйларында «такейра» дигән гаҗәеп кабилә яши.* Татарстан яшьләре

5) *кыек форм.* Якын-тирәсендәге, янәшәсендәге, янындагы, чиктәш. *Тозны, бричкага, арбага төяп, --- Идел буендагы Владимир пристанена илткәннәр.* А.Муранов. *Уразбайга, төп нигезебез исәпләнгән шушы тау буендагы өйгә кайтып, өстәл янында бераз юангач, күңел күзләрем белән дә күрергә тырышып карарга өйрәнгән ике урыным бар.* Р.Ишморат. *Инеш буендагы талларга хәтле, яфракларын коеп, сусызлыктан көйрәп утыралар.* К.Нәҗми

6) Нәрсәнең дә булса өстендә, нинди дә булса җирлектә сузылып киткән сызыкларның, төсле эзләрнең, бизәк юлларының эзе. *[Кыйналган картның җилкәсендә] Ике буй булып, камчы эзе каралып ята иде.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Билгеле бер үлчәм озынлыгында булган. *Миңа кысалык ике буй дүрәл генә кирәк булыр.* Т.Мөбарәков

2) Озынлык белән бер юнәлештә булган. *Ул [барабанлы җыйгыч] ике буй борыс ярдәмендә комбайнның ургычына беркетелә.* Урып җыю машиналары. *Судан чыгарып, киптерергә таратып салганнар иде, ике буй мунчаланы, кәчтүн эченнән биленә урап, алып кайтып китте.* Ф.Сафин

3) Сузылып-озынаеп торган, озын; биеклеккә таба үскән (сабаклар, кәүсәләр һ.б.ш. турында). *Буй камышлар, буй курайлар җиргә бөгелеп сындылар.* Н.Исәнбәт

4) *махс.* Тукыманың озын якка сузылган җепләре; *киресе:* **аркау**. *Чалбарны кискәндә, тукыманың буй җебе арт һәм ал як ятрыларының уртасыннан уза.* Йорт эшләре

◊ **Буй бирмәү** Буйсынмау, санламау, күнмәү. *Сәлмән карт йортка буй бирмәс бу «малай актыгы»ның мондый сүзләрен, башта, колак яныннан игътибарсыз уздырырга тырышып йөрде.* Ф.Хөсни. **Буй бөгү** Бил бөгү, буйсыну, түбәнчелек күрсәтү. *Пугачау патшаны күрсә идең, Алларыннан буй бөгеп узса идең.* Җыр. **Буйга җитү** *сир.* Гәүдәгә, буйга үсеп җитү. *[Габбас] Кече яшьтән, үзебезнең фәкыйрьлек аркасында, дөньяның рәхәтен күрмәде. --- буйга җитә башлагач, авыр эшкә чумды.* Ш.Камал. **Буйга узу** Йөкле булу. *Бертөрле дә авыруың юк синең. Син бары буйга гына узгансың, кызым, буйга.* А.Шамов. **Буйга һәм аркылыга** Бик җентекләп, бөтен нечкәлекләренә дә игътибар итеп. *Маркс белән Энгельс, һәркайсы, – философия тарихын буйга һәм аркылыга өйрәнеп чыккан галимнәр.* К.Гыйззәтов. **Буй җиткезү** *к.* **буй җитү.** *Буй җиткезеп килә торган яшь кыз бит, әллә нәрсәләр булуы бар...* Г.Гыйльман. **Буй җиткерү** *к.* **буй җитү.** *Кызың буй җиткерә, аңа да бирнәлек акча хәстәрләрсең.* Н.Гыйматдинова. **Буй җитмәслек** Тиңләшү мөмкин булмаган, зур бөеклеккә ирешкән. *Аяз ага – минем өчен, гыйбрәтле язмышы белән дә, олы иҗаты белән дә, буй җитмәслек илаһи шәхес.* Р.Вәлиев. **Буй җитү** 1) Үрелгәндә, кул җитәрлек булу. *Габдулла верстак өстенә менеп басты һәм шүрлеккә үрелде. Юк, болай гына буй җитәрлек түгел икән.* Ә.Фәйзи; 2) Мөмкинлеге булу, көч җитү; берәр нәрсәгә, максатка ирешергә көченнән, хәленнән килү. *– Егет бит бу, – диде начальник, хатынына Сәлимне мактарга тотынды. – Ләкин политбүлек бүләгенә буйлары җитмәде менә.* Г.Гобәй; 3) Балигъ булу, җитлегү. *Газизә буйга җитте инде.* Ә.Фәйзи. *Кызык кына сүзләр дә булгалап ала, кайчакта, ана белән буй җиткән кыз арасында.* Ф.Хөсни. **Буй тарту** Гәүдәгә, озынлыкка кинәт үсеп китү. *Шул бер-ике ел эчендә Айсылу, буй тартып, үсеп китте.* Н.Исәнбәт. **Буй үстерү** Гәүдәгә, буйга үсеп җитү. *Бер егетне карата алмый Буй үстермәм, кыз булып.* Г.Ибраһимов

**БУЙ** II *и. голл.* Сай яки балыкчы ятьмәләре салынган урынны күрсәтү өчен куелган калкавыч. *Буйга хәтле йөзү*

**БУ́Й-БУЙ** *с.* Берәр өслек, тукыма һ.б.ш. өстендә берничә рәт булып сузылган, буй сызыклы бизәк юллары булган. *Өстәлләрем – буй-буй такта, Гөлләрем урам якта. Якты йолдызларга карыйм, Сине сагынган чакта.* Җыр. *Суфия күз яшен сөртә, ә битендә буй-буй кара эз сызыла.* Н.Гыйматдинова. *Фәтхетдин өстенә саргылт буй-буй коленкордан теккән пинҗәк, шакмаклы чиста күлмәк кигән.* Р.Хафизова

**БУ́ЙВОЛ** *и. лат.* Партояклылар отрядына караган күшәүче эре хайваннар ыругыннан, кыска аяклы һәм кыска муенлы, зур башлы хайван (Кавказда эш үгезе буларак үрчетелә). *Мөгезлеләрдән иң озын мөгез – Һиндстанда яшәүче буйволда.* Р.Фәизов. *Әмма, еш кына, буйвол да аның үзен мөгезенә күтәреп ала һәм җиргә китереп кыса.* Кызыклар дөньясында

**БУЙДАК** *с.* **1.** Әле гаилә кормаган, өйләнмәгән, гаиләсез, ялгызак. *Ләкин аны Әсфан исемле буйдак егет коткарып кала.* Ә.Мотыйгуллина

**2.** *и. мәгъ.* Өйләнмәгән ир-ат. *Димәк, ул янәдән карт буйдак булып калды.* Т.Галиуллин. *Буйдакларның хәзер бездә базары зур.* М.Кәрим

**3.** *рәв. мәгъ.* Өйләнмичә, өйләндермичә. *Егет кешене озак буйдак йөртү дә килешми.* Ф.Сафин. *Апабызның улы Мансур һаман буйдак булып йөри иде.* Сөембикә

**БУЙДАКЛЫК** *и.* Буйдак булу, гаиләсез тормыш. *Яшь килен белән яшь кияүләрнең кайберләре буйдаклык рәхәтен җуйган беренче көннәрендә үзгәреп, аптырап киткәнне күргән дә бар.* Казан утлары

**БУЙДА́Н-БУЙГА** *рәв.* Бер баштан икенче башка кадәр; бөтен озынлыкка. *Болары урманны буйдан-буйга буразналап үткән.* Г.Хәсәнов. *Бу кортлар агачны ашап, аның эченә керәләр һәм,*

*еш кына, агачта буйдан-буйга озын кәкре юллар ясыйлар.* Йорт эшләре

**БУЙЛАП** *бәйл.* 1) *к.* **буенча** (*1–3 мәгъ.*). *Ул, төзелеш идарәсенә килеп керүгә, гөрелдәтеп аваз сала, кабинетлар буйлап, пышылдау китә: «Хәтамтаев килде... Хәтамтаев үзе...»* М.Галиев. *Насретдинны алып киткән көнне, аналы-уллы күршеләренә керделәр, авыл буйлап йөрделәр.* Т.Миңнуллин. *Аны мир буйлап эзләп интекмәс бит инде, янында гына син тыпыр-тыпыр биегәндә.* Н.Гыйматдинова. *Карап йөрим кораб буйлап, сөйләшеп утырыр кеше юк.* Ә.Хәбибуллин

2) Яныннан, кырыеннан, янәшәсеннән, буеннан. *Уң якта стена буйлап, уң һәм арт як диварга беркетеп, киң сәке ясалган.* Ф.Бурнаш

**БУЙЛАТА** *бәйл.* 1) *к.* **буенча** (*1–3 мәгъ.*). *Бөдрә яфраклы тал-тирәк һәм анда-санда чәчелгән балан агачлары арасыннан сузылган үләнле сукмак буйлата берникадәр барганнан соң, Фәтхи сөзәк елга кырыена барып чыкты.* Ш.Камал

2) Яныннан, янәшәсеннән, кырыеннан. *Бәрәңге кыры буйлата бер егерме-утыз адым баргач, Миңсылуларның өе.* Г.Минский

**БУЙЛАТЫП** *бәйл.* 1) Буйга таба юнәлештә; буйлап. *Ефрейтор, дамба буйлатып, кәкре адымнар белән карышлап, теге якка чыга һәм иңенә аскан автоматын күтәреп бер болгый да «Старт!» дип аваз сала.* А.Тимергалин

2) Нинди дә булса әйбердән, җайланмадан файдаланып, шуның ярдәмендә; белән, аркылы, аша. *Җаны күтәрә алмастай кичерешләрен дә ул толымнары буйлатып җиргә тапшыра сыман.* К.Тимбикова. *Елганы басма буйлатып чыктым*

3) Яныннан, янәшәсеннән, читеннән, кырыннан. *Кайберләре, сихерләнгән шикелле, койма буйлатып [Әхмәт] артыннан баралар: – Инде дә үзәкләрне өзә, инде дә йөрәкләрне телгәли шул моңнары белән, – диләр.* Г.Бәширов. *Партизаннар шуны гына көтеп торганнар икән, тау буйлатып, эшелонга ата башладылар.* Р.Мостафин

**БУЙЛА́У** *ф.* 1) Бер баштан икенчесенә таба бару, буй юнәлешендә үтү. *Буй белән су буйламыйлар.* Мәкаль. *Су буйларын ничә буйладым, Бирим, диеп чәчәк бәйләмен.* Җыр. *Озак-озак, тауар кибетләрен буйладым.* Н.Гыйматдинова

2) Сулыкның тирәнлеген – баскан килеш, ә тирән урында, чумып, буй белән чамалау. *Янә китә идек уйнарга, Йә җиләк җыярга, йә урманга, Йә Уралга, суын буйларга.* М.Фәйзи

3) *махс.* Буй юнәлешендә нәрсә булса да тоту, беркетү, буй итеп тегү. *Тәрәзә төбем – роза гөл, Лента белән буйлыймын.* Җыр

4) Тоттырмыйча, буйсынмыйча чабу. --- *бераз юантыграк Зариф калыша башлый. Алай да, сер бирәсе килмичә, «ат буйлады» дигән булып, кырыйга чабып кереп китә, ягъни аты хуҗасына буйсынмаган, янәсе.* Р.Әмирхан

**Буйлап бетерү** Буй юнәлешендә үтүне төгәлләү, ахыргача буйлау

**Буйлап кую** Алдан ук буйлау

**Буйлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр буйлау

**БУЙЛЫ** *с.* 1) Буй сызыклары булган; буй-буй. *Әнә шул буйлы материалдан бер чалбар белән бер пинҗәклек бирергә кирәк аңа.* Ш.Маннур

2) Алдында килгән сүзләр белән, озынлыкта, буе шуның кадәр, дигән мәгънә белдерә. *Ак күлмәктән, каратут йөзле, уртача гына буйлы, имәндәй таза гәүдәле бер егет, тәрәз буена утырган җиреннән, тирә-якны күзәтеп уйга талган.* Н.Хәсәнов. *Тирән чанага утырып, нindидер бер озын гына буйлы кеше белән бергә, Габдулланың әнисе килеп төште.* Ә.Фәйзи. *Кыска буйлы кеше үҗәт була, дия иде күрше.* М.Галиев. *Җиңел, җыйнак гәүдәле, кечерәк буйлы, түгәрәк йөзендә балалык алсулыгы һәм чисталыгы сакланган утыз тирәләрендәге кеше иде бу.* М.Маликова

3) Озын гәүдәле, буйчан. *Ул, буйлы булса да, кайбер кинәт үсеп киткән кызлар кебек, котсыз сузан, юка кыз түгел иде.* А.Гыйләҗев

**БУЙЛЫГЫ** *бәйл.* Баш һәм иялек килешендәге сүзләр белән килеп, шул озынлыкта, буе шуның кадәр, дигән мәгънәне белдерә. *[Шүрәленең] Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.* Г.Тукай

**БУЙЛЫЙ** *бәйл. к.* **буенча.** *Тукай бу мәгълүматны --- бүлмә буйлый әрлебирле йөренеп бәян итте.* Р.Батулла

**БУЙЛЫК** *и.* 1) Төзелештә: буйга салырга яраклы, буе белән шуңа туры килгән материал (агач, борыс һ.б.). *Манара үзгенә дигән агачботаксыз кара чыршы, йә булмаса төз нарат булсын, ди. Дүрт буйлык агачны каян табасың тиз генә.* М.Мәһдиев

2) Тукыма тукуда: буй җебе; *киресе:* **аркаулык**. --- *чәпер – аркавы калын, буйлыгы нечкә тукыма.* Р.Әхмәтьянов

**БУЙЛЫ́-СЫНЛЫ** *с.* Килешле, төз гәүдәле, гадәттә озын буйлы. *[Ул кеше] Үзе сүзгә йомшак, буйлы-сынлы гына картрак сәүдәгәр икән.* М.Гали

**БУ́Й ПЫЧКЫ** *и.* Буйга (такта) яра торган пычкы

**БУ́Й-СЫН** *җый. и.* Килеш-килбәт, тышкы кыяфәт, гәүдә. *Директор буйсыныма тагын бер мәртәбә текәлеп карады.* Н.Гыйматдинова. *Буй-сыны сылу булган кешене әллә каян күреп аласың.* Сөембикә

**БУЙСЫНУ** *ф.* 1) Берәүнең хакимлеге астында булу, аңа баш ию, хөкеменнән чыкмау; куелган таләпләрдә, шартларда, кысаларда яшәү. *Каһәр суксын бу буйсынып яшәүне!* Ш.Маннур. *Кем дә кем әмеремә буйсынмый, ачлыктан тәгәрәп үләчәк.* Н.Гыйматдинова

2) Нәрсәгә дә булса бәйле булу яки бәйле хәлгә төшү. *Шулай да, баш очында «кулак улы» дигән домокл кылычы эленеп торуга карамастан, әти, еш кына, карарларны идеологиягә буйсынып түгел, ә халыкка яхшы булсын, дип кабул итте.* М.Шәймиев. *Инде үземне «җүләр» дип әрләүләрдән дә арыдым һәм, тәкъдиремә буйсынып, тып-тын гына яраттым.* Н.Гыйматдинова. *Күк гөмбәзе, ни гаҗәп, табигатьнең җәйге кануннарына буйсынмыйча, бозлы яңгыр яудыра иде.* Н.Гыйматдинова

3) Кемнеңдер яки нинди дә булса оешманың һ.б.ш.ның турыдан-туры җитәкчелеге астында булу, рәсми рәвештә аның карамагында тору. *Югары*

*Авыл, Сазтамакларның һәрберсендә үз советлары бар иде. Алар сиңа [Кариле авылы советына] буйсынмый иде.* Э.Касыймов

4) Кемнең дә булса хөкеменә, ихтыярына яки нәрсәнең дә булса иркенә бирелү. *Аның бу куркак хатынга буйсынырга исәбендә дә юк иде.* Н.Гыйматдинова. *Ибәт Атабаевичка буйсынмау, тәвәккәллегенә сокланмау мөмкин түгел.* М.Галиев

**Буйсына бару** Торган саен ныграк буйсыну, акрынлап буйсыну. *Аит, берничә минуттан теше сызлый башлаячагын сизеп торган кеше кебек, арыну чарасы булмаган курку тойгысына буйсына барганын тоеп алды.* Ә.Гаффар

**Буйсына башлау** Буйсыну билгеләре күренү. *Ахыр килеп, күпсанлы шивәләр, диалектлар, сөйләшләр ике төп полюс – борынгы болгар теле һәм борынгы татар теле нормаларына буйсына башлаганнар.* Р.Әхмәтьянов

**Буйсына төшү** Берникадәр, бераз буйсыну

**Буйсынып бетү** Тәмам, тулысынча буйсыну. *Саулыгы ташып тормаса, Чыңгызхан, җитмеш ике яшендә, Кытайның аңа буйсынып бетмәгән өлкәләрен яуларга походка чыгып китмәс иде.* А.Хәсәнов

**Буйсынып йөрү** Һәр урында, һәрвакытта буйсыну. *Мин гел ниндидер программага буйсынып йөрергә, гел аерылырга, гел китәргә тиеш.* М.Мәһдиев

**Буйсынып калу** Ниндидер моменттан, сәбәптән соң буйсыну. *Седовның «Фока» исемле корабын бозлар кысалар ---. Седов аларга буйсынып калмый, киртәләргә карап тукталмый.* А.Алиш

**Буйсынып килү** Һәр очракта, электән үк даими буйсынган булу. – *Сез моңарчы Мусаның һәрбер фәрманына буйсынып килдегез, инде, зәкят дип, ул сезнең малларыгызны алмакчы була, сез нишләп торасыз? – диде.* Ж.Зәйнуллин

**Буйсынып тору** Һәрвакыт, гел буйсыну. *Синең белән тора башлавына ике-өч ай да узмаган, беткәнче сиңа бирелеп, буйсынып торган хатыныңнан шикләнә дә башла, имеш!* Ә.Еники

**БУЙУРМАН** *и.* Нинди дә булса рельефка карата буе белән утыртылган урман полосасы. *Бу очракта, буйурманнар рельеф таләбен исәпкә алып утыртылган булалар.* Татарстан

**БУЙЧА** *и.* Берәр җирлек өстендә буй юнәлешендәге кыска сызык бизәк, кыска-кыска, юл-юл бизәкләрнең берсе; кыска гына буй. *Бизәкле буйчаларны, бизәксез соры буйчалар белән чиратлаштырып, култык уемына таба 15 сантиметр бәйлиләр.* Йорт эшләре

**БУЙЧАН** *с.* Озын буйлы. *Каратуткыллы, зур күзле, буйчан һәм шаян сүзле шул Фәрит аңа барысыннан да күбрәк ошый иде.* Ә.Салах

**БУКЕТ** *и. фр.* Чәчәк бәйләме. *Үсемлек үскән урыннарда көтү йөртү һәм чәчәкләрне, күпләп, букетларга җыю сәбәпле, алтын туй чәчәге – сирәгәеп бара торган төр.* Л.Мәүлүдова

**БУКИНИСТ** *и. фр.* Борынгы, күптән басылган һәм сирәк очрый торган яки кемнең дә булса файдалануында булып, шуннан алынган китаплар белән сату-алу итүче. *Теге йолдызлы түрәнең китапларын әллә кайчан инде букинистка илтеп биргәнбез, аның әсәрләре басылган «роман-газета»ны билгеле инде, макулатурага тапшырганбыз.* М.Мәһдиев. *Ул кунагын кабинетка чакырды, күптән түгел генә букинистлардан сатып алган, сирәк очрый торган китапларын күрсәтте.* Г.Әпсәләмов

**БУКЛЕ** *и. фр.* Өске ягы вак кына бөрчекләр белән кабарып торган тукыма

**БУКМЕ́КЕР** *и. ингл.* Ярышларда тотализаторга куелган акчаларны җыеп алучы

**БУКМЕ́КЕРЛЫК** *и.* Букмекер вазифасы, букмекер эшчәнлеге. *Тагын бер ел яшәгәннән соң, ике көн элек, британияле букмекерлык конторасыннан 5 мең фунт белән кайтып киткән.* Ватаным Татарстан

**БУКСИР** *и. голл.* **1.** Тагып яки этеп йөртә торган үзйөрешле судно. *Идел белән Камада купец Стахеевның икмәк баржаларын тартып йөргән бу буксирны мин бик яхшы беләм.* С.Сабиров. *Кырмыскадай тырыш, көчле буксир зур корабны пирслар арасыннан порт уртасына сөйрәп чыгарды да борынын ак маяк ягына каратып борып куйды.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* 1) Су транспортын, йөзмә корылмаларны һ.б.ш.ны тагып йөртә торган (суднолар турында). *Ә без затонда буксир пароходларны сугыш корабларына әйләндерәбез, броня белән ныгытабыз, туплар, пулемётлар белән коралландырабыз.* С.Сабиров

2) Төзеклеген югалткан коры җир транспорты машиналарына ярдәм күрсәтә, аларны тагып сөйри торган. *Буксир машина*

◊ **Буксирга алу** Эштә артта калучыларга ярдәм итү, ярдәмгә килү. *Башта, безне узып китмәсеннәр, дип тырыштык, тырыштык та, инде, алар артка калгач, буксирга алабызмы?* Р.Ишморат

**БУКСИРЛА́У** *ф.* Буксирга тагып тарту

**Буксирлап бару** Һәрберсен, булган берсен буксирлау

**БУКЧА** *и. гади с.* Киндердән, күннән теккән сумка. *Мин, кыршылган буш букчамны селки-селки, вак, ач башаклы арыш арасы сукмакларын үтеп, авылдан-авылга йөрим.* А.Гыйләҗев. *Букча аскан теләнче карт, көртләр ерып, Айга карап юл бара.* Р.Фәйзуллин. *Ул аңа киндердән әйбәт букча да тегеп бирде.* М.Маликова

**БУКЫ́Й-СУКЫЙ** *с.* Кирәксез, әһәмиятсез, дәрәҗәсе түбән булган. *Беркем дә юк монда букый-сукый, Барсы – даһи, барсы – генийлар.* Л.Лерон

**БУЛА** *бәйл.* Үзе бәйләп килгән сүз сәбәбендә, шуның нәтиҗәсендә, максатында, мәгънәсен белдерә; аркасында, белән, өчен. *Шушы һөнәренә була шәһәрнең теләсә кайсы клиникасында «Рәхим ит!» дип торуларын күргәч, Шәрәф әтисенең чыннан да акыллы киңәш биреп калдыруын тагын бер кат аңлады.* Г.Минский

**БУЛА́ВКА** *и. бор. слав.* Тукыманы кадап, эләктереп кую өчен, нечкә тимерчыбыктан бөгеп эшләнгән, бер очы – очлы энәдән, икенчесе каптырмалы йозактан гыйбарәт эләктергеч әсбап (йозагы бизәкле булырга да мөмкин). *Булавкадан җиң күзләрен*

*энгә күчерәләр дә, оек бәйләме белән, 35 сантиметрлап, түбән таба бәйләп төшәләр.* Йорт эшләре

**БУЛАНУ** *ф.* 1) Пар бөркү, пар чыгарып тору. *Ә тәлинкәләрдә инде дәү әнинең, мул итеп май салган, бераз шикәрләгән ак боткасы булана.* М.Рәфыйков. *Кышкы авыр йокыдан соң әкренләп уяна барган җир булана, юл кырыйларында умырзая башын калкыта, агачлар бөреләнә...* Г.Әпсәләмов

2) Парлану, пар тамчыларыннан дымлану. *Тәрәзә пыялалары буланган.* Ш.Камал. *Көннәр кызу, ә безнең өстәге киемнәр авыр, респиратор аркылы суларга һава җитми, күзлекләр булана.* Ә.Салах

**Булана бару** Торган саен ныграк булану

**Булана башлау** Буланырга тотыну

**Булана төшү** Беркадәр булану

**Буланып бетү** Тәмам, бик нык булану

**Буланып калу** Нинди дә булса сәбәп белән буланган хәлгә килү. *Яңгыр явып үтте, җир җәйгедәй буланып калды.* Ш.Галиев

**Буланып китү** Азрак булану

**Буланып тору** Әле, күз алдында бу чыгару. *Бәрәңгеләр, табак тулып, буланып торалар.* Г.Ибраһимов. *Буланып торган бәрәңге өеме безнең алга килеп басты.* М.Кәрим

**Буланып чыгу** Кинәт бу барлыкка килү

**Буланып яту** Әле, сөйләү моментында бу чыгарып тору. *«Диңгез күзе» инде бу. Аны бөтен авыл шулай дип йөртә. Ул, кечкенә булса да, кыш буе катмый, гел буланып ята.* Г.Бәширов

**БУЛАТ** *и. фар.* **1.** Югары сыйфатлы корыч. *Булатлары ялтырасы чакта, Җир сарысы өстә тирбәлде.* К.Булатова

**2.** *с. мәгъ.* Шул корычтан эшләнгән. *Ә ул аждаһаны һични белән дә җиңмәле түгел, ди. Безнең авылның батырлары, булат кылычлар тагып, менеп-менеп карадылар инде.* Ф.Яруллин

**БУЛАЧАК** *с.* **1.** Булу-булмавы алдан билгеле булган; нәрсәгә булса да әзерләнгән. – *Энем җаным, булачак ул яңа фатирыңа мин дә сыя алмам микән? – диде ул.* Р.Вәли. *Булачак филологлар, иң борынгы төрки текстларны уку, тәрҗемә итү процессында, тарихи-чагыштырма анализ элементлары белән таныша.* Ф.Нуриева

**2.** *и. мәгъ.* Киләчәк, туар вакыт. *Ышанычым арта минем, Үз-үземә өмит белән карый башлыйм булачакка.* Г.Тукай

**БУЛГАН** *с.* Эшчән, уңган, булдыклы; җитез, эшне тиз башкара торган. *Булмаган – атасыннан тумаган.* Мәкаль. *Киленегезнең сеңлесе нинди нәрсә? Төскә-биткә чибәрме? Яхшы, булган нәрсә микән?* Г.Камал. *Аналары булган да соң иде инде, әйләнеп карарга да өлгермисең – табын тулы ризык.* Сөембикә

**БУЛГАНЛЫК** *и.* Эшлеклелек, булдыклылык. *Очрашуның шатлыгыннан аңа Юлдаш була уңган, булганлык. Мәкер-көнчелектән өстен торган, Нинди бөек нәрсә – туганлык!* Ф.Чанышева

**БУЛДЫК** *и. сир. гадәттә тартымлы форм.* Булдыклылык, бар булган сәләт. *Бариев, үзенчә, Баязитовның бар булдыгын сөйләп китте.* Б.Камалов

**БУЛДЫКЛЫ** *с.* **1.** Эшлекле, сәләтле, уңган. *Татарның булдыклы егетләре бер-берсен таптый, изә.* Ф.Сафин

**2.** *и. мәгъ.* Нинди дә булса сәләткә ия кеше. *Булдыклылар заманы хәзер, бүректәш.* Н.Гыйматдинова

**БУЛДЫКЛЫЛАНУ** *ф.* 1) Булдыклы булып кылану, үзеңне булдыклы итеп күрсәтергә тырышу

2) Булдыклы булып китү

**Булдыклылана бару** Торган саен булдыклылыгы арту

**Булдыклылана төшү** Беркадәр булдыклылану

**Булдыклыланып китү** Кинәт, соңгы вакытта булдыклылану

**БУЛДЫКЛЫЛЫК** *и.* Булганлык, уңганлык, эшлеклелек. *Сабыр акыл белән булдыклылык, үз дигәненә ирешү кебек сыйфатлар – егеткә әбисе белән олатасы тарафыннан калдырылган олы мирас.* Я.Зәнкиев

**БУЛДЫКСЫЗ** *с.* **1**. Эш рәтен белмәгән, булдыра алмый торган, эшкә сәләтсез, кулыннан эш килмәгән. *Мин үзем, заманында, булдыксыз кеше түгел идем. Кулымнан килмәгән эш юктыр.* С.Сабиров

**2.** *и. мәгъ.* Кулыннан эш килми торган кеше. – *Булдыксыз, дип, каенанам җелегемне киптерә инде-е-е, – дип үкерергә тотынды.* Н.Гыйматдинова. *Күпме әрәмтамакны, булдыксызны, бушбугазны алып ташларга булышты минем язганнарым.* Г.Ахунов. *Сөенәмен дусларым күпкә, Булдыксызның булмый дуслары. Сөенәмен дошманым күпкә, Мескеннәрнең булмый дошманы.* Ф.Яруллин

**БУЛДЫРУ** *ф.* 1) Барлыкка китерү, тудыру, иҗат итү, эшләү; ясау; тормышка ашыру, үтәп чыгу. *Булдырган да – хатын, бөлдергән дә – хатын.* Мәкаль. *Көчле гаскәр булдырып, тәхеткә үзегезнең шаһиншаһны утыртып кую урынына, менә нинди хәлгә төштегез, ә?* Б.Рафиков

2) Нинди дә булса эшне үти алу мөмкинлеге булу, көч, сәләт, булдыклылык җитү. – *Рәхмәт, апайлар, булдыргансыз, – диде ул.* Х.Сарьян

3) Өлгертү, әзерләп җиткерү. *Ул, самавырын тизрәк булдыру өчен, ашыгып чыгып китте.* А.Расих. *Аш булдыру. Мунча булдыру*

**Булдырып бару** Һәммәсен рәттән булдыру

**Булдырып бетерү** Барысын да булдыру, үти алу. *Баһманны алыштырырга хыялланучы егетебез дә бар... Булдырып бетерә алмыйбыздыр, билгеле, ләкин омтылыш бар.* Ф.Баттал

**Булдырып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә булдыру. *Эшне алып бара алуыма шикләнмим. Иң кыены – үзеңнең уйларыңны «подпольеда» тоту. Шунысын булдырып җиткерүемә ышанып бетмим.* Х.Камалов

**Булдырып йөрү** Әле, сөйләү моментында нинди дә булса эш белән мәшгуль булу. *Абыең күптән мунча булдырып йөри.* Д.Бүләков

**Булдырып калу** Нинди дә булса вакытка, эшкә кадәр булдырырга өлгерү. *Кулың көчле икән – эш булдырып кал, Бу күңлемнең чәреген сындырып ал.* Котб

**Булдырып карау** Булдырырга омтылу. *Ләкин, булмый, кулымнан килми,*

*дигәнгә генә тормыш җайланмый бит. Булдырып карарга кирәк.* М.Кәбиров

**Булдырып килү** Аз-азлап, акрынлап булдыру. *Беркөнне Әпсәләмов, гаҗәпләнеп: «Маһинур апа, булдырып киләсез бит, байтак киметкәнсез», – дип шаяртты.* М.Фәйзуллина

**Булдырып кую** Алдан ук булдыру. *Балалар мәктәптән кайтып җиткәнче, ашны булдырып куярга кирәк.* Г.Камал

**Булдырып тору** 1) Һәрвакыт, гел булдыру. *Ә шатлыклы хисләр кеше өчен турыдан-туры ләззәт чыганагы булдырып тора.* К.Гыйззәтов

2) Әле, хәзерге вакытта булдыру. *Ул инде [шкаф белән бүленгән ара квартирада] прихожийны булдырып тора.* К.Гыйззәтов

**Булдырып чыгару** Ахырына кадәр булдыру, эш сәләте, булдыклылыгы җитү. *Шул өстләренә алган эшне матур иттереп булдырып чыгаруны бөтен күңелемез берлән телимез.* Г.Исхакый

**Булдырып чыгу** Булдыра алу, ахырына кадәр эшләргә көче, сәләте җитү. *Кайсыдыр командир сугышчыларын атакага күтәрә алмый. Тагы Мамакка кушалар. Булдырып чыга.* Х.Камалов. *Шуны булдырып чыксаң, бурычның мөһимлеген истә тотып, үзеңә, беренче чиратта, диңгез буена юллама булыр...* Р.Мирхәйдәров

**БУЛКА** *и. пол. сөйл.* Бодай онынnан пешерелгән озынча яки түгәрәк күмәч. *Күрсәң иде, Ибраһим, бөтен булка. Күңел хакы өчен тешләп тә, кабып та карамаганнар.* А.Шамов

**БУЛМАГАН** *с.* **1.** Кулыннан эш килмәгән, булдыксыз, уңмаган, эшкә сәләтсез, җебегән. *Абзый! Абзый! Булмаган син, пешмәгән, Корсагың үскән, ә гакылың үсмәгән.* Г.Тукай

**2.** *и. мәгъ.* Кулыннан эш килмәгән, булдыксыз кеше. *Җыен булмаган, җыен җебегән безнең трестка җыелган. Соң, шул плитәләрне дә кайтарта алмагач, ник йөрисең монда җил куып?!* Казан утлары

◊ **Булмаганны болгату** Юкны бар итеп күрсәтеп, шаулап йөрү, юкны сөйләү. *Куй әле, зинһар, Габделкави, булмаганны болгатма.* Казан утлары

**БУЛМАС** *с.* Тормышка ашмый торган, ышанычсыз, өметсез. *Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр.* Г.Тукай

**БУЛУ** *ф.* **1.** 1) Чынбарлыкта, вакыт һәм пространствода урын алып тору. *Җеннәр төнге сәгать уникегә хәтле богауда булалар.* Татар мифлары. *Дөньяда ничә җан булса, шунча йөрәк, шунча табигать бар; һәм шунча теләк вә әмәл бар.* Г.Ибраһимов. *Шул җыр булмаса – җирдә беркайчан да Таһир Зөһрәне яратмас иде.* Р.Әхмәтҗанов. *Менә нәрсәне истә тотарга кирәк: һәркем үз урынында булсын.* И.Гази

2) Берәүнең милке, байлыгы саналу, аның карамагына керү, файдалануында тору. *Әлтафи – класста иң зур малай, аның кесәсендә һәрвакыт чакматаш белән филтә һәм бакчада үстергән яшел тәмәке булыр.* М.Мәһдиев. *Хөррият булгач, эшлисе килми, Ашыйсы килә, дустым.* Г.Афзал. *Чикерткәнең биш баласы була – өчесе малай, икесе кыз.* Ә.Еники. *Бүлмәнең булу-булмавын белү максатыннан, кичке җидегә кадәр тулай торак ишек төбендә утырдык.* Татарстан яшьләре // *юн.* *килешендәге тәмамлыктан соң* Берәүнең карамагына, милкенә күчү. *Өзелеп сөярмен, Үземә булсаң гына.* Җыр

3) Кемдер сыйфатында яшәү, тору. *Кыскасы, җыр, көндәлек тормышта турылыклы юлдаш буларак, авыл халкын военкомат ишегенә кадәр озатып куя иде.* М.Мәһдиев. *Балаларга – йомшак, ягымлы, кирәгенчә таләпчән һәм каты куллы ана, иренә игелекле һәм тугры хатын була белде...* Ф.Латыйфи

4) Табылу, килеп чыгу; мөмкинлек, шартлар туу

5) Барлыкка килү; хасил булу; ясалу. *Анда җиләк тә булмый иде.* М.Мәһдиев. *Яктылык барда – биеклек күләгәсез булмый.* М.Әгъләмов

6) Үсү, уңу (иген һ.б.ш. турында). *Бөтен сынамышлар буенча, уңыш мул булырга тиеш иде – халык, җиң сызганып, кыр эшенә тотынды.* М.Мәһдиев // Яралу, туу, үсеп чыгу

7) Әзерләнеп бетү, өлгерү // Өлгереп җитү, җитлегү

8) Булып узу, фактка әйләнү. *Шәяхмәтнең беренче кат өйләнүе ундүртенче елда булды.* М.Мәһдиев

9) Җитү, килү, туу (ел фасыллары, көн-төн турында). *Иртә булды, [алар атка] атландылар.* М.Госманов. *Әллә соң, мин йоклаганда, кыш була башлаганмы?* Г.Галиев

10) Тулу; үтү. *Ул арада, балага биш яшь ярым була.* Г.Гобәй

11) Барып чыгу, уңышлы тәмамлану. *– Булмый, – диде, чырылдавык тавыш белән, Бикташов. – Булдыра алмыйм.* А.Гыйләҗев. *– Булды бу! – диде Шәймәрдән агай, эченнән генә кәефләнеп ---.* Ә.Еники. *– Булды болай булгач, – диде Нигъмәтулла абзыкай, сүзне тизрәк бетерәсе килеп.* Ә.Еники

12) Үтәлү, гамәлгә ашу. *Исемлек тикшерү менә болайрак булды.* М.Мәһдиев. *Булмады, бәхет булмады.* М.Мәһдиев

13) Үткәрелү-оештырылу, үтәлү-башкарылу. *Бу арада митинг буласы бит.* Г.Коләхмәтов. *Җыелыш була, Газзәгә байрак тапшырасы бар.* С.Баттал. *Елмаерга тырыштык, булмады.* М.Мәһдиев. *Аның дәресе дүшәмбедә беренче сәгать булганлыктан, соңга калучылар да, йоклап утыручылар да була.* М.Мәһдиев // Игълан ителү, белдерелү, әйтелү // Бирелү (рөхсәт һ.б.ш. турында). *Мин инде, әни, әгәр сезнең рөхсәтегез булса, быел --- өйләнергә, диебрәк йөри идем.* Г.Бәширов

14) Барып-килеп җитү, ишетелү, әйтелү (сүз, хәбәр, яңалык, хат һ.б.ш. турында). *Мөселманнар җыелышына кереп, җәнҗал куптарган Абдул икәне мәгълүм булды.* Г.Ибраһимов

15) Берәр максат белән кайда булса да бару, кемгәдер керү. *Гомеремнең икенче яртысында мин бик ерак илләрдә булдым ---.* М.Мәһдиев. *Минем котыпта булганым юк, әмма папанинчыларга кабатланмас хөрмәт саклыйм.* А.Гыйләҗев // Катнашу. *Маслов губком бюросы утырышында булу сәбәпле, Һидият аны барган көнендә күрә алмады.* Ш.Камал

16) Вакытны белдергән сүзләрдән соң килеп, берәр җирдә шулкадәр вакыт тору яки үткәрү. *Без анда озак*

*тормыйбыз, ике, өч, күп булса – дүрт көн булырбыз.* Г.Ибраһимов

17) Әзерләнеп бетү (берәр җиргә бару, нәрсә дә булса эшләү өчен)

18) Чагыштыруны белдергән сүзләрдән соң килеп, сиземләүне белдерә; тоелу. *Коридор буйлап, электр тогы узгандай булды ---.* М.Мәһдиев. *Кыек авыз турында сүз кузгату Исәнтәйнең өстенә салкын су койгандай булды.* Н.Фәттах. *Шулай да, Әмин Буранбаевич, сез әйткән язгы боздай булса булыр, мин үз фикеремне үзгәртми торам.* Х.Сарьян

19) Тартымлы исемнән соң: тәэсир итү, йогынты ясау; тию. *Бар нәрсәсен төяп алып китсен. Соңыннан миңа бәласе булмасын.* Г.Камал

20) Чыгыш килешендәге тәмамлыктан һәм иясез җөмләдәге *-п, -рга, -са* форм. соң: эшли алу, булдыру, хәлдән килү. *Синнән булмаса, үзем сөйләшәм.* М.Мәһдиев. *[Клараның җиңгәчәсе:] Һи, мут күз, Иркә туташымны колхоз эшенә чыгарып имгәтер идеңме әллә? Булыр синнән, денсездән...* Ә.Еники, *Мондый товар белән хан сараена да, Казаннан көнбатыштагы башка мәмләкәтләргә дә үтеп кереп була.* Ф.Латыйфи

21) Һава торышы турында: яңгыр, кар яву; кояш яктырту һ.б. *Ничек инде караңгы була, дөнья аларныкы инде.* Ф.Әмирхан. *Икенче, өченче көнне дә тоташ яңгыр булды.* М.Мәһдиев

22) иярчен вакыт җөмләдә тартымлы исем фигыльдән соң килеп, бер-бер артлы барган вакыйга-хәлләрне атаганда: шунда ук, хәзер үк, дигән мәгънәне белдерә. *Үзе – бер карыш, сакалы биш карышның сикереп төшүе була, болар дөнья куптарып сугыша башлыйлар.* Әкият. *Егетләрнең җиргә сеңүләре булды, арыш өстен шаулатып, көчле җил исеп китте, һәм, яман үкереп, зур кара күләгә шуып узды.* Ә.Еники. *Шәмсинең сикереп менүе булды, атлар тагын элеп алып чаба башладылар.* Г.Бәширов

23) Иясез җөмләдә: җитте, җитәр, бетте, дигән мәгънәне белдерә. *Туй агасы: [Исламга] Булдымы? Җырлап бетердеңме? [диде].* Т.Миңнуллин

24) *юкл. форм.* Иясез җөмләдә: мөмкин түгел, ярамый, дигәнне белдерә. *– Алдама, – дип әйтә китап. – Алдамый булмый, – ди дөнья.* Г.Афзал. *Аңа хәзер кайнар аш кирәк, ансыз булмый.* Э.Касыймов

25) Диалогта, ким җөмлә сыйфатында килеп: риза булуны, килешүне белдерә; ярый, яхшы, эшләнер. *– Вәгъдәме? – Булды – вәгъдә!* Ә.Еники. *– Абдуллиннан [кымызны] кәрзине белән алып бир! – Була ул! – диде озын егет.* Ә.Еники

26) Чыгыш килешендәге исемнәрдән соң килеп, кисәтеп куюны, боеруны белдерә. *Үпкәләштән булмасын, үзе гаепле.* Ә.Еники

27) Инфинитив формадагы, *-макчы/-мәкче, -рга/-ргә, -асы, -мак/-мәк* формасындагы фигыльләр белән килеп, ниятләүне белдерә. *Шәяхмәт, тәмле тел белән, тынычлык урнаштырмакчы булды.* М.Мәһдиев. *Мине, кунак дип, түр өйгә яткырмакчы булганнар иде, ләкин мин туй мәҗлесе өчен шулкадәр тырышып юган-җыештырган җиргә кереп ятарга бер дә теләмәдем.* Ә.Еники. *Булатлар шунда, капка төбендә, аны көтәчәк булдылар.* Г.Ибраһимов. *Бөтенләй үк китеп барганчы, бикә үзләренең өйләре янына да сугылырга булды.* Н.Фәттах

28) *-нда, -да* формасындагы фигыль белән килеп: дәвам итү, дигәнне белдерә. *--- берни белми йоклавында булды.* Н.Фәттах

29) *-ырдай/-рдай* формасындагы фигыль белән килеп: чарасызлыкны белдерә. *Бик килердәй булырсың – без булмабыз.* К.Тинчурин

30) Киләчәк заман сыйфат фигыль белән килгәндә, зарурлыкны, кирәклекне белдерә. *Сөйсәң, ярның сөй матурын, Сөйгәч, аласы була.* Җыр // Катгый боеруны белдерә. *Хәзер үк саласы бул галошыңны!* К.Тинчурин // Боерык фигыльнең юклык формасында, катгый тыюны, кисәтеп куюны белдерә. *Күренеп йөрисе булма!*

31) Башка формадагы фигыльләр янында хикәяләүне белдерә. *Кырмыска оясына таяк тыгып бутар да китте барды булыр.* И.Гази. *Ул [Габдулла] агач заводында кара эшче булып тамак туйдыра булган.* Г.Ибраһимов

32) Билгесез үткән заман хикәя фигыль формасындагы фигыльләр янәшәсендә: юри генә эшләү, кылану, мәгънәләрен белдерә. *Ул, җиңелчә гаҗәпсенү белән, миңа караган булды.* Ә.Еники. *[Хәлил Шимаев] Кайткач, Мәрвәр ханымның ашын ашады, чәен эчте, нәрсәдәндер зарлануын тыңлаган булып утырды.* Ә.Еники. *--- имеш, зоология укытучысына корчаңгы йоккан, шуңа күрә, дәрес вакытында, сәгать караган булып, бер кашынып ала икән.* М.Мәһдиев

33) Шарт һәм хәл фигыльләрдән соң килеп: мөмкин, дигәнне белдерә. *– Табылдыкны бирсә дә була. – Була, ник булмасын.* Н.Фәттах. *Мәхәббәткә каршы нәрсә әйтеп була?* Ә.Еники

34) **булыр** *Икән* ярдәмче фигыле белән берлектә, ачулануны, гаҗәпләнүне белдерә. *Булыр икән бу хәтле дә теңкәгә тигән эсселек!* Ә.Еники

35) **булса** Үткән заман сыйфат фигыль янәшәсендә үкенүне белдерә. *Эшләнгән булса, мондый хәлгә төшмәс идек*

36) **булдымы** Эш-хәлләрне санаганда: әйеме, аңлашылдымы, шулай бит, дигәнне белдерә

37) Исем, сыйфатлар белән кушма хәбәр ясый. *«Җиңел» генә дигән эш шактый авыр булып чыкты.* М.Мәһдиев. *Бер көн эчендә басу ала-тилә булып калды.* М.Мәһдиев. *Аңа җылы, рәхәт булып китте.* Н.Фәттах. *Аннан, ир бала, әнисенең җылы канаты астында гына үссә, нечкә көпшә кебек зәгыйфь, йомшак, кыюсыз була...* Ә.Еники

**2.** *кер. сүз функ.* 1) Фигыль янында килгәндә: шулай итү хәерлерәк, мәгънәсен белдерә. *Булмаса, кайтыйк, карчык, [балык] чиртми башлады.* Г.Минский

2) **була, булды** Димәк, дигәнне белдерә. *Алмыйм, дигәч, алмыйм була. Зинһар, юкка бәйләнмәгез.* Г.Коләхмәтов

3) Югыйсә, юкса; алайса; һич югында. *Булмаса, матурлыкны без үлчәп күрик...* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Үзем сөйләшеп карыйм, булмаса!* А.Гыйләҗев

4) Бәлки. *[Камилне «китәргә ашыкма» дип кыстаучы Сөләйман:] Син, булмаса, бүген төнге поезд белән китәрсең.* Һ.Такташ

**3.** *бәйл. функ.* 1) **буларак** Баш килештәге исемнән соң: кемдер сыйфатында, ниндидер сәбәптән, шулай булган өчен, мәгънәсен белдерә. *Инде мин, олы кеше буларак, үземнең гомеремдә алган тәҗрибәдән чыгып, бернәрсә әйтмәкче булам: дөньяның төрле вакыты була.* М.Мәһдиев

2) **булып** Хезмәтендә, эшендә, вазифасында, сыйфатында, мәгънәсен белдерә. *– Без фәлән патшалыктан илчеләр булып килдек, – ди юлчы.* Ә.Еники // Исемнәрдән һәм сыйфатлардан соң нәрсәгә булса да охшату, чагыштыру, мәгънәсендә; кебек, шикелле, сыман. *Әле генә бит сабан тургайлары яшел уҗым өстендә ук булып атылып сайрыйлар иде.* М.Мәһдиев. *И телем – таныш мәкальләр, Әбиләр кылган дога – Ташландык мәктәп түрендә Көзге җил булып ела!* Г.Афзал. *Тик буйга таза ирнең куе кашлары бер-берсенә тартылган, иреннәре кысылган, шуңадыр, ахры, йөзе артык җитди, хәтта караңгы чырайлы булып күренә.* Ә.Еники. *Шәмси караңгыда аеруча зур булып күренгән бу кешенең монда, Сиваш уртасында, берүзе нишләп торуын төшенеп өлгергәнче, ул, карлыккан тавыш белән: – Кабельгә бәрелмә! – диде.* Г.Бәширов

**4.** *терк. функ.* 1) **булсын** *кбт. форм.* Һәм, да/дә, мәгънәсен белдерә. *Соңгы елларда аңа митингларда булсын, җыелышларда булсын, күп кенә чыгышлар ясарга туры килде.* А.Расих

2) Яки, яисә. *Кем белә, бәлки, яшь егетнең кич кунарга, булмаса чәйгә-фәләнгә килүе дә бик ихтимал.* А.Шамов

**5**. *кис. функ.* 1) **булгач** Кабатлап әйтелгән сүзләр арасында килгәндә, көчле басым ясауны белдерә. *[Илгизәр:] Рәхәт булгач рәхәт инде.* Т.Миңнуллин

2) **булып** Гадәттә кабатланган исемнәр арасында килеп, хәтта, мәгънәсен белдерә. *Мәдинә булып Мәдинә --- Борһанны мыскыл иткәндәй, кәкрәеп торган була бит.* М.Хәсәнов

3) **булыр** Исем, алмашлык, хәзерге заман хикәя фигыльләр янәшәсендә чамалауны, фаразлауны белдерә, *-дер/-дыр* кисәкчәсе функциясендә кулланыла. *Белә булыр: бала пәйгамбәрләр Кәнтәйлеккә аннан өйрәнгән.* А.Хәлим

◊ **Булмаса булган икән** Берәр эшкә тәвәккәлләүне белдерә. *Бәй, аннан эш тормас, булмаса булган икән!* Г.Бәширов. **Булса (булырга) кирәк** Мөгаен, бугай. *Шулардан уңайсызланып булса кирәк, үзенчә сылтау табып, җәһәт кенә урыныннан торды.* Ә.Еники. **Булсын дип (эшләү), булсынга (йөрү, эшләү)** Чын күңелдән тырышып, көч куеп, яхшы итеп (эшләү). *Йокламый, бер ул йокламый, булсынга дип, булсынга, Ап-ак чәчле Вакыт булып, иелгән дөньясына...* М.Галиев. *Бер дә булсынга йөргән кебек түгел.* Г.Гобәй. **Булуы җиткән** Әхлакый яктан соң дәрәҗәгә җитеп бозылган, тәртипсезләнгән. *Малайның булуы җиткән: авызда – папирос, башта – кепканың тар козырёклысы.* Г.Гобәй

**Булып алу** Кыска вакыт эчендә булу. *Тик берчак төнлә әти белән әни арасында бу хакта җитди сөйләшү булып алды...* Ә.Мушинский. *Идарәдә, һәр иртәне диярлек, вакытлы утырышлар булып ала.* А.Гыйләҗев

**Булып бару** 1) Һәрберсе эшләнү, тормышка ашу

2) Акрынлап, эшнең ахырына, көтелгән нәтиҗәгә якынлашу

**Булып бетү** Башкарылуы, ахыргача тәмамлана алуы тәгаен күренеп тору. *[Килделе-киттеле сөйләүчеләр] Монда килеп, булып беткән эшне бүлмәкчеләр.* Г.Лотфи

**Булып җитү** Тиешле дәрәҗәдә булу, җитлегү. *Мин, үземнең лаеклы булып җитүемә һәм лаеклы рәвештә башкаруыма ышанып җитмәс борын, тынычлана алмыйм.* Г.Бәширов

**Булып калу** 1) Элеккечә калу, үзгәрмәү. *Автор яңа әсәрләрендә дә туры, кыю сүзле булып кала.* Ә.Гадел. *[Китапта сүз] Гуннарның үзенчәлекле тормыш рәвеше, ирекле халык булып калу өчен алып барган көрәшләре, башка илләргә яулар оештырып, үзләрен дөньяга көчле кавем буларак танытулары турында бара.* С.Шәмси

2) Ниндидер вакытка, вакыйгага кадәр булырга өлгерү

**Булып китү** Билгеле бер моменттан соң, кинәт барысы да нинди дә булса сыйфатка, дәрәҗәгә ия булу. *Кичәге колхозчылар бер көндә эшче булып киттеләр.* А.Гыйләҗев. *Коточкыч дәһшәт урынына әверелде, җан өзгеч фаҗигаләр мәйданы булып китте бу – якты офыкларга сузылган җәйге ямьле юллар!* Ә.Еники. *Эш узгач, барыбыз да акыллы, зирәк булып китәбез.* Г.Бәширов

**Булып кую** Көтмәгәндә, кинәт булу. *Бу кечкенә буйлы энекәш киләчәктә Наполеон булып куярга да мөмкин әле.* З.Хөснияр

**Булып тору** 1) Даими рәвештә яки еш кабатлану. *Андый хәлләр алгы сызыкта көн дә булып тора.* Х.Камалов. *Моның ише кансыз кыйнаулар еш кына булып тора иде.* Ә.Еники

2) Һәрвакыт булу. *Андый кешеләр, һәрвакыт, милләтнең горурлыгы булып торалар.* Р.Иллялов

**Булып узу** Кайчандыр булу, булырга өлгерү. *Әлеге әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар Башкортстан төбәгендә үткән гасырда булып узган хәлләргә нигезләнгән.* В.Имамов

**Булып чыгу** Эш яки хәл көтелгәнчә, уйланылганча яки, киресенчә, көтелмәгәнчә булу. *Алар өчәү булып чыктылар.* А.Гыйләҗев. *Күз тиюнең бер катнашы да юк икән монда. Бар гаеп ала каргада булып чыкты.* Н.Сладков. *--- нихәл итмәк кирәк, чынбарлык хәтта хыялдан да көчлерәк булып чыкты.* Н.Фәттах

**БУЛЫШ** *и. сөйл. к.* **булышлык**. *Әни, көтүчеләргә булышка мин дә барам.* Н.Фәттах

**БУЛЫШЛЫК** *и.* Ярдәм. *Без бервакытта да үзебез генә тора алмыйбыз; һәрвакытта кешеләр белән бергә яшибез; бер-беребезгә булышлык кылабыз...* Г.Гобәйдуллин. *[Кави:] Миннән нинди булышлык кирәк соң сиңа, Хөршидә апа?* Б.Камалов. *[Әти-әнием] Сөенеп кенә калмадылар, булышлык та күрсәттеләр.* Идел. *Булышлык таләп ителсә, ярдәм кулы сузарга әзербез.* Ватаным Татарстан

**БУЛЫШЛЫКЛЫ** *с.* Ярдәмчел, булышучан. *Булышлыклы күрше белән яшәү*

**БУЛЫШУ** I *ф.* 1) Ярдәм итү, ярдәм күрсәтү. *Аңа урам аша чыгарга булыштылар, кая ничек барасын аңлаттылар.* Ә.Мушинский. *Булышырга сезнең кебек яшьләр кирәк.* Н.Фәттах. *Гөлҗиһан авылга теге атнада гына кайтып килде, әниләренә бәрәңге алырга булышты.* Ф.Бәйрәмова

2) Файдалы булу, ярдәме тию. --- *киләчәккә ышанычыбыз нинди нигезгә корылган, дигән сорауга җавап эзли, бүгенге көнебезнең дәверләр чылбырындагы урынын, әһәмиятен тоярга булыша...* М.Вәлиев. *Мондый [капма-каршы төшенчәләрне бәйләнештә сурәтләү] алым[ы] шагыйрьнең уй-ниятләрен халыкка үтемлерәк җиткерергә булыша.* Х.Миңнегулов. --- *йолдызнамә ярдәмендә, кызларга үз-үзләрен аңларга булыша, файдалы киңәшләр бирә.* Кызлар энциклопедиясе

**Булыша башлау** Ярдәмгә килү, булышырга тотыну. *Урманов, бераз хәл җыйгач, аңа булыша башлады.* Г.Әпсәләмов

**Булыша килү** Элек-электән, даими булышу. *Күрше килер, күрешә килер, үлсәң-калсаң, булыша килер.* Мәкаль

**Булыша төшү** Бераз булышу

**Булышып алу** Чагыштырмача кыска вакыт аралыгында бераз булышу. *Бакчалар да начар эшкәртелгән... Бераз булышып алмый булмас, дип уйлады Хәлим.* Г.Гыйльманов. *Ә иртәгәсен уракчыларга бер-ике сәгать булышып алырга булдык.* А.Алиш

**Булышып бетү** Барысына да булышу. *Белмим, бар кешегә булышып бетә алыр микән?* Г.Каюмов

**Булышып җибәрү** Бераз булышу, нәрсә дә булса эшләргә ярдәм итү. *Исем табышуда булышып җибәрүен көтеп, әтисенә карады, әмма әтисе малаеның үз башын эшләтүенә өметләнде.* М.Хуҗин

**Булышып йөрү** Әле, хәзерге вакытта булышу. *Гадирәк процедуралар үткәргәндә, санитаркаларга, шәфкать туташларына булышып йөрдек.* Г.Галиев. *Әмма минем, шулкадәр тырышып, безгә ихлас күңеленнән булышып йөргән әбиемне алдаганы, аннан астыртын гына көлгәне өчен, әнигә ачуым килә.* Э.Шәрифуллина

**Булышып карау** Булышырга омтылу. *Чөнки, өеннән бигрәк, аның ясаган сыннары, архивы да юкка чыкты. Аңа фатир алырга булышып карадык, барып чыкмады.* Т.Миңнуллин

**Булышып килү** *к.* **булыша килү.** *Ә бит, төптән уйласаң, хезмәте булган язучыларга һәм мораль, һәм матди, бүтәнчә әйтсәк, социаль яклау ягыннан хәйран гына булышып килә журнал.* Р.Фәйзуллин. *Бу вакыт эчендә, кулдан килгәнчә, колхозга булышып килдем.* Борынгы Калатау итәгендә

**Булышып тору** 1) Әледән-әле, еш булышу. *Алар [ястыкчы кызлар], туйга әзерлек башланган көннән алып, кызны кияү куенына керткәнчегә кадәр, гел кыз янында булып, бөтен эштә аңа ярдәмләшеп, булышып торалар икән.* Ә.Еники

2) Әле, сөйләп тору моментында булышу. *[Фидаил] --- сул аягы белән тезгенгә басып, үрмәләп диярлек, ат сыртына менеп китте. Габделхәй аңа арттан булышып торды.* Н.Фәттах

**БУЛЫШУ** II *ф.* 1) Кызыксынып китү, мавыгу, мәшгуль булу. *Үз мәшәкатьләре белән булышып, хатын-кыз Булатны онытып җибәрде.* Я.Зәнкиев

2) Берәр кешегә бәйләнү, аны бимазалау, борчу. *[Хуҗа Ахунга:] Моннан соң, минем эшемә тыгылып, минем белән булышмассыңмы?* Н.Исәнбәт

**Булыша төшү** Тагын да булышу

**Булышып алу** Кыска вакыт аралыгында, бераз булышу. *Бусы инде, кем әйтмешли, карты белән булышып алудан тәм табарга өйрәнгән карчыкның, форсаттан файдаланып, күңелен күкәй салдырып калырга маташуы гына.* Ф.Сафин. *Мин яшьтән үк гармун уйнарга яратам. Хромкада уйныйм. Бервакыт, баянда да булышып алдым.* И.Юзеев

**Булышып йөрү** Әле, хәзерге вакытта төрле урыннарда төрле кешеләр белән булышу

**Булышып карау** Булышырга омтылу. *Атаң да минем белә булышып караганые, оттырды.* Т.Миңнуллин

**Булышып тору** 1) Әледән-әле, еш булышу

2) Әле, сөйләү моментында булышу. *Бала-чага белән булышып тормыйм, ди, күрәсең.* Ә.Хәсәнов. *Фатыйх абзый, синең белән булышып торырга минем вакытым юк, ни йомыш белән йөрүеңне әйт тә, давай, сызу җаен кара, диде.* М.Шаһимәрдәнов

**Булышып утыру** *к.* **булышып тору** (*2 мәгъ.*). *Ярый, минем белән булышып утырма. Әнә бар, утын ярып кер.* Т.Гыйззәт

**Булышып яту** Әле, хәзерге вакытта булышу. – *Кызым, әллә соң, белгән кебек... – диде ана кеше. – Атаң әҗәл белән булышып ята.* Рифә Рахман. *Иртәнге өчләр-дүртләр тирәсе. Бала йокысының иң татлы, ләззәтле төшләр белән булышып яткан мәле.* Т.Галиуллин

**БУЛЫШЧЫ** *и.* Ярдәмче, булышучы, булышлык итүче кеше. *Авыл кызы, бик яшьли, олыларның кул арасына керә, кош-корт карый, каз бәпкәләре, тавык чебиләре тулаем аның карамагында була; бәрәңге утыртканда, ул – иң зур булышчы ---.* Я.Зәнкиев. *Җиле дә булышчы: өйнең җылысын суыра.* Ф.Җамалетдинова. *Миңа хәзер Алла, шайтан, фәрештә – бөтенесе булышчы.* Ә.Гаффар

**БУЛЫШЧЫЛЫК** *и.* Ярдәмчелек, булышчы булу. *Рәмиевнең үтенүе буенча, вакытлыча, аңа булышчылыкны кабул иттем.* М.Фәйзи

**БУЛЬВАР** *и. фр.*< *нем.* **1.** Шәһәр урамы уртасындагы аллея, агачлар утыртылган киң урам. *Ә Берлин – таштан койган музыка. Мондагы скверлар, бульварлар, чәчәкләр тагын!* Т.Әйди. *Үскән ничек бульвар, бакчалар, – Еллар, ахры, байтак үткәннәр ---.* Х.Туфан. *Хәзер сәбәбен беләм: зур бульварларда йөргәндә, затлы рестораннарда ашапэчеп утырганда, миемне өзлексез бер фикер тукып торды – боларның күп нәрсәсе безнең белән уртак лабаса...* М.Мәһдиев. *Казан урамында – саф татарча, Париж бульварында – французча, Лондон урамында инглизчә Сорый замандашлар: – Сәгать ничә?* Р.Низамиев

**2.** *с. мәгъ. күч.* Түбән сыйфатлы. *Укучылар күңелен яуламак булып, «бульвар» яки «вульгар» басмалар ишәйде.* Р.Фәйзуллин

**БУЛЬДОГ** *и. ингл.* 1) Этләр семьялыгыннан, зур гәүдәле, киң күкрәкле, юан кыска аяклы, тупыйк борынлы эт токымы; шул токымлы эт. *Бәлки, синең солдат ышанычлы, бульдог сыман әрсез сакчыдыр?!* Х.Туфан. *Ак тәбәнәк эте дә, йөрисез шунда юкны майтарып, дигәндәй, хуҗасы аягы ягында гамьсез ятты, машинадагы бульдогның ырлауларын да ишетмәгәнгә салынды.* М.Хуҗин. *Бульдог токымлы этне беләсезме?* Юлдаш

2) Кыска көпшәле пистолет

**БУЛЬДО́ЗЕР** *и. ингл.* Гадәттә җир тигезләүдә, туфрак күчерүдә кулланыла торган, тракторның алдына беркетелгән, киң көрәк сыман җайланма; шундый җайланмасы булган трактор. *Ул нидер әйтте, тик нәкъ шул вакытта теге бульдозер тагын үкерергә тотынды, һәм аның сүзләрен Василий ишетмәде.* А.Гыйләҗев. *Һәрҗирдә күтәрү краннары, тырыш бульдозерлар, тынгысыз машиналар искеләрне ваталар, җимерәләр, яңаларны төзиләр.* Р.Кәрами. *Җимеш куакларын бульдозер белән актарып, болынны сөреп яталар.* Г.Бәширов. *Күк тулы кояш, авыл урамындагы бульдозер өйгән кар диварлар хәлсезләнеп калган, юлда юка боз элпәләре тирләгән, биек зәңгәр күктә – яз шавы.* М.Мәһдиев

**БУЛЬДО́ЗЕРЧЫ** *и.* Бульдозерда эшләүче. *Бульдозерчы, нәрәтен куен кесәсенә тыгып, машинасын кабыза ук башлады.* А.Гыйләҗев

**БУЛЬМАСТИФ** *и. ингл. зоол.* Бульдог һәм мастиф кушылудан барлыкка килгән, эре авыр сөякле, зур башлы, кыска йонлы эт токымы. *Бульмастиф асрау*

**БУЛЬТЕРЬЕР** *и. ингл. зоол.* Терьерлар төркеменнән, инглиз терьерын инглиз бульдогы белән кушылдырудан барлыкка килгән, көчле мускуллы, кыска йонлы эт токымы. *Бультерьер – килмешәк эт.* Т.Миңнуллин

**БУМ** I *иярт.* Каты итеп сәгать суккан, барабан каккан һ.б.ш. тавышларны белдерә. *Бу вакытта аның тавышы бөтенләй икенче – үпкәләү ноталарында яңгырый: Бум-бум-бум! Бум-бум-бум!* М.Мәһдиев. *Шулай ук, кояш баеган чакта гына, аргы Димнән, «бум... бум» дигән төслерәк, өзеп-өзеп кычкырган калын бер тавыш ишетелә торган иде.* Ә.Еники

**БУМ** II *и. ингл. сөйл.* 1) Ыгы-зыгы, сенсация. *Ни өчен дигәндә, бүгенге ФТР заманында, информация «бумы» чорында балаларны нәрсә белән булса да шаккаттыру, гаҗәпләндерү – үтә дә авыр эш.* Р.Миңнуллин

2) Дөнья базарында билгеле бер төр эшчәнлектә, җәмгыятьтә, берәр тармакта активлык арту күренеше. *Төзелеш бумы шартларында, архитекторларның хезмәт күрсәтүләренә сорау күләме һәм бәяләр артканда да, шундый үзенчәлек характерлы.* Икътисад теориясе нигезләре

**БУМА** *и.* **1.** Баш мие зарарлануга бәйле, һушны югалту, тән тартышу, көзән җыеру кебек өянәкләр рәвешендә бара торган авыру; зыяндаш авыруы; эпилепсия. *Бума икәнен шәйләдем, сугыш елларында бу афәтнең бик күп кешеләрне тинтерәткәнен хәтерли идем.* А.Гыйләҗев. *Тукмәт Михайласы армиядән бума чире алып кайтты.* А.Гыйләҗев. *Иван Телепнев сөйгәненең аягына төште, аякларыннан кочты: – Ул бума чире белән авырыймыни, Еленушка?!* М.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Буылдыра, сулышны кыса торган

2) Бума авырулы. *Ләкин бума Шәрәфетдин аңа гына канәгать түгел иде.* Х.Сарьян

**БУМА́ЖНИК** *и. рус* Акча янчыгы. *Мәснәви, костюм кесәсеннән бумажнигын чыгарып, аннан даны таралган теге өч фотоны алды һәм Курамшин алдына ыргытты.* Ш.Бикчурин. *Талавын таладылар, анысы... Бумажник юкка чыккан.* М.Маликова. *Тик ятсын иде, буаз бумажнигын кочаклап, янымда!* А.Гыйләҗев

**БУМАЗИ** *и. фр.* **1.** Бер ягы йомшак төкле киҗе-мамык тукыма. *Баланы түшәгемә салып чишендердем дә, Хәдичә ханым мичтә җылытып килгән бумази белән, тәнен уарга керештем.* Р.-Н. Гүнтәкин

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Ул бумази күлмәк өстенә җиңсез камзул кигән...* Г.Исхакый. *Сәрия җизнәсенә ярарлык кофта таба алмый бәргәләнде, ахырда, коенгач кия торган бумази халатын аның җилкәсенә салды.* М.Маликова. *Шәмәхә кара таплары белән чуарланып беткән яшел бумази материяле өстәл янында утырган чулак милиционер белән исәнләштем.* Р.Төхфәтуллин

**БУМАЛЫ** *с. к.* **бума 2.** (*2 мәгъ.*)

**БУМА́ ҮЛӘН** *и. бот.* Куыгутчалар семьялыгыннан, бөҗәкләрне үзенә тартып китерү һәм ябыштыру өчен сыекча бүлеп чыгарганга, яфраклары май сөрткән кебек ялтырап торган, дымлы, бөҗәк ашаучы үсемлек; *русчасы:* **жирянка**

**БУМА́ ЮТӘЛ** *и. мед.* Коклюш таякчыгы китереп чыгара һәм көчле ютәл белән үтә торган йогышлы авыру (гадәттә 10 яшькә кадәрге балаларда була); *русчасы:* **коклюш.** *Бума ютәлнең яшерен чоры 3 көннән 15 көнгә кадәр дәвам итә.* Иң шәп календарь. *С.Җәлал ярдәмчел остазының бума ютәлдән интегүен, көннән-көн сүнә баруын күреп тора, аның газаплы вафатын авыр кичерә.* Казан утлары. *Туберкулёз, кызамык, кызылча, полиомиелит, гепатит, бума ютәл һәм паротит кебек авырулар кичерүнең ахыры бик аянычлы тәмамланырга мөмкин.* Мәгърифәт

**БУМЕРАНГ** *и. ингл.* 1) Ыргыткannan соң, билгеләнгән ноктага тиеп, ыргытучыга кире әйләнеп кайта торган, як-яклары очлаеп килгән, бөгелгән яссы формадагы, тышкы ягы үткен йөзле һөҗүм итү коралы. *Хәмит коңгырт күзләрен челт-челт йомып куйды, бумеранг сыман уртадан кырт бөгелеп төшкән мул кашлары турайды.* Р.Вәлиев. *Үч алам, дип, ахмак хәлдә калырга ярамый миңа. Мин аткан укның, мин төзәгән йөрәккә тимичә, бумеранг булып, үземә кайтуына һич кенә дә риза түгел.* Т.Миңнуллин

2) Шул коралга охшаган рәвеш; алда эшләгән тискәре гамәлләрнең үзеңә

начарлык булып әйләнеп кайту күренеше. *Табигать, әлбәттә, җавапсыз калмады – бумеранг үзебезгә кайтып бәрде. Безнең эчәргә чиста суыбыз, суларга саф һавабыз юк икән, моңа без үзебез, бары тик үзебез генә гаепле.* Ф.Әһлия. --- *җитәкчелекнең бер даирәсе, формаль сәбәпләр табып һәм хакимият көченнән явыз файдаланып, мәгълүматны чикләүне дәвам итә икән, бу гамәлләре, бумеранг рәвешендә, үз башларына кайтып төшмәсме икән?!* Татарстан яшьләре

**БУНА́У** *ф. диал.*1) Тапау, кискәләү, сую

2) Агачны ботакларыннан юнып чистарту

**БУНГА́ЛО** *и. ингл.*< *һинд.* Гадәттә Һиндстанда, шәһәр читендә җиңелчә генә төзелгән верандалы йорт, өй. *Йорт хуҗасы: – Йә, ничек? Кунакка минем бунгалом ошыймы? – дип сорагач, Наталья шулай җавап бирде дә...* Р.Мирхәйдәров

**БУНДЕСВЕР** *и. нем.* Германия Федератив Республикасы хәрби көчләре

**БУНДЕСТАГ** *и. нем.* Германия Федератив Республикасы парламенты. *Берлиндагы камер-егерьләр бундестаг бинасыннан 17 тычканны эвакуацияләгән.* Мәдәни җомга

**БУ́НКЕР** *и. ингл.* 1) Коела, чәчелә торган йөкне ташу, саклау өчен, үзбушаткыч махсус савыт-җайланма. *Сезнең менә күргәнегез бармы Бункерлардан икмәк акканын?* М.Әгъләмов. *Их! Алдан килгән булсагыз, мин сезгә быелгы әпәйнең бункердан ничек акканын күрсәтер идем.* К.Тимбикова. *Мин хәзер көненә сигезәр бункер ашлык суктырам.* И.Сирматов

2) Судноларда: (бер) рейска җитәрлек күләмдә каты ягулык саклау өчен махсус урын, бүлмә һәм шул ягулыкның үзе. --- *кораб бункер алган арада, утрауга чыгып кирәргә вакыттыр.* М.Юныс

3) Тормышка куркыныч янаган чакта вакытлыча яшәү, эшчәнлек итү өчен махсус җиһазландырылган җир асты корылмасы. *Ә ярты сәгать үткәч, шәһәрдә, металл катыш бетоннан салынган бункер эчендә, дөньяда иң куәтле «Суперфазатрон» эшли башлады.* А.Тимергалин

**БУНТ** *и. пол. сөйл.* 1) Хакимияткә, җәмгыятьтәге кагыйдә-таләпләргә каршы чыгу, баш күтәрү; фетнә. *Ләкин бу – акыл белән уйланган бунт. Самозванец үзен, патша, ди. Ул патшаның үз дәүләте бар. Ул дәүләтнең халкы аңа ышана, аңа табына.* Т.Миңнуллин

2) Тавыш-гауга, ризасызлык. *Егетләр бунт күтәрә, эшкә чыкмыйбыз, диләр.* Р.Вәлиев. *Шул Суыгаяк забастовканы бозды, Бунт чыгарып, начар ясады.* Х.Туфан. *Бу – демократия түгел. Бу – просто бунт!* Х.Сарьян. *Кибеттә нәни генә булса да бунт күтәрде.* А.Гыйләҗев

**БУНТАРЬ** *с. рус кит.* **1**. Тынгысыз, көрәшкә атлыгып, ашкынып торган. *Эшнең төбен бунтарь, баш бирмәс табигатьле Хәбиптән күрделәр...* Г.Ибраһимов. *Бунтарь кеше күңеле, ярларына кайтып төшкән дулкыннарга карап, монда тынычлык тапкан.* С.Сөләйманова. *Шул ук вакытта бунтарь шагыйрьнең бер шигъри юлы мәһабәт ирнең эчке халәтен аңлата иде бугай.* С.Сөләйманова. *Артык кайнар, бунтарь хисләремне Бәйләп куям Казык йолдызга.* Р.Низами

**2**. *и. мәгъ.* Гыйсъянчы, баш күтәрүче кеше. *Сәгыйть әфәнде, бунтарь белән бунтарьның аермасы бар бит.* Ә.Фәйзи. *Иртән җыйды мөдир-профессор «Әллуки»нең барлык бунтарен.* Р.Рахмани

**БУНТАРЬЛАНУ** *ф.* Ризасызлык күрсәтү, тискәреләнү, тәртипсезләнү

**Бунтарьлана бару** Торган саен ныграк бунтарьлану

**Бунтарьлана төшү** Бераз бунтарьлану

**Бунтарьланып алу** Азрак, берара бунтарьлану

**Бунтарьланып бетү** Бөтенләй бунтарьга әйләнү

**Бунтарьланып йөрү** Озак вакытлар бунтарьлану. --- *бунтарьланып йөргән Айдар һәм сылу, чибәр Вәсилә язмышы барчасын исәрткән иде.* Б.Камалов

**Бунтарьланып китү** Кинәт бунтарьлану

**Бунтарьланып кую** Вакыты-вакыты белән азрак бунтарьлану. *Бераз башына киткән булса, азрак бунтарьланып та куя [әти].* Г.Гобәй

**БУНТАРЬЛЫК** *и.* Бунтарь булу, бунтарь кешегә хас сыйфатлар; фетнәчелек. *Такташ, вак милекчелекне, индивидуаль бунтарьлыкны гаепләп, «Мокамай»ны яза.* Г.Нигъмәти. *Такташның сезнең заманда сүгелгән символикасы, бунтарьлыгы яшьләрне тарта.* Р.Батулла

**БУНТЧЫ** *и.* Бунт, фетнә оештыручы яки шунда катнашучы. *[Хабул абыймыдыр] Аркан буенча төшергән Ялкыннан бәрәнне Бунтчылар ягына сөйрәде.* Х.Туфан

**БУНЧУК** *и. төрки тар.* 1) Бер башы очланган яисә шар куелган, ат койрыгы бәйләнгән таяк; төрек генералларының, соңрак поляк һәм украин гетманнарының, казак атаманнарының хакимлек билгесе. *Ат кешнәгән тавыш ишетелде, Күңелемдә ерак чорлар көлде, Уклар очты, җәя тартылды да, Тастымалны бунчук итте колга, Аргамакта килде җилдерәсем, күкрәгемә тутырып дала исен. Тик кайда соң гаярь җайдак шаны?* Р.Зәйдулла

2) Хәрби оркестрларда: ат койрыгы тагылган бәрмә музыка коралы

**БУП-** *кис. Б* авазына башланган *буш* сыйфатына ялганып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Кырга уракчылар килеп беткәнгә, юл буп-буш булса да, бөтен йир тулы халык иде.* Г.Исхакый. *Пароходлар Казанга җиткәндә, пристань элеккечә буп-буш иде.* К.Нәҗми. *Урам буп-буш иде.* А.Гыйләҗев. *Тәнендә итләре тәмам беткән, буп-буш, шыр сөякләр генә [Әнвәрнең].* Х.Камалов

**БУР** I *и. сөйл.* Ак төстәге йомшак известь. *Балалар бур белән асфальтка рәсем ясый*

**БУР** II *и. диал.* Карак. *Караклар, бурлар гына ата-ана кушкан исемнәрен бозалар, имеш.* А.Гыйләҗев. *Ләкин бер тотыла язып калганнан туктаган бур – нинди бур, ди, ул!* Х.Сарьян. *Олигархмы, скинхедмы, законлы бурмы – алар да бит кемнәрдер өчен авторитет, кумир, темабыз терминологиясе белән әйтсәк, герой, каһарман.* Казан утлары

**БУР** III *и. нем. махс.* Туфрак, тау токымнарын өйрәнү, тикшерү өчен, нефть һәм кайбер газларны табуда скважиналар бораулау өчен махсус борау. *Нииндидер каты токым бурны кирегә этәрә, бәреп чыгарырга теләгәндәй сиртмәләндерә.* Ә.Айдар

**БУРА** I *и.* 1) Агачтан эшләнгән корылмаларның бүрәнәдән торган диварлары өлеше; бүрәнәләрдән салынган өлеше. *Абзар җимерелгән, аның янында сыер күренми, еракта – Масра тавы буендагы кое бурасы да күренми.* М.Мәһдиев. *Тау өстендә, уртада, юан-юан карагай бүрәнәләрдән өеп мендерелгән сигез почмаклы бура --- калкып утыра иде.* Н.Фәттах. *Буа бурасы да, каралып, зәңгәрсу бака үләне, су төбеннән калыккан куе яшел суүсемнәр ябышып ямьсезләнде.* Ә.Гаффар

2) Келәттә, амбарда ашлык салу урыны, бүлемтек; лар. *Ашлыгы уңган, җимеше мулдан, Буралар тулган, Шуңа сөенгән.* З.Туфайлова. *Бушап калган бураларны тутыру өчен, бик нык эшләргә, бик күп хезмәт көне җыярга кирәк иде.* М.Мәһдиев. *[Ат] Он бурасына башын тыккан да рәхәтләнә.* М.Мәһдиев

3) Үлгәннәрне җирләү өчен махсус ясалган корылма. *Тегендә, еракта, түң җир астындагы бурада калган кеше инде беркем белән дә икәүдән-икәү генә ята алмаячак.* Н.Фәттах

◊ **Бурасы буш түгел** Тормышы, яшәеше тыныч түгел, нинди дер борчуы, кайгысы бар. *Бу хатынның янынан киткәч, Зәйнең башына, беркемнең дә бурасы буш түгел: берсендә – бер бәла-кайгы, икенчесендә бөтенләй башка төрле каза, дигән уйлар килде.* Х.Камалов

**БУРА** II *и.* Печтерелмәгән нәсел дөясе; ата дөя. *Алтмыш көн атан булганчы, алты көн бура бул.* Мәкаль. *Карагай буе кола аты Аелдаен айкалды, Бурадаен чайкалды, Буралып утырып атына, Чайкалмады Кыпчак би.* Дастан. *Гарасат уты янганда, Бура боздан тайганда, Бутасы баш күтәреп торганда, Каз, очып, шоңкар куганда, Ханнан гайрәт киткәндә, Бигә мидәт иңгәндә, --- Идегәй мырза, талашып, Ил соңына төшкәндә, – Хан Туктамыш, гарьләнеп, Байтагым, дип зарланып, Аны әйтеп тулгады.* Дастан

◊ **Бура кадәр(ле)** *к.* **бура кебек.** *Бура кадәр сыер тоту авыр аңа, кәҗәлек азыкны ничек тә юнәтер идем, ди ул.* А.Төхвәтуллина. *Ә менә Наил Исхаков хуҗалыгында бура кадәр дүрт сыер бар.* Ватаным Татарстан. *Йөгереп килсәк, сарай уртасында бура хәтле бер сыер үлеп ята. Уен эш түгел бит, бура кадәрле сыер!* Безнең гәҗит. **Бура кебек** Зур гәүдәле, симез, көр (сыер яки ат турында). *Бурлы бия быел кысыр калды. Ул бура кебек таза, калын булып симереп китте. Берүзе биш атның эшен эшләрлек.* Г.Ибраһимов. – *Ә мин менә кара буранда, суык абзарда бура кебек сыерны көчкә савып кердем, уф Алла! – диде әниләре, авыр көрсенеп.* Б.Ислам. **Бура хәтле** *к.* **бура кебек.** *Якындагы яланда утлап йөргән бура хәтле, кара чуар нәселле унлап башмак тана – аларныкы.* Ватаным Татарстан

**БУРА** III *и. диал.* Таяк (тәпәч, бура таягы, аткы) атып, кыска таякчыкларны урыннарыннан бәреп чыгарудан гыйбарәт, ике командага бүленеп ярыша торган уен. *Бура уйнау*

**БУРА́ БАТЫРУ** *ф.* Чишмәне, кое эчен буралау. *Чишмәләрне әрчетергә, бура батырырга кирәк, дип уйлады ул.* И.Гази

**БУРАБЗАР** *и. диал.* Кышкы салкыннарда яшь терлекне тоту өчен, бурап, мүкләп эшләнгән җылы абзар. *--- аю төнлә тайгадан чыккан да, авылга килеп, берәүнең бурабзар ишеген вата башлаган.* М.Мәһдиев

**БУРАЗНА** *и. рус.* **1.** 1) Җирне сөрүсукалаудан барлыкка килгән, тар гына ерым булып сузылган эз. *Карчык бер буразна бәрәңгене казып бетереп килгәндә, бакчага, берәм-берәм, көрәк-чиләген тотып, авыл хатыннары җыела башлады.* Р.Газизов. *Буразнага төшеп, җирдә калып, Бер орлык та әрәм югалмый.* Г.Афзал. *Менә мин, йомшак буразнага басып, сабан артыннан атлыйм.* М.Юныс

2) Игенченең, сөрүче-сукалаучының эшләп торган урыны. *Без буразнага килгәндә, Чулпан калыкмаган иде әле.* М.Җәлил

3) Җир өстендәге буразнага охшаш ерганак. *Юл буендагы буразна чокырыннан куян атылып чыкты.* Г.Бәширов. *Аларның [тауларның] күк кырые буйлап сузылган зәңгәрсу буразналары арасыннан кояшның озынча сары сызыклары гына күренеп калды.* Г.Бәширов

4) Кешенең баш миендәге сыр, йөзендәге җыерчык. *Авыруның баш миендә гадәти буразналар да юк.* Х.Сарьян. *Ике каш арасына сызылган тирән буразнада какшамас көч яшеренеп ята шикелле.* С.Сөләйманова

5) *күч.* Сайланган яшәү рәвеше, юнәлеш. *Ир кешедән мир кешесе булып Күтәрелеп, буразнадан чыкма!* М.Әгъләмов. *Театрның эстетик нигезе дә бар, Сәлимҗановка театрны яңа буразнага күчерергә кирәкми.* Татарстан

**2. буразна!** *ы. мәгъ.* Атка буразнадан тайпылмаска кушып өндәү сүзе. *На, на, хайван, буразна! дип, Син сукалап йөргән җирме ул?* З.Бәшири

◊ **Буразна салу (сызу, яру)** Берәр өлкәдә яңалык ачу, зур эшчәнлек күрсәтү. *Һәм менә монда беренче буразна салучыларның да берсе ул булачак.* Н.Фәттах. *Давылларда бер буразна ярып Тапкан дуслык мәңге адашмас.* А.Хәлим. *Ул үзенең халыкны агарту юнәлешендә беренче адымнарны, буразналарны сызуын яхшы аңлый.* Татар балалар әдәбияты

**БУРАЗНАЛА́У** *ф.* 1) Буразна сызу, буразна ясау. *Буразналап сипкәндә, сугарыла торган бүлекчәләрне зур ясыйлар.* Яшелчәчелек

2) Җир өстен буразнага охшаш канаулар белән ермачлау

3) Йөздә җыерчыклар барлыкка килү, елаудан эз калу. *Күз яшьләре ике бит очын буразналап агып төшкән.* Х.Камалов

**Буразналап бетерү** Нәрсәнең дә булса өслегендә күп итеп буразналар, ермаклар ясау. *Тау битләрен яңгыр сулары һәм язгы гөрләвекләр буразналап бетергән.* М.Хәсәнов

**Буразналап тору** Әле, хәзерге вакытта буразналау

**Буразналап төшү** Өстән аска таба эз калдырып үтү. – *Ялгышканмын...*

*Рәхмәт сезгә... – дип, яңакларын буразналап төшкән сызыклар арасына елмаюын яшерде, Галимҗан Ибраһимовның халык иҗатына мөнәсәбәте хакында сөйләп китте.* М.Галиев

**Буразналый төшү** Тагы да бераз буразналар ясау

**БУРАЛА́У** *ф.* 1) *к.* **бура батыру.** *--- безнең бу бик борынгы чишмәбез өр-яңадан туган шикелле булды. Авылымның игелекле куллары, аның төбен ләмнән чистартып, матур итеп буралап, әкияттәгедәй итеп бизәделәр.* Р.Әхмәтҗанов

2) Ашлык, он салу өчен, келәт эченә бүлемтекләр ясау

3) Бура итеп эшләү. *Шунда ук, сирәк-мирәк кенә булса да, буралап эшләнгән чардуган калдыклары күренгәли.* М.Хәсәнов. *--- алар [чокыр] эчендә биеклеге ике метрга кадәр булган күмү камералары табыла. Алар карагай агачыннан ике катлап буралап эшләнгән.* Г.Фәйзрахманов

**Буралап алу** Тиз арада буралау

**Буралап кую** 1) Алдан буралау, буралаган хәлгә китереп калдыру. *Бер елганы уздык, – туктамадык, юлда очраган авылның коесын карап киттек, – туктамадык, аннан арырак буралап куйган чишмә очрады, – туктамадык...* И.Юзеев. *Равилнең бик эчәсе килгән иде, ул буралап куелган чишмәнең улагы янына тезләнде дә бите белән суга капланды.* Н.Әхмәдиев

2) Кыска вакыт эчендә буралау. *Бер атна эчендә осталар бу өйне буралап, түбәсен ябып куйдылар.* Ә.Еники

**Буралап тору** Әледән-әле, еш буралау

**БУРАЛГЫ** *и. сир.* Карак. *Бүген морлок нәселе күпчелекне тәшкил итә һәм тыелгысыз үрчи: фатир басучылар, --- зимагурлар, буралгылар...* А.Тимергалин

**БУРАЛКЫ** *и. диал.* Иясез ат. *Буралкы аттан ярышмын, Бугалак салсаң, туктамам!* Дастан

**БУРАЛЫ** *с.* Буралап эшләнгән, бура I куелган. *Елгадан ерак та түгел, тыкрык турында буралы чишмә бар икән.* А.Гыйләҗев. *«Кое» дип аталса да буралы чишмә иде.* Ф.Яхин. *Борым хәлләре бөтен авылны тетрәндерде, тик һәркем станция һәм кара буралы плотинаның исән калуына шатлана.* Ә.Гаффар

**БУРАЛЫК** *и.* **1**. Бура I бурау өчен әзерләнгән бүрәнәләр. *Түр караватастындагы фанер чемоданда – яңа өй буралыгына диган акчалары икән!* Б.Камалов

**2**. *с. мәгъ.* Бура II бурау өчен, бура бурарга яраклы. *Шулай өч-дүрт көн үтте, буралык агачларны аударып, иңнәренә бау уздырып, бауны бүрәнә башына бәйләп, һай-һайлап, кирәк кадәр агачларны аланга ташып та куйдылар.* Я.Зәнкиев

**БУРАН** *и.* **1.** 1) Көчле җил белән күтәрелгән кар өермәсе. *Җәяүле буран декабрь карын тарата.* А.Гыйләҗев. *Ашыктырып этә иңнәремнән Туган якка буран. Өянкеләр авыл башынача Каршы чыгып торган.* Р.Вәлиев. *Тышта буран улый, маяклы юл, моңсу гына булып, еракка сузылган.* М.Мәһдиев

2) Гадәттә тартымлы формада: җил белән күтәрелеп бөтерелгән тузан, ком өермәсе. *Алабай, кая керергә белмичә, тузан бураны күтәреп, аларга өрергә, чәбәләнергә тотына.* З.Зәйнуллин. *Бигрәк тә, ком бураны белән бергә күмелеп, ком астында калган скрипкачының фаҗигасе, --- аның күңеленә нык сеңеп калган иде.* Ш.Камал. *Кил яныма ком бураны булып. Чишмә булып типсәм дә – үкенмәм.* Сөләйман

3) Кояшның магнит активлыгына бәйле тирбәнешләр. *--- геомагнит тикшеренүләр обсерваториясе белгечләре, магнитлы бураннарга ышанырга кирәкми, дип саныйлар.* Иң шәп календарь

4) *күч.* Көчле гауга, ызгыш-талаш. *Тыштагы буран – буран түгел, өйдәге буранга чыдап булмый.* Мәкаль. *Чөнки каршы әйтелгән сүз, аталарының ачуын арттырып, буранны гына көчәйтәчәк.* Г.Ибраһимов. *Тышта буран булса булсын, Өйдә буран булмасын.* Р.Мөслимов // Тынгысызлык. *Күңелдә – буран да, яңгыр да...* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Буранлы (көн, һава турында). *Бу ел кышлар бик буран, Җаныем, шәлеңне уран.* Г.Тукай

◊ **Буран күтәрү** *к.* **буран уйнату**. *Моңа каршы ике кандидат та буран күтәрделәр.* Г.Ибраһимов. **Буран уйнату** 1) Тузыну. *Оляның ялгыш кына бүтән ирләргә күзе төшсә, Мидхәт буран уйната.* А.Гыйләҗев; 2) Тиз эшләү. *Бу малайның кулы нык булырга охшаган, пычкыны әйбәт тарта. Кар көрәсә – буран уйната.* Р.Мөхәммәдиев

**БУРА́Н-ҖИЛ** *җый. и.* Буран һәм җил. *Шулай бер көнне, буран-җил томалаган ишекне көч-хәл белән каерып ачып, --- берәү килеп керде.* Я.Зәнкиев

**БУРА́Н-КАР** *и. сир.* Көчле кар бураны; кар-буран. *Бураны-кары да, зәһәр суыгы да инде куркытмый иде.* Г.Ибраһимов

**БУРАНЛАТУ** *ф.* **1.** 1) *сөйл. к.* **буранлау**. *Иртә белән буранлаткан иде.* Ш.Камал

2) Ком, тузан, кар бөртекләрен очыртып, тузгытып тарату. *Буранлатып, кар көрәү*

3) *күч. сөйл.* Бик каты ачулану, тавыш чыгару. *Абыйсы, кайтып, тагын буранлатты*

**2**. **буранлатып** *рәв. мәгъ. сөйл.* Тизтиз, кызу-кызу, барысы бердәм. *Алар тагын буранлатып эшләп алдылар*

**Буранлатып алу** Бераз гына, кыска вакытка буранлату

**Буранлатып җибәрү** Кинәт буранлата башлау. *Шул шул, чын шагыйрь сүзенең сере шунда: ул минем дә моңарчы тын судай изрәп кенә аккан хисләремне «буранлатып» җибәрә.* Х.Сарьян

**Буранлатып тору** Әле, хәзерге вакытта буранлату

**БУРАНЛА́У** *ф.* 1) Буранлы булу, буран уйнап тору (көн, һава турында)

2) Буран рәвешендә җил бөтерелеп исү, шулай, җилләп, көчле итеп яву, тузу. *Буранлап яуган яңгырда берни күрер хәл юк.* Г.Нәбиуллин. *Кар иртәдән кичкә кадәр буранлап яуды.* М.Рәфыйков

3) *з.-сыз.* Һава торышының буранлы булуы турында. *Төнлә азрак буранлаган, юлга бераз себергән иде.* М.Гали

**Буранлап алу** Аз вакыт аралыгында буранлау. *Яз уртасы якынлашса да, көннәр салкын әле. Агачлар яшәргәч тә буранлап ала торган.* С.Шәрипов

**Буранлап җибәрү** Кинәт буран чыгу, буранлый башлау. *Тагын буранлап җибәргән*

**Буранлап китү** Кинәт буранлау. *Соңгы вакытта көннәр буранлап киткәнлектән, төпләр кар астында калган.* Ф.Яруллин

**Буранлап тору** Әледән-әле яки билгеле бер вакыт дәвамында буранлау. *Ә вакыт бик соң: төнге унбер тулып килә. Буранлап тора.* В.Нуруллин. *Көн кичкә авышып бара, нык кына буранлап та тора.* Ф.Хөсни

**Буранлый башлау** Буранларга тотыну. *Көн кичкә авышкач, буранлый башлады*

**Буранлый төшү** Бераз буранлау

**БУРАНЛЫ** *с.* 1) Буран уйнап торган, буран чыккан. *Буранлы атна башындарак, Сәрвәргә яман бер төш керде.* Я.Зәнкиев. *Буранлы төн иде.* М.Мәһдиев // *сир.* Буран белән бергә була торган. *Буранлы давыл кузгалды.* А.Алиш

2) *күч.* Шау-шулы, ызгыш-талашлы. *Бик буранлы төш иде бит, чишенеп үк ташланылган икән, каһәр, дип көлгән булдым.* М.Әмирханов. *Буранлы җыелыш*

3) *күч.* Хисләргә бай; ашкынулы. *Буранлы яшьлек*

**БУРА́Н ТУРГАЕ** *и. диал.* Карабүрек

**БУРА́У** I *ф.* Бура итеп эшләү, бура ясау. *Мунча һәм сарайны бурарга керештем.* Ф.Яхин. *Җир сөрәсе, бәрәңге утыртасы, яшелчә үстерәсе, бура бурыйсы килә.* Р.Сибат. *Ир-атлар арасында өй бурау, бүрәнә юнәтү турында сүз чыкса, Нәүширван абзый шунда ук аркылы килә.* М.Галиев. *[Татарның] Баераклары, хәллерәкләре мәчет салдырган, мәктәп-мәдрәсә ачкан, --- итек-читек теккән, тула баскан, йөзек-алкалар, беләзек-чулпылар койган, бура бураган, тәрәзә йөзлекләре ясаган.* Сөембикә

**Бурап алу** Тиз арада бурау

**Бурап бетерү** Бурау эшен тәмамлау. *Санап чыгар иде ниргәсен ул, Бурап бетергәч үк бурасын.* Ш.Маннур. *Җәйнең соңгы, ләкин әле кояшлы, җылы аенда уңган балта осталары Сафуанның бурасын бурап бетерделәр.* Ә.Салах

**Бурап йөрү** Әле, хәзерге вакытта бура бурау белән мәшгуль булу. *Капкара кием белән, ул [әтисе] аның [Галимҗанның] төшенә керде. Шул кара киемдә үзенә бура бурап йөри.* С.Поварисов

**Бурап кую** Буралган хәлгә китерү. *Элек, тормыш тагын да авыррак чакларда, әби-бабаларыбыз чишмәләрне барлап, кадер-хөрмәт күрсәтеп, тазартып, карап торганнар, бурап куйганнар.* Ф.Гарипова

**Бурап чыгу** Тоташтан, башыннан ахырына кадәр бурау

**БУРА́У** II *ф.* Бик каты бөтереп буранлау. *Бурый буран, елый олан, бармый ат, кыйный карт.* Такмак. *Шул ук мизгелдә, бурап-бурап әйләнгән кар пәрдәсе эченнән, бер-бер артлы атлаган ике гәүдә күренде.* З.Зәйнуллин. *Хәзер менә юеш җиргә, Бурап-бурап, яфрак ява.* Р.Зәйдулла

**Бурап йөрү** Озак вакытлар буе бурау. *Алданудан җил, йокысын җуеп, Бурап йөри дөнья буйлата.* Ә.Баян

**Бурап килү** Буран буратып якынлашу. *Урап, бурап килгән бураннарга Кереп киткән идем син юкта, Чак төртелми калдым буран аша Томрап торган ике зур утка.* Ф.Тарханова

**Бурап тору** Әледән-әле, еш бурау. *Тышта ап-ак карлар ява, Бураннар бурап тора.* Ф.Чанышева

**БУРАЧЫ** *и.* Бура бурау остасы. *[Кәбир] Ишегалды ягына керде һәм бурачыларны карарга булды.* А.Гыйләҗев

**БУ́РГЕР** *и. ингл.* Гамбургер, чизбургер һ.б.ш. Америка кухнясы ризыкларының гомуми исеме. *Бургер әзерләү*

**БУРГОМИ́СТР** *и. нем.* 1) Европадагы кайбер дәүләтләрдә шәһәр үзидарәсе башлыгы

2) Пётр I заманыннан алып XIX гасырның 60 нчы елларына кадәрге Россиядә: шәһәр идарәсе башлыгы. *Моның өстенә шәһәр бургомистры ярдәмчесе --- аякларын көчкә-көчкә сөйрәп йөрүчеләрне дә, үзе карап торып, әледән-әле, мәрхәмәтсез төстә җәзалата икән.* Ш.Рәкыйпов

**БУРГОМИ́СТРЛЫК** *и.* Бургомистр хезмәте һәм вазифасы

**БУРДАК** *и. тар.* Эчемлекләр салу өчен савыт. *Казаннарда туктаусыз ит пеште, бурдаклардан туктаусыз эчемлек акты.* Н.Фәттах

**БУРЖУА** *и. фр.* 1) Буржуазия сыйныфы вәкиле, хосусый милекче. *Байтак еллар үткән шуннан соң, Царизм да, буржуа да беткәч, Аның белән тагын очраштым.* Х.Туфан

2) *тар.* Көнбатыш Европада феодализм чорында һөнәрчелек һәм сату-алу белән шөгыльләнгән урта катлау шәһәр кешесе

3) *җый. и.* Буржуазия. *Болар эчендә Себер татарларының буржуасы килеп чыкты.* Г.Гобәйдуллин. *Буржуа кулыннан властьны алмый торып, сугышның тиз генә тукталуын көтәргә ярамый.* Ш.Камал

**БУРЖУАЗ** *с.* 1) Буржуазиягә хас. *Буржуаз мөнәсәбәтләр*

2) Буржуазия хакимлеген чагылдыра яки ныгыта торган; аның ихтыяҗларын, теләкләрен яклый торган. *Халык хуҗалыгы һәм дәүләт белән идарә итүне буржуаз белгечләр кулына тапшыру да бу очракта коткара алмый.* Ә.Борһанов. *Буржуаз идеологиянең төп асыл төшенчәләре: хосусый милек, базар икътисады, демократия...* Ә.Борһанов. *Милли дәүләтчелеккә омтылыш, ишетмәсәгез ишетегез, ул – буржуаз уйдырма түгел.* Р.Мөхәммәдиев. *Чит ил кешеләре, сезгә карап, совет кешесенең нинди булуын, аның буржуаз илләрдә яшәүчеләрдән кайсы ягы белән аерылып торуын беләчәкләр.* М.Юныс

**БУРЖУАЗИ́Я** *и. фр.* 1) Феодаль җәмгыятьтә: шәһәр кешесе

2) Марксистик караш буенча, капиталистик җәмгыятьтә төп җитештерү чараларына һәм җитештерү көчләренә ия булып, яллы эшчеләр хезмәте хисабына өстәмә табыш алып баючы хаким сыйныф. *Көнбатыштагы буржуазия талау юлына басмаган, аның үз байлыгы да җитәрлек булган.* Ә.Борһанов. *Буржуазия – җитештерүче милекчеләр, икътисади тормышны оештыручылар булган ---.* Ә.Борһанов. *Мин, тәмле ашау – буржуазия калдырган гадәт, ашау өчен яшәү –*

*оят максат, дигән фикергә кушылырга мәҗбүрмен.* М.Юныс. *Татар буржуазиясе үзен милләтнең юлбашчысы итеп күрергә теләгән.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

3) *сөйл.* Бай кешеләр (*эшмәкәрләр, олигархлар, мультимиллионерлар*) катламы

**БУРЖУАЗЛАШУ** *ф.* Буржуазиягә хас сыйфатларны алу; буржуазия вәкиле булып китү. *Анда буржуазия дворяннарның буржуазлашкан өлеше белән союзда чыгыш ясый ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**Буржуазлаша бару** Акрынлап буржуазлашу. *Кендегә белән шул сыйныфка береккән бу зыялылар, чынлыкта буржуазлаша барып, Ватанын да үз милке итеп караячаклар, аларда чын зыялылар психологиясе калмаячак та калмаячак.* Ә.Борһанов

**Буржуазлаша төшү** Бераз буржуазлашу

**Буржуазлашып җитү** Буржуазиягә хас сыйфатларга тулысынча ия булу

**Буржуазлашып китү** Буржуазлашу стадиясенә керү

**БУРЖУАЛАШУ** *ф.* Буржуага әйләнү. *Татар «йомышлыларының», буржуалашкан сәүдәгәрләренең мондый фикерләре үз заманының хаким идеологиясе белән каршылыкка керде.* Н.Исмәгыйлов

**Буржуалаша бару** Акрынлап буржуалашу

**Буржуалаша төшү** Бераз буржуалашу; тагын да ныграк буржуалашу. *Беренче рус революциясеннән соң тагын да буржуалаша төшкән либераль язучылар, журналистлар, сәүдәгәрләр ---.* Р.Нуруллина

**Буржуалашып җитү** Буржуага хас сыйфатларны тулысынча алып бетерү

**Буржуалашып китү** Буржуалашу стадиясенә керү

**БУРЖУАЛЫК** *и.* Буржуа идеологиясе, карашлары; буржуага хас сыйфатлар. *Ләкин әле анда [Такташта] вак буржуалык тойгылары үзләрен сиздерә торалар, ул, авылның стихиялелеген җимермәстән, аны революциягә кертүнең юлларын эзли.* Г.Нигъмәти

**БУРЖУАЧЫЛ** *с. сир. к.* **буржуаз**. *--- Һади Такташның беренче чордагы вак буржуачыл, идеалистик карашларына таянып, аны тиешле кыйммәттән мәхрүм итәргә омтылырлар ---.* М.Җәлил

**БУРЖУАЧЫЛЫК** *и.* 1) *к.* **буржуалык.** *--- матбугатыбыз мәгънә ягыннан элекке милләтчелек, динчелек, буржуачылык сөремнәреннән котылып килсә дә, тыш яктан әле элекке мәдрәсә, Мисыр-Истамбул сүзләреннән ясалган гарәпчелек сәләмәләреннән азат була алганы юк.* Г.Ибраһимов

2) Буржуазия яклы булу. *Күп иптәшләр сине мактап сөйләделәр. Кайберләре сине буржуачылыкта гаепләделәр.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**БУРЖУЙ** *и. рус* **1.** *гади. с. к.* **буржуа**. *Иллә комсыз, иллә кансыз да инде «буржуй» дигәннәре.* Г.Бәширов. *Соңгы кабат яулык болгар өчен, Палубага чыкты Буржуйлар.* Х.Туфан. *[Вилдан:] Син аны беләсеңме? [Хәлил:] Белмичә, сезнең цехтан инженер, буржуй.* А.Гыйләҗев. *Буржуйлар һәм алпавытлар үзләренең элеккеге – патша вакытындагы хакимлекләрен, мал-мөлкәтләрен кире кайтарып алырга телиләр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**2.** *с. мәгъ.* 1) *к.* **буржуаз**. *Син, әлегә, Буржуй илләрнең ---, Аларның бер гади бәндәсе.* Х.Туфан

2) *сөйл.* Зур, бик каты бүлтәеп чыккан. *Кайсы кайда урын табып, кешеләр йоклап беткәч тә, Ишәй абзый калай мичкәдән ясалган буржуй корсаклы мич каршында утыра бирде.* Ш.Бикчурин

**БУРЖУ́ЙКА** *и. рус гади. с.* Төтен юлы зур булмаган тимер мич. *Йорт нык суынган. – Буржуйканы ягып җибәр, – диде Рамил.* Я.Шәфыйков

**БУРЗАЙ** *и. рус* 1) Нечкә озын аяклы, очлаеп килгән озынча танаулы ау эте токымы, чапкыр эт. *Бу – аның кәсебе: атларын һәрвакыт таза, көр тота, ә көз җитеп, беренче кар төшкәч, шул атларның берәрсен иярләп, төлке, бүре сугарга да чыга иде. Шуның өчен генә ул ике бурзай да асрый иде.* Ә.Еники. *Сәет-Әхмәт, шигырь аңламавы өстенә, бик гарьчел дә иде, күзе киек исен сизгән бурзайныкы кебек сузайды, ул, кулы белән, мәчет эченә тулган кешеләргә ишарәләде.* Г.Зәйдулла. *[Этләрнең] Бер ишесе, эзгә төшеп, җанварны урыннан кузгатучылар, бер ишесе – бурзайлар, болары, кай яклары беләндер, әкәмәт зур борчаларны хәтерләтәләр.* Ә.Гаффар // Ау эте, чапкыр эт; теләсә нинди зур гәүдәле, мәһабәт кыяфәтле эт. *Куян аулыйсың килсә, бурзай ал.* Мәкаль. *Бүре тотар бурзай эт бөереннән беленер, бүре сугар ир-егет беләгеннән беленер.* Мәкаль. *Дүртенче көн китте, дигәндә, аларны --- эткәләп-төркәләп, бурзайларыннан талатып, агач вагоннарга тутырдылар.* Г.Кашапов. *Кечкенә эт бик зур бурзайга өрә икән.* А.Хәсәнов

2) *сөйл. кимс.* Гәүдәгә зур яшүсмер, кеше. *[Рәфис:] Ач ишекне, бурзай. [Галиулла:] Син сүзеңне үлчәп сөйлә, ярыймы. Күрсәтермен мин сиңа бурзаеңны.* Т.Миңнуллин. *Малайлар каршына авыл советы рәисе килеп басты: – Ну, бурзайлар! Тәмле булдымы бәрәңгегез?* Р.Бәшәр

**БУРИ́ЛЬЩИК** *и. рус сөйл.* Скважиналар бораулаучы эшче, оста. *Һәй, туган, бурильщик булу өчен, аңа биш пот тоз ашарга кирәк әле!* Ш.Бикчурин. *Әсәрнең үзәгендә – бурильщик Кәрим Тимбиков.* Х.Камалов

**БУ́РКА** I *и. төрки этн.* Кавказлыларда: җиңсез, плащ сыман киез кием. *Йонлач бурка бөркәнгән, сөңге тоткан ике атлы урам буенча чабып узды.* И.Гази

**БУ́РКА** II *и. төрки этн.* Кунычы киез яки тукымадан сырып тегелгән, күн (соңрак резин) табанлы аяк киеме. *Ул озынчарак буйлы, арык йөзле, башына – каракүл бүрек, өстенә – утырма якалы зур кара толып, аягына сары бурка белән резинка галош кигән.* Г.Ибраһимов

**БУРЛАК** *и. иск.* 1) Елек: елгаларда, төркемләп, аркан белән пароход, баржа тартучыларның берсе. *Бурлаклар кырыйга чыгып, кайберләре утын җыеп килеп, шунда ук ут ягып җибәрделәр.* М.Гафури. *Нәрсә, без, Калач шәһәрен эзләп, сал тартып бара торган бурлаклар көненә калдыкмыни?* Н.Исәнбәт

2) *диал.* Хезмәтче; кара халык. *Акчарлакның ачы авазларын Тыңлыйтыңлый, халкым, уйлап бар: Өзелерме*

*аркан йә түземлек, – Булырбызмы мәңге бурлаклар?..* И.Юзеев

3) *сөйл. кыек килешләрдә. к.* **бурлаклык.** *Гомере буе башы бурлактан кайтмаган Гаделшаның.* Г.Толымбай

**БУРЛАКЛЫК** *и.* Бурлаклар эше, кәсебе. *Ул зимагурлык, бурлаклык тормышы белән мәңгегә бәхилләшергә уйлый.* М.Гали. *Араларында, байтак кына хатын-кызлар белән бергә, элек вакытта гомер буена бурлаклыкта, зимагурлыкта, көтүчелектә йөргән Чатан Шаһи, Кушавыз Гыймади шикелле, авылның ярлылары, батраклары да бар.* М.Гафури

**БУРЛАНУ** *ф.* Көрәнсу кызылга, кызгылт төскә керү. *Кулымдагы кульъяулыгым яңгыр тигәч бурлана.* Бәет

**Бурлана бару** Торган саен ныграк бурлану

**Бурлана төшү** Бераз бурлану

**Бурланып китү** Кызгылт төс йөгерү, нинди дә булса берәр сәбәптән җиңелчә генә, кинәт бурлану

**Бурланып тору** Әле, хәзер, күз алдында бурланып күренү

**Бурланып чыгу** Бурланган хәлгә килү

**БУРЛАТ** *и.* **1**. 1) Куе кызыл төс. *Бурлат та чаршау, ефәк бау, Кор, дисәң дә, кормам, инәкәм.* Җыр. *Елгага да ут капкан бит! Дулкыннар, берчә – бурлат кызыл, берчә чи сары телен чыгарып азарына ләса.* Г.Якупова. *Бал-маскарад беткәндә, аларның чырайлары бурлат кебек иде инде.* Ф.Садриев

2) Шундый төстәге тукыма

**2**. *с. мәгъ.* Куе кызыл төстәге тукымадан тегелгән. *Бурлат чаршау шәүләсе [кызның] битенә төшә.* К.Нәҗми

**БУРЛА́У** *ф. диал.* Акбур белән агарту. *Олы кодаларның морҗасын Ап-ак бурлар белән бурлаган.* Җыр

**Бурлап алу** Тиз арада бурлау

**Бурлап җибәрү** Бераз бурлау

**Бурлап кую** Бурлаган хәлгә китерү

**Бурлап ташлау** Бик тиз вакыт эчендә бурлау

**Бурлап чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр бурлау

**БУРЛЫ** *с.* Кызыл өстендә ак таплары булган (гадәттә ат төсе турында). *Аның [атның] коласы да, җирәне дә, алмачуары да, бурлысы да була икән!* М.Мәһдиев. *Ул, икенче көнне, Миңлегалинең яратып җигә торган бурлы атына башак биргәндә, атның башын кочаклап озак елады, ул көнне бурлыга онны бер соскычка күбрәк сипте.* М.Мәһдиев. *Гусар яткан арбаны тарткан ике бурлы бия бер уңайга атлыйлар да атлыйлар.* З.Зәйнуллин

**БУРЛЫК** *и. сөйл.* Караклык, угрылык. *Аннан киләчәктә башкаеңның ни күрәчәге өчен курку китми: хакимнәрнең әллә ниткән бәхетләр, игелекләр ышандырып кытыклауларына, ә үзләренең астыртын бурлыгына, азуның чигенә җитүләренә чыдарлык түгел.* Ә.Гаффар. *Остарып беткәнсез бурлыкка. Минә ничек? Кеше таламакчы.* Ә.Баянов. *Ачтан үлсәм – үләрмен, әмма баламның бурлыгын күтәрә алмам.* Р.Мулланурова

**БУРМИСТР** *и. пол.< нем. тар.* Крепостнойлык заманындагы Россиядә: алпавыт утары белән идарә итүче; 1861 елгы реформадан соң: эре волостьларда старшина

**БУРМИ́СТРЛЫК** *и. тар.* Бурмистр вазифасы һәм хезмәте

**БУРОВОЙ** *с. рус* **1.** Җир токымнарын бораулау белән бәйле. *Әйе, кая гына карасаң да яңалык биредә: буровой вышкаларын, тәгәрмәчләр куеп, рельстан тәгәрәтеп йөриләр, скважиналарны кыеклап бораулыйлар.* Ш.Бикчурин

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* 1) Скважина янындагы ярдәмче корылмалар (каланча һәм будка). *Ә бездәге буровойлар – исәпсез-хисапсыз.* Ф.Яруллин. *Һәрбер буровой өчен директор да, баш инженер да, участок начальниклары да куярга мөмкинлекләре юк бугай шул…* М.Хәсәнов

2) **буровойлар** *сөйл. к.* **буровойчы**. *Ул әби, буровойлар килгәч, өйләрне сүтәләр, авылларны күчерәләр, дип тә сөйләп чыкты.* А.Әхмәт

**БУРОВОЙЧЫ** *и.* Җир токымнарын бораулаучы яки шуңа мөнәсәбәтле эшләрдә эшләүче

**БУРРЕ** *и. фр.* Борынгы француз биюе, хоровод

**БУРРЕТ** *и. фр.* Түбән сыйфатлы ефәк җепләр әзерләүгә китә торган чимал калдыклары

**БУ́РСА** *и. лат.* 1) Урта гасырларда: ярлы студентлар өчен тулай торак

2) Революциягә кадәрге Россиядә: дини мәктәп, семинария каршында дәүләт хисабына тотылган тулай торак

3) Шундый тулай торагы булган дини мәктәп, семинария

**БУРСАЛАНУ** *ф. диал.* Борчылу, кайгыру. *[Сөләйманның качып йөрүенә] Киная дип уйлап, ул бурсаланды.* К.Тинчурин

**Бурсалана башлау** Бурсаланырга тотыну

**Бурсаланып алу** Бераз борчылу, кайгыру

**Бурсаланып тору** Хәзер, сөйләү моментында бурсаланган булу

**БУРСУ** *ф.* 1) Бозыла башлаудан исләнү, сөрсү (азык-төлек турында). *Өстәлдә торганга, май бурсыган*

2) Дымланудан күгәрү, черү. *Биек, бурсыган такталы койма артыннан --- үбешү тавышы гына яңгырады.* А.Гыйләҗев

3) Авыр исләр катнашудан, дымланудан һәм бөркүлектән, сулау өчен һава начарлану (бүлмә, торак урыннар, транспорт турында). *Кечкенә бүлмә һавасы бөтенләй бурсыган иде*

4) *күч.* Борчылу, пошыну. *Гафиятулланың күзен йокы алмады. Әле бер ягына, әле икенчесенә әйләнеп, озак кына бурсып ятканнан соң, йоклап булмаслыгына тәмам ышанып, кинәт сикереп торды.* Ф.Хөсни

**Бурсый бару** Торган саен ныграк бурсу

**Бурсый төшү** Бераз бурсу

**Бурсып бетү** Тулысынча бурсу. *Олы-олы тарихчыларга, өлкән язучыларга ул «бурсып беткән мәдрәсә белеме белән, университет бетермәгән башыгыздан, сез ничек итеп тарихка тирән керә алырсыз икән» кебегрәк фикер әйткәне хәтердә калган.* Р.Батулла

**Бурсып китү** Бераз бурсу, бурсыган хәлгә килү. *Мәдинә, берничә йөз кешенең тирләвеннән бурсып киткән һаваны җилләтү өчен, --- тәрәзәне ачты.* К.Нәҗми

**Бурсып тору** Билгеле бер вакыт дәвамында бурсу

**Бурсып яту** 1) Озак вакытлар дәвамында файдаланмаудан, күптәннән тотылмаудан бурсыган булу. *Тик торганчы, тун итәгең уа тор, дисәгез, оланнар, шушы Николай патша тагарагы төбендә бурсып яткан бүкәннәрне бераз кымшандырып карамыйсызмы, диюем.* К.Миңлебаев

2) *күч.* Һавага чыкмыйча, бина эчендә озак вакыт булу. *Һаман шулай китап тузаны сулап, тынчу бүлмәләрдә бурсып ятмасыннар – кайтып, әти-әниләренә хезмәт итсеннәр, ди торганнардыр инде.* С.Поварисов

3) *күч.* Кеше белән аралашмау, яңалыклар белән кызыксынмау. *Әллә ул бары тик безне – «генерал утарында бурсып яткан буржуйларны» уятыр өчен генә, мәҗлесне кыздырыр өчен генә сөйлиме?* Р.Батулла

**БУРСЫК** *и.* 1) Сусарлар семьялыгыннан, очлаеп килгән башлы, озын тупас йонлы ерткыч җәнлек; *русчасы:* **барсук.** *Каршыдагы егет аңа, үзенең шомалыгы һәм елтыр күзләре белән, нигәдер, бурсык сыман тоелды.* М.Мәһдиев. *Ул карт заманында бу тирәләрдә аккошлар, торналар, бурсыклар булган.* Г.Бәширов. *Бал кортлары исәбенә генә тукланырга күчкәч, бу кош яңа ояларны да эзли башлый, ә, тапкач, умарта семьясын үзе генә җиңә алмаганлыктан, көчлерәк юлбасарларга: --- бал ашаучы бурсыкларга үзенең табышы турында кычкырып хәбәр итә.* Кызыклы физиология. *Өлкән бурсыкның авырлыгы көз көне 14–18, ә кайчак 20–26 килограммга җитә, озынлыгы да 70–90 сантиметр тәшкил итә.* Кызыклар дөньясында

2) Шул җәнлекнең тиресе

**БУРТАШ** *и.* Кальциттан һәм башка катышмалардан гыйбарәт булган, төзелештә, химия сәнәгатендә, авыл хуҗалыгында кулланыла торган утырма токым; известьташ. *Йорт нигезләре, базлар кору өчен, таш биналар сүтелә, известь өчен бурташ яндырыла.* Мирас

**БУРЫЧ** *и.* 1) Кире кайтару шарты белән, кемгәдер бирелгән яки кемнәндер алынган акча, әйбер; әҗәт, бирәчәк, көтәчәк. *Бичара хатын аның өчен муеныннан бурычка батkандыр, үзе ипи белән суда гына утыра торгандыр...* Ә.Еники. *Нәҗип дәшмәде, күңеленнән генә кемнәргә, күпме акча бурычы барлыгын санап барды.* А.Гыйләҗев. *Бурычны, алдан сөйләшкәнчә, ит-май ише нәрсә белән каплаячак.* М.Хәсәнов

2) Һичшиксез үтәлергә тиешле эш. *Ул [Әнвәр] аны намус бурычы дип карый иде.* Х.Камалов. *[Анисимов:] Шуңа өстәп, яңа план, яңа бурычлар турында да берничә сүз әйтерсез.* Р.Ишморат // Үтәлүе мәҗбүри булган конкрет эш, йөкләмә. *Эшче – фидакяр, ул үзенең ил алдындагы бурычын тоеп эш итә.* С.Сөләйманова. *Йөкләтелгән бурыч шундый зур булганга, карт үзен Якты Күлдән Кызылкортларга җибәрелгән илче итеп уйлады.* Г.Ибраһимов. *Шушы сугышларның берсендә Нуруллинга бик зур бурыч йөкләделәр.* А.Шамов. *Сугышчан бурычны сезгә майор Гыймаев аңлатыр.* Ф.Латыйфи // Төгәл максат. *Бурыч белән намус, нигәдер, күп вакыт бер-берсенә каршы килә.* Х.Камалов. *Татар музыкасының үзенчәлеген саклаган хәлдә, аны югары техникага ия итү, аны үстерү – шактый авыр бурыч.* М.Җәлил. *Сезнең яхшы укуыгызга ирешү – минем изге бурычым.* М.Мәһдиев // Вазифа. *Инде алар [ата-анам] картайды, бер эшкә дә ярамыйлар. Ашатып, эчертеп, бурычымны түлим.* Дәрдемәнд

**БУРЫЧКА́ КЕРҮ** *ф. к.* **бурычлану**. *Кеше бурычка кердеме, ул, ихтыярсыздан, синең колыңа әверелә.* А.Гыйләҗев

**БУРЫЧЛАНУ** *ф.* 1) Бурыч алу, әҗәткә керү

2) Кемнеңдер каршында җаваплы булу. *Кечкенә бала көннәремдә, һичбер эшкә ярамасам да, ата-анам мине киендереп, асрап үстерделәр. Аларга бурычландым, тәкъсир.* Дәрдемәнд

**Бурычланып бетү** Бурыч күп булу, бурычка бату

**Бурычланып китү** Кинәт кенә бурычлану. *Менә бурычланып киттеләр. Кәримгә ике мең тәңкәгә йортлары залукта булган, ул саттырырга тели башлаган.* Г.Исхакый

**Бурычланып тору** Әледән-әле бурычка алу

**БУРЫЧЛЫ** *с.* **1.** 1) Бурычы булган, әҗәткә алган. *Ә эш табарбыз. Димәк, урнаштырган өчен, фирмага 150 доллар бурычлы буласыз.* Ф.Җамалетдинова

2) Тиешле. *Үзләренә хезмәт итәргә бурычлы кәнизәк дип карыйлар.* Ф.Әмирхан

**2.** *хәб. функ.* Яхшылык белән кайтарырга тиешле. *Ир-ат әгәр дә бөек җиңүләргә ирешә икән яки зур гамәлләр кылырга сәләтле икән, беренче чиратта, ул моның өчен хатын-кызга, бары тик хатын-кызга гына бурычлы!* З.Хөснияр

**БУРЫЧЛЫЛЫК** *и.* Бурычлы булу. *Тәрбия һәм үзтәрбия егетләр һәм кызлар өчен органик бердәмлек булып кушыла, чын мәгънәсендә җаваплылык, бурычлылык, дисциплина халәте барлыкка килә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**БУРЫЧЧЫ** *и.* Бурычка биреп торучы; кредитор. *Болар [завод капкасы төбендәге хатыннар], башлыча, икегә бүленәләр. Бер төрлесе – бурыччылар: квартир хуҗасы, кибетче, яшерен аракы сатучы кебекләр.* Г.Ибраһимов

**БУРЯТ** *и.* Телләре монгол телләре семьялыгына караган, шаманизм да саклаган һәм шулай ук будда динен дә тоткан, Бурятиядә яшәүче төп милләт атамасы һәм шул милләтнең бер вәкиле (үзатамалары – *буряад*). *Хәтерлисездер, шагыйрьнең рус, белорус, казак, бурят, корея, тау халыклары, Кырым, Ерак Көнчыгыш әкиятләре һәм легендаларына таянып язылган күп кенә әсәрләре бар.* З.Мансуров. *Кояш чыкканда Җыр яңгырый таудан Кайгы-сагышсыз. Бурят та җырлый, Ойрот та җырлый ---.* Ш.Маннур. *Мәйдан уртасында милли киемле баһадир аучы бурят басып тора.* Г.Әпсәләмов. *Бурятларда луслар ир-ат һәм хатын-кыз (лусут эхенер), ягъни Су кызы җенесеннән булырга мөмкин.* Татар мифлары

**БУРЯ́ТЧА** *рәв.* **1.** Бурят телендә. *Бурятча сөйләшү. Бурятча уку*

**2.** *с. мәгъ.* Бурятларга хас булган. *Бурятча йола*

**БУСАГА** *и.* 1) Ишекнең, тәрәзәнең (сирәк кулланылышта) аска яткырып

салынган борысы. *Кияү ишектән кергәндә, бусагада сузылып яткан хатын-кыз яшьләр арасында иң өлкәне иде.* Н.Фәттах. *Мин, бусага төбенә килеп, ишек ярыгыннан гына шул якка күз ташладым.* Р.Зәйдулла. *Тәрәзәнең бусагасы бик киң микән, тар микән, Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бик киң микән, тар микән. Хафизә күк матур ярлар бу дөньяда бар микән, Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бу дөньяда бар микән?* Г.Камал

2) Су төбендә ташлардан барлыкка килгән калкулык. *Дон буйларында, Днепр бусагалары тирәсендә казаклык иткән рус качкыннары (бродниклар), ә андыйлар мондый болганчык чорларда аз булмаган, Батый чакыруы буенча, үз теләкләре белән, яңа хезмәткә үткәннәр.* М.Гайнетдинов. *Бусагаларга, шарлавыкларга һәм сайлыкларга бай булган көчле агымлы елгаларда йөзүче сиглар, сёмгалар, кутәмәләр һәм башка балыклар – бик яхшы сикерүчеләр.* Су асты дөньясы

3) *күч. кит.* Нәрсәнең дә булса башланышы, алды. *XXI гасыр бусагасына без һәммәбез – бөтен кешелек дөньясы – зур өмет һәм ышанычлар белән аяк баскан идек.* Р.Низами. *Табигать үзе конструкцияләгән бу гаҗәеп җылы алмаштыргыч гәүдәнең периферијасенә китүче канга үзенең артык җылысын май барьеры бусагасында калдырырга мөмкинлек бирә.* Кызыклы физиология

4) *күч. кит.* Нигез, туган җир. *Сезнең кебек янып яшәмәсәк, Кабул итмәс туган бусага.* М.Әгъләмов

◊ **Бусага атлау** Керү. **Бусагага бару (килү, егылу)** Кемгә дә булса үтенеч, гозер белән килү. *Минем улларым бервакытта да андый үтенеч белән кеше бусагасына бармаслар.* А.Шамов. **Бусага таптау** Кемгә дә булса, үтенеч белән, бик еш мөрәҗәгать итү. *Менә хәзер инде шул юл өчен нефтьчеләр бусагасын таптый.* Х.Камалов

**БУСАГАБАШ(Ы)** *и. тар.* Ишекне ачып, килгән кешене каршы алып, киткәнен озатып торучы сарай хезмәтчесе. *Шул турыда уйлап утырганда, кулына ут тоткан бусагабаш килеп чыкты.* М.Хәбибуллин

**БУСАГАЧЫ** *и. тар. к.* **бусагабаш**. *Бусагачы хан мәчетенең мәзине килүен хәбәр итте.* Р.Зәйдулла. *Бусагачы аңа гаҗәпләнеп карады.* Р.Зәйдулла

**БУСАНУ** *ф. диал.* 1) Пошыну, тынычсызлану, хафалану; ачу килү, ачу кабару. *Йокы алмый бусанып яту*

2) Эсселәп тирләү, кызышу, кызу. *Кайнар мунчада хуш исле себерке белән кат-кат чабынып, бусанып, чәй эчеп, янә чабынып, коенып, тышка – эссе һавага чыксаң, челләнең эссесе сизелмәс.* Р.Батулла. *Әйтерсең вак-вак күмер тузаннары шулай җемелдәшеп яна, тәне кызыша, гасабиланган җаны бусана.* Н.Хәсәнов

**БУСАРЫНУ** *ф. диал.* 1) Нык дулкынлану; кайгыру, борчылу, пошынып газаплану. *Ярсып, бусарынып, һәммәсе кычкыралар, йодрык күрсәтәләр, кулларын болгыйлар; муеннарын сузып, аяк очларына басып, һәммәсе лапас эченә, аның да җир иденә карыйлар.* Г.Бәширов

2) Йөзе кызарып бүртенү, чырай үзгәрү. *Сельпо кешесе белән мөгаллим сәгатьне алып капчыкка төргәндә, ишектән, бусарынып, төсләрен бозып, баягы алъяпкычлы хатын килеп керде.* Г.Бәширов

**Бусарынып йөрү** Соңгы вакытта яки күптәннән бусарынган булу. *Шул уйлары белән бусарынып йөргән чакта, кешеләр Шәвәли картны ашка чакырып алдылар.* Г.Ахунов. *Өстәл белән тәрәзә арасында бераз бусарынып йөрде дә Гайнанга дәште: – Йә, син нинди акыллы эшләрең белән куандырмакчы буласың?* Г.Бәширов

**БУССОЛЬ** *и. фр.* 1) Магнит меридианы белән нинди дә булса юнәлеш арасындагы горизонталь почмакларны үлчи торган геодезик корал. *Яңа җирләрнең картасын карау, буссоль сайлап алу һәм башка шундыйрак эшләрен бетергәч, Равил үзенең бер якын иптәше Мусин Камил гаиләсенә кереп чыгарга булды.* И.Хуҗин. *Асма буссоль*

2) Компастан, почмак үлчәгеч түгәрәктән, монокулярдан яки перископтан торган артиллерия коралы

**БУТА** *и.* 1) Бер яшькә кадәрге дөя баласы. *Бутасыннан аерылган дөядәй бузлай калдың син, Күп тубыннан аерылган коштай моңлай калдың син.* Дастан. *Арбаларның, иярле атларның, өйләр арасындагы халыкның саны арткан саен, бу бәйләүле малларга да мәрхүмнең фидиясе өчен дуслары, кардәшләре тарафыннан китерелгән буталар, кысыр бияләр, яшь тайлар, чирле башмаклар, рәнҗү куйлар һаман кушыла бара, кушыла бара...* Г.Ибраһимов

2) **бутам.** Иркәләп мөрәҗәгать итү сүзе. *Килер-китәр юлыңа киндер чәчтем, яр-яр, Киндер китән булганчы, килгел, бутам, яр-яр.* Җыр

**БУТАВЫЧ** *и. к.* **бутагыч**

**БУТАГЫЧ** *и.* 1) Бутау, болгату өчен җайланма. *Илсөя, бер кулына май канаты, икенче кулына күкәй бутагыч тоткан килеш, ишектән башын сузып, Шәмсигә ымлады.* Г.Мөхәммәтшин

2) *күч. сөйл.* Үзара мөнәсәбәтне бозучы, ике арада йөрүче кеше

**БУТАДИЕН** *и. гр.* Туендырылмаган алифатик углеводород, исе үзенчәлекле төссез газ

**БУТАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бутау** (*1–4, 6 мәгъ.*)

2) Чорналып, уралып, хәрәкәтләнергә комачаулау. *Егете чалбар чабуына буталып йөрүче бер баламут булса икән. Чибәр, акыллы, бик әдәпле!* А.Хәсәнов. *Хәлим, буталып барган чалбар чабуларын кесәләреннән тотып, кызу-кызу атлый.* И.Гази

3) Нәрсәнең дә булса тирәсендә еш булу, янында, эчендә вак-төяк эш эшләү, кайнашу. *[Галиулла:] Тракторда идем, хәзер мастерскойда буталам шунда.* Т.Миңнуллин. *Тартып чыгарыр идем, су буенда сыер савучылар бутала.* Т.Миңнуллин

4) Бергә кушылып, тәртипсез аралашып бетү. *Аның тавышы, барыбер, төнге тулай торак гүелдәвенә кушылып буталачак иде.* Н.Гыйматдинова. *Көпә-көндез кеше эзләп киләм, Кеше диңгезендә буталып.* А.Хәлим. *Мәйдан буталды.* М.Гафури. *Яңгыр эченнән барам, бер тавышсыз, балык кебек. Тыным кысылган, аяклар буталган, күк асылынган.* М.Галиев

5) *шелт.* Берәү белән бәйләнү, бәйләнешкә керү. *Аның эше тыгыз,*

*вакыты юк синең белән буталырга.* Ш.Бикчурин. *[Яңа кеше] Эчмиме, тартмыймы, хатын-кыз белән буталмыймы?* Ш.Бикчурин

6) Бәйләнеш, эзлеклелек, аныклык югалу; ялгышу. *Син күп укыгансың, әмма үзең буталасың ---.* Г.Ибраһимов. *--- кичәге кара күзләр, кайнар үбү һәм Вәдүтләрнең несчастный өч үрдәк бәпкәсе – барысы бергә буталды.* М.Мәһдиев

7) Адашу

**Бутала бару** Торган саен ныграк буталу

**Бутала башлау** Буталырга тотыну. *Тәбрикнең күңелендә тагы аңлаешсыз фаразлар бутала башлады.* Ә.Баян

**Бутала тору** Әледән-әле буталу. *Миңа Филәриттән сорарга иде, сәхнә тирәсендә бутала торган кеше бит.* Аманулла

**Бутала төшү** Бераз буталу

**Буталып алу** 1) Аз гына вакытка буталу, фикер эзлеклелеген аз вакытка югалту. *--- болай эшләсәк, ни... Болай итик без, – дип буталып алды, шул арада фикерен авылны тоташ күмәкләштерергә килгән вәкил һичшиксез аңларлык итеп түгәрәкләргә тырышты.* М.Хуҗин

2) *күч.* Кыска гына вакыт дәвамында гыйшык уены уйнау

3) *күч.* Кыска вакыт эчендә үзара мөнәсәбәтләр бозылу

**Буталып бетү** Тулысынча, тәмам буталган хәлгә килү. *Башкаларның да язмышлары буталып беткән.* Г.Ибраһимов. *Шуны уйлап --- буталып беттем.* Ш.Камал. *Охшаш яңгырашлы әлеге атамалар аның башында тәмам буталып бетте.* Ә.Мушинский. *Бернинди сәбәпсез яктыртырга ярамый, ул чагында ата бөҗәкләр буталып бетәр иде, утлачлар ыругы җир йөзеннән юкка чыгар иде.* Кызыклы физиология

**Буталып җитү** Тиешенчә, катышып беткәнче буталу

**Буталып йөрү** 1) Озак вакыт, бертуктаусыз әрле-бирле килеп буталу. *[Эт] Ашарлык берәр нәрсә таммасмы дип, янымда әрле-бирле буталып йөрергә тотынды.* С.Җәлал

2) Нәрсәне дә булса таба алмыйча адашып әйләнгәләү. *Штабны эзләп, шактый буталып йөрдем.* А.Шамов

**Буталып калу** Кинәт кенә дөрес җавап таба алмыйча аптырау, вакытлыча төгәл бер фикергә килә алмыйча тору. *– Буталып калдым әле мин, доктор Зәйтүнә, – диде ул [Мөдәррис].* М.Маликова. *--- беренче мәртәбә уңышсызлыкка очраудан, очсыз-кырыйсыз лабиринтка охшаган төзелеш проблемалары эчендә буталып калуыннан гаҗиз булуын тойды.* Р.Вәлиев

**Буталып килү** Күптәннән, озак вакытлардан бирле буталу. *Эш шунда ки, тарихи әдәбиятта халыкның оешу дәвере --- күп еллар дәвамында ясалма рәвештә буталып килде.* Р.Әмирхан

**Буталып китү** Нинди дер бер моменттан, көтмәгәндә, кинәт бутала башлау. *Әгәр вакыйгалар бер-берсен узышып, көннәр-айлар, хәтта ки еллар буталып китә икән, моңа вакыт гаепле.* А.Гыйләҗев

**Буталып кую** Кинәт, бер тапкыр буталу

**Буталып тору** Әледән-әле, еш буталчыклык барлыкка килү. *Дөнья буталып тора, казна урманында качкыннар пәйда булган, ди.* К.Тинчурин

**Буталып яту** Буталган хәлдә булу

**БУТАЛЧЫК** *с.* **1.** 1) Буталган, чуалчык. *Игнатюкны тыңлаганда да, беркетмә язганда да, Ибраһимовның башында, буталчык җеп бәйләмнәре кебек, төрледән-төрле юрама, тикшерү юнәлешләре барлыкка килә торды.* М.Насыйбуллин

2) Тәртипсез, оештырылуы түбән дәрәҗәдә булган яки бөтенләй оештырылмаган. *Мәдрәсә тормышы, андагы шәкертләрнең буталчык хәятлары һаман бер көе дәвам итте.* М.Гафури

3) Авыр аңлаешлы яки бөтенләй аңлаешсыз, бәйләнешсез. *Чыңгыз, Батый ханнарга, татар-монголларга карата минем эчемдә нинди дер буталчык, капма-каршылыкка баткан тойгылар яши иде.* М.Юныс. *Таң алдыннан йоклап китте, тик йокысы тыныч булмады: буталчык төшләр күрде, саташты, нидер сөйләнде, кычкырынды.* Б.Камалов. *Әхмәтшаның буталчык аңлатуын парторг түземлек белән тыңлый.* А.Расих

4) Катлаулы, четерекле; каршылыклы. *Пичуговның тормышына һаман төшенеп җитә алмый әле Кәрам. Сәер, буталчык нәрсә.* Ш.Бикчурин. *Ул ни әйтер, бу гаҗәеп сәер, буталчык хәлгә нинди ачыклык кертер – шуны ишетәсе килә иде.* Ә.Еники. *Тик миңа, аңа эндәшү өчен, үзенең һәм атасының исемен әйтермен, димә инде. Буталчык, озын, нинди дер эт эчәгесе...* Ш.Бикчурин

5) Озын һәм аңлау өчен авыр булган. *Ә без бирердә бик үк аңлашылып җитмәгән буталчык җөмләләр генә күрәбез.* Р.Миңнуллин

6) Болганчык, болгавыр, тынычсыз (ел, заман, чор турында). *Теге буталчык төнне Гәүһәрия, ни уйлап, калырга риза булды икән?* А.Гыйләҗев. *Аларның котын алган бик буталчык, куркыныч вакытлар үтте бит инде.* Ә.Еники. *Буталчык еллар. Буталчык заманда яшибез*

**2**. *и. мәгъ. к.* **буталыш.** *Семьялылар казармасындагы җанлылык бүген бөтенләй башкача --- нәрсәнедер ашыгып көткән вакытта гына була торган ашыгыч бертөрле буталчык күзгә ташлана.* М.Гафури

**БУТАЛЧЫКЛЫК** *и.* Тәртипсезлек, анык булмаганлык, таркаулык, буталыш. *Ни әйткәнен дә һич аңламассың, Буталчыклык дөнья сүзендә...* Б.Рәхимова. *Бүгенге көненең авырлыгы, буталчыклыгы аның тойгыларын, хисләрен тупасландырган иде.* А.Гыйләҗев. *Нәтиҗәдә, шактый буталчыклык хасил булды.* М.Госманов. *Буталчык гомерем сиңа юлыккач, нинди дер мәгънә тапкан кебек булдым. Буталчыклыгы бетүгә таба борылды.* Х.Камалов

**БУТАЛЫ** *с.* Бутасы булган, колынлаган (дөя турында). *Аңарчы тик барган Сарыбай телгә килде: – Ул исәр картка мин, тун белән чапан гына түгел, иярле ат белән буталы дөя биргән булыр идем!* Г.Ибраһимов

**БУТАЛЫШ** *и.* 1) Ыгы-зыгы, тәртипсезлек. *Канталыев шушы буталыш мизгеленнән файдаланды...*

Я.Зәнкиев. *Ләкин, румнарның беренче рәтләрен сытып китә, дигәндә, ташкын сөрлекте, буталыш башланды.* Р.Зәйдулла

2) Ризасызлык белдереп ясалган массакүләм чыгыш, чуалыш, күтәрелеш. *Бу исә сөннәр арасындагы буталышны тагын да арттыра төште.* Н.Фәттах

3) Гауга, талаш. *[Чәпәли чуак] Кешеләр арасында буза, буталыш ясап йөрүче ярым мифик зат.* Татар мифлары

4) Аңлашылмаучанлык; тәртипсезлек. *Икешәр исем буталыш кертә, эзләгән йортны табуны читенләштерә.* М.Юныс. *Димәк, фаҗига Рәхимнең башына яңа җитәкче уйлаганнан катырак суккан, аңын томаландырган, югыйсә ул, әлеге сәбәпне аңласа, бәлки, буталыштан чыгу җаен күптән табар иде.* М.Хуҗин

**БУТАЛЫШУ** *ф.* Тәртипсез аралашу, ыгы-зыгы килү. *Кешеләр үзара буталышкан арада, мин тиз генә таеп өлгердем.* Ф.Хөсни

**Буталыша бару** Торган саен ныграк буталышу

**Буталыша башлау** Буталышырга тотыну

**Буталыша төшү** Бераз буталышу

**Буталышып алу** Кыска гына вакыт эчендә буталышу

**Буталышып бетү** Тәмам буталышкан хәлдә булу. --- *геннар буталышып бетәләр, имгәнешәләр, гарипләнәләр.* З.Хөснияр

**Буталышып йөрү** Бертуктаусыз ыгы-зыгы килеп буталышу. *Керә-чыга, мәш килеп, буталышып йөрделәр...* М.Насыйбуллин

**Буталышып китү** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт буталышу

**Буталышып тору** Әледән-әле буталышу

**Буталышып яту** Буталып таралган, сибелгән хәлдә булу. *Өстәгеләргә берниндиди ышаныч юк, үзара буталышып яталар шунда.* М.Маликова

**БУТАН** *и. гр.* Нефть куганда табыла торган, углеводородка бай органик кушылма, табигый газлар компоненты. *Аннары чималны изобутан һәм гади бутанга таркаталар.* М.Зарипов

**БУТА́У** I *ф.* 1) Төрле нәрсәләрне кушып аралаштыру, болгату. *Кәлимуллин кисәүләрне бутаган таягын ямып торган учакка ыргытты.* Г.Иделле. *Оя каты чыбыкларны бер-берсенә аралаштырып, бутап, беркетеп ясалган иде, тиз генә сүтелмәде.* М.Мәһдиев

2) Эченә катнаштыру, кушу, өстәп салу. *Аю мае бутап, сөт җылытып эчте, мәтрүшкәле, җиләкле чәй ясады, аю тамырын – женьшеньне – төнәтергә куйды.* Х.Ширмән

3) Нәрсәнең дә булса урнашу тәртибен, эзлеклелеген бозу, урынын буташтыру

4) Нәрсәне дә булса катлауландырып, үзгәртеп чуалту, аңлашылмый торган итү. *[Мария:] Дөньясы буталды шул. [Нурхәмәт:] Буталмады. Бутадылар.* Т.Миңнуллин

5) Аралаштырырга, берләштерергә ярамаган нәрсәләрне кушу, бер рәткә кую. *Бу әсәрдә Нәҗминең төрле вакыйгаларны [әһәмиятләре төрле дәрәҗәдә булуларына карамастан], бутап, аралаштырып йөрүе дә әллә ничек кенә урынсыз кебек тоела.* Г.Нигъмәти

6) *сөйл.* Болгау, изү. *Кайбер җирдә ташкын ярларыннан бәреп чыкты, һәм үзләрен, ничектер, ирекtә дип исәпләгән тоткыннар, кулларын бутап, кычкырып, абына-сөртенә, түбәнгә – үзән ягына ыргылдылар.* Н.Фәттах

7) *күч.* Бер нәрсәне икенчесеннән аера алмау, ялгышу, хаталану. *Тышкы кыяфәт еш кына алдый, бутый.* А.Гыйләҗев. *Чиягезгә карап кайттым кабат, Бутамадым башка өйләрне.* М.Әгъләмов. *Бәдәвиләрне чегәннәр белән бутарга ярамый.* С.Сөләйманова. *Кайсы хатын үз ирен ятлар белән бутый ала?* Р.Зәйдулла // Эзлеклелекне, бәйләнешне югалту. --- *Сәкинә склероз белән газап чигә башлады. Саташа, адаша, бутап сөйли.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Ялгыштыру, саташтыру. *Шайтан бутаганны Алла чишәр, бухгалтер бутаганны кем чишәр?* Әйтем. *Ачуланма, туган, Иблис телемне бутый.* Ә.Еники. --- *сәяси төшенчә булган «дәүләт»не рухи төшенчәле «Ватан» белән бутамасыннар иде.* Мирас

9) *күч.* Кемне дә булса тыелган, ярамаган эшкә катнаштыру, тарту, җәлеп итү. *Зинһар, дип әйтәм, Сафиулла абый, бутама син мине бу эшләргә!* Г.Иделле

10) *күч. сөйл.* Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бозу. *Бу юлы аңа [Шомага] масштаблы эш тапшырдылар – Аксу өлкәсендәге барлык милли көчләрне таркату, халыклар арасын бутау.* Ф.Сафин

**Бутап алу** Тиз генә, бераз бутау. *Хәмдия, ап-ак тигез тешләрен күрсәтеп елмайды да, Булатка: «Хатын-кыз белән менә ничек сөйләшәләр, ә син – «карчык» та «карчык» – дип, аның чәчләрен бутап алды.* С.Таһиров. *– Чынлап! – диде Белугин, кызарынып һәм, иптәшләре белән бәхәсләшкәндәге шикелле, баш өстендә кулларын бутап алды: – Нигә безгә белмәгән кеше?* Н.Фәттах

**Бутап ату** Бик тиз арада, аннан-моннан бутау

**Бутап бетерү** 1) Барысын да салып бутау; тәмам катышканчы бутау

2) Аңлый алмаслык дәрәҗәгә җиткереп бутау. *Зонада, төрмәдә чакта якларның кайдалыгын бутап бетергән иде егет, хәзер, төгәл итеп, көнчыгышны эзләп тапты ---.* Я.Зәнкиев. *– Бар нәрсәне бутап, бозып бетермәсәң ярый инде, – диде әнисе.* Н.Фәттах. *Шулай аңлатып бирмәсәм, язган чагында бутап бетерериең син аны.* И.Сирматов. *Ярый сине җитәкче итмәгәннәр. Бөтенесен бутап бетерер идең.* Г.Нәбиуллин

**Бутап җибәрү** 1) Бераз бутау. *Ул тагын да зуррак күбәләк корты табып китереп түмгәккә ташлады да аны чыбык очы белән бутап җибәрде.* З.Фәйзуллин

2) Ялгыштыру, буталу. --- *димәк, әлеге «фәнни хезмәткәр» дигәнебез, «тел» белән «язу» төшенчәләрен бутап җибәрә.* Ф.Галимуллин

**Бутап йөрү** 1) Озак вакыт дәвамында һәрберсен бутау. --- *ул кадерле хезмәтне «Йолдыз» берлә бутап йөрмәдек.* Г.Исхакый

2) Якларны бер-берсенә каршы котыртып тору. *Син, кызый, белер-белмәс*

*башың белән, әллә ниләр бутап йөрмә!* А.Гыйләҗев

**Бутап китү** Нindidер вакыттан соң бутый башлау. *Казанлыларга хөсетле Шаһгали дөньяны бутап киткәннән бирле, кырмыска оясыдай гөжләгән каланың тынычланып җитә алганы юк.* Ф.Латыйфи

**Бутап кую** Көтмәгәндә, кинәт, ялгыш бутау. *Фәрдәнә әбине кызлар итеп киендерәсеңмени? Кара аны, бутап куймагаем!* Ә.Гаффар. *Зөфәр барыбызның да башын бутап куйды.* Г.Гыйльман

**Бутап ташлау** Бөтенләй аңламаслык дәрәҗәгә җиткереп бутау; астын-өскә китереп бутау. *Ләкин ул картның зиһенен бөтенләй саташтырып, бутап ташлады...* Г.Гыйльман. *Аның, мәрхүмнең истәлек-йоласын тоту вакытын көтмәстән, Джульеттаның ниятләрен бутап ташлап, кызының туен бер көнгә алга күчерергә карар кылуы шул хакта сөйли.* Татар театры

**Бутап тору** Бертуктаусыз, әледән-әле бутау. *Үлчәү генә кайчак, тибрәнгәләп, Төшергәләп тора «майлылар»ны. Әле – анда, әле монда салып, Бутап кына тора «җәйлылар»ны.* Н.Сафина

**Бутап утыру** Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында бутау. *Син нәрсә бутап утырасың, кычыткан чыпчыгы! Белмәгәнеңә?!* Г.Каюмов

**Бутап яту** Озак вакытлардан бирле, бертуктаусыз бутау. *– Дөньяны бутап яталар шунда! – диде [Хисмәт].* Ф.Яхин

**Бутый башлау** Бутарга тотыну. *Көннең көне прилавка артында торып, күзләр тона, кешеләрне, кинодагы шикелле, бер-берсе белән бутый башлыйсың.* Т.Галиуллин

**Бутый бирү** Бутауны дәвам итү

**Бутый төшү** Тагы да бераз бутау

**БУТА́У** II *и.* Бутап, болгатып бирелгән терлек азыгы. *Бия зур улакта бутау ашый иде.* Г.Ибраһимов

**БУТАФОР** *и. рус* **1.** 1) Бутафория белән эш итүче театр хезмәткәре

2) Бутафория ясау остасы. *Бутафорлар ясаган әйберләр реквизитлар цехында урын алган.* Сәхнә

**2.** *с. мәгъ.* Ясалма, чын булмаган. *Сәхнә уртасында, иркенәеп, иске китель белән төсе уңган хәрби чалбар кигән, биленә бутафор кылыч таккан Җиһангир Биктаһиров басып тора.* М.Маликова

**БУТАФО́РИЯ** *и. ит.* 1) Сәхнә өчен ясалган декорация (чын әйберләрне алмаштырырлык итеп ясалган муляж – җиһазлар, скульптура, савыт-саба, бизәнү әйберсе, корал, кием-салым һ.б.). *Сәхнәдәге тормыш чынбарлыгын тудыруда бутафория предметлары гаять зур урын алып тора.* Сәхнә

2) Нәрсәне дә булса яшерү максатыннан эшләнгән ясалмалылык. *Мин хатыннар янында, иңемә чалгы салып, «печәнче» булып йөрсәм дә, ул бутафориянең кирәге булмады, фашистлар очрамады.* С.Таһиров

3) Реклама максатыннан, күрсәтмәлелек буларак кулланыла торган ясалма (чын булмаган) предметлар

4) *күч.* Мишура, ясалма зиннәтлелек. --- *шигырьнең гомуми төзелеше, олы төшенчәсе югала, җитди драматизм бутафория чүбенә урала. Бу сюжет җитдирәк нәтиҗәгә лаеклы.* Казан утлары

**БУТЕРБРОД** *и. нем.* Бер ягына май ягылган, аның өстенә сыр, ветчина һ.б.ш. ризыклар куелган юка гына икмәк телеме. *Алар, эндәшмичә генә, бутерброд чәйнәделәр.* Р.Зәйдулла. *Вәсилә Хакова конфет кабының капкачын ачты, кечкенә суыткычтан варенье, ике бутерброд алып, тәлинкәгә салды.* М.Хәбибуллин. *Буфетчы хатын өстәлгә балык уылдыгы яккан бутербродлар, казылык, сыр һәм төрле җимешләр куйган.* М.Юныс. --- *рестораннарда аны тәмле, кыздырылган ризык, --- калорияле бутербродлар белән сыйлыйлар.* Иң шәп календарь

**БУТИК** *и. фр.* Танылган маркалы, брендлы, модалы, кыйммәтле товарлар сатыла торган, югары класслы кибет. *Алар белән бергә кыйбатлы бутикларга барып, егетләр, көне буена, фотосессия өчен яраклы киемнәр эзләгәннәр.* Кәеф ничек. --- *олигарх андагы XVII гасырда төзелгән складларны сәнгать галереясе, бутик, отель һәм ресторан итеп үзгәртергә ниятли.* Мәдәни җомга

**БУТИЛ** *и. гр.* Бутаннан бер водород атомын аерганда хасил була торган радикал. *Икенче әһәмиятле сәбәп – әчешү вакытында, организм өчен зарарлы матдәләр: этил һәм бутил спиртлары, сөт һәм май кислоталары, ацетон һәм башка матдәләр барлыкка килүдә.* Кызыклы физиология

**БУТИЛЕН** *и. гр.* Молекуласында ике водород атомы булган, газсыман, чикләнмәгән углеводородлы ациклик матдә. *Ачышның яңалыгы бутиленны таркату процессына эффектлылык китерде.* М.Зарипов. *Арадаш бутилен дивинилга әверелсен өчен, аның молекуласыннан ике водород атомын аерып алырга кирәк ---.* Казан утлары

**БУТИРОМЕТР** *и. гр.* Сөтнең майлылыгын билгели торган прибор

**БУТКА** *и. сөйл.* 1) *к.* **ботка**. *Утыралар, аяк бөкләп, каршы утка, болар инде тәмләп кенә ашый бутка.* Г.Тукай. *Әрәмләр лә булып кала майлы бутка ---.* Х.Туфан

2) Ботка сыман ярым сыек, йомшартылган катнашма. *Ә пресс калаклары туктаусыз әйләнә, тыгыз, дымлы балчык буткасын дүрткел авыз аша өзлексез этеп тора.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Буталчыклык, тәртипсезлек. *Тагы ярты сәгатьтән, көрәкләр кара туфракка җиттеләр. Чокыр янында – тау кебек өелгән кәгазь буткасы.* М.Госманов

**БУТЛЕГ** *и. ингл.* 1) Урлап язылган аудиотасмалар чыгару

2) Шул ысул белән чыгарылган аудиотасма

**БУТЛЕ́ГЕР** *и. ингл.* **1.** 1919 – 1933 елларда, АКШта эчүчелеккә каршы «коры закон» гамәлдә булган чорда, исерткеч эчемлекләрне илгә яшертен кертү, тарату, сату һәм законсыз рәвештә алкогольле эчемлекләр эшләп чыгару белән шөгыльләнә торган кеше яки оешма

**2.** *с. мәгъ.* Законсыз, лицензиясез эшләнгән; контрафакт. *Бутлегер тасмалар*

**БУТОНЬЕ́РКА** *и. фр.* 1) Чәчәк өчен, күлмәккә беркетелә торган пробиркасыман кечкенә савыт

2) Киемгә беркетелә торган чәчәк букеты

**БУ́ТСЫ** *и. ингл. махс.* Футбол уйнау өчен, табанында чыгынтылары яки аркылы планкалары булган, каты башлы махсус аяк киеме. *Әнә бит ул, камыл ерып үскән кәкрерәк ныклы аякларына чит илдә эшләнгән бутсылар киеп, аксөякләр генә уйный торган теннис уенын да, түземлек, үҗәтлек белән, үзенә буйсындырды.* М.Галиев

**БУ́Т ТАШЫ** *и.* Гадәттә, бурташ, доломит кебек ташларны чыгарганда (шартлатканда) хасил булып, фундамент, юллар, гидротехник корылмалар төзегәндә кулланыла торган тау токымнарының зур кисәкләре, акташ. *Бут ташы чыганагы*

**БУТЫ́ЛКА** *и. фр.< лат. сөйл.* Шешә. *Бер атна, буш бутылка төсле, идәндә аунадым, һаман караватюк.* Г.Тукай

**БУТЫ́ШНИК** *и. рус тар. сөйл.* Октябрьгә кадәрге Россиядә: будка янында каравылда торучы полицейский. *Кара сакаллы бутышник та сызгысы белән бергә [полк артыннан] иярде.* К.Тинчурин

**БУУ** *ф.* **1**. 1) Нәрсәне дә булса тартып бәйләп яки өстенә бармак белән басып яисә башкача кысу. *[Дәү әнисе] Ахырда, башындагы ак ситса яулыгын салып, тасма-тасма ертырга тотынды. – Ичмасам, [җәрәхәтне] чүпрәк белән буып бәйлик! – дип ашыктырды.* Ш.Янбаев

2) Нәрсәне дә булса чорнап, урап бәйләү. *– Бичара, кешедән оялып, гел эчен буып йөргән шул, шуның белән харап булды, – дип сөйләнде [хатын-кыз].* М.Мәһдиев. *Көлтә кебек кысып буганга, Бүселмичә торды кайгылар.* М.Әгъләмов. *Алар [малайлар] әтиләренең җәясен тарта алырга һәм каешын буарга тиеш булалар.* Татар мифлары

3) Сулыш, тын алуны авырлаштыру. *Ютәл буа. Суык алды, ахры.* Ә.Фәйзи

4) Сулыш юлларын кысып үтерү; элмәк салу. *Мара – Европа халыкларының түбән мифологиясендә явыз рух, ул төнге кошмар булып килә, кеше өстенә сикерә, аны буа, шулай ук елан рәвешенә керә ала.* Татар мифлары. *Йорт мәчесеннән дә кечкенә булган шушы җәнлек үзеннән шактый зур куян, урман тавыгы, су күсесе һәм, хәтта, үрдәкләрне дә тотып буа.* Кызыклар дөньясында // Бугазны яралап үтерү. *Хәбирә карчыкның нәкъ шундый ала төстәге карт сыерын шул көнне кич әвеслек янында бүре буып китте.* М.Мәһдиев

5) Буа ясап, суның юлын томалау. *«Буа буыйк, буалар!», диешәләр балалар, Ыштаннарын күтәреп, яланаяк чабалар.* Н.Думави. *Буаны быелга будылар болай гына.* М.Мәһдиев

6) *куч.* Юлына каршы төшеп, үткәрмәү, тоткарлык, киртә ясау, каршылыклар тудыру. *Кызыл гаскәргә ярдәм биреп, Явызларның юлын будык без.* М.Фәйзи

7) *куч.* Изү, кысу; үстермәү, мөмкинлек бирмәү; юк итү. *Җәза отрядлары бары тик сине буарга әзер.* А.Гыйләҗев. *Хакыйкатьне буарга җай гына булсын.* А.Гыйләҗев

8) *куч.* Тынгылык бирмәү. *Гарьлек буа аны, көнчелек калтырата иде.* Б.Камалов

**2. буып** *рәв. мәгъ. куч. сөйл.* Ирексезләп; аптыратып; интектереп, йөдәтеп. *Бугазыңнан буып алачак, Урынын-вакытын, хак-нахагын Бәйнәбәйнә тезеп салачак...* Р.Зарипов. *Буып сорау. Буып таләп итү*

**Буа бару** Торган саен ныграк буу. *Менә шулай, ул [яралгы] Барков белән бергә үскән, аны эчтән һаман күбрәк буа барган.* Юлдаш

**Буа башлау** Буарга тотыну. *Җомга намазыннан чыгып барганда, аны буа башлаганнар, халык коткарып калган.* Р.Батулла

**Буа төшү** Тагын да ныграк буу

**Буып алу** 1) Кинәт буу. *Тозак «выжжт», [куянның] муенынан буып та алды.* Г.Мөхәммәтшин. *Җирән чәч аның бугазыннан буып алды.* Р.Сибат

2) Бөтен яктан да буу. *Аклы-каралы ямаулар белән чуарланган, җиңнәре кыскарган бишмәтләрен юкә бау белән буып алган малайлар, билләренә – балталар, култык асларына пычкылар кыстырып, мәктәп янына җыелдылар.* Я.Зәнкиев. *Инде эш уеннан узган – буып алган иҗат.* М.Әгъләмов

**Буып ату** Авыр хәлгә төшерү, изеп ташлау, юкка чыгару. *Авылда буып атачаклар ич сине.* Я.Зәнкиев. *Ир заты малайны бу минута буып атарга да әзер иде.* Х.Ибраһим

**Буып бетерү** Ахыргача, тәмам буу. *--- иң кимендә өч йөз илле кеше барган вакытта да, буаны буып бетерү өчен, бер атналап вакыт кирәк булачак икән.* Н.Фәттах

**Буып җибәрү** Буган хәлгә китерү. *Ниһаять, мин дә үземә ярагандай бер шинель киеп алдым, билемне буып җибәрдем...* Ф.Хатипов

**Буып йөрү** Һәрвакыт нәрсә дә булса буган булу. *[Сәүдәгәр Биккол] --- кара чикмән өстеннән кызыл билбау буып йөргән әрмәннәр аша Багдадка да барды ---.* М.Хәбибуллин. *Алтынчы класста күн итек, галифе чалбар киеп, билен киң каеш белән буып йөргән Рафаэль «үскәч кем буласың?» дигән сорауга, һич икеләнмичә: «Марс Макаров кебек баянчы булам!» – дип җавап бирә.* М.Галиев

**Буып килү** 1) Аз-азлап, акрынлап аттыра барып буу. *Инешнең ике ягыннан да буып килгәч, көннәрдән бер көнне, су агардай тар ярык кына кала.* Н.Әхмәдиев

2) Элек-электән, күптәннән, даими буу. *Әйтик, демократияләштерү процессы иҗат әһелләре ирeгeн әлегәчә буып килгән тоталитар режимның идеологик кысасыннан азат итте.* М.Арсланов

**Буып кую** Буылган хәлгә китереп калдыру. *Суы бәләкәй икән, буып куйгач, диңгезгә әйләнер ---.* А.Гыйләҗев. *Юлларны буып куйган бураннарга төрле кеше төрлечә карады.* Я.Зәнкиев. *[Командировочный] Берни хәтерләмәгәндәй, зур авызын ерып елмайды, киң каеш белән буып куйган гимнастёркасын артка таба җыя-җыя күреште.* М.Мәһдиев. *Талантны бит аны, агым суны буып куйган шикелле, бик җиңел генә туктатып булмый.* Х.Сарьян

**Буып ташлау** Юк итү, юкка чыгару, үтерү. *Монда да реакция үзенең пычрак тырнакларын тырпайткан, революцион хәрәкәтне буып ташларга ашкына*

*иде.* А.Расих. *Аны буып ташлардай булдым.* А.Гыйләҗев. *Усалны бүре буып ташлады ич.* Х.Бәдигый. --- *бу мәченең шундый бер гадәте бар: ул, еш кына, кирәгеннән артык җанварны буып ташлый.* Кызыклар дөньясында

**Буып тору** 1) Бераз вакытка, вакытлыча буылган хәлдә тоту. *Хәлим хәтта аның йөрәк тибешен дә ишеткән кебек булды. Үзе исә бераз вакытка сулышын буып торды.* Г.Гыйльманов

2) Бертуктаусыз буу; иреген кысу, мөмкинлекләрне чикләү. *Чөнки, эчкән саен, акылын-җанын буып торган тышаулардан үзен бушана барган шикелле тойды.* Ә.Еники. *Кешенең рухын буып торган мондый режимның яшәргә хакы бар идеме?* С.Шәмси

**Буып чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы буу. *Берне генә алып китсәләр ярар иде әле, [соры ерткычлар] абзардагы бөтен малны буып чыгалар бит.* Я.Шәфыйков

**Буып яту** Билгеле бер вакыт дәвамында буу; әле, хәзерге вакытта буу. *Бу ярсуга каршы кешелек юлын Буып яткан көчләр егылыр.* Ә.Фәйзи. *Ул да түгел, кыш буе өстен каплап, тынын буып яткан калын бозны шатыр-шотыр китереп ватып ыргыта да, кабарынып, бүртенеп, өскә бәреп чыга.* Г.Бәширов

**БУ́ФЕР** *и. ингл.* **1.** 1) Вагоннарның бәрелү көчен йомшарта торган пружинасыман җайланма. *Бу юлы --- үземнең эш урыным саналган иң соңгы вагонның буферына учым белән шапылдата-шапылдата, байтак кына уйлана калдым ---.* Ә.Рәшит. *Паровоз тагы әкрен генә кычкыртып куйды да кузгалды һәм беренче вагонны, буферын шалтыратып, тартып алды, икенчесен урыныннан кузгатты.* Г.Гобәй. *Ул арада паровоз да кычкыртты. Буферлар тагын дөбер-шатыр килеп алдылар.* М.Мәһдиев. *Кыса алдына төртү чикләре – буфер, ә артына тарту ыргагы урнаштырыла.* Тракторлар һәм автомобильләр

2) *күч.* Капма-каршы якларны аерып, алар арасындагы кискенлекне йомшартып торган арадашчы. *Геосәяси күзлектән караганда, далага тарих сәхнәсендә үзара даими көрәштә торган өч бөек цивилизация арасында (көнчыгышта – Кытай, көнбатышта – носари Аурупа, көньякта – ислам дөньясы) буфер ролен үтәү вазифасы тапшырылган.* Р.Сафин. *Дөрес, --- мөмкин кадәр --- аябрак әйтергә тырыша, моның өчен еш кына «хәлбуки», «безгә калса», «кызганычка» кебек буфер ролен үтәрдәй сүзләр дә куллана.* Ә.Еники

3) Автомобильдә: рессор белән рам арасындагы резин прокладка. *Өлкән тикшерүче Фаршатовның «Жигули»е, арткы буферы белән, Ибрайлар янындагы ерганакның былчырак чокыры янына эләгеп калды.* Ә.Гаффар

4) *хим.* Химик процесста водород концентрациясе үзгәргәндә дә тотрыклы яки аз үзгәрүчән эремә. *Нигез буферның тирәлеген* pH = 14 – pK(BOH) + lg ν (BOH) / ν(BA) *формуласы буенча исәплиләр.* Фән һәм тел

5) *информ.* Мәгълүматларны вакытлыча саклау өчен, компьютер хәтерене бер өлеше. *Мәгълүмат әлегә буферда кала*

**2.** *с. мәгъ. кит. күч.* Ике каршы як арасындагы кискенлекне йомшарту, бәрелешләрне булдырмау өчен хезмәт иткән, арадашлык иткән (оешма, дәүләт турында). *Казан белән Мәскәү дәүләте арасында буфер (фасыйлә) Касим (Хан Кирмән) ханлыгы Россиядә ихтиляль (смута) булган чакта исән иде...* Г.Гобәйдуллин. *Совет хөкүмәте Ерак Көнчыгышта вакытлы буфер дәүләт төзүгә барды.* СССР тарихы

**БУ́ФЕРЛЫК** *и. к.* **буфер 1.** (*2 мәгъ.*). *Туфайлов исә арада буферлык ролен башкарырга тиеш.* Х.Камалов

**БУФЕТ** *и. фр.* 1) Табак-савыт, кабымлык һәм эчемлекләрне кую, саклау өчен шкаф. *Айдарлар фатиры: уң якта – гомуми коридорга чыга торган ишек; аннан керүгә, буфет артындарак – элгеч; буфет алды якта – туры диван.* Н.Исәнбәт. *Буфетны ачып карады, бүлмә буйлап әрле-бирле йөренде – баш төзәтерлек нәрсә тапмады.* Ә.Мушинский. *Каләмне буфеттан алып килеп, Тукай, ниһаять, язарга утыра.* И.Нуруллин. *Каютада ашамлык саклау өчен суыткыч тора. Шунда ук – савыт-саба буфеты, китап шкафы, кием-салым гардеробы.* М.Юныс

2) Ашханә, ресторааннарда: кабымлык һәм эчемлекләр сату өстәле; төрле эчемлекләр, кабымлыклар белән сату итә торган, зур булмаган чәйханә. *Шул рәвешчә, буфетка барып килергә дә куркып утырган чакта, күршемдәге кресло бушады.* Ә.Еники. *Фәһим картны җылы мич янына китереп утыртты да буфетка юнәлде.* Г.Бәширов. *Постау күлмәкле кыз иңбашын җыерып алды да буфеттан чыгу ягын карады.* А.Толстой

**БУФЕ́ТЧИК** *и. иск. рус к.* **буфетчы**. *Башта – лакей, аннан – буфетчик, аннан... Мин үзем дә шуннан башладым.* Н.Исәнбәт

**БУФЕТЧЫ** *и.* 1) Буфетта эшләүче, сатучы. *Йомры гәүдәле, ак алъяпкычлы буфетчы кыздан ул ашамлыкларның әле анысын сорашгырды, әле монысының бәясен белеште.* С.Рафиков. *Кок, ипи пешерүче, буфетчы, җыештыручы – болары «обслуживающий персонал», диңгезчеләр шивәсендә: «абслуга».* М.Юныс

2) Буфет тотучы, буфет хуҗасы. *Буфетчы марҗа бурычка бирүне дә туктата.* Г.Ибраһимов

**БУХ** *иярт.* **1.** 1) Шартлаганнан, бәргән-бәрелгәннән чыга торган көчле, кискен тавышны, ухылдауны хәтерләткән авазларны белдерә. *[Әхмәтгәрәй:] – Шуннан карыйм – чурный туча булып, аэропланнар! Бервакыт – бух! И мин – без память.* М.Мәһдиев. *[Малай] Безгә каршы «сугыш ачты». Үзе команда бирде,... үзе туп атты: – Бух, бах!* Г.Гобәй

**2.** *рәв. мәгъ. кбт. форм. яки «бах» ияртеме белән* Шундый тавышлар чыгарып. *[Пароход] Үзенең морҗасыннан куе кара төтен чыгарып, бух-бух суларга тотынды.* Г.Гали

**3.** *хәб. функ.* Бухлау, бухылдату, бухылдау, мәгънәсендә кулланыла. *Бер иптәшемнән хат килде. Немец очучысын Селигер күленә батырган. Атып түгел, алдап. Патроны булмаган, тегене үз өстенә юнәлдергән, күлгә төшеп җиткәндә генә читкә тайпылып*

*калган. Ә немец кулгә – бух!* С.Баттал. *Читендә күлнең – генерал. – Мә, самурай, тот менә! Һәм үзен, самолётын ул Күл төбенә: бух! – менә.* Г.Афзал

**БУХА́НКА** *и. пол.< нем. сөйл.* Гадәттә, формага салып пешерелгән бөтен икмәк. *Бер буханка ипине күл суына манып ашап бетерер дәрәҗәдә идем.* Р.Сибат. *Шул больницадан терелеп чыгып киткәч, һич көтмәгәндә, миңа ике банка тушёнка, бер буханка ипи китереп бирде.* Х.Камалов

**БУХА́НКАЛЫ** *с.* Буханка формасындагы. *Утыз алтынчы – икмәккә кытлык елны Хәйдәр белән Фёдор (безнең авылда урыслар да яши), бәләкәй чана тартып, район үзәгенә буханкалы икмәккә киткәннәр.* Г.Галиев

**БУХГА́ЛТЕР** *и. нем.* Коммерция һәм акчалата исәп-хисап эшләрен алып баручы бухгалтерия белгече, хисапчы. *Үзенең ысул дәфтәре белүе белән, «бухгалтер» дип, [ул] бер галантерейный магазинга конторага кирә алды.* Г.Исхакый. *Бухгалтер башыгыз белән коммерциянең серләрен белмисез...* Ә.Еники. *Кулында – «бухгалтер» дигән катыргы диплом.* А.Гыйләҗев

**БУХГАЛТЕ́РИЯ** *и. нем.* 1) Продуктлар җитештерү буенча хуҗалык операцияләренең исәбен яисә акчалата исәп-хисапны алып бару эше һәм аның теориясе. *Иң гади бухгалтериядән чыгып әйтәм: табигать сезгә бу чаклы изгелекне бирде дә бушка гына расходланды, дип уйлыйсызмы?* Н.Исәнбәт

2) Предприятие, учреждениеләрдә исәп-хисап эшләрен алып бара торган бүлек. *Бухгалтерия җәйге сезонга алынган ярдәмче эшчеләр белән исәп-хисап алып бара.* Ә.Айдар

3) *сөйл.* Исәп-хисап; сан. *Вапшым, Мөдир абзый, бодай исәбен тәртипкә салдым, дип уйлый инде. Ну көн саен бозалар моның бухгалтериясен.* И.Сирматов. *Семья мәсьәләсендә – минем үз бухгалтериям, Николаша.* Б.Камалов

**БУХГА́ЛТЕРЛЫК** *и.* 1) *к.* **бухгалтерия** (*1 мәгъ.*). *Отчёт мәгълүматларының дөреслеген тикшерү пропагандисттан бухгалтерлык --- өлкәсендә махсус белеме булуны таләп итә.* Татарстан коммунисты

2) Бухгалтер эше. *Кәбирнең --- бер апасы ясләдә балалар карый, икенчесе колхозда бухгалтерлык эшен алып бара.* Г.Галиев. *Сатирик журнал бимазасын кичке мәктәпкә йөрү, бала тәрбияләү һәм иҗат эше белән бергә уңышлы алып бару өчен, зур түземлек кирәк. Белмим, бәлки моңа да [Шәүкәтне] бухгалтерлык өйрәткәндер.* Казан утлары

**БУХЛА́У** *ф. к.* **бухылдау**. *Каядыр бухлады зур снаряд.* К.Нәҗми

**БУ́ХТА** *и. нем.< голл.* Диңгездә кечкенә култык. *Таганрог бухтасында торган Азов диңгезе флотилиясенә --- безнең гаскәрләрне акларның диңгез флотилиясе һөҗүменнән саклауны тәэмин итәргә кушылды.* Г.Бәширов

**БУХЫЛДАТУ** *ф. сөйл.* 1) *йөкл. юн. к.* **бухылдау**

2) *куч.* Ату (утлы коралдан)

**Бухылдата төшү** Тагы да катырак, көчлерәк бухылдату

**Бухылдатып алу** Бераз яисә кыска вакыт арасында бухылдату

**Бухылдатып җибәрү** Көтмәгәндә бухылдата башлау

**Бухылдатып кую** Бер тапкыр бухылдату

**БУХЫЛДА́У** *ф.* «Бух» сыман тавыш чыгарып яңгырау; ухылдау

2) Каты тавыш чыгарып егылу, бәрелү, төшеп китү

**Бухылдый төшү** Тагы да катырак, көчлерәк бухылдау

**Бухылдап алу** Бераз яисә тиз арада бухылдау

**Бухылдап җибәрү** Көтмәгәндә бухылдый башлау

**Бухылдап кую** Бер тапкыр бухылдау

**Бухылдап тору** Бертуктаусыз бухылдау

**БУШ** *с.* **1.** 1) Бернәрсә дә салынмаган, урнаштырылмаган. *Шул арада, буш чиләк төбенә борчаклар салган төсле тавыш ишетелде.* Ш.Камал. *Эче буш, телләре, саннары ялтыравыклы кәгазьгә буяп кына ясалган, юри сәгатьләр иде ул.* Р.Батулла. *Җиләннәре бөрмәле буш янчык шикелле җыерылып, кечерәеп калган.* Ә.Еники. *Аннан соң --- буш шүрәләрне алып, алар урыйына җепле шүрәләр куеп, Әсма белән бергәләп утырды.* М.Гафури // Өстенә бернәрсә дә куелмаган. *Ә хәзерге кебек яңгырлы көннәрдә, баргач та, еш кына, буш арба белән кайтырга туры килә.* А.Шамов. *Тәрәзә артында, катып, тәмам бозлавыкланган кантарлы юлдан, буш арбаны яман доңгырдатып, бер атлы узды.* М.Хәсәнов

2) Һичкем алмаган, биләмәгән. *– Менә монда буш урыннар бар, – дип, ул алгы рәттәге буш урыннарга төртеп күрсәтте.* А.Шамов. *Газиз кирә, буш урынга – Сәхипҗамал янына барып утыра.* А.Әхмәт

3) Һичкем билгеләнмәгән, берәүнеке дә булмаган; вакант. *Ул Бохарадан яшел чапан киеп, зур чалма чалып кайтса да, --- якын арада гына зур калаларда буш мәхәллә барлыгы күренмәде.* Г.Ибраһимов

4) Торучысы, karаучысы булмаган, кеше яшәми, йөрми торган (йорт, юл турында). *Тын, буш юл.* Ә.Еники. *Буш өй сакларга калдырып, әнкәңне бичура ясамакчы буласыңмыни!..* Казан утлары

5) Шәрә, шыр. --- *күзгә кояш, буш кырлар өстеннән, авылны читләтеп кенә узып бара иде.* Ә.Еники. *Аның күз алдында – Казанка буендагы шикелле буш кыр.* А.Шамов

6) Сусыз (кое һ.б.ш. турында). *Бер тамчы да суы юк. Буш кое ул.* Казан утлары

7) Итсез, кысыр (аш турында). --- *коры аш, буш аш, кысыр аш, итсез, катыклы, бәрәңгеле шулпа ишеләр.* Н.Исәнбәт

8) Куыш. *Буш эчле агач*

9) Корылмаган, ядрәләре булмаган. *Пулемёт тынды, Ленталар буш.* Ф.Кәрим. *Ә буш гильзаларны эретәләр...* Ә.Гаффар

10) Шушы вакытта файдаланууда булмаган (транспорт, корал һ.б.ш. турында). *Буш машиналарыгыз бер сәгатьтән медсанбатта булсын!* Ш.Маннур

11) Ял вакытына караган, эшкә дип билгеләнмәгән. *Каравылчының көндезләрен буш вакыты күп.* Г.Галиев. *Бер буш кичемне мин сиңа багышладым.*

М.Җәлил. *Кыргызстанда ветврач булган бу кешенең [Рушатовның] сәнгать өлкәсендәге барлык мәгълүматы буш чакларында мандолина чирткәләүдән генә гыйбарәт иде.* Ш.Маннур

12) Ирекле, беркетелмәгән, бәйләнмәгән, хәрәкәте чикләнмәгән. *Һавалардан очкан ике кош: Берсе дә генә бәйле, берсе буш.* Җыр

13) Тартып, кысып тормый торган, бераз зуррак, киңрәк, иркен; *киресе:* **тыгыз.** *Озын мыеклы абзый баскыч буйлап ашыкмыйча гына төшә, аның буш галошы --- бөтен өйалдын яңгырата.* А.Шамов

14) Тиешенчә тартылмаган, җитәрлек дәрәҗәдә борылмаган, салынып торган, сүлпән. *Печән олавы өстендәге буш бастырыкны тарттырып бәйләп куйды*

15) Орлыксыз, төшсез, өлгермәгән. *Бу дөньяны аңлап кара, кагыйдәсен кем белгән: буш башаклар үрә баскан, тук башаклар иелгән ---.* М.Галиев

16) Тулы түгел, җитешсез. *Табынның уртасында күзләрне кызыктырып утырган аракы шешәләренә шулкадәр ияләшелгән, ризык белән тулы табын беренче карашка буш кебек күренә, мәҗлес күңелсез үтәр, эчпошыргыч булыр сыман тоела*. Т.Миңнуллин

17) Җиһазлары булмаган. *Директор, аннан соң да әле, яртылаш буш, буяулы идәнен тузан баскан шыксыз квартира буйлап, ишекләрне шак-шок ябып, нидер исбатламакчы булып йөрде-йөрде дә дачага китеп барды.* А.Толстой

18) *махс.* Файдалы эшкә тотылмаган, файдалы эш коэффициенты булмаган. --- *агрегат йөрүне кишәрлекнең бер кырыеннан башлый һәм, аның тар башына җиткәч, уңга борыла, урмыйча гына аны узгач, икенче ягыннан, урып, кире бара. Шулай итеп, ул кишәрлекнең баш-башларында гел буш йөреш ясый*. Урып җыю машиналары

19) *махс.* Әһәмиятле казылмалары булмаган (җир катламы турында*). Буш катлам*

20) *хим.* Кушылмага кермәгән. *Буш атом*

21) *хим.* Билгеле бер шартларда практик әһәмияте булмаган. *Буш токым*

22) Түләүсез. *Буш концерт*

23) Рухи ихтыяҗлары, дәрт, омтылышлары булмаган. *Күңел буш, йөрәк тын – анда үлем тынлыгы.* Г.Ибраһимов. *Аның күңеле һаман да буш һәм шыксыз, анда дала җиле кебек ачулы тынгысызлык кына каңгырып йөри иде.* Г.Бәширов

24) Әһәмиятсез, мәгънәсез. *Ну, егетләр, буш сүзләрне куегыз.* Ш.Камал. *Буш сүз генә түгел инде бу*. Г.Бәширов. *Барча фәлсәфәләр – буш сүз, Кеше кадерсез булса…* Г.Афзал

25) Чынбарлык белән бәйләнеше булмаган. *Буш сылтау гына ул.* Ш.Камал. *Ибраһим, кулын селтәп, Фәһим сүзләрен юкка чыгара барды: – Буш хәбәр!* Г.Бәширов

26) Тормышка ашмастай. – *Буш хыялга бирелмәгез, – диде ул [хирург].* Ш.Маннур. *Әллә буш өмет микән?* Ә.Ерикәй

27) *күч.* Булдыксыз, сәләтсез. *Ул үзен мәгънәсез, буш бер кешегә генә түгел, хәтта суы агызылган балчык кувшинга тиңли башлады.* Ф.Латыйфи

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Вакытны биләмичә, эштән азат булып. *Буш йөрү*

2) Мәгънәсез, булдыксыз, сәләтсез. *Мондый камил килеш-килбәтле кеше буш булмаска тиеш.* Ә.Еники

3) Арзан бәягә. *Алар, кыш буе, итне буш диярлек ашап чыгалар.* Ә.Еники

4) Көч куймыйча. *Буш табылмый дөньяда бернәрсә дә, Ал тимерне, бәр тагын бер мәртәбә.* Н.Исәнбәт

◊ **Буш баш** Уйсыз, фикерсез, надан кеше. *И карчык, буш башлар күк, син дә инде һаман киленне кыерсытасың.* А.Әхмәт. **Буш бугаз** Корыга мактанып, күп сөйләп йөрүче, әмма надан кеше. *Халык арасында аның турында: «төпле егет», «дөнья күргән егет», «буш бугаз түгел», «сүзен җилгә очырмас» --- кебек сүзләр дә йөри башлады.* Ә.Еники. **Буш гөбе** *к.* **буш баш.** *Бу шалак Альберт алай ук буш гөбе түгел икән.* Р.Батулла. **Буш итмәү (калдырмау, куймау)** Бурычлы булып калмау. *[Сафи:] Ә, алайса, мин дә сезнең белән барам, минем акчам табылмас микән шунда, гаспадин исправник? Буш итмәс идек.* К.Мотыгый. *Булышсаң, буш итмәм.* Э.Касыймов. *Аның чыгар чишмәсе бик иркен: дәүләткә дә полный итеп биреп була, безне дә буш итмәскә була.* Ә.Еники. **Буш кул белән** 1) Бернәрсәсез; бүләксез. *Буш кул белән килмәгән ул тәти егет.* Г.Бәширов. *Аны буш кул белән җибәрергә ярыймы?* Г.Ибраһимов. *Берсе дә буш кул белән килми, кервә-керешкә, бүләген суза.* Н.Әхмәдиев; 2) Табышсыз. *[Аудан] Әлбәттә, буш кул белән кайткан чаклар да булгалый иде.* Г.Әпсәләмов. **Буш куык** 1) Мактанырга яратучы, булдыксыз кеше. *Кычкырган адәм – буш куык, Мыштым адәмнән син курык.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Ишеткәнең бармы шундый бер буш куык турында?* Г.Бәширов. *Син бит – яман рәссам, дан-шөһрәт өчен генә сәнгать тирәсенә елышкан ялган рәссам, буш куык!* Н.Гыйматдинова; 2) Чынбарлыкка туры килмәгән нәрсә. *Ир белән хатын арасын ныгытып килгән татлы уйлар ялган, буш куык булып чыкты.* А.Гыйләҗев. **Буш куык очыру (ату)** Юкны бар дип сөйләү. *Күрмәде гами аны, ул буш куыклар атмагач.* Г.Тукай. **Бушны бушка аудару (бушату)** Эшсез йөрү. *Телевизор белән тулган Бик күпләрдә буш вакыт... Кемнәрдер әле үткәргән бушны бушка бушатып.* Ш.Галиев. **Буш урын** Әһәмиятсез, дәрәҗәсез кеше; беркем дә түгел. *Хәзер Ләйлә аны күрми, Фәһим – аның өчен буш урын.* Г.Бәширов

**БУШАНУ** *ф.* **1.** 1) Эштән арыну, эш кимү, иркенәю, бушау. *Мәрьям кунак сыйлаудан бушанды.* М.Гафури

2) Арынып калу, котылу. *Тукал эчендәге авыр хәсрәтеннән гүя бераз бушанды…* Г.Ибраһимов

3) Киеренкелек кимү, бетү. *Бер бушану кирәк була Хәтта иң-иң көчле иргә.* Ф.Яруллин. *Еласам, бераз бушаныр идем инде.* М.Юныс

4) *эвф.* Табигый ихтыяҗны үтәү, йомышлау

5) *махс.* Электр корылмаларыннан арыну

**2.** *и. мәгъ.* Заряды алыну, заряды бетү процессы. *Эльм утлары атмосферада электрның тыныч бушануы аркасында хасил булалар*. М.Зиннәтов.

*Газдагы бушану читтән тәэсир итүче ионизатордан башка да булырга мөмкин.* Физика

**Бушана бару** Акрынлап бушану. *Чөнки, эчкән саен, акылын, җанын буып торган тышаулардан үзен бушана барган шикелле тойды.* Ә.Еники

**Бушана төшү** Бераз бушану. *Казарма эче кешеләрдән бушана төште.* И.Туктар

**Бушанып алу** Тиз арада, кыска вакытка бушану. *Безнең халык та, кайгыңны үз эчеңдә генә саклап, үзеңне бетермә, кайгыңны кешеләргә сөйләп, эчеңне бушат, уртаклаш, булмаса, елап бушанып ал, дип киңәш итә ләбаса.* Г.Хөсәенов

**Бушанып бетү** Тулысынча бушану. *Вакыт күпме узгандыр, иләһи рәхәтлек бушанып бетте.* Р.Батулла. *Рим кебек зур шәһәрләр бөтенләй үк бушанып бетә алмый, әлбәттә.* Р.Фәйзуллин

**Бушанып калу** Бөтенләй, тулысынча бушану. *Кешене тыңлаудан бигрәк, үзең сөйләп, бушанып калырга ашыгасың.* Ш.Галиев. *Сөйләшеп утырырлар, күңелләре бушанып калыр.* М.Кәбиров

**Бушанып китү** Бераз бушану; билгеле бер вакыттан, сәбәптән соң бушану. *Нәфрәт җыймагыз авылга, Җәфалар күрсәткән булса да. Бушанып китәрсез, кайтыгыз, Эшегез тезелеп торса да. Хәтердән җуймагыз авылны, Туганнар калмаган булса да.* М.Әхмәтҗанов

**Бушанып тору** Бераз ара, вакытлыча бушану. *Йөрәк шикелле мускулга да ял кирәк. Ул да, эшләгәндә, бераз тартылып, бераз бушанып торырга тиеш.* Г.Хөсәенов

**БУШАТКЫЧ** *и.* **1.** Йөк бушату-төяү эшен башкару өчен махсус җайланма, механизм. *Завод вак таш бушаткычларны моннан ике ел элек үк кайтарткан иде.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Йөк бушату-төяү эшләрен үти торган (машина, җайланма турында). *Йөк бушаткыч машина*

**БУШАТУ** *ф.* 1) Нәрсәнеңдер эчендәге яки өстендәге әйберләрне алу, буш калдыру. *Шулай, айдан артык, дәрестән соң пристань буена төшеп, эш булган көннәрне ашлыктыр, бәрәңгедер бушатып, 4–5 сумга яшәп карады да, өйдән алып килгән ике капчык сохарие беткәч, «ярый, киләсе елга килермен әле» дип, укуын ташлап кайтып китте.* Х.Сарьян. *Вагоннар килеп җиткәч тә, бушатырга булышыгыз.* Р.Ишморат

2) Нәрсәнеңдер эчендәге, өстендәге әйберләрне алып, икенче урынга кую. *Эшләпәсендәге җиләкне аның алдына бушатты.* Г.Гобәй. *«Карачкы» --- онны асфальтта җыелып калган яңгыр суына бушатып (менә кызык), камыр баса башлый.* Г.Гобәй

3) Тыгыз, тартылган хәлдән буш хәлгә китерү, иркенәйтү. *Ир, дилбегәсен бушатып, кинәт кенә артына борылды да: – Минем өчен генә, Камышлы күлне ясар идеңме, Рабига? – диде.* Н.Гыйматдинова

4) Торган, утырган һ.б.ш. урыннан китү, аны калдыру. --- *аларга өч көн эчендә квартираны бушатырга тәкъдим итә* ---. А.Шамов. *– Абый, бушат, монысы – Минем урын бит, – диләр. – Ике урын билгәч, Ал ике билет, – диләр.* Н.Гайсин

5) *сөйл.* Эш урынын азат итү, эштән китү

6) *сөйл. сир.* Азат итү. *Шәһәрне дошманнан бушату*

7) *күч.* Тоту, сарыф итү, юкка чыгару. *Дәүләтнең хәзинә сандыгын сindәй тиле юмартлар бушата.* Н.Гыйматдинова

8) *күч.* Күңелендәге киеренкелекне киметү, сөйләп тынычлану, борчып торган уйлардан арыну. *Күрше-күлән арасында, бер-берсенә кереп, хәл белешеп тору, хәбәр ишетеп, кайгы бушатып чыгу – безнең татар авылларында борын-борыннан килгән йола инде ул.* М.Әмир. *Гомәр энем, әйтәсеңне әйтеп бетердеңме? Эчеңдә җыелып калмасын, бушат, әйдә.* И.Гази

9) *күч. гади с.* Берәүнең сүзләрен икенче кешегә сөйләү

10) *күч. гади с.* Эчү, ашау. *Мич башында гел ымсындырып, чакырып торган мичкәдән янә бер чәркәне үзенә бушаткач, күңеленә тагын талымсыз рәхәтлек белән бергә кыюлык иңә.* Т.Галиуллин

**Бушата бару** Аз-азлап, акрынлап бушату. --- *баштук каты итеп торткан сүз тезгенен акрынлап-акрынлап бушата барырга уйлады ул.* С.Поварисов

**Бушата башлау** Бушатырга тотыну. *Бер яшь кыз белән бер егет, көлешә-көлешә, машинадан капчык бушата башладылар.* Г.Сабитов

**Бушата килү** Акрынлап, дәвамлы рәвештә бушату. *Яңгыравык исемнәр, буш, соры әсәрләрдән, бәхетебезгә, гөмбәзне бушата киләләр.* Т.Галиуллин

**Бушата тору** Бер-бер артлы бушату. *Хәйдәр мулла, авыр сулап, чәйне чынаяк артыннан чынаяклап бушата торды.* С.Рафиков

**Бушата төшү** Бераз бушату. *Кулыңдагы кош баласын күз алдына китер: кысып тотсаң – зәгыйфьләнәчәк, бушата төшсәң – очып китәчәк бит.* Р.Низамиев. *Айгырның дилбегәсен, бушата төшеп, кузлага бәйләп куялар да Чынлы юлы белән иң алдан җибәрәләр.* К.Миңлебаев

**Бушатып алу** Кыска вакытка, бераз бушату. *Ул, онығы Фарукның яшьрәк чагын сөйләп, күңелен дә бушатып алды.* М.Шаһимәрдәнов

**Бушатып бетерү** Тулысынча бушату. *Бокалларны тырышып бушата торгач, минем иптәшләр бутылкаларны да бушатып бетерделәр.* Ф.Әмирхан

**Бушатып җибәрү** Тиз арада яки кинәт бушату. *Гаделнең күңел бауларын бушатып җибәрердәй нәрсә бар соң?* Г.Гыйльман

**Бушатып йөрү** 1) Әле, хәзерге вакытта бушату; бик еш бушату. *Гыйлем үзе пристаньнарда йөк бушатып йөргән.* И.Салахов

2) Бушату белән шөгыльләнү. *Рувим Израилевичы да – ни күреп, ни чакыртып сүз катмады. Ректорга бушатып йөриме әллә юкса?..* Х.Сарьян

**Бушатып кую** Бушаган хәлгә китерү. *Соңгысының иминлегенә бушатып куйыйк, егетләр!* Т.Галиуллин

**Бушатып ташлау** Тиз арада бушату. *Култыгындагы әйберләрне сәке өстенә бушатып ташлады.* М.Гафури. *Үзе белән әле генә танышкан бу ханымның шулай тиз арада эчен бушатып*

*ташлавына Билал гаҗәпләнеп куйды.* М.Вәли-Барҗылы

**Бушатып тору** 1) Әле, хәзер бушату

2) Әледән-әле, еш бушату

**Бушатып чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да бушату. *Баржаны бушатып чыгу өчен, бер көн генә җитми*

**Бушатып яту** Әле, хәзер, сөйләү моментында бушату. *Хурлыгаян, казаннан аш бушатып яткан җиреннән, ишек катына күз салды.* Р.Батулла

**БУША́У** *ф.* 1) Нәрсә дә булса өстендәге яки эчендәге әйберләрдән арыну, азат ителү. *Искене җимерү белән, мәйдан бушый, хәят эченнән бәреп чыгачак яңа куәтләргә юл ачылган була.* Г.Ибраһимов. *Бушаган ике кешелек бүлмәгә урнашсам, туктаусыз тәмәке көйрәтүчегә, аракы эчеп, былагайланып йөрүчегә юлыгырмын, дип курыктым.* М.Юныс. *Балыктан, иттән бушагач, бу матур калай савытлар һәр өйнең түренә гөл савыты булып менеп утырды.* Р.Батулла

2) Хуҗасыз, буш калу, караучысы, торучысы булмау. *Йорт бушау*

3) Буш, вакант булу

4) Берәр төрле шөгыльдән, мәшгуль булудан туктау, азат булу. *Зур йортларда һәркөн берничә адәм, кар көрәп, өйдән – келәткә, келәттән абзаргафәләнгә сукмак салудан, ишек төпләрен көрәүдән бушамый.* Г.Ибраһимов. *Каравылдан бушагач, Сөт бирермен үзеңә.* М.Җәлил. *– Бушап булмый... Умарталыкта эш – менә! – Гайнан кулы белән муенын сызып күрсәтте.* Г.Бәширов. *Кыска кичләрне, дәрестән бушагач, шәкертләр, симәнке, чикләвек сатып алып, әлеге почмак өстәл тирәсенә җыелдылар.* Ә.Фәйзи

5) Буш булу, файдаланудан туктау. *Әйдә, Мәрьям апай, үтүк хәзер бушады.* Ф.Кәрим

6) Хәрәкәтләнә алырлык, ирекле хәлгә килү. *Кул бушау*

7) Тыгыз, кысан булудан туктау, иркенәю, йомшару. *Көпчәк шипы ләпшерәп төшкән, тәмам бушаган.* А.Шамов

8) Тартылып, киерелеп торудан туктау; салыну (бау, уен коралларының кылы һ.б.ш.). *Чәче тузган, каешы бушап, наганы тезенә чаклы асылынып төшкән.* Х.Камалов

9) *күч.* Физик хәлсезләнү, йомшау. *– Газизә! – дип кычкырган иде, тамагы буылды, тез буыннары бушап, креслога утырды.* Ш.Камал

10) *күч.* Арыну, котылу (уйлардан, борчулардан). *– Ярар, балам... йөрәгем бушады.* Г.Ибраһимов. *Ярсуы, дуамаллыгы басылган, тәне җиңеләеп, җаныкүңеле бушап, күзләре тоныкланып калган...* Г.Гыйльманов. *Күңеле бушап, җиңеләеп киткәндәй булды.* И.Гази

**Бушап алу** Кыска вакытка, азга гына бушау. *Чәчүләр бетеп, печәнгә төшкәнче, халык эштән берара бушап ала.* Н.Гариф

**Бушап бару** *к.* **бушый бару.** *Житте, җитте, туктагыз! Бушап бара нуктагыз... Әрләшәсез юктан сез!* Р.Харис. *Югыйсә, аның бушап барган күңеленә тагын кем якты уйлар, игелекле гамьнәр салыр?* Р.Шәрәфиев

**Бушап бетү** Тәмам, бөтенләй бушау. *Әхнәф белән Сәлахов бюро членнарының чыгып киткәнен дә, залның бушап беткәнен дә урыннарыннан кузгалмыйча көтеп утырдылар.* Ф.Садриев. *Әниемнең төсе итеп, Саклап киләм мендәрен. Йомшак кына, бушап беткән – Йомшара күңелләрем.* Б.Батталов

**Бушап калу** Тулысынча бушаган хәлгә килү. *Юныс морза, бушап калган чүмечне тупсабашка бирде дә, Сөембикә янына килеп, аягына төште.* М.Хәбибуллин. *Чикерткәнең капчыгы бик тиз бушап кала.* Ә.Еники. *Ишегалды бөтенләй бушап калды.* Ф.Хөсни. *Бушап калган шәһәргә дошман гаскәрләре кереп тула.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**Бушап китү** Кинәт бушау. *[Анастасиянең] --- аяк буыннары бушап китте, башы әйләнде.* М.Хәбибуллин. *Аның [Бүре Әскыйның] рәвешен күргәч үк, нервлар туарылып, бушап китә.* М.Мәһдиев. *Егетнең чиләк кырыен тоткан кулы бушап китте һәм түбән салынып төште.* Ә.Гаффар. *Чәмәт кинәт, баш миендәге бер шөребе бушап китеп, урындык өстенә ыргып менде ---.* Х.Сарьян

**Бушап тору** 1) Әлегә, бераз вакытка бушау. *Бүгеннән башлап, бер-ике атна ул клиника ваемнарыннан бушап торачак.* М.Маликова. *Тугыз мәчетнең берсе дә бушап тормаган.* К.Миңлебаев

2) Еш, әледән-әле бушау. *Кешеләрнең кесәләре бушап тора, Кибетләрнең киштәләре бушап тора, Дәүләтләрнең казналары бушап тора – Тик тәхетләр генә бушап тормый.* Г.Афзал

**Бушый бару** Торган саен ныграк бушау

**Бушый төшү** Бераз бушау. *Чәй тәмамлангач, өстәл өсте шактый бушый төшкәч, кыз Фәргатьне, җай гына култыклап алып, озата чыкты ---.* Ф.Бәйрәмова

**БУШАЮ** *ф. к.* **бушау** (*7–9 мәгъ.*). *--- тезләрем, бушаеп, бөгелергә тора вә калтырый иделәр.* Ш.Камал

**Бушаеп бетү** Тәмам, тулысынча бушаю

**Бушаеп калу** Бөтенләй буш хәлгә килү

**Бушаеп китү** Бераз бушаю. *Ул хәзер сәер хис кичерә иде: --- үзенә бик якын, кирәкле булса да, авыр һәм эчпошыргыч йөктән инде котылгач, җаны бушаеп киткәнен.* А.Вергазов

**Бушаеп тору** Әле, хәзер бушайган булу

**Бушая бару** Аз-азлап, акрынлап бушаю

**БУШБУГАЗ** *и.* Корыга мактанып, шапырынып йөрүче, буш вәгъдәләр бирүче кеше. *Бушбугазлар оҗмах вәгъдә итә, Әнә ничек шома алдалый.* Н.Әхмәдиев. *«Себергә барабыз, нефтяник булабыз!» – дип, кем «ура!» кычкырды? Син үзең түгелме? Ах син, бушбугаз!* Ш.Бикчурин

**БУШЕ** *и. фр.* Эчендә крем булган, кечкенә түгәрәк булка формасындагы бисквит пирожное

**БУШЕЛЬ** *и. ингл.* Англиядә, АКШта һ.б. илләрдә: сыеклыкларны һәм чәчелә торган җисемнәрне үлчәү берәмлеге (якынча 35–36 литр)

**БУШКА** *рәв.* 1) Файдасызга, кирәксезгә. *Тагы ике көн бушка үтте.* Г.Исхакый. *Син түгелме мәктәбеңдә бушка уйнап ятучы, Лаф оручы, бармыйм, дип, хәлфә-остаз суйса да?*

Н.Думави. *Бушка узмасын һич безнең һәр ай, һәр ел, Тәрәкъкый итеп, тотыйк алга юл.* Г.Тукай. *Йөрүе бөтенләй бушка булмаганга охшый: аякта – итек, өстә – кара чикмән, кулда – күн бияләй, башта – кырпу бүрек.* Г.Ибраһимов

2) Кулланылмыйча, файдалы эш коэффициенты булмыйча. – *Нигә монда эшче, ат көчләрен бушка тотарга?* Т.Гыйззәт. *Трансформатор бушка эшләгәндә, беренче чылбырдан икенче чылбырга энергия тапшырылмый.* Физика курсы

3) Сәбәпсезгә, нигезсезгә. *Мылтыгым бер вакытта да бушка шартламый иде.* А.Шамов

4) *күч.* Бик арзанга; түләүсез. *Дөрес инде, ул, ишегенә килсәң дә, барыбер бушка гына бирми, аның өчен әллә никадәр хезмәт иттерә.* М.Гафури. *Осталар «бушка эшлибез» дип торалар.* Ә.Еники. *Камилгә бернәрсә дә бушка килмәде. Ул барысын да сатып алды: аттестатны да, дипломны да, дусларын да, дошманнарын да.* М.Сәлимов

◊ **Бушка китү (чыгу)** Файдасыз булу. *Тир түгүләребез бушка китмәде.* А.Алиш

**БУШКУЫК** *и.* Үзен әллә кемгә санаучы, корыга шапырынучы, будыксыз кеше. *Ә мин – ялкау, мин – булдыксыз, мин өй турында кайгыртмыйм, мин – бушкуык, мин, юк нәрсә турында хыялланып, гомеремне уздырам ---.* Р.Вәлиев

**БУШЛАЙ** *рәв.* **1.** 1) Түләүсез, бушка. *[Фазыл:] Аның каравы, Сәрвиназ апага, шыңгырдап торган нараттан, бушлай, алты почмаклы өй салып бирдең.* К.Кәримов

2) Хезмәт куймыйча. *Бушлай килгән мал бушлай китә.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Бушка, түләве булмаган. *Чирмешәнгә баргач, кереп, рәхмәт әйтеп чыгам әле үзенә, кич концертка чакырып, бушлай билет бирәм әле...* Г.Мөхәмметшин

**БУШЛАТ** *и. нем.* Ике якка да төймәләнә торган кыска пальто; диңгезчеләр өчен җылы кием. *Ниһаять, [егетләр] чишенешеп бетте, бүрекләр, бушлатлар чөйгә эленде.* М.Әмирханов

**БУШЛАТА** *рәв. сөйл. к.* **бушлай**. *Бушлата бирү. Бушлата китерү*

**БУШЛЫЙ** *рәв. сөйл. к.* **бушлай.** *Бушлый килгән бушка китәр.* Мәкаль. *Юлда бушлый йөрү*

**БУШЛЫК** *и.* 1) Буш булу. *Көннәр, туарга да өлгермиләр, көзен агачыннан коелган яфраклар төсле, вакыт бушлыгына төшеп югала торалар.* Р.Хафизова

2) Бернәрсәсе дә булмаган, буш пространство. *[Әтинең] Бакчасы юк та юк, өендә дә футбол кырыдай бушлык.* Ә.Баянов. *Ядрә бушлыкка очмады, үлем тоеп бәргәләнгән ябалакка тиде.* Н.Гыйматдинова

3) Тереклек билгеләре булмаган, һичкем (һичнәрсә) тарафыннан биләнмәгән урын, мәйдан, җир. *Бу тирәдә тынлык һәм бушлык хөкем сөрә иде.* А.Толстой. *Кая гына карасаң да – уңда-сулда, алда-артта, өстә-аста – бөтен җирдә күксел зәңгәр су төсендәге очсыз-кырыйсыз сыек томан. Һәм иксез-чиксез бушлык та бушлык.* Кызыклы физиология

4) Рухи ихтыяҗлар, теләк-омтылышлар булмау халәте. *Безнең гомер тулы һәр ваклыкка, Эчпошыргыч ямьсез бушлыкка.* М.Җәлил. *Алар – тук корсактан, акыл бушлыгыннан, эшсезлектән, эч пошудан азынып хыялланучылар.* Г.Нигъмәти. *Өй эчендә мәет чыкканнан соң була торган җан өшеткеч бер соры бушлык та сагышлы тынлык кына иде.* Г.Бәширов

5) Кадерле кешене югалтудан, юксынудан туган күңел халәте. *Уз улы булмаса да, егет, читләтеп кенә, әнә шул моңсу бушлыкны тулыландырып тора.* Г.Бәширов

6) Өстенә бөрчек билгеләр төшерелмәгән домино шакмагы

**БУЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *кайт. юн., төш. юн. к.* **буу**

2) Бума чире кузгалу, бума өянәге тоту

**2.** *и. мәгъ.* Һава җитмәүдән сулыш ала алмау хәле. *Буылу башлана, аңны югалтасың һәм һичбервакытта яшел үләннәрне, кояш яктысын күрә алмыйсың – үләсең.* Диңгез тирәнлегендә

**Буыла башлау** Буылырга тотыну. *Фрунзеның түгәрәк дип әйтерлек тулы йөзе ничектер берьюлы сулыгып, агарынып китте, ул, гүя тыны буыла башлагандай, шинель якаларын чишеп җибәрде.* Г.Бәширов

**Буыла төшү** Бераз буылу. – *Белмәсәң, әйтим алайса, – диде ул, буыла төшеп.* Ә.Еники. – *Кичер! – диде ул буыла төшкән тавыш белән һәм мине кочагыннан җибәрде.* Ә.Еники

**Буыла язу** Чак буылмый калу. *Ул, көчкә-көчкә генә авыру аякларын өстерәп, күкрәгендәге авырудан, ачудан, гарьлектән буыла язып, ютәленә карлыгып, кибеттән чыгып, кибет алдындагы баганага сөялде.* К.Тинчурин

**Буылып бетү** 1) Тулысынча, бөтенләй буылган булу. *Халык шул петляның тизрәк буылып бетүен көтә, улым, бик көтә.* Ә.Еники

2) Бик нык буылу

**Буылып йөрү** Нинди дә булса вакыт арасында буылган халәт кичерү. *Көне буе ачуыма буылып йөргән идем.* А.Гыйләҗев

**Буылып калу** 1) Кинәт буылу, ниндидер сәбәптән буылу. *Тавык кетәге кадәр радиорубкасында төтенгә буылып калгач, кычкырмый нишләсен [Рәсим]!* Ф.Шәфигуллин. *Кинәт сулышым буылып калды.* Н.Дәүли

2) *күч.* Кинәт өзелү, юкка чыгу, бетү. *Инде тормышка аша башлады гына, дигәндә, буылып калачак хыялы янында дөньяның барлык авырлыклары, бөтен куркыныч нәрсәләре дә вак иде аның өчен.* М.Кәбиров

**Буылып китү** Кыска вакытка, көтмәгәндә буылу. *Газинур Гали абыйның тамагы буылып китүен сизде: гүя аңа һава җитми иде.* Г.Әпсәләмов

**Буылып кую** Кинәт буылу. *Йөрәге кысылып, сулышы буылып куйды аның.* М.Хәсәнов

**Буылып тору** 1) Буылган хәлдә булу; туктаган булу. *Моңа кадәр буылып торган матбугат буасын ертырып, газета-журналлар ташкынын барлыкка китерде.* С.Алишев

2) Берникадәр вакытка, берара буылу. *Минем күзләремне яшь басты, тын буылып торды.* М.Мәһдиев. *Малай, әтисенең кымшанмавын күреп, рәнҗеп, беркавым сулышына буылып торды.* Р.Зарипов

**Буылып яту** Озак вакытлар дәвамында буылган хәлдә булу. – *Ниһаять, шигырьнең энергиясе бер йодрыкка тупланды – өлгереп, буылып яткан сүзләр ирек алды, ерылып агарга формасы табылды.* Ш.Галиев

**БУЫН** *и.* 1) Умырткалы тереклек ияләрендә сөякләр тоташкан хәрәкәтчән урын. *[Хәмитнең] Буыннары, тамырлары, авырсынып, сыкрап куйды.* Г.Исхакый. *Ул, буыннары калкып чыгып торган бармаклары белән тезенә орынып, күзләрен рәсемгә юнәлтте.* А.Шамов. *Буыннарга һәм сеңерләргә кальций утыру нәтиҗәсендә, умырткалык, сыгылмалылыгын югалтып, катып кала.* Юлдаш. *Бехтерев авыруына дучар булганда, умырткаара буыннар зарарлана, һәм хәрәкәтләнү чикләнә ---.* Юлдаш

2) Тиренең буын турысындагы өлеше. *[Бабай] Бармак буыны белән күз төпләрен сыпыргалап алды.* Г.Әпсәләмов. *[Заһит] Һәркөн, ятар алдыннан, Зәнфирәнең аякларын җылы су белән юды, буыннарына массаж ясады.* Ф.Садриев

3) Аяк-кул чукларындагы вак сөякләрне тоташтырган хәрәкәтчел урыннар. *[Бәкернең] Зур кулларының кайсыдыр бармаклары тырнаксыз, кайсының беренче буыны бөтенләй юк.* Ф.Садриев. *Гармунчы егетнең бармак буыннары хәл җыеп, гармунның үзенә җан кергәнче, кортканың «тузт! тузт!» итеп сыер сауганы ишетелде.* Ә.Дусайлы

4) *бот.* Үсемлек бәбәгенең яфрак, бөре һәм кайвакыт өстәмә тамырлар ясала торган өлеше. *Сабакның яфрак тоташкан урыннары – «сабак буыннары», ә сабакның буыннар арасындагы өлешләре «буын арасы» дип атала.* Ботаника

5) Үсемлектә: буын араларының берсе. *Ирек, иелеп, бер сарут сабагын өзеп алды, бәләкәй чактагы кебек, аның буынын теше белән чәйнәде, суырып карады.* Заман

6) Чылбыр рәвешендә үзара тоташкан, бәйләнгән кисәкләрнең һ.б.ш. нәрсәләрнең тоташкан урыны. *Чылбыр буыны*

7) Чылбыр рәвешендә тоташкан кисәкләрнең берсе. --- *мин үземне Хәлимҗан абый белән Галия апа арасындагы мәхәббәтне бәйләп торучы бер чылбыр буыны дип хис итә идем.* Ә.Рәшит

8) Бербөтен системаның, күренешнең, нинди дә булса алымның состав өлешләреннән берсе. *Моңа ул, юлларда аерым ритмик буыннарны төшереп калдыру яки артык буын өстәү, шигырьгә прозаизмнар алып керү --- кебек, үзгә тәртипкә буйсынган яңа система куллану аша ирешә.* М.Гайнетдинов

9) *мат.* Күпбуынлы тигезләмәләрдә кушыла торган өлешләрнең берсе. *Даян мәсьәләнең бөтен нечкәлекләрен аңлата-аңлата чишә. Менә бу буынны болай эшләргә кирәк, чөнки аның гади формуласы менә ничек ---.* Х.Камалов. *Бу тигезләмәләр бәйсез түгел. Берсенең буыннары тамгаларын үзгәртсәң, икенчесе килеп чыга.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Һәр тигезләмәнең барлык буыннарын сул якка күчереп, килеп чыккан аңлатманы стандарт рәвештәге күпбуынга үзгәртсәк,* $x^4-10x^3+35x^2-50x-96=0$ *тигезләмәсен табарбыз ---.* Алгебра. *Геометрик прогрессиянең беренче n буынының суммасы A һәм аларга кире булган зурлыкларның суммасы B (B≠0) икәнлеге билгеле булса, беренче n буынының тапкырчыгышын табыгыз.* Алгебра

10) *күч.* Нәсел, ыруны дәвам итүчеләрнең һәрберсе. *Буын арты буын алмашынып, Гасыр арты узар гасырлар.* Ш.Галиев. *Бу юрган астында Бәдретдин балаларының бишенче буыны канат чыгара.* А.Хәлим. *Бездәге бүреләрдә дә шул ук хәл – зур гаилә, берничә буын бергә көн итә.* Кызыклар дөньясында

11) *күч.* Уртак бабага карата бер үк дәрәҗәдә кардәшлектә торучы нәсел, ыру вәкилләренең берсе. *Илсур – Шәяхмәт кызының кызыннан туган бала, икенче буын оныгы.* Б.Камалов. *Алдан килешү буенча, Тәгин углан Албуга аланнарның Күкәл буыны – Елдырым бәкнең Алтын Бөртек кызына өйләнер.* Н.Фәттах

12) *җый. и. мәгъ. күч.* Яшь аермалары зур булмаган яисә бер чорда яшәгән кешеләр. *Прогрессив кешелек, барыннан да бигрәк, балалар мәнфәгате, алда яшәячәк буын язмышы турында кайгырта.* Р.Ишморат. *Яңа буынга, кеше булып калыр өчен, фән һәм техника казанышлары гына җитәрме?* Татарстан

◊ **Буын бетү** Буын мускуллары хәлсезләнү. **Буынга төшү** 1) Физик арудан, авыртудан, аяк буыннары ару, талу; 2) Аптырату, төпченеп сорашу, йөдәтеп бетерү. *Ә кулга корал тоткач, атып карыйсы килә. «Атыйм инде» дип, әтинең буынына төшәм.* Ф.Яруллин. **Буынга сикерү** Үсемлекләрдә: буын чыгарып, үсә башлау. *Ике якта да – буынга сикергән арыш басуы.* Х.Сарьян. *Тирә-якта берничә буынга сикергән иген кырлары дулкынлана.* Сөембикә. **Буынга утыру** 1) *к.* **буын ныгыту;** 2) Үсемлекнең берничә буынга үсүе. *Игеннәр буынга утыргач, бәлки, Сабан туе чорында тагын бер килермен.* Г.Ахунов. **Буын ныгыту** Үсү, көч туплау. *Макар буын ныгытты инде. Бик суктырып тормый.* М.Маликова. **Буынсыз итү** Хәлсезләндерү. *Елау мине буынсыз итте.* Х.Сарьян. **Буыны йомшак** Куркак. *Буының йомшак, энем: шылт иттеме, – Куян кебек, тыр-тыр чабасың. Тауларны да күчерә ала торган Халкыңнан син читкә таясың ---.* Х.Туфан. **Буыны сыек** Ныгымаган. *[Альфред:] Аерылсаң, бетәсең, малай. Бетәсең! Буының сыек синең.* Р.Вәлиев. *Буыны сыек кешедән ныклы характерлы солдат чыкмый.* Ф.Яруллин. *Буыны сыек, акылы утырып бетмәгән яшь кешене тәрбияләүгә әллә болар аз өлеш кертәме?* Сөембикә

**БУЍН-БУЫННАН** *рәв.* Бабадан – атага, атадан балага күчкән, элек-электән, электән үк. *Буын-буыннан килә торган йолалар*

**БУЫНЛАНУ** *ф.* Буыннар барлыкка килү (үсемлектә). *Авыл зиратында, муртаеп, ботак-чатаклары терсәкләнеп, буынланып утырган карт каен бар иде.* Ш.Галиев

**Буынлана бару** Акрынлап, буыннарының саны арту

**Буынланып китү** Кинәт буыннар барлыкка килү яки буыннарның саны арту, тармакланып китү

**Буынланып тору** Буыннар ясалган хәлдә булу, буыннары ачык күренү

**БУЫНЛА́У** *ф.* **1.** 1) Тирәли киртләү (агачны); буынлы, буынтыклы итү

2) Буыннарга аеру, бүлгәләү. *Бу мәкальләр берәр генә җөмләдән торсалар да, аларның мәгънәсен кешегә җиткерү өчен бертоташтан гына әйтү җитми, буынлап, арага чак кына тынып биреп, бер буынын күтәреп, икенчесен төшереп, аваз ымлыгы һәм басымнар биреп әйтергә кирәк була*. Н.Исәнбәт

**2. буынлап** *рәв. мәгъ.* Буынын буынга аерып. *Җавапны белер өчен, чылбырны буынлап сүтәбезме?* М.Хуҗин. *Бу тигезләмәләрне буынлап тапкырлап табабыз:* $xy = a^{log} a^{x}.\ a^{log}\ a^{y} = a^{log\ a\ x\ +log\ a\ y}$. Алгебра

**Буынлап чыгу** Һәрберсен буынлау

**Буынлый төшү** Бераз буынлау

**БУЫНЛЫ** *с.* 1) Буын(нар)ы булган; бөгелүчән, хәрәкәтләнә торган. *Баксаң, монда да – өчәр-өчәр буынлы симметрик бөтен*. Х.Курбатов

2) Таза, көчле, буыннары нык булган. *[Хисмәтулла] Мәктәпне бетергәндә, хәтәр буынлы гына егетләр белән бил алыша башлады*. Ә.Моталлибов

**БУЫНСЫЗ** *с.* 1) Буын(нар)ы, буынтык(лар)ы булмаган, буыннарга аерылмаган, бүлгәләнмәгән. *Гадәттә, мондый буынсыз тоташу сабый чакта ук авыр эштә изелгән, көненнән дә алда тәртә арасына җигелгән кешеләрдә очрый*. А.Хәлим

2) Буын мускуллары бик йомшак булган, бөтенләй хәлсез; зәгыйфь гәүдәле. *Аның хәлсез, буынсыз тәнен, машинага салып, шәһәр хастаханәсенә алып киттеләр*. Г.Гыйльманов

3) *күч.* Ихтыярсыз, үз фикере булмаган. *Татар милләтенең умыртка баганасын хасил иткән исламчылык, төркичелек, халыкчанлык принципларына буынсыз, кыйбласыз татарчылык, биләмәчелек, көнбатышчылык идеяләре каршы куелды*. И.Әмирхан

◊ **Буынсыз җир** Йомшак урын. *Буынсыз җиргә пычак салу*. Әйтем

**БУЫНСЫ́З КАЛУ** *ф.* Буыннар, катып, хәрәкәтчәнлеген югалту (авыр эштән, картаюдан)

**БУЫНСЫЗЛАНУ** *ф.* Буын мускуллары йомшару, хәлсезләнү

**Буынсызлана бару** Торган саен ныграк буынсызлану. *Монах куркуыннан төртенә, калтырый, буынсызлана барды*. Л.Гомәров

**Буынсызланып калу** Кинәт, нинди дә булса сәбәптән буынсызлану

**БУЫНТЫГАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Җирдә иң зур күпчелекне тәшкил иткән умырткасыз хайваннар тибы (бөҗәкләр, үрмәкүчсыманнар, кысласыманнар); *русчасы:* **членистоногие.** *Ихтимал, ташлар, кошлардагы кебек үк, азыкның каты өлешен: моллюск кабырчыкларын, буынтыгаяклыларның хитин панцирен изеп йомшартырга ярдәм итә торгандыр*. Кызыклы физиология. *Башка барлык буынтыгаяклыларныкы шикелле үк, елга кысласының да каты япмасы бар*. Биология: хайваннар. *Иң борынгы буынтыгаяклылар – трилобитлар*. Гомуми биология

**БУЫНТЫК** *и.* 1) Буынтыгаяклыларда: гәүдәнең һәм аякларның өлешләре тоташкан хәрәкәтчән урын. *[Үрмәкүчнең] Корсак буынтыклары барысы бергә тоташып үскән*. Биология: хайваннар

2) Буынтыгаяклыларда: гәүдәнең һәм аякларның бүлгәләнгән өлешләреннән берсе. *Ана кыслаларның корсак буынтыклары башкүкрәккә караганда киңрәк була*. Биология: хайваннар

3) Тирәли калынаеп яки батып торган урын, бәҗрасыман сыр (*аяк-кулда, үсемлекләрдә, бөҗәкләрдә һ.б.ш.да). Кишернең чугын өзеп ташлап, тешләремне бер буынтыгына батырдым*. Г.Гобәй

**БУЫНТЫКЛАНУ** *ф.* Буынтыклар барлыкка килү

**Буынтыклана башлау** Буынтыкланырга тотыну

**Буынтыклана төшү** Тагы да бераз буынтыклану

**Буынтыкланып китү** Берникадәр, бераз буынтыклану

**Буынтыкланып тору** Буынтыклар ясалган хәлдә булу, буынтыклары ачык күренү

**БУЫНТЫКЛЫ** *с.* Буынтыкларга бүлгәләнгән, буынтыгы булган. *Миләүшә инде уянган, буынтыклы ак куллары белән киерелеп ята иде*. Г.Ахунов. *Кысланың гәүдәсе ике өлештән тора: зур гына башкүкрәк һәм яссылана төшкән буынтыклы корсак*. Биология: хайваннар

**БУЫНЧӘЧӘК** *и. бот.* Фәрештә чәчәге, һиндыба; *русчасы:* **цикорий**. *Буынчәчәк – күкчәчәк Сокланырга ярады: Шул зәңгәрлек эченнән Гүя әнкәй карады*. С.Гәрәева

**БУЯГЫЧ** *и.* **1**. 1) Буяу өчен кулланыла торган махсус корал, җайланма

2) *к.* **буяу** II (*1 мәгъ.*). *Уильям Генри Перхин (1838–1907) анилин белән калий дихроматы тәэсир итешкәндә хасил булган утырымнан җете кызыл буягыч матдә – мовеин* (*беренче синтетик буягыч*) *аерып ала*. Фән һәм тел. *Каучукны вулканлаштырганда, аңа корым һәм шулай ук төрле буягычлар да өстиләр*. Химия

3) Азык-төлеккә салына һәм аңа төс бирә торган матдә. *Мәсәлән, шоколад конфетларының кайбер төрләренә Е-124 буягычы кушыла*. Ватаным Татарстан. *Үзебез үстергән яшелчәләргә беркайчан да пестицид, гербицид сипмибез, йорт шартларында әзерләнгән ризыкларга буягычлар, консервантлар кушмыйбыз*. Ватаным Татарстан. *Еш кына, йогурт составында «Е-120 табигый буягычы бар» дигән язу очратырга була*. Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* Буйый торган; төс бирә торган. *Кысланы пешергәндә, япмадагы буягыч матдәләр таркалып, төсен үзгәртә – кысла кызара*. Биология: хайваннар

**БУЯНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **буяу**. --- *безнең тормышыбызга да яраклаштылар, аның иң изге саналган әйберләре белән алыш-биреш ясарга өйрәнделәр, безнең байрагыбыз төсенә буянып алдылар*. Татар театры

2) Бизәнү, ясану, төзәнү. *Буянган кыздан оялган кыз матур*. Мәкаль. *Миләүшә – болай да пешкән кура җиләге – иртән буянып, ясанып, кыска итәкле модный күлмәген киеп, эшенә китте*. Д.Гыйсметдин

**Буяна башлау** Буяныргa тотыну

**Буяна төшү** Бераз буяну

**Буянып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә буяну

**Буянып йөрү** Һәрвакыт буянган булу. *[Нина Ахуновна] Буянып йөри торган хатын.* Х.Камалов

**Буянып тору** 1) Әле, хәзерге вакытта буяну

2) Һәрвакыт, гел буяну

**БУЯ́У** I *ф.* 1) Әйберләргә теге яки бу төсне бирә торган махсус матдә сөртү, сылау, сеңдерү. *[Капка] Башы тимер белән ябып буяган ---.* Г.Ибраһимов

2) Биткә, тәнгә (ясалма) матурлык, нәфислек бирү чараларын куллану, бизәнү. *[Вәли:] Бервакыт хатын «бик матур була» дигәч, котырынып, шушы мыегымны карага буяган идем.* Г.Камал. *Ирен буяу*

3) Пычрату. *Бая яр читеннән бөрлегән җыеп йөргәндә, менә күлмәк изүен буяды.* Г.Гобәй

4) *күч.* Чәч, керфек, сакал-мыекның, төрле тышкы тәэсирләр, яшь белән бәйле рәвештә табигый төсләре үзгәрү. *Кеше түзә алмастай авыр эш, йокысыз төннәр, барлы-юклы шушы бер ел эчендә, аның маңгаена ике тирән сызык сызып куйды, кара чәчен соргылт төскә буяды.* Г.Бәширов

5) *күч.* Күпертеп, кабартып, матурлатып сөйләү. *Ул, үзенең хыялы белән ашлама сибә-сибә үстергән үсемлектәй, Ирекне әллә нинди аллы-гөлле буяуларга буяп, илаһи биеклекләргә күтәргән, үзе тудырган шул ялган сынга үзе үк табынган, үз-үзен югалтып, аңа хезмәт иткән.* Ф.Садриев

6) *күч.* Гаепләү, оятка (хурлыкка) калдыру; тап төшерү. *Усал кеше – ул күмер белән бер, Көйдермәсә дә буяр барыбер.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Яшьлектә бер адашу – гомер буе биографияңне буйый ул.* Х.Камалов. *Җәһелгә пумаланы манып алып, Халыкның буяганнар йөзләрене.* Н.Думави

**Буяп алу** Тиз генә буяу. *Бераз мыекны буяп аласы иде.* К.Тинчурин

**Буяп ату** Тиз-тиз, аннан-моннан буяу

**Буяп бару** 1) Нәрсәне дә булса тоташтан, рәттән буяу

2) Нинди дә булса бер әйберне, төсе тоныкланган саен, системалы буяу

**Буяп бетерү** 1) Тулысынча, башыннан ахырына хәтле буяу. *[Сарайның түбәсен] Буяп бетерүгә, аңа бер саесскан килеп кунган, ди.* Х.Мәхмүтов

2) Бик каты, бөтен җирен буяу. *[Вәли:] Җитмәсә тагын, мыекка сөртәм, дигәндә, битләрне буяп бетердем.* Г.Камал. *--- җәйге эссе һавада йомшап җебегән бу конфет картның кулларын, авызларын буяп бетергән.* М.Мәһдиев. *Бозаулары чирләп тора әле. Бөтен лапасны буяп бетерде инде.* Р.Зәйдулла

**Буяп җибәрү** Бераз, аз гына буяу

**Буяп йөрү** 1) Һәрвакыт, даими буяган булу. *Бу чагында инде кашны гына түгел, чәчне дә буяп йөриләр.* Г.Камал. *Үзләрен, каравыл кычкыртып, чыбык белән сыптырасы иде. Шуннан соң теләсә кайда тырнап, буяп йөрмәсләр иде.* Г.Мөхәммәтшин

2) Әле, сөйләү моментында буяу эше белән мәшгуль булу. *Яңа төзелеп яткан дачада тәрәзә рамнары буяп йөрим.* Т.Миңнуллин

**Буяп кую** Алдан буяу, буяган хәлгә китереп калдыру. *Әйтерсең лә илаһи бер даһи рәссам Мүксаз буйларын, без кайтуга, исәпсез-хисапсыз төрле төсләргә буяп куйган.* И.Юзеев. *Ул, тирән сулап, пумаласын акшарга манып алды да койманың иң өстәге тактасын буяп куйды.* М.Твен

**Буяп тору** 1) Нәрсәне дә булса хәзер, сөйләү моментында буяу

2) Һәрвакыт, гел буяу. *Аны [зиратны] чистартып, рәшәткәләрен төзекләндереп, буяп торалар.* Ф.Гарипова

**Буяп чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр буяу. *Аннары соң, авызын бер җәеп, бер җыеп, иреннәрнең бөтен җирен буяп чыга.* Т.Миңнуллин

**БУЯ́У** II *и.* 1) Әйберләргә сөртеп, сеңдереп, манып, теге яки бу төс бирә торган матдә. *Очкыч, яшел буяуга буялып, гаҗәп матур итеп эшләнгән иде.* А.Әхмәт. *Бер мыскал шәмәхә кара буявын күргәч, Ярмөхәммәт елмайды.* Р.Батулла. *Ак буяу юк иде, известь белән буйдылар, кызыл буяу урынына Гөлсем ападан кызыл кара сорап алдылар, күрән буяу урынына суган кабыгы суы ярап торды.* Г.Гобәй

2) Нинди дә булса берәр предмет өслегендәге аңа төс биргән матдә катламы. *Идән буявы кубып бетү*

3) Төсмер, тон, колорит. *Читләренә алтын буяу йөгерткән, аз гына хушбуй исе аңкып торган тагын бер кәгазь килеп чыкты.* Н.Дәүли. *Картинада алтынсу буяулар өстенлек итә*

4) Макияж. *Базы үзәнендә үскән кызыл тал төсле зифа буйлы, сурәтләрдә генә күрергә мөмкин булган һәм буяуга бөтенләй мохтаҗ булмаган матур йөз.* Ә.Баянов. *Битенә-башына бернинди буяу якмаган, алсу түгәрәк йөзле, икегә аерып таралган коңгырт кара чәчле, ясап куйгандай матур гәүдәле бер кыз иде бу.* Х.Сарьян

5) *күч. кит.* Ясалмалылык, тышкы бизәк. *Аларның һәммәсе – ялган, һәммәсе – буяу.* Ш.Әхмәдиев. *Бездә хәзер бәхет буявына буялмаган сыңар аяклы тычкан да табып булмый.* Ф.Хөсни

6) *күч.* Әдәбиятта, сөйләм телендә: сурәтләү чаралары. *Г.Ибраһимовның бу ун ел эчендә чыккан әсәрләре, азмыкүпме, романтизм буявына сугарылып язылган.* Г.Нигъмәти. *Хәтеренә килгән нәрсәләр һәммә буяулар белән килеп чыга торалар иде.* Ш.Камал. *Х.Туфанның 20 нче еллар поэзиясендәге яңа герой тибы, аның рухи йөзе аеруча тулы итеп, реалистик буяулар белән гәүдәләндерелгән.* М.Гайнетдинов

◊ **Буявы уңган, базары тузган** Элеккеге даны-шөһрәте беткән, яшьлеге үткән. **Буяуны артык куерту** Эшне зурга җибәрү, катлауландыру

**БУЯ́У КУАГЫ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, яфраклары гади, чәчәкләре акациянекенә охшаган алтын сары төстә, озын чукларда булган үсемлек; *русчасы:* **дрок**. *--- буяу куагының яфраклары гади, тоташ, озынча; ракитникныкы – катлаулы, өчәрле.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**БУЯУЛА́У** *ф. сир.* Буяу II катламы белән каплау

**Буяулап алу** Тиз генә буялау. *Булатов матрицаны валикка беркетеп,*

*буяулап алды да аяк машинасы әйләндерә башлады.* Ш.Маннур

**Буяулап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, беткәнче буяулау

**Буяулап бетерү** Тулысынча буяулау; буяулау эшен төгәлләү

**Буяулый төшү** Бераз буяулау

**БУЯУЛЫ** *с.* 1) Нинди дә булса төскә буялган, буяу белән капланган. *Буяулы ишектән чыпта җилкән артык.* Мәкаль. *Әгәр аңласалар, «Хәзрәте Гали» урынына «Хәсрәте Гали» дип, «чумарилар» тарафыннан язылган буяулы пыяла кисәкләрен калтырый-калтырый качырып йөрмәсләр иде бит (гарәп язуында бер ноктаның артык-кимлеге менә шундый мәгънә бозуларга китерә!)* М.Госманов. *Ул арада тыштан аяк тавышы ишетелде, буяулы нечкә ишек ике якка ачылды.* Г.Ибраһимов. --- *буяулы идән туңдырырлык салкын иде.* А.Шамов

2) Составында буяу яисә буйый торган матдәләр булган

3) Эченә буяу салынган. *Ул, әкренләп, үзенең алтын сары төсенә кереп бара – әйтерсең кемдер аны, ялгыш, кызыл буяулы чиләккә төшергән дә хәзер, кеше-кара күргәнче, дип, ашыгаашыга сөртә иде.* Р.Вәлиев

**БУЯУСЫЗ** *с.* 1) Буялмаган; үз төсе үзгәртелмәгән. *[Тикшерүче] Түргә атлап, сәке янындагы зур, буяусыз агач өстәлгә калын портфелен ташлады.* Г.Ибраһимов. *Сәке белән сандык арасында – сөян тактадан ясалган буяусыз өстәл.* М.Юныс

2) Төрле төс катнашмалары булмаган. *Тере, буяусыз йогырт сайларга кирәк.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Сурәтләү чаралары кулланылмаган, артык күпертелмәгән, ясалма булмаган (сөйләм турында)

**БУЯ́У ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Мареначалар семьялыгыннан, буявы өчен үстерелә торган, ачык төсле, вак чәчәкле үсемлек; *русчасы:* **марена**

**БУЯУХАНӘ** *и. иск.* Әйберләрне буяу, ману хезмәтен күрсәтә торган эшханә. *[Хуҗа] Үзенең буяуханәсенә, аның ишегенә карап утырырга гадәтләнеп китә.* Әкият

**БУЯ́У ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* Сары ромашка. *Оешма чәчәклеләрнең халык телендә «ромашка» дип аталучы төрләре күп. Болар – болын ромашкасы, дару ромашкасы, --- сары ромашка – буяу чәчәге яки сары чәчәк.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**БУЯУЧЫ** *и.* 1) Буяу, ману эшләрен башкаручы кеше, шул эшнең остасы. *Әтинең эше бик күп. Буяучыдан киндер аласы, мал-туар базарында терлек бәяләрен белешәсе ---.* Г.Бәширов. *Ә Чуриле урыслары! Алтын куллы буяучы, калайчы, тимерче, манучылар!* М.Мәһдиев. *Буяучылар бригадиры Зөһрә Кәбирова – кырыкны яңа гына тутырган, нык карашлы, киңчә яңаклы, биек маңгайлы, урта буйлы татар хатыны иде.* Р.Кәрами

2) Буяулар белән сәүдә итүче. *Ак та була, күк тә була Буяучының буявы.* Җыр

**БУЯУЧЫЛЫК** *и.* Буяучы һөнәре яки кәсебе

**БҮГЕН** *рәв.* **1.** 1) Бу көндә, сөйләнә торган көндә. *Җәһәтрәк бул, яңгыр тынды, синең көеңне көйләргә, дип чыкмадым юлга, бүген үк әйләнеп тә кайтасым бар.* М.Хуҗин. *Бүген кич дәрестән соң мөдирә ханым мине үзенә чакыртып алды да күңелсез генә дәште.* Р.-Н.Гүнтәкин

2) *күч.* Хәзерге заманда, хәзерге вакытта. *70 ел буе татар әдәбиятының үзәген тәшкил иткән бу язучыларның иҗатын бүген, кыйммәтләр тагын алышынган заманда, ничек бәяләргә?* Р.Нуруллина. *Намусым минем эшләгән эшләремә ревизия ясый бүген.* Т.Миңнуллин

◊ **Бүген – бар, иртәгә – юк** 1) Үлем алдында тору; 2) Мал яки байлык белән масаюлыкка, дөньяның фанилыгына карата әйтелә. **Бүген генә эш бетми** Киләчәкне алдан күреп, план белән эш итәргә кирәк, дигән мәгънәдә. *Бүген белән генә эш бетми бит, әни.* Ф.Хөсни. **Бүген килеп** Инде менә хәзер, хәзерге вакытта. *Әле кичә генә арба җиленнән очып китә торган бала йон, бүген килеп, тубал башлы фән артыннан йөгерә.* Ф.Хөсни. **Бүген таңда** Бүгенле-иртәгәле, шушы көннәрдә, якын арада

**БҮГЕНГӘ́ЧӘ** *рәв.* 1) Шушы көнгәчә, бүгенгә кадәр. *Хәзер чирле! Шуның аркасында, бүгенгәчә бәбигә уза алмый.* А.Гыйләҗев

2) Хәзергәчә, шушы вакыткача. *Гел файда гына китерә торган зыянсыз препаратлар, бүгенгәчә, Җир шарында юк.* Юлдаш

**БҮГЕНГЕ** *с.* 1) Шушы, сөйләнә торган көндәге. *Бүгенге ачуны иртәгәгә саклама.* Мәкаль. *Яхшылык бүгенге көннән бетерелә!* А.Толстой

2) *күч.* Сөйләнә торган вакыттагы; хәзерге замандагы. *Шикләнмибез дошманнарның көчендин без, Бүгенге көн Гали, Рөстәмнәргә тиң без.* Г.Тукай. *Бүгенге мал бүлешү чорында, бу исә калҗаның зуррагын эләктерергә мөмкинлек бирә.* М.Әмирханов. *Бу бит... бу бит... бүгенге гүзәл тормышыбызга ялагарга маташу бит бу!* А.Гыйләҗев

**БҮГЕ́Н-ИРТӘГӘ** *рәв.* Бик тиз арада, шушы көннәрдә, менә-менә. *Әллә нинди бик зур парахут планыны ясап, бүген-иртәгә шуның очына чыгып, инженер була торган егет тә бунда!* Г.Исхакый. *Бүген-иртәгә уракка төшәм, дип торганда, --- тугыз йортның тугызына да бергә тотынырга мөмкин түгеллеген барысы аңлыйлар иде.* А.Гыйләҗев

**БҮГЕНЛЕ́-ИРТӘГӘЛЕ** *рәв. к.* **бүген-иртәгә**

**БҮГЕНЛЕК** *с.* Бүгенгә дип билгеләнгән; бүгенгә җитәрлек. *Бүгенлек тә иртәлек – берсекөнгә киртәлек.* Мәкаль. *Бүгенлек ризыгыгыз булса, иртәгәсе өчен кайгыртмагыз, бу дөнья – фани, үтәр дә китәр, тәмле йокыга ни җитәр!* Ш.Мөхәммәдев

**БҮДӘНӘ** *и.* 1) *к.* **бытбылдык.** *Бүдәнә, симереп, батман булмас.* Мәкаль. *[Базар] Киштәләре --- бозау, сыер, дуңгыз, аеруча бәһасез курдюклы сарык, тавык, күркә, каз, үрдәк, бүдәнә --- түшкәләреннән сыгылып тора.* Р.Мирхәйдәров. *Монда филләр – киң яфраклы бик озын үлән ешлыкларында, бүдәнәләр --- солыга яшеренгән шикелле, --- кумелеп яшеренәләр.* Хайваннар турында очерклар

2) *күч. гади с. хур.* Кечкенә буйлы, тулы, юан гәүдәле кеше. *[Хулиган*

*малай] Илдарның якасыннан эләктереп тә алды: – Измәңне изәм бит, бүдәнә!* Г.Гобәй

◊ **Бүдәнә симертү** Эшсез яту. *Ул тагын бер айга якын резервта бүдәнә симертергә мәҗбүр булды әле.* Ш.Маннур

**БҮЗ** I *и.* **1.** *к.* **бәз**. *Бүз – күлмәк булыр, сүз – имгәк булыр.* Мәкаль. *Йөгереп тә кердем, йөз күрдем, Тәрәзкәйләргә бүз кордым.* Җыр

**2.** *с. мәгъ.* Бүздән торган, бүздән тегелгән. *Пәрдәләрем – зәңгәр бүз, Мин сөямен зәңгәр күз.* Җыр. --- *үзе исә күзне камаштырырлык ап-ак бүз чүпрәкләргә төренгән.* Г.Гыйльманов

**БҮЗ** II *с. иск.* 1) Соргылт; аксыл соры төстәге (атка карата әйтелә). *Бүз алашам арыса, Бүре ханга җиталмам, энемуглым күп туды, күп туса да кол туды, ханга гарызым әйталмам.* Җыр. *Сәүдә, имеш – Сату, имеш, Миннән артмыш, Сиңа җитмеш. – Бүз аргамак! – Турка ефәк! – Алтын-көмеш! – Татлы җимеш! Өлгер-җите-е-еш!* Р.Юныс

2) *иск.* Үсмер, яшь егет. *Бүз бала кайгыдан кыз ала.* Мәкаль

**БҮЗӘРҮ** *ф.* Төсе чыгу, төссезләнү. *Без табынган «кызыл» йөзен борды, Зәңгәрләнә төште… бүзәрде…* Ә.Гадел

**Бүзәрә төшү** Бераз бүзәрү

**Бүзәреп калу** Нәрсә дә булса эшләгәннән соң (мәс., юганнан, кояшта торганнан соң) бүзәргән хәлгә килү

**Бүзәреп бетү** Бөтенләй бүзәрү

**БҮК** *и. бот.* Бүкчәләр семьялыгыннан, шома кайрылы, тыгыз һәм авыр, дымга чыдам үзагачлы, яфрагын коючан агач; *русчасы*: **бук**. *Бүк һәм дәфнә агачларын яшен сирәгрәк суга.* Кызыклар дөньясында. *Кагыйдә буларак, агач ишекләр имән, бүк, каеннан һәм кызыл агачның төрле төрләреннән ясала.* Идел

**БҮКӘВЕЛ** *и. иск. к.* **бөгәвел**. *Яман илгә ясавыл булма, бөлгән илгә бүкәвел булма.* Мәкаль

**БҮКӘ(Й)** *и.* **1.** 1) *бор. төрки* Зур елан. *Йети башлыг йел бүкә.* М.Кашгарый

2) Мифик-фантастик зат (гадәттә, сабыйларны куркытканда искә алына). *Куркытып тотынма син, апа! Бүкәй белән кемнең котын алмакчы буласың?* М.Маликова

3) *күч.* Куркыныч нәрсә. *Үтә гомерләр, килгән буыннарны безнең белән өркетерләр, һәр чор үз бүкәйләрен тудыра.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Куркыныч; шыксыз. *Бүкәй йөз*

**БҮКӘН** *и.* **1.** 1) Юан агачның яки бүрәнәнең кисеп алынган очы, бүрәнә башы; юан агачларны тураудан барлыкка килгән кисәк. *Дөрест, бу аяклар бик нәфис түгелләр, аяктан да биграк, кәкре башлы бүкәннәргә охшыйрак төшәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Бүкәнгә утырган җиремнән йокымсырап киткәнмен.* Р.Фәизов // Металл һ.б.ш. материалдан бүкәнгә охшатып эшләнгән җайланма. *Матрос абыйлар чуен бүкәнгә эләктерелгән тимерчыбык арканнарны пароход эченә тартып алдылар.* Г.Мөхәммәтшин

2) *махс.* Арба тәгәрмәченең уртадагы, күчәргә кидерелә торган өлеше. *Инеш ярында --- арба бүкәне кырдым, араталар ясадым.* А.Гыйләҗев. *Ияртүче муфта бүкән капкачы белән бүкән арасына беркетелә.* Тракторлар һәм автомобильләр

3) *күч. туп.* Кыска буйлы, юан, авыр хәрәкәтле яки булдыксыз, аңгыра кеше. *Честь биреп азапланма, бүкән!* Ә.Мушинский. *Күпме әйттем, койрыгы киселгән тиреләрнең ярты бәясе төшерелә, дип, ә, башсыз бүкән!* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* Бүкәнне (*1 мәгъ.*) куышлап ясаган. *Бүкән умарта*

◊ **Бүкән шикелле** Дәшмичә, кымшанмыйча. *Бүкән шикелле утырдым, шуңа үкенәм, иптәш Ибраһимов.* М.Насыйбуллин

**БҮКИ** *и. к.* **бүкә(й)**. *Территорияләр, илләр буйлап, террор өрәгеме анда йөри? – Яңа «бүки» уйлап тапты заман, кабатлана тарих гүя юри…* Л.Шагыйрьҗан. *Сөембикәне күрү аңа никадәр куаныч-бәхет вә яшәү дәрте китергәнен бүки гәүдәле Җангали ханга аңларгамы соң!* М.Хәбибуллин

**БҮКСӘ** *и.* 1) Үңәчнең киңәйгән өлеше (мәс., күп кенә моллюскларда, бөҗәкләрдә, кошларда). *Симез бүксәсен сөйри алмас хәлгә килгән сугым казы кебек, як-якка янтаеп, чокырлы-чокырлы юлдан тәгәрәгән йөгебезне ихатага бору белән, капка эчтән ачыла башлады.* А.Хәлим

2) *сөйл.* Гәүдәнең ашкайнату органнары, эчәкләр урнашкан өлеше; корсак. *Әхмәт ыштансыз малайны иданнән күтәреп алды да, битләреннән, бүксәсеннән чат-чот үбеп, кире бастырды.* Ф.Садриев. *Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында бүксә кап булганчы ашыйбыз.* А.Гыйләҗев. *Өрәккә көлүе кыен, бүксәсе комачаулый, ахрысы, дип уйлады Ярмөхәммәт.* Р.Батулла

3) *сөйл.* Кайбер савытларның бүлтәеп чыгып торган ян йөзе. *Самавыр бүксәсе. Колба бүксәсе*

4) *күч. кимс.* Юан корсаклы кеше. *Ул мондый гына бүксәләрне күрмәгән дисеңме?* А.Хәсәнов

**БҮКСӘ́-БҮКСӘ** *с.* Зур, калын, кабарып торган. *Юлда бүксә-бүксә кәс йомарламнары тырпаеп тора.* М.Әмирханов

**БҮКСӘЛЕ** *с.* 1) Бүксәсе зур булган (кош-корт турында)

2) *гади с.* Корсагы зур булган (кеше турында). *Почмактагы агач караватта зур бүксәле бер ир-ат ята.* З.Хөснияр

3) Ян йөзе чыгып торган (савытлар турында). *Өстәл тартмасыннан кулына ияреп чыккан савыт мәктәпнең химия кабинетыннан соратып алынган бүксәле колба иде.* К.Кәримов

**БҮЛӘК** *и.* **1.** 1) Кешенең күңелен күрү, шатландыру, берәр вакыйгага бәйле рәвештә котлау һ.б. шуның кебек яхшы теләкләрдән бирелгән әйбер. *Бүләк биргән – бүләк көтә.* Мәкаль. *Бик нечкә эш ул – бүләк табу!* Ә.Еники. *Бүләкне кешесен яратканың өчен алырга кирәк икән. Кешесен. Ә мин бүләкләрен генә яраттым шул.* Ю.Әминов

2) Клиентларны күбрәк җәлеп итү максаты белән, бушлай бирелә торган әйбер

3) Күчтәнәч. *Туй-төшемдә була торган бүләкләрне, дәрәҗәсенә күрә бүлеп, кәгазьләргә яздылар.* Г.Исхакый. *Ә армиядән нинди бүләк, күчтәнәчләр алып кайткан иде ул!* Р.Мирхәйдәров

4) Нинди дә булса эшне уңай хәл итүдә күрсәткән ярдәм өчен, рәхмәт йөзеннән бирелә торган әйбер. *[Галим абзый] Акча, көч кызганмады; мәхәлләнең тирес кешеләренең тамгасын сатып та алды; түрәләрнең авызыны бүләк берлә каплады.* Г.Исхакый. *Бүләк китергәнне, бүләк биргәнне ярата ул.* Р.Мөхәммәдиев

5) Нинди дә булса өлкәдә ирешкән уңышлары, яхшы хезмәте өчен бирелә торган кызыксындыру чарасы (премия, мактаулы исем, акча, орден, медаль һ.б.ш.). *Косыгин барысы алдында: «Өлкән метрдотельне хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итәргә!» – диде.* Б.Сабитов

6) Ярышта җиңеп чыгучыга бирелә торган акча яки әйбер. *Ат юыртты-рып, бүләккә [чәчкеч] алды.* Г.Галиев. --- *махсус премия, 1967 елдан башлап, елның иң үткен каләм хуҗасына бирелеп килә. Бу бүләк 28 иҗат әһеленә тапшырылды инде.* Татарстан. *Бәйгедә катнашучы һәр кешегә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылачак.* Мәдәни җомга

**2.** *с. мәгъ.* Бүләк итеп бирелгән, бирелә торган. *Бүләк атның тешенә карамыйлар.* Мәкаль. *Кыз күренүгә, Гарифулла кыю гына атлап, аның янына килде, бүләк сөлгесе өчен рәхмәт әйтте: «Бигрәк матур чиккәнсең! Ә үзең – тагын да матуррак!».* Г.Хәмиди. *Бүләк түбәтәйләр тәрәзә төбендә өелеп тора.* М.Әмирхан

**БҮЛӘ́К БАГУ** *и. этн.* Элек: кыз алу, кыз бирү вакытында кода-кодагый, күрше-күлән арасында кием-салым, кул эшләрен күрсәтешү йоласы. *Фәлән көнгә Нәгыйм байда бүләк багу мәҗлесе булачак, шуңар өлгертергә алган эшләрем бар, ди.* Г.Камал

**БҮЛӘ́К ИТҮ** *ф.* Бүләк рәвешендә бирү. *Бу мәктәпкә мин үземнең рәсемнәрем күргәзмәсен бүләк иткән идем.* Татарстан. *Сибгат абыйга нәрсәдер бүләк итте дә, аш янына утырмыйча, чыгып та китте.* Таныш өянкеләр

**БҮЛӘКЛӘ́Ү** *ф.* Бүләк (*5, 6 мәгъ.*) бирү. *Җиңүчеләрне шулай бәллүр әйберләр белән юмарт бүләклиләр.* Р.Мирхәйдәров. *Без бүген, иптәшләр, кыр батырларын бүләкләдек.* Ф.Яруллин. *Минем дәрәҗәм шулкадәр күтәрелде ки: барлык күрше-күләннәр кереп, мине котлап, хәтта бүләкләп чыктылар.* А.Тимергалин

**Бүләкләп кую** Көтмәгәндә бүләкләү. *Көт тә тор, сине «бабай» исеме һәм кара борынлы малай белән бүләкләп тә куярлар әле.* Я.Зәнкиев

**Бүләкләп тору** Еш, әледән-әле бүләкләү

**Бүләкләп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы бүләкләү; һәрберсен, берәүне дә калдырмыйча бүләкләү

**БҮЛӘКЛӘ́Ү КӘГАЗЕ** *и.* Аерым кешене, оешманы бүләкләү турында рәсми документ. *Телеграмманы «Бүләкләү кәгазе»ндәге мәгълүматлар белән чагыштырырга керештеләр.* Ш.Рәкыйпов

**БҮЛӘКЛЕК** *с.* Бүләккә дип билгеләнгән. *Бүләклек сөлгеләр*

**БҮЛӘ́К-САНАК** *җый. и. к.* **бүләк-ярак.** *[Вахид хәзрәт] Бәйрәм алдында, атына утырып, базарга барып, әллә никадәр бүләк-санак алып кайтучан булды.* Г.Исхакый. *Искә төшкән саен, янына кергәләргә, бүләк-санак бирергә, күрешергә мөмкин.* В.Имамов. *Аларның һәммәсенә дә, дәрәҗәсенә карап, сый-хөрмәт, бүләк-санак кирәк булачак.* А.Гыйләҗев

**БҮЛӘ́К-ЯРАК** *җый. и.* Бүләк, күчтәнәч итеп бирелә торган әйберләр. *Юлга, вак-төяк бүләк-яракка бер унбиш сум эшлим дә, авылга кайтам.* Г.Ибраһимов

**БҮЛБЕ** *и. лат.* Сабакның җир өсте яки җир асты өлешендә юанайган, файдалы матдәләре (мәс., крахмал) туплана торган урыны; яңару һәм вегетатив үрчү органы. *Бәрәңге бүлбеләреннән крахмал, бәрәңге балы, спирт һәм башка продуктлар алына.* Биология. *Бүлбеләрнең югары очында урнашкан бөреләрдән җир өсте бәбәкләре үсеп чыга.* Биология. *Беренче бүлбеләрне Петербургка дворяннар алып кайта.* Кызыклар дөньясында

**БҮЛБЕЛӘНҮ** *ф.* Үсемлектә: бүлбе(ләр) яралу, бүлбе(ләр) барлыкка килү. *Бәрәңге бүлбеләнү*

**БҮЛГӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **бүлү**

2) Күп һәм вак өлешләргә, кисәкләргә аеру. *[Хисләремне] Төрле-төрле кисәкләргә Бүлгәләп вакламадым.* Ә.Ерикәй

**Бүлгәләп алу** Кыска вакыт аралыгында, тиз-тиз бүлгәләү. *Без, түй ашын кичкә өлгертергә, дип, биянең итен, эчәкләрен, карталарын, карыннарын тизрәк бүлгәләп алдык.* М.Әмир

**Бүлгәләп ату** Тиз арада, аннан-моннан бүлгәләү

**Бүлгәләп бару** Һәммәсен, булган берсен бүлгәләү

**Бүлгәләп бетерү** Нәрсәне дә булса ахырына кадәр бүлгәләү; тәмам бүлгәләү. – *Әгәр без татарларны кабул ителгән әдәби телдән аерып, һәр төбәк сөйләшендә әдәби әсәрләр яза башласак, болай да тотрыксыз булган татарны бүлгәләп бетерәчәкбез, – диде.* Т.Миңнуллин

**Бүлгәләп йөрү** Әле, хәзер бүлгәләү белән шөгыльләнү. *Бер булсын, берәгәйле булсын, шушы берне үстерсәк, дөньябызны да бүлгәләп йөрисе булмас, үзебез дә өебезнең түрендә утырырбыз, дип уйлаганнар.* Э.Шәрифуллина

**Бүлгәләп ташлау** Кинәт бүлгәләү. *Мәүлиха түти әле сугылмаган, бер өлеше ындырга да кереп җитмәгән игенне алай алдан-ала бүлгәләп ташлауны ошатмый иде булса кирәк.* Г.Бәширов

**Бүлгәләп тору** Әледән-әле, еш бүлгәләү. *Шәфкать туташлары Сәетнең зиһенен талкыган хатирәләр шаукымы агышын бүлгәләп торсалар да, туктата алмадылар.* Т.Галиуллин

**Бүлгәләп чыгу** Нәрсәне дә булса һәрберсенә, башыннан ахырына кадәр бүлгәләү

**БҮЛГЕ** *и.* 1) Бүлеп, аерып торган нәрсә. *Сосудлар арасында аркылы бүлгеләр таркала, кузәнәк тышчалары катылана һәм калыная.* Биология

2) *анат.* Борын куышлыкларын аерып торган кимерчәк. *Отолорингологка күренгәч, егетнең борын бүлгесе кәкрәйгәне ачыклана.* Мәдәни җомга

**БҮЛГЕЧ** *и. махс.* Бүлү, аеру хезмәтен башкаручы җайланма. *Бүлгечтә золотник нейтраль хәлдә булганда,*

*клапан ачык була, һәм май кудыргычтан бүлгеч аша бакка кайта.* Тракторлар һәм автомобильләр. *Золотниклар – бүлгечнең төп эшче органнары.* Тракторлар һәм автомобильләр

**БҮЛЕК** *и.* 1) Бүлем, бүлемтек; өлеш, кисәк. *Өй икегә бүленгән, ишектән аяк атлауга, беренче бүлмәгә керәсең. --- бу бүлектән үтеп, эчке якка атлыйм дигәндә – бик зур, тәбәнәк мич.* Г.Ибраһимов. *Кайткач, мине өч бүлеккә кис.* Татар мифлары

2) Бөтеннең нумерация яисә исем белән (мәс., китапта, сәхнәдә) аерылып торган өлеше. *Бүген алтынчы бүлеккә тотынып-тотынып карасам да, тиз генә юлны табып булмады әле.* А.Гыйләҗев. *План өч бүлектән тора: доклад, концерт һәм төрле уеннар.* Ш.Камал

3) Тармак (мәс., предприятиедә, учреждениедә һ.б.ш.да). *Кибетнең балык бүлегендә дә мичкә-мичкә уылдык – карасы да, кызылы да өзелмәгән, затлы балыклар да торган.* Р.Мирхәйдәров. *Бахырлар күпсанлы төрле бүлек, бюроларда, өсте-өстенә өелешеп дигәндәй, бушка гомер уздыралар – ыштан туздыралар бит.* Р.Мирхәйдәров. *Институтның тел белеме бүлеге*

4) *иск.* Төркем, даирә (кешеләр турында). *Капканың теге ягында хатыннар күбрәк иде. Бу бүлеге [ирләргә караганда] бөтенләй башка иде.* Г.Исхакый. --- *ысуле җәдидә яклы байлар, муллаларны – җыенысын бер гөруһка бүлеп, аларны да үзләре берлән бер бүлеккә кертәләр ---.* Г.Исхакый. *Халыкның бер бүлеге хәзрәткә әйләнеп карадылар.* Ф.Әмирхан. *Чынлап та Хәяттә хатын-кызның бер бүлегендә бик куәтле була торган көнләшү тойгысы аз иде.* Ф.Әмирхан

5) *хәрби* Зур булмаган гаскәри берләшмә, часть. *Олы Ширмә авылында акларның җәяүле бер бөтен бүлеге ята.* Һ.Такташ. *Бер урында дошманның резервта яткан кавалерия бүлекләре ике полк арасына килеп кергән.* А.Шамов

6) Бүлеп алынган җир. *Түтәлләр бүлеге белән кәбестә, помидор бүлекләрен аерган үзән турысында, камышлы күл белән сөзәк арасындагы тигез чирәмдә учак корылган.* Ш.Камал. *Инеш буендагы сөзәк урынның Сакмарга табангы өлешендә берникадәр өзәннәр белән бүленгән аерым-аерым бүлекләрдә бик күп санда эшләнгән түтәлләр күренеп китә.* Ш.Камал

**БҮЛЕКЧӘ** *и.* 1) Бүлек (*1, 2, 3 мәгъ.*) эчендәге кечерәк бүлекләрнең берсе. *Әсәр ике бүлектән тора --- беренче бүлектәге өч бүлекчә аерым юлларда ике нокта куеп бирелгән «Истә» белән башлана.* М.Максуд. *Гөл-Төркем белән телефоннан сөйләштеләр, «Сельхозтехника»ның район бүлекчәсенә барып килделәр.* Б.Камалов

2) Кечкенә бүлем. *Һәр вак бүлекчә, командаларга хәтле җәяү йөреп чыкты ул [Муса].* Ш.Маннур. *Сафка тезелгән егетләр, үзләренең шул ышанычлы адымнарын бозмыйча, җырлый-җырлый, казармаларына килеп җиттеләр дә, шып туктап, үз бүлекчәләренә таралыштылар.* Ш.Маннур

3) Оешмаларның үзләреннән читтә урнашкан бүлеге. *Бер ел дигәндә, ул гади мастердан – прораблыкка, аннары төзелеш идарәсе бүлекчәсе башлыгына кадәр күтәрелә.* Р.Мирхәйдәров. *Барган-барган, почта бүлекчәсенә сугылып чыгар.* Н.Гыйматдинова. *Һәр эш көнемне, иртәнге җидедән дә калмыйча, аның структур бүлекчәләрен әйләнеп чыгудан башлыйм.* Татарстан

**БҮЛЕМ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса бүлеп, аерып куелган бер өлеше. *Кирпеч заводының йөрәге – Гоффман миче. Ул түгәрәк буенча урнашканлыктан, кирпеч яндыру бер генә минутка да тукталып тормый. Әмма бүлемнәрнең берсе һәрчак ялкынсыз кала.* М.Гыйләҗев

2) Нәрсәне дә булса өлешләргә бүлү, аеру хезмәтен үти торган әйбер. *Һава үтү юллары борын куышлыгыннан башлана, борын куышлыгы, сөяккимерчәк бүлем белән, уң һәм сул яртыларга бүленә.* Биология

3) Әйберләрне (мәс., акча, савыт-сабаны) саклау, йөртү өчен ясалган җайланмалардагы бер-берсеннән аерылып торган өлешләрнең берсе

4) Бина, каралты һ.б.ш.ның аерымланган өлеше; бүлмә (вагонда һ.б.ш.да). *Казарманың күрше бүлемендә чиертеп уйнаган музыка тавышы ишетелә иде.* Ш.Камал. *Санитарка белән сестра урта бүлемдә утыралар.* С.Сөләйманова

5) Кечкенә җир мәйданы, кишәрлек

6) *иск.* Бүлек (китапта, кичәләрдә һ.б.ш.да). *Кичә өч бүлем булып, әүвәлге бүлемдә, хор белән, «Шәкертләр садасы» җырланды.* Ф.Әмирхан

7) *иск.* Төркем (кеше, хайваннар турында)

8) Махсус сызыклар белән тигез араларга бүленгән үлчәгечләрдә: ике сызык арасы. *Аның кәеф стрелкасы, шкала буенча, кисәктән җиде бүлемгә югары күтәрелде.* Ш.Мөдәррис. *Линейкадагы бүлемнәр*

9) *күч.* Нәрсәләрнең дә булса охшаш һәм аермалы, уңай һәм тискәре якларын күрсәтеп, алар арасында үткәрелгән чик. *Беренчедән, педагогик статьяларымда белем һәм тәрбия арасында мин үткәргән бүлем ясалма рәвештә булды, дияр идем.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**БҮЛЕ́М-АРАН** *җый. и.* Бина, каралты һ.б.ш.да бүленеп алынган мәйданнар. *Уртада – ак бетоннан эшләнгән юл, ике якта ак бетон плитәләрдән төзелгән бүлем-араннар иде.* Х.Камалов

**БҮЛЕМЛӘҮ** *ф.* 1) Бүлемнәргә аеру

2) Бүлемнәр ясау

**Бүлемләп бетерү** Тулысынча, ахыргача бүлемләү

**Бүлемләп кую** Бүлемнәргә бүленгән хәлгә китерү

**БҮЛЕМЛЕ** *с.* Бүлеме (*1–5 мәгъ.*), бүлемнәре булган, бүлемнәрдән торган, бүлемләнгән. *Өй ике бүлемле иде: алгысында --- алмалар салынган әрҗәләр хуш ис таратып тора, эчке бүлмәдә – карават, такта өстәл.* И.Гази

**БҮЛЕ́М САНЫ** *и. лингв.* Предметларның бертигез төркемнәргә бүленүен белдергән сан. *Барлык форма бүлем саннарына өстәмә -лап/-ләп кушымчасы да ялганырга мөмкин: икешәрләп, өчәрләп-дүртәрләп, бишәрләп-унарлап.* Татар грамматикасы

**БҮЛЕМТӘ** *и. сир.* 1) *к.* **бүлемте.** *Нибары ике бүлемтәдән торган бу киң абзарга [сыерларны урнаштырдылар].* С.Рафиков

2) Бүлмәләрне, бүлемнәрне (бүлемтеләрне, бүлемтекләрне) бер-берсеннән аерып торган юка стена. *[Сахап] Такта бүлемтә артында кешеләрнең сөйләшкәннәрен тыңлап торды.* С.Рафиков

**БҮЛЕМТЕ** *и.* Кечкенә бүлем. *Саву бүлемтесендәге «ёлочка»ның ялтыравык никель уентысындагы тәмле комбикормага танауларын төрткәч, сыерлар тына-тынычлана язды.* Э.Касыймов. *Газизҗан сузган кызгылт сары әфлисун бүлемтеләренә кабыгыннан калган нәзек-нәфис алтынсу ефәк җепселләр сарылган иде.* М.Маликова

**БҮЛЕМТЕК** *и.* **1.** *к.* **бүлемте**. *Ул ниндидер могҗиза белән генә исән булган бозауны кеше күзеннән еракkарак – абзарның иң эчке бүлемтегенә кертеп япты.* Г.Гыйльманов. *Унҗиденче бүлмә уртадагы бүлемтекнең иң азагында, җир астына уелып кергәндәй, тар бер аралыкка урнашкан иде.* Ф.Латыйфи. *Елның кайсы фасылында, көннең кайсы бүлемтегендә булмасын, төрледәнтөрле уйлар, шакып-нитеп тормыйча, чиксез озын җеп булып башыма уралалар да, ми шарларым йомгак булып авыраялар иде.* А.Гыйләҗев. *Гомологик хромосомалар мейоз процессында аркылы кисешәләр һәм бүлемтекләрен алмашалар.* Гомуми биология

**2.** *с. мәгъ.* Бүленгән, бүленеп ясалган. *Бүлемтек почмакта әнисе йоклый, түрдә – балалар, ә ир белән хатынга ишек төбендәге борынгы сиртмәле карават кала.* Н.Гыйматдинова

**БҮЛЕМТЕКЛӘҮ** *ф.* Бүлемтекләргә аеру, бүлемтекләр ясау

**БҮЛЕМТЕКЛЕ** *с.* Бүлемтекләре булган, бүлемтекләрдән торган; бүлемтекләнгән. *Бу лагерьга тоташтырып, тагын әллә ничә бүлемтекле яңа читлекләр корылды.* Ш.Маннур

**БҮЛЕНДЕК** *и.* **1.** Бүленеп чыккан нәрсә. *Җир тетрәү сүнгән яки йоклаган вулканның пар һәм газ хәлендәге бүлендеге өскә бәреп торган ярыкларны томалап куйган.* В.Обручев. *«Яраксыз» бүлендекләр --- туктаусыз рәвештә тәнебезнең үсемлек өлешенә агылалар, һәм Кояш аларны файдалыга әверелдерә.* Күп белергә теләсәң

**2.** *с. мәгъ.* Зуррак предприятиедән аерылып чыккан, кечерәк. *Проектта катнашучыларның уңышсызлык ихтималын үзара бүлешүләре – өстәмә акция бастырып чыгару, бүлендек (дочернее) предприятиеләр төзү --- зур роль уйный.* Икътисад теориясе нигезләре

**БҮЛЕНЕШ** *и.* 1) Өлешләргә, кисәкләргә аерылганлык, ярылганлык

2) Төркемнәргә аеру, классларга бүлү, классификацияләү; төркемләнеш. *Әгәр күпчелек югары белемгә ия икән, аннан да югарырак белемлеләр булырга тиеш, чөнки базар мантыйгы бу бүленешне бүген үк таләп итә.* А.Мөхәммәтҗанов. *Монда типтәрмазар дигән бүленеш юк.* А.Гыйләҗев. *Кешеләр, гаилә мөнәсәбәтләре, хезмәт бүленешендәге бөтен уңай һәм тискәре яклар аларда да [кошларда да] бар икән.* М.Мәһдиев. *Физик хезмәттә – мускул эшчәнлеге, ә акыл хезмәтендә фикерләү өстенлек ала. Бу – шартлы бүленеш.* Биология // Билгеле бер тәртиптә урнашу үзенчәлеге. *Елгалар челтәренең материк буйлап бүленеше тигез түгел.* Материклар һәм океаннар географиясе

3) Бүленүдән барлыкка килгән берәмлек. *Казан ханлыгы заманыннан сакланып килгән административ бүленеш булган Җөри юлында --- Колсары авылы шушы Колсары бәк тарафыннан нигезләнгән булса кирәк.* М.Әхмәтҗанов

**БҮЛЕНТЕ** *и. к.* **бүлемте.** *Көзен анның [бәрәңге базының] бүлентеләренә, түбәләмә тутырып, бәрәңге салганнар иде.* Э.Касыймов

**БҮЛЕНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **бүлү** (*1–7 мәгъ.*). *Келәт эче иңеннән-иңенә зур, чуар чаршау белән бүленгән булып чыкты.* Ә.Еники. *Белем бирү дә, тәрбияләү дә бүленмиләр.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Аның сөйләме алга таба да кызның сорау-үтенечләре белән бүленеп бара.* Х.Миңнегулов

2) Аерылу, башка юлдан китү. *Аерылганны – аю ашар, бүленгәнне – бүре ашар.* Мәкаль. *Әмма алар дошман хәйләсен яхшы белә, чөнки бүленеп калган гаскәрнең кече өлеше генә утраудa.* Н.Гариф

3) Өзелү, тукталу. *Күкләр януы, гармун моңы бергә тоташа да, йокылар бүленә, уянып китәсең.* Ф.Әмәк

**Бүленеп бетү** Барысы да, тулысынча бүленү. *Анда бөтен постлар да әллә кайчан бүленеп беткән, әшнәлек, туганлык җепләре белән беркетелгән.* Р.Сәгъди. *Боларның һәрберсе тагы әллә ничәшәр аерым шивәләргә, аерым сөйләшләргә бүленеп беткән.* Г.Алпаров

**Бүленеп йөрү** 1) Күптәннән, озак вакытлардан бирле бүленгән хәлдә булу. --- *татарлар «йомышлы» һәм «ясаклы»ларга гына бүленеп йөргәннәр.* Д.Исхаков

2) Әле, сөйләү моментында бүленү белән мәшгуль булу

**Бүленеп калу** 1) Нинди дә булса тоткарлыкны үтеп чыга алмый бүленү, тоткарлану. *Вагон эчендә көндезге һава бүленеп калган.* К.Кәрим. *Ә инде язгы ташуда бүленеп калган көннәрдә әлеге хис тагын да көчәя.* Р.Вәлиев

2) Кинәт кенә, вакытлыча бүленү. *Ул кыз бүлмәгә күптәнге таныш кебек килеп керә ярты сүздә бүленеп калган сыман кушылып китә.* Ш.Галиев

**Бүленеп кую** Алдан бүленгән булу. *Һәр укучыга егерме бишәр сотый исәбеннән, кишәрлекләр алдан ук бүленеп куелган иде.* В.Нуруллин. *Чаршау белән генә бүленеп куелган, киенү бүлмәсе ролен үтәгән кечкенә аралыкка килеп кергәч, аптырап калды.* А.Әхмәтгалиева

**Бүленеп тору** Күпмедер вакытка бүленү, вакытлыча бүленгән булу. *Бу йортларда, күбрәк, роман-повестьлар язучы өлкән әдипләр һәм сугыш нәтиҗәсендә иҗатлары бүленеп торган фронтовиклар яшәп иҗат итә иде.* Л.Ихсанова – *Бер пот… – димен һәм, бүленеп торганнан соң: – Саф һава, – дип өстим.* Юлдаш

**Бүленеп чыгу** 1) Аерымлану, төп төркемнән, төбәктән читкәрәк китү. *Ак Чишмәдән бүленеп чыгабыз, «Ак су» дигән фирма төзибез, диярбез.* К.Кәримов

2) Аерылу, таркалу. *Бу очракта химик реакциядә бүленеп чыккан энергиянең бер өлеше турыдан-туры яктылык*

*энергиясенә әверелә, ә җисем үзе салкын килеш кала*. Физика

3) Үзенә аерым мөстәкыйль хуҗалык кору, башка чыгу

**БҮЛЕНҮЧӘНЛЕК** *и. мат.* Бүленә алучанлык. *Саннарның 9 га бүленүчәнлек билгеләрен исбатлагыз.* Алгебра

**БҮЛЕНҮЧЕ** *и. мат.* Икенче бер санга бүленә торган сан; *русчасы:* **делимое**

**БҮЛЕ́Н-ЯРЫН** *рәв.* 1) Аерым-аерым, төрле җиргә таралып

2) Бүленеп-бүленеп, өзә-өзә

**БҮЛЕШ** *и.* Кисәкләргә, өлешләргә бүлү, төркемләү эше. *Менә шунлар арасында Хәйдәр шәкерт мулла була башлагач та башланган бүлеш, яңа мулла указлы булып килгәч, тагы кызды.* Г.Исхакый

**БҮЛЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **бүлү** *(1–2, 4 мәгъ.). Эш бүлешү мәсьәләләрен артык кичектерергә ярамый.* Ш.Камал

2) Уртаклашу. *Үзенең «Юл картиналары»нда Гейне авылларны һәм крестьяннар тормышын күзәтүдән алган тәэсирләрен бүлешә.* Г.Нигъмәти. *Хәсрәтен бүлешергә иренең өйдә булмавы Нәсимә абыстайга бигрәк тә авыр тоелды.* С.Җәлэл. *Ә монда Галимә ханымга тапкан кызыкны да бүлешергә кеше юк.* Г.Толымбай

3) *күч.* Үзара дәгъвалашу, талашу. *Нәрсә бүлешкәннәрдер, коточкыч рәхимсезлек белән, бер-берсенә тондырышалар.* М.Әмир

**Бүлешеп алу** Өлеш алып бүлешү, өлешләргә аерып бүлешү. *Ә байлыкка хуҗа булуның ике юлы бар: искечә – дәүләт кулында саклау; яңача – үзара бүлешеп алу...* Ә.Еники. *--- аларның яраннары әйбәт җирләрне үзара бүлешеп алдылар.* М.Сәлим. *Аксыл чырайлыларның уе – бөтен Америка җирләрен бүлешеп алып, җирле халыкларны кол итү.* И.Хуҗин

**Бүлешеп бетерү** Тулысынча, беткәнче бүлешү. *Председательләр алышынган арада, гасырлар буе сабантуйлары гөрләгән Мәдрәсә бакчасын бүлешеп бетергәннәр.* К.Кәрим. *--- ә сине, чакырып, кунак итәргә минем өем юк, хатын, бала-чагам кеше мунчасында тора, терлек-туарымны бүлешеп бетерделәр.* Ф.Хатипов

2) Барысына да, бүлешеп, өлеш бирү. *--- сәламәт аягын – олы малайга, ике алгы аякны – уртанчы малайларга бирмәк булганнар. Аксак аяк исә кече малайга калган. Бүлешеп беткәч, кәҗә бәтиенең үскәнен көтә башлаганнар.* Әкият

**Бүлешеп йөрү** Әле, сөйләү моментында бүлешү белән мәшгуль булу. *Хәзер мал бүлешеп йөриләр*. Ф.Сафин

**Бүлешеп кую** Алдан бүлешү. *Син патша да мин – вәзир, мин вәзир дә син – патша, дип, үзебез генә бүлешеп куйыйк әле*. Р.Сәгъди

**Бүлешеп тору** 1) Әле, сөйләү моментында бүлешү. *Гыйльфан төптән таза чыккан ярау егет иде. Чәкәләшеп, кыз бүлешеп тормадык*. Р.Низами

2) Һәрвакыт, гел бүлешү

**Бүлешеп яту** Әле, сөйләү моментында бүлешү. *Икенчедән, халыкның мәчеткә йөрүен теләсәләр, дин әһелләре бераз халык белән эшләсеннәр, булмаган властьны бүлешеп ятмасыннар*. Т.Миңнуллин

**БҮЛК, БҮ́ЛК-БҮЛК** *иярт.* Тар авызлы савыттан сыеклык акканда яки савытка эре тамчылар тамып торганда чыккан тавышны белдерә

**БҮ́ЛК-БҮЛК ИТҮ** *ф. к.* **бүлкелдәү.** *Анда җылыткыч торбаларыннан бүлк-бүлк итеп аккан су тавышы гына ишетелә иде.* А.Хәлим

**БҮЛКЕЛДӘ́Ү** *ф.* Тар авызлы савыттан сыеклык салганда, «бүлк» иткән тавышлар чыгару

**БҮЛМӘ** *и.* 1) Йортта, фатирда: стеналар белән аерып эшләнгән бүлем. *Бүлмә якты, чиста һәм җыйнак иде.* И.Гази. *[Лениза] --- чәчләрен бигуди кәтүкләренә чорный-чорный, йокы бүлмәсенә атлады.* Х.Камалов. *Бу бүлмәдә түгел, әллә коридорда, әллә күрше бүлмәдә тамаклары карлыгып беткән кешеләр сөйләшәләр.* Г.Гобәй

2) Предприятие, учреждение һ.б.ш. урыннарда махсус бүлем. *Бәлки, сезне спорт бүлмәбез кызыксындырыр.* Ф.Яруллин. *Сулда – чишенү бүлмәсе.* Д.Аппакова. *Канцеляриягә – үз бүлмәсенә алып керде.* М.Әмир

**БҮЛМӘДӘШ** *и.* Бер бүлмәдә яшәүче кешеләрнең берсе. *Гамьсез йоклап яткан бүлмәдәшләрен күргәч кенә иркен тын алып куйды – эшкә барасы түгел.* Ш.Бикчурин. *Зараның да йокысы качкан иде бугай, бүлмәдәшенә таба борылып ятты.* М.Маликова

**БҮЛТ, БҮ́ЛТ-БҮЛТ** *иярт.* Тар авызлы савытлардан сыеклык агызганда ишетелә торган тавышны белдерә. *Бүлт-бүлт итеп, шешәдән сыеклык аккан тавыш ишетелде.* Р.Батулла

**БҮЛТӘЙМӘ** *и.* Бүлтәеп торган нәрсә. *Аннары камыт бөятенә, яраның ике ягына ике бүлтәймә ясап куясың.* Х.Камалов. *Аның [Рәсимәнең] муенында зоб бүлтәймәсе зурая бара иде.* Х.Камалов. *Аның [полипның] тәнендә кечкенә бүлтәймәләр рәвешендә бөреләнү хасил була.* Диңгез тирәнлегендә

**БҮЛТӘЮ** *ф.* Кабарып чыгу. *[Ул] --- трубкасын элде дә кучтәнәч тутырганга бүлтәйгән портфелен кулыннан-кулына алыша-алыша чыгып чапты бугай.* Ә.Гаффар. *Билен кысып бәйләгән бу бүлтәйгән эчле хатын --- коточкыч булып тоелды.* А.Чехов

**Бүлтәеп тору** 1) Әле, күз алдында бүлтәйгән хәлдә булу. *Менә орысы әле дә бүлтәеп тора.* М.Кәрим. *Айсин аягының баш бармагы янындагы сөяле, хром итеге эченнән, башмак тоягы сыман бүлтәеп тора.* А.Хәлим. *[Баланың] Тулып, бүлтәеп торган матур бит очлары, шулай ук авыз читләре, бармаклары кебек үк, ниндидер нәрсәгә пычранган иде.* Н.Фәттах

2) Артык күзгә ташлану, аерылып тору. *Булмый бит: әле берсе, артык кычкырып, бүлтәеп тора, әле икенчесе мәгънәне биреп җиткерми ---.* Р.Мирхәйдәров

**Бүлтәеп чыгу** Бүлтәйгән хәлгә килү. *Очлы, кәкре борыннары, алга бүлтәеп чыккан килбәтсез иякләре күзгә чалынып китә.* Г.Гыйльманов

**БҮЛТЕРЕК** *с.* **1.** 1) Җәйге, соңга калып туган. *Сәдакасына [Иргали] аяклы мал – бүлтерек бәрән бирде.* М.Хәсәнов. *Юеш, бүлтерек бер ат кисәгенең дөньяга килүе булды, елагандайкөлгәндәй итеп, тавыш биреп тә*

*куйды.* М.Хуҗин. *Әнә теге бүлтерек бәрән баллы әйбер ярата, теләсә, койманы да сикереп чыга.* Ф.Садриев. *Бу бүлтерек тәкәләрне тиккә җыйганчы, берәр файдаларын күрергә кирәк.* Ф.Яруллин

2) *диал.* Тәбәнәк буйлы. *Ачынуы – бүлтерек Васяга түгел, үз хәлләренә, үз абыйлары Айдаш белән Вәсимгә иде, әлбәттә!..* Э.Касыймов. *Әзмәвердәй адәмең мышный-мышный боргаланып кыланган арада, бүлтерек бәндәң, аны-моны уйлап тормастан, нәселен үрчетеп тә өлгерә.* Э.Касыймов

**2.** *и. мәгъ.* Соңга калып туган бәрән. *Бөлгән илдән бүлтерек алма.* Мәкаль. *Әле Аксыргак авылында өстән генә карап торган зәңгәр тауларда --- симез-симез печкән бүлтерекләр чабып йөри.* А.Гыйләҗев

**БҮЛТЕРЕКЛӘ́Ү** *ф.* Җәен яки көзен бәрәнләү. – *И улым, – диде әнисе. – Көздән бүлтерекләп калалар бит. Суярга кызганыч.* Ф.Садриев

**БҮЛҮ** *ф.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса кисәкләргә, өлешләргә аеру. *Бер алманы бишкә бүләек, Беребез өчен беребез үләек.* Җыр. *Аны линейка белән графаларга бүлде дә иртәгә эшләячәк эшләргә план төзеде.* М.Әмир. *Алар [робинзоннар] бөтен утрауны биш кисәккә бүләләр.* Кызыклар дөньясында

2) Аерым савытка салып бирү. *Өйләнешеп яши башлаганда, беркөнне Зәнфирә өстәл әзерләде, аш бүлде.* Ф.Садриев. *Тизрәк бүлеп бир инде миңа, үлеп ашыйсым килә!*

3) Төркемләү; төрләргә аеру. *Белинскийның фәлсәфи карашлары формалашуын ике дәвергә бүлеп карыйлар.* К.Гыйззәтов. *Ислам диненең кануннары хәрамны өч төрлегә бүлә: батыйль, фасид, сахих.* Г.Бәширов. *Торгынлык елларының гадәте буенча, кешеләрне, дәрәҗәләренә карап, өчкә бүлделәр.* Ватаным Татарстан

4) *мат.* Бер санның икенче санны ничә мәртәбә үз эченә алганын белү; *киресе:* **тапкырлау**. *Алар чәчү орлыгын исәпкә алалар, шуны чәчү мәйданына бүләләр.* Ф.Хөсни

5) Зуррак корылмаларны кечерәкләргә аеру (бүлмә, бүлемтек һ.б.ш. турында). *[Председатель] Канцеляриянең сул яклап такта белән бүлгән кечкенә ягына – «үзенең кабинетына» кереп, тунын, бүреген салды.* Ә.Еники

6) Вакытлыча туктатып тору; өзү. *Аны ярты сүздә бүлделәр ---.* Ә.Мушинский. *Бу уйлар, бу фикерләрне картның намаз укып бетерүе бүлде.* Г.Исхакый

7) Нәрсәнең дә булса хәрәкәтен тоткарлау, юлына киртә булу. *Ташу суы минем юлымны бүлә.* М.Хуҗин

8) Бирү, сарыф итү. *Сиңа эшкә киләбез, сиңа көчне бүләбез ---. Яшәртәбез сине, җир!* М.Җәлил

9) *сөйл.* Уртаклашу. *Бу зур шатлыгымны Синең белән килә бүләсем.* С.Урайский

10) *икът.* Җитештерелгән продуктларны, эшләп тапкан байлыкны, иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән чыгып, җәмгыять әгъзаларына бирү, өләшү, хезмәткә түләү. *Фирманың материаль байлыгын бүлү. Көндәлек керемне бүлү*

11) Аеру. *Буталыш эчендә Фидан Илһамияне бүлеп алып калды.* Х.Сарьян

**2.** *и. мәгъ. мат.* Бер санның икенче санны ничә тапкыр үз эченә алганлыгы турындагы гамәлнең атамасы. *Бүлү гамәле. Бүлү билгесе*

**Бүлеп алу** Бүлеп, аерып кую. **---** *кайбер урыннарда биләмәләрне тимерчыбык белән бүлеп алганнар.* Р.Мирхәйдәров

**Бүлеп бару** Рәттән бүлү, берсе артыннан берсен бүлү

**Бүлеп кую** Алдан бүлү, аерып алу. *Бүлеп куйган чәемне эчәргә дә тынычлык юк!* Г.Бәширов

**Бүлеп тору** 1) Бер нәрсәне икенчесеннән бүлгән булу яисә бүленгән хәлдә тоту. *Хәзер биш почмаклы өйне пыяла ишек бүлеп тора.* К.Кәримов. *Безнең Васильево янындагы дачалар – бер меридианда, араны ике күл дә чаукалык бүлеп тора.* М.Галиев

2) Хәзер, сөйләгән вакытта бүлү

**Бүлеп утыру** Әле, хәзер бүлү белән мәшгуль булу. *Шул исемлек буенча, һәркемгә тиешле акчаны бүлеп утырдым.* Р.Фәизов

**Бүлеп чыгару** Бүлентек аерылып чыгу. *Сезгә кислород каян килә соң, аны бүлеп чыгарырга яшеллек кирәк бит?* Р.Сәгъди. *Сидекчә бүлеп чыгару – көндез югары.* Сәламәт яшәү нигезләре

**Бүлеп чыгу** Бөтенесен бүлү, һәрберсенә дә бүлеп бирү. *Әнкәсе --- һәркемнең коштабагына буы чыгып торган кайнар аш бүлеп чыкты.* Н.Фәттах

**Бүлеп яту** *к.* **бүлеп утыру**. *Габдрахманнар Әмрикә күчтәнәче бүлеп яттылар.* Р.Сибат

**БҮЛҮЧЕ** *и. мат.* Икенче бер санны бүлә торган сан; *русчасы:* **делитель.** *--- n санының бүлүчеләрен табыгыз.* Алгебра

**БҮРӘНӘ** *и. рус.* **1.** Ботаклары һәм башы киселгән агач кәүсәсе. *Бүрәнәнең юан башы кем җилкәсендә булса, шуңа авыр.* Мәкаль. *Шулкадәр тын, якынтирә шулкадәр хәрәкәтсез оеган, тик, суыкка чыдый алмыйча, ара-тирә, капка баганалары, каралты-кура бүрәнәләре генә шартлап ала.* Г.Бәширов. *Нарат бүрәнәләрнең сыткый сагызларын күз яше кебек итеп тамдырырлык моң тулды әлеге өйгә.* Таныш өянкеләр

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бүрәнәдән эшләнгән. *Багана башындагы фонарь каравыл йортының бер як бүрәнә стенасын яктырта.* Д.Салихов

2) *күч.* Таза, нык. *Ун ел сабантуйларда батыр калып, аның мондый бүрәнә мускуллы, юан беләкле көрәшче ир затын очратканы юк иде әле.* Р.Сибат

3) *күч.* Каткан, бөкләнмәс хәлгә килгән (буыннар турында). *Минзәлә баеның беләгенә бүрәнә бармакларын куеп, тыныч кына сөйләп тә бирде.* Ф.Яхин

◊ **Бүрәнә аркылы (аша, үтә) бүре куу** Булмаган куркынычны бар итеп, шикләнеп, борчылып утыру. *Бүрәнә аркылы бүре куарга гадәтләнгән татар зыялыларының әле чыбыркы күргәннәре, камчы татыганнары юк.* А.Гыйләҗев. *Ауга йөргәнең юк, «куян бетте, төлке уйнамый» дип, бүрәнә аркылы бүре куып утырасың.* А.Гыйләҗев. *Малайлар шаулаштылар, ләкин барысы да моның болай гына – бүрәнә аша бүре куу гына икәнен беләләр иде.* М.Мәһдиев

**БҮРӘНӘ́-БҮРӘНӘ** *с.* Таза, зур, юан. *Аның төшенә бүрәнә-бүрәнә балыклар кергән иде.* Р.Сибат

**БҮРӘНӘ́ ГӨМБӘСЕ** *и. биол.* Үрчү өлеше җәелгән, элпәсыман, каешсыман, кайвакыт бераз итчел, саргылт кызыл яки көрән төстәге гөмбә; *русчасы:* **домовой гриб.** *Чын бүрәнә гөмбәсе --- өй бүрәнәләрен, идән такталарын черетеп, хуҗалыкка зур зыян китерә.* Л.Мәүлүдова

**БҮРӘНӘЛЕК** *с.* **1**. Бүрәнәгә ярарлык, бүрәнә булырлык. *Вак агачлар гел дә юк. Гел зур-зур имән, усак кебек бүрәнәлек агачлар гына калган.* М.Гали

**2.** *и. мәгъ.* Бүрәнәгә ярарлык агач. *Ул урманнарда нарат, чыршы кебек яхшы агачлар булмаса да, өйгә ярарлык усак бүрәнәлекләр [бар иде].* З.Һади

**БҮРӘНКӘ** *и. рус* **1.** 1) Сыеклыкларны тар авызлы савытларга салу, сөзү өчен кулланыла торган, төбендә нечкә көпшәсе булган конуссыман җайланма. --- *бүрәнкәгә бульон сала ул [Ася].* Х.Камалов. *Бугаз бүрәнкә рәвешендәрәк була, аның стеналарын берничә кимерчәк тәшкил итә.* Биология

2) Артиллерия снаряды, бомба, мина шартлаудан, җирдә барлыкка килгән чокыр яки һава дулкыны белән күтәрелгән өермә. --- *әшәке үкереп килә торган танклар, болганчык күл, сызгырып, бомба коелу һәм быкырдыктан күтәрелгән кара бүрәнкәләр аны саташтыра башлады.* Ш.Маннур

**2.** *с. мәгъ.* Кечкенә һәм түгәрәк. *Теге бәләкәй генә, бүрәнкә авызлы гына, шадра гына башкорт егете Кылычбайның үз эченә бөтенләй сыймастай калын һәм гайрәтле тавышы белән --- шаңгыратып җибәрүе залдагы бөтен кешене таң калдырды.* Ш.Маннур

**БҮРӘНКӘЛӘНҮ** *ф.* Бүрәнкә кебек булу, бүрәнкә формасын алу. *«Җиде күл»дән әйләнеп килгәнче, Каратаев заводында төгәлләнмичә калган коеның авызы, ишелеп, бүрәнкәләнгән иде ---.* К.Кәримов. *Булатовның бөрмә иреннәре бер бүрәнкәләнде, бер җәелде.* Р.Төхфәтуллин

**Бүрәнкәләнә бару** Торган саен бүрәнкәгә охшый төшү, бүрәнкәләнүе көчәю

**Бүрәнкәләнеп калу** Бүрәнкә кебек формага килеп, шул форманы саклау. *Баш врачның «яңа сотрудник» турындагы сүзләрен ишеткәч, аның авызы, менә-менә сызгыра башларга җыенган кешенеке сыман, бүрәнкәләнеп калды.* М.Хәсәнов

**Бүрәнкәләнеп тору** Бүрәнкәгә охшаш хәлдә булу. *[Мирас малае Мөнәвирнең] Авызы бүрәнкәләнеп торганга, авылда малайлар аны «Бүрәнкә» дип йөртәләр.* Т.Мөбарәков

**БҮРЕ** *и.* **1.** 1) Этләр семьялыгыннан, гадәттә соры төсле, чабуга җайлашкан озын аяклы имезүче ерткыч хайван. *Котырган бүре утка керер.* Мәкаль. *Диде бүре: «Сарык ашап йөргән кеше – Шушы икән, китерегез бәйләргә җеп!»* М.Гафури. *Бүреләрнең яңа шартларга яраклаша белүенә исең китәрлек.* Кызыклар дөньясында

2) *күч. гади с.* Усал, явыз кеше. *Минем юаш табигатем Сезгә бик ошый кебек... Сез бүреләр арасында Мин – яшим поши кебек.* И.Юзеев

**2.** *с. мәгъ.* Бүре тиресеннән эшләнгән яки тегелгән. *Куян бүрек, төлке бүрек, Кемнәр бүре бүректән.* М.Галиев

◊ **Бүре булып улау** 1) Чарасызлыктан нишләргә белмәү; 2) Ашыйсы килү. *Ашказаннары болай да бүре булып уларга гына тора.* Ә.Гаффар. **Бүресе улау** Теләгәненә ирешү; бәхет басу. *– Баһауның бүресе улый!.. – диләр иде кешеләр.* Х.Сарьян

**БҮРЕ́ АЯГЫ** *и. бот.* Плаунчалар семьялыгыннан, тармакланып киткән сабаклы, яфраклары чиратлашып та, бәҗра ясап та урнашкан мәңге яшел күпьеллык үлән; *русчасы:* **плаун.** *Бүре аягы спораларын һәм чәчәк серкәләрен коры көннәрдә генә җыялар.* Урман аптекасы

**БҮРЕБАСАР** *и.* Бүре аулый, бүре куа торган эт; бүре эте. *Табылган сөякләргә карап фикер йөрткәндә, һуннарда кәҗә, дөя кебек хайваннар да булган; хуҗалыкны кыска борынлы дала этләре саклаган. Хәер, арада эре гәүдәле бүребасар этләрнең сөякләре дә очрый.* Ә.Мөхәммәди

**БҮРЕ́ БӨРЕСЕ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, катнаш һәм ылыслы урманнарда үсә торган, өчәрле каурыйсыман яфраклы, кызыл, кара яки ак төстәге җимешле, күпьеллык агулы үләнчел үсемлек; карга җиләге; *русчасы:* **воронец**

**БҮРЕ́ ҖИЛӘГЕ** *и.* Бүре җиләгечәләр семьялыгыннан, хуш исле чәчәкләре ак, ал, саргылт төсле, формасы белән сирень чәчәкләренә охшаш, биек булмаган куакчыл үсемлек; *русчасы:* **волчьи ягоды.** *Өйдәгеләрне, урманда, ялгыш, бүре җиләге ашадык, эчебез авырта, дип хәйләләргә туры килде.* З.Хөснияр. *Берничә бала, бүре җиләге ашап, башлары әйләнеп, коса-коса, күзләре атылып чыга язды.* Р.Батулла. *Ямь өстенә ямь өстим, дигәндәй, бүре җиләге куаклары чәчәк атты.* Г.Хәсәнов. *Бүре җиләге куагы үзенең алсу миләүшә төсендәге хуш исле кечкенә кыңгырауларын элеп куйган.* Мәдәни җомга

**БҮРЕК** *и.* 1) Җылы баш киеме. *Без аны шул рәвешчә карап тикшергән арада, ул да, керүчеләргә юл биреп, бер-ике адым читкәрәк басты да, ике кулы белән дә бүреген тоткан көе, безне күзеннән үткәреп чыкты.* Х.Сарьян. *Башында – сусар бүрек, өстендә – чәшке тун.* А.Гыйләҗев. *Ул [Сәлимҗан] аягүрә басты, әһәмиятле эшкә керешкәндәге кебек, бүреген арткарак этәрде.* Г.Бәширов. *Кырпу бүрек. Камчат бүрек. Камалы бүрек. Мескен бүрек*

2) Кайбер кошларның баш түбәләрендә кабарып, тырпаеп торган йон. *Күкшә – кызгылт көрән төстәге кошчык. Ак канатларында зәңгәр тапплар күренә. Башында бүреге дә бар.* Н.Сладков

3) *хәтле, тикле, кадәр* бәйлекләре белән күләмне чагыштыру өчен кулланыла: зур йомарлам. *Бүрек хәтле булып, башкалардан бөтенләй аерым урында, «әйләнчек» атлы үлән урнашкан иде.* Г.Галиев

◊ **Бүрек белән киңәшү** Үзе генә, уйлап, бер фикергә килү. *Бу хакта күп уйладым. Бүрегем белән күп киңәш иттем.* М.Гафури. **Бүрек тотып бару** Сорану. *Оябыз зур булмаса да, биләгән җирләребез җитәрлек иде, мал-туарга бай идек, бүрек тотып, берәүгә дә бармадык.* М.Хәбибуллин. **Бүрек чөю** Тантана итү. *Ләкин соңгы берничә*

*көндә фрицлар кинәт авызларына су каптылар, эфирда бүрек чөю бетте.* Ш.Маннур. **Бүрексез нәрсә** Үз фикере булмаган кеше. *Хәзер хатын сүзе белән йөрисең син, бүрексез нәрсә!* З.Зәйнуллин

**БҮРЕКЛЕ** *с.* 1) Бүрек (*1 мәгъ.*) кигән. *[Сәхнәгә] Бик франт кына киенгән, бүрекле --- егет килеп керә.* Ф.Әмирхан

2) Бүреге (*2 мәгъ.*) булган. *Мәсәлән, аның [Гөлйөзем әбинең] бүрекле тавыгы, кызыл әтәче «Гөлйөзем әби тавыгы», «Гөлйөзем әби әтәче» дип йөртелә.* Г.Исхакый. *Зәйтүннәрнең авылда усаллык белән дан тоткан бүрекле ата казлары да шунда.* А.Гыйләҗев. *Бүрекле песнәкләр дә көттермәде.* Г.Хәсәнов. *Бүрекле алтынсу пингвиннар да, балалары аз гына үсә төшү белән, аларны оядан куып чыгаралар.* Кызыклар дөньясында

**БҮРЕКЧЕ** *и.* 1) Бүрек тегүче; бүрек тегү остасы. *Гыйсмәтне, уналты яшеннән, Мәскәү татар сәүдәгәренә бүрекче малай итеп җибәрделәр.* М.Гали

2) Бүрекләр белән сәүдә итүче. *Чирмеш әкәе, дигәннән, шуны әйтим әле, теге бүрекче Гобәйдулладан калган Мәфтуха үзләрендә торган Хәйретдингә кече хатынлыкка бара, ди.* Г.Камал

**БҮРЕКЧЕЛЕК** *и.* Бүрекче һөнәре, кәсебе

**БҮРЕ́ УЫ** *и.* Тән кычыткан чаккандагы кебек кабарып чыга торган, аллергиягә бәйле реакция; кычыткан бизгәге; *русчасы*: **крапивница.** *Корт чакса, аңа [әнигә] һәрвакыт бүре уы (аллергия) була...* М.Мәһдиев. *Аннан соң, бүре уы булганда, уылдый-уылдый, мунчада чапканнар, «у-у-у-у» дип, бүре тавышы чыгарып.* Ф.Җәүһәрова

**БҮРЕ́ЧӘ** *рәв.* 1) Бүре булып, бүреләр кебек итеп. *Бүреләр белән яшәсәң, бүречә уларсың.* Мәкаль. *Бүренең һәр хәрәкәте, гамәле – бүречә!* М.Маликова. *Тормыш кайчакта эткә дә бүречә уларга боера.* Мәгърифәт

2) Усал, явызларча.

**БҮРЕЧЕ** *и.* Бүре аулаучы. – *Әти, бир мылтыкны, мин үзем өерне туздырам, – диде Нурихан. [Аучы Миннехан:] --- – Әтәчләнмә, малай! Син бүре хәйләсен үрәнмәдең әле! – диде. – Соң... соң үзең бар, әлсә. Рас мактаулы бүречe икән син, – дип чәпчеде үсмер.* Н.Гыйматдинова

**БҮРЕ́ ЮКӘСЕ** *и. к.* **бүре җиләге.** *Өлгергән, свежий йә кипкән гади бүре юкәсе җимешен көн саен берәрне ашарга.* Идел

**БҮРТӘ** *с.* Саргылт яки аксыл таплары булган туры төстәге (ат турында). *Мин бүртә алашама печән сала калдым.* Х.Кәрим

**БҮРТӘЮ** *ф. диал. к.* **бүртү. ---** *яр читендә үскән йөзьяшәр өянкеләр көмеш толымнарын агымсуда чайкый, бүртәеп, бирчәләнеп, шәрәләнеп беткән тамырлары, ярга чат ябышып, җирне кочкан...* Х.Мөдәррисова

**Бүртәеп килү** Акрынлап бүртәя башлау. *Март кояшы астында инде тернәкләнеп, бөреләре бүртәеп килгән тал-туйра бәбәген кыркып кинәнделәр генә кәҗәләр.* Т.Мөбарәков

**БҮРТЕК** *с.* Тулы, таза. *Аңышырга да өлгермәдем, алыптай калын гәүдәле, чиертсәң каннары чәчрәп чыгардай бүртек йөзле ике конвоир, мизгел эчендә, кулларымны артка каерып, чылбырлап та куйдылар.* М.Әмирханов

**БҮРТЕНКЕ** *с.* Бүрткән; кабарынкы. *Аның бүртенке бармаклы куллары аяклары арасында асылынып калды.* М.Хуҗин

**БҮРТЕНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **бүртү**

2) Кан йөгерүдән кызару. *Сәгыйдә кызарды, бүртенде.* Г.Исхакый. *Мин кызарам, бүртенәм, сикереп торып җавап бирмичә торам.* Г.Исхакый. *Ярсудан бүртенгән ачулы йөзләр, һавада айкалган йодрыклар, усалланган күзләр – кыскасы, таякның авыр башы вәкилгә юнәлде.* Г.Бәширов

3) Артык тулылану, кабарынкы булу. – *Кабахәт!.. Кан эчеп бүртенгән кандаламыни!* М.Хәсәнов. *Бүртенгән борыннар, күрәмсез, Йөзләрдә – кыргыйлык, гамьсезлек.* Г.Афзал

**Бүртенеп бетү** Тәмам, бик нык бүртенү. *Хәдичәнең кисәтүе ярты юлда бүленде, аның каршына кызарынып, бүртенеп беткән марҗа кодагый килеп басты.* К.Тимбикова. *Түрдәге аяклы бишектә җан ярсуы белән елап яткан сабый шешенеп, бүртенеп беткән.* Г.Гыйльманов

**Бүртенеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта бүртенгән хәлдә булу. *Баш редактор Чекулаев, хезмәткәрләрең белән тәрбия эше алып бармыйсың, дип, безнең мөхәррирне шактый пешергән. Шуңар бүртенеп йөргән көннәренә туры килгәнмен икән.* Л.Ихсанова

**Бүртенеп китү** Кинәт, бераз бүртенү. *Ул кояшта кызарып, бүртенеп китте.* Г.Исхакый. *Яралы кинәт бүртенеп китте.* Г.Әпсәләмов

**Бүртенеп тору** Әле, хәзерге вакытта бүртенгән хәлдә булу

**Бүртенеп чыгу** Кинәт кенә бүртенү. *Денис чөгендердәй бүртенеп чыкты.* А.Иванов. *Баян баһадирның йөзе бүртенеп чыкты, әмма түзде, дәшмәде, кул бармаклары гына кылыч сабында калтыранып торды.* М.Хәбибуллин

**Бүртенеп яту** *к.* **бүртенеп тору.** *Язгы дымга бүртенеп яткан җир өстенә янган керосин исе таралган.* М.Мәһдиев

**БҮРТМӘ** *с.* Бүрткән, бүлтәйгән

**БҮРТМӘЧ** *с. диал.* Кабарынкы. *Аның [Зикендорфның] йөзе ниндидер кыргый куанычлы тантана бозы белән каткан, тик күзләре генә, менә хәзер үләксә өстенә ябырылачак карчыганыкы шикелле, агына сибелгән бүртмәч кан тамырлары белән кызарып яна иде.* Ш.Маннур. *Беренче күргәндә, мин аны бер дә ошатмаган идем. Түгәрәк, бүртмәч чырай.* М.Галиев

**БҮРТМӘЧЛӘНҮ** *ф.* Кабарынкылану, бүлтәю. *Маңгайда бер генә җыерчык та юк, ләкин аның тиресе, бармак белән бөреп-бөреп куйган төсле, йә бүртмәчләнеп, йә чокырланып тора.* Ф.Садриев

**Бүртмәчләнеп бетү** Тәмам бүртмәчләнгән хәлгә килү

**Бүртмәчләнеп тору** Бүртмәчләнгән хәлдә булу. *Бер кыз күренде. Битләре нәрсә беләндер янганмы яки пешкәнме шикелле, ямьсез кызыл булып, бүртмәчләнеп тора иде.* Ш.Маннур

**БҮРТТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **бүртү**. *Бер чынаяк ногыт борчагын суда бүрттерәләр.* Акчарлак

2) *күч. сөйл.* Эшләү, уңышка ирешү, алга китү. *[Зөфәр:] Соң... эшләр ничек? [Таһирҗан:] Әллә ни бүрттереп булмады әле.* М.Шәрифуллин

3) *туп.* Балага узу, авырлы булу. *Артёмка белән зина кылып, корсак бүрттергәнсең әнә.* А.Иванов

**Бүрттереп алу** Бераз, тиз генә бүрттерү. *Башта вак бәлеш өчен эчлек әзерлә. Моның өчен дөгене яхшылап ю һәм, кайнап торган суга салып, бүрттереп ал.* Кызлар энциклопедиясе

**Бүрттереп бетерү** Тәмам, бик нык бүрттерү. *– Кара аны, Зәйтүнәгә сиздермә, кычыткан бүрттереп бетерер үзен, ыярткәнеңә үзең дә үкенерсең! – дип, арттан кычкырып калды.* Д.Гайнетдинова

**Бүрттереп кую** 1) Алдан бүрттерү

2) Бүрткән хәлгә китерү. *Инде еллар катламы кулларындагы тамырларын зәңгәргә буяп, бүрттереп куйган.* Ә.Сафиуллин

**Бүрттереп тору** Әле, сөйләү моментында бүрттерү

**БҮРТҮ** *ф.* 1) Дымнан, юештән кабару, калынаю. *[Капка] Яңгырдан бүртеп авырайган.* Г.Минский. *Йомырка бүртә башлый һәм күз алдында өч-дүрт тапкыр зурая.* Кызыклы физиология

2) Шыту, яфрак чыгару алдыннан тулылану. *Юкә, каеннарда, Америка чаганында бөреләр бүрткән.* Б.Камалов. *Орлыкларның тишелергә сәләтлеләре дә, сәләтсезләре дә бүртә.* Биология. *Бу вакытта агач һәм куаклар яфрак ярмый әле, ә инде бөреләре бүрткән, һәм сок хәрәкәте башланган була.* Табигать белеме

3) Кабарып, калкып чыгу. --- *Мамак тамырлары бүрткән зур учы белән күзен каплап торды, аннары гаҗиз рәвештә уфтанып куйды.* Х.Камалов

4) *к.* **бүртенү.** *Мин кызардым, бүртгем.* Г.Исхакый

5) *сөйл.* Тулу. *Болгаушинья яңгырларыннан соң, ике көн эчендә елгалар бүртте, юллар бозылды.* М.Мәһдиев

**Бүртә башлау** Бүртергә тотыну. *Ботаклар кисүне бөреләр бүртә башлаганчы тәмамларга кирәк.* Ф.Ибраһимова

**Бүртә төшү** Бераз, җиңелчә генә бүртү. *Такта койманың эчке ягында, аның өстеннән урам якка үрелеп карап үскән алма, армут, чия, шомырт агачларының бөреләре кояшта җылынып бүртә төшкән.* З.Зәйнуллин

**Бүртеп килү** 1) Акрынлап, аз-азлап бүртү

2) Кинәт бүртү, бүрткән торыш алу. *Сары ут яктысында яңагы уйнаклап алды, чигә тамырлары бүртеп килде.* Ә.Гаффар

**Бүртеп тору** Әле, хәзер, күз алдында бүрткән хәлдә булу. *– Әй улым, ялгыз кешенең тормышын әйтмә инде син аны, – диде карчык, зәңгәрсу тамырлары бүртеп торган, коры сөякле кулын селтәп.* Ә.Сафиуллин. *Ике көннән, берни булмагандай, Ванечкам килеп җитте, бераз йөзе шешенгән дә, муенындагы кан тамырлары бүртеп тора.* Ә.Мушинский

**Бүртеп чыгу** Кискен рәвештә кинәт бүртү. *Аның аскет дәрвишнекедәй бронза йөзе бөтенләй үзгәреп китә, изүләре ачык кызыл күлмәгеннән кан тамырлары бүртеп чыкканы күренә.* Р.Мирхәйдәров. *Ә Рүдәл, киресенчә, тулыланып киткән, бит алмалары йодрыктай бүртеп чыккан, борын яфраклары тырпайган ---.* Р.Вәлиев

**БҮСЕЛҮ** *ф.* 1) Бер якка ишелеп җимерелү, бер яктан таркалу, таркалып китү; эчтән этеп тишелгән булу. *Фермаларыбызга гына күз салыгыз, иптәшләр! Адәм мәсхәрәсе бит. Яртылаш тирес, пычракка батканнар, ишелеп, бүселеп төшмәсеннәр өчен, якяктан терәүләр белән терәтелгән ич.* М.Хәсәнов

2) *диал.* Тузу, сүсәрү. *Шакмаклы пиджагының якасы тәмәке көленә буялган, иске модалы галстугы бераз кыйшая төшкән, чалбарлары тез турысында бүселеп чыккан.* Р.Мостафин

3) Калынаю, зураю. *[Болытлар] Үзләре, кияү түшәгедәй бүселеп, төрле рәвешләргә керәләр, әллә нинди әкияти җанварларны хәтерләтәләр.* М.Әмирханов // *туп.* Симерү, юанаю. *Урта буйлы, яшьтән үк юанайган егет, барыннан бигрәк, бүселеп чыккан арыш капчыгына охшап тора иде.* М.Насыйбуллин

4) Ачулану, үпкәләү. *Нәрсә бүселеп барасың, мә, хет, мылтыкны тотып кайт.* К.Кәримов. *Зәһәрләнеп, бүлмәне бер әйләнде дә, тагын кемгә бәйләнергә белми, бүселеп чыгып китте.* Ф.Сафин

**Бүселеп китү** Кинәт бүселү. --- *мал карыныннан тегелгән капчык ватылмый да, су да үтми, ялгыш бүселеп китмәсә...* Г.Якупова

**Бүселеп тору** 1) Әле, хәзер, күз алдында бүселгән булу. --- *ак башлыгыннан буялган чәчләре бүселеп торган ханымга аңлатырга ашыкты: – Кызыма бит әле ике генә яшь тулып килә.* Г.Галиев

2) *күч.* Яңгыр явып, көн бозылган булу. *Малай, арыганын онытып, киртә буйлап сузылган сукмактан йөгерәатлый, йөзе кояштай якты, бүселеп торган көнгә дә исе китми – бүген бәйрәм, чын бәйрәм иде аның өчен.* Ф.Сафин

**БҮСЕНКЕ** *с.* Бүселеп торган. *Зурзур бүсенке капчыклар, чабаталы, ябык чырайлы татар бабайлар --- белән очрашкач, Тазюков эре генә көлемсерәде.* А.Гыйләҗев

**БҮСЕР** *и. гар.* 1) Кешедәге кайсы да булса әгъзаның (күбесенчә нечкә эчәкнең) эч куышлыгыннан тире катлавы астына бүселеп чыгуыннан гыйбарәт авыру. *Гади төер түгел, арка мие бүсере.* С.Сөләйманова. *[Катәмтай:] Бүсерем бүселгән минем.* Ф.Шәфигуллин. --- *ул чакта өч төрле авыру бар иде: бүсер чыгу, аш үтмәү, яман шеш.* М.Юныс

2) Шул рәвешле бүлтәеп чыгып торган әгъза

**БҮСЕ́Р ҮЛӘНЕ** *и.* Канәферчәләр семьялыгыннан, комлы ачык җирләрдә, тау битләрендә, елга ярында үсә торган, составында агулы алкалоидлар булган үләнчел үсемлек; касык үләне; *русчасы:* **грыжник**

**БҮСҮ** *ф.* 1) Җимерү, ишеп төшерү; тишеп, үтәли чыгу. *Әмма күңелдә җыелган ярсу хисләр, йөрәк таләп иткән сүзләр, бөяләрне бүсеп уза торган язгы кар суыдай, барыбер, агылмыйча кала алмыйлар икән.* Ш.Маннур

2) *күч. гади с.* Күп һәм талымсыз ашау-эчү яисә йоклау. *Йокы бүсмәсен-*

*нәр өчен, Рәүф хәбәрләшү әмәлен дә тапты: дежур торучылар --- утрау каравылына сәгать саен кесә фонаре белән якты күрсәтергә тиешләр иде.* А.Тимергалин. *Хыялларың тормышка ашмас. Йокы бүсәргә яратасыз.* Д.Салихов

**Бүсә төшү** Бераз бүсү

**Бүсеп ташлау** Кинәт, көтмәгәндә бүсү. *Яңа корал, яшел Җиреrезне җансыз таш өеменә әйә булмаса комета-мазарга әйләндереп, бөтен Кояш системасын бүсеп ташларга бик мөмкин...* А.Тимергалин

**Бүсеп тору** Бертуктаусыз бүсү

**Бүсеп чыгу** Өслекне бозып, астан өскә калку. *Газзә бишмәтен салып карасa, чыннан да, аркасы буйдан-буйга ертылган, эченнән мамык урынына язып салынган ак йон бүсеп чыккан.* М.Маликова

**БҮТӘКӘ** *и.* 1) Кошларның ашказаны. *Үрдәкләр, борын очлары белән күл төбен актарып, бүтәкәләренә ком тутыралар.* К.Нәҗми

2) *куч. хур.* Кечкенә гәүдәле кеше

3) *күпл. сөйл.* Ашкайнату органнары (кешедә). *[Сәкинә] Елады, елады да, пружиналы караватына бөгәрләнеп ятты. Йөрәгемә ябышты, бүтәкәләремә кадәр сызлый, үләм, ди.* Ю.Әминов

**БҮТӘН** *с.* **1.** Башка, гайре бер. *Бүтән халыкларны якын күргән кеше – илдә ихтирамлы кеше.* Г.Хәсәнов. *АКШта өермәләр бүтән илләргә караганда да ешрак була.* Кызыклар дөньясында

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Моннан ераграк, моннан күбрәк һ.б.ш.

2) Башка вакытта, моннан ары. *Бу – минем иң ахыргы теләгем, бүтән борчымам...* Г.Бәширов

**3.** *бәйл. функ.* Чыгыш килешендәге исем белән килеп, исемдә күрсәтелгән төшенчәне чикләүне белдерә; тыш, башка. *Баязит карыйның Давыт Урмановтан бүтән кардәше юк.* Г.Ибраһимов

**БҮТӘНӘЮ** *ф. к.* **бүтәнләнү.** *Юл узышлый гына эндәшсә дә, Бөтенәер, Бүтәнәер иде дөньялар.* Зөлфәт. *Тормыш бүтәнәйде, Бусы инде Тегесенә бер дә охшамый.* Х.Туфан

**Бүтәнәеп бетү** Тулысынча бүтәнәю

**Бүтәнәеп калу** Нindидер процесс, күренешләр нәтиҗәсендә бүтәнәю, башка сыйфатлар барлыкка килү

**Бүтәнәеп китү** Бераз үзгәрешләр барлыкка килү

**Бүтәнәя бару** Торган саен ныграк бүтәнәю

**Бүтәнәя төшү** Бераз бүтәнәю

**БҮТӘНЛӘНҮ** *ф.* Башка, гайре сыйфат(лар) алу

**Бүтәнләнә төшү** Бераз бүтәнләнү

**Бүтәнләнеп бетү** Тәмам бүтәнләнү

**Бүтәнләнеп калу** Бөтенләй башка сыйфатлар үзләштереп, шуларны үзендә чагылдыру

**Бүтәнләнеп китү** Аз гына бүтәнләнү

**Бүтәнләнеп тору** Әледән-әле, еш кына бүтәнләнү

**БҮТӘ́НЧӘ** *рәв.* 1) Башкача, үзгә. *Яшь буыннар исә бүтәнчә уйлый, бүтәнчә фикер йөртә.* Р.Мостафин. *Әхмәдулла, бәлки, сеңелкәше белән бүтәнчәрәк тә сөйләшер иде...* Н.Гыйматдинова. *Карынчыкта зур пуля утыргач, йөрәк бүтәнчәрәк типкәндер.* Х.Камалов

2) Яңадан, кабаттан. *Кадыйр, бүтәнчә тукталмаска тырышып, ашыгып-ашыгып сөйләп бирде.* И.Низамов. *Искәндәр карт бүтәнчә әрепләшмәде.* М.Кәрим

◊ **Бүтәнчә сайрый башлау** Башта – бер төрле, соңыннан икенче төрле, башкача сөйләү, фикерен җиңел үзгәртү (принципсыз кешеләр турында)

**БЫГЫР, БЫГЫ́Р-БЫГЫР** *иярт.* **1.** Сыеклык кайнаганда яки газлар аерылып чыкканда ишетелгән тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* «Быгыр», «быгыр-быгыр» иткән тавышлар чыгарып. *Бабай учак өстендә быгыр-быгыр кайнаган балык шулпасын тәмләп азаплана иде.* Г.Мөхәммәтшин. *Учакларга асылган зур казаннарда, быгыр-быгыр, ит кайный, исе инде бөтен болынга таралып өлгергән иде.* Р.Зәйдулла. *Быгыр-быгыр кайный ботка. Җор-уен китә хутка.* Ә.Баянов. *Быгыр-быгыр кайный аның миендә фикерләр.* Х.Камалов

**БЫГЫ́Р-БЫГЫР ИТҮ** *ф. к.* **быгырдау.** *Казандагы ботка быгыр-быгыр итә*

**БЫГЫ́Р-БЫГЫР КИЛҮ** *ф. к.* **быгырдау.** *Шунда ук, быгыр-быгыр килеп, казан кайнап утыра.* А.Хәлим

**БЫГЫРДА́У** *ф.* 1) «Быгыр» иткән яки шуңа охшаш тавышлар чыгарып кайнау. *Аш, куерып, быгырдау*

2) Үзалдына сөйләнү, мыгырдау, быдырдау. *Габделхәй тагын бер-ике тавыш бирде дә тончыккандагы кебек быгырдап тынды.* Р.Батулла

3) *куч.* Лыгырдау, такылдау

**Быгырдап алу** Кыска вакытка, аз гына быгырдау. *Казандагы умач бераз гына быгырдап алуга, пешкәндер, дип, Доха түти ашны, зур агач табакка сосып, төнге кунаклар алдына утыртты.* Н.Әхмәдиев

**Быгырдап кую** Кинәт кенә, бер тапкыр быгырдау. *Кайгысын уртаклашкандай, ашказаны быгырдап куйды.* Л.Закирова

**Быгырдап тору** Бертуктаусыз быгырдау. *Килгәннән бирле, эчем быгырдап тора.* Х.Ибраһим

**Быгырдый башлау** Быгырдарга тотыну

**Быгырдый бирү** Бернәрсәгә карамастан, быгырдавын дәвам итү

**Быгырдый төшү** Бераз быгырдау

**БЫГЫРТ** *иярт.* Кинәт быгырдап куюны белдерә

**БЫДЫР, БЫДЫ́Р-БЫДЫР** *иярт.* **1.** Ачык әйтелмәгән яки ишетелеп җитмәгән сөйләмне яки шуңа охшаш тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ. кбт. форм.* Ачык итеп, ишетелерлек итеп әйтмичә. *Быдыр-быдыр сөйләшеп тордылар да, һәркайсы үз юлына китеп барды.* М.Әмирхан. *Эчтә быдыр-быдыр сөйләшәләр.* М.Әмирхан. *Шулай шыпырт кына быдыр-быдыр сөйләшеп алалар.* Х.Камалов. *[Әбием] Кисәк-кисәк кенә авыз эченнән быдыр-быдыр сөйләнеп ала, шыңшып-шыңшып кына җыр көйләп куя.* А.Хәсәнов

**3.** *с. мәгъ. кбт. форм.* Ачык ишетелмәгән, аңлашылмаган. *Умартачы йортына җитәрәк, быдыр-быдыр тавышлар ишетелде.* Р.Зәйдулла

**БЫДЫ́Р-БЫДЫР ИТҮ** *ф. к.* **бырдау.** *Күпернең коргаксыган вак такталары аяк астында быдыр-быдыр итеп калдылар.* И.Гази

**БЫДЫ́Р-БЫДЫР КИЛҮ** *ф. к.* **быдырдау**

**БЫДЫРДА́У** *ф.* Аңлаешсыз авазлар чыгару яки, ачык әйтмичә, ишетелер-ишетелмәс кенә, авыз эченнән сөйләү. *– Ничек? Нәрсә? Кайсы профессор? – дип быдырдады кыз.* М.Маликова. *Дөресрәге, шул нарасыйның җылысы белән җылынырга теләп, үзебез аны куенга алабыз. Бик тә олы кеше исәпләп, иртәдән кичкә кадәр, быдырдап, сөйләшеп йөрибез.* Э.Шәрифуллина

**Быдырдап кую** Кинәт, бер тапкыр нәрсәдер быдырдау

**Быдырдап тору** Үзалдына бертуктаусыз быдырдау

**БЫДЫРДЫК** *с.* Сүзләрне ачык итеп әйтеп бетермичә сөйләүче; өзлексез сөйләнүче; лыгырдык. *Быдырдык бала*

**БЫЕЛ** *рәв.* Бу, шушы елда. *Былтыр көйгән, быел исе чыккан.* Мәкаль. *Без Хөршит белән быелга кадәр очрашмаган идек.* Ф.Әмирхан. *Без быел икебез дә җәй буе кырда эшләдек.* Г.Бәширов. *[Алар] Быел көзгә, өйләнешеп, бергә яши башлаячаклар.* Ш.Маннур

**БЫЕЛГЫ** *с.* Бу, шушы елгы. *Монда [бүре төркемендә] читләр юк: әти-әни, быелгы һәм үткән ел туган балалар.* Кызыклар дөньясында

**БЫЖ, БЫ́Ж-БЫЖ** *иярт.* **1.** Нәрсәнеңдер **«**быж» сыман тавыш чыгарып гүләвен белдерә. *Урманнан ияреп кайткан уй көченнән аерылган бал кортлары кебек тузынган, кая төртелергә белмичә, быж-быж, баш кабыгында гүелдәшә иде.* Н.Гыйматдинова

**2**. *рәв. мәгъ. кбт. форм.* Шундый авазлар чыгарып, әле – бер якка, әле – икенче якка. *Кичке караңгыда быж да быж май коңгызлары оча.* А.Гыймадиев

**БЫЖАН** *и.* Чын шөпшәләр семьялыгыннан, күпчелек кызгылт төстә, башка шөпшәләргә караганда зуррак булган, ояларын агач куышларында ясый торган элпә канатлы бөҗәк; *русчасы:* **шершень**. *Быжан ачулы кыяфәт белән килеп чыкты да тагын выжылдап очып китте.* И.Гази. *Чебеннәр оча, почта йорты почмагында, бүрәнә тишеге эзләп, куе шәмәхә төстәге быжан выжылдый.* А.Гыйләҗев

**БЫЖ (БЫ́Ж-БЫЖ) ИТҮ** *ф. к.* **быжлау** (*1 мәгъ.*)

**БЫЖ (БЫ́Ж-БЫЖ) КИЛҮ** *ф. к.* **быжлау** (*1 мәгъ.*). *Телен тыя белмәүчеләр, беркатлылар умарта оясына бикләнгән корт күче шикелле бызылдаган булды, авыз эченнән генә быж-быж килде.* В.Имамов

**БЫЖГАК** *с. сөйл.* **1.** 1) «Быж» иткән тавыш чыгара торган

2) *күч.* Гел зарланучан, шелтәләүчән. *Быжгак, усал кеше! Чамасыз... Бәйләнмәгән чагы гел юк, күзгә чебен кебек.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* Гел зарланып, шелтәләп торган кеше. *Аның яшендә кайберәүләр килбәтсез быжгакка әверелә.* Г.Бәширов

**БЫЖГАКЛАУ** *ф.* 1) Быжгак (*2 мәгъ.*) булып китү

2) Шелтәләү, тузыну

**Быжгаклап йөрү** Гел, бертуктаусыз үзалдына быжгаклау (янда, әйләнәтирәдә)

**Быжгаклап тору** Туктаусыз яки әледән-әле быжгаклау. *Аның үзен дә әле – өлкә комитетыннан, әле авыл хуҗалыгы министрлыгыннан туктаусыз быжгаклап торалар*... Ф.Садриев

**Быжгаклый төшү** Бераз быжгаклау

**БЫЖГУ** *ф.* 1) *диал. к.* **быжгыру**

2) *к.* **быжлау** (*2 мәгъ*). --- *мин булмасам, ничек яшәр идегез, дигән була. Быжгый-быжгый да себеркесен ыргытып чыгып китә.* М.Мәһдиев

**Быжгып йөрү** Әле, сөйләгән вакытта быжгу. *Ләкин идарәдә Улибаева быжгып йөри иде.* М.Мәһдиев

**Быжгый башлау** Быжгырга тотыну. *Әти кеше нәрсәгәдер борчыла, быжгый башлый.* М.Мәһдиев

**БЫЖГЫРУ** *ф.* 1) Ыжгыру. *Җил быжгыра*

2) Шелтәләү, ашыктыру

**БЫЖГЫТУ** *ф.* 1) *з.-сыз* Салкын җил ыжылдап исеп тору

2) *күч.* Шелтәли-шелтәли, ирексезләп ашыктыру. *Дәрес калдырды, дип, саботаж, дип, техникумнан быжгытып чыгарырлар инде аны, и-и, бәхетсез!* В.Имамов

**Быжгытып алу** Көтмәгәндә, кыска вакыт эчендә быжгыту

**Быжгытып тору** Бертуктаусыз быжгыту

**БЫЖЛАВЫК** *с. к.* **быжгак**

**БЫЖЛА́У** *ф.* 1) «Быж» иткән тавышлар чыгару. --- *тычкан тишеге тирәсендә быжлаган төклетура, әллә кая – карама куыш тирәсенә очып китте.* А.Гыйләҗев. --- *әллә каян гына төклетура быжлап килеп куна.* М.Мәһдиев

2) Канәгатьсезлек белдереп, тавышны күтәрмичә генә, туктаусыз сөйләнү. *Бер яктан бала җылый. Икенче яктан әнкәй быжлый.* А.Гыйләҗев

**Быжлап алу** Аз гына, кыска вакыт быжлау. *Пыяла буйлап үрмәлиләр дә, теләр-теләмәс кенә канат кагып, быжлап алалар.* Р.Батулла

**БЫЖЫК** *с.* Бертуктаусыз явып, җебетеп торган. *Нәрсә, көзге быжык, кара яңгырларны көтеп утырсынмы ул?!* А.Хәлим

**БЫЖЫЛДАВЫК** *с. к.* **быжгак.** *Быжылдавык бөҗәкләр*

**БЫЖЫЛДА́У** *ф. к.* **быжлау**. *Гүя әйтә, әйдә, шартлаганчы чинагыз, быжылдагыз, миңа – барыбер...* Х.Камалов

**Быжылдап тору** 1) Бертуктаусыз, өсте-өстенә быжылдау. *Үзгәргәнсең, төсең киткән ич, дип, атлаган саен быжылдап торсалар, сәламәт җиреңнән дә чирли башларсың.* Г.Кутуй

**БЫҖЫ́Р-БЫҖЫР** *иярт.* **1.** Җиңелчә генә быҗырдауны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* «Быҗыр» иткән яки шуңа охшаш тавыш чыгарып. *[Сулыктан барганда] Түмгәгендә озаграк торсаң, күз алдында ул югала, быҗыр-быҗыр күбекләнеп чыккан җирән су итек кунычын күмә башлый.* Ш.Маннур

**БЫҖЫ́Р-БЫҖЫР ИТҮ** *ф.* «Быҗыр» сыман тавыш чыгару. *Эч быҗыр-быҗыр итә*

**БЫҖЫ́Р-БЫҖЫР КИЛҮ** *к.* **быҗыр-быҗыр итү**

**БЫҖЫРДА́У** *ф.* 1) *к.* **быҗыр-быҗыр итү**

2) Бик сыек пычрак хәленә килү

**Быҗырдап бетү** Бөтенләй быҗырдаган хәлгә килү

**Быҗырдый төшү** Бераз яки урыны белән быҗырдау

**БЫЗ, БЫ́З-БЫЗ** *иярт.* 1) «Ыз», «быз-з-з» сыман тавышлар чыгарып хәрәкәт итүне, гадәттә, очуны белдерә. *Колак төбендә чебен-черки тавышы: «быз-з-з».* Идел

2) *күч.* Шелтәле тонда өзлексез сөйләнеп торуны белдерә

**БЫЗ (БЫ́З-БЫЗ) ИТҮ** *ф. к.* **бызлау**

**БЫЗ (БЫ́З-БЫЗ) КИЛҮ** *ф. к.* **бызлау**

**БЫЗГУ** *ф.* 1) *к.* **быжгыру**

2) *к.* **быжлау** (*2 мәгъ.*)

**БЫЗЛАВЫК** *и.* **1.** Озынча кара гәүдәле, җеп сыман мыеклы, аяклары йөгерүгә җайлашкан коңгыз

**2.** *с. мәгъ. к.* **бызылдавык**

**БЫЗЛА́У** *ф.* 1) «Быз» яки шуңа охшаш тавышлар чыгару. *Өйдә бер генә чебен дә бызламый.* М.Максуд

2) *к.* **быжлау** (*2 мәгъ.*)

**Бызлап тору** Өзлексез, өсте-өстенә бызлау. *[Ул] Куй, бызлап торма, дигән шикелле кулын селтәде дә Газинурның сүзләренә бөтенләй җавап бирми башлады.* Г.Әпсәләмов. *Картлыгы да дөрестер шул, мескенкәйнең, «Келт! Келт!» иткән чакта, теле бызлап тора.* Ә.Фәйзи

**БЫЗЫЛДАВЫК** *и.* **1.** 1) Бызылдый торган нәрсә. *Шулай йөдәп барган чакта, Ишектә, уң кул якта, Нindидер бер бызылдавык, Тыңлап тора ул бера-вык.* Ш.Маннур

2) **бызылдавыклар** *күпл. зоол.* Катыканатлылар отрядыннан, озынча гәүдәле, җепсыман мыеклы, озын аяклы кара яисә чуар төстәге коңгызлар семьялыгы һәм шул семьялыкка караган коңгызның үзе; *русчасы:* **жужелица.** *Татарстанда иң күп санлы коңгызлар – бызылдавыклар, филчекләр, май коңгызлары, шартлавык коңгызлар.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Ә бызылдавык, азык эзләп, бер төн эчендә чакрым ярым юл үтә.* Кызыклар дөньясында

**2.** *с. мәгъ.* Бызылдый, «быз» сыман тавышлар чыгара торган. *Берничә мәртәбә колак яныннан, бызылдап, пуля үтсә дә, мине дә, башкаларны да бызылдавык пулялар гына туктата алмадылар.* Р.Ильяс

**БЫЗЫЛДА́У** *ф. к.* **бызлау**. *И бызылдыйм, и бызылдыйм! Петр Ильич кулын селти, ә мин китмим, бөтереләм.* Г.Әпсәләмов. *Неон сүзләр черки шикелле бызылдыйлар. Күзеңә сукыр чебен булып керергә торалар.* М.Юныс. *Беренчеләрдән булып, зирек һәм чикләвек куагы чәчәк ата, аларда инде беренче бөҗәкләр бызылдый ---.* Мәдәни җомга

**БЫЗЫЛДЫК** *и. к.* **бызлавык** (*1 мәгъ.*)

**БЫК, БЫ́К-БЫК** *иярт.* 1) Үрдәк бакылдавын хәтерләткән һ.б.ш. тавышларны белдерә

2) Сүзләрен аңлап булмый торган кеше сөйләмен белдерә. *Исерекнең теленә бик мәгънәле бер сүз килгән. Авызы, шуны әйтим дисә, «бык-бык» дигән.* Н.Исәнбәт

**БЫ́К-БЫК ИТҮ** *к.* **быкылдау.** *Менә ерактан гына «бык-бык» иткән үрдәк тавышлары ишетелде.* Г.Исхакый

**БЫ́К-БЫК КИЛҮ** *к.* **быкылдау**

**БЫ́КЫ-БЫКЫ** *иярт.* 1) *к.* **бык**

2) *к.* **быгыр**

**БЫКЫ́-БЫКЫ ИТҮ** *ф.* 1) *к.* **быкылдау**

2) *к.* **быгырдау**

**БЫКЫ́-БЫКЫ КИЛҮ** *ф.* 1) *к.* **быкылдау**

2) *к.* **быгырдау.** *Машина янына килгәндә, Кәшиф учак ягып җибәргән, ә сөремле бәләкәй казанда, быкы-быкы килеп, балык шулпасы кайный иде.* Н.Хәсәнов

**БЫКЫЛДА́У** *ф.* 1) «Бык», «бак» яки шуңа охшаш тавышлар чыгару. *Үрдәкләр быкылдау*

2) *сөйл.* Сүзләрне аңлап булмаслык итеп сөйләү (балалар, сакау кешеләр, исерекләр сөйләме турында)

3) *күч. гади с.* Такылдау, күп итеп сөйләү. --- *малайны ул, күрәсең, тагын да нәрсә быкылдар, нәрсә сорар, нәрсә булыр, дип көтте.* А.Хәлим. *Ул, хәзерге кебек, микрофон янына кердең дә быкылдап чыктың, түгел иде шул.* Р.Заһидуллина

**Быкылдап утыру** Әле, хәзер бераз быкылдау. *Галиябану, тагын бераз быкылдап утырганнан соң, чыгарга җыенды.* Ф.Яруллин

**БЫКЫР, БЫКЫ́Р-БЫКЫР** *иярт.* **1.** Сыеклык хәлендәге яки составында сыеклык булган матдәләр кайнаганда ишетелгән тавышларны белдерә. *Мазаны белми ул, утын әзерлисе юк, печән чабасы юк, быкыр-быкыр кайнаган казан янында йөрү – рәхәт кенә ич ул!* Я.Зәнкиев

**2**. *рәв. мәгъ. кбт. форм.* «Быкыр» (*1 мәгъ.*) иткән яки шуңа охшаш тавышлар чыгарып. *Чумар быкыр-быкыр кайнап утырсын иде, тәмле исләр чыгарып...* А.Гыйләҗев

**БЫКЫ́Р-БЫКЫР ИТҮ** *к.* **быкырдау**

**БЫКЫ́Р-БЫКЫР КИЛҮ** *к.* **быкырдау.** *[Өйрәтүче абзый] Малайларның ботларыннан тотып, акырта-бакырта, суга ыргыта. Тегеләр быкыр-быкыр киләләр, «туйганчы» су эчәләр, --- йөзәргә өйрәнәләр.* И.Гази

**БЫКЫРДА́У** *ф.* 1) «Быкыр» иткән яки шуңа охшаш тавышлар чыгару. *[Шәмси] Әллә ни эшләгән кебек, кычкыра-кычкыра, тавышлана-тавышлана йөзде, чумды, быкырдады, быгырдады.* Г.Исхакый. *Казанда, пар бөркеп, быкырдап аш кайный: Тоз каян алырга ул ашка?* Ф.Гыйззәтуллина

2) Суда яки сазламыкта туенып, шаулашып яту (каз-үрдәкләр турында)

3) Пычрану. *Бала-чага көннәр буе --- суда быкырдый.* Р.Хафизова

4) Нык юешләнүдән, җебүдән сазлану, баткаклану, былҗырау (аяк асты, туфрак, юл турында)

**Быкырдап бетү** Бик нык быкырдау. *[Сазда] Сыерлар да, корсакка тикле батып, дуңгызлар шикелле быкырдап бетәләр.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Быкырдап тору** Бертуктаусыз быкырдау. *Күлнең суын су дисәң – су түгел, нindидер сасы сыекча быкырдап тора шунда.* Г.Әпсәләмов

**Быкырдап яту** Әле, хәзер, күз алдында быкырдау. *Егетләрнең берсе, йөгереп килеп, быкырдап яткан Нәҗипкә кулын бирде.* А.Гыйләҗев

**Быкырдый башлау** Быкырдарга тотыну. *Бер үрдәк артыннан берникадәр үрдәк балалары, сөйләшә-сөйләшә, почмакка җыелган суга таба барып, суда былчырана, быкырдый*

*башладылар.* Г.Исхакый. *Мәнә шул саташуның әллә бишенче тапкырында, сазның былчырагы артыграк кайнарланып китте. Күбекләнеп быкырдый башлады.* Г.Рәхим

**Быкырдый төшү** Бераз быкырдау

**БЫКЫРДЫК** *с.* **1.** 1) Быкырдый, быкырдап торган. *Алар, быкырдык сулы баткак эченнән көч-хәл белән атлый-атлый, ике йөз метрлар чамасы алга уздылар.* Ш.Маннур. *Инеш саеккан, быкырдык сазлыкка әйләнгән.* А.Гыйләҗев

2) Нык юешләнүдән, җебүдән сазланган, былчыраган, баткакка әйләнгән (туфрак, аяк асты турында). *Яңгырлар башланса, бәләкәй түмгәкләр белән капланган бу үзән --- быкырдык сазлыкка әйләнә.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* Нык җебүдән, юешләнүдән сазланган, баткакка әйләнгән урын. *Әллә нинди үләннәр үскән, су да түгел, былчырак та түгел, бер быкырдык эчендә ваннада яткан шикелле ятам.* Г.Рәсим

**БЫКЫРДЫКЛАНУ** *ф.* Быкырдыкка әйләнү, сазлану, баткаклану. *Яңгырдан соң, юл быкырдыкланды*

**Быкырдыкланып бетү** Тәмам, бик нык быкырдыклану

**БЫКЫРТ** *иярт.* Кинәт быкырдап куюны белдерә

**БЫЛАГАЙ** *с.* 1) Булдырам, дип, коры вәгъдә биреп масаючан, әмма сүзендә тормаучан; вафасыз. *Ул, түгәрәк кенә корсак үстерә башлаган, нечкә сыйраклы, симез муенлы, былкылдаган былагай кеше булып чыкты.* Г.Бәширов

2) Бик вак, бәйләнчек. *Турыдан-туры бәрелешергә, Рамусның директор малае булуы да, артык оятсыз, былагай булуы да комачаулый иде бугай.* Н.Фәттах

**БЫЛАГАЙЛАНУ** *ф.* 1) Вәгъдә биреп, сүздә тормау

2) Вакчылланып бәйләнү. --- *менеп утыра Аюның иңбашына. Тартып үтә йә Төлкенең койрыгын, Йә Юлбарысның мыегын; Анысына сугыла, Монысына кагыла, Тегесенә бәйләнә, Кыскасы, теләгәнчә былагайлана.* Ә.Исхак

3) *диал.* Артык кыланчыклану, юри шаяру. *Талиб хан иярләп алган байтал сәрпи ук та куып җитә алмаслык гаярь тулпар иде. Шуны белгәнгә күрә, Талиб, әүвәл, былагайланып, юри атын тыя-тыя барды.* В.Имамов

**Былагайланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта төрлечә былагайлану. *Алар, бүтәннәргә ияреп, коридорга чыгып былагайланып йөрмәделәр.* А.Гыйләҗев

**БЫЛАЗА́У** *с. диал.* **1.** Ялкау. *Былазау кеше*

**2.** *и. мәгъ.* Ялкау кеше. *Былазау кузгалганчы, эшлекле эшләп ара.* Мәкаль. *Былазау белән этләч – пар килгәннәр инде.* Әйтем

**БЫЛБЫЛ** *и. гар. шигъ.* 1) Сандугач. *Бакчасыз йортка былбыл кунмас.* Мәкаль. *Аккош очар күл күреп, былбыл очар гөл күреп.* Мәкаль. *Арган чырайлар елмая, Былбыллар талга кунса.* Г.Афзал

2) *күч.* Яраткан кешегә мөрәҗәгать сүзе. *Әй, югалттым сәгать лә чылбырын, Күрмәдеңме, сылуым, былбылым?* Җыр

◊ **Былбыл төкерегедәй саклау** Кадерләп кенә тору, бик нык саклау. *Өйгә укол ясарга килә торган шәфкать туташлары аны [спиртны], былбыл төкерегедәй, саклап кына торалар.* Ф.Яруллин

**БЫЛБЫ́Л КОШ** *и. к.* **былбыл.** *Былбыл кошым, сандугачым, Ник сайрамыйсың?* М.Җәлил. *Былбыл кошлар кунып җырлар өчен, Гөл утыртыр көннәр уздылар.* Г.Галиев

**БЫЛҖЫРА́У** *ф.* Пычрак булу. *Карлар эреп, аяк асты былҗыраган чак иде.* Җ.Рәхимов

**БЫЛКЫЛДА́У** *ф.* 1) Тар авызлы савыттан сыеклык салганда, «былк» иткән тавышлар чыгару. *Шешәдән су агызгандай, нәрсәдер «былк-былк» былкылдый.* Н.Сладков

2) *күч.* Артык симергән кешенең, хәрәкәтләнгәндә, тәне селкенеп тору

**Былкылдап тору** Әле, сөйләү моментында былкылдау. *Ит Букәне, былкылдап торган янбашына таянып, Нәҗипкә таба атлады.* Р.Батулла

**БЫЛКЫН** *с. диал.* Көпшәк булганга, һәр хәрәкәткә тәне селкенеп торган; бик таза, симез. *[Егет] Инде симез, былкын булса, мае эреп агар, дияр идең.* А.Гыйләҗев

**БЫЛТ, БЫ́ЛТ-БЫЛТ** *иярт.* Сыеклыкны тар авызлы савыттан икенче савытка күчергәндә, эре-эре тамчылар тамганда ишетелгән тавышны белдерә. *Шешәдән су агызгандай, нәрсәдер былт-былт былкылдый.* Н.Сладков. *Томшыгын тыга суга, Сузыла уңга, сулга: Былт, былт, былт, былт! Бака юк... Бәлкем, булыр, пока юк.* Ш.Галиев

**БЫ́ЛТ-БЫЛТ ИТҮ** *ф.* **1.** 1) Шундый авазлар чыгару

2) Таза, симез булу, һәр хәрәкәткә тәне селкенеп тору. *Аның [Галимәнең] сызганган җиңе астында калын, тулы, былт-былт итеп торган беләге күренә иде.* Г.Исхакый

**2. былт итеп** *рәв. мәгъ.* Кинәт, көтмәгәндә. --- *су өстенә, калкавыч шикелле, былт итеп, меркантиль хаҗәтләр калкып чыкты.* М.Әмирханов

**БЫ́ЛТ-БЫЛТ КИЛҮ** *ф. к.* **былт-былт итү**

**БЫЛТЫР** *рәв.* Узган ел. *Былтыр үлгән ябалак быел башын күтәргән.* Мәкаль. *Кәрим абыйның бу әсәре былтыр бер куелган иде инде.* Ә.Еники. *Беркөн бер дәрестә, институтны былтыр гына бетереп, беренче елын гына укыткан яшь-яшь апага Фәйзәви үзенең мәкерле соравын бирмәсенме!* Х.Сарьян

**БЫЛТЫРГЫ** *с.* Узган елгы, үткән сәнәдәге. *Былтыргы эш – үткән эш.* Мәкаль. *Былтыргы ачлык афәтеннән соң аякка басулары бик кыенга килә.* Г.Бәширов

**БЫЛЧЫРАК** *с.* **1**. 1) Пычрак. *Минап, ирдә утырып кала алмыйча, юлдагы былчырак суга барып төште.* Г.Кашапов. *Былчырак су бик җылы, хәтта кайнар.* Г.Рәхим. *Кырык өченче елның май бәйрәме бик былчырак вакытка туры килде.* М.Мәһдиев

**2**. *и. мәгъ.* 1) Сазламык җир. *Тагы шул былчыракларда үрдәкләр --- быкырдашырга тотындылар.* Г.Исхакый. *Мәнә шул саташуның әллә бишенче тапкырында сазның былчырагы артыграк кайнарланып китте.* Г.Рәхим

2) Пычрак, болганчык су. *Ул [Насыйр], үзенең дошманын җиңгән солдат кебек елмаеп, аның [калушның] тишекләреннән аккан судан, аның*

*эчендә шылтырый торган былчырактан көлә калды.* Г.Исхакый

3) Суда җебеп изрәгән урын, быкырдык җир. *Юл һәйбәт, былчырак ерасы юк, каткалак.* М.Хәсәнов

4) *күч.* Мәкер, бозыклык. *Бирегә килеп кергәндә, хисләре якты, уйлары изге иде, инде теләгенә иреште – бөтен күңелен тутырып, былчырак алып чыкты.* М.Хәбибуллин

◊ **Былчырак ату** Нахак сүз әйтеп хурлау. *Инде туктыйм, ак күңелемнән шул нәләт суккан көнче күбәләкләрнең исемнәрен мәңгегә онытам, хәтеремне сафлыйм, дип уйлап кына өлгерәм, тагын берсе караңгы почмактан чәчрәп чыга да былчырак ата.* А.Гыйләҗев

**БЫЛЧЫРАТУ** *ф.* Пычрату. *Кул керенә былчыраткач, Һәфтиякнең һәр битен, Уртасыннан капкалап, тәмләп кимергәннәр читен.* Г.Тукай. *Ул, оясыны былчыраткан каз кеби, иртәдән кичкә кадәр, өенә керергә курыккан кеби, өе тирәсендә әйләнә башлады.* Г.Исхакый. *Күңел хөҗрәсен былчыратып, каян килеп чыкты соң әле бу кара мәче?* М.Әмирханов

**Былчыратып бетерү** Бик нык былчырату. *Кеше җир йөзен буяп, былчыратып бетерде, табигатьнең ямен, җүнен бетерде.* Р.Мөхәммәдиев

**БЫЛЫ́К-БЫЛЫК** *иярт. к.* **былт**

**БЫЛЫ́К-БЫЛЫК ИТҮ** *ф.* Тар авызлы савыттан сыеклык салганда яки сыеклыгы тулып җитмәгән савыт селкенгәндә, «былык» иткән тавышлар чыгару. *Самавырда су бетә, тамчы гына тама, пелт-пелт килә. Безнең эчләр тула, үпкәдән уза, кузгалып йөри башласаң, былык-былык килә.* М.Әмир

**БЫЛЫ́К-БЫЛЫК КИЛҮ** *ф. к.* **былык-былык итү**

**БЫР, БЫ́Р-БЫР** *иярт.* **1**. *гадәттә сузыбрак яки кбт. форм.* Нәрсәнең дә булса, кызу әйләнеп, бөтерелеп торуыннан чыккан тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шуңа охшаш тавышлар чыгарып

2) Сүзләре ачык әйтелеп бетмичә яки ишетелеп бетмичә. *Ерак та түгел, быр-быр сөйләшкән тавышлар ишетелә башлады.* М.Гали

3) Курку, җирәнү һ.б.ш. тойгыларны белдерә

**БЫРГЫ** *и.* 1) Башы җәенке металл көпшәдән торган (яки мөгездән ясалган) тынлы музыка һәм сигнал бирү коралы. *[Егет] Дүртесенә дүрт кычкырмый торган тимер быргы китереп бирде.* Әкият. *Мәктәп балалары, быргылар кычкыртып, барабаннар кагып, тигез сафлар белән, ашханәгә кереп киттеләр.* Ш.Бикчурин. – *Сиңа җиз сыбызгы булса, чын исеме аның – быргы! – диде эшләпәлесе.* К.Латыйп

2) Быргы кычкыртып бирелгән сигнал. *[Зәбих – Мусага:] Өченче быргыда сез һәлак булачаксыз.* Н.Исәнбәт

3) *сөйл.* Рупор. *Буксир пароходлар баржаларны өстериләр, өсләрендәге кызыл йөзле капитаннары, тагы да кызара төшеп, быргылар аркылы әллә нәрсәләр кычкырыналар.* Ф.Әмирхан

**БЫРГЫЧЫ** *и.* Быргыда уйнаучы; быргы белән сигнал бирүче. – *Син кем? – дип сорадым мин аңардан. – Филармония артисты, быргычы, – ди бу.* К.Латыйп. *Быргычы уйнагач, марш моңнары, беренче мәхәббәттәй, күңелемә сеңеп калды.* К.Латыйп. *Каяндыр «Кузгалырга!» дигән гөрелдек тавыш яңгырый, атын юырттырып, уртага моңарчы күзгә күренмәгән быргычы чәчрәп чыга.* Ә.Гаффар

**БЫР ИТҮ** *ф.* Шуңа охшаш тавышлар чыгару

**БЫРКЫЛДА́У** *ф.* Бырык-бырык итү

**Быркылдап җибәрү** Көтмәгәндә быркылдый башлау

**Быркылдап чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында быркылдау

**Быркылдый төшү** Бераз быркылдау

**БЫРЛА́У** *ф. к.* **быр итү**

**Бырлап җибәрү** Көтмәгәндә, кинәт бырлый башлау

**Бырлап тору** Бертуктаусыз бырлау

**Бырлап чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында бырлау. *Төн буена орчык бырлап чыкты*

**БЫРР** *иярт.* Гадәттә, калтыратып (ике «р» белән) әйтелә: салкынлык тоюны, чиркануны белдерә. *Салкын су Байгышны куырып алды булырга кирәк. Тонык судан ярты тәнен күтәреп, --- бырр ---, тәнен дә уа башлады.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**БЫРЫК, БЫРЫ́К-БЫРЫК** *иярт.* **1.** 1) Суда, өзек-өзек сулыш алып, батар-батмас хәрәкәтләнгәндә яки тончыкканда ишетелгән тавышларны белдерә

2) *к.* **бырр**. *[Балтамыш:] Сыны ката, тын алалмый, тәгәри дә үлә, ди. Быр-р, бырык-бырык! (бармакларын уйната). Әһә, менә куркынычмы?* Р.Батулла

**2**. *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып

**БЫРЫЛДА́У** *ф. к.* **бырлау**. *Янган чыра бырылдаса, татар буран көтә.* К.Насыйри

**БЫТ, БЫ́Т-БЫТ** *иярт.* **1.** 1) Бытбылдык кычкырган авазларны белдерә. *Ә бытбылдык, бытылдык Такмаклый янда быт-быт.* Ш.Маннур

2) Кечкенәрәк двигательләр һ.б.ш. эшләгәндә ишетелгән тавышларны белдерә

3) Теле ачылып җитмәгән бала яки сүзләре ачык әйтелеп яисә ишетелеп җитмәгән сөйләмне белдерә

4) Бик тиз сөйләүне белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* «Быт» иткән яки шуңа охшаш тавышлар чыгарып

**БЫТБЫЛДА́У** *ф.* 1) Бытбылдык сайравына охшаш тавышлар чыгару. *Еракта, урман артында, нәрсәдер бытбылдады.* К.Нәҗми

2) Туктаусыз, күп сөйләшү. *Миңа көндә-әш?! Шулай дип бытбылдый мәллә карт төлке?!* Н.Гыйматдинова. *Аптыраганнан бытбылдыйм ла мин, кызый. Сиңа бытбылдап та була бит әле.* Н.Гыйматдинова

**Бытбылдап алу** Кыска гына вакыт эчендә бытбылдау

**Бытбылдап чыгу** Билгеле бер вакыт дәвамында бытбылдау

**БЫТБЫЛДЫК** *и.* 1) Фазан кошлар семьялыгыннан, кырларда, болыннарда яши торган, кыска канатлы, кыска койрыклы, кечкенә һәм кыска томшыклы, кечкенә йомры гәүдәле кош; бүдәнә; *русчасы:* **перепел.** *Һәр бытбылдык үз сазын мактый.* Мәкаль. *Бытбылдык рәттән күп кычкырса, борай уңар.* Сынамыш

2) Шул кошның ите. *Хуҗабикә зур табак белән кабымлыклар куйды: куй бавыры һәм май белән тутырылган бытбылдык түшкәләре авыз суын китерерлек итеп кыздырылган иде.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч. сөйл.* Күп, тиз сөйләшүче кеше. *Әй, бытбылдык, бабаңны туйдырып бетергәнсең инде.* Н.Хәсәнов

**БЫ́Т-БЫТ ИТҮ** *ф.* 1) *к.* **бытылдау**

2) Шундый авазлар чыгару. *Ык ягыннан, быт-быт итеп, моторлы көймә гөрләве ишетелә.* Г.Мөхәммәтшин

**БЫ́Т-БЫТ КИЛҮ** *ф. к.* **быт-быт итү**

**БЫТКЫЧ** *с. сөйл.* Вак һәм бәйләнчек. *Лобков, бригадир буларак, явыз түгел, мәгәр, тик торганны сөйми торган, шактый быткыч адәм иде.* А.Гыйләҗев. *Яныңа быткыч, явыз, тешләк, ачәрвах, тилемсә, вак, ахмак, өчләтә юньсез тоткыннарны китереп тыга [ул].* А.Гыйләҗев

2) *күч. сөйл.* Тиз, күп сөйләүчән; такылдык

**БЫТКЫЧЛАНУ** *ф. сөйл.* Әһәмиятсез нәрсәләргә бәйләнү. *«Әле синең шулай быткычланып, күзәтеп һәм донос ясап йөри торган гадәтең дә бармыни?» – дигәнен Ихлас сизми дә калды.* А.Гыйләҗев

**Быткычлана төшү** Тагын да быткычлану

**Быткычланып бетү** Тәмам быткычлану

**Быткычланып китү** Кинәт быткычлана башлау

**БЫТЫЛДА́У** *ф. сөйл.* 1) Сүзләрне дөрес яисә ачык итеп әйтә алмау яки бозып сөйләү

2) Нииндидер аңлашылмаган ят телдә сөйләү. *Урам тутырып йөриләр, һәммәсе үз телендә бытылдый.* Т.Әйди

3) Ашыгып яки күп сөйләү, гөжләп тору. *Я, я, абыйны бүлдермәгез әле, бытылдамагыз, малайлар!* А.Расих. *Бытылдама әле син, юньләп кенә сөйлә.* Ю.Әминов. *– Әле мин салоннан киләм... – дип бытылдап бара иде кунак хатын...* Р.Зәйдулла. *[Таймас:] Бытылдама әле, фикерне чуалтасың.* А.Гыйләҗев

4) «Бак-бак», «быт-быт» иткән тавышлар чыгару (кошлар турында). *Көне буе эссе кояш астында бытылдап бытбылдыклар да арыган – тавыш-хәбәр бирмичә ял итәләр.* К.Тәхау. *Әнә тагын бытбылдык бытылдый, тартар, аңа кушылып, әлеге дә баягы җырын җырлый, аны бүдәнәнең сәер тавышы алмаштыра.* Р.Батулла

**Бытылдап алу** Тиз арада бераз бытылдау. *Тылмач, яшь лейтенант, майорның колагына иелеп, үзенчә нидер бытылдап алды.* Ә.Гаффар

**Бытылдап тору** Бертуктаусыз бытылдау. --- *кызлар уенча, алдында бытылдап торган егет – әсир ителгән мескен, аны теләсәң нишләтергә була.* Т.Миңнуллин

**Бытылдый башлау** Бытылдарга тотыну. *Яктылык белендеме, үрдәкләр бытылдый башлый.* М.Мәһдиев

**Бытылдый бирү** Бернәрсәгә карамастан, бытылдавын дәвам итү

**БЫТЫЛДЫК** *и. сөйл. к.* **бытбылдык** (*3 мәгъ.*). *Сөйлим, дип уйлый бытылдык та, сайрыйм, дип уйлый бытбылдык та.* М.Галиев

**БЫТЫРДА́У** *ф. сир. к.* **бытылдау.** *Бытырдама, малай, күрмисеңмени, Галиәкбәр әфәндегә кунаклар килде!* Г.Исхакый

**Бытырдап утыру** Бертуктаусыз, үзалдына бытырдау. *Колтамакларда, күрше Әнәч, Ишле, Качаган, Җилдәрләрдәге шикелле, өйләрдә дә, багана башларында да ырадиу бытырдап утырмый.* А.Хәлим

**БЬЕННА́ЛЕ** *и. ит.* Һәр ике ел саен үткәрелә торган чаралар (мәс., рәсем сәнгате күргәзмәләре, кинофестивальләр һ.б.)

**БЬЕФ** *и. фр.* Елганың, каналның яки сусаклагычның плотинага, шлюзга чиктәш өлеше

**БЭР** *и. хим.* Ионлаштыргыч нурланыш дозасын үлчәү өчен кулланыла торган, системалаштырылмаган берәмлек: 1 бэр=0,01 Дж/кг=0,013в

**БЮДЖЕТ** *и. фр.* 1) Дәүләтнең билгеле бер вакытка исәпләнгән керемнәре һәм чыгымнарының законлы рәвештә расланган исемлеге. *Тик, ничек кенә тарткаласаң да, бюджет артмый, киресенчә, федераль хакимият басымы астында, елдан-ел юкара, кечерәя генә бара.* М.Авзалова

2) Дәүләт, учреждение яки аерым кешеләрнең билгеле бер вакыт аралыгында алыначак керемнәре һәм тотылачак чыгымнарының якынча хисабы. *Өлкән кеше үз мәшәкатьләренә йөзләрчә җепләр белән бәйләнгән бит: эш, хатын, балалар, гаилә бюджеты.* Р.Мирхәйдәров. *Таможня җыемнарының барысы да федераль бюджетка китеп бара.* Татарстан. *Дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина ярдәме, гражданнарга тиешле бюджет, иминият взнослары, башка керемнәр исәбенә, түләүсез күрсәтелә ---.* Татарстан

**БЮДЖЕТ-ИМИНИЯТ** *җый. и.* Бюджет һәм иминият. *Бюджет-иминият моделе эшмәкәрләрнең, хезмәт ияләренең максатчан взнослары һәм дәүләт субсидияләре исәбенә финанслана.* Татарстан

**БЮДЖЕТЛАШТЫРУ** *ф.* Бюджетка кертү. *– Бездә һәр муниципаль берәмлекне бюджетлаштыру исәпләнгән, – диде Татарстан Президенты.* Татарстан

**БЮДЖЕ́ТНИК** *и. рус сөйл.* Бюджет хисабына финанслана торган учреждение хезмәткәре. *«Бюджетник» дигән сүзне мин кабул итмим, кушамат дип кенә саныйм.* Ватаным Татарстан

**БЮДЖЕТ-СМЕ́ТА** *и. фр.-рус* Бюджет һәм смета. *Күп очракта, бу – чын мәгънәсендә гадәти бюджет-смета финанславы гына иде.* Татарстан

**БЮКС** *и. нем.* Тикшеренүләр өчен кирәкле сибелүчән материал саклый торган, юка стеналы капкачлы пыяла савыт

**БЮЛЛЕТЕНЬ** *и. фр.* 1) Нинди дә булса мөһим, гадәттә, күпчелек өчен кызык булган вакыйга турында язма

2) Кайбер даими яки вакытлы басмаларның атамасы. *Һәркөн иртәле-кичле эре хәрефләр белән басылып таратыла торган «Сугыш хәбәрләре» дигән бюллетеньнәр, ике көннән бирле,*

*таратылудан туктатылды.* М.Гафури. *Билгеле булганча, сугыш вакытында фронт газеталары чыккан. Судан саклану корылмалары төзелешендә шундыйрак махсус бюллетень чыгарылып, аның хәбәрчеләренең берсе мин булдым.* Ә.Баян

3) Аерым бер сайлау округында сайлауга куелган кандидатларның фамилияләре, исемнәре күрсәтелгән кәгазь. *Урналардагы бюллетеньнәрнең төгәл исәбе алынгач, сайлау комиссиясенә председательлек итүче Гозәеров шаккатты.* Ф.Батттал. *Бюллетеньнәрне саный башлагач, ул Арсланов бүлмәсендә әрле-бирле йөрде, сайлау нәтиҗәләрен, туктаусыз, Казанга хәбәр итеп торды.* Ф.Садриев

4) *сөйл.* Авыру кешенең хезмәткә яраксызлыгы турында табиб белешмәсе. *Бюллетеньдә атна чамасы өйдә яткан арада, бригадир исеме белән «Акбулат» дигән очерк язылa.* Ә.Баян

**БЮ́РГЕР** *и. нем. тар.* Германиядә һәм кайбер башка илләрдә: шәһәр кешесе. --- *Мюнхен бюргерлары безнең турыда фикерләрен кискен рәвештә үзгәртергә мәҗбүр булырлар, дип уйлыйм.* Т.Галиуллин

**БЮРЕ́ТКА** *и. фр.* Сыеклык микъдарын төгәл үлчәү өчен бүлемнәре һәм краны булган пыяла көпшә. *К.Мор титриметрия ысулын камилләштерә, соңрак аның исеме белән аталган бюретка, кыскыч, үлчәү уйлап таба.* Фән һәм тел

**БЮРО** *и. фр.* 1) Төрле оешмаларда: идарә, җитәкчелек итүче үзәк; берәр эшкә җитәкчелек итү өчен билгеләнгән кешеләр. *Мәсьәлә зурая-зурая да, бюро утырышында гына хәл итәрлектән чыккач, гомуми җыелышка куела.* М.Әмир. *– Йә, – диде ул, Тимерханның эше турында бюро членнарыннан бер хатын-кыз сөйләп биргәч.* М.Мәһдиев. *Бюро әгъзаларыннан булган бер кыз кулына кызыл тасмалар тотып керде.* Ә.Баян. *Бер литр сөт кимесә, бюрога чакыралар.* Х.Камалов

2) Канцелярия, контора

3) Гадәттә киштәләре, тартмалары булган язу өстәле

**БЮРОКРАТ** *и. фр.-гр.* **1.** 1) Югары чиновник. *Унсигез миллионлы бюрократлар армиясе, дип, үзләре лаф ора.* Р.Зәйдулла. --- *балаларга ни-нәрсә укытасын, Вашингтондагы бюрократлар түгел, ә алар үзләре – җирле төбәктә хәл итәләр.* Татарстан

2) Җәмгыять, аерым кеше ихтыяҗлары турында кайгыртмаска тырышып, мәсьәләнең асылына игътибар итмичә, бары тик формаль якны гына уйлап эш итүче чиновник, түрә. *«Вакыт» дигән нәрсә белән, бюрократлар һәм Кояш кадәр Кояшның үзе белән ярышып, өч көн узды.* А.Тимергалин. *Бюрократка әйләнеп бетәбез инде...* Ш.Бикчурин. *Бюрократка холуй булып Йөрүләре рәхәтме?* Г.Афзал. *Ничек тоталар икән аны партия эшендә? Бюрократ ич ул, чиновник!* М.Әмирханов

**2.** *с. мәгъ.* Бюрократиягә караган. *Бюрократ галим әнә шулай фикер йөртә.* М.Мәһдиев. *Хәзерге Россиядә бюрократ түрәләр саны элекке СССРдагыдан өч мәртәбә диярлек артты.* Ә.Борһанов

**БЮРОКРАТИЗМ** *и. рус* 1) Аерым югары катлам мәнфәгатьләренә яраклаштырылган идарә яки эш итү системасы. *Бюрократизмны бүре кебек чәйнәп ташлар идем, явызны.* Ә.Фәйзи. *Аның [Ленинның]: «Совет власте һәлак була-нитә калса, сәбәпчесе бюрократизм булыр», – дигән сүзләре тормышка ашты бит.* Ә.Борһанов

2) Эшкә формаль караш. *Мостафин җитешмәгән нәрсәләр турында, аларны табу кыенлыгы һәм шунда килеп туган бюрократизмны әйтеп бирде.* Х.Камалов

**БЮРОКРА́ТИК** *с.* Бюрократиягә, бюрократларга хас; бюрократиягә мөнәсәбәтле. *Печатьләр, кемдер кул куясы кәгазьләр – алар барысы да сезгә кирәкле бюрократик әйберләр бит.* Ф.Садриев. *Чүки торгач, ирек һәм сүз бирде Бюрократик балта мылтыкка.* Ә.Баян. *Алар бит һаман да бюрократик дәүләткә хезмәт итәләр...* Казан утлары

**БЮРОКРА́ТИЯ** *и. фр.* 1) Хакимлек итүче катламның мәнфәгатьләрен яклаучы югары чиновниклар администрациясе. *Бюрократия җәмгыятькә хезмәтче буларак кирәк.* Ә.Борһанов. *Аның каравы, вертикаль хакимияткә хезмәт күрсәтүче бюрократия котырып үрчеде.* Н.Әхмәдуллин

2) Мәсьәләнең асылына игътибар итмичә, бары тик формаль якны гына уйлап эш итү алымы. *Бюрократия, һәр җиңелүеннән соң, яңа тәрәүләр эзли башлый.* Ә.Борһанов. *Бюрократия киртәләрен ничек тә урап үтәргә иде.* Х.Камалов. *Ике-өч атна дигәндә, [Камил белән Чәчкә] барлык бюрократия киртәләрен үтеп, кирәкле кәгазьләрне җыеп бетерделәр.* Ф.Яруллин

**БЮРОКРАТЛАНУ** *ф.* Бюрократларга хас булганча эш итү

**Бюрократлана төшү** Бюрократларга хас сыйфатлар арту

**Бюрократланып алу** Кыска вакыт дәвамында бюрократлык күрсәтү

**Бюрократланып бетү** Тәмам бюрократлану

**Бюрократланып килү** Бюрократларга хас сыйфатларга ия була башлау

**Бюрократланып китү** Кинәт бюрократлану. *Әллә бюрократланып киттең инде, димме. Килмисең. Чакырганны көтәсең.* Г.Минский

**Бюрократланып тору** Озак вакытлар бюрократлык күрсәтү

**БЮРОКРАТЛА́РЧА** *рәв.* Бюрократиягә, бюрократларга хас булганча. *Имеш, мин семья мәсьәләсен бюрократларча хәл итәм ---.* Н.Исәнбәт

**БЮРОКРАТЛАШУ** *ф.* 1) Дәүләт идарә итү эшендә бюрократия системасы урнашу

2) *к.* **бюрократлану**. *Иң мөһиме – үзебезгә бюрократлашырга ярамый.* Татарстан

**Бюрократлаша башлау** Бюрократлашу билгеләре күренү. *Алар [җитештерү мөнәсәбәтләре], атап әйткәндә, Үзәкнең тоталитар стильдә җитәкчелек итүендә, Үзәк аппаратының бюрократлаша башлавында иде.* К.Гыйззәтов

**Бюрократлаша төшү** Бераз бюрократлашу

**Бюрократлашып бару** Аз-азлап, акрынлап бюрократлашу. *Сез миңа хат язган елларда бюрократлашып баруым хәзер үзем өчен дә ачык.* С.Баттал

**Бюрократлашып бетү** Тулысынча бюрократлашу. *[Ибраһим Гази] --- тормышның кимчелекләрен дә күрә белә, җитәкче органнарның начар эшләрен тәнкыйть итүдән дә куркып тормый, бюрократлашып беткән кайбер аңгыра, мокыт түрәләрне ул, еш кына, «чуен башлар» дип атый торган иде.* Ә.Еники

**Бюрократлашып җитү** Тулысынча бюрократлашкан булу. --- *соңгы вакытта ул беркем белән дә санашмый, кеше сүзенә колак салмый башлады, бюрократлашып җитте, һәм ректорга бу бозыклыклары өчен түләргә дә вакыт җитте.* Т.Галиуллин

**Бюрократлашып килү** Акрын гына бюрократларга хас сыйфатларны туплау

**БЮРОКРАТЛЫК** *и.* 1) Бюрократ булу. *Мостафин да бу бюрократлыктан гаҗиз иде, әмма, кискен сөйләшеп, мөнәсәбәтне бозасы килми бугай.* Х.Камалов

2) Бюрократка хас сыйфатлар. *Халык контроленең район комитеты члены Фәйзиев Ташбуа кирпеч заводы директоры Солтан Ярмиевнең бюрократлык кыланышларын, тупаслыгын камчылый.* Б.Камалов

**БЮСТ** *и. фр.* 1) Кешенең биленә кадәр өлешен сурәтләгән скульптура. *Ул Садыйк Әхмәтовка бюст куйганда да Тутайга кайтты. Актив эшләде.* М.Рафиков. *Нәсимә китергән бюст Фәнияр тумбочкасы өстенә озакка менеп кунаклады.* Ф.Яруллин. *Шиллер бюсты алдында торганда, ул Рянага: – Аның пьесалары татар театрларында да сәхнәләштерелә, – диде.* Т.Әйди. *Мин үзем, чакырулы булуга карамастан, якын дустыма бюст кую һәм музей ачу тантанасына бара алмадым.* Казан утлары

2) Хатын-кыз күкрәге. *Тә-әк, биләрең үз урынында. Әйбәт. Яхшы. Бюст – нормальный! Тагын чүт кенә күтәрсәк... менә болайрак. Хәзер шундый күкрәкләр модада.* Аманулла

**БЮСТГА́ЛТЕР** *и. нем.* Күкрәкчә. *Шулар янында ук – нулевой размерлы бюстгалтер, панталон, сәдәпләре коелган пальто, сары шиньон… Хуҗаларның нинди һәм кем булуын беләсең килсә, балконнарына карау да җитә.* Ф.Баттал. *– Ә мин кушканны китердеңме соң? – Нәрсә иде ул? – Минем челтәр бюстгалтерымны?* Ә.Еники. *[Нина:] Бюстгалтерның татарчасы ничек?* Т.Миңнуллин

**БЮСТЬЕ** *и. фр.* 1) Кыскартылган корсет формасындагы бюстгалтер. *Челтәр бюстье. Бюстье сатып алу*

2) Тар бретелькалы кыска майка (хатын-кыз өс киеме)

# В

**ВА** *ы.* 1) Кинәт куркып китүне, көяләнүне, гаҗәпләнүне, аптырап калуны, шаккатуны белдерү өчен әйтелә. *Ва! Дускаем, бигрәкләр дә соңладың шул!* М.Мәһдиев

2) Бөтен кеше берьюлы ризасызлык белдереп кычкырышкан яки барысы бердән, кычкырып, аңлаешсыз сөйләшкән тавышны белдерә. *Тотасыз да, «ва! ва!» дип акырырга, бакырырга тотынасыз.* Г.Камал. *Ишегалдындагы халыкның «ва! ва!» килеп үкерешкәннәре ишетелеп тора.* М.Фәйзи

**ВАБА** *и. гар.* 1) Төп билгеләре косу, эч китүдән гыйбарәт булган көчле йогышлы авыру; үләт; *русчасы:* **холера**. *Пуледин котылып килсәк тә, вабага тотылдык без.* Бәет. *Хәмдениса карчык гомере буе боларның әниләренең үлгәнен көтеп яшәгән, әмма беркөнне аның үзенә дә авыру – ваба эләккән.* М.Мәһдиев. *Фәлән елны халыкны ваба кырган, төгән елны терлек-туар үләте килгән...* М.Рафиков. *Инде сугышлар тынды, дигәндә, дәһшәтле ачлык, ваба елы башлана.* Казан утлары

2) *күч. тирг. кимс.* Үлем китерә торган нәрсә, үләт. *Кара үләт кебек шомлы афәт булып, «фашист» дигән ваба үрмәли.* Г.Бәширов

3) *күч. тирг.* Бәла-каза китерә торган нәрсә, хәл. *Җәмгыяте хәйрияләрнең эшсезлекләренә баш сәбәп – сәяси вабаларның хәзерге халәте икәненә без ышансак та, ләкин хокуклары даирәсендә эш итәргә теләмәгәнлекләре вә иң күп әһәмиятне үлек күмүгә игаңә бирер өчен сарыф иткәнлекләре күз алдыбыздадыр.* Ф.Әмирхан

**ВАБАЛЫ** *с.* Ваба авыруы булган; ваба авыруы йоккан. *Адәмнәр вабалы йортны әйләнеп үттеләр.* Г.Исхакый

**ВА-БАНК** *рәв. фр.* 1) Карта уенында: уенчының иң зур ставкасы; картасын ачып та карамыйча, уенга билгеләнгән барлык акчасын конга куеп. *Шуның өстенә, Мөхәрләмов Афзалованың сөйләгәннәрен дә, миндә булган башка мәгълүматларны да белми, кәрт уены сөючеләр теле белән әйтсәк, «ва-банк» уйный иде.* Ф.Галиев

2) *күч.* Югалтудан курыкмыйча, бернәрсәгә карап тормыйча, зур тәвәккәллек күрсәтеп. *Нигә миңа Сабит абый хуҗалыгын алып калмаска?! Нигә аны Ихласка бирергә?! Нигә ва-банк бармаска?!* А.Гыйләҗев

**ВА́БИК** *и. рус махс.* Кош яки җәнлекләрне аларның тавышларына охшатып чакыру әсбабы. *Вабик ярдәмендә аулау*

**ВАГАЮ** *ф.* 1) Кечерәю, бәләкәйләнү, вак хәлгә килү; *киресе*: **эреләнү**. *Ә җир һаман бездән ераклаша, андагы үләннәр, вагаеп, сузылып, артка кала баралар.* С.Баттал

2) Кыскару, ваклану. *Әкренләп, аның адымнары вагайды.* М.Галәү

3) *күч.* Әһәмияте, мөһимлеге кимү яки югалу. *Сүз үлем яки тормыш турында барганда, барлык тормыш мәшәкатьләре вагая.* А.Гыйләҗев

**Вагаеп бетү** Тәмам вак хәлгә килү

**Вагаеп калу** Алдагы белән чагыштырганда, нindидер сәбәптән соң, хәзер вагракка әйләнү

**Вагаеп килү** Әз-әзләп вагаю

**Вагаеп китү** Хәзер, соңгы вакытта вагаю

**Вагая бару** Торган саен вагракка әйләнү. *Кешеләр гәүдәгә вагайганнан-вагая барып, иң ахырында, мичтә әвен сугарлык кечкенә кешекәйләр булып калачаклар, имеш, дигән карашка корылган.* Н.Исәнбәт. *Ярга якынлашкан саен, дулкыннар вагая бара, ләкин алар барыбер ишле һәм көчле әле.* З.Хөснетдинов

**Вагая башлау** Ваклыгы сизелү, вагаерга тотыну

**Вагая тору** Берсе артыннан берсе вагаю; торган саен ныграк вагаю

**Вагая төшү** Беркадәр, бераз вагаю. *Каланың бу як читендә йортлар вагая төште.* М.Галәү

**ВАГОН** *и. фр.* **1.** 1) Тимер юлда: юлчылар йөртү һәм йөк ташу өчен махсус җиһазландырылган, тәгәрмәчләр өстенә утыртылган корылма. *Ул үз вагонына җәһәт кенә сикереп керде дә, күз ачып йомганчы төенчеген алып чыгып, ике состав арасыннан вокзалга таба йөгерде.* М.Мәһдиев. *Поезд кузгалып киткәч, Ильяс, вагонның өстәге сәкесенә менеп, почмакка ятты.* И.Салахов. *Алдагы вагоннар ягыннан дөбердәгән тавыш килде, тәгәрмәчләр күндәм кузгалыштылар ---.* А.Гыйләҗев

2) Шул корылма тулырлык яки шундый корылмага сыешлы йөкнең, әйбернең микъдар күләме. *[Сезгә] Бер вагон да икмәк җибәрелмәс.* Ш.Усманов. *Бер вагон кирпечне тиз бушатып бетерделәр.* Казан утлары

3) Кырчылык, төзелеш, юл салу, тимер юл һ.б.ш. тармакларда торак итеп яки кирәк-ярак саклау өчен файдаланыла торган, күчереп йөртерлек итеп эшләнгән корылма. *[Ул] Тракторчыларның кыр вагонына да бик еш барып йөри башлый.* Р.Төхфәтуллин

4) Вакытлыча яшәү яки төн куну өчен җиһазландырылган һәм, бер урыннан икенче урынга күчерү өчен, тәгәрмәчләр яки чана өстенә утыртылган кечкенә өйсыман корылма. *Без, вакытлыча торырбыз, дип урнашкан вагонда биш ел яшәдек.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* Саннардан соң килеп, бик күп, чиксез, хисапсыз күп, дигән мәгънәне белдерә. *Бу мидә бардыр [надանлык] ун вагон, «Минбеләмлек» дәгъвасы – бер мең вагон.* Г.Тукай

**ВАГОН-АРБА** *и. к.* **вагон** (*3–4 мәгъ.*). *Аларга кышны тагын вагон-арбада чыгарга туры килде.* М.Мәһдиев

**ВАГОНДАШ** *и.* Бер вагонда утырып барган кешеләрнең берсе, юлдаш.

*Вагондашым бик күп сөйләшә торган, өлкән яшьтәге ханым булып чыкты.* А.Гыйләҗев. *Поезд Алатырь урманнарын шаулатып узганда, Кайман вагондашларына үзе турында сөйли иде.* Х.Садри. *Вагондаш күршеләребез безне чәй эчәргә чакырдылар.* Г.Бәширов

**ВАГОНЕ́ТКА** *и. фр.* Тар колеялы яки асылма юлларда йөк ташу өчен файдаланыла торган ачык өсле кечерәк вагон. *Кешеләр өч вагонетканы чак-чак тутырганда, без Насрый абыең белән дүртне тутырып ташлыйбыз.* Ш.Камал. *Тегесе гадәттә ике-өч кеше этеп йөртә торган вагонетканы берүзе этеп алып бара иде.* М.Хәсәнов. *Мескеннәр [атлар], гомерләре буена шунда – җир астында – вагонетка тартып интегәләр икән.* Ф.Хөсни

**ВАГОНЛАП** *рәв.* 1) Саннардан соң килеп, шул кадәр вагонга сыярлык, шул вагон күләмендә яки чамасында, дигән мәгънәне белдерә. *[Җылымнан] Ике вагонлап балык чыккан.* Ш.Камал

2) *күч.* Бик күп, зур күләмдә. *Балыкны без аны вакытында вагонлап озата торган идек.* Ш.Камал. – *Ул чагында аракыны – чиләкләп, мичкәләп, селёдканы – вагонлап, кыярны баржалап җибәрер идек,* – *диде поручик.* К.Тинчурин. *Салам түбәләр дәвере иде әле ул чаклар. Гайсә, вагонлап, шифер ташырга тотынды.* Ф.Садриев

**ВАГОНЛЫ** *с.* Саннардан соң килеп, шул сан исәбендәге вагоннары булган, шул сандагы вагоннардан торган. *Иң азакта килә торган дүрт-биш вагонлы состав – юл күрсәткеч поезд булып --- күперләрне, ваттырып, һавага күтәртеп килә.* Ш.Усманов. *Әлегә юл буш түгел, анда кырык вагонлы йөк поезды туктап тора.* Г.Ахунов

**ВАГОНЛЫК** *с.* Саннардан соң килеп, шул кадәр сандагы вагоннарга җитәрлек яки сыярлык. *Әллә ничә мең вагонлык күмер тауларыннан, болытларга таба сузылган морҗалардан, көйгән нефть исе белән катыш эсселек чәчелеп тора.* Ш.Камал. *Ике вагонлык чан төбенә егерме-егерме биш пот балыкны сибеп салгач, Шәрәфи агай, үзенең кыска саплы матур көрәген ак кар кебек тоз эченә бик оста гына чумырып алып, берничә мәртәбә чәчеп җибәрде.* Ш.Камал

**ВАГО́Н-РЕСТОРАН** *и. рус* Ресторан урнашкан тимер юл вагоны. *Егет аны вагон-ресторанга чакырды.* М.Мәһдиев

**ВАГОНЧЫ** *и.* 1) Вагоннар ясый торган завод эшчесе

2) *иск.* Трамвай йөртүче. *Вагон саен пар ат җиккәннәр дә тимер юл буенча өстерәп киткәннәр. Кулына озын саплы чыбыркы тоткан вагончы --- җирәнкәй белән көрәнкәйне әйдәп барган.* И.Рәми

**ВАГРА́НКА** *и. нем. тех.* Металл һәм чуен эретү яки төрле әйберләрне яндырып ныгыту, чыныктыру өчен махсус авызлы мич. *Анда, биектә-биектә, --- эрегән чуен тутырылган вагранка түнтәргәндәй булдылар.* Г.Әпсәләмов

**ВАГЫЙЗ** *и. гар. иск.* Вәгазь сөйләүче, үгет-нәсыйхәт бирүче; вәгазьче. *Вагыйз мәчеттә, бал янына җыелган чебеннәр шикелле, халыкны үз әйләнәсенә җыеп, һәр изгелекләргә боерып, һәр әшәке эшләрдән тыеп, көйләп-көйләп, вәгазь әйтәдер иде.* Г.Тукай

**ВАДИ** *и. гар. сир. кит.* 1) Таулар арасындагы уйсу җир, тарлавык, чокыр. *Разведканың инженер-техник эшчеләре таулардан кайтарылган җиһазларның иң кыйммәтлеләрен түбәнгә – вадига озаталар.* Ә.Айдар

2) Коры үзән, елга үзәне. *Кайчандыр зур елга узган киң бер вади – коры үзән.* Р.Әхмәтҗанов

**ВАЕМ** *и. гар.* 1) Нәрсә турында булса да кайгыртучанлык, борчу; гамь, уйисәп. *Бүгеннән башлап, бер-ике атнага, ул клиника ваемнарыннан бушанып торачак.* М.Маликова. *Мифтахта ул ваем түгел иде инде.* Г.Бәширов. *Килер иде, «ваем» дигән нәрсә җитми…* М.Әмир

2) Кайгы-хәсрәт. *Яшь картаймый, ваем картайта.* Мәкаль. *Ни гамь – бөлсәм? Әгәр үлсәм – ни ваем?* Дәрдемәнд. *Башыңда ваем булса, дөньяның шатлыгы, куанычлары күзгә күренми шул.* Г.Бәширов

◊ **Ваемга да алмый** Гамьсез карый, уйлап та карамый. *Һи, ул инде бу шелтә бирүләргә күнегеп беткән, ваемга да алмый.* **Ваемга керү** Кеше хәлен аңларга тырышу, уртаклашу. *Мостафа Алексейның --- һәркемнең хәленә, ваемына керә белүен, кайгыртучанлыгын [ошатты].* К.Нәҗми. **Ваем чигү** Берәр хәсрәт кичерү, кайгыдан өзгәләнү. *Алай булгач, өйлән, дус, чикмә ваем.* Г.Тукай. **Ваемы юк** Бернәрсә өчен дә борчылмый, бернәрсә турында да уйламый, эше юк, дигән мәгънәдә. *Бу баланың бернәрсәдә ваемы юк.* Р.Төхфәтуллин

**ВАЕМЛА́У** *ф. сир.* Туктаусыз берәр нәрсә турында борчылу, уйлану, кайгырып тору. *«Урал», башкалардан аермалы рәвештә, халык ихтыяҗын ваемлый иде.* Р.Вәлиев

**Ваемлап тору** Даими рәвештә яки әле, сөйләү моментында ваемлау

**ВАЕМЛЫ** *с.* 1) Берәр нәрсә турында борчыла, уйлана, хәсрәтләнә торган, хәсрәте булган. *Бар иде, дип, бер ваемлы бала, халкым мине бер яд итәрме?* Н.Арсланов

2) Уйлы-исәпле, тормышка җитди карый торган; җитди, төпле акыллы. *Аерым кеше ихтыяры түгел, идарә системасы үзе ваемлы сакчылларны күтәрсен, үсендерсен, җәмәгать милкенең кадерен белмәүчеләрне, исрафчыларны җавапка тартсын иде.* Казан утлары

3) Борчуны, нәрсәдер турында уйлануны чагылдырган. --- *бу титанның йөзе нигә шулай борчулы, нигә шулай ваемлы соң әле?* Р.Сабиров. *Түрдә утыручы кызның ваемлы йөзе күренә.* Ш.Камал. *Бикмаев, Никонов, Фазлый ваемлы чырай белән килеп керәләр.* Ш.Камал

**ВАЕМЛЫЛЫК** *и.* Ваемлы булу, җитди уйлап эш итү(чәнлек). *Айдарның ваемлылыгы йөзеннән күренә.* Казан утлары

**ВАЕМСЫЗ** *с.* **1.** 1) Дөнья мәшәкатьләреннән, кайгысыннан, борчуыннан азат, гамьсез, уйсыз-исәпсез. *Урам шау-шуы, атлыларның һай-һулап чаптырып үтүе дә, дистәләрчә кырыктартмачыларның малларын мактап кычкырышуы да, яшь-җилкенчәкнең ваемсыз уен-көлкесе дә ишетелми.* Ф.Латыйфи. *Ә болай рәхәт, ваемсыз бала чагыбызның соңгы көнен берничә*

*сәгатькә булса да озайтканбыз, ичмаса…* В.Нуруллин

2) Эшкә салкын карашлы, эш турында уйламаучан, игътибарсыз. *«Пөхтәлек», «сафлык», --- «мәрхәмәт», «тәүбә» кебек сүзләр, акрынлап, телдән төште, онытылды. Бу хәл, табигый буларак, әдәбиятта, сәнгатьтә дә кире чагылыш тапты, әдәбиятка телсез, димәк гамьсез, ваемсыз язучылар килде.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Бернәрсә белән дә кызыксынмыйча, уйламыйча, гамьсезлек күрсәтеп, исе китмичә. *Ваемсыз булып, гүя кешеләр арасыннан түгел, ә урман эченнән барам.* М.Галиев. *Бураларда он тулып ятканда ваемсыз гына йөргәннәр иде, тора-бара, бу хәл күп читенлекләр тудырды.* А.Гыйләҗев. *Хәзер иң мөһиме – тыныч һәм ваемсыз калып, бернәрсәне дә расламаска һәм кире какмаска.* Т.Галиуллин. *Никадәр генә ваемсыз булып күренергә тырышса да, Әпипәнең борчылуы һәм үкенүе ачык сизелә иде.* Г.Бәширов

**ВАЕМСЫЗЛАНУ** *ф.* Бернәрсә турында да уйламау, борчылмау, ваемсызлык күрсәтү, уйсыз-исәпсез яшәү; гамьсезләнү. *Бу вакыт Асылгәрәйнең шуннан башка бер кайгысы да юк, бөтен дөньясы түгәрәк кебек иде. Һай шулай ваемсызланмаган булсачы Асылгәрәй!* М.Шабай. *Әхәт Идриснең торган саен ваемсызлануына игътибар итте.* А.Гыйләҗев

**Ваемсызлана бару** Торган саен ныграк ваемсызлану, игътибарсызлыгы арту. --- *әбиләренә кунакка барганда гына парлашып йөргән, күзгә күренеп ваемсызлана барган ирләрен, җилтерәтеп, спектакльгә алып китәләр.* Т.Мөбарәков. *Нәби көн саен йомыла, ваемсызлана бара.* К.Тимбикова

**Ваемсызлана башлау** Ваемсызлык билгеләре күренү

**Ваемсызлана төшү** Бераз ваемсызлану

**Ваемсызланып бетү** Тәмам ваемсызлану

**Ваемсызланып карау** Бик нык ваемсызлану

**Ваемсызланып китү** Кинәт ваемсызлану

**ВАЕМСЫЗЛЫК** *и.* Эшкә, тормышка, кешегә карата салкын караш, игътибарсызлык; гамьсезлек, битарафлык. *Чишмә, янына килгән кешегә, ваемсызлык түгел, сабырлык бирә.* С.Сөләйманова. *Балачакның татлы назлары, үсмер вакытның ваемсызлыгы – барысы да кеше булырга өйрәнү өчен кирәк икән.* М.Юныс. *«Эх, дуамаллык, эх, ахмаклык», – ди ул, ачынып һәм, үзенең бала вакытта артык шуклыгы, ваемсызлыгы аркасында, биш классны бетерер-бетермәс, укуын ташлавын исенә төшерә.* Ә.Еники. *Ничек кенә аңлатып, ни белән генә аклап булыр икән мондый ваемсызлыкны!* Г.Минский

**ВАЕР** *и. ингл.* Балык тралын тагып тарттыру өчен, корыч чыбыктан ясалган трос. «*Аннары сөйләрмен», – дип, корабның иң арткы ваер блогы янына киттем.* Ә.Хәбибуллин

**ВАҖИБ** *с. гар.* 1) *дини* Дин гамәлләрендә үтәлүе тиешле булган, мәҗбүри (зарурилык дәрәҗәсе буенча фарыз гамәлләргә якын торган гамәлгыйбадәт турында). *Хатыннар һәм сабыйлар кебек җомга фарыз булмаган кешеләргә гает намазлары да ваҗиб түгелдер.* Ә.Максуди

2) *иск. кит.* Мәҗбүри үтәлергә, вакытында башкарылырга тиешле, үтә кирәкле. --- *җиткән кызны тапшыруда ашыгу – савап, бәлки ваҗиб эштер.* Г.Камал. *Тәрәккъкыйга чакыра торган музыка – ваҗип уктыр.* Г.Тукай

3) Өскә йөкләнгән, эшләми калу мөмкин булмаган. *Сезгә ваҗибтыр миңа ярдәм кылу.* Г.Тукай

**ВАҖИБ ИТҮ** *ф.* Өскә йөкләү. *Ерак җиргә сәфәр кылу ваҗиб итте.* М.Гафури

**ВА́ЗА** *и. фр.* Җиләк-җимешләр салу, чәчәкләр утыртып кую яки бүлмә бизәү һ.б. өчен кулланыла торган, төрле формаларда ясалган декоратив савыт. *Җиңел ак өстәлләр --- бәллүр вазалардагы җиләк-җимеш --- күз явын алып тора иде.* Т.Әйди. *Суынгач, паштетны кисеп, тәлинкәләргә яки вазаларга матур итеп тезеп, табынга чыгаралар.* Ю.Әхмәтҗанов. *Кунак табынына ваза белән чәчәкләр куйсаң, матур була.* Йорт эшләре. *Хуҗабикә, берничә вазага тутырып, алмалар чыгарды.* Сөембикә

**ВАЗГЫЙ** *с. гар.* Шартлы; билгеләнгән. *Үлгәнчегә чаклы, нәфесең ни тели, шуны эшли бир. «Гөнаһ» дигән нәрсәләр – бар да вазгый гына.* М.Хәнәфи

**ВАЗГЫЯТЬ** *и. гар.* Эшләрнең, вакыйгаларның барышында төрле шартлардан, факторлардан барлыкка килгән тулы күренеш, хәл. *Язу – аерым бер сәяси вазгыятьтә халыкның аңын, фикер юнәлешен билгели булып чыга.* Ф.Сафин

**ВАЗЕЛИН** *и. фр.* Нефтьтән аерып чыгарыла һәм медицинада, техникада, гигиенада киң кулланыла торган май. *Йокларга ятканчы, Наҗия кулларына вазелин тидерде.* Г.Ахунов. *Ишек пары белән, өйгә мамык шәл бөркәнгән, кыска жикет кигән, битенә мул итеп вазелин сөрткән кыйгач кашлы кыз килеп керде.* М.Мәһдиев. *Бу крем составына вазелин кушылган.* Сөембикә

**ВАЗЕЛИНЛА́У** *ф.* Вазелин сөртү, вазелин тидерү, вазелин белән майлау. *Ул, иң беренче эш итеп, сыерның җиленен, яхшылап, җылы су белән юды, аннары вазелинлады.* М.Мәһдиев

**Вазелинлап алу** Бераз гына вазелин белән майлау

**Вазелинлап бетерү** Бар җирен дә вазелин белән майлау, вазелин ягу

**Вазелинлап кую** Алдан ук вазелин сөртү, вазелинланган хәлгә китерү

**Вазелинлап тору** Даими рәвештә вазелин сөртү

**Вазелинлап чыгу** Һәрберсен берәмберәм вазелинлау

**Вазелинлый башлау** Вазелинларга тотыну

**Вазелинлый төшү** Бераз вазелинлау

**ВАЗЕЛИНЛЫ** *с.* 1) Составында вазелин булган. *Вазелинлы сабын*

2) Вазелин сөртелгән, вазелин тидерелгән, вазелин сыланган. *Кухняда ут яндырып, вазелинлы мамык белән гримны сөртә башладым.* Р.Хәбибуллина. *Вазелинлы куллары белән, ул рифыкка үрелде.* С.Сөләйманова

**ВАЗИФА** *и. гар.* 1) Үтәлергә тиешле бурыч, өскә йөкләнгән эш. *Авыруларга ярдәм күрсәтү – минем төп вазифам.*

М.Хәсәнов. *Бу вазифаны, башлыча, Хөснетдин үтәде.* Ш.Камал. *Янгынга каршы чаралар буенча нормалар һәм кагыйдәләрнең үтәлешен тәэмин итү һәм саклау управление вазифаларына керә.* Авыл хуҗалыгы куркынычсызлык техникасы. *Моны күреп, батучыларны коткару вазифасын башкаручы ике егет йөгереп килеп җиттеләр.* К.Миңлебаев

2) Үзеннән алдагы исем белдергән әйбер яки кеше функциясенә керешү, аның сыйфатларын алу, аңа тиеш хезмәтне башкару, аның урынына хезмәт күрсәтү хакында. *Йомшак чирәмгә басып, каз бәпкәсе көтеп йөргән малайлар өчен, авыл урамы – матурлык чыганагы, үзенә күрә күргәзмә залы, сынлы сәнгать музее вазифасын үтәгән.* Р.Мөхәммәдиев. *Анысы – мәхәббәткә сусаган яшь йөрәкләрне очраштыру-кавыштыру, ягъни елганың үзенә күрә бертөрле яучылык вазифасы.* Ф.Яруллин. *Сыйныфта кизү торучы малай үз эшен онытканга, укытучыга кизүлек вазифасын да өстенә алырга туры килде.* М.Мәһдиев

3) Берәр оешмада, предприятиедә алып барган хезмәте, эш урыны белән бәйле бурычлар. *Берничә көн үтүгә, Шәйдулла, ат абзарына килеп, өлкән ат караучы вазифасын кабул итеп алды.* М.Мәһдиев. *Гомәр кызы Лилия, гражданлык бурычын намус белән үтәп, авыл мөгаллимәсе вазифасын башкарып кына калмый; шунда гомерлек юлдашын таба, гаилә кора һәм Мөхәммәт Мәһдиевнең тышка бәреп чыгарга әзер табигый таланты ачылып китүгә җирлек әзерли.* Т.Галиуллин

4) *иск. сөйл.* Хезмәт хакы. *Аларның аена 15 – 20 тәңкә вазифалары өчен баш ватып, көн уздырып --- утырыр хәлем юк.* Г.Камал

**ВАЗ КИЧҮ** *ф. фар.-тат.* 1) Якын кешеләрдән яисә нинди дә булса эштән, хокуктан баш тарту, алардан файдаланмау. *Аннары, утырып барырга мөмкинлек булганда, нигә ул мөмкинлектән ваз кичәргә тиеш, ди, әле мин?* В.Нуруллин. *[Николай II] Улы Алексей файдасына тәхеттән ваз кичә.* Х.Кәрим. *Чөнки бик тәкъваланып китте: йорт эшеннән ваз кичеп, намаз-нияз булып йөри башлады.* М.Мәһдиев

2) Кире уйлау, кире кагу, алдагы фикерне инкяр итү. *Ләкин, шул уй уңае белән, төенчекне тагын бер тапкыр тотып карагач, ул уеннан ваз кичте.* Ш.Камал. *Кәефе кырылган, җаны бәргәләнгән чакларда, әтисе, еш кына «Хаҗ кылырга иде! Зәмзәм сулары белән юынып, изге җирләрдә дөнья гөнаһларыннан ваз кичәр вакыт җитте», – дип сөйләнергә ярата.* Ф.Латыйфи. *Ник кәнсәләргә барудан ваз кичкән соң ул?* Г.Гыйльман. *Чөнки мин аларның күбесенең, гаиләле булгач, андый фикерләрендән ваз кичәчәк икәнчелекләрен сизә идем.* Шура

**ВАЗЫЙФА** *и. гар. к.* **вазифа.** *Мансур берничә ел мөдирлек вазыйфасын башкарды.* Г.Ахунов. *1958 елга тикле шушы вазыйфаны башкара.* Татарстан

**ВАЙ** *ы.* **1.** 1) Кинәт куркып киткәндә, аптыраганда, авырткан-сызлаган вакытта әйтелә. *Вай! Тагын соңга кала бу бала.* Ф.Әмирхан. *Ух маңгаем, вай, вай.* Д.Аппакова. *– Вай, харап булдык! – диде карчык.* Мәҗмугыл хикәят

2) Шигырьләрдә, җырларда иҗек санын тутыру өчен файдаланыла. *Ай былбылым, вай былбылым, Агыйделнең камышы.* Җыр. *Ай Дилбәр, вай Дилбәр! Йөзең гөлгә тиң, диләр, Күңелең күктәй киң, диләр.* М.Фәйзи. *Ай Сөнбел, вай Сөнбел! Керфегең – гөл, күзең – күл. Сөйгәнемне үзең бел!* М.Фәйзи. *Ай нужа да вай нужа, Кемнәр башыннан уза!* Н.Исәнбәт

**2.** *хәб. функ. к.* **аптыраш.** *Бай – ахыры вай.* Мәкаль. *Болай да вай, тегеләй дә вай. Икесе дә күңелне өшетә.* Р.Ишморат. *Китсәң дә вай! Китмәсәң дә вай!* Г.Камал. *Алай китерсәм дә вай, болай китерсәм дә вай.* Г.Әпсәләмов

◊ **Вайга алмау** Эшне, сүзне, зарны, фикерне игътибарсыз калдыру, аларга ис китмәү

**ВАЙВАЙЛА́У** *ф. сир.* Өзгәләнү, кычкырып зарлану, кычкырыну. *Йорт эчендә килен вайвайлый.* М.Мәһдиев

**Вайвайлап алу** Бераз вайвайлау

**Вайвайлап кую** Кинәт вайвайлау

**ВАК** *с.* **1.** 1) Күләме, зурлыгы ягыннан кечкенә; *киресе:* **эре.** *Итле дөге сумсалары бик үк йомшак булмаса да, малай, вак тешләрен батыра-батыра, бер-ике тапкыр каерып капты...* А.Гыйләҗев. *Көлгән чакта, зәңгәр күзләре, вак җыерчыклар эченә төренеп, сөйкемле ялтырый.* И.Гази. *– Карагыз, – диде Нәсимә, – ашыкмыйча гына ашагыз, вак сөякләргә кадала күрмәгез.* Ш.Камал. *Ләкин алар ваграк куакларны тамырлары белән алсалар да, арадан берсенә – иң зур куакка көчләре җитмәгән.* Д.Аппакова

2) Яшь, кечкенә. *Бүлмә яныннан үтеп-үтеп киткән вак малайларны күреп кенә бераз рәхәт таба идем.* М.Гафури. *Вак кызлар, чыр-чу килеп, сызык уйный.* С.Сөләйманова. *Уенга вак балалар да килеп кушылды.* М.Мәһдиев

3) Кечкенә бөртекле, тамчылы. *Вак тамчылар салкын пыяла буйлап тәгәрәп-тәгәрәп төшәләр.* С.Сөләйманова. *Бөркеп яуган вак яңгыр аларның чәчләрен юып, муеннарына агып төшә иде.* Ә.Айдар. *Томан, бераздан, вак яңгырга әйләнеп, ява да башлады.* А.Гыйләҗев

4) Төелгән, вакланган, уалган. *Ярый әле, белеп өлгергәннәр, тиз генә Пучинкәгә төшеп, ярты шешәне алып менгәннәр дә, вак тәмәке салып, авызын каерып, шуны койганнар.* М.Галәү. *Өстәлдә вак тәмәке сала торган савыт тора.* М.Гафури

5) *күч.* Икътисади яки иҗтимагый яктан зур булмаган, көчсез. *Дөрес, бездә вак сәүдәгәрләр белән эре буржуа беркадәр дәрәҗәдә бар иде.* Һ.Такташ. *Шуның өстенә, ирекле вак җитештерүчеләр – крестьяннар һәм һөнәрчеләр – төрле дәүләт йөкләмәләре һәм налоглары белән интеккәннәр.* Политэкономия. *Миллионнарча вак ялгыз хуҗалыклар, ирекле рәвештә, колхозларга берләштеләр.* Казан утлары

6) Түбән дәрәҗәдәге. *Вак чиновник: «Син – җәнҗалчы! – диде. – Кәгазеңне ал да бар кит инде!»* Г.Афзал

7) *күч.* Зур әһәмияткә ия булмаган. *Яшь автор исә үзенчә – вак бәхет белән бәхетле иде.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Аз санлы. *Вак отрядларны --- җыеп, полклар төзү --- нәүбәттә тора.* Ш.Усманов. *Безнең кебек вак*

*төркемнәргә үтәргә бик җиңел иде.* Ә.Айдар

9) *күч.* Җентекләп, зур игътибар белән эшләүне сорый торган (эш турында). *Чәчүлек тары чүплерәк иде – җилгәрттерде. Җилгәргеч аера алмаган чүп-чарларны кул белән чүпләтте [Шәйхаттар бабай]. Дөрес, бик вак, бик ялыктыргыч эш булды бу.* Г.Гобәй

10) *күч. сөйл. к.* **вакчыл**. *Рәмзи абыең коточкыч үзгәрде, вак, көнчел әдәмгә әйләнде.* В.Нуруллин

**2**. *и. мәгъ.* 1) Кирпеч, печән, агач кебек нәрсәләрнең вакланган, уалган оны, чүбе, тузаны. *Кыз, җәһәт кенә иелде дә, сыер аягы астыннан салам вагын кулы белән сыпырып җыя башлады.* Ә.Еники. *Фатихның җилкәсенә коелган печән ваклары аның аркасын кычыттырып, тырнап торалар иде.* А.Шамов. *Чебиләр астына печән вагы кертеп салдым, маллар астын җыештырдым.* Азат хатын

2) *иск.* Исни яки тел астына сала торган тәмәке тузаны; нас. *Әфьюн ашау, вак салуны куячакмын, Җәдитләрне гайбәтләүдән туячакмын.* Г.Камал. *Мәгъсүмнең савыты берлә вагы онытылып калды. Хәят абыстай табып алды да иснәп карады, борыч исе кеби куәтле ачы ис борынына кереп, төчкерде.* З.Һади

3) Суммасы түбән кыйммәткә ия акча; тиеннәр. *Акчаларымның вагын бөтен ике йөзәрлекләргә алмаштырып, йөрәк өстенә бөти тектем.* Г.Ибраһимов. *Хәергә өләшә торган кәгазь акчаларым беткән, ваклар гына калган.* Казан утлары

4) *күч. сөйл.* Акыл, зиһен; белем. *Мин урысчаны [ярыйсы ук] төшенәм икән хәзер ---, шулай да, үзем сөйләшкәндә, вак җитеп бетми әле, еш төртеләм.* Ш.Маннур

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Кыска адымлап. *Секретарь исә мантосын, бик саклык белән генә, эч ягын әйләндереп элеп куйганнан соң, вак кына атлап, директор кабинетына кереп китте.* М.Хәсәнов

2) Әһәмиятсез, кирәксез, мөһим түгел. *Кара-каршы әйтешеп утырганда, Харраска Әскәр сүзләре бик вак тоелган иде, вакыты-вакыты белән йөзен җыерып кына тыңлады ул аны.* К.Тимбикова. *Бик кадерле нәрсәләр, олы тарих таләпләреннән чыгып уйлаганда, микроскопик вак булып калмыймыни?!* А.Гыйләҗев

◊ **Вак балык** *кимс.* Зур, әһәмиятле эшләр күрсәтмәгән, җәмгыятьтә әһәмияте бик кечкенә булган, икенче дәрәҗәдәге кеше. *Мәкаләнең баш өлешендә, бик тәфсилләп, Янгураның медицина өлкәсендә кем булуы, аның кыю фикерле новаторлыгы һәм аңа каршы өерләре белән кузгалган вак балыклар турында язылган иде.* Г.Әпсәләмов. **Вак балыклар арасында йөзгән чабак (кебек)**. Вак-төяк, әһәмиятсез кешеләр арасында үзен дәрәҗәле күрсәтеп, ялтырап йөрергә яратучы, үзе дә алар чамасыннан күп ерак китмәгән кеше. *Малайны да, мине дә беләләр, вак балыклар арасында йөзгән чабаклар түгел без.* Ф.Хөсни. **Вак бәрәңге** *кимс.* Җәмгыятькә файдасыз, әһәмиятсез кеше. **Вак бөҗәкләрне күреп тә филне абайламау** *ирон.* Бик күренекле, бик әһәмиятле, билгеле нәрсәне күрми үтү, сизмәү. *Ясыйсы нәтиҗәне алдан ук билгеләп кую – фактлар белән үзе теләгәнчә уйнауга, чебенне фил итүгә, яисә, киресенчә, вак бөҗәкләрне күреп тә, филне абайламый узуга китерергә мөмкин.* И.Нуруллин. **Вак җанлы** Вөҗдансыз, әхлаксыз, түбән; вакчыл (кеше турында). *Мин сине олы йөрәкле, кыю егет дип йөрсәм, син, Әнвәр, вак җанлы мещан икәнсең.* Р.Ишморат. **Вак җанлылык** Вөҗдансызлык, түбәнлек; вакчыллык. *Куркаклыкны, вак җанлылыкны берничек тә аклап булмый.* Ш.Хөсәенов. **Вак иләк** Бик нечкәләп, җентекләп үткәрелгән тикшерү. **Вак иләктән иләү (уздыру, үткәрү)** Берәр эшкә бик җентекләп тикшереп сайлап алу. **Вак кеше** Вак табигатьле, вакчыл, ваксынучан, тормыш вагына батып яшәүче, холыксыз, бәйләнчек кеше. **Вак кул бай** Вак сатучы, вак товарчы, вак сәүдәгәр. **Вак пешка** Коллективта, җәмгыятьтә әһәмияте бик кечкенә булган, абруйсыз, дәрәҗәсез кеше. *Унлап кешене тоттыруы өчен генә гитлерчылар аның җинаятен гафу итмәячәк. Ул һаман вак пешка булып калачак.* Г.Әпсәләмов. **Вак салу** *иск.* Вак тәмәкене тел астына салу. *[Мәгъсүмнең] Эче пошар, вак салыр, шуның берлә башын җиңелләндерер, кайгысын таратып, күңелен юатыр иде.* З.Һади. **Вак сүзле** Вакчыл, юк-бар кимчелекләр таба торган. *Сөйкемле әнкәсенең хәзер әнә шулай вак сүзле, кырыс чырайлы, көнчел һәм бәйләнчек каенанага әверелә баруы бик аяныч иде.* Г.Бәширов. **Вак сүзлелек** Вак сүзле булу. *Аның Хәбирәсе – качып киткән хатыны – бу өйдә ике нәрсәдән газап чикте: берсе – Сафаның аз сүзлелеге, --- ә икенчесе – Мәликәнең бик күп һәм бик вак сүзлелеге иде.* А.Шамов. **Вактан турау** 1) Нәрсәне дә булса бик ваклау. *[Лоточы:] 6, 19, 2, 7, 3, 2. [Кәрим:] Бигрәк вактан турый башладың.* Г.Камал; 2) Җентекләү, бөтен нечкәлекләренә кадәр игътибар итү, җиренә җиткерү. *[Биюче] Гыйльми түтигә аеруча ошады: «Һәй, вактан да турый инде, әй, рәхмәт төшкере!» – [диде ул].* Г.Бәширов. **Вак тараканга азык булу** *сөйл.* Бирелгән вәгъдәләр, корылган планнар үтәлмәү, тормышка ашмау. *Әмма ул вәгъдәләр, халык әйтмешли, вак тараканга азык булып кала.* Г.Ахунов. **Вак халык** 1) Иҗтимагый әһәмияткә ия була алмаган, тормыш ваклыкларына батып калган кешеләр; 2) Югары сыйныфлар яки үзләрен беренче сорт санаучы түрәләр, чиновниклар каршында «кара халык». **Вак чабак** *кимс. к.* **вак балык**. *Сәүдә дөньясында Африкан Африканычның исеме билгеле. Ул Исмәт кебек вак чабакларга сәлам дә бирми.* Г.Әпсәләмов

**ВАК АКЧА** *и.* Суммасы түбән кыйммәткә ия акча; тиеннәр, вак (*3 мәгъ.*). *Аңарда бит вак акча юк.* Р.Зәйдулла. *Мин кесәләремә әни биргән вак акчаларны салдым.* М.Мәһдиев. *– Бу назлы мине шулкадәр сөя икән, – дип фикер кылды, бер яулык вак акча өстенә сипте.* Мәҗмугыл хикәят

**ВАКА́НСИЯ** *и. лат.* 1) Штаттагы буш урын. *Институтта вакансияләр юк.* М.Мәһдиев. *Бик шәп белә ул бу гәҗитне, бигрәкләр дә «Вакансия» дип язылган төшен.* К.Кәримов. *Безнең*

*кафедрада бер өлкән укытучы вакансиясе бар.* Х.Сарьян. *Сугыш башланганнан бирле буш торган урын иде бу. Вакансия.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Беркем дә биләмәгән буш урын (йөрәктә, күңелдә). *Йөрәгемдә бер матурга вакансия бар әле.* М.Саттаров. *Анда, күңелдә, дигәнем, урын бушмы? Безнең икътисадчылар телендә әйткәндә, вакансия бармы?* Т.Галиуллин

3) *хим.* Структур берәмлекләрдән бушаган урыннар булу; кристалл челтәренең җитешсезлеге, дефекты

**ВАКАНТ** *с. к.* **вакантлы.** *Урыс язучысы Владимир Солоухин болай ди: «Шигырь язганда, бер вакант урынга егерме яисә утыз сүз дәгъва кыла».* И.Низамов

**ВАКАНТЛЫ** *с.* Эштә, фирмада, уку йортында, штатта каралып та, шул урынга хезмәткәр алынмаган, буш. *Андый вакантлы урынга миннән башка да дәгъвачылар бардыр.* Ф.Яруллин. *А.И.Данилов һәм Н.А.Гуляев Казан университетына вакантлы вазифаларга килләр.* Я.Шәфыйков. *Укытучы булыр өчен, вакантлы урын юк.* М.Бөдәйли

**ВАКБАШ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, сирәк агачлы нарат урманнарында, басуларда, болыннарда, юл буйларында үсә торган вак чәчәкле үлән үсемлек; дәрвиш үләне; *русчасы:* **мелколепестник.** *Әлегә минем гербарийда вакбаш юк.* Л.Ихсанова

**ВАК БӘЛЕШ** *и. кулин.* Юка итеп җәлгән камыр эченә ит һәм ярма катыштырып салып, аны бөреп томалап пешерелә торган татар милли таба ашы. *Вак бәлешләрне майлы тирән табада шактый кызу мичтә пешерәләр.* Ю.Әхмәтҗанов. *Вак бәлеш төрле ярмалардан: дөге, борай, карабодай ярмаларына ит кушып пешерелә.* Татар халык ашлары

**ВА́К-ВАК** *рәв.* **1.** 1) Эре, озын булмаган, кыска итеп. *Икенче классның иркен, чиста палубасында вак-вак кына атлап йөргән затлы киемле, мәһабәт ханымнарга, камыш көрсиләрдә, атылып, папирос көйрәткән кешеләргә үзенең татар икәнлеген, әнә шул кой рыкта утырган, мең мәшәкать белән, нужа куып юлга чыккан авыл гыйбадлары белән кан кардәш икәнлеген күрсәтәсе килмәде аның.* А.Гыйләҗев. *[Ул] Ашыгып, каушап, карчыкларча вак-вак атлап, аның артыннан бара башлады.* А.Расих

2) Аз күләмдә, аз-азлап, кечкенәкечкенә итеп. *Әхәт исә вак-вак кабып, тиз-тиз чәйнәп ашый иде.* А.Гыйләҗев. *[Гөлчәчәк] Чүмечтәге салкын суны самавыр астында таманлап, вак-вак йотымлап бөркеде дә арышны калын җәймә белән каплап куйды.* К.Кәримов

3) Сизелер-сизелмәс һәм еш. *Сабый бала, нә кылырга белми, анасы теләге белән ризалыгын белдереп, вак-вак баш какты.* М.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ.* Бик вак; берсеннән-берсе вак. *Башмагымның башы – башка, басмас идем вак-вак ташка.* Бәет. *Җирән, этне күрсәтеп, тигез тезелгән вак-вак тешләрен ыржайтты.* А.Гыйләҗев. *Бәбиләр: нәни кызчыклар, малайлар, колыннар бәй-бәй итәргә яткач та, үләннәргә, яфракларга вак-вак көмеш тамчылар куна.* А.Гыйләҗев. *Менә бит, каенлык арасында әле дә вак-вак калкулыклар сибелеп ята.* Ә.Баянов

**ВАККОРСАК** *и. зоол.* Элпә канатлылар отрядыннан, личинкалары башка бөҗәкләрдә паразит булып яши торган вак бөҗәк; *русчасы*: **наездник**. *Кәбестә күбәләгенең гусеницаларын кайчакта ваккорсаклар бөтенләй бетерәләр.* Зоология. *Бакчада ваккорсаклар бик нык үрчегән.* Сөембикә

**ВАКЛАГЫЧ** *с.* **1.** Каты нәрсәне вак кисәкләргә бүлгәли, турый, ваклый торган. *Юлларга таш җәю өчен, безгә ваклагыч машина алырга кирәк.* Татарстан яшьләре

**2.** *и. мәгъ. тех.* Каты нәрсәне вак кисәкләргә бүлгәли, турый, ваклый торган машина, механизм. *Ваклагычта ташларны ваттырсак, эш тизрәк алга китәр иде.* Татарстан яшьләре. *Азык ваклагыч. Салам ваклагыч*

**ВАКЛАНМА** *и. мат.* Берәмлекнең бер яки берничә тигез өлешеннән төзелгән сан. *Әмма татарча вариант ⅔ вакланмасын табуның, ягъни икене өчкә бүлүнең табигый технологиясен дөресрәк чагылдыра.* Фән һәм тел. *Гади вакланма. Аралаш вакланма*

**ВАКЛАНМАЛЫ** *с. мат.* Составында вакланма булган, вакланмадан торган. *Татар телендәге өлеш саннары яки вакланмалы саннар да микъдар саннарына кертеп өйрәнелә. Телебездә вакланмалы санның санаучысы – баш килештә, ә ваклаучысы чыгыш килеше формасында әйтелә.* Ч.Харисова

**ВАКЛАНУ** *ф.* **1.** 1) *кайт. һәм төш. юн. к.* **ваклау** (*1 мәгъ.*). --- *утын түмәркәсе, шыңгырдап, урталай ярыла да, сызгырып, ике якка оча. Шыңгыр да шыңгыр килеп, шул арада бер түмәркә, ике, өч... түмәркә вакланды.* Г.Бәширов. *Кәбестәне аерым тактада яки тагаракта, вакланганчы, тәпке белән бик яхшылап чабалар.* Ю.Әхмәтҗанов. *Юлга ташның бик нык ваклан ганын алып кайтып җәйделәр.* Мәдәни җомга

2) Зурлыгы, күләме ягыннан кимү, кечерәю, вакка әйләнү; сыйфат, нәсел билгеләре начарлану. *Хәдичәттинең соңгы елларда казлары вакланды.* Азат хатын

3) *күч.* Катнашучылар арасында яшьләр күбрәк булу, ешрак яшьләр очрау, яшьләр тартылу; яшәрү

4) *күч.* Дәрәҗә төшү; сафлыкны, чисталыкны югалту. *Әле бу чакта сүз кирәкми, хисләр әле вакланмаган, иң риясыз уйлар бары тик бер генә затка төбәлгән чак...* А.Гыйләҗев. *Шәхес ваклана, таркала, халыкның умырткасы булудан туктый.* Т.Галиуллин. *«Намус – зур!» – диган идек, Намусын югалтканнарны Гаепләп йөргән идек. Инде җаннар вакланды – Вәгъдәләрне үтәмәдек, Намусыбыз тапланды.* Э.Шәрифуллина

5) *күч.* Дәрәҗә төшерә торган әһәмиятсез эшләрдә катнашу. *Бүген милләтнең дә, татар авылларының да иң йомшак урыны – менә шушы милли идеологиянең булмавы, халыкның вак максатлар белән вaклануы һәм кыйблысыз калуы ---.* Мәдәни җомга

6) *күч.* Вак-төяккә әһәмият бирү; вакчыллык күрсәтү, вакчыллану. *Әллә соң юбилей үткәреп ваклaнмыйсыңмы?* М.Галиев. – *Син аның ашап утырганын күргәнең бармы? – Ашау белән ваклана, ди!* М.Галиев. *Алар белән*

*сүзгә килешмәм, тик Вакланырга нигә ул чаклы!* Х.Туфан

**2. вакланып** *рәв. мәгъ.* Вакчыллanып, вакчыллык күрсәтеп. *Аның көлке хаталарын җаһилләр күрми, ә галимнәр, вакланып, тел әрәм итеп тормыйлар.* А.Тимергалин

**Ваклана бару** Вакыт үткән саен, акрынлап, тагы да ныграк ваклану. *Бу инде хыялның буыннан-буынга ваклана баруын күрсәтә.* М.Юныс. *Аларның болай да түбән рухлары, үзара дошманлашып, бер-берсенең эшчәнлеген бозып, торган саен ныграк ваклана баралар.* З.Мифтахов. *Аяз Гыйләҗевнең хәзерге прозаның ваклана баруы турында, «уртача» әсәрләр күбрәк булуы хакында язуы һәм борчылуы урынлы.* Г.Бәширов

**Ваклана башлау** Вакланырга керешү. *Тик Мәләкәстән кайткан бу асыл сөяк сыерның нәселе, ни хикмәттер, безнең Яуширмәдә мантый алмый, икенче, өченче буыннан ук, акрынлап, ваклана башлый, тора-бара, бөтенләй югала иде.* Ә.Еники

**Ваклана төшү** Бераз ваклану. --- *бу дәүләтләрдә үзләренә бәйсезлек таләп итүче яңа этник группалар үзләре турында белгертә башлый, шул сәбәпле, Югославия һәм Чехословакия тагын да таркала, ваклана төшә.* К.Фәсхетдинов

**Вакланып бару** *к.* **ваклана бару.** *– Чыныккан кешеләр кирәк. – Бик кирәк, югыйсә вакланып барабыз. Балачага күбәйде.* Г.Ахунов

**Вакланып бетү** 1) Бөтенлеге тулысынча бозылып, бик вак кисәкләргә вакланган булу. *Сөрсеп, вакланып беткән, авыр сагыштан арыган, тормыштан йөз чөергән җаныңны уятырга, аны яшәүгә, өметкә, мәхәббәткә кайтарырга килдем мин сиңа...* Г.Гыйльманов

2) *күч. сир.* Бик нык ваклану, вакчыллыгы көчәю. *Эгоист кеше тормышта бик вакчыл була. Ул юнәлешен югалта. Ишетәсеңдер, хәтта олы галимнәр дә вакланып бетәләр...*Т.Миңнуллин

**Вакланып җибәрү** Кинәт ваклана башлау. *– Бигрәк вакланып җибәрәсең кайчагында, – диде Сафура, ачуы килгәч.* Гөлшаһидә

**Вакланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта тормыштагы юк-бар, артык вак әйберләрне ачыклау белән шөгыльләнү. *Әйдә, балам, болар белән вакланып йөрмә.* Т.Миңнуллин

**Вакланып китү** Нинди дер сәбәп белән, кинәт кенә вакка әйләнү

**Вакланып тору** Әледән-әле, һаман, гел ваклану, вакчыллык күрсәтү. *Егет кеше шулай вакланып торамыни, дигән сыманрак итеп, чак кына турсаеп та куйды.* В.Нуруллин. *Ихтимал, бер көтү хатыннар алдында сүз куертудан качканмын, әллә инде, үземне егеткә санап, вакланып тормаганмын.* К.Миңнебаев // *юкл. форм.* Бервакытта да вакланмау, һичкайчан вакланмау. *Ләкин хак мөселман алай вакланып тормаган.* Х.Сарьян

**ВАКЛАНУЧАН** *с.* 1) Вакланып китә торган. *Җимеше – вакланучан тартмачык, ул, өлгергәндә, ояларга таркала, үзәгендә баганачык кала.* Л.Мәүлүдова

2) *к.* **вакчыл**. *Кияү болай бик акыллы, тыйнак күренә, ләкин бераз вакланучан булмагае, дим.* Д.Каюмова

**ВАКЛАНУЧАНЛЫК** *и. к.* **вакчыллык.** --- *кием-салымы артык пөхтә, бу – вакланучанлык билгесе.* Д.Каюмова

**ВАКЛА́П-КҮПЛӘП** *рәв.* Аз-азлап та, күпләп тә. *Татар телен ваклапкүпләп сата, Читләр түгел, татар баласы.* Җ.Сөләйманов

**ВАКЛА́П-ТӨЯКЛӘП** *рәв.* 1) Азазлап, бүлгәләп, берәмләп. *Зифа карчык, идәнгә чүгәләп утырып, мич эченә, ваклап-төякләп, утын ташлый иде.* А.Шамов

2) Җентекләп төпченеп, бөтен нечкәлекләренә игътибар итеп. *Ваклап-төякләп сөйләү. Ваклап-төякләп сорау*

**ВАКЛАТУ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **ваклау**

2) *к.* **ваклау** (*2 мәгъ.*). *Билет алганда, ул [Зәкәрҗан] тагын бер йөзлекне ваклатты.* М.Мәһдиев

**ВАКЛА́У** *ф.* **1**. 1) Вак-вак, кечкенә кисәкләргә, өлешләргә бүлгәләү, вату, тураклау, аеру; вак итү. *Койма буендагы такталарны, кисеп, утынга вакларга кирәк.* М.Мәһдиев. *Роторлы җайланманың җитешсезлеге – ул, гадәти барабанга караганда, саламны шактый күбрәк ваклый.* П.Макаров

2) Эре акчаны шул ук суммадагы вак акчага алмаштыру. *[Тәзкирә:] Соңгы егерме бишлекне вакларгамы?* А.Гыйләҗев. *Йөзлек кенә икән, әйдә, кассада ваклыйбыз...* Н.Фәттах. *Чөнки көне буе, акча ваклауларын үтенеп, аларның [кибетчеләрнең] үзәкләренә үтәләр. Ә мин – --- эреләндерәм.* М.Мәһдиев

3) Бүлгәләү, төркемнәргә аерып карау. *Тишковның максаты: Россия халкыннан бер милләт – россияннар милләте ясау. --- ул, милләтне конструкцияләп була, дип уйлый. Татарны ваклау шуның өчен кирәк.* Татар календаре

4) Билгеле бер яшькә, вакытка җитү. *Соңрак, үзенең дә кырык бишне ваклаганы, чәчләренең бәскә манчылганы исенә төште [Сәетнең].* Т.Галиуллин. *Әлеге беренче очрашуыбызда янып торган егерме ике яшьлек егет булган якташым, күрше авыл егете Әхәт Гаффарыбыз да алтмышны ваклый икән ләбаса.* В.Нуруллин

5) *күч.* Бөтен нечкәлекләренә кадәр игътибар итү, җентекләү, бөртекләү

6) *күч.* Көчне, энергияне, хисләрне, рухи байлыкны әһәмиятсезгә, вак-төяккә, кирәкмәгәнгә әрәм итү; тиз арада бүлү, таркату. *Безгә, киләчәк алдында бик үк гаепле булып калмас өчен, җаныбызны ваклamаска, намус, вөҗданыбызны саф килеш сакларга кирәк.* Т.Миңнуллин. *Кыйбламны җуеп әйтмим, җанымны ваклавым да түгел, һуштан түнәрлек хәсрәтемнән гаҗиз булып сөйлим...* Б.Камалов. *[Хисләремне] Төрле-төрле кисәкләргә Бүлгәләп ваклamадым.* Ә.Ерикәй

**2**. **ваклап** *рәв. мәгъ.* 1) Аз-азлап, өлешләп, өзек-өзек бүлгәләп. *Фәния, кисәк-кисәк, ваклап сөйләшә торган теле белән, зарланып та алырга өлгерде.* Ф.Яхин

2) Данәләп, берәмләп, берәрләп; килолап, граммлап. *Күгендә-түшәгендә чалкан яткан, ваклап сатучыларның кыланышына өйрәнгән айның да исе китми.* Т.Галиуллин. *Электр энергиясен күпләп сату базарының яңа кагыйдәләре кертелгәч һәм ваклап сату базары кагыйдәләре кабул ителгәч, энергия белән тәэмин итүче оешмалар һәм*

*энергия кулланучылар арасында үзара бәйләнеш нык үзгәрәчәк.* Идел

3) Нечкәлекләренә төшенеп, җентекләп, төпченеп. *Кыздырып барган кояш нуры астында, ваклап, тармаклап, җинаятьнең урынын сыйфатлап язды.* Г.Ибраһимов

◊ **Ваклап турау** Артык төпченү, бөтен нечкәлекләрен дә исәпкә алу; җентекләү

**Ваклап алу** Тиз генә ваклау, бүлгәләү, тураклау

**Ваклап ату** Тиз-тиз, аннан-моннан вак кисәкләргә ваклау, бүлгәләү, тураклау

**Ваклап бетерү** Бөтенесен ваклау; нәрсәне дә булса бик вак итү. *Кара син аларны, халык өчен бары тик «җир» дигән сүз генә бар иде, болар нишләтеп ваклап бетергәннәр!* М.Мәһдиев. *[Эльвира телеграмманы] --- башта – икегә, аннары дүрткә бөкләде, әкрен хәрәкәт белән ерткалады, тәмам теткәләп, ваклап бетерде.* М.Маликова

**Ваклап кую** Алдан ук вак кисәкләргә бүлгәләү; вакланган кисәкләр рәвешенә китерү

**Ваклап тору** Әле, хәзерге вакытта ваклау. *Яшь аналар балаларына ипи ваклап тора, сабыйлар кошларны ашата.* Р.Батулла

**Ваклый башлау** Вакларга керешү. *--- алтмышын ваклый башлап, инде шактый олыгая төшкән чын остазның бераз сәер дә, ләкин шул ук вакытта ифрат гүзәл дә булган бу гамәлен, гаҗәпләнү катыш соклану белән, башларын чайкый-чайкый, байтак карап тордылар.* Р.Вәли. *Карап торам да, [эшне] бик ваклый башлагансың әле син, Нәфисә кодача.* Г.Бәширов. *Соңгы декаданы да ваклый башладык бит.* Р.Төхфәтуллин

**Ваклый төшү** Бераз ваклау; тагы да ваклау

**ВАКЛАУЧЫ** *и. мат.* Вакланмада берәмлекнең ничә тигез өлешкә бүленүен күрсәтә торган сан; бүлүче. *Бер дәрестә ул бака суйды, икенчесендә винтовкага өйрәтте, өченчесендә иң зур уртак ваклаучыны таптырды.* М.Мәһдиев

**ВАКЛАШУ** *ф. сөйл. к.* **вакчыллану.** *Сатыла торган әйберләр тирәсендә, безнең авылның бай кешеләре печән чабу, урак урдыру өчен алдан акча бирергә сатулашалар, урак урырга дисәтинәсенә ике тәңкә акча һәм бер пот арыш оны биреп ваклашалар иде.* М.Галәү. *Без күп телләр белән ваклашырга яратмый идек, бертын сатулашып торганнан соң, аралашу коралы итеп, инглизчәне сайладык.* М.Юныс

**Ваклаша башлау** Ваклашырга тотыну

**Ваклашып китү** Кинәт ваклаша башлау

**Ваклашып тору** Әле, күз алдында, хәзер ваклашу. *Бу эш гараж һәм складлар каравылчысының вазифасына керми керүен, әмма гомере буена ялкаулыкның нәрсә икәнен белмәгән карт әллә ни ваклашып тормый.* М.Шәрифуллин. *Кешеләрнең сәламәтлегенә кагылышлы эштә акча белән артык ваклашып торуны кирәк дип санамыйм мин.* В.Нуруллин

**ВАКЛЫК** *и.* 1) Күләм, зурлык ягыннан кечкенә, вак булганлык. *Алмабикә яратуын ихлас күңелдән әйтте. Ләкин ул яратуда да ярма бөртеге ваклыгы сизелеп тора.* С.Поварисов. *Бәрәңгеләрнең ваклыгы эчне пошыра*

2) Нечкәлек, җентеклелек, вак деталь. *Бәхетлемен, ахры, Җир үзенең Сөйдерә алды бөтен Ваклыгын* Һ.Такташ. *Шәһәр урамнарын, зиннәтлерәк йортларны кешесез чакта, аулак иртәләрдә күзәтергә ярата Идрис, андый чакта шәһәрнең бөтен ваклыгы, барлыгы күзгә күренә торган була.* А.Гыйләҗев. *Инде менә ярты гасырга якын вакыт узган, әмма шушы вакыйга минем хәтеремә бөтен ваклыклары белән уелып калган.* Ф.Латыйпов

3) Әһәмиятсез вакыйга, күренеш. *Безнең гомер тулы һәр ваклыкка, Эчпошыргыч ямьсез бушлыкка.* М.Җәлил. *Аннан [магнитофоннан], күңелдәге иң яшерен, иң нечкә хисләрне уятып, тормышның бар ваклыкларын оныттыра торган моң агыла.* Р.Габделхакова

4) *к.* **вакчыллык.** *Көлмәгез минем сүзләрдән, Табып ваклык хатасы.* Г.Сәгыйров. *--- бик җентекләп сөйләп чыгуымны ошатып та бетермәсләр, ваклык дип санарлар.* Р.Хәйретдинова. *Дөрес, хуҗа хатынның холкында ваклык бар барын, аның каравы, бик тәмле телле үзе.* К.Тимбикова

5) *күч.* Дәрәҗәне, абруйны төшерә торган эш. – *Мин анда кереп җавап бирүне үземә ваклык саныйм! – диде.* Г.Ибраһимов. *Китап сүзе адәм баласын түбәнлектән, рәхимсезлектән, ваклыктан аралаган.* М.Вәлиев. *Бу – аларның, шулкадәр ваклыкка төшеп, бер яртылык теләнүләре иде.* Н.Хәсәнов

6) Әшәкелек; түбәнлек. *Анда ни булса да, мондагы төсле кабахәтлек, ваклык, күңелсезлекләр булмаска тиеш.* Ш.Камал. *Буе кәтәнәй кешенең эче мәңге ваклык, хөсетлек, мәкер белән тулы була.* В.Имамов

**ВАКЛЫ́-ТӨЯКЛЕ** *с.* **1.** *к.* **вак-төяк** (*2, 3 мәгъ.*). *Ваклы-төякле балаларын иятеп, кунаклар килеп төште.* М.Мәһдиев

**2**. *рәв. мәгъ.* Җиңелчә. *Бикмүш бабай, эше алга бармаган чакларда, ваклы-төякле сүгенгәләп алырга, «тпру, шайтан!» дип, төкергәләп куярга ярата иде.* Г.Гобәй

**ВА́КСА** *и. нем.* Туң май һәм балавызга корым кушып ясалган, гадәттә, күн әйберләрне чистарту, ялтырату өчен кулланыла торган крем. *Походта итек чистарту иң кирәкле эшләрдән саналса да, щёткалары һәм ваксасы белән урман буендагы агач төбендә утырган итек чистартучы, әллә ничек, бик сәер булып күренер иде.* Г.Ибраһимов. *Вакса белән ялтыратылган сары күн курткасы кояшта ялтырапялтырап китә.* Г.Ахунов. *Кара Чыршы кибетеннән теш порошогы белән вакса, ислемай һәм «Пушки» папиросы кебек әйберләрне Нургали генә ала иде.* М.Мәһдиев

**ВА́КСАЛАУ** *ф.* Күннән эшләнгән нәрсәләргә вакса сылау, вакса белән чистарту, ялтырату. *Эштән кайтуга, Вәгыйз аяк киемнәрен ваксалады.* Ш.Әхмәдиев

**Ваксалап алу** Тиз арада ваксалау

**Ваксалап бетерү** Ваксалауны төгәлләү; барысын да ваксалау

**Ваксалап җибәрү** Бераз, җиңелчә генә ваксалау

**Ваксалап кую** Алдан ваксалау; ваксаланган хәлгә китереп калдыру. *Әй,*

*кызым, минем яңа штиблетларымны ваксалап куй әле.* Ф.Әмирхан

**Ваксалап тору** Әледән-әле, еш ваксалау. *Чаллыга укырга йөргәндә, бик игътибарлап, ваксалап тора идем мин аларны [туфлиләрне].* М.Галиев

**Ваксалап чыгу** Һәрберсен, берәмберәм, ахырга кадәр ваксалау

**ВАКСЫНУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса вак, әһәмиятсез дип санау. *Сатулашып торуны ваксыну*

2) Үзен түбәнсетү, дәрәҗәсен төшерү. *Ул иптәшләре, хосусан яшьрәкләре белән артык ваксынмый, аларның уен-көлке, бозыклыклар турындагы сүзләренә бер дә катнашмый.* Ш.Камал

3) Вак-төяккә игътибар бирү, вакчыл булу. *Ваклыгы берлән җиһанның Ваксынасым килмәде, Ят үлемне каршы алдым, Ятсынасым килмәде.* Ш.Бабич

**Ваксына башлау** Ваксынырга тотыну

**Ваксына төшү** Азрак ваксыну

**Ваксынып алу** Бераз ваксыну

**Ваксынып йөрү** Озак вакытлар дәвамында, һәрвакыт ваксыну. *Бер кыз, үзе танышырга теләп, миңа яучы җибәрмәсә, мин һичвакыт, танышырга эзләп, ваксынып йөрмим.* Г.Тукай. *Рәис, үчегешеп, ваксынып йөрми, Зәйнәпкә карап, ярты сүз генә әйтә.* А.Гыйләҗев

**Ваксынып карау** Бик нык ваксыну

**Ваксынып китү** Кинәт ваксына башлау

**Ваксынып тору** Әле, хәзер, күз алдында ваксыну күрсәтү. *Малайның әллә эше бик тыгыз иде, әллә ваксынып торасы килмәде, --- тавышын олыларча итәргә тырышып, сүз башлады.* Г.Гобәй

**ВАКСЫТУ** *ф.* **1.** Кимсетү, түбәнсетү; мыскыллау, хурлау. *Ни эшлисең, сүз көрәштереп, үзеңне ваксытыр хәл юк, аның әйткәненә каршы китмәдем.* Г.Ибраһимов. *Табигатемезнең яхшы яклары исә – горуранә, үзләрен ваксытмыйча, башка халыктан зур тотулары, сабыр, һәрнәрсәне күтәрә торган, үткен, һәрнәрсәне белергә кабил --- бер табигатьтер.* Г.Газиз. *Г.Исхакый «Җан Шәриф» имзасы белән язучыны кискен тәнкыйтьли, аларның Тукай мәрхүмнең кыйммәтле мәхәббәт хисенә тиешсез кагылуларын, ваксытуларын ачык яза.* Мәдәни җомга

**2.** *и. мәгъ.* Мыскыллау, кимсетеп көлү, хурлау. *Хәзрәт, мыскыллау кебек, үзен ваксыту кебек бер хис астында калды.* Г.Исхакый

**Ваксытып алу** Бераз ваксыту

**Ваксытып җибәрү** Көтмәгәндә, бераз ваксыта башлау

**Ваксытып ташлау** Кинәттән, көтмәгәндә бик каты ваксыту

**Ваксытып тору** Еш, әледән-әле ваксыту

**ВАК ТОВАРЧЫ** *и.* Вак-төяк әйберләр сатучы сәүдәгәр; кырыктартмачы. *Вак товарчы Сафый, аз гына баргач та, сүзне хәзер генә үткән җыелышка борды.* М.Гафури

**ВА́К-ТӨЯК** *с.* **1**. 1) Күләме, микъдары зур булмаган; вак. *Вак-төяк китаплар басылып бетте.* Г.Тукай. *Сайрап торган вак-төяк кошлар туктадылар.* Г.Тукай. *Иртән торгач, ул казан астына вак-төяк такта яргалады.* Ш.Камал. *Иртәгәсен колхоз автобусын белештеләр, Хәернисаның йорт-җирен, вак-төяк кош-кортларын Исламгалигә ышандырып, Әхтәм-Жораны шәһәргә алып киттеләр.* М.Мәһдиев

2) Башкалар белән чагыштырганда, күләме дә, әһәмияте дә әллә ни зур булмаган. *Бу арада кулга төшкән вак-төяк китапларны укып маташам.* Г.Исхакый. *Татар янында сандал һәм вак-төяк нәрсәләр ята.* М.Фәйзи

3) Зур булмаган, күп көч түкми торган, тиз генә эшләнә торган. *Беркөнне колхозның вак-төяк эшләрендә йөрүче корма кызларга бригадир яңа нәрәт кушты.* Н.Гыйматдинова

4) Кече яшьтәге. *Чатыр янына вак-төяк бала-чага җыелды.* М.Фәйзи

5) Түбән яки уртача хактагы, кыйммәте булмаган (гадәттә кечерәк әйберләр турында). *Сабира карчык үлгәч, балалары вак-төяк әйберләрне күршеләргә таратты.* Ч.Әхмәтова

6) *күч.* Җәмгыятьтә дәрәҗәсе түбән булган, зур урын тотмаган. *[Мәхмүт] Үзенең, хәзрәт белән, вак-төяк кешеләр аңламый торган зур мәсьәләләр хакында сөйләшеп утырганын белдерә.* М.Гафури

7) *күч.* Әһәмиятсез, игътибарга алырлык булмаган. *Алар арасында вак-төяк сүз алышудан башка аерым аңлашу булмады.* И.Гази. *Аны вак-төяк эш белән генә берәр җиргә җибәрмиләр.* Р.Мирхәйдәров. *Аның уйларын сизгәндәй, Бәһрәмия дә, балаларга гына вак-төяк сүз катып, тынып калды.* Ә.Баянов

**2.** *җый. и. мәгъ.* 1) Күләме ягыннан чагыштырмача кечкенә, игътибарга лаек булмаган җанлы-җансыз нәрсәләр, бөтен ваклы-төякле кирәк-ярак. *Таза, нык келәтләрдә чәчүлек тә саклана, фураж да, колхоз кирәк-ярагына җыелган башка вак-төяк тә шунда иде.* А.Гыйләҗев

2) Нечкәлек, бик кечкенә ваклыклар, детальләр. *Нури карттан бөтен эшнең вагы-төягенә чаклы сөйләтмәкче була.* М.Гафури. *Димәк, аның белән, ныклап, барлык вак-төякләренә кадәр ачыклап сөйләшергә кирәк.* А.Расих. *Ул [Регина] әтисеннән кызәтүчәнлеккә, вак-төякне хәтердә калдыруга һәм үҗәтлеккә өйрәнгән иде.* Т.Галиуллин

3) Әһәмияте зур булмаган мәсьәлә, эш-хәл, вакыйга һ.б.ш. *Сүзне тормыштагы вак-төякләргә борырга туры килде.* А.Шамов. *Хатынының тормыш вак-төякләре белән борчыганын ул бер дә яратмады.* М.Мәһдиев

**ВАКУОЛЬ** *и. лат.* Күзәнәк протоплазмасында мембрана белән капланган, төрле тупланмалары булган сыекчалы куышлык

**ВА́КУУМ** *и. лат. физ. тех.* 1) Герметик томаланган сыешлык эчендәге газның, гадәттә, махсус насос ярдәмендә сирәкләндерелгән халәте (электр лампаларында, электрон приборларда, химия, азык-төлек сәнәгатендә һ.б. өлкәләрдә кулланыла). *Вакуум буш булмый.* М.Юныс. *Ике-өч секунд эчендә, магнитофон кәтүкләре тыз-быз әйләнеп ала, вакуумда нәрсәдер сызгырып куя, аллы-гөлле лампалар бер янып, бер сүнеп торгалый һәм «Әсле-200» телгә килә.* Ф.Баттал. *Кем булыр икән ул ---? Куышы кипкән үләннәрдәнме, әллә гравитация вакуумыннанмы?* Ә.Гаффар

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса бөтенләй булмавы. *Вакуум юк безнең сафларда:*

*Төркем-төркем дәвамнар килә – Безнең юлда яшь фидакярләр, Алмаш булып, яңалар килә.* Х.Туфан

**ВА́КУУММЕТР** *и. рус* Атмосфера басымы һәм сирәкләндерелгән газ басымы арасындагы аерманы үлчәү приборы. *Вакуумметр белән эшләү*

**ВАКХАНА́ЛИЯ** *и. гр.* 1) Борынгы Рим һәм Грециядә: йөзем үстерү, шәраб ясау һәм күңел ачу тәңресе Вакх хөрмәтенә үткәрелә торган бәйрәм. *Борынгы Рим вакханалияләре*

2) *күч.* Фәхеш һәм бозыклык белән үтә торган эчү мәҗлесе; оргия. *Вакханалияләр тавы эченнән, тантана итүчеләр эченнән, кинәт, кара фикер күтәрелә.* А.Герцен

3) *күч.* Тәртипсез, әхлаксыз тормыш

**ВАКЦИ́НА** *и. лат.* 1) Кеше һәм хайван организмында иммунизация булдыру өчен, микроорганизмнардан яки алар эшләп чыгарган матдәләрдән алып ясалган препарат. *Соңгы елларда вакцинага карата да төрле фикерләр ишетелә.* Ватаным Татарстан. *Хезмәткәрләрнең барысына да грипкка каршы вакцина ясалды.* Ватаным Татарстан. *Америка галимнәре дару һәм вакциналарны организмга медицина энәсеннән башка да кертү юлын тапкан.* Мәдәни җомга

2) *күч. информ.* Нәрсәдән булса да саклану, нәрсәне дә булса булдырмау чарасы. *Вируслардан саклану өчен вакцина программалары*

**ВАКЦИ́НАЛАУ** *ф.* Йогышлы авырулардан саклану һәм дәвалану өчен, организмга вакцина кертү

**Вакциналап бетерү** Тулысынча, барысын да вакциналау

**Вакциналап тору** Даими рәвештә вакциналау

**Вакциналап чыгу** Һәммәсен дә берәм-берәм вакциналау

**Вакциналый башлау** Вакциналау эшенә керешү

**ВАКЦИНА́ЦИЯ** *и. рус* Йогышлы авырулардан саклану өчен ясала торган вакциналы прививка. *Грипкка каршы вакцинация*

**ВАКЦИНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Вакцинация ясау

**Вакцинацияләп бетерү** Тулысынча, барысын да вакцинацияләү

**Вакцинацияләп тору** Эзлекле, даими рәвештә вакцинацияләү

**Вакцинацияләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да вакцинацияләү

**ВАКЦИНОТЕРАПИ́Я** *и. рус* Йогышлы авыруларны дәвалауда вакциналар куллану. *Вакцинотерапия үткәрү*

**ВАКЧЫЛ** *с.* 1) Юк-барга игътибар итүче, вак-төяк өчен ачуланучы, тиргәүче; вак сүзле. *Җитәкче кеше, бәлки, вакчыл да булырга тиештер.* М.Мәһдиев. *Бу Ильясова да бик вакчыл кеше булып чыкты.* М.Маликова. *Әмма характеры начар, холыксыз, үзе бик вакчыл иде.* Х.Камалов

2) Саран, кысмыр. *Фатыйма ханбикәне табынга дәшкәннән соң, Елена Глинская тәмам инанды – Шаһгали ханга ышанырга була: Җангали түгел, үтә ялагай, үтә хөсет, үтә мал ярата, тар күңелле, вакчыл, юк кына бүләккә дә сабый балаларча кинәнә, нарасыйлана, ышана.* М.Хәбибуллин

**ВАКЧЫЛЛАНУ** *ф.* Вакчыл булу, вакчылга әйләнү. *Мәхмүт абзый, вакчылланма, зинһар!* А.Шамов. *Теллетешле түгел, юкка-барга бәйләнми, тырыш, вакчылланып маташмый.* А.Гыйләҗев. *Элек комсомол сафларында торганмы ул, юкмы – вакчылланып тикшерергә вакыт җитмәгән.* А.Гыйләҗев. *Ләкин председатель вакчылланган: Очкынны, идарә сараена алып, бикләтеп куйган иде.* Х.Камалов

**Вакчыллана бару** Торган саен ныграк вакчыллану

**Вакчыллана башлау** Вакчылланырга тотыну

**Вакчыллана төшү** Бераз вакчыллану

**Вакчылланып бетү** Бик вакчыл кешегә әйләнү

**Вакчылланып йөрү** Әле, хәзер вакчыллык күрсәтү. --- *нәрсә укыганга кадәр тикшереп, вакчылланып йөри.* А.Гыйләҗев

**Вакчылланып карау** Бик нык вакчыллану; артык вакчыллык күрсәтү

**Вакчылланып тору** Һәрвакыт, гел вакчыллану. *Пионерның һәр адымын контроль астына алып, тикшереп, вакчылланып торсаң, җиңеннән тотсаң, ул алдан бара алмаячак, алга әйди алмаячак.* А.Тимергалин

**ВАКЧЫЛЛЫК** *и.* Вакчыл булу. *Зөфәр бабай, үзенең үтә вакчыллыгы белән, башкалардан аерылып тора.* М.Гали. *Моңа кадәр мөһим тоелган вакчыллыкларның бәясе төште.* М.Юныс. *Ачу да, үч алырга омтылу да бар иде бу көлүдә, тантанага сусау бар иде, вакчыллык*, *явызлык бар иде.* А.Гыйләҗев. *Яшәү белән үлем арасында эш йөртә торган бу кешеләргә бүтәннәргә гафу ителгән кимчелекләр, ялгыш-хаталар кичерелми, гадәти тормышта була торган вакчыллык, урынсыз шаярулар, уйламый әйткән сүзләр аларга килешми, чөнки без аларга илаһи затка караган кебек карыйбыз.* М.Маликова

**ВАКЫЙГ** *и. гар. иск. кит.* **1.** Чынбарлыкта булган эш, хәл, очрак; чынбарлык

**2. вакыйгда** *рәв. мәгъ. у.-вак. кил.* Чынында, дөресендә. *Ул вакыйгда чын ихласлы бер мөэмин иде.* Г.Ибраһимов. *Иске мәхәббәтләребез искә төшеп, «сөеклем» дип яза башладым. Вакыйгда синң «хыянәтче, алдакчы бер намуссыз» дип [эндәшергә] кирәк.* М.Гафури

**ВАКЫЙГА** *и. гар.* 1) Шәхси яки иҗтимагый тормышта килеп чыккан, истә калырлык эш-хәл, күренеш. *Кронштадка бару – үзе бер онытылмас вакыйга.* С.Сөләйманова. *Экке эшләр министрлыгында көндәлек вакыйгаларны теркәп бара торган кенәгәгә яңа хәбәр өстәлде.* М.Насыйбуллин. *Якташым һәм каләмдәшем белән бәйле берничә вакыйганы бу истәлекләрдә сөйләп бирүне кирәк дип табам.* Г.Ахунов

2) Көтелмәгән, искитмәле хәл. *Бу бөтен район өчен вакыйга булды инде.* М.Вәли-Барҗылы

3) *әд.* Әдәби әсәрләрдә сурәтләнә торган эш-хәл. *Әсәрдә вакыйга сугыш турында бара.* М.Мәһдиев

**ВА́КЫЙГАН** *кер. сүз гар. иск. кит.* Чынлап та, дөрестән дә. *Юлда Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган, минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты.* Г.Тукай. *Вакыйган, бер кешенең корсагының түгәрәклеге өчен, әллә ничә мең кешене алдап тор, имеш!..*

Г.Исхакый. *Һәм дә, вакыйган да, Тургенев китаплары Мансур әфәнденең тамырларыннан йөреп, аны әллә нинди электрикләнгән кебек итәләр.* Г.Исхакый. *Вакыйган, бу вак сәнгатьчеләрнең вә фокараның урамы иде ---.* Г.Гобәйдуллин

**ВАКЫЙГ БУЛУ** *ф. иск. кит.* Чынга ашу; барлыкка килү. *Бу ял бөтен табигатькә ят бер хәл вакыйг булган.* Г.Тукай. *1912 нче елда --- «Вакыт» белән «Йолдыз» мөхарәбәләре вакыйг булды.* Г.Тукай

**ВАКЫЙФ** *с. гар. иск. кит.* Нәрсәне дә булса аңлаучы, төшенүче, нәрсәдән булса да хәбәрдар. *Толстой әсәрләренең дә хәзер дөньяда бик куәтле бер [мәктәп] тәрбия иткәнлеге [дөнья халләреннән] вакыйф һәркемгә мәгълүмдер.* Ф.Әмирхан

**ВАКЫЙФ БУЛУ** *ф. иск. кит.* 1) Аңлау, төшенү, белү. *Моңарчы хикәяләрдә генә укыган бу як тормышын үзем күрәм, үзем, аралашып йөреп, күп кенә серләренә вакыйф булам.* М.Фәйзи

2) Дучар булу. *Җәләлов, чын вакыйф булдың әсирлек хәленә.* Ш.Бабич

**ВАКЫТ** *и. гар.* **1**. 1) Фәлсәфи яктан караганда, материя яшәешенең объектив формасы. *Илләр беткән җирдә, телләр беткән, Халык булып, беткән халыклар. Ул бетмәгән: Вакыт төпкеленнән Һаман өскә, өскә калыккан.* Х.Әюп. *Зәйнәп сарайларының җимерекләре мине хәйран калдырды, зиһенемне алды, рухымны дер селкетте. Монда Адәмнең иҗат куәте белән Вакытның җимерү кодрәте арасында меңәр елдан артык алыш, Фанилык белән Мәңгелек арасында өзлексез кыйралыш барган.* М.Кәрим

2) Яшәешнең гасыр, ел, тәүлек, сәгать, минут һ.б. белән исәпләнгән дәвамлы аралык кисеме, мизгеле һәм аларның бер-бер артлы алмашыну процессы. *Менә шул вакыттан игътибарән безнең тормышыбызда бертөрле үзгәрү сизелә башлады.* Ш.Камал. *Кышкы нардуган башы шулай ук кышкы чиллә, ягъни иң суык кырык көнлек (25 декабрь – 5 февраль) вакытның да башы булган.* Р.Әхмәтьянов. *Мәгълүм булганча, Казан Кремлендәге Сөембикә манарасы, хәзерге вакытта, вертикаль сызыктан 1 метр 75 сантиметрга авышкан.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

3) Яшәеш дәвамлылыгын үлчәү берәмлеге. *Мәскәү вакыты. Җирле вакыт. Кичке эңгер вакыты. Ахшам вакыты*

4) Берәр эш, вакыйга белән бәйле чак; нинди дә булса күренеш, хәрәкәт, эшчәнлек өстенлек иткән заман. *Чөнки караңгы әле, сәгать дүртләр чамасы гына. Халыкның иң тәмле йокы вакыты.* В.Нуруллин. *Миңа бит, судта җәмәгать гаепләүчесе булып чыккан вакытта, --- хатны файдаланырга кушып биргәннәр иде.* Г.Минский. *Гатият абзый авылның җәй көнен, аның да көтү кайткан вакытын бик ярата...* М.Мәһдиев. *Тау битләрендә умырзаялар бөгелеп утырган вакыт.* Н.Измайлова

5) Берәр нәрсә эшләр өчен мөмкинлек биргән уңайлы чак, момент, мизгел; форсат, җай, очрак. *Кара аны, --- вакытны ычкындырма, берәр көн алданрак барып күр.* Г.Минский. *Безгә уңайлы вакыттан файдаланып калырга кирәк.* А.Расих. *Ул Нәфисәдән нидер көтә, ниндидер сер әйтәсе бар кебек, җайлы вакыт чамалап йөри.* Г.Бәширов

6) Кешелек җәмгыятендә, ниндидер дәүләт, халык яки аерым кеше тормышындагы билгеле бер мөһим чор, дәвер. *Әйтегезче, зинһар: шуларга хаким булган вакытымда, бөтен дөньяның падишаһлары минем каршымда чүп булып калмыймы соң?..* Г.Рәхим. *Безнең сабый күңелләргә бер генә көн дә шатлык китермәде. Балалык вакытының очы югалды.* М.Мәһдиев

7) Елның, тәүлекнең билгеле бер өлеше. *Икенде вакыты җиткәч, кояш баюга якынлашкач, --- [әсирләрне] таш зинданга бикләделәр.* Ш.Мөхәммәдев. *Аның хезмәте өчен иң кыйммәтле вакыт – иртәнге һәм көндезге сәгатьләр иде.* Г.Кутуй

8) Берәр эш, шөгыль, гамәл өчен билгеләнгән срок. *Тар гына вакыт эчендә, эзләгән нәрсәң табылмыйча, һич уйламаган нәрсәләр килеп чыгуга инде күнегелгән.* И.Абдуллин. *Кандидатлык диссертациясен язар өчен бирелгән вакыт узса да, эштә күренми.* К.Латыйп. *Вакыт җитми чәчәк атмый Бакчадагы гөлләр дә.* Җыр

9) Төп эштән тыш, башка төрле шөгыльгә бирелгән буш ара. *Рәхим, шундый [вакыттан дөрес файдалану турындагы] уйлар белән дәртләнеп, һәрбер буш вакытын [фәнни] эшенә бирде.* А.Расих. *Гәүһәрнең тагын ике сәгатьләп вакыты бар иде, туп-туры Галимҗан абыйларына китте.* Г.Әпсәләмов. *Минемише бала-чага белән аралашырга аның вакыты-җае да булмагандыр инде.* К.Миңлебаев

10) Елның берәр эш өчен уңайлы чагы, нинди дә булса эш өсте; сезон. *Печән вакыты җитте.* Ш.Камал. *Җиләк-җимеш җыю вакыты. Ау вакыты башланды*

11) **вакыты** *тарт. форм.* Берәр төрле эшнең башкарылырга тиешле чоры; срок. *[Чәчәкләрнең] Кыңгыр салган чалмаларында ниндидер моңсулык бар. Вакыты җиткәч, өзми дә чараң юк шул.* Г.Әпсәләмов. *Әллә, көне җитмичә кош сайрамый, дигәндәй, вакыты җитмичә, бу уйлар да кешенең башына килмиме?* Г.Әпсәләмов

12) Нинди дә булса эш-хәрәкәтне башкаруда билгеле бер эзлеклелек, чират. *Гаҗәп шул. Бөек әсәрләр, миңа калса, галәм белән бергә яралган да дөнья күрергә үз вакытын, үз чиратын көтеп яткан.* М.Кәрим

13) Гомер, гомернең бер өлеше. *Бер сәгать, ике сәгать, өч сәгать яттым. Вакыт бик акрын уза, минем өчен исә барыбер иде.* Г.Рәхим. *Озак вакытлардан соң, картайган егет булып, авылга кайттым.* М.Мәһдиев. *Вакыт агышы сизелми дә үтә икән. Алмазның вафатына да биш ел үткән, әле кичә генә кебек иде, югыйсә.* Мәдәни җомга

14) Хат, документ, шигырь, хикәя һ.б.ш.ларның язылу, иҗат ителү моментын күрсәткән билге; тутыру көне; дата. *Җыентыкка кергән җырларның берсенең дә җырлану, күчерелү вакытлары юк.* М.Җәлил

**2.** *хәб. функ.* Берәр эшне үтәү, башкару моменты җитүне белдерә. *Ну,*

*Җәгъфәр, мин озак утырдым --- кайтырга вакыт.* Г.Әпсәләмов. *Бәйдән ычкынырга вакыт инде безгә, вакыт-вакыт...* В.Имамов

**3.** *бәйл. функ.* 1) Нинди дә булса эшхәлнең, күренешнең срогы ягыннан чиген, чикләнүен белдерә; ара. *Мин тагын әллә никадәр вакыт йокылы-уяулы яттым.* Г.Рәхим

2) **вакытта** *у.-вак. кил.* Нинди дә булса эш-хәлнең, күренешнең шарт мәгънәсен белдерә. *Аем туры баккан вакытта – йолдызларга йодрык.* Мәкаль

3) Берәр эшне үтәргә комачаулаган кире сәбәпне белдергән сүзне шул сүзгә караган җөмлә кисәгенә бәйләп килә; урынына. *Мәсҗед карты булып йөрер вакытымда кире дөньяга керешергә туры килә инде.* М.Гафури

◊ **Вакыт җитми үлү** Вакытсыз, вакытыннан элек, иртә үлү. *Ялгыз картлык – вакыт җитми үлүгә тиң икән ул, Галиулла балам.* Н.Хәсәнов. **Вакытны тиз тоту** 1) Эштә темп саклау; 2) Вакытны бушка уздырмау. **Вакыт(ны) оту** 1) Вакытны дөрес итеп бүлә белү, вакытны уңышлы файдалану. *--- аның, һәрвакыт, инде легендага әйләнгән трубкасы белән мәшгуль булуы да – фикер юклыгын яшерү, вакыт оту өчен бер хәйлә генә.* Т.Мөбарәков; 2) Вакытка экономия ясау. **Вакыт сыйдырганча** Нәрсә дә булса эшләргә вакытын бүлә алганча, вакыты булганча. *Гомумән, ул Газинурны ярата, аны һаман күзәтә, әледән-әле үзе янына чакырып яки правлениедә, клубта, кырда, абзарда очратып, аның белән вакыт сыйдырганча сөйләшә, аңа үзенең киңәшләрен бирә иде.* Г.Әпсәләмов. **Вакыты белән** 1) Вакыты җиткәч, үз вакытында; кайбер вакытта, кайчакларда. *Кыен булсын, хәтта, вакыты белән, нужа да күрсен.* Г.Бәширов. *Үз язганыма, вакыты белән, үзем дә икеләнебрәк карыйм.* М.Кәрим; 2) Кирәк булганда, кирәге чыкканда, кирәкле урынында. *Вакыты белән җитди була алу. Вакыты белән кызык сүзләр сөйләү.* **Вакыты җитеп** Картаеп, олы яшькә җитеп, яшен яшәп. *Ул, бичара, вакыты җитеп, гыйбадәтен кылып, намазлыгы өстендә үлде, дип әйтерлек, һаман изгелек кылып үлде.* М.Гафури

**ВАКЫ́Т-ВАКЫТ** *рәв.* 1) Ара-тирә, кайбер вакытта, кайчакта, кайвакыт. *Җәгъфәр, бер сүз әйтмичә, ашамыйэчми чыгып китте. Ул да ябыккан, Гәүһәр аны вакыт-вакыт кызганып та куя иде.* Г.Әпсәләмов. *Вакыт-вакыт, йокы белән аңгырайган акыл саташып куя.* Н.Гыйматдинова

2) Әледән-әле, еш кына. *Тегермәнче улактан аккан онны, вакыт-вакыт, учына алып карый, бармаклары белән уа һәм ике таш арасына коелган орлыкның күләмен, тизлеген көйли.* М.Мәһдиев. *Кап-кара күктә, вакыт-вакыт, яшькелт ялтыраулар хасил була.* Г.Әпсәләмов. *Бу сагыш, вакыт-вакыт, Бибинур апалар өендә дә кабынып китә торган иде.* Г.Ахунов

**ВАКЫТЛЫ** *с.* **1**. 1) Билгеле бер вакыт кысаларында, чикләнгән вакыт аралыгында бара, хәрәкәт итә, исәпләнә яки кулланылышта була торган; *киресе*: **даими**. *Янар таулар көчле – Җирне тетрәтәләр, Тик вакытлы алар – сүнәчәк.* Ф.Кәрим. *– Бернинди табышу, пар килү юк. Фәгыйлә бездә болай гына – вакытлы фатирчы булып кына тора, – дип, акрын гына әйтеп куйды [Шакирҗан].* С.Сабиров

2) Уза торган, үтә торган, тиз үтеп китәчәк. *Без ул чакта күңелләребез белән сизә идек, болар – вакытлы адашулар, болар – акыл җитмәүдән.* М.Мәһдиев. *Болар – әле вакытлы кыенлык, вакытлы газап, вакытлы ачлык.* М.Мәһдиев. *Җәгъфәр белән ара көннән-көн катлаулана, кискенләшә барса да, Гәүһәр һәлакәт киләсенә һич ышанмый иде. Кайгырса да, газапланса да, боларны вакытлы бер чир итеп карый.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Билгеле бер срокка кадәр, вакытлыча. *Майор янә, улларын күрү куанычын уртаклашып, берничә җылы сүз әйтә, күрешүнең бик кыска вакытлы булуына тәәссеф белдерә.* Ә.Еники. *Кавышу һәм вакытлы аерылып тору ---.* Н.Исәнбәт

2) Соңга калмыйча, үз вакытында; кирәк вакытта. *Киләләр бугай, ярый, бик яхшы, бик вакытлы киләләр.* Г.Камал. *Бик вакытлы – җинаять өстендә капты кулга.* Ә.Баян. *Әтисе кызын үз янына бик вакытлы алдыра.* Мәдәни җомга

3) Төгәл билгеләнгән тәртип белән, режим буенча. *Вакытлы ятып, вакытлы йоклап, вакытлы торганга күрә, ул бүген үзендә --- башка көннәрдәгедән аерым, җиңелчә генә бер көч сизә иде.* Ф.Әмирхан

**ВАКЫТЛЫ́-ВАКЫТСЫЗ** *рәв.* **1.** 1) Кирәкле-кирәксез вакытта, тиешсез чакта, теләсә кайчан. *[Әхмәтсафа агай] Угылы Хәсәншага һәм приказчикларына, вакытлы-вакытсыз шәһәргә чыгып, эшсез, анда-монда йөрергә рөхсәт бирми торган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Нинди сессия ул, нигә, вакытлы-вакытсыз, ферма турында сүз кузгатасыз?* Ә.Еники

2) Көтмәгәндә, искәрмәстән; җайсыз вакытта. *Гармунда хәзер үк уйнап карыйсы килсә дә, Мөнирҗан тыелырга мәҗбүр булды: вакытлы-вакытсыз кычкыртканны яратмаслар йә бөтенләй яшереп куярлар.* Н.Әхмәдиев. *[Доцент Янгура] --- болай вакытлы-вакытсыз борчуы өчен бик түбәнчелек белән гафу үтенгәннән соң, шаян тонга күчеп: --- – Кич өйдә булырсызмы, кунакка барам, – диде.* Г.Әпсәләмов

3) Тиешсезгә, урынсыз яки мәгънәсез рәвештә. *Шунда Факлә апа, тота да, кычкырып, такмак әйтергә тотына яки, вакытлы-вакытсыз, кодакодагыйларны мактап алып китә.* Н.Измайлова

**2**. *с. мәгъ.* Кирәк булмаган, артык, урынсыз. *Хәзер инде вакытлы-вакытсыз явымнарны көт тә тор.* Ш.Камал. *Ташлагыз әле шул вакытлы-вакытсыз шаяруларыгызны.* И.Гази

**ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ** *и.* Билгеле бер вакыт арасы эчендә кабатланып чыга торган, көндәлек вакыйгаларны чагылдырып барган газета һәм журналлар. *1905–1907 елгы беренче Русия революциясе тәэсирендә барлыкка килгән вакытлы татар демократик матбугаты, үзенең беренче адымнарыннан ук, полиция һәм цензураның өзлексез эзәрлекләүләренә юлыга.* Р.Әмирхан. *[Тинегин] Баш идарәгә, вакытлы Ка-*

*зан матбугат комитетын биш кешедән төзү турында, «кыю» проект тәкъдим итә.* Р.Әмирханов. *Русиядәге беренче халык революциясе елларында, массаларның хәлиткеч көрәше нәтиҗәсендә, милли телләрдә вакытлы матбугат ачу мөмкинлекләре туа.* Иманга тугрылык

**ВАКЫТЛЫ́ЧА** *рәв.* 1) Билгеле бер вакытка (срокка) кадәр. *Вакытлыча гына озата барам, диеп, Минем йөрәгемә ут салма.* Җыр. *Җәгъфәр хатынына икенче тәкъдим ясады, --- әллә вакытлыча эштән китеп торасыңмы? Ял да итәр идең...* Г.Әпсәләмов

2) Бераз, аз гына. *Гөлбану карчык исә, кызы кайтуы шатлыгыннан, Рәүф семьясындагы бәрелешләрдән, вакытлыча булса да, читкә китә.* Г.Нигъмәти. *Кайбер нәрсәләрне вакытлыча үзгәртсә дә, актыктан, барыбер, иске эзгә кайтачак.* Г.Әпсәләмов

**ВАКЫТСЫЗ** *с.* **1**. 1) Буш вакыты булмаган; тыгыз. *Бакчы, уенын башлаган, күңелен биргән курчагына, Күр бәхетсезлекне, тап килдем вакытсыз чагына.* Дәрдемәнд

2) Урыны яки вакыты уңайсыз булган, көтелмәгән, беркемне дә күрәсе килмәгән. *Бик вакытсыз чакта Нургалинең күзенә күренде бу Сөләйманов.* Ә.Еники

3) Вакытыннан элек булган, бик иртә, яшьли. *Өзелеп яраткан иреннән, шулкадәр шәфкатьсезлек белән, вакытсыз аерылып калган яшь хатынның күзенә йокы керми, ул яткан урынында борсалана иде...* М.Әмир

4) Үз вакытына туры килмәгән, бик соң я бик иртә; гадәттәгедән кичеккән, соңга калган яки алданрак булган. *Вакытсыз азан әйткән мәзиннәр яисә вакытсыз чиркәү каккан звонарьлар була инде.* Г.Тукай. *Вакытсыз йөрүченең аяк тавышын сизеп, ферма эте Сатурн кабаланып өрә башлады.* Ф.Хөсни

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Соңлап, тиешле вакыттан кичегеп. *Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?* Г.Тукай

2) Вакытыннан элек, яшенә туры килмичә. *Вакытсыз тирәнәйгән сызыклар – аның иреген буган чәнечкеле тимерчыбыкларның каһәрле шәүләсеннән уелып калган яра истәлек кебек.* М.Галиев. *Вакытсыз гүргә керү. Кайгы кешене вакытсыз картайта*

3) Билгеләнгән, тиешле вакытыннан узып, үз вакыты җитмичә. *Вакытсыз чәчәк атмый, үстергән гөлләрең дә.* Җыр

◊ **Вакытсыз чак (вакыт)** Кеше кабул итми торган чак, тыгыз эш яки ашау-эчү, ял-йокы вакыты. *[Гайни:] Бу вакытсыз вакытта кем йөри, дисәм, син икәнсең әле.* Г.Камал

**ВАКЫТТАГЫ** *с.* Билгеле, алда әйтелгән вакытта була торган, шул заманга, чорга караган. *Ул вакыттагы тәртипләр буенча, ашау өстәлендә үзең алып кергән җиләк-җимеш, боржоми, шәраб, чикләвек һәм затлы коньяк тора иде.* М.Мәһдиев

**ВАКЫТТАГЫ́ЧА** *рәв. сөйл. Бу, шул, ул, теге* һ.б.ш. алмашлыклар белән килеп, эш-хәрәкәтнең, хәлнең контекстта әлеге алмашлыклар белдергән вакыт аралыгына туры килүен аңлата. *Әйдә, белсеннәр, авылга бит Зәкәрҗан кайтты. Кайтты, ул вакыттагыча җәяү түгел, ә үз хутына, мотоциклга утырып.* М.Мәһдиев

**ВАКЫТ ХӘЛЕ** *и. грам.* Процессның үтәлү вакытын яки билгенең булу-булмау вакытын белдерә торган кисәк

**ВАКЫ́ТЧА** *рәв. к.* **вакытлыча.** *Зәйнәп инде – әүвәлге Зәйнәп түгел, күңеле тәмам сүнгән, --- вакыт җитеп үлмәгәнгә күрә, вакытча бу дөньяда тора иде.* М.Гафури

**ВАКЫТЫ-ВАКЫТЫ** *рәв.* Кайвакыт, кайчакта, еш кына; ара-тирә. *Әниләре үлгәннән соң, Бибисара (алма апа) күбрәк – Мифтахетдин абый йортында, ә Мөхәммәткәрим абый нигез йортта һәм, вакыты-вакыты белән, Кыйгазытамакта яшәүче туганнарында тәрбияләнгәннәр.* Г.Гыйльманов. *Вакыты-вакыты белән, алардан [балалардан] туйганчы көләсең, вакыты-вакыты белән, бик тирән уйга каласың.* Г.Әпсәләмов

**ВАКЫТЫНДА** *рәв.* 1) Кайчандыр, билгесез бер вакытта; элек. *Вакытында бу җирләрдә сазлык булган*

2) Тиешле, кирәкле вакытта (сәгатьтә). *Бу кешеләр Габдулла Тукайның Олы Мәңгәргә килүе хакында кызыклы истәлекләр сөйли торган булганнар, ләкин, вакытында язылып алынмыйча, онытылганнар.* М.Әхмәтҗанов. *Инде бүген вакытында кайтам, дип, кабинетыңнан чыгып барганда, гафу итегез, бер генә минутка, дип, берәрсе килеп керә дә бөтен планыңны боза да куя.* В.Нуруллин. *Ул [Гәүһәр] авырсынмый укый, --- имтиханнарын берсе артыннан берсен вакытында бирә бара.* Г.Әпсәләмов

3) Иң кирәкле вакытта, моментта (көтелмәгән хәл булганчы). *Мисбах, басма аркылы чыкканда, суга егылып төшә язды. Ярый әле арттан килүче сержант Морозовның көчле куллары аны вакытында тотып калды.* Г.Әпсәләмов

**ВАКЫФ** *и. гар.* 1) Мөселманнарда: дәүләт яисә аерым затның, дин үсешенә ярдәм итү максатында, иганәчелек рәвешендә тапшырган яисә васыять иткән күчемле һәм күчемсез милке. *Вакыф сыйфатында бирү өчен, милекнең – хәләл, хуҗасының аңа ия булуы, аның табыш китерә алуы шарт.* Татар энциклопедиясе. *Вакыф, әлешчә, татар җәмгыятендә дини оешмаларның, уку йортларының чикләнгән яшәү чыганагы булып торган.* Мәдәни җомга

2) Шул мөлкәт белән эш итүче фонд, рәсми оешма. *1917 елда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә вакыф бүлеге оештырыла.* Мәдәни җомга. *Моннан унбиш еллар элек, Төркиягә баргач, мин анда төрле вакыфлар, фондларның күплегенә гаҗәпләнгән идем.* Идел

**ВАЛ** I *и. нем.* Дошман явыннан саклану өчен яки хуҗалык максатларыннан чыгып, туфрак өеп ясалган озын һәм биек ныгытма, туфрак өеме; ур. *Унбиш, ә урыны-урыны белән утыз-кырык метр биеклегендәге валлар, меңнәрчә километрларга сузылып, бу илләрне диңгез китерүе мөмкин булган һәртөрле афәтләрдән саклап торалар.* Х.Ярми

**ВАЛ** II *и. нем. тех.* Төрле механизмнарның әйләнә торган өлешен тотып торган деталь; күчәр, әйләнмәле үзәк. *Тракторның нииндидер валы ычкынган икән, валның башындагы тишеккә*

*Сәхия алып килгән дага кадагы кереп ипләнде.* Ф.Яруллин. *Шундый ашыгыч кирәк булган бөлү валлары кайтып өлгермәде.* Ә.Еники. *Ахырда, бөлү валларын Казаннан сората башлыйлар. Вәгъдә тиз килә, ләкин валлар үзләре, шушы көнгә кадәр, һаман килеп җитә алмыйлар.* Ә.Еники

**ВАЛЕНТЛЫК** *и. нем.-тат. хим.* Берәр атомның билгеле бер сандагы башка атомнар белән химик бәйләнешләр хасил итү үзлеге. *Метанда углеродның валентлыгы дүрткә тигез*

**ВАЛЕРИА́Н(А)** *и. фр.* 1) *биол.* Валерианачалар семьялыгыннан, туры сабаклы, озынлыгы ике метрга кадәр биеклектәге, тамырлары шифалы күпьеллык үләнчел үсемлек; песи үләне. *Ә теге «мәче ярата торган» үләннең нәрсә икәнен мин 30–40 еллардан соң гына белдем. Мәрфугатти валериан үләнен җыйган икән.* М.Мәһдиев. *Татарстан Республикасы территориясендә дару валерианасы урман буйларында, сазлык, елга һәм күл ярларында үсә.* Мәдәни җомга. *Валериана Ерак Төньяктан һәм чүлләрдән башка һәр җирдә үсә*

2) *мед.* Шул үсемлек тамырыннан ясалган дару. *Ул, ашыга-ашыга, стаканга валериан тамчысы тамызды да тизрәк эчеп җибәрде.* Н.Дәүли

**ВАЛЕРИА́НКА** *и. рус сөйл. к.* **валериан(а).** *Валерианка гына тота идем. Кайчакны тынычлану өчен...* Э.Касыймов

**ВАЛЕРЬЯ́Н(А)** *и. рус к.* **валериан(а)**

**ВАЛЕРЬЯ́НКА** *и. рус сөйл. к.* **валериан(а)**

**ВАЛЕТ** *и. фр.* Уен карталарында: унлык белән дама арасындагы егет рәсеме ясалган карта; сурәтле уен карталарының иң кечкенәсе. *Үтте, юнкер, фартлы заманың, Кызыл валет яба даманы!* Х.Туфан. *Мин крест тугызлысы. Минә сиңа валет, аны баса.* Г.Гомәр

**ВАЛИ** *и. гар.* Өлкә, губерна, вилаять башлыгы, губернатор. *Күп валиләр ярышты, Манифестка карышты.* Г.Камал

**ВАЛИДОЛ** *и. лат. мед.* Кан тамырларын киңәйтеп, йөрәкне тынычландыра торган дару

**ВА́ЛИК** *и. рус* 1) Кечкенә вал II. *Булатов матрицаны валикка беркетеп, буяулап алды да аяк машинасын әйләндерә башлады.* Ш.Маннур. *Валик белән түшәмне буяу*

2) Диван яки тахтаның ике башына куела торган озынча түгәрәк мендәр

**ВА́ЛЛА(Й)** *ы. сөйл. к.* **валлаһи.** *Җанашым, бәгырькәем, валлай, мин сине ташламам.* А.Расих

**ВА́ЛЛАҺ** *ы. гар. сөйл. к.* **валлаһи.** *Үзе бик сөядер, валлаһ.* Г.Кандалый

**ВА́ЛЛАҺИ** *ы. гар.* **1**. 1) Нәрсәнең дә булса чынлыгына, дөреслегенә ышандырып әйтелә торган ант сүзе. *Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи, Бәхте барлар, кырда җәйли, валлаһи!* Г.Тукай. *[Гәүһәр] Уй-сагышка чумып утыра, кемнедер юксынамы, болай кайгысы бармы – менә канаты сынган кош диярсең, валлаһи.* Г.Әпсәләмов. *Валлаһи менә, билләһи. Көннең йөзен күрмим. Кесәмдә сукыр бер тиен дә юк.* Ш.Усманов. *Эч поша, йөрәк яна ---. Ә син шул чакта йөгерергә, сикерергә, бөгелергә, сыгылырга тиешсең. Мәгънәсезлек, валлаһи!* Ә.Еники

2) Берәр нәрсә эшләмәскә сорау, ялвару, үтенү сүзе. *Җизни --- валлаһи, әйтмә, мин, әйтсәң, дөнья туздырып елыйм.* Г.Ибраһимов. *Аңлатып әйт, валлаһи, нинди эш соң ул? Кулга тотып, эш эшләрлекмени без хәзер?!* Идел

**2**. *и. мәгъ.* Ант, катгый вәгъдә. *Хөкем вакытында, Чалудан китерелгән шаһитләрнең күрсәтүе, Минтукның «валлаһие» нигезендә булган бер карар кабул ителә.* К.Миңлебаев. *Синең валлаһиеңа ышануы авыр*

◊ **Валлаһе әгъләм** *гар. дини* Гарәпчәдән, Аллаһ кына белә, иң белгәне – Аллаһ, дигән мәгънәдә; бер-бер эш я бер-бер сүзнең төбе дөресме, барып чыгармы-юкмы – ансын Аллаһ белсен, дигән мәгънәдә. *Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм, Кырылмасмы вавы, валлаһе әгъләм?* Г.Тукай. **Валлаһи әгәр** 1) *дини* Әгәр әйткән сүзем дөрес булып чыкмаса, дип, үзенә яманлык теләп каргану. *Валлаһи әгәр, икмәкнең бөртеген күрергә мохтаҗ булыйм*; 2) Әгәр дә сине ышандырырга Аллаһ белән ант кына җитмәсә, дип, элекке мәҗүси иляәрне дә кушып каргангандa әйтелә. *Валлаһи әгәр, кызарып чыккан кояштыр, торган җиремдә җир упсын!* **Валлаһи газим** *дини* Олуг Аллаһ исеме белән, дип, гарәпчә ант итү. *Тыңлыйсыңмы, валлаһи газим, хәзер алып китәм үзем.* Г.Тукай. *Валлаһи газим, дип әйтәм, сезгә караганда күбрәк файда бирер идем.* М.Әмир. *Валлаһи газим, шулай итәм дә. Әнә үгезләрен үзе карасын, хәләл көчкәйләрем җилгә очса очар...* Н.Измайлова

**ВАЛЛОТА** *и. лат. биол.* Амариллисчалар семьялыгыннан, ак яки куе кызыл төстәге чәчәкләре туры торучан, суганчалы, яктылык яратучы үләнчел үсемлек. *Валлота Татарстан Республикасында декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә, җәй ахырында, көзен чәчәк ата.* Мәдәни җомга

**ВАЛОКОРДИН** *и. лат. мед.* Нервларны тынычландыра торган йөрәк даруы

**ВАЛТО́РНА** *и. нем. махс.* Бөрәнкәсыман киңәйгән авызлы, спираль рәвешендә бөгелгән җиз көпшәле, йомшак тавыш чыгара торган тынлы музыка коралы. --- *Саба якларыннан Чистайга килеп «адашып» калган чибәр, уңган кыз, эти-әнисен, туган ягын, тынлы оркестрда, валторнада уйнап йөргән үсмер чакларын сагынуга түзә алмыйча, бөтен хисләрен, сагышларын, --- шигырь юлларына сала башлый.* Ф.Тарханова

**ВАЛТОРНАЧЫ** *и.* Валторнада уйнаучы музыкант

**ВАЛУ́Й ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Ал гөмбәләр ыругыннан, шартлыча ашарга яраклы эшләпәле гөмбә. *[Валуй гөмбәсе] Дымлы һавада – лайлалы, корыда ялтырап тора.* Биология

**ВАЛУН** *и. рус* Зур йомры таш, тау токымы ватыгы; сарыкташ. *Бу юлны үтәр өчен, валуннарны шартлатырга яки күтәреп ташларга кирәк.* Г.Әпсәләмов. *Иптәшләре яр буендагы зур валуннар артына йөгерделәр, Хисмәт алардан чокырда аерылып калды һәм, берзаман, аңын югалтты... Икенче көнне Хисмәт, валуннар арасыннан, шуышып, диңгез буена килде.* М.Мәһдиев

**ВАЛЧЫК** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса вак, вакланган бөртеге. *Хәдис шәрифтә: «Төшкән икмәк валчыкларын ашаган тарлык күрмәс һәм балалары ахмак булмас» [диелә].* Мөселман гаилә календаре

2) Берәр каты әйбердән кителеп төшкән кыйпылчык, ватык. *Идәндә чәчелеп яткан кара валчыклар – «Комсомолка Гөлсара» дигән җыр кисәкләре булып чыга, [Марва]---, шыңшый-шыңшый, пластинка ватыкларын җыйды ---.* Ә.Баян. *Чүлмәк валчыгы*

3) *күч.* Аерым җәмгыять, сыйныф, ил яки нәселнең аңа гына хас үзенчәлекле сыйфатларын туплаган бер вәкиле. *Минем бөтен теләгем --- Майсәрәне аерып калдырмау иде. Чөнки Майсәрәнең әтисе валчыгы булуын, табигате, характеры белән атасына охшаганын да яхшы белә идем.* Ф.Сәйфи-Казанлы

4) *күч.* Бала, нарасый, сабый. *Әле генә күрдем, Миус буенча агып китте минем Наташенькам ... Әйдәгез, алыйк аны – баланы, әрәм итмик валчыкны.* Ф.Хөсни

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса бер өлеше, кисәкчеге. *Мин – аның туган иленең бер валчыгы бит.* И.Гази. *Әтисенә җан җылысы, яшәргә көч биреп торган, аның өчен Ватанның бер сөекле валчыгы, сагынмалыгы булган, күренекле профессор-тюрколог Сәгадәт Чыгатайның хезмәтләрен тәрҗемә итә башларга иде.* Мәдәни җомга

6) *күч. сөйл.* Бик кечерәйтеп яки азайтып сурәтләү образы

◊ **Валчыгын да калдырмау** Берәр нәрсәне бөртеген дә калдырмыйча ашап бетерү. **Валчык та капмау** Бөтенләй дә, бернәрсә дә ашамау. *Гәүһәрнең иртәдән бирле бер валчык та капканы юк, нибары бер стакан чәй генә эчкән иде.* Г.Әпсәләмов

**ВА́ЛЬДШНЕП** *и. нем. зоол.* Шөлдиләр семьялыгыннан, озын, көчле томшыклы, урман зонасында, сазлы урыннарда яши торган кош; урман шөлдие. *Саклагыч төсе вальдшнепны дошманнарыннан саклый.* Биология

**ВАЛЬС** *и. фр.* 1) Өч ритмлы, салмак кына әйләнеп барудан гыйбарәт парлы бию. *Әйдә, дуслар, вальс биик, ардырмыйк гармунчыны.* Җыр. *Ул --- вакыты белән – салмак кына, ә вакыты белән бөтерелеп-бөтерелеп, вальс әйләнде.* Р.Кәрами

2) Шул биюнең көе. *Хәби һәркөнне «На сопках Маньчжурии» вальсын җырлый – көнчыгыш тарихы аңа аеруча якын, аның яшьлеге Владивостокта, Порт-Артурда узган.* М.Мәһдиев. *Баянист Миша, көндәлек гадәтенчә, ял итүчеләрне иртәнге физзарядкага чакырып, беренче вальсны уйнап җибәрде.* Ә.Еники

**ВАЛЬЦО́ВКАЛАУ** *ф. тех.* Нинди дә булса әйберне (мәс., тимерне) берберләренә тиеп әйләнә торган цилиндрсыман валлар арасыннан үткәреп җәю

**ВАЛЮ́ТА** *и. ит.* 1) Берәр ил акча системасының нигезе, илдәге акча берәмлеге (мәс., *Грециядә – евро, Япониядә – иена*). *Төркиянең милли валютасы – төрек лирасы.* Мәгърифәт

2) Билгеле бер илнең акча системасы төрләре (*кәгазь акчалар, алтын һәм көмеш*)

3) Гадәттә чит илләрнең халыкара исәп-хисапларда файдаланыла торган акча берәмлекләре, шулай ук кредит һәм түләү средстволары (вексель, чек). *--- тансык һәм кадерле сәфәр иде бу. Аның кадере шунда: гастроль көннәре өчен бирелә торган тәүлеклек акча – шул илнеке, ягъни валюта белән түләнә иде.* Р.Вәли. *Сумның чит ил валюталарына карата нисбәтен Россия Федерациясенең Үзәк банкы билгели, һәм валюта бәясе, бюллетеньнәр аша, даими рәвештә хәбәр ителеп тора.* Мәдәни җомга

4) *күч.* Илнең эчке һәм тышкы базарында товар алмашуда акча функциясен үти алырлык теләсә нинди товар. *Тыелган эчемлек «сыек валюта»ны аңа базадан, Минзәләдән яисә Удмуртиядән машинасы белән китереп бирделәр.* Я.Шәфыйков

**ВАЛЮ́ТА КЕРЕМЕ** *и.* Бүтән илләргә товарлар сатудан, хезмәт күрсәтүдән кергән һәм, шулай ук, халыкара кредит итеп алынган чит илләр валютасы; *русчасы:* **валютная выручка**

**ВАЛЮ́ТА КУРСЫ** *и.* Илдәге акча берәмлегенең башка илләрнең акча берәмлекләре белән чагыштырма бәясе; *русчасы*: **валютный курс**. *Валюта курсын билгеләү, гадәттә, валюта биржаларының махсус комиссияләре тарафыннан тормышка ашырыла*

**ВАЛЮ́ТА КЫЙММӘТЛӘРЕ** *и.* Чит ил валюталары белән исәпләнә торган кыйммәтле кәгазьләр, кыйммәтле металлар, затлы табигый ташлар кебек хәзинәләрне аңлаткан икътисади төшенчә; *русчасы:* **валютные ценности**

**ВАМПИР** *и. нем. миф.* 1) Славян һәм алман халыкларында, имештер, йоклаган кешеләрнең канын суыру өчен, кабердән чыгып йөри торган мәет

2) Кеше энергиясен суырып яши торган кеше. *Вампирлар электромагнит кырлары көчле булганда гына үзләрен кеше итеп сизәләр. Әгәр ул көч үзләрендә кими башласа, аны бүтәннәрдән, ягъни мәсәлән, донорлардан алалар.* Т.Миңнуллин. *Хуҗа, лып итеп, кәнәфиенә сеңде: «Вампир, убыр икән, мылтыкны гына түгел, хәлне дә суырды».* Т.Галиуллин

3) *зоол.* Кулканатлылар отрядына караган ярканатның бер төре. *Бу сүзнең татарчасын белмим, «убыр» микән, «аждаһа» микән, «вампир» – кан эчеп яшәүче ярканат була инде, җан ияләренең иң кабахәте.* А.Гыйләҗев. *Вампирлар [ярканатлар] – имезүчеләр, кошлар канын эчеп туклаåналар.* Биология

4) *күч.* Кансыз, рәхимсез, шәфкатьсез зат; канечкеч кеше

**ВАМПИРИЗМ** *и. рус к.* **вампирлык.** *Бу авыруның төп билгеләреннән берсе – кан эчүгә һәвәслек, ягъни вампиризм.* Мәдәни җомга

**ВАМПИРЛЫК** *и.* Кан эчүчәнлек, кан эчеп туклануçанлык, вампиризм. *Тарих китапларында язылганча, Рим империясендә җәмгыятьнең югары катлауларында кан эчү – вампирлык күренеше барлыкка килгән. Гладиаторлар сугышыннан соң, кайберәүләр сугыш мәйданында коелган канны яшәрү өчен дару урынына куллана торган булганнар.* К.Гыйззәтов

**ВАНА́ДИЙ** *и. лат. хим.* Химик элемент; югары сортлы корыч коюда кулланыла торган ачык соры төстәге металл

**ВАНДАЛ** *и. лат.* 1) Рим империясенең бер өлешен басып алып, Римны тар-мар иткән һәм талаган борынгы герман кабиләсе

2) *күч.* Культура хәзинәләрен явызларча җимерүче кеше; варвар. *Иван Грозный вандалларының иң беренче эше шуннан гыйбарәт: татарларның байлыкларын талау белән бергә, ничә гасырлар тупланып килгән елъязмаларны, архивларны яндыру коточкыч вәхшилек белән башкарыла.* М.Юныс

**ВАНДАЛИЗМ** *и. рус к.* **вандаллык.** *Аның [кабер ташының] урынында тимер казык кына тырпаеп тора иде. Бу вандализмны башкаручылар – татарны сөймәс бәндәләр, әлбәттә.* Л.Хәмидуллин

**ВАНДАЛЛЫК** *и.* Культура һәм сәнгать хәзинәләрен, гомумән рухи кыйммәткә ия әйберләрне кирәксезгә аяусыз җимерү һәм юк итү; варварлык. *«Чиркәүләргә нигез булып яткан бабамнарның кабер ташлары» ди шагыйрь... Ә бит бу – караңгы гасырлар өчен дә кабул итеп булмаслык олы вәхшәтлек, вандаллык турында искә төшерә!* И.Вәлиуллин

**ВАНИЛИН** *и. фр.* 1) Ваниль кузагыннан алына яки ясалма юл белән табыла торган хуш исле матдә. *Ванилин парфюмериядә еш кулланыла. Пычкы чүбеннән азык продуктлары, шикәр-глюкоза һәм ванилин алырга мөмкин.* Ботаника

2) Кулинариядә кулланыла торган, шул матдәдән эшләнгән тәмләткеч. --- *плащ эченнән бөркелгән җылы пар мин көткәнчә хәтәр булып чыкмады. Бары тирә-якка татлы ванилин исе генә җәелде.* М.Әмир

**ВАНИЛЬ** *и. фр. бот.* 1) Сәхләбчәләр семьялыгыннан, яшькелт сары чәчәкле, үрмәләп үсә торган лианасыман үсемлек. *Ваниль чыбыкчалар ярдәмендә үрчи.* Ботаника

2) Аның, киптереп, кулинариядә тәмләткеч итеп файдаланыла торган җимешләре. *Ваниль, ясмин исе күңел тынычлыгын сакларга булыша.* Мәдәни җомга

**ВАНИЛЬЛЕ** *с.* Составында ваниль булган, ваниль кушылган. *Кәстрүлдә май, шикәр комы, тәмләткечләр – ванилин яки ванильле шикәр комы болгатабыз.* Малайларга-кызларга: «тәмле» киңәшләр. *Ванильле хәлвә. Ванильле шоколад*

**ВА́ННА** *и. нем.* 1) Торба ярдәмендә канализациягә тоташтырылган, формасы һәм эшләнгән материалы төрле булган, коену, юыну өчен хезмәт итә торган зур сыешлык. *Эшләрен бетергәч, ул тиз генә ваннада коенып чыкты.* А.Расих. *Мин, алайса, тиз генә ванна керәм.* Т.Гыйззәт

2) Формасы белән шундыйга охшаган, бала юындыру өчен кулланыла торган кечерәк төрдәге савыт. *Бала үзенең ваннасында бик рәхәтләнеп утыра*

3) *махс.* Эчендәге сыеклыкка төрле әйберләр салынып эшкәртелә торган, төрле зурлыктагы һәм формадагы савыт (фотографиядә һ.б.)

4) Шул савытка тутырылган сыеклык; юыну һәм дәвалану максатыннан, аның эчендә ятып тору процессы. *Шуннан дәвалану башланып китә: укол, пластинка, ванна, душ.* М.Гафури

5) Тәнне кояш нурлары, һава, төрле катнашмалар һ.б. ярдәмендә дәвалау, ныгыту, чыныктыру. *Көньякка барып, файдалы ләм ванналары алыгыз.* А.Гыйләҗев

6) *сөйл.* Юыну, коену өчен шундый сыешлык белән җиһазландырылган махсус бүлмә; юыну бүлмәсе. *Ул тиз генә ваннага чыгып, коенып керде.* А.Шамов

**ВА́ННА БҮЛМӘСЕ** *и. сөйл к.* **ванна** (*6 мәгъ.*). *Ванна бүлмәсенә кергәч, башта, кулы белән ияген, яңагын ышкып карады*... Ә.Еники

**ВАНТ** *и. голл. махс.* Борт белән мачтаны тоташтыручы канат, аркан. *Шторм вакытында, ванттан йөгереп менеп, бомбрамсель биеклегендә риф алу өчен, ай-һай, нинди акробат осталыгы кирәк!* М.Юныс

**ВАРАН** *и. лат. зоол.* Тәңкәле сөйрәлүчеләр асотрядыннан, көньякта яшәүче зур гәүдәле кәлтә еланның бер төре. *Кәлтәләр, вараннарның --- гәүдәләре җир өстеннән аз гына күтәрелә, һәм алар корсакларын җирдән өстерәргә мәҗбүр булалар.* Биология. *Кимерүчеләргә һәм кәлтәләргәерткыч кошлар, имезүчеләр, вараннар һәм еланнар һөҗүм итә.* Башлангыч география курсы

**ВА́РВАР** *и. гр.* **1.** 1) *тар.* Борынгы грек һәм римлыларда: аларга ят булган культурадагы һәм аңлашылмый торган телдә сөйләшүче чит ил кешесе. *Римлылар, башка ят ил кешеләрен атаган шикелле, германнарны да «варварлар» дип атаганнар.* Борынгы заман тарихы

2) Башкаларга карата рәхимсез, ерткыч кеше; вәхши. *Халык Җиңү белән алга барганда, куркып качкан фашист варварлары.* Ә.Исхак

3) Тәртипсез, тәрбиясез кеше. *Исламгали өйгә керсә, бәләкәй варвар, сәгать чылбырының очын учына чорнап, гер селтәп, идән уртасында әйләнеп уйный иде.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Мәдәни үсеше буенча үзләреннән түбән баскычта торган, кыргый. *Варвар кабиләләр*

**ВАРВАРИЗМ** *и. гр. лингв.* Чит телдән алынып, әдәби тел нормаларына ярашмый торган сүз һәм сүз тезмәләре. *Сәгыйть сөйләүченең чыгышында варваризмнар куллануына игътибар итте.* Х.Сарьян. *Варваризмнар, кайвакыт, чит илләр алдында баш июче персонажларның, мәсәлән, русча сөйләшкәндә дә француз сүзләре катнаштырып сөйләшүче рус аристократларының сөйләмен күрсәтү өчен файдаланыла.* Әдәбият белеме

**ВА́РВАРЛАРЧА** *рәв.* Аяусыз, вәхшиләрчә, ерткычларча, явызларча, рәхимсез. *Колониядәге җирле халык варварларча талануга һәм көчләүләргә дучар ителә.* Тарих

**ВА́РВАРЛАШУ** *ф.* Варварга әйләнү, вәхшиләнү

**Варварлаша бару** Акрынлап, варварлыгы арту

**Варварлашып бетү** Тәмам варварга әйләнү, бик нык варварлашу

**Варварлашып җитү** Соңгы чиккә җитеп варварлашу

**ВА́РВАРЛЫК** *и.* 1) Мәдәнилек, белем дәрәҗәсе иң түбән баскычта булу, алгарыштан читтә калган булу

2) *тар.* Кешелек җәмгыятендәге мәдәният үсешенең вәхшилек һәм циви-

лизация арасында булган билгеле бер баскычы // *махс.* Борынгы җәмгыять үсешендәге аерым чорның Л.Морган тарафыннан кертелгән, искергән атамасы. *АКШ галиме Льюнс Морган теориясе буенча, кешелекнең кыргыйлык стадиясеннән – варварлыкка, варварлыктан цивилизация стадиясенә күчүе шулай ук төрле формалардагы сикерешләрне гәүдәләндерә.* К.Гыйззәтов

3) Аерым кешегә, халыкка, тарихи һәм мәдәни хәзинәләргә һ.б. тупас, рәхимсез мөнәсәбәт; культурасызлык. *– Үгезләрне үтерүдә сез безне варварлыкта гаеплисезме? – ди бер матадор.* Р.Фәйзуллин. *Кайбер язучыларыбыз, шушы төзелешләргә багышланган сандык зурлыгы романнарында, варварлыкка мәдхия җырлады.* М.Юныс. *Мәскәүдә булып үткән вакыйгалардан соң, кайбер яшүсмерләр варварлык өчен кулга алынды.* Ватаным Татарстан

**ВАРЕНЕЦ** *и. рус* Кайнатып әчетелгән сөт. *Инде уйлап карыйк: кеше һәркөнне сау-сәламәт яшәрлек сөт һәм сөт ризыклары куллана алсын өчен, күпме терлек үрчетергә, күпме май, каймак, брынза, кефир, эремчек, катык, варенец, мороженое, ряженка, простокваша, әйрән, сыр ясарга кирәк.* М.Зарипов

**ВАРЕ́НИК** *и. рус* Эченә эремчек, төрле җиләкләр һ.б.ш.лар салып ясалган зур пилмән. *Чия варениклары*

**ВАРЕ́НЬЕ** *и. рус* Шикәр ширбәтенә җиләк-җимеш салып кайнатылган яки шикәр комы белән аралаштырып, бутап, туглап куелган җимешләр яки җиләкләр катнашмасы; кайнатма. --- *өстәлдәге майлар, баллар, вареньелар, кечкенә бәлешләр, алмалар, яңа гына табадан чыгып килгән пәрәмәчләр аның [Газилнең] ашау дәртен кайнаттылар.* Г.Ибраһимов. *Өстәлгә савыт белән варенье да куярга кирәк.* Г.Камал. *Минә монысы – балан вареньесы!* М.Мәһдиев. *Татар халкы чәй янына, бал, май, сөт, шикәр, варенье, каклар белән бергәттән, төрле-төрле чәй ашлары да куя.* Татар халык ашлары

**ВАРИАНТ** *и. лат.* 1) Эш башкаруда төп чараларның, юлларның, ысулларның төрле төрләреннән берсе; нәрсәнең дә булса үзгәрәк төре. *Укучыларга тәкъдим ителгән контроль эшнең өченче варианты да бар.* Г.Гобәй. *Катлы паштет пешерү өчен кирәк әйберләр беренче варианттагы кадәр алына.* Ю.Әхмәтҗанов. *Рәмзи үртәвендә дә күпмедер хаклык барын тойгач, табышмакның чишелү вариантлары күбәя баруын чамалады.* Т.Әйди

2) Нинди дә булса фәнни хезмәтнең, әдәби-музыкаль әсәрләрнең һ.б. бераз үзгәртелгән, әмма асылы шул ук калган нөсхәсе. *Укучы игътибарына тәкъдим ителгән бу әсәр – либреттоның соңгы варианты.* М.Җәлил. *1907 елда басылган икенче вариантында исә аның бу әсәре беренче басмасы белән чагыштырмаслык дәрәҗәдә үзгәрде.* М.Гафури. *Уен яңадан башлана, санамышның икенче варианты әйтелә.* С.Сөләйманова. *Беренче вариантында «Без – кырык беренче ел балалары» повесте кырык-илле биттән артмый иде.* Г.Ахунов

3) Шахмат уенында: фигураларның билгеле торышында мөмкин булган йөрешләрнең берсе. *Соңгы еллардагы җитди ярышларда Рубинштейн варианты сирәк очрый.* Р.Нәҗметдинов

**ВАРИАНТЛЫЛЫК** *и.* Төрле вариантлар булу; төрлелек. *Халык иҗатының тагын бер үзенчәлеге – күп вариантлылык.* М.Бакиров. *Безнең фамилияләрдә вариантлылык көчле, тотрыклылык, стабильлек бик аз.* Ф.Фәсиев

**ВАРИАЦИОН** *с. к.* **вариацияле.** *Вариацион форма* (мәс., *музыкада*); *вариацион рәт* (мәс., *биологиядә*)

**ВАРИАЦИОН СТАТИ́СТИКА** *и. рус махс.* Табигать, җәмгыять күренешләрен өйрәнүдә математик анализ куллану

**ВАРИА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Берәр нәрсәнең нигезе, төп эчтәлеге сакланган хәлдә, икенче дәрәҗәдәге өлешләренә генә кагылышлы үзгәлек, төрлелек. *[Мәкальләрнең] Төрле вариацияләрдә булуын күрсәтү – бик әһәмиятле.* Н.Исәнбәт

2) *бот.* Хайваннар яки үсемлекләр төзелешендә төп типтан читкә тайпылу һәм кайбер үзгәрешләр. *Ул, врач һәм культуралы кеше буларак, анатомик вариацияләр, имгәнү, бәхетсезлек очраклары һәм башка факторларның, кайчак, организмның табигый төзелешенә зарар китерүен --- белергә тиеш иде.* Ф.Углов

3) *муз.* Төп тема шул ук булып, яңгырашын төрлечә үзгәртеп (ритмны, тональлекне һ.б.) эшләнгән музыкаль әсәр, бию һ.б.ш. *Глинканың әлеге җиңел, җилкендергеч «Камаринская» вариацияләрен күңелдән тыңлап барам.* М.Рафиков. *«Татар халык җырлары» темасына музыкаль вариация*

4) *муз.* Музыка әсәрен башкарганда, кушылып уйнагандагы үзгәрешләр, күчешләр

**ВАРИА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Төрле үзгәрешләр кертү, төрләндерү, вариантлар бирү. *Борынгы классик шигырь, үзендә буын араларын ачык саклаганга, яңадан-яңа строфа калыпларын иҗат итәргә, ритмик буыннарны төрле-төрле рәвешләрдә вариацияләргә мөмкинлек бирә.* Х.Госман

**Вариацияләп бетерү** Барысын да вариацияләү; вариацияләүне төгәлләү

**Вариацияләп тору** Бертуктаусыз вариацияләү

**Вариацияли бару** Акрынлап, бераз-берәм, барысын да вариацияләү

**Вариацияли төшү** Бераз вариацияләү

**ВАРИА́ЦИЯЛЕ** *с.* Төрле вариантлары булган

**ВАРИС** *и. гар.* 1) Мираска хуҗа булып калучы; үлгән кешенең калган малына хуҗа булып калучы, мирас алучы кеше. *Бала бит – варис, өмет, көч, киләчәк!..* А.Гыйләҗев. *Нигә Эдуард, Зәкиевләр нәселенең бердәнбер варисы, бабасының каберен белмәскә тиеш? Хәзер аңа – утыз.* Р.Батулла

2) Нәсел, милләт, дәвамчы. *Мәһдиев өчен иң зур сөенеч – варисларының татарча белүе, тар, кысан кухняларында ана телендә аралашулары турында бәян итү.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Кемнеңдер эшен, тәҗрибәсен өйрәнеп, аны дәвам иттерүче кеше; шәкерт. *Ак сакаллы карт мастер егетләр янына килгәч, Лёша дәдәй Мансурның җилкәсеннән каты итеп кочты да аны мастер янына алып барды: – Минә*

*сиңа, Иван Савельевич, минем варис, – диде ул. – Мин үз урыныма шушы егетне калдырам!* А.Расих

**ВАРИСЛЫК** *и.* Варис булу; мирас иясе булу; варис хокукы. *Нигъмәтулла бабайның оныклары, берсен-берсе уздырып, варислыкка дәгъва итә.* Сөембикә

**ВАРИСТАШ** *и.* Бер-берсенә карата: мирас алучыларның, варис булучыларның берсе

**ВАРФОЛОМЕЙ ТӨНЕ** *и. тар.* 1) Изге Варфоломей төнендә (1572 елның 24 августына каршы төндә) Парижда католикларның ике меңнән артык гугенотны (протестантларны) суеп үтерүе белән дөньяга билгеле вакыйга. *Давыллар да җирдә, концлагерь да – әйтерсең лә берни булмаган; Варфоломей төнендәге сыман Битараф ай тыныч, тын һава.* Г.Хуҗиев

2) *күч.* Күпләп суеш, үтереш, канкоеш. *Варфоломей төне, Үлем көне Кабатланып тора бирсә.* Г.Хуҗиев. *Татар тарихының Кара канга баткан хәтәр төне – Варфоломей төне. Җимерелгән Казан, Ишетелми азан, Татар – ут-кан, зар-яшь эчендә...* Х.Бәдигый

3) *күч.* Нинди дә булса шау-шулы, ыгы-зыгылы вакыйга (күпчелек очракта төнлә була торган). *Күршенең ире, көн дә диярлек исереп кайтып, өйдәгеләргә йокы бирми, «варфоломей төне» оештыра*

**ВАРЬЕТЕ** *и. фр.* Төрле җиңел (театр, музыка, цирк) жанрдагы эстрада театры. *«Ницца» диганнәре – гап-гади бетон идәнле «пыяла тартма» икән, башка шундый урыннардан варьете биюле кичке ресторан хисапланып йөртелүе белән генә аерылып тора иде.* Р.Мирхәйдәров

**ВАРЯГ** *и. бор. сканд. тар.* IX–X гасырларда Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа җирләренә талау һәм сәүдә итү максатыннан һөҗүм иткән һәм борынгы Русь, Византия армияләрендә ялланып хезмәт иткән норманнарны борынгы руслар һәм византиялеләр шулай дип атаганнар; *к. шулай ук* **викинг** (*1 мәгъ.*). *Кенәз Юрий Долгорукий – әнә шул баскынчы варягларның ерак булмаган дәвамы.* М.Хәбибуллин. *Алманиядә, хәзерге Бонн шәһәре тирәсендә X–XI гасырларда ясалган франк кылычлары болгарларга варяглар (викинглар, норманнар) аша килеп кергәндер, дип фаразлана.* Ф.Хуҗин

**ВАСИТА** *и. гар. иск. кит.* 1) Кешеләр яки оешмалар арасында бәйләнеш булдыручы, ике арада эш йөртүче; арадашчы. *Өйләр, киемнәр дә – һава үзгәрүдән сакланыр өчен генә воситадыр.* Г.Тукай. *[Егет] Теге татар гаиләсе һәм татар кызлары белән танышасы килгәнлеген сөйләде һәм васита булучылыгын үтенде.* Ф.Әмирхан. *Хәзерге көндә дә, «илче» дип, сугыш өчен түгел, бәлки нинди булса да бер мәслихәт өчен, арада бер дуслык мөнәсәбәте ясау өчен васита булып килгән кешегә әйтәләр*. Җ.Вәлиди

2) Берәр эшне булдыру яки башкарып чыгу өчен күрелә торган чара, җай, әмәл. *Хәзерге вакытта, махсус «перископ» исемле корал васитасы белән, бу атуларны һәрвакыт тәфтиш итеп торырга мөмкиндер.* Ф.Әмирхан

3) Ярдәм, булышлык. *Туганнар васитасы белән уку*

**ВАСИТАЛЫК** *и.* Васита булу, васита вазифасы. *Акчалар товарларның кыйммәтен күрсәтәләр, алмашу васиталыгы хезмәтен итәләр.* Г.Тукай. *Васиталыкка риза булу. Васиталык өчен түләү*

**ВАСИТАЧЫ** *и. иск. кит.* 1) Сатучы белән сатып алучы арасында арадашлык итүче, маклер; арадашчы. *Фатир сату-алу эшендә васитачы*

2) *махс.* Бәхәсле эшләрдә каршы якларны килештерергә ярдәм итүче. *Фольклорда кош образы – васитачы, ике арада хәбәр ташучы булса, Муса Җәлил бу образны бик нык үстереп ала.* Г.Кашшаф

**ВАСИТАЧЫЛЫК** *и. иск. кит.* 1) Васитачы вазифасы, васитачы эше; арадашчылык

2) *махс.* Бәхәсләшүче, дәгъвалашучы, сугыш алып баручы якларны үзара килештерергә ярдәм итү эше. *Урта һәм Көньяк Азия белән генә түгел, Һиндстан һәм Кытай белән элемтәдә дә рус сәүдә капиталы татар сәүдәгәрләренең васитачылыгыннан файдаланган.* К.Фәсиев

**ВАССАЛ** *и. фр.* 1) *тар.* Урта гасырларда Көнбатыш Европада: эре җир биләүче феодалга бәйле булган вак җир биләүче. *Перчатканы ыргыту вассалның буйсынмый башлавын аңлаткан.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Буйсындырылган ил яки кеше. *Аксак Тимер аңа үз вассалы итмереп кенә карый иде.* Н.Исәнбәт

**ВАССАЛЛЫК** *и.* Вассал булу. *Урта гасырларда Көнбатыш Европа илләрендә вассаллык иткән рыцарьларга феодал перчатка бирә торган булган.* Мәдәни җомга

**ВАССА́ЛЧА** *рәв.* Вассал сыйфатында, вассал буларак. *Алар Урдага вассалча буйсыналар иде.* Н.Исәнбәт

**ВАСЫЙ** *и. гар.* Регент; опекун. *Васый ятимнәрнең рөшедкә ирешүләрен теләмәгән кебек, залим бер хөкүмәт тә тәбәгасының гыйлем белән зурлануын теләмәс.* Г.Бубый

**ВАСЫЙЛЫК** *и.* Регентлык; опекунлык, опекун вазифасы. *Ислам тәэсире астында, халкыбыз дингә тиешеннән артык бирелеп китсә дә, соңгы вакытта милли шагыйрь, милли әдип, милли мөәррих, милли халык хадимнәребез җитешә башлау, безнең дә, дин васыйлыгы астыннан чыгып, миллият буйсынуы астына керә башлавыбызны күрсәтә.* Г.Шәрәф

**ВАСЫЯ** *и. гар.* Васый хатын-кыз. *Ханның васыяте буенча, Казан тәхетенә аның яраткан хатыныннан туган улы сабый Үтәмешгәрәй утыртыла. Сөембикә үзе сабый ханның җитәкчесе, регенты, Ризаэддин Фәхретдин сүзенә мөрәҗәгать итсәк, васыясе була.* Ф.Урманче

**ВАСЫЯТЬ** *и. гар.* 1) Кешенең, үләр алдыннан, якыннарына киңәш яки боерык рәвешендә әйтеп калдырган теләк-үтенечләре. *– Әйе, миңа синнән берни дә кирәкми, – дип кабатлады ул, Сәет янына ук килеп. – Әмма әтиеңә биргән сүзем бар, васыятен үтәми калып, гомер буе күңелемдә гөнаһ ташы йөртәсем юк.* Ф.Латыйфи. *Васыятем шул: авыл читенә чыгам да чыбыркымны ыргытам. Чыбыркым кай җиргә төшсә, шунда күмегез...* М.Мәһдиев. *Без, Татарстан язучылары һәм Арча*

*хакимияте башлыклары, Мөхәммәтне – үзенең васыяте буенча – Гөберчәккә алып кайтып җирләдек.* Г.Ахунов

2) *юг.* Исәннәргә һәм киләчәк буыннарга әйтеп яки язып калдырылган сүз, теләк, киңәш, күрсәтмә. *Кайчандыр авылны ташлап чыгып киткән егетләр, кызлар үләр алдыннан васыять әйтәләр икән: мине үз авылымның зиратына алып кайтып күмегез [дип].* М.Мәһдиев. *Тере чагында, кодагыем, сөягемә керә күр инде, дип, кат-кат васыять әйтте.* М.Кәрим

**ВАСЫЯТЬ ИТҮ** *ф.* 1) Үлеменнән соң нәрсәне дә булса мирас итеп тапшыру турында әйтеп калдыру. *Ул үзенең бар мөлкәтен балалар йортына васыять итте*

2) Үләр алдыннан, нинди дә булса теләк-үтенеч белдерү. *Шуннан артык нәрсә әйтә алмыйм, әмма аларны васыять итеп калдырам.* А.Шамов

**ВАСЫЯТЬ КЫЛУ** *ф. к.* **васыять итү**. *Казанда бер бай адәм вафат булып, берничә мең сум акчасын мәсҗед вә мәдрәсә файдасына васыять кылып калдырган.* З.Һади

**ВАСЫЯТЬНАМӘ** *и. гар.-фар.* Гражданның, вафат булган очракта, варисына калдырган мирасы турындагы карары язылган рәсми таныклык; васыять язылган кәгазь. *[Петр I төзегән, 1725 елгы яшерен] «Васыятьнамә»нең төп эчтәлеге, гомумән, күп гасырлык.* Х.Миңнегулов. *Хуҗа әби ярата аны, үз кызы кебек күрә. «Үлсәм-нитсәм, фатир сиңа калыр», – дип, васыятьнамә дә язмакчы иде, кыз каршы килде.* Р.Мулланурова

**ВАТА́-ҖИМЕРӘ** *рәв. к.* **вата-сындыра.** *Көчле су ташкыны күтәреп алды һәм, вата-җимерә бөтәрләп, тыелгысыз бер көч белән, каядыр агызып китте...* Ә.Дусайлы. *Бәләкәй адашының, вата-җимерә, гарәп сүзләрен тәкрарлавын тыңлап, мич буенда басып торган Абдулла башын күтәрде, мәдрәсәнең бәләкәй тәрәзәсенә карады.* Җ.Рәхимов

**ВАТАН** *и. гар. юг.* 1) Аерым кеше өчен: үзе туган һәм шуның гражданины булган ил; туган ил. *Менә без дә Ватанга кайтып кердек.* М.Мәһдиев. *Анда әйтелгән: Ватанны саклау эше – намус һәм вөҗдан эше, диелгән.* М.Мәһдиев. *Үтә шәхси бер факттан шагыйрь, үзе дә сизмәстән, олы борчылуга – халык, Ватан, дөнья язмышын кайгыртуга күчә.* С.Сөләйманова

2) Кешенең туган ягы, туып үскән җире; туган төбәге. *Ватан – Хөсәен өчен менә шушы басулар, елга буйлары, шушы бормалы юллар, исемсез тәбәнәк таулар ул.* А.Гыйләҗев

**ВАТА́Н АНА** *и. юг.* Туган ил (туган илнең поэтик символы). --- *явыз дошман туган илебезнең изге җиренә басып керә. Ватан ана лачындай яшь егет һәм кызларына мөрәҗәгать итә.* С.Шакир

**ВАТАНДАР** *и. гар.-фар.* 1) *иск. к.* **ватанпәрвәр**. *Чөнки Ватан тарихлардан зуррак. Ватандарлар үлми илемдә.* С.Рөстәмханлы. *Бу үрнәк һәркемне ватандар булырга, җан-тән белән, бирелеп, туган илгә хезмәт итәргә өйрәтә.* Казан утлары

2) Билгеле бер дәүләтнең, илнең гражданнары. *«Империя» төшенчәсенең бик күп билгеләмәләре бар. Бу очракта, мин, бер суверен дәүләтнең икенче бер суверен дәүләтне яисә берничә шундый ук дәүләтне яулап алып, үз территориясенә китереп кушуын, анда яшәүче халыкларны коллыкка төшерүен яисә икенчел ватандарларга – гражданнарга әверелдерүен күз алдында тотам.* Мирас

**ВАТАНДАРЛЫК** *и.* Ватандар булу. *Сәлам, сәлам, дәү әтием! Күз зәңгәрлегем өлгесе, ватандарлыгымның алтын кыясы.* Р.Харис. *Шигырь юлларына олы бер тормыш юлы узган кешенең гыйбрәтле язмышы, ватандарлык хисләре сыйган.* Казан утлары

**ВАТАНДАШ** *и.* Бер-беренә карата: уртак ватанлы, бер илдә туып үскән һәм яшәгән кешеләр. *Илнең һәр төбәгендә безнең ватандашларның сагынып искә алырдай хатирәләре калган.* С.Сөләйманова. *Ул көн ерак түгел, кадерле ватандашлар.* М.Мәһдиев. *Мәскәүлеләр арасында, бу вазгыятьтә ни эшләр идең икән, дигән темага сорашу күрсәткәнчә, һәр бишенче ватандаш, үземне теге хикмәти фильм герое кебек тотар идем, дип белдергән.* Мәдәни җомга

**ВАТАНПӘРВӘР** *и. гар.-фар. кит.* Ватанын яратучы, шуның файдасына армый-талмый эшләүче; ватанчы, патриот. *Юлдаш дуслары – дан-шөһрәткә эремәгән, затлы кәнәфиләр җылысына оемаган, үз персонын ярату белән авырмаган чын ватанпәрвәрләр.* Р.Рахмани. --- *татарларда, бакый заманнардан ук, азатлыкка ирешүдә ватанпәрвәр шәхесләр аеруча зур роль уйнаган.* М.Хәбибуллин

**ВАТАНПӘРВӘРЛЕК** *и. иск. кит.* Ватанчылык, патриотлык. *[Сенкевич] Поляк милләтенең мөкатдәс нәрсәләре алдында баш ию белән яза вә әсәрләренең һәрберсендә гаять самими ватанпәрвәрлек --- [күрсәтә] иде.* Ф.Әмирхан

**ВАТА́Н СУГЫШЫ** *и.* Туган ил азатлыгы, бәйсезлеге өчен, чит ил илбасарларына каршы алып барылган гадел сугыш. *Ватан сугышы чорында, ике ут арасында калып, аяусыз кырылган белорус халкы язмышы Быков кебек көчле каләм иясенә иҗади тәҗрибәләр ясарга менә дигән җирлек иде.* М.Галиев. *Аңа гайрәтен Ватан сугышы кырларында күрсәтергә туры килгән, һәм шунда ул корбан да булган, диделәр.* М.Әмир

**ВАТАНЧЫ** *и.* Үз илен, ватанын сөюче, иленә һәм халкына җаны-тәне белән бирелгән кеше, илсөяр; патриот. *Ә минем канга сеңгән: сүздә ватанчы булып сөйләшкәч – гамәлдә дә ватанчы булу, әз генә дә икейөзлеләнә алмый яшим...* Х.Камалов

**ВАТАНЧЫЛ** *с.* 1) Ватанын, илен сөюче, ватанга җаны-тәне белән бирелгән; патриотик. *Ватанчыл өлкән буын инде сирәгәеп бара*

2) Ватанны сөю хисләре белән сугарылган. *[Гәрәй:] «Хөр мәмләкәт, хөр Россия!» – дип, үзенең революцион ватанчыл фикерен иптәшләренә сөйли.* Л.Җәләй

**ВАТАНЧЫЛЫК** *и.* Ватанчыл булу, ватанпәрвәр булу, патриотлык. *Фронтта ватанчылык хисе, дошманнарга нәфрәт, ниһаять, үлсәң, нәрсә намына үлүеңне аңлау куркуны җиңәргә көч бирә иде.* Г.Әпсәләмов

**ВАТА́-СҮТӘ** *рәв. к.* **вата-сындыра**

**ВАТА́-СЫНДЫРА** *рәв.* Бозып, җимереп (сөйләмдә – тел законнарын, җырлаганда – көйне). *Шәяхмәт, үзенең кытыршы теле белән, русчаны вата-сындыра, Фәхринең язмышын сөйләп китте.* Г.Ибраһимов

**ВАТЕРПАС** *и. голл. тех.* Агач, җир һәм таш эшләрендә горизонталь тигезлекне тикшерә һәм зур булмаган авышу почмакларын үлчи торган гади прибор; тигезләгеч. *Эреле-ваклы кул пычкылары. Ашыгып, бер – алга, бер артка качып, тигезлекне эзләп торучы тынгысыз ватерпас.* И.Салахов

**ВАТЕРПО́ЛО** *и. ингл. спорт* Ике команда арасында суда туп белән уйнала торган уен

**ВАТЕРПО́ЛОЧЫ** *и. спорт* Ватерполо уйнаучы. *Казанда ватерполочы командалар арасында ярыш үткәрелде. Казан ватерполочылары беренче урын яулады.* Татарстан яшьләре

**ВАТЕРСЫЗЫК** *и. махс.* Пароход, көймәләрнең ян стеналарында суда утыру тирәнлегенең тиешле нормасын күрсәткән сызык. *Алар, бауга асылынган урындыкларга утырып, басып, корабльнең ватерсызыгын, тышын буйый башладылар.* А.Таһиров

**ВАТИН** *и. рус* 1) Киемнең эчлеге белән тышлыгы арасына җылылык өчен куела торган, сирәк тукылган йонлы-мамыклы йомшак тукыма

2) Шундый ук максатта файдалану өчен, ике кат марля арасына юка итеп җәеп, сырып эшләнгән метрлы мамык. *Пальтога бер кат ватин кую*

**-ВАТКЫЧ** Кушма сүзләрдә: каты әйберне ваклый, китә, җимерә торган, мәгънәсендәге икенче кисәк (мәс., *асфальтваткыч, бозваткыч, ташваткыч, шикәрваткыч*)

**ВА́ТМАН** *и. ингл.* Сызым һәм рәсем ясау өчен кулланыла торган, яхшы сыйфатлы калын кәгазь. --- *үткән-сүткән мут ир-атның күзе гел шул хатында иде, тик ул гына беркемгә дә игътибар итми, ул гына башын аска – өстәлгә, ватманга игән һәм, тырышып-тырышып, сызым сыза.* Ә.Салах

**ВА́ТМАН КӘГАЗЕ** *и. к.* **ватман.** *Җәүдәтнең үзенең дә, култык астына папкалар, ватман кәгазьләре кыстырып, --- чыгып килгәнен күрдем.* Г.Ахунов. *Күзлеген маңгай өстенә күтәреп, минем ватман кәгазенә, дәфтәр кәгазенә, сары катыргыларга төшергән рәсемнәремне күздән үткәрә башлады.* Гөлшаһидә

**ВАТТ** *и. физ.* Пар машинасы уйлап тапкан Джемс Уатт исеменнән: электр чылбырының актив көчен үлчәү берәмлеге. *Егәрлек ваттлар белән үлчәнә.* Физика курсы

**ВАТТМЕТР** *и. рус тех.* Электр чылбырының актив көчен ваттларда үлчи торган җайланма, прибор. *Ваттметр күрсәткече буенча, актив егәрлек 12,5 кВт, көчәнеш 380 В, ә ток 45 А.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *Ваттметрның күрсәтүе дөрес булу-булмавын амперметр һәм вольтметрның күрсәтүләренә карап тикшерергә кирәк.* Физика курсы

**ВАТТ-СӘГАТЬ** *и. тех.* Бер ватт егәрлегендәге токның бер сәгать эчендә башкарган эшенә тигез электр тогы эшен үлчәү берәмлеге

**ВАТТ-СЕКУНД** *и. рус тех.* Бер ватт егәрлегендәге токның бер секунд эчендә башкарган эшенә тигез электр тогы эшен үлчәү берәмлеге

**ВАТТЫРУ** *ф.* 1) Техника ярдәмендә вату; җимертү, тар-мар итү. *[Японнар] Порт-Артурны, көлен күккә очырып, бөтенләй ваттырып, харап итеп бетергәннәр.* Ш.Мөхәммәдев. *[Мәскәү патшасы] Җиде ел камап торганнан соң, шәһәр диварларын ваттырып, Казан шәһәрен алган.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) Яраксыз хәлгә китерү; эшләми торган итү, ватык, җимерек хәлгә китерү. *Бичара егет, мине таптатмас өчен, машинасын фонарь баганасына бәреп ваттырган.* Т.Гыйззәт

3) Юкка чыгару, бетерү. *[Сөмбел:] Күзенә ак-кара күренми. Авызы тулы таза тешләрен ваттырып, ялтыравыклы тешләр куйдырган.* Г.Бәширов

**Ваттыра бару** Берсе артыннан икенчесен ваттыру

**Ваттыра башлау** Ваттырырга тотыну

**Ваттыра төшү** Тагы да бераз ваттыру

**Ваттыра язу** Чак кына ваттырмый калу

**Ваттырып бетерү** Барысын да ахырга кадәр ваттыру, ваттыруны тәмамлау. *Хуторны кичәге сугышта ук ваттырып бетерә язганнар иде.* Г.Бәширов

**Ваттырып карау** Ваттырырга омтылу. *Подвалның тимер ишегенә гранаталар ыргытып ваттырып карадылар, әмма, ишекләр берничә кат тимердән эшләнгән булганга, анда үтә алмадылар.* Х.Камалов

**Ваттырып тору** Еш яки әледән-әле ваттыру

**Ваттырып яту** Әле, хәзер, күз алдында ваттыру. *Болар барып җиткәндә, патшаның солдатлары моның [Алпамшаның] памятнигын, атып, ваттырып яталар икән.* Әкият

**ВАТТЫРЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **ваттыру**

2) *күч. сөйл.* Бәхәсләшү, сүз көрәштерү; талашу

**ВАТУ** *ф.* **1.** 1) Бөтенлеген бозу, ваквак кисәкләргә аеру, таркату. *Аннан соң, ул как-төшне мәхәлләнең мәзине, ватып, мәҗлестәге халыкка өләшә, тәлинкәгә салып, һәркем алдына куя.* К.Насыйри. *Такта чәйне, ватып, чәйнеккә салды да гөҗләп кайнаган самавыр өстенә утыртты.* Г.Ибраһимов. *Алай да бу – кәйлә белән таш вату түгел инде.* Г.Ахунов

2) Берәр каты әйберне ике яки берничә кисәккә бүлү, яргалау. *Әмма Ишкәйнең зарланырлык чамасы юк иде: --- эсседә, билдән чишенеп ташлап, утын вата, артезиан коесыннан цистерналарга су тутыра ---.* Т.Әйди. *Их, безнең яшь чаклар, Әткәй шикәр ваткан чакта Без ялаган пычаклар!..* Г.Ахунов. *Ун градус салкында, шакыраеп каткан арыш икмәген, бүкәнгә куеп, балта белән ваттылар.* Г.Бәширов

3) Бетерү, җимерү, яраксызга чыгару. *Бала өйдә теләсә нәрсә эшли: гөлләрне йолка, чынаяк вата.* М.Мәһдиев. *Шунда дару шешәсен ваттым, бармагым киселде.* А.Гыйләҗев. *Балалар класстагы бер нәрсәне дә ватмаска, сындырмаска, җимермәскә тырышалар.* Г.Әпсәләмов

4) Хәрабә хәленә китерү, җимерү. *Японнар туп аталар, Порт-Артурны ваталар.* Җыр. *Ялланам да кучмәләргә Бу шәһәрне мин ватам.* Н.Исәнбәт. *Талаучылар бандасы --- юлда бөтен нәрсәне талый, җимерә, вата.* Ш.Усманов // Талау максатында эчкә үтү өчен, өлешчә җимерү. *Кибет ватып, акча табып, кесәсен тулдырганнар.* Бәет

5) Эшләми торганга әйләндерү, механизмын бозу. *Киләсе чәршәмбегә мин кырык кеше әзерлим, аларга үзем командир булам да «Фикер» идарәханәсендәге машиналарны, кассаларны – һәммәсен ватабыз.* Г.Тукай. *Автобусны ватканнар, хәерсезләр, ике-өч сәгать көттереп утырдылар да, бүген бара алмыйбыз, автобус юк, диделәр, хәтта ки гафу да үтенмәделәр, мәгънәсезләр…* Г.Ахунов. *Фатир йозагын ватмыйча гына кереп, сейфның ачкычын тапканнар һәм аны ачканнар.* З.Фәтхетдинов

6) *күч.* Тар-мар итү, җиңү. *Дошманнарның кат-кат сафын ватып, дәвам итәм барыр юлымны.* Ш.Маннур

7) *күч.* Бәреп, кагып җибәреп, тигезлеген, шомалыгын бетерү. --- *укытучы апа --- кояшлы чишмәнең суына бераз карап торды да, тигез өслекне ватып, учлары белән, чумырып, су алды.* Д.Каюмова

8) *күч. сөйл.* Бәясе зуррак акчаны шул ук бәядәге враграк акчаларга алмаштыру; акча ваклау. *Меңлекне вату*

9) *күч.* Юкка чыгару, юк итү, бетерү. *Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидегебез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады.* Г.Тукай. *Нурланып чыксын кояш, бу төнге зульмәтне ватып.* Һ.Такташ

10) *күч.* Ябу, яптыру, эшләүдән туктату. *Инде редакцияне дә шулай, хәрам дип, ватасыңмыни?* Г.Тукай

11) *күч. сөйл.* Авазларны, сүзләрне, гомумән, тел законнарын бозып сөйләү яки көйне бозып җырлау. *Тел ватып, «тил»ләрне каттык, бер татып күр – нинди тәм: Биргәнең – бер болганчык су, салганың – ватык сабу.* Дәрдемәнд. *Тыңкышланып сайрыйсың, Коръән ватасың, тук сыер күк мышнанып.* Г.Тукай. *Тел хакында бәгъзеләр ләчтит сата, Телкәйнең кабыргасын ватавата.* Р.Ханнанов

12) *күч. сөйл.* Буыннарда, сөякләрдә, мускулларда һәрвакыт авырту тою. *Артык изрәтми дә, тәнне дә ватмый.* А.Гыйләҗев. *Мин каты авырыйм. Миндә – коры сызлау… Аяк сөякләрем вата, чыдар хәл юк.* Г.Ибраһимов

13) *күч.* Кешенең сәламәтлеген какшату. *Иртә ватты мине дөнья. --- мин инде ватылып егылдым.* Г.Ибраһимов. *Атны бераз куаласаң, арба, түмгәктән түмгәккә сикереп, Нәфисәнең кан сауган гәүдәсен вата.* К.Кәримов

14) *күч.* Авыр эштән, күп йөрүдән соң арыту, талдыру, йончыту. *Юл ваткандыр, ял итегез!* К.Нәҗми. *Әни дәрес әйтә, бик нык вата икән ул – җир сөрү.* В.Нуруллин. *Чөнки бүген шактый арытты, ватты, душта коенып алырмын да ял итәрмен, дигән иде.* З.Хөснияр

15) *күч.* Бик каты итеп кыйнап ташлау, тукмау. *Шакирны дуңгыз урынына кыйнап, ватып җибәргәннәр.* Әкият. *Ерактан кайткан кунагым өчен, дип ялвардым үзенә, --- тыңламады бит, мөртәт, тотып ватасыңмыни ул сабакыны!* Ә.Еники. *Барысы да шунда таба йөгерә, урлаганын күрсә-күрмәсә дә «карак»ка ташлана, кулына ни эләксә – шуның белән ватарга тотына.* Ә.Еники

16) *күч.* Кыйнап йомшарту, сүсәртү. *Инде җитенне, судан чыгарып, җир өстенә тезделәр дә менә нығытып кыйнарга, менә ватарга тотындылар.* Дәрдемәнд

17) *күч.* Тормыш агышын чуалту, җимерү, таркату. *Галимҗан абыйга Гәүһәрнең болай уйлавы ошады, оешкан семьяны вату, җимерү – кыен түгел, ә менә саклап калу, туздырмау, айһай, күп көч сорый.* Г.Әпсәләмов. *Мин семьяны ватарга, җимерергә теләмим, Шәриф Гыйльманович. Шул ук вакытта минем өметем дә калмаган.* Г.Әпсәләмов

18) *күч.* Рухи газаплау, йончыту, авыру хәлгә китерү, нерв системасын какшату. *Сине кыса, вата хурлыклы тормыш.* М.Гафури. *Кызым, зинһар, үзеңне нык тотарга тырыш. Бердән, үзеңне ватасың, икенчедән – аны.* М.Фәйзи

19) *күч. информ.* Компьютер программасына үтеп керә алу, компьютер мәгълүматларын саклау системасын юкка чыгару

**2**. *и. мәгъ.* 1) Җимерү, юкка чыгару белән бәйле эшчәнлек. *Алпавытның резиденцияләре, революциядән соң, бик хәтәр җимерелүләргә, кыргыйларча котырынып ватуларга дучар ителсәләр дә, әле һаман кирпеч стеналарын, гөмбәзле түшәмнәрен саклыйлар.* Г.Ахунов

2) Наркоманнарда ияләшкән наркотикны кабул итүдән кинәт туктагач була торган авыр физик һәм психик халәт; *русчасы*: **ломка**

**Вата башлау** Ватарга тотыну. *Килә дә ул бу таш тауны вата башлый.* Г.Тукай. --- *аю төнлә тайгадан чыккан да, авылга килеп, берәүнең бурабзар ишеген вата башлаган.* М.Мәһдиев

**Вата бирү** Бернигә дә карамыйча ватуын дәвам итү. --- *имгәнүләргә Коръән хафизның һич исе китмәде, аз гына да тыела белмәде, һаман әүвәлгечә, елмайгандай ыржаеп, тиргәмисүкми генә, шәкертләрне вата бирде.* Ә.Еники

**Вата тору** Һәрберсен бер-бер артлы вату, ватуны дәвам итү. *Ә экзотика эзләп килгән туристларның һәрберсе кыйммәтле борынгы мирасны «истәлеккә» алып китәргә тырыша – таш орнамент, сыннарны чукып, кубарып, вата торалар.* А.Муранов. *Ягъфәр лом белән вата торды, Земфира кирпечләрнең матурларын гына сайлап тезде.* Я.Шәфыйков

**Вата төшү** Тагы да бераз вату

**Вата язу** Чак кына ватмау. *Егет җиңел генә әлеге уенчыкны кысты. – Вата яздың! – диде Сәет, егетнең кулларындагы көчкә вәйран калып.* Т.Галиуллин

**Ватып алу** Тиз-тиз генә, кыска вакыт арасында вату

**Ватып бетерү** 1) Барысын да вату, тәмам, төзәтә алмаслык дәрәҗәгә китереп вату. *Кемдер, тырышып-тырышып, шул урындагы язуны балта беләнме, кискеч беләнме, кылыч беләнме*

*каезлап, ватып бетергән.* Р.Батулла. *Җитмәсә, дошман снарядны кыйпылчыклары аның аякларындагы протезларны ватып бетерәләр.* Кызыклар дөньясында

2) *күч.* Бик нык вату, изү. *Шуның төсле үк, сине дә явыз язмыш теләсә ни кыландырып, изеп, яньчеп, ватып бетерәдер.* Г.Тукай

**Ватып җибәрү** Кинәт вату; ялгышлык белән вату. *Чү, урынына куй, ватып җибәрмә*

**Ватып карау** Ватарга омтылу, ватарга тырышу. *Бабай йомырканы ватып караган – вата алмаган. Әби ватып караган – вата алмаган.* Әкият

**Ватып кую** Кинәт, уйламаганда вату; ялгыш вату; ватылган хәлгә китерү. *Велосипедка ышанып харап булдым ла. Кичә Хәмит ватып куйган үзен.* Г.Нәбиуллин

**Ватып ташлау** Кинәт, дуамалланып вату, бөтенләй юкка чыгару. *Акпатша әйткән: – Гөлчәһрәнең туку станогын ватып ташлагыз! – дигән. – Үзен, богаулап, бирегә китерегез!* Р.Батулла

**Ватып тору** Бертуктаусыз, рәттән вату. *[Дулкыннар] Урын даулый, кысырыклый, Бер-берсен ватып тора.* Р.Юнысов

**Ватып чыгу** Һәрберсен, булган берсен вату, барысын да берәм-берәм вату. *Ул «борыннарның» очларын әйтерсең кемдер бик зур чүкеч белән махсус рәвештә ватып чыккан да ватыкларын шунда – су төбенә сибеп киткән.* А.Муранов

**ВАТУ́-ҖИМЕРҮ** *ф.* Хәрабәгә әйләндерү, туздыру, җимерү, юк итү. *Башкалардан уздыру өчен, яисә кызыксынудан гына булса да ватып-җимереп, сытып-изеп ташласалар?* Н.Вәлитова. *Кайчагында ул йөрәгенең шулай тыныч тибүенә, күкрәк читлеген ватып-җимереп, мәхәббәтнең үзгәсен, кайнарын таләп итмәвенә сәерсенеп тә куя иде.* Н.Гыйматдинова. *Туктаусыз, дип әйтерлек исеп торган каты җилләр --- бозы югарак булган урыннарның бозын вата-җимерә, ватык бозларны тоташ боз өслегенә этеп менгерә.* А. Муранов

**Ватып-җимереп тору** Бертуктаусыз вату-җимерү. *Үзәк Онегада туктаусыз диярлек исеп торган көчле җилләр суны дулкынландырып, аңа туңарга комачаулыйлар, юка бозларны ватып-җимереп торалар.* А.Муранов

**ВАТЫК** *с.* **1.** 1) Төрле кисәкләргә, өлешләргә ваклаган. *Якында гына яньчелеп беткән канистралар, ватык әрҗәләр аунап ята.* Н.Вәлитова. *Ватык көзге ярчыклары кебек сибелгән вак-вак күлләр, Чулман буендагы киң комлыклар аның күңелен дәртләндерде.* Д. Каюмова

2) Ватылган, кителгән, ярык. *Хафиза балчык әзләп йөри, ватык чүлмәк сыларга.* Г.Камал. *Ватык тәрәзәдән яңгырлы җил керә бүлмәгә.* Ш.Маннур

3) Файдаланып булмый торган хәлгә китерелгән; эшкә яраксыз. *Әгәр чит кеше аның күкрәгенә кулын куйса, һичшиксез, йөрәкнең ватык молотилка шикелле тигезсез, ритмсыз эшләгәнен сизәр иде.* М.Мәһдиев. *Клубта бер ватык хромкадан башка берни дә юк икән.* Ф. Садриев. *Җимерек, ватык, ташландык әйберләр идәндә аунап ята.* Г.Әпсәләмов. *Ул [Хәлим] кичә... юк ла, былтыр җәй, МТМдагы ватык комбайнны караштырып, ашлык сугарга төшәргә сүз биргән иде.* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Күп йөрүдән җимерелгән, чокырланган, тигезлеген югалткан, күп тапкыр файдаланудан һ.б.ш. сәбәпләр аркасында таушалган. *Туймазы – Уфа юлы бик шәп, киң, тигез асфальт, йөзеп кенә барасың, әмма, Бүздәктән Дәүләкәнгә борылгач, алтмыш километр чамасы юл бик алама булып чыкты. Шулхәтле ватык һәм тузанлы иде.* Ә.Еники. *Ватык юллар, янган зур калалар Без килгәнне көтеп яталар.* М.Җәлил

5) *күч. сөйл.* Тел законнарын бозып әйтелгән, бозык. *[Кемдер] Бераз ватык, шулай да җиңел русча тел белән сорады.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Авыртуы булган, авырта торган. *Һәм без караватта йокладык. --- ул минем кулымны үзенең ватык йөрәге өстенә куйдыртты да, балаларча мине кочаклап, төне буе сөйләшеп чыкты.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* Ватылган нәрсәнең китеге, кисәге, кыйпылчык, ярчык. *Археологлар бик күп тимер, бакыр көлләре, чүлмәк китекләре, кирпеч ватыклары, «сфероконус» дип атала торган терекөмеш савытлары тапканнар.* К.Тимбикова. *Шулпадагы сөяк ватыклары, оешкан күбекләр – барысы да сөзгечтә калачак.* Ю.Әхмәтҗанов. *И, мондагы пыяла ватыгы!* А.Гыйләҗев

◊ **Ватык авыз (агыз)** Тел законнары бозылган сөйләм, бозык тел. *Үзенең ватык агызлары илә яңадан бер кәррә сәлам биреп, --- мосафир үзенең анатолияле бер төрек идекене, һөнәре дә бакчачылык булып, ушбу шәһәрдәге Лимонадов нам бер бакчачыда иптәше илә бакчада хезмәт кыйлганнарыны ярым-ярты тупас төрек теле илә аңлатты.* Г.Камал

**ВАТЫ́К-ҖИМЕРЕК** *с.* **1.** 1) Ватылган, җимерелгән. --- *бик күп ватык-җимерек җиһазлар тирәсендә кайнашкан кешеләр, төтеннән кызарган күзләрен кара йодрыклары белән уа-уа сөйләнәләр: «Әле дә ярый төнлә булмады, мондый корыда, бу җилдә балачага белән шырылдап янасы икәнбез, Ходаем».* А.Гыйләҗев. *Уйсу җирдә – тезеп салган кебек рәт-рәт дошман үлекләре, ватык-җимерек корал калдыклары, ташландык инструментлар, тишек, яньчек каскалар, патрон, гильза өемнәре…* А.Таһиров

2) *күч. сөйл.* Авазларны, сүзләрне бозып әйткән; бозык. *Алар әлеге ватык-җимерек немец телендә тагын берхәтле сөйләшеп алдылар.* Ш.Маннур

**2.** *и. мәгъ.* Ватык, китек, җимерек әйберләр, нәрсәнең дә булса ватык, ярык урыннары. *Һәр ел көз, укучы балаларның аталары белән, мәктәпкә нигез салып, ватык-җимерекләрен төзәтеп йөрү Габденнасыйрны туйдырып бетергән иде.* М.Гали

**ВАТЫКЛЫК** *и.* Ватык, җимерек, китек булу. *Лампаларының кечкенәлеге, пыялаларының корымлы һәм пычраклыгы, ул корымлы пыялаларның да күбесенең ватыклыгы аларның яктырту хасиятләрен югалта язган.* Ш.Камал

**ВАТЫ́К-ПОТЫК** *с.* **1.** *сөйл. кимс.* Төрле кисәкләргә таркалган, җимерелгән, кителгән, сынган

**2.** *и. мәгъ.* Кыйпылчыклар, вак кисәкләр, чүп-чар. *Уртага ватык-потыкларын тутырып, сыек бетон белән ныгытсаң, --- йөз меңнән артыграк экономия [аласың].* А.Гыйләҗев

**ВАТЫ́К-СЫНЫК** *җый. и. сөйл.* Ватылган, җимерелгән, сынган төрле әйберләр. *Алардан да шушындый ватык-сыныклар гына калырмы?* М.Маликова

**ВАТЫ́К-ЧАТАК** *с. сөйл. к.* **ватык-чатнак**

**ВАТЫ́К-ЧАТНАК** *с. сөйл.* Ватылган, кырыйлары кителгән, ярык. *[Әби] Ватык-чатнак булсалар да, чынаяклары да куйган иде.* Г.Толымбай

**ВАТЫЛГА́Н-ҖИМЕРЕЛГӘН** *с. к.* **ватык-җимерек.** – *Ә син нык бул, калтырап төшмә, – диде. – Бу дөньяда ватылган-җимерелгәнне күп күрерсең әле.* М.Маликова

**ВАТЫЛУ** *ф.* **1.** 1) Кисәкләргә ваклану, чатнап ярылу, таркалу, сыну, җимерелү. *Тәрәзә ватылып кына, Урал тауларының бирге як табигатенә тәрәзә аша карап сокланудан барыбер туктамадык без.* Ә.Галиев. *Кирәк бит, шешә Мөзәкирнең тезенә килеп бәрелде, ватылмады, әмма тез күмәчен нык кына авырттырды.* А.Гыйләҗев. *Өй эчендә нәрсәдер шартлап ватылды һәм чәлпәрәмә килде.* М.Мәһдиев. *Андый ташлар, кәйлә белән дә, кувалда белән дә, бик зур көч куйганда гына ватыла.* Г.Ахунов

2) Хәрабә хәленә килү, җимерелү. *Кавдивизиянең йөгерек атлары баскан җирдә дошманның --- ватылган, җимерелгән станцияләре генә калды.* А.Шамов

3) Яраксыз хәлгә килү, эшләми башлау. *Автобус ярты юлда ватылды да, шәһәрдән кырык-илле чакрымдагы авылда куна калды ул.* К.Тимбикова. *Исламгали агайның өендә инде телевизор, күкеле сәгать, кырыну машинкасы, электр чәйнеге ватылган.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Бозылу, начарга әйләнү, кыенлашу. *Юкса, начар семья аркасында, тормышлар ватыла, кешеләр биртелә, гарип тойгылар җәмгать эшенә начар тәэсир итә.* Г.Кутуй

5) *күч. сөйл.* Авыр эштән, йөрүдән ару, талчыгу, йончу. *Мин юлда бик ватылганга һәм дә өйдә әллә нинди хиссиятләр башымнан кичкәнгә, бик арыган идем.* Г.Исхакый. *Хатынының көне-төне эштә ватылуын күреп, Нурулла яраланган җәнлек кебек ыңгырашып-ыңгырашып җибәрә иде.* А.Гыйләҗев. *Зиннәт вә тәкәллефаттан ерак торалар; ачлык күрмиләр, эшләп тә ватылмыйлар иде.* Г.Ибраһимов

6) *күч. сөйл.* Рухи кичерешләрдән, борчу-хәсрәттән, газаплардан, авыр тормыштан кешенең сәламәтлеге какшау, авыру хәлгә килү. *Әйе, бер кеше гомерендә – никадәр алмашыну, никадәр сытылу, ватылу, имгәтелү!* М.Мәһдиев. *Шул китүеннән елдан артык юк булып торып, унтугызынчы елның дикъәбер азагында гына, ранный булып, ватылып кайтып егылды.* З.Зәйнуллин. *Кичен чәй эчәр-эчмәс егылам... Иртән кузгала алмыйм, бөтен тәнем ватылган.* И.Салахов

**2. ватылган** *с. мәгъ.* Газапланган, йончыган, талчыккан. *Әгәр боларның һәммәсе бәрабәренә тагы бер генә сәгать йокы бирсәләр, аның ватылган сөякләре, бәлки, бераз ял итәрләр иде.* Г. Ибраһимов

◊ **Ватылмый торган** Җиңел, зур физик көч таләп ителмәгән, артык авыр булмаган. *Гомере буе ватылмый торган эштә генә эшләгән Имаметдиндә көч күбрәк иде.* З.Фәйзи

**Ватыла бару** Һәрберсе, булган берсе бер-бер артлы ватылу. *Минем өметләр, язгы гөрләвекләр өстендәге юка боз кебек, атлаган саен чатный, челпәрәмә килеп ватыла бара.* И.Салахов

**Ватыла башлау** Ватылырга тотыну, ватылу билгеләре күренү

**Ватыла тору** *к.* **ватылып тору.** *Ә өйләрдә чынаяклар, әйдә, ватыла торсын, өйләр гадәтле булсын, тату-әдәпле булсын.* К.Латыйп

**Ватылып бару** Акрынлап ватылу, торган саен, көннән-көн ныграк ватылу. *[Тегермән] Канатларының җиляңгырда калшаеп, ватылып баруы да ачык шәйләнде.* А. Гыйләҗев

**Ватылып бетү** Барысы да, тулысынча ватылу. *Совет заманыннан калганнары – барысы да [уенчыклар] искереп, ватылып беткәннәр иде инде.* А.Гыйләҗев. *Хәзер инде алар урынына ватылып беткән тау түбәләре генә калган.* Н.Вәлитова

**Ватылып китү** Кинәт, көтмәгәндә, уйламаганда ватылу. – *Минем дә – «Волга», тик менә ватылып китте әле, төзәтәсе бар, – дип уфтанып куйды Зәйнулла.* М.Насыйбуллин

**Ватылып тору** Һәрвакыт, еш ватылу. *Комбайннар беренче көннәрдән үк ватылып тора башлады.* Г. Кашапов

**Ватылып төшү** Ватылуга дучар булу, ватылган хәлгә килү. *Каюм, тиз генә, бишле лампаны рәтләп, ут кабызып җибәрде һәм ватылып төшкән башына калай әйләндереп утырткан куыкны лампага кигезде.* Ә.Фәйзи

**Ватылып чыгу** Ватылуга дучар булу, ватылган хәлгә килү. *Шулай булмаган очракта [инструкциясен өйрәнмәгәндә], техникагыз бик тиз янып, ватылып чыгачак яки сез аны тулы көчкә эшләтеп җибәрә алмаячаксыз.* Ф.Бәйрәмова. *Такта ишекнең астагы күгәне ватылып чыкты.* М.Мәһдиев

**Ватылып яту** Күпмедер вакыт ватылган хәлдә булу, ватылып, туктап калу. *Ирексездән ул юлларны, аларда чабышкан елгыр машиналарны бездәге чокыр-чакырлы, баткак-тумгәкле юллар, аларда ватылып яткан машиналар --- белән чагыштырдым.* Г.Тавлин. *Ярты ел буе ватылып яткан --- мототилканы төзәтер өчен, бары ике көн вакыт билгеләгәнсез.* Р. Ишморат

**ВАТЫЛУЧАН** *с.* Тиз ватыла торган, нык булмаган; бик нәфис, юка. *Киптерелгән кыслалар бик ватылучан.* А.Халидов

**ВАТЫ́П-ҖИМЕРЕП** *рәв. к.* **ватасындыра.** *Ике айда ул безне рус телендә укырга-язарга гына түгел, ватып-җимереп булса да, үзара бераз сөйләшергә дә өйрәтте.* Г.Лотфи. *Картның русчаны ватып-җимереп сөйләвенә дә карамастан, Усольцев аны игътибар белән тыңлады.* Н.Вәлитова. *Аларның [милләтләрнең] динен кысып, күнегелгән милли тормышын ватып-җимереп, фаҗига арты фаҗига китерүе рас.* Т. Әйди

**ВАТЫ́П-СҮТЕП** *рәв. сөйл. к.* **вата-сындыра.** *Сүзне Бәк-Бәкич алды.*

*Татарчаны ватып-сүтеп, русчаны сындыргалап, биш-алты сүз әйтте.* Х.Кәрим

**ВАТЫ́П-СЫНДЫРЫП** *рәв. к.* **ватасындыра**. *Тыңкыш тавышлы чандыр студент, «Су өсте» көенә, ватып-сындырып җырлый да башлады.* К.Нәҗми. *Имештер, ул [егет] телен онытып кайткан була… Ата-анасына русчаны ватып-сындырып сүз куша икән дә, тегеләр аңламыйлар.* Г.Толымбай

**ВА́У** I *и. гар.* Гарәп алфавитында егерме җиденче хәреф исеме. *Бер аятен гарәпчә мыгырданып, корышкан бармагы белән йөртеп чыкты да, тамак кырып тезде, вау килсә, бәхетле булыр, халык арасында кадерле булыр --- дип, эшлекле кыяфәт белән, Коръәнне киштәгә алып куйды.* М.Мәһдиев. *«Әлиф»не – таяк, «вау»ны чукмар дип белми икән – минем өчен ул бернәрсә дә түгел.* Г.Ибраһимов

**ВА́У** II, **ВА́У-ВАУ** *иярт.* **1.** Эт өргәндә чыккан тавышны белдерә. *Төнге маэмай – вау-у, вау… Килде микән әллә бүреләр?..* Х.Туфан. *Вау да вау – этләр өрә, Су анасы, этләрдән куркып, кирегә йөгерә.* Г.Тукай

**2**. *и. мәгъ.* Сабыйлар телендә эт. *Песи баскан каршына, Вау-вау качкан артына.* М.Саттаров

**ВА́У-ВАУ ИТҮ** *ф.* Эт өргән тавыш чыгару; өрү

**ВА́УЧЕР** *и. ингл.* 1) Дәүләт тарафыннан чыгарылган исемле хосусыйлаштыру чегы; кыйммәтле кәгазь. *«Ваучер» дип аталган мошенниклыктан соң, авылда «пай» дигән нәрсә пәйда булды.* Т.Миңнуллин

2) Товар сатып алу яки хезмәт күрсәткән өчен акчалата кредит бирү хокукы булган рәсми язу, документ

**ВАФА** *и. гар. иск. кит.* 1) Биргән вәгъдәдә, сүздә тору, тугрылык. *Россия --- вәгъдәсенә вафа күстәрмәде.* Г.Тукай

2) Ышанычлылык

**ВАФА́ ИТҮ** *ф.* 1) Изгелек, яхшылык итү, тугрылык күрсәтү. *Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам Галигә әйтте: «Йә Гали, инде нәзеремгә вафа итмәк вакыт булды: тор, бу кяфернең башын кис!» – диде.* К.Насыйри

2) Рөхсәт итү, мөмкинлек бирү. *[Шевченко] Тагы малорус телендә тарих, җәгърафия, риязият язмакчы иде, ләкин гомере вафа итмәде.* Г.Ибраһимов

3) Ышану. *Белеңез, дөнья дүгелдер пайдар, Һичкемә итмән вафа, әйләр гөзар.* М.Әмин

**ВАФА́ КЫЛУ** *ф. к.* **вафа итү**. *Аның өчен вәгъдәгә вафа кылуның кирәге бармыни?* Х.Кәрим

**ВАФАСЫЗ** *с.* **1.** *иск. кит.* Тугрылыксыз, хыянәтчел, былагай (*1 мәгъ.*). *Күрмәгез, бер яклы дип, сез бу вафасыз дөньяны, ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы.* Г.Тукай. *Ала чагыр дигән ала үрдәк Ак күлләргә төшеп таш ашый; Ышанмагыз һәрбер дус-ишләргә, Вафасыз ук дуслар баш ашый.* Җыр

**2.** *и. мәгъ.* Тугрылыксыз, хыянәтчел кеше. *Һай вафасыз, ни гаҗәп хәйлә куптарды, дип, ишектән чыгарга карады.* К.Насыйри

**ВАФАСЫЗЛЫК** *и. иск. кит.* Вафасыз булу, ышанычсызлык. *Сугышның мәрхәмәтсез вафасызлыгын үз күзе белән күрде ул.* Ә.Еники. *Хәят абыстай --- икенче мәхәббәтеннән дә аерылды. Дөнья да үзенең вафасызлыгын җиренә китерде.* З.Һади. *Вафасызлык – бу дөньяның эшедер, Вафасыз нәрсәдән бизмәк кирәкдер.* Ш.Зәки.

**ВАФАТ** *и. гар. кит.* Үлем. *Әнисе вафатыннан соң гына, ул сукырларча гомер сөрә башлаган.* К.Латыйп. *Әбүгалисинаның вафатын бер кешегә дә белдермәенчә, мәйданга китерде.* К.Насыйри. *Сәрия әтисенең вафат хәбәре килгәч, әниләре белән туган якларына кайтып киттеләр.* С.Сөләйманова

**ВАФА́Т БУЛУ** *ф.* Үлү. *Кыскасы, ике көн эчендә безнең кечкенә генә авылдан алты кеше вафат булды.* В.Нуруллин. *1549 елның март башында Сафагәрәй хан вафат булды.* Һ.Атласи

**ВАФА́Т ИТҮ** *ф. иск. кит. к.* **вафат булу**. *Вакыт ирешеп, Әбүгалисина вафат итте.* К.Насыйри

**ВА́ФЛЯ** *и. нем.* Шакмаклап яки туры почмаклык формасында ясалган, эченә әчкелтем, баллы шоколад һ.б.ш. эчлек сыланган татлы ризык. *Монда китап төялеп килгән --- ящиклардан кровать ясау – вафля пешерү шикелле тиз.* Г.Тукай

**ВА́ХМИСТР** *и. нем.* 1) *тар.* Патша Россиясендә: атлы гаскәрдә солдатның югары дәрәҗәсе (пехотада фельдфебельгә туры килә). *Запас атлы полк[тагы] --- вахмистр Шеликов, шулай ук, кичектерелмичә кулга алынырга тиеш.* К.Нәҗми. *Кавалериядә вахмистр булдым.* Ш.Усманов

2) Кайбер чит ил гаскәрләрендә солдатның югары дәрәҗәсе. *Карабиның немец вахмистрына биргәндә, [Шәрифҗанның] күзләреннән яшь атылып чыкты.* И.Гази

**ВА́ХТА** *и. голл.* 1) *махс.* Корабль иминлеген, тынычлыгын тәэмин итү өчен, билгеле бер урында дежур тору. *Бергә учебный отрядта булдык, бергә хезмәт итәбез, төнге вахталарда туган өйне сагынып гөрләшәбез.* М.Мәһдиев. *Хәйдәр Ваняның бушлатын салдыра да, --- көч-хәл белән генә рульне тотып торучы иптәшен алмаштырып, вахтага баса.* Г.Әпсәләмов. *Бүген вахтаның урыны – бакта түгел, ә капитан күпере янында.* Ә.Хәбибуллин

2) Кайда да булса озак вакыт дежурда тору. *Шулай Казанга кадәр шәп кайттык, тоткын кыз ашамадыэчмәде, әмма вахтаны мин өзмәдем.* М.Мәһдиев. *Милиция бүлегенә керәп, хәлне яхшылап аңлатып бирдем дә телефон янына вахтага бастым.* М.Юныс

3) Дежур тору урыны, вахтёрлар бүлмәсе. *Вахта каршысындагы баганага элеп куелган рельс кисәгенә сугалар. – Даң-доң! Даң-доң!* И.Салахов

4) Өзлексез эшләүне таләп иткән эш; шул эшләрдә бер смена эчендәге эш сәгате. *Иртән эшкә килгәндә, вахтадагы каракучкыл егет янында басып тора идең, мине күргәч, аның белән елмаеп-көлеп үк сөйләшә башладың.* Ә.Баянов. *Вахтадан кайтканда була бу хәл.* С.Сөләйманова. *Әйдә, дим, минем бүлмәгә керик, вахтадан соң чәй эчәсең киләдер, яңа таңны бергә каршылыйк.* Д.Каюмова

5) *махс.* Корабль экипажының, нефть чыгару бригадасының һ.б.ш.ларның

дежурлык итә торган бер өлеше. *Монда бернинди тәртип бозу юк. Казан егетләренең нәкъ, Түмәнгә йөреп, вахта алмаштырулары инде.* М.Мәһдиев

6) Аерым кеше яки кешеләр тарафыннан вахта хезмәтен башкару вакыты; смена. *Вахтада чагым туры килсә, дип, квартира ачкычын Лизаветаның кесәсенә салып китте.* С.Сөләйманова

7) *күч.* Гомумән яшәешне билгеләгән хезмәт, эшчәнлек. *Хәзер алар вахтага басты: бабайларына, аталарына алмаш үсте.* Ә.Хәбибуллин

8) *күч.* Берәр вакыйганы билгеләү йөзеннән яки махсус максатларда югары күрсәткечләр белән башкарылган эш, үткәрелгән чара, әмәл. *Багышлап, зур бәйрәменә Туган илнең, Килеп басты бүген тагын ул вахтага.* Ә.Исхак. *Трибунага, берәм-берәм, Яңа ел вахтасының алдынгылары чыга башладылар.* Г.Минский

**ВА́ХТА БҮЛМӘСЕ** *и.* Аерым кеше яки кешеләрнең вахта хезмәтен башкара торган урыны, вахтёрлар утыра торган бүлмә. *Вахта бүлмәсендә --- башта кешеләр берән-сәрән генә күренәләр, бераздан инде төркем-төркем булып килеп керәләр.* М.Шабай

**ВА́ХТА ЖУРНАЛЫ** *и.* Вахта вакытында булган вакыйгаларны, үтәлгән эшләрне хронологик тәртиптә теркәп бару өчен махсус журнал. *Һәр корабның иң мөһим документы – вахта журналы. Анда --- корабның бөтен көндәлек тормышы язылып барыла.* Р.Мостафин. *Будкага кереп, вахта журналына тиешле саннарны да утырттым.* Р.Төхфәтуллин

**ВА́ХТАЧЫ** *и.* Вахтада торучы кеше

**ВАХТЁР** *и. нем.* Учреждениедә дежур каравылчы; сакчы. *Капкага чабам. Вахтёр пропуск сорый.* Х.Гарданов. *Пропускымны вахтёрга күрсәтеп, цехтан чыгам.* М.Хәбибуллин. *Алар проходнойга керделәр, вахтёрлар белән саубуллаштылар.* Г.Әпсәләмов

**ВАХТЁРЛЫК** *и.* Вахтёр булу; вахтёр булып эшләү

**ВА́ХТМАН** *и. нем.* Немец полициясендә надзиратель. *Вахтманнар, мылтык түтәләре белән кизәнә-кизәнә, әсирләрне төрткәлиләр.* Н.Дәүли. *Абзар капкасы авызыннан немец вахтманының яшел тавышы яңгырады.* Ш.Маннур

**ВАҺҺАБИ** *и. гар.* 1) Ваһһабчылыкка караган юнәлеш, караш. *Исламның ваһһаби мәзһәбе*

2) *к.* **ваһһабчы.** *Бәхетең, безнең як басуларда җир астында газ торбалары юк, югыйсә, террорчы ваһһаби, дип, аягыңны җиргә дә тиермәсләр иде...* Р.Зарипов

**ВАҺҺАБЧЫ** *и.* Ваһһабчылык тарафдары. *Бу яман ярлыкны кемнәр уйлап тапкан да, «ислам терроризмы» дигән гыйбарә нәрсәне аңлата икән, Мирза әфәнде? Шулай ук хәзер еш яңгырый торган «ваһһабчы» сүзенә аңлатма биреп китсәгез иде.* Р.Вәлиев

**ВАҺҺАБЧЫЛЫК** *и.* Мөхәммәд бине Габделваһһаб исеменнән: XVIII гасырда Гарәбстанда барлыкка килгән, гарәп кабиләләрен берләшүгә һәм төрек басып алучыларына каршы көрәшкә чакырган дини-сәяси тәгълимат; XIX гасырда бу тәгълимат беренчел прогрессив характерын югалта, хәзерге вакытта Согуд Гарәбстанында рәсми идеология булып тора. *Рәсәйдә соңгы сәяси вакыйгалар, кайбер дин әһелләренең, татар дөньясын ваһһабчылык идеяләре басып китте, дип лаф орулары үзебезнең дини мәгариф системасын булдыруның нинди мөһим эш икәнлеген тагын бер мәртәбә искәртте.* Г.Исхакый

**ВА́ШГЕРД** *и. нем. тех.* Ләмле һәм бөртекле руданы, аеруча алтынга бай комны юдыру җайланмасы. *Буа тирәсендә рәттән тезелгән вашгердлар янында алтын юучы хатын-кызлар һәм ирләр мыжгып эшлиләр иде.* М.Гафури. *Вашгердта алтын бөртекләрен җыяр өчен махсус урын бар.* М.Гафури

**ВӘ** *терк. гар. кит.* Һәм. *Фатыйманың ачык вә матур йөзе һәм тавышындагы самимилек вә кайгырту аһәңе Шакирны инде гаҗәеп бер айныту белән айнытып җибәрде.* Ф.Әмирхан. *Ул, аның хәленең кәефсезлегенә вә тормышының караңгылыгына гаҗәпләнеп, сораша башлады.* Г.Тукай

**ВӘ ӘЛЕХ** *и. гар. кит.* Һәм башкалар, һәм болардан башка..., моннан башкалар. *Татарча газета вә журналлар чыга башлагач, мин, әүвәл, бер журналда язышучы булып, аннан соң бер газетада баш мөхәррир булып бардым вә әлех, вә әлех...* Ф.Әмирхан

**ВӘ́-ВӘ** *иярт.* Бала елаган тавышны белдерә. *Улым башта матур итеп елмайды, аннары, авызын бөрештереп, «вә-вә» дип елап җибәрде.* М.Мәһдиев. *Яшьтәш исә, әнисенең беренче онытын күтәреп, «вә-вә-вә» дип көйли.* М.Мәһдиев. *Гайшә, Вәлине үчекләгән кебек, авызын бозып, «вә-вә-вә» дип куя.* К.Әмири. *Күрше бүлмәдәге баланың «вә-вә» дип елаганы ишетелә.* Сөембикә

**ВӘГАЗЬ** *и. гар.* 1) Үгет-нәсыйхәт, яхшылыкка өндәү, акыл бирү. *Вәгазь рәвешендә язылган китапларның никадәр тәэсире булачаклыгын күрәсебез килә.* Ф.Әмирхан. *Вәгазь тыңлау күңелне йомшарта һәм безне кылган гамәлләребезгә нәтиҗә ясарга этәрә.* Г.Исхакый

2) *дини* Җомга һәм дини бәйрәмнәрдә күмәк намазлар укыганда, мәчеттә – имамның, дини мәҗлесләрдә Коръән укучының, гыйбрәтләр китереп, дини нәсыйхәт бирү төсендәге чыгышы; хөтбә. *Милләтебезнең терәкләре – байлар, сез – малларыгыз белән, газиз динебезнең баганалары – муллалар, сез – вәгазьләрегез белән бу ярдәмне, беренче нәүбәттә, сез күрсәтергә тиешсез.* К.Тинчурин. *Менә мәчеттә, безнең кебек ярлы, зәгыйфь кешеләрне рәнҗеткән байларга азрак вәгазь бирер идең, хәзрәт.* Ш.Камал

3) Үгетләп, өйрәтеп, акылга өндәп, димләп сөйләнгән сүз(ләр). *Безнең яшь язучы шагыйребезгә хас --- агитация, вәгазь юк диярлек, аз.* Г.Нигъмәти. *Яратмыйм шундый вәгазе белән тыгылган кешене.* Г.Бәширов. *Хәзер әти-әнисенең вәгазьләре янына Вәсиләнең дә тавышы кушылып китә.* А.Гыйләҗев. *Үзләренең бүлмәсенә кайткач, ул әлеге «шахмат уены» турында шактый үтемле бер вәгазь сөйләп алды.* Г.Ахунов

**ВӘГА́ЗЬ ИТҮ** *ф. к.* **вәгазьләү.** *Зәйнәп өйгә кергәч, алар вәгазь итәргә керештеләр.* М.Гафури

**ВӘГА́ЗЬ КЫЛУ** *ф. к.* **вәгазьләү**. *Сәхабәләре үкүш (күп) булды эрсә, пәйгамбәргә, вәгазь кылмак өчен, мөнбәр бирделәр.* М.Булгари

**ВӘГАЗЬЛӘҮ** *ф. иск. кит.* Үгет-нәсыйхәт бирү, үгетләү, акылга өндәү. *Аннары, басуга чыгып, мулла безне бик нык вәгазьләде, бар гөнаһлардан тәүбә кылырга кушып, икешәр рәкәгать намаз укытты.* М.Гали. *Атасы, хатынны еш яз, укуыңны тизрәк бетереп кайт, дип вәгазьли.* Г.Ибраһимов

**Вәгазьләп алу** Бераз вәгазьләү, тизтиз, кыска вакыт арасында вәгазьләү. *Яшьләр арасында чагыр турысында сүз кузгалса да, Фәтхулла агай бик нык каршы торды һәм азрак вәгазьләп алды.* Ш.Камал

**Вәгазьләп йөрү** Кемгә яисә кемнәргә дә булса әледән-әле вәгазь уку. *Син монда абыйны вәгазьләп йөрисең йөрүен дә, дәресләреңне укыганмы?* Ф.Әмирхан. *Кеше вәгазьләп йөргәнче, бөтенләй үзең укып чыксаң, яхшырак булыр иде.* Ф.Әмирхан

**Вәгазьләп карау** Вәгазьләргә омтылу. *– Ходайга шөкереңнән гаҗиз булырга кирәк; «эчем поша», имеш, ни дигән сүз ул, башыңа нинди кайгы төшкән соң синең? – дип, вәгазьләп карады.* Ф.Әмирхан. *Фәтхулла хәзрәт, төрле кыяфәтләргә кереп, мине вәгазьләп тә карады, җәһәннәм белән куркытып та карады.* Ф.Әмирхан. *Нишлим соң инде, әти, мин аны инде бик озак вәгазьләп карадым.* Г.Камал

**Вәгазьләп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта вәгазьләү. *Шулай торганда, аны староста дәшеп алды: – Әй, нәрсә вәгазьләп торасың тагын анда?..* Г.Бәширов

2) Һәрвакыт, гел вәгазьләү. *Әмнә сезне нинди дер милли мәмләкәт төзергә вәгазьләп торган бу адәм – Чирканды мулласы малае!* В.Нуруллин

**Вәгазьли башлау** Вәгазьләргә тотыну

**Вәгазьли бирү** Бернәрсәгә карамастан, вәгазьләүне дәвам итү

**Вәгазьли төшү** Тагы да бераз вәгазьләү

**ВӘГА́ЗЬ-НӘСЫЙХӘТ** *җый. и. гар. кит.* Акыл өйрәтеп сөйләгән сүз, үгет-нәсыйхәт. *Бер кермәсә, бер керер, дигән ният белән, телевидение, радио аркылы да вәгазь-нәсыйхәт кылабыз.* Г.Исхакый. *Хәзер бөтен педагогия голәмасы, коры вәгазь-нәсыйхәт һәм кушу белән, шәкертләрне бер мәсләктә тәрбия итүдә дөньяга һичбер төрле нәзар бирә алуны мөмкин тапмыйлар.* Ф.Әмирхан. *– О, тагын вәгазьнәсыйхәт, – диде Закиров, кулларын бутап җибәреп.* А.Шамов. *Нәрсәдер бар синең бу вәгазь-нәсыйхәтеңдә.* А.Шамов

**ВӘГА́ЗЬ УКУ** *ф. к.* **вәгазьләү**. *Малай белән булганда вәгазь укымам, дип вәгъдә бирсә дә, ул бу юлы тыела алмады.* А.Гыйләҗев

**ВӘГАЗЬЧЕ** *и.* **1.** Вәгазь сөйләүче, үгет-нәсыйхәт бирергә яратучы кеше; вагыйз. *Туйдым инде бу вәгазьчеләрдән. Бөтенесе өйрәтә, киңәш бирә.* М.Әмир

**2.** *с. мәгъ.* Нинди дә булса бер фикер, караш таратучы, пропагандалаучы. *Татарның ул чордагы язучыларыннан Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Гафил бине Габдулла, Закир Һади, Фатих Халиди һәм башкалар кебек, Г.Камал – вәгазьче, әхлакчы язучы түгел.* М.Гали // Һәркайда үгет-нәсыйхәт сүзләре сөйләп, акыл биреп йөрүче. *Синең вәгазьче дустың үзенең гадәтен ташламый*

**ВӘГАЗЬЧЕЛЕК** *и.* Вәгазьче булу; вәгазь уку белән мәшгуль булу. *Кайбер тәнкыйтьчеләр --- Тукайның кайбер шигырьләрендә артык вәгазьчелек, әхлакчылык күрәләр.* Җ.Вәлиди. *Шулай булуга карамастан, аның беренче әсәрләре булган «Бәхетсез егет» белән «Өч бәдбәхет»тә, заман модасына бирелеп, берникадәр әхлак сату һәм вәгазьчелек тенденцияләре үткәрү юк түгел, ләкин алар нык кабартылып күрсәтелмиләр.* М.Гали

**ВӘ ГА́ЙРЕ** *и. гар. кит. к.* **вә әлех.** *Әбүҗәһил вә гайре кемсәнәләр мигъраҗ инкяр иттеләр.* К.Насыйри. *Башка йортларның да кайсының – берәр стенасы, кайсының түбәсе юк икәнлеге, кайсына пар белән җылыту өчен көпшәләр үткәрелсә дә, пар казанының куелмаганлыгы вә гайре вә гайре кимчелекләре мәгълүм булды...* Ә.Исхак

**ВӘ ГА́ЙРЕҺИ** *и. гар. кит.* Һәм башкалар, моннан башкалары

**ВӘГАЛӘ́ЙКЕМӘССӘЛАМ** *ы. гар.* Очрашканда кулланыла торган «әссәламегаләйкем» сүзенә каршы сәлам кайтару сүзе («сезгә дә тынычлык, иминлек телим!»). *Һәр хәрефне җиренә җиткереп, тавышны борынгарак җибәреп һәм сузып, булачак мулла сәламне кайтарды: «Вәгаләйкемәссәлам».* Г.Исхакый. *Вәгаләйкемәссәлам, хаҗи әфәнде, әйдә, хуш киләсез.* Ш.Камал. *Вәгаләйкемәссәлам, Баймөрат. Әйдә, теге якка узыйк.* Т.Гыйззәт

**ВӘГЪД** *и. гар. дини* Ахирәттә бүләкләү вәгъдәсе

**ВӘГЪДӘ** *и. гар.* 1) Берәр нәрсәне эшләргә, үтәргә, башкарырга ышандырып әйтелгән, үз ризалыгы белән алынган йөкләмә; нәрсә дә булса үтәргә, эшләргә бирелгән сүз. *Тик менә шунысы бар: быел яздан ук, Габделкаюмга, Казанга җыен кунакларын алырга барганда, сине дә утыртып җибәрермен, Казан күреп кайтырсың, дип биргән вәгъдәм бар иде.* М.Гали. *Әллә кичәге вәгъдәсе исеннән чыкты инде.* Ш.Камал. *Минем көй чыгарырга биргән вәгъдәмне үз файдаңа бормакчы буласыңмы?* М.Фәйзи. *Ләкин ул да биргән вәгъдәсен үтәмәде.* Г.Ибраһимов

2) Ант; ихлас биргән, үтәлүе мәҗбүри булган сүз. *Вәгъдәңне, сәүдәгәр сүзенә, Казан-йортка тугрылыгыңны кан белән беркетү фарыз.* Ф.Латыйфи

3) Нәрсә дә булса эшләү яки эшләмәү турында үзара килешү, алдан сүз беркетү. *Бәлки, чын да вәгъдәң бардыр, Парлашып ял итәргә.* М.Җәлил. *Вәгъдә буенча, алдагы базар көнне, төнге сәгать уникеләрдә, тар, караңгы тыкрыкка, акрын гына атлап, сиртмәле тарантас җигелгән ат килеп керде.* М.Мәһдиев

4) Егет белән кызның гомергә бергә булырга сүз куешуы. *Сәҗидә белән Илдарның вәгъдәләре бар икән, Үзләре дә бик пар килгән, Уйлары да пар икән.* М.Җәлил

5) *сөйл.* Алдан килешенгән вакыт, билгеләнгән срок. *Шулвакыт, вәгъдәсе җиткәч, Габденнасыйр, һөнәргә өйрәнер, дип, Габделкаюмны, Казанга*

*илтеп, балтачы Әхмәтҗанга өйрәнчек малайлыкка бирде.* М.Гали

6) *иск. кит.* Язмыш тарафыннан билгеләнгән вакыт. *Белмәссең, бәлки, Ходайдан вәгъдә җитмәсә, терелеп тә китәр.* Г.Камал

◊ **Вәгъдә алу** Икенче якның өйләнешергә ризалыгын алу. *Кыз ягының вәгъдәсен алдык инде алуын. Хәзер алда туй мәшәкатьләре тора.* Казан утлары. **Вәгъдә бирү** 1) Нәрсә дә булса эшләргә яки эшләмәскә сүз бирү, ант итү. *Әйткәне хак иде, вәгъдәне биргән иде.* Ф.Латыйфи; 2) Ышандыру, сүзен ныгытып кую. *Әткәй-әнкәй алдында биргән вәгъдәм өчен, Салават баһадирның Мәргәне каберендә эчкән антым өчен, мин еланнарга очрамаска, боларның агуы белән зәһәрләнмәскә тырыштым.* Г.Ибраһимов. *Ул Газинурдан биргән вәгъдәсен онытмаска, укырга, берәр һөнәргә өйрәнүен үтенгән.* Г.Әпсәләмов; 3) Сөйләшеп килешү, сүз беркетү; бер сүздә булу турында алдан килешеп кую; 4) Егет белән кызга карата: өйләнешү турында үзара сүз беркетү, килешү; 5) Егет белән кызны өйләндерергә ике якның да уртак килешүе, сүз беркетү. *Ходайга тәвәккәлләп, Гаптерәшиткә вәгъдә бирикме әллә, кызым?* М.Фәйзи. **Вәгъдә бозу** Биргән антын, сүзен үтәмәү, яки үтәүдән бөтенләй баш тарту. *Мин Галләмгә биргән вәгъдәмне боздым.* М.Фәйзи. **Вәгъдәдә тору** Биргән вәгъдәсен үтәү. **Вәгъдәдән кайту** *к.* **вәгъдә бозу**. *Кичәге вәгъдәгездән, шаять, кайтмагансыздыр бит?* Г.Кутуй. **Вәгъдә йоту** *к.* **вәгъдә бозу**. *Безнең атлар бик шәп түгел, Үр куяны тотарга; Әллә, җаныем, саташтыңмы, Вәгъдәләрең йотарга?* Җыр. **Вәгъдә куешу** Үзара килешеп вәгъдәләшү. *Ахырында, Батыргали агай илә икәү бергә, дус-ишләргә сиздермичә генә, сугышка китәргә вәгъдә куештылар.* Ш.Мөхәммәдев. **Вәгъдә кую** *к.* **вәгъдә бирү.** *Мәрьямне, мин кайтмый торып, Мәхмүткә бирергә вәгъдә куймагыз.* М.Гафури. **Вәгъдә кылу** *к.* **вәгъдә итү.** *Аталарына каршы торып булса да, кылган вәгъдәсенә хилафлык итмәс өчен тырышты.* М.Гафури. **Вәгъдәсен вак таракан ашау** *к.* **вәгъдәсен вак тараканга ашату**. – *Әй, бушка лыкылдау гына булып калды ла ул! Вәгъдәне вак таракан ашады. Район алдында оятлы гына булдык, – диде.* Г.Бәширов. **Вәгъдәсен вак тараканга ашату** Әйткән сүзен, вәгъдәсен үтәмәү. *[Мәликә апа] Сиңа, йөз мәртәбә, уенчык алып бирәм, дип вәгъдә итә, әмма вәгъдәсен гел вак тараканга ашата.* Г.Ахунов. *Менә шушы ханым үзе кыю, үзе ягымлы, вәгъдәсен беркайчан да вак тараканга ашатмас, әйткән сүзен ул егылып үлсә дә үти, эшне оештыра белә.* Г.Ахунов

**ВӘГЪДӘ́ БИРНӘСЕ** *и. этн.* Башкода килеп сөйләшкәндә, ризалык билгесе итеп, кыз ягыннан егет ягына бирелә торган бүләк. *Вәгъдә бирнәләрен дә бик һәйбәт итәчәкләр, сиңа – күлмәклек җон, кияүгә...* Г.Камал

**ВӘГЪДӘ́ БҮЛӘГЕ** *и. этн.* Кыз белән егетне өйләндерү хакында беренче килешү булгач, ике яктан да бирелә торган бүләк. *Кияү булачак кеше [бу башмакларны] вәгъдә бүләге итеп җибәргән.* Т.Гыйззәт

**ВӘГЪДӘ́-ИМАН** *и. гар.* Әйткән сүзендә нык торачагына ышандыру, ант итү сүзе; вәгъдәнең һичшиксез үтәләчәгенә ышандыру сүзе. *Вәгъдә-иман! Әйттеңме – сүзеңне үтә!* З.Ганиева

**ВӘГЪДӘ́ ИТҮ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса эшләргә сүз бирү, үз өстеңә йөкләмә алу. *Инде, вәгъдә иткәнгә, каберен ныгытыйм, ташлап китмим, вәгъдәне җиренә җиткерү өчен, шунда каберен саклыйм, дидем.* Мәҗмугыл хикәят. *Кырым, көне буе ял итүче, дәвалanучы халыкка матур сәгатьләр вәгъдә итеп, уянып килә иде.* М.Мәһдиев. *Сабан туена йон кофта алырга, шәллек мамык җыярсыз, дип, мамык кәҗәсе асрый башларга вәгъдә итәм.* Ә.Гаффар

2) Берәр нәрсә бирергә ышандыру. *Хаҗи әфәнде вәгъдә иткән егерме биш сумны бирер, аннан гына тормас.* Ш.Камал

3) Үз эшендә яки берәр өлкәдә уңышларга ирешәчәгенә өмет тудыру. *Ул – бердәнбер эшче театры һәм күп нәрсәләр вәгъдә итә торган театр.* М.Җәлил

**ВӘГЪДӘ́ КӨНЕ** *и.* 1) *дини* Ислам динендә бәндәнең кавышу көне, тәкъдирдә, язмыш (ләүхелмәхфүз) китабына алдан язып куелган көн, шунлыктан, никах, кавышу кебек олы эшләр, шушы алдан билгеләнгән вәгъдә көне җитү белән, сәгатендә булмыйча калмый, дигән ышанудан. *Күрәсең, хәзергә әле вәгъдә көне генә җитмәгән.* Ф.Хөсни

2) Туйга, никахка яки берәр эшкә вәгъдәләшкән көн. *Вәгъдә көне иртәгә бит, мин нишлим?* М.Мәһдиев. *Вәгъдә көне дә җитеп, түземлек тә төкәнә башлады.* Г.Бәширов

**ВӘГЪДӘЛӘ́Ү** *ф. сир.* Берәр нәрсә бирергә яки башкарырга ышандыру, вәгъдә итү. *Кайчан кайта соң инде ул? Һаман вәгъдәлисез дә вәгъдәлисез.* А.Шамов. *Ә 1939 елны әти, татар язучылары арасында беренчеләрдән булып, орден белән бүләкләнде. Бу инде – аның киләчәк юлының якты нурлар астында гына барачагын вәгъдәли иде кебек.* К.Гыйззәтов

**Вәгъдәләшеп кую** Алдан вәгъдәләү

**Вәгъдәләп тору** Һәрвакыт, даими вәгъдәләү

**ВӘГЪДӘЛӘШҮ** *ф.* 1) Вәгъдә куешу, килешү, сүз беркетү. *Кайдадыр очрашалар, сөйләшәләр, вәгъдәләшәләр дә эшне бетерәләр.* Г.Ибраһимов. *Шул арада, бер-берсенә генә ишетелерлек, өзек-өзек шыпырт кына тавыш белән, вәгъдәләшә иделәр.* Ш.Камал

2) *этн.* Өйләнешергә сүз куешу. *Алар җәйгә, Һашим кайткач, туй итәргә вәгъдәләшкәннәр.* Г.Әпсәләмов. *– Ул – алтынчылар, зәргәрләр нәселеннән. Мин аның белән сүз куештым... Вәгъдәләштек инде. Казандагы иң маһир зәргәр Галиәкбар оста кызы, – диде Шәһит.* Ф.Латыйфи. *Мин ул егет белән вәгъдәләштем инде. Аннан башка беркемгә дә бармыйм.* Ф.Хөсни. *Вәгъдәләшкән кызымны бер мужик малае кулымнан тартып алсын да, мин баш иеп калыйм, имеш.* М.Фәйзи

**Вәгъдәләшеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта вәгъдәләшү йолаларын үтәү белән мәшгуль булу

**Вәгъдәләшеп кую** Алдан вәгъдәләшү, вәгъдәләшергә өлгерү. *Нигә? Нигә гөнаһ булсын? Минем колагымны*

*тешләтеп, вәгъдәләшеп куярга аларның ни хакы бар? Колагымны тешләгән, дип кенә, яратмаган кешемә ничек барыйм мин?* М.Фәйзи. *Ә Зөһрә белән Батырҗан күптән инде вәгъдәләшеп куйган булганнар*. Ф.Яруллин

**Вәгъдәләшеп тору** Әле, хәзерге вакытта вәгъдәләшү

**ВӘГЪДӘЛЕ** *с*. **1**. 1) Нәрсәне дә булса эшләргә, башкарып чыгарга ризалык белдергән. *Әгәр кумаса, әгәр иреннәреннән бер үптереп кенә яки берәр вәгъдәле җылы сүз пышылдап кына кире җибәрсә дә, ул барысын да аңлар иде.* Ә.Еники

2) *этн.* Вәгъдә биргән, вәгъдәләшкән, өйләнергә яки кияүгә чыгарга ризалык биргән, килешенгән, сүз куешкан. *Ул кыз бала күптән вәгъдәле инде. Туй көннәрен генә билгелисе калган.* Ф.Әмирхан

3) Алдан билгеләп куелган. *Көннәр бик тиз уза. Вәгъдәле көн дә җитеп килә.* М.Укмасый

4) Әйткән сүзендә нык торган. *[Геннадий:] Фәрит бик вәгъдәле кеше икән. Әгәр дә нәрсәне дә булса, эшлим, дип тотына икән, һичшиксез башкарып чыга.* Казан утлары

**2**. *и. мәгъ.* Вәгъдә куешкан кеше, өйләнешү турында сүз беркеткән кеше. *Кичәгә нур өстенә нур булып коелганы – ул вәгъдәлеләр тантанасы.* Э.Касыймов

**ВӘГЪДӘСЕЗ** *с*. Сүзендә, вәгъдәсендә тормаган, ышанычсыз. *Мөхәммәт абый миннән, егерме еллар, әнә шул шигырьне көтеп йөргән, ә мин, вәгъдәсез, язмаганмын...* Р.Харис. *Никләр генә киттем икән – никләр генә шул вәгъдәсез Тим-Тимгә ышандым икән?* Ф.Яруллин. *Аның вәгъдәсез кеше икәнлеген белгәч, башка сөйләшмим дә.* Казан утлары

**ВӘГЪДӘСЕЗЛЕК** *и.* Вәгъдәсез булу, ышанычсыз булу, вәгъдәне бозу, сүзендә тормау. *Бу нинди вәгъдәсезлек инде бу, ә? Ничәнче көн инде кереп тә чыкмый бит яныма.* Н.Исәнбәт

**ВӘГЪДӘЧЕЛ** *с*. 1) Вәгъдәсендә, сүзендә торган, вәгъдәсен бозмый торган. *Хәер, әле башы яшь, шулай да, мондый вәгъдәчел ярдәмчеллеге белән, бүгеннән депутат итеп куярлык*. Х.Ибрагимов. *Аның гадәте, какшамас яшәү халәте шул иде: беркем үтенмәсә дә, ул яшь талантны күзеннән ычкындырмый, эш дигәндә – үтә вәгъдәчел, тугры сүзле, аның өчен тик йөрү, ялган, кода-кодагыйлык бөтенләй чит-ят нәрсә иде.* А.Гыйләҗев

2) Вәгъдә (*1 мәгъ.*) бирергә яратучы, вәгъдәгә юмарт. *Безнең күрше вәгъдәчел вәгъдәчелен дә, әйткән сүзен генә үтәми.* М.Мәһдиев

**ВӘГЪДӘЧЕЛЛЕК** *и.* Вәгъдәчел булу. *Дустымның вәгъдәчеллегенә мин ышандым инде*

**ВӘГЫД** *и. гар.* 1) Кол, хезмәтче. *Бу халыкның барчасы – вәгыд хәлендәдер.* И.Салахов

2) Түбәнлек; хурлык. *Вәгыдтан чыгарга омтылу*

**ВӘГЫДДАР** *с. гар.-фар. кит.* Түбәнлекле, түбән, хурлыклы. *Наданлык вә һөнәрсезлек кеби ике олуг вәгыддар...* М.Акъегет

**ВӘЗГЫЯТЬ** *и. гар. к.* **вазгыять**. *Хәлбуки, бүгенге халәттә, вәзгыятьтә үзем белән мин канәгатьмен.* К.Латыйп. *Анда Россиядәге сәяси вәзгыять, татар һәм Татарстан халкының бүгенге проблемалары, аларны хәл итүдә милли оешмаларның бурычлары, Россиядә халык санын алу h.б. мәсьәләләр каралачак.* Мәгърифәт

**ВӘЗЕМЛӘ́Ү** *ф.* **1**. Нәрсәне дә булса җентекләп, аңлаешлы, матур итеп, тәфсилләп сөйләү. *Аңа Әнвәрнең хәле турында шомартып-түгәрәкләп кенә язган идем мин, инде, күзгә-күз карап сөйләшкәндә, барысын да вәземләргә туры килде.* Э.Касыймов. *Болар икесе дә алай чемченергә, вәземләргә дә яратмыйлар, сүзне кыска тоталар.* Э.Касыймов

**2**. **вәземләп** *рәв. мәгъ*. Җентекләп, бөтен нечкәлекләрен дә әйтеп, тәфсилләп. *[Фәтхерахман (артыннан карап калып):] Мәгънәсез кеше икән, аңгыра нәрсә икән, вәземләп сөйләгәннең дә мәгънәсен белми, – ди.* Г.Камал. *Мәүлиха түти, урманның тонык шаулавын бүлдермәскә теләгәндәй, йомшак тавыш белән, бик вәземләп сөйли.* Г.Бәширов. *Ләкин шундый нечкә әйберләр турында вәземләп сөйләшә торган матур русча сүзләрне кайдан алырга?* Г.Бәширов. *Шуларның хасиятен, серхикмәтләрен берәмтекләп, вәземләп аңлатып йөргән булды [ул]*. Г.Ахунов

**Вәземләп тору** Әле, хәзерге вакытта вәземләү

**Вәземләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да вәземләү

**ВӘЗЕН** *и. гар. әд.* Шигырь үлчәве, ритм, такт, иҗек саны. *Бәхерләрнең үз эчендәге үлчәмнәре «вәзен» дип атала. Бәхерләр төренә карап, вәзеннәрнең дә саны төрлечә була.* Х.Курбатов. *Шагыйрьнең әйтергә теләгән фикерләре, бирергә уйлаган тойгылары вәзен, бетем, строфалар эчендә кысылып калмаска тиешле.* Г.Нигъмәти. *Инде хәзер, заманыбыздагы кечкенә генә калфаклы туташларыбыз тугрысында җырлаганда да, барыбер шул ук вәзен, шул ук рәвеш белән җырлагандыр.* Г.Тукай. *Мин исә, бераз вәзен мәсьәләләре өстендә эшләп алыйм, дип, өстәл янына барып утырдым.* Г.Ибраһимов

**ВӘЗЕНДӘШ** *с. әд.* Бер үлчәмдәге, ритмдаш, берүк төрле үлчәмле. *Чөнки «ученья»гә «мученья» яхшырак вәзендәш ич!* Г.Тукай. *Бу персиян..., «якыйн» вә «амәфтә хуп» сүзләренең вәзендәш түгеллекләрен сизәр иде.* Г.Тукай

**ВӘЗЕНДӘШЛЕК** *и. әд.* Бер үлчәүдә, бер вәзендә булу

**ВӘЗЕНЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) *к.* **вәземләү.** *Вак-төяк хәбәрләрне дә вәзенләргә ярата.* Казан утлары

2) *күч. сөйл.* Тәфсилләп, төпченеп, нык төшенеп эшләү, сөйләү

**2. вәзенләп** *рәв. мәгъ.* Тәфсилләп, нечкәләп. *Мөрәҗәгать хатның азаккы юлларын Хөсәен һәр сүзенә аерата басым ясап, вәзенләп укыды.* А.Расих. *Әгәр эшне белеп, вәзенләп оештырсаң, дошманнарны берәм-берәм төбенә төшерергә җайлы җим буласы икән.* А.Гыйләҗев. *[Кулешов] Кирпечләрне ничек ялгарга да җекләрне ничек сыларга кирәклеген вәзенләп сөйләп бирде.* А.Гыйләҗев

**Вәзенләп тору** Һәрвакыт, гел вәзенләү // *юкл. форм.* Вәзенләргә, артык

күп сорашырга кирәк тапмау. *Утырып чыгуы хак, дидем, нинди сәбәпләр аркасында – анысын вәзенләп тормадым.* Р.Низамиев

**ВӘЗЕНЧӘЛЕК** *и. әд. к.* **ритмика.** *Без, Йосыф китабы үлчәвен, халкыбызның үз вәзенчәлеге нигезенә корылган, дип язып киләбез.* Н.Исәнбәт

**ВӘЗИР** *и. гар. тар.* Урта гасырда Көнчыгыш илләрендә: патша яки ханның дәүләт эшләрен башкаручы иң зур дәрәҗәле вәкиле. *Сакчы – бер якка, хан, үз вәзире белән, икенче якка юнәләләр.* Н.Исәнбәт. *Солдат кызын сөеп газап чиккән Вәзир улы идең түгелме?* Ф.Бурнаш. *Сезне дә үз сараема вәзир итеп алам.* Д.Аппакова. *Аның барлык яхшылыкларыннан берсе бу иде: акыллы, укымышлы, мөхтәрәм, игелекле, тугрылыклы, өлгер, булдыклы бер кешене вәзир итеп куйганнар.* Мәҗмугыл хикәят

**ВӘЗИ́Р-ВӨЗӘРА** *җый. и. гар.* Вәзирләр, аларның ярдәмчеләре, якыннары, киңәшчеләре. *[Егет] Падишаһчык, вәзир-вөзәра илә исәнләшеп, поездга утырып китте.* Г.Тукай

**ВӘЗИРЛЕК** *и. тар.* Вәзир вазифасы, вәзир хезмәте, вәзир булу. *«Бу елны вәзирлекне миңа бирүеңне үтенәм», – диде. Вәзир дә, бер дә аптырамыйча: «Мин Иранда тудым, хезмәтем вәзирлек иде», – ди.* Г.Тукай. *Вәзирлек хезмәте Урта гасырларда алай аталмаган. Ханның иң якын киңәшчесе – вәзир түгел, башкарачы. Казан ханлыгы чорында – карачы.* Р.Батулла. *Патша риза булды, вәзирлекне аңа бирде.* Мәҗмугыл хикәят. *Син, яхшылык күрсәтеп, безне туфрактан күтәреп, кадерләп, вәзирлек урынын миңа боердың.* Мәҗмугыл хикәят

**ВӘЙРАН** *с. фар.* **1**. 1) Ватык, җимерек, туздырылган, хәрабә хәленә килгән. *Авылыгыздагы вәйран маллар, әрәм җирләр әнә шул ашъяулык кадәр генә булса иде әгәр.* Р.Төхфәтуллин. *Без ярлыйкларымызда: монда урын буш – вәйран, акчасыз кешеләргә торырга мөмкин түгел, дип яздык. Безнең падишаһымыз – олуг кенәз, безгә тормышлык җибәрсен иде, дидек.* Һ.Атласи

2) *күч.* Гаять аптыраган, нык гаҗәпләнгән. *Хисап итеп караса, калды хәйран, Үзенең кылдыгый малына вәйран.* Ә.Фәйзи

**2**. *рәв. мәгъ.* Зая(га), әрәм(гә), буш(ка). *Алар сүзенә карап, яшь башың белән, гомереңне вәйран үткәр, имеш!...* Г.Рәхим

◊ **Вәйран башын хәйранга калдыру** Болай да авыр хәлдә булган кешенең эшен тагын да катлауландыру. *Әллә, Ходаем, болай да вәйран башымны хәйранга калдырып, берәр урынга куймакчы булалармы?* Ф.Хөсни

**ВӘЙРАНӘ** *и. фар.* Җимерекләр, җимерелергә торган корылмалар. *--- җил сызгырып торган, ташландык вәйранәләр шикелле буш биналар янына килеп чыктык.* Ш.Камал

**ВӘЙРА́Н БУЛУ** *ф.* 1) Җимерелү, ватылу, тузу, хәрабә хәленә килү; тар-мар ителү, юкка чыгу. *Пуля һәм снаряд белми аяуны, --- Шәһәр була вәйран, кабер.* К.Нәҗми

2) *күч.* Харап булу, һәлак булу; бәлагә очрау. *Үзе, малы белән халыкка никадәр хезмәт күрсәтә ала торган бер егет, вәйран булып китсенме?* М.Фәйзи

3) Чиктән тыш гаҗәпләнү, аптырау, хәйран калу. *Күз алдында узган хәлләргә вәйран булып калдык.* И.Салахов

4) Кызганыч, ямансу хәлдә булу, заяга үтү. *Вәйран булып ята үткән гомер – Ничек бара моңа адәм кулы!* Г.Афзал

**ВӘЙРА́Н ИТҮ** *ф.* 1) Җимерү, вату, юк итү. *Такташыбыз торган ташпулатны вәхшиләрчә вәйран иткән.* Казан утлары

2) *күч.* Тар-мар итү, һәлак итү, бетерү. *Ләгыйньнәр дөньясын вәйран итәрбез.* Ә.Исхак

3) Аң югалту, аңгыраеп китү, аптырап калу. *Базарлардан кайтканда Вәйран иттем башымны.* Бәет. *Бер кискән икмәк кире ябышмый, акылыңны җый, илдә сылу бетмәгән, тәмле ашыңның тәмен калдырып, хәйран башыңны вәйран итеп... Нәфисә шикелле матурлар тагын да табылмас дисеңме?* Г.Бәширов

**ВӘЙРА́Н КАЛУ** *ф.* 1) Бушау, бушап калу. *Төшсез чикләвек шикелле, кешесез вәйран калган ташпулатлар, биек сарайлар --- чын сур илә җаваплашалар.* Г.Тукай

2) *күч.* Аптырау, гаҗәпләнү, хәйранга калу, гаҗәпләнгән хәлдә булу. *Синең бу гамәлләреңә вәйран калам мин, дустым. Боларны бары тик син генә булдыра аласың.* Г.Бәширов. *– Вата яздың! – диде Сәет, егетнең кулларындагы көчкә вәйран калып.* Т.Галиуллин

**ВӘЙРАНЛЫК** *и.* Хәрабәлек, җимереклек, хәрабә хәлдә булу, җимерек хәлдә булу. *Безнең илебезгә фашист мордарлар китергән җимерүләрне, вәйранлыкларны төзәтүгә күпме еллар кирәк булыр икән?...* М.Максуд

**ВӘКАЛӘТ** *и. гар.* 1) Берәр кешегә яки төркемгә нинди дә булса ил, оешма яисә җәмгыять тарафыннан рәсми рәвештә бирелгән хокук. *Оешманың барлык эшен башкарырга аңа тулы вәкаләт бирелде.* Ф.Хөсни. *Сицилия, Италия конституциясе буенча, аерым автоном хокукларга һәм вәкаләткә ия.* Казан утлары

2) Вәкиллек, икенче бер ил яки оешма тарафыннан нәрсәне дә булса эшләргә бирелгән хокук. *Хезмәтне саклау буенча җәмәгать инспекторы, профсоюз җыелышында, ачык тавыш бирү юлы белән, профгруппа вәкаләтләре срогына сайлана.* Авыл хуҗалыгы куркынычсызлык техникасы

**ВӘКАЛӘ́Т КӘГАЗЕ** *и.* Нинди дә булса эшкә вәкаләтле булуны яки эш йөкләтелгәнлекне раслый торган таныклык, мандат. *Вәкаләт кәгазе тапшыру. Вәкаләт кәгазе алу*

**ВӘКАЛӘТЛЕ** *с.* 1) Авторитетлы, зур абруйлы, мөһим мәсьәләләр чишәргә хокуклы. *Казанда булган бик вәкаләтле бер җыелышта уңышка ирешкәч, гостиницада Фәүзия хәтта үз бүлмәсендә сөйләшеп утырырга да чакырды.* Ә.Баянов *Бу сүзләрдән шулкадәресе аңлашылды: әлеге зур, вәкаләтле комиссиянең төп отчётын да шушы иптәшләр төзиячәкләр икән.* М.Хәсәнов

2) Нинди дә булса проблемаларны чишәргә хокук бирелгән, рәсми хокуклары булган. *Советлар иленең*

*вәкаләтле илчеләре, галәмдә булып кайтып, «кешелек җәмгыятенең киләчәк буыннар өчен мул җимешләр китерердәй гигант казанышлар яулавына» ныклы нигез салулары белән үлемсезлек казандылар.* В.Шурлыгин. *Янгураз, якягына каранып: «Ә закон, хөкем итәргә вәкаләтле хәрби трибунал кайда?» – дип аптырады.* Т.Әйди

**ВӘКАЛӘТЛЕК** *и. к.* **вәкаләтлелек**

**ВӘКАЛӘТЛЕЛЕК** *и.* Аерым вәкаләткә ия булу. *Бу илченең вәкаләтлелеге тәмамланды инде.* М.Хәбибуллин

**ВӘКАЛӘТНАМӘ** *и. гар.-фар. кит. к.* **вәкаләт кәгазе;** мандат. *Авыл халкы тарафыннан үз исеменә бирелгән вәкаләтнамә морзага вексельдәге Әкрәм карый имзасын законлаштыру, тасдыйк итү өчен кирәк булыр, дигән уй бу минутта аның башына да кереп карамады.* М.Галәү. *Патша хәзрәтләренә вәкаләтнамә язып тапшырырга кирәк.* Казан утлары

**ВӘКАЛӘ́Т ЯЗУЫ** *и. к.* **вәкаләт кәгазе**

**ВӘКАРЬ** *и. гар. кит.* **1.** Мәһабәтлек, горурлык; җитди кыяфәт. *Ул үзенең дәрәҗәсен нинди генә хәлләрдә дә онытмый, вәкарь саклый.* А.Расих. *Шулай да фигурасы, сыны бик күп татар хатыннарыныкы шикелле зәгыйфьләндерелгән булмавы, карашындагы вәкаре, причёскаланган чәче өстенә куелган калфагының үзенә килешеп торуы белән, миндә яхшы хис калдырдылар.* Ф.Әмирхан. *Сәетнең һәр сүзендә вәкарь, үз дәрәҗәсен белгән кешеләрнекечә салмаклык, олылык сизелә.* Ф.Латыйфи

**2. вәкарь белән** *рәв. мәгъ.* 1) Үз дәрәҗәсен белеп кенә, горур кыяфәт чыгарып. *Егет җавап биреп өлгермәде, сабырлык белән, вәкарь белән атлап, салкын караш белән, байбичә килеп керде.* Г.Ибраһимов. *Ул, ашыкмыйча, вәкарь белән генә сөйләшә.* Г.Коләхмәтов. *Барыгыз да чыгып торыгыз, диде ул, вәкарь белән генә.* М.Мәһдиев. *Вәкарь белән генә, төркемләнеп, чит ил студентлары үтеп китте.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Горурсымак, горур гына. *Нәкъ болар ишек ачуга, кабинеттагы җиз битле зур сәгать, көттереп кенә, вәкарь белән, тугызны сукты.* Г.Бәширов. *Бик вәкарь белән, бер ак кош йөзә. Нәрсәдер эзләнгәләп, күктә бер зур кош гизә.* Р.Харис

3) **вәкарь илә** *к.* **вәкарь белән**. *Кояш --- тавышсыз, акрын гына, вәкарь илә генә «Суык бабай»га каршы күтәрелә башлады.* Шура

**ВӘКАРЬЛЕ** *с. кит.* 1) Үзенең бәясен, дәрәҗәсен, тоткан урынын, кадерен белгән, эре, мәһабәт, горур. *Боярлар, кенәзләр, вәкарьле кыяфәткә кереп, тезелешеп бастылар.* М.Әмирханов. *Этләр арасында Сабирҗан абзыйның бозау хәтле, яман да көчле, йонлач карабайлары да бар иде – үзенең аяусыз кодрәтен белгән сыман, бик вәкарьле генә кыяфәттә, алдан атлый ул.* М.Рафиков

2) *күч. кит.* Күңелгә рәхәтлек биреп торган, мәгърур. *Бөтен урамга иңгән ниндидер вәкарьле бер тынлык фәкать ара-тирә ишетелә торган хайван тавышлары белән генә бозылып китә.* Ф.Әмирхан. --- *авылга иңгән шушы вәкарьле тынычлыкны саклаучының торышы – шушы игътикатлы вә тәртипкә өйрәтелгән көтүне күзәтә торган хаким көтүченең торышы төсле тоела иде.* Ф.Әмирхан

**ВӘКАРЬЛЕК** *и.* Олысымаклык, мәһабәтлек, горурлык, җитди кыяфәт. *Салмаклыгы, кеше белән аралашуда вәкарьлеге белән танылган Сәет сәүдәгәрнең болай пырдымсыз кылануын башка вакытта күпләр сәерсенеп карап калыр, бер-бер хәл булгандыр, дип фараз итәр, ярдәмгә ашыгыр иде.* Ф.Латыйфи. *[Ул] Мин белгәнне сез белмисез, сез белгәнне мин беләм, дигән вәкарьлек белән, әрле-бирле йөренә-йөренә сөйли дә башлады.* Ш.Галиев. *Сакаллы хәлфәләр, мыеклы пишкадәмнәр кибет, ашханә, тәһарәтханә арасында аеруча көязләнеп, вәкарьлек күрсәтеп йөреп торалар.* К.Тинчурин

**ВӘКАРЬЛЕЛЕК** *и.* Вәкарьле булу, мәһабәтлек, мәгърурлык. *Яшь мулланың вәкарьлелеге үзенә бер ягымлы, ятышлы иде.* Мирас

**ВӘКИЛ** *и. гар.* 1) Берәр төрле оешманың яки аерым кешенең мәнфәгатьләрен кайда да булса яклаучы, алар исеменнән эш йөртүче ышанычлы кеше. *[Аллаһ] Фәрештәсен вәкил итеп вәхи җибәрә.* М.Гафури. *Бүгенге әңгәмә-киңәшмәдә Кама каскадының иң эре ГЭСын салачак «Камгэсэнергострой» вәкилләре дә катнашачак иде.* М.Хәсәнов. *Дәүләт регистры вәкилләре пароходны җентекләп карап йөриләр.* М.Юныс. *Вәкил --- тузан сарган күн итекләренең кунычын гармунлап аска төшерде дә шыгыр-шыгыр басып китте.* А.Гыйләҗев

2) Берәр ил мәнфәгатьләрен яклаучы вәкаләтле кеше, дәүләт хезмәткәре. *Франция вәкиле Лайх моңар каршы: «Бу тугрыда Франция хөкүмәте Англия хөкүмәте белән аерылыша», – [дигән].* Ф.Әмирхан. *Дипломатия вәкиле*

3) Теге яки бу катламга, төркемгә, иҗтимагый хәрәкәткә караган һәм аларга хас сыйфатларны үзендә берләштергән кеше. *Һәр сыйныфның вәкилләре шул сыйныфның файдасына химая итәргә вә шулар фикерендәге нәрсәләрне сөйләргә башладылар.* Ф.Әмирхан. *Айсылу – авыл советларында һәм колхоз идарәләрендә эшләүче меңләгән хатын-кызлар вәкиленнән берсе.* Г.Бәширов. *Әсәрдә үзәк урын тоткан шәхесләр, гади психологик типлар, җәмгыять тормышында берәр төркемнең типик вәкилләре итеп бирелүдән бигрәк, индивидуаль эчке сыйфатларга ия булган, һәрберсе берәр хирыска бирелгән кешеләр итеп бирeләләр.* Г.Нигъмәти

4) Иҗтимагый эшчәнлек төре, алып барган хезмәте белән аерымланган төркемнең бер кешесе. *Матбугат дөньясы вәкилләреннән игъланчы, календарьчы Шәрәфетдин Шәһидуллин беренче була.* И.Рәмиев

**ВӘКИЛЛЕК** *и.* 1) Вәкил булу, вәкил булып тору. *Башкортстан Язучылар берлеге каршындагы татар телле язучылар берләшмәсе рәисе Рәшит Сабит җитәкчелегендәге вәкиллек тәгаенләнде.* Ф.Фаткуллин

2) Вәкил вазифасын үтәү хокуклары. --- *кияү буласы егет, үзенең атасы яки ага-энесе булмаса, вәкиллекне кемгә тапшырса да ярый; хәтта атасы*

*сәламәт булса да, ят кешегә вәкиллек бирсә дә ярый.* К.Насыйри

3) Берәр оешмага җибәрелгән вәкилләр. *Ә дипломатия, илчелек, вәкиллек – бүгенге вазгыятьнең вакытлы уеннары гына, дөресрәге, күз буяу.* М.Әмирханов

4) Берәр төрле оешма, ил мәнфәгатьләрен күзәтүче оешма. *Корабта Сингапурдагы Совет сәүдә вәкиллеге хезмәткәре булды.* Р.Мостафин. *Иң элек, Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты тарафыннан, Мәскәүдә, Алма-Атада һәм Санкт-Петербургта сәүдә-икътисад вәкиллекләре ачылды.* Сөембикә

**ВӘКИЛЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Вәкил вазифасын үтәү. *Абруйлы үзәкнең Ходайны һәм Аның пәйгамбәрен вәкиллек итү функциясен үз өстенә алырга ни хакы бар?* Р.Хәким

**ВӘКИЛЛЕКЛЕ** *с.* 1) Оешма яки җәмәгать эшләрен үтәргә тулы хокукы булган, тулы вәкаләт бирелгән, вәкаләтле. *Үз заманында Жан Жак Руссо, вәкиллекле демократиягә аклау тапмыйча, аны тәнкыйтьләгән.* Р.Хәким

2) Сайлап куелган вәкилләрдән торган. *Халык депутатлары Советлары, халыкның вәкиллекле органнары буларак, дәүләтнең сәяси нигезен тәшкил итә.* Татарстан Республикасы Конституциясе

3) Күпсанлы катнашучылар вәкиллегеннән торган. *Дәүләт Думасы – 1905–1917 еллардагы революция барышында төзелгән, вәкиллекле, формаль яктан закон чыгару функцияләре булган учреждение.* Р.Мөхиярова

**ВӘКЫФ** *и. гар. кит.* **1.** *к.* **вакыф**. *Әхмәт байның вәкыфыннан мәдрәсәгә күпме өлеш чыккан?* К.Нәҗми

**2.** *с. мәгъ.* Берәр бай яки җәмәгатьчелек тарафыннан уку-укытуга, ярлыларга ярдәм йөзеннән бүләк итеп бирелгән. *Мәдрәсә хәзрәтнеке түгел, ул – вәкыф йорт.* Г.Ибраһимов

◊ **Вәкыф козгыны** *тирг. кимс.* 1) Бүләк итеп бирелгән акчаны яки малны үзләштерүче кеше. *Вәкыф козгыны Вәли мулла моңа риза булмады.* Ф.Әмирхан; 2) Эш вазифасыннан файдаланып, үз мәнфәгатьләре өчен, хөкүмәт малын астыртын рәвештә үзләштерүче кеше. – *Вәт тибә раз, Ибрай таз! – диде ул. – Шундый аңгыра булгач, төзелеш трестын ничек җитәкләдең соң син, вәкыф козгыны?!* З.Мәхмүди

**ВӘКЫ́Ф ИТҮ** *ф.* Мәдрәсә яки мәчет тоту өчен, акча яки мал бүләк итү. *Бәхтияров үз кулындагы бөтен байлыгын уку-укыту юлына вәкыф итеп калдыра.* Ф.Әмирхан. *Ул, янәсе, үз милкендәге җирләрне, урманнарны, болыннарны Казанда яңа мәчет белән мәдрәсә асрау өчен вәкыф итеп бирәчәк, имеш, дигән ялган хәбәр тарат тыра.* К.Нәҗми

**ВӘКЫФНАМӘ** *и. гар.-фар. кит.* Вәкыф итеп бирелү турында рәсми документ; вәкыфны билгеләү турындагы акт

**ВӘЛӘ́КИН** *терк. гар.* Җөмләдәге тиңдәш кисәкләрдән яки ике мөстәкыйль җөмләдән аңлашылган фикерләрне капма-каршы куя; ләкин, әмма, тик. *Яратырга ярый кышны, вәләкин зәмһәрире бар.* Г.Тукай. *Вәләкин, яһүд сәүдәгәрләре тырышлыгы белән, кахан ислам диненнән ваз кичә.* М.Хәбибуллин

**ВӘЛИ** *и. гар. кит.* 1) Ия, хуҗа (берәр нәрсәгә); башлык (берәр эштә). *Без, иң беренче, вәлиебез фикеренә колак салырга тиешбез.* Г.Тукай. *Гарәп хәрефләрендәге нокталар вә башка бәгъзы бер ишарәтләр, --- Габделмәлик заманында, Гыйрак вәлисе Хиҗҗаҗ бине Йосыф әмере белән чыгарылган.* Г.Алпаров. *Бу заманга кадәр шәһәр вәлиенең хезмәтләрен күп башкардым, күп кирәк-ярагым аның сәбәбеннән хасил булды.* Мәҗмугыл хикәят

2) Кемне дә булса яклаучы, кайгыртучы, аңа ярдәм итеп торучы, опекун. *Имам Мөхәммәд Һарун әр-Рәшит заманында Бәйтелмалның вәлисе иде.* К.Насыйри

3) *дини* Үзенең гомерен дингә, Аллага багышлаган, дин кануннарын төгәл үтәүче изге, әүлия кеше. *«Дөнья» дигән сарайга җәбер-җәфа тулдыйа. Урыс халкы ишәйде, мөселманнар хур булды, Ничә вәли, ничә газиз Шәһадәтләр таптыйа.* Бәет. *Инде [хаҗи] булган вәлиләрдән: бохарча чалмасы.* М.Укмасый. *Бу адәм – вәлиләрдән, дия иде.* З.Һади

**ВӘЛИ́ ВӘКИЛ** *и. этн.* Никахка кадәр, әле килешү вакытында үтәргә кирәк булган эшләрне кыз яки егет исеменнән алып баручы кеше. *Кызның вәли вәкиле дигәне атасы Нурмөхәммәт иде.* Г.Ибраһимов. – *Ә син, мулла кем, Әхмәдһади Максуди, Биби Кәүкәбелфәна Календаретдин кызыны, вәливәкил булып, «Азад»етдин бине Социалистетдин угылына бирдеңме? – Бирдем ... Бирдем.* Г.Тукай

**ВӘЛИЛЕК** *и. кит.* Вәли булу. *Сез бит – беренче суфилык, хәтта вәлилек дәгъвасы кылган кеше.* Г.Тукай. *[Мөхетдин Гарәбинең] Шөһрәте галәмгә җәелде. Аннан соң, суфичылык гыйльме белән шөгыльләнеп, вәлилек дәрәҗәсен тапты.* К.Насыйри

**ВӘЛИ́ НИГЪМӘТ** *и. иск.* Ашамлык-эчемлекләр булдыручы, шуларга хуҗа кеше; кемнәрнедер ашатучы, туйдыручы кеше. *Башына киткәч, --- вәли нигъмәтләре исерек марҗага мәдхия җырлый.* Г.Тукай. *Сез безнең тәрбиябездән чыккан, дип хисап ителеп, шул хакта вәли нигъмәтләрегезгә хәбәр күндерәчәкбез.* К.Тинчурин

**ВӘЛҮК** *и. рус сөйл. диал.* Атларны арбага, чанага яки сабанга җиккәндә, мичәү баулары бәйләнә торган агач; мичәү агачы. *Берние дә юк икән лә. Ике постромка бавы да бер вәлүк. Эләктердең куйдың...* Ф.Шәфигуллин. *Атларны вәлүктән ычкындырды да китте бу.* Ф.Хөсни

**ВӘС, ВӘ́С-ВӘС** *ы.* Сарык, сарык бәтиләрен чакырганда яки куганда әйтелә торган сүз. *[Гапсаттар] Ризасызланып, чыбыркысын шартлатып кычкыра: «Һәйт, вәс!»* Ю.Әминов. *Әбинең урамда, «вәс-вәс-вәс» дип, сарыкларны чакырганы ишетелә.* Казан утлары

**ВӘСВӘСӘ** *и. гар.* 1) Кешенең күңелен ялган хәбәр белән дулкынландыру яки нинди дә булса кирәксез гамәлләр кылырга котырту, саташтыру гамәле; коткы, котырык. *Имештер, күл төбендә су кызлары, җен-пәриләр яши,*

*дип, әкиятләр тыңлап үскән кызның, кайчагында, күңеленә вәсвәсә иңә.* Ф.Латыйфи

2) Шикләнү, икеләнү хисе; төрле шик-шөбһә, борчу. *Өметсезлек, усаллык, вәсвәсәләр Зәгыйфь җанны теләләр һәм кисәләр.* Г.Тукай. *Син, акыллым, вәсвәсәгә бирелмә инде. Эшлә, укы.* Г.Әпсәләмов

3) Шомлану хәле, хәвеф, курку хисе. *Диңгез вәсвәсәсе минем күкрәгемә оялап өлгергән иде инде.* М.Юныс

◊ **Вәсвәсәгә килү** Күңел шикләнү, икеләнү, шик-шөбһәгә бирелү. *[Шәвәли абзый] --- уйлары белән вәсвәсәгә килеп ята торгач, түзмәде, хатынына дәште.* Г.Ахунов

**ВӘСВӘСӘ́ БИРҮ** *ф.* Кемне дә булса берәр эшкә, гамәлгә котырту; тәшвиш кузгату. *Син, халыкны котыртып, вәсвәсә биреп йөрмә!* Ф.Әмирхан

**ВӘСВӘСӘЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Шикләндерү, борчылдыру

2) *к.* **вәсвәсә бирү.** *Шомырттай кара күзләре, тулы алсу иреннәре, кабарыбрак торган алма бите, сызылып киткән нәзек кашлары, йомры ияге күңелне вәсвәсәләндереп, үзенә тартып тора.* М.Әмирханов

**Вәсвәсәләндереп алу** Кыска вакыт эчендә, бераз вәсвәсәләндерү

**Вәсвәсәләндереп тору** 1) Һәрвакыт, гел вәсвәсәләндерү. *Кыскасы, шул: шайтан күңелне ничек кенә итеп вәсвәсәләндереп тормасын, Шәйхигә тел тидерергә ярамый иде әле.* В.Нуруллин. --- *Татар педагогия техникумы. Анда – бөтенләй башка рухи дөнья... Әле ахыргача аңлашылып бетмәсә дә, күңелне җилкендереп, вәсвәсәләндереп торган яңа дәвер.* Ә.Рәшит

2) Вәсвәсәләнгән хәлдә булу; вәсвәсәләнерлек итү

**ВӘСВӘСӘЛӘНҮ** *ф.* Вәсвәсәлегә әйләнү, нәрсәдән дә булса шикләнү, шөбһәләнү; тынычсызлану. *Боларны күз алдына китерсәң, Ларисаның бу рәвешле вәсвәсәләнүен аңларга да була.* М.Маликова. *Соңгы көннәрдә Хәерниса карчык бик тынычсызланды, вәсвәсәләнде.* Г.Газиз

**Вәсвәсәләнә башлау** Вәсвәсәләнергә тотыну. *Хәерле эшне ашыктырмасаң, шайтан катыша. Вәсвәсәләнә башлыйсың.* Н.Исәнбәт

**Вәсвәсәләнә төшү** Бераз, тагы да вәсвәсәләнү

**Вәсвәсәләнеп алу** Кыска вакыт эчендә вәсвәсәләнү

**Вәсвәсәләнеп калу** Ниндидер сәбәптән, тәэсирдән вәсвәсәләнгән халәт алу. *Ул, каушап, үз эченнән вәсвәсәләнеп калды: «Бу – нинди бәхетсезлек? ...Әллә язмышның берәр бәласе миңа таба якынлашып киләме?»* Г.Ибраһимов

**Вәсвәсәләнеп карау** Бик нык вәсвәсәләнү

**Вәсвәсәләнеп яту** Вәсвәсәләнгән халәт кичерү. *Мәгыйшә түти, Йөзлекәй карчыкның яңа йортта ни өчен төшкә керүен аңлый алмыйча, төрле гөманнар эчендә вәсвәсәләнеп ята торгач, таң алдыннан тагын йоклап китте.* Г.Ахунов

**ВӘСВӘСӘЛӘНҮЧӘН** *с.* Шикшөбһәгә бирелүчән, шөбһәләнүчән. *Кызның күңеле бик вәсвәсәләнүчән иде.* М.Мәһдиев. *Әллә барын да минем шикләнүчән, вәсвәсәләнүчән хыялым гына уйлап чыгарамы?* Г.Ибраһимов

**ВӘСВӘСӘЛӘ́Ү** *ф. к.* **вәсвәсә бирү.** *Вәсвәсәли уңган егетләрне Хәмерләрнең төрле-төрлесе.* И.Сабиров

**Вәсвәсәли башлау** Вәсвәсәләргә тотыну. *Башта аяк терәп каршы торсам да, хур кызлары, затлы исерткеч эчемлекләр белән вәсвәсәли башлагач, үзем дә сизмәстән, муенына менеп атландым.* З.Мәхмүди

**Вәсвәсәләп тору** Һәрвакыт, гел вәсвәсәләү

**ВӘСВӘСӘЛЕ** *с.* **1.** 1) Күңелне котырта, аздыра торган. *Рәшиднең шәрә ботлары, изүенең ачылып киткәләве Мансурны вәсвәсәле уйларга этәрә.* С.Шәрипов. *Вәсвәсәле күңелгә исә шайтан кереп оялый.* Ф.Сафин

2) Шик, шикләнү, шөбһә тудыра торган, шикләндерә торган. *Бу вәсвәсәле шомның кара афәте, иң беренче булып, шушы өйгә бәреп керә.* Р.Төхфәтуллин

3) *к.* **вәсвәсәчел.** *Соңгы вакытларда Лариса – бик вәсвәсәле, уйчан.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Борчулы, шикләнүчән, хафалы, тынычсыз. *Күршебез бик тынычсыз, вәсвәсәле булып чыкты.* Ф.Хөсни

2) *куч.* Шау-шулы, гөж килеп торучан. *Май аенда Горький урамы аеручан вәсвәсәле була.* М.Юныс

**ВӘСВӘСӘ́ САЛУ** *ф.* Күңелгә шик салу, шикләндерү, коткы салу, котырту. *Шулай булгач, хатын-кыз хакында сөйләп, кызның күңеленә вәсвәсә салуның кемгә хаҗәте бар*? Ф.Сафин. *Бу кызый минем күңелгә әллә нинди бер вәсвәсә салды бит әле.* И.Салахов. *Шунысын онытма, затлы мал дошман җанына вәсвәсә сала, үчләштерә, көнләштерә, нәфесен котырта.* Ф.Латыйфи

**ВӘСВӘСӘ́ ТАРАТУ** *ф.* Шик-шөбһә тудыру

**ВӘСВӘСӘЧЕ** *с.* **1**. 1) Күңел аздыручы, нинди дә булса ярамаган, кире эш эшләргә котыртучы. *Безнең арада вәсвәсәче кеше булырга тиеш түгел.* Г.Әпсәләмов

2) Күңелгә шик-шөбһә салган, борчулы, тәшвишле хәбәр тараткан. *Теге вәсвәсәче карчык тагын килеп утырган безгә.* Ш.Камал

**2**. *и. мәгъ.* Күңел аздыручы, котыртучы, шик-шөбһә, коткы салучы кеше. *Вәсвәсәче, ачуын йөзенә чыгармыйча, тыныч кына сүз башлады.* З.Мәхмүди

**ВӘСВӘСӘЧЕЛ** *с.* Шикләнүчән, һәркемгә, һәрнәрсәгә шикләнеп караучан. *Вәсвәсәчел күңелемә тагын шик, шом керде.* М.Юныс. *Гайниянең, болай таң тишегеннән, көрәк тотып, су буеннан менүен күреп, вәсвәсәчел хатын бераз шикләнебрәк калды.* Ф.Хөсни

**ВӘСИКА** *и. гар. кит.* 1) Документ. *Архив вәсикаларында Закир ишан имамлык иткән мәчетнең һәм мәхәлләнең кайчан салынуы яки оешу вакыты анык күрсәтелмәгән* ---. Р.Әмирхан

2) Нигезле дәлил

**ВӘССӘЛА́М** *ы. гар. сөйл.* Җөмләдән аңлашылган берәр эш яки хәлнең тиз арада үтәлеп, төгәлләнүен белдереп әйтелә; тәмам, бетте-китте. *Чөнки безгә шулай яхшы, безгә шулай кирәк һәм – вәссәлам*! Р.Вәлиев. *Эш-эш, дигән булып, балаларны әни өстенә ташладык та, вәссәлам.* Ф.Сафин. *Эшне тикшерүне коммуналь*

*министрлыктан үтенерләр, шуның белән вәссәлам*! А.Гыйләҗев

**ВӘСЫФ** *и. гар. иск. кит.* Сыйфатлау, тасвирлау эше. *Берәр нәрсә, күренеш яки табигатьнең сыйфатларын тасвир итү төсендәге вәсыф жанрына, иң беренче чиратта, «Бу көндә бер сарай ачты әһали» дип башлана торган шигырь керә.* Ә.Исхак

**ВӘСЫФ КАТУ** *ф. иск. кит.* Сыйфатлап бирү, тасвирлап күрсәтү. *Ул матурны мактамак булдым әле такмак белән, Ямьле әйберләргә охшатмак, вәсыф катмак белән.* Ш.Бабич

**ВӘХА́ЛӘНКИ** *рәв. гар. иск. кит.* Чынлыкта (исә), чынбарлыкта, асылда; чынында, гамәлдә, дөресендә. *Вәхаләнки, бу – гаять дәрәҗәдә зур ялгышу.* А.Расих. *Аз ашасаң – күп ашарсың, дигән булалар, вәхаләнки татар эшчеләре гомерләре буена аз ашыйлар да, берсенең дә күп ашар дәрәҗәгә җитешкәне күренми әле.* Г.Тукай

**ВӘХИ** *и. гар. дини* Аллаһ тарафыннан пәйгамбәр күңеленә салынган яңа фикер; хәбәр. *[Аллаһ] Фәрештәсен вәкил итеп вәхи җибәрә.* М.Гафури. *Ишетелде колагына Һатифтән серле тавыш. Пәйгамбәргә вәхи булып Килгән тавыш ул, – таныш.* С.Баттал

**ВӘХШӘТ** *и. гар.* Рәхимсезлек, явызлык, вәхшилек. *Сүз җитәрме сөйләп аңлатырга Бу йорттагы вәхшәт, коллыкны?!* М.Җәлил

**ВӘХШӘТЛЕ** *с. кит.* Рәхимсез, явыз; ачы, бик авыр. *Вәхшәтле сугыш елларында авыл халкы бергә булды.* М.Мәһдиев. *Вәхшәтле еллар авазы һаман да үзен сиздерә.* А.Гыйләҗев

**ВӘХШӘТЛЕК** *и.* Рәхимсезлек, явызлык, кансызлык. *Казаклар да, карательләрнең вәхшәтлегенә түзә алмыйча, атка атланып, кулларына корал алдылар.* И.Салахов

**ВӘХШИ** *с. гар.* **1.** 1) Кеше кулына ияләшмәгән, иректә яшәгән, кыргый. *Вәхши хайваннарны бер җиргә җыелып торырга мәҗбүр итүче – су эчәсе килү теләге икән.* Г.Тукай

2) Мәдәният үсешенең иң түбән баскычында торган, варвар. *Вәхши, мескен, мондый золымнарга үкереп елаудан башка хәйлә дә кора алмый.* Г.Тукай

3) *күч. тирг.* Явыз, варвар, ерткыч булган. *Менә берзаман вәхши адәмнәр җыелыша башлыйлар.* Г.Тукай

4) *күч.* Рәхимсез, коточкыч, канечкеч. *Татар теленә мең елдан артык хезмәт итеп килгән гарәп язуын яклаган нихәтле зыялыларыбыз вәхши ГУЛАГның канлы кочагына эләгеп харап булдылар.* Ә.Кәримуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кыргый хайван. *Ул вәхшиләр, җыелышып, бергәләшеп, дошманнарына ташландылар.* Г.Тукай

2) Мәдәният үсешенең иң түбән баскычында торучы кеше. *Әгәр бу вәхшиләр, берләшмичә, ялгыз-ялгыз торсалар, бичараларның һичберсе кәҗә итек күрмәс иде.* Г.Тукай. *Инсаннар чокырлардагы ялангач вәхшиләр кебек торганнар.* Г.Тукай

3) Явыз, усал, рәхимсез, ерткыч кеше. *Барысының да вәхшиләрне тизрәк табасы, кем булуын ачыклыйсы килә.* Мәдәни җомга

**ВӘХШИ́АНӘ** *рәв. фар. иск. кит.* **1.** Ерткычларча, вәхшиләрчә. *Әллә сезнең үз кулыгыз берлә Койган сөңгеләр, Чәнчелеп саф бәгърегезгә, Вәхшианә көлделәр?!* Һ.Такташ

**2.** *с. мәгъ.* Явыз, рәхимсез. *Аны безнең арабыздан вәхшианә үлем алып китте.* Казан утлары

**ВӘХШИЛӘНҮ** *ф.* 1) Вәхшигә әйләнү, кыргыйлану. *[Робинзон] Ялгыз атауга барып урнашып, вәхшиләнгән.* Г.Газиз

2) Явызлану, усаллану, рәхимсезләнү, ерткычлану. *Заман үзгәрә: бәяләр арта, бер төркем кешеләр дингә тартыла, икенчеләре, киресенчә, вәхшиләнә.* Татарстан яшьләре

**Вәхшиләнә бару** Вәхшилеге торган саен көчәю

**Вәхшиләнә төшү** Бераз, аз дәрәҗәдә, тагы да вәхшиләнү

**Вәхшиләнеп бетү** Тәмам, соңгы чиккә җитеп вәхшиләнү

**Вәхшиләнеп китү** Нинди дер бер моменттан соң, берәр төрле сәбәп белән вәхшиләнгән халәт алу

**ВӘХШИЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Аяусыз, рәхимсез рәвештә; вәхши хайваннар кебек, ерткычларча. *Бу урынга вәхшиләрчә җәзалап үтерелгән кеше күмелгән.* Я.Зәнкиев. --- *1919 елның 14 нче марты көнне ак фетнәчеләр тарафыннан вәхшиләрчә үтерелгән Сәхәбиев Вәҗи, Күкрәков Хәбибрахман һәм башка коммунистларның батырлыгына --- тирән ихтирам белән багышлыйм.* Ю.Әминов

**ВӘХШИЛӘШҮ** *ф. к.* **вәхшиләнү.** *Ачу белән исергән, вәхшиләшкән, Котырган эт шикелле анда дошман.* Б.Рәхмәт

**ВӘХШИЛЕК** *и.* Явызлык, рәхимсезлек; варварлык, ерткычлык. *Сугышның нинди вәхшилек икәнлеген монда, сугыш уты көйдереп киткән җирләрдә, бигрәк тә ачык тоясың.* С.Сөләйманова. *Инде айдан артыкка сузылган төрмә тормышы, нинди генә вәхшилекләре белән җәберләмәсен, Мусаны изеп ташлый алмады.* Ш.Маннур. *Йа-а Ходаем, нинди кансызлык... вәхшилекнең дә вәхшилеге бит бу!.* М.Хәсәнов. *Төзәтеп булмаслык хата, башка сыймаслык вәхшилек кылганнарын аңласа да, инде җинаять өчен җавап бирер чак җитүенә төшенеп бетми әле алар.* Мәдәни җомга

**ВӘҺЕМ** *и. гар.* Хыял, фараз. --- *соңында күп вакытлар үтмәде, ошбу «дин»гә чит халыклар вә башка мәзһәбләрдә булган вәһемләр, хорафәләрдән бик күп нәрсәләр кушылды.* Р.Сафин

**В-ВШЧ-Ч** *ияр т.* Сызгырган тавышны белдерә. *[Галәү] Үзалдына, «в-вшч-ч» иттереп, акрын гына сызгырып куйды.* Г.Ибраһимов

**ВЕ** *и.* «В» хәрефенең исеме, алфавитта дүртенче хәреф исеме. *Юк, Галиуллин түгел, Валиуллин. Ве, ве, беренче хәрефе – Володя.* Ш.Хөсәенов

**ВЕ-ВЕ-ВЕ** *иярт.* Аңлаешсыз, бер көйгә, авыз эченнән генә әйтелгән сүзне белдерә. *Бала авыз эченнән, «веве-ве» дип, нидер сөйли. Әмма тирәюньдәгеләр берни аңламый, аптырап, аңа карап тора.* Сөембикә

**ВЕГЕТАРИАН** *и. лат.* **1.** Вегетарианлык тарафдары, вегетарианнарча тукланучы. *Бомбей штатында күбрәк вегетарианнар яши. Алар, үсемлек маен мул салып, яшелчә, камыр ашлары, сөт, борчак, фасоль ашыйлар.* М.Мәхмүтов

**2.** *с. мәгъ.* Яшелчә, җиләк-җимеш, сөт ризыкларыннан торган; кысыр, итсез. *Нигездә вегетариан ризыклар әзерлим.* Сөембикә

**ВЕГЕТАРИА́НЕЦ** *и. рус к.* **вегетариан.** *– Балык белән итне бөтенләй кулланмаска, барлык кешеләрне дә вегетарианецлар итәргә – сәламәтлек өчен дә шулай яхшырак, – ди аларның берсе.* Химиянең киләчәге

**ВЕГЕТАРИАНЛЫК** *и.* Бары тик үсемлек ризыклары белән (катгый вегетарианлык) яки, үсемлек ризыклары белән берлектә, йомырка, сөт, сөттән әзерләнгән ризыклар белән туклану системасы. *Гомеренең соңгы көннәрендә абзый вегетарианлыкка күчте.* М.Мәһдиев

**ВЕГЕТАРИАННА́РЧА** *рәв.* Вегетарианнарга хас булганча. *Вегетарианнарча яшәү кешедән зур чыгымнар сорый.* Татарстан яшьләре

**ВЕГЕТАРИА́НЧА** *рәв. к.* **вегетарианнарча**

**ВЕГЕТАТИВ** *с. лат. биол.* 1) Кеше, хайван яки үсемлекләрдә организмның үсүенә, туклануына хезмәт итә торган. *Эчкечелек организмда ачык күренеп торган вегетатив һәм нерв үзгәрешләре тудыра.* С.Шәрипова. *Вегетатив нерв җепселләре тәннең барлык органнарына барып җитәләр.* Кеше анатомиясе. *Әгәр берничә бөрене буйга кисеп карасак, кайберләренең эчендә башлангыч бәбәк тирәсендә фәкать башлангыч яфраклар гына урнашканлыгын күрербез. Мондый бөреләрне «вегетатив» яки «яфрак бөреләре» дип атыйлар.* Ботаника. *Аларның [аскомицетларның] вегетатив өлеше тармакланган һәм күзәнәкләргә бүленгән гөмбәлектән тора.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) Үсемлек һәм хайваннарны тукландыруга мөнәсәбәтле. *Вегетатив чор*

**ВЕГЕТАТИ́В ОРГАННАР** *и. бот.* Үсемлекләрнең туклану, үсү һәм үрчү өчен хезмәт итә торган органнары (тамыр, сабак, яфрак). *Яхшы тамырланган бәбәкләр үзләренә аерым үсемлек булып үсеп китә. Үсемлекләрнең вегетатив орган өлешләреннән: мыекчалардан, үргелекләрдән, тамырчалардан, суганчалардан, бүлбеләрдән һәм чыбыкчалардан үрчүе дә нәкъ шулай бара.* Ботаника

**ВЕГЕТАТИ́В ҮРЧҮ** *и. бот.* Үсемлекләрдә, җенси юлдан башка, вегетатив органнар ярдәмендә үрчү. *Үсемлекләрнең вегетатив органнар ярдәмендә үрчүләре «вегетатив үрчү» дип атала.* Ботаника

**ВЕГЕТАЦИОН** *с.* Вегетациягә караган, вегетациягә мөнәсәбәте булган. *Вегетацион чор – язгы иң соңгы кыраулардан башлап, көзге беренче көчле кырауларга кадәрге чор.* Биология

**ВЕГЕТА́ЦИЯ** *и. лат. бот.* Үсемлек тереклегендәге үсү, җитлегү, өлгерүне чагылдырган актив халәт. *Вегетация барышында, рәт араларындагы туфракны ике-өч тапкыр йомшартып чыгалар.* Бакчачы календаре

**ВЕГЕТА́ЦИЯ ЧОРЫ** *и.* 1) Ел тәүлегендә үсемлекнең үсү, җитлегү, үрчү чоры. *Кубесенең вегетация чоры озакка сузылганга күрә, аларны бик иртә чәчәләр.* Йорт эшләре // Агаччыл үсемлекләрдә сок хәрәкәте башланганнан алып яфрак коелып беткәнгә кадәрге чор

2) Үсемлекләрнең тулаем яшәү циклына кирәкле вакыт, авыл хуҗалыгында үсеш башлану чорыннан уңыш өлгереп, аны җыеп алганга кадәрге вакыт

**ВЕ́ДОМОСТЬ** *и. рус* 1) Фактик мәгълүматлар (мәс., хезмәт хакы, акча керем-чыгымы, бүләкләү һ.б.) исемлеге. *Беләсең, мин үткән айны 24 көн эшләдем, ведомостька 22 көн дип кенә язып куйганнар.* Һ.Такташ. *Группада – егерме дүрт студент. Ведомостька әле нибары унбер билге куелган.* М.Мәһдиев

2) **ведомостьлар** *күпл.* Кайбер газета-журнал исемнәренең состав өлеше; хәбәрләр. *Пётр патша үз кулы белән редакцияләгән «Гаскәре вә гайри эшләр турындагы ведомостьлар»да «Идел буенда нефть табылган, Казаннан хәбәр иттеләр», – дигән язу саклана.* Г.Ахунов

**ВЕ́ДОМСТВО** *и. рус* Дәүләтнең административ-хуҗалык системасында аерым бер тармак белән идарә итә торган учреждениеләр челтәре. *Үзләре саклаган стройны, мәңгелек, дип, бала чактан ук ышанып яшәүче бу чиновникларга, элекке ведомстволар бәйләныш җепләрен кинәт кенә өзгән.* К.Нәҗми. *Иң зур акчалар сарыф итүчеләр – эшмәкәрләр яки банкирлар түгел, шоу-бизнес йолдызлары яки законлы караклар да түгел, ә министрлык һәм ведомстволарның чиновниклары, дәүләт аппараты хезмәткәрләре, лоббист депутатлар.* Р.Мирхәйдәров

**ВЕ́ДОМСТВОАРА** *с.* Берничә ведомство тарафыннан төзелгән, шуларның эшчәнлеген координацияләгән; берничә ведомство белгечләреннән торган. *М.В.Келдыш җитәкләгән ведомствоара киңәшмәләрнең берсендә бу мәсьәлә буенча баш конструктор түбәндәгеләрне әйтте...* А.Романов. *Ул, шулай ук, сәламәтлекләре какшаган кешеләргә ярдәм буенча министрлык, ведомствоара оешмалар эшчәнлеген координацияләү советын яңадан торгызу мәсьәләсен күтәрде.* Мәдәни җомга

**ВЕ́ДОМСТВОЛЫ** *с.* Ведомстволар челтәренә таянган, ведомстволарга нигезләнеп эш итә торган. *Ведомстволы идарә*

**ВЕ́ДОМСТВОЧЫЛЫК** *и.* Аерым ведомство мәнфәгатьләрен гомумдәүләт мәнфәгатьләреннән өстен кую принцибы. *Пленум резервларны оста таба белүне, ведомствочылыкны бетерүне --- таләп итте.* К.Нәҗми

**ВЕЗДЕХОД** *и. рус* Начар юллардан яки бөтенләй юл булмаган җирдән йөрү өчен көйләнгән махсус автомобиль. *Антарктиданың ярмаланып торган кары өстеннән куәтле вездеход көч-хәл белән генә үрмәли.* Кызыклы ихтиология. *Ихтимал, зур булмаган төш реакторы ярдәмендә, су белән һавадан автомашина өчен ягулык ала башларлар. Бу – вездеходлар өчен бигрәк тә уңайлы булыр --- иде.* Химиянең киләчәге. *Авыл урамы буйлап, вездеходтан башка машина үтә алмый.* Татарстан яшьләре

**ВЕ́КСЕЛЬ** *и. нем.* Бурычка алган акчаны билгеләнгән срокка кире кайтару турында бирелгән язма йөкләмә; кыйммәтле кәгазьләрнең бер төре. *Үткән ел мин, вексель белән, илле сигез меңлек товар алган идем, бик күп зыян иттем, түли алмадым.*

Т.Гыйззәт. *Инде мондый күп вексельләр эченнән Әхмәтҗанов векселен табып алырга кирәк булгач, Галиәкбәр агай Әхмәтгалине чакырды.* Ш.Мөхәммәдев. *Картның кәефе кырылып, Хәйригә барын сөйләгән дә, аның ярдәме белән кайдандыр акча табып, мулладан векселен алып кайткан.* Г.Ибраһимов

**ВЕ́КТОР** *и. лат. мат.* Билгеле торыш һәм юнәлеш алган туры сызыкның бер өлеше. *A һәм B векторларының проекцияләре билгеле булганда, аларның скаляр тапкырчыгышы болай языла: C=AB cos φ*... Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

**ВЕ́ЛИК** *и. рус гади с.* Велосипедны кыскартып атау сүзе. *Анда бер велик бар!* А.Гыйләҗев

**ВЕЛО-** *лат.* Кушма сүзләрнең «велосипед» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәге (мәс., *велойөреш, веломарафончы, веломаршрут, велоспорт, велотренажёр*)

**ВЕЛОДРОМ** *и. рус* Велосипедларда узышу һәм күнекмәләр үткәрү өчен катлаулы трассасы булган махсус спорт мәйданы

**ВЕЛОРИ́КША** *и. лат.-яп.* Көнчыгыш һәм Көньяк Азия илләрендәге җәяүле рикшалар үрнәгендә барлыкка килгән һәм хәзер бөтен дөньяда, бигрәк тә туристлык үзәкләрендә киң таралган транспорт төре: велосипед-такси. *Адым саен диярлек, миңа инде күптәннән таныш булган велорикшалар очрап тора.* Н.Хәкимуллин

**ВЕЛОСИПЕД** *и. фр.* Аяклар ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган, ике яки өч тәгәрмәчле, гади, җиңел транспорт чарасы. *Бу акчага, тимераяк кына түгел, өр-яңа велосипед та алып була, бәлки, әле аннан да артып калыр.* А.Шамов. *Велосипед җил шикелле Җитез оча киң юлдан.* М.Җәлил. *Без бала вакытта --- урамнан велосипед узганда, без, малайлар, дөньяны онытып, шуның артыннан чаба идек.* М.Мәһдиев. *Язучылар килү хәбәрен ишетеп, яшь-җилкенчәк, мотоциклга, велосипедларга атланып, күрше авыллардан киләләр.* С.Сөләйманова

**ВЕЛОСИПЕДЧЫ** *и.* Велосипедта йөрүче, велосипед спорты белән шөгыльләнүче кеше. *Йөгерешчеләр, велосипедчылар кайтты, мотоциклчыларны хәбәр иттеләр — көрәш әле һаман бара.* Г.Ахунов

**ВЕЛЬБОТ** *и. ингл.* Зур булмаган, мачталы һәм җилкәнле, дүрт яки алты ишкәкле, ике башы да очлаеп торган, җиңел, тиз йөрешле көймә. *Айзирәк егете белән бүген вельботта йөрде.* Н.Хәкимуллин

**ВЕЛЬВЕТ** *и. ингл.* **1.** 1) Хәтфәгә охшаш куе төкле, буй-буй сырлы, гадәттә киҗе-мамык тукыма. *Хәзер вельвет модага кереп бара. «Ли», --- «Вранглер» – шушы фирмаларныкын алырга тырыш.* М.Юныс. *Нәрсәдән тегәләр аны? Вельветтанмы? Киндердәнме?* М.Мәһдиев

2) *к.* **вельветка**. *Һәр кечкенә күлне көзге итеп, үз-үземә сокланып, фасонлы, замоклы вельветны карап үтәм.* Ш.Шәйдуллин

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Йон свитер өстеннән вельвет куртка кигән гид, чакрым саен диярлек, төшеп, су эчә.* С.Сөләйманова

**ВЕЛЬВЕ́ТКА** *и. рус сөйл.* Вельвет тукымадан тегелгән кыска җиңел куртка. *Институтның беренче курсында вакытта, [Ишбулат] --- бумази чалбар, зәңгәр вельветка белән йөргән.* М.Мәһдиев. *Аннары, инде шактый искергән вельветка төймәләренә бармаклары белән кагылып алды да: – Их, брамат, өс-башыңны әйтер идем ---, – диде.* Казан утлары

**ВЕЛЬМО́ЖА** *и. бор. рус* 1) *иск.* Бай, аксөякләр нәселеннән, җәмгыятьтә, дәүләттә югары дәрәҗәсе булган кеше. *Вельможаларга каршы көрәшү мөмкинме?* М.Җәлил. *Идарәчеләр һәм вельможалар үз җирләрендә 500–1000 чамасы бәйле кешеләр тоталар, аларны аерым бистәләргә урнаштыралар.* Урта гасырлар тарихы

2) *күч. ирон.* Үзен зурга санап, эреләнеп, масаеп йөрүче кеше. *Юк, әтигә карата, масайгансың, вельможага әйләнгәнсең, дип әйтү – монысы инде чамадан тыш, минемчә.* Р.Ишморат

**ВЕЛЮР** *и. фр.* **1.** 1) Хром белән иләнгән тыгыз күннең җиңел аяк киеме яки кайбер өс киемнәре тегә торган замшасыман төре

2) Драп, бәрхет, плюш кебек тукымаларның кайбер сортлары атамасы. *Чалбар тегәр өчен вельвет та бар. Костюм тегәр өчен габардин, бостон, велюр да китергәннәр.* Ф.Сафиуллина

3) Куе, йомшак, аз гына беленерлек кыска төкле итеп махсус эшкәртелгән постау яки иң яхшы сортлы юка фетр. *Велюрны берничә төрле юл белән чистартырга мөмкин.* Йорт эшләре

**2.** *с. мәгъ.* Велюрдан (*1 мәгъ.*) тегелгән, шундый материалдан эшләнгән. *Кибеткә бик күп велюр материал кайтарганнар.* А.Гыйләҗев. *Куе чия драп пальто кигән, изү – чишек, башында – алтмышынчы елларда модага кереп чыккан яшел велюр эшләпә ---.* М.Мәһдиев

**ВЕ́НА** *и. лат.* Әгъзалардан һәм тукымалардан йөрәккә таба кан үткәрә торган тамыр. *Канны йөрәктән әгъзаларга үткәрүче эре кан тамырлары – «артерияләр» дип, ә йөрәккә таба үткәрүчеләре «веналар» дип аталалар.* Йорт эшләре. *Бүген дә, укол салу өчен, аның веналарын таба алмадылар.* С.Сөләйманова. *Кирәк булса, гипноз сеанслары алырсыз. Веналарга магнезия уколлары кадарбыз.* А.Гыйләҗев

**ВЕНГЕ́РКА** *и. пол* 1) Венгр гусарлары формасына охшатып, алгы өлешен аркылыга ука шнурлар белән бизәп тегелгән куртка. *Николай Иванович, элгечтә эленгән венгеркасын алып, ишеккә юнәлде.* Җ.Тәрҗеманов. *Ул --- француз хушбуе исе килгән кульяулыкны тагын бер кабат битенә китерде, шуннан соң гына, саклык белән, венгерка кесәсенә салып куйды.* Җ.Тәрҗеманов

2) Венгр халык биюләренә нигезләнгән бал биюе һәм шул биюнең музыкасы

**ВЕНГР** *и.* Телләре белән фин-угор төркеменә караган, Венгриядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер вәкиле; маҗар. *Айдар үз алдына венгр телен өйрәнүне максат итеп куйды.* Г.Гобәй. *Венгрларның, үз ана телләреннән тыш, өч-дүрт телдә теттереп сөйләшүләрен ишеткәч, аның гаҗәпләнүе соң чиккә җитте.* А.Гыйләҗев

**ВЕ́НГРЧА** *рәв.* **1.** 1) Венгр телендә. *Венгрча «пушта» дип аталган кара*

*туфраклы дала бөтенләй сөрелеп беткән диярлек.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Ә кайбер сүзләр инде үзгәргән: борчак – венгрча – борсо, киндер – кендер ---.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Килгән кунаклар венгрча сөйләшәләр иде.* Татарстан яшьләре

2) Венгрларга охшатып

**2.** *с. мәгъ.* Венгр телендәге, венгрларга караган

**ВЕНЕ́РИК** *с. лат.* **1.** Күбесенчә җенси юл белән күчә торган. *Бу төрмәләрнең кешегә хисапсыз хәсрәт китерүен, явызлык, көчләүне законлаштыруын һәм, өстәвенә, венерик авырулар өчен җирлек тудыруын без әле һаман да ахыргача аңлап бетермибез.* Идел

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Җенси юл белән күчә торган (сифилис, шанкр, гонорея һ.б.) төрле йогышлы чирләр белән авыручы кеше. *Сена күпере астында Парижның бөтен кызганыч элементлары күзгә ташлана: картаеп, урамга ташланган фәхишәләр, ач калган картлар, шулар арасында венериклар һәм балалар да бар.* Г.Гобәй

**ВЕНЕРО́ЛОГ** *и. рус* Венерик авырулар буенча белгеч, шундый авыруларны дәвалаучы табиб. *Эльмира венеролог булып эшли.* Татарстан яшьләре

**ВЕНЕРОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Медицинаның венерик авыруларны өйрәнә торган бүлеге. *Венерология диспансеры белешмәсенә караганда, йогышлы авырудан дәваланган.* М.Насыйбуллин. *Кыз, шактый вакыт, венерологияне җентекләп өйрәнде.* Татарстан яшьләре

**ВЕ́НЗЕЛЬ** *и. пол.* Исем-фамилиянең яки ике исемнең бер-берсенә матур итеп чорналып язылган баш хәрефләре. *Аның картузы кызыл тирәле булып, шинель погоннарында, сары буяу белән, Германия императорының вензеле төшерелгән иде...* Ш.Камал. *Карлен «Золотой петушок» эмблемасы һәм вензеле төшерелгән салфетканы сак кына күтәрде – кардан да ак инглиз фарфоры өстендә авыр алтын браслетлы алтын сәгать ята иде.* Р.Мирхәйдәров

**ВЕНОЗ** *с. рус анат.* Веналарга бәйләнешле; веналар буенча ага торган. *Дүрт камералы йөрәк һәм кан әйләнешенең ике түгәрәге артериаль канны веноз каннан аера, шуңа күрә кошларның барлык органнарына чиста артериаль кан килә.* И.Рәхимов

**ВЕНОК** *и. рус* Зур масштаблы ярышта, бәйгедә җиңүчене бүләкләү өчен яки һәйкәл, кабер янына салу өчен, түгәрәк яки озынча формада үрелгән чәчәк, яфрак яки ботаклар бәйләме. *Ул үзләре төне буе утырып ясаган венокларга күмелеп калган дусты кабере өстенә капланды ---.* Г.Гобәй. – *Кипкән яфраклардан чәчәк композицияләре, веноклар һәм башка әйберләр ясыйлар.* Л.Мәүлүдова. *Ясалма чәчәкләрдән үрелгән веноклар. Шомлы матурлык...* Ш.Галиев

**ВЕ́НСКИЙ УРЫНДЫК** *и.* Агачтан бөгеп ясалган җиңел һәм нык урындык. *Сул якта – агач кәнәфи, аш өстәле һәм венский урындыклар.* Г.Коләхмәтов. *Ниһаять, хуҗа карт аңа утырырга бик яхшы сакланган венский урындык тәкъдим итте.* Р.Мирхәйдәров

**ВЕ́НТИЛЬ** *и. нем.* 1) *тех.* Сыекча, пар, газ һ.б.ш. агымын ачу, киметү, туктату җайланмасы, клапан. *Гайнан абыйсы, вентильне ябып, су килүне туктатты да, Рафиска аңлата-аңлата, көйләп тә куйды.* Н.Әхмәдиев

2) *тех.* Пневматик шинада һаваны камерага үткәрә, ә кире чыгармый торган җайланма. *Камераларның вентильләрен башка төрле бөке белән алмаштырырга рөхсәт ителми.* Тракторлар һәм автомобильләр

3) *электр.* Электр тогының бер якка гына агуын тәэмин итә торган прибор. *Ике төрле электрүткәрүчәнлекле катлаулар арасында бикләвеч катлау – вентиль ясала.* Серле кристаллар. *Подстанцияләрнең электр җиһазлары изоляциясен атмосферадагы артык көчәнешләр --- бозудан саклау өчен вентильле һәм көпшәсыман бушандыргычлар хезмәт итә.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

4) *муз.* Кайбер тынлы музыка коралларының канал озынлыгын үзгәртү, гадәттә озайту өчен механик җайланма

**ВЕНТИЛЯ́ТОР** *и. нем.* Биналарны җилләткәндә, машина җайланмаларын суытканда, сибелүчән яки җепселле материалларны үткәргеч торбадан транспортировкалаганда, һава агымын этәрү, көчәйтү өчен хезмәт итә торган җайланма. *Гигант вентиляторлар сыман бертуктамый зырылдыйлар гына.* А.Алиш. *Җир астыннан вентилятор торбасын да суза кил.* Ә.Галиев. *Цех бинасы иркенәйтелде, вентиляторлар эшли, производство мөмкин булганча механикалаштырылды.* М.Маликова. *Авыл хуҗалыгында бер фазалы алмаш токны зур булмаган вентиляторларга, кәнкүрештәге электр приборларына энергия бирү өчен, шулай ук электр белән эретеп ябыштыру эшләрендә кулланалар.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

**ВЕНТИЛЯЦИОН** *с.* Вентиляциягә мөнәсәбәте булган, вентиляциягә караган; җилләтү, вентиляция хезмәтен үти торган. *Вентиляцион торба. Вентиляцион корылма*

**ВЕНТИЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Ябык бинаның һавасын җилләтү. *Авыл хуҗалыгы биналарында вентиляциянең роле бик зур.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе. *Балалар бүлмәсенә вентиляция үткәрелде. Вентиляция сәгатьләре*

2) Бинаның һавасын җилләтү өчен хезмәт итә торган җайланма яки җайланмалар системасы. *Вентиляция участогы десятниклары, маркшейдер, нормировщик сыйфатында гына, хатын-кыз җир астына төшә ала.* Ә.Галиев. *Калориферлар янкорма рәвешендә корылган вентиляция камераларына куела.* Авыл хуҗалыгы электригы белешмәсе

**ВЕПС** *и.* Россиянең Ленинград, Вологда өлкәләрендә һәм Карелиядә яшәүче фин-угор халыкларының берсе һәм шул халыкның бер вәкиле. *Ладога күле белән Ак күл арасында яшәгән борынгы халык һәм шул халык яшәгән җир; хәзерге вакытта, кечкенә вепс халкын шул вису халкының калдыгы, дип уйлыйлар.* Н.Фәттах

**ВЕРА́НДА** *и. ингл.* Өй тирәләп яки өйнең бер дивары буйлап эшләнгән бүлмә яки ябык балкон. *Верандага караган иркен бүлмәдә чәй табыны әзерләнгән*

*иде.* Ә.Еники. *Килен төшерәсе йортта әзерлек эшләре тәмамланды: йорт, верандалар буялды, каралты-кура тирәсе җыештырылды.* М.Мәһдиев. *Бу хакыйкатьнең ачысы минә хәзер, верандага кайтып яткач, Ирекнең йөрәген, ярып тоз сипкәндәй, зәһәр итеп өттерергә тотынды.* Ф.Садриев

**ВЕРБАЛЬ** *с. лат.* Сүздәге, телдән әйтелгән; сүз белән белдерелгән. *Аралашуның вербаль чаралары*

**ВЕРБА́ЛЬ НО́ТА** *и. рус кит.* Дипломатиядә: кул куелмаган, шуңа күрә телдән әйтелгән белдерү белән бер дәрәҗәдә йөри торган язма белдерү

**ВЕРБО́ВКА** *и. нем. сөйл.* Вербовкалау, нинди дә булса хезмәткә яллау эше. *Иптәш председатель, минем килүем, сез уйлаганча, вербовка белән шөгыльләнү түгел.* А.Әхмәт. *Ничә еллар элек, алар, вербовка белән, БАМга киткәннәр иде.* Г.Ахунов. *Мине, вербовка оештыру буенча ике сметаны раслату һәм хәбәрләшү өчен, Кәнчыгыш фронт штабына җибәрделәр.* Казан утлары

**ВЕРБО́ВКАЛАУ** *ф.* Кешеләрне нинди дә булса эшкә, оешмага, өлкәгә тарту, яллау

**ВЕРБО́ВКАЛАУЧЫ** *и.* Вербовка белән шөгыльләнүче кеше. *Әхмәт вербовкалаучы булып озак эшләгән.* Г.Әпсәләмов

**ВЕРБО́ВЩИК** *и. рус сөйл. к.* **вербовкалаучы.** *Яшьләрне җыючы вербовщик сөенә: «Ниһаять, чын шахтёр килде!» – ди.* Г.Ахунов. *Үсмер егет --- сизенеп кенәме: «Кызлар җыючы вербовщик сезме, абый?» – дип сорады.* Ш.Рәкыйпов

**ВЕ́РМАХТ** *и. нем. тар.* Фашистлар Германиясенең коралы көчләре, армиясе. *Хәрби фортунаны үзләренең гомерлек юлдашы дип санаган вермахт гаскәрләрен бүгенге җиңелү тәмам шашындыра иде, әлбәттә.* Ш.Рәкыйпов. *Вермахтның үткән сугыштан соң суд карары белән асылмый калган реваншист генераллары җинаятьле кулларын Көнчыгышка сузалар.* Ш.Мөдәррис. *Соңрак ГФРга яңа вермахтны --- атом коралы белән коралландырырга рөхсәт ителде.* Иң яңа тарих. *Исәпләүләр күрсәткәнчә, 1941–1945 елларда, ягъни сугышның башыннан ахырына чаклы, вермахт барысы 61196 танк, ә без 95000 танк югалтканбыз.* Кызыклар дөньясында

**ВЕРМИШЕЛЬ** *и. ит.* Фабрикада яки махсус цехларда эшләнгән озынча нечкә токмач. *Базарда вермишель сатып алырга оныткан булып чыктым.* С.Сөләйманова. *Күркә ите – кош итләренең иң тәмлесе. Аның шулпасында пешерелгән токмач, салма, макарон һәм вермишель бик тәмле була.* Ю.Әхмәтҗанов

**ВЕ́РМУТ** *и. нем.* Йөзем шәрабына үлән төнәтмәләре кушып ясалган исерткеч эчемлек. *Аракиян өстәл башында кычкырып әйтеп тора: – Зәйтүн маенда кыздырылган ике айлык кабан дуңгызы! Ак вермутта томалап пешерелгән шампиньон гөмбәсе!* Н.Әхмәдиев. *Берәр шешә вермут алабыз да таңга тиклем сөйләшеп чыгабыз.* М.Кәбиров

**ВЕРНИСАЖ** *и. фр. сәнг.* 1) Сәнгать күргәзмәсенең тантаналы беренче ачылу көне (иң баштагы мәгънәсе – картиналарны, күргәзмә ачылыр алдыннан, лак белән каплау). *Кыйммәтле рестораннарга, казиноларга, төнге клубларга йөр, мода күргәзмәләрен, вернисажларны, театр премьераларын калдырма.* Р.Мирхәйдәров

2) Гомумән күргәзмә. *Шулай йөрүләрнең берсендә, ул Горький ял паркы каршындагы Кырым валын үзе өчен яңадан ачты. --- Чын-чынлап, ачык һавадагы салон, әллә ничә чакрымнарга сузылган вернисаж!* Р.Мирхәйдәров

**ВЕРСАЛЬЧЕ** *и. тар.* Революцион Париждан 1871 елның 18 мартында Версаль шәһәренә качкан контрреволюцион француз хөкүмәте тарафдарлары һәм җитәкчеләре. *Парижны версальчеләрдән саклауда да хатын-кызлар актив катнашалар.* Яңа тарих. *Ул, вакытлы килешү шартларына каршы килеп булса да, версальчеләргә армияне арттырырга мөмкинлек бирә.* Яңа тарих

**ВЕ́РСИЯ** *и. лат.* 1) Берәр факт, хәл яки вакыйга турында бер-береннән аермалы булган төрле аңлатмаларның берсе; мәсьәләгә бер караш. *Һәр очракта да сүз хәтер чамасына гына нигезләнгәнлектән, ул даталарны, әлбәттә, теге яки бу күләмдә дөреслеккә якын версияләр итеп кенә карарга туры килә.* Г.Халит. *Минем версиям бик төзек, бик ышандырырлык, бик нигезле ләбаса!* М.Маликова. *Яшь Тукайның дәрәҗәсен тагын да күтәрә төшсә дә, егетнең ягымлы беркатлылыгы безне елмайтса да, бу версиядән, күренә ки, баш тартырга туры килә.* И.Нуруллин

2) Җинаять эшен тикшергәндә теге яки бу фактларга нигезләнеп төзелгән фараз, гипотеза. – *Йә ничек, иптәш тикшерүче, – диде ул миңа. – Безгә версияләр төзергә вакыт.* М.Маликова. *Нәҗип сүтелгән версия җепләрен тиз генә бер йомгакка җыйды.* З.Фәтхетдинов

3) Әдәби әсәрнең күчермәсе, редакцияләнү, автор төзәтмәләре һ.б.ш. белән аерылып торган варианты, башка, икенче нөсхәсе. *Аның, теле җиңеләйтелеп, 1914, 1918 елларда Казанда чыккан басмалары, кулъязма версияләрдән беркадәр аерымлыклары булса да, мавыгып укырлык әсәрләр.* М.Әхмәтҗанов

4) *күч.* Уйдырма, гайбәт. *«Совет куркынычы» турында версия тараталар.* Татарстан коммунисты

**ВЕРСТАК** *и. нем.* Агач яки металл әйберләрне кулдан эшкәрткәндә, шул әйберләрне беркетү өчен җайланмалары булган эш өстәле. *Әле верстак янында аптырап басып торган Сәлимгә карап, Наил сүз башлады.* А.Әхмәт. *Тышкы якта, корпус ишек төбендә генә верстак ясап, алар эшкә керештеләр.* М.Гафури. *Салам түбәле ярым җимерек иске каралтыга терәп урнаштырылган верстагына килеп таянды Гыйлемхан.* Р.Мөхәммәдиев

**ВЕРСТА́ТКА** *и. голл.* Хәрефләрне кул белән җыйганда кулланыла торган типография җиһазы. *Верстатка янә сафтан чыкты.* М.Гафури

**ВЕРТИКАЛЬ** *с. лат.* **1.** 1) Горизонтка карата перпендикуляр, астан өскә 90°ка күтәрелгән яки өстән аска 90°ка төшкән; асылма, асма. *[Мәрьям] Институтта урамнар перспективасын*

*ясаса, өйдә --- яшелләндерү планын сыза. Аннары – районның өстән караганда күренеше, вертикаль планировкасы.* М.Маликова. *Җепнең үзенә асылган йөк тәэсирендә алган юнәлеше «вертикаль юнәлеш» дип атала.* Физика. *Вертикаль почмаклар үзара тигез була.* Геометрия. *Туп җирдән вертикаль юнәлештә өскә таба 15 м/с тизлек белән ыргытылган.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

2) *куч.* Түбәндәге структуралар югарыдагы структураларга буйсынган (идарә системасы). *Дөрес, тиешле дәрәҗәдә эшли торган вертикаль идарә структурасын булдыру өчен күп кирәк әле.* Г.Исхакый. *Аның каравы, вертикаль хакимияткә хезмәт күрсәтүче бюрократия котырып үрчеде.* Н.Әхмәдуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Горизонтка карата перпендикуляр рәвештә. *Балык су катлавында вертикаль хәрәкәт иткәндә, барометрик үзгәрешләргә караганда, басымның күбрәк үзгәрүенә дучар була.* Кызыклы ихтиология

**3.** *и. мәгъ.* 1) Асма белән бер юнәлештәге туры; вертикаль сызык. *Самолёт вертикаль буенча өскә күтәрелә башлады.* Ә.Баян. *Ачыграк күзаллау өчен кәгазьгә сызып карасак, бу – вертикаль буенча берлекне, бердәмлекне, дәвамлылыкны аңлау булыр.* Казан утлары

2) *куч.* Идарә системасында урындагы органнарның югарыдагы органнарга тулысынча буйсыну принцибы. *Дәүләт системасында «тыеп тору һәм каршылык күрсәтү» механизмнары реаль булмаса, «башкарма вертикальне» үзгәртү мөмкинлеге, чынлыкта, бернәрсә белән дә чикләнмәгән булачак.* Казан утлары. *Урыннарда милли компонент мәсьәләсе, халык тарафыннан түгел, бәлки хакимият вертикале тарафыннан хәл ителә бара.* Мәдәни җомга

**ВЕРТИКАЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф.* Югарыдан идарә итүне көчәйтү, түбәндәге оешмаларның югарыдагыларга буйсыну дәрәҗәсен арттыру. *Хакимиятне «вертикальләштерү» бюрократияне канцлер Карл Нессельроде фикерләренә кушылырга мәҗбүр итә.* Ә.Борһанов

**Вертикальләштерә бару** Вертикальләштерүне көннән-көн көчәйтү

**Вертикальләштереп бетерү** Барчасын югары органнарга буйсындыру

**ВЕРТЛЮГ** *и. рус* Механизмның үз күчәрендә бер-берсенә бәйсез рәвештә әйләнеп торган ике өлешен берләштергән буын. *Килгән көнне үк, агрегатның һәр җиһазы, һәр эш коралы белән җентекләп танышып чыкты ---. Аның көндәлек эш барышында еш телгә алына торган ротор, редуктор, барабан, вертлюг, насос ише кирәк-яраклары күргәне бар.* К.Кәримов. *Каһәр төшкән втулкаларыннан арынган вертлюгларны күргәч, Зәйни карт, үз күзләренә үзе ышанмаган сыман, тар кысалы, түгәрәк пыялалы күзлеген маңгаена ук күтәреп куярга мәҗбүр булды.* М.Хәсәнов

**ВЕРТОЛЁТ** *и. рус* Винтларның үзенчәлекле конструкциясе һәм урнашуы нәтиҗәсендә, вертикаль рәвештә һавага күтәрелә, бер урында асылынып тора һәм шул рәвештә җиргә төшә ала торган очкыч. *Вертолёт, кояшлы киңлекләргә чикерткә күләгәсе ташлап, тирбәтә-тирбәтә, хәтсез очканнан соң, учак төтене күтәрелгән урман аланына төшеп утырды.* М.Галиев. *Вертолёт тар гына тарлавык буйлап оча башлады...* М.Маликова. *Рәкыйп белән Фәезхан, иртәнге ашка балык чистартырга дип, катердан пычаклар алып чыкканда, үзләренә таба очып килүче вертолётны күрделәр.* Д.Вәгыйзов

**ВЕРТОЛЁТЧЫ** *и.* Вертолёт белән идарә итүче очучы; вертолёт спорты белән шөгыльләнүче кеше. *Айдар үзенә якынлашып килүче вертолётчыны күрде.* Д.Вәгыйзов

**ВЕРФЬ** *и. голл.* Суднолар төзү һәм төзәтү белән шөгыльләнә торган предприятие. *Ул, Пётр Михайлов исеме белән, Голландия верфенә корабль төзүче булып языла.* Тарих. *Король боерыгы белән, илнең коньяк өлешендәге Сагриш борынында обсерватория һәм кораб верфьләре төзелә.* Урта гасырлар тарихы. *Пётр бер зур верфьнең корабльләр остасына өйрәнчек булып керә.* Тарих

**ВЕРХОВОЙ** *и. рус махс.* Бораулау вышкасының өске өлешендә эшләүче кеше. *Кәримов! Сине, верховой булып эшли, диләр. Бу дөресме?* Х.Әхмәт

**ВЕРХОЛАЗ** *и. рус иск.* Төрле корылмаларның өске өлешендә, зур биеклектә эшләүче эшче, белгеч. *Зур төзелешләрдә Эшли минем сөйгәнем. Кыю верхолаз булганга, «Карлыгачым» дигәнем.* Ш.Галиев

**ВЕРШОК** *и. рус* Русларда метрик система кергәнче кулланылган һәм якынча 4,4 сантиметрга туры килгән озынлык үлчәү берәмлеге; ишарә бармакның төп фалангасы озынлыгындагы. *Ул, икешәр бармак иңлеге, хәтта калынлыгы икешәр вершок булган бик күп китапларны үзе күчереп язып алган һәм кешеләрдән дә бик күп яздырган.* М.Гафури. *Әмма, тутый кошча йөрим, дип, үз йөрешеннән адашкан саескан кебек, Батыргали агай да, уналты вершок бәһасы илә егерме ике вершок товарны сату бик файдалы түгел икәнен еллык хисап вакытында гына аңлады!* Ш.Мөхәммәдев

**ВЕСТЕРН** *и. ингл.* Америкадагы ковбойлар, индеецлар турындагы мажаралы кинофильмнар жанры. *Америка киноиндустриясе гангстерлар турында вестерн төшерүдән баш тартмый.* Татарстан яшьләре

**ВЕСТИБУЛЯ́Р АППАРАТ** *и. лат. махс.* Умырткалы хайваннарда, кешедә: башның һәм гәүдәнең пространствода торышындагы һәм хәрәкәт итү юнәлешендәге үзгәрешләрне тоя торган, эчке колак эчендә урнашкан тою органы. *Табиб хатынның вестибуляр аппаратында үзгәрешләр булуга игътибар итте.* С.Сөләйманова

**ВЕСТИБЮЛЬ** *и. фр.* Җәмәгать урыннарында бинаның эчке өлеше алдында урнашкан зур киң бүлмә. *Мин күргәндә, Айдар вестибюльдә басып тора иде.* Д.Хәбибуллин. *Минем дә карчык килгән иде әле, вестибюльдә сөйләшеп утырдык.* Б.Камалов. *Кинотеатрның вестибюленә барып кергәч, пальтосын каккалап караган иде дә, кулы гына чыланды.* М.Маликова. *Администратор белән икәү вестибюльгә чыгып басканнар гына иде, тышкы ишектән, атылып-бәрелеп, берәү килеп керде.* З.Фәтхетдинов

**ВЕСТОВОЙ** *и. рус хәрби сөйл.* Офицерларның хезмәткә бәйле эш-йомышларын үтәү өчен билгеләнгән йомышчы солдат. *Комиссар вестовойга штаб начальнигын чакырырга кушты.* А.Шамов

**ВЕТ-** Кушма сүзләрдә: мәгънәсе «ветеринария» сүзенә туры килә торган беренче кисәк, мәс.: *ветбаклаборатория, ветврач, ветпункт* һ.б.ш.

**ВЕТВРАЧ** *и. рус* Ветеринария врачы, ветеринария табибы, байтар. *Аның бүген сыерны ветврачка күрсәтәсе бар.* Т.Гыйззәт. *Безнең авылга яңа ветврач киләсе, дигәннәр иде. Алай-болай, шул түгелсеңдер бит?* Р.Вәлиев. *Учхозда ветврач булып эшләгән җиреннән, ассистент итеп алды, аннары диссертация якларга ярдәм итте.* А.Расих. *Әтисе – районның баш ветврачы. Әнисе – сәүдәдә бухгалтер. «Нәсимә» дип суламаган сулышлары юк.* Б.Камалов

**ВЕТВРАЧЛЫК** *и.* Ветврач булу, ветврач вазифасы, байтарлык. *Күрше егете ветврачлыкка укый башлады.* З.Ганиева

**ВЕТЕРАН** *и. лат.* 1) Күп хезмәт иткән тәҗрибәле сугышчы; күп сугышларда катнашкан кеше. *Сугыш ветераннары Советының җаваплы секретаре Алексей Маресьев кечкенә малай җитәкләгән инвалидны ишек ачып каршы алды.* М.Мәһдиев. *Ветераннардан соң, призывниклар артык яшь, сабый булып күренәләр.* С.Сөләйманова

2) Нинди дә булса өлкәдә озак һәм күп хезмәт күрсәткән кеше. *Без бүген заводыбыз ветераны Кәшиф иптәш Фәтхетдиновның юбилеен билгеләп үтү өчен җыелыштык.* Ф.Баттал. *Чәчкаб авылыннан 80 яшьлек хезмәт ветераны Рабига апа Закированың да күзләре дымлы.* Сөембикә. *Минем әнием – хезмәт ветераны.* Татарстан яшьләре

**ВЕТЕРИНАР** *и. рус* Ветеринария буенча белгеч; мал табибы, байтар. *Аның әтисе авылда ветеринар булып эшли.* М.Мәһдиев. *Ә-һә-әә, баш ветеринар урынын да киявенә саклап тоткан, дияр.* Г.Ахунов. *Равил, ветеринар булып, берничә ел гына эшләде.* Татарстан яшьләре

**ВЕТЕРИНА́РИЯ** *и. лат.* Хайваннардагы авырулар һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнә торган фәннәр системасы. *Ветеринариядә бу үсемлектән ясалган порошокны терлекләрнең яраларына һәм яман шешләренә сибәләр.* Җ.Хөсәенов. *Алга таба [А.Расих] Казан дәүләт ветеринария институты каршындагы аспирантурага укырга керә һәм аны 1950 елда уңышлы тәмамлый.* Р.Зарипова. *Хәлим авылда ветеринария буенча зур белгеч санала.* Татарстан яшьләре

**ВЕТЕРИНАРЛЫК** *и.* Ветеринар булу, ветеринар вазифаларын башкару. *Ветеринарлык һөнәреннән тиз генә ваз кичеп, нишләп шулай, тырыша-тырмаша, биналар корылышына керешеп киткәндер.* Ә.Баянов. *Әт мине беренче көннән үк дошман күрде. Уйлана торгач, бу хәлнең төбенә төшендем тәки. Әлеге дә баягы, ветеринарлыгым булышты.* М.Әмирханов

**ВЕ́ТО** *и. лат.* 1) Дәүләткүләм хокук нигезендә: бер дәүләт органының шундый ук дәрәҗәдәге башка бер орган тарафыннан кабул ителгән карарын бөтенләйгә яки шартлы рәвештә тыюы, юкка чыгаруы. *«Трибун» латинча «тыям» дигәнне аңлаткан, «вето» сүзен әйтеп, хәтта сенат карарын да кире кага алган.* Тарих. *Түбән палата депутатлары бу эшне болай гына калдырмаячак һәм сенаторларның ветосын җиңәчәк, дип хәбәр итте кичә спикер Борис Грызлов.* Ватаным Татарстан

2) Халыкара хокукта: теге яки бу мәсьәләне бары тик бертавыштан хәл итә торган коллегиаль органнарда шул орган әгъзасының бер каршы тавыш бирүе

3) Гомумән нәрсәне дә булса эшләүдән тыю, аны эшләргә рөхсәт бирмәү. *НАТО вәкилләре, Франциядә, Голландиядә, Италиядә төзелгән судноларны стратегик корал категориясенә кертеп, вето салганнар.* М.Юныс. *Мин --- уйлап табучының яңа иҗат эшенә вето салдым.* А.Тимергалин. *Ул җыелышның теләсә нинди карарын тыя алган, ягъни вето салган.* Тарих

**ВЕТСАНИТАР** *и. рус* Ветеринария санитары. *Андый-мондый хәлнең юклыгын белгәч, ул җиңел сулап куйды: хәзер Сәлимнең колхозда кайчандыр начар ветсанитар булганлыгын бөтенләй онытачаклар, алай гына да түгел, ул әле, эшне яхшылап алып барганда, үткән көннәрнең каһарманы булып әверелүе дә мөмкин.* Г.Әпсәләмов. *Курсларда йөреп кайттым, ветсанитар булдым.* М.Мәһдиев. *Сугышта аягы яраланып кайтканнан соң, колхозда ветсанитар булып эшли иде ул [Зөфәр абый].* Ф.Хөсни

**ВЕТФЕ́ЛЬДШЕР** *и. рус* Ветеринария фельдшеры. *Ветфельдшер идарәгә килде: – Иптәш председатель, «Йолдыз»ны суйыйк, – диде.* М.Мәһдиев. *Ветфельдшер Сәлим абыйны утлы табага бастырган кебек кыздыра.* Г.Әпсәләмов. *Ферма мөдире, агроном, ветфельдшер сөйләде.* М.Мәһдиев

**ВЕТЧИНА** *и. рус* Тозлап ысланган дуңгыз ите яисә, итне вак кисәкләргә турап, төрле тәмләткечләр өстәп ясалган казылык төре. *Тарелка белән чәнечкеләр юллап, шакмак итеп киселгән кечкенә ипи өстен бизәгән колбаса, ветчина, сыр, кабак икрасы ягылган нигъмәтләрне аласың да, янәдән үз өстәлеңә кайтасың.* Т.Галиуллин. *Ветчина тәмлерәк булсын өчен, пешергән чакта суга берничә бөртек хуш исле борыч һәм берничә лавр яфрагы да салалар.* Йорт эшләре. *Кибеттә ветчинаның берничә төре бар.* Заман

**ВЕ́ЧЕ** *и. бор. слав. тар.* Борынгы Русьта X–XIV гасырларда дәүләт, җәмгать эшләрен тикшерү өчен чакырылган шәһәр халкы җыены; кайбер шәһәрләрдә һәм кайбер славян халыкларында югары хакимият органы булган халык җыелышы. Ә дәүләт эшләрен, иң зур мәсьәләләрне вечега җыелган халык хәл иткән. Җ.Тәрҗеманов. *Ул шәһәрнең – Псковның – Троицкий собор дип аталган таш чиркәвендә вече җыела торган булган.* А.Муранов. *Киевның Сәүдә мәйданында гомуми җыелыш – вече җыялар.* Тарих. *Кабиләләрдә барлык мөһим мәсьәләләрне халык җыелышы – вече («вещать» дигән сүздән – белергә, белеп сөйләргә) хәл иткән.* Урта гасырлар тарихы

**ВЕ́ШАЛКА** *и. рус сөйл.* 1) Кием эләргә элгечләре, кадаклары булган җайланма; кием элгеч. *Әхмәт яңа*

*вешалка сатып алырга булды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Кием элә торган махсус бүлмә. *Варис пальтосын салды. Кепкасын. Әмма вешалкада бер генә буш элгеч тә юк иде.* М.Хәсәнов. *Вешалкага директор беренчеләрдән булып йөгереп килә, йөзенә матур елмаю чыгарып, саннары язылган тимерләрне өлкән яшьтәге апага суза.* Т.Галиуллин

**ВЁРСТКА** *и. рус* 1) *к.* **вёрсткалау.** *Хәбиб әзерләгән наборны әбәткә килгәндә китерер. Вёрстка сездә әбәттән соң башлана бит әле?* Г.Минский

2) Гадәттә, типографиядә биткә салынган набор. *Вёрстканы карап чыгу*

**ВЁРСТКАЛАУ** *ф. махс.* Наборны биткә салу. *Болай булса, без газетаны вёрсткаларга өлгермәячәкбез.* Г.Әпсәләмов

**Вёрсткалый бару** Һәрберсен, булган берсен вёрсткалау

**Вёрсткалап бетерү** Вёрсткалауны төгәлләү

**Вёрсткалап тору** Вёрстка эше белән мәшгуль булу, әлеге моментта, хәзер вёрсткалау

**Вёрсткалап чыгу** Башыннан ахырына кадәр вёрстка ясау

**ВЁРСТКАЛАУЧЫ** *и. махс.* Наборны биткә салу белән шөгыльләнүче типография эшчесе

**ВЖЖТ** *иярт.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса бик тиз хәрәкәт итүен һәм шул хәрәкәттән барлыкка килгән тавышны белдерә. *Машинаның «вжжт» иткән тавышы гына ишетелеп калды.* Г.Ибраһимов. *Ул каршыдан «вжжт» итеп үтеп тә китте.* М.Мәһдиев

**ВЗВОД** I *и. рус* Җәяүле гаскәрләрдә – ротаның, кавалериядә – эскадронның, артиллериядә – батареяның һ.б.ш. зур булмаган бүлекчәсе. *Уңышсыз атакадан кайткан чагында, Хәлимнәр взводының бер кызылармеецы каты яраланып калган иде.* А.Шамов. --- *татар-монголларда --- һәрбер кеше гаскәр хисаплана, һәрбер кабилә унар кешелек взводларга бүленә.* Г.Гобәйдуллин. *Отделениесе нык булган взвод, взводы нык булган рота, ротасы нык булган батальон гына җиңүгә ирешә ала.* Г.Бәширов

**ВЗВОД** II *и. рус махс.* Ату коралында затворның яки йозакның бәрмә механизмын атуга әзер хәлдә тота торган бер детале. *Автоматымны кысып тоттым, чакылдатып взводка куйдым, иптәшләремә мине ут белән сакларга кушып, камышлыкка ташландым.* М.Мәһдиев

**ВЗВОДТАШ** *и.* Бер взводта хезмәт итүче яки хезмәт иткән кешеләрнең берсе. *Взводташларым хәлемне аңлыйлар, мине, стройдан качырып, санчастька җибәрделәр.* Н.Сабиров

**ВЗНОС** *и. рус* Берәр нәрсә өчен түләнелгән яки түләнеләсе акча суммасы. – *Профсоюз взносы җыю – синең эшең түгел... – дип, сүзен түгәрәкләде Скалов.* М.Хәсәнов. *Милиционер, җентекләп, партия билетымны карады. Битләрен ачып, взнос түләгәнме, юкмы икәнлеген тикшерде.* Л.Ихсанова. *Без күпме еллар комсомол взносы түләдек.* Татарстан яшьләре

**ВИАДУК** *и. фр. < лат.* 1) Тирән чокыр, тарлавык, юл өстенә салынган күпер. *Ул йортка барып җиткәнче, башта виадук аша чыгарга кирәк.* Г.Әпсәләмов

2) Юл салучы, юл яручы кеше. *Борынгы греклар юл салучыларны, юл яручыларны «виадук» дип атый торган булганнар.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Әйдәп баручы, беренче башлап китүче. *Мин, виадук булып, җирдә юл ярып, үзләре артыннан башкаларны да җитәкли алучылар турында әйтәм.* М.Хәсәнов

**ВИАДУКЛЫК** *и.* Юл яручы хезмәте, юл салучы вазифасы. *[Борынгы греклар] Виадуклыкны иң турылыклы, иң ышанычлы, изге дип аталган кешеләренә генә ышанып тапшыра торган булганнар.* М.Хәсәнов

**ВИБРА́ТОР** *и. нем. < лат. тех.* Төрле тибрәнү, калтырау, электр дулкыннары һ.б.ш. тирбәнешләр барлыкка китерә торган прибор, механизм, җайланма. *Моторлар үкерә, төрле вибраторларның пулемёттан атканга охшаган авазлары һава яра.* М.Хәсәнов. *Ул арада вибраторлар да эшкә тотына, җир чын-чынлап калтырый башлый.* Ә.Баянов. *Дулкынсыман хәрәкәтне өзлексез булдырып тору өчен, вибраторга өзлексез рәвештә энергия өстәп торырга кирәк.* Физика

**ВИБРАЦИОН** *с.* Вибрация белән бәйле, вибрациягә нигезләнгән, вибрация белән булдырыла, эшләнелә торган. *Вибрацион үзгәрешләр*

**ВИБРА́ЦИЯ** *и. лат. физ.* Тыгыз яки сыгылмалы җисемнең тибрәнүле хәрәкәте, калтыравы; периодик механик тирбәнеш. *Бүлмәдә нindидер вибрация барлыгы сизелә.* А.Тимергалин. *Кузгалып, диңгезгә чыккач, тагын бер яңалыкка – вибрациягә юлыктык.* М.Юныс

**ВИБРА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Вибрациягә дучар булу, калтырау, дерелдәү

**ВИБРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Вибрациягә дучар итү, калтырату, дерелдәтү. *Кешенең күзе берөзлексез дерелди, тирбәлә, вибрацияли икән.* В.Комаров

**ВИБРИОН** *и. фр. биол.* Бөгелгән таякчык яки өтер рәвешендәге бактерия. *Ваба вибрионы*

**ВИБРО́МЕТР** *и. лат.-гр.* Вибрация дәрәҗәсен үлчи торган прибор

**ВИБРОСКОП** *и. лат.-гр. тех.* Механик тирбәнешләрне билгели, үлчи торган прибор, җайланма. *Мәктәп лабораториясенә яңа виброскоп алынды.* Мәгърифәт

**ВИВА́РИЙ** *и. нем.<лат. махс. к.* **виварium**

**ВИВА́РИУМ** *и. лат. махс.* Хайваннарны өйрәнү, алар өстендә тәҗрибәләр ясау өчен махсус җиһазландырылган бина. *Яңа виварium төзү турындагы сүзне яңадан күтәрергә кирәк.* А.Расих

**ВИГОНЬ** *и. фр.<исп.* **1.** Көньяк Америкада яши торган, нечкә, йомшак йонлы, дөя сыман имезүче хайван (ламаның бер төре). *Борынгы заманнарда ук җирле халык берничә төрле кыргый хайванны үзенә ияләштергән. Монда иң таралган йорт хайваннары – ламалар, вигоньнар һәм альпаклар.* А.Муранов. *Анд тауларында вигонь яши.* География

**2.** *с. мәгъ.* Шул хайван йонынnan бәйләнгән, тукылган. *Вигонь кофта. Вигонь бияләй*

**ВИДАГ** *и. гар.* Озату, саубуллашу. *Андан Миртимер хәзрәтләре, видаг итеп, Сәмәркандка китде.* М.Әхмәтҗанов

**ВИДАГЛАШУ** *ф.* Хушлашу, саубуллашу. *Җавад, ата-анасының хикәяте буенча Әбүгалисина хәзрәтләренә халис мохлисен мәхәббәт итеп, ата вә анасы белән видаглашып, хәер-догаларыны алып, шул сөекле остазы тарафына юл алды.* К.Насыйри. *Халык берсе артыннан берсе керә, Габдулла әфәнде белән видаглашып, авыр сулап чыгып китә...* Мирас. *Сәрви Хөраманны, әманәт итеп, Шаһбал шаһка калдырып һәм яраннар вә видаглашып, сөһман диюнең аркасына утырып, сәмругъның торган җиренә юнәлделәр.* Дастан

**ВИ́ДЕО** *и. лат. к.* **видеомагнитофон**

**ВИ́ДЕО-** *лат.* 1) Кушма сүзләрдә: электрон-нурланыш трубка экранында сурәтләр күрсәтүгә мөнәсәбәтле, дигән мәгънәне аңлаткан беренче кисәк (мәс., *видеотелефон, видеокамера, видеомагнитофон*)

2) *сөйл. к.* **видеокамера.** --- *Россия шәһәрләре урамнарында яшьләрнең ачыктан-ачык зина кылып, шуны фотога һәм видеога төшерүләре хакында хәбәрләр бастырганнар иде.* Р.Фәтхерахманов. *Барлык суд утырышлары да видеога төшерелә.* Юлдаш

3) *сөйл. к.* **видеомагнитофон.** *Шундый елларның берсендә, --- Рамил, бераз ял итеп алу нияте белән, видеосын кабызды.* Ф.Бәйрәмова

**ВИДЕОЖУРНАЛ** *и. лат.* Бер темага багышланган кыска метражлы фильм. *Һиндстанның «Айуитнис» видеожурналы --- фильм төшерү төркеме тарафыннан тасмага алынган бу күренеш --- Бихорның бүгенге чынбарлыгына хас вакыйга икән.* Юлдаш

**ВИДЕОИНЖЕНЕР** *и. лат.-фр.* Видеотехника, видеоязмалар белән эшләүче белгеч, инженер

**ВИДЕОКА́МЕРА** *и. лат.* Турыдантуры күреп, күзәтеп тору, күзәтү объектындагы хәрәкәтне һәм тавышларны яздыру аппараты (кассеталы видеомагнитофон белән берләштерелгән портатив телевизион камера). *Хәер «авыл» сүзе монда килеп тә бетмидер, чөнки аларның өйләрендә, космик корабтагы кебек, бөтен электрон җиһазлар шыплап тулган – монда интернет та эшләп тора, сканерлар, факслар, видеокамералар, лазерлы принтерлар – барысы да авылга хезмәт итә.* Ф.Бәйрәмова. --- *мәктәпләрнең өчтән берендә видеокамералар урнаштырылган.* Юлдаш

**ВИДЕОКАССЕ́ТА** *и. лат.-фр.* Видеоязмасы булган кассета. *Малай, бу вакыйгадан соң, Аргентина хилерлары турында видеокассета караган ---.* Ватаным Татарстан

**ВИДЕОКЛИП** *и. лат.-ингл.* Махсус төшерелгән сурәттән һәм җырдан торган, телетапшыруларда файдалану өчен эшләнгән кыска сюжетлы музыкаль номер; видео кушымта. *Күп җырлар видеоклипка да төшерелгән.* Татарстан яшьләре

**ВИДЕОКОНФЕРЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Телефон яки компьютер челтәрендә, берничә абонент яки кулланучы катнашында, берсен-берсе күреп аралашу чарасы. *Быел республика игенчеләре рекордлы уңыш җыеп алган, бу хакта Премьер-министр Р.Миңнеханов рәислегендә узган видеоконференциядә хәбәр ителде.* Мәдәни җомга. *«Татмедиа»да үткәрелгән видеоконференция вакытында Илгиз Миңнуллин җирле муниципалитет җитәкчеләрен бу хакта тагын бер кат кисәтте.* Мәгърифәт

2) *махс.* Шундый аралашуны оештыра торган техник мөмкинлекләр

**ВИДЕОМАГНИТОФОН** *и. лат.-гр.* Мәгълүматны магнитлы лентага яздырып, экранда карау һәм тыңлау өчен файдаланыла торган аппарат. *Идәндә – калын келәмнәр. Аргы почмакта – видеомагнитофон, япон телевизоры.* М.Галиев. *Милиционер видеомагнитофонга кассета куйды һәм, идарә итү пультын кулына тотып, диванга килеп утырды.* Ф.Яруллин. *Ротада яңа видеомагнитофон, телевизор, аквариум һәм магнитофоннар барлыкка килә.* Юлдаш

**ВИДЕОМОНИТО́РИНГ** *и. лат.-ингл.* Видеокамералар ярдәмендә күзәтү. *Видеомониторингта җайланмалар ярдәмендә юлларның тәүлек дәвамында күзәтелүе инспекторлар өчен бик уңай.* Мәдәни җомга

**ВИДЕОПЛЕ́ЕР** *и. лат.-ингл.* Көнкүреш видеомагнитофоны, кассеталы видеоуйнаткыч

**ВИДЕОСТУ́ДИЯ** *и. лат.-ит.* Видеомәгълүматлар әзерли торган студия

**ВИДЕОТАСМА** *и.* Видеокассеталарда кулланыла торган магнитлы тасма. --- *Рамил, видеотасмалар, китаплар арасыннан, бик матур итеп сырлап-бизәлеп ясалган икона табып алды.* Г.Бәйрәмова. *Яшьләрнең үз-үзләрен белештерми котырынуларын лидер видеотасмага терки бара.* Юлдаш. --- *кайбер урамнарга мониторинг системасы камералары урнаштырылган. Алар юл кишәрлекләрен видеотасмага төшерәләр.* Мәдәни җомга. --- *сеңлесе байлыгына кызыккан ханымны, «киллер»-оперативник шушы видеотасманы күрсәткәч, «хезмәтләр» өчен алыш-биреш ясау белән эләктереп алалар.* Мәдәни җомга

**ВИДЕОТЕ́КА** *и. лат.-гр.* Видеокассеталар җыелмасы, тупланмасы, шулай ук аларны саклау урыны

**ВИДЕОТЕЛЕФОН** *и. лат.-гр.* 1) Экранда бер-береңне күреп сөйләшергә мөмкин булган телефон. *Казанда күп кенә сөйләшү пунктларында видеотелефон урнаштырылган.* Татарстан хәбәрләре

2) Шундый элемтәне тормышка ашыру аппараты

**ВИДЕОУЕН** *и.* Телевизор экраннарында күрсәтелә торган компьютер уены. *Миллиардер кызларын телевизор караудан һәм видеоуеннар уйнаудан тыйган ---.* Мәдәни җомга

**ВИДЕОУЙНАТКЫЧ** *и.* Әзер видеокассеталарны экранда карау һәм тыңлау өчен файдаланыла торган аппарат

**ВИДЕОФИЛЬМ** *и. лат.-ингл.* Магнитлы тасмага яздырылган фильм. *Роберт бермәлгә югалып калды, аннары акланырга кереште: – Әйе... юк... менә Эдик видеофильмга билет алган булган.* З.Хөснияр

**ВИДЕОЯЗМА** *и.* Магнитлы тасмага яздырылган мәгълүмат. --- *егетне бер оперативникның соравы туктата. – Нәрсә, брат, аңладыңмы инде видеоязманың кайдан килгәнен?* Законлы газета. *Аның гаебе беркемдә дә шик уятмый, хәтта аудио һәм видеоязмаларга чаклы бар бит.* Мәдәни җомга

**ВИ́ДИК** *и. рус сөйл. к.* **видеомагнитофон.** *Бүлмәне --- юан аяклары бизәкле агачтан эшләнгән диван, ике тирән кәнәфи, өстенә видик куелган япон телевизоры --- бизи.* Т.Галиуллин. *Миләүшә видикка кассета куеп маташканда, кемдер, килеп, Әлфредне эшкә чакырды.* Ф.Яруллин

**ВИ́ЗА** *и. фр. < лат.* 1) Нинди дә булса дәүләткә, илгә керү, аннан китү яки аның территориясе аша үтү өчен, хөкүмәт тарафыннан паспортка мөһер сугып бирелгән рөхсәтнамә. *Шул хәлдә мин чит ил паспорты һәм виза артыннан чаптым.* З.Хөснияр. *Телен кыскартырга бик вакыт бит аңа. Алайса тагын визасын ябачаклар.* Ә.Хәбибуллин. *Зур ашкынулар тудырган, бөек хикмәтләр вәгъдә иткән, өч айлап виза көттереп, Казан – Мәскәү тимер юлында киләп сардырган атаклы Парижның беренче вокзалы менә шушы инде.* Г.Гобәй

2) Нинди дә булса эш башларга берәр документка, гаризага салынган резолюция, рөхсәт. *Мин үзем, транзит визасы алырга һәм шуның өчен Мәскәүдә латыш канцеляриясенә акча түләргә туры килгәч кенә, дөньяда «Латвия» дигән «аерым» хөкүмәт булганлыгын ныклап белдем.* Г.Гобәй. *Заграница паспортының дүрт ягын да штамплар белән тутырып, әнә шул визаларны җыйганда, шул штампларның һәммәсенә акча түләүне искә алгач, күңелгә «бу – тере кешеләргә салына торган пошлинадыр инде» дигән уй килә.* Г.Гобәй

3) *күч.* Берәр нәрсә эшләргә рөхсәт, фатиха. *Такташны күмеп кайткан көннең кичендә үк, берәү дә кушмыйча һәм берәүдән дә виза алмыйча, ничектер, стихиячел бер төстә үзебездән-үзебез җыелып, --- Такташка багышлап, кичә уздырдык.* Ф.Хөсни

**ВИЗАЖИСТ** *и. рус < фр.* Гигиена һәм эстетика кагыйдәләре буенча бизәнү-төзәнү, тән тиресен, колак, күз, теш, чәчләрне һ.б. тиешле тәрбиядә тоту эше белән шөгыльләнүче белгеч; косметолог

**ВИЗАНТИ́ЯЛЕ** *и.* Рим империясе таркалганнан соң IV–XV гасырлар чигендә яшәгән Византия дәүләте кешесе, румлы, руми. *VIII гасырда византиялеләр Сүриядәге һәм Әрмәнстандагы гарәп кабиләләренә үзләре басып керә башлыйлар.* Урта гасырлар тарихы. *Византиялеләр, диңгездә һәм коры җирдә алып барган сугышларда, «грек уты» ярдәмендә, күп кенә җиңүләргә ирешәләр.* Урта гасырлар тарихы. *Димәшкъка византиялеләр килгәч, алар гыйбадәтханәне христиан чиркәве итеп үзгәртә.* Юлдаш

**ВИЗИР** *и. нем.* 1) *махс.* Рәсемгә төшерелә торган әйберне карау өчен, фотоаппарат яки киноаппарат объективын турылау җайланмасы, оптик система

2) *хәрби* Артиллериядә: тупларның төзәү җайланмаларында карау өчен тар ярыгы булган махсус пластинка

3) *геогр., астр. авиа.* Оптик приборны яки почмак үлчәү приборын билгеле бер ноктага төбәү өчен махсус җайланма. *Казаннан визир яручы таксаторлар килгән иде. Визир үтә торган урын куе усаклыкка туры килде.* Х.Камалов. *Ирләр халкы урман кисү, агач әзерләү, визир юлы ачу, ботак яндыру кебек эшләр башкара иде.* М.Мәһдиев

**ВИЗИРЛА́У** *ф.* Оптик һәм почмак үлчәү приборын бер ноктага төбәү

**ВИЗИТ** *и. фр.<лат.* Тиз генә кая булса да килеп китү, кереп чыгу, зиярәт (гадәттә рәсми рәвештә). *[Сабантуй] --- көнне Петр, иртән иртүк, матур киенеп, абыйсы өенә – Митрәйгә китә ---. Бу – һәр елны эшләнә торган, мәҗбүри бер эш сыман визит.* М.Мәһдиев. *Мин бүген 20 җиргә визит ясап, 20 чынаяк чәй эчтем, әллә никадәр хәбәр ишеттем.* Ф.Әмирхан. *[Мирсәет] Аннары: – Иртәгә дә сезнең янга дуслык визиты белән килергә рөхсәт булыр микән? – дип елмайды.* С.Зыялы. *Бу вакыт аралыгында мин, гомумән, республикада булмадым да: башта ялда идем, аннан Германиягә визит белән бардым.* Шәһри Казан

**ВИЗИ́ТКА** *и. рус сөйл. к.* **визит карточкасы.** *Визиткада аның банк директоры икәнлеге, банкның адресы һәм директор әфәнденең эш телефоннары басылган иде.* Т.Әйди

**ВИЗИ́Т КА́РТОЧКАСЫ** *и.* 1) Кешенең исем-фамилиясе, атасының исеме, профессиясе һәм дәрәҗә-званиесе, шулай ук адресы, телефоны, эш урыны язылган махсус кәгазь (берәр кеше белән танышканда, аның белән бәйләнешне дәвам итү максатында, үзенең координатларын белдерү өчен бирелә). *– Тик көтәм мин сине, Исмәгыйль. Ярыймы? Менә адресым... – Ул аңа сумкасыннан визит карточкасын алып бирде.* Ә.Сафиуллин. *[Митрийнең абыйсы] Мәскәүдәге адресы басылган визит карточкасы өләшә...* М.Мәһдиев. *Адвокат, сүз башлагач ук, үзенең визит карточкасын сузды.* Л.Ганиева. *Шактый күп фирмалар визит карточкалары ясый башладылар.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Берәр кешегә хас сыйфатлар. *Юдина – удмурт нәселеннән. Зәңгәр күз. Камырны чеметкән шикелле өскә чөелгән борын. Төс-бит, чырай – визит карточкасы.* Х.Камалов. *Баягы пеләш агай гына, борынын төшермәскә тырышып: – Чү! Җинаятьчененң визит карточкасы булмагае әле бу! – дигән булды.* З.Фәтхетдинов

**ВИЗУАЛЬ** *с. лат.* Гади күз яки оптик прибор ярдәмендә күренә, тикшерелә торган. – *Нәрсә бирәләр? – Шәһәр хатын-кызы моны, чиратның койрыгына килеп басып, алдагы һәм үзеннән соң килгән кеше белән «визуаль» контакт урнаштыргач кына --- сорый.* М.Мәһдиев

**ВИ́КА** *и. пол< нем.* Кузаклылар семьялыгыннан, культуралаштырылган күпьеллык үсемлек; кәрешкә. *Күрше басуга быел вика чәчкәннәр.* Ә.Еники. *Арбага кичтән чабып салынган солылы вика, клевер түшәлгән иде.* М.Мәһдиев. *--- виканы солы белән катнаштырып чәчәргә мөмкин.* Ботаника

**ВИ́КИНГ** *и. бор. сканд. тар.* 1) Швед галиме Ф.Аскеберг гипотезасы буенча, VIII–XI гасырларда Борынгы Скандинавиядән табыш эзләп чыгып киткән диңгез сугышчысы, пират (инглизлар аларны «викинглар», французлар «норманнар» дип атаганнар); *к. шулай ук* **варяг.** *Алманиядә, хәзерге Бонн шәһәре тирәсендә X–XI гасырларда*

*ясалган франк кылычлары болгарларга варяглар (викинглар, норманнар) аша килеп кергәндер, дип фаразлана.* Ф.Хуҗин. *Викинглар, еш кына, диңгез аша Англиягә һәм Франциягә һөҗүм иткәннәр. Исландия сагаларында викинглар канечкеч, комсыз талаучылар, пиратлар итеп сурәтләнә*

2) Борынгы язма истәлекләр буенча: талау походы

**ВИКОНТ** *и. фр.* Франциядә һәм Англиядә баронлык белән графлык арасындагы дворянлык дәрәҗәсен белдерә торган титул һәм шул титулга ия кеше. *Король герцоглар һәм графлар өчен сеньор була. Бер баскыч түбәнрәк герцог һәм графларның вассаллары – бароннар һәм виконтлар тора.* Урта гасырлар тарихы. *Бәхетсезлегенә, автомобиль хуҗасы виконт булып чыккан.* Юлдаш

**ВИКТОРИ́НА** *и. лат.* Аң-белемне сынау һәм күтәрү максаты белән, фәнгыйлемнең төрле өлкәләренә караган сорауларга телдән яки язма рәвештә җавап бирү уены. *Бөек шагыйребез Г.Тукайга карата әдәби викторина оештырдык, шуның сорауларына җавап эзләдем.* Г.Ахунов. --- *дуслар белән елга буйлап байдаркада сәяхәт итүләр, викториналар, танцылар – өйләнешкәнче табигый булып күренә.* Тигез гомер итегез! *Викторина сораулары алдан хәбәр ителгән.* Мәгърифәт

**ВИКТО́РИЯ** *и. лат. бот.* 1) Төнбоекчалар семьялыгыннан, эре чәчәкле, табасыман гаять зур яфраклы күпьеллык су үсемлеге (су өстендә йөзеп йөри торган яфракларының читләре өскә кайтарылып тора)

2) *сөйл.* Бакчада үстерелә торган, культуралаштырылган эре каен җиләге. *Кура җиләгеннән, җир җиләгеннән һәм викториядән вареньелар кайнаткач, җиләкләр бөтен килеш сакланса, вареньеның тәме дә, сыйфаты да яхшы була.* Ю.Әхмәтҗанов. *Чүпчәрларын һәм бозылганнарын чистарткач, викторияне салкын суда юалар һәм изәләр.* Ю.Әхмәтҗанов. – *Минә викториядән рәхим ит, алар инде күптән өлгергән, – дип, миңа түтәлдә тәгәрәшеп яткан каракучкыл кызыл төстәге җир җиләкләрен күрсәтте Гадел.* Р.Ишморат

3) *миф.* Борынгы Рим мифологиясендә җиңү патшасы

**ВИЛАЯТЬ** *и. гар. кит.* 1) *иск.* Өлкә, губерна. *Мөхәммәт, шул төбәктән чыккан, туып-үскән туфракка садә мәхәббәт ихтирамнарын гел сиздереп, әйтеп-язып торган якташ язучыларыннан аермалы буларак, туган вилаятеннән яшьли чыгып китми.* Т.Галиуллин

2) Кайбер көнчыгыш илләрендә (мәс., Төркиядә, Туниста) эре административ-территориаль берәмлек. *Һинд шаһы Һушаң шаһ белән сугышырга әзерләнә башлады. Шул максат белән, үзенең мәмләкәтендә булган вилаятьләргә төрле намә вә язулар җибәреп, халыкны сугышка өндәде.* Дастан. *Кыргыз вә Кәмкәмҗут – ике вилаять булып, бер-беренә якынлардыр*. Һ.Атласи. *Кич буе баш ватты Шәһит, әмма борчылырлык сәбәп күрмәде. Мөгаен, атасы мәмләкәтнең көньяк вилаятеннән – Нугай дәругасыннан килгән дусты Дәүран би хөрмәтенә мәҗлес җыя.* Ф.Латыйфи. *Ничә йөз еллардан бирле, без, Оренбург вилаяте, Орски вә кыргыз сахраларында икамәт итүче, «сурка» дигән хайван идек.* Ш.Маннур

**ВИЛДАН** *и. гар. иск. кит.* 1) Мөселман дине буенча, оҗмахта хезмәт күрсәтүче егет, җәннәт хезмәтчесе. *Вилдан, гыйльманнар, --- ак алъяпкычлар бәйләп, аларга* [*оҗмахка кергән кешеләргә*] *хезмәт итеп йөриләр.* М.Гафури

2) *күч.* Яшь егет. *Сайла да син ал матурлардан-матур җир вилданын.* Ф.Бурнаш

**ВИ́ЛКА** *и. рус* 1) *тех.* Сәнәккә охшаган, ике ябе чыгып торган төрле детальләр исеме. *Хәрабәләр арасында электроплитәнең янып бетмәгән ташы һәм стенадагы розетка эченә тыгылган вилка тимерләре күренеп тора иде*. Ф.Яруллин

2) *хәрби* Артиллериядә төбәү ноктасыннан ары һәм бирерәк төшкән снарядлар арасындагы ераклык

3) Шахмат уенында: бер фигураның бер үк вакытта ике яки берничә фигурага куркыныч тудырып торышы. *Картның ладьясы вилкага эләгеп, карт оттырды.* И.Гази

**ВИ́ЛЛА** *и. лат.* Шәһәрдән читтә, гадәттә аерым бакча эченә салынган бай һәм зиннәтле йорт яки дача. *Назмый, бер җилкапканы кыю гына ачып, биләмә түрендәге ике катлы виллага кереп китте.* Т.Әйди. *Бу биналар алгы якларыннан кырыс булып күренгәннәр һәм замокларны, шәһәр читендәге виллаларны, университетларны, госпитальләрне, базарларны хәтерләткәннәр*. Урта гасырлар тарихы. *Казан тирәсендә бик матур итеп салынган виллалар күренә башлады.* Заман

**ВИЛЯЯТЬ** *и. гар. кит. к.* **вилаять.** *Гали бай бу вилаятьтә бөек таҗҗар иде.* М.Акъегетзадә

**ВИНЕГРЕТ** *и. фр. кулин.* Гадәттә, ваклап туралган чөгендер, кишер, тозлы кыяр һәм кәбестәгә төрле тәмләткечләр һәм үсемлек мае салып әзерләнгән салкын ашамлык. *Мәдинә кунакларга винегрет ясарга булды.* М.Мәһдиев. *Винегрет өчен бәрәңге белән чөгендер, әрчелмичә, кабыгы белән генә пешерелә.* Ю.Әхмәтҗанов. *Табын мул иде – көне буе кызлар кышкы салат, «шуба», винегрет әзерләделәр, токмачлы-итле аш пешерделәр.* Р.Зәйдулла

**ВИНО** *и. рус* Йөзем шәрабы, исерткеч эчемлек. *Исендә дә юк, арбасында – урлаган вино, көпә-көндез чит кеше йортына кайтып бара.* А.Гыйләҗев. *Ресторанда рәтле вино да, теләгән ризык та юк иде.* М.Маликова. *Һәр кеше алдына аракы һәм вино эчү өчен рюмкалар, минераль сулар һәм җиләкҗимеш сулары өчен стакан куелырга тиеш.* Йорт эшләре

**ВИНОГРАД** *и. рус бот.* Виноградчалар семьялыгыннан, мыекчалар ярдәмендә ябышып, үрмәләп үсә торган күпьеллык куак үсемлек, йөзем. *Һәрбер агач, колмак үләне кебек лиана, виноград белән, үтә алмаслык хәлдә чорналган.* А.Фәтхуллин. *Кызык: тау башларында – кар, түбәндә виноградлар, әфлисуннар үсә.* Г.Әпсәләмов. – *Исән булсак, быел көзли Кырымда булабыз, – ди Дәүләтшин, – нәкъ виноград сезонына барып өлгерә бу.* И.Гази. *Үсәр чүлдә*

*мамык, виноград, Саран сахра ямьгә төренер!* Ш.Маннапов

**ВИНОГРАДЛЫК** *и.* Виноградлар күп үсә торган урын. *Туфрак уңдырышсызрак урыннарда мамык басуларын җиләк-җимеш бакчалары һәм виноградлыклар алмаштыра.* Җ.Хөсәенов. *--- хроникачы хуҗалыкның бөлгенлеккә төшүен менә ничек сурәтли: «Виноградлыклар эшкәртелми, кырлар сукаланмый --- .»* Урта гасырлар тарихы

**ВИНОГРАДЧЫЛЫК** *и.* Йөзем үстерү эше, авыл хуҗалыгының йөзем үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Ибраһим абый Аитов Ростов-Дон шәһәрендә яши һәм, озак еллар Виноградчылык институты белән бәйләнештә булып, виноградның яңа сортларын булдыру өчен тырыша.* Б.Камалов. *Коньяк Болгариядә --- виноградчылык әһәмиятле урын тота.* География. *Украинада --- виноградчылык алга киткән.* География

**ВИНТ** I *и. нем.* 1) *сөйл.* Агач, металл әйберләрне беркетү өчен, спираль сырлы кадак; шөреп. *Василий дәдә комбайнга иңе белән бик каты төртеп карады, эчендә нәрсәнеңдер шотырдаганын тыңлап торды һәм, нindidер винтын бора-бора, кичә башлаган сүзен дәвам итте.* Г.Гобәй

2) Корабльне яки самолётны хәрәкәт иттерүче механизмда: үз күчәрендә әйләнә торган валга беркетелгән калаклар. *Аерылышуны яңа гына сизгән Казбек [эт] инде ябылырга өлгергән ишеккә сикерде, самолётның әле – алдына, әле артына чыгып бәргәләнергә тотынды. Сафуан абый кабина тәрәзәсен шудырып ачты да: – Казбекны тотыгыз, винтка урала күрмәсен! – дип кычкырды.* М.Галиев. *Хәтта «Ленин» исемендәге гигант атом бозваткычына да винтлар куелган, ди.* М.Хәсәнов. *[Очучы балык] Гәүдәсенең алгы өлеше судан калкып чыккач, гидросамолёт винты кебек, койрыгын хәрәкәтләндерә башлый.* Кызыклы ихтиология. *--- корабльгә икенче торпеда килеп тия. Корабль ике ишү винтын һәм рулен югалта.* Кызыклы дөнья

3) *күч.* Кечкенә детальләр, әйберләр; яшәешнең һәрбер факты, эшчәнлек кисемнәре. *Ул тормыштагы бөтен күтәрелешләрне, бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп китәргә, һәрбер тәгәрмәчнең хәрәкәте китергән энергиянең күләмен үлчәп үтәргә тиешле.* Һ.Такташ

◊ **Винты бушаган** *сөйл. к.* **винты какшаган. Винты какшаган** *сөйл.* Аңгыра, акылга сай. *Я бу мине алдап саташтыра, яисә үз башымның винтлары какшаган, тигез әйләнми.* Ш.Камал. *Саташкан ул, винтлары какшаган.* Ш.Камал

**ВИНТ** II *и. нем.* Карта уенының бер төре. *Алар һәммәсе – Дмитрий Степановичның бер үк вакытта клиентлары да, винт уйнауда партнёрлары да иде...* А.Толстой

**ВИНТО́ВКА** *и. нем.* Сырлы көпшәле мылтык. *Ныгытып винтовка тоткан корыч куллар, завод цехларына кереп, яңа көч, чиксез энтузиазм белән эшли, заводны аякка бастыралар.* Ш.Камал. *Өйрәтәбез аны, Якуп абый, винтовкадан атарга, граната чөяргә дә.* И.Гази. *Корыган куаклар арасындагы постка иңенә винтовка аскан озын буйлы карт белән немец автоматы тоткан бер таза егет баскан иде.* З.Фәтхетдинов. *Бераздан соң, бер автоматтан, ике винтовкадан залп бирдек.* А.Шамов

**ВИНЧЕ́СТЕР** *и. ингл.* 1) Магазинлы автомат мылтык (XIX гасыр урталарында Америкада чыгарылган). *22 яшендә Сара Парди винчестер мылтыгы уйлап табучы һәм җитештерүче Оливер Фишер Винчестерның улы Уильм Виртка кияүгә чыга.* Юлдаш

2) Ау мылтыгының бер төре. *Әчкә кергәч, өй эче тагын да иркенрәк тоелды. Уртада тимер мич гөрли. Бер як стенада – ике винчестер, икенчесендә – җиде кыллы гитара.* А.Хәсәнов

3) Информатикада: каты магнитлы диск

**ВИНЬЕ́ТКА** *и. фр.* Эчтәлек белән бәйләнешле итеп, китаптагы бүлек башына, ахырына, почта кәгазьләренә, альбом, көндәлек һ.б.ш. нәрсәләрнең битләренә төшерелгән кечкенә бизәк, рәсем. --- *китапны яки аның аерым бүлеген төгәлләп куючы, китап битендәге текст полосасы киңлегендә яисә аннан таррак, зур булмаган композиция, рәсем, виньетка һ.б. [соңгы рәсем-бизәк була].* М.Вәлиев

**ВИОЛОНЧЕЛИСТ** *и. рус к.* **виолончельчы.** *Ә скрипачлар, виолончелистлар уен коралларын үзләре белән сөйрәп йөртүчән.* М.Маликова. *Илһамның грим бүлмәсенә клуб директоры йөгереп керә: – Ростропович дигән кеше билетсыз кермәкче. Кем ул, танышыгызмы әллә? – Ростропович – сезнең Мәскәү кешесе. Дөньяның атаклы музыканты, виолончелист, дирижёр.* М.Галиев

**ВИОЛОНЧЕЛЬ** *и. ит. муз.* Бас-тенор диапазонлы, дүрт кыллы, скрипкага охшаган, сызгыч (смычок) белән уйный торган зур музыка коралы. *Мәктәп директоры Рувим Львович Поляпов малайга виолончель классына укырга йөрергә тәкъдим ясый.* Казан утлары. *Шул чорда ук Фәрит Яруллин виолончель һәм фортепьяно өчен соната --- яза.* Казан утлары

**ВИОЛОНЧЕЛЬЧЫ** *и.* Виолончельдә уйнаучы музыкант. Соңгы вакытларда, Казан музыка училищесы укучылары скрипкачылар Заһид Хәбибуллин, Хәсән Гобәйдуллин, виолончельчы Хәмит Абубәкеров һәм тагын әллә кем, квартет оештырып уйнаулары белән, тыңлаучыларда мәхәббәт казана башладылар. Җ.Фәйзи

**ВИ́РА** *ы. ит. сөйл.* Йөк ташучылар, төзүчеләр, бораулаучылар, диңгезчеләр телендә «күтәр!», «югарыга!» дигәнне аңлата торган боерык сүзе; *киресе:* **майна**! *Шулчак кемдер аны, тупас итеп, билбавыннан ыргакка эләктерде. «Вира!» дип кычкырган тавыш ишетелде, һәм ул кранның ләкләк борыны артыннан өскә күтәрелә башлады.* Р.Вәлиев. *Эш, көндәгечә, йөк тагып торучының: «Вира!», «Майна!» дип аваз салуыннан башланып китте.* Н.Хәсәнов

**ВИРАЖ** I *и. фр.* 1) Төрле техниканың: самолёт, автомобиль, велосипед һәм мотоциклның кәкре сызык буенча борылуы. *Бер самолёт шулкадәр югары күтәрелгән һәм, әллә нинди виражлар, элмәкләр ясый-ясый, бөтерелә*

*башлаган.* Ф.Шәфигуллин. *Ә менә бер урында әйләнеп, вираж ясап оча башласаң, алар [болытлар] бөтенләй җанлы нәрсәләр булып күренәләр.* С.Баттал. *«Ил-18» сул як виражга янтайды.* М.Юныс

2) *сир.* Кәкре сызык буенча борылыш ясап очу. *Петропавел чиркәвенең чәукәләре кыш алдыннан соңгы вираж ясый күктә...* Р.Әхмәтҗанов

3) Транспорт кинәт борылганда аумасын өчен, юлның эчке якка авыш итеп салынган өлеше

**ВИРАЖ** II *и. фр. махс. фото* Билгеле бер төс бирү өчен, басылган фоторәсемне юдыра торган химик эремә

**ВИРАЖЛА́У** *ф. фото* Кинотасма, фоторәсем сурәтенә кирәкле төс һәм ныклык бирү; виражда тоту. *Виражлау ике стадиядән тора: башта фоторәсемне агарталар, соңыннан аңа төс бирәләр.* Ф.Акчурин

**ВИРД** *и. гар. дини* Билгеле бер вакытта укылырга тиешле дога, аять. *Бу бер догалык һәм вирд иде.* Г.Ибраһимов. *Һәр намаз соңында, вирд догалары җөмләсенә берничә сүз дә куша, хосусән ястүләрне бик ихлас вә бик озак үти.* Г.Ибраһимов

**ВИРТУАЛЬ** *с. ингл.* 1) Уйдырма, ясалма, күзаллаган. --- *чик-чама белмәстәй хыяллар да барып җитмәслек әллә нинди виртуаль дөньялар хасил ителергә мөмкин.* Ә.Рәшит

2) Компьютер челтәре белән бәйле, шуның ярдәмендә башкарыла торган. *Яшәү дөньялары – Интернетта, Тормыш итүләре – виртуаль! Йөрәкләре – сайт та файл гына, Ачкыч ярат, «тычкан» кертеп ал!* С.Гәрәева. *«Уеннан уймак чыга» дип әйтеп калдырганнар борынгылар, виртуаль уеннарның ни икәнен белмәсәләр дә.* Кәеф ничек

**ВИРТУОЗ** *с. лат.* 1) Үз эшен югары дәрәҗәдә, камил башкара торган; үз эшенең остасы булган. --- *хайваннар дөньясында, гәүдә торышының әллә ни әһәмияте булмаган, ярканат кебек виртуоз клоуннар да аз түгел.* Кызыклы физиология

2) Югары техник осталыкка ия булган. *Сәнгать дөньясына иң ошаганнарның берсе, һичшиксез, виртуоз баянчы Мирзанур Фарукшин булды.* Р.Ишморат. *Үз гомерендә залны күкрәткән виртуоз гармунчыларны --- күргәне булды аның.* Г.Ахунов

**ВИРТУОЗЛА́РЧА** *рәв.* Виртуозлык күрсәтеп. *Егет машинасын авыллар арасында виртуозларча йөртергә тәмам өйрәнеп беткән икән.* Ә.Еники

**ВИРТУОЗЛЫК** *и.* Нинди дә булса эшне башкарудагы гаять зур осталык. *Бер караганда, ул – без белгән элекке Шәүкәт Галиев: шундый ук осталык, тапкырлык, виртуозлык. Икенче караганда, ул инде – өр-яңа Шәүкәт Галиев: темалары, күтәрелгән проблемалары, балалар дөньясына карашы яңа.* Р.Миңнуллин

**ВИ́РУС** *и. лат. биол.* 1) Йогышлы авырулар тудыра торган бик кечкенә микроорганизм. *Әлеге чирне таратучы А һәм В вирусларының әнә теге түшәмдә дә, медикаментларда да, җыештыручыларда һ.б.ларда да булуы мөмкин иде.* Ф.Садриев. *Оксфорд галиме Д.Бромхолл соматик күзәнәк төшен кроликның күкәй күзәнәгенә күчереп утырта. Ул, махсус вирус ярдәмендә, күзәнәкләрне кушу ысулын файдалана.* Могҗизалы энциклопедия. *Коты-ру вирусы нерв тукымалары буйлап үзәккә хәрәкәт итә һәм, ахыр чиктә, --- буыннарның параличына китерә.* Сәламәт булыйк!

2) *информ.* Башка программаларга үзлегеннән кереп, шул программалар эшчәнлеген зарарлый торган (файлларны бозу, мәгълүматларны бетерү һ.б.) компьютер программасы. *Компьютер вируслары көннән-көн камилләшә бара, һәм, алар белән көрәшер өчен, яхшы антивирус программалары кирәк.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Кемдер яки нәрсәдер тарафыннан кемгә дә яки нәрсәгә дә булса ясала торган тәэсир, йогынты. *Кайберәүләрне шовинистик вируслардан дәвалау өчен, крокодил тиресеннән киселгән каешның үтә дә яхшы икәне һәркайсыбызга мәгълүм.* Ф.Баттал

**ВИ́РУСЛЫ** *с.* 1) Вируслары булган

2) Вирус китереп чыгарган, вирус тудырган. --- *озакка сузылган стресс иммунитетны киметә. Шуңа күрә, борчылу, стресс озакка сузылса, салкын тию, вируслы авырулар тизрәк эләгә.* Р.Гыйльметдинова. *Чөгендер һәм лимон соклары кушылмасы – вируслы авыруларга каршы көрәштә беренче чара.* Юлдаш

**ВИРУСО́ЛОГ** *и. рус* 1) *биол.* Вирусология өлкәсендә вирусларны өйрәнүче белгеч

2) *информ.* Компьютер вирусологиясен өйрәнүче белгеч

**ВИРУСОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* 1) Йогышлы авырулар тудыра торган вирусларны өйрәнә торган фән. *Россиядә 10 меңнән артык кешедә A/H1N1 гриппы бар, диләр. Ивановский исемендәге вирусология институты директоры, Россия медицина фәннәре академиясе академигы Дмитрий Львов әнә шундый сенсацион белдерү ясый.* Кәеф ничек

2) *информ.* Компьютер вирусларын һәм алардан саклану ысулларын өйрәнә торган фән

**ВИ́СКИ** *и. ингл.* Әчегән арпа, арыш яки кукуруз салаты дистиллятын агач савытларда берничә ел тотып әзерләнә торган, югары градуслы исерткеч эчемлек; аракы төре. *Иллә дә мәгәр шәп кеше иде. Белмәгән нәрсәсе бар иде микән? Өй коньягы гына түгел, әмриканский виски ясарга да өйрәтә иде егетләрне.* Ф.Баттал. – *Сез сыра өнәмисезмени? Сыра – плебейлар эчемлеге шул... – Сез әллә джин, кальвадос, виски гына эчәсезме?* М.Юныс

**ВИСКО́ЗА** *и. лат.* **1.** 1) Целлюлозадан җитештерелгән ясалма ефәк, целлофан җитештерүдә кулланыла торган куе, сузылучан матдә. *[Кукуруза] Сабагы һәм яфракларыннан кәгазь, линолеум, вискоза, ясалма бөке ясыйлар.* Л.Мәүлүдова

2) Ясалма ефәк

**2.** *с. мәгъ.* Шундый матдәдән эшләнгән, шундый матдәдән ясалган. *Вискоза ефәкне мамык тукыманы манган кебек үк маналар, ләкин әйберне салкын эремәгә салалар һәм, акрынлап җылытып, кайнатып чыгаралар.* Өегез ямьле булсын

**ВИ́СМУТ** *и. нем. хим.* Җиңел эретмәләр ясау өчен файдаланыла торган, ал төсмерле көмеш соры металл; химик

элемент. *Висмутта яисә алтында барысы да киресенчә: магнитның төньяк полюсы янында – төньяк полюс, ә көньяк полюсы янында көньяк полюс барлыкка килә.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Висмут кушылмалары медицинада, яңгынга каршы чараларда кулланыла*

**ВИ́СМУТЛЫ** *с.* 1) Висмут кушылган, висмут катнашмасы булган. *Висмутлы руда*

2) Висмут порошогы кушып ясалган, яисә висмуттан җитештерелгән. *Висмутлы язу карасы*

3) Висмут кушып ялтыратылган. *Висмутлы буяу*

**ВИТАЛИЗМ** *и. лат. биол.* Биологиядә: матди сәбәпләрне инкяр итеп, тереклекнең, яшәүнең сәбәбен тәндәге матди булмаган башлангыч «җан», «тормыш көче» белән аңлата торган идеалистик караш. *Витализм «җан»ны, төгәлрәк әйткәндә «яшәү көчен», материянең физик-химик төреннән аерым, мөстәкыйль бер күренеш дип саный.* К.Гыйззәтов

**ВИТАЛИСТ** *и. рус* Витализм тарафдары

**ВИТАЛИ́СТИК** *с.* Витализмга нигезләнгән, шуңа караган, асылы витализм булган

**ВИТАМИН** *и. лат.* 1) Организмның эшчәнлеген, нормаль үсүен тәэмин итү өчен кирәк булган төрле химик составлы органик матдәләр. *Кәбестәдә инде ул витамин!* Р.Батулла. *Ул [Маштаков] кайсы ашамлыкта күпме калория, күпме витамин һәм никадәр файдалы матдә булуын өйрәнә.* М.Юныс. *Тутыкмый торган корыч пычак яшелчә һәм җиләк-җимештәге витаминнарны таркатмый, лимон суыннан каралмый.* Өегез ямьле булсын. *Шифалы кайнатмалар һәм төнәтмәләр әзерләү өчен, үги ана яфраклары кулланыла. Чөнки аларда С витамины, --- мөһим микроэлементлар күп тупланган.* Табигать даруханәсе

2) Шул матдәләрне үз эченә алган препарат. *Бүгеннән башлап, шәфкать туташы сезгә магнезия белән витамин кадый башлар.* З.Мәхмүди

**ВИТАМИНЛАШТЫРУ** *ф.* Витаминга баету, витамин кушу. *Витаминлаштырылган азык. Витаминлаштырылган сабын*

**Витаминлаштыра бару** Витаминлаштырылган продуктларны торган саен арттыру, тагы да күбрәк витаминлаштыру. *Балалар азыгын елдан-ел витаминлаштыра баралар*

**Витаминлаштырып бетерү** Барысын да, тулысынча витаминлаштыру

**Витаминлаштырып тору** Даими, һәрвакыт витаминлаштыру. *Сатудагы сөт ризыкларын витаминлаштырып торалар*

**Витаминлаштырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да витаминлаштыру

**ВИТАМИНЛЫ** *с.* Витаминнары булган, витамин катнаштырылган. *Тән тиресе өчен витаминлы крем.* С.Гәрәева. *[Балаларны] Кояш һәм һава ванналары алырга өйрәтәләр, яшелчә, җиләк-җимеш, витаминлы азыклар белән тукландыралар.* Т.Нәҗмиев

**ВИТАМИНЛЫЛЫК** *и.* Витаминлы булу дәрәҗәсе. *Кара карлыганның витаминлылыгы башка күп кенә җиләк-җимешләрнекеннән зуррак*

**ВИТР** *и. гар. дини к.* **витр намазы**. *Важиб гамәлләр: витр һәм гаид намазларын уку, фитыр сәдакасын бирү, корбан чалу.* И.Әмирханов. *--- ястү намазы берлә кеше эшен тәмам итә, һәм дә ястүдән соң витр укыла, ул да – олуглыкка дәлил.* Г.Исхакый

**ВИТРАЖ** *и. фр.* Төсле пыялалардан ясалган бизәк яки картина (тәрәзә, ишек һ.б. әйберләрдә). *Чиркәү тәрәзәләренең зурлыгына исең китәрлек. Тоташ витражлар.* М.Әмирханов. *Гаять зур тәрәзәләрне астан өскә кадәр витражлар – үтә күренмәле төсле пыяла кисәкләреннән эшләнеп, бөгелгән кургаш кыршау белән беркетелгән картиналар һәм бизәкләр тутырып тора.* Урта гасырлар тарихы

**ВИТРИ́НА** *и. фр.* 1) Кибетләрдә сатуда булган төрле товарларны күрсәтү максатында, махсус җиһазландырылган тәрәзә. *Безнең дамалар витриналарга гына карап уза башладылар.* С.Сөләйманова. *Шуңа күрә Урам әле – безнең «Мәктәбебез», Витриналар – безнең «Әлифба».* Х.Туфан

2) Күргәзмә экспонатлар тезеп куела торган пыяла шкаф яки тартма. *Витриналарның берсендә Руфия дәфтәр битләренә ябыштырылган иске почта маркалары күргәч, филателия белән мавыгучы күрше малаен сөендерергә уйлады.* С.Сөләйманова. *Җиңел ак өстәлләр бер-берсеннән гөлләр белән аерылган, бар витринасы бәллүр вазалардагы җиләк-җимеш --- белән күз явын алып тора иде.* Т.Әйди

3) Яңа газеталар, белдерүләр элеп яки ябыштырып куя торган махсус такта. *Әйләнмәле витринада – кичә уйналган спектакльгә афиша.* Н.Исәнбәт. *Почмактагы гәзит-журнал киоскысы янында бүгенге гәзитләр ябыштырылган озын витрина тора иде.* А.Тимергалин

**ВИТР НАМАЗЫ** *и. гар.-фар.* Ястү намазыннан соң, иртә намазына кадәр укыла торган өч рәкәгатьле намаз

**ВИ́ЦЕ-** *лат.* 1) Кушма сүзләрдә, урынбасар, ярдәмче, мәгънәсен белдергән беренче кисәк (мәс., *вице-губернатор, вице-президент, вице-консул*)

2) Кушма сүзләрдә исеме, дәрәҗәсе, казанышлары белән икенче урында булганлыкны белдергән компонент (мәс., *вице-мисс, вице-чемпион*)

**ВИ́ЦЕ-АДМИРАЛ** *и. голл.* Контрадмирал һәм адмирал арасындагы хәрби дәрәҗә һәм шул дәрәҗәне йөртүче гаскәри (адмирал дәрәҗәсеннән кечерәк, ә контр-адмиралдан зуррак булган хәрби диңгезче дәрәҗәсе)

**ВИ́ЦЕ-ГУБЕРНА́ТОР** *и. лат.* Губернатор урынбасары (ярдәмчесе). *Мәсәлән, 2005–2007 елларда Коряк автономиялеокругыгубернаторыВ.Логинов, Амур өлкәсе губернаторы Л.Коротков, Новгород өлкәсе вице-губернаторы Н.Иваньков һәм Сахалин губернаторы И.Малахов ришвәтчелектә фаш ителде.* Кызыл Таң. *Уфа провинциясенең вице-губернаторы Аксаковка бәйле жалулар билгеле.* Җ.Рәхимов

**ВИ́ЦЕ-КО́НСУЛ** *и. лат.* Консул урынбасары, консул ярдәмчесе

**ВИ́ЦЕ-МЭР** *и. лат.* Мэр урынбасары, мэр ярдәмчесе. *Вице-мэр посты*

**ВИ́ЦЕ-ПРЕЗИДЕНТ** *и. лат.* Нинди дә булса дәүләткүләм фәнни яки

финанс учреждениесендә, сәнәгать берләшмәсендә президент урынбасары (ярдәмчесе). *Танылган фирманың вице-президенты*

**ВИ́ЦЕ-ПРЕМЬЕР** *и. лат.* Премьер-министр (дәүләт башлыгы) ярдәмчесе. *Вице-премьер итеп билгеләү*

**ВИ́ЦЕ-СПИ́КЕР** *и. лат-ингл.* Спикер урынбасары (ярдәмчесе). *Үзәкне тәмамлаучыларга, РФ Дәүләт Думасы вице-спикеры Олег Морозов --- имзасы белән, «Яшь лидерлар мәктәбе»ндә актив катнашканнары өчен, сертификатлар тапшырыла.* Мәгърифәт

**ВИЦМУНДИР** *и. лат. тар.* Россиядә: 1917 елга кадәр хәрби булмаган чиновникларның махсус киеме (сюртук). *Беренче рәтләргә --- вицмундир кигән кунаклар – шәһәр думасы членнары [утырган].* Җ.Тәрҗеманов

**ВКЛАД** *и. рус* Саклык кассасына һәм банкларга сакларга салынган акча, кертем. *Күпчелек очракларда акча алу яңа вкладлар кертү белән тигезләшә.* Икътисад

**ВКЛАДЧЫ** *и.* Саклык кассасына акча салучы кеше. *Ул чакта вкладчылар вкладны кайтарып бирүне таләп итәләр.* Политэкономия

**ВКЛА́ДЫШ** *и. рус* 1) Китап, журнал, газета эченә салынган махсус кәгазь, өстәмә бит. *Китап эченә куйган вкладышымны тагын төшергәнмен.* М.Мәһдиев. *Теләгәннәргә – Татарстан һәм Россия гражданлыклары, һичшиксез, аерым графаларда күрсәтелгән, «милләт» графасы булган паспорт. Вкладыш турында сүз дә булырга тиеш түгел.* Т.Миңнуллин

2) *тех.* Берәр механизм, җайланма эченә куела торган деталь. *Машинаның алыштырасы вкладышларын куярга гаражыгызда чокыр да юк.* Ф.Яруллин

**ВКЛЮЧА́ТЕЛЬ** *и. рус* Электр тогын тоташтыру яки өзү җайланмасы; тоташтыргыч. *Кызым, включательгә бас әле.* Г.Мөхәммәтшин. *Яңа йортларда включательләр европача урнаштырылган.* Ватаным Татарстан

**ВЛАСТЬ** *и. рус* 1) Дәүләт белән идарә итү хокукы, сәяси хакимлек. *– Безгә халык власте, демократия власте, учредительное собрание кирәк, – дип, сүзен тәмамлады Мөхтәр.* Ш.Камал

2) Дәүләт идарәсе органнары, хөкүмәт. *Берни дә әйтә алмыйм, чөнки хәзер илдә закон да, власть та юк.* Т.Гыйззәт. *Власть өчен көрәшкәндә, эш ташлауны корал итүчеләргә дә камчы куркынычы юк түгел.* Ш.Камал. --- *демократия урынына ярым демократик, ярым бюрократик, авторитар бер власть алмабызмы икән?* Ә.Еники

3) Башкалар өстеннән хакимлек итәргә, боерыклар бирергә хокук һәм мөмкинлек; җитәкчелек итү хокукы. *Власть үзебезнеке була торып, шушы егетләргә мыскыл иттереп торабызмы инде шулай?* М.Фәйзи. *Өйдә власть минем үз кулымда.* И.Гази. *Кай арада бу арык кыз аның өстеннән власть алды соң әле?* М.Маликова

4) **властьлар** *күпл.* Дәүләт башындагы кешеләр; администрация; түрәләр. *Бу эшләрне властьларга хәбәр итәргә кирәк.* Г.Ибраһимов. *Мәсьәләне властьлар гына хәл итә алачак.* Ш.Камал. *Робертның кем икәнлеген инглиз властьлары, һичьюгы редакция хезмәткәрләре сизеп калмасын өчен, аны бирәү дә эзләргә тиеш түгел.* Г.Хисамов

◊ **Властька кайту** Властьны яңадан алу

**ВЛАСТЬЛЫ** *с.* **1.** Властька (*4 мәгъ.*), власть көченә ия булган. *Фәрит һәрвакыт, сөйләгәндә, үзенең властьлы булуына ишарә ясый.* Казан утлары. *Бабагызның властьлы вакытлары үтте шул.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* Властька ия булуын күрсәтеп, белгертеп. *[Зәйнаговның] Йөзе бик дәһшәтле һәм властьлы иде.* Х.Камалов. *– Авыз өчен баш җавап бирә! – диде, ныклы һәм властьлы итеп.* Казан утлары

**ВЛАСТЬЛЫ́К ИТҮ** *ф. сөйл.* Хакимлек итү. *Начальстволар --- үзләренең көчләре зур, властьлык итүләре нык икәнлеген күрсәтмәкчеләр иде.* М.Гафури

**ВЛАСТЬЛЫ́К КЫЛУ** *ф. сөйл. к.* **властьлык итү.** *Беренче самодур булып, сәхнәгә акча белән властьлык кылучы --- Дикой чыга.* Г.Кутуй

**ВЛАСТЬЛЫЛЫК** *и.* Властька ия булу

**ВЛА́СТЬ ТОТУ** *ф.* Хакимлек итү. *Бик күп еллар, ди, районда власть тотты.* Татарстан яшьләре

**ВО́БЛА** *и. рус* 1) Карплар семьялыгыннан, озынча юка диңгез балыгы. *«Балык» кибетендә соңгы вакытта вобла сатылмый башлады.* Казан утлары

2) Киптерелгән балык, кипкән балык. *Җирдә ташлап калдырылган күмәч-икмәк кисәкләре, йомырка кабыгы һәм вобла калдыклары ауный.* Г.Кутуй

**ВОДЕВИЛЬ** *и. фр.* 1) *иск.* Элекке Франциядә Нормандиядәге үзән исеменнән: беренче тапкыр XV гасырда барлыкка килгән сәхнә сәнгате жанры буларак, феодаллардан көлә торган сатирик эчтәлектәге халык җырлары

2) Диалоглары шаян җырлар белән чиратлашып килә торган, гадәттә берике пәрдәдән торган комедия. *Бу спектакльне, беләсең килсә, әкият итеп, водевиль итеп куярга кирәк иде. Җыртакмак белән, уйнап-биеп кенә.* М.Маликова. *Җомга көн кич белән Шәрекъ клубында Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның бенефисы булып, Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем» әсәре илә «Кызлар шулай кызык итәләр» (Г.Атави) исемле бер пәрдәлек водевиль тамашага куелды.* «Йолдыз» газетасы. *Соңгы вакытта театрларда водевильләр куелмый.* Татарстан яшьләре

**ВОДИ́ТЕЛЬ** *и. рус гади с.* Автобус, троллейбус һ.б. машиналар йөртүче. *Водитель булып эшләү*

**ВОДОКА́ЧКА** *и. рус* Су суырткыч насослар урнаштырылган махсус бина. *Тиздән, кыя таш кебек биек водокачка турыннан үтеп бераз баргач, Юдино посёлогына күренеш ачыла.* С.Сабиров. *Юл кырыенда, биек булып, буынтыклы водокачка сөрәеп утыра.* Г.Бәширов. *Игеннәребез дә ярыйсы, яшелчә бакчабыз дә үсә, водокачкабыз да шаулаттырып су җибәрә.* Ш.Камал

**ВОДОЛАЗ** *и. рус* Махсус кием киеп, су астында эшли торган кеше, гаувас. *Водолазлар тели океан төбендәге җиңүләрен аңа сөйләргә.* Ф.Кәрим. *Кандалый водолаз (гаувас) образын*

*сөю ләззәтенәирешү – бәхеткә чуму идеясен бирү өчен ала.* Ш.Усманов

**ВОДОЛА́ЗКА** *и. рус* Водолазлар киеменә охшаган, изүсез, биек якалы, тәнгә сыланып торган свитер. *Ул [Әминә] күбесенчә костюм-чалбар, водолазка кия, чәчләрен кыска итеп йөртә.* Ф.Садриев. *Рәмзи, ак водолазкасының итәген муенына кадәр күтәреп, салып азаплана иде инде ---.* М.Маликова

**ВОДОПРОВОД** *и. рус* Халыкны, барлык объектларны су белән тәэмин итүче инженерлык корылмалары (трубалар, һава насослары, фильтрлар) системасы. *Йортның водопроводы эшләми, өйдә --- су юк.* Ш.Камал. *Мәктәпнең водопроводы сафтан чыккан.* Татарстан яшьләре

**ВОДОПРОВОДЧЫ** *и.* Водопроводларны тикшереп, карап, төзәтеп торучы; аларның төзек булуы, нормаль эшләве өчен җаваплы кеше

**ВОДОРОД** *и. рус* Кислород белән кушылып, су ясый торган җиңел газ, химик элемент. *Ул зонт-шарларга һавага караганда җиңелрәк булган водород газы тутырыла.* Х.Курбатов. *Су ике атомлы водородтан һәм бер атомлы кислородтан тора.* К.Гыйззәтов. *Водород белән кислород, су хасил иткәндә, бер-берсенә тәэсир итеп, шулкадәр үзгәрәләр – водород яну үзлеген югалта, ә кислород януга ярдәм итми башлый; су кислородның да, водородның да үзлекләренә ия түгел.* Органик химия

**ВОДОРО́Д БОМБАСЫ** *и.* Водородның атом-төш энергиясен файдалануга нигезләнгән һәм гаять зур шартлау көченә ия булган бомба. *Биредәге галимнәрнең хезмәте дә, алар үзләре дә, атом һәм водород бомбаларын ясаучылар, --- дәүләт сере булып сакланды.* М.Маликова

**ВОДОРОДЛЫ** *с.* Составында водород булган, водород кушылган, водород белән баетылган

**ВОДЯ́НКА** *и. рус мед.* Йөрәк, бөер, үпкә һ.б. әгъзалардагы авырулар нәтиҗәсендә, тукымаларга һәм төрле куышлыкларга сары су җыелудан гыйбарәт авыру

**ВОЕВО́ДА** *и. рус* 1) *тар.* Борынгы Русьта гаскәр башлыгы, шулай ук XVI–XVIII гасырларда шәһәр яки өлкә идарәчесе. *Патша Указы дигәннәре хактыр, шаять. Югыйсә, воевода аны юкка-барга бимазаламый торган иде.* В.Имамов. *Воеводаларның тәкъдиме буенча, дары запасына су сибеп боздырган, кальга диварларындагы кайбер тупларны Зөя каласына җибәргән, дигән мәгълүматлар бар.* С.Алишев

2) Польшада воеводалык (*2 мәгъ.*) башлыгы

**ВОЕВО́ДАЛЫК** *и.* 1) Воевода булу халәте, воевода эше. *Ул янарал Митрәй кенәзне воеводалыктан алып аткан.* В.Имамов

2) Польшадагы административ-территориаль берәмлек, өлкә

3) XVI–XVIII гасырларда административ-территориаль берәмлек. *[Воевода:] Падишаһыбыз Пётр Алексеевич галиҗәнаплары безнең Минзәлә вә Уфа воеводалыкларына үзенең ике олуг эмиссарларын җибәргән.* В.Имамов

**ВОЕНКОМ** *и. рус сөйл. тар.* Хәрби комитет. *Военком, КГБ, милиция хуҗалары Ходайның асыл кошларын күз карасыдай саклый.* Т.Галиуллин

**ВОЕНКОМАТ** *и. рус сөйл. тар.* Хәрби комиссарат. *Тормышның әнә шундый җайсыз бер көнендә, мине военкоматка чакырдылар.* М.Мәһдиев

**ВОЕНРУК** *и. рус* Уку йортларында яшьләргә башлангыч хәрби белем бирү эше белән шөгыльләнгән укытучы. *Наганны военруклары тимер шкафка бикләп куйды.* Д.Галимов

**ВОЖА́ТЫЙ** *и. рус* 1) *тар.* Совет чорында мәктәптә, пионер лагерында, балалар йортында пионер отряды яки дружинасы җитәкчесе. – *Мин сезгә менә нәкъ шул заманнардан калган бер риваятьне сөйләп бирмәкче булам, – диде бабай, һәм без, зур учакны түгәрәкләп утырган малайлар һәм кызлар, вожатый апалар да, шып булдык.* Р.Фәизов. *Әле ул сөйләп туктагач та, зур учакны түгәрәкләп утырган пионерлар, вожатыйлар, лагерь хезмәткәрләре шактый вакыт сүзсез, тирән тынлык саклап утырдылар.* Р.Фәизов

2) Башлап йөрүче, алдан баручы, әйдаман

**ВОКАЛ** *и. лат. муз.* Җыр сәнгате. *Кунаклар бинаны, вокал классларын, иҗат студиясен, --- хозур кылды.* М.Җәлил. *Язмышымны җыр белән бәйләргә теләп, Лениногорск педагогика училищесының музыка бүлегенә юл тоттым. Шунда вокал белән хордан ике остаз тәрбияләде.* Юлдаш

**ВОКАЛИЗМ** *и. лат. лингв.* Телнең сузык авазлар системасы. *Рентген сурәтләре һәм палатограммалар ярдәмендә, татар теленең вокализмы һәм консононтизмы тасвирлана.* Татар грамматикасы

**ВОКАЛИСТ** *и. рус* 1) Вокаль сәнгате буенча белгеч, җырчының тавышын куючы, үстерүче белгеч. *Безне татар теле, әдәбияты буенча мәшһүр Латыйф Җәләй, сөйләү техникасы һәм сүз осталыгына Луиза апа Салиәскәрова (Х.Туфан хатыны), атаклы вокалист Федор Витт укыта иде.* Г.Әхмәтҗанов

2) Тавыш мөмкинлекләреннән оста файдаланучы (файдалана белүче) җырчы. *Франциядә Тулуза шәһәрендә узган вокалистлар арасында халыкара конкурста Казан дәүләт опера һәм балет театры солисты М. Казаков төп призга ия булды.* Ватаным Татарстан

**ВОКАЛЬ** *с. муз.* Җырга, җырлауга бәйле; җырлау өчен билгеләнгән. *Кеше юк урында, еш кына, Фәрдәнә дә Илсурга кушылып җырлый. Үзенә күрә матур гына вокаль дуэт барлыкка килә.* А.Вергазов. *Вокаль сәнгатьтә үз урыныңны эзләп тап, камиллек биеклегенә күтәрел – шул чагында сине танырлар.* В.Шәрипов

**ВОКЗАЛ** *и. ингл.* Тимер юл, автобус станцияләрендә яки пристаньда юлчылар өчен билгеләнгән бина. *Мин вокзал идәнендә төн кичергәндә, бәрәңге басуларына кырау төшкән иде.* М.Мәһдиев. *Казан вокзалына аларны Маресьевның машинасында секретарь кыз китерде.* М.Мәһдиев. *Вокзал, андагы ыгы-зыгы Идрискә тагын бер кат Диләне, аерылышуны хәтерләтеп, йөрәген авырттырып алды.* А.Гыйләҗев

**ВОЛ-** *рус иск.* Кушма сүзләрдә «волость» мәгънәсен белдергән беренче кисәк; мәс.: *волком, волкомол,*

*волмилиция. [Вафинны] Волкомол секретаре итеп җибәрделәр.* Ф.Хөсни

**ВОЛЕЙБОЛ** *и. ингл. спорт* Тартып куелган ятьмә аша бер командадан икенче командага кул белән туп ыргытып уйный торган спорт төре. *Ул шәһәрнең һәрбер йорты шул кадәрле дәү иде ки, әгәр аларның бер тәрәзәсен генә алып җиргә салсаң да, без аның өстендә волейбол уйный алыр идек.* Р.Фәизов. *Кызлар-егетләр волейбол суга, баскетбол, футбол уйнаучылар да бар.* Р.Кәрами. *Киң эрудицияле һәм тирән белемле генә түгел, волейбол командасындагы иң җитез спортчы булуы белән дә, ул студентлар дөньясының авырлык үзәге иде.* Ә.Дусайлы

**ВОЛЕЙБОЛЧЫ** *и.* Волейбол уйнаучы кеше. --- *частька барып урнашуга, «дед»ларның берсе белән дуслашып киттем. Ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыкты, ул мине яхшы волейболчы, футболчы булганым өчен ихтирам итте.* М.Маликова

**ВОЛОКИ́ТА** *и. рус* Суд һәм административ эшләрдә, шулай ук тормышта, көнкүрештә, нинди дә булса мәсьәләне, эшне хәл иткәндә, артык формальлеккә бирелеп, эшне озакка сузу. *Эшен беренче көннән үк ошатты Җәлил. Кәгазъ волокитасы бар барын, тик хәзерге дөньяда ансыз урынны каян табасың?* Н.Әхмәдиев

**ВОЛОКИ́ТАЛЫ** *с.* Волокита белән, төрле формальлекләр белән бәйле, мәшәкатьле. *Эт эчәгесе – чормавык үлән. Шуның кебек, бәйләнчек кеше сүзенең яки волокиталы эшнең дә очына чыгу авыр булыр.* Н.Исәнбәт

**ВОЛОКИ́ТАЧЫ** *и.* Эштә волокита тудыручы кеше; тапшырылган эшне юри озакка сузып, буталчыклык тудыручы. *Волокитачының җавабы бер: иртәгә мин юкта килерсең.* Мәкаль

**ВОЛОНТЁР** *и. фр.* 1) Үзе теләп, гаскәри хезмәткә баручы; ирекле, үзирекле

2) Оештыру эшләрендә үзе теләп ярдәм итүче; үз ирке белән оештыру эшләрендә катнашучы

**ВОЛОСТНОЙ** *и. рус сөйл. тар.* Патша Россиясендә волость башлыгы, старшина. *Мәмсәнең Әхмәтҗан хәзрәткә газета килгән икән, дигән хәбәрне волостной да сөйләп кайтарды.* Г.Газиз

**ВО́ЛОСТЬ** *и. рус тар.* 1) Патша Россиясендә һәм элеккеге Советлар Союзында, 1929–1930 елларга кадәр, өяз составына кергән кечерәк административ-территориаль берәмлек, олыс. *Волость советына чакырып, кәгазь килде. Син кайтканны көтеп, бармыйча тордым.* И.Гази. *Сугышлар һәм канлы бәрелешләр волостьның башка авылларында да, бигрәк тә Нәҗәрдә, Мордвада һәм Балтачта була.* Җ.Рәхимов. *Игеннәрне, җыйнап, амбарларга да тутыра алмадылар, барча волостьларны махсус чапкын айкап чыкты.* В.Имамов

2) Шул идарә урнашкан авыл; волость үзәге. *Комсомолның волость комитетына сайлап куйдылар.* М.Әмир

**ВОЛЬЕР** *и. фр.* Хайваннар һәм кошларны ачык һавада ябып асрау өчен, аерып, киртәләп алынган урын, мәйданчык. *Хәзергә яңа вольер, читлекләр ясауга керешергә мөмкинлегем юк.* З.Фәйзуллин

**ВО́ЛЬНАЯ** *и. рус тар.* Крепостнойлыктан азат итү турында бирелгән язу, азатлык кәгазе (документ)

**ВОЛЬТ** *и. ит.* Электр тогы көчәнешен үлчәү берәмлеге. *Аннары, шул тимерчыбыкларны бер-бере белән тоташтырып, түбән вольтлы электр энергиясенең бер фазасын – аларга, ә икенчесен арматурага ялгыйлар.* Р.Кәрами. *Көнкүрешебезгә электр килеп керү сәбәпле, «вольт» сүзе еш кулланыла башлады.* И.Гази

**ВО́ЛЬТА БАГАНАСЫ** *и. физ.* Бербер артлы тоташтырылган гальваник элементлардан торган батарея. *Вольта Алессандро – күренекле итальян физигы. Ул, төрле металларны бер-берсенә орындырганда, электр корылмалары барлыкка килү күренешен ачкан һәм «вольта баганасы» дип атаган.* Физика курсы

**ВО́ЛЬТА ДУГАСЫ** *и. физ.* Газ эчендә дугасыман яктылык бөркеп торган электр бушануы

**ВОЛЬТАЖ** *и. фр. махс.* Электр тогының көчәнеш дәрәҗәсе

**ВО́ЛЬТ-АМПЕР** *и. ит.-фр. тех.* Алмаш электр тогы егәрлеген үлчәү берәмлеге

**ВОЛЬТЛЫ** *с.* 1) Үзеннән алда килгән сандагы вольт белән исәпләнә торган. *Менә безнең комсойөрәк миллион вольтлы токтан көчлерәк.* М.Җәлил

2) «Югары» һәм «түбән» сүзләреннән соң килеп, зур яки кечкенә көчәнешле, дигәнне белдерә. *Балалар йөри торган сукмакка югары вольтлы электр тогы үтә торган чыбык төшкән булган.* Татарстан яшьләре

**ВО́ЛЬТМЕТР** *и. рус тех.* Электр чылбырының ике ноктасы арасындагы ток көчәнешен үлчи торган прибор. *Әгәр R=200 Ом каршылыклы вольтметр белән аккумулятор клеммаларындагы көчәнешне үлчәп, ул көчәнеш аккумуляторның ЭЙК ε га тигез дип алсаң, ε 1,48 % ялгышлык белән табыла.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Мәктәп лабораториясенә яңа вольтметрлар сатып алынды.* Мәгърифәт

**ВОЛЬФРАМ** *и. нем. хим.* Көмешсыман төстәге авыр эрүчән металл; химик элемент. *Рентген көпшәсенең антикатоды вольфрамнан эшләнгән булса, вольфрам атомының М-катламыннан L-катламына электрон күчкәндә, дулкын озынлыгы λ = 0,143 нм лы рентген нурлары барлыкка килә.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Вольфрам электр лампочкаларының кыздыргыч җепселләрен ясаганда файдаланыла*

**ВОЛЬФРАМИТ** *и. рус* Корычның үтә каты сортларын койганда кулланыла торган минерал

**ВОЛЬФРАМЛЫ** *с.* 1) Составында вольфрам булган яки вольфрамга охшаш минерал катнашкан. *Вольфрамлы тозлар*

2) Вольфрамнан яисә аның кушылмаларыннан ясалган, эшләнгән. *Вольфрамлы лампочка*

**ВОЛЮНТАРИЗМ** *и. лат.* 1) *филос.* Объектив закончалыкларны һәм зарурилыкны инкяр итеп, җәмгыять һәм табигать үсешендә бары кеше ихтыяры гына хәлиткеч роль уйный, дип санаган фәлсәфи концепция. *Субъектив идеалистлар, кешенең ирекле-леген, объектив шартлардан аерып, бар нәрсәдән*

*бәйсез, дип карыйлар. --- Аның теоретик нигезләрен XIX гасырда немец галимнәре Шопенһауэр, Вагнер, Ницше һ.б. төзергә тырышалар. Философия фәнендә ул агым «волюнтаризм» дип атала.* К.Гыйззәтов. *Сталинның явызлыгы, волюнтаризм шаукымы, торгынлык еллары галәмәте бер татар халкына гына кагылмады.* Т.Миңнуллин

2) *психол.* Психик халәттә бары тик ихтыяр көчен генә хәлиткеч фактор дип санауга нигезләнгән караш

**ВОЛЮНТАРИСТ** *и. рус филос.* Волюнтаризм (*1 мәгъ.*) тарафдары. *Алар [волюнтаристлар], тарих тәгәрмәчен теге яки бу якка бору аның [интеллигенциянең] ихтыярында, диделәр.* КПСС тарихы

**ВОЛЮНТАРИ́СТИК** *с.* Волюнтаризмга нигезләнгән, волюнтаристларга хас. *Волюнтаристик фәлсәфәне яклау*

**ВОЛЮ́ТА** *и. лат. архит.* Спираль, бөтерке формасындагы архитектур деталь, бизәк

**ВОРО́НКА** *и. рус* Бомба, снаряд һ.б.ш. шартлау нәтиҗәсендә барлыкка килгән чокыр. *Лейтенант воронканың төбенә үк поскан, ә кызлар, воронка кырыена утырып, тыныч кына ут бетүен көткәннәр.* Фән һәм тел

**ВОССТА́НИЕ** *и. рус* Милли һәм сыйнфый мәнфәгатьләрне яклау максатыннан, массакүләм кораллы чыгыш; фетнә. *Якуб, әлбәттә, бөлә: Корнилов восстаниесе өчен, меньшевиклар да, эсерлар да гаепле.* И.Гази. *Җитәкче Үзәк членнарына Корнилов восстаниесе турында доклад ясаучы Васильев меньшевикларны, эсерларны «революция муенындагы авыр таш» дип атады ---.* И.Гази

**ВОССТА́НИЕЧЕ** *и.* Восстаниедә катнашучы кеше; фетнәче. *Ниятләре ачылган восстаниечеләр авылга һөҗүм итәргә мәҗбүр булалар, ләкин җиңеләләр.* Җ.Рәхимов. *Аны [Аит Уразмәтовны], Ефим Попов, Йосыф Енгалычев белән берлектә, восстаниече крәстияннәрнең башлыклары буларак, башта – Чирмешәннән Кичүй креспостена, аннан Казанга Яшерен комиссия хөкеменә җибәрәләр.* М.Гайнетдинов

**ВО́ТУМ** *и. лат.* Тавыш бирү юлы белән кабул ителә торган карар, фикер. *Парламент ышаныч вотумы белдерде*

**ВО́ТЧИНА** *и. рус тар.* Россиядә XII – XVIII гасырларда эре җир биләүчеләрнең ата-бабадан мирас булып килгән җир биләмәсе

**ВОТЯК** *и. удм. иск.* Удмуртиядә яшәүче төп халык булган удмуртларның борынгы атамасы, шул халыкның бер кешесе. *Малоросслар, үзләренең чын атамалары булган «украинлы» исемен алдылар, «хохол» дигән атаманы да кире какмадылар, остяклар – хантларга, самоедлар – ненецларга, чирмешләр – мариларга, вотяклар – удмуртларга әйләнде, ягъни һәммәсе үз атамаларына кайттылар.* Ә.Кәримуллин. *Удмуртларны хәзерге заманда да «вотяк» дип атауларын очратырга мөмкин.* Ватаным Татарстан

**ВОҺ** *ы.* Нәрсәнең дә булса бик әйбәт, шәп икәнлеген аңлатып, мактау сүзе буларак кулланыла. *– Воһ! – диде Карл Фёдорович, хатынына борылып.* М.Гали. *– Воһ! – диде ул, болар янына килеп җитүгә, уң кулының баш бармагын күрсәтеп. – Сембер ярминкәсендә дә сирәк очрый андый чабышкылар.* М.Гали. *Яңа күлмәк киеп чыккан Сәриясен күргәч, Вафа бөтенләй телсез калгандай булды, бармагы белән «Воһ, шәп!» дигәнне аңлаткан ишарә ясады да кадерлесен күтәреп алды.* Сөембикә

**ВОЯЖ** *и. фр.* Сәяхәт, ил гизү. *Кайбер җитәкчеләр кебек, сәяхәт һәм вояжларда еш йөрмәсәгез дә, соңгы вакытта гына Бакудан кайтуыгызны ишеттек.* Р.Миңнуллин

**ВОЯЖЁР** *и. фр. иск.* Сәяхәтче, илгизәр, турист. *Иптәш белән Троицкида вәгъдә куешкан тройкалы ике немец вояжёры безне урманда туктап көтәләр икән.* Г.Тукай. *Урамнар купецлар, банкирлар, фабрикантлар, вояжёрлар, алып-сатарлар, исерекләр, каракларлар, аферистлар, авантюристлар, фахишәләр белән тулган.* К.Тинчурин. *Синең шикелле вояжёр әллә кайларга да барып җитәр әле.* Казан утлары

**ВӨҖДАН** *и. гар.* Аллаһ алдында, әйләнә-тирәдәге кешеләр, җәмгыять алдында үз эшләрең, үз-үзеңне тотышың өчен әхлакый җаваплылык хисе. *Ничә еллар буе Суфиянның вөҗданын газаплап торучы сораулар һәм күп ноктапар урынына ныклы нокта куелды.* С.Сөләйманова. *Тәкъдир Ананың балалары алдына зур сынау әзерләп куйган, бу – аларның кешелеклелеген, намусын һәм вөҗданын сынау.* Сөембикә

◊ **Вөҗдан газабы** Үзеңне гаепле дип санап җәфалану, борчылу, тынычсызлану, газаплану хисе. *Кайчаннардан бирле вөҗдан газабы кичерәм. Үз вакытында хатамны төзәтсәм, болай булмас иде.* Ф.Әмирхан. **Вөҗданга көч килү** Берәр ярамаган эш өчен уңайсызлану хисе кичерү. *Яныңа барып, сабырлыгыңны, мәрхәмәтлелегеңне күрүгә, телем аңкавыма ябышты, вөҗданыма көч килде.* А.Чехов

**ВӨҖДА́Н ИРЕГЕ** *и.* Гражданнарның үзләре теләгән динне тота алу хокукы. *Хәлбуки, соңгы елларда бездә дә берникадәр фикер һәм вөҗдан ирекге урнаша башлагач, Яңа елны, рәсми рәвештә булмаса да, мартның егерме берендә билгеләп үтү гадәткә кереп бара.* Ф.Урманче. *Әмма җан, вөҗдан ирекге – бер Аллаһыга сыену, Иманга бару мөмкинлеге... Андый ирекле җәмгыять кайда соң? Рәсәйдәге вазгыять, һәрчак, вөҗдан ирекен изүгә, басуга корылган булды.* М.Мирза

**ВӨҖДА́Н ИРКЕНЛЕГЕ** *и. иск. к.* **вөҗдан ирекге**. *Бу дөньядагы бәхетеңә, яшәячәк матур көннәреңә, алдагы гомереңә өмет тотып, ышанып яшәү генә вөҗдан иркенлеге, намус хөрлеге, күңел көрлеге китерми әле ул ---. Тулысынча бәхетле булу өчен, Аллаһы һәм теге дөньяга да өмет итеп, ә тәгаене: ышанып-инанып яшәргә кирәк.* Р.Сибат

**ВӨҖДАНЛЫ** *с.* Вөҗданы булган, гадел эш итә торган, намуслы. *Ә халыкны һәр вөҗданлы күңел Күрсәтсен һәм күрсен шул килеш.* Казан утлары. *Ярый әле арабызда вөҗданлы кешеләр күп.* Татарстан яшьләре

**ВӨҖДАНЛЫЛЫК** *и.* Гаделлек, намуслылык; вөҗданлы булу. *Нурулла – әсәрдәге төп герой --- вөҗданлылыкның һәм гаделлекнең тере символы.* Р.Мостафин. *Халкыбызда булган*

*гаделлек, вөҗданлылык сыйфатлары сокландыра.* Татарстан яшьләре

**ВӨҖДАНСЫЗ** *с.* **1.** Вөҗданы булмаган, оят белмәгән; намуссыз. *Вөҗдансыз ул. Үзенең шәхси даны өчен, фабриканы да, мине дә, безнең барыбызны да алдарга әзер икән.* Р.Ишморат

**2.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия кеше. *Болар бит – шәкертләрнең өйләренә язган хатлары. Сез аларны, җибәртмичә, тотып каласыз? Оялмыйсызмы вөҗданыгыздан? Вөҗдансызлар!* С.Рәмиев

**ВӨҖДАНСЫЗЛАНУ** *ф.* Вөҗдансызга әйләнү; намуссызлану, оятсызлану. *Әй энем, соңгы вакытларда бигрәк вөҗдансызланасың бит.* М.Мәһдиев

**Вөҗдансызланып бетү** Тәмам, соңгы чиккә җитеп вөҗдансызлану

**ВӨҖДАНСЫЗЛЫК** *и.* Вөҗдансыз булу; намуссызлык, гаделсезлек. *Вөҗдансызлык белән башкарылган вак караклыкта гаепләнеп, ирегеннән мәхрүм ителә.* М.Мәһдиев

**ВӨҖҮД** *и. гар. кит.* 1) Яшәеш, тормыш, барлык. *Аның бар вөҗүден Кадыйрга бәйле уйлар-истәлекләр биләгән иде.* К.Тимбикова

2) Рухи халәт, күңел. *Ул, яшьләр арасында иң сөекле, иң игътибарлы бер яшь буын булып, үзенең вөҗүде, хәрәкәтләре вә киңәшләре белән, яшьләр хәрәкәтенә рух биреп тора иде.* Р.Ишморат. *Каршыбызда, коточкыч сугыш афәтенең ни-нәрсә икәнен миләребезгә, вөҗүдебезгә сеңдерергә теләгәндәй, бу сугышның тере шаһиты басып тора иде.* Шәһри Казан

**ВӨҖҮДКӘ́ АШУ** *ф. кит.* Тормышка ашу, уйлаганча килеп чыгу. *Янәсе, менә хәзер дә, үз республикабыз вөҗүдкә ашканнан соң да, татар егетенә югары уку йортын тәмамлап чыгу ансат түгел.* И.Гази

**ВӨҖҮДКӘ́ АШЫРУ** *ф. кит.* Тормышка ашыру, уйлаганча эш итү һәм уңышка ирешү. *Уйлаган эшемне вөҗүдкә ашыра алсам, миннән дә бәхетле кеше булмас иде.* Ә.Еники

**ВӨҖҮДКӘ́ КИЛҮ** *ф. кит.* Барлыкка килү, туу; язылу, дөнья күрү. *Безнең көйләребезнең, безнең музыкабызның андый булуы иттифакый гына вөҗүдкә килгән бер эш түгел, аны тарих агымы тудырган.* Г.Ибраһимов

**ВӨҖҮДКӘ́ ЧЫГУ** *ф. кит. к.* **вөҗүдкә ашу**. *Бу эш вөҗүдкә чыкса, ифрат яхшы булыр иде.* М.Фәйзи

**ВРАЧ** *и. рус* Югары медицина белеме алып, авыруларны дәвалау белән шөгыльләнүче кеше; табиб. *Врачлар – антка тугрылыклы халык, авыруның үзенә тормыш вәгъдә итәләр.* Ә.Галиев. *Бүгеннән ул – врач, кешеләр аңа өмет һәм ышаныч белән текәләчәкләр.* М.Маликова. *Врач бит ул шәм төсле: үзе яна, яктысын авыруларга бирә.* Г.Әпсәләмов

**ВРАЧЛА́РЧА** *рәв. сөйл.* Врачларга хас булганча, врачлар алымы белән, табибларча. *Мира аның иңнәрен врачларча тотып карады да әйтте, монда әле бик нык туласы бар, диде, госпитальдән чыгу хакында авыз да ачмаска кушты.* Х.Камалов. *Әйе, серемне врачларча саклармын.* Д.Салихов

**ВРАЧЛЫК** *и. сөйл.* 1) Врач һөнәре; табиблык. *Хәдичә, озак уйлаганнан соң, врачлыкка укырга карар кылды.* Г.Бәширов. *Чакыру кәгазеңне күрсәт, эшеңне тапшыр, фанер чемоданыңны ал да, бар, врачлыкка укый бир!* М.Рафиков. *Себергә барып урнашкан елларда, Гөлүсә, хат аша, Газиның врачлыкка укырга китүе турында ишетә.* М.Хәсәнов

2) Дәвалау эше. *Аның куллары врачлыкка бик ятып тора.* А.Шамов. *Врачлык эшен өр-яңа ысул белән башлау Уразаевага булган игътибарны арттырды.* Г.Ахунов

**ВРАЧЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Врач булып эшләү, врач хезмәтен башкару, табиблык итү. *Утыз ел врачлык иттем. Утыз ел кешеләрнең йөрәк тибешен тыңладым.* А.Шамов. *Гомере буе врачлык итте Гыйльмениса апам.* Казан утлары

**ВРРР** *иярт.* Нәрсә дә булса бик кызу әйләнгәндә барлыкка килә торган тавышны белдерә. *Сепаратны туктатканнан соң да, әле шактый вакыт, ул «врр, врр» иткән тавыш чыгарып әйләнеп утырды.* Г.Минский. *[Суккыч] «Зз... вз... вррр...» – дип сызылдап, выжылдап әйләнеп тора, көлтәне бер яктан йота бара.* Г.Ибраһимов

**ВРРХ** *иярт.* Берәр нәрсә бик кызу әйләнеп яисә эшләп торган җиреннән кинәт туктаганда чыга торган тавышны белдерә. *Әйбәт кенә эшләп утырган кер юу машинасы «веррх» итте дә туктап калды.* М.Мәһдиев

**ВТУ́ЛКА** *и. рус тех.* 1) Машина яки техник җайланманың эченә икенче бер детальне кертеп утырту өчен тишеге булган цилиндрик деталь. *Безнең мастерскойда, күпме генә эзләсәк тә, машина өчен втулка табып булмады.* И.Гази. *Менә шушы втулкаларны бәрдереп чыгарасы да бөҗраларын гына алыштырасы.* М.Хәсәнов

2) Металлдан яисә агачтан ясалган бөке (пробка)

**ВУАЛЬ** *и. фр.* 1) Үтә күренмәле җиңел тукыма. *Днепр өстеннән, әкрен генә, беленер-беленмәс кенә булып, нечкә вуаль шикелле үтәли күренә торган җиңел томан күтәрелә иде.* А.Шамов. *Вуальдән бер күлмәк тектерергә хыялланам, тик тегүчемнең генә һаман вакыты тыгыз.* Казан утлары

2) Хатын-кыз баш киеменә, гадәттә эшләпәгә, беркетелеп, бераз битне капларлык итеп төшерелә торган, үтә күренмәле юка тукыма яки челтәр. *Хатынның йөзе ачык күренми, аны вуаль каплаган иде.* Г.Галиев. *Туташ киң читле эшләпәсенә беркетелгән вуальне бер якка таба ачып җибәрде.* Г.Ибраһимов

3) Фото- яисә киноплёнкада сурәтнең сыйфатын бозып торган, каралган, тапланган урыны. *Ничек мин башта ук негативтагы вуальгә игътибар итмәгәнмен – үзем дә шаккатам.* Юлдаш

**ВУЗ** *и. рус сөйл.* Югары уку йорты сүзтезмәсенең русчадан кыскартылган исеме: **высшее учебное заведение.** *Шәмсуллин агай – Бөек Ватан сугышына кадәр үк вуз тәмамлаган тарихчы.* Б.Камалов. *Әлеге студентлар вузда кыскартылган махсус программа буенча укыйлар.* Ватаным Татарстан. *Вуз тәмамлаганнарның 80 проценты үз һөнәре буенча эшләми икән.* Ватаным Татарстан

**ВУЗДАШ** *и. сөйл. сир.* 1) Бер үк югары уку йортында белем алучылар. *Мин күрше кызы белән вуздаш булып*

*чыктым бит әле: икебез дә педагогика институтында укыйбыз.* Юлдаш

2) Бер югары уку йортын тәмамлаучылар. *Тиздән вуздашлар белән очрашачакбыз.* Г.Минский. *Вуздашлар белән очрашканнан соң, яшьлек хатирәләрем кузгалды.* М.Гали

**ВУЛКАН** *и. лат.* 1) Түбәсендәге кратерыннан, вакыт-вакыт, эрегән кайнар лава, газ, тау токымнары һәм көл атылып чыга торган конус сыман тау; янар тау. *Ассаб порты вулкан кратерыннан агып чыккан каткан магма өстендә утыра.* М.Юныс. *Академик Валерий Алексеевич Легасов Чернобыль авариясен иң хәтәр, иң зур вулканнар ату белән чагыштыра, кешелек тарихына мәңгегә кереп калачак фаҗига, дип атый.* М.Хәсәнов. --- *хәрәкәттәге вулкан сыман, тау-тау порода сыртлары болытларга ак төтен бөрки.* Ә.Галиев. *Вулкан җанлангач, шәһәрдә яшәүче 4,5 мең кеше тиз арада эвакуацияләнгән.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Күңелдәге тынычсызлык, бәргәләнү; нык дулкынланганлык, хисләргә бирелүчәнлек. *Йосыф Гөлчәчәк белән янәшә атлый, йөрәгендә – вулкан, тыеп торыр хәл юк.* И.Сираҗи. *Мин күз алдына китерәм инде, хисләр колы Сара апа белән хисләр вулканы Мостафа агайның бу хикмәтне күргәч нинди халәткә килгәннәрен.* М.Мәһдиев. *Эчендә вулканнар кайнады, таулар тетрәде.* Ф.Яруллин

3) *күч. сөйл.* Вакыйгалар үзәге; җаваплылык, активлык таләп итә торган иҗтимагый тормыш. *Үзләре бернинди эштә башлап йөрмәсләр, «вулкан»ның үзәгеннән читтә торырлар, үзләре исә, кеше ясаган хатадан күз ачып йомганчы гыйбрәт чыгарып, аны берәр әйтем-мәкальгә калыплаштырып куярлар.* Юлдаш

**ВУЛКАНИЗА́ТОР** *и. рус тех.* 1) Велосипед, автомобиль һ.б.ларның резина камераларын, тәгәрмәч покрышкаларын төзәткәндә, җылытып ябыштыру, вулканизация ясау җайланмасы. *Алексей Семёнович, сез – яңа кеше, белмисездер әле: шин заводын сафка бастырганда да вулканизаторлар өчен кирәкле прессформаны Фоат Шәйхелмәрданов ясады бит.* Казан утлары

2) *к.* **вулканлаштыручы.** *Марат, абыйсы янына, вулканизатор булып эшкә урнашты.* Юлдаш

3) Вак каучук материалларын вулканлаштырганда кулланыла торган металл мичкә

4) Каучук белән кушылганда резина хасил итә торган матдә

**ВУЛКАНИЗМ** *и. рус геол.* Җир шары эченнән вулкан рәвешендә өскә күтәрелә яки Җир кабыгы эчендә ката торган, кайнар масса хәрәкәте белән бәйләнгән күренешләр җыелмасы. *Вулканизмны өйрәнү*

**ВУЛКА́НИК** *с.* Вулканга бәйләнешле, вулканга мөнәсәбәте булган. *Вулканик утраулар тезмәсе 1250 км га сузыла, ә көнчыгыштан бик зур океан сулары белән юыла.* Җ.Хөсәенов. *Таш сыннарның барысы да бер үк үрнәк буенча эшләнгән: колаклары озын, куллары гәүдәләренә кысылган, барысы да вулканик туфрактан ясалган.* Җ.Хөсәенов. *Укытучының, вулканик токымнар турында укып килегез, диюен укучылар ишетмәде дә, кыңгырау шалтырауга, коридорга чаптылар.* Казан утлары

**ВУЛКАНЛАШТЫРУ** *ф. тех.* Җылытып эшкәртү; ныклык, тыгызлык сыйфатлары бирү өчен, каучукны югары температурада күкерт яки башка матдә белән эшкәртү. *Каучукны вулканлаштыру ысулы. Вулканлаштыру цехы*

**Вулканлаштырып бетерү** Вулканлаштыруны төгәлләү, тәмамлау

**Вулканлаштырып тору** Даими вулканлаштыру, билгеле бер вакыт үткән саен вулканлаштыру

**Вулканлаштырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да вулканлаштыру

**ВУЛКАНЛАШТЫРУЧЫ** *и. тех.* Вулканлаштыру эше белән шөгыльләнүче белгеч. *Вулканлаштыручы янындагы чиратны күреп, Сабир кире борылды.* Казан утлары

**ВУЛКАНО́ЛОГ** *и. рус* Вулканология белгече; вулканнарны өйрәнүче, күзәтүче кеше. *Безнең курку белмәс вулканологларыбыз Бөек Ватан сугышы алдыннан Ключи сопкасы кратерында булып кайттылар.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Мәскәүдә вулканологлар зур сөйләшү үткәрделәр.* Ватаным Татарстан

**ВУЛКАНОЛО́ГИК** *с.* Вулканологиягә мөнәсәбәте булган, аңа бәйләнешле. *Вулканологик тикшеренүләр. Вулканологик эзләнүләр*

**ВУЛКАНОЛО́ГИЯ** *и. лат.* Вулканнарның төзелешен, барлыкка килү сәбәпләрен өйрәнә торган фән тармагы

**ВУЛЬГАР** *с. кит.* **1.** 1) Зәвыксыз, чама хисе булмаган, мәгънәсез. *Кунак кызы бик вульгар булып чыкты.* Казан утлары. *Матур түгел, яисә, кеше ни әйтер, дип тормый хәзерге яшьләр, чамадан тыш вульгар киемнәр сайлый.* Сөембикә

2) Тупас, дорфа; оятсыз, әдәпсез. *Кызның сөйләмендә вульгар сүзләр күп.* М.Мәһдиев. *М.Мәһдиевнең дә чамадан уза төшкән вульгар урыннары бар.* Казан утлары

3) Мәгънәсе бозылырлык, үзгәрерлек дәрәҗәдә яки тупас итеп гадиләштерелгән. *Вульгар материализм*

**2.** *рәв. мәгъ.* Әдәпсез, тупас. *Ләкин Рушан, авыз ачып, аңа: «Син үзеңне артык әдәпсез, артык вульгар тотасың», – дип әйтә алмады.* Р.Мирхәйдәров. *Үзен әллә кемгә куйган һәм, вульгар сөйләшеп, ачуын китергән бу егет кисәген баштан ук кабул итә алмады Әдилә.* Казан утлары

**ВУЛЬГАРИЗМ** *и. лат. лингв.* Телгә берәр җирле сөйләштән яки жаргоннан кергән һәм әдәби тел нормаларына туры килми торган тупас, әдәпсез сүз, әйтем, гыйбарә. *Соңгы елларда китап, журнал, газета битләрендә вульгаризмнар артык еш кулланыла башлады.* Мәдәни җомга

**ВУЛЬГАРЛАШТЫРУ** *ф.* Берәр нәрсәне мәгънәсе бозылырлык, үзгәрерлек дәрәҗәдә тупас гадиләштерү. *Шигъри фикерне, кичерешне аның чынбарлыктагы, көнкүрештәге сынына тиңләү лириканың катлаулы табигатен таратып, хәтта вульгарлаштырып аңлауга да юл калдырды.* Т.Галиуллин. --- *күрәсеңме, син ничек вульгарлаштырасың мәсьәләне!* А.Расих. *Безнең*

*абый, шулай, бөтен нәрсәне вульгарлаштырырга ярата ул.* Казан утлары

**Вульгарлаштыра бару** Торган саен күбрәк вульгарлаштыру. *Син сөйләмеңне торган саен вульгарлаштыра барасың.* Х.Хәйри

**Вульгарлаштырып бетерү** Тәмам вульгарлаштыру

**ВУЛЬГАРЛАШТЫРУЧЫ** *и.* Мәгънәсен бозып, гадиләштереп, тупас итеп сөйләүче. *Син дә вульгарлаштыручылар исемлегендә инде әллә?!* Казан утлары

**ВУЛЬГАРЛЫК** *и.* Тупаслык, әдәпсезлек, оятсызлык. *Үз-үзеңне табигый иркен тоту белән тупас әдәпсезлеккә якын вульгарлык арасын кем сизә, кем сизми, дигәндәй, шул чикне Рушан сизә-тоя, ә Валентина үзе чамалап бетерми иде, ахрысы.* Р.Мирхәйдәров. *Сөйләшүендә үк вульгарлык ярылып ята ул иптәшнең.* Казан утлары. *Үз кыланышларыңның нинди зур вульгарлык булуын үзең дә аңламыйсың бугай шул син.* Юлдаш

**ВУЛЬГАРЧЫЛЫК** *и.* Нәрсәне дә булса мәгънәсе бозылырлык, үзгәрерлек дәрәҗәдә тупас гадиләштерү күренеше. *Шул рәвешле, халык мәкальләрен ликвидацияләүгә чакыручылар, Марр теориясе нигезендә, аерым «сыйнфый» сүзләр эзләп, шуларга бәйләнү, вульгарчылык, схематизм һәм шул ук феодализм чорының калдыгы булган догмачылык, нәкылчелек, тәкълитчелек булып, бу чирләр белән, мәкальләрдән бигрәк, ул иптәшләр үзләре чирләгән булулары аңлашыла.* Н.Исәнбәт. *Вульгарчылыкның әдәбият үсешенә тискәре йогынты ясавы – бүген генә мәгълүм булган хакыйкать түгел.* Мирас

**ВУНДЕРКИНД** *и. нем.* **1.** 1) Үз яшендәгеләргә хас булмаган акылга, сәләткә ия бала. *Вундеркиндлар турында махсус фильм караганнан бирле, күңелен гел бер сорау борчый әле Гадиләнең.* Мәгърифәт

2) *сөйл.* Башкалардан аермалы буларак, нииндидер сәләткә, өстенлеккә ия булучы; бик акыллы, белемле. --- *район мәктәпләренә чыгып, шигырь язучы «вундеркинд»ларның исемлекләрен алып кайтабыз.* Р.Әхмәтҗанов. *Вундеркиндлар булып тумадык без, Дәү абыйлар гафу итсеннәр.* Х.Туфан

**2.** *с. мәгъ.* Югары сәләткә ия булган; аеруча талантлы, белемле. *Матур табигатьле Түбән Симет авылына, җәй саен, Казаннан вундеркинд малай Рөстәм кайтып ял итә торган була.* Т.Нәҗмиев. *Вундеркинд балалар белән махсус методика буенча шөгыльләнә торган мәктәпләр, үзәкләр ачыла башлады.* Мәгариф

**ВУУ** *иярт.* Улауга охшаган тавышны белдерә. *Урамда буранның «вуу, вуу» дип улаганы ишетелә.* Г.Әпсәләмов

**ВУУ́ ИТҮ** *ф.* Вуылдаган, вуу иткән тавыш чыгару; выелдау. *Җилнең дулаганы басыла төшкән кебек кенә булган иде, «вуу» итеп, ишек ачылып китмәсенме?* Казан утлары

**ВШТ** *ы. к.* **выжт**. *Башка күземә күренмә. Тай, моннан, вшт.* М.Мәһдиев. *Вшт моннан, мөртәт...* К.Нәҗми

**ВЫ́БОРЩИК** *и. рус иск.* Сайлау вакытында (сайлау турыдан-туры булмаганда) вәкил итеп җибәрелгән кеше. *Тиреçе әфәнделәр, аю, маймыл, кәҗә, ишәкләрнең музыка уйнарга утырганнары төсле, үзара иске мунчага җыелып: «Әхмәтҗан абзый, син выборщик бул; юк, Мөхәммәтҗан абзый, син булчы, син – мәчет карты», – дип, төртешә-тартыша, берничә аксак-туксакларны выборщик тәгъйин итәләр.* Г.Тукай. *Думага выборщик сайлау тугрысында да җитәрлек эшләр эшләдегез.* Ш.Мөхәммәдев

**ВЫ́ВЕСКА** *и. рус* 1) Оешма, ширкәт, кибет һ.б. исемен, эш төрен күрсәткән элмә язу, элмә такта. *Әгәр алтын, көмеш, чуен медаль бирелә калса, пәрәмәччеләр Габделкадир Сәгъдиев, Мөхәммәтҗан Галиев вывескалары кеби, медальне вә пәрәмәч сурәте төшерелгән зур вывескалар ясатачаклар, имеш.* Г.Тукай. *Фәндилә, вывесканы, җил-давыллар куптара алмаслык итеп, кибет ишеге түбәсенә беркеттергәч, әлеге эшнең нәтиҗәсен көтә башлады.* Г.Ахунов. *Инде татар ягындагы кибетләр арасында йөрсәң, монда, әллә кайдан ук, татарча гына язылган зур-зур вывескалар күзеңә ташлана: фәлән ширкәт тә, төгән ширкәт...* Ә.Еники

2) Берәр әйбер, кибет, оешма һ.б.ларны рекламалау максатында, баганаларга беркетелеп эленгән зур плакат (кәгазь, тукыма һәм башка төрле материалдан, утлар белән яктыртылып эшләнергә мөмкин). *Шәһәр урамнары буйлап барабыз, баганалардагы аллыгөлле вывескалар һәрберсе үзенә тарта, кызыктыра.* Шәһри Казан. *Энем яңа эшкә урнашты бит әле – реклам баганаларына вывескалар элеп йөри.* Юлдаш

3) *күч.* Ялган исем, пәрдә, битлек. --- *«Милли мәдәни мохтарият» вывескасы астында Идел-Урал штатын игълан итәргә маташа.* Т.Гыйззәт

**ВЫЕЛДА́У** *ф. к.* **выжгыйлау.** *Бөтен тирә-юнь пулемёттан аткандай текелдәп, выелдап, зырылдап тора.* Ә.Галиев. *Выелдап, электровоз килеп туктады.* Ә.Галиев

**ВЫЖ, ВЫ́Ж-ВЫЖ (ВЫ́Ж ДА ВЫЖ)** *иярт.* **1.** 1) Берәр нәрсә, зур тизлек белән, әле – бер, әле икенче якка хәрәкәт итүне белдерә. *Юлда машиналар выж да выж!* Э.Касыймов. – *Ускәч мин шуфил булам, – ди малай. – Ту-ту, выж-выж...* Ф.Яруллин. *Ул да булмады, баш өстеннән, выж да выж, миннекләр оча башлады.* Ш.Маннап

2) Бөҗәкләр канатлары белән һаваны ярып очканда чыгарган тавышны белдерә. *Бал кортлары яшькелт сары юкә чәчәкләре арасында выж-выж бөтереләләр, кайвакыт, ачык тәрәзәдән өйгә дә керәләр.* Ф.Яруллин. *Түбәннән генә, выж да выж, май коңгызлары очып үтә.* М.Шаһимәрдән

**2.** 1) *хәб. функ. к.* **выжт, выжжт, выжт-выжт (2.)**. *Әти иртәнге намазга бармый калмас. Мин шул арада – тагын «выж!»* Г.Гобәй. *Укытучы сүз әйтеп өлгергәнче, Илһам «выж» класстан.* М.Әмир. *Ә Маһир, матайны кулга төшерү белән үк, «выж» ындыр артына.* М.Шаһимәрдән. *Син барын да белешеп кайт та, көннәрдән беркөнне без «выж» чирәм җирләргә!* А.Расих

◊ **Выж, Галләм (Галиәхмәт)** *гади с.* Эштән чыгарылу яки берәр кая китү, куу, мәгънәсендә кулланыла; моннан

кит. *Алайса, озакламый, Ифрат «выж, Галләм» икән, дип уйлады Баһави.* А.Расих. *Эчеп күзгә чалынса, шундук... выж, Галиәхмәт!* А.Хәлим. «*Выж, Галләм» бит мин хәзер, дүрт ягым – кыйбла.* Казан утлары

**ВЫ́Ж-ВЫЖАК, ВЫЖВЫЖАК** *и. иск.* 1) Түгәрәкләнеп һәм кулларын артка яшереп идәнгә утырган балаларның, кулдан-кулга ишелгән сөлге йөртеп һәм уртадагы «тәкә» дип исемләнгән уенчыга, ул күрмәгәндә, тиз генә сугып алып, сөлгене кабат яшереп йөртүдән гыйбарәт борынгы уен. *Тезелешеп утырып, выж-выжак, йөзек салыш, сукыр тәкә уйнаулар – бүгенгедәй күз алдымда...* Казан утлары

2) Очыргыч, җыеп тартылган пружинаның киңәюе белән хәрәкәтләнә торган балалар уенчыгы. *Очыргыч җибәрсә, аның очыргычы болытлар эчендә уйнаклап йөрергә тиеш; --- кәтүк агачын зырылдатып тартып әйләндергәч тә пырылдап очып киткән выжвыжагы иң ерак араны үтәргә тиеш.* Ш.Рәкыйпов

**ВЫ́Ж (ВЫ́Ж-ВЫЖ) ИТҮ** *ф. к.* **выж (выж-выж) килү**. *Әмма машиналар аның [Гөлшаһидәнең] кулына карамыйлар, пычрак чәчрәтеп, «выж» итеп үтәләр дә китәләр.* Г.Әпсәләмов

**ВЫЖ (ВЫ́Ж-ВЫЖ) КИЛҮ** *ф.* Зур тизлек белән выжылдап очу, выж-выж иткән тавыш чыгарып хәрәкәтләнү. *Бал кортларының выж-выж килеп очканы ишетелә.* Р.Ишморат

**ВЫЖГЫЙЛА́У** *ф. сир.* **1.** 1) Бик тиз хәрәкәт итү нәтиҗәсендә, канатлар, снаряд, пуля, машина һ.б.ш.ларның «выж-выж»га охшаш тавыш чыгаруы

2) Җил улау, выжылдау. *Урамда җил выжгыйлый.* Г.Бәширов

**2. выжгыйлап** *рәв. мәгъ.* Ачы тавыш белән, сызгырып. *Авыл өстеннән, выжгыйлап, снарядлар оча.* Г.Әпсәләмов. *Выжгыйлап килгән пулядан ничек котылдың, дисеңме?* Казан утлары

**ВЫЖГЫЛДА́У** *ф. к.* **выжылдау**. *Ул күсәкләр һәм уклар, выжгылдап, безнең баш очларыбызда очып йөриләр, килеп эләккән иптәшләремезне аякларыннан ега вә җәрәхәтлиләр иде.* Ф.Әмирхан. *Рәсимҗан зур-зур сикәлтәләрне коштай очып үтә, артыннан җил генә выжгылдап кала.* М.Әмирханов. *Баш өстеннән, выжгылдап, пулялар оча.* Ш.Маннур

**ВЫЖГЫРТУ** *ф. гади с.* Ачуланып, бик тиз генә куып чыгару, куып җибәрү. *Хәйрулла барлык ачуны хатынныннан алды. Кайтуга, аны өйдән выжгыртты.* Азат хатын

**Выжгыртып чыгару** Кискен рәвештә куып җибәрү

**ВЫЖГЫТУ** *ф. гади с. к.* **выжгырту.** *Заводтан шул көнне үк выжгыттылар абзыйны...* Казан утлары

**Выжгытып чыгару** *к.* **выжгыртып чыгару**. --- *теңкәсенә тигән урам этләрен шунда ук выжгытып чыгарды Сәлимә түти.* Мәгърифәт

**ВЫЖЛАВЫК** *и.* Уҗымнарга зыян сала торган ерткыч коңгыз; *русчасы*: **жужелица**. *Выжлавыкларның әле тагын «үрмәлмәч» дигәне бар.* Г.Хәсәнов. *Выжлавык коңгызлар --- оча алмыйлар. Ник дигәндә: элпә канатлары юк.* Г.Хәсәнов. *Кай арада кулына килеп кунган выжлавык...* Азат хатын

**ВЫЖЛАТУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **выжлау**

2) *күч. сөйл.* Берәр төрле физик эшне тиз, җитез, оста башкару. *Башта кулымны кисәрмен дип курка идем, хәзер у-у-у, выжлатам гына.* Р.Батулла

3) *күч. сөйл.* Кош-корт, хайваннарны яки кешене куу; куып чыгару. *Ачуымны китереп утырма. Хәзер выжлатырмын.* А.Гыйләҗев. *Хәерниса бүген соңга калып торды. Иң беренче эш итеп, тиз генә юынды, сыерны сауды да малларны көтүгә выжлатты.* Б.Камалов

**2. выжлатып** *рәв. мәгъ.* 1) Бик тиз, кызу итеп. *Үзең башкаларны выжлатып узып китү – бик күңелле икән ул!* М.Әмир. *Атның сыртына шарт-шорт төшкән чыбыркы тарантас тәгәрмәчен выжлатып әйләндерә.* Ф.Кәрим. *Әмма минем атлар, җан кисәкләрем, ят кешеләр икәнен сизеп, пошкырышып торып уң як читкә тайпылдылар да, выжлатып, теге юлбасарлар яныннан үтеп киттеләр.* В.Нуруллин

2) Берәр нәрсәне бик зур тизлек белән хәрәкәткә китереп, ашыктырып, кызулатып. *Менгән атың айгыр булса, Выжлатып чап, кайгырма!..* И.Туктар. *Вакыт-вакыт аның [ишанның] хәтта сикереп торасы, тәбәнәк өстәлне тибеп очырасы, чалмасын сүтеп ыргытасы, ә бу «аңгыра сарыкларны» выжлатып куып чыгарасы да килеп китә.* Ә.Еники. *Ачуланып, өеннән чыгып киткән Рәмис машинасын выжлатып китеп барды.* Татарстан яшьләре

3) *к.* **выжлап** (*2 мәгъ.*). *Көрмәнтәйгә җиткәч, машина туп-туры, выжлатып, авыл читендәге ялгыз кымыз өенә барып туктады.* Ә.Еники

**Выжлата башлау** Выжлатырга тотыну

**Выжлата бирү** Выжлатуны дәвам итү

**Выжлата төшү** Тагы да ныграк выжлату

**Выжлатып җибәрү** Выжлата башлау. *Галимә исә, тиз генә чишенеп ташлап, өйдәшләренең бердәнбер куанычы булган кечкенә генә җиз самавырга су салып, тиз генә выжлатып җибәрде дә, көянтә-чиләк алып, мастерскойга җылы суга чыгып китте.* Т.Мөбарәков

**Выжлатып карау** Бик нык выжлату; выжлавын сынау

**Выжлатып тору** Бертуктаусыз выжлату

**ВЫЖЛА́У** *ф.* **1.** Зур тизлек белән очканда, хәрәкәт иткәндә яисә берәр нәрсә эшләгәндә, һавада «выж-выж» иткән тавыш чыгару. *Колак төбендә тыгыз, каты җил выжлады.* Н.Фәттах

**2. выжлап** *рәв. мәгъ.* 1) Бик тиз; зур тизлек белән. *Арырак Сестрорецк, Солнечное, Репино, Комарово, Зеленогорск кебек эреле-ваклы кала-салаларны машина выжлап кына үтте.* Р.Кәрами. *Балаң булса, ут булсын, выжлап очар ук булсын.* З.Бәшир

2) «Выж-выж» иткән тавыш чыгарып. *Шул чакта әлеге өчтән ишкән чыбык, кинәт, баш очыбыздан выжлап, берәрсенең сыртына барып төшә.* Ә.Еники. *Очты ул выжлап! Зыңгылдап җәя язылды. Яшен булып, язның сүзе күккә язылды...* Зөлфәт

3) Җәһәт кенә, уйламыйча да. *Шунда Гыймай сүзсез-нисез генә төште дә машинаның арт ягын күтәрде.*

*Баткан җиреннән, машина выжлап чыгып китте.* Ф.Яруллин. *Бер сөмсезе шунда җыелган яңгыр суына выжлап килеп керде дә, янәсе, күп мыгырданып торма, Мәүлияне бензинлы түгәрәкләр уйнаган пычрак су белән коендырды.* А.Юнысова

4) *куч.* Бик тиз; сизелмичә дә. *Тормыш яныбыздан выжлап үтә, без, байтак, юлларыбыз читенә басып, аңа кул болгап кына утырабыз кебек...* М.Зарипов

**3**. *и. мәгъ.* Бертуктамый сөйләнү, сукрану, тавыш-гаугa. *Җитәр! Хатын выжлавыннан гарык, язны көтә-көтә саташып беттем, көннәр җылына башлауга, аякны киенеп алдым, белеш-танышлардан сораштырып, ары-бире юргаларга тотындым.* Р.Мостафин

**Выжлап алу** Берара, кыска вакыт выжлау

**Выжлап җибәрү** Кинәт выжлый башлау

**Выжлап йөрү** Анда-монда, тирә-якта выжлау. *Ташка әйләнгәндәй торам, көтәм, ләкин юк, ишетелми, тып-тын, бары тик җил генә әйләнеп, выжлап йөри.* Ә.Еники

**Выжлап карау** Бик нык выжлау

**Выжлап китү** Кинәттән, ниндидер сәбәптән соң выжлый башлау

**Выжлап кую** Бер генә тапкыр, кыска гына выжлау

**Выжлап тору** Бертуктаусыз выжлау. *Үзе әнә форточкадан миңа карап ыслап тора, нидер әйтеп выжлап тора.* Р.Фәйзуллин

**Выжлап узу** Зур тизлек белән, выжлаган тавыш чыгарып, яннан үтеп китү. *Рәшидәнең хикәятен урамда әледән-әле выжлап узган машиналар тавышы күмә.* С.Сөләйманова. *Мин йөгердем. Мине арттан куып, Очлы ташлар выжлап уздылар.* М.Җәлил

**Выжлый башлау** Выжларга тотыну

**Выжлый бирү** Выжлавын дәвам итү

**Выжлый төшү** Тагын да ныграк выжлау

**ВЫЖТ, ВЫЖЖТ, ВЫЖТ-ВЫЖТ** *иярт.* **1.** 1) *к.* **выж, выж-выж** (**1**.). *Бүлмәнең ишеге ачылып-ябылып кына тора: выжт! шарт! выжт! шарт!* М.Маликова. *«Кожедуб» белән «Чкалов» [карусель самолётлары], тавышсыз-тынсыз, һаман әйләнәләр дә әйләнәләр. Выжт-выжт... Выжт-выжт!..* А.Гыйләҗев. *Утыннар, кызларга тими генә выжт-выжт очып, җиргә барып төште.* Ирек мәйданы

2) Зур тизлекне, хәрәкәтне белдерә. *Яныбыздан выжт-выжт машиналар үтеп тора.* А.Шамов. *Өчәүләшеп, үзен тотарга дип йөгергән малайларны бар дип тә белмәде, араларыннан выжт кына үтә дә кире якка торып чаба иде.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *хәб. функ.* 1) *сөйл.* Тиз генә уйлап яисә берәр кая җәһәт кенә җыенып, кинәт китеп бару; тиз генә кереп яисә чыгып китүне белдерә. *Кыш көне чаңгы шуарга әйбәт. Абзар капкасын ачып куясың да – выжт!..* Г.Мөхәммәтшин

2) *сөйл. куч.* Нәрсәне дә булса тиз эшләү, җәһәтлек күрсәтү турында. *Ярамыйга карамый, болар, икәүләп, Сәхәбетдингә тиясе капчык ярым урынына ике капчык бодай тутырып, үлчәүгә куеп кына алдылар да, выжт – олауга.* Р.Мулланурова. *Безнең заводларда һәр минут саен бер машина – выжт! – ясалып кына тора бит!* Р.Төхфәтуллин

3) *сөйл. куч.* Акчаның, мал-мөлкәтнең, кыйммәтле әйберләрнең бик тиз тотылуы, сарыф булуы турында. *Әле номерга кереп җитмәгән, ике сум егерме биш тиен – выжжт!* Г.Тукай. *Минем кесәдәге теге меңнәр шул килеш тора, дип беләсеңме әллә? Беренче көнне үк – выжжт.* Юлдаш

4) *гади с.* Кемне дә булса куу. *Сабур йортта үзе хуҗамыни, читән башындагы малайларны куа ук башлады: – Югалыгыз күздән, выжт хәзер үк!* З.Зәйнуллин. *Сугышырга ирек бирмәделәр: Выжт Минапны цехның тышына.* Х.Туфан

**ВЫ́ЖТ (ВЫ́ЖТ-ВЫЖТ) ИТҮ** *ф.* 1) *к.* **выжлау**. *Колак кырыеннан гына, выжт-выжт итеп, пулялар узганы ишетелә ---.* Х.Камалов. *«Выжт» иткән тавыш та чыкмады бит, ичмаса.* Мәгърифәт

2) Бик тиз, зур тизлек белән хәрәкәт итү. *Нәкъ үзебезнең ишегалды уртасына выжт итеп кенә очып төшәр идем.* Р.Хафизова. *Башка авылларда машиналар яңгырлы көннәрдә дә выжт итеп кенә үтеп китәләр.* Г.Галиев

3) Тиз узып китү, вакыт узганы тоелмый калу. *Менә, январьдан соң февраль генә кала, марты сизелми дә узып китә аның, аннан апрель «выжт» кына итә.* Р.Мөхәммәдиев

**ВЫ́ЖТ (ВЫ́ЖТ-ВЫЖТ) КИЛҮ** *ф. к.* **выжт (выжт-выжт) итү**. *Выжт-выжт килгән машинага сәерсенеп карап тора бабай.* Казан утлары

**ВЫЖТУ** *ф. гади с.* 1) Берәр җирдән тиз генә китү, әйтмичә-сорамыйча китү, качу. *Әй, озак тормадым мин сездән соң, выжтым.* М.Әмир

2) **выжтыгыз**! *боерык ф. күпл. форм.* Берәр җирдән, урыннан куып җибәрүне, тиз арада китүен таләп итүне белдерә. *Габделмән, ачуланып, һәммә баланы куа: «Әйдә, выжтыгыз моннан!»* М.Фәйзи. *– Выжтыгыз барыгыз да тиз генә, бүтән күренәсе булмагыз, – дип сукранып калды Мәрфуга җиңгәй.* Азат хатын

**ВЫЖУ** *ф. гади с.* 1) Нинди дә булса урында озак тоткарланмау, тиз китеп бару. *Эшнең нидә икәнен аңлап алуга ук, тиз генә выждым мин аннан.* Казан утлары

2) **выжыгыз!** *боерык ф. күпл. форм. к.* **выжтыгыз**. *Әгәр чүп утарга риза булмасагыз, выжыгыз моннан!* З.Зәйнуллин

**ВЫЖЫЛДАВЫК** *и.* Бик кызу бөтерелеп, выжылдап әйләнә торган балалар уенчыгы, бөтерчек; *русчасы*: **юла, волчок**. *Алиягә выжылдавык алып биргәннән соң, ул бөтенләй дөньясын онытты – көне-төне шуның белән генә әвәрә килә.* Р.Төхфәтуллин. *Без, таш өйнең караңгырак почмагында выжылдавык уйнатып, «Без-без-без идек, без уникe кыз идек» көенә әкрен генә такмаклап, күңел ачып утыра идек.* Ф.Хөсни

**ВЫЖЫЛДАТУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **выжылдау**. *Риза бүген көне буе ватык машинасын выжылдатты.* Г.Гобәй

2) Ачулану, әрләү

**2. выжылдатып** *рәв. мәгъ.* 1) Зур тизлек белән, выжт итеп. *Менә куәтле моторын выжылдатып кына тауга*

*күтәрелеп килгән машина да күренә.* Р.Фәизов. *Шул сүзне генә көтеп торган диярсең – бүрекле кешенең велосипедка утыруы булды, выжылдатып, урман ягына китеп баруы булды.* Ф.Шәфигуллин

2) Кыенлык күрмичә, җиңел генә. *Башка чаңгычылар суга батып ятканда, мин аларны выжылдатып узып киттем.* М.Сәлим

**Выжылдата башлау** Выжылдатырга тотыну

**Выжылдата бирү** Выжылдатуны дәвам итү

**Выжылдата төшү** Тагын да бераз выжылдату

**Выжылдатып алу** Берара, кыска вакыт, бермәл выжылдату

**Выжылдатып җибәрү** Кинәт выжылдата башлау

**Выжылдатып карау** 1) Бик нык выжылдату

2) Выжылдавын сынау

**Выжылдатып кую** Кыска гына выжылдаган тавыш чыгару

**Выжылдатып тору** Бертуктаусыз выжылдату; еш выжылдату

**ВЫЖЫЛДА́У** *ф.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса (очкыч, машина, бөҗәкләр һ.б.) һаваны кисеп, бик тиз хәрәкәт итүе нәтиҗәсендә выжылдаган тавыш чыгару. *Һәм шул мәлне, аз гына ачык калган ишектән бер шөпшә кереп, өзми-куймый выжылдарга кереште.* М.Шаһимәрдән. *Пулялар выжылдавы күбәйде.* Х.Камалов. *[Җилләр җыры] Илләр ашып, Карлар ташып Выжылдыйбыз: «Выж-ж-жжж!»* М.Касыймов

2) *к.* **выжлау**. *Туйдым бертуктаусыз выжылдавыңнан.* Азат хатын

**2. выжылдап** *рәв. мәгъ.* 1) Бик зур тизлек белән хәрәкәт иткәндә, «выж-выж»га охшаш тавыш чыгарып. --- *бераздан, выжылдап килеп, окоп кырыенда гына миналар шартлый башлый.* Х.Камалов. *Ул да түгел, куелык арасыннан күке кычкырганы ишетелә, колак төбеннән, выжылдап, төклетура уза.* Р.Низамиев. *Шәһәр читендәге тукталыш яныннан выжылдап үтеп барган машина, кинәт тизлеген киметеп, туктап калды, артка чигенде.* Мәдәни җомга

2) Тиз генә. *Шәвәли йорт саен керә, выжылдап чыгып йөгерә.* М.Мәһдиев. *Ирек кырыннан выжылдап китеп барды.* Ф.Садриев

3) *күч. сөйл.* Ачуланып, әрләп

**Выжылдап алу** Берара, кыска вакыт выжылдау

**Выжылдап җибәрү** Кинәт выжылдый башлау

**Выжылдап карау** Бик нык выжылдау

**Выжылдап кую** Бер тапкыр, кыска гына выжылдаган тавыш чыгару

**Выжылдап тору** Бертуктаусыз выжылдау; еш выжылдау

**Выжылдый башлау** Выжылдарга тотыну

**Выжылдый бирү** Выжылдавын дәвам итү

**Выжылдый төшү** Тагын да ныграк выжылдау

**ВЫКЛЮЧА́ТЕЛЬ** *и. рус сөйл.* Электр тогын тоташтыра яки өзә торган җайланма, сүндергеч, өзгеч. *[Карчык] Выключательне аска таба басты. Өй эче караңгы һәм тын булып калды.* Г.Галиев. *Әнә бит инде выключатель, сүндер утны тизрәк.* Мәгърифәт

**ВЫМПЕЛ** *и. голл.* 1) Очы, өчпочмаклап, икегә аерылган, озынча тар яки өчпочмак формасындагы кечкенә флаг (хәрби диңгез кораблендә аның кайсы илнеке икәнен күрсәтә торган билге ролен үти). *Корабның вымпелын күргәч, күзмә яшьләр килде: сагындырган икән туган як...* Азат хатын

2) Нинди дә булса ярышта, бәйгедә җиңүчеләргә яисә, зур уңышка ирешеп, башкалардан алда баручыларга тапшырыла торган кечкенә флаг. *Вагонга җыелышкач, удар айлыкта җиңеп чыкканнары өчен, бригадага күчмә вымпел тапшырылды.* Р.Вәлиев. *Безнең теплоходка күчмә вымпел тапшырачаклар.* С.Сабиров. *Былтыр да бер бишкөнлектә күчмә вымпелны үзендә тотты.* Б.Камалов

3) Бер башына төсле озын тасма беркетелеп, эченә хатлар, газета-журналлар, посылка һ.б.ш. нәрсәләр салып, самолёттан җиргә ыргытыла торган тартма яки төргәк. – *Вымпел!.. [Самолёт] Вымпел ташлады! – дип кычкырды Тамара, ни өчендер шатланып.* Г.Мөхәммәтшин. – *Вымпел түгел бу, – диде Пётр Петрович. – Берәр кирәкле әйбердер.* Г.Мөхәммәтшин. *Безгә ашыгырга кирәк, вымпелларны әзерләп бетерәсебез бар.* Ватаным Татарстан

4) Өстенә рәсем ясалып яки язу язылып, берәр кая җибәрелә, ыргытыла торган, төрле формадагы металл кисәге. *Айда вымпел күрерсең, дисәләр, һич ышанмас идем.* Г.Бакиров

**ВЫ́Р-ВЫР** *иярт.* Нәрсәнең дә булса бертөрле әйләнүеннән, хәрәкәт итүеннән чыккан тавышны белдерә

**ВЫ́Р-ВЫР ИТҮ** *ф. к.* **выр-выр килү**

**ВЫ́Р-ВЫР КИЛҮ** *ф.* «Выр-выр» иткән тавыш чыгарып әйләнү, вырылдау. *Озын төннәргә, өй эчендәге эчпошыргыч сүрән тормышка, выр-выр килеп әйләнгән орчык тавышына бу озын көй бик пар булып төшә.* К.Нәҗми. *Выр-выр килеп әйләнеп утырган сәер уенчыкны күргәч, Алсу елавын да онытты хәтта.* Идел

**ВЫ́РТ-ВЫРТ** *иярт.* Сыеклык эченнән һава куыкчыклары күтәрелеп чыгып шартлаганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Нинди тавыш икән бу, диеп, кәстрүлемнең капкачын ачсам, чынлап та, «уңмаган» камырым җанланган: вырт-вырт...* Казан утлары

**ВЫ́РТ-ВЫРТ ИТҮ** *ф.* Вырт-вырт иткән тавыш чыгару. *Катыгым, әчеп, вырт-вырт итеп сөйләшеп утыра.* Сөембикә

**ВЫ́РТ-ВЫРТ КИЛҮ** *ф. к.* **вырт-вырт итү**

**ВЫРТЛАВЫЧ** *и.* Бер башына төбе тишкәләнгән кечкенә савыт куелган таяк (ятьмә белән балык тотканда, балык куркытыр өчен кулланыла: аны суга батыргач, «вырт-вырт» иткән тавыш чыга). *Бала-чага, дөбер-шатыр килеп, выртлавычлар белән куркыта-куркыта балык сөзә.* Г.Толымбай. *Үзе балык тотарга китте, үзе выртлавычын оныткан, ярты юлдан әйләнеп кайтыр инде тагын [Шәвәли]...* Казан утлары

**ВЫРЫЛДА́У** *ф.* «Выр-выр» иткән тавыш чыгару. *Күктә вертолёт вырылдый.* Ш.Бикчурин. *Килә бу кош. Әй*

*вырылдый үзе. Тәпиләре тәгәрмәч сыман.* Ф.Кәрим

**Вырылдап алу** Берара, кыска вакыт вырылдау

**Вырылдап җибәрү** Кинәт вырылдый башлау

**Вырылдап карау** Бик нык вырылдау

**Вырылдап кую** Бер тапкыр, кыска гына вырылдаган тавыш чыгару

**Вырылдап тору** Бертуктаусыз вырылдау; еш вырылдау

**Вырылдый башлау** Вырылдарга тотыну

**Вырылдый бирү** Вырылдавын дәвам итү

**Вырылдый төшү** Тагын да ныграк вырылдау

**ВЫ́СТАВКА** *и. рус* Күргәзмә. *Выставкаларга йөрергә генә куш минем әнигә!* Юлдаш. *Укучылар ясаган рәсемнәрдән кечкенә генә выставка оештырылган иде...* Казан утлары

**ВЫ́ШКА** *и. рус* 1) Саклау, күзәтү, бораулау һ.б.ш. максатлар өчен салынган тар, биек корылма яки биек багана башына ясалган мәйданчык. --- *Җәмитләрнең бәрәңге бакчасы артында гына, «нефтеразведка» дигән биек вышка көне-төне гөрләп утыра.* Р.Төхфәтуллин. *Нинди җитди объект саклавын яхшы белгән солдат тревога кнопкасына басты, вышканың читенә үк килеп, алгарак авышып, карабинның көпшәсен һавага каратты да, саклагычтан алып, атып җибәрде.* Р.Кәрами. *Кая карама анда буровой вышкалары утыра, факеллар яна.* Х.Камалов. *Вышкаларда – автоматлар, эре калибрлы пулемётлар белән коралланган немец сакчылары.* Р.Мостафин

2) *сир.* Суга сикерү өчен махсус ясалган тар корылма. *Яр тирәли – сикерү вышкалары.* Ә.Галиев. *Сикерү вышкасы янына егетләр-кызлар җыелган.* Казан утлары

3) Кабельле телевидение, кесә телефоннары һ.б. заманча технологияләрнең сигналларын кабул итү өчен җайлаштырылган махсус биек корылма. --- *ел саен дөньяда 50 миллион кош һәлак була икән, һәм бу сан елдан-ел арта. Үтерүчеләр исә – кесә телефонннары сигналын кабул итүче вышка-ретрансляторлар.* Мәдәни җомга. *Америка биологы Д.Геринг фикеренчә, кошларны вышкалардагы кызыл ут җәлеп итә.* Мәдәни җомга

4) *жарг.* Төрмәдә утыручылар жаргонында «иң югары җәза» дигән мәгънәне аңлата. *Бу кыз аны [Серыйны] эләктерә икән, аңа барыбер «вышка». Бу юлы инде чынлап та «вышка».* М.Хәбибуллин

**ВЫ́ШКАЧЫ** *и.* Вышкалар коручы, җыючы, сүтүче кеше. *Александр Григорьевичка телеграмма китергән машинада миңа урын табылмады, мин вышкачы егетләр янында кыр уртасында басып калдым.* Г.Тавлин. *Бүген беренче көн вышкачылар эшкә чыктылар.* Г.Ахунов. *Даннары бөтен илгә танылган вышкачылар Александр Тимченко һәм Гәрәй Баһманов та – «Татбурнефть» тресты тәрбияләгән белгечләр.* Казан утлары

**ВЬЕТНАМЛЫ** *и.* Вьетнамда яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе. *80 нче еллар ахырында Рәсәйгә эш эзләп килгән вьетнамлылар бүгенге көндә инде баеп беттеләр.* Татарстан яшьләре

## ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Файдаланылган махсус әдәбият исемлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Лексикографик чыганаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Сүзлектә файдаланылган башка чыганаклар турында мәгълүмат . . . . . . . . . . 11
Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21

Справочное издание

# ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

(на татарском языке)

**Том I**

**(А–В)**

Редактор *Н.К. Нотфуллина*
Корректор *Н.К. Нотфуллина*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 28.12.2015.
Формат 84×108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 44,5. Уч.-изд. л. 88,41
Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20